ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

## III том

## К

Казан • 2017

УДК 811.512.145'374.3
ББК 81.2Тат-4
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

«2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

*Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы законнары белән саклана (РФ ГК, 4 өлеш). Китапны тулысы белән яки өлешчә, төрле, шул исәптән электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки яздырып алу, сурәтен төшерү авторлык хокукына ия юридик затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела*

**Проект җитәкчесе –** А.Ә. Тимерханов

**Төзүче авторлар:**
И.И. Сабитова, А.Ф. Гайнетдинова, Ю.Ф. Борһанова, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова, Э.И. Сафина, А.Ә. Тимерханов, Р.Р. Абдуллина, Р.Т. Сәфәров, Ф.И. Таһирова

**Фәнни редакторлар:**
Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров, Ф.Ф. Гаффарова

**Бәяләүчеләр:**
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге* (мөдире – Р.В. Шәйдуллин, тарих фәннәре докторы, профессор);
*М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогика университеты Филологик белем бирү һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы* (мөдире – И.С. Насипов, филология фәннәре докторы, доцент)

**Т 23** **Татар теленең аңлатмалы сүзлеге:** III том: К. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 744 б.
ISBN 978-5-93091-225-8

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлеге – күләме һәм эчтәлеге белән мондый төр сүзлекләрдән иң тулысы. Ул татар тел белеме, тюркология һәм гомуми лексикографиянең ирешкән уңышларын, уңай тәҗрибәсен исәпкә алып төзелде.

III томда барлыгы 10500 гә якын сүз һәм 2600 дән артык фразеологик берәмлек теркәлде. Төп фигыль оясында мәгънә төсмерләренә ия булган тезмә фигыльләр дә исәпкә алынды. Сүзлек хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасы һәм фразеологиясеннән, төрле фән һәм хуҗалык тармакларына караган термин, атамалардан гыйбарәт. Анда соңгы вакытта татар теленең үз мөмкинлекләре исәбенә ясалып, кулланышка кереп киткән неологизмнар, кабат активлашкан сүзләр, телне баетырдай диалектизмнар, алынмалар да чагылыш тапты.

Сүзлек киң катлау укучыларга, шулай ук төрле фән белгечләренә гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-225-8** © ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2017

# СҮЗ БАШЫ

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлегенең I томына А – В, II томына Г – Й хәрефләренә башланган сүзләр кертелде. III том тулысы белән К хәрефенә башланган сүзләрдән тора. Сүзлеккә кагылышлы белешмә материаллар тулы шәкелдә I томда бирелде.

Проектның гомуми координаторы һәм җитәкчесе – А.Ә. Тимерханов.

Сүзлекнең III томын төзүдә түбәндәге хезмәткәрләр катнашты: Ф.Г. Гаффарова (К – калыплашу), Ф.И. Таһирова (калышу – кампания), Э.И. Сафина (кампаниячел – кар-яңгыр; көймә I – көрчек), А.Ф. Гайнетдинова (кара II – каршы I; кертү – кинотеатр; компанияләп – кору I; кронглас – кул [◊ кулга иярләшү] – кул яссуы; кыңгыраулау – көйләү II), Ю.Ф. Борһанова (каршы II – керт-керт; комиссарлык – компания, Г.Г. Саберова (кинофестиваль – комиссариат; көрәш – күбесе), А.Ә. Тимерханов (кору II – крона), О.Н. Галимова (кул [◊ кулга керәм дип тору] – кыешу; кым-кырыч – кырялан), Р.Т. Сәфәров (кыз – кыйпылчык), И.И. Сабитова (кыйраәт – кылыччы; күбесенчә [күәс] – khe-khe), Р.Р. Абдуллина (кырып-бетереп – кыңгырау үлән). Сүзлек материалы элекке алфавит тәртибендә бүленде, соңыннан хәзерге алфавитка туры китереп урнаштырылды.

Сүзлекнең III томын түбәндәге хезмәткәрләр редакцияләде: Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров, Ф.Ф. Гаффарова.

Томны, берләштереп, алфавитка салу эшен А.Ә. Тимерханов һәм Р.Т. Сәфәров башкардылар.

Авторларның исемнәрен албиттә күрсәтү тәртибе аларның сүзлек төзүгә керткән өлешләрен исәпкә алып билгеләнде.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.

# СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

## I. Сүзлеккә сүзләр алу тәртибе

§ 1. Сүзлекнең нигезен хәзерге әдәби тел сүзләре һәм фразеологик берәмлекләре тәшкил итә.

§ 2. Сүзлеккә түбәндәге төркем сүзләр дә кертелде:

а) урта мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә очраган төп төшенчәләрне белдергән сүзләр (**БА́ЗИС, БАКТЕ́РИЯ, ТИГЕЗЛӘМӘ, ФО́РМУЛА** һ.б.);

ә) газета-журналларда урын алган күпчелек иҗтимагый-сәяси терминнар (**ДОТА́ЦИЯ, ВӘКАЛӘТ, РЕФЕРЕ́НДУМ, РЕЙД** һ.б.);

б) моңа кадәр басылып чыккан лексик минимумнарда һәм терминологик сүзлекләрдә тәкъдим ителгән аерым терминнар яки аларның тәрҗемәләренең шактый күләме (**АСТӨШЕРМӘ, БАШЛАМ, БИЗӘМ, ӨЛГЕ, ТАМГАХАНӘ, ТЕРКӘ́Ү** һ.б.);

в) бүгенге көн өчен яңа булган, вазгыятьнең үзгәрүе белән килеп кергән, язма әдәбиятның барлык төрләрендә дә очраган Европа телләреннән алынган сүзләр (**БА́ЙКЕР, БАЙТ, БО́НУС, ДИВИДЕНД, ДИ́ЛЕР, ИПОТЕ́КА** һ.б.);

г) дингә, халык ышануларына, мифологиягә, йолаларга, төрле ырымнарга бәйләнешле сүзләр (**БАКЫЙ, БАПТИЗМ, БӘДӘЛ, БӘРМӘНЧЕК, НАРДУГАН, ФАНИ** һ.б.);

д) яңадан кулланышка актив кереп бара торган, телдә кабат торгызылган искергән сүзләр (**БАГАВЫЛ, БАЕК, БАЙСА, БАЛГА** һ.б.);

е) хәзерге чорда активлашкан һәм урта мәктәп, югары уку йортларында өйрәнелә торган борынгы әдәбиятта очраган гарәп һәм фарсы телләреннән кергән шактый алынма сүзләр (**БАБ, БАГБАН, БАЗАРКӘН, ҖӘНҮБ, ИГАНӘ, ИГЪДАДИ, ИГЪТИБА́РӘН** һ.б.);

ж) тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган искергән сүзләр (**ӘДЕРНӘ, БАРЫМТА, БАТМАН, БАТРАК, БИЗМӘН, КАБИЛӘ, КАГАН, КАГАНЛЫК, НӨГӘР** һ.б.);

җ) әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган диалекталь сүзләр (**ӘНӘЧӘ, БАДЪЯН, БАШБАТА, КАБЫГУ, КАЗЫМА, ШАМА** һ.б.);

з) матур әдәбият әсәрләрендә очраган яки хәзерге әдәби телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре (**БӘЛШӘЮ, БӘРГӘЛӘШ, БЕЛӘМӘН** һ.б.);

и) киң кулланышка кергән яңа реалияләрне белдерү өчен, телнең үз җирлегендә ясалган яки мәгънәләре киңәйгән яңа сүзләр (**БАКЫЙЛЫК, БАРЛАМА, БАСМАК, ИГАНӘЧЕ, КОЛАКСА, КЕРТЕМ, ЭШМӘКӘР** һ.б.).

§ 3. Сүзлек берәмлеге итеп барлык грамматик сүз төркемнәренә дә караган сүзләр алынды. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләр һәм аларның мәгънәләре төп сүз мәкаләсендә күрсәтелде.

**ӘВӘРӘ** *и. фар.* **1.** Бик буталчык хәлләр, вакыйгалар. *Аның ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич аңлап та булмый, юкса, иреккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган.* Казан утлары

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* Бер нәрсәгә бирелеп китү, мавыгу. *Нинди эшкә башың әвәрә?* Н.Исәнбәт

§ 4. Мөстәкыйль сүзлек берәмлеге буларак, тамыр сүзләр белән беррәттән, барлык сүз төркемнәренә дә караган төрле типтагы ясалма сүзләр дә кертелде. Шул исәптән: а) кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр (**ӘЙЛӘНЕШ, ВӘКАРЬЛЕК, ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК** һ.б.); ә) саф кушма сүзләр (**АМПЕРМЕТР, АРПАБАШ**, **АЯ́ГҮРӘ, БАШКИСӘР** һ.б.); б) кыскартылган кушма сүзләр (**БАТРАЧКОМ, БЕНЗОВОЗ, РАБФАК** һ.б.); в) парлы сүзләр (**АНДА́-МОНДА, БАШ-АЯК**, **КҮРШЕ́-КҮЛӘН, САВЫТ-САБА** һ.б.); г) компонентлары аерым язылса да, кушма һәм тезмә сүзләр (**БАКА́ ЕФӘГЕ**, **БАКА́ ЯФРАГЫ**, **БАЛА́Н БАРМАК, БАСЫМЧА́К ИТҮ, ВАСЫЯ́ТЬ КЫЛУ, КЫШТЫР-КЫШТЫР ИТҮ** һ.б.).

§ 5. Киң кулланылышлы һәм продуктив булган алкушымчалар, шулай ук кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәкләре сүзлектә аерым мәкалә итеп бирелде (**АВИА-, АВТО-, АГРО-, -АРА, БИ-, БИО-, НЕО-, -СЫМАННАР** һ.б.).

§ 6. Сүзлектә түбәндәге сүзләр бирелмәде: а) үтә профессиональ сүзләр, ягъни фәннең һәм техниканың тик аерым тармакларында гына белгечләр тарафыннан кулланыла торган сүзләр; ә) әдәби телне баетмый һәм әдәбиятта гомумән очрамый торган җирле сөйләм сүзләре (диалекталь сүзләр); б) тупас сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр; в) хәрефләрдән һәм авазлардан торган кыскартылма сүзләр; г) ялгызлык исемнәре.

## II. Сүзлекнең төзелеше

§ 7. Сүзлектә баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылды, һәм алар үзләренә караган материал (аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

§ 8. Баш сүздән соң аның сүз төркемен, чыганак телен, стилистик үзенчәлекләрен сыйфатлый торган билгеләре куелды. Шуннан соң мәгънәгә аңлатма бирелде, иллюстратив материал китерелде. Сүзнең барлык мәгънәләрен дә ачып бетергәннән соң, кызыл юлдан шул сүз белән башланган фразеологик берәмлекләр теркәлде.

§ 9. Башка сүз төркеменә күчеп ясалган сүзләр нокталы калын, ә аларның мәгънәләре җәяле якты гарәп цифрлары белән аерылды.

**ИКМӘК** *и.* **1.** 1) Ачытылган камырдан мичтә пешерелгән ризык; ипи. *Һади, ап-ак тешләрен икмәккә батырып: – Тәмле! – диде. Икмәк телеме күз ачып йомганчы юкка чыкты.* А.Гыйләҗев ...

2) Ашлык. *Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалык күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды.* М.Мәһдиев ...

3) Кырда үсеп утырган иген. *Болгарларның җирләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән.* Г.Гобәйдуллин ...

**2.** *ы. мәгъ. сөйл. к.* **икмәктер**. *Конкурста мин беренче урынны алам, Гөлүсә. Чын, икмәк!* Н.Гыйматдинова ...

§ 10. Һәр мәгънә кызыл юлдан башланып китте. Сүзнең якынрак мәгънә төсмерләре параллель сызыклар (//), ә тагы да якын мәгънәләре нокталы өтер (;) ярдәмендә аерып күрсәтелде.

**ӘДӘП** *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә гомум кабул ителгән әхлак кагыйдәләре; яхшы гадәтләр ... // Кеше арасында үз-үзеңне әхлак кагыйдәләренә туры китереп тота белү сыйфаты ...

2) Яхшы гадәт, йола ...

**АРКАДАШ** *и.* **1.** Иптәш, дус; таяныч. *Иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде.* Г.Исхакый ...

§ 11. Тигез хокуклы грамматик һәм фонетик вариантлар мөстәкыйль сүзлек берәмлекләре итеп алындылар, һәм һәркайсы алфавит тәртибендә үз урынында бирелде.

**АСТРОЛЯБ** *и. гр. сөйл. к.* **астролябия**. *Бер якта астролябка таянган Әбелхарис күренә. --- Әбелхарис астролябын тоткан килеш катып кала*. Н.Исәнбәт

**АСТРОЛЯ́БИЯ** *и. гр.* Астрономиядә: озынлык һәм киңлекне, шулай ук җир үлчәү эшләрендә горизонталь почмакларны билгели торган почмак үлчәү әсбабы

§ 12. Компонентлары аерым язылган, лексик берәмлек тәшкил иткән кушма һәм тезмә сүзләр дә аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде, сүзлектә алфавит тәртибендә урнаштырылды һәм аңлатылды.

**ӘҖЕ́-ГӨҖЕ КИЛҮ** *ф.* Озак итеп, дусларча сөйләшү ...

**ИГЕ́Н ГӨМБӘСЕ** *и. а.х.* Ашлык бөртекләрен, зарарлап, кара тузанга яки кибәккә әйләндерә торган гөмбә авыруы; корымбаш; *русчасы:* **головня**

§ 13. Омонимнар шулай ук һәрберсе аерым мөстәкыйль сүзлек берәмлеге итеп алынды һәм якты рим цифрлары белән күрсәтелде.

**БИК** I *и.* 1) *иск. кит. к.* **бәк**

2) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә сакланган компонент: *Биктимер, Бикбулат, Ханбиков*

**БИК** II *и.* 1) Бикләп кую җайланмасы; йозак, келә, бастырык, бикләвеч. *Сыерның тыныч кына күшәп ятуын ишеткәч, җиңел сулап җибәрә, чолан ишегенең биген тикшерә, өй ишеген «бисмилла» әйтеп яба, аннары түшәген җәеп, ятарга әзерләнә башлый.* И.Гази ...

**БИК** III *рәв.* **1**. 1) Гаять, көчле дәрәҗәдә, гадәттән тыш, чиктән ашкан, югары дәрәҗәдә, искиткеч, искитмәле. *Шулай бик озак барганнан соң, алда, бик еракта, кыр өстендә аз гына калкып, соры карамчык кына булып, бер авыл күренә башлады.* Г.Бәширов ...

## III. Сүзләрнең мәгънәләрен билгеләү һәм аларны аңлату

Мәгънәләрне алу һәм урнаштыру тәртибе

§ 14. Сүзлектә китерелгән һәр тел берәмлегенең хәзерге әдәби телдә кулланылган барлык мәгънәләре дә аерып күрсәтелде.

§ 15. Алынма сүзләрнең бары тик татар телендә кулланылган мәгънәләре генә китерелде.

§ 16. Күп мәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алынып, аерым мәгънәләре билгеле бер тәртиптә урнаштырылды:

а) мәгънәләрнең бирелеш тәртибе, беренче чиратта, аларның хәзерге әдәби телдәге кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнде; мәгънәләр логик эзлеклелекне һәм генетик бәйләнешне мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырылды;

ә) мәгънәләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне хәзерге тел материаллары ачык күрсәтеп торганда, сүзнең мәгънә төзелешен аңлауны җиңеләйтерлек очракларда, беренчел мәгънәләр, искергән булса да, алдан бирелде. Калган барлык очракларда искергән мәгънә, кагыйдә буларак, хәзерге мәгънәләрдән соң гына теркәлде;

б) конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алдарак урнаштырылды;

в) киң кулланыштагы мәгънәләр аның таррак кулланыштагы (гади сөйләм, диалекталь, терминологик һ.б. өчен хас булган) мәгънәләреннән алдарак китерелде;

г) диалекталь мәгънәләр гомуми һәм махсус кулланыштагы мәгънәләрдән соң теркәлде;

д) күчерелмә мәгънәләр туры мәгънәләрдән соң бирелде;

е) бер үк стилистик төсмергә ия булган мәгънәләрнең куллану ешлыгы югарырак булганы алданрак китерелде;

ж) сүзнең аерым синтаксик позициядә ачылган мәгънәләре төп мәгънәләрдән соң урнаштырылды.

**БА́ЙТАК** *рәв.* **1.** Шактый, шактый зур, шактый күп. *Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә, капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без.* М.Вәли-Барҗылы ...

**2.** *с. мәгъ.* Шактый санда булган, күп. *Инде байтак гомер яшәлгән, байтак һава суланган, су эчелгән, дөнья күрелгән, дигән сүз.* Ф.Латыйфи ...

**3. байтагы, байтагысы** *и. мәгъ. тартымлы форм.* Зур өлеш, зур кисәк, зур төркем; бөтеннең зуррак өлеше. *Үрдәкләрнең байтагысы күл өстендә пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр.* Я.Зәнкиев ...

ж) мөстәкыйль сүзнең ярдәмлек функциясендә кулланылган мәгънәсе (яки мәгънәләре) аның мөстәкыйль мәгънәләреннән соң бирелде.

**БӘРАБӘР** *с. фар.* **1.** Бердәй дәрәҗәдәге, тиң булган, лаек. *Үзенә бәрабәр ана арыслан белән юлдаш булып, сахрада кунды.* Дастан ...

**2.** *рәв. мәгъ.* Бердәй, тиң. *Ә бит чыдамлык белән сабырлык фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

**3. бәрабәренә** *бәйл. функ.* Хакына, исәбенә. *Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен – фашизмны җиңеп чыктык.* А.Гыйләҗев ...

§ 17. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләрдә ачылган мәгънәләр шул ук мәкалә эчендә төп мәгънәдән соң теркәлде.

**ЕЛДЫРЫМ** *и.* **1.** 1) Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен, төннәрен офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; ажаган. *Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез, ул яшен елдырымны никтер «рәшә уйнау» дип атыйлар.* А.Хәмидуллин ...

2) *диал.* Яшен. --- *бөтен тирә-якны сызылып яктырткан елдырым балкышындагы төсле [күзаллады]*. Т.Әйди ...

3) Нинди дә булса утлар уйнау чагылышы. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов ...

4) *күч.* Берәр өлкәдә аз вакыт эчендә эз калдырган күренекле кеше. *Үзе дә әдәбият тарихында якты эз сызып, мәдәниятебез күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында мондый сүзләр язып калдырган ---.* Л.Хәмидуллин ...

5) *күч.* Көтмәгәндә һәм тиз арада булып алган нинди дә булса физик яки рухи халәт, психик күренеш. *Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды.* Х.Камалов ...

**2.** *с. мәгъ. күч.* Елгыр, җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем. [Гарифҗан:] Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н.Исәнбәт ...

§ 18. Сүзнең берәр кыек грамматик формасы өчен генә хас булган мәгънә (яки мәгънә төсмере) шул ук мәкалә эчендә әйтелгән грамматик формада гомуми кагыйдәләр нигезендә бирелде.

**БАШ** *и.* **1.** 1) ...

21) **башында** *күч. тарт. һәм кыек килеш форм.* Төп җитәкче, оештыручы урынында, башлык дәрәҗәсендә. *Иптәшләр, хәзер җирле граждан эшләре башында торучы Ногматов иптәшкә яшьләрнең регистрацияләре турында хәбәр итү өчен сүз бирелә.* Ф.Бурнаш

**БАГУ** I *ф.* **1**. 1) *диал.* Карау, күз карашын юнәлтү, күз салу. ...

**3**. **бак, ба́ксана** *ы. мәгъ.* «Кара син аны», «кара әле», мәгънәсендә, игътибар итәргә кирәклекне, гаҗәпкә калуны белдерә. *Баксана! Бөтен күлем айкала!* Н.Исәнбәт. *Гөлҗамал абыстай, ишеткәнең бармы әле, менә бу кем малаеннан, баксана, аты коргыры, үләме әллә югыйсә...* М.Гали

**4. баксаң, бактың исә** *кер. сүз мәгъ.* 1) Чын-чынлап уйласаң, игътибар итсәң. *Баксаң, шунда бер матур кыз тынып калган.* Н.Исәнбәт. *Бактым исә, бер дә катлауландырасы юк, барысы да мөмкин икән.* Ф.Хөсни

2) Соңыннан билгеле булганча, чынлыкта, чынбарлыкта. *Баксаң, әле генә китерелгән сан да «соңгы сүз» булмаган икән.* М.Госманов...

§ 19. Алынма сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибе татар телендә кулланылган мәгънәләренең үзара бәйләнешеннән чыгып билгеләнде.

**РАДИА́ТОР** *и. лат.* 1) Эчке янулы двигательләрне сыеклык ярдәмендә суыту җайланмасы. *Йөк машинасында йөрүче безнең бер шофёрның радиаторына ябалак бәрелгән булган.* Г.Әпсәләмов

2) Үзәктән ягып җылыту системасында пар яки кайнар су йөри торган торбаларга тоташтырылган җайланма

Мәгънәләргә аңлатма бирү тәртибе

§ 20. Сүзлек берәмлеге итеп алынган барлык гади, кушма һәм тезмә сүзләрнең һәм фразеологик гыйбарәләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә тиешле аңлатма бирелде.

§ 21. Аңлатмалар стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр ярдәмендә генә төзелде. Тар кулланылышлы (гади сөйләмгә караган, поэтик, диалекталь, махсус һ.б.), сирәк очрый торган, искергән сүзләр яки сүзләрнең күчерелмә мәгънәләре, шулай ук бу сүзлеккә кермәгән сүзләр аңлатмаларда файдаланылмады.

§ 22. Сүзлектә, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аңлатмаларның өч төрле ысулы кулланылды:

1. Тасвирлаулы аңлатма. Сүзләрнең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре күпчелек очракта кыскача аңлатма бирү юлы белән ачыкланды.

**ҖАМАЯК** *и.* Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү ...

2. Синонимик аңлатма, ягъни сүзнең мәгънәсен ачу өчен, аның синонимын (синонимнарын) файдалану. Мондый аңлатмалар бигрәк тә нинди дә булса берәр стилистик төсмере булган (искергән, диалекталь, гади сөйләмгә караган һ.б.) сүзнең яки алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланылды.

**ӘШТЕ́Р-ӨШТЕР** *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә ...

3. Башка сүзгә яки аның аерым мәгънәсенә (мәгънәләренә) җибәрү. Бу ысул мәгънәләре охшаш яки бик нык якын булган сүзләрдә (синонимнарда) кулланылды. Төп аңлатма тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз янында бирелде, ә калганнарының мәгънәсе шул сүзгә җибәрү юлы белән аңлатылды.

**БАЛАШАР** *и. к.* **балимәр**

**БАЛИМӘР** *и.* Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан, тоныл көрән яки яшел төстә, тел очында чәчәкләрнең баллы суын суырырга махсус щёткасыман әгъзасы булган кечкенә көньяк кошы; *русчасы:* **медосос**

Күпмәгънәле сүзләргә яки омонимнарга җибәргән очракларда, сүзнең кайсы мәгънәсенә яки кайсы омонимга җибәрелүе күрсәтелде. Искәрмә буларак, сүзлекнең зур күләмле булуын исәпкә алып, икенче сүзнең мәгънәсенә җибәргәндә, ул сүз кергән томның басылып чыккан булу шарты куелды. Бу шартка туры килмәгән очракларда, сүзләр алда күрсәтелгән тәртиптә (нигездә синонимын күрсәтү юлы белән) ачыкланды.

**КАЕРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **каеру**. *Урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган.* Ә.Еники ...

5) *к.* **каеру** (*5 мәгъ.*). *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

§ 23. Сүзнең мәгънәсен тулырак ачыклау өчен, кайбер аңлатмаларда кулланылган өстәмә чаралар:

1. Әгәр сүзнең мәгънәсе тасвирлау юлы белән генә ачылып бетмәсә, аңлатмага өстәп, шул сүзнең синонимнары да китерелде.

**КАЗЫЙ** *и. гар. тар.* Шәригать законнарына нигезләнеп хөкем итүче рухани; хаким, судья. *[Хуҗа:] Өч сум өчен, минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы*? Н.Исәнбәт ...

2. Аерым очракларда бирелгән сүзнең аңлатмасы аның капма-каршы мәгънәдәге сүзләре (антонимнары) белән дә тулыландырылды.

**ҖИҢЕЛЛЕК** *и.* 1) Авырлыгы аз булу; *киресе:* **авырлык**. *Җисми кагылу түгел, Мамык җиңеллеге белән Ачылып китте күгем*. Б.Рәхимова ...

2) Уңайлы, җиңел булу: *киресе:* **авырлык, кыенлык**. *Һәр авырлыкның бер җиңеллеге бар.* Мәкаль ...

3. Сирәк очракларда, бигрәк тә вариантлары күп булган, төрле сүзлекләрдә төрлечә бирелгән атамаларның русчага тәрҗемәләре дә китерелде.

**БАКА́ ТӘҢКӘСЕ** *и. бот.* Нәрсенчәләр семьялыгыннан, вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; нәрсен; *русчасы:* **ряска**

4. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (антонимнар) һәм тәрҗемәләр аңлатма ахырында нокталы өтер белән аерып бирелделәр.

**БАЙЛЫК** *и.* ...

2) Җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе*: **ярлылык**, **мохтаҗлык**

§ 24. Сүзнең телдә сирәгрәк кулланылган мәгънәләренә сылтамалар биргәндә, ул мәгънә җәя эчендә күрсәтелде.

**ВАФАСЫЗ** *с.* **1.** *иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел, былагай (*1 мәгъ.*) ...

§ 25. Сүзләрнең индивидуаль, метафорик, шигъри мәгънәләренә, шулай ук чагыштыруларда очрый торган мәгънәләренә аңлатмалар бирелмәде. Сүзләрдәге мондый мәгънәләр, аерым очракларда, мисалларда гына күрсәтелеп китте.

### IV. Иллюстратив материалны бирү тәртибе

§ 26. Сүзләрнең мәгънәләренә аңлатмалар биргәннән соң, аерым очракларны исәпкә алмаганда, иллюстратив материал белән ныгытып барылды.

§ 27. Иллюстрация өчен китерелгән мисаллар, күбесенчә, татар телендә басылган матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән һәм вакытлы матбугаттан алынды.

§ 28. Мисалга китерелгән җөмләләр артык озын булган очракта, мәгънәгә зыян китермичә, кыскартулар ясалды. Сүзләр төшеп калган урыннар өч сызыкча (---) белән күрсәтелде:

**ӘБИ́-БАБА(Й)** *җый. и.* 1) ... 2) ...

3) Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Бу китапны укып, мәктәп балалары --- хәтта ике-өч буын әби-бабалары да белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар --- дәрьясына чумачаклар.* Р.Әмирхан

§ 29. Китерелгән мисаллардагы алмашлык алыштырган сүз, эш-хәрәкәтнең кем тарафыннан башкарылуы, репликаның кемгә төбәлгән булуы яки кем тарафыннан әйтелүе яисә алдагы җөмләләрдән аңлашылган әйтелми калган сүз квадрат җәяләр эчендә искәрмәләр рәвешендә биреп барылды:

**БӘЙЛӘВЕЧ** *и.* 1) Бербөтеннең очларын, ян-якларын (мәс., изүне, балак очларын һ.б.) тоташтыру, бәйләү өчен кара-каршы тагылган бауларның берсе. *Ул [лейтенант], сөйләшү тәмам, дигән шикелле, папкаларын ябып, бәйләвечләрен бәйли башлады.* Х.Камалов ...

**БИКЛЕ** *с.* 1) Йозак белән бикләнгән; нәрсә белән дә булса керә алмаслык итеп ябылган, йозакланган. *Капка бикле иде, [Камали] авыр гәүдәсе белән ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* К.Нәҗми ...

**ӘЙТЕШҮ** *ф.* 1) ...

2) Гаепләшү, тиргәшү, ачуланышу. *Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр дә иде [каенана белән килен].* М.Маликова ...

§ 30. Һәр җөмлә янында чыганакның авторы күрсәтелде.

§ 31. Аерым очракларда, мисал итеп, сүз тезмәләре яки кыска җөмләләр дә китерелде:

**АБАЙСЫЗ** *рәв. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек күрсәтеп, хафасыз; таркау. *Абайсыз бәреп төшерү*

**БУР** I *и. сөйл.* Ак төстәге йомшак известь. *Балалар бур белән асфальтка рәсем ясый*

### V. Алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү тәртибе

§ 32. Тел хәзинәсендә чит (рус, гарәп, фарсы, фин-угор һ.б.) телләрдән турыдан-туры күчкән алынма сүзләр бар. Алар татар халкының күп гасырлар буена бу халыклар белән якыннан аралашып яшәве нәтиҗәсе булып тора. Борынгы алынмалар, фонетик һәм морфологик үзләшеп, татар теле грамматикасына тулысынча буйсынганнар, аның үз сүзләренә якынайганнар. Хәзерге тел хәлендә бу алынма сүзләрне аерып алу гади кулланучыга мөмкин дә булмас иде.

§ 33. Татар телендә шулай ук европа телләреннән алынган сүзләр дә бар. Алар, нигездә, хәзерге чорда рус теле аша күчкән сүзләр. Сүзлектә мондый сүзләрнең беренчел чыганагы – европа телләре күрсәтелде.

Сүзлек массакүләм белешмәлек булганлыктан, сүз турында мәгълүмат алу өчен, барлык алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү кирәк дип табылды.

### VI. Сүз төркемнәренең бирелеше

§ 34. Сүзлек берәмлеге буларак барлык төр сүз төркемнәре дә алынды. Баш сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик билгеләр белән күрсәтелде: *и.* (исем), *ф.* (фигыль), *с.* (сыйфат), *а.* (алмашлык), *сан* (сан), *рәв.* (рәвеш), *бәйл.* (бәйлек), *терк.* (теркәгеч), *кис.* (кисәкчә), *ы.* (ымлык), *ияpт.* (ияртем), *хәб. сүз* (хәбәрлек сүз), *мод. сүз* (модаль сүз).

§ 35. Исемнәр сүзлектә берлек санда, баш килештә китерелде һәм *и.* грамматик билгесе белән аерымланды.

§ 36. Җыйма мәгънәдәге парлы исемнәр сүзлек берәмлеге буларак китерелде һәм *җый. и.* грамматик билгесе белән аерымланды:

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ** *җый. и.* 1) Аласы һәм бирәсе әйбер(ләр); алачак һәм бирәчәк нәрсә(ләр) ...

2) Сәүдә, сату-алу эше, кәсебе ...

**ӘЙБЕ́Р-КАРА** *җый. и.* Төрле кирәк-яраклар ...

§ 37. Ялгызлык исемнәренең, күмәклек мәгънәсе алып, киң кулланышка кереп киткәннәре сүзлектә китерелде (**А́МПЕР, ӘБҮҖӘҺЕЛ, ГАЗРАИЛ, ГАЙДАМАК, ГАЙДУК, ДӘҖҖАЛ, ИБЛИС, МА́УЗЕР, ОМ** һ.б.).

§ 38. Урта мәктәп дәреслекләрендә һәм матбугатта еш очрый торган төрле ил халыкларының һәм милләтләренең исемнәре чикләнгән күләмдә китерелде (**АБХАЗ, АВАР, АВСТРА́ЛИЯЛЕ, А́ВСТРИЯЛЕ, АЗӘРБАЙҖАН, АЛБАН, ӘРМӘН, ӘФГАН, БАЛКАР, БАШКОРТ, БОЛГАР** һ.б.).

§ 39. Исемләшкән исем һәм сыйфат фигыльләр (**АВЫРУ, АСРА́У, БЕЛДЕРҮ, ЧӘЧҮ, САТУ, ӘЙДӘҮЧЕ, БИЮЧЕ, ОЕШТЫРУЧЫ, УКУЧЫ** һ.б.), сыйфатлашкан сыйфат фигыль (**ЕЛЛАГАН, ЯРАТКАН** һ.б.), рәвешләшкән хәл фигыльләр (**БАГАНАЛАП, БАЛЛАП, БАТМАНЛАП, ЕЛЛАП, ИПЛӘП** һ.б.) аерым сүзлек мәкаләсе итеп алынды.

§ 40. Алмашлыклар *а.* грамматик билгесе белән аерымланды. Сүзлек мәкаләсендә зат алмашлыкларының һәм *ул, бу, шул* алмашлыкларының кыек килеш формалары да бирелде. Ул баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең нигезе үзгәргән очраклар аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде:

**МИН** (**минем, миңа, мине, миннән, миндә**) *а.* Сөйләүченең үзен атап күрсәтү өчен кулланыла торган беренче зат алмашлыгы

**УЛ** II (**аның, аңа, аны, аннан, анда**) *а.* 1) Өченче затны яисә гомумән предметны белдерә …

2) Исемнәрне ачыклаган сүзне алмаштырып килә торган күрсәтү алмашлыгы; *андый, мондый, шундый*…

**АҢА** *а.* *Ул* алмашлыгының юнәлеш килеш формасы

§ 41. Фигыльне сүзлектә бирү формасы итеп, төп юнәлештәге (*-у/-ү*) исем фигыль формасы алынды һәм *ф.* грамматик билгесе белән аерымланды: **АЛУ, ӘЙТҮ, ДИМЛӘ́Ү, ЗЫҢЛА́У, КҮЗӘТҮ, КАЙТУ, КӨЛҮ** һ.б.

§ 42. Грамматик мәгънә белдерә торган фигыльләрнең саф юнәлеш формалары телнең грамматик төзелешенә карый, шунлыктан алар сүзлектә теркәлмәде.

§ 43. Лексик мәгънәгә ия булган фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә бирелде. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп формага җибәрү юлы белән күрсәтелде, ә лексик мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатмалар китерелде:

**АШАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*). *Хәзрәтләр – шактый күп алган туй сәдакасыннан, авыл кешеләре – тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар – яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча затлы үтүеннән разый калдылар.* Г.Исхакый

2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү (йөз-кыяфәт, кием-салым һ.б.ш. турында). *Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе*

*җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары яныннан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага.* А.Алиш

3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ашалган үкчәләрен дә төзәткән иде ул.* А.Шамов

§ 44. Дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләрнең телдә киң кулланылганнары, төп сүзгә аңлатма бирелгәч, фразеологизмнарны күрсәтеп бетергәннән соң, беренче сүз принцибы белән шул фигыль янында ояда алфавит тәртибендә теркәлде:

**БӘЙЛӘ́Ү** I *ф.* 1) ...

2) ...

◊ **Бәйләп тоту** Ирексезләү, көчләү

**Бәйләп алу** Тиз генә бәйләү; бәйләгән булу

**Бәйләп ату** Аннан-моннан, ничек кирәк шулай бәйләү

**Бәйләп бару** Эзлекле рәвештә бәйләү; бер-бер артлы бәйләү

**Бәйләп бетерү** Тулысынча бәйләү; бәйләү эшен тәгәлләү

**Бәйләп кую** 1) Алдан бәйләп әзер итү

2) Бәйләнгән хәлдә калдыру, бәйләнгән хәлдә тоту

**Бәйләп ташлау** Тиз-тиз генә бәйләү

**Бәйләп тору** 1) Булган берсен, һәрберсен бәйләү

2) Сөйләү моментында, әле бәйләү белән мәшгуль булу

3) Һәрвакыт, гел бәйле итү

**Бәйләп чыгу** Һәммәсен бер-бер артлы бәйләү; һәрберсен бәйләү

**Бәйли бару** Һәммәсен тоташтан яки эзлекле рәвештә бер-бер артлы бәйләү

**Бәйли башлау** Бәйләргә тотыну

**Бәйли төшү** Тагын да кысыбрак, тыгызрак бәйләү

§ 45. Сүзлектә тезмә фигыльләр ясый торган түбәндәге модификацияләүче фигыльләр (дәрәҗә фигыльләре) кулланылды: **алу, ату, бару, башлау, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, житкерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, ташлау, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту**

§ 46. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары, грамматик категория буларак, сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Бу очракта төп сүзнең барлык мәгънәләренә дә аңлатма биргәч, нокталы ярымкалын гарәп цифрыннан соң, алар аерым күрсәтелеп теркәлде һәм лексик мәгънәләре аңлатылды:

**ВАКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Вак-вак, кечкенә кисәкләргә, өлешләргә бүлгәләү, вату, тураклау, аеру; вак итү. *Койма буендагы такталарны, кисеп, утынга вакларга кирәк.* М.Мәһдиев

2) Эре акчаны шул ук суммадагы вак акчага алмаштыру. *[Тәзкирә:] Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?* А.Гыйләҗев...

**2**. **ваклап** *рәв. мәгъ.* 1) Аз-азлап, өлешләп, бүлгәләп. *Фәния кисәк-кисәк ваклап сөйләшә торган теле белән зарланып та алырга өлгерде.* Ф.Яхин

2) Данәләп, берәмләп, берәрләп; килолап, граммлап. *Күгендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кыланышына өйрәнгән айның да исе китми.* Т.Галиуллин

3) Нечкәлекләренә төшенеп, җентекләп, төпченеп. *Кыздырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җинаятьнең урынын сыйфатлап язды.* Г.Ибраһимов

§ 47. Татар телендә кайбер мөстәкыйль фигыльләр ярдәмче фигыль функциясендә йөри. Сүзлектә бу күренеш күрсәтелде:

**КИТҮ** *ф.* **1.** 1) ... ; 2) ... .

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Юнәлеш килешендәге кайбер исем, сыйфат, рәвешләр белән килеп, шулардан аңлашылган торыш, билге һәм рәвешкә күчүне белдерә. *Эшләр уңайга китте. Талашуга киткәч булмый инде ул*

2) Эш-хәлнең кинәт булуын белдерә. *Балкып китте*

3) Эшнең башка бер эш уңаенда кыска гына аралыкта булуын белдерә. *Таныштырып китү. Искә төшереп китү*

4) Эшнең башлануын һәм дәвам итүен белдерә. *Сөйләп китте. Санап китү*

### VII. Сүзнең басымын күрсәтү тәртибе

§ 48. Татар телендә басым, күбесенчә, сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. Баш сүз булып килгән мондый очракларга (шул исәптән алынма сүзләргә дә) басым куелмады. Басым башка иҗекләргә төшкән очракларда гына сүзнең басымы күрсәтелде.

**БАТЫРЛА́РЧА** *рәв.* ...

**Ю́ГЫЙСӘ** *тер.*

**ГИГИЕ́НА** *и.* ...

Бу кагыйдә омографларга да карый, әмма басымның кайда булуына карамастан, чагыштыру һәм дөрес уку өчен, басым икесенә дә куелды.

**А́РКА** *и. лат.* 1) *махс.* Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсәләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме)

**АРКА́** *и.* **1.** 1) Кеше гәүдәсендә муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы як ...

§ 49. Татар телендә *-а / -ә* сузыкларыннан соң килгән *-у / -ү* авазлары сөйләмдә, кыскарып, ирен-ирен *в [w]* сонанты булып әйтелә, ә төзелмә үзе *[aw] / [әw]* тибындагы ялган дифтонг булып ишетелә, шул сәбәптән, басым *-а / -ә* сузыкларына төшә. Бу очрак сүзлектә күрсәтелде.

**АБА́У** *ы.* ...

**АҢКА́У** II *и. анат.* ...

**БИКЛӘ́Ү** I *ф.* ...

**ВАКЛА́У** *ф.* ...

**ДӘ́Ү** *с. фар.* ...

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*а.* – алмашлык
*авиа.* – авиация
*агроэкол.* – агроэкология
*анат.* – анатомия
*артык.* – артыклык (дәрәҗәсе)
*археол.* – археология
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономия
*афр.* – Африка телләре
*а.х.* – авыл хуҗалыгы
*әд.* – әдәбият термины
*әрл.* – әрләү
*баш. кил.* – баш килеш
*бәйл.* – бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*берл.* – берлек сан
*биол.* – биология
*биохим.* – биохимия
*б-сез.* – билгесезлек
*бор.* – борынгы (сүз)
*бот.* – ботаника
*бүл. саны* – бүлем саны
*вет.* – ветеринария
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*геол.* – геология
*геом* – геометрия
*грам.* – грамматика
*дәр.* – дәрәҗә
*диал.* – диалекталь сүз
*дини* – дини сүз
*диңгез.* – диңгезчелек термины
*жарг.* – жаргон
*җый. и.* – җыйма исем
*җыр* – халык җыры
*җыю саны* – җыю саны
*зоол.* – зоология
*з.-сыз* – затланышсыз (фигыль)
*и.* – исем
*икът.* – икътисад
*информ.* – информатика
*ирк.* – иркәләү сүзе
*ирон.* – ироник мәгънәдә
*иск.* – искергән сүз
*иял. кил.* – иялек килеше
*иярт.* – ияртем
*иҗт.* – иҗтимагый
*йөкл. юн.* – йөкләтү юнәлеше
*к.* – кара
*кбт. форм.* – кабатлаулы формада
*кайт. юн.* – кайтым юнәлеше
*карг.* – каргау (каргыш) сүзе
*кер. сүз* – кереш сүз
*кеч.* – кечерәйтү
*килеш* – килеш (формасында)
*ким.* – кимлек дәрәҗәсе
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кино* – кинематография
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*комп.* – компьютер
*көч.* – көчәйтү
*кулин.* – кулинария термины
*күпл.* – күплек санда
*күрс.* – күрсәтү
*күч.* – күчерелмә мәгънәдә
*лингв.* – лингвистика
*лог.* – логика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус термин
*мәгъ.* – мәгънәдә, мәгънәсендә
*мәс.* – мәсәлән
*мед.* – медицина
*метеор.* – метеорология
*микробиол.* – микробиология
*минер.* – минералогия
*миф.* – мифология
*мод. сүз* – модаль сүз
*мод. ф.* – модаль фигыль
*мөн.* – мөнәсәбәтлек (сүз)
*муз.* – музыка
*мыск.* – мыскыллау сүзе
*неол.* – неологизм
*нәфр.* – нәфрәтләнү
*окказ.* – окказионализм
*пед.* – педагогика
*психол.* – психология
*радио* – радиотехника
*рәв.* – рәвеш
*рәсм.* – рәсми
*ритор.* – риторик
*с.* – сыйфат

*сан* – сан
*сәнг.* – сәнгать
*сәяси* – сәяси термин
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләм телендә
*спорт* – физкультура һәм спорт
*сын.* – сынлы (сәнгать)
*тар.* – тарихи
*тарт. форм.* – тартымлы формада
*тасв.* – тасвири сәнгать
*тәрт. саны* – тәртип саны
*театр* – театр сәнгатенә караган сүз
*терк.* – теркәгеч
*тех.* – техника термины
*типогр.* – типография термины
*тирг.* – тиргәү сүзе
*төзел.* – төзелеш термины
*төш. кил.* – төшем килеше
*төш. юн.* – төшем (юнәлеше)
*туп.* – тупас сүз
*тур.* – турында
*урт. юн.* – уртаклык (юнәлеше)
*у.-вак. кил.* – урын-вакыт килеше
*ф.* – фигыль
*фарм.* – фармацевтика
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*филос.* – философия
*финанс.* – финанслар
*фольк.* – фольклор
*форм.* – формасында
*фото.* – фотография
*функ.* – функция
*хим.* – химия
*хуплм.* – хупламау
*хупл.* – хуплау
*хурл.* – хурлау
*хәб. функ.* – хәбәр функциясендә
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хәрби* – хәрби сүз
*чаг.* – чагыштыру
*чыг. кил.* – чыгыш килеше
*шаярт.* – шаярту сүзе
*шелт.* – шелтәләү сүзе
*шигъ.* – шигъри сөйләмдә
*шөб.* – шөбһәләнү
*ы.* – ымлык
*эвф.* – эвфемизм
*энд.* – эндәш сүз
*электр.* – электротехника
*эпис.* – эпистоляр стиль
*этн.* – этнография
*юг.* – югары стиль
*юкл.* – юклык
*юн.* – юнәлеш
*юн. кил.* – юнәлеш килеше
*юр.* – юридик термин
*ялг.* – ялгыш куллану варианты
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

**Чыганак телләрнең кыскартылмалары**

*алб.* – албан теле
*амхар* – амхар теле
*әрм.* – әрмән теле
*баконго* – баконго теле
*бурят* – бурят теле
*венг.* – венгр теле
*гар.* – гарәп теле
*герм.* – герман телләре
*голл.* – голланд теле
*гр.* – грек теле
*груз.* – грузин теле
*ингл.* – инглиз теле
*исланд* – исланд теле
*исп.* – испан теле
*ит.* – итальян теле
*кельт* – кельт теле
*кечуа* – кечуа индеецлары теле
*коми* – коми теле
*кыт.* – кытай теле
*лат.* – латин теле
*литв.* – литва теле
*малай* – малай теле
*малаял.* – малаялам теле
*мар.* – мари теле
*монг.* – монгол теле
*мордв.* – мордва теле
*нем.* – немец теле
*пол.* – поляк теле
*португ.* – португал теле
*румын* – румын теле
*рус* – рус теле
*саам* – саам теле
*санскр.* – санскрит теле
*сканд.*– скандинав телләре
*слав.* – славян телләре
*тамил* – тамил теле
*тат.* – татар теле
*төрек* – төрек теле
*төрки* – борынгы төрки сүз
*тунг.* – тунгус теле
*тупи* – тупи теле
*удм.* – удмурт теле
*уйг.* – уйгур теле
*укр.* – украин теле
*үзб.* – үзбәк теле
*фар.* – фарсы теле
*фин* – фин теле
*фин-угор* – фин-угор телләре
*фр.* – француз теле
*һинд.* – һинди теле
*чех.* – чех теле
*эст.* – эстон теле
*як.*– якут теле
*яп.* – япон теле
*яһүд* – яһүд теле

**ТАТАР АЛФАВИТЫ**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Дд | Зз | Мм | Пп | Үү | Чч | ь |
| Әә | Ее | Ии | Нн | Рр | Фф | Шш | Ээ |
| Бб | Ёё | Йй | ң | Сс | Хх | Щщ | Юю |
| Вв | Жж | Кк | Оо | Тт | Һһ | ъ | Яя |
| Гг | Җҗ | Лл | Өө | Уу | Цц | Ыы | |

# К

**КААН** *и. тар. к.* **каган**. *Тирә-якка мәгълүм, мәшһүр була ул кааннның гайрәт атагы.* Гыйффәт Туташ. *Чыңгыздан соң тәхеткә менгән кааннарның һәрберсе бабаларының юлын тоткан, диндә иркенчелек ягыннан барлык Европа миссионерларын да хәйран калдырган.* Р.Әмирхан

**КААНЛЫК** *и. тар. к.* **каганлык**. *Без зәгыйфь коллар беләлмибез Каанлык серләрен...* Һ.Такташ

**КАБА** I *и.* 1) Җеп эрләү өчен тетелгән йон, сүс, мамык йомарламын беркетеп куя торган, агачтан эшләнгән тараклы җайланма. *Сәкедә Галимә каба белән җеп эрләп утыра.* М.Фәйзи. *Сафа килеп кергәч, ул кабасын бер читкә куйды.* А.Шамов. *Бу юлы Миңнисә җиңги бер сүз дә дәшми почмакка барып утырды һәм, ачу белән кабасындагы сүсне йолка-йолка, сүзе ишетелер-ишетелмәс мыгырдады.* Ә.Фәйзи

2) Агач сукада: тәрәнне беркетеп куя торган кисәк

**КАБА** II *с.* Киң һәм зур. *Галәлхосус тәрҗемәсендә гыйбарәсе тигез вә ифадәсе каба вә татсыз дәгелдер.* Г.Кәрам. *Каба сакал. Каба кул*

**КАБА́ АГАЧЫ** *и.* Кабаның тараклы җайланмасы беркетеп куела торган такта; каба төбе. *Каба агачындагы чүбекләрне йомарлап, ачу белән почмакка тондырды.* И.Гази

**КАБАК** I *и.* 1) Кабакчалар семьялыгыннан җирдә үрмәләп үсә торган, эче куыш калын сабаклы, кызгылт сары йолдызсыман чәчәкле, яссы куе яшел яфраклы бакча үсемлеге; яшелчә. *Беренче класслар табигать почмагында ике әрҗәгә кабак утырталар.* Г.Гобәй. *Үсә бара торган айда: рассадага помидор, ташкабак, баклажан, кабак, борыч утырту башлана.* Татар мөселман календаре

2) Шул үсемлекнең азык буларак кулланыла торган зур озынча яки шарсыман җимеше; орлыгы шулай ук азык буларак кулланыла, эфир майларына бай булуы белән аерылып тора. *Сөембикә апа әйтә, монда, ди, минә мондый кочак җитмәс кабаклар үсәр, ди.* Ә.Еники. *Минем әни чәйгә дип кишер киптерә, кабак көйдерә.* Д.Каюмова

◊ **Кабак баш** Аңгыра, миңгерәү, булдыксыз (кешегә карата). **Кабак бәлеше** Җебегән, йомшак, булдыксыз (кешегә карата). **Кабак булу** Арудан, гаҗизлектән баш миңгерәү, аңлый алмас дәрәҗәгә килү. *Аның күзе томаланган, башы кабак булып каткан иде.* Г.Ибраһимов

**КАБАК** II *и.* Күз алмасын томалап ала торган хәрәкәтчән тире катламы; каштан түбәнгә кабарып торган өлеш. *Әйтәм аны ике-өч көннән бирле сул кабагым тарта иде, шуңа икән.* Т.Гыйззәт. *Ниһаять, Хәлимнең күз кабаклары калтыранып алдылар да киң ачылып киттеләр.* Г.Гыйльманов. *Аның әйләнеп төшкән калын кабаклары астындагы кысык күзе хәтәр елтырап куйды.* Ф.Хөсни

◊ **Кабак җыеру** *к.* **каш җыеру**

**КАБАК** III *и. иск.* Капка, капу. *Болар, байның килгәнен күреп, кабакны тутырып ачып, ачык йөз, татлы сүз белән каршы алдылар.* Әкият. *Кодалар килде кабакка, кыз утырды кабага.* Мәкаль. *Күк кабагы ачылуын көттем.* М.Галәү

**КАБАК** IV *и. нем. тар.* 1) Арзанлы исерткеч эчемлекләрне ваклап сату, эчү урыны; трактир. *Шул рәвештә бер атна – ун көн чамасы Галиәкбәр агай шәһәрнең астын-өстенә китереп, беренче класс рестораннарыннан башлап түбән дәрәҗәдәге кабакка кадәр һич бер зиярәт итмәгән җирне калдырмады.* Ш.Мөхәммәдев. *Берлинның бөтен-бөтен кварталларын каплап алган кафелар, рестораннар, кабаклар, фәхешханәләр яшиләр.* Г.Гобәй. *Кабак, түбән пробалы булса да, үзенә күрә бер клуб иде. Реформадан соң кабаклар ябылды.* М.Мәһдиев

2) *гади сөйл.* Ресторан

**КАБАКЛАНУ** *ф.* Кабакның чәчәге коелып, төбендә җимеше барлыкка килеп үсә башлау

**Кабакланып килү** Җимшән төбендә кабак бөреләре күренү

**КАБАКЧА** *и. бот.* Гади кабакның озынча формалы җимеш бирә торган төре

**КАБАКЧЫ** *и. иск.* Кабак (IV) тотучы, кабак хуҗасы. *Шәһәрдә безнең авылдан чыккан бер кабакчы бар иде.* Г.Әпсәләмов. *Кабак янында беркем юк, Кабакчы хатын белән ялгыз калды тик тал гына, Тирбәнеп акрын гына.* М.Җәлил

**КАБАЛ** *и. фар. к.* **кавал**. *Хәер, Казан җирендә кабал сукмыйлар, монда гөслә, кубыз ише уен кораллары таралган. Нугай илендә чакта кызлар белән ярыша-ярыша кабал сугалар иде. Көйләрне һәр бормасына туры китереп...* М.Әмирханов

**КАБАЛА** *и. гар. тар.* 1) XIV–XVII йөзләрдә Урта гасыр Русенда ясак-бурычларын түли алмаудан барлыкка китерелгән гомерлек бәйле булу хәле; крепостнойлык

2) *күч.* Бәйлелек, бәйле хәлдә булу. *Туган Ватан кабалада булса да, Татарстан дигән җиребез бар. Мәдәниятебез, телебез, динебез.* З.Хөснетдинов

3) *күч.* Бик авыр матди хәл, матди яктан тулы бәйлелек

◊ **Кабалага керү** Мөстәкыйльлекне, бәйсезлекне югалту, кемгә дә булса бәйле булу. **Кабалага төшү** *к.* **кабалага керү**. **Кабалага эләгү** *к.* **кабалага керү**. *Көнбатыштан кайткан нәрсәләр исәбенә күпме яшәп була? Бу бит коллыкка төшүнең, кабалага эләгүнең иң туры юлы...* Т.Галиуллин. **Кабаладан чыгу** Бәйсезлеген кире кайтара алу,

мөстәкыйльлеген торгызу. *Тоталитар хакимият ач-ялангач крестьянны җиргә мәҗбүри бәйләп тору юлын тапкан: крестьянга паспорт бирелми. Кабаладан чыгасың килә икән, «дусиш» тап.* Н.Фәттах

**КАБАЛАЛЫ** *с.* Кабалага кертә торган, бәйлелеккә төшерә торган *[Крестьяннар] Җирне алпавыттан кабалалы шартларда арендага алырга мәҗбүр булдылар.* Яңа тарих

**КАБАЛАН** *рәв. диал.* **1.** Бик ашыгыч, тиз, җәһәт. *Һәр эшне дә кабалан башкару*

**2.** *с. мәгъ.* Ашыгучан, кабаланучан. *Беләм, дускай, айлар ашкынулы, Йөгең авыр, көннәр кабалан.* Ф.Чанышева. *Директорның һаман вакыты юк, Аның эше һаман кабалан!* М.Җәлил

**КАБАЛАНА́-КАБАЛАНА** *рәв. к.* **кабаланып** (*1 мәгъ.*). *Нигъмәт кабалана-кабалана эшләпәсе белән улактагы суны түгәргә тотынды.* Ф.Кәрим. *Ул, бабасына куелган кашыкны алып, кабалана-кабалана ашарга тотынды.* Ф.Садриев

**КАБАЛАНУ** *ф.* **1.** 1) Ашыгудан артык хәрәкәтләр ясап нәрсәдер эшләү, тиз-тиз эшләргә тырышу. *Берәү кергә, берәү чыга – барысы да ут капкан кебек ашыга, кабалана.* И.Гази. *Повар да кычкырып көлде һәм капкадан чыгып китәргә ашыгып кабалана башлады.* Г.Гобәй. *Әнвәр ишекне үзе генә япмакчы иде дә, элгечне бигенә туры китерә алмыйча, озак кабаланды.* К.Нәҗми

2) *диал.* Бик нык ашыгу, тиз-тиз, җәһәт эш итү. *Юк, юк, мин кабаланам, озатып йөрмәгез, мин чаптым.* Ф.Садриев. *Кунаклар китәргә кабаланды*

**2. кабаланып** *рәв. мәгъ.* 1) Ашыгып, бик тиз, җәһәт. *Ул озак йөрүдән читләре киселә башлаган соры конвертны кабаланып ачарга тотынды.* Г.Бәширов. *Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар [кылганнар]...* Ә.Еники

2) *к.* **кабалап**. *Вакытсыз йөрүченең аяк тавышын сизеп, ферма эте Сатурн кабаланып өрә башлады.* Ф.Хөсни

**Кабалана башлау** Кабаланырга тотыну. *Әмма бу сәер тәкәнең әрсезлеген сизеп алган теге иң дәү кәҗә аны күргәч яңадан кабалана башлады.* Р.Мөхәммәдиев. – *Кил, яме, менә адресым, тукта, язып ук бирәм, – дип, Айсылу ничектер каушаудан кабалана башлады, сумкасыннан каләм алырдай итте.* Ф.Яхин

**Кабалана төшү** Бераз кабалану, кабаланулары сизелеп тору. *Тыныч кына кичне көткән кешеләр, кузгалу вакыты җиткәч, үзләре дә сизмәстән бераз кабалана төшеп, винтовкаларын астылар.* Г.Бәширов. – *Юк, юк, – диде ул һәм, кабалана төшеп, авызындагы ризыкны тумылдатып чәйнәргә кереште.* Р.Мөхәммәдиев

**Кабаланып алу** Бераз, аз гына вакыт эчендә кабалану

**Кабаланып йөрү** Күз алдында әле бер якка, әле икенче якка ашыгып йөгеренеп кабалану. *Хәлим, аның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып кабаланып йөрде.* И.Гази

**Кабаланып китү** Кинәт, кирәгеннән артык ашыгып кабалана башлау. *Холкы сабыр, әтрафлы, беркайчан да йөгереп, кабаланып китмәс, чебенгә чукмар күтәрмәс...* Т.Галиуллин

**Кабаланып куюю** Кинәт, кыска вакыт аралыгында кабалану, кабаланганын сиздерү. *Миңлегаяз кинәт кабаланып куйды һәм чанага таба ашыкты.* Р.Мөхәммәдиев

**КАБАЛАП** *рәв. диал.* Үтә ярсып, абалап (эт өрү тур.). *Ул яшел киемле бу ят кешегә кабалап өреп барды да, аның тавышын ишетүгә, кинәт аңына килеп, гафу үтенгәндәй, акрын гына чинап җибәрде.* Г.Бәширов

**КАБАЛА́У** *ф. диал.* Кул белән эзләнү, кармалау, капшау. *[Мәдинә] Бармагына кигән йөзеген кабалап карады.* Ш.Хөсәенов. *Аягына йомшак тиде. Кабалап караса – имән төбе туп-тулы бал.* К.Насыйри

**Кабалап алу** Тиз генә кабалау хәрәкәтләре ясау, ашыгыч рәвештә, аз гына кабалау

**Кабалап бетерү** Башыннан ахырына хәтле кабалау; барысын да, берсен дә калдырмастан кабалау

**Кабалап кую** Искәрмәстән, кинәт, бер генә тапкыр кабалау

**Кабалап чыгу** Һәрберсен берәмберәм кабалау

**Кабалый башлау** Кабаларга тотыну. *«Балаларның күпчелеге, я күлмәк итәген кабалый башлап, я чәчләрен төзәткәләп, игътибарын икенчегә юнәлтте», – дип искә алды «дөнья гүзәле» әнисе.* Ватаным Татарстан

**КАБАН** *и.* 1) Дуңгызлар семьялыгыннан, урман куелыгында, сазлыкларда, түбәнрәк урыннарда төркемләп яши, күшәми торган, партояклы, имезүче хайван; кыргый дуңгыз. *Капкынга берничә кабан, хәтсез генә куян эләкте.* Г.Гыйльманов

2) *астр.* Борынгы Көнчыгыш йолдызнамәсендә алтмыш еллык календарь циклның 12 төрле хайван белән билгеләнгән соңгы уникенче билгесе; шул билгегә туры килгән елда туган кеше. *Шәрык календаре һәм ырымнары буенча, кабан елында туганнар матурлыкны ярата гына түгел, үзләре дә матур булырга тырыша.* Т.Әйди

**КАБА́Н ДУҢГЫЗЫ** *и.* **кабан** (*1 мәгъ.*). *Шуның янында ук алар буран басылганнан соң төшеп калган һәм урманга таба кереп киткән кабан дуңгызлары һәм бүре эзләрен күргәннәр.* М.Гали. *Куян түгел, бүредән, кабан дуңгызы белән шулай очрашканда да куркуның ни икәнлеген белмәгән, урманда гомер кичергән урманчы түзмәде.* Р.Мөхәммәдиев

**КАБА́Н ТЕШ** *и. к.* **казык теш**. *Теге кызыл сакаллы кечкенә офицер кабан тешләрен ыржайтып көлеп торды ---.* Г.Гобәй

**КАБА́Р АГАЧЫ** *и.* Кабарчалар семьялыгына караган, составында гуттаперча матдәсе булган куак; *русчасы*: **бересклет**. *Көзен зелпе, кура җиләге, эт шомырты, гөлҗимеш, кабар агачы кебек куакларның җиләк һәм сусыл җимешләре күпчелек кошлар өчен тәмле азык санала.* Ботаника

**КАБАРГА** *и. алтай зоол.* Боланнар семьялыгыннан арт аяклары алдагыларыннан озынрак булган, ак тимгелле көрән төстәге, артык зур булмаган мөгезсез хайван

**КАБАРДА** *и.* Төньяк Кавказда Кабарда-Балкар республикасында яшәүче

ике төп милләтнең берсе булган халыкның үзатамасы һәм шул халыкның бер вәкиле

**КАБАРДИ́НКА** *и. рус* Төньяк Кавказда ирләр биюе; лезгинканың бер төре

**КАБАРЕ** *и. фр.* Үзендә эстрадасы булган кечерәк кафе яки ресторан. *Парижның хәзерге зур кафелары әнә шулай кабарелар, рестораннар белән кочаклашып алга баралар.* Г.Гали. *Чат саен кабаре. Даны дөньяга таралган «Тропиканка» рестораны үзе генә дә ни тора!* Р.Ибраһимов

**КАБАРЛЫК** *с.* 1) Авызга алырлык, ашарлык, ашарга яраклы. *Ботканы пешереп, өстәлгә утырттылар. Ул шыр тоз, кабарлык та түгел.* Х.Камалов

2) *к.* **кабым**. *Кабарлык икмәк табылыр микән.* М.Гафури. *Җәйләүдәге мал чеметеп кабарлык үлән таба алмады.* И.Салахов. *– Әнием ачтан үлә... Шушы балта хакына бер кабарлык кына май бирче, җиңги, – дип, көчкә йомышын әйтте.* Ш.Янбаев

**КАБАРТМА** *и. махс.* Мич алдында майлы табада яки кайнап торган майда йөздереп пешерелә торган, йомры формадагы, ачыга күпертеп әзерләнгән камыр ризыгы. *Аннан чәй-шикәр, майлы күмәчләр, ләвәшләр, вак бәлешләр, кабартмалар, тагы әллә ничаклы тәмле ашамлыклар чыкты.* Г.Ибраһимов. *Кешеләр коймаклар коялар, кабартмалар пешерәләр, малайларына яңа күлмәкләр тегәләр.* И.Гази. *– Гөлүсәкәем, җүри сиңа дип атап, мул итеп пешердем... – дип, тирән коштабак тулы кабартмаларын күрсәтте.* М.Хәсәнов

◊ **Кабартма бит** Кабарып, түгәрәкләнеп торган тулы, симез бит. *Рафис та шунда, кабартма бит Ленар, әрекмән колак Ясәви дә калмаган иде, ятабыз җыйнаулашып тау башында.* Н.Хәсәнов. **Кабартма ирен** Бүлтәеп торган калын ирен. *Нур тулган ике күздән башка егетнең йөзендә җәлеп итәрдәй нәрсә юк иде. Җәенке борын, дугаланып тоташкан каш, кабартма ирен, маңгаена алкаланып төшкән кара чәч ---.* Н.Гыйматдинова

**КАБАРТУ** *ф.* 1) Тигез өслекне күтәрелеп тора торган итү, бүлтәйтеп чыгару, бүлтәйтеп кую. *[Гыйният] Яңадан көзге алдына барып, ике кулын бөгеп, көчле мускулларын кабарта.* А.Әхмәт

2) Нинди дә булса сәбәптән (ышкылып, өшетеп, пешереп һ.б.) тәннең берәр җиренә куык, кабарчык барлыкка китерү. *Кыска саплы көрәк белән куркыныч янау астында дөнья кадәр җир казу, балчык ыргыту, кулларын кабартып, билләрен бетереп кенә калмыйча, тәмам хәлдән тайдырган иде.* З.Фәйзуллин

3) Салкын алу, ялкынсыну. *Зыкы суыкларда урманнан ач-ялангач килеш утын тартып ташулар --- бердән-бер көнне, Маһиянең үпкәсен кабартып, аны түшәккә екты.* Н.Хәсәнов

4) Басылганлыгын, ятканын, изелгәнлеген бетерү, күпертү. *Яңадан бер кат көзгегә күз төшерде дә чәчләрен тагы бер кат бармаклары белән кабартты.* Ф.Әмирхан. *Киң агач ятакның өстенә тау-тау өелгән түшәк-ястыкларны, мендәрләрне яңадан кабартып җәйде.* Г.Ибраһимов

5) Басылып яткан җиреннән кузгатып, астын өскә каратып кую, әйләндерү. *Ә без, Зөфәр абый белән икәү генә калып, көннәр буена печән кабартабыз, печән киптерәбез.* Р. Мөхәммәдиев

6) Җирне казып йомшарту, көпшәкләндерү. *Алмагачларның төбен кабартты.* И.Гази. *Һәрбер кантарны кул белән диярлек уып, җирне түшәк сыман итеп кабартканнан соң гына, Иргали абый туфрак куенына бөртек керткән, имеш.* М.Хәсәнов

7) Камырны басканнан соң һәм ясап бетергәннән соң мичкә тыгар алдыннан җылыда тотып күпертү. *Син – шәһәр кызы, камырны ничек кенә кабартсаң да, авылда ипиең уңмас.* Н.Гыйматдинова

8) Сөтне яки токмачлы ашны кайнатып чыгарып күпертү. *Токмачыңны тизрәк кабартып чыгар! Ишетәсеңме, килен?* С.Рафиков

9) Тырпайту, өскә таба күтәрү (хайван, кош-кортларның мамыгы, йоны, сырты һ.б. тур.). *Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан, зур күренергә тырышып сыртын кабарткан, эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган.* А.Алиш. *Каурыйларын күркәсыман итеп кабартып юындылар алар.* Ш.Маннур

10) Эченә һава, газ өрдереп тутырып күпертү, күләмен зурайту, тыгызлау. *Яңакларын тыны белән кабартып, иреннәреннән нindидер сагышлы көй кысып чыгарырга тотынды.* Ә.Фәйзи. *[Фәрит] Тау-тау күбекләр кабартып, бөтенесен берьюлы уды.* Ә.Дусайлы

11) Җил киереп күпертү (җилкәнне, киемне һ.б.). *Атауга таба искән көчле җил җилкәннәрне әнә ничек кабарта, җилкән тукымасы барабан тавышы чыгарып дөпелдәп куя.* М.Юныс. *Ап-ак күлмәген җил кабарта. Рәсүлә ояла-ояла күлмәк итәген тезләренә тарта.* Р.Бәшәр

12) *куч.* Чамадан арттырып җибәрү, үзеннән өстәп сөйләү, күпертү. *Бу хакта җиңелгән, җәберләнгән булып күренү өчен, үзе теләп моны кабартты.* Г.Ибраһимов. *Серне сезнең берегезгә генә ач, китәсез барыгыз да кабартып.* Т.Әйди. *Фантазиямне тавис коерыгыдай кабартам да, җанны атам көтелмәгән рифма өере иркенә.* Р.Харис

13) *куч.* Башка мәсьәләләрдән аерып алып игътибарны юнәлтү, аны иң мөһиме итеп күрсәтергә тырышу. *Алманиянең тарихи үз мәйданына көнетөне бомба ява башлаганда, шул уңайдан җитәкчелеккә зарлану хатлары агылганда, Шәмсинең татар мәсьәләсен кабартырга тырышуына кайсы алман илтифат бирсен икән?* Т.Әйди

14) *куч.* Арттыру, көчәйтү, куәтләү. *Бу хәл карчыкның ачуын гына кабартты.* Г.Гобәй. *Укучылар алдына аларның яхшы яклары кабартып бирелгән.* Г.Нигъмәти

**Кабарта бару** 1) Берсе артыннан икенчесен кабарту; эзлекле рәвештә бер-бер артлы кабарту

2) Кабаруын акрынлап көчәйтү. *--- алгы пыялага туктаусыз чәчрәп сыланган сыек лай эчтәге ачуны отыры кабарта барды.* М.Маликова

**Кабарта башлау** Кабартырга тотыну. *Дөресен әйткәндә, Гөлчирәнең үзен болай үтә кырыс тотуы Әсфанның ачуын да кабарта башлаган иде инде.*

Ф.Хөсни. *Хәзер сыртын кабарта башлар, йон уңаена сыпырырга кирәк.* И.Нуруллин

**Кабарта төшү** Тагы да бераз кабарту; кабаруын көчәйтү, арттыру. *Бу нәрсә Мәликәнең ачуын тагын да кабарта төште.* А.Шамов. *Гаязның тынычлыгы Шәфыйкның ачуын кабарта төште.* М.Әмир

**Кабартып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә кабарту, тиз-тиз күпертү. *Чаршау артындагы урыннарын рәтләп, иплe генә бер-бер артлы мендәрләрен кабартып алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Кабартып ату** Тиз-тиз, аннан-моннан кабарту

**Кабартып бетерү** Барысын да, берсен дә калдырмыйча кабарту; тәмам, бик нык кабарту. *Аена – алты мең! Акча санатып, бармакларыңны кабартып бетерәм әле мин синең, бабай!* Р.Вәлиев

**Кабартып җибәрү** Бераз кабарту, берникадәр кабаруын көчәйтү; ниндидер сәбәп нәтиҗәсендә кабару. *Бу малайның яралануын башта ук белдермәве яңадан ачуын кабартып җибәрде.* Г.Бәширов. *--- куна тактага таратып куйган токмачны бармак очлары белән генә күтәреп-сикерткәләп кабартып җибәреп, суган әрчергә тотынды.* З.Фәйзуллин

**Кабартып кую** Кабартылган хәлгә китерү. *Сандыкны ябып, янә ястыкмендәрләрне өеп-кабартып куйды.* Р.Батулла. *Лак белән катырып, кабартып куелган куе кара чәчләрен каплаган затлы челтәр яулык йөзендәге шатлыгын яшерә алмады Фәзилә Хәмитовнаның.* Г.Мирһади

**Кабартып чыгу** Һәрберсен берәмберәм кабарту

**КАБАРУ** *ф.* 1) Тигез өслектә чыгынтылар барлыкка килү, бүлтәеп, күпереп тору. *Әнә, яшел бөдрә дулкыннары белән кабарып, тирә-юньгә урман җәелеп киткән.* Р.Фәизов

2) Тән күзәнәкләренә сыеклык тулып шешенү, шешкән булу, ялкынсыну. *Гәрәйнең үзендә шешенү сизелде... Балтырларыннан башлап, ботка таба кабару артты.* Г.Ибраһимов. *Марат исә чакыручының кызыл йөзенә, күп эчүдән кабарып капчыклана башлаган күз төпләренә игътибар итеп алды.* З.Фәйзуллин

3) Сугу, бәрелүдән, көч төшүдән имгәнеп күпереп чыгу, бүлтәеп аерылып тору. *--- ләкин хатынның җилкәсенә төзәлгән кул ялгыш битенә эләкте, сул яңагы, күз төбе кара янып, шешеп кабарды...* Г.Ибраһимов. *Авыр эштән аяктагы кан тамырлары кабарган*

4) Тәннең берәр урынында куык, кабарчык барлыкка килү. *Аякларның кабарган һәм чиләнгән җирләре башта авырткан кебек булсалар да, бара-бара кызып, авыртулары сизелми башлады.* М.Гафури. *Тик учлары гына кабара язды бугай.* М.Фәйзи. *«Тырма сабы тотсаң, кул кабара! Аннан соң бил авырта!» – дип кычкырды.* Н.Фәттах

5) Ачып күперү, күтәрелү. *Биш литрны көн дә өсти бара, апарасы һаман кабара.* М.Җәлил // Көпшәкләнеп күтәрелү, йомшау. *Буразна араларыннан гөрләвекләр ага башлады. Җир камыр кебек күперде, кабарды.* М.Галәү

6) Кайнап чыгып күперү, кайнавы белән күтәрелеп менү (мәс., сөт, аштагы токмач)

7) Һава тулып өрелү. *Сабын күбеге кебек кабаралар күбекләр алдымда.* Ә.Ерикәй. *Күкрәге бер кабарып, бер төшеп, авыр-авыр сулый.* Ш.Камал. *Суда һава белән кабарган күлмәгеннән тоттым дигәндә генә, «бульбаш» йөзүен тизләтеп, яр кырыена килеп җитте дә өскә үрмәли башлады.* К.Латыйп

8) Тырпаю, күперү, үрә басу. *Каپкара чәчләре кабарып, бөдрәләнеп тора.* Г.Ибраһимов. *Муенына каз итләре чыккан, бала йоннары кабарган, чәчләре суга манып алган мәче йоны кебек укмаш-укмаш кибеп каткан иде.* Г.Гобәй

9) Масаю, эреләнү, үзен зурга кую, һавалану. *Һәрвакыт бераз кабарырга, куык очырырга тырыша.* Г.Ибраһимов

10) Арту, күбәю, көчәю; таралу. *Айлы төндә ярдан-ярга сыя алмый аккан Кама бозлары өстеннән чыгып качулары турындагы сүзләр тагы ныграк кабарды.* Г.Ибраһимов. *Кинәт кенә болытлар кабара башлады, җир өстенә әллә ничек кинәт кенә караңгылык төште.* Д.Каюмова

11) *сөйл.* Симерү, юанаю, калынаю

12) Бөтен хәлгә килү, түгәрәкләнеп тулышу; тиешле күләменнән зуррак булып күренү. *Ул [кояш] әле ялкынсыз, әмма шулкадәр кызып кабарган, аның шәүләсеннән бөтен көнчыгыш шомлы кызарып, күңелгә куркыныч салып тора.* И.Салахов

13) *күч.* Ярсып китү, кызу. *Бу оятсыз кешенең авызына сугардай булып ачуы кабарды.* Ш.Камал. *Куллары да калтырана, ачуы да кабара.* М.Җәлил. *Әле ярый җилкәсендә авыр көянтә бар. Югыйсә Сәүбән, күңеленә тулышкан үпкә-ачуыннан кабарып, өскә күтәрелеп китәр иде.* Г.Гыйльманов

14) *күч.* Арудан баш кату, уйлый алмас дәрәҗәгә җитү. *Егетнең бу сораулардан башы кабарды, акылы томаланды.* Г.Ибраһимов

**Кабара бару** Акрынлап, аз-азлап кабаруы арту. *Ирнең ачуы кабарганнан-кабара барды: «Анда синең ни эшең? Синең әйбереɴ минем әйберем түгелмени?»* Г.Ибраһимов. *Юк, алар, чынлабрак баксаң, тик кенә тормыйлар икән, алар һаман кабара баргандай үсәләр, куералар һәм бик әкрен генә болай таба авышалар да иде...* Ә.Еники

**Кабара башлау** Кабарырга тотыну; кабару билгеләре күренү. *Күптән инде шул исереккә аның ачуы кабара башлаган иде.* А.Алиш. *Кинәт кенә болытлар кабара башлады, җир өстенә әллә ничек кинәт кенә караңгылык төште.* Д.Каюмова

**Кабара тору** Кабаруын дәвам итү, кабаруы көчәю. *Өзгәләнеп әрнегән җирләрен төкереклэп кашый бара – борчак-борчак ак бөрчекләр кабара тора.* З.Фәйзуллин

**Кабара төшү** Тагы да бераз кабару. *Маңгае турысыннан тигез итеп кискән кара чәчләре, кичке җилдә кабара төшеп, бераз дулкынлана ---.* А.Вергазов

**Кабарып бетү** Тәмам, бик нык кабарган булу. *Әтисе аның маңгаеннан үпте, кабарып беткән зур кулы белән Газинурның җиткән чәчләреннән сыйпады.* Г.Әпсәләмов. *Линдаль кабарып*

*беткән куллары белән ишкәкләрен кысыбрак тота.* Ф.Хәсәнов

**Кабарып җиту** Тәмам, бөтен көченә кабару. *Ачуы кабарып җиткән Акбүз ят кешенең каршысына сикерергә килеп басты.* Г.Гобәй

**Кабарып йөрү** Озак вакытлар дәвамында ачу саклау. *Ә теге техникка һаман ачуым кабарып йөри әле.* Ф.Хөсни

**Кабарып килү** Кабарырга әзерләнү, аз-азлап, акрынлап кабара башлау. *Чөнки председатель белән секретарьга Шәмгун картның да ачуы кабарып килә иде.* А.Шамов

**Кабарып калу** Кабарган хәлгә килеп, шул торышын саклау

**Кабарып киту** Ниндидер сәбәптән, этәргечтән соң кинәт кабару. *Бер дә көтелмәгән җирдән һәммәсенең кесәләре кинәт кабарып китте.* Г.Ибраһимов

**Кабарып тору** Әле, хәзер кабарган хәлдә булу. *Тәгәрмәчләр белән ат эзе арасыннан --- кабарып тора торган чирәмле сызыклы сызылып киткән тигезсез юллары бик матур булып күренәләр.* М.Галәү. *Ак мендәрләр кабарып тора, түрдәге көзге башына да сөлге эленгән.* Г.Әпсәләмов. *Җилкәсе киң, беләгендәге мускуллар ничек кабарып торалар.* А.Әхмәт

**Кабарып чыгу** Кинәт кабару, нинди дә булса сәбәптән кабарган хәлгә килү. *Теге кешенең муен тамырлары кабарып чыкты.* Ш.Камал. *Минем сул кулга 25 кайнарны чәпәгәннән соң, уч төбем кабарып чыкты.* Ә.Айдар. *[Күкшәләр] Ашаганда авызларын төйгечләп тутыралар, хәтта тамаклары кабарып чыга.* Н.Сладков. *Ике учым да кабарып чыккан иде.* М.Юныс

**КАБАРЧЫК** *и.* 1) Тире өслегендә барлыкка килгән сулы яки үлекле куык; авыртулы төер. *Ишкәк ишкәнгә, кыш буе кара эш эшләмәгән кулларга кабарчыклар чыга, аның каравы күкрәкләр киң сулый, үпкәләр язгы саф һавага рәхәтләнәләр иде.* Р.Гали

2) Сыеклык эчендә барлыкка килгән һава яки газ куыкчыгы

3) *күч.* Мактанчык, буш сүз сөйләүче, шапырынырга яратучы. *Һәм шул хәлләр аның халык телендә «җилкуар, мактанчык, куык вә кабарчык» дип тә аталгалавына сәбәп булалар.* Г.Ибраһимов

**КАБАРЫНКЫ** *с.* 1) Кабарып, өскә калкып торган. *Кабарынкы коңгырткарасу чәчләре тулы түгәрәк йөзенә килешеп тора.* Н.Хәсәнов. *Шәмсир --- бокаллардагы мул вә кабарынкы күкрәкле, кып-кызыл иренле, сары чәчле шәрә чибәркәй сурәтенә [карый].* Т.Әйди. --- *кибет мөдире, кабарынкы җирән мыегын кулы белән баскалап бераз дәшми торач, үз кабинетына кереп китте.* Г.Ахунов

2) *махс.* Өслеге калкып, йомрыланып торган. *Үрмәкүч бөтенесен үзенең кабарынкы аркасына өйгән.* Р.Хафизова. *Кабарынкы күзге*

3) Катлы-катлы. *Аның өстеннән диярлек искиткеч зур җилкәннәр сыман кабарынкы болытлар Көмеш Алан ягына таба агылалар иде.* Г.Кашапов. *Күкне бизәп, каурый болытлар әкрен генә селкенгәләп тора, ара-тирә кабарынкы болытлар күренгәли.* Д.Каюмова

4) *күч.* Югары стильдәге, нәзакәтле дип саналган (мәс., стиль, сүз һ.б.)

5) *күч.* Чынбарлыктагыдан, гамәлдәгедән чамасыз арттырылган. *Кабарынкы сүзләр*

**КАБАРЫНКЫ́-БАТЫНКЫ** *с. махс.* Бер ягы кабарып, икенче ягы батып торган. *Кабарынкы-батынкы линза*

**КАБАРЫНКЫЛАНУ** *ф.* Кабарынкы хәлгә килү

**Кабарынкылана бару** Аз-азлап, акрынлап кабарынкылану

**Кабарынкыланып бету** Бөтенләй, тәмам кабарынкылану

**Кабарынкыланып тору** Әле, хәзер кабарынкы булу, кабарынкы хәлен саклау

**КАБАРЫНКЫЛЫК** *и.* Кабарынкы булу сыйфаты. *Аның күз алдына улының зифа буе, балаларча кабарынкылыгы да чыгып бетмәгән чиста чибәр йөзе килеп баса.* Ф.Латыйпов

**КАБАРЫНУ** *ф.* 1) Йоннарын, төкләрен тырпайту. *Таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабарынган кыяфәте белән тыныңны куыра иде.* Г.Бәширов

2) Һава белән өрелү. *Хәлим дә, мәчедәй атылып, өй түбәсенә менеп китте: аның күлмәге, җилдә кабарынып, җилкән кебек киерелде.* И.Гази

3) *күч.* Эреләнү, масаю, үзен эре тоту. *Ләкин арыганмы, --- башка сәбәбе бармы, Булат алай бәхеттән, шатлыктан кабарынмады.* Г.Ибраһимов. *Ләкин Гаяз үзендә һәм миндә туа башлаган кабарынуны икенче төрле басу юлын тапты.* М.Әмир

4) *күч.* Дулап киту, ачудан ярсу, тузыну. *Нигъмәт казый бөтенләй ачу белән кабарынды, сезнең белән уртак телем юк минем, дип, чыгып китәргә атлады.* Г.Ибраһимов. *Хатын шартлар дәрәҗәгә җитеп кабарынды, бүртенде дә пыр тузып чыгып китте...* Г.Гыйльманов

**Кабарына башлау** Кабарынырга тотыну. *Яз җиттеме, шул нәзек кенә елга киң дәрьяларга охшарга тырышып кабарына башлый.* Л.Гайнанова

**Кабарынып алу** Беразга гына кабарыну. *Ләкин кая ул, ана тавык кабарынып ала да аны очыртып алып китә.* Ф.Исламова

**Кабарынып бету** Тәмам кабарыну. *– Син нәрсә, Ярулла, кызганмыйсыңмы әллә аларны? – Ул көлеп җибәрде, кабарынып беткән кулы белән кытыршы ташны сыйпарга тотынды.* Г.Әпсәләмов

**Кабарынып йөрү** Гел, һәрвакыт кабарыну. *Мин мин микән, мин кем икән дип, күркә сыман кабарынып йөрим.* В.Имамов

**Кабарынып килү** Әкренләп кенә кабарыну. *Чилләдә коеп яварга кабарынып килгән мул яңгыр болытларының һәммәсе дә газиз авылым Яңа Сәеттән йөзеп килгәндәй тоела миңа.* Зөлфәт

**Кабарынып кую** Тиз арада кабарыну. *Кифаяныкы [кушаматы] кияүгә килгәнче Керпе – кайвакыт, кызып киткәндә, керпе кебек кабарынып куя, кызган Кифая кырыена килмәвең күпкә кулайрак.* Х.Зәйнуллин

**Кабарынып тору** Кабарынган хәлдә булу

**Кабарынып чыгу** Кинәт кабарынган хәлгә килү

**КАБАТ** *рәв.* **1.** 1) Яңадан, тагын бер тапкыр, икенче мәртәбә. *Байтак вакытлар ул моның белән бөтенләй*

*кызыксынмаган булып, бу турыда икенче кабат сүз кузгатмый йөрде.* Ш.Камал. *Безне кабат күрмәссез, хушыгыз инде, диделәр.* А.Алиш. --- *иртәгә барысын да берьюлы хәл итәрмен дип, кабат рәхмәтләр әйтеп, ул [Иргали] Гыйззәт хәзрәтләрдә кунарга калды.* М.Хәсәнов

2) Тапкыр, мәртәбә, кат. *Үксеп үпте үксез балаларын соңгы кабат кысып, суырып.* М.Җәлил. *Әгәр ул шунда кызса яисә яңагыма сугып җибәрсә, мең кабат җиңелрәк булган булыр иде.* А.Шамов

**2.** *с. мәгъ. саннар янында яки кбт. форм.* Өсле-өсле, кат-кат, катлы-катлы. *Җитмеш кабат күлмәк аркылы тәннәре күренеп тора, ди бит.* Ш.Камал

**КАБА́Т-КАБАТ** *рәв.* 1) Берничә тапкыр, әллә ничә мәртәбә, кайта-кайта, кат-кат. *Батырша пьесасының кайбер урыннарын кабат-кабат уйнатты.* К.Нәҗми. *Улы белән килене язып калдырган хатны алып, кабат-кабат укый.* Г.Бәширов. *Тикшерүче кабат-кабат менә шул сорауларга җавап эзләде.* З.Фәтхетдинов

2) Өсте-өстенә, берничә тапкыр. *[Акмалның] Йөрәге кабат-кабат кысылып килде, сулыш алуларына хәтле ешайды.* Г.Ахунов

3) Катлы-катлы итеп, берничә кабат. *Көн яңгырга тартып, болытлар кабат-кабат өелгән*

**КАБАТЛАНМА** *с.* Кабатланып торган, даими, һәрвакыт булгалап тора торган

**КАБАТЛАНМАЛЫ** *с. к.* **кабатланма**

**КАБАТЛАНМАС** *с.* Бүтән күрелмәгән, башка кабатланмаган; бердәнбер. *Минем котыпта булганым юк, әмма папанинчыларга кабатланмас хөрмәт саклыйм.* А.Гыйләҗев. --- *кайчандыр зәвык белән ясалган тәрәзә йөзлекләре, кәрниз һәм капкалары, хәтта коймалары Нурлы Аланның кабатланмас йөзен тәшкил итә иде бит.* Р.Мөхәммәдиев

**КАБАТЛАНУ** *ф.* 1) Бер үк эш, хәл, вакыйга яңадан, кабат башкарылу, янәдән үтәлү. *Ул хәлләрнең Казанда кабатлануына юл куймас өчен, ныклы чара күрергә.* К.Нәҗми. *Тагын тынлык урнашкач, җәнлек йөридер ахры, дип уйлады лейтенант, әмма кыштырдау тагын кабатланды.* З.Фәтхетдинов

2) Яңартылу, яңадан кичерелү; яңадан барлыкка килү. *Бу гаҗәп шомлы уй аның башында туктаусыз кабатлана.* А.Шамов. *Ничә тапкыр күргәндер Габдрахман бу төшен, ярый әле авылында аның кабатланганы юк.* Ф.Яхин

3) Кайтаваз ясалу. *Мостафаның тавышы, төнге тынлыкны ярып, Сакмар буйлап яңгырап китте һәм кабатланып кире чагылды.* Ш.Камал

4) Тапкырлану, арту

**Кабатлана бару** Бер-бер артлы эзлекле рәвештә кабатлану. *Ә йөгергән саен, теге тәмле папиросның матур исеме синең телеңдә кызурак кабатлана бара.* Ш.Камал

**Кабатлана башлау** Кабатланырга тотыну. *Хастаханәдән соң әйбәтләнебрәк тора да, аннан тагын өянәге кабатлана башлый.* Д.Булатова. *Калган көннәрдә әлеге хисләр бер кич дәвамында ук кабатлана башлады.* Х.Ширмән

**Кабатлана тору** *к.* **кабатланып тору**. *Кичен һәм иртән кабатлана торган җәйге бәйрәмнең көтмәгәндә кечерәюе Юртайның уйлы кешеләрен пошаманга салды.* М.Хуҗин. *Ә-ә, сез бит Фәлән Фәләнеч, дип танып, кул биреп, хәл сорашулары кабатлана торды.* Ф.Яхин

**Кабатланып бару** *к.* **кабатлана бару**. *Башламдагы бу бер юл шигырьнең эчендә рефрен булып, кабатланып-кабатланып бара да, ниһаять, шигырь шул ук юл белән тәмамлана.* Х.Госман

**Кабатланып йөрү** Күп тапкырлар кабатлану. *«Контрактация» дигән әкәмәт сәер сүз җыелыш саен кабатланып йөрде.* Г.Ахунов

**Кабатланып тору** Даими, һәрвакыт кабатлану, еш кабатлану. *Һава тревогасы бу шәһәрдә еш кабатланып торды.* Г.Гали. *Ә кичкә таба --- бер ханымның пальтосы югалганлыгы мәгълүм булды ---. Мондый хәлләр сирәк булса да, кабатланып тора.* Г.Ахунов. --- *бу дөньяда һәммә нәрсә кабатланып тора, кичә баеган кояш бүген иртән тагын чыга ---.* М.Маликова

**КАБАТЛАНУЧАН** *с.* 1) Еш кабатлана торган, еш очрый торган. *Диалектика кануны предметлар, күренешләр арасында тотрыклы рәвештә кабатланучан ---.* К.Гыйззәтов

2) Кабат-кабат әйтелгән, тәкрарланган

**КАБАТЛАНЫШ** *и.* Кабатланганлык, кабатлану. *Үкенү, зарлану түгел, Бу – йөрәкнең тавышы. Илаһи бер мәхәббәтнең Җанда кабатланышы.* Ф.Яруллин. *Авазлар кабатланышы*

**КАБАТЛА́У** *ф.* **1.** 1) Алдан эшләнгән эшне нәкъ шул ук рәвештә яңадан икенче тапкыр башкару. *Салих әфәнде ни өчендер бер сүз дә әйтмәде, тик яңадан игътибар беләнрәк кабатларга кушты.* А.Еники. *Узгандагы хаталарыңны хөкем итә белмәсәң, аларны яңадан кабатлавың мөмкин.* А.Гыйләҗев

2) Икенче кешенең эш-хәрәкәтен, ишарәсен, сүзен, сөйләмен, кыланышын аныңча күрсәтү. *Туркин ---, кәгазен вак-вак кисәкләргә ертып, тартмага ташлады, Гәрәй дә шул ук хәрәкәтләрне кабатлады.* А.Гыйләҗев

3) Тәкрарлау, бер сүзне кайта-кайта сөйләү. *Попугай шикелле бер сүзне эләктереп алганнар да урынлы-урынсыз кабатлыйлар да торалар.* Ш.Камал. *Үзалдына үзе сөйләнеп, «аллаһу», «ләхәүлә» сүзләрен кабатлап, Тәхвә Сәхәү килеп керде.* М.Әмир

4) Кайтаваз булып яңгырау

5) Искә төшерү, хәтердә ныгыту өчен кат-кат уку, укып хәтергә сеңдерү

6) *мат.* Тапкырлау

**2.** *и. мәгъ. әд.* Бердәй авазларның яки сүзләрнең билгеле бер эзлеклелектә килүенә нигезләнгән шигъри алым. *Әдип – каһарман сүзләре берләшеп киткән монологлар, лирик кабатлаулар, сыйфатлауларда дини, мистик сурәтләүләрнең саклануы еш очрый.* Г.Нигъмәти

**3. кабатлап** *рәв. мәгъ.* Кабат, икенче тапкыр, яңадан. *Шулай да мин канәгатьләнә алмадым, яңа редакциядә боларга кабатлап тукталдым.* Г.Ибраһимов

**Кабатлап алу** Тиз генә кабатлау. *Карын бик ачып кайткан иде, аннан шундый җылы сүзне ишеткәч, кызларның үземне кыерсытуларын да онытып, теге сабакны тагын ике-өч тапкыр кычкырып кабатлап алдым.* М.Галәү

**Кабатлап бетерү** Барысын да кабатлау; ахырына кадәр кабатлау

**Кабатлап йөрү** Һәрвакыт, бертуктаусыз кабатлау. *Марат исә гүя көлгәнне ишетмәде, елмайганны күрмәде, үзенчә сөйләнеп, сестра нишләсә, шуны кабатлап йөрде.* Г.Гобәй. *Күңеленнән кабатлап йөргән берничә дога гына ярдәм итмәс шул...* Г.Гыйльманов

**Кабатлап килү** Бер-бер артлы, эзлекле рәвештә кабатлау; берсе артыннан икенчесен кабатлау. *Шулай көнне көнгә кабатлап килә торгач, ул [Зөһрә] өйрәнелми калган кагыйдәгә дә килеп җитте.* Г.Гыйльманов

**Кабатлап кую** Бер тапкыр кабатлау, алдагы сүзне кабат әйтеп кую. *Фәхринең юкка-барга бәйләнү гадәте юк иде, булмаганны сөйләп маташасыз дип, каты итеп кабатлап куйды.* Г.Ибраһимов. *Рәхилә ихтыярсыз янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды.* Ә.Еники

**Кабатлап тору** Берничә тапкыр кабатлау; бертуктаусыз кабатлау. – *Шулай булгач... шулай булгач,* – *дип кабатлап торды да, кинәт, янәшәсендәгеләрне сискәндереп, һич көтмәгәндә, чалышма аяклы өстәлнең утызлы такталарына авыр йодрыгын төшерде.* Г.Кашапов

**Кабатлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, яңабаштан кабатлау. *Нинди дога булды әле? Онытканчы, тагын бер мәртәбә кабатлап чыгасы иде!* Г.Гыйльманов

**Кабатлый бару** Эзлекле рәвештә һәрберсен кабатлау

**Кабатлый башлау** Кабатларга тотыну. *Бераз бер урында таптангач, Гөлкәй якын-тирәдәге шактый остарган биючеләрнең хәрәкәтләрен кабатлый башлады.* Х.Ширмән

**Кабатлый төшү** Тагы да бераз кабатлау

**КАБАТЛАУЛЫ** *с.* 1) Берничә тапкыр кабатлана торган

2) *лингв.* Эш яки хәлнең кабатлануын яки сирәгрәк булуын аңлата торган (фигыль формасы тур.). *Татар телендә йөргәләү, баргалау, эшләштерү, укыштыру кебек кабатлаулы фигыльләр бик еш кулланыла*

**КАБАТЛЫ** I *с. сөйл.* Берничә катлы, өсте-өстенә яткан. *Өстәлдә кабатлы папкалар өеме*

**КАБАТЛЫ** II *с. мат.* **1.** Нинди дә булса санга калдыксыз бүленә торган. *Кабатлы саннар*

**2.** *и. мәгъ.* Калдыксыз бүленә торган саннарның үзе. *Кабатлысын табу*

**КАБА́ ТӨБЕ** *и.* 1) Кабаны беркетеп куя торган тактасы. *Бер уйласаң, бик кызык инде: каба төбендә орчык эрләп утыручы шушы Фатыйма өчен сугышып йөрде бит.* И.Гази. *--- иске кабаның тәрәш тарагын яңа каба төбенә сыйдыру өчен бер суккан иде, яңа каба төбе кинәт ярылып китте.* Д.Каюмова

2) Эрләгәннән соң каба тарагында калган чүбек

**КАБАТТАН** *рәв.* Яңадан, тагын, кабат. *Шундый матурайган ул [Нәфисә], әле бая кабаттан гашыйк булып чыктым...* Г.Гыйльманов

**КАБАХӘТ** *с. гар.* **1.** 1) Җирәнгеч, әшәке, шакшы. *Иң кабахәт шартлар эчендә эшләп килгән эшчеләргә, --- үзләренең аң-белемнәрен күтәрүгә, үзләрен сәяси үстерүгә мөмкинлек булмагандыр.* Һ.Такташ. *Аларны көндез кырларда арпа, богдай урдырып, дөге иктереп, печән чаптырып, кояш баеганда, шәһәрдәге караңгы, һавасыз, сасы, җәһәннәм чокыры кебек кабахәт зинданнарга тутырып, ачлы-туклы асрый иде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Түбән җанлы, әхлаксыз, кеше намусына тия торган. *Менә бит, шундый вакытта кайсыдыр бер кабахәт җанның гайбәт сөйләргә теле бара.* Г.Бәширов. *Кабахәт шартларга куелган бу гәзитне, шул шартларга күнеп-җайлашып беткән ул кешеләрне барыбер үз күреп бетерә алмаячагым билгеле иде...* З.Мифтахов

3) Тупас, тәрбиясез. *Гәрчә Бохара зур мәдрәсәләре, галим мөдәррисләре илә искедән бирле атаклы икәнен һәркем белсә дә, анда бик начар эшләр, кабахәт, мордар гадәтләр күптер.* Ш.Мөхәммәдев

4) Әдәпсез, оятсыз, яман. *Гыйрфан бай, бөтен дөньяның нигъмәтен җыеп бетерә алмаячактыр дип, артык кабахәт сүз белән сүгенеп, Галинең яңагына шундый салып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Ә кичә әнә килеп керүгә нинди кабахәт сүзләр белән сүгенде, җикеренде, хәтта сугарга омтылды – кулын тотып калдым.* И.Салахов

5) Коточкыч явыз, имәнеч. *Хәзерге фашист палачларының җирәнгеч ерткычлыклары, күләм һәм куркынычлык ягыннан кешелек тарихында булып үткән иң кабахәт ерткычлыкларны да бик күп артта калдыра.* Ш.Камал. *Фин сугышын күрдем. Бусы фин сугышы гына түгел, герман армиясе – бик кабахәт армия ул.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тискәре, начар сыйфатларга ия кеше. *Син – иң кабахәтләрнең кабахәтрәге, иң намуссыз адәмнәрнең дә намуссызрагы, имешсең.* Ш.Мөхәммәдев. *Ничек итеп мин шундый кабахәтне башта таный алмадым?!* Т.Гыйззәт

2) Сүгенү сүзе. *Әй, кабахәт, җыен чүп-чар кәгазьләр.* М.Фәйзи. *Кабахәт!.. Кан эчеп бүртенгән кандаламыни!* М.Хәсәнов

**3.** *рәв. мәгъ.* Әхлаксыз, түбән җанлы, җирәнгеч. *Шулкадәр кабахәт булып күренде миңа ул кеше: ачуымнан ярылырга җитешеп, бөтен тамырларым буенча каным таша башлады.* М.Әмир

**КАБАХӘТЛӘНҮ** *ф.* Намуссызлык күрсәтү, кабахәт гамәлләр кылу

**Кабахәтләнә бару** Торган саен ныграк кабахәтләнү, кабахәтлеккә көчәю

**Кабахәтләнә башлау** Кабахәтләнергә тотыну

**Кабахәтләнә төшү** Тагы да кабахәтләнү

**Кабахәтләнеп бетү** Тәмам, бик нык кабахәтләнү

**Кабахәтләнеп китү** Кинәт, кайсыдыр вакыттан соң кабахәтләнү

**КАБАХӘТЛӘ́Ү** *ф.* Әшәке, оятсыз, әдәпсез сүзләр әйтеп хурлау. *Шакир сугышта, солдатта, төрмәдә алган барлык начар сүгенү сүзләре белән боларны кабахәтләп куа.* Г.Ибраһимов

**Кабахәтләп бетерү** Тәмам, бик нык кабахәтләү

**КАБАХӘТЛЕК** *и.* Кабахәт гамәл, түбән җанлылык; явызлык, әшәкелек. *Инде моннан соң да үзенең кабахәтлеген ташламый икән, әйдә, чәнчелеп*

*китсен.* Ш.Камал. *Ул [Фәтхерахман] да, Мөгълифә карчык кебек, акча өчен дөньядагы һәрбер кабахәтлекне эшләүдән тартына торган кеше түгел.* М.Гали. *Ярый, кабахәтлегеңне танырга йөрәгең җитмәсә дә, аны кире какмавың әйбәт анысы.* В.Нуруллин

**КА́БЕЛЬ** *и. голл.* Ерак араларга электр энергиясен, сигналлар тапшыру өчен кулланыла торган герметик тышчалы бер яки берничә электр чыбыгы. *Күрәсең, телефон кабеле шул таякларга эленгән булгандыр.* Г.Бәширов. *Телефоннан сөйләшкәндә, кабельнең икенче очындагы кешенең йөзен күрергә тилмереп, газапланып бетәм.* М.Юныс

**КА́БЕЛЬЛЕ** *с.* Кабель ярдәмендә тапшырыла һәм кабул ителә торган, кабель куллану нигезендә эшли торган. *Кабельле телевидение*

**КА́БЕЛЬ-МА́ЧТА** *и. голл.* Старттагы космик комплексны хәрәкәткә китерә торган системаның бер өлеше

**КА́БЕЛЬТОВ** *и. голл. махс.* 1) Диңгездә 185,2 м озынлыкка тигез булган үлчәү берәмлеге

2) Судноларда кулланыла торган 150 мм дан 300 мм га кадәр юанлыктагы киндер сүсеннән ишелгән тросс

**КА́БЕЛЬЧЕ** *и. махс.* Кабель сузу яки кабель эшләү белән шөгыльләнүче зат

**КАБЕР** *и. гар.* 1) Мәет җирләү өчен махсус тәртипләрен үтәп казылган чокыр; мәет җирләнгән урын, гүр. *Кабер өелеп бетүгә, рота командиры үзенең будёновкасын салып, Бикмуш бабайның кабере өстенә куйды.* Г.Гобәй. *Эш күрсәткән ирне ил онытмас, каберенә эзне суытмас.* М.Җәлил. *Аның ире полк командирының урынбасары булган, ул хатын иренең каберен күрергә килгән.* Г.Ахунов

2) *күч.* Үлем, һәлакәт. *Дошман өчен совет иле кабер генә була ала.* Ә.Исхак. *Бу чокыр калганнарына – немец, фин еланнарына – котылмас кабер булыр.* Ф.Кәрим

◊ **Кабер алу** Үлү, гүр иясе булу. *Анамны хәтерли алмыйм: минем гомерем яшь ярымга җитмәстән элек, аны кабер алган.* Г.Ибраһимов. **Кабер газабы** 1) Ислам динендә: үлгәннән соң кабергә күмелгәч чигеләчәк газап; гүр газабы. *Уф Алла, кабер газабы да хак, Мәкәрҗә дә хак диеп, бик киң сулыш алды.* Ш.Мөхәммәдев; 2) *поэт.* Газаплы, авыр тормыш. **Кабер газабы чигү** 1) Ислам динендә: үлгәннән соң кабердә газап чигү; 2) Бик нык борчылу, өзгәләнү. **Кабергә басу** *к.* **кабер якасына басу**. *Әй, картлач, үзенең бер аягы кабергә баскан, үзе кеше тикшереп торган була.* Р.Ишморат. **Кабергә кертү** Вакытсыз үтерү яки үләр хәлгә җиткерү. *Салкын барак өч баласын тереләй кабергә керткән.* Г.Кутуй. *Син түгелме әтине вакытсыз кабергә кертүче?* Ш.Әхмәдиев. **Кабергә керү** *к.* **кабер табу**. *Кабаланып, кешедән элек кабергә барып керде.* И.Гази. **Кабердән чыккан кебек (төсле)** 1) Бетеренгән, хәлсез, авыру кеше турында; 2) Ерактан, тонык кына ишетелгән тавыш турында. *Шушы арада лабазның аръягыннан әллә нинди сөйкемсез җикеренүләр, кабердән чыккан тавышлар шикелле авыр ыңгырашулар ишетелә башлады.* Ш.Камал. **Каберең ерак булсын** «Бу яман кешеләр белән бәйләнеш тотарга ярамый» мәгънәсендә. **Каберең якын (янәшә) булмасын** *к.* **каберең ерак булсын**. *Кибетче Сирайныкыларга каберең якын булмасын.* Ф.Хөсни. *Куян Кыямның ачуы килүен яшереп булмый, Миргазыйга тәмам үпкәләп, турсайган иренен итәгенәчә асылындырып, бөтенләй дә икенче урынга ук күченеп утырган. Имеш, мондый кешегә каберең якын булмасын, рәхмәтсез, гөнаһ шомлыгы!* Ф.Яхин. **Кабер казу** Үлем теләү, һәлакәт әзерләү, юкка чыгару өчен астыртын эшләр башкару. *Революция яши, һәм ул үзе турында белдерер әле сезгә, кабер казучы әфәнделәр...* К.Нәҗми. *Кеше үлем алдында булган, үлә башлаган, ә сез, бәладән йолып аласы урынына гайбәт чәйнәшеп, аңа кабер казыгансыз.* Г.Кутуй. *Ул мәңгегә кире кайтмас итеп искелеккә казый кабер-не.* Ә.Исхак. **Кабер кебек** Бик тар, кысан һәм караңгы. *Өй бер якка салынып тора, тәрәзәләре ватык, эче кабер кебек караңгы...* Ш.Камал. *Бүлмәң кабер кебек: тар, кысан, утырам дисәң – урындыгың юк.* И.Гази. **Кабер кочу** *к.* **кабер алу**. *Күптән инде мескенне салкын, юеш кабер кочкандыр.* Ф.Бурнаш. **Кабер сөале (соравы)** Ислам дине буенча: үлгәннән соң кабердә соралачак сорау(лар). **Кабер табу** Һәлак булу, үлү, юк булу. *Йолдыз кебек атылып төштем туфрагыңда кабер табарга.* А.Алиш. **Кабер тынлыгы** Шомлы, тирән тынлык, бернинди хәрәкәт беленмәү. *Дөнья тынды, зинданны кабер тынлыгы каплады.* Г.Ибраһимов. **Кабер якасына басу** Үләр көннәре якынлашу, гомер бетү. *Кабер якасына килгәнсең бит инде.* Ш.Камал. **Кабер якасына җитү** *к.* **кабер якасына басу**. **Кабер якасына килү** *к.* **кабер якасына басу**. **Кабер якасында** 1) Үләр хәлгә җиткән, үлемгә якынлашкан, гомере беткән. *Каберем якасында мин инде.* Ф.Бурнаш; 2) Үлгәндә. *И туганым, алтыннарның алтын түгеллеген, ә дөньяның – кояш, урман-кыр, су-дәрьяларның – чиксез каderле алтын икәнлеген без бик соңлап, кабер якасында гына аңлыйбыз икән шул!* Р.Хисмәтуллин

**КАБЕРГӘ́ЧӘ** *рәв.* Үлгәнче, гомер буе, бөтен яшәешенә. *Мәрьям туташны, үзе белгәннән бирле яратышып йөргән вә кабергәчә бергә булырга вәгъдә куешкан ярлы Зыяга бирмичә, икенче бер егеткә биргәннәр.* Г.Ибраһимов

**КАБЕ́Р КАЗУЧЫ** *и.* 1) Зиратта кабер казу эшен башкаручы кеше

2) *күч.* Астыртын гамәлләре белән кемгә дә булса бәхетсезлек, һәлакәт әзерләүче кеше

**КАБЕРЛЕК** *и.* Үлекләр күмү өчен махсус аерып алынган урын; гүрстан, зират. *Каберлекнең урта бер җирендә биш-алты төп картайган имән агачларын көзге кичнең үткен, салкын җиле ия, сыга, ыңгыраштыра.* Ш.Камал. *Күмәргә килгән халык, кара болыт булып, бөтен каберлекне каплап алды.* Г.Ибраһимов. *Кинәт Жуковка каберлектәге иксез-чиксез тәреләрнең берсе хәрәкәтләнә, дөресрәге, үз күчәре тирәсендә әйләнә сыман тоелды.* З.Фәтхетдинов

**КАБЕРНЕ** *и. фр.* 1) Шәраб җитештерү өчен үстерелә торган куе зәңгәр төстәге виноград сорты

2) Шул сорт виноградтан җитештерелгән шәраб

**КАБЕ́Р САДАКАСЫ** *и. дини* Исән чагындагы гөнаһларын йолу өчен, өченә кадәр бирелә торган, мәетнең өстенә әйтеп аталган аяклы малдан гыйбарәт садака. *Кабер садакасына бер тавыгыңны бирерсең.* Ш.Камал

**КАБЕРСТАН** *и. гар.-фар. к.* **каберлек**. *Арбалар, иярле атлар кузгалдылар, җәмәгать мәет артыннан каберстанга юнәлде.* Г.Ибраһимов. *Пөхтә итеп койма белән уратып алынган түбәтәй-таулыкка урнашкан каберстанга ялгыз керү көндезен дә шомландыра.* Г.Гыйльманов. *Кышкы зәмһәрир суыкта Дәрдемәнднең җәсәден нибары ике кеше каберстанга алып килә: ызба хуҗасы белән аның кызы, Дәрдемәнднең җеназасын чыптага төреп, чанага салалар.* Б.Урманче

**КАБЕРЧЕ** *и. к.* **кабер казучы** (*1 мәгъ.*). *Ул ята, Иске тормышны күмәргә килгән бөек каберче.* Һ.Такташ. *Ике каберче табутның өстен каплап каберга төшерделәр, кешеләр учлап туфрак ташлый, арттагылар сөйләшә.* Р.Батулла

**КАБЕСТАН** *и. фр. махс.* Йөкләрне бер урыннан икенче урынга күтәреп күчерү җайланмасы; лебёдка

**КАБЗЫЯТЬ** *и. гар. иск. кит.* Куркып калу, каушау. *Әллә нишләп мине кабзыять алып тора.* Ш.Камал

**КАБЗЫЯТЬЛЕ** *с.* Каушаулы, куркынулы. *Бабай угылын кочакламакчы булган иде, ләкин Җәгъфәр, аягына егылып, кабзыятьле тавыш илә бу сүзләрне сөйли башлады: «Менә, әткәй, мин сезнең хозурыгызга тагы килдем, сезнең сүзегезне ишетергә яндым, ашыктым».* Г.Тукай

**КАБИЛ** I *с. гар. кит.* Булдыклы, сәләтле, булдыра, үзләштерә, аңлый алучы. *Табигатемезнең яхшы яклары исә – горуранә, үзләрен ваксытмыйча башка халыктан зур тотулары, сабыр, һәрнәрсәне күтәрә торган, үткен, һәрнәрсәне белергә кабил --- бер табигатьтер.* Г.Газиз. *Балалар – һәртөрле язу язылуы кабил булган ак кәгазь вә яки һәртөрле нәрсәнең сурәте күрелергә мөмкин булган көзгеләрдер.* Р.Фәхретдин

**КАБИЛ** II *и. гар. кит. гадәттә тартым һәм кыек килеш форм.* Төр, төркем; категория, сорт. *Һәрбер сүзе аның өчен кызыл фонарьга кору, җан вә табигате илә кирәксенә торган бер ихтыяҗ, бер зарурәт кабиленнән икәнен белдереп тора.* Г.Ибраһимов

**КАБИЛӘ** *и. гар.* 1) Үзара кардәшлек мөнәсәбәтләре белән берләшкән, телләре һәм гореф-гадәтләре уртак булган, бер территориядә яшәүче берничә ырудан торган төркем. *Соңгы утыз ел буенча найман белән сарман кабиләләре арасындагы талашларны ---, талашларның фаҗигаләрен озак-озак итеп, бер-бер санап чыкты.* Г.Ибраһимов. *Аның янына күрше дус кабиләләрнең юлбашчылары күңел ачу мәҗлесенә җыелган.* Н.Вәлитова

2) Ыру, бер ырудан булган халык. *Борынгы төрек кабиләләреннән кергән сүз.* М.Җәлил. *[Мелла Мөхәммәдҗан мөфти] Руслар белән аралашып яшәүдән курыккан һәм аларга буйсынырга теләмәгән казак, башкорт һәм башка кабиләләрне төрле юллар белән кызыктырып һәм куркытып буйсындыруда катнаша һәм бу юлда зур нәтиҗәләргә ирешә.* Ш.Мәрҗани. *Бу кыпчак кабиләсенең урамыннан исән-сау үтеп, сәүдәгәрләр, җилкәннәрен киереп, ишкәкләрен салмак кына салып, Идел белән өскә күтәрелеп киттеләр.* Г.Гобәйдуллин

3) Парлы сүзләрдә бер компонент: ыру, ерак туган. *Кардәш-кабилә сөенде. Галим абзый да шатланды.* Г.Исхакый

**КАБИЛӘДӘШ** *с.* Бер кабиләдән булган. *Кызганычка каршы, имәнкискәлеләр дә һәм аларның кабиләдәш күршеләре дә безгә үзләренең исемнәрен дә, тел мирасларын да калдырмаганнар.* Р.Фәхретдинов. *Өйләренә кайткач, аучылар үзләренең кабиләдәшләренә нинди матур һәм бай җирләргә тап булулары турында сөйлиләр.* Ф.Урманче

**КАБИЛӘЧЕЛЕК** *и. тар.* Кабилә булып яшәү рәвеше, кабилә булып яшәү чоры. *XVII гасырда Нократ буена килеп утырган татарларның борынгы ыру, кабиләчелек бәйләнешләре чагылышы булган «җыеннар» яңадан җанлана.* М. Әхмәтҗанов

**КАБИЛИЯТ** *и. гар.* 1) Табигый сәләт, талант, булдыклылык, кулдан килү. *Ә бәлки, чын музыкант та булып китәр, бөтен эш аның кабилиятенә һәм сезнең теләккә бәйләнгән.* Ә.Еники

2) Белү, төшенү, аңлый алу сәләте; мөмкинлек; потенциал. *Өгрәтсәң беләр, шулай булса да, кабилият һәм сәлахият төрлечәдер.* З.Һади

**КАБИЛИЯТЛЕ** *с.* Табигый сәләте булган, талантлы, булдыклы. *Онычгыз кабилиятле, истигъдатлы күренә, Казанга-фәләнгә җибәреп укыту чарасын күрәсе иде.* М.Хәсәнов

**КАБИЛИЯТЛЕЛЕК** *и.* Сәләтлелек, булдыклылык, талант

**КАБИ́НА** *и. фр.* Билгеле бер максатларга туры китереп махсус җиһазландырылган аерым кечерәк бүлмә яки бүлем. *Күзен ачкач, кабина баскычына аягүрә баскан кук комбинизонлы, ялан-башлы бер егетне күрде.* Г.Әпсәләмов. *МТС директоры Зәйнуллин, шофёр кабинасына утырмыйча, кунаклар янына кузовка урнашты.* Г.Минский. *Һәркем үз йөген кулга алуга, штурман тагын кабинасына кереп югалды.* З.Фәтхетдинов

**КАБИНЕТ** *и. фр.* 1) Язу өстәле артында эшләү мөмкинлеге булган бүлмә. *Минем кабинет биредә хәзер.* Р.Ишморат

2) Учреждениедә эш бүлмәсе, гадәттә, җитәкче бүлмәсе. *Икенче көнне Нияз белән берничә егетне шахта директоры үзенең кабинетына чакырды.* Д.Каюмова. *Яңа эшкә керешер алдыннан, Борһановны ул үз кабинетына чакырып, озаклап әңгәмә корды.* Г.Ахунов

3) Билгеле максатларга туры китереп аерым бер эш өчен махсус җиһазландырылган бүлмә (уку йортларында, фәнни тикшеренү, дәвалау учреждениеләрендә). *Докторның кабинетында авыруларны кабул итү бара.* Һ.Такташ. *Аннары рус теле һәм әдәбияты кабинетында китапханәче булып эшләвем дә үсүемә аз ярдәм итмәде.* Г.Кутуй

4) Күңел ачу урыннарында, ресторанда аерым бүлмәләр. *Ну-ка, Яфил, безгә бик шәп бер кабинет бир әле.* Г.Камал

5) *сәяси* Хөкүмәттәге министрлар составы. *Министрлар Кабинеты*

6) *ирон.* Тормыш, яшәү тәҗрибәсе белән бәйләнеше булмаган, дөреслеккә, чынбарлыкка туры килмәгән, бары уйлап кына чыгарылган фикер, караш булуны белдерү өчен кулланыла. *Чыпчыклар, имеш, бөртеклеләрнең явыз дошманнары... ну язалар да инде кабинет галимнәре кайчакта.* М.Мәһдиев

**КАБИНЕТЧЫ** *и.* Тормыш, яшәү тәҗрибәсе белән бәйләнеше аз булган, җитәкчелек эшен бюрократик юл белән генә алып бара торган кеше

**КАБИ́НКА** *и. рус к.* **кабина**. *Тышка карый Әнвәр кабинкадан.* Ш.Маннур

**КАБИХ** *с. гар. иск.* Чирканыч, начар, әшәке, түбән. *Инсанга зарарлы булган эшләрдән, кабих гадәтләрдән ничек сакланырга, --- әдәпле булырга юллар күрсәтеп, --- акчалар җыеп, фәкыйрь таләбәләр яхут ятимәләр файдасына тәгаен кылалар.* Ш.Мөхәммәдев. *--- безнең картлык миһербансыз кабих бер заманга туры килде. Шуның аркасында яшисе килү белән дөньядан бизү гүя үзара тигезләнделәр.* Ә.Еники

**КАБИХӘ** *с. гар. иск. к.* **кабих**. *Берәүдән, дөньяны ни кәйфияттә күрәсең, дип сорадылар, ул әйтте: бер кабихә хатындыр, бер көн гаттарда, бер көн байтарда, диде.* К.Насыйри

**КАБЛОГРА́ММА** *и. фр. махс.* Су асты кабеле аша тапшырыла торган телеграмма

**КАБОТАЖ** *и. фр. махс.* Диңгездә яр буе судночылыгы; бер үк ил, бер диңгез ярларында урнашкан портлар арасында йөзү. *Яшь капитанга тәҗрибәлерәк ярдәмче куйыйк дип, кадрлар бүлегеннән өлкән штурман итеп, күп еллар каботажда капитанлык йөгген сөйрәгән Вакх Андреевич Сторожевны беркеткәннәр.* М.Юныс

**КАБОТАЖЧЫ** *и. махс.* Каботажда йөзгән диңгезче

**КАБРИОЛЕТ** *и. фр.* 1) Биек күчәрле, ике тәгәрмәчле, бер атка гына җигелә торган җиңел арба

2) *махс.* Өсте һәм яннары ачыла торган кузов; шундый кузовлы җиңел автомобиль. *Кеннеди утырган кабриолетның хәтта тенты да күтәрелмәгән була.* Татарстан яшьләре

**КАБУ** *ф.* 1) Ашау-эчү өчен авызга алу. *Ул ара-тирә җиләк алып каба, сөйләнә.* А.Әхмәт. *Авыз тутырып кабарга ярыймы?* Ш.Камал. *Нариман – Айдарның ярты кабымлык икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты.* Г.Мөхәммәтшин // Авызда тоту. *– Абау, син кызлар янында да шулай авызыңа су кабып утыра идеңме? – дип сорый икенче берәү.* Г.Әпсәләмов

2) Ашау, ризыклану. *Вакыт соң, йокым килә димәсәң, әйдә, сабыем, «Казан» ресторанына кереп, берәр җылы ризык кабып чыгыйк.* Ф.Хөсни

3) Иреннәр, томшык белән тотып тору. *Әниләр безне үзләре белән арыш басуына уракка алып киткәннәр. Без шунда Мөҗәй белән чүмәлә төбендә, бөркәвечле кечкенә кабык арбада, имезлек кабып, тын гына ята торган булганбыз.* Г.Галиев. *Кулларына дүрт кыллы думбра алып яисә авызларына курай кабып уйнап торганнар.* Г.Гобәйдуллин. *Авызына нәрсәдер кабып кайтты да томшыгын оя авызыннан эчкә сузып торды һәм тиз генә очып та китте.* Г.Гобәй

4) Тешләү, тешләр белән кысу. *Колхоз кешесенең бер гадәте бар: икмәк көшеле янына килгәч, сүз башлаганда ул, һичшиксез, башта бөгелеп учына орлык ала, шуны теш арасына кабып кетердәтеп карый.* М.Мәһдиев

5) Умырып алу, талау. *Эт, тота алса, куянны кабып кына йота.* Г.Гобәй

6) Кармакка, ауга эләгү, чиертү. *Кармак салсам суга, балыклары ятсынмыйча килеп каптылар.* Һ.Такташ. *Әйтик, җәй азакларында спиннинг тотып Идел өстенә чыксаң, җәпле кармагың янына ялтыравык урынына мүштугыңны яки трубкаңны бәйләп сал, чуртан барыбер каба.* М.Әмир

7) Үзенең тәэсире белән авырттыру; тию (баш авыртуы тур.; эссе, авыр һава, көчле тавыш һ.б. тәэсире). *--- соңгы вакытларда аңа гасабилану, нервы бозу бер дә ярамый иде. Шунда ук йөрәккә суга, башына каба, җитмәсә, хәтере дә кинәт кенә югалып торгалый.* Ә.Еники. *[Гаяз] Эшләпәсен тизрәк кире киде, башына кояш кабудан курка булса кирәк.* М.Шәрифуллин

8) *күч.* Эләгү, тотылу, фаш булу. *Озак йөрде, җаен тапты, йөри торгач килеп капты.* Г.Афзал. *Бу Фәхри эше белән ире килеп капкач, ул тагы әрнеде.* Г.Ибраһимов

9) *күч.* Шаукымына, йогынтысына бирелү *Тора-бара Атлантида җәмгыяте килмешәкләр йогынтысына кереп каба.* С.Шәмси. *– Әһә, килеп капкан икән безнең чибәр егет! Ычкындырмагыз инде үзен! – диган булды.* Г.Бәширов

10) *күч.* Кысылу, буылу, буу (сулыш). *Берсе маяклар кабызырга төшеп барганда сулуы кабып килеп егылды.* Г.Гобәй. *Зәһәр салкын тынга каба.* М.Хәсәнов. *Көн шулхәтле кызу, хәтта сулуга каба.* Б.Ислам

11) *күч.* Ут алу, үрләп янып китү. *Кайберәүләр, беренче сүздән үк кабынып китеп, ут капкан коры салам кебек дөрләделәр.* И.Гази

**2.** *и. мәгъ.* Сулыш кысылу, тын ала алмый тору халәте. *Сулышы кабудан авызын зур ачып, тирән итеп сулый да тагын иелә-бөгелә әллә нинди хәрәкәтләр ясый.* И.Сирматов

◊ **Кабар җирем юк** *к.* **кабар урыным калмады**. *Минем кабар җирем юк. Әле генә Саҗидә апа бәрәңге күзикмәге керткән иде, шуны бик тәмләп ашадым.* Д.Салихов. **Кабар ризыгы бетү** Гомере бетү, яшәү вакыты узу. **Кабар урыным калмады** 1) Бик нык ашап туклану, тагы да ашарга теләге калмау; 2) Кемнән яки нәрсәдән дә булса бик нык тую, күрәсе килми башлау. **Кабып йоту** Юкка чыгару, һәлак итү. *Сталинград сугышында совет солдатлары барышнялар кебек моңаеп, җебеп төшсәләр, берниндi җиңү дә булмас иде, Гитлер безне күптән инде кабып йоткан булыр иде.* Н.Фәттах

**Каба башлау** Кабарга тотыну. *Бармаклары кытыршы ипи катысына тигәч, түзмәде, бер кисәк сындырып алып, авызына каба башлады.* М.Галәү. *Кайнарларын алып кергән әби канәгать: карты тамагына каба башлаган, иншалла, терелер.* Т.Галиуллин

**Кабып алу** Бер тапкыр тешләп кабу, кабу хәрәкәте ясау. *Азык чөелүгә, [эт]*

*кинәт сикереп кабып ала.* Г.Гобәй. *Башын чыгаруга өстенә сикереп, кабып алу нияте белән корткычның оясына карап тора башлады.* Г.Гобәй. *Кешегә ташланырга нәрсә мәҗбүр иткәндер, җәен егетнең аягыннан кабып ала.* В.Сабунаев

**Кабып җибәрү** Тиз генә кабу, кабып йоту. *[Ирләр] Озак юанмадылар, итәкләренә төшкән ипи валчыкларын учларына җыеп кабып җибәрделәр дә капчык авызын бәйли башладылар.* Г.Гыйльманов

**Кабып карау** Тәмләү, кабып тәмен белү. *Тәмле әйбердер, ахры – белер өчен кирәк, малай, кабып карарга.* Һ.Такташ. *Менә бу кызыл алмасын кабып кара.* А.Шамов. *Шәмсир борщны кабып карады.* Т.Әйди

**Кабып кую** Бер тапкыр кабу, кабу хәрәкәте ясау

**Кабып тору** 1) Әледән-әле кабу, капкалау; әле, хәзерге вакытта кабу

2) Капкан хәлдә авызында тоту. *--- әледән-әле, үзен яратып сыйпаган, кадерләгән кешеләр хакына гына дип, --- ул нәрсәне авызына да кабып торды.* Р.Мөхәммәдиев

**Кабып чыгу** Барысын да кабу; бөтенесен дә кабып карау

**КАБУЛ** *и. гар.* Нәрсәгәдер теләп яки теләмичә риза булу. *Кыз күтәрелеп карамады, акрын эчке аваз белән җавап кайтарды: – Әйткәнем шул: минем аңа кабулым юк! Күңелем башкададыр!* Г.Ибраһимов

**КАБУ́Л ӘЙЛӘҮ** *ф. к.* **кабул итү**. *Кабул әйлә, тәңрем, әле мин бик «нәни».* Г.Тукай. *Әсма исә боны [алтын тәңкәне] гадәттән тыш бер шатлык белән кабул әйләде.* Р.Фәхретдин

**КАБУ́Л БУЛУ** *ф.* Тормышка ашу, үтәлү, теләгәнчә, уйлаганча килеп чыгу. *Күп тә үтмәде – кабул булды теләк.* Г.Тукай. *Бәрәңге генә ашап үссә дә, кабул булгандыр теләге.* Ш.Мөхәммәдев. *Кыз чагында теләгән теләк кабул була.* Д.Каюмова

**КАБУ́Л ИТҮ** *ф.* 1) Биргән, бирелгән, тапшырылган берәр әйберне үз карамагына алу, үзенеке итү. *Мә сиңа, бүләгем булсын, азсынмыйча кабул ит, диде ул, кулындагы әчмуха чәйне карчык алдына куйды.* Г.Минский

2) Эшне бетереп тапшырганда яраклылыгын рәсми танып файдалануга алу, яраклылыгын рәсми теркәү

3) Төрле максатларда (әңгәмә алып бару, сәламәтлеген тикшертү, кунак яки өйдәш итеп һ.б.) янына керергә, янында булырга рөхсәт бирү. *Сәркатип, алай булгач кабул итмибез, дип әйтәсезмени?* Г.Камал. *«Күрәзәче Рухия»не сорап килгән кешеләрне иң элек [Мәрзия карчык] үзе кабул итә башлады.* Г.Гыйльманов // Рәсми сөйләшү өчен, үзенә чакыру. *Кабул итү бүлмәсендә утырган Тимерханга күз дә салмастан, үз дәрәҗәсен саклап, телефоннар янында --- утырган --- кыздан --- сорады.* Г.Ахунов. *Райкомда яңа секретарь Хөсәенов аны ул көнне кабул итмәде.* Г.Ахунов

4) Каршы алу, каршылау, мөгамәлә күрсәтү. *Газизә абыстай Лизаны бик хөрмәтләп кабул итте.* Ф.Әмирхан. *Район прокуроры Исрафилов аны ачык йөз белән кабул итте.* Г.Ахунов. *Фрау Софи, шуны гына көтеп утырган диярсең, Янгуразның телефон чылтыратуын бик ягымлы кабул итте.* Т.Әйди

5) Үзенә алу, урын бирү, сыендыру, урнаштыру. *Төрле йортта аны [Тукайны] төрлечә кабул иттеләр.* Ә.Фәйзи. *Менә ул, Олы Җәке авылына кайтып, җәй буе мәдрәсәне көздә балалар кабул итәрлек дәрәҗәгә китерер өчен тырышып әзерләттерде ---.* Ф.Яхин

6) Үз итү, якын итү, ят күрмәү, читләшмәү. *Аңа [Түләккә] бит Сайдәгә карaганда да кыенрак, авыл бу табигать баласын – «су җенен» – бик озак үзенә кабул итмәячәк әле.* Г.Гыйльманов. *Мин башта аның [Рихард Вагнерның] иҗатын ятсыныбрак кабул иткән идем.* Т.Әйди

7) Ишеткәннән, белгәннән соң уйлап нәтиҗә чыгару, аңлау, төшенү, юрау. *Габдулла моны үз хисабына кабул итте.* Ә.Фәйзи. *Бу бер дә бәла-каза түгел, бу сынау гына... Шулай кабул итик...* Г.Гыйльманов. *Янгураз үзенең Вустрауга килеп эләгүен нәкъ менә шушы аңлашу нәтиҗәсе дип кабул итте.* Т.Әйди

8) Җитәкчелек итәргә алыну; вазифа, чин, дәрәҗә алу. *[Шәмсир] аннан [госпитальдән] инде Ленинград фронтына җибәрелде. Монда ул лейтенант дәрәҗәсендә яңа рота кабул итеп алды.* Т.Әйди

9) Белем дәрәҗәсен тикшереп бәяләү, уку йортына алу. *Кабул итү имтиханнарында башка милләтләр керүне тыйсак, илнең башка вузларында укучы татарларны да куып кайтармаслармы?* Г.Ахунов

10) Куллану, файдалану өчен алу. *Әдәби бүлек тарафыннан нигездә шушы либреттолар кабул ителеп, тулырак эшләү һәм төзәтү өчен, авторга кире кайтарылды.* М.Җәлил

11) Берәр төрле группа, оешма составына кертү; катнашырга рөхсәт итү

12) Хәбәрләрне, сигналларны ишетү, тыңлап язып алу (радио, телеграф, телефон аша тапшырылган). *Кыз бу сүзләрне бөтенләй ишетмәде, чөнки аның гипноз томалаган аңы фәкать Стенли тавышын, Стенли сүзләрен генә кабул итә иде...* А.Тимергалин. *Кем кабул итте телефонограмманы? Кем дип белик? Фамилияңне әйт!!* А.Расих

13) Алу, алып тору. *Барыбыз да эшкә җигелдек, безнең арада моңарчы булмаган татулык һәм бердәмлек хөкем сөрде: кем билетлар язып, аларга мәктәпнең мөһерен суга, кем ул билетларны сатып торачак, кемдер ишек төбендә контролёр булачак, кемдер гардеробта кием кабул итәчәк.* К.Миңлебаев

14) Алыш-биреш итеп тапшыручыдан алып калу; нәрсә дә булса эшләргә заказ алу. *Ике куяныгызны бераз шикләнеп алам, кабул итмәсәләр, кире кайтарырмын.* А.Әхмәт. *Ул тиз арада шәһәрнең төрле почмагында шешә кабул итү пунктлары ачты.* Г.Гыйльманов

15) Килешү, ризалашу, риза булу. *[Поп] Иванның боерыгында казанлылар өчен бик авыр шартлар булганга күрә, аларның күбесе ул шартларны кабул итәселәре килмәде.* Һ.Атласи. *Кабул итте һәрбересе ошбу сүзне.* М.Гафури. *Райбашкарма, райком белән киңәшеп, алар куйган эш бәяләрен кабул итте.* Г.Ахунов. *Фрау Эваның серле үткәнен беләсе килгәнлектән,*

*Янгураз куршеләре чакыруын кабул итте.* Т.Әйди

16) Дөрес дип табу, хуплау, уңай карау. *Укып чыгып, колхоз председательләре, совхоз директорлары булгач та спортны да, музыканы да ташламыйлар. Халык моны яратып кабул итә.* Г.Ахунов

17) Кемдер яки нәрсәдер сыйфатында, дәрәҗәсендә, кем яки нәрсәдер дип тану, исәпләү, санау. *Ходай Тәгалә җибәргән сынау дип кабул итик без бу кыенлыкларны.* Г.Гыйльманов. *Өйгә килен булып төшкән Розаны да үз кызларыдай якын кабул иттеләр.* Р.Низамиев. *Капитан булырга җыенган егеткә болай каютя-компаниядә сөйләшеп утыру башбаштаклык булса да, шул көннән мин аны үземнең дустым итеп кабул иттем.* Ә.Хәбибуллин

18) Уңай тавыш бирү, гомуми тавышка куеп раслау. *Нәтиҗәдә, вакыйганы контрреволюция чыгышы дип карар кабул иттек.* Ш.Камал

19) Берәр төрле дин тота башлау. *Ул бичара, баласының бөтен гаиләсе христианлык кабул иткәннәр икән дә чиркәүгә баралар икән, үзен дә шунда алып барырга телиләр икән дип курка иде.* Ф.Әмирхан. *Ягъни кияүгә чыгу өчен ислам динен кабул итү мәҗбүри булганга гына бу дингә күчмиме ул?* Г.Бәширов

20) Якын алу, теләктәшлек белдерү. *Ул үзенең кечкенә кайгысын онытып, бу гаиләнең кайгы-хәсрәтен үзенеке итеп кабул итте.* Д.Каюмова

21) Гадәткә кертү, күнегү, ияләшү. *--- яңа әдәп кагыйдәләрен халык кабул итәргә өлгермәгән яисә моңа әзер түгел.* Ф.Яхин

22) Сәламәтлекне ныгыту, гигиена максатларында төрле процедуралар алу. *Ванна кабул итү*

23) Бала тудырганда ярдәм итү. *Саниянең баласын Тәңребез үзе кабул итеп алган, югыйсә берьялгызы урман юлында бала китерә алыр идеме ул?* Г.Гыйльманов

**КАБУ́Л КЫЛУ** *ф. к.* **кабул итү**. *Анда бик зурлап кабул кылып, аңа сыйхөрмәт күрсәткәннәр.* Г.Ибраһимов

**КАБУЛНАМӘ** *и. гар.-фар. рәсм.* Кабул итү акты

**КАБУЛХАНӘ** *и. гар.-фар. неол.* Рәсми урыннарда мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү бүлмәсе. *Иркен кабулханәгә килеп кергәч кенә, мондагы келәмнәр һәм гөлләр, алардан да бигрәк, өстәлдәге телефон аппаратларының күплеге аны сагаерга мәҗбүр итте.* Т.Әйди

**КАБЫГУ** *ф. сир. диал.* 1) Озак ятып басылу, укмашу

2) *күч.* Беркая да чыкмый яту

**КАБЫЗГЫЧ** *и.* 1) Нәрсәне дә булса кабызып, эшләтеп җибәрү җайланмасы. *Шәүкәт телевизорның кабызгычын борды, бүлмәгә матур гына үзбәк музыкасы таралды.* Д.Каюмова. *Тиешле урынга биоягулык салып җибәрәсең дә махсус кабызгычка басасың гына.* Шәһри Казан

2) Мич, учак һ.б.ш.ны ягып җибәргәндә, ут тизрәк үрләп китсен өчен куелган коры йомычка, туз кебек нәрсәләр

3) Тәмәке, газ плитәсе кебекләрне кабыза, ут төртә торган әсбап. – *Абый, – ди, – гафу итә күр, тәмәке кабызгычымны кесәгә салмаганмын.* Ф.Баттал

4) Шартлаткыч матдәне кабындырып җибәрү өчен махсус патрон; *русчасы:* **запал**

**КАБЫЗУ** *ф.* 1) Яндыру, яндырып, яктыртып җибәрү; ут үрләтү, ут тергезү. *Алдагы солдатларның берсе юлны яктырту өчен алган фонарена ут кабызды.* К.Нәҗми. *Берьюлы ике лампа кабызды: сукыры мич кучкарына куелды, куыклысы табын турында матчага эленде.* М.Хәсәнов. *Ул туктап уйланып торды да урындыкка утырды, папирос кабызды.* И.Салахов

2) Эшләтә башлау, хәрәкәткә китерү (двигательне). *Шофёр Зәбир абыйның машинасын кабызырга төшүен күреп калырга кирәк.* Н.Хәсәнов. *Яңа түгел түгелен дә, тик гөрелтесе шәп, --- пускачы җиңел кабыза.* К.Кәримов. *Нурислам мотоциклны бер тибүдә кабызды да бетон юлга чыкты.* Р.Вәлиев

3) Электр чыганагына тоташтырып эшләтә башлау (радио, телевизор һ.б.ш.). *Аннан телевизор кабыза, күрәм: фәлән авылга кунаклар, геройлар, артистлар, галимнәр, язучылар килгән.* М.Мәһдиев. *Телевизор кабызырга да, радионы тыңларга да, газеталарны караштырырга да мөмкинлек тәтемәде.* Ф.Яхин. --- *Рамил бераз ял итеп алу нияте белән видеосын кабызды.* Г.Бәйрәмова

4) *күч.* Дәрт, хис, тойгылар һ.б.ны уяту, күңелгә уңай тәэсир ясау. *Ул монда бик күпләрнең күз яшен киптерде, йөрәкләргә сүнмәслек ут кабызды.* Г.Бәширов. *Ул сыра дигәндә бөтен дөньясын онытa, аны сусавын басу өчен генә түгел, яшәү дәртен кабызу, тормыш ямен тою өчен кирәкле бер шифа, кодрәтле бер дәрман чыганагы итеп саный иде.* Т.Әйди

**Кабыза бару** Бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесен кабызу

**Кабыза башлау** Кабызырга тотыну. *Суханов аны Каблукка күз-колак булырга күндерде, күршесе мотоциклын кабыза башласа, үзенә шылтыратуын үтенде.* З.Мурсиев. *Анда кергәч, кем кая урын табып чүмәштеләр дә тәмәкеләрен кабыза башладылар.* Шәһри Казан

**Кабызып алу** Тиз арада, тиз генә кабызу. *Тәмәкене кабызып алдым да бер кул белән өстәл тартмасын тартып ачып җибәрдем.* Ш.Усманов

**Кабызып җибәрү** 1) Кинәт кабызу, тиз арада кабызырга да өлгерү. *Каюм тиз генә бишле лампаны рәтләп, ут кабызып җибәрде.* Ә.Фәйзи. *Биш-ун минут эчендә --- бакны тутырып ягулык салдым да моторны кабызып җибәрдем.* Тәмуг чәчәге

2) Кабынырга этәргеч бирү, кабынган хәлгә китерү. *Ул көннәр йөрәк ярсуын кабызып җибәрә.* Ф.Кәрим. *Бу яшьлек җилкенүен яңадан кабызып җибәрергә кирәк тә түгелдер.* Г.Бәширов

**Кабызып чыгу** Һәрберсен берәмберәм кабызу. *Фонарьларга керосин салды да маякларны кабызып чыкты.* Г.Гобәй

**КАБЫК** *и.* **1.** 1) Агачның үзагачтан аерылып тора торган тышкы катлавы, кайрысы. *Аннан соң [Хәят] шул ук ботакның кабыгын әрчеп карады. Кабык бармакларны яшькелткә буйый: кабыгы әрчелгән ап-ак чыбык, юешләнеп, тайгак булып тора иде.* Ф.Әмирхан. *Монда кылый куян усак кабыгы*

*кимереп тик ята.* Ш.Маннур. *Гагра урамында тезелеп утырган йөзьяшәр эвкалиптлар иске кабыкларыннан арына башлаганнар, ләкин ул кабыклар, буй-буй булып эсседә бөтерелеп, агач кәүсәләренә асылынып калганнар.* М.Мәһдиев

2) Махсус суеп алынган карама яки юкә кайрысы. *Арба төбенә түшәгән юкә кабыгының буеннан-буена тигезлетигезсез хәрефләр белән язылган сүзләрнең мәгънәсен дә әйттеләр.* М.Хәсәнов. *Көч-хәл белән күтәреп кайтырлык кабыкны аркага салып, урман авызына чыкты малайлар.* Г.Ахунов. *[Гайфулла] Кабыкны күлгә батырып, ташлар белән бастырып куйган икән.* Ф.Яруллин

3) Яшелчә, җиләк-җимеш, чикләвек кебекләрне тыштан каплап торган тышча. *Кабыклары саф алтыннан – җимнәре гел зөбәрҗәт.* Дәрдемәнд. *Суфи суган сөймәс, күрсә, кабыгын да куймас.* Мәкаль. *Өч тәүлек батальон солдатлары, сержантлары һәм офицерлары кабыгын Сираҗи белән мин әрчегән бәрәңгене ашадылар.* К.Латыйп. *Әнә чи-чи чыпчык каен алкаларын кабыгыннан әрчи.* Н.Сладков

4) Йомырка тышчасы. *Җирдә ташлап калдырылган кумәч-икмәк кисәкләре, йомырка кабыгы һәм вобла калдыклары ауный.* Г.Кутуй. *Ала карга эше инде бу – йомырка кабыгын тишеп эчендәге сарысы белән агын эчкән дә буш кабыгын ташлап калдырган.* Н.Сладков

5) Кайбер җан ияләренең тышкы каты тышчасы (елан, кәлтә, балык, бөҗәкләр). *Бакча киртәләре кичке кояшка җылынган, аларны теге юл-юл кабык кигән әрсез коңгызлар сырып алган.* М.Мәһдиев. *Елан кабыгы кебек юка соргылт сукнодан теккән шинель --- кигән немец солдатларына 1941 нең кышы бик рәхимсез булды.* З.Зәйнуллин. *Ул [көньяшәр күбәләк] күкәйдән корт булып чыга, аннан кабыгын ташлап бөҗәккә әйләнә, ул арада бераз үсә, тагын кабыгын ташлый.* Кызыклар дөньясында

6) Мәетне каберлеккә кадәр озатып бару өчен агач кайрысыннан эшләнгән носилка; җеназа агачы. *[Малай] Авыл буйлап кешеләрнең җилкә өстендә колашалы кабыкта баручы май әбисенә моңаеп карый.* Г.Ахунов. *Капка баганасына --- соңгы юлга озата торган кабык сөяп куелган икән.* М.Хәсәнов

7) *күч.* Чын йөзен күрсәтмичә, ясалма, башка төрле кеше итеп таныту тышчасы. *Василий яңадан үзенең кабыгына керде, гаҗәеп бер мәнсезлек белән авызын зур-зур ачып иснәргә тотынды.* Ә.Еники. *[Фәйрүзә] моның һаман да шул элеккеге илгәзәк Шәмсия икәнен, тик кабыгы гына бераз үзгәрүен күреп, аңа үзенең эш таба алмый йөрүен сөйләп бирде.* Г.Ахунов. *Еллар һәм торкыннар ялгышмый: надзирательләр бер кигән кабыкларын һәм битлекләрен салмыйлар.* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Тышкы күренеш. *Бервакыт урамнан күрше авыл хатыны үтеп киткәч, бабай башын чайкап, кабыгы чибәр генә, дип куйды.* Г.Гобәй. *Кем уйлаган шундый ефәк кабык эчендә шундый башсызлык яшеренеп яткандыр дип?* Ф.Хөсни. *Барысы да тышкы кабык кына! Ә эчтә... ислемае беткән шешә кебек.* Г.Әпсәләмов

9) *күч.* Кием. *Өстәге фашист кабыгын салып аттым да тегеләрнең кайнаша башлавын көтеп яттым.* Г.Нәбиуллин

10) *күч.* Кешене чын тормыштан, башкалардан аерып торган тирәлек, кешенең үзенә генә хас эчке дөньясы, күзаллавы. *И, мин томана да булганмын соң, таш кабыкта яткан әкәмтөкәм!* Ш.Маннур

11) *геол.* Җир шарының өске катламы. *Ул кабык ике катлы, өске өлеше гранитлардан тора, ә аскы кат – базальт токымнары.* Кызыклар дөньясында. *--- кайнар мәхәббәт беркөнне, каты җир кабыгын бәреп чыккан вулкан кебек, йөрәк түреннән ургылып чыкты.* Д.Каюмова

12) *кит.* Югары нерв эшчәнлегендә төп урынны тоткан, зур ми ярымшарларын каплап торган өске катлам. *Кешеләрдә ишетү информациясе баш мие ярымшарлары кабыгының чигә өлешендә анализлана.* Кызыклы физиология

**2.** *с. мәгъ.* Агач кайрысыннан эшләнгән. *Саҗидәнең имчәк баласы кабык бишектә --- үзен-үзе яткан җиреннән тирбәтеп ята.* М.Гафури. *Арба төбенә капчык белән чәчүлеген, кабык тубалын, бөкре сукасын салды.* И.Гази. *Тәмам савыккач, кабык арбага салынган Габидинне тартып, урак уручы әнием янына бара башладым.* К.Латыйп

◊ **Кабык авыз** Авазларны йотып, аңлаешсыз сөйли торган кеше. **Кабыкка төренү** *к.* **кабыгына бикләнү**. *Инде күптән берәү дә туп-турыдан әйтеп борчымаган, кабыкка төренгән күңеленә тидерәме.* М.Хуҗин. **Кабыгына бикләнү** Тормыштан, тирәюньдәге кешеләрдән аерылу, кеше белән аралашмау. *Музейда эшләү тарих кабыгына бикләнү дигән сүз түгел бит әле ул.* Э.Касыймов. *Әкәм-төкәм ише, һәркайсы үз кабыгына бикләнеп яшәде, береңнеке икенчеңә артмады.* Ә.Гаффар

**КАБЫКЛАНУ** *ф.* Нәрсәнең булса да өслеге кабык белән каплану

**Кабыклана бару** Аз-азлап, акрынлап кабыклану

**Кабыклана башлау** Кабыклану билгеләре күренү

**Кабыкланып җиту** Тиешенчә кабыклану, тиешле дәрәҗәдә кабык ясалу. *Суга салынган юкә кабыкланып җитте*

**Кабыкланып килү** Аз-азлап кабык белән каплану

**КАБЫКЛЫ** *с.* 1) Кабыгы белән, кабыгыннан чистартылмаган килеш, әрчылмаган. *Кем нәрсә алып килгән – бары уртак: кабыклы бәрәңге, кара ипи, әйрән, катык.* Д.Каюмова

2) *күч.* Чын йөзен яшергән, үзен башка кеше итеп таныткан. *Сезнеңчә, бөтен кеше, шул исәптән үзегез дә, әллә ничә кабыклымыни?* Ф.Яруллин. *Хәсрәтем – әллә минем нурлы, кабыклы бер җылан.* Г.Тукай

**КАБЫКЛЫ́ БАКА** *и.* Ташбака

**КАБЫКЧЫ** *и. зоол.* Кабыгашарлар семьялыгына караган, личинкалары һәм җитлеккән коңгызлары агач кайрысы астында аның үзагачын кимереп яши торган, гәүдәләре цилиндр формасында, канат очларында батынкылыклары булган кара яки коңгырт төстәге корткыч бөҗәк

**КАБЫКЧЫЛ** *с.* Кабыктан торган, кабыгы булган. *Бу үсемлекнең [физалисның] ашамлык өлеше – кабыкчыл пәрдә эчендәге җиләк.* Яшелчәчелек

**КАБЫ́Л-КОБЫЛ** *рәв.* Аннан-моннан, тиз-тиз, бик ашыгып, кабаланып. *Кабыл-кобыл гына ашап алу*

**КАБЫ́Л-ТИБЕЛ** *рәв. к.* **кабыл-кобыл**. *Аю аланлыкта бик бирелеп агач төбен актарып торганда, янына куян сикергәләп килде. Килде дә кабыл-тибел генә тезеп китте.* Н.Сладков

**КАБЫМ** *с.* **1.** 1) Бер тапкыр кабарлык. *Тик бер кабым ипине Кабар җирем калмады.* Х.Халиков. *Сазлык ташбакаларының селәгәй бизләре юк: алар ризыкның һәр кабымын күп итеп су эчә-эчә ашыйлар.* Кызыклы физиология

2) Бик кечкенә, сынык кына булган. *Кабым икмәккә мохтаҗ булып, урамнарда көтүләре белән йөрүче йөзләрчә ярты ялангач теләнчеләреннән --- хәбәрсез яшиләр.* Ш.Мөхәммәдев. *Актык кабым икмәгеңне тартып алыр.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Кечкенә кисәк, сынык, бер кабарлык азык кисәге. – *Габдулла, яманнан ярты кабым калдырма, ашап бетер, – диде аңа Газизә апасы.* Ә.Фәйзи. *Кабымнарын да уртаклап яшәделәр*

**КАБЫМЛЫК** *и.* **1.** 1) Эчемлекләрдән соң кабып кую, кайнар аш алдыннан аппетит ачу өчен куела торган җиңелчә салкын ризыклар, закуска. *Шундук эчемлекләр, кабымлыклар алып килделәр.* Т.Әйди

2) Ашамлык, ризык. *Көймә утыргычындагы кабымлыкларны кара бармаклары белән әвеш-түеш китерде.* Г.Бәширов. *Хуҗабикә зур табак белән кабымлыклар куйды: куй бавыры һәм май белән тутырылган бытбылдык түшкәләре авыз суын китерерлек итеп кыздырылган иде.* Р.Мирхәйдәров

3) *к.* **кабым 2**. *Әйтерең бармы, яшьти, кабымлыгын бүлеп бирер иде.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Бер тапкыр кабарга җитәрлек. *Һарун --- Белугин кулыннан бер-ике кабымлык икмәк сындырып алды.* Н.Фәттах. *Нариман – Айдарның ярты кабымлык икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты.* Г.Мөхәммәтшин. *Ә дәү әти нигәдер Мактарга сүз тапмады, Авыр сулап куйды да: – Улым, – диде, – их сине! Китәләрме калдырып бер кабымлык ипине.* Х.Халиков

**КАБЫНДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **кабызу**. --- *фикерне эшләтү, хыялны җигү, сәләтеңне сынау – иҗатны шулар кабындыра бит инде.* Ә.Еники. *Оча безнең самолётлар дошман күгендә, кабындырып якты утлар дуслар күңелендә.* Ә.Исхак

**Кабындырып җибәрү** 1) Кабындырып эшләтә башлау

2) Дәрт уяту, дәрт уянырга этәргеч булу. *Ярышны кабындырып җибәрү өчен, колхозчының күңел ачкычын табарга кирәк.* Г.Бәширов

**КАБЫНУ** *ф.* 1) Ут үрләү, яна башлау, янып китү. *Тәрәзәдән ургылып чыга торган куркынычлы ялкын туфаны арасыннан сакаллары, чәчләре көйгән, битләре пешкән, күлмәгенә ут кабынган бер ир кеше җиргә ташланды.* М.Галәү. *Салам гөлт итеп кабынып китте һәм чатыр-чотыр килеп яна башлады.* К.Латыйп

2) Яктырып, ялтырап күренү. *Зәңгәр күктә нур сибеп безгә, кабына йолдызлар.* Ф.Кәрим. *Ай катында бер-бер артлы эреле-ваклы йолдызлар кабынды.* Г.Гобәй. *Кояш баешындагы болытның өске кырыена ут кабынып, аның сары алтындай кайный-кайный януын карап утырды.* Г.Бәширов

3) Электр белән туклана торган яктырткыч эшли башлау. *Ә ёлкада якты нурлар сибеп утлар кабына.* З.Мансур. *Электр баганаларында утлар кабынганда, боз өсте шау-гөр килә иде инде.* Н.Хәсәнов

4) Электр челтәренә тоташтырудан эшли башлау (радио, телевизор һ.б.ш.). *Компьютер экраны яңадан кабынды, анда сурәтләр, шартлы билгеләр барлыкка килде.* З.Мифтахов

5) Ниндидер тышкы тәэсир нәтиҗәсендә эшли башлау (двигатель тур.). *Тик аңа карап кына моторы барыбер кабынмады.* В.Нуруллин. *Тегесен-бусын җайлагач, «Газиг»ы теләр-теләмәс кенә --- кабынып китте.* Ф.Яхин

6) Башлану, килеп чыгу, кузгалу. --- *каршылыкларның торган саен тирәнәя барачагы, ахырда моның цивилизацияләр көрәшенә китерәчәге, моңарчы күрелмәгән зур дөнья сугышы кабыну ихтималы турында сөйли башлаганнар иде.* З.Мифтахов

7) Тыны кысылу, сулышы каплану. *Габделкаюм, сулуына кабынып, атасы янына йөгереп килде.* М.Галәү. *Нурсыз чырай, әмма күзләре ут чәчә, тынына кабынып, үзе гәп ора.* М.Хәсәнов

8) *күч.* Хис-тойгылар барлыкка килү, хисләр уяну, туу. *Үзенең кем һәм кайда икәнен искә төшерү дә сүндерә алмады йөрәгендә кабынган ялкынлы хисне.* З.Фәтхетдинов. *...Фәриттә яңа көч белән яшәү дәрте кабынды.* З.Мифтахов. *Шәмсирнең генә андый шөгыльләргә дәрте кабынмады – аңа җанлы, хәрәкәтчән эш кирәк иде.* Т.Әйди

9) *күч.* Кинәт ярсу, кызып китү. *Тегесе [Фәтхия], картының ашалган, сирәк тешле авызын ерып утыруын бер генә дә килештермичә, карашына зәһәрлек кертеп, уенны чынга алды да, кеше бар дими, ни дими, кабынып чәпчеп китте.* Э.Касыймов. *Гадәттә ике авыз сүз дә кайтарып әйтә алмый торган мескен, йомыкый кешенең кинәт кабынып китүенә, әллә нинди аңлаешсыз, бәйләнешсез сүзләр сөйләп ташлавына Садыйк абзый чын-чынлап гаҗәпкә калды.* Н.Фәттах

10) *күч.* Эш-хәрәкәт көчәю, киеренке төс алу, массакүләм таралып китү. *Халыкта ачу уты кабынуы ачык күрсәтелергә тиеш.* М.Җәлил. *Кырыкилле ел буена бер кабынып, бер сүрелеп торган шушы ышна җире ызгышы, аталардан балаларга күчеп, кешеләрнең күңелләрен гел ярсытып торган.* И.Гази

◊ **Кабынып китәргә тору** Дуамалланып кызып, ярсып китәргә әзер булу. *Бөтен кешегә хәтере калгандай, кара янып йөри, бер сүз әйтергә ярамый үзенә, хәзер кабынып китәргә тора.* Ә.Еники. **Кабынып китү** 1) Кинәт киеренке төс алу, ачуы кинәт көчле кабару, ачу белән кызып китү. *Эш гаеплелектә түгел, диде Якуб, кешеләргә кабынып китәргә ирек бирмичә.* И.Гази. *Бөтен*

*шәкерт бердән кабынып китә.* Т.Гыйззәт. *Юктан гына кабынып китә дә, туткыллы йөзе кара көя, әбинең күмер чиләгенә охшап кала.* Н.Хәсәнов; 2) Кызыксыну уяну, кызыксына башлау. *Безнең чынлап сөйләшүебезгә төшенгәч, ул [Баграт] да кабынып китте.* М.Юныс

**Кабына бару** Эзлекле рәвештә бер-бер артлы кабыну. *Ризасызлыклар моның белән генә сүнмәде, кабына барды.* Ә.Фәйзи

**Кабына башлау** Кабынырга totыну. *Йомыш табып Әминә апага сугылган хатыннар, караңгы төшеп, күк йөзендә йолдызлар кабына башлагач кына таралышты.* Р.Мөхәммәдиев. *Күктә чынлап та бер-бер артлы йолдызлар кабына башлады, һәм тиздән бөтен авыл якты нурга чумды.* М.Кәбиров

**Кабына язу** Чак кына кабынмый калу. *Мөштегенә төпчек кыстырган Николайның авыз тирәсендә шырпы кабызырга үрелгән куллар пәйда булды, шырпыларның кайсы кабынмады, кайсысы кабына язып сүнде.* Н.Акмал. *Калганы барысы томаланган – кабына язып сүнгән сөю дә, җанны ярсытып торган ымсындыргыч дәрт тә...* Г.Гыйльманов. *Бик авырлык белән булса да, кабына язып атлады, ашыкынды, үзе бертуктаусыз кабатлады ---.* Д.Каюмова

**Кабынып алу** Кыска вакытка, азга гына кабыну. *Бер бөртек хатирә, бер мизгел гомер, гөлт итеп кенә булса да кабынып алган берәр күренеш, манзара булсын иде дә бит...* Г.Гыйльманов

**Кабынып йөрү** Озак вакытлар дәвамында рухланган, дәртләнгән халәт кичерү. *Һәм шуннан Габдулла көн-төн бер нәрсә белән хыялланып кабынып йөрде.* Ә.Фәйзи

**Кабынып килү** Акрынлап кабыну; бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесе кабыну. *Күз бәйләнеп, йолдызлар кабынып килгән чак иде.* И.Гази. *Шатлыгымны минем эчтән, еракtan кабынып килгән вөҗдан газабы әкрен генә кимерә иде инде.* А.Шамов

**Кабынып китү** Кыска гына вакытка ялтырап, яктырып күренү, азга гына кабыну; кинәт, искәрмәстән кабыну. *Менә аның [университет бинасының] манарасына беркетелгән кызыл утлар кабынып китте.* М.Юныс. *Алар [прививкалар] гадәттә җәен кабынып китә торган эпидемияләрнең килеп чыгуын һәм таралуын булдырмый калалар.* Биология. *Бәхәс юктан гына кабынып китте.* Т.Әйди

**Кабынып тору** Озак вакыт яктыртып, ялтырап күренү; бертуктаусыз әле берсе, әле икенчесе кабыну. *Кар өсте --- җемелди, атлаган саен як-ягында шул җемелдекнең искеләре сүнеп, яңалары кабынып тора.* Н.Исәнбәт. *Тәрәзәләрдә кабынып торган утлар сүнделәр.* Ә.Фәйзи. *--- бер сүнеп, бер кабынып торган яшелле-кызыллы-зәңгәрле-сарылы утлар түшәмдә әйләнгән көзгеле шардан стеналарда, идәндә уйный башлады.* Батулла

**КАБЫРГА** *и.* 1) Умыртка баганасының ике ягыннан күкрәк куышлыгына таба дугаланып кара-каршы килгән тар сөяк. *Дмитровск шәһәрен алдык. Кабыргам җәрәхәтләнде.* З.Зәйнуллин. *[Атларның] Кабыргаларын ярты чакрымнан санарга мөмкин.* В.Нуруллин

2) *күч.* Гәүдәнең шул сөякләр урнашкан уң яки сул ян ягы. *Күк биянең башы минем алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез.* Г.Ибраһимов. *Матрос киемле тиз генә бер кулын ычкындырды да надзирательнең кабыргасына шундый иплe итеп утыртты, теге тынын да ала алмыйча, бөгәрләнеп, коридор идәненә ауды.* Г.Гобәй

3) *күч.* Берәр нәрсәнең ян ягы, кырые, чите. *Карлыгач-Сылу өйнең түренә, ике як кабыргасына кат-кат тезелгән күп сандыклар, палас, юрганнар арасыннан нидер эзли иде.* Г.Ибраһимов. *Уң кулын тимер мич кабыргасына тидереп, сүгенеп җибәрде.* И.Салахов. *Аннан ялтырап торган кечкенә бер әйбер чыгарып кабыргасына баскан иде, капкачы ачылып, гөлт итеп ут кабынды.* Ә.Еники

4) Як, тараф. *Бу авыл да зур куркыныч астында: уң кабыргадан --- фронт ярып үтә.* Г.Ибраһимов

5) Ике яссылык кисешеп тоташу сызыгы. *Пирамида кабыргасы. Кубта 12 кабырга була*

6) Почмак ясап борылган урын. *Теге елга кабыргасына җиткәч, [әби] кечкенә агачларга тотына-тотына, өскә менеп китте.* М.Гали

7) Калкып, калкуланып торган урын, тау сырты. *Тауның әйләнә-тирәсен каплап алган куе чытырманлык, текә тау кабыргасында теш-теш булып чыгып торган очлы таулар [күренә иде].* Г.Рәхим. *«Кымыз» сүзен ишеткәч, башкорт далаларында йөргән елкы көтүләре, тау кабыргасына кырын ятып курай тартучы түгәрәк йөзле башкорт егете күз алдымнан узып китте.* М.Юныс

◊ **Кабыргага төрттерү** 1) Кинаяләп, кадап әйтү; 2) Тәнкыйть итү, кимчелекләрне күрсәтү. **Кабыргалары күренеп (беленеп) тору** Артык арык, бик ябык. *Дөрес, аның кабыргалары әле дә беленеп тора.* Г.Гобәй. **Кабыргасына төртү** Исенә төшерү, искәртү. *Утыз тиен көмешне Габдуллага сузыйм дигәндә генә, саранлык җене кабыргасына төртте булса кирәк, көмешләрне янчыгының икенче бүлегенә салып куйды да, икешәр тиенлек алты бакырын санап, шалтыратып, Габдулланың учына салды.* Ә.Фәйзи. **Кабыргасы белән кую** Катгый, кискен итеп әйтү, таләп итү. *Мәсьәлә әнә шулай кабыргасы белән китереп куелса да, мин ризалык бирергә ашыкмадым.* В.Нуруллин. *Иң уңайсыз чакта әмир Хөсәен бурычны кайтаруны кабыргасы белән куя.* С.Шәмси. **Кабыргасын каезлау** *к.* **кабыргалау**. **Кабыргасын санау** *к.* **кабыргалау**. *Рәхәтләнеп тә кабыргасын санар идек.* Д.Аппакова. *Бу кешене, ягъни Прорехинны тукмавым хак, кабыргасын санадым мин аның.* З.Фәтхетдинов. **Кабыргасын тетү** 1) *к.* **кабыргалау**; 2) Туздыру, әрәм-шәрәм итү (акчаны, байлыкны). *Кыз сыйлап ике ел үтә, яше җиткәнне көтә, акчаның кабыргасын тетә.* Ш.Мөхәммәдев. **Кабыргасын яру** *к.* **кабыргалау**. **Кабыргасы юка** Көчсез, хәлсез, җитәрлек көч җыймаган

**КАБЫРГАЛАНУ** *ф.* Киртләчләнү, сыртлар ясалу

**Кабыргаланып яту** Кабыргалар ясап сузылып китү. *Санап бетергесез*

*чокырлар, кабыргаланып яткан сырт-лыклар – бу күренеш Василга таныш иде.* С.Рафиков

**КАБЫРГАЛА́У** *ф.* Дөмбәсләп кыйнау, тукмау. *И, кыен да була инде кайчагында үз-үзеңне җиңү. Үзең сугасың үзеңә, үзең әйләнеп төшәсең, торып, тагын үзеңне кабыргалап әйләндереп саласың.* Ф.Шәфигуллин

**КАБЫРГАН** *рәв. иск.* Яны белән

**КАБЫРЧЫК** *и.* 1) Кайбер умырткасыз хайваннарның тышкы тәэсирдән саклый торган каты кабыклы тышчасы. *Дулкын калдырган кабырчыклар, мәрҗән валчыклары, кояшта кызып, тирә-юньгә йод һәм бозыла башлаган балык исе тарата.* М.Юныс. *Зәйтүнә камның өс киемнәренә, шалтыравык бака кабырчыкларына игътибар итте.* М.Хәбибуллин. *Ихтимал, ташлар, кошлардагы кебек үк, азыкның каты өлеше: молюск кабырчыкларын, буынтыгаяклыларның хитин панцирен изеп йомшартырга ярдәм итә торгандыр.* Кызыклы физиология

2) Куыкчык. *Кем дә кем үзен сиздерсә: камышы селкенсә яки камышы төбеннән кабырчыклар чыкса, аңар җәза бирелә.* Г.Гобәй

3) *куч. к.* **кабык** (*9 мәгъ.*). *Коллектив әкренләп бердәмлеген югалта башлады, һәркем үзенең шәхси кабырчыгы эченә кереп бикләнү ягын карый.* М.Юныс

**КАБЫРЧЫ́К КИСӘ́Ү** *и. а.х.* Югары төзелешле үсемлекләр хисабына яши торган гөмбә ыругыннан, сабакта, чәкәндә, яфракта була торган кара тузанлы каты кабыклы үсемлек авыруы

**КАБЫРЧЫКЛАНУ** *ф.* Кабырчык белән каплану, кабырчык барлыкка килү

**Кабырчыклана бару** Аз-азлап кабырчыклану

**Кабырчыкланып тору** Кабырчык барлыкка килгән булу, өсте кабырчык белән капланган булу. *Йөзе килеп, касмакланудан кабырчыкланып торган балыкның иң матур, иң эре кисәкләре Гази савытына салынды.* М.Хәсәнов

**КАБЫРЧЫКЛЫ** *с.* Кабырчыгы булган, өсте кабырчык белән капланган. *Әнә каты кабырчыклы җир тараканы, ашыга-ашыга, караңгылыкка таба кереп бара.* М.Мәһдиев

**КАБЫШТЫРУ** *ф.* 1) *кбт. форм.* Аз-азлап, сирәк-сирәк кабу

2) Эчкәләү, сирәк кенә исерткеч эчемлекләр куллану. *Ара-тирә кабыштырса да, [Вафа] аракы белән артык мавыкмады.* З.Моталлапов

**КАВАЛ** *и. фар. муз.* 1) Бәрмә уен коралы, барабанның бер төре; туй барабаны

2) Кыллы чиртмә уен коралы

**КАВАЛЕР** *и. фр.* 1) *сөйл. к.* **кавалерист**. *Абый – батыр командир, ул бит атлы кавалер.* К.Нәҗми

2) *сөйл.* Өйләнмәгән егет. *[Маһруй:] Ал якта минем кавалерым да бар бит әле.* Ф.Әмирхан. *Хәзер инде аны назлый алырлык кавалерлар еракта – я Аурупаның төрле тарафларында, я Африкада – Өченче Рейх чикләрен киңәйтеп йөри.* Т.Әйди

3) Парлы биюдә хатын-кыз белән каршы биюче ир-егет

4) Хатын-кызга илтифат күрсәтеп, төрлечә күңелен күтәрергә тырышучы ир кеше. --- *театр буфетыннан шоколад алып партадашына тәкъдим итүе исә аның үзен кавалер итеп танытасы килүеннән түгел иде микән?* Т.Әйди. *[Торышым] --- барышняларны сәламләп каршылаучы кавалер торышына охшый иде булса кирәк.* К.Басыйров. *Баш түбәләре такырая төшкән кавалерлар берәм-берәм читкә тайпылырга мәҗбүр булды.* Р.Мөхәммәдиев

5) Ордены булган, орден белән бүләкләнгән кеше. *Икегез дә Георгий кавалерлары, оялмый шул сүзне сөйләп утырасыз.* М.Гали. *Ике мәртәбә Татарстан депутаты. Ике орден кавалеры. Кыскасы, мин сезгә бик яхшы кадр алып килдем.* Г.Ахунов. *Закон буенча, Дан орденының тулы кавалерлары Геройларга тиңләштереләләр.* Г.Гыйльманов

**КАВАЛЕРГАРД** *и. фр. тар.* Россия империясендә VIII гасырдан 1917 елга кадәр булган, башлыча патшаның шәхси гвардиясе ролен үтәгән авыр кавалерия офицеры

**КАВАЛЕРИСТ** *и. рус* Атлы гаскәри, атлы сугышчы. *Кавалеристлар саф саен дүртәр-дүртәр тезелешеп, ләкин саф тәртибен сакламыйча, таркала төшеп, аның артыннан юыртып баралар.* А.Шамов. *Ләкин Костинның анадан кавалерист булып туган башкортны үз яныннан җибәрәсе килмәде.* Г.Гобәй. *Кавалерист батыр булсын, аты таза, матур булсын.* Әйтем

**КАВАЛЕРИСТЛА́РЧА** *рәв.* Кавалеристка охшаш, кавалеристлар кебек. *Аның өстендә утырган капитан Прокофьев исә, аты юыртканда, кавалеристларча --- калкына, ләкин аның калкынышы нәкъ исерек кешенеке кебек.* А.Таһиров

**КАВАЛЕ́РИЯ** *и. фр.* Атлы гаскәр. *Алдан – кавалерия, аннары, саф-саф тезелеп, пехота, аннары тупка җигелгән атлар әкрен генә басу капкасыннан чыга башлады.* И.Гази. *Бер урында дошманның резервта яткан кавалерия бүлекләре ике полк арасына килеп кергән.* А.Шамов

**КАВАЛЕРЛА́РЧА** *рәв.* Кавалерлар кебек илтифат күрсәтеп. *Кавалерларча иелә биреп, Сабирага кереп утырырга тәкъдим итте.* Ә.Еники

**КАВАЛЬЕ́Р** *и. фр. махс.* Казылган канау һәм канал кырыйлап өелгән балчык

**КАВАЛЬКА́ВИА** *и. ит.* Ат юлы. *Шундагы [Венециядәге] Кавалькавиа дип аталган мәйданнан автобус сине Әдрән диңгезнең иң гүзәл энҗесенә алып китә.* М.Юныс

**КАВАЛЬКА́ДА** *и. ит.* Бергәләшеп йөргән җайдаклар төркеме

**КАВАМ** *и. гар.* Нигез, терәк, таяныч. *Тәннең каваме җан белән, җанның каваме тән беләндер.* К.Насыйри

**КАВАСА́КИ** *и. яп. махс.* Ерак Көнчыгыш суларында балык тоту өчен кулланыла торган, борын ягы биек, койрык өлеше киң итеп эшләнгән җилкәнле-моторлы көймә

**КАВАТИ́НА** *и. ит. муз.* Гадәттә лирик хикәяләү характерындагы зур булмаган опера ариясе

**КАВӘС** *и. гар. иск.* 1) Борынгы ук ату коралы; җәя

2) Математикада, язу-сызудагы җәя тамгасы

3) Зодиак йолдызлыкларының берсе – Укчы йолдызлыгы

4) Игенчелек календаренда тугызынчы ай (хәзерге ноябрь аена туры килә). *Кавәс керми, кыш булмый.* Сынамыш

**КАВДИВИ́ЗИЯ** *и. рус* Кавалерия дивизиясе. *Кавдивизиянең йөгерек атлары баскан җирләрдә дошманның кисеп, изелеп ташланган хәрби бүлекләре, таркалган, юк ителгән обозлары, ватылган, җимерелгән станцияләре генә калды.* А.Шамов

**КАВЕЛ** *и. гар. иск.* Сүз, сөйләм. *Фикердә фаикъ, кавелдә садыйк.* К.Насыйри

**КАВЕМ** *и. гар.* 1) *сөйл.* Нәселнәсәбә, бер ыру кешеләре. *Болай да сезнең кавемнең җүнле кушаматы юк: Катыржан да Төлке, Карун да Кулак.* Н.Гыйматдинова

2) Кабилә, халык. *Кавемнәрдән гыйлем-мәгърифәттә, һөнәрдә бик артта, бик еракта калганыбызны балаларыбызга, халкыбызга аңлата башладылар.* Ш.Мөхәммәдев. *Ә шул чакта ил башкаласында ят кавем егетләре күкрәк киереп хөрриятта йөри.* Т.Әйди. *Татарны башка, чит-ят кавемнәр нигәдер, хәйләкәр, диләр.* Ф.Яхин

3) *күч.* Токым, зат. *И-и, юләр, хатын-кыз кавемен беләм инде мин! Әгәр синең чынлап яратуыңны сизеп алсалар, хәзер хан кызына әйләнәләр*... В.Нуруллин. – *Кайсыгыз бу, җен кавеме! Җибәр! – дип чәбәләнә башлый.* Г.Лотфи

**КАВЕМДӘШ** *и.* Бер-берсенә карата: бер кавемнән булган кешеләр. *Шушы кадәр җәһәннәм ераклыгына кавемдәшең килеп чыксын әле, ничек кызыксынмыйсың!* Н.Әхмәдиев

**КАВЕ́М-КАБИЛӘ** *и. гар.* Кардәшыру, туган-тумача, бер ыру кешеләре. *Ыруг-кардәш, кавем-кабилә – һәммәсе сау-сәламәтләр.* Ш.Камал

**КАВЕ́РНА** *и. лат.* 1) *мед.* Берәр төрле авырудан эчке әгъза тукымасы таркалып барлыкка килгән бушлык. *Үпкәдә бик зур каверна барлыкка килү*

2) *геол.* Тау токымнары массивында барлыкка килгән куыш урын, бушлык

**КАВКАЗЛЫ** *и.* Тумышы белән Кавказдан булган, Кавказда яшәүче халыкларның бер вәкиле. *Ул --- кавказлы, чуваш, чеген һ.б. азчылык милләтләрнең көйләреннән күп кенә үрнәкләр уйный.* М.Җәлил. *Анысы кавказлы иде, әллә әрмән, әллә грузин инде.* А.Расих

**КАВКА́ЗЧА** *рәв.* Кавказ халыкларына хас итеп, кавказлылар сыман

**КАВЫЗ** *и. гар.* 1) *диал.* Ясалма күл, бассейн, хавыз. *Безгә хәзер бер генә юл: ничек кенә булса да вакытлы буабызны күтәрергә, отводный каналның тамагын киңәйтергә, казылып бетмәгән кавыз юлын ачарга.* Т.Гыйззәт. *Аның бер як кырыендагы таш улактан челтерәп су агып тора, кавызда исә төрле суүсемнәр чайкала, төбендәге төрле төстәге чуерташлар, вак дулкыннар аркылы, биеп торучы нindидер җан ияләрен хәтерләтәләр.* Ф.Латыйпов

2) Су тегерменәнә су җибәрү өчен тактадан яки таш җәеп ясалган улак. *Бүре кызып кына онны ялап азапланган арада, Төлке тиз генә барып тегермәннең кавызын ачып җибәрә.* Әкият

**КАВЫК** *и.* Баш тиресенең чәч төбендә тупланган үле тукымалары; кубалак. --- *кара чәчләрен ишле рәвештә кавык сарган, алар аның күлмәк якасына да шактый коелганнар* ---. Р.Сибат. *Канлы үләнне кычыткан белән төнәтеп, шул су белән чәчне чайкасаң, кавыкны бетерә.* Ватаным Татарстан

**КАВЫКЛАНУ** *ф.* Чәч төбе кавыклар белән каплану

**Кавыкланып бетү** Бик нык кавыклану

**КАВЫКЛА́У** *ф.* Чәч төбендә кавык барлыкка килү

**Кавыклап бетү** Бик нык кавыклау

**КАВЫКЛЫЛЫК** *и.* Кавык күп булганлык. *Баш кавыклылыгын бетерә торган күптөрле баш югычлар уйлап табылган*

**КАВЫМ** *и.* Бер тын алырлык кына кыска вакыт арасы, берникадәр вакыт, мизгел. *Тавыш белән түгел, кайнар сулыш белән генә әйтелгән бу сүздән Хәлимнең бер кавымга хәтта тыны кысылды.* И.Гази. *Бер кавымга тынлык урнашты.* З.Фәтхетдинов. --- *ул, сулуы кабынып, бер кавым тәмам өнсезләнеп торды.* В.Нуруллин

**КАВЫН** *и.* 1) Кабакчалар семьялыгына караган, эче куыш озынча яки шарсыман формадагы, сусыл итле эре җимешле, түгәрәк эре яфраклы, уртасы куыш шуышма сабаклы игүле бакча үсемлеге. *Ул быел җәй күрше авылында, Сашка дигән рус крестьян баенда, кавын бакчасын каравыллаган иде.* Г.Ибраһимов. *Тау итәгендәге түтәл бакчасына билгеләнгән җирдән таллар әрчелеп бетүгә якынлашу сәбәпле, ирләр югарыга – кавын, карбыз һәм бәрәңгегә билгеләнгән җирдән агач тамырлары төпләргә киттеләр.* Ш.Камал

2) Шул үсемлекнең җимеше. *Алар артыннан кыяр, кишер, кавын шикелле кадерлерәк яшелчәләр җитешә.* М.Әмир

**КАВЫН-КАРБЫЗ** *җый. и.* Кавыннар һәм карбызлар; гомумән шундый татлы бакча яшелчәләре

**КАВЫРСЫН** *и.* **1.** 1) Кош канатындагы эре каурый. *Минем, каз кавырсыннары, чүпрәкләр сатып, сөенчегә дип әзерләгән алты тиен акчам бар иде.* Г.Ибраһимов

2) *диал.* Пластмасса. *Кавырсын тәме суга чыгып кына калмады, күзләрне ачыттыра торган исе бөтен өйгә таралды*... А.Хәйртдинова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кош канатындагы эре каурыйдан ясалган. *Кавырсын каләм*

2) Пластмассадан эшләнгән, пластмассадан торган; полиэтилен. *Хуҗа кеше кавырсын бөкене ачты да фарфор рюмкаларга салды.* Ә.Баян. *Берсе малын мактый, икенчесе аны төрергә әзерләнә, маймыл рәсеме төшерелгән кавырсын пакет тартып чыгара.* Т.Галиуллин

◊ **Кавырсыны кату** Балалыктан чыгу, җитлегү. *Әнә шул егетләр әтиле гаиләдә үскән ир балаларга караганда һәр яктан да иртәрәк өлгерә, кеше булара та тизрәк формалаша иделәр, аларның кавырсыннары алданрак ката иде.* М.Вәлиев

**КАВЫШТЫРУ** *ф.* 1) Аерылышып торганнан соң, кабат очраштыру, бергә туры китерү. *Кавыштырсын безне яңадан Идел ярындагы ак каен.* Ф.Кәрим

2) Гашыйкларга яшерен очрашу оештырып, күрешергә мөмкинлек бирү. *Кавыштыра айлы кичтә Яшерен утта янганнарны.* М.Җәлил. *Үзләрен кавыштырган утрауга да юлны онытмады Альбинос белән Альбиноза* ---. Р.Мөхәммәдиев

3) Ир белән хатынны кушу. *Юк, ди, Ходай безне кавыштырмаса,*

*нишләрмен, дип елый, ди.* Ф.Әмирхан. *Кайсын табыштырасың да аннан кавыштырасың.* М.Җәлил

**Кавыштыра бару** Һәрберсен, булган берсен кавыштыру

**Кавыштырып тору** Һәрвакыт, еш кавыштыру

**Кавыштырып чыгу** Барысын да бер-бер артлы кавыштыру

**КАВЫШТЫРУЧЫ** *и. иск.* Ир-ат белән хатын-кызны үзара парлаштыруда арадашлык итүче; димче, яучы

**КАВЫШУ** *ф.* 1) Аерылып торганнан соң кабат очрашу. *Бияләр, сыерлар көн буенча аерылган балаларына кавышып шатланалар, ялап, шаярып иркәлиләр.* Г.Ибраһимов. *Ләкин мондый кадерле кунаклар яныма килгән яки сөекле дусларым белән кавышкан көннәрем минем бик сирәк була.* Ә.Еники

2) Бергә булу, берләшү. *Бу ике халык бер кавышып, укмашып вә оешып җитсә, каршы торыйм димә, чөнки ул халык госманлылар белән канкардәш.* М.Хәбибуллин

3) Гашыйклар очрашу, күрешү. *Атта кунып яткан җиреннән таң алдында кайтып, ындырда сызгыра икән, төн буена зарыгып көткән гашыйк кыз Фатихә үзенең сердәше Гыйльминур җиңгәсен уята икән дә, болар комганнарын алып, икәү абзарга чыгалар икән, шунда егет белән кыз кавышалар икән --- дип гайбәтлиләр.* Г.Ибраһимов

4) Тормыш кору, бергә кушылу, ир белән хатын булып яши башлау. *Шау чәчәккә күмелеп яз килгәндә, иркәм, кавышырбыз дип өмет итәм мин.* Ә.Ерикәй. *Ата чыпчык белән ана чыпчык бергә кавышты исә, аерым оя коруны карый.* Ш.Камал. *Бер кавышкач, ике ел аерым торулары бик кыен диләр ич!* В.Нуруллин

5) *күч.* Яраткан эшенә кире кайту мөмкинлеге чыгу, кабат шул эшкә керешү. *Ул игенчелек турында, үзенең җир белән кавышудан бәхет, ләззәт табуы турында сүз башлады.* М.Хәсәнов

**Кавышып бетү** Барысы да кавышу

**Кавышып калу** Кавышырга өлгерү. *Сабыр итәм, сине көтәм, Кавышып калуларга ни җитәр.* Җыр

**Кавышып кую** Кинәт, көтмәгәндә кавышу. --- *күп еллардан соң, очраклы рәвештә генә Казанда күрешкәч, алар тагын бер-берсен ошатып, кавышып та куйганнар...* З.Хөснетдинов

**Кавышып тору** Еш очрашкалап, әледән-әле кавышу

**КАГАЙТУ** *ф.* 1) Ит, балык кебекләрне һавада, җилдә киптереп ашарга яраклык итү, каклау

2) *күч.* Озак вакыт көттереп тоту

3) *күч.* Ач тотып ябыктыру, ачлык белән азаплау

**Кагайтып бетерү** Бик нык, тәмам кагайту

**Кагайтып кую** Алдан кагайтып әзер хәлдә тоту

**Кагайтып тору** Һәрвакыт, гел кагайту

**КАГАН** *и. тар.* Урта гасыр төрки дәүләтләрдә чикләнмәгән хокукларга ия булган дәүләт идарәчесе, берләштерелгән империянең башында торган иң олуг хан титулы һәм шул титулга ия кеше. *Безнең ятим угланыбыз да әнә каган кулына әсир төшкән.* М.Хәбибуллин. *Рина астыртын гына күз салгалап, ят егеттә теге гайрәтле Атилланың – Көнбатыш Аурупага килеп җиткән азиат каганның яугирлек чалымнарын ачарга тырышты...* Т.Әйди

**КАГАНАТ** *и. тар.* Башында каган торган дәүләт

**КАГАНЛЫК** *и. тар. к.* **каганат**. *Төрки каганлыгы вакытында диндә сыйнфый бүлгәләнеш тә ачык чагыла.* Г.Дәүләтшин

**КАГАЮ** *ф.* 1) Балык, ит әйберләрне ашарлык хәлгә килеп җилдә кибү, каклану

2) *күч.* Озак вакыт бер урында эшсез басып тору, булу. *Чәч алучы Ибраһимнан чәчләрен алдырып, сакалмыекларын кырдырып кайтканнан соң, хәзрәти Мөхәммәт тик кагаеп номерда ята иде.* С.Җәләл. – *Такта бетте, ярырга бүрәнәләр кирәк, болай да озак йөрдең, кайтып җиткәч, нишләп монда кагаеп торасың? – дияр иде.* Р.Батулла. *[Ябалак] Икенче куыш эзләр иде, монысы кызганыч, куыш янында кагаеп утырса, үзе җәл.* Н.Сладков

3) *күч.* Нык ябыгу

**Кагаеп бетү** Тәмам, бик нык кагаю

**Кагаеп йөрү** *к.* **каңгырып йөрү**. *Миңа да, туган-үскән җирләрне ташлап, байтак чит җирләрдә кагаеп йөрергә туры килде.* С.Җәләл

**Кагаеп калу** Кагайган хәлгә килү

**Кагаеп килү** Акрынлап кагаю, каклану дәрәҗәсенә җиту

**КАГОР** *и. фр.* Аерым сорт виноградтан әзерләнә торган куе, караңгы кызыл төстәге шәраб

**КАГУ** *ф.* 1) Тигез тавыш чыгарып бәргәләп тору; шаку. *Гайса, сүздән туктальп, бер аягын --- һәм янындагы агач өстәлгә бармаклары белән кага иде.* Ф.Әмирхан. *Әйтәм аны, турыларыннан уза башладыңмы, тәрәзә кагалар, кул болгыйлар.* Т.Гыйззәт. *Йокы бирми һаман... һаман. Төн буена ишек кага, кем ул килгән?* Һ.Такташ. *Ишеген кемдер бик каты кага башлагач та, озак кына уяна алмый ятты.* З.Фәтхетдинов

2) Чакырып яки игътибарны җәлеп итү максаты белән нәрсәгә булса да суккалап торып, бәргәләп ритмлы тавыш чыгарып тору, сигнал бирү. *Озак та үтмәде, ишегалды уртасындагы пожар каланчасыннан обедка туктарга чаң кактылар.* М.Гали. *Карчык чиләк төбе кага һәм такмак әйтә.* А.Әхмәт. *Мәктәп балалары, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып, тигез сафлар белән ашханәгә кереп киттеләр.* Ш.Бикчурин

3) Дулкын ярга чайкалып бәрү. *Күлнең көмеш дулкыны ярларга кага, Ак бөдрә чәче таралып кала.* Ш.Маннур

4) Кадак, казык, чөй һ.б.ш. очлы нәрсәләрне бәреп кертеп ныгыту. *Чокырга көндез әзерләп куйган казыкларны кагып, өстенә ике капчыктан тегелгән җәймәне кордылар, капчык өстенә үлән йолкып салдылар.* Г.Гобәй. *Брезент кием, брезент бияләй кигән зур куллар бер потлы кувалда белән тимер казык кага.* Р.Кәрами

5) *к.* **кадаклау** (*1 мәгъ.*). *Гөлсем апа ишегалдында куе яфраклы карт юкә күләгәсендә имтиханнарга әзерләнеп утыра, Илдар эт оясының купкан тактасын кагып маташа иде.* Г.Гобәй

6) Тузаннан, чүптән арындыру өчен суккалау, селкү. *Марат торып, карлы*

*тез башын кага.* Г.Гобәй. *Рина иелеп кар алды да егетенең өстенә сипте ---. Янгураз, өстен дә какмыйча, аны елмаеп карап калды.* Т.Әйди. *– Йөрәгемне яра язды, җен, – дип, [кызлар] тиргәнә-тиргәнә өс-башларын кагарга керештеләр.* Ф.Шәфигуллин

7) Бөртекле, түгелүчән нәрсәләрне савыттан кою, түгү, селеккәләп бушату. *Ялангач аяк өстенә генә киелгән зур юкә башмагын салып какты.* М.Әмир. *Самавырның көлен кагу*

8) Кул белән иңбашка суккалап, дустанә мөнәсәбәтне, теләктәшлекне белдерү. *Сафа бабай башкортның аркасыннан кага.* Г.Ибраһимов. *Ягез, дусларым, хәерле юл дип, берәм-берәм өчесен дә кочаклап үпте дә, Сөләймановның аркасыннан кагып, исән-сау әйләнеп кайтыгыз, диде.* И.Гази. *Секретарь аның [Мәлсның] җилкәсеннән какты.* Ф.Садриев

9) Баланы чәбәкләп, кул белән йомшак бәргәләп торып иркәләү; юату. *Барган җирләрендә малайны кызгандылар, башыннан сыйпадылар, аркасыннан кактылар.* И.Гази

10) Канат җилпү, җилпү хәрәкәтләре ясау. *Канатларын кагып, тагы да кереште шунда сайрарга.* М.Гафури. *Карчыга оча канат кагып, бара канатыннан кан тамып.* М.Фәйзи. *Чебен дә канатларын кага.* А.Алиш

11) Күз кабагын ачып ябу; күз сирпү. *Өчәр төн рәттән керфеккә керфек какмыйча, аяк өсте йөргән чаклар да була иде.* Г.Гобәй. *Наилә Гөлнараны бүлдермәде, керфек какмады, йотлыгып тыңлады.* А.Гыйләҗев

12) Мимика, күз карашы белән баш селкеп ымлау, ни дә булса белдереп ишарә ясау. *Фатыйма аяз күктә йөзгән тау-тау ак болытларга карап торды да тын гына гармунчыга баш какты.* Г.Әпсәләмов. *Иягемне кагып, «ярар» дигән җавапны аңлатып утырдым.* М.Гали. *Айсылу, бригадирны тынычланырга өндәп, ым какты.* Г.Бәширов

13) Кузгалып китәргә, йөрешен тизләтергә әйдәп, дилбегәне, өзәңгене җиңелчә генә селкетеп атка сугып кую. *Дилбегәне какмыйча ук кош кебек очып торган бер ат алырбыз.* А.Әхмәт. *Изге эшләр өчен бервакытта да соң түгел, диде ул, һәм аннары үзе дә соңга калудан хәвефләнгәндәй дилбегәләрне какты.* Г.Минский. *Минһаҗ абыйның дәртле генә: «Әйдә, юргак», – дип дилбегә кагуыннан мин барысын да аңлап алдым.* Н.Гыйматдинова

14) Җилдә җилфердәү, селкенеп тору, тирбәнү. *Карт каеннар какмыйлар бер яфрагын да, тып-тын.* Н.Исәнбәт

15) Килеп бәрелеп селкетү, тибрәтү (җил тур.). *Иске җил тегермәне канатларын шыгыр-шыгыр китереп кага*

16) Бәреп егу, түшәлдерү, сөрлектерү. *[Игеннәр] күкрәп үскәннәр бит! Җил-фәлән кагып, боз-фәлән сукмаса, быел крестьянның бүресе улый инде!* З.Бәшири

17) Каты-каты бәреп, еш-еш тибү (йөрәк тур.). *Бу вакытта йөрәкләрнең кагулары ешайды.* М.Гафури. *Йөрәгем кага башлады минем, Шәрифҗан абый, дигән булды теге егет.* И.Гази. *Әллә нәрсә булды шунда Янгуразга: йөрәге кагып, күз төбенә кадәр дым бәреп чыкты.* Т.Әйди. *Миңнулланың йөрәге какты, тамагы карлыкты.* М.Мәһдиев. *Һава шартларын барометрдай сизгән кебек йөрәге кага башлады.* Н.Хәсәнов

18) Читкә тибәрү, кырыйга этәрү; баш тарту, ризалык бирмәү. *Аннары кружканы кулы белән бер читкә какты.* А.Шамов. *Европа һәм рус музыкасындагы югары техниканы читкә кагу аңарда юк.* М.Җәлил. *Тик минем соңгы теләкләрне кире кактылар.* Һ.Такташ. *Аның сүзен какмадым.* М.Гафури

19) Тыю, юкка чыгару. *Трибун, латинча «тыям» дигәнне аңлаткан «вето» сүзен әйтеп, хәтта сенат карарын да кире кага алган.* Тарих

20) Дошман һөҗүмен кире кайтару, җиңү. *Һәм, авылда ныгып калып, безнең эре көчләребез килеп җиткәнгә кадәр, дошманның барлык контратакаларын кире кага.* И.Гази

21) Уен коралында сыйфатсыз итеп уйнау яки уйнаганын өнәмәгәнне белдерү

22) *күч.* Исерткеч эчемлек эчү

23) *күч.* Үз күрмәү, рәнҗетү, кыерсыту, җәберләү. *Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим.* Г.Тукай. *Эш була калса, боерган булса, сине читкә какмыйбыз инде, булсын гына инде, аннан соң сине бөтенләй башыңнан малга күмәрбез.* Г.Камал. *Әй-йе, Газиулла балакай, тормыш дигән нәрсә җитәрлек каккан алайса үзеңне...* М.Хәсәнов

◊ **Каккан казыгы да юк** Бик ярлы, йорт-җир тотмый торган, хуҗалыгы булмаган кеше турында («йорт салырга түгел, җир алып казык кагарга да хәленнән килми» мәгънәсендә). **Каккан казык кебек** Кузгалмыйча бер урында тик басып тору, баскан җирендә катып калу турында. *Әхияр карт, бу хәлләргә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, баскан урынында каккан казык кебек торып калды.* Г.Гыйльманов

**Кага бару** Берәм-берәм рәттән кагу. *Кешегә авыр сүз әйткән саен, бер кадак кага бар.* Өмет

**Кага башлау** Кагарга тотыну. *Башка вакытлардагы шикелле үк, бүген дә буран башлануга чаң кага башладылар.* Н.Яһүдин. *Сәет, үзе дә сизмәстән, бар көченә ишек кага башлады...* Г.Гыйльманов

**Кага тору** Бертуктаусыз кагу; озак кагу. *Тик шулай да, хәтер янчыгыбызны кага торгач, бабайның борынгы тормыш турындагы бер әкиятен исебезгә төшерә алдык.* Г.Гобәй

**Кагып бетерү** Бөтенләй, тулысынча, берни дә калдырмыйча кагу. *---икеләнү, көтү һәм өметләнүләрнең тузанын кагып бетерергә теләгәндәй, аяклары белән тибенгәләп алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Кагып җибәрү** Кинәт кенә кагу. *Фатыйма малайны кагып җибәрде.* И.Гази. *Кыз Хөрбануның кулын кагып җибәреп кымызын түгә.* М.Фәйзи. *Дилбегәне кагып җибәрү белән, егәрле мал йөрешен кызулатты.* С.Рафиков

**Кагып йөрү** Бертуктаусыз, һәрвакыт кагу. *Ярты гомереннән бирле, хатыны үлгән сагыштан, думбыра кагып йөрүдән башка бернәрсә дә белми.* Ф.Бурнаш

**Кагып китү** Билгеле бер моменттан соң кагарга керешү, кага башлау. *Конторда мондый хата эшләр булганда, Галиәкбәр агайның ачудан шулай кагып китә торган гадәте бар булса да, бу*

*ел каенатасы хәзрәт, хаҗга барырга вакыт, бу эшләрне куярга кирәк инде, диеп күп нәсыйхәт биргәч, әчмәскә тәүбә дә кылган иде.* Ш.Мөхәммәдев

**Кагып кую** Бер тапкыр кагу, сугып кую. *Аша-эч, әти тапкан мал түгел, үзебез тапкан җәл түгел, дип дусларча җилкәмә кагып куялар.* Ф.Хөсни. *--- абыйсы, исе китеп, Равилнең аркасыннан кагып куйды.* В.Нуруллин. *Әтисе, җимеш тәмен сизгәндәй, иреннәре һәм күзе белән ишарә ясап, ым кагып куйгандай булды.* Г.Ахунов

**Кагып тору** Бертуктаусыз кагу. *Канат кагып тора тегермән.* Ә.Ерикәй

**Кагып чыгару** Читкә, кырыйга этәрү, кырыйга китәргә мәҗбүр итү. *Бүтән ат белән ярышырга туры килсә, яхшы карап бар, усал ат туры килеп, атыңның бер-бер җирен тешләп алмасын, я булмаса читкә кагып чыгармасын.* М.Гафури. *Алтын комлы яр буенда йөзтүбән каплап куелган алюмин көймәләр дулкын кагып чыгарган эре балыклардай ялтырап ята.* Н.Хәсәнов

**Кагып чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы берәм-берәм кагу; барысын да кагу. *Солдатның кан кызу: урысчалатып бер сүгенеп ала да казыкларны тагын кагып чыга.* Г.Ахунов. *Йортын караштырды, купкан киртәләрен кагып чыкты.* Г.Мирһади

**КАГУ́-СУГУ** *ф.* Һәртөрле кыерсыту, рәнҗетү, җәберләү. *[Сафура] Балаларын какты-сукты, елатып урамга куды.* Г.Ибраһимов

**КАГЫЙДӘ** *и. гар.* 1) Нинди дә булса күренешләрнең даими мөнәсәбәтләрен, закончалыкларын чагылдырган билгеләмә. *Грамматика кагыйдәләре*

2) Гомуми тәртип урнаштыру максатында аерым оешма тарафыннан рәсми кабул ителгән, расланган күрсәтмә; төп шарт; закон. *Борын хәзрәтнең кысынкы кагыйдәләре эчендә яшәгән шәкертләр --- башларына килгән һәрбер эшләрне кыла башладылар.* Г.Ибраһимов. *Хәрби кагыйдәләрне бозып, әтисе исеме белән олылап атап йөртә идек.* А.Шамов

3) Үз-үзеңне тоту нормасы, гомуми кулланыштагы тәртип; норма. *Ләкин андагы тәртип, низам, әхлак кагыйдәләре белән килешә алмадым.* Т.Гыйззәт. *Үзе ул, әдәп кагыйдәсеннән һич чыкмаса да, безнең араны ничек тә гадиләштерергә тырыша кебек.* Ә.Еники

4) Хезмәт иминлеген, эш барышында куркынычсызлыкны тәэмин иткән рәсми күрсәтмәләр. *Тимерхан алардан [белгечләрдән] өйрәнә, агротехника һәм зоотехника буенча элементар кагыйдәләрне төшенә башлый.* Г.Ахунов

5) Уенның тәртибе белән бәйле үтәлергә тиешле таләпләр. *Борһанов, шәһәрдәге кебек, спортның барлык кагыйдәләрен саклап үткәрергә булды милли көрәшне.* Г.Ахунов

6) Урнашкан гадәт, гадәтигә әйләнгән тәртип, язылмаган, рәсми кабул ителмәгән таләпләр. *Кайсы гына укучы тәртип бозса да, аны бөтен коллектив белән төзәтергә дигән кагыйдә юк.* З.Фәйзуллин. *Берничә көн күзәтүләрдән соң, мин песнәкләрнең ашау-эчү, үзара мөнәсәбәт мәсьәләләре бөтен бер системага салынып, аерым кагыйдәгә корылганын төшендем.* М.Мәһдиев

◊ **Кагыйдә буларак** *кер. сүз* Гадәттә, нигездә, кабул ителгәнчә. *Кагыйдә буларак, аларны авторның үзеннән башка берәү дә укып килмәгән.* М.Әмир. *Иркә бала, кагыйдә буларак, ялкау була.* Г.Гобәй

**КАГЫЛГЫСЫЗ** *с.* 1) Билгеле бер вакыт эчендә тотылмыйча сакланып торырга тиешле. *Кагылгысыз запас*

2) *мах.* Закон белән саклана торган. *Кагылгысыз милек*

3) *күч.* Аеруча кадерле, хөрмәт ителгән, бик нык саклана һәм изге санала торган

**КАГЫЛГЫСЫЗЛЫК** *и.* Закон белән сакланганлык. *Ул [барс] хакимлекнең шаһият тарафыннан бирелүен, аның изгелеген, кагылгысызлыгын белдерә.* Г.Дәүләтшин

**КАГЫЛМА** *и. диал.* Кышкы юлда чана читкә тайпылудан ясалган тайгак авыш урын, чалу. *Кагылмада чанадан тәгәрәп кала язгач кына, Хәлим уйларыннан айнып китте.* И.Гази

**КАГЫЛМАЛЫ** *с. диал.* Кагылмалары булган, чалулы (юл)

**КАГЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кагу**. *Баганаларга өч почмаклы дар агачлары кагылган.* Г.Гобәй. *Һәм бер-берсенә янәшә китерелеп тыгызлап кагылган, шомарып беткән зур эшләпәле кадакларга кулы белән шапылдатып сугып куйды.* А.Шамов. *Вәрәшбашның утыз йортына, тәрәзәләренә аркылы такта кагылган итеп күрү аның өчен ифрат авыр иде.* Г.Ахунов

2) Җиңелчә генә бәрелү, тиеп китү, орыну. *Һәм Иргали тәвәккәлләде, йөрәкләнеп китеп, бөтен ихтыярын бергә туплады да җиңелчә генә ишек келәсенә кагылды.* М.Хәсәнов. *Бераздан Фатыйма аларны куып җитә һәм арыш башакларына бармак очлары белән кагыла-кагыла янәшә бара башлый.* И.Гази. *Ирек ---Зәнфирәнең битләренә, күзләренә, иягенә кагылды.* Ф.Садриев

3) Тиеп вату, орынып җимерү, бөтенлеген бозу. *Саламын бик зур эскерт итеп шул җиргә өйдерде дә мал-фәлән кагылмасын өчен киртәләтеп куйды.* Г.Ибраһимов. *Бу хыялын ул хәтта үзеннән үзе яшерә, якты йолдыз нурына соклангансыман, аңа ерактан гына кызыгып йөри, хәтта ул турыда чынлабрак уйлый башласа, бик пакь һәм саф бер нәрсәгә кагылып, аны буягандай, үзендә бер уңайсызлык хис итә иде.* Г.Бәширов

4) *юкл. форм.* Сузылып алмау, орынмау, ашамау яки эчмәү. *Мин алдыма куйган чәйгә бөтенләй кагылмыйча, саргайган фоторәсем карап утырам.* М.Мәһдиев

5) Барган юлыннан, утырган, баскан урыныннан читкәрәк китү, тайпылу. *– Әй, кагыл! – Хәлим чак кына тайчанып өлгерде.* И.Гази. *Нәгыйм тиз генә тәрәзәдән читкә кагылды.* Ш.Камал

6) Чит әйбергә тию, рөхсәтсез алу, орыну; үзеңнеке итәргә тырышу, үзләштерү. *Кешенең энәсенә дә кагыласы булма!*

7) Берәр кешегә яки әйбергә караган булу, аның белән бәйле, мөнәсәбәтле, кагылышлы булу. *Мәрьямбикәләрнең, Сираҗиларның шаукымы кагылудан гына башланган ул чир шулай ук тиз бетеп китте.* Г.Ибраһимов. *Галиәсгар Камал турында яза башласаң – татар театрының туу һәм үсү тарихына, татар театры турында яза башласаң,*

*Галиәсгар Камалның тормышына һәм иҗатына кагылмый һич мөмкин түгел.* М.Гали. *Миңа йөкләнгән эш гаять зур әһәмияткә ия булганга, кайбер мәсьәләләрне ачыклаганчы беркая да чыгып йөрмәвегезне үтенәм. Бу башка иптәшләргә дә кагыла.* З.Фәтхетдинов

8) Сөйләмдә аерым тукталып китү, искә алу, билгеләп үтү. *Шуңа күрә азмыкүпме югарыдагы мәсьәләләргә кагылырга туры килде.* М.Җәлил. *Авылдагы хәлләргә, культура мәсьәләләренә, комсомол эшләренә дә кагылдык.* М.Әмир. *Тормышта --- Галина үзен дустанә итеп тота, әмма пенсия кебек четерекле мәсьәләгә кагыласыңмы – ул аяусыз, законга гына буйсына.* Г.Ахунов

9) Авыр сүз әйтү, тәнкыйтьләү, сүз белән рәнҗетү. *Кем кагыла сиңа, кемнәр тел тидерә?* Г.Бәширов. *Җир сөрмисең, күп көч түкмисең дип, күңелемә, дустым, кагылма, сабанчыдан артык арый шагыйрь акыллы җыр язган чагында.* З.Мансур

10) Тию, зыян салу (тешләү, кыйнау, сугу). *Билгеле, эт аңар кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган.* А.Алиш

11) Юл уңаенда узышлый кереп чыгу; сугылу. *Кайткан чакта аптекага кагыл, хуҗага әйт: больница сораганнарның бөтенесен бирсен.* И.Гази. *Маһибәнең һәр кагылуы, күзләремә карап әйтелгән иркә сүзләре ихтыярымны йомшарта баралар иде.* М.Әмир. *Кара, кара, минем янга кагылмыйча да китеп баралар.* Г.Гобәй. *Юл уңаенда ул китап кибетенә дә кагылды.* Т.Әйди

12) Кыерсытылган булу, җәберзолым күрү. *Тормыш тарафыннан кагылып, куылып дигәндәй йөртелгән Фазыл белән, кулдан-кулга күчеп йөргән Габдулла кебек үксезләр җырламый кем җырласын соң мондый җырны.* Ә.Фәйзи. *Бу әсәрдә Кәрим бай асравы Сәлимә – беркадәр Г.Камалның башка әсәрләрендәге асраулардан аерылыбрак торса да шул, барыбер, байлар тарафыннан нык кагылып, кимсетелеп, куркакка әйләнеп беткән яшь татар кызы.* М.Гали

13) Тию, борчу, психикага, күңелгә начар тәэсир итү, онытылган элекке авыр истәлекләрне кузгату. *Күңел таш түгел бит, уңайсыз бер яктан, сүз ачарсың да картның яралы йөрәгенә кагылырсың.* Г.Ибраһимов. *Әмма җаныма тимә син минем, күңелем ярасына кагылма.* Г.Бәширов

14) Мөрәҗәгать итү, сорау, үтенү. *Урып җыю чорында --- байтак машинаны --- ашлык ташу эшенә озатканнар иде. Фуатка башта кагылмадылар.* Э.Касыймов

15) Нәрсәгә булса да хирыслыкны, һәвәслекне белдереп килә. *Әнкәй бер көлә, бер ачулана, сиңа, ахры, ат җене кагылгандыр, торсаң – шул, ятсаң – шул, бар белгәнең шул булды, ди.* Г.Ибраһимов. *Бу җен кагылган хәерченең ишегалды да тыныч түгел.* Д.Аппакова

**Кагыла бару** Һәрберсенә берәмберәм кагылу. *Мин рухи мәсьәләләргә кагыла бардым, ә менә матди яктан ничек яшәвем миңа үзгәреш ясаганмы, юкмы икәнлегенә аерым тукталмадым.* Татарстан яшьләре

**Кагыла башлау** Кагылырга тотыну. *Милли җирлегебезгә куәтле кара дулкыннар кагыла башлады.* Ватаным Татарстан

**Кагылып алу** Аз гына кагылу, тиеп китү. *Капитан бил каешын сыпырып җибәрде, йолдызлы биек фуражкасын чигереп, чәчләренә кагылып алды.* Г.Ахунов. *Ул тәмәке төтененнән саргая башлаган ак сакалына тагын бер кагылып алды.* Г.Гыйльманов

**Кагылып йөрү** *к.* **кагылыпсугылып йөрү**. *[Шәйми] --- нәрсә генә эшләсә дә, үзеннән риза булмыйча, әле монда, әле тегендә кагылып йөрде дә бер җәйне кинәт укырга китте.* Г.Галиев

**Кагылып калу** 1) Ниндидер сәбәп, вакыйганың тәэсирендә булу, шул шаукым кагылу. *Тимерхан Борһановка Кырлай музееннан соң тарих җене кагылып калган.* Г.Ахунов

2) Читкәрәк китәргә, кырыйгарак кагылырга өлгерү

**Кагылып китү** Аз гына, чак кына кагылу, орынып китү. *Сирень яфраклары, төн җиленә кагылып китеп, гөлен сиптеме?* Н.Исәнбәт

**Кагылып кую** Бер тапкыр кагылу, кинәт аз гына кагылу. *Эшнең тәмам кызып җиткән чагында, Нәфисә үзенең иңбашына кемнеңдер йомшак кына кагылып куюын тойды.* Г.Бәширов

**Кагылып узу** *к.* **кагылып үтү**. *Мин тегендә кагылып узыйм, нишлиләр икән анда ул хәтле шаулашып?* И.Гази. *Әгәр синең үзеңә дә азрак җиле кагылып узган булса, алда тагын да бер хәл иде әле.* Г.Бәширов. *[Табындагыларның] Сүз елгасы самолётларның егылуы, поездларның бәрелүе, газларның шартлавы, җирләрнең тетрәве кебек утрауларга кагылып узды.* Ф.Садриев

**Кагылып үтү** Тиеп китү, орыныпорынып алу; аз гына сизелеп калу, җиңелчә килеп бәрелү. *Сайдә, үрелеп, бармак очлары белән генә аның бүртепкабарып торган беләкләренә, кулбашларына, күкрәкләренә кагылып үтте, аннары чәчләрен сыйпап куйды.* Г.Гыйльманов. *Миңлегаязга аның хушбуй исләре бөркеп торган эчке күлмәк җилләре кагылып үтте.* Р.Мөхәммәдиев

**Кагылып чыгу** Һәрберсенә берәмберәм кагылу, барысына да бер-бер артлы кагылу. – *Әле былтыргы бүләкләрегез дә шул килеш сандыкта ята,* – *дип, сак кына, балаларының күңелен рәнҗетмәс өчен генә, бүләкләргә кагылып чыга.* Ф.Яруллин. – *[Килен] Баскан җиреннән ут чыгара, Хуҗаның Миңлегалие ирештe бәхеткә,* – *диделәр кибеткә кагылып чыккан күршеләре.* Р.Мөхәммәдиев

**КАГЫЛУ́-СУГЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **кагу-сугу**

◊ **Кагылып-сугылып йөрү** 1) Андамонда барып, ни-нәрсә эшләргә белми аптырап йөрү; 2) Җәберләнү, кыерсытылу

**КАГЫЛЫШ** *и.* Кемгә яки нәрсәгә булган мөнәсәбәт, катнашканлык, бәйләнеш. *Кем белсен, әтисе янында әвәрәләнеп, башына машина исе кергән Госманның зур мәгънәдә хезмәт сукмагына басуына шул лобогрейкага кагылышы сәбәп булгандыр?* Б.Камалов. *Бу хәлнең эшкә кагылышы юк*

**КАГЫЛЫШЛЫ** *с.* Кагылышы булган. *Шул ук вакытта монда бөтен илгә кагылышлы зур эшләр тикшерелә,*

*төрле уеннар, ярышлар уздырыла иде.* Н.Фәттах. *Сугышка кагылышлы мәсьәләдә һәрвакыт сорау бирә торган Хәерниса бу юлы да сорау биргәч, Исламгали агай элеккеге дулкынына кире кайтты.* М.Мәһдиев. *Матбугат битләрендә аларның кемлегенә, ниндилегенә кагылышлы бәхәс кузгалды.* Шәһри Казан

**КАГЫЛЫШУ** *ф.* 1) Үзара орыну, бер-береңә тиеп китү

2) Барысы да читкә китеп юл бирү, урыннарыннан кырыйга тайпылу

**КАГЫНУ** I *ф.* 1) Канатларны җилпү. *Бирге якта, су читендә ап-ак казлар канат кагына.* Ә.Еники. *Әллә ничек ак каз, каң-каң --- итеп, канатларын җилпеп кагына.* М.Гафури

2) Өс-баштан кар, чүп, тузан һ.б.ш. бәргәләп, суккалап төшерү. *Кунак өйалдында, ишек төбендә бераз кагынганнан соң, хуҗалар белән бергә өйгә керде.* А.Шамов

**Кагына башлау** Кагынырга тотыну. *Киерелеп кагына башлады теге кош, кагынган саен алтын каурыйлары җиргә коела, имеш.* Д.Булатова

**Кагынып алу** Тиз-тиз кагыну, берничә кагыну хәрәкәте ясау. *Бөтен гәүдәсен калтыратып кагынып алды [кәҗә тәкәсе] Микәй.* Р.Мөхәммәдиев

**Кагынып җибәрү** Кинәттән кагыну, кагыну хәрәкәтләре ясарга керешү. *Җилкәңә канат үскәндер, менә хәзер кагынып җибәрсәң, очып китәрсең кебек.* И.Гази

**Кагынып кую** Бер тапкыр кагыну. *[Кәҗә тәкәсе] Муенын сузып турайта төште. Кар тузаннарыннан кагынып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**КАГЫНУ** II *и.* Кагыну (I) процессы. *Кошның канат кагынуы Гөлфияне әйтеп бетергесез шатландыра.* Ф.Яруллин. *Мин сиңа каз канатындагы кагыну каурыйларын көздән күп итеп, күп итеп әзерләп куярмын.* М.Хуҗин

**КАГЫТ** *и. диал. к.* **как** I (*1 мәгъ.*). *Румия дүртенче сыйныф укучысы гына булса да, җәйге ялда авылда әбисенә бәрәңге чистартырга да, кагыт ясаганда алма турарга да булышканга, пычак белән эш итү аңа таныш.* В.Ильясов

**КАДАВЫЧ** *и.* Нәрсәне булса да кадап куя торган әйбер

**КАДАК** I *и.* **1.** 1) Бер башы очлы, икенчесе эшләпәле металл таякчык. *Итек үкчәсенең кадаклары эченә тишеп чыкканнар, шуларны төйгечләр өчен, күрше Җиһанша бабайдан кендек алып торган да кире илтеп бирергә оныткан – менә бөтен тарих шул.* Г.Ибраһимов. *Туфли эчендәге җиз кадак исә эчкә тырпаеп, чүпрәк олтыракны тишеп чыккан иде.* Т.Әйди. *Аның җилгә җибәрелгән сырмасы, пиджагының кесәләре тулы кнопка, шөреп, авызында бер уч кадак иде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Әйбер элү өчен кагылган агач яки металл чөй; элгеч. *Менә ул Гөлләрнең колагына нәрсәдер пышылдады, аннары сәхнә артына йөгереп чыкты, яңадан керде һәм алдан әзерләнгән кадакларга Гөлләрнең чертёжларын элә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Җәйне хәтерләтеп мәтрүшкә, бөтнек исләре аңкыды: өйалды диварындагы кадакларга бәйләм-бәйләм дару үләннәре эленгән иде.* Н.Гыйматдинова. *Хәлим, бар, чоланнан үзеңнең бишегеңне алып кер, әнә теге кадакка элеп куй ---.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Берәр төрле эшнең, мәсьәләнең, күренешнең үзәге, иң әһәмиятле урыны. *Фәхри югалган төннән бирле һәммәсенең уйлары бик чуалган, миләрендә утлы кадак туктаусыз әйләнә, өйләрендә караңгы төн басып торган кебек иде.* Г.Ибраһимов. *Менә кайда иң төп мәсьәлә, көннең кадагы!* З.Мифтахов

**2.** *с. мәгъ.* Кадак калынлыгында, кадак зурлыгындагы, кадакка охшаш. *Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә ---.* Ә.Еники. *Аннары кадак үкчәле кара лаклы туфлиләренең тар очларына гына басып, көзге каршында бер-ике әйләнеп алды.* Э.Касыймов

◊ **Кадак булып** Күңелне борчып, тынгылык бирмичә (берәр йөдәткеч уй, фикер тур.). *Солтанның миенә кадак булып бер уй кадалды.* Г.Ибраһимов

**КАДАК** II *и.* 409,5 граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге, гөрәнкә. *Ә Хөсәен мирза ачларга бирелгән онның һәр кадагы өчен миңа йөз камчы ашатырга вәгъдә итә.* Ф.Бурнаш. *Ярты кадак күмәч алдым да шул якка ашыктым.* М.Әмир. *Җимеш рәтеннән бер кадак хөрмә сатып алды.* Ә.Фәйзи

**КАДАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кадаклау**. *Ике юл чатындагы күрсәткеч баганага аркылы-торкылы кадакланган ике такта кисәге кемгә кая китәргә кирәклекне әйтеп торалар.* Ш.Камал. *Өйнең ишекләре бикләнгән, тәрәзә капкачлары ябылган. Өсләреннән аркылы-торкылы такталар кадакланган.* Н.Дәүли. *Утыз йортның тәрәзәсенә такта кадакланды.* Г.Ахунов

2) Беркетелү, беркетелгән булу, эленеп тору. *Ул [белдерү] станция бинасының тышкы диварына кадакланган.* Р.Кәрами. *Каршыдагы стенага көзге кадакланган икән.* Ф.Яруллин

◊ **Кадакланган кебек (шикелле)** Селкенмичә, чак кына да кымшанмыйча. *Телеме бәйләнгән: бер сүз әйтә алмый, күзләре мөбһәм бер ноктага карап, кадакланган кебек торалар.* Г.Ибраһимов. **Кадакланып калган** *к.* **кадакланган кебек**. *Ә хәзерге минуттагысы шул: кыз, тылсымланган кебек, бер урында кадакланып калган.* Ф.Хөсни. **Кадакланып куелган кебек** *к.* **кадакланган кебек**

**КАДАКЛАП** *рәв.* Кадак (II) үлчәме авырлыгында, кадак үлчәме белән

**КАДАКЛА́У** *ф.* 1) Бер-берсенә кадак ярдәмендә беркетү. *Алмаларны әрҗәләргә, ящикларга тутыру башланды: ярык турысына иң матур, иң эре алмаларны салып, ящикларны кадакладылар.* И.Гази. *Өегезне ятим итеп калдырасым килми, тәрәзәләрен кадаклап китәргә кулым бармый.* В.Нуруллин. *Кырык ел чамасы элек тәрәзәләренә үзе такта кадаклап киткән --- иске йорт күренмәде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Белдерү, стенгазета, күрсәткеч, өндәмә һ.б.ш. әйберләрне кая булса да беркетеп элеп кую. *Ә гражданнар сугышына кадәр урман каравылчысы торган әлеге алачыкны төзәтәләр, тәрәзәләрен куялар, тышкы стенасына мемориаль такта кадаклыйлар.* Г.Гобәй

3) *тар.* Җәзалауның бер төре

◊ **Кадаклап куйгандай** *сөйл. к.* **кадакланган кебек**. **Кадаклап кую** Кузгалмаслык, селкенмәслек итү. *Хур кызы --- бер взвод солдатны бер мизгелдә*

*урынга кадакларлык командарм карашы белән олуг җитәкчене өстәле артына кадаклап куйды.* Ф.Яруллин. *Ләкин иң соңгы мәлдә ниндидер көч аның чабуыннан тотып алып калды, җиргә кадаклап куйды.* Г.Гыйльманов

**Кадаклап бару** Берсе артыннан икенчесен бер-бер артлы кадаклау. *Аның [Хәбиб абзыйның] шундый гадәте бар: уң аягын сул тезенә атландыра да, кулларын «йозаклап», кул сырты белән уң тезенә кагыла-кагыла сөйләшә, гүя һәр әйткән фикерен кадаклап бара.* Б.Камалов

**Кадаклап бетерү** Барысын да кадаклау; кадаклау эшен төгәлләү

**Кадаклап йөрү** Анда-монда килеп, анысын-монысын кадаклау. *Аның, шушы нигездә байтактан бирле гомер кичергән хуҗа кебек, йорт тирәсендәге аунаганны торгызып, сүтелгәнне кадаклап йөрүе, әлбәттә, ризалык билгесе иде.* Н.Гыйматдинова

**Кадаклап кую** Кадаклап беркетелгән хәлдә калдыру. *Ул [ишек] ике такта белән аркылы-торкылы итеп кадаклап куелган.* Г.Гобәй. *Бер сәгатьтән соң инде ул – әлеге кенәз – җәзага тартыла, аны аяк-кулларыннан агач тәрегә кадаклап куялар.* Ф.Урманче. *Өй кыегына кадаклап куйган әтәчмени.* Р.Мөхәммәдиев.

**Кадаклап чыгу** Барысын да, берсе артыннан берсен кадаклау

**Кадаклый башлау** Кадакларга керешү. *Түгәрәкләнгән тоякны вак тешле рашпиль белән шомартып тигезләгәннән соң, даганы тоякка кадаклый башлады.* З.Зәйнуллин

**КАДАКЛЫ** *с.* Бер кадакка (II) тигез булган, кадак авырлыгындагы. *Кадаклы чәй кәгазен ачу Сәмигулла абыйның дөньяда иң яратып эшли торган эшләреннән берсе иде.* Ф.Әмирхан. *Абыстай менә шул эре чикләвекне бөкләп салган тастымал өстендә ике кадаклы гернең чокыры белән бәреп вата да, төшен чүпләп, күрәгә һәм йөзем белән кушып, кыстый-кыстый малаена ашата...* Ә.Еники

**КАДА́К СУЫРГЫЧ** *и. махс.* Башында кадак эшләпәсен эләктереп тоту өчен киртләче булган, каерып алырга уңайлы итеп бөгелгән тимер. *Ломнар, кадак суыргычлар тотканнар, ирләр, хатыннар арбаларын тартып шунда таба җыелалар.* Н.Хәсәнов

**КАДАЛДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **кадалу**

2) *күч. сөйл.* Үтерү, юк итү

**Кадалдырып бетерү** Барысын да кадалдыру

**КАДАЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **кадау**. *Стенага бик күп кызыл әләмчекләр кадалган зур бер карта --- эленгән.* Г.Бәширов

2) Тамак төбенә, үңәчкә, тәнгә чәнчеп керү (сөяк, кылчык, шырпы һ.б.ш.). *Ә үзләре сөяккә кадалган төсле төелеп калганнар, ләм-мим бер сүз әйтә алмаганнар.* Ш.Камал. *Яңа урылган арыш камылы аның яланаягына кадала.* Г.Гобәй. *Очраклы рәвештә исән калган икән, егылып китмәсә, пычак нәкъ күкрәгенә килеп кадаласы булган.* З.Фәтхетдинов

3) Кан суыру өчен борыны белән тирене тишеп тәнгә үтеп керү, тәнгә ябышу (бөҗәкләр). *Әйтерсең лә шунда урман бете кадалган да, шуны йолкып чыгарырга тырыша.* Ә.Гаффар

4) *күч.* Көчле агым белән килеп бәрелүдән кадаган кебек тәэсир калу. *Җиле биткә инә очы булып кадала.* Г.Гобәй

5) *күч.* Күңелгә авыр тәэсир итү, йөрәккә, күңелгә, бәгырьгә үтеп керү, тию. *Кабатлап әйтәм, ул моны шундый салкын итеп, чит итеп, үтерерлек итеп әйтте, һәр сүзе йөрәгемә әрнүле ук булып кадалды.* А.Шамов. *Соңгы сүз Тоякка пычак кебек кадалды.* С.Салахов. *Бу тавыш Фаязның йөрәгенә килеп кадалды, аңа ярсу гына өстәде.* С.Шәмси

6) *күч.* Төбәп, текәлеп, тишеп карау. *Атаның күзе үткенләнеп улына кадалды, тавышы кискенләнде.* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Баштүбән килеп төшү, башы белән түбән карап егылу. *Егет еракка ук китеп, ду-фәрманга йөгереп, куллары белән бар куәтенә этенеп, кузланың өстеннән ялт итеп үтте бу юлы һәм коры җиргә йөзе белән барып кадалды.* Т.Галиуллин. *Самолёттан төтен чыга башлады, аннары ул агач башларын сындыра-сындыра бераз очты да җиргә кадалды.* Г.Әпсәләмов // Баш белән түбәнгә карап суга чуму. *Күлнең уртасына барып җиткәч, ул, кинәт башы белән суга кадалып, күл өстеннән юк булды: аяк табаннары гына ялт итеп күренеп калды.* И.Гази. *Чыннан да, тавык бәпкәләрне су буена илтми, рәхәтләнеп йөздерми, чумып уйнарга, башлары белән суга кадалып, койрыкларын текә күтәреп торырга өйрәтми.* Ә.Еники. *Күл эченәрәк кертеп ясалган биек вышкадан суга сикерәләр, түбән сузылган куллары белән яшькелт Кабан өстенә барып кадалалар.* Н.Фәттах

8) *күч.* Комсызланып ташлану, ябырылу. *Ачыгып беткән атларым арышка кадалалар.* Ш.Әхмәдиев

9) *күч.* Зур көч кую, бөтен көчкә тырышу. *[Сәхия] Тегү машинасына кадалып, шалтор-шолтыр нидер тегеп утыручы апасын күргәч катты да калды.* Ф.Яруллин. *Крестьяннар үзләренең бер кисәк җирләренә кадалып ничек тамакларын туйдырырга белмиләр.* Урал

10) *күч.* Ни, нәрсә белән булса да мәшгуль булу, озаклап, тырышып шөгыльләнү. *Гасыйм --- күбрәк вакытын китапка кадалып уздыра иде.* Н.Фәттах

11) *күч.* Каныгу, көн күрсәтмәү, каты шелтәләү. *Монда рәт юк, таралды ла, Совет безгә кадалды ла, «Вольный сәүдә»не иттерми, ябып куя караңгыга.* Г.Камал. *Сүзнең ахырында тагын Паларусовка кадала.* Г.Ибраһимов

12) *күч. гади. с.* Үлү, юкка чыгу. *Үзе башлап кабызган ут эчендә мәңгегә кадалды да калды.* Г.Камал. *Валлаһи, син чәнчелеп кит, тончыгып үл, бет, кадал. Шунда да һичкем дә күрмәс, валлаһи, бер эт кадәр.* Ш.Бабич. *Күп ерткычлыклар эшләдең, бәдбәхет, кадал!* А.Алиш

**2. кадалып** *рәв. мәгъ.* 1) Көчле ташкын булып, ургылып. *Ялангач калган тәне кüшегергә дә өлгермәде, кадалып аккан Агыйдел суына күмелде.* М.Әмир

2) Башын да күтәрмичә, бернәрсәгә дә игътибар бирмичә. *Кайчан карама, алманча өйрәнә, --- әле университет дәреслекләренә кадалып утыра.* Т.Әйди

3) Зур тизлек белән (йөгерү, чабу)

4) Бик нык текәлеп, төбәлеп, җентекләп (карау)

◊ **Кадалып кату** Дөньясын онытып, һич кымшанмыйча төбәлеп карау; бөтен дикъкатен бирү. *Разия, үзенең франт егетләрен онытып, Вәли башкортның йөзенә кадалып катты.* Г.Ибраһимов. **Кадалып китсен** 1) «Бетсен, юкка чыксын, үлсен» мәгънәсендә каргау, тиргәү сүзе. *Бетсен, кадалсын нифакъ.* Г.Тукай. --- *теләсәләр кадалып китсеннәр иде, безнең анда эшебез юк* ---. Ш.Мөхәммәдев. *Муллалыгыңны ташламагаең, ташла, кадалып кит!* А.Шамов; 2) «Мөһим түгел, игътибарга алмыйм» мәгънәсендә. *Хәер, буесыны кадалып китсен иде әле, ә минә көлүенең бер рәте-чираты юк инде*... В.Нуруллин. *Ярый, малае да, скрипкасы да кадалып китсеннәр,* --- *малайны Себергә озатылды дип билге куям.* К.Латыйп. **Кадалып киткере** *к.* **кадалып китсен** (*1 мәгъ.*). **Кадалыплар китим** Сүзенең дөреслеген исбат итү өчен, кат-кат каргану сүзе. *Шул кеше сезне алдамаса, кадалыплар китим.* К.Тимбикова

**Кадала бару** Рәттән һәрберсенә берәм-берәм кадалу. *Һәр мактау сүзе Гыйсметдиннең бәгыренә хәнҗәр булып кадала бара, һәм ул беркөнне Айтуланы аулакта очратып көчли.* Р.Батулла. *Һәрбер исән-сау кайтып төшкән фронтовик аның күзенә кылчык булып кадала барды.* Безнең гәҗит

**Кадала башлау** Кадалырга тотыну. *Бәс, бер залим үзен үзеннән гыйлемдә югары бер кешенең алдында күрде исә, үзенең кимчелеген сизенә, йөрәгенә хәнҗәрләр кадала башлыйдыр.* Г.Бубый. *Бераздан алар да, бер-бер артлы яныл-шартлап, борыннары белән җиргә кадала башлады.* З.Мәхмүди

**Кадала төшү** Тагы да ныграк кадалу. *Моннан соң Сабайкин тагын да кадала төште: тәрбия белән чынлап шөгыльләнмисез*... З.Фәйзуллин

**Кадалып бетү** Бик күп булып, бөтен җиренә тоташ кадалу. *Аяклары тырналып, кадалып бетте, йөз-бите, ботакчатакка сыдырылып, тоташ бер әрнешкә әверелде.* Г.Гыйльманов

**Кадалып калу** Кинәт кадалу, кадалган хәлдә торышын саклау

**Кадалып тору** Әле, хәзер кадалган булу. *Тәне мең урында мең энә кадалып торган кебек сызласа да, Булат хәллерәк уң кулы белән этенеп, торып басты.* Г.Гыйльманов

**Кадалып төшү** Ялгыш ычкынып китеп егылу, югарыдан төшеп кадалу. *Миус кыяларыннан аска кадалып төшәргәме?* И.Гази. *Атсалар, пуля тиеп, җиргә кош сымак кадалып төшәсең.* К.Латыйп

**КАДÁУ** I *ф.* **1.** 1) Очлы, үткен очы белән чәнчү, төртеп тишү. *Атакага барганда, ертылганчы «ура» кычкырдык, штык белән кададык.* И.Гази. *Шул рәвешчә часовойдан читкә алып китәргә дә, хәнҗәр белән йөрәгенә кадап, эшне бетереп ташларга уйлады.* Г.Гобәй. *Түзмәде Әминә, берьюлы берничә укол кадап, коралларын җыештыра башлагач, кыенсынып кына сорап куйды: – Ә нигә ул төне буе утырды?* Г.Гыйльманов

2) Угы, чәнечкесе белән чәнчеп авырттыру, тәнне тишеп кан эчү, батыру (бөҗәкләр, үсемлекләр һ.б.). *Ашыгып-ашыгып кан эчәр якны карый, күз төбенә тиз генә борнын кадый.* Ш.Бабич

3) Очлы башы белән өслеккә батыру, чәнчеп кую, көч белән өслек эченә батырып утырту. *Бераз баргач, староста теге сөлгеле колганы юл кырыена китереп кадады.* М.Гали. *Шул арада мин, алдан сөйләшенү буенча, тәрәзәсенең түбәнге өлгесенә, рамга үземнең ак саплы пәкемне китереп кададым.* Ф.Хөсни. *Чаңгыларын салып, кар күмеп китмәсен өчен, эскерт буендагы көрткә кадады да эскертнең җилгә аркан ягына чыкты.* В.Нуруллин

4) Терәп кую. *Тик хәзер мәтәлчекне генә булдыра алмады, башын җиргә кадап, аякларын күтәрә башлауга, яны белән лап итеп авып төште.* З.Фәйзуллин

5) Булавка, энә белән эләктереп яки чәнчеп беркетеп кую. *Әгәр бу чәчләрегезгә кадаган матур калфак булмаса, сезне мөселман кызы дип танып та булмас иде.* Ф.Әмирхан. *Эшсез кешеләрнең хаклары юк сезне түшләренә кадарга.* М.Гафури. *Кайберләренең күкрәгендә кызыл бантиклары бар, ләкин бит аны хәзер теләсә кем кадый ала шикелле.* Ә.Еники

6) Эләктереп, беркетеп элеп кую. *Мин авылдан киткәндә диварга кадап калдырган Ленин рәсемен әнкәй җиде ел саклаган.* Һ.Такташ

7) *күч.* Берәр әгъзада чәнечкән кебек авырту тою

8) *күч.* Кисәк каты итеп йодрык белән бәрү, сугу

9) *күч.* «Төбәп, текәлеп карау» мәгънәсендә. *Ник елмайдың утлы карашыңны йөрәгемә кадап, акыллым?* М.Җәлил

10) *күч. кимс.* Тиешсезгә, файдасызга утыртып, бастырып кую

11) *күч.* Койрыкларын югары күтәргән булу (терлек, хайван тур.). *Чиләдә койрыкларын кадап чабалар.* Т.Гыйззәт

**2. кадап** *рәв. мәгъ.* Үзәккә үтәрлек итеп, хәтер сакламыйча. *Малай, йөгерүеннән туктамыйча гына, тагын да усалрак кадап әйтте.* К.Нәҗми

◊ **Кадап куйгандай** Селкенмичә, кымшанмыйча тик тору турында. **Кадап куйган казык кебек** *к.* **кадап куйгандай**. **Кадап куйган казыктай** *к.* **кадап куйгандай**

**Кадап алу** Уйламастан, кинәт кадау. *Ул бары тик, төсен бозып, тешләрен шыгырдатып бик каты кизәнә генә, сукмый, ә инде кайчак бик ачуы килгән минутларда каты һәм тупас итеп кадап ала.* А.Шамов. *Ә малайлар --- шунда йөрәккә шырпы да кадап алалар: – Нәгыйм абыйлар кибәннәрен очлап килә, безнеке яртысына да җитмәгән.* М.Әмирханов

**Кадап бетерү** Бик күп урыннан кадау; барысын да, берсен дә калдырмыйча кадау

**Кадап җибәрү** Кинәт кадау, көтмәгәндә кадау. *Ул [Чалдунов], кунычыннан пычагын чыгарып, торып килгән Фёдорның култык астына кадап җибәрде.* Ш.Усманов. *Җамали гөрселдәп җиргә ауды, ләкин шунда ук, Җамалиның отделениесендәге бер солдат йөгереп килеп, немецның биленә кадап җибәрде.* М.Гали

**Кадап кую** Беркетү, кузгалмаслык итеп кадау. *Өстәлне җыеп бетергәч, Хәсән стенага рәсемнәр кадап куярга керešте.* Ф.Әмирхан. *Зонтигын йөзенә күләгә төшәрлек итеп җиргә кадап куйды.* Т.Әйди. *[Төхфәт] Балтасын идәнгә кадап куйды, ике кулы белән бөренә таянды.* Э.Касыймов

**Кадап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, бер-бер артлы кадау. *Бөтен тәненә мең төрле энә кадап чыкканнар диярсең.* Г.Гыйльманов

**Кадый бару** Эзлекле рәвештә, берсе артыннан икенчесен кадау

**Кадый башлау** Кадарга тотыну. *Әгәр дә мин әйткәнне белсәләр, минем күземне ачырмаслар, бөтен зәхмәт укларын миңа кадый башларлар.* Г.Камал. *Бүгеннән башлап, шәфкать туташы сезгә магнезия белән витамин кадый башлар.* З.Мәхмүди

**Кадый язу** *сөйл.* Чак кына кадамый калу. *Күптән түгел --- Мөхетдиновка пычак кадый язганнар.* Кәеф ничек?

**КАДА́У** II *с.* Теле белән кадап сөйләшә торган, әче телле. *Кадау кеше*

**КАДАУЛЫ** *с.* Кимсетүле, мыскыл итә торган. *Мин инде, билгеле, Хохловага кадаулы сүзләр әзерләми идем.* К.Басыйров

**КАДАСТР** *и. фр.* 1) Нинди дә булса объектларны өзлексез күзәтү яки тикшерү юлы белән рәсми рәвештә төзелә торган системалы мәгълүмат җыелмасы. *Җир кадастры*

2) *икът.* Җир һ.б.ш. табигый байлыкларның сыйфаты, бәясе турында мәгълүмат җыелмасы

**КАДӘР** *бәйл. гар.* 1) Юнәлеш килешендәге пространство төшенчәсен белдергән сүз белән килеп, шул араның, хәрәкәтнең икенче бер чик ноктасын билгеләү өчен кулланыла; чаклы, тикле. *Шул озын, авыр ПТРны бик яратып китүен, аны Германия җиренә кадәр җилкәсендә күтәреп илтүен сөйләп алды.* Ә.Еники

2) Юнәлеш килешендәге вакытны белдергән сүз белән килеп, аның вакыт ягыннан ахыргы чиген билгеләү өчен кулланыла. *Уку башланганга кадәр коллектив эчендә тәмам үзләшеп, туганлашып беттем.* М.Әмир. *Яктырганга кадәр яңадан ун сәгать көтәргә кирәк.* М.Гали

3) Юнәлеш килешендәге сүз белән килеп, шуннан алда булган, шуннан элгәре эш-хәрәкәт, вакыйганы белдерә. *Моңа кадәр тик кенә, сабыр гына ашап утырган Миңнур карт карчыгына җавап бирергә уйлады.* А.Шамов

4) Юнәлеш килешендәге сүз белән килеп, бөтен ваклыклары белән, тулысынча эченә алуны белдерә; бөтенләе белән, тулысынча, барысы да. *Ак өйнең стеналарына, түшәмнәренә кадәр юылып, миче агартылып, бик матурлап җыелган, түр як сәкесенә зур табын әзерләп куелган.* М.Гали. *Куркак куяннан алып олпат аюга, явыз бүрегә кадәр яши урманда.* Г.Гыйльманов

5) Күләм, микъдар, вакыт ягыннан чагыштыру, тиңләштерүне билгеләү өчен кулланыла. *Миңа күз ачып күз йомган кадәр генә тоелса да, байтак вакыт үткән иде.* Г.Ибраһимов. *Нургали мәктәпнең рәшәткә белән әйләндереп алган ялан кадәр ихатасына килеп кергәндә, бүрәнәдән салган ике катлы зур бина өлкән тынлык эчендә утыра иде.* Ә.Еники. *Урындык авып калды, аның тез өстендә ясмык кадәр генә кан күренде.* А.Гыйләҗев

6) Нинди дә булса үзлек-үзенчәлекнең, сыйфатларның югары дәрәҗәгә җитүен белдерү өчен кулланыла. *Гыйләҗи Бикмулланың бу кадәр ваемсыз сөйләшүенә тәмам гаҗәпләнеп, башын кат-кат селкеп куйды.* Ә.Еники. *Тормышта мондый хәлләр була алмый, чынлыкта бу кадәр явызлык булмый.* Г.Гыйльманов

7) Кабатланган исемнәр арасында килеп, шул әйбернең иң мөһиме булуын басым ясап күрсәтү өчен кулланыла. *Усал телле булулары белән тирә-юнь йортларында дан алган хатыннар, кулларына туп кадәр туп дәлил булып кергәч, бөтенләй тугарылганнар.* А.Гыйләҗев

8) *-ган* кушымчасын алган фигыль белән килеп, мөмкинлекнең чиген белдерү өчен кулланыла. *Хәтта Мәликә дә көткән кадәр усал булып чыкмады.* А.Шамов. --- *Хәлим исә булдыра алган кадәр кызга булышырга тырыша иде.* Г.Гыйльманов

**КАДӘРГЕ** *бәйл.* Эш-хәлнең, вакыйганың үзе бәйләп килгән сүздә күрсәтелгән вакыттан алда булуын белдерү өчен кулланыла. *Шушы ун айны окопларда уздырганнан соң үткән гомергә совет офицеры һәм укытучы күзе белән карасам, сугышка кадәрге эшебез дә, хәзергесе дә мине канәгатьләндерми башлый.* Г.Бәширов

**КАДӘРЕ ХӘЛ** *рәв. гар.* Хәл кадәренчә, көч җиткәнчә, булдыра алганча. *Шигырь дөрест – нәсыйхәте камил булса, иясе кадәре хәл галим булса…* М.Акмулла

**КАДӘРЛЕ** *бәйл. к.* **кадәр**. *Мансуровның бу соравы сугышка кадәрле вакытларны, төрле яңалыклар белән ялкынланып, үзара сүз көрәштереп яшәгән укытучы иптәшләрен хәтерләтте.* Г.Бәширов. *Мин бит барлык иптәшләрне дә сине якын иткән кадәрле якын итә алмыйм.* Г.Ахунов

**КАДӘХ** *и. гар. иск.* Шәраб эчә торган савыт; бокал. *Күтәргәчтен кадәх бернечә тапкыр, Оят качты, күңелләр булды шат, хөр.* Котб. *Дөрес, ул кичә Оренбург казакларының ерткычлыкларына тирән нәфрәт белдереп кадәх күтәрде.* К.Тинчурин. *Рәис инде тынды, һәм мәҗлескә җыелган бар халык берьюлы кадәхләрен күтәрде, бөтенесе берьюлы тын гына эчеп бетерделәр.* С.Җәләл

**КАДЕ́НЦИЯ** *и. ит.* 1) Музыкаль әсәрнең азагында аңа бербөтенлек, тәмамланганлык бирә торган гармоник әйләнмә

2) Инструменталь музыкаль әсәрнең башкаручы тарафыннан виртуоз уйнала торган яки композитор тарафыннан виртуоз итеп язылган соңгы өлеше

**КАДЕР** *и. гар.* 1) Хөрмәт, ихтирам. *Ал да гөл, кадер дә түр, оҗмах та нур булыр.* Г.Ибраһимов. *Җаек татарларын бу бик сәерсендерде, ягъни ничек инде бу мөселман кешесе урыс мәчетенә бу хәтле кадер һәм хөрмәт күрсәтә.* Ә.Фәйзи

2) Югары бәя, кыйммәт. *Гүя, каза вә кадернең әзәлдә язып куйган бик зур бер эше хәл кылына, яисә бу кавышуда шундый бер нәтиҗә чыга кебек сизенделәр.* Г.Ибраһимов. *Бичара ярлырак*

*кешенең кызларының сарык кадәре дә кадере юк.* М.Гафури

3) Абруй, авторитет, дәрәҗә, тоткан урын. *Пакь кием кадер арттырыр.* Мәкаль. *Ясаган иям тел бирде, акыл бирде, мәгәр малың булмагач, бу дөньяда кадерең юк икән!* Г.Ибраһимов. *Якыннанрак белгән саен, бу кешенең минем каршымда кадере арта һәм, дөресен әйтәм, кыланышлары да ягымлылана барды.* М.Әмир. *Кадер, бәя, чын хак кайчак иясеннән, һай, ерак.* Р.Фәйзуллин

◊ **Кадергә кия торган** Кеше арасына чыкканда, яхшыга кия торган (кием, өс-баш). *Кадергә генә кия торган җәйге чалбарымны арттырырга булдым.* Ф.Хөсни. **Кадерен белү** 1) Тиешле бәя бирү, олылау. *Атна саен ишан китереп булмас, килгәндә кадерен белеп, фатихасын алып калырга кирәк.* К.Тинчурин. *Яшьләргә гыйбрәт булыр, хәзергенең кадерен яхшырак белерләр, сөйлә булмаса, күрше.* А.Әхмәт; 2) Сак тоту, әрәм-шәрәм итмәү. *Бүгенгесе көнне бер пот орлык өчен аһ-ваһ килеп йөргән чагыбызда булган орлыкның кадерен белик.* Г.Бәширов. *Һәр минутның кадерен беләм мин.* Ә.Ерикәй; 3) Кыйммәтен, кирәклеген аңлау. *Дөнья хәлен кем татыса, чишмә кадерен шул белә.* Ә.Ерикәй; 4) Булганына риза, канәгать булу. *Ачыны алдан татыганда гына төченең кадерен беләсең.* А.Гыйләҗев. **Кадерен җибәрү** Тиешенчә бәя бирә алмау, олылыкламау. *Иң матур вакытларыбызның юк-бар сүз белән кадерен җибәрдек.* М.Мәһдиев. **Кадер китәрешү** Үзара хөрмәт, илтифат, олылау, бер-береңне санлау белән исәпләшмәү, араны бозу. *Ягез, егетләр, кадер китәрешмик, талаш бетсен, әйбәт кешеләр булып килдек, әйбәт кешеләр булып таралыйк.* Ш.Камал. **Кадер китү (калмау, калдырмау)** 1) Кыйммәте бетү, сыйфаты начарлану; 2) Абруе, дәрәҗәсе бетү. *Син буш бугаз дип, җыелышта эт кадерен калдырмаган, диләр.* Г.Ибраһимов. *Хатынкызның кадере китте.* Ф.Яхин

**КАДЕ́Р КИЧӘСЕ** *и. дини* «Язмышны билгеләү төне» – рамазан аеның соңгы декадасына туры килә торган так төн (еш кына егерме җиденче төнгә туры килә); догалар укып, изге теләкләр теләп үткәрелә

**КАДЕ́Р КИЧЕ** *и. дини к.* **Кадер кичәсе**. *Бу Кадер кич – елда бер кич, барча кичләр изгесе.* Г.Тукай

**КАДЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Иркәләнү; багулы, тәрбияле булу

2) *к.* **кадерлеләнү**

3) Саклык белән тотылу, сак файдаланылу

**Кадерләнә бару** Аз-азлап, акрынлап кадере арту, кадерлерәк булу

**Кадерләнә төшү** Тагы да кадерлерәккә әйләнү

**Кадерләнеп калу** Кадерләнергә өлгерү

**КАДЕРЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Олылыклау, хөрмәт итү, ихтирам күрсәтү. *Тимерхан туган, син монда иртәгәчә кал: мәрхүм Камәр иптәшне кадерләп, олылап күмәрсез.* Г.Ибраһимов. *Әнине кадерли алмадык.* А.Шамов. *Аның --- җитдиҗылы карашына әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде.* Ә.Еники

2) Иркәләү, яратып тәрбия итү, карап үстерү. --- *атасы һәрвакыт «ялгызым» дип, «иркәм» дип кадерли ---.* Г.Ибраһимов. *Бар кешегә кадерле сеңлемне мин генә кадерләмәсәм, гаеп итәрләр.* Ф.Әмирхан

3) Зур көч, хезмәт куеп үстерү. *Киң кырларны буйлап, шаулый бодай уйнап – Без үстердек аны кадерләп.* Ш.Маннур. *Антанас карт түтәл булып торган кабер өстенә чәчәкләр утыртты, аны җәй буе бик тырышып, кадерләп, бөтен күңелен биреп карады.* А.Шамов

4) Тиешенчә тәрбияләү, карау, тиешле шартлар булдыру. *Үзеңне бик аз гына киендерсәң, бераз гына кадерләсәң, сине күргәч, ирләр егылып --- төшәрләр, диде.* Г.Ибраһимов

**2. кадерләп** *рәв. мәгъ.* Сак кына, зур саклык белән. *Китапныябып күкрәгенә китерә дә кадерләп кенә өстәлгә куя.* М.Фәйзи. *Аның сандык төбендә әллә ничә кат чүпрәккә төреп, кадерләп кенә саклый торган үткен мирас пәкесен һәркем белә иде.* Ә.Фәйзи

**КАДЕРЛЕ** *с.* **1.** 1) Ихтирамлы, хөрмәтле, хөрмәткә, ихтирамга лаек (кеше). *Кадерле әткәй, сез ялгыш аңладыгыз ул сүзне.* Ш.Камал. *Сез – кадерле яшь кызлар, сез уңган, сез чибәр, ил күгендә йолдызлар.* Н.Исәнбәт. *Кеше үз кадерен үзе белсә генә кадерле.* Ф.Яхин

2) Көтелгән, хөрмәт белән каршы алынган (кунак). *Без инде мондагы халыкларның кадерле кунакларны башта трубка белән сыйлаганнарын белә идек.* А.Шамов. *Язын бакчага кайталар кошлар, безнең кадерле канатлы дуслар.* М.Җәлил

3) Иркә, йөрәккә якын, сөекле, яраткан. *Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!* Г.Тукай. *Һаҗәр зур байның кадерле яшь бикәсе булачак, зур сарайларда ефәк, алтын эчендә йөзәчәк.* Г.Ибраһимова // Кадер-хөрмәт эчендә яшәгән. *Ата-анасының кадерле баласы бит, ялынып сорагач, каршы килмәдек.* Т.Гыйззәт

4) Бик кирәкле, әһәмиятле, кыйммәтле, мөһим (әйбер). *Моның белән озак сөйләшеп, мин кадерле вакытымны бушка уздырмыйм.* А.Алиш. *Тоз – хәзер иң кадерле нигъмәт!* Ә.Еники

5) *күч. шигъ.* Җылы, изге саналган, күңелдә сакланган, онытылмаслык. *Бу чирек гасырлык гомер эчендә минем берничә генә кадерле минутларым булды.* Ф.Әмирхан. *Минем үзем өчен генә бик әһәмиятле, бик кадерле кичерешләрем бар.* Ә.Еники. *Тормыш кебек кадерле нәрсәсен калдыргандай булды [Хәйруш] кардонда.* М.Хәсәнов

6) Иң түрдәге, иң дәрәҗәле, иң яхшы саналган (урын). *Идәнгә тагы бер кат ак киез, аның өстенә палас җәелде, түрдәге кадерле урынга озын кызгылт йонлы куй тиресе җәелде.* Г.Ибраһимов

**2. кадерлем** *и. мәгъ. тарт. форм.* Яратып, иркәләп, сөекле кешегә эндәшү сүзе. *Минем эшем бар бит, кадерлем.* Р.Ишморат. *Үзең үлсәң үл, кадерлем, ләкин даның үлмәсен.* Ә.Ерикәй

**3.** *рәв. мәгъ.* Яхшы тәрбиядә, багулы. *Гөлчирә кадерле яшәде Сабир кулында.* М.Мәһдиев

**КАДЕРЛЕЛӘНҮ** *ф.* Кадерлегә әйләнү, әһәмияте, мөһимлеге үсү; ихтыяҗ арту; тансык була бару

**Кадерлеләнә бару** Вакыт узган саен кадере арту, кадерлерәк булу

**Кадерлеләнеп китү** Ниндидер вакыттан, сәбәптән соң кадерлегә әйләнү

**КАДЕРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Кадере булмаган, кадер-хөрмәт күрмәгән. *Бу адымың ясап, кадерләнә башлаган тормышың кадерсез итмә.* М.Хәбибуллин. *Мене үлгән инде, бер кадерсез зат дөнья мәшәкатеннән котылган, урыны оҗмахта булсын.* Татарстан яшьләре

2) Файдасы тими торган, бернигә яраксыз, кирәксез. *Бу вакыт атамның ата-анасы (бабай вә әби) күптән вафат булып, авылда башка туганнарым булмаганлыктан, мин бу карчык ханәсендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән ---.* Г.Тукай. *Аллаһы Тәгалә юмарттыр, юмартлыкны һәм бөек гүзәл холыкларны сөя, түбән һәм кадерсез эшләрне яратмый.* Р.Фәхретдин

3) *куч.* Хурлыклы, оялырдай; яман

4) *сөйл.* Әдәпсез, тәрбиясез, тәртипсез

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кадер-хөрмәт күрмичә. *Революция тәмам җиңгәннән соң, Вәли бай да, иленә кайтып, кадерсез, хөрмәтсез яши башлый.* Г.Нигъмәти. *Кадерсезләмә башымны, мин кадерсез үсмәдем.* Ә.Ерикәй

2) Тәртипсезләнеп, әдәпсезлек күрсәтеп

**КАДЕРСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Кадерсезгә әйләнү, әһәмияте, зарурияте бетү, кирәге калмау

2) Бәясе төшү, бәясе югалу

3) Тәртипсезләнү, әдәпсезләнү, затсызлану

**Кадерсезләнеп бетү** Тәмам, бик нык кадерсезләнү

**КАДЕРСЕЗЛӘ́Ү** *ф.* 1) Хөрмәт итмәү, ихтирам итмәү. *Җитмәсә егетләрнең кыланулары, һушын алгандай, назлы җанын кадерсезли.* Ф.Яхин

2) Бәясен төшерү, кадерен җибәрү

3) Сак файдаланмау, сакламау, кадерләп тотмау. *– Менә мин дә иске чалбардан чыктым. – Дөрес эшләгәнсең. Нигә әйберне кадерсезләргә?* Ф.Яруллин

**Кадерсезләп бетерү** Тәмам, бик нык кадерсезләү

**Кадерсезләп тору** Һәрвакыт, гел кадерсезләү

**Кадерсезли башлау** Кадерсезләү билгеләре күренү. *Үзеңне кадерсезли башлаган көнне үк барысына да нокта куярга кирәк булган.* Ватаным Татарстан

**КАДЕРСЕЗЛЕК** *и.* 1) Кадере булмау, әһәмияте, зарурияте булмау; кирәксезлек // Кадерләп карап, сак тотмау, игътибарсызлык. *Без бу кадерсезлекне тәмам канунлаштырып та бетердек бугай инде.* К.Тимбикова

2) Начар, түбән мөнәсәбәт, кимсетүләр

3) Әдәпсезлек, тәрбиясезлек

**КАДЕР-ХӨРМӘТ** *җый. и.* 1) Һәртөрле хөрмәт, олылыклау, ихтирам. *Сезнең бу кадер-хөрмәтегезне фронтта булсын, әдәбиятта булсын, чын эш белән акларга сүз бирәм.* М.Җәлил. *[Сәхәп энисенең] Нәкыя исемле игезәк сыңарын да шундый ук кадер-хөрмәткә күмде.* Г.Гыйльманов

2) Абруй, авторитет, дәрәҗә

**КАДЕР-ШӘФКАТЬ** *җый. и.* Һәртөрле хөрмәт, олылыклау белән эшләнгән ярдәм. *Сәхәп бөтен вакытын анасы янында уздырды. Аңа һәртөрле кадер-шәфкать күрсәтте, аны дәвалады, ашатты.* Г.Гыйльманов

**КАДЕТ** I *и. фр. тар.* Кадет корпусында тәрбияләнүче. *Сезгә ектырсам, кадет булып та йөрмим мин.* Р.Мөхәммәдиев

**КАДЕТ** II *и. тар. сәяси* Патша Россиясендә конституцион-демократик партия әгъзасы. *Ул программа татар буржуа хәрәкәтен бер җиргә оештыру һәм, русның кадетлар партиясе белән блокка кереп, --- Дума мөнбәрләренә хәтле менеп, үз теләкләрен әйтү һәм үткәрергә тырышудан гыйбарәт.* Г.Нигъмәти

**КАДЕ́Т КОРПУСЫ** *и. тар.* Патша Россиясендә дворян балаларын офицерлыкка әзерли торган ябык урта хәрби уку йорты

**КАДЕ́Т МӘКТӘБЕ** *и.* Гомуми фәннәр белән берләттән хәрби предметлар да укытыла торган мәктәп. *Кайларда гына булмаган да, ниләр генә күрмәгән бу малай-кызлар. Белмәгән нәрсәләре юк, укыган җирләре дә кадет мәктәбе я гимназия генә.* Р.Мөхәммәдиев

**КА́ДИМ** *и. гар. иск. кит.* Аяк атлаучы, баручы. *Тәрәкъкый вә тәгали юлларына улалым кадим.* Г.Тукай. *Бөеклеккә барып җитәр фәкать кадим.* А.Тимергалин

**КАДИ́М** *с. гар. иск. кит.* **1.** 1) Борынгы, әллә кайчангы, иске. *Кадим чорлар кадим мәхәббәте Ни дисәң дә күркәм, мәһабәт...* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Иске карашлы, консерватор. *Монда байбәтчәнең хәятын начар якка борып йибәргән сәбәпләрнең мөһимрәге аның Сәхилә карчык фикере белән җәдит мәктәбеннән алынып, ниндидер кадим, бохара бер мәхтүмгә бирелүе чыга.* Г.Исхакый

3) Дини схоластикага нигезләнгән. *Аны [Баязитны] Каргалының биш йөз шәкертле, кара, кадим, фанатик мәдрәсәсенә салалар.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Борынгы заман, иске заман, үткән вакыт. *Кадимнән бу җирләрдә [Себердә] ханнар булган, Төрле җенес халыклары монда тулган.* М.Гафури. *Әллә кайчангы, кадимдәге хәлләр: югалган кер баулары, онытылып беткән сыңар галошлар, сөткә төшкән тычканнар, ниндидер велосипед тәгәрмәчләре дә телгә алына.* А.Гыйләҗев

2) Борынгы, иске, дини караш, искелек. *Болардан башка тагы шулай искелекне, кадимне, хөкүмәтне яклаучы булып танылган зур, атаклы берничә ишан, берничә ахун боларның планына кергән.* Г.Ибраһимов. *Мөхәррирнең бу өченче дәверендәге әсәрләрендә «Инкыйраз»гача чыкканнарындагы кебек милли тәрәкъкыйпәрвәрлек, җәдит һәм кадим көрәше дә юк.* Г. Гобәйдуллин

**КАДИМГЕ** *с. иск. к.* **кадим 1.** (*1 мәгъ.*). *Кадимге дошман ил булмас.* Мәкаль. *Дәүләкәнем – кадимге Дәүләкән – бер дә үзгәрмәгән диярлек, шул ук йортлар, тик алар шактый искергән, тузганнар иде.* Ә.Еники

**КАДИМГЕ́ДӘЙ** *рәв. к.* **кадимгечә**

**КАДИМГЕ́ЧӘ** *рәв.* Искечә, элеккечә, борынгыча. *Бөтенесе дә кадимгечә һәм бөтенесе дә яңа.* А.Хәлим

**КАДИМИ** *с. гар. иск.* 1) Борынгы, әллә кайчангы, электәге. *Оча торган тәлинкәләр бик борынгыдан билгеле булганнар. Кадими китапларда шуны күрү очраклары теркәлгән.* А.Гыйләҗев. *Диңгез корабы кадими татар авылларына охшаш, анда кушаматсыз кеше булмый.* М.Юныс

2) *к.* **кадимче**. *Үз чорының җимеше буларак, кадими мәдрәсә татар милләте өчен бик күп зыялылар, галимнәр, әдипләр җитештергән, халыкны аң-белемле иткән.* Р.Әмирхан. *--- хатын-кызларның тигез хокуклылыгын яклап әйткән сүзләре өчен кадими дин әһелләреннән эләкте үзенә.* Р.Мөхәммәдиев

**КАДИМИЯ** *и. гар. иск.* Иҗтимагый тормышны, аның социаль институтларын үзгәртмәү яклы, традиционализмга нигезләнгән тәгълимат

**КАДИМЛЕК** *и.* Кадим булу. *Әгәр кадимлек мәсләге хак булса, дөньяма зарар килмәс иде.* Г.Тукай. *Күл буе мәдрәсәсе ул елларда кадимлеге белән аерылып тора иде.* Р.Мөхәммәдиев

**КАДИ́МЧӘ** *рәв. к.* **кадимгечә**. *Кадимчә уку вакытыннан тагын кайбер нәрсәләр истә калган икән әле.* Г.Бәширов

**КАДИМЧЕ** *с. иск.* **1.** Иске карашлы, реакцион. *Кадимче шәкертләр*

**2.** *и. мәгъ.* Иске карашлы кеше, реакционер

**КАДИМЧЕЛЕК** *и.* XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар җәмгыятендәге консерватив хәрәкәт. *Каләм ияләрен дә кадимчелеккә каршы көрәштә кыю булырга чакыра.* М.Гайнуллин

**КАДИР** *с. гар.* **1.** Һәрнәрсәгә көче җитә торган, көче чикләнмәгән. *Яраббе Алла, кадир мәүла, ниләр яздың микән башыма.* Т.Гыйззәт

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия зат. *Күрең кадир кодрәтен, эшли, йөгерә көн дә дөн.* Г.Кандалый

**КА́ДМИЙ** *и. гр. хим.* 1) Цинк рудасын эшкәрткәндә аерылып чыга торган көмешсыман ак йомшак металл

2) Төрле төсмерле ясалма сары буяу

**КАДР** I *и. фр.* 1) Иҗтимагый эшчәнлекнең теләсә нинди тармагындагы хезмәткәрләрнең әзерлекле, квалификацияле төп составы. *Шуны әйтергә кирәк, хореографик училищены тәмам итүче безнең яшь кадрлар эшкә булдыклылыклары, сәләтләре һәм тырышлыклары белән мактаулы урын тоталар.* М.Җәлил. *Докладчы --- урман эшен механикалаштыру, аңа даими кадрлар булдыру, урман кисүчеләр алдында торган зур бурычлар турында сөйләде.* Г.Әпсәләмов. *Әмма син бит хуҗалыкны үзең алып бармыйсың, сиңа ышанган җитәкче кадрлар – колхоз рәисләре, аларны тыңлый белгән урта буын тармак җитәкчеләре алып бара.* Г.Ахунов

2) Хезмәткәр буларак аерым бер кеше

3) *хәрби* Регуляр армиядә даими төп хәрби состав

**КАДР** II *и. фр.* 1) Кинотасмадагы, фототасмадагы бер сурәт. *Тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр, кино тасмасында алышынып торган кадрлар кебек, Хәлимнең күз алдыннан үтеп тордылар.* Г.Гыйльманов

2) Кинофильмның бер күренеше, эпизоды

**КАДРИЛЬ** *и. фр.* 1) Кара-каршы басып парлашып башкарыла торган алты фигуралы бию. *Аннары Фәхрия пианинода уйнарга утырды, Яхъя, Нажҗия һәм Камилә белән чиратлашып, кадриль биеде.* А.Таһиров

2) Шул биюнең көе, музыкасы

**КАДРОВИК** *и. сөйл. рус* 1) *хәрби* Даими хәрби хезмәттәге гаскәри

2) Югары тәҗрибәле эшче, зур тәҗрибә туплаган белгеч

3) Кадрлар бүлегендә эшләүче кеше

**КАЕЗ** *и.* 1) Юкә, каен, карама кебек агачларның нәрсә дә булса ясарга дип эшкәртелгән кайрысы

2) *диал.* Карама агачы. *Утынга каез кисү*

**КАЕЗЛАМА** *и. диал.* Карт юкә агачының тупас тышкы кабыгын чистарткannан соң икенче кабат каезлап алган кайрысы

**КАЕЗЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса тышкы кабыгын актарып куптару, каеру, өске катлавыннан арындыру. *Шалашның түр стенасы булып күренгән каен тармаклары арасында аяклары каезламыйча, өсте ышкылмыйча ясалган тәбәнәк өстәл күрде.* Г.Гобәй

2) Чоку, чокып алу, казу. *Кемдер, тырышып-тырышып, шул урындагы язуны балта беләнме, кискеч беләнме, кылыч беләнме каезлап, ватып бетергән.* Р.Батулла

3) Кыру, кырып куптару. *Инде икеме-өчме тапкыр кырылган казанны яңадан ялтыратканчы каезларга керешәләр.* М.Хәсәнов

4) Хайваннарга карата: яшь агачларның кәүсәсеннән кайрысын кимереп ашау

5) Тәнгә ышкылып, кадалып, төртелеп авырттырып тору. *Синең белән берәү трамвай эчендә кысылып, сыңар аягына басып бара, газаплана, аның үткен почмаклы портфеле синең тез астыңны каезлый.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Чыбыркы, камчы яки чыбык белән кыйнау. *Сыртын каеш чыбыркы белән каезлыйсы нәрсә.* Р.Ишморат. *Тәнемне таяклар белән каезлаганнармыни, сулыгып авырта, башыма әйтерсең кургашын койганнар, күзләрем йомыла, алдымда әлҗе-мөлҗе утлар уйный сыман.* Г.Тавлин. *Бер көнне борынын канатып, икенче көнне сыртын каезлап кайтаралар.* Н.Гыйматдинова

7) *күч.* Бертуктаусыз искә төшеп борчып тору, җан тынычлыгын алу. *Хәлим, баш миен каезлаган сорауларны сыгып чыгарырга теләгән кебек, ике кулы белән башын кысып тотты...* Г.Гыйльманов. *[Көн дә үлем, көн дә үтереш ишетү] --- исә безне баса, җаннарны каезлый, яшәвебезнең ямен кисә барды.* Ф.Яхин

8) *күч.* Бик нык ачулану, тәнкыйтьләү; нәрсәдер әйттерү, эшләтү максаты белән өзлексез таләп итү, басым ясау. *Директор каезлый башлагач табалар!..* Г.Ибраһимов. *Шәп каезлагансың! Бөтен гомеребез ялган чәйнәп узды инде, дөресен ярып салырга да вакыт.* Т.Әйди

9) *күч.* Кабат-кабат тәкрарлап, инандырып үзенекен сөйләү, үз фикерен үткәрергә тырышу. *Ул гаҗәп бер салкын кан белән һаман үзенекен каезлый.* Ш.Камал

10) *күч.* Талау, көчләү

**Каезлап бетерү** Бик нык, тәмам чиләндереп каезлау. *Әнә бит, айгырны камчылап, сыртын буй-буй ярып каезлап бетергәннәр, миһербансызлар!* Ф.Яхин

**Каезлап тору** 1) Әле, хәзерге вакытта күз алдында каезлау. *Капка төбендә шырпы кабыннан китеп алынган чыра белән теш каезлап торган бу ир уртасы кешене Гыйлемхан танымады.* Р.Мөхәммәдиев

2) Һәрвакыт, бертуктаусыз каезлау

**Каезлап чыгу** Һәрберсен, берсен дә калдырмыйча, бер-бер артлы каезлау

**Каезлый бару** Һәрберсен берәмберәм каезлау

**Каезлый башлау** Каезларга тотыну. *Болай минут саен сыртыңны каезлый башласалар, билсез калуың да бар!* Ф.Яхин. *Ә ул түйдан соң икенче көнне үк җилкәңә менеп атланыр да муеныңны каезлый башлар.* И.Хәйруллин. *--- идарә эшеннән бушаган араларда шул өйгә дигән бүрәнәләрнең кабыкларын каезлый башладым.* В.Нуруллин

**КАЕК** *и.* Агач кәүсәсен чокып ясаган көймә. --- *ныгытмадан унлап гаскәр чыгып, каекка утырып, сәүдә көймәсе янына килеп җиттеләр.* Г.Гобәйдуллин. *Ул – байның кызлары гына йөри торган каек.* М.Фәйзи. *Гази, җитез-өлгер хәрәкәтләнеп, ярык соскы белән каек эченә тулган суны түгәргә кереште.* М.Хәсәнов. *Каек төбендә беләктәй калын-тыгыз кара балыклар тыпырдашып ята.* Ә.Еники // Гомумән, кечкенә көймә

**КАЕКЧЫ** *и.* Кешеләрне каек белән елга аша чыгарып йөрүче кеше. *Каекчы карт, тыңла сүземне, Җилкән белән озат кызымны.* М.Җәлил

**КАЕН** *и.* **1.** Каенчалар семьялыгына караган, ботаклары нечкә сыгылмалы чыбыкларга тармакланган, йөрәксыман яфраклы, кара таплары булган ак кайрылы агач. *Җил булмаса да җилферди яландагы яшь каен.* М.Фәйзи. *Каен агачы дымлы урында үсә алмый, корый.* М.Мәһдиев. *Җәйдән ярылмыйча калган биш-алты каен түмәре бар иде.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Каен агачыннан, ботакларыннан эшләнгән, каеннан булган. *– Кичә генә урманнан алып кайткан мәтрүшкәләр катнаштырып җыйган яшь каен себерке куйдым, туйганчы рәхәтләнеп чабыныгыз! – диде ул.* М.Гали. *Каен бүрәнә. Каен утын*

◊ **Каен боткасы ашату** Чыбык белән суктыру, кыйнау. *Утергәнче, шәрә калдырып, каен боткасы ашатканнар.* К.Латыйп

**КАЕНАГА(Й)** *и.* Иргә (хатынга) карата хатынның (ирнең) абыйсы, никах кардәшлегендә ирнең (хатынның) өлкән ир туганы. *Ул каенагалары төркеменә якынрак килде, аларның каны качкан, боек, түшенке йөзләренә берәмберәм күз йөртеп чыкты.* Н.Фәттах

**КАЕНАНА** *и.* Хатынга иренең әнисе. *Егетен белмим, нинди нәрсәдер? Әмма безгә кодагый булачак, Гөлбануга каенана булачак Сабираны бик беләм.* Г.Ибраһимов. *Әмма Мәликә кушарга, үзенең каенана икәнен күрсәтергә ярата.* А.Шамов

**КАЕНАНÁ ТЕЛЕ** *и. бот.* Яфрагы озын кылыч шикелле булып озаеп үсә торган, драценалар семьялыгына караган сансевиерия гөленең халык атамасы

**КАЕНАПА** *и. сөйл. к.* **каенигәч**

**КАЕНАТА** *и.* Хатынга ирнең әтисе. *Килен каенатасыннан тел яшерми иде.* А.Шамов. *Шулай да каенатасы Мәрьямне ялгызын гына җибәрергә теләмәде.* К.Латыйп. *Шуннан берьюлы каенатаң Биктимер картны чакырып кайтырсың.* Т.Гыйззәт

◊ **Каената туфрагы** Кайната, кайнана йорты (киленгә). **Каената туфрагыннан яралган** Килеш-кыяфәте, холкы-фигыле һ.б. нинди дә булса ягы белән төшкән йортына охшап торган килен турында

**КАЕ́Н ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Болетачалар семьялыгыннан кабарынкы кара көрән эшләпәле, ашарга яраклы көпшәле гөмбә; *русчасы:* **подберёзовик**

**КАЕНЕ** *и.* Иргә (хатынга) карата хатынның (ирнең) энесе, никах кардәшлегендә кече ир туган. *Бүлмә тактасы аркылы сәгать йөргәне, каенесе Илгизәрнең ара-тирә кәгазь кыштырдатканы ишетелгәләп китә.* Г.Бәширов

**КАЕ́Н ҖИЛӘГЕ** *и. бот.* 1) Розачәчәклеләр семьялыгыннан, ак чәчәкле, хуш исле алсу-кызыл тамчысыман җимеш бирә, җиләгенең бәбәкләре җиргә ятып, мыекчалар җибәреп үсә торган үлән үсемлек

2) Шул үсемлекнең җиләге. --- *нарат күркәсе белән чәй кайнатканын, шул арада урманнан савыт тутырып мөлдерәп пешкән каен җиләге җыеп чыгарга да өлгерүен һәм --- чирәмлектә тирләп-пешеп чәй эчүләрен күреп китү, мотлакан, кирәк.* Ф.Хөсни. *Башына нәкъ аныкы төсле каен җиләкләре белән бизәлгән киң кырыйлы эшләпә дә алып киде.* Г.Гобәй

**КАЕНИГӘЧ** *и.* Хатынга ирнең апасы. *Әйдә, Заһидә кайнигәчем, фронтка китик, Йосыфны сакларга.* Р.Батулла

**КАЕНИШ** *и.* 1) Иргә хатынның энесе. *Аллаһы боерса, каенишенең үчен кайтарачак әле ул, кайтарачак!* М.Әмирхан

2) Хатынга ирнең кыз һәм ир туганнары. *Болай өй эчендә, йорт арасында Нурҗиһан каенишенә бик үк чекерәеп күренмәскә, аның белән сөйләшмәскә тырыша иде.* Г.Бәширов

**КАЕНЛЫК** *и.* 1) Күпчелек каен агачларыннан торган, каен агачлары үскән урман. *Юлдан дүрт йөз метр чамасы гына читтә, тигез кыр уртасында, кечкенә ап-ак каенлык күренә иде.* Ә.Еники. *Үр менә башлар алдыннан йомшак карда батып калган чаңгы эзләренә, ерактагы каенлыкка карап алды.* Н.Фәттах. *Авылның бер ягында, ярты чакрымда ук – куе нарат урманы, икенче ягында исә – каенлык.* Т.Әйди

2) *диал.* Каберлек

**КАЕНСАР** *и. диал. к.* **каенлык**. *Бигрәк матур шул каенсар, җир җиләге пешкәндә.* З.Мансур

**КАЕНСАРЛЫК** *и. ялг. к.* **каенсар**. *Теге каенсарлыкта атлар көтәр идем.* Һ.Такташ

**КАЕНСЕҢЕЛ** *и.* Хатынга ирнең кече кыз туганы. *– Менә бусы каенсеңлем Гөлбануга, – дип, зур матур шәл тартып чыгарды.* Г.Ибраһимов

**КАЕ́Н СУЫ** *и.* Яз башында каен кәүсәсен ярып яки тишеп алына торган, кәүсә тукымасыннан саркып чыккан татлы су. *Шешә белән пәке алып*

*бакчага чыга иде дә татлы каен суы җыеп эчә иде.* И.Гази

**КАЕ́Н ТУЗЫ** *и.* Каен кәүсәсеннән каезлап алынган тышкы ак кабык. *Әллә кайгы-хәсрәт каен тузына язылганмы?* С.Зыялы. *Каен тузы белән тугыз кат ураган ярканатның күзләрен.* Җ.Тәрҗеман

**КАЕРУ** *ф.* **1.** 1) Нык беркетелгән, ныгытылган әйберне кирегә йолкып, суырып чыгару. *Гайфи, ике дә уйлап тормыйча, төтенләнеп яткан амбарның такталарын каерырга керешә.* Г.Гыйльманов. *Бикмуш бабай иданнең бер тактасын каерып ачты да аннан бүрек хәтле бер төргәк алып, Мәрдән абзыйга бирде.* Г.Гобәй

2) Әйбернең башларын, очларын, тармакларын кире якка әйләндереп бору, як-якларын кире якка юнәлтү, сындырып ботарлау. *Урманда бер агачны җил каерса да, ул, мөгаен, җилгә түгел, Әхмәдуллага сылтыйдыр.* Н.Гыйматдинова

3) Аяк, кул, бил, баш һ.б.ш. әгъзаларны көч белән кире якка тарту, бору, имгәтү. *--- бер кулы белән Мәдинәнең имән бармагын каерып сындырырга керешә.* Ш.Камал. *Палач килеп ашыгыч каты хәрәкәт белән аның кулларын каерганда да, артка каерып бәйләгәндә дә, бу уй аның башыннан чыкмады.* Г.Ибраһимов. *Хәнифә Вәлиулловна чанасыннан сикереп төшеп, атының башын каерып тәртәгә бәйләде...* В.Нуруллин

4) Зур-зур күләмдә куптарып актару, зур кисәкләр белән куптарып алу. *Төрле якта кешеләр безнең кебек үк җир каера, мыжгып хәрәкәтләнеп торалар.* Ш.Камал. *Ибрайга әле генә үз төрәне каерып салган кантарны ыргытты.* Г.Гобәй. *Көне буе салам каерып, кулсыз, беләксез калып кайтып керә ул [Хәлим].* Г.Гыйльманов

5) Хәрәкәт юнәлешен үзгәртү, читкә бору, тайпылу. *[Бәдретдин] --- атны олы юлдан уңга каерды.* Ә.Еники. *[Рәмзи] Безне күрүе булды, уңга борыласы урынга сулга каерып, капка төбенә килеп тә туктады.* Ф.Садриев. *Аяклар туган нигезгә каерды.* Р.Мөхәммәдиев

6) *күч.* Нинди дә булса мәнфәгатьләрне, мәсьәләне, фикерне үзәккә алып, игътибарны шуңа юнәлтү; аны кайгырту, яклау. *Монда калганнарның кайсы байлар ягын каера башлаган, кайсы эчүгә сабышкан, иң элекке юлны бөтенләй ташлаган.* Г.Ибраһимов. *Әгәр колхоз үз ягына гына, завод үз ягына гына каерса, без ерак китә алмабыз.* Г.Әпсәләмов. *Аны [Мирсәет Солтангалиевны] Питерга чакырып китергән Әхмәт бай Цаликов сул меньшевиклар ягына каера ---.* Р.Мөхәммәдиев

7) *күч.* Әңгәмәнең темасын үзенә кирәк якка бору, сүзне үзенә кирәк якка үзгәртү. *Ләкин Нәфисәнең исәбе Габдрахман турында сүз куертып, Давытның үзеннән актык нәрсәне әйттерү иде. Шуңа күрә ул һаман шикле якны каерды.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Күп итеп, мул итеп табыш алу, файда күрү. *Әле сорап-нитеп тормаган өчен алардан тагын да ныграк каерырга иде дә...* А.Әхмәт. *Кеше тота, квартирант. Акча каера.* Г.Нәбиуллин. *Гектарыннан тартып-сузып сигез-тугыз центнер арыш алган басулардан егермешәр-утызар центнер уңыш каералар.* Ф.Яруллин

9) *күч.* Башкару, эшләү, майтару. *– Я Әхмәт, үзең ни эшләр каерасың? Һаман союзда эшлисеңме әле? – диде.* Ш.Камал

**2. каерып** *рәв. мәгъ.* 1) Көчләп; ватып-җимереп. *Лазаренко аның авызын хәнҗәр очы белән каерып тешләрен ачты да, ике бармагын тыгып, аны костырды.* З.Зәйнуллин

2) Төбенә кадәр, киң итеп. *Чөнки авылда бары тик ул гына ишекне шулай киң итеп, тупсасына хәтле каерып ача иде.* А.Шамов. *Харис Рәмзия апасы алдыннан ишекне каерып ачты, аннары рәхим итегез дигәнне аңлатып, артистларча кулын алга сузды.* Б.Камалов. *Әмма чирек сәгать тә үтмәгәндер, кемдер зур якның ишеген каерып ачты, нидер карады, эзләде дә гөрселдәтеп кире япты.* Казан утлары

3) Көч белән, киң колачлап. *Шул арада Бикмуш бабай каерып-каерып ике тапкыр ишәргә өлгерде.* Г.Гобәй. *Сәгыйть, кояшта янган көчле беләкләре белән тыгыз суны каерып ишә-ишә --- икенче як яр читендәге биек карамаларга таба йөзеп китте.* Н.Фәттах

4) Әйләндереп, бөкләп. *Яулыкны каерып бәйләү*

5) Мул итеп, күп итеп. *Зөһрә апа баздан салкын катык алып керде, каерып икмәк кисте.* Ә.Фәйзи

6) Үз теләгеннән башка, ирексезләп. *Менә бу старшина --- бәлки, минем кебек үк авыл малаедыр инде. Әллә Мәскәү, Ленинградтанмы, музыка мәктәбен тәмамлаган вакытында каерып хәрби хезмәткә алганнармы?* М.Мәһдиев. *Ул шешә капкачын таза теше белән генә каерып алды да, башын артка ташлап, голт-голт эчә башлады.* М.Маликова

**Каера башлау** Каерырга керешү. *Мине бер кырыйга кысрыклап, вагон ишеген каера башладылар.* З.Мәхмүди. *Базар мәчете дип аталган мәчет түбәсенә менеп, калайларын каера башлый.* Р.Батулла

**Каера бирү** Бернигә карамыйча каеруны дәвам итү. *Төхфәтнең куллары сикерергә ирек бирми башлагач, айгыр аягы белән җир тырнады, башын каера биреп, ирек эзләп карады.* З.Зәйнуллин

**Каера төшү** Тагы да бераз каеру

**Каерып ату** Дорфа, тупас, ватып-җимереп каеру

**Каерып бетерү** Тәмам имгәткәнче, авырттырганчы, җимергәнче каеру

**Каерып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә каеру. *Җил уралып килеп ишекне каерып җибәрде.* И.Салахов. *Гандольер пассажирның алдына дөя йонынnan тукылган кыйммәтле плед япты да озын ишкәк белән канал суын бер генә каерып җибәрде.* М.Юныс

**Каерып калу** Каерырга өлгерү, мөмкинлектән файдаланып, күбрәк каеру

**Каерып кую** Алдан каеру, каерылган хәлгә китереп калдыру

**Каерып салу** Артка таба каерып салындырып кую. *Ә ул крокодил тиресеннән тегелгән портфеленең көмеш йозагын ---, гайрәтле хәрәкәт белән шартлатып ачып, капкачын артка каерып салды.* Ә.Гаффар

**Каерып ташлау** Тиз-тиз каеру, аннан-моннан актарып каеру. *Гәрәй ачудан кызып, сүгенергә тотынды, бер шкафны каерып ташлады.* Г.Ибраһимов. – *Егетләр, түбәне каерып ташлагыз, түбәне! Багорлар белән! – дип кычкырды Гафиятулла бабай.* Г.Әпсәләмов

**Каерып тору** Гел, бертуктаусыз каеру. *Кайберәүләрнең аяклары гел шунда [аракы кибетенә] каерып торды: мыштым гына керер киттеләр дә кош тоткандай очынып чыктылар.* Р.Мөхәммәдиев

**Каерып чыгару** Ахырга кадәр төбе-тамыры белән кубарып каеру. *Берсе чыра белән яктыртып тора, икенчесе, пычак йөзендә нурлар уйната-уйната, Хәлимнең җанын каерып чыгарырга тели*... Г.Гыйльманов

**Каерып яту** *сөйл.* Мөмкинлекләрдән файдаланып, һәрвакыт, даими каеру, зур файда, табыш күрү. *Узенә бергәләп каршы төшү булмаганга, курыкмыйча училище байлыгын каерып ята ул.* З.Фәйзуллин

**КАЕРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **каеру**. *Урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган.* Ә.Еники

2) Гәүдәнең табигый торышын үзгәртеп, артка таба борылу; киерелеп артка борылып карау. *Алар Рәхимнең өенә каерылып карый-карый акрын гына узып киттеләр.* М.Хуҗин. *Лима каерылып Янгуразга карады.* Т.Әйди. *Каерылып артына борылып карарга теләмәде Мөнәвәрә, иманнан аерылып, абына-сөртенә алга ашыкты.* Н.Гыйматдинова

3) Көч белән ботарланып зәгыйфьләнгән, имгәнгән булу. *Шул вакыт давыллы җилдә каерылган, кышкы ачы салкыннарда чатнаган я яшен сугып киткән агачларның кайберләре җиңелчә генә шыгырдап, сыкранып куя.* З.Фәйзуллин

4) Кабыгы арчылып кубу, каезлану. *Каерысы каерылган черек бер усак агачыннан гыйбарәт.* Ш.Камал

5) *к.* **каеру** (*5 мәгъ.*). *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

**2. каерылып** *рәв. мәгъ.* 1) Мул булып, күпләп. *Әнә каерылып уңган иген кырына, кешеләрнең дәртләнеп эшләүләренә карап гыйбрәт ал, ичмасам.* Р.Ишморат. *Каерылып үлән үскән тын яткылны урталай ярып аккан йөгерек инеш каядыр кояш баешына ашыга.* Җ.Рәхимов. *Бер елны каерылып иген уңды – хезмәт көненә җидешәр килодан өләштек.* Т.Әйди

2) Киң итеп, төбенә хәтле. *Кечкенә капка каерылып ачылды һәм койма арасына шартлап бәрелде.* М.Хуҗин. *Урам якта машина гүләп килеп туктаганы ишетелде, олы капка каерылып ачылып, әрҗәсенә берничә озын торба салган «КамАЗ» әкрен генә керә башлады.* М.Маликова

3) Киерелеп, киң колач белән. *Менә ул туктап чалгысын кайрап ала да тагын каерылып-каерылып чабарга тотына.* И.Гази

4) Кизәнеп, бар куәткә, бар көчкә. *Каерылып, башына таяк белән сугу*

5) Юнәлешен үзгәртеп, барырга тиеш юлыннан тайпылып. *Гомер юлының бик мөһим бер борылышында читкә каерылып китте дә... юлдан язды, сукмагын югалтты*... Г.Гыйльманов

**Каерыла башлау** Каерылырга тотыну. *Мәскәү җасусы Иван Оболенскийны куганнан соң, Әҗем хан бераз үзгәрде, ләкин ул хәзер баш карачы Булат бәк ягына каерыла башлады.* Р.Батулла

**Каерыла төшү** Тагы да бераз каерылу

**Каерылып бетү** Тәмам, бик нык каерылу; нигезеннән кубып чыкканчы каерылу. --- *як-якка карый-карый, муеннарым каерылып бетте.* Г.Кутуй. --- *фермадагы элекке төзек, агарып-балкып торган биналар бушап калган, аларның тәрәзәләре ватылып, ишекләре каерылып беткән.* Г.Гыйльманов

**Каерылып калу** Күпмедер вакыттан, нindidер сәбәпләрдән каерылган торыш алу. *Аларның [урман сукмакларының] кайсыдыр өзелеп калды, кайсыдыр урау якка каерылып калды.* Г.Гыйльманов

**Каерылып китү** Кинәт, көтмәгәндә каерылу. *Менә аның сул кулы кинәт артка таба каерылып китте.* А.Әхмәт

**Каерылып ташлану** Төрле кисәкләре төрле якка каерылып ыргытылган хәлдә булу. *Ишекләре каерылып ташланган буш амбарлар эчендә күзге җил айкалып йөри.* И.Гази

**Каерылып тору** Әле, хәзер каерылган хәлдә булу

**Каерылып төшү** Нигезеннән үк кубып чыгу, төбеннән үк каерылу. --- *ишек элгече каерылып төшкән иде.* Ш.Камал

**Каерылып чыгу** Ахырга кадәр каерылу, төбеннән үк йолкыну

**КАЕШ** *и.* **1.** 1) Иләгән яки чи күн һәм шул күннән эшләнгән төрле калынлыктагы һәм киңлектәге тасма. *Ул нечкә каеш белән иңенә эленгән биноклен күзенә китереп теге як ярга текәлде.* Г.Бәширов. *Кыяфәтләр бер дә галәмәт: ул аркылы-торкылы каешлар, ул чырайдагы бөркет кыюлыгы!* Г.Ахунов

2) Күбесенчә күннән эшләнгән тасмасыман билбау. *Өсләрендә аларның билен каеш белән буган гади солдат гимнастёркасы һәм кыскарак кара юбка.* Ә.Еники. *Бил каешына лимонкалар таккан егет --- җавап бирде.* З.Фәтхетдинов

3) *тех.* Бер шкифтан икенче шкифка әйләндерү хәрәкәтен тапшыру өчен кулланыла торган, калын күннән яки башка нык материалдан эшләнгән йомык түгәрәк тасма (машинада, механизмда). *Үсеп күп еллар үткәч, молотилкада эшләгәндә, Гафиятнең күлмәк итәге привод каешына эләгеп, үзен чак-чак кына машина бәреп үтермәде.* Ә.Айдар. *Габделгазиз инде сугу машинасын әллә кайчан туктаткан да көненә кимендә ике-өч тапкыр өзелеп үзәккә үткән, барабанны маховик белән тоташтыра торган иске каешны ялгарга керешкән иде.* В.Нуруллин

4) Багаж бәйләү өчен махсус тасма, бау

**2.** *с. мәгъ.* Каештан ясалган, каештан торган. *Өч-дүрт каеш йөгәнне бергә бәйләп аркасына аскан килеш, ялкау гына атлап кайтып килүче бер яшь егет әйтте бу сүзне.* М.Әмир. *Сикереп менүе булды, төшәргә теләмичә киреләнгән егетләрнең аркасына каеш камчы белән тамыза башлавы булды.* Т.Ахунов

**КАЕШЛАНУ** *ф.* 1) Туктаусыз ышкылудан, орынып торудан ялтырап шомару (кием тур.). *Тимерчелектә каешланып каткан картузын арткарак чигереп, зәңгәрсу яшькелт күзләрен җиргә төбәп --- өзеп кенә әйтте.* Г.Ахунов. *[Яшьләр] – И Гата абзый, түбәтәең, күн итек төбенә салдырсаң, өч елга түзәр иде, – дип көлделәр. Шулхәтле озак кигәч, каешланмый хәле юк.* Г.Толымбай

2) Сөялләнеп, кутырлар белән капланып бетү, каты булып шомару (куллар, уч төбе тур.). *Бу – зур буйлы, каты каешланган куллы --- [кеше].* Г.Ибраһимов. *Тузудан чуклана башлаган ыштан балагы эченнән чыгып торган тәпие, кутыр-чатыр чебиләп, тәмам каешланып каткан иде.* М.Хәсәнов

3) Камыры уңмаудан, күпереп күтәрелмәүдән кайрыланып кибү, кату (икмәк тур.)

4) *күч.* Остару, шомару, үткенгә әйләнү. *Без яшь, без әле каешланмаган, шомармаган.* Н.Фәттах

5) *күч.* Бернәрсәгә дә исе китми торган гамьсез кешегә әйләнү. *Председатель – күптән инде һәртөрле шелтәдән каешланган утызлар тирәсендәге егет – бик өлгер җавап бирде.* Ә.Еники. *[Тәзкирәнең] --- Һарунныкыише «тәнкыйть» сүзләренә аның күптән колагы каешланган иде.* Н.Фәттах

**Каешлана бару** Көннән-көн күбрәк, ныграк шомарып, үткенләнеп каешлану

**Каешлана төшү** Тагы да бераз каешлану

**Каешланып бетү** 1) Тәмам, бөтенләй ялтырап каешлану. *Башындагы ертык фуражка, өстендәге әллә ничә ямаулы каешланып беткән кыска киемнәр белән ул Мәрьям күзенә үксез бала кебек кызганыч күренә иде.* Ш.Камал

2) *күч.* Бик нык шомару, үткенләнү. *--- еллар буе каешланып беткән бюрократ абыйларның кырга сыймас кыланышларын тәнкыйтьләргә алынам.* К.Тимбикова. *Инде шул чагында ук, конституцион ирекләр һәм гарантлар турында сөйләшкәндә, демагоглыкта шомарып, каешланып беткән.* Р.Мирхәйдәров. *Кара син аны, кызыл сүз сөйләп каешланып беткән ---.* Р.Вәлиев

**Каешланып калу** Каешланган хәлгә килү

**Каешланып тору** Ялтырап шомарган, каешланган хәлдә булу

**КАЕШЛА́У** *ф.* Каеш белән кыйнау, каеш белән суктыру. *Сизмәстән генә, үги әти диган бу явыз бәндәнең берәр җирен умырып тешләп алам. Ул, сикереп торып, мине каешлый башлый.* Ф.Яруллин

**КАЗ** *и.* 1) Үрдәкләр семьялыгыннан, аккошлардан калынрак гәүдәсе, кыскарак муены, кыскарак сары томшыгы белән аерылып торган, ак яки соры төстәге каурыйлы эре су кошы. *Чөнки тавыклар да, чебешләр дә, үрдәкләр дә, казлар да бертуктаусыз йөгерешеп, җим ашап, бер-берсен куышып кына торалар.* А.Әхмәт. *Тын урман өстеннән бер көтү кыр казы шаулап узды.* Г.Гобәй

2) Шул кошның итеннән әзерләнгән ашамлык. *Казы да, пилмәне дә, сумсасы да, гөбәдиясе дә – берсе дә калмады.* Ш.Камал. *Ярый әле, бәхеткә каршы, Хәдичә түтинең тозлаган казы бар икән.* Г.Бәширов

◊ **Каз башы** Икмәкне урак белән урганда 25–50 көлтәдән куела торган чүмәлә төре. **Каз боты** Киемнең берәр өлешенә юешләп, чиләндереп, бик каты кысып ясалган төен. *Илдар бая Әкбәр вәгъдә иткән каз ботының шушы икәнен аңлады.* Г.Гобәй. **Каз йөреше** Күкрәкне киереп, башны артка ташлап йөрү рәвеше. **Каз муены булу** Салкын тиюдән яки ипсез-уңайсыз ятудан муен каерылып, кыйшаеп сеңере кату, муен борылмау. **Каз тәне** Салкыннан, нык дулкынланудан, кинәт куркудан тән өслеген каплап ала торган вак-вак төерчекләр. *Бозлы баткак, ботинка ертыкларыннан табанга, тубыкка сыланып, бөтен гәүдәне каз тәне белән каплый.* К.Нәҗми

**КАЗА** *и. гар.* 1) Афәт, бәла, зарар, бәхетсезлек. *Каза килсә берәүгә, димә: килсен, Берәүгә килсә сырхау, димә: үлсен.* Г.Утыз Имәни. *Шулар аркасында илгә никадәр каза килгәнне белмисең, шул гөнаһ шомлыкларын яклап торасың.* М.Гафури. *Сугыш елларында, ярый, сүз әйтмәдек. Анысы бөтен ил белән килгән каза булды.* В.Нуруллин

2) Зыян, югалту. *Олы мәетнең һәрвакыт казасы була: я ат үлә, я сыер… безнең менә кәҗә үлде.* И.Гази. *Йортка килгән казаны уртак күтәрик.* Г.Нәбиуллин

3) Үз вакытында үтәлмәгән, үтәлүе мәҗбүри булган эш, үтәп өстән төшерелергә тиешле бурыч. *Син нигә намазы казага калган картлар төсле моңайдың?* Ф.Бурнаш. *Яшьрәк чакта укылмыйча казага калган китапларны укып гомер уза.* М.Әмир

◊ **Казалы булу** Каза күрү, бәлаказаларга тару, казалану. *Казалы булдым, халык теленә «Нәкыя» дип менгән маркалы кесә телефонымны җуйдым.* Р.Зарипов. *Исәнләшкәч: «Нурәхмәт җаным, – диде ул, тавышына бар булган назлылыгын салып, – казалы булдым әле, казаным тишелде».* Г.Шакиров. **Каза табу** Зыян күрү, бәлагә, бәхетсезлеккә юлыгу. *Анда [фронтта] күпме асыл егет чебендәй кырылды лабаса, бәлки, инде бу ханымның да яры каты бәрелешләрнең берсендә каза тапкандыр?* Т.Әйди

**КАЗА́ КЫЛУ** *ф.* Берәр сәбәп белән үз вакытында үтәлә алмыйча калган бурыч дәрәҗәсендәге эшне соңыннан, башка вакытта үтәү. *Ярар, мин алайса, чәйгә кадәр тәһарәт алып, юлда калган намазларымны каза кылып алыйм.* М.Гафури. *– Иртәгә каза кылырмын инде, – диде.* Ш.Камал. *[Сабира кодагый] --- түргә барып, намазлык алып, иртәнге намазны каза кылырга әзерләнде.* Г.Ибраһимов

**КАЗАК** I *и. төрки* 1) XV–XVII йөзләрдә крепостной изүдән рус дәүләте чикләренә (Дон, Җаек, Запорожье) качып киткән ирекле кеше, качак. *Себердә урыс экспансиясенең иң алгы сафында казак төркемнәре баруын да истән чыгармаска кирәк. Ә ул халык һәртөрле качкыннардан, «беткән башлар»дан оешкан булып, иген игү яки мал асрау исәбенә түгел, юлында очраган халыкларны талау исәбенә көн күргән.* З.Мифтахов

2) Россиянең XVIII йөзләрдә формалашкан чик өлкәләрендәге (Дон,

Кубан, Терек, Оренбург һ.б.) махсус гаскәри частьларда хезмәт иткән өчен, җирдән ташламалы файдалану хокукы булган хәрби катлау вәкиле. *Килүчеләр Дон казаклары отряды булып чыкты.* М.Гали. *Шуның өчен сез минем унбиш яшәрлек бердәнбер кызымны рус казагына тотып бирдегез.* Ф.Бурнаш

3) Шул катлау вәкилләреннән төзелгән хәрби частьта хезмәт итүче рядовой. *Әй, кызлар, карагыз, кара, атлы казаклар үтә.* К.Тинчурин. *Ишектән тагы бер атлы казак кереп, Илсөярне тотып алды һәм Бикмуш бабайны җилтерәтеп алып чыгып китте.* Г.Гобәй. *[Ат чабыштырганда] Камчыңны бик ныклап кулыңа чалып тот. --- Казак шикелле алгарак ятып бар.* М.Гали

4) Шул чик өлкәләрдә туып үскән крестьян. *Чөнки кәрван кебек төялеп күчүләр, мәшәкатьле булса да, казак өчен бер бәйрәм, уен-көлке кебек бер ихтыяҗ иде.* Г.Ибраһимов

**КАЗАК** II *и.* Казакстанда яшәүче төрки телле төп халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Үзбәкләрне, казакларны солдатка алмыйлар икән...* Г.Ибраһимов

**КАЗАКИ** *и. иск. к.* **казакин**. *Авылда яшьләр арасында җиңсез камзуллар, киртек якалы казакилар кию модага кереп китте.* М.Гали. *Мәрфуга әбидән бик тиз хәзрәттән калган әдрәстән казаки да тектерде.* Г.Исхакый

**КАЗАКИЛЫК** *и.* **1.** Казаки тегү өчен билгеләнгән материал. *Габделнасыйрга казакилык, балаларга күлмәклек-ыштанлыклар, кәләпүшләр, пәкеләр чыгарып, сәкенең буш урынына таратты.* М.Гали

**2.** *с. мәгъ.* Казаки тегәргә яраклы, казакига җитәрлек

**КАЗАКИН** *и. фр. иск.* Аркасын тоташ һәм билле итеп, эчлек куеп, озын җиңле, утырма якалы, сул якка каптырылган озын яки кыска чабулы итеп тегелгән язгы һәм көзге ирләр киеме

**КАЗА́КЧА** I *рәв.* Казакларга (I) хас булганча, алардагыча итеп. *Казакча киенү*

**КАЗА́КЧА** II *рәв.* Казак (II) милләтенә хас булганча, алардагыча итеп; казак телендә. *Җөмләне казакча әйтеп бирү*

**КАЗАКЪ** *и. к.* **казак** II. *Казакъның кымызы җилле иде.* А.Расих. *Казакълар кышлак халкы, чын күчмәләр булса, татар-башкортлар – җәйләү халыклары, борынгы, традицион тормышта алар чын күчмәләр түгел, ярым күчмәләр булганнар.* З.Мифтахов

**КАЗАЛАНУ** *ф.* Каза күрү, казага тару

**Казаланып бетү** Күпсанлы, төрлетөрле казалар күрү, бик күп казалану

**КАЗАЛА́У** *ф.* Вакытында үтәлмичә, бурыч булып калган эшне икенче вакытта башкару

**КАЗАЛЫ** *с.* Казалардан торган, бәла-казалары күп булган

**КАЗАМАТ** *и. фр. иск.* Сәяси тоткыннарны ябу өчен, ныгытмалардагы бер кешелек төрмә камерасы. *Никах булган көнне капкагыз янына килеп, сине коткарырга йөреп, казаматка менде, мескен.* Г.Коләхмәтов

**КАЗАН** *и.* 1) Астына ут ягып ризык пешерү өчен кулланыла торган йомры төпле, җәенке авызлы чуен савыт. *Хатыны казаннан ясмык чумарын соса башлады: җылы пар эчендә калган Фатыйма казан янында бераз вакыт күренмичә торды.* И.Гази. *Әбиләр янәшәдәге тәбәнәк мич казанында пешереnеп йөриләр.* Г.Гыйльманов

2) *тех.* Ягулык, электр энергиясе һ.б.дан файдаланып, кайнар су яки пар ясый торган җайланма. *Скважина ягыннан ротор әйләнүе, пар казаннары гөрләве ишетелеп китә.* А.Әхмәт

3) *сөйл.* Су төбендәге яки җир өстендәге тирән булмаган, киң авызлы чокыр. *Шул мәлдә үк, көчле агымга эләгеп, [кошчык] аска – чишмә казанына төшеп китә.* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Тупланыш, тупланган урын; үзәк. *Схоластик моназара казанына, башка күпләр арасына, аталары тарафыннан Йосыфҗан белән Давыт та китереп ябылалар.* Г.Ибраһимов

◊ **Казанга сыймас кабырга** Үзен тәкәббер, башкалардан өстен тотучы кеше турында. **Казаны әйбәт кайный** Башы яхшы эшли, акыллы, зиһенле. *Башлы малай булырсың, казаның әйбәт кайный...* Г.Гыйльманов. **Казанына күрә чүмече** «Иш ише белән туры килгән» мәгънәсендә. **Казанында кайнату** Аерым карашлар тәрбияләү, идеяләр, фикерләр сеңдерү. *[Революция] --- иске тәрбиядә үскән кешеләрне дә, үзенең казанында кайнатып, үзгәртеп чыгара.* А.Шамов

**КАЗА́Н АСЛЫК** *и.* Учак өчен махсус вакланган утын

**КАЗА́Н АСТЫ** *и.* Учак, казанны кайната торган ут. *Иртән торгач, ул казан астына вак-төяк такта яргалады.* Ш.Камал. *Гөлчирә, самавырны карарсың, мин казан астына утын яргалыйм.* Т.Гыйззәт. *Аннары кизәк казан астына бик килешә, ашны әкрен генә кайната.* Ә.Еники

**КАЗА́Н АСУ** *ф.* Казан астына ягып ризык пешерергә әзерләнү. *– Газинур, сиңа югла май атлыйлар бит, – диде мич янында казан асып маташкан әнисе.* Г.Әпсәләмов

**КАЗАНДАШ** *и.* Бер казаннан ашаучы, бер казаннан файдаланучы. *Казандаш булачак шәкертләрнең миңа сәерсенеп, бераз читләштереп карауларын сизелеп тора иде.* М.Гафури

**КАЗА́Н КАБЫ** *и. тар.* Элек юлда, яуда йөргәндә, корымы буялмасын өчен, казанны салып йөрткән махсус кап

**КАЗА́Н КУНАСЫ** *и.* Казан капкачы. *Килене казан кунасын ачты, пар томаны --- кечкенә өйнең һәр почмагын томалап алды.* С.Рафиков

**КАЗАНЛЫ** *и.* Казан шәһәрендә яшәүче кеше. *Мин кайгымны кемгә сөйлим: угълыма сөйлимме, ул сөттән аерылмаган; атама сөйлимме, ул моннан бик ерак; казанлыларга сөйлимме, алар бит үз ирекләре илә ант итеп мине урысларга бирделәр.* Һ.Атласи

**КАЗАНЛЫК** *и. геогр.* Тирән сөзәк, киң авызлы чокыр

**КАЗАНУ** *ф.* Үз-үзен тотуы, тырышлыгы, хезмәте белән уңай мөнәсәбәткә, мактауга, мактаулы исемнәргә, дәрәҗәгә һ.б. ирешү. *Бөтен офицерлар арасында хөрмәт казанды.* А.Шамов. – *Ихтирамны таләп итмиләр, аны казаналар: эш, изгелек, яхшылык белән, – дип, акрын гына башлады сүзен җитәкче хатын.* Г.Мирһади. *Рәхмәт тирә-юньдә үтә дә тәвәккәллеге, кыюлыгы, алып*

*йөрәкле кеше булуы белән дан казанган.* Г.Гыйльманов

**Казана бару** Торган саен күбрәк казану. *Үзе лидер булган фирканең узган сайлауларга караганда яхшырак эшләвен, халык арасында абруй казана баруын ассызыклады.* Безнең гәҗит. *Елга круизлары, тау чаңгысы туризмы да популярлык казана бара*

**Казана башлау** Казаныргга тотыну. *Тома ятим Арсланбай акылы-фигыле белән халык арасында абруй казана башлаган.* Мәдәни җомга

**Казанып алу** Тиз арада казану. *Ул бик тиз аларның ышанычын, мәхәббәтен казанып ала.* А.Шамов

**Казанып килү** Электән, күптәннән хәзерге көнгә кадәр казану. *Әлегә кадәр кешене кадерсез итүчеләр, кешене бәхетсез итүчеләр дан казанып килгәннәр.* И.Гази

**Казанып китү** Берәр төрле сәбәптән, вакыйгадан соң казану

**КАЗАНЧЫ** *и.* 1) Казан ясаучы, сатучы яки сипләүче оста. *Казанчының ирке бар, кайдан колак чыгарса!* Мәкаль

2) *иск.* Казан асып аш пешерүче

3) Пар казаннары белгече

**КАЗАНЧЫК** *и.* 1) Кечкенә казан. *Казанчык капкачы*

2) Җеп эрләгәндә орчык җиңел һәм озак бөтерелеп торсын өчен, орчык төбе куела торган кечкенә йомры савыт. *Бизәкләп эшләнгән казанчык*

**КАЗАНЫШ** *и.* Хезмәт, тырышлык, акыл, сәләт белән зур көч куеп яулап алынган уңыш; хезмәтнең ахыргы югары нәтиҗәсе. *Һәм заманыбызның бөек казанышы, безнең илебездә генә элеваторлар, тимер юл вагоннарына сыеп бетмәслек мул икмәк үстерелгән.* М.Мәһдиев. *Ә хәзер ул әсәр [Безеның «Кармен» операсы] унтугызынчы йөз музыка сәнгатенең иң югары казанышы санала.* З.Фәтхетдинов. *Азчылык милләт легиончыларына сак мөнәсәбәт күрсәтелү исә Татар арадашлыгы бюросының казанышы, аның рәсми тылмачы Янгуразның да тырышлыгы нәтиҗәсе, чөнки вермахт бу тәкъдимне кабул итәргә һич тә теләмәгән иде.* Т.Әйди

**КАЗА́РМА** *и. ит.* 1) Хәрби частьларны урнаштыру өчен махсус торак бина. *Артистлар белән бергә төрле җирләргә, бигрәк тә казармаларга барып, шундагы концертларга да катнаша икән.* Ә.Еники. *Ахыр чиктә аларны урман ышыгына посып утырган казармаларга илтеп яптылар.* М.Хәсәнов. *Авыл уртасындагы казармадан үлем сиптерүче эре калибрлы пулемёт түбәсендә ялкын бии башлагач кына тынды.* З.Фәтхетдинов

2) *иск.* Вакытлы, сезонлы вахта хезмәтендәге эшчеләр өчен тулай торак. *Икешәрләп, өчәрләп казармадан чыгып, эшкә таралдылар.* М.Гафури. *Ә медпункт, кагыйдә буларак, әҗәл мәйданыннан --- чак кына читтә, комендатура, каравыл казармалары, административ корпуслар урнашкан җирдә.* М.Хәсәнов

**КАЗАХ** *и. рус* < *төрки к.* **казак** II. *Авырып ятканда, аны минем янга әлеге Бөркетбай дигән казах алып кергән иде.* Ә.Фәйзи. *Монда татар, башкорт, кыргыз, казах һәм башкалардан һәртөрле халыклар бар.* М.Гали

**КАЗА́ЧИЙ** *и. рус сөйл.* Казаклар (I) отрядында хезмәт итүче рядовой гаскәри. *Кубань казачийлары --- аның әмерен --- җиренә җиткерә иделәр.* Ш.Усманов

**КАЗАЧОК** *и. рус* 1) Бию исеме

2) Шул биюнең көе

**КАЗАЯК** *и. бот.* 1) Казаякчалар семьялыгыннан, су читләрендә үсә, сары чәчәк ата торган, кискен ачы исле, агулы сутлы үлән үсемлек; *русчасы:* **лютик**. *Сәвәләйдә казаяклар үсә, әби чәче тузгып утыра.* К.Булатова

2) Көлтәләрне вакытлыча кую рәвеше

**КАЗАЯКЧАЛАР** *и. бот.* Килеп чыгышлары һәм төзелешләре белән казаякларга якын торган бер ыру үсемлекләрнең гомуми уртак семьялык атамасы

**КАЗГАНУ** *ф.* Үзеңне аямыйча, бар булган көчеңә, сәләтеңә эшләү. *Я, шулай казганасың инде син, әмма ул балаларыңнан картлыгыңда игелек күрерсеңме?* М.Мәһдиев. *Көннең-көн буе казганып, арып-ватылып, ярты төннәрдә өйгә кереп авылардан да рәхәтрәк нәрсә булдымы икән?!* М.Хәсәнов. *Безнең кеше үз тормыш кирәген гомере буе казганып тапса, алар «умырып алу», басып кереп урнашу, хәйлә белән эләктерү кебек «метод»ларны өстен күрәләр.* З.Мифтахов

**КАЗЕИН** *и. лат.* Сөт оеганда сөт аксымыннан барлыкка килә торган, сыр һәм эремчекнең төп состав өлешен тәшкил иткән катлаулы аксым

**КАЗЕМАТ** *и. фр.* 1) Сугыш кирәк-яраклары, кораллар саклау, артиллерия, авиация утыннан саклану корылмасы. *Таң беленә башлаганда, кыяны нигезенә кадәр тетрәтеп, ике җирдә бик каты шартлау ишетелде. Күрәсең, безнең сапёрлар немецларның төп казематларын, дотларын тол куеп шартлаттылар.* Г.Әпсәләмов

2) Корабль артиллериясен урнаштыру һәм шәхси состав саклану өчен бронялы стенасы булган урын

3) *к.* **казамат**

**КАЗЁНКА** *и. рус иск.* Элекке Россиядә аракы сатыла торган урын. *Әйдә китәбез казёнкага, Камали бер бөтенне алам, ди.* Г.Камал

**КАЗЁННЫЙ** *с. рус сөйл. иск.* 1) Казнаныкы, казнага караган. *Казённый акча*

2) Казнадан, дәүләт исәбеннән бирелә торган. *Хәер, кыяфәтенә караганда солдат булырга да охшаган, тик бераз корсагы зуррак, казённый шинель таррак булыр...* Ш.Мөхәммәдев

3) *күч.* Формаль, бюрократларча

**КАЗИНО** *и. ит.* Төрле күңел ачу чаралары белән берлектә рестораны да булган комарлы уеннар уйнау йорты. *Кыйммәтле рестораннарга, казиноларга, төнге клубларга йөр, мода күргәзмәләрен, вернисажларны, театр премьераларын калдырма.* Р.Мирхәйдәров

**КАЗНА** I *и.* 1) Дәүләтнең барлык төр байлыклары җыелмасы; дәүләт милке. *Сәгать уннар чамасында казна ашы да пеште.* Бәет. *Өч елга көтәргә казнадан ат та алдым, көзге сайлаулар вакытында, үземне авыл советына член да итеп уздырдылар...* М.Гали. *Бер бүлмәле казна йортының стенасыннан, күз явыңны алырдай җете*

*бизәкле келәмнән, чәчәкләр сиңа балкыйлар.* Г.Ахунов

2) Шул байлыкларның хуҗасы булarak дәүләт үзе һәм шул байлыклар белән идарә итә торган дәүләт учреждениесе. *Үткән көз мин лашманда казна хезмәтендә йөргән вакытта, имана түләргә юне булмаганга, минем хатынның актык кәҗәсен саттыргансыз.* М.Галәү. *Тирә-як авыллардан казнага тиреяры, сүс, йомырка җыю өчен контракт төзергә йөри, ди.* И.Гази. *Әй, чукынып китсәң иде шул казнаң белән!* Т.Гыйззәт

3) Байлык, хәзинә; тупланган акча. *Байлык Ходай биргәннән, казна тапканнан, очраклы рәвештә байлыкка юлыгудан кебек җаваплар белән изах ителә килә.* Г.Нигъмәти

4) *неол.* Дәүләт бюджеты

5) *күч.* Тупланма, тупланыш. *Син генә иң нечкә хисләр, нечкә моңнар чишмәсе, син тавышлар казнасы һәм син уеннар патшасы.* Ш.Бабич

◊ **Казна суы** *иск.* Аракы, исерткеч эчемлек. *Корбангали тегүчене тамак колы дип әйтеп булмаса да, --- «казна суы»н артка куймаганлыгы билгеле.* Ф.Хөсни

**КАЗНА** II *и.* 1) *к.* **казналык**. *Миңа сугып карасын иде, мин аның теш казнасын кулына тоттырып җибәрер идем.* Т.Гыйззәт

2) Сәке йөзлеге

3) Мич асты куышлыгы, шул куышлыкны каплаган агач кыса; нигез. *Башкаларга сиздерми генә, каенишь, мич казнасын кара, дип кенә әйтә алды.* Т.Гыйззәт

**КАЗНА́БАШЫ** *и. тар.* Халыктан барлык төр дәүләт салымнарын җыючы; шул җыемнар белән идарә итүче кеше. *Әмир Хаҗи, гомумән, тимерчеләр, һөнәрчеләр белән кызыксынмады, казнабашы җыем һәм салымнарны төгәл үти, кул астындагы җиде-сигез кеше белән барысына да өлгерә.* М.Хәбибуллин

**КАЗНАЛЫК** *и.* Тешләр урнашкан яңак сөяге. *[Япон акуласының] Өске казналыгы алга таба сузылып, үзенә бертөрле үсенте хасил итә.* В.Сабуев

**КАЗНАЧЕЙ** *и. рус* 1) Учреждениеләрдә, җәмәгать оешмаларында акча һәм кыйммәтле әйберләр белән идарә итүче

2) Гаскәри частьларда: азык-төлек, кием-салым, акча кабул итеп, аларны өләшү эшен башкаручы кеше

**КАЗНАЧЕЙЛЫК** *и.* Казначей вазифасы

**КАЗНАЧЫ** *и. иск.* Казнаның иминлеге өчен җаваплы кеше

**КАЗНАЧЫЛЫК** *и.* 1) Казначы булу; казначы вазифасы

2) *к.* **казначейлык**. *Сәхип солдат үзе болай аңлатты: шәһәр башлыгы Дьяченко бу эшкә риза булган, әмма управада казначылык эшен алып баручы гласный Борһан Муллин моңа каршы килгән.* Ә.Фәйзи. *Казначылык департаментының төп функцияләре – республика бюджетын төзү, гамәлгә ашыру, --- департамент компетенциясе чикләрендә методологик һәм инструктив материаллар булдыру.* Фәнни Татарстан

**КА́З ӨМӘСЕ** *и. этн.* Көзен казлар суйган вакытта, каз мамыгын йолку һәм эшкәртү өчен, яшь киленнәр, кызлар чакырыла торган, үзенең махсус йолалары булган уен-көлкеле өмә. *[Гөлбану] --- каз өмәсенә, урак, печән өмәләренә чакырылганда, --- ананың йөрәге бер дә тыныч кала алмады.* Г.Ибраһимов. *Туйга бик әзерләнер идем дә, Гарәфи абзый, каз өмәләре җитмәгән шул.* Г.Әпсәләмов.

**КА́З ТӘПИЕ** *и. бот. к.* **каз үләне**

**КАЗУ** *ф.* 1) Көрәк белән җирне әйләндереп йомшарту. *Ул көрәк алды да, тирән батыра-батыра, чи калган бер җирне казырга тотынды.* Г.Гобәй

2) Туфрагын, балчыгын чокып ала барып, тирәнлеккә уенты ясау. *Башта без әнә тегендә пулемёт оялары казыдык.* И.Гази. *Башта ул, абзар читәненә терәп үк, тышкы якта чокыр казыды.* С.Зыялы

3) Җир астыннан чокып чыгару. *Җирне чукыйсың, чукыйсың, күкрәк көчләре белән казып, патша сарайлары салырлык алтын табасың.* М.Фәйзи

4) Җирдән актарып чыгарып җыю. *Кешеләр бәрәңге казырга чыкканнар, басуларда инде ут та ягып җибәргәннәр.* М.Мәһдиев

5) Тоягы яки тырнаклары белән азык эзләп тырнау, актару; тибенү. ---*безнең бабайларда кыш көне тибендә йөри торган хайваннар булган. Ягъни, атлар һәм сарыклар, чөнки алар гына тояклары белән артык тирән булмаган карны казып, тибенеп азык таба белгәннәр.* З.Мифтахов

6) Колак, борын тишекләрен, теш араларын чоку. *Ул өйгә кергәндә, карт ялгызы гына өстәл янында тешләрен казып утыра, Сәхип өстәл җыйнаштырып маташа иде.* Ш.Камал. *Илдар, казыма борыныңны, бармагың сынар.* Г.Гобәй. *Ул, печән бөртеге алып, йөзен сыта-сыта тешен казырга кереште.* М.Шәрифуллин

7) *күч.* Төпченү, тикшеренү, казыну

◊ **Казыган базына төшкән** Кешегә яманлык теләп, үзе бәлагә тарыган кеше турында. **Казып чыгару** 1) Булган вакыйганы хәтердә яңартып, искә төшереп сөйләү, булып үткән эш-хәлләрне кабат күңелдә яңарту. *Күңел сандыгымның төбендә сакланып калган алтын бөртекләрен акрын-акрын актарып, берсе артыннан берсен казып чыгарам.* Гали Рәхим. *Бездә шулай инде ул, бер-бер бәхәс чыга калса, кырык бабаңның кабер такталарын кубаралар, әллә кайчан онытылып беткәнне казып чыгаралар, «сөякләрен юарга» керешәләр.* Ф.Яхин. *Бер күмгәч, ул аны күңеленнән казып чыгара алмый.* Ф.Хөсни; 2) Кирәкмәгәнне күрү, чокчыну, урынсыз сүз чыгару. *Нәрсә казып чыгара бу тагын кирәкмәгәнне!* Н.Исәнбәт. *Тимерхан алдында оятлы итмә инде мине, әллә кайчангы гөнаһларымны казып чыгарма.* Г.Ахунов; 3) Җинаятьнең эзенә төшү, эзләп табу. *Бригадир итеп куйгач ук әйттем: «Нәфисә өчен җаным фида, бодаен җир астыннан казып чыгарырмын», – дидем.* Г.Бәширов

**Казый башлау** Казырга тотыну. *Әле кичә генә яңа скважина казый башладык.* Безнең гәҗит

**Казый тору** 1) Башкалардан алдарак, бераз, берникадәр казу. *Тапса, ярдәм килгәнче тишек турысын казый торыр.* И.Гази

2) Казыган өстенә казу, озак казу. *«Тагын бер төртәм дә, тагын бер*

*төртәм дә...» – дип казый торгач, тагын берничә көрәк калынлыгы җир үтте ул.* Г.Гыйльманов

**Казып алу** Тиз генә, тиз арада казу. *– Позициясе дә җайлы, обзоры да киң, – диде ул үз-үзенә һәм ашыга-ашыга кардан окоп казып алды.* Г.Әпсәләмов

**Казып ату** Аннан-моннан тиз-тиз казу

**Казып бетерү** Бөтенләе, тулысы белән казу. *Тимерхан абый, үзебез казыйбыз, хәзер кыш көне түгел, җирдә туң юк, без аны, алмаш-тилмәш, бер сәгатьтә казып бетерәбез, диделәр.* Г.Ахунов. *Карчык бер буразна бәрәңгене казып бетереп килгәндә, бакчага берәм-берәм көрәк, чиләген тотып, авыл хатыннары җыела башлады.* Р.Газизов

**Казып кую** Казып, әзер хәлгә китерү

**КАЗУАР** *и. индон. зоол.* Казуарлар семьялыгыннан Төньяк-Көнчыгыш Австралия яр буйларында, Яңа Гвинея тропик урманнарында яши торган, башында мөгезсыман үсентесе булган, башы каурыйсыз йөгерүче эре кош. *Шуннан соңгы тикшеренүләр Австралия һәм Көньяк Америка илләрендә яши торган тәвә, моа, эму һәм казуар кебек авыр әйтелешле эре кошларның моннан 65 миллион ел чамасы элегрәк очудан туктауларын күрсәткән.* Ватаным Татарстан

**КАЗУИСТ** *и. лат. махс.* 1) Суд практикасында катлаулы, буталчык эшләрне хокук нормаларына нигезләнеп, оста логик фикерләп чишкән юрист

2) *күч.* Ялган, шикле әйберләрне дә төрлечә чуалтып, оста итеп ышандырып, дөрес дип исбат итүче кеше

**КАЗУИ́СТИКА** *и. лат.* 1) *юр.* Гомуми юридик закон статьяларын төрле очракларга карата куллану

2) *күч.* Ялган, шикле очракларны исбат итүдә осталык, тапкырлык

**КА́ЗУС** *и. лат.* 1) *юр.* Суд практикасында катлаулы һәм буталчык эш

2) *юр.* Тышкы билгеләре белән закон бозган сыман, ә гаепләү элементлары булмаган, шуның өчен дә җавапка тартылмый торган очраклы хәл, ялгышлык

3) Гадәттә катлаулы, буталчык, көлкеле вакыйга

**КА́З ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Розачәчәклеләр семьялыгыннан, вак яфраклы, сары чәчәкле кыска үлән; *русчасы:* **гусиная лапка**. *Түбән башы бераз чүпле, урыны-урыны белән билчән, каз үләне баскан.* Г.Ибраһимов

**КАЗ-ҮРДӘК** *җый. и.* Гомумән казлар һәм үрдәкләр, кош-кортлар. *Аларга [адашып чит-ят утарга кергән бәрәннәрнең ара-тирә кычкырып куюына] капка төпләрендәге яшел чирәм өстендә түшәлеп яткан каз-үрдәкләрнең мыгырданып сөйләшүе өстәлә.* Г.Гыйльманов. *Шәйхи карт --- сарай әйләнәсендә каз-үрдәкләрне куыштыргалап йөри иде.* М.Мәһдиев

**КАЗЧЫЛЫК** *и.* Каз үрчетеп, үстереп халыкка сату эше. *Моннан 5 ел элек казчылык бик отышлы иде әле. Бәяләр дә тәмам бәйдән ычкынмаган, катнаш азык заводлары да яхшы эшли иде. Хәзер акчага – им, казларга җим җитми башлады.* Идел

**КАЗЫГЫЧ** *и.* Казый торган корал; казу өчен яраклаштырылган әйбер

**КАЗЫ** *и.* Майлы ат итен вак-вак кисәкләргә турап эчәккә тутырып, ышык җиләс урында кагайтып, гадәттә, өйдә әзерләнә торган ашамлык; колбаса. *Зикремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз.* Г.Тукай

**КАЗЫЙ** *и. гар.* Шәригать законнарына нигезләнеп хөкем итүче рухани; хәким, судья. *[Хуҗа:] Өч сум өчен минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы*? Н.Исәнбәт. *Эш бик зурга китсә, казыйга хөкемгә барырга туры килә.* М.Гафури. *Казыйлар ярлыларны яратмыйлар.* Д.Аппакова

**КАЗЫЙЛЫК** *и.* Казый вазифасы. *Тагын бер елдан --- имамәтлек хезмәтендә исә ихлас гадел кеше сыйфатында танылып өлгергән Р. Фәхретдиновка --- казыйлык дәрәҗәсен тәкъдим итәләр.* Казан утлары

**КАЗЫЙХАНӘ** *и. гар.-фар. тар.* Казыйлар мәхкәмә эше башкара торган бина

**КАЗЫК** *и.* 1) Бер башы очланып, җиргә кагып утыртыла торган кыска колга. *Кода кеше казык башына зәһәрләнеп тагын бер сугып алды.* Г.Бәширов. *Инешнең икенче ярына чыгып, казык кага ул. Менә шушында Җәмил солдатның нигезе булачак.* Г.Ахунов. *Яр буенда ике кешенең колачы көчкә генә җитәрлек юан өянкеләр үсә, алар ышыгында казыкка бәйләнгән кимәләр тезелеп киткән.* Т.Әйди. *Бер карт яшелләнеп муртайган, казыклары авышкан киртәгә сөялгән.* М.Мәһдиев

2) *күч. сөйл.* Берле (1) билгесе (мәктәптә иң түбән билге)

◊ **Казык башына тукмак** Берсе өстенә икенчесе дә килү (мәшәкать, бәла). *Ансыз да өзек тә өтек тормышларына тагын бер ятимәнең килеп өстәлүе казык башына тукмак булды.* М.Хәсәнов. **Казык башына утырту** 1) Каты җәза төре; 2) Җәзалау; каты җәзага дучар итү; 3) Алдау. **Казык кагу** 1) Үз йорт-җирен җиткерү, шәхси хуҗалыгын булдыру. *Бабайлар, казык каккан җиргә мал ияләшер, дигәннәр.* Ә.Еники. *Күреп торасыз, кардәшләр, тормышыбызны буш урынга, тигез җиргә казык кагудан, беренче учак ягудан, беренче казан асудан башларга туры киләчәк.* М.Хәсәнов; 2) *к.* **казык утырту**. *Дәфтәреңә казыклар кагалар, сеңелкәй.* Д.Аппакова. **Казык төсле (кебек) тору** 1) Катып калу, хәрәкәтсез тору; 2) Сынын туп-туры тоткан, иелергә-бөгелергә иренгән кешегә карата әйтелә. **Казык утырту** Берле билгесе кую. *Әниеңә әйт түлке, миңа казык утыртмасын.* Г.Гобәй

**КАЗЫ́К ЙОЛДЫЗ** *и. астр.* Поляр йолдыз; Тимер казык йолдызы. *Артык кайнар, бунтарь хисләремне Бәйләп куям Казык йолдызга.* Р.Низамиев

**КАЗЫ́К ТЕШ** *и. анат.* 1) Алгы кискеч тешләрдән соң урнашкан, башка тешләрдән калкып аерылыбрак торган тешләр, кабан теш (кеше һәм имезүче хайваннарда); *русчасы:* **клык**. *Яшь баланың казык теше алдан чыкса – усал була.* Сынамыш. *Озын казык тешле Кабан Дуңгызы да, койрыгын бот арасына кыстырып, яхшы чакта качып калу ягын хәстәрләде.* Р.Батулла

2) Авыз куышлыгыннан ике яклап тышка чыгып тора торган зур тешләр; *русчасы:* **бивень**. *1970 нче еллар башында Иделнең уңъяк яры буенда*

*Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылы янында, яр астыннан мамонтның казык теше сыныгы килеп чыга.* Р.Фәхретдинов

**КАЗЫЛДЫК** *с.* Борынгы дәверләрдә яшәп, үсеп, хәзер җир кабыгы катламында катып калган, шуннан казып табылган

**КАЗЫЛМА** *с.* **1.** 1) Казып табыла, казып чыгарыла торган

2) *к.* **казылдык**. *Африка саваннасы. Саваннада кайназой эрасында яшәгән казылма җәнлекләргә охшаш ялгыз агачлар.* М.Юныс. *Инде күптән үлеп беткән кайбер казылма акулаларның тешләре төшмәгән.* Кызыклы физиология. *Палеонтология үлеп беткән организмнарның казылма калдыкларын өйрәнә.* Биология

3) *күч.* Эволюция тукталган, борынгы заманнардагыча үзгәрешсез калган. *Гаттерияләр – бик борынгы тереклек ияләре, чын мәгънәсендә тере казылма хайваннар.* Кызыклы физиология

**2.** *и. мәгъ.* 1) Җир астыннан казып чыгарылып табылган әйбер, җир асты байлыгы. *Җир асты казылмаларына үзе хуҗа булу гарәпләрнең матди хәлен бик нык яхшырткан.* Т.Галиуллин. *Болгар казылмаларында кабан яисә дуңгыз сөякләре табылу читләтеп кенә тагын шуны бер кат раслый.* З.Мифтахов

2) Юлдагы чокыр-чакыр, сикәлтәләр

3) Тирән итеп казылып кергән чокыр. *Шул тынлыкта күпер янындагы казылмадан хатын-кыз тавышы ишетелде.* К.Нәҗми

**КАЗЫЛМАЛЫ** *с.* Чокыр-чакырлы, сикәлтәле. *Мотоцикл казылмалы урман юлыннан алга элдерде.* С.Рафиков

**КАЗЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **казу**. *Ике яктан канау казылган, сирәк-сирәк кенә каеннар үсеп тора торган, телефон, телеграмм баганалары тезелгән киң юл буйлап, --- дырык-дырык атлап килә.* М.Гали

2) Чокыр-чакырлар ясалу, сикәлтәләр барлыкка килү. *Алар гранаталар, миналар ярылуыннан казылган, каралган урынга кадәр барып җиттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Таш түшәлмәгән бу юл да, без очраткан башка юллар шикелле үк казылып, җимерелеп беткән иде.* А.Шамов

3) Җиргә уелып керү. *Балчык белән сыланган бу читән өй яртылаш җиргә казылган, түбәсе туфрак белән тигез капланган.* Г.Ибраһимов

**Казыла башлау** Казылырга тотыну. *1997 елның март аенда Кремль эчендә урнашкан, 1991 елга кадәр хәрбиләр казармасы булган дүрт катлы бина алдында --- диаметры илле метрлар чамасындагы чокыр казыла башлый.* З.Зәйнуллин

**Казыла төшү** Тагы да бераз, тирәнгәрәк казылу

**Казылып бетү** Тәмам чокыр-чакырланып казылу; ахыргача казылу, казуны төгәлләү

**Казылып калу** Ниндидер сәбәптән соң казылу; казылган хәлгә килү

**КАЗЫЛЫК** *и.* **1.** 1) Атның түш ите. *Йортта кунак булгач, ит пешкәндер, казылыктан бер согынып килим дип уйлады.* Г.Ибраһимов. *Чак кына сабыр итегез, хәзер мин сезгә берәр таба казылык булса да кыздырып бирим.* М.Хәсәнов

2) *сөйл. к.* **казы**. *Бу сәфәргә, гадәтенчә, бер ярты казылыкны кәгазьгә төреп алып чыккан иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Алар белән кунакка чакырышты, симез елкы казылыклары, сары майда гына пешкән бәлешләр белән сыйлашты---.* Г.Ибраһимов. *Аннары инде каклаган каз, камыт бөяте кадәрле казылык, атланмай һәм берничә төрле таба ашлары өстәл өстенә өелде.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Казы ясар өчен яраклы (ит тур.). *Казы ул бары тик җылкы итеннән генә, казылык иттән генә ясала.* Татарстан яшьләре

**КАЗЫЛЫКЧЫ** *и. сир.* Казы ясау остасы, казылык әзерләүче. *Җирән биягә атланган күк фәсле кешенең казылыкчы Хәйрулла икәнен белгәч, Сөләйманның аңа карап эче катып көләсе килде.* К.Тинчурин

**КАЗЫМА** *и. диал.* Лом, тимер таяк. *Юл буенда җансыз һәйкәл шикелле ---, көрәк вә казымаларына таянган хәлдә, поездны озатып калучы --- кешеләр күзгә чагылып кала.* Ш.Камал

**КАЗЫМТЫ** *и.* Казылып кергән урын, чокыр. *Грузовик ниндидер казымтыга дырык итеп утырды.* С.Рафиков

**КАЗЫНУ** *ф.* 1) Җирдә эшләү, нәрсә булса да үстерү, игү. *Андагы эшне тавык та чүпләп бетерерлек түгел: ашлык сугасы бар, яшелчә бакчасында казынасы бар, утын әзерлисе, мал карыйсы…* Г.Гыйльманов. *Баш күтәрми бакчада казыну, чүп үләне утау белән генә бастырып булмый икән шул эшкә сусауны.* Г.Мирһади

2) Берәр җирдә чокчыну, актарыну, нәрсә дә булса эзләнү. *Акбай хуҗасы белән шәһәр читендәге чүпрәк-чапрак, чүп-чар ташланган урыннарда булды, йорт алдындагы әрҗәләрдә казынды.* К.Латыйп. *--- теге малай һаман әле чүп савытында казына иде.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Онытылган әйберләрне кабат күңелдә яңарту, искә төшерү. *Хәзер инде үткәндә генә казынырга түгел, киләчәкне кайгыртырга кирәк.* Т.Әйди

4) *күч.* Чокчынып эзләнү, асылына төшенерлек итеп тикшеренү, төпченү, җентекләү. *Андагы дәресләргә йөреп, алманчасын да шомарта төште, китапханәдә казынулар да файдага китте.* Т.Әйди. *Бик катлаулы ул «психология»дә һич тә казынасы килеп тормый.* З.Мифтахов. *Компьютерда казынырга дигәндә рәхәтләнеп китәм, ул эштә балык кебек йөзәм.* Татарстан яшьләре

5) *күч.* Акрын кыймылдау, мыштырдау. *Ни шайтаныма шулкадәр озак казыналар дип уйлады.* И.Гази

6) *күч.* Җитешсезлекләр, кимчелекләр табарга тырышып төпченү. *Янәсе, күрәсең килсә күр, бухгалтер-инструктор: синең пүчтәк казынуларыңнан берни дә барып чыкмады.* Г.Ахунов. *Абвер казынып фаш итсә, моның өчен кайберәүләрнең вакытсыз гүргә керәчәге ачык иде.* Т.Әйди

**Казына башлай** Казынырга тотыну. *Бераз баргач, алар туктап, куак төбендә казына башладылар.* Р.Вәлиев. *Әни авызыннан: «Әйбәт кенә булдылар, карышмадылар», – дигән җөпләү ишеткәч, саран гына елмаеп, кесәсендә казына башлый.* Сөембикә

**Казынып алу** Бераз, кыска вакыт арасында казыну

**Казынып йөрү** Анда-монда, төрле урыннарда казыну. *Әйе, сине күрми йөргәнбез, алданрак күтәрәсе калган*

*икән, синең көчеңне сизгән ул адәмнәр бездә болай казынып йөри алмас иде.* Р.Мирхәйдәров

**Казынып калу** Вакытыннан, мөмкинлектән файдаланып казыну, казынырга өлгерү; казынуны дәвам итү. *--- комсомол ячейкасы секретаре Нәҗми белән бюро члены Җамал гына, ячейка эшләрен актарып, нәрсәләрдер казынып калдылар.* М.Әмир

**Казынып карау** Сынау өчен казыну. *Казынып карасаң, һәркемнең тормышында оялырлык, бит кызарырлык зур яисә кечкенә вакыйгалар була.* Безнең гәҗит

**Казынып тору** Һәрвакыт, гел, бертуктаусыз казыну

**Казынып утыру** Үзалдына, бертуктаусыз казыну. *Күңел төбемдә казынып утырган чакларда шул вакыйга исемә төшә.* М.Әмир

**Казынып яту** Озак вакыт казыну процессында булу. *Юкса эштән ел буе арына алмас, хуҗалыкта, бакчада гел казынып ятыр идек.* Татарстан яшьләре. *Мин, читтән торып укыган студент, университет китапханәләрендә казынып ятканда, үзебезнең Мөслим районы оешты, газета чыга башлады.* Ватаным Татарстан

**КА́З ЮЛЫ** *и. астр.* Аяз төндә гади күзгә якты ак юл булып күренә торган йолдызлар тупланышы; Киек каз юлы. *Каз юлыдай сузылып кала паровозның төтене.* Ф.Кәрим

**КАЙ** *а.* 1) Нинди, ни, кайсы. *Кай төшеннән мин моны, дим, ләктерим?* Г.Тукай. *Кай төштә салмак-әкренрәк, кай төштә югарырак-көчлерәк – шуларга игътибар итегез.* Ә.Еники. *Кай ара яхшы ук көчәеп, кай ара тоныкланып, дәртле җыр тавышлары яңгырый.* С.Рәфиков

2) *к.* **кайбер**. *Хәлим, --- әнисенең кай көннәрдә аш пешерергә дә вакыты булмаганны хәтерләп, эндәшми калды.* Г.Гобәй

3) *к.* **кая**. *Туып килгән яңа ел безгә нәрсә әзерли дә, язмыш сукмаклары безне кайларга алып бара?* А.Шамов

◊ **Кай җирең кычыта** *ирон.* «Бик нык кыйнау, бөтен җиренә сугу» мәгънәсендә. **Кай таба** Нәрсәне булса да бик нык мактаганда әйтелә. *Улының аягындагы читеге кай таба!* Ә.Фәйзи. **Кай тирәдә** Эш яки хәлнең торышын, үтәлү дәрәҗәсен сораганда кулланыла; ничек, ни хәлдә. *– Я дускай, эшләр кай тирәдә, андагы иптәшләр ничек, минем хатны алдыңмы? – дип, ул Фәтхигә бер-бер артлы сораулар биреп куйды.* Ш.Камал

**КА́ЙБЕР** *а.* Арадан аерып берничәсе. *[Шәкертләрнең] кайберләре, туңган әгъзаларының әрнүенә чыдаша алмыйча, сыкрап еларга керешә.* Т.Гыйззәт. *Баштарак кайбер көйләрне ярыйсы гына уйный идем.* Ә.Еники

**КА́ЙБЕРӘҮЛӘР** *а. купл.* Кайсыбер кешеләр, кайсылары. *Кайберәүләрнең аптыраулары эчләренә сыймый, алар кычкырып ук җибәрәләр.* А.Әхмәт. *Үзенә күрә бер хобби: кемдер маркалар җыя, кайберәүләр буш шырпы капларыннан коллекция туплый.* М.Хәсәнов

**КА́ЙВАКЫТ** *рәв.* Кайчан, вакытывакыты белән, ара-тирә, аерым вакытларда. *Кайвакытлар һәр сәгадәттән өмидемне өзәм.* Г.Тукай. *Күренә бәгъзан ярты икмәк төсләнеп, кайвакыт кызлар кашыдай нечкәреп.* Ш.Бабич

**КА́ЙВАКЫТНЫ** *рәв. к.* **кайвакыт**. *Ләкин нишләмәк кирәк, кайвакытны яныңда утырса да, бер авыз сүз дә әйтә алмыйсың.* Г.Бәширов. *Кәеф кайвакытны күтәрелә, кайчакта төшә.* Казан утлары

**КА́ЙВАКЫТТА 1.** *а. к.* **кайчак**. *Тик менә сезнең белән аңлашырга кирәк: сезнеңчә кайвакытта мәслихәт булыр?* Ш.Камал

**2.** *рәв. к.* **кайвакыт**. *Биш яшьлек энесе, җиде яшьлек агасы кайвакытта аны чәченнән тартып елаталар, кайвакытта, сугып китеп, аңар золым итәләр иде.* Ф.Әмирхан

**КАЙГЫ** *и.* 1) Газап, хәсрәт, рухи сызлану кичерүдән гыйбарәт тирән психик халәт; җанны әрнеткеч авыр тойгы. *Кайгы – йөрәккә батып, кисеп кергән агулы хәнҗәр.* И.Салахов

2) Авыр тәэсирләр уята торган эш, хәл, вакыйга; бәла-каза, афәт. *Әйтерсең лә бүген бер шомлы кайгы булачак – ул шуны сизә.* Ф.Кәрим

3) Мәшәкать, башкарып чыгарга тиешле эш турындагы уй. *Боларда урак кайгысы түгел болай булгач.* В.Нуруллин. *Бәләкәй чагында баланың хәсрәте дә бәләкәй, ә үскәч кайгысы үзеннән дә зур була икән.* М.Насыйбуллин. *Бүген ул, дөнья кайгыларын онытып, тулысынча дин-йола, ата-баба кайгылары белән мәшгуль.* Н.Фәттах

4) Теләк, ихтыяҗ. *Икешәрләп, өчәрләп укмашкан сарыкларда инде ашау кайгысы беткән, бер-берсенең күләгәсенә сыенып, әлсерәгән хәлдә, үләнгә битараф карап торалар.* М.Галиев

5) Борчып торган уй, фикер. *Бар белгәне акча күбәйтү вә мал кайгысы гына.* Ш.Мөхәммәдев. *Аны күрер өчен бер юл табу кайгысы каплап алган иде.* Ф.Әмирхан. *Хәзер мал кайгысы түгел, җанны саклап алып калырга кирәк.* З.Зәйнуллин

6) Мәнфәгать; мәсьәлә, проблема. *Айсылуның бу картка торган саен ихтирамы арта бара, ил кайгысын шулай чын күңелдән кайгыртуы аңа аеруча ошый иде.* Г.Бәширов. *Гадел кеше, диләр аны, крестьян кайгысын аңлый торган кеше.* К.Нәҗми. *Мәрьям абыстай исә, чын ана буларак, гаиләнең эчке сәясәте турында гына уйланудан һәм балалары кайгысын гына кайгыртудан уза алмый.* Ә.Еники

7) Игътибар, дикъкать. *Ул Зыяга кыенлык булыр, ул газап күрер, авыр яшәр диеп уйламый, ничектер бу бер дә аның башына килми һәм кайгысы да ул ноктада түгел.* Г.Ибраһимов. *Аларда кайгым юк, өйдәге нәрсәләремне генә харап итә күрмә.* М.Фәйзи

◊ **Кайгы басу** Бик зур кайгы килү; күп төрле кайгылар берсе өстенә берсе өелү. *Ләкин күтәргесез авыр кайгы басты аны, ә шулай да җиңә алмады.* Г.Гобәй. **Кайгы болыты** Бөтен халыкның да бердән хәсрәт тойгысы белән йөрү халәте. **Кайгыга бату** Бик нык кайгыру, тирән борчуга төшү, хәсрәтләнү. *Анда тормыш кайгы сөременә батканлыгын кошлар да сизә.* Ф.Кәрим. *Хәтта бу минутта ул [Габдел-басыйр] чын күңеле белән зур бер кайгыга батты.* Ф.Әмирхан. *Берәр сәбәп аркасында кибеткә ипи кайтмый калса, хатын-кыз кара кайгыга бата.* М.Мәһдиев. **Кайгыга калу** *к.* **кайгы-**

**га бату**. *Гайфулланың фаҗигале үлемен, японнарның мәкерлелеген онытаалмыйча, кара кайгыга калып йөрде.* Ә.Ахунов. **Кайгыга салу** Кайгы китерү, борчу ясау, аптырауга калдыру. *Мин моны тик сезнең өчен генә, бигрәк тә сине кайгыга салмас өчен эшләдем.* А.Шамов. **Кайгыга төшерү** *к.* **кайгыга салу**. **Кайгыга төшү** *к.* **кайгыга бату**. **Кайгы йоту** Кайгысын кешегә белгертмичә кичерү, эчтән яну. **Кайгы күрү** Кайгысы булу, кайгырып йөрү. **Кайгы салу** Кайгы китерү, кайгылы, борчулы итү. *Дәрья бәхет бирдем – алмадың, Кайгы салдың тыныч күңлемә.* Н.Исәнбәт. *Ләкин бу юлы аның елавы Гарифның күңеленә тупас өметсезлекләр, ачы кайгылар салмый, бәлки аның күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык, эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде.* Ш.Камал. **Кайгы сөреме** *к.* **кайгы болыты**. **Кайгы төшү** Кайгы килү, кайгыда калу. **Кайгы чигү** *к.* **кайгы күрү**

**КАЙГЫЛА́У** *ф. сир. к.* **кайгырту** (*2, 3 мәгъ.*)

**КАЙГЫЛЫ** *с.* 1) Кайгыга тарыган, кайгыга дучар ителгән. *Ябык, кайгылы Гөлйөзем, өзелеп-өзелеп, үзенең солдатта югалып калган ире Усманны сөйләде.* Г.Ибраһимов. *Тик кайчан гына әле пешергән казларын мактап-мактап ашаган, өендә кунак булган адәмнәр кайгылы хатынны тыңларга да, ярдәм кулы сузарга да вакыт тапмадылар.* Г.Мирһади. *Фашистлар ботарлап ташлаган Вәрисәнең кайгылы йөзе өнендә дә, төшендә дә тынгылык бирми йөдәтә...* Г.Гыйльманов

2) Кайгылардан торган, кайгылар белән тулы, борчулы. *Шул ирексез, кайгылы сәфәр алдыннан бу ыруның өлкәннәреннән саналган Ходайбиргән әкә әрвахларга илнең соңгы догасын тапшыра.* И.Салахов

3) Кайгы билгесе булган, кайгы чагылдырган. *Тик бу юлы күрделәр анда кайгылы рәсмен аның.* Һ.Такташ. *Кемдер, егетләрдән берсе, гармонь тартып җибәрде, кемнәрдер бераз исерек, шулай да матур, моңлы кайгылы тавыш белән озын көйгә сузды.* Г.Ибраһимов. *Йосыф аны юатырга тырышып, сәкенең бер очына утыра, Һаҗәрнең агарган йөзенә, эчкә батып кергән кайгылы кара күзләренә карый.* К.Нәҗми

**КАЙГЫЛЫ́-ХӘСРӘТЛЕ** *с.* Кайгылар һәм хәсрәтләр белән тулган. *Андый вакытларда мин иң кайгылы-хәсрәтле уйларны башыма китереп карыйм, үлем турында уйлап карыйм, --- ләкин берсе дә файда итә алмый, һаман да көләсе килә.* М.Әмир

**КАЙГЫРТУ** I *ф.* 1) Кайгыга салу, кайгылы итү. *Аның хәзер ни хәлдә булуы да хәзрәтне кайгыртмый.* Г.Ибраһимов

2) Нәрсәгә дә булса алдан әзерләнү, хәстәрен күрү. *Театр булса да, театрдагы иҗат эшләрен тәгәлләү өчен, миңа кечкенә бер отпуск бирү турында кайгыртсын иде.* М.Җәлил. *Хәстәрен алдан күрергә өйрәнгән балалар инде яңа дәреслекләр турында, алдагы ел өчен карандаш-каләм турында кайгырттылар.* Г.Гобәй. *--- ындыр табагында колхоз амбарына кертелмичә күпмедер борчак калды – син шул турыда кайгырт әле.* К.Латыйп

3) Берәр кешегә яки нәрсәгә карата кайгыртучанлык күрсәтү, игътибар бирү, дикъкать итү. *Ай йөзәдер күк йөзендә, Кем дә кайгыртмый аны.* Ф.Бурнаш. *Командир үзенең сугышчылары турында туктаусыз уйлар уйларга, кайгыртырга тиеш.* Г.Әпсәләмов. *Колхозларны бер Борһанов кына кайгыртмый, алар бюро әгъзаларына бүлеп бирелгән.* Г.Ахунов

4) Уйлау, борчылу. *Сан артыннан гына кума, сыйфат турында да кайгырт.* Р.Ишморат. *Әйе, әйе, дөнья ул – мәхәббәт бер оя, тик ярлар гына ишелмәсен, менә шул турыда кайгыртырга кирәк.* К.Латыйп. *Иң әүвәл елга ярларын ныгыту, уңдырышлы җирләрне саклау, дамбаларны өю белән бергә, республикабызны илгә, дөньяга танытткан нефть ятмалары мәйданнары турында да кайгыртырга кирәк иде.* М.Хәсәнов

**Кайгырта башлау** Кайгыртырга тотыну. *Һәр төбәк кенә түгел, үз белгечләрен эшле итү буенча һәр вуз кайгырта башларга тиеш булып чыга.* Ватаным Татарстан

**Кайгыртып йөрү** Һәрвакыт, даими кайгырту, бар итү, булдыру. *Өстәл янына килеп утыруга, әнисенең караңгы белән үк торып аны кайгыртып йөрүе Гайнанның күңелен йомшатып җибәрде.* Г.Бәширов. *Халидә, телдән алтын таулары вәгъдә итмәсә дә, йорт һәм хуҗалык кирәкләрен күңеленнән бик нык кайгыртып йөри иде.* Ф.Хөсни. *Без икенче штурман Китайгородский белән вахтада торабыз, мәҗлесләрнең барышын, кемгә эчемлек, кемнәргә ашамлык кирәклеген кайгыртып йөрибез.* М.Юныс

**Кайгыртып тору** Һәрвакыт кайгырту. *Кемнең нәрсәсе җитеш түгел, кем нәрсәгә мохтаҗ, хәзер бу турыда Фәрдәнә үзе кайгыртып торды.* Г.Гобәй. *Хан ялчыларының зур катламы казнага акча кертүне кайгыртып торган: ясак, гошер (пошлина) җыючылар, тамгачылар (таможнячылар), үлчәүчеләр, бахшилар (язу-сызу эшен башкаручылар).* Р.Мостафин

**КАЙГЫРТУ** II *и.* Яхшырту, камилләштерү максатындагы тырышлык, ярдәм итү йөзеннән башкарылган гамәл. *Үтә шәхси бер фактан шагыйрь үзе дә сизмәстән олы борчылуга, халык, Ватан, дөнья язмышын кайгыртуга күчә.* С.Сөләйманова

**КАЙГЫРТУЛЫ** *с. к.* **кайгыртучан**

**КАЙГЫРТУЧАН** *с.* Кайгырта торган, игътибарлы, ярдәм итәргә әзер булган. *Шундый кайгыртучан, шундый яхшы күңелле, ягымлы ир булыр ул аңа.* Ә.Фәйзи. *Ә сез, күренеп тора, куркусыз ир! Һәм кайгыртучан, ярдәмчел ир – чын рыцарь!* Т.Әйди

**КАЙГЫРТУЧАНЛЫК** *и.* 1) Кайгыртучан булу. *Күзләре һәм иреннәре белән елмайган хәлдә, аның йөзендә уйчанлык, кайгыртучанлык чагылып тора иде.* Ш.Камал

2) Кайгырту, игътибарлылык; ярдәм, хәстәр. *Миңа күрсәткән кайгыртучанлыгың өчен сиңа чын күңелдән рәхмәтемне юллап калам.* М.Җәлил. *Дәүләт семья турында зур кайгыртучанлык күрсәтә.* Тигез гомер итегез!

**КАЙГЫРТУЧЫ** *и.* Булдырырга, бар итәргә, эшләргә тырышып йөрүче кеше. *1939 елда үзара һөҗүм итешмәү турында килешү төзегәннән соң, Алмания дус илгә әверелде, аның*

*җитәкчеләре, шул исәптән, Һитлернең милли социалистик эшчеләр партиясе, халык мәнфәгатьләрен кайгыртучылар төсендә таныла башлады.* Т.Әйди

**КАЙГЫРУ** *ф.* 1) Кайгы, хәсрәт кичерү, хәсрәтләнү. *Син кайгырма, чәнчелеп китсәләр дә, мин сине аларга бирмим.* Т.Гыйззәт

2) Нәрсәдер, кемдер турында борчылу, уйлану. *Ишкәйне эшкә авылга җибәрделәр. И шуның өчен кайгырды да инде әнисе.* Т.Әйди. *Шатланырга да, кайгырырга да белмим, әрекмән яфрагы төсле ләпшердәдем.* А.Гыйләҗев. *Дүртле белән бишле арасында барган акыллы укучы өчле алса да әллә ни кайгырмый.* М.Юныс

3) Артыннан йөрү, хәстәрлек күрсәтү, кайгырту. *Заман үтәр, бу ахмак дулкын басылыр, минем фикерләремне шәкерт аңлар, мин алар файдасы өчен кайгырам.* Г.Ибраһимов. *Кеше минем өчен кайгырмый, мин кеше өчен кайгырмыйм.* Р.Ишморат

**Кайгырып алу** Аз гына, кыска вакытлы кайгыру

**Кайгырып йөрү** Бертуктаусыз кайгыру; озак вакытлар кайгыру хәле кичерү. *Урман буенда өрәк булып кайгырып йөргән Хәлимең дә, тынычланып, үз урынына кереп яткандыр инде...* Г.Гыйльманов

**Кайгырып кую** Көтелмәгән сәбәптән кайгыру. *Бу вакыйгаларны сөйләп беткәч, карт бөтен сахрада ялгыз калган адәм тавышы белән кайгырып куйды.* Г.Ибраһимов

**Кайгырып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә кайгыру. *Кыяфәте һаман кайгырып торган кебек күренә.* Г.Камал

**КАЙГЫ-САГЫШ** *җый. и.* Гомумән борчу-сагышлар, хәсрәтләр. *Бу юлы инде егет, ничаклы гына үзен кайгы-сагыш баскан булса да, көлмичә түзә алмый.* Г.Минский

**КАЙГЫСЫЗ** *с.* **1.** 1) Кайгысы булмаган, кайгысы юк (кеше)

2) Борчусыз, тыныч (тормыш, яшәеш). *Шулай итеп бик рәхәт һәм кайгысыз чәй эчеп тәмам иттеләр.* М.Гафури

3) Ваемсыз, пошмас, исе китмәүчән

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кайгылар күрмәстән, кайгылардан башка. *Яшь гомер шулай шатлыкта, кайгысыз үтәргә тиеш кебек күренә.* Г.Коләхмәтов

2) Ваемсызлык күрсәтеп, игътибарсыз рәвештә

**КАЙГЫСЫЗЛЫК** *и.* Кайгымәшәкать булмау; ваемсызлык, игътибарсызлык

**КАЙГЫ-ХӘСРӘТ** *җый. и.* Гомумән һәртөрле борчулар, кайгылар һәм хәсрәтләр. *Гаҗәп, мин сугышта ут эченә кергәндә дә куркуның, кайгыхәсрәтнең ни икәнен белмәдем.* Р.Ишморат. *Юлында тап булган кайгыхәсрәттән арынмаса, аның өчен яшәүнең бер кызыгы да калмас иде.* Р.Хафизова. *Ул [сугыш] кешеләрне ачлык-ялангачлыкка дучар итә, башка күп кайгыхәсрәтләр алып килә.* З.Фәтхетдинов

**КАЙГЫ-ХӘСРӘТЛЕ** *с.* Кайгылары, хәсрәтләре күп булган. *Бәет ул көз көне ага торган караңгы чырайлы, кайгыхәсрәтле Идел шикелле.* Г.Әпсәләмов

**КА́ЙДА** *а.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнең урынын ачыкларга теләп бирелгән сорау җөмләдә кулланыла. *Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?* Г.Тукай. *Солтан Уразбаев иптәш бу палатада булса кирәк, аның ятагы кайда икән?* Г.Ибраһимов. *Ә минем бабаем кайда соң?* Г.Гобәй

2) Нәрсәнеңдер булмавына гаҗәпләнү, көенү белдереп әйтелгән сораулы-өндәү җөмләләрдә кулланыла. *Чәй эч, дип сөйләнәсең дә, кайнаган самавырың кайда соң синең?* Р.Ишморат. *Кайда ул картның элекке гөл кебек яшь чаклары?* Н.Исәнбәт

3) Нилектән, ник, ни өчен. *Бу хәлләрнең, бу черүләрнең сәбәбе кайда?* Г.Ибраһимов

4) *ялг.* Кая. *Калтырыйм, куркам: «Ходай! – дим. – Инде мин кайда барыйм?»* Г.Тукай. *Кайда гына качып котылыйк, дип кычкырып карады, ләкин артык курку сәбәпле, кеше ишетерлек тавыш чыгара алмады.* Ф.Әмирхан. *Кемдә торасың, кайда урнаштың?* Г.Бәширов

5) Төшенчәләрне капма-каршы куеп, «анда»–«монда» мәгънәсендә кулланыла. *Германия кайда да, без кайда.* И.Гази

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кайсы урында, кай җирдә, нинди урында. *Үзенең кайда икәнлеген чак-чак аңлады.* Ш.Камал. *Димәк, сезгә дә сыер алудан элек аны кайда асрау турында уйларга кирәк икән.* Ә.Еники. *Әмма синең белән бу дипломатия өлкәсенә бик тирән кереп китмичә, менә нәрсәне аңлап җиткерик әле: кайда төп көч, икенче фронттамы, әллә үзебездәме?* Г.Бәширов

2) Кай урында булуга карап, урынына карап. *Башым минем тиле булса да, карчык, кайда бөгелергә, кайда югары торырга икәнен белә ул.* А.Шамов

3) «Кайсы урында булса да», «тагын да» мәгънәләрен белдерә. *Мондый хуш исле болыннар безнең колхозлардан башка тагын кайда бар икән?* Ә.Исхак

4) «Бик күп җирдә», «теләсә нинди урында», «кая теләсә, шунда» мәгънәләрен белдерә. *Мин тәмам гиздем җиһанны, – кайда, кайда йөрмәдем.* Г.Тукай. *Кайда гына йөзми, кайда гизми салчы белән юлчы башлары.* Н.Исәнбәт. *Мин кайда гына булмадым, бу кадерле рәсемне кайда гына күрмәдем, аның бөек исемен кайда гына ишетмәдем.* А.Шамов

5) «Нинди генә урында, кай җирдә генә булмасын» мәгънәләрен белдерә. *Аңа кайда да бер... төрмәдә дә ач, монда да ач.* И.Гази. *Кайчан гына, кайда гына очрашмасыннар, хәзер эт кебек үзара эләгешергә генә торалар.* Г.Ибраһимов

6) *әнә, менә* алмашлыклары белән килеп, игътибарны мәсьәләнең асылына, предметның төп урынына юнәлдерә. *«Вәт, – дип уйлыйм мин эчемнән генә, – чын дуслык менә кайда беленә ул».* А.Шамов. *Ә, менә кайда утыралар икән алар.* Ф.Бурнаш. *Менә егетлек кайда, ике үрдәк очрады, икесен дә атып төшерде Әхмәт.* М.Фәйзи

7) Җөмләнең тиңдәш кисәкләре алдыннан кабатланып килеп, «бер урында», «икенче урында…» дип саналып китә. *Кайда ат белән, кайда җәяүләп, авылдан авылга бер ун көнләп йөрде ул.* И.Гази

**3.** *мөн. сүз мәгъ.* Баш җөмләдәге *шунда, анда* алмашлыгын ачыклап, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә ияртү өчен кулланыла. *Аларны кайда күрсәң, шунда үтерергә, ди.* Г.Ибра-

һимов. *Кайда иң батыр, иң чыдамлы сугышчылар кирәк – гвардиннар шунда. Менә бит ул, кайда нечкә, шуннан өзелә.* Т.Гыйззәт. *Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.* Г.Тукай

**4.** *кер. сүз мәгъ.* Я булмаса, һич югында, әйдәле бер. – *Кайда, йөгәнне алып бир әле монда, – дип, ат җигәргә кереште.* М.Гафури. *Кайда, монда ике кешегә сыра китер әле.* Г.Камал. *Кайда, кайсыгызның учына салыйм.* М.Фәйзи

**5.** *кис. функ.* 1) Хәбәре исем фигыль белән белдерелгән тойгылы җөмләдә эш-хәлнең үтәлү мөмкинлеге булмауга басым ясый. *Кайда әле барып җитү.* М.Гафури. *Кайда аңлау миңа! Бер сүз дә аңламыйм.* Г.Тукай. *Кайда монда килү, өйгә дә көчкә генә кайтып җиттем.* Г.Камал. *Ю-ю-юк, җәяү килә алу кайда.* М.Фәйзи

2) Раслау, хуплау төшенчәсен көчәйтеп килә. *Кайда ул картаймаган.* Ш.Камал

3) Үзе генә яки көчәйткеч сүзләр белән бергә килеп, мөмкин булмау, юклык мәгънәсен белдерә. *Миңа уку кайда ул*

**КА́ЙДАГЫ** *а.* 1) Кемнең яки нәрсәнең кай яктан, нинди урыннан булуын белү өчен бирелгән сорау җөмләдә кулланыла. *Әллә соравымны ишетмәде, әллә ишетеп тә, кем булуын һәм кайдагы икәнен әйтергә теләмәде.* А.Шамов

2) Кай урындагы, урынын белеп. *Кайда, кемне ничек күреп, кайдагы кыңгырауны басарга белер идем.* Г.Ибраһимов

**КА́ЙДАДЫР** *а.* Тәгаен билгеле булмаган, кайда да булырга мөмкин булган җирдә яки шундый җиргә юнәлүне белдерә. *Башта кемнәрнеңдер сөйләшүләре, кайдадыр атлар пошкыруы, кичтән үк йокыга киткән егетләрнең мышнаулары, гырылдаулары ишетелеп торды.* И.Гази. *Аның очы кайдадыр, ямь-яшел булып җәелеп яткан болыннар буйлап китеп, күздән югала.* А.Шамов. *Бер атна чамасы кайдадыр эш беләнме, кунактамы йөреп әйләнеп кайтты.* Ә.Фәйзи

**КАЙДАЛЫК** *а.* Урнашкан урын, торган җир. *Ниһаять, баш бандитның кайдалыгын белеп, ул кергән өйне камыйлар.* М.Әмир. *Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан.* А.Алиш. *Зиннәт аны шундый сыздырып уйный, шундый моңлы итеп, шундый үзәкне өзә торган итеп уйный иде ки, Нәфисә, сихерләнгәндәй, үзенең кайдалыгын онытып, хәйран калып тыңлый.* Г.Бәширов

**КА́ЙДАН** *а.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнең нинди урыннан, кайсы яктан булуын ачыкларга теләп бирелгән сорау җөмләдә кулланыла. *Тукта, кайдан килдең син монда, ничек кердең минем яныма!* Ф.Бурнаш. – *Сез кайдан? – дип сорасагыз, Без – Казаннан, Иделдән.* Ә.Ерикәй // Нинди чыганактан, кайсы урыннан, кай яктан, кемнән, нәрсәдән. *Башына киләчәк бәлане белсә, бу адәм, бәлки, Батыргали агай утырган залдан үтмәгән булыр иде; әмма киләчәк казаны кайдан белсен?* Ш.Мөхәммәдев

2) Ник, ни өчен, ни сәбәптән. *Кайдан башыңа керә шундый уйлар?* И.Гази. *Чыкты соң кайдан адаштыргыч буран – бу куркыныч?* Г.Тукай. *Бу җыры кайдан телемә керде тагын?* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кайсы урыннан, кайсы яктан, кайсы баштан. *Ничек, кемгә, кайдан өйләнмәкче буласың?* Ш.Камал. *Кайдан килеп, кайда баруы һичкемгә мәгълүм булмаган бер үткенче мөсафир бабай бездә хәл җыярга туктаган вакытта үлеп калды.* Г.Ибраһимов. *Ул малайның кайдан килүе дә билгеле инде.* М.Фәйзи

2) Ник кенә, ничек, һич уйламаганда. *Булып беткән эшкә бусы кайдан килеп катнашты тагын Габделкәримгә.* Г.Камал. *Кайдан шул торгаш, спекулянт кызына килеп каптың?* Ш.Камал

3) Анык кына билгеләнмәгән урын. *Кайдан булса да акча табарга кирәк*

**3.** *мөн. сүз мәгъ.* Баш җөмләдәге *шуннан* алмашлыгын ачыклап, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә ияртү өчен кулланыла

◊ **Кайдан җил ташлады** «Көтмәгәндә-уйламаганда ничек килеп чыгасы иттең» мәгънәсендә (кемне дә булса каршы алганда). **Кайдан кайда** Җәелеп яткан киңлекне белдергәндә кулланыла; иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз

**КА́ЙДАНДЫР** *а.* Тәгаен билгеле булмаган, билгесез җирдән; ниндидер билгесез чыганактан, кемнәндер. *Самавыр кайнап чыккач, Нәгыймә чәй әзерләде, кайдандыр алып кортлы май да китереп куйды.* М.Гали. *Коммунист булгач, икмәк бирәләр икән, дигән хәбәрне кайдандыр ишетеп, коммунист булган иде.* Һ.Такташ

**КА́ЙЗЕР** *и. лат. тар.* Изге Рим империясе (962–1806) һәм Германия империясе (1871–1918) императоры титулы атамасы һәм шул титулга ия булган кеше

**КАЙЛҮЛӘ** *и. гар.* Көндезге йокы. *Ислам динендә кайлүлә дигән әйбер бар. Бу төштән соң язгать ярым алу дигәнне аңлата.* Р.Юныс

**КАЙМА** *и.* 1) Әйбернең, тукыманың аерым бер төс, бизәк белән аерылып торган чите, кырые. *Иярләре ефәк каймадан да чуктан, йөгәннәре көмеш таңкә белән чуарланган.* М.Хәсәнов

2) Читләрен уратып алып чикләгән сызык. *Мәрхүмнең кара кайма тотылган фоторәсеме куелган*

3) *күч.* Сөрмәләнеп, караңгыланып торган чик, аерылып караңгыланып торган урын. --- *йөзендә артык зур үзгәреш күрмәдем мин аның: шул ук коңгырт кара кайма белән әйләндерелгән яшькелт күз алмалары һәрнәрсәне тигез белергә теләгән төсле ашыгып йөриләр.* М.Әмир. *Аның күпереп торган коңгырт чәчләре дулкын-дулкын купшы җәелеп, җилкәсенә кадәр төшкән; --- шул кайма белән каймаланган йөзе, җир җиләгедәй кызарып, сәламәт һәм килешле төскә кереп, кунак күңелен үзенә тарткан иде.* Т.Әйди

◊ **Кайма тоту** Каймалау

**КАЙМАК** *и.* 1) Сөтнең өске куе, майланып торган өлеше. *Каймак – тәмле әйбер, каймак эчеп, җанын җуя бик күп песиләр.* Һ.Такташ. *Күмәч валчыкларын чәчә-чәчә ашарга, каймаклы салкын сөтне эчәргә тотындым…* А.Шамов

2) Сепаратор аша сөттән аертып алынган майлы куе масса. *Чәй һәм сепаратордан чыккан куе каймак күп итеп салынды.* Ш.Камал. *Госман, «хәзер» дип чыгып, бик куе каймак, яңа язган май, хәзер табадан гына төшкән коймак алып кереп, ашъяулыкка куйды да сүзен дәвам иттерде.* Г.Ибраһимов.

*--- хуҗабикә җылы сөт, каймак, тозлаган кыяр, бер каравай арыш икмәген китереп куеп, иренең сәламәт кулына ярты литрлы бер шешә аракы һәм кырлы стакан тоттырды.* К.Латыйп

3) *күч.* Нәрсәнеңдер сайлап алынган иң әйбәт өлеше, иң сыйфатлысы, иң әйбәте. *Кораллы көчләргә без егетләрнең каймагын гына алабыз.* М.Мәһдиев. *Безнең Арча ягында Сабан туеның каймагы, иң күңелле өлеше --- икенче көнне башлана.* Г.Бәширов. *Сталинда булган палачлык – милләтләрнең каймагын, иң зур зыялыларын юкка чыгару --- нияте Тимерхан Борһановка барлык фаҗигасе белән ачылды.* Г.Ахунов

4) *күч. сир.* Иң авыр, җитди, катлаулы өлеш. *Монысы аның сөте генә, каймагы соңыннан булыр, ди торган иде.* Г.Әпсәләмов

◊ **Каймакка караган мәче кебек** Кызыккан кыяфәттә, бик кызыгып. *Үзең бит, каймакка караган мәче кебек, миннән күзләреңне ала алмыйсың.* Ф.Яруллин

**КАЙМАКЛАНУ** *ф.* Күпмедер торганнан соң, каймагы аерылып сөтнең өске өлешенә җыелу

**Каймакланып тору** 1) Сөтнең майлылыгы зур булганга, куе каймаклы икәнлеге күзгә күренеп тору

2) *күч.* Кулга тотып карауга каймак кебек йомшак, яхшы эшкәртелгән булу (күн тур.)

**Каймакланып чыгу** Сөтнең өстенә каймак аерылып чыгу

**КАЙМАКЛЫ** *с.* 1) Каймагы алынмаган, аертылмаган, куе; каймагы күп, мул (югары сыйфатлы сөт тур.)

2) Өстәп каймак салынган, каймак кушылган

**КАЙМАЛАНУ** *ф.* 1) Читенә төсе, бизәге, сыйфаты белән аерылып торган кайма тотылган булу. *Рина башына зәңгәрсу берет чәпеп куйган, өстенә шундый ук төстәге, әмма киң кайтарма якалары ука белән каймаланган нәфис халат кигән.* Т.Әйди. *Габделхәмитнең кеш тиресе белән каймаланып тегелгән бүреге лычма булды.* С.Зыялы

2) *күч.* Сызык белән уратып алыну. *Таңсылуга нәрсә: авыз мыймылдык, күзкаш тирәләре каймаланып бизәлгән, колак алкалары болыт арасында уйнаган яшендәй елык-ялык килә.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Читләре кайма тотылган кебек караңгыланып, томаланып тору; уратылып алыну. *Аның алгы планындагы инеш буйлап уң якка таба куе үлән һәм биек камышлар белән каймаланган тезмә күлләр сузылып китә.* Ш.Камал

**Каймаланып тору** Әле, хәзер күз алдында кайма тотылган кебек күренү

**КАЙМАЛА́У** *ф.* 1) Читендә төсе, бизәге белән аерылып торган кайма булдыру

2) *күч.* Уратып алу, әйләндереп чыгу

**Каймалап алу** Һәрьяклап уратып каймалау. *Йөзен каймалап алган кара чәчләре дә, алсу янып торган бит алмалары да, уймак ирене дә, үзен, милләтенә хас булганча, һавалырак тотуы да – барысы килешә иде аңа.* Г.Ахунов. *Күлне каймалап алган биек тауларда чыршы, нарат, ак чыршы, граб, бүк агачлары һәм мәңге яшел тәбәнәк куаклар үсә.* А.Муранов

**Каймалап кую** Алдан каймалау; каймалы итү

**Каймалап кую** Алдан ук каймалау, каймаланган хәлгә китерү

**КАЙМАЛУ** *ф. диал.* Җилфердәү. *Ударниклар байрагы уйный җилгә каймалып.* М.Җәлил

**КАЙМАЛЫ** *с.* 1) Каймасы булган, кайма тотылган. *Иртәгесен Муса торып ишегалдына чыгуга, һәр бинаның стеналарына, капка һәм тәрәзә башларына кара каймалы кайгы флаглары эленгән иде.* Ш.Маннур. *Нурҗиһан боларга күлмәкчән генә килеп кергән иде. Абыстай аңа зәңгәр хәтфәдән тегелгән көмеш каймалы камзул бүләк итте.* Г.Бәширов. *Өс-башы бөтен: әйбәт бүректән, соры каракүл якалы пальтодан, аягында – каймалы ак фетр.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Каймага охшаган, кайма кебек итеп уратылган

**КАЙМАН** *и. исп. зоол.* Американың көньяк һәм үзәк өлешендә яши торган эре крокодил төре

**КАЙМА́У** *ф. к.* **каймалау**. *Тау биек, биек. Күкләргә тиеп, Кар бүрек киеп, Кояшта көлеп, сафка тезелеп каймаган күлне.* Ш.Маннур

**Каймап тору** Менә хәзер, әлеге вакытта каймаган булу

**КАЙМЫГУ** *ф.* Буыннар кузгалып урыныннан чыгу, таю. *Егетләрнең бите сыдырылган, кул-аягы каймыккан, әмма --- үләр дәрәҗәгә җитеп яраланган кеше юк иде.* Г.Ахунов. *Авыр эш, авыр хезмәт, шунда кулы-аягы тайган, бармагы, кулбашы каймыккан кешеләр һәр атна саен булып тора иде.* М.Мәһдиев

**Каймыгып китү** Кинәт каймыгу

**Каймыгып чыгу** Нинди дер сәбәп аркасында каймыгу

**КАЙМЫКТЫРУ** *ф.* Буыннарны кузгатып урыныннан чыгару, тайдыру, тайдырып чыгару. *Гөлшәһидә җайсыз басып аягын каймыктырган иде.* Г.Әпсәләмов. *Суга барганда таеп егылган да аягын каймыктырган.* Р.Батулла

**Каймыктыра язу** Чак каймыктырмый калу. *Аягын каймыктыра язу*

**Каймыктырып бетерү** 1) Күп тапкырлар, әллә ничә тапкыр каймыктыру

2) Берничә җирдән каймыктыру

**Каймыктырып йөрү** Күп тапкырлар каймыктыру. *Шпаналардан таланып, алардан куркып сикереп, шлаклы откосларда авыз-борын канатып, кулларны каймыктырып йөргән көннәремне исемә төшердем.* М.Мәһдиев

**КАЙНАГА** *и. к.* **каенага**. *Юк, Шакир кайнага! Йөрәк чыдамас, менә хәзер калтырап егылырга торам.* Г.Ибраһимов

**КАЙНАНА** *и. к.* **каенана**. *Ахрысы, аның кайнана булып түрдә утырасы, килен рәхәте күрәсе бик килә торгандыр.* Г.Ибраһимов. *Ниса кайнанасы белән ике еллап яшәп калды.* М.Хуҗин

**КАЙНАР** *с.* **1.** 1) Кайнап суынмаган, суынырга өлгермәгән; эссе. *Чүлмәкләрне шау кайнар су белән пешекләргә тотынды.* А.Шамов. *Кайнар ит былары чыгып тора.* Г.Гобәй. *Эх, булса иде шушында бер табак кайнар бәрәңге!* Г.Бәширов

2) Кызган, пешерә торган. *Кара диңгез ярларында кайнар җил өрде.* Ф.Кәрим. *Җиргә сыенган үләннәр, чәчәкләр, чыклы башларын калкытып турайдылар да, кайнар кояш астында ялт-йолт килеп рәхәтләнеп утыра башладылар.* И.Гази. *Кайнар батареяларда лиф-*

*чик, трусик, оек ише вак-төяк.* Н.Гыйматдинова. *Челләдә исеп куйган кайнар җилдәй тәэсир итте бу манзара ---.* Р.Мөхәммәдиев

3) Тән температурасы гадәти халәттән югарырак булган, тәне кызышканны белдереп торган. *Кайнар сулышы битләремә килеп бәрелде.* Н.Хәсәнов. *Күпме яшь йөрәк шул сукмаклар янында, шушы әрәмәлекләр буенда икенче бер яшь йөрәккә иң газиз тойгыларны --- әйтмәгәндер дә, нинди кайнар иреннәр шушында кушылмагандыр.* Г.Ахунов

4) *күч.* Дәрт белән тулы, дәртле, ялкынлы, ярсу. *Шакирын элеккечә бик ярата кебек, һәрхәлдә Мостафин өчен ул – һаман дәртле, кайнар хатын.* Ә.Еники. *Дөрес, алар кызу, кайнар мәхәббәт белән тулган хатлар языштылар.* А.Шамов

5) *күч.* Тирән тойгылы, хискә бай. *Дусларча кайнар сәламемне кабул ит.* М.Җәлил. *Гаилә мәсьәләсен кайнар тойгылар кушуыннан чыгып кына түгел, бәлки, уйлап, акыл белән хәл кылырга кирәк.* Р.Ишморат

6) *күч.* Көчле, дәррәү хупланган. *Суд карарын аклый кайнар алкыш, Ак сакаллы картлар, балалар.* Ф.Кәрим. *Ләкин, шундый ук кайнар вәгъдәләрне, мөгаен, совет илендәге һәр намуслы кеше бүген бирергә әзердер һәм бирәдер.* Г.Әпсәләмов

7) *күч.* Зур көч, энергия сарыф ителгән, киеренке, кызу. *Әйе, кайнар эш белән үтә хәзер безнең айларыбыз.* Ә.Еники

8) *күч.* Ачулы, нәләтле, үзәк өзгеч, ачы, аянычлы. *Нинди ачы бу яшь, нинди кайнар, Нишләдең син, җирем, нишләдең!?* М.Җәлил. *Кайнар күз яшьләре Гафифәнең кулына тама иделәр.* Ш.Камал

9) *күч.* Тиз кабынып, кызып китүчән, ярсучан. *Нургали кара мыек үстереп җибәрде, һәм кара мыек аның кыю, кайнар характерын тагы көчәйтә төшкән бик кирәкле бер нәрсә булып чыкты.* Ә.Еники. *Миргали – чыннан да, горур зат, шуның өстенә әле шактый ук каудар, кайнар йөрәкле, шашканрак хыяллы кеше.* М.Хәсәнов

10) *күч.* Кайнаган сыман күбекләнеп торган, куыклар чыгарган. *Күз алдыма килер дулкыннар, Дулкыннарда кайнар ак күбек.* Ф.Кәрим

11) *күч.* Әле генә булып үткән. *Көйләүче слесарьлар кайнар эздән эшкә керештеләр.* С.Рафиков. *Интернет, радио һәм телевидениенең «кайнар» яңалыклары итеп күрсәтелә торган вакыйгалар һәм сәяси күренешләр белән беррәттән, бик үк күзгә ташланмый торган, әмма гаять мөһим үзгәрешләр дә күзәтелә.* Татарстан

12) *күч.* Кискенлеге белән аерылып торган, тәэсир итү көче зур булган. *Өч көн алдан берничә җөмләдән гыйбарәт кенә бик «кайнар» бер нотык кисәге дә әзерләп куйды.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Якын итеп, дулкынланып. *Сине кайнар үбеп ала «Таң» колхозы кызлары.* М.Җәлил

**3.** *и. мәгъ.* Уч төбенә каты итеп сугу, чәбәк, чәпәк. *Минем сул кулга 25 кайнарны чәпәгәннән соң, уч төбем кабарып чыкты.* Ә.Айдар

◊ **Кайнар баш(лы)** Артык тәвәккәл, ахырын уйлап тормый торган, тиз кабынып китүчән, кызу канлы кеше турында. *Юк-юк дигәндә дә, нindидер каны кызган кайнар башларның тынычлыкны бозулары хакында һаман ишетелгәли иде әле.* М.Әмир. *Ничек син, кайнар баш, шуны гына төшенергә теләмисең?* Г.Бәширов. *Һәм акыллы, һәм кайнар баш кирәк бу заманда.* Ш.Камал. **Кайнар нокта** *сөйл.* Хәрби конфликтлар килеп чыккан, сугыш хәрәкәтләре алып барылган урын. *«Кайнар нокта»ларда барган вакыйгаларга, эре террор актларына карaганда, дөресрәге, аларны политик күзлектән чыгып бәяләүгә карaганда, иң зур көрәш ислам дине хакына (яки аңа каршы) алып барыла кебек.* З.Мифтахов. **Кайнар учак** Вакыйгаларның, шартларның нәкъ уртасы, үзәге, иң киң таралган урыны. *Репортаж сүз боткасыннан түгел, эш кайнаган, вакыйгалар куерган, мәсьәләләр чишелгән кайнар учактан языла.* К.Тимбикова

**КАЙНАРЛАНУ** *ф.* **1.** 1) Пешерерлек хәлгә җитеп җылыну, кайнар хәлгә килү

2) Тән температурасы күтәрелү, кызышу

3) Эсселәнү, кызу хәлгә килү. *Кызны биленнән кочаклап алганлыктан, аларның күкрәкләре орынган, сулышлары кайнарланган иде.* Т.Әйди

4) *күч.* Дәртләнү. *Кайсы татарның бу моңнарны тыңлаганда йөрәге кайнарланмас?!* А.Гыйләҗев. *Айдарсылу, маңгай чәчең айдарланган, күзләреңдә гыйшык буы кайнарланган.* Ш.Бабич

5) *күч.* Кабынып китү, кызу, ярсу. *– Әгәр кешенең биологиясе үзгәрсә, ул инде кеше булмаячак! – диде шагыйрь, кайнарланып.* А.Тимергалин

**2. кайнарланып** *рәв. мәгъ.* Дәртләнеп, күтәренке күңел белән. *Председатель дә аяк өсте басты һәм бик ихлас күңелдән, кызу-кызу, кайнарланып сөйли башлады.* Г.Ахунов. *Сез мине Шәрык культурасын яхшы белүегез, аның хакында кайнарланып сөйләвегез белән дә сокландырдыгыз.* Т.Әйди

**Кайнарлана бару** Торган саен ныграк кайнарлану. *Кызмыйм дип ант итеп килсә дә, председатель кайнарлана башлады.* А.Гыйләҗев. *Очрашкан саен, безнең хисләр кайнарлана бара иде.* Р.Батулла. *Аннан ул кешеләрне һәм дөньяны җылыту өчен генә югары күтәрелә, йөзе дә яктыра, нурлары да кайнарлана бара.* Р.Фәизов

**Кайнарлана башлау** Кайнарланырга тотыну. *Һава температурасы югарырак күтәрелгән саен, организмга температура балансын саклавы шулкадәр авырлаша, ул кирәгеннән артык кайнарлана башлый.* Ватаным Татарстан

**Кайнарлана төшү** Тагы да кайнарлану, эссерәк хәлгә килү. *Гусев, алай бик күтәрелеп бәрелмәсә дә, шактый кайнарлана төште.* С.Рафиков

**Кайнарланып бетү** Тәмам, бик нык кайнарлану. *Ә яшьләр рәхәтләнә аулак өйдә: йөзек салыш, күз бәйләп качышлы уйнау, арка сугыш, тагын әллә нинди уеннар уйнап, тәмам кайнарланып бетәләр.* В.Нуруллин

**Кайнарланып китү** Артык, теләгәннән күбрәк кайнарлану, эссерәк хәлгә килү. *Минә шул саташуның әллә бишенче тапкырында сазның былчыгы артыграк кайнарланып китте.*

Г.Рәхим. *Дуслыктан артык кайнарланып китеп, әдәп кысасыннан чыга күрмим тагын, дип хафаландым.* Т.Әйди

**КАЙНАРЛАТА** *рәв.* Кайнар килеш, кайнар көенчә. – *Бар, йөгереп кенә, бәпкәм, Җәһәт кенә илтче, – ди, – Кайнарлата иң әүвәле Алар авыз итсен, – ди (коймакны әби белән бабай).* Ш.Галиев

**КАЙНАРЛАТУ** *ф.* 1) *к.* **кайнарлау**. *Гөлҗамал, син бар, миңа сөт кайнарлат.* Ш.Камал. *Ире эштән кайта, хатыны ачык йөз белән каршы ала, юынгач сөртенергә сөлгесен тотып тора, чәен куеп җибәрә, бәлешен кайнарлата.* Римз. Вәлиев

2) Кыздыру, кызыштыру

**Кайнарлата бару** Торган саен һаман кайнарлату. *Эчем пошу гына түгел, вакытның тиз үтүенә ачуым да кайный, холкымны да кайнарлата бара иде.* Ф.Яхин

**Кайнарлата башлау** Кайнарлатырга керешү

**Кайнарлата төшү** Тагы да ныграк кайнарлау

**Кайнарлатып алу** Тиз генә кайнар хәлгә китерү, эсселәндерү

**Кайнарлатып җибәрү** Бераз, берникадәр кайнарлату

**Кайнарлатып килү** Байтактан бирле акрынлап, аз-азлап кайнарлату, кызыштыру. *Без инде эшчеләрнең настроениясен ярыйсы гына кайнарлатып киләбез, иптәш Башилов.* Ш.Камал

**КАЙНАРЛА́У** *ф.* Кайнар хәлгә китерү, кайнар итү

**Кайнарлап алу** Тиз генә кайнарлау, ашыгыч рәвештә кайнар хәлгә китерү

**Кайнарлап җибәрү** Бераз, берникадәр кайнарлау

**Кайнарлый төшү** Тагы да бераз кайнарлау

**КАЙНАРЛЫЙ** *рәв. к.* **кайнарлата**

**КАЙНАРЛЫК** *и.* 1) Кайнар хәлдә булу, кайнар халәт. --- *әлеге утның кайнарлыгын һәммәсе дә ачык сизәдер һәм моңа Зәнфирә сәбәпче икәнен аңлыйдыр кебек тоелды.* Ф.Садриев. *Камил мунчаның каен, имән себеркеләре, йомшак сөлгеләр эленгән алгы бүлмәсендә --- чишенде дә, ишекне ачып, --- әчкелтем кайнарлыкка чумды.* М.Галиев

2) Салкын тиюдән, авырудан, дулкынланудан барлыкка килгән тән кызулыгы, югары температура. *Алабуга, әллә кызның кул кайнарлыгыннан, әллә әнисенең хәйләсеннән уңайсызланып, җиңелчә генә кызарынып куйды.* Н.Фәттах. *Аның [Рухиянең] чәчләренең хуш исен, битләренең кайнарлыгын әлегә Килдеков түгел, Равил тоеп тора.* В.Нуруллин. *Тән кайнарлыгын басмасмы дип, көч-хәл белән торып су эчәм дә тагын урынга килеп егылам.* Р.Вәлиев

3) *күч.* Тәвәккәллек, кыюлык. *Шулардан үзенә дә тынгысызлык, кайнарлык йогып калды.* А.Гыйләҗев. *Сөйләшүне, зур кайнарлык белән, инде мәктәптән куылган Әүһади Ишмурзин алып барды.* Р.Мөхәммәдиев. *[Мансур Вәлиев] Дәлилләп бирүдән, анализдан бигрәк, ул еш кына хис белән, кайнарлык белән алдыра.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Дәрт. *Бәхетле гаилә тормышының калын өресе астында, үзенең эсселеген, кайнарлыгын яшергән, саклаган аның йөрәк уты шул көзге җилнең искәртмәстән исүе берлә пәрдәсез, калкансыз калды.* Г.Исхакый. *Яшьлек мавыгулар, мәхәббәт кайнарлыгы белән кадерле түгелмени?* Т.Әйди

5) *күч.* Кирәклелек, бүгенге көнгә туры килгәнлек, актуальлек. *Чехов әсәрләре үзләренең яңалыкларын, кайнарлыкларын югалтмыйлар.* Г.Нигъмәти

6) *күч.* Кызу канлылык, ярсучанлык, дуамаллык. *Аның шулай буйсынучан тыныч тавыш белән җавап бирүе, әз генә дә бу гаделсезлеккә каршылык күрсәтергә тырышмавы Габделхәйнең кайнарлыгын сүрелдерә төште.* Н.Фәттах

**КАЙНАТА(Й)** *и. к.* **каената**. *Без киткәч, кайнатай кайтыр, ул сорар, безне «кайда киттеләр?» дип.* Г.Камал. *Миңлеасия әтисе кырыенда, карават буенда басып тора, кайнатасына кашык белән су каптыра иде.* Г.Ахунов. *Васфикамал кайнатасы белән кече якта стаканнарга компот сала.* М.Мәһдиев

**КАЙНАТМА** *и.* 1) Дару үләне яки җиләк-җимеш салып кайнатып төнәтелгән шифалы су. *Нәфисә дә терелеп бетә алмады. Әнкәсенең тәмле сүзе, назлары да, Саниянең шифалы кайнатмалары, үлән сулары да, Ак бабайның догалары, Васимә карчыкның имләүләре дә ярдәм итмәде.* Г.Гыйльманов

2) Шикәр ширбәтенә салып кайнатылган җиләк-җимеш, варенье. *Бөтнекле чәй бик тә тансык, алма бәлеше ашап туйгысыз, ә инде җир җиләге кайнатмасын әйтеп тә торасы юк.* М.Маликова

**КАЙНАТУ** *ф.* 1) Сыеклыкны җылытып, температурасын кайнау дәрәҗәсенә җиткерү. *Әнинең җәй көне туплауда сөт кайната торган, корымга буялып, кап-кара булып беткән бер чәйнеге бар.* Г.Ибраһимов. *Ишектән кергән җирдә мич алдында Газизә агач кисәкләре белән самавыр кайнатып маташа иде.* Ш.Камал. *Алар балык пешерергә чиләк, чәй кайнатырга чәйнек алып тордылар.* Г.Гобәй

2) Үзлеген, сыйфатын үзгәртү өчен, берәр әйберне кайнап торган сыеклык эчендә тотып эшкәртү. *Ася приборларны кайнатырга куйды, зур шкафны ачып, аннан кирәкле ампулалар, дарулар алырга кереште.* Х.Камалов. *Баланың күлмәген Бибиәсма каен селтесе белән казанда да кайнатып карады.* Д.Каюмова

3) Технологиягә туры китереп, кайнау температурасына җиткереп әзерләү, ясау. *Без кайнаткан сабынның ачысы ашаган аны.* Ә.Фәйзи. *Идел киң, Идел тузансыз, Иделдә асфальт та кайнатмыйлар ---.* К.Нәҗми

4) Куу, кудырып әзерләү. *Көмешкә кайнату*

5) *күч. Баш, ми, йөрәк, кан, сару* һ.б.ш. сүзләр белән килеп, ярсыту, ачу китерү, ризасызлык тудыру кебек тискәре хисләрне, кичерешләрне көчәйтүне белдерә. *Хәзер Александра Сигизмундовнаның сүзләре аның башын кайнаттылар.* Г.Ибраһимов. *Шәйхи мәзин мине җәзалаучыларның уртасында иде, минем битемә төкерә-төкерә, йөрәгемнең ярасына тоз салып кайнатты.* Ш.Камал. *Җир йөзендә куерган артык фаҗигый хәлләр аның ачуын кайнатамы?* С.Поварисов

6) *күч. Күңел, йөрәк* сүзләре белән килеп, «үзе аша үткәрү, асылына төшенү» мәгънәсен белдерә. *Өч тәүлек*

*буенча ул хикәясендәге каһарманнар белән сөйләшеп, аларның тормышлары белән яшәп, алар төсле үк шатланды, газапланды. Аларның йөрәк кайгыларын үз йөрәгендә кайнатып кәгазь өстенә төшерде.* К.Тинчурин

**Кайната башлау** Кайнатырга тотыну. *Мәгәр карт озак көттермәде, кымызның куәте тамырларга таралып, канны бераз кайната башлау белән, үзе серне ачты.* Г.Ибраһимов

**Кайнатып алу** Тиз генә, ашыгыч рәвештә кайнату. *Аннары «Тефаль» чәйнеге белән тиз генә чәй кайнатып алды.* Ф.Яруллин

**Кайнатып кую** Алдан хәстәрен күреп кайнату. *Әминә кул астында сестра булып эшләргә тиешле уңган кыз Камилә чәй дә кайнатып куйган.* Г.Минский. *Шулай да син теге чәнечкеле гөлне кайнатып куй әле.* А.Шамов. *Ул тиз генә кереп чыгар, әнисе чәй кайнатып куйсын.* Г.Ахунов

**Кайнатып җибәрү** 1) Бераз гына кайнату, тиз генә кайнату, азрак кайнарлау. *Алай булса, зинһар өчен, [төнәтмәне] кайнатып җибәрә күр инде.* А.Шамов

2) Көтмәгәндә, кинәт кайнату, кайнарга этәргеч бирү. *Егетнең мондый кирелек белән кәгазьне кире ыргытып бәрүе аның канын кайнатып җибәрде.* Г.Ибраһимов

**Кайнатып тору** Һәрвакыт, даими кайнату; бер-бер артлы кайнату. *Әби самавыр кайнатып тора*... Ш.Усманов

**Кайнатып чыгару** Кайнау температурасына җиткерү

**КАЙНА́У** *ф.* 1) Пар хәленә күчү дәрәҗәсенә җиткереп җылытылган сыеклык, быгырдап, күбекләр чыгарып утыру. *Әни, кайнаган самавырым да бар, эчми китмәсеннәр, ди.* Г.Ибраһимов. *Чүлмәктә кайнаган су ошамый миңа, диде командир.* А.Шамов.

2) Кайнаган сыман хәрәкәтләнү, күбекләнү, күбекләр чыгару. *Читләрендә бернәрсә дә күренми, тик кара диңгезе генә кайный.* Ш.Камал. *Ак болыттай, кайнап, күбекләнеп, сауган сөте ташый чиләктән.* Ф.Кәрим

3) Бөтен барлыгын биләп кыздыру, авырттыру. *Капкан дарулары да, үзенә ясаган уколы да әллә ни ярдәм итмәде, эчендә тоташ ут кайный.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Киләчәктә башкарачак эшпланнар, бик күп төрле уйлар күңелне тынгысызлау. *Шундый гаҗәеп бер логика белән Нургали эшкә тотынмакчы була, аңарда дәрт, энергия һәм адарыну – барысы бергә кайный.* Ә.Еники. *Башында, гадәтенчә, мең төрле исәпхисап кайный иде.* Т.Әйди.

5) *күч.* Хис-тойгылар, эчке кичерешләр көчәю, ярсу, тынгысызлык кичерү. *Фәхринең кем кулыннан үлүе турында күңелләрдә шөбһә бик кайный иде.* Г.Ибраһимов. *Әгәр Гайни белсә иде минем йөрәгемдә нинди мәхәббәт ялкыннары кайнаганын.* Г.Камал. *Кичәдән бирле минем йөрәктә ниндидер бер моң кайный.* Р.Ишморат

6) *күч.* Кайнашу (*1 мәгъ.*), күмәкләп гөҗ килеп тору, мыжгу. *Бүген завод корт иле төшкән кебек кайный.* Г.Әпсәләмов. *Рина сату эшләрен дә башкара ала, тик кеше күп кайнаган чакта, әнисе аны ул эшкә җәлеп итми.* Т.Әйди. *Шәһәрнең кырмыскадай кайнаган кешеләре, биек йортлары, машина-трамвай шавы белән гөрләп торган таш урамнарыннан соң авыл бик бәләкәй, гади, оялчан кебек тоелды.* Р.Низамиев

7) *күч.* Күпкырлы актив эшчәнлек алып бару, башкаларны тарту, әйдәү. *Тормышның төбендә кайнап, ун ел буе аңлый алмаган нәрсәләрне син монда бер елда, бәлкем, тизрәк тә аңлаячаксың.* Ф.Садриев

8) *күч.* Вакыйгаларның, булып үткән эшләрнең эчендә катнашу, үзәгендә булу. *Хуҗалык эшендә дә күптән кайнады.* Г.Ибраһимов. *Г.Коләхмәтов бишенче ел дулкыннарында кайный.* Г.Нигъмәти

9) *күч.* Аерым вакыйга, шартларның нәкъ уртасына, үзәгенә әйләнү, иң киң таралган ноктасы булу. *Схоластик «белем» кайнаган җир булган Бохарага бар.* Г.Нигъмәти. *Рәхми төштән соң гел әвеслектә булды, урак өстендә эшнең кайнаган үзәге шушында бит.* М.Хуҗин

10) *күч.* Озак вакытлар бергә булу, аралашып яшәү, уртак вакыйгалар кичерү, бер үк эшләр башкару. *Һаман бергә кайнаган бу иптәшләр мәсьәләгә ничектер салкын караган кебек күренделәр.* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Эш әйбәт бару, барысы да эш белән мәшгуль булып, бердәм эшләү. *Кайный монда илнең төзелеше, һәм соклана кеше елмаеп.* Ш.Маннур. *Шулай да монда зур күтәренкелек, зур социализм төзелеше кайный.* М.Гали

**Кайнап йөрү** Бертуктаусыз тынычсызлау, тоташ борчып тору, үзенә урын тапмаслык дәрәҗәгә җиткерү. *Эчтә бертуктаусыз кайнап йөргән билгесез ачу хәзер әзрәк билгеле була башлады.* Ф.Хөсни

**Кайнап китү** Кинәт, көтмәгәндә кайный башлау, билгеле бер моменттан соң кайнарга тотыну. *Шәкерттә тагы гайрәт кайнап китте.* Г.Ибраһимов

**Кайнап тору** Әле, хәзер, күз алдында кайнау; даими, һәрвакыт, ыгы-зыгы килеп, шау-шулы хәрәкәт итү. *Көмеш кебек самавыр күңелле, бәйрәмчә кайнап тора.* С.Сүнчәләй. *Казаннарда гөбер-гөбер бәрәңге кайнап тора.* Ф.Яруллин. *Бауман урамында халык кайнап тора. Авыз ачып йөрсәң – хәзер кемгә дә булса килеп бәреләсең.* З.Фәйзуллин

**Кайнап утыру** Әле, хәзер, күз алдында кайнаган хәлдә булу. *Кайтса, ни күрә: үги әнисе Бибисара, аның ике кызы шаулап кайнап утырган самавыр янында чәй эчәләр.* Г.Ахунов

**Кайнап чыгу** 1) Кайнау халәтенә, кайнау ноктасына җитү. *Хәзер кайнар күмер белән самавыр да куеп җибәрәм, күз ачып-йомганчы кайнап чыга.* Г.Әпсәләмов. *Өстәл түрендә утырган самавыр байтактан кайнап чыккан иде инде ---.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Ачуыннан ярсу, кинәт кызып китү. *Ул мине күреп түгел, адымымнан танып шулай кайнап чыкты.* Ф.Хөсни

3) *күч.* Хисләр кинәт ташу. *Телләгеңне белмәдем, ул [җыр] күкрәгемнән үзе кайнап чыкты.* М.Фәйзи

**Кайный башлау** Кайнарга тотыну. *Тик кайсы арада пыш-пыш кына: «Менә диңгез кайный башлар, менә янар», – дигән тавышлар ишетелә иде.* Г.Тукай. *Хәзер исә бу ачу-нәфрәт, бик*

*табигый буларак, минем эчемдә бөтенләй кайный башлады.* Ә.Еники

**Кайный бирү** Бернигә дә карамастан, һаман кайнау. *Безнең казан ташыса да кайный бирә, Пешә ашы, берүзенә – ике башы.* С.Әхмәтҗанова. *Бүген Сәйтәк авылы яшүсмерләре күңелләре белән тартылган спорт дөньясында «кайный» бирә.* Балтач таңнары

**КАЙНАШ** *и.* 1) Ыгы-зыгы, шаушулы хәрәкәт; мәшәкать. *Туй кайнашы көчәйгән саен, кызның күңелендәге Лотфи каядыр артка, томан эченә табарак китә барды.* Г.Ибраһимов

2) Тынычсыз халәт, шикле-шөбһәле хәлләр. *Юк-бар кайнашларны ишеткәч, ул үзен юатырга тырыша. Юк! Дөнья буталыр, әмма минем шәкертләрем миңа мантыйг калыр, ди.* Г.Ибраһимов

**КАЙНАШТЫРУ** *ф.* 1) Нинди дә булса эш эшләргә тырышу, җаен чыгару, чарасын табу, эшләп башкару

2) *куч.* Законга сыймаган, ярамаган гамәлләр кылу, яшерен, астыртын эшләр эшләү. *Кызны бит алай юримарый гына кайнаштырырга, ай-һай, хәзер закон четерекле, малай.* Ф.Бурнаш. *Кул кулны юа – бергә кайнаштыралар, шулай булгач, әйтүдән ни файда.* З.Фәйзуллин

**Кайнаштырып бетерү** Бик нык кайнаштыру, тәмам кайнаштыру. *Әнә кыш көне мәктәптә әдәбият кичәсе ясаган булып, кулак та мулла, мулла да кулак сүзләрен чәйнәп, дөньяны кайнаштырып бетерделәр.* Ш.Камал

**Кайнаштырып кую** Алдан әзерлек күреп, чаралар табып кайнаштыру

**Кайнаштырып тору** Әледән-әле, еш кайнаштыру

**КАЙНАШУ** *ф.* 1) Бер урынга тупланган кешеләр төрлесе төрле яктан тәртипсез хәрәкәт итү, һәрберсе үзенчә мәшгуль булу. *Күк йөзен томалап өлгергән каракучкыл болытлар тау-тау булып берсе өстенә берсе актарылды, болганып кайнашырга тотынды.* Г.Бәширов. *Ябык ындыр эчендә, тирә-яктагы бөтен әйберләрне селкетеп, сугу машинасы үкерә, җилгәргеч зырылдый, кешеләр кайнаша.* Г.Әпсәләмов. *Учак янында һәм учакка якын җирләрдә төркем-төркем булып, берән-сәрән булып кешеләр кайнаша иде.* Н.Фәттах

2) Аерым бер кеше нәрсәдер эшләү, ни беләндер шөгыльләнү, берәр эш белән мәшгуль булу. *Әнисе һаман мич янында кайнаша.* Р.Мөхәммәдиев. *Алъяпма бәйләгән --- бер хатын казан тирәсендә кайнаша иде.* Г.Исхакый. *Кызның көймә тирәсендә сокланырлык оста кайнашканын күреп, ачкан авызын япты.* Г.Гобәй

3) Эшкә катышып китү, ярдәмләшү, эшләүчеләр арасына керешеп китү. *Назлы килен Гыйззелбанат белән матур җиңги Мәфтуха шунда [туй табынын әзерләүдә] кайнашалар иде.* Г.Ибраһимов. *Шул тирәдә кайнашырга маташкан Мөнәвәрәне ул, син – хатынкыз, ирләр эшенә тыкшынма, дип, балта-пычкыга якын да җибәрмәде.* Н.Гыйматдинова

4) Аралашу, тирәсендә чуалу, янында һәрвакыт булу. *Ләкин малай аңа карамады, икенче, өченче, бишенче, унынчы көннәрдә дә һаман шул Сафый карт өе тирәсендә, Миңлекәй янында кайнашты.* Г.Ибраһимов. *Нәҗип аның тирәсендә аеруча масаю, канәгатьләнү белән кайнашты.* Г.Гобәй

5) *кимс.* Ярарга тырышып, сүз куштын калап, тирәсендә чуалу, игътибарын җәлеп итәргә тырышу. *Әбәткә акча чыгарасылары килмичә, пешекчеләр тирәсендә ничек кайнашалар.* З.Фәйзуллин

6) Нидер эшләү, маташу, мәшәкатьләнү. *Нурыйның күптән аерылган зур улы Төхфәт белән аның хатыны Мәрфуга, өченче чанада Шәйхел, матур җиңги Мәфтуха, кунак килен Мәрхәбәләр мыж килеп әйбер алып кайнаштылар.* Г.Ибраһимов. *Ул хәзер, тирләгән, пешкән хәлдә, көлтә бәйләп яисә эскерт өеп кайнаша булыр.* Ш.Камал. *Тизрәк кайнашыгыз... күрсәләр, яхшы түгел.* Ф.Бурнаш

7) *куч.* Ярсу, хисләр, тойгылар, кичерешләр көчәю, кайнау. *Маратның Тәнзиләгә әйтергә йөргән ярату сүзләре пычак ярасы кебек әрнүле һәм боз кебек салкын нәфрәт белән буталып кайнаша башлаган иде.* З.Фәйзуллин

8) *куч.* Күңелендә, йөрәгендә, башында төрле-төрле уйлар, хис чуалу, кайнап тору. *Шелтәләр, сагынулар, сөю һәм рәнҗү дулкыннары – барысы бергә кайнашып, кара кан булып укмашкан иде.* Г.Ибраһимов. *Аның тойгылары шундый кайнашалар, ул үзендә шундый бер дәрт сизә.* Г.Бәширов. *Башында кайнашкан шомлы уйлардан йөзгә кадәр санап арынмакчы булып та карады – файдасыз.* З.Фәйзуллин

**Кайнаша башлау** Кайнашырга тотыну. *Шәйхетдин абый күчәрне, суынсын дип, җиргә төшереп куйды да учак белән кайнаша башлады.* З.Тимергалиев. *Фатыйма да ушына килеп үз эше белән кайнаша башлады ---.* З.Кадыйрова

**Кайнашып йөрү** Күп булып, төрле яклап әрле-бирле килеп кайнашу. *Еракдагы авылның карт таллары өстендә чәүкәләр төркеме үзара кайнашып йөриләр.* С.Җәләй. *Мин чыкканда, университет ишегалдында абитуриентлар кайнашып йөри иде.* М.Юныс

**Кайнашып тору** Бертуктаусыз, һәрвакыт кайнашу. *Губкомга кергәндә, коридорда, гадәттәгечә, кешеләр арлы-бирле үтеп кайнашып тора иде.* Ш.Камал

**Кайнашып яту** Үзләренчә ыгы-зыгы ясап, озак вакыт дәвамында кайнашу. *Менә шулар белән ашханәгә төшеп бикләнәләр дә эчеп, кайнашып яталар.* З.Фәйзуллин

**КАЙНЕШ** *и. к.* **каениш**. *Үтерелгән Фәхринең кайнеше комсомолец Шаяхмәт тә шөбһә белән Җиһанша картка карый һәм чәнчүле сүзләр әйтә.* Г.Нигъмәти

**КАЙНИГӘЧ** *и. к.* **каенигәч**. *Ярый, кайнигәч, бик рәхмәт сезгә, әйе, рәхмәт.* Ш.Камал

**КАЙНИШ** *и. к.* **каениш**. *Чокыр Хәбипкә дә туйның икенче көнендә кайнише белән хатыны килеп төштеләр.* Г.Ибраһимов. *Шәбрәк җиһаз белән барса, Галиябануның үзенә дә кайниш арасында йөз аклыгы булыр.* М.Фәйзи

**КАЙНИШЛЕ** *с.* Иргә яки хатынга: хатыны яки ире ягыннан тугантумачасы күп булган. *Зур кызларын бик байга бирәбез дип, кайнишле йортта череткәннәр иде, инде бусын ялгызрак җиргә бирергә исәпли, ди.* Г.Ибраһимов

**КАЙНОЗО́Й** *и. гр. геол.* Җирнең геологик тарихында иң яңа эра: өченчел, дүртенчел дип аталган ике чорга бүленә, соңгысына хәзерге дәвер дә керә. *Африка саваннасы. Саваннада кайнозой эрасында яшәгән казылма җәнлекләргә охшаш ялгыз агачлар.* М.Юныс

**КА́ЙРА** *и. рус зоол.* Чистиклар семьялыгыннан, аркалары кара, түшләре ак төстәге, бала чыгару чорында зур колония булып, кош базары ясап, текә кыялы яр буйларына оялый торган төньяк диңгез кошы. *Күп төрле меңнәрчә кошлар: акчарлаклар, кайралар, чистиклар, давыл кошлары, гагаралар, бакланнар, шөлдиләр боз араларында һәм елуларда туенып йөриләр.* Дөньяда ниләр бар

**КАЙРАГЫЧ** *и. сөйл. к.* **кайрак**. *Хәстәрен күргән: пычагын да, кайрагычын да үзе белән алып килгән икән Данил.* Безнең гәҗит

**КАЙРАК** *и.* 1) Кисү коралларының йөзенә сызып үткерли торган махсус таш. – *Әй син, Габделхак, бар әле, – диде һәм башы белән ишеккә таба ишарәләде дә, кайракны малайдан алып, үзе әйләндерә башлады.* Г.Гобәй. *Чалгысын дымлы үлән белән буйдан-буйга сыпырды, тула оегы кунычына кыстырган агач саплы кайрагы белән аны янап алды.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Уңмаган ипидә күпермичә тыгызланып аерылып торган өске яки аскы катысы

◊ **Кайрак йөзе күрмәгән** Бернәрсәгә дә яраксыз дәрәҗәдә үтмәс, беркайчан да кайралмаган

**КАЙРАКЛАНУ** *ф.* 1) Шомару, ялтырап тору. *Кызган ташлар кайракланган аяк табаннарын рәхәт кенә иркәлиләр иде.* А.Гыйләҗев

2) Ипинең аскы яки өске катысы пешмичә тыгызланып аерылу

**КАЙРАКЛЫ** *с.* Ипигә карата: уңмаган, өске яки аскы катысы янында бер илле калынлыкта күзәнәксез тыгыз камыры булган. *Аннан әнә Шәмсенисаны кара: ипие гел кайраклы.* М.Мәһдиев

**КАЙРАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кайрау**. *Пычак әйбәт кайралган*

2) Ышкылып ялтырау, күп ышкылудан ялтырап тору. *Күрәкнең туфракка шомарып кайралган йөзе Габдулланың аяк тирәсендә ялтырады.* Ә.Фәйзи

3) Күп ышкылып яки нык кысудан кыршылу. *Ялчы белсә дә белмәмеш булып, йөрәге сызланып, тешләре кайралып, үз эшендә йөри, ди.* Әкият

4) *күч.* Үткенләнү, шомару; күпне күреп тәҗрибә туплау

**Кайралып бетү** Тәмам, бик нык кайралу. *Егет үзе дә кайралып беткән.* Ш.Камал

**КАЙРА́У** *ф.* Кисү коралларын кайрак белән яки башка шундый үткерли торган әйберләргә сызып, ышкып үткерләү. *Бритва кайрый торган каешының бер башын тоттырды.* Ш.Усманов. *Ишкәй чәчкечләрне көйләде, сабан төрәннәрен кайрады.* Т.Әйди. *Бичара Овсюк беседкага утырып, кулларын каната-каната, ярты көн буе якорь җәпләкәсен кайрады.* М.Мәһдиев

**Кайрап алу** Тиз генә, җитез хәрәкәтләр ясап кайрау. *Менә ул, туктап, чалгысын кайрап ала да тагын каерылып-каерылып чабарга тотына.* И.Гази. *Чыпчык капка башында чыр-чу килеп әйләнгәли дә, --- аннан томшыгын ике яклап тактага кайрап ала.* Ә.Фәйзи

**Кайрап бетерү** Ахырга кадәр, үткенләнгәнче кайрау; барысын да, берсен дә калдырмыйча кайрау

**Кайрап йөрү** Төрле урыннарда булып, кайрау, үткерләү белән шөгыльләнү

**Кайрап кую** Алдан ук хәстәрлек күреп кайрау

**Кайрап тору** Хәзерге вакытта, әле, күз алдында кайрау; һәрвакыт, кирәк саен, әледән-әле кайрау. *Кешеләрнең икенчесе --- бик бирелеп, әледән-әле күзләренә якын китереп карый-карый, ниндидер озынча, юка ак тимер кайрап тора.* Г.Гобәй

**Кайрап чыгу** Һәрберсен, берәмберәм кайрау

**Кайрый башлау** Кайрарга тотыну. *Авыл җитәкчесе итеп сайланган җыен әтрәк-әләм, ярлы-ябагай дин әһелләренә теш кайрый башлады.* Г.Бәширов. *Килгәч, эш креслосына утыртты да, берничә укол ясаганнан соң, бер сүз әйтми-нитми, тешләремне кайрый башлады.* Безнең гәҗит

**Кайрый төшү** Тагы да бераз кайрау

**КАЙРАУЛЫ** *с.* Кайралган, үткенләнгән. *Теше кайраулы ак филне Төшәр юлга куйдырып, Өстенә чатыр кордырып, Эченә үзен кундырып, --- Ул да килеп туктады.* Дастан

**КАЙРАУЧЫ** *и.* Кайрау эшен белүче, шул эш белән шөгыльләнүче кеше. *Соңыннан баягы кайраучы килеп чыга.* Г.Коләхмәтов

**КАЙРЫ** *и. бот.* 1) Агачның тышкы каты кабыгы. *Агач кайрысына чигелгән серле эзләр, үзеннән зур ботак кисәге күтәреп йөрүче кырмыскалар тормышы турында, кайда утыруыңны онытырлык мавыктыргыч хикәяләр сөйли.* Г.Бәширов. *[Гыйлемхан] --- ялгыз каенның бирчәеп чыккан калын кара кайрыларына карангалап торды.* Р.Мөхәммәдиев

2) *к.* **кайры балы**. *Топольләрдән баллы кайры исләре аңкый.* Ш.Камал

◊ **Кайры каезлау** Юри, үчегеп, әйткәннең киресен сөйләү, сүзне юри икенчегә бору

**КАЙРЫАШАР** *и. зоол. к.* **кабыкчы**. *Тукраннарны яратам мин. Алар бит әллә никадәр кайрыашар бөҗәкләрне юк итәләр, безгә – урманчыларга файда итәләр.* Н.Сладков

**КАЙРЫ́ БАЛЫ** *и.* Агач кабыгы һәм үзагачы арасындагы катлавында минераль һәм органик матдәләргә бай сыекча

**КАЙРЫ́ КОҢГЫЗЫ** *и. зоол. к.* **кабыкчы**. *Гомумән, бер генә хайванның да, хәтта бары үзагач кына ашап яшәүче кайры коңгызлары һәм һәртөрле агач кортларының да мондый [клетчатканы таркатырлык] ферментлары юк.* Кызыклы физиология

**КАЙРЫ́ КОРТЫ** *и. зоол. к.* **кабыкчы**

◊ **Кайры корты кебек йөрәкне кимерү** Нинди дә булса күңелсез вакыйга, эш, хәл истән чыкмыйча, гел күңелгә тиеп, борчып тору. *Көн саен туза, җимерелә барган хуҗалыгы өчен борчылу, кайры корты кебек, йөрәген кимерә башлады.* Г.Ахунов

**КАЙРЫ ТОЛЫП** *и. к.* **кайры тун**. *Якасы җыерылып тора торган*

*тышсыз сары кайры толып кигән Вахит абзый белән камчат бүрек өстеннән калын шәл ябынып, кара чикмән бөркәнгән Бәдриҗамал җиңги шул чанага утырдылар.* Ш.Мөхәммәдев

**КАЙРЫ ТУН** *и.* Иләнгән тиредән тегелгән тышсыз тун. *[Зиннур Мәгъсумов] Өстендә кайры тун, башында бүре бүрек, аның йөнтәслеге йөзенең ябыклыгын бераз каплап, киметеп тора иде.* Г.Ахунов

**КА́ЙСЫ** *а.* **1.** 1) Күпләр арасыннан берсен аерып алу, аерып белү максаты белән сорау биргәндә кулланыла. *Скамьяларның берсенә утырдым да Разыяларның кайсы юлга кереп китәчәкләрен карап калмакчы булдым.* Ф.Әмирхан. *Хәлим, аның артыннан барырмын, кайсы авылга, кайсы йортка кергәнен күзәтермен, дип уйлаган иде.* Г.Гобәй

2) Риторик җөмләләрдә эмоциональлекне көчәйтеп, беркайда да башкача кабатланмауны, мондый рәвештә булмауны белдереп килә. *Кайсы илдә бар бездәге шикелле зур халык, кайда бар бездәге шикелле чын дуслык, дип уйлады Газинур.* Г.Әпсәләмов

3) Кайбере, кайберсе. *Әнә аларның кайсылары тырышып-тырышып сайрарга ук керештеләр, менә саба җиле исте.* Ф.Әмирхан

4) *Икенчесе* сүзе белән килеп яки кабатланып, «әле берсе», «әле икенчесе» мәгънәсендә кулланыла. *Кайсы су астыннан баш калкытып чыга, икенчесе аны урталай сындыра, кыш буе тыныч кына яткан бозлар өерелә-өерелә болганыша.* Н.Хәсәнов. *Кызлар бертавыштан, кайсы үпкәләгәндәй булып, кайсы ихлас күңелдән ышандырырга тырышып, шауларга тотындылар.* Ә.Еники

5) Кем, кем генә. *Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?* Г.Тукай. – *Мондый буранлы төндә кайсы йөрер икән? – диде ул сукранып.* А.Шамов. *Кайсы татарның бу моңнарны тыңлаганда йөрәге кайнарланмас?!* А.Гыйләҗев

**2.** *мөн. сүз мәгъ.* Баш җөмләдәге *шул* яки *шуны* сүзләрен ачыклап, иярчен аергыч яки иярчен тәмамлык җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә...* Г.Тукай

◊ **Кайсы кайда** Төрле-төрле якта, төрле урыннарда, төрле тарафта. *Мендәрләр, савыт-сабалар кайсы кайда чәчелеп яталар, көрпәләрне, әйбер эзләгәннәрдер инде, телгәләп бетергәннәр иде.* Г.Гобәй. **Кайсы(н) кая** Төрлесе(н) төрле якка, төрле урынга, төрле тарафка. *Малайлар тилгән төшкәндәге тавык чебиләре кебек кайсы кая йөгереп юк була.* З.Зәйнуллин. *Мостафа абый балаларына җиләк-җимеш үрентеләрен ничек карарга икәнен күрсәтте, озаграк торылса, кайсын кая күчереп утыртырга икәнен әйтте.* Г.Гобәй. **Кайсы яктан гына алып карама** «Кайсы фикердән чыгып, мәсьәләнең кайсы ягыннан карап уйласаң да, шул бер үк уртак нәтиҗәгә кайтып кала» мәгънәсендә фикерне йомгаклау алдыннан әйтелә

**КА́ЙСЫБЕР** *а. к.* **кайбер**

**КА́ЙСЫБЕРӘҮ** *а. к.* **кайсыбер**. *Кайберләре шунда егылып кала, Кайсыберәүләрдән кан ага.* М.Гафури

**КА́ЙСЫБЕРСЕ** *а. к.* **кайбер**. *Кайсыберсе көнгә каршы елмаеп, бөгелеп тора.* М.Гали

**КА́ЙСЫДЫР** *а.* 1) Кемдер, арадан берсе. *Соңгарак, кайсыдыр бер укытучының киңәше буенча, йокы алдыннан берәр физик эш эшләп кирергә гадәтләнде: кар көрәде, утын ярды яки чаңгыда йөрде.* Г.Гобәй

2) Нәрсәдер. *Бөтенләй якында гына нәрсәдер «лап» итеп төште, күрәсең, давыл кайсыдыр өйнеңме, сарайныңмы түбәсен кубарып ташлады.* Г.Әпсәләмов

**КА́ЙСЫСЫ** *а. к.* **кайсы**. *Лазареттагыларның кайсысы агент: хе змәткәрләрнең берәрсеме? Әллә авыруга салышып ятучымы?* З.Фәтхетдинов. *Казаклар кулларын угалап тордылар да берсенә-берсе нәрсәдер әйтешеп алдылар, аннары кайсысы тәмәке төреп, кайсысы папирос чыгарып тарта башладылар.* Г.Гобәй

**КАЙТАВАЗ** *и.* 1) Йотылмыйча кире кайтып кабатланган тавыш. *Михнәтле тавыш әле көчәеп, әле кайтаваз кебек тоныкланып ишетелде.* М.Хуҗин. *[Идриснең] Кычкырулырына тонык кайтаваз гына җавап бирде.* А.Гыйләҗев. --- *күк күкрәү озакка сузылган кайтаваз булып яңгырый, бүтән авазларны күмеп китә иде.* З.Фәтхетдинов

2) *күч.* Алда булып үткән эш-хәрәкәт, вакыйгаларга җавап буларак барлыкка килгән, кабатланган күренеш, хәрәкәт, эшчәнлек, җавап реакция. *Сез бит, оланнар, безнең бик ерак бабаларыбызның кайтавазы.* М.Хәсәнов. *Сүзләр мириадасы… Хәтер ятьмәсенә эләккән кайбер асылташтай сүзләрне үзалдыма кабат-кабат әйтеп карыйм: борынгы заманнар кайтавазы яңгырап ишетелә.* М.Галиев

**КАЙТАДАН** *рәв.* Яңадан, тагын бер кат, икенче тапкыр, кабатланып. *Утә гомерем, югала, кайтадан әйләнеп килмәс!..* М.Гафури

**КАЙТА́-КАЙТА** *рәв.* Берничә тапкыр кабатлап, кабат-кабат, кат-кат. *Хатын үз тормышының бу авыр кайгысын ярым елап, ярым каргап кайта-кайта сөйләде, башына төшкән бу хәсрәттән ничек котылырга аптырап әрнеп кабатлады.* Г.Ибраһимов. *Башта, кайта-кайта, бик озаклап күк күкрәде, аннары шыбырдап яңгыр яварга кереште.* Г.Бәширов

**КАЙТАРА́-КАЙТАРА** *рәв. к.* **кайта-кайта**

**КАЙТАРГЫЧ** *и. махс.* Яктылык, җылылык нурларын, электрлы магнит дулкыннарын кире кайтара торган җайланма

**КАЙТАРМА** I *с.* **1.** 1) Кайтарып бөкләп куела торган. *Рина башына зәңгәрсу берет чәпеп куйган, өстенә шундый ук төстәге, әмма киң кайтарма якалары ука белән каймаланган нәфис халат кигән.* Т.Әйди

2) Күтәреп куела торган. *Кайтарма күпер*

3) Мехы тышка калдырып тегелгән. *Кайтарма тун*

**2.** *и. мәгъ.* Кайтарылып бөкләнеп торган урын. *Пиджак кайтармасында, хәзер инде хәтерләмим, Алтын Йолдыз ничәү иде: берәүме, икәүме?* М.Мәһдиев

**КАЙТАРМА** II *и. диал.* Сабанда туфрак катламын әйләндереп каплау өчен хезмәт итә торган калак; *русчасы:* **отвал**

**КАЙТАРУ** *ф.* **1.** 1) Кире кайтырга кушу, кайтырга боеру, киткән жиреннән чакыртып алу. *Сафия абыстай идән уртасына баскан килеш нәрсә дип әйтергә белмичә, аны кире кайтарырга сүз табалмыйча аптырап калды.* А.Шамов // Кире кайтып китәргә мәҗбүр итү, тагы да калу мөмкинлегеннән мәхрүм итү. *Менә шул хәбәр аларны кыш көне кузгатып, Караюргага кайтарды.* Г.Ибраһимов. *– Бәйләнмә миңа, башкаларга әйт! – дип, бер-ике мәртәбә тегене ачуланып кайтарсам да, ул тагын әйләнеп миңа килә.* Ш.Камал

2) Нинди дә булса хәлгә төшереп кире бору. *Аны кемнәрдер таш коймадан ыргытып, аягын шунда кыскартып кайтарганнар, ди.* Г.Бәширов. *Ник турсайдың? Малайлар кыйнап кайтардыларммы әллә? Ә.Фәйзи*

3) Кайтырга рөхсәт итү, җибәрү. *Солдатларны армиядән кайтару башланды.* Г.Ахунов

4) Кире кагу. *Сылу мәхәббәтле елмаю белән: – Көтеп алган җегетне кире кайтарырга кайсы кызның куәте җитәр, – дип җавап кайтарды.* Г.Ибраһимов. *Күп еллар «утырган», күп егетләрнең яучыларын кире кайтарган менә шул Фатихә турында ил теле куркыныч, серле гайбәт сөйли башлый.* Г.Ибраһимов

5) Алган, югалган әйберне хуҗасына кире тапшыру, киредән үзенә бирү. *Мин берсен дә алмадым, кире үзләренә кайтардым.* Г.Ибраһимов. *Юлда үлеп калган, мәрхүм... Кайсыдыр авыл зиратында җирләгәннәр үзен, атын гына да кайтармадылар бит, ичмаса...* М.Хәсәнов. *«Галиябану» либреттосы шулай ук әдәби бүлек тарафыннан 3–4 мәртәбә җентекләп тикшерелеп, тиешле консультация белән авторга кайтарылды.* М.Җәлил // Кире бирергә мәҗбүр итү, кабаттан тартып алу. *Бәлки, ул зур өстәлләргә җәелгән картаның бер ноктасына, нәкъ менә Калинин өлкәсенең дошман кулында калган җирләренә карый торгандыр һәм бу җирләрне тизрәк Ватанга кайтарырга кирәк дип уйлый торгандыр.* Г.Әпсәләмов. *Илнең бәйсезлеген кайтару өчен, Көнбатыш баскынчыларына – тәре йөртүчеләргә каршы көрәш башлап җибәрә.* С.Сөләйманова

6) Тотылган чыгым күләмендә файда китерү, чыгымнарны каплау. *Күңел биреп тотынсаң, җир дигәнең йөзе белән кайтара инде ул.* Г.Бәширов. *Карабодайны кырау алды, борчак җир өстендә үк ярылып, орлыгын да кайтармады, солы чүмәләләренең байтагы кар астында калды.* Г.Бәширов // Күрелгән зыян, чыгым күләмен хуҗасына түләп бирү. *Бөтен зарарны кайтарырбыз.* Ш.Усманов

7) *гади сөйл.* Борып җибәрү, буш калдыру. *Буш кул белән кайтармам, үзем рәтләп җибәрермен.* Г.Ибраһимов

8) Эш, хәрәкәт, сүз белән җавап бирү. *Аның каравы үзләре дә үчне кайтардылар: мәчеткә килгән кешеләрнең башмакларын буташтырып чыктылар.* И.Гази. *Карт, вәгаләйкемәссәлам, дип сәлам кайтарды.* Г.Ибраһимов. *Сез мине үз итәсез, сезнең игелекне кайтарырга кулымнан килмәгәнлектән мин оялам.* Ш.Камал

9) Каршы эндәшү, кире җавап бирү. *Бер сүзеңә бишне кайтарыр*

10) Әңгәмәнең, сүзнең темасын икенчегә бору, үзгәртү. *Сүзне көлкегә кайтару*

11) Элекке хәлен торгызу, торышын, рәвешен элеккеге хәленә китерү. *Бары бергә эшне бетереп, капканы элекке рәвешенә кайтарып утырттылар.* Г.Ибраһимов

12) Элекке тәртипләрне кире урнаштыру, торгызу. *Иртәгә ул фронтка – Донда, Кубаньда безнең муеннарга иске богауларны кайтарырга көч җыеп маташучы генералларга каршы сугышырга, тагын кан, газап, үлем эченә китәчәк.* Г.Ибраһимов

13) Яңадан кабатлау, кабат кичерү. *Их, кайтарып булсын иде шул үткән матур көннәрне!* В.Нуруллин

14) Терелтү, тергезү. *Үлгәнне кайтарып булмый, дигән дә кайгыга төшкән.* Г.Коләхмәтов

15) Берәр нәрсәне, кешене алып кайту, китерү, озатып кую. *Саламны ул [Фәйзи Әхмәтович], әрәм-шәрәм итмичә, көздән үк терлек амбарлары янына кайтарып өйдергән.* Мәдәни җомга. *Берникадәр вакыттан соң, дөньядан хәбәре булмастай гарипләнгән олы улының, ни үле, ни тере дигәндәй, хәрәкәтсез гәүдәсен кайтаралар...* Казан утлары

16) Торган, яшәгән җиргә нидер китерү, алдыру. *Кибеткә товар кайтару*

17) Кирегә әйләндереп салу, кире якка әйләндерү. *Галләметдин --- урталыкта бәләкәйрәк чүмәлә рәвешендә өелгән печәннәрне артка таба кайтарырга керешә.* Ш.Камал. --- *Каһир граммофонның тавыш чыгаргычын янга кайтарып боргычын борды да тагын әйләндереп җибәрде ---.* Ә.Гаффар

18) Кирегә бөкләп кую (өс-баш киемнәре тур.). *Газизә кер юып торган җиреннән кинәт идәнгә утырды да башындагы яулыгын кайтарып күзләрен каплады.* Г.Ибраһимов. *Яканы кайтару* // Эленеп, ябылып торган әйберләрнең читен бөкләп күтәреп ачу. *Ул җиң очын аз гына кайтарды да, сәгатенә күз төшереп, коры гына: «Алты тулып унбиш минут...» – дип әйтеп куйды.* Г.Бәширов

19) Һөҗүмне туктату, чигенергә мәҗбүр итү, җиңү. *Ләкин тау өстенә урнашкан батарея тигез интервал белән тыныч һәм ышанычлы җавап кайтара иде.* А.Шамов. *Кызыл гаскәр беренче һөҗүмне кире кайтарды.* Ш.Усманов

20) *тар.* Катлап үрү, катлап чыгу (чабатаны). *Чабатаны кайтаруын гына кайтар, үрүен кирәк кем дә үрер.* Мәкаль

21) Кискеч коралларны үтмәсләү, йөзен тупасландыру. *Пәкенең йөзен кайтару*

22) Икенче төрле уйларга мәҗбүр итү, алдагы фикереннән, карашыннан баш тарттыру. *Шәрифулла, әйберләрен алып, китәргә җыена башлады, ләкин Миңнур карт аны бу уеннан шунда ук кайтарды.* А.Шамов

23) *куч.* Көчен, тәэсирен бетерү, киметү. *Сихер кайтару*

**2. кайтарып** *рәв. мәгъ.* 1) Икенче кабат, яңадан кабатлап. *Галинур кайтарып җавап бирмәде, түр бүлмәгә узып, өстен чишенде.* М.Хуҗин. *«Я, я, Иранда ниләр бар», – дип кайтарып сорады Габделвәли.* Ә.Фәйзи

2) Шуңа нигезләнеп, шуны сәбәп итеп алып, шул сәбәптән чыгып. *Димәк, нинди генә хыялый, легендар сурәтләрдә бирелгән әсәр булмасын, без андагы сурәтләрне тикшерүне сыйныфлар көрәше күренешләренә кайтарып, шуларның чагылышы итеп алып тикшерергә, шуннан килеп бәя бирергә тиешбез.* Г.Нигъмәти

◊ **Кайтарып алу** Авыру яңадан көчәеп китү, өзлегү. *Мине яңадан грипп кайтарып алды әле*. **Кайтарып калдыру** 1) Сылтау итү, нәрсәгә дә булса бәйләп аңлату. *Ләкин бөтен нәрсәне басымга кайтарып калдыру да ярамый.* М.Җәлил. *Бар гаепне сугыш кыенлыкларына гына кайтарып калдыру да дөрес булып бетмәс.* В.Нуруллин. *Бөтенесен фәнгә генә кайтарып калдырма син. Игенченең тырышлыгын, үз өстенә төшкән җаваплылыкны ныграк тоюын онытма.* Ф.Яруллин; 2) Әңгәмәнең, сүзнең темасын бүтәнгә күчерү. *Соңыннан сүзен бертуган сеңелләре Ләйсән белән Динәгә кайтарып калдырды, аларның кайда гомер итүләрен сораштырды.* Н.Хәсәнов

**Кайтара бару** Һәрберсенә, берәмберәм, бер-бер артлы кайтару. *Шуннан соң әкренләп-әкренләп ул акчаларны ияләренә кайтара барыр.* Р.Батулла

**Кайтара башлау** Кайтарырга тотыну. *«Татфондбанк»та акча кертемнәре булган клиентларга бүгеннән акчаларын кире кайтара башладылар.* Сөембикә

**Кайтара төшү** Тагы да бераз кайтару, арттыра төшеп кайтару

**Кайтарып бетерү** Ахырга кадәр, берсен дә калдырмыйча, тулысынча кайтару. *Ничекләр генә кире кайтарып бетерермен икән бу игелекләреңне?..* Г.Гыйльманов

**Кайтарып ташлау** Тиз генә кайтару; тиз арада кире илтеп кую. *Апалар аны, ничек кирәк алай көйләп, бәхилләтеп кайтарып ташладылар.* А.Шамов

**Кайтарып тору** Гел, һәрвакыт кайтару

**КА́ЙТЕР** *и. ингл.* Кайтинг белән шөгыльләнүче кеше

**КА́ЙТИНГ** *и. ингл.* Сноуборд, чаңгы яки тимераякта тизлекне арттыру өчен зур очырткыч кулланып шуу

**КАЙТМА** *с.* 1) Яңара, кабатлана торган. *Кайтма бизгәк*

2) Бер үк вакытта капма-каршы юнәлештә бара торган. *Кайтма реакция*

**КАЙТУ** *ф.* 1) Чыккан нигезенә, ата-анасына, туган ягына кабат әйләнеп килү. *Озак вакытлардан соң картайган егет булып авылга кайттым.* М.Мәһдиев. *Җир бит! Ни йөзе белән авылга кайткан, диң син.* Н.Гыйматдинова. *Кинәт аның Кырлайга кайтасы, әтисен бик-бик күрәсе килеп китте.* Ә.Фәйзи // Гомумән алдан булган, чыгып киткән урынына кабат әйләнеп килү. *Шәһәргә эш белән килгән авыл кешеләре барысы да диярлек монда кунарга гына кайталар иде.* М.Әмир. *--- партизан аэродромыннан унике чакрым көнчыгыштарак урнашкан лагерьга кайтырга чыктылар.* З.Фәтхетдинов // Килгән юлдан кире юнәлештә хәрәкәт итү. *Аннан алар Гөлҗамал белән икәү, юл буенча бөтен үткән гомерләрен исләренә төшереп, әкрен генә сөйләшеп кайттылар.* Ә.Еники. *Кичә базардан кайтканда чыбыркымны җуйдым.* Ә.Фәйзи

2) Кая да булса товар, әйберләр килү. *Берәр сәбәп аркасында кибеткә ипи кайтмый калса, хатын-кыз кара кайгыга бата.* М.Мәһдиев

3) Вакытлыча тукталып торган, алдан эшләнгән булган, ләкин тәмамланып бетмәгән эшкә яңадан тотыну. *Тимерхан аны кат-кат кайтып карар, тәҗрибә туплаган саен, ул аннан үзенә кирәклесен алыр.* Г.Ахунов

4) Элекке халәткә, торышка килү. *Райкомолның беренче секретаре үзенең колхоз комсомол оешмасы секретарен әнә шулай сәламләде, һәм бу Ирекккә элеккеге хәленә кайтырга, тынычланырга ярдәм итте.* Ф.Садриев

5) Төзәлү, савыгу. *Рухия [хастаханәдә] төгәл бер атна ятты. Җәрәхәте бик тиз кайтып, яра җөйләре бик тиз йомылса да, илаһи дөнья юлларына ялгыш кына ачылып киткән зиһен капусы ябылмады да ябылмады.* Г.Гыйльманов

6) Алдан әйтелгән фикердән, сүздән баш тарту, тану. *Ләкин бераздан башында эшләпә вә өстендә урыс киеме икәнен исенә төшерде, ул фикереннән кайтты да, шушы кыяфәттә килеш теге хәзрәтләрнең күзләренә күренүдән куркып, креслоның түренәрәк яшеренде.* Ф.Әмирхан. *Ул да түгел, бу уеннан кайтып, [Микәй] кырт борылып кире йөгерде.* Р.Мөхәммәдиев

7) *юкл. форм.* Үз фикерендә, үз сүзендә нык тору, әйткән сүзен бирмәү. *Әмма әткәй үз сүзеннән кайтмый.* Г.Ибраһимов

8) Көче кимү, сүрелү (кызу, эссе тур.)

9) Начарлану, көчсезләнү, куәте, егәре кимү

10) Ирдән аерылу. *Икәү генә калганнан соң, Газизә апасы Габдуллага бу хатынны җизнинең кияүдән аерылып кайткан өлкән кызы дип аңлатты.* Ә.Фәйзи

◊ **Кайта күзгә** Икенче тапкыр караганда, кабат уйлап караганда («килешмәслек түгел, начар түгел» мәгънәсендә). **Кайту белән кайту** «Нинди планнар белән, күпмегә, бөтенләйгәме кайтуың» дип сорау мәгънәсендә. *Я, ничек кайту белән кайттың? Ягъни күпмегә диюем.* Г.Бәширов. **Кайтып калу** 1) Сәбәп булу, нәтиҗә нәрсәгә дә булса бәйле булу; әйләнү, әверелү. *Кабан проблемасы техник якка яки финанс мәсьәләләренә генә кайтып калмый, иң әүвәл бу – аңлылык, вөҗдан мәсьәләсе.* Р.Мостафин. *Кеше тормышта шәхси гадәт-холкына бәрабәр хәрәкәт итә, киресенчә булса, ул үз-үзен көчләүгә кайтып кала.* Ф.Галиуллин; 2) Фикер, сүз бер үк юнәлешкә әйләнеп кайту, бер үк мәгънә, эчтәлек алу. *Сүз нинди генә тыкрык-борылышларга кереп китмәсен, ахыр чиктә бүгенге көнгә, узган елгы корылыкка, шуның нәтиҗәсендә туган ачлыкка кайтып кала иде.* М.Хәсәнов. *Турыдан-туры шулай әйтелмәсә дә, большевиклар иманы шуңа [туган телебезне оныттыруга] кайтып кала.* Т.Әйди. **Кайтып төшү** 1) Әңгәмәдә элекке темага кире

әйләнеп кайту; сүзнең темасы кисәк үзгәрү; башка, үзгә тема алу. *Әйләнә-тулгана торгач, сүзләре гаилә хәлләренә кайтып төште.* Б.Камалов; 2) Элеккечәгә әйләнү, элекке халәтен алу. *Өч көннән Сайдә үзенең элеккеге халәтенә кайтып төште.* Г.Гыйльманов; 3) Фикереннән, карашларыннан, уеннан кире кайту, тану, баш тарту; ачуы басылу, алдагы халәтеннән йомшару. *Хәзрәт, бөтенләй кайтып төшкән бер кыяфәткә кереп, халыкның явызлыгыннан да гайре аның комсызлыгыннан, хөсетлелегеннән зарлана башлады.* М.Хәсәнов. *Сафура бураннары уйнаса да, Ярулла бабай хатынына кул күтәрми, сукмый, тиз кайтып төшә.* Т.Галиуллин

**Кайтып җиту** Шул арада кайту, кайтырга өлгерү, кайтып ирешү. *Кулларны кысышып, кабат саубуллашып торган арада, фатир хуҗасы да кайтып җитте.* М.Хәсәнов. *Сугыша-сугыша Сталинградка тикле чигендем, сугыша-сугыша Полесьега, Кременецка кайтып җиттем.* К.Латыйп. *Әти, менә мин дә кайтып җиттем.* Г.Ахунов

**Кайтып йөрү** Һәрвакыт, гел кайту. *Мостафин да бу көннәрне төшке чәйгә һәм кичке ашка әбиләренә кайтып йөрде.* Ә.Еники. *Тукайның 90 еллык юбилее вакытында ул [Хәсәнов] Арчага атнасына ике мәртәбә кайтып йөрде.* Г.Ахунов

**Кайтып керү** Кинәт, уйламаганда, уйламаган-көтмәгән хәлдә кайту. *Заһир мәктәп ишегалдына буш чана белән кайтып керде.* М.Мәһдиев. *Әтисенең исерек, бигрәк тә чайкала-чайкала кайтып кергән чагын күрсә, ул аны кызгана, аңардан ераклаша иде.* Р.Низамиев. *Язын каен җиләге пешкәннән башлап көзен чикләвек җитешкәнче, авыл малае урманнан кайтып керми.* Г.Ахунов

**Кайтып тору** Һәрвакыт, еш кайту; кабат килү шарты белән әлегә, вакытлыча кайту. *Ярый, иптәш Борһанов, бүгенгә кайтып торыгыз, мәсьәләне иртәгә хәл итәрбез.* Г.Ахунов

**Кайтып төшү** Кисәк, көтмәгәндә, уйламаганда кайту. *Әллә инде биш тәүлек буе су өстендә килеп коры җиргә аяк басуданмы, әллә тагы зур гомердән соң беренче тапкыр иске таныш җирләргә кайтып төшүдәнме, ни булса да, эшне кайдан тотып башларга белмичәрәк аптырап калды.* Г.Минский. *Мәдрәсә ачылуга, Кәбир әфәнде Петербургтан кайтып төште.* Ә.Фәйзи. *Баһаветдин дигән үсеп буй җиткән егет Хәсән байлардан, тарантаска кола бия җигеп, әнисе йортына кайтып төшә.* Г.Ахунов

**КАЙТЫ́М ЮНӘЛЕШЕ** *и. лингв.* Нинди дә булса эш яки хәрәкәтнең субъектка әйләнеп кайтуын белдергән фигыль формасы (мәс., *коену, киенү*)

**КАЙТЫШ** I *и.* Кире әйләнеп кайтып килеш. *Аулыма кайтышта мин бер чит авылга туктадым.* Г.Тукай. *Моның бер генә дә түгел, ике үрдәк белән өйгә кайтышы өйдәгеләрнең тәмам исен китәрде.* Ш.Камал

**КАЙТЫШ** II *с.* Үзара чагыштырылган берәмлекләрнең алдагысыннан чагыштырмача кимрәк, түбәнрәк булган. *Ул малай сәләте белән Алёшадан кайтышрак.* З.Фәйзуллин. *Оригиналда ул әдәби эшләнеше ягыннан кайтышрак булса да, театр белгечләре аны арсеналга алырга булдылар.* Г.Ахунов. *Иң шәбе җитмеш биш тиен тора, кайтышрагы – илле, иң арзанлысы – егерме биш тиенлек.* М.Әмир

**КАЙТЫШЛЫЙ** *рәв.* Кайту уңаенда, кайтып барган чакта, кайткан юл уңаенда. *Вәли карт намаздан кайтышлый, үз өенә кермичә, бер туган агасы Сәйфулла картка үтте.* Ш.Камал. *Әхмәт кайтышлый хәзрәтне рәсемнәр музеена алып керде.* Ф.Әмирхан

**КА́ЙЧАГЫНДА** *рәв. к.* **кайчакта**. *Кайчагында атналар буе өйдән чыкмаска туры килә миңа.* Р.Ишморат. *Бәдри абзыйның Казанда озак кайтмый йөрүе белән борчылып, Гайшә апа кайчагында сукрана башлый, ирләрне битәрләргә тотына.* Ә.Фәйзи. *Кайчагында шигырен дә язып ташлыйм, бигрәк тә мине сонет җәлеп итә.* К.Латыйп

**КА́ЙЧАК** *рәв. к.* **кайчакта**. *Бу хозурдан онтыла кайчак эчү берлән ашау.* Г.Тукай. *Исән-сау кешеләрнең дә кайчак йөрәге сызлый, Разия апа, бик нык сызлый.* Р.Ишморат

**КА́ЙЧАКНЫ** *рәв. к.* **кайчакта**. *Ул шушында китап укый, кыяр белән ипи ашый, хыял дәрьясында йөзә, хәтта кайчакларны йоклап та ала иде.* Р.Низамиев

**КА́ЙЧАКТА** *рәв.* Кайвакыт, кайсыбер вакытта, вакыты-вакыты белән, ара-тирә. *Анысы инде, алтыным, кайчакта дагалы ат та абына.* Р.Ишморат. *Кайчакта аны уртага алып татарча җырларга яки русча җырларга өйрәтәләр.* Г.Әпсәләмов. *Шулай да була: кеше кайчакта үз күз алдында үлгән, үзе җирләп кайткан әти-әнисенең, баласының үлеменә дә озак вакытлар ышанасы килмичә йөри.* Г.Гобәй

**КА́ЙЧАН** *а.* **1.** 1) Вакытын ачыклау өчен бирелгән сорау җөмләдә кулланыла. *Беркөн Сабит әткәсен күреп әйтә әйтәсен: «Әти, миңа әлепби кайчан алып кайтасың?»* Г.Тукай

2) *Менә* кисәкчәсе белән берләктә килеп, эш яки хәрәкәтнең үтәлү вакытын билгели. *Менә кайчан пароход күрә икән Хәлим?* И.Гази

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кайвакыт, вакыты-вакыты белән, уйламаганда. *Музыка бит ул – бик бәйләнчек нәрсә, кайчан йоклаганда да колактан китмичә йөдәтә.* Ә.Еники

2) Ике җөмләдәге мәгънәләрне бербересенә капма-каршы куеп әйткәндә һәр җөмлә алдыннан китерелә. *Кайчан йомшак кичке җилләр исә, кайчан саз тарталар, көйлиләр.* Ф.Бурнаш

3) Нинди вакытта гына булмасын, һәрвакыт. *Кайчан гына карама, [сестра] шунда иде.* А.Шамов

4) Бик күптән, әллә кайчан. *Сездә дә гаеп, трактор соң Кайчан килде безнең кырларга.* М.Җәлил

**3.** *мөн. сүз мәгъ.* Баш җөмләдәге *шунда* сүзен ачыклап, иярчен вакыт җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла

◊ **Кайчан да булса** Бер-бер вакыт, кайсыдыр бер вакытта. *Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк.* Ф.Әмирхан. **Кайчан да кайчан** Икенче эшнең үтәлүе өчен нindидер шартлар килеп чыкса, шул шартлар үтәлсә. *Кайчан да кайчан малайлар белән барыбыз бергә җыелгач, мин сиңа таба борылырмын.* Г.Гобәй. **Кайчан карама** Гел, һәрвакыт, ничә тапкыр күрсәң дә

(бер үк хәлнең кабатлануына басым ясау өчен әйтелә). *Кайчан карама, урам буйлап кемнәр терлеге каңгырып йөри дисәк, шуларныкы булып чыга.* А.Шамов

**КА́ЙЧАНГЫ** *а.* Кайсы вакытта булуын ачыклау өчен бирелгән сорау җөмләдә кулланыла. *Кайчангы хәлне сөйлисез?*

**КА́ЙЧАНДЫР** *а.* Әллә кайчан бер, үткән көннәрнең берсендә. *Николай Яковлевич Марр дигән академик кайчандыр яңа лингвистик агым – яфәтизм теориясенә нигез салган икән.* М.Мәһдиев. *Бу кайчандыр шушы мәдрәсәдә укып киткән, аннан соң Бозаулык ягында мөдәррис булып торган.* Ә.Фәйзи. *Кайчандыр таза, нык һәм шаян егет хәзер аягында чак-чак кына басып тора, күкрәгеннән тотып еш кына йөткерә, кан төкерә.* А.Шамов

**КАЙЧЫ** *и.* 1) Кара-каршы китереп уртадан тоташтырылган үткен йөзле ике пычактан гыйбарәт, очларындагы балдаксыман боҗраларын баш һәм урта бармакларга киеп хәрәкәтләндерә торган кискеч корал. *Ак атласым җитмәде, алмас кайчым үтмәде.* М.Фәйзи. *Капчык төпләреннән пәке, кайчы, бритва шикелле солдат кирәк-яраклары чыкты.* Г.Бәширов. *Хуҗа хатын сарык йоны кыркый торган зур кара кайчы китереп бирде.* А.Шамов

2) Йортның стеналарыннан түбәсенә таба почмак ясап, кара-каршы беркетелгән ике агачтан торган терәк

◊ **Кайчы белән кереп чыгасы бар** Озын чәчле, сакал-мыек баскан ир-атка тышкы кыяфәтеннән ризасызлык белдереп әйтү. *Болай ул үзе матур егет. Тик менә артык озын чәчләренә бераз кайчы белән кереп чыгасы бар ---.* Ф.Яруллин

**КАЙЧЫКОЙРЫК** *и. зоол.* Дымлы урыннарда үрчи торган, гәүдәсенең арткы өлеше икегә аерылып торган бөҗәк; *русчасы:* **двухвостка**

**КАЙШАЛУ** *ф. диал.* 1) Гәүдәсе белән артка яки кырыйга каерылу, артка бөгелү. *Галияр сулга кайшалып, кулы һавада асылынып торган арада, Сәрвиянең башыннан әнә шундый уйлар җәһәт йөгереп узды.* М.Хуҗин

2) *к.* **каймыгу**. *Кайшалган, сынган җирем юк микән дип, Равил яткан килеш кенә кулларын-аякларын селкеткәләп карады.* В.Нуруллин

3) Бер-берсенә керешү, чуалу, укмашу. *Кайшалып үскән клевер басуы урман полосасына кадәр тоташ диңгез булып җәелеп яткан.* М.Мәһдиев

**Кайшалып китү** Кинәт, уйламаганда кайшалу

**КАК** I *и.* 1) Өлгергән җиләк-җимештән изеп ясалган массаны тактага юка гына җәеп, кояшта киптереп әзерләнгән чәй ризыгы. *Кәримә апа как янына бер лимон да бирде.* Н.Хәсәнов. *Мин хәзер карлыган кагы кайнатып эчерермен.* М.Гафури. *Җиләк җыям, как коям, падишага бүләккә.* М.Фәйзи. *Алмалары тәмле булса да, сатып алырга күңеле тартмады, һәм ул алма урынына как алып кайтып китте.* К.Латыйп

2) *диал.* Җиләк-җимешкә шикәр, бал кушып кайнатып әзерләнгән камыр ризыклары өчен эчлек; повидло. *Эш беткәч, Рәйханә аларны тәмле как сумсасы һәм вареньелы чәй белән сыйлады.* А.Расих. *Ак өемнең шкафында Балдан койган кагым бар.* Җыр

**КАК** II *и.* Кипкән кура, коры чыбык. *[Карт] Куе как төбеннән җәлтерәп чыкты да, ди, егетне кочаклап еларга тотынды, ди.* Әкият

**КАК** III *с.* 1) Коп-коры, бик нык кипкән. *Как агач*

2) Берни түшәлмәгән, бернәрсә белән дә капланмаган. *Как идәнгә ятып тирән уйга батты.* М.Гафури. *Аның [хәлфә] янына аяк бөкләп, берни дә җәелмәгән как идәнгә утыра идек.* М.Әмир

3) *күч.* Бик нык ябыккан, коры сөяккә калган

◊ **Как баш** Надан, аңгыра, уй-фикер үзгәрешләренә, тормыш яңалыкларына иярә алмый торган кеше турында. **Как сөяккә калу** Бик нык ябыгу, арыклану. *Как сөяккә калган Гөлниса белән баланы күтәреп алып чыгалар да, ястык түшәлгән арбага сузып салып, алып китеп баралар.* М.Хәсәнов. *Урман дигәннән, Хәлим олан, ул сине дә шактый изалаган, ахры... Әнә бит, как сөяккә калгансың.* Г.Гыйльманов

**КАКАДУ** *и. нем.<малай. зоол.* Тутый кошсыманнар отрядының ассемьялыгына караган, бүрекле булуы белән аерылып торган тутый кош төре

**КАКА́О** *и. исп. < ацтек.* 1) Стеркулчалар семьялыгының теоброма ыругыннан, орлыкларыннан шоколад ясый торган тропик агач

2) Шул агач орлыкларыннан ясалган порошок һәм аны сөттә яки суда эретеп әзерләнә торган эчемлек. *Сабый, ирennәренә какао тигәч, --- кинәт очынып чапылдатырга тотынды.* Г.Гобәй. *Нәрсә белән сыйлыйм үзеңне? Бисквит белән какаоны яратасыңмы?* Т.Әйди

3) Ачык көрән төсне белдерү өчен кулланыла. *Киемнәре пөхтә: коңгырт костюмнан, ак күлмәктән, какао төсендәге галстуктан.* Т.Әйди

**КАКАЮ** *ф. диал.* Берүзе, бербашы булу, ялгызы торып калу. *Я кукуруза арасында үзенең какаеп карап торган рәсемен күргәч, ачуланыр, кәефе китәр дип уйлады.* Г.Галиев

**Какаеп калу** Элек күбәү булып та, хәзер берүзе, бербашы калу, башкалардан аерылу, аның яныннан барысы да киткән булу. *Нинди уңайсыз, нинди оят монда утырып тору, какаеп калганыма бу урам халкы дикъкать итми торгандырмыни?* Ф.Әмирхан

**КАКЛАГАН** *с.* Кояшта яки җиләс коры урында озак тотып киптерелгән. *Шәмсинур җиңгинең атланмае, каймагы, юкә балы, каклаган ите, чәкчәге – барысы да табынга тезелде.* Г.Әпсәләмов. *Андрей, өстенә киеп, ашарына ипи белән каклаган дуңгыз ите алып, каядыр чыгып китте, бары икенче төнне генә кайтты.* А.Шамов. *Машинага обкатка ясады, шәһәр тирәсендәге авылларда йөреп, профессор кулына каклаган каз тоттырды.* К.Латыйп

**КАКЛАНУ** *ф.* 1) Ысланып кибү, ыслану (ит, балык ризыклары)

2) Кояшта яки җиләс коры урында озак торып кибү

3) Җилдә, кояшта кибеп, каралып яргалану (бит, йөз). *Аннары скрипка моңына сокланып, бабасының җыерчыклар ермачлаган, җилдә-кояшта какланып бронзаланган олпат йөзенә текәлеп утырды.* Б.Камалов

4) Артык кибү, кибеп тыгызлану (агач, такта)

**Каклана башлау** Какланырга тотыну

**Какланып бетү** Бик нык каклану; тәмам каклану. *Идән, түшәм такталары тора-тора какланып беткән, кадак та кирәрлек түгел.* Ә.Еники. *Тозлы җилгә какланып беткән диңгезче халкына бернинди чир йокмый.* М.Юныс

**КАКЛА́У** *ф.* Ит, балык ризыкларын кояшка, җилгә элеп киптерү. *[Мирсәет:] --- безнең яклардагы кебек шәп итеп беркайда да каклый белмиләр казны.* Р.Төхфәтуллин // Махсус технология белән ыслап киптерү

**КАКЛЫГУ** *ф. диал.* Кире атылу, бәрелеп кире кайту. *Нургали авызыннан ычкынган һәрбер сүзенең каклыгып суккан таяк шикелле кире үзенә кайтуыннан гаҗиз булып, бөтенләй сабырлыгын җуяр хәлгә килде.* Ә.Еники

**КАКМА** *и.* Элек авылларда төнге кизүдә шакылдатып йөрү, бер-бер котелмәгән хәл килеп чыкса, шакылдатып, халыкны аякка бастыру өчен махсус ясалган корал; шакылдавык

**КАКОФО́НИК** *с. муз.* Аһәңсез, колакка ятышсыз авазлар җыелмасыннан торган

**КАКОФО́НИЯ** *и. гр. муз.* Аһәңсез, колакка ятышсыз авазлар җыелмасы; музыкаль хаос

**КАКСУ** *ф.* Җылы урында озак торудан, дөрес сакламаудан тәмсезләнеп бозылу; күгәрү, күксү. *[Май] Базда озак торган, каксыган, базарлыклы түгел.* Г.Бәширов

**Каксып бетү** Тәмам, бөтенләй каксу

**КАКСЫТУ** *ф.* Берәр төрле ризыкны дөрес сакламыйча яки озак тотып тәмсезләндерү, бозу; күксетү

**Каксытып бетерү** Тәмам, бөтенләй каксыту

**КАКТӨШ** *и.* 1) *диал.* Чәкчәк. *Шул кактөш мәҗлесенә кодача булып барырга кирәк дип, Вафа хаҗилардан биш асыл күлмәк керттеләр.* Г.Камал

2) Ширбәт, бал сеңдереп әзерләнгән татлы, баллы чәй ризыгы. *Үзе шулай үпкәләсә дә, абзасына әллә ничаклы туй күчтәнәчләре – чәкчәкләр, казлар, казылыклар, кактөшләр, бәлешләр, ләвәшләр җибәргән.* Г.Ибраһимов

**КА́КТУС** *и. лат. бот.* Кактуслар семьялыгына караган, кызу комлыкларда үсә торган, калын итле чәнечкеле сусыл сабактан торган, яфраксыз көньяк үсемлеге

**КАКТЫ́-СУКТЫ** *рәв.* Кагылыпсугылып, җәбер-золым белән. *Хава да шулай яшь балалык гомерен ятимлектә, авыл байлары тарафыннан какты-сукты булып үскән.* Г.Бәширов

**КАКТЫРЫ́П-СУКТЫРЫП** *рәв.* Читләтеп, төрттереп, киная белән. *Сүз җае чыгарып, егет, кактырып-суктырып кына булса да, үзенең күңеле барлыгын аңлатырга ниятләде.* Г.Гафурова. *Бу кактырып-суктырып әйтүләргә дә оста җавап бирү кирәк иде. Әмма алманчасы аксау Янгуразны харап итә язды.* Т.Әйди

**КАКУЛ** *и. фар.* Кайбер (төрки, монгол, тунгус, кытай һ.б.ш.) халыкларда ир-егетнең баш түбәсендә китәрелмичә калдырылган бер тотам чәче

**КАКЧА** *с.* Ит кунмаган,ябык, чандыр (гадәттә йөз, гәүдә тур.). *Кәгазь кулдан-кулга күчкән арада, Якуб Дәүләтьяровның ач яңаклы какча йөзенә тагын бер тапкыр карап алды.* И.Гази. *Какча бәдәнле бу кеше күп дигәндә егерме бишләр тирәсендә булгандыр.* М.Әмир. *Ачык, какча йөзенә килешеп торган сары мыегы аның көләчлеген тагын да арттырыр өчен махсус үстерелгән диярсең.* М.Әмир

**КАКЧАЛАНУ** *ф.* Какчага әйләнү, ябыгу, арыклану. *Шулкадәрле авыр күп эштән ул ябыгып, какчаланып, сөяк белән тирегә торып кала.* З.Зәйнуллин

**Какчаланып бетү** Тәмам какчалану, нык ябыгу

**КАКЧЫЛ** *с.* Ябыграк, арыграк

**КАКШАГА** *и. диал.* Су белән килгән агач өеме. *Авылда яңа мәктәп салу өчен, хөкүмәт бер зур сал какшагасы биргән.* М.Хәсәнов

**КАКШАК** *с. диал.* Какшаган, урыныннан кузгалып селкенеп тора торган. *Йортларның күбрәге какшак, басынкы, таушалган.* Ш.Камал

**КАКШАМАС** *с.* Какшамый торган, нык, җимерелмәс. *Үзенең какшамас закончалыклары буенча колхоз тормышы элекке ике ялчыны өлешле, мул тормышлы иткән.* М.Максуд. *Чын иманлы ир-егетләр какшамас һәм каушамас.* М.Гафури

**КАКШАМАСЛЫК** *с. к.* **какшамас**. *Какшамаслык изге дуслыгыбыз иң зур бүләк булсын аларга.* Г.Кутуй

**КАКШАТУ** *ф.* 1) Бушатып, урынында селкенеп тора торган хәлгә китерү

2) *күч.* Җимерү, эчке ныклыгын бозу, эчтән таркату, җиңелү хәленә җиткерү. *Безнең көчебезне какшатырга, безнең арага курку салырга маташалар.* Ш.Камал. *Дуслыкны какшату*

3) *күч.* Элек нык ышанган фикеренә, уена шөбһә ияту, башкача, киресенчә уйларга мәҗбүр итү. *Иптәшләре аның булдыклылыгына ышанычларын какшаталар, семья тормышы бозыла, Габбасның эш перспективасы тикшерелү алдына килеп баса.* Г.Нигъмәти. *Бәхетсез тормыш аның кешегә булган ышанычын көннән-көн какшата, ягымлы күңел хисләрен көннән-көн тупасландыра, саектыра бара иде.* З.Фәйзи

4) *күч.* Арыту, вату, йончыту; көчне, хәлне, саулыкны алу (физик эш, авыру һ.б.). *Чамадан тыш авыр физик хезмәт аның сәламәтлеген какшата, ул авырый башлый.* Г.Ахунов. *Нервыны какшату*

**Какшата бару** Аз-азлап, акрынлап какшату. *Җәмгыять тормышын зәһәрләп какшата баралар.* Ш.Камал

**Какшата башлау** Какшатырга тотыну. *Йөгереп барып казыкка ике куллапябышты да аны какшата башлады.* З.Зәйнуллин. *Беренче империянең нигезен какшата башлаган 1905 елгы революциядән соң без беренче рухи һәм милли күтәрелеш кичердек.* Ватаным Татарстан

**Какшата язу** Чак кына какшатмый калу. *Дин тотмады, юк-барга ышанмады, ләкин әйтеп бетермәслек кайгы аны какшата язды, ул беркөн эштән кайтышлый Хәбирә карчыкның карындык тәрәзәсен какты.* М.Мәһдиев

**Какшатып бетерү** Бик нык, бөтенләй юкка чыгарлык итеп какшату

**КАКША́У** *ф.* 1) Ныклыгы бетеп, селкенеп тору, бушау. *Янаганда, кулыңны кыеп төшермә, чалгы сабыңны җиргә нык терә, какшау булмасын дип*

*өйрәтеп яткан була.* А.Гыйләҗев. *Кояш һәм яңгырлар тәэсире белән искереп беткән арба шикелле какшап, кызганыч хәлгә килгән.* Ш.Камал. *Машинасы бозылган яисә куәтле берәр винты какшаган дисәң, анысы бер хәер.* Ш.Камал. *Карале, улым, җайлап кына әйт әле, тәрәзә яңаклары какшаган, бер килеп рәтләп китмәс микән.* М.Маликова

2) Эчке ныклыгын югалту, бозылу, җимерелү, юкка чыгып таркалу, бетү (хуҗалык, гаилә тормышы, тәртип һ.б.). *Берәү үлми, икенчеләр көн күрми дигәндәй, Җәләш мулланың «хаҗга» китүе Сабирны бик тиз авылга кайтара, һәм ул какшаган хуҗалыкны нызытып, үстереп җибәрә.* Г.Нигъмәти

3) *күч.* Төшенкелеккә бирелү, рухи таркалу. *Аннары, немецның рухы бөтенләй какшаган чак була бит инде ул.* И.Гази

4) *күч.* Авыр кичереш, җәфа белән нык йончу, хәлсезләнү, саулык бетү. *Соңгы айларда аның нервлары бик какшады, бер сүз әйтер хәлем юк, хәзер кабынып китә.* Т.Гыйззәт. *Ә менә хәзер сәламәтлек бик какшады, йөрәк аксый, Дамир энем, йөрәк.* Д.Салихов. *Дөресен генә әйткәндә [Дугласның] исәнлеге дә какшады соңгы вакытта.* Р.Ишморат. *Әгәр организмда аксым җитмәсә, сәламәтлек какшый. Димәк, һәр көн аксымлы азыклар ашау шарт.* Биология

5) *күч.* Кимү, юкка чыга бару, кирегә китү. *Халыкның ышанычын югалтып барасың, Борһан. Ә халыкның ышанычы какшадымы, аннары бетте инде.* М.Хәсәнов

**Какшый башлау** Какшау билгеләре күренү. *Татар кызының ышанмавы какшый башлады.* Ф.Әмирхан

**Какшап бетү** Тәмам, җимерелергә җитеп какшау. *Дога белән ныгытмакчы була какшап беткән чиркәү нигезен.* М.Гафури

**Какшап китү** Бераз, берникадәр какшау; аерым шартларга бәйле рәвештә какшау. *Кызу эш арасында нервлар бик какшап киткәч, зимагурларча, бурлакларча сүгенгәләп тә алгалый.* М.Гафури

**КАКШАЮ** *ф.* Артык кибеп ныгу, кагаю. *Арслан җирдән үлән сабагы алып, аны теше белән өзәргә тотынды, ләкин сабакның катысы, какшайганы туры килде, ул тиз генә өзелми.* Г.Ахунов

**КАКЫ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгына караган, сары чәчәкле, калын итчел, сусыл, тәме әчкелт, ашарга яраклы сабаклы үлән үсемлек; *русчасы:* **свербига восточная**. *Балтырганнар, баллы какылар бер-берсеннән тәмле, татлылар.* Ш.Маннур. *Бу тирәдә үлән генә түгел, ис тә үзгә. Какы, кузгалак, тагын әллә нинди үсемлекләр исләре.* М.Хәсәнов. *Еланнар эзләдек, катканрак булса да юалар, яңа гына чыга башлаган балтырган көпшәләре ашап, соңра уҗым ягына какыга чыктык.* Г.Ибраһимов

**КАКЫЛДА́У** *ф.* 1) *к.* **каңгылдау**. *Ишектән дә кер, котым, Тишектән дә кер, котым! Каз кебек какылдап, Үрдәк кебек бакылдап.* Такмак

2) *күч.* Бертуктаусыз артык кычкырып сөйләү

**КАКЫЛДАШУ** *ф. урт. юн.* 1) Каңгылдашу. *Кояш баер алдыннан, су буенда йөргән бер көтү йорт казлары какылдашып, --- кайтып керделәр.* М.Гафури

2) *күч.* Берничә кеше берьюлы артык кычкырып сөйләшеп тору

**КАКЫЛЫК** *и.* Какы күп үсә торган урын

**КАКЫРУ** *ф.* Тын юлларына утырган какырыкны йөткереп чыгару. *Авызларыбыздан төкерек урынына тузан гына какырабыз.* М.Гафури

**Какырып җибәрү** Кисәк кенә какыру. *Яхшы ук кызып алган Сарсымбай, утырган җиреннән ишеккә таба каты итеп какырып җибәрде дә: – Атаңа нәләт, шул найманнардан Сары-Арканың котылыр көне булырмы, юкмы?.. – дип, тәмләп, каһәрләп сүгенә башлады.* Г.Ибраһимов

**КАКЫРЫК** *и.* Тын юлларына утыра торган лайлалы куе сыекча. *Җавапка мондый тупаслык көтмәгән әбинең өстенә үк диярлек тегеләрдән берсенең сасы сары какырыгы лачкылдап килеп төште.* Ф.Яхин

**КАЛА** *и. гар.* Шәһәр. *Капчыкта кала күчтәнәчләре генә түгел, зур төргәк комсомол билетлары.* М.Әмир. *Литерлы поездны ялга, аулак юлга күчерделәр, министр шан-шәүкәтле борынгы калага аяк басты.* А.Гыйләҗев

◊ **Кала алган кебек, кала алгандай** Нинди дә булса сәбәптән бик нык куанып, шатланып, горурлык хисе белән. – *Менә, Пәсхи абый... синең мылтыгың... – диде ул, кала алгандай булып, мылтыкны Пәсхигә китереп бирде.* Ф.Хөсни. **Кала суккан кебек** Йортның зур, биек булуына, матурлыгына ишарә белән әйтелә. *Йорты янында узуы үзе бер куаныч – кала суккан кебек бит.* Г.Ахунов

**КАЛАЙ** *и.* **1.** 1) Табаклап җәелгән юка тимер. *Калайлардан, фанера кисәкләреннән оештырылган алачык.* А.Әхмәт. *Шыбыр-шыбыр яңгыр ява өй түбәсе калайга.* М.Фәйзи. *Аның [Тукай йортының] күгәрми торган калай белән ябылган түбәләре кояшта ялыкйолык килә.* Г.Ахунов

2) Шундый материалдан эшләнгән яки тышланган әйбернең үзе. *Әсәрнең сыйфатын әдәбиятның төп канунnарына таянып бәяләү юкка чыккач, авторның түшендәге калайларга, алган бүләкләренә, хакимияткә якын булуына таянып эш итү киң колач җәйде.* М.Юныс. *Атылган да җиргә төшкән, ярылып киткән калай эченнән килеп чыккан нужа бабай.* Н.Исәнбәт

3) Мичтә ашамлыклар пешерү өчен, шундый тимердән читләрен бөгеп ясаган савыт

**2.** *с. мәгъ.* Шундый юка тимердән эшләнгән. *Кайда булса да авылның уртасында, калай түбәле берәр йортта.* Ф.Хөсни. *Гәрәфи абзый, юлда чәй күп эчелә дип, тишек калай чәйнеген тимерчедән кургаш белән ямытып алды.* Г.Әпсәләмов. *Без калай кружкалардан кура җиләгенең таш борчагын, бөтнек яфрагы салып кайнаткан чәй эчәбез.* М.Мәһдиев. *Бар да таныш, бар да туган: мич янында баулы суган, соры песи, калай комган.* Г.Афзал

◊ **Калай этәч** 1) Һәрвакыт вак нәрсәләр өчен дә бәйләнергә, сугышырга торган кеше. – *Ни җитмәгән ул калай этәчләргә? – дип кенә куйды Хәйрүш.* М.Әмир. *Акырды да җикерде Морза,*

*шулай итенде, калай әтәч шикелле.* Ш.Маннур. *Тагын шул калай әтәч эшләпәдер инде дип, ачу белән борылып селкеп атмакчы булган иде – өлгерә алмады...* В.Нуруллин; 2) Мактанчык, бушкуык, юкка мактанып йөри торган кеше. *– Бүрәнә аша бүре үтермә, калай әтәч... – диде Гәззән, Сәлимне яклап, һәм кроватын шыгырдатып икенче ягына әйләнеп ятты, – йокла.* Г.Әпсәләмов. **Калай әтәчләнү** 1) Юкка бәйләнеп, сугышып китү; 2) Урынсыз мактану, артык шапырыну. **Калай күзле** Нурсыз, төссез күзле

**КАЛАЙЛАНДЫРУ** *ф.* Нурсызландыру, тондыру (күзен). *Сөйләп торган җиреннән кырт туктады да, Равилгә текәлеп һәм күзләрен калайландырып: – Нигә шушылай ыржаеша бу класс, комсорг... – диде.* В.Нуруллин

**КАЛАЙЛАНУ** *ф.* Тону, нурсызлану (күз тур.). *Инспекторның башта күзләре калайланды, аннары бөтен гәүдәсе калтырана башлады.* В.Нуруллин

**Калайланып чыгу** Калайланган хәлгә килү. *Болай да зур, чәркә хәтле соры күзләре тагын да зураеп, калайланып чыга.* В.Нуруллин

**КАЛАЙЛА́У** *ф.* Калай белән ябу, тышлау. *Башта көймәнең урындыкларын ныгыттылар, аннары борын өлешен калайладылар.* М.Хәсәнов. *Өй түбәсен калайлау*

**КАЛАЙЛЫ** *с.* Калай белән тышланган, калай капланган

**КАЛАЙЧЫ** *и.* Калай эшләре остасы. *Көзгә, институтның стеналары өелеп беткәч, калайчылар артеленә кушылды.* Х.Хәйруллин. *Балта осталары, столярлар, пыяла куючылар, слесарьлар, калайчылар, буяучы-малярлар табарга кирәк.* Т.Ахунов. *Миндә балта осталары, калайчылар, тәрәзә куючылар, миччеләр бар.* К.Латыйп

**КАЛАЙЧЫЛЫК** *и.* Калайчы һөнәре, калайчы кәсебе

**КАЛАК** *и.* 1) Чәй кашыгы, балкашык. *Лида шикәрсез чәен калак белән болгата-болгата байтак кына утырды.* А.Гыйләҗев. *Арсланов иреннәрен кыскан хәлдә чынаяктагы чәен калагы белән челтер-челтер болгатты.* Ф.Садриев

2) Берәр нәрсәнең көрәксыман яссы киң очы (ишкәкләрдә, измә изгечтә һ.б.ш.ларда); *русчасы:* **лопасть, перо**. *Пропеллерның калаклары кыеклатып ясалганга күрә, әйләнгән чакта, ул һаваны бораулап, көрәп артка ташлый.* С.Баттал. *Ә пресс калаклары туктаусыз әйләнә, тыгыз, дымлы балчык буткасын дүрткел авыз аша өзлексез этеп тора.* А.Гыйләҗев

3) Суканың җирне куптару, күтәрү һәм әйләндереп салу җайланмасы; *русчасы:* **отвал**. *– Нихәл, егетләр, җир юеш түгелме, калакка балчык сыланмыймы? – ди.* М.Гафури. *Мин, ул җирне саруттан арындыра алмыйча, өч сука калагы сындырдым. Ул [Аптул] игелекләнсен дип сындырдыммыни мин ул калакларны?* Ф.Хөсни

4) Пароход, су тегермәне һ.б.ш.ларның тәгәрмәчендәге ишү коралы; *русчасы:* **гребок**

5) *диал.* Янавыч; *русчасы:* **оселок**

6) Аяк киеменең үкчәсен таптамыйча кию өчен, ике кырыен бөгеп, очын ярым түгәрәкләп ясалган җайланма; *русчасы:* **рожок**

7) Мичкә ипи кую өчен кечкенә агач көрәк; *русчасы:* **лопатка**

**КАЛА́К ОНЫ** *и.* Элек тегермән тарттырган өчен тегермәнчегә бирелә торган он өлеше; көрәк оны

**КАЛА́К СӨЯГЕ** *и. анат.* Арканың өске өлешендә өчпочмак рәвешендәге яссы сөяк. *Сул яктагы калак сөягеннән алынган пуляны истәлеккә саклыйм.* К.Латыйп // Арканың шул сөякләр урнашкан урыны. *Ул барган төшкә мылтык көпшәсен әсирнең калак сөягенә тигезеп-тигезеп ала, янәсе, син мушкада, фашист.* М.Әмирханов. *Камчы бераз итләрәк урын эзләп торды да, таба алмагач, калак сөякләре буйлап аска таба сузылды.* Ә.Гобәй

**КАЛАКТОМШЫК** *и. зоол. к.* **кашыктомшык**

**КАЛАКЧА** *и. спорт к.* **ракетка**. *Теннис калакчасы*

**КАЛАМБУР** *и. фр. әд.* Бер үк сүзнең төрле мәгънәләрен яки аваздаш сүзләрне очраштыру юлы белән комик эффект тудыра торган тел-сурәтләү чарасы. *Башлап аның авызыннан ишеткәч, ул минем күңелемдә Галиәсгар абзый каламбуры булып калды.* М.Әмир

**КАЛАМБУРЛА́У** *ф.* Каламбур белән сөйләү, сөйләмдә каламбур куллану

**КАЛАМБУРЧЫ** *и.* Каламбурлар кулланып сөйләшүче; аларны уйлап табучы

**КАЛАН** *и. тар.* 1) Сугышта җиңелүчеләр җиңүчеләргә түли торган еллык салым. *Кара ханга калан түләп, уң ярда торып калган.* Н.Фәттах

2) Алтын Урда һәм татар ханлыкларында җан башына яки җир биләмәсенә салына торган салым төре. *--- син, минем колым Күрән би, өч җыл миңа калан түләмәдең. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм, ыруыңны юк итәм.* Н.Фәттах

3) Гаскәр тоту өчен халыктан җыелган җыем

**КАЛАНЧА** *и.* 1) Тирә-юньне күзәтү өчен, манарасыман биек итеп эшләнгән, югары очына күтәрелү өчен баскычлары булган корылма. *Акбүз, шалаш яныннан бер сөяк табып, тәмен белеп кенә кимерде дә кыр каланчасына менде.* Г.Гобәй. *Кешеләрнең җанына шик-шөбһә салып, иң элек каравыл өе янындагы каланча чаңын суктылар.* М.Хәсәнов

2) *диал.* Манара, башня. *Каланча сәгатенең моңланып-моңланып дүрт тапкыр чыңлаганын Хөснулла дикъкать белән тыңлады.* Ш.Камал. *Поезддагы теге матросның сүзен әйтүгә, Габдрахман каланчаның ачык җиреннән чыкты да башы белән Ярмәкәй тавы астындагы амбар-амбар ташларга таба очты.* Р.Сибат

3) *күч.* Үзенең кешелек сыйфатларына бәйле рухи биеклеге, рухи югарылыгы. *Һәркемнең хәлләргә, вакыйгаларга бәясендә үз каланчасы була.* Т.Галиуллин. *Син үз авылыбыз каланчасыннан карап кына хөкем йөртмә, Мәгышия апа.* В.Нуруллин

4) *күч.* Озын буйлы кеше. *Буе каланча, акылы бер тиенгә дә тормый*

**КАЛАЧ** *и.* **1.** Күпереп торган ак күмәч. *Берәүнең ап-ак калачны көнбагыш маена манып ашавын күреп, авызымнан сулар килгән иде.* М.Әмир. *--- калач сыныкларын чәйнәп йотарга*

*да өлгермәгән ике солдат --- арыш көлтәседәй җиргә ауды.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* Шуны хәтерләтә торган, шундый формада булган. *Кафия түти юантык, алтын тешле, көмеш калач алкалы, сәхнәдәге байбичәләр сыман бер хатын иде.* М.Мәһдиев

**КАЛА́ЧА** *рәв. сир.* Каладагы кебек, кала кешесе шикелле. *Аның өс-башын тәмам калача, каланың да мирзаларыча ясый.* Г.Ибраһимов

**КАЛАЧЧЫ** *и.* Калач пешерү остасы

**КАЛӘМ** *и. гар.* 1) Карага яки тушька манып язу өчен, эре каурыйдан, камыштан, корычтан ясалган әсбап. *Теге егет һаман эндәшми-тынмый каләм белән кыштырдатып утыра.* Ш.Камал. *Сугыштан тынган арада, Каләмне манып карага, Хат язар идем сезгә, Их кызлар, уңган сеңелләр, Хат язар идем сезгә.* М.Җәлил. *– Бераз гына җитми, – редактор кәгазь алды, каләмен карага манды.* И.Гази

2) Карандаш, ручка, гомумән язу яки рәсем ясау әсбабы. *Хәйдәр, художник каләме белән яңадан туган бу таныш җирләрдән күзен ала алмыйча, рәхәтләнеп карап торды.* Г.Бәширов. *Үз гомеремдә хаттан гайре нәрсә язмаганлыктан, кулы каләмгә күнекмәгән ---.* Х.Сарьян. *Язар өчен каләм сайлыйм, Төрле-төрле төрлеләрен. Табигатьнең үзе кебек Гамьлеләрен, серләрен.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Язма әсәрнең стиле. *«Кыямәт» --- әдипләремездән Гаяз әфәндenең оста һәм матур каләме берлә тасвир ителмеш бик мәгънәле һәм көлке комедиядер.* Йолдыз. *Каләме шома егетнең, Зөлфә язып алган истәлекләрне ул үзе үк менә дигән иттереп төзәтеп чыккалар иде.* Э.Касыймов. *Укучы автор каләменнән канәгать кала.* М.Вәлиев

4) *күч.* Язучылык осталыгы, әдәби талант. *Әдип үзенең әсәрендә кайбер каһарманнары хәрәкәтен йоларга тырышып караса да, яхшы ук җитди күзәтүче әдип каләме аларның гаебен ачып бирә.* Г.Нигъмәти. *Редакциядә эшләү өчен, язучы каләме генә җитми, Мансур каләмдәш, тәнкыйтьче каләме дә кирәк.* Ш.Маннапов. *Жаклинның буй-сынын тасвирлаганда, мәшһүр рәссамның каләме бөтен сизгерлеген, тылсымлы көчен кинәт югалткан диярсең.* М.Маликова

5) *күч.* Әдәби эшчәнлек, язучылык. *Телем, сүзем, каләмем, эшем белән һичбер вакытта да, һичбер урында һичбер каршылык кылмам дип вәгъдә итә аласызмы?* Г.Ибраһимов. *Мин революциянең беренче көннәреннән башлап ук каләмем белән катнаштым.* М.Гафури. *Аның каләменнән тагы да матуррак гөлләр түгелер.* М.Фәйзи. *Конкурсның ябык булуы Мәрьямне кулына каләм алырга дәртләндерде.* М.Маликова

6) *күч.* Язучы, әдәби, фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүче. *Быел март аенда яшь каләмнәрнең республика күләмендәге семинарын уздыру аеруча отышлы булды.* Ф.Галимуллин

◊ **Каләм балы** *иск.* Гонорар, авторга түләнә торган акча. *--- мин, ди, аның өчен юл башына утыз тиенгә чаклы каләм балы түләр идем, ди...* Г.Ибраһимов. **Каләм йөгертү** *к.* **каләм тибрәтү**. **Каләм каш** Гүзәл кыз, чибәркәй. *Менә хәзрәтләр барысы да: «Каләм кашым, хурыйльгайнем, матур апаем!» – дип, урыннарыннан сикерешеп торып, теге кызны кочакламакчы булдылар икән.* Ф.Әмирхан. **Каләм остасы** Әсәрләрен матур стиль белән, сурәтләү чараларыннан оста файдаланып яза торган автор; гомумән, язучы. *Бу көзне язучылар союзы рәисе каләм осталары турында зур кайгыртучанлык күрсәтте.* М.Маликова. **Каләме өметле** Беренче әсәрләрен язган авторның язучылык таланты, иҗади сәләте булу турында. *Каләмегез өметле, тик шигырь язу техникасы җитенкерәми сезгә.* Г.Минский. *Госман Гомәр дигән өметле каләм иясе бар бездә. Аңа уңышлар телик. Тик масаеп китә күрмәсен. Остарасы да остарасы әле аңа.* Б.Камалов. **Каләм сынау** Әдәби әсәр язып карау, иҗат эшенә керешү. *Менә шул вакытларда, өйрәнчек язучы сыйфатында төрле жанрларда язып, үзенең каләмен сынап карый.* М.Гафури. **Каләм тибрәтү** 1) Нәрсә дә булса язу, кәгазьгә төшерү. *Тирән аңлап тойсам да Синең мәхәббәтеңне, мин Чын күңелдән дулкынланып Укысам да хатыңны, Әллә ничек база алмадым Мин каләм тибрәтергә, Бәлки, бүген көчем җитәр Телем белән әйтергә...* М.Җәлил; 2) Әдәби әсәрләр иҗат итү, язучылык белән шөгыльләнү. *Шуның өстенә каләм тибрәтә белү, гәзитләргә мәкаләләр язып тору мине халык арасында танытты.* Г.Ахунов. **Каләм тота башлау** *к.* **каләм сынау**. *Барыбыз да диярлек – шул бер-ике ел арасында кулларына каләм тота башлаган яшьләр.* М.Әмир. **Каләм тоту** Бераз әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнү. *Әлбәттә, электән үк каләм тота иде инде ул. Аның «Шәһри Казан» һ.б. газеталарда чыгып барган үткен һәм кызыклы мәкаләләрен укучылар хәтерлидер әле...* Л.Шагыйрьҗан. **Каләм тыгу** Әсәрне төзәтү, редакцияләү. *Мин аларны [хикәяләрне] карап кына чыгам, әллә ни каләм тыкмыйча, шунда ук гәзитнең алдагы саннарына тәкъдим итәм.* Госман Гомәр

**КАЛӘМДӘШ** *и.* Бергә әдәби эшчәнлек алып барган кеше, язучылык эшендә аркадаш, коллега. *Судья Ибраһимов турында Карамалыдагы каләмдәш дустым Барый Сафин да бик яратып сөйли иде.* М.Әмир. *Гали Халит – талантлы язучы, галим, тынгы белмәс эш кешесе, безнең каләмдәшебез һәм дустыбыз.* Х.Госман. *Нинди югары дан-дәрәҗәләргә ирешсә дә, Гариф [Ахунов] иптәшләренә, каләмдәшләренә, таныш булмаган гади кешеләргә булышудан туктамады.* Х.Камалов. *Каләмдәшләр арасында корпоратив этика дигән нәрсә бар.* М.Юныс

**КАЛӘМ-КАРА** *и.* Язу әсбаплары. *Фәтхулла хәзрәт бик аптырап уйланып калды да, бер минуттан соң кулына каләм-кара алып, сихер кайтару догасын язарга тотынды.* Ф.Әмирхан

**КАЛӘМ-КӘГАЗЬ** *и.* Язу өчен кирәк булган нәрсәләр, язу кирәк-ярагы. *Маһира тиз генә каләм-кәгазь алып килеп утыра.* М.Җәлил

**КАЛӘМЛЕК** *и.* Кошларның контур каурыйларының мамыксыз урыны

**КАЛӘМХАК** *и. неол.* Гонорар, авторлык акчасы. *Ул мәкалә Көнбатышта түләнәсе каләмхак-гонорарның күләмен биш мәртәбә киметеп күрсәт-*

*сә дә, Россиядә андый акчага да чиксез шатланалар.* Р.Мирхәйдәров

**КАЛӘ́М ХАКЫ** *к.* **каләмхак**. *Гаиләдә очны очка ялгый алмый интегеп яшәгән бер көндә кинәт кенә әнә шул каләм хакы килеп төшү Таһир өчен олы шатлык булды.* Н.Акмал. *Каләм хакын үзебез дә бик көтеп торган идек.* Р.Мулланурова

**КАЛГАН** *с.* 1) Бүтән, башка, икенче. *Калган кешеләр иртәгә киләчәк*

2) Моннан соңгы. *Калган вакыт*

3) Файдаланганнан арткан. *Калган аш. Калган өлеш*

**КАЛГА́Н-ПОСКАН** *с. к.* **калдык-постык**

**КАЛГУ** *ф.* 1) Утырган урында оеп, йоклап китү, йокымсырау. *Утырган җирдә шунда калгыганмын.* Г.Тукай. *Уйлар, уйлар, калгып тирән хистә Мозаффаров бара урамнан.* Ш.Маннур

2) *күч.* Тынычлану, басылу, онытылу

**Калгып алу** Йокымсыраудан вакыт-вакыт башы төшеп китү. *Йокысыз узган төн миңгерәтте күрәсең үзен, мачтага сөялеп утырган да [Искәндәр] калгып-калгып ала.* Г.Минский

**Калгып китү** Калгый башлау, йокыга китүдән башы кисәк төшеп китү. *Иргали, калгып китеп, маңгае белән сәке баганасына бәрелде дә сискәнеп башын күтәрде.* И.Салахов

**Калгый башлау** Калгырга тотыну. *Ут алынганчы, мин дә башымны урынга төртеп, әкрен генә калгый башладым.* Н.Исәнбәт

**КАЛГЫ́Й-КАЛГЫЙ** *рәв.* Йокысы килүдән башы төшеп-төшеп китеп. *Коридор башында артсыз урындыкка утырып, стенага сөялгән килеш калгый-калгый йокларга гадәтләнеп китте.* Г.Ибраһимов

**КАЛДА́У** *с.* **1.** 1) Иген чәчми ташланган, яткын. *Һәркайда фәкыйрьлек, ятимлек, күпчелек хуҗалыкларның сөрим дисә аты, чәчим дисә орлыгы юк иде. Шунлыктан калдау җир, биләмәләрнең иге-чиге юк.* М.Хәсәнов. *Бөтен Союз күләмендә, 1954 елдан алып, барлыгы 40 млн. гектарга якын чирәм һәм калдау җир сөрелде.* Ф.Фаткуллин

2) Яткын җирдә үсеп, кар астында калып кышлаган, үткән елгы. *Калдау үлән*

**2.** *и. мәгъ.* Иген чәчми калдырылган җир. *Миннән [мулладан] тартып алган җирләр тоташтан диярлек кысыр калдау калды.* М.Хәсәнов

**КАЛДАУЛЫК** *и.* Калдау җир

**КАЛДЫК** *и.* **1.** 1) Нинди дә булса эш башкарганнан соң артып калган өлеш. *Ревизия өч көн дәвам итте. Барлык точкаларда товар калдыгын исәпкә алдылар.* Ә.Еники

2) Җимерелү, ватылу, таркалудан бөтенлеген югалткан кисәкләр. *Җил онытканда бер исеп куя, ә өзгәләнгән җилкән калдыклары кебек юка ак болытлар шундый тиз йөзәләр, ай аларга каршы очып бара кебек күренә.* Г.Гобәй. *Юл буендагы машина калдыклары, унар, уникешәр йортлы кечерәк, күбесе җимерелеп беткән авыллар – барысы да кар астында.* Г.Әпсәләмов

3) Тар-мар ителүдән, җиңелүдән исән калган өлеш. *Актыгында эшнең болай булып чыкканлыгы аңлашылды: сугышның башындарак генерал Самсонов корпусы Көнчыгыш Пруссиядә тиешеннән артык алга китеп тар-мар ителгәч, аның бик аз гына калдыклары, мең бәла белән чигенеп, үзләренең җаннарын коткаралар.* Ш.Камал

4) Нәрсәнеңдер эшкәрткәннән, файдаланганнан соң калган ташландык, яраксыз өлеше. *Идәннәр, диваннар, өстәлләр тәмәке калдыклары, ташландык кәгазьләр белән тулалар.* Г.Ибраһимов. *Ашарга-эчәргә утыргач та, табын янында җиде-сигез тапкыр кубар ул, я ризыкның икенче төрен китерер, азык-төлек калдыкларын сыпырып алыр...* М.Хәсәнов. *Алар спирт заводыннан сыерларга һәм сарыкларга ашату өчен бәрәңге калдыкларын алырга килештеләр.* Г.Ахунов. *Күл төбендәге калын ләм катламында органик әйбер калдыклары черүдән газ хасил була.* А.Муранов

5) *к.* **калдык-постык**. *Әниләр сугыштагы ирләре, уллары өчен саклап киленгән он, ярма калдыкларыннан, бүгенге җир бүлешүгә атап, табын хәстәрлиләр иде.* К.Нәҗми

6) Алда булып үткән вакыйгалардан күңелдә калган, күңелгә тәэсир иткән кичерешләр. *Эчтә кичәге борчуларның тик ачы калдыклары гына бар.* Г.Ибраһимов

7) *мат.* Бер санны икенче санга бүлгәндә бүленми калган өлеш. *Калдык чыгу*

8) Борынгыдан калган, электән килгән, иске күренеш. *Аның атаклы «Яңа Кисекбаш»ы – менә шушы иске феодализм калдыкларына, реакцион-консерватив катлауларга каршы юнәлтелгән көчле сатира.* М.Җәлил. *Кулакларны гына түгел, аларның иярченнәрен дә, нэпман калдыкларын да тамыры-ние белән корыту фарыз.* М.Хәсәнов

9) Борынгы үсемлек, хайваннарның җир катламында сакланып калган кисәкләре, эзләре. *Терек организм һәм үсемлек калдыкларының яшен билгеләү өчен камил методлар юк иде.* Кызыклы ихтиология

10) Кешедән калган иске кием, кеше искесе. *Аягым юньле кәвеш кимәде, өстемә синең калдыкларыңнан башка нәрсә насыйп булмады.* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Әшәке, явыз кеше. *[Латыйфа:] Инәмне дә калдырмам. Гомерем буена бөртекләп җыйган әйберләрем белән немец калдыкларын кинәндерер хәлем юк.* Т.Гыйззәт. – *Калай түбәле алачыкта эш майтарамсың, каммун калдыгы? – дип җикеренә.* Б.Камалов. *[Военком:] --- үз әтиләренә кул суза башлаган ул егет калдыкларын мин нинди төр войскога җибәрим? Ә?* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Артып калган, файдаланмыйча калган

**КАЛДЫ́К-ПОСТЫК** *с.* **1.** Аз-маз калган, бераз булган. *Чәчнең калдык-постык унике бөртеге.* А.Әхмәт

**2.** *и. мәгъ.* Ташландык, яраксыз, эшкәртүдән, файдаланудан калган нәрсәләр

**КАЛДЫРУ** *ф.* 1) Китеп барганда, үзең белән алмау. *Алар былтыр Ума Башына җыенга кайтканнар иде, шунда, салып куйган җирендә, бөтилеген онытып калдырган.* Г.Камал. *Гашыйк абзый кисәк кенә сүзен бетереп өстәл яныннан китте һәм скамьяда калдырган колаклы бүреген сыңар кулы белән башына батырып киде дә урынына*

*утырды.* Ә.Еники. *Тәрәзә рамына кадаган пәкемне онытып калдыра язганым.* Ф.Хөсни

2) Яныннан китеп бару, ераклашу. *Урман һәм кырларны, алан һәм болыннарны калдырып, инде өй яки келәт кәрнизендә кыш чыгарга җыенган бу кошлар, гүя, кара каргаларны озатып, үзләре моңаеп калалар, шуңа зык кубалар иде.* Г.Хәсәнов

3) Хәрәкәт иткәндә арттан җиткермәү, башкалардан алга чыгу, бөтенесен дә узып, алдан килү. *Икенче: ул хәзер Сабан туенда башка атларны икешәр чакрым артта калдырып, гел беренче килерлек булган бер ат – чабышкы тотарга тели.* Г.Нигъмәти. *Үзән буйлап бераз баргач, Нуруллин иптәшләрен арттарак калдырып үзе алга китте.* А.Шамов. *Җыйнак гәүдәле ат күрше колхоз чабышкысын, ким дигәндә, дилбегә буе артта калдырган иде.* Р.Мөхәммәдиев

4) *юкл. форм.* Нәрсәне дә булса һәрвакыт үзе белән йөртү, үзе янында тоту. *Имеш, ди, «Капитал»ны яныннан калдырмый иде, имеш, Николай патша заманында тоткынга эләксә, шул «Капитал»ны соратып ала, сөргенгә җибәрелсә, култык астына кыстырып китә, ди.* Г.Ибраһимов

5) Килеп җитмичә, ара ясап туктау. *Сәлим җиде-сигез адым ара калдырып, аның каршысында туктап калды.* Г.Гобәй. *Беркөнне Миңнулла, Гафият һәм тагын берничә кеше атларын урман буенда калдырдылар да, тездән җепшек кар сөреп, нарат агачлары арасына кереп киттеләр.* И.Гази

6) Нәрсә белән булса да өстеннән бастыру, басылып аста калу. *Хәзер ул чишмә челтерәми, Җәләй аның кояшта уйнаган нурлы күзен җир катламы астында калдырды.* Н.Хәсәнов. *Теге Гәрәй әйтә, аларны тактага салып, күмеп калдырырга кирәк, ди.* Ш.Камал

7) Килгәнен, булуын белдереп, хәбәр итеп куеп китү; тапшыру өчен бирү. *Мин аңа өйдә язу калдырдым.* Р.Ишморат. *Менә абзагыз сезгә юл садакасы биреп калдырды.* Г.Камал

8) Үзеннән соң берәр башка күренешнең, халәтнең барлыкка килүенә сәбәпче булу. *Миндә онытылмас бер җәрәхәт калдырдыгыз.* М.Гафури. *Алар, караңгыланып килә торган һавада кинәт ялтырап, үзләре артыннан куе кара төтен калдырып шартлыйлар.* А.Шамов. *Ярый әле күзгә-башка тимәде, берданка атуга ярылып китеп, Илдарның уч төбен чәрдәкләде, Фәритнең өске иренендә мәңгелек җөй ясап калдырды.* Г.Гобәй

9) Өлеш итеп бүлеп алу, аерып кую, бүлеп алып саклау. *Сиңа дип аш калдырган идем.* Г.Камал. *Получка саен кесәдә икмәклек-тозлык, чәйлек-шикәрлек калдырам.* Ф.Хөсни

10) Нindидер максатка яраклаштырып, сайлап алып калу. *Һәр елны нәселгә калдырган бер әтәчен күршесенең усал әтәче талап аптыраткан.* Г.Әпсәләмов. *Саламны ул [Фәйзи Әхмәтович], әрәм-шәрәм итмичә, көздән үк терлек амбарлары янына кайтарып өйдергән, бәрәңгене дә башкаларга караганда күбрәк калдырган.* Г.Ахунов

11) Тәмам юкка чыгармау, бөтенләй, тулысынча бетермәү. *Запаста берәр генә граната калдырырга.* Ә.Айдар. *Разведкадан кайтучыларга кечкенә генә булса да бер өй калдырганнар икән.* Г.Бәширов. *Бездә җыен йоласы буенча беренче җамаякны калдырырга ярамый дип, Тимербай үзенә бирелгән җамаякны төбенә кадәр эчеп бетерде.* М.Гали // *юкл. форм.* Тулысынча, соңгысына кадәр бетерү, юкка чыгару, юк итү. *Авылны, бернәрсәсен калдырмыйча, иң соңгы каралтысына кадәр яндырдылар.* А.Шамов. *Бер кантарын калдырмыйча тырмала.* И.Гази

12) Үзеннән соң кемнеңдер карамагына тапшыру, файдалану өчен бирү, милеккә, мираска хуҗа итү. *Бу иске өйне сиңа калдырам, үзем сарайга күчәм.* Д.Аппакова. – *Бөтенесен сиңа калдырабыз, сиңа ышандырып куябыз,* – *диделәр.* Г.Бәширов. *Булган гомерендә халкына хезмәт күрсәтүдән башканы белмәгән, әдәбиятыбызның алтын хәзинәсен тәшкил итәрлек әсәрләр калдырган шәхеснең якты рухы каршында баш ияр өчен туган мөмкинлек иде бу!* Э.Шәрифуллина

13) Торышын, хәлен, күренешен, эчтәлеген үзгәртмәү, элекке рәвешен саклау, ничек булган, шул килеш саклау. *Без болай гына калдырсак, фермадан файда урынына зыян гына булачак колхозга.* Ә.Айдар. *Карт, ул мәсьәләне озайтмыйча, шулай гына калдырырга тиеш күреп, башка сүзгә китте.* Ш.Камал

14) Нәрсәне дә булса бирмичә, үзенә алып калу, биреп бетермәү. *Кысык күзле кеше мылтыкны үзендә калдыру өчен тарткалашып тормады.* Г.Гобәй. *Югары сорт мехлардан бер тюк үзенә калдырып, аның урынына хлам җибәрткән.* Ш.Камал

15) Нәрсәнеңдер хозурында, иркендә калырга мөмкинлек бирү, юл кую, ирек бирү. *Әгәр эскертне тычканнар ихтыярына калдырсаң, язга кадәр алар аны турап, тетеп бетерәчәкләр.* А.Шамов. *Менә ул иң биек агачлар башында соңгы мәртәбә ялкынланды да, бу һәлакәт чокырын караңгылык ихтыярына калдырып, бөтенләй сүнде.* Г.Бәширов

16) Нәрсәнеңдер яки кемнеңдер янында, кем беләндер күзгә-күз яки үзе генә япа-ялгыз калуны сорау, калырга мәҗбүр итү. *Нәкыя ханым, Ганбәр, сез мине Бәкер абзый белән генә калдырсагыз иде.* М.Фәйзи. *Тик нәрсә генә тәкъдим итсәк тә, Артыкбикә бездән үзен калдыруыбызны үтенде.* М.Әмир

17) Мәхрүм итү; югалту. *Шулай ук энисез дә калдырдылармыни инде сине, кызым.* Г.Гобәй. *Беребез дә күрмәгән машина өчен зык килеп төн йокысын калдырмасалар, башка эшләре юктыр шул...* К.Нәҗми

18) Чакырмау, арасында катнаштырмау. *Беркөннәрдә кызлар җыены җыйган, шунда күршедә тора торып, мине утыртып калдырган.* Г.Камал

19) Нindидер максатлардан чыгып тоткарлау, җибәрми алып калу. *Нинди юллар табып экспедицияне тагын беразга калдырырга да тагын ун гына метр бораулап карарга!* А.Әхмәт. *Аны яшерен эшкә калдырганнар булса кирәк.* А.Шамов. *Сабакны белмәгән өчен әллә нигә бер мәктәп ягарга калдыра икән, аның өчен Хәлимнең бер дә исе китми: ичмасам, бер рәхәтләнеп көлдә бәрәңге пешерә ул.* И.Гази // Эш урынында алып калу, эшеннән җибәрмәү. --- *хуҗа*

*булып районга кем килсә дә, мине эш урынымда калдырсалар да, китүемне үтенсәләр дә, шуңа хәтле мин мәгариф бүлеген синнән арындырам.* Г.Мирһади. *Полковник Һайдельне аерым чит ил батальонының командиры итеп калдырырга боерам.* Т.Гыйззәт. *Гвардия капитаны Шахов, Харрасны санитар итеп минем янымда калдырды.* Ә.Айдар

20) *сөйл.* Класстан класска күчермәү. *Мотлакан, сыйныфларында калдырырлар.* Ф.Әмирхан. *Урыс теленә җитәрлек дәрәҗәдә игътибарлы булмаган укучыларны ул әледән-әле чиреккә, еллыкка «начар» кую белән, икенче елга класста утыртып калдыру белән куркыта.* Н.Фәттах

21) Ташлап чыгып китү; дошман кулына бирү. --- *йортларын калдырып, казак канаты астына сыгынган ---.* Ш.Усманов. *Мәскәүне Наполеонга калдырган да, Наполеонны Мәскәүдән куган да без булдык.* М.Гафури. *Бүген 21 нче октябрьдә безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң Харьков шәһәрен калдырдылар.* Г.Гобәй

22) Ташлап китү, ярдәменнән, тәрбиясеннән мәхрүм итү. *[Сәмигулла абзый] Ерак китмәде китүен, каршы якта иске өен сипләп торгызды да, хатыны белән бишектәге Байтирәген калдырып, биш-алты өй аша гына яшь хатынга йортка керде.* М.Галиев. – *Әткәй, карт көнемдә ялгызымны калдырдылар дип рәнҗемә, үлсәк, бәхил бул! – диделәр дә, үзләре теләп, кызыл байрак астында фронтка киттеләр.* Г.Ибраһимов. *Йосыф мирза хатынының кабер ташына алтынсу хәрефләр белән шулай яздырды: «Казан каласыннан Нугай иленә килен булып төшкән Мәхмүт хаҗи кызы, --- игезәкләре Сөен бәк олан белән Сөем тутыйны калдырып, дарелфәнадин дарелбәкагә рихләт итте».* Р.Батулла

23) Яннарыннан читкә җибәрмәү, үзләре янында яшәтү. *Өлкән балаларны кайтарып булмый инде, төпчегебезне яныбызда калдыру өчен, башлы-күзле итү дәртенә керешә башлау кирәк.* Я.Зәнкиев

24) Тиешле урынга бармый калу, тиеш эшне башкармау. *Кайтма сабак калдырып дип, анасы күп таяклады, үги ананың чыраларыннан аркасында, беләкләрендә кара янмаган урын аз калды.* Г.Ибраһимов. – *Моннан соң, улым, дәрес калдырып --- йөрмәссеңдер бит инде?! – дип сорады әнисе.* А.Әхмәт. *Намаз калдырганга атаңның да бер дә ризалыгы юк.* Ф.Әмирхан

25) Шуннан ары узмау, шуның белән чикләнү, артыгына тотынмау. *Икесен дә телдә генә калдырдылар.* А.Шамов

26) Сөйләгәндә, язганда, вакыйгалар эзлеклелегеннән нәрсәне булса да әйтмәү, төшерү, сикертеп үтү. *Нәбир әфәнде сөйләмәгән иде дип, боларны язмый калдырса, һичшиксез, хикәянең бер чите китек булачак.* Ә.Фәйзи. *Хәмзә байны бер якта калдырып, аның балаларының кыланышларын тәнкыйть итәләр.* Ф.Әмирхан. *Ахун, халык авызында үзенә каратып сөйләнгән кайбер гайбәтләр белән бәйләнешле бу эшне бер якка калдырып, сүзне туйлар, никахлар, мәҗлесләр тирәсенә күчерде.* Г.Ибраһимов

27) Күтәреп чыкмау, игътибарны юнәлтмәү. *8 нче ротаның солдатлары бу эштә фельдфебельне гаепләп, аны полк штабы аркылы җавапка тарттырырга дип йөрсәләр дә, рота командиры аны яклап, бу нәрсәне басып калдырды.* М.Гали

28) Тайпылу, читләтеп үтү. *Күзең йомсаң, Бишбалтаны бер якта калдырып, Юдино станциясенә баргандай буласың.* Г.Гобәй. *Сәлим белән Кәли Акбүзне ияртеп чыктылар да каланча сукмагын сулда калдырып узып китә башладылар.* Г.Гобәй

29) Эшнең вакытын икенче срокка күчерү, вакытлыча чигерү. *Әхми миннән судта ниләр булганын сораган иде дә, мин, кат-кат сөйләмәс өчен, сез килгәч сөйләргә дип калдырган идем.* Г.Камал. *Әйтеп үттем бит инде, мине бер елга калдырдылар.* А.Шамов

30) Нинди дә булса максатларда арттанрак килүен яки калуын сорау. *Ильинны артта андый-мондый хәл була калса дип калдырдым*... Ә.Айдар

31) Нидер эшләп яки сөйләп торганда, шул эштән, сүздән туктатуны сораганда, туктатканда кулланыла. *Әй, калдыр әле, андый ялтыравыклы әйберләргә кызыкма!* Т.Гыйззәт

32) Нинди дер хәлгә дучар итү, берәр хәлгә төшерү. *Фазыл бу турыда әйтеп Хәлимне уңайсыз хәлдә калдырасы килмәде.* Г.Гобәй. *Гали мулланың байлар файдасына гына эшләп килүен бер-бер артлы санап биреп аптырауда калдыра.* М.Фәйзи

33) *юкл. форм.* Нинди дә булса чаралар күреләчәген кисәтү, куркыту, янауны белдерә. *Мин әле сине болай гына калдырмам, җиде буыныңа җитәрмен.* Г.Камал. *Елама, туташ, мин аны – татар кызын, татар милләтен мыскыл итүче жуликны – болай гына калдырмам.* Т.Гыйззәт

34) *юкл. форм.* Барын да эшләү, теләгәнен ахырга кадәр әйтү, ни теләсә, шуны кылану һ.б. аңлата. *Кыйммәтле рестораннарга, казиноларга, төнге клубларга йөр, мода күргәзмәләрен, вернисажларны, театр премьераларын калдырма.* Р.Мирхәйдәров. --- *акылдан язу, җенләнүләрнең берсен дә калдырмый.* М.Гали

◊ **Калдырып китү** Ташлау, мөнәсәбәтләрне өзү. *Мин аңардан әллә кайчан киткән булыр идем инде, тик кызым турында уйласам, аңа гомер буе: әтиең юк, яисә әтиең сезне ташлап киткән яки әтиегезне калдырып киткәнсез, дип әйткәннәрен күз алдына китерсәм, йөрәгем бозлана.* Ф.Углов

**Калдыра бару** Даими рәвештә бер өлешне аралап аерып калдыру. *Моның өчен яхшы нәселле яңа сыерлар сатып алу да кирәкми, моның өчен бары үзебезнең шул күп итле сыерларның бозауларын гына ферма өчен калдыра барырга кирәк.* Ә.Еники

**Калдыра башлау** Калдырырга тотыну. *Торган саен зирәкләнә баруы белән колыным күрше-күләнне дә гаҗәпкә калдыра башлады.* Г.Галиева. *Университетта дәресләрен дә калдыра башлады.* Мәйдан

**Калдыра килү** *к.* **калдырып килү**. *Ләкин ни өчендер язарга ашыкмыйм, аны һаман алдагы көнгә калдыра килә идем.* М.Әмир. *Һәр председатель бу эшне үзеннән соңгы алмашына калдыра килде.* Н.Хәсәнов

**Калдыра төшү** Тагы да бераз калдыру

**Калдырып килү** Һәрвакыт, даими калдыру, үтәлү вакытын туктаусыз чигереп тору. *Эш менә нәрсәдә, Фәтхи: без синең белән минем кучү турында, миңа лаек эш табу турыларында сөйләшәбез, әмма шактый бер әһәмиятле мәсьәләне ничектер читтә калдырып киләбез.* Ш.Камал. *Антракт вакытында ничә мәртәбә сөйләргә дип авызымны ачсам да, кайтканда иркенләп аңлатырмын дип, ниятемне озату вакытына калдыра килдем.* М.Юныс

**Калдырып тору** Хәзергә, вакытлыча калдыру. *Ә инде Биктимер абзыйны кулга алуны калдырып торырга мөмкин.* Т.Гыйззәт. *Югыйсә аларның барысының да төп эш урыннары бар бит, кем табип, кем журналист ---, ә милләт дигәндә, --- гаиләләрен дә калдырып торып, --- ерак юлга чыгып китәләр.* Ф.Бәйрәмова

**КАЛДЫРЧА** *и. диал. к.* **калтырча**. *Һәркайсының башында бер генә уй: ничек итеп, «гаишник»ларның рәхимсезлегенә дучар булмый гына, үзенең «калдырча»сында бакчасына тизрәк барып җитәргә һәм тагын шул 4–5 сутый җиргә суган-бәрәңгесен утыртырга.* Шәһри Казан

**КАЛЕБ** *и. гар.* Йөрәк, күңел. *Калебеңдә ни сер бар, гаян ит, Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.* Дәрдемәнд. *Нишлисең, калебендә ак эз булмагач, Кәкре бармак башта ук төз булмагач.* Ш.Бабич. *Ерактагы Воронеж ягыннан килеп тимер юлда эшләүче Иван кызы Анна туташ, калебенә иман нуры иңеп, ислам динен кабул итте.* Г.Бәширов. *Хыянәтсез садә калебле моңлы татар.* М.Гафури

**КАЛЕЙДОСКОП** *и. гр.* Эченә берберсенә почмак ясап урнаштырылган берничә көзге һәм төрле төстәге пыяла ватыклары, кәгазь кисәкләре салынган, башын тоник пыяла белән каплаган трубкадан гыйбарәт оптик прибор; пыяла һәм кәгазь кисәкләре көзгедә чагылып, төрле геометрик фигуралар барлыкка китерәләр (балалар уенчыгы)

**КАЛЕНДАРЬ** *и. лат.* 1) Төрле бүлешмәләр белән берлектә эзлекле тәртиптә елның барлык көннәре исемләнгән биргән таблица яки кенәгә

2) Стиль; ел исәбен алып бару ысулы. *Җәйне озаткан Симеон көне элек беренче сентябрьдә булган, хәзер яңа календарь буенча – үндүртендә.* М.Мәһдиев. *Шәрык календаре һәм ырымнары буенча, кабан елында туганнар матурлыкны ярата гына түгел, үзләре дә матур булырга тырыша.* Т.Әйди

3) Күк җисемнәре хәрәкәте белән бәйле бер-бер артлы килгән табигать күренешләре нигезендә вакыт арасын исәпләү системасы. *Ай календаре. Кояш календаре*

**КАЛЁВКА** *и. рус* Такта һәм планка читләрен фигуралап ышкылау өчен кулланыла торган ышкы

**КАЛҖА** *и.* 1) Кисәкләп туралган пешкән төрле итне (терлек, кош-корт) коштабакка өеп, өстенә суган сибеп, кайнар шулпа салып, табын уртасына куела торган ризык төре. *Анда кунакларга калҗа пешә түгелме соң?* Г.Минский. *Идәш буйларының урамын Яхшы атлар җигеп урадым. Ашагыз, туганнар, и калҗасын, Кулларымны юып урадым.* Җыр

2) Шактый зур ит кисәге. *[Баһави] тәмләп-тәмләп симез ит калҗаларын ашарга тотынды.* А.Расих. *Һәркем үзенә майлырак, зуррак калҗа эләктереп калырга теләде.* Н.Дәүли. *Дорогомилов, кулына агач кашык алып бер калҗа ит кабып җибәргәч, --- ашыкмый гына сүз башлады.* Г.Ахунов. *Хуш ис аңкыткан калҗалар шау күмердә куырылганда, телләр тик торамы?* А.Гыйләҗев

3) *куч.* Табыш китерә торган эш, төшемле урын; бик уңайлы форсат. *Поезд Германия белән Франция арасында җәнҗаллы калҗа булган Эльзас – Лотарингия өлкәсенә таба йөгерә.* Г.Гобәй. *Хәзер бу майлы калҗаны Малик үз кулына эләктермәкче була.* И.Гази. *Җае туры килгәндә, минем малайга калҗаның калынрагын бирерсең.* М.Маликова

4) Зур табыш, керем, гадәттә шактый җиңел юл белән табылган зур акча. *Колхоз кассасына илле мең сумга якын саф табыш керә. Ярыйсы калҗа!* Социалистик Татарстан

**КАЛҖАЛАП** *рәв.* Калҗаларга бүлеп, аерып, кисәкләргә турап. *Әүвәл бер-ике кадак яхшы сарык ите ал, калҗалап тура, әмма бик вак итмә.* К.Насыйри. *Казакларның һәркайсында үткен пычак яки пәке, шуның белән итне җиңел генә калҗалап кисә дә пычак өстеннән төшермичә кабып та җибәрә.* Ә.Еники

**КАЛҖАЛЫ** *с.* 1) Калҗаларга бүленгән

2) Итле, кисәк-кисәк ите булган. *Ләкин, кая гына барса да, калҗалы пылауны бушка гына ашатмыйлар икән.* Г.Кашшаф. *Врачларга калҗалы әбәт әзерләгәннәр иде. Анда аларны Мөхетдинов сыйлап йөрде.* Х.Камалов

3) *куч.* Төшемле, файда китерерлек, һәрьяктан уңайлы. *Әст-вәст киләләр. «Калҗалырак» детальләр алар ягына ычкына.* Н.Хәсәнов

**КАЛҖАЮ** *ф.* Төзлеген, турылыгын, тигезлеген югалту, бер якка бөгелү, кәкрәю. *--- арзанлы буяу белән каткат сыланган ишегә калҗаеп, салынып төшкән мунча тыштан караганда бер дә кешене җәлеп итәрлек түгел.* Ф.Латыйпов

**Калҗаеп бетү** Тәмам калҗаю. *--- [ул] су кырыенда, җиргә иңеп, бүрәнәләре калҗаеп беткән һәм шул калҗайган бүрәнәләрне берничә җирдән терәтеп, кызыл балчык белән сылаган, шалаш шикелле кечкенә бер өйдә тора.* М.Гафури

**Калҗаеп калу** Ниндидер сәбәптән калҗайган хәлгә килү. *--- нәкышләп, бизәкләп ясалган такталарның буяулары кояш-яңгырдан уңган, аннан да, моннан да калҗаеп калган.* Н.Хәсәнов

**Калҗаеп килү** Күзгә күренеп калҗайган торыш ала бару

**Калҗаеп тору** Калҗайган булып күренү; калҗайган хәлдә булу. *Безнең офицерларның погоннары да иләмсез, коргаксыган чабата олтырагы сымак калҗаеп тора ---.* М.Галиев

**Калҗая бару** Торган саен ныграк калҗаю, акрынлап, аз-азлап калҗаю

**Калҗая башлау** Калҗаерга тотыну

**Калҗая төшү** Бераз калҗаю; тагын да ныграк калҗаю

**КАЛИБР** *и. фр. махс.* 1) Ату коралы көпшәсенең диаметры. *Мин вак калибрлыдан яхшы атам.* Г.Гобәй. *Шуның артыннан эре калибрлы пулемётларның такылдаганы ишетелде.* Ә.Айдар. *Авыл уртасындагы казармадан үлем сиптерүче эре калибрлы пулемёт түбәсендә ялкын бии башлагач кына тынды.* З.Фәтхетдинов

2) *тех.* Күпләп эшләп чыгарыла торган эшләнмәләрнең төрле зурлыгы

3) *күч. сөйл.* Төрле-төрле зурлыклар, күләм төрләре, формалар

**КАЛИ́БРЛАУ** *ф.* Калибрына карап аеру, сортларга бүлү, ишен ише белән туплау

**КА́ЛИЙ** *и. гар. хим.* 1) Көмешсыман ак төстәге йомшак металл, химик элемент. *Авыруның кан анализлары калийның кимүен күрсәтә*

2) Шул химик элемент катнашкан ашлама. *Бер центнер бодай ясалсын өчен, җирдә ничә килограмм азот, күпме фосфорит һәм калий булырга тиешлеген белмәгәч, мин сезгә нинди билге куйыйм?* М.Мәһдиев. *Калий үсемлекләр физиологиясендә әһәмиятле урын тота.* Ф.Вәлитова

**КАЛКАВЫЧ** *и.* **1.** 1) Кармак җебенә яки ятьмәгә беркетелгән, су өстендә йөзеп йөри, батып китсә балык кабуны аңлата торган бөке. *Чыннан да, минем калкавыч күренми, суга чумган иде.* А.Әхмәт. *Бераздан соң бер батып, бер калкып уйнаган кармак калкавычы рәвешендә генә күренә башлады.* Ш.Камал. *Баштарак калкавычтан күземне алмыйча утырсам да һәм берничә тапкыр кармакны кинәт күтәреп җибәрсәм дә, балык җимне ашап, су төбендә кала бирде.* Ә.Еники

2) *тех.* Төрле механизмнарда сыеклыкны бер кимәлдә тотуны күзәтү өчен хезмәт иткән корылманың хәрәкәт итә торган өлеше. *Су башнясы калкавычы*

**2.** *с. мәгъ.* Су өстендә батмыйча, калкып тора торган. *Караңгы күктә тонык йолдызлар калыкты, су өстендә калкавыч маяклар кабынды.* С.Сабиров

◊ **Калкавычы батмау** Хәйләсе барып чыкмау, хәйләсенә капмау

**КАЛКАН** *и.* 1) Борынгы гаскәриләрнең гәүдәсен ук, кылыч, сөңге кебек салкын кораллар тиюдән саклау өчен, тире, такта һ.б.ш.дан эшләнгән сугыш кирәк-ярагы. *Җик, кылыч һәм калканын тотып, батырны көтеп кала.* М.Җәлил. *Калкан гадәттә иң каты корычтан эшләнә.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Саклагыч, саклаучы. *Теге калкан була торган дога һәм сүрәләрне укыдылар.* М.Гафури. *Бәхетле гаилә тормышының калын өресе астында, үзенең эсселеген, кайнарлыгын яшергән, саклаган аның йөрәк уты шул көзге җилнең искәртмәстән исүе берлә пәрдәсез, калкансыз калды.* Г.Исхакый. *Күкрәгеңне миңа калкан итеп илткән идең алгы кырыйга.* Ш.Маннур

3) *күч.* Яңак сөяге (эре сөякле, чыгынкы яңаклы йөз тур.). *Куе кашлы, эре яңак калканнары күпереп торган кара тутлы йөзендә көчләр генә түгел, ихтыяр да җитәрлек икәнен сиземләү кыен түгел иде.* М.Хәсәнов

**КАЛКА́Н ЧӘЧӘК** *и. бот.* Чатыр формасындагы чәчәк

**КАЛКАНЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Аркаларында калкансыман каты кабыгы булган имезүче хайваннар (Көньяк һәм Урта Америкада яшиләр); *русчасы:* **броненосцы**

**КАЛКА́НСЫМАН** *с.* Формасы белән калканны хәтерләтә торган, шуңа охшаш. *Әнвәр, пациенттан бушап торган арада, кайчандыр калкансыман биз авыруына каршы көрәшү өчен оештырыла башлаган, ләкин күптән ишегенә йозак эленгән лаборатория бүлмәсенә керде.* Ә.Сәйфетдинов. *Калкансыман кимерчәк йотканда өскә күтәрелә, аннары кире үз урынына кайта.* Биология

**КАЛКУ** I *ф.* 1) Яткан, утырган җирдән аякка торып басу, аякка басып күтәрелү; күтәрелү, калкыну. *Арба туктауга, бердән бөтен балалар аякка калыкты.* Г.Исхакый. *Дога тәмам булып аякка калыкканда, өй эче халык белән, бигрәк тә хатыннар белән тулган иде.* Г.Ибраһимов. *Кашын җыерып, чал сакалы, олы гәүдәсе белән дәү булып, Айтуган калыкты.* Г.Бәширов

2) Югарыга, үргә менү, берәр әйбер өстенә менеп басу, башкалардан биек булып күренү. *Зур борынлы, ямьсез, бакыр күзле исерек майор өскә калыкты.* М.Җәлил. *Иске тужуркалы ярлы шәкерт, күзләрендә ут уйнатып, сикереп тәрәзә төбенә калыкты да ачы, кискен, кызганыч тавыш белән кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Монда калка металл вышкалары һәм торбалар җирдән сузыла.* Ш.Маннур

3) Җир асты юлларыннан өскә күтәрелү, килеп чыгу. *Алар метроның бер юлыннан икенчесенә күчә-күчә барып, Фридрихштрассе станциясендә җир өстенә калыктылар.* Т.Әйди. --- *ояларына чиләк белән су салуга, тычканнар тончыга-тончыга өскә калыктылар.* Г.Гобәй

4) Кабарып беленеп тору, бәреп, өскә күпереп чыгу; өслектә калку булып күренү. *Тамак авырта, муенга бизләр калыккан.* Ш.Камал. *Одеал астыннан калкып, беленеп торган күкрәге бер күтәрелә, бер төшә.* А.Шамов. --- *кан тамырлары бүртеп өскә калыккан.* Г.Гыйльманов. *Ул, буыннары калкып чыгып торган бармаклары белән теземә орынып, күзләрен рәсемгә юнәлтте.* А.Шамов. *Күбесенең эчләре суырылып, иңбашлары таяк башыдай калкып, кабыргалары сырланып тора.* Ә.Еники

5) Яткан, егылган, ауган хәленнән күтәрелү, торып басу, кабару. *Әнә аның аягы эзендә үләннәр дә калкып өлгермәгәннәр.* Г.Бәширов. *Ул төнге кунак иптәшенең яңгырлы, суык җилдә күгәргән иреннәренә, күшегүдән вак сары йон калыккан карарак шадра йөзенә карады.* Г.Ибраһимов

6) Сыеклык эчендә батмыйча, өстә йөзеп йөрү. *Әртил дә әртил сал салладык, сал салладык суда калкыр дип.* Н.Исәнбәт // Су төбеннән өскә күтәрелү. *Вакыт-вакыт бу сунарчы кошлар яшен тизлегендә дулкыннар арасына ташлана һәм, кыю чумып, өскәрәк калыккан балыкларны эләктерергә тырыша.* Т.Әйди. --- *тыны тәмам беткәч, пух итеп өскә калыкты.* Ф.Садриев. *Иделгә төшкән камка Бер бата да бер калка.* Ш.Галиев

7) Эчтән, астан, катлам аша бәреп чыгу. *Гимнастёркалары манма су булган, иңбашларына тир тозы калыккан, яңаклары буйлап кара тир агып*

*төшкән.* Ә.Еники. *Киң маңгаена калыккан тирләрен яулык белән сөртте.* Г.Ибраһимов

8) Кубу, күтәрелү. *Пожар балкыр, утлы тайфун калкыр.* Ә.Ерикәй

9) Үсү, сузаеп, зураеп китү, озынлыкка күтәрелү. *[Игеннәр] --- башаклානып өскә калыктылар.* М.Җәлил. *Бар тереклек җирдә калыккан кук, яшәү алып кояш нурыннан.* Ә.Исхак. *Тизрәк май ае җитсен иде дә, ташландык басуларда кәҗә сакалы, кукы, йөннекәй, чыпчык, күгәрчен күзләре кебек үләннәр калыксын иде.* Р.Хисмәтуллин. *Яшел келәм булып калка чирәм.* З.Маннур

10) Офыктан күтәрелү, күренү (күк җисемнәренә карата). *Таң йолдызы калыкмаган әле.* Г.Әпсәләмов. *Ул арада күктә йолдызлар калка, үзәннәрнең һавасы салкыная башлый.* Г.Бәширов. *Тиздән тонык кына ай калыкты.* З.Фәтхетдинов. *Ул офык артында көрәшә-көрәшә озын юл үтә, көн дә иртән калка торган урынына килә һәм Кара Төнне тагын куып җибәрә.* Р.Фәизов

11) Пәйда булу, күз алдына кисәк килеп басу. *Чокыр Хәбипнең ялчысы, кулына чыбыркы тотып, бусагада калыкты.* Г.Ибраһимов

12) *күч.* Алга китү, алдынгылыкка ирешү, үсү, күтәрелү. *Татар нигә һаман кодрәтле бер даһины тудыра алмый соң? Нигә ул калкыр өчен һаман оеша алмый?* Т.Әйди

13) *күч.* Барлыкка килү, килеп чыгу, күренү. *Тәрәзә ватылып, алдымда ак, карлы урам калыккач, йөземә җан иясе кебек тере җил килеп бәрелгәч, йөрәккә көч кергән иде.* С.Хафизов. *Мулланың йөзенә тиз арада тагы ачу калыкты.* Г.Ибраһимов

14) *күч.* Булып үткән хәлләр, вакыйгалар хәтердә яңару

◊ **Калкып чыгу** 1) Кинәт, көтмәгәндә барлыкка килү, пәйда булу. *Сивашка әйләнеп карамакчы булып борыла гына башлаган иде, куаклар арасыннан тавышсыз-тынсыз зур гына бер папаха калкып чыкты.* Г.Бәширов. *Алдыбызда дүрт-биш метрлар чамасы биеклектәге кызыллы-каралы балчык өеме калкып чыкты.* Р.Ишморат. *Аның урынына алты почмаклы яңа йорт калкып чыккан.* Р.Мөхәммәдиев. *Хәлим ---, ничек юкка чыккан булса, шулай ук кинәт кенә каяндыр калкып чыккан Аккүзне ияртеп, урман караңгылыгына кереп китте.* Г.Гыйльманов; 2) Күптән онытылган әйберләр кабат әйләнеп кайту, кабат искә төшү. *Күңелнең ерак почмагыннан берничә минутка гына калкып чыгып, тойгыларны нечкәртеп җибәргән икенче дөнья тагын үз почмагына кереп посты.* Г.Гази. *Хәзер тарихның иң тирән катлавы эченнән тормыш өстенә калкып чыкты.* К.Нәҗми. *Шулай итеп, йомгаклап әйткәндә, бер яманның яхшы ягы да калкып чыкты.* Р.Рахмани

**Калка башлау** Калкырга тотыну. *Шәһәребез урамнарында кар һәм боз фигуралар калка башлады.* Нократ. *Бераздан, җирдән үсеп чыккандай, мәчет ае, манарасы калка башлый.* Мәгариф

**Калка бирү** Бераз, берникадәр калку. *Күкрәгенең нәкъ астына куйды, калка биреп яткан җиреннән.* Ш.Маннур

**Калкып алу** Кыска вакытка, азга гына калку. --- *әле берничә минут элек кенә күңелдә калкып алган сәер уйлардан оялып куясың.* Г.Гыйльманов

**Калкып җитү** Ахырга кадәр, тәмам калку, калкырга өлгерү. *Ул уянып киткән чакта, йолдызлар сүнгән, Идел өсте яктырган, ә кояш әле калкып җитмәгән иде.* И.Гази

**Калкып калу** Ниндидер сәбәптән соң, нәрсәдер нәтиҗәсендә калку һәм шул халәтне саклау. *Авылдан чыгып, ябык сыер сырты кебек калкып калган тиресле юл буенча чабып барганда, Хәлим кинәт туктады...* И.Гази

**Калкып килү** 1) Аз-азлап, акрынлап калку, яңа күренә башлау. *Бөек кояшның җир астыннан калкып килүен күреп, тезмәдәге кораллы ирләр, изге бер тынлык белән, көнчыгышка таба борылдылар.* Н.Фәттах

2) Үсә башлау, бераз калкыну

**Калкып кую** Кисәк калку. *Габделхәйнең күңелендә яшь бабасына карата кызгану һәм әрнү хисе калкып куйды.* Н.Фәттах

**Калкып тору** Калыккан хәлдә булу, күзгә бәрелеп, ачык күренеп тору. *Еракта, дулкыннар арасында, бер югалып, бер калкып торган көймә һаман да бер урында төсле күренә.* Ш.Камал. *Ике яктан да Әстерхан чикләвеге хәтле бизләре калкып тора.* К.Нәҗми. *Юл аркылы икеме-өчме катлы гүзәл бер ак бина калкып тора. Урта гасырлар стилендә салынган.* М.Мәһдиев

**Калкып утыру** Ерактан ук, ап-ачык булып күренү. *Тау өстендә, уртада, юан-юан карагай бүрәнәләрдән өеп мендерелгән сигез почмаклы бура --- калкып утыра иде.* Н.Фәттах

**КАЛКУ** II *с.* **1.** 1) Тирә-юньдәге әйберләр белән чагыштырганда калкып, өскә күтәрелеп торган, биек. *Әмма ләкин калку җирләрдә бөтенләй кибеп бара, хәтта тузаннар да очкалый.* Ш.Камал. *Калку басулардан борыннарга аңкый җир исе.* Ш.Маннур. *Калку урын булганлыктан, аннан бик ерак җирләр күренә.* М.Гали

2) Чыгынкы, кабарынкы. --- *гүя сугыш кырындагы күкрәүләрне тыңлагандай, башын иеп җиргә текәлде, калку маңгаена җыерчыклар чыкты.* Г.Бәширов. *Бер күтәрелеп, бер төшеп сулый торган калку күкрәгеннән агып чыккан үтә саф тавышның кеше тавышы булуына ышанасы килми.* М.Әмир

3) Озын, зур, биек. *Томрап торган кара күзле, кара туткыллы, бүгенге күк тора күз алдында, Мараттан ул калку буй-сынлы.* Н.Исәнбәт. *Уртачадан бераз калкурак, ыспай гына киенеп йөри торган егет.* Ә.Фәйзи

**2.** *и. мәгъ.* Калкулык, биек урын. *Шаһны шул мөдһиш сарайга керттеләр, бер тәхет күк калкуга утырттылар.* Ш.Бабич. *Һәр үзәнсу урынына, һәр калкуына кадәр җентекләп күздән кичерде.* Г.Бәширов. *Менә бер калку. Шуннан куе ак төтен чыгып, салкын тыгыз һавада аз гына да җәелмичә, таралмыйча, зур калын багана кебек, туры күккә менеп тора.* Г.Ибраһимов

**3.** *рәв. мәгъ. күч.* 1) Аеруча басым ясап, ассызыклап, ачык итеп. *Кайчак гаҗәпләнеп тә куясың: артист аларны сәхнәдә кабатланмас рәвештә калку итеп гәүдәләндерүгә ничек ирешкән?!* Казан утлары

2) Өстен, югары; аерылып, беленеп, күзгә бәрелеп торырлык. *Шулай*

*да Риза Фәхреддиннең куәтле сәләте, иҗтимагый, фәнни интересларының әтрафлылыгы, колачы барыннан да калкурак аның тарихи эзләнүләрендә чагылыш тапты.* Р.Әмирхан. *Әмма бу тормыш гел актан гына тормый шул, ул аклы-каралы, ак янында – кара, каралык янәшәсендә аклык бигрәк тә калку булып күренә.* Ф.Бәйрәмова

3) Күпертелеп, арттырып, үзеннән өстәп. *Кеше берәр бәхетсезлеккә генә тарсын, шунда ук аның кимчелекләре дә калкурак --- күренә башлый.* М.Хәсәнов

**КАЛКУЛАНУ** *ф.* 1) Тигез өслектән аерылып, калку булып тору // Күтәрелеп, кабарып тору

2) Үсеп китү, озынаю, сузаю

**КАЛКУЛЫ** *с.* 1) Калкулыклары булган, калкулардан торган, таулы (рельеф). *Таулы-калкулы яклар*

2) Кабарынкы, чыгынкы. *Бердәмлекне калкулы итеп күрсәтү*

**КАЛКУЛЫК** *и.* 1) Җир өслегендә күтәрелеп, калку булып торган урын, биеклек. *Без гүя ефәк чатыр эчендә, махсус безнең өчен генә эшләнгән яшел келәм белән капланган калкулык өстендә.* Ә.Еники. *Авыл яныннан башланып, калкулыкның уң ягыннан узып киткән үзәнне ул бик җентекләп ике мәртәбә карап чыкты.* А.Шамов. *Калкулыктан үзәнлеккә төшкәч, тирә-юньдә күптән инде көз хакимлек итүе үзен аеруча нык сиздерде.* М.Хәсәнов. *Батальон килеп төшкән урыннан бер-ике чакрымдагы калкулыкта каен урманы бар иде.* Г.Ахунов

2) *геогр.* Диңгез өсте тигезлегеннән 200 м дан алып 500 м гача биеклектә булган тигезлек. *Урта Рус калкулыгы. Идел буе калкулыгы*

**КАЛКЫМ** *и.* Чыгынкы, калку булып торган урын. *Яңак калкымнары нык беленеп тора, борыны юкарган кебек.* Г.Әпсәләмов

**КАЛКЫНУ** *ф.* 1) Яткан, утырган җиреннән аз гына кузгалып күтәрелү, калку. *Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә, калкынып ук, көтеп торган халык алдына килеп, көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады.* Ш.Камал. *Шулвакыт якындагы бер кабер балчыгын шабыр-шабыр як-якка коеп, эчтән нәрсәдер калкына башлады.* З.Фәйзуллин

2) Тору, аякка басу. *Учак янындагылар шунда ук калкындылар.* Э.Касыймов. *Менә ул, нидер яңа бернәрсә исенә төшкәндәй кинәт калкынып, Айсылуга таба үрелде.* Г.Бәширов. *Егет бар буена калкынып басты.* Н.Гыйматдинова. *Мәрфуга җиңги, гайрәт орып, урыннан калкынды.* М.Шабай

3) *күч.* Үсү, зураю. *Бераз калкынып егет була башлауга, кешегә ялланып урман кисте, ындыр сукты, печән чапты.* И.Гази. *Малайлар да җирдән калкыналар: олысы ярый хәзер тырмага.* Ш.Маннур. *[Айсылу апа] Азатның инде гәүдәгә шактый калкынган булуын искә алып кына [кочаклау] ниятеннән кире кайтты.* Р.Мөхәммәдиев

4) *күч.* Гамьсез халәттән чыгу, хәрәкәткә килү

5) *сөйл.* Күренү, күзгә чалыну, күз алдында булу, тирәсендә буталу

**Калкына башлау** Калкынырга тотыну. *Авылларны коллективлаштыру турындагы сүзләр калкына башлауга, мал-туарын әкренләп бетерде.* С.Зыялы. *Әйе, ята иде, чөнки чак кына калкына башласа, аны җил, сукмактан кубарып, үзе белән әллә кайларга алып китәр төсле иде.* Г.Гыйльманов

**Калкына бирү** Бераз, берникадәр калкыну. *Бөтен торышыннан һәм калкына биреп кычкыруыннан аның сугышны күңелле эш итеп санавы сизелеп тора.* Ә.Еники

**Калкына төшү** Тагы да бераз калкыну. --- *янәшәсеннән «өч төрле җаваплылыкны күтәргән» мандатлы вәкил атлап бара икән ләбаса. Ияк тә калкына төште, гәүдә офицерныкыннан да болайрак.* Р.Мөхәммәдиев

**Калкынып алу** Азга гына, кыска вакытка калкыну. --- *урман аръягындагы ак юллар һәм шул юлларның очындагы ак кыялар турындагы ак хыял аның [Микәйнең] хәтерендә янә калкынып алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Калкынып китү** Кинәт калкыну. *Аннары йокысыннан уянган сыман калкынып китә дә берүзе бөтен өйне тырып, тагын шул ук тал тирәкле су буйларын сузарга тотына.* Г.Бәширов. *Гәүдәгә нык кына калкынып киткән Азатка да күз кыстылар хәтта.* Р.Мөхәммәдиев

**Калкынып кую** Кинәт, искәрмәстән калкыну. *Куркып уянган кеше кебек, кинәт калкынып куя.* И.Гази. *Ярым йомык күзләренең ара-тирә калкынып куюы тәнендәге чыкмаган җанга ишарәләп торса да, бу көннәрдә ул тере мәет хәлендә яшәде.* Г.Гыйльманов

**Калкынып тору** 1) Әле, хәзер, сөйләгән мәлдә калкынган булу. *Бераз узыбрак машина туктаган, аның кабинасыннан бер баш калкынып тора.* Г.Гыйльманов

2) Һәрвакыт күз алдында булу, күтәрелеп тору. *Сыек томан сыман зәңгәрләнеп торган су белән чолганган эрелеваклы йортлар, агачлар, урыны-урыны белән калкынып торган торбалар белән чуарланган матур шәһәр панорамасы пәйда булды.* З.Фәйзуллин

**КАЛКЫТУ** *ф.* 1) Аз гына югарыга, өскә күтәрү. *Юлның уң ягында, яшел сыртын калкытып, озын тау сузылып ята.* И.Гази. *Абау, кеше кебек йөрмәс бу урманчы хатыны дип, такта белән бүленгән яктан хат ташучы Әлфинур баш калкытты.* Н.Гыйматдинова

2) Яткан, егылган, иелгән хәленнән торгызу, турайту. *Җиргә сыенган үләннәр, чәчәкләр чыклы башларын калкытып турайдылар.* И.Гази. *Шул авыр тамчылар аңар башын калкытырга, торырга ирек бирмәде.* Р.Мөхәммәдиев

3) Чыгынтылы, калку итеп, күпертеп эшләү. *Кабер ташларындагы язмаларны калкытып язу*

4) *күч.* Көч-куәтен арттыру, көчәйтү, көчлегә әйләндерү. *Бөтен рухы алманнарны калкыту, ара дәүләтен көчәйтүгә юнәлгән.* Т.Әйди

**Калкыта башлау** Калкытырга тотыну. *Көннәр салкынайту белән, ОРЗ, ОРВИ, грипп кебек авырулар баш калкыта башлый.* Кызыл таң

**Калкыта төшү** Тагы да бераз калкыту. *Туман тархан Салчак алыпның сүзен тыңлап тормады, башын калкыта төшеп, үзенең боерыгын белдерде.* Н.Фәттах

**Калкытып кую** 1) Калкынган торыш бирү һәм шул торышта калдыру

2) Сирәк-сирәк, вакыт-вакыт калкыту; калкынган хәрәкәт ясау. *«Бу көннәрне дә күрәсе бар икән» дигән уй туса, икенче яктан: «Инде кая барырга?» дигән сорау да башын калкытып куя иде.* М.Хәсәнов. *Баш калкытып куйды Нуриман карт, Гүя эчте Әбелхәят суын...* Ф.Яруллин

3) *күч.* Игътибарны юнәлтү, калку итеп сурәтләү. *Урыны-урыны белән тормышның матур нокталарын калкытып куя.* Ф.Әмирхан

**КАЛЛИГРАФ** *и. гр.* Матур итеп, сырлап, бизәкләп язу остасы; матур язу остасы; хәттат. *Ул – заманның алдынгы журналист-публицисты, күренекле юмористы һәм сатирачысы, вакыты өчен яраклы тәнкыйтьче, шагыйрь, танылган тәрҗемәче, татарча әдәби тел эшләп бирүчеләрнең берсе, беренче карикатурачы, вакытында тәкъдир ителгән артист-режиссёр һәм яхшы каллиграф.* М.Гали. *Менә бу хәлләр барысы да татар каллиграфлары тарафыннан күчерелгән китапларда колофон дигән бетем язуының, ягъни күчермәгә аны эшләүче тарафыннан бирелә торган махсус «паспортның» сирәк булуына китерәләр.* М.Госманов

**КАЛЛИГРА́ФИК** *с.* Каллиграфиягә бәйләнешле; аерым каллиграфия белән язылган

**КАЛЛИГРА́ФИЯ** *и. гр.* Матур язу сәнгате. *Оста гармунчы, җир җимертеп биюче, һәммә кешене авызына каратып тота ала торган оратор, иң әйбәт каллиграфия белән яза алучы.* Г.Ахунов

**КАЛЛИГРАФЧЫЛЫК** *и.* Каллиграфия эше, шөгыле, һөнәре; хәттатлык. *Татар каллиграфчылыгы тарихында аның бу хезмәтләре дә һичшиксез зур урын тотарлар.* М.Гали

**КАЛМЫК** *и.* Нигездә Калмык республикасында яшәүче төп халык атамасы һәм аның бер вәкиле. *Гыйбрәт алды Шәрыктән магул, калмык.* М.Гали

**КА́ЛОМЕЛЬ** *и. гр. мед.* Хлорлы терекөмеш; медицинада эчне йомшарту һәм дезинфекцияләү чарасы буларак кулланыла

**КАЛОРИ́МЕТР** *и. физ.* Җылылык микъдарын үлчәү әсбабы

**КАЛОРИМЕ́ТРИЯ** *и. гр. физ.* Физика фәне кысаларында төрле җисемнәрнең җылылык микъдарын үлчәү белән шөгыльләнә торган бер бүлек

**КАЛО́РИЯ** *и. лат.* 1) *физ.* Җылылык микъдарын үлчәү берәмлеге

2) Бер грамм азыктан организм эшләп чыгарган, калория белән исәпләнә торган энергия микъдары

**КАЛО́РИЯЛЕ** *с.* Күп калория бирә торган, җылылык калориясе зур булган. *Без калориялерәк ризыкларга да заказ бирик инде.* Т.Әйди. *[Инар белән әтисе] кухнядагы электрон пешекчегә бер көнгә җитәрлек калорияле ризыклар пешерергә меню язып бирделәр.* Р.Фәизов. *Табигать бүрене җир йөзендәге иң калорияле дефицит ризык – ит ашый торган итеп яраткан.* М.Мәһдиев

**КАЛО́РИЯЛЕЛЕК** *и.* Югары калориягә ия булу сыйфаты. *Күптән түгел генә Walt Disney үзенең бренды астында сатыла торган азык-төлек калориялелеген чикләде ---.* Ватаным Татарстан

**КАЛОШ** *и. к.* **галош**. *Кызыл эчле калошлары белән --- Килә иде алар йомшак басып, Киек казлар кебек тезелеп.* М.Садри. *Бай калошына табан һәм үкчә булган Мостафа.* Г.Тукай

**КАЛПАК** *и.* 1) Төрле-төрле тукымалардан, йоннан, тиредән һ.б.дан төрле формаларда тегелгән ирләр баш киеме

2) *махс.* Төрле формадагы капкач, япкыч

**КАЛПАКЧЫК** *и.* Кечкенә калпак. *Аның агачсыман касә яфракчыклары һәм җимешәне кып-кызыл төскә буялганнар, ә ап-ак таҗ яфраклары бик тыгыз калпакчык булып укмашканнар.* Робинзон эзләреннән

**КАЛТА** *и. иск.* Күннән тегелгән акча янчыгы

◊ **Калта калынайту** Кеше исәбеннән баю, зур байлык туплау

**КАЛТАЮ** *ф. к.* **калҗаю**

**КАЛТЫ́Й-КОЛТЫ́Й** *рәв.* Аватүнә, ян-якларга янтаеп

**КАЛТЫРАВЫК** *с.* **1.** 1) Калтырап тора торган. *Калтыравык чәчәкнең тәлгәшләре бик матур була.* Робинзон эзләреннән. *Чөнки моның [Сәхиянең] мотоциклы кебек тотенле, тавышлы калтыравык мотоцикл авылда юк иде.* Ф.Яруллин

2) Калтырап, өзек-өзек кенә ишетелгән. *Фәтхи бизгәкле кеше шикелле калтыравык тавыш белән [җырлап җибәрде].* Ш.Камал

**2.** *и. мәгъ. диал.* Койка

**КАЛТЫРАВЫКЛЫ** *с.* **1.** 1) Калтырап чыккан (тавыш)

2) Калтыранып, дерелдәп торган

**2.** *рәв. мәгъ.* Калтырап, тигезсез

**КАЛТЫРАНУ** *ф.* 1) Өзек-өзек калтырап чыгу. *Крестьяннарның күзләре һәр яктан үзенә текәлгән килеш, шуны йөрәге белән сизгән көенчә, кендекне яңадан әйләндереп карады, тагын кулына алды, баягы сүзен тагы шундый ук калтыранган тавыш белән кабатлады.* Г.Ибраһимов. *Минем тавыш калтыранды, үземә ят булып тоелды.* Ә.Айдар

2) Кеше, җанлы әйберләр дер-дер килү, селкенеп, калтырап тору (эчке кичерешләрдән, куркудан, җилдән, туңудан һ.б.). *Уйламаган, көтелмәгән бу шатлыктан яшьләнгән күзләр бербарсенә туп-туры тегәлделәр, куллар калтырандылар, бу зур шатлыкны аңлатырга телләр әйләнми башлады.* М.Гали. *Кочаклады мине калтыранып, маңгаема иренен тигезде.* Ф.Кәрим. *«Ах, әни!» – ди, ләкин яшьләренә буыла һәм сүзсез генә, бөтен тәне белән калтыранып елый, елый да елый.* Ә.Еники

3) Физик тәэсирдән җансыз әйберләр селкенеп тору, калтырау. *Самавыр пар бөркеп калтыранырга тотынды, казанда шулпа гөбердәп тавыш бирде, бүлмәгә тавык ите исе таралды.* А.Гыйләҗев

**Калтырана башлау** Калтыранырга тотыну. *Бала куркуыннан акрын гына калтырана башлады.* Ә.Еники. *Бала калтырана башласа, аны әйбәтләп төреп яткырырга кирәк.* Кызыл таң

**Калтырана бирү** Калтырануын дәвам итү. *Шаһвәлиев калтырана биреп көлде, бөтенләй уен эченә чумып, яңадан фронтны бераз төзәтү чарасын күрде.* Г.Ибраһимов

**Калтыранып алу** Бераз, берникадәр, аз гына вакыт калтырану. *Баштан*

*салкын су сипкән төсле калтыранып алдым, йөрәгем жуу итте, аңымны җуйгандай булдым.* Г.Минский. *Ниһаять, Хәлимнең күз кабаклары калтыранып алдылар да киң ачылып киттеләр*. Г.Гыйльманов. *Газ биргәч, мотор гайрәтләнебрәк эшли башлады, трактор калтыранып алды, аннары --- акрын гына, теләр-теләмәс кенә алга таба китте.* Г.Кашапов

**Калтыранып бетү** Бик каты, бик көчле калтырану, калтырану дәрәҗәсенә җитү. *Калтыранып бетеп, иреннәрен ике якка аерды.* Г.Ибраһимов

**Калтыранып китү** Көчле тәэсирдән кинәт калтырана башлау. *Нуруллин кинәт, нәрсәдер сизенгән, нәрсәдер төшенгән шикелле, калтыранып китте.* А.Шамов. *Шул вакыт тавышы калтыранып китеп, күз яшьләрен чак-чак кына тыеп калды.* И.Гази. *Ләкин кинәт тавышы өзелде, бөгелеп төште һәм иңбашлары калтыранып китте.* Ә.Еники

**Калтыранып кую** Кисәк, бер тапкыр калтырану хәрәкәте ясау. *Кысык күзле, тар маңгайлы кешенең тәне ялгыш электр тогына кагылгандагы кебек калтыранып куйды.* Г.Гобәй. *--- тик усак кына әллә нигә бер калтыранып куя.* И.Гази. *Йөрәге ниндәндер курыккандай кинәт калтыранып куйды.* Г.Бәширов

**Калтыранып тору** Бертуктаусыз калтырану, әле, хәзер, күз алдында калтырану. *Баскан җирендә калтыранып торган чагында, Насрыйга бик кызганыч кыяфәттә күренде.* Ш.Камал. *Калтыранып торган йолдызларга карап, төнге тавышларны тыңлап, уйланып ятты.* И.Гази

**КАЛТЫРАНУЛЫ** *с.* Калтырап тора торган, калтыравыклы. *Аннары йөзенә чиксез гаҗәпләнү бәреп чыккан карт укытучының калтыранулы тавышы ишетелде.* Г.Минский

**КАЛТЫРАТУ** *ф.* 1) Калтырау дәрәҗәсенә җиткерү. *Йөрерләр чана җигеп, чалулатып, салкыннан иреннәрен калтыратып.* М.Гафури. *Хатны укып бетергәндә, Бибисара апаның бөтен тәнен ачу бизгәге калтырата иде инде.* Г.Минский // Дер-дер килү, өзек-өзек чыгу. *Өзек-өзек калтыратып сызгырды.* К.Нәҗми. *Башын аска иде, аскы иренен калтыратып салындырды.* А.Шамов

2) *з.-сыз* Ниндидер тышкы сәбәпләрдән калтырау барлыкка килү. *Үзең саташасың, үзеңне бизгәк калтырата.* Г.Гобәй. *Менә шул тискәрелек аның кәефен кыра, аны эчтән калтырата иде.* А.Шамов

3) *күч.* Куркыту, курку хәленә төшерү, куркуга салу. *Елмайсаң да калтыратты никтер: «Сау булыгыз, киттем!» – диюең.* Ф.Кәрим. *Дошманны калтырату*

**Калтырата башлау** Калтыратырга тотыну. *Кояш яктыртканда сизелмәгән суык, аяк-кул бармакларын чымырдатып, тагын да югарырак үрмәләде, аннары, эчкә үк үтеп, бөтен тәнне калтырата башлады.* Г.Әдһәм

**Калтырата төшү** Бераз гына калтырату. *Ул үзе дә озын көйләргә шактый матур, моңлы итеп җырлый иде. Гадәттә, аягүрә басып, тавышын аз гына калтырата төшеп сузып җибәрә иде...* З.Низаметдинов

**Калтыратып алу** Бераз, берникадәр калтырату. *Ыргып-ярсып искән көзге ачы җил үзенекен итте: Газины чынлап торып дерелдәтеп, калтыратып алды.* М.Хәсәнов. *Тәне буйлап салкын йөгерде, калтыратып алды.* М.Хәсәнов

**Калтыратып бетерү** Тәмам, бик нык калтырату, калтырату дәрәҗәсенә җитү

**Калтыратып җибәрү** Бераз, аз гына калтырата башлау

**Калтыратып кую** Кинәт, аз вакытка калтырату

**КАЛТЫРА́У** I *ф.* **1.** 1) Тәндә кабатланулы еш-еш, вак-вак хәрәкәтләр барлыкка килү, дер-дер селкенү, дерелдәү. *Әле аңа күнегеп җитешмәгән, шул суык үзәккә үтеп, тәннәр дер-дер калтырый, тешләр шак-шок бәрелә.* Г.Ибраһимов. *Сандыктан төргәк-төргәк кәгазь акчалар алып, өстәлгә куя башлый, куллары калтырый, күзләре акайган.* А.Әхмәт. *Иргали күкрәгенә капланган Гөлнисаның үксеп-үксеп елаудан бары тик җилкәләре генә калтырый иде.* М.Хәсәнов

2) Тирбәлеп, дерелдәп, селкенеп тору; вибрацияләү. *Каршыдагы өянке, урам, өйләр йөзтүбән әйләнеп, керфекләре арасында калтырый башлады.* М.Галиев. *Я станок калтырый, я [кискеч]. Я деталь белән [кискеч] икесе бергә калтырый.* Г.Әпсәләмов. *Ул арада вибраторлар да эшкә тотына, җир чып-чынлап калтырый башлый.* Ә.Баян

3) Ритмсыз, тигезсез тибү (йөрәк)

4) Нык курку, куркыну. *Аллага сыгынып, җанын учка тотып, Калтырыйдыр «исме әгъзам»нар укып…* Ш.Бабич. *Аның янына кергән чакта, елан янына кергән кебек дер калтырап керәләр иде.* И.Гази. *Джо агай Фрицны якасыннан эләктерсә, калтырарсың да.* Т.Әйди

5) Тигезсез, өзек-өзек булып ишетелү, өзелеп-өзелеп яңгырау. *Тавышы бераз калтырый --- иде.* Г.Ибраһимов. *Киленнең зур ачылган, очкынланган күзләре, гарьләнеп калтыраган газаплы тавышы карчыкны айнырта төште.* Г.Бәширов

**2. калтырап** *рәв. мәгъ.* Бөтен барлыгы белән кайгыртып, бик нык кадерләп

◊ **Калтырап тору** 1) Артык саранлык күрсәтеп, бик нык саклап тоту, аз гына да әрәм-шәрәм итмәү; 2) Нык курку, хәвефләнү. *Тагы шуны кара, без остазлар алдында калтырап тора идек.* Г.Ибраһимов

**Калтырап алу** Аз гына, кыска вакытка калтырау. *Очкыч кинәт калтырап алды. Автопилот көйлиләр дип уйладым.* М.Юныс

**Калтырап бетү** Тәмам, бөтенләй, бик каты калтырау. *– Алтыны бармы, көмешеме – үзең карарсың, битенә керשәнне үзең як, иннекне үзең сөрт, сөрмәне үзең тарт, югыйсә, каушап, калтырап бетәр, елый күрмәсен, уенкөлке сөйлә, – диде.* Г.Ибраһимов

**Калтырап китү** Кинәт калтырый башлау. *Фатыйманың да тавышы калтырап китте.* И.Гази. *Минем тез буыннарым җиңелчә генә калтырап киттеләр, алар әллә ничек кенә, бик аз гына исергәннәр шикелле иде.* Ф.Әмирхан. *– Хуш инде, Хәмидә, без китәбез, – дип, Гариф аның кулын кыскан вакытта, ул калтырап китте, агарды, әллә*

*нәрсә әйтергә телдә, тагы туктады.* М.Гафури. *Карчыкның зәңгәр тамырлар бүртеп чыккан куллары калтырап китә.* С.Рафиков

**Калтырап кую** Кинәт, дерт итеп, бер тапкыр калтырау. *Шул эчке карары астында аның түбәнге ирене дереләп, бармаклары калтырап куйдылар.* Г.Ибраһимов. *Шушы тынлык уртасында кинәт чатыр-чотыр итеп күк күкрәде, агачлар калтырап куйды.* И.Гази. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов

**Калтырап тору** Бертуктаусыз калтырау. --- *йомшак карлар дер-дер итеп калтырап торалар.* Ә.Ерикәй. *Аның бик кечкенә тәрәзәсеннән күренгән яктылыкның шул куе караңгылык эчендә «бетәм-бетәм» дигән төсле калтырап торуы ул --- күренешнең биргән авыр тәэсирен дәхи арттырмактадыр.* Г.Ибраһимов

**Калтырап төшү** Үз-үзен югалтырлык дәрәҗәдә курку алу, каушап, югалып калу. – *Син шуңа калтырап төштеңме, – диде Гафият, чырае киткән Гапсаттарга мыскыллы карап.* И.Гази. – *Мәнә бит, Ходаем, мәнә бит... – дип, үзалдына сөйләнә башлады калтырап төшкән Рәисә карчык.* Г.Мирһади. *Мактанчык чыпчык куркуыннан калтырап төште, сүзен дә әйтә алмады.* А.Алиш

**Калтырап чыгу** Өзек-өзек ишетелү. *Вәсилә хәзер үзе күренми, бары тик калтырап чыккан тавышын гына ишетәм.* Ф.Хөсни

**Калтырый башлау** Калтырарга тотыну. *Куркыныч узгач кына, аларның аяк-куллары калтырый башлады.* З.Тимергалиев. *Аның бөтен тәне дер-дер калтырый башлады.* Г.Исхакый

**КАЛТЫРА́У** II *и.* Бизгәк. *Арба янына килеп, яту, йоклау хәстәрен күрә башлагач, мине бизгәк кебек калтырау алды.* Г.Ибраһимов. *Тик бераздан соң гына бу калтыравым басылды.* М.Гали

**КАЛТЫРАУЛЫ** *с. к.* **калтыравыклы**. *Мин калтыраулы кулларым белән аларны [рәсемнәрне] актарырга тотындым.* Гали Рәхим

**КАЛТЫ́Р-КОЛТЫР** *рәв. к.* **калтыйколтый**. *Акчарлак баласы, калтыр-колтыр аякларына басып, канатларын җилпеп, оясыннан кыю гына чыкты да суга төшеп йөзеп тә китте.* Н.Сладков

**КАЛТЫРЧА** *и.* 1) Киндер, тула сугу өчен шүрегә җеп чорный торган корал; *русчасы:* **сучило**. *Сәке астыннан калтырчасын алып шүре ясады; тырупчага чолгаган мамык җепләрен рәтләде.* М.Гали. *Калтырчалар шыгыр-шыгыр җырлап, Җеп чорныйлар курай шүрегә.* Ш.Маннур. *Калтырчага шүре киертү*

2) *күч.* Искергән, тузган, җимерелү дәрәҗәсенә җиткән техника турында, иске-москы машина. – *Теге «җен калтырчасы» [иске мотоцикл] чыккан инде, – дип сукранып калалар иде карчыклар.* Ф.Яруллин

**КАЛУ** *ф.* **1.** 1) Сөйләгәнгә кадәр урынында булуны, торуны дәвам итү, шул урыннан китмәү. --- *кара кичтә безнең машина бер хутор артына килеп туктагач, малайларга җиргә коелырга команда бирелгәч, мин машина өстендә калдым.* М.Мәһдиев. *Татлы әсирлектән һаман айный алмыйча, бер урында басып калдым.* Н.Гыйматдинова. *Юл читендә ялгыз нарат кебек калдың басып. Кайтыр өчен китеп барам синнән саубуллашып.* Ш.Таһирова

2) Кайда да булса торуны, булуны берәр максатка яраშлы рәвештә дәвам итү. *Өчесе, бирелгән заданиене үтәп, техникумда калалар.* М.Әмир. *Шунлыктан, иртәгә барысын да берьюлы хәл итәрмен дип, кабат рәхмәтләр әйтеп, ул Гыйззәт хәзрәтләрдә кунарга калды.* М.Хәсәнов. *Дәү тәкәнең дә сеңгере нык булып чыкты, ул да бирешмәде, аякларында калды.* Р.Мөхәммәдиев

3) Алмау, алмыйча калдыру, элекке хәлен, урынын, торышын дәвам итү. *Безнең вагон идәненең бер почмагында теге фонарь калды.* М.Мәһдиев. *Кар астында калып өшегән черек бәрәңгене изеп, аз гына арыш онында әвәләп, --- кыздырсаң – телеңне йотарлык кәлҗәмә була иде.* Казан утлары

4) Берәрсе янында күзгә-күз булу, башкалардан аерым гына булу; аның яныннан китмәү. *Шунда мин үз гомеремдә беренче һәм соңгы тапкыр Туфан белән ялгызга-ялгыз калып урман сукмагында йөрдем.* М.Мәһдиев

5) Кемне дә булса алмаштыру, аның урынын алу. *Атасы узган кышын чирләп үлгәч, Саимә өчен бердәнбер якын кеше булып Нәсимә калган иде.* К.Нәҗми. *Дәү апасы, үзе дә бала көенчә, әнисе урынына калды*

6) Элекке торышын, мөнәсәбәтен һ.б.ш. үзгәртмәү, элеккечә булуны дәвам итү. *Ишек шар ачык калу. Дуслар булып калу*

7) Фикерен, карашларын, принципларын үзгәртмәү. *Ләкин ул һаман үз сүзендә калды.* Ф.Әмирхан

8) Бер сыйныфтан икенчесенә күчмәү. *Классында күчми калу*

9) Нинди дә булса сыйфат, халәт, хәл үзгәрешсез саклану. *Бары тик Иргали абыйның гына йөзе җитди калды.* М.Хәсәнов. *Чәчүлек җирләренең яртысыннан артыгы кысыр калган.* И.Салахов. *Кабереңне кочып еласам да, Калды мәңге әрнеп йөрәгем.* Ш.Маннур

10) Чарасын күрмәү, игътибарга алмау, ни дә эшләмәү. *[Зөләйха] Монда сиңа ике генә юл: я башыңны иеп тик каласың, я көрәшеп исемеңне аклыйсың.* М.Фәйзи

11) Хәтердә булу, башта, истә, күңелдә саклану. *Әмма ул елларда иң хәтердә калганы, әлбәттә, колхозлашу чоры булгандыр.* М.Хәсәнов. *Җанда егетне көткән бәхетле көннәр дә әрнү белән катышкан сөю чаткылары гына сибелеп калды.* Н.Гыйматдинова

12) Юкка чыккан, югалган нәрсәләрнең калдыгы, эзе сыйфатын алу, нәрсәнедер хәтерләтерлек кисәккә әйләнү. *Хәзер инде алар урынына ватылып беткән тау түбәләре генә калган.* Н.Вәлитова

13) **калмау** *юкл. форм.* Бетү, юкка чыгу. *Гасырларга килгән яшьләр китте, Кимсенүләр бетте күңелдә, Һәм калмады авыр моңаюлар, Зур сагышлар йөрәк төбендә.* Ш.Маннур

14) Кемнең дә булса эшен, яшәешен дәвам итү, үлгәннән соң, яңа буын килү

15) Файдаланудан, чыгымнардан соң ахыргача бетмәү. *Бәлки, табынна-*

*рыннан калган каты-котылары авыз суларыңны корыткандыр.* М.Хәсәнов // Алдан әзерләп тә файдаланмау, кулланмау. *Былтырдан калган әзер кармак бар икән, шуны алдым да кая баскаымны белмичә малайлар янына чаптым.* Г.Ибраһимов

16) *з.-сыз* Эшнең төгәлләнүе, мәсьәләнең хәл ителүе өчен, нәрсә дә булса эшләргә кирәк булу, тиеш булу, шул эштән генә тору. *Тәртип. Үтешли капкаларга гына аласы калды.* З.Фәйзуллин

17) Билгеле бер чиккә, урынга, моментка кадәр нинди дә булса зурлык тәшкил итү. *[Карт:] – Ямансазга моннан тугыз гына чакрым калды, – дип сөйләнә-сөйләнә, атын борды.* К.Нәҗми. *Тамаша башланырга берничә минут кына калды*

18) Сайлаганнан аерымлану, бүленеп чыгу, аерылу. *Без калырбыз намуссызлар, кыюсызлар, телсезләр, Дошмансызлар һәм дуссызлар, Көрәшсез, җиңүсезләр.* Н.Измайлова

19) Нинди дә булса киемен салганнан соң өлешчә яки бөтенләй киемсез булу. *Хуҗа да кара хәтфә кәләпүш, озын ак күлмәк, кара камзол, йомшак читектән генә калды.* М.Хәсәнов

20) Башка кеше карамагына күчү, милкенә әйләнү, өлешенә тию. *Әтидән калган имән бүкән һаман үз вазифасын үти әле.* Н.Хәсәнов // Борынгыдан килү, ата-бабадан сакланып дәвам итү. *Кара акылым белән аңлавымча, сәүдә – батырлык, тәвәккәллек, тапкырлык сорый торган, Мөхәммәд пәйгамбәрдән калган изге һәм игелекле шөгыльдер ул.* М.Хәсәнов. *Фәсхи иптәш килгәнче, совхоз, әти-бабайдан калган юл белән барып, өч басудан котыла алмый иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Хаҗ ул зәмзәм суын тәмләп кайту гына түгел, аның мәҗбүри үтәлергә тиешле, борынгыдан калган үз эчке кануннары бар.* Т.Галиуллин

21) Чара, юл, мөмкинлек чикле булу. *Әгәр син агаларың котырыгы белән безне ата-ана итми башласаң, алар шикелле башбаштакланып, үзең белгәнчә йөрсәң, безгә кайгыбыздан үләргә генә кала.* Ф.Әмирхан. *Күп белдекле, акыллы баш булып кыланырга да, качышлы уйнап маташырга да урын калмаган.* М.Хәсәнов

22) Мәхрүм булу, нәрсәне дә булса югалту. *Ул ачлык елны, ун яшенә чыкканда, өй тулы эне һәм сеңелләре белән ата-анадан ятим калды.* Г.Бәширов // Берәр төрле табигый халәтне, табигый сәләтне саклау. *Әйтергә генә ансат ул, Миңзаһит Усманович. Ничә ел халык белән эшләп, нервысы калганмыни инде аның.* Ф.Садриев

23) Нинди дә булса яман, куркыныч хәлдән котылу. *[Шәмсия:] Бичара егет, мине таптатмас өчен, машинасын баганага бәреп ваттырган. Шулай итеп үлемнән калдым.* Т.Гыйззәт

24) Яныннан үтеп киткәндә күренеп китү. *Анда-санда ялтыр көзге төсле җемелдәшеп калды буалар.* Ш.Мөдәррис

25) *сөйл.* Уенда отылу. *Юләр калу. Кәҗә калу*

26) Башкаларның артында булу, аларга караганда акрынрак бару. *Әмма «йөрәксез айгыр», инде юкәче марилардан да калып, мескен кыяфәтендә сөйрәлә, хуҗасына үзе урынына арбага җигелеп барырга кушадыр кебек тоела башлады.* Ф.Яхин

27) Акрынрак эшләү, калышу, вакытында бетерә алмау, иң соңгы булу. *Башкалар күптән эшләрен тапшырдылар, ә мин калдым.* А.Гыйләҗев

28) Башкалар белән чагыштырганда түбәнрәк булу, тиешле дәрәҗәгә, үсешкә җитмәү. *Менә без кем булдык та, син нинди хәлдә калгансың.* М.Мәһдиев

29) Берәр төрле транспортка өлгермәү, вакытында килеп җитмәү. *Поездан калу. Самолёттан калу*

30) **калмау** *юкл. форм.* Юклык формасындагы фигыльләр янында килеп, шул эшнең һичшиксез эшләнәчәген, үтәләчәген белдерә. *[Галиябану:] Бүген инде [Хәлил] янына чыкмый калмыйм.* М.Фәйзи. *Үз сүземне әйтмичә калмыйм*

31) **калмау** *юкл. форм.* Алдында килгән фигыль белдергән эш белән генә чикләнмәү, тагы нинди дә булса эш башкару. *Савытлар аларны механик җәрәхәтләнүләрдән саклап кына калмый, --- вентиляция һәм суынуны җиңеләйтә.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

32) **калмау** *юкл. форм.* Тулысынча үтәлү, бар булганны эшләү, бернәрсә дә калдырмау. *Бүләкләрне биреп кенә торалар, значоклары да калмый, хәтта медален дә тактылар...* Н.Хәсәнов. *Чиркәү эчләре, монах хөҗрәләре калмады, хәтта мунча белән ат сараен да җентекләп тикшерделәр.* З.Фәтхетдинов

33) Тиешле, булуы мәҗбүри урынга бармау, килмәү. *Инде әйтсәм әйтим: берәр көн занятиесеннән дә калырсың.* Ф.Садриев

34) Үз вакытында эшләмәү, вакытын кичектерү. *[Карлыгач:] Юк, язга калырга ярамый, көздән үк, бәйрәм үткәч үк!* Г.Бәширов

35) Чикләнү, мохтаҗлык күрү. *Ашау такы-токыга калу*

36) Уфтану, үкенү, ачыну мәгънәсен белдерә. *Бары да ерак, бәхетле, матур төш кебек сагынып уйларга, сагынып еларга калды.* Г.Ибраһимов

37) Нинди дә булса эш-хәлнең булмавын, үтәлмәвен белдерә. *Уйнасам, дәресем кала [диде бала].* Г.Тукай

38) *Көлке, оят, хурлык* һ.б.ш. сүзләр янында килеп, шул хәлгә төшү. *[Гыйльми карчык:] Минем кызларым да, уллары да болай хурлыкка калып, акылдан язып ятканнары юк.* М.Гафури // Ярдәмгә, тәрбиягә мохтаҗлык кичерү. *Шөкер Ходайга, мин үзем алай кеше кулына калырмын дип уйламыйм, калырга язмасын Ходай.* Ф.Хөсни

**2.** *ярд. функ.* 1) Эш-хәлнең тәмамланмавын, дәвам итүен белдерә. *Ринат артыгын дәшмәде. Кызның турыдан чәчкән сүзләренә аптырап, уйланып калды.* Н.Хәсәнов

2) Мөмкинлек булу, мөмкинлектән файдаланырга тырышу, файдаланырга өлгерү. *Кворум җитмәү аркасында, Татарстан парламенты ничаклы яхшы карарларны кабул итә алмыйча калды.* Т.Галиуллин. *Ничек инде мин генә ул хикмәтле хәлләрне күрмичә калырга тиеш, ди.* М.Хәсәнов

3) Нәрсә дә булса эшләргә өлгерү, эшли алу. *Ярый әле Иргали үзе йөгереп килеп хатынын тотып калырга,*

*кочагына алырга өлгерде.* М.Хәсәнов. *Сибгат абый аны күргәч урыныннан торды, аны абруйлы бер урынга китереп утыртты, мәҗлес бу вак мәшәкатьне сизми калды, чөнки Вафирә үзенең көмеш тавышы белән --- җыр җырлый иде.* М.Мәһдиев

4) Эш-хәлнең нәтиҗәсен, сәбәбен белдерә. *Ел да болай ишелсә, нигезгә барып җитәргә дә күп сорамас. Тал тамырлары ярга пәрәвездәй ябышып калган.* Н.Хәсәнов. *Тор әле. Сәйфулла дим, тор! Әткәйләр китә башлар, йоклап кала күрмик.* З.Зәйнуллин

5) Нинди дә булса торышка, хәлгә кисәк күчүне белдерә. *Ачуы йөзенә бәреп чыккан Мазһар котырган исерек каршында каушап калмады.* М.Әмир. *Миңа төбәлгән күксел зәңгәр күзләрнең карашыннан мин ничектер югалыбрак калдым.* Ә.Еники. *Көймә астыннан беренче булып Гази чыкты. Чыкты да хәйран булып катып калды.* М.Хәсәнов

6) Эш-хәлнең өлешчә генә, тиз арада башкарылуын белдерә. *Габдулла күз кырые белән генә Сәрвинең, сөлгене тотып, өйгә кереп китүен күреп калды.* Ә.Фәйзи

7) Нәрсә дә булса эшләүдән баш тартуны, кинәт өзүне белдерә. *Карт нәрсәдер әйтергә теләп иреннәрен дерелдәтеп алды, ләкин ярамас сүз әйтермен дип тыелып калды.* Н.Хәсәнов

8) Алда эшләнәсе эш, үтәләсе нәрсә булуны аңлата. *Ярылмый калган ботаклы кисәкләр шактый җыелган.* Н.Хәсәнов. *Университетны тәмамлагач, үз-үзеңне илтифатлы тотып, күрсәткән ихтирамга лаек булырга тырышасы гына кала.* М.Юныс

9) Үтәлмәгән, башкарылмаган эш өчен үкенүне белдерә. *Күз керфекләрем талганчы Карыйсым калган икән.* Җыр

**3. кала** *бәйл. мәгъ.* 1) Урынны яки вакытны белдергән саннар янында килеп, тулы күләмгә җитмәүне күрсәтә. *Ирләр китәргә ярты сәгать кала һәр вагон эченә бәйләме чишелмәгән шинельләр ыргыттылар, икешәр әрҗә консерва куйдылар.* З.Зәйнуллин. *Өянке бүгенгедәй хәтерли әле: бәйрәмгә ике көн кала, төне буе гарасатлы давыллап, яшенле яңгыр яуды.* М.Галиев

2) Тыш, соң, башка. *Шуңа күрә Галиәсгар Камалны, Каюм Насыйридан кала, татар милли культурасының тарих җебе барып бәйләнгән төп багана дип атарга туры килә.* М.Гали

**Кала бару** Һаман да арттарак калу, калуын дәвам итү, ерагаю

**Кала башлау** Калырга тотыну. *Бераздан ул үзе дә усалланды, урамнан таш атып үтүчеләргә, тешләрен ыржайтып, ырылдап кала башлады.* Г.Гыйльманов

**Кала бирү** Һичнигә карамастан, элекке рәвешен, хәлен, торышын үзгәртмәү, элеккечә калуын дәвам итү. *Кол Гали поэмасы, үзенең чагыштырмача архаиклыгына карамастан, татарлар арасында иң популяр --- әсәр булып кала бирә.* М.Госманов. *Микәй аның саен кымшанмады, моңарчы ничек торган булса, шул хәлендә кала бирде.* Р.Мөхәммәдиев. *Дүрт елда ике тапкыр яңа толь япсалар да, уңмадылар, әллә тольнең начары туры килде, әллә япканда тишкәләнде шунда, астарлык тактага яңгыр саркый торган урыннар кала бирде.* М.Хуҗин

**Кала килү** Электән үк кичектерелә барып калу, туктаусыз чигерә барып калдыру

**Калып бару** 1) *к.* **кала бару**

2) *күч.* Аз-азлап, акрынлап нинди дә булса торышка күчү, хәлгә төшү. *Кыенлыкка калып бара көннәребез, Зынҗыр берлән беркетелде телләребез, Аһ-ваһ илә үтәдер һәм төннәребез.* Ш.Мөхәммәдев

**Калып бетү** Бөтенләй, тулысы белән нинди дә булса халәттә калу; тәмам калу. *Моңарчы да, аларның ризалыкларын алабыз дип, кара җәяүгә калып беттек инде.* Г.Камал

**Калып тору** Вакытлыча калу, әлегә калдырылу. *Милиционер, бәйрәм көн булмаса, штраф чәпи идем, ярый, бу юлга калып торсын, миннән булсын яхшылык дигәндәй елмаеп бармак янады.* Р.Вәлиев

**КАЛФАК** *и.* 1) *этн.* Татар хатынкызларының бәрхеттән тегелгән, сәйлән яки энҗе белән чигеп бизәлгән, маңгай турысына киелә торган милли баш киеме. *Шунда бер якка иске йозак, --- калыбы җимерелгән кәләпүшләр, бишмәтләр, --- калфаклар берәм-берәм урнаша башлыйлар.* Г.Ибраһимов. *Залда барысы да: түбәтәй, картуз, эшләпә, калфаклар кигән башлар тавыш килгән якка борылдылар.* А.Таһиров

2) *диал.* Балалар башлыгы

3) *диал.* Суганның орлыкланган башы

**КАЛФАКЛАП** *рәв.* Яулыкны туры бәйләгәндә маңгайга төшеребрәк, алгы яктан калфакка охшатып, очларын бөкләп арттан бәйләү рәвеше турында

**КАЛФАКЧӘЧӘК** *и. бот. диал. к.* **кыр бәрәңгесе**

**КАЛФАКЧЫ** *и.* Калфак тегү, чигү остасы

**КАЛШАЮ** *ф. к.* **калтаю**

**КАЛЫМ** *и.* 1) *этн.* Кияү ягыннан кәләшнең ата-анасына яки туганнарына бирелә торган йолым, мал, акча (ыруглык чорыннан калган йола). *Минем кебек мөхтәрәм кешегә алдау килешмәсә дә, калым белән яңадан килермен дип, көч-хәл белән тайдым тегеләрдән.* Н.Әхмәдиев

2) *күч.* Законлы хезмәттән тыш өстәмә эшләгән эш өчен түләнгән акча. *Зур калым алу*

**КАЛЫМЛЫК** *и.* Калым түләү өчен билгеләнгән акча, әйбер, мал-туар

**КАЛЫМЧЫ** *и.* Калымга эшләүче кеше

**КАЛЫН** I *с.* **1.** 1) Яссы әйбернең аркылы киселеме чагыштырмача зур булган; *киресе*: **юка**. *Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә.* Ә.Еники. *Кулларында кармак чыбыклары, берсенең калын гына портфеле дә бар.* М.Мәһдиев

2) Юан, әйләнәсе киң булган. *Чокырның нәкъ төбендә калын агач ята.* Г.Әпсәләмов. *Нюра бүген чәчен икедән үргән дә озын калын толымнарын иңбашына салган.* Г.Бәширов

3) Бер-берсенә якын урнашып, куе, тыгыз булып үскән. *Калын чәчләрен шәмәхә тасма белән кичәгечә үк кысып бәйләгән.* М.Хуҗин. *Киң җилкәле таза гәүдә, озынча матур бит, әрсез коңгырт сакал, шуның төсле үк калын мыек, тынгысыз үткен күзләр, чәчендә*

*анда-монда җемелдәгән ак бөртекләр – үзе әйтмешенчә, окопта узган озак еллар истәлеге – менә шундый иде Әхмәди.* Г.Бәширов. *Монда калын урманнар, кыш көне җиргә тирән кар ята, малларны тибендә йөртү мөмкин түгел.* З.Мифтахов

4) Тулы, юан гәүдәле. --- *түрдәге калын казак, бикәгә карап: – Борынгыларның бер сүзе бар: «Корымаган кое булмас, ярылмаган таш булмас», – --- диде.* Г.Ибраһимов

5) Итләч, кабарып торган. *Хәят, бу куркыныч сурәтне күңеленнән чыгарыр өчен, бакчада урын биргән студентны, калын һәм кызыл иренле Евгенийны, --- тагы әллә кемнәрне уйлап карады.* Ф.Әмирхан

6) Катлы-катлы булган, берничә каттан торган. *Монда коры һава, күмер катламы калын, өч метрдан алып алты метрга кадәр, катламнар текә, күмерне чабу җиңел, төяп җибәрү уңайлы.* Д.Каюмова. *Күл төбендәге калын ләм катламында органик әйбер калдыклары черүдән газ хасил була.* А.Муранов

7) Түбән тембрлы, түбән яңгырашлы. *Пыялачы, малайларга күтәрелеп карап, калын тавыш белән: – Кайсыгыз ватты? – дип сорады.* А.Гыйләҗев. *Чәчәктән чәчәккә очканда, мәк чәчәгендә бал суырып ятканда, калын тавыш белән тагын кемдер эндәшә.* А.Алиш. *Бар икән затлылык, бар икән Ходай биргән матур калын тавыш.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Бай, мул. *Ташлытау базары калын була, Заһри шикелле үткен кешегә анда да маклер булып көн итәрлек җай чыга торды.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Кабат-кабат, катлы-катлы булып. *Урман буйларына, болыннарга кар, җил белән себерелеп килеп тә, аеруча калын булып ята.* З.Мифтахов

◊ **Калын җилкәле** Хәлле-маллы, мул тормышлы кеше турында. *Җизнәң – бик калын җилкәле кеше, сора, ярдәм итәр.* Н.Исәнбәт. **Калын тиреле** Бернәрсәгә дә исе китми, кайгырмый, борчылмый торган, гамьсез, ваемсыз

**КАЛЫН** II *и. диал. этн.* Электә: булачак кияү ягыннан кызга бирелә торган кием-салым, әйберләр

◊ **Калын кәгазе** *диал. этн.* Кияү ягыннан кызга биреләчәк әйберләрнең исемлеге язылган кәгазь

**КАЛЫНАЙТУ** *ф.* 1) Калын итү, калынлыгын арттыру

2) Юан күрсәтү. *Бу күлмәк калынайтып күрсәтә*

**КАЛЫНАЮ** *ф.* 1) Калынлыгы арту. *Кар калынайганчы, киселгән бүрәнәләрне авылга кайтару хәстәрлеген күрергә кирәк иде.* Г.Гыйльманов

2) Юанаю, симезгә әйләнү. *Син дә үзгәргәнсең. Калынайгансың, чәчләреңә чал төшкән ---.* Д.Каюмова. *Көннәрнең берендә калынаеп кына, авыраеп кына Нечкәбил эштән кайтса, хәйранга кала.* А.Алиш. *Бу вакытта Сайдә нык кына тазарып, калынаеп өлгергән иде.* Г.Гыйльманов // Эче үсеп юанаю. *Хәер, күп көттермәс инде: биянең эче калынайганнан-калыная бара. Сафа бабай әйтә, озакламый колыннар инде, ди.* Г.Ибраһимов

3) Түбәнәю, түбән тембрлыга әйләнү; тупаслану (кеше тавышы тур.)

**Калыная башлау** Калынаерга тотыну. *Корсагы калыная башлаган, әмма озын халат астында сизелми диярлек.* Г.Әпсәләмов

**Калыная төшү** Тагын бераз калынаю. *Инде еллар узгач, аңа бәйле вакыйгалар гасыр тузанына күмелгәч, серлелек пәрдәсе тагын да калыная төшкән, Әбүгалисинаны олылыклаган әсәрләр иҗат ителгән.* Р.Рахман

**Калынаеп китү** Кинәт калынаю, калынрак була башлау. *Каршыдагы җир өстендә тамырлар калынаеп киткәндәй булды.* З.Мифтахов. *Гомеремә күрелмәгән хәл: кинәт кесәм калынаеп китте.* Ф.Яхин

**КАЛЫНЛЫК** *и.* 1) Әйбернең аркылы кисеме зурлыгы. *Хәлим өч көн дигәндә ике карыш калынлыгындагы саман кирпичне тишеп чыкты.* Г.Гыйльманов. *Шулардан [сәке тактасыннан] иңе ике карыш, калынлыгы бер илле, буе өч аршын чамасы берсен тартып алды да яргалады.* Г.Ибраһимов. *Әйберләрне багажникка урнаштырганнарын доцент Мәрдиев, пәрдә читен лезвие калынлыгы гына ачып, тәрәзәдән карап торды.* М.Галиев

2) Куелык. *Чирәмнең үтә дә калынлыгы, куелыгы, җетелеге ошады аңа [Хәлимгә].* Г.Гыйльманов

**КАЛЫНЛЫ́-НЕЧКӘЛЕ** *с.* Калын һәм нечкәдән торган

**КАЛЫ́НЧА** *с.* Ярыйсы ук калын, калынга якын

**КАЛЫП** *и.* 1) Аяк табынына охшатып ясалган агач форма. *Югары шүрлектә әтисе аның өчен калыпка тартып куйган читек башы тора.* Ә.Фәйзи

2) Баш киемнәренә билгеле бер рәвеш бирү өчен кулланыла торган форма. *Баштагы кырма бүрек, яңа калыптан алган кебек, бераз кырынрак, назлатып киелә.* Г.Ибраһимов

3) *махс.* Корыч һ.б. металларны эретеп коюда кулланыла торган форма // Кирпеч сугуда кулланыла торган форма

4) Матур әдәбиятта чынбарлыкны чагылдыру чаралары һәм алымнары җыелмасы; форма. *Әкиятне шигырь калыбына салып язып чыктым.* М.Әмир

5) *күч.* Эшне бер рәвештә алып бару өчен билгеләнгән тәртип; әзер үрнәк, штамп, шаблон. *Аларга тормышны өйрәнергә вакыт тудырмавыбыз өстенә, аларны тын да алырга вакыт калдырмаслык итеп башка эшкә җигеп, башларындагы темаларны бертөрле калыпка салуга вакытларын калдырмыйбыз.* Һ.Такташ

◊ **(Бер) калыпка салу** Эшнең асылын исәпкә алмыйча, барысын да бер иштән карау. **Калыпка салыну** Билгеле бер җайга төшү, эзлекле тәртип алу, көйгә салыну. *Аны нинди дә булса хәлгә, күренешкә бәяләмә дип атыйбызмы, – барысы да, үз вакыты җиткәч, барыбер мәгънәви калыпка салына икән.* З.Хөснияр. **Калыпка сыймау** Кабул ителгән, күнегелгән гадәтләргә, тәртипләргә туры килмәү; килешле кыланмау. **Калыпка утыру** Җитлегү, акыл керү. **(Үз) калыбына кайту** Элекке хәлен, рәвешен алу, элеккечәгә әйләнү. *Тәне ничек тә үз калыбына кайтыр, җаны да тынычланыр; зиһене генә иләсләнеп китмәсен, ул ялгышса, баш бетте дигән сүз*... Г.Гыйльманов

**КАЛЫПЛАНУ** *ф.* 1) Калыпка салынган булу, билгеле бер калып формасын, рәвешен алу

2) *күч.* Җитлегү, үсү, формалашу. *Менә ни өчен ул сурәтләнүче кешеләрнең тормыш йомгагын сүтүгә, аларның холык-фигыльләре калыплану үзенчәлекләрен тәфтишләүгә аеруча җентекле игътибар итә.* М.Насыйбуллин. *Разил туган, мин, каядыр чалулап, читкәрәк кереп киттем, ахрысы. Әмма зыянлы булмас! Сүз бит биредә шагыйрьнең ничек калыплануы турында бара.* Р.Вәлиев

**Калыпланып җитү** Тиешле дәрәҗәдә калыплану. *Шигырьләрдә --- фикри яклары дөрес калыпланып җитә алмаган урыннар бар.* Г.Ибраһимов

**Калыпланып бетү** *к.* **калыплашып бетү**. *Ни өчен алай булгач ул, безнең аңыбызда калыпланып беткән гыйбарә белән әйтсәк, тормышта үз урынын таба алмаган бер «сәрхуш» турындагы әсәр --- Айрат ага Арслановның репертуарыннан озак еллар төшмичә яшәп килде ---.* Зөлфәт

**Калыпланып килү** *к.* **калыплашып килү**. *Хәзер исә музыка өлкәсендә динебез белән бәйле сегмент та калыпланып килә.* М.Вахитов. *ТР Мөселманнары диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов исә: «Казанда бүген дә 50 мең кулъязма китап булуы – бездә тулаем кулъязма китап культурасы калыпланып килүенең ачык дәлиле», – дип белдерде.* Шәһри Казан

**КАЛЫПЛА́У** *ф.* 1) Калыпка тарту, калыпка кидерү; калыпка салу

2) Берәр төрле үзенчәлек хасил итү, формалаштыру. *Яруллаңы табигать, татар халкы шундый итеп яраткан, немецлармы, французлармы аның яхшы сыйфатларын үстергән, калыплаган.* Т.Галиуллин

**КАЛЫПЛАШУ** *ф.* 1) Нинди дә булса форма алу, кидерелгән калып формасында ныгып калу

2) Төгәл форма алу, урнашып китү, таралу. *Бәет жанрының калыплашуы катлаулы һәм бертөрле генә түгел.* Г.Макаров. --- *XX гасыр башындагы татар яшьләренең ничек калыплашуы төрле-төрле язмышлар аша тасвирлана.* Р.Раскулова

**Калыплаша бара** Торган саен калыплашу. *Нәтиҗәдә, --- тәкфирчеләр, шигый һәм башка шикле фигураларның идеологияләре калыплаша бара.* Безнең гәҗит. *Системалы рәвештә шомара һәм калыплаша бару нәтиҗәсендә, XX йөзгә чыккач проза әсәрләре телендә стиль кытыршылыклары, аерым кимчелекләр кими.* Р.Закирова

**Калыплаша башлау** Калыплашырга тотыну. *Бу дәвердә документаль повесть жанрының мемуар-автобиографик дип исемләнгән канаты калыплаша башлый.* Н.Йосыпова, Г.Гайнуллина

**Калыплашып бетү** Тәмам калыплашу

**Калыплашып килү** Күптәннән бирле калыплашу процессында булу

**КАЛЫШУ** *ф.* 1) Хәрәкәт тизлеге кимрәк булу аркасында, башкалардан артка калу, аларның хәрәкәтенә, адымына өлгермәү. *Санитарлар командасын бомба янында сафка тезделәр, алып килүче командир кешеләрне кулы белән санап чыкты һәм, бер-берсеннән калышмаска кушып, команданы үз артыннан алып китте.* Г.Бәширов. *Җилкапкадан урамга килеп чыгуга малай, атасының зур адымнарыннан калышмаска тырышып, кәҗә бәтие кебек сикергәләп бара башлады.* И.Гази. *Әнә алар [торналар], тигез өчпочмак ясап, авыр болытлардан калышырга теләмәгәндәй, хәтәр, ифрат та авыр сәяхәткә чыкканнар.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Эштә, ярышта сыйфат, тизлек, нәтиҗәлелек һ.б.ш. күрсәткечләр башкаларныкыннан кимрәк булу, башкалар кебек эшли алмау. *Бу Галимә менә диган егетләрдән калышмый.* М.Гафури. *Беләм мин сине, синең кешедән калышасың килми.* Г.Гобәй. *Яшьләр артыннан калышмый килгән картрак, өлкәнрәк уракчылар да сүзгә кушылалар.* А.Шамов

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса сыйфаты башкаларга караганда түбәнрәк булу. *Илшат тәбәнәк буйлы, чандыр гәүдәле, төс-бит белән дә башка яшьтәшләреннән шактый калыша иде.* Ф.Яруллин. *Авыл өйләре дә бүтәнчә хәзер: шәһәр коттеджларыннан һич калышмый ---.* А.Гыймадиев

**Калыша бару** Торган саен күбрәк калышу, өлгерә алу сәләте һаман кимү. *Безнең көннән-көн европалылардан калыша баруыбызны сез бер дә күрмисезмени?* Р.Ишморат

**Калыша башлау** Калышуы сизелү, калышуы күренү. *Башта бу ике «сакаллы сабый» тигез йөгерсәләр дә, бераздан юантыграк дәү әти калыша башлады.* Ф.Әмирхан

**Калыша бирү** Калышуын дәвам итү, һаман да калышу

**Калыша төшү** Чагыштырмача артка калу сизелү, тагын да бераз калышу. *Угор алыплары Буйтурдан чак кына калыша төшеп* чабалар. М.Хәбибуллин

**Калышып килү** Эзлекле рәвештә, күптәннән, электән аз-азлап калышу

**КАЛЬГА** *и. гар.* Кирмән, ныгытма, крепость. *Калкулык сыртында соры томан аша, тылсымлы шәүлә булып, борынгы ныгытма – кальга төсмерләнә.* М.Юныс

**КА́ЛЬКА** *и. фр.* 1) Сызымнардан яки рәсемнәрдән күчермә алу өчен, югары сыйфатлы үтә күренмәле кәгазь яки май, балавыз, сумала кебекләрнең эремәсе сеңдерелгән нәзек киҗе-мамык тукыма, гадәттә батист. *Этикетканың зурлыгы, аның карандаш яки тушь белән, калькада яки сызым кәгазендә язылуы коллекцияне саклау ысулы белән бәйле.* Ә.Халидов

2) *лингв.* Чит тел сүзе, сүзтезмәсе үрнәгендә телнең үз чараларыннан төзелгән сүз яки гыйбарә. *Мисаллар: «Тәрәзәгә җил ком көлтәсе китереп сылады». Ком көлтәсе булмый ---. Бу – калька, теле бозылмаган татар болай сөйләми ---.* Х.Сарьян. --- *алынма сүзләр ярым калькалар рәвешендә дә килеп керәләр.* Ф.Сафиуллина

**КА́ЛЬКАЛАШТЫРУ** *ф.* 1) *сир.* Рәсемнәрне яки сызымнарны калькага алу

2) Чит телгә хас калып белән сүз яки гыйбарә ясау, калька ясау. --- *төрле милләт кешеләренең сәнгатьле фикерләвендәге гомумилекләр нигезендә бик күп тропларның бер телдән икенче телгә калькалаштыру юлы белән җиңел күчүен күрдек.* Р.Юсупов

**КАЛЬКУЛЯ́ТОР** *и.* 1) Калькуляция төзүче хезмәткәр

2) Катлаулы булмаган арифметик гамәлләрне башкара торган гади исәп-

ләү җайланмасы. *Солтания өстәл тартмасыннан калькулятор тартып чыгарды.* М.Маликова

**КАЛЬКУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Продукт, товар, хезмәт һ.б.ш.ларның үзкыйммәтенә һәм сату бәясенә кергән барлык элементларын исәпләү. --- *тәэминат бүлеге начальнигы виза салыр. Виза салганнан соң, бухгалтериягә кереп калькуляция ясат.* М.Юныс

2) Җитештерүгә, идарә эшенә, предприятиедәге әйләнешкә караган чыгымнарны исәпләү белән шөгыльләнә торган хуҗалык исәп-хисап тармагы

**КАЛЬКУЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Калькуляция төзү, товарның үзкыйммәтен һәм сату бәясен исәпләү

**КАЛЬМАР** *и. фр. зоол.* Башаяклы моллюсклар классының унаяклылар отрядына караган асотрядыннан, торпедасыман тар гәүдәле, кармавычлы, реактив ысул белән хәрәкәтләнә торган диңгез хайваны. *Корабль кальмар шикелле үк хәрәкәт итә, ягъни бер тишек аша су суырып, аны икенчесе аша этеп чыгара. Моның өчен корабльгә гидрореактив двигатель куела.* Кызыклы ихтиология. *Алар токымыннан бүгенге көндә кальмар һәм каракатица очрый.* А.Фаткуллин

**КАЛЬСОН** *и. ит.* Ирләрнең эчке киеме: чалбар астыннан кия торган озын балаклы ыштан. *Тагы шунысын күрәм: аягын бер-берсенә ишеп утырганга, бераз күтәрелә төшкән чалбар балагы астыннан ак кальсон очы һәм кунычы сыдырылып төшкән шакмаклы фильдеперс оекбашы күренә.* М.Әмир

**КА́ЛЬЦИЙ** *и. лат. хим. Ca* символы белән билгеләнгән, табигатьтә катнашмалар рәвешендә таралган (акбур, мәрмәр, гипс һ.б.), металлургиядә, төзелештә, медицинада кулланыла торган көмешсу ак төстәге җиңел металл. *Туфракта кальций җитешмәсә, үсемлекләрнең тамырлары авырый башлый.* Ф.Вәлитова. *Кальцийга бай азыклар нерв системасына яхшы тәэсир ясыйлар.* Совет мәктәбе

**КАЛЬЦИТ** *и. лат. хим.* Табигатьтә киң таралган, тау токымнарының зур массивларын – известьташларны тәшкил иткән, яндырганнан соң акбур бирә торган минерал. *Байкин, бер ярчыкны кулына алып, бик кызыксынып карады. – Бу аронит дигән кальцит, 700 метрда, шулаймы?* Х.Камалов

**КАЛЬЯН** *и. фар.* Тәмәке куела торган савыттан, су салынган савыт белән тоташкан төтен суыру көпшәсеннән гыйбарәт тәмәке тарту приборы; наргилә. *Көндез урамнар тып-тын, халык намаз вакытында гына кузгалып алып, башка гомерен чәй артында, ышыкта уздыра, тәмәке, кальян төтәтә.* Т.Галиуллин

**КАМ** *и. иск.* Мәҗүсилек тотучы төрки халыкларда багучылык, имчелек итүче дин әһеле, шаман. *Камның түшендә балык тешләре, тире сырмасына төрле ялтыравык ташлар таккан, сул иңендә ике елан эленеп тора, уң иңендә мәче башлы ябалак утыра.* М.Хәбибуллин. *Редактор Рәис Даутов шул тылсымны ясый белүче шаманга, камга охшашлы.* М.Юныс

**КАМА** *и.* **1.** 1) Сусарсыманнар семьялыгына караган, озын гәүдәле һәм кыска очлыклы, затлы мехлы, башлыча төче сулыкларда яшәүче хайван. *Безнең урманнардагы елга камалары балыклар белән мәче-тычкан булып уйныйлар: тотып алалар да җибәрәләр, тагын тотып алалар.* Кызыклар дөньясында

2) Шул хайванның куе коңгырт төстәге кыйммәтле күреге. *Кияүнең өстендә яшькелт тышлы, бәрән эчле тун, башында кама читле бүрек ---.* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* Шул хайванның күреләннән эшләнгән. *Аларның кама бүрек, җилән кигән ирләре дә, алтын балдаклы һәм ефәк күлмәкләргә төренгән хатыннары да, Добролюбов сүзләре белән әйткәндә, өй хайваннары булудан югары күтәрелмиләр.* М.Гафури. *Өстендә кама якалы, кара тышлы тун, аягында тезеннән югары менгән озын чуар пима.* Г.Ибраһимов

**КАМАКЫШ** *и. диал.* 1) Авыз кышлыгының өске өлеше; аңкау

2) Мич эченең түгәрәкләнеп торган өске өлеше; көймә

**КАМАЛА́У** I *ф. иск.* 1) Кама тоту

2) Кама күреге тегү

3) Кама белән тирәләү

**КАМАЛА́У** II *ф. диал. к.* **камау**. *Татар эте булса, кунак килеп кергәннән алып чыгып киткәнчегә хәтле, үз-үзен ярсытып, чәчәп, карлыгып, ябыгып беткәнче, камалый-камалый өргән булыр иде.* Р.Вәлиев

**КАМАЛУ** *ф.* **1.** 1) Төрле яклап камап алыну, камалышта калу. *Ул мескен башын түбән игән хәлдә, халык дулкыны уртасында камалып торып калды.* М.Гафури. *Ә урман кырыеннан читкә китеп, олы юлга чыкканда, без дошман пехотасы тарафыннан камалып алынган идек инде.* Г.Гобәй. *Август ахырында Казан тулысынча камалса да, каланы саклаучылар менә инде айдан артык баскынчыларга ныклы каршылык күрсәтеп киләләр.* Ф.Зариф

2) Чорналу, әйләндереп алыну, уралу. *Кояш нурына камала, Тәне янып карала.* М.Җәлил. *Ул каланың бөтен тирә-юне Камалган, ди, чуен коймага.* Ш.Маннур. *Көмеш Яр боҗра белән камалган – бер алар гаиләсе генә кара йоктырмыйча яши ала идемени?!* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ. к.* **камалыш**

**Камала бару** Торган саен ныграк камалу

**Камала төшү** Тагын да ныграк камалу

**Камалып калу** Камалган хәлдә булу. *Алар хәзер камалып калдылар.* Т.Гыйззәт

**Камалып тору** Әле, хәзерге моментта камалу

**КАМАЛЫ** *с.* Кама тотылган, кама читле. *Кыш көне бәрән эчле камалы тун, тигез түбәле, эрерәк йонлы зур каракүл бүрек, җәй көне соры полотно казаки белән шул ук тигез түбәле каракүл бүрекне кия.* Ш.Камал. --- *башында чите камалы мескен бүрек, аягында оек, чабата.* Г.Ибраһимов. *Берничә көннән соң мәчет мөтәвәллие – камалы бүрекле, кәҗә сакаллы бер карт – бу мәсьәләне авыл җыенында кузгатты.* А.Шамов

**КАМАЛЫШ** *и.* Сугышта бер шәһәрнең, территориянең яки тере көчләрнең каршы як тарафыннан уратып алынган хәле; үзенең тылыннан, төп көчләрдән аерылып, тулы изоляциядә

калуы; блокада, чолганыш. *Ленинград һаман камалышта иде әле, ялкын эчендә калган Сталинградта һәр урам, һәр йорт өчен сугыш бара иде.* Г.Гобәй. *Кырык беренче елны камалышта калган, хәзер менә партизан – взвод командиры [Шилков].* М.Хафизов

**КАМА́РИНСКИЙ** *и. рус* Шаян бию көе һәм шул көйгә биелә торган тиз ритмлы рус халык биюе. --- *кайсыберләре ду кучереп «Камаринский»га басалар.* Ш.Камал

◊ **Камаринскийга биетү** Катгый таләпләр куеп интектерү, төрле шартларга яраклашырга мәҗбүр итү. *Унике айга диеп алсак та, Сроклар килеп җитәдер, Вексель дигән хәвефле нәрсә Камаринскийга биетәдер.* Ш.Мөхәммәдев

**КАМА́У** *ф.* **1.** 1) Төрле яктан якынлашып, уратып, әйләндереп алу, һәр ягын биләү. --- *көчәеп килә торган җил ялкын баганасын Хәйриләрнең салам түбәләренә аударды да, күз ачып йомганчы аны ут камап алды.* М.Гафури. *Зиннәтне шау-шулы кызлар төркеме бөтенләй камап алды.* Г.Бәширов. *Учактан чәчрәгән очкын бөтен йортны камаган кебек, гайбәтчедән чыккан бер яла бөтен авылны камаган.* Азат хатын

2) Чигенергә, читтән ярдәм алырга мөмкинлек калдырмыйча, дошманны чолгап алу, боҗрага алу. *Поручик һәм солдатлар аларны камаган килеш торалар.* Ш.Камал. *Тик ул як-ягына карарга өлгерми калды, погонлылар аның үзен камап алдылар.* Г.Гобәй. *Үз дошманын кара көл итүче Үч ялкыны булып камый ул.* Ф.Кәрим. *Иртәгә бүреләр камарга бару турында уйларга да мөмкин түгел иде шикелле.* М.Пришвин

**2.** *и. мәгъ. к.* **камалыш**. *Монда камауда калган казанлыларның яшерен су алу урыны булган.* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

**Камап алу** Һәрьяктан тулысынча камау. *Сез Фрунзеның Врангельне, Кырымга чигенергә ирек бирмичә, Тавриядә камап алып бетерергә дигән приказын ишеттегез бит?* Г.Бәширов. *Шаяхмәтнең пулемётына ачулары кабарган немецлар, аны камап алырга теләп, төрле яктан елан кебек үрмәли башладылар.* А.Әхмәт. *Бөгелмәне камап алган дошманнар боҗрасыннан ул ничек үткәндер, анысын белмим.* Г.Әпсәләмов

**Камап килү** Әкренләп якынлашып камау. *Бәйрәмгали кул астында җибәрелгән полиция отряды Щербаково крестьяннарын камап килгән чакта, урманнан чыкканнар да, коралларын алып, үзләрен тураклаганнар.* Т.Гыйззәт

**Камап тору** 1) Әле, хәзерге вакытта камаган булу

2) Озак вакыт дәвамында камалган хәлдә тоту. *Урыслар Казанны илле ике көн камап тордылар.* М.Әмирханов

**КАМАУЛЫ** *с.* 1) Камалган, тирәсе камап алынган

2) *мат.* Икенче бер фигура эченә урнаштырылган. *Радиусы R булган түгәрәккә камаулы тигезьянлы өчпочмаклардан мәйданы иң зур булганын табарга.* Югары математика нигезләре

3) *әд.* Шигырь строфасының беренче һәм соңгы юллары ярашудан гыйбарәт (рифма төре тур.). *Фатих Кәрим, аралаш рифмаларны куллану белән бергә, югарыда китерелгән үрнәктәгечә, камаулы (охватные) рифмаларны да еш куллана.* М.Максуд

**КАМАШТЫРУ** *ф.* 1) Көчле яктылык, ачык төсләр һ.б. күзләрне чагылдыру, күзне ачып туры карарга бирмәү. *Кояшның үтә көчле нурлары Әхмәтнең күзләрен камаштыра, битләренә аз гына җылы бәрелгән төсле дә була.* Ш.Камал. *Элекке генераллар алтын ялтыравыгы белән күзне камаштыра, таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабарынган кыяфәте белән тынының куыра иде.* Г.Бәширов. *Шул беләзектән агылган нур күзләрен камаштырды да инде аның.* Ф.Латыйпов. *Кояш чыгып кына килә, тыкрыктагы бәпкә үләнендә, күзне камаштырып, чык ялтырый.* М.Маликова

2) Артык ачы ризык тешкә тию; чыелдык, кискен тавыш нервыга тию. --- *үч иткәндәй, аяк атлаган саен, тешләрне камаштырып, идән шыгырдый.* Р.Вәлиев

**Камаштыра башлау** Камаштырырга тотыну. *Ниһаять, күзне камаштыра башлаган артистлар тамашачы булып кына утырды...* Шәһри Казан

**Камаштырып алу** Беразга, бер мизгелгә камаштыру. *Карашларны камаштырып ала Көйсезләнгән төсләр уены.* Р.Аймәт

**Камаштырып бетерү** Тәмам, бик нык камаштыру

**Камаштырып килү** Күптәннән, электән үк камаштыру. --- *болары җил-яңгыр күрмичә яши бирделәр, җете төсләре белән ярты гасыр буена безнең күзне камаштырып килделәр.* Ә.Еники

**Камаштырып тору** Бертуктаусыз камаштыру. *Бүрәнәләрнең күбесе инде каезланган, алар ап-ак сөяктәй ялтырап, күзләрне камаштырып тора.* В.Имамов

**Камаштырып утыру** Әле, хәзер, күз алдында камаштыру. *Харис шул биек залларда тезелгән шома өстәлләрне, алар өстендә экраннары белән күзне камаштырып утырган мониторларны --- күз алдына китерде.* М.Маликова

**КАМАШТЫРЫРЛЫК** *с.* Камаштыра торган дәрәҗәдәге. *Мин аның уйнап торган зифалыгына, күзләрне камаштырырлык чисталыгына, кайнар яшьлегенә, тиңсез матурлыгына сокланып, онытылып калдым.* М.Әмир. *Күзләрне камаштырырлык сылу иде шул кыз бу мизгелдә, карап туйгысыз иде.* М.Хәсәнов

**КАМАШУ** *ф.* 1) Яктылыктан, нурдан, төрле төсләрдән күз чагылу, күзне ачып туры карый алмау. *Яктыга чыгып күз камашкач кына, караңгыга иярәшеп, шул хәлнең гадәтигә әйләнгәнен аңлыйсың.* Ш.Галиев

2) Ачы ашаганнан теш чагылу

3) Аяк-кул оешып, буйсынмас хәлгә килү, хәрәкәт тизлеген югалту. *Әллә мин бераз исергән, әллә аяклар камашкан, әллә нинди дулкындагы көймә өстендә барган шикелле, стеналар, идәннәр тирбәлә.* Г.Камал

**Камашып бетү** Тәмам, бик нык камашу. *Ашый-ашый тешләре камашып беткән, тел очларына төерчекләр чыккан.* Д.Аппакова. *Танца кичәсе бүген шәп булыр әле, җәй буе тик торып, аяклар камашып бетте инде.* Г.Камал

**Камашып калу** Берәр сәбәптән камашу. *Моңарчы дөньяда бары тик ак белән кара төсләр генә күрергә*

*өйрәнгән күз нурлар балкышыннан камашып кала.* Г.Афзал

**Камашып китү** Кинәт камашу. *Тартманы ачып җибәрүгә, Гүзәлнең күзләре камашып китте. Аклы, сарылы, кызыллы, әллә нинди аллы-гөлле төймәләр иде анда.* Н.Гәрәева

**Камашып тору** Билгеле вакытка камашу. *Дәрвиш белән егетнең бераз вакыт күзләре камашып тора.* Ш.Камал

**КАМӘТ** *и. гар.* 1) *иск.* Гәүдә, буйсын; буй озынлыгы. *Кайда китте бу озын, аристократический бөгеләсыгыла белә торган камәтең?* Ф.Әмирхан

2) *дини* Намазның фарызына керешү алдыннан аягүрә укыла торган махсус дога; икамәт. *[Мәхмүт:] тиз генә ваннага кереп тәһарәт алып, намазлыкка басты; башта азан, аннары камәт, аннан ниятен әйтте: – Илаһи ният кылдым ясыйгы намазымның дүрт рәкәгать фарызын үтәмәккә...* Р.Зарипов. *Шафигыйлар да камәт сүзләрен берәр генә әйтеп, күкрәк астына кулларын куялар ---.* Ш.Мәрҗани. *Балага исем кушканда, баланың бер колагына азан, икенче колагына камәт әйтелә.* Дин дәресләре

◊ **Камәт китерү** *к.* **камәт төшерү**. *Килгән сораулардан тагын берсе: «Кайбер кешеләр, камәт китергәндә, кулларын намаздагы кебек алга куеп торалар. Кирәкме бу?»* Инсан һәм дин.

**Камәт төшерү** *дини* Намазга кереш ясау. *Соңыннан Хәсән бабай торып басты. Калын, егетләрчә мөбарәк тавыш белән камәт төшерде.* Җ.Зарифоглу. *Фарыз намазларга керешер алдыннан азан әйтү вә камәт (икамәт) төшерү тиештер. Пәйгамбәребез заманында шулай намаз алдыннан азан әйткәннәр вә камәт төшергәннәр.* Дин дәресләре

**КАМБАЛА** *и. фин.* Камбалалар семьялыгына караган, Төньяк диңгезләрдә таралган, су төбендә тереклек итә торган яссы ассемметрик тәнле, күзләре тәненең бер ягында урнашкан балык төре. *Шунысы кызык, камбалалар гәүдәләренең өске өлешенең генә төсен үзгәртәләр; ә түбәнге өлеше, балыкның ятып торган түше, һаман аксыл килеш кала.* Кызыклы ихтиология

**КА́МБУЗ** *и. голл.* Суднода аш әзерләү бүлмәсе, кухня. --- *менә бит теге көнне ул ун минутка соңга калып кайтты, командир аңа җәза бирде, ул сиңа сәлам әйтте, ул бүген, бичара, шуның аркасында камбузда төне буе бәрәңге арчый, савыт-саба юа...* М.Мәһдиев. *Камбузга чәй алырга барышлый, Зәйтүнә дә кызыксынып туктаган иде.* С.Сабитов

**КАМЕ́ЛИЯ** *и. фр.* Чәйчәләр семьялыгына караган, матур чәчәкле төрләре декоратив максат белән, кайбер төрләре чәй җитештерү чималы буларак үрчетелә торган, Көнчыгыш Азиядән чыккан мәңге яшел агач яки куак. *Систематик яктан ул чәйгә якын, шуңа күрә кайбер галимнәр бу ике ыругны бер камелия ыругына берләштерә.* Л.Мәүлүдова

**КА́МЕРА** *и. лат.* 1) Төрмәдә һ.б.ш. урыннарда ирегеннән мәхрүм ителгән кешеләр өчен бүлмә. *Зиндан ишегенә каушабрак аяк атлаган Баязит электән үк инде камералар арасында стена чиертеп аңлашу, сөйләшү барлыгын ишеткән иде.* Г.Ибраһимов. *Фрунзе ике ай ярым буена үлем көтүчеләр камерасында яткан.* Г.Бәширов. *Тимер челтәрле тәрәзәдән камерага көн яктысы саркып керә иде.* Г.Әпсәләмов

2) Махсус максатлар өчен билгеләнгән бина, бүлмә. *Ул кыршылган дерматин чемоданын саклау камерасыннан алды да кырыйдагы йомшак кәнәфигә утырды.* М.Маликова

3) *тех.* Двигатель, казан һ.б.ш. прибор, агрегат, машиналар эчендә йомык пространство. *Нинди дә булса берәр сәбәп белән бердәнбер калган күкерт камерасы сафтан чыкса, заводның бөтен цехларын эштән туктату куркынычы туа.* Ш.Камал. *Шул чакта, кислород камерасына кертеп чыгардыларммыни, кинәт айнып киттем.* Б.Камалов. *Бу ысул сурәтне кояш нурлары ярдәмендә махсус камерада металл пластинкага төшерүгә нигезләнә.* Г.Милашевский

4) Көпчәк, туп кебекләрдә калынрак тышча эченә куеп һава тутырыла торган нечкәрәк резин куык, капчык. *Алгы кырыйга бик ашыгып барганда, Глубокое шәһәрендә машинабызның берьюлы ике камерасы тишелде.* А.Шамов. *Камерадан ике каеш телеп алды һәм бик шәп рогатка ясады.* А.Гыйләҗев. *Камераларның вентильләрен башка төрле бөке белән алмаштырырга рөхсәт ителми.* Тракторлар һәм автомобильләр

5) *анат.* Бер орган эчендә аерым куышлык. *Крокодилларның йөрәк карынчыгында бүлге карынчыкны ике камерага тулысынча бүлә, һәм йөрәк дүрт камералыга әйләнә.* Биология. Хайваннар

6) Фото, кино төшерү җиһазы, телевизион аппарат. *Тик аның сүзенә колак салучы булмады, чөнки өстәл тирәсендә, гыйфрит күзе кебек объективларын акайтып, телевидение камерасы шуышып йөри иде.* М.Маликова

**КА́МЕРАДАШ** *и.* Бер камерада утыручы кеше. *Камерадашларының сүзсезлеген күреп, ул: «Нигә безне монда тоталар? Ни гаебебез бар безнең?!» – дип, ишекне төя башлаган иде, таза-таза ирләр кереп, аны эләктереп алдылар.* А.Гыйләҗев

**КАМЕРГЕР** *и. нем. тар.* Патша Россиясендә, Германиядә сарай хезмәтендә булган дворяннарга бирелә торган зур дәрәҗә; шул дәрәҗәгә ия булган кеше

**КАМЕРДИ́НЕР** *и. нем.* Дворяннарның яки буржуаның көнкүрешендә хуҗаның бүлмәсендә хезмәт күрсәтүче хезмәтче ир. *Ап-ак чиста перчатка кигән ике камердинер безнең һәр тәләгебезне дәшми-тынмый гына үтәп торды.* И.Тургенев

**КАМЕРИ́СТКА** *и. ит.* Сарай, зур дворян яки буржуа йортында хуҗабикә бүлмәсендә хезмәт күрсәтә торган асрау кыз

**КАМЕРТОН** *и. нем. муз.* Уен кораларын көйләгәндә файдаланыла, каты әйбергә сукканда, билгеле югарылыктагы тавыш чыгара торган, тар дуга формасындагы корыч корал. *Тамаша залына килеп кергәндә үк, күңел кыллары режиссёр камертоны тавышына көйләнә башлый.* Р.Батулла

**КА́МЕР-ЮНКЕР** *и. нем. тар.* Кайбер монархияләрдә һәм патша Россиясендә сарайда хезмәт итүче дворяннарга бирелә торган дәрәҗәләрнең иң кечесе; шул дәрәҗәгә ия кеше

**КАМЗОЛ** *и. фр.* Урта гасыр Европа илләреннән киңрәк территорияләргә таралган, озынчарак, гадәттә җиңсез ир-ат өс киеме. *Башта озын йонлы толыбын салдыралар, анда юк. Аның астыннан яхшы тунын салдыра башлыйлар, аның эчендә бишмәт, аннары камзол, аннан да эчтәрәк җылы күлмәк була.* Г.Бәширов

**КАМЗУЛ** *и. к.* **камзол**. *Рәсемнәрнең берсендә ука чуклы асыл күлмәк вә аның өстеннән чатма камзул кигән дүрт татар хатыны төшерелгән иде.* Ф.Әмирхан. *Авылда яшьләр арасында җиңсез камзуллар, киртек якалы казакилар кию модага кереп китте.* М.Гафури. *Хәтта килен булып төшкәч тә, җиде ел килен камзулы кидереп, биатай, бианай кебек иң якыннарыбыздан да тел яшерергә киңәш бирдегез!* Т.Гыйззәт

**КАМЗУЛЛЫ** *с.* Камзулдан булган, камзул кигән. *Түбәтәйле һәм камзуллы атасы. Чигүле алъяпкычлы һәм шәльяулыклы әнкәсе.* Ә.Гаффар. *Эре чәчәкле яшел яулык бөркәнгән, кара бәрхет камзуллы, көмеш чулпылы су кызы күренмәсме?* Ф.Латыйпов. *Килбәтле вә гыйззәтле, олуг вә кодрәтле, бәрхет камзуллы, сафьян читекле Бакир улы Геннадий хәзрәтләре!* Х.Ибраһимов

**КАМЗУЛЛЫК** *и.* **1.** Камзул тегү өчен билгеләнгән материал. *Күп дип әйтергә, алар әллә нәрсә сорамыйлар: эче-тышы, әйләнәсе белән камзуллык чатма, аннан соң, хәзерге заманча булсын дип, бер озын сак.* Г.Камал. *[Галимә:] Шунда бер очтан гына Садрига да камзуллык алырсың.* М.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* Камзул тегү өчен ярарлык, шуңа җитәрлек

**КАМИКА́ДЗЕ** *и. яп.* 1) Икенче бөтендөнья сугышы елларында дошманга һөҗүм итеп, очкычы белән бергә һәлак булучы, үзен-үзе үтерүче очучы

2) Гомумән, үлемгә баручы; соңгы вакытта җәмгыятьне куркуга салу максаты белән үзенең өстенә беркетелгән бомбаны шартлатып һәлак булучы кеше. *Янә берәү үз-үзен (камикадзе диләрме әле) шартлаткан.* Р.Фәйзуллин. *Аяз күкне камикадзе айкый, американ куркып башын чайкый. Һавалардан террор исе аңкый...* Л.Шагыйрьҗан. *Нинди задание белән сине җибәргәннәр алар? Террорист итеп түгелме? Син алай-болай камикадзе түгелме?* З.Хәким

**КАМИЛ** *с. гар.* **1.** 1) Тулы, чиксез, бернәрсә белән дә чикләнмәгән. *Икесенең дә бер-берсенә мәхәббәтләре камил булып, бик тыныч, бик рәхәт көн күрә торганнар иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Большевиклар әйтә: «Һәрбер илгә Камил мохтарият бирелсен! Һәрбер ярлы, мазлум изелгән ил Мохтарият алсын, терелсен!»* Ш.Бабич

2) Кимчелексез, бар яктан да килгән, идеаль. *Ул хәзер камил егет булып, ир булып үсеп җиткән инде.* Г.Ибраһимов. *Адәм балалары камил түгел, Хата йорты дөнья электән.* Ф.Бурнаш. --- *[Кызның] буе-сыны да, гәүдәсе дә, төсе-бите дә – бар җире дә камил.* Н.Фәттах. *Мәкалә чиктән тыш камил, искиткеч уңышлы булу сәбәпле, мин андый гына ялгышлыкларны күрмәскә тырыштым.* М.Юныс

3) *иск.* Туры итеп тоташтан бәйләнгән, бөтен, кыекча булмаган. --- *[Җәннәтнең] башында энҗеле калфак, ак камил шәл.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тулысынча, бөтенләй. *Бу кырык биш тиен акча Шәрифнең ихтыяҗына камил җиткән.* М.Гафури

2) Бик әйбәт итеп, җиренә җиткереп. *Музыка әсәрен камил башкару*

**КАМИЛӘН** *рәв. иск. к.* **камил 2.** *Бу районнарда камилән татар тормышыннан алынган типлар бер-икене истисна белән юк дияргә мөмкиндер.* Ф.Әмирхан. *Ләкин каршыларында 20 ел тәрбияләнгән бер карт белән бер карчыкка аңлатудан камилән гаҗиз икәнлегебезне уйлап карамыйбыз.* Ф.Әмирхан

**КАМИЛЛӘНҮ** *ф. к.* **камилләшү**

**КАМИЛЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Яхшырту, әйбәтләү. *Шәһәр һөнәрчеләре, үз белгечлекләре белән генә шөгыльләнеп, осталыкларын камилләштерә, эш коралларын һәм алымнарын яхшырталар.* Урта гасырлар тарихы

2) Төгәл, бөтен, идеаль хәлгә китерү

**Камилләштерә төшү** Бераз камилләштерү; тагын да камилрәк итү

**Камилләштереп бетерү** Һәрьяклап камилләштерү; тулысынча камиллек дәрәҗәсенә җиткерү. *Польшадагы «гравёрлар»га Франклин сурәте төшерелгән үз долларларын тулысынча камилләштереп бетерергә ярты ел вакыт җитми кала.* Р.Мирхәйдәров

**Камилләштереп җибәрү** Камилләшүгә этәргеч булу; тагын да камилрәк итү. *Ул, гүзәл архитектура истәлеге буларак, Ирек мәйданының ансамблен тагын да баетып, камилләштереп җибәрде.* М.Шиһапов

**Камилләштереп җиткерү** Камил итү

**Камилләштереп килү** Күптәннән бирле, даими рәвештә камилләштерү. *Шуңа өстәп, редакторлык эшендә озак еллар тел, фикер йөртү алымнарын аңлау сәләтен туктаусыз камилләштереп килгән әдәбиятчы [Р.Даутов].* М.Юныс

**Камилләштереп тору** Һәрвакыт, гел, бертуктаусыз камилләштерү. *Житештерү мөнәсәбәтләрен һәрвакыт камилләштереп тору сорала.* К.Гыйззәтов

**КАМИЛЛӘШҮ** *ф.* Яхшыру, әйбәтләнү; камил хәлгә килү. *Менә бу минутта, куе таллар арасындагы кыз сынын күргәч, аннан агылган, күзгә күренмичә тәнгә, күңелгә турыдан-туры килеп ирешә торган нурны тойгач, дөнья камилләште, түгәрәкләнде.* М.Маликова. *Камилләшкән җөмлә тойгыларны җанландыра, көчәеп киткән фикерне акыл рәхәтләнеп кабул итә.* М.Юныс

**Камилләшә бару** Торган саен күбрәк камилләшү. *Билгеле инде, Рабига остазбикәнең белеме акрынлап арта, караш даирәсе киңәя, укыту ысуллары камилләшә барган.* И.Нуруллин

**Камилләшә башлау** Камилләшү билгеләре күренү. *Берләштерү «җиле» кагылгач, ул Иске Шөгер мәктәбе белән кушылып, татар теле һәм әдәбиятын укыту ягыннан да камилләшә башлады.* Заман сулышы

**Камилләшә төшү** Тагын да камилләшү, бераз камилләшү. --- *М.Хәбибуллинның «Атилла» романы – бүгенге татар тарихи әдәбиятының зур казанышы. Күрсәтеп үтелгән аерым*

*кимчелекләрдән арынганда, ул тагын да камилләшә төшәчәк.* Ф.Урманче

**Камилләшеп җитү** Камиллек дәрәҗәсенә ирешү

**КАМИЛЛЕК** *и.* Кимчелексез булу хәле, бар яктан да камил булу күренеше; идеал. *Форма белән эчтәлек бердәмлеге ракета сыман. Формасы – камил гадилек, эчтәлеге – гади камиллек.* Ш.Галиев. *Соңгы елларда кешеләрнең бихисап явызлыклар кылуы, пычрак уйлар, шөгыльләр белән мавыгуы күз алдында бит. Болар һәммәсе галәмнең камиллеген боза, анда төрле гайре табигый үзгәрешләр тууга китерә.* М.Маликова. *--- бар әсәрләрне дә югары үсеш баскычында тора дип булмый. Ә телгә керү-кермәүгә килсәк, бу фактор әсәрнең сәнгатьчә камиллегенә генә бәйле түгел.* Казан утлары

**КАМИЛСЕЗЛЕК** *и.* 1) Җитешсезлек, кимчелек

2) Нәрсәнеңдер идеаль булмавы, кимчелекле, хаталы булу күренеше. *Бәндәң генә микән, белмим, Ходай, Камилсезлек Җирдә бик күп бугай?* Ә.Синугыл-Куганаклы

**КАМКА** I *и.* Камкалар семьялыгыннан, төрле төстәге өске каты канатларына кара тørткеләр төшкән бөҗәк; *русчасы*: **божья коровка**. *Жанның кул сыртына яшел камзулында кара тørткеләре булган түгәрәк камка төшеп кунды һәм, канат сүрүен дә җыймыйча, әрле-бирле йөренә башлады.* Ш.Рәкыйпов. *Камка, үсемлек корткычларының: үлән бете, ак күбәләк, ефәк талпанының личинкаларын да, олы бөҗәкләрен дә ашап, кеше хуҗалыгына ярдәм итә.* Биология. Хайваннар

**КАМКА** II *и. кыт.* **1.** Кытай ефәге. *Торга булсын бу җирдән-әй! Камка булсын бу җирдән-әй!* Дастан. *Камка сүзе борынгылыктан ук рус теленә кергән. Рус телендә бу камка – «бизәкле тукыма» сүзеннән камчатый дигән сыйфат ясалган ---.* Ә.Кәримуллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, шуның белән тышланган, бизәлгән һ.б.ш. *Өстеңдәге камка тун – Түрдә утырган биләргә.* Дастан. *– Әни, әни, – диде Әхмәт, – бая гына мин камка бизәк тоткан идем.* Г.Әпсәләмов

**КАМКАЛАР** *и. күпл. зоол.* Кабарынкы гәүдәле, канатлары җете төсле һәм гадәттә тøрткеле, үсемлек бетләре, вак бөҗәкләр белән туклана торган вак ерткыч коңгызлар семьялыгы. *Кыяфәтләре белән бик матур һәм тыйнак күренсәләр дә, камкалар – ерткычлар.* Ф.Ибраһимова

**КАМЛА́У** *ф.* Төрле сүз, тавыш, кыланыш, магик предмет һ.б.ш. ярдәмендә кешегә яки берәр объектка кирәкле йогынты ясарга омтылу, ырымлау, имләү. *– Камла әйдә, шаман, камла тизрәк! – диде башлык.* Р.Батулла

**Камлап карау** Камларга омтылу, камларга тырышу. *Көннәрдән бер көнне Майя Хәлимгә әйтеп куйды: – Сания әнкәнең күзләрен үзем камлап карыйм әле. Мин моның серен беләм.* Г.Гыйльманов

**КАМПА́НИЯ** *и. фр.* 1) *хәрби* Билгеле вакытта билгеле кирлектә алып барылган, бер стратегик максатка буйсынган сугышчан хәрәкәтләрнең барлыгы. *Финляндия кампаниясенә катнашкан сугышчылар бу кышны яхшы беләләр.* Г.Әпсәләмов. *Менә минем әти дә фин кампаниясендә башын куйды.* Х.Камалов

2) Берәр мөһим иҗтимагый-сәяси яки хуҗалык мәсьәләсен хәл итүгә юнәлгән чараларның барлыгы. *Сайлау кампаниясенә йомгак ясаган чакта, Якуб: – Бу – зур җиңү, иптәшләр, – диде.* И.Гази. *Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты шушы елның октябрь аенда үткәрелергә тиешле Бөтенроссия халык санын алу кампаниясе өчен халыклар исемлеге төзегән.* И.Таһиров. *Бишьеллык планнар нигездә үтәлмәде, шау-шулы, мактанулы кампанияләргә генә әверелде.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**КАМПА́НИЯЧЕЛ** *с.* **1.** Кампания төсендә, эзлексез һәм системасыз, әллә нигә бер генә үткәрелә торган. *Шунлыктан акыллы тәкъдимнәр кампаниячел күренеш булудан ары китә алмый.* Шәһри Казан. *Дәүләтнең гаиләне кайгыртуы бары тик Гаилә көне, Гаилә елы үткәрү кебек кампаниячел чара булудан туктап, төп бурычка әверелсен иде.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Кампания рәвешендә

**КАМПА́НИЯЧЕЛЕК** *и.* Плансызлык, системасызлык; кампанияләр белән мавыгу, ашык-пошык эшләү. *Бәла дә шунда, бу халыкчанлыкның бездә үзенчәлекләре өйрәнелмәгән һәм бу арындырулар да мәкальнең үзенә, үзлегенә таянып эшләнмичә, бәлки кампаниячелек һәм вульгар-социологиячелек күзлегеннән югартын торып кына эшләнгән эшләр булуында.* Н.Исәнбәт

**КАМСА** *и. гр. зоол.* Сельдь балыклары семьялыгына керә торган вак диңгез балыгы; хамса. *Балык дигәч тә, Каспий камсасы белән Балтыйк килькиен ашап утырмый инде.* А.Гыйләҗев. *Синең апаң Привозда камса сата.* М.Юныс

**КАМУС** I *и. гар. иск.* Сүзлек. *Каюм Насыйри татар теленең имля һәм инша кагыйдәләрен төзегән, татар теленең лөгатьләрен җыеп, үзенә күрә бер камус мәйданга китергән.* Җ.Вәлиди. *Тел – океан ул. Шуңадыр гарәпләр сүзлекне дә әл-камус (океан) диләр.* Х.Сарьян. *Тукайның «Яңа камустан берничә лөгать» памфлетының дәвамы «Җен» имзасы белән басылган.* Казан утлары

**КАМУС** II *и. диал. этн.* Болан тиресеннән тегелә торган аяк киеме. *Өстенә башлыклы болан туны, аягына камус кигән каюр килеп керде.* Казан утлары

**КАМУФЛЕТ** *и. фр. махс.* Снаряд яки минаның, чокыр ясамыйча, җир астында шартлавы

**КАМУФЛЯЖ** *и. фр. махс.* **1.** Биналар, корабльләр, туплар, машиналар һ.б.ш.ны төрле сызыклар, таплар төшереп маскировка ясауның бер ысулы. *Сорымы яки карамы икәне дә бәхәсле, кыскасы, төрле төс – камуфляж.* Х.Мөҗәй. *Аның як-ягында камуфляж формасы кигән ике әзмәвер басып тора иде.* Я.Шәфыйков

**2.** *с. мәгъ.* Шундый ысул белән яки шуңа охшатып төшерелгән, ясалган. *«Даным» бик тиз пароходка таралды. Өстемдәге фронт истәлеге – камуфляж бизәкле ала-кола тужуркам да реклама хезмәтен үтәде.* С.Баттал

**КАМУФЛЯЖЛЫ** *с.* Камуфляж ысулы белән маскировкаланган, чуарланган; төрле төсләр, билгеләр

төшерелгән. *Камуфляжлы плащ-палаткаларыннан корылган чуар чаршау ачылып китте.* Ш.Маннур

**КАМФАРА** *и. гр. мед.* 1) Медицинада һәм техникада кулланыла торган көчле зәһәр исле, төссез кристаллик матдә. *50 грамм коры камфара порошогы (даруханәдә сатыла), горчица, спирт, 3 йомырка агыннан дару ясыйлар.* Ватаным Татарстан

2) Шуннан ясалган сыек дару. *[Әгъләм] озак тормый янә һушыннан язды: аңа камфара уколы биреп тордылар.* С.Рафиков. *[Дәүранны] Урынына салыгыз! Камфара бирегез, камфара!* Т.Гыйззәт. *Әнис маең бармы, камфара, канәфер майларымы, ванилин яки валерианка – барын да сал, хәзинәңдә булмаса, тап!* М.Әмир

**КАМЧАДАЛ** *и. рус* Күптәннән Камчаткада яшәгән русларның ительмен, коряк, чуван кебек җирле халыклар белән аралашу тәэсирендә формалашкан этник төркеменең бер вәкиле. *Гимнастёркалары тозланып чыккан солдатлар, причал докерлары, брезент алъяпкычлар киеп алган балык комбинаты эшчеләре, чаналарының табаннарына күн кидереп, этләр җигеп килгән камчадаллар, шәфкать туташлары курсларына укырга йөрүче яшь-җилкенчәк... Барысы да, артларына ут капкан шикелле ашыга-ашыга, кораб бушаталар.* В.Имамов

**КАМЧАТ** *и. рус* **1.** 1) Сусарлар семьялыгыннан затлы мехлы су җәнлеге; диңгез коңгызы, калан. *Камчат күрсәң атып ал, мәкаль сүзне отып кал!* Мәкаль

2) Шул җәнлекнең мехы. *Казанның Проломный, 13 урамындагы зур магазин хуҗасы Газиев Сәгъди белән шул ук Казанда җиде-сигез кеше яллап тегү тектерүче, камчат һәм кама мехлар белән сату итүче --- «Әсәт Валлаһи тегүче» дип вывескалар куйдырган Әсәдулла агай да --- кайтып җиттеләр.* Г.Камал

3) *тар.* Тыгыз һәм шома итеп тукылган, гадәттә бер төстәге бизәкләр сугып эшләнгән тукыма

**2.** 1) *с. мәгъ.* Шул мехтан тегелгән. *Саҗидәнең камчат бүрке – Күз өстендә күләгә; Монда уйнаган монда калсын, Анда кайтып сөйләмә.* Җыр. *Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ирегет чагында, камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән сөлектәй яшь айгырга атланып далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп һәм ун-унбиш чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде.* Ә.Еники

2) Шул тукымадан тегелгән. *Камчат шәл*

**КАМЧАТЧЫ** *и.* 1) Камчат бүрек тегүче. *Аның (Галиәсгарның) әтисен Камчатчы Галиәкбәр дип йөртәләр.* М.Гали. *Элек Казанның Яңа бистәсендә ике мәшһүр кеше яшәгән, ди. Аларның берсе – Кара Савыт Шаһи, икенчесе – Камчатчы, ягъни бүрек тегүче Галиәкбәр Камалетдин углы.* Р.Батулла

2) Камчат бүрекләр белән сәүдә итүче. *Мәсәлән, «Бәянелхак» газетасының 1907 елгы 20 май санында «Т.З.» имзасы белән басылган хатта: «...Бәнем төшкән җирем камчатчы Гыйззәтуллада иде ---».* Г.Тукай. *Минем әти белән Кариев заманында артист булып озак вакытлар уйнап йөргән кешеләрдән Ишми дигән артистның атасы Кара Савыт Шаһи дигән кеше хакында: – Кара Савыт Шаһига хатын ярамый, камчатчы Галиәкбәргә фатир ярамый, – дип шаяртып сөйли торган булган.* Г.Камал

**КАМЧЫ** *и.* 1) Каеш яки баудан үреп, ишеп ясалган кыска саплы чыбыркы. *Аларның кигән киеме – киң эшләпә, киң каеш, җитеннән тукылган джинсы чалбар-күлмәк, янда пистолет, кулда озын камчы...* А.Хәлим. *Иренеп кенә кайтыр юлга борылган Сәлимханның бәләкәй чакта атай каешы төшкәли торган урынын камчы кылы суеп үтте...* К.Кәримов. *Николай авызын ачарга да өлгермәде, поручик атларны камчы белән сызгыртып алды да, алар урыннан капыл гына кузгалып, экипаж китеп тә барды.* Ә.Мушинский

2) Шундый чыбыркы белән сuктырудан гыйбарәт җәза бирү төре. *[Әмирхан:] Яшьрәк чакта камчы эләкмәсә, юк инде ул!* А.Гыйләҗев. *Качучыларга 25 әр камчы билгеләнде.* Казан утлары

3) *эфв.* Елан. *Елан димә – чага, камчы дисәң – кача.* Әйтем. *Татар халкында да яшерен телнең кайбер үрнәкләре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Мәсәлән, еланны – кара таяк, камчы, каеш; аюны олы ата, олы әкә, көрән дип атаулар ---.* Ф.Урманчеев

4) *күч.* Кыенлык, авырлык, газап. *Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы ---.* Г.Тукай. *Кыскасы, ул вафасыз дөньяда җил-яңгыр тимичә, мәрхәмәтсез урам тормышының камчысын да, тукмакларын да күрмичә, тәмсез сүзләрен ишетмичә, җылы оранжереяда, чәнечкесез гөлчәчәкләр һәм купшы пионнар арасында үскән самими һәм тыйнак малай иде.* А.Тимергалин

◊ **Камчы алу** 1) Кыйналу, камчы җәзасы алу; 2) Рәнҗетелү, авырлык күрү. *Ләкин дөресен язу ул – хаким көчләрнең гаебен ачу дигән сүз. Чөнки «түзалмаслык йөрәк янса» да, сереңне язма рәвештә сөйләсәң, һәр хәрефе саен бер камчы алачаксың.* Татар әдәбияты. **Камчы асты** Җәберләүләрдән гыйбарәт михнәтле тормыш. **Камчы ашау** *к.* **камчы алу**. **Камчы тамызу** Камчы белән сугу. *Берсе хәтта, явызлыгын тыя алмыйча, аркасына ике-өч тапкыр камчы тамызды.* Б.Рафиков

**КАМЧЫЛА́У** *ф.* 1) Атларны камчы белән сугып куу. *Шәехгали атын кара күбеккә батырганчы камчылады.* М.Әмирханов. *Як-яктан камчылап, туп-туры текә ярга таба кудылар [атларны].* Т.Нәбиуллин

2) Сuктыру, камчы белән җәзалау. *Берничә кешене, аяк-кулларын богаулап, ат арбаларына бәйлиләр. Калганнарны, көтү куган кебек камчылап, урман аркылы чиркәүгә алып китәләр.* Т.Вафин. *Дөрес, алар (һуннар) эштән тайпылырга маташучыларны камчылау белән генә шөгыльләнмәде, төзелештә дә катнашты, сунарчылык һәм балык тотуны оештыруны үз өсләренә алды.* Б.Рафиков

3) *күч.* Куалау, ашыктыру, кызылату; тиз һәм күп эшләргә мәҗбүр итү.

*«Жигули»не камчылаганымны килештереп, спидометр шаян күз кыса, я туксанны, я йөзне үк күрсәтә.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Тәнкыйтьләү. *Аларны беренчеләрдән булып, К.Тинчурин һәм Ф.Бурнашлар белән янәшә торып, Н.Исәнбәт тә күреп алды, камчылады.* А.Әхмәдуллин. *Ә җәйләрен колхозның да, бригаданың да «Сугышчан сәхифә»ләре минем карамакта: алдынгыларны мактыйм, ялкауларны камчылыйм.* Ә.Рәшит. *Алда безне күләм ягыннан кыска шигырьләр, дүртьюллыклар, эпиграммалар каршылый. Аларда шагыйрь кешедәге әхлакый кимчелекләрне камчылый.* Казан утлары

5) *күч.* Арышлар өлгергәндә, офыкта яшен яшьнәү, елдырым уйнау, аҗаган уйнау. *И яшеннәр камчылады, телгәләде...* Р.Зәйдулла. *Фронт сызыгы өстендә, камчылау утлары сыман, ракеталар күтәрелә.* Г.Әпсәләмов

**Камчылап алу** Аз гына, тиз арада камчылау. *Әйтерсең лә яр өсте басуының арышы серкә очырганда уйнаклап, яшен камчылап алган да, таш чартлап ярылган, шул кысанлыкта җир кочагына посып сәфәр чыккан әрсез орлык шыткан ---.* М.Рәфыйков. *Ул да булмады, бөтен күк йөзен иңләгән болытларның ишелеп-кайнап торган урынын кискәләп, ботлы-чатлы, берничә җәпле яшен камчылап алды.* М.Хәсәнов

**Камчылап тору** Туктаусыз камчылау; әледән-әле камчылау. *Алар бетсә, кем ярсытып торыр, Кем камчылап торыр йөрәкне!* Ф.Яруллин. *Язучы үзен гел камчылап торырга тиеш.* Т.Миңнуллин

**Камчылый башлау** Камчыларга тотыну. *Соңгы һәр хатында Рәхилә дә камчылый башлады, Рамазанның котын алды.* Ш.Янбаев

**Камчылый бирү** Камчылавын дәвам итү. *Ногайбәк ага да токмачларны чынлап торып куертмаска булды бит. Дүрт тәгәрмәчле айгырын камчылый гына бирә.* А.Хәсәнов

**КАМЫЛ** *и. а.х.* 1) Өлгергән ашлыкның көпшәсе, сабагы. *Аннары коры камылдан учак тергезеп җибәрәләр, бодайлы табаны ут өстенә куялар.* Р.Фәизов. *Офыкларга тиклем җәелгән камыл нурыннан күз алды яктырып китте.* К.Кәримов. *Юл читләре әрем-кура, апайлар урак ура. Һәр кич саен сыер эзлим, камыллар ера-ера...* Р.Әхмәтҗан

2) Игеннәрне урып җыйганнан соң, тамыр өстендә калган сабак төбе. *--- урылган игеннең камыллары сапсары булып ялтырап ята, сөрелгән җирләр Габделнурлар авылындагы кебек чем-кара түгел түгелен, шулай да киләсе елга муллык вәгъдә итеп күпергәннәр.* Р.Кәрами. *Яланаякка камыллар кадала, карамыйрак атласаң, күзлутның зәһәр инәләре авырттырып чәнчеп кала.* Г.Бәширов. *Алар артыннан, камыл арасында саескан кебек сикерә-сикерә башак җыеп, балалар килә.* Л.Ихсанова

3) Үлән сабагы. *Урган камылдан су чыкса, яңгыр явар.* Сынамыш. *Шәһәрдә кар югалды. Көздән тырмаланмыйча калган сарут камыллары шакыраеп кипкәч, тротуар читләреннән тузан исе күтәрелде.* К.Кәримов

**КАМЫЛЛЫ** *с.* Камыл белән капланган. *Камыллы басу уртасыннан сузылган аксыл юлдагы бу тузан Ленарны да, аның мотоциклын да күмгән иде.* М.Мәһдиев. *Очтың камыллы кырлар аша, Үзең дә камыл төсендә – күренмисең дә!..* Р.Әхмәтҗан. *Камыллы кырны тансыклап Кызды аяк табаны.* М.Галиев

**КАМЫР** *и. гар.* 1) Ипи һәм төрле ризыклар пешерү өчен, онны су, сөт, йомырка һ.б. белән катнаштырып изүдән барлыкка килгән куе масса. *Гадәттә күәсне юып тормыйлар, өстәвенә, ипи салу өчен баш ясарга дип, бер тотам әче камырын да калдыралар.* Г.Галиева. *Ул үзен куна тактадагы төче камыр кебек хис итте.* Н.Гыйматдинова. *Анналары әбисе ипи я көлчә пешергәндә, камырдан вак-төяк фигуралар ясап, шуларны кызган кирпечкә тезәп пешереп ашарга ярата...* Т.Нәҗмиев

2) *күч.* Йомшак, җебегән кеше. *Дөнья авыр, Булсаң камыр... Йөрәгеңне Сагыш сарыр, Булсаң да син Артык сабыр.* Р.Мөхияр

◊ **Камыр батыр** 1) Камырдан әвәләп ясалган бала сыныннан яралган көчле, куәтле әкият герое; батырлыгы җитмәгән кешегә карата мыскыллап әйтелә. *[Дәрига:] Синнән башкалар дәшми утырганнардыр әле? Бу каян килгән Камыр Батыр!* Т.Миңнуллин. – *Сезнең кебек камыр батырлардан да куркып торсам! – дип җикеренде Минвәли егетләргә.* Ватаным Татарстан. **Камыр булу** Хәлсезләнү, буыннар йомшау. *(Хәмдия абыстай) Чирнең имен табып, оста табибә була. Чувашлардан көмешкә, дуңгыз мае барып ала да шуларны Галимҗанның бөтен әгъзаларына камыр булу дәрәҗәсенә җиткереп сылый.* С.Поварисов. **Камырга әйләнү** *к.* **камыр булу**. *Ике багана арасы да үтмәстән салкын тиргә батты, сулышы капты, буыннары камырга әйләнде.* М.Кәбиров. *Ашаган бәлешем корсактан төшеп беткәнче ярдан сикердем, беләкләр камырга әйләнгәнче агымга каршы йөзеп, тын куырылганчы тирәнгә чумып су коендым.* Ф.Яруллин

**КАМЫ́Р АГАЧЫ** *и. бот.* Розачәчәклеләр семьялыгыннан агач яки куак рәвешендә үсә торган чәнечкеле үсемлек; дуләнә, бөгән; *русчасы*: **боярышник**. *Ялтырап торган чуерташ җәелгән киң сукмак кырыйларында – зәңгәр чыршылар, ихатаны әйләндереп алган, өсте киртле кирпеч стена буйларында алмагач, камыр агачы, миләш, каен үсә.* М.Маликова

**КАМЫ́Р БАШЫ** *и.* Таба ашлары пешергәндә камырны ачыту өчен махсус бүлеп калдырылган яисә суга чүпрә салып, он туглап ясалган ачыткы. *Беләм бит, арыш тартылса, әни ипи салачак, камыр башыннан гына бәрәңге пәрәмәче дә әмәлләми калмас.* Ә.Хәсәнов

**КАМЫ́Р ҖИМЕШЕ** *и. бот. диал.* 1) Камыр агачының җимеше, дуләнә. *Камыр җимешенә спирт кушылган төнәтмәне медицинада кулланалар.* Кызыл таң

2) Гөлҗимеш. *Чикләвек, камыр җимеше ашап йөргән җиреннән, аны фин чик сакчылары тотып алалар.* З.Мәхмүди

**КАМЫРЛЫ** *с.* Камырга буялган

◊ **Камырлы кул** Камыр ризыкларын оста пешерүче кеше. *Хислимәне ашханәгә повар ярдәмчесе итеп алдылар,*

*нәселләре камырлы кул аларның.* К.Кәримов

**КАМЫРЛЫК** *и.* Камыр агачы, дүләнә. *Күл тирәли – камыш, елга-инеш буйларында – тал, әрәмә, камырлык, гөлҗимеш, шомырт куаклары.* В.Имамов. *Ничек итеп камырлык чәнечкеләренә кадала-кадала куактан төшүләрен дә, бакча артындагы биек койма аша сикереп чыгуларын да сизми калды малайлар.* А.Габделхакова. *Шомырт, балан, карама, тал, камырлык куакларының ялтыравыклы яшел яфраклары арасына яшеренгән мең төрле кошларның мең төрле җырлары сузып-сузып та, чут-чут итеп тә, алсу таң нурларына кушылып, бөтен һавага тарала ---.* Ф.Садриев

**КАМЫРЛАНУ** *ф.* Камырга буялу. *Галия камырланган куллары белән тиз-тиз телефон төймәләренә басты, кабаланып кирәкле номерны эзли башлады.* Мәдәни җомга

**Камырланып бетү** Бик нык камырга буялу. *Әнисә телефон янына йөгереп килсә дә, камырланып беткән куллары белән трубканы алмаска булды.* Казан утлары

**КАМЫТ** *и.* 1) Җигү дирбиясенең ат муенына кидерелә торган әйбере. *Озын яллы сары ат җиз кыңгыраулы кара дуга һәм эшлияле камыт белән читән тарантаска җигелгән.* Ә.Еники. *Курку һәм ашыгу аркасында каушап, кемнәрдер камытларын ат муенына тискәре ягы белән кидерде, чөелдереген кыса алмый интекте.* Н.Әхмәдиев. *Камыт агачы шыгырдый, мичкәдә су чайпала, арба ераклаша, әмма Сафый абзый бәхетле.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Күп көч, энергия сарыф итүне сорый торган берәр эш, мәшәкать, вазифа һ.б. *Хәтта арттырып җибәргән чаклары да булды: «камыт»ның олысын киярга, «бүрәнә»нең авыр башын күтәрергә тырышты [Габделнур].* Р.Кәрами. *Дөнья – камыт, Туу белән киясең дә – Булмый кабат салып.* Ф.Яруллин. *Колхоз рәисе камытын киеп җигелеп тартучы Мидхәт Хәсьянов хәзер шулай уйлый.* Н.Әхмәдиев

◊ **Камыт аяк** Кәкре аяклы кеше турында. *[Бөек княгиня:] Ул камыт аякның Мәскәүгә мондый ультиматум куярга хакы юк, аңлыйсыңмы, дундук, хакы юк!* М.Әмирханов. *Якты дөньяга чыгу белән, коткаручысының муенына менеп атлана да аны интектерә башлый әлеге «камыт аяк».* М.Вәлиев.

**Камыт аяклы** Кәкре аяклы. *Сабый! Юктыр, юктыр, ничек инде шундый гүзәл сабый кыек тешле, саргылт йонлач яңаклы, камыт аяклы Фәхразый кызы булсын.* М.Мәһдиев. **Камыт кию** 1) Авыр эшкә алыну, үз өстенә җаваплылык алу. *Миңа монда редакциянең кара эшләрен бик зур камыт киеп алып барырга туры килә.* А.Шамов. *Хәзер инде, яшь чактагыча, муенга кырык төрле хезмәт камыты киясе юк.* С.Поварисов; 2) Гаилә кору, өйләнү. *Ә син гаилә баткаклыгына кереп чумарга, камыт кияргә атлыгып торасың!..* З.Хөснияр. *Классташлары кайсы кая укырга кереп, эшкә урнашып, армиягә китеп ыгы-зыгы килгән арада, ул унсигез яше тулган сөенечтән миңа – сөйгән егетенә вәгъдә биргән килеш башка берәү кулыннан нужа камыты киеп өлгергән...* К.Кәримов

**КАМЫ́Т ЭНӘСЕ** *и.* Күн һәм калын тупас тукымалар тегү өчен кулланыла торган махсус зур энә. *Аркасына камыт энәсе кадалгандай, әллә Нурсөянең, әллә Ильясның үзенә төбәлгән авыр карашын тоеп ятты.* Р.Мулланурова

**КАМЫ́Т БАВЫ** *и.* Камытка тәртә һәм дуганы беркетеп кую өчен хезмәт итә торган күн элмәк; *русчасы*: **гуж**. *Атаң тырыш булса, камыт бавың каеш булыр.* Мәкаль. *Мөнирҗан Күк бияне туктатып, түшлеген тарттырып бәйләде, камыт бауларына күз төшерде.* Н.Әхмәдиев. *Атны рәхәтләнеп мин җигәм. Камыт бавын тартырга гына көчем җитми.* А.Хәсәнов. *Камыт бавы, су астында калып, инде шактый бүртергә дә өлгергән.* Ж.Дәрзаман

**КАМЫТ-ДИРБИЯ** *җый. и.* Ат җигү кирәк-яраклары. *Әмир аңа Яков биргән иске камыт-дирбияне кидерә башладымы, сыртына иң зәһәр кигәвеннәр болыты килеп ябырылган диярсең, бер урында тик кенә тора алмый, Афоня шундук быжгып уйнакларга тотына.* В.Имамов. --- *Печән базары, шундагы дегет, сары каеш һәм яңа камыт-дирбия исләре, хәтта шкафчы Мөхәммәтҗанның тәмләп сүгенгәннән соң үзенә-үзе сокланып, кулларын уа-уа кет-кет көлүләре дә хәтердә яңарды.* А.Тимергалин

**КАМЫ́Т СУГУ** *ф.* 1) Ат муенын камыт белән кырдырып чиләндерү. *Элегрәк карамыйча, атына камыт, ыңгырчак суктырган адәмнәр була иде. Шундыйлар --- үзгәрмәде. Карарга иренеп, машина, механизмнарны җимертә башлады. Атка камыт суктырып, муенын чиләндергән шикелле...* Х.Камалов

2) *күч.* Бер эшне эшли башлаганнан соң киреләнеп, авырсынып ташлап китү, чыгымлау

**КАМЫ́Т ТИЮ** *к.* **камыт сугу**

**КАМЫТ-ЫҢГЫРЧАК** *җый. и. к.* **камыр-дирбия**. *Нәсел айгыры тәмам картайгач, инде алашага әйләнделеп үз үлеме белән үлгәннән соң, аның алаптай камыт-ыңгырчаклары бүтән бер атка да ярамый, һәм Маликов аларны музейга дип сорап ала.* А.Тимергалин. *Алар камыт-ыңгырчакларын, ашамлык салынган төенчекләрен алдылар да якындагы бер йорт ишегенә карап китеп бардылар.* Н.Фәттах

**КАМЫТЛАНУ** *ф.* Камытка охшау, камыт рәвешен алып кәкрәю. *[Өлфәтнең] ачуы килә башлады: әкертен Гамилгә, эчен авырттырган җимеш суына, Мәмдүдә абыстайның чак кына камытланып торган кызыл читекләренә.* А.Тимергалин

**Камытлана бару** Торган саен ныграк камытлану; кәкрәя төшү

**Камытланып калу** Камыт рәвешенә керү; камытланган хәлгә килү

**Камытланып килү** *к.* **камытлана бару**

**Камытланып тору** Камытланган хәлдә булу; һәрвакыт камыт кебек булу. *Бирсә бирә бит Ходай адәм баласына үз һөнәренә килешеп торган гәүдәне һәм шул гәүдәнең бу дөньяга тикмәгә генә килмәгәнлеген раслап торган җиңел дә, төгәл дә хәрәкәтләрне, камытланыбрак торган аякларны!* Ф.Баттал

**КАМЫТЛА́У** *ф.* Камыт кидерү. *Мине җөгәнләгәннәр, җаныма ыңгыр-*

*чак аша аркалык-түшлек үткәргәннәр, камытлап, чөелдерекләп...* Ә.Гаффар. *Әллә юкса ул [дөнья] кудымы мине, Нык камытлап, кысып йөгәнләп ---.* Ә.Хәсәнов

**Камытлап алу** Тиз арада камытлау. *Атны камытлап алу*

**Камытлап кую** Камытлап, әзер хәлгә китерү. *Моның белән мине «камытлап» куймакчы буласыңмы?* Н.Хәсәнов

**Камытлап тору** Әле, хәзер камытлау. *Гали атын камытлап тора иде*

**КАМЫТЛЫ** *с.* 1) Камытланган, камыт кидерелгән

2) Ат көче кулланылган. --- *Дворяннар җыенының тәбәнәк йорты, альъяпкычлы, сакаллы ямщиклары белән бетмәс-төкәнмәс «барабыз» рәтләре һәм күпере буенча элеккеге камытлы Россиянең сафка тезелгән солдатлар строе аркылы үзләре сайлаган юлга – каторгага озатканда иң яхшы уллары һәм кызлары узган атаклы Себер заставасы...* Ә.Мушинский

**КАМЫТЧЫ** *и.* Камыт ясаучы; камыт ясаучы оста. *Үзем авыруым, картлыгым сәбәпле, гариза белән җитәкчеләргә танылган камытчы йортын саклыйк, Казан атларын караучылар музее итик дип мөрәҗәгать итә алмадым.* С.Галиева. *Авылда көмешче, сәгатьче, пыялачы, камытчы, столяр һәм балта осталары шикелле һөнәр ияләре дә бар.* Гасырлар авазы

**КАМЫТ-ЭШЛИЯ** *җый. и. к.* **камыт-дирбия**. *Бу өйнең эчендә табак-савыт, кашык-чүмеч, камыт-эшлия кеби нәрсәләр генә булып, җиһазфәлән кеби нәрсәләр бер дә юк иде.* Г.Тукай

**КАМЫШ** *и.* **1.** 1) Күрәнчәләр семьялыгына караган, чәчәге катлаулы чәчәк төркеменә җыелган башактан гыйбарәт, сазлыкларда үсә торган кыяклы биек үлән үсемлек. *Бу юлы гадәт бозылды. Дөресрәге, башлар үзеннән-үзе горур вә көяз кыяфәттә түр башындагы кәнәфидә күл камышыдай төзгә катып утыручы бикә ягына борылды.* М.Әмирханов. *Шул хәлдән соң ярлы халык җир куышларына күчәргә мәҗбүр була, чөнки ул вакытта инде урман кисәргә рөхсәт бирмиләр, соңрак исә саманнан һәм камыштан йортлар сала башлыйлар.* Ф.Бәйрәмова. *Камышлар арасында үрдәк ботлы яшел бакалар.* К.Кәримов

2) *к.* **камышлык**. *Бабайларның моңлы җыры кебек, Камыш шаулый шулай...* Г.Афзал. *Ай-һай гына дигән, ай, тавышка Кыр казлары кача камышка шул.* Җыр

**2.** *с. мәгъ.* 1) Камыштан ясалган, камыштан эшләнгән. *Варнаның иске өлешеннән барганда, үзеңне нәкъ йөз ел элек яшәгән кебек хис итәсең – биредә генә күрергә мөмкин булган таш коймалар, тәрәзәсез амбарлар, акшарланган камыш йортлар...* Ф.Бәйрәмова. *Аның үзенә күрә тәрәзәләре һәм чаршау шикеллерәк ачыла торган ишеге бар, ишек төбенә аяк киемен сөртү өчен камыш палас җәелгән иде.* А.Тимергалин. *Өстен сырлап бизәлгән ташлар тезелгән идәнгә – камыш чыпта, камыш чыпта өстенә йомшак палас җәелгән.* Н.Фәттах

2) *күч.* Озын һәм чандыр (кеше гәүдәсе тур.). *Ялтыр кара чәчле, тулы канлы, камыш буйлы бер егет, кулындагы камчысын уйната биреп, көләкөлә нидер сөйли иде.* Г.Ибраһимов

**КАМЫШ КИРПЕЧ** *и. к.* **камышит**

**КАМЫ́Ш ТУРГАЕ** *и. зоол.* Әрәмә чыпчыклары семьялыгына караган, камышлар арасында һәм яр буе куаклыкларында яши торган сайрар кош; *русчасы:* **камышевка**

**КАМЫ́Ш ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол. к.* **камыш тургае**. *Белдем хәзер, әти, камыш чыпчыгы белән чебенченең күке курчагы башына кунып ашатканын күргәнем бар.* М.Рафиков

**КАМЫШИТ** *и. рус махс.* Камыштан гипс, балчык һ.б.ш. нәрсәләр кушып, пресслап, плиталар рәвешендә ясалган җылылык саклый торган төзү материалы

**КАМЫШ-КҮРӘН** *җый. и.* Камыш һәм шуңа охшаш кыяклы үләннәр. *Күл тирәсендә каракучкыл тора камыш-күрән, Ул болыннар туп-тулыдыр төрле төстә төрле үлән.* М.Гафури. *Хәзер Иске Ыкта агым да юк, ярлары да тәбәнәкләнеп, камыш-күрән белән капланган, елга саеккан.* Р.Хәбибуллина

**КАМЫШЛЫ** *с.* Камышы булган, камыш күп үскән. *Кала ягыннан килгән юл, елгага якын килергә курыккандай, бераз җир читтәрәк барды да, уңга борылып, камышлы ярлар ягына каерды.* Н.Фәттах. *Җил искән саен тирбәлеп-тирбәлеп ала торган камышлы күлләр, моң тулы чишмәләр, балыклы һәм кыслалы инешләр, күркәм итеп бизәлгән чиста авыл йортын хәтерләткән түгәрәк урман аланнары --- туган ягыбыз табигатенең бер кисәген тәшкил итәләр.* Ф.Гарипова

**КАМЫШЛЫК** *и.* Камыш күп үсә торган урын. *Елга буйларында камышлык.* А.Гыйләҗев. *Аһ, андагы язгы һава, аһ, андагы язларда, җир яшәргәч, Әлә елгасы бөгәлләрендәге камышлыкларда бәрде, табан, мәрсин балыкларының бар тирә-юньгә такта бушаткан, суда ишкәк чайпалткан тавышлар бар итеп, камыш сабакларын дөңгердәтә-дөңгердәтә уылдык чәчүләре!..* А.Хәлим. *Ә безнең Шушманың кызыл ярга борылып киткән урынында нинди шәп камышлык!* Казан утлары

**КАН** *и.* **1.** 1) Организмда тамырлар буенча хәрәкәт итеп, тәннең күзәнәкләрен туендырып, матдәләр алмашуны тәэмин итә торган кызыл сыекча. *Башкалар абайлап, култыклап өлгергәнче, йөткерә биргән шагыйрьнең авызыннан кан китте...* Р.Низамиев. – *Сорама, табам инде, – ди хатыны. Баксаң, ул кан тапшыра икән, шул акчага тоткын ире өчен ризык хәстәрли.* Ә.Сәлах. *Кан басымың да даими түгел, диләр. Ничек бертөсле булсын инде ул.* А.Хәмзин

2) Малның килеп чыгышы, токымы турында. *Әлбәттә, ат үрчетү белән шөгыльләнүче югары кимәлдәге осталар затлы малкайларның нәсел шәҗәрәсен, «кан чисталыгы»н кайгыртып торалар.* М.Галиев

3) *күч.* Бер каннан, ягъни бер ана яки атадан булу белән бәйләнешле якын туганлык; кардәшлек, борынгыдан килгән нәсел бәйләнешләре. *Кан гына түгел, җан, рух, мәңгелек моңнар да берләштерә Ярулла бабай оныкларын...* Р.Низамиев. *Шул форсаттан катнаш никах туа; Нәсел китә ятка, кан китә!* Ф.Гыйззәтуллина. *Югыйсә бит әлеге*

*Сүз мең тапкырлар инде тел өстеннән тәгәрәп дөньяга чыккан – игътибар итмәгәнсең, җан тибешен, кан кычкыруын ишетмәгәнсең генә.* М.Галиев

4) *күч.* Сугыш кырында көрәшеп үлү; үлем. *Салават мәңге сәламәт! Каны безгә – аманәт, китермәбез яман ат.* Ш.Бабич

5) *күч.* Кеше үтерү, шуның гаебе. *Җинаятьчеләргә хас алым – кан белән, ягъни үтереш белән бәйләп куймакчы.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* Бик якын туган булган, каннары бер булган. *Ватансыз калган кан кардәш Кырым татарларының фаҗигасе таулар күкрәгенә мәңге кичерелмәс яра булып уелган.* М.Галиев

◊ **Кан агулау** *к.* **кан бозу** (*2 мәгъ*). **Кан агызу** *к.* **кан кою** *Күсәк белән башка ору, бәкегә салу, асу-кисү, кан агызу кебек вакыйгалы, төннәрен саташып уянырлык бәетләрдән туйган булгандыр Хатип ага.* М.Галиев. **Кан бәрү** *к.* **кан йөгерү**. **Кан бозу** 1) *к.* **кан бутау**; 2) Ачуланышу, әрләшү, ярсу һ.б. аркасында кәефне төшерү. *Кичә [Тәзкирәгә] үз бригадасындагы кайбер кешеләр белән әчелешле булырга, канын бозарга туры килгән иде.* Ф.Хөсни. *– Сезнең бәрәңге эре ---. Өч-дүрт төп казыйм әле кунакларга бәлешкә, – дип, канны боза иде [Гөлсем].* Н.Гыйматдинова. **Кан бутау** Төрле дин, башка милләт кешесе белән өйләнешү. **Канга бату** Сугышып яки кыйналып, бик нык канга буялу. *Канга баткан Саруханов янында теге кызлар елаша, ике зур кунак та югалып калган иде.* Р.Сәгъди. **Канга буялу** Кеше үтерү, шуңа катнашы булу турында. **Канга сеңдерү** Истә калдыру, ныклап үзләштерү. *Ярый әле, бәхетемә күрә авылда туып үскәнмен, шуңа күрә өлкән яшьтәге кешеләрнең сөйләшүен, хәрәкәтен, үзара мөгамәләсен каныма сеңдергән булганмын.* Казан утлары. **Канга сеңү** Нык урнашу, гадәт булып китү. *«Вакыт ага» дибез, һәм без аны, канга сеңгән гадәт буенча, аккан су кебегрәк күз алдына китерәбез.* А.Гыйләҗев. *Шәле тәрбиясе канына сеңгән куркусыз Камил Кәримов кына: – Ринат Мөхәммәдиев режимын урнаштырсаң, без Сезне Рәмис Аймәтнән кыйнатабыз, – дип, бер күзен кысып кына елмайгандай итте дә, «юк, юк, мин бер сүз дә әйтмәдем» дигәндәй, як-ягына каранып алды.* Т.Миңнуллин. **Канга тоз салу** Хурлап, кимсетеп, явызлык эшләп рухи газаплау. *Һидаят абый миңа карый да, укытырга иде сине, буең юк шул, дип канга тоз сала.* Сәхнә. **Канга төшү** Үзәккә үтү, тәмам туйдыру. *ГЭСны төзеп бетергәннән бирле, менә елдан артты инде, [Фёдор Иванович] тәмам каныбызга төште.* А.Гыйләҗев. **Канга тузу** *к.* **канга бату**. *Канга тузып ята юл чатында Бер өч яшьлек бала гәүдәсе.* М.Җәлил. **Кан дошман(ы)** Бик нык дошман яисә күрә алмаган кеше турында. --- *Патшалы Россия хәтта үзе дә олы музыка дөньясына соңлабрак килеп керә. Шулай булгач, аның биләмәсендәге башка милләтләргә, бигрәк тә дәүләтчелеген югалткан, чукынырга теләмәгән «кан дошман» татарга ни сан кала соң?* Р.Низамиев. *Җырлавыңнан ничек тукталасың Кан дошманың анда сөендереп, Кыр казына яфрак изәп калган Каеннарның башын иелдереп.* Ф.Гыйззәтуллина. **Кан елау** Зур кайгыдан, хәсрәттән бик әрнеп елау; 2) Авыр тормыштан, хәсрәттән интегү, зарлану. *Соңыннан гомер буе күз яше түккәнче, бер тапкыр кан елау хәерлерәк.* М.Хәсәнов. **Кан иму** *к.* **кан эчү**. **Кан йоту** Бик нык борчылу; тирән кайгы кичерү. *– Я инде, илаһым, боларның миндә ни эше бар икән?! – дип кан йота [Мәрьям].* Г.Ибраһимов. **Кан йөгерү** 1) Кан тамырлары шартлап, тәннең бер урынына күпләп кан җыелу. *[Фатыйманың] йөзендә кызгылт таплар күренә, күзләренә кан йөгергән иде.* Ш.Камал; 2) *мед.* Баштагы кан тамырларының шартлавы аркасында мигә кан җыелу, таралу; инсульт булу. **Кан кайнау** 1) Ярсу, кызып китү. *Әйе, шушы Бөтенроссия мөселман хәрбиләрнең Шурасын барлыкка китергән данлыклы морзалар токымының дәвамчысы, 22 яшьлек прапорщикның милли тамырлары кузгалып, каны кайнаган көннәр бу.* И.Таһиров; 2) Дәртләнү. *Яшьләрнең каны кайный.* М.Галиев. **Кан кату** 1) Артык нык курку, тирән кайгы кичерү турында... кып катып калганда була торган тойгы турында; 2) Бик нык ачу килү, рәнҗү, күңел кату, гафу итә алмау турында. *[Башкирцев] атасы граждандар сугышында үлеп калгач, революция дошманнарына карата каны катып, канлы көрәш юлына кереп киткән.* М.Әмир. **Кан катыштыру** *к.* **кан бутау**. **Кан качу** 1) Каты курку, ачу яки берәр төрле авыру аркасында иреннәрнең, битнең агарып, күгәреп китүе турында. *Тәнзиләнең йөзеннән кан качты. Эндәшерлек көче юклыгы күренеп тора иде.* Шәһри Казан; 2) Үлгән кешенең йөзе агарган булу турында. *Аның каны каччкан, сүрелгән йөзен, тирән итеп казылган, аста махсус уем-ләхет алынган кабергә төшерер алдыннан, салкын кояшка ачканнар иде.* Ә.Мушинский. **Кан корыткыч** Кешеләрне җәфалаучы, йөдәтүче, бәйләнчек кеше турында. **Кан костыру** Кешегә берәр төрле яхшылык кылып, соңыннан, «мин сиңа шуны эшләдем, моны эшләдем» дип, я башкача ул кешенең күңелендә уйнау, йөдәтү. **Кан косу** Чирләү, авыру. *Кан косудан ничек аралыйсың Гамилләрең... Тукай... Туфаннарың?* Ф.Гыйззәтуллина. **Кан кою** 1) Күпләп кеше үтерү. *– Без кан коюга каршы, – диде Фәрит. – Без бандитлар түгел. Ә җинаятьләре өчен тиешле урында хөкем ителерләр.* И.Хуҗин; 2) Сугышу, сугышта катнашу, яралану. *Тагын 114 татар язучысы һәм шагыйре XX гасырның иң зур афәтләреннән берсе – Ватан сугышы кырларында кан койды.* Казан утлары. **Кан коюлы** *к.* **канкойгыч**. *Ләкин бу кан коюлы болгавыр чор адәми затның биологик күңел төпкелендә йокымсырап яткан динозаврны уяткан – фаҗига шунда.* А.Тимергалин. **Кан кыздыру** Ачуын китерү. *Дус санаган кешесенең тирәякта явызлыгы, наданлыгы, кансызлыгы һәм ришвәтче булуы белән дан тоткан прокурор икәнен белеп алгач, төрмәдәшләре дә канын кыздырырга үз өлешләрен кызганмаганнар.* Р.Мирхәйдәров. **Кан кызу** Ачу килү. *Мәүлиха түтинең [Әпипәгә] күптән үк каны кызып утыра иде.* Г.Бәширов. **Канлы яшь белән** Бик каты ялынып,

ялварып. **Каннан килү** Нәселдән килү. **Кан(ны) корыту** Аптыратып бетерү, йөдәтү. *Кайткач тотып каезлармын әле мена үзен, бик канымны корытса [дип уйлады Фатих].* Р.Төхфәтуллин. **Кан саву** 1) Берәр әгъзага, органга кан җыелу. *Харам эчемлек куллангач сүзгә килдек, һәм мин бер кешегә суктым, ул, бәрелеп, баш миенә кан савып үлде.* Х.Гәрәй. *Сулыш алулары да кыен, тамактан ризык та үтми, тәмәке тартырга да хәл юк – бөтен эч мускулларына кан сауган.* М.Галиев; 2) Онытылмыйча, истән чыкмыйча, күңелне әрнетеп тору. *Чыдаса да чыдый икән бу йөрәк дигәнең... Ул көннәрдән соң юкса алтмыш еллап вакыт узса да, йөрәгемдә калган шул җәрәхәттән әле дә булса кан сава.* Г.Галиева. *Зәңгәр экраннардан Бөек Ватан сугышы, Әфган сугышы турындагы кинофильмнарны караганда, йөрәкләргә кан сава.* Юлдаш. **Кан сыеклау** Ачу китерү, интектерү. **Кан тарату** Кан хәрәкәтен, йөрешен көчәйтү, активлаштыру. *Тик аякларыгызның канын таратып алсагыз, кайтырга җиңелрәк булыр иде.* М.Фәйзи. --- *учак янында гәпләшеп-бәхәсләшеп, кымыз йота-йота кан таратып, акыл җыеп утырырга яраткан Баһадур җания --- болай ди: – Арысланнар белән боланнар бер көтүгә йөрмиләр.* М.Галиев. **Кан тарту** Туганлык мөнәсәбәте өстенлек алу. *Җан тартмаса, кан тарта.* Мәкаль. *16 яшемнән үзлегемнән татар телен өйрәнә башлавым – кан тартуыдыр.* Сәхнә. **Кан түгү** *к.* **кан коюю**. **Кан уйнау** *к.* **кан кайнау**. *Кыскасы, Регина тиле көчкә ия, касык, таза гәүдәле Шөрепкә битараф булмаса да, дөньясын онытып мөкиббән китмәде. Каны артык уйнамады.* Т.Галиуллин. **Канын сыгу** *к.* **кан эчү**. **Кан эчү** 1) Бик нык җәберләү, мыскыл итеп яшәү. *Бушка эшләп йөреп, төрле яклап сөлекләр кебек кан эчүчеләр чорнап алса, өстәвенә зыялылар матбугат аша икенче сортлыга аерып ятса, эчү түгел, әллә нинди хәлләргә төшәрсең...* Татарстан яшьләре; 2) Изү, эксплуатацияләү, файдалану. *Кан эчкән кара хөсет Иделгә көри гайбәт: – Чукынган милләт әйбәт! – Буйсынган милләт әйбәт!* Ф.Гыйззәтуллина. *Дөрес, хәзерге сәяси режимнар заманча политтехнологияләр һәм пиар ярдәмендә ялганны нечкәрәк җептән тукый, һәм талау, кан эчү масштабы белән элгәрләреннән күп тапкырлар уздырып җибәрә.* Ватаным Татарстан. **Кан ягу** *иск.* Каныгу, үчегү. *Авылга керү белән этләре дә теләнчегә каннарын ягалар тагын.* Г.Толымбай. **[Күзне] кан басу** Ачудан, бик нык ярсудан бернәрсә дә күрмәс хәлгә килү; күзләр томалану.

**КАНА** *кис. диал.* Лабаса, бит, ич. *[Әни:] Җүнлерәк әйбер, кием-салым сорап язсаң лутчы кана...* К.Кәримов. *Табын янына килгәч тә: – Олаеп барган көнемдә бер сыер алып унны кайтарасымны белсәм, гомеремдә сөтле чәй күрмәсәм дә риза булыр идем кана, – дип кенә әйтә алды [Җиһанша].* Р.Рахман. *Дөньяны оныттырырлык Сүз әйтсәң икән кана!* М.Әгъләм

**КАНАЛ** *и. лат.* 1) Елга, күл яки диңгезләрне үзара тоташтыру, җирне су белән тәэмин итү, сугару һ.б. өчен казып ясалган су юлы. *Күлнең вак балыклары, су кудыра торган насосның эре саңаклары аша исән-имин үтеп, каналга килеп төшә дә озынборын личинкалары, төрле бөҗәкләр мыжгыган җылы суда симереп, кемнеңдер килеп тотканын көтеп ята.* К.Кәримов. *Төшемә кергән шәһәрнең икенчесе – Венеция. Урамнары – синең торак йортыңның дәвамы; мәйданнары, каналлары, базарлары – барысы да кочакларын җәеп сине көтеп торалар.* М.Галиев. *Каналның ике як яры да тигез итеп киселгән таш койма белән ныгытылган.* Н.Фәттах

2) *тех.* Кайбер көпшәле әйберләрнең эчендәге озынча тар куышлык (мәс., мылтык көпшәсендә һ.б.)

3) *анат.* Кеше яки хайван организмында теге яки бу матдәләр үтеп йөри торган юл, куышлык. *Ашкайнату каналы. Теш каналы*

4) *информ.* Коммуникация системасының бер өлеше, мәгълүмат бирү өчен хезмәт итә торган элемтә линияләре (радио, телеграф, телевидение һ.б.). *Алик Чаллының, Әлмәтнең, Алабуганың татарча хосусый FM каналларын боргалап карады.* А.Хәлим. *Тик барыбер ул үзенең туган ягын күбесенчә газета-журналлардагы рәсемнәрдән, милли каналдагы сюжетлардан гына күреп белә икән бит.* К.Кәримов. *Телевизор каналлары аша гына да һәр көн 2–3 өр-яңа фильм тәкъдим итела.* Казан утлары

5) *куч.* Нәрсәгә дә булса ирешү юлы, чарасы. *Ил һәм республика прокуратуралары кичекмәстән күргән чаралар искиткеч нәтиҗәләр бирде, миллионнарча байлыкларны урлаучы дистәләгән каналлар ябылды.* Р.Мирхәйдәров. *Мин менә шуларның кем һәм нинди каналлар аркылы урлашуларын да, ул акчаларны кая куячакларын да --- бик беләм ---.* Ф.Баттал

**КАНАЛИЗА́ТОР** *и. рус* Канализация эшләре белгече

**КАНАЛИЗА́ЦИЯ** *и. рус* Торак йортлар, предприятиеләр һ.б.ш.ның тотылган пычрак суларын чистарту, агызып җибәрү өчен кулланыла торган торбалар, жир асты каналлары һ.б.ш. санитар-техник корылмалар системасы. *Су, газ, җылыту, канализация торбалары үткәрәләр, экскаваторлар, тракторлар шаулап тора.* Г.Әпсәләмов. *Чыннан да, инфратавыш тудырырлык корылмалар калада бик күп бит: лифтлар, балкон яисә лоджия рәшәткәләре, трамвай һәм троллейбусларга энергия бирә торган җайланмалар, чүп чыгару торбалары, начар ябылган яисә бөтенләй ачык калган канализация люклары...* Казан утлары

**КАНАТ** I *и. гр.* Сүстән яки тимерчыбыктан кат-кат ишелгән, үрелгән калын, нык бау; аркан. *Балдакларны беренче булып үзем уйлап таптым дип йөрде ул, бу аңарда яңа көч, яңа ышаныч үстерде, ә корыч балдаклар аркылы үткәрелгән канатлар гүя аны бүгенге тантаналы көнгә алып килделәр.* Г.Әпсәләмов

**КАНАТ** II *и.* 1) Кошларда, бөҗәкләрдә һ.б. парлы очу органы. *Кош – канаты белән, кеше дус-иш белән.* Мәкаль. *Әйе, әйе, ап-ак күбәләк. Ул һаман килә, ул кеше кебек көлә-көлә канатларын җилпи.* А.Хәмзин. *Күргәнем*

*бар канат ныгытканда Кош баласы егылып төшкәнен...* И.Иксанова

2) Кошлардагы (гадәттә, йорт казларындагы) әлеге органның идән себерү өчен файдаланыла торган өлеше. *Мин ишегалдына чыгып, башта пинжәгемне салып, аны канат белән чистарттым, аннары чалбарыма тотындым.* Ә.Еники. *Әби канат белән идәнне себереп чыгарды да яраткан оныгына коймак пешерергә тотынды.* Сөембикә

3) Таба ашларын майлау өчен җыеп бәйләнгән эре каурыйлар (гадәттә, каз каурыйларыннан ясала). *Мичкә тыгар алдыннан өчпочмак, бәлешләрне майлап ала әни ул канат белән.* Юлдаш

4) Балыкларның суда хәрәкәтләнү органы, йөзгеч. *Бәргәләнә суда авыру балык. Силетёрлы диләр белгечләр. Күрер күзгә таза: сырты көчле, урынында канат-йөзгечләр.* Р.Фәйзуллин. *Беренче тапкыр балык канатларын үз күзләрем белән күрүем лә, Салих абый.* Сөембикә

5) Самолётның як-ягына урнашкан кош канатына охшаш яссылыклар. *Йомшак саклык белән самолётның Канатына чыгып бастың да Сикердең син киң бушлыкка.* Ф.Кәрим. *Беркөн кичен, инде көтүләр кайткач, авыл өстеннән Мещан урманына таба түбәннән генә, тавышы белән авыл халкын өркетеп, ике катлы канатлы самолёт очып узды.* Г.Мөхәммәтшин. *Казан аэропортында «кукурузник» дип йөртелгән ике канатлы җиңел самолёт бераз гына җирдән җилдереп барды да улый-үкерә һавага менеп тә китте.* Р.Кәрами

6) Чана үрәчәсе. *Пьявкин артык төпченмәде, арба канатына аркасы белән ята төшеп, башын өске үрәчәгә куеп хәл алуын дәвам итте.* Х.Камалов

7) Җил тегермәне чарыгындагы әйләнә торган калак. *Холкы-фигыле дә, тегермән канаты төсле, җил искән якка кыйбласын үзгәртеп торуны өнәми.* Т.Галиуллин. *Пропеллерларына утырып, без белмәгән җирләрне күреп әйләнәсе килгән җил тегермәне канатлары янынннан үтеп, Табан асты дигән җиргә китте.* Р.Шәрәфиев. *Авыл тормышының көлкеле дә, фаҗигале дә чынбарлыгы тегермән ташына уралып, җил һәм тегермән канатлары тавышына кушылып, он белән аралашып ага да ага.* Р.Рахмани

8) Комбайнда, урак машинасында ашлыкны кискечкә юнәлдерә һәм урылган ашлыкны өем-өем итеп читкә ташлап бара торган калак. *Мостафа, лобогрейка канатлары астына җыйнала торган солы кисенделәрен кулындагы агач сәнәге белән бертуктаусыз почмакка тартып, өемнәр ясый.* Ш.Камал

9) Су һәм пычрак чәчрәүдән саклау өчен, тәгәрмәч өстенә аска таба колашаландырып урнаштырылган калай япма (автомобиль, велосипед һ.б. ларда). *Машинаның канатына басып, Җилгә куеп егет күкрәген, Җилкәсенә автоматын асып, Бара тыңлап туплар күкрәвен.* Ш.Маннур

10) Капка, тәрәзә, ишек һ.б.ш. якякка ачыла торган ике капкачның берсе. *Өч тарантас янәшә сыярлык капканың тимер читән канатлары ачылгач, ГАИ инспекторлары кулындагы аклы-каралы кәрлә күсәккә охшатып ясалган шлагбаум күтәрелде.* К.Кәримов. *Ике канаты челтәрләнеп коелган капкаларны узуга, күпсанлы болгарлар гөлбакчадан бара башладылар.* М.Хәбибуллин

11) *сир.* Нәрсәнең дә булса бер аерчасы. *Маңгай чәче каш канатына тигән саен өф-өфләп өргәли үзе.* К.Кәримов. *Дәфтәр канатларындагы вак, тигез җөмләләр Гөлкәй күңелендәге бик күп серне ача ала иде.* Р.Габделхакова

12) Йорт, корылма, бина һ.б.ның ян корпусы; флигель; нииндидер җирлекнең бер ягы (өлеше). *Бер йорт немецлар кулында иде, дип сөйләде ул үзе. Бер канатын, ниһаять, алалар.* А.Тимергалин. *Чак-су буйлап сузылган Кизләүне ике яктан да калкулыклар озата бара, әле булса көмеш бөдрәләрен коймаган өянкеләр авылның уң канатын каплап тора икән.* А.Хәлим

13) *сәяси* Теге яки бу сәяси партиядә яки гомумән сәясәттә карашлары белән башка партияләрдән, башка төркемнәрдән аерылып торган агым. *Гомумән, татарчылык проекты ул сәясәттәге «сул» канатның (ләкин коммунистик булмаган) доктринасына нигезләнә.* Д.Исхаков

14) *хәрби* Гаскәр сафларының, сугышчан позицияләренең, фронтының уң яки сул як өлеше; кул, фланг. *Уң канаттан рота командирының кул изәгәне күренде.* Г.Бәширов. *Көнчак хан үз гаскәрен сул канатка куйды.* М.Хәбибуллин. *Болгарны тар-мар иткәннән соң, татар-монгол гаскәрләре Иделне кичкәннәр дә ике канатка бүленгәннәр.* Р.Хәкимов. *Аксак Тимер камалышта калган уң канатындагы сугышчыларына резервтан да ярдәм җибәрә.* Казан утлары

15) *күч.* Өмет, стимул; таяныч, терәк. *Болар өстәвенә, аның иҗади омтылышларын, канатын сындырдылар.* Р.Низамиев. *Галимҗан Ибраһимов дәресләре аңарга [Салих Сәйдәшевка] яңа канатлар куйды.* Р.Низами. *Бу вакыйга минем тормышымны үзгәртеп җибәрде, гүя алар миңа тылсымлы канат бирделәр.* Ә.Сәлах. *Андый мәхәббәтне тудыра алган кеше минем канатымны каермас. Ул миңа яңа канат бирер.* Г.Әпсәләмов

16) *күч.* Тормыш иптәшенә карата әйтелә торган сүз. *Ир-канаты авызыннан бу сүзне ишетүгә, Назлыгөл кинәт торып утырды ---.* М.Хәбибуллин. *Ир-канаты «Туйбикә» дип еш телгә алгалагач, Зөбәрҗәт ханбикә оста Алпарны барып күрергә уйлады.* М.Хәбибуллин

17) **канатым** *тарт. форм.* Яратып, иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе. *Син миңа пләмәш буласың, канатым! Ник дисәң, синең атаң белән мин ике бертуган малайлары булабыз.* Ә.Еники. *– Кемнәргә турыладың, канатым, – диде хатын.* Н.Гыйматдинова. *Берни дә булмады, оланым-канатым, берни дә булмады.* М.Хәбибулин

◊ **Канат астына алу** Яклау, кайгырту; терәк булу. *Бер-берсе белән узышып үскән агачларны караңгылык үз канаты астына алган.* Р.Мирхәйдәров. *Ул үз куышына «кырык беренченең беренче хәтәр көннәрендә үк бөтен гаиләсен – хатынын, балаларын, туганнарын югалткан» бәхетсез ирне сыендырды,*

*канат астына алды.* Ә.Мушинский. **Канат астына керү** Кемнең дә булса яклавында, химаясендә булу. *Мин бар көчем илә очып, аз вакытта күп җирләрне, күп нәрсәләр күреп, янә синең канат астыңа кайтып керермен.* Г.Тукай. *Болгар христиан динен кабул итү белән империя канаты астына керер.* М.Хәбибулин. **Канат астында тоту** Саклап, иркәләп тоту. *Өлкән хатын вазифаларын Хәдичә ханбикә башкара. Чебеш анасыдай сарайдагы хатын-кызларны үз канаты астында тота.* М.Әмирханов. **Канат бирү** *к.* **канат кую**. *Нинди көчләр миңа канат бирә Текә кыяларга очарга?* В.Галиев. **Канат җәю** 1) Зур мәйданга таралу, каплап алу. *Фәйзиев белән күрше өлкәдән төн канатын җәйгәч кенә әйләнеп кайттылар*. Р.Мирхәйдәров. *Җырым канат җәяр иде шунда, Җаннарга наз, сөю таратып.* Ф.Шәех; 2) Кыю рәвештә эшләү, хәрәкәт итү. *Шулай итеп, милли хәрәкәтнең шактый көчәйгән, киң канат җәйгән чорында Михаил Георгиевич Худяковның хезмәте дә иҗтимагый аңыбыз үсүгә үз өлешен кертте дип әйтергә мөмкин.* М.Госманов. **Канат җибәрү** Ярсу, очыну. *– Ә биләрләр? – диде ярсып, канат җибәргән хан.* В.Имамов. **Канат кагу** Шатлану, куану. *Концерт бирә кичен сандугачкай, Илһамланып, канат кагынып.* Ф.Шәех. **Канат каерылу** Авыр кайгы яисә борчу-мәшәкатьләр тәэсирендә яшәү дәрте сүнү. *Мин адашкан дустымның, канаты каерылган дустымның – Ленаның бәхетсезлегенә таба барам.* А.Гыйләҗев. **Канат кую** Көч бирү, илһам бирү. *Инде үзе өчен иң җаваплы бу минутларда да Газзәбану апасының янәшәдә генә булуы, әйтерсең лә, кызга канатлар куйды.* Г.Галиева. *Мин сездән бөркелгән җылы хисләрне тоям, алар миңа канат куя, рухымны югарыга, биеккә күтәрә.* М.Маликова. **Канат ныгыту** Көч, тәҗрибә туплау, нәрсәгә дә булса өйрәнү. *Өлкәннәр белән беррәттән монда яшь каләм ияләре дә зур юлга чыгар алдыннан канат ныгыталар.* М.Галиев. **Канат салындыру** Яшәү дәрте сүнү; ышанычны, көчне һ.б.ны югалту. *Иң якын дустын югалту бик авыр тәэсир ясады Рафаэльгә. Эшкә шыпырт кына, иплe адымнар белән чыгып китә һәм шул рәвешле, канатларын салындырып, күңелсез генә кайтып керә.* Р.Мөхәммәдиев. **Канат сыну** Ышаныч, өмет, көч һ.б. бетү, югалу. *Әле генә ничектер боегып, сынган канатларын читлектәге кош кебек очлайтып утырган балаларның сары коелган йөзләренә шушы унөч юллык шигырьдән нур һәм алсулык кунды.* А.Хәлим. *Ул һичшиксез зур шагыйрь, талантлы егет, канаты, күңеле сынарлык бик күпләрне күрсә дә, язмышның авырлыгына бирешмәгән лачын иде.* Казан утлары. **Канат үсү** 1) Рух күтәрелү, яшәү көче арту, нәрсәдер эшләргә зур теләк, дәрт уяну. *Мәхәббәт бөтен тормышыма нур сибә, миңа гүя канатлар үсте, атлап йөрмим, ә очам!* Р.Габделхакова. *Үзгәрдем, сизәм үзем дә, Канатлар үсте хәтта.* Ф.Яруллин; 2) Көч арту, көчләнү. *Кулларын як-якка матур итеп болгый-болгый килүче Фатыйманы күргәч, аның эченә җылы йөгерде, өстән авыр йөк төшеп, берничә мизгел эчендә канатлары үсеп чыккандай булды: хәзер ул менә-менә очып китәр сөйгәненең каршысына.* З.Хәким. **Канат чыгу** 1) Нинди дә булса эшне башкарырга мөмкинлек ачылу, ышаныч, теләк, илһам туу. *Нина иңенә канатлар чыккандай тиз генә китеп барды.* Ә.Еники. *Канат чыкканмыни малаеңа, Атлап түгел, очып йөри ул.* Р.Вәлиева; 2) Мөстәкыйль яши, эшли алырлык хәлгә килү, җитлегү. *Хәтерлим әле: без бөтенләй канат чыкмаган кошчыклар гына идек, ишегалдында кыш, минем әни мичтән өсләре кызарып пешкән өчпочмаклар чыгара...* Ә.Мушинский. *Унбиш-уналты яшьлек кызларның канат чыгарып беренче очышка әзерләнгән кош балаларыдай талпынулары, тәүге мәхәббәттән зиһеннәре чуалыр дәрәҗәдә әсәрләнүләре – барысы да бар иде ул биюләрдә!* Р.Кәрами. **Канатын каеру** Кемнең дә булса көчен, эшчәнлеген, мөмкинлеген бетерү, теләк-омтылышларына чик кую. *Аермыйкчы эзләп гел аерма – Канат каеручы җитәрлек.* Р.Юныс. **Канат яру** 1) Үсеп җитү, балигъ булу; җитлегү (мәс., шагыйрь, язучы булып һ.б.). *1981 елда оешманы Чаллыда канат ярган шагыйрь Р.Вәлиев җитәкли башлады.* Казан утлары; 2) Илһамлану, очыну. *Сөю килде, гүя яшьлек кайтты кабат, Сүнеп барган күңел яшьнәп ярды канат.* Р.Вәлиева. *Рухланган күнел канат яра, Очмак булып яши һавага.* В.Галиев

**КАНАТЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Очарга өйрәтү. *Балаларын канатландыргач Карасазга сыптырса (үрдәк), очты, очты үрдәкләр дип, авызыңны күккә терәп карап калырсың.* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Рухландыру, дәртләндерү, илһамландыру. *Алга китеш күренмәсә дә, аны бер нәрсә канатландырды: Илһам сынып төшмәде.* Р.Галиуллин. *Ихтирам сине канатландырып, яшәү көче биреп тора.* М.Юныс. *– Кыю икәнеңне мин яхшы беләм, – диде Рәсул, Сәлимне канатландырып.* Д.Гайнетдинова

**Канатландыра төшү** Тагын да ныграк канатландыру. *Әнисе, матур сүзләр әйтеп, кызын канатландыра төште.* Казан утлары

**Канатландырып алу** Тиз арада, кыска вакытка канатландыру. *– Күрәзәче апаң тагын ниләр әйткән соң, Нәгыйм? – дип, председатель аны канатландырып алды.* К.Кәримов

**Канатландырып җибәрү** Бераздан канатландыру; канатланырлык этәргеч ясау. *Почтамт якында гына, имеш. Бу киңәш аны канатландырып җибәрде.* А.Хәлим. *Район халкы шау-гөр килде, бу тәнкыйть күпләрне канатландырып җибәрде ---* Ф.Садриев. *1991 елның октябрендә шәһәрдә «Аргамак» журналын нигезләү дә Кама буендагы һәм чиктәш төбәкләрдәге әдәби хәрәкәтне канатландырып җибәрде.* В.Имамов

**Канатландырып тору** Даими канатландыру. *Тиздән Казанда очрашу хыялы икесен дә канатландырып торды: Вәсим университетка керергә җыена иде.* З.Хәким. *Күп акча, байлык кына да адәм баласының кәефен һәрвакыт күтәреп, күңелен канатландырып тора алмый икән шул!* З.Хөснияр

**КАНАТЛАНУ** *ф.* 1) Канат чыгару, канат үсә башлау, очарга өйрәнү

(кошлар тур.). *Феникс дигән кошны яндыралар. Үлде, бетте дип уйлыйлар. Ләкин ул үз көленнән яңадан чыгып канатлана.* Ә.Баян

2) *күч.* Дәртләнү, рухлану. *– Әйдәгез, ун елдан соң дип сөйләшик, – диде Зөфәр, канатланып. – Шушында очрашабыз да кемнең ни кылганын карыйбыз.* М.Маликова. *Әнсарның канатланып эшкә тотынуы – күбрәк гаилә бәхетеннән ул.* З.Хәким. *– Барабыз, җиңгәчәй, барабыз! – диде Клара, чынчыннан рухланып, һәм аны кинәт ниндидер бер канатлану, җилкенү биләп алды.* Ә.Еники

**Канатлана башлау** Канат күренү; канат чыгару. *Каз бәпкәләре канатлана башлады*

**Канатлана төшү** Бераз канатлану; тагын да канатлану. *Бу көннәрдә бәйсезлегебез дошманнары тагын да канатлана төштеләр.* Казан утлары

**Канатланып алу** Кыска вакытка канатлану; бераз ашкыну, дәртләнү. *Шулай да, тарихны белмәгәндәй, без дә бер канатланып алдык.* Р.Зәйдулла. *«Шулай да поэзия бар бит!» – дип, җан өшеткән әйберләргә кул селтибез; шунда, күз ачып йомган арада булса да, күңел канатланып ала, матурлык арасында яшәвең җан көюләрен оныттыра, яшисе һәм язасы килеп китә, чөнки: «Юлда адашып калганга Маяклар тезәсе бар».* Н.Нәҗми

**Канатланып җитү** Тиешле дәрәҗәдә канатлану; канат чыгару. *Кош балалары канатланып җиттеләр*

**Канатланып йөрү** Шактый вакыт канатланган халәттә булу. *Көне буе канатланып йөрде хуҗабикәм!* А.Зарипова. *Гаиләдә көтелгән шатлыклы вакыйгалар белән канатланып йөргән шул көннәрнең берсендә Рафаэль эшеннән кәефсез кайтып керде.* Р.Мөхәммәдиев

**Канатланып килү** Канатлануга таба бару. *Үрдәк бәпкәләре канатланып килә*

**Канатланып китү** Кинәттән, көтмәгәндә канатлану, дәртләнү. *Таз абзый канатланып киткән һәм җыру сузган.* М.Әхмәтҗанов. *Эш тансыклаганга, ахрысы, ул бу көннәрдә аеруча җанланып, канатланып китә.* Ә.Еники. *Тәнгә, мускулларга ниндидер дәрт тула, хыяллар канатланып китә.* Х.Камалов

**Канатланып кую** Бер тапкыр яисә кыска вакыт эчендә канатлану. *Әбисенең сүзләреннән Надир үзен очарга әзерләнгән дала бөркетедәй хис итте, канатланып куйды.* Н.Каштанов. *Менә ул да килеп кочар диеп, Канатланып куям эчемнән.* Д.Сирай. *Күңел өметләнеп-канатланып куйды: димәк, бүген Ул киләчәк!* Н.Гыйматдинова

**КАНАТЛЫ** I *с.* Канаттан эшләнгән; канат буйлап йөри торган. *Канатлы юл*

**КАНАТЛЫ** II *с.* 1) Канаты булган; оча торган. *Дүртәр канатлы энә караклары оча.* М.Галиев. *[Салих:] Ә син уйнаганда, минем канатлы кош буласым, болытларга, йолдызларга хәтле күтәреләсем килә, Валя...* Р.Низамиев. *Нурихан Фәттах аны хәтта Атлантида башкаласындагы, диңгез патшасы Посейдон гыйбадәтханәсендәге канатлы атлар белән дә тәңгәл куя.* Казан утлары

2) Як-якка ачыла торган ике капкачы булган. --- *Туфан, самолёт трабына чыккан президент кыяфәтендә, коттеджның икенче катына менде. Ике канатлы ишекләрне җырлатып кына ачып, балконга чыкты.* М.Галиев

3) Җиңел, җиңсез киемнең җилкә турысына тегелгән волан. *Озын җиңле, ябык изүле ак кофта өстеннән канатлы кара сарафан кигән [Мөнирә апагыз].* К.Кәримов

4) *күч.* Ашкынучан, омтылучан. *Күңелем канатлы – Җиһанны кочамын.* Л.Фәтхетдинова. *Шәһәр өстен бизәп, канатлы хыялларны хәтерләтеп, күктә ак күгәрченнәр оча!* Р.Низамиев. *--- бу хис шундый көчле иде ки, Нурия үзенең яшәргәнен тойды, канатлы җаны дәртләнеп, газиз балалары, оныгы, якыннары өчен һәр мизгелдә батырлыкка, ярдәмгә, яратуга әзер иде!* Р.Хәбибуллина

◊ **Канатлы җөмлә** Тапкыр, үткен, оста әйтелгән җөмлә. *Канатлы җөмлә яшен тизлеге белән бөтен мәктәпкә таралды.* Г.Кутуй. **Канатлы сүз** 1) Авторы яки чыганагы билгеле булган әйтем, афоризм. *Гәүһәршадның «итәк-чабуларны җыештырырга вакыт җитте» дигән канатлы сүзе шул үзгәрешләргә ишарә иде.* М.Әмирханов. *Күпне күргән карт редакторның, яшь хезмәткәрләр белән сөйләшкәндә, бик еш әйтергә ярата торган канатлы сүзе инде бу.* К.Кәримов; 2) Әдәби телдә гомуми кулланышка кергән үткен, сәнгатьле сүз яки фраза, гыйбарә. *Гөпе-гөпе бииләр, биегән саен шәҗәрә тиресенең көрән каләм язган канатлы гыйбарәләреннән утлы күзләр чәчрәп чыга.* А.Хәлим. *Күренеп тора, монда мәкаль генә түгел, канатлы гыйбарә дә бар.* Ф.Хәсәнова

**КАНА́У** I *и. лат.* Озын, тар чокыр. *Канау казып, сөяк тапкан саен, Тирәнәйтәм, димә, тарихны!* Р.Идиятуллин. *Ул болында ялгызы йөргәндә, таеп китеп, күрәсең, тирән канауга сырты белән килеп төшкән.* Р.Фәизов. *Машинадан төшеп, пычрак су тулы канауны сикереп чыктылар, чыклы клеверны ерып, эчкәрәк уздылар.* М.Маликова

**КАНА́У** II *ф.* Кан чыгу, кан агу. *Көчәнүдән иренең чәйнәлә, сыдырылып, беләкләрең каный, тырнакларың каерыла.* Н.Әхмәдиев. *Тырнак астында җәлладлар керткән бамбук шырпысы каный.* А.Хәлим

**Канап бетү** Канау дәрәҗәсенә җитеп җәрәхәтләнү. *Ялтыраган һәр төрткене, яр буендагы һәр ташны актарды, аларның һәрберсен тотыптотып карады, бармаклары канап бетте, ә балдак барыбер табылмады, суга төшкәндәй юк булды...* А.Хәсәнова

**Канап тору** Сөйләү моментында канау; озак вакыт дәвамында канау. *Шулардан Б.Рәхимова үз халкына «ятка бишмәт сырма» дип мөрәҗәгать итсә, «тормышы проза булса да, үзе шигырьдән генә торган» Н.Сафина: «Без әлегә хыялларны кочып, Канап торган җиргә иңдәбез...» – дип яза.* Казан утлары

**Канап чыгу** Билгеле бер вакыт арагында канау

**Каный башлау** Канарга тотыну. *Пычак тиеп киткән бармак каный башлады*

**КАНӘГАТЬ** *хәб. гар.* **1.** Риза, мәмнүн. *Бүген радиода «Җидегән*

*чишмә»дән бер өзек тапшырдылар – «Юл чатында» дигән Гайнан белән Шәүрә өлешен. Һәйбәт укыдылар, мин канәгать.* Г.Бәширов. *Син монда шат, ахры... Син канәгать, Син килмисең монда – кайтасың.* Р.Мөхәммәтшин

**2.** *рәв. мәгъ.* Канәгатьлеген белдереп, канәгатьлек сиздереп. – *Бусы тулысынча минем дизайн, – диде Хәнәфи, канәгать елмаеп.* М.Маликова. *Карчыгының да канәгать кенә елмаеп утыруын күреп, атын да кумаска булды.* Г.Галиева. *Канәгать кенә сакалын сыпырып куйды хәзрәт.* Р.Мөхәмәдиев

**3.** *с. мәгъ.* Ризалык, канәгатьлек белдергән. *Аның бик тә канәгать кыяфәтендә тизрәк «шеф»ын куандырасы килгәне ярылып ята иде.* М.Маликова. *Ханның бу мәрхәмәтлелеге бик ошады, төрле яктан канәгать авазлар яңгырады: – Авызыңа бал да май, хан!* М.Әмирханов. *Хуҗаның йөзенә канәгать елмаю җәелде.* А.Хәсәнов

**КАНӘГАТЬЛӘНГӘНЛЕК** *и.* Канәгать булу, канәгатьлек хисе. *Каюм һәм Әхмәтнең йөзләрендә дә канәгатьләнгәнлек әсәре чагылды.* Ш.Камал

**КАНӘГАТЬЛӘНДЕРЕРЛЕК** *с.* *к.* **канәгатьләнерлек**. *Гөлфия, тынлыкны артык озакка сузмыйча, яучыны да, ата-аналарны да канәгатьләндерерлек тәкъдим әйтте: – Әйдә, Мөхәммәт, урам әйләнеп керик, бәлки, клубка ук барып җитәрбез ---.* С.Шәрипов. *Сыйныфташлар арасында мөгаллимне канәгатьләндерерлек чишелеш вариантын тәкъдим итүче «кырлы баш» малайлар да табылды.* К.Шакиров

**КАНӘГАТЬЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Кемнең дә булса теләк, үтенечен һәм таләпләрен үтәү, тормышка ашыру. *Кытай, Япония якларындагы милләттәшләребез, үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү йөзеннән, татар телендә, гарәп графикасында күпсанлы китаплар, төрле гәзит-мәҗмугалар да бастыралар.* Х.Миңнегулов. *Иң тыйнак ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, шәһәр кешесе иртәнге җидедән кичке җидегә кадәр эштә йөри.* М.Шиһапов. *Бирүдә исә җирне пүчтәк адәмнең капризын канәгатьләндерү өчен әрәм итәләр.* Х.Камалов

2) Таләпләргә, сорауга җавап бирү, туры килү. *Игенчелек кенә авыл халкының ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый.* Ф.Гарипова. *Дәгъваларым булса да, бүгенге вазгыятьтә республикабыз Президенты алып барган сәясәт мине канәгатьләндерә.* Т.Миңнуллин. *Мине инде алар тулысы белән канәгатьләндерә.* Х.Туфан

3) Нәрсә дә булса җитәрлек күләмдә булу. *Сарай тулы алтын-көмеш тә канәгатьләндерми кызны.* Әкият. *Егет һәрвакыт канәгатьсез, ачулы, чөнки аның карыны ач, шундый зур гәүдәне мондый мәче ашы гына канәгатьләндерә алмый иде.* Х.Камалов

**Канәгатьләндерә бару** Торган саен күбрәк канәгатьләндерү. *Күз тимәсен, моңарчы ул үзенә тапшырылган төп вазифаны – яшьләрнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә бару бурычын – нигездә уңышлы үтәп килде.* Ә.Баян

**Канәгатьләндерә башлау** Канәгатьләндерүгә таба бару. *Шундыйлар нинди дә булса властьлы урынга менеп ала да мактауга гуҗлыгын канәгатьләндерә башлый.* Х.Камалов

**Канәгатьләндереп алу** Беркадәр вакыт канәгатьләндерү

**Канәгатьләндереп килү** Даими яки регуляр рәвештә канәгатьләндерү. *Болгар-татар әдәбиятында исә «Кыйссаи Йосыф» бу темага язылган бердәнбер шигъри әсәр булып кала, һәм ул татар укучыларының яңадан-яңа буыннарына эстетик тәрбия биреп, зәвыкларын канәгатьләндереп килә.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**Канәгатьләндереп тору** *к.* **канәгатьләндереп килү.** *Алар безнең теләкләрне тиз арада канәгатьләндереп торалар.* Шәһри Казан

**КАНӘГАТЬЛӘНЕРЛЕК** *с.* **1.** 1) Нинди дә булса таләпләргә туры килгән, тиешле дәрәҗәгә ирешкән. *Әллә арбаның төзеклеге канәгатьләнерлек түгелгәме, әллә аяк сызлавы көчәйгәннәнме, әллә кече улының сугышып кайтуыннанмы, аның бүген бөтенләй кәефе юк иде.* З.Хәким. *Вафинның соравына да канәгатьләнерлек җавап бирмәдем.* Г.Кутуй

**2.** *рәв.* 1) Шактый тулы, җитәрлек; тиешенчә. *Моны һәр тармакның үз белгечләре генә канәгатьләнерлек итеп эшли ала.* Җ.Вәлиди. *Ирек имтиханда канәгатьләнерлек җавап бирде.* Казан утлары

2) Күңел булырлык, туярлык, яхшы. *Артистлар, гомумән алганда, канәгатьләнерлек уйнадылар.* Һ.Такташ

**3.** *и. мәгъ.* Түбән уңай бәяне белдерә торган билге (белем, тәртип һ.б. бәяләгәндә). *[Асия:] Имтиханны бөтенләй белмәдем... --- Ә ул «канәгатьләнерлек» дип язып куйды.* И.Юзеев. *Ә Люциягә «канәгатьләнерлек» дигән билге бик җитә.* Ф.Яруллин

**КАНӘГАТЬЛӘНҮ** I *ф.* 1) Канәгатьлек тою, берәр нәрсәдән мәмнүн калу, риза булу. *Беренче мәртәбә күргән Гарифка бу эш ярыйсы гына ошады, һәм бу халыкның шушы эштә пешеп чыккан кешеләр икәнлегенә ул тәмам канәгатьләнде.* Ш.Камал. *Әйтәсе килгәннәрен әйтү белән генә канәгатьләнде.* С.Поварисов. – *Шәп!* – *дию белән канәгатьләнде.* Р.Кәрами

2) Булганы белән чикләнү, риза булу, артыгын таләп итмәү. *Кайчагында исә ике-өч мантый вә бер ләвәш белән дә канәгатьләнә ул.* Р.Мирхәйдәров. *Чәйне кайнарлап маташмады: тавык боты белән өчпочмаклар өстенә бер чүмеч салкын су салып кую белән канәгатьләнде.* Ф.Яруллин

**Канәгатьләнә башлау** Канәгатьләнүгә таба бару. *Бу эт миңа баштарак өргәләп маташкан иде, соңыннан иснәп карау белән канәгатьләнә башлады.* Г.Афзал

**Канәгатьләнә төшү** Бераз канәгатьләнү. *Сәлим канәгатьләнә төште*

**Канәгатьләнеп бетү** Тулысынча канәгатьләнү. *Моңа ул үзе дә бик үк канәгатьләнеп бетми, ахры.* А.Гыйләҗев. *Сөләймановның күңелендә бер канәгатьләнеп бетмәгән теләк – үз авылында эшлисе килү теләге – һаман сакланып йөри иде.* Ә.Еники

**Канәгатьләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә канәгатьләнү, тәмам канәгатьләнү

**Канәгатьләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында канәгатьлек кичерү

**Канәгатьләнеп калу** Нindидер сәбәптән, вакыйгадан соң канәгать булу. *Гадәттә, күп сөйләшергә яратучылар энергияләрен сөйләшүгә тотып алҗыйлар да, чара күрәсе урынга, шул әйтелгән сүз белән канәгатьләнеп калалар.* М.Юныс. *Картлар кайтыр юлга чыга, Канәгатьләнеп калгач.* Ә.Хәсәнов

**Канәгатьләнеп китү** Нindидер сәбәптән канәгатьләнү

**Канәгатьләнеп тору** Канәгатьләнгән хәл кичерү, канәгатьләнгән хәлдә булу. *Син шул утыз-кырык малайны төрки таныту берлә канәгатьләнеп торасыңмыни?* Г.Исхакый

**КАНӘГАТЬЛӘНҮ** II *и.* Канәгатьлек, ризалык. *Мин сезне зур канәгатьләнү белән үз классыма алам.* Р.Низамиев. *Иң зирәк, иң чибәр, иң хәйләкәр кызыннан ул мондый эчтәлекле хәбәр көтми иде, яраткан кызымны бик дәрәҗәле, бик мөхтәрәм җиргә урнаштырдым дип, зур канәгатьләнү хисләре кичерә иде.* М.Әмирханов. *Бу хәл, ягъни авылда ислам динен хөрмәт итүчеләрнең күбәюе, Мөхәммәтнең үз вазифасын ихластан үтәве әтиәнисенең күңелләренә канәгатьләнү һәм сөенү хисләре өсти иде.* С.Шәрипов

**КАНӘГАТЬЛЕ** *с.* 1) Канәгать булган, риза булган; шатлыклы; канәгатьлек белдергән. *Тагын бер мизгелдән исә аның яңак астына төшеп җиткән бакенбардлы йөзенә канәгатьле елмаю кунды: – О-о!.. Гафу итегез, месье Нуриев! Исәнмесез! Тыңлыйм...* Р.Вәли

2) Канәгатьләнә белә торган, шөкер иткән. *Канәгатьле кешедә көнчелек булмас.* Мәкаль. *Комсыз байдан канәгатьле ярлы баерак.* Мәкаль. *Шуның өчен сез дә бәхетне байлыктан яки ат, арба вә олы сарайлардан эзләмичә, бәлки күңелегезнең канәгатьле, вөҗданыгызның тыныч булуыннан эзләгез.* Р.Фәхретдин

**КАНӘГАТЬЛЕК** *и.* Канәгать булу. *Аның йөзендә эчке мәгърурлыгын чак тыеп торган канәгатьлек һәм шул ук вакытта үзе генә белгән ризасызлык та чагыла.* М.Галиев. *Канәгатьлек, тормыштан канәгать булу хисе белән яшәп, оныкларым булыр дип өмет итәм әле Ходайдан.* А.Хәсәнов. *Маэмай, башын кыегайта төшеп, акыллы күзләре белән күбәләккә карап алды, аннары үзләренә таба йөгереп килүче малайны күреп, чын адәми канәгатьлек белән елмайган төсле булды.* А.Тимергалин

**КАНӘГАТЬСЕЗ** *с.* **1.** 1) Канәгать булмаган, канәгатьсезлек белдергән. *Миңа карагач, канәгатьсез һәм тупас тавыш белән: – Нәрсә кирәк? Караңгыда шулай борчып йөрисең... – диде.* Ф.Галиев. *Тик ул сәламемне алып вакланмый, миңа канәгатьсез караш ташлый да кабат өйгә кереп китә.* Р.Габделхакова

2) Туймас, канәгать була белмәгән, шөкер итә белмәгән. *Канәгатьсез һәм комсыз кешеләр генә бара ала мондый адымга.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Канәгать түгел; канәгать булмыйча. *Ул үз-үзеннән соң дәрәҗәдә канәгатьсез иде.* М.Әмирханов. *Сталин канәгатьсез генә Хрущёв тарафына карап алды да дәвам итте: – Җинаятьчеләрдән алынган байлык халык файдасына күчерелергә тиеш.* Р.Батулла. – *Казан үзенчә яшәргә, үзе теләгән ханны тәхеткә утыртырга, үзенең мөстәкыйль эчке һәм тышкы сәясәтен алып барырга тиеш, – диде йорт хуҗасы, канәгатьсезрәк рәвештә.* М.Әмирханов

**КАНӘГАТЬСЕЗЛЕК** *и.* 1) Канәгатьләнмәгән булу, ризасызлык. *Бар, канәгатьсезлек белдереп кара: аларның беркем бәйләнә алмаслык сәбәпләре әзер.* Р.Мирхәйдәров. *Алай да Кармак бер урында канәгатьсезлеген белдереп куйды: – Бигрәк әйбәт урнаштырдык инде, – диде.* М.Маликова. *Хәлиулла Әнсар белән янәшә атлаганда: – Бик салынып төштең шикелле, улым, – дип канәгатьсезлек белдерде. – Бәлки әле, сез барып җиткәнче, сугышы да бетәр.* З.Хәким

2) Туймаучанлык, комсызлык

**КАНӘГАТЬСЕЗЛӘНҮ** *ф.* **1.** Канәгатьсезлек туу, риза булмау. *Алар белән беррәттән әсәрдә төрле җәнлекләр, кошлар, мифик затлар да очрый. Алар кешеләр кебек сөйләшәләр, уйланалар, эшлиләр, яраталар, канәгатьсезләнәләр.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* Канәгатьсезлек хисе. *Ногайбәк ага алай да: – Башта берәрне тотарга булган инде, – дип канәгатьсезләнү белдереп, бераз сагая төшеп, рюмкасын өстәлгә утыртты.* А.Хәсәнов

**Канәгатьсезләнеп алу** Беркадәр вакыт канәгатьсезләнү. *Иренең тагын командировкага китәсен белгәч, Асия башта канәгатьсезләнеп алды алуын.* Шәһри Казан

**Канәгатьсезләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында канәгатьсезләнү

**Канәгатьсезләнеп тору** Канәгатьсезләнгән хәлдә булу; канәгатьсезлек кичерү

**КАНӘГАТЬЧЕЛ** *рәв.* **1.** *с.* Булганга канәгать була белүче. *Шул ук вакыт татарның бу «уртача» дигән әхлакый сыйфатына ач күз, комсыз булмаска, канәгатьчел булырга чакырган мәкальләрне дә кушарга кирәк.* Н.Исәнбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* Канәгатьлек кичереп, канәгать була белеп. *Тормышлар әйбәт: ашыйм-эчәм дисәң – мул ризыгы, киим дисәң, төрледән-төрле киеме бар, канәгатьчел булып яшәргә өйрәнүе генә ай-һай авыр икән.* Юлдаш

**КАНӘФЕР** *и. гар. бот.* 1) Зәйтүнчәләр семьялыгыннан аерча таҗ яфракчыклы, шәмәхә, кызыл, ал, ак чәчәк ата торган тәбәнәк агач (куак); сирень. *Төштән соң безнең сарай кабарып торган зур ябалдашлы канәфер агачы һәм ишегалдында ялгызы гына биек булып калкып торган (куаклыклар исәпкә керми) алыптай нык имән күләгәсенә яшеренә.* Ә.Мушинский. *Читән белән уратып алынган, канәфер, балан куакларына чумып утырган Шәрифелҗамал түти йорты Аргыяк урамның урта бер җирендә.* Т.Мөбарәков. *Ә ул канәфер – сирин инде – бер дә бер заманны, тәмам шау чагында яшел корттан – сасы яшел кандаладан – тәмам гаҗиз була.* Ә.Гаффар

2) Шул агачның чәчәкләре. *Урамнан узучы яшь-җилбәзәк, бигрәк тә кызлар, канәфер чәчәгенең урам якка салынып торган зур-зур тәлгәшләренә сокланып, бу яклардан аерылып китә алмыйлар.* Г.Бәширов. *Даңгөл, җиңелчә генә кагылып китеп, кунак егете алдына*

*канәфер чәчәкләре төшерелгән ташаяк тәлинкә куйды.* А.Хәсәнов

3) Канәферчәләр семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел яки ярымкуак үсемлек; шуның хуш исле төрле төстәге чәчәге (канәфер чәчәк); *русчасы*: **гвоздика**. *Төнге салкында басып тора-тора, инде шиңә, сула да башлаган канәфер чәчәкләрен, бераз уңайсызлана төшеп, Резидә Рудольфка сузды: – Исән-сау гына кайтып җиттеңме, кадерле энебез безнең! – диде ул, керфек очларына эленгән күз яшьләрен җемелдәтеп.* Р.Вәли. *Ул яшәреп киткән, битләре алланып тора, иреннәренә елмаю эленгән, кулында кызыл канәфер чәчәкләре.* Ф.Садриев

4) Мәрсидчәләр семьялыгыннан алсу яки ак төстәге вак чәчәк ата торган мәңге яшел тропик агач; хуш исле һәм майга бай бөреләре парфюмериядә, медицинада, микроскопик техникада кулланыла

5) Шул агачның киптерелгән бөреләреннән ясалган аштәмләткеч. *Качып эчә алу мәртәбәгә әверелде, «аек туй» кунаклары чоланнан чыкмады, киңәшмәләргә керәсе кызыл чырайлар кершән белән акшарланды, тыйнак сөйләшүләрдә лавр яфрагы, әнис, тмин, канәфер кебек тәмләткечләр авыздан төшмәде.* К.Кәримов

**КАНӘФЕРЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Ике өлешле үсемлекләрнең бер семьялыгы. *Бик күп канәферчәләр болыннарда, урман аланнарында һәм, чүп үлән буларак, кырларда үсә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Күпчелек канәферчәләр, аеруча канәфер чәчәк, декоратив үсемлек буларак үстерелә.* Ботаника

**КАНВА** *и. фр.* 1) Тапкырлап чиккәндә кулланыла торган крахмаллап эшләнгән челтәрсыман тукыма. *Ак мамык киндергә канва белән затлы бизәкләр, әтәч сурәтләре чигелгән озын сөлгене солдатлар өй әйбере итеп кызыксынып карыйлар.* Ф.Хөсни. *Бәдриҗиһан да, Зәйтүнә дә әниләренә ярдәм итәләр: канва чигәләр, сөлге башлары, карават кырыйлары бәйлиләр.* М.Гариф. *Озак та үтмәстән ул башлары канва белән чигелгән ап-ак сөлгегә сөртенә-сөртенә килеп керде ---.* Ә.Фәйзи

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса нигезе; төп линиясе. *Мәхәббәт маҗаралары белән бәйле мавыктыргыч борылышлар, укучыны кулда тоту максаты белән уйлап табылган көтелмәгән хәлләрне сурәтләүгә маһирлык, сюжет канвасының иректе чигелүе ягыннан Т.Галиуллин әсәрләре Көнбатышта «Декамерон»нан башланып, ничә гасыр дәвамында яшәгән «азгынлык, алдакчылык романнары»н («плутовской роман») искә төшерәләр.* А.Әхмәдуллин

**КАНДАЛА** *и.* 1) Ярым каты канатлылар отрядына караган, кеше каны белән туклана торган паразит бөҗәк. *Кандалалар бигрәк тә борчый башлаган чак иде.* Ә.Гаффар. *Мөнирҗаннарның танкы дошманның әллә ничә ут ноктасын изде, пехотасын кандала урынына сытты, пулемёттан кырды. Кайнар сугыш булды ул.* Н.Әхмәдиев. *Сәндерә башларында, такта ярыкларында эреле-ваклы, төн буе кан эчкән кып-кызыл кандала иде.* З.Зәйнуллин

2) Үлән бете, телә, гөблә. *Аргамактан ат туа, кандаладан бет туа.* Мәкаль. *Ә ул канәфер – сирин инде – бер дә бер заманны, тәмам шау чагында яшел корттан – сасы яшел кандаладан – тәмам гаҗиз була.* Ә.Гаффар

3) *күч.* Явыз, кансыз, шәфкатьсез кешеләргә карата әйтелә. *Кандала син! Затсыз җаһил! Ялганлыйсың! Кушмадылар сиңа! Гаепләмә үткән заманны! Ахмак замана ахмак кешеләрне тудырмый!* Р.Батулла

◊ **Кандала оясы** Кандаласы күп булган бүлмә; кысан, тар, бик аз урынлы бүлмә, берәр җиһаз. *Кайберләре инде атна-ун көн тикшерелмичә, чират көтеп тора, бу кандала оясында озак тотудан зарланып, шау-шу кузгаталар.* С.Сабиров. **Кандала туе** Кандала күп булган урын. *Төрмә күңелсез, анда тычканнар һәм сәке тулы кандала туе.* М.Җәлил. **Кандала урынына сыту** Изү; мөмкинлекләрне чикләү. *Гитлер власте зур, көчле гигант машина әле, кандала урынына сыта ул сине.* Х.Камалов

**КАНДАЛА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан тармакланып үсә һәм ак яки сары чәчәк ата торган көчле исле үсемлек (элек кандала бетерү өчен кулланылган); *русчасы*: **клоповник**. *Ачыклыктагы кандала үләне ачы җилдә чайкала.* А.Расих. *Көнбагыш, горчица, шепкән кебек культуралардан һәм кандала үләненнән дә шактый күләмдә бал алырга мөмкин.* Г.Тавлин. *Ерактан күренгән шоссе юлындагы автомобиль утларына карап, ул күптән сөрелмәгән һәм кандала үләне басып киткән кыр аша кабереккә таба юл тотты.* Р.Зарипова

**КАНДАШ** *и.* **1.** Туган, кардәш кеше. *Эндәшегез, кандаш, нәселдәшләр, Гомер буе көтә Ил-табын...* Р.Әхмәтҗан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бертуган. *[Хәйруллин] бит минем кандаш энем.* Ә.Айдар. *[Карчык:] – Монысын кандаш туганыңнан төпчен, – дигәч, Рәхимҗан ирексездән телен шартлатты. Кандаш туган?! --- София аның сеңлесе булып чыгамы?* Н.Гыйматдинова

2) Тугандаш, кардәш; борынгы бабалары уртак булган. *Кайчандыр кандаш бабайлар җиңелгән Бәйгеләрне күңелемнән кичерәм.* М.Әгъләм. *Туганым, ыруым, кандашым, тыңлачы!* Р.Әхмәтҗан. *Ишә алмый кандаш халыкларны, Ишә алмый ятлар яу белән, Бармак белән төртеп тишкән кебек Алалар бит аны ау белән.* М.Әгъләм

3) Рухи яктан нык бәйләнгән. *Ай янында Зөһрә йолдыз калган, Кандаш булып Сөембикәгә...* Ф.Гыйззәтуллина. *Зур булмаган иҗат мирасындагы һәр шигырь ярдәмендә шагыйрь укучы – милләттәше, кандашы, рухташы белән сөйләшә.* С.Рәмиев. *Үз кандашы, галимголәмасы Аны саткан чакта ятларга, Бугаздагы ачы төер булып, Ватанына кайтты татар да!* Л.Лерон

**КАНДИ** *и. фар. а.х.* Бал кортлары өчен балга шикәр комы кушып әзерләнгән азык; сироп. *Корт анасы казаннарын читлеккә урнаштыру вакытына канди дип атала торган махсус азык әзерли.* Умартачылык

**КАНДИДАТ** *и. лат.* 1) Кая да булса сайланырга, җибәрелергә, ниндидер эш башкарырга һ.б.га билгеләнгән кеше. *Без Сездән иң лаеклы кандидатыгыз турында белешмә җибәрүегезне көтеп калабыз.* Г.Морат. *Чөнки мин –*

*баш технолог, күпләрнең уйлавынча, ул урынга лаеклы бердәндер кандидат идем.* Р.Мирхәйдәров

2) Нindидер вазифага, эшчәнлеккә һ.б.га туры килүче, иң лаеклы дип саналучы кеше. *Дәүләт иминлеге сагында торучы органнар үзләренә шымчы булырдай кандидатларны еш кына бәхеттән өлешсез калганнар, нәүмизләр арасыннан эзлиләр һәм табалар да.* А.Тимергалин. *[Рәүф:] Баҗайлыкка кандидатлар арасында Азат – беренче!* Л.Лерон

3) Кандидатлык диссертациясе яклаучыга бирелә торган гыйльми дәрәҗә һәм шул дәрәҗәне алган кеше. *Утыз бер яшьлек фәннәр кандидаты, төпле сүзле, чын мәгънәсендә эшлекле яшь галим, әлбәттә, республика җитәкчеләре күзенә дә чалына.* Ф.Галимуллин. *Фәннәр кандидаты булгач, дус-ишләре күптер инде...* К.Кәримов. *Әйттем мин сиңа җиде ел элек: энем, дидем, югары уку йортына кер, дидем, һич югы аспирантура тәмамла, фәннәр кандидаты бул, фәнни анализ белән яшәргә өйрәнерсең, дидем...* Ф.Баттал

**КАНДИДАТЛЫК** *и.* Кандидат булу. *Шул рәвешле мине ике мәртәбә исемлектән (Г.Тукай исемендәге бүләккә кандидатлыктан) төшереп калдырдылар.* Г.Бәширов. *Кандидатлыкка частьта гына кабул итсәләр, партия әгъзалыгына алу – Габделнур өчен истәлекле вакыйганың иң мөһим өлеше – Мәскәүдә икән.* Р.Кәрами. *Радио тарихын кандидатлык диссертациясе итеп якларга җыенган, КГБ архивларындагы материалларны да өйрәнгән бер журналистым бирде миңа аны.* Ә.Рәшит

**КАНДИДАТУ́РА** *и. рус к.* **кандидат** (*1 мәгъ.*) – *Кандидатуралар күрсәтегез, – дигәнемне дә игътибарсыз калдырдылар.* Т.Миңнуллин. *Хезмәттәшлек өчен кандидатуралар сайлап йөрүче пропагандистлар килгәч, Яббарда өмет уянды.* З.Хәким

**КАНДИЛ** *и. гар.* Берничә шәм яки электр лампочкалары куела торган зур шәмдәл. *[Карадәрвиш:] Мөлек сүрәсе, бишенче аять: хактыр ки, сезгә иң якын күкне кандилләр белән бизәдек.* Р.Батулла. *Гыйбадәт башланыр алдыннан, чиркәү хезмәткәре, люстраны ыргак ярдәмендә якынайтып, озын таяк башындагы кечкенә факел белән андагы шәмнәрне кабызып чыккан да кандилне үз урынына кайтканчы ук ыргактан ычкындырган.* К.Шакиров

**КАНДИЛЬ** *и. гр. бот.* Сусыл озынча алма бирә торган алмагач сорты. *---ә кайвакытта ике шәфталу яки сутлары сыгылып торган груша ала, әмма күзе күбесенчә кызлар бите төсле нәфис алсу кандиль алмасына төшә иде.* Р.Мирхәйдәров

**КА́НЕЧКЕЧ** *с.* **1.** 1) Кан эчә торган; кан белән туклана торган. *Тик канечкеч кигәвеннәр безелдәвеннән гайре тавыш ишетелмәде.* М.Әмирханов. *Хәнәфи җавап бирергә дип авызын ачкан иде, идәндәге, өстәлдәге кәгазьләргә күзе төште дә әйтер сүзен онытып катып калды: аларда дөньядагы иң кабахәт хәшәрәтләр ясалган иде – кыргаяк, таракан, елан, канечкеч ярканатлар...* М.Маликова. *Һәр чокыр, һәр канау мөлдерәмә тулы, кояш астында кайнап чыгардай була, канечкеч хәшәрәтләр өчен менә дигән инкубатор.* К.Кәримов

2) *күч.* Мәрхәмәтсез, каты күңелле, кансыз, явыз. *Сталинга, халыклар атасына, бөтен дөньяга бәхет, тынычлык өләшүчегә канечкеч капиталистлардан башка кем каршы булсын.* Н.Әхмәдиев. *Таланган кәрван ияләре, таланган калаларның башлыклары миңа илче күндерделәр: алар канечкеч башкисәр Кара Йосыфтан коткаруымны үтенделәр.* Р.Батулла. *Сугышның никадәр хәтәр икәнен белә иде ул. Әмма бу чаклы канечкеч һәм кешелексез булыр дип башына да китерә алмаган иде.* Г.Гыйльманов

**2.** *и. мәгъ.* Каты күңелле, явыз, мәрхәмәтсез кеше. – *Хәсән! Син бит безнең кан түгәргә теләмәгәнне беләсең, – диде Фәрит. – Соң шундый канечкечне тере калдырыйкмыни?* И.Хуҗин

**КАНҖЫГА** *и. иск.* Ияргә әйбер беркетергә җайлап куелган каеш бау (ауланган кошларны гадәттә шуңа бәйләгәннәр); *русчасы*: **торока.** *Чөймәгә бирсәң, карчыга бир, Канҗыгаңны буш итмәс.* Мәкаль

**КАНИ́КУЛ** *и. лат.* 1) Мәктәптә һәм уку йортларында укуларның тукталып тору вакыты; тәгътил. *Ул чаңгы шуам дисәң – көн саен берәр тау алыштырсаң да, кышкы каникулыңа җитәрлек.* К.Кәримов. *Мозаффар каникуллар вакытында Казандагы остаханәсендә эшләде.* М.Маликова. *Кифая безнең бусаганы атлап кергән көнне, каникулым да тәмамланмаган килеш, мин Казанга китеп бардым.* Р.Габделхакова

2) Парламент эшендә тукталып тору вакыты. *Моннан ике көн элек Дәүләт Советы Президиумының парламент каникулыннан соң беренче утырышы булып узды.* Ватаным Татарстан. *Билгеле булганча, ТР Дәүләт Советы депутатлары, җәйге каникулга киткәнче, Россиянең истәлекле даталар исемлегенә яңа истәлекле датаны – Россиядә ислам дине рәсми кабул ителгән көнне кертүне сорап Федерация Советы башлыгы Сергей Миронов исеменә мөрәҗәгать юллаган иде.* Казан утлары

**КАНИ́СТРА** *и. ингл.* Бензин, май, су һ.б.ш. сыеклыклар салып саклау, ташу өчен, тоткычы һәм борып ябыла торган герметик капкачы булган, металл, алюминий, пластик һ.б. материалдан эшләнгән савыт. *Чакырылмаган кунакларның тагын бер зыянлы ягы бар: каршыбыздагы чишмәгә суга чыктың исә, тиз генә алырмын димә: канистралап та, фляжкаларга, шешәләргә тутырып та һаман шул үткенчеләр су алып ята.* З.Кыдашева. *Айбулат якташлары белән мунчага баргач, «суынып киткән ич» дип, мичкә утынны шыплап тутыра һәм ишек төбендәге канистрадан утка соляр бөрки.* Татарстан яшьләре

**КАНИТЕЛЬ** *и. фр. к.* **кәнитил**. *Кыйммәтле асылташлар, энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш, алтын канитель сатучыларга сәүдә салымы салынмаган.* Р.Хәкимов. *[Госман] эшенә, заводның үзәк лабораториясенә барса, тагын канитель.* Э.Касыймов. *Вәзыйх ни дип тә әйтмәгәч, ул тагы сөйләп китте: – Вил Садриевичка әйтсәң, канитель тудыра.* Х.Камалов

**КАНИФАС** *и. лат.* Өстенә бизәге күпертеп тукылган җиңел тыгыз киҗемамык тукыма. *Күлмәклек канифас*

**КАНИФОЛЬ** *и. гр. махс.* Ылыслы агачларның сумаласыннан ясала торган уалучан, пыяласыман матдә; сәмих (сәнәгатьтә изоляция өчен һәм җилем буларак, шулай ук кыллы уен коралларының смычокларын ышку өчен кулланыла). *Карагай сумаласыннан – канифоль, скипидар, кабыгыннан таннин алалар.* Ботаника. *Монтажда эшләүче кызлар, бүлмәне канифоль исе белән тутырып, тырышып-тырышып ябыштыралар, ә үзләре астыртын гына яңа инженерга күз ташлап алалар иде.* И.Гази. *Наратның үзагачын эшкәртеп, эфир майлары, скипидар, канифоль, дегет алалар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КАНИФОЛЬЛӘ́Ү** *ф.* Канифоль, сәмих сөртү, канифоль белән ышку. *Дәүли бабай ашыкмыйча гына смычогын канифольли, берәүгә дә карамый гына скрипкасын чирткәләп рәтли.* А.Әхмәт

**КАНКАН** *и. фр.* 1) Аякларны югары күтәреп, бик тиз хәрәкәтләр ясап биелә торган француз эстрада биюе. *Шулай ук классик (вальс), эстрада (канкан), сюжетлы – барысы 20 ләп бию бар.* Идел таңнары

2) 4/2 музыкаль үлчәм; кызу темп. *Күтәренке рухтагы бәйрәм рәвешләренә композитор бию такмакларын өсти, хәрби марш һәм канкан чалымнарын куша.* Казан утлары

**КА́НКОЙГЫЧ** *с.* Кан коела торган, күпсанлы кешеләр үлеменә китерә торган. *Фронтларда канкойгыч каты сугышлар бара.* Х.Камалов. *Биредә Сәлах-карач илбасарларга каршы соңгы канкойгыч сугышлар оештыра.* А.Хәлим. *Рафаэльгә дә 1947 елның декабрь ахырларына кадәр, кулына корал алып, канкойгыч сугыш вакыйгаларында катнашырга туры килә.* Р.Мөхәммәдиев

**КАНЛАНУ** *ф.* 1) Канга буялу, канлы булу. *Шуннан соң калган кешеләрне тугры булучылыкка канланган кылыч үбү илә ямин иттереп, һәрбер кешегә ясак салды.* Һ.Атласи

2) Кан басу, кан каплау. *Кайгылардан, күрче, Канланды күземнең алмасы.* Һ.Такташ

**Канланып бетү** Тәмам канга буялу, канга бату. *Болыннан маллар кайта башлагач, авыл халкы, Алыпның чиләнеп, канланып беткән ярым үлек гәүдәсен дарагач янында калдырып, көтү каршыларга таралды.* Р.Батулла

**Канланып тору** Канланган хәлдә булу

**КАНЛЫ** *с.* 1) Кан каплаган, канланган. *Дерелдәгән керфекләре арасыннан чак кына күренеп калган дөнья атынып китте, һәм ул әнисенең канлы бите, алтын-көмешләре, чүпрәк-чапраклары белән буталып, урыныннан кузгалган җир белән әйләнергә тотынды.* А.Хәмзин. *Булат бәк, тән сызлавын басып, канлы авызыннан соравын тәкерде: – Барча Казан җиренең баш карачысын шушылай мәсхәрәләргә ничек батырчылык иттең, Хәмзә бәк?* М.Әмирханов. *Заһитның канлы күлмәкләре белән Фатыймаларга килүе үзенең «дуслары»ннан качуы иде.* Ф.Яруллин

2) Кан агып торган, кан саркып торган (яра һ.б.лар тур.). *Урамда булмасын, мәктәптә булмасын, ихатада булмасын, маңгае, тез башлары, терсәкләре канлы яра, кутыр белән каплана, күгәрмәгән җире калмый иде.* Ф.Садриев

3) Үтерешү, күп кешеләр һәлак булу белән бара торган (сугыш һ.б.). *Әмма Марат абый барыбер алар белән кешечә сөйләшүләр алып бара, русларны тынычландыру өчен, бөтен көчен куя, нәтиҗәдә, бу бәрелеш зур канлы вакыйгага әйләнми.* Ф.Бәйрәмова. *Ун көннәр чамасы барган канлы көрәш дәвамында ике яктан да югалтулар күп була.* А.Хәсәнов. *Волхов тирәсендә барган канлы сугышлар вакытында аларның часте чолганышта калып, М.Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә...* Казан утлары

4) *күч.* Рәхимсез, кешелексез

◊ **Канлы яшь** Зур кайгы, борчудан бик нык әрнү турында. *Яңа гына әле, яңа гына Язмыш суккан иде яңагыма, Канлы яшьләремне сөртәсөртә Йөгердем мин бары алга гына.* Ф.Яруллин. *Күздән түгел, йөрәгеннән Тама канлы яшьләре.* Ә.Ситдыйкова.

**Канлы якшәмбе** *тар.* 1905 елның 9 гыйнварында Санкт-Петербургта патшага петиция белән барган эшчеләрнең тыныч демонстрациясен (140 меңкешедән артык) патша гаскәрләреннән аттырган көн (революция башланып китүгә этәргеч биргән вакыйга). *Канлы якшәмбе бөтен илне тетрәтә, миллионлаган кешеләрдә самодержавиегә каршы көчле нәфрәт тудыра.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Тарихта ак таплар калырга тиеш түгел икән, нигә әле 1905 елның 9 гыйнварын, ягъни «канлы якшәмбе»не, Лена елгасы буенда йөзләгән эшчеләрне аттыруны да онытырга, ди?* Ватаным Татарстан

**КАННИБАЛ** *и. фр. кит.* 1) Кеше ашаучы; вәхши кеше. *[Хания:] Кем ул каннибал? [Аймәт:] Кеше ашауцы.* Т.Миңнуллин. *Ул үзен бер каннибал итеп сизде.* М.Кәбиров. *Рус чыганаклары, тарихи романнар, фильмнар, дәреслекләрдә, хәтта балалар өчен чыгарылган китапларда без – явызлык эквиваленты, сабый балаларны ашаучы каннибаллар, чәчәк аткан Русьне 300 ел буе «иго» чиктергән, талаган, изгән, каһәрләгән затлар буларак танытылабыз...* Казан утлары

2) *күч.* Чиктән тыш рәхимсез, ерткыч кеше. *Бел, каннибал, сиңа туры килер Җир астында бездә кышларга.* М.Җәлил. *«Демократия» дип җәелеп китеп, Комсызларга яман көч бирдек. Бандитлык һәм азгынлыкны татып, Калигула заманына кайтып, Илдә каннибаллар үстердек.* Ф.Тарханова

**КАННИБАЛИЗМ** *и. фр.* 1) Кеше ашаучылык. *«Тарих куласасы адәмнәрне янә вәхшилек һәм каннибализм чорына кайтара түгелме?» дигән зәһәр сорау туа.* А.Тимергалин. *Бу вакытта Яңа Гвинеядә каннибализм (кеше ашау) закон белән тыелган булган инде. Шуңа күрә кеше ашаучыларны төрмәгә ябып куйганнар.* Т.Миңнуллин

2) Бер биологик төрдәге хайваннарның бер-берсен ашау күренеше; төр эчендәге ерткычлык. *Шул сәбәпләр аркасында бер пробиркага бер урыннан*

*җыйган бер төрдәге үрмәкүчләрне тутырырга ярамый. Шуның өстенә алар арасында каннибализм (бер биологик төрдәге хайваннарның берберсен ашау күренеше) киң таралган.* Ә.Халидов

3) *күч.* Ерткычлык, рәхимсезлек. *Менә хәзер цивилизацияле каннибализм килде, мине ашарга җыенасыз...* Ф.Садриев

**КАНОНА́ДА** *и. фр. хәрби* Күпсанлы артиллерия орудиеләреннән озак вакыт яисә еш-еш ату һәм шуннан ишетелгән көчле гүләү тавышы. *Ул ашыкмыйча, чын күңелдән сөйләшә, ә мин аның сугышта дошман канонадасыннан катырак кычкырып тавыш ярыларын өзүен һәм карлыккан тамагыннан чыккан «ура» белән сугышчыларны атакага күтәрүен күз алдыма китердем.* Ә.Мушинский. *Пенути халкының аларга каршы торырлык көче юк. Моны шул яктан ишетелгән туплар канонадасы буенча да аңларга була иде, ләкин инде алар да ишетелми.* И.Хуҗин. *Әлегә монда тыныч, сугыш канонадасы ишетелми.* Р.Кадыйров

**КАНОНЕ́РКА** *и. рус хәрби* Диңгез яр буйларында һәм елга, күлләрдә сугышчан хәрәкәтләр алып бару өчен, артиллерия орудиеләре белән коралландырылган хәрби диңгез судносы. – *Мәсәлән, 1904 елның 9 февралендә, рус-япон сугышының беренче көнендә, – дип дәвам итте сүзен замполит, – ундүрт корабльдән торган япон эскадрасы безнең «Варяг» крейсерын һәм «Кореец» канонеркасын чолгап ала, ультиматум куя: «Бирелегез!»* Р.Кәрами

**КАНО́НИК** I *и. лат. дини* Католик соборындагы рухани

**КАНО́НИК** II *с.* Классик кагыйдәләргә туры килгән, гомуми кабул ителгән, үрнәк дәрәҗәсендәге. *Шигъриятендә ул ритмик төгәллеккә һәм рифма-кафия төгәллегенә өстенлек бирсә дә, дүртьюллыкларын арадаш кафия белән бизәргә дә ярата («Тама торгач» – а-а; а-а), сонет, баллада кебек Көнбатыштан иңгән каноник шәкелләр мөмкинлекләреннән иркен файдалана.* Т.Галиуллин. *Бүгенге көндә әсәрнең бердәнбер каноник тексты сакланып калган.* И.Гафаров. --- *сонет жанры татар шигъриятендә мантып китә алмаган, дөресе, бөтенләй булмаган, чөнки аның формасы каноник һәм бик катлаулы, мескен татар язучысының башы, акылы җитәрлек, теше үтәрлек кенә түгел.* Т.Галиуллин

**КАНОНИР** *и. нем. тар.* XIX йөздә Россиядә артиллерия солдаты; тупчы солдат. *Өч туп артына 15 е көнне крестьяннар ягына чыккан канонирлар баса.* В.Имамов. *Кызыксынган укучыларга аның «Крепость сугыша» дигән китабыннан бер өзек китерик: «23 июль, сугышның утыз икенче көне.... Күзләремне йомып, канонир почмагында ятам».* З.Зәйнуллин. *Канонирлар аттылар да аттылар. Тавыштан колаклар тонды.* Казан утлары

**КАНО́Э** *и. исп. спорт* Беркетелмәгән кыска ишкәкле җиңел спорт каегы. *Ишкәк ишү спорты ике төргә бүленә: академик ишү һәм каноэ белән байдаркаларда йөзү.* А.Гафиятов. *Каноэ – кыска ишкәкле җиңел спорт көймәсе. Төньяк Америка индеецларының чокып ясалган көймәсен элек шулай дип йөрткәннәр.* Г.Мөхәммәтшин

**КАНО́ЭЧЫ** *и.* Каноэда ишкәкче спортчы. *Бу юлы Россиягә югары бүләкләрне каноэчы Максим Опалев һәм синхронисткалар командасы китерде.* Ватаным Татарстан

**КАНСУ** *с.* Кан кебек, кан төсендәге. *Иң элек Камилнең күзенә ташланган нәрсә иңеннән-иңенә кансу ал ут шәүләсе белән капланган офык булды.* М.Әмир. *Кара күктә йөзгән китек ай да Ни өчендер аның күзенә, Канга баткан пилоткасы кебек, Кансу кызыл булып күренә.* М.Фәйзуллина. *Әле без бирегә килеп туктаганда гына, һава чалт аяз, көнбатышта офык буйданбуйга кансу кызыл иде.* С.Сабиров

**КАНСУЛАНДЫРУ** *ф.* Кансу төскә кертү. *Офык итәкләрен кансуландырып, моң гына булып кояш баеп килә.* А.Шамов

**Кансуландыра бару** Акрын гына, аз-азлап кансуландыру

**Кансуландырып җибәрү** Бераз, берникадәр кансуландыру

**КАНСУЛАНУ** *ф.* Кан төсенә керү, кан кебек булу

**Кансулана бару** Торган саен ныграк кансулану

**Кансуланып килү** Әкренләп кансулану

**Кансуланып китү** Кинәттән кансулана башлау

**Кансуланып тору** Кансу булып күренү

**КАНСЫЗ** *с.* 1) Каны аз, каны беткән. *Бу күзләр каный да белми. Алар кан эчеп кансыз калган.* А.Хәлим

2) Агарынган, каны качкан; төссез. *Гадәттән тыш яссы һәм кансыз йөзенең урта бер җирендә биек һәм бераз бөкре борынының төбе һәрвакыт бераз юешләнеп тора; тирәләре канлы, зур һәм акаюлы күзләреннән һәрвакытта бите буенча яшь ага.* Ш.Камал

3) *күч.* Рәхимсез, мәрхәмәтсез, явыз. *Шатлык та түгел иде ул, иң кадерле нәрсәнең юкка чыгуы аны бу вәхши дөньяга, кансыз чынбарлыкка тоташтырып торган элемтә җепселләрен шытыр-шытыр өзде шикелле ---.* З.Хәким. *Андыйларны шул борынгы заманнарда кансыз байлар үзләренең кальга-крепостьларында гына эшли торган булганнар...* М.Маликова. *Артык каты күңелле, кырыс, кансыз иде яңа рәис.* Н.Әхмәдиев

**КАНСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Кан качу, төссезләнү. *Йөзе кансызланып калган*

2) *күч.* Мәрхәмәтсезләнү, рәхимсезләнү, кешелексезгә әйләнү. *Ләкин әлеге сугышта кеше нәфислекне тоймас була, кансызлана дигән сүз дөрес микән?* Г.Бәширов

**Кансызлана бару** Торган саен ныграк кансызлану. *Соңгы елларда еш кына балаларыбызның шәфкатьсезләнә, кансызлана баруыннан зарлану ешайды.* Э.Шәрифуллина

**Кансызлана башлау** Кансызлануга йөз тоту. *Менә бит элек-электән шундый бер сүз бар: сугышта озак йөри торгач, кеше кансызлана башлый, аның йөрәге тупасланып, кешедә кыргый, хайвани тойгылар өстенлек ала, диләр.* Г.Бәширов

**Кансызлана төшү** Тагын да ныграк кансызлану

**КАНСЫЗЛЫК** *и.* 1) Кансыз булу, азканлылык. *Егет арык куллары белән кансызлыктан агарып беткән битен уа-уа, чурык-чурык борынын тарта-тарта мышкылдый башлады.* Р.Батулла

2) *күч.* Мәрхәмәтсезлек, рәхимсезлек, кешелексезлек. *Дус санаган кешесенең тирә-якта явызлыгы, наданлыгы, кансызлыгы һәм ришвәтче булуы белән дан тоткан прокурор икәнен белеп алгач, төрмәдәшләре дә канын кыздырырга үз өлешләрен кызганмаганнар.* Р.Мирхәйдәров. *Дөньяны аз булса да кабахәтлекләрдән, гаделсезлекләрдән, кансызлыктан һәм башка бик күп яман гадәтләрдән чистартып булмасмы диди, гомер буе язам бит инде, югыйсә тырышам, җан-фәрман киләм үземчә!... Ә ул пычрана гына бара...* Ф.Баттал. *Теленнән, моңыннан, милләтенең рухи тамырларыннан коточкыч тизлек белән ераклашып баручы бүгенге буын вәкилләренең күзендә – бушлык, мәнсезлек, кансызлык.* Казан утлары

**КАНСЫРА́У** *ф. иск.* Бераз кан чыгып, кан күренеп тору; канланып тору. *Әҗәленә дәва көтеп кансырый Кылыч белән туракланган барча җан.* Ф.Гыйззәтуллина

**Кансырап китү** Кисәк, көтмәгәндә кансырау

**Кансырап тору** Озак вакыт кансырау; кансыраган хәлдә булу. *Бер кулы белән кансырап торган икенче кулын каплаган каравылчы һәм үз батырлыгына үзе хәйран калган Карлыгачның карашлары очрашты.* А.Хәлим

**Кансырый төшү** Беркадәр кансырау

**КАНТ** *и. нем.* Кайбер киемнәрнең кырые яки җөе буйлап тегелә торган, гадәттә башка төстәге тар тасма. *[Габделхәйнең] Өстендә чиккән күлмәк белән кызыл кантлы галифе чалбар.* Х.Гарданов

**КАНТАР** *и. гр.* Нинди дә булса каты әйбернең формасыз зур кисәге (мәс., балчыкның, җирнең һ.б.). *Бераз тын алгач, [гәүдәне] аска томырдылар. Кантарларны куптарып, шатыр-шотыр төшкәне ишетелде.* Х.Камалов. *Шартлау бик көчле була, каты балчык кантарлары әллә ни ерак атылмаса да, вак кисәкләр шыбыр-шыбыр будка түбәләренә коела, әллә кайларга оча иде...* Р.Кәрами. *Аста эңгер-меңгер, төрлечә таралып яткан искитмәле дәү таш кантарлары, кыя ватыклары.* Р.Фәизов

**КАНТАРЛЫ** *с.* 1) Кантарлары булган, зур-зур каты кисәкләрдән, кантарлардан торган. *Аяк астында кантарлы кирпеч ватыклары.* М.Юныс. *Тәрәзә артында катып, тәмам бозлавыкланган кантарлы юлдан, буш арбасын яман доңгырдатып, бер атлы узды.* М.Хәсәнов. *Кантарлы тар юл буйлап җил-җил барды да барды [Исхак].* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Җиңел булмаган, сикәлтәле, катлаулы. *Алга таба шушы язучы кантарлы иҗаты белән әдип икәнен исбат итәргә тиеш.* Р.Батулла. *Тәүфыйк үзе дә элеккеге җилкенчәк, таукашларны актарып ташларга әзер торган эшче егет түгел, тормышның ачысын-төчесен байтак татыган, мәкер, хөсет дигән кантарлы тормыш сукмакларыннан узып, күптән инде киң юлга чыккан.* Җ.Дәрзаман

**КАНТА́ТА** *и. ит.* 1) *муз.* Солистлар, хор һәм оркестр өчен язылган зур күләмле тантаналы вокаль-инструменталь әсәр. *Хәер, Роза Мөхетдинова Җәүдәт Сөләйман сүзләренә иҗат иткән «Тамырлар» кантатасын тыңлаганда ук, Резеда Галимованы гамьле җырчы итеп хәтерләп калган идем.* А.Юнысова. *Күпсанлы җырлар, пьесалар, кантата, оратория, симфонияләр – һәммәсе музыкаль мирасыбызның алтын фонды.* С.Зыялы

2) *әд.* Аерым бер тантанага яисә мифологик темага багышланган, одага охшаш борынгы лирик шигырь төре. *Р.Харис – утыздан артык поэма, дистәгә якын шигырь циклы, йөздән артык җыр, романслар, кантаталар авторы.* Ф.Хәсәнова

**КАНТИЛЕ́НА** *и. лат. муз.* Салмак моңлы көй. *«Кантиленалар, кантиленалар гармониясе, тавыш барышы (голосоведение), ритм, авазлар колориты – болар барысы да кеше күңеле халәтен чагылдырган чаралар гына...» – дип язган [А.Н.Серов].* К.Гыйззәтов

**КАНТКОМ** *и. рус тар.* Кантон комитеты. *Кичә Голҗа канткомы аның эт-башын вә сыер-аягын бөек Мао Цзе-дун хәзрәтләренең коммунистлар фиркасеннән чыгарып, чүплеккә ыргытты!* А.Хәлим. *Хәлле кресть-яннарга карата кантком ике генә гамәлне белә: кулга алырга, мөлкәтен туздырырга.* Ф.Сафин. *Хәтта бераз ачылып та куйды ул безгә: «Кантком күләмендә дә, үзебезнең волость оешмасы тирәсендә дә фаш ителеп бетмәгән кулак агентлары бар. Шулар аяк чала», – диде.* М.Әмир

**КАНТЛА́У** *ф.* Кант тегү, кант тоту. *Күлмәкне кантлау*

**Кантлап бетерү** Тулысынча кантлау

**Кантлап кую** Кант тегеп чыгу; кантлап, әзер хәлгә китерү

**Кантлап тору** Сөйләү моментында кантлау

**Кантлап чыгу** Барысын да кантлау

**КАНТЛЫ** *с.* Кант тотылган, кант тегелгән. *Кантлы итәк*

**КАНТОН** *и. фр.* 1) Кайбер дәүләтләрдә административ-территориаль берәмлек. *Канаданың Квебек провинциясе, Швейцариянең кантоннарында булган хокукларның уннан бере дә юк иде әле ул «суверен» республикаларда.* Ватаным Татарстан

2) *тар.* XVIII–XIX гасырларда Башкортстандагы административ округ. *Аның шулай икәнлеген типтәрләрнең бер төбәктә булмыйча, таралып утырулары да раслый (Уфа кантонында – 6278 кеше, 4 волостьта; Бөре кантонында – 8348 кеше, 8 волостьта; Тамьян-Катай кантонында – 5703 кеше, 1 волостьта; Бәләбәй кантонында – 1633 кеше, 5 волостьта; Эстәрлетамак кантонында – 428 кеше, 2 волостьта).* Д.Исхаков. *[М.Галәү] 1919 да Башкортстан АССР Мәгариф халык комиссариатының кантон бүлегендә, 1920 дә Оренбург, Мәскәү шәһәрләрендә мәгариф системасында һәм нәшриятларда эшли.* Казан утлары

2) *тар.* Татарстанда 1921–1926 еллардагы административ-территориаль берәмлек. *Шул рәвешле Татарстан 67,126 квадрат километр мәйдан җирлектәге һәм баштарак 10, соңрак*

*13 кантоннан тора торган республика буларак барлыкка килә.* Казан утлары. *Булачак шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Чаллы кантонының Иске Теләнче авылында дөньяга килә.* Казан утлары

**КАНТОНАЛЬ** *с.* Кантон күләмендәге. *Кантональ сайлаулар*

**КАНТОНЛЫК** *и.* Кантоннар системасы, кантоннар идарәсе. *Башкорт җирләрендә кантонлыклар бетерелгәч тә, ул, гәрчә элекке байлыгы кимесә дә, элекке дәрәҗә китсә дә, һаман да бөтенләй егылудан ерак иде.* Г.Ибраһимов

**КАНТУР** *и. рус сөйл.* Контора. *Мин эшләгән кантур пичәтен югалтты.* А.Хәлим. *Сәлим урыныннан кузгала: – Бар, кантурга керә тор, анда ачык.* Р.Габделхакова. *Ул шулай ук кантур, амбар ягына барып кайтырга да, иртүк Яңавылга базарга чыгып йөгерергә дә иренми.* Н.Фәттах

**КАНТЧЫ** *и. филос.* И.Кант фәлсәфәсе тарафдары

**КАНТЧЫЛЫК** *и.* XVIII йөздә яшәгән алман фәлсәфәчесе И.Кант һәм аның тарафдарларының идеалистик тәгълиматы

**КАНУ** *ф. сир.* 1) Басылу, канәгатьләнү (үч, ачу, үпкә, сусын һ.б.). *Еректагы су белән сусын канмый.* Мәкаль

2) *күч.* Игеннәр, кар һ.б. суга туену турында

3) *күч.* Гомумән тую, туену, җитәрлек алу

**КАНУН** *и. гар.* 1) *дини* Шәригать хөкемнәре. *Моны татар әхлагына, ислам кануннарына таянып эшләп була.* Р.Юныс. *Күз алдымда юдырып, кәфенлек үлчәп, ахирәт күлмәге кидереп, ислам кануннары белән күммәгәч, күңелем суынмыйча калды...* К.Кәримов. *Аллаһы Тәгаләгә чын күңеле белән ышанган һәм аның кануннары буенча яшәүче дин әһелләре, бәхеткә, бар, һәм Рәсәйнең якты киләчәге шундый кешеләрнең күплегенә дә бәйле.* Казан утлары

2) Хакимият тарафыннан кабул ителгән һәм югары юридик көчкә ия норматив акт; закон. *Русия кануны нигезендә никахны теркәгәндә дә, аерылышканда да, кешеләргә милләтен күрсәтү мәҗбүри түгел.* Л.Харрасова. *2010 елның 31 декабрендә Русия президенты Дмитрий Медведев төбәк башлыкларын президент дип атауны тыю турындагы канунны имзалады.* Р.Бикмөхәммәтова. *Кертемнәргә бәйле яңа кануннар Татарстан эшмәкәрләре җилкәсенә дә авыр йөк булып төшкән.* Ватаным Татарстан

3) Җәмгыятьтә формалашкан кагыйдә, калыплашкан гореф-гадәт; традицион, мәҗбүри булып саналган норма. *Әмма ләкин тормышның үз кануннары бар иде.* А.Хәлим. *Һәр милләтнең үз гореф-гадәтләре, үз яшәеш кануннары.* И.Иксанова. *Таһир тиз сиземләде: бу гаилә патриархат кануннары белән яши.* А.Хәсәнов

4) Теге яки бу өлкәнең үзенә хас кагыйдәләре, нормалары. *Әгәр син, рәссам, бу кемсәнең сурәтен ясыйсың икән, бу канунны боза алмыйсың: җемелдәгән күзләр урынына ботак тишеге утыртасың.* Н.Гыйматдинова. *Дөрес, сәхнә кануннары кушканча, залга арт белән басу тыела.* К.Кәримов. *Бел, сатлыкҗаннарга гафу юк – караклар канунының иң мөһиме шул.* Р.Мирхәйдәров

**КАНУНИ** *с. гар. кит.* Канунга бәйләнешле; канунга әйләнгән. *Ул – ханбикә! Барча Казан җиренең кануни ханбикәсе!* М.Әмирханов. *Әдәбият белеме жанрларны кануни һәм кануни булмаганга аера.* Ф.Хәсәнова

**КАНУНИЯТ** *и. гар. кит.* 1) Канунилык, законлылык. *Хакимлек вертикален ныгыту, Русия эчендә кануният системасын тәртипкә салу, «олигархия» дигән төшенчәне китереп чыгарган күренешләргә чик кую – Владимир Путин Русия сәяси скульптурасын өр-яңадан шулай сынландыра башлады.* Кызыл таң. *Бүгенге демократик кануният бу мәсьәләне чишәргә мөмкинлек бирә.* Безнең гәҗит

2) Закончалык. *Бу кануният татарның чын милли әдибе булган Г.Исхакый өчен аеруча хас.* Х.Миңнегулов

3) Законнар җыелмасы

**КАНУНЛАШУ** *ф. сөйл.* 1) Канун көчен алу; рәсмиләшү

2) Кагыйдәләшү, калыпка салыну. *Шул рәвешле декабрьлар, частьлар, семьялар дип язу канунлаша.* Казан утлары

3) Гадәткә керү, ныклап урнашу. *Чөнки әдәбиятыбызда «икона – тәре» белән «крест – хач» мәгънәләрен бутау инде канунлашкан.* Р.Батулла. *Гомумән, Уралда туып үскән кешеләрнең канунлашкан бер гадәте бар: үзләре сайлаган юлдан барып, эшләрен басынкы рәвештә горурлык хисе белән башкара.* Кызыл таң

**КАНУНЛЫ** *с.* 1) Законлы, закон тыймаган; закон төсен алган, канунлашкан. *Совет чоры котыра башлаган узган гасырның утызынчы елларыннан башлап күпме язылган андый канунлы калыптагы эчпошыргыч әсәрләр.* М.Галиев

2) Билгеле бер кагыйдә кысаларында булган, кагыйдәгә туры килгән. *Ләкин мондагы кисәкләр, ул сүзләр, ул төрләр кебек, кагыйдәле, канунлы түгелләр, ягъни болар теләсә нинди сыйфатларга билгеле бер кагыйдә буенча ясалып кушыла алмыйлар ---* . Г.Алпаров

**КАНУНЛЫК** *и. к.* **закончалык**. *Менә бу сыйфатлар билгеле бер канунлыкта Тукай шигырьләренең күпчелегендә дә күренә.* Г.Нигъмәти

**КАНУНЧЫ** *и.* 1) *сир.* Канун, закон белгече

2) *күч.* Кануннарны, җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләрне һ.б.ны яхшы белүче, аларга таянучы кеше; формалист. *--- бик артык канунчы, формалист дип танылган рәис Биганов алдына үзен, үзенең гаепләнүчесен рәсми яктан һаман үгәйләтелгән итеп күрсәтергә бәһанә (сылтау) табылсын өчен, карт адвокат юри бу ике шаһит турында каты бәйләнде.* Р.Гайфуллина. *Җир йөзендә күпме акыллы кеше дингә өйрәтүче-канунчы тукыганга оятсыз рәвештә «ышана»!* Җ.Ильясов

**КАНУНЧЫЛЫК** *и. к.* **догматизм**. *Шул ук вакытта ихтималлык теориясе һәм статистик канунчылыклар очраклылыкларның, ахыр чиктә, билгеле зарурлыкларны чагылдыруын аңларга мөмкинлек бирделәр.* К.Гыйззәтов. *Без, төрки-мөселман татарлары, табигый рәвештә татар теле канунчылыгына яраклаштырылган гарәп*

*имласына кайту ягында.* И.Әмирханов. *Шәрыкнең традицион канунчылыгыннан Европа тибындагы баскычына күчеш күренеше буларак, декадентлык татар әдәбияты тарихында шактый тирән эз калдырды.* Казан утлары

**КАНЦЕЛЯРИСТ** *и. рус сөйл.* 1) Канцеляриядә эшләүче, канцелярияче

2) Берәр эшне башкаруда артык формальлек күрсәтүче. *Андый җаваплы басманы матбугатка югары администрациядәге бер-ике «канцелярист» кына әзерләмәскә, моңа белгечләр дә катнашырга тиеш дигән тәкъдим кертәм.* А.Тимергалин. *Хәзер бөтен группаны үз ягына аударды, инде «справка» дип авызыңны ачсаң, көлке генә килеп чыкмасмы? Нинди формалист, нинди канцелярист булдың, димәсләрме?..* Н.Фәттах

**КАНЦЕЛЯ́РИЯ** *и. лат.* Теге яки бу оешманың эш кәгазьләре, хатлар һ.б. белән эшләү бүлеге һәм шул бүлек урнашкан бүлмә; кәнсә. *Канцелярия башлыгы сөйләшү тәмамланганнан соң бик озак аптырашта утырды.* Р.Мирхәйдәров. *Рядовой Зәйнуллинга борылды: – Бүген кереп, канцеляриядән увольнительный ал. Ун көнгә ял синңа.* З.Зәйнуллин. *Карандаш, блокнот биреп утырыр өчен белгеч булу кирәкми, канцеляриядә эшлим, исемем Света.* Г.Бәйрәмова

**КАНЦЕЛЯ́РИЯЧЕ** *и.* 1) Канцеляриядә эшләүче

2) Канцелярия эшендә формальлек күрсәтүче; канцелярист

**КАНЦЕЛЯ́РИЯЧЕЛЕК** *и.* Эш йөрткәндә, берәр эшне эшләүдә артык, урынсыз формальлек

**КА́НЦЛЕР** *и. нем.* Кайбер дәүләтләрдә идарә хезмәтендәге югары вазифа һәм шул вазифаны башкаручы кеше. *Хан Акмалның бу сүзләреннән соң икеөч атна үттеме-юкмы икән, Горбачёв соңрак дуслашкан канцлер Коль аны «хөрмәтле немец» дип кенә йөртә башлады, хәтта аның ялганлау осталыгын Геббельснукына да тиңләп ташлады.* Р.Мирхәйдәров. *Конгресста катнашучыларны үзләренең резиденцияләрендә Германиянең Федераль Канцлеры Ангела Меркель, Берлинның идарәче бургомистры Клаус Воверайт кабул итте.* Казан утлары

**КА́НЧА** *а. диал.* **1.** Күпме, ничә. *Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван, Килеп кичте җиһандай канча илләр!* Дәрдемәнд. *Кан-яшьләрем сауган кардәшлекне аңлый алмый канча ел барам.* З.Мансуров. *Илтифат: биш гасырлык коллыгы чорында урыс бәхете өчен татар аз кырылдымы? Канча миллион?* А.Хәлим

**2.** *рәв. мәгъ.* Никадәр, ничаклы. *– Әнә кандай чибәр кимпер йөреп ята, авылда канча буш йортлар үксеп утыра, кайт та кил!.. – диде инде чишенеп тә өлгергән Иркен ага.* А.Хәлим

**КАНЫГУ** I *ф.* 1) Юк-бар сәбәпләр белән бәйләнеп йөдәтү; бәйләнеп тынычлыкны алу. *Чирлегә чебен каныга.* Мәкаль. *Аудиториягә җил-җил атлап керә, башка укытучылар кебек хәлахвәл сорашып тормый, шундук лекциясен башлый. Студентларны «батыру», каныгу ише нәрсәләрнең эзе дә юк.* А.Гыймадиев. *[Римма:] Мин теге бәйләнчектән качып килдем, Рая. Нишләргә дә белмәдем, һаман миңа каныга.* Х.Камалов. *Көне-төне мир эше белән йөргәнгә рәхмәт юк, һәммәсе шул бер Гыйбашка каныга.* Г.Бәширов

2) *күч.* Берәр нәрсә белән артык мавыгу, кызыксыну, шуңа бирелү. *Китапка каныгу*

**Каныга башлау** Каныгырга тотыну. *Менә шул егеткә Галәветдин бигрәк тә каныга башлады.* Р.Мөхәммәдиев. *Башка линиягә күчү өчен, әйбәт характеристика кирәк. Ә миңа соңгы вакытта капитан каныга башлады.* М.Юныс

**Каныга бирү** Бернигә дә карамый каныгу, каныгуны дәвам итү

**Каныгып алу** Бер вакыт аралыгында каныгу. *Тилгән-карчыга да, бер каныгып алса, чукымаган бер җирен калдырмас.* А.Хәсәнов

**Каныгып тору** Даими каныгу. *Имтиханнарына да исе китмичә (бишенче курска укытучылар артык каныгып тормый), койрыгын сыртка салып, әти-әнисенә, туган-тумачаларына, күрше-күләнгә, чыбык-чабыкка, энесе Самат кебек эбер-чебергә, этенәбетенә күчтәнәчләр җыйды Зөлфия.* Т.Галиуллин

**КАНЫГУ** II *ф.* Кан төшү, канлану. *Күз каныгу*

**Каныгып бетү** Тәмам каныгу

**Каныгып тору** Бертуктаусыз каныгу; әле бераз каныгу

**КАНЬОН** *и. исп. геогр.* Су ашап ясалган тирән, текә ярлы тар елга үзәне. *Нәтиҗәдә 8,2 метр тирәнлектәге бетон каньонда сакланган, тутыкмый торган корычтан эшләнгән савыт тулысынча юкка чыга.* Ватаным Татарстан. *Бу – сигез километрга сузылган гаҗәеп матур Юпшар тарлавыгы. Югарыга күтәрелгән саен, юл тарая, һәм 500 метр араны үз эченә алган каньон барлыкка килә.* Ватаным Татарстан

**КАН-ЯШЬ** *җый. и.* 1) Тирән кайгы, авыр газап; җәбер. *Илгә-көнгә кан-яшь, үлем, кара кайгы, хәрабәләр, бихисап газаплар алып килгән сугыш Таңчулпан авылын да ярты ел дигәндә ир-атсыз калдырды.* Б.Камалов

2) Авыр кайгы, тирән хәсрәттән түгелгән күз яше. *Ходай аңа катырак җәза сайлады: Чатан Рауза үзе җәфалаган, кан-яшь койдырган, төрмәсөрген юлларында йөрткән авылдашларының җирәнүле, нәфрәтле карашы астында яшәде дә яшәде...* Ф.Баттал. *Иңнәремдә авыр кайгы. Көч-хәл белән Атлап барам, кан-яшь белән юлны «сыйлап».* Э.Шәрифуллина. *--- эткәсен – укымышлы мулла, аннан мөгаллим булган Сәхипгәрәйне – балаларын канъяшь елатып алып чыгып китүләре истән чыкмады...* Р.Мулланурова

◊ **Кан-яшь түгү** Тирән кайгы, авыр җәбер-газап кичерү. *Барча халык куркышып кан-яшь түгә.* Р.Мәрданов. *Ни хәл итәсең, туган авылы аны үгисетте, әткәсен-әнкәсен кан-яшь түктереп, җиде ятлар арасына озатты.* А.Әхмәтгалиева

**КАҢ** *иярт.* Казлар кычкырган тавышны белдерә. *Карга мең карылдаса да яз булмас, каз бер каң итсә дә яз булыр.* Мәкаль. *Әнә ничек ак каз, каң-каң килеп, Канатларын җилпеп кагына.* М.Гафури

**КАҢГЫ** *и. бор.* 1) Күчмә тормышта көнкүреш кирәк-ярагы төяп йөртелә

торган бик зур арба. *Тотыш углан [кеше исеме] яткан ялгыз тирмәне, сүтеп тормыйча, киң арбага – каңгыга урнаштырдылар.* Н.Фәттах

2) Сугыш сәфәрендә кораллар төялгән арба, күчмә арсенал. *Кыз бала – каңгыда яткан ук.* Мәкаль

**КАҢГЫЙ** *и. иск.* Әкияттәге тау иле, «ерак һәм билгесез җир» мәгънәсендә. *Моннан соң аларның бик еракка – таулар иленә, Каңгый җиренә күчеп китүләре хәбәр ителә.* Ф.Хатипов. *Менә әтиәни белән Каңгый иленә үк – әкиятләрдә сөйләнә торган ерак-ерактагы таулар иленә дә барып чыктык.* М.Хуҗин

**КАҢГЫЛ** *с. диал.* Киңчә, гадәттәгедән киңрәк. *Каңгыл сөякле бит*

**КАҢГЫЛДАТУ** *ф.* Каз кычкырганга охшашлы өзек һәм яңгыравыклы аваз чыгару. *Зиннәт гармунын каңгылдатып бер тартып алды.* Г.Бәширов

**КАҢГЫЛДА́У** *ф.* Каң-каң итеп кычкыру. *Тугай болынында казлар ап-ак көтү булып җыелышалар, каңгылдашалар, тегермән буасында чумачума туйганчы йөзәләр.* Р.Хафизова. *Әнә ишегалды тузанында тавыклар коена, капка төбенә су буеннан каңгылдап казлар кайтып җиткән.* Ф.Бәйрәмова. *Син инде, Мәхмүт энем, ялгыз каз шикелле каңгылдап, болай ялгыз йөрмә.* С.Шәкүров

**Каңгылдап алу** Кыска вакыт эчендә, бер ара каңгылдау. *Урыс капка шапылдап ябылды, ишегалдында кунаклаган казлар каңгылдашып алдылар, абзар куначасыннан сузып кына карлыккан әтәч кычкырды.* Я.Зәнкиев

**Каңгылдап җибәрү** Кинәт кенә каңгылдау, каңгылдаган тавыш чыгару. *Ана каз каңгылдап җибәрде дә, томшык кырыйларыннан су чәчрәтәчәчрәтә, башын муены җиткәнче югары чөя-чөя ашарга кереште.* Ә.Гаффар

**Каңгылдап кую** Бер мәртәбә каңгылдаган тавыш чыгару. *Ходай рәхмәте белән, я берәр каз каңгылдап куя, я чыбык-мазар сынган тавыш ишетелә дә, куркуыннан Зарифның кочагына тагын да ныграк сыена иде Сания.* Г.Әдһәм. *Миңа җавап биргәндәй, арттарак барганы каңгылдап куйды.* Татарстан яшьләре

**Каңгылдап тору** Берөзлексез каңгылдау

**Каңгылдап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, билгеле бер вакыт аралыгында каңгылдау

**КАҢГЫРА́У** *к.* **каңгыру**. *Чит җирләрдә каңгырау*

**КАҢГЫРУ** *ф.* 1) Миңгерәү, аңгыралану, тинтерәү, онытылу, зиһенсезләнү. *Ярлының хатыны үлсә, башы каңгыра.* Мәкаль. *Аһ орып каңгырмавың, ыгы-зыгыга ашкынып тыкшынмавың, онытылып шатланмавың хәерле – шушы кагыйдәгә табынып яшәде Айгузин.* М.Хуҗин. *Барасы чишмәңә барып җитә алмый каңгырып, юынтык сулар янында юанып йөрерсең.* С.Сөләйманова

2) Урын эзләп аптырау; эзләгәненне таба алмыйча йөрү. *Кайчан карама, урам буйлап кемнәр терлеге каңгырып йөри дисәң, шуларныкы булып чыга.* А.Шамов. *Сандугачлар сусап су тапмыйлар, Баласыз каз ялгыз каңгыра ---.* Х.Әюпов

3) Күнекмәгән, ят җирдә, гадәтләнмәгән шартларда, чит илдә яшәү. *Шулар аркасында үзебезнекеләр белән Нижнийга яңа корабль алырга китми калдым. Менә хәзер монда каңгырып ят инде.* С.Сабиров. *Кемдер хәләл йортыннан куылып, кайталмыйча чит җирләрдә каңгыра.* Р.Батулла

**Каңгырып бетү** Бөтенләй, ахыргы чиккә җитеп каңгыру

**Каңгырып йөрү** Әле, хәзерге вакытта каңгыру. *Нигъмәтҗан һаман эш таба алмый каңгырып йөри, мәхлук...* Ә.Фәйзи. *Адашкан торна баласыдай ике-өч көн каңгырып йөрдем дә... киңәшкә киттем!* А.Гыйләҗев. *Йөгердем бәпкәне эзләргә. Ярты юлда үлән арасында каңгырып йөри, кадалып киткере!* Г.Якупова

**КАҢКАЮ** *ф.* Муенны сузган килеш катып калу. *[Бәпкәле каз бәпкәсенә:] – Нишләп ялгыз башыңны каңкайтып, минем балаларым янында йөрисең? – ди.* Г.Галиев

**КАҢСА** *и. диал.* Махсус формадагы сөяк төрепкә, челем. *Каңсасын бер дә авызыннан төшерми торган Корман агай – бик гади кеше.* Ш.Маннур

**КАОЛИН** *и. кыт.* Фарфор, фаянс, кәгазь, резин, тукыма һ.б. җитештергәндә кулланыла торган утка чыдам үзле ак яисә ачык төсләрдәге балчык. *Измәгә каолин кушу*

**КАП** I *и.* 1) Зур капчык. *Авыл халкы игенчелек, яшелчә үстерү белән, кыш көннәрендә чабата үрү, кап сугу, җеп эрләү, киндер сугу эшләре белән шөгыльләнгән.* Ф.Гарипова

2) Кәгазьдән ясалган кечкенә пакет. *Авырган вакытта, әнисе аңа ике кап тәмле конфет алып килгән иде.* Юлдаш

3) *сир.* Футляр, тышча

4) Конверт. *Хат кабын ертып, күземне язу юлларына төшердем.* Ә.Айдар

5) *иск.* Тире, мех. *Күреклегә куян кабы да килешә.* Мәкаль

6) Тартма. *Сервантыңның аскы тартма төпкеленнән бер кәгазь кап алып, өстәлгә куясың. Кап тулы фотолар: «Шәриф җибәргән иде, – дисең. – Ленинградта үзе төшергәннәре!»* Р.Юсупова. *Утыз җиденче размерлы туфлидән бушаган кап визит карточкалары белән шыгрым тулы: егерменче гасыр азагында башланган базар ислахының соңгы унбиш елы сыйган.* К.Кәримов

7) Азык-төлек продуктлары (мәс., чәй, шикәр, тоз) һәм шырпы, кнопка кебек вак-төяк әйберләр салу өчен, каты кәгазьдән ясалган тартмачык. *Арбада зур гына тартма бар иде. Аны өйгә алып кереп, өстәлгә конфетпрәннекләр, биш-алты кап шикәр алып куйды.* Ф.Садриев. *Төрле тәмтомнар арасында күзне кызыктырган цейлон чәенең бер кулга икешәр генә кап бирелүен белеп алгач, мин, бөтен сәләтемне эшкә җигеп, сатучы ханымны авызыма караттым.* М.Галиев. *Кульяулык, көзге, ирен буявы ишеләр арасыннан дару капларын аерып алды, шытыр-шытыр ачып, вак төймәләрне учына җыйды.* М.Маликова

◊ **Кап булу** Кап кебек зур булу. *Ну бер сыйлый идем үзегезне! Бүксәләрегез кап булганчы ашата идем.* А.Гыйләҗев. **Кап корсак** Зур корсак. *Буаз биядәй кап корсаклы, кәҗә сакаллы димче боярларны күп күрде Үрбәт.* М.Әмирханов

**КАП** II *кис.* Нәкъ, төп-төгәл. *Шул мизгелдә иртәнге күктән түбәнтен генә яшен ташы очып узды, аның якты эзеннән түгәрәк аланны кап урталай ярган куш салават күпере пәйда булды.* А.Тимергалин. *Ул ара да булмый, әлегә юньле-рәтле танышып та өлгермәгән Кәҗә Зөфәр абзалары монда, Татарстанның кап уртасы булган Чаллыда, Чаллының уртасы булган Үзәк Базар мәйданында --- «Баламишкин» көйләренә үзе үк җырлап та җибәрде...* А.Хәлим

**КАПЕ́ЛЛА** *и. лат.* 1) *муз.* Хор һәм оркестрдан торган катнаш ансамбль. *Капелла чын капеллага якын булырга тиеш ---.* Г.Әпсәләмов. *Мондый җырлар 1943 елның җәендә музыкаль капелла репертуарында күп булган.* М.Җәлил. *Бу көнне Санкт-Петербургның дәүләт академия капелласы бинасында Татарстан сәнгать осталары катнашында концерт та булды.* Казан утлары

2) *муз.* Билгеле бер составтагы оркестр һәм кайбер зур симфоник оркестрларның атамасы. *Музыкаль капеллага ышанычлы кешеләр тупларга кушкан Муса!* Р.Мостафин. *Мусаның һәм иптәшләренең ышанычын һәрьяклап казанган, иптәшлеге, турылыгы хәтәр эшләрдә сыналган шул Гайнан Кормаш «Җыр-музыка капелласы»на язылуга иң нык каршы торучыларның берсе булды.* Г.Әпсәләмов

3) Католик һәм англикан архитектурасында аерым кешеләргә гыйбадәт кылу урыны буларак яисә чиркәү җырчыларын урнаштырыр өчен һ.б. храм яки сарай янында төзелгән кечкенә бина, часовня; ишегалды чиркәве

**КАПЕЛЬДИ́НЕР** *и. нем. иск.* Театрда, концерт залында билет тикшереп, урыннар күрсәтеп һәм тәртип булсын дип күзәтеп торучы

**КАПЕЛЬМЕ́ЙСТЕР** *и. нем. муз.* XVI–XVIII гасырларда – инструменталь һәм вокаль капелла җитәкчесе, XIX гасырдан – гомумән дирижёр, хәзер – хәрби оркестр дирижёры. *Үзенең гражданлык бурычын аңлаган, үгетләүгә тиз бирелә торган Сәйдәш Беренче татар укчы бригадасына трубачы һәм капельмейстер булып китәргә ризалык бирде.* Р.Низамиев. *Ниһаять, капельмейстер кулын күтәрде, илле-алтмыш кешелек оркестр марш уйнап җибәрде.* Г.Әпсәләмов

**КАПИЛЛЯР** *и.* 1) *физ.* Бик нечкә каналлы көпшә. *Пыяла капилляр*

2) *биол.* Нечкә канал (мәс., үсемлек, агач күзәнәкләрендә һ.б.да)

2) Кан тамырлары, лимфатик системада иң нечкә тамыр. *Минә шул нечкә кан тамырлары – капиллярлар – бик зур функция үтиләр: алар канда эрегән матдәләрне күзәнәкләргә чыгару һәм күзәнәктән канга кирәкле матдәләрне алу, сеңдерү эшен башкаралар.* Ф.Бәйрәмова. *Донорлардан венадагы чиста канны алалар. Капиллярлардагы һәм тире астындагы оешкан канны алу белән аны берничек тә чагыштырып булмый.* Ирек мәйданы. *Сарымсакның сидек, үт суы куу, кан тамырларын киңәйтү һәм капиллярларны ныгыту үзлекләрен дә билгеләп үтәргә кирәк.* Ватаным Татарстан

**КАПИТАЛ** *и. лат.* 1) *икът.* Эш барышында, җитештерү процессында тупланган кыйммәтле кәгазьләр, акча, материаль байлык һ.б.ш. *Милли капитал ныгып бергә туплангач, безнең сәнәгатьчеләр, сәүдәгәрләр һәм финансчылар үз илеңдә ялчы түгел, хуҗа булырга кирәклеген һәм мөмкинлеген ахырынача аңлап алгач, мондый диктатура хәзерге вазгыятькә җавап рәвешендә һичшиксез барлыкка киләчәк.* Р.Хәкимов. *Даими үсеп барган капитал иясе буларак, мин җитештерүгә йогынты ясый алам.* Р.Мирхәйдәров. *Бүген, шәхси эшмәкәрлек, капитал мөнәсәбәтләре алга чыккан вакытта, әлеге караш белән килешү кыен.* Ә.Закирҗанов

2) *тар.* Марксизмда: яллы эшчеләр хезмәтен кулланып, хосусый милек иясенә табыш китерә торган кыйммәт

3) *сөйл.* Акча байлыгы; байлык. *«Читен тормыш! – капиталга табынмасаң...» Әйе, бүген капиталга табынучылар заманы килде.* А.Тимергалин. *Ә бу чорларга Әбү-Бәкер агасы белән бергә байтак капитал туплап өлгергән булырга тиешләр.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Кадерен белерлек нәрсә, иң кирәкле, иң мөһим нәрсә. *Ә җир ул – дөньяда иң зур капитал!* З.Хөснияр

**КАПИТАЛИЗМ** *и. икът.* Җитештерү чаралары хисабына тупланган шәхси милек, яллы хезмәт, гражданлык җәмгыяте, базар мөнәсәбәтләренә, ирекле эшмәкәрлеккә һ.б.га корылган иҗтимагый строй. *Чигенүләр Рәсәйдә капитализм төзи башлау һәм ашыгыч рәвештә миллионерлар-миллиардерлар ясау – «буржуйлар» сыйныфын хасил итүгә бәйле микән әллә?* Р.Юныс. *Матди байлык рухи байлыкны тезләндерүен дәвам итә. Илдә кыргый капитализм үр алды.* Р.Фәйзуллин. *Капитализмга беренчеләрдән булып коммунистлар партиясенең өлгер вәкилләре барып керде.* А.Гыйләҗев

**КАПИТАЛИСТ** *и. лат.* 1) Капиталистик җәмгыятьтә хакимлек иткән сыйныф вәкиле: капитал хуҗасы, яллаган эшчеләрне эксплуатацияләүче. *Мәсәлән, ул менә шушы кечкенә хакыйкатьне аңламый: әгәр бу инсаннар хезмәткә баралар икән, нигә аларны эшләтүче хуҗа – капиталист – автобусларны җитәрлек бүлми?* А.Хәлим. *Саттарның галәмгә очуына өч атнадан артык вакыт үткәч, дөньядагы аракы заводларының хуҗалары – күп миллиардлар туплаган капиталистлар – баш вата башлаган: кешене шул гомер буена бер локма ризыксыз яшәтә, тәүлегенә унбиш-уналты сәгать эшләтә ала торган Минзәлә аракысының хикмәте нәрсәдә?* Ф.Баттал

2) Капитал хуҗасы; эшләп тапкан керемен табыш алу өчен файдаланучы. *Мал арбаларга гына сыймаган, шытып килгән капиталистның куллары буш түгел, уңына-сулына дәү-дәү буаз букчалар эленгән, иң өсләре дә буш түгел, биленә дә уннарча капчык-янчыклар асылган.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Бай кеше. *Туксан чакрым тизлек белән чигенә алырдай машинаның безнең илдә генә түгел, байлыгы череп ятучы капиталистларда да юклыгын уйлап, бик аптырап башын чайкады.* М.Галиев. *– Акчасын җәлләгәндер ул капиталист! – диде шул ук тавыш иясе.* Х.Әхмәт-Вәли

**КАПИТАЛИ́СТИК** *с.* 1) Капитализмга мөнәсәбәтле, капитализмга хас булган. *Татарларның буржуаз үсеш юлыннан китүләре шактый иртә башланса да, алар капиталистик модернизация юлын тулысынча үтә алмадылар, чөнки аңа алмашка бик иртә совет модернизациясе килде.* Д.Исхаков. *[Гөлчирә:] Капиталистик хезмәт алдынгыларына ялкынлы сәлам!* Т.Миңнуллин

2) Капитализм принципларына нигезләнгән. *Капиталистик илләрдәге хәерчелек, балаларның рәтсез тормышы хакында сөйләгәндә, «нигә безнең якка чыкмыйлар икән ул бәхетсез балалар?» дип аптырап уйлана идем.* М.Галиев. *Кыскасы, социализм дип шапырынган Россиягә (СССР) караганда капиталистик Англия көнләшерлек дәрәҗәдә социаль ил икән.* Л.Закир. *Планетабыз кешелек тарихында гаять авыр һәм катлаулы бер чор кичергәндә, иң алга киткән капиталистик илләрнең берсенә совет моряклары капка шакыйлар.* А.Хәсәнов

**КАПИТАЛЛАШТЫРУ** *ф. махс.* 1) Капиталга әйләндерү, капитал итү (өстәмә кыйммәтне)

2) Нинди табыш китерүенә карап, милекнең (нигездә акция, облигация һ.б.) хакын исәпләү

**КАПИТАЛЛАШУ** *ф. махс.* Капиталга әйләнү (өстәмә кыйммәт тур.)

**КАПИТАЛЬ** *с.* 1) Күләме һәм әһәмияте белән зур, мөһим. *Алар үзәкләштерелгән капиталь чыгымнар исәбенә генә түгел, сәнәгать предприятиеләре, нефть, химия, машина төзелеше, колхоз-совхозлар исәбенә дә күтәрелә һәм җиһазландырыла.* Ф.Галимуллин. *2006 елда журналның меңенче санына багышлап чыгарылган «Сүнмәс утлар балкышы» дигән капиталь хезмәт милләтебезнең мең еллык мәдәни тарихын инде тагын бер тапкыр черемәс фикер гранитында раслаган рухи капиталыбызга әверелде.* Казан утлары

2) Тулы, зур масштаблы. *Авыл җирләрендә капиталь төзелешләр алып бара торган бер оешманың урта кул җитәкчеләреннән икән [Пәриев].* Г.Әпсәләмов. *2006 елның февралендәге янгыннан һәм дүрт елга сузылган капиталь ремонттан соң, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы кабат ачылды.* Казан утлары

**КАПИТАН** *и. фр.* 1) Армиядә офицер дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия кеше. *Полк белән Польша татары капитан Тальковский җитәкчелек итә.* М.Галиев. *Контрразведка капитаны – коры сөякле, урта яшьләрдәге кеше – папиросын күзләрен чекрәйтеп суырасуыра башта бик озак нидер күчереп язды.* З.Хәким

2) Судно башлыгы, кораб командиры. *Әйе, корабның комсомол оешмасы эшләре белән капитан каютасында Таһирның моңарчы да булганы бар.* А.Хәсәнов. *Җитмәсә, капитан көтә алмавын әйтеп, тиешле вакытында кузгалып киткән.* И.Хуҗин

3) Команда җитәкчесе (спорт, төрле ярышлар, бәйгеләрдә). *Комитет, Галим Урмановны бу эштән алып, команданың капитаны итеп унынчы классның комсоргы Хафиз Гайнуллинны билгеләде.* Г.Әпсәләмов. *Ул ун ел буе атаклы «Спартак» командасының капитаны вазифаларын башкара.* А.Гафиятов. *Мин үзебезнең элекке команда капитаны Рамайга шылтыраткан идем.* Ф.Яруллин

**КАПИТАНЛЫК** *и.* Капитан вазифасы, хезмәте. *Менә күрерсең, каботажда мин өч-дүрт елдан капитанлыкка күтәреләчәкмен.* М.Юныс

**КАПИТЕЛЬ** *и. лат. архит.* Колоннаның яки пилястраның түшәм белән тоташып киткән фигуралы өске өлеше. *Колоннаның югары очы гадәттә мендәр сыман капитель белән тәгълләнә.* Ф.Хатыйпов. *Монда күпер төзү буенча архитектура үзенчәлекләрен, детальләрен (вант, пилон, эстакада, колонна, капитель, ростверк һ.б.) өйрәнергә кирәк.* Татарстан яшьләре

**КАПИТУЛЯНТ** *и. лат.* Капитуляция ясаучы

**КАПИТУЛЯНТЛЫК** *и.* Капитулянт булу; көрәш алып барудан хыянәтчел рәвештә баш тарту

**КАПИТУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *хәрби* Җиңүче як таләпләренә, шартларына риза булып, сугыш хәрәкәтләрен туктату, корал ташлау. *Шундый зур һәлакәттән соң, япон императоры сугышны туктатырга, кичекмәстән капитуляция кабул итәргә ризалашкан.* Л.Бадыйкшан. *Сугыш бетте, немец гаскәрләре капитуляция ясады, ди!* Р.Сәгъди. *Владимир кенәзлегенең төньяк өлеше исә вакытында уздырылган сөйләшүләр һәм һөҗүм итүче татар-монгол армиясенә азык-төлек һәм атлар биреп капитуляция ясау аркасында исән-имин калган.* Р.Хәкимов

2) *иск.* Чит ил гражданнарына үз гражданнарыннан артыграк хокуклар һәм өстенлекләр бирә торган килешү төре

3) *күч.* Җиңелүеңне, хаксызлыгыңны танып, көрәшне дәвам итүдән, үзеңнең карашларыңны яклаудан баш тарту; чигенү. *Капут! Чынбарлык алдында капитуляция.* А.Хәсәнов. *Аның бу сүзләреннән соң үзеңә дә бераз уңайсыз булып китә, артык әрсезләнеп ташладым бугай дип уйлап куясың. Ләкин әле капитуляция ясарга иртәрәк.* Н.Әхмәдиев

**КАПИТУЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Капитуляция ясарга мәҗбүр булу. *– Өстәвенә, мәсьәлә шулай карала: бу илләрне кабул итү – Россиядән өстен чыгу, ә кабул итмәү безнең алда, янәсе, «капитуляцияләү» дигәнне аңлата, – дип билгеләп үтте Россия лидеры.* Ватаным Татарстан. *2 нче сентябрьдә Токио култыгында Америка линкоры Миссури палубасында Япония капитуляцияләү актына җиңелүе турында кул куйды.* Яңарыш

**КАП-ЙОТ** *и.* Комсыз, саран, ертлач кеше. *Вулкан өстендәге Утрау кисәгенә сыенган Япон халкын шулай сыкратырга Ничек кулың барды синең, хам?! Аһ бәдбәхет! Кап-йот! Убыр! Үләт!* Х.Туфан. *Затлы «Вольво»га күз төшереп алуга, Камалов Совминдагы эре кап-йотның киявен – ОБХСС майорын исенә төшерде.* Р.Мирхәйдәров

**КАП-ЙОТЛАНУ** *ф.* Комсызлану, саранлану. --- *кап-йотланып йөргәч шулай була ул дип, улын шелтәләп алды Нәфисә апа.* Казан утлары

**КАП-ЙОТЛЫК** *и.* Кап-йот булу, саранлык, комсызлык, ертлачлык.

*Бистәләрне әйләнгәндә, базарга кереп йөргәндә, әллә ничә кеше салымчылар тарафыннан кап-йотлык илә җәберләнгәннәрен сөйләде.* Р.Батулла. *Аның елмаюы күзенә тагы бер ялтырау – туя белмәү, кап-йотлык ялтыравы арттырды.* XX йөз башы татар прозасы

**КАПКА** *и.* 1) Корылма, бина, йорт һ.б.ның ишегалдына кереп-чыгып йөрү өчен гадәттә алдында калдырылган ачыклык һәм аны ябар өчен ясалган тупсалы зур ишек. *Төрмә капкасының теге ягыннан чыгучылар арасында кара кәләпүш һәм таушалганрак җилән кигән Насретдин җизнәсе дә күренде.* Р.Низамиев. *Капка төпләренә килеп җиткәч тә чаңгыны салырга ашыкмадым.* К.Кәримов

2) *спорт* Хоккей, футбол һ.б. спорт уеннарында туп, алка яки шар бәреп кертелә торган урын. *Мин, булдыксыз капкачыдан көләргә дә һәм аның өчен җанатарга да әзерләнеп, капка артындагы бүрәнәгә килеп кунакладым.* Ә.Мушинский. *Футбол капкасының баганалары ауган, атынчык-таган җимерелгән.* Ф.Яруллин

3) *иск.* Авылга кергән җирдә куела торган корылма. *Татар авылы тормыш авырлыгыннан сыгылып төшсә дә, тамырларының исән вакыты әле. Кыр капкалары аумаган, мәчетләрнең манаралары киселеп, азан тавышы яңгырамаса да, күңеленнән иман нуры юкка чыкмаган чак.* Н.Гариф. *50–60 йорттан торган Аксу халкына авылдан чыгу өчен бары бер капка булган.* Ф.Гарипова

4) *күч. сөйл.* Хуҗалык. *Афисирский старшиналар авыл саен, капка саен чыкмый.* В.Имамов. --- *унбишләп сарыктан башланган көтү, капка саен ишәя барып, икенче очка җиткәндә, зур бер чирүне хәтерләтә иде.* Н.Әхмәдиев

5) *күч. хәрби* Дошман чолганышын яки киртәләрне үтү өчен тар аралык (тауларда, диңгездә, сугыш кырында һ.б.)

◊ **Капка баганалары бертуган** Туган булмаган, бөтенләй чит кешеләр турында

**КАПКА́ АКЧАСЫ** *и. тар.* Зур сәүдә үзәкләре булган шәһәрләргә, сату-алу алып барыла торган урыннарга капка аша узган вакытта түләнә торган акча. *Бу кәрван төн тарафыннан. Җиз әйберләр, йомшак тиреләр сатучылар. Әле алардан капка акчасын түләтәләр.* Б.Рафиков

**КАП-** *кис.* «Ка» дип башланган кайбер сыйфат һәм рәвешләргә ялганып һәм һәрвакыт басымны үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәкчә (мәс., *кап-кайнар, кап-кара, кап-караңгы* һ.б.). *Син мине велосипедка утыртып йөртә идең. Синең кап-кайнар сулышың Муенны өтә иде.* Ф.Яруллин. *Зөлфия, ичмасам, әзрәк яшәп карады, ә бу бала ни инде: аның дөньяга күзе дә ачылмаган, ә алдында кап-кара пәрдә...* Н.Гыйматдинова. *Карасам, малай, саргаеп беткән кап-карт җәен, белдеңме!* Р.Батулла

**КАПКА-КОЙМА** *җый. и.* Капка һәм өй алдын тотып алган койма, рәшәткәләр. *Капка-коймалар хуҗаларын көтә-көтә арып ауган.* Ә.Баян. *Ул бервакытта да капка-койма буендагы сукмактан йөрмәс, бары урам уртасындагы ат юлыннан гына йөрер иде.* Ә.Еники. *Кызыл коңгызлар күзгә таба саргылт пута белән бизәләләр икән. Алар, ди, абзый, хәзер капка-коймага сырышалар, кояшта җылыналар.* М.Мәһдиев

**КАПКАН** *и. диал. к.* **капкын**. *Арырак куелган икенче капкан да урынында түгел.* Н.Яһудин. *Ул капкан куярга булган.* А.Галиева. *Бүген дә эшли түгелме шул ук «капкан»?* Р.Ханнанов

**КАПКАЧ** *и.* 1) Савыт-сабаларның өстен каплый торган җайланма. *Чәйнек капкачының шылтыравында да күңелне юатырдай яңа авазлар юк иде.* Р.Низамиев. *Гәүһәршад морзага казан капкачын үзенә ачып ташларга ирек бирде, бүлдермичә генә сүзен тыңлады.* М.Әмирханов. *Җәбир бер-ике көрәк балчык алып ташлады да алтынлы чүлмәккә капланган тупас капкачны алды.* Н.Фәттах

2) Төрле нәрсәләрдәге каплавыч; кечкенә ишек. *Әниләре: «Йөзләре килә микән? Күеп китә күрмәсеннәр тагы», – дип, мич капкачын ачкалап караган саен, бала-чага да мич авызына ук кереп китәрдәй булып мәш киләләр.* Г.Галиева. *Тимер келәле итеп ясалган кечкенә тишекнең капкачы эчке якка ачылды.* З.Зәйнуллин. *– Монда кемнәр яши? – дип сорады ул сабыйдан, тәрәзә капкачлары һәм тимердән ясалган урам капкалар зәңгәр белән ак буяу аралаш буялган йортка күрсәтеп.* А.Хәлим

**КАПКАЧЫ** *и.* 1) *тар.* Сарай капкаларыннан керүче-чыгучыны тикшереп торучы сакчы, җаваплы кеше. *– Безгә сарай капкасыннан үтүче һәр йөкне тикшерергә әмер бирелде, – диде баш капкачы, Үрбәт алдында билен бөгеп.* М.Әмирханов

2) *спорт* Футбол, хоккей һ.б. спорт уеннарында капка алдын саклаган уенчы. *Капкачыларга рәхәт, яннарында чуалган малайларның учыннан көнбагыш алып, чарт-чорт шуны яралар.* А.Гыйләҗев. *«Ак Барс» командасы өчен Чехиядән махсус чакыртылган капкачы үзенә миллион доллар сораган.* А.Хәлим. *Үзе яшен ташыдай атылган резин шайбаны тота алучы, курку белмәс капкачы, йөзендә ничәмә-ничә җөй, ә үзе тычканнан да курка.* Р.Кәрами

**КАПКЫН** *и.* 1) Җәнлек аулау өчен алдавыч җим куеп калдырыла торган махсус җайланма. *Безнең авылда балалардан калган бүре капкыннары, юл йөргәндә янда тота торган кистәннәр, үкчәсенә бозау тиресе каккан киң чаңгылар (тауга менгәндә, тиренең мехы кире шудырмый), тагын әллә ниләр бар иде.* М.Мәһдиев. *Ул да булмый абзардан: – Әлеү-әлеү! Беттем-беттем! – дигән тавыш ишетелде һәм, --- капкынга капкан уң аягы белән сикергәләп, кәтүк сыман кечкенә буйлы адәмзат килеп чыкты.* А.Хәлим

2) *күч.* Кемне дә булса кулга төшерү максаты белән оештырылган хәйлә; тозак. --- *аларны аулау максаты белән, әледән-әле тикшерүләр үткәрелә, документсыз шикле кешеләрне кулга алалар икән. Бу капкынга эләгүдән ничек котылырга белмичә, Фәгыйлә куркуга төшә, поезд туктаган саен, ишеккә борчулы карана башлый.* С.Сабиров

◊ **Капкынга кабу** *к.* **капкынга төшү**. *Икенче кат бер үк капкынга*

*килеп каптым бит аңгыра баш, бар икән дөньяда бер уңмас, бәхетсез җан!* Р.Габделхакова. **Капкынга каптыру** Эләктерү, тоту, качып йөргән кешене кулга төшерү. *Әйе, Камаловны капкынга каптыру хәзер җиңел булмас, ул хәзер бик сак, хәтта хастаханәдә ятканда да үзе беренче булып атты бит.* Р.Мирхәйдәров. **Капкынга төшү** 1) Тотылу; 2) Башкаларның хәйләсен сизмичә, белмичә калып, кемнеңдер кулына эләгү, бәйле хәлгә калу, фаш ителү. *Хәзер инде капкынга төшүләрен тәмам аңладылар: «террористлар» янкиларны утлы табада елдан-ел шәбрәк биетәләр!* Ф.Баттал. **Капкынга эләгү** *к.* **капкынга төшү**. *Нинди капкыннарга эләккәнне Барып күргәч кенә аңладым...* И.Гыйләҗев. *Ни кызганыч, әдипнең зур иҗат планнары тормышка ашмый кала: ул репрессия капкынына эләгә.* Казан утлары. **Капкын кору** Хәйлә кору. *Тотылмаган карак карак түгел, ди ---, аны эзләргә, табарга кирәк. Моның өчен бердәнбер юл: капкын кору, засадада утыру.* М.Насыйбуллин. *Ярты сәгать элек кенә мин Фирганә вакыйгалары вакытында безгә капкын коручыларның берсен күрдем.* Р.Мирхәйдәров. *Тормыш тагын нинди капкын корып куйган аңа?* Җ.Ильясов

**КАПЛАВЫЧ** *и.* 1) Каплап тора торган җайланма, капкач. *Савытына күрә каплавычы, Маена күрә атлавычы.* Мәкаль. *Әнә өч катлы таш йортның аскы тәрәзәләренә тимердән үреп ясалган каплавычлар беркетеп куелган.* Р.Низамиев. *Лачынның башына кидереп күзен каплый торган каплавыч җибәргән.* Г.Якупова

2) *тех.* Кожух, чехол, тышлык. *Салам туплагычка кибәк белән бергә ач бөртекләр эләксә, вентиляторның каплавыч ачылышын яки әйләнү ешлыгын киметәләр.* Урып җыю машиналары

3) *хәрби* Дошман игътибарын үзләренә җәлеп итеп, төп көчләрнең китүенә яки нинди дә булса операцияне башкарып чыгуына ярдәм итү өчен махсус билгеләнгән отряд

**КАПЛАМ** *и.* Нәрсәне дә булса каплап алган тышкы катлам. *Кар капламы, җирнең туны сыман, җылыны тышка чыгармый, үзе табигый парник төзи.* Ф.Ибраһимова. *Кайбер очракларда тыгыз хитин капламы булмаган личинкаларны һәм курчакларны җитлеккән бөҗәкләр кебек ансат кына киптереп булмый, әмма алардан мумия ясарга мөмкин.* Яшь натуралистларга

**КАПЛАМА** *и.* 1) Киемнәрнең төймә һәм элэктеречләр урнашкан өлеше. *Ул чалбарының төймәләрен дә каптырып бетерми, каплама читеннән һәрвакыт берме-икеме төймәсе баш тыгып кала, берәрсе килеп колагына әйтмәсә, Камил өчен ул бармы да юкмы инде.* Х.Сарьян. *Капламаны рәсемдәге кебек үк түгел, башкачарак итеп тегәргә дә була.* Сөембикә

2) *диал.* Бал, май һ.б.лар салу өчен капкачлы кечкенә савыт. *Ә каплама дигәнем уртача табак зурлыгындагы, эчен чокып ясаган капкачлы агач савыт иде.* Ватаным Татарстан

3) Нәрсәнең дә булса өстен ябу яки берәр өслеккә җәяр өчен кулланыла торган япма. *Шуннан соң, рам эченә сыярлык итеп, юка фанердан эшләнгән каплама ясала.* Фокус серләре. *Яңа футбол кыры һәрьяклап камил: яшел үлән төсендәге каплама астына калын ком катламы салынган.* Ватаным Татарстан

**КАПЛАМЫШ** *и. диал. к.* **каплама** (*2 мәгъ.*). *– Күрше әби бер капламыш бал кертте бит әле менә, әйдәгез, тәмле итеп чәй эчәбез, – диде Мәрьям куанып.* Татарстан яшьләре

**КАПЛАН** *и. зоол.* Мәчесыманнар семьялыгыннан сары тиреле, кара тимгел-тимгел таплары булган имезүче ерткыч хайван; *русчасы*: **леопард**. *Яшьлегендә ир булган, Судай булат бәйләгән, Арыслан, каплан аулаган, җитмеш җиде ил гизгән ---.* Дастан. *Миңа кол анда бар җанвар: арыслан, хәтта капланнар*. Г.Тукай. *Председательнең каплан шикелле бу кадәр кинәт ташлануыннан Нургали аптырау гына түгел, бөтенләй каушап төште.* Ә.Еники

**КАПЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **каплау**. *Аларның өсте чүп-чар, ком-балчык белән капланган, дегет катыш машина пычраклары да күзгә ташлана әнә.* Р.Низамиев. *Менә ул, чынаягын тоткан килеш, салмак кына торып басты да, киндер белән капланган мольбертны әйләнеп узып, ишек ягына атлады.* М.Маликова

2) Төбе, аскы ягы белән өскә әйләнү; асты өскә әйләнү. *Кул астында бүтән машина-фәлән булмаганлыктан, икәүләшеп бер «Беларусь» тракторын кабызып, Зәет болынына киткәннәр һәм, Убса тавын төшкәндә тракторлары капланып, икесе дә һәлак булганнар.* И.Сабиров

3) Йөз белән нәрсәгә дә булса яту, йөзне каплау. *Өзгәләнеп кычкырып, әнием өстенә капланам: «Әнием! Мин кайттым, тор инде, әнием! Әнием, мин бит бу, ач инде күзеңне. Тор инде, зинһар! Әнием, бәгърем!»* Р.Габделхакова. *Менә бер мәлне, ап-ак йөзен ике кулы белән учлап, пианино өстенә капланды ул.* Р.Низамиев. *Әмма моннан берни дә барып чыкмады, ул, ыңгырашып, мендәргә капланды: – Ыһ-һ!..* Г.Гыйльманов

4) Йөзтүбән егылу, йөзтүбән авып төшү. *Ул сузылып җиргә ятты да, йөрәгенең белемсез ашкынуына түзми, җиргә капланды...* Һ.Такташ. *Сабанчы кыз, кычкырып елап, җиргә капланды.* Р.Хәбибуллина. *Одинцов юл читеннән канауга тәгәрәде, Шәүкәт тузанлы юлга капланды.* Р.Бәшәр

5) Бик нык якын килү. *Ләкин һич көтмәгәндә, Мияу-мияу, бөтен гәүдәсе белән тәрәзәгә капланып, ямьсез итеп мияулап җибәрде.* Р.Хафизова. *– Кем бар анда? – дип кычкырды Барие, бөтен гәүдәсе белән караңгы тәрәзәгә капланып.* Н.Фәттах

6) *күч.* Барлык игътибарны берәр нәрсәгә юнәлтү, берәр нәрсә белән бик нык мавыгу. *Шундый булдың инде син, улым, укырга яраттың, кечкенәдән капланып китап укый идең.* Мәдәни җомга

**Каплана башлау** Капланырга тотыну. *Күк йөзе тагын кара болытлар белән каплана башлады.* Ялкын

**Каплана төшү** Беркадәр каплану; тагын да ныграк каплану. *Бүген урамыбыз кар белән тагын да каплана төшкән, дип куаныштылар чаңгы шуарга яраткан малайлар.* Сабантуй

**Капланып бару** Торган саен ныграк каплану. *Хатыннарның чиләкләрендәге*

*суларының өсләре чыйрап, боз булып капланып бара иде инде.* Н.Кәримова

**Капланып бетү** Бөтенләй каплану. *Кеше аягы басмаудан үлән белән капланып беткән тар юлдан алар тагын унунбиш минут бардылар һәм зур булмаган аланга килеп чыктылар.* Ә.Сәлах. *Кеше-кара керәсе юк, әнигә хәзер ул кадәр капланып бетмәсә дә ярый инде.* Г.Бәширов

**Капланып калу** Ниндидер сәбәп аркасында каплану. *Шуңа күрә бу эчке күңел тормышын дулкынландырган төп сәбәпләр дә капланып калды.* З.Мөхәммәтшин. *Печән белән капланып калган чалгысын эзләп тапкач, Данияр әтисе артыннан йөгерде.* Казан утлары

**Капланып тору** Капланган хәлдә булу. *Ничектер, моны әүвәл бер пәрдә белән каплап торганнар да, кинәт ул пәрдәне тартып алып, аның артында капланып торган салкын һәм куркыныч нәрсәне күрсәтеп калдырганнар шикелле итеп кинәт сизде.* Ф.Әмирхан. *– Юк, – диде Гата. – Ул чокыр күптәннән бар инде. Әмма ул элек капланып тора иде, мин аны ачтым.* Р.Хафизова

**КАПЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **каплау**. *Алар гаиләсендә хатын-кызның йөзен каплату, аларны дөнья яктылыгыннан мәхрүм итеп яшәтү кебек тар күңеллелекләр булмады.* Ш.Поварисов. *Кайтуга, бабасыннан тәрәзәләрне каплатты ул.* Мәдәни җомга

2) Кушылдыру, качыру, аталандыру (йорт хайваннары тур.). *– Кая булсын, каплатырга алып барам! – дип кычкырды Шакир, үгез артыннан калышмаска тырышып.* А.Нуруллин. *– Ни өчен каплатылмаган? – Димәк, үгез актив булмаган, – дип куйды Мотыйк, җитди генә.* Х.Камалов

**КАПЛА́У** *ф.* 1) Нинди дә булса өслеккә икенче бер әйбер түшәү, җәю. *Һәр тактасы бүрәнәдән яңа гына телеп алынганмы – сап-сары килеш. Аның садәлеген капламас өчендер, постау я эскәтер япмаганнар, хәзинәдә бары ялангач такта өстенә шул килеш кенә тезелгән.* К.Кәримов

2) Берәр әйбернең өстен капкач яки башка берәр нәрсә белән томалау, ябу. *Суны капламасаң, Бичура тыгылып кулын юа, имеш, савыт-сабаны юмый калдырсаң, Бичура килеп ялый икән...* Р.Габделхакова. *Бу якларның сәер бер үзенчәлеге бар шул: август урталарында нык кына суытып ала, бакчадагы помидор-кыяр түтәлләрен капламасаң, бетерә.* М.Маликова

3) Тән, баш, кул-аяклар һ.б.ны нәрсә белән дә булса ябу, бөркәү. *Ә тегесенең исендә дә юк: шакмаклы фуражкасын ямьшәйтеп башына каплады да, ирене белән генә пачкадан суырып чыгарып, авызына сигарет капты, бер кулын рульдән ычкындырып, фокусчыдай җәһәт кенә шырпы кабызды.* Р.Вәлиев. *Ләкин мунчага кергән вакытта – ялгыз, әгәр кеше булса, гәүдәнең билдән түбән өлешен каплау өчен, билгә бәйли торган җәймә белән булырга тиешле.* Р.Фәхретдинов

4) Нәрсәнең дә булса икенче бер әйберне күренмәслек итүе, ышыклап тору. *– Каплама кояшны, миңа яктылык, җылылык кирәк! – дип кычкыра Гыймай болытка.* Ф.Яруллин. *Хатыннар мине чорнап алдылар: «Кайда ул? Кайда? Без күрмибез!» – диләр. «Әнә теге торба каплый. Хәзер килеп чыгачак», – дим.* М.Юныс

5) Кереп-чыгып яки үтеп йөрү юлын бикләү, ябу. *Машиналар бер-берсенә юлны каплый-каплый чабышалар.* Р.Батулла

6) Тәрәзә, ишек һ.б.ларны берәр нәрсә белән ябу, томалау. *– Ә моны ник каплап тотасың? – дип сорады Зөфәр, дивардагы каплаулы рамга ишарәләп.* М.Маликова. *Төн авышкач, тәрәзәне әйбәтләп каплады да ут кабызды.* Р.Сәгъди

7) Берәр нәрсәнең астын өскә әйләндерү. *Әсхәт стаканны әйләндереп үк каплады.* И.Нуруллин. *Ул чынаягын каплады да, аның өстенә тастымалын ябып, торып китәргә әзерләнде.* Г.Бәширов. *Кодагый, кияү белән чәкештереп, тынмыйчы бер кружка бузаны эчеп бетерде дә өстәлгә каплады.* Һ.Такташ. *[Әнкәм] Бер иртәдә ярты чынаяк чәй эчкәч, чынаягын каплады, озак итеп амин тотты ---.* Д.Салихов

8) Томалау (болыт, томан, караңгылык, күз яше һ.б.ш.лар тур.). *Кояш янып торса, Болыт каплау белән Сүнәмени җирдә яктылык.* Ф.Кәрим. *Дары төтене, дегет кебек корым яктылыкны каплады.* Х.Камалов. *Күзне яшь каплады.* М.Мәһдиев

9) Үз гәүдәң белән томалау. *Читтән карап торган кеше әлеге күренешне, ике балалы тигез гаилә учагын саклап калу өчен амбразура каплау, дияр иде.* К.Кәримов. *Ватан-Ана ягына очкан ядрәләрне күкрәгең белән каплау өчен генә дә бу дөньяга килүең – үзе зур Бәхет!* Ш.Мостафин

10) Буяу; сөртү. *Аерым өлешләрне сварка ярдәмендә үзара беркетәләр һәм камераның эчке ягын силикатлы эмаль белән каплыйлар.* Суыту машиналары һәм криоген техника. *Балавыз акбур белән ясалган рәсемне төзәтү дә, бер төсне икенчесе белән каплау да мөмкин түгел.* Рәсем ясарга өйрәнәбез

11) Басу, күмеп китү (үлән, кар, тузан һ.б.). *Кышка да кердек: урамнарны, йорт түбәләрен ап-ак, йомшак кар каплады (ул чакларда Уфа карлары бик чиста була торган иде).* Ә.Еники. *Ләкин андый сукмакларның берсе дә гамәлгә ашмады, аларны үлән каплады.* Х.Туфан. *Март аенда ук җир ачылып, апрельдә, офыктан офыккача, бөтен дөньяны яшеллек каплады.* Г.Гыйльманов

12) Бик күп булу, күпләп чыгу (сипкел, бетчә, җыерчык һ.б. тур.). *Оялмаслык та түгел, бөтен битен бетчә каплаган бит ---.* Сабантуй

13) *хәрби* Махсус билгеләнгән сугышчылар отряды дошман игътибарын үзләренә җәлеп итеп, төп көчләрнең чигенүенә яки нинди дә булса операцияне башкарып чыгуына ярдәм итү. *Газинур Володяның соңгы группа белән безнекеләрнең чигенүен капларга калганлыгы турында әле бүгенгәчә [Екатерина Павловнага] әйткәне юк.* Г.Әпсәләмов

14) *сир.* Талант, сәләт яки мөмкинлекләрдән файдаланмыйча, омтылышларны басып, томалап тору. *[Иштуган]: Ник, мин әйтәм, мондый кыйммәтле тәҗрибәңне каплап яттың?* Г.Әпсәләмов

15) *куч.* Тотылган акча, чыгым, зыян һ.б.ны кире кайтару. *Концерттан*

*килгән керем бар чыгымнарны да каплады.* Р.Миңнуллин. *Куян асрауга тоткан чыгымнарны каплау бер хәер, зур керем алу турында хыялланып йөри [директор].* Р.Мулланурова. *Минем эшчеләрем генә эш хаксыз калырга мөмкин, безнең зыянны каплаучы, дотация, субсидия бирүчеләр юк.* Р.Мирхәйдәров

16) *күч.* Җитешсезлекләрне, начар эшләрне яшерү, күрсәтмәү. *Матурлык йөз гаепне каплый.* Мәкаль. *Мин дә ялкау ягын якламыймын, Гөнаһлының гөнаһларын капламыймын.* З.Мансуров

17) *күч.* Биләп алу, киң мәйданга, урынга, өлкәгә таралу, җәелү турында (тавыш, куркыныч хәл, дәһшәт, кризис һ.б.). *Бу вакытта инде төтен бөтен тирә-якны каплаган иде.* А.Галиева. *Бөтен дөньяны сугыш сөреме каплады.* Г.Бәширов. *Кинәт бөтен дөньяны Караңгылык каплады...* Л.Лерон

18) *күч.* Күңелне, эчке дөньяны биләп алу (кайгы-хәсрәт, борчу, сагыш, күңелсезлек һ.б.). *Күз аллары караңгыланды, күңеле болганды, миен хәвефле уйлар каплады.* Т.Галиуллин. *Ләкин ниндидер бер курку күңелен каплый да бөтен батырчылыгын һәм танышасы килү тойгысын югалттырырга тырыша иде.* Ф.Әмирхан

19) *күч.* Суны, эчемлекне төбенә кадәр эчү, бушату. *Бер рюмка затлы эчемлекне каплагач, телләр ачыла башлады.* Г.Галиев. *Бернәрсәгә кул бармый иде, җаен туры китереп берәр стакан каплау турында гына уйлап йөри идем.* Г.Мөхәммәтшин. *Сәлах батырлык өчен икенче рюмканы да каплады.* Г.Әпсәләмов

**Каплап алу** Тиз арада каплау. *Күз алдын ялкын каплап алды.* Н.Фәттах. *Коңгырт куе чәче матур булып түгәрәкләнеп килгән шәрә муенын, иңбашларын, бөтен йөзен каплап алды.* Г.Бәширов. *Борынгы Истанбулны төрле төстәге утлар каплап алды.* Н.Нәҗмиев. *Кара кайгы каплап алды бар дөньямны.* Казан утлары

**Каплап бару** Рәттән барысын да каплау. *Кайберәүләр өчен тәрҗемә ул бер сүзне икенче сүзгә каплап бару гына кебек ---.* Х.Сарьян. *--- товарлар ала һәм аларны өч-дүрт бәя белән базарга чыгарып сата, шулай итеп, көндәлек расходларын каплап бару өстенә, Җәлтәфиновның жалованьесе, 140 сумнар гына булса да, янга кала бара.* Һ.Такташ

**Каплап бетерү** Бөтенләй каплау, барысын да каплау. *Өеңдә бөтен җирне тузан каплап бетергән икән бит.* Сөембикә

**Каплап җиткерү** Тулысынча каплау; тиешле дәрәҗәгә китереп каплау. *Чәйнекне каплап җиткермәгән булганнар ахры.* Юлдаш

**Каплап калу** Каплаган хәлгә китерү. *Безнең арттан күк йөзен кара болыт каплап калды.* М.Мәһдиев

**Каплап килү** Даими яки регуляр рәвештә каплау; аз-азлап каплау. *Чыгымнарны каплап килү*

**Каплап китү** Көтмәгәндә каплау. *Җидегән вакыйгалары исә аның яңа әсәренең пафосын, рухын тоташ фаҗига күләгәсе белән каплап китте.* Г.Бәширов. *Ул, кар каплап киткәнче, минем эзне югалтмаска тырышып, артымнан килә.* Г.Галиев. *--- сугыш заманы күренешләре элекке тыныч еллар күренешләрен каплап китә.* Г.Әпсәләмов

**Каплап кую** Капланган хәлгә китерү. *Комган авызына каплап куйган көмеш аякны бер кулына, комганның үзен икенче кулына тотып, бик бирелеп ачы бал агыза башлады.* Н.Фәттах. *Камил чынаягын, авылча итеп, төбен өскә каратып каплап куйды.* Г.Бәширов

**Каплап тору** Капланган хәлдә тоту. *Җиңсез ул киемнәрнең озынрак булган сул як итәге ирләрнең сул як ботларын каплап тора иде.* Н.Фәттах. *Кәефе нәкъ әнә шул томанмы, вак яңгырмы каплап торган шыксыз пычрак һава төсле – өметсез.* Г.Бәширов

**Каплап чыгу** Барысын да каплау. *Кунаклар җыелганчы дип, сыйнигъмәт белән тулы өстәл өсләрен зур япма белән каплап чыктым.* А.Галиева

**Каплый бару** Торган саен ныграк каплау. *Аңа мондагы җанлы, яңа, «интересный» егетнең ачык сурәте ерактагы тонык Сәгыйтьне каплый бара, аны кызыксызга әйләндерә бара шикелле тоелды.* Н.Фәттах

**Каплый башлау** Капларга керешү. *Җил-давылсыз тынычлыкта яшәгәндә, теләкләрне, омтылышларны май каплый башлый.* М.Юныс. *Хатынымның болытсыз күк шикелле зәңгәр күзләре кинәт зурайдылар, аннары аларны томан каплый башлады.* Ф.Яруллин

**Каплый төшү** Бераз каплау; тагын да күбрәк каплау. *Әни, авызын каплый төшеп, елмаебрак өйалды ишегеннән карап тора.* Г.Бәширов

**КАПЛАУЛЫ** *с.* 1) Өсте ябылган, капланган. *Йөзләре җиңелчә каплаулы хатын-кызлар бөртекләп дөге чистартып утыра.* Р.Батулла. *Бу кем рәсеме? Нигә өсте каплаулы?* Р.Вәли

2) Нәрсә белән дә булса тышланган. *Уянып китсәм, мин брезент белән каплаулы машина әрҗәсендә.* Ф.Яруллин. *Паром янында, түбәләре каплаулы хәрби йөк машиналарын үткәрә торгач, шактый тоткарланырга туры килде.* Ә.Мушинский

**КАПЛУН** *и. нем. а.х.* Печеп, иткә симертелгән әтәч. *Француз романнарында геройларның бик тәмләп каплун ашаулары турында укыганда, нәрсә икән соң ул дип гел уйлый идем, печтерелгән әтәч икән бит ул.* Татарстан яшьләре

**КАПМА́-КАРШЫ** *с.* **1.** 1) Бөтенләй киресенчә булган; бер-берсенә каршы килгән, бер-берсен инкяр итә торган. *Менә нәрсә, әйдәгез сүз көрәштермик, чөнки без – капма-каршы фикер кешеләре, ярты сәгатьләп сөйләшәбез инде, ә эшкә керешкәнебез юк...* Р.Мирхәйдәров. *Нух пәйгамбәребез шулай кушкан. Табигатьтә җан ияләренең дә, җансыз җисемнәрнең дә, гүзәллек, батырлык, хәтта явызлыкның да капма-каршы ише булырга тиеш, дигән.* К.Кәримов. *Бу, минем уйлавымча, температураларның капма-каршы төрлелегеннән килә.* А.Хәлим

2) Кара-каршы; бер-берсенә каршы. *Капма-каршы якка кузгалган ике эшелон да ухылдап туктадылар, пар чыжылдады.* М.Мәһдиев

3) Каршылыклы. *Шундый капма-каршы уй-кичерешләр эчендә ятканда, кулына кефирлы стакан тотып, янә Данәгөл керде.* А.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Кара-каршы, йөзгә-йөз. *Самолёттан төшкәч тә күрерсез: бетон юлның ике тарафында капма-каршы диярлек урнашкан ике бина булыр, утрауда булган ике кунак йорты шулар.* Р.Мөхәммәдиев

**КАПОНИР** *и. фр. хәрби* 1) Туптан капма-каршы юнәлештә ут ачарга мөмкинлек бирә торган оборона корылмасы. *Менә капонир эчендә гранатамы, снарядмы – нәрсәдер шартлады.* З.Зәйнуллин

2) Тау куышы, зур канау һ.б.ш. кебек самолётларны яшерү урыны. *Тагын да күбрәк юл үтәсе, сугышны тизрәк бетерәсе килә. Командир да, шул теләкне аңлаган кебек, безнең сафны капонирлар өстеннән үткәрә.* С.Баттал

**КА́ПОР** *и. голл.* Битне генә ачык калдырып, башлык өлеше белән муен өлеше тоташып киткән, балалар һәм хатын-кызлар кия торган баш киеме (элек ияк астыннан тасма белән бәйләп куела торган булган). *Бер заман, модасы чыккан вакыт булды ахры, барлык хатын-кызлар ангора капор киеп йөри башлады.* Татарстан яшьләре

**КАПОТ** I *и. фр. иск.* Өйдә кияр өчен киң итеп тегелгән хатын-кызлар халаты. *Төсе-буенда яшерелә торган артыклыклар булганга, өстенә, узул кеби иттереп, ак ефәктән эшләнелгән капот кидерде [Габдулла Сәгадәткә].* Г.Исхакый

**КАПОТ** II *фр. техн.* Төрле механизмнарда детальләрне тузан, юеш һ.б.ш.дан саклый торган ачылмалы тимер капкач. *[Машинаның] --- капотына кәрзине белән чәчкә беркетелгән, түбәсе аша кызыллы-зәңгәрле ефәк тасмалар сузылган иде.* М.Маликова. *Бу очрашудан һәм сөйләшүләрдән күңеле тулган карт шофёр, дымлы күзләрен кешегә күрсәтмәс өчен, машинасының капотын ачып, нәрсәгәдер кул тидергән булды, караштырды.* Р.Кәрами. *Инде капотын ачкач, бөтен җире электроникага корылган бу затлы машинаның әле бер, әле икенче чыбыкларын тарткалап карыйм.* А.Хәсәнов

3) *сөйл. к.* **капотаж**. *Очучылар арасында да андый мәтәлү «капот» дип атала.* С.Баттал

**КАПОТАЖ** *и. фр. махс.* Күтәрелгәндә яки җиргә төшкәндә, самолётның баш аркылы әйләнүе. *Самолётыбыз чак кына капотаж ясамыйча калды бугай.* Мәдәни җомга

**КАПРАЛ** *и. фр. иск.* XVII йөздән XIX йөзгә кадәр рус армиясендә һәм башка кайбер илләрдә: кече командир дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәдәге кеше. *Аның янында басып торган капрал кычкырып боерык бирде.* З.Зәйнуллин. *Пленга алынган капрал бу рәсемнәрне солдатларга таратыр өчен командиры биргәнлеген сөйләгән.* Г.Әпсәләмов. *Фетнәгә кадәр аның (Г.Бигашевның) әүвәл флотта – капрал, туган ягына кайткач, мулла булуы мәгълүм.* В.Имамов

**КАПРИЗ** *и. фр.* 1) Характердагы, үзен тотышындагы көйсезлек, кирелек. *Олуг кенәз аның һәр капризын үтәргә тырыша иде.* М.Әмирханов. *Әллә аның минем белән никахлашуы әти-әнисе алдында чираттагы капризы гына булды микән?* Г.Галиева. *Ул маякларга тиң әсәрләр санап бетергесез күп югыйсә, тик болары, адәмнәргә хас каприз аркасында, күләгәдәрәк кала...* А.Тимергалин

2) *күч.* Табигать, әйләнә-тирә белән бәйле нинди дә булса көтелмәгән, очраклы хәл. *Ә менә Җир кешесеннән тәрбияләнгән пәйгамбәр, табигатьнең гап-гади капризы аркасында булса кирәк, башка барлык дөньяларда да хезмәт итә ала, ягъни ул универсаль.* А.Тимергалин. *--- суы ярларыннан ташып чыга, үзәнлекләргә җәелә, шәхси хуҗалыкларга хәтсез зарарлар да китерә. Түбән урынга урнашкан Эзмә халкы аның капризларыннан күп җәфалар кичерә.* Борынгы Калатау итәгендә

**КАПРИЗЛАНУ** *ф.* Иркәләнеп көйсезләнү, киреләнү, холыксызлану. *Аның урынында шул чакта башка берәү булган булса, бу нинди капризлану тагы, фәлән дә фәсмәтән дип пыр тузына башлар иде.* В.Нуруллин. *– Бусы инде капризлану! – Әти кыза башлады. – Укыйсы килми, эшләргә теләми.* Ф.Яруллин. *– Бу нинди капризлану? – диде Гаяз, тавышын күтәреп. – Бүгенгә генә ташлап тор, ичмасам, шул мещанкалыгыңны!* М.Әмир

**Капризлана бару** Торган саен ныграк капризлану. *Картайган саен капризлана бара, тач бала-чага инде.* Җ.Юныс

**Капризлана башлау** Капризланырга тотыну. *Мондый очракта ул тагын капризлана башларга мөмкин.* Ватаным Татарстан

**Капризлана төшү** Тагын да күбрәк капризлану. *Бала тагын да капризлана төште.* Г.Галиева

**Капризланып алу** Аз гына капризлану. *Нәкъ менә шул вакытта бераз капризланып аласың.* М.Мәһдиев. *Рәүфә, әлбәттә: «Әй хыялланасың да инде, атасы!» – дип капризланып алса да, үзе аңа ышана, чынлап та шундый көннең киләчәгенә шикләнми, өметен өзми, һичшиксез, Вәлиәхмәт әйткәнчә булачагын белә.* Җ.Юныс

**Капризланып йөрү** Соңгы вакытта, озак вакытлар капризлану. *Көннәр буе капризланып йөреп булмый, үзеңне кулга ал әйдә.* М.Мәһдиев

**Капризланып китү** Тагын да бераз капризлану. **–** *Халыкның бу дәрәҗәдә «капризланып» китәсен кем белгән? – диделәр миңа паспорт-виза хезмәтендә, әлеге проблеманы ачыклау йөзеннән чылтыраткач.* Татарстан яшьләре

**Капризланып тору** Сөйләгән моментта капризлану; даими капризлану. *[Әпсәләм:] Госман абый, кыз капризланып тордымы, урлыйлар да китәләр.* Х.Вахит

**КАПРИЗЛЫ** *с.* 1) Көйсез, кире, холыксыз, артык назлы. *Кыдрач, капризлы улының шулай тәмле итеп, иркәләп сөйләгәнен бер тапкыр да ишеткәне юк иде әтисенең.* А.Гыйләҗев. *– Әйе, әтиемнең бердәнбер, ләкин бик иркә, бик тә капризлы кызы Данәгөл туташ булам, – диде дә, башта книксен чүкте, аннары кулын сузды ул.* А.Хәсәнов. *Ә үсмер чак ул, белүебезчә, аеруча капризлы чор.* Казан утлары

2) Нәзберек. *Иҗат дигәнең, бик капризлы, бик үзенчәлекле бер нәрсә.* Г.Бәширов. *Җырчылар да капризлы халык: ниндидер сүзләрне матур итеп әйтә алмый интегә башлыйлар.* Р.Миңнуллин

**КАПРОН** *и. ингл.* **1.** 1) Ясалма сүснең бер төре. *Дүрт пакетка сүсләр салынган: киҗе-мамык тукыма, йон, ацетат сүс һәм капрон.* Органик химия. *Нәкыйп эшли торган завод капрон җитештерү буенча ил күләмендә беренче урында.* Казан утлары

2) Шул сүстән ясалган тукыма. *Төсле капроннан күлмәк тегәргә ниятләп торам, актан киясем килми.* А.Гыйләҗев. *Ниндидер каптырмалар чыртлап ычкынганы, капрон кыштырдаганы ишетелде.* Х.Камалов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Арттан менсә, туташының капрон оек баганасының бераз кыеграк торуын күреп, аны уңайсыз хәлгә куюы мөмкин.* А.Хәсәнов. *Күлмәк-итәккә карый чалбар җайлырак шул, дустым. Бер киюдә ертылып чыга торган капрон оек түгел инде.* Р.Габделхакова

2) Шул материалдан ясалган. *Сөембикә зәңгәр капрон чиләк алып килде.* Ф.Садриев. *Ул арада кызлар багажникларыннан матур итеп үргән сары капрон аркан алдылар.* А.Хәсәнов

3) *күч.* Табигатьтән ераклашкан; ясалма, табигый түгел. *«Шәһәрләшеп» баралар әнә. Барысы да дип әйтмим, әмма нәкъ менә шулар арасыннан акрынлап туган телен, милли гореф-гадәтләрне оныткан маңкортлар, капрон яшьләр үсеп чыкты да инде.* Р.Низамиев. *Хәтерлибез бит: кеше җанына кагылмый торган докладларда капрон тел барлыкка килде.* М.Галиев

**КАПРОНЛЫ** *с.* Капрон (*1 мәгъ.*) катнашкан, капроны булган. – *Үзең ки, капронлы тукыманы җенем сөйми, – дип, ул кибеттән чыгып ук китте.* Ирек мәйданы

**КА́ПСУЛ** *и. сөйл. к.* **капсула**. – *Свердловскида дәвалыйлар икән, – дип куйды Вәзыйх. – Арт очага капсул тегәләр, ди.* Х.Камалов

**КА́ПСУЛА** *и. лат. махс.* 1) Бер йотым даруның крахмал, желатин яки кәгазьдән ясалып, йоткач эреп бетә торган юка тышчасы. *Кич белән башта Касап белән Марс үзе керде. Арнольд Львович башта аларга кызгылт сары төстәге капсулалар каптырды да: – Йотыгыз, егетләр! – дип, бер стакан су сузды.* Р.Сәгъди. *Капсуланы ачып, эчеп җибәрде [язучы].* М.Кәбиров

2) Космик очу аппаратының бер өлеше

3) *сөйл. к.* **капсюль**. *[Мидхәт:] Аларның шартлаткычы капсулаларда, җир токымына зур булмаган тишекләр ясап тыгып кына куясы.* М.Маликова

**КА́ПСЮЛЬ** *и. фр.* 1) Артиллерия снарядлары, патрон һәм гранаталарда, бәрелү нәтиҗәсендә шартлап китеп, патрон һ.б.ларның зарядын кабызырга ярдәм итә торган металл калпак. *Бетон идәндә таралып яткан меңләгән капсюльларны күреп, Гадел сүзсез калды.* Казан утлары

2) *к.* **капсула** (*1 мәгъ.*). *Әнә берләшмә инженеры арт йомшагына капсюль тектергән, хәзер эчми.* Х.Камалов. *Горкомда берничә татар капсюль белән йөри, диләр.* Х.Камалов

**КАПТА́Ж** *и. фр.* 1) Җир асты сулары, нефть, газ чыгарганда башкарыла торган инженер-техник эшләр. *«Теплосервис» ҖЧҖнең И.Салихов бригадасы авыл башында тибеп ята торган чишмәгә каптаж ясап, ягъни әлеге су чыганагын файдаланып, барысы 2200 метр торба суза – нәтиҗәдә, авыл янә чиста, тәмле чишмә суына тиенде.* Татарстан яшьләре

2) Җир асты байлыкларын суырту өчен ясалган җайланмалар (скважина, кое һ.б.). *Аның өчен һәр хуҗалыкка шланг кына сатып алырга кирәк, экскаватор белән Рузил абый үзе ярдәм итәргә вәгъдә иткән, каптаж савытны исә совхоз бушка биргән.* Акчарлак. *Районыбызда лицензия алынмаган нибары 9 каптаж һәм 6 скважина гына калды инде.* Ватаным Татарстан

**КАПТАЖЛА́У** *ф.* 1) Җир асты байлыклары – нефть, газ, су чыганакларын ачып җибәреп, аларны торбалар һ.б. аша җир өстенә чыгару

2) Язгы сулар һәм чүп-чар кермәсен өчен, чишмәләрне тимер-бетон белән буралап, өсләрен томалау. *Чишмә каптажлау эшенә мине абыең өйрәтте бит.* А.Нуруллин

**Каптажлап алу** Кыска вакыт эчендә каптажлау

**Каптажлап бетерү** Барысын да каптажлау

**Каптажлап тору** Сөйләгән моментта каптажлау; даими каптажлау

**КАПТЕНА́РМУС** *и. фр. иск.* Армиядә: азык-төлек, кием-салым, коралларны саклау һәм бирү өчен җаваплы кеше. *Каптенармус азык алырга барырга кеше эзләп йөри иде, мин «теләп барам» дидем.* А.Таһиров. *Әйе, мин писер дә булдым, старшина да, каптенармус та.* Г.Бәширов. *[Нургали:] Бездә бер сәүдәгәр малае каптенармус булып хезмәт итә, шуңа әйтеп карасак.* Т.Гыйззәт

**КАПТЫРГЫЧ** *и.* Төрле нәрсәләрне кыстыру, эләктерү, беркетү өчен хезмәт итә торган җайланма. *Кара сызыклы ачык коңгырт костюмы, керсез ак күлмәге, алсу галстугындагы каптыргычта җемелдәгән асылташ, --- ялт итеп торган көрән штиблетлар – болар барысы да затлы картинаның бик тә кыйммәтле кысасы шикелле иде.* М.Маликова. *Кыз ашыкмыйча гына (сокланып үзәге өзелсен әле, дигәндер, валлаһи!) ак, нәфис куллары белән чәчләрен артка җыеп, аларны тарак сыман каптыргыч белән (аның берәр исеме бардыр инде, тик Гафиулла белми генә) эләктереп куя.* Ә.Сафиуллин. *Эре сәдәфләрен Миргаяз нечкә бакыр чыбык белән тегеп куйган. Аягында ботинкага охшаган иске нәрсә, бәйли торган бавы да, каптыргычы да юк.* Ф.Садриев

**КАПТЫ́Р-КОПТЫР** *рәв.* Ашык-пошык, тиз-тиз. *[Әнисә:] Каптор-коптор җыенып чыгып киткән иде, эт баласы иртәп кайтып килә әнә.* Мәдәни җомга

**КАПТЫРМА** *и.* Кием һ.б. нәрсәләрдә эләктерү, каптыру өчен хезмәт итә торган җайланма. *Ул өстендәге вельвет курткасына кадап куелган миниатюр Әмрикә туграсының каптырмасын ычкындырды һәм аны кызчыкның күлмәк якасына эләктереп куйды.* А.Хәлим. *Бермәлгә кызыкайның күзенә тәти каптырмалар, алкалар булып күренде ул күбәләкләр...* Г.Якупова. *Әтисенең өстендә каптырмасыз юка камзул, чүпрәк кәпәч, ә инде улының башында касмаклана төшкән иске кара кәләпүш.* Р.Низамиев

**КАПТЫРМАЛА́У** *ф.* Каптырманы эләктерү. *Андый кечкенә сәдәфләрне каптырмалау үзе үк күпме вакытымны ала иде әле.* Г.Шәрифуллина

**Каптырмалап алу** Кыска вакыт эчендә каптырмалау. *Туфлиләремне каптырмалап алдым да йөгердем урамга.* Ялкын

**Каптырмалап бетерү** Барысын да, тулысынча каптырмалау. *Утүкләп, барлык төймәләрен каптырмалап бетергәч, әнинең күлмәкләрен алгы яктагы шкафка элеп куйдым.* Г.Сафина

**Каптырмалап кую** Каптырмаланган хәлгә китерү. *Күлмәк төймәләрен каптырмалап кую*

**КАПТЫРМАЛЫ** *с.* 1) Каптырмасы булган, каптырма белән эләктерелә, ябыла торган. *Егет исә шәһәрчәрәк: өстендә аның эре шакмаклы «молния» каптырмалы күлмәк, балаклары бөрмәле күк шаровар, аягында «тапочка» дип йөртелгән резин чүәк ---.* Ә.Еники. *Күптән, бик күптән чормаңда тузан җыеп яткан гармунның каптырмалы путасы шартлап өзелә дә, күрегe бар кодрәтенә тартыла...* К.Кәримов. *Төргәк-төргәк калын кульязмалар, чөй язулы таш такталар, җиз дисбеләр, көмеш каптырмалы, тышлары асыл ташлар илә бизәлгән китаплар – барысы да якты көннәр килгәнчегә кадәр ышанычлы урында сакланыр.* Ф.Латыйфи

2) *этн.* Сәке такталарының берничәсен алып, сәке кысасына гына эләктереп җайлана торган (стан тур.). *Зәкия апаларның каптырмалы станнарын уллары музейга тапшырган икән.* Шәһри Казан. *--- музейдагы каптырмалы стан янында фотога да төштек.* Казан утлары

**КАПТЫРУ** I *ф.* 1) Кабарга бирү. *Мәдинәсенең аңа эчермәгән үләне, каптырмаган җиләге, авыз иттермәгән азыгы калмады.* А.Хәлим. *Әй, ипподром аты атмыни ул?! Аларны укол кадап, витамин каптырып үстерәләр бит.* Ф.Яруллин

2) Ашарга бирү, бераз гына ашату. *Бер генә кулда булу, Мөнирҗанның авызыннан өзеп икмәк каптырулары, какмавы-сукмавы, бик тәҗел чакларда чыбыркысын офыкта нәҗагай урынына ялтыратып кына алулары Күк биянең хәлен күпкә яхшырткан иде.* Н.Әхмәдиев. – *Болар – узган ел туган чәүкәләр, – диде ул, аларга ипи катысы каптырып.* З.Фәйзуллин

**Каптыра башлау** Каптырырга тотыну. *Имидән аеру дигәннән, ике балага Фәүзиянең күкрәк сөте җитмәгәч, базлап елаган Илүсәгә, тынычландырыр өчен генә булса да, Мәрхәбә карчык үз имиен каптыра башлады.* Ф.Дәүләтгәрәева. *Минем әни балага ике ай булу белән күк җиләк каптыра башлады...* Безнең гәҗит

**Каптырып алу** Тиз генә һәм аз гына каптыру. *Хәле әйбәтләнмәсә, дару каптырып алырга кирәк булыр ---.* Казан утлары

**Каптырып бетерү** Барысын да каптыру. *Алып кайтканнарын каптырып бетергәч, кош кабат китә.* Казан утлары

**Каптырып кую** Тиз генә каптыру. *Мин нәрсә дә булса уйлап өлгергәнче, авызыма тәмәке каптырып та куйдылар.* М.Кәбиров. *Кулларына уенчык тоттырып, авызларына имезлек каптырып куярга гына кала.* Шәһри Казан

**Каптырып тору** Бертуктаусыз каптыру; сөйләү моментында каптыру. *Өйгә керсәк, Маһруй әби генә Нәсимәнең башын тотып, чәшкә белән чәй каптырып тора иде.* Ш.Маннапов. *Айдар үзенең дустына ипи сыныгы каптырып тора иде.* Г.Гыйльманов

**Каптырып чыгу** Барысына да каптыру. *Бал белән он, майны болгатып пешерә дә, кунак ашы дип, кеше саен шуны каптырып чыга.* Ф.Баязитова. *Тансык аңа бу сөт. Сәхәпкә эчергәч, башкаларга да каптырып чык, зыянга булмас.* Г.Гыйльманов

**КАПТЫРУ** II *ф.* 1) Эләктерү (сәдәф, каптырма һ.б.ны). – *Бетәр әле, кайгырма! – Фатыйма халат төймәләрен каптырмакчы иде, ләкин бик борчылган ир хатынының бөтен җирен тикшереп чыкмыйча туктамады.* Ф.Яруллин. *Үзе --- тунны кулына алды, тиз генә өстенә элеп, төймәләрен дә каптырып тормыйча, урамга атылды.* Р.Габделхакова

2) *сөйл.* Кармак белән балык тоту. *Кайвакыт ул көне буена югалып тора, димәк, ул инде балык каптыру белән мавыга.* Р.Мостафин. *Бу вакытта инде авыз ачып тормаска, балыкны каптырып, тартып чыгарырга кирәк.* Ә.Сәлах. *Яңгыр ява башлаганда, Әнвәр яшьтәш дуслары Фәрит, Газизҗан, Әмир, Фирдүсләр белән Актайның комлы яры буенда балык каптырып утыра иде.* Ә.Хәсәнов

3) *күч.* Тоту, яшеренеп йөргән кешене эләктерү, кулга алу. *«Әгәр мин бу бандаsucc каптырмасам, иңемдәге старшина погоннарын үзем үк йолкып атып, милициядән китәчәкмен», – диде ул.* Ф.Яруллин. *Тагын эләгә бичара, каптыралар тегене...* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Яшерен эшне ачу, билгесез әйберне ачыклау, кемнеңдер серен алу. – *Ай-яй, җиңел генә каптырмакчы, кабахәт! – Халитовның йөзе каралып чыкты. – Барысын да үз кубызына биетмәкче.* Р.Мирхәйдәров. *Иң яхшысы: бозыклык эшендә Мәймүнәнең үзен каптыру һәм ире белән араларын бозу, дөресрәге, кыек эшләреңне ирең җиткерәм дип өркетеп торып, Арыслангалине курыкмыйча бүлешү.* З.Хөснияр

**Каптыра башлау** Каптырырга тотыну. *Мин гел дөньямны онытып, балык каптыра башладым.* Идел

**Каптырып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә каптыру. *Ятьмә корылган... Кемнедер каптырып алырга әзерләнгәннәр!* А.Гыйләҗев. *Әйтер, әйтер, хәзер әйттерәбез аны дип уйлап бетердем дә, уйлаганны эшләргә дә кирәк бит инде: Барыйның муеныннан каптырып алып, башын җиргә таба бөктем.* З.Хөснетдинов. *Айгырны каптырып алса, аңа сикереп кенә менмәкче дә аннары безгә койрык күрсәтмәкче.* В.Имамов

**Каптырып бетерү** Барысын да каптыру

**Каптырып кую** Каптырган хәлдә калдыру. *Табаны төшеп калмасын өчен, кәгазь эләктерә торган скрипкәләр белән каптырып куйдым.* М.Галиев. *Колхоз рәисе Мәүлә абый өстәл өстендәге кәгазьләрен җыеп, йомшарып беткән кыр сумкасына салды, челт итеп йозагын каптырып куйды да, янәшәдәге урындык өстеннән*

*фуражкасын алып, сумкасына каплады.* Л.Ихсанова

**Каптырып тору** Сөйләгән моментта каптыру; каптыру белән мәшгуль булу. *Әлеге чөгәләрне, астан чумып, аның кармагына каптырып торырбыз.* Р.Батулла. *Келәне каптырып тормадым, өйгә кереп киттем.* Н.Фәттах

**Каптырып чыгу** Һәрберсен берәмберәм каптыру

**КАПУ** *и. иск.* 1) *к.* **капка**. – *Күк капусы ачылды, балам, теләкләреңне телә, – диде әбисе.* Ф.Бәйрәмова. *Күк капусы ачылганны күргән кеше бармы, Нурислам абый?* Р.Батулла. *Калибрланган юан-юан бүрәнәләре кояш баегач та алтын төсен югалтмаган, капу түбәсе зәңгәр черепицалар белән ябылган, чорма тәрәзәләре бизәкле, унҗиде эргәле, әмир сараедай матурлык янына килеп туктагач, үзеңне мең ел элек тасвирланган борынгы тарихка әсир төшкәндәй хис итәсең...* К.Кәримов

2) *к.* **капкач**. *Тәрәзәңнең капусына Моңлы кош килеп кунган.* Җыр

**КАПЧЫК** *и.* 1) Коела, чәчелә торган әйберләрне саклау һәм бер урыннан икенче урынга ташу өчен, тупас тукымадан яки башка материалдан бер башын ачык калдырып тегелгән кап. *Әнә бер атның авызына солылы капчык бәйләгәннәр.* Р.Низамиев. *Язгы баткагында да интектеләр, көзгесендә дә капчык өстенә капчык төягән атлар үр менәлми тилмерде, иллә дә мәгәр, тегермәннәрне генә рәтлик соң, дигән сүз ишетелмәде.* Р.Рахман

2) Төрле әйберләр салу өчен хезмәт итә торган кап, пакет. *Элеккеге заманнарда кибеттәге сөт савытлары пирамида кебек очлы түбәле иде, хәзергеләре полиэтилен капчык шул...* К.Кәримов. *Хатын целлофан капчыктагы даруларны өстәлгә бушатып, караштыра башлады.* А.Хәлим. *Менә ул, ниһаять, миңа якын гына өеп куйган чүпләренең бер «чүмәләсен» каралып, таушалып беткән кәгазь капчыкка тутырып маташа.* Ф.Баттал

3) *сөйл.* Бөртекле әйберләрне үлчәү берәмлеге: 3–5 пот чамасы. *Тик Аширов алай сай йөзә торган затлардан түгел иде. Аның хакы: бер капчык бодай өчен – ике мең сум!* Ә.Мушинский. *Хәл белүче кунагыбыз бик юмарт булып чыкты, җилтерәтеп ике капчык бәрәңге кертеп куйды, сумкасыннан ит, күпереп торган авыл ипие чыгарды: «Болары – күчтәнәч».* Р.Габделхакова. *Урман үстерүчеләргә ел саен икешәрөчәр капчык нарат күркәсе җыеп тапшыра торгач, агач башына менәргә бөтенләй һәвәсләндем.* К.Кәримов

4) Үсемлекләрдә яки тере организмнар тәнендә гадәттә нинди дә булса сыеклык белән тулы тышча. *Ут капчыгы. Сидек капчыгы. Споралы капчык*

5) *хәрби* Гаскәрнең тулы камалышы

◊ **Капчык авызы** *хәрби* Капчыктан (*5 мәгъ.*), камалыштан чыгып була торган ачыклык. *Артта ике-өч чакрым гына киңлектәге «капчык авызы» калды.* Ш.Маннур. **Капчык төбен селкү** 1) Барлык запасны бетерү. – *Капчык төбен күптән селкедек, – дип, авыр сулап куйды Ибрай.* Казан утлары; 2) Серне ачу, барысын да сөйләп бирү

**КАПЧЫКЛАНУ** *ф.* 1) Капчык формасын алу, салыну, киңәеп калу (киемнәр тур.). – *Капчыкланган кызыл кофтасын әле дә булса киеп йөриме шулай? – дип, Заһирә дә сүзгә кушылды.* А.Галиева

2) Шешенкеләнү (күз төбе, тамак асты һ.б.). *Аның зур күзләре һәрвакытта әллә нинди тирән мәгънәле төс алып, капчыкланып салынып төшкән күз төпләре, куе чал кашлары --- аңар махсус мәһабәтлек, зурлык бирәләр иде.* К.Тинчурин. *Аның агарган чәчләре, капчыкланган күз төпләре, каралып киткән йөзе тормышының бер дә җиңел булмаганлыгы турында сөйли иде.* Сөембикә

**Капчыклана бару** Аз-азлап, акрынлап капчыклану. *[Илсөяр:] – Бу кофтаң кигән саен капчыклана бара синең, мә, минекен киеп йөр әле бераз, – дип, үзенең йон кофтасын сузды Сәлимәгә.* А.Нуруллин

**Капчыклана башлау** Капчыклануга таба бару. *Өстендә капчыклана башлаган пиджак, яшькелт күлмәгенә галстук таккан.* Х.Камалов

**Капчыклана төшү** Тагын да бераз капчыклану. *Шешенке битенә әллә кершән ягып, иннек салган инде, бит урталары алсуланып яна, ә кечкенә йомшак ияге, гел тирләүчән борыны, капчыклана төшкән күз төпләре агарып тора.* Ә.Еники

**Капчыкланып бетү** Бөтенләй капчыклану; тәмам капчыкланган хәлгә килү. *Ул арада ишектән, иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, бригадир белән председательләр өстендә генә очрый торган, капчыкланып беткән зәңгәр пинжәктән Сәетгали үзе дә килеп керде.* Ә.Еники. *[Зариф:] Күз төпләрең капчыкланып беткән әнә, шуның кадәр эчәргә ярыймы соң инде?!* Казан утлары

**Капчыкланып калу** Капчыкланган хәлгә килү

**Капчыкланып тору** Капчыкланган хәлдә булу. *Киемнәрегез капчыкланып тора икән, минем янга килегез.* Сөембикә

**КАПЧЫКЛЫ** *с.* 1) Капчык тоткан, капчык күтәргән. *Юлларына капчыклы бер карт очраган, ди.* Әкият. *Әнисенә ияреп базарда йөрү, җитмәсә, капчыклы карт хатын-кыз янына килеп чыгу Җәбирнең үзенә дә оятрак иде, әлбәттә.* Н.Фәттах

2) Капчыкка тутырылган, капчыкка салынган. *Безне вагоннарга төягәндә, ике урында зур эскерт итеп өелгән капчыклы оннар яна башлады.* А.Таһиров. *Ул күрсәткән якка карасам, чыннан да, капчыклы он!* Г.Бәширов. *Кызый, капчыклы бодайларны арбага ыргытырлык беләкләрен киереп, горур рәвештә үтеп китәргә теләгән иде. – Сөмбелә, нихәл? – дигән мыгырдау аны кинәт туктатты.* К.Кәримов

**КАПЧЫКЛЫК** *с.* **1.** Капчык тегә торган, капчык тегәргә яраклы

**2.** *и. мәгъ.* Капчык тегәргә җитәрлек, яраклык материал. – *Бер капчыклык кына булса да җитәр иде миңа, – диде Мәрфуга ---.* Татарстан яшьләре

**КАПЧЫ́К СУГЫШЫ** *и. этн.* Ике агач баганага аркылы урнаштырылган шома бүрәнәгә утырып, көндәшеңне йомшак нәрсә тутырылган капчык белән бәреп төшерүдән гыйбарәт уен; гадәттә, Сабан туенда уйныйлар. *Сабантуйда алар татарча көрәш, капчык сугышы кебек милли уеннарны*

*күрсәттеләр.* М.Мәһдиев. *Йөгерешчеләр килеп беткәч, капчык сугышы уеннары башланган.* Ф.Яруллин. *Кемнәрдер капчык сугышына ихласын салган, ә кемнәр – колга башына үрмәләүчеләргә...* Р.Зарипов

**КАПЧЫКЧЫ** *и. иск. сөйл.* Спекуляция, алып сату белән шөгыльләнүче. *Капчыкчылар заманы иде бит, нишлисең...* Мәдәни җомга

**КАПШАВЫЧ** *и.* 1) Күп кенә умырткасыз хайваннарда сизү, эләктерү, ә кайбер вакытта сулыш органы да булып хезмәт итә торган хәрәкәтчел үсенте. *Барысын да үз кубызына биетмәкче. Сигезаяк диярсең, капшавычларын бар якка таратып салган.* Р.Мирхәйдәров. *Сигезаяк, өч капшавычы белән кыяга тотынып, калганнары белән Жилбернең тәнен уратып ала.* Р.Зарипов. *Сигезаякның өзгәләнгән капшавычлары палуба буйлап сөйрәлеп барды.* Казан утлары

2) *тех.* Төрле максатлар белән нәрсәне дә булса капшап тикшерү өчен, борау, тимерчыбык яки башка формадагы җайланма

**КАПШАНУ** *ф.* Кармалану, эзләнү. *--- Үлән арасында капшанып вакыт үткәргәнче, балык тотуга ни җитә! – дип үзләрен акларга тырышалар (малайлар).* Ф.Яруллин. *Үч алырга уйлыйсыңмы? – Гарифҗан артка яшергән кулы белән капшанып чүкеч алды.* Ә.Гаффар. *Куллары, капшанып, кульъяулык эзләде.* Р.Мулланурова. *Таһир күзләрен йомды. Капшанып тәрәзә төбеннән графин алды.* Г.Мөхәммәтшин

**Капшана башлау** Капшанырга тотыну. *Ул кулын сузып капшана башлады.* Г.Әпсәләмов. *Зөһрә, бераз тынычлангач, кузгалмыйча гына капшана башлады.* Г.Гыйльманов

**Капшана тору** Озак вакыт капшану. *Капшана торгач, ул Әхмәди абзасына капчык төбендә кысылып калган бер шакмак шикәр сузды.* Г.Бәширов. *Капшана торгач, аягы нәрсәгәдер төртелде.* Р.Мулланурова

**Капшанып алу** Кыска вакыт эчендә капшану

**Капшанып тору** Бертуктаусыз капшану; сөйләү моментында капшану. *Следователь, өстәл артына утырган килеш, бераз кесәсенә кулын тыгып капшанып торды да Әскәргә пистолет чыгарып бирде ---.* С.Баттал. *Асылбикә ишек тимеренә элмәле йозак таккан иде, Хафиз ачкыч капшанып тормады, йодрыгы белән генә сугып ачты.* Н.Гыйматдинова

**КАПША́У** *ф.* 1) Кул белән эзләү, кармалау. *Уң як кабыргасын капшый башлагач, Рәдиф тагын җан өшеткеч итеп илереп куйды.* В.Нуруллин. *Газинурның бармаклары кечкенә генә җиз этикетканы капшый.* Г.Әпсәләмов. *Үз-үзенә ышанмагандай, Мансур түш кесәсен капшады: шөкер, хат урынында иде.* Р.Юсупова

2) *сөйл.* Берәр нәрсәне эзләп табу, урынын билгеләү өчен, пулемёт уты, ут көлтәсе, фонарь һ.б. белән яктыртып, нииндидер урынны, өслекне һ.б. җентекләп тикшерү. *Прожектор, төн карасын телеп, Елга өстен капшый, яр буен.* Е.Уткин

3) *күч.* Җентекләп карау, игътибар белән күзәтү. *[Хис-тойгылар] Сабырсызлана, каядыр карурманга кереп адашканмын да кебек, бозы арчылып бетмәгән агымсуда коенам да сыман, күз карашым каушап тирә-якны капшый, тишә, үтәли күрә ---.* А.Гыйләҗев. *Күзләре белән капшамыйча сөйләшә дә башламас иде ул.* А.Нуруллин. *Алар, хан кызына һәм шөһрәтле Әмәт хатынына сүз катарга базмасалар да, күзләре белән капшауларын куймыйлар иде.* Т.Нәбиуллин

4) *күч.* Нәрсәне дә булса белергә, ачыкларга, эзенә төшәргә, табарга тырышып төпчену яки сынау, игътибар белән карау, күзәтү, өйрәнү. *Бу – үзенә күрә икесенең дә күңелләрендә нәрсә ятканын капшау кебегрәк халәт булды.* Ф.Садриев. *Бу гадәти кызыксыну, ваемсыз капшау гына түгел иде.* Т.Галиуллин. *Ул менә бүген минем бу Язманы капшый бугай: «Ни өчен автор, – янәсе, – Үз ягын мактый шулай».* Х.Туфан

**Капшап алу** Бер тапкыр капшау. *Галим билендәге кайчыны капшап алды да алга атлады.* Г.Әпсәләмов. *Тирләп чыккан маңгаемны ирексездән капшап алдым: кем икәнлегем анда язып куелмагандыр ич?* Н.Әхмәдиев

**Капшап бару** Аз-азлап, акрынлап капшау

**Капшап бетерү** Җентекләп, озаклап, бөтен җирен капшау. *Гәүдәңне аркылыга-буйга үлчәп, капшап бетерәләр икән.* Ә.Хәсәнов

**Капшап йөрү** Анда-санда капшау

**Капшап карау** Капшап тикшерү. *Кыз күлмәкнең җиликәләрен капшап карый.* М.Юныс. *Дәүләтшин (ул хәзер минем рәсми ярдәмчем) егетләрнең көрәкләрен, котелокларын һәм башка тимер-томырларын капшап карый: яхшы тагылганнармы, шалтырамыйлармы?* И.Гази

**Капшап кую** Бер тапкыр капшау. *Аның [Алексейның] дежурда бирелгән пистолеты бар иде, ул шуңа канәгать булып капшап куйды.* Х.Камалов. *Ә инде сәкегә тезелеп утырган ике карчык Шәрифелтти белән Хәбибҗамалтти оек куныларын капшап куйдылар.* Н.Кәримова

**Капшап тору** Сөйләгән моментта капшау; даими капшау. *Аннары, күкрәге турына тезләнеп, йөрәген капшап торды да: – Милашкин исән! – дип кычкырып куйды.* Х.Камалов. *Агачларның ботакларын Тынгысыз җил капшап тора.* Л.Шәех

**Капшап чыгу** Һәрберсен аерым-аерым капшау. *Кирәкле кәгазен таба алмыйча, Әхәт һәр кесәсен капшап чыкты.* А.Галиева. *Ә колхозлашу чорында авылларга кайткан зур тимер көпчәкле тракторны күргәч, Азат бала чагына кайткандай булды, куанды, тракторның бөтен нәрсәләрен капшап чыкты.* А.Тимергалин

**Капшый башлау** Капшарга керешү. *Уйлар аның башын җирдән күтәрделәр, ул томанлы күзләре белән авыл урамнарын капшый башлады.* А.Гыйләҗев. *Мулланың тавышы тынгач, әтисе кесәсен капшый башлады.* Р.Зәйдулла

**Капшый тору** Туктаусыз, озак вакыт капшау. *Бөтен авыл халкы белән урманны капшый торгач, әтине тапканнар.* З.Хәким

**Капшый төшү** Тагын да күбрәк капшау

**КАПЫЛ** *рәв. гар.* **1.** Кинәт, бик тиз, көтмәгәндә, искәрмәстән. *Менә аларның берсе рульне капыл уңга борды.* И.Хуҗин. *Дөнья капыл караңгыланып китте: әллә аң-зиһенгә чак барып җиткән кара кайгыдан, әллә тырым-тырагай таралышып яткан кара кисәүләрдән?..* Г.Якупова. *– Дусларым! – диде Әхмәров, капыл гына урыныннан күтәрелеп, җан яраткан кайнишенә караш ташлап.* Р.Низамиев

**2.** *с. мәгъ. сөйл.* Кабынып китүчән, кискен хәрәкәтле, тотнаксыз. *Бик капыл кеше иде шул ---, шул бетерде дә аны.* Татарстан яшьләре

**КАПЫ́Л-КОПЫЛ** *рәв.* Ашыкпошык, аннан-моннан. *Кинәт аның күңеле боекланды, үзенең болай гайрәт чәчеп утыруы урынсыз бер эш булып тоелды, ул, урыныннан сикереп торып, капыл-копыл гына саубуллаша башлады.* А.Гыйләҗев

**КАПЫЛЛЫК** *и.* 1) Кинәтлек, тизлек. *Капыллык белән берни майтара алмыйсың бу очракта.* Казан утлары

2) Кабынып китүчәнлек, кызу холык. *Тумыштан килгән капыллыгы Асияне бик күп тапкырлар кыен хәлдә калдырачак әле ---.* А.Галиева

**КАПЫЛТ** *рәв. гар. к.* **капыл**. **1.** *Яббар бакча артыннан әкрен генә аксап кайтып килүче атасының күзенә чалынмас өчен капылт кына капкадан чыкты да Чишмә тыкрыгыннан томырылып йөгерде.* З.Хәким. *– Юк! Тәүбә-тәүбә диген! – Дияр карт, йодрыкларын күз алдында йомарлап, утырган җиреннән капылт сикереп торды.* К.Кәримов. *Ул арада, ничек капылт кына килеп кергән булса, шулай ук көтмәгәндә кабинеттан чыгып та китте минем юлдашым.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Кискен, көтелмәгән. *Хәер, бу капылт үзгәрешнең асылын Ак күлгә кадәр үк җиткергәннәр иде анысы.* М.Әмирханов

**КАПЫЛТЛЫК** *и. к.* **капыллык**. *Жаденко сак кына уйлана иде, яшь журналистның капылтлыгы, ордымбәрдем юлга чыгып китүе аңа бер тамчы ошамаса да, ул әлегә аны сиздермәде.* А.Гыйләҗев

**КАПЮШОН** *и. фр.* Өске киемнәрнең якасына тоташтырылып тегелә һәм кирәк очракта кияргә яисә җиңел генә салырга (төшереп җибәрергә) мөмкин булган башлык. *Музыка тавышына ул башын күтәрә, баш җәймәсе – капюшоны – кульяулык зурлыгына кадәр җәелә.* М.Мәһдиев. *Кызганыч хәл, --- без үз сүзләребезне оныта барабыз икән. Катаракта сүзе кергәнче, халыкта кылау сүзе йөргән ---, капюшон урынына көрәпәлә йөргән...* Ф.Сафиуллина

**КАР** I *и.* 1) Төрле формадагы ак кристалл сыман бик вак бөртекләрдән торган атмосфера явым-төшеме. *Кичтән җылы иде әле, ә төнлә туңдырып җибәрде, һәм кар ява башлады.* Ә.Сәлах. *Тимердәй авыр-тыгыз җил исеп, шуның өстенә җепшек кар катыш яңгыр да сибәли башласа, эшләр харап инде.* Р.Низамиев

2) Әлеге явым-төшемнең җир өстен каплап алган массасы. *Төнлә кар явып узган, күрәсең, күперенке көртләр өстенә кер кунып өлгермәгән әле.* М.Маликова. *Битне кар белән юдым да өйгә йөгердем...* Ф.Җамалетдинова

**КАР** II *иярт.* Карга кычкырган тавышны белдерә торган сүз. *Күктә бик күп карга, «Кар», «кар» килә бар да.* Ф.Яруллин. *Кар-кар дип кычкырышкан каргаларга, җим эзләп сикерешкән чыпчыкларга карап торды Сәлим карт.* Казан утлары

**КАРА** I *с.* **1.** 1) Корым төсендәге; иң караңгы төсле. *Төрмә капкасының теге ягыннан чыгучылар арасында кара кәләпүш һәм таушалганрак җилән кигән Насретдин җизнәсе дә күренде.* Р.Низамиев. *Ә анда акка кара белән язып куелган: бер үк кеше рәис булып ике генә тапкыр сайлана ала, диелгән.* Г.Морат. *Урам чатында кара кофта, кара чалбар кигән, түшенә эре ак төймә таккан кара чәчле кыз күренде.* М.Маликова

2) Куерак, караңгырак төстәге. *Менә ишегалларында ниндидер кара киенгән кешеләр күренә башлады.* Г.Бәширов. *Ташла кара киемнәр киеп йөрү гадәтеңне, дип ничә әйттеләр инде миңа.* Мәдәни җомга

3) Караңгы; яктылык төшми торган, куе, калын. *Арышлы белән Камышлы арасында әлгәре кара урман шаулап үскән, дип сөйлиләр.* К.Кәримов. *Басуларны кылган баскан... «Шүрәле асрап ята торган» кара урманнарны да кисеп-егып киләләр...* А.Тимергалин

4) Негроид расаның билгесе буларак, ак тәнлеләрдән нык аерылган караңгы төстәге. *1950 елдагы халык санын алган вакытта ак һәм кара тәнлеләрнең катнаш никахларыннан туган балалар барысы да негр өммәтенә кертелде* А.Хәлим. *Докладымны кыскартып шуны гына әйтәсем килә: Африка! Кырык яшьлек кара хатын баш өстенә кырык килолы йөк күтәргән...* Казан утлары

5) Тумыштан каратутлы, чәче һәм тән төсе башкаларныкыннан караңгырак булган. *Безгә бер врач кергәләп йөри... Мәкаләләрен дә бастык. Яшь кенә, кара гына...* А.Гыйләҗев. *– Һай, Гадәния абыстай, күрегезсәнә, кара халыктан ким сикерми, – дип көлеште бикәләр.* М.Әмирханов. *Вагонда безнең ише «куылган-сөрелгән» качаклар гына түгел, зур-зур букча-капчыклар аскан кара халык та бар.* Р.Габделхакова

6) Кояш астында озак булудан, җылы якларда яшәүдән аклыгын югалткан, каралган, кояшта кызган (кешедә бит, тән төсе тур.). *Өйгә шакып-нитеп тормыйча антрацит күмере кебек кара кеше килеп керде.* А.Хәлим

7) Керле, пычрак, юынмаган. *Өсбашың кара, әйдә юынып ал, су җылыттым, диде әнисе.* Казан утлары

8) Сөт кушылмаган (чәй, кофе һ.б.ш.)

9) *иск.* Махсус исерткеч итеп эшләнә торган (кымыз)

10) Морҗасыз, төтене махсус тишектән – төнлектән чыга торган (мунча, өй тур.). *Иртә белән торгач, үземне бер кара өй эчендә күрдем.* Г.Тукай. --- *Бәдәр туган апаның балдан әчетелгән «нәстүйкә»сен авыз итеп, инеш кырыенда утырган кара мунчаларында парланып-чистарынгач, юлны дәвам итәргә исәп иде.* Р.Сибат. *Бина! Монысы шәһәр татарының сүзе инде! Ә авылда аны кара мунча диләр.* Р.Габделхакова

11) *иск.* Хезмәтчеләр тора торган, кышын терлек-туар кертелә торган

(өй, бүлмә тур.). *Әмма бу юлы урынны төпчек кызга да кара өй сәкесенә, абыйлары-апалары янына җәйделәр.* Ә.Баян. *Ул сәер бер шомлы халәттә кара өй ишеген ачты.* Р.Батулла

12) *күч.* Квалификациясез; белем түгел, ә физик көч таләп итә торган (авыр, пычрак, гадәттә физик эшкә карата әйтелә). *Тик андый китапларда безнең әти белән әни шикелле кара эштәге кешеләр турында юньле сүз язылмавы гына эчне пошыра иде.* Г.Бәширов. *Миңа монда редакциянең кара эшләрен бик зур камыт киеп алып барырга туры килә.* А.Шамов. *Иртән укырга дип мәктәпкә китә, кичен колхоз эшеннән кайта торган булды. Шулай сабый чактан кара эшне яратты...* А.Хәлим

13) *иск.* Гади халык арасыннан чыккан; укымаган, надан. *Тик бу – бик культуралы адәм. Минем атам – кара татар, тәрбиясез, әхлаксыз бер бәндәдер.* Г.Исхакый. *Әле, Аллага шөкер, кара мужикларның да күңелләре бозылып бетмәгән икән.* Т.Гыйззәт

14) *күч.* Культурасыз, надан, артта калган. *Ул, сүзен куәтләп, колакчынын айкап куйды. – Сатучы дигәненнән дә нәрсәсе барые соң аның ул тикле?! Кара мужик ич ул!* Г.Бәширов. *[Вәлиәхмәт:] Кара мужикның аңгыра башына аң кертергә тырышкан.* Т.Миңнуллин

15) *күч.* Фаҗигале, кайгы-хәсрәтле, шатлыксыз, авыр. *Чәчләренең тонык яктысында күрәм кара еллар шәүләсен...* З.Мансуров. *Кылыч кайрагыдай кара еллар Әҗәл булып өстә кагына.* Ф.Гыйззәтуллина. *Әтисе кайта-кайта сөйли иде шул: «Минем мөәзин бабайны кара елларда, дин ялчысы дип гаепләп, атарга кушканнар».* Р.Габделхакова. *--- бай малае Илһаметдин белән булган кара вакыйганы әнисенә төкми-чәчми сөйләп бирде Галимҗан.* С.Поварисов

16) *күч.* Бик көчле. *Бала туу белән исем кушу мәсьәләсендә безнең өйдә кара тавыш куба торган булды.* А.Хәлим

17) *күч.* Явыз, мәкерле, астыртын, җинаятьчел. *[Эдика:] Мин алар оештырган кара эшкә юри ризалык бирдем. Вигилне монда алып килер өчен.* З.Хәким

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кер, пычраклык. *Акка кара тиз йога.* Мәкаль

2) Караңгылык. *Ышанычгыз, дуслар, давыл тынар, Төн карасын якты таңнар куар – Үлем килер фашист өеренә!* С.Урайский. *Таң төн карасын суыргач, киенеп баскычтан төште [кыз].* Н.Гыйматдинова. *Төннең куе карасын елгыр таң бүген кичәгедән алдарак җуйдырды.* М.Хуҗин

3) Кара төстәге (ат тур.). *Туры юртакны төпкә, шомырт карасын мичәүгә җигеп, кызны уртага салып, таң кызыллыгын артта калдырып, шәһәрне һәм аны камаучыларны сулдан урап, егетләр көнбатышка таба чаптылар.* И.Хуҗин

4) *күпл.* **каралар**. Шахмат, шашка уеннарында акка капма-каршы фигуралар. *– Мин нигәдер каралар белән уйнарга яратам шул, – дип елмайды егет.* Мәдәни җомга

5) Начарлык, яманлык. *Түз, Гаҗилә! Синә тормышның карасын-пычрагын байтак күрергә туры килгән.* В.Нуриев. *Кыскасы, аның ак һәм пакь күңеле бу дөньяның карасына бирешми, туганнары белән элемтәсен саклый, әтисенең кендек каны тамган Татарстан җирен, газиз телен дә онытмый ---.* Т.Нәҗмиев. *Син дә шул ук тормыш арбасыннан Күзәтәсең агын-карасын, Ышанулар, ышанмаулар арасыннан Изгелекләр эзләп барасың.* Г.Афзал

◊ **Кара акыл** Тегe яки бу мәсьәләне төптән аңлап, өйрәнеп, ул өлкәдә белгеч булып түгел, ә үз исәбенә, фаразлавына, белеменә таянып кына фикер йөрткәндә әйтелә. *Югыйсә кара акыл белән исәп йөрткәндә, безнең хакыбыз зуррак шикелле.* Г.Бәширов. *Кара акыл белән аны минем бабай да әйтеп биргән булыр иде.* Юлдаш. **Кара алтын** Нефть. *Кара алтын – җир мае, аның белән ил байый.* Мәкаль. *Бәлкем, Татарстан «кара алтын» табучыларының чит илләрдәге героик хезмәте турында турыдан-туры Нобель премиясенә лаек булырлык берәр роман да язып куярмын әле.* А.Хәсәнов. **Кара ачу** Көчле ачу, зәһәр ачу. **Кара бай** Кулак, черегән бай. *«Кара бай» дигәнең нинди якты йорт эшләткән.* Г.Бәширов. **Кара бәхет** Бәхетсезлек, бәхетсез язмыш, җәфалы гомер. *Кара бәхет бер яр булса, сарылып ятыр.* Мәкаль. **Кара болыт** Куркыныч, дәһшәт. *1953 елда М.Җәлил өстеннән «кара болытлар» алып ташлана, берничә елдан аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә, «Моабит дәфтәре» Ленин премиясенә лаек була.* Казан утлары. **Кара болыт булып** Нәрсәнең дә булса күплеге турында әйткәндә кулланыла. *Кара болыт булып агылган кешеләрне күргәч, Мөэзкирнең күзе шакмакланды: кайда, ди, ул монда җизнине эзләп табу!* А.Гыйләҗев. *Әтиемә рәнҗү-үпкәләрем кара болыт булып бар күңелне биләп алган, җылы хисләргә урын калмаган иде ул чакта...* Р.Габделхакова. **Кара болыт каплау** Нинди дә булса кайгы, күңелсезлек булу, килү. *Әле генә тулган айдай балкып торган нурлы йөзен әйтерсең лә кара болыт каплады.* Г.Галиева. **Кара болыт кебек** *к.* **кара болыт булып**. *Кара болыт кебек җыелган халык, урталай ярылып, юл бирде.* М.Хәсәнов. *Кояш чыгыш яктан Кояш баеш якка, Кара болыт кебек, Дәһшәт килеп ята.* Г.Афзал. **Кара болыт рәвешендә** *к.* **кара болыт булып**. *Колчак бандаларының куркыныч кара болыт рәвешендә Волгага якынлашып килгән көннәрендә, мин исемне, төсне, өсбашны алмаштырып, шул көчле контрреволюциянең артына төшәргә карар бирдем.* Г.Ибраһимов. **Кара гайбәт** Бик начар, әшәке гайбәт. *Сөйләгәнең кара гайбәт булса, Дошман керми калмый арага.* Ф.Гыйззәтуллина. *Мәфти ише карчыкларның кара гайбәте кызыйның киләчәгенә хәтле караңгы чокыр казып куйган иде инде.* Г.Бәширов. **Кара гүргә керү** Үлү. *Яшә инде, яшә инде, үлмә инде, үлмә инде. Кара гүргә кермә инде.* К.Латыйп. *Кара тап белән кара гүргә керер микәнни!* М.Хәсәнов. **Кара җәяү калу** Бөлеп бетү, бернәрсәсез калу. *Бала-чагасы, мал-туары белән кемнең кычкырып янасы я булмаса кара җәяү каласы килсен?* Г.Бәширов. **Кара җәяү калдыру** Мал-мөлкәтен тартып алу; бернәрсәсез калдыру. *Халыкны*

*туган җиреннән сөрделәр, татар морзаларының җирен тартып алып, кара җәяү калдырдылар, мәчет-мәдрәсәләребезне яндырдылар.* Г.Бәширов. **Кара исәп** Күңелдән, якынча гына исәпләү. *Кара исәп белән генә дә монда илле капчык бодай булыр.* Казан утлары. **Кара исемлек** Нинди дә булса шикле яки гаебе булган кешеләр теркәлгән, язылган исемлек. *Һәркайда «кара исемлек» төзелгән. Кемнең ни әйткәнен, ничек сулыш алганына хәтле бар яктан тикшереп торалар.* Р.Низамиев. *Композитор Салих Сәйдәшев «кара исемлек»тә бармы-юкмы – ул моны анык кына белми.* Р.Низамиев. **Кара йөз** 1) Исеме чыккан, хурлыкка калган кеше; 2) Усал, рәхимсез, кабахәт. *Кара йөзләр кабат ил өстенә Кызыл бурзайларын өстергән.* Г.Морат. **Кара йөрәк** Әшәке, усал, астыртын эшләр эшләүче кеше. *«Нижнекамскнефтехим»да, КамАЗда кара йөрәкләр – безнең канны, ә менә бу Ярковлар инде кара йөрәкләрнең үзләренең канын суыра...* А.Хәлим. *Мәхәббәттән, шигърияттән бизгән Кара йөрәкләрдә җан кысан!..* Ф.Гыйззәтуллина. **Кара кайгы** Бик зур кайгы, афәт. *Илгә-көнгә кан-яшь, үлем, кара кайгы, хәрабәләр, бихисап газаплар алып килгән сугыш Таңчулпан авылын да ярты ел дигәндә ир-атсыз калдырды.* Б.Камалов. *Берәү таба, берәү югалта, ди, Сөенбикә әнә кара кайгыда.* М.Әмирханов. *Һа-ай, ул коточкыч хәбәрне ишетеп өнсез калганнарым, кара кайгыда керфек тә какмый йокысыз узган төннәрем исемә төшсә, йөрәккәем әле дә булса нәкъ шул вакыттагыча сызып-сызып сулкылдый башлый.* Г.Галиева. **Кара кайгы басу** Кайгыру, күңелне кайгы-хәсрәт биләп алу. *Кызны юатса да, үзенең күңелен кара кайгы басты.* Р.Хәбибуллина. **Кара кайгыга бату** Бик нык борчылу, кайгыру. *Без үзебез дә бит, балаларыбызны җәберләсәләр, кара кайгыга батабыз.* Ф.Яруллин. *Татар башын саныйлар, ди, тагы да, Өлкән туган батты кара кайгыга: Баш санын булыр кечрәйтеп, тарайтып, Җанын ничек иманыннан аерырга?* М.Мирза. **Кара кайгыга төшерү** Кайгыга дучар итү. *Әмма яшьләрнең бик кыенсынып кына аларга җиткергән әлеге хәбәре Ногайбәк аганы да, Фәйрүзә апаны да кара кайгыга төшермәде.* А.Хәсәнов. **Кара кәгазь** *к.* **кара хәбәр**. *Улыкаем, бәгырь кисәгем, чынмы бу! --- Без кара кәгазь алган идек, батырларча... диеп.* Х.Мөдәррисова. *Сугыш бетәргә бер ай кала аның Польша җирендә үлүе турында Рабига апага кара кәгазь килеп төште.* Г.Галиев. **Кара козгын** Гаепләнүчеләрне йөртә торган ябык машина. *Кәрим Тинчуринны аста «кара козгын» машинасы көтеп тора икән.* Р.Низамиев. **Кара коелу** Кәефсезләнү, чырайсыз булу, ни сәбәпледер борчылу. *Редактор яныннан ул кара коелып чыкты.* А.Гыйләҗев. *Шулай да аның эченә пошаман кергәнлеге йөзенә кара коелудан сизелә иде.* Х.Камалов. *Ул табынның башыннан ахырына кадәр берни дәшмичә, кара коелып утырды.* Р.Рахман. **Кара континент** Кара тәнлеләр яши торган континент; Африка. **Кара күз** Күзнең иң пычрак, ямьсез көннәре, кышка якынрак өлеше. *Хәтерлим, тышта кара күз иде.* Г.Әпсәләмов. **Кара көлгә әйләндерү** Юкка чыгару; таптау, изү, яндыру һ.б. *Чыккан да [җылан], халыкларның котын алып, иген басуларын кара көлгә әйләндереп, адәмнәрне җортсыз-җирсез калдырып җөри башлаган.* Р.Батулла. **Кара көн** Кайгылы, фаҗигале вакыт. *Степан Бикланов кулын күтәрде. – Ягез, шауламагыз! – диде ул кискен итеп. – Бухенвальдның иң авыр, иң кара көннәрендә дә без үзебезнең ленинчылар икәнебезне онытмадык, хәзер дә онытмыйбыз, онытмабыз да.* Г.Әпсәләмов. **Кара көнгә калдыру (саклау)** Берәр нәрсәне алдагы, гадәттә авыр көннәр өчен саклау, калдыру. *– Өстәл тактасы сыгылырлык итеп турыйлар ипекәйне, – дип, эченнән сыкрана ул. – Кара көнгә сакларга иде бераз.* Г.Сабитов. **Кара көнгә калу** Бөлү, матди яктан мохтаҗлык, авыр көннәр кичерү. **Кара көч** 1) Гайре табигый, явыз мифологик зат. *Пәри – шул ук җен ләбаса инде ул, адәм баласын аздыра, ялгыш юлга кертә. Кара көч, Иблис токымы.* М.Әмирханов; 2) *сәяси* Алдынгы, прогрессив карашларга, яңалыкка, үзгәрешләргә дошман караучы һәм иске тәртипләрне саклап калу яки кире кайтару өчен көрәшүчеләр. *Кара көчләрне җиңү фәкать Октябрь инкыйлабыннан соң гына булды.* Р.Низамиев. **Кара көю** 1) Бәрелү, сугылудан тәннең берәр урыны каралу. *Җаен туры китереп, кызыксынуымны бик сиздермәскә тырышып кына сорадым: – Әти, күз төбеңдәге кара көеп чыккан таплар каян килде сиңа? Әллә берәрсе белән сугыштыңмы...* Ф.Галиев. *Йөзе ап-ак булып суырылган, бит очлары гадәти булмаганча тимгеллетимгелле, кызыл күзләре эчкә баткан, иреннәре кара көйгән.* Х.Мөдәррисова; 2) Нинди дә булса сәбәптән йөз-чырай караңгылану, бик кәефсез булу. *Ләкин һәр мәҗлес саен өстәл тирәли куелган урындыкларның өчесе буш кала килә, соңарган берәр кеше шул буш урынга утыра калса, Сталин кара көя ---.* Батулла. *Чыннан да, Тәнәкәнең тәкъдиме мәрхүм ханның дошманнарын гына түгел, корылтай әгъзаларын да кара көйдерде.* М.Әмирханов. **Кара куркуга төшү** Нык курку. **Кара күзлектән карау** Бар нәрсәне дә начар итеп күрү. **Кара күбеккә батыру** Бик нык куалап, атларны ардыру, хәлдән тайдыру. *Шәехгали атын кара күбеккә батырганчы камчылады.* М.Әмирханов. **Кара күмергә әйләнү** 1) Янып бетү. *Шуңа күрә эссе җәй көннәренең берсендә авылда ут чыгып, байтак йортлар кара күмергә әйләнсә дә, дуңгыз караучы кызның ап-ак итеп агартылган балчык куышы афәттән котылып кала.* А.Тимергалин. *Париж кара күмергә әйләнеп, икенче Нагасаки булачак!* А.Хәсәнов; 2) *к.* **кара күмергә калу**. *Бу хурлыкка йөрәгең янып, кара күмергә әйләнерсең.* Р.Габделхакова; 3) Юкка чыгу, бетү. *Женяга булган хисләр кара күмергә әйләнде, алар тапталган, югалган, онытылган.* Р.Габделхакова. **Кара күмергә калу** Кайгы-хәсрәт аркасында, нык борчылудан, сагышланудан каралу, ябыгу, ямьсезләнү. *Күпме янарга, күпме көярге болай?! Кара күмергә калам ич инде мин!..* А.Хәсәнова. **Кара мәче узу** Кешеләр арасы бозылу, ачуланышу. --- *башлагач, аның*

*белән ике араларыннан «кара мәче» узу сәбәпле, Язидә яңадан фермага кайткан иде*. Г.Бәширов. **Кара мөһер** Ярлык, яманат. *Ябып ук куймасалар да, «сатлыкҗан» дигән кара мөһер шунда ук маңгайга сугылачак иде.* Х.Мөдәррисова. **Кара реакция** *тар.* Реакциянең иң катысы, рәхимсезе. *Әйе, ул чор кыска булды, артыннан кара реакция еллары килде, әмма бу котылгысыз идеме?* Р.Шәрәфиев. *1820 елда кара реакция башлана.* Р.Батулла. **Кара сакал** Мохтаҗлык, бәхетсезлек. *Кара сакалың кая барсаң да үзеңнән калмый бит*. А.Хәсәнов. *Кара сакалны юып кына агарта алмассың!* А.Гыйләҗев. **Карасына бату** Караңгы чырайлы булу, күңелсез, кәефсез булу. *Наилә нигәдер күңелсез, карасына батып, терсәгенә таянып, тәрәзәгә карап утырган иде.* А.Гыйләҗев. *Халык карасына батты*. М.Мәһдиев. *Әтисе шулай бер ай чамасы карасына батып, аш пешереп, ипи салып, мал карап йөрде дә беркөнне сакалмыегын рәтләп каядыр сәфәр чыкты*. М.Мәһдиев. **Карасына кату** *к.* **карасына бату**. *Әлтафи карасына катты*. М.Мәһдиев. **Карасына коелу** *к.* **карасына бату**. *Хатыны өйдә иде, карасына коелып каршылады.* Х.Камалов. *Холодец, президиумда бүртенеп, карасына коелып утырды, ләкин әйткәннәрне кире какмады*. Х.Камалов. **Карасына күмелү** *к.* **карасына бату**. *Чөнки Язидә нишләптер көне буе якты чырай күрсәтмәде, юньле-башлы бер сүз дәшмәде, карасына күмелеп йөрде*. Г.Бәширов. **Кара такта** Артта калучылар яки нәрсәдә дә булса гаепләнүчеләр исемнәре языла торган такта. **Кара тамга** *к.* **кара мөһер**. *«Халык дошманы» дигән кара тамга сугылу сәбәпле, әти-әнием һәм безнең гаилә кыерсытуларга дучар ителә.* Казан утлары. **Кара тап** Халык теленә кергән яманат. *Ярый әле Аллаһ Тәгалә күңеленә шәфкать иңдереп, телен тыеп калды. Алла саклады! Гомерләре буена кара тап булып каласы икән ләбаса!* Г.Бәширов. --- *нахакка гаепләнгән язучыларны халыкка кайтару, аларның исемнәренә кайчандыр ягылган кара тапларны юып төшерү – җәмгыятебез алдындагы зур бурычларның берсе.* Р.Мостафин. **Кара тиргә бату** Нык ару. *Аждаһа аны күтәреп бара-бара кара тиргә баткан.* Ф.Яруллин. *Суның ачык җирен тапканчы кара тиргә баттык.* Ә.Мушинский. *– Керәстиән баласы икәнеңне оныт инде, пажалсты, өлүфмән ләбаса син, – диде Муллый, – без бер тиен өчен кара тиргә батып сатулашучы инглиз сәләмәләренең исен-акылын алырга тиеш.* М.Әмирханов. **Кара тир түгү** Ару-талуны белми эшләү, бик нык тырышу. *Баштарак көч сарыф итми, кара тир түкми булмас.* М.Хәсәнов. **Кара төн** Төннең бик караңгы вакыты; караңгылык. *Кычкырып та куела шул, Ычкынып та куела. Йокысыз кара төндә Бимазалый уй гына.* Р.Бәшәр. *Камыш шаулый җилсез көнне дә, Уйга салып кара төнне дә...* Ф.Гыйззәтуллина. **Кара урман** 1) Билгесез, аңлашылмый торган, бик буталчык нәрсә. *Шубарин моны шаярту дип кабул итте һәм, көлемсерәп, бүленгән фикерен ялгап китте: – Андагылар өчен минем эшем кара урман иде, мин, әлбәттә инде, аларга аңлатып торуны кирәк санамадым.* Р.Мирхәйдәров. *Үзүзеңә күпме генә сораулар яудырма, дөрес җавабын табып булмас – әлегә яңа хуҗасының уй-ниятләре аның өчен кара урман кебек.* Р.Мирхәйдәров; 2) Юл таба алмыйча, адашып йөрерлек. *Кыскасы, башкала үзе безгә, провинция кешеләренә, зур бер кара урман кебек...* М.Вәли. **Кара хәбәр** 1) Сугыш вакытында теге яки бу кеше үлде дигән язу, хәбәр. *(Марфа түти:) Ике улым да сугышта иде минем, олан, бер улымның кара хәбәре килде, икенчесенең – төпчегемнең дә – байтактан хәбәре юк инде*. Р.Вәлиева. *Әллә нинди кайгылы, кара хәбәрләр йөри ил буйлап.* З.Хәким; 2) Гомумән, кайгылы хәбәр. *Былтыргы кыш аяусыз булды, аяктан екты, синнән кара хәбәр дә шул чакта килде.* Х.Мөдәррисова. **Кара хәсрәт** Авыр кайгы. *Инде өйдәгеләр дә яңалыкларның соңгысын радиодан ишеткән, кара хәсрәткә баткан иде.* Р.Рахман. **Кара хисап** *к.* **кара исәп**. **Кара чутыр** Кара тутлы кешене тиргәп, ачуланып әйтелә. *Габделбәр малае Карип килеп әйтте. Кара чутыр, чегән кисәге!* Ә.Хәсәнов. **Кара шар** Берәр төрле сайлауларда кандидатка каршы тавыш бирү. *Галим, кайнарланып, йодрыгына йөткереп алды: – Миңа каршы килү бу, «кара шар» салып карадылар разживинчылар.* Ф.Сафин. **Кара шәүлә** Начарлык, яманлык; яман ат. *Ничек уйлыйсыз: тиражларыбыз һаман да төшә барса, бу хәл милли матбага һәм ана телебезнең яшәвенә, киләчәгенә кара шәүлә булыпябырылмас микән?* Казан утлары. **Кара эчле** Мәкерле, явыз, эшәке. *Бел, аерата усал, кара эчле кешеләр юаш эт асрарга яраталар.* А.Гыйләҗев. **Кара эш** Яманлык, начарлык; мәсхәрәләү. *Язмыш җиле, гади җилләр, Сез бар да туганнармы? Әллә сез кара эш өчен Күктән куылганнармы?* Б.Ибраһимов. *Кара эшләр кылырдай, җинаять юлына басардай, мәңге юылмаслык әшәкелекләр эшләрдәй баламыни соң аның Яббары!* З.Хәким. **Кара эшче** Гадәттә аз хезмәт хакына авыр эш башкаручы. *«А» классындагы командадан «Б» классына уйнарга күчәм... Мин – кара эшче...* А.Гыйләҗев. *Янә бер ел кара эшче булып урнашудан башка чара юк.* С.Поварисов. **Кара яз** Иртә яз; язның пычрак, карлы-сулы вакыты. *Хәзер бакчаны да дача дип йөртәләр бит! Кара яздан карчыгы белән киткәннәр иде...* А.Гыйләҗев. **Кара ягу** Гаеп ташлау; кемне дә булса яманлау, хурлау, начар итеп сөйләү. *– Минем хезмәттәшләргә кара ягуыңны туктатмасаң, мин синең белән икенче төрле сөйләшермен, – диде Гали.* Казан утлары. **Кара яну** 1) *к.* **кара көю**. *Кинәт томан эченнән Чернов белән комиссар калкып чыкты. Күз аклары ялтырый, чырайлары кара янган.* Х.Камалов. *Кендек әби Гөлҗәүһәрнең тәнендәге хисапсыз кара янган урыннарны күреп: «Һай балакаем, ни хәлләр түзәргә кирәк! Күпме бәби кабул итеп, мондый җәбер кичергән хатын-кызны беренче күрәм», – дип аптырап калган.* Г.Галиева; 2) *к.* **кара күмергә калу**. *Унсигез яшьлек улы Агыйдел суларында һәлак булгач, аңа акылын җуймаска, кайгы-хәсрәт утында кара янып үлмәскә ярдәм*

*итүче нәкъ шул Шигърият булгандыр, мөгаен.* Казан утлары; 3) Җиләк-җимешнең гадәттәге төстән куерак булып пешүе турында. **Кара яла** Дөрес булмаган, нахак сүз. *Тик безнең балалар турында шундый гайбәтне, кара яланы сөйләргә ничек телең барды?* А.Гыйләҗев. *Бу язуда бер хаклык юк, барысы уйдырма, кара яла!* Х.Камалов. **Кара ялганчы** Бик күп ялганлый торган кеше. *– Моны нинди кара ялганчы уйлап тапкан тагын? – Сәгыйдә әбинең тавышында артык дәрәҗәдә аптырау, гаҗәпләнү төсмерләре яңгырады.* Ә.Хәсәнов

**КАРА** II *и.* Язу өчен кулланыла торган, берәр төрле буяу эретеп ясалган сыекча. *Адушкин карага манган каләмен күтәреп, маңгаена якын ук китереп, озак уйлады: «Ничек башларга?»* А.Алиш. *Хәлим сәер дулкынланудан калтырана башлаган куллары белән Тәкыя карчык сузып торган кара савытына ябышты. Аннары, савыт читендә яткан канатны алып, шәмәхәкөрән карага чумырып манып алды.* Г.Гыйльманов

**КАРААЯК** *и.* Үсемлекләрнең сабак төбе черү белән характерлана торган бактериаль авыру

**КАРАБАИР** *и.* **1.** Урта Азиядә киң таралган эссегә чыдам, иярргә, йөккә һәм җигүгә яхшы яраклашкан ат токымы. *Карпатта – гуцул, Урта Азия тауларында локай, карабаир, кыргыз нәселле атлар хакимлек итә.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* Шул токымнан булган. *Татар җырында – алтын бүре башы чигелгән байракларын җилфердәтеп, карабаир юргаларда кыйтгаларны биләп тә, төрле ил-исемнәргә таркалган төркләрнең Сак белән Сок язмышына тиң үкенечле хәсрәте бар ---.* М.Галиев

**КАРАБАЙ** *и.* 1) Башкорт халык биюе һәм шул биюнең көе

2) Куе көрән, кара төсле этләргә бирелә торган исем

**КАРАБАЛЫК** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан Европа төче сулыкларында яши торган бик вак тәңкәле кара төстәге балык; *русчасы*: **линь**. *Хазар диңгезендә карабалыклар алтын уылдык чәчә...* К.Кәримов. *Монда килолы корбаннар да, чучка баласы кебек симез-йомры сазаннар да, күлдән тотып китерелгән табан балык белән карабалык та бар иде.* М.Хәсәнов

**КАРАБАШ** *и. бот.* Җикәнсыманнар семьялыгыннан, ана чәчәкләр төркеменнән дымлы урыннарда үсә торган кара чәкән башлы, камышка охшаш үсемлек; *русчасы*: **рогоз**

**КАРАБИН** *и. фр.* Кыскартылган көпшәле чагыштырмача җиңел винтовка. *Һәр вагонның баскычында кызыл кырыйлы фуражка кигән, карабин аскан солдатлар тора иде.* М.Мәһдиев. *Чыннан да, яңа килгән солдатларда сыңар мылтык та юк, Әхәтнең үзендә дә приклады ярчык белән җәрәхәтләнгән иске карабин иде.* Р.Кадыйров

**КАРАБИНЧЫ** *и.* Карабин белән коралланган гаскәри, сугышчы һ.б.ш. *Безнең карабинчылар, ат тояклары астыннан кар аттыра-аттыра, [бандитларны] куа киттеләр.* И.Гази

**КАРАБОДАЙ** *и.* 1) Карабодайчалар семьялыгыннан, хуш исле һәм баллы чәчәк ата торган игүле берьеллык үлән үсемлек, бөртекле культура. *Ара-тирә яңгырлар була торганга, тары, карабодайның да шәп булачагына камил ышандыралар.* Г.Ибраһимов. *Калкулыктан сулдарак уйсу җирдә карабодай басуы өстеннән ак дулкыннар йөгерә.* М.Юныс

2) Шул үсемлекнең ярма һәм он рәвешендә азык буларак файдаланыла торган өчкырлы орлыгы. *Абыстай Нурҗиһанга карабодай орлыгы хәтле генә бер бөртек сузды.* Г.Бәширов. *Һаман шул килен хезмәтеннән башы айныганы юк [Мәхүп әбинең]: һаман шул кичтән карабодай коймагын әчегә изеп калдырасың, иртә таңнан торып мич ягасың.* А.Алиш. *Айдар үз алдына куелган карабодай боткасына кашыгын тидергән генә иде, янына әлеге дә баягы Хәмис килеп басты. Юк ла, карабодай боткасы кирәк түгел аңа, шул ботка янына бирелә торган ит кисәгенә кызыккан ул.* Г.Гыйльманов

**КАРАБОДАЙЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Карабодай, кузгалак, кымызлык кебек икеөлешле үсемлекләрне берләштерә торган бер семьялык. *Кузгалак – карабодайчалар семьялыгына керә торган күпьеллык үсемлек.* Җиләк-җимеш

**КАРА БОРЫЧ** *и. бот.* 1) Борыччалар семьялыгыннан, кайберләре үрмә сабаклы үсемлек һәм аның ачы түгәрәк орлыгы. *Кара борыч – Көнчыгыш һәм Көнбатыш Һиндстанда үсә торган үрмә куак.* Ботаника

2) Шул үсемлекнең орлык һәм кузагын төеп ясалган тәмләткеч. *[Җамал:] Яшел суган турадым, укроп орлыгы йөздердем, кара борыч сиптем.* А.Гыйләҗев. *--- чегән хатыны трамвай көтүчеләрнең борыннарына төртәтөртә кара борыч тәкъдим итте дә безнең янга килде: – Хуш исле кара борыч.* М.Юныс. *Тик кофесына бер чеметем тоз, ике кашык каймак, шакмак ярым шикәр, бер-ике генә бөртек кара борыч салырга онытмагыз.* Ф.Яруллин

**КАРА БӨРЛЕГӘН** *и. бот.* 1) Розачәчәклеләр семьялыгыннан, үрмәләп үсә торган чәнечкеле үсемлек; *русчасы*: **ежевика**. *--- талларга сарылып үскән яшел яфраклар астында кара бөрлегәннең күкшел чуклары сыгылып тора.* Р.Хәбибуллина. *--- йорты каршысында зур ясалма күл бар, аның тирәягында кара бөрлегән куаклары тузанга манчылып утыра.* И.Нуруллин. *Уртада бормаланып-бормаланып аккан елга, кәҗәләр кимерүенә бирешмичә үскән кара бөрлегән, колмак сырган тугай чытырманлыгы.* Ш.Янбаев

2) Шуның формасы һәм зурлыгы белән кура җиләгенә охшаш каралҗым шәмәхә төстәге җиләге. *Мүк арасында кара бөрлегән елтырый.* Р.Мулланурова. *Без бер җирдә, гөләп чытырманлыгы арасында, күп кенә кара бөрлегән таптык.* Р.Гали. *--- майлаган коймак, яңа гына аертылган каймак, чияле атланмай, быелтыргы кара бөрлегән, җиләк кайнатмасы һәм башка бихисап нигъмәтләр куелган табын янына утырдылар.*А.Хәлим

**КАРАБҮРЕК** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан баш түбәсе, муены, канатлары һәм койрыгы кара, аркасы соры, койрык өсте ак, аталарының түшләре кызыл, аналарыныкы

көрән төстә булган урман кошы; *рус-часы*: **снегирь**. *Карабүрекләр агач ботакларына кызыл алмалар шикелле тезелешкәннәр.* К.Тәхау. *Төньяклардан безгә урман чыпчыклары, карабүрекләр, тау чыпчыклары кышлар өчен кайта.* Сабантуй

**КАРАВАЙ** *и. рус сөйл.* Мич төбенә салып пешерелә торган түгәрәк ипи. *[Мөнирә:] --- кайтырга чыктым, бер беләгемдә бала, икенчесендә – ашъяулыкка төреп элгән ике зур каравай...* Ә.Еники. *[Безнең халык] --- килгән затлы кунакларны икмәк-тоз белән, зур түгәрәк каравай пешереп каршы ала.* А.Гафуров

**КАРАВАТ** *и. гр.* Дүрт ягына дүрт аяк беркетелгән, баш-башларында терәк-аркасы булган, озынча кыса формасындагы, йоклау өчен хезмәт итә торган йорт җиһазы. *Мәнә-мәнә, сине караватың-ниең белән күтәреп күчерәләр, мәнә кемдер мыш-мыш килеп синең карават астында идән юа, җәфалана, ә синең эш – йоклау!* М.Мәһдиев. *Моннан соң опер үзе дә карават астына кереп китте.* И.Салахов

◊ **Карават үлчәп яту** Авырып яту; эшсез, тик яту. *Карават үлчәп яткан янында нием калган соң әле минем?* Б.Камалов

**КАРАВАШ** *и. тар.* Хан кызының хадимәсе, аңа хезмәт күрсәтүче кол кыз. *Мең дөягә төяп төрле мал китергән, һәр атка бер чибәр караваш мендергән ---.* Кол Гали. *Ширингә бирделәр ничә караваш, бөтенесе яшь, акылсыз, кара-буш.* Котб. *--- баһадир караваш кызлар тота, ә инде кемнедер ярату яки яратмау – аның тәгаен үз эшедер.* М.Хәбибуллин

**КАРАВЫЛ** *и. монг.* **1.** 1) Корал белән сакта тору, кизү. *Табын янында Туңгак алып юк иде, каганның иминлеген саклап, ул сакчылар белән тышта, каравылда калды.* Н.Фәттах. *Моңарчы басудан келт-мелт каз куып йөргән Шәйхи хәлфә янгын сараена каравылга килде.* М.Мәһдиев

2) Авыл халкы йоклаган вакытта, аларны нинди дә булса бәла-каза, хәвеф-хәтәрдән саклап, авыл буйлап йөрүдән гыйбарәт эш, урамны каравыллау вазифасы. *Соңгы тапкыр ул [Борһан] урам каравылына шактый салып чыккан иде, тәмәкесен учына яшерде дә күпер кырыендагы тал төбенә утырды.* М.Мәһдиев

3) *җый. и.* Кораллы сакчылар, сакта торучы кешеләр. *Залга гаепләнүчеләрне керттеләр. Алда-артта мылтыклы каравыл.* Г.Ибраһимов. *Юлны карап килергә бер-ике җәяүле каравыл чыгарылды.* Ш.Усманов. *Иң алдан, юл күрсәтеп, як-якны күзәтеп, кораллы кылавызлар барды, алардан бераз калышып – каравыллар, каравыллардан да арттарак йөз кешелек кораллы алай барды.* Н.Фәттах

4) *иск.* Авылларда җәмәгать милкен саклау, каравылчылар кереп йөрү һәм төрле җыеннар үткәрү, шулай ук гаепле кешеләрне вакытлыча ябып тоту өчен файдаланыла торган урын. *Бер вакыт ул [Василий Краснов] сугышчан постында винтовкасын каравыл йорты диварына сөяп куйган да дөньясын онытып тәмәке төреп маташа иде.* Ш.Алпар. *Элеккеге тыныч тормыш бетте: элек, каравылга чыккач, урамны бер-ике әйләнә идең дә каравыл өенә кайтып әкият сата идең...* М.Мәһдиев. *[Халыкның] бер төркеме каравыл лапасы астында җәйдән бирле сусыз торып коргаксыган һәм коршаулары таралган мичкәләр --- тирәсендә акрын гына уен-көлке сөйләшә, тәмәке тарта.* М.Галәү

5) Махсус төркем составында күзәтү максаты белән сакта тору урыны. *Каравыл тавы*

**2.** *ы. мәгъ.* Куркыныч килеп чыкканда ярдәмгә чакырып кычкыру сүзе. *Кызның әнисе, кич ятар алдыннан, бисмилласын укый-укый, комганын алып чоланга чыгуы булды, Шәйхинең аягына сөртенде. – Каравыл! – дип кычкырып та җибәрде.* М.Мәһдиев. *Болдырга чыгу белән Сәкинә ачы чырылдау һәм елау тавышы белән сөрән салды: «Каравыл! Күршеләрем, җан туганнарым, коткарыгыз, ирем үтерә бит мине. Каравыл, каравыл!..»* Л.-Х.Таналин

◊ **Каравыл кычкыртып** Ярдәм сорап кычкырырлык итеп, каршы килүгә карамастан, мәҗбүри рәвештә, көчләп; ай-ваена карамыйча. *Шулай итеп мине ат арбасына бәйләп, каравыл кычкыртып, Казанга алып киттеләр.* Р.Сәгъди. *Чаллы ягыннан да килеп карыйм Казанга, Биектау ягыннан да, Кадышево, Юдино, Лаеш ягыннан да – туктаталар, каравыл кычкыртып штраф түләтәләр, талонны тишәләр.* К.Кәримов. *Фаягөл Гөлүсә янына килде дә сузылып яткан кызны каравыл кычкыртып кытыклый башлады.* Х.Ширмән. **Каравыл кычкырырлык** Бик мөшкел, үтә дә начар. *Бигрәк тә фермер һәм шәхси хуҗалыкларның хәле каравыл кычкырырлык. Күпләр, өметсезлеккә бирелеп, савым сыерларыннан тизрәк котылу ягын карый.* К.Сәгъдәтшин. **Каравыл салу** 1) Кая да булса, кемне дә булса чакырып кычкыру, сөрән салу. *Туфан каравыл салып кычкырганга, ни булды икән дип, йөгерешеп чыксак, мондый хәлне күреп аптырап калдык: газ плитәсендәге зур ак кәстрүлдән япон дөгесе ташыпмы-ташый, Туфан нишләргә белми.* Р.Батулла; 2) Кемне дә булса чакырып кычкыру; берәр хәвеф-хәтәр барлыгын кешеләргә белдерү. *Бар, мәдрәсә шәкертләрен уят, каравыл салып халык җый.* Т.Гыйззәт

**КАРАВЫ́Л АГАСЫ** *и. тар. к.* **каравыл башы**. *Тәгин углан алып килгән яңалыкны торгаклар иң элек каравыл агасы Туңгак алыпка әйтергә булдылар.* Н.Фәттах

**КАРАВЫ́Л БАШЫ** *и. тар.* Хан каравылы составындагы сакчылар отрядының башлыгы. *Кушкан һәр нәрсәне җиренә җиткереп үтәгәне өчен генә, ул аңа – бикәгә – яхшы ир, яхшы каравыл башы булып тоелгандыр.* Н.Фәттах

**КАРАВЫЛЛА́У** *ф.* 1) Берәр объектны һәртөрле һөҗүм, фетнә яки бәла-казадан, караклардан саклап тору. *Абыйлары йокыларыннан уянып Батырдан көлделәр, безне каравылларга теләгән кеше үзе йоклап ята, дип.* Әкият. *Авылның халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты складын каравыллаучы Шәрәфигә быел да Яңа ел төнендә дежурлык туры килде.* Ф.Имамов. *Узган язда исә бүтән эш тапты: бәрәңге каравылларга куйды.* М.Зәкиев

2) Кемне дә булса качып китүдән саклап тору, күзәтү. *Без – биш тоткын. Ә безне каравыллап төрмәгә алып барырга алты конвоир һәм бозау хәтле бер эт килгән.* И.Салахов

3) Көтү, саклау. *Малайларны үзем белән елга буена, болынга, бия каравылларга алып китәргә әзерләнә башладым.* Г.Ибраһимов

4) Сагалап тору. *Әнә Андрюша тычкан каравыллаган мәче шикелле утыра.* К.Латыйпов

5) *сир. сөйл.* Билгеле бер тәртип яки йолага туры китереп, кемне дә булса янында саклап утыру; карау, карап тору

6) *күч.* Нәрсә янында да булса яки гомумән эшсез вакыт үткәрү. *Уз җәйларын үзе белештереп, Бәя биреп үткән-сүткәнгә, Йөрде шулай кичне каравыллап, Исе китми үзен сүккәнгә.* Һ.Такташ

**Каравыллап йөрү** Шактый озак вакыт каравыллау. *Кара әле, Марат, нигә син мине каравыллап йөрисең*? Т.Гыйззәт. *[Әти:]* --- *Бик курыксаң, малайлар белән көндез каравыллап йөр, кич өйгә кайтарырсың, – ди.* Г.Ибраһимов. *Сафа туктады. – Сине ике көн каравыллап йөрим инде, үзеңне генә туры китерергә, – диде малай, Сафага якынлашып.* М.Галәү

**Каравыллап тору** Каравыллау хәлендә булу; әле, хәзер каравыллау. *Уртанчы улы төнлә итлек янында каравыллап торды.* Әкият. *[Рудиның] Таланты алдында баш иючеләр сәгатьләр буе, чәчәк тотып, урам чатларында, театр ишеге төбендә дә аны каравыллап торалар --- иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Каравыллап чыгу** Билгеле вакыт өзлексез, даими каравыллау. *Миңа бәйләнгәннәрен күргәч, кайнанама Алланың рәхмәте яусын, төне буе мине караватым янында каравыллап чыкты.* Татарстан яшьләре

**Каравыллап яту** *сөйл.* Әле, хәзер каравыллау; озак берни эшләмичә каравыллау. *Давай китәбез, безгә бу башкорт авылын каравыллап ятудан файда булмас.* М.Гафури. *Көннәрнең берсендә, без, берничә студент, Айдар каравыллап яткан балалар бакчасына барып чыктык.* Р.Бәшәр

**Каравыллый башлау** Каравылларга керешү. *Бераздан Рәмзил тагы кызны каравыллый башлады.* З.Дәүләтов

**КАРАВЫЛЛЫК** *и.* Каравыл хезмәте, каравыллау вазифасы. *Хивадан ун вә Һәзарасыбтан ун кешене Даруган-Атага хутның әүвәл көнне каравыллыкка җибәрделәр.* Ә.Баһадир хан. *Борынгы заманнарда, Идел өстеннән килгән дошманнарны карап тору өчен, бу тау каравыллык урынын үтәгән булса кирәк.* Т.Гыйззәт

**КАРАВЫ́Л СУКЫРЫ** *и. сөйл.* Эңгер-меңгердә һәм аз яктылыкта күрми башлау авыруы; тавык күз

**КАРАВЫЛЧЫ** *и.* **1.** 1) Каравылда, сакта торучы; кораллы сакчы; кизү. *Бикә, малга бүре тия, салам вә игенне бик урлыйлар дип, йортка каравылчы да куя.* Г.Ибраһимов

2) Авыл халкы йоклаган вакытта, аларны нинди дә булса бәла-каза, хәвеф-хәтәрдән саклап, авыл буйлап йөрүче сакчы, урамны каравыллаучы кеше. *Төнге каравылчы. Урам каравылчысы*

3) Кайбер күмәк уеннарда башкаларны эзләп табучы, куып тотучы, гөрләүче һ.б.ш. төп фигура. *[Сафа белән Саҗидә] Түгәрәк уртасыннан чыккач, так-каравыл уенын уйнаучыларга кушылып, беренче пар булып бастылар. ---. Каравылчы зәңгәр күлмәкле, сипкелле битле ямьсез генә бер егет иде. Ул Саҗидә артыннан йөгерде.* М.Галәү. *Каравылчы малайларны тотарга тырыша. Тотса, тотылган малай каравылчы булып, тотучы гади бер уйнаучы гына булып кала.* Н.Исәнбәт

**2.** *с. мәгъ.* Каравылчы ролен, хезмәтен үти, башкара торган. *Дию пәриенең якынлаша башлавын сизеп, теге каравылчы солдат уята башлый. Уянмый гына бит теге.* Әкият. *Зиндан капусы янында ук бер төнге каравылчы солдат стенага сөялеп гырылдап йокламакта иде.* Ш.Мөхәммәдев

**КАРАВЫЛЧЫЛЫК** *и. к.* **каравыллык**. *[Локман:] Әгәр дә, Гарәфи агай, муллага кайтырга теләмәсәң, без сиңа мәктәптә каравылчылык хезмәтен бирер идек.* Т.Гыйззәт. --- *Тешсез Ибрайны һәм безнең кичәбездә актив катнашу теләге белән каравылчылык эшен бүгенгә башка берәүгә тапшырып торган Имәлине сайларга тәкъдим иттек.* М.Әмир. --- *безнең илдә паспортың юк икән, син инде кеше түгел. Шулай итеп, каравылчылыктан да кудылар.* Татарстан яшьләре

**КАРАГАЙ** I *и.* **1.** 1) Наратчалар семьялыгыннан көз көне йомшак ылысын коя торган кыйммәтле үзагачлы зур агач; *русчасы*: **лиственница**. *Түгәрәк күлне калын кара карагайлар белән капланган тау урап алган.* И.Салахов. *Урамнарда --- зәйтүн, хөрмә куаклары күкрәп утыра, арада керпе сыман бөгәрләнгән күгән-сырганаклар, борыннарын күккә сузган каурыйларга охшаган карагайлар, кипарислар да күп.* В.Имамов. *Кайчандыр бире дә кара урман булган, диләр. Хәзер исә ялгыз карагайлар гына анда-санда күренгәли.* М.Шабай

2) *диал.* Нарат. *Карагайлар шаулый алар, Кайсы чыршы булып калыккан ---.* М.Әгъләмов. *Көмештәй сулы елгалар, Башы болытларга тигән Горур карагайлар ---.* Г.Гатауллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул агачтан ясалган, җитештерелгән. *Калын карагай бүрәнәләр. Көч-хәл күтәрәбез, үзләре сөяк сыман каты, карандаш очлый торган үткер балта чапкан саен сикереп-сикереп китә, бигрәк тә туң вакытта.* И.Салахов

**КАРАГАЙ** II *и. зоол.* Үрдәк кошлар семьялыгыннан кыр үрдәгенең кара каурыйлы, кыска муенлы, чагыштырмача зур башлы бер төре; *русчасы:* **чернеть**. *Бездән ерак та түгел, камыш арасында бер карагай күренде.* Ак юл

**КАРАГАЙЛЫК** *и.* Карагай агачлары күпләп үскән урын, карагай урманы. *[Мотаһар белән Фирая] --- Фираяларның тау арасында, карагайлыкта посып кына утырган авылына килеп керделәр.* Д.Бүләков. *XII гасырда Россиянең Европа өлешендә үтә алмаслык карагайлыклар булган.* Ботаника

**КАРАГАНДА** *бәйл.* 1) «Белән чагыштырганда» мәгънәсен белдерә. --- *Зөлхиҗә кире борылып чапты. Безгә караганда да катырак чаба иде бу кечкенә кыз.* М.Әмир. *Моның [Зәйтүнәнең] йөзе дә Иданыкы кебек тулы, түгәрәк иде, ләкин аныкына караган-*

*да шундый яшь, шундый сабый иде.* Н.Фәттах. *Гөлчәчәк тамчы да үпкәләмәгән икән: ул учындагы кура җиләкләрен, төгәл ике өлешкә бүлеп, әүвәл миңа (мин Барыйга караганда шактый читтәрәк торсам да) аннан соң Барыйга сузды.* З.Хөснияр

2) Буенча, күрә. *Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, «остару» дигән төшенчәгә бу «ысулларның» барысы да керә, имеш.* Ә.Еники. *Малайларның әйтүенә караганда, ул алма сатучы безнең авылдан чыгып киткән.* Ф.Хөсни

**КАРАГАТ** *и. диал.* Кара карлыган. *Күзкәйләреңнең карасы Карагатлардан кара.* Җыр. *Ул елларда җиләк-җимеш исәп-хисапсыз иде. Нарат җиләген, эрбет чикләвеген, карагатны ат йөге белән ташыйлар.* Ш.Маннур. *Тау битләрендә җир җиләге белән бөрлегәннәр учлап-учлап сибеп чыккан сыман, янәшәдә кыргый чия белән кыргый карагатлар.* В.Имамов

**КАРАГАТЛЫК** *и. диал. к.* **карлыганлык**

**КАРАГАЧ** *и. бот.* 1) Элмәсыманнар семьялыгыннан урта поясның җылырак урыннарында үсә торган агач. *H1N1 гриппы эпидемиясе кызган чорда --- Олег Киселёв россиялеләргә җәмәгать урыннарында ылыслы агачлар – нарат, чыршы, пихта яки карагачның эфир мае тамызылган марля битлекләр киярге киңәш итте.* Ватаным Татарстан

2) *диал. к.* **карагай** I. *Шул язда Рушан утырткан зәгыйфь үсентеләр хәзер --- көчле карагачлар, колач җитмәс тирәк һәм өрәңгеләр булып шаулап утыралар.* Р.Мирхәйдәров

**КАРАГРУҺ** *и. тар.* **1.** 1) Шовинист, үтә реакцион караштагы кеше. *Татар карагруһлары үз әдәби хәрәкәтләрен тудыра алмадылар.* Г.Нигъмәти. *Әмма минем өчен ул (Солженицын) бары тик карагруһ урыс кына.* Т.Миңнуллин

2) Инкыйлаптан соң социалистик үзгәрешләргә каршы торган реакцион төркемнәр. *Икътисади мәсьәләләрдә советның болай эшне кыска тотуы алпавытлар, байлар, карагруһларга бер дә ярамады.* Ш.Әхмәдиев. *Ул [Кариев] Колчакстанындагы тормышы хакында сөйләгәндә: – Мин унбиш ай карагруһлар эчендә газап чиктем, – ди торган иде.* Г.Ибраһимов.

**2.** *с. мәгъ.* Шундый сыйфатлар хас булган. *Консерватив руханилар, карагруһ буржуазия һәм алпавытлар халык арасыннан чыккан җыр-музыка талантларына каршы ерткычларча көрәштеләр.* М.Җәлил

**КАРАГРУҺЧЫ** *и.* Үтә реакцион, инкыйлапка каршы катлам вәкиле. *Татар динчеләренең, рус карагруһчыларының бергә тоташкан зынҗырларын өзеп, ниһаять, егерменче гасыр башында татар милли театры төзелә.* А.Гыйләҗев. *Карагруһчыларның мәкерлелеге, үч алулары аркасында булса кирәк, аның [дәмолланың] өен ике мәртәбә ут төртеп яндыралар.* Р.Әмирхан. *Пушкин белән Лермонтовны мөселманча хәзрәт дип атау --- байтак реакцион дин әһелләренең һәм карагруһчыларның ачуларын кабарта.* Шәһри Казан

**КАРАГРУҺЧЫЛ** *с.* Карагруһчыларча, карагруһчыларга хас булган. *Бу [1909–1911] еллар өчен карагруһчыл шовинизмның котырынуы һәм милләтчелекнең үсүе характерлы булды.* И.Нуруллин. *Һәрхәлдә, без бик еш очраша торган шаукым – татарга карагруһчыл ташланулар булмады диярлек.* Ватаным Татарстан

**КАРАГРУҺЧЫЛЫК** *и.* Карагруһчылар хәрәкәте. *Тукай иҗатында карагруһчылык идеологиясенең һәртөрле күренешләренә каршы нәфрәт идеясе үсте.* Г.Халит. *Башта төп сәяси провокатор Жириновский, чәчрәп чыгып, милли республикаларга ябырыла – чираттагы карагруһчылык адымына безнең реакцияне тикшерә.* Ватаным Татарстан

**КАРАЕЛАН** *и. зоол.* 1) Караеланнар семьялыгыннан, тәне кара яки соры төстә, башы яссы ромб рәвешендә булган, дымлы урыннарда яшәүче агулы елан; *русчасы*: **гадюка**. *Сарник агай: – Авылга аракы керде ни, караелан керде ни! Адин чорт! – дип әйтеп салды.* Г.Бәширов. *[Абруй:] Караеланнан да зәһәррәк.* Т.Гыйззәт

2) *күч.* Эчкерле, мәкерле кеше турында. *Һәммәсенә Виолетта гына гаепле, фәкать ул гына. Караелан икән... Хәер, елан телефон аша чага алмый бит!* М.Маликова. *Шомлы караелан заманасы Үчләшүдән әллә көч аламы?* Ф.Гыйззәтуллина

**КАРАҖИЛӘК** *и. бот.* Арчанчалар семьялыгыннан дымлы, сазлыклы урманнарда җиргә сырышып үсә торган вак куак үсемлек һәм шуның ашарга яраклы күксел кара җимеше; *русчасы*: **черника**. *Күгелҗем караҗиләкләр яшел яфрак арасында шундый күңелле булып мөлдерәшеп утыралар иде.* Р.Гали. *Биредә җиләкнең нинди генә юк: караҗиләк, җир җиләге; карлыган, бөрлегән... Барысы да бар.* Н.Хәсәнов. *Әйе, мондагы урманнар калын. Караҗиләк, мүк җиләге күп.* Р.Кәрами. *Караҗиләк күрсәм, кара җирдән Син карыйсың кебек тоела.* Ш.Галиев. *Урманнарда анда-монда, шәрә ботаклы, тәбәнәк караҗиләк куакчыкларын күрергә була.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КАРАҖИМЕШ** *и.* 1) Тышчасы һәм орлыгы белән бергә киптерелгән слива; *русчасы*: **чернослив**. *Табынга тозлы ризыклар да, өрек, күрәгә, йөзем, караҗимеш кебек тәмләткечләр дә куйды ул [Хәдичә].* К.Тимбикова. *Күрәгә, караҗимеш, шәфталу, өрек, ананас, гөлҗимеш, бәрәңге, кәбестә, баклажан бик файдалы.* Ватаным Татарстан. *Әзер салатны салат савытына салып, чөгендер һәм караҗимеш белән бизибез.* Сөембикә

2) Слива агачы. *Монда алма, груша, караҗимеш агачлары күп, җирдә җыелмыйча сибелеп яткан груша, сливалар күп ---.* Ә.Еники. *Әгәренки боз зәхмәтен юкка чыгара алса, матур-матур алмалар, грушалар, караҗимеш, карлыганнар гөрләп үсәр иде ---.* Ә.Баян

**КАРАЗИР** *и.* Лютиксыманнар семьялыгыннан карасу чәчәкле үсемлек; *русчасы*: **чернуха**. *Болары әле әбинең эшләнмәгән дарулары иде. Боларның эчендә канәфер дә, дарчин дә, каразир орлыгы да, зәгъфран да, тагын әллә ниләр, әллә ниләр бар иде.* Ак юл

**КАРАИМ** *и. эһ.* Кырым, Көнбатыш Украина һәм Литвада яши торган аз

санлы төрки халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Караим теле*

**КАРА́ЙМЧА** *рәв.* Караим телендә. *Караимча сөйләшү. Караимча язылган китап*

**КАРА́Й** *и.* Караимнарның үзатамалары

**КАРА́К** *и.* **1.** Даими урлашу белән шөгыльләнүче кеше, угры; кеше әйберен, милкен үзләштерүче. *[Фәкыйрь] уйлый: «Бу нинди тимер?» – ди, ипләбрәк карый. Казый-казый, бу зур капкач булып чыга. «Бу, – ди, – караклар малыдыр, ахры, моны караклар куйгандыр», – ди.* Әкият. *Каракның бүреге яна дигәндәй, кайтып җиткәнче Әлинә хакында хикәя дә уйлап чыгарырга өлгерде.* Ф.Яхин. *Нәкъ шул төндә милиционерлар район үзәгендә бер кибетне басып ун холодильник, егерме телевизор урлаган каракны тотканнар.* М.Кәбиров

**2.** *с. мәгъ.* Угры табигатьле, урлаша торган, урлашуга һәвәс. *[Чекушкин] --- Болак күперен чыгып сулга борылгач, тагын як-ягына карана башлый. Аның болай боргалануы тавык чәлдереп кайткан карак төлке кыланышларын хәтерләтә.* М.Насыйбуллин

◊ **Каракның бүреге яна** Гомуми бер нәрсә хакында сүз барганда, шул нәрсәгә мөнәсәбәтле берәр гаебе булган кешенең, сүз үзе хакында бара дип уйлап, гаебен сиздерүе. *Ә ул, Камәретдин, юләр, каракның бүреге яна дигәндәй, аны үзенә ала...* М.Әмир. *Һәр кешедән шикләнәм, мине һәр адымда эзәрлекләп килүләр сыман, «каракның бүреге яна» дигән гыйбарәнең чын мәгънәсен шул көннәрдә аңладым.* М.Насыйбуллин

**КАРАКА́Й** *и.* Карасу йөзле бала яки яшь кыз (яратып, иркәләп эндәшү сүзе). *Каракаем, карыйсың, Карап кемне таныйсың?* Җыр

**КАРАКА́Л** *и. төрки зоол.* Мәчесыманнар семьялыгыннан йоны ком төсендәге, колак очларында чугы булган, үтә дә җитез җәнлек; кыргый мәче; кыр селәүсене

**КАРАКАЛПА́К** *и.* Үзбәкстанның төньягындагы Каракалпакстан республикасында һәм аңа чиктәш өлкәләрдә яшәүче төрки халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Каракалпак теле. Каракалпак милләте. Каракалпак киеме*

**КАРАКАЛПА́КЧА** *рәв.* Каракалпак телендә; каракалпакка хас рәвештә. *Китап базарларында татар әдипләренең татарча, русча, каракалпакча басылып чыккан китаплары сатылды ---.* Р.Миңнуллин. *Татарча боз сүзе каракалпакча муз формасында кулланыла.* Н.Фәттах. --- *Нукус (Каракалпак республикасының башкаласы) театрында «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе каракалпакча уйналды.* Ф.Галимуллин

**КАРА-КАЛӘМ** *җый. и.* Кара, каләм, карандаш һ.б.ш. язу әсбаплары. *Мулла дәфтәрләрен, кара-каләмнәрен букчасына тыкты.* Г.Ибраһимов

**КАРА КАРГА** *и. зоол.* Каргалар семьялыгыннан кара ялтыравык каурый белән капланган күчмә кош; *русчасы:* **грач**. *Аның йөрәге дөп-дөп типте. Чирле басулар өстеннән бер мең, бәлки ике мең кара каргадан торган туплау өерелеп үтте. «Болар да китәргә җыеалар, бугай».* А.Хәлим. *Ак карга кунса да, кара карга карда кара күләгә калдырмый.* М.Галиев

**КАРА́-КАРШЫ** *рәв.* 1) Йөзгә-йөз; алгы яклары белән, бер-берсенә карап. *Казак илендәге зур туйларның берендә бүз балалар белән яшь сылулар кара-каршы утырганнар.* Г.Ибраһимов. *Бервакытны чепи күзле, пеләш башлы Мыжык белән утырам мин кара-каршы.* Г.Афзал. *Тоткыннарны көне-төне сорау алырга ташучы бу түләүсез таксиның эчке төзелеше миңа бик таныш. Анда кара-каршы өчәр-өчәрдән алты кеше көчкә сыеп утыра торган, бастырып куелган табут төсле тап-тар бүлмә.* И.Салахов

2) Бер-берсенә каршы фикердә, каршы як булып. *[Рефератны тикшерү] дошманнарның кара-каршы бәрешүләренә, талашуларына әйләнеп китте.* Г.Ибраһимов

3) Уртага салып, фикер алышып. *Бу турыда [мәхәббәтең турында] әтиәни белән кара-каршы сөйләшмиләр дә бугай.* Г.Бәширов

4) Түләү шарты белән кире кайтару. *Бәйрәм ашы кара-каршы.* Мәкаль

**КАРАКА́ТИЦА** *и. рус зоол.* Башаяклы моллюсклар классыннан, кыслаларга якын торган диңгез хайваны. *Мондый трактор Әлшәй районында беренче була. Халык аны яратып «Каракатица» дип йөртә.* Кызыл таң

**КАРА-КАТЫШ** *рәв. диал.* Катнаш, аралаш. *Бу пьесада [«Бүләк өчен»] --- Әхмәтҗан байның өе «калын байларныкыннан» аерылып тора. Автор [Г.Камал] аны «өй җиһазлары иске заман нәрсәләре белән кара-катыш» дип бәяли.* Н.Ханзафаров

**КАРАКА́Ш** *и.* Матур кара кашлы хатын-кызга яисә ир-егеткә яратып, иркәләп әйтү сүзе. *Каладагы кебек читек-кәвеш киеп, «керт-керт» кенә басып йөрүче кем дисәләр, ул минем Наилә каракаш булыр.* Ф.Хөсни. *И минем каракашым, Ятасың ялгыз башың, Бу хәлләр ничек, Камәр, Йөрәкне яндырмасын.* Х.Туфан

**КАРАКЛАНУ** *ф.* Карак булу; караклык итү. *Үзең укып йөр, үзең караклан, кеше әйберсенә кул суз [имеш]!* Ш.Маннур. *Элек авыл җирендә аерым кешеләр генә урлашса, бу чорда байлыкның теге яки бу төрен (икмәк, сөт, йомырка, мал-туар өчен азык һ.б.) алырга мөмкинлеге булган һәркем караклана.* М.Мәхмүтов

**Караклана бару** Торган саен тагын да караклану

**Караклана башлау** Каракланырга керешү

**Каракланып алу** Берникадәр вакытка, азга гына караклану

**Каракланып бетү** Тәмам, бик нык караклану

**Каракланып йөрү** Төрле җирдә, төрле вакытта караклану. *Ризван кистерергә өлгермәгән карт өянкеләр арасында ара-тирә каракланып йөрүче саесканнар күренгәли ---.* Г.Бәширов. *[Хәбир:] --- Кайда булган? [Фәрдәнә:] Мишаларда. [Хәбир:] Алар икесе каракланып йөргәннәр!* Х.Камалов

**КАРАКЛА́РЧА** *рәв.* Каракларга хас булганча. *Каракларча яшеренеп кергән дошман үз эзләгәнен табарга [тар-мар ителергә] тиеш.* Г.Кашшаф. *Рәсемнәрнең --- икенчесе – бер хатынның кухняда этне кыйнап торуын, шул арада*

*бер якта мәченең өстәл өстендәге ит кисәген эләктереп, күзләрен эт кыйнаучы хатынга таба каракларча әйләндергәләп, ит ашап торуын көлке итеп ясаган бик кызык рәсем иде.* Ә.Фәйзи

**КАРАКЛЫК** *и.* Урлашу шөгыле, урлау. *Карак каракльгын куйса да, карак аты онытылмас.* Мәкаль. *Мин тозга таба бозау кебек сузылып якынлашам. Әллә алып чыгып кына китәргә инде? Бигрәк озаклады! Юк, ярамас, караклык була. Ә карак – Ходайның каһәре!* Ф.Яхин. *Күчмәләрнең табигать эчендә кайнаулары, хайваннарны, бигрәк тә атны яратулары, --- караклык һәм уйнашлык өчен рәхимсез җәза бирү йолалары замандашларында «дала каһарманнары» образын тудырган.* Р.Фәхретдинов

**КАРАКОЛАК** *и. зоол. к.* **каракал**

**КАРАКОРТ** *и. зоол.* Үрмәкүчсыманнар семьялыгыннан Урта һәм Үзәк Азия чүлләрендә очрый торган агулы үрмәкүч; *русчасы*: **каракурт**. *Каракортлар кебек Агу чәчеп Ябырылдыгыз гөлле җиремә.* Х.Мөҗәй

**КАРАКОШ** *и. зоол.* Карчыга кошлар семьялыгыннан зур ерткыч кош, кара бөркет; *русчасы*: **орёл**. *Каракошның күзләре үткен булса да, тамыры черегән агачка оя ясый.* Мәкаль. *Шулай итеп егет, бу хәбәрне ишетеп, кырга чыга да каракошның каурыен авызына кабып сызгырта.* Әкият. *Паспортның ике башлы каракош төшерелгән җирендә полиция түрәсенең әллә ниләр кыландырып куйган имзасының бер сызыгы каракошның муеныннан эләктереп алган ыргак кебек кәкрәеп тора иде.* Ә.Фәйзи

**КАРАКУРА** *и.* Биек булып үскән чүп үләннәре. *Каргалган йортка каракура үсәр.* Мәкаль. *Азсанлы терлек, каракура баскан басуларны күргән яшь кешенең нишләп авылга кайтасы килсен?* Кызыл таң

**КАРАКУЧКЫЛ** *с.* Бик кара, көрәнсу кара. *Авыл артта калды. Алда каракучкыл урман.* М.Мәһдиев

**КАРАКУЧКЫЛЛАНУ** *ф.* Каракучкыл булып китү; караңгылану. *Караңгы төште. Су каракучкылланып, дегеткә охшап калды.* М.Хәсәнов

**Каракучкыллана бару** Акрынлап каракучкыллану

**Каракучкыллана башлау** Каракучкыллану билгеләре күренү, шундый төскә керергә тотыну. *Акрын гына баткан кояшның күк йөзендә калдырган ялкынлы кызыллыгы каракучкыллана башлады.* Ф.Әмирхан

**Каракучкыллана төшү** Берникадәр, тагын да каракучкыллану

**Каракучкылланып бетү** Бик нык, тәмам каракучкыллану

**Каракучкылланып тору** Каракучкыл булып күренү

**КАРАКУЧКЫЛЛЫ** *с. к.* **каракучкыл**. *Шундый яңгырлы төндә Якты күл буендагы «Светог рэс» төзелеше, каракучкыллы булып, караңгылыкны ерта.* А.Алиш

**КАРАКЧЫ** *и. иск.* Карак. *Анда әйтте Идегәй: – Илеңдә йөргән каракчы Өч ат урлап котылса, Дүртенчедә тотылса ---.* Дастан. *Өч бала: бәгъзесе, кулына чыбыркы тотып, мин көтүче булам, бәгъзесе, мин урман саклыймын, бәгъзесе, мин каракчы булам, дип әйтәләр иде.* З.Һади

**КАРАКЧЫЛЫК** *и. иск.* Караклык. *Айбалталы Дөрмән би – Дөрмән улы Урман би – Туксан бала эчендә Каракчылык кылган би: Балалар менгән таяк ат – Аны урлап тотылды.* Дастан

**КАРАКҮЗ** *и.* 1) Кара күзле балага яки яшь кызга иркәләп яки шаяртып әйтү сүзе. *Шулай да менә бу минутта кайларда һәм ниләр эшләп йөргән була икән ул каракүз [Нажия]?* Ф.Хөсни

2) Төркиядә традицион халык тамашасы булган күләгәле курчак театры һәм шул театрның төп персонажы

**КАРАКҮЛ** *и.* **1.** 1) Урта Азиядәге каракүл токымыннан булган сарык бәрәннәренең махсус эшкәртелгән тиресе. *Бу кәрванчы байларның берсе --- тимер һәм чуен әйберләр шикелле фабрик һәм завод маллары илтеп, аннан ефәк, каракүл, илтер, җимеш һәм дөге шикелле нәрсәләр алып кайтып кәсеп итүче атаклы һәм данлыклы Мортаза бай иде.* М.Галәү

2) Шундый тиредән тегелгән кием. *Байлар кияр каракүл, без киябез эшләпә; Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә.* Җыр

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тиредән эшләнгән. *[Алма сатучы] каракүл бүрекне кыңгыр салган, өстендә трико кәзәки, кәзәки кесәсеннән сәгать чылбыры салынып тора, ә телгә дисәң, товарын мактарга дисәң, авызына шайтан төкергән инде.* Ф.Хөсни. *Өстенә җөббә, аягына шиблет, башына каракүл бүрек кигән, җитү чәчле шома Казан шәкерте Зәки Гайфи тәкәллеф белән генә атлап барды.* Г.Ибраһимов. *Каракүл якалы пәлтә киеп йөргән нәчәлникләрнең яңаклары кырынмаган булмый.* М.Мәһдиев

**КАРАКҮЛЧЕ** *и.* 1) Каракүл бүрекләр, туннар һ.б.ш. кием тегүче кеше. *[Гыйсмәтне] атасы Мәскәүдәге бер авылдашы каракүлчегә малай итеп җибәргән, [ул] анда бүрек тегәргә өйрәнгән.* Г.Гали

2) Каракүл сарыклары асрау белән шөгыльләнүче кеше

3) *иск.* Каракүл әйберләр белән сату-алу итүче сәүдәгәр. *Кибетең матур, җиһазлары ару, каракүлчеләрдә тагын мондый кибетләр бармы икән?* Г.Әпсәләмов

**КАРАКҮЛЧЕЛЕК** *и.* Хуҗалыкның каракүл куйлары асрау һәм каракүл эшләнмәләр әзерләү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Авыл хуҗалыгы институтының каракүлчелек бүлеге*

**КАРАЛАЙ** *рәв.* Каралып, кара төскә кереп, кара булып; кара көенчә. *Ак бүреләрнең [ыруг исеме] йөзе каралай янып чыкты.* Н.Фәттах

**КАРАЛАМА** *и.* **1.** Акка күчерелмәгән, төзәтү хәлендә булган язу-сызу һ.б.ш. *Ни гаҗәптер «Әнкәмнең догалары»н бик җиңел яздым. Хәзер менә искә төшерергә тырышып утырам... Караламасы да калмаган, кәгазе дә...* Р.Миңнуллин. *Караламаны Әхмәров әзерләгән иде, аны яңадан кат-кат тикшереп чыктылар.* Ф.Әмәк

**2.** *с. мәгъ.* Акка күчерелмәгән, төзәтү хәлендә булган. *Ильяс үзенең яраткан хыялы турында бик озак сөйләде, үзенең булачак комбайнының каралама эскизларын күрсәтте.* Г.Әпсәләмов. *Каралама сүзлекчәнең*

*язмышы миңа билгесез, һәрхәлдә аның дөнья күрмәгәнлеген генә беләм, чөнки ул рефераттан башка яшь ала торган мөстәкыйль хезмәт түгел.* А.Тимергалин

**КАРАЛАНУ** *ф. сир.* 1) Нәрсәгә дә булса буялып каралу; кара төскә керү. *Кайбер бүлмәләрнең ишек башлары күмерләнеп караланган.* Ш.Камал

2) Керләнү, пычрану. *Минем өстем тузган, ертык-пыртык, Караланган керле күлмәгем.* М.Җәлил

3) *күч.* Яла ягылу, кимсетелү. *Дошманга ялланганчы, үлгәнең артык. Без алай да җитәрлек караланган.* Г.Әпсәләмов

**Каралана бару** Акрынлап каралану

**Каралана башлау** Караланырга тотыну; каралану билгеләре күренү

**Каралана төшү** Тагын да каралану; бераз каралану

**Караланып алу** Азга гына, берникадәр вакытка каралану

**Караланып бетү** Тәмам, бик нык каралану

**Караланып тору** Даими яки әледәнәле каралану; караланган хәлдә булу

**КАРА́ЛЕ** *ы.* 1) Төрле тон белән әйтелеп, нәрсәгә дә булса игътибар итәргә кирәклекне белдерә. *Дәшә Алмаз әнисенә: – Әни, әни, карале. Күчтәнәч итеп бүген дә Мине алып бар әле.* Р.Миңнуллин

2) Таң калуны, сокслануны, гаҗәпләнүне белдерә. *Хәзер Наташа әйтә: «Карале, анда безнең үзебезне өйрәтә башладылар».* Г.Бәширов

**КАРАЛҖЫМ** *с. ким. дәр. к.* **кара**. *Шуннан соң озак та тормый май коңгызлары күренде. Каралҗым кызгылт бөҗәкләр күрер күзгә бик матурлар.* Ә.Кари. *Ут капкан йортларның ишектәрәзәләреннән сумала агымы төсле куе каралҗым төтен бөркелеп чыга.* К.Нәҗми. *Әнә бер якта каралҗым төстә бик зур һәм ямьсез чатырга охшаган лабаз ---.* Ш.Камал

**КАРАЛТУ** *ф.* 1) Кара итү, карага буяу; кара төскә кертү. *Ай урагы кебек кашларыңны Кем бәхтенә шулай каралттың?* Н.Исәнбәт. *Казансуда коткаручылар боз кисү, каралту белән шөгыльләнде.* Ватаным Татарстан

2) *махс.* Металл өстенә тутыктырмый торган кара окись йөгертү. *Урмановның күзләре каралтылган корыч кебек ялтырый.* Г.Әпсәләмов

3) Каратутлы итү. *Бу вакытта аның [Шәйхаттар бабайның] язгы җил каралткан җыерчыклы йөзендә һәркайчан була торган елмаю юк иде.* Г.Гобәй

4) Керләндерү, пычрату. *Аклы күлмәк якаларын Кимичә каралтмагыз.* Җыр

5) *күч.* Кайгылы, хәвефле, бәхетсез итү; төшенкелек китерү. --- *йортның хәзерге кыяфәте, ала-колалыгы, купкалаган, җимерелгәнлеге, тузан белән яшькелткә әйләнгән тәрәзә пыялалары, гомумән, әллә ничек янган, көйгән, ташландык шикелле булып торуы минем эчемне пошыра, күңелемне каралта, моңландыра, әллә нишләтә иде.* Ф.Әмирхан

6) Яманлап күрсәтү, начар итеп таныту

7) *иск.* Алдау, күз буяу, ялгыш юлга этәрү. *Җитәр дин исеменнән кеше талау, җитәр шәригать исеменнән халыкны каралту, җитәр болганчык суда балык тоту!* Г.Тукай

8) Исемен пычрату, яла ягу

**Каралта бару** Торган саен тагын да каралту

**Каралта башлау** Каралтырга керешү

**Каралтып алу** Азга гына каралту; тиз арада каралту

**Каралтып бетерү** Тәмам, бик нык каралту

**Каралтып куюу** Тиз арада каралган хәлгә китерү. *Янгын салам түбәне бераз көйдереп, каралтып куйды.* Г.Ибраһимов

**Каралтып тору** Даими яки әледәнәле каралту; каралту белән шөгыль итү

**КАРАЛТЫ** *и.* Абзар-кура, амбаркеләт, мунча, лапас, әвен һ.б.ш. хуҗалык корылмалары. *Каралты – түбә белән, адәм – кием белән.* Мәкаль. *Зур каралтыдан кечкенә бер келәт кенә торып калган иде.* Р.Рахман. *Иргали туган нигезен кабат күздән кичерде. Каралтыларның эзе дә калмаган.* М.Хәсәнов

**КАРАЛТЫ-КУРА** *җый. и.* Төрле каралтылар. *Болар колхоз эшендә бик актив, боларның колхоз һәрвакыт алда, каралты-кура таза, холыкфигыль уртача.* М.Мәһдиев. *Чакырылмаган кунакларның комсыз теләкләрен канәгатьләндерү өчен, кайбер ярлырак хуҗалыклар хәтта үзләренең кием-салым, каралты-кура шикелле нәрсәләрен дә сатарга мәҗбүр булдылар.* М.Галәү

**КАРАЛУ** I *ф.* 1) Кара төс алу, шундый төскә керү, караңгылану. *Көз. Кырысланды һава, Көн-төн яңгыр ява. Каралдылар кырлар, Баткакланды юллар.* Ә.Исхак. --- *аргы яктагы таулар элек зәңгәрләнеп күгәрделәр, аннан соң каралдылар.* Р.Гали

2) Каратутлану, кара төскә керү. *Комбатның йөзен җил ашаган, каралган булса да, ул яп-яшь, дулкынланудан яңакларына хәтта алсулык та чыккан.* Г.Әпсәләмов

3) Керләнү, пычрану. *Аның [Мәскүдә түтинең] артыннан яңагын яулык белән бәйләгән, кайчандыр зәңгәр төстә булып, хәзер инде яка, җиң, корсак тирәләре пычак кайрарлык ялтырап каралган, салават күперенең бар төсләрен үзенә җыйган пинжәк кигән --- мари карты Биктубай үрмәләде.* Х.Мөдәррисова. *Габделнур берчакны, сынап карар өчен генә: – Күлмәк якасы каралган икән, – диде.* Р.Кәрами

4) Куе булып, кара, караңгы төстә күренү. *Тик каршыдагы урманнар гына кашларын җимергән усал кеше төсле үз караларына каралып, өскә җимерелердәй булып торалар...* Ә.Еники

5) *күч.* Наданлану, аңсызлану, әхлакый һәм рухи яктан тупаслану. *Күңел каралу*

**Карала бару** Акрынлап, торган саен каралу. *Машина артыннан күтәрелгән тузан торган саен куера, карала барды.* Ф.Зыятдинов. *Никонов сөйләгән саен, Штельмахның йөзе карала барды.* З.Зәйнуллин

**Карала башлау** Каралырга тотыну. *Бүрәнә юанлыгы шомырт агачларыннан карала башлаган зур шомырт тәлгәшләре асылынып тора ---.* Г.Бәширов. --- *күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган.* Ф.Яруллин. *Кышның гомере кыскарган, тау битләре дә карала башлаган.* Ш.Янбаев

**Карала төшү** Берникадәр каралу; тагын да каралу. *Мәүлетдиннең йөзе карала төште.* З.Зәйнуллин

**Каралып бару** Акрынлап каралу. *Уз матурлыгын югалтып, Кар да каралып бара.* Алмаш

**Каралып бетү** Тәмам, бик нык каралу. *Каралып беткән сәләмә шахтёрлар рудник тирәсендә дәрья кебек дулкынлана, кайный иде.* Ш.Камал. *Ә безнең ишеләр гөнаһка чумып, каралып бетә.* К.Тинчурин. *Ихата каралып беткән тәбәнәк койма белән әйләндереп алынган.* Р.Кәрами

**Каралып калу** Нindидер бер вакыйгадан соң каралган хәлгә килү. *Өстәлдәге лалә чәчәкләре дә нидер сизенгәндәй моңаеп, каралып калдылар.* Тел – белемнең ачкычы

**Каралып китү** Кинәт каралу. --- *Ык суы шул болытлар астына кояш кереп качкач каралып китте.* Ф.Садриев. *[Сиринә Сәмигулловнаның] --- болай да озын кара керфекләре буяудан тагын да каралып киткән кебек.* З.Хөснияр

**Каралып тору** Гел, даими каралу; каралган хәлдә булу. *Малайның ике тез башы да каралып тора.* З.Хөснияр. --- *«К-700» көпчәге --- яссы таш уртасындагы тишектә бәке күк каралып тора.* Ә.Гаффар

**Каралып утыру** Каралган хәлдә булу. *Кама урманчылыгы хәзер каралып утырган ул имәннәрне нишләтергә белми.* М.Мәһдиев. *Ихатасыз өйләр каралып утыралар.* Т.Миңнуллин

**Каралып чыгу** Тиз арада тәмам каралу. *Хуҗаның йөзе каралып чыкты.* З.Хөснияр. *Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан.* К.Закирова

**Каралып яту** *сөйл.* Каралу хәлендә булу; каралган булу. *Вәлимхәммәт белән атлый-йөгерә, караңгыда абынасөртенә өч километр ярым юл үтеп, кар өстендә каралып яткан нарат бүрәнәләр янына килеп җитсәләр, «чүрәкәй Апанасова» инде шунда --- иде.* Л.Хәмидуллин

**КАРАЛУ** II *ф.* 1) *төш. юн. к.* **карау**

2) Сәламәтлек ягыннан тикшерелү, медицина комиссиясе үтү. *Шушы очрашудан соң ул [Тукай], солдатка каралырга дип, авылга кайтып китте.* Г.Камал. *Яшьтәшләре беренче мәртәбә каралырга киткән көнне Әхмәтзариф ат җигеп көлтә кертергә чыкты ---.* М.Мәһдиев. *Аннан соң [Габделхәйне], көтмәгәндә, каралырга барган җиреннән «годен» дип, туп-туры сугышка алып куйдылар.* Т.Мөбарәков

3) Тиешле дәрәҗәдә төзек тотылу, ныгытылу, төзекләндерелү; төзәтелү, тазартылу. *Ә өй каршында бакча. Тик анысы каралмаган.* В.Нуруллин. *[Карт:] Улым, быел әле каберлек каралмаган. Чүп-чарга баткан дип аптырама.* Р.Рахман

**Каралып бетү** Тәмам, тулысынча каралу

**Каралып йөрү** Хәзер яки күптәннән бирле каралу

**Каралып тору** Гел, даими каралу

**КАРАЛЫ** *с.* **1.** Кара төс белән башка төс аралашкан, катнашкан (мәс., *каралы-кызыллы, каралы-күкле*). --- *төрле төсләрне белдергән ясалма сыйфатлар парлашып килә: аклы-каралы, кызыллы-яшелле, зәңгәрле-яшелле һ.б.* Ф.Хисамова. *Иң беренче шунысын әйтергә кирәк, ул вакытта (1977 ел) Татарстан телевидениесе бары тик аклы-каралы төс белән эшли торган аппаратурага гына ия.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* Карага манылган, кара төстәге яки кара бизәкләре, кара буйлары булган кием. *Аклылары акка калсын, Каралыны киегез.* Җыр

**КАРАЛЫК** *и.* 1) Кара төстә булу. *Каралыгына киная итеп, аны [Баязитны] «чуенның ундүртенче кичәсе» дип йөртәләр.* Б.Камалов

2) Караңгылык. *Төн караңгы, җиркүк куе каралык эченә кереп югалган.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Наданлык, аңсызлык. *Наданлык, каралыктан череп беттек, Гыйлем белән үзебезне саклау кирәк.* Г.Камал

4) *күч.* Рухи җитешсезлек, әшәкелек, әхлакый-рухи яктан тупаслык. *Өй эчендә бер генә минут тору да күңелгә авыр сымак тоела, күңелгә каралык китерә төсле.* М.Гафури. *Балалар күңеленә каралык каян иңә?* Идел

**КАРАМА** *и.* **1.** 1) Элмәчәләр семьялыгыннан киң ябалдашлы агач; *русчасы:* **вяз**. *Әрәмәдә карама, Карамада кондыз бар.* Җыр. *Тауның сөзәкләнебрәк сазлыкка барып тоташкан битендә, куе ябалдашлары белән болытларны тәрәп, куш карама үсә.* Ф.Шәфигуллин

2) Арба, чана кебек әйберләрнең аерым кисәкләрен бер-берсенә беркетү өчен, йомшак, сыек агачтан, гадәттә яшь карамадан (*1 мәгъ.*) бөгелгән җайланма. *Мирвәли ике кулы белән дә арбаның шомарып, ялтырап беткән сөяк төсле арт карамасына ябышып бара иде.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Шул агачтан эшләнгән. *Карама дуга, кара юрга, Каян алдың бу атны?* Җыр

◊ **Карама көленә утыру** Алданып, төп башына утырып калу. *Гитлерчылар бу эшне бик соң абайладылар һәм, карама көленә утырып калуларын күреп, ачуларыннан шартлар хәлгә җиттеләр.* Г.Әпсәләмов

**КАРАМАЙ** *и. сөйл.* Нефть яки шуннан эшләнгән ягулык. *Тышта, төн карасын ярып, багана башларындагы пыскыйларда карамайлар янды.* Н.Фәттах

**КАРАМАК** *и. кыек килеш. форм.* 1) Берәр шәхес яисә оешманың ихтыяры, җаваплылыгы яки җитәкчелеге. *[Әҗәл:] Анысы минем карамакта түгел. [Әлмәндәр:] Карамак, карамак. Муенның сузып, минем янга син килгәнсең ич.* Т.Миңнуллин. *Дилбегә миңа тоттырылды. Арба минем карамакта.* М.Юныс. *Габдулланы Өчиле авылына Зиннәтулла бабасы карамагына озаталар.* Н.Хисамов

2) Мөмкинлек, файдалана алу хакы. – *Минем карамакта, – диде Закир, сәгатенә күз ташлап, – бер сәгать тә ун минут.* Г.Минский

**КАРАМАЛА́У** *ф.* Арба һәм чанага карамалар кую. *Карамалының кара малаена чана карамалатырга биргән идем ---. Ул карамаламаса, үзем карамалармын.* Тизәйткеч

**Карамалап бетерү** Карамалауны тәмамлау

**Карамалап тору** Хәзер карамалау

**КАРАМАЛЫК** *и.* Карама агачлары күпләп үскән җир; карама урманы. *Яздан яңгыр мул яуганга, җәй башыннан ук җылы көннәр торганга, Карамалык*

*башка еллардагыга караганда да хуш ислерәк иде.* К.Тимбикова

**КАРА́МАСТАН 1.** *рәв.* Нәрсәгәдер игътибар итмичә, шуны исәпкә алмыйча

**2.** *бәйл. мәгъ.* Юнәлеш килешендәге сүз янында килеп, кире җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Март урталары җитүгә карамастан, кыш әле сынын нык тота.* Ф.Хөсни. *Россиядә авыр икътисади шартлар булуга карамастан, Татарстан лидеры Рөстәм Миңнехановның стратегиясе Республикага яңа инвестицияләрне җәлеп итүгә йөз тота.* Л.Мифтахова

**КАРАМЕЛЬ** *и. лат.* **1.** Шикәрне җылыту яисә шикәр эремәсен һәм бәрәңге крахмалын кайнату юлы белән әзерләнә торган кондитер эшләнмәсе яки шундый эшләнмәнең состав өлеше. *Лифтёр карт, соң дәрәҗәдә сөенеп, тәм белән уйный, уң кесәсеннән очсызлы карамель чыгара да теш арасында кетер-кетер кимерә башлый.* М.Галиев. *Журналист, йөзенә чиркану чыгарып, стаканлы чәйне читкәрәк этеп куйды, ләкин авызында эреп бетмәгән карамель тынгы бирмәгәч, чәйне тагын үзенә алды.* К.Кәримов. *Әткәй белән әнкәй ризалыгыннан башка Иосифка әйләнгән кешегә хан бабабыз сандык эченә берәр генә карамель булса да салды микән?* Д.Салихов

**2.** *с. мәгъ.* Шундый ысул белән әзерләнгән. *Иртән кибеткә кереп, матур ялтыравыклы кәгазьләргә төрелгән карамель конфетлар алдым.* Г.Галиев

**КАРАМЕЛЬЛЕ** *с.* Составында карамель булган. *Карамельле торт*

**КАРАМЧЫК** *и.* Тонык кара тап, силуэт; карачкыл. *Берзаман, ялгыз уйланып йөргәндә, күккә таба караган иде, еракта бер зур карамчык очып килгәнне күрде.* Әкият. *Уң якта, бик еракта, кыр өстеннән аз гына калкып, соры карамчык булып, бер авыл күренә.* Г.Бәширов. *Яңгыр астыннан бер карамчык чыгып, тәрәзәгә якынайды.* А.Гыйләҗев

**КАРАМЫК** *и.* Кара чәчәк авыруы. *Бәхете караның боламыктан теше сынар, баласына карамык чыгар.* Мәкаль

**КАРАМЫШ** *и. иск.* Карау, карап тору рәвеше; караш. *Кызның кыйгач кашлары, күз карамышлары шулкадәр җазибәле иде.* З.Һади

**КАРАНДАШ** *и.* Графитка яки башка берәр төрле буяуга агач һ.б.ш. тышча киертелеп ясалган, таякчык формасындагы язу-сызу әсбабы. *Ул [әти] верстагы янында бармак юанлыгы калын зәңгәр карандашы белән рамга ярасы такталарын сызгалый.* Г.Бәширов. *--- якынча 1790 елда австралиялеләр һәм французлар, бер-берсеннән бәйсез рәвештә, карандаш өчен грифель уйлап табалар.* М.Вәлиев. *Директор, борчылып, түбән караган килеш утырды, кулындагы карандашны өзлексез әйләндерде.* З.Гиниятова

◊ **Карандаш очына алу** Язып, теркәп кую. *Бер фикер тудымы – карандаш очына ал.* Г.Әпсәләмов

**КАРАНТИН** *и. фр.* Йогышлы авыру таралмасын өчен, инфекцияле яки инфекция йоктыру ихтималы булган объектларның (кеше, хайван, товар, йөк, территория һ.б.ш.) тышкы бәйланышларын чикләү чаралары системасы. *Хастаханәдә узган атнадан бирле карантин.* Гаилә учагы

**КАРАНУ** *ф.* Әле бер, әле икенче якка карау. *Фәтхулла хәзрәт ашый һәм шул ук вакытта күзе белән тирә-якны карана иде.* Ф.Әмирхан. *Шәмси, күзләрен угалап, як-ягына каранды.* Г.Бәширов. *Җиһангир тукталып, кашларын җыерып, як-ягына каранды.* Н.Хәсәнов

**Карана башлау** Каранырга тотыну. *Ул [Исмаилҗан] күтәрелә төшеп, тирә-ягына карана башлады.* Г.Әпсәләмов. *Утыра торгач, Касыйм ага як-ягына карана башлады ---.* И.Хуҗин

**Карана төшү** Каракуны тагын да арттыру

**Каранып алу** Тиз-тиз карану. *Сумка тулы пачка-пачка акча күргәч, Сәгыйтьнең аяк-куллары калтырый башлады. Ул тиз генә як-ягына каранып алды ---.* Ә.Дусайлы. *Колакларына орылып киткән «Хаба» сүзен һичкем искәрмәде. Бары тик Хәбибрахман гына уңына һәм сулына каранып алды.* Ф.Яхин

**Каранып тору** Озак вакыт карану. *Баштарак кыяр-кыймас кына каранып торган Һади да тыгыз рәт булып баскан малайлар янына килде.* А.Гыйләҗев

**КАРАҢГЫ** *с.* **1.** 1) Якты булмаган; якты төшмәгән. *Курыкма, атым, кыю «чикмәнле»нең Караңгы төн туры юлдашы.* М.Җәлил. *[Муса] Төшемдә үз-үземне бер караңгы җирдә күрдем, дөм караңгы җирдә. Шушы караңгы җирдән чыгарга бик телим икән, имеш тә, тик юл таба алмыйм, имеш.* З.Бигиев. *Бүлмәнең караңгы бер почмагындагы киң бер караватка чалкан яткан бер кеше минем аяк тавышларыма бераз гына кымшанган шикелле итте ---.* Ф.Әмирхан

2) Төп төстән куерак, каралҗым төсмердәге. *Миңлегөл үзенә бик килешле караңгы зәңгәр күлмәктән, яланбаш.* Р.Төхфәтуллин. *Тәвә абаганың спорофиллары башта ачык яшел төстә, ахырдан караңгы көрән төскә керә.* Ботаника

3) *күч.* Надан, белемсез, артта калган; мәгърифәтсез. *Халык мохтаҗлыкка һәм җелекне суыра торган авыр хезмәткә дучар ителеп, мәдәнияттән читләтелгән бер заманда, Тукайның шигырьләре һәм шигырьләре белән бергә исеме, үзе исән вакытта ук, иң караңгы татар авылларына кадәр барып җиткән.* И.Нуруллин

4) *күч.* Кәефсез, күңелсез (кеше йөзе тур.). *Бирмә сер һичкемгә; сөйләшсәң сөйләш өстән генә; Көл – караңгы йөз бирү анчак килешмәстән генә ---.* Г.Тукай

5) *күч.* Усал, төксе, ризасызлык белдергән (кеше йөзе тур.). *Инде кызлар дисәң, алар да караңгы чырай күрсәтми төсле.* Г.Бәширов. *Ул арада кара киемле, караңгы чырайлы, телсез надзирательләр, ым белән генә юллап, мине тар тимер баскычлардан төрмәнең югары катына алып менеп киттеләр.* И.Салахов. *Әйттем бит: караңгы чырайлы бер кызый, тамчы да кызыгы юк...* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Серле булган, билгесез. *Кияү ат шикелле: караңгы товар.* Мәкаль. *Шомлы киләчәгем караңгы минем.* Ш.Мостафин

7) *күч.* Ямьсез, шатлыксыз, күңелсез, өметсез; авыр тәэсирле, начар. *Бөтен*

*җәй яңгыр таммады --- бу кечкенә караңгы тормышта мыжгырдаган крәстиәннәр ачыгып хәлдән тайдылар.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Караңгылык. *[Хәйретдин абзый] Киндер алъяпкычын бәйләгән, себеркесе-көрәге кулында, һәркөн караңгыдан торып, кыштыр-кыштыр урам себерә ---.* Ә.Еники. *[Мирхас] Караңгыда кардыга килде, тайлар ярата торган яланнарны, үзәнлекләрне айкап чыкты.* Х.Камалов. *Ләйсән, борылып, караңгыда сәер ялтыраган күзләрен иренә күтәрде ---.* М.Маликова.

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Караңгылык хәле. *Караңгы дип килми калма, Ай булмаса, йолдыз бар.* Җыр. *Ниһаять, тәрәзә рәшәткәсе күгәреп беткән озынча бүлмә. Ярым караңгы.* И.Салахов

◊ **Караңгы иңү** *к.* **караңгы төшү**. *Тиздән караңгы иңәр.* К.Нәҗми. **Караңгы кабу** *к.* **караңгы төшү**. *Без торган саен ашкыныбрак атлый бирдек. Чөнки караңгы капканчы ничек тә тау түбәсенә менеп җитәсе килә иде.* Ф.Абдуллин. **Караңгы күздә** Көн яктысы булмаган вакытта. **Караңгы күзле** Көн яктысы җитмәгән. *Ир-ат караңгы күзле кышкы көннәрдә читкә китеп, сезонлы эшләрдә йөри иде.* С.Рафиков. **Караңгы почмак** Илнең мәдәни үзәкләреннән читтә торган җире. *Олы Россия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары да илнең караңгы почмакларында яшәгән халыкларның кайбер караңгы катлауларына баштарак менә шулай булып тоелды.* Г.Ибраһимов. **Караңгы төшү** Караңгы була башлау, кич караңгылыгы куеру. *Укый торгач кич булды, караңгы төште, өйгә ут алдылар.* Г.Бәширов. *--- кич караңгы төшкәч, Кызыл Яр катау турысына, ташлы ярга бер көймә килеп туктады.* Н.Фәттах. *Ул арада кояш баеды, караңгы төште. Көндез шау-шу килеп кайнап торган шәһәр тынып калды.* Ш.Еникеев. **Караңгы чүгү** *к.* **караңгы төшү**

**КАРАҢГЫЛАНУ** *ф.* 1) Кич җитү, караңгы төшә башлау; караңгы булып китү. *Бара-бара аңа һава караңгылана башлагандай булып тоелды.* Г.Әпсәләмов

2) *з.-сыз* Караңгы төшү; караңгы булып китү турында. *Тышта караңгылана. Еракта, Идел өстендә, татарча җырлаган тавышлар ишетелә.* Т.Гыйззәт. *--- караңгылана, бөтен дөньяны кара болыт каплап алган төсле була.* Г.Камалетдинов. *Караңгылангач, Озын Гайса, ниндидер яшерен эшкә җыенган төсле, капкасын бикләде.* К.Нәҗми

3) *күч.* Кырыслану, усаллану, кәефсезлек төсмерләре чалыну (йөз, чырай тур.). *Әминәнең битенә кинәт кызыллык бәреп чыкты, иреннәре тетрәнеп куйды, йөзе әкренләп караңгыланды ---.* Р.Вәлиев.

4) *күч.* Томаналану, артка калу. *Аерымлану – корсагаяклы бөҗәк әкәмтөкәм кебек үз кабырчыгың эченә кереп яшеренү, цивилизацияле дөньядан артка калу, тагын да ныграк караңгылану, тормыш дәрәҗәсе начарлану --- ул.* Н.Шәрифуллин

**Караңгылана бару** Торган саен, акрынлап караңгылану. *Төн караңгылана бара, болытлар куера, көзге вак яңгыр акрын, ләкин туктаусыз һаман сибәли иде...* Г.Ибраһимов. *Өй эче якты түгел, караңгылана бара; кояш иңгәнгә байтак вакыт үткән иде.* Ш.Камал

**Караңгылана башлау** Караңгылану билгеләре барлыкка килү. *Тирә-як караңгылана башлады.* Г.Коләхмәтов. *Бервакыт кояш баеп, урталык караңгылана башлады, урам тын булып калды.* Ш.Камал

**Караңгылана төшү** Бераз караңгылану; тагын да ныграк караңгылану. *Миннехановның йөзе тагын да караңгылана төште, сынаулы карашын Бәһрамга төбәде.* М.Хәсәнов

**Караңгыланып бару** Акрынлап караңгылану. *Пыяла чәчәк-чәчәк булып бозланган, тышта буран ыжгыра, карларны тәрәзәгә китереп-китереп бәрә, көн дә караңгыланып бара.* Г.Мортазин

**Караңгыланып бетү** Бик нык караңгылану

**Караңгыланып калу** Ниндидер бер вакыйгадан, хәлдән соң караңгылану. *Тирә-як караңгыланып калды, һәм алда да, уңда да, сулда да рәтләп берни күренмәде.* Н.Фәттах. *Көләч йөзле кеше шикелле балкып торган больница кинәт төсен югалтты, караңгыланып калды.* Р.Вәлиев. *Хыяллары җимерелгәч, Ания өчен дөнья тагы да караңгыланып калды.* Р.Габделхакова

**Караңгыланып килү** Акрынлап караңгылану. *Җир өсте караңгыланып килә.* Ә.Еники. *Инде караңгыланып килә.* Ә.Сәлах

**Караңгыланып китү** Кинәт караңгылану. *Рәшидә моны ишеткәч, берьюлы җитдиләнеп, хәтта караңгыланып китте.* Ә.Еники

**Караңгыланып тору** Караңгыланган хәлдә булу. *Тәрәзәләрнең зурлыгына карамыйча, бүлмә әллә ничек каралып, караңгыланып тора иде.* Ф.Әмирхан. *Монда калкып торган ташлар юк иде, су өсте караңгыланып тора, төбе күренми.* Н.Каштанов

**КАРАҢГЫЛА́У** I *ф.* **1.** 1) Караңгы итү, яктылыгын киметү, яктылыкны каплау, яктылык төшермәү. *Бүлмәне караңгылау*

2) Нинди дә булса якты әйберне, яктылыкны каплау, күләгәләү. *Күкне болытлар караңгылау*

3) *макс.* Маскировка максатларыннан утларны томалау

4) *күч.* Каралау; кара төсмер бирү. *Шатлыкны куркыныч караңгылады.* Г.Гобәй. *Нәфисә уйлый: сугышчан егетләрнең йөзен икеләнү күләгәсе караңгыламыймы?* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* Сугыш вакытында дошман тарафыннан утка тотылу куркынычы булган объектларны төнлә яктыртмау, утларын каплау, яшерү һ.б.ш. чаралар системасы. *Караңгылау әле һәр йортта, – Кичләрен ут алмый Минзәлә.* Г.Хуҗи

**Караңгылап алу** Азга гына караңгылау

**Караңгылап бетерү** Тәмам, бик нык караңгылау

**Караңгылап тору** Әледән-әле караңгылау; берөзлексез караңгылау; хәзерге вакытта караңгылау

**Караңгылый бару** Акрынлап тагын да караңгылау

**Караңгылый бирү** Бернигә карамый караңгылау

**Караңгылый тору** Караңгылауны акрынлап башлау; акрынлап караңгылау

**КАРАҢГЫЛТ** *с. сир. ким. дәр. к.* **караңгы**. *Иске авылның Кара күренешләре китми һаман, чыкмый исемнән; Караңгылт бер Кабер төсле булып, Калкып ята хәтер читендә.* Х.Туфан

**КАРАҢГЫЛЫК** *и.* 1) Якты булмау, караңгы булу. *Айсыз төн. Бер кеше юк, тышта тып-тын, тик караңгы төн генә, Шул караңгылык эчендә «ул» да һәм тик «мин» генә.* М.Гафури. *Кояш чыгышы ягында өметсез караңгылык, моңлы күңелсезлек хөкем сөрә иде.* Р.Гали

2) Караңгы булу хәле; караңгы чолганыш, караңгы фәза. *Дөньяны төн караңгылыгы баскан.* Г.Әдһәм. *Тиздән карт белән эт тә кичке караңгылыкта эреп күренмәс булдылар.* Я.Шәфиков

3) *күч.* Наданлык, томаналык, мәгърифәтсезлек. *Халык массаларын наданлыкта, караңгылыкта тотарга тырышкан патша хөкүмәте [мәктәп ачарга] рөхсәт итми.* С.Алишев. *Сүзләренә, кыланышларына караганда, алар [татар ак качаклары] киткәч, йортта бәрәкәт, культура, акыл калмаган, совет наданлыкка таянып тора, ил караңгылыкта калган.* Г.Исхакый

4) *күч.* Явызлык; реакционлык. *Кешеләр мәңгелек караңгылык коллыгыннан якты дөньяга киләләр дә тормышның күз яшьле, канлы коллыгына барып эләгәләр.* Ә.Гаффар. *[Язучы] Тормышны караңгылык, газап, ерткычлык оясы итеп күрсәтә.* Д.Заһидуллина

◊ **Караңгылык кабу** Караңгы төшү, караңгылану. *Шакып үттем һәрбер капкага, – Караңгылык җиргә капкан ла...* Г.Сәлим. **Караңгылык куеру** Тагын да караңгылану. *Ул [поезд] алга барган саен, караңгылык та куера иде.* Р.Габделхакова. *Атау өстендә караңгылык куера барган саен, басу читендәге ташпулатлардан саркыган сүрән яктылык көчәйде ---.* Р.Вәлиев. *Тиздән караңгылык тагын куера төште, һәм тирә-юньдә берни дә күренмәслек булды.* С.Сабиров

**КАРАҢГЫЛЫ́-ЯКТЫЛЫ** *с.* **1.** 1) Караңгыланып яки яктырып җитмәгән; ярым караңгы яки бер өлеше генә яктыртылган. *Мәдинә һаман йөгерә. Алдын-артын карамый чаба да чаба... Аның белән бергә уйлары чаба. Алар да шушы урамнар кебек караңгылы-яктылы... Иртән караңгылы-яктылы мәлдә Сәгыйдә апа сукрана-сукрана иренә ат җигәргә булышты.* Б.Ислам

2) *күч.* Мәгърифәт, алга китеш җитмәгән. --- *татар тормышының караңгылы-яктылы базларыннан торып фикер йөрткәндә, ул [Миргазиян Юныс] чыгышлары белән татар булган Буниннардан биш башка өстен дә кебек.* А.Хәлим

**2.** *и. мәгъ.* Таң ата башлаган гына вакыт; иртәнге ярым караңгы чак. *Әгъләм аннан-моннан гына капкалап, караңгылы-яктылыда ук чыгып китте.* Ф.Хөсни. *Караңгылы-яктылыда ишек шакыдылар.* Кәеф ничек?

**КАРАП** *бәйл.* 1) Юнәлешендә, табан. *Тиешле кирәк- яракларны алгач, өчесе дә арбага утырып, авылга карап киттеләр.* Г.Минский

2) Билгеле бер вакытка каршы, шул вакытка таба. *Син кичкә карап нишләп йөрисең?* Ф.Бурнаш

3) Нәрсәгә дә булса ярашлы рәвештә, туры китереп. *Үлегенә күрә мазары, товарына карап базары, дигән бабайлар.* Т.Гыйззәт

4) Карата, күрә, нәрсәнедер исәпкә алып, нәрсәдәндер чыгып. *Кешесенә карап эш итү. Анасына карап – кызын, атасына карап улын коч.* Мәкаль

**КАРА ПАР** *и. а. х.* Эшкәртелеп, бөтен җәйгә чәчелми калдырылган җир

**КАРАР** *и. гар.* 1) Ныклап уйланган төпле фикер, ният. *Ике уйла, бер көт, шуннан карар беркет.* Мәкаль. *Без, иптәшләр белән сөйләшеп, туйны иртәгә үк ясарга карар бирдек.* Ф.Бурнаш. *Карар салып, ишәк китте кырга атлап.* М.Гафури. *Кабилә башы Фау аксакалларны җыйды. Алар шундый карарга килделәр: ялгыз йөрмәскә, суга кораллы сакчылар белән бергә җыйнау барырга ---.* Р.Фәхретдинов

2) Нинди дә булса җыелыш, киңәшмәдән соң туган нәтиҗә, эш планы яки йөкләмә; шул турыдагы рәсми кабул ителгән документ. *Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү фонды КБО 10 500 000 сумлык микрозайм бирү турында карар кабул итте.* Татарстан

3) Суд хөкеме. *Килер ул көн, халык хөкем итәр, Карар булыр кискен һәм кыска. Каным белән язган соңгы җырым, Бул гаепләү акты фашистка.* М.Җәлил

4) Нинди дә булса билгеле бер нәтиҗәгә яисә анык фикергә килеп тынычлану, канәгатьләнү. *Ул [Мавия] – байлыкта да, мәхәббәттә дә карар таба алмаган кыз.* М.Фәйзи

**КАРА́Р ИТҮ** *ф. иск.* Бер карарга килү, хәл итү, ният итү. *Карар иткән, үгез җиккән, Каф тавына җиткән.* Мәкаль

**КАРА́Р КЫЛУ** *ф. к.* **карар итү**. *Уйлап-уйлап та эшләре алга китмәгәч, уйлау өчен үзләренең генә башлары җитмәгәч, алар күрше патшадагы данлыклы бер таҗ ясаучы останы чакырырга карар кылдылар, ди.* А.Алиш

**КАРАРЛАНУ** *ф. сир.* Ныклы бер карарга, анык фикергә килү. *Хәмиданең күңеле һаман карарланмый иде.* М.Гафури. *[Миргали] Бикташев алдында җиңелеп калу гарьлеге белән үлү уеннан кайта да каршылыкны, һөҗүмне дәвам иттерергә карарлана.* М.Җәлил

**КАРАРЛАШУ** *ф.* Тәмам урнашу, ныклап кабул ителү (билгеле бер тәртип, кагыйдә һ.б.ш. тур.). *Татар теле грамматикаларында сүз төркемнәре ун төрдә карарлашты.* В.Хангилдин

**Карарлашып бетү** Тулысынча карарлашу

**КАРАРЛЫ** *с.* Төпле булган, ышанычлы; икеләнүсез, тәвәккәл. *Кар суы юлын табар, Карарлы кол йолым табар.* Мәкаль. *Мохтар карарлы тавыш белән: – Ләкин моннан болай күрәләтә җәберләтергә һич ярамый, – диде.* Ш.Камал

**КАРАРЛЫЛЫК** *и.* Төплелек, ышанычлылык. *Гыйльменисаның төп сыйфатлары карарлылык, кыюлык булса, горурлыгы да аны күркәм итә.* Ф.Галимуллин

**КАРАРСЫЗ** *с.* Икеләнүчән, нинди дә булса бер төпле карарга килә алмаган. *Мавия әллә нинди карарсыз бер хәлдә күренә.* М.Фәйзи

**КАРАРСЫЗЛАНУ** *ф. сир.* 1) Зәгыйфьләнү, көчсезләнү, тотрыксызла-

ну. *Кызның гасабилык күрсәтә торган йөзе, пошынып һәм карарсызланып карый торган күзләре --- Галигә таныш шикелле иделәр.* Ф.Әмирхан

2) Икеләнеп калу

**Карарсызлана бару** Акрынлап карарсызлану; торган саен тагын да карарсызлану

**Карарсызлана төшү** Тагын да карарсызлану

**Карарсызланып тору** Әле, хәзерге вакытта карарсызлану

**КАРАРСЫЗЛЫК** *и.* Ышанычсызлык, икеләнүчәнлек. *[Асяның] Тавышында нindидер ныксызлык, карарсызлык беленеп калды.* Х.Камалов. *Көтеп тору, карарсызлык никадәр озакка сузылса, шулкадәр начар, чөнки тымызык күлдә корт үрчи.* Р.Шәрәфиев

**КАРАСАКАЛ** *и. этн.* Кыпчак халыкларында урта яшьтәге ир кеше. *Икенче сафта карасакаллар – ир уртасы казакълар [утыра].* И.Салахов

**КАРА СОЛЫ** *и. бот.* Сабан ашлыклары арасында үсә торган чүп үләне; *русчасы:* **овсюг**. *Ә басуларда кара солы шактый киң таралган.* Т.Нәҗмиев

**КАРАСУ** *с.* 1) Кара төскә тартым; каралҗым. *Йолкынган чәчкәләргә охшаган сәләмә бер төркем халык, карасу җепшек ком өстендә борыннары белән җиргә хәтле иелә-иелә, калын бер аркан тарталар...* Ш.Камал

2) Каратутлы (тән төсе тур.). --- *карасу йөзле, тараеп килгән иякле, сызылып чыккан кара мыеклы, ялтыр кара чәчле, тулы канлы, камыш буйлы бер җегет, кулындагы камчысын уйната биреп, көлә-көлә нидер сөйли.* Г.Ибраһимов

3) Төп төскә караңгы төсмер кушылуын белдерә. --- *көтүче Әбеш боларны [сыерларны] якты кояш астында ялтырап уйнаган Алтын-Күл буе белән, яшел сахраның чыклы үләне өстендә карасу зәңгәр эз калдырып, акрын гына куалап китеп бара иде инде.* Г.Ибраһимов. *Ә диңгездә... карасу яшел дулкыннар шаулый, көймә бер йомычка кебек чайкала. Куркыныч!..* Г.Әпсәләмов. *Карасу яшел ылыс белән капланган чыршы ябалдашлары шундый калын, шундый куе.* М.Әмир

**КАРАСУЛАНУ** *ф.* Карасу төскә керү. *Ләкин озак юлда булудандыр, яңаклары, муеннары күгәреп, ярты каралып киләләр, иреннәр көйгән, карасуланып көеп, бераз кызу канлылык әсәре күрсәтәләр. Фазыйлда элек бу юк иде.* Г.Ибраһимов

**Карасуланып китү** Кинәт яисә әледән-әле карасулану. *Мансурның күзләре зәңгәр, ләкин вакыт-вакыт карасуланып китәләр.* Г.Әпсәләмов

**Карасуланып тору** Карасу булып күренү

**КАРАСЫЛУ** *с.* Тәне тумыштан ук карасу булган (хатын-кыз тур.). *Кызларның икесе карасылу, гәүдәгә коеп куйган сындай --- иде.* Х.Сарьян

**КАРАТ** *и. гр.* Ювелирлык эшендә асылташларны үлчәү өчен кулланыла торган 0,2 граммга тигез авырлык үлчәү берәмлеге; кыйрат

**КАРАТА** *бәйл.* 1) Юнәлеш килешендәге исем янында килеп, эш-хәрәкәтнең кемгә, нәрсәгә юнәлдерелүен белдерә: мөнәсәбәттә; мөгамәләдә. *Бәлки, аның күңелендә дә Газинурга карата җылы хис калкынып куйгандыр, өмет уянгандыр.* Г.Гыйльманов

2) Кемгә дә булса атап, мөрәҗәгать итеп

3) Кемгә, нәрсәгә дә булса атап, юнәлтеп; кем, нәрсә турында, хакында. --- *булачак солдатларга карата яңа медицина таләпләре дә кертелде.* Авыл утлары. *Рөстәм Миңнеханов үзе өчен тавыш биргән сайлаучыларга алдагы эшчәнлегендә үзенә карата ышаныч белдерүләре өчен рәхмәтен җиткерде.* Татарстан яшьләре

4) Кемгә, нәрсәгә дә булса багышлап, атап. *Халык шаулашып, яратып, кул чабып алды, кияү белән кызга карата мактау сүзләре әйтелде.* А.Шамов. *Әсирләр лагеренда бер иптәшем белән фаҗигале очрашуга карата язылган бу шигырьне күп әсирләр үзләренең дәфтәрләренә күчереп алганнар иде.* А.Алиш

5) Нәрсәгә дә булса яраштырып, килештереп, юнәлдереп. *Сыйныфсызлык ягына кучәбез, һәрбер проблеманы үзебезнең файдабызга карата чишәбез.* Һ.Такташ

6) Билгеле бер нәрсәгә муафикъ, ярашлы, бәйләнешле. *Әдип күбесенчә авылның бай һәм хәлле катлавын яза, жанр картиналары да шуңар карата, шуңар муафикъ рәвештә бирелә.* Г.Нигъмәти

**КАРАТАЙ** *и. мор.* Мордва халкының татарча аралаша, христиан динен тота торган бер этник төркеме. *Каратайлар – тау халкы кебек озын гомерле, туксанга җитеп килүче өлкәннәр – күз тимәсен, үз акылларында, сәхнәдә биеп-җырлап йөриләр.* Шәһри Казан

**КАРА ТАКТА** *и.* Мәктәпләрдә, уку йортларында акбур белән язар өчен хезмәт итә торган җайланма. *Иптәш Үзбеков ана теленнән язма дәрес игълан итте дә кара тактага акбур белән берничә сүз язды.* Ә.Баян. *Кара такта сөя акбур төсен, ак таш битен ача күмергә: Тел хакына алар гел бергә...* Л.Шагыйрьҗан. *Шунда автор безнең карамакка тагын бер өр-яңа символ тәкъдим итә. Бу – кара такта.* Р.Рахмани

**КАРАТАЛ** *и. бот.* Талчалар семьялыгына керә торган карасу соры ботаклы, куе яшел яфраклы агач яки куак, биш серкәчле тал; *русчасы*: **чернотал**. *Каратал ыраена карап үсәр.* Мәкаль. --- *аръяктагы кичке уенга җыелгач, кемдер: – Һәр кичне каратал төбендә Габдерәхим уенны күзли-күзли дә шыпырт кына тая, – дигәч, ничә төн каратал саклады.* Н.Гыйматдинова

**КАРАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **карау**

2) Билгеле бер тарафка юнәлтү, юнәлдерү. *Байроннарча, күлмәгенең ак якасын өскә каратып кигән Рәдиф.* М.Галиев. *Гариф бик ыспай һәм чибәр егет иде. Артка каратып таралган, дулкынланып торган кара чәч, коңгырт күзле, кыйгач кашлы ---.* З.Зәйнуллин

3) Кемнең дә булса игътибарын җәлеп итү, үзенә тарту. *Батюшка тавышының ягымлы гөрелтесе белән дә халыкны үзенә каратты ---.* Г.Бәширов. *[Әмин Галимович] Бер генә дә тотлыкмады. Җор, шаян сүзләр дә кыстырып, залны үзенә каратты.* З.Дәүләтов

4) Яраттыру, үзенеке итү. *[Гөлфизә] Типсә тимер өзәрлек бер авыл егетен үзенә каратты да куйды.*

И.Хәйруллин. *Егетләр сизәләр, шушы коры сөяк Казбек Фаягөлне әллә кай ягы белән үзенә каратты.* А.Хәсәнов. *Мин бит сине, Ләйләдер дип белеп, Мәҗнүн кебек үлеп яраттым. Аһ, өченче, ул өченче йөрәк! Ул үзенә сине каратты!* Р.Корбан

**2. каратып** *рәв. мәгъ.* 1) Кем яки нәрсә турында, кемгә, нәрсәгә багышлап. *Син дустыма каратып, Җырлар язам яратып.* Җыр

2) Яраштырып. *Ул [иптәш] чынлап та «Интернационал»ны үзгәртеп, үзе әйтмешли, хәзерге чорга каратып, бик иркен эшләгән.* М.Җәлил

**КАРА́ ТУРЫ** *с.* Ялы һәм койрыгы кара, гәүдәсенең төсе дә кап-кара диярлек куе җирән яки көрән (ат төсе тур.). *Бу атлар асылда кара туры булып та, тирләп чыккан парлары өсләренә бәс булып ябышкач, ап-ак булып күренәләр иде.* М.Гафури

**КАРАТУТ** *с. к.* **каратутлы**. *Врангель диюгә, нигәдер, каратут тәнле, ач яңаклы, карчыгадай кәкре борынлы, чыелдык тавышлы берәү күз алдына килә.* Г.Бәширов. *[Ания] Казахка тартым каратут түгәрәк йөзле, күмер күзле бер кыз.* Р.Габделхакова. *Комсыз каратут бу бәндәләр сатучы белән пышын-пышын сөйләштеләр дә әфлисунны әрҗәсе белән алдылар да куйдылар.* В.Нуриев

**КАРАТУТЛЫ** *с.* Тәне кояшта кызынып каралган яки тумыштан шундый булган (кеше тур.). – *Мин тегү мәктәбендә укыйм, – диде каратутлы кыз.* А.Алиш. *Шул арада ишектән дәү генә бер кеше килеп керде. --- Хосусан, түгәрәкләнеп кырыккан чал сакалы, киң һәм каратутлы йөзе белән, ул төтен дулкыннары арасында әллә нинди «дию» кыяфәтендә булып күренә иде.* Ш.Камал

**КАРА́У** I *ф.* **1.** 1) Күзләрне билгеле бер нәрсәгә юнәлтеп, күреп, шул нәрсә турында билгеле бер мәгълүмат алу. *[Гөлшаһидә] Сәгатькә карады. Дүрт тулып бишенче киткән ---.* Г.Әпсәләмов. *Илсөяр ялт итеп иелеп аска карады.* Г.Гобәй

2) Тамаша итү. – *Нәрсә сөйлисең син?! – дидем мин агарынып. – Нәрсә сөйлисең?! – Әле генә телевизордан кино карадык.* Н.Акмал. *Рәсемле китап карыйбыз Икәүләп энем белән.* Сабантуй

3) Нәрсәне дә булса тикшерү, бәяләү. *Ашның тозын карау*

4) Авыруның яки авыруы бар дип уйланган кешенең хәлен тикшерү, ачыклау. *Медпунктта Мансур иң элек пилотка ярдәм күрсәтте. Аннары мондагы авыруны карады.* Г.Әпсәләмов

5) Хөкемгә кую, тикшереп, ачыклап хәл итү. *Шәһәр төзелеше һәм социаль мәсьәләләр буенча депутат комиссияләрендә Владислав Гавриловның депутат мандатыннан азат итүләрен сорап язган гаризасын карадылар.* Шәһри Чаллы

6) Аерым бер караштa тору, билгеле бер мөнәсәбәттә булу. *Аның эшкә килмәвен, хәтта бер сәгать соңга калуын да күрми калмаслар иде, ә ул үзенә шикләнеп карауларын теләми.* Р.Мирхәйдәров

7) Нindидер бер фикердә тору. *--- бу кыз моңсуланып, сагышланып, хәтта бераз гына үз итеп карый...* Г.Гыйльманов

8) Тиешле тәрбия күрсәтү; тиешле хезмәт кую. *[Вәлиулланың] Ялгызын бер хуторга китерделәр. Ат карау эшен йөкләделәр.* Ф.Яхин

9) Билгеле бер эшне башкару, шул эшкә җаваплы булу. *Сезнең вазифагыз бер генә: укымак, укымак, тагы укымак, әмма идарә, программа эшләрен мөгаллимнәр карар.* Г.Ибраһимов

10) Берәр нәрсәне төзек яки җыйнак хәлдә тоту. *Шулкадәр өлгермим, котчыккыч! Өйне дә карый алмыйм.* А.Расих

11) Урын-җир, табын һ.б.ш. әзерләү. *Сафия абыстай самавыр карарга, чәй урыны хәзерләргә керешә.* А.Шамов

12) Нәрсәне дә булса эшләүне, башкарып чыгуны максат итеп, шуның хәстәренә керешү, җаен, мөмкинлекләрен эзләү. *Николай Сәхиләнең бу халәтен бик тиз аңлап алды. Башы әйләнеп китүе – аны күреп каушап калуы икәнен аңлап, тизрәк чыгып китү ягын карады.* Д.Каюмова

13) Ау корылмаларын, кош ояларын һ.б.ш. табыш бармы икән дип тикшереп чыгу. *Күлнең бер як читендәрәк балыкчылар ишкәкләре белән суны шапырдатып, әрле-бирле йөриләр, кичтән салып калдырган нәрәтәләрен карыйлар.* М.Гафури. *[Гайшә:] «Бәлки, тавыкларым салгандыр, ичмасам, өчдүрт йомыркадан тәбә ясармын», – дип уйлап, абзарга оя карарга йөгермәк булды.* Г.Ибраһимов

14) Билгеле бер тарафка юнәлгән, юнәлдерелгән булу. *Төньякка караган, калын имән такталардан ясалган ачык капка янында, аклы-каралы итеп буялган шлагбаум кырында, кулында озын штыклы мылтык тоткан, култык асты сүтелгән ак толып кигән, шулай да ярыйсы гына өшегән олы яшьтәге мыеклы солдат таптана.* З.Зәйнуллин

15) *куч.* Нәрсәгә дә булса бәйләнешле, шуңа мөнәсәбәтле булу, аның составында, эчендә тору. *Ел фасыллары, табигать күренешләренә караган мәкальләр һәм әйтемнәр*

16) *куч.* Иярү, охшарга тырышу, үрнәк алу

17) *куч.* Билгеле бер хәлне, мөһим факторны күз алдында тоту, исәпкә алу. *Юрганыңа карап аяк суз.* Мәкаль. *Картлыгыма карама. Кирәк икән мин бүген дә солдат.* Н.Исәнбәт

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Эшнең нинди дә булса тәҗрибә, сынау сыйфатында башкарылуы төсмерен белдереп килә. *Нинди генә врачларга бармадылар да нинди генә әбиләрдән өшкертеп карамадылар Белла белән әнисе.* Д.Булгакова. *[Фәрит] Бераз тынычлангач, тозы тонсын дип куйган суын бер йотым гына кабып караган иде, шаккатты: су төчеләнеп калмасынмы!* Ш.Алпар

2) Боерык фигыль формасында янау төсмерен белдереп килә. – *Җибәреп кенә кара, – мәйтәм, – яучыңның сөякләрен җыйнарга үзең килмәгәең.* Г.Минский

**3. кара** *ы. мәгъ.* 1) Янау, шелтәләү төсмерен белдерә. *Явыз хатын, кара, ни дип сөйләнә!* Н.Исәнбәт. *Кара, кара, моның да теле бар икән!* М.Фәйзи. *Кара безнең Шиһапны, хикәя яза башлаган!* М.Җәлил

2) Гаҗәпләнү, үчекләү, соклану, игътибарны җәлеп итү өчен кулланыла;

бак, баксана. *Карасана, алмагач төпләре ап-ак булган: алмалар тәгәрәшеп ята.* Г.Әпсәләмов. *Бу хәлне бер яшь Тычкан күргәч, иптәшләренә хитабән: «Карагыз әле! Бу койрыксыз Күсе ни өчен безгә хөкем итә?»* Г.Тукай. *Күрше Фазлый, без бераз җыйганчы, әллә ничаклы җыйган да: – Карагыз әле, алпавыт кебек булдым бит. Шушындый корсагың булса, ай-яй! – дип тора.* Г.Толымбай

◊ **Кара(гыз) аны** Янау-кисәтү сүзе. *--- Я, ярар алайса, сөйлим инде, әмма карагыз аны, мыскылдан булмасын.* А.Шамов. *[Галим:] --- Бу бит ЧП! Хәзер үк милициягә хәбәр итегез! Таптырыгыз малайны! Әгәр тапмасалар, карагыз аны!* М.Маликова. **Кара син аны** Нәрсәнең дә булса көтелмәгәнрәк, гаҗәбрәк ягына игътибар иттерү өчен әйтелә. *Кара син аны, нинди зур егет булган.* Т.Гыйззәт. *Кара син аны. Бүрене самолёттан гына «сугалар» диген, ә?..* Ә.Еники. *[Мөнәвәрә] Кара син аны, ничек сөйләшеп, безне куркытып кысмакчы була.* З.Зәйнуллин. **Карар күзгә** Беренче карашка, өстән генә караганда. *Мәсәлән, җыр, гармун кычкырту яки карар күзгә тәүфыйклы гына бер егетнең --- бичара кызны чырылдатып кычкыртып җибәрүе – моның ише вактөякләрне кем исәпләп торган инде анда.* Ф.Хөсни. *Карар күзгә корсак Аллага шөкер күренә.* А.Алиш. *[Василь Шевченко] Карар күзгә дә бик килешле, баһадир бәдәнле егет, киң җилкәле, тулы гәүдәле.* И.Салахов

**Карап алу** Тиз арада карау; күз төшереп алу. *Җирән малай, иптәшләре көлеп туктагач, Габдуллага үз итмичә генә карап алды да: – Уйнасаң, кузнаңны куеп уйна, – диде.* И.Нуруллин. *Бабай, уйларымны сизенепме, күзләремә үтәли карап алды.* Ф.Яхин

**Карап бетерү** Барысын да, ахырга кадәр карау; карауны тәмамлау

**Карап кую** Бер мәртәбә яки сирәк кенә карау. *Батрак ана, улын сагынганда, Карап куя шушы сурәткә.* М.Җәлил. *Ир, чынлап сөйлиме бу дигәндәй, аңа сәер генә карап куйды, аннан соң ашыкмый гына чишенә башлады.* М.Кәбиров

**Карап тору** Күзне алмый, озаклап карау; өзлексез карау. *Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар; мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.* Г.Тукай. *Алар... Алар җыйнап аналарны, Балаларны кырга кудылар. Казыттылар чокыр, ә үзләре Читтән көлеп карап тордылар...* М.Җәлил

**Карап үтү** Өстән-өстән генә карау. *Паларусов артель, коммуна, колхоз турындагы кечкенә китапларны бик өстән генә карап үтте.* Г.Ибраһимов

**Карап чыгу** Башыннан ахырына кадәр карау. *Үги әти белән Мингазый абый өйгә кереп идәннәрне, түшәмнәрне, мичне карап чыктылар.* Н.Дәүли. *Рюмкаларны чәкәштереп эчкәч, әлеге кәгазьне, изге бер мирас сыман кулдан кулга күчереп, яңадан карап чыктылар.* М.Кәбиров

**Карап яту** *сөйл.* Карау хәлендә булу

**Карый башлау** Карарга керешү. *Әхтәм абзый да урта кул балта остасы иде. Ул хәзер Гафинең тегермәннәрен карый башлады.* Ш.Маннур

**Карый бирү** Бернигә игътибар итмәстән карау

**Карый төшү** Тагын да карау

**КАРА́У** II *и.* **1.** Каралу, тикшерелү процессы. *Бер сәгать вакытны үткәрү аның [Вахит] өчен чиксез озак тоелды, һаман да карау башланмый иде әле.* М.Гафури

**2. каравында** *сир. бәйл. функ.* Карамагында, җаваплылыгында. *[Капитан:] Мин бүген килгән отрядтан тагын алтмыш кешене Хәмит старшина каравында качкыннарның чигенү юлын кисәр өчен җибәрдем.* Ф.Бурнаш

**КАРАУЛА́У** *ф. сөйл. к.* **каравыллау**. *Көннәр, төннәр, зобаныйлар Тәрәзәмне караулый.* С.Рәмиев

**КАРАУЛЫ** *с.* 1) Төзек тәрбияле

2) Караучысы булган, тиешле тәртиптә булган. *«Балалар да караулы булыр, хатын-кызларыбызга өстәмә эш урыннары ясалыр иде», – диде бу тәкъдимне яңгыратучы Николай Токарев.* М.Мартынова

**КАРАУСЫЗ** *с.* Тәрбиясез, караучысы булмаган

2) Хуҗасыз; каравылсыз, саклаучысыз. *Караусыз балалар кемнеке?* Р.Биктимеров

**КАРАУЧЫ** *и.* 1) Тәрбияләүче, карап-тәрбияләп үстерүче; тәрбияче. *Балаларны гаилә коруга әзерлек эшен мәктәптән үк башлау аерылышуларның, караучысыз калган балаларның, ятимнәрнең кимүенә китерер дип әйтәсе килә.* Мәгариф. *Ләкин ул гел матур була бик аз вакыт, Караучысыз, ялгыз башы һәлак була.* Ш.Мөдәррис

2) Хезмәт күрсәтеп торучы кеше, хезмәтче. *Патшаның ат караучылары якын да килә алмый, байтал китерми.* Әкият

3) Нинди дә булса объект һ.б.ш. төзеклеге, җыйнаклыгы өчен җавап бирүче, күзәтеп торучы кеше

4) Карап күзәтеп торучы кеше; тамашачы. *--- телевизор караучыларның игътибарын җәлеп итәрдәй үткен тапшырулар ясарга тырыша иде безнең 3 – 4 кешедән торган иҗат төркеме.* Безнең гәҗит

**КАРАЧ** *и. диал.* Кара төстәге яшь терлек (йорт хайваны). *Бәрән белән минем арада бик зур дуслык башланды. Мин шул Карачның хуҗасы булып киттем.* Ф.Әмирхан

**КАРАЧА́** *и.* Кечкенә кара тап һ.б.ш. нәрсә. *Ары да барыр карача, бире дә килер карача; Тал төбендә тонык су – тондырып эчәр карача.* Табышмак

**КАРА́ЧА** *с.* **1.** Морҗасы булмаган, түтене төннектән генә чыга торган (өй, мунча тур.). *Болар биш җәяүле, бер атлы булып тагы чыгып киттеләр. Инде тагы бер ай тулганда, юл буенда бер карача гына өйгә туры киләләр.* Әкият

**2.** *рәв. мәгъ.* Кара акыл белән генә, наданнарча

**КАРАЧАЙ** *и.* Төньяк Кавказда, башлыча Карачай-Чиркәс Республикасының таулы районнарында яшәүче төрки халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Карачай теле*

**КАРАЧА́ЙЧА** *рәв.* Карачай телендә. *Карачайча сөйләшү*

**КАРАЧКЫ** *и.* 1) Кырда, бакчада кошларны куркыту өчен куела торган, күбесенчә, кеше кыяфәтендәге

куркыткыч. *Хисам бабай – [баганага] аркылы таяк кадап, Иске-москы кидереп, Бик куркыныч иттереп Карачкы ясап куйды.* Ш.Маннур. *Аны [бүре тиресен] карачкы казыгына махсус кешеләргә күрсәтү өчен элеп куйгандыр.* Л.-Х.Таналин. *Каргалар да, тилгәннәр дә Гел куркышып беттеләр. Карачкыны әллә каян Әйләнеп үк үттеләр.* Мөҗәһит

2) Кеше яки хайван формасында ясалган фигура, сөкәт. *Иң элек еракта бер карачкы куеп, һәрберебез шул карачкыга төзәп атабыз. Кемнең угы кардан өеп ясалган шул карачкыга тими үтсә, ул кеше отылган исәпләнә.* М.Гафури

3) Тышкы сызыклары беленер-беленмәс, томанлы гына булып күренгән караңгы шәүлә, тонык сурәт, тонык силуэт. *Юлның әле бер ягында, әле икенче ягында күңелгә шом салып торган карачкылар хәзер инде салам өемнәре, печән чүмәләләре, ялгыз агачлар булып ачылалар.* И.Салахов

4) *күч.* Ямьсез, шөкәтсез, килешсез кыяфәтле кеше яки берәр җан иясе. *Алма кебек кызны бер карачкыга димләр хәлем юк.* М.Фәйзи

**КАРАЧКЫЛ** I *и. к.* **карачкы** (*3 мәгъ.*). *Тирә-якта әллә нинди карачкыллар күренәләр. Барсаң, я берәр өем таллык була, яки бернәрсә дә булмый.* М.Гафури. *Чү! Тукта! Алда бер карачкыл тора.* Г.Ибраһимов

**КАРАЧКЫЛ** II *с.* 1) Күгелҗем кара, каракучкыл. *Карачкыл чүл уртасында күкләргә ашкан саргылт колонналар, җимерек стеналар.* М.Мәһдиев. *Притыкино авылы янында зур гына бер күл бар. Ул бик карачкыл төстә.* Я.Шәфиков

2) Үтә дә каратутлы (кеше йөзе тур.). *Карачкыл йөзендәге ап-ак тешләрен җемелдәтеп, үпкә-сокта белдермичә генә, Шварценеггер көлеп куйды ---.* Р.Вәли

**КАРАЧКЫЛЛАНУ** *ф.* Тонык кара төскә керү; карасулану. *Әле кичә генә өскә таба ашып утырган яшькелт бәрәңге сабагы дулкыны карачкылланып, саргаеп егылган да калган.* М.Мәһдиев

**Карачкыллана бару** Акрынлап карачкыллану

**Карачкыллана төшү** Тагын да карачкыллану

**Карачкылланып бетү** Тәмам карачкыллану

**Карачкылланып тору** Карачкыл булып күренү. *Карачкылланып торган суда яшькелт кырлы ак бозлар ага.* А.Расих

**КАРАЧМАН** *с. диал.* Карасу тәнле. *Карачман кыз – кайнар кан, сары кыз – салкын кан.* Мәкаль

**КАРАЧЫ** *и. тар.* Алтын Урда һәм татар ханлыклары хөкүмәтендә диван әгъзасы, иң югары түрәләрдән берсе һәм шуның титулы. *Акыллы карачы кара җирдән каек йөртер.* Мәкаль. *Акыллы карачы акыллы караны [гади кешене] хан итәр.* Мәкаль

**КАРА ЧУАР** *с.* Кара катыш ак; ак өстендә кара таплар булган (хайван, кош-корт төсе тур.). *Ала-кола, кара чуар – бары бетеп, Кызыл байрак кына калыр Җир шарында.* М.Гафури. *Шушында ук Агыйдел үзәнендә кара чуар сыер көтүләре рәхәтләнеп утлап йөри.* Кызыл таң

**КАРА ЧУТЫР** *с.* 1) Эре шадралары булган һәм каратутлы (кеше йөзе тур.). *Безнең ярлар карасылу, Сезнеке – кара чутыр.* Җыр

2) Гомумән карасу йөзле. *Чәй яныннан кузгалган гына идек, боларга бишенчедәме, алтынчыдамы укый торган бер кара чутыр малай килеп керде.* Ә.Дусайлы

**КАРАШ** *и.* 1) Карау юнәлеше. *Әмма шул аңсыз чагында, күз карашлары аша ятланып, күңеленә салып куелган табигать мизгелләре гөлт-гөлт итеп янып-балкып китә кебек.* Г.Гыйльманов

2) Карау рәвеше, караудагы хис чагылышы, билгеле бер тойгы. *Ник елмайдың, утлы карашыңны Йөрәгемә кадап, акыллым?!* М.Җәлил. *Борис сүзеннән тукталды да ачулы караш белән Андрейга текәлде.* В.Имамов

3) Фикер йөртү рәвеше. --- *аларның [киртәләрнең] иң зурысы – иске карашларга ябышып ятучы һәм үзләрен галим дип атаучы затларның яңарыш идеяләренә каршы чыгуы.* А.Мәхмүтова

4) Чынбарлыкны аңлау, бәяләү; иҗтимагый чынбарлыкка мөнәсәбәт. *Кешелегең синең һәр кешедә Шундый матур караш калдырды.* З.Мансур. *Эшкә сау караш белән карыйк.* М.Җәлил

◊ **Караш ноктасы** Кемнеңдер нәрсәдер турында фикере; ноктаи назар. *Өченче схема, караш ноктасы буларак, әүвәл Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» очеркында урын алып, аннары Г. Нигъмәти хезмәтендә уздырылды, соңрак Г. Халит хезмәтләрендә яклау тапты.* Н.Хисамов. **Караш ташлау** Тиз генә яки мәгънәле итеп карап алу. *Шул авылга таба ымлап, Газизәгә сораулы караш ташлады.* Ә.Дусайлы. *Дженни, тәмам уңайсызланып, күлмәк итәген төзәткәләде һәм егетләргә ялварулы караш ташлады.* А.Тимергалин. *[Борһан] Табак өстендәге ашъяулыкны ачып, егетләргә мыскыллы караш ташлады.* М.Мәһдиев. **Караш төшерү** *к.* **караш ташлау**

**КАРАШТЫРУ** *ф.* 1) Өстән-өстән генә яки бүленеп, артык зур игътибар бирмичә, туктап-туктап карау. *[Гөлгенә:] Рәсимә апа иптәшләремнең лекцияләрен алып килеп тора. Караштырып барам ---.* Ә.Сафиуллин

2) Тиз-тиз яки әледән-әле карау, күзәтү. *Тик буфет урынында Кекин гастрономындагы сымаграк азык-төлек бүлеге урнашкан, имеш. Мин нәрсәдер караштырып йөрим.* Ж.Дәрзаман. *--- кайсы чатырлар кору өчен урын эзләргә, кайсы җиләк караштырырга урманга кереп китте.* Ш.Бикчурин. *[Такый] Утны караштыр, яме, Һәдия бит әле?* Г.Якупова

3) Ашыкмыйча гына берәр эш башкару, нәрсәне дә булса хәстәрләү, әзерләү. *Эзи белән авылы арасын Сабит капма-каршы уйларга уралып үтте. --- Йорт-җирләрен әз-мәз караштырасы иде...* А.Гыйләҗев

4) Билгеле бер нәрсәне сатып алу һ.б.ш. ният белән эзләп, булдырырга тырышып йөрү. *Ат караштырам дисеңме әле син, Хәйбулла дус? Бик шәп, бик шәп.* Ш.Камал

**Караштыра башлау** Караштырырга тотыну. *Һади шуларның [башакларның] берсен тагын да ия төшеп, караштыра башлады.* М.Хәсәнов. *Хәлим шунда ук киемнәрен караштыра*

*башлады.* Г.Гыйльманов. *[Зәлинә] Кичен алып кергән газетаны караштыра башлады.* Ф.Тарханова

**Караштыра тору** Караштыру процессында булу. *Кибеткә керү белән ул [әтисе]: «Мин шылтыратып кына алам, ә син караштыра тор», – диде дә директор бүлмәсенә узды.* Р.Юсупова

**Караштырып алу** Тиз арада караштыру

**Караштырып бару** Даими караштыру. *– Кая ул газеталар караштырып бару, – дип елмайды Шәүкәт.* Ә.Хәсәнов

**Караштырып йөрү** Караштыру хәлендә булу. *Ул урам капкасыннан кергәндә, Рәхим ишегалдында эш-көш караштырып йөри иде.* Ә.Моталлапов

**Караштырып тору** Даими рәвештә яки әледән-әле караштыру

**Караштырып чыгу** Барысын да, берсен дә калдырмыйча караштыру. *Башта зират очыннан башланган урамга күз салдым, Олы урам ягына да карадым. Тыкрыкларны да караштырып чыктым.* Л.-Х.Таналин

**Караштырып яту** *сөйл.* Караштыру хәлендә булу

**КАРАШУ** *ф. урт.* 1) Бер-береңә карап алу. *Тәрәзәләрдән карашыйк, Алтын балдак алышыйк.* Җыр

2) Карарга, тәрбияләргә ярдәм итү. *[Җәләй:] Ата-анасыз, туган-ырусыз тилмереп калган малайны карашып йөрүме, Шәмсәттәй?* М.Фәйзи

**Карашып алу** Тиз генә карашу. *Габдрахман белән Зариф күзгә-күз генә карашып алдылар.* А.Шамов

**Карашып кую** Бер мәртәбә яки сирәк кенә карашу

**Карашып тору** Гел карашу; хәзер карашу

**КАРАЮ** *ф. сир.* 1) Каралу, кара төскә керү

2) Керләнү, пычрану. *Безнең өйдә хатын-кыз затыннан бер кеше дә булмаганга күрә, әйберләр тырым-тарагай ята башладылар. Идән карайды. Мич тирәсе чүп-чар белән тулды.* М.Гафури

**Караеп бетү** Бик нык караю, тәмам караю. *Өйнең түбә такталарына яшел мүк чыккан, бүрәнәләре тәмам караеп беткән.* Ә.Еники

**Карая төшү** Берникадәр караю, тагын да караю. *[Фатыйманың] кара күзләре тагын да карая төшкән кебек булды.* И.Гази

**КАР БАБАЙ** *и.* Кардан әвәләнгән өч түгәрәкне берсе өстенә берсен куеп ясалган фигура. *Эре-эре карлар ява иде, шуңа күрә икебез дә кар бабайның үзе кебек ап-ак булдык.* Р.Габделхакова. *Урамга малай-шалай чыкса, uяреп уйнарга, кар бабай ясарга, окоплар өяргә әзер иде ул хәзер.* К.Кәримов. *Каршы искән җилләрне дә тансыклый икән күңел. Кабартылган кар бабайлар Ул инде бабай түгел...* Г.Бәйрәмова

**КАР БАЗЫ** *и.* Азык-төлек һәм тиз бозыла торган ризыкларны саклау өчен махсус казылган һәм, гадәттә, җәйгелеккә боз яки кар салып калдырыла торган салкын баз. *Нәрсә-кара кирәк булса, ул иренең күз карашыннан аңлый, ә дигәнче кар базына төшеп менә, чоланга йөгерә, соралган нәрсәне ялгышусыз китереп бирә.* А.Гыйләҗев. *Кар базы турысында, агач келәткә хәтле, коймага терәп утын әрдәнәсе өелгән.* Р.Кәрами. *Хуҗа хатын кар базыннан тозлы кәбестә һәм чүлмәк белән кәҗә сөте алып керде.* Р.Мөхәммәдиев

**КАРБАМИД** *и. лат. к.* **бәвелчә**. *Терлекләргә арзанлы, аксымга мул, биологик яктан рациональ булган туклыклы меню хәзерләү өчен, нибары карбамид дип атала торган азотка бай матдә генә кирәк икән.* М.Хәсәнов

**КАРБИД** *и. лат. хим.* 1) Металларның углерод белән кушылмасы. *Калий карбиды. Натрий карбиды*

2) Суга кальций карбиды кушып әзерләнә торган ягулык. *Карбид лампасы белән яктырту*

**КАРБИ́ДКА** *и. рус сөйл.* Ягулык буларак кальций карбиды һәм су кулланыла торган махсус лампа. *Карбидка яктылыгы астында штольня эчендә төн белән көнне аерып булмый.* Ә.Айдар

**КАРБИКӘ** *и. миф.* Әкиятләрдә кардан яралган яшь кыз рәвешендәге персонаж, кар кызы. *Кыз әйтте көлеп: «Кояшыгызга Һәм язгызга һич китмисем, Нәрсә ул ялкын карга һәм бозга, Карбикә белми мәхәббәт хисен».* М.Җәлил

**КАРБИЯ** *и. бот.* Алабутачалар семьялыгыннан булган үсемлек; вак алабута. *Сарут, кычыткан, балтырган, песи тарысы һәм карбия үләне – туфракта азот күп булуны күрсәтә торган үсемлекләр.* Робинзон эзләреннән

**КАРБОН** *и. лат.* 1) *хим. иск.* Углерод. *Карбон оксиды*

2) *геол.* Полеозой эрасының бишенче чоры; ташкүмер чоры. *Борау һаман аска төште. Менә карбон – күмер туган чорлар. Ерак калды җирнең өсте.* Ш.Маннур

**КАРБОНАД** *и. фр.* Дуңгызның сырт итеннән кыздырып пешереп, ыслап яки каклап әзерләнгән затлы ризык

**КАРБОНАТ** *и. лат.* Углерод кислотасының тозы. *Түбәнге сазлыклы үзәнлектән башланып, Агыйдел Көньяк Урал таулары каньонына ярәшеп, известняклар, карбонатлар һәм доломитлар арасыннан үзенә юл ала ---.* Я.Шәфиков

**КАРБОНАТЛЫ** *с.* Составында карбонат булган. *Көнбагар сөтлегән – берьеллык үсемлек, яшелчә бакчаларында чүп үлән буларак очрый, карбонатлы, кальцийга бай туфракны ярата.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КАР-БУРАН** *җый. и.* Кар һәм буран. *Бер татар шагыйре әйтмешли, Сәйдәш кар-бураннар аша үзенең кара роялен тартып бара.* Р.Низамиев. *Җәһәннәмдәге буровойларга барып-кайту, бигрәк тә көзге-язгы юл өзеге айларында, кышкы кар-бураннарда интегүләр, вахта сәгатьләренә тиң өстәмә вакыт югалтулар... Мондый шартларда ничек укымак кирәк?!* Ә.Сәлах. *Яңгыр яварга яисә кар-буран булырга торса, ул ике-өч көн алдан авырый башлый.* З.Зәйнуллин

**КАРБЫЗ** *и.* 1) Кабакчалар семьялыгыннан үрмәләп үсә торган берьеллык үсемлек, бакча культурасы. *Карбыз басуы*

2) Шул үсемлекнең татлы эчле шарсыман зур җимеше. *Карбыз эчендәге бәләкәй генә кара орлыкта да зур*

*тарихи вакыйганы чагыштырып күрсәтү хасияте яшеренгән икән.* С.Поварисов

◊ **Карбыз кабыгы ташлау** Кемнең дә булса абруен төшерергә тырышу, хәйлә-мәкерләр белән комачау тудыру, аяк чалу. *«Кешесен тапсаң инде», – дип мыскыллап та куя. Шулай итеп, Тимер очраган бер урында Фәсхинең астына карбыз кабыгы ташлый иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**КАРБЫЗЧЫ** *и.* 1) Карбыз үстерүче, карбыз игүче. *Карбызчылар бригадасы*

2) Карбыз белән сату итүче. *Карбызчылар, алмачылар яныннан да егетне [Хәлимне] бик тиз өферттеләр. Кайсы гына кибет каршына барып туктамасын: «Эй, шалама, сыпырт моннан!» – дип кычкыралар.* И.Гази

**КАРБЫЗЧЫЛЫК** *и.* Үсемлекчелекнең кавын, карбыз һ.б.ш культуралар үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы

**КАРБЮРА́ТОР** *и. фр. тех.* Эчке янулы двигательләрдә сыек ягулык белән һава кушылып, янучан кушылма барлыкка килә торган узел. *Ташлытаудан хат-хәбәр генә килеп торды: «Зәнәтиеләр бик авыр, инде кәлинвалларны өйрәнеп беттек, хәзер карбюратор белән магнето өйрәнә башлыйбыз...».* М.Мәһдиев. *[Фарис:] Карбюратор гына булса бер хәл. Бензин кәчәт итә торган насостан шлангы ычкынып, бөтен горючий агып беткән.* Л.Лерон. *Дәрес бара. Карбюратор. Ягулык белән һаваны бергә кушып өрдерүче җайланма.* Ф.Яхин

**КАРБЮРАТОРЛЫ** *с.* Карбюраторы булган, карбюратор ярдәмендә эшли торган

**КАРГА** *и.* 1) Козгыннар семьялыгыннан елтыр кара яки шәмәхә кара каурыйлы урта зурлыктагы кош. *Карга килсә, кар китәр.* Мәкаль. *Адашып калган хәлсез чебине сырып алган дәү каргалар кебек, аны [Һадины] бишалты хатын-кыз урап алган. Каргалар башында дәү козгын керфексез күзле, юантык гәүдәле, беренче катта яшәүче инженер Сәйфуллин хатыны Өммегөлсем икән.* А.Гыйләҗев. *Агач башларында, кара кайгыларның тамгасы булып, каргалар каңгылдаша. Зират агачларына әллә каргалар гына куна микән?* С.Зыялы

2) *күч.* Башкалар исәбенә яшәүче, әрсез, паразит кеше. *Ил өстендә илле карга.* Мәкаль. *Монда Мифтах мулла дигән бер карга бар.* Һ.Такташ

3) *күч.* Тиешсезгә нәфес сузучы кеше. *Бер чибәррәк кыз булса, аңа күз салган әллә ничаклы каргалар буладыр.* М.Гафури

4) *күч.* Почмак рәвешендә сызылган билге яки тамга. *Ифрат мәсьәләне хәл итеп, кайбер паспортларга тәре билгесе, кайберсенә «карга» тамгасы салды.* А.Расих

5) *күч. жарг.* Уен картасы (кәрт) билгеләренең берсе; пики. *Ә бездә пикины «карга» дип тә йөриләр. «Карга валеты» дисәң, тагын да шәбрәк яңгырый икән, каһәр!* Р.Мирхәйдәров

◊ **Карга бураны** Кара каргалар килер алдыннан була торган бик көчле язгы буран, март бураны. *Карга бураннары иңгән көндезләрдә.* Р.Фәйзуллин. *Күңелемә минем кага Бары карга бураннары.* Ф.Мөслимова. **Карга кары** Эре булып ява торган, авыр бөртекле җепшек язгы кар. *Һаваның салкынлыгына карамастан, карга кары өзлексез явып тора.* К.Тинчурин. **Карга җимгә төшмәс борын** Бик иртә, таң атарга атмас. *Карга җимгә төшмәс борын, кая болай кузгалдың, Шәйхи абзый?* М.Хәсәнов. **Карга мие эчкән** Тиз оныта торган, бик хәтерсез, башсыз. *Юк, булмас инде, булмас андый этләр. Эх, чүбек баш, эх, карга мие эчкән нәрсә!* Ш.Еникеев. **Карга канаты кебек** Чем кара, шәмәхә төсмере булган һәм бераз ялтыраулы кара. *Илдарның башында кечкенә козырёклы кепка булыр, читеннән карга канаты кебек җете кара чәче чыгып тора.* Г.Гобәй

**КАРГА́ БОРЧАГЫ** *и. бот.* Кырлы борчак; чина. *Җир башларын, юл буйларын, уем-уем чи урыннарны, тоташ-тоташ кишәрлекләрне әрем, алабута, карга борчагы, тигәнәк, сарут басып китә.* Р.Төхфәтуллин

**КАРГАБОРЫН** *и. тех.* Очлы кешчә. *Каргаборын белән карга борыны бер-береннән бик ачык аерылалар. Болардан беренчесе карга борынына охшаган коралны, икенчесе карганың үз борынын, ягъни томшыгын аңлата.* Л.Җәләй

**КАРГА́ БОРЫНЫ** *и. бот.* Пасленчалар семьялыгыннан вак-вак кара җимешле үлән; *русчасы*: **паслён чёрный**. *Яшел таплы җир өстендә күгәргән, мүкләнгән нигез ташлары арасыннан юан сабаклы алабуталар, карга борыннары, сукыр кычыткannар котырып үсеп чыккан.* А.Гыйләҗев

**КАРГА́ БОТКАСЫ** *и. этн.* Яз ахырларында үткәрелә торган календарь йолаларның берсе – язны каршылау йоласы. *Беренче арпадан изге ботка – карга боткасы пешерелә ---.* Н.Фәттах. *Җиребезгә язлар килгәч, Кошлар кайткач ерактан, «Карга боткасы» пешергән Халкыбыз чын йөрәктән.* Йолдыз

**КАРГА́ КУЗАГЫ** *и. бот. к.* **карга борчагы**

**КАРГА́ КҮЗЕ** *и. бот. к.* **карга борыны**. *Карга күзенең бер-берсенә аркылы-торкылы торып үскән эре-эре дүрт яфрагы һәм уртада карга күзе шикелле кап-кара җиләге була.* Робинзон эзләреннән

**КАРГА́ МИЛӘШЕ** *и. бот.* Зелпесыманнар семьялыгыннан кара яисә кызыл төстәге ваграк җимешләре булган куакчыл үсемлек; *русчасы:* **бузина**. *Карга миләше әфлисун эче кебек кызгылт сары төскә керде; канәфер, зирек куаклары һаман яшь әле.* Г.Гобәй

**КАРГАНУ** *ф.* 1) Кемне, нәрсәне дә булса каргап-сүгеп сөйләнү, сукрану; кемнедер, нәрсәнедер каһәрләү, ләгънәт уку. *Фагыйлә абыстай әрнеп карганды: – Шул зимагурың белән рәхәт күрмәсәң иде...* Ф.Яхин

2) Бик каты антлар итеп ышандырырга тырышу. *Карга каргылдап, карак карганып котылыр.* Мәкаль. *Мәзин белән сөйләшеп куйганча, барысын да инкяр итәргә керешә. – Юк, знакум... Билләһи, нитү... сәбчим ялган! – дип карганды.* М.Галәү

**Каргана бирү** Бернигә карамастан каргану

**Карганып алу** Аз гына, тиз арада гына каргану

**Карганып тору** Даими яки әледән-әле каргану; каргану хәлендә булу

**КАРГА СӨЯК** *и.* Кошларда һәм кайбер имезүчеләрдә күкрәк мускулларының өстәмә рәвештә беркетелүе өчен түш сөяге үсентесе; *русчасы:* **киль**. *Үрдәкборынның кулбаш поясында карга сөяк бар.* Зоология

**КАРГА́У** *ф.* Кемгә яисә нәрсәгә дә булса карата начар теләк теләү. *Мулла белән улының ни турында сөйләшкәнен ишеткәч, ул түзмәде, еламсыраган бер тавыш белән каракларны каргарга кереште.* М.Галәү. *Халык каргаучы ЖКХдан алып дәүләт бәйсезлегенә кадәр бөтен очраклар буенча еллар сынавын узган Шагыйрь сүзенә юлыгасың.* Ә.Ханнанов

**Каргап алу** Бераз гына каргау

**Каргап кую** Бер генә тапкыр, азга гына каргау

**Каргап бетерү** Тәмам, бик нык каргау; каргауны тәмамлау

**Каргап тору** Даими яисә әледән-әле каргау; каргау хәлендә булу

**Каргый бирү** Бернигә карамастан каргау

**КАРГАУЛЫ** *с.* Каргау өчен яки каргау тоны белән әйтелгән. *Хафиза әрнүле, каргаулы тавыш белән каенанасына ташлана: – Карт башың белән юкны чәйнәп торма, әнкәй.* Г.Ибраһимов

**КАРГЫ** *и. зоол.* Карчыганың кечерәк гәүдәле бер төре. *Каргы – карчыганың азгыны.* Мәкаль

**КАРГЫЛДА́У** *ф.* Каркылдауны хәтерләткән, ләкин алай ук кискен яңгыравыклы булмаган аваз чыгару (карга, козгын һ.б.ш. тур.). *Карга булып тугач каргылдарга гына кала.* Әйтем

**Каргылдап кую** Кинәт каргылдау

**Каргылдап тору** Берөзлексез каргылдау; хәзер каргылдау

**КАРГЫЛТ** *с. диал.* Карага тартым, каралҗым. *Аның [Аляның] шулай сихерле елмая торган киңчәрәк каргылт йөзе бу көнге язгы төн шикелле: нурлы.* Ф.Әмирхан

**КАРГЫШ** *и.* Ләгънәт, каргау сүзе; үтә ачулы, үчле теләк. *Сөйгәнгә алкыш, сөймәгәнгә каргыш.* Мәкаль. *Әни мәрхүмә китап алып, «Сак-Сок»ны көйли иде. Әниләренең каргышы төшкән, дип сөйли иде.* Р.Хисмәт. *Шушы җирдән киткән ерак юлга, Су анасы биргән алтын тарак, «Мескен булып торган өч йөз ел»га, Караңгыга, каргышларга карап.* А.Гамил

◊ **Каргыш алу** Ниндидер начар гамәл кылып, каргалуга дучар булу. *Кәбир үзе кыйнады, үзе сүгенде: – Мондагы муллалардан гына каргыш алуың җитмәгән, Казанга барып, Казан муллаларыннан да каргатасың килә икән!* Ф.Хөсни. **Каргыш төшү** Каргыш нәтиҗәсе буларак, берәр бәлагә дучар булу. *Эт каргышы бүрегә төшмәс, сычкан каргышы мәчегә төшмәс.* Мәкаль

**КАРГЫШ-ЛӘГЪНӘТ** *җый. и.* Һәртөрле каргышлы һәм ләгънәтле сүзләр, теләкләр. *Безне изүчеләргә каргыш-ләгънәт яудырам.* А.Алиш. --- *хәзер бәян ителәчәк туйның ахыры хәерле түгел, хәтта фаҗигале дип әйтсәң дә ярыйдыр. Аны әле дә бик күпләр каргыш-ләгънәт белән искә ала.* Ватаным Татарстан

**КАРГЫШЛЫ** *с* 1) Каргыш төшкән, каргалган. *Дөресрәге, әлегә бу каргышлы дөньяга кереп бетмәгән, бәлки, аңа керү өчен кирәк булган мөһим код-исемне генә пышылдый иде ---.* Г.Гыйльманов

2) Каргыш итеп әйтелгән яки кабул ителгән. Каргышы булган. *Тоткыннарның йөрәген өшетә торган, нервларын өзелердәй итеп какшата, акылны томалый торган чаң! Шомлы, кара каргышлы чаң!* И.Салахов

**КАРДӘШ** *и.* **1.** 1) Бер нәселдән булган, туган кеше. *Бикбулат мулла Гали байга кияү буладыр, мулланың хатыны Гали байның кардәше иде.* М.Акъегет

2) Иптәш, дус. *Кыен эшме? Әйе, кардәш, Эчтә әрнү, әр кала.* Б.Рәхимова

3) *күч.* Уртак сыйфатлар, кызыксынулар буенча якын, үз кеше. *Син миңа якын... Мин – синең җаныңның кардәше, игезәге...* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Туган тиешле, бер нәселдән булган. *Кардәш телләр*

2) *күч.* Дусларча мөнәсәбәттә булган, тугандаш

**КАРДӘШ-КАБИЛӘ** *җый. и.* Нәсел, ыру-кардәш. *Кардәш-кабилә сөенде. Галим абзый да шатланды.* Г.Исхакый. *Әлеге эш турысында уйлаштык, сөйләштек, күрше-күлән дигәндәй, кардәш-кабилә белән дә мәслихәтләштек.* Ш.Камал

**КАРДӘШ-КАЛӘМ** *и. иск.* Карандаш. *[Гәүһәр туташ] ридикюлен ачты, нечкә күк кардәш-каләм белән блокнотын тартып чыгарды.* Г.Ибраһимов

**КАРДӘШЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Кардәшләргә хас булганча; кардәшләр кебек. --- *татарның исемен дә җир йөзендә калдырмаска тырышкан «Бәянел хак»тан башка барлык газеталар бербере белән кардәшләрчә генә эш итәргә тиешләр.* Г.Тукай

**КАРДӘШЛӘШҮ** *ф.* Үзара кардәшлек мөнәсәбәтләренә керү, туганлашу, кодалашу. *Якын белән ярдәмләш, ят белән кардәшләш*! Мәкаль

**Кардәшләшә бару** Әкренләп кардәшләшү

**Кардәшләшеп алу** Бер ара кардәшләшү

**Кардәшләшеп кую** Тиз арада кардәшләшү

**КАРДӘШЛЕК** *и.* 1) Туганлык, нәсел, кан уртаклыгы. *Габдулланы яхшы каршы алдылар. Бу каршылауда, ни әйтсәң дә, кардәшлек олылыгы сизелеп торды.* Ә.Фәйзи. – *[Фәтхинең] Мәдинәгә бераз кардәшлеге дә бар бугай, – диде Каюм.* Ш.Камал

2) Кардәшләрдәге кебек якын мөнәсәбәт, үзара дуслык. *Ирек, кардәшлек юлында һәр кеше булсын игез.* Г.Камал. *Гадәләт, туганлык, кардәшлек, закон һәм тәртип яклы кешеләр безнең исемлеккә тавыш бирсен!* Ш.Маннур

**КАРДӘШ-ЫРУ** *җый. и.* Кардәш, дус-иш, ыругдаш кешеләр. *Күршекүлән, Тату кардәш-ыру – Таяныч ул җирдә, зур терәк!..* Э.Шәрифуллина. *Мөхәммәткамал Мозаффаров белән әлеге «бай Хәкимев» кардәш-ыру тиешле ---.* Л.Хәмидуллин

**КАРДӘШ-ЫРУГ** *җый. и. к.* **кардәш-ыру**

**КАРДИНАЛ** I *и. лат. дини* Католикларда пападан кала иң югары рухани дәрәҗә һәм шул дәрәҗәдәге кеше. *Картлач кардиналлар, епископлар --- поплар тезелеп, СССРга ләгънәт яудыралар, Тәреле киемнәргә төренеп.* М.Гафури

**КАРДИНАЛ** II *и. зоол.* Кардиналсыманнар семьялыгыннан, Төньяк һәм Көньяк Америкада яши торган кызыл каурыйлы уртача зурлыктагы кош

**КАРДИНАЛЛЫК** *и.* Кардинал вазифасы, дәрәҗәсе

**КАРДИНАЛЬ** *с. кит.* Төп, иң мөһим. *Урта гасырлардагы әдәбиятыбызны яңа нәзарый-методологик принципларга таянып, җентекләп, хәтта кардиналь дип тә әйтергә мөмкин, тикшерү көн тәртибендә актуаль булып кала бирә.* А.Әхмәдуллин. «*Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законны тормышка ашыру юнәлешендә бик күп эшләр эшләнде, татар теле дөньясында кардиналь үзгәрешләр барлыкка килде.* Р.Миңнуллин

**КАРДИНАЛЬЛЕК** *и.* Кардиналь булу. *Проблеманың кардинальлеге*

**КА́РДИО-** *гр.* кушма сүзләр составында һәм кайбер махсус терминнарда «йөрәк» мәгънәсендәге сүз (мәс., *кардиосклероз, кардиохирургия*)

**КАРЕ** *и. иск.* Ике аршынга тигез, 1,42 м чамасындагы озынлык үлчәү берәмлеге – ун басма, ярты тырма. *Бер каре озынлыктагы киләп*

**КАРЕЛ** *и.* Башлыча Карелиядә, шулай ук Тверь, Мурманск һәм Ленинград өлкәләрендә яшәүче угро-фин телле халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Безнең карел халкының шундый бер гадәте бар: кеше үләр алдыннан үзенең иң яхшы киемнәрен кия.* Г.Әпсәләмов

**КАРЕ́ЛЧА** *рәв.* Карел телендә. *[Робин Истон:] Татарчадан тыш финча, шведча, инглизчә, русча, карелча, маричa һәм испанча беләм.* Мәдәни җомга

**КАРДИОГРА́ММА** *и. гр. мед.* Йөрәк эшчәнлегенең график сурәте. *Николай Максимовичны бик авыр хәлдә китереп салдылар. Тагын йөрәк... Кардиограммасын алып килдегезме?* Г.Әпсәләмов

**КАРДИО́ЛОГ** *и. гр. мед.* Кардиология өлкәсендәге белгеч. --- *безгә бер килгән кеше икенче доктор эзләп йөрми, – ди кардиологның шәфкать туташы Гөлназ Фәхретдинова.* Кызыл таң

**КАРДИОЛО́ГИЯ** *и. гр. мед.* Медицинаның йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеген өйрәнә, тикшерә торган бүлеге. *Кардиологиянең хәзерге үсешенә моннан 5 ел элек нигез салынган.* Ватаным Татарстан

**КАРЕНДӘШ** *и.* Кардәш, туган. *Карендәш мәхәббәте бал-шәкәрдин Ләззәтледер, кыйммәтене белер булсаң.* М.Колый. *Якын карендәшләреннән мәхрүм улган Әсманы авылның игътибарлы кемсәләреннән саналмакта улган Йосыф бабай тәрбия итмәк улып ханәсенә алды.* Р.Фәхретдин. *Күренә ки, Сиражетдин дөньяви һәм дини әхлак кануннары белән санашмый, җинаять юлына баса. ---. Үзе генә түгел, аның тирәсендә эш итүче бертуган карендәшләре Җамалетдин белән Камалетдин дә – дөньядан артта калган кешеләр.* Н.Ханзафаров

**КАРЕНДӘШЛЕК** *и.* 1) Кардәшлек

2) Туганлык, үзара дуслык, якынлык. *Мал башка, карендәшлек башка.* Әйтем. --- *Йосыфның агалары карендәшлекнең асыл мәгънәсен төшенеп җиткерә алмыйлар, хәтта алар әтиләре Ягъкуп пәйгамбәргә нәрсә дип җавап бирәчәкләре хакында да уйламыйлар* ---. Ф.Яхин

**КАРЕ́ТА** *и. пол.* Рессорларга утыртылган, дүрт тәгәрмәчле, бөтен яктан да ябык көймәле арба. *Атлар белән генә хәрәкәткә китерелеп йөртелә торган кара карета әкрен генә икенче җиргә барып туктады.* М.Гафури

**КАРЕ́ТНИК** *и. рус иск. сөйл.* Кареталар саклана торган махсус каралты. *Кучер Галиулла, капкадан кереп, каретникка таба китте.* Ш.Мөхәммәдев. *Кармак [кушаматлы кеше], элекке йорт хуҗасының каретнигын утын сараена әйләндереп, шунда үзенә мастерской кебек бернәрсә корып җибәргән иде.* Ш.Еникеев

**КАРИ** *и. гар.* 1) Яттан Коръән укучы кеше. *Салихҗан кари Россиядәге кариларның кыйраәтләре дөрес түгеллек хакында сөйләп йөрде.* Ф.Әмирхан. *Баязит кари матур моң, көчле күкрәк тавышы белән көйләп мәчеттә Коръән укый.* Г.Ибраһимов

2) *к.* **кариэ**

**КАРИАТИ́ДА** *и. гр. архит.* Балкон, кәрниз кебек конструкцияләрне күтәреп торган хатын-кыз сыны итеп эшләнгән колонна. *Кариатидалы бина*

**КА́РИЕС** *и. лат. мед.* Тешләр черү авыруы

**КАРИКАТУ́РА** *и. ит.* 1) Кемне, нәрсәне дә булса мәсхәрәләп, көлкеле итеп төшерелгән сурәт, рәсем. *1910 елда «Ялт-йолт» журналының җиденче санында Сабирның «Дилбәр» шигыренә «Шагыйрьләребез тәүсыйфе (тасвиры) буенча матур кыз» дигән пародия-нәзыйрә басыла һәм карикатура белән иллюстрацияләнә.* Р.Ганиева. *«Яшен»дә аның «Нашир әфәнде» дип исемләнгән рәсем-карикатурасы бар.* Х.Миңнегулов

2) Сәнгатьнең башка жанрларында шундый характерда иҗат ителгән әсәр. *Сюитаның икенче бүлегендә безгә Ключарёв авылдагы яшьләр җыенын бирә. Шул ук вакытта автор бик оста гына музыкаль карикатуралар эшләп керткән.* М.Җәлил

3) *күч.* Берәр чын нәрсәгә охшатырга тырышып та бик кимчелекле, көлкеле килеп чыккан предмет, күренеш. *Кинодагы Сабан туе Сабантуй түгел ул, мәсхәрә ул, карикатура.* Г.Ахунов

**КАРИКАТУРАЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Тискәре һәм кире сыйфатларны аеруча көлкеле итеп тасвирлау, күпертеп, калку итеп күрсәтү. *Образны үтәдән-үтә карикатуралаштыру – үзе үк инде мыскыллау, көлү.* З.Мәҗитов

2) Җитди күренешне артык гадиләштереп, аның әһәмиятен, дәрәҗәсен тәмам төшерү; карикатура хәленә китерү

**Карикатуралаштырып бетерү** Тәмам карикатура хәленә китерү

**Карикатуралаштырып тору** Даими яисә әледән-әле карикатуралаштыру

**КАРИКАТУ́РАЧЫ** *и.* Карикатуралар төшерүче рәссам; карикатуралар остасы. *Ләкин шагыйрьне шактый ямьсез кыяфәттә рәсемгә төшергән бер карикатурачыны санамаганда, Астрахань татар интеллигентларыннан берсе дә шагыйрь белән кызыксынмады.* И.Нуруллин

**КАРИКАТУ́РАЧЫЛЫК** *и.* 1) Карикатуралар төшерү шөгыле, эше. *Карикатурачылыктан кала, Г. Камал – үз заманында танылган каллиграф та.* М.Гали

2) Сәнгатьтә карикатуралаштыру күренеше. *Сатирада --- бер нәрсә күзгә ташлана: образны сурәтләүдә карикатурачылык.* З.Мәҗитов

**КАРИЛЫК** *и.* Кари һөнәре һәм кәсебе; кари булу. *Баязит күп газаплар эчендә елны үткәрә дә, рамазан якынлаша башлагач, тагы шул карилык белән эш итәргә исәп кора.* Г.Ибраһимов. *Минем мәдрәсәдә карилыктан килгән берничә йөз сум акчам безнең икебезгә июль числосына кадәр дә җитмәдә.* Г.Кариев

**КАРИП** *с. гар. иск.* 1) Якын торган, якынлашкан. *Бу елда кузгалдылар мөселманнар, Үләргә карип булган гарип җаннар.* М.Гафури

2) Якынча, чамасында. *Өч йөз меңгә карип сума калган булырга кирәк.* Ш.Мөхәммәдев

**КАРИЭ** *и. гар.* 1) *иск. кит.* Китапны, әсәрне укучы. *Яшь Тукай монда укучысына: «Кариэм, күп тә яздым, сез ардыгыз...» дип урынлы эндәшә һәм «язу язмакта» булган гадәтен дәвам итәчәген белдерә.* С.Лашманчы. *Бераз гына сабыр итче, кариэм, төп фикергә якынлашып киләбез.* З.Мансуров

2) *к.* **кари**

**КАР-КАР** *иярт.* Карга кычкыруын яки шуңа охшаш авазларны белдерә. *Карга әйтә: кар-кар, җирдә орлык барбар, урлап кына китим әле, сакчылары ялда...* Р.Батулла. *Укытучы – ала карга Кычкыра бит: – Кар да кар, Мондый мәктәп, Әйтегезче, Тагын кайсы җирдә бар?* Р.Вәлиев

**КАРКАС** *и. ит.* **1.** 1) Бина, корылма яки нindидер эшләнмәнең бөтен конструкцияне тотып тора торган эчке төп кысасы. *Эх-ма! Каркас өстендә йөрүче монтажчыларга исе китеп онытыла язган.* Ф.Абдуллин. *Скульптор да, рәссам да кеше анатомиясен шәп белергә тиеш. Шунсыз каркаска «ит кундырып» булмый.* Ш.Галиев. *[Марат:] Җиһаз түгел, скульптура дияр идем мин [җырчыны], Сөмбелә. Материалың бар, образ бар, каркасың әйбәт...* К.Кәримов

2) Нинди дә булса эшләнмәләрнең күпчелек очракта тимерчыбыктан булган каты нигезе. *Беренче тукталыш Татарстан – Ульян арасында. Чикне белгертеп, буяулары кырылып беткән тимер каркаска Татарстан флагы белән гербы менеп кунаклаган.* Н.Гариф

**2.** *с. мәгъ.* Агач яки металл каркастан (*1 мәгъ.*) тиз вакыт арасында төзелә торган. *Министрлар Советы 1970 еллар уртасында Язучылар союзына өч җыелма каркас йорт һәм аларны урнаштыру өчен акча бүлеп бирү карарын чыгарды.* Л.Хәмидуллин

**КАРКЫЛДАВЫК** *с.* 1) Күп каркылдый торган (карга, козгын тур.)

2) Каркылдау кебек ямьсез (тавыш тур.)

**КАРКЫЛДА́У** *ф.* 1) Кар-кар итү, кар-кар кычкыру. *Ялгыз карга каркылдап яу китермәс.* Мәкаль. *Карга каркылдап яз ясый алмаган кебек, бүре улаганга гына кыш та килми.* Ф.Яруллин. *--- кошлар, ни гомер ямьсез каркылдап, Әхмәтҗан өе өстендә бөтерелделәр, аннан ояларына әйләнеп кайттылар да тынып калдылар.* Р.Рахман

2) *күч.* Ачулану, тиргәү (гадәттә сөйләүчене, аның әйткән сүзен өнәмәгәндә, ошатмаганда әйтелә). *Аңа берьюлы өч-дүрт яктан ачуланып кычкырдылар: – Хәерлегә юра! Бәла чакырып каркылдама!* Р.Мулланурова

**Каркылдап алу** Берникадәр вакыт каркылдау; бераз каркылдау. *Карт каргалар шыпырт оча, бакчага мыштым гына төшә. Каркылдап алган чаклары – бала очырганда.* Ш.Галиев. *--- тал башындагы карга көтүе, зират каргаларына охшатып, дәррәү каркылдап алды.* Р.Вәлиев

**Каркылдап җибәрү** Кинәт каркылдау. *Карга каркылдап җибәрә дә, сыр җиргә төшә, төлке аны эләктереп кача.* Т.Миңнуллин

**Каркылдап йөрү** Гел, һәрвакыт каркылдау. *[Әхмәтҗан] Каркылдап йөрмәсә дә, Карга дигән кушамат йөртте.* Ә.Гаффар

**Каркылдап кую** Бер генә тапкыр каркылдау; кинәт каркылдау. *--- төп башындагы карга борынын күтәрә-күтәрә каркылдап куйды: «Кар-р-р-р, кар-р-р-р...».* Н.Хәсәнов

**Каркылдап тору** Берөзлексез, бертуктаусыз каркылдау. *Ихлас шулай! Кемнәр, бөтен юньле эшкә кара пичәт басып: «Хәрам, хәрам, хәрам!» – дип каркылдап тора?* Г.Бәширов

**Каркылдап утыру** Каркылдау хәлендә булу; әле, хәзер каркылдау. *«Каркылдап утырудан файда юк, ятьмәдән ничек котылу ягын уйларга кирәк», – дигән сыерчыклар.* Әкият. *--- ялгыз өянкедә бер карга каркылдап утыра анысы.* Г.Бәширов

**Каркылдый башлау** Каркылдарга тотыну

**КАРКЫЛДЫК** *с. к.* **каркылдавык**. *Күпме шулай сыенышып утырганнардыр, карчыкларның үзәккә үтәрлек каркылдык тавышына сискәнеп киттеләр алар.* Г.Гыйльманов

**КАРЛАНУ** *ф.* Кар белән каплану, кар астында калу; карга бату, карга буялу. *Һәр җир карланган, Сулар бозланган, Уйный җил-буран.* Г.Тукай. *Станциядән ерак түгел диптерме, аның [Кадергөл агайның] карланган гәүдәсен өенә түгел, ә кызының йортына алып киләләр.* Ш.Янбаев

**Карлана бару** Акрынлап карлану

**Карлана төшү** Торган саен тагын да ныграк карлану

**Карланып алу** Берникадәр вакытка гына карлану

**Карланып тору** Даими яисә әледән-әле карлану; карланган булып күренү

**КАРЛА́У** *и. диал.* Кечкенә көрәк; зур калак. *Әнә карлау, әти аның белән атларга [башак] болгата.* К.Латыйпов

**КА́РЛИК** *и. рус сөйл.* **1.** 1) Кәрлә кеше. *Сукыр һәм чукрак батырны карлик та җиңә.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Вак табигатьле, көчсез характерлы кеше. *Ләкин синең кебек генийларны да мескен карликка, аяк астындагы чүпкә әйләндерерлек көчнең барлыгына ышанмый идем мин.* Г.Иделле

**2.** *с. мәгъ.* Кәрлә булган. *Лихтенштейн дигән бер ил бар. Карлик ил.* Р.Миңнуллин

**КАРЛЫ** *с.* 1) Кары булган, карга буялган, кар каплаган. *Башкалар һәммәсе дә җиргә ташландылар, ертык капчыкка тыгылдылар, каушап, калтырап, карлы бәрәңгеләр белән авызларын тутырдылар, дөньяларын онытып, йотлыгып ашарга атылдылар.*

Г.Ибраһимов. *Әни, мескен, мине исергән дип уйлап, башыма карлы чүпрәк китереп куйды.* А.Шамов

2) Кар явып торган. *Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы көннәр килә.* Г.Ибраһимов. *Тәрәзәгә карлы җил каты итеп бәрелә, өй диварларын селкетә, улый.* З.Зәйнуллин

**КАРЛЫ́-БОЗЛЫ** *с.* Карлы һәм бозлы; кар белән боз катыш. *Туңса җаным, карлы-бозлы яңгыр явып, Кара көйсәм, йөрәгемә каннар савып, Кулларыма алам, теләп, Тукай томын, Тылсым тулы дөньясына чумам аның...* С.Гәрәева

**КАРЛЫ́-БУРАНЛЫ** *с.* Карлы һәм буранлы; кар яуган һәм буран бураган. *Яңгырлы-болытлы көз, аның артыннан карлы-буранлы каты кыш үткән: минем баштан әллә ничаклы хәлләр кичкән, ләкин Зәңгәр Чишмә аз гына да үзгәрмәгән.* Г.Ибраһимов. *Җитмәсә кышның иң яман, карлы-буранлы көне.* Ф.Яхин. *Карлы-буранлы кыш кына араларын өзебрәк тора – менә бер атналап инде очрашканнары юк.* Г.Гыйльманов

**КАРЛЫГАН** *и.* 1) Крыжовникчалар семьялыгыннан әчкелтем-баллы җимешле, бакчаларда да, кыргый хәлендә дә үсә торган куак үсемлек. *Безне – бала-чаганы кызыксындырганы шул зелпе төпләрен каплаган җир җиләге, тал араларында үскән карлыган, кара бөрлегән була иде...* М.Әмир. *Бакчада бик күп җиләк-җимеш агачлары һәм куаклары: берничә төп алмагач, груша, слива, чия агачлары, кызыл һәм кара карлыган куаклары үсеп утыра.* Ф.Хөсни. *Урманнарда җиләкҗимеш үсә, берничә гектарга җәелгән чиялекләр, карлыган һәм балан, шомырт һәм бөрлегән куаклары каплаган әрәмәлекләр.* М.Юныс

2) Шул куакның кара, кызыл һәм башка төсләрдәге әчкелтем сусыл җимешләре. *Хәзер карлыганның өлгергән мәле. Ә ул – С витамины «келәте», температураны төшерүче «дару». Карасы да, кызылы, агы да бердәй файдалы.* Ватаным Татарстан

**КАРЛЫГАНЛАНУ** *ф.* Карлыганның куагында җимеше ясала, йомарлана башлау. *Карлыган карлыганландымы икән, карлыганланмадымы икән?* Тизәйткеч

**Карлыганлана башлау** Карлыганлану билгеләре күренү

**Карлыганланып бетү** Тәмам, тулысынча карлыганлану

**Карлыганланып җитү** Ахыргача, кирәгенчә, тиешле дәрәҗәгә җитеп карлыганлану

**Карлыганланып тору** Хәзерге вакытта карлыганлану

**КАРЛЫГАНЛЫК** *и.* Кыргый карлыган куаклары күпләп үскән урын. *Ярларының көнчыгышка караган өлеше – атлап керергә сагайта торган урман-чытырманлык: миләшлек, шомыртлык, карлыганлык.* Ә.Хәсәнов. *[Нигъмәтҗан] Карлыганлыкта туктады, дымсу яфракка битен тидерде, тәмле ис борынын йомшак кытыклап рәхәтләндерде.* М.Хуҗин

**КАРЛЫГАЧ** *и.* **1.** Чыпчыксыманнар отрядыннан бик җитез оча торган, аксыл түшле, икегә аерылып торган кара койрыклы кош. *Алып чыга шәһәр өсләренә Уйнаклатып карлыгачларны ---.* Х.Әюпов. *--- үз-үзләрен тотышлары белән сокландыра, яраттыра торган кошлар ул карлыгачлар.* Ә.Хәсәнов. *Карлыгач аксыл түшле, очлаеп килгән тар озын кара канатлы, сәнәксыман аерылып торган койрыклы була.* Т.Шакирова

**2.** *с. мәгъ.* Кыйгачланып торган кара матур каш яки мыек турында. *Улчәүдә эшләүче карлыгач мыек Шәмәрдән абзый – әле ир уртасына да җитмәгән бер кеше.* Ф.Хөсни

◊ **Карлыгач койрыклы** Астан икегә аерылып торган арт чабулы. *Кәбир әфәнде карлыгач койрыклы фрак өстеннән яшелле-кызыллы буй-буй чапанны җилбәгәйгә җибәреп киеп алган.* Ә.Фәйзи

**КАРЛЫГУ** *ф.* Кемнең дә булса тавыш ярыларына көч килү яки салкын тиюдән тавыш үзгәрү. *Аның да күзләре канлы, тавышы карлыккан, үзе анда йөгерә, монда йөгерә, шул бозык гырылдавыклы тавыш белән бертуктаусыз акырына ---.* Г.Ибраһимов. *Минем тавыш беткән, карлыккан; Ә җырлыйсым килә шашып-шашып, Тәбрик итеп язлы көннәрне!* М.Җәлил. *Карт полковник, карлыккан тавыш белән кычкырып, гаскәриләргә команда бирде.* Ш.Камал

**Карлыга башлау** Бераз карлыгу. *Асаф та карлыга башлаган икән, – кычкырып бетерүенә җир селкенеп алды, болардан дүрт йөз метрлар чамасы алда балчык баганасы күтәрелде.* М.Мәһдиев

**Карлыга бару** Торган саен ныграк карлыгу

**Карлыга төшү** Тагын да ныграк карлыгу; бераз карлыгу. *[Гафиятулла бабай] абзар ишекләре янында туктады һәм, башын эчкә тыгып, бераз карлыга төшкән тавыш белән кычкырды: – Газинур улым, син биредәме?* Г.Әпсәләмов

**Карлыгып бетү** Тәмам, бик нык карлыгу. *Кычкыра-кычкыра тамагым карлыгып бетте. Ай-һай, бу хәтле дә йөгәнсез булыр икән хатын-кыз дигән халык!* И.Салахов

**Карлыгып тору** Даими яки әледәнәле карлыгу; карлыккан хәлдә булу

**КАРМАВЫЧ** *и.* 1) Кайбер түбән төзелешле хайваннарның (бөҗәкләрнең, кыслаларның һ.б.ш.) кармау һәм капшау, шулай ук тотып алу хезмәтен үти торган алгы әгъзасы. *[Икекапкачлыларның] Мантия җыерчалары алгы, арткы һәм корсак ягында салынып тора, анда кайчак кечкенә кармавычлар, хәтта күзләр үсәргә мөмкин.* Биология. *Әкәм-төкәмнең башында бер пар кыска һәм бер пар озын кармавычлар була.* Зоология

2) *тех.* Шул әгъзага охшаган җайланма. *Әкиятләрдәге коточкыч зур кыслага охшаган тали блогы, кармавычлары белән эләктереп, торбаның аргы башын югары күтәрде.* Г.Ахунов

**КАРМАК** *и.* 1) Очы ыргактан гыйбарәт балык тоту җайланмасы. *Малайның бер кулында кавырсын, икенчесендә җепкә тагылган ике кармак күренә.* Г.Ибраһимов. *Өч классташыбыз балык тотарга һәвәсләр икән. Кармак, нечкә капрон җеп алып килгәннәр.* Л.-Х.Таналин. *Ул арада Расих та кармагында шома һәм матур кызылканат тартып чыгарды.* Ф.Яхин

2) Озын саптан һәм шуңа беркетелгән кармаклы (*1 мәгъ.*) озын җептән гыйбарәт булган балык тоту коралы. *Өй түбәсеннән абыйның зур кармагын алып төштем. Ике шырпы кабы суалчан җыйдым да Ыкка киттем.* Г.Мөхәммәтшин. *Бакчаның уртасында шактый зур ясалма күл бар – балаларның кайбер һәвәскәрләре кармак салып, балык тотарга өметләнәләр, күзләрен дә йоммый, суда йөзгән тәтәлнең суга батканын көтәләр.* Л.-Х.Таналин

3) Кармак (*1 мәгъ.*) формасындагы тимер ыргак, эләктергеч. *Бөти тауның башына менеп булмый кармаксыз.* Җыр. *Дәү, биек кранның угы очындагы трос кармаклары, җилдә тибрәнеп, буш килеш һава сөзәләр.* А.Гыйләҗев

◊ **Кармакка кабу** Нинди дә булса хәйлә-мәкергә алдану. *Бераз җырладым да: – Их, гармун да булса иде! – дип туктап калдым. Арапиян капты бит кармакка ---.* Н.Әхмәдиев. **Кармакка каптыру** Кемне дә булса берәр төрле хәйлә-мәкер белән алдау. **Кармакка төшерү** Нинди дә булса хәйлә-мәкер белән кемне дә булса үз ихтыярыңа буйсындыру яки кемгә, нәрсәгә булса да ия булу. *Сиңа ышаныч юк, Сабирҗан абзый, берәр тол хатынны кармакка төшерергә чамалап йөри торгансыңдыр.* Ф.Хөсни. **Кармакка эләгү** *к.* **кармакка кабу**. *Әтрафтагы нәрсәләрнең бик күбесенә бик шөбһәле күз белән карап өйрәнгән карт бу кармакка эләкте ---.* Ф.Әмирхан. *[Рәфис] --- яланың авторы Шәмсүн икән дип уйлап куйды. Ләкин ни өчен Гөлфинур бу кармакка эләккән?* А.Вергазов. **Кармакка эләктерү** *к.* **кармакка каптыру**. *Колак торырлык сүз ычкындырып, тыңлаучыларны кармакка эләктергәч, Шапырай карт хикәясен өзә.* М.Хәсәнов. **Кармак салу** Берәр төрле файда һ.б.ш. өмет итеп, нинди дә булса хәйләгә керешү

**КАРМАКЧЫ** *и.* Кармак белән балык тотучы кеше. *Кармакчыдан күрмәкче.* Әйтем. *--- таң каршылаучы турист халкы, кармакчылар, коенучылар, балконга чыгып җәймә селкүче хатыннар, ашыгып эшкә баручылар – боларның барысы минем күңелдә җанлы манзара булып уелып калды ---.* М.Юныс

**КАРМАЛАНУ** *ф.* Кул белән капшап эзләнү. *Нәзыйфә торып утырды, киемнәрен табып киде. Аннан соң кармаланып мич янына килде һәм итекләрен эзли башлады.* Ф.Зариф. *Васильев акрын адымнар белән стенадагы Татарстан картасы янына килде, бармагы белән салмак кармаланып, Актайны эзләп тапты.* А.Вергазов. *Гөлсинә, яланкуллап, әүвәлге чәчәкле болын печәне боткасында ни рәвешле кармаланып торганнан соң: – Карале, Рәҗәп! Инә кергән булган икән ---.* Ә.Гаффар

**Кармаланып тору** Хәзер карамалану; әледән-әле яисә даими кармалану

**КАРМАЛА́У** *ф.* Озаклап һәм дикъкать белән капшау, кармау. *Тыңлаусыз бармакларым белән эчке кеlә очын элмәк тишегенә кармалап керттем.* Ә.Гаффар. *Еллар аша бардык сөртенеп: Табан белән җирне кармалап.* Б.Рафиков. *Ногман ялгыз карама төбеннән кармалап ботаклар җыйды.* М.Хуҗин

**Кармалап алу** Тиз арада кармалау

**Кармалап карау** Белергә теләп кармалау; кармаланган итү. *Назимов уң кулын сузып капшана башлады. Янында кемдер ята. Ул аның күкрәген, йөзен кармалап карады.* Г.Әпсәләмов

**Кармалап тору** Даими яисә әледән-әле кармалау; сөйләү моментында кармалау

**Кармалый башлау** Кармаларга тотыну. *Караңгыда берни күрмәсәм дә, әле бер, әле икенче якка сузылып, әйләнә-тирәмне кармалый башладым.* С.Сабиров. *Сания, таянырга иңнәр эзләгәндәй, бармаклары белән шома диварны кармалый башлады.* Р.Рахман

**Кармалый төшү** Тагын да кармалау. *Аякларны җайдак кебек аерып куеп, таныш бүрәнәләрне кармалый төшкән җайга, угрыны су эчендә зарыгып, пешеп яткан тал чыбыгы кармалый.* Т.Галиуллин

**КАРМАНУ** *ф. диал. к.* **кармалану**. *Килделәр капка янына Йөгреп тә, карманып та, Куанып дога укып та, Каралып-карганып та...* Зөлфәт. *Карманып, мин дә үз урыныма барып яттым.* М.Әмир. *Бу урында Нурулла туктады, кулы белән карманып, өстәл өстеннән суган кыягы тапты ---.* А.Гыйләҗев

**Кармана башлау** Карманырга тотыну

**Карманып алу** Бераз карману

**Карманып йөрү** Озаклап карману. *Кладовой эче кап-караңгы иде. Караңгыда карманып йөри торгач, бер кулым май кисмәгенә [чумды].* Г.-Х. Садри

**Карманып калу** Карману белән генә чикләнү. *Карманган карманып калмас.* Әйтем

**Карманып тору** Даими яки әледән-әле карману

**КАРМА́У** *ф.* Нәрсәне дә булса тоткалап карау, капшау. *[Заһит] Стенаны кармап утны кабызгач кына, үзенең кайда икәнлегенә төшенде.* Ф.Яруллин. *Хәлим ярым һушсыз хәлдә, куллары белән капшап, кармап, сәке кебек нәрсә эзләп тапты ---.* Г.Гыйльманов

**Кармап алу** Тиз генә кармау. *Кәрим урынына чүгүгә, янында утырган Мәҗит аның кулын кармап алып, нык кына кысып куйды.* Ф.Сафин

**Кармап тору** Гел кармау

**КАРМИН** *и. фр.* Җете кызыл буяу. *Карминны кызыл төстәге йонлач үлән бетеннән ала торган булганнар.* Робинзон эзләреннән

**КАРНАВАЛ** *и. ит.* 1) Урам буйлап маскарад киемендә җырлап-биеп йөрүдән гыйбарәт бәйрәм. *Якты-Күл җәйләве таң иртәдән Шәрыкның базары, Гарепнең карнавалы, гарәпнең мәхшәр дигәне кебек кайный башлады.* Г.Ибраһимов. *Европа илләрендәге карнавал, бездәге Сабантуй бәйрәмнәрендәге кебек, төрле уен-йолаларны һәм бәйгеләрне үз эченә алган.* М.Бакиров

2) Биюләр, уеннар белән үткәрелә торган маскарадлы күмәк күңел ачу күренеше. *[Ләйлә:] Хәтерлисеңме, Яңа ел кичәсендә карнавал ясарга әзерләнгән идек. Әти – хан малае, син – хан кызы, мин – куян, Равил – соры бүре...* М.Маликова. *Галимнәр күрсәткәнчә, безнең бабаларыбыз борынгы заманнарда ук карнаваллар, мәйдан тамашалары уздыра торган булганнар.* Р.Ягъфәров

**КАРНАЙ** *и. этн.* Тавышы бик ераккa ишетелә торган озын җиз быргы. *Бу*

*сазларны, кифарларны, флейталарны, тыйбелләрне, быргыларны, карнайларны, курайларны, нәкъкарларны, гөсләләрне --- Лобачевский һәрвакыт бик рәхәтләнеп күздән кичерә.* Җ.Тәрҗеман

**КАРНАША** *и. диал.* Кабыктан эшләнгән яки юкәдән үрелгән җиңел кызау, тубал. --- *вак сәүдәгәр – асламчы яки кырлай – үзенең товарын ике кесәле капчыкка – артмакка яки ике ялпак кәрзингә – карнашага (курҗынга) тутырып, атның савырына –ияр артына – ике яклап аскан.* Р.Әхмәтҗанов

**КАРНИЗ** *и. гр. к.* **кәрниз**. *Мостафа, тамагына килеп тыгылган ярсуын басып, бертуктаусыз чыжлап торган пулялардан саклана-саклана, тар карниз буенча алга шуышты.* Г.Әпсәләмов

**КАРОТАЖ** *и. фр.* Бур тишеп үткән скважинадагы геологик токымнарны геофизик яктан тикшерү. *Өч тәүлек буе скважиналарда каротаж ясап йөргәннән соң, рәттән ике көн ял алдым.* Э.Касыймов

**КАРОТАЖЧЫ** *и.* Җир асты токымнарын скважина ярдәмендә тикшерүче белгеч. *Зур машиналарда каротажчылар килгән, скважинага резин көпшә төшереп, бораунының кайсы якка, ничә градус авышлык белән киткәнен үлчәгәннәр.* Ш.Бикчурин

**КАРОТЕЛЬ** *и. лат.* Тупыйк очлы татлы кишер сорты

**КАРОТИН** *и. лат.* Кишердә, йомырка сарысында һ.б.ш.ларда була торган поливитаминлы кызгылт сары төстәге пигмент (башлыча А витаминыннан тора). *Кабакта кишердәге кебек үк каротин күп.* Ватаным Татарстан

**КАРП** *и. рус* Төче суларда яши торган вак сөякле каралҗым алтын сыман тәңкәле балык, сазанның бер төре. *Алтынсу кара кәрәкә, ара-тирә карп балыклары поскан урыннарыннан атылып чыга да туп-туры ятьмәгә эләгә.* Ә.Гаффар

**КАРПЫЧ** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан терлек ашый алмый торган бик каты сабаклы үлән

**КАРСАК** I *с.* 1) Кыска буйлы һәм юантык; кыска аяклы (кеше һәм хайваннар тур.). *Мәйдан уртасында башларына зур-зур каракүл бүрекләр кигән юан, нечкә, озын, карсак кешеләр авыл агай-энеләреннән тире-яры сатулыйлар.* К.Тинчурин. *Минем Сарбай ул карсак, кыска аяклы.* Г.Лотфи

2) Тәбәнәк, биек булмаган. *Эчпошыргыч шомлы тынлык басты Тирәдәге карсак өйләрне.* М.Җәлил

**КАРСАК** II *и. зоол.* Бүресыманнар (этсыманнар) семьялыгыннан Антарктидадан кала барлык материкларда да киң таралган имезүче ерткыч хайван. *Колаклары кабырчык Карсагы күп Балкан тау.* Дастан. *Мин бер арык бурзаймын, җилеп йөргән, Куян, карсак, төлке эзен сизеп йөргән.* Акмулла

**КАРТ** I *с.* **1.** 1) Олы яшьтәге, өлкән яшьтәге; озак яшәгән. *Рушания акрын гына: – Исәнмесез, – диде. Карт әби ялт итеп борылып карады, исенә төшерергә теләгәндәй, бик озак аңа карап торды.* З.Кадыйрова

2) Бик күптәннән, әллә кайчаннан бирле үсеп утырган. *Бу мәчет --- йөзләрчә ел яшәгән карт агачлар арасында, махсус эшләнми калдырылган урман эчендәге күренеше белән бертөрле серрият кәсеп итә иде.* Ф.Әмирхан. *Үсеп утыра бер карт имән. Тирә-ягы яшел чирәм, Ботаклары җиргә тигән.* М.Җәлил

3) Озак эшләгән, тәҗрибәсе булган; күпне күргән, бик күп белүче, күпне кичергән

4) Үз вакытында өйләнми яки кияүгә чыга алмый калган, сазаган. *Карт кыз комарланып ызба эченә карашын ташлады.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Олы яшьтәге ир кеше. *Дәрья булып, болыт булып кайнашкан бу исәпсез мал картның күңелен кыздырды ---.* Г.Ибраһимов. *Картлар киткән, киткән малайлар. Әйтерсең лә, далаларга китеп, Язмышыннан качкан бала бар.* Р.Вәлиев. *Хәтмулла картның күзенә йокы кермәде.* Г.Гыйльманов

2) Никахлы ир, хәләл җефет. *Ләкин китәргә өлгерә алмый калдым, карчыкның җавабы мине тагын шушы изге дә, гөнаһлы да җиргә кайтарды. – Тәкъдирем янына. Бергә гомер иткән картымның исеме шулай иде.* Г.Гыйльманов

◊ **Карт алаша** Һәртөрле авыр эшкә күнеккән, күндәм һәм юаш табигатьле карт ир кеше. **Карт алаша – тарт, алаша** Олы кешегә яңадан-яңа эшләр йөкләү турында әйтелә. **Карт бүре** 1) Күпне күргән, тәҗрибәсе булган кеше. *Яганов эшкә каян тотынырга, ничек тәмамларга икәнен белә. Карт бүре. Егерме биш елдан артык эш тәҗрибәсе.* Ш.Бикчурин; 2) Шомарган, хәйләкәр, явыз эшләргә остарган карт кеше. *[Мине] Кәримовларның Шәрифҗан исемле бер карт бүресе алдады.* М.Фәйзи. **Карт карга** Күп сөйләшә торган усал карчыклар турында. *[Вәли җиргә төкерә:] Тфү! Карт карга, синең белән үбешергә дураклар дисеңме безне? Кызларыңны дим, кызларыңны үптер.* М.Фәйзи. **Карт төлке** Шомарган, һәртөрле хәйләле эшләргә остарган кеше. *Камали абзый карт төлке бит. Боларның тәүбәсенә генә ышанмый, ошбу рәвештә протокол ясатты.* Ш.Мөхәммәдев. **Карт чыпчык** Өлкән яшьтәге тәҗрибәле кеше. *Карт чыпчыкны кибәк белән алдый алмассың.* Мәкаль. *Комиссар, әлбәттә, үзе дә күптәнге «карт чыпчык» иде, шуңа күрә үз алдында кемнәр утырганын бик тиз танып алды.* М.Әмир

**КАРТ** II *и. ингл.* Кузов белән капланмаган гади ярыш автомобиле

**КАРТÁ** *и.* 1) Күшәүче хайваннар ашказанының алгы аерым өлеше. *Гаҗәп таныш ис аның [Габдулланың] борынын кытыклады: пешкән карта исе.* Ә.Фәйзи

2) *диал.* Тукыманы җыерып тегү юлы белән ясалган бизәк, бөрмә бизәк

**КÁРТА** *и. фр.* 1) Җир өстенең яки күк йөзенең төзелешен шартлы билгеләр ярдәмендә сурәтләгән сызым; харита. *Тукай, географик карта алып, Бәләбәй шәһәренең Аксаково станциясеннән унөч кенә чакрымда урнашканлыгын белә.* Г.Мөрсәй

2) Теге яки бу үзенчәлекле билгеләрне исәпкә алган, шулай ук хуҗалык тармакларының һ.б.ш. урнашуын күрсәтә торган шундый ук сызым. *Һәр группада терлекне симертү буенча технологик карта төзедек.* С.Хәсән

3) Төрле белешмәләр теркәлә торган махсус кәгазь, бланк. *Курорт картасы тутырып, анализлар белән*

*мәшәкатьләнеп ике-өч көн үтте.* Г.Мөхәммәтшин

4) Очколар санынча шартлы билгеләр, уен фигуралары һәм мастьлары төшерелгән кәгазь, картон кисәкләре; кәрт. *Закир өстәлдә ята торган карта колодасын алып, хәзрәт каршысына килде.* Ф.Әмирхан

5) Шундый карталар белән төрле формада уйнала торган уен, кәрт уены. *[Суфиян] --- кышын бер-ике айга курортка китә, я булмаса, үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра ---.* Ә.Еники. *Алар бик озак карта уйнадылар. Нурми башта шактый оттырды, әмма азакка барыбер көтүчеләрне отып бетерде.* Гасырлар авазы

◊ **Карта ачу** 1) *к.* **карта салу**; 2) Ниндидер яшерен серләрне, эчке ниятне белдерү, ачып салу, сөйләп бирү. *Барысыннан да бигрәк Галимулла әтәчләнде: – Хәзер карталарны ачып сөйләргә вакыт.* К.Нәҗми. *Эшләр зурга китсә, барлык карталарны ачып салачакмын.* Г.Әпсәләмов. **Картага алу** *к.* **картага төшерү**. **Картага алыну** *к.* **картага төшерү**. **Картага куелу** Югалту куркынычы булу. *Илдә революциянең яшәве картага куелган заманда кулларыбызны баглап утырасыбыз килми.* Ш.Усманов. **Картага кую** 1) Нәрсәне дә булса зур хәвеф астына кую, тәвәккәлләү (язмышның нинди дә булса очраклылыкка бәйле булуы тур.); *Бөтен халыклар китте сугышка, җаннарын куеп эшче ирке өчен картага.* Г.Камал. **Картага төшерү** 1) Билгеле бер җир мәйданының картасын сызу, аерым бер участокны картага алу. *[Миләүшәне] җир катламнарын картага төшерә торган партиягә коллектор итеп алдылар.* М.Әмир; 2) Берәр объектны картада билгеләү, картага кертү. *Григорян Газинурның әйткәннәрен картасына төшерде дә дошманны өзлексез күзәтергә кушып китеп барды.* Г.Әпсәләмов. **Карталарны бутау** Алдан корылган катлаулы планны көтелмәгән бер эш белән җимерү, бозу. *Сабир-баба Акмал ханны кулга алуда бары бер кешенең – прокурор Камаловның гаепле икәнен белә иде. Менә тагын ул карталарны бутап ташлады.* Р.Мирхәйдәров. **Карта салу** Уен карталары белән күрәзәлек итү. *Маһикамал чегән хатыннарыннан карта салдырды.* Л.Гыйльми. **Карта сугу** Карта уйнау

**КАРТАЕЛУ** *ф. з.-сыз* Гомер узып, олы яшькә җитү. *Яшьлек үтте, инде картаелды, Яшим хәзер читтә, ышыкта.* М.Җәлил

**КАРТАЙТУ** *ф.* 1) *йөкл. к.* **картаю**

2) Организмны таушалдыру, йончыту; вакытыннан алда картаерга мәҗбүр итү. *Егетне – кыз, ирне тоз картайта.* Мәкаль. *Эш картайтмый, кайгы картайта.* Мәкаль. *Газизнең үлүе бер картайтты, хәзер монысы икенче картайта.* Г.Бәширов

3) Карт дип табу, картка санау. *Газинур «апа» дигәч, Мәйсәрә тагын да кызара төште. – Ул хәтле картайтмасаң да ярар иде, – диде ул, елмаеп.* Г.Әпсәләмов

**КАРТАЛАНУ** *ф.* Карта сыман катлы-катлы булып тору, кырык картага охшап катлану (тән, тире тур.)

**Карталана бару** Акрынлап карталану

**Карталана төшү** Тагын бераз карталану

**Карталанып бетү** Бик нык, тәмам карталану

**КА́РТАЛЫ** *и.* Карталар белән уйнала торган уен, кәртле. *[Алафузовның] йөзе көләч, күзләре шундый ягымлы: аның, эшчеләр әйткәнчә, рәхимсез булуына, эчеп, карталы уйнап йөрүенә ышанасы килми.* Г.Гобәй

**КАРТАМАН** *и. иск.* Кесә карагы. *Картаман картайса ялганчы булыр.* Мәкаль

**КА́РТАЧЫ** *и. сөйл.* Карта уйнаучы, карта уйнау белән мавыгучы; картёжник. *Исерек картачылар компаниясе бер минут гаҗәпсенеп карадылар да, ава-түнә, Булатовны сырып алдылар.* Г.Ибраһимов

**КАРТАЮ** *ф.* 1) Олыгаю, олы яшькә җитү. *Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул: Картаеп каткач буыннар эш белү уңгайсыз ул!* Г.Тукай. *9 оныгы, 2 оныкчыгы бар Зәйнәпбикә әбинең. «Пенсиям әйбәт. Яшәве бик рәхәт хәзер, тик без генә картайдык», – ди ул.* Ватаным Татарстан

2) Яшьлек сыйфатларын югалта бару, картлык төсмере күренә башлау. *Яхшыга төшкән [килен] ярпайган, яманга төшкән – картайган.* Мәкаль. *Маликның атасы Биктаһир бик картайды.* И.Гази

3) *күч.* Искерү; муртаю, какшау. *Әүвәл заманнарда көне буе ачык, аның аркылы өзлексез йөрелеп торыла торган бу картайган капка хәзер эчке яктан бикләнеп куелган иде.* Ф.Әмирхан

4) *күч.* Өлгерү вакыты узудан кату, агачлану, сутсызлану (үлән сабаклары, сусыл җимешләр һ.б.ш. тур.). *Җир өемнәре картаеп катудан көпшәләнеп беткән кәҗә сакаллары белән капланган.* М.Хәсәнов. *Картайган кыярлар алар, орлык кыярлары.* М.Әмир

5) *күч.* Башаклары кибү, бөртекләре җиргә коела башлау (ашлыклар тур.). *Дүрт-биш көн эчендә урып та, җыеп та өлгерергә исәп. Арышка картаерга ирек куймаска кирәк.* Х.Госман

6) *күч.* Бик нык кибеп китү, үзлелеген югалту, кату (камыр, измә тур.). *Хатын-кызлар --- берсе икенчесен ашыктыра-ашыктыра кайнашырга тотыналар: – Токмачыңның камыры картая.* Ф.Хөсни

7) *күч.* Үз чоры, үз вакыты узу; әһәмияте югалу. *Бөек кешеләр бервакытта да картаймыйлар.* А.Шамов

8) *күч.* Сазау, карт кыз яки карт егет булып калу. *Кыз азрак картайса да Сайлый белде кияүне.* Ш.Камал

◊ **Картайган көндә** *к.* **картаймыш көндә**. *Шулай итеп безнең Гыйльменисабыз картайган көнендә тагын ялгыз калды.* Ф.Хөсни. **Картаймыш көндә** Картайгач; картайган вакытта, картлык чорында. *Төпчегең – картаймыш көнеңдә ярдәмчең.* Мәкаль. *[Нәзиф Хисмәт картка:] Э-э --- картаймыш көндә вөҗдан бик интектермиме?* Ә.Баян

**Картаеп бетү** Бик нык, тәмам картаю. *Бар иде безнең авылда картаеп беткән әби, Берүзе – ялгыз башы, йортында юк бер адәми.* Г.Тукай. *Фирәвия һич уйламаганда гына Биюшеннән көнләшеп куйды. --- Кибеткә еш керә*

*башлагансың. Ахры, кибетчене күзләвең инде, – диде ул. – Картаеп беткән башың белән кеше көлдереп йөр тагын ---.* М.Хуҗин

**Картаеп җитү** Картаюның соңгы дәрәҗәсенә, соңгы чигенә кадәр барып ирешү

**Картаеп китү** Соңгы араларда картаю; кинәт картаю. *[Галләм карт] тагын да картаеп киткән, тирән җыерчыкларга чорналган йөз-чырае белән үзенең әҗәленә – Ходай Тәгалә ихтыяры булып өстәлендә яткан кәгазь кисәгенә карап торды.* Г.Гыйльманов

**Картая бару** Акрынлап картаю; торган саен тагын да ныграк картаю. *Минем башымда һаман бер уй. Атай картаеп бара. Гомере шул тирес башында үтә.* Г.Ибраһимов

**Картая башлау** Акрынлап картаюга табан бару

**Картая төшү** Берникадәр картаю

**КАРТВЕЛ** *и.* Грузиннарның үзатамасы. *Картвел телләре*

**КАРТЁЖНИК** *и. рус сөйл.* 1) Карта уйнарга яратучы кеше. *Шул кулларга карап, аның [Фәхретдиновның] ата картёжник икәнен чамалап була иде.* Р.Мирхәйдәров

2) Карта уенында алдан хәрәмләшеп акча эшләүче; шулер

**КАРТЕЛЬ** *и. фр.* Монополияләрнең бер формасы – сәнәгатьнең бер үк тармагында эш йөртүче эре предприятиеләр берләшмәсе. *Рәшидов үлгән елда кылган гамәле аңа карата бар шикләнүләрне алып ата, Шубарин картеле мәнфәгатьләре орбитасына эләккән барлык кешеләрне тикшергән кебек, аны да энә күзеннән үткәрү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде.* Р.Мирхәйдәров

**КА́РТЕР** *и. ингл.* Двигательнең аскы өлешен тузаннан, пычрактан саклау, май салу өчен хезмәт итә торган һәм двигательнең эшли торган механизмнары урнашкан металл тартма. *Богатырев, үлчәүле савыт белән алып килеп, картерга май салды.* Ф.Хөсни

**КАРТЕЧЬ** *и. пол.* 1) Якын арага ату өчен, түгәрәк пулялар белән тутырылган артиллерия снаряды

2) Эре ядрә (ау мылтыгы өчен)

**КАРТИ́НА** *и. рус* 1) Киндер, кәгазь яки тактага буяу белән ясалган рәсем сәнгате әсәре. *Сәлимнең күзләре зур тарихи фаҗигане чагылдырган картинага төште.* Г.Гобәй. *Кем соң әле ул Пилат дигәне? Рәсем белән шөгыльләнгән чакларында ниндидер бер картинада күргән иде бугай ул аны.* Ә.Дусайлы

2) Драма әсәрләрендә акт бүлекчәсе. *Өченче актның беренче картинасы Галимәнең трагедиясен тирәнәйтә.* М.Җәлил

3) *сөйл. к.* **кинофильм**. *Бергә картина карап утырудан нәрсә булган, ди! Бардык, карадык.* Ш.Камал. *Төшке ашны ашаганда, Рәшитнең абыйсы: – Әнием, бүген кинода «Полк улы» дигән картина күрсәтелә икән, – диде.* А.Әхмәт

4) *гади с. к.* **картинка** (*2 мәгъ.*). *Кыз, бизәнгәч, нәкъ картина инде*

5) Конкрет образларда күрергә һәм күз алдына китерергә мөмкин булган нәрсә, күренеш, манзара; панорама. *Айның күтәрелүе белән кыскара барган агач күләгәләре Хәятнең күңелендә хыялый картина тудырдылар.* Ф.Әмирхан. *Әнә кояш та күренеп китте. Шәһәр берничә генә минутка төсле кинога охшап калды. Аннары бу картина соры төскә кереп тә өлгермәде, тагын гөлт итте.* Ә.Дусайлы

6) Тормыш күренешләре, көндәлек вакыйгалар һәм хәлләр. *Сәрвәр хатны укып чыкканнан соң, караватбашына сөялеп уйга калды. Аның күз алдыннан бик күп картиналар тезелеп үтте.* Ф.Хөсни. *Күренә ки, шагыйрь вакыйгага барачак фонны конкретлаштыра, әкият-легендадагы «саф» фантастик картина урынына көндәлек, табигый, реалистик картина тудырырга омтыла.* И.Нуруллин

7) *күч.* Гомуми бер хәл, ситуация; берәр нәрсәнең гомуми торышы. *Мин уйлыйм, иптәшләр, безнең күз алдыбызда ачылган күңелсез картина безне һич тә куркытмаска тиеш.* Ш.Камал

**КА́РТИНГ** *и. ингл. спорт* 1) Карт автомобильләрендә ярышу

2) *махс.* Шундый ярышлар үтә торган мәйданчык

**КАРТИ́НКА** *и. рус сөйл.* 1) Китаптагы рәсем, иллюстрация. – *Нәрсә картинка карап утырасың? Төя тизрәк! – дип кычкырган тавышка Хәлим арбадан очып төште дә баскыч алдында өелеп торган китапларны җәлт-җәлт арбага сала башлады.* И.Гази

2) *күч.* Матурлыгы, нәфислеге, төз буй-сыны белән сокландыра торган кем яки нәрсә. *Минем кара айгыр ничек уйнап тора иде. Картинка иде, үзең беләсең.* С.Рафиков

◊ **Картинкадагы кебек** Бик матур, көяз, купшы. *Өйнең уң ягында шундый ук калай башлы яңа капка ачып кергәндә, биге түй кыңгыравы кебек уйнап кала. Бөтен нәрсә үз урынында, бөтен нәрсә картинкадагы кебек.* Ф.Хөсни

**КАРТ-КОРЫ** *җый. и.* Картлар һәм карчыклар, олыгайган, карт кешеләр. *Авыл тагын карт-корылар, куштаннар, ярлы халыкның җирен биләүче байгуралар кулында калды.* К.Тинчурин. *Ташаяктан ерак түгел чүплек. Казыналар чүплек башында Картқорылар белән бала-чага: Әллә хәзинәләр бар шунда?* М.Шабаев

**КАРТЛА́РЧА** *рәв.* Карт кешегә хас булганча; картларга охшатып. *Хәер, соңрак, 1944 нче елның җәендә эти сугыштан гарипләнеп кайтып, зурәни яңадан үз өенә күчеп киткәч, аның картларча гел кимчелек табып «мытырдап» йөрүләрен ничектер сагынып, юксынырга да тотындым әле.* Ш.Алпар

**КАРТЛА́Ч** *и. сөйл.* **1.** 1) Олы яшьтәге кешегә карата шаярып, үз итеп яки шелтәләп әйтелә торган сүз. *Элеккегә караганда да ныграк аксый башлады [карт]. – Тизрәк бул, кемгә әйтәм, картлач!* И.Салахов. *Иген-иген дип, бөтен тазалыгыннан, акылыннан яза бит картлач...* Г.Гыйльманов

2) Гомумән ир кешегә дусларча эндәшү сүзе

**2.** *с. мәгъ.* Картайган, олы яшьтәге. *Күптән инде синең азаныңны Тыңлый иде картлач бабайлар.* М.Касыймов

**КАРТЛЫК** *и.* 1) Карт булу. *[Профессор] карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык белән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» – диде.* Ә.Еники

2) Гомернең ахыргы чоры, соңгы дәвере. *Яшьлегендә яшьнәмәгән, картлыгында кала алса да, танылмас.* Мәкаль

◊ **Картлык көне** Гомернең соңгы дәвере, соңгы чоры; картаймыш көн. *Картлык көнебездә бер-беребезне юатып яшәр идек тә соң...* Г.Гыйльманов. *Ә үзенә картлык көнендә кеше почмакларында яшәргә кала.* Г.Зәйнуллина

**КАРТОГРА́ММА** *и. гр. махс.* Билгеле бер территория буенча нинди дә булса күренешкә караган аерым статистик мәгълүмат график юл (штрихлау, буяу һ.б.ш.) белән күрсәтелгән карта. *Алик кайсы басуга күпме һәм нинди ашлама кертү турында туфрак картограммалары төзетте.* Казан утлары

**КАРТО́ГРАФ** *и. гр.* Картография, географик карталар буенча белгеч. *Картограф өлгермәгән аны Карта битләренә язарга; Ләкин ул [шәһәр] бар.* С.Урайский

**КАРТОГРА́ФИК** *с.* 1) Картографиягә караган, шуңа бәйләнешле; картография күрсәткән яки картография өчен билгеләнгән. *Картографик экспедиция*

2) Географик карталар эшләп чыгару белән шөгыльләнә торган. *Картографик фабрика*

**КАРТОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Географик карталар төзү турындагы фән һәм карта төзү эше үзе

**КАРТОН** *и. ит.* **1.** Калын каты кәгазь, катыргы. *Картоннан ясалган тартма*

**2.** *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Картон уенчык*

**КАРТОТЕ́КА** *и. гр.* Белешмә характерында яки санлы һ.б.ш. мәгълүмат язылган карточкаларның системалаштырылган җыелмасы. *Сүз авторына, әсәр исеменә, композиторга төзелгән картотекалар, алфавит һәм система буенча оештырылган каталоглар, электрон каталог бүлекнең китап фондын һәм аудиоматериаллар фондын тулырак кулланырга мөмкинлек бирәләр.* Ә.Солтанова

2) Шул карточкаларны саклау өчен билгеләнгән махсус тартмалар

**КА́РТОЧКА** *и. рус* 1) Берәр мәгълүмат язу һәм саклау өчен файдаланыла торган кечкенә форматлы кәгазь яки катыргы кисәге. *Бередә татар халык иҗатыннан һәм язма әдәбияттан үрнәрча, хәтта йөзләрчә мисаллар китереп булыр иде. Аларга караган аерым мисалларның бихисап чыганаклары шушы юллар авторы тарафыннан дистәләрчә еллар дәвамында берничә мең карточкага теркәлеп барган.* Ф.Урманче

2) Кешенең исем-фамилиясе һ.б.ш. язылган яки аның билгеле бер әйбер алырга хокукы булуын белдергән талоннардан торган кәгазь кисәге, бланк. *Рәхимә абыстай карточканы акрын гына оештырып укыды. Анда русча: «Гали Мөхәммәт углы Арсланов. Москва университеты студенты» дигән сүзләр язылган иде.* Ф.Әмирхан

3) Конвертка салмыйча гына җибәрелә торган, кыска гына хат язу өчен урыны булган махсус почта бланкы

4) *сөйл.* Кәгазьгә төшерелгән фотосурәт, фотография. *Ул [Шәмсетдин] тагы карточканы карады: «И, бик искитәрлек инде. Безнең татарларда мондый кызлар беткәндер инде».* Г.Исхакый. *Мәхүп әби шул уйлар белән карточканы кат-кат әйләндерде.* А.Алиш

5) Банк тарафыннан бирелә торган түләү һәм исәп-хисап операцияләре башкару өчен билгеләнгән исемле пластик карта. *[Ф.Сибагатуллин:] Депутат буларак, миңа дәүләт ай саен 220 мең сум түли. Мин аларны банкта да, карточкада да йөртмим.* Ватаным Татарстан

6) *спорт* Кайбер командалы спорт төрләрендә уенчыны кисәтү билгесе. *Башта тик торганнан гына Рональду командасын пенальти белән сынады, аннары әлеге команда уенчысы Пепега кызыл карточка күрсәтте.* Безнең спорт

**КАРТУЗ** *и. голл.* Козырёклы ирләр баш киеме – фуражканың бер төре. *Йорт хуҗасы Степан – билен бөргән кара бишмәт, зур кара картуз киеп йөри торган таза гына карт – һәр җомганы йорттагы малайларга өр-яңа икешәр тиенлекләр өләшә.* Ә.Фәйзи. *Замандашлары тагын Габдулланың еш кына рус картузы, озын киндер күлмәк, киндер чалбар һәм аягына чабата киеп чыкканлыгы һәм хәтта шул кыяфәттә бакчаларга барганлыгы турында язалар.* И.Нуруллин. *Ишек төбендә укалы картуз кигән швейцар (киемнәр музейга куелган) Закирга сәлам биреп, тимер баскычтан өченче катка күтәреләбез.* Н.Гыймадиева

**КАРТСЫНУ** *ф.* Карт дип санау, карт дип кабул итү. *Салих әүвәл бас (калын тавыш) белән сөйләгән иде дә, Хәят аны картсынгач, баритон (ачык вә урта калынлыктагы тавыш) белән сөйли башлады.* Ф.Әмирхан

**Картсынып тору** Бераз вакыт картсыну

**Картсына төшү** Берникадәр картсыну

**КАРТЫ́-ЯШЕ** *җый. и.* Картлар һәм яшьләр, төрле яшьтәге кешеләр. *Бер язда сабан сөрүчеләр арада ак торна күреп, авылга кайтып әйтәләр. Бу могҗизаны күрергә карты-яше шунда ашыга.* Н.Әхмәдиев. *Авылның карты-яше даими рәвештә татар матбугатын шуннан алып укый ала иде.* Л.Хәмидуллин. *Апрель керү белән халкыбызның карты-яше үзен әллә нинди бер бурыч алдында кебек хис итә башлый.* Р.Мөхәммәдиев

**КАРУ** *и.* 1) Каршылык, тискәрелек; үчегүчәнлек. *Каруга кару, карт алашага ябу.* Мәкаль

2) *диал.* Авыр, күңелсез, кыен хәл. *Сөйгәнемне ятлар алды, Шуңа төштем мин каруга.* Җыр

◊ **Кару кайтару** Каршы дәшү, ризасызлыкны белдерү. *[Бәдигыльҗамал:] Анда синең эшең булмасын. Миңа кару кайтарма.* Г.Камал; 2) *к.* **каруын алу**. *Монысы былтыргы җәфаларның каруын кайтарырга булыр.* Р.Төхфәтуллин. **Кару саклау** Үч саклау. *Әйтә дә кайта ул безнең әни. Кару саклап йөрми.* Б.Камалов. **Каруын алу** Бер урында отылу исәбенә икенче урында, икенче очракта оту, уңышка ирешү. *Эшнең һәр ягы күңелсез булуның каруын сабактан ала идек.* М.Гафури

**КАРУЛАНУ** *ф. к.* **карулашу**. *Әмма хәзрәт ничек кенә каруланмасын,*

*сыерларны аның үзенә барып алырга туры килде.* С.Рафиков

**Карулана бару** *к.* **карулаша бару**

**Карулана башлау** *к.* **карулаша башлау**

**Карулана төшү** *к.* **карулаша төшү**

**Каруланып тору** *к.* **карулашып тору**

**КАРУЛА́У** *ф.* Киреләнү, карышу; тыңламау; баш бирмәү

**Карулап алу** Азга, кыска гына вакытта карулау

**Карулап тору** Хәзер карулау; гел яки әледән-әле карулау

**Карулый бару** Торган саен карулау

**Карулый башлау** Карауларга тотыну. *Давыт машинаның серләрен төшенеп алды. Комбайны карулый башласа да хәзер көйгә китерә.* Р.Төхфәтуллин

**Карулый төшү** Тагын да карулау

**КАРУЛАШУ** *ф.* 1) Киреләнү, карышу; каршы килү, каршы тору. *Карулашты Әүхәди, Капчык бераз шиңгәч кенә Татулашты Әүхәди.* Ә.Фәйзи

2) Каршы әйтү, каршы җавап кайтару, телләшү. *[Малайлар:] Сыер очамыни? Әһә! Ят әле, без синең аркага бер кайнар пәрмәчне салып алыйк! – Мин бит сыерчык дип әйтәсең дип торам! – дип карулаша тегe.* Ә.Фәйзи

**Карулаша бару** Торган саен ныграк карулашу

**Карулаша башлау** Карулашырга тотыну. *Мин берәр төрле карулаша башласам, тыңламасам, хәзер күз алдыма Алмачуарны китереп куялар.* Г.Ибраһимов

**Карулаша төшү** Тагын да карулашу

**Карулашып тору** Гел, һәрвакыт карулашу

**КАРУЛЫ** *с.* 1) Кире кайтарыла, хакы алына торган. *Икмәк-тоз карулы.* Мәкаль

2) Кара эчле, үчле, ачу саклаучан. *Карулының тозагы корулы.* Мәкаль

**КАРУЛЫК** *и.* Каршылык, кискен ризасызлык. *Кара эчле залимнәр Сине, ярлы, тунады, Карулык кылсаң бераз, Бәйләп алып кыйнады.* Н.Арсланов. *[Карамыш] Безнең халык дини яктан болгар белән тәңгәл килә. Аллаһка инануда артка калмый, алгарак та уза булыр әле. Бәс, шулай икән, монда карулык юк.* Т.Нәбиуллин

**КАРУН** *и. гар.* **1.** Үтә саран һәм вакчыл табигатьле кеше. *– Ну, саран да соң син, малай! – диде Ислам, егетне оялтып. – Карун дип юкка гына әйтмиләр икән сиңа...* Н.Фәттах. *Балыкчы Шәйхулла – үзенә генә йолкырга өйрәнгән карун.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* Саран һәм вакчыл табигатьле. *[Хөбәйбулла:] Сәләхи абзый бик карун кеше ул, ипиен дә иләтмичә генә салдыра, ә үзенең ындырында сукмаган эскерте тора...* Ә.Еники. *[Егет] --- кызының кулыннан алды да китеп барды. – Бигрәк карун карт икән. Ике алмадан нигезе корыр дип белдеме, – дигән сүзләре ишетелеп калды.* Ф.Латыйфи

**КАРУНЛАНУ** *ф.* Үтә нык саранлану, вакчыллану. *Карунланма, Нәбиуллин, монда ярминкә дә, базар да түгел. Сатулашма!* С.Рафиков. *[Тимерҗан:] Әбелсаттар убырның күзе кызар инде. «Юк бит, җиңги, бер умач ясарлык арыш оны да юк», – дип карунланып сөйләнә-сөйләнә дә ахырында барыбер дә инәкәйгә он чыгарып бирә.* В.Имамов. *Кеше дигәнең бу дөньяга мәңгегә килгәндәй карунланып, комарланып мал җыя, ашкына...* Р.Мулланурова

**Карунлана бару** Торган саен карунлану

**Карунланып бетү** Бик нык карунлану

**Карунланып килү** Соңгы арада карунлану

**Карунланып китү** Кинәт карунлану

**Карунланып тору** Әле, хәзерге вакытта карунлану; гел, һәрвакыт карунлану. *Спорт заллары, мунчалар булдыруга карунланып торырга ярамый.* Т.Галиуллин

**КАРУНЛЫК** *и.* Бик нык саранлык. *[Камил:] Син, сеңлем, биргәндә ал. Мин алай юмартлардан түгел. Хатын мине гел карунлыкта гаепли.* Ф.Яруллин. *Кешеләрнең түбән хисләре һәм омтылышлары – комсызлык, карунлык, байлыкка табыну, караклык – алгы планга чыга башлый.* К.Гыйззәтов. *Карунлык әсирлегенә төшә күрмә син ялгыш: Тынычлык белән бәхетне китермәс сиңа язмыш.* Ф.Тарханова

**КАРУРМАН** *и.* 1) Зур агачлардан торган бик куе урман. *Алдыгызда биек таулар, Карурманнар булырлар ---.* Н.Баян. *Карурманда юлны табар өчен, Бер уч нуры җитә кояшның.* Ф.Яруллин. *Карурманнар уртасында, черек наратка сөялеп, мин гомер турында уйлыйм... Уйларым инде сөялле.* Р.Харис

2) *күч.* Артык катлаулы, буталчык эш; билгесез, шомлы әйбер. *Татар әдәбияты өчен татар тарихы ул беркем аягы басмаган иксез-чиксез карурман кебек.* Н.Фәттах. *Карурманнар үтеп чыккан халкым, Нидер көтеп сыңар кош юлыннан.* Р.Аймәт

**КАРУСЕЛЬ** *и. ит.* **1.** 1) Үзәк багана тирәсендә әйләнеп торган баскычлардан яки ат, дөя һ.б.ш. сыны рәвешендә ясалган утыргычларга утырып әйләнү өчен махсус эшләнгән корылма, аттракцион. *Бик күп урында кибетчекләр ачылган, сәүдә гөрли, базар кайнап тора, мәйдан уртасында карусель әйләнә.* Г.Бәширов. *Гасыйм абый каруселҗгә утырып әйләнер өчен акча бирде.* Г.-Х.Садри. *Ни генә юк анда [паркта]. Атынганда, болытларга менеп җитәрлек таганнар дисеңме, «үлем элмәге» ясаучы самолёт дисеңме, ракета тизлегендә әйләнүче карусель дисеңме ---.* Ф.Яруллин

2) *тех.* Бер үзәк тирәсендә әйләнә торган мәйданчыклардан торган корылмалар; авыл хуҗалыгында: механик саву җайланмасы. *Фермага карусель урнаштыру. Карусель ясау*

**2.** *с. мәгъ.* Шуңа охшаган, шуның сыман. *Карусель станоклар*

**КАРУСЕЛЬЧЕ** *и.* Карусель (*1 мәгъ.*) әйләндерүче, каруселҗне эшләтүче кеше. *Иртәгесен ул [Фәйзук] тагын кичәге урынга – карусель янына йөгерде. Карусельчеләр аны әллә кайчангы танышлары күк итеп, көлеп каршыладылар.* Ф.Хөсни

**КАРУСЫЗ** *с.* **1.** 1) Күндәм, карышмый торган һәм һәрвакыт әзер булган. *Тора-бара сабый аның җилкәсеннән-кулыннан төшмәү ягын карый башлый. Алданган ир-атка бөтен күңел җылысын карусыз сабыйга юнәлдерүдән гайре ни кала?* К.Миңлебаев

2) Тел-тешсез, көчсез, ярдәмсез. *Күрсәткән бу хатын безгә үги ананың ни икәнен. Бигрәк тә миңа, карусыз сабыйга.* Э.Касыймов

**2.** *рәв. мәгъ.* Бернинди каршылык күрсәтмичә. *Генерал карусыз рәвештә Фәниснең таләбен үтәп, Генераль штаб белән элемтәгә керде ---.* Ш.Алпар. *Бәдри җәен-көзен колхозда эшли, карусыз гына йөри, әмма колхозда эш бетүгә, беркем дә белми торган әллә кай якларга чыгып китә ---.* М.Мәһдиев

**КАРУСЫЗЛЫК** *и.* Күндәмлек, юашлык. --- *тыңлаучанлык һәм уйфикерсезлекне, карусызлыкны нәкъ менә әхлак таләпләре аша аера белергә кирәк.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Әйе, Сандраның гүзәллеге, аның карусызлыгы, Сафуанның үзенең исә артык хислелеге аны кинәт гыйшык дәрьясына алып ташлады – бусы бәхәссез.* Ә.Сәлах. *Парламентның карусызлыгы бервакыт аның төп кимчелегенә дә әйләнергә мөмкин, чөнки бүген ул синең сүзеңне үти, ә иртәгә яңа хуҗаның кушканына берсүзсез буйсына һәм үзеңә каршы корал итеп тә файдаланыла.* Ватаным Татарстан

**КА́РХ-КЫРХ** *иярт.* Йөткерү тавышын белдерә. *[Тукай] Минут саен әллә ничә мәртәбә карх-кырх йөткерә, вакыты-вакыты белән томлыгып, әллә никадәр газапланып тора иде.* К.Бәкер

**КА́РЦЕР** *и. лат.* Нәрсә дә булса өчен җәза итеп, тоткыннарны вакытлыча ялгыз гына ябып тоту өчен махсус камера. *Төрмәдә чакта да камерадашын суя язган Тутыкны карцерга утырту Морат өлешенә туры килде.* Н.Әхмәдиев. *Колунның җәзалау бүлмәсендә сәгатьтән артык аның «эшкәртүен» үтеп, тәмам һушын җуеп егылган Кави Нәҗмине карцерга өстерәп алып кереп ыргыталар.* З.Зәйнуллин. *Канга баткан немец офицерын медпунктка озаталар, ә татар егетен карцерга ябып өч көн тотканнан соң, шәһәр читенә алып чыгалар да, баганага бәйләп, өстенә керосин сибеп ут төртәләр.* М.Кәбиров

**КА́Р ЧӘЧӘГЕ** *и. бот. к.* **умырзая**. *Карагыз әле: нинди матур күлмәге! Башында – кар чәчәге.* К.Закирова. *Карлар ачыла башлауга, җир йөзен матурларга ашыккан бу чәчкәне юкка гына кар чәчәге дип атамаганнардыр.* Сөембикә

**КАРЧЫГА** *и. зоол.* 1) Карчыга кошлар семьялыгыннан урта зурлыктагы, кәкре томшыклы һәм озын тырнаклы ерткыч кош. *Әбелхарис гыйльме симия куәте белән бер карчыга иҗат кыйлып, кызның кулына бирде ---.* К.Насыйри. *Карчыгалар кагына, кунган җирен сагына; Чит илдә дә мал табыла, йөрәккә кан савыла.* Г.Тукай. *Көндезге ерткыч кошларга бөркетләр, грифлар, карчыгалар, лачынсыманнар һ.б. керә.* Биология

2) *күч.* Бик кыю, үткен, җитез кеше турында. *Егет кенә түгел, карчыга ул безнең кияү.* М.Фәйзи

◊ **Карчыга борын** Очы аскарак бөгелеп торган борын. *Төз, зифа буй. Матур, килешле гәүдә. Чем-кара, озын, калын толымнар тузгып җилкәгә төшкән. Калын кыйгач кара кашлар. Карчыга борын.* И.Салахов. *Карчыга борынлы, яңак сөякләре калкулы йөзле, кырма сакаллы Садыйк шулай күп сөйләнә иде.* А.Алиш. **Карчыга булып ташлану** 1) Бик җитез һөҗүм итү; 2) Бик усал кылану, бик каты һөҗүм итү. *Кайсыдыр районның мебель комбинатыннан килгән вәкил директор өстенә карчыга булып кына ташланмый иде.* М.Хәсәнов. **Карчыгадан калган тавык шикелле** Бик өтек, сәләмә. *Бакчаларның күбесен бомба, снаряд, мина харап итеп бетергән. Карчыгадан калган тавык шикелле йолкынып, яраланып беткән алмагачларны кызганып, Гаяз бакча эчендә бик озак йөрде.* И.Гази. **Карчыга кебек** Бик җитез, үткен, батыр, чая. *Вәдүт дускай! Яшь карчыга кебек идең бит син сугыш кырында.* Ш.Маннур. *Үзе янына карчыга кебек очып килеп җиткән кондукторга калайланган күзен әйләндереп карады ---.* Ватаным Татарстан

**КАРЧЫГА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан вак кына сары чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы:* **ястребинка**. *Апомиктик рәвештә ябык орлыклылардан ике өлешле (чөгендер, мамык куагы, җитен, карчыга үләне, казаяклар, тузганаклар), шулай ук бер өлеше үсемлекләр (арпа, бодай, йонча һ.б.) үрчи.* Фән һәм тел

**КАРЧЫК** *и.* 1) Олы яшькә җиткән, картайган хатын-кыз. *Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып ---.* Г.Тукай. *Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле, һәм Акбикә дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә авыл халкы карчыкны күптән инде Акъәби дип кенә йөртәләр.* Ә.Еники. *Карчык димәссең! 97 яшьлек американ карчыгын хастаханәгә эшкә алганнар.* Ватаным Татарстан

2) Өлкән яшьтәге хатын-кызның исеменә өстәп әйтелә торган сүз. *Врач егет өстәл тартмасыннан бер кап дару алып, Гөлбәдрән карчыкка сузды, аннары җәһәт кенә су салып бирде.* Г.Гыйльманов. *Габдулла Саматовның фронттан сау кайтуына әнкәсе Нәгыймә карчык һәм туганнары бик шатландылар.* Ш.Камал. *Хәтимә карчык үзе Маяковский урамындагы бер бүлмәле фатирында гомер кичерә.* Ватаным Татарстан

3) Өлкән яшьтәге ир кешенең хатыны; өлкән яшьтәге ирләрнең үз хатыннарына мөрәҗәгать итү һәм аларны атау сүзе. *Бабай карчыгына әйтә: – Кая, карчык, су бир әле, сусыным басылмады, – ди.* Әкият. *Карт Зөфәрләрдән ерак түгел, бер йортның ярым подвалында карчыгы белән генә тора.* Ә.Еники. *Гыйльметдин карт бу хакта карчыгы Гөлбикә белән сөйләшергә булды.* Ф.Яруллин

**КАРЧЫК-КОРЧЫК** *җый. и.* Карчыклар. *Делегация булып Фәгыйлә апа белән Әминә машина эченә мине чакырырга кергәннәр: – Зәки әфәнде! Безнең карчык-корчыклар, хатын-кызлар сезне чакыралар.* З.Зәйнуллин. *Карт-коры, карчык-корчык үзара җыелалар да, тик шундый юк-бар сүзләр, куркынычлар сөйләшеп күз яше түгәләр, дога кылалар ---.* Р.Гайфуллина. *Сабан туена таякка таянып килгән корткаларның, йомшак күңелле карчык-корчыкларның күзләреннән яшь чыгарып, сокланып нидер укынырга мәҗбүр итеп,*

*моңлы, сагышлы татар көйләре агыла.* Ф.Латыйпов

**КАРЧЫК-КОРЫ** *җый. и. к.* **карчык-корчык**. *Җыела башлады хатын-кыз, яшь-җилбәзәк, карчык-коры.* Г.Бәширов. *Зәйтуганны әйләндереп алган тау итәкләрендә җир җиләкләре пешкән, әрәмәләрдә карлыган, бөрлегән өлгереп килә. Карчык-коры, бала-чага шунда җыелып ята.* Ф.Бәйрәмова

**КАРЧЫКЛА́РЧА** *рәв.* Карчык рәвешенә китереп, карчыкларга охшатып, карчыкларга хас булганча. *Карчык кешенең карчыкларча булыр инде аның.* Г.Камал. *Патый әби, өстен чишенеп, карчыкларча вак һәм йомшак кына басып, түргә узды.* А.Шамов. *Күптән зарыгып көткән хыялымның кул белән үрелеп тотар хәлгә җитеп якынаюы күңелгә шом сала. «Хәерлегә генә булса иде», – дип куям карчыкларча.* М.Юныс

**КАРШЫ** I *с.* **1.** 1) Кем яки нәрсәнең күз алдындагы; билгеле бер әйбернең алгы ягына капма-каршы яктагы. *Каршы йорт тәрәзәсендә Күрдем кызның гүзәлен. Йөрәгемдә ут кабынды, Өзгәләнә үзәгем. Өзгәләнә үзәгем...* Җыр. *Каршы тау шул сүз, шул тавыш белән җавап кайтара.* Г.Ибраһимов. *Каршы як стенадан кинәт гигант күз чекерәйде. Убырмы әллә?* М.Юныс

2) Сөйләүче яки сөйләүченең игътибарында торган объект белән көрәшә торган, аңа дошман булган. *Каршы як безнең максатны белмәскә тиеш ахырына чаклы, ә үзебезнекеләр бөтенесен белеп эш итәргә тиешләр.* М.Миначев

3) Кире булган, тискәре характерлы, холыксыз. *Каршы кеше уенны бозар.* Мәкаль

4) Билгеле бер нәрсәне инкяр итә, шуны теләмәүне белдерә торган. *Кем нәрсә генә кычкырмасын, Татарстанның сайлаучы халкының 68 % ы Ельцинга каршы тавыш бирде*... З.Зәйнуллин. *Вәсвирахман үзенең якын дусты белән авыл уртасында зур тавыш куптарып, «Мөбарәк Совет властена каршы сүз әйтте» дип, ялган хәбәр тарата.* Кызыл таң

5) *диал.* Ярырга, эшкәртергә кыен булган. *Карама агачы – каршы агач.* Мәкаль

**2.** *хәб. функ.* 1) Нинди дә булса карарга, хөкемгә, күренешкә, теләккә каршылыкны белдерә. *Очрашырга, сөйләшергә мин каршы түгел.* Ә.Еники. --- *«Син нәрсә, совет властена каршымы?» Шуннан бетте-китте, бөтенебез бертавыштан: «Юк-юк, тәүбә-тоба, каршы түгел», – дия торган идек.* М.Миначев

2) Фикер алышу вакытында яисә җыелышта һ.б.ш. нинди дә булса фикер, тәкъдим яклы булмауны, аны хупламауны белдерә; *киресе:* **яклы**. *– Димәк, [тәкъдимгә] каршы кеше юк? – диде Һидият. – Ул чагында тавышка куеп та тормыйм, Мостафа, син үзең дә каршы түгел бит?* Ш.Камал

**3.** *рәв. мәгъ.* Кире җавап биреп, җавап кайтарып. *Яңадан каршы әйтергә һичкемнең батырлыгы җитмәде.* Г.Ибраһимов. *Мөнәвәрә каршы бер сүз дә әйтмәде.* З.Зәйнуллин

**4.** *и. мәгъ.* Күз алдындагы урын; алдагы як, алдагы юнәлеш. *Без авылга карап бер җир буе да бармадык, каршыдан абзый килеп чыкты.* М.Гафури. *Кычкырма, күке, каршымда, кычкыр агач башында* ---. Г.Тукай. *Шул вакытларда каршыда көчле куллы, нык сөякле ирнең – атаның булмавы һәрвакыт үзен сиздерә.* М.Мәһдиев

**5. каршында** (**каршысында**) *бәйл. мәгъ.* 1) Кемгә, нәрсәгә булса да билгеле бер (чагыштырулы, каршылыклы) мөнәсәбәттә булуны белдерә. *Бахыр каршысында батыр, батыр каршысында үзе бахыр.* Мәкаль. *Күңелем пакь, ул дәрес искә төшкән саен, коллегам, классташым, гаиләбез дусты каршында үземне бүген дә гаепле саныйм.* Ватаным Татарстан

2) Кем дә булса карап, күреп торганда, кемнең дә булса алдында. *Патшаның түбәсе түшәмгә тия, сөенә, ят патшалар каршында мактана бу.* Әкият. *Тимери уйга калды. Аланбашлар каршында колхозның болай оятка калуы аны аеруча гарьләндерде.* Г.Бәширов

◊ **Каршы алу** 1) Килүчене каршылау, аның каршысына чыгу яки аңа игътибар юнәлтү, сәламен алу, аны сәламләү. *Газиз Йосыф бик күп гаскәр әзер кылды, Атасын каршы алырга үзе барды.* Кол Гали. --- *аш хәзер булгач, Җиһанша Гыйбадулла хәзрәтне арбага ястык өстенә генә утыртып, ат берлә алып килә. Дәүләтша агай каршы ала.* З.Һади; 2) Нинди дә булса яңа вакыйгага, берәр хәбәргә һ.б.ш. билгеле бер мөнәсәбәт күрсәтү. *Шуңа күрә электр станцасы салыну турындагы хәбәр шәһәр халкы тарафыннан зур шатлык белән каршы алына.* А.Алиш. **Каршы бару** Билгеле бер эш яки фикер белән килешмәү; аны инкяр итү; дәвамлы рәвештә актив карышу. *[Искәндәр] --- үзенең башын җуйган шикелле, вакыты-вакыты белән үзе дә аңламаган көч каршында хисенә каршы баргандай була иде.* К.Тинчурин. **Каршы килү** Килешмәү, риза булмау, карулык күрсәтү. *Бүре абзый, ашасаң ашарсың, мин һич тә каршы килә алмыйм.* Әкият. *Моңа мин һичбер каршы килмәс идем.* К.Сәйфи. *Алайса, каршы килмәсәгез, үзебез илтеп куярбыз.* Ю.Җәүдәт. **Каршы кую** 1) Билгеле бер сыйфатларны ачыклау өчен, нәрсәләрне дә булса үзара чагыштыру. *«Өч бәдбәхет» драмасында автор [Г.Камал] ике туганны – укыган Гомәр белән укымаган Мәхмүтне каршы куеп сурәтли.* Татар әдәбияты тарихы. --- *шунда ук әлеге катлаулы проблеманың икенче – гаять тә катлаулы ягы калкып чыга: автор [М.Хәбибуллин] тәңречелекне христианлыкка каршы куеп, соңгысының кайбер кимчелекләре турында киңәеп, әйтергә мөмкин, хәтта рәхәтләнеп сөйли.* Ф.Урманче; 2) Дошманлаштыру, каршы итү. *Менә сезне бүген Совет ядрәсенә каршы куеп, Яшеренмәкче була баегыз.* М.Җәлил. **Каршы тору** 1) Каршылык күрсәтү, бирешмичә көрәшү. *Комсомолка Биби мылтык төзи Синең дошманыңның күзенә. Ничек каршы торып шул күбәккә, Мылтык төзәшерсең үзеңә? Аңа [Кызыл байракка] нинди көч Каршы тора ала?* М.Җәлил. *Сигез пленар утырышның калганнарында исә сәяси проблемалар каралды: --- Ерак Көнчыгышта Америка Кушма Штатларына каршы сугыш алып баручы Япониягә күмәкләшеп каршы тору һәм башкалар.*

И.Хужин; 2) Карышу; ризасызлык белдерү. *Җыелышны кич белән ясауга Сәләхи нык каршы торды.* Ш.Камал. *Чаршау кордык, Кояш безгә Нурын чәчеп Җибәрсә дә; Каршы тордык, Кудык, безгә Яктылыктан Ни килсә дә.* Г.Тукай. *Кайвакытларда кулларын, аякларын биләүгә чолгап, аны [кешене] хәрәкәтләнмәскә мәҗбүр иттеләр... Ләкин ул моңа каршы торырга, риза түгеллеген белгертергә кодрәтле --- иде.* Ф.Әмирхан. *Их йөрәк, син нигә акылга каршы баш күтәрәсең?* М.Юныс. **Каршы төшү** Ризасызлык белдереп яки кискен рәвештә каршы килү. *Башта биш кешене, заводтагы эшләреннән аермыйча гына, яңа төзелешкә билгеләргә уйлаганнар иде. Ләкин партячейка вәкиле каршы төште: – Андый зур эшкә ун комсомолны бөтенләйгә күчерергә кирәк, – диде.* А.Алиш. **Каршы чыгу** 1) *к.* **каршы алу**. *Кухняда звонок шалтырый башлады. – Килде бугай, – дип, Сәҗидә апа ишеккә ашыкты. Аның белән бергә Ильяс та каршы чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Әлеге безнең көләч хозяйка йөзләре агарган килеш каршы чыкты.* М.Әмир. *Әнисе, онлы кулларын алъяпкычка сөртә-сөртә, аларга каршы чыкты.* Р.Вәлиев; 2) Баш күтәрү; 3) *к.* **каршы тору** (*1 мәгъ.*) *18–19 яшьлек егетләр, барлы-юклы кораллары белән, Тула аша Мәскәүгә ыргылган немец генералы Гудериан танкларына каршы чыктылар ---.* З.Зәйнуллин; 4) *к.* **каршы төшү**. --- *Галимҗан Ибраһимов хәреф алмаштыруга кискен каршы чыга.* Р.Батулла. *Анда укырга китүемә беренче булып колхоз рәисе каршы чыкты.* Г.Галиев. *Авыл халкының шактый өлеше колхоз төзүгә кискен каршы чыга.* Ф.Урманче

**КАРШЫ** II *бәйл.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса карап урнашу мөнәсәбәтен белдерә. *Аңа каршы – ярь-яшь егет, Пешеп җиткән җимеш кебек ---.* Г.Сәгыйров. *Һич югы кәтиб Хафизга тапшырырсыз, алар каршы капка гына торалар.* М.Хәбибуллин. *Кулын кояшка каршы маңгай турысына күтәреп, Зәйнәп аңа карады.* Ә.Гаффар. *Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак.* Г.Тукай

2) Билгеле бер күренешкә карата юнәлдерелгән эш яки хәрәкәтне белдерә. *Янгынга каршы көрәш инспекциясе җитәкчесе капитан Нәсих Шәрифҗанов хәрбиләрчә җитезлек белән урыныннан күтәрелде.* Ә.Моталлапов. *Пулемёт уты астында Сапёр – яшь солдат Үрли үлемгә каршы.* Ф.Кәрим. *Шушы артыш таягыма таянам да Җилгә каршы гайрәтләнеп алга барам.* Г.Ахунов. *Урманда янгын чыгу сәбәпләрен алдан ук белеп тору, аларга каршы нәтиҗәле чараларны күрү, иң беренче чиратта, ялкын телләре булып күзгә ташланмый.* М.Насыйбуллин

3) Кемгә яки нәрсәгә булса да карата берәр нинди эш, хәрәкәт эшләнүне белдерә. *Фашизмга каршы көрәшеп туфракка һәм көлгә әйләнгән ике шагыйрьгә һәм ике поэмага мәңгелек дан!* И.Юзеев. *[Исхакый:] Авыл халкы, крестьяннар арасында сәяси чыгышлар ясый, хөкүмәткә каршы агитация алып бара.* Г.Исхакый. *Безнең көннәрдә сирәк була торган хәл – положениесе ягыннан баштин-аяк аңа буйсынган гап-гади хезмәткәр профессорга каршы өр-яңа тезислар белән чыга.* К.Тимбикова

4) Берәр затны, күренешне, объектны, процессны бетерү, туктату, юк итү һ.б. максатларны белдереп килә. *Миңа каршы котырдылар, рәхимсез аттылар ташлар.* Г.Тукай. *Күтәрелдек бүген ханга каршы, Чык, явыз хан, әйдә мәйданга!* М.Җәлил. *Аңа ышанып, Илһам хан мангулларга каршы көч туплый алмый калыр.* М.Хәбибуллин. *Бу вакытта инде илдә революция казанышларына каршы көрәш зур колач җәя.* Р.Әмирхан. *Хәзер икенче чор – Татарстанның суверенитетына каршы ачыктан-ачык көрәш башланды.* Т.Галиуллин

5) Билгеле бер вакыт аралыгы җитә башлау мөнәсәбәтен белдерә. *Ялга каршы буяуларымны, этюдникларымны төяп, художниклар дачасына, – Касә-күл буена киттем.* Г.Сабитов. *Барысын алдык та кичкә каршы эткәй белән тимерлеккә киттек.* Г.Ибраһимов. *Беркөнне төнгә каршы Ильяс бабай Володяның тәрәзәсен какты.* Г.Әпсәләмов

6) Җавап бирү, җавап кайтару мөнәсәбәтен белдерә. *Тәкый абзый аңа каршы ләм-мим дәшмәде.* Г.Сабитов. *– Безгә артыгы кирәкми, – диде аңа каршы анасы.* Ә.Гаффар. *Фатих каршы хат яза ---.* Г.Исхакый. *Бу куәтләү сүзләренә каршы берничә җирдән я көлеп, я бик акыллы булган булып әйткән сүзләр дә ишетелде.* Ә.Еники

7) Берәр нәрсәгә сәбәп булуны белдерә. *Бәхетсезлегемә каршы, ул вафат булып киткән.* Н.Хисамов. *Кызганычка каршы, кешенең ул сыйфатлары яшь башлагач кына беленә, ә матурлык күзгә бәрелеп тора шул.* Г.Сәгыйров. *Бу язмаларымда, гаҗәпкә каршы, сыздым-боздымнар артык күп түгел.* Г.Сабитов. *Ярты дөньяны әйләнеп чыктым, дип мактана алмыйм, кызганычка каршы, минем әле чит илләрдә сәяхәттә йөргәнем юк, шулай да үз илебезне аркылыга-буйга иңләдем.* И.Юзеев

**КАРШЫГА** *рәв.* 1) Каршы юнәлештә, каршы якка таба. *Яшь егетләр чакырсыннар --- Кызлар чыксын каршыга.* Җыр. *Халык каршыга килгән; барчасы бергә җыелганнар...* Г.Тукай. *Машинада – чибәр егет, Төшеп, килде каршыга ---.* Г.Сәгыйров. *Минем каршыга ике баһадирыгыз килеп сыгынып киттеләр инде.* М.Хәбибуллин. *Каршыга йөгереп килүче кызны күрүдән Самат җырын өзеп, атын чыбыркылап куа башлады.* Г.Галиева

2) Алга, алдына. *Бүгенге язу каршыга яңа сораулар куйды.* А.Тимергалин

**КАРШЫДАГЫ** *с.* 1) Капма-каршы, каршы яктагы. *Мирза каршыдагы диванга килеп утырды.* Ә.Моталлапов. *Каршымдагы кыз йокыдан торды да чәч тарый.* А.Гыйләҗев. *[Муса] каршыдагы метро баскычыннан төшеп юк булды.* Ш.Маннур. *Мөхәммәт, уйга баткан килеш, каршыдагы наратлыкка карап торды.* М.Насыйбуллин

2) Берәр нәрсә турысындагы. *Каршыдагы ап-ак шомырттан Чәчәкләрен юкка өздегез ---.* Җыр. *Тәрәз каршымдагы өянкеләр Синең кебек ак шәл ябынган.* Җыр

**КАРШЫДАН** *рәв.* 1) Алдан, алгы яктан. *Безнең алда күпер астыннан Үтә торган юлдан – каршыдан – Икмәк*

*төяп йөкләр уздылар.* М.Җәлил. *Шул вакыт каршыдан асыл айгырларны иярләп менгән ике кыз, өч җегет килеп чыга.* Г.Ибраһимов. *Әнә теге биек калкулык артындагы озын борылышны күрәсеңме, әгәр каршыдан машина килеп чыкмаса, һөҗүм итәр өчен моннан да уңайлы урын булмас.* Р.Мирхәйдәров

2) Каршы килә торган, каршыга таба. *Каршыдан искән җил*

**КАРШЫДАШ** *с.* **1.** Кара-каршы якларда, берсе икенчесенә каршы, симметрик рәвештә торган. *Ә яфраклары каршыдаш булган сирень, аю баланы, ясмин, зелпе һәм бүлмә үсемлеге тамчы гөл бәбәкләрендә бөреләр дә икешәрләп, берсе каршына икенчесе, ягъни каршыдаш урнашкан.* Биология

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Берсе каршына икенчесе. *Сирень, ясмин, өрәңге, тамчылы гөл, сукыр кычыткан яфраклары сабакта берәрләп түгел, ә икешәрләп: бер яфрак икенчесенең каршында ук урнашкан. Яфракларның болай беркетелүен каршыдаш урнашу дип атыйлар.* Ботаника. *Яфраклары вак, төрле (чәнечкесыман, овал, безсыман һ.б.) формада, бәбәктә чиратлашып, каршыдаш (ягъни берсе каршында икенчесе) яки сабак тирәли таҗ рәвешендә бөҗра ясап урнаша.* Биология

2) *диал.* Кыйгач, кыйгачлап, кыйгач итеп; чатлаш; диагональ буенча; *русчасы:* **наискосок**. *Дөрес юлны табар өчен, турыга түгел, ә каршыдаш барырга кирәк*

**КАРШЫДАШЛЫК** *и. махс.* Каршыдаш булу. *Почмакларның каршыдашлыгы*

**КАРШЫЛАНУ** *ф.* 1) Каршы, тискәре булып китү, киреләнү, карышу, сүз тыңламау, ризалашмау, килешмәү. – *Алай бик каршылансаң, Алмачуарыңны [тотарбыз да] урманга җигәрбез, – дип куркыталар мине.* Г.Ибраһимов

2) Каршы юнәлеш алу. *Кичкә калып җиләк җыйган киң урманда – Кайтканыңда кичке җилләр каршылanса --- Син шомланма, Гөлкәй!* М.Җәлил

**КАРШЫЛА́У** I *и.* Исәнләшү, сәлам бирү, сәламләү. *Яңгырады каршылаулар, ул сәламнәр, Чәчрәп очты алтынланган шәм, сәнамнәр!* Я.Кәрим

**КАРШЫЛА́У** II *ф.* 1) Каршы алу. *Азамат аларны гармун уйнап каршылый.* Г.Ахунов. *Саимә Саматны салкын каршылады.* Г.Галиева. *Аны кулына ялтырап торган ачкыч тоткан берәү каршылый.* Ш.Рәкыйпов

2) Билгеле бер моментны, вакыт берәмлеген, дәверне башлау, вакыйганың, күренешнең башланганын күрү. *Кызның йөзеннән тама тамчылар, Бу – аның кайнар сөю яшьләре, Ул елый, сөю язын каршылап, Сүтелә җилдән көмеш чәчләре.* М.Җәлил. *Сүрелмәсен күңел түре, Җырлап каршылыйк кышны.* Г.Вәлиди. *Төнне тыныч каршылау һәм тизрәк каршылау өчен, Рөстәм йокларга ятты*. Г.Кутуй

3) Берәр нәрсәнең башлану хөрмәтенә бәйрәм, мәҗлес үткәрү. *Чиксен тасма яшь туташлар Ука белән аралаш, Юбилейны дәү бүләксез Каршылау һич ярамас.* Г.Вәлиди. *Яз көне ташу каршылау җомгасында Кызлар тавында үзебезнең авыл егетләре, урамга-урам каршы килеп, канга тузып сугышты.* М.Кәрим. *Шунда яңа елны каршыладык, минем туган көнне үткәрдек.* Я.Абдуллин

4) *куч.* Яңарак килгән кешегә яки яңа күренешкә, вакыйгага, хәбәргә һ.б. аерым игътибар күрсәтү. *Нурлы йөзкәең шиңгән гөл кебек, Каршылый идең таңны гел көлеп.* Г.Сәгыйров. *Яңа демократик Германиянең тамашачылары татар композиторының әсәрен алкышлап каршылыйлар.* И.Юзеев. *Матур табигать аларны колач җәеп каршылады.* М.Насыйбуллин

**Каршылап йөрү** Каршылау эшләре белән мәшгуль булу

**Каршылап тору** Берөзлексез, даими яки регуляр рәвештә каршылау эшен башкару; хәзерге моментта каршылау. *«Бигрәк беркатлы минем хатын, – дип сәерсенде, – элеп алып селкеп саласы урында, ишек ачып каршылап тора» ---*. К.Тимбикова

**Каршылап утыру** Бернинди эшхәрәкәт ясамыйча гына каршылау. *Гадәттә, 85 яшендә кеше кәнәфидә аяк бөкләп, бәхетле картлыгын каршылап утырырга гына күнеккән.* Ватаным Татарстан

**КАРШЫЛАШУ** *ф.* 1) Каршы тору, карышу, каршылык күрсәтү, киреләнү, үз сүзеңдә тору, сүз кайтару, ризалашмау. *Кеше көн буена төрле авырлыклар белән каршылаша ала.* Х.Яхья. *Каршылашсам, бу мәхәббәт каршысында тез чүгәм, «Инде мин качтым» дисәм, барып керәм кочагына.* М.Гафури. *Өч бүрегә [корт] каршылашканда, чыбыкка төртелеп, Бер аягы каймыгып калган, ничектер, биртелеп.* Х.Исхакый

2) *к.* **каршылау** II (*1 мәгъ.*)

**КАРШЫЛЫК** *и.* 1) Каршы булу, тискәрелек, кирелек. *Һәрхәлдә мин үземдә кияүгә чыгарга каршылык, теләксезлек таба идем.* Г.Сөнгати. *Сөбханголовтан каршылык көтмәгән иде ул.* М.Насыйбуллин. *Кирәк булгач, йөрим, бернинди каршылыгым юк.* Н.Фәттах. *Рушан тыштан караганда кирелеккә охшаш, әмма ниндидер эчке бер каршылык-протест белән, хезмәттәшләрен аптырашта калдырып, кинәт кенә кистереп әйтеп салды ---*. Казан утлары

2) Каршы тору, ризасызлык, канәгатьсезлек, килешмәүчәнлек. *Бакуда нефть промыселларында --- патшага каршылыклар көннән-көн үсә.* Х.Садри. *Җирле халыкның кычкыртып талауга, чукындыруга торган саен ныграк каршылык күрсәтүенә карамастан, яңа «хуҗаларның» аппетитлары кимеми.* Р.Әмирхан. *Димәк, бу версия буенча, Идегәй гаиләсе белән Туктамыш хан арасындагы каршылык бик күптәннән килә.* Ф.Урманче

3) Икенче бер нәрсә белән охшаш булмау, туры килмәү, капма-каршы булу, үзара каршы булу. *Археологиянең яңа каршылыкларына багышланачак мәкаләсе турында сөйләп туктагач, Солтания Кәримә күңелендәге газаплану хикмәтен дә тойды.* К.Тимбикова. *Бүлектәге каршылыкларның газетада фаш булуы галимнәр дөньясын гөж китерде.* К.Тимбикова. *Ф.Бәйрәмова олы шагыйрьнең хис-кичерешләр байлыгын, каршылыгын, җан газапларын бөтен күңеле белән аңлап, үзенеке кебек кабул иткән һәм драмада сәнгать чаралары белән шуларны сурәтли алган.* Казан утлары

4) Хәрәкәт итәргә, каядыр керергә, барырга комачаулаган, киртә булган, тоткарлаган нәрсә. *Теләгең төпле икән, бер каршылыгым юк.* Ә.Моталлапов. *Дошман немец армиясенең Ленинградка юнәлгән юлында әлеге армиянең җитди каршылык булуын яхшы аңлый.* Ә.Мәхмүдов. – *Әгәр ул [Шамин] чын-чыннан эшне рәтләргә ябышкан икән, каршылыклар, бәрелешләр килеп чыгарга тиешме? – Тиеш, иптәш Адаев...* А.Гыйләҗев

5) Комачау, тоткарлык. *Кешегә үз юлында очрый торган авырлыклар, каршылыклар белән көрәшергә туры килә.* Г.Иделле. *Ләкин көтелмәгән каршылык килеп чыкты.* Ш.Маннур. *Ничек итеп Гамбәрне офицерга яучылавыбызны, туй үткәрергә җыенгач кына, һич көтелмәгән каршылыкка очравыбызны, кәләшнең түбән катлаудан икәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.* Г.Шәрипова

6) Конфликт. *Каршылыксыз һәм көрәшсез драма әсәре була алмый.* М.Җәлил. *Тарих шуны раслады: ул мәдрәсәләрдә укучы сәләтле яшьләр, аларда бирелгән гыйлем-мәгълүмат, тәрбиядән канәгать булмыйча, татарның ул вакыттагы укыту-тәрбия системасы белән каршылыкка керәләр.* Г.Исхакый. *Әсәрдәге каршылыкларны, төп конфликт характерын персонажның социаль хәленә бәйләп аңлату да җитди мәсьәлә буларак урын ала.* Ә.Закирҗанов

7) *физ.* Җисемнәрнең нәрсәнеңдер тәэсир итү көченә каршы тора алу үзлеге, сыйфаты, табигате. *Кешегә докторлар дарулар биреп карыйлар. Ләкин булмый, чир, ниһаять, организмның каршылык көчен тәмам җиңә; кеше канындагы шариклар да, йөрәк тә, дарулар да һични эшли алмыйлар.* Ш.Маннур. *Радиоалгычка яңа блок өстәгәч, аларның каршылыгы үзара ярашмаска тиеш ич!* А.Тимергалин. *Һаваның каршылыгы аркасында аның очу тизлеге акрынлап кими бара һәм очыш юлының ахырына таба аның тизлеге секундка 40 метр чамасы гына кала.* Кызыклы физика

8) *филос.* Табигать һәм җәмгыять күренешләренә хас булган үзара кире мөнәсәбәт, килешмәүчәнлек, кискен аерма, уртаксызлык, капма-каршылык. *Габдулла мулла белән Г.Камал арасындагы фикер каршылыгы көннән-көн тирәнәя.* М.Гали. *Ул заманында киң җәмәгатьчелекне борчыган мәсьәләләргә, гомумән, милләтнең хәле, тәрәккыяте, социаль каршылыклар, сәясәт, тәрбия һ.б. барып тоташа.* Г.Исхакый. *Әгәр дә дарвинизм Дарвин каләме астыннан чыккан төсендә дөньяга идеалистик караш белән каршылыкта булган булса, материалистик тәгълиматның үсеше бу каршылыкны тагын да күбрәк тирәнәйтте.* Биология фәнендәге хәл турында

9) *куч.* Кыенлык, киртә; авырлык. *Матур, төпле шигырьләр язган Хәнәфинең тормышында бер генә каршылык та булмаган дип уйласак, ялгышырбыз, аңа тормыш юлында зур авырлыклар, очлы казык башларыннан торган ясалма коймалар аша да үтәргә туры килде.* Ә.Мәхмүдов. *[Ул] Иң авыр, иң олы каршылыклар тупланган юлга аяк баскан.* М.Вәлиев. *Кәлимә белән Шәрәфә арасындагы мөнәсәбәт тә мең каршылык аша шул дәрәҗәгә үсеп җитте.* К.Тимбикова

◊ **Каршылыгын сындыру** Җиңү, буйсындыру. *Димәк, каршылыкны сындырыр, үзеңә буйсындырыр, шуның белән аларны курку хисе читлегендә тотар өчен, аларга ярашырга кирәк.* Ә.Гаффар. *Бу урыннарда канлы фашизмның соңгы үлем ачысы каршылыгы сындырылган бик каты сугышлар үткән.* Р.Төхфәтуллин. *Суфианов та алар турында нидер әйтте түгелме? Аларның каршылыгын да сындырачак ул! Үгет-нәсыйхәт белән маташмаска, шытырдатып кысарга!* А.Гыйләҗев. **Каршылыгы сыну** Әхлак, әдәп нормалары һ.б.ш. басым ясап яки көч кулланып кемне булса да җиңү, бастыру, буйсындыру турында. *Ләкин иптәшләре каты-каты әйтә башлагач, Вәлиевнең каршылыгы озакка бармады, сынды.* С.Рафиков. **Каршылыкка керү** Кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы берәр нинди эш, хәрәкәт эшләү, көч белән каршы тору; карышу. *[Ул] Хәтта аны тәхеткә утыртуда төп роль башкарган морзалар белән, ягъни Шәрык төркеме белән дә каршылыкка керә һәм Коләхмәтне кулга алдыра.* Ф.Урманче. *Драматургның игътибар үзәгендә котылгысыз каршылыкка кергән Туктамыш хан белән Идегәй мирзаның һәм якыннарының максат-омтылышларын, шуңа бәйле эш-гамәлләрен ачыкләу тора.* Ә.Закирҗанов. **Каршылык күрсәтү** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы берәр нинди эш, хәрәкәт эшләү; көч белән каршы тору, каршы сугышу. *Дошман нык каршылык күрсәтә, орудиеләрне ут астына алырга тырыша, без аның саен ныграк бәрәбез.* Г.Галиев. *Хатыннар юл бирмәсәләр дә, артык каршылык та күрсәтмиләр иде.* И.Гази. *Бинадан каршылык күрсәтү туктатылды. 10 сәгать 38 минутта Руцкой: «Атмаска. Каршылык күрсәтмәскә...» – дигән әмер бирде.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Карышу, ризалашмау. *Патша бердәнбер улына каршылык күрсәтми.* Дастан. *Милиция. Минә сезне тентергә кушып, өяздән язу килде. Минә язуы, властька каршылык күрсәтмисездер бит?..* М.Гафури. *Инде Әнвәр аз гына каршылык күрсәтсә, аяклары белән тыпырдап чәбәләнергә, еларга тотына.* Ә.Еники

**КАРШЫЛЫКЛЫ** *с.* 1) Каршылыгы булган, каршылыклар килеп чыккан. *Укучы Г.Коләхмәтовның «Ике фикер»ендәге катлаулы ситуацияләрдә яшәүче, икеләнүче, каршылыклы уйлар белән хакыйкать юлына килүче геройларны да сагына башлагандыр.* И.Юзеев. *Өстәвенә, Ибраһим ханның сәясәте дә ярыйсы ук каршылыклы булып чыга.* Ф.Урманче. *Вакыйгаларда һәрберсенең диярлек каршылыклы рухи дөньясы, эчке фаҗигасе ачыла.* Ә.Закирҗанов

2) Төрле, икеләнү хисен уяткан, капма-каршы булган фикерләр кузгата торган, катлаулы. *Археологлар янына кайтканда, башында туган каршылыклы сорауларына җавап алырга ашыккан Кәриммәне өр-яңа табыш көтә иде.* К.Тимбикова. *Зөләйха каршылыклы хисләр кичерә.* Н.Вәлиев. *Әмма шул сәгатьтә икеләнү, каршылыклы уйлар өере килеп сарылды чигәмә.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу аның тынычлыгын җуя,*

*үзенең каршылыклы сүзләре аркасында буталып калырга мәҗбүр итә.* М.Насыйбуллин

**КАРШЫЛЫКСЫЗ** *рәв.* **1.** Карышмыйча, каршы килмичә, киреләнмичә; талаш-ызгышсыз, низагсыз. *Заһит атасы әйткәнгә каршылыксыз буйсынды.* Я.Хамматов. --- *Вәгыйзьләрнең, Мансурларның, орлык ташучыларның, шофёрларның аның һәрбер сүзенә, һәрбер теләгенә каршылыксыз риза булулары да --- барысы да, барысы да шул турыда сиздереп торды.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Икенче бер нәрсә белән капма-каршы булмау. *Евклид геометриясе һәм Лобачевский геометриясе каршылыксыз була аламы дип, укучы сорарга мөмкин.* Геометрия. *Һәр яктан килеп чыккан атлы партизаннарны күреп, конвойның күпчелеге каршылыксыз кулларын күтәрде.* А.Расих

**КАРШЫНА** *рәв.* Кемгә я нәрсәгә булса да кара-каршы, каршыга, алдан, я, киресенчә, каршы яктан килү. *Әллә кемнәр каршына мин сорап бардым ---.* Г.Сәгыйров. *Камил очынып аның каршына килеп басты.* Г.Галиева. *Икесе дә тәвәккәл хәрәкәт белән немец каршына бастылар.* Ш.Маннур

**КАРШЫНДА** *бәйл.* 1) Берәр кем я нәрсә алдында урнашу. *Көзге каршында хат яза.* Ш.Җиһангирова. *Хәзер ул биек, түшәмгә кадәр җиткән киштәләрнең берсе каршында авышрак итеп тезелгән китапларны күз алдыннан кичерә.* Ә.Гаффар. *Хәлимнең каршында – ак кәгазь, кулында – карандаш.* И.Гази

2) *күч.* Берәр нәрсә алдында мәгълүматларны яшермичә тору, аларны әйтү. *Йосыфка хөкем каршында җавап бирергә туры килә.* Дастан. *Бу эшләр һәммәсе дә яшерен эшләнгәнгә күрә, ул кәгазьләрнең закон каршында, әлбәттә, һичбер көче юк иде.* Ш.Маннур

**КАРШЫНДАГЫ** *бәйл.* Нинди дә булса оешмага һ.б. буйсынган (шуның идарәсендә) булу мәгънәсен белдерә һәм кушма аергыч ясап килә. *Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе 1938 елның көзендә үзенең эшен төгәлләде.* М.Җәлил. *Халык бик тиз баһадир юртасы каршындагы мәйданга җыелды.* М.Хәбибуллин. *Шуның өстенә ул аны, вагонга кергән саен, тәрәзә каршындагы өстәлгә утыртып куя да оныта.* Ш.Маннур

**КАРШЫСЫ** *и.* Турысы; туры, алды

**КАРШЫСЫНА** *бәйл.* Янына, алдына, катына; *к.* **каршына**. *Камәров тезелеп өлгергән беренче взвод каршысына килде.* А.Таһиров. *Гармунчыга баш игән чакта Сәләхи кереп, кияү белән кыз каршысына туктый.* Г.Ахунов. *Әти урыныннан торып, Зиннәт абыйның каршысына басты.* Г.Тавлин

**КАРШЫСЫННАН** *рәв.* 1) Каршы яктан. *Һәр көн иртән тәрәз каршысыннан Ашыга-ашыга атлап үтәсең. Син беләсең, анда, Классыңда, Ничәмә күз сагынып көтәсен.* Р.Шаммас. *Тәрәзә каршысыннан нindидер күләгәләр уза башлады.* И.Гази

2) Инкяр итү нигезендә, кире фикердән башлап

**КАРЫ** *с.* Карт. *Какшакта (сазлы урманда) кара болан егылса, Ите, ятып, корт булыр. Кем карысын сыйласа, Калган да йортка кот булыр. Кем карысын сыйламаса, Күп яман таңлангы (киләсе) көн Янган утта ул булыр.* Дастан

**КАРЫГУ** *ф. диал.* Җенси теләккә килеп, тынычсызлану (терлек тур.)

**Карыгып тору** Карыгу хәлендә булу

**КАРЫЗ** *и. гар. иск.* 1) Шартнамәдә катнашучы бер як тарафыннан икенче якка өстәмә түләү һәм кире кайтару шарты белән бурычка бирелгән акча яки матди кыйммәтләр. *Карыз, карызны бирү фарыз.* Мәкаль. *Хаҗибаевка карызга биш йөз сум акча биреп торган идем.* Г.Газиз. *Хәзрәтнең дә, абыстайның да иманы юк! Атай үзләренә күпме эшләде, бушка малларын бакты. Ә алар, үлгәч тә, аннан карыз сорыйлар.* И.Салахов

2) Вазифа, эш, йөкләмә. *Бу – безнең милли карызымыз! Мин, әфәнделәр, бөтен төрек-татар милләте исеменнән газәмәтле (данлы) чех-словак гаскәренә актык канымызгача ярдәм итәргә ант итәмен ...* Г.Ибраһимов

**КАРЫЗБА** *и. диал.* Өйнең аш-су пешерә торган ягы. *Без монда карызбада гына ашыйбыз*

**КАРЫЙ** *и. иск.* **1.** 1) Өлкән яшьтәге, бик карт кеше. *Карый килсә, сүз бетәр, Егет килсә, эш бетәр.* Мәкаль. *Карый белән сабый бер хөкемдә.* Мәкаль. *Бу утырган батырлар Нарәң батырны күреп: – Әй карт! Синдәй карыйлар җыраучы була торган, җырлачы, – диделәр.* Дастан. *Кыш булса төрлүк мивә (җиләк-җимеш) түгеләдер, Күреклек нәбат бөгелеп иңеләдер (иеләдер). Карыйларга манәнд (охшаш) улып бөгеләдер, Карыйлар тик хәлсез булыр кодрәт берлә.* М.Колый

2) *дини* Коръәнне укый торган, аны яттан белүче кеше, хафиз. *Ул атасыннан рөхсәт килгәнен дә көтми, карт сукыр карыйга тезләнеп, фатиха ала, аның атаклы шәкерте Сафый карыйга утырып, Коръән ятлый башлый.* Г.Ибраһимов. *Кыш булдисә, йир йөзендин нигүмәт китәр, Яз булдисә, утнәбәт кайра бөтәр, Рузә, намаз йөгет кыйлса, куәте бар, Карый булса хәлсез булыр кодрәт берлә.* М.Колый. *«Көлке»дә баш кешеләр – хәзрәт, карый әфәнде, дамелла, Садыйк хәлфәләр, учительләрдер. --- «Көлке»нең зур каһарманнары – хәзрәт берлә карый әфәндедер.* Т.Гыйлаҗев

3) Эшче. *Моның үзләренә өч көн үткәч, Дәһханә Басра вакытта атасының бер ничә төрле үлән яратып ашый торган ашыны пешертеп, ахшам булдыкда, караңгылык булгач, бер карый далай лама хатынының киемене киеп, бу ашны бер савытка салып, вади зинданына килеп, зинданчыга ярты алтын биреп әйтте ---.* Ф.Халиди

**2.** *с. мәгъ.* Карт, өлкән яшьтәге. *Күңелегез булгандыр инде карый кешене шулай бимазалап йөрткәч!* Ф.Хөсни

**КАРЫЙ БАШ** *и.* Аксакал, идарәче

**КАРЫ́Й КҮРҮ** *ф. диал.* Йөз чөерү, дошман күрү. *Үлесен дә карамадылар, карый күрделәр авыл кешеләре*

**КАРЫЙ КЫ́З ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан берөйле, серкәчле чәчәкләре күпләп, җимшәнлеләре парлап урнашкан үлән үсемлек; *русчасы:* **дурнишник**

**КАРЫЙЛЫК** *и. иск.* Картлык, картайганлык. *Карыйлык килде миңа, тәкатем юк.* М.Колый. *Мәула Колый, яз*

*кебек яшьлек китәр, Кышка охшаш карыйлык сәңа йитәр.* М.Колый

**КАРЫК** *иярт.* Каргылдау, карылдау авазын белдерә; карга тавышы. *Ишегалдына чыккач та «карык, карык!» дигән ямьсез карга тавышы ишетелде.* Х.Кәрим

**КАРЫК-КОРЫК** *иярт. к.* **кар-кар**. *Карга кара, кара карга! Карык-корык каркылдама*

**КАРЫЛДА́У** *ф.* 1) Бик тупас итеп каркылдау. *[Ирсай:] Карга карылдый. Бик карт, ахры: карылдавы бигрәк ямьсез...* Р.Харис. *Ала карга Үз телендә Салмыш бер шагыйрьдәй Карылдый да карылдый.* Ә.Мәхмүдов. *Инеш буе чиләк-ләйкәләр чыңлавы, әби-апаларның гөрләшеп сөйләшүләре, каргалар карылдашуыннан күңелле генә яңгырап тора.* Р.Төхфәтуллин

2) Тавыклар һәм тавыкка охшашлы кошлар өчен характерлы булган тамак тавышы чыгару. *Мылтык тавышыннан өркегән каргалар, чәүкәләр, ояларыннан тузгып, чәрелди-карылдый һавада очып йөри башладылар.* М.Галәү. *Ул гомере буе тырнагы белән җир тараган, кырда-болында уралган һәм вакыт-вакыт башын күтәреп офтанган, еракларга күз салган, карылдашып үткән торналарга кул селкеп калганда, аның сагыш тулы күзләрендә рәхәтлек уты кабынган.* А.Гыйләҗев

**Карылдап алу** Бераз, берара, кыска вакыт эчендә карылдау

**Карылдап йөрү** Берөзлексез карылдау

**Карылдап китү** Кинәт, нindидер сәбәптән карылдау

**Карылдап кую** Бер генә тапкыр яки кинәт кенә карылдау. *Әтәч, бик аптырагандай, карылдап куйды.* М.Гали

**Карылдап тору** Бертуктаусыз, даими рәвештә яки вакыт-вакыт карылдау

**Карылдый башлау** Карылдарга тотыну

**КАРЫЛУ** *ф. диал.* Тамак карлыгу, карлыга төшү. *Тагын да матур җырлар идем, Тамакларым карылган.* Җыр. *Камыр кеби изелгәннәр, аракыдан тамаклары карылган, «Самокат»тагы Петрушка тавышы белән җырлыйлар.* Г.Тукай

**КАРЫМСА** *и. диал.* Бавыргалык, түшлек. *Атның карымсасы асылынып тора, күтәреп бәйлә*

**КАРЫМТА** *и.* 1) *тар.* Талап алынган малны кайтарып алу өчен оештырылган һөҗүм, поход, яу; кару кайтару, үч алу, үч кайтару. *Байга барымта юк, ярлыга карымта юк.* Мәкаль. *Таланган кабилә бер көнне үзе җавап һөҗүм ясый, моны «барымтага карымта» дигәннәр.* Н.Исәнбәт

2) *иск. кит.* Кан дошманыннан үч алу. *Карымтага карымта*

◊ **Карымта кайтару** Кан дошманыңнан үч алу, кару кайтару

**КАРЫМТАЧЫ** *и.* Карымтада катнашучы; дошман. *Унике яшем тулганда, карымтачы минем агаемны үтерде. Өй эчендә ир затыннан иң өлкәне мин торып калдым. Әтием төрек сугышында гаеп булган иде. Үч алу минем өскә төшә. Карымтачының елга-ел, айга-ай, көнгә-көн миңа яшьтәш улы бар. Боташ исемле. Унҗидебез тулган көнне, мин аны үтереп, үч кайтарырга тиешмен. Йола шулай куша. Әгәр карымтачының үзен юк итсәң, ул үлә дә котыла, ә менә улсыз калдырсаң, гомер буе газап чигәчәк.* М.Кәрим

**КАРЫН** *и.* 1) Күшәүче хайваннарның күшәлмәгән азык тула торган капчыксыман эчке органы. *Йотылган азык башта зур күләмле карынга эләгә.* Зоология

2) *сөйл.* Ашказаны. *Бай тук була, ә ярлы ач – буш була карыны.* Н.Арсланов. *[Фәридә:] Сезнең карыныгыз ачкандыр. Әзерләп бирим әле.* Ю.Әминов. *Карыным ачты, бүре йотардай булдым.* А.Гыйләҗев. *Карынны тутырып, ашыйсы килүне бераз басып торырлык аш кына булсын!* А.Шамов

3) Корсак, эч. *Кабан кабанның карынын ярмас.* Мәкаль. *Борыны буртас (озын), карыны картас (калын, юан), Атка менмәс, җәяү йөрмәс, тик тормас.* Табышмак. *Хөппениса шуның эчәк-карынын юарга кушты.* Я.Хамматов. *Юк бит, туган, ди, бот кысудан карын тарайммый, ди иде.* Г.Ибраһимов

4) Аналык, бала урыны. *Карындагы бала – алынмаган кала.* Мәкаль. *Мөгаен, шушыдыр туачак адәми затка җан иңдерү, шушы мизгелдә туадыр яңа җан иясе, тугыз ай ана карынында йөреп түгел.* М.Хәбибуллин. *Баланың ана карыныннан билгесез дөньяга килеп чыккан мәлендәгечә, тәне җыерылып, куырылып килде.* Ә.Гаффар. *Әтисе Госман Тимәш авылы кешесе булган, улына әтисен күрергә насыйп булмаган, Габдерәхим ана карынында чагында ук вафат булган.* Ә.Мәхмүдов

5) Карындыктан торган капчык, янчык. *Кайда булган безнең өй карын май?* Х.Кәрим. *Бер чеметем тоз, кечкенә кисәк икмәк катысы. Болар һәммәсе карынга төрүле.* Г.Ибраһимов. *«Корсак» дигәне гамәлдә турсык – мал карыныннан тегелгән капчык, ватылмый да, су да үтми, ялгыш бүселеп кенә китмәсә...* Г.Якупова

6) *махс.* Тиренең карын өлеше. *Бай хатыннары тун кия, алтас тун, гадәти төлке карыны эчле яки карсак карыны эчле.* К.Насыйри

7) *күч.* Нәрсәнең булса да эче, яисә эченә камап алынуы. *Дөнья карынына кереп ятасың да, калганы җиде катлы Асыл Рух ихтыярына бәйләнгән.* Ә.Гаффар. *Батальон колоннасын урман үз карынына йотып бетерә язган иде инде.* Ш.Маннур. *Дөм караңгы дөнья карынында Тыпырчындым! – Мин бер яралгы.* Р.Зәйдулла

◊ **Карының белән кар ярып, борының белән боз тишеп** Тормышта бик күп авыр михнәтләр, газаплар чигеп, анда да бирешмичә, үзең юл ярып яшәргә туры килү

**КАРЫН АЧУ** *ф.* Ашыйсы килү, ашказаны тартылу. *Карыныбыз бик ачса да, иске гадәт буенча, урманны чыкканчы ашау юк иде.* А.Гыйләҗев. *[Гөлүзә:] Уты да капты, карын да ачты.* Ю.Әминов. *[Ул] Карыны ачса, өйгә кайтып, ян тәрәзәдән генә керә дә, аңа дип калдырылган бәрәңге белән ипине ашап, тагын урамга атыла.* И.Нуруллин

**КАРЫНАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Иң күп санлы моллюсклар классы; *русчасы:* **брюхоногие**

**КАРЫНДАШ** *с.* **1.** 1) Бер анадан туган; карендәш. *Күкрәк сөте имезеп үстергән, телен ачкан анасына,*

*уналты ел хәләл икмәген-тәгамен ашаткан атасына, бер ятакта аунаган карындаш агасына кул күтәрсенме?!* Ф.Латыйфи

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сеңел (абыйсына карата)

2) Кардәш, туган. *Үзенең башын зур тоткан, агаеның башын хур тоткан Карындаш тапмай ятта үләр. Тауда булыр таргыл таш, Тарыкса, күздән чыгар яшь, Тар култыктан ук тисә, Тартып алыр карындаш. Карындашың юк булса, Далада калыр ялгыз баш.* Дастан. *Арсланбай эшне җиңел өзде: – Безгә карындаш булган ике ыруғның өлкәннәре биргән киңәшне бозарга амалыбыз юк.* Г.Ибраһимов. *Ә монда хәзер аның бөтенесе дә бар. Чөнки карындашы – туганы бар!* Г.Гыйльманов

**КАРЫНДАШЛЫК** *и.* Туганлык, кардәшлек, кардәш-ырулык. *Туганлык, карындашлык хисенең, кан һәм җан тойгысының көче хакында сөйли бу вакыйга.* Г.Гыйльманов

**КАРЫНДЫ** *и. диал.* Яры, элпә. *Граф киемендәге кеше --- кесәсеннән әллә нәрсәләр чыгарды да үлем карындысы белән каплангандай күзе белән сөзде.* Т.Госман

**КАРЫНДЫК** *и.* **1.** 1) Күшәүче хайваннар карынының тышчасын тәшкил иткән юка, нык яры. *Ибәт абзайга --- хатыннар күренмәсен дип, тәрәзәсенә карындык корса да, Хәдичә абыстайны кыр хезмәтенә җибәрә иде.* З.Һади. *Ачып җибәрсәң – тегермән ташыдай бер бөтен ипи, торна хәтле бер бөтен каз – каклаган, карындыкка төргән, и чүтеки майлары тамып тора!* Ш.Маннур. *Баш очында карындыкка төрелгән каклаган каз эленеп тора.* Г.Сабитов

2) *сөйл.* Бала сүрүе, соңгылык, плацента. *Бәхетле буласы бала карындагын башына киеп туа, имеш.* Мәкаль. *Бала карындагы белән туды*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күшәүче хайваннар карынының тышчасын тәшкил иткән юка, нык яры элпәдән ясалган әйбер. *Гөлнур, Сирай белән янәшә, тәрәзә төбенә утырып, карындык бөктәрне актара башлады.* К.Нәҗми. *Карындык өлгеләр, бер эчкә, бер тышка таба кабарып, лап-лап иткән тавыш чыгаралар.* Х.Садри. *Карындык тәрәзәле, җир идәнле тәбәнәк куышларда яшәгән кешеләр икенче төрле...* А.Гыйләҗев

2) Юка, карындыкны хәтерләткән, карындыкка охшаган. *Карындык тәрәзәдән таңның беренче нурлары өй эченә сибелде.* Я.Хамматов. *Кайбер өйләрдән карындык тәрәзәләр аша тонык кына яктылык күренә.* А.Расих. *Мөгаен, карындык тәрәзә аша дөнья ничек күренә, бу баланың күз күрүе дә шул чама гынадыр.* Г.Якупова

◊ **Карындыгын башына киеп туган** *к.* **карындык белән туган**. **Карындык белән туган** Бәхет йөзлеге белән туу, бәхетле булып туу (карындыгын башына киеп туган бала бәхетле була, имеш, дигән ышанудан алып әйтелгән, ягъни ул кеше тумыштан бәхетле, тормышта һәрнәрсә үзеннән-үзе аның җаена килә)

**КАРЫНДЫКЧЫ** *и. тар.* Электә тәрәзәләргә хәзерге пыяла урынына хайван ашказаны (карын) ярысын, үгез куыгын тарттырып куючы оста

**КАРЫ́Н-КАРЫН** *с.* Күп карындыкларга тутырып, төреп куелган. *Базар тулы ризык: капчык-капчык он, тушлап-тушлап сарык ите, карын-карын туңмай.* Ә.Исхак. *Сандыкларда өелеп ята торган карын-карын сары май --- хәзер бары төштә генә күрергә калды.* И.Салахов

**КАРЫНКЫ** *с. диал.* Карлыккан, тоныкланган, гырылдаулы (тавыш тур.). *Бабай карама эченнән: – Сөйлә! – ди карынкы аваз белән.* Әкият. *Рәхим бераз карынкы, шулай да матур тавыш белән сөйли башлады.* Ф.Әмирхан. *Мин кереп, чирек сәгать кадәр торгач, Габдулла әфәнде көтмәгән җирдә миңа бер сөаль бирде, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс кенә, карынкы вә зәгыйфь бер тавыш белән: – Актык корректура кайчан? – диде.* Г.Халит

◊ **Карынкы тавыш** Бераз карлыккан, кыркуланган тавыш. *Аның колак төбендә генә Зәйнәпбануның карынкы тавышы ишетелде.* Г.Бәширов

**КАРЫ́Н ПӘРДӘСЕ** *и.* Корсак ярысы

**КАРЫНЧЫК** *и. анат.* Йөрәкнең кан тамырлары буйлап канның әйләнешен тәэмин итә торган, тәртипкә салучы өлеше. *[Йөрәк] ике яртыга бүленә. Бу яртыларның һәркайсы бер-берсе белән аралаша торган ике бүлектән: колакчыктан һәм карынчыктан тора.* Анатомия. *Йөрәкнең һәр өлеше үз чиратында бер-берсе белән тоташа торган ике бүлеккә: өске – йөрәгалдына һәм түбәнге – карынчыкка бүленгән. Карынчыклар шактый зур эш башкаралар, канны кан тамырларының бөтен озынлыгы буйлап этәрәләр.* Биология

**КАРЫШ** I *и.* Озынлык үлчәве берәмлеге – киерелгән кулның баш бармак очы белән урта бармак очы арасы (уртача чирек аршынга тигез озынлык үлчәве берәмлеге). *Мөсәббикә буе ике карыш, иңе бер карыш булган агач тартма китерде.* Г.Галиев. *Кышкы көннең озынлыгы – бер карыш.* Ә.Моталлапов. *Шуннан соң бу каравылчылар, бер карыш читкә китмичә, каккан казыктай тораташ катып калдылар.* Ә.Гаффар. *Тик түшәмнән бер карыш чамасы түбәнрәк бордюр сызыгы кирәк булачак.* Г.Сабитов

**КАРЫШ** II *диал.* Каршы, каршы як

**КАРЫШ** III *рәв.* Пычранып, керләнеп, каралып

◊ **Карыш каткан** «Пычранып беткән, каткан кер, тузан каткан» дигәннән. *Пычрак ыштан, карыш каткан якаларны әниемнән юдыра алмыйм бит инде.* Ә.Баян. *Тәрәзә пәрдәләре тузанга карыш каткан, караңгы.* Г.Камал. *Бакчада эшләгәнгәдер инде, бер карыш пычрак каткан.* Р.Хафизова

**КАРЫШКЫ** *и. диал.* Таяк. *Шуннан соң хәзрәти Муса карышкысын җиргә ташлады. Таяк шундук аждаһага әверелде...* Р.Батулла

**КАРЫШЛАВЫК** *и. зоол.* Гәүдәсенең уртасын бик дугалап, карыш белән үлчәгән шикелле үрмәли торган яфрак ашаучы, кечкенә генә, киң канатлы, зарар китерүче күбәләкнең корты; *русчасы:* **пяденица**. *Карышлавык карышлап йөреп ашар.* Мәкаль. *Бу вакытта кабык өстендә кышлаган башка корткычлар да (ябалак көясе, көя күбәләге, утлач коңгызлар, кышкы карышлавык, таң коңгыз һ.б.) һәлак була.* Бакчачы белешмәсе. *Крыжовник карышлавыгы*

*крыжовник һәм карлыган яфракларын зарарлый.* Бакчачы белешмәсе

**КАРЫШЛА́У** *ф.* 1) Берәр араны, ераклыкны яки берәр нәрсәнең озынлыгын карыш белән үлчәү. *Тегүче карчык буен карап та чамалый, ә кыз буен җиде карышлар, имеш.* Мәкаль. *Тукыманың иңен-буен карышлау*

2) *күч.* Кыйнау, сугу. *Становойның чигә тамырларын карышлаганнармы, зөбә кабыргаларын санаганнармы – аларны мин күрә алмадым.* Х.Кәрим. *Аркасын шактый карышладылар*

**Карышлап алу** Беркадәр, кыска вакыт эчендә, тиз генә карышлау

**Карышлап бару** Акрынлап, ашыкмыйча гына карыш белән үлчәү

**Карышлап бетерү** Тәмам, ахырга кадәр карышлау

**Карышлап бирү** Бернигә карамыйча карыш белән үлчәүне дәвам итү

**Карышлап йөрү** Һәрвакыт, күптәннән карышлау

**Карышлап калу** Күптәннән, әллә кайчан карышлау

**Карышлап тору** Эзлекле рәвештә, даими карышлаган хәлдә булу

**Карышлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр карышлау. *Шулай да борчылма син, әби, әйтәм ич, әти эшләячәк эшләрен элгәре уенда карышлап чыккан инде ул.* М.Хуҗин

**КАРЫШЛЫ** *с.* Бер карыш озынлыктагы. *Карышлы үлчәм*

**КАРЫШЛЫК** *с. к.* **карышлы**. *Бер карышлык*

**КАРЫШТЫРУ** *ф. диал.* Үзеннән-үзе мускуллар тартышу (авыртудан, сукташ һ.б.ш.лардан), көзән җыеру

**КАРЫШУ** I *ф.* Әйтелгәнне үтәмәү, кушылганны тыңламау, буйсынмау, каршы килү, киреләнү, үзсүзләнү. *– Көчләү башландымы – бала карыша; киресен эшли, – дип үз киңәшләрен бирде Бибинур.* Г.Галиева. *[Нури:] Уч тутырып акча алганда, кая кушсаң шунда йөгерә иде. Хәзер әйткән бер сүзгә карыша.* Ю.Әминов. *Тешем-тырнагым, җаным-тәнем белән карыштым. Мин карышкан саен, ул ныграк ябышты.* М.Кәрим. *Кемдер йокы аралаш мыгырдана, карыша, тартыша, кемдер елый, илерә, гафу үтенә иде.* Г.Әпсәләмов

◊ **Карышып каткан** Тискәре, үҗәт, киребеткән кеше. *Кире дигәндә дә инде моннан артык кире булмас, бөтенләй карышып каткан.* Г.Камал. *[Абдулла:] Зинһар дип әйтәм, карышып катма, мин синең ахмак икәнеңне болай да беләм.* Г.Ахунов. *Бакасы алга, кысласы артка тарткан, Аяк-куллары карышып каткан.* Н.Исәнбәт

**Карышып алу** Берара, кыска вакыт эчендә карышу

**Карышып йөрү** Һәрвакыт, гел карышу

**Карышып килү** Даими рәвештә карышу. *Андан Түләк кызга әйтде: – Сәфәр кылдык йөз кеше, Җөгән суйды уч кеше; Атым кәлде ярышып, Кулым кәлде карышып ---.* М.Хәбибуллин

**Карыша төшү** Тагы да бераз карышу

**Карышып тору** Даими рәвештә, бертуктаусыз карышу; карышу хәлендә булу. *Малайлар аны уратып алдылар да кесәләрен актара башладылар, Кәли карышып тормады.* Г.Сабитов. *Фәридә шалтыратты, барып йөрмә, яңгыр сибәләп тора, диде. Карышып тормадым.* Я.Абдуллин. *Карышып тору мәгънәсезлек кебек тоелды: Сәгадәт ризалашты.* Г.Әдһәм

**Карышып утыру** 1) Карышу хәле кичерү

2) *ф. к.* **карыштыру**

**КАРЫШУ** II *ф.* Табигый, гадәти рәвештә үсмәү, боргалану, кәкре-бөкре булып үсү (агач тур.); кәкрәеп кату. *Карышып үскән караманы турайталмассың.* Мәкаль

**Карышып алу** Берара, бер вакыт аралыгында кәкрәеп үсү

**Карышып бетү** Тәмам, бөтенләй кәкрәеп үсү

**Карышып калу** Беркадәр вакыт узгач, ниндидер сәбәптән соң боргаланып үсү

**Карышып тору** Бертуктаусыз, даими рәвештә карышу

**Карышып утыру** Кәкрәйгән, бөкрәйгән хәлдә үсү

**КАРЫШ УЕН** *и. диал.* Язгы чәчү эшләре беткәч, җыеннар башланганчы, тирә-як авыл кешеләре арасында берәр атна кара-каршы кунакка йөрешү, күңел ачу йоласы

**КАРЫШУСЫЗ** *рәв.* **1.** Каршылык күрсәтмичә, тоткарсыз, баш тартмыйча. *– Барыбызга да шунда барасы бит, – диде колхоз рәисе Мөнәвир Әмин улы, бернинди карышусыз.* З.Хәмидуллин. *Бу хакта шактый күп сүзләрдән соң, Вәлиулла тоткынлыктан котылу хыялын күңеленнән бөтенләй чыгарып ыргытты, шуның аркасында барсын да карышусыз үтәүче колга әверелде.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* Күндәм, тыңлаучан

**КАРЬЕР** I *и. фр.* Атның иң җитез чабу ысулы (атны сикертеп чабу)

**КАРЬЕР** II *и. фр.* 1) Сай яткан файдалы казылмаларны (таш, балчык, ком, руда һ.б.) ачык ысул белән чыгару урыны. *Таң ату белән карьерга таш ватучылар, таш юнучылар, башка эшчеләр килделәр.* Ш.Бикчурин. *Тау буендагы карьерлар белән лагерь арасында туктаусыз йөреп торучы машиналар төзелеш мәйданын таш белән күмеп ташладылар.* Г.Сабитов. *Харис тракторын тирән карьердан чыгу ягына борды.* Ә.Моталлапов

2) Ачык ысул белән файдалы казылмаларны табу буенча эшләгән тау сәнәгате предприятиесе

**КАРЬЕ́РА** *и. фр.* 1) Хезмәттә яки башка өлкәдә танылу, күтәрелү, үсү, мәшһүр булу, дан казану; авторитет һәм дәрәҗә. *Үсеп барган карьераның, коммуна начальниклары алдында казанган ышанычның бер көн эчендә кинәт җимерелүе генә борчыды аны.* Л.Гыйльми. *[Хашим әфәнде:] Сиңа кабат өйләнү турында, карьераң турында уйларга вакыт.* Г.Ахунов. *Әмма туган халкының язмышы аның өчен кадерлерәк булып чыккан. Шәхси карьера икенче планда калган.* Ә.Мәхмүдов

2) Билгеле бер өлкәдә эшләү, хезмәт итү. *Аның табиблык карьерасына юл ачкан сәбәпләрнең беренчесе аның үзенең «бүре зәхмәте» дигән җәнлекләр авыруына дучар булуы булган.* К.Тинчурин. *Әнә шул халык сынавын уңышлы үтсәң, иҗади карьераң да озын гомерле була.* Ватаным Татарстан. *Әгәр тулысынча сәламәт кеше булса, КЭЦ, ихтимал, педагог карьерасына канәгатьләнер иде.* Мәдәни җомга

**КАРЬЕ́РАЧЫ** *и.* Үзенең шәхси уңышы турында гына уйлаучы, үз мәнфәгатьләрен иҗтимагый эшләрдән югары куючы кеше, үз карьерасының үсеше өчен тырышучы. *Теңкәбезгә тигән карьерачы – Дәрәҗәгә менгән туң агай.* Ә.Баян. *Карьерачыга җитәкчелек урындыгы гына кирәк*

**КАРЬЕ́РАЧЫЛЫК** *и. к.* **карьеризм**. *Ни этәрде икән утыз бер яшьлек язучыны – заманының күренекле җәмәгать эшлеклесен – мондый әшәке эш эшләргә? Карьерачылыкмы, көнчелекме, даһиларны күралмаумы?* Р.Мостафин

**КАРЬЕРИЗМ** *и. фр.* Төрле юллар белән үзенең карьерасы өчен генә тырышу, хезмәттә күтәрелү, алга, үсешкә омтылышы. *Хезмәт положениесе белән файдалану һәм карьеризм фактларының тамырына балта чабыйк.* Ә.Фәйзи. *Гөлсем тагын бер нәрсәне искә алды: иренең һаман капитан булып йөрисе килмидер. Моны карьеризм, эгоизм ише төшенчәләргә кайтарып калдыру гына дөрес түгелдер, кеше кайда гына булмасын, нинди генә эштә эшләмәсен, ул – беренче чиратта, кеше. Ә кеше өчен алга, үсешкә омтылу хас бит.* Р.Кәрамиев

**КАРЬЕРИСТ** *и. фр. к.* **карьерачы**. *Карьеристлар, шөһрәт сөючеләр Киләкитә, китә, онытыла.* Г.Афзал. *– Сез аны карьерист иде димәкче буласыз? – Әйе, әйе, нәкъ үзе... Бик дөрес әйттегез. Карьерист иде, беткәнче карьерист иде, тик кызганыч, шул чакта мин аның йөзен менә болай дөрес итеп билгели белмәгәнмен... Заманга бик оста яраклашкан акыллы карьерист иде шул! Коточкыч кеше!..* Ф.Әмирхан. *Файдалы танышлык – карьеристлар эше, герой-адмирал исә – романтик.* М.Юныс

**КАРЬЕРИ́СТКА** *и. к.* **карьерачы**

**КАРЬЕРИСТЛЫК** *и.* Үзе өчен уңыш, алдынгылык казаныргa омтылыш

**КАРЬЯ** *и. гар. иск.* Авыл. *Хәлфәбез тотты да мәдрәсәбезне, мәдрәсәбезне генә түгел, карьябезне ташлап каядыр китте.* Ә.Еники. *Бишенче шарт шулдыр: мөсафирга ляземдер, кайу шәһәргә яки карьягә барса, мөмкин кадәр олуглар йортына төшәргә яки олуглар илән өлфәт итәргә, димешләр.* Ф.Халиди. *Күрше-тирә карьялардән шундый хәбәрләр ишетелеп тора.* С.Рафиков

**КАРЬЯЛЕ** *с.* Авылдан килгән, авыл кешесе, авылныкы. *Карьяле кызлар*

**КАР-ЯҢГЫР** *и.* Явым-төшем. *Күкләрнең пәрдәсе чишелеп, Яуса да карянгыр ишелеп, Эткәләп яисә төрткәләп Рәнҗетмәс табигать кешене.* Р.Низамиев. *Чынлап та, балчык ызбасын кар-янгырдан саклап утырган такта түбәнең кыегын кыекка аергач, шактый зур булып чыктылар.* К.Миңлебаев. *Сипли алсак йортны, түбәбездән Кайгы үтмәс – акмас кар-янгыр ---.* Ә.Баян

**КАС** *хәб. сүз. гар.* Үч, каршы, биграк тә дошман; үзара ызгышкан, үчеккән, дошманлашкан хәлдә. *Шырпы кулга кас, кылыч кынга кас.* Мәкаль. *Ике яхшы кас булмас, ике яман дус булмас.* Мәкаль

◊ **Кас дошман** Җан алучы дошман, эзәрләүче, явыз, кара дошман. *Караңгы төндә йөргәнемдә Кара этләр мине абайлый; Кас дошманнар мине әй сагалый, Хода ихтыяр итми, аралый.* Җыр

**КАСАБА** *и. гар.* Шәһәрчек, зур авыл, бистә. *Касаба халкы әйтүенчә, әгәр эчү белән мавыкмаса, әни кеше малаен иртәрәк тә тапкан булыр иде.* Өмет

**КАСАВӘТ** *и. гар. иск.* Караңгы чырайлылык, күңелсезлек, сүрәнлек, кайгылылык. *Касавәт кәлмәйүр кальбә: сәнең шигъриң мөнафиһа ---.* Г.Тукай

**КАСА́ТИК** *и. лат. бот.* Касатиклар семьялыгыннан күпьеллык үлән үсемлекләренең бер төре; ирис, сусын. *Ирис (касатик) – тармакланучан тамырсабаклы, яхшы кышлый торган үсемлек.* Йорт эшләре

**КАСА́ТКА** *и. лат. зоол.* Карлыгач кошлар семьялыгыннан, яр карлыгачы, керәшә

**КАСӘ** *и. фар.* 1) Кисек конус формасындагы тоткасыз чынаяк, йомры (чәй, варенье, шикәр һ.б. салына); җам, җамаяк. *Тирән яшел касә төбендә ялтырап яткан көзге кебек, кечкенә генә түп-түгәрәк күл.* Г.Сабитов. *Газзә түти чәчәкле касә белән Сәйфулла алдына сөзмә дә китереп куйды.* Ә.Еники. *Әче бал салынган касә табынны бер әйләнеп чыккач кына җанлану башланды.* Я.Хамматов. *Түшәкне ул Үргәнечтән җибәргән иде, касәләрне Бохарадан, чапаннарны, кием-салымны Сәмәркандтан.* М.Хәбибуллин

2) Гомумән, эчемлекләр салына торган кечкенә савыт. *Нигъмәтулла әфәнде, хадимне чакырып алып, тагы берәр касә кофе китерергә кушты.* З.Бигиев. *Алар хрусталь касәләрен чәкештергәннән соң озак чыңлатып торып эчеп җибәрделәр.* Ш.Маннур. *Иртән аңа шул ук әнисе бер касә арак бирде, бер чүмеч кымыз, тутәрәме белән ит китерде.* М.Хәбибуллин

3) *бот.* Чәчәк таҗы астында үзара тоташып үскән яшел яфракчыклар бөҗрасы. *Чәчәкләре ачык ал төстә, биш аерчалы, таҗы һәм касәсе тар көпшәгә тоташкан, баш-башлары бөгелмәле.* Урман аптекасы. *Гөлҗимешне кырау төшкәнче җыялар. Җимешләрен киптерәләр, касә яфракчыгын киптергәннән соң гына кубарып алалар, чөнки алардан башка җимеше тиз бозыла һәм кукси.* Бакчачы белешмәсе

4) *күч.* Нәрсәнең булса чиге, сыйдыра алу мөмкинлеге. *Әҗәл касәсе дәхи тулмыш иде.* Дастан

**КАСӘМ** *и. гар. иск.* Вәгъдә, ант. *Анам киткәч, бу шәхес миңа әйтте: – Касәм эч, дөньяда гомерем булганча адәм балаларына зарарымны тигерермен, – дип, мәңа касәм эчерде.* Ф.Халиди

◊ **Касәм итү** Ант итү, вәгъдә бирү. **Касәм эчү** Ант эчү, ант итү. *Һәм ничә касәм эчеп рәҗа кылдым.* Ф.Халиди. *Аем ханым ничә касәмнәр эчеп әйтте: – Мәнем атамнан асыл хәбәрем юк, – диеп.* Ф.Халиди

**КАСД** *и. гар. иск.* 1) Теләк, омтылыш, максат, ният, кызыгу. *Аннан соң мин үземдәге кәефле каушауны көчләнеп җиңдем дә Аляның күзләрен үбәргә омтылмакчы булдым; ләкин нәкъ шул вакытта ул күзләрен миңа күтәрде дә, оялып, иркәләнеп, минем касдымны белгән шикелле итеп карады.* Ф.Әмирхан. *Бай булу касды белән гомреңдә күпме шартладың? Алдашып җыйган малыңны ни рәвешле капладың?* М.Га-

фури. *Мин теләмәдем баерга, һәм дә касдым булмады, Юк, кирәкми матди байлык, чөнки рух бай булмады ---.* Г.Сөнгати

2) Явыз ният, теләк, уй, үч, план. *Җаныма касд әйләмәздем хәсрәтемдән гяһе гяһ ---.* Г.Тукай. *Вирмә күңелең сандыгын шайтан әленә кем, аның Касды – иманыңда вә җаныңда вә каныңдадыр...* Ш.Зәки

**КА́СДАН** *рәв. гар. иск.* Юри, аңлы рәвештә, белә торып, хәйлә белән. *Сагышың шул кадәр касдан, басып өстән дә һәм астан, Көчәйтте дәрт белә хастам, ничә кәррә, ничә катлар.* Г.Кандалый. *Юк, бәлки ул [туташ] онытып түгел, касдан калдырып киткәндер рәсемен.* Ф.Әмирхан. *Беләсеңме, касдан һөҗүм шәригатьтә Йөридер үтерү белән бер рәттә. Әлбәттә, син явызга кыйсас лазем, Калсын бу эш башкаларга гыйбрәткә!* М.Гафури

**КА́СД ИТҮ** *ф. иск. к.* **касд кылу**. Максатка омтылу, теләү. *Ләйләнең кабиләсе Мәҗнүнне үлдерергә касд итеп, атасы, моннан агаһ булып, улын әзләгәләп йөрде.* Дастан. *Бу баланың атасы, бичара, кәмале мәхәббәтеннән үзене дәрьяга атмак касд итте, көймә халкы аңлап, моны тотып бәйләделәр.* К.Насыйри. *Аның ул куәсенә өмидемез кямил, касд итсә, мотлак, булдырачак.* Г.Исхакый

**КА́СД КЫЛУ** *ф. иск.* 1) Һөҗүм итү, һөҗүмгә бару, һөҗүмгә килү. *Төшендә күрде кем, Таһирнең дүрт ягын кара этләр килеп камалап, Таһиргә касд кылдылар.* Дастан. *Бүре дә юлдашына касд кылмас.* Мәкаль. *Сәнәкләр, мылтыклар, этләр – барчасы моңар [аюга] касд кылалар.* Г.Тукай

2) Нәфес сузу, үчегү, усаллану, явызлану, яман нияттә, теләктә тору. *Син инде, киявем, эчтән уйлагансың, бу падиша мине касд кылып, үтерер өчен бу сәяккә, богага, каракошка, Барса Килмәс падишага йөрткән, дип. Мин касд кылудан җибәрмәдем сине.* Дастан. --- *Алар Йосыфның биленә бау тактылар, Үзләренең бәгыренә ут яктылар, Шул коега төшерергә касд кылдылар, – Йосыф ялварса, барсы аны сүгәр имди.* Кол Гали

3) Билгеле бер максатка омтылу, теләү. --- *– Әгәр атам мине гайре кешегә касд кылса, үземне һәлак кылырмын, – дип, кауле карар вә видаг кылыштылар, вә антлар итеп бер-берсен ышандырдылар.* Дастан. *Кочаклап үбим дип касд кылды.* К.Насыйри

4) Кул салу. *Нигә бездән үч алырга... Кеше бәхетенә касд кылганчы, Аллаһы Тәгаләдән үзенә сораса ни булыр иде...* Г.Ибраһимов

**КАСДЛЫК** *и.* Касд (*2 мәгъ.*) булу, үчлек. *Кешегә касдлык итү*

**КАСИК** *и. исп.* 1) Мексика, Вест-Индия һәм Үзәк Америкада индеецларның юлбашчысы, кабилә башлыгы

2) Испания һәм Латин Америкасының кайбер илләрендә берәр өлкәдә ихтирамга лаек, абруе, авторитеты булган кеше

**КА́СКА** *и. фр.* Гаскәриләр, төзүчеләр, высотниклар, янгын сүндерүчеләр, металлурглар, спортчылар һ.б. кия торган шлемга охшаган, башны пулялардан, ярчыклардан, бәрү-сугулардан саклау өчен, металлдан, пластмассадан эшләнгән тирән баш киеме. *Кухняга килгәч, ул аңа такта өстенә калган ботка салып бирә, каяндыр табылган немец каскасына су да салып куя.* Ә.Еники. *Таптыйк дошманны, Тере калмасын; Немец каскасы Җирдә аунасын.* Ф.Кәрим. *Шул секундта ике зәһәр пуля яньчеп үтте корыч каскамны.* М.Җәлил

**КАСКАД** *и. фр.* 1) Табигый рәвештә елга агымы буйлап киртәләр аша баскычланып төшә торган шарлавыклар яки ясалма шарлавыклар системасы

2) *спорт* Берәр нәрсәдән төшүне имитацияләгән акробатик ысул, алым (киртә аша, турникет, велосипед, аттан төшү алымы)

3) *муз.* Опереттада: җыр белән кушылып килгән тиз, кызу бию

4) *тех.* Бер-бер артлы тоташтырылган элементлардан торган механизм, корылма, җайланма. *Ә гидроэлектростанция каскадын нишләтергә? Анысын да туктатыргамы? Юк, алар эшли бирә. Моның өчен Севанга Варденис сырты артыннан аккан Арпа елгасының суын кушарга булалар.* А.Муранов. *Моңа өстәп, тыныч кына агып яткан елгаларда (мәсәлән, Идел) электр станцияләре каскады төзү һәм шуның аркасында иң уңдырышлы күпме кара туфраклы җирләрне су астында калдыруны да әйтергә мөмкин.* С.Шәмси

5) *физ.* Электр лампасыннан яисә ярым үткәргеч прибор һәм радиоэлементтан торган көчәйткечнең бер өлеше

6) *күч.* Бер-бер артлы килеп торган күренешләрнең алмашынып, чиратлашып торуы, берәр нәрсәнең күплеге һәм ашкынулы, тыелгысыз, өзлексез, тоткарсыз көчле агышы. *Бер якта --- ялгызлык. Икенче якта музыканың мәһабәт каскадлары.* Ш.Хөсәенов. *Югары пилотаж фигураларын башкару өчен, Анисимов чакырылды. Ул --- фигуралар каскадын уңышлы башкарып чыкты.* С.Баттал

**КАСКАДЁР** *и. фр.* 1) Кинофильмнарда артистны алыштырып, физик һәм техник яктан әзерлеге җитәрлек булган, катлаулы яки тормыш өчен куркыныч булган трюкларны башкаручы кеше. *– Актёр һәм каскадёр Алик Гөлханов үзе дә ятимлек ачысын татыган. Хачик, үзе әйтмешли, экстремал бит ул. – Яшь чагында каскадёр булмагандыр бит?* Җ.Юнысов. *Ничә кинода уйнаганын хәтерләми дә инде. Утызынчыдан соң каскадёрлар санамый, ди.* Кәеф ничек?

2) Циркта акробатик элементларны (каскадларны) башкаручы кеше

**КАСКАДЛАП** *рәв. физ.* Каскад итеп берләштереп, бер итеп. *Каскадлап тоташтыру*

**КАСКАДЛА́У** *ф.* Табигый я ясалма киртәләр ясау, баскыч, яруслар ясау

**КАСКАДЛЫ** *с.* Табигый яки ясалма киртәле, баскычлы, яруслы. *Стильләрнең (ысулларның) каскадлы таблицалары CSSны өйрәнәбез*

**КА́СКАЛЫ** *с.* Каскасы булган; каска кигән. *Ә бәрәңге бакчасының Тирәсе – яңа читән; Каскалы сакчылар сыман, Һәр казык чүлмәк кигән.* С.Баттал

**КАСКЕТ** *и. фр.* Франциядәге хәрбиләрнең баш киеме

**КАСКЕ́ТКА** *и.* Фуражка тибындагы, җиңел, җәй көне генә киелә торган

баш киеме. *Килүченең кулында винтовка, үзе мәче кебек посып атлый, зәңгәрсу-соры каскеткасына кара канат кыстырган.* Г.Әпсәләмов

**КА́СКО** *и. ит. икът.* Җир өсте, җир асты, һава, су транспорты чараларын страховкалау (самолёт, пароход, корабль, машина, вагон, цистерна һ.б.)

**КАСМАК** *и.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса савыт төбенә утырган, көеп ябышкан калдыгы, калган өлеш. *Минһаҗ шаярып: – Их, Гөлбану касмак яраткан икән! Туе нинди буранга туры килә, – ди.* Г.Ибраһимов. *Касмак кыру. Ботка касмагы. Сөтнең касмагы*

2) Кабык булып ябышкан юка катлам. *Хлорид кислотасын металларны тутыктан һәм тимер касмагыннан чистарту өчен файдаланалар.* Химия

3) *хим.* Югары температурада тимер һәм тимер эретмәләре оксидлашу продукты (нигездә, тимер оксидларыннан FeO... $Fe_2O_3$ ($Fe_3O_4$) тора). *Ул [фильтр] ком, тимер касмагы кебек катышмалардан, өлешчә хлор, авыр металл калдыклары, гербицид, нефть калдыкларыннан чистарта.* Химия

4) Имчәк баланың башында була торган кабык, кабырчык

5) Тәңкә. *Баягы аждаһаны чапкан чакта, бер касмагы анда калды, ул касмак казан булды.* Дастан

6) *диал.* Өре, элпә. *Шулпа касмагы. Кайнаган сөт өстендәге касмак*

**2.** *с. мәгъ. диал.* Шапшак, җыйнаксыз

**КАСМАКЛАНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **касмаклану**

**КАСМАКЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Касмак, кырындык белән каплану; пычрану. *[Кыз] Чәченә ямьсез «химия» ясаткан (ул әле касмакланып, төрле якка тырпаеп тора!) ---.* Х.Ибраһим. *Аның стеналары касмакланып купкан, шунлыктан ул, кырык ямаулы иске чикмән төсле, алаша булып күренә.* Г.Бәширов. *Гәүдәсе бөкрәйде, күз кырыйлары эренләп касмакланды, тәне каралды...* Я.Зәнкиев. *Иданнәре касмакланып каткан авыл советларына, идарәләргә барып керсәң, анда зәңгәрсу гәләфи чалбар балакларын гармун-кунычларга тыгызлап тутырган тук, кызыл чырайлы вәкилләр утыра.* А.Гыйләҗев

2) Берәр кайнаган сыеклык, шулпа өстенә күбек, өре җыелу

3) Кабык, кабырчык белән каплану

**Касмаклана башлау** Яңа гына бераз касмаклану

**Касмакланып бетү** Бик нык касмаклану, тәмам касмакланган хәлгә килү. --- *Бу җиңнәр хәлфәгә кульяулыгы хезмәтен үти, ахры, касмакланып беткәннәр.* К.Нәҗми

**Касмакланып китү** Кинәт кенә касмаклану

**Касмакланып тору** Берөзлексез, һәрвакыт касмаклану

**КАСМАКЛЫ** *с. сөйл.* Касмагы булган. *Без, кызгылт касмаклы рус капкалап, корсакны ныгытып алдык та, сумкаларны эләктереп, Петя белән бергә русча белем алырга киттек.* М.Рафиков

**КА́ССА** *и. ит.* 1) Акчалар һәм кыйммәтле кәгазьләр саклана торган урын. *И-и, күпме интектем шул кассадагы акчага кызыгып!* М.Насыйбуллин. *Кибетчеләр зар елыйлар: [Закир] кассадагы акчаны ала да чыга да китә, чыга да китә, диләр.* Г.Камал. --- *Ике көн элек мин кергәндә, кассада егерме бишлекләр түгел, унлыклар да санаулы гына иде бит.* М.Насыйбуллин

2) Түләнгән акчаның суммасын талонга, чекка суга торган аппарат, шулай ук аппарат һәм хезмәткәрләр урнашкан урын, кабинка. *Аптекада кеше юк диярлек. Касса алдында --- урта яшьләрдәге мыеклы бер ир басып тора.* Г.Сәгыйров. *Юлия Михайловнаның кассада утыруы безнең өчен бик җайлы иде бит.* А.Расих. *Өстәлгә калын кәгазьдән эшләнгән бер бәйләм касса тасмасы һәм төймәле зур счёт куйды.* М.Насыйбуллин

3) Учреждениенең, предприятиенең, оешманың финанс операцияләр (акча алу-бирү, билет сату һ.б.) алып барыла торган бүлеге. *Кәлимәнең тизрәк кассага йөгерәсе, иртәгә булачак шул ук концертка билет аласы килде. Билетлары да театр кассасында сатылмый.* К.Тимбикова. *Аның һәр сукбай чиратта басып торган билет кассасы янына барасы да килмәде.* Ә.Мәхмүдов. *Беркөн менә, кулга акча төшкәч, Ирешергә уйлап морадка, Билетка дип театрга барам. Керәм. Касса. Басам чиратка.* М.Хөсәен

4) Финанс операцияләре алып барыла торган бүлекнең урнашкан бинасы, эш бүлмәсе яки эш өстәле, эш тәрәзәсе. *Керсә, ни күзе белән күрсен, коридорда гомергә булмаганча ут яна, касса бүлмәсенең һәрвакыт бикле торган ишеге шар ачык.* М.Насыйбуллин. *Кассаның озынча түгәрәк тәрәзәсеннән кассир кызның шома итеп таралган чәче, чәч өстендә энҗеле калфагы күренеп тора иде.* Г.Шәрипова. *Сине аулакта бер кат ашатып, көйләп алганнан соң, касса тәрәзәсенә бастым да яшен суккан агачтай миңгерәүләнеп калдым: кул сумкасыннан акчаларымны урлаганнар!* Р.Низамиев

5) Кредит учреждениеләренең, гадәттә саклык банкының гади сөйләмдәге атамасы. *[Илдар:] --- Саклык кассасында да мең ярым сум запасыбыз бар бит, әнкәй, я, нәрсәгә җыясыз ул байлыкны?* Ю.Әминов. *Менә шундый хәлдә, йөрәге белән инде кемнедер берәүне эзләп йөргән чакта, ул район саклык кассасында эшләүче Нажия исемле кызны очратты.* Ә.Еники. *Мин ашыгып кына җыена башладым, саклык кассасындагы таныш хезмәткәргә чылтыраттым (безнең кассабыз бик тыныч, кечкенә, кайвакытта аларда акча да булмый, зур сумма аласы булганда алдан әйтүне үтенәләр).* М.Мәһдиев

6) Учреждение, предприятиенең, оешманың кыйммәтле кәгазьләре, акчасы. *Кассадагы дәүләт акчасының һәр тәңкәсенә хәтле белергә тиеш ул.* М.Насыйбуллин

7) *махс.* Типографиядә шрифтлар алфавит тәртибендә тутырып куелган күп оялы тартма, әрҗә. *Идән чүп-чар белән тулды, кассалар таптап изелде, басу станоклары сафтан чыгарылды, хәрефләр түгелде-чәчелде, конфискацияләнде.* Ш.Рәкыйпов. *Күк күлмәген кигән наборщиклар Кассаларга килеп бастылар.* М.Крыймов. *Хәреф кассалары тирәсендә чуалгалыйм, хәреф җыярга өйрәнеп маташкан булам.* Ф.Хөсни

8) *күч.* Акча. *Әти мине кешегә санамый, бер сүз әйтми, арага кертми, кассасын гына миннән саклый, якын җибәрми, сату иттерми.* Г.Әпсәләмов. *Әйтерсең кассирның башы ике дә, аның кулындагы касса – төпсез тоба.* М.Насыйбуллин. *Бәйрәм җиткән. Акча кирәк – касса коры.* Г.Тукай

**КАССА́НДРА** *и. гр.* 1) Борынгы грек эпосында Троя патшасы Приамның кызы

2) *бот.* Арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел куакларның бер төре, поляр өлкә буендагы сазлыкларда, дымлы төньяк урманнарда үсә; сарыклар һәм кәҗәләр өчен агулы үсемлек

**КАССАП** *и. кит. иск.* 1) Мал суючы эшче. *Сарыкның үлеме кассаптан.* Мәкаль. *Карап торып өйрәнеп булса, эт кассап булыр иде.* Мәкаль. *Кәҗәгә җан кайгысы, кассапка мал кайгысы.* Мәкаль

2) Мал сую белән шөгыльләнә торган урын, сугымханә (бойня). *[Хәсәнша] мойкада йон юуны тикшерә, кассапта мал суюны караштыра.* Ш.Камал

**КАССАПЧЫ** *и. ялг. к.* **кассап** *(1 мәгъ). Кассапчыга май кайгы, Кара кәҗәгә җан кайгы.* Мәкаль

**КАССАПЧЫЛЫК** *и.* Кассапчы эше, кассапчы һөнәре

**КАССА́ТОР** *и. юр.* Беренче баскыч судның карарын үзгәртүне таләп итеп, судның икенче (югары баскыч) инстанциясенә шикаять биргән зат

**КАССАЦИОН** *с.* Кассациягә бәйләнешле. *Кассацион шикаять. Кассацион тәртиптә эшне яңадан карау*

**КАССА́ЦИЯ** *и. лат. юр.* 1) Югары судның түбәнге суд органы чыгарган хөкем карарын яңадан каравы һәм шуның рәсми тәртибе

2) *сөйл.* Суд карарыннан ризасызлык белдереп, югарыдагы судка яңадан карауны сорап бирелгән шикаять. *Кассация бирү*

**КАССЕТ** *и. сөйл. к.* **кассета**. *Озерцов уйланып яткан җиреннән торды да, чиста кассет алып, магнитофонына куйды һәм кнопкага басып җибәрде* ---. Р.Мөхәммәтҗанов

**КАССЕ́ТА** *и. фр.* 1) Рәсемгә төшерү вакытында фотография пластинкаларын яки фото- һәм киноплёнкаларны сала торган, яктылык тәэсиреннән саклый һәм яктылык үткәрми торган футляр. *Фоторәсем төшерүгә хәзерлек кассеталарны һәм аппаратны корудан башланып китә.* Фотосөючe. *«Киев» аппаратының кассетасын кору өчен, билгеле бер күнегү таләп ителә.* Файдалы киңәшләр

2) Магнит лента бер катушкадан икенче катушкага уралган, ике ягына да информация язылган магнитофон ленталарыннан һәм яссы ябык тартмадан гыйбарәт предмет. *Сейф киштәләрендә кәгазь тасма рулоннары, магнитофон кассеталары бар иде.* А.Тимергалин. *Егет, өр-яңа ак күлмәген, әйбәт костюм-чалбарын киеп, машинасына сәхнә йолдызының кассеталарын көйләп, чакырган җиргә китте.* Э.Шәрифуллина. *Ферромагнитик тасма кассетага, металл яки пластмасса бөкәнгә тигез һәм тыгыз итеп чорналырга, тыгыз катыргыдан ябыштырып ясалган тартмага салып куелырга тиеш.* Файдалы киңәшләр

3) Бомбардировщикларда: бер-бер артлы бомбалар төшерү өчен җайланма. *Самолётлар, вак бомба тутырылган кассеталар ташлап, мөмкин хәтле күбрәк үтерергә тырыштылар.* Ш.Маннур

4) Бертөрле предметларны, детальләрне, материалларны саклау һәм күчереп йөртү өчен махсус җайланма. *Иң гади конструкцияле бал агызгычларда кассеталар барабанга беркетелеп куела.* Умартачылык. *Әгәр кассеталарны артык тиз әйләндермәсәң, кәрәз умартачылар бик ярата торган бу операциягә дә бирешми, үзенең 3–4 кг балын хуҗасына биргәч, кабат тулу өчен, яңадан корт оясына әйләнеп кайта.* Үсемлекләр һәм бал кортлары

**КАССЕ́ТАЛЫ** *с.* 1) Кассетасы булган, кассета уйната торган. *Кассеталы видеомагнитофон*

2) Кассеталарга урнаштырылган. *Кассеталы бомбалар*

**КАССИР** *и. нем.* Акча кабул итү, бирү, кыйммәтле кәгазьләр, билет сату һ.б. операцияләр башкаручы касса хезмәткәре. *Вәгыйзь Каюмов белән танышканда, автотранспорт конторында кассир булып эшли идем.* М.Насыйбуллин. *Бухгалтер бит ул касса белән эш итми. Касса – кассирда.* М.Мәһдиев. *Кассирның хәтта кечкенә генә станциядә эшләүчесенә дә никадәр күп сандагы билетлар белән эш итәргә туры килүен уйлап та карамыйлар.* Кызыклы математика

**КАССИРЛЫК** *и.* Кассир эше. *Сания кулындагы дәфтәрне өстәлгә куеп, урынына утырырга өлгермәде, мәктәптә секретарьлык һәм кассирлык хезмәтен алып баручы ханым аңа зур конверт китереп тоттырды.* М.Әмир. *Мәчеттә кассирлык эшен искиткеч төгәллек белән башкара.* Безнең гәҗит

**КАССИ́РША** *и. рус сөйл.* Кассир булып эшләүче хатын-кыз. *[Бану:] Кассирша булып гомеремне черетмәс идем. Туйдым кассирша булудан. Көнозын акча санап утыр, имеш.* Р.Ишморат. *Таракан ашаган кумәч шикелле кытыршы битле бер хатын кассирша булып, картасын бер тиеннән лото карталарын сата башлады.* К.Тинчурин. *Исәпхисапны өзгәч, яшьләр сөенешеп, кассиршага рәхмәт әйтеп чыгып китте.* Р.Батулла

**КАССИТЕРИТ** *и. гр. хим.* $SnO_2$ – аккургаш минералы; коңгырт яки кара төстәге алмазсыман ялтыравыклы матдә; аккургашташ

**КА́ССИЯ** *и. лат. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел, куак яки зур булмаган агаччыл үсемлек

**КАСТ** *и. гар. иск. кит.* 1) *к.* **касд** (*2 мәгъ.*). *Яхшының дусты күп, яманның касты күп.* Мәкаль

2) *диал.* Хәстәрен күрү, алдан чарасын күрү. *Кастын күрсәң, хет нинди эшне дә булдырасың аны*

**КА́СТА** *и. португ.* 1) Һиндстанда һәм кайбер Көнчыгыш илләрендә үзләренең чыгышлары, кәсепләре, иҗтимагый хәлләре буенча аерылып, башкалар белән якын аралашмый торган кешеләр даирәсе, ябык иҗтимагый группа, социаль катлам. *Бер төр һөнәр кешеләре, һинду дине күрсәтүе буенча, аерым каста тәшкил иткән.* М.Мәхмүтов. *Һиндстан халкы дүрт кастага бүленгән. Югары кастага*

*брахманнар, икенчесенә сугышчылар, өченчесенә крестьяннар һәм сатучылар, түбән кастага ялчылар кергән.* Урта гасыр тарихы

2) *күч.* Башкалардан читтә торып, үзенчә генә яшәүче иҗтимагый төркем, катлам. *Партноменклатура дип әйтергә генә җиңел, бу бит үзенә күрә бер академия узган каста.* Р.Мөхәммәдиев

**КАСТА́** *и. диал.* **1.** Авыру, чир, хаста, сырхау. *Мөҗип кызышып авырып ята икән. Сәйфетдин аны юатып әйтә икән: – Зарар юк, каста үтә дә китә, үләргә генә булмасын.* Н.Исәнбәт. *Аннан соң, кастаны бетереп булмасмы дим. Казан кебек калада духтырлар бирәдәгеләргә пар булмаслар.* Э.Касыймов

**2.** *с. мәгъ.* Авыру, чирле, сырхау, хаста. *Каста бул минем өчен, Үлием синең өчен.* Мәкаль. *Каста кеше*

**КАСТАЛАНУ** *ф. диал.* Авыру, чирләү, хасталану. *Абзыең үзе касталанып ята. Айшә базарга китте.* А.Расих

**Касталанып алу** Бераз вакыт авыру

**КАСТАЛЫ** *с. диал.* Авыру, чирле кеше. *Минем койрык бәйләнмәгән. Касталы кешене кайда да тота алмыйлар...* Э.Касыймов

**КАСТАНЬЕ́ТАЛАР** *и. исп. муз. күпл.* Биегәндә ритмлы шакылдату өчен бармакларга киелә торган махсус агач (пластмасса) шакылдавыклар; музыка коралы. *Йөрәкнең иң сизгер урынына китереп бәрүче алты кыллы испан гитарасы, кастаньеталар (кастаньо – каштан чикләвеге) шакылдавы... У-у-ух! Әйттер, кызым!..* М.Юныс

**КА́СТАЧЫЛЫК** *и.*1) Каста йомыклыгы. *Кастачылык калдыклары*

2) *күч.* Чикләнгәнлек, тарлык. *Фәндә кастачылыкны бетерү*

**КАСТЕЛЯН** *и. лат.* 1) Урта гасырлар Франциясендә сеньор, феодал крепостеның хуҗасы

2) Урта гасырларда күп кенә Көнбатыш Европа илләрендә феодал крепостен, җәмәгать бинасын күзәтеп торучы, саклаучы кеше

**КАСТЕЛЯ́НША** *и. рус* Урын-җир һ.б.ш. белән тәэмин итүче хезмәткәр (хастаханәдә, тулай торакта, кунакханәдә һ.б.). *– Бар андый бирәү! – диде дә кастелянша ап-ак җәймәләрне киштәгә куйды.* Р.Батулла

**КАСТЕТ** *и. фр.* Бармакларга киерү өчен тишекләре булган, учка йомарлана торган авыр металл пластина; салкын коралның бер төре. *Озерцов, кулына алган сигаретын өстәл тартмасына куеп, Чехиревка усал итеп карады да өстәлгә бер-бер артлы кастет, пәке, кульяулык чыгарып куйды.* Р.Мөхәммәтҗанов

**КА́СТИНГ** *и. ингл.* 1) Балыкчыларның кирәк-яраклар белән техник яктан эш итә белүен сынау өчен махсус күнегүләр кертелгән спорт төре; спиннинг белән еракка һәм төз ыргыту буенча ярышлар

2) Актёр, модель һ.б.ш. һөнәр кешеләрен аерым максаттан чыгып сайлап алу. *Кастингта катнашу. Баш рольгә актёр билгеләү өчен кастинг уздыру*

**КАСТОР МАЕ** *и.* Кастор үләне орлыкларыннан алынган үсемлек мае; ачык сары яки төссез куе сыеклык. *Кастор мае – эч йомшарту өчен (көчлерәк тәэсир итә).* Файдалы киңәшләр. *Кастор мае чәч өчен иң яхшы май булып санала.* Йорт эшләре

**КАСТОР ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Африкада, Һиндстан, Америка, Төньяк Италия, Россиядә үстерелә торган, сөтлегәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык агачсыл үсемлек; орлыкларыннан кастор мае алына; *русчасы:* **клещевина**

**КАСТО́РКА** *и. сөйл. к.* **кастор мае**. *Әгәр югач баш тиресе тартылып торган кебек булса, мамык кисәген җиңелчә генә җылытылган майга (касторка, прованс яки чистартылган көнбагыш маена) манчып, чәч төбен һәм чәчне бераз гына майларга кирәк.* Йорт эшләре

**КАСТРАТ** *и. лат.* 1) Печелгән ир кеше

2) Нечкә, югары тавышлы җырчы ир кеше *(XVI–XVIII гасырларда Италиядә опера театрларында һәм чиркәүләрдә җырлаучыларның тавышлары нечкә һәм югары тонда булсын өчен (сопрано яисә меццо-сопрано), кечкенә вакытта аларны печә торган булганнар)*

**КАСТРА́ЦИЯ** *и. лат.* Печү – хирургия юлы белән ата һәм ана хайваннарның җенес бизен алу яисә аларның функцияләрен башка ысуллар белән туктату

**КА́СТЭРД** *и. ингл. кулин.* Сөт белән каты чәйдән һәм күкәйнең сарысы белән шикәр комыннан ясалган, сыек татлы крем рәвешендәге кайнар десерт

**КАСЫЙД** *и. гар. иск.* Хәбәр китерүче

**КАСЫЙДӘ** *и. гар.* 1) *кит.* Шәрык поэзиясендә ода формасында, мактау яисә үгет-нәсыйхәт характерындагы, баштан ахырына кадәр бер рифмага тезелгән озын шигырь. *Бу Габделмән [үз] заманасының билгеле кешесе булган дип уйларга кирәк. Аның турында Сәфәр мелла Салих углы да бер касыйдә (мактау шигыре, мәдхия) язган.* Х.Хисмәтуллин. *Кара такталар тоткан ачык йөзле кечкенә шәкертләр тезелеп --- касыйдәләр укый башладылар.* Х.Кәрим

2) *иск. этн.* Кызлар исеменә мәдхия, ода язуы яшерелгән бөти (кызлар аны чәчүргечкә тагып йөрткәннәр). *Чәчкә касыйдә тагу*

**КАСЫЙР** *с. гар.* Кыска, ким, җитешмәгән; дефектлы, кимчелекле

**КАСЫК** *и.* Гәүдәнең корсактан түбәнге өлеше белән бот төбе арасы. *Икенчесе әллә ике, әллә өч мәртәбә касыкка тибеп алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Минә бер заман аның тын алуы җиңеләеп киткәндәй булды, касыктагы каты авырту юкка чыкты.* Н.Фәттах. *Урам чатындагы карт чаганнар күләгәсендә гамьсез йоклап яткан Дамир, ишекне ачып, касыгына ике-өч төртмичә күзен ачмады.* Х.Хәйруллин. *Касыгына төрттеләрмени, Каюм урынынан сикереп торды, юрганын ачып ташлады.* Г.Шәрипова

**КАСЫРКА** *и. диал.* Үрмәкүчсымаңнар классыннан буынтыгаяклы бер хайван; урман бете

**КАТ** I *и.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса өстен каплап тора торган әйбернең бер катлавы, катлам; яссы җисем (саннар яки аергычлардан соң гына кулланыла). *Мирхәйдәр абзыйга өйалдын икенче кат такта белән әйләндереп, ике такта арасына пычкы вагы тутырып, өстәмә бүлмә ясарга туры килде.* Ә.Фәйзи. *Башымда бер кат яулык кына*

*булуга карамастан шабыр тиргә баттым.* Р.Хафизова. *Шәһидә алай итте, болай итте, яз җитүгә, Муллагалигә бер кат күлмәк, чалбар юнәтте.* А.Расих. – *Укырга ирек бирмиләр!* – *дип, ачу белән үзалдына сөйләнде Коля һәм, тәрәзәнең ике катын да ябып, китабына иелде.* Җ.Тәрҗеман

2) Бинаның, корылманың аслы-өсле торган бүлемнәренең берсе. *Гыймазовлар йортның аскы катында торалар иде.* С.Рафиков. *Тугызынчы каттагы бер кешелек бүлмәгә кайтып кердем.* Р.Мөхәммәдиев. *Китапханә белән уку залы зур йортның икенче катын биләгән икән.* И.Туктар

**2.** *рәв. мәгъ.* Мәртәбә, тапкыр. *Җиде кат үлчә, бер кат кис.* Мәкаль. *Мин бу вакыйганың ничек булганын, бер нәрсәсен дә калдырмыйча, баштанаяк, тагын бер кат сөйләп бирдем.* А.Шамов. *Тагын бер сыйфат: һич тә беткәнче ашыйсы түгел, ә иртәнге аш вакытында бер кат тамак ялгап алгач туктыйсы.* М.Мәһдиев. *Шәһит җиргә төшәргә әзерләнде һәм очар кошлар биеклегеннән тагын бер кат әйләнәтирәгә күз салды.* Ф.Латыйфи

**КАТ** II *и.* 1) *иск.* Тартым яки килеш кушымчалары белән генә кулланыла: нәрсәнеңдер яны, турысы, аңа якын торган урын. *Шул вакыт мәчет катында дөм сукыр бер карт тора.* Г.Тукай. *Ул, тупаслыкка каршы тупаслык белән җавап бирер өчен, офицер хатынын өстәл катына чакырып китереп, стаканның китеген күрсәтте.* К.Тинчурин. *Фәрдәнә апа да, елаганын күрсәтмәс өчен, тәрәзә катына китеп басты.* Р.Хафизова

2) Кем дә булса тора торган, яши торган урын. *Кияү --- кыз катына кичкич кенә барып йөри.* К.Насыйри. *Атлар катына йөгереп килсәм – атлар юк! Менә агай, йөдәдем бит.* Х.Кәрим. *Әгъләмне шул Исхак үтергән, дигәч, түзмәдем, туган, сезнең катыгызга килдем.* С.Рафиков

3) Кемнең дә булса алды, каршысы. *Гүя син патроннар салып Торасың минем катта.* Ф.Кәрим. *Бер туку станогы янында өч-дүрт ир кеше басып тора иде, Хәлим алар катына да туктыйсы итте.* И.Гази. *[Туктар] Сәрхушлегенең аргы ягына чыгып, үпкәсенә бик каты салкын тидереп алгач кына, кабат әнисе катына кайтып егылды...* Х.Ибраһим

**КАТА́** I *и.* Тула оек яки читек белән киелә торган җиңел, тиз генә киеп алырга уңайлы булган кыска кунычлы киез яки күн аяк киеме. *Әле аның тез буыннары калтырый, аяклары ачыган йоннан басылган җәенке киез катаны чак кына өстери иде.* А.Шамов. *Катаны югалтмый гына урам аркылы чыгу зур эшкә әйләнде.* Ә.Фәйзи. *Газзә, аягына ишек янындагы катаны гына эләктереп, яланөс кар базына чыкты.* М.Маликова

**КАТА́** II *бәйл. диал.* Буенча, буена. *Хәзер төн ката каравылда ятуны үзең дә яратмассың...* Э.Касыймов. *Ә теге купец үзен ябып куйган баздан чыгу юлы казыган. Төн ката. Бернәрсәсе дә юк, кулы белән каезлаган җирне.* З.Фәтхетдинов. – *Быел мин җәй ката атлар сакладым, илле эш көнем бар, үз исәбемә язгыз,* – *диде Андрюша.* К.Латыйпов

**КА́ТА** *и. яп. спорт* Дзюдо көрәше буенча халыкара спорт разрядын алу өчен мәҗбүри булган махсус алымнар һәм күнегүләр җыелмасы

**КАТАЙ** I *и.* 1) X–XI гасырларда яшәгән, каты сугышларда күп табыш алуы белән мәшһүр булган борынгы монгол кабиләсе. *Атай малы – катай малы.* Мәкаль

2) Башкорт кабиләләренең берсе. *Бу авыл Кәртәле исемле кечкенә генә катай авылы иде.* М.Гафури

**КАТАЙ** II *и. диал.* Керне йомшарту, сырларын язу өчен кулланыла торган сырлы бәләк

**КАТАКЛИЗМ** *и. гр. кит.* Табигатьтә, җәмгыятьтә кинәттән булган борылыш, һәлакәт, җимергеч үзгәреш яки көтелмәгән авыр бәла-каза, фаҗига, хәвеф-хәтәр һ.б. *Тормышның төрле катаклизмнары тудырган бу яшь кешеләргә [зәгыйфь зиһенлеләргә] мастерскойлар --- бирелгән.* А.Гыйләҗев. *Җир астындагы катаклизмнарның көче җир тетрәү учагының нинди тирәнлектә булуына бәйле.* Галәм. Җир. Кеше

**КАТАКО́МБА** *и. ит.* 1) Борынгы Римда һәм Рим империясенең башка шәһәрләрендә беренче христианнарның эзәрлекләүләрдән качу, гыйбадәт кылу урыны булып хезмәт иткән ясалма яисә табигый мәгарә

2) Озын коридорлы буталчык йөрү юллары булган табигый җир асты галереясы. *Катакомбаларның, төрмәләрнең Канлы диварлары эчендә Богау тавышлары шалтырый.* Һ.Такташ. *Катакомбалар берничә километрга сузыла*

**КАТАЛА́ЖКА** *и. сөйл.* Тоткарланган хулиганнарны, җинаятьчеләрне вакытлыча тоту урыны. *Тоткынны кире каталажкага ябып куегыз, янына берәүне дә кертмәгез!* Т.Әйди. *Ир-атларга камчы да эләкте, шикле күренгәннәрне каталажкага илтеп яптылар.* И.Салахов. *Аны бүген каталажкадан төрмәгә озатмагайлары, качып котыла алмады бит, эх-ма!..* И.Туктар

**КАТАЛА́У** *ф. диал.* Тәгәрәү. *Аның эше тауга каршы каталый (тәгәри), бармаганныкы тау астына да төшми.* Мәкаль. *Күп җылап утырганнан соң, малай: «Болай утырып, эш булмас»,* – *дип, тау башыннан тәгәрәргә тотынды. Өч көн, өч төн каталаганнан соң, бер сукмакка килде.* Әсирлектән кайткан экиятләр

**КАТАЛЕ́КТИКА** *и. гр. әд.* Клаузулалар – шигырь ахырларының ритмикасы (соңгы басымлы иҗек һәм аңардан соң килгән басымсыз иҗекләр) турындагы өйрәтмә

**КАТАЛЕ́ПСИЯ** *и. гр. мед.* Гәүдә һәм очлыкларның мускуллары гипноз һәм кайбер психик авырулар вакытында тулысынча хәрәкәтләнү функциясен югалтуына бәйле рәвештә катып калу халәте

**КАТАЛЕ́ПТИК** *с.* Каталепсия күренеше белән бәйле

**КАТА́ЛИЗ** *и. гр. хим.* Реакция процессында үзләренең составларын саклаучы матдәләр – катализаторлар тәэсирендә химик реакцияләрнең тизләнүе яки тизлегенең үзгәрүе

**КАТАЛИЗА́ТОР** *и. гр.* 1) *хим.* Сайланма рәвештә химик реакция тизлеген арттыра, акрынайта, тик реакция ахырында үзгәрешсез (диярлек) кала

торган матдә. *Конверсия реакциясе өчен катализаторны озак эзләргә туры килмәде.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Ул серне ачу авыл хуҗалыгында гына түгел, хәтта промышленностьта да, бигрәк тә химиянең яңа технология тармагын ачуда, гелиоэнергетиканы үстерүдә, яңа катализаторлар, чималлар ачуда --- зур уңышларга китерәчәк.* Җир һәм туфрак. *Әгәр дә реакция җитәрлек дәрәҗәдә тиз бармаса, катализаторлар аны тизләтәләр.* Химиянең киләчәге

2) *күч.* Нindидер процессны китереп чыгарган яки аны тизләткән фактлар, күренешләр. *Һәм шул чагында чәчәкләр серкәләндерүче канатлылар (үсемлекләр эволюциясе процессының бу терек катализаторлары) табигыйфәнни формалар төзелешендә шундый чараларның берсе булып әверелерләр ки, алардан файдалану аркасында, Җир шары (бу юлы инде бөҗәкләр тарафыннан түгел, бәлки кешеләр тарафыннан) яңача итеп, гөл бакчасына әйләндерелер.* Умарта кортлары

**КАТАЛИ́ТИК** *с.* Катализатор катнашында эшкәртелгән, катализатор белән барган. *Каталитик процесс. Каталитик крекинг*

**КАТА́ЛКА** *и. сөйл.* Үзе хәрәкәтләнә алмаган авыруны салып йөртү өчен кулланыла торган тәгәрмәчле носилка. *Элекке авырулардан берәү генә калган, бүтәннәре яңа. Каталка белән кемне алып килгәннәрен, әлбәттә, теге иске таныш әйткән.* С.Сөләйманова. *[Изаил Харисович] Хәтта аларны өстәлдән каталкага да үзе күтәреп сала иде мондый чакта, ул эшне дә беркемгә ышанып тапшырмый иде.* М.Маликова. *Каталка этеп кергән ике шәфкать туташы туры шуңар юнәләләр һәм караватта яткан мәрхүмәне каталкага күтәреп салалар.* А.Гәрәева

**КАТАЛОГ** *и. гр.* 1) Китапларның, картиналарның, экспонатларның, кульязмаларның һ.б. билгеле бер системада, тәртип буенча төзелгән исемлеге. *Ул махсус китап шкафлары эшләтеп алды, һәм Коля менә хәзер, каникулга чаклы, аңарга китапларны телләренә һәм форматларына карап рәткә китерергә, каталог төзергә бик теләп булыша.* Җ.Тәрҗеман. *Укучы балаларга нәшриятлар тарафыннан чыгарыла торган тематик планнар, библиографик язмалар, каталоглар белән танышу да файдага гына булыр.* Р.Фәйзуллин. *Хәтта иң кечкенә китапханә өчен дә каталог кирәк, аңа яңа алынган һәр китапны язып куялар.* Файдалы киңәшләр

2) Исемлеге булган белешмә китап. *Бөтен дөньяга танылган мәшһүр Италия нәшрияты «Рицциоли», японнар, французлар, испанлылар басып чыгарган бөек рәссамнарның иҗатлары бергә теркәлгән, аерым рәсем галереяларының байлыкларына багышланган затлы җыентыклар, каталоглар – исең-акылың китәрлек!* М.Юныс

3) Китапханәдә булган китап исемлеге. *Алфавит каталогы. Укучы каталогы. Электрон каталог*

4) *информ. к.* **директория**. Дискета, винчестер һ.б. саклана торган, файллар кертелгән папка

**КАТАЛОГЛАШТЫРУ** *и.* Мәгълүматны каталогка теркәү, язып кую; каталог тәртибенә китерү

**Каталоглаштыра башлау** Каталоглаштыруга керешү

**Каталоглаштырып бетерү** Барысын да каталоглаштыру

**КАТА́ЛЬПА** *и. лат. бот.* Бигнониячәләр семьялыгыннан яфрагын коючан, биек булмаган, декоратив максат белән дә үстерелә торган агач үсемлек. *Алардан [роза гөлләреннән] һәм катальпа дип аталган киң яфраклы агачларның шәмәхә кыңгырау төсле чәчәкләреннән аңкыган хуш ис бераз гына башны әйләндерә.* М.Маликова

**КАТАМАРАН** *и. тамил.* 1) Ике корпустан эшләнгән, бер корпус белән икенчесе ике йөзмә балансир белән тоташтырылган уртак палубалы елга яки диңгез судносы

2) Һинд һәм Тын океан утрауларындагы халыкларда җилкән яисә ишкәк ярдәмендә йөртелә торган гади судно

3) Ике яктан да очланган берничә агач бүрәнәдән ясалган, басма белән тоташтырылган, җилкән яисә ишкәк ярдәмендә йөртелә торган кечкенә судно

**КАТА́МНЕЗ** *и. гр. мед.* Авырган кешегә диагноз куелганнан соң һәм хастаханәдән чыгарганнан соң, бер яки берничә тапкыр җыелган мәгълүмат

**КАТА́НА** *и. хәрби* XVI–XIX гасырларда Япониядә: чәнчү һәм чабу өчен кулланылган салкын корал – бер йөзле озын кылыч

**КАТАПУ́ЛЬТА** *и. гр.* 1) *тар.* Борынгы заманда крепостьларны камап алу вакытында кулланылган, зур-зур ташлар, бүрәнәләр, уклар, сыек ягулык салынган мичкәләр һ.б. ата торган зур хәрби машина

2) *тех.* Очучыны, космонавтны һ.б. очу аппаратларыннан автомат рәвештә ыргыту, этеп чыгару җайланмасы

3) *тех.* Кечкенә аэродромнан, мәйданнан очып киткән самолётка башлангыч тизлек бирү өчен механик җайланма

4) *тех.* Механизмнарны тикшерү, катапультәлау ысулларын кабатлау, очучылар һәм космонавтларга тренировка ясау өчен кулланылган җир өсте җайланмасы

**КАТАПУ́ЛЬТАЛАУ** *ф.* Очучыны, космонавтны катапульта ярдәмендә очу аппаратыннан этеп чыгару. *Смит, барлык ихтыяр көчен җыеп, утыргычның уң терсәкчәсенә беркетелгән катапульталау рычагына баса.* Космик ракеталар

**КАТАР** I *и. иск. кит.* 1) Рәт, саф, тезем. *Дөяләр катары*

2) Чират. *Бүркемне салырга өлгерә алмадым, катарга тезелергә мәҗбүр булдым.* М.Фәйзи

3) *күч.* Даирә, катлам. *Бай баласы булса да, кәнфит суырып үскән байбәтчәләр катарына куярга ярамый аны [Бәширне].* Н.Исәнбәт

**КАТАР** II *и. гр. мед.* Нинди дә булса эчке органнарның лайлалы тышчалары ялкынсыну авыруы. *Эвкалипт мае белән фурункулларны, лайлалы тышчаларның эрозияле җәрәхәтләрен, югарыгы сулыш алу органнары катарларын дәвалыйлар, миозитлар һәм радикулитлардан, авыртуларны баса торган дару буларак файдаланалар.*

Урман аптекасы. *Катар авыруы организмга салкын тию яки микроблар тәэсире нәтиҗәсендә килеп чыга.* Йорт эшләре

**КАТАРА́КТА** *и. гр. мед.* Күз ясмыгы тукымасының яисә капсуласының өлешчә яки тулысынча тоныклануы аркасында килеп чыккан күз авыруы (күзнең начарлануына һәм сукыраюга китерә); кылау. *Шунлыктан күз эчендәге басым күтәрелми һәм, күзнең алгы өлешендәге дымлылык даими алышынып тора. Бу исә күзне катаракта чиреннән саклый.* Мөселман гаиләсе календаре

**КАТАРАЛЬ** *с. мед.* Лайлалы тышчаларның ялкынсынуы белән бәйле

**КАТАРГЫ** *и. гр. иск.* Борынгы зур судно. *Кимә килсә каек качар, катаргы килсә кимә качар.* Мәкаль. *Аннан соң янә Болгар шәһәренә килергә ярakландылар, күп-күп катаргылар белән Болгар шәһәрен алырга менде.* Риваять

**КАТА́РСИС** *и. гр.* 1) *юг.* Укучының яисә тамашачының трагедия барышын күзәткәндә кызгану, геройларның кайгысын уртаклашу хисләреннән соң барлыкка килгән аермачык күзаллау, эчке чистарыну халәте. *Аристотель, «катарсис» терминын фәнни кулланышка керткәндә, трагик әсәрләрне зиһенгә алудагы кичерешләрне күздә тоткан була.* К.Гыйззәтов

2) *псих.* Эмоциональ тетрәнү һәм кайгылы хис-тойгыларны кичерүдән соң барлыкка килгән аермачык күзаллау, эчке чистарыну халәте

**КАТАРХЕ́Й** *и. лат. махс.* Җирнең геологик тарихында кембрийга кадәр булган беренче эра. *Катархей – кембрийга кадәр булган беренче эра (докембрий I). Бу заманда Җирнең тышкы кабыгы яңа гына катыланган, һәм көчле вулкан чыгу процессында шактый гына магма таралган булган.* Җир һәм туфрак

**КАТАСТРО́ФА** *и. гр.* 1) Кинәт килеп чыккан зур һәлакәт. *Милли иминлек комитеты вәкилләре катастрофа булган урынга караңгылы-яктылы вакытта ук килеп җиттеләр, ә берничә сәгать үтүгә, гадәттән тыш комиссия җимерекләр, ватык-сыныклар арасында актарына иде инде.* А.Тимергалин. *Катастрофа нәтиҗәсендә барлык терек организмнар һәлак булганнар; коры җирдә яшәүчеләр туфан белән, ә диңгездәге хайваннар корыда калып һәлак булганнар.* Дарвинизм нигезләре. *Тимер кою заводларында мондый катастрофалар элек, чынлап та, булгалап торган.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

2) Иҗтимагый яки шәхси тормышта кискен үзгәрешкә, һәлакәткә, фаҗигале нәтиҗәләргә китергән гадәттән тыш вакыйга, бәла. *Көнчыгыш фронты катастрофа хәлендә. Бигрәк тә өченче армия участогында.* Х.Садри. *Ул кинода уйнаган француз актрисаларының берсе соңыннан автомобиль катастрофасына эләгеп һәлак булган, диләр.* М.Маликова. *Бу еллар эчендә катастрофа якынлашып килә иде инде.* Җир чәчәктә

**КАТАСТРО́ФАЛЫЛЫК** *и.* Һәлакәт, бәла-каза куркынычы. *Хәлнең катастрофалылыгы ачык күренә*

**КАТАСТРО́ФИК** *с.* 1) Һәлакәтле, бәлале, казалы. *Кювье теориясе буенча, Җир төрле урыннарда вакыт-вакыт катастрофик үзгәрешләргә дучар булган.* Дарвинизм нигезләре. *Безнең Җир планетасында бу күренеш үсемлек, тереклек өчен иң беренче катастрофик хәл була.* Н.Гомәров

2) Бик начар хәлдәге, бик түбән яки бик югары дәрәҗәдәге. *– Без сездә чакны, әле материал тупланмаган дип, сез бездән дөреслекне яшердегез, – диде ул, – сезнең план катастрофик бер хәлдә бит.* А.Расих

3) Котылгысыз характердагы, чарасыз. *Морганчыларны туктатканга кадәр, бу арышның уңыш бирүчәнлеге дә катастрофик рәвештә кимеде.* Җир чәчәктә

**КАТАТО́НИЯ** *и. гр. мед.* Мускулларның тартышуы, ирекле хәрәкәтләр ясауның авыраюы һ.б. характерлы нерв эшчәнлегенең бозылуы

**КАТА́У** *и. иск.* 1) Балчык стена белән әйләндереп алынган ябулы абзар, келәт. *Кыйнаганнан соң, аның кулларын каерып бәйләделәр, өстерәп алып киттеләр һәм тыкрыктагы катауга ябып, өстеннән биклә куйдылар.* З.Хәким

2) Балчык стеналы ныгытма, кальга, крепость, ныгытылган лагерь. *Катауның ике капкасы бар, --- капка төпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде.* Н.Фәттах. *Катау капкасы*

**КАТАФАЛК** *и. ит.* 1) Мәетне зиратка илтү өчен махсус арба яки автомашина. *Карага чорналган мәет арбасы – катафалк тирәсенә путаллы тәреләр төшерелгән киң киемле архиерей һәм әллә ничаклы поплар тезелгән.* М.Гафури

2) Ябык бина эчендә табут кую өчен калку урын

**КАТАХРЕ́ЗА** *и. гр. лингв.* Каршылыклы төшенчәләрне бергә кушу, сүзнең лексик мәгънәсенә игътибар итмичә куллану, сүзнең башка сүзләр белән сәер мөнәсәбәтләргә керүе (мәс., *кызыл кара, кара аккош, утсыз яну* һ.б.)

**КАТАШЛЫК** *и. диал.* Арыштан башка бөртекле ашлыклар, каты ашлык. *Без арышны үтеп, сабан ашлык басуына килеп чыктык. Каташлык кырындагы солылар шактый агарганнар.* З.Бәшири

**КАТГЫЙ** *с.* **1.** 1) Кискен; җитез, бик тиз. *Катгый адымнар*

2) Нык, төгәл, аңлаешлы, икеләнүсез, тәвәккәл. *Мин дә катгый карарга килдем: ана саесканның тиешле ялы бетеп, балаларын ияртеп урманга таба очуы булды, сәнәк алып, теге ояны туздырдым.* М.Мәһдиев. *Бу минем катгый җавабым иде.* А.Шамов. *Бу «син мине күндерә алмадың, әти кеше, алай гына да түгел, минем карарым катгый, мине бу юлымнан беркем дә яздыра алмас» дигән мәгънәне аңлата иде.* А.Расих

3) Хәлиткеч, җитди. *Николай Григорьевич бу чирне бик тиз сизеп алды һәм барлык корабларның командирларын, комиссарларын җыеп үткәргән оператив киңәшмәдә катгый чара күрергә кирәклеген әйтте.* С.Сабиров. *Тамашаның традицион үз катгый тәртипләре бар.* Р.Фәйзуллин

4) Кырыс, таләпчән. *Шуны раслаган кебек, өй хуҗасының кырыс һәм катгый сүзләре яңгырый.* С.Шәкүров. *Казаннан да, районнан да бу турыда катгый директив бар. Без аны гамәлгә*

*ашырырга тиешбез.* Г.Толымбай. *Рейдтагы барлык транзит буксирларга һәм үзебезнең баркасларга шундый катгый команда бирегез: хәзер үк рейдка чыгып, бәлага очраган краннарга, баржаларга ашыгыч ярдәм күрсәтсеннәр...* С.Сабиров

5) Ташламасыз, аяусыз, каты. *Менә авыл хуҗалыгы уставын бозучылар турында бик катгый карар да чыкты.* Р.Төхфәтуллин. *Ул әле һаман да астыртын гына пыскып яшәүче сыйнфый дошманга һәм аларның иярченнәренә катгый кисәтү булып яңгырады.* С.Шәкүров

**2.** *рәв. мәгъ.* Каты итеп, кискен, икеләнүсез. *Күпернең аргы ягына чыгу катгый рәвештә тыела.* Р.Мөхәммәдиев. *Өч ай буе квартирага түләмәгән өчен, катгый рәвештә кисәтү кәгазе иде анда.* М.Хәсәнов. *Катгый сөйләшә җитәкче: сүзен әйтте, җавапны тыңлап тормады.* М.Маликова

**КАТГЫЙЛЫК** *и.* 1) Ныклык, тәвәккәллек. *Хәмдиевнең бөтен барлыгыннан, үз-үзен тотышыннан --- катгыйлык һәм җитдилек бөркелеп тора иде.* Р.Төхфәтуллин. *– Әбеләсезме, иптәш Нурсәетов, – диде райком секретарена беркадәр тантана белән, – күрше районда инде өченче көн чәчәләр! – Бераздан исә тынычрак тонга күчеп, әмма шулай да катгыйлыгын, таләпчәнлеген әз генә дә йомшартмыйча: – Юк, иптәшләр, һич тә кояш киптергәнне көтеп ятарга ярамый.* Н.Фәттах

2) Төгәллек, ачыклык, ныклык, аныклык. *Бу төр бөҗәкләрнең тормышында тикшерелгән һәм статистик яктан дөрес һәм инде катгыйлык алган шушы юл буенча тайпылышсыз баруны без инстинктив тәртип дип кабул итәбез дә инде.* Үсемлекләр һәм бал кортлары. *Фикерләрнең катгыйлыгы. Җавапның катгыйлыгы*

3) Хәлиткеч булу. *Вакытның катгыйлыгы. Бәрелешләрнең катгыйлыгы*

4) Кискенлек, кырыслык, таләпчәнлек. *Карашының катгыйлыгы. Сорауның катгыйлыгы каушатты*

5) Ташламасыз булу, катылык

**КАТЕГОРИАЛЬ** *с.* Категориягә хас; категориянең билгесе булып торган. *Мәсәлән, исемнәрдә берлек санының категориаль мәгънәсенә барлык тартым формасын алган һәм теләсә нинди килештә килгән исемнең берлек саны мәгънәләре керә ---.* Татар грамматикасы

**КАТЕГО́РИЯ** *и. гр.* 1) *филос.* Чынбарлык күренешләренең гомуми сыйфатларын һәм бәйләнешләрен чагылдыра торган төшенчә. *Шәрыкчә караганда, файда һәм сәнгать – бербересенә буйсынмый торган капмакаршы категорияләр.* М.Юныс. *Һәрбер фәннең үз категорияләре бар, һәм ул шул категорияләр белән эш итә.* М.Абдрахманов

2) Фәнни терминологиядә: тикшерелә торган предметларның төркемен яки аларның иң гомуми билгеләрен белдерә торган төшенчә (төр, дәрәҗә, разряд). *Грамматик категория буларак, сан исемдә предметның бер яки бердән артыклыгын, ягъни билгесез күплеген белдерә.* Татар грамматикасы. *Төп синтаксик категорияләрне билгеләгәндә рус теле грамматикалары файдаланыла, рус теле белән чагыштырып, татар сөйләменең үзенчәлекләрен ачуга ныклы омтылыш ясала.* М.Зәкиев

3) Бертөрле предметлар, күренешләр һәм кешеләр төркеме. *Хәзер Сабантуй мәйданына үлчәү категориясе белән кертәләр, фәнгә нигезләп көрәштерәләр.* М.Мәһдиев

4) *соц.* Бертөрле үзенчәлекле сыйфатларга, билгеләргә (мәс., яше, профессиясе һ.б. яклары белән) хас булган аерым кешеләрдән (индивидуумнардан) торган төркем. *Социолог буларак, Энҗе андый категориягә керүчеләрне дә белә: публикага речь сөйләүче бер ир. Гадәттә, мондый категория кешеләре алтмышны узган пенсионерлар була.* М.Мәһдиев. *Аның логик фикер йөртүе, төрле категория кешеләрнең психологиясен нечкәләп белүе күп кенә хезмәттәшләрен сокландыра.* Х.Вәлиәхмәтов

**КАТЕГО́РИЯЛЕ** *с.* Разрядлы, дәрәҗәле. *Спорт разрядлары исә судьялар коллегиясе составында түбәндәге квалификацияле судьялар булганда бирелә: I разряд – республика категорияле бер яки беренче категорияле өч судья булганда ---.* Халык һәм спорт уеннары

**КАТЕЛ** *и. гар. иск.* Үтерү, үтерү күренеше, һәлак итү

**КАТЕ́Л ИТҮ** *ф. иск.* Үтерү. *Зөләйханы кател итмәделәр. Зөләйха үз-үзен револьвер илә кател итте.* З.Бигиев

**КАТЕ́Л КЫЛУ** *ф. к.* **кател итү**

**КАТЕНА́НА** *и. лат. хим.* Циклик фрагментлар чылбыр бүлекләре кебек тоташтырылган химик кушылма. *Химикларны гаҗәпкә калдырган бу катнашмаларны катенаналар («катена» – чылбыр сүзеннән) дип атаганнар. Катенаналар – химик синтезның иң яшь тармакларыннан берсе.* Б.Ляпунов

**КА́ТЕР** *и. ингл.* 1) Якын араларга йөри, кешеләр яки йөк күчерү өчен, туризм, саклау һәм таможня хезмәтен үтәү өчен файдаланыла торган моторлы яки җилкәнле-ишкәкле кечерәк судно. *Авыр, юан чылбырлар белән яр кырыена тартылып куелган дебаркадер як-якка әүмәкләнде, түгәрәк тәрәзәле кыска катерлар, дегеткә буялган кара, җәенке көймәләр чайкалды, ә баш өстендә эчне пошырып телефон чыбыклары сызгырды.* Н.Фәттах. *Иделгә чыгу белән, Җәүдәт катерны бар куәтенә җибәрде.* С.Сабиров. *Җәй коры килү сәбәпле, ул быел бик нык кайткан, саеккан, ләкин суы, катер артыннан яр читләп дулкын йөгереп үтүгә карамастан, аяз күк йөзедәй саф, чиста иде.* Х.Сарьян

2) Хәрби хәрәкәтләр алып бару максаты белән кулланылган кечкенә хәрби корабль. *Бөтен бер флотилия ләбаса: туп, пулемётлар белән коралланган тиз йөрешле алты катер, алтмышлап хәрби матрос.* И.Низамов. *Ул аңына килгәндә, катерлар утрау янына килеп десант төшергәннәр иде.* Рәхмәт сиңа, солдат!

**КА́ТЕТ** *и. гр. мат.* Турыпочмаклы өчпочмакта туры почмак ясаучы ике якның берсе. *Турыпочмаклы өчпочмакта кысынкы почмакка каршы яткан катетның икенче катетка чагыштырмасы шул почмакның тангенсына тигез була.* Югары математика нигезләре

**КАТЕ́ТЕР** *и. гр. мед.* Дәвалау яки диагноз кую максатында тышка

ачылган табигый канал яки берәр орган эченә кертелә торган эче куыш көпшә. *Каты катетер. Йомшак катетер*

**КАТЕТО́МЕТР** *и. гр. физ.* Ике нокта арасындагы вертикаль ераклыкны үлчәү приборы

**КАТЕХИЗА́ЦИЯ** *и. дини* 1) Христиан тәгълиматын сорау алу һәм җавап бирү формасына әйләндерү

2) *күч.* Артык гадиләштерү, коры логикага яки исәпләүгә кайтарып калдыру

**КАТЕХИ́ЗИС** *и. гр. кит.* Христиан дине нигезләренең башлангыч курсы һәм шуның сораулар һәм җаваплар формасында төзелгән кыскача дәреслеге. *Җәйге имтиханнар тәмамланды. Катехизис белән изге тарихтан кала барлык фәннәрдән дә Коля «отлично» алды.* Җ.Тәрҗеман

**КАТЕХУ́МЕН** *и. гр. дини* Православиедә: христиан динен кабул итүгә әзерләнә торган кеше

**КАТИБӘ** *и. гар. кит. иск.* Секретарь хатын-кыз, секретарша, сәркатип. *Конторда дәфтәр тотучы катибәләр тезелеп тормакта.* Р.Фәхретдинов

**КАТИЛ** *и. гар. кит. иск.* Кеше үтерүче, җан кыючы

**КАТИЛЕНӘФЕС** *и. гар.* Үз-үзен үтерүче. *Гүя әйткән булалар: «Шәригатьтә катленәфес хәрам. Катиленәфес, әлгаязе биллаһи, мөртәд китәр, дигән китаплар. Бәс, Баязид карыйга җеназа укымак җаиз дәгел!» – диешеп, дини бойкот ясаганнар.* Г.Ибраһимов

**КАТИОННАР** *и. күпл. гр. физ.* Төрле юллар белән матдәдә барлыкка килә торган, яки металл окисе, сульфидларның кристалл почмакларында урнашкан уңай корылмалы ионнар (мәс., $Na^+$, $H_3O^+$, $NH_4^+$ һ.б.). *Гадәттә коагуляция (укмашу) коллоидлардан торган эремәгә икенче бер электролит (тоз эремәсе, кислота, селте), ягъни яңа катион керткәннән соң килеп чыга.* Җир һәм туфрак. *Шулай итеп туфрак бөртеге өстендәге катион аның эремәсендәге катионына алышына.* Җир һәм туфрак

**КАТИП** *и. гар. кит. иск.* Секретарь, язып торучы кеше, сәркатип

**КАТИПЛЕК** *и. кит. иск.* Катиб (сәркатип) эше, катип вазифасы

**КАТКАК** *и. диал.* 1) Кибеп каткан урын. *Ишәк эзе каткакта калмый, баткакта кала.* Мәкаль. --- *Тавис, бичара, күтәрелгән олы юлдан торна каенына таба кисәгрәк борылган икән. Башы белән каткакка туры килгән.* М.Мәһдиев

2) *к.* **каткалак**

**КАТКАЛАК** *и. диал.* Туңган катлам, туң җир, каткан җир

**КАТКАНАК** *с. диал.* **1.** Кибеп каткан, тигезсез. *Гаязны --- катканак урам да, ереле-ваклы өйләр дә, тау битендәге пожар тасмагы да --- куанып каршы алдылар.* Х.Сарьян

**2.** *и. мәгъ. к.* **каткалак**

**КА́Т-КАТ** *с.* **1.** Күп катлы, күп катламлы, катлы-катлы. *Каз канаты каткат була, Ир канаты ат була.* Җыр. *Аланда күл. Кечкенә, түгәрәк кенә. Кыш бабай боз белән томалап, өстенә кат-кат юрган ябып киткән.* Г.Гобәй. *Өстә кат-кат ямау белән йөргән еллар да әле ерак түгел.* С.Рафиков

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Берничә кат итеп, катлы-катлы булып. *Йолдызлар шундый күп, әйтерсең берсе өстенә берсе кат-кат өелешеп беткәннәр.* Г.Әпсәләмов. *Өстән яңгыр ява торды, юеш ашлыкны кат-кат өйделәр.* М.Мәһдиев. *Кат-кат үрелгән тоташ спираль.* Р.Мөхәммәдиев

2) Берничә мәртәбә, күп тапкыр, берничә тапкыр, кабат-кабат. *Исламгали агай хатны кат-кат укыды һәм укыган саен үзенең наданлыгын ныграк сизә барды.* М.Мәһдиев. *Моны безгә Фәрдәнә апа кат-кат сөйләде.* Р.Хафизова. *Сүз алып, иптәшләре алдына чыгып баскан һәр галим үз бурычын уңышлы үтәвен расларга тырыша, кат-кат бер үк хакыйкатьне тәкрарлый.* К.Тимбикова

**КАТКЫ** *и. диал.* Чана артына озын бүрәнәләрне ташу өчен тагыла торган җайланма

**КАТКЫЧ** *и. махс.* Җеп ката торган җайланма. *Җеп каткыч. Электр каткычы*

**КАТЛАМ** *и.* 1) Кат-кат булып торган нәрсәнең бер каты. *Яшел борчак басуы зәңгәр күккә кояш нурлары аша тоташа да басу өстендә баш әйләндергеч яшькелт-зәңгәр һава катламы ясый.* М.Мәһдиев. *Тону процессында чанда өч өлеш нефть катламы барлыкка килә.* М.Хәбибуллин. *Майның карасу төстәге урта катламын һәм аскы катламны икенче итеп бирелә торган ашлар әзерләү өчен файдаланалар.* Татар халык ашлары

2) *геол.* Геологик катлау. *Җир катламы вакыт-вакыт авыр ыңгырашып, калтырап-дерелдәп китә шикелле...* Э.Касыймов. *Бу елларда Татарстан нефтьчеләре «кара алтын»ны катлам басымы ярдәмендә чыгаруга күчтеләр.* Ш.Бикчурин. *Нефтьчеләр, галимнәр белән бергәләп, девонга яңа көч-куәт өстәргә, ягъни җир астына көчле басым белән су кудырып, катлам басымын саклап калырга мөмкин, дигән фикергә килделәр.* М.Хәсәнов

3) *күч. к.* **катлау** II (*3 мәгъ.*). *Хан карачыларына (министрларына) тиң, дәрәҗәле бу кешенең өенә керү – югары катламга күтәрелү белән бер.* Ф.Латыйфи. *Киң катлам әдәбият сөючеләргә Гәрәй Рәхимнең лирик пландагы уйчан шагыйрь һәм прозаик булып танылуы бер дә гаҗәп түгел.* Р.Фәйзуллин

4) *күч.* Зур вакыт аралыгы, дәвер. *Ераграк гасырлар катламнарын ныграк белгән саен, гыйбрәтле хәлләр күбәя генә.* Р.Фәйзуллин. *Гасыр катламнары астыннан табылган асыл ташлы муенсалар, алтын-көмеш беләзекләр янына килгән саен: – Безне, ирләрне, бөлдерә торган әйберләр менә шулар инде, – дип кабатлый.* С.Сөләйманова

**КАТЛАМА** *и. кулин.* 1) Ачы яки төче камыр җәймәсе өстенә май, мәк, варенье, төелгән киндер орлыгы һ.б.лар ягып, аны берничә кат бөкләп пешерелгән ашамлык. *Кичә көлтә кертергә барганда, әнкәй кесәмә салган төче катлама хәтеремә килде. Катламадан да тәмле әйбер бар микән дөньяда.* А.Гыйләҗев. *Саҗидә түти безне күкәй күмәчләре, бодай катламалары белән сыйлый иде.* Г.Галиев. *Бәлкем, как-төш өстенә дигән чәчәкле кәнфитне ярты кадакка калдырып, аның урынына сумсага, катламага дигән майдан берәр кадак өстәмәскәме дип тора идем.* Ә.Гаффар

2) *диал.* Төче яки ачы камырдан майда пешерелгән катлы җәймә. *Бераз гына кортлы май белән катлама тыктым.* Р.Төхфәтуллин

**КАТЛА́МАРА** *с. геол.* Ике катлам арасына урнашкан. *Әгәр су йөртүчән катлам ике су үткәрмәүчән катлам арасына туры килсә, катламара сулар хасил була.* Башлангыч география курсы

**КАТЛА́М-КАТЛАМ** *с.* **1.** Берсе өстенә берсе, кат-кат. *Риза казыйның да катлам-катлам өйрәнелмәгән хезмәтләре бар.* Мәдәни җомга. *Катлам-катлам кар. Катлам-катлам таш. Катлам-катлам болытлар*

**2.** *рәв. мәгъ.* Берсе өстенә берсен куеп, кат-кат итеп. *Кама өстендә иләмсез кара болытлар катлам-катлам булып өелгән иде.* И.Низамов. *Бәлешнең эчен болгатмыйча гына, катлам-катлам итеп: ит, суган, бәрәңге, май һәм шулпа, алар арасына тоз, борыч сибеп салырга да мөмкин.* Татар халык ашлары. *Бәрәңгене катлам-катлам итеп салырга һәм һәр катлам саен иләк яки марля капчык аша препарат сибәргә кирәк.* Файдалы киңәшләр

**КАТЛАМЛАНУ** *ф.* Катламнар хасил булу, барлыкка килү. *Әлеге күл буендагы үзәнлектә хәзер катламланып иртәнге томан гына тирбәлә, кулыңны сузсаң, аның дымсу салкынын тоярсың кебек.* М.Хәсәнов

**Катламлана бару** Акрынлап, торган саен катламлану

**Катламлана башлау** Катламланырга тотыну

**Катламланып бетү** Тәмам, ахырга кадәр катламлану

**Катламланып калу** Катламланган хәлгә килү

**Катламланып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә катламланган хәлдә булу

**КАТЛАМЛА́У** *ф.* Катлам-катлам итү, катлам-катлам итеп салу. *Физик карталарда рельеф горизонтальләр белән төрле төсләргә катламлап буяп күрсәтелә.* Физик география. *Камырны катламлап салу*

**Катламлап бетерү** Тулысынча, ахырга кадәр катламлау

**Катламлап кую** Тиз генә, бер тапкыр катламлау

**Катламлап тору** Һәрвакыт, даими яки регуляр рәвештә катламлау

**Катламлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр катламлау

**КАТЛАМЛЫ** *с.* Катламы булган, катламнардан торган, катлы-катлы. *Кыш көне катламлы болытлар күкне каплаганда, гадәттә болытсыз көннәрдәгедән җылырак була.* Физик география. *Яктыру белән томан таралмый, ә тиз арада түбәндә генә катламлы болытларга әйләнә.* Дөньяда ниләр бар

**КАТЛАМЛЫЛЫК** *и.* Нәрсәнең дә булса берничә каттан торуы. *Җирнең катламлылыгы. Тау токымнарының катламлылыгы*

**КАТЛАНУ** *ф.* 1) Бөгелү, бөгәрләнү, йомарлану. *Очырма туфрагына урам көчеге кебек чумып, өчкә катланып, аркасын җылы мич морҗасына терәп, безнең Йосыф йоклап ята.* Г.Гобәй

2) Катлар, катламнар тәшкил итү. *Мария Петровна үзе тәбәнәк, үзе артык юан, ияге ике катланып салынып төшкән.* И.Салахов. *Соңгы озын күз белән бергә катланган җепне эләктереп бәйлиләр, аннары 3 күз үрәләр һәм катланган җепне дә эләктереп, аскы рәтнең 3 күзен сикертеп, күз сузып чыгарып бәйлиләр. Бәйләгәндә катланган җепләр борылып калмасын, параллель барсын.* Мәктәптә кул эше

**Катлана бару** Акрынлап, әкрен генә, вакыт үтү белән катлану

**Катланып бетү** Тәмам, ахырга кадәр катлану

**Катланып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә катланган хәлдә булу

**КАТЛА́У** I *ф.* Берничә кат итү, кат-кат итү. *Бәйләгән деталь комбинацияләгән тукымадан юка булмасын өчен, җепне берничә катларга кирәк.* Файдалы киңәшләр. *Ике катлап теккәндә, чикләгеч линейкадан файдаланырга мөмкин, ул чагында җөй тагын да тигезрәк була.* Көнкүреш хезмәте

**Катлап бетерү** Тәмам, ахырга кадәр барысын да катлау

**Катлап кую** Катланган хәлгә китерү. *Җепне катлап кую*

**Катлап тору** Һәрвакыт, даими, регуляр рәвештә катлау. *Җепләрне катлап тору*

**КАТЛА́У** II *и.* 1) Берәр нәрсәнең бер каты, катламы. *Басуга калын кар катлавы ятты.* Ә.Фәйзи. *Рәйсә карның күпме явуын белмәкче булып чүгәләде дә юл читендәге карны ялангач кулы белән сыпырды, юка иде шул быелгы беренче кар катлавы.* М.Хуҗин. *Яңа җыйган гөмбәне салкын су белән яхшылап юалар, майлы гөмбә булса, эшләпәсенең өске юка катлавын кубарып алалар.* Татар халык ашлары

2) Геологик пласт, катлам. *Ул атмосфераның химик хәзинәсе дә, Җирнең иң тирән катлаулары да, атом энергиясенең дә кешегә хезмәт итүе турында сөйли.* Химиянең киләчәге. *Кювье, хайваннарның төрле геологик катлауларда табылган казылма калдыкларын өйрәнеп, Җирдә органик тереклекнең берничә чоры булганын билгеләгән.* Дарвинизм нигезләре. *Таш, су һәм һава катлавы белән янәшә – Җирнең терек катлавы...* Җир чәчәктә

3) *җый. и.* Социаль-экономик хәлләре, дөньяга карашлары, культура дәрәҗәләре буенча бериш кешеләр төркеме, сословие. *Син яшь кеше... Милли республика вәкиле. Язучы. Димәк, киң катлау халык исеменнән дә сөйлисең.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул халык улы, хезмәт һәм икмәк тәмен яхшы белгән катлаудан – түбәннән күтәрелгән талант, халыкның рухи ихтыяҗын яхшы тойган әдип, ул үз талантын һәрдаим ил ихтыяҗы белән бергә бәйләп алып бара алган шәхес.* Р.Фәйзуллин. *Арсланов киңәше буенча Мәрдән белән секретарь Вафа бүген иртүк кулак һәм таза катлауларны берәм-берәм авыл советына чакырттылар.* Г.Толымбаев

**КАТЛА́У-КАТЛАУ** *с.* **1.** Күп катлаулардан торган, берничә катламнан торган. *Трактор җир буйлап сөреп, катлау-катлау кара балчыклы җирне ишеп бара.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Шахтёр, тук-тук чукып, катлау-катлау ташны җимерә.* М.Гафури

**2.** *рәв. мәгъ.* Күп катлауланып, берничә тапкыр катлауланып. *Һәр яңа чор, катлау-катлау итеп, Үз төсләрен сала тормышка.* С.Хәким. *Тигезлекләрне төзи торган токымнар: балчык, ком, вакташ, чуерташ, лёсс, известьташ*

*һ.б.лар, гадәттә, горизонталь яки бераз авыш рәвештә катлау-катлау булып ята.* Физик география. *Флювиогляциаль утырмалар күбесенчә хәзерге елга буе утырмалары шикелле катлау-катлау булып ясалган булалар.* Җир һәм туфрак

**КАТЛАУЛАНДЫРУ** *ф.* Катлаулы итү; четереклеләндерү, кыенлаштыру, читенләштерү, авырлаштыру. *Салкыннар һәм бураннар хәзер дә әле нефтьчеләр эшен шактый катлауландыра.* Р.Төхфәтуллин. *Тригонометрик тамга астындагы аргументны катлауландырып, тригонометрик функцияләрне үзара һәм башка функцияләр белән комбинацияләштереп, бик катлаулы күренешләрне өйрәнү өчен функцияләр төзергә мөмкин.* Югары математика нигезләре

**Катлауландыра бару** Торган саен, көннән-көн, тагы да ныграк катлауландыру

**Катлауландыра башлау** Катлауландырырга тотыну

**Катлауландыра төшү** Бераз, беркадәр катлауландыру. *Галим тәҗрибәне бераз катлауландыра төшеп, янәшәдә үсеп утыручы икенче шундый ук гөлнең яфрагын кисә.* Ф.Имамов

**Катлауландырып бетерү** Бөтенләй, тәмам катлауландыру

**Катлауландырып кую** Кинәт кенә, көтмәгәндә катлаулы хәлгә китерү. *Эш шунда ки, Түбән Кама эчке эшләр идарәсе башлыгы --- мәсьәләне берникадәр катлауландырып куя.* Безнең гәҗит

**КАТЛАУЛАНУ** I *ф.* 1) Кат-кат булу, катлау-катлау булу, берничә кат хасил итү. *Болытлар катлауланып-катлауланып шәһәр өстенә таба агыла башладылар.* Г.Ибраһимов. *Кар катлауланып утырган*

2) Төзелеше, эчтәлеге ягыннан катлаулы хәлгә килү; гадилектән катлаулылыкка табан үзгәрү. *Алар җир өстендә ничәмә миллион еллар буена төрле-төрле организмнарның яшәү үзенчәлекләрен, нинди төр тармакларына бүленеп туктаусыз үзгәрүләрен, торган саен катлаулана барып үсешләрен һәм аларның яңалары борынгы төрләрдән төзелешләре ягыннан ничек аерылып килүләрен ачык күрсәтәләр.* Җир һәм туфрак

3) Иҗтимагый катлауларга (төркемнәргә) бүленү, аерылу. *Крестьяннар арасында да ризасызлык үскәннән-үсә, һәм авылның үз эчендә сыйныфларга катлаулану [бара], шул катлаулар арасындагы дошманлык кыза.* Г.Нигъмәти

4) Тагын да кыенлашу, авырлашу; кискенләнү, киеренкеләнү. *Әсәрдәге [Т.Гыйззәтнең «Кыю кызлар»ындагы] фаҗига тирәнәя һәм катлаулана.* М.Җәлил. *Наганы да кулдан ясалган булырга охшый! Димәк, бу эшне тагы да катлауландыра.* Х.Вәлиәхмәтов. *Әгәр дә отряд башка отрядлар белән якын арада кушыла алмаса, хәлебез тагын да катлауланачак.* И.Туктар

**Катлаулана бару** Торган саен ныграк катлаулану. – *Әфәнделәр, – диде ул уйчан кыяфәт белән, – табигатьтәге башлангыч хакыйкатьләргә якынлашкан саен, төшенчәләр катлауланганнан-катлаулана бара, бу кыенлык шулай ук икенче юнәлештә дә – акыл яңа танып белүләргә омтылган чиккә таба да үсә.* Җ.Тәрҗеман. *Кызының авыруы һәм үлеме белән артык дәрәҗәдә борчылуы да булгандыр инде, катлаулана барган тормыш мәшәкатьләре дә карт сөяккә җитә калгандыр, бу язны Сәгъди абзый үзе дә түшәккә егылды.* Ә.Фәйзи

**Катлаулана башлау** Катлауланырга тотыну

**Катлаулана төшү** Беркадәр, бераз катлаулану. *Кызлары тугач, аралар тагын да катлаулана төште.* С.Сөләйманова

**Катлауланып алу** Тиз генә, бер арада, кыска вакытка катлаулану. *Хатынның сырхавы шактый ук катлауланып алды, аны шифаханәдә өч атнага якын дәваладылар.* М.Хуҗин

**Катлауланып бетү** Бөтенләй катлаулану

**Катлауланып китү** Тиз арада, кинәт кенә катлаулану. *Халыкара хәлләр бик катлауланып киткән көннәрдә Хәсән карт ярты сәгатьлек «Время» тапшыруына гына риза булмыйча, идарәгә килә.* М.Мәһдиев

**Катлауланып тору** Даими рәвештә катлауланган хәлдә булу, әледән-әле катлаулану. *Туфрак чынлап та борчак оны катыштырып пешергән карабодай күмәче төсле сорылы-аклы булып катлауланып тора һәм уалаган чакта бармаклар арасыннан комланып коела иде.* Ә.Фәйзи

**КАТЛАУЛАНУ** II *и.* Кыенлык, авырлык. *Тире, күз, бавыр, йөрәк-кан тамырлары, нерв системасы ягыннан күп төрле катлауланулар башланып китәргә мөмкин.* Татар халык ашлары. *Бу вакытта үзенчә катлауланулар һәм кыенлыклар да килеп чыкмый калмагандыр.* Галәм. Җир. Кеше

**КАТЛАУЛЫ** *с.* 1) Катланган, бөкләнгән. *Катлаулы яулык. Катлаулы кәгазь*

2) Аерым катлаулардан, катламнардан торган. *Күк йөзен карасу-соры, катлаулы болытлар каплап баралар.* Г.Ибраһимов. *[Җик:] Атам минем – Кара тау, Туксан тугыз катлаулы, Анам минем Агыйдел, Туксан тугыз тармаклы.* М.Җәлил. *Катлаулы елга яры. Катлаулы шоколад*

3) Берничә өлештән, элементтан торган. *Белгеч булмаган кешегә аңлавы бик кыен булган катлаулы формулалар артына еш кына практика өчен гаҗәеп киң мөмкинлекләр ача торган нәрсәләр яшеренгән була.* Химиянең киләчәге. *Терек матдә төзелеше өчен әлбәттә кирәк булган дүрт химик элементның: углерод, водород, кислород һәм азотның бергә кушылуыннан гыйбарәт катлаулы органик кушылмалар килеп чыккан.* Дарвинизм нигезләре. *Өстә калган күп катлаулы матдәләрнең басым авырлыгы аркасында --- Җир эчендә калган авыр массалы матдәләр, югары температурага карамастан, сыек хәлдә булмыйча, бик тыгыз хәлдә булырга тиеш.* Җир һәм туфрак

4) Күптөрле өлешләрдән, юнәлешләрдән, бүленешләрдән торган, күп тармаклы, күпъяклы, киң колачлы, күпкырлы. *«Яшь йөрәкләр» романының сюжеты артык катлаулы түгел.* Г.Нигъмәти. *Миңа бөтенләй таныш булмаган формулалар буенча һәр көнне әллә нинди катлаулы мәсьәләләр чишә.* Р.Төхфәтуллин

5) Күптөрле, еш кына каршылыклы якларны, үзенчәлекләрне эченә алган

(кешенең эчке дөньясы, хисләре тур.). *Яшүсмернең күз алдыннан томан таралгандай булып, әле күптән түгел генә катлаулы күренгән нәрсә аермачык аңлашылган төсле тоелды.* Җ.Тәрҗеман. *Әниемнең сүзләрендә үкенечле горурлык, яшерен офтану, йөрәк кенә сизә торган тагын әллә нинди катлаулы тойгылар бар иде.* М.Юныс. *Һади мулла ифрат дәрәҗәдә авыр, бихисап катлаулы кичерешләр эчендә яши.* И.Туктар

6) Төзелеше, формасы буенча четерекле, хикмәтле, үзенчәлекле. *Анда ул салмак менуэт белән катлаулы контрдансны тиз үзләштерде һәм җитез полька-кадрильне дә җиңел биергә өйрәнде.* Җ.Тәрҗеман. *Катлаулы приборларның тавышсыз-тынсыз гына ак кәгазьгә төшергән тамгалары Гөлсинәгә хәзер серләрне элеккегә караганда күп тапкыр артыграк ача.* К.Тимбикова. *Җитди һәм патетик, катлаулы һәм лирик көйләрне барысы да бирелеп тыңладылар.* И.Туктар

7) Зур хезмәт, көч, тырышлык куюны сорый торган, хәл итү кыен булган; четерекле, мәшәкатьле, авыр. *Иң катлаулы заман сынауларын Синнән башка узды моңнарың.* С.Хәким. *Катлаулы икән тормыш дигәнең: бер төрле фараз итәсең, икенче төрле ага да тора!* Т.Әйди. *[Бу кызлар] Ватаныбызның азатлыгы, бәйсезлеге өчен барган зур көрәшнең барлык авырлыкларын күтәрәләр, меңнәрчә-меңнәрчә сугышчыларны үлемнән коткаралар, яраларны бәйлиләр, катлаулы операцияләрдә катнашалар, дәвалыйлар, тәрбиялиләр һәм бик күпләрен яңадан сафка кайтаралар.* А.Шамов

8) *лингв.* Икедән артык җөмләдән торган. *Икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә катлаулы кушма җөмлә дип атала.* М.Зәкиев

**КАТЛАУЛЫЛАНУ** *ф.* Катлаулы булып китү, катлаулану. *Чәчәклеләрнең органнар төзелеше бик катлаулыланган, ә тукымалары югары дәрәҗәдә специальләшкән, ягъни аерым бер функцияне үтәүгә нык җайлашкан.* Биология

**Катлаулылана бару** Торган саен ныграк катлаулылану

**Катлаулылана башлау** Катлаулыланырга тотыну

**Катлаулыланып бетү** Бөтенләй катлаулылану

**Катлаулыланып калу** Катлаулы, четерекле хәлдә калу

**Катлаулыланып китү** Көтмәгәндә, тиз арада катлаулылану

**Катлаулыланып тору** Катлаулыланган хәлдә булу

**КАТЛАУЛЫК** *и. ялг. к.* **катлаулылык**. *Формулаларның символикасын һәм геометрик фигураларның катлаулыгын үзе өчен әйтерсең лә бер биек дивар итеп, математика тормыштан ваз кичкән.* Җ.Тәрҗеман. *Примерканы ничә кат ясау материянең нинди төгәллек белән киселүенә дә, гәүдәнең үзенчәлекләренә, шулай ук сайланган фасонның катлаулыгына да бәйләнгән.* Файдалы киңәшләр

**КАТЛАУЛЫЛЫК** *и.* Катлаулы булу сыйфаты. *Әмма җинаятьне ачыклауның ничеклеген без күз алдына да китерә алмыйбыз, чөнки ул хезмәтнең авырлыгын, катлаулылыгын бөтен нечкәлеге белән белмибез.* М.Насыйбуллин. *Хәлнең катлаулылыгы тагы шунда иде: ничәмә гасырлар буена фаҗигале көрәш алып барылган һәм менә, ниһаять, безнең шартларда гына ирек яулаган мәхәббәткә каршы закон һәм логика нигезендә кул күтәрергә тиеш иде ул.* А.Расих

**КАТЛАУСЫЗ** *с.* 1) Катлаулардан тормый торган, берекқән, тоташ. *Рәмиевләр --- массага үпкәләргә, аны сүгәргә тотыналар. Ә бу массаның катлаусыз бернәрсә генә булмаганын, аның сыйныфларга аерылганын аңламыйлар.* Г.Нигъмәти

2) *күч.* Гади, җиңел аңлаешлы. *[Гайфулланың] көрәш чаралары зәгыйфь һәм катлаусыз.* М.Җәлил

**КАТЛАУСЫЗЛЫК** *и. сир.* Гадилек, садәлек; самимилек. *Дөньяда гел мавыгу белән яшәүче бу сөйкемле карт үзенең катлаусызлыгы белән бөтен кешеләрне үзенә караткан иде.* Ф.Хөсни. *Холкының катлаусызлыгы*

**КАТЛЕГАМ** *и. иск.* Геноцид; милләтчелек мотивына нигезләнеп, халыкны үтереп бетерү сәясәте. *Мәҗит Гафури да [реакция елларында] төркестанлыларга катлегам ясалган вакыйгалар мөнәсәбәте белән «Бер нәүхә» исемле шигырен яза.* Х.Госман

**КАТЛЕНӘФЕС** *и. иск.* Үз-үзеңне үтерү. *Гүя әйткән булалар: «Шәригатьтә катленәфес хәрам ---» – диешеп, бойкот ясаганнар.* Г.Ибраһимов

**КАТЛЫ** *с.* 1) Берничә тапкыр катланган. *Ике катлы тәрәзәдән карыйм, Тукай аша карыйм дөньяга.* С.Хәким. *Әле генә оетып суыткан катыкны ике катлы марлядан теккән кечкенә капчыкка салалар да салкынча урынга элеп куялар.* Татар халык ашлары

2) Катламы булган. *Күпереп, кызарып пешкән ике катлы кош теле барлыкка килә.* Татар халык ашлары. *Ике катлы тукымадан тегелгән яканы башта өч ягыннан чалмыйча ясалган баганалар белән бәйләп чыгалар, ә анары челтәрле рәтләр бәйлиләр.* Мәктәптә кул эше

3) Этажлы, яруслы, берничә этажы, ярусы булган. *Кызыл кирпечтән салынган өч катлы затлы бина.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул ике катлы таныш йортның болдырына менеп, ишек белән янәшә тәрәзәгә чиертте.* Җ.Тәрҗеман. *Ошбу гамәл җиде катлы Күкнең җимерелеп төшеп, юктан бар булмас, бардан юк булмас дөнья өстенә кабер ташы булып ятуы белән генә тәмамланыр.* Ә.Гаффар

**КАТЛЫ́-КАТЛЫ** *с.* 1) Күп катлы, күп катламлы. *Бөтен җиренә катлы-катлы булып тәмәке төтене сеңгән була.* Г.Мөхәммәтшин. *Катлы-катлы буынлы исемнәрне өнәмим мин.* Ш.Еникеев. *Гөбәдия дә – бик үзенчәлекле ашамлык, аны күбрәк шәһәр халкы әзерли. Ул катлы-катлы, түгәрәк биек бәлеш, бер генә тантана, бәйрәм табыны да ансыз гына үтми.* Татар халык ашлары

2) Этажлы, яруслы. *Катлы-катлы яруслары, трибуналары һәм утыргычлары белән безнең стадионнарны һәм циркларны хәтерләтсә дә, арена – үзгә бер корылма.* Р.Фәйзуллин

**КАТЛЫЛАНУ** *ф.* Катлар, катламнар хасил итү. *Әтинең кулы верстактагы аршынга сузылган кебек*

*күренгәч, ничектер, үзеннән-үзе, инеш буе, анда көлеп торучы Закир абый, аның көлгәндә ике катлылана торган сәер ирене күз алдыма килде.* Г.Бәширов

**Катлыланып тору** Катлы булып күренү. *Аз гына ике катлыланып торган бу елмаюлы калын иреннәр, аннары әле сержантның башындагы ялтыр бөркетле фуражкалары, самолёт сыман нәрсә кадалган кук погоннары безнең Ильясның да телен ачып җибәрергә җитә калды.* Р.Төхфәтуллин

**КАТМАР** *с. к.* **катмарлы**. *Мәсәлән, әгәр дә бакчачы чәчәктә бер яки ике данә артык таҗ яфрагы күрсә, ул, сайланышны кулланып, берничә елда катмар чәчәкләр үстереп чыгарачагына ышана.* Дарвинизм нигезләре

**КАТМАРЛЫ** *с. бот.* 1) Таҗ яфракчыклары күп катлы булган (чәчәк). *Һәркемгә дә мәгълүм декоратив үсемлек булган левкойлар орлык чәчеп үстереләләр; бу орлыклардан төрле төстәге: кар кебек ак, крем төсле, сирень төсендә, ал, чуар чәчәкләрнең катмарлы бүреге белән очланган нык куаклы сабаклар үсәләр. Катмарлы чәчәк тик таҗ яфракчыкларыннан гына тора. Ләкин үрчемсез катмарлы чәчәкләр белән беррәттән, орлыклар бирүче гади чәчәкләр дә барлыкка килүләрен дәвам итәләр; бу орлыклардан тагын, үрчемсез катмарлы чәчәкләре дә һәм аз гына санда гади чәчәкләре дә булган үсемлекләр килеп чыгалар ---.* Умарта кортлары

2) Чачаклы, катлаулы; *русчасы:* **махровый**. *Катмарлы сөлгеләр вакыт узу белән катылана һәм суны начар сеңдерә башлый. Катмарлы сөлгеләрне үтүкләргә һәм тәгәрәтергә киңәш ителми, шулай ук аны крахмалларга да ярамый.* Файдалы киңәшләр

**КАТМЫШ** *с. диал.* Эшлексез, катып торучы кеше. *Төшемдә дә күргәнем юк синең кебек катмышны.* Җыр

**КАТНАР** *и. диал.* Түшәмнең өске ягы; чорма. *Стеклография шул Федька торган тимер юл эшчесе, паровоз слесареның катнарына (өй түбәсенә) китерелеп, прокламация бик күп итеп басылды.* Т.Госман

**КАТНА́У** *ф. диал.* Ишелгән бауны юанайту яки тукылган, үрелгән нәрсәне калынайту өчен, җеп яки тасма өстәп тукып, үреп чыгу, кат өстәү. *Солтангәрәй, билгеле, чабата катнау белән генә чикләнмәде, вакыт булганда хуҗалык эшләренә дә булышты.* Ш.Еникеев

**КАТНАШ** I *и.* 1) Берәр эштә, вакыйгада башкалар белән бергә күрсәтелгән эшчәнлек, кертелгән өлеш, ярдәм, булышу. *Карелиядә артиллерия һәм авиация катнашы белән киң күләмдә сугыш операцияләрен җәелдерү өчен мәйданнар бик аз.* Г.Әпсәләмов. *Берүзем эшләдем моны, башка берәүнең дә катнашы юк.* Х.Вәлиәхмәтов

2) *күч.* Кемнең яки нәрсәнеңдер эшенә, вакыйгага мөнәсәбәте, кагылышы, бәйләнеше. *Сәйранга чыккан яшь угланда кемнең ни катнашы бар?!* Ф.Латыйфи. *Әмма Камил барыбер өнәми бу кешене, ул аның нәрсәдә гаепле икәнен дә әйтә алмый, әмма бу бәхетсезлекләрдә катнашы барлыгын белә.* Ф.Бәйрәмова. *Сәрхушне җаваплы урыннан куалар. Гарипов катнашында эшләнә бу.* М.Насыйбуллин

3) *сир.* Аралашу, йөрешү. *Ике коданың катнашы күп, сыйлары уртак, уен-көлкеләре бергә бара.* Г.Ибраһимов

4) *лингв.* Һәм ияртүле, һәм тезүле бәйләнештәге җөмләләрдән торган. *Катнаш кушма җөмләдә, кагыйдә буларак, баш җөмләләр үзара тезүле юл белән бәйләнәләр.* М.Зәкиев

**КАТНАШ** II *с.* **1.** Төрле элементлардан, компонентлардан, өлешләрдән торган, төрле нәрсәләр белән кушылган, составы, сыйфатлары буенча төрле, катлаулы. *Колхоз басулары, ак каеннар үскән уйсулык, тырпаешып торган яшь чыршылар артта калып, катнаш урман башланды.* М.Насыйбулин. *Әлбәттә, үлчәнелә торган зурлыкны без үлчәү берәмлегенең (яки масштабның) башка өлешләре белән дә чагыштыра алабыз. --- Ул вакытта үлчәү нәтиҗәсендә, гади вакланмалар яки катнаш саннар килеп чыга.* Югары математика нигезләре

**2.** *бәйл. мәгъ.* 1) Белән, бергә, аралаш. *Чыкырдап торган таш катнаш балчыкларны тимер иләкнең бер ягыннан икенче ягына йөгертәбез.* М.Гафури

2) Берәр нәрсә белән бергә, бер үк вакытта. *Тәзкирә, анасына гаҗәпләнү катнаш аптырау белән карап, үзеннән-үзе кызарып алды.* Ф.Хөсни. *Нәфисәнең йөзендә гаҗәпләнү катнаш тирән борчылу күренде.* Г.Бәширов

**3.** *рәв. мәгъ.* Күп компонентлардан, өлешләрдән, төрле нәрсәләр белән кушылып. *Бер үк бүлмәдә берничә төр яктырткычтан файдаланырга мөмкин. Андый яктыртуны катнаш яктырту дип йөртәләр.* Көнкүреш хезмәте. *Катнаш туклану*

**КАТНАШЛЫК** *и.* 1) *к.* **катнаш** I (*1 мәгъ.*)

2) Мөнәсәбәт, кагылыш. *Токым өстендә беренче туфрак ясалу әнә шул организм калдыкларының һәм аларның үзгәрешендә организмнарның үзләренең дә тыгыз катнашлыгы белән башлана да.* Җир һәм туфрак. *Үсемлек һәм хайваннар калдыгыннан микроорганизмнар һәм башка шартлар катнашлыгы белән хасил булган черемә инде туфракның иң кирәкле, иң файдалы өлеше булып тора.* Җир һәм туфрак

**КАТНАШМА** *и.* 1) Төрле матдәләрне, элементларны механик юл белән кушып, берләштереп, аралаштырып ясалган масса, кушылма продукт. *Менә шунда галимнәр, нефтьтән аерып алынган суны тоздан, башка төрле механик катнашмалардан чистартып, яңадан продукт катламына куарга, дигән тәкъдим ясадылар.* М.Хәсәнов. *Катнашманы эчәк тулганчы салырга ярамый, чөнки пешкәндә ярма бүртә, һәм тутырма ярылып китәргә мөмкин.* Татар халык ашлары

2) Төрле сорт катнаштырудан барлыкка килгән ашлык, иген һ.б. *Беренче метод – серкә катнашмасын куллану. Мәсәлән, алмагачны груша белән кушканда, ул алмагач чәчәкләрен төрле сорт груша серкәләре катнашмасы белән серкәләндергән.* Дарвинизм нигезләре. *Ул аның «ял итүче» туфракта ничек торгызылганлыгын өйрәнде һәм башаклы-кузаклы катнашмаларны чәчәргә кирәклекне алдан ук күрсәтте: алар – туфрак структурасын торгызучылар.* Җир чәчәктә

3) Берәр нәрсә составына өстәлгән, килеп кергән башка нәрсә. *Сортларның берсе сынауга түзмәде: анда катнашма бар булып чыкты.* Җир чәчәктә

**КАТНА́ШМАУЧАН** *с.* Берәр эшкә, вакыйгаларга катышмаучы

**КАТНА́ШМАУЧЫЛЫК** *и.* Катышмаучылык, битарафлык, нейтральлек. *Катнашмаучылык сәясәте*

**КАТНАШТЫРУ** *ф.* 1) Катыштыру, кушу, аралаштыру, буташтыру, бутау. *Абыйсы турында шулай имеш-мимеш катнаштырыбрак сөйләсәләр, әтисе турында бик белеп, бик тәфсилләп сөйлиләр.* Р.Төхфәтуллин. *Китапта Аллаяр суфи мөнаҗәтләре гарәп, фарсы сүзләре катнаштырып, бик авыр тел белән язылган.* Ә.Фәйзи. *Гасырлар буена үзара гына өйләнешү, кан катнаштыру нәтиҗәсендә, андагы кешеләр дегенерация юлына басканнар.* А.Тимергалин

2) Берәүне үз араларына алу, даирәгә кабул итү; кемне дә булса нәрсәгәдер җәлеп итү, тарту. *Узган яз Мөгаҗи тавында шапталка уйнаганда, безне уенга катнаштырмаганнары өчен, Әхсәнәнең кулмәге эченә бака салган идек.* Р.Хафизова. *Элекке елларны аны концертка түгел, тәнәфес вакытында әйлән-бәйлән уйнарга да катнаштырып булмый иде.* Р.Хафизова. *Аларны полкның ерткычлык эшләренә катнаштырырга ашыкмадылар.* И.Туктар

**Катнаштырып кую** Тиз генә катыштыру. *Мине шунда ук бу концертка катнаштырып куйдылар.* Г.Мөхәммәтшин. *Калийлы һәм азотлы ашламаларны, фосфорит онын һәм преципитатны алдан ук катнаштырып куярга мөмкин.* Яшелчәчелек

**Катнаштырып тору** Гел катнаштыру, әледән-әле катнаштыру

**КАТНАШТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **катнаштыру**. *Күселәрне бетерүдә башка чаралар да кулланырга мөмкин: бер савыт белән салат һәм шикәр катнаштырылган сүндерелмәгән известь һәм шуның янына ук икенче савыт белән су куялар ---.* Файдалы киңәшләр

**КАТНАШУ** *ф.* 1) Башкалар белән бергә берәр вакыйгада эшлеклелек күрсәтү, эш итү. *1905 елда авылда рус-япон сугышында катнашкан бер нәселдән ике туган – Вәли белән Гомәр кайтып төшкән.* М.Мәһдиев. *Мөнир катнашкан башка җыелышлар кебек үк, монысы да бик җанлы һәм эшлекле үтте.* Р.Төхфәтуллин. *7 класс укучысы Рәдиф Әхмәдуллин баянда оста уйный, ул катнашкан концертлар бик күңелле үтә...* Ф.Шәфигуллин

2) Башкалар белән бергә булу, кушылу, аралашу. *Моңарчы сүзгә катнашмаган Халидә түти кинәт башын күтәрә.* Р.Төхфәтуллин. *Әгәр дә шушы Яңа елда тылсым иясе булсалар, безнең әңгәмәгә катнашмаган башка балалар нишләрләр иде икән, шуны беләсегез киләме сезнең?* Ф.Шәфигуллин. *Анда инде танцы башланган булыр, Рәмилә аңа катнашып китәрме-юкмы, әмма ул анда Әминәнең чын әхвәлләрен төгәлрәк һәм эчкәртенрәк белгән берәр кемсәне очратмый калмастыр әле...* Э.Касыймов

3) *кимс.* Кирәкле-кирәкмәс эшләргә тыгылу, кысылу, катышу. *Укытучылар катнашып эшне бозмасалар, сугышның ни белән бетәсе мәгълүм түгел иде әле.* Р.Хафизова. *Хатыннар аңа юньләп аңлатып бирә алмадылар, ачуланып, тиргәп, бүлмәдән куып чыгардылар. Шуннан соң Коля аларның сүзенә катнашмады.* Җ.Тәрҗеман

4) *хим.* Берәр реакциягә, процесска кушылу. *Үсемлек, тамырларыннан туфракка органик кислоталар бүлеп чыгарып, туфрак составына кергән минералларның химик таркалуында катнаша. Бактерияләр һәм гөмбәләр корыган үсемлекләрне һәм хайван үләксәләрен таркатуда катнашалар.* Дарвинизм нигезләре

**Катнаша башлау** Катнашырга тотыну. *М. Максуд иҗат эшчәнлегенең тәүге елларыннан ук матбугатта әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән катнаша башлый.* Совет Татарстаны язучылары

**Катнашып алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына катнашу

**Катнашып йөрү** Озак, дәвамлы яки регуляр рәвештә катнашу

**Катнашып килү** Баштан ук, эзлекле рәвештә катнашу. *Яки менә Латыйфханны алыйк. Безнең хәрәкәттә күптәннән катнашып килә.* Т.Әйди

**Катнашып китү** Азрак яки көтмәгәндә килеп катнашу. *Картның артыннан куып барып, башыннан сыйпарга яисә нинди дә булса берәр ягымлы сүз әйтергә тели иде шикелле. Ул арада Госман карт башка шахтёрлар арасына катнашып китте.* Ш.Камал

**Катнашып кую** Бик сирәк, озак вакыттан соң бер тапкыр катнашу. *Кунаклар бер Вилданга карадылар, аны үз күрделәр, бер шикләнделәр. Бигрәк тә теге сирәк-мирәк катнашкалап куя торган карт шикләнде.* Г.Толымбай. *Бертолет тозының таркалу һәм аңа орынып торган янучан матдәләрнең яну реакциясе шырпы башында гына барса – бер нәрсә, ә әлеге тозның уннарча тонналары реакциягә катнашып китсә, бөтенләй башка хәл килеп чыга.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

**Катнашып тору** Даими рәвештә, һәрвакыт катнашу. *Безнең укучылар мәктәп олимпиадаларында катнашып тора*

**КАТНАШУЧАН** *с.* 1) Аралашучан, компаниячел. *Бөтен эштә актив катнашучан бала*

2) Кысылучан, катышучан. *Бөтен нәрсәгә катнашучан кеше*

**КАТНАШУЧЫ** *и.* 1) Катнашкан кеше. *Телефонны урынына куйгач, Зәйнулла тикшерүдә катнашучыларга рәхмәт әйтеп, акча белән бергә аларны министрлыкка озатып калды.* М.Насыйбуллин. *Ярышта катнашучылар җиңел атлетика, өстәл теннисы, волейбол, йөзү, кул көрәше, катнаш эстафета кебек спорт төрләре буенча көч сынаша.* Кызыл таң

2) Пьесада, спектакльдә һ.б. уйнаган кешеләрнең берсе (күбрәк күплек санда килә). *Шәриф Хөсәенов әсәрләренең үзенә тарта торган тагын бер күркәм ягы бар: аның пьесасындагы персонажлар – катнашучылар дикме – табигый мохиттә, табигый ситуациядә, табигый халәттә сөйләшәләр, хәрәкәт итәләр, яшиләр.* Р.Фәйзуллин. *Алтынчы-җиденче классларда инде алар мәктәп театрының афишаларын, катнашучыларның, режиссёр, художник, композиторларның фами-*

*лияләрен күрсәтеп, Камил Якуб типографиясендә (шефлары) бастырып ала башлыйлар.* С.Шәкүров. *Бу җиңел эш түгел, шуңа күрә тамаданың сүзләренә мәҗлестә катнашучыларның тиешле хөрмәт белән караулары һәм аның барлык төпле тәкъдимнәрен күтәреп алырга тырышулары бик мөһим.* Татар халык ашлары

**КАТНАШЧЫ** *и.* Берәр коллектив эш-хәрәкәттә катнашкан кеше. *Кешенең табигать эшләренә иң бөек кагылуының замандашы һәм катнашчысы Вильямс хәзер практик рәвештә кеше кулы тимәгән һәм аның хезмәте куелмаган җирләр юк икәнлекне яхшы белә иде.* Җир чәчәктә

**КАТНАШЧЫЛЫК** *и.* Катнашчы булу. *Катнашчылык итү*

**КАТОД** *и. гр. техн.* 1) Электролитик ячейка аша электр үткәндә тискәре корылган электрод. *Гальваник элементлар, анод һәм катод арасындагы ионнар хәрәкәте турында Рушад татарча ярды да салды.* М.Мәһдиев. *Телевизорны электр челтәрендәге көчәнеш кимегәндә эшләтү радиолампаларга һәм электроник нурлы көпшәгә зыян китереп, аларның катодларын җимерә, ягъни аларның тиз тузуларына сәбәп була.* Файдалы киңәшләр

2) Тискәре полюстагы электр тогының чыганагы белән тоташтырылган приборның электроды (мәс., электр лампасының)

3) Электр дугасының тискәре электроды

**КАТОДЛЫ** *с. техн.* Катоды булган. *Катодлы лампа. Катодлы турайткыч*

**КАТОК** I *и. рус* Тимераякта шуу өчен ясалган, боз белән капланган махсус мәйдан; шугалак. *Бүген кич алар Черек күл катогында очрашачаклар.* И.Гази. *Әллә нишләп үзгәрде ул хәзер. Тимераякларын ала да катокка элдерә.* Р.Хафизова. *Катокка чыгуга, Суфиянның аяклары яңа туган бозау аяклары шикелле төрле якка китеп барды да, үзе лып итеп бозга утырды.* И.Гази

**КАТОК** II *и. рус техн.* 1) Асфальтлы, комлы, ташлы җирне тигезләү өчен кулланыла торган үз күчәрендә әйләнгән цилиндрлы авыр җайланма һәм шул җайланмалы машина. *Киң табанлы зур катоклар, Тәгәрәп алга-артка, Урам өстен шомарттылар, Асфальты кайнар чакта.* Ш.Маннур. *Һәр төр өчен урын билгеләнә, аңа ком җәелә һәм су сиптерелә. Җир кипкәч, аны каток белән тигезлиләр.* Халык һәм спорт уеннары

2) *а.х.* Сөрелгән туфракны тыгызлау һәм кантарларын бетерү өчен кулланыла торган киң көпчәк рәвешендәге тагылма инвентарь. *Туфрак салу алдыннан тирес өстен таптап яки барабан маркер тибында эшләнгән җиңел агач каток белән тигезлиләр.* Яшелчәчелек. *Менә шуның өчен кайбер культураларны (тары кебекләрне) чәчкәннән соң, җирне каток белән бастырып чыгалар.* Җир һәм туфрак

3) Авыр әйберләрне тәгәрәткәндә кулланыла торган тәгәрәткеч. *Каяндыр тасма транспортёрлар табып, аның катокларын файдаланып, пилорамалар астына бүрәнәләр бирүне механикалаштырдылар.* М.Хәсәнов

4) *махс. иск.* Кер тәгәрәтү станогы

**КАТОКЛА́У** *ф.* Катоклар ярдәмендә юлларны тигезләү; сөрелгән туфракны тыгызлау. *Чәчү алдыннан туфракны катокларга кирәк.* Яшелчәчелек. *1969 елның язында барлык мәйданны 3–4 эздән лущильниклар белән эшкәрттеләр, катокладылар һәм чуар гибридлы люцерна, болын солычасы һәм болын саруты катнашмасы чәчтеләр.* Н.Григорьев

**Катоклап бару** Акрынлап катоклау эшен башкару. *«Гигант» басуларында бүген чәчүдә дүрт агрегат эшли. Дүрт агрегат культивация ясый, ике агрегат катоклап бара.* Кызыл таң

**Катоклап бетерү** Бөтенләй, тулысынча катоклау

**Катоклап кылу** Күптәннән бирле катоклау. *Чәчү комплексы артыннан Флүз Вәсилев ДТ-75 тракторы белән җирне катоклап килә.* Кызыл таң

**Катоклап кую** Алдан катоклау

**Катоклап тору** Һәрвакыт, даими, регуляр рәвештә катоклау

**Катоклап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тулысынча катоклау

**КАТО́ЛИК** I *с. гр.* Католицизмга мөнәсәбәтле. *Малайның фәнни хәзерлегенә югары бәя биреп, руханилар үз араларында зур галим булдырырга исәплиләр һәм аны монастырь акчасына Эйхштадт шәһәрендәге католиклар университетына укырга җибәрәләр.* Җ.Тәрҗеман. *Хөсәен сүзне католик чиркәвеннән, фәннең шул чиркәү белән көрәшеннән башлады ---.* А.Расих. *Католик чиркәве Чехиядә югалткан җирләрен тулысынча кире кайтара алмый һәм аның җимерелгән монастырьларын торгызуга да көче җитми.* Урта гасырлар тарихы

**КАТО́ЛИК** II *и. гр.* Католик динендәге кеше, католицизм тарафдары; католицизмны кабул иткән кеше. *Католиклар хөкем сөргән заманда, баш иеп килгән кешенең дә иң әүвәл, «абсолжоте» дип, гөнаһын кичергәннәр, аннары артыннан кораллы рыцарь җибәреп, башын кистергәннәр.* М.Насыйбуллин. *Лобачевский борылып карады һәм үз янында илле яшьләрдәге католик руханиен хәтерләткән бер кешене күрде.* Җ.Тәрҗеман. *Раштуа бәйрәмендә англикан чиркәвенә йөрүчеләргә дүрт тәүлек, католикларга биш тәүлек ял бирелә.* М.Юныс

**КАТО́ЛИКЛЫК** *и. к.* **католицизм**. *Католиклык йолалары*

**КАТОЛИКОС** *и. гр.* Әрмән, грузин, албан чиркәүләрендә иң югары дәрәҗәдәге рухани

**КАТОЛИЦИЗМ** *и. гр.* Башында Рим Папасы торган һәм үз иерархиясе булган христиан диненең төп юнәлешләренең берсе; католиклар дине. *Католицизм дине никахны Ходай эше дип карый һәм гаиләләрне саклауга зур өлеш кертә.* М.Әхмәтҗанов

**КАТО́МКА** *и. сөйл.* Кирәк-ярак белән тутырылган сумка, рюкзак һ.б. юлчы әйбере. *Анықылар инде шинель, катомкаларын, хәтта мылтыкларын да ботакларга элеп, кайсы печән, кайсы чыбык-чабык эзләп тарала башлаганнар иде.* И.Низамов

**КАТО́ПСИС** *и. лат. бот.* Бромелийчалар семьялыгыннан киң яшел яфраклы, үзәк тамыры җир астында нығып үскән ак чәчәкле бүлмә үсемлеге

**КА́ТОР** *и. сөйл. к.* **каторга**. *Акылыңдамы син? Андый эш өчен катор җибәрәләр.* Х.Сафина

**КА́ТОРГА** *и. гр.* 1) *иск.* Хөкем ителгәннәрне каты режим шартларында авыр физик эшләрдә эшләтү белән бәйләнгән аерым бер җәза төре һәм шундый мәҗбүри эшләрнең урыны. *Аңа гимназиядә укытырга түгел, ә каторгада юлбасарлар надзирателе буласы калган...* Җ.Тәрҗеман. *– Аның идеяләре өчен төрмә һәм каторгаларда газап чиксәк тә, көрәшкә әзер булырга тиешбез, – ди торган иде.* И.Туктар. *Бородихин эше буенча каторгага хөкем ителгәннәр.* И.Салахов

2) *күч. сөйл.* Йончыткыч, хәлдән тайдыргыч, чиксез авыр булган эш һәм чыдый алмаслык тормыш турында. *Каторгага хөкем ителгәннәрне дә шулай камерага кертеп яптылар.* М.Галәү. *Бу кешенең тормышы авыр, каторга хезмәте белән тулган иде.* Җир чәчәктә. *Баткаклы сазлыкларда эшләгән кешеләрнең хезмәте каторга хезмәтеннән бер дә ким булмый.* Җирәнкәнең зәңгәр күзләре

**КАТОРЖАН** *и. рус сөйл. к.* **каторжник**. *Качкын каторжанның кайнар йөрәге бозга әвереләде.* М.Хәбибуллин. *Әмма каторжаннар бу зәһәр буранга да, баракның көндезләрен дә караңгы булуына хафаланмыйлар, киресенчә, куаналар гына. Каторжанның сукыр черкиләрне куарга вакыты да, көче дә юк.* И.Салахов. *Әлбәттә, лазареттагы эш забойдагы каторжан эшенә тиң түгел.* Р.Мостафин

**КА́ТОРЖНИК** *и. гр.* 1) Каторгага сөрелгән яки шунда булып кайткан кеше. *[Зариф:] Әллә мин каторжникмы, җимерелеп эшләргә?* Ш.Камал. *[Давыт:] Әллә каторжникмы мин шул тикле! Бәйдәге эт тә түгел, ни хаклары бар аларның...* Р.Төхфәтуллин

2) *гади с.* Җинаятьчел, законга каршы эшләр башкаручы кеше. *Җыен каторжник шул Заболотноега барып оялый башлады.* К.Нәҗми

**КАТР** *и. сөйл. к.* **каторга**. *Бер бала тапкан хатыннарга бер штраф, ике бала тапканнарга ике штраф, өч бала табучыларга төрмә, дүртне табучыларны катр җибәрергә кирәк.* К.Тинчурин

**КАТРАН** *и. лат.* 1) *бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; чәчәкләре ак, яфраклары сусыл, зур, нык тармакланучан үлән яки куак

2) *зоол.* Катранчалар семьялыгына караган, барлык океаннарда очрый торган, озынлыгы бер метрга кадәр җиткән акула; дөньяда иң киң таралган төрләрдән саналган чәнечкеле акула

**КАТРӘ** *и. гар. иск.* Тамчы. *Галәм каршында син үзеңне кечкенә, катрә бер тере нокта гына итеп тоясың. Катрәлек тойгысыннан аң, акыл коткара.* М.Юныс. *Эченә катрә су булмаса заһир, Бирермән барчаңа дөррежәваһир.* Дастан. *Җәмиләнең күзенә һаман йокы килми, һаман һичтуктаусыз уйлана, бетмәс күз яшен бер катрәсеннән соң катрәсенә агызып кына тора иде.* М.Гафури. *Аракының катрәсе каннан яман.* Мәкаль

◊ **Катрә бөртек кадәр** Бик аз гына. **Катрә бөртеге кадәр** *к.* **катрә бөртек кадәр**. *– Я-а, катрә бөртеге кадәр дә кешелегең юк икән, – диде Мортаза.* М.Хәсәнов

**КАТРЕН** *и. фр. әд.* Дүрт юлдан торган строфа. *Фәлән Фәләнеч әфәнденең нишләптер кысыр чобар сыерының берсәбәпсез җан тәслим кылуына да бер-ике катрен табып алырга була, мәсәлән.* Татар, уян

**КАТТЛЕ́Я** *и. лат. бот.* Сәхләбчәләр семьялыгына кергән, оранжереяда ел буе чәчәк атып утыручы үсемлек

**КАТУ** I *ф.* 1) Каты хәлгә килү, кибү. *Өстәл өстендә бер кыерчык каткан күмәч белән бер стакан тора.* Г.Камал. *Шәрәләнгән җир әүвәле чуен булып катты, аннан тамыр-тамыр булып ярғаланды-ыржайды.* И.Салахов. *Тора һәйкәл ядкәр булып батырларга, Җизгә катып баһадирлык ныклыклары.* Ш.Мөдәррис

2) Туңу, түбән температурага җитү нәтиҗәсендә каты хәлгә килү (сыеклыклар тур.). *Кичке салкын белән аяк асты ката башлаган, артык пычрак түгел.* Ш.Камал. *Тиз генә чишенде дә бишмәтен, юешләнеп каткан бияләйләрен мич башына томырды.* Г.Шәрәфи. *Килде кырыс төннәрең – Кантарланып катты юл.* З.Нури. *Агыйделнең агым җире Кыш булса да катмыйдыр.* Җыр

3) Нәрсәгә булса да бик нык буялу, таплану. *Йөзе танырлык түгел: күз төпләренә, мыегына тоташ лай каткан иде.* Х.Сарьян. *Бу яңгырлы көннәрдә урамнан күпләп-күпләп ияреп кергән кара балчыкка катып, җир белән бер булган идәнне дә ә дигәнче чистартып алды.* М.Әмир. *Кызыл йолдызлы будёновкалар, кызыл петлицалы шинельләр, кан укмашып каткан туннар, чикмәннәр...* И.Салахов

4) Керләнү, пычрану. *Битен сакал баскан, өстендәге киемнәре керләнепмайланып каткан. Кулларына сабын тимәгәнгә биш былтырдыр.* М.Насыйбуллин. *Кайтып керсәң, баланың тамагы ач, өс-башы катып беткән була.* Ф.Шәфигуллин. *Өс-башына кара инде: күлмәк-ыштаны каткан, чалбарының тез турысы тагын умырылган...* Р.Хафизова

5) *сөйл.* Хәрәкәтсезләнү, тикторыш, хәрәкәтсез калу, тынсыз калу. *Пәһлеван гаять арып, эштән чыгып, Ун минут торды катып, гаклын җыеп.* Г.Тукай. *Авызымны ачып аңа карап каттым.* Р.Хафизова. *Кай җиредер авырткандай акырып елаган баланың сыны катты, йөзенә зәңгәрлек иңә башлады.* М.Хәсәнов

6) *туп.* Үлү, дөмегү. *Фәхри бабай, Галимә апаның нәкъ өстенә карап: – Илаһем, шул яткан урыныңда кат!.. – дип әйтте дә ишекне шап иттереп ябып чыгып китте.* М.Гафури. *Шәмсетдин хәзрәт агу эчеп катарга өлгергән.* Э.Касыймов

7) *күч.* Рәхимсезләнү, миһербансызга, шәфкатьсезгә әйләнү; усаллану, хиссезләнү. *Мәдинә гарьлегеннән булып еларга теләп карады. Тик булдыра алмады. Бәгырь дигән нәрсә тәмам каткан иде.* М.Хәсәнов. *Сәхап карт, җавап кайтармыйча, тын калды. Аның төсенә ачу чыгып катты, зәңгәрсу кул тамырлары бүртеп киттеләр.* С.Рафиков

8) *күч.* Бик каты өшү, туңу, күшегү. *Колак очлары катып өлгергән юеш бәтине кулыма кысып тоттым да*

*өйгә йөгердем.* Ф.Шәфигуллин. *Шулай берәм-берәм һәрберебезнең бар җирен тикшереп карыйлар. Катып, туңып беттек.* И.Салахов

**Ката башлау** Бераз кату

**Ката бару** Торган саен ныграк кату

**Ката төшү** Беркадәр, бераз кату. *Көй табындагыларны берьюлы әсир итте, көндәлек мәшәкать белән ката төшкән күңелләр назланып, хисләр сафланып, җанга һәм тәнгә табигый халәт кайтты.* Х.Сарьян

**Ката калу** *сир.* Кинәт кенә каткан хәлгә килү. *Без баскан җиребездә ката калдык.* Г.Ибраһимов

**Катып бетү** Бөтенләй, тәмам кату. *Кабартып куелган мендәрнең бер почмагы яньчелгән иде, шунда ук бите ачык бер китап аунап ята иде, ә идәндә, койка астында, тышына аш катып беткән, юылмаган кәстрүл утыра иде.* Н.Фәттах. – *Без ир-атның хәлен үзең беләсең, Әнисә җаным, яшеренбатырын түгел, әнә ничек катып беттек. Гаепкә алмыйча, шушыларны гына юып бирсәңче, – дидем.* М.Шабай

**Катып җитү** Тиешле дәрәҗәгә килеп бөтенләй кату. *Тимер багана астына салынган цемент катып җиткән*

**Катып калу** Кинәттән кату. *Пошиның дымлы, зур күзләрендә тирән хәсрәт, әрнү катып калды.* М.Насыйбуллин. *Укучылар авыр сулап куйдылар; укытучы ютәлләүдән туктагач, алар яңадан таш кебек катып калдылар.* Ж.Тәрҗеман. *Кердем дә, авызымны ачкан килеш, бусагада катып калдым.* Р.Төхфәтуллин

**Катып килү** Торган саен ныграк кату

**Катып китү** Кинәт, кыска вакыт эчендә каткан хәлгә килү. *Тамырда калган үләннәр көзге күрән кебек катып киткәннәр, чалгы аларны кыштырдатып авырлык белән генә кисә.* Х.Сафина. *Әзер балны майлы салкын табага бушатырга да салкын суга яки карга куярга, боларның барысын да бик тиз башкарырга һәм, катып китмәсен өчен, балның кырыен һәр яктан да пычак белән күтәреп, әйләндереп торырга кирәк.* Татар халык ашлары

**Катып тору** Хәрәкәтсез булу. *Төп кебек баскан да тик катып тора, урынынан кымшатам димә.* Р.Хафизова. *Аның уйларын сизгәндәй, Иван сәүдәгәр тавыш бирде: – Я, таш сындай катып торма! Хәзер икенең бере: я Казанны тончыктырып малны кайтарабыз, я булганны җыеп эшкә җигәбез.* Ф.Латыйфи. *Бәрән күргәч авыз сулары килә башлаган ач бүре кебек, иреннәрен ялый-ялый, баскан җирендә катып тора бирде.* Г.Ибраһимов

**Катып утыру** Каткан хәлдә булу. *Параша озак кына бер урында таш сын кебек катып утырды, аннары акрын гына урыныннан күтәрелде, төштәге кебек тавышсыз гына чайкала-чайкала, бүлмә буенча атлады.* Ж.Тәрҗеман

**КАТУ** II *и.* 1) Кызу йөргәндә, авыр физик хәрәкәтләр ясаганда яки йөгергәндә кинәт авырттырып сулыш кысылу, тын бетү күренеше; эчтәге органнарда барлыкка килгән кистереп авырту. *Кәләпүшне салгач, мин теге малайның артыннан җиттем һәм, эчкә кату чыкса да, инде егылганчы барырга уйладым.* М.Гали. *Тыны кысылды, сулуы капты. Эченә кату чыкты. Эчәсен китерде...* Х.Ибраһим

2) Шул күренешне тудыра торган берәр төрле авырту. *Минем эчтә кату бар, походка ярамыйм.* Т.Гыйззәт. *Тын алып булмый да – шабаш. Кату... Минем әнине дә шул кату гүргә алып китте.* Ф.Сәйфи-Казанлы

3) *күч.* Җыелып килгән пошыну, тынычсызлану, кайгы яки ачу хисе. *Күкрәп үскән күкрәгемдә Хәсрәт катулары бар.* Җыр. *Җаны аеруча газаплана башлагач, эченә кату булып җыелган серләрен уртаклашу өчен дип, бер көнне ул [Мөнәвәрә] әниләренә барып утырды.* Г.Ахунов. *Юк, бу сөю көнчелеге түгел, ә йөрәккә утырган шәфкатьсез ачу катуларының ишелүе генә.* А.Шамов

**КАТУ** III *ф.* 1) Бутау, салу, кушу, берләштерү. *Мин катык катып чумар ашадым, бер йомры сөт күтәреп эчтем.* Р.Хафизова. *Теләгән кешеләр катык катып ашыйлар.* А.Шамов. *Шулай да катыкны бик кайнар ашка катарга ярамый, ул эремчекләнә.* Татар халык ашлары

2) Ялгау, дәвамын өстәү. *Көнне төннәргә катып син эшләсәң дә һәр заман, Ярты тиенлек файда итмисең, ялангач син һаман.* М.Гафури. *Көнне төнгә кату*

3) Ике яки берничә җепне бергә кушып бөтерү, бер җеп ясау. *Өстәл тирәсенә тезелеп җиде авыл хатыны, биш авыл кызы утырганнар. Кайсы җеп эрли, кайсы ката.* М.Фәйзи. *Гөлгайшә нәрсәдер каеп утыра, әнкәсе җеп ката иде.* М.Кәрим. *Катылган ефәк тагын да әйбәтрәк.* Мәктәптә кул эше

4) Аерым тезмәләр составында килгәндә аралашырга теләк белдерү, сүз әйтү мәгънәсен белдерә. *Ярдәмгә килүчеләр дә юк үзләренә, сүз катучы да юк.* Р.Мөхәммәдиев. *Үз уена чумган Рахманкол табындашының бөтен сүзләренә дә колак салып тормады, сәлам биреп узган ир-атларга да җавап катмады, «вәгаләйкем» дип утыруына караганда, аларның һәммәсе кабартма яңак танышлары иде.* Т.Әйди. *Шул вакыт эчендә олаучы абзый аңа ник кенә бер сүз катсын.* С.Шәкүров

**КАТУЛА́У** *ф. сөйл. к.* **кату** I

**КАТУЛЫ** I *с.* Берәр нәрсә салынган, кушылган, буталган. *Борын яфракларына катулы умач исе килеп бәрелмәгәч, аптырабрак калдым.* Ф.Шәфигуллин. *Катулы аш*

**КАТУЛЫ** II *с.* Катуы булган. *Катулы эч*

**КАТУ-ЧӘНЧҮ** *җый. и. гади с. к.* **кату** II. *Ике атнага бер кату-чәнчү авыруы белән авырыйм. Ул сез сугышка киткәч кайгырудан булды, балакайлар.* Г.Толымбай

**КАТУ́ШКА** *и. рус* 1) Бау, тимерчыбык, шнур, электр үткәргечләр һ.б.ш. әйберләр уратыла торган махсус цилиндр, зур шүре, кәтүк. *Алда взводның телефон аппаратларын, катушкаларын төягән зур фургон бара. Шул бер катушка җитмәү аркасында алгы сызык элемтәсез калырга, һәм иң мөһим операция өзелергә мөмкин.* С.Шәкүров. *Үзенчә планы бар иде: пуля башка яки йөрәккә тимәсә, теләсә нинди яра белән дә ул, катушканы сүтеп, чыбыкны илтеп җиткерәчәк.* М.Мәһдиев

2) Видеофильм төшерелгән, музыка яки башка мәгълүмат язылган махсус лента. *Мәсьәлә шунда, бу катушкада*

*әлеге останың шул тиңдәшсез номерын башкарганда куллары-бармаклары нинди-нинди хәрәкәтләр ясаганы электр импульслары тәртибендә язып барылган. Шушындый ук катушкалар иң оста биюченең, тиңдәшсез скрипачның, гаҗәеп балта остасының, беренче кул токарьның, иң өлгер шофёрның – тагын, тагын никадәр зур һөнәр ияләренең бар осталыкларын сиңа бик тиз арада өйрәтеп җиткерә алачак.* Р.Төхфәтуллин

**КАТЫ** *с.* **1.** 1) Физик җисемнәр турында: газсыман җисемнәрдән һәм сыеклыклардан аермалы буларак, үзләренең формаларын, күләмнәрен, халәтен саклый ала торган. *Һәр тау бозлыгының туену өлкәсе бар, анда каты хәлдәге атмосфера явым-төшемнәре тупланса, алар тыгызлана бара, һәм боз барлыкка килә.* Физик география. *Хайван майлары, кагыйдә буларак, каты матдәләр. Үсемлек майлары күбесенчә сыек була.* Органик химия. *Корылма механикасы – каты җисем механикасының мөһим өлкәләреннән берсе.* Корылма механикасы

2) Яньчүгә, бөгүгә, кисүгә, сугуга, изүгә һ.б. физик тәэсирләргә, деформацияләнүгә кыенлык белән бирешә торган; *киресе:* **йомшак**. *[Рәуф]: Әйе, алмаздан да каты әйберләр таба, эшли хәзер фән.* Х.Хәйруллин. *Бер дворник хатын, иелеп, озын саплы тимер көрәк белән йорт буендагы каты карны ваткалап ята иде.* Н.Фәттах. *Оя каты чыбыкларны бер-берсенә аралаштырып, бутап, беркетеп ясалган иде, тиз генә сүтелмәде.* М.Мәһдиев

3) Тотрыклы, чайкалмый, селкенми торган. *Каты җиргә баскач та, кинәт аның башы әйләнә, күңеле болгана башлады.* Н.Фәттах. *Калын каты боз алай тиз генә бирешмәде, ике бәке тишкәнче, сөймән берничә мәртәбә кулдан кулга күчте.* Җ.Тәрҗеман. *Бусы артык каты чикләвек түгел.* Р.Фәйзуллин

4) Нык, көчле; бирешми торган. *Каты, нык куллар богавында ул үзен нindидер тоткында шикелле итеп, нindидер читлектә шикелле итеп сизде.* Н.Фәттах

5) Кытыршы, тупас, тыгыз булган. *Галия иренең башыннан фуражкасын салдырды, җилдә, кояшта каралган битендә кара җөй күреп, бармаклары белән шуңа орынды – кытыршы һәм каты иде.* Х.Сафина. *Нитрон тукымалардан тегелгән костюм һәм пальтолар, шулай ук нитроннан ясалган каты ворслы ясалма мехлар җылы суда сабынсыз да әйбәт юыла.* Файдалы киңәшләр

6) Калын җеп кушып, бик тыгыз тукылган, тупас. *Җәмиләнең өстендә тигезле-тигезсез йорт туласыннан эшләнгән каты чикмән иде.* К.Басыйров. *Каты тула*

7) Куе (ботка тур.); пешеп беткән, әзер (йомырка тур.); тыгыз, үзле, җәергә авыр булган (камыр тур.). *Токмач камыры төсле шактый каты камыр басарга, юка итеп җәяргә һәм юка стакан белән түгәрәкләр кисәргә.* Татар халык ашлары. *Йомырканы әкренләп, сүрән утта пешерсәң, йомырканың агы йомшак, сарысы катырак булачак.* Файдалы киңәшләр

8) Нык тартылган, киерелгән, тыгызланган. *Кулларын баш артына куеп, каты һәм буш диванга сузылып ятты.* Л.Ихсанова. *Бераздан тагын аңарга Маһруй җиңги сүз кушты: – Урының каты түгелме? – Урын шәп. Рәхмәт сезгә.* Г.Толымбай

9) Начар ишетә торган (кеше тур.). *Күзенең зәгыйфьлеге өстенә, ул колакка да катырак иде.* Ә.Фәйзи. *Алгы өйдә йоклаган Мәхмүт абзый, фронтта алган контузиясе аркасында, колакка катырак иде.* З.Фәтхетдинов. *Өйләрендә малайның колакка катырак әбисе генә кала.* Л.Ихсанова

10) *а.х.* Клейковинага бай, аз крахмаллы (ашлык сортлары). *Аларда көзге игеннәр өчен дә, язгылары өчен дә, каты бодай һәм йомшак игеннәр өчен дә, бәрәңге һәм һәртөрле үләннәр өчен дә урын табыла...* Җир чәчәктә. *Каты бодай һәм йомшак бодай иң әһәмиятлеләрдән санала. Каты бодайның бөртеге тыгыз була. Аны пычак белән кисеп карасаң, ул пыяла кебек ялтырап тора.* Ботаника

11) *махс.* Пассажирлар йөртү өчен техник эшләнеше һәм комфортлылыгы ягыннан иң гади һәм очсыз. *Каты вагон*

12) Бик көчле, гадәттәгедән артык. *Ә кайчак, төннәрдә, каты яңгыр шаулап уза.* А.Шамов. *Сүзгә сүз ялганып, җилемләнеп бара торгач, Хәлим, ахырда, агайны тәмам тел яздырып, каты бәхәскә алып керде.* И.Гази. *Алты-җиде кешеләре каты яралы, пулемётчылары Фролов күз алдымда...* И.Низамов

13) Тәэсир итү көче шактый кискен, көчле булган. *Көне буе ике яктан да дәвам иткән каты атышлар басылган, һәм табигать ничектер тынып, талгынланып калган.* А.Шамов. *Әмма дават коточкыч каты булды.* С.Сабиров. *Минем бик каты ачу чыкты, тоттым да моны элеп алдым!* И.Гази

14) Рәхимсез, шәфкатьсез, мәрхәмәтсез, аяусыз. *Хәрби комиссар фаҗигасенә катнашы барлыгы исбатланса, хөкем каты булачак.* Т.Әйди. *Әмма соңга таба кешеләр динне оныттылар, җирдә бозыклык артты. Аллаһ аларга каты җәза бирде.* Ф.Бәйрәмова. *Син бит хәлнең бөтен нечкәлекләрен белергә теләмәдең дә, бары аның тышкы күренешеннән чыгып кына үзеңнең каты хөкемеңне булдырырга ашыктың, ди.* А.Расих

15) Бик нык сизелеп торган, көчле дәрәҗәдәге. *Тегесе каты Кавказ акценты белән сабыр гына җавап бирә ---.* З.Фәтхетдинов. *Ул каты акцент белән тиз-тиз сөйли, йомры сүзләре авыз эченнән тәгәрәп чыгалар шикелле тәэсир калдыра иде.* Х.Камалов

16) Тәме нык беленә торган, куе; организмга тәэсире көчле булган (чәй, кофе, тәмәке һ.б.). *Әнә Иван Кириллович әйтә, чын татарча каты чәй эчәсем килә, ди...* С.Сабиров. *Капитан баш авыртудан каты чәй эчеп утыра иде.* З.Фәтхетдинов. *Кара чәчне чемкара төскә кертү өчен, кынаны басмага кушмыйча, үзен генә каты чәйдә изәргә һәм бер стакан кынага каймак куелыгында итеп сыегайтылган ике чәй кашыгы какао порошогы өстәргә кирәк.* Файдалы киңәшләр

17) Минераль тозларга бай булган. *Кар суы каты булмас, кыз кебек ха-*

*тын булмас.* Мәкаль. *Ждановның суы каты, нindидер тозлы су.* М.Юныс. *Каты суда сабын начар күбекләнә һәм гадәттә аксыл соры куnык булып чәчтә кала.* Йорт эшләре. *Каты суны йомшак судан аеру бик җиңел. Су каты булса, суынганда, стакан өстендә яры утырып кала.* Файдалы киңәшләр

18) Тирән, тиз генә уянмаслык (йокы тур.). *Әмма көтүне бүреләрдән саклар өчен тышка еш чыгып йөрергә туры килгәнлектән, башы мендәргә тиюгә каты йокыга тала торган егет ул үзгәрешне сизмәде дә.* Т.Әйди. *Уе еракка китмәде аның, бер-ике минут үтүгә каты йокыга китте.* Г.Толымбай. *Ашаганнан соң ул каты йокыга талды.* З.Хәким

19) Шартлары артык кырыс булган, салкын. *Димәк, Урал һәм Себернең (бу урыннарда күп кенә гигант заводлар һәм яңа шәһәрләр төзелде) каты климаты өчен дә җимеш агачлары сортларын тудырырга кирәк иде.* Җир чәчәктә. *Башкаларының җимешләре начар, һәм үзләре каты климат шартларына чыдамсыз булалар.* Дарвинизм нигезләре

20) *күч.* Кырыс, катгый, таләпчән, кискен. *Талантка җәмгыятьнең таләбе дә әнә шуларга бәйле рәвештә ташламасыз һәм каты булырга тиеш.* Р.Фәйзуллин. *Вахитов абый мине эштә каты таләпчәнлек, төгәллек белән эшләтте, ләкин туганыдай якын күрде.* Х.Сарьян. *Бала яшеннән үсмер яшькә күчкәч, киресенчә, аны каты кулда тоталар.* М.Юныс

21) *күч.* Күп көч, батырлык, ныклык таләп итә торган, кискен, аяусыз, бик нык. *Мәскәү янында хәзер каты сугышлар бара.* Р.Хафизова. *Иртәгә дә каты, мәрхәмәтсез сугышлар булачак.* А.Шамов. *Әнә Иделдә каты сугыш төннең-төн буе дәвам итә, туплар өзлексез гөрселдәп тора.* С.Сабиров

22) *күч.* Тышкы йогынтыга, тәэсиргә бирешми торган. *Таш каты, таштан бигрәк баш каты [сүз аңлатып булмый].* Мәкаль

23) *күч. сир.* Саран, карун. *Акчага каты кеше*

24) *күч.* Ачы; тупас, дорфа. *Күңелгә килсә дә телгә килмәслек һәм бер кабатлануы белән генә дә колакны өшетеп ала торган... бу каты сүз...* Ф.Хөсни. *Ихтыяҗың гарз итеп килсә теләнче капкаңа, Каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама.* Г.Тукай. *Ишектән кереп китәр алдыннан әйләнеп карады, каты сүзләрен йомшартырга теләгәндәй: – Гафу итегез, бераз башым әйләнә, мин керим инде, – дип өстәп куйды.* С.Сабиров

25) *күч.* Нык ихтыярлы, тәвәккәл, категорик, какшамас. *Каты ихтыяр. Каты характерлы кеше*

26) *күч.* Авыр (күз тур.). *Күзем дә каты түгел, югыйсә, әллә күз тиде үзенә.* Р.Мөхәммәдиев

27) *күч.* Нык, чыдам, калын. *Мәрьям үзенең җылан кебек булуына куанып көлеп җибәрде, каты кара чәчле авыр башны йомшак куллары белән кочаклап алды да яратып күкрәгенә кысты.* Н.Фәттах. *Нина Петровна җавап бирмәде. Шаярып, Гыймазовның чәчен тартты: – Әһә, синең чәчең каты. Карчыклар моны усаллык билгесе диләр.* С.Рафиков

**2.** *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса каты җире, каты урыны; каты өлеше. *Икенче берәүләре йомшак җәеп катыга утыртырга һәвәс иде.* М.Хәбибуллин. *Йөгәнне тотып ат янына киттем. Икмәк катысын сузам да: «Ваһ! Ваһ!» – дип, үземчә бик ягымлы итеп кенә дәшеп карыйм.* И.Гази. *Ул чирәмгә урнашып икмәк катысы кимерүче пөхтә киемле олы яшьтәге хатынга кызып-кызып нидер сөйли иде.* А.Расих

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик нык, кинәт, кискен, көчле итеп. *Җилләр катырак иссә дә, Тәрәзәм куркып ябам.* С.Хәким. *Кояш бүген әкәмәт каты кыздыра.* Р.Хафизова. *Елга киң һәм тирән булмаса да, каты ага иде.* И.Туктар

2) Катгый рәвештә, кистереп. *Җыелышта бик каты әйткәннәр үзенә.* Р.Төхфәтуллин. *Ваһим тын алды, аңа Моназыйрга каты бәрелеп сөйләүдән тыелу кыен иде.* М.Хуҗин. *Бу инде бөтенләй каты әйтү иде. Чөнки хәзерге көндә аксөяк саналган Дүрткара кабиләсе хакында чыннан да шундый бер әкият бар иде.* Г.Ибраһимов

3) Рәхимсез рәвештә, ачы, нык итеп. *Окопларда яткан 5 нче һәм 6 нчы роталар бик каты каршы тордылар.* Ш.Усманов

4) Катгый, таләпчән, җитди итеп. *Каты сорау. Тәртипне каты кую*

5) Нык итеп, тоярлык итеп. *Һәм Кәшшаф, гадәтенчә, каты гына итеп минем иңбашыма сугып җибәрде.* Р.Төхфәтуллин. *Степан кулы белән каты басып битен сыпырды.* Ә.Гаффар. *Башта аларны бик каты ярдылар. Аннары штабка алып киттеләр.* Я.Зәнкиев

6) Бик нык, бик көчле. *Үзем өзеп алма бирдем, Яраттым күз карашын. Белмәдем шул йөрәгемнең Болай каты янасын.* С.Хәким. *Бик каты куркыттылар куркытуын.* Ф.Шәфигуллин. *Зиннур исә, каты яраланган хәлдә, ничектер немец солдаты астында калып, өскә чыгарга азаплана иде.* Ә.Шәмин

7) Шәп, җитез, тиз. *Ул барадыр йөгрек аттан да каты Һәм җәядән аткан уктан да каты.* Г.Тукай. *Тыныч кына эшләп йөргәндә берни юк, ә инде гадәттәгедән артыграк хәрәкәтләнергә, әйтик, бик каты йөгерергә туры килсә, аның башы әйләнә, хәтта тәмәке тартырга да өйрәнә алмады.* М.Әмир. *Куркып күзе тонган ат арба күчәренә аягы тигән саен катырак чаба, яшендәй алга атыла.* С.Рафиков

8) Тирән, уянмаслык итеп (йокы тур.). *Иптәш кызлары чыгып китү белән, Фәридә йокыга китте. Ул бик каты йоклады.* Н.Фәттах. *Шул әкәмәткә уянмый ятуын әйт син аның, үлгән кебек каты йоклый, илаһем.* М.Әмир

9) Тәме нык беленеп; организмга көчле тәэсир итеп (чәй, тәмәке, кофе һ.б.). *Әминә атасына чәйне каты итеп ясады да үзе тагын өстәл башында өнсез утырган улына текәлде.* И.Салахов. *Чәйне каты итеп, кайнар көе, кайчагында сөт белән эчәләр.* Татар халык ашлары

10) Озак кайнатылып (кыздырылып). *Күршем каты итеп пешерелгән күкәйнең яртысыннан күбесен авызына кабып җибәрде.* Ш.Усманов. *Каты пешкән күкәй Маратның авыз суларын китерде.* Г.Гобәй. *Каты пешкән*

*йомырканы салат яки бутерброд өчен кисү җиңел түгел.* Файдалы киңәшләр

11) *куч.* Көчле, ишетерлек итеп. *Теге көнне Моталлап аның эш бүлмәсеннән соңгы кеше булып чыкты, ишекне бик каты шапылдатып япты.* М.Насыйбуллин. *Түзмәдем, күкрәгем тутырып бер тирән сулыш алдым да, үзем дә сизмәстән, шул малай кебек, Идел ярларын, биек тауларны яңгыратып, бик каты итеп сызгырып җибәрдем.* С.Сабиров. *Пуля тиеп, корпус каты зыңлый.* И.Низамов

12) *куч.* Нык, какшамас. *Бер мәртәбә йокыңны кызганмыйча саклап тор да үзләреннән җыештырт. Каты тор. Баш бирмә.* М.Юныс. *Фәкыйрь ата тегеләй дә, болай да баш тартып карый. Ячы каты тора.* К.Тимбикова

◊ **Каты әйтү** Көчле тәэсир итәрлек итеп, шелтәле яки ачулы сүз әйтү, кисәтү ясау. *Мин дә җүләр, яныма утыртып, аңа отрядтан качарга ярамавын яхшы гына, матур гына итеп аңлатып бирәсе урында каты итеп әйтеп ташладым: «Җүләрләнмә, Шәвәлиева, бу эш синең өчен бик начар булып бетәчәк. Моны исеңдә тот», – дидем.* А.Шамов. *Гайнан чыгырдан чыгарлык дәрәҗәдә ачуланган чагын хәтерләми, ләкин кирәк вакытында каты әйтүдән тартынып тормый.* М.Насыйбуллин. **Каты бавырлы** *иск.* Каты күңелле, шәфкатьсез, мәрхәмәтсез, кызганмаучан. *Биремҗан карт – каты бавырлы, аз акыллы бер чал.* Г.Ибраһимов. **Каты бәгырьле** *к.* **каты бавырлы**. *Галиәкбәр Әлфиянең кирәгендә мондый каты бәгырьле дә була алуын әле беренче тапкыр күрә иде.* А.Расих. *Нинди каты бәгырьле зат тамаша кылган боларны? Мондый сурәтләрне төшерү өчен җаның булмаска кирәк!* А.Тимергалин. *Яшь булса да, илтабарлары каты бәгырьле, нык куллы, диләр.* М.Хәбибуллин. **Каты бәрелү** Кискен һәм тупас сөйләшү. *Вәлиев күңеленнән үзен гаепле санады, хәзер иптәшләренең аңа каты бәрелмәүләренә ул бер яктан аптырый, икенче яктан куана иде.* С.Рафиков. *Син миңа ачуланма, Самат туган, әгәр үзең Хәбиргә болай каты бәрелмәсәң, әйтмәсә түгел ием бу сүзләрне, синең дә биш балаң бар ич, алар хакына әйтмәс ием.* В.Нуруллин. **Каты борын** *эвф.* Дуңгыз, чучка. *Арбага утырып, печәне җыеп алынган болын юлыннан узып бара идек. Дуңгыз көтүе очрады. Каты борыннар, мыркылдый-мыркылдый, болынны сөреп йөри.* М.Әмир. **Каты кул белән** 1) Ныклы, тотрыклы, ышанычлы итеп. *Әле ярый, каты кул белән бәйләгәнсең, таралып китмәде.* Ф.Хөсни. 2) Авторитар рәвештә, кырыс таләпләр куеп. *Мин моны сулъякка приказ язганда куертмадым, анда бу мәсьәлә алай ук куркыныч түгел, Юдин яхшы башлаган эшне Смирнов та, Павлов та, аңлап, каты кул белән дәвам итәләр.* И.Низамов. **Каты куллы** 1) Авыр, катлаулы эшләрне булдыра ала торган. *Үги әнәй җен күк эшли безнең. Теләсә нинди эшкә шундый каты куллы, шундый җитез ул: аңа ни җитте кеше тиңләшә торган түгел.* Ш.Маннур. *Хәмдүневләр – каты куллы кешеләр, эшне сытып эшлиләр, ләкин колхоз техникасын күбрәк үзләренә хезмәт иттерәләр.* М.Мәһдиев; 2) Таләпчән, кырыс, дорфа мөгамәләле. *Каты куллы Сафагәрәй ханның үз авызыннан чыккан фәрман көне-сәгате белән Иделнең өске агымындагы ерак Саклаубашка да килеп җиткән иде.* Ф.Латыйфи. *Ә капитан – фронтлар үткән солдат, каты куллы булса да һәрвакыт гадел.* Р.Төхфәтуллин. *Закон сагында торган кешеләр, гомумән, кирәк чагында каты куллы һәм кырыс та булырга тиеш.* М.Насыйбуллин; 3) Башкаларга сугу гадәте булган (кеше тур.). **Каты куллылык** 1) Кырыслык, дорфалык, таләпчәнлек. *Пәрхулла абзыйның тәүфигы-инсафы дисәң – ике муллага җитәрлек. Каты куллылык дисәң – малайларыннан сорагыз.* Ш.Маннур; 2) Рәхимсезлек, шәфкатьсезлек. **Каты күңелле** Мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, рәхимсез, кешелексез, миһербансыз. *Каты күңелле булса да, кәефе килгәндә абыйсының шаян сүзләр әйтеп көлдерә торган гадәтен белгән һәм бер гаиләдә, бер өйдә аның бу табигатенә күнегеп беткән энесе Мөбарәкҗан, Исхакның чыраенда кырыслык, караңгылык күреп, үзенең ризасызлыгын белдерде ---.* С.Рафиков. *– Ай-яй-яй!.. Бигрәк каты күңелле кеше икәнсез!.. – диюгә, кызның матур йөзе тагы да яктырып, матураеп киткән төсле булды.* К.Тинчурин. **Каты өн** Үз-үзеңне катгый һәм тупас тоту, кыланыш, мөгамәлә тәэсире. *Аның [үги ананың] мәрхәмәтле булып күренергә тырышуларында ук бер ясалма куштанлык бар, бу ясалма куштанлыкның каты өне балаларны һәрвакыт өркетеп тора иде.* Ф.Хөсни. **Каты тоту** Үзенә буйсындырып, беркая иркенләп китәргә мөмкинлек бирмәү, рәхимсез, кырыс итеп, ачулы мөнәсәбәт күрсәтү. *Әллә ничек әле бу: кичә генә бергә шау-гөр киләләр иде, бригадир булып алгач, Әнәс үзен каты тотмакчы. Анысы, ул элек тә җитди иде җитдиен. Тик болай ук кырыс түгел иде сыман.* Р.Хисмәтуллин. **Каты чикләвек** Беркемгә, бернәрсәгә бирешми, бирелми торган, нык. *Шактый каты чикләвек булып чыкты ул ханым.* З.Фәтхетдинов

**КАТЫ АҢКА́У** *и.* Авыз эченең өске өлешендә урнашкан, авыз куышлыгын борын куышлыгыннан аерып, авыз куышлыгын формалаштыручы аңкау. *[ч] авазын әйткәндә, тел очының өске өлеше каты аңкауга таба якыная, ләкин тулысынча тими – ачыклык кала.* Хәзерге татар әдәби теле

**КАТЫ БИЛЧӘН** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан аксыл шәмәхә чәчәк ата торган ике яки күпьеллык биек чүп үләне; *русчасы:* **бодяк полевой**. *Көнбагыш, кашкарый, тузганак, дәлия, билчән, каты билчән һәм күп кенә башка үсемлекләрнең чәчәкләре кәрзин дигән чәчәк төркеменә җыела.* Ботаника

**КАТЫ БҮРЕК** *и. иск.* Цилиндр сыман тигез түбәле биек эшләпә. *Тарантаста башына каты бүрек киеп утырган бер бай баласы.* Г.Газиз

**КАТЫ ГӨМБӘ** *и. бот.* Гадәттә агачларда үсә торган, ашарга ярамаган, агулы гөмбә; *русчасы:* **гриб-трутовик**. *Урман хуҗалыгына, бакчаларга һәм паркларга каты гөмбәләр – трутовиклар – зур зыян китерә, алар агачларның үзагачын җимерә.* Ботаника

**КАТЫ́-КАТЫ** *с.* **1.** *куч.* Кырыс, ачы, кискен; тупас, дорфа. *Киресенчә, яңа бригадирның каты-каты сүзләреннән соң аңа хәтта күңеллерәк тә булып китте.* Н.Фәттах. *Элек ияк кагып, аның һәр сүзенә ышанып утырган тикшерүче бу юлы үтә кырысланган, каты-каты сораулар белән аннан дөреслекне таләп итә иде...* Я.Зәнкиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Нык итеп, тоярлык итеп, көчле. *Үзенең кайтканлыгын белдерү өчен, аны уяту һәм, уяткач, икәүдән-икәү генә очрашу, сөйләшү нияте белән, ул ишекләрне юри дөбердәтеп ачты, тамак кырды, сеңгеренде; бүлмәгә кергәч, авыр итекләре белән әле тимер мичкә, әле сәкегә орынып китте, идәнгә каты-каты басып куйды, ләкин күрше бүлмәдә берникди уяну галәмәте сизелмәде.* Н.Фәттах. *Үзенең кат-кат юылудан инде шактый уңган, ямалган ситсы күлмәген киеп маташканда, кинәт йөрәгә бик авырттырып каты-каты тибеп куйды ---.* Р.Төхфәтуллин. *Йөрәгем каты-каты тибә башлады.* Г.Мөхәммәтшин

**КАТЫ́-КОТЫ** *җый. и.* 1) Каткан, кипкән камыр ашамлыклары. *Һаҗәр, шуны гына көтеп утырган кеше кебек, ашыга-ашыга аны өстәлгә утыртты. Каты-коты, коры-сарылардан табын тезде.* К.Тимбикова. *Син, егет, минем капчыкка кагылма, күзеңне текмә, зинһар. Аның эчендә каты-котыдан башка бернәрсә дә юк.* И.Туктар

2) *куч.* Гайбәт. *Ул инде, Харрастан күрмәкче, җирдәге һәр каты-котыга колак салырга өйрәнеп килә иде.* К.Тимбикова

**КАТЫК** *и.* Кайнаган сөткә оеткы салып әчетелгән ашамлык. *Бер савыт катык белән бер кыерчык ипи ашасам, үлсәм дә үкенмәс идем...* М.Мәһдиев. *Габдрахман абый баздан бер чүлмәк салкын катык алып менде.* Р.Хафизова. *Ләкин хатынның табын уртасында һәр көнне катыгы була.* А.Шамов

**КАТЫКАНАТЛЫЛАР** *и. бот.* Бөҗәкләр классыннан иң күп санлы отряд; йомшак япмалы корсак өлеше һәм икенче пар элпә канатлары өске каты канатлар белән капланган тулы әверелешле бөҗәкләр; *русчасы:* **жесткокрылые**

**КАТЫ КИНДЕР** *и. бот.* Киндерчәләр семьялыгыннан яхшы сүсле күпьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **кендырь**

**КАТЫ КОРТ** *и. бот.* Шыртлавык коңгыз личинкасы – буынтыклы, озынча сары корт (тиресле һәм көпшәк туфракта очрый)

**КАТЫ КУРА** *и. бот.* Каты курайчалар семьялыгыннан бер яки күпьеллык үлән; *русчасы:* **дербенник**

**КАТЫКЛЫ** *с.* Катык салынган, катылган. *Малайлар әниләренең катыклы салмаларын ашарга кайтып киттеләр.* Л.Ихсанова. *Катыклы аш*

**КАТЫЛАНУ** *ф.* Каты *(1, 2, 5, 9, 12, 13 мәгъ.)* булып китү, каты хәлгә килү. *Нинди генә фаҗигаләр кичерсә дә, күңеле катыланмый торган кешеләр бар дөньяда.* М.Маликова. *Хөсәеннең туктаусыз тәмәке тартудан тамагы карлыкты, тавышы катыланды.* Г.Мөхәммәтшин. *Коры вакытта бу туфрак төрлечә формада яргалана. Өсте катылана, такырлана, тоз кристаллары белән каплана.* Җир һәм туфрак

**Катылана бару** Акрынлап, торган саен ныграк катылану. *Крепостьта режим катыланганнан-катылана бара.* Ә.Давыдов

**Катылана башлау** Катыланырга тотыну. *Галим карт урыс капкасын инде шактый өелергә өлгергән кар көртеннән арындырып, җырлатып ачты да, тыгызланып катылана башлаган карны усал шыгырдатып, урамга чыкты.* Р.Галиуллин. *Озаграк тотсаң, катылана башлый.* Шәһри Казан

**Катыланып бетү** Тәмам катылану

**Катыланып җитү** Ахыргача, тиешенчә катылану

**Катыланып калу** Катыланган хәлен саклау. *Сөяк беткән җирдә тире тупланып, катыланып кала*

**Катыланып килү** Бераз гына катылану

**Катыланып китү** Кинәт катылану. *Хәсән итеген салып куйды да, барып, репродукторның тавышын көчәйтте. Чөнки бу бер-ике елда колагы катыланып китте аның.* Х.Хәйруллин

**КАТЫЛЫК** *и.* 1) Каты булу үзлеге. *Бөтен сабырлыгын җыеп, валчык арты валчык куптарды, катылыкның ни икәнен белде. Чүлмәк катылыгы иде бу.* К.Тимбикова. *Механик составка карап, аның [туфракның] төсе дә, структурасы да, катылыгы да, шулай ук һәрбер катлауның калынлыгы да, сыйфаты да үзгәрә килә.* Җир һәм туфрак. *Агачны төз утыртучы кәүсәнең катылыгын һәм ныклыгын нәкъ менә лигнин билгели.* Биология. *Корычның катылыгы. Металл катылыгы*

2) Тәэсир итү көче шактый кискен, көчле булган (җил, буран, агым һ.б. тур.). *Җилнең катылыгына каршы торырлык түгел*

3) Сыеклык составында минераль тозлар күп булу. *Көйдерүләр булмасын өчен, эремәнең катылыгын һәр тапкыр берничә үсемлеккә контроль бөркү юлы белән тикшерергә кирәк.* Яшелчәчелек. *Суның катылыгы*

4) Тәме яки тәэсире көчле булу (чәй, тәмәке һ.б. тур.). *Белмим, әллә чәй катылыгыннан, әллә томан куелыгыннан, башым әйләнде.*

5) *хим.* Каты җисемнең тышкы механик тәэсиргә каршы тору үзлеге, паскальләрдә үлчәнә. *Катылык ягыннан беренче урында хәзер табигый алмаз түгел, ә ясалма боразон тора.* Химиянең киләчәге

6) Тирәнлек (йокы тур.). *Иртәнге йокының катылыгы*

7) Саңгыраулык, начар ишетү (кеше тур.). *Хәпәзә әби артык узынырга ирек бирмәсә дә, әйтерлек ачуыбызны китерә алмады: колакка катылыгы әйбәт иде.* М.Әмир

8) Кырыс, тупас (тавыш тур.). *Аның күзләре ачулы, аяусыз, ә тавышында тимер катылыгы һәм салкынлыгы бар иде.* М.Маликова. *Тавышның катылыгы магнитофон һәм радиоалгыч регуляторлары белән көйләнә.* Файдалы киңәшләр

9) Кырыслык, рәхимсезлек, мәрхәмәтсезлек, тупаслык. *Күрше белән борыннан Булмады һич татулык: Көн саен бер усаллык, Көн саен бер катылык.* М.Җәлил. *– Талны яшь чагында бөгәләр. Хәзер бөкмәсәң, соңрак сындырырга туры килмәгәе, – дип, үч итеп, аның янына юри бармаган, җәзасының*

*катылыгын җанына үткәреп белгертергә, ачуының тирәнлеген сиздерергә теләгән иде.* Ф.Латыйфи

10) *куч.* Катгыйлык, каты тору. *Иркенлек боза, катылык төзә.* Мәкаль. *Аңа карата вакытыннан элек, сезнең әмердән башка, усаллык, катылык күрсәтергә базмадым...* Ф.Латыйфи. *И, әйтергә кирәк, халык та моны аңлый: урынлы катылык өчен гаепләмиләр.* М.Әмир. *Кысып тоткан мал кулдан ычкынмаган кебек, кыз балага да катылык кирәк, азгын булмый!* Я.Зәнкиев

**КАТЫЛЫК ҮЛЧӘГЕЧ** *и. махс.* Төрле материалларның катылыгын үлчәүдә кулланылган приборларның (мәс., *дюрометр, склероскоп* һ.б.ларның) гомуми атамасы; *русчасы:* **твердомер**

**КАТЫН** *и. диал.* Хатын; хатын-кыз. *Күрше Мөкатдис әйтә, алты бала үстереп, тиле катын шикелле, бәләкәй арба тартып утын ташып йөрисең, ди.* М.Юныс

**КАТЫНША** *и. сөйл.* **1.** Вакчыл, хатын-кыз эшенә тыгылучан ир кеше. *Катыншадан хатын артык.* Мәкаль. *Ирдәүкә булса – хатының яу. Катынша булса – ирең яу.* Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* Хатын-кыз эшләгәнчә

**3.** *с. мәгъ.* Ычкынырлык итеп төйнәлгән. *Төенең катынша булмасын, нык булсын.* А.Гыйләҗев

**КАТЫНШАЛАНУ** *ф. сөйл.* Катынша *(1 мәгъ.)* булып китү; катыншалык күрсәтү. *Йөрмәле монда катыншаланып, --- синнән башка да өйрәтүчеләр җитәрлек.* Н.Фәттах

**Катыншаланып бетү** Тәмам, ахырга кадәр катыншалану

**Катыншаланып йөрү** Гел, еш кына катыншалану

**Катыншаланып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә катыншалану

**КАТЫНШАЛЫК** *и. сөйл.* Катынша холыклы булу сыйфаты, вакчыллык. *Сакалның бер тотамнан озын булуы ахмаклык, бөтенләй кыска булуы катыншалык галәмәте.* Н.Исәнбәт

**КАТЫР** I *и. геол.* Атмосфера сулары белән юылмаган шартларда башка төр туфраклар белән бер комплекста хасил булган тозлы туфрак. *Алар белән бергә нык тозланган – катыр яки солонец туфраклар очрый.* Җир һәм туфрак. *Тозланган туфракның ясалышы төрле тизлек белән барырга мөмкин. Бик көчле барган вакытта нык тозланган туфрак ясала (Na > 20%). Аны солонец (катыр) туфрак дип йөртәләр.* Җир һәм туфрак

**КАТЫР** II *и. рус сөйл. к.* **каторга**

◊ **Катыр китү** Сөргенгә җибәрелү. *Шушы бер йолкыш офицер өчен ничә кешенең атылуы, ничә кешенең гомерлеккә дип әйтерлек катыр китүе аның икеләнүләрен көчәйтте.* И.Салахов

**КАТЫРГАН** *и. диал.* Крыжовник (куагы һәм җимеше). *Син миңа бер-ике бөртек катырган җимеше өзеп бир. Җиде төп катырган куагы булырга тиеш бу бакчада.* М.Әмир

**КАТЫРГЫ** *и.* **1.** 1) Берничә кат катланып, махсус эшкәртелгән калын, каты кәгазь; картон. *Идәнне әйткән дә юк, --- урта бер җиргә куелган зур өстәлдә тузгып яткан кәгазь, карандашлар, почмаклардагы рамнар, катыргылар тәртипсезлекне тагын да арттыра иде.* М.Маликова. *Мәрвәр йөгереп килеп катыргыга ясалган портретын күрде дә шаклар катты.* М.Хәсәнов. *Катыргының икенче ягына чыккан тасма очларын катыргыга ябыштыралар һәм, ныграк булсын өчен, өстенә йомшак кәгазь кисәге дә ябыштырып куялар.* Файдалы киңәшләр

2) Нәрсәнең дә булса шул материалдан эшләнгән детале. *Башына катыргысыз рус картузы, аягына искергән кәвеш, җилкәсенә тапланып беткән пиджак салып чыгучы кеше шәкерт Гыйззәт иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**2.** *с. мәгъ.* Катыргыдан эшләнгән. *[Ул] Катыргы савытны ачып, юан, озын бер папиросны авызына алып капты да, тартасызмы дигән кебек, егетләргә тәкъдим итеп чыкты.* Н.Фәттах. *Аларга биш тартма катыргы патрон да кайтты.* Г.Мөхәммәтшин. *Мин, булган хикәяләремне җыеп, катыргы папка эченә салдым да Сәнгать идарәсенә киттем (ул вакытта шундый идарә бар иде).* Х.Сарьян

**КАТЫРГЫЧ** *и. хим.* Матдәнең катуын (полимерлашуын) тизләтү өчен аз микъдарда өстәлә торган матдә

**КАТЫР-КОТЫР** *иярт.* Каты азыкларны ашаганда чыккан чәйнәү, кимерү тавышларын белдерә. *Арпа бирсәң, атка бир – катыр-котыр чәйнәсен.* Мәкаль. *Катыр-котыр сохари ашау*

**КАТЫРМА** *и. диал.* Майда кыздырып пешерелгән көлчә. *Әнкәй, уртага дәстерхан җәеп, зур тәлинкәгә салып кайнар катырма китерде.* Н.Сәфәрев. *Катырмамы, әллә катламамы – исеме хәтердән чыккан. Әче камырдан ясаган көлчә өстенә әни йомыркага болгаткан эремчек ягып мичкә куя иде. Шундый тәмле була иде әни пешергән ул катырма! Итальяннарның пиццасы шул ук катырманы хәтерләтә.* М.Юныс

**КАТЫРУ** *ф.* 1) Каты хәлгә китерү, катыландыру. *Гыймазов нихәтле күңелле күренергә тырышса да, аның гипска катырылган кулы үзенең авыртканлыгын, уңайсызлаганын сиздерми калмады.* С.Рафиков. *Тик монда Гәрәйхан бабайның шомырт-миләшләренә генә урын калмады, өй таш, бетон, асфальт белән катырылып, чорнап алынган иде.* Ф.Бәйрәмова. *Нарат урманын кисеп асфальтка катырырлар, таш сыннар бастырып куярлар.* Г.Мөхәммәтшин

2) Туңдыру. *Су сибеп махсус катырылган кар катламнары, күпсанлы дзотлар, чәнечкеле чыбык киртәләре белән ныгытылган ул.* М.Әмир. *Су сибеп катырган шоп-шома бозда электр нуры күл булып җәелеп ята иде.* И.Гази. *Шуңа күрә, хатын-кызлар керләрен туңдырып киптергән шикелле, көшелне туңдыралар, салкында катырып киптерәләр иде.* Җир чәчәктә

3) Киптерү. *Сохари катыру*

4) Берәр эретмәдән коеп яки берәр ябыштыручан сыек әйбер, измә ярдәмендә ныклы предметлар, корылмалар ясау. *Мин кардан, су сибеп катырып, төньяк хайваннарының сыннарын эшләп куярга уйлыйм.* И.Салахов. *Канауның күпер тирәсендәге ярлары ике яклап бетон белән катырылган.* Ә.Шәмин. *Сәке балчыктан катырылган булса да, ул – безнең иң яраткан урыныбыз.* Н.Сәфәрев

5) *сөйл.* Туңдыру, өшетү, күшектерү. *Җир-су хайваннары, мәсәлән, тритон-*

*нар, боз булып катырганнан соң, ягъни бөтен физиологик процесслар туктатылгач, әкрен генә җебеткәндә, яңадан тормышка кайталар...* А.Тимергалин. *Баланы бөтенләй катыргансыз*

6) Суыту нәтиҗәсендә кырып бетерү. *Таракан катырасызмы әллә? Нишләп суыкта утырасың?* М.Маликова. *Шул Мәрдән дигәне юл тапкан: тоткан да, тараканнарны катырган кебек, кортларны тышка, салкынга чыгарып катырган.* Г.Толымбай

7) *сөйл.* Керләтү, пычрату. *Күлмәкнең якасын катыру*

**Катыра бару** Акрынлап, торган саен ныграк катыру

**Катыра башлау** Катырырга тотыну. *Көзен катыра башлау белән, шул тирә бала-чагасы өчен Петруш исемле каток була иде.* Мөҗәһит

**Катырып бетерү** Тәмам, ахырга кадәр катыру. *Үзенең урынлы-урынсыз әйтеп ташлаган ярым-йорты сүзләре белән репетиция вакытында ук эчебезне катырып бетергән Гаптери, тамашачылар алдына чыга башлагач тәмам каушап, бичарадан ни чара дигәндәй, коеп куйган шамакайга әйләнде дә куйды.* Г.Шәрәфи

**Катырып җибәрү** Кинәт кенә катыру. *Быел көз иртә килде. Башта коеп яңгырлар яуды, аннары катырып җибәрде.* Ж.Тәрҗеман. *Узган елны өч көн эчендә катырып җибәргән иде. Быел да, шөт, озакка тартылмас.* М.Шабай

**Катырып кую** Кинәттән генә катыру

**Катырып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә катырган хәлдә тоту

**КАТЫ САБАН** *и. а.х. иск.* Көзге сабан эше һәм сөрелгән җир. *Балдыз, каты сабаныңны бу юлы мин сөрә алмыйм.* К.Тинчурин

**КАТЫК-СӨТ** *җый. и.* Сөт һәм сөттән әзерләнгән төрле ашамлыклар. *Әминә аларны катык-сөт белән сыйлады, ә карт драбанд, титаклап, аларны Казантауга чиягә, җиләккә алып барып йөрде.* И.Салахов. *Бу якынлашуга өлкәннәр дә сәбәпче булды ахры, чөнки малайларның әнкәләре әсир немецлардан сабын, шырпы ишеләрне катык-сөткә алыштырып алырга мөмкин икәнлекне белеп алганнар иде.* Ф.Яруллин

**КАТЫ СУКА** *и. а.х. иск.* 1) Җирне сукалау эше. *Каты сука вакыты икән, Хәбибулла абзый, кибән куярга дип, ике япьле сәнәген тотып кырга киткән.* М.Мәһдиев. *Узып китә язган беренче көнне исәпләмәгәндә, ул өч көннең бер генә көне ял булачак иде, чөнки өченче көнне профилактик ремонт булырга, шуннан соң исә каты сука башланырга тиеш иде.* Н.Фәттах. *Каты сука өсте. Көтүчеләр терлекләрне елга буена утлауга төшерәләр.* С.Рафиков

2) Парга сөрү җире. *Өем-өем тирес каты сукага чыгарып түгелгән дә, инде сукаланган.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**КАТЫ ТАРАКАН** *и. зоол.* Тирес коңгызының кечерәк төре. *Син ат тизәгеннән корт эзлисең, каты таракан нәселеннән түгелсең ләбаса.* Ф.Хөсни

**КАТЫШ** *с.* **1.** 1) Нәрсә белән дә булса катнашкан, кушылган, буталган. *Ә күзләрендә ниндидер курку, ялвару катыш өметсезлек чагыла.* Р.Хафизова. *Ком катыш вак таш җәелгән киң юл такыр иде, тигез иде.* Н.Фәттах. *Бу минутларда икесенең дә күңелләре каушау, тынычсызлык катыш ниндидер билгесез рәхәтлеккә чумды.* С.Рафиков

2) *сир.* Шикле, шөбһәле, тынычсыз. *Аның [Зыяның] вәгъдәле көннән кичегүе Зөләйха абыстайда әллә нинди катыш хиссият уятты.* Г.Ибраһимов. *Бары тавышының гадәттәгедән катырак һәм әллә ничек катышрак чыгуы аның [Лизаның] яшерергә теләгән нәрсәсен ачык күрсәтә иде.* Ф.Әмирхан

**2.** *и. мәгъ. диал. к.* **катнаш** I. *Катышлыга катышың булмасын.* Мәкаль. *Эш бар икән, синең катышың шуның хәтле, җаный.* С.Рафиков

**КАТЫШЛЫ** *с. диал.* Вәсвәсәле, гасаби; каудар, дуамал. *Мөнәвәрә иренең муеныннан кочып алды: – И сине, катышлы. Хәзер дулап китәргә генә тора.* А.Расих. *Сәер малай иде ул, катышлырак дип әйтимме шунда, белмим.* Ш.Маннур

**КАТЫШМА** *и. к.* **катнашма**. *Табигый суның ят катышмалардан ничек арына баруын күздән кичерик.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Пробирканы газүткәргеч көпшәле бөке белән ябалар, авызы яныннан горизонталь рәвештә штативка беркетәләр һәм, аерылып чыгарга тиешле метанны катышмалардан чистарту өчен, су салынган пробирка белән тоташтырып, катнашманы ут ялкынында җылыталар.* Органик химия

**КАТЫШТЫРГЫЧ** *и. махс.* Болгаткыч (изгеч) машина; *русчасы:* **смеситель**

**КАТЫШТЫРУ** *ф.* 1) Катнаштыру, катнашырга мөмкинлек бирү. *Сүзлек төзүгә катыштыру. Концертта катыштыру*

2) Икенче бер нәрсәне кушу, болгату, аралаштыру, бутау, өстәү. *Өйдә без татарча сөйләшәбез, әни Илаһиядән өйрәнгән латыш сүзләрен җае саен катыштыра.* М.Хуҗин. *Спектакльгә --- кызлар катыштыру хакындагы һәрбер тәшәббесебез нәтиҗәсез калды.* М.Фәйзи. *Аны бу сәяси ыгы-зыгыга катыштырасы килми иде минем.* Р.Мөхәммәдиев

**Катыштыра төшү** Беркадәр, бераз катыштыру

**Катыштырып тору** Һәрвакыт катыштыру

**КАТЫШУ** *ф.* 1) Катнашу, кушылу, буталу. *Катышты алтын-көмеш бакыр-җизгә, Бер сурәттә күренделәр болар күзгә.* М.Гафури. *Бодае, арпасы катышып беткән. Чистасы-пычрагы бергә катышкан*

2) Башкалар белән бергә булу, кушылу, аралашу. *Фатих катышмады, карап кына торды. Безнең авылда бер малайга каршы ике малай сугышу юк.* Р.Хафизова. *Сәгыйть тә баштарак аларга катышмакчы булды, ләкин үзе бөтенләй диярлек аңламаган нәрсәләр турында тыңлап утыру, җитмәсә шул турыда акыл сатарга тырышу аны тиздән бөтенләй кызыксындырмый башлады.* Н.Фәттах. *Мәрвәр янә сүзгә катышасы итмәде.* М.Хәсәнов

3) *сөйл.* Аралашу, килешү-йөрешү. *Фәхри бик яшьтән үк бу йортка катышты, үзе калада торса да, Гәрәй мирзаларга килеп-китеп йөри иде.* Г.Ибраһимов

4) Кысылу, тыгылу, читтән килеп катнашу. *Карагыз, сез дә анда сайлау эшләренә катыша күрмәгез.* Ш.Мөхәммәдев. *Бер күке кычкырган вакытта икенчесе катышмый, ялгышып катышса – шундук туктап төзәтәләр.* М.Мәһдиев

**Катыша башлау** Катышырга тотыну. *Хәят, бу гаиләгә катыша башлагач та, акрын-акрын үз тормышларын ярлы, кечкенә һәм тар итеп күрә башлады.* Ф.Әмирхан

**Катышып бетү** Тәмам катышу

**Катышып йөрү** Бертуктамый катышу

**Катышып китү** Бераз килеп кушылу. *Әбиемне ышык кына, уңайлы гына бер җиргә утыртып, үзем йөрүчеләр арасына катышып киттем.* Ф.Әмирхан. *Сүзгә катышып китәргә теләп, берничә тапкыр ымсынып, авыз ачарга итеп тә карадым, булмады...* Р.Мөхәммәдиев. *Кай арада ялган сүзгә дә дөреслек катышып китә, кай чагында кыек атып та туры китерәсең.* Я.Зәнкиев

**Катышып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз катышу

**КАТЫ ЮКӘ** *и.* Каезланган, телемләнгән, ләкин, җебетелеп, аерым катламнарга аерылмаган юкә кабыгы. *Каты юкәдән иләк үрергә, аны кысага беркетергә кирәк.* Г.Галиев

**КАТЫ ЯГУЛЫК** *и.* Мазут, керосин һ.б.ш. сыек ягулыклардан аермалы буларак, ташкүмер, утын, торф кебек ягулыклар

**КАТЮ́ША** *и. гр. сөйл.* Бөек Ватан сугышы вакытында гади халык арасында реактив миномётның шаяртыпиркәләп әйтелә торган атамасы. *Шулвакыт кинәт җирләрне дер селкетеп, траншеяларның астын-өскә китерердәй итеп, йөзләгән орудие гөрселдәде. «Катюша»лар ут көлтәләре яудырырга тотынды.* С.Шәкүров. *Алар артыннан бастырып ук пушкалар тагылган автомашиналар, «Катюша»лар килеп җитте.* Г.Шәрәфи. *Гитлер разведкасы, бигрәк тә сугыш вакытында, Совет Армиясендәге яңалыклар белән нык кызыксынган, әлбәттә. «Катюша»ны кулланган совет белгечләреннән ни көтсә дә мөмкин.* С.Баттал

**КА́У** *и. диал.* **1.** 1) Чакма белән ут кабызу өчен кулланыла торган махсус киптерелгән гөмбә, мәшкә. *Чакма чакмый кау янмый.* Мәкаль

2) *к.* **каудан 1.** *Күк үләнкәй нигә үсә икән, янып-көеп китәр кау өчен; Кыз балакай нигә үсә икән, Сатылып та китәр мал өчен.* Җыр. *Каугa ут төртү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кипкән, корыган, былтыргы үлән. *Ул да булмый, чү, янымда бер тавыш. Өззз... итә, нәкъ җилдә шаулый кау камыш.* Н.Исәнбәт

2) Ут саклау өчен калдырылган (ут, учак һ.б.ш.)

**КАУГА** *и. диал.* 1) Гауга, тавышталаш

2) *иск.* Бәла-каза килгәнен белдергәндә кага торган зур барабан. *Козгын коркылдаган саен, кауга какмыйлар.* Мәкаль

3) Шундый барабан куелган урын (гадәттә авылның кое яки чишмә яны). *Авылы кайда, каугасы шунда.* Мәкаль

4) *бор.* Коедан су алу өчен тире чиләк, күнәк; тире цилиндр, барабан

**КАУГАЛАНУ** *ф. диал.* Кайгырып тынычсызлану, борчылу, дулкынлану; ыгы-зыгы килү. *Кайсылары «егетне харап иттерер бит» дип каугаланырга, кайсылары, бәреп калдырмагае [айгыр] дип, урамнан балаларын җилтерәтеп алып китәргә тотындылар.* Ф.Хөсни

**КАУГАЛЫ** *с. диал.* Гауга, тавышталаш чыгаручан. *Балалы тавык – каугалы халык.* Мәкаль. *Каугалы хатын*

**КАУДАЛЬ** *с. гр.* Койрык ягын белдерү өчен кулланыла торган анатомик термин

**КАУДАН** *и.* **1.** 1) Корыган, саргайган үлән сабагы. *Җәй айлары үтеп, көз айлары кергән. Агачларның коры чыбыклары, үләннәрнең кипкән кауданнары калган, кыр эшләре беткән.* З.Һади

2) *диал.* Былтырдан калган кипкән үлән, каудар. *Ишегалдым каудан-каудан, Каудан башлары ауган. Җыр*

**2.** *с. мәгъ.* Корыган үләннән торган. *Аккан суга кан койма, эчәр суың тапмассың. Каудан җиргә ут куйма, керер куыш тапмассың.* Мәкаль

**КАУДАР** *и.* **1.** Былтырдан калган кипкән коры үләннәр (ягулык итеп кулланыла). *Учакка каудар ягу*

**2.** *с. мәгъ.* Тиктормас, ыгы-зыгы килүчән, тынгысыз. *Сәлим үзе батыр һәм зирәк булып, моның өстенә бик каудар һәм кискен табигатьле дә адәм иде.* Г.Ибраһимов. *Аермалары тик шул гына: Гайникамал каударрак, ә Сәлимә, киресенчә, сабыр, йомшак табигатьле, шуңа күрә аның сипкелле булуы да алай артык күзгә ташланмый, ничектер үзенә бертөрле ягымлы сөйкемлелек биреп тора иде.* М.Шабай

**КАУДАРЛАНУ** *ф.* 1) Каудар холыклыга әверелү

2) Ашыгу, кабалану, кызулану; шаушу, ыгы-зыгы килү. *Карт, каударланып, берәр хәвефле хәл булмагае тагы дигән шомлы уй белән конвертны кулына алды, ертып, аның эченнән кәгазь кисәге чыгарды.* А.Расих. *Егетнең каударланып, ашыгып, ашкынып сөйләнүе, мәхәббәте хакына бөтен нәрсәдән ваз кичәргә әзерлеге сокландыра һәм әллә нишләп бераз шикләндерә дә иде.* Ф.Латыйфи. *Петров мине тынычландырды, каударланмаска, әлегә беркемгә дә хәбәр итмәскә кушты.* Т.Галиуллин

**Каударлана төшү** Бераз каударлану. *Шулай да арада иң олысы мин булгангамы, әллә инде үзем артык каударлана төштем, бу җилбәзәк тормыш белән саубуллашырга башлап мин батырчылык иттем.* М.Шабай

**Каударланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта каударланган хәл кичерү

**Каударланып тору** Бераз каударланган хәлдә булу

**КАУДАРЛЫ** *с.* 1) Кабаланулы, ашыгыч, тынычсыз (күренеш, вакыйга тур.)

2) Ашыгучан, мәшәкатьле, тынгысыз, кабаланучан (кеше тур.)

**КАУЗЫ** *и.* Ат муенына тага торган дүртпочмаклы кыңгырау. *Айлы төннәрдә каузылар шалтыравы, чыклы таңнарда яшь тай кешнәүләре --- ишетелә.* Г.Мөхәммәтшин

**КАУЛАК** *и. диал.* 1) Биек булып үскән яшь үлән, кургы. *Көтү каулакта йөри*

2) *күч.* Яңа буын. *Болар [Агыйдел буе башкортлары] – баягы тере, җитез, арыслан башкортларның торыннары, каулаклары.* Шура

**КАУЛАН** *и.* Бик биек булып үскән үләннәр. *Кауланга [аулаган] кошың төшмәсен, наданга эшең төшмәсен: кошың табылмый калыр, надан якаңнан алыр.* Мәкаль

**КАУЛА́У** *ф. диал. к.* **куалау**. *Малай куйларны каулап алып кайтты.* Әсирлектән кайткан әкиятләр. *Шулай да, ятып калганчы атып кал дип, атларны кауларга тотындык.* Г.Ибраһимов. *Бала-чага төяп, кыз-кыркын ияртеп мал артыннан каулыйлармы?..* Я.Зәнкиев

**Каулап тору** Бертуктаусыз куу. *Тын алырга да вакыт юк. Шуның өстенә, өч ноктага баскан солдатлар: «Тизрәк! Җәтрәк! Ух сезне, фашистлар!» – дип, өзлексез каулап торалар.* А.Гыйләҗев

**КА́УПЕР** *и. ингл.* Домна мичләренә бирелә торган һаваны җылыту аппараты

**КАУРЫЙ** *и.* **1.** 1) Кошлар тиресендә ян-якларында мамыклы төкләре булган эче куыш мөгезсыман үсенте. *Ул, арткы ишекне ачып, машина эченә карады: анда берничә кош каурые ята, кипкән ал таплар да күренә иде.* М.Насыйбуллин. *Аннары бит әле аларга быел каурыйлар җыярга да кирәкми, көзен Акчулпан каз канатларындагы каурыйларны күп итеп, күп итеп әзерләячәк...* М.Хуҗин. *Тавыкның башын кайнар суга салып 2–3 минут пешекләргә, йонын йолкып, корытканчы сөртергә, өтеп, каурый төпләрен, күзен алырга, томшыгын чабып ташларга кирәк.* Татар халык ашлары

**2.** *с. мәгъ.* 1) Каурыйдан, каурыйлардан торган; каурыйдан ясалган

2) Формасы, структурасы, төсе белән каурыйны хәтерләткән, каурыйсыман (кайбер классификацияләрдә кулланыла); *русчасы:* **перистый**. *Күктә каурый болытлар сызылып-сызылып агарып тора.* И.Низамов

**КАУРЫЙ-КАУРЫЙ** *с.* Каурыйлардан торган; каурыйларга охшап торган; һәрбер каурые беленеп, күренеп торган

**КАУРЫЙКАНАТЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Канат кырыйлары төкләр белән капланып, каурый яки җилпәзәне хәтерләтүче иң вак коңгызлар; *русчасы:* **перистокрылые**

**КАУРЫЙЛАНУ** *ф.* Канат чыгу, йон чыгу (кошлар тур.)

**Каурыйланып җитү** Тиешле каурыйлары булу

**КАУРЫЙЛЫ** *с.* Каурые булган; каурыйлардан торган. *Ә башына Анисимов Ольга Эразмовнаның (Чкалов хатыны) яшькелт каурыйлы бүреген кидереп җибәргән икән...* С.Баттал. *Башына тутый кош каурыйлы очлым кигән хазар койрыкчысы Дәнисне күрүгә койрыкны ярдәмчесенә бирде һәм кылычын чыгарды.* М.Хәбибуллин. *Өстендә билләре өзелеп торган, төлке якалы кара бәрхет күлмәк, башында шәмәхә каурыйлы мех бүрек, аякларында биек үкчәле җылы туфлиләр.* Ш.Рәкыйпов

**КАУРЫЙЛЫЛАР** *и. сөйл.* Кошлар

**КАУРЫЙСЫМАН** *с.* Формасы каурыйга охшаган. *Яфраклары чиратлы торышлы, сузынкы-йомыркасыман, ике телмәле каурыйсыман, өске яклары куе яшел, аслары ачык яшел, сузынкыланцетсыман пычкы читле вак яфраклы.* Урман аптекасы. *Ике өлешле үсемлекләрнең яфрак сеңерчәләре еш кына бармаксыман яки каурыйсыман була.* Ботаника

**КА́УСТИК** *и. к.* **каустик сода**

**КА́УСТИК СОДА** *и. хим.* Зәһәр натр (натрийлы селте). *Ацетат ефәктән тегелгән әйберләрне балалар сабыны, сабын вагы яисә «Новость» порошогы белән юалар. Андый әйберләрне юганда, сода, каустик сода һәм нашатырь спирты кулланырга һич тә ярамый.* Файдалы киңәшләр. *Мәсәлән, мамыкҗеп тукымаларны сода, поташ, көл селтесе белән кайнатканда берни дә булмый, әмма каустик сода белән кайнатырга ярамый.* Файдалы киңәшләр

**КАУЧУК** *и. ингл.* Кайбер тропик үсемлекләр согыннан алына яки химик юл белән табыла торган эластик сумала (резин һәм резин әйберләр, шина, җилем ясау өчен китә). *Җитмәсә, кызлары да балта белән каткан каучук чабып ята.* Р.Хисмәтуллин. *Аңа [Түбән Кама шәһәренә] нибары унбиш яшь, ә синтетик каучук, автомашина шиннары җитештерү, төзелешләренең колачы, шәһәрнең төзеклеге, яңалыгы ягыннан ул йөзьяшәр калалар белән ярыша башлады.* И.Низамов. *Резина җилемен өйдә дә әзерләп була. Моның өчен бер кечкенә банка белән чиста бензин алалар һәм аңа берничә кисәк вулканлаштырылган каучук салалар.* Файдалы киңәшләр

**КАУЧУКЛЫ** *с.* Каучук алына торган. *Каучуклы үсемлекләр*

**КАУШАТУ** *ф.* 1) *з.-сыз* Югалып калу, дулкынлану. *Үз башына төшкәч, бигрәк тә күңелеңә хуш килгән артистның хур егете кебек, ә син үзең әштерөштер генә киенгән авыл кызы булсаң – шактый каушата икән.* К.Тимбикова

2) Берәүне оялту, дулкынландыру. *Аңа, чыннан да, бер фикергә килү кыен, мондый тәкъдимнәр отыры каушата, кыюлыгын шиңдерә иде.* З.Фәтхетдинов

**Каушата башлау** Каушатырга тотыну. *Шуннан каушата башлый инде.* Ялкын

**Каушатып җибәрү** Бераз каушату. *Кала үзенең олылыгы һәм сәерлеге белән Габдулланың кечкенә йөрәген каушатып җибәрде.* Ә.Фәйзи. *Хәйдәр муллага калса, кинәт яңгыраган бу тавыш аны каушатып җибәрде, кулындагы тәлинкәсе идәнгә төшеп челпәрәмә килде.* С.Рафиков. *Ләкин начальникның кырыс карашы аны каушатып җибәрде, шунлыктан соравы дорфарак чыкты, ахрысы.* М.Маликова

**КАУША́У** **1.** *ф.* Югалып калу, аптырап калу, фикер чуалу, зиһен таралу. *Шундый гап-гади сорау да ир кешене каушатыр икән!* Р.Хафизова. *– Исемнәрен үзем сайладым, әтиләренең фамилиясен йөртәләр, – диде хатын, һәм көтмәгәндә, нидер тоемлапмы, каушый һәм борчыла төшеп сорап куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Мине театрга алдылар һәм күп тә үтми роль бирделәр. Ләкин мин хәтта шул рольне дә уйный алмадым. Әллә курыктым, әллә каушадым.* М.Хәбибуллин

**2.** *и. мәгъ.* Куркып калу, дулкынлану. *Шулай да пулемётчылар каушауны җиңәргә тырыштылар, аларга бик төз атарга кирәк иде: үзебезнекеләргә дә тимәсен, батареяларын коткарабыз дип ыргытылган пехотаны да тоткарларлык булсын.* И.Низамов. *Икесенең дә күңелен нindидер эчке каушау, югалып*

*калу кебек бер хис биләде.* С.Рафиков. *Аның каушавы, дулкынлануы күренеп тора иде.* А.Шамов

**Каушап калу** Кинәт каушаган хәлгә килү. *Ике яктагы ике куак артыннан каршына чыгып баскан кораллы кешеләрне күреп, юлаучы егет бер генә мизгелгә каушап калды, әмма артка чигенмәде.* Ф.Латыйфи. *Әнвәр Бһаветдинов та – типсә тимер өзәрдәй егет – яңгырга эләккән көзге чебештәй каушап кала.* М.Насыйбуллин. *Бу минутта ул югалып, каушап калыр, аклана башлар дип уйлаган иде Зәйтүнә.* М.Маликова

**Каушап китү** Кинәт каушау. *Болай, шәкертенең кайбер сикәлтәләрне бик оста борылып үтүенә дә, кай салуларда, каушабрак китеп, дырык-дырык рессорлар тетрәтүенә дә остазның бер үк дәрәҗәдә битараф калуы сәеррәк сәерлеккә...* Р.Төхфәтуллин

**Каушап тору** Каушаган хәлдә булу. *Илсөяр берникадәр каушап торды да су читенә каплап куелган җимерек паром артына посты.* Г.Гобәй

**Каушап төшү** Беркадәр, азрак каушау. *– Укырга?! – Миңнисәттәй кинәт каушап төште, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, тагын кайтарып сорады ---.* Н.Фәттах. *Яхин да каушап төшмәде: шундук җавап кайтарды ---.* М.Зарипов. *Әмма тәвәккәл сугышчы каушап төшми – аның тубы атудан туктамый.* Рәхмәт сиңа, солдат!

**КАУШАУЛЫ** *с.* Каушаган, әсәрләнгән. *Ишекне ачып кергәндә, Тәслимәнең йөзе шактый борчулы-каушаулы иде.* Р.Төхфәтуллин. *Баязид карый эчтән бераз каушаулы тавыш белән: – Мин чишенгәнмен, һич булмаса чалбар кигәнче сабыр итегез! – дип кычкырды.* Г.Ибраһимов

**КАУШАНКЫРА́У** *ф.* Бераз каушау, каушый төшү

**КАФ** *и.* Гарәп әлифбасында каты *к* хәрефе (ق)

**КА́Ф ТАВЫ** *и. миф.* Төрки халыклар мифологиясендә дөнья читендәге таулар тезмәсе; әкиятләрдә сөйләнә торган зур тау. *Сәетнең йөрәге ашкына; һәр ике ягына нindидер аңлаешсыз билгеләр, башына таҗ кидерелгән канатлы елан сурәте төшерелгән тәңкәнең көчен сынап карыйсы, кәрваны белән ерак сәяхәтләргә, каф тау илләренә, сартлар арасына, Рум базарларына сәфәр чыгасы килеп талпына.* Ф.Латыйфи. *Алда – йөзләгән шаһитны табу, җавап алу, энәсеннән җебенәчә төпченү. Кара-каршы утыртып сорау, ун еллар буе җыелып, Каф тавыдай өелгән документларны актару, җентекләп өйрәнү, күчермәләр алу.* М.Насыйбуллин. *Без кырып салган дошман яулары, без кисеп төшергән аждаһа башлары... Бергә җыеп өйсәң, җир упсын менә, үзе бер Каф тавы булыр иде.* Г.Сабитов

◊ **Каф тавы арты** «Бик ерак урын» мәгънәсендә. *Әллә ычкынганмы баудан Каф тау арты җеннәре? Я тишелгәнме Ходайның бихисап зур мендәре?* Г.Тукай. *Корт башын колакка куеп тыңласаң, анда әллә нинди ерак җил ыжылдавына охшаган тавыш килә. «Каф тавы артындагы дәрья шаулый» дип аңлата иде моны апасы.* Ә.Фәйзи. *Яшь кенә булса да, Әбүгалисиналар таптаган ул көнчыгыш җирләрен, диңгезләр аръягын, Каф тавы артларын күргәне булды бит Зәлифәнең.* Р.Хисмәтуллин

**КАФӘС** *и. гар. иск.* 1) Читлек. *Җан кошына мескен адәмдүр кафәс, Гаклыңа килгел, фәкыйрь, сән бер нәфәс.* Мөхәммәдьяр

2) Кәрзин; челтәрләп, рәшәткәләп ясалган әйбер

**КАФЕ** *и. фр.* Зур булмаган гади ресторан. *Озак та үтмәде, пристань каршындагы кафедан бер кыз белән ике матрос килеп чыктылар да чиратсызнисез алга үтә башладылар.* С.Сабиров. *Эштән соң кафеда аяк өсте генә капкалап алгач, Гренвиль белән очраштык.* А.Тимергалин. *Йортларның беренче катында я кибет, яисә ресторан, бар, кафе, траттория (трактир).* М.Юныс

**КАФЕ́-БА́Р** *и. фр.* Үз эчендә гади ресторан һәм төрле эчемлекләрне сатып алып, шунда ук эчеп утыра торган, прилавка артында хезмәт күрсәтүчесе булган ашау-эчү урыны. *Смена бетәргә шактый вакыт бар иде әле, бригадир Людмила апалары аларны нинди эшкә кушар икән; спорт залындагы измә сылаучыларга булышмага җибәрерме, әллә «кафе-бар» дигәненә бүгеннән үк бизәү төшерә башларга диярме?* Э.Касыймов. *Ә Тоглар исә, чишенеп, кафебар янындагы утыргычларның берсенә барып утырды, анда шундый тәмле кофе хуш ис аңкытып тора, ерак калган утызынчы-кырыгынчы елларның моң-көйләре әкрен генә агыла иде.* Р.Мирхәйдәров

**КА́ФЕДРА** *и. гр.* 1) Лекцияләр уку, докладлар, чыгышлар ясау өчен махсус ясалган биек урын; мөнбәр. *Гимназистларны укытучылар язган речьләрне күңелдән ятларга һәм кафедрадан торып сөйләргә мәҗбүр итәләр иде.* Җ.Тәрҗеман. *Лобачевский кызыл агачтан эшләнгән кафедрага менде һәм аудитория өстеннән күз йөртеп чыкты.* Җ.Тәрҗеман

2) Югары уку йортларында билгеле бер тармакка караган предметларны укыту белән шөгыльләнгән фәнниадминистратив бүлек. *Кафедра әгъзаларының һәрберсе илле килограмм печән җыеп тапшырырга тиешләр.* М.Мәһдиев. *Шундый әзерлектән соң диссертация гыйльми советка тагы куела һәм, совет кафедра фикере белән килешсә, кафедраның сүзе карар буларак рәсми төс ала.* А.Расих. *Шамилне, авыл хуҗалыгы институтын бетерү белән, гыйльми яктан өметле дип, кафедрада ассистент итеп калдырдылар.* Х.Сарьян

**КАФЕДРАЛЬ** *с. дини* Гыйбадәт кылуны урындагы епископ үзе алып бара торган үзәк (гыйбадәтханә тур.). *Шактый еракта зәңгәрләнеп күккә ашкан Алатау түбәләре генә түгел, шәһәрнең мактанычы һәм горурлыгы булган зур кафедраль собор – Рәсәйдәге агач чиркәүләр арасында иң биеге исәпләнгән гыйбадәтханә гөмбәзләре дә ак давыл карынында калып юкка чыккан иде.* Т.Әйди

**КА́ФЕЛЬ** *и. нем.* Стеналарны каплау, судан саклау өчен һәм матурлык өчен кулланыла торган керамик плитка. *Бер почмакта ялтыравыклы кафель плитәләр ябыштырылган түгәрәк галанка мич.* С.Шәкүров. *Аннары өч кам-*

*форкалы польский плитәгә ут төртеп җибәрә, кухняның ак кафель стенасына бәреп, тәбә пешерер өчен, йомыркалар сыта.* Ф.Яруллин. *Бина эченнән алып китәргә мөмкин булган бөтен нәрсәне, ишекләр, кухнядагы плитәләргә кадәр каерып алып чыгып киткәннәр, хәтта стенага ябыштырылган кафель шакмакларын да куптарганнар.* М.Маликова

**КА́ФЕЛЬЛЕ** *с.* Кафель белән капланган. *Аннан йомшак сөлгегә уралып ак кафельле кухняда чәй эчү, аннан мамык юрган астына чумып, чиста тәненең рәхәт сулавын тоеп яту аны тәмам исерткән иде.* Н.Гыйматдинова

**КА́ФЕЛЬЛӘҮ** *ф.* Кафель белән каплау. *Ванна бүлмәсен кафельләү*

**Кафельләп алу** Тиз генә кафельләү

**Кафельләп кую** Кафельләнгән хәлгә китерү

**Кафельләп тору** Кафельләү эшен хәзерге моментта башкару

**КАФЕТЕ́РИЙ** *и. исп.* Үзеңә-үзең хезмәт күрсәтеп, тиз генә ашап чыгу урыны; кафеның бер төре

**КАФЕШАНТАН** *и. фр. иск.* Сәхнәсендә җыр һәм биюләр, кайвакытта шактый әдәпсез нәрсәләр күрсәтелә торган кафе яки ресторан. *Ильяс абыем сугыштан гарипләнеп кайтып, кафешантан марҗасына өйләнде, үзен кызыллар атып үтерде.* Р.Батулла

**КАФИЛӘ** *и. гар.* Кәрван; эшелон, олау, колонна; конвой. *Ятма, тор, күрче, үтте ич кафилә, Бирмәсләр бит һичбер өлеш гафилгә.* Мөхәммәдьяр

**КАФИЯ** *и. гар. шигъ.* Рифма

**КАФИЯДӘШ** *и.* Рифмадаш, рифма хасил иткән

**КАФИЯЛӘ́Ү** *ф.* Рифмалау

**КАФТАН** *и. фар. иск.* Күп кенә халыкларда озын чабулы ирләр өс киеме. *Аларның шушы сүзләрен ишеткәч, киңәшен бирергә булды: – Сез бу кафтаннарыгызны салыгыз, гади һәм гадәти итеп киенегез.* Ф.Яхин. *Аңа патша кафтан бүләк итеп биргән. Алтын бизәкле кафтан булган ул.* Я.Хамматов

**КАХАН** *и. тар. к.* **каган.** *Үзенә аркадаш табу белән үк, Бумын кахан жужаннарга яу кузгала.* М.Хәбибуллин.

**КА́Х-КАХ** *иярт.* Көчле йөткерү, какыру тавышын белдерә. *Утыра шунда карт тәмәкече кебек ках-ках йөткереп!* Г.Сабитов

**КА́Х-КОХ** *иярт. к.* **ках-ках**

**КАХБӘ** *и. гар. иск.* 1) Фахишә, уйнашчы хатын. *Кахбә мөхтәсибтән куркыр.* С.Сараи

2) Хәйләкәр, ышанычсыз кеше

**КАҺАН** *и. к.* **каган**. *– Юк, бирмим! – дигән Алмыш хан. – Алайса, мин аны сугышып алачакмын! – ди каһан.* Р.Батулла

**КАҺАРМАН** *и. фар.* **1.** 1) Батыр көрәшче, ветеран, герой. *Генерал Далинның большевикларны җиңүче каһарман даны бөтен дөньяга таралган икәнен хәтереңнән чыгарма.* Ш.Усманов. *Октябрь каһарманнары, революцияне үз куллары белән яулаган ветераннар хәзер дә туган колхозларына кулдан килгән кадәр ярдәм итәләр, аның белән бергә сулыйлар.* Х.Хәйруллин. *Араларында Ватан сугышы каһарманнары да, колхоз алдынгылары да бар.* М.Әмир

2) Матур әдәбият әсәрләрендә, кинофильмнарда һ.б. сурәтләнгән һәм укучының яисә караучының игътибар үзәгенә куелган образ; герой. *Аны, татар малае диюдән битәр, француз язучысы Дюма романнарының каһарманы – Урта гасыр мушкетчысы дип атарга булыр иде.* А.Расих. *Себер аюлары турында Голливуд чыгарган арзанлы фильмнар каһарманы кебек иде ул.* А.Тимергалин

3) Берәр эштә, хезмәттә аеруча үзен күрсәткән, төп урында торган кеше. *Кибернетиканы һәм автоматлар теориясен ул үзлегеннән өйрәнде, чөнки монда математик фикерләү сәләте генә кирәк, ә ул безнең каһарманда җитәрлек иде.* А.Тимергалин. *Килүчеләргә, оста гына итеп, Херсонскоега һөҗүмне сөйли башладылар. Бу эшнең каһарманнары – кавалеристлар.* Ш.Усманов

**2.** *с. мәгъ.* Батыр, кыю, булдыклы, данлы. *Татар халкы үзенең Гайфуллин Закир кебек атаклы каһарман уллары белән мактана.* Ш.Мөдәррис. *Баксаң, халкыбызның каһарман уллары теләсә нинди шартларда көрәштән туктап калмаганнар икән: хәрәкәт иткәннәр, тарих, заман һәм киләчәк хакында уйланганнар, ---.* Х.Миңнегулов

**КАҺАРМАНЛЫК** *и.* 1) Каһарман булу; батырлык, геройлык. *Тарихта булмаган каһарманлыклар күрсәткән һәм күрсәтә торган геройлар бик күп бездә.* Рәхмәт сиңа, солдат! *Ничә мәртәбә чын каһарманлык күрсәтте ул шушы залда, берьялгызы калган сәгатьләрдә дә җиңелмәде.* Р.Мөхәммәдиев. *Анда безнең чекистларның авыр сугыш елларындагы каһарманлыгы тасвирланган иде.* Җ.Дәрзаман

2) Каһарманнарча эшләнгән эш. *Малай чагымда мин яраткан батырыма әллә нинди каһарманлыклар уйлап чыгара, төшемдә дә, өнемдә дә саташып бетә торган идем.* Җ.Тәрҗеман. *Җәлил, беренче чиратта, рухи яктан, тарихи каһарманлык эшләгән кеше буларак якын һәм кадерле.* Р.Фәйзуллин

**КАҺАРМА́НЧА** *рәв.* Батырларча, геройларча, батыр рәвештә. *Гражданнар сугышының беренче айларында каһарманча сугышкан, армый-талмый эшләгән егет соңгы вакытларда нәрсәгәдер рухсызланып киткән иде.* Ш.Усманов

**КАҺАРМАННА́РЧА** *рәв.* Каһарманнарга хас булганча, каһарманнар кебек, каһарманнарга охшаш. *Кирәк, бик кирәк иде аларга өстәмә көч. Биредә алар бүген дә каһарманнарча сугышалар иде.* И.Низамов. *Кыскасы шул, каһарманнарча үлүе турында хәзер үк өенә хат язарга, ә иртәгә мәетен җирләргә.* М.Шабай

**КАҺВӘ** *и. гар. к.* **кофе**. *Ике нәрсә харап итте җиһанны: Йәмәннең каһвәсе, Румның доханы [тәмәкесе].* Мәкаль. *Аның куе каймак берлән бирелгән каһвәсе телләрне йоттырды.* Г.Исхакый. *Ана белән кыз кухняда, каһвә эчә-эчә, акчаны ничек алу турында план кордылар.* И.Сиражи. *Каһвә китергән кызыл иренле, туп шикелле официант кыз да, идәндәге ишек тоткасын күреп, хәрәкәтсез, өнсез калды.* Р.Гаффар

**КАҺВӘХАНӘ** *и. гар. к.* **кафе**. *[Хуҗаның] Каһвәханәдән башы чыкмый,*

*безнең янга әллә нигә бер кереп, тегесенә-монысына җикеренеп ала да тагын шунда олага.* М.Галәү. *Ул моны шәһәрнең уртасы булганын, әнә почтаханә, әнә кибетләр, әнә каһвәләр (каһвәханәләр) булганын күрсәтә башлады.* Х.Миңнегулов. *Анысын ясап бетерергә өлгермәделәр, 15 август кичендә шул ук урамда урнашкан «Шоколадница» каһвәханәсе бинасының өченче катындагы балконы җәяүлеләр юлына җимерелеп төште.* Шәһри Казан

**КАҺВӘЧЕ** *и. иск.* Каһвәханә тотучы; каһвәханә хезмәткәре. *Каһвәчеләр каһвәханәсене ачып сату итә башладыгы кеби, урамнарда, базарларда халык та ары-бире йөреп кайный башлаган иде.* Ш.Мөхәммәдев

**КАҺИН** *и. гар.* Фалчы, багучы, күрәзәче; шаман, кам. *Борынгы заманда күкне күзәтү эше белән, кагыйдә буларак, дин әһелләре, каһиннәр (жрецлар) шөгыльләнүе очраклы хәл түгел.* Галәм. Җир. Кеше. *Чәчүлек җир өч өлешкә бүленә: бер өлешеннән алынган уңыш – каһингә, икенчесе баш инкага бирелә, уңышның өчтән бере генә общиначыларның үзләренә кала. Инклар белән каһиннәр игенчеләр хисабына яшиләр.* Урта гасырлар тарихы

**КАҺКАҺӘ** *и. гар.* 1) Бик нык кычкырып (хахылдап) көлү, шаркылдап көлү; мәсхәрәле, яман көлү турында. *[Камилә] булган җирдә уен, көлке, каһкаһә күтәрелә.* Г.Ибраһимов. *Дәрвиш йөзекне алганда, үткен бер сызгыру тавышы белән нечкә генә каһкаһәләп көлү тавышлары ишетелә. Ул каһкаһәләр бушка булмаган икән.* Ш.Камал. *Кинәттән һавада кемнеңдер каһкаһә белән көлгән тавышы яңгырагандай булды.* А.Хәлим

2) Мыскыл, сарказм. *Әһлиуллин, мышкылдап утырган җиреннән башын күтәреп, каһкаһә белән көлә башлады.* Р.Мөхәммәтҗанов. *Тавышында каһкаһә сизелә иде*

**КАҺКАҺӘЛЕ** *с.* Ачу катыш мыскыллы, саркастик. *– Мин – хөр илнең иректә кешесе, – дип башлаган идем, Гренвильнең каһкаһәле көлүен ишеткәч туктап калдым.* А.Тимергалин. *Кәгазь ертыгындагы күз Аликны мыскыл итә, аңардан көлә; әнә ул күздә әллә нинди салкын чаткы ялтырап китте, әнә ул күз кысыла төште, һәм аңардан каһкаһәле елмаю сирпелде ---.* А.Сафин. *Каршындагы ермак чите, миһербансыз пулемётның чекерәйгән күзе, Хәйрулның каһкаһәле көлүе хәтеренә төшкән иде.* И.Низамов

**КАҺКАҺӘЛӘҮ** *ф.* Кычкырып, мыскыллап, сарказм белән көлү; каһкаһәле көлү. *Күңелендә тамчы да шәфкать дигән нәрсә юк икән. Өенә кайткач каһкаһәләп көлгәндер әле бер рәхәтләнеп...* М.Хәсәнов. *Алар тышкы ишекне ябып чыкканда, каһкаһәләп көлгәндәй, бакалар бакылдавы ишетелде.* М.Маликова

**КАҺӘР** *и. гар.* 1) Каргыштан килгән җәза, газап. *– Бер килгән кешегә килә бит ул, каһәр, – дип куйды ул бераздан, – тәки игелеген күреп булмады бит.* Г.Сабитов. *Ә минә котыртучыга – каһәр! Каһәр укыйм.* М.Хәбибуллин. *Җилкәмне ваттылар пуля белән, каһәр.* З.Фәтхетдинов. *Каһәр төшсен сиңа, дип бәддога укыды.* Д.Гайнетдинова

2) Каты ачу. *Кайгы – күздән, каһәр йөздән беленә.* Мәкаль. *Немец, каһәр, сугышта да адәмчә яшәргә омтыла икән.* Ш.Рәкыйпов. *– Минә инде бүген суд булды, егерме биш сум түләтәләр, каһәрләр, – ди.* Г.Толымбай. *Ул, ник ачмыйлар соң моны, каһәр, шулкадәр озак ашамасалар, соңгы ашаулары түгелдер бит, дип сукрана.* Г.Мөхәммәтшин

3) Вак-төяк каршылыклар, бәхәсләр, кыенлыклар, проблемаларга, шулай ук кешеләргә карата ачусыз гына әйтелә торган каргау сүзе. *Галәү бабай сукрана-сукрана тәрәзәгә килде. – Әле генә йокыга китеп бара идем, каһәр. Шырпысы кайда соң әле?* Г.Гобәй. *Кая китте бу бала, каһәр?*

4) Сокланганда, ошатып-яратканда әйтелә. *И матур да бит, каһәр! Эшкә дә уңган, каһәр!* Ш.Рәкыйпов. *Озын кара керфекләре шундый матур каһәрнең: карандаш тидерүнең дә кирәге юк.* М.Насыйбуллин. *Ләкин ул чакта ничектер игътибар ителмәгәнме, бу юлы шаккатым. Чибәр икән, каһәр!* Р.Төхфәтуллин. *Безнең казнага әйбәт бүләк алып килгән, каһәрең.* З.Фәтхетдинов

◊ **Каһәр китү** Берәрсенең ачуы, каргышы нәтиҗәсендә нинди дер һәлакәткә дучар булу, җәзасын күрү дип уйлау. *Алдагы елда Ходаның каһәре китеп, кар явар.* Н.Сәфәрев. **Каһәр салу** Интектерү, газаплау, тилмертү, җәфалау. *Еладым мин. Хәзер дә бик сыкрыйм. Каһәр укыйммы? Дәррәү күтәрелеп якламавы өчен, халкыма каһәр салыйммы? Каһәрләмим. Халкыма илне торгызуда каһарманлык телим. Каһарманлык!* М.Хуҗин. **Каһәр сугу** Берәрсенең ачуы, үпкәсе, рәнҗешкаргышы нәтиҗәсендә бәла-казага, ниндидер һәлакәткә дучар булу, җәзасын күрү дип уйлау. *Шул төнне яшеннән ут чыгып, алпавыттан калган әйбәт нарат өйләр, амбарлар янып бетәләр. Карт-карчыклар исә: – Яшен сукмады, Алланың каһәре сукты! – дип юрап куйдылар.* Г.Ибраһимов. **Каһәр суккан** Бик яман итеп, ачынып каргау сүзе. *Шундый ук куркыныч затмыни соң ул? Бәлки, теге каһәр суккан янчык шулай тәэсир итәдер.* Ф.Латыйфи. *Каһәр сукканнар, сакал кырырга да ирек бирмәделәр.* А.Шамов. *Нинди каһәр суккан кара көч күмергә әйләндерде бу гүзәл гөлбакчаны?..* М.Әмир. **Каһәр суккыры** Каргап, каһәрләп сүгү, кемгәдер ләгънәт төшүен теләү. *Каһәр суккыры Сайгушев, азгын җан, пычакны сындырды, кибеттә пычак юк чагында.* М.Хуҗин. **Каһәр төшкән** *к.* **каһәр суккан** *Ә ул, каһәр төшкән нәрсә, нигәдер сөремләнмәкче була, ара-тирә, сүнәргә теләгәндәй, өзек-өзек талпынып куя...* А.Шамов. *Шуның өстенә тагын бу каһәр төшкән грипп!* А.Шамов. *Каһәр төшкән «перестройка» дөньяның астын өскә китерде.* Х.Ибраһим. **Каһәр төшкере** *к.* **каһәр суккыры**. *Ә паром йөртүче карт: – Мине дә хәләл ризыгымнан мәхрүм иттеләр бит, Алланың каһәре төшкерләре, – дип зарланудан башканы белмәде.* М.Шабай. *Каһәр төшкерене көч-хәл карцерга өстерәп керүгә, ишек ябылды.* И.Салахов. **Каһәр төшү** *к.* **каһәр сугу** *Әйе, әйе, менә шул каһәр төшкәнгә бара торган юл.* А.Шамов. *Каһәр генә төшсен, яңа гына җылынып, йоклап киткән идем, тагын бүләләр.* И.Салахов

**КАҺӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **каһәрләү**. *Сания чит җирнең иң каһәрләнгән төрмәсендә ятып калды.* Я.Зәнкиев. *Мин миллионнар тарафыннан каһәрләнгән сугыш аркасында югалган тәүге мәхәббәтем каршында чал башымны иярргә тиеш.* Г.Госман. *Каһәрләнгән дөнья. Каһәрләнгән, изелгән халык*

2) Бик ачынып, усал итеп әйтү, каргау, сүгенү

**КАҺӘРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Каргау, каргышлау, янау; сүгү, хурлау, яманлау, тиргәү. *Ә ул сыерчыкларны каһәрләп качырып бетергән.* М.Мәһдиев. *Аңа карап, сакал-мыегы җиткән өч-дүрт солдат әрнеп, ярым пышылдап, язмышны каһәрли башладылар.* Ш.Рәкыйпов. *Үзе эшли, әмма күңеле тыныч түгел Ногманның. Соңгы көннәрдә Галимов белән конфликтка керүе дә җанын бик нык каһәрләде.* М.Хәсәнов

2) Бик каты тоту; шәфкатьсез җәзалау. *Залим Россия хөкүмәте, кан эчүче бюрократия, юан корсаклы буржуазия бичара җирсез-сусыз, ач-ялангач авыл халкын талап, казаклардан суктырып, аттырып каһәрләгән.* Ш.Мөхәммәдев

**Каһәрләп алу** Билгеле бер момент эчендә каһәрләү. *«Малаен да котыртып өлгергән икән», – дип, ул Карибулланы күңеленнән каһәрләп алды һәм шактый кырыс тавыш белән Гафияттән сорады ---.* Э.Касыймов

**Каһәрләп йөрү** Һәрвакыт каһәрләү. *Яланга укытырга килгәч, авылны бер дә яратмыйча, тешен кысып кына сөйләшеп, язмышын каһәрләп йөргән Айсетдин иде бу!* Я.Зәнкиев

**КАҺӘРЛЕ** *с.* 1) Каргаулы, усал, ачулы. *«Тар балакларны» дружина штабына алып кереп «эшкәртәләр» дә, чәчләрен алып, «стиляга» дигән каһәрле мөһер сугып чыгаралар.* М.Юныс. *Кичтән сөйрәлеп, исереп кайткан иргегет анасына нинди генә каһәрле сүзләр ишеттермәде дә, никадәр пычраклаганнар такмады...* А.Бикбаева. *Нуриәхмәт Зиннурович, күзләрен әрле-бирле йөртеп, каһәрле карашы белән берара бүлмәдәгеләрне ашады.* Р.Зарипов

2) Бик җәфалы, газаплаулы, интектергеч, борчулы. *Теге каһәрле төнне исенә төшерсә, бөтен тәне калтырана башлый.* С.Шәкүров. *Тирә-ягымны каһәрле сораулар чолгап алганнар да миңа һөҗүм итәләр.* Ә.Фәйзи. *Тормышта аяк атлаган саен туып торучы каһәрле сорау бу.* М.Юныс. *Тансык балалар урынына каһәрле язмышлар туган илдә иминлек булырмы?* Т.Миңнуллин

3) Каты: шәфкатьсез, мәрхәмәтсез, рәхимсез. *Каһәрле кеше. Каһәрле дошман*

**КАҺӘРЛЕК** *и.* Шәфкатьсезлек, мәрхәмәтсезлек, рәхимсезлек, җәзалаучанлык, үч. *Мөстәбидләр [колбиләүчеләр] --- каһәрлек белән даннар чыгарган.* К.Тинчурин. *Ә Хәдичә селкенергә дә курыккандай утыра да утыра. Күңелендә бушлык, салкынлык, рәнҗү, каһәрлек.* М.Хәсәнов

**КАЧАГАН** *с. диал.* Көтүдән яки йорттан качып китүчән, качкын (терлек тур.). *Качаган мал кашкырга җим.* Мәкаль. *Качаган сарык. Качаган кәҗә*

**КАЧА́-КАЧА** *рәв.* Яшеренеп, посып, ышыкланып. *Кача-кача безнең авылга хәтле килеп җиткәннәр.* Р.Хафизова. *Кечкенә Гали дә шунда, малайлар белән эскерт тирәсендә саламны казып кереп, кача-кача уйнап йөри дә, иптәш малайлары кайтып беткәч, үзе ясаган салам ояда, молотилка җырын тыңлый-тыңлый, изрәп йокыга китә...* Р.Төхфәтуллин

**КАЧАК** *и.* 1) Дошманнардан һ.б. качып, илен-йортын ташлап киткән кеше. *Качаклар ипи, күмәчләрне капчыкларга тутырып, пароходка ташып тордылар.* К.Тинчурин. *Качып баручы үз турысына килеп җитү белән, капитан языльп киткән пружинадай атылып юлга чыкты, кинәт егылгандай булып, качакка аяк чалды.* М.Насыйбуллин. *Болар – качаклар. Шәһәрдәге кибетләрен, зур йортларын калдырып, казак канаты астына сыгынган халык.* Ш.Усманов

2) Качып йөрү хәле. *Качакта йөрү. Качактан кайту*

3) *диал. к.* **качкын**. *Мишәрләрдән икәве атларын борып, камчылары белән кизәнделәр дә качак артыннан ташландылар.* Җ.Рәхимов. *Качаклар кайсы кая: өй кыекларына, сарайларга, ишегалдындагы яисә кырдагы салам өемнәренә, мал абзарларына яшеренә.* Рәхмәт сиңа, солдат!

**КАЧА́ЛКА** *и.* 1) Дугасыман табанчалы тирбәлмә кресло. *Профессор бакчада качалкада утыра иде*

2) Бишек

**КАЧКАЛАК** *с. сөйл.* Качучан, кача торган; яшеренгән. *Качкалак бозауларын каенлыкта ботарланган килеш тапканнар.* А.Хәсәнов. *Өч-дүрт ай эчендә Гафәр ишегалдында качкалак әтәч белән ялгыз сыер гына торып калды, бөтенесе дә казанга кереп бетте.* Ш.Янбаев

**КАЧКЫ** *и. диал. к.* **качкын 1.** *Качкы баласы качкыга булышыр.* Мәкаль. *Ләкин элек-электән анда качкылар яши дип сөйлиләр.* Х.Сарьян

**КАЧКЫН** *и.* **1.** Хөкем итүдән, дәүләт органнарыннан качып, яшеренеп йөрүче, качкан кеше, качак; дезертир. *Нишләп ялгышты соң әле ул болай? Бу килеш ул – качкын – кемгә кирәк?* М.Насыйбуллин. *Күз ачып йомган арада егетләр качкынның кул-аягын бәйләп ташладылар.* Н.Фәттах. *Качкыннар башта партизаннарга килеп эләктеләр, аннары көнбатышка таба сугышып баручы бер хәрби частька кушылдылар.* Ф.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Качучан, кача торган. *Хәер, ул чакта бит төрле качкын җинаятьчеләр, исерек мотоциклчылар, урман сукбайлары... бөтенесе буталып беткән иде.* Ф.Галиев. *Качкын сыер. Качкын бозау*

**КАЧКЫНЛЫК** *и.* Качкын булу хәле. *Качкынлык нәсел-чыгыш ягыннан тигезлеккә, язылган законнарның булмавына, хакимиятнең һәм судның сайланып куелуына нигезләнгән.* Р.Хәкимов. *Кайсылары, ул качкынлыкта йөри икән, әнисенең хәлен белергә килгәли икән, дип тә сөйләделәр.* И.Хуҗин. *Солдатлыктан яисә сөргеннән качу нинди генә куркыныч булса да, качкынлыкта яшәү дә җиңел түгел.* Ф.Урманче

**КАЧУ** *ф.* 1) Хәвеф-хәтәрле урыннан, әсирлектән, кешеләрдән һ.б. яшерен рәвештә рөхсәтсез китү, ычкыну, котылу. *Шулчак артыма чигенергә, бу ерткычтан котылырга, качарга теләгән идем, артымда тагын бер кеше*

*барын күрдем, анысы хатын-кыз иде.* М.Насыйбуллин. *Косовның ике сугышчы белән әсирлектән качуы, партизан отрядында сугышуы да ачыкланды.* Ф.Галиев. *Чигенә-чигенә Польша чигенә җиткәндә, төнге бер бомбёжка вакытында фашистларның штаб машинасыннан кача алган һәм ике көн буе туңып, күшегеп ятканнан соң, үзенең нәкъ чик буенда икәнен аңлаган ---.* М.Мәһдиев

2) Яшеренү, посу, ышыклану. *Болытлар арасына качкан кояш күренде, һәм яңа яуган карның һәр бөртеге якут төсле җемелди башлады.* Җ.Тәрҗеман. *Куак арасына качу. Качып кына җиләк җыю*

3) Качышлы уенында яшеренү, посу

4) Әйдәүче, оештыручы һ.б. күзенә күренмәскә тырышып, берәр җиргә посу. *Яшел чирәм өстендә кызыл бозау сузылып ята, көтүдән качып калган бер кәҗә читәнгә ышкынып тора.* И.Гази

5) Күренмәскә, очрашмаска тырышу; читтәрәк, кырыйлап йөрү, читләтеп йөрү, аралашмау. *Карга – үләксәдән, мәзин үлектән качмас.* Мәкаль. *Танышлардан качу*

6) Мөселман гадәте буенча ир-затлардан йөз яшерү, сөйләшмәскә тырышу (хатын-кыз тур.). *Уңмаган килен --- каенатадин качмыйдыр, оятсыздыр.* К.Насыйри

7) *юкл. форм.* Кем яки нәрсәнең һәрвакыт янында, кул астында булуын белдерә. *Иген өлгерсә, башта байныкын ур, үзеңнеке качмас.* И.Гази. *Эшең качмас, әйдә киттек*

8) Югалу, бетү, юкка чыгу (яхшы, уңай сыйфатлар тур.). *Гайнан ул көннәрне кипкән балыкны хәтерләтә иде. Аш-судан – тәм, күздән йокы качты.* М.Насыйбуллин. *Күңел дигәнең бер бәйдән ычкынып кузгалса, кызык икән: кешедән оят та кача, ул, --- чибәр хатынның инде баласы барын белүгә үк, эшне өйләнүгә җиткермичә, тизрәк качу ягын карады.* Ә.Сафиуллин

9) Аталану (йорт хайваннары тур.)

10) *күч.* Баш тарту; читтә калу, читләшү. *Күңелдә шом туды: бу масаю түгелме соң? Бу бишлегә укырга көч җитмәгәч, авырлыктан качу, чигенү булса, ни эшләрсең?* М.Юныс

**Кача башлау** Качарга тотыну. *Икенчесе Югары Совет ягына кача башлый, өченчесен «плен» алабыз.* З.Зәйнуллин

**Кача төшү** Бераз качу

**Качып бару** Качу юлында булу. *Бер минут эчендә станица урамы үзенүзе белештермичә качып барган халык белән тулып калды.* Ш.Усманов. *Гаяз, алар килеп җиткәнче дип, качып баргандай тиз-тиз атлый башлады.* Х.Сарьян. *Сукмакка аварга торган зур таш артына йөгереп чыгу белән, алда ниндидер бер кешенең качып баруын күрде ул.* Ә.Шәмин

**Качып йөрү** Гел качырга тырышу. *Фәрит башта хатыныннан качып йөри башлады.* А.Расих. *Ул Миңнәхмәт дигәне унтугызынчы елларны дезертир булып качып йөрде.* Г.Толымбай. *Ә сиңа әйтер сүзем бар: моннан соң бер көн дә качып йөрмәм һәм караклык итмәм, гаделлекне халкым белән бергә эзләрмен!* М.Хәбибуллин

**Качып калу** Качкан хәлдә читтә, кырыйда калу. *Башка вакыт булса, Камил туп-туры әрәмәгә кереп чумар, учлап-учлап бөрлегән ашар, кычыткан араларына качып калган кураларны җыяр иде.* Ф.Бәйрәмова. *Шушындый матур туташлар килгәндә, егет кеше качып калырмы?..* Ш.Маннур

**Качып тору** Билгеле вакытны качкан килеш уздыру

**Качып утыру** Качкан хәлдә булу. *Асыл качып утырган җиреннән чыкты да, болан кебек сикерә-сикерә, аның артыннан сак кына атлады.* Х.Хәйруллин. *Арыш кырын, ефәк ябалдашлы юкәләрне, котырып үскән сусыл печән арасында качып утырган алсу битле җир җиләкләрен, салпы колаклы тугры Акбайны, әни кулларын, бала чагымдагы якын дусларым Мидхәт белән Кәбирне искә төшерде бу җыр.* Ф.Шәфигуллин. – *Нәрсә, качып утырдыңмы, эт җан!* – *ди караңгы чырай белән аның янына килеп баскан Васютин һәм, каерылып, йодрыгы белән битенә китереп суга.* Ф.Галиев

**Качып яту** Шактый озак вакыт качкан хәлдә булу. *Качып ятканын үзем беләм.* Г.Толымбай. *Рәхмәтулла урманда качып ятса да, дөнья хәлләре белән таныш диярлек иде ---.* Я.Зәнкиев

**КАЧА́-ПОСА** *рәв. к.* **качып-посып**

**КАЧЫНУ** *ф. сөйл.* Яшеренү, посу, ышыклану. *Диләфрүз теге әүвәлге тәрәзәнең пәрдәсе артында качынып калды.* Ф.Әмирхан. *Әнә тагын... ишек ачылып, Берәү... икәү... күләгәләр керә качынып.* Һ.Такташ. *Шул арада Кәрим зал ишегенә килеп, качынып тыңлый башлый.* Г.Исхакый

**КАЧЫ́П-ПОСЫП** *рәв.* Яшеренеп, ышыклана-ышыклана, качып кына, башкаларга сиздермичә, белгертмәскә тырышып. *Инде түләүле концертларга качып-посып билетсыз кергәндә, элеккечә клуб ишегеннән дә чыгарып ата алмаслар.* М.Мәһдиев. *Качып-посып булса да, Ашманскийларның «ишегалды театры»на йөрүен дәвам итте малай.* С.Шәкүров. *Иртәгәл качып-посып кына тәрәзәдән карап тора иде.* А.Тимергалин

**КАЧЫР** *и. зоол.* Ишәк белән биянең кушылуыннан туган йорт хайваны. *Инде тагын бер чагыштырып кара, уйлап бак: ат белән ишәк кушылганнан ни туа? Качыр туа. Качыр дигән мәхлугыбыз инде ат та, ишәк тә түгел... Ул, мескен, нәсел калдыра алмый.* Ф.Латыйфи. *Ат тибәр, качыр тибәр, ике арада ишәк үләр.* Мәкаль

**КАЧЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **качу**

2) Качып китәргә мөмкинлек бирү. *Митька Сабадырёв һәм аның компаниясен тагын бер тапкыр качыру милиция хезмәткәрләренең мин-минлегенә шактый нык тиде.* З.Фәтхетдинов

3) Нинди дә булса мөмкинлекне ычкындыру, файдаланмау. *Кызлар, форсатны качырмыйча, тиз генә идән тактасын капладылар да аның өстенә икәүләп менеп утырдылар.* М.Гали

4) Яшерү, күрсәтмәү, белгертмәү. *Берәү йөгереп килде дә бездән үзен качырып калдырырга сорады.* Г.Гобәй. *Авыл мәктәбендә кизү булып торганда, мин сине, атаңнан качырып, өч көн асраган идем.* М.Гали. *Шикләнмәгез, муеныгызга асылынырга да, кылган языгымны качырырга да җыенмыйм.* Я.Зәнкиев

5) Каплату, аталандыру (йорт хайваннары тур.)

**Качыра төшү** Тагын да качыру

**Качырып тору** Билгеле вакыт дәвамында качыру

**Качырып яту** Шактый озак вакыт качыру

**КАЧЫШ-КАЧЫШ** *и. к.* **качышлы**. *Кичке кояшның соңгы нурлары яфраклар арасыннан төшеп, качыш-качыш уйныйлар иде.* И.Туктар. --- *Әллә син караңгыда мине тапмам дип куркасыңмы? Качыш-качыш уйнарбыз, кызык булыр.* М.Маликова. *«Нәрсә соң бу?» янәсе. Балалары белән качыш-качыш уйнаучы аю инде, югыйсә.* И.Сирматов

**КАЧЫШЛЫ** *и.* Бер-береңнән каядыр качып, яшеренеп уйнала торган уен төре. *Анда без аккошлар белән танышабыз, бергәләп чумышлы уйныйбыз, качышлы уйныйбыз.* Ә.Баян. *Качышлы уйный башлыйлар – тәкә булып Айсетдин кала.* Я.Зәнкиев. *Киресенчә, үзенең бала-чага кебек качышлы уйнавын ул, ниһаять, сизенеп алды ---.* Н.Фәттах. *[Зәйтүнә] Шул балалар белән куыша, йөгерешә, качышлы уйный, чуерташлар җыя, күбәләк тотарга маташкан була.* Ш.Маннур

**КАШ** *и.* **1.** 1) Күзләр өстендәге дугаланып үскән куе төкләр. *Аның йөзе тагын тартышып куйды, кашлары өскә сикерде, һәм ул театрдагыча кулын җәеп җибәрде.* Җ.Тәрҗеман. *Шул секундта аның кашлары, иреннәре кинәт калтырый башлады, һәм ул, ашыгып, каушап, яшь егеткә таба китте.* А.Шамов. *Аның сипкел баскан йөзе ачулы, аксыл кашында ләйсән кебек вак яңгыр бөртекләре елтырый.* Х.Хәйруллин

2) Алка, йөзек-беләзек, санчак һ.б.ш. әйберләргә бизәк итеп беркетелә торган төрле типтагы асылташ, яки шуңа охшаш нәрсә. *Йөзекнең кашы төшкән, кашны тотып торган тырнаклар эчкә яньчелеп кергәннәр, балдагының күп урында көмеше кырылып, астыннан бакыры чыгып килә иде.* Ә.Фәйзи. *Аксыл болытлар арасыннан күз сирпегән кояш яктысында йөзек кашыдай ялтырап алды да үзе шикелле үк шаян, җитез кар бөртекләре арасына кереп югалды.* Ф.Шәфигуллин

3) Иярнең алда һәм артта калкып торган урыны. *[Хәмдия – Бакыйга:] Ал, илче, бу хатны! Ал да, яшь мирзага илтеп, ахак кашлы көмеш иярен сора.* М.Фәйзи. *Тезгенен ияре кашына ташлап, атына чөңгереп алды, хәбәрсез иркенләп бармакчы иде.* Җ.Рәхимов

4) *к.* **кашлак**. – *Әнә шул кашка чыккач та, Дадашев промыслолары күренер, – диде Хәлил.* Ш.Камал. *Иртәнге кояш авыл янындагы каш артыннан яңа гына күтәрелеп чыккан.* С.Җәләл

5) *диал.* Калкулык өсте, тауның биек, калкып торган урыны. *Галияр солдаттан кайткан көнне, син авылның тавы кашына мендең. Күреп тордым. Тауның кашында кыя нигезе бар.* М.Хуҗин. *Тау кашындарак безнең артызба дип йөртелә торган бәләкәй генә өй бар иде.* Ф.Шәфигуллин

**2.** *с. мәгъ.* Тау бите сыман калкып торган. *Каш җир түгел, киресенчә, бик аулак уйсу, имеш. Арышлар бик сыгылмалы, Газзә бик моңсу, имеш.* С.Баттал. *Тиресле җирләрдә, кашрак урыннарда җирләре булган кешеләр ара-тирә ургалый да башладылар.* М.Гали

◊ **Каш астыннан карау** Ачуланып, ярсып карау, хисләрне һ.б. яшереп карау, астыртын, үпкәле, рәнҗүле караш турында. *Кинәт ул каш астыннан гына Исламның үзенә карап утырганлыгын күреп алды.* Н.Фәттах. *Ниһаять, олуг хан башын күтәрде. Киң куе кашлары астыннан тирәли утырган кунакларга сөзеп карап чыкты.* М.Хәбибуллин. *Гали, бер тәлгәштәге шомыртлар күк, Сәрвәр апаныкына охшаган чемкара күзләре белән каш астыннан гына карап куйды.* Р.Төхфәтуллин. **Каш җимерелү** Ризасызлык, үпкә, ачу билгеләре чыгу. *Моңарчы бик кәефле генә сөйләшеп утырган Әсәдуллинның җәенке кашлары җимерелде, күзләрендә зәһәр очкыннар кабынып китте.* С.Сабиров. *Кассирның кашы җимерелүе яңалык түгел иде.* М.Юныс. *Аның юка иреннәре бөрелгән, кашлары җимерелгән. Җете зәңгәр күзләре зәһәр ялтырыйлар.* Г.Сабитов. **Каш җимерү** Канәгатьсезлек, рәнҗеш, үпкә белдергәндә, кашларның табигый торышын бозып, ямьсез итеп карау. *Кубрат хан куе кашларын җимерде, бертын уйланып ятты, ниһаять, ул авыр карашын философка төбәде.* М.Хәбибуллин. **Каш җыеру** Ризасызлык, канәгатьсезлек, аптырауны йөзгә чыгару, күрсәтү. *Хәмдиев аны, чыннан да, бик яман кашларын җыерып каршылады.* Р.Төхфәтуллин. *Миңнур карт исә, нәрсәнедер яратмыйча, кашларын җыерды, тешләрен кысты, һәм аның яңак сөякләре очлаеп калкып чыкты.* А.Шамов. **Каш җыерылу** Йөзгә ризасызлык, канәгатьсезлек билгеләре чыгу. *Хәзер инде Туфаилнең карашы идәнгә төбәлгән, кашлары җыерылган, тавышы калынайган иде.* М.Хуҗин. *Оятыннан, ачуыннан хәзер дөрләп китәргә әзер торган Рәшитнең кинәт кашлары җыерылды.* Н.Фәттах. **Каш салындыру** *к.* **каш салыну**. *Чырык дәшмәде, кашларын салындырды.* Я.Зәнкиев. **Каш салыну** Ниндидер күренешкә, нәрсәгәдер ризасызлык, үпкә белдергәндә, кашлар түбәнрәк төшү. *Ясәви картның чырае җитди, кашлары салына төшкән, ул Мусага, аның шикелле меңләгән әсирләргә карап сөйли, имеш ---.* Г.Әпсәләмов. *Ул инде элеккедәй минем белән ачылып сөйләшми, киңәшми. Кашлары салынган, йөзе һәрвакыт чытык.* И.Салахов. **Каш сикертешле** *иск.* Аулак өйләрдә уйнала торган гыйшык уены. *Аннан аулак өйдәге барлык яшьләр, кызлар куырылган борчак ашыйлар. Уеннар китә... Каш сикертешле уйныйлар.* С.Рафиков. **Каш сикертү** Кемгәдер яшерен ым кагу өчен, гаҗәпләнү һ.б. белдереп, кашларны хәрәкәтләндерү. *Башын уңга янтайтып, кашларын сикертеп, мондый тасвирына үзе үк аптырап куйды: кеше ак буламы инде, я ак тәнле дисәң, дөрес чагыштыру булыр иде.* М.Хуҗин. *Надзиратель, сул күзен кысып, кашын сикертсә дә, малайны бирелеп кенә тыңлый иде.* И.Салахов. *Унтер-офицер тырпайган кашларын сикерткәләп алды.* И.Туктар. **Каш сындыру** *к.* **каш җимерү.** *Хәлим аягүрә басты да борынына төшеп торган кепкасын ачу белән күтәреп җибәрде, кара кашларын сындырды.* И.Гази. **Каш тарту** Кашларны махсус

карандаш белән буяп каралту. *Шәһәр тумасы бит минем Миһриҗамал, үзенә күрә түгел, чәчләрен бөдрәләтеп, кашлар тартып, чәмчәле читекләр киеп кайткан.* М.Гали. **Каш төзәтәм дип күз чыгару** Файдалы, кирәкле эш эшлим дип, зыян, зарар китереп чыгару. *Каш төзәтәм дип күз чыгаруың, планны өзүең бар.* Ш.Бикчурин. **Каш ясыйм дип күз чыгару** *к.* **каш төзәтәм дип күз чыгару**. *Рәшат Галиевич, каш ясыйбыз дип күз чыгармыйбызмы без? Куәтле техникага юл ачабыз дип, саламны яндыруны әйтәм.* Х.Хәйруллин. *Каш ясыйм дип, иптәш Ходайбирдин кебек, күз чыгаручы – скважинаны ике ремонт срогын үткәреп файдаланучы, нефть бирәм дип, кадерле икмәкне юк итүче коммунистка партия сафында урын булмаска тиеш.* М.Хәбибуллин. **Каш уйнату** Шаяртып, кемгәдер ым кагу өчен кашларны хәрәкәтләндерү. *Нинаның йөзендәге алсулык тагын да куерды, карлыгач канатларыдай кыйгач кашларын уйнатып, үз итеп, якын итеп, Гыймазовның күзләренә текәп карады.* С.Рафиков

**КАШАВАЙ** *и.* Сөялеп утырыр өчен уңайлы күшле чана; кошёвка. *Туйга барсаң җик кашавай: Чана печән ашамый.* Мәкаль. *Берсе төпкә, икенчесе очтан җибәреп, кашавай чанага җигелгән почта атлары урта урамдагы кызыл калай түбәле, алты почмаклы йорт алдына килеп туктадылар.* С.Рафиков. *Ир чөмгереп атын кузгатты да, үзе кызлар янына басып, кашавай артыннан җәяүләп атлады.* Я.Зәнкиев

**КАШАВЫЧ** *и. диал. к.* **кашау**

**КАШАГА** *и.* 1) Тәрәзә яки ишек өстенә эчке я тышкы яктан горизонталь кадакланган бизәкле такта. *Йортларының кәрнизләре, тәрәзә кашагалары, коймa, капкалары – һәммәсе берочтан челтәрләп эшләнгән, зәңгәргә буялган.* Р.Хафизова. *Шунда аның күзе почмакта яңа гына суелган сап-сары юкә тасмаларына һәм аның өстендә кашагага кыстырылган берничә яңа гына ишелгән чыбыркыга төште.* Ә.Фәйзи. *Беркөнне шулай шифаханәнең карлы тәрәзә кашагасына песнәкләр килеп кунды.* Р.Хисмәтуллин

2) Өй стенасының югары өлешенә, ишек, тәрәзә башларына эленә торган бизәкле озын тукыма; пәрдә. *Шул арада Гөлчәһрә ханым үзенең гардеробыннан, әле «Сәйяр»дан ук калган иске күлмәкләрен сүтеп, манып, пәрдә, ак марля кисәкләреннән сәхнәнең янякларын һәм түшәмнәрен каплау өчен чаршау, кашага кебек нәрсәләр текте.* С.Шәкүров. *Утка чорналган кашагалар уфылдап идәнгә килеп төшә.* Р.Низамиев. *Андый чакларда өй түрендә буйдан-буйга сузылган кашагадан түбәнрәк эленеп торган фоторәсемгә бер карап кую да җитә иде аның өчен.* Р.Мөхәммәдиев

3) Мич авызы өстендәге киштә кебек чыгынты урын, уенты; кучкар. *Мич кашагасына утырткан сукыр лампадан бүлмәгә сүрән генә яктылык сирпелә.* Р.Хафизова. *Ай, әнә шул мич кашагасындагы тозның бөтенесен салып корырга [мылтыкны].* Г.Гобәй

4) *куч. диал.* Бүрек, кепка һ.б.ш. кебек баш киеменең маңгай турысына гадәттә төшерелмәслек итеп тегелгән козырёгы. *Локман кашагасы белән артка карап торган бүреген әйләндереп киде.* Чаян. *Бүрек кашагасы*

**КАШАГАЛА́У** *ф.* Кашагалы итү, кашага кую. *Өскә кашагалап корган чыбылдык күгелҗем ак төстә, күтәренке җәйге ак болытлар төсле тора.* Н.Исәнбәт. *Тәрәзә кашагалау*

**КАШАК** *и.* Урман кырые. *Урман кашагына якынлашу. Урман кашагы буйлап салынган юл*

**КАШАЛОТ** *и. фр. зоол.* Тешле китлар семьялыгыннан зур башлы имезүче диңгез хайваны. *Кашалотның корсагын ярып, йотылган гарпунчыны кире чыгаралар.* М.Юныс. *Шушы сыйфат кашалотка 30 – 50 минутка суга чумып, бу вакыт эчендә шактый зур ара йөзеп узарга мөмкинлек бирә.* Кызыклы физиология

**КАША́У** *и.* Атның тәнен чистарту өчен махсус кыргыч, ат кыргычы. *Атның яме ашавы белән дә кашавы белән.* Мәкаль

**КАШАЯК** *и. диал.* 1) *сөйл.* Вак-төяк савыт-саба кую өчен махсус шүрлек, киштә. *Стенага кашаяк беркетү*

2) *к.* **кашык-аяк**. *Кашаяк шалтыраган саен, син надан шофёрдан тупаслыктан башка нәрсә көтәргә була дип, миннән көләргә ярата ул.* Г.Галиев. *Чөйләргә акка кызыл белән чигелгән берничә озын сөлге, кул һәм аш-су тастымаллары, кашаяк мунчалалары эленгән.* И.Туктар

**КАШБА́У** *и. этн.* Алгы ягы сәйлән, энҗе һәм тәңкәләр, асылташлар белән бизәлгән тасма яки такыясыман хатынкыз баш киеме. *Зәңгәр күлдә яшел төнбоек, Чәчкәсеннән кашбау ишәрмен.* М.Җәлил. *Йөзекнең иң күркәме, ханшалар кия торган алтын кашбау кебек ялт-йолт килеп торганы Кәүсәрия Фатыйховнага насыйп булды.* Т.Галиуллин

**КАШЕВАР** *и. рус сөйл.* Хәрби бүлектә, эшчеләр артелендә, поход отрядында аш пешерүче. *Ә без, әти, яхшы кешеләр идек бит! Теге дүртбиш кашеварны искә алмаганда инде.* Ә.Гаффар. *Кашевар кичә кичтән аш пешергән казанда чәйгә су кайнаткан, һәркемгә бер чүмеч кайнаган су сала.* А.Таһиров

**КАШЕМИР** *и. фр.* **1.** Йомшак юка йон тукыма. *Күлмәклек кашемир*

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Кулбашларга салынган кашемир яулык алтын алкаларны, тулы ап-ак муенны һәм җете кара чәчләрне каплап, бөтенләй яшерде...* И.Туктар. *Башына кашемир яулык бәйләгән, өстенә ирләр пиджагы кигән бик матур бер әби башкалардан читтәрәк утыра иде.* Х.Сарьян

**КАШКА** *и.* **1.** 1) Хайваннарның маңгаенда була торган ак тап. *Тәки карап үстердем шул колынны. --- Маңгаенда яңа туган айга охшаган кашкасы да бар иде. Шуңа карап исемен дә Айбаш дип куштык.* Г.Сабитов. *Кияү тиз генә чыга да, каяндыр буяулар табып, бабасының атын кашка итеп, үз атының кашкасын бетереп куя.* Татар халык әкиятләре

2) Кашкалы ат. *Аю кашка булмас, яман яхшы булмас.* Мәкаль. *Нина Петровна аяктан егылган җирән кашка атның авыз-борынын, ял асларын карап, борчылулы рәвештә йөренә иде.* С.Рафиков. *Революция Артёмга җирән*

*кашканы алып бирде.* М.Шабай. *Кагылмалы кышкы юлдан җирән кашка айбат кенә юырта башлагач, чанада баручы егет күздән күмелә язган шәһәргә тагын бер тапкыр каерылып карады.* И.Гази

**2.** *с. мәгъ.* Маңгаенда ак тап булган. *Теге кашка сарык быел тагын көздән бәрәнләде бит. Үзенә охшаган ике кашка бәрән китерде, икесе дә саулык.* М.Хуҗин. *Үзләрен Тәңренең кашка тәкәсе дип белгән патрицийларның эче янар иде, мәгәр.* Р.Зәйдулла. *[Сәйлән:] Кашка сыерым бозаулады бүген төнлә.* Р.Батулла

**КАШКАЛАК** *и. зоол.* Су тавыгысымannар семьялыгыннан урта зурлыктагы ак маңгайлы кош. *Хан углына кашкалак, би углына бизгәлдәк.* Мәкаль. *Су буе кошларының төп составын акчарлаклар, каз, үрдәк, кашкалак тәшкил итә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Монда аккошлар, кыр үрдәкләре, ала чумгалак, чүрәкәйләр, игәү борын, юан муен кашкалаклар кышлый.* А.Муранов

**КАШКАЛЫ** *с.* Маңгаенда кашкасы булган. *Сыртлан Сәли ак кашкалы туры атта юл буйлап җай гына юыртып бара.* Р.Төхфәтуллин. *Кашкалы бозау. Кашкалы колын*

**КАШКАРА** *и. иск.* Каш каралту өчен махсус буяу. *Кашкаралары кирәкми, Үз кашларым да кара; Кеше ярлары кирәкми, Үз ярларым да кала.* Җыр. *[Сәхилә:] Әй, үземдә соң кызларның асылы. Кашкара тарткан кирәкме, тешкара тарткан кирәкме?* Н.Исәнбәт

**КАШКА́Р ГӨЛЕ** *и. бот. сөйл. к.* **кашкарый**

**КАШКАРЫЙ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үсемлек; астра. *Саубуллашканда Михаил дәдәй Зина апага нәни генә төргәктә ак кашкарый орлыклары бүләк иткән.* Р.Хафизова. *Аның кулында бер кәрзин чәчәк – ак кашкарыйлар белән куе кызыл канәферләр иде.* М.Маликова. *Май аеннан тюльпан, нәркис чәчәк ата, июньдә – роза, аннары дәлия, кашкарый...* С.Сөләйманова

**КАШКИ** *терк. фар. иск. кит.* Әгәр, гәрчә. *Кашки шул бер елны гына күрмәгән булсамчы! Шул бер елда картаюым, шул бер елда бетүем!* М.Гали. *Бу егет – гүзәллектә Йосыф пәйгамбәр, Булсачы, кашки, бер җаваплы хезмәткәр.* Ә.Исхак. *Тагы ни хәлләр булырын Ходай белсен, кашки, халаекларны куәтләндерү өчен, күп кешеләр җибәрегезче, дәхи үз хозурында кешеләр алып торган булсаңызчы?!* Ж.Рәхимов

**КАШКЫР** *и. диал.* Бүре. *Качаган мал кашкырга җим.* Мәкаль. *Кем белә, төн кара, камыш калын, кашкыр, шакал дигән җот авыз салмасын! Ал, ут җансын. Кашкыр утка килмәйде. Ходайга тапшырдык.* И.Салахов

**КАШ-КЕРФЕК** *җый. и.* Кашлар һәм керфекләр. *Кызларның өсләренә, каш-керфекләренә кар кунган иде.* С.Сабиров. *Бу каш-керфекләре белән киявенә беренче кат күренү оят булыр инде.* Ә.Гаффар. *Егетнең йөзендә дә, чәчләрендә дә таш оны, он хәтта керщән булып каш-керфекләренә дә кунган иде.* М.Хәбибуллин

**КАШ-КҮЗ** *җый. и.* Кашлар һәм күзләр. *Бикташның тавышы ничектер нечкәреп, мескенләнеп чыкты, ә бот буе Васька, кашын-күзен җыерып, кәпрәеп чәрелдәде ---.* М.Маликова. *Аның каравы егетең кашы-күзе бик килгән.* И.Гази. *Мөслимә буе-сыны, кашы-күзе, киеме-салымы белән башкалардан бер дә аерылмаса да, миңа аның сары чәче дә --- гомумән, барысы да, барысы да килешле, мондый камиллек, мондый матур кием бүтән бер кызда да юк кебек тоела.* Г.Әпсәләмов

**КАШЛАК** *и.* **1.** Калкулык, калкып торган урын, калку рельеф. *Студентлар, гармун уйный-уйный җырлашып, авылдан чыгып китәләр, без аларны Каенлы кашлакка кадәр озата барабыз...* М.Рафиков. *Кашлакта, калку җирдә утырган авыл тирәсендә кар әзрәк иде, яуган берен җилләр алып китеп торганнар.* Я.Зәнкиев. *Юлның сул ягында тауның ярты кашлактан ук текә убылган төше күренә: ул текә яр берничә катлы йорт биеклегендә булыр.* З.Фәтхетдинов

**2.** *с. мәгъ.* Калкып торган, калку. *Инде кашлак басуларда тракторлар гөрелтесе ишетелә.* Р.Төхфәтуллин. *Үлән калкынмады, болыннар кабармады, башта кашлак урыннар, тау битләре саргаеп кипте.* Я.Зәнкиев

**КАШЛАН** *и.* Калку җир, калку җирдәге басу. *Кашланга чәчелгән солы*

**КАШЛЫ** *с.* 1) Күзләр өстендәге дугаланып үскән куе төкләр булган. *Сызылып киткән чем-кара кашлы, эчке бер яктылык балкытып торган шомырт кара күзле һәм ак, нәфис битле бу яшь хатын үзенең яшьлеге белән генә түгел, бәлки табигый матурлыгы белән дә матур иде.* Н.Фәттах. *Җирән чәчле, җирән кашлы урта буйлы кеше – кырчылык бригадасы бригадиры Сәлмән Галләмов кайтырга җыена башлады.* Х.Сарьян. *Бу озын буйлы, шомырт кара күзле, куе кашлы, коңгырт йөзле апаны мин кайдадыр күргән идем кебек.* Н.Сәфәрев

2) Алка, йөзек-беләзек, брошка һ.б.ш. әйберләргә бизәк итеп беркетелә торган төрле типтагы кыйммәтле асыл ташы булган. *Моннан да артыгын көтмәгән юмарт Аверкиев кызның калтыранган бармагына кыйммәтле якут кашлы йөзек кигезде.* Ж.Тәрҗеман. *Яссы капкачны ачкач, чүлмәк эченнән тәңкәләр, кашлы берничә көмеш йөзек, иң астан гаҗәеп матур алтын алкалар килеп чыкты.* К.Тимбикова. *Кулында гәрәбә кашлы йөзек, тырнагында маникюр...* С.Сөләйманова

**КАШЛЫК** I *и.* Зур булмаган калкулык, калку җир; тау бите. *Йөгерешеп качты малайлар якындагы кашлык артына.* М.Сөндекле

**КАШЛЫК** II *и.* Кашык, пычак кебек әйберләр кую өчен үреп эшләнгән тартма, шулай ук шундый әйберләрне кыстырып кую өчен стенага кадаклаган каеш яки тар агач. *Карчык калтыранган куллары белән кашлыктан кармаланып, Зиннуры киткәндә каптырып, теш эзләрен алып калган, сохари итеп киптерелгән ипи кисәген табып алды.* Я.Зәнкиев

**КАШМА** *и. диал.* Сарык йоныннан басылган киез келәм, бизәкле киез җәймә. *Идәнгә кашма җәелгән*

**КАШНЕ** *и. фр.* Муенга урый торган юка шарф. *– Башкача мөмкин түгел,*

*башкача булганда без үзебезнең юл өчен, безнең програм, безнең тактикага каршы торганнар белән рәхимсез сугыш алып барачакбыз!.. – диде дә, аягүрә торып, муенындагы кашнесын төзәтә-төзәтә, өстәл тирәсендәгеләрне кузгатып чыга башлады.* Г.Ибраһимов. *Мусаның өстендә кул белән бәйләнгән свитер, аның өстеннән соры вискоз кашне уралган.* Ш.Маннур

**КАШПО** *и. фр.* Эченә гөл чүлмәге утыртыла торган декоратив ваза

**КАШТАН** *и. гр. к.* **кәстәнә**. *Каенсарда әле, ихтимал, карлар эри генә башлагандыр, биредә инде җирләр кибеп бетте, чирәмнәр яшәрде, каштаннар яфрак ярды.* Р.Төхфәтуллин. *Ә инде көньякка таба очрый торган соры, кара, каштан, көрән, соры җир туфракларның яше арта бара.* Җир һәм туфрак

**КАШТЫ́Р-КОШТЫР** *иярт. к.* **кыштыр-кыштыр**

**КАШУ** *ф.* 1) Тәннең кычыткан урынын бармаклар яки тырнаклар белән тырнау, ышку. *Маклаков башын кашыды, йөзләрен чытты.* Х.Хәйруллин. *Мин гипс астына сыйган кадәр бармакларымны тыгып кашып карыйм, күрше караватта ятучы абый табып биргән озын чыбыкны тыгып та кашыйм.* Р.Төхфәтуллин. *Үзем ашыйм, башны кашыйм, тирләп бетәм.* Л.Лерон

2) *күч.* Камчылау, таяклау, кыйнау. *Алашлар бераз җилкәсен кашыганнар тегенең...* И.Салахов. *– Тик менә шунысы, – диде Миңнулла, – алпут җиренә ташлана-нитә калсак, бишенче елдагы кебек арканы кашымаслармы?* И.Гази. *Малайның аркасын ярыйсы кашыдылар*

**Кашый башлау** Кашырга тотыну. *Ул янә башын кашый башлады, кашый торгач бер фикер тапты, ахрысы, елмайды, тын алды һәм нык ышаныч илә әйтеп куйды.* Мәдәни җомга

**Кашый бирү** Кашуын дәвам итү. *Мәхәлләбездә бер томана кеше, кызына чәчәк чыккач, ярасы кычыткан саен кашый биреп, баласының күз тирәсендәге эреннәрен сытып бетергән.* Н.Сәфәрев

**Кашып алу** Кыска вакыт эчендә кашу. *Ул кул сырты белән башын кашып алды һәм, кире якка авыштырып, сырлый-сырлый «Сәвия» дип язды.* Х.Хәйруллин. *Җилкәсен кашып алгач, Госман карт борчулы, акрын тавыш белән: – Күтәрүен күтәрер дә... – диде.* М.Шабай. *Контролёр колак артын кашып алды.* З.Фәтхетдинов

**Кашып бетерү** Бар урынны да кашу

**Кашып кую** Бер мәртәбә, тиз генә кашу. *Хәйрулла агай хәзрәтне озатып кереп, өстәл эченә яшереп куйган коймакларын чыгарып, яртышар коймак туры китереп, балаларына бүлеп бирде, әмма Мөхәммәтханга бөтен коймак тоттырып: – Зур улыма!.. Мин аны, Алла теләсә, кибеткә бирәм, ул кибетче булыр, – дип, Мөхәммәтханның башыннан сыйпап, тагын нәрсәдер әйтмәкче булды да, ләкин сүз тапмагач, иңсәсен генә кашып куйды.* К.Тинчурин. *– Һе... – Әхмәт ни әйтергә белми башын кашып куйды.* Р.Хафизова

**Кашып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә кашу. *Гадәтенчә җилкәсен кашып торганнан соң, сүзне кинәт икенчегә борып, хәрби эшелон мәсьәләсен яңадан кузгатып җибәрде.* М.Шабай

**Кашып утыру** Кашу эше белән мәшгуль булу

**КАШУЧ** *и. диал. к.* **кашау**

**КАШУЧЛА́У** *ф. диал.* Атны кашау белән чистарту, кыргычлау. *[Кәрим:] Галәви! Син нишлисең анда?! Кашучлап бетергәч, тарантаска җигеп куй.* Г.Камал

**КАШЫК** *и.* 1) Төрле ашамлыкларны (сыек яисә ярмалы ризыкларны) савыттан аз-азлап алу өчен, агачтан яки металлдан эшләнгән озын саплы әсбап. *Бал тоткан бармак ялый, май тоткан кашык ялый.* Мәкаль. *Әни табак-савыт шылтырата, кашык белән кытыр-кытыр нәрсәдер кыра.* Ф.Шәфигуллин. *Яшәеш фәлсәфәсенең нигез ташы – «коры кашык авыз ерта».* М.Насыйбуллин. *Рәссамнарның һәркайсына лесхозда эшләнгән агач кашыклар белән бергә ачык буяулы, ялтырап торган агач вазалар да бүләк иттеләр.* М.Маликова

2) Шул әсбапка сыя торган әйбернең күләме. *Яман кешедән ярты кашык аш кала.* Мәкаль. *– Һаман үлә алмадым бит әле, кызым, – дип пышылдады ул, Роза кулындагы бер кашык суны күреп.* Г.Рәхим. *Сабирҗанга мин аңа бер кашык су да бирмим.* Т.Миңнуллин

3) *муз.* Озын саплы ике агач кашыктан (*1 мәгъ.*) торган бәрмә музыка коралы

4) *күч. сөйл.* Гаиләдәге шәхес, җан, аерым кеше. *Ул күбесенчә мулла йортында әрәмтамак, артык кашык, килмешәк саналды.* С.Рафиков. *Торыр җире калмаган икән моның, матчасы сынып төшкән. Ә туган-тумача бик якын җибәрми икән. Соң артык кашык кемгә хаҗәт ул елларда?* К.Тимбикова. *Бу йортка Мөхәммәтнең рәхмәте аерата зур: нинди кыен чакларда, йорттагы һәр кашык исәптә чакта, алар Шамилне карап, өс-башын юыштырып, ашатып-эчертеп тоттылар...* Я.Зәнкиев

◊ **Кашык күтәрү** 1) Ашау, тукланып тору (гаиләдәге һәр кешегә карата). *Авылда абыйның көймәсе комга терәлгән. Бер иманага алты кашык күтәрәләр.* К.Тинчурин; 2) Мөстәкыйль рәвештә ашау (нәни балалар тур.). *– Зурысы унөчкә чыкты. Болары яңа гына кашык күтәрә башладылар, – диде әни.* Х.Садри

**КАШЫГАЯК** *җый. и. к.* **кашык-аяк**. *Кухня тирәсендә дә кашыгаяк, савыт-саба шалтыраганы ишетелми иде.* С.Шәкүров. *Исемлектәге савыт-саба, кашыгаяклар, фарфор статуэткалар кимендә бер ат йөге булгандыр әле.* А.Тимергалин

**КАШЫК-АЯК** *җый. и.* Төрле савыт-саба (кашык, тәлинкә, табак һ.б.). *Габдулла нәкъ аш вакытына тап булган икән, бүлмәләрдә кашык-аяк шалтыраган тавышлар ишетелеп тора, хатын-кыз, савыт-саба күтәреп, ыгы-зыгы килеп йөри.* Ә.Фәйзи. *Өйгә көчкә кайтып кердем. Талчыгудан күзләрем йомыла. Кашык-аяк юа башлавымны да хәтерләмим.* Х.Сарьян. *Өчаяклар, кашык-аяк, җылырак өс киемнәре (сазлыкта төннең нинди булуын кем белми?!), балта-пычкылар, ризык-мазар тутырган арбага юлаучылар сыймады.* Я.Зәнкиев

◊ **Кашык-аяк шалтырату** Гаиләдә вак-төяк ызгыш-талашлар булу. *Дөнья*

*булгач, кашык-аяк шалтырамый тормый.* Мәкаль. *Кашык-аяк шалтыраган саен, хатын аермыйлар.* Мәкаль

**КАШЫКЛАП** *рәв.* 1) Кашык белән. *Ике карт, ике яктан утырып, Солтанхәкимгә кашыклап тавык шулпасы ашаттылар, кәрәзле бал белән чәй эчерделәр, аннан авылдан килгән бишмәткә төреп яткырдылар.* Ф.Бәйрәмова. *«Кар астында калып, салкын тидергәндер» дип аһ иткән Фаягөл марҗа әбиләреннән дуңгыз мае юнәтеп кайтты, шуны эретеп, кашыклап улына эчерде.* А.Әхмәтгалиева. *Хәл белергә Билгенең өлкән хатыны кергән иде, ул тиз генә мәк төнәтмәсе китертте һәм авыруга кашыклап эчерергә кушты.* Б.Рафиков

2) Әз-әзләп кенә, бераз, әз күләмдә. *Кашыклап җыйганны чүмечләп түгәсе килми.* Мәкаль. *Кая инде ул вакытта онны потлап үлчәү! Кадаклап та гөрәнкәләп яки кашыклап үлчи торган чак иде.* М.Хәсәнов. *Кислород мендәрен имеп кенә ята, ди. Кашыклап ашаталар икән ул батырны!..* Я.Зәнкиев

3) *күч.* Аз-азлап, кечкенә өлешләр белән, ваклап. *Кашыклап җыйган малыңны Чүмечләп чәчеп – бетәр ул.* Дастан. *Ташы мәгърифәтне авылга, Хәнәфи абзый, кашыклап булса да ташы!* Г.Бәширов. *Үз-үзен генә яратучы һәм мәхәббәтен кашыклап өләшүче эгоист ирләр күбәеп киткән җәмгыятьтә әхлак чишмәләре саега башлый.* Р.Низамиев

◊ **Кашыклап җыйганны чүмечләп түгү** Нәрсәне дә булса кирәкмәгәнгә, уйламыйча гына туздыру, әрәм-шәрәм итеп бетерү

**КАШЫКЛЫК** *и.* 1) Кашык ясауга китә торган агач. *Кара урманнарның уртасында Кучаланып үскән кашыклык.* Җыр. *Безнең республикада калканлы абага, кашыклык үлән, яки атириум, бөркет канаты (кара абага), тәвә абага таралган.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Кашыклар, тәлинкәләр, табаклар һ.б. куела торган махсус киштә. *Стенаның нәкъ шул сандык торган тәнгәлендә кашыклык ясалган.* М.Гафури

**КАШЫКТОМШЫК** *и. зоол.* Ибис кошлар семьялыгыннан озын томшыгының очы яссыланып торган кош; *русчасы:* **колпица**

**КАШЫ́К УТЫ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан иң аскы яфраклары кашыкны хәтерләткән икеъеллык дарулы үлән үсемлек; *русчасы:* **ложечница**

**КАШЫКЧЫ** *и.* 1) Агач кашык ясаучы оста

2) Кашыкларда (*3 мәгъ.*) уйнаучы музыкант. --- *ул тәрбияләгән мандолиначылар, баянчылар, кашыкчылар да әллә ничә буын инде хәзер.* Кызыл таң

**КАШЫЛ** *муз.* Адыгей халкының тынлы уен коралы

**КАШЫНУ** *ф.* 1) Туктаусыз, берөзлексез үз-үзеңне кашып тору. *Сыер өй почмагына килеп озак кына кашынып торды.* А.Гыйләҗев. *Бабасы шулай диде дә бакча читәненә кашынып торган бозауга таба кизәнде.* И.Гази

2) *күч. сөйл.* Кысылу. *Җылы су дигәч, мунчасы да искә төште: – Күптән түгел чабыштылар, хәзер тагын ябыштылар! – дип кашынып, үпкә шулпасын чөмерергә тотынды.* И.Туктар. *Кашынып йөрмә монда!*

**КАЮ** I *ф.* **1.** Материя яки күннең читен чигеп яки тегеп бизәкләр төшерү. *Атлас белән кайый ул якасын, Ука белән тота җиң очын.* М.Җәлил. *Аклы күлмәк матур була Якаларын каегач.* Җыр. *Тамбур белән читен каегач, Сыпылмас та китмәс булды.* К.Булатова

**2.** *и. мәгъ.* Материя яки күннең читен чигеп яки тегеп бизәкләр төшерү эше. *Болардан бушады исә, бирнәсенә тотынды: күз, кыш чигүенә, каюына, тегүенә утырды, исәпсез күп сөлгеләр, киҗеле ашъяулыклар, чаршаулар, чыбылдык, чолгау, намазлыклар, киндер күлмәкләр, шарфлар, бияләйләр белән кайнашып чыкты.* Г.Ибраһимов

**КАЮ** II *а. иск. к.* **кайсы**. *Бай әйтте: «Җәмәгать, – диде, – һәр каюгыз беләсез, дошманнарым нахак бәлагә грифтар кылдылар».* Г.Ибраһимов. *Бу шәһәрдәге барлык учреждениеләрдә аппаратны тазарту үткәрелеп вә һәр каюсында моның өчен махсус комиссияләр оештырылып, чит элементларны куып чыгарырлар иде.* Ә.Исхак

**КАЮК** *и. гади с.* Бетү, һәлак булу турында. – *Шулай, ике-өч көн эчендә боларга каюк, кызым, совет власте килә, үзебезнең власть килә, – диде Бикмуш бабай.* Г.Гобәй. *[Кириллов:] Әйе. Большевиклар властена каюк.* А.Гыйләҗев

**КАЮЛЫ** *с.* Каелган, каеп чигелгән. *Сөләйман итәкләре каюлы ак күлмәк киеп, өстеннән зәңгәр зинар баглаган.* Ф.Әмирхан. *Шунда ук өченче берсе аның аягындагы каюлы читекләрен тартып ята иде.* Н.Фәттах. *Төшкә керә туй атлары, Каюлы алтын балдак.* Ф.Гыйльфан

**КАЮСЫ** *а. иск.* Кайсы. *Муллаларның каюсы яңа, каюлары иске булса да, гәзиткә яманлап яздырудан куркалар.* Г.Ибраһимов. *Барлык кызлар бердән авыр сулышларын сулап куйдылар, һәр каюсы үз өйләренә тарала башлады.* А.Таһиров

**КАЮ́ТА** *и. нем.* Пароход, корабльләрдә экипаж һәм пассажирлар өчен аерым бүлмәләр. *Әмма Саттар ялгышмаган, үз каютасына дөрес кергән иде.* С.Сабиров. *Мин шулай сөйләп бетереп килгәндә генә пароход палубасында хатыным күренде, үзебезнең кече улыбыз Әнвәрне ияртеп, каютадан һавага чыккан иде.* И.Гази

**КАЮТ-КОМПА́НИЯ** *и. нем.* Пароход һәм корабльләрдә ашау-эчү, ял итү, җыелышлар үткәрү һ.б. өчен уртак зур бүлмә. *Кызыл почмакта, кают-компаниядә, салоннарда, коридорларда бармак очы кадәр дә буш урын юк; стеналар күренми, кораб эче кызыл чүпрәккә язылган лозунглар, диаграммалар, стендлар, күрсәтмәләр белән капланган иде.* М.Юныс. *Кичә без дә кают-компаниягә җыелып, шул хакта ләчтит сатып утырдык.* М.Юныс. *Кают-компаниядә юлбашчыга багышланган почмак бар.* И.Низамов

**КА́Я** *а.* **1.** 1) Кайсы җиргә, кайсы якка. *Ә йөрәге урыныннан кубардай булып дөп-дөп тибә, каядыр ашкына ул йөрәк.* Ш.Маннур. *Шунда ук шофёр егет белән Гарапша да тора: йөкне кая, ничегрәк бушату хакында баш*

*ваталар, ахрысы.* Э.Касыймов. *Машинабыз безне йомшак кына тибрәткәләп, шәһәр урамнары буйлап шома гына тәгәри, уңда да, сулда да иске йортлар белән аралаш яңа, мәһабәт йортлар, тротуарларны тутырып агылган, каядыр баручы, каядыр ашыгучы кешеләр кала.* А.Шамов

2) *мөн.* Баш җөмләдәге *анда*, *шунда* сүзләре белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Кая барма, шунда халык тулган. Кая карама – ак, соры, яшел, чуар, чәчәкле-гөлле, ямаулы-ямаусыз чаршаулар эленгән.* И.Туктар. *Кая карама, облава, күзәтү...* Ф.Галиев. *Ул үзен җәннәт бакчасында дип хис итте, берни ишетмәде, кая төрткәләсәләр, шунда барды.* Җ.Рәхимов

3) *диал.* Кайда. *Каядыр кычкырып-кычкырып көлешкән авазлар ишетелә.* С.Рафиков. *Кая соң сез, Гейне һәм Марксны Тыңлап үскән мәгърур егетләр?* М.Җәлил

**2.** *кис. мәгъ.* 1) *сөйл.* Кем белән булса да килешмәгәндә яки көтелгән, фараз ителгән халәтнең чынбарлыгыннан аермасы зур булуын риторик сорау белән белдерелгәндә кулланыла. *Куркам, тын да алмый ятам. Кая ул монда йокы!* Н.Дәүли. *Карап тик утыра песи, тавышка илтифат итми; Кая курку дигән нәрсә? Колак, койрык та селкетми.* М.Гафури. *[Сәгыйдә:] Юк. Кая инде ул безгә. Биредә мин сторожиха, ягъни каравылчы.* Т.Гыйззәт

2) Үткән заман сыйфат фигыльнең юклык формасы янында килеп, риторик раслау әйләнмәсе төзи. *Белмәгән кая, беләм, бик беләм, бер бөртеге дә әрәм булмас.* Р.Ишморат. *[Нургаян:] Белмәгән кая, мин шушы колхозда утыз биш ел бозау карамаган шул.* А.Гыйләҗев

**3.** *хәб. функ.* Риторик җөмләләрдә «кая китте, кайда, нишләп юк» мәгънәсен белдерә. *Айсылу! Кая синең ялкынлы сүзең, кая җитезлегең!* Г.Бәширов. *Кая монда безнең татар кызларына хас тугрылык? Кая аның биргән вәгъдәләре?* В.Нуруллин

**4.** *ы. функ.* Игътибарны җәлеп итү, берәр эшне үтәүгә чакыру өчен кулланыла. *[Полковник:] Кая, миңа да берәр кружка ясап бирегез әле.* И.Туктар. *– Кая, китер, соңга калабыз, – диде Зәйтүнә.* М.Маликова. *Кая, ферма малларына да такы-токы гына җитәрлек булмады анда, вөҗданың күтәреп сорарлык та булмады...* Р.Төхфәтуллин

◊ **Кая басарга белмәү** *к.* **кая басканны белмәү** *Җамалиның башы күккә тиде. Куанычыннан кая басарга белмәде.* Г.Ибраһимов. **Кая басканны белмәү** Шатлыктан, дәрт, илһам, күтәренке кәеф булганлыктан яки башка сәбәптән бик җанлану, тынычлана алмау. *Көне буе кая басканын белми йөрде Гәрәй.* А.Гыйләҗев. **Кая кую** 1) Нишләтү. *Соңгы сүз аныкы. Нишләп соңгысы гына? Беренчесе үк аныкы. Әйтик, бүлмәдәге җиһазларның кайсын кая кую, кайсы бүлмәгә нинди обой алу.* Э.Шәрифуллина; 2) Нинди хисапка кертү (кем яки нәрсә турында булса да искәртеп әйтелә). **Кая куярга белмәү** Нишләргә, нишләтергә белмәү. *Бөтен өметләре юкка чыккан һәм көнләшүдән үз-үзен кая куярга белми йөргән Сәлим, тыштан бер дә исе китмәгән кешегә салынып, түйга килде.* Г.Әпсәләмов. *Хәлим, көчен кая куярга белмичә, сабанны этеп бара башлады.* Г.Гобәй. **Кая ул** 1) «Ерак тора, бөтенләй киресенчә, икенче нәрсә», «якын да килми торган» мәгънәсендә. *Күрәсең, баю турында уйлау кая ул, эшләп алган акча тамак туйдырырга да чак-чак җитә.* Г.Нигъмәти. *Борһан элеккеге Борһан түгел инде. Кая ул! Басылган.* М.Хәсәнов; 2) «Ихтималы да юк» мәгънәсендә. *Кызларның күп чагы, минәйтәм, үзеңә ошаганны сайла да өйлән... Юк, кая ул, кулын гына селки. Миңа бүтән кирәкми, имеш.* Г.Бәширов. *Володя үзе чит илгә чыгып укырга рөхсәт бирүләрен сорап карый. Кая ул! «Уңышсызлыклары сәбәпле (аны чит илгә дә чыгармадылар, гомумән, бичарага бик кырын карыйлар, бөтенесен искиткеч күпертәләр...), энем ничектер боега...», – дип яза ул көннәрдә Анна Ильинична үзенең бер хатында.* И.Низамов

**КАЯГЫ** *с.* Каян килгән; кайсы якныкы. *Әлеге дә баягы, сез үзегез каягы?* Мәкаль. *Кичәге яшь егет [Рөстәмгә] ашарга китерә, [аның] каягы икәнен сораша.* С.Җәләл

**КАЯГЫМ** *и. муз.* Корея халкының күпкырлы чиртмә уен коралы

**КАЯЗ** *и. зоол.* Елгаларда яшәүче карпсыман балык төре; *русчасы:* **усач**

**КАЯН** *а.* **1.** *к.* **кайдан**. *Тик башта үзегез турында сөйләсәгез иде: кем сез, каян килдегез, нәрсә булды?* Ф.Галиев. *Ә каян алганымны син сорама, Йосыф абый, мин әйтмим!* В.Нуруллин. *Каян башларга дип уйлагандай, ул бераз гына тын торды да үз алдына уйчан карап сүз башлады ---.* Ф.Галиев

**2.** Нишләп, ни өчен, ни сәбәпле, нилектән. *Нәфисә: – Әти, кара әле, бу ни эшең бу? – диде. – Әйтче, зинһар, сиңа нәрсә җитми? Бу хурлыкны каян уйлап чыгардың?* Г.Бәширов. *Ринат, каян уйлап чыгардың әле син моны дигәндәй, көлемсерәп ---.* Н.Хәсәнов

◊ **Каян килеп, кая китмәгән** «Кызганырлык түгел, күп нәрсә югалмый» мәгънәсендә (сарыф ителгән мал, акча, вакыт һ.б. тур.). *Хатын әйтә: – Булмаса, карт, хәзрәттән яңа бөти яздырып кайт, унбиш тиен каян килеп кая китмәгән.* С.Җәләл. *– Бер киклек [киек кош] каян килеп, кая китмәгән. Окоптагылар өчен бирәм, – диде карт.* Ә.Айдар. *Ике мең алты йөз сум акча каян килеп, кая китмәгән, миннән булсын яхшылык.* В.Нуруллин. *Кызганыч шул. Бөтен цех яклап күтәрелгәндә, мин генә читтә калмам. Бер имза каян килеп, кая китмәгән.* К.Кәримов. **Каян килү** Ничек барлыкка килү (гаҗәпләнү яки инкяр итү интонациясе белән әйтелә*). [Сания Гөлзадәгә:] Син ничек ачык һәм кыю итеп сөйлисең хәзер. Каян килде сиңа бу кадәр кыюлык?!* Р.Ишморат. *Очрашулар каян килер иде, Аерылулар әгәр булмаса.* З.Нури. *Күрешкән саен, егетнең аңа соклануы арта торды: каян килгән кызга шушы кадәр сизгер акыл?* А.Гыйләҗев

**КАЯС** *и. бор.* Бау белән аркага асып йөртелгән, туздан ясалган зур савыт

**КӘБАП** *и. гар.* Күмер өстендә яки башка юл белән кыздырылган ит, кырма; шашлык. *Дию өчен көн дә йөз учакта Кәбап кыза адәм итеннән.*

М.Җәлил. *Ачы булды ал шәраб, Тере балыклар кәбап, Ничек ашыйк, ни эчик?* Н.Исәнбәт. *Шунда миннән күлде йолдыз, күлде ай күктән карап, Ник газаплыйлар мине? Ансыз да җан күптән кәбап*... Ш.Бабич

◊ **Кәбап булу** Әрнү, яну. *Йөзләр сулып, йөрәгебез булды кәбап.* М.Гали **Кәбап итү** Бик нык кайгыга төшерү, бик нык көйдерү, әрнетү, яндыру (күңелне, йөрәкне һ.б.). *[Зөһрә:] Ханҗәреңнән кискен сүзләр белән Итмәсәңче кәбап күңелне.* Ф.Бурнаш

**КӘБАПХАНӘ** *и. иск. гар.* Кәбап әзерләү, пешерү, сату-алу, ашау урыны; шашлыкханә

**КӘБАПЧЫ** *и.* Кәбап, шашлык ясаучы һәм сатучы

**КӘБӘ** *и. гар. диал. к.* **кәбәм**

**КӘБӘМ** *и. диал. тартым форм.* Балам, бәпкәм, җаным. *[Зөһрә:] – Бар, кәбәм, син сандугач бул, иртә-кич адәмнәрнең күңелен юат, – ди.* Әкият. *Я, тагы уйна әле, кәбәм.* Г.Гобәй. *[Килен:] Дәшермен, кәбәм, дәшмәгән кая, Солтан абзыкай белән парлап дәшермен!* Г.Бәширов

**КӘБӘРЕ** *и. иск. диал.* 1) Кулдан сугу өчен җәелгән көлтәләр тезмәсе. *Бер кәбәре арыш сугу*

2) Нәрсә дә булса пешерү өчен әзерләнгән камыр. *Бер кәбәре токмач кисү*

3) Нәрсә дә булса эшләү, җитештерү, ясау өчен алдан әзерләп куелган материал

**КӘБӘРТКЕ** *и. диал.* Мич белән дивар арасындагы кереп-чыгып йөрү өчен махсус калдырылган аралык яки шунда урнаштырылган сәке

**КӘБЕН** *и. фар. этн.* Никах йоласы, никах. *[Хәмидә:] Вәгъдә бирнәсенә дә, кәбен бирнәсенә дә, актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт, калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар.* Г.Камал

◊ **Кәбен кою** Керәшен татарларында егет белән кызны чиркәүдә никахлау

**КӘБЕНЛЕ** *с. иск.* 1) Никахлы. *Кәбенле хатыны*

2) Тулы бирнәсе булган, бирнәле

3) Ярәшелгән

**КӘБЕСТӘ** *и. рус* 1) Әвернәчәчәкләләр семьялыгыннан яфраклары күпкатлы булган бакча үсемлеге һәм шул үсемлекнең күчән булып үскән һәм ашамлык итеп кулланыла торган итләч яфраклары. *Койрыкны да бүтән кешеләр кәбестә күчәне кебек, ялангач беләк кебек ямьсезләп кыралар.* Г.Ибраһимов. *Күз ачып йомганчы дигәндәй, өстәлгә олы гына агач коштабак белән салкын ит, зур гына ипи түгәрәге һәм бу як халкы өчен бөтенләй ят ризык – тозлы кәбестә килеп утырды.* Җ.Рәхимов. *Илгизәр Илгизәрович кәбестә башын уң кулына ала, сулы белән кәбестә башын сыйпап-сыйпап ала.* С.Гаффарова

2) *куч. сөйл.* Акча

**КӘБЕСТӘ́ БЕТЕ** *и. зоол.* Чын бетләр семьялыгыннан, яшькелт төстәге, кәбестә уңышына бик зур зыян китерә торган корткыч бөҗәк. *[Санберри] Үсеш чорында кәбестә бете белән авырырга мөмкин, шуңа кәбестә культуралары янына утыртмагыз.* Серле сандык

**КӘБЕСТӘ́ БОРЧАСЫ** *и. зоол.* Катыканатлылар семьялыгыннан, яшькелт кара җирлеккә сары, кызыл, ак тимгелләр, сызыклар һәм төрткеләр төшкән, кәбестәгә зыян китерә торган корткыч бөҗәк. *Кәбестәне күп төрле корткычлар зарарлый. Кәбестә борчасы, кәбестә күбәләге, кәбестә ябалакчыгына каршы көрәштә халык куллана торган чаралар зур ярдәм итә.* Өегез ямьле булсын

**КӘБЕСТӘ́ КОРТЫ** *и. зоол.* Кәбестә ябалакчыгы, кәбестә күбәләге һ.б.ш. корткычларның гусеницасы

**КӘБЕСТӘ́ КӨЯСЕ** *и. зоол.* Урак канатлы көяләр семьялыгыннан, кәбестә уңышына искиткеч зур зыян китерә торган карасу коңгырт төстәге зур булмаган күбәләк

**КӘБЕСТӘ́ КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Аккүбәләкләр семьялыгыннан ак канатлы, корты кәбестә корткычы булган көн күбәләге. *Бакчада зонтиклы үсемлекләрне үстерү дә (укроп, орлыклык кишер һ.б.ш.) кәбестә күбәләге кортларына каршы көрәштә әйбәт чара.* Өегез ямьле булсын

**КӘБЕСТӘЛЕ** *с.* Кәбестә белән пешерелгән, эченә кәбестә салынган. *[Дилбәр:] Яшелчә салаты, кәбестәле аш, тозлы кәбестә бик яратам.* Тәмлетамак

**КӘБЕСТӘЧЕ** *и.* Кәбестә үстерү белән шөгыльләнүче кеше

**КӘБЕСТӘ́ ЧЕБЕНЕ** *и.* Чәчәк чебеннәре семьялыгыннан канатлары үтә күренмәле, үзе саргылт соры төстәге, кәбестәнең тамырын черетеп, кәбестә уңышына зур зыян китерә торган бөҗәк

**КӘБЕСТӘ́ ЯБАЛАКЧЫГЫ** *и.* Төн күбәләкләре семьялыгыннан алгы канатлары карасу коңгырт, арткы канатлары караңгы соры төстәге кәбестә һәм шулай ук борчак, суган, чөгендер һ.б.ш. уңышына бик зур зыян китерә торган корткыч бөҗәк

**КӘБИР** *с. гар. иск.* Олы, бөек, зур

**КӘБИСӘ** *и. гар.* **1.** Февраль ае 29 көннән килгән ел. *Кәбисә дип тормаган, ул елларда туган сабыйлар саны да шаккатырлык* ---. Р.Ногманова

**2.** *с. мәгъ.* Дүрт елга бер 366 көннән килә торган (29 нчы февраль өстәмә көн булып кергән). *Быелгы кәбисә елы бөек шәхесләребезне бер-бер артлы чүпләп кенә тора. Сәхнәдә кабатланмас геройлар тудырган Татарстанның халык артисты Хәлил Мәхмүтов белән мәңгегә саубуллашу да бик авыр булды безгә.* Ватаным Татарстан

**КӘБҮТӘР** *и. фар. иск.* Күгәрчен

**КӘВЕС** *и. гар. диал. к.* **кавыз**. *Сугыш вакытында [тегермәннең] куласаларын ваткалап ягып бетергәннәр, кәвес такталарына хәтле ботарланган иде.* Х.Сарьян

**КӘВЕШ** *и.* Йомшак күннән тегелгән кунычсыз аяк киеме. *Бервакыт минем Казаннан киеп кайткан --- кәвешләрем, кәзәкиләрем тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән угылының күк киндер күлмәге илә бишмәтен миңа бирмәкче булды.* Г.Тукай. *Бераз вакыт үтмәде, шәл ябынып, оялганлыктан күзене түбән таба төшереп Саҗидә, казакидән, ыштан өстенә генә ялан аякка кигән кәвештән мулла кияү мунчага таба киттеләр.* Г.Исхакый

**КӘВЕШЧӘН** *рәв.* Кәвеш белән генә, кәвеш кигән килеш. *Кәвешчән генә кар өстеннән йөрү*

**КӘВЕШЧЕ** *и.* Күннән кәвеш тегүче. *Бичара бу адәм дә чикте җәфаны:*

*астында кабак, төн буе җырлыйлар, сугышалар, күрше бүлмәләрдә кайсы кәвешче, кайсы тегүче.* К.Насыйри

**КӘВЕШЧЕЛЕК** *и.* Һөнәрчелекнең бер тармагы буларак, кәвеш тегү эше

**КӘГАЗЬ** *и. фар.* **1.** 1) Күпчелек очракта агачтан, шулай ук чүпрәкчапрактан яки башка төр чималдан ясалып, язу, китап басу, әйберләр төрү һ.б. максатлар белән кулланыла торган юка табаклардан гыйбарәт материал. *Эшчеләрнең газетасын салам кәгазьгә басабыз, буржуйлар безгә ак кәгазь сатмый.* И.Гази. *Берзаманны аның авызыннан, телетайптагы кебек текетеке килеп, түгәрәк мөһерләр сугылган кәгазь тасмасы чыга башлады.* З.Мәхмүди. *Авыр әйберләрне бүлмәдән чыгармыйча идән уртасынарак куясың да клеёнка яки берничә кат кәгазь белән каплыйсың.* Өегез ямьле булсын

2) *сөйл.* Рәсми төстәге язма документ. *Затлыдан-затлы кигән алыпсатарлар, суга төшсә калкып чыгар эш кешеләре, кулларына подорожный кәгазьләре тоткан гаскәриләр вә башка кешеләр атларына утырып, үз юлларына китә торалар.* Җ.Рәхимов. *Ун минут үткәндерме-юктырмы, чирләп эшкә бармаганлыкны күрсәткән кәгазь кесәмә кереп ятты.* Ф.Баттал. *Ниндәй зур кешеләр дә күп вакытта кәгазьне укымаенча гына кул куялар.* Ш.Мөхәммәдев

3) Нинди дә булса таныклык, мандат, шәхес таныклыгы. *Саный, уйлана, мисаллар китерә башласаң, исең китмәле. Элемтә аша килгән кәгазьләре буенча берәүне дә танып булмый, анда барысы да ал да гөл, тот та үзеннән кешелек өчен үрнәк мәрмәр һәйкәл коеп куй.* Т.Галиуллин. *Әчтерханда бер югарыдагы әфәндедән законлы кәгазь юнәттем.* Ә.Гаффар. *Аларны кунакка озаткач кына, мылтык, кылыч, хәнҗәрне тагып һәм юл кирәкләрен хәзерләп, губернатордан кәгазь алырга да, добровольный булып, әйдә Порт-Артурга!* Ш.Мөхәммәдев

4) Язуы яисә тексты булган теләсә нинди бит, язулы табак кисәге. *Айсылу Тимеринең температура кәгазе яныннан озын-озын цифрлар баганасы тезелеп төшкән иkенче бер кәгазь алды.* Г.Бәширов

5) *иск. сөйл.* Обой. *Зур гына, биек кенә, стеналары кәгазьсез агач өй.* М.Фәйзи

6) *күч. к.* **кәгазь акча**. *Шул арада ук ниндидер солдат, итекченең кулына 5 тәңкәлек кәгазь төртеп, итек алып маташа.* Г.Тукай. *Унҗиде сум урынына өстәлгә егерме биш сумлык кәгазьне ташлады экономист.* Ф.Баттал

**2.** *с. мәгъ.* Кәгазьдән ясалган, кәгазьдән әзерләнгән. *Мәдинә кәгазь пуляны карау өчен Әнвәрнең янына ук барып утырды.* К.Нәҗми. *Ничә көннәр буе кәгазь торналар ясап очырткан авыру япон кызының ап-ак йөзе чагылып китә.* Д.Галимов. *Монда... әрҗәләп өелгән кәгазь томнар.* Н.Хәсәнов

◊ **Кәгазьдә калу** Нәрсәнең дә булса тормышка ашырылмавы, язуда гына булуы. *Уф Алла дигәнебез, Ындырда кибәнебез. Тик кәгазьдә калыр микән Бәйсезлек дигәнебез?* М.Саттаров. **Кәгазь кыштырдату** 1) Язучылык эше белән шөгыльләнү. --- *бичара шагыйрь минем университет студенты икәнлегемне, әз-мәз кәгазь кыштырдатуымны да белгәч, чиксез куанды.* А.Гыйләҗев; 2) Кәгазь, язу-сызу, документлар белән эш итү. *Шулай итеп, көндезләрен дәүләт эшендә кәгазь кыштырдатып, төннәрен --- гаилә йөген җигелеп тарта иде Альбина.* А.Касыймова. **Кәгазь миллиардер** *кимс.* Кыйммәте, бәясе төшкән кәгазь акчаларга ия булган миллиардер. *[Фазыйл:] Мин Чех-Колчак белән бергә Себердә кызылларга каршы сугышып йөргән чакта, [Гәүһәр] ниндидер вак приказчиктан кәгазь миллиардерга әйләнгән бер спекулянтка кияүгә чыккан.* Г.Ибраһимов. **Кәгазь пычрату** Нидер язып, кирәкмәгән эш белән шөгыльләнү. *[Рифат:] Ие... Әдәбият кирәк нәрсә түгел ул... Тормыш арбасына җигелеп тартасы урынга, язучылар кәгазь пычратып яталар.* Т.Галиуллин. **Кәгазь ясау** Рәсми билгеләнгән тәртиптә килешү төзү

**КӘГАЗЬ АКЧА** *и.* 1) Дәүләт тарафыннан чыгарылып, әйләнештә алтынны алыштыра торган, дәүләт эчендә кабул итү мәҗбүри булган төрле кыйммәттәге акча билгесе төшерелгән кәгазь. – *Минә өстәвенә тагы кәгазьләре дә, – Хисами кесәсеннән берничә кәгазь акча чыгарып, тегеләре өстенә куйды, – ал, Хәйри дус, бушлай бирә дип уйлый күрмә түлке, белдеңме?!* Г.Минский. *Аннан байтак кына көмешләр, бакырлар һәм берничә кәгазь акча килеп чыкты.* К.Нәҗми. *Биктаһир карт, портманетны ачып, аның урта бүлекчәсеннән бер сумлык кәгазь акча тартып чыгарды.* И.Гази

2) Алтын белән чагыштырганда, бәясен югалту ихтималы булган акча. *Көннән-көн чүпрәккә әйләнеп барган кәгазь акчага нигә алар икмәк сатсыннар?* Т.Гыйззәт

3) Пластик картада, банк исәбендә булган акчадан аермалы буларак, кулдагы акча

**КӘГАЗЬ-КАЛӘМ** *җый. и.* Язу әсбаплары; кәгазь һәм каләм. *Абдулла исә ташка төшәргә тиешле сүзләрне бер утыруда язып ташламакчы булып өйгә керде, кәгазь-каләм алып сәкегә утырды.* Җ.Рәхимов

**КӘГАЗЬЛӘНҮ** *ф.* 1) *махс.* Кәгазьгә әверелү, кәгазьгә әйләнү

2) *сөйл. иск.* Кәгазь (*5 мәгъ.*) белән каплану, кәгазь ябыштырылу; кәгазь белән әйләндереп алыну. *Дивар аксыл җирлектә зур-зур бизәкле кәгазь белән кәгазьләнгән.* Ф.Әмирхан

3) *күч.* Бик нык тузу, искерү аркасында артык нык сәләмәләнү, юкару. *Бу күлмәк бик искерде, тәмам кәгазьләнеп калды*

**КӘГАЗЬЛӘ́Ү** *ф.* Кәгазьгә төрү, кәгазьгә урау, кәгазь белән чорнау

**КӘГАЗЬЛЕ** *с.* Кәгазе булган. *Күп тә үтмәде, өстәлдә чуар кәгазьле шәраб шешәсе, елык-елык килеп торган матур-матур фужерлар, төрле-төрле җимешләр пәйда булды.* Ә.Дусайлы

**КӘГАЗЬЧЕ** *и.* Кәгазь җитештерүче яки кәгазь сәнәгате эшчесе. *Ни әйтергә теләгәнне шәйләдеңме? Димәк, бюрократлар яшәгәндә, кәгазь җитештерү кимемәячәк, артачак кына дигән сүз. Кәгазьчеләр эш белән тәэмин ителәме? Ителә.* Ф.Дәүләтбаев

**КӘГАЗЬЧЕЛЕК** *и. хуплм.* Кирәккән-кирәкмәгән документлар, белеш-

мәләр таләп итеп, ниндидер эшне башкаруны сузу, теләмичә, күңел бирмичә эшләү. *Хәзер кәгазьчелек заманасы*

**КӘГҮ** *ф. гади с.* Эчү, салу (исерткеч эчемлек тур.). *Дустым Харис шунда яшәп ята, Ярата шул бераз кәгәргә.* Х.Камалов. *Әйдә, яшь килен саулыгына берәрне кәгик тә, сөякләрең каз мамыгы кебек йомшарып китәр.* Ф.Бурнаш. *Кәгеп тә өлгердемени инде?* Ш.Камал

**Кәгеп алу** Тиз арада кәгү. *Бары иртәдән бирле арык чәүкәләр төсле җебенеп, көтә-көтә чыдарлыклары калмагач, икесенә бер бутылканы кәгеп алган исерек ламовойлар гына торалар.* К.Нәҗми. *Елмая безнең егет тә: – Әйдә кил, кәгеп алыйк! Тик бу утыннарны башта ушбу арбага салыйк!* М.Саттаров

**Кәгеп бетерү** Кәгүне тәмамлау. *Ул килеп җиткәндә, егетләр кәгеп бетергәннәр иде инде*

**Кәгеп йөрү** Еш кәгү. *Алай кәгеп йөргәч, әҗәт түләп булмый ул...* Акчарлак

**Кәгеп кую** Тиз генә кәгү. *Хуҗа үзе юк. Әйдә, аның исәнлегенә тагын берне кәгеп куйыйк.* З.Зәйнуллин

**Кәгеп җибәрү** *к.* **кәгеп кую**

**Кәгеп тору** Әледән-әле яки даими кәгү; кәгү халәтендә булу. *Ул күрше егетләрнең аракы кәгеп торган вакытына туры килде. Зиннәт бабай бер кияве белән чәкүшкәне кәгеп утыра иде.* Р.Риян

**КӘГЪБӘ** *и. гар.* 1) *дини* Мәккә шәһәрендә Хәрам мәчетенең ишегалдында урнашкан, мөселманнар тарафыннан изге дип саналган һәм зиярәт ителеп тәваф кылынган куб формасындагы бина. *Ишектән кергәч тә, уң якта ап-ак агартылган зур мич бар, --- сәгать, кечерәк көзге, әллә нинди күгәрченнәр төшергән яңа календарь, берничә шәмаил, Истанбул, Мәккә, Кәгъбә рәсемнәре өйнең зиннәтен тагы бер кат арттыралар.* Г.Ибраһимов. *Хәзерге вакытта да Кәгъбә хаҗ кылу урыны булып тора.* Ислам дине турында белешмә-сүзлек. *[Юлаучы] --- Хаҗилар Кәгъбәне күрергә мохтаҗ булган күк, йөзеңне күрергә зар булып, ерак җирдән шатланып килдем.* Җ.Рәхимов

2) *күч.* Бөтен күңелне, игътибарны бик нык җәлеп иткән, изге дип саналырлык әйбер яки күренеш. *Мине күңелләрегезгә кәгъбә иткән назлы ил уллары! Хәмдиянең мәхәббәт былбылы кайсыгызның җилкәсенә басып сайрар икән?* М.Фәйзи. *Салават – Урал баласы, Салават – йөрәк кәгъбәсе; Җирдә әнвәр гәүдәсе, Күктә зәңгәр шәүләсе.* Ш.Бабич. *Авыл тормышы күңелемнең кәгъбәсе иде, аның бәндәсе булу, аның бер баласы белән берләшеп тормыш кору – миңа зур бәхет!* М.Фәйзи

3) *күч.* **кәгъбәм** *тарт. форм.* Кемнең дә булса сөйгән кешесе һәм шул кешегә иркәләп эндәшү сүзе. *[Зөһрә:] Кара чәчләреннән сөя-сөя, кемгә «сөям, кәгъбәм!» диярмен.* Ф.Бурнаш. *Ялынма син, кәгъбәм, аңарга.* Ф.Бурнаш

**КӘГЪБӘ БОДАЕ** *и. иск.* Кукуруз, Мәккә бодае

**КӘГЪБӘТУЛЛА** *и. гар дини. к.* **Кәгъбә** (*1 мәгъ.*). *[Хаҗи:] Мин Кәгъбәтуллада хаҗ кылган вакытта бер хикмәтле төш күрдем ---. Гамиләнең авыру икәнлеген, тиздән үләчәген, Кәгъбәтуллада төш күргәнлегемне, ярты дәүләтне яздыру турында нәзер әйткәнлегемне – һәммәсен бәйнә-бәйнә колагына тукыштыр, яме?* Ш.Камал. *Кәгъбәтуллада җир йөзеннән җыелган хаҗилар Коръән укыйлар.* Ф.Әмирхан

**КӘГЪБӘТУЛЛАҺ** *и. гар дини. кит. к.* **Кәгъбәтулла**

**КӘЕГҮ** *ф. диал. к.* **кәйләнү**

**КӘЕКТЕРҮ** *ф. сөйл. к.* **кәегү**

**КӘЕФ** *и. гар.* **1.** 1) Кешедә нинди дә булса физик хәлгә яки кичерешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән хис, эчке кичереш, рухи халәт. *Әмма ничек кенә булмасын, фермага килүе белән иң яхшы нәселле сыерларның шулай исәнсау бозаулап торуы Нургалинең кәефен бер мәлгә яхшы якка таба шактый нык үзгәртеп җибәрде.* Ә.Еники. *Гөлләрнең дә кәефләре яхшы, ахры, яңгыр явып үткәндер.* Ә.Ерикәй. *Күп тә үтмәде, ниндидер күңелле җыр көйликөйли, ишектән колхоз рәисе Рифкать Сәлимович килеп керде. Кәефе күтәренке.* Г.Гыйльманов

2) *сөйл.* Кешенең үз-үзен яхшы хис итүе, сәламәт булуы турында. *Анда килеп бераз ятканнан соң, аның температурасы нормаль хәлгә төшеп, кәефе тәмам яхшырды.* М.Гали. *Ул: «Бүген бер дә кәефем юк, әллә нишләп авырып торам», – дип кенә җавап бирде.* М.Гафури. *Килен керде --- миңа сәлам бирде, Исән-аманлыкны сорады: «Кәеф начар мәллә, абзыем?» – ди, «Да, – мин әйтәм, – сырхап торамын...»* Ш.Маннур

3) Кәеф-сафа, күңел ачу. *Кайберсе, эч пошканнан вакытларын кәеф вә хозур илә үткәрмәк өчен, арпа һәм арыш сулары илә тутырылган шешәләр илә «уйнарга» тотындылар.* Ш.Мөхәммәдев

4) *күч. сөйл.* Исерткеч эчемлекнең күңелне ача торган көче. *Сүзләр кабынды. Кымызның кәефе мигә йөгерде.* Г.Ибраһимов

**2.** *хәб. функ. күч. сөйл.* Кыйммәтле. *«Чайка-2» телевизорын сатып алдым. Бәясе дә кәеф кенә: бөтен кирәкяраклары белән 407 сумга төште.* Социалистик Татарстан

◊ **Кәеф ачу** Күңел ачу, кәеф-сафа итү. **Кәеф ачылу** Күңел ачылу, кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. *Баланың кәефе ачылды.* Г.Ибраһимов. **Кәеф бозылу** *к.* **кәеф киту**. *Өйгә сыймас, андый зур аюдан Кызларымның кәефе бозылыр.* Ф.Кәрим. **Кәеф ватылу** *к.* **кәеф бозылу**. *Ләкин аның кәефе бик тиз ватылды.* Ф.Әмирхан. **Кәеф килү** Кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. *Әхмәтҗан кәефе килүдән телен шартлатып куйды.* Г.Минский. *Тыңлап торучыларның күбесе, шул арада Төхфәт белән Гариф та, аның сүзләренә кәефләре килеп: – Дөрес! – дип кычкырдылар.* Ш.Камал. *Наташа бу чандыр кызның терелегенә кәефе килеп, көлә-көлә аның муенын кытыкларга тотынды.* Г.Бәширов. *Бу сүзне ишеткәч, хәзрәтнең бик кәефе килде ---* Ф.Әмирхан. **Кәеф кителү** *к.* **кәеф китү**. *Шул җитә калды, кибетләрдән юньле ит таба алмау аркасында кителгән кәефем нерв кылларыма кабат ышкылып үтте.* Ф.Баттал. **Кәеф китерү** Кәефне күтәрү. *Ичмасам бераз кәефне китереп, сөйләшеп утырырга күңелле була.* Г.Камал. **Кәеф китү**

1) Яхшы кәеф юкка чыгу, бетү. *Минем бу эшкә кәефем китсә дә, аның үзенә белдермәскә уйладым.* Ш.Мөхәммәдев. *Кайсысы үзенең алдануына ачуы килеп, кайберсе үзен аббатның алдый алуына кәефе китеп, кайберсе үзенең юк-барга шулай тиз ышанып куркуга төшүеннән гаҗәпләнеп, кычкырышалар, шаулашалар.* Р.Мөхәммәдиев. *Бераз кәефе китсә дә, Хәбир моны аларга сиздермәскә тырышты, йөгерә-атлый ихатага чыгып, янәшәдә генә торган ат арбасы өстенә менеп утырды...* Г.Гыйльманов; 2) Хәтер калу, үпкәләү. *Үзенең кыш буе узганнары белән абыйсының исен китәрергә уйлап торганда, аның үзен болай кимсетүенә Габделкаюмның шактый кәефе китте.* М.Гали. **Кәеф кору** *к.* **кәеф ачу**. *Кәеф корып яшәүчеләр Көн буе кырын ятып, Көн итәләр талчукларда Артыкпортыкны сатып.* Г.Камал. *Кайда ул кәеф корулар, Кайда ул киң ресторан? Көне-төне типтерүләр, Сиптерүләр бар иде.* Ш.Бабич. **Кәеф күтәрелү** *к.* **кәеф ачылу**. *Ике савыт сыраны тәхилләгәннән соң, Иннокентийның кәефе күтәрелде.* З.Мәхмүди. **Кәеф кылу** *иск.* Күңел ачу. *Бер кичне Батыргали агай зур гына бер трактирда кәеф кылып утырганда, коньяклар, ромнар чамадан артыграк әсәр кылып, күз аллары томанлана башлады.* Ш.Мөхәммәдев. *Уйныйк, көлик, кәеф кылыйк, Һәр җирдә булыйк богачом, Үзебезнең күңел шат булгач, Эшче халык безгә нипочём.* Ш.Мөхәммәдев. **Кәеф кырылу** *к.* **кәеф киту**. *Котлымөхәммәт кәефе кырылып кабат күзләрен йомды.* Җ.Рәхимов. *Кәефем кырылып кибеттән кайтышым иде, баскыч төбендә очрады бу [Самат].* Ф.Баттал. *Мал хуҗаларының артык кәефе кырылган да, күп киңәшеп-нитеп тормыйча, безнең исәпкә яллап, икенче берәүне көтүгә чыгарганнар.* Г.Ибраһимов. *Данилов тәмам кәефе кырылган хәлдә, Шәмсигә әйләнеп тә карамастан, кызу-кызу атлап, взводын куып китте.* Г.Гобәй. **Кәеф сөрү** Күңел ачу, кәеф-сафа корып яшәү. **Кәеф хушлану** *к.* **кәеф килү**. *Бу хатны укыгач, Галиәкбәр агайның кәефе бераз хушланган иде.* Ш.Мөхәммәдев. **Кәеф чигү** *к.* **кәеф сөрү**. *Мине управляющий ясарсың, кәеф чигәрбез, ичмаса*! Ш.Камал. **Кәеф чыгу** *к.* **кәеф килеп чыгу**. *Беләсеңме, кичкә яшьләр уены оештырабыз да, ул гармоньсыз бик кәеф чыкмый.* Г.Бәширов. **Кәефкә чуму** *диал.* Тынычлану, яхшы кәефле булып китү. *Үзе елмайды. Ап-ак тешләре айга каршы көлде. Үзе тагы уйга, кәефкә чумды.* Г.Исхакый. **Кәефне бозу** Яхшы кәефне юкка чыгару, күтәренке кәефне бетерү. *Әни, кунакларының кәефен бозмаска тырышып булса кирәк, безнең сүзләрне дөресләп көлә...* М.Әмир. *Торакта чакта --- бер-ике генә минут булса да изрәп яту өчен тартышырга, дежурныйның кәефен бозарга туры килгән көннәр күп була иде.* М.Әмир. **Кәефне җибәрү** *к.* **кәефне бозу**. *[Дирижёр:] Әфәндем, монда алай тавыш чыгарып, халыкның кәефен җибәреп утырмагыз!* Г.Камал. *Ләкин бераз кәефегезне җибәрергә туры килә, аерырга туры килә сезне.* Г.Гобәй. *Сыерчыклар бер сүз әйтмәделәр, мактанчыкның кәефен җибәрмәделәр.* А.Алиш. **Кәефне китәрү** *к.* **кәефне җибәрү**. **Кәефне кыру** *к.* **кәефне бозу**. **Кәефне табу** Кемдә дә булса яхшы кәеф барлыкка китерү, кемнең дә булса кәефен күтәрү. *Бу юлы инде ул Зифа карчыкның кәефен табарга, аңа ошарга тырыша һәм вакыт-вакыт аңа мактау сүзләре дә әйткәләп ала иде.* А.Шамов

**КӘЕФЛӘНДЕРГЕЧ** *с.* Кәефне күтәрә, кәефне яхшырта торган

**КӘЕФЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кемнеңдер кәефен күтәрү, күңелен табу, күңелен күрү. *Нәгыйм өйгә кайтып килгән чакта, хаҗиның бүләге аны яңадан кәефләндерәчәк дип уйлана-уйлана кайтты.* Ш.Камал

**Кәефләндерә бару** Акрынлап тагын да кәефләндерү. *Телевизордан күрсәтелгән «Көлке-шоу» барысын да кәефләндерә бара*

**Кәефләндерә төшү** Тагын да кәефләндерү. *Ул сөйләгән мәзәк кәефләндерә төште*

**Кәефләндереп җибәрү** Кинәт кәефләндерү. *Кәефләндереп җибәрә торган бер нәрсә.* М.Гали

**Кәефләндереп тору** Өзлексез яки әледән-әле кәефләндерү. *Яхшы хәбәрләр кәефләндереп тора*

**КӘЕФЛӘНҮ** *ф.* 1) Кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. *[Батырша] Шуңа да җил-давыллы көннәрне көтеп ала, диңгез-дәрьяда котырынган дулкыннарның саңгырау авазларын кәефләнеп тыңлый.* Җ.Рәхимов

2) Рәхәтлек сизү; күңел хушлану. *Куе, озын, тәртипсез, ләкин матур таркалган чәчләрен ал якка, күкрәге өстенә чыгарып куйды һәм көзгедән карап, үз сурәтеннән үзе кәефләнде***.** Ф.Әмирхан. *Хәтта мич алдында булышкан Газзә түти дә, аз гына соңга калып булса да бик кәефләнеп, сузып кына көлеп җибәрде.* Ә.Еники

3) Исерткеч эчемлектән кызмачалану, исереп, кәеф күтәрелү. *Майлы күзле майор бу сыйдан кәефләнде, тәмам исерде.* М.Җәлил. *Анда инде бандитларның атаманнары үз дуслары белән кәефләнә булыр.* Н.Дәүли. *[Сәгыйтьҗан] Шактый ук кәефләнеп килгән. Күзләре мут ялтырый. Аяклары чалыш-молыш атлый.* Д.Галимов

**Кәефләнә бару** Торган саен кәефләнү. *Чәй эчкән саен кәефләнә бара.* М.Гафури. *Ләкин җырчы ныклы ир икән, тик кәефләнә генә бара.* Г.Ибраһимов

**Кәефләнә төшү** Тагын да кәефләнү. *--- ничектер тагын да кәефләнә төшеп, алар күрсәткән сукмак белән Идел ярыннан китте.* Г.Бәширов

**Кәефләнеп йөрү** Соңгы арада яки күптәннән кәефләнү. *Соңгы вакытта бик кәефләнеп йөрүче Рифкать бригадирның соңга калып килүен карашы белән генә кичерде дә сүзен дәвам итте.* Г.Гыйльманов

**Кәефләнеп китү** Кинәт яки соңгы арада кәефләнү. *Кухня табылуга кәефләнеп киттем.* Ш.Усманов

**Кәефләнеп тору** Кәефләнү халәтендә булу яки әледән-әле кәефләнү. *Ә аннан үз баласының булдыклылыгын күреп елмаеп, кәефләнеп тора икән.* А.Алиш

**Кәефләнеп утыру** *к.* Кәефләнеп тору. *Без шатлыктан бераз гына кәефләнеп утырырга уйладык.* Ш.Камал

**Кәефләнеп яту** *сөйл.* Әле, хәзер кәефләнү. *Ул киң яланда хатыны сауган биянең кымызын эчеп, курай уйнап, дәрт укып кәефләнеп ята торган башкорт кебек, баштанаяк эшсезлеккә чумды.* Г.Исхакый

**КӘЕФЛЕ** *с.* **1.** 1) Күңелгә ятышлы, күңелгә ошый торган, күңелле. *Аннан соң мин үземдәге кәефле каушауны көчләнеп җиңдем дә Асяның күзләрен үбәргә омтылмакчы булдым, ләкин нәкъ шул вакытта ул күзләрен миңа күтәрде дә, оялып, иркәләнеп, минем касдымны белгән шикелле итеп карады.* Ф.Әмирхан. *Гаскәриләр --- кәефле җыр җырлыйлар.* Ш.Усманов

2) Күтәренке күңелле, кәефе яхшы. *Кәефле чак*

3) *күч.* Җиңелчә исерек, кызмача. *[Шәмсетдин] Тизрәк исереп, кәефле хәлгә килүчән булды.* Г.Исхакый

**2.** *рәв. мәгъ.* Күңелле итеп. *Гөлҗиһан, бик кәефле булып, анасының токмач кискәнен карап тора.* М.Гафури. *– Уйлама да, тәхсир, – дип, бик кәефле көлемсерәп, хәзрәтнең күзләренә карады.* Ф.Әмирхан. *Хәйрүш --- кәефле елмая.* М.Җәлил

**КӘЕФЛЕК** *и. ялг. к.* **кәеф** (*1 мәгъ.*). *Моны күргәч, Габделбасыйрның каушавы бер кәефлеккә әйләнде.* Ф.Әмирхан

**КӘЕФЛЕЛЕК** *и.* Яхшы кәефле булу; яхшы кәеф. *Чынлап та, Миңсылуның чыраенда кәефлелек әсәре күренми иде.* Ш.Камал

**КӘЕФ-САФА** *и.* 1) Кайгысыз, күңелле вакыт уздыру рәвеше; күңел ачу күренеше. *Кремльдәге комендант йортында бүген тагын кәеф-сафа.* В.Имамов. *Тыелгысыз кәеф-сафа, искиткеч сый-хөрмәтләрне дә, азгынлык-фәхешлекләрне дә, төрле низаг-ызгышларны да, үлем-китемнәрне дә күп күргән сарай һәм пайтәхет өстеннән узган төнге зилзилә дәрья уртасындагы утрау-кальганың өч сажин ярым калынлыгындагы диварларын үтеп керә алмады.* Җ.Рәхимов

2) Күңелгә ял, рәхәтлек бирә торган кызык һәм уен-көлке; хозур эш. *Кешеләр һәммәсе кәеф-сафада, кешеләрнең һәммәсе дә шатланып, шау-шу килеп көлешеп, рәхәтләнеп бәйрәм итеп йөриләр.* Г.Камал

◊ **Кәеф-сафа кору** *к.* **кәеф-сафа сөрү**. *Шуларга каршы байларның рәхәттә кәеф-сафа корып яшәүләрен ачынып яза.* М.Җәлил. *Ә менә өч мең ---. Кыскасы, бу сан бигрәк тә бушлай кәеф-сафа корып, тел шомартып утырырга яратучыларның колаклары аша үтеп, минең фән-мазар борчымый, хатын бәйләнүе дә онытмырмый торган бер киштәсенә кереп, ныклап урнашты.* Т.Галиуллин. *Әнә шул очсыз-кырыйсыз кәеф-сафа корулар бөтен вакытын алып бетерә дә инде императрицаның.* Җ.Рәхимов. **Кәеф-сафа кылу** *к.* **кәеф-сафа сөрү**. *Шундый зур сарайларда, җәннәт бакчасы кебек бакчаларда кәеф-сафа кылып гомер итә башлагач, әсирлектә күргән җәфалар, зинданда чиккән михнәтләре – барысы да онытылачагын сөйләп, әллә нинди хыялларга талды.* Ш.Мөхәммәдев. **Кәеф-сафа сөрү** 1) Берәр төрле кызык һәм уен-көлке белән күңел ачу. *Ул тәмле сүзле, матур йөзле кешеләр, ай шикелле балкып, кәеф-сафа сөреп утыралар.* Ф.Әмирхан. 2) Гамьсез, эшсез, рәхәт итеп вакыт уздыру. *Падишаһлар кәеф-сафа сөрә, бал-май эчендә йөзә, халык исә, алар рәхәттә яшәсен өчен, ясак түли.* Җ.Рәхимов. *Петербургка барып үзенең кадет дусларына кушылмакчы, анда кәеф-сафа сөрмәкче була.* Г.Ибраһимов

**КӘЕФСЕЗ** *с.* **1.** Кәефе төшенке, начар булган; күңелсез. *Синең өчен һич көтелмәгән рәвештә кәефсез чырай һәм тупас тавыш белән сиңа сорау куя: «Нишләп бик озак йөрдең?»* Ш.Камал. *Ашлык базары минем өчен һәрвакытта иң кызыксыз, иң кәефсез җир: анда һичбер кыз күрмисең, һичбер ачык йөзле, үзеңә ышаныч белән карый торган кеше күрмисең.* Ф.Әмирхан. *Хәмдия карчык, картының кәефсез чагын шәйләбрәк, гел аның сүзен җөпләп утырды, «карт, карт» дип, һаман аның тирәсендә бөтерелде, күмәчен кисте, чәен ясады, шикәрен салды.* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* Күңелсез итеп, күңелсез рәвештә. *Фәхри карчык нәрсәгәдер кәефсез күренә, --- сөйләшмичәрәк йөри.* Ш.Камал. *Күңелдәге әллә нинди бер ургып тору, авыздагы тәмсезлек, баштагы миңгерәүлек аңар кичә үзенең исерек булганлыгын хәтерләтте: кызыксыз һәм кәефсез булып китте, кем алдындадыр уңайсызланган шикелле булды.* Ф.Әмирхан. *Яныма килгәч, Иннокентий кәефсез генә мыгырданып куйды ---.* З.Мәхмүди

**КӘЕФСЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кәефне бозу, күңелне төшерү, кәефне җибәрү. *Башка кешеләрнең аны болай сөюләре, мактаулары бик үк көнләштермәсә дә, Мәрфуга апа сөюе, аны миннән артык сөюе мине борчый һәм бик кәефсезләндерә иде.* Ф.Әмирхан

**КӘЕФСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Кәеф бозылу, кәеф кырылу, күңел төшү. *Мин Мәрфуга апаның бу сүзләреннән соң дәрәҗәдә кәефсезләндем.* Ф.Әмирхан

2) *күч. сөйл.* Чирләү, авыру

**Кәефсезләнеп китү** Кинәт яки соңгы арада кәефсезләнү. *Тик монда да юлы уңмады Абдулланың: ахун кәефсезләнеп киткән икән, урында ята, диделәр.* Җ.Рәхимов

**КӘЕФСЕЗЛӘ́Ү** *ф. к.* **кәефсезләндерү**

**Кәефсезләп тору** Гел яки әледән-әле кәефсезләнү

**КӘЕФСЕЗЛЕК** *и.* Кәеф юклык, кәеф начар булу; күңелсезлек. *Чаршауның икенче ягында әрле-бирле йөреп торучы әнкәсенең күләгәсе үк гәүдәләнгән кәефсезлек булып аның күзенә, бигрәк тә күңеленә чагылып тора иде.* Ш.Камал

**КӘЕФ-ХӘТЕР** *җый. и. к.* **кәеф** (*1 мәгъ.*). *Кәеф-хәтерләребезнең ничек булуын сорашты.* Ф.Әмирхан

**КӘҖӘ** *и.* **1.** 1) Куышмөгезлеләр семьялыгыннан ит, сөт, мамык бирә торган, гәүдәгә артык зур булмаган, куштояклы, мөгезле күшәүче йорт хайваны. *Бу бусаганы үз аягы белән атлап кереп, кәҗә кебек чигенеп киткәннәр булгалады, дустым.* Т.Галиуллин. *Хәзерге заман кешесе кәҗә түгел, аны бүре белән генә куркытып булмый! Хәзер әрләннәр заманы.* М.Маликова. *Югары Сөн кода чанадан төште һәм толыпка үрелде. Аның астында, керт-*

*керт солы саламы чәйнәп, нәни генә бер җан иясе – кәҗә бәтие утыра иде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Куышмөгезлеләр семьялыгының куштояклылар ассемьялыгына караган кайбер хайваннарның кыргый (гадәттә теше) вәкиле. *Кыр кәҗәсе. Тау кәҗәсе*

3) *сөйл.* Карта уены, домино уенының бер төре

4) *сөйл.* Шундый уенда оттырган кеше. *Ул тагын «кәҗә» калды*

5) *күч. тирг.* Тискәре, кире, начар яки шулай дип саналган кеше турында әйтелә

6) *спорт* Гимнастик күнегүләр башкару өчен күн белән тышланган кыска борыс. *Кичен спорт мәйданчыгына барып, «кәҗә»не кочаклап, туйганчы җылады, аңа йөргән ачты Сәгыйрь.* Т.Галиуллин

7) Борыслар, киртәләр белән аркылы-торкылы ныгытылган һәм басып эшләү өчен өстенә такталар җәелгән җайланма, терәк

8) Пычкы белән утын кисү өчен, дүрт яки алты аяклы борыс, җайланма

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кәҗә тиресеннән ясалган; кәҗә тиресеннән тегелгән. *Кәҗә тун*

2) Берәр нәрсәсе белән кәҗәне хәтерләткән, кәҗәгә охшаган. *Кәҗә сакал*

◊ **Кәҗә аягы** *к.* **кәҗә сыйрагы**. **Кәҗә бәясе** 1) Бик очсыз, бик арзан бәя; 2) Бик вак, әһәмиятсез нәрсә. **Кәҗә билеты** *иск.* Башка эшкә яки уку йортына керү хокукын бетерә торган, дәүләт хезмәтеннән яки уку йортыннан чыгарылу турында таныклык. **Кәҗә билеты бирү** *кимс.* Эштән, хезмәттән ирексезләп куып чыгару. **Кәҗә калдыру** Карта, домино кебек уеннарның «кәҗә» дип аталган төрендә яки гомумән берәр нинди ярышта оту, җиңү. **Кәҗә калу** Җиңелү. *Аннары, утырып хәл дә алмыйча* (*мин булсам, ичмасам, кинәнеп тәгәрәп алыр идем*)*, йөгереп килеп, «кәҗә» калганнарның кишәрлеген тигезләргә керештеләр.* Д.Галимов. **Кәҗә мае чыгу** Берәр эшне башкару өчен үтә зур көч салу, тир агызу. **Кәҗә мае чыгару** 1) Нинди дә булса эшне башкарып чыгу өчен бик күп көч куярга мәҗбүр итү; тир түктерү. *Без барган көнне алар «кәҗә маен чыгарган» печәнне кайтарып, печәнлеккә тутырып бетереп баралар иде.* Өмет; 2) Чәчне, бармаклар белән бик нык басып, кирегә, каршыга сыпыру. **Кәҗә маңгай** *тирг.* Акылы, фикер йөртү сәләте югары булмаган яки бик уйлап бетермичә, акылсызрак эш иткән кеше. **Кәҗәне кәбестә сакларга кую** Кемне, нәрсәне дә булса ул бик нык зарар китерә алган урынга кертү, керергә мөмкинлек бирү, шундый җиргә эшкә билгеләү һ.б.ш. **Кәҗәсе түгел, мәҗәсе** *к.* **кәҗәсе түгел, мәзәге**. **Кәҗәсе түгел, мәзәге** «Нәтиҗәсе түгел, ә гомумән шул эш үзе» мәгънәсендә. *Хәер, кәҗәсе түгел, мәзәге дигәндәй, киек-җәнлек аулауга әллә ни исе китми мулланың, урман-әрәмәләр, болынкырлар урап, сәйран кылып кайтса, шуңа күңеле була сыман.* Җ.Рәхимов. **Кәҗә сыйрагы** Кәгазьне озын бүрәнкә сыман итеп төреп, аны урталай бөгеп, махорка-фәлән тутырып ясаган тәмәке төреме. **Кәҗә тәкәсе** Хатын-кызлар артыннан йөрергә, алар белән шаярырга ярата торган ир кеше турында. **Кәҗә тоягы** Кулны йодрыклап, урта бармак белән имән бармак арасыннан баш бармакны чыгару – кемне дә булса үртәү, берәр нәрсәне бирмәү, баш тарту билгесе; күкиш. *Ләкин намусны алырга дип кулын сузгач, ахырием иң соңгы мизгелдә, үзе дә сизмәстән, аңа кәҗә тоягы күрсәтте.* З.Мәхмүди

**КӘҖӘ ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Эшләпәсе эре җыерчыклар белән капланган, түгәрәк яисә овал формада булган кыска аяклы гөмбә; *русчасы*: **сморчок**

**КӘҖӘ́ ИМЧӘГЕ** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан болында үсә торган һәм өске сабагы ябышкак булган үлән үсемлек; *русчасы*: **смолёвка белая**

**КӘҖӘЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл.* Киреләндерү; көйсезләндерү. *Әхмәтнең кытыршы сораулары да Хәмәй картны кәҗәләндерделәр.* Х.Кәрим

**КӘҖӘЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Киреләнү; көйсезләнү. *Ашыгам, ә бозау кәҗәләнә, сыртын кытыклаганны көтәдер: койрыгын селкетеп куйды да артын атып уйнаклап китте.* Ш.Галиев. *Чаналар батты, атлар кәҗәләнде.* В.Имамов

**Кәҗәләнә бару** Торган саен кәҗәләнү. *Бала үсенгән саен кәҗәләнә бара*

**Кәҗәләнә башлау** Кәҗәләнергә тотыну

**Кәҗәләнеп алу** Берникадәр вакыт кына кәҗәләнү, бераз кәҗәләнү. *Сабый кәҗәләнеп алды*

**Кәҗәләнеп йөрү** Кәҗәләнү халәтендә булу. *Авыру бала көне буе кәҗәләнеп йөрде*

**Кәҗәләнеп китү** Кинәт кәҗәләнә башлау. *Бала матур гына уйнап йөргән җиреннән кинәт кәҗәләнеп китте, әллә корт чакты*

**Кәҗәләнеп тору** Һәрвакыт яисә әледән-әле кәҗәләнү. *Бер сәбәпсез кәҗәләнеп тору – тәрбиясезлек билгесе ул*

**КӘҖӘЛӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **кәҗәләнү**

**КӘҖӘЛЕ** *с. сөйл.* Көйсез, кире, җайсыз характерлы

**КӘҖӘМӨГЕЗ** *и.* 1) Куышмөгезлеләр семьялыгына караган озын ак йонлы, кечкенә генә өркәчле кыргый тау кәҗәсе

2) *астр.* Көньяк ярымшардагы йолдызлык, йолдызнамәдәге унике йолдызлыкның беренчесе (22 декабрьдән 19 январьга кадәр вакытны үз эченә ала); *русчасы:* **козерог**

**КӘҖӘ́ МӨГЕЗЕ** *и. бот.* 1) Кузаклылар семьялыгыннан яфраклары мәңге яшел җимеш агачы; *русчасы*: **рожковое дерево**

2) Шул агачның төче җимеше

**КӘҖӘ́ САКАЛЫ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан сөт сыман сыекча бүлеп чыгара торган үлән үсемлек; *русчасы*: **козлобородник**

**КӘҖӘСАКАЛ** *и.* 1) *бот. к.* **кәҗә сакалы**

2) *этн.* Халык ышануларында: урак урган вакытта, киләчәктә дә уңыш мул булсын дип, бергә кушып төенләп калдырылган бер учма үсеп утыра торган иген

**КӘҖӘ́ СУКМАГЫ** *и.* Урманда, тау битләрендә һ.б.ш. урыннарда вак терлек йөри торган тар гына сукмак. *Кәҗә сукмагына һәм куак төпләренә шыбырдашып эре чикләвекләр коелды.* Р.Низамиев

**КӘҖӘ́ ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан, очы тар-

макланып киткән туры сабаклы, вак ак чәчәкле, җимеше элпәле кузак булган, терлек ашамый торган үләнчел үсемлек; кыркырый, очкылык үләне; *русчасы:* **икотник**

**КӘҖҮЛ** *с. рус иск.* Кәҗә күненнән тегелгән, эшләнгән. *Әбисе, малайның күңеле төшмәсен дип, бер төн эчендә аңа кәҗүл читек тегеп бирергә була.* Әдәбият. *[Әхмәдулла:] Әби, сыерны куып алып кайтма, каймагы чайпала, ди… Минем эти кайткан, миңа кәҗүл читек алып кайткан… Өр-яңа кәҗүл читек.* Г.Исхакый

**КӘҖҮНКӘ** *и. рус иск. сөйл.* Инкыйлапка кадәр: дәүләт карамагындагы аракы сату кибете

**КӘҖҮННИ** *с. рус иск. сөйл.* 1) Дәүләткә караган, дәүләтнеке булган. *Янәсе, дачалары да кәҗүнни акчага салынган.* Ф.Баттал

2) *күч.* Артык рәсми булган, формаль

**КӘЗ** I *и. диал. к.* **кәс**. *Юл буендагы канауларга кәз төшәп чөйләгәннәр.* М.Хәсәнов

**КӘЗ** II *и. фар. иск.* Аршын. *[Бай хатынының] калфак төбе ике кәз.* Н.Исәнбәт

**КӘЗӘКИ** *и. рус < фар. иск.* Җиңле һәм кечерәк кенә утыртма якалы, тегелеше белән озын камзулны хәтерләтә торган өс киеме; казаки. *Бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәкыштаннарым, читек-кәвешләрем, кәзәкиләрем тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән угылының күк киндер күлмәге илә бишмәтен миңа бирмәкче булды.* Г.Тукай. *Каракүл бүрекне кыңгыр салган, өстендә трико кәзәки, кәзәки кесәсеннән сәгать чылбыры салынып тора.* Ф.Хөсни.

**КӘЗӘНКӘ** *и. рус диал.* Чоланда, мич артында төрле азык-төлек саклау өчен ясалган кечкенә, караңгы бүлмә

**КӘЗБЕРӘ** *и. бот. гр.* Кәзберәчеләр семьялыгыннан җәйрәп үсә торган чәнечкеле үсемлек һәм шуның кулинариядә кулланылган чәчәк бөреләре; *русчасы*: **каперсы**

**КӘЗБЕРЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Җылы яклардагы агач, куак һәм үлән үсемлекләрнең 300 дән артык төрен берләштерә торган семьялык

**КӘЗЗАБ** *и. гар. иск.* Ялганчы

**КӘ́З-КӘЗ** *ирт.* Гәүдәне туры тотып, аякка нык басып, вак-вак адымнар белән көязләнеп атлау рәвешен белдерә. *Тегеләр алдында кәз-кәз басып, Фәтхием җаныем, дип кенә йөргән була, урамга чыксаң, хәзер мине подручка ала.* М.Гали

**КӘЗЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **кәсләү**. *Көньяк һәм көнбатыш тау битләрендә күпьеллык үләннәрдән буфер полосалары ясалырга, кәзләү, агач утырту чаралары үткәрелергә тиеш.* А.Фаткуллин

**КӘЙ** *с.* 1) Начар, әшәке; яман. *[Фатыйма:] Кәй кеше булып чыктың син болай булгач.* А.Расих

2) Начар, зәгыйфь. *Аннары, янчык саен йөзәр генә бодай алып, тишелдереп карыйсы. Менә шул әйтеп бирә инде ул: йөздән ничәсе тишелә? Уҗымы көр буласымы, уртачамы, әллә кәй үкме?* Г.Бәширов

**КӘЙЛӘ** *и.* Озын сапка утыртылган, бер ягы очлы итеп эшләнгән чүкеч сыман тимер корал (күпчелек очракта тау токымнарын һ.б.ш.ны вату өчен хезмәт итә). *Алар кәйлә, көрәкләрен сәке астына, мич башларына ыргыттылар.* М.Гафури. *Ни пычагыма инде тукран төсле һәр көн шул кәйләңне такылдатасың.* Ш.Камал. *Көрәк белән кәйләсен алып, малай әле генә аю чыгып качкан чокырга төште.* Г.Хисамов

**КӘЙЛӘНҮ** *ф.* Начарга әйләнү, әшәкеләнү, кирегә китү

**Кәйләнә башлау** Кәйләнергә тотыну. *Минем эш бераз кәйләнә башлады, ләкин чиккә үк барып терәлмәгән иде әле.* Г.Ризван

**КӘЙТӘН** *и. гр.* **1.** Киемнең кыркырына яки җөе буйлап тоту өчен кулланыла торган, бизәкле итеп үрелгән яки тукылган махсус җеп яки тасма. *Ниһаять, хөкем йортының авыр ишеге шапылдап ачылды да, бусагада агара башлаган тузгак чәчле, чигә сакаллы, өстенә җиң очлары зәңгәр кәйтән белән каелган, керле, иске мундир кигән бер кеше күренде.* М.Галәү

**2.** *с. мәгъ.* Шундый җептән яки тасмадан эшләнгән. *Кәйтән элмәк*

**КӘЙТӘНЛЕ** *с.* Кәйтәне булган, кәйтән белән эшләнгән

**КӘЙФИЯ** *и. гар. кит. иск.* Кәефләнә, күңел ача торган урын (кабак, мәйханә һ.б.ш.). *Ач авыл, мохтаҗ авыл! Җимерек өй каршында ич Оҗмах кеби кәйфиясе.* Г.Тукай

**КӘКЕЛ** *и.* 1) Ир-егетләрнең яшьтән үк баш түбәсендә кырылмыйча калдырыла торган чәч тотамы; какул

2) Атның маңгай чәче

3) Кошларда: бүрек

4) Баш киеменә, ат дирбиясенә беркетелә торган чук

**КӘКЕЛДӘ́Ү** *ф. диал.* Бар нәрсә белән дә килешеп, барысына да риза булып баш селкеп тору

**КӘКЕРЛЕ** *с. диал.* Бөгелгән, кәкрәйтелгән. *Кәкерле торбалар*

**КӘКЕРЧЕК** *и.* Мичәү атын сабанга җигү өчен кулланыла торган күчәргә беркетелгән нечкәрәк кәкре агач

**КӘКЕ́Р-ЧӨКЕР** *җый. и. диал.* Чәй ашлары, чәй янына бирелә, чәй табынына куела торган азык-төлек. *[Суфия] ашны бер-ике кашык кына капты, чәй янындагы кәкер-чөкерләрдән бары ярты печенье генә сындырып ашады.* А.Расих

**КӘККҮК** *и. к.* **күке**. *Кычкырма, кәккүк, ай, каршымда, Кычкырсана агач башында, Моңлы да гына бала түгел идем, Моңнар төште ич минем, Моңнар төште ич башыма.* А.Әхмәт. *Шулай да безнең мәхәббәтебезне берәү күрде: ул кәккүк иде.* Ә.Еники. *Моңлы кәккүктән сорадым: – Алда гомерем озынмы? Унга чак-чак тутырды ул Киләчәк бер язымны.* Г.Гыйльманов

**КӘК-КҮК** *ирт.* Күке кычкырган тавышны белдерә. *Аларның сүзен сузып-сузып кычкыручы кәккүк тавышы булде: «Кәк-күк», «Кәк-күк» ---.* Г.Гыйльманов

**КӘККҮ́К ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан сабагында селәгәйгә охшаш күбек була торган күпьеллык үсемлек; сабын үләне, күке сабыны; *русчасы*: **кукушкин цвет**

**КӘКРӘЙТҮ** *ф.* 1) Билгеле бер әйберне кәкре хәлгә китерү, бөгү. *Туптүгәрәк алашалар, пошкырынып вә һәр икесе башларын купшы кәкрәйтеп*

*сикерешәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Чәпелдекне төшермәс өчен, аягын әллә ничекләр кәкрәйтеп шуыштыра-шуыштыра, ул Гарифҗан ята торган палатага керде.* Ф.Садриев

2) *сөйл.* Авызга табигый булмаган рәвеш бирү, кыйшайту, кыегайту

3) *күч. гади.* Үтерү, һәлак итү

**Кәкрәйтә бару** Торган саен ныграк кәкрәйтү яки һәрберсен рәттән кәкрәйтү

**Кәкрәйтә төшү** Тагын бераз кәкрәйтү

**Кәкрәйтеп бетерү** Тәмам кәкрәйтү, бик нык кәкрәйтү

**Кәкрәйтеп җибәрү** Аз гына кәкрәйтү

**Кәкрәйтеп кую** Кәкре халәткә китерү, кәкрәйтү

**Кәкрәйтеп тору** Әледән-әле кәкрәйтү яисә гел кәкрәйтү

**Кәкрәйтеп чыгу** Барысын да кәкрәйтү; кәкрәйтүне тәмамлау, кәкрәйтеп бетерү

**КӘКРӘ́ ҮЛӘН** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан туры сабаклы, вак башакчыклы, иген арасында үсә торган северкәч чәчәкле чүп үләне; сүсән; *русчасы*: **метлица**

**КӘКРӘЮ** *ф.* 1) Кыйшаю, бөкрәю, бөгелү. *Газинур үрелгән яки кәкрәйгән үзагачлар турында, ярык яки черек үзагачлар турында, үзәкләре зәңгәрләнә башлаган үзагачлар турында сөйләп китте.* Г.Әпсәләмов. *[Микәй] күз ирмәс тизлек белән арткы аякларына басты да сорау билгесе сыман кәкрәеп алга ыргылды, теге ристанның муен төбенә китереп ямады.* Р.Мөхәммәдиев. *Рахит бик азып киткәндә, баланың хәтта тышкы күренеше дә үзгәрә: башының формасы бозыла, күкрәк челтәренең түбәнге өлеше киңәя төшә, аяклары кәкрәя.* Өегез ямьле булсын

2) Турылыгын югалту, бөкрәю (кеше гәүдәсе тур.). *Гомере гел хурлыкта үткән, кәкрәеп каткан бабай: «Я Ходай, үтер мине, тындыр мине!» – дип чир көтә ---.* Ш.Бабич

3) *сөйл.* Авышу, янтаю. *[Немец танкы] бөтенләй кәкрәеп, җиргә сеңеп бара: тиздән сазлык аны бөтенләй йотачак.* Г.Әпсәләмов

4) *күч. гади сөйл.* Үлү, вафат булу, һәлак булу. *[Әхмәди:] Сугышта кәкрәеп калмасам, зур командир булмыйча, авылга аяк та басмас идем.* Г.Бәширов

**Кәкрәеп бетү** Тәмам, тулысынча кәкрәю. *Ә үзе әлеге кәкрәеп беткән киң итекләрне бик авыр нәрсә китереп куйган шикелле куйды.* А.Алиш. *Карт, кәкрәеп беткән бармаклары белән кемнеңдер бугазыннан кысарга теләгән шикелле, кулын күтәрде, ләкин ярты-лаш күтәрелгән кулы, хәлсезләнеп, түбән төште.* Г.Әпсәләмов

**Кәкрәеп калу** Нәрсәнеңдер тәэсиреннән соң кәкре хәлгә килеп кату

**Кәкрәеп килү** Әкренләп кенә кәкрәя башлау. *Капка аша гына торучы сулга кәкрәеп килгән бер карчык, гайбәтченең дә гайбәтчесе булу өстенә, былтыр оныгын классында калдырган өчен, Гөлсем апага ачу тотып йөри иде ---.* Г.Гобәй

**Кәкрәеп китү** Кисәк кенә кәкрәю

**Кәкрәеп тору** Бераз кәкре хәлдә булу; әледән-әле яисә туктаусыз кәкрәю. *Бара торгач әллә нинди кәкрәеп торган агач тамырына аягы эләгеп, сөртенеп китә.* Ш.Камал

**Кәкрәеп җиту** Тәмам яки тиешенчә кәкрәю

**Кәкрәя бару** Торган саен кәкрәю

**Кәкрәя башлау** Кәкрәергә тотыну

**Кәкрәя төшү** Тагын бераз кәкрәю

**КӘКРӘЮ-БӨКРӘЮ** *ф.* Төрле юнәлештә кәкре хәлгә килү, бөгелү. *Агачларның сирәгрәк җирләреннән кәкрәеп-бөкрәеп төшкән кызгылт төстәге кояш нуры күренә.* М.Гали

**КӘКРЕ** с. **1.** 1) Туры түгел, төз булмаган. *Буш кулы белән кәкре кылычын кынынннан алды да, уңга-сулга болгыйболгый, граната төшеп кар катламы --- күтәрелгән җиргә ташланды.* Г.Гобәй. *Әлифне таяк дип белмәгән, гомерендә дә кәкре сабаннан башка әйбер тотмаган караңгы татар авылында нинди социализм булырга мөмкин!* Г.Ибраһимов. *Без кәкре борынлы суканы Тракторларга алмаштырырбыз.* Һ.Такташ

2) Турыга үсмәгән, туры булып үсмәгән. *Озын йонлы, кәкре мөгезле бер кәҗә иярткән дә әллә нинди соргылт, чирәмсез тау битендә йөрде дә йөрде.* Г.Гобәй. *Хәзер ул кәкре агач янында башын кашып, уйланып басып тора иде.* Г.Әпсәләмов

3) Бормалы; бер бу якка, бер теге якка боргаланган (юл һ.б.ш.). *Ташлы киң кырларда, Кәкре сукмакларда, тар юлларда Йөгерешәләр кара шәүләләр, Аунап ята канлы гәүдәләр.* Ә.Исхак. *Кәкре юллар ясап, Сызып-сызып алды тиз генә ---.* Һ.Такташ

4) *сөйл.* Бөкре, бөкресе чыккан; кәкрәйгән. *Аны [гайбәтне] чыгаручының әлеге кәкре карчык икәнен дә белде ул.* Г.Гобәй

5) *мат.* Туры булмаган, бөгелгән (сызык тур.)

6) *күч.* Гадел түгел, турылыклы булмаган; дөрес түгел, ялгыш. *Эше кәкре, сүзе төз ---.* Р.Ишморат

**2.** *и. мәгъ.* 1) *мат.* Туры булмаган сызык. *Бу өч векторны үзара ортогональ итеп алып була. Әгәр өслектәге кәкрене карасак, бу векторлар кәкрене билгеләүче параметрлар булып торалар.* Математика

2) Гадел булмаган эш; кыңгыр эш. *Укымак – дөреснең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр.* Г.Тукай

**3.** *рәв. мәгъ.* Чалыш-чолыш. *[Кодача:] «Ходай орыр әле барыгызны да!» – дип кычкырды, һәм үзе кәкре-кәкре басып икенче бүлмәгә чыгып китте.* Ф.Әмирхан

◊ **Кәкре атып**, **туры тидерү** *к.* **кыек атып**, **туры тидерү**. *Әнисенең кәкре атып, туры тидерүеннән югалып калган Света: «Әйе шул, каян беләсең?» – дип кенә сорый алды.* Т.Галиуллин. **Кәкре кабыргалы** Тиз үпкәләүчән. **Кәкре каенга терәтү** Алдау, алдап, хәйләләп, кемнедер нәрсәдән дә булса мәхрүм итү, нәрсәсездер калдыру. *Әй туташ, туташ, мине дә бит синең кебек кәкре каенга терәттеләр.* Т.Гыйззәт. *Кара, сине кәкре каенга терәтеп калдырмасыннар!* Ф.Бурнаш. **Кәкре каенга терәү** *к.* **кәкре каенга терәтү**. *Хәтерегездәдер, туксанынчы елларда «МММ», «Властелина», «Русский Дом Селенга», АО «Русская недвижи-*

*мость» кебек финанс пирамидалары миллионлаган кешене кәкре каенга терәде.* Өмет. **Кәкре килү** *к.* **кәкрегә бөкре (килү)**. **Кәкре китерү** Кирәкмәгән эш эшләү; берәр кыенлык, киртә, комачау барлыкка китерү. **Кәкре койрык** Эт. *Башны күргәч, кузгалып гайрәтләре, Өрде барча итчеләрнең этләре. Йөгерәләр аллы-артлы бер көтү Кәкре койрыклар! – кая Башны җитү!* Г.Тукай. **Кәкре койрыклы** *к.* **кәкре койрык**. **Кәкре кул(лы)** Кеше әйберенә кул суза, урлый, урлаша торган, урлашучан (кеше). *Андый кәкре куллы хәерче кызын асрар хәлем юк.* А.Шамов. **Кәкре юл** *к.* **кыек юл. Кәкрегә бөкре килү** Нинди дә булса бер эш барып чыкмау; юлында берәр кыенлык, киртә, комачау барлыкка килү. *Кәкрегә бөкре туры килә дип, бик белеп әйтәләр. Әтием ул мәлдә – студент. Әнинең дә югары белемле буласы килгән. Икесенең дә яшь бала биләвенә ураласы килмәгән шикелле...* Кызыл таң. **Кәкрене кыекка саплау** Ялгыш аңлау яки сөйләү; аңлы рәвештә ялган сөйләү

**КӘКРЕ-БӨКРЕ** *с.* 1) Төрле юнәлештә кәкрәеп беткән. *Кәкре-бөкре хәрефләр тезелгән юллар буенча абыстайның бармаклары шактый тиз йөриләр һәм, нәрсә икәнен аермасалар да, минем күзләр дә аның бармакларыннан калышмыйлар иде.* М.Гали. *Сизеп торам: хәзер аның башында тарих түгел, ә математикадан еллыкка чыга торган кәкре-бөкре «өчле» кайгысы.* Д.Галимов

2) Туры булмаган; әле теге якка, әле бу якка борылган. *Кәкре-бөкре ямьсез урамнары, өйләрендә тычкан утлары ---.* М.Гафури

**КӘКРЕЛӘНҮ** *ф. сөйл. к.* **кәкрәю**. *Брюкасы да күптәннән үтүкләнмәгән, ахрысы: тез башлары ике якка кәкреләнеп кыйшаеп торалар.* Ш.Камал

**КӘКРЕЛЕК** *и.* 1) Кәкрәйгән булу, кәкре булу хәле

2) *мат.* Туры сызыктан читкә авышу дәрәҗәсен билгели торган зурлык. *n – матди ноктадан кәкрелек үзәгенә юнәлгән берәмлек вектор, r – кәкрелек радиусы.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

3) *күч.* Кыңгыр эшкә һәвәслек, гадел булмау. *Менә без хәзер шул кешеләр ясаган тәртипләрнең турылыгы, кәкрелеге хакында сүз сөйләмәкче булабыз.* Т.Гыйззәт. --- *егетнең кулы кәкрелегенә юл бирмәскә тырышты.* Г.Ибраһимов

**КӘКСЕЛДӘҮ** *ф. диал.* Сәлперәю; хәлсезләнү

**КӘКСЕТҮ** *ф. з.-сыз* Бик каты йончыту, йончу

**КӘКСҮ** *ф. диал. к.* **кәкселдәү**. *Әй, кәксегән нәрсә, әллә кая барырлыгың калмаган инде.* С.Кудаш

**КӘКШӘЮ** *ф. сөйл. к.* **кәкшү**. *Кәкшәйгән сары йөзле бер абзый, радиола янына берәүне дә китермичә, команда булганны көтеп тора.* Г.Ахунов

**Кәкшәеп бетү** Тәмам, бик нык кәкшәю. *[Абдулла] Атасы өйдә юк вакытны чамалап, келәттән кәкшәеп беткән җәя белән күгәргән сөңге, иске ияр алып чыкты, аларны тәртипкә китерде.* Җ.Рәхимов

**КӘКШЕТҮ** *ф. сөйл.* Каклау, кипterү. *[Миңнулла:] Былач [власть] кешеләрен ике багана арасына кәкшетергә эләрләр.* И.Гази

**Кәкшетә бару** Акрынлап кәкшетү

**Кәкшетә төшү** Тагын бераз кәкшетү

**Кәкшетеп алу** Кыска гына вакыт аралыгында кәкшетү

**Кәкшетеп җиткерү** Бик нык кәкшетү, тәмам кәкшетү

**КӘКШҮ** *ф. сөйл.* Каклану, кибү

**КӘЛАМ** *и. гар. к.* **кәлям**. *Китер дәвәт-каләмең, Укы китап кәламен.* Дастан. --- *Юк иде һичбер кәлам. Бергә йөргән дусларым бирмиләр инде сәлам.* Ш.Мөхәммәдев

**КӘЛӘВӘ** *и. гар.* Майда пешерелгән камырга кайнатылган бал яки шикәр комы сеңдереп әзерләнә торган мамыксыман, уалучан, йомшак татлы ризык. *Әзер форма бирелгән кәләвәне капкачлы савытка салып салкынга куярга.* Татар халык ашлары

**КӘЛӘВӘЧЕ** *и.* Кәләвә пешерү остасы

**КӘЛӘПҮШ** *и. фар.* Баш түбәсен каплый торган, хәтфәдән тегелгән баш киеме; түбәтәйнең бер төре (гадәттә бүрек эченнән кияләр). *Әйтмәсә дә, үзем беләм мин: кызлар сөйсен өчен, иң элек бер пар ялтыравыклы итек, бер тужурка, сатин күлмәк, хәтфә кәләпүш кирәк.* Ф.Хөсни. *Шулар арасында шәһәр башы... Солтан абзый кәләпүшен култык астына кыстырып кына хезмәт итте, дип әйтәләр.* Ш.Мөхәммәдев. *[Азамат карт малайлары] Чәч йөртәләр, дүртесе дә мыеклы, кара җилән, яшел сатин чалбар, читек, кара кәләпүш киеп җибәрсәләр, әллә ниткән укымышлыларга охшап калалар.* Ә.Гаффар

**КӘЛӘПҮШЧЕ** *и.* Кәләпүш тегүче һөнәрче. *Безнең күрше читекче Вәлидә, башмакчы Кәбирдә, кәләпүшче Миңсылуда, тагы кемнәрдәдер булган идегез.* М.Галәү

**КӘЛӘШ** *и.* Кияүгә чыгарга килешенгән кыз, ярәшелгән кыз; яңа гына кияүгә чыккан хатын-кыз. *Хизбулла исә, никах укыткан кәләшеннән колак кагу хурлыгын күтәрә алмыйчамы, Идрисне күргән саен, шкаф хәтле кибетеннән башын чыгарып, берәр усал сүз әйтеп кала иде.* К.Нәҗми. *[Егетләр] Томана, надан булып үсмәсеннәр, тормыш юлына кергәнче, кәләшләренең нindirәк буласын белеп яшәсеннәр.* Ф.Баттал. *Иренең халәтен аңлаган кәләше инициативаны үз кулына алды, назлады, иркәләде.* Т.Галиуллин

**КӘЛӘШ ӘЙТТЕРҮ** *ф. этн.* Кыз ярәшү

**КӘЛӘШЛЕК** *и.* Кәләш булу хәле. *[Гариф] Менә сине үземә кәләшлеккә яучылаган идем ---.* Ш.Камал

**КӘЛҖЕМӘ** *и.* 1) Бәрәңгедән бик калын коймак кебек итеп пешерелгән ризык. *Кош тоткандай кайтып керде Рүзәл өйгә. Ни әйтсәң дә, тамак та тук, ярты чиләк чамасы черек бәрәңге дә җыелды ---. Лотфикамал түти бәрәңгене яхшылап чистартты да кәлҗемә пешерде.* Ф.Зыятдинов

2) *диал.* Бөккән (эченә бәрәңге, кабак һ.б.ш. салып пешерелә). *Яңа гына мичтән җылынып чыккан вак бәлешләр, юачалар, кәлҗемәләр, салкыннан кергән кортлы май белән кәрәзле бал да килеп утырдылар.* М.Гали

3) *күч. шелтә* Начар башкарылган эш; начар эшләнгән әйбер (күбрәк тәрҗемә тур.)

**КӘЛИГӘ** *и. рус диал.* Гәрәнкә

**КӘЛИГӘ ШАЛКАН** *и. к.* **кәлигә**

**КӘЛИМӘ** *и. гар.* Сүз. *Шуңар күрә: – Әйе, мин татар, – дип, татар кәлимәсендә тавышымны күтәрә төшебрәк җавап бирдем.* Ф.Әмирхан. *Башлам кәлимә.* Т.Галиуллин. *Күпмедер вакыт бер кәлимә сүз дә сөйләшмичә тәмәке көйрәттек.* З.Мәхмүди

**КӘЛИСӘ** *и. гар. иск.* Христиан гыйбадәтханәсе, чиркәү. *Тау буена тезелеп утырган Ослан [авылының] матур-матур йортлары, кәлисәсе Иделгә --- матурлык бирмәктә иде.* Ш.Мөхәммәдев

**КӘЛПӘК** *и.* 1) Очлаебрак торган баш киеме, калпак

2) Самавыр кайнап чыкканнан соң, төтен чыкмасын өчен, күмерлегенең өстен томалап куя торган капкач; самавыр түбәтәе. *[Рәйханның] кулында кайнар үтүк --- [аны] китереп, өстәлдә яткан самавыр кәлпәге өстенә куя.* Н.Исәнбәт. *Килим микән, юк микән дигән төсле курка-курка гына безнең янга якынлашкан күк күлмәкле, ыштансыз малай, атасы ыргыткан самавыр кәлпәген эләктереп кире борылды һәм атылган ук җитезлеге белән күздән югалды.* М.Әмир

**КӘЛТӘ** *и. зоол.* **1.** Тәне вак мөгез тәңкәләр белән капланган, сузынкы гәүдәле, озын койрыклы, кечерәк кенә сөйрәлүче хайван. *Кәлтә, әгәр аны дошманы койрыгыннан эләктерсә, койрыгын ерткычка калдырып кача. Аннан соң кәлтәнең койрыгы яңадан үсә.* Биология

**2.** *с. мәгъ. диал.* Кыска, озынлыгы тиеш яки кирәк булганнан кимрәк. *Киңәш белән теккән тун кәлтә булмый.* Мәкаль

**КӘЛТӘ ЕЛАН(Ы)** *и.* 1) *к.* **кәлтә** (*1 мәгъ.*). *Акрын гына чирәм асларыннан кәлтә елан китә шуышып.* Ш.Мөхәммәдев. *Алан уртасында гомердә уйламаган уйларыма чумып утырганда, аяк астындагы җәлпәк таш астыннан бер кәлтә еланы атылып чыкты да, үчләшкән кебек, койрыкларын болгыйболгый, үлән өстендә бормалы эз калдырып йөгереп китте.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Мәкерле, хәйләкәр, усал кеше

**КӘЛТӘ́Ү** *и. диал.* Оешып каткан балчык, кантар

**КӘЛТӘФИ** *с. фар. сөйл.* Фырт, тәти. *[Арслан:] Кәлтәфи егет булгансың икән син хәзер.* Ш.Маннур

**КӘЛЧӘК** *и. зоол.* Карпсыманнар семьялыгыннан Себер елгаларында яши торган балык; *русчасы*: **чехонь**

**КӘЛШӘ** *и.* Чабылганнан соң яңадан үсеп чыккан иген яки үлән; курпы

**КӘЛҮ** *ф. иск.* «Килү» фигыленең борынгы формасы. – *Атамдин дәстүр булды, хәбәр кәлде: сине җефетлеккә алмага! – тиде.* Дастан. *И гүзәл, кәл каршыма, кәл.* Г.Тукай

**КӘЛЯМ** *и. гар.* 1) *иск.* Сүз, сөйләм. *Алдым каләм, яздым кәлям, бездин бәет булсын дип, Моны укыган мөселманнар безгә дога кылсын дип.* Бәет

2) Урта гасырлар мөселман әдәбиятында дини-фәлсәфи темага сүз көрәштерү, фикер алышу

3) *дини* Ислам диненең иман-игътикад белән бәйле сорауларына акылга нигезләнгән дәлилләр кулланып исбатлар китерү максаты белән барлыкка килгән дини-фәлсәфи белем тармагы. *Кәлям, хакимлек итүче дини тәгълиматны теоретик нигезләүне һәм аклауны күздә тотып, формаль-логик фикерләүләргә корылган.* Ислам дине турында белешмә-сүзлек

**КӘЛЯМЕ ШӘРИФ** *и. гар дини. к.* **Кәлямулла**. *Ул [Абдулла] инде бишенче кышында ук кирәк гарәп-фарсыдан, яки мөтәрҗимдә булсын, кирәк Кәляме шәрифтә яисә шәригать кануннарында булсын, мөдәррисе Габделрахманны узып ук киткән иде.* Җ.Рәхимов

**КӘЛЯМУЛЛА** *и. гар дини.* Коръән, Аллаһның сүзе

**КӘМ** *рәв. диал. к.* **ким**. *Мин даһи!.. Йөрмәм үземне кәм тотып, Тергезәм үлгән йөрәкне ант итеп!..* Ш.Бабич

**КӘМАЛ** *с. гар. иск.* **1.** Камил, тулы. *Ул хәтта дөньяга кәмал нәфрәт вә истигъфаф белән карый.* М.Галәү

**2.** *и. мәгъ.* Камиллек; тулылык. *Һәр кәмалның бер зәвалы бар.* Мәкаль

**КӘМАЛӘТ** *и. гар. иск.* Камиллек, камил булу дәрәҗәсе. *Кәмаләтең бөек синең, Өммикамал, Җанны җанга тоташтырган син бер канал, Тупас, надан сине күрсә, ул да әйтә: «Нәгъләт икән, нинди чибәр монави мал!»* Ш.Бабич

**КӘМАНЧА** *и. фар.* 1) *иск.* Скрипка сызгычы, смычок

2) Көнчыгыш халыкларның кайберләрендә сул тез өстенә куеп уйнала торган скрипканың бер төре

**КӘМӘ** *и. диал. к.* **көймә**. *Һәм тизтиз сикереп төшеп, кәмәне кырыйга да тартып чыгардык.* М.Җәлил. *Кәмәң комга терәлде шул.* М.Гали

**КӘМӘЛ** *и.* Билгеле бер җайланма, корылма, предмет һ.б.ның нигез өлеше; каркас

**КӘМӘНЧӘ** *и. фар. к.* **кәманча**

**КӘМӘР** *и. фар.* Билбау, пута. *Өстәл янында, алдына бер китап ачып, яланбашлы, кыска гына чәчле, рус күлмәге киеп, биленә кәмәр бәйләмәгән хәлдә Газиз утыра.* Ф.Әмирхан. *Сәхип акчаны бик артык кысып тота торган кешеләрдән, аңа үз гомеренә ярты кадак арыш икмәге алыр өчен бер тиен бакыр таба алмыйча ач утырырга, билендәге каешын кибетчегә салып, кәмәрсез йөрергә бик-бик күп туры килгәләде.* Г.Ибраһимов. *Ул кызыл итекләр, кондыз бүрек кигән; билендә көмеш кәмәр, кулында камчы.* М.Фәйзи

**КӘМӘРЛЕ** *с.* Кәмәре булган, кәмәр белән бизәлгән

**КӘМӘШ** *и. диал.* Ниндидер югары сыйфатларга ия булмаган әйбер, зат, предмет. – *Атсыз кеше – аяксыз-кулсыз кеше инде ул, – ди Миңнулла, юл өстендәге пычраклар аркылы атлап, – минем ат кәмәшем бар барын да...* И.Гази

**КӘМИТ** *и. гр.* 1) *иск.* Цирк. *Әллә син дә кәмиттә паяз булмакчы буласыңмы?* Г.Камал

2) *иск.* Цирк бинасы. *Нәкъ сурәттәгечә киң ыштанлысы, кәмитнең алдында җыелган халыкка карап, кыңгыравыклы бүреген салды да, бик түбән иелеп алды һәм шунда ук кире кереп китәргә уйлады.* Ә.Фәйзи

3) *гади сөйл.* Гомумән нинди дә булса тамаша (спектакль, концерт һ.б.). *Кәмитләр ясап акча җыйнарга керешкәннәрмени инде?* Ш.Камал

4) *күч. сөйл.* Көлкеле тамаша, көлкеле нәрсә. *Ә ир-ат киемендәге юанюан дамалар үзләре бер кәмит – гел сыерлар инде.* Җ.Рәхимов. *Хәйри бу кәмитнең асылын әле дә булса аңлап*

*җиткерми иде*. Г.Минский. *Кайсының башы түбән, аяклары югары күтәрелгән дип тә өстәсә, тәмам кәмит була ич.* Ш.Камал

◊ **Кәмит уйнау** 1) Спектакль-концерт һ.б. катнашу; артист булу. *Инде бүгенге көндә генә кәмит уйнар өчен, мөселман баласы димләп адәм көлкесенә кала күрмим.* Ш.Камал; 2) Кылану, тыштан бер төрле күренгән, эчтәлеге бүтән булган эш эшләү; 3) Ярамаган эш эшләү, ярамаганны эшләп кеше көлдерү, көлкегә калу. *Без, әлхәмделилла, барчабыз да мөселман бит, безгә нигә хаҗәт ул ала бия ахшамнары, безгә нигә кәмит уйнаулар.* Ш.Мөхәммәдев

**КӘМИТ-ТАМАША** *и. к.* **кәмит** (*3 мәгъ.*). *Көннәрдән бер көнне өйдә тагын күтәрелде кәмит-тамаша.* Ш.Маннур

**КӘМИТИТ** *и. лат. сөйл.* 1) *к.* **комитет**. *Әйдә, кәмититкә алып барабыз үзен.* Г.Камал. *Җитмәсә тагын, үзләренә кәмитит төзеп алганнар.* Г.Ибраһимов

2) Комитетта эшләүче кеше. *[Тимеркәй:] Кәмитит абзый, ышанма бу картка! Ул күзеңә карап ялганлый: аты да, арбасы да бар.* Г.Ибраһимов. *Анда, син – кәмитит Сираҗи малае, дип исләре китеп тормыйлар икән.* Г.Камал

**КӘМИТЛӘНҮ** *ф.* Үзеңне көлке итеп күрсәтү, көлдерү

**КӘМИТЛЕК** *и.* 1) Кәмит (*3 мәгъ.*) эчтәлекле, кәмит (*3 мәгъ.*) булу. *Әсәрдәге кимчелекләрдән тагын урыны-урыны белән кәмитлеккә шарж бирелүне әйтергә кирәк.* М.Җәлил

2) Бик нык кыланчыклык, артык ясалма кыланышлар; үтә көлкелелек; шамакайлык

**КӘМИТСЕНҮ** *ф.* Кәмиткә (*3 мәгъ.*) санау, көлке дип табу; җитди итеп кабул итмәү. *Гариф кәмитсенгән шикелле елмаеп --- тора иде.* Ш.Камал

**КӘМИТЧЕ** *и.* Кәмиттә (*1 мәгъ.*) уйнаучы, цирк артисты

**КӘМИТЧЕЛЕК** *и.* 1) *к.* **кәмитлек** (*2 мәгъ.*). *Бу иптәшләрнең уеннарында артык кыланышлардан, кәмитчелектән качу --- күзгә бәрелә.* М.Җәлил. *--- Россия театрларында куелып йөртелгән әсәрләр «кәмитчелек» – театральностька корылган булып, Чехов әнә шул кәмитчелеккә каршы чыкты.* Г.Нигъмәти

2) *сөйл.* Спектакль, тамаша кую эше; кәмит артисты булу, гомумән артистлык

**КӘМШӘЮ** *ф. диал.* Кәкрәю. *Янышның үзенә бер кальга булып утырган, имән текмә белән уратып алынган чиркәү хәтле йортының капкасы төбендә аны өстенә сәләмә бишмәт, башына кәмшәеп беткән мескен бүрек кигән шадра битле базык кеше каршылады.* Җ.Рәхимов

**КӘМШЕК** *с. диал.* Кәкре. – *Кем, минме акылдан язган? – дип ысылдады Иннокентий теш арасыннан. – Мин туганда син амёба гына идең әле, кәмшек танау!* З.Мәхмүди

**КӘН** *и. фар. иск.* Шахта, рудник

**КӘНӘ** *терк. иск. кит.* Янә, тагын

**КӘНӘ́ УТЫ** *и. бот. к.* **кәнә үләне**

**КӘНӘ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Сөтлегәннәр семьялыгыннан орлыгыннан кастор мае алына торган үлән үсемлек; *русчасы*: **клещевина**

**КӘНӘФ** *и. фар. бот.* Мальвачалар семьялыгыннан, җепселле текстиль чималы буларак кулланыла торган берьеллык көньяк үлән үсемлеге. *Көньяк Казахстанда кәнәф, көньяк киндере күп игелә.* СССРның экономик географиясе. *Алар арасында кәнәф (Hibiscus cannabinus) үсемлеге – иң билгелесе. Аны Африка, Көньяк Азиядә борынгыдан ук игәләр.* Ботаника

**КӘНӘФИ** *и. төр.* 1) Кечкенә, гадәттә йомшак итеп эшләнмәгән җыйнак диван. *Борһан абзый белән Газизә абыстай ястүләрен укып алдылар да, көндәгечә, Газизә абыстай кухняга аш өлгертергә чыгып китте; Борһан абзый кәнәфи* (*диван*)*га утырды, кул бармакларын аралаштырып эләктереп, баш бармакларын бер-берсе тирәсендә әйләндереп, аш өлгергәнен көтеп тора башлады.* Ф.Әмирхан. *Барып керсәм, тагын да аптырап калдым, дустым эшләпәсен кашына ук төшереп, башын иеп кәнәфидә утыра, ә Зәмзәмиясе яулыгына капланып үкси-үкси яшь коя.* Ф.Баттал. *Әмма Сергеевның усал карашы җитә калды, алар бик тиз генә кәнәфиләргә кире сеңде.* В.Имамов

2) *күч.* Дәрәҗәле, мактаулы урын; түрә урыны. *Аристовлар Казанда аның артын үбәрдәй булып ялагайланмаса, воевода кәнәфиен кем яулар иде әле, аны Алла белгән.* В.Имамов

**КӘНӘФИ-КАРАВАТ** *и.* Кәнәфи дә һәм караватта булган җиһаз төре

**КӘНДЕ** *а. иск. кит.* Үз, үзе. *Рәсемеңне күргәч, кәндеңне күргән кеби булдык.* Ш.Мөхәммәдев

**КӘНДИ** *и. фар. диал.* Зур булмаган коштабак, кечкенә аш савыты. *Тимер рәшәткәле тәрәзәнең иң өстендәге тар тасмадан төшкән яктылык һәм шул якты буй сызыктан вакыт-вакыт күренеп киткән итекләр һәм читеккәвешләр дөньяда әле хәят барын белдереп торсалар, көнгә өч тапкыр ишектәге тишектән бирелә торган бер кәнди ашлы су һәм ипи кыерчыгы аны бөтенләй үк истән чыгарып бетермәүләре хакында сөйлиләр иде.* Җ.Рәхимов. *Анасыннан «улым» сүзе дә ычкынгач, Хәлимнең эченә җылы керде: агач кәнди алып, күршегә катык сорарга кереп китте.* И.Гази. *Ә менә бүген бер дистә йомыркамны, кәнди буе маемны урлаган.* А.Шамов

◊ **Кәнди тоту** Ялагайлану, ярарга тырышу; *к.* **тәлинкә тоту**. *Хәтәре – мөртәтләр. Чөнки алар иманнарын сатып, дошманга кәнди тоту юлына басканнар.* Җ.Рәхимов

**КӘНДИЛ** *и. гр. к.* **кандил**. *Идел өстен алып торган нурлы кәндил Казан.* Н.Исәнбәт

**КӘНДИТЕР** *и. лат. < гар. сөйл. к.* **кондитер**. *Бу оннан, Алла боерса, кәндитер күмәче салдыртсаң да оятлы булмассың.* Ф.Әмирхан

**КӘНИЗӘК** *и. фар.* Ханга яисә ханның берәр якынына хезмәткә алынган кол хатын яисә кыз, җария. *Сөембикә баскычтан хан турына төшеп туктый, артында кәнизәкләре тезелә.* Н.Исәнбәт. *Алтынчәч, елап, янындагы бер кәнизәкнең күкрәгенә ята.* М.Җәлил. – *Туташ, сез кәнизәк буласызмы? --- – Беләм инде, бу вакытта кәнизәкләр юк: ләкин юрамалый, оятлы итәр өчен сорыйм аны.* Ф.Әмирхан

**КӘНИСӘ** *и. гар. иск. к.* **кәлисә**

**КӘНИТИЛ** *и. фр.* 1) Алтын яки көмеш йөгертелгән нечкә чыбыклардан үрелгән, тегү-чигү эшендә кулланыла торган укалы җеп. *Чигү өчен төрле материал кулланган алар: үзләре суккан һәм сатып алынган тукымалар, йон һәм ефәк җепләр, мулине, кәнитил, сәйлән...* Ватаным Татарстан

2) *күч. сөйл.* Нинди дә булса буталчык эш, катлаулы вакыйга, четерекле мәсьәлә. *Шүрләмәгәндә, алар җыелышлар ясап, кәнитилләр корып йөрмәс тә иделәр.* Ш.Камал. *Сәйфи Мингалимович, зинһар, бүтән мондый кәнитил куптарма!* З.Хәким

3) *күч. сөйл.* Мәшәкать, мәшәкатьле эш

◊ **Кәнитил тарту** *к.* **кәнитилләү**

**КӘНИТИЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Вак эш белән маташу

2) Юк белән булышу, юкны тикшерү

**КӘНИТИЛЛӘ́Ү** *ф.* Кәнитил белән бизәү

**КӘНИТИЛЛЕ** *с.* 1) Кәнитил кушып, кәнитил белән чигелгән-тегелгән, кәнитил белән бизәлгән. *Башында кәнитилле укалы тар гына калфак ---.* Н.Исәнбәт. *Икенчесе озын буйлы, сары сакаллы, зәңгәр күзле, башына кәнитилле кәләпүш кигән утыз яшь чамасында бер адәм булып, уң кулының терсәге илә өстәлгә, учы илә яңагына таянган. Идел өстендә ары-бире йөрүче көймәләрне тамаша кылып утырмакта иде.* Ш.Мөхәммәдев

2) *күч. сөйл.* Катлаулы, буталчык, четерекле

**КӘНСӘ** *и. сөйл. к.* **кәнсәләр**. *Баш исән-сау чакта моннан китеп котылырга мәллә дип йөргәндә, Абдулланы Уфа провинсә кәнсәсенә чакырттылар.* Җ.Рәхимов. *[Һөнәрче:] Янарал Кудрявцев кәнсәсендәге бер тылмач әйтте. Ул янарал кенәзне воеводалыктан алып аткан.* В.Имамов

**КӘНСӘЛӘР** *и. лат. сөйл. к.* **канцелярия**. *Сүзне Хәмдия абыстай башлады: – Яңгыр дигәннән, карт, кәнсәләргә барып кайтырга кирәк, син әйткән дөрес була торганые, мужыт, тыңларлар...* Г.Гыйльманов. *[Мирсәет:] Мин биредә, кәнсәләрдә генә утырып торырсың.* Р.Ишморат. *Сугыш алды елларында Фәридә апа белән әткәйнең кәнсәләрдә эшләгән чаклары.* К.Йосыпов

**КӘНСИР** *и. лат. сөйл. к.* **консервы**. *Китереп ач шунда кәнсир заводы – помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме, үстереп өлгертәбез.* М.Әмир

**КӘНТ** I *кис. диал.* Нәкъ шулай, нәкъ

**КӘНТ** II *и. тар.* Шәһәр; ныгытма. *Яхшы – йөргән җиренә кәнт салыр.* Дастан

**КӘНТӘЙ** *и.* **1.** 1) Ана эт. *Аңа бирергә минем кәнтәем балаламаган әле, дип әйтте Таҗетдин карт, диген.* Г.Ибраһимов. *Кәнтәен ярашлы нәсел эте белән аталандыру түгел бит сиңа!* Р.Гаязетдин

2) *күч. гади с. тирг.* Ир-ат халкы белән чуалырга ярата торган хатын-кыз. *Бу кәнтәйне өйрәтим әле мин дип, эт урынына кыйнады.* Г.Ибраһимов. *Менә яшь чагында да шундый кәнтәй иде ул!* Т.Миңнуллин. *Алайса, бу кәнтәеңне дә иярт, бар, аркаңны ышкырга кирәк булыр!* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* Ирләр белән чуалырга ярата торган, йөремсәк. *Харап итте ич бу кәнтәй марҗа!* Г.Ибраһимов

**КӘНТӘЙЛӘНҮ** *ф. гади с.* Чытлыклану, ирләр белән чуалу; җилбәзәкләнү. *Тешсез карчыкны өшкертеп пычагым да булмас, дидем. Кәнтәйләнеп, үз сүзеңне иткән булдың.* М.Әмир

**Кәнтәйләнеп китү** Кинәт кәнтәйләнү. *Мин дә җир ертып: «Яшә!» – дип, сөенә-сөенә кычкырам, Юкка бик кәнтәйләнеп киткән иде маэмай халык!..* Ш.Бабич

**КӘНТӘЙЛЕК** *и. гади с.* Чытлыклык; үзен кәнтәйләр (*2 мәгъ.*) кебек тоту; җилбәзәклек (хатын-кыз тур.)

**КӘНТӘК** *с. диал.* Тәбәнәк, кыска. *Саратов якларындагылар түгел инде: үзләре кәнтәк, үзләре нәзек.* М.Хөсәен

**КӘНТИ** *и. фар. диал. к.* **кәнди**. *Малайлар анда зур кәнти яисә кувшин тотып җиләк җыярга баруны үзләре өчен бик зур мәртәбә саныйлар.* С.Җәләл

**КӘНФИТ** *и. ит. сөйл. к.* **конфет**. *Су килми торган номерларга кайнар һәм салкын сулар килә торган иттердем, --- өченче-дүртенче катларда утырган дорфа кизү хатыннарның пычрак телләренә кәнфиттән дә баллы сүзләр салып куйдым.* З.Мәхмүди. *Мине күрсә, Газинур абыеңнан хатлар юкмы дип аптыратып бетерә торган иде, кайчак кәнфит тә бирә торган иде.* Г.Әпсәләмов. *Ипи җитмәгәч, кәнфит, яшел суган, тозлы гөмбә, теш пастасы беткәч, үзләре эш ташлаган.* Ф.Баттал

◊ **Кәнфит корты** Бик нык баллы ризык, конфет яратучы кешегә карата әйтелә. *Юк, Рөстәм алай, әнисе әйтмешли, кәнфит корты түгел.* Сөембикә

**КӘНФИТЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Кылану, төчеләнү; ялагайлану, тәмле телләнү. *Бирәүләргә ялынып сорасалар да әләкми, ә син китереп биргәнне алмыйча кәнфитләнәсең.* Г.Бәширов

**Кәнфитләнә башлау** Кәнфитләнергә тотыну

**Кәнфитләнеп тору** Кәнфитләнү хәлендә булу

**Кәнфитләнеп утыру** *к.* **кәнфитләнеп тору**

**КӘНФИТЛӘП** *рәв.* Конфет белән. *Компенсациясе кайчан булыр... Тагын бирәр хата табарлармы, әллә кәнфитләп чәй эчкәндә, анысын җайларлармы?..* Кызыл таң

**КӘНФИТЛЕ** *с.* 1) Кәнфит белән булган

2) *күч.* Татлы, тәмле, ягымлы (сүз һ.б.). *«Уфа – Болгар – Казан маршрутына рәхим итегез! Сезне тарихи ватаныгыз буйлап сәяхәт иттереп кайтабыз» мәгънәсендәге татлы, кәнфитле чакырулар хәзер җәйләрен Уфаның һәр урам чатына ябыштырылган.* Кызыл таң

**КӘНФИТЧЕ** *и. сөйл.* Кәнфит җитештерүче яки аны җитештерүдә эшләүче яисә кәнфит сатучы. *Ипи салучылар да монда икән, кәнфитчеләр дә, теплица кешеләре дә...* Ф.Баттал

**КӘНҮШНӘ** *и. рус сөйл. к.* **кәнүшни**. *– Укырга вакытыбыз юк, Сәгыйтьҗан байның чәй төрү заводында яшьнекләр ташыйбыз, кәнүшнә тазартабыз, йомышка йөгерәбез, – диде.* Ә.Фәйзи

**КӘНҮШНИ** *и. рус сөйл.* Ат абзары. *Кәнүшнидә яңа бер колын туса, иң элек*

*ул [Хәсән] килеп җитә.* Г.Ахунов. *Юл бозлы, шуңа күрә олаучы --- атын бик куаламаска тырыша: ат хөкүмәтнеке, кантон кәнүшниеннән бирелгән, аяктоягын имгәтеп кайтсаң, көт тә тор, мәхкәмәсез-нисез Минзәлә төрмәсендә ике-өч ай яткырып, сохари кимертеп чыгарырлар.* Ф.Сафин

**КӘҢКӘЮ** *ф. диал.* 1) Йончу, начарлану

2) Салыну, бер якка авышу (мәс., кикрик)

**КӘПӘРЕНҮ** *ф. к.* **кәпрәю**. *Хәбибулла, --- хәзер замана безнеке, дип кәпәренде.* Ш.Хөсәенов. *Хатын, председатель Вәлиевкә барып, Шәвәлине кичерүне сорагач, теге, мәсьәләне кабыргасы белән куябыз, дип кәпәренде.* С.Рафиков

**Кәпәренә биру** Бернигә карамастан кәпәренү

**Кәпәренә төшү** Тагын бераз кәпәренү

**Кәпәренеп йөрү** Гел кәпәренү

**Кәпәренеп җибәрү** Кинәт аз гына кәпәренү

**КӘПӘЧ** *и. диал.* 1) Түбәтәй, кәләпүш. *Ул, учитель булса да, кәпәч кигән.* Г.Тукай. *Шул чак өстенә буй-буй зыбан, башына кара кәпәч, аякларына күн итекләр кигән базык гәүдәле берәү, төркемнән аерылып, кунаклар янына ташланды.* Җ.Рәхимов

2) Берәр төрле баш киеме (гадәттә кимсетү төсмере бирә). *Салкыннар җитте бит, малай, син бу кәпәчеңне бүтән нәрсә белән алыштырыр идең.* Ф.Хөсни

◊ **Кәпәч борын** Дуңгыз. *Кәпәч борыннар тик тауны сөрсеннәр.* Ә.Еники

**КӘПӘЧЛӘГӘН** *ы. сөйл.* Бик төгәл туры килүне белдерә. *[Кирамов:] Пьесаның чын исеме дә «Галимнәр белән наданнар» түгел, ә «На чужом пиру похмелье». Кәпәчләгән!* Н.Исәнбәт

**КӘПӘЧЛӘ́Ү** *ф. гади.* 1) Нинди дә булса эшне тиз генә эшләп кую (сыйфаты бик үк яхшы булмаска да мөмкин)

2) Эшне төгәлләү

3) *күч.* Берәүне алдау. *Бу ачык авызны кәпәчләгәннәр*

**КӘПӘЧЛЕ** *с.* Кәпәче булган, кәпәч кигән

**КӘПЕРЕНҮ** *ф. сөйл. к.* **кәпәренү**

**КӘ́П-КӘКРЕ** *с.* 1) *арт. дәр. к.* **кәкре**. *Шүрәленеке бигрәк охшаган, нәкъ Тукайдагыча: мөгезләренә, таякларына, «кытыкларга яралган» бармакларына, «кәпкәкре борын»ына кадәр бар иде.* Г.Гобәй

2) *күч.* Гел дөрес булмаган, бөтенләе белән ялган булган

**КӘПРӘЮ** *ф.* Артык һавалану, үзүзеңне бик эре тоту; масаю; кукраю. *[Дүртенчесе:] Куярмын әле, бер дә кәпрәймә, өчлеләрең белән әллә кая бара алмассың!* Ш.Камал

**Кәпрәя бару** Акрынлап кәпрәю

**Кәпрәя башлау** Кәпрәергә тотыну

**Кәпрәя төшү** Тагын да кәпрәю

**Кәпрәеп йөрү** Кәпрәю хәлендә булу

**Кәпрәеп тору** Даими яисә әледәнәле кәпрәю. *Табын тулы сый. Ара-тирә берничә шампан шешәсе дә кәпрәеп тора.* Г.Гыйльманов

**КӘПИРӘТИВ** *и. сөйл. к.* **кооператив**. – *Я, кәпирәтивкә ярар, хакын бик арзан бирәләр, – дип, киемне сәкегә ата.* Г.Ибраһимов. *[Сәхипҗамал:] Беркөн кәпирәтив Шакирны гәзиткә язганнар, судка бирәләр икән, дигәннәр ие.* А.Әхмәт

**КӘРАМӘТ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Әүлия, изге кешеләр генә күрсәтә алган гайре табигый гамәл, эш. *Алмый әле һаман кузгалмаенча, Бу эш нәрсә – кәрамәт булмаенча.* М.Гали. *Үзенә генә махсус бер тынычлык белән --- Зөфәр ишанның кәрамәтләрен сөйләп утыра бирә.* Г.Ибраһимов

2) *сир. к.* **кәрамәтче**. *Күрәзәләре, сихерчеләре, кәрамәтләре, йолдызга һәм башка нәрсәләргә карап һәртөрле серләрне сөйләүчеләре күп булып, һәртөрле юллар илә надан халыкны шаштырып торалар.* Шура

**2.** *с. мәгъ.* Гайре табигый көчкә ия булган. *Саҗидә бер кәрамәт саз шикелле, Сазына миллион сәҗдә аз шикелле, Кәгъбә итеп әйләнәсең-әйләнәсең, Барыбер ул Алла кушкан хаҗ шикелле.* Ш.Бабич

**КӘРАМӘ́Т ИЯСЕ** *и. к.* **кәрамәтче**

**КӘРАМӘТЛЕ** *с. дини* Әүлиялар, изгеләр генә күрсәтә ала торган, гайре табигый. *Менә бу хәлләрдә шул зур нәселнең кәрамәтле канының тәэсире юк түгел.* Г.Ибраһимов

**КӘРАМӘТЧЕ** *и. дини* Кәрамәтләр (*1 мәгъ.*) күрсәтә алучы кеше

**КӘРӘЗ** *и.* Бал җыеп туплау һәм күкәй салу өчен, бал кортлары яки шөпшәләр тарафыннан тигез рәтләр итеп балавыздан ясалган күзәнәкләр

**КӘРӘЗЛЕ** *с.* 1) Кәрәзләре булган; кәрәзе белән бергә, кәрәздән аерылмаган. *Яңа гына мичтән җылынып чыккан вак бәлешләр, юачалар, кәлҗемәләр, салкыннан кергән кортлы май белән кәрәзле бал да килеп утырдылар.* М.Галәү

2) Абонентлары бер урыннан икенче урынга күчеп йөри алган радиоэлемтә белән бәйле булган; шундый элемтәдән файдаланган. *Аннары, дулап, кәрәзле телефоныннннан Хәтимәнең номерын җыярга кирәште.* З. Мәхмүди. *Кәрәзле элемтә*

**КӘРӘЗЛӘНҮ** *ф.* Кәрәзнеке кебек кечкенә куышлар барлыкка килү, кәрәздәге кебек тишекләр ясалу

**Кәрәзләнә бару** Торган саен кәрәзләнү

**Кәрәзләнә башлау** Кәрәзләнергә тотыну. *Елгалар күперeп шартладылар да кәрәзләнә башлаган боз тауларын еракларга алып киттеләр.* Г.Ибраһимов

**Кәрәзләнеп бетү** Тәмам кәрәзләнү

**Кәрәзләнеп тору** Өзлексез рәвештә яки әледән-әле кәрәзләнү

**Кәрәзләнеп җитү** Бик нык, тәмам кәрәзләнү; кәрәзләнеп җитлегү, өлгерү

**КӘРӘКӘ** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан зур булмаган төче су балыгы, табан балык; *русчасы*: **карась**

**КӘРӘКӘ́ БАЛЫГЫ** *и. к.* **кәрәкә**

**КӘРӘМӘТ** *и. гар. сөйл. к.* **кәрамәт**

◊ **Кәрәмәт шәп** Бик шәп

**КӘРӘШКӘ** *и. рус бот.* Кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык үсемлек, виканың бер төре; кырмыска борчагы; *русчасы:* **горошек заборный**

**КӘРБӘЗ** *с. фар. иск.* Купшы, көяз, франт

**КӘРБӘЗЛЕК** *и. иск.* Купшылык, көязлек, франтлык. *[Каринның] киенүендә нииндидер үзенә күрә элегантлык, кәрбәзлек, хәрәкәтендә салмак сынлылык, әмма эшләпә киюендә аерым бер чибәрлек бар иде.* Б.Урманче

**КӘРБӘН** *с. фар. сөйл.* Кечкенә түгел, чагыштырмача зур булган. *Хәзрәт үзе сөйләгән арада тик тормады, үрдәкне юып, эчләрен тазартып кискәләде дә, кәрбән генә бер корымлы кәстрүлгә салып, тимер мич өстенә куйды.* Ш.Маннур

**КӘРВАН** *и. фар.* 1) Ерак араларга юлчыларны һәм сәүдә малларын ташыган йөк хайваннары тезмәсе (дөя, ишәк һ.б.ш.). *Бу чак Йосыф кардәшләре тауда иде, Ул тирәдә кәрван барын бар да күрде, Бик ашыгып, кабаланып, йөгереп килде, – Тик Йосыфны тапмадылар анда имди.* Кол Гали

2) *күч.* Зур бер төркем хәлендә бербер артлы хәрәкәт итә торган нәрсәләр. *Кырык-илле олау көзге туң юлда дөбердәп-шалтырап ике авыл арасын үтүгә, аларга тагы шул хәтле үк күршеләре кушыла. Бераздан инде кәрванга күршеләрнең күршеләре, аннан инде аларның күршеләре иярә.* Җ.Рәхимов. *– Минемчә, монысы да начар картина түгел, – диде ул, кыр казлары кебек тезелеп, Идел өстеннән бара торган юлчылар кәрванына күрсәтеп.* М.Гали. *Ерак-еракларда, тере күлдә, Тоньк суда үтте чагылып Шау яшьлегем! – Торна кәрванына Минем еллар китте тагылып...* Зөлфәт

**КӘРВА́Н БАШЫ** *и.* Кәрван башлыгы, кәрванны алып баручы, аңа җитәкчелек итүче. *Кәрван башы бу товарга 15 мәртәбә артыграк бәя сорый.* Р.Фәхретдинов

**КӘРВАНБАШ** *и. к.* **кәрван башы**. *Бу шәһәрдән ерак-ерак илләргә кәрван чыгып бара икән күп мал белән. Малай кәрванбашка бара.* Әкият

**КӘРВАНСАРАЙ** *и. фар.* Мөселман җирләрендә олы юл өсләрендә кәрван тукталу өчен салынган махсус тораклы зур йорт. *Оренбургта янә бер хәбәр: Кәрвансарай мәчетенең имамы булып, шуның углын имам сайламак булып, мәхәллә халкы приговор җыеп йөри ---.* Ш.Мөхәммәдев. *Кәрвансарай – Екатерина II патша заманында Оренбургта салынган крепость.* Ш.Усманов

**КӘРВАНЧЫ** *и.* Кәрванның хуҗасы яки кәрванны озатып баручы кеше. *Бу кәрванчы байларның берсе --- каракүл, илтер, җимеш һәм дөге шикелле нәрсәләр алып кайтып кәсеп итүче атаклы һәм данлыклы Мортаза бай иде.* М.Галәү. *Кәрванчылар күп алтын алып кайтып китәләр.* Татар халык иҗаты

**КӘРЕШКӘ** *и. рус к.* **кәрәшкә**. *Агыйделнең буе гел кәрешкә, Башларында тора күк чәчкә.* Җыр

**КӘРҖИН** *и. рус диал. к.* **кәрзин**. *[Тәмәкене] Кабызып бер-ике суыруыма, күршем буш кәрҗинемә ым какты: – Өйдән чыгып киткәндәге кебек үк үтә күренмәле синең бу кәрҗинең, күрше.* Ф.Баттал

**КӘРҖИНЧЕ** *и. диал. к.* **кәрзинче**. *Кичә мин кайтып киткәч, мәйданда зур шау-шу булган икән. Кәрҗинчеләр дә, кәнфитчеләр һәм ипичеләр дә берберсен куа башлаганнар. Бүген барысы да, ягъни алар да, эшкә чыккан.* Ф.Баттал

**КӘРЗИН** *и. рус* 1) Нәрсәне дә булса салып йөртү яки саклау өчен тал чыбыкларыннан, камыштан һ.б. үреп эшләнгән савыт. *Кышкы саклауга куелачак җимешләрне сак кына, каты кысмыйча, бөтен уч белән тотып алалар һәм төбенә йомшак әйбер җәелгән тартма яисә кәрзиннәргә җыялар.* Өегез ямьле булсын

2) *бот.* Үсемлекләрдә тәлинкә сыман киңәйгән үзәктә бик еш булып утырган чәчәк төркеме тибы (мәс., көнбагыш чәчәге һ.б.ш.)

3) *комп.* Кулланучының график интерфейсында барлык бетерелгән файллар җыелып бара торган махсус папка

4) *спорт* Баскетбол уенында туп кертү өчен билгеләнгән ятьмәле боҗра. *Уенчының кичәге матчта 23 очко җыюыннан бигрәк, аның кәрзингә иң соңгы 3 очко китергән туп ыргытуы алтынга тиң булды кебек.* Безнең спорт

5) Һава шарында пассажирлар өчен кабина

6) Интернет кибетләрдә сайлап алынган товарларны вакытлыча саклау урыны

◊ **Кәрзингә озату** Яраксызга чыгару, ташлау

**КӘРЗИНЛӘП** *рәв.* Кәрзин белән, кәрзин-кәрзин. *Чиләкләп тә, кәрзинләп тә, соңрак «уфалла» арбасы белән дә җыйдык без гөмбәне*

**КӘРЗИНЧЕ** *и.* Кәрзин үрүче яисә кәрзин сатучы

**КӘРКӘДӘН** *и. фар. иск.* Мөгезборын. *[Арыслан], юлбарыс, кәркәдән, каплан, фил, кабан дуңгызы кебиләрне каршына чакырып: «Сез Бүрене ничек дип беләсез?» – дип сораштьы.* Г.Тукай

**КӘРКЕШ** *и. морд. диал. к.* **киндерә**

**КӘРЛӘ** *и. рус* < *нем.* **1.** 1) Көнбатыш Европа риваятьләре һәм әкиятләрендә: урманда яки тауларда яши торган, кечкенә буйлы, тылсымга ия кеше

2) Нормадан күпкә тәбәнәк буйлы кеше. *--- каяндыр килеп кергән кәрлә сыман кечкенә генә гәүдәле, өстенә озын ак күлмәк һәм кара камзул киеп, камзул кесәсеннән алтын сәгать чылбырын чыгарып салган, тере генә кыяфәтле берәү эшләүчеләргә нидер кычкырган икән.* Ә.Фәйзи

3) Гомумән буйга тәбәнәк кеше. *Кемдер: – Бушатырга кирәк, болай кузгатып булмас, – диде. Кәрләгә бу фикер ошамады булса кирәк, ул, кызакыза кулларын бутап, нәрсәдер кычкырынды.* Ә.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* 1) Артык кечкенә. *Тау битендә тамырланып яшәүче кәрлә чикләвек куаклары да кар әсирлегендә.* Р.Низамиев. *Тоньк кына күкрәү ишетелә, Килер еллар безне бер аклар. Шыпырт яла сыман яр астына Егылалар кәрлә куаклар.* М.Галиев. *Ул – каен. Татарстанда аның өч төре бар икән. Иенке, бөдрә һәм кәрлә каеннар.* Шәһри Казан

2) *астр.* Кечкенә һәм яктысы бик зәгыйфь булган (йолдыз тур.)

3) *күч.* Кечкенә, әһәмиятсез. *Кәрлә эш*

**КӘРЛӘЧ** I *и. бот.* Кантибәрчәләр семьялыгыннан сабак өлеше һәм яфраклары сусылланып торган үлән үсемлек; сахра борычы, дөя борычы; *русчасы:* **очиток**. *Кәрләч тамыры*

**КӘРЛӘЧ** II *с. к.* **кәрлә 2.** (*1 мәгъ.*). *Шулчак яныбызга камыт аяклы кәрләч бер егет килеп басты.* З.Мәхмүди

**КӘРНИЗ** *и. лат.* 1) Бина диварының иң югарыгы өлешендә, шулай ук тәрәзә, ишек башларында яңгырдан

саклау өчен ясалган горизонталь чыгынты. *Тегермән стенасындагы, кәрниз астындагы бихисап тишек-тошыклардан әллә нихәтле күгәрчен, чәүкә, чыпчык тузгып чыкты.* Ә.Гаффар. *Иң элек мин шуны искәрдем: тәрәзә кәрнизләрендә күгәрченнәр белән чәчәкләр сирәгәйгән, башка сурәтләрдә дә якты буяуларга караганда караңгырак төсләр күбәеп киткән.* Г.Гыйльманов

2) Пәрдә-челтәр элү өчен тәрәзә яки ишек өстенә беркетелә торган аркылы металл яки агач таяк, борыс

**КӘРНИЗЛӘ́Ү** *ф.* Кәрниз кую, кәрниз белән бизәү. *Кәрнизләп салынган мич*

**КӘРНИЗЛЕ** *с.* Кәрнизе булган. *Кукчәтаудагы иң матур, челтәр кәрнизле, өлге тәрәзә капкачлы өйләр – аның эше...* И.Салахов

**КӘРРӘ** *и. гар. иск.* Мәртәбә, тапкыр. *Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син, Һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.* Г.Тукай. *Кичер мине, бер горурлык белән Аваз салсам: Без бар! Без әле!.. – Бер кәррәлек зәррә булган Җирнең Инсан дигән гамьле бизәге.* М.Галиев

**КӘРТ** *и. фр. сөйл. к.* **ка́рта** (*4 мәгъ.*). *Хатыны белән туган авылына, әнисе, абыйлары янына кереп чыкты да, пожарка янында кәрт суккан ирләргә дә байлыгын күрсәтеп тормастан, Казанга чыгып китте, ерак туганнары ярдәмендә хәрби заводка эшче буып урнашты.* Т.Галиуллин. *Моның өчен «Золотой петушок»ка даими килеп йөрү генә җитми, ә бик эредән кубып зур суммалар тәгәрәтүче кәрт уенчыларының нинди дә булса бер ябык катранында үз кеше булырга --- кирәк.* Р.Мирхәйдәров

◊ **Кәртен бутау** Ниндидер эшкә киртә булу, комачаулык тудыру. *Һай, бу Тирсә! Бөтен кәртен бутады морзаның.* Җ.Рәхимов

**КӘРТӘ** *и. диал.* 1) *к.* **киртә**

2) Ихата

**КӘРТӘЛӘ́Ү** *ф.* Киртә тоту

**КӘРТЛЕ** *и. сөйл.* Кәрт уены. *Хәйдәрем бу сүзләрдән соң йомшап калды. Ярдәмче буларак мин аннан бернинди дә файда күрмим, баланда чөмереп бүксәсен тутыра да: «Әйдә, поп, кәртле уйныйбыз», – дип кенә тора.* Г.Фәхретдинов

**КӘРТЧЕ** *и. сөйл.* Кәрт уйнарга яратучы, кәрт уйнарга һәвәс кеше

**КӘРЧӘ-МӘРЧӘ** *җый. и. диал. к.* **кәкер-чөкер**

**КӘРЧЕМӘ** *и.* Озак торып бик нык әчегән катык

**КӘРШЕ** *и. иск.* Югары сыйфатлы нечкә күн

**КӘС** *и.* 1) Туфракның үләннәр тамыр җибәреп үсеп утыра торган өске катлавы

2) Шул катлаудан кисеп алынган яки каерып ташланган кисәк, катлам. *Бакча артындагы сөзәк урыннарга кәс җәю*

**КӘСАФӘТ** *и. гар. иск.* Билгеле бер эшнең начар йогынтысы, зарары, шаукымы. *Хәрбилек кәсафәтләре бер дә күзгә бәрелми иде егеттә.* Р.Төхфәтуллин

**КӘСӘ** *и. фар. к.* **касә**. *Көн буе --- йөреп, кич өйгә кайтсам, анда һичкем юк, һичнәрсә юк, ватык кәсә белән тишек чәйнекләргә чаклы алып киткәннәр.* Г.Ибраһимов. *Өстен-башын алыштырырга өлгермәгән каган, кымыз салынган алтын кәсә тотып, керүчеләргә каршы атлады.* Н.Фәттах. *Икеөлешлеләрнең аерымлык билгеләре: --- чәчәкләре биш- һәм дүртбуынлы, ягъни кәсә һәм таҗ яфракчыкларының саны дүрткә яки бишкә кабатлы.* Биология

**КӘСӘБӘ** *и. гар.* 1) Җәнлек, кош, балык һ.б.ш.ны аулау предприятиесе; промысел

2) Җитештерү чималы табу предприятиесе

**КӘСӘБӘЧЕ** *и.* Җәнлек, кош, балык һ.б.ш.ны аулау эшендә эшләүче

2) Кәсәбә (*2 мәгъ.*) хуҗасы. *Күптән түгел бер киңәшмәдә бер кәсәбәче: «Электр энергиясе җитми», – диде.* Я.Шәфыйков

**КӘСӘБӘЧЕЛЕК** *и.* Җитештерү һәм сату, хезмәт күрсәтү һ.б.ш.дан системалы рәвештә табыш алуга юнәлгән эшчәнлек. *Без алга таба да кече һәм урта кәсәбәчелекне үстерүгә җитди әһәмият бирергә тиешбез.* Мәдәни җомга

**КӘСӘРТКЕ** *и. диал. к.* **кәлтә**

**КӘСЕП** *и. гар.* 1) Кешенең даими шөгыльләнә торган һәм шул ук вакытта яшәү чыганагы булган эше, хезмәте, шөгыле. *[Габделсәлам:] – Ие, үзебез дә өйрәнәбез, сабак та тыңлатабыз. – Габделсәлам, зур өслекле артсыз урындыкка көрпә салып, кунакка утырырга ишарә ясады. – Кәсебем шул бит: мөдәррислек кылу.* Җ.Рәхимов. *Үзем кыенсынам: язасы әйберем – татар җырлары – төп кәсебем өлкәсеннән шактый ерак.* К.Йосыпов

2) Сәүдә, сәүдә эше, сәүдәгәрлек

3) Файда табу, отыш

**КӘСЕП ИТҮ** *ф.* 1) Берәр төрле эш, шөгыль белән көн күрү. *Аталы-аналы ике карчыга бер тау башында урын тота иделәр. Вә дәрәҗәләренә карап лаек кәсеп итеп, куанычлыкта гомер итә иделәр.* Әкият

2) Сәүдә итү, сату-алу белән шөгыльләнү. *Бу кәрванчы байларның берсе --- каракүл, илтер, җимеш һәм дөге шикелле нәрсәләр алып кайтып кәсеп итүче атаклы һәм данлыклы Мортаза бай иде.* М.Галәү

**КӘСЕП КЫЛУ** *ф. к.* **кәсеп итү**

**КӘСЕПЛЕ** *с.* Кәсебе булган

**КӘСЕПЛӘНҮ** *ф.* Билгеле бер кәсеп белән шөгыльләнү, шуның белән көн күрү

**КӘСЕПСЕЗ** *с.* Кәсебе, шөгыльләнә торган эше булмаган

**КӘСЕПСЕЗЛЕК** *и.* Кәсебе, шөгыле, эше юклык; хезмәт урыны булмау

**КӘСЕПТӘШ** *и.* **1.** Кем белән дә булса бер үк кәсеп белән шөгыльләнүче, уртак кәсеп итүче кеше. *Ул арада телефоннан тагын бер кәсептәш шалтырата. Һәм «әсәр»дә өстәмә персонаж барлыкка килә.* Безнең гәҗит

**2.** *с. мәгъ.* Берәү белән уртак кәсебе булган. *Кәсептәш дус*

**КӘСЕПТӘШЛЕК** *и.* Һөнәри дуслык. *Кәсептәшлек итү*

**КӘСЕПЧЕ** *и.* 1) Яшәү чыганагы булып торган нинди дә булса һөнәр белән көн күрүче кеше

2) *сөйл. хупл.* Нинди дә булса шәхси файда өмет итеп, рәсми булмаган берәр эш белән шөгыльләнүче кеше

**КӘСЕПЧЕЛЕК** *и.* Кәсеп итү эше

**КӘСЕР** *и. гар.* 1) *диал. к.* **кантар**

2) *мат. иск.* Берәмлек өлешләреннән торган сан; вакланма

3) *мат. иск. к.* **калдык** (*5 мәгъ.*)

**КӘСЕРКӘ** *и. диал. к.* **кәчеркә** (*2 мәгъ.*)

**КӘС-КӘС** *иярт. к.* **кәз-кәз**. *Кәс-кәс басып, җитез кызый бара. Бөтерелмә итәгеннән, башы әйләнеп, чәчәкләр түгелеп кала.* М.Галиев**.** *Кәс-кәс басып, гүзәлкәйләр уза. Кысыр хыялларга мөһер булып, «тояк» эзе кала йөрәкләрдә.* М.Галиев

**КӘСЛӘ́Ү** *ф.* Нәрсәне дә булса кәс (*2 мәгъ.*) белән ныгыту, кәс белән каплау

**Кәсләп бетерү** Барысын да кәсләү; кәсләүне тәмамлау, тәмам кәсләү

**Кәсләп килү** Акрынлап барысын да кәсләү

**Кәсләп тору** Даими яки әледән-әле кәсләү

**Кәсләп чыгу** Барысын да кәсләү; тәмам кәсләү

**КӘСРӘ** *и. гар.* Гарәп язуында берәр тартыкка *и* яки *ый* авазы кушып укылганын белдерә һәм хәреф астына куела торган хәрәкә

**КӘСРӘЛЕ** *с.* Кәсрә белән укылган, астына кәсрә хәрәкәсе куелган. *[р] һәм [л] авазлары кәсрәле булганда һәрчак нечкә итеп укыла*

**КӘСРӘТ** *и. гар. иск.* Күплек, муллык, артыклык. *Гамеңнең кәсрәте кемнәргә хәсрәт?* Г.Тукай

**КӘССАП** *и. гар. иск.* Мал суючы; мал чалучы

**КӘСТӘНӘ** *и. гр.* **1.** 1) Бүкчәләр семьялыгыннан, урта зонаның җылы якларында үсеп, бик эре чикләвек бирә торган агач

2) Шул агачның чикләвеге

**2.** *с. мәгъ.* Шуның чикләвеге төсендәге, коңгырт төстәге

**КӘСТӘНӘ ТУФРАКЛАР** *и. күпл. геол.* Аксыл коңгырт төстәге бераз татырлырак коры дала туфраклары. *Кара, шулай ук соры дала, кәстәнә һәм көрән туфракларда, әгәр дә гөлләр утыртканга яки чәчкәнгә кадәр органик ашламалар күп кертелгән булса, ашламаларның югарыдагы күрсәтелгән дозаларын 1/3 өлешкә киметәләр.* Йорт эшләре

**КӘСТӘНӘЛЕК** *и.* Күп итеп кәстәнә агачлары үсә торган урын

**КӘСТРҮЛ** *и. нем.* Аш-су пешерә торган, гадәттә цилиндр формалы, металл, пыяла яки башка материалдан эшләнгән саплы һәм капкачлы савыт. *Сөртер әйбер бетте диган нәтиҗә ясап өлгерүемә, кухня ягыннан назлы көлү яңгырады.* --- *Кәстрүлдә атна буе аш әчеп утырган бит.* Ф.Баттал. *Кер күтәрә дип, кухня стеналарын, шкаф ишекләрен караңгы төсләргә буярга, караңгы төсләрдәге кәстрүлләр алырга киңәш ителми.* Өегез ямьле булсын

**КӘТАВЫЛ** *и. монг. тар.* Кальга яки шәһәр коменданты

**КӘТӘНӘ** *с. диал.* Бик кечкенә буйлы. *Үзенең тиңдәшләре арасында кыяр-кыймас кына буталып йөрүче кәтәнә генә бер малай.* Т.Миңнуллин

**КӘТЕРКӘЙ** *и. диал.* Ипи катысы, каткан, махсус киптерелгән ипи; сохари. --- *Авыр сугыш еллары иде әле. Алабута оны кушып пешерелгән кәтеркәй кимереп, ачлы-туклы яшәгән еллар.* Ф.Зыятдинов

**КӘТЕРМӘЧ** *и. диал.* 1) Солы оныннан бармак калынлыгы итеп пешерелгән җәймә (ашамлык)

2) *к.* **кәтеркәй**

**КӘТЛИТ** *и. сөйл. к.* **котлет**. *Байконурда туган ханымның камыр салырга, бәлеш, гөбәдия түгел, гадәти шулпалы аш пешерергә дә теләге юк. Әзер кәтлиткә өйрәнгән кеше башка тормышка күнегә алмый икән шул.* Т.Галиуллин. *Ашханәдәге балык кәтлитен поварлар үзләре ашасын, рестораннарда да сагынып кына сөйләсеннәр – моннан соң ике аягымның берсен дә атлыйсым юк.* Ф.Баттал

**КӘТТӘ** *с. һинд. сөйл.* 1) Һавалы, мин-минле, үзен артык эре тота торган. *Машина эчендә Бик кәттә егетләр. Сөяркә-җанашлар Хур кызы кебекләр!* Ф.Яруллин

2) Дәрәҗәле, абруйлы. *Дистәләгән еллар буена Мулланур Вахитовны күкләргә чөеп, аңа һәйкәлләр торгызып, конференцияләр багышлап, эшчәнлеге турында китаплар язып, исеме белән гамәлдә сәүдә итсәләр дә, аның әнисенең каберенә аз гына булса да әһәмият бирү кәттә чиновникларның вазифасына кермәгән ахры.* Р.Әмирхан. *Кәттә кыяфәтле, мәгърур Камил бәй очраклы вә гади шәкерт белән кулга кул тотышып фотога төшәрме?* Р.Батулла

3) Бик яхшы, бик шәп. *Бүген алар планның кәттәләрен кордылар.* Т.Миңнуллин. *Югыйсә китапларыбыз сабыйлар өчен кәттә сурәтләр белән бизәлгән такмаза дәфтәренә – примитив уенчыкка әйләнеп бара.* А.Тимергалин. --- *Нурлыбикә бөтенләй икенче кешегә әйләнгән: күлмәге дисеңме, яулыгымы, хәтта аяк киеме дә яңа гына фабрикадан чыккан кебек ялтырап тора. Бик кәттә хушбуй исе дә аңкып тора җитмәсә!* Ф.Баттал

4) Бик каты, бик көчле. *Кәттә суыклар*

**КӘТТӘЛЕК** *и.* Кәттә булу үзлеге. *Психологлар әйтүенчә, теге яки бу һөнәрне сайлаганда, күпчелек, беренче чиратта, аның модада булу-булмавына игътибар итә. Кәттәлек – яхшы сәбәп, әлбәттә.* Ватаным Татарстан

**КӘТТӘҖИ** *и. фр.* Татар хатын-кызларының яулык яки шәл астыннан киелә торган, маңгай турысы чигүле баш киеме

**КӘТҮК** *и. рус* **1.** 1) Җеп яки тасма чорнау өчен, ике як башы түгәрәктән гыйбарәт эче куыш агач, пластмасс яки катыргы үзәк

2) Шундый үзәккә чорналган җеп (күпчелек очракта алдында сан килә). --- *Ә песи яшьрен генә яткан, кәтүкне күзлидер. «Тукта, селкенмәсме?» – ди ул; бер дә җаны түзмидер. Ул хәзер сикрер менә, хәзер тотар, хәзер басар, Ул кәтүкне уйнатыр, уйнар, үзенә шар ясар.* Г.Тукай. *Кәтүк кадәр малай тора. Бер кулына бавын кысып тоткан. Берсендә – алма...* Р.Фәйзуллин

3) *күч.* Кечкенә буйлы кеше

4) *тех. физ.* Металл чыбык чорнау өчен стержень. – *Игътибар итегез, әфәнделәр, – диде ул. – Ташбакалар эчендә конденсаторлар, кәтүкләр генә булса да, тере ташбакадан ким җирләре юк.* А.Тимергалин

5) Металл чыбык чорналган эче куыш цилиндр

**2.** *с. мәгъ. күч.* Кечкенә буйлы. *Ул – үзен бәхетсезгә санап йөргән кәтүк малай.* Р.Фәизов

**КӘТҮКЛЕ** *с.* Кәтүккә чорналган. *Кәтүкле җеп*

**КӘҮСӘ** *и.* Агач үсемлекләрнең төбеннән очына кадәр ботаклар җибәрә торган өлеше, төп сабагы. *Шушы ук чорда җимеш бирә торган агачларның ботакларын һәм кәүсәсен корыган сабаклардан, лишайниктан чистартырга, яңа сүндерелгән известь эремәсе белән агартырга кирәк.* Өегез ямьле булсын

**КӘҮСӘР** *и. гар.* 1) *дини* Ислам динендә: җәннәттә ага торган бик тәмле сулы елга. *Төшемдә [оҗмах] эчен күрдем. Бер тарафта балдан вә сөттән гыйбарәт кәүсәр елгасы агып ята.* Г.Тукай. *Елатасың, юатасың, И туган тел, туган тел, Кәүсәр сулар юган тел!* М.Галиев

2) *күч. шигъ.* Нинди дә булса бик татлы яки шундый булып тоелган әйбер турында. *Сылубикә, сылу туташ, кыз солтаны, Авызың зәмзәм, ирнең кәүсәр, тешең гәүһәр.* Ш.Бабич. *Безнең апай гәүһәрдер, Тәннәре чын мәрмәрдер; Ләгыль, якут, гәүһәрдер, Аузы балдыр, кәүсәрдер.* Җыр

**КӘФАЛӘТ** *и. гар. иск.* 1) Берәү өчен җаваплылыкны үз өстенә алу

2) Гарантия

**КӘФАЛӘТНАМӘ** *и. гар.-фар. иск.* Берәү өчен җаваплылыкны үз өстенә алу турында язылган кәгазь

**КӘФЕН** *и. гар.* 1) Мәетне төреп күмә торган ак тукыма. *Ә Исламны мин хәтерләмим. Аның беренче һәм соңгы күлмәге кәфен булган шул, дөньяга исемен генә калдырып киткән.* Ш.Галиев. *Нәрсә бу? Аның баш очында кәфенгә төренгән хатын-кыз күренә иде.* З.Мәхмүди

2) *сөйл.* Кәфенлек, кәфенлек материал. *Кәфене алып куелган*

◊ **Кәфендәй агарыну** Ап-ак булу (йөз, бит тур.)

**КӘФЕНЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кәфенләү**

2) *күч.* Каплану, каплап алыну (кар белән)

**КӘФЕНЛӘ́Ү** *ф.* Мәетне кәфенгә чорнау, кәфенгә төрү. *Гайфи әфәнде мөселман лазаретында бер --- төрек офицерының вафат булганын белдереп, шуны кәфенләп җирләү өчен, мәҗлестән алты кеше сорады.* К.Нәҗми

**Кәфенләп бетерү** Кәфенләүне тәмамлау; тәмам, тулысынча кәфенләү

**Кәфенләп кую** Тиз арада яки алдан кәфенләү

**Кәфенләп чыгу** Барысын да кәфенләү, ахыргача кәфенләү

**КӘФЕНЛЕК** *с.* **1.** Кәфенгә дигән, кәфен өчен билгеләнгән

**2.** *и. мәгъ.* Кәфен өчен билгеләнгән, кәфенгә дигән тукыма, материал. *Кәфенлек төсенә кергән Жихарёв ни кылырга да белмичә, әле Дохов, әле Ураков йөзенә төбәлеп тора иде.* В.Имамов. *Әсмабикә калага бара икән, кәфенлегем җитмәс сыман – бераз ак алырга куштым.* Г.Гыйльманов

**КӘФИЛ** *и. гар. иск.* **1.** Гарантия бирүче, җаваплылыкны үз өстенә алучы, ышаныч күрсәтүче. *Малыңа дошман булсаң – кәфил бул.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Җитәрлек дәрәҗәдә булган, җитә торган

**КӘФФАРӘТ** *и. гар. дини* Нинди дә булса гөнаһлы эш урынына Аллаһтан ярлыкау өмет итеп кылынган гамәл (ураза тоту, садака бирү, корбан чалу һ.б.ш.). *Кәффарәте иң азы ун мескенгә кием бирү яки тамак туйдырырлык ашарга бирү була.* Р.Фәхретдин. *Андый кешегә рамазан ае үткәннән соң уразасын каза кылу тиешле була, ә кәффарәт тиеш түгел.* Ә.Максуди. *Аларга фәтва китаплары буенча да әле кәффарәт важип түгел, каза гына важип.* Ф.Әмирхан

**КӘФФАРӘТ КЫЛУ** *ф.* Нинди дә булса гөнаһтан котылыр өчен, шәригатьтә каралган гамәлне үтәп, җәза күрү. *Рамазан уразасын үз ихтыяры белән бозган кешегә һәр көн урынына бер көн каза кылу һәм бозган өчен кәффарәт кылу фарыз була.* Ә.Максуди

**КӘҺРЕБА** *и. гар. иск.* Гәрәбә

**КӘЧЕРКӘ** *и. диал.* 1) Яшь бала башындагы кавык; йокылык

2) Кайбер яңа туган балаларның аркасына чыгып бик кычыта торган кара төк; йокылык

**КӘШӘКӘ** *и. фар.* 1) Боз яки җир өстендә уйналып туп яисә алка сугудан гыйбарәт булган спорт уенында кулланыла торган кәкре башлы таяк; *русчасы*: **клюшка**. *Димәк, ирнең дә җәфалана-җәфалана, сүгенә-төкеренә, уенчыларның капкага кәшәкә, туплар керткәненә исе китеп, экран артында төннәрен сарыф иткән чагы түгел.* К.Йосыпов

2) Боз яки җир өстендә шундый таяк белән туп яки алка сугудан гыйбарәт булган спорт уены; *русчасы*: **хоккей**

**КӘШӘКӘЛЕ ТУП** *и.* Чирәм хоккее

**КӘШӘКӘТАЯК** *и. к.* **кәшәкә.** *Хәлимне – ир баланы – кәшәтаяк, футбол, балык тоту, төннәрен ат сакларга йөрүләр үз эчләренә алып кереп киткәләр.* Г.Гобәй

**КӘШӘКХАНӘ** *и. иск. к.* **кәшәнә**. *Хәзерге Башкортстанның район үзәге булган Чишмә авылы янындагы Тураханкәшәкханәсе XIV йөздә шул рәвешле салынган.* Казан утлары

**КӘШӘЛӘНҮ** *ф. диал.* Кубалаклану, купшаклану; бозылу

**Кәшәләнеп бетү** Бик нык кәшәләнү. *Иреннәре җилдә йөреп кәшәләнеп беткән*

**Кәшәләнеп тору** Кәшәләнгән булу яки әледән-әле кәшәләнү

**КӘШӘЛӘ́Ү** I *ф. диал. к.* **кәшәләнү**

**КӘШӘЛӘ́Ү** II *ф. диал.* Аралау, әләктереп, аерып алу

**КӘШӘНӘ** *и. фар.* 1) Кабер өстенә куела торган чагыштырмача зур гына төрбә. *Былтыр Башкортстан археологлары Бәйчә дип аталган кәшәнәне казыганнар. Шуннан байтак алтын әйбер табылган.* Г.Хисамов

2) *диал.* Чардуган

**КӘШӘНКӘ** I *и. бот.* Кайбер үсемлекләрдә җимеш төбен тәшкил иткән яфраклардан гыйбарәт үсенте. *Өлгермәгән чикләвекне кәшәнкәсеннән аеру бик кыен*

**КӘШӘНКӘ** II *и. диал.* Түгәрәкләп җәйгән камыр өстенә бәрәңге боламыгы, эремчек яки сөткә кушып туглаган йомырка ягып пешерелә торган камыр ашы; дучмак

**КӘШӘТАЯК** *и. сөйл. к.* **кәшәкә** (*1 мәгъ.*). *Малае-кызы – һәммәсе бергә*

*тау шуып, боз өстендә кәшәтаяк уйнап, бергә аунап үскән балалар.* Г.Бәширов

**КӘШЕФ** *и. гар. иск. кит.* Уйлап табылган нәрсә, ачыш

**КӘШЕФ ИТҮ** *ф. иск.* Ачыш ясау, ачу; уйлап табу, уйлап чыгару

**КӘШЕФ ИТҮЧЕ** *и. иск.* Уйлап табучы, ачыш ясаучы

**КӘШЕФ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **кәшеф итү**

**КӘШЕФЧЕ** *и.* Уйлап табучы, уйлап чыгаручы, ачыш ясаучы

**КӘШИМИР** *и. к.* **кашемир**. *[Мәрфуга:] Кодагыйга бит инде кәшимир күлмәк дигән идек, кызыл кәшимир алырсыңмы, алнымы инде?* Г.Исхакый. *Сәгыйдәгә – бик гүзәл зур кәшимир шәл белән ак батис яулык...* Г.Галиева

**КӘШИШ** *и. фар. кит.* Христиан рухание; монах

**КӘШКӘЮ** *ф. сөйл.* 1) Өскә карау, өскә таба күтәрелү (кием чабуы, аяк киеменең башы)

2) Эсседән бөтерелү (яфрак). *Иген кыяклары кәшкәйгән*

**КӘШЛӘКӘ** *и.* Агачны эләктереп ию өчен бер башы ыргаклы таяк

**КӘШФИЯТ** *и. гар. иск. кит. к.* **кәшеф**

**КВАДР** *и. ит. архит.* Параллелепипед формасына туры китереп, юнып шомартылган таш (стеналар салу өчен кулланыла)

**КВАДРАНТ** *и. лат.* 1) *геом.* Квадратның дүрттән бер өлеше, сектор; *Яссылыкның дүрттән бер өлешен чирек яки квадрант дип атыйлар, димәк, яссылык дүрт чиреккә бүленгән була. Чирекләр (квадрантлар) уңнан сулга таба, почмаклар тәртибе белән саналалар.* Югары математика нигезләре

2) *астр.* Күктә яктырткычларның биеклеген почмак ярдәмендә үлчи торган борынгы прибор. *Астролябия белән рәттән квадрант дип аталган астрономик прибор да гамәлдә була. --- Квадрант горизонт өстеннән күк җисемнәренең биеклеген үлчәү өчен дә кирәк ---.* Татар милли педагогикасы

3) *хәрби* Артиллерия орудиеләрен вертикаль юнәлеш буенча төзәгәндә, почмаклар үлчәү приборы

**КВАДРАТ** *и. лат.* 1) Барлык яклары тигез булган турыпочмаклык; шуңа охшаш нәрсә турында. *Каршыдагы әнә теге квадратны миналар белән «сөрдереп» ташласаң, андагы солдатлар һөҗүмгә күтәрелә алмаячак.* Ш.Рәкыйпов. *Көтү йөргән болын җиңел ток җибәрелгән тимерчыбык белән вак квадратларга бүленгән.* М.Юныс. *Квадрат битлесе, күлмәген салып ташлап, кара йон баскан зур аркасын иптәшенең борын төбенә китереп куйды да: – Сана, ничә яра табарсың, – дип тотынды.* И.Гази

2) *мат.* Санны үз-үзенә тапкырлаганнан килеп чыккан тапкырчыгыш. *Тигезлекләренең һәр ике кисәген квадратка күтәрик тә килеп чыккан тигезлекләрне буынлап кушыйк.* Югары математика нигезләре. *Әгәр ике нейтрино хасил булса, эффект икенең квадратына – дүрт тапкырга көчлерәк булыр иде.* А.Тимергалин. *Бишне квадратка күтәрү*

3) *полигр.* Текст юлларын җыюдагы типографик үлчәү берәмлеге; ул – 48 пунктка, ягъни 18 мм га тигез

**КВАДРАТ ҖӘЯ** Квадрат формасындагы җәя [ ]. *Билгеле булмаган, әмма редакция тарафыннан куелган дата квадрат җәяләр эченә алынды.* Г.Тукай. *--- Баш җөмлә квадрат җәяләр эченә алына, ә иярчен җөмләләр түгәрәк җәяләргә алыналар, ---.* М.Зәкиев

**КВАДРАТ КИЛОМЕТР** *и. мат.* Мәйдан үлчәү берәмлеге (квадрат метрга кабатлы булган). *Ләкин биш йөз ун миллион квадрат километрлы Җир шарының коры җир (бу битләрдә шуның турында сүз барды) өлешенә барлыгы бер йөз кырык миллион квадрат километры гына туры килә.* Җир чәчәктә. *Мәсәлән, Һиндстанда вулкан чыкканда таралган лаваның 3 млн. квадрат километр җирне каплавы һәм 2000 мең метр калынлыкта булуы билгеле.* Җир һәм туфрак. *Безнең планета өслегенең һәр квадрат километры 10 миллион тоннадан артык һава басымына дучар була!* Галәм. Җир. Кеше

**КВАДРАТ МЕТР** *и. мат.* Мәйдан үлчәү берәмлеге (иңе һәм буе берәр метр булган мәйдан). *Биш кеше ундүрт квадрат метрлы бүлмәдә тора идек.* Р.Хисмәтуллин. *Үзенең серләрен гасырлар буе кешедән яшереп саклаган шәһәрнең берничә миллион квадрат метрга җәелгән мәйданын Харрас хәзер уч төбендә тота.* К.Тимбикова. *Техникум общежитиесе булганлыктан, егерме сигез яшьлек укытучы Айгөл Хәбировнага монда берүзенә тугыз квадрат метрлы бүлмә бирелгән иде.* З.Хәким

**КВАДРАТЛА́У** *ф.* Квадрат формасын бирү, квадратларга бүлү

**КВАДРАТЛЫ** *с.* Квадрат формасында булган

**КВАДРАТКА КҮТӘРҮ** *ф.* 1) Санны үз-үзенә тапкырлау. *Төрле квадратларның мәйданнарын исәпләп чыгарганда, саннарны квадратка күтәрергә туры килә.* Геометрия

2) *күч.* Нәрсәне дә булса арттыру. *Ник күтәрдек квадратка, кубка Җан ачуын, күңел тарлыгын.* М.Хөсәен

**КВАДРАТУ́РА** *и. лат. махс.* Квадрат берәмлекләр белән үлчәнә торган мәйданның зурлыгы. *Ә Анаксимандр зинданда да түгәрәкнең квадратурасын табарга тырышып баш вата...* Җ.Тәрҗеман. *Шулай итеп, квадратураларны исәпләгәндә, сызымга игътибар итәргә кирәк.* Югары математика нигезләре. *Бу доцентның күз алдында искиткеч вакыйгалар була килде, аның илендә терек табигать турындагы фән хәл ителмәслек һәм хәтта, түгәрәкнең квадратурасы шикелле үк, гомумән мөмкин булмаслык дип исәпләнгән бурычларны тиңдәшсез кыюлык белән алга куеп хәл итә иде.* Җир чәчәктә. *Бүлмәнең квадратурасы. Кечкенә квадратура*

**КВАДРИЛЛИОН** *и. к.* **квадрильон**

**КВАДРИЛЬОН** *и. фр. мат.* 1 санынннан соң 15 нуле булган сан. *Унсигез квинтильон дүрт йөз кырык алты квадрильон җиде йөз кырык дүрт триллион җитмеш өч биллион җиде йөз тугыз миллион биш йөз илле бер мең алты йөз унбиш, падишаһым!* Кызыклы математика

**КВАЗАР** *и. ингл. астр.* Җирдән миллиард яктылык еллар ераклыгында урнашкан радиояктылыкның интенсив чыганагы. *«Квазар» сүзе астрономнар*

*һәм астрофизиклар теленә беренче мәртәбә моннан җиде ел элек килеп керә. Квазар – инглиз сүзенең кыскача әйтелеше булып, «йолдызга охшаган радиочыганак» дип тәрҗемә ителә.* Зур галәм турында кечкенә хикәяләр. *1963 елны безнең Галактикадан бик еракта, күзәтелә торган Галәм чикләрендә үк, гаҗәеп объектлар табылды һәм соңыннан аларга квазар дигән исем бирелде.* Галәм. Җир. Кеше

**КВАЗИОМО́НИМНАР** *и. лингв.* Ялган омонимнар

**КВАЗИ-** *лат.* «Уйланма, ялган, чынында булмаган», «уйдырма, чынлап булмаган» мәгънәсендә килә торган алкушымча. *Квазигалактика йолдызларын яныбызда яшәүче кешедән яхшырак беләбез без.* М.Юныс

**КВАЛИФИКА́ТОР** *и.* Филологиядә: фигыль һәм сыйфатлар белдергән төшенчәләрне ачыклаучылар. *Ачыклагыч дигән терминны без рус телендәге конкретизатор (яисә квалификатор) дигән атама өчен кулланабыз.* Хәзерге татар әдәби теле. *Бу төр синтаксис [семантик синтаксис] иянең семантик ягын – субъект, хәбәрнең семантикасын – предикат, тәмамлыкның семантик ягын – объект, аергычныкын – атрибут, хәлнең семантик ягын – ачыклагыч (квалификатор яки конкретизатор) тәшкил итә дип өйрәтә һәм аларның лексик-синтаксик мәгънәләрен ача.* М.Зәкиев

**КВАЛИФИКА́ЦИЯ** *и. нем.* 1) Кешенең теге яки бу эшкә, хезмәткә яраклылык, белемлелеге, тәҗрибәлелеге. *Швейтрест менә... эшчеләргә хезмәт хакы түләргә акчасы юк, аны яба калсаң, нихәтле татар эшчесе биржага агылачак, авылларга чәчелеп, квалификациясен онытачак.* И.Гази. *Әмма миңа калса, хикмәт, батырлыктан бигрәк, үз-үзеңә ышануда, җаваплылыкта, квалификацияңә дөрес вә хак бәя бирүдә.* Сөембикә. *Звеноларны комплектлауга, работникларның, бигрәк тә машина белән саву мастерларының квалификация дәрәҗәсенә аеруча игътибар бирергә кирәк.* Н.Григорьев

2) Кешенең теге яки бу эшкә, хезмәткә хәзерлек дәрәҗәсе. *Фаҗига алдыннан гына ул Киевка квалификация күтәрү курсларына укырга җибәрелгән булган.* Ә.Сәлах. *Квалификацияне билгеләү өчен оештырылган ярышта шәхси беренчелек тә, командирларның урыны да билгеләнми, ә спортчыларның разрядын барлау яисә аны күтәрү генә күздә тотыла.* Халык һәм спорт уеннары

3) Профессия, һөнәр, белгечлек. *Анатолий Спивак, кушаматы «Бомбардир». Кайчандыр бомба ясаган булган, шуны сынап караганда, күршесенең сараен күккә очырган. ---. Аннары квалификациясен үзгәрткән, «коммерсант»ка әверелгән.* Ф.Галиев. *Ул хәрби флотта хезмәт иткән, укыган, квалификация алган, мин күргәндә дә, хәрби корабларда электрик булып эшли иде.* Ә.Еники

**КВАЛИФИКА́ЦИЯЛЕ** *с.* 1) Югары квалификациягә ия булган, хәзерлекле, белемле, тәҗрибәле. *Алар – хәзер квалификацияле, белемле, тәҗрибә туплаган кадрлар.* Х.Хәйруллин. *Беркөнне чан эчендә йөргәннән соң идәнгә төшкәндә, аягы тырналып китә. Тире микроблары тырналган ярасына эләгеп, аягы шешә башлый. Ашыгыч һәм квалификацияле ярдәм кирәк.* С.Баттал. *Алар арасыннан инженерлар, агрономнар, язучылар, галимнәр, офицерлар, врачлар һәм югары квалификацияле эшчеләр чыкты, кайберләре хезмәтләре белән бөтен республикага танылдылар.* А.Шамов

2) Үтәү, башкару өчен махсус хәзерлек, белем, җитештерү күнекмәләре сорый торган (хезмәт, эш тур.)

**КВАЛИФИКА́ЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Югары квалификациягә ия булу

**КВАЛИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Квалификация бирү. *Квалификацияләү комиссиясе*

**КВАНТ** *и. лат. физ.* Физикада: нинди дә булса энергиянең иң кечкенә өлеше яки кисәге. *Андый молекулалар – чын-чынлап тереклек учаклары, алар бөтерелә һәм сүтелә, «танып белә», «истә калдыра», реакцияләрне туктата яки аларны тизләтә, яктылык квантларын тотып ала һәм меңнәрчә башка эшләр эшли алалар.* Үсемлекләр һәм бал кортлары. *Шуңа күрә бу өлкәдә яктылыкның дулкын үзлекләре белән беррәттән квант үзлекләре дә чагылыш таба. Яктылык квантының энергиясе түбәндәгечә язылa: ---.* Физика

**КВА́НТ МЕХА́НИКАСЫ** *и. физ.* Квант теориясе ярдәмендә атом төзелешен тасвирлый торган математик теория; *русчасы:* **квантовая механика**. *Моның өчен молекуляр-кинетик теория методларын һәм квант механикасын файдаланалар.* Техника термодинамикасы. *Физика факультетында акыллы яшьләр укый, алар квант механикасы, синхрофазотроннар, атом таркату дөньясында яши иде.* Р.Хәкимов

**КВА́НТ РАДИОФИ́ЗИКАСЫ** *и. физ.* Квантлар системасы ярдәмендә электромагнитик тирбәнешне булдыру, көчәйтү һәм пространствога тартуны тикшерә торган фән; *русчасы:* **квантовая радиофизика**

**КВА́НТ САНЫ** *и. физ.* Электрон үзлеген (халәтен) тасвирлый торган дүрт санның берсе; *русчасы:* **квантовое число**. *Молекуляр орбитальгә билгеле бер квант саннары туры килә.* Гомуми химия

**КВА́НТ ТЕО́РИЯСЕ** *и. физ.* Энергия квант һәм өзлекле рәвештә йотыла яки бүленеп чыга дигән фаразга нигезләнгән теория; *русчасы:* **квантовая теория**. *Индетерминизм бигрәк тә 20 нче еллар физикасында квант теориясе барлыкка килгәндә җанланып китә.* Философия

**КВА́НТ ХИ́МИЯСЕ** *и. хим.* Химия бүлеге, квант механикасы күзаллауларына нигезләнгән (химик бәйләнеш, валентлык, кисәкчәләрнең электронлы төзелеше, электрик һәм магнитик үзлекләре турындагы тәгълиматларны үз эченә ала); *русчасы:* **квантовая химия**

**КВАНТИТАТИВ** *с.* Микъдари. *Моның өчен заманча технологияләр файдаланылды: компьютерда җыр текстлары банкы булдырылды, махсус программалар нигезендә квантитатив тикшерүләр үткәрелде; шулай ук җырлар лексикасының кулланылыш ешлыгы чагылдырылган сүзлек төзелде.* К.Миңнуллин. *Шулай акрынлап гаруз, ягъни шигырь төзелешендә квантитатив*

*принцип (озын һәм кыска авазларның чиратлашу системасы) барлыкка килгән.* К.Гыйззәтов

**КВА́РТА** *и. лат. муз.* 1) Дүрт баскыч күләмендәге аралык; язуда 4 рәкыме белән күрсәтелә

2) Диатоник гамманың дүртенче баскычы. *Пифагор тарафдарлары карашынча, музыка аһәңе тибрәнүче кыллар авызының (звукның) озынлыгы белән билгеләнә. Алар музыка теориясенә көй, ритм, гамма, октава (беренче һәм сигезенче тон арасындагы интервал), квинта (диатоник гаммада бишенче баскыч), кварта (диатоник гамманың дүртенче баскычы) төшенчәләрен кертәләр.* К.Гыйззәтов

**КВАРТАЛ** *и. лат.* 1) Елның дүрттән бер өлеше (өч ай). *Димәк, беренче квартал – январь, февраль, март – 90 көн була?* Кызыклы математика. *Киләсе кварталда дүрт яңа кораб алабыз.* М.Юныс. *Монда көнлек, айлык, квартал планнарының үтәлеше дә, материаль һәм мораль стимулларның картага куелуы да һәркемгә мәгълүм.* М.Хәсәнов. *Шикләнмәскә мөмкин, бу кварталда планны шактый арттырып үтибез, болай булгач.* Р.Төхфәтуллин

2) Шәһәрнең дүрт яктан кисешеп үтә торган урам һәм мәйданнар белән чикләнгән өлеше. *Шулай итеп, бу дүрт бина тау итәге буйлап аскы урамга – Проломнаяга ук төшкән зур кварталны тәшкил итә иде. Румовский архитекторга бу кварталның планын эшләргә кушты, ә үзе Училищелар баш идарәсеннән гимназия янәшәсендәге губернатор йортын университетка бирүне һәм, булачак югары уку йорты биналарын бербөтен итеп берләштерү максатында, күршедәге тагын ике таш пулатны сатып алуны сорарга булды.* Җ.Тәрҗеман. *Күршедәге кварталның өске ягында гына 1 нче клиник больница бар иде, әбине шунда салганнар икән.* Х.Сарьян. *Ярты гына ел элек өч квартал араны ял итми бик ансат кына бара булган, хәзер бер квартал да йөри алмый икән.* И.Гази

3) Урамның ике чат арасындагы өлеше. *Шәйхетдинов ярты кварталга сузылган чиратның койрыгына килеп басты.* И.Гази. *Квартал саен – собор, һәр юл чатында – Иисус Христос сыны.* М.Юныс

4) *махс.* Урман хуҗалыгында билгеле мәйданнарга, территорияләргә бүленгән квадрат формалы участок. *[Малай:] Әти утыз сигезенче кварталга китте. Анда Тукай колхозыннан, урман кисеп, агач чыгаралар.* Э.Касыймов. *Район һәм шәһәр тирәсендәге фәлән-чәфәләнчә урман кварталларын самолёттан агулау үткәрелачәк, диелгән иде анда.* А.Хәсәнов

5) *махс.* Парникларның туры почмаклары. *Парникларны туры почмаклы формадагы аерым парник кварталлары итеп урнаштыралар. Зур булмаган хуҗалыкларда парникларның туры почмаклары (кварталлары) арасындагы юл, әгәр алар тик ике генә булса, 5 метр чамасы киңлектә эшләнә.* Яшелчәчелек

**КВАРТАЛЛЫК** *с.* Бер кварталга (өч айга) билгеләнгән, җитәрлек, бер кварталда эшләнерлек (план, бюджет, эш һ.б.). *Хәзер бер цех җитәкчеләре алдына шундый таләп куябыз: алар һәрбер эшчегә аның айлык, кварталлык планын кулына бирергә тиешләр.* Г.Әпсәләмов. *Кварталлык эш*

**КВАРТА́ЛЬНЫЙ** *и. рус* Надзиратель; өстән карап, күзәтеп, тикшереп торучы кеше. *Берәр сәгатьтән, аларны эзләп, полиция килде. Өйдәге барлык әйберне актарып, әллә ниткән кәгазь эзләделәр. Квартальный, очына-очына, Гыймадига бәйләнде ---.* К.Нәҗми. *Ә менә Түбән Елгада зур үзгәреш бар: әнә квартальныйлар чаба-чаба тырышып йөриләр.* Г.Толымбай

**КВАРТЕТ** *и. ит. муз.* 1) Дүрт тавыш яки дүрт уен коралы өчен язылган музыка әсәре. *Студия дәвере татар совет музыкасы үсешендә --- яңа яшь композиторлар үсеп чыгу һәм татар музыкасының күп тавышлы хор, сюита, квартет, симфония һәм опера кебек катлаулы жанрларга баюы белән характерлы.* М.Җәлил. *Вена классик мәктәбе симфония, соната, концерт, квартет һ.б. жанрларның тәмам формалашып җитүен тәэмин итә.* К.Гыйззәтов

2) Дүрт кешелек музыкантлар яки җырчылар ансамбле. *Үзешчән сәнгать смотрында безнең квартет беренче урынга чыкты.* А.Гыйләҗев. *Сәхнәгә дүрт музыкант – квартет: пианист, контрабас, ударник һәм кларнетист урнаштылар.* М.Маликова. *Олы кунаклар хөрмәтенә мәҗлескә шәһәрдә тиңнәре булмаган кыллы квартет чакыртылган иде.* Р.Мөхәммәдиев

**КВАРТИР** *и. к.* **квартира**. *Квартир алдым, өйләндем, инде менә бәби көтәбез дип, шәхси тормыштагы шатлыкларны да бүлешеп.* Ф.Галиев. *Меңләгән кеше зарыгып көткән яңа квартирларына ярты елга алдан күчәчәк.* Р.Хисмәтуллин. *Иптәшләрдән аның квартир номерын сорадым да, пиджагымны иңбашыма гына салып, аның кватирына чаптым.* Г.Толымбай. *Монда фатир хакы кыймәт. Квартирга түләргә мескеннәрнең акчалары җитми.* М.Юныс

**КВАРТИ́РА** *и. нем. кит.* 1) Торак йортның бер яки берничә бүлмәсе, кухнясы һ.б. (тулы яки өлешчә уңайлыклары) булган бер өлеше. *Шунда мин управдом кешеләреннән квартирага теркәлү тәртибен сораштым.* С.Баттал

2) Гомумән тору, яшәү урыны. *Гөлчәһрә апалары белән бер квартирада яшәү – алар өчен тормыш мәктәбе.* С.Шәкүров. *Яковкиннар квартирасында кемнеңдер клавесинда уйнаганы ишетелде.* Җ.Тәрҗеман. *Квартирам тулысынча җиһазланган: суыткыч кына түгел, һава кондиционерына кадәр бар.* А.Тимергалин

3) Билгеле бер түләү шартларына килешеп, вакытлыча тору урыны. *Баштагы хыялыннан кайтып, бу квартирадан үзе китү юлы белән усал күршедән котылу фикеренә төште һәм сабырлык белән уңайлы квартира табылу җаен көтә башлады.* М.Әмир

**КВАРТИ́РАЛЫ** *с. к.* **квартирлы**. *Шулай шаяру белән башланган әңгәмәдән соң, Рәсүл квартиралы булып кала.* М.Хәсәнов. *Икенчедән, бу эшкә юл куйган әбиләренең нинди ният белән балаларны алып калуы хәзер һәркем өчен ачык күренеп тора: үлгән кызы*

*балаларының язмышын ул тере кызын квартиралы итү хакына корбан итәргә әзер тора. Моңар юл куймаска кирәк.* С.Баттал. *Бикташлар пыяла заводының бер катлы, өч квартиралы озын агач өендә яшиләр.* М.Маликова

**КВАРТИРАНТ** *и. рус* Билгеле бер түләү шартларына килешеп (яшәгән квартирына берниндн хокукы булмаган), вакытлыча квартирда торучы, өйдәш, фатирчы. *Элекке хуҗалар хәзер үз өйләренә квартирант булып кына, вакытлыча керергә хокук яулап алганнардыр инде.* С.Баттал. *Әниле-кызлы икесе дә Хәлимгә әллә ияләшеп җитә алмыйлар, әллә авылларында гадәт шундыймы, квартирантлары белән чаршау аркылы гына сөйләшәләр.* И.Гази. *Ләкин монда мин чит кеше, квартирант кына...* Ә.Баян

**КВАРТИРЛЫ** *с.* 1) Берничә квартирдан торган (гадәттә сан белән янәшә килә). *Әйе, гадәти биш катлы, дүрт подъездлы, 64 әр квартирлы йортлар булачак алар.* М.Маликова. *Әйе, Уфада гаиләле, эшле, квартирлы булып, журналистикада да шактый танылып, тәмам тамыр җибәреп яшәп киткәндә генә, тәртәне кире Казанга борырга мәҗбүр идем.* Х.Сарьян

2) Үз квартирасы булган; яшәү, тору урыны булган

**КВАРТИРМЕ́ЙСТЕР** *и. нем. хәрби* Гаскәрләрне азык-төлек, квартир белән тәэмин итү эшләрен башкаручы. *Менә бу бүлмәдә квартирмейстер поручик Михайлов яши.* Җ.Тәрҗеман

**КВАРТИРЬЕР** *и. нем. хәрби* Гаскәрләр бер урыннан икенче урынга күчкәндә, алдан барып, квартир белән тәэмин итеп торучы хәрби кеше. *[Алёша], квартирьер булып, ерактагы бер авылга киткән иде, аны шунда тотып алганнар.* А.Шамов. *Квартирьерлар тырышалар. Сезнең отряд кешеләре өчен башка йортлар табылачак.* И.Туктар

**КВАРТО́ЛЬ** *и. лат. муз.* Өч өлешле озынлыкны шартлы рәвештә өч урынына дүрт тигез кисәккә бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган вәзенле төркем

**КВАРТПЛА́ТА** *и. рус* Квартир хакы; квартир өчен ай саен түләнә торган билгеле бер акча күләме. *[Алсу:] --- Квартплата түләдем, баланың яслесенә дә түләр чак җиткән иде, язгы пәлтәңнең тышлыгын әйләндерергә бирдем, җир участогы өчен взнос тапшырдым, йорт әйберләрен страховать итәргә агент килде, ссуданың бер өлешеннән котылдым...* К.Кәримов. *Ел буена ял күрмичә ат кебек эшлисең, ә бар акчаң квартплата белән хатынның кредит түләвенә китеп бара.* И.Хәйруллин

**КВАРЦ** *и. нем. махс.* 1) Кристалл рәвешендәге төссез минерал (кремний диоксиды, силикатлы беренчел минерал). *Аларның гәүдәләре аксым кушылмаларының эсседән курыкмый торган аналогларыннан төзелгән, ә каннарында – сыек кварц. Һәм көз көне кварц елгасының өсте кварц бозы белән каплангач, бу затларга салкын була – аларның туган стихияләре туңа.* Химиянең киләчәге. *Солодь ясалу процессында, көлсу туфраклардагы шикелле тимер һәм алюминий окислары, юылып, иллювиаль катлауда тупланса, кремнезем, киресенчә, кварц яки аморф матдә хәлендә өске катлауда җыйнала килә.* Җир һәм туфрак. *Гравитлы кварц*

2) *сөйл.* Кварцлы лампа белән нурландыру эше; билгеле бер процедура. *Аның өстенә иртәнге якта кайсын рентгенга, кайсын кварцка, кайсын ингаляторга алып барырга кирәк.* Э.Шәрифуллина. *Аңа грязелечение, кварцлар, тагын ниләрдер кирәк түгелме?* М.Мәһдиев. *[Людмила Герасимовна:] Күреп торасыз ич: уколларын ясыйбыз. Кварцка йөртәбез.* Ф.Яруллин

**КВАРЦИТ** *и. нем. геол.* Кремнезем белән цементлашкан кварц комнарыннан торган метаморфик тау токымнары. *Ә вольфрам чыганаклары, киресенчә, моннан миллион еллар элек җир астыннан өскә эрегән гранит һәм кварцитлар бәреп чыккан урыннарда гына булырга мөмкин.* Дөньяда ниләр бар. *Шуңа күрә мондый тауларда метаморфик, палеозой токымнарыннан сланец, кварцит, комташ, известьташ һәм башкалар очрый.* Җир һәм туфрак

**КВА́РЦЛЫ** *с.* Составында кварц булган. *Әче интрузив токымнарга – гранит һәм гранодиорит, эффузив токымнарга липарит һәм кварцлы порфир керә.* Җир һәм туфрак. *Аны известь измәле кварцлы токымнан җитештергәннәр.* Татар милли педагогикасы. *Кварцлы руда*

**КВА́РЦЛЫ ЛА́МПА** *и. махс.* Ультрафиолет нурлар булдыру өчен, кварцтан ясалган, кечерәк көпшә формасындагы электр лампасы (медицинада, авыл хуҗалыгында һ.б. кулланыла)

**КВАС** *и. рус сөйл.* Арыш ипиен кыздырганчы киптереп, шуннан ясалган әчкелтем эчемлек. *Нина, эч әле әйдә. Алай килешми инде ул. Квас кына ич...* С.Рафиков. *Әтисенә салкын квас алып килгәндер.* Ф.Шәфигуллин. *Егет белән кызны тәмле квас белән сыйлагач, ул аларның квасны мактавына бик канәгать булып сакалын сыйпаштыргалады, мыек чылгыйларын югарыга таба бөтереп җибәрде.* Э.Касыймов

**КВИКСТЕП** *и. ингл. муз.* Фокстрот биюенең бер төре. *Кайчандыр «борынгы» танецларны өйрәнсәм дә, мин үзем замана кешесе бит. Квикстеп, самба дигәннәре дә бар бугай әле.* Р.Кәрами

**КВИ́НТА** *и. лат. муз.* 1) Биш баскыч күләмендәге тавыш аралыгы; язуда 5 рәкыме белән күрсәтелә. *Әсәрнең төп үзенчәлеген музыкаль җөмлә башындагы квинта интервалының түбән төшүен чагылдырган интонация хасил итә.* Милли моңнар

2) Диатоник гаммада бишенче баскыч. *Пифагор тарафдарлары карашынча, музыка аһәңе тибрәнүче кыллар авазының (звукның) озынлыгы белән билгеләнә. Алар музыка теориясенә көй, ритм, гамма, октава (беренче һәм сигезенче тон арасындагы интервал), квинта (диатоник гаммада бишенче баскыч), кварта (диатоник гамманың дүртенче баскычы) төшенчәләрен кертәләр.* К.Гыйззәтов

3) Кайбер музыка коралларының иң нечкә кылы

**КВИНТЕТ** *и. ит. муз.* 1) Биш тавыш яки биш уен коралы өчен язылган музыка әсәре

2) Шундый әсәрне башкаручы биш кешелек музыкантлар яки җырчылар төркеме. *Безнең квартет квинтетка әйләнде, шунда өйрәнер идек [ул җырны].* А.Гыйләҗев. *Тәртипләре әллә*

*ни түгел, күрәсең, оркестр дигәннәре квинтет кына булып чыга.* Ә.Баян

**КВИНТИЛЛИОН** *и. к.* **квинтильон**

**КВИНТИЛЬОН** *и. мат.* 1 саныннан соң 18 нуле булган сан. *Унсигез квинтильон дүрт йөз кырык алты квадрильон җиде йөз кырык дүрт триллион җитмеш өч биллион җиде йөз тугыз миллион биш йөз илле бер мең алты йөз унбиш, падишаһым!* Кызыклы математика

**КВИНТОЛЬ** *и. лат. муз.* Төп озынлыкларны шартлы рәвештә дүрт урынына биш тигез өлешкә бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән вәзенле төркем

**КВИНТЭССЕ́НЦИЯ** *и. лат. кит.* Нәрсәнең дә булса нигезе, төп асылы, эчтәлеге, иң мөһиме. *Соңгы ике юлны Дәрдемәнд эстетик карашының тозы, квинэссенциясе һәм Тукайга киңәше дияргә мөмкин.* Г.Халит. *Бишенче элементның латинча исеме – квинтэссенция сүзе – бүгенге көннәргәчә безнең телебездә һәр нәрсәнең, һәр күренешнең нинди дә булса иң төп ягының символы буларак сакланып килә.* Галәм. Җир. Кеше. *Шигырьнең соңгы ике юлы – аның квинтэссенциясе*

**КВИТА́НЦИЯ** *и. ит.* Акча, документлар һ.б. нәрсәләр кабул итү турында бирелә торган махсус формадагы рәсми кәгазь. *Биекъяр элеваторында бер төркем кеше, икмәк тапшыру турында ялган квитанцияләр сатып, хөкүмәтне алдап, талап ятканнар икән.* М.Маликова. *Инде йокларга вакыт җитте дигәндә, Шәмгун карт башлыкка берсекөнгә үк мүкләк сыерын хәзерләүләр конторасына җитәкләп килеп, аны тапшырганына квитанция алып китәргә вәгъдә итте.* Ә.Гаффар. *Хуҗа, бик эре кыланып, икмәк тапшыру квитанцияләрен авыл советы членының күзенә китереп терәде.* Я.Зәнкиев

**КВО́РУМ** *и. лат.* Берәр оешманың җыелышын тулы хокуклы итеп санау өчен, закон яисә инструкция буенча беркетелеп куйган җитәрлек катнашучылар саны. *Депутатларга юлланылган телеграммалар барып җитмәсә дә, самолётларга утыру һәм шәһәрләреннән чыгып китүдә төрле-төрле каршылыклар тудырылуга да карамастан, кворум артыгы белән бар иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Теләсә нинди мәсьәләне хәл итәргә дә безнең кворум җиткән булыр иде.* Ш.Мөдәррис. *Гаепле кеше кебек бик авырлык белән Нуриев торып басты: – Иптәшләр, чыннан да, җыелышның кворумы җитеп бетмәгән безнең.* Ф.Садриев

**КВО́ТА** *и. лат. икът.* Компаниядә катнашучыларның һәркайсы җитештерергә яки сатарга хаклы булган товарлар күләме, нормасы. *Минем чыгышым квота буенча эшкә урнаштырылырга тиешле гражданнарга каршы дип бәяләнмәсен иде.* Т.Миңнуллин. *Аннары чит ил профессорларын бирегә китереп укытуга да квоталар калдырдык.* Шәһри Казан

**КЕБЕК** *бәйл.* 1) Бер нәрсәне икенче нәрсә белән чагыштырып, тиңләштереп, охшатып әйткәндә кулланыла. *Ул аю кебек юан, таза бер кеше иде.* Н.Фәттах. *Мамык кебек йомшак кар яуган иде.* А.Шамов. *Шамил башын күтәргәндә, тегеләр, салкын суга төшкән мәче балалары кебек, төрле яклап чинаша, елаша иделәр.* З.Фәтхетдинов

2) Берәр нәрсәне шартлы рәвештә чамалап әйткәндә кулланыла. *Кабинетка җыелучылар барысы аңлый һәм сиземли иде кебек: хәлиткеч сәгатьләр якынлаша.* Р.Мөхәммәдиев. *Шулай да ниндидер шатлык көтә төсле аны, күңеле дә шуңа җилкенә кебек.* Ш.Маннур. *Ләләнең йөзе агарынган, интеккән кебек күренә.* Г.Әпсәләмов

3) Берәр нәрсә турында чамалауны, шөбһәләнүне, икеләнүне, шикләнүне белдерә. *Кемдер, нидер аны менә хәзер үк тотып алыр кебек тоела.* Ш.Маннур. *Рәхиләнең колагына аяк тавышы, ишекнең ачылганы ишетелгән кебек булды...* Н.Нотфуллина. *Сәламләшү каяндыр кое төбеннән ишетелгән кебек тоелды.* Н.Гыйматдинова

4) Бер-беренә нинди дә булса үзенчәлекләре белән охшаш предметларны санап киткәннән соң, шундый ук әйберләр тагы да барлыкны күрсәтә. *Халык телевизор, суыткыч, кер юу машинасы кебек әйберләрне ремонтлатырга күрше районнарга йөри.* Ф.Садриев. *Пычак, ачкыч, кайчы, шырпы, каләм, кәгазь вә язу карасы кебек әйберләр, ашханә әсбаплары – һәркайсы үз урыннарында, билгеле бер җирдә торырга тиеш.* Р.Фәхретдинов

5) Кем яки нәрсәнең бөтен, тулы сыйфатлы булмавын, шуңа беркадәр охшашлыгын гына белдергәндә кулланыла. *Агач ботакларыннан кап кебек нәрсә ясап, ул малайны шунда утыртты, аннан, иелеп, капны аркасына киде.* Ф.Бәйрәмова. *Бәлкем, бергәләп, берәр кибет кебек нәрсә дә ачып җибәрербез.* Ф.Садриев. *Агроном кебек нәрсә. Өстәлдә коймак кебек нәрсә*

**КЕБИ** *бәйл. иск. к.* **кебек**. *Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга, Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.* Г.Тукай. *Үзем дә, шуңар тәмам бирелеп, иске хатирә дәфтәрен актарган адәм кеби, артта калган күренешләрне актара башлыйм!* Г.Ибраһимов. *Менә монда Казандагы кеби купальнялар булса, һәйбәт булыр иде.* Г.Исхакый

**КЕГЕЛЬБАН** *и. нем. спорт* 1) Кеглиларны урнаштыру, басмага тезеп кую, шарларны тәгәрәтү урыны

2) Кегли уйный торган урын, мәйданчык, бүлмә

**КЕ́ГЛИ** *и. нем. спорт.* 1) Билгеле бер тәртиптә тезелгән таякларны агач шар белән бәрдереп аудару уены

2) Шушы уен өчен шомартылган таяклар. *Кеглиләрне тезү*

**КЕГЛЬ** *и. к.* **кегель**. *Кегль зурлыгы*

**КЕ́ГЕЛЬ** *и. нем. типогр.* Шрифтның зурлыгы (ул литерларның өске һәм аскы стеналары арасындагы аралык белән үлчәнә). *– Ә ник башы мондый вак хәреф – уналтынчы кегель белән генә? – дидем.* Ш.Камал. *Аның тырышлыгы белән гарәпчә басма хәрефләр камилләштерелә: яңа кегельләре булдырыла.* Х.Миңнегулов

**КЕ́ДА** *и. чех. спорт* Брезенттан тегелгән, сырлы резин аслы, шнурлы, җиңел спорт аяк киеменең бер төре (көндәлек тормышта да киелә). *[Ренатның] аягында кыска кунычлы кедалар.* А.Гыйләҗев. *Сәетҗан абыйның күк чалбар балаклары, күлмәк җиңнәре ләмгә буялды, Бикташның кедаларына су тулды, ләкин алар берсе дә моңа игътибар бирмәде.* М.Маликова. *Уенга*

*егетләр өсләренә футболка, трусик, кызлар футболка, юбка, гетры, аның эченнән аякны саклагычлар, бутсы (кеды яки тапочка да ярый) киеп чыга.* Халык һәм спорт уеннары

**КЕДР** *и. гр. бот.* 1) Наратчалар семьялыгыннан ылыслы мәңге яшел агач. *Көмешлесу авылының ындыр артыннан ук кедр урманы башлана.* Я.Зәнкиев. *Кедр башларына үрмәләп, урман мәчесе җитезлегенә өйрәндем.* Р.Низамиев. *Әллә нишләтә кедр урманы кешене, һавасының сафлыгы күкрәкләрне киңәйтә, беләккә көч, күңелгә дәрт өсти.* Я.Зәнкиев

2) Чикләвек бирә торган кайбер нарат төрләренең халыкта киң таралган исеме. *Байкал күле буенда, кедр һәм карагай агачлары арасында «Байкал» санаториеның матур корпуслары урнашкан.* Социалистик Татарстан. *Себер кедры*

**КЕДРАЧ** *и. рус к.* **кедр**. *Ындыр артыннан гына кедрач башлана, ул балыклары белән дан тоткан Йөгәр күлгә барып тоташа.* Я.Зәнкиев

**КЕЙЛОННАР** *и. күпл. мед.* Тукымадагы күзәнәкләр бүленешен һәм ДНК синтезын туктатып торучы шул тукыма матдәләре (аксым яисә гликопротеидлар)

**КЕЙС** *и. ингл.* Китап, дәфтәр, кәгазь, документларны һ.б. салып йөрү өчен уңайлы кечкенә портфель, чемодан сыман яссы сумка. *Диңгездә очраган авырлыкларны, аның каршылыкларын тәти галстук, атташе-кейс белән генә җиңеп булмый.* М.Юныс. *[Фарис:] Кем чемпиондыр әле? Мин үземне призёрга гына чутлыйм. Туган көнең белән, дускай. Менә бу кейс бездән, докторлык диссертацияңне ташып йөрергә.* Р.Зарипов

**КЕЙФ** *и. мед.* Гашиштан исерүнең беренче стадиясе; бу вакыт өчен канәгатьлек, рәхәтлек, үзеңне көчле итеп тою хисе хас

**КЕКС** *и. ингл. кулин.* Май һәм йомыркага гына изелгән камырга йөзем һ.б. тәмләткечләр кушып, төрле формаларга салып пешерелә торган татлы ашамлык. *Рәхим кибеткә кереп --- ике кекс һәм ике йөз грамм шоколад конфет алып чыкты.* А.Расих. *Әле ярый кесәгә берничә кекс төреп тыккан идем.* Ф.Шәфигуллин. *Гамир рәхмәт әйтеп эчеп җибәрде дә шоколад сындырып капты, анннары сыр белән кекска үрелде.* З.Фәйзуллин

**КЕ́ЛАРЬ** *и. лат. дини* Монастырьда хуҗалык эшләре белән идарә итүче монах

**КЕЛӘ** *и.* Ишек, капка, чолан һ.б.ш. кебекләрнең ыргаксыман бигe. *Чәйләгәннән соң, маллар янына чыгарга торганда, өйалды ишеге келәсе күтәрелгән тавыш ишетелде.* М.Хуҗин. *Этне оясына кертеп келәне элде дә чүгәләгән көе катып калды.* Г.Рәхим. *Ул капканың тимер келәсен чыңлатып ачты да, ярсаланып беткән имән баганага сөялеп, әйләнә-тирәсенә күз салды.* Ә.Гаффар

**КЕЛӘЙ** *и. рус* Әйберләр ябыштырганда кулланыла торган ябышкак куе сыекча; җилем. *Моның өчен шөреп урыннарын нечкә борау белән тишеп, шул тишекләргә сумала яки келәй салына, шөрепләрне шуңа борып керткәч, чаңгылар табаны белән өскә каратып куела.* Чаңгы юллары

**КЕЛӘЙЛӘНҮ** *ф.* 1) Әйберләр ябыштырганда кулланыла торган ябышкак куе сыекчага пычрану, буялу

2) Бозылу, эштән чыгу, яраксызга әйләнү

**Келәйләнеп бетү** Тулысынча ябышкан хәлдә булу

**КЕЛӘЙМӘ** *и. рус* 1) Товарда аның сортын, артикулын, эшләп чыгарган предприятиенең исемен һ.б. күрсәткән билге, мөһер. *Яковенко аннан бер әйбер алды да, утка якынрак килеп, келәймәсен карады. «Күрәсеңме?» Келәймә французныкы иде.* Рәхмәт сиңа, солдат! *Хәзер Сания әзер продукцияне контрольсез, үз келәймәсен сугып кына тапшыра.* Казан утлары. *Ботинкаларга келәймә сугу*

2) Хайван тиресенә яндырып сугылган билге, тамга. *[Атның] Уң ботында өч боҗралы келәймәсе булырга тиеш... Әһә, нәкъ шундый келәймәсе дә бар.* М.Әмир

3) *тар.* Гадәттә, өстәмә җәза буларак, җинаятьченең тәненә хәреф формасында яндырып ясалган тамга (кайбер феодаль һәм буржуаз илләрдә һәм 1863 елга кадәр Россиядә кулланыла)

4) Келәймә сугу коралы. *Газинур келәймә сабы белән бүреген күтәрә төшә.* Г.Әпсәләмов

◊ **Келәймә сугу** 1) Берәр нәрсәнең билгесен, төсен бирү. *Кысык, тар гаилә тормышы эчендә, аннан ярлы үткәрелгән шәкертлек гомере мәдрәсә яшьләренең йөзенә каторга келәймәсе суга.* Г.Ибраһимов; 2) Хурлыклы исем бирү. *Шундый чакта йөрәгендә әхлакның югары суды аны хөкем итә иде, төрле келәймәләр сугып...* Р.Харис

**КЕЛӘЙМӘЛЕ** *с.* 1) Келәймә сугылган. *Келәймәле ит*

2) *күч.* Начар ягы белән танылган, начар ягы белән халыкка билгеле (кеше тур.)

**КЕЛӘЙМӘЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **келәймәләү**

**КЕЛӘЙМӘЛӘ́Ү** *ф.* Келәймә сугу. *Әзер мехларны келәймәләү*

**Келәймәләп бетерү** Бөтенесен дә келәймәләү

**Келәймәләп кую** Келәймә сугып, әзер хәлгә китерү

**Келәймәләп тору** Даими яки регуляр рәвештә, һәрвакыт келәймәләү

**Келәймәләп чыгу** Һәммәсен, барысын да келәймәләү

**КЕЛӘМ** *и. фар.* 1) Идәнгә җәю, стеналарны бизәү һ.б.ш.лар өчен кулланыла торган, төрле төстәге рәсемнәр, бизәкләр төшереп эшләнгән әйбер; ковёр. *Идәнгә буйдан буйга яхшы келәмюл җәелгән, стенада да келәм, ә каршы як стенада – ат чаклы пар аккош рәсеме.* Р.Төхфәтуллин. *Миңа каршы стенада затлы келәм, идәндә келәм, коридорда келәм, йокы бүлмәсе идәненә дә келәм.* М.Хәбибуллин. *Кыйммәтле келәмнәрдән, машиналардан, алтын йөзекләрдән түгел, әнә чабата саткан тиеннәрдән дә башлана икән ул тату, бәхетле тормыш.* Р.Хисмәтуллин

2) *күч.* Нинди дә булса урынны тоташ каплап алган, куе үскән нәрсә (гадәттә, үсемлекләр тур.). *Хуш исле нарат урманнарына, көмеш елгаларга, якты күлләргә, хәтфә келәм япкан төсле ямь-яшел тауларга карап кем генә сокланмас икән!* М.Насыйбуллин.

*Без үз әйләнә-тирәбездә болыннарны һәм урманнарны, башаклы ашлыклар келәме артындагы елга буйларында үскән камышларны күрәбез. Җирнең йөзе ул – тереклекнең йөзе.* Җир чәчәктә

3) *спорт* Спортчылар егылган яки сикергән вакытта бәрелеп-сугылып имгәнүдән саклау өчен калын җәймә. *Көндәшеңне келәмнән күтәреп, күкрәк аша бәрү өчен, сөлгене уң кулыгызга чорнагыз.* Халык һәм спорт уеннары

**КЕЛӘМЛЕ** *с.* Келәм эленгән яки җәелгән; келәме булган. *Ул башын келәмле стенага таба борды, берникадәр сагаеп, тынып утырганнан соң, йомшак кына итеп Гөлфиягә эндәште.* Ф.Шәфигуллин. *Хәзер аларны тарих истәлеге итеп, келәмле стенага элеп куярга ярый.* С.Сөләйманова

**КЕЛӘМЧЕ** *и.* Келәм сугучы. *Аннары сеңлесе Зәйтүнәне келәмче әрмән сорады.* М.Хәбибуллин. *Шуннан соң келәмче Салия эзсез юкка чыкты.* Р.Батулла

**КЕЛӘМЧЕЛЕК** *и. махс.* Декоратив-гамәли сәнгать төре; интерьерны бизәү, матурлау, өйнең җылылыгын саклау өчен кулланылган келәм җитештерү; *русчасы:* **ковроделие**

**КЕЛӘНҮ** *ф. диал.* Теләнү; хәерсадака сорап йөрү, сорашу. *Ә син... йөр инде төсләнгән тәртә арасына кереп келәнеп! Келәнмәсәң кая бара аласың? Кем син?!* И.Салахов

**КЕЛӘНЧЕЛ** *и. бот.* Ялтырап торган кыяк яфраклы, кар эрү белән чыгып, төрле төстә чәчәк ата торган, лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык суганчалы үлән үсемлек; *русчасы:* **пролеска**. *Келәнчел яки умырзая кебек үсемлекләр кыш көне кар астында ук үсәләр.* Ботаника

**КЕЛӘТ** *и. рус* 1) Иген салу, он һ.б. кирәк-яракны саклау өчен хуҗалык корылмасы; амбар. *Ниса казларны агач келәткә тәрәп салынган кирпеч сарайга чыгарып урнаштырды.* М.Хуҗин. *Келәттән урланган дүрт капчык бодайны башта аңарга куеп торганнар.* Г.Толымбай. *Зур таш келәтнең бер почмагында тау булып эреле-ваклы капчыклар ята.* И.Салахов

2) Эссе җәй көнендә тору өчен, йорт янына яки аннан читкәрәк салынган мичсез махсус бина. *Берничә көннән соң инде ул, тынычлана төшеп, ындырлар, келәтләр тирәсендә нык-нык басып, ашыгып, ашыктырып эшләп йөри башлады.* А.Шамов. *Җәй көне келәттә йоклаудан да рәхәт нәрсә юк. Үзе салкынча, үзе караңгы.* С.Шәкүров. *Ян тәрәзәгә каршы кечкенә келәт. Келәткә ялганып артка таба сузылган лапас.* М.Әмир

**КЕЛӘТЧЕ** *и.* Иген салу, он һ.б. кирәк-яракны тарату эшен башкаручы эшче. *Колхозның Югары Тегермәнлек авылындагы келәтчесенә кереп яхшы гына сыйланып та чыкканлыктан, аның йөрәге ярсулы иде.* С.Рафиков. *Саран булмаса да, сак тота иде хисапчы кыз. Әйтерсең гомере буена келәтче булып эшләгән.* Н.Әхмәдиев. *Авыруын авыру, әмма Потый Шәфикъ тормышка берегеп яши: колхозда келәтче, эшен тырышып башкара, исәп-хисапны да төгәл алып бара ---.* Ә.Сәлах

**КЕЛӘШЧӘ** *и. рус* Нәрсәне дә булса кыстырып алу һәм суырып чыгару өчен кулланыла торган кыскыч формасындагы металл инструмент; каргаборын. *Борһан шул кызган утлы тимерләрне келәшчәгә эләктереп ала да сандалда чүки.* С.Рафиков. *Тамак ялгагач, алар кулларына чүкеч, келәшчә алалар, уенчык шикелле кечкенә өстәл-урындыкларның сынган аякларын, какшаган аркаларын кагып-сугып куялар.* М.Маликова. *Шунда тышкы стенасы буенда бик яхшы итеп эшләнгән верстак тора, ә эчке бер стенасына төрле эш кораллары эленгән: балта, пычкы, чүкеч, келәшчә, борау, кыскыч, өтерге, фуганка һәм башка шуның кебекләр.* А.Шамов

◊ **Келәшчә белән тартып алу** Аз сүзле кешене бик авырлык белән сөйләтү, аңардан мәгълүмат алу. *Әйтсә, бераәйле әйтә, әйтмәсә, сүзен авызыннан келәшчә белән дә тартып ала алмыйсың.* Ш.Рәкыйпов. **Келәшчә кебек** Бик каты. *Кемдер арттан килеп, үзенең келәшчә кебек куллары белән мине эләктереп, кочаклап күтәреп тә алды.* Ә.Айдар. *[Җирән эт:] Җибәр, җибәр, дим мин сиңа! Нәрсә келәшчә кебек эләктердең!* Ә.Хәсәнов. *Әмма сазлык аны нык тоткан, аякларыннан келәшчә кебек эләктереп алган иде.* Ф.Бәйрәмова. **Келәшчә шикелле** *к.* **келәшчә кебек**. *Маһруйның бит очлары, сипкелләре чәчрәп коелырлык булып кызышкан, ул курка, чөнки Салыйның бер яман гадәтен бик яхшы белә: мыекларын тырпайткан бу егет кызларны авырттырып чеметмичә яннарыннан уза алмый. Ә бармаклары каты, келәшчә шикелле!* М.Маликова

**КЕЛӘ́Ү** *и. диал. к.* **гыйбадәт**. *Болгармы бу, келәү йортымы, Тулган җыен кирәмәт имчесе.* Н.Исәнбәт. *Әле ни бәйрәм, ни келәү, тиле кызның туедай, тик тормыштын эчеп утыруны кайдан уйлап чыгардың?* Г.Камал. *Шуннан соң шыйлык йоласын җитәкләүче олы агайлар, картлар, табакларны тотып, кабат келәү әйтәләр.* Р.Ягъфәров

**КЕЛӘҮ АЕ** *и.* Октябрь. *Келәү ае керүгә карамастан, мәдрәсәдә сабакларны башламый торды имам-мөдәррис: һаман да хуҗалык кирәк-яраклары артыннан йөрде.* Җ.Рәхимов

**КЕЛӘ́Ү ИТҮ** *ф. дини* Гыйбадәт кылу. *[Татарларның юраулары буенча] астында келәү ителә торган агачны, мәсәлән, чуваш кирәмәтен кисәргә ярамый.* К.Насыйри. *Ел фасылларына караган иҗтимагый йолаларга язгы чәчү, сабан йолалары, нардуган, раштуа, кызыл йомырка, тәкыя, аулак өйләр, өмәләр, келәү итү, корбан чалу, кунаклашу, яңгыр сораулар, түгәрәк уеннар һ.б. керә.* Татар милли педагогикасы

**КЕЛӘ́Ү ЙОРТЫ** *и. дини* Гыйбадәт йорты, гыйбадәтханә; *русчасы:* **молельня**

**КЕЛӘҮЛЕК** *и. диал. дини* Гыйбадәт кылу урыны. *Куе наратлык эчендә бу алан – Ак бүре ыруының келәүлеге, келәүлек уртасындагы изге нарат – Ак бүре ыруының табына торган изге нараты иде.* Н.Фәттах

**КЕЛЕ́РИЯ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлек, озынлыгы 20–60 см булган, яз көне хайваннарга азык булып торган үлән

**КЕЛТ** *рәв к.* **кылт**. *Аның күңеленә келт итеп Ләлә төште.* Г.Исхакый. *Бары тик идәннән түшәмгә кадәр сузылган озын буйлы, җиз битле карт*

*сәгатьнең озак көттергән вәкарь белән «келт, келт» иткәне генә ишетелеп торды.* Г.Бәширов. *Кәшфи кызык хәзер, келт иттеме, күзенә яшь килә.* М.Мәһдиев. *Шөрепнең исенә келт итеп соңгы көннәрдә булган бер вакыйга төште.* Т.Галиуллин

◊ **Келт итеп искә төшү** Нәрсә дә булса кинәт искә төшү, бер уйламаганда искә килеп төшү. *Ибристан дигәч, Камалетдиннең келт итеп исенә төште: болар – Казан мөселман социалистик полкыннан.* И.Низамов. *Хәзер әнә шулар келт итеп аның исенә төште.* М.Шабай. *Келт итеп исемә килеп төште: оста әйткән тагын бер ачкычны алмадым түгелме соң?* Р.Төхфәтуллин. *Келт итеп искә төште: миннән алда гына хатыным ишегалдында байтак кына торып кергән иде...* Ш.Маннур

**КЕ́ЛТ-КЕЛТ** *иярт.* Бертигез ритмны, кабатланып торган тавышны белдерә. *Тик стенадагы сәгатьнең генә келт-келт йөреп торганы ишетелә...* Х.Хәйруллин. *Шак-шок, дөп-дөп, келт-келт – Михаил Лермонтов, Антон Чехов, Муса Җәлил һәм Габдрахман Рахманкулов таптаган баскычларга студентларның үкчәләре бәрелә.* М.Юныс. *Тып-тын, тик әнә умывальник борыныннан чутылдап тамчы тамгалый да, келт-келт сәгать йөри.* Р.Төхфәтуллин. *Менә секундомер теле келт-келт йөри башлады.* С.Шакир

**КЕ́ЛТ-КЕЛТ ИТҮ** *ф.* Салмак кына бертигез ритмик тавыш чыгару (сәгать теленең йөреше тур.). *Директор өстәлендәге сәгать келт-келт итә, минем газаплы минутларымны саный.* М.Насыйбуллин. *Кызчыкка ят абыйның сүзләре, аннан да бигрәк, кулына бәйләгән, келт-келт итә торган ялтыравыклы тәтие ошап китте булса кирәк, ул акрынлап елавыннан туктады.* Р.Төхфәтуллин. *Бар да тынды, мич артындагы чикерткәнең черт-черт дигән җыры белән стена сәгатенең келт-келт иткән тавышы бишеккә салып тирбәткәндәй йокыны китерә иде.* М.Маликова

**КЕЛТЕР** *иярт. к.* **келтер-келтер.** *Шулай барганда, кемнеңдер лапас түбәсенә куелган «җил тегермәне» келтер-р-р итеп тавыш бирүгә, Гыймазов сискәнеп китте.* С.Рафиков

**КЕЛТЕ́Р-КЕЛТЕР** *иярт.* Бертигез ритмда келт-келт иткән тавыш чыгаруны белдерә. *Тегү машинасының келтер-келтер әйләнгән тавышы ишетелә башлады.* А.Сафин. *...Менә, ниһаять, келтер-келтер килеп, билгесез авыл һәм станцияләрне артта калдырып, поезд Мәскәүгә чаба.* Р.Низамиев. *Амбар алдында келтер-келтер бодай җилгәрәләр.* Г.Мөхәммәтшин

**КЕЛТЕРӘВЕК** *с.* Келтерәп торган, бертигез ритмлы; көчле булмаган. *Карт минем янга төшеп корал өйрәнә, келтерәвек тавышы белән бертуктаусыз кабатлый.* С.Баттал

**КЕЛТЕРӘ́Ү** *ф.* 1) Бертигез ритмик тавыш чыгару (мәс., арбаның бик җиңел генә тәгәрәп баруы, тегермән, тегү машинасы, поезд, машинаның тавышы һ.б.). *Көзге такыр юлдан келтерәп барган арба тавышы басу ягына китеп югалды.* Х.Сарьян. *Салмак кына келтерәгән тегермән тавышы көенә иренеп кенә гәп сатучы өч кеше Хәлимнең килеп керүен сизми калды.* И.Гази. *Бүлмәдә яңгыраган дәртле, көмеш авазларга кояш нуры, тәгәрмәчләр келтерәве, чалгы чыңы, Сабантуй сөлгеләре җилфердәве, гомер мәгънәсе – тагын-тагын әллә ничаклы моңнар кереп тулган иде.* Р.Низамиев

2) *күч.* Җиңел генә, ансат, уңайлы, шома гына бару (эш, тормыш һ.б.). *Келтерәп тартып утырган Иҗатым тегермәнен Туктатса кемдер, хәзер мин Болынга төшеп, Китәмен шунда хисләрнең Буылган төшен эзләп.* С.Хәким. *Тормышта үз урынын тапмаганмы... келтерәп агар, үз көенә яшәр иде, бац! – юлына буа буганнар, директор иткәннәр үзен.* А.Ганиев

3) *к.* **гөлдерәү**. *Кучкылланып кара болыт йөри, Күк келтери, кыя таулар тетри.* Ш.Маннур. *Яшен яшьни, күк келтери*

**КЕЛТЕРДӘ́Ү** *ф.* Бертигез ритмда келт-келт иткән тавыш чыгару. *Ул да булмады, атлар пошкырганы ишетелде, ябулы арба келтердәде, нарасый аваз салды, йолдызлар астында ялгыз учак җемелдәп күренде.* Р.Зәйдулла

**КЕЛТЕ́РТ-КЕЛТЕРТ** *иярт. к.* **келтер-келтер**. *Колагына келтерт-келтерт иткән тавыш керә башлагач, Ильяс уянып киткәндәй булды, Раузадан, Чишмәлесеннән аерылып, яңадан Иделгә, «Урал»га кайтып төште. Капитан каютасындагы арифмометр тавышы иде бу.* И.Низамов

**КЕ́ЛЬМА** *и. нем. махс.* Штукатурлау һ.б.ш. эшләрдә тигезләү, измә сылау һ.б. өчен кулланыла торган саплы калак. *Бригадир кельманы кулына алды, измәне ашыкмый гына болгатты.* Б.Камалов. *[Владимир:] Ә кем сиңа, кулыңа кельма тотып кирпеч саласың, ди? Анысы ташчылар эше.* Ә.Сафиуллин

**КЕ́ЛЬНЕР** *и. нем.* Германия һ.б. кайбер Көнбатыш Европа илләрендә сырахәнә, ресторан, кунакханә хезмәтчесе. *[Һадиев] нәрсәдер әйтергә теләде шикелле. Ләкин шул чакта кельнер аш китерде.* Ш.Маннур

**КЕ́ЛЬТЛАР** *и. нем. күпл.* Б.э.к. беренче меңьеллыкның икенче яртысында Көнбатыш Европа илләрендә яшәгән, б.э.к. беренче меңьеллык уртасына римлылар тарафыннан буйсындырылган борынгы һинд-европа кабиләләре

**КЕ́ЛЬЯ** *и. лат.* Монастырьда монах, монахиня яши торган аерым бүлмә яки йорт

**КЕ́ЛЬЯ-КАБИНЕТ** *и.* Монастырьда монах, монахиня яши торган аерым бүлмә. *Келья-кабинет тынлыгында ул зур һәм кечкенә латин хәрефләрен төрлечә кушкалап карады.* Җир чәчәктә

**КЕМ** *алм.* **1.** 1) Нинди яки кайсы кеше икәнен белергә теләгәндә кулланыла. *--- районндагы ярты колхозда кем кошчылык фермаларын бетертте?* Х.Хәйруллин. – *Кем минем чәчемне сүткән? Кем ефәк тасмамны идәнгә ташлаган? – диде ул, еламсырап.* Р.Хафизова. – *Кем сез? – дип сорады Никитин әкрен генә.* Ф.Галиев. *Сезгә бирегә керергә кем рөхсәт бирде?* И.Туктар

2) Нинди кеше, нинди эш белән шөгыльләнүче һ.б. булуын ачыклау мәгънәсендә килә. *Хәзер мин синең иптәшләрең кем икәнен беләм.* А.Расих. *Ни булды? Кем алар сиңа? Бик тыкшына башласалар, җибәр син*

*аларны... ераккарак!* М.Маликова. *[Сәлим Гаязов] Фронтка киткәнче авылда, колхозда кем булып эшләгән, тормышта нинди матур эз калдырган? Фронтта нинди батырлыклар күрсәткән?* А.Шамов

3) Якын таныш, берәр үз иткән кеше. *[Заһид Мәдинәгә:] Минемчә, сезнең кемегез булса да бар.* А.Расих. *[Маһирә:] Бер егет? Кемегез соң ул егет?* Г.Зәйнашева. – *Бу чибәр ханым сезнең кемегез дип белик? – диде Шәвәлиев.* Ф.Садриев

4) *Дә* кисәкчәсе янында *беркем, һичкем* алмашлыклары мәгънәсендә килә. *Ай йөздәдер күк йөзендә, Кем дә кайгыртмый аны.* Ф.Бурнаш. *Минем авыр язмышымны Кем дә күрмәсен иде.* М.Җәлил. *Кем дә булса бардыр бит райкомда, берәрсе белән тоташтырыгыз, зинһар...* Т.Миңнуллин

5) *Әнә, менә* алмашлыклары белән килеп, нәрсәне дә булса аерып күрсәтүне, басым ясап әйтүне белдерә. *Рәхилә, менә кемнәр турында пьесалар язарга иде сиңа!..* И.Туктар. *Менә кем ул безнең җитәкче! Әнә кем икән ул!*

6) Ике яки берничә җөмләнең һәрберсендә килеп, бүлгәләү мәгънәсен белдерә: берсе, икенчесе (икенчеләре), кайсы (кайсылары). *Кем туздырса, кем минем нәрсәне алса, хәтереңә алып бар.* Г.Толымбай. *Кем җырлый да кем тыңлый хәзер моның ишене!* М.Маликова. – *Кем ашаткан, кем туйдырган аларны? – ди әтием, гаҗиз калып.* Э.Шәрифуллина. *Табигый хәл, яр буе җирләре дә, материал, заводлар да аерым хуҗалар кулында, килештереп кара аларны, күпер кемгә файда, ә кемгә зыян китерәчәк бит.* И.Низамов

7) Риторик сорауларда һәм өндәү җөмләләрдә *теләсә кем, һәркем* мәгънәсен белдерә һәм хәбәр булып килгән фигыльнең киресе эшләнүен аңлата. *[Мәгъсүмә:] Мин – өяз тарафыннан куелган мөгаллимә, минем яныма кем килмәс!* И.Гази. *Кем кызганыр изге көчен Кадерле Ватан өчен?* Ә.Ерикәй. *Волжск кәгазь-целлюлоза комбинатының продукциясе кемнәргә мәгълүм түгел!* И.Низамов

8) Кабатлаулы формада төрле килешләрдә (*кем-кем, кем-кемне, кемгә-кемгә, кемнән-кемнән* һ.б.) кемне дә булса үз ишләреннән аерып күрсәтү өчен кулланыла. – *Кемнең кем икәнен бик яхшы беләбез! – диде ул.* М.Маликова. *Әни исә, тагы да гайрәтләнеп: – Мин өйрәтмим аларны, хәзер алар зур. Кемнең кем икәнен үзләре күрә, – ди.* Э.Шәрифуллина. *Кем-кем, ә монда профессор Хайрамның гади кеше түгеллеген яхшы беләләр.* А.Тимергалин

9) Кушма җөмләдә кире җөмлә составында килеп, баш җөмләдәге *барыбер* сүзе белән бергә иярчен кире җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Кем булсаң да (кем генә булма), барыбер...*

**2.** *мөн.* Баш җөмләдәге *ул, шул* сүзе белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен ия җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Кем эшләми, шул ашамый.* Мәкаль. *Кем җиңә, шуның сүзе өстен чыга.* Ш.Рәкыйпов. *Кем боерса, шул солтан, кем йөгерсә, шул куштан.* Мәкаль. *Кем өскә чыкса – кызны шул озата.* В.Нуруллин. *Кем арбасына (чанасына) утырсаң, шуның җырын җырларсың.* Мәкаль

◊ **Кем әйтмешли** Билгеле булганча. *Кем әйтмешли, сүз үрчетеп торыр нәрсә юк.* Ф.Галиев. *Шулай дип үзүзен юатты, сабыр итәргә булды: кем әйтмешли, сабыр төбе сары алтын бит.* М.Хәбибуллин. *Кем әйтмешли, бер күрүдә гашыйк булган да хәзер башына урын таба алмый.* Ф.Галиев. *Кем әйтмешли, хезмәтенә күрә хөрмәте.* Н.Акмал. **Кем белә** Билгесезлекне аңлата. *Кем белә бит алай буласын, мондый очрак миллионга бер туры килә.* М.Маликова. *Кем белә, бәлки, эчтәрәк берәр нәрсә эләгеп калгандыр.* Ф.Галиев. *Кем белә, бәлки, тагын өч-дүрт елга сузылыр ул.* В.Нуруллин

**КЕ́МБРИЙ** *и. ингл. геол.* Җирнең геологик тарихында палеозой эрасының беренче чоры. *Калифорния ярлары тирәсендә билгеле булмаган моллюск очраган (неопилина). --- Күрәсең, неопилина – кембрий чорында яшәгән җаннарның бер токымы.* Җир һәм туфрак. *Булат Дияров Себер нефтен, кембрий нефтен ачарга китә.* Г.Ахунов. *Архей – кембрийга кадәр икенче эра (докембрий – II).* Җир һәм туфрак. *Бу эра үзе генә дә берничә чорга бүленеп, пермь чоры, ташкүмер чоры, девон чоры, силурий чоры, кембрий чоры дигән исемнәр белән йөртелә икән.* Ш.Бикчурин

**КЕ́МДЕР** *алм.* Ниндидер, кайсыдыр, берәү, билгесез кеше. *Тавыш-тын юк, бары тик сәгать текелдәгәне дә кемнеңдер җиңелчә гырлаганы ишетелә.* М.Насыйбуллин. *Кемнедер якын итәрлек, кемгәдер сыенырлык көч таба алмам дип тә уйлады Мөршидә.* М.Хәбибуллин. *Кемнәрдер тагын керде, кемнәрдер чыкты.* И.Гази

**КЕМЛЕК** *и.* Кем булу, нинди кеше булу. *Малайга кемлегемне, нишләп йөрүемне кыскача гына аңлатып бирергә туры килде.* Ф.Шәфигуллин. *Сәбәбе бар: адәм балаларының үткәне, кемлеге, ниләр кылганын белмәгәнгә, мин аларның тышкы кыяфәтләренә тотынам.* А.Гыйләҗев. *Ниемә кирәк иде миңа аның кемлеге?* Ш.Маннур

**КЕ́МПИНГ** *и. ингл.* Автотуристлар өчен махсус җиһазландырылган җәйге лагерь, база. *Шунда ук ямьле генә архитектуралы кемпинг тора.* З.Мурсиев

**КЕМСӘ** *алм. иск. кит.* 1) *к.* **кем**. *Анда инде танцы башланган булыр, Рәмилә аңа катнашып китәрме-юкмы, әмма ул анда Әминәнең чын әхвәлләрен төгәлрәк һәм әчкәртенрәк белгән берәр кемсәне очратмый калмастыр әле...* Э.Касыймов

2) *к.* **кеше**. *Чит илләрдәге тормыш шартларын, андагы яхшылыкларны кимчелекләре белән бергә бәйләп сөйләгәндә, Илечко, мине – беркатлы кемсәне – хак юлга төшерергә тырышу белән бергә, үзе кайчандыр яшәгән җәмгыятьне, аның бай күңелле хуҗаларын, илләрне, илләр бизәге булган эшчән, тырыш кешеләрне сагына торган иде.* А.Гыйләҗев. *Уйлап карасак, без, чыннан да, балчыктан, туфрактан яратылган кемсә булып чыгабыз түгелме соң?* С.Шәмси

**КЕМӘЙ** *и. кыт.* Дус, сердәш. *Кызның кемлеге кемәеннән беленә.* Мәкаль. *[Гайнавал:] Кемәйләр, хәзрәткә юл бирегез!* Т.Гыйззәт

**КЕНӘ** *кис. к.* **кына.** *Вәкил сүзе тик көнчелек кенәме, явыз ниятме?* Ш.Маннур. *Бәлки, болар бөтенесе дә бер саташу гына, коточкыч төш кенәдер?* Ф.Галиев. *Татар халкының традицион культурасына караган күп кенә күренешләрнең тамырлары ачыла.* Г.Дәүләтшин

**КЕНӘГӘ** *и. рус* 1) Нинди дә булса мәгълүматларны язып теркәү өчен кулланылган катыргы тышлы дәфтәр. *Хәлфә берәм-берәм аларның исемнәрен, фамилияләрен сорады һәм аларны кенәгәгә терки барды.* Ә.Фәйзи. *Эзләгәнен тиз табуына сөенгән кыз, күбәләктәй очынып, кенәгәне тикшерүче алдына китереп куйды.* М.Насыйбуллин. *Бухгалтерия кенәгәсе*

2) Нинди дә булса текст һәм төрле рәсми билгеләр, саннар өчен урыны булган, төпләнгән документларның атамасы. *Билге куяр алдыннан, ул зачёт кенәгәмне актарып карады.* М.Юныс. *Тәрҗемәи хәлне хезмәт кенәгәсенә ятыштырып язып бирдем.* И.Салахов. *Безнең имтихан беткән, зачёт кенәгәсендәге билгеләр дә ярыйсы гына ---.* Х.Сарьян. *Гимнастёркамның түш кесәсендә – ике кызылармеец кенәгәсе.* Х.Камалов. *Китапханә кенәгәсе*

**КЕНӘГИНӘ** *и. рус к.* **княгиня**. *Кенәгинә янында мин дә кенәз!* М.Гәрәев. *Автор икесе ике чорда яшәгән шәхесләр – Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикә һәм кенәгинә Ярославна диалоглары аша бу геройларның хис-кичерешләр драматизмын гына сурәтләп калмый.* М.Әгъләмов. *Бары тик монастырь казнасын, кайбер иконаларны, савытларны, китапларны гына алды, аннары, кайчандыр бөек кенәгинә Ольганың туган җирен кызганып, җанын җәзалар белән басу өчен Мәскәүгә кайтып китте.* Ватаным Татарстан

**КЕНӘЗ** *и. рус к.* **князь**. *Әнә шулай болгар белән урыс кенәзләре арасы акрынлап бозыла башлый.* М.Хәбибуллин. *Дружинада, чыннан да, әче бал эчү белән бәйле ритуаллар булган, һәм кенәз бөтен дружинаны, бу йолалардан баш тарттырып, үзенә каршы куя алмаган.* Татар мөселман календаре. *Кубрат хан да антлар белән тату яши, күрше-тирә илләрне буйсындыргач, антларга юнәлә, кенәзгә бик күп бүләкләр алып бара.* М.Хәбибуллин

**КЕНӘЗБИКӘ** *и. к.* **кенәгинә**. *Кенәзбикә уң яктан, кенәз сул яктан килә. Кенәзбикә тәмам өлгереп, өзелеп җиргә төшкән алмадай сылу иде.* М.Хәбибуллин. *Болай булса, яраннарыңа таянып яшәрдәй өметеңышанычың бер дә юк икән бит синең, кенәзбикә!* В.Имамов

**КЕНӘЗЛЕК** *и. к.* **княвьлек**. *Аның үз гаскәренә Туктамыш хан татарлары, көньяк рус кенәзлекләре полклары, поляклар һәм тәре йөртүче Ливон ордены рыцарьлары да өстәлде.* С.Шәмси. *Касыйм ханлыгы – 1450 елда Василий II тарафыннан урыс ягына хезмәткә күчкән татар морзалары һәм бәкләре өчен төзелгән аерым кенәзлек.* Н.Әхмәдиев

**КЕНӘЙНӘ ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Тырнакгөлчәләр семьялыгыннан үләнчел үсемлек; *русчасы:* **мальва дикая**

**КЕНӘР** *и. иск.* Бик яраткан, сөйгән кеше

**КЕНӘРИ** *и. рус зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан ачык сары йонлы, бик матур сайрар кош (бүлмә кошы буларак таралган). *Каурыйларын коеп яңа каурыйлар үстереп сайрый башлаган ата кенәриләрне август азагында ана кенәриләрдән аералар һәм, яхшы сайрый торган олы кошларга якынрак, аерым читлеккә күчерәләр.* Файдалы киңәшләр. *Ак алъяпкычындагы кызыл йолдызчыкта шаян нурлар җемелдәтеп, әлеге сихри гөлләргә тере суы сибеп чыкты кызчык, балыкларга, тутый кошларга, кенәриләргә җим өләште.* Ж.Дәрзаман

**КЕНӘРИ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **канареечник**

**КЕНДЕК** *и.* 1) *анат.* Кеше яки хайван яралгысын ана организмы белән тоташтыра һәм яралгыны тукландыру каналы булып хезмәт итә торган көпшә. *Багучылары ханга җиткерделәр: имеш, бала кендеген кисүгә, әти кеше угылының кулына чүкеч тоттырган икән, шуңа тиңсез оста икән ул наный.* М.Хәбибуллин

2) Корсак уртасындагы кечкенә генә батынкы урын (тугач та баланың кендеген кискәннән соң калган җөй) һәм гомумән шул урын, тирә. *[Харисның] бөтен киеме бер чалбардан гыйбарәт булып --- үзенә бик зур, кендектән әллә никадәр югары күтәреп кигән булуга карамастан, балагы җир себереп йөри.* Г.Гобәй. *Чалбары тар да, кыска да иде, ә күлмәге кендектән генә.* М.Кәбиров. *Най кулына алгач, үлем алды тыпырчынуы белән бәргәләнгән селәүсен арт аякларының тырнаклары белән Найның кендектән астарак корсагын ярып өлгерде.* Т.Нәбиуллин

3) Арбага алгы күчәрне тоташтыра торган кыска тимер таяк. *Көчәнә торгач, тезләр калтырый, тыннар кысыла башласа, Ильяс бер очы арба кендегенә бәйләнгән дилбегә белән капчыкны биленнән уратып тактага бәйләп куя да сулулары ипләнгәнче хәл җыеп ала, аннары, учларына төкереп, яңадан тәгәрәтергә тотына иде.* Р.Төхфәтуллин. *Алар арба артын күтәреп, кендекне кигерткән арада, сыерчык, атка кунып, тагын бер чеметем ябага йоны йолкып китте, бүтән күренмәс булды.* Ә.Гаффар

4) Йозак, элмәк. *Хәйрулла абзый, капканы тимер кендек белән бикләп, әкрен генә өй ишегенә таба юнәлде.* А.Шамов. *Җентекләбрәк карый башлагач, тагын бер нәрсә сизелде: йозакны җыеп торучы кендекләр заводта эшләгәнчә түгел, ә кулдан чүкелгән.* К.Кәримов

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса үзәге, иң әһәмиятле урыны. *[Венера:] Сез, ирләр, үзегезне дөньяның кендеге итеп тоясыз инде.* Р.Зәйдулла. *Кайчандыр Гөлзиләгә үзен дөньяның кендеге итебрәк күрсәтергә теләгән кешенең шулай куштанлануы кызның ачуын чыгарды.* М.Кәбиров. *Һәр буын үзен дөньяның кендеге дип саный.* Ш.Галиев

6) *күч.* Кирәкле, күренекле, данлыклы кеше турында. *Шәһәрнең кендеге ул*

◊ **Кендек бәйләнү** 1) Билгеле бер нәрсәгә бәйләнгән булу; 2) Кем белән дә булса рухи бәйләнгәнлек. *Гомергомергә Иделгә кендеге белән бәйләнгән,*

*азыктыр, тәм-ямьдер, шөгыльнедер шунда табып яшәгән халыкны шуңардан биздерергә маташ инде.* И.Низамов. **Кендек ябышу** *к.* **кендек бәйләнү** *Кендегебез ябышмаган ич аларга, киттек, мин әйтәм.* К.Нәҗми

**КЕНДЕ́К БАВЫ** *к.* **кендек** (*1 мәгъ.*). *Мин дә эзлим... Кендек бавым тарта, Дала күкрәгендә – үз каным.* Р.Аймәт

**КЕНДЕ́К ӘБИСЕ** *и.* Бала тудыру вакытында ярдәм күрсәтүче, дәва, имтомнарны белүче, бала кабул итүче карчык; акушер. *Ахырда, һәртөрле имтомнарга оста булган кендек әбисен чакырдылар.* А.Шамов. *Хан сараена, ханбикә Зөбәрҗәт янына бердәнбер кеше – кендек әбисе рөхсәтсез-нисез керә ала.* М.Хәбибуллин. *Минә бер язның кояшлы көнендә кендек әбисе малайны җитәкләп, авыл башына алып чыккан.* М.Маликова

**КЕНОТРОН** *и. гр. физ.* Алмаш токны турайту өчен хезмәт итә торган ике электродлы электроник лампа

**КЕНТАВР** *и. гр. миф.* 1) Грек мифологиясендә: гәүдәсе атныкы, башы һәм күкрәге кешенеке булган ярым кеше, ярым ат. *Грек мифыннан: Кентавр Хиронның тау куышында аллалар башлыгы Зевсның оныгы Пелей белән алиһә Фетиданың туе бара.* Т.Миңнуллин. *Колоннаның иң өске өлешендә, тәрәзәләрдә, стена һәм ишек рельефларында кентаврлар (ярымкеше-ярымхайваннар) һәм башка әкияти җан ияләре сурәтләнә.* Урта гасырлар тарихы

2) *астр.* Күкнең көньяк ярымшарындагы йолдызлык

**КЕПЕ́Р-КЕПЕР** *иярт.* Нәрсәне дә булса кискәндә, тапаганда, көрәк белән эшләгән вакытта һ.б.ш. очракларда ишетелгән шытырдау тавышын белдерә. *Әле тыгызланып өлгермәгән, күбек кебек җиңел, шикәр кебек ак карларны зур агач көрәк белән тапталган кар катылыгына кадәр кепер-кепер итеп көрәү аның күңеленә ниндидер рәхәтлек сала, ул бу эшне яратып башкара иде.* С.Рафиков

**КЕ́ПКА** *и. ингл.* Ирләрнең козырёклы йомшак баш киеме. *Рамазанга җиде тирәләре. Зәңгәр кепка кигән, чалбардан.* С.Хәким. *Казан артында гадәт бер генә: кепканы, бүрекне кырынайтыбрак киясе. Егетлекнең иң беренче билгесе ул бездә. Һәм без иске кепкаларны кыегайтып куйдык та туп-туры кызлар янына юл алдык.* М.Мәһдиев. *Ул яңа туфлиен дә, костюмын да киде, галстугын да такты, хәтта кепкасын да кулына тотты да, аны чоланда калдырып, урамга чыкты.* Н.Фәттах

**КЕ́ПКАЛЫ** *с.* Кепка кигән. *[Түбәннән] берсе шлемлы, берсе соры кепкалы ике баш калыкты.* Г.Ибраһимов. *Ак кепкалы кеше сөйләнә-сөйләнә хисапчы каршына килеп утырды.* М.Әмир. *Ә каршы якта аларны озын таяклы, кызыл кепкалы милиционер абыйлары каршылады.* Ф.Җамалетдинова

**КЕР** *и.* **1.** 1) Юылган яки юылырга тиешле кием-салым һәм төрле тукымадан тегелгән көнкүреш кирәк-яраклары. *Әбиең кергәч, онытмыйча гына әйт әле: баудагы керләрне алып кереп куйсачы.* Р.Төхфәтуллин. *Керләрен элеп, идәннәрне юып чыкканда, кояш әле төшлеккә күтәрелеп кенә бара иде.* Х.Сарьян. *Хатын-кыз, әни булган кешенең бурычы – кыз баланы идән юу, кер юу, кер үтүкләү, тегү, кухня тирәсендә аш-су пешерергә өйрәтү.* Р.Вәлиев

2) Пычрак, шакшы, былчырак, буялган тап (тәндәге, киемдәге һ.б.). *Югыйсә бүген генә Мишәдә коенып чыкты бит инде, тәнендә бер тузан әсәре, кер калдырмады.* Ф.Бәйрәмова. *Бәйләним дисә, тырнак астында кер җитәрлек.* Н.Фәттах. *Кер тимәгән, ялтырап торган мебельләр ниндидер кадерле кунакны көтеп зарыкканнар төсле, аларда ятимлек сизелә.* Х.Хәйруллин. *Битне – сакал, тәнне кер басты.* Ф.Яхин. *Аның ап-ак кофтасында кер әсәре юк, ул чиста һәм чибәр күренә иде.* М.Маликова

3) *күч.* Тап, начарлык, әшәкелек, начар як (күңелдәге, намустагы). *Камилнең мәнә нәкъ шул урында чумып-чумып йөзәсе, бөтен борчылуларын, тормышның бар керен шунда калдырасы килде.* Ф.Бәйрәмова. *Тышлары керле, вә ләкин юк аларда эч кере.* М.Гафури

**2.** *с. мәгъ.* Кер юу өчен билгеләнгән. *Форточка ачык булуга карамастан, бүлмәдә тәмәке төтене катыш --- кер сабыны исләре аңкый.* Ш.Камал

◊ **Кер куну** 1) Пычрану, тап төшерү, каралу. *Айсетдиннең башында кардай ак фуражка, өстендә ап-ак җитен костюм-чалбар, аягындагы ак ботинкага да кер кунарга өлгермәгән.* Я.Зәнкиев; 2) Таплану, әшәкеләнү, пычрану (намус, күңел һ.б.). *Бу «ачышым» турында Мирсәет абыйга язсам, нәрсә дияр иде икән? Юк, кирәкмәс. «Минем изге истәлекләремә аз гына да кер кундырмыйча саклый белүеңә ышанам», – дип язды бит ул миңа. Кер кундыру түгел, һичвакыт кузгатырга да хакым юк минем ул истәлекләрне!..* Р.Төхфәтуллин. *Кер кунмастай җаннар, гөнаһ ябышмастай тәннәр акрынлап бетә барды.* Т.Галиуллин. **Кер күтәрә торган** Тиз керләнми, пычранмый, керләнгәне беленми торган. *Ефәк җептән бәйләнгән гипюр ул, җаныемдыр ла! Ак, ап-ак! Миңа нәкъ шундые кирәк иде. Кер күтәрә торган күлмәкләрдән туйган. Кер тидерергә ярамый торганын эзләдем.* К.Тимбикова. **Кер күтәрми торган** Керләнә, пычрана торган. **Кер төшү** *к.* **кер куну**. *Элеккечә калыр иде хисләр; Хәсрәтеңне эчкә яшереп тә Асрар идең, йөрер идең горур, Кер төшерми үткән яшьлеккә...* С.Хәким

**КЕ́Р САБЫНЫ** *и.* Үзендә майлы кислоталар һәм зур күләмдә селте булуы белән аерылып торган сабын төре; *русчасы:* **хозяйственное мыло.** *Кер сабынында селте күп булганлыктан, ул баш тиресен бозарга мөмкин.* Йорт эшләре. *Ләкин алай зурлап телгә алырлык әйберләр чыкмады аннан: ярты кирпеч кара икмәк, азрак шикәр, кер сабыны зурлыгында ниндидер ак әйбер, сабын, бит яулыгы һәм кырыну приборы – бар булган нәрсәсе шул иде.* В.Нуруллин. *[Әнкәй] Бисмилласын әйтеп, кер сабыны белән эчемә массаж ясый башлый.* Э.Шәрифуллина

**КЕРАМЗИТ** *и. гр.* Җиңел эрүчән балчык токымнарын яндырып алынган төзү материалы; бетон тутырмасы. *Керамзит бөртекләренең эчке ягы катып калган күбексыман, ә тышкы ягы нык тышча белән капланган була.* Төзү материаллары. *Кирәкле материаллар*

*кайтарып, керамзит бетоннан гараж салып куйды.* Шәһри Казан

**КЕРА́МИК** *с. гр.* Керамикадан (*3 мәгъ.*) эшләнгән, керамикадан ясалган. *Керамик подставка үтүкнең җылысын металл подставкага караганда озаграк саклый.* Файдалы киңәшләр. *Казу эшләре вакытында күпләгән керамик әйберләр: савыт-саба, кеше гәүдәсе рәвешендәге сыннар табыла.* Урта гасырлар тарихы. *Керамик вазаларга, тар муенлы чүлмәкләргә һәм банкаларга – кыр чәчәкләре бәйләмен, биек тар хрусталь һәм пыяла вазаларга яшел үлән уртасына озын сабаклы бер-ике чәчәк кую бик матур була.* Файдалы киңәшләр. *Андый аскуйма итеп, мәсәлән, стена тышлау өчен хезмәт итә торган керамик плитка яки түбә яба торган шифер кисәге кулланырга мөмкин.* Файдалы киңәшләр. *Ләкин бу чор өчен яндырылган балчыктан керамик әйберләр, шул исәптән савыт-саба ясау хас булмаган әле.* К.Гыйззәтов

**КЕРА́МИКА** *и. гр.* 1) Чүлмәк-кирпеч җитештерү. *[Ул] Сынлы сәнгатьне яратып, күңел биреп укый, нәкыш белән генә канәгатьләнмичә, Урманче кул астындагы керамика мастерскоенда да сабаклар алып, утызынчы елны техникумны тәмамлый.* М.Әмир

2) *җый. и.* Яндырылган балчыктан, балчык массасыннан ясалган әйберләр. *Иске Казан урыныннан җыелган керамика һәм Мишә буендагы аерым табылдыклар [болгарлар килүенә] дәлил булып тора.* Казан утлары. *Археологлар тарафыннан монголларга кадәрге чорда ук Идел Болгарында металлдан, сөяктән, керамикадан эшләнгән әйберләр табылды.* И.Гафаров. *Агач, тире ише органик әйберләр череп-таркалып туфракка әйләнгән, ә керамика, металл, сөяктән эшләнгәннәре сакланган.* Ф.Хуҗин

3) *махс.* Шундый әйберләр ясау өчен кулланыла торган масса. *Соңгы вакытта радиотехникада слюдалы конденсаторлар урынына керамикалы конденсаторлар кулланыла башлады.* Физика. *Яңа спиральне плитканың керамика буразналарына урнаштыру алдыннан тиешенчә сузарга кирәк.* Файдалы киңәшләр. *Саклагыч сылама – катлы-катлы тун ул; аның катлаулары керамикадан эшләнә, атмосфераның тыгыз катлауларына килеп кергәч, алар эреп юкка чыгалар.* Зур галәм турында кечкенә хикәяләр

**КЕРАТИН** *и. гр. биол.* Составында бик зур күләмдә күкерт булган аксым матдәсе (чәч, тырнак, тире һ.б.ларның состав өлеше)

**КЕРАТИТ** *и. гр. мед.* Күздәге мөгезсыман катлауның ялкынсынуы, аның тоныклануы

**КЕРАТОЗ** *и. гр. мед.* Эпидермисның мөгез катламы калынаю белән характерланучы дерматозларның гомуми атамасы

**КЕРӘЛЕ́-ЧЫГАЛЫ** *с. к.* **кердpoints-чыктылы**. *Халык бераз сүрелгән арада, Фәйзулла староста тагын сүзгә кереште. – Картлар! – диде ул. – Болай керәле-чыгалы җикеренүдән мәгънә юк...* М.Галәү. *Сиксән яшьтә зиһен дигәне дә керәлегә-чыгалыга әйләнә икән.* М.Әмирхан

**КЕРӘН** *и. бот.* 1) Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан тамыры аш тәмләткеч буларак кулланыла торган үсемлек. *Вак кыярларны сайлап алып юабыз, чәнечке белән кадап, банкаларга тутырабыз. Өстен уылган керән, сарымсак, укроп сабаклары һәм карлыган яфрагы белән каплыйбыз.* Туган як

2) Шушы үсемлекнең ачы тамыры һәм шуннан әзерләнгән аш тәмләткеч. *Каймакка керән, шикәр комы, аш серкәсе кушып, барысын бергә болгатабыз. Әзер салатны салат савытына салып, чөгендер һәм кара җимеш белән бизибез.* Татар халык ашлары

**КЕРӘЧ** *и. фар.* Фаянс, керамика. *Бер генә фиркадә дә әгъза булып тормаучы Фәүзия түти озын итәкле күлмәк кигән, алъяпкыч япкан, керәч тәлинкәләргә кайнар аш бүлә.* М.Шаһимәрдәнов. *Чәйне пешергәндә, нинди савытка өстенлек бирергә соң? Моның өчен иң яхшысы – фарфор, керәч (фаянс) һәм пыяла савыт сайлау.* Шәһри Казан

**КЕРӘШӘ** *и. зоол.* Карлыгач кошлар семьялыгыннан очлаеп киткән озын канатлы кечерәк күчмә кош; яр карлыгачы; *русчасы*: **береговая ласточка**. *Чулман туктады, керәшәләр, акчарлаклар күктә очалмыйча катып калдылар.* Н.Фәттах. *Шулай май аеның аяз көнендә Румия абыйсы белән су буена төшкән иде, һавада су өстендә акчарлаклар белән ярышып, керәшәләр кыелып-кыелып оча ---.* В.Ильясов. *– Нәрсә соң ул керәшә? – диде Мөбарәк. – Керәшә ул – яр карлыгачы, – диде Ташпулат.* Р.Батулла

**КЕРӘШЕН** *и. рус этн.* Идел-Урал төбәгендә яшәүче татарлар составында булып, христиан динен тотучы этноконфессиональ төркем һәм шул төркемнең вәкиле. *Милициядә эшләүче егетләр арасында керәшен егетләре байтак кына: азанның кайчан әйтеләсен алар белми иде.* М.Мәһдиев. *[Шәехгали:] Ядкәр анда, керәшенгә чыгам, Дигән сүзен биргән Иванга!* Ф.Яхин. *--- Әйтик, «Их, тала-тала» – Сармандагы Ләке керәшен авылының бәйрәм җыры.* Ватаным Татарстан

**КЕРГЕЗИН** *и.* Юка мамык тукыма. *Миңа бирәр бишмәт алсалар, нинди күңелле булыр иде дип, кызыл кергезин бишмәтемне күз алдыма китерәм.* М.Гафури

**КЕРДЕЛЕ́-ЧЫКТЫЛЫ** *с.* 1) Бормалы, төз түгел, туры булмаган. *Кердeле-чыктылы урам*

2) *күч.* Принципсыз, үз фикере булмаган, сүзендә тормаучан, аумакай (кеше тур.). *Аның авызыннан шундый сүз ишеткәч, Һарунга ничектер җиңелрәк булып киткән шикелле булды. «Шулай да начар кеше түгел бу Тәзкирә, кердeле-чыктылы», – дип уйлады ул.* Н.Фәттах. *Кердeле-чыктылы акылга ия булган начальниктан Госман һәрвакыт шикләнеп йөри иде, чакыруга канатланмады, кабинетка хәвефләнеп, сүлпән генә барып керде.* И.Салахов

3) *күч.* Буталчык, таралган, мәгънәсез, абсурд. *Әмма кинәт таралып киткән фикерләрен ул берьюлы гына җыйнап өлгерә алмады, шуңа күрә аның беренче сүзләре әллә ничек кердeле-чыктылы булды ---.* Ә.Фәйзи. *Кеше акылы кердeле-чыктылы ул, элгәре: «Ник безне уникешәр сәгать эшләтәләр?» – дип тыпырчына идем, хәзер, ышанасызмы-юкмы: «Нигә тәүлек буе тоташ эшләтмиләр икән, ул арада*

*ялгыз баштан мин Ленага нинди хатлар язмас идем!» – дип көяләнәм...* А.Гыйләҗев. *Моннан ике ел элек кенә хатыны Камилә дә дөнья куйды. Холкы керделе-чыктылы булса да, хатынсыз торган ише түгел, үз урынына ярый иде әле...* С.Зыялы

**КЕРДЕШ** *и. диал. ирон.* 1) Йортка кергән ир

2) Вакытлыча гына гаиләдә яши торган чит кеше

3) *физ.* Кристалларда челтәрнең төенара бушлыгына кергән ят атом

**КЕРЕ́К-КЕРЕК** *иярт.* Йомшак кына өзек-өзек тавыш чыгарып көлү. *Үзе керек-керек көлә, үзе кулындагы кәгазь битләрен селки.* Ф.Шәфигуллин. *Залда леңгер-леңгер сөйләшәләр, керек-керек көлгәләп тә алалар.* Ф.Шәфигуллин

**КЕРЕМ** *и.* 1) Дәүләт, сәүдә-промышленность оешмалары, аерым кешеләр һ.б.ш. тарафыннан нинди дә булса эшчәнлек нәтиҗәсендә алына торган, җитештерү чыгымнарыннан калган акча һәм материаль кыйммәт, табыш. *Сыгылма аракы заводы елныңелына планны үтәп килә, кереме дә зур гына икән.* М.Насыйбуллин. *Мондый кибетләрдә сәүдәдән кергән керем дистә меңнәр белән исәпләнә бит.* Х.Вәлиәхмәтов. *Король хезмәтендә дәрәҗә алуга ирешергә һәм зур керемнәр алырга мөмкинлек була.* Урта гасырлар тарихы. *Әмма үзе эшләмичә, Себер акчасы белән «фарсить итеп» яшәргә өйрәнгән әнигә мондый керемнәр төкерек кенә.* Э.Шәрифуллина

2) Бухгалтерия кенәгәсендәге акча һәм материаль кыйммәтләр табышын язып бара торган графа. *Аның үзенә дә эләкте: – Былтыр яз идарә айгырының аягын сындырып суйдырдың. Аның зыянын капладыңмы, и ул керем кенәгәгә теркәлдеме?* Х.Сарьян. *Табышны керемгә язып кую*

3) *тех.* Кертү урыны, кертелгән урыны. *Электр кереме. Керем тишеге*

**КЕРЕМ-ЧЫГЫМ** *и.* Кергән һәм тотылган акча, материаль кыйммәтләр. *Ул бик хаклы рәвештә В.Р.Вильямсны тәнкыйтьләде һәм туфракта ашламалар керемен-чыгымын баланслауны чәчү әйләнешенең агрономик мәгънәсе дип санады.* Җир һәм туфрак. *Гыймазов хисапчы белән керем-чыгым турында бер-ике сүз алышырга өлгермәде, ишек ачылды.* С.Рафиков. *Ә менә шуннан калган акча – анысы инде сезнең керемчыгымнарыгызның иреклерәк өлеше.* Тигез гомер итегез!

**КЕ́РЕНКА** *и. сөйл.* Башында Керенский торган Вакытлы хөкүмәт чыгарган кәгазь акча. *Тукмаков кесәсеннән сары, яшел керенкалар чыгарып, пенснесын рәтләп, бик озаклап кат-кат санаганнан соң, акчаларны өстәл уртасына салып: – Чехлар бәхетенә куям!.. – дип, карталарны таратырга кереште.* К.Тинчурин. – *Минем өчен барыбер. Төтене чыкса, канәгать, – дип, кырык сумлык керенканы кызга сузды.* К.Тинчурин

**КЕРЕНТЕ** *и.* Кереп торган, уелып кергән урын. *Кембрий катламнары Фин култыгының яр керентесен тәшкил итәләр.* Үткән заманга сәяхәт. *Яр буендагы керенте*

**КЕРЕНТЕЛЕ́-ЧЫГЫНТЫЛЫ** *с. к.* **керделе-чыктылы** *(1 мәгъ.)*

**КЕРЕШ** I *и.* **1.** 1) *сөйл.* Керү. *Барып керешкә абындым. Барып керешенә туп-туры: «Әни кайчан үлде?» – дип сораган [Гали].* Г.Коләхмәтов. *Хупҗамал, кайтып керешкә үк, Сәнифәнең укытучысына хат язып, уртанчы улын басуга йөгертте.* Э.Шәрифуллина

2) Әдәби һәм музыкаль әсәрләрнең, доклад һ.б.ларның башлангыч өлеше, төп өлешкә кадәр булган кисәге. *Димәк, сүзнең кереш өлеше тиешле микъдарда булды, димәк, төп мәсьәләгә күчәргә вакыт.* А.Расих. *Бернинди музыкаль кереш булмады, һәм экранда сурәт оешты.* А.Тимергалин. *[Азат:] Поэмага керешне яңадан яздым.* И.Нуруллин

3) *иск. к.* **керем**. *Смета буенча без тамашачыларны 60 процент хисаплаганда, билет сатудан кереш 9633 сум көткән идек.* К.Тинчурин

**2.** *с. мәгъ.* Беренче, баштагы. *Коля кинәт кереш имтиханда да шундый ук сорау ишетүен исенә төшерде.* Ж.Тәрҗеман

**КЕРЕШ** II *и.* 1) Җәя бавы. *Кулында – керешен тарткан җәясе, бармак арасында – кыскан угы.* М.Хәбибуллин. *Алай да каган керешен җибәрергә өлгерде, каганның угы кылганнар арасына килеп төште.* М.Хәбибуллин

2) *диал.* Оекны тотып торучы резинка. *Түгәрәк кереш кию зарарлы*

3) *анат.* Тел астындагы яры (нәни балаларда була, сизелгәч тә аны кисәләр, чөнки ул имәргә, ә теле ачыла башлагач, сөйләшергә комачаулый)

**КЕРЕ́Ш ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Хикәяләү уңаенда төп фикернең агышын туктатып, кинәт кенә искә төшкән, юл уңаенда әйтелгән искәрмәләрне, сөйләмдә әйтелгән фикерләрне белдерәләр, ачыклап киләләр; күпчелек очракта җөмләнең уртасында килеп, ике яктан җәяләр эченә алыналар. *Кереш сүз, кереш җөмләләр беркадәр тавышны төшереп, --- тавышны бераз күтәребрәк әйтеләләр.* Г.Алпаров. *Кереш җөмлә гомумән җөмләнең я аның кайсы да булса бер кисәгенең эчтәлегенә сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә.* М.Зәкиев

**КЕРЕШ ИНТОНА́ЦИЯ** *и. лингв.* Кереш җөмлә баш җөмләдән пауза белән аерыла торган, җөмлә интонациясеннән түбәнрәк тонда, тизрәк, тавышны төшеребрәк әйтелә торган интонация. *Эксперименталь булмаган күзәтүләр шуны күрсәтә: кереш сүз (модаль кисәк) функциясен үти торган аналитик иярчен җөмлә (кереш җөмлә) баш җөмләдән пауза белән аерыла, җөмлә интонациясеннән түбәнрәк тонда, тавышны төшеребрәк, тизрәк әйтелә. Бу интонацияне хәзергә кереш интонация дип атарга була.* М.Зәкиев

**КЕРЕШЛЕ** I *с.* Сыя торган, сыешлы. *Гадәттә чиләкләр 12 кг су керешле була.* Кызыклы математика. *Җиде батман су керешле казанны кайнатып, кызны кайнар су өстенә бастырып бәйләп куйгачтыннан, солдатка – табибка инде эндәшәләр.* Әсирлектән кайткан әкиятләр. *Надзирателе бик усал бәндә иде, шул аңа йөз чиләк керешле бакка инештән су ташытты.* Г.Бәширов

**КЕРЕШЛЕ** II *с.* Керә торган. *Өйнең ике ишеге бар, икесе дә террасадан керешле.* Д.Аппакова. *Кабинетына да секретарь кыз аша гына керешле.* Х.Ибраһимов

**КЕРЕШЛЕ́-ЧЫГЫШЛЫ** *с.* Нәрсәгә дә булса кереп, шунда ук чыга торган. *Колхозга керешле-чыгышлы уйнарга ярамый инде!* Г.Толымбай

**КЕРЕШЛИ** *рәв.* Кая да булса кергәндә, керү уңаенда. – *Эшләдем, булды, – диде ул эче-тышы белән куанып һәм бусагадан атлап керешли үк чатнатып укырга тотынды ---.* Ф.Шәфигуллин. *Сарутның төз лапас түбәсенә тараткannan соң, өйгә керешли, аның уң кочагында бер кочак утын, сул кулында баздан алып чыккан бәрәңге була.* М.Юныс. *Ул ишектән керәкерешли Зифа белән сөйләшә башлады ---.* К.Тимбикова

**КЕРЕШ СҮЗ** *и. лингв.* 1) Башлангыч сүз, сүз башы. *Тамашаны Усманов үзе ачып җибәрде, кереш сүзен озын-озак тукталышлар белән бер сәгатьтән артыкка сузды.* Т.Галиуллин. *Бу томга кереш сүзне, әдипнең иҗатына фундаменталь бәя биреп, танылган тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин язган.* А.Хәсәнов. *Әлеге китап язучы Альберт Хәсәновның «Язмыйча түзә алмаганга...» дигән кереш сүзе белән ачыла.* М.Әхмәтҗанов

2) *лингв.* Сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә, сөйләм обстановкасына сөйләүченең төрле мөнәсәбәтен белдереп, бер сүздән һәм сүзләр тезмәсеннән гыйбарәт булган сүзләр. *Модаль кисәкләргә эндәш сүзләр һәм кереш сүзләр керә.* Г.Нәбиуллина. *Кереш сүз җөмлә була алса ла, нәхү кануны буенча тегеләргә охшамаганга, алар арасына кертелми.* М.Зәкиев

**КЕРЕШҮ** I *ф.* 1) Берәр нәрсә эшли башлау, эшкә тотыну. *Якынрак килеп, читтән генә күзәтергә кереште, сүзләренә колак салды.* Ф.Латыйфи. *Гөлзифа шигәеп үк куйды: әллә, ярсуына чыдый алмыйча, машинасын ватарга керештеме?* Р.Төхфәтуллин. *Саттар исемлектә һәр кранга аерым-аерым тукталып карарга кереште һәм ирексездән көрсенеп куйды.* С.Сабиров. *Вәлиулла, үзе керешеп, энекәше этләнеп маташкан унбиш минутлык эшне башкарып та ташлады.* Ф.Яхин

2) **керешмәү** *күч. юкл. форм.* Кагылмау, тыгылмау, кысылмау, нинди дә булса мәсьәләне читләтеп үтү. *[Шамил:] Алай дисәң, безгә хәбәр итми керешмәсләр иде мондый зур эшкә.* З.Фәтхетдинов. *Исереклек беләнме, түгелме, мин анысына керешмим, әнә минем балам, яныма да кермичә, урамда йөри.* Ф.Бурнаш. *[Мөрид:] Әгәр дә берәр кешенең фатихасын ала алсаң, мин анысына керешмим.* К.Тинчурин

**КЕРЕШҮ** II *ф.* Бер-берсе янына керү, үзара йөрешү. *Күршеләр белән керешү*

**Керешеп тору** Гел, һәрвакыт керешү

**КЕРЕШҮ** III *ф.* 1) Укмашу, киезләнү, тыгызлану (йон, киез һ.б. әйберләр тур.). *Ак тулалар тиз керешә, аркау-буе тигез эрләнсә.* Җыр

2) *күч.* Кушылу. *Стильләр керешә. Телләр үзара керешә*

**Керешә алу** Тиз генә керешү. *[Фәрәх:] Алайса мин берәр атнасыз эшкә керешә алмыйм. Чөнки без әле генә авылдан килдек.* В.Нуруллин

**Керешә төшү** Бераз керешү; керешкән хәлгә килү. *Ситуациягә керешә төшү*

**Керешеп бетү** Тулысынча, тәмам керешү

**Керешеп китү** Кинәт кенә керешү. *Үзләренең чатырларына кайтып, өстәл тирәсен, тимер мич тирәсен каплап алгач та егетләр, шаулашып, берберсен бүлеп, шул турыда гәп сатарга керешеп киттеләр.* Н.Фәттах

**Керешеп тору** Һәрвакыт, даими рәвештә керешү. *Әти минем хәлгә керешеп тормады: үзе тизрәк онытсын, дигәндер.* М.Рафиков

**КЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Каралу, пычрану, буялу. *Фуражка инде уңып, керләнеп, үз төсен югалткан, үзе зур, малайның колакларына төшеп тора.* Ә.Фәйзи. *Аларның берсе өсте-башы керләнеп, чабаталары тузып беткән карт рус крестьяны, икенчесе әрмән егете иде.* И.Туктар. *Аяк чолгауларың керләнгәндер, аларын алып китәрмен.* М.Шабай

2) *күч.* Таплану, пычрану (исем, мәхәббәт һ.б.). *Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк; Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?!* Г.Тукай. *Керләнмәгән, пакь балачак тойгысы этне бик тиз аңлый һәм аның белән бер телдә сөйләшә белә.* М.Юныс. *Менә ул, анасының беләкләрендә яткан килеш, моңарчы бер генә кайгы сөреме дә керләндермәгән, бер генә ачы күз яше дә төсен уңдырмаган, чык тамчысыдай ачык-саф күзләре белән анасына караган хәлдә имеп ятадыр.* Г.Бәширов

**Керләнә бару** Торган саен ныграк керләнү

**Керләнә башлау** Керләнү билгеләре күренү

**Керләнеп бетү** Бөтенләй, тәмам керләнү. *Асыл башын күтәрде, күзләрен керләнеп беткән җилән җиңе белән сөртте, авызына җыелып барган тоз тәмен җиргә төкерде, күкрәгән киереп, иркен сулыш алды...* Х.Хәйруллин. *Бикташ майланып, керләнеп беткән тимер саплы җыелмалы пәкене бик кадерле нәрсә сыман саклатып кына кулына алды.* М.Маликова. *Яза-яза кечерәеп калган, кесәдә йөреп шомарып, керләнеп беткән акбур.* Р.Төхфәтуллин

**Керләнеп җитү** Тәмам, ахырга кадәр керләнү

**Керләнеп калу** Нининдидер хәлдән, вакыйгадан соң керләнгән хәлгә килү

**Керләнеп китү** Бер арада, кисәк керләнү

**КЕРЛЕ** *с.* 1) Пычрак, шакшы, буялган, каралган, керләнгән, чиста булмаган. *Ул каршында бары тик Тимурның керле кара кулларын һәм анда җемелдәшеп яткан ап-ак төймәләрне генә күрде.* Ф.Бәйрәмова. *Түшәмнән төшкән яктылыкта аның нәфис колагы һәм нечкә муены шактый керле күренде.* М.Маликова. – *Монда керегез! – дип кычкырды Зөлфия һәм ашык-пошык чаршау артына керде, Нишанбайның авызына тыгылган керле чүпрәкне тартып алды.* Ә.Шәмин

2) *күч.* Начар, пычрак (ният, күңел һ.б.). *Син, якын кардәшебез, җирдәге явызлыкны, зольмәтне җиңү өчен көрәшеп, шул көрәш утында яндың, күмерләндең, тик бу каһәр суккан керле дөньяны пакьли алмыйча, яшьли киттең!* М.Латыйфуллин. *Без вак җанлы, әйе, без мәкерле, Уйлар керле безнең, күңел керле.* Н.Акмал

**КЕРЛЕЛЕК** *и.* 1) Керле булу, керләнгән, каралган, пычранган булу (кием һ.б.). *Бу курчак бүлмәгә аяк басуым белән үк өстемдәге киемемнең керлелеген, аягымдагы итегемнең тузанлылыгын сизеп алдым.* А.Шамов

2) *күч.* Начарлык, пычраклык. *Тик ул сүзләрдә чишмә суы сафлыгы түгел, ә сафлыкны бозучы керлелек бар иде.* С.Поварисов. *Ниятнең керлеге. Күңел керлелеге*

**КЕРН** *и. нем. махс.* 1) Җир бораулаганда, скважинадан (төрле тирәнлектән тикшерү өчен) алына торган таяк формасындагы үрнәк токым, порода. *Рәхимә белән Нарский бүлмәдә, өстәл артында, скважинадан алынган керннарны тикшереп утыралар.* А.Әхмәт. *Бары тик хәзер генә Миргали кечкенә өстәл янында төрле төстәге ташлар һәм кернлар тутырылган тартмаларны һәм бернично төрле нефть салынган озын пыяла савытларны күрде.* М.Хәсәнов

2) *тех.* Механик эшкәртүгә җибәрелгән детальләрне билгеләп чыкканда, кернер белән төшерелгән нокта

3) *астр.* Теләсә нинди галактика төшенең тыгыз өлеше, үзәге

**КЕ́РНЕР** *и. нем. тех.* Детальләргә билге кую, эз ясау өчен кулланыла торган конус очлы, кыска гына корыч инструмент. *[Смирнов] түгәрәк сызыклар ясый, шунда ук түгәрәкләрнең нәкъ уртасына карандаш кебек очлы корыч кернер белән эз төшереп куя.* А.Расих. *Очлы кернер белән эз төшерү*

**КЕРОГАЗ** *и. рус* Керосин парлары янып кызулык барлыкка китерә торган әсбап, тавышсыз примус төре (ашамлыклар әзерләгәндә кулланыла). *Керогаздан файдаланганда, иң элек аның туптуры торуын күзәтергә кирәк, югыйсә ул бик ялкынланып яна һәм төти.* Файдалы киңәшләр. *[Ул] Курмашевкада өстен чишенергә кирәклеген искәртеп, башы белән элгечкә таба ымлады да керогаз кабызырга кереште.* М.Зарипов. *Мин керогазга ут кабызып, су куям, ит кисәге салам, тегеләр бәрәңге әрчи, ярма юа, суган турый.* Ш.Маннур

**КЕРОСИН** *и. гр.* Нефтьне кудырып алына торган углеводород катнашмасы, сарырак төстәге сыек ягулык (реактив самолётлар өчен һәм көндәлек тормышта кулланыла). *Эченә, кечкенә шешәгә керосин салып, сүс филтә куясың. Фонарең әзер.* Р.Хафизова. *Ул өстәл өстендәге тәмәке төпчекләрен ашыкмыйча гына идәнгә себереп төшерде, лампадагы керосинга хуҗаларча карап алды һәм, мич артыннан себерке алып, идәнне себерергә кереште.* А.Шамов. *Залдагы асылмалы зур лампа леп-леп килеп караңгырак яна башлагач, Сәгыйтов керосин салды, ут яңадан балкып китте.* С.Рафиков

**КЕРОСИ́НКА** *и. рус* Керосин янып кызулык бирә торган филтәле җылыткыч көнкүреш приборы. *Кәстрүл төбендә калган саргылт сыекчаны күтәреп эчтем дә керосинканы сүндердем.* Ф.Шәфигуллин. *Миңсылу иртә белән сәгать җидедә үк торып, түбә өстендә йөргәндәй, кайда басканын белештерми, шатлыгына чыдаша алмый, кулы кулга йокмаенча самавырын да куйды, тиз кулга керосинкада гына бер-ике таба төче коймак та салып алды.* К.Тинчурин. *Бу вакыт чаңгыны кыздыру лампасы белән яисә плитә, примус, керосинка һ.б. ш. өстендә тотып җылыталар.* Файдалы киңәшләр

**КЕРОСИНЛЫ** *с.* Керосин белән тутырылган (фонарь, керогаз һ.б.). *Керосинлы шешәгә стеарин шәменең яртысын кырып салырга да, шешәне җылы сулы савытка тыгып җылытырга (еш-еш селкеткәләп) кирәк.* Файдалы киңәшләр. *Алюмин көпшәләр эченә керосинлы мамык тутырылган иде.* Х.Хәйруллин. *Малайларның арбаларында керосинлы мичкәдән башка берни дә юк.* Г.Галиев. *Ул ни булганын абайламый торганда, егет, кулындагы керосинлы сүс пумаласына ут төртеп, Гыйфрит өстенә ыргыта.* Ә.Моталлапов

**КЕРОСИНЧЫ** *и.* Керосин сатучы кеше

**КЕРПЕ** *и.* 1) *зоол.* Бөҗәк ашаучылар отрядының керпеләр семьялыгыннан, аркасы һәм ян-яклары энәләр белән капланган, куркыныч килгәндә йомгак булып бөгәрләнә торган кечкенә генә җәнлек. *Төлке белән керпе турындагы әкиятне ишеткәнем бар иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Куак астыннан бер керпе чыгып килә. Елан, авызыннан ике япьле угын чыгарып, керпегә ташланырга тора.* Г.Сабитов. *Шундый абыйсын эзли Марат! Үзенең керпеләре, кәлтәләре, тузбашлары, кошлары белән бергәләп эзли.* Р.Төхфәтуллин

2) *хәрби* Танклар һәм пехотаны тоткарлау өчен, чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алынган аркылыторкылы казыклардан торган корылма. *Каланың бөтен әйләнәсе Кырык катлы «корыч керпе».* Ш.Маннур. *Шәһәргә керү юлында катлы-катлы «керпе» куелган*

3) *күч.* Үпкәләтүче дип күренгән сүзләргә, кыланышка чәнечкеле, зәһәр, усал сүзләр белән җавап бирүче кеше турында

4) *күч.* Зәһәр, усал, үпкәләтүче сүзләр. *Яңа мөдир ул сөйләгәнне тыңламый, ә үзе сөйләшә, күңелгә барып йокмый, әйтерсең лә авызыннан сүз түгел, вак-вак керпеләр коела иде.* Х.Сарьян

◊ **Керпе сырты төсле** Бар ягы да тигез булган, чәнечкеле. *Керпе сырты төсле тырпаеп торган сакалын бервакытта да әлиф озынлыгыннан кыскартмый да, озайтмый да.* К.Тинчурин. **Керпе энәсе кебек** Каты, тырпаеп торган чәч турында. *Мәнә җыелышны алып баручы райком вәкиле – чәчләре керпе энәсе кебек тырпаеп торган бәләкәй генә кеше – мәгариф бүлеге мөдире трибунага күтәрелде.* Х.Хәйруллин. *Маңгае керпе энәләре кебек текә итеп кыркылган каты чәчләре яныннан очлаеп күренеп тора.* Һ.Дәүләтшина. *Киб көчле куллары белән Джекны үзенә якынрак китерде дә малайның керпе энәләре кебек каты, уттай янып торган бакыр чәчләреннән сыйпады.* А.Тимергалин. **Керпе энәсе сыман** *к.* **керпе энәсе кебек**. *Ямьшәеп, яньчелеп беткән бүреген салып кулына тоткан, чәчләре тузгыган, өч-дүрт көн кырылмаган сакалы, салкында үрә басып, керпе энәләре сыман төрлесе төрле якка тырпаешкан, шинеленең чабулары җилбәгәй җибәрелгән.* Җ.Дәрзаман

**КЕРПЕБАШ** *и. бот.* Җикәнбашчалар рәтеннән, керпебашчалар семьялы-

гыннан сазлыкларда, баткаклыкларда үсүче күпьеллык, вак чәчәкле үләнчел үсемлек; *русчасы:* **ежеголовник**

**КЕРПЕ́ ГӨМБӘ** *и. биол.* Гөмбәләрнең бер ыругы, Төньяк ярымшарда киң таралган; *русчасы:* **ежовик**

**КЕРПЕЛӘНҮ** *ф.* **1.** Усаллану, зәһәрләнү, кырыслану, бик төксе, дорфа, тупас сөйләшү. *[Зобәрҗәт:] Син бүген иртәдән бирле керпеләнеп йөрисең, минем белән күңелсездер шул.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Гыйймади абзый, ник син шулай керпеләнеп сөйләшәсең?* И.Гази

**2. керпеләнеп** *рәв. мәгъ.* Тырпаеп торган, бик кыска итеп алынган чәч турында. *[Бәк-Бәкчи]нең чәче керпеләнеп кырылган булыр, ияк ялтырап тора.* Х.Кәрим

**КЕРПЕ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык, серкәче дә, җимешлеге дә булган бер чәчәктән торган башакчыклары куе, ләкин берьяклы себеркәчләр хасил иткән үләнчел үсемлек; *русчасы:* **ежовник**

**КЕРПЕЧЕБЕН** *и. биол.* Гәүдәсенең өске каты төкләр белән капланган бөҗәк, чебен; *русчасы:* **ежемуха**

**КЕРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Чиста, пычранмаган, буялмаган, керләнмәгән, каралмаган. *Киеменең очсызлы һәм искерә төшкән булуына карамыйчан, керсез, тузансыз булуы әүвәлге карашымнан ук бу татарны миңа сөекле күрсәтте.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Саф; риясыз, хәйләсез, самими, чын. *Аз гына да керсез, самимисаф хисле, чын-чын бәхетле чаклар!..* Р.Төхфәтуллин. *Мәнә шушы түгелмени инде ул үзешчән сәнгатькә булган чын керсез энтузиазм?!* Р.Хисмәтуллин. *«Ул минеке, минеке», – дип пышылдап, үзенеке булганга әле һаман ышанып җитә алмыйча, йокыдагы сабый балага караган кебек, саф керсез караш белән аңа карап тора иде.* И.Гази

**2.** *рәв. мәгъ.* Хәйләсез, эчкерсез. *Шулай булгач, мондый хәлдә керсез инанып, бөтен күңелеңне салып, аңарга нинди җавап язып булсын.* И.Низамов. *Волхов шаһит: изге сугыш антын Соң чиккәчә керсез сакладым.* М.Җәлил

◊ **Керсез күңелле** Эчкерсез, ихлас, саф, турылыклы, самими. *Мөхәммәт керсез күңелле, гали рухлы, әдәпле, шул ук вакытта сабый җанлы кеше иде.* М.Мәһдиев

**КЕРСЕЗЛЕК** *и.* 1) Чиста булу, буялмаган, пычранмаган булу, каралмаган булу (кием, тән, өс-баш һ.б.ш.)

2) *күч.* Сафлык, ихласлык, эчкерсезлек, саф булу, риясыз булу. *Каян килә миңа бу гадәт – белмим. Бала чакта мондый күңелле, матур китаплар кулга бик кермәгәнме, әллә шигъри юллардагы, хикәяләрдәге, әкиятләрдәге керсезлек, сафлык, самимилек, хәтта беркатлылык, мавыктыргыч маҗаралар, алар аша тормышка ашып бетмәгән хыялларым җәлеп итәме?* Г.Гыйльманов. *Ә бу бит – рухи, әхлакый чисталык, сафлык, керсезлек билгесе!* М.Вәли-Барҗылы

**КЕРТ** *иярт.* Нәрсәне дә булса ашаганда, тешләп алганда, кимергәндә, кискәндә, тапаганда һ.б.ш. очракларда ишетелгән тавышны белдерә (күбесенчә кабатлап әйтелә). *Мәнә машина бөтенләй колак төбендә генә чышылдап килеп туктады да, ян ишеге керт итеп ачылып та китте.* Р.Төхфәтуллин. *Җир өстенә барып төшкәч, абый белән апай, җиңсәләрен киеп, алъяпкыч итәкләрен билләренә кыстыралар да, икесе ике кишәрлек алып, керт тә керт урырга тотыналар.* Г.Бәширов

**КЕ́РТ-КЕРТ** *иярт. к.* **керт**. *Кара борынлы малайларның шатлыктан елтыраган күзләрен күрү, куян кебек керт-керт кишер кимерүләрен карап тору җанына рәхәтлек бирә аның.* Ф.Яруллин. *Тынлыкта елга дулкыннары кагуы, атның умарталар арасында керт-керт яшь үлән утлавы ишетелә иде.* Ә.Гаффар. *Борчак саламы эскертенә куыш ясап керәсең дә комбайн барабаныннан исән калган саргылт ахак кузакларны эзләп табып, керт-керт ашыйсың.* М.Мәһдиев

**КЕРТҮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса эченә үткәрү. *[Арбадагыларның берсе] Капканы ачып атны кертте, капканың мунчала бавын яңадан казык башына элде дә, арбага утырып, дилбегәне какты.* М.Галәү. *Морат, комган тотып, өйдән атылып чыкты да әбрәкәйгә кереп бикләнде. Ул арада Сәлҗия капканы ачып, Хөрдунны ишегалдына кертте.* Р.Батулла. *Көне буе каядыр китеп югалган песи ишекне тырный башлаган иде, [Ирек] аны ачып кертте.* Г.Рәхим

2) Кая да булса керергә рөхсәт бирү, үткәрү. *Анда – күзләр, монда – күзләр. Аудитория ишеге төбендәгеләр егеткызларның паспортын һәм БДИ бирергә рөхсәт кәгазен тикшереп кертәләр.* Ватаным Татарстан

3) Үткәрү, үтәргә мөмкинлек бирү; үтәрлек итү (су, суык, җил һ.б.ш.). *Хәерченең төрттереп әйткәне Тукайның ачуына барып кадалды, ул: – Яп авызыңны! – дип кычкырды. – Ишекне дә яп, җил кертәсең.* Р.Батулла

4) Кемне яки нәрсәне кая да булса алып керү, урнаштыру. *Палатага кертеп салгач, газапларым бетәр дип уйлаган идем, әле тәмугның ишегалды гына булган икән. Палатада тимер карават өстенә такта җәйделәр.* Ф.Яруллин. *[Биктимер абзый] Капчыгы белән онны кертеп өйалдына утыртты да, тагын керермен әле, дип чыгып китте.* З.Зәйнуллин. *Тиз генә Фәридәне каталкага күчереп салдылар да биш урынлы буш бүлмәгә кертеп яткырдылар.* Ф.Тарханова

5) Нинди дә булса исемлеккә теркәү, берәр нәрсә составына билгеләү. *Мәнә шунда вулыс прсидәтеле Сабир Мәксутов авылның хәлфәләрен, мулла-ишаннарын кертеп, ГПУдан килгән слидывателгә исемлек төзеп биргән.* З.Зәйнуллин. *Килгән елны ук «Колхоз утлары» стена газетасының редколлегиясе составына керттеләр ---.* Г.Гәрәева. *Союздагы милләтләр Россия составына үзләре теләп кергәннәр.* И.Хуҗин

6) Нәрсә белән дә булса тиңләштерү, билгеле бер дәрәҗәгә җиткерү. *Алексей Федорович, без соң Татарстанны «икенче Баку»га кертер өчен йөрибез түгелме?* А.Әхмәт

7) Берәр нәрсә өчен түләү, хак бирү. *--- транспорт картасына айның тугызыннан соң акча кертсәң, транспорт картасыннан бары тик киләсе айда гына файдалана аласың.* Шәһри Казан

8) Нәрсәне дә булса гамәлгә ашыру, урнаштыру, канунлаштыру. *Галим турындагы мәсьәләне гомуми җыелышка*

*куюны да ул – Хафиз кертте.* Г.Әпсәләмов. *Екатеринбург ата-аналары хакимияттән педофилларга карата үлем җәзасы кертүне таләп итә.* Безнең гәҗит

9) *күч.* Нәрсәгә дә булса аерым бер төс, кыяфәт һ.б.ш. бирү, аны билгеле бер рәвешкә китерү; берәр нәрсә өстәү. *Ул [малай] килә-килешкә үк бораулап карый торган күзләре белән солдатка бер караш ташлап алды да, оста клоун сыман, йөзен көлке кыяфәткә кертеп чалшайтты ---.* З.Хәким. *[Авыл] Клубын курчак күлмәге кебек киендереп куйдылар, урамнарын адәм рәтенә керттеләр, яңа мәдрәсәсе тагын...* А.Әхмәтгалиева

10) Үткәрү, урнаштыру, тоташтыру (электр, су, телефон, антенна һ.б.ш.). *Су чәчрәтеп аккан Иштирәк, Табыр, Мотаука чишмәләрен соңгы елларда бер улакка кушканнар да 13 чакрымлы суүткәргечләр аша һәрбер өйгә керткәннәр.* Ватаным Татарстан

11) Абстракт исемнәр белән килеп, әлеге исемнәр белдергән хәл, күренешкә дучар итүне аңлата. *Тик Йомагуҗадан булган фельдшер Мәсәлим бабайны яхшы белгән әтисе ачыклык кертте: – Ул малайның әтисе районга атаклы бик шәп тегүче иде.* З.Зәйнуллин

**Кертә бару** Акрынлап һаман кертү. *– Андый чагыштыруларны җыеп, китабыңа кертә барырсың, – диде Әхнәф көлеп.* Ф.Садриев

**Кертә башлау** Кертергә тотыну. *Төз гәүдәле --- Герман армиясе фельдмаршаллары, генераллары танкларын, тупларын тыныч йокыда җәелеп яткан Россия кырларына кертә башлаган минутта Кара Чыршы авылы, чыннан да, татлы йокыда иде әле.* М.Мәһдиев

**Кертә бирү** Бернигә карамастан кертү. *Аның идеяләре бүген дә әһәмиятен югалтмаган, фәннең бу өлкәсен үстерүгә һаман да зур өлеш кертә бирәләр.* Шәһри Казан

**Кертә тору** Акрынлап кертү; әле кертә торган булу. *Гали абзыйның хатыны – ак яулыгын колак артына кысып бәйләгән кара кашлы, күркәм йөзле, тулы гына гәүдәле Галимә апа – аларны ачык йөз белән каршы алып, ак өйгә, Гали абзый янына кертә торды.* Г.Әпсәләмов

**Кертә язу** Чак кына кертми калу. *Аның кәмитләре Гыйззинасны гүргә кертә язды.* Безнең гәҗит

**Кертеп алу** Тиз арада кертү, кыска вакытка кертү. *– Юк, быелгысы алтынчы, Марсик, – дип, Дамир төзәтмә кертеп алды.* Р.Сәгъди

**Кертеп бару** Акрынлап кертү яки һәрдаим кертү. *Шакир бабайны мин әсәрләремә Ак Бабай итеп кертеп барам.* Г.Гыйльманов. *[Дилбәр:] Социаль ипотекага ай саен тиешле акчаларны кертеп барам, чөнки бары шушы программага гына өметләнәм.* Мәдәни җомга

**Кертеп бетерү** Тәмам, ахырга кадәр кертү. *Алар [авыл хуҗалыгы предприятиеләре] былтыргы бурычларын да кертеп бетерде.* Мәдәни җомга

**Кертеп җибәрү** Бераз кертү. *Бу сабый акыллы бала белән шаяртып сөйләшеп алу хәл кертеп җибәргәндәй булды.* Г.Гыйльманов

**Кертеп йөрү** Кертү процессында булу

**Кертеп калу** Кертергә өлгерү

**Кертеп карау** Кертергә тырышу. *Әмма аңа бары тик көзгегә генә карау кирәклеген, ул аны шунда күрәсен, сөйләнелгән сүзләрнең үзе хакында барганлыгын башына да кертеп карамады.* Ф.Яхин

**Кертеп килү** Электән үк даими кертү. *Менә инде биш гасыр дәвамында татарлар шушы ил халыклары белән бергәләшеп, икътисади һәм социаль үсешкә, мәдәниятка, фәнгә һәм мәгарифкә үз өлешен кертеп килә.* Римзил Вәлиев

**Кертеп кую** Нәрсәне дә булса кертеп, тиешле урынында итү. *Асрау әйберләр кертеп куя.* Г.Исхакый. *Машинаны «Мир»ның парковкасына кертеп куям һәм туп-туры өченче катка менәм.* Л.Әбүдәрова

**Кертеп тору** Даими яки әледән-әле кертү; вакытлыча кертү. *Мәсәлән, Яңа ел алдыннан каты салкыннар башлангач, Фатыйма карчык белән Газиз карт, сак кына кыланып, табакны өйгә кертеп тордылар.* Г.Гыйльманов. *«Суярга алып бара, ахры, мине», – дип курыккан Тукмар [әтәч]. Ләкин әби аны күршеләргә генә кертеп торган.* А.Алиш

**Кертеп чыгу** Тиз арада нәрсә дә булса кертү. *[Биктимер абзый] Икенче көнне ике кило чамасы симез генә сарык ите кертеп чыкты.* З.Зәйнуллин

**КЕРФЕК** *и.* Күз кабаклары читендәге күзне чүп керүдән һ.б.ш.дан саклый торган төкләр. *Шәфкать кызы, бер селкенеп, шул минутта ук Керфекләрен йомды, мәңге күтәрмәскә...* Һ.Такташ. *Юешләтте аның керфекләрен Яңгыр түгел, назлы күз яше.* М.Җәлил. *Докторның соравына тәүдәрәк керфекләрен сирпеп, соңрак инде баш кагып яки кул хәрәкәтләре белән җавап бирде.* М.Кәбиров

◊ **Керфеген дә селкетмәү** Бер дә исе китмәү. *Мин мондый гүзәллеккә йөрәгем сокланудан аһ иттем ---. Ул [Зариф] бит – асыл зат, эре сөяк. Керфеген дә селкетмәде.* Ф.Яхин. *Бу сүзләрне әйтү бик үк җиңел булмады Кәримгә, ә ханым керфеген дә селкетмәде кебек.* Ф.Сафин. *Илүсә бу хакта шундук Мәстүрә карчыкка әйтте. Тегесе керфеген дә селкетмәде.* Г.Гыйльманов. **Керфек тә какмау** Йокламау. *Ул инде берничә көн керфек тә какмый, газиз баласы, җан кисәге, бәгырь ите янында бөкрәеп утыра.* Г.Гыйльманов. *Керфек какмый төн уздырды Галим, Таңда гына кайтты иптәше.* Ф.Кәрим. **Керфек тә кактырмау** Йокларга ирек бирмәү. *Үги әти, көндезләрен күрмәмешкә салынып шома гына йөрсә дә, төннәрен әнием Саниянны талап, керфеген дә кактырмады.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**КЕРФЕКЛЕ** *с.* Керфекләр белән капланган. *Керфекле инфузорияләр*

**КЕРЧӘН** *с.* Тиз керләнүчән. *Кеше киеме керчән, кеше аты тирчән.* Әйтем

**КЕРШӘН** *и.* Пудра. *Йортка кершән исе, салкын һава исе таралды.* М.Мәһдиев. *Гөләнвәр киенеп, ясанып, җиңел генә кершән һәм иннек ягып, миң төртеп, өстәл алдына килеп утырды ---.* Ә.Фәйзи. *Кунаклар ашап туктаган арада, Исәнтәйнең курчак*

*кебек итеп төзәндергән, бизәндергән, битләренә кершән яккан, кара чәчләре күпереп торган чибәр кызлары ят җырлар җырладылар, төрле уен коралларында уйнадылар.* Н.Фәттах

**КЕРШӘН-ИННЕК** *җый. и.* Гомумән бизәнү кирәк-яраклары; бизәнү-төзәнү әйберләре. *[Хатынның] Беренчесе көн-төн йоклауны, кершәнинекне яратты.* З.Зәйнуллин

**КЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса эченә таба хәрәкәт итү, кая да булса үтү, берәр нинди чикне узу. *[Хатын-кызлар] Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр.* Ә.Еники. *Урамның тайгакларыннан үткәндә, ул куркып-куркып басканга, Шәмсетдин аны култыклады да, аулак кына тыкрыкка кереп, ике этажлы гына агач өйгә йиткәч тә, марҗа: – Менә минем өем, рәхмәт озатуыңызга, – дип кулын сузды.* Г.Исхакый

2) Нәрсәнең дә булса эченә үтү; кадалу. *[Нурый:] Әпрәй --- 18 ендә эшләде. 19 ында бармагына шырпы керде, кайтып китте.* А.Алиш

3) Кая да булса юл табып үтү, эчкә үтү, берәр җиргә тулу (су, суык, җил, тузан һ.б.ш.). *Ишек шыгырдап, чинап ачылды, ургылып кар бураны* керде. И.Салахов. *[Хатын] Суык керә башлаганга, курка-курка аргы бүлмәгә барып, тәрәзәнең эчкесен рәтләп япты да, картның көндез яшереп куйган җиреннән әйбәт йомшак арыш икмәге эзләп тапты...* Г.Ибраһимов

4) Аерым бер максат белән өйгә, бүлмәгә һ.б.ш. яшерен рәвештә үтү. *Карак керсә стеналар кала, уттан берни калмый.* Мәкаль

5) Эшкә, уку йортына һ.б.ш. кабул ителү, урнашу. *[Фазыйл] Авылда күренмәде, шунда каралып алынганмы, ничектер, Мәскәүгә барган да лашманчыларга башлык сыман булып урынга кергән.* Г.Ибраһимов. *Казанда университет рабфагына укырга кердем.* Г.Кутуй

6) Нинди дә булса оешма, җәмгыять әгъзасына әверелү. *Борис тагын каршы төшеп карады: – --- Мин бригадага керә алмыйм.* А.Алиш. *Пример, без колхозга кергәч, ат-туарлар һәммәбезнең күмәк ителде...* Һ.Такташ

7) Билгеле бер вакытка дәвалану максаты белән яту, урнашу (хастаханә, госпитальгә һ.б.ш.). *1913 елның 26 февралендә (15 мартында) Тукай авыр хәлдә больницага керергә мәҗбүр булды.* Г.Халит

8) Хөкем ителү, утыртылу, ябылу (төрмәгә һ.б.ш.). *Бара торгач, Мансур мулланың үзенә һәм бәддога төшеп, ахыр гомерендә зина вә хәмер белән бәлагә тарып, кайбер эшләре өчен төрмәгә кереп, шунда һәлак булгандыр.* Риваять

9) Нәрсәнең дә булса составында саналу, составына билгеләнү. *«Изге Рим империясе» составына кергән Европа илләренең барысында да диярлек Көнчыгыш телләре институтлары һәм аларның филиаллары булдырыла.* Казан утлары

10) Кая да булса язылган, теркәлгән, исәпкә алынган булу. *Кушнаренко укыган исемлеккә керү өчен синең эш белүең, осталыгың, сәләтең, талантың – болар берни түгел?* М.Юныс. *Балалар өчен язылган «Сөяк саплы пәке» исемле җыентыкка 14 авторның хикәяләре кергән.* Ватаным Татарстан

11) Савытка билгеле бер күләмдә сыю. *3 литрлы банкага 4 кг 300 гр бал керә*

12) Берәр ел фасылы, календарь ае, нинди дә булса билгеле бер көн һ.б.ш. житү, башлану. *Инде кыш та керде, Игенне бетерде; Чаналар астында Ак карлар шытырдый.* Г.Тукай. *Җиләк җитсә, кечкенә-кечкенә тубаллар, көз керсә, авылның бер башыннан икенче башына ишеттерерлек яңгыратып суга торган биек, текә какмалар – болар һәммәсе шул атасына охшап туган Гыйлаҗи кулыннан ясалып килә.* Г.Ибраһимов

13) Аерым бер күренеш, вакыт арасын һ.б.ш. үтеп, икенче бер күренеш, вакытка һ.б.ш. күчү. *Җәй, көз, кыш үтә. Яз килә. Минем Алмачуар өченчегә керә. Авылда, бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр.* Г.Ибраһимов

14) Нинди дә булса бер төс, кыяфәт һ.б.ш. алу, билгеле бер рәвешкә килеп үзгәрү. *Бер минут эчендә бөтен йорт җәһәннәм рәвешенә керде.* Г.Тукай. *Жихарев дәрәҗәле түрә кыяфәтенә керде.* В.Имамов

15) Укыту эше алып бару, кайсы да булса фән буенча дәрес бирү. *Диксон абый безгә 7 нче класста сызымнан, ә 10 нчыда рус теле һәм әдәбиятыннан керде.* Г.Гәрәева. *Татар теле һәм әдәбияты укытучысы икән үзе. Дәресләр җитмәгәндер инде, безгә физкультурадан керде.* Безнең гәҗит

16) Укытылу. *[Сара Садыйкова:] Һо-о, ул гимназия бүгенге университетыңа тора. Фәннәр, телләр, диннән башка анда нәфислек дәресләре дә керә иде.* Р.Батулла. *--- атнасына бер генә сәгать керә дип, татар телен читкә куеп яки, ике сәгать кенә керә дип, әдәбиятны укымыйча булмый бит.* Ватаным Татарстан

17) Үтү, үткәрелү, тоташтырылу, куелу (электр, су, телефон, антенна һ.б.ш.). *Авылга күптән газ керде.* Мөҗәһит

18) Билгеле бер табыш булу, акча, байлык һ.б.ш. килү. *Юкса, озын юлда ул бераз гына акча-төшем керәсенә дә өметләнми түгел иде.* Р.Мирхәйдәров

19) Берәр урынга урнаштырылу, куелу (ашлык, иген һ.б.ш.). *Иген керде ындырларга, Кибән-кибән өелеп.* М.Җәлил

20) Абстракт исемнәр белән янәшә килеп, нәрсәнең дә булса кабул ителүен, ныклап урнашуын белдерә. *Әнвәр Абидовичның Мәскәүгә укырга киләчәген белүгә үк, ул телефоннан ялынып-ялварып башлыклы, аксыл төстәге дублёнка алып килүен үтенә башлады, хәзер шундыйлар модага кергән икән.* Р.Мирхәйдәров. *[Әминә:] Кара әле, туганым, менә хәзер шушындый кофточка модага кергән инде.* Ф.Әмирхан. *Шөһрәт баштарак, вакыты җитмәгәндә яки үзе аңламаганда гына Гадиләдән кучергәләсә, тора-бара бу аның гадәтенә кереп китте.* Ф.Яруллин

21) Нинди дә булса сыйфатны, хәлне һ.б.ш. атаучы исем белән килгәндә, шул сыйфат, хәл һ.б.ш. барлыкка килүне, шуңа ия булуны белдерә. *Еллар үтте. ---. Миңа инде көч кереп килә, һәм бер кеше дә «моның әтисе юк» дип, мине җәберли алмас...* М.Мәһдиев. *Канат очына дәрт кергән казларның да*

*тук тавышында якынлашып килгән күз ялкыны сизелә иде.* М.Галиев. *Табигатькә тагын бер яз килә, Бар җанлыга җирдә дәрт кергән.* Ф.Шәрипова

22) Нинди дә булса эш, үтенеч белән кемгә, кая да булса мөрәҗәгать итү. *Кукчәтауда рус телендә өлкә газетасы чыга икән. Беркөнне редакторга кердем, үземнең Казанда республика газеталары редакциясендә эшләвемне --- сөйләдем.* И.Салахов

23) Кайбер юнәлеш килешендәге исемнәр янында килеп, шул исем белән белдерелгән нәрсәнең, хәлнең башлануын аңлата. *Иң элек ул [Газинур] бакыйлыктан иңгән илаһи сын белән бәхәскә керде, аннары тыныч кына, дустанә сөйләшергә, гәпләшергә өйрәнде, бераздан алласының һәр әйткәненә, һәр ымына разый булып, баш кагып тора башлады...* Г.Гыйльманов

**2.** *ярд. ф. функ.* Хәл фигыль янында килеп, билгеле бер тарафка хәрәкәт итүне, нәрсәнең дә булса эченә үтүне белдерә. *– Мин хәзер әйләнеп керәм, – дидем дә келәттән чыгып киттем.* Ф.Хөсни. --- *Арт бакчалар аша кайтып керде, Йомшак ябып каты ишекне.* Ф.Кәрим. *Гамил өенә атылып кайтып керде.* Л.Шәех

**Керә бару** Акрынлап керү; торган саен тагын да керү. *Мәрьям авызында икмәге тулы көенчә: – Бабай, оят була бит, гөнаһ була бит, – ди, үзе, тук заманында иренә иркәләнүдән калган гадәте буенча, картның кочагына керә бара.* Г.Ибраһимов. *«Сәгатьләп түгел, минутлап акыл керә бара моңа», – дип, күңелле уйлап куйды Сенатор капитан турында.* Р.Мирхәйдәров

**Керә башлау** Керергә тотыну. *Барысы да берәм-берәм керә башлыйлар.* Д.Салихов

**Керә бирү** Бернинди каршылыкларга да карамастан керү; тагын да ныграк керү. *Ул [малай] анасының ябык, кипкән кочагына керә биреп: – Әнкәй, мин бер дә китмәс идем дә бит... әнә теге җиде хатыннан бик куркам шул, – дип, тагы күз алдындагы кебек куркынычларны хыяллый башлады.* Г.Ибраһимов

**Керә тору** Хәзерге вакытта керү; кемнән дә булса алданрак керү. *Шагыйрьнең каләменнән бер-бер артлы шигырьләр, поэмалар, пьесалар чыга торды. Чыга торды һәм коргаксыган күңелләргә шифа булып керә торды.* М.Кәримов

**Керә язу** Аздан гына керми калу

**Кереп бетү** Тәмам, тулысынча керү; бар булган нәрсә билгеләнгән урынга тулысынча керү. *Көзге яңгырлар башланганчы, бөтен уңыш җир келәткә кереп бетте.* Г.Гыйльманов

**Кереп карау** Керергә тырышу; керергә омтылыш ясау

**Кереп тору** Даими, гел керү; билгеле вакытка гына керү

**Кереп утыру** Нык урнашу. *Озак-озак Гайнияне уйладым. Бу кыз белән вәгъдә алышу түгел, җүнләп сөйләшкәнем дә юк. Шулай булса да, ул минем йөрәгемә хатыным булып кереп утырган.* Г.Ибраһимов. *Хәлимнең күңеленә Майя кереп утырган, ә Нәфисә, үз язмышына буйсынып, үз яшәеше белән тәмам килешкән иде...* Г.Гыйльманов

**Кереп чыгу** Аз гына вакытка керү. *Фазыйл атасы янына кереп чыкты да: – Вәт нәрсә, Шаһбаз, – диде, – ул җиңгәң барыбер көн күрсәтмәс, син бездә кал!* Г.Ибраһимов. *Искәндәр идәндә гаҗәпләнеп утырган арада, Сөмбел кухняга кереп чыкты ---.* Р.Вәлиев. *Башка күршеләр дә Хәлимнәр капкасына юлны онытып бетермиләр. Хәтта бер аулакта Нәфисә дә кереп чыкты.* Г.Гыйльманов

**КЕСӘ** *и.* **1.** 1) Өске киемнең (пальто, чалбар, күлмәк һ.б.ш.), төрле нәрсәләр салып йөртү өчен, эчке яки тышкы ягына тегеп куелган кечкенә янчык. *Мин үземчә аңа [апама] киңәш биргән булам: «Ике кесәңә дә авыр таш салып чыкмасаң, үзеңне җил очыртып алып китәр...».* М.Юныс. *Тирән төпле чалбар кесәмнән йолдызлы сап-сары тимер солдат төймәсе чыгарам да аның күз төбенә сузам: – Менә мондыйны күргәнең бармы? Алтын! Йолдызлы!* Ф.Яхин. *Галәү костюм кесәсеннән бер уч акча чыгарып миңа тоттырды да поездга таба йөгерде.* И.Салахов

2) Чемодан, портфель кебек әйберләрдә махсус кечкенә бүлекчә. *Изаел читтәрәк урнашкан касса тәрәзәсе янына баса, сумкасы кесәсеннән паспортын чыгара.* Р.Гаязетдин

3) *куч. сөйл.* Күп акча, байлык. *Һи, кесәң булсын, тагын табылыр татарның бер кызы!* Н.Исәнбәт. *Егет булгач егет булсын ул – эше белән дә, киеме-салымы белән дә, кесәсе белән дә.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кесәдә йөртерлек, кесәдә һ.б.ш. йөртер өчен җайланган; үзең белән йөртергә кулай булган. *Телевизор юк, компьютер һәм кесә телефоннарын әле ишеткән дә юк.* Р.Мөхәммәдиев. *Германиядән, башка Европа илләреннән килгән солдат посылкалары белән байтак кына төзәтелергә тиешле кесә һәм кул сәгатьләре килә башлады.* Ф.Нәкыйпов. *Ярты төн уртасында кесә телефоны шылтырады.* Н.Гыйматдинова

2) Күләме, үлчәме ягыннан зур булмаган; үзең белән йөртергә кулай булган. *Газета укучылар өчен кесә сүзлеге*

◊ **Кесә бушату** Кемнең дә булса берәр әйберен урлау, төрле мәкер, хәйлә белән кеше малын үзләштерү. *[Өйрәнчекләре] Синең кебек яклаучысыз ялгыз хатыннарның кесәсен бушата!* Н.Гыйматдинова. **Кесә бушау** Акча бетү. *– Ник башта ук күрсәтмәдең? – диде Тотыш, күрәләтә үкенү белән. – Кесә бушады.* Н.Фәттах. **Кесә буш булу** Байлык булмау, акча юклык. *Кесә буш булса да, кыяфәт хуш.* И.Рәмиев. *Кесә буш булгач, горурлык та, үз-үзеңә ышаныч та юк.* Р.Вәлиев. *Казанга Михаил Жванецкий килде. ---. Мондый очрашулар өчен кесәң калын булсын. Ә минем кесә буш та, тишек тә.* Казан утлары. *Бушрак шул әле кесәң, дустым, Йомшак әле асыл сөягең ---.* Ф.Яхин. **Кесәгә дә йокмау** Бик аз булу (акча тур.). *Алманың акчасы кесәгә дә йокмады: ертык-тишек урын күп булгач, акчаны күрми дә калдылар.* И.Гази. **Кесәгә кереп тормау** Сүзгә аптырап калмый торган кеше турында әйтелә. --- *Исмәгыйль кытыршы кулларын Зарифның җилкәсенә салды: – Ярар, Зариф энем, исең китмәсен иске чикмәнгә. Ну малай, җавабына да кесәгә кереп тормадың ---.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Үскәндә Уфаның үзләре яшә-*

*гән бистәсендә иң чибәр, зирәк, теремек кызларның берсе булды Галия. Сүзгә дә кесәгә керми, үртәшергә аңа куш.* Д.Булатова. **Кесәгә керү** 1) Кемнең дә булса кесәсеннән акча һ.б.ш. алу, урлау. *[Җабир:] Аларны бит әллә кем кесәсенә кереп алмаганнар, шушы авыл кешеләренең тырыш хезмәтенең өлешеннән алар барлыкка килгәннәр.* Ф.Яхин; 2) *к.* **кесәгә кереп тормау** (сүз өчен). *Үзен кыерсыттырмады, кирәк чагында сүзгә дә кесәгә кермәде [Галия].* Л.Ибраһим-Вәлиди. **Кесәгә кою** Баю; акча, байлык керү. – *Юлың уңдымы, ханым? – диде би. – Уңды, би, – диде Алмыш хан. – Моннан соң Чулман Ителгә түгел, минем кесәгә коячак.* Н.Фәттах. **Кесәгә кулны тыгып** Бернинди уй-хәсрәтсез һәм эшсезшөгыльсез, ваемсыз (йөрү, яшәү). *Берәү эштә «булсын» диеп ут йотып йөри, берәү, кесәсенә кулын тыгып, төтен йотып йөри.* Ә.Дусайлы. **Кесәгә сугу** Нинди дә булса зур чыгым аркасында акчага кытлык булу, акча ягыннан авырлык килү турында. – *Сер булмаса, клип төшерү күпмегә кесәгә сукты? – Беренче клип 80 мең сумнан артык булды.* Ирек мәйданы. **Кесәдә җил уйнау** Акча булмау. – *Тамагым тук минем, – диде [Талип]. Горур, янәсе. Кесәсендә җилләр уйнаганын белгертми, янәсе.* Н.Гыйматдинова. **Кесәдә йодрык йөртү** Кинә саклау. *Ул [Шамил] элеккеге дошманнарыннан үч алу юллары да кормады, кесәсендә йодрык та йөртмәде, аларны эзләп тә йөрмәде, һич юк.* Л.Ибраһим-Вәлиди. **Кесәдә калу** Экономия булу, экономия ясау. --- *бер-бер нәрсә сатып алырга тугры килсә, үз-үземә: «Сыбызгыга артык бирмә!» – дия идем дә, акчам кесәдә кала иде.* Г.Тукай. **Кесәдән йодрык күрсәтү** Ризасызлыкны турыдан-туры әйтергә, эшләргә батырлык, кыюлык җитмәү. *Милләтнең хокукын кесәдән йодрык күрсәтеп кенә, чәпчепкычкырып кына яклап булмый.* Р.Вәлиев. **Кесә законы** Бар нәрсәнең дә акчага, байлыкка корылган, нигезләнгән булуы турында. --- *мәчет Тәлгать Таҗетдингә буйсына, татар байлары кесә законына буйсына, Аллаһ законнарына гына буйсынырга теләүче юк...* Ф.Бәйрәмова. **Кесә калынаю** Акча күп җыелу, баю. *Гомеремә күрелмәгән хәл – кинәт кесәм калынаеп китте.* Ф.Яхин. – *Үзең үк әйтеп торасың, ханым: юлың уңган, кесәң калынайган, – диде би.* Н.Фәттах. *Кесә көн саен калынаеп торганда, нәрсәгә аларга алга киткән сәнәгать, икътисади бәйсезлек, нигә ул азык-төлек куркынычсызлыгы?* Ватаным Татарстан. *Эше бераз җайланып, кесә калыная төшкәч, [Габделбәр] кассап салдырып җибәрде.* А.Расих. **Кесә карагы** Кесәгә кереп яки ваktөяк урлашып йөрүче кеше; кесәче, картаман. *[Прокурор:] Тагын ике кесә карагын тап, милиция капитанына ассистентлыкка алардан да кулай кеше булмас.* Р.Мирхәйдәров. *Вөҗдансыз кешеләр шигырь язмый. Һәрхәлдә, кесә карагы гимн язганын ишеткәнем юк әлегә.* Р.Нуруллин. **Кесәне саву** Акрынлап берәр кешенең акчасын, байлыгын алып бетерү. *[Мәликә картына:] Кесәңне саварга тели торгандыр шул [киленең].* А.Шамов. **Кесәне тишмәс** «Кирәге чыгар», «файдасы тияр» дигән мәгънәне аңлата (кулга кирәргә торган байлыктан баш тартмаска өндәгәндә кулланыла); «эчне тишмәс» мәгънәсендә. *Шулай итеп, мәгълүм эшмәкәр, авыл җирлеге, район советлары депутаты да, акча кесәне тишмәс дигән принцип буенча эш иткән.* Н.Вахитов. *Артык керем кесәне төртеп тишми, әбигә күп калмады инде аңа, әби үләр дә бетәр, ә өй бит кала…* Безнең гәҗит. **Кесә партиясе** Һәртөрле вак партияләр турында. *Ул [Михалков] шулай ук «беркем һәм бернәрсәне тәкъдим итми торган кәрлә, уенчык, кесә партияләре сәяси көрәш сәхнәсеннән китәргә тиеш» дип саный.* Ватаным Татарстан. **Кесә саегу** *к.* **кесә такыраю**. *Әмма монда да газета-журналлар тирәсендә эшкә урнашу мөмкин булмады, һәркайда кыскартулар бара икән. Шулай көннәр, атналар үтә, кесә саега.* Г.Иделле. **Кесә сай булу** Акча аз булу, акчасызлык. *Кесә сай, кул кыска.* Мәкаль. *Баем, баем, бай гына, Инде кесә сай гына, Ашый алмый май гына* ---. Г.Камал. *Вакытын табар да идең, кесә ягы сай.* М.Бакиров. **Кесә сайга калу** *к.* **кесә такыраю**. *Кызларын бирәләр байга, туйлары тартыла ике айга, Кесәләре каладыр сайга.* Ш.Мөхәммәдев. **Кесәсе калын** Бай, акчалы кеше турында. *Хак, алар [хатын-кызлар] арасында елгырлары бар иде, алар тормышка тиз җайлашты: яшь кызлар үзе карт, ләкин кесәсе калын абзыйлар куенына елышса, урам чатларын «төнге күбәләкләр» сарды.* Н.Гыйматдинова. *Ә кече улы – Роберты – ничек укырга керде соң? Дуслар булсын дөньяда һәм алар янына бара алырлык якты йөзең, калын кесәң, юмарт кулың!* Ф.Яхин. **Кесәсенә керү** Берәүнең байлыгы, мөлкәте берәр кеше тарафыннан үзләштерелү. *Дәүләтнең эре завод-фабрикалары, оешмалары кемнеңдер кесәсенә кереп утырды ---.* Н.Гыйматдинова. **Кесәсен тикшерү** Кемнең дә булса күпме акчасы (байлыгы, мөлкәте) булу, аны ничек тотуы белән кызыксыну. *[Галия:] Әй лә, кеше кесәсен тикшермик, Наташа. Теләсә нишләсен.* Д.Булатова. **Кесәсе юан** *к.* **кесәсе калын**. **Кесәсе такыр** *к.* **кесә буш булу**. *Кесәсе такыр булса да, Күңеле миллионер.* В.Хәйруллина. *[Малай:] Ширбә-әт! Сап-салкын ширбәт! Яңа гына кар базыннан ширбә-әт! Нибарысы өч бакыр, ширбә-әт! Кемнең кесәсе такыр, булыр бер бакыр – ширбәт!* Р.Батулла. **Кесә такыраю** Акча бетү; бөлү. *Кесәң такырайса, күршең сукырая.* Мәкаль. **Кесә такыр булу** *к.* **кесә сай булу**. *Өйләнергә минем кесә ягы такыр.* Д.Булатова. **Кесә талаучы** 1) *к.* **кесә карагы**; 2) Төрле юллар белән кеше малын, акчасын үзләштерүче, башкалар хисабына яшәүче. *Монда бар залим тараф, күзгә карап алдаучылар, Башкаларның күзләрен бәйләп, кесә талаучылар.* М.Гафури. **Кесә төбе саегу** *к.* **кесә саегу**. *Шәвәлине эчереп, Кесә төбе саекты.* М.Саттаров. **Кесә файда итү** *иск.* Акча, байлык керү. *Ишан килүдән кесә файда итсә дә, күңел файда итмәде, тагы элгәреге кеби бушлык биләде.* Г.Исхакый. **(Үз) кесәсен кайгырту** Үз файдасын гына кайгырту, үз ягын гына карау. *Угры түрә, урып җыю*

*эшләреннән бигрәк, үз кесәсен күбрәк кайгырта бит ул.* Н.Вахитов. *Кичә генә партия җитәкчесе булган, илгә тугры хезмәт иткән хуҗа бүген үз кесәсен генә кайгырта башлаган икән, димәк, ул белеп эшли: гайре юлдан дөнья бара алмый!* Ф.Яхин. **(Үз) кесәсеннән чыгару** Үзең түләү. *Иң киме – ун мең сумнар акча кирәк булыр. Моның яртысын Сарсымбай үз кесәсеннән чыгарса, калганын башкалар күтәрер.* Г.Ибраһимов

**КЕСӘБИКӘ** *и. нем. иск.* Кыска җиңле, мамык белән сырып эшләнгән, кырыйларына мех тотылган хатын-кыз киеме; *русчасы*: **кацавейка**. *Ирләр киеме белән хатыннар киеме арасында күп аерма бар. Инде хатын-кыз киемнәре менә: күлмәк, ыштан, читек, башмак, кәвеш, камзул, тун, кесәбикә, яулык ---.* К.Насыйри

**КЕСӘЛ** *и. рус* 1) Җиләк-җимеш суына, сөткә һ.б.ш. крахмал кушып әзерләнгән койка сыман ризык. *Килгән чакта дөнья бетеп, Ясалып ята, имеш, Гүя сөт һәм кесәл тулып Елгалар ага, инеш.* Ф.Яхин. --- *Яшел укроп, суган сибеп җибәрәсең дә ипигә калын итеп ак май сылап, башта үзең утырып ашыйсың... Аннан сөтле чәй, кофе, телисең икән – кесәл, я булмаса компот.* Р.Сәгъди

2) Ачыга изелгән солы онынннан сөзеп пешерелгән боламык (сөт белән ашыйлар). *Солы кесәле*

3) *күч.* Нинди дә булса үзле, ярым сыек масса. *Бу агайлар әйткән: – Көрәк юк. Булса да бу пычракта ничек әйбер тапмак кирәк? Кара, ничек бу төшне кесәл шикелле таптап, изеп бетергәнсең, – дигәннәр.* Әкият

**КЕСӘЛЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кесәл хәленә китерү

**Кесәлләндерә бару** Торган саен ныграк кесәлләндерү

**Кесәлләндереп бетерү** Бик нык кесәлләндерү; ахыргача, барысын да кесәлләндерү

**Кесәлләндереп тору** Даими яки әледән-әле кесәлләндерү

**Кесәлләндерә төшү** Берникадәр күләмдә тагын да кесәлләндерү

**КЕСӘЧЕ** *и.* Кесә карагы, картаман. *Кырмыска күче төсле бертуктаусыз кайнап тора торган базарлары һәм атаклы кесәчеләре белән Казан кичкенә Фәйзулланы шаулап каршы алды.* Ф.Хөсни. *Кесәчеләрне таныйбыз, бөтенесен белеп-күреп торабыз.* Безнең гәҗит

**КЕССОН** *и. фр. махс.* Елга яки диңгез төбенә төшеп эшләгәндә кулланыла, су үткәрми торган зур камера. *Гыймал эшләгән өченче номерлы кессон Идел төбендә өч метрлардан да артыграк җиргә керсә дә, таш багана һаман сеңә дә сеңә.* Т.Госман

**КЕССО́Н АВЫРУЫ** *и.* Кессонда эшләүчеләрдә югары атмосфера басымы нәтиҗәсендә барлыкка килә торган авыру

**КЕССОНЧЫ** *и. махс.* Кессон белән эшләнә торган эшләр белгече; кессонда эшләүче

**КЕТА** *и. лат. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан диңгез балыгы. *Симка үзе курҗыны актарып, өстәлгә бернича бәйләм колбаса, зур бер кета балыгы ташлады.* И.Салахов

**КЕТӘК** *и.* 1) Йорт кошларын асрый торган махсус корылма. *Тавык үз кетәген мактый.* Мәкаль. *1 нче апрель көнне иртән иртүк малайлар бик җитди кыяфәт белән Хикмәтулла бабайларга килеп керделәр. Алар кергәндә, бабай үзалдына сөйләнә-сөйләнә, тавык кетәген чистартып маташа иде.* Р.Хафизова

2) *күч.* Кысан, бик кечкенә бүлмә. *Фәтхине караңгы кетәк өзелеп сөйгән Мәдинәсеннән аерды.* Ш.Камал

**КЕТӘКЛЕК** *и. диал. к.* **кетәк**. *Хәмдия абыстайның кетәклек ягыннан ишетелгән тавышын тыңлый-тыңлый, ул [Хәтмулла карт] чишенә башлады.* Г.Гыйльманов. *Ярар инде дияр идең, кетәклек кадәр генә шул иске өйләре дә ипотекада бит.* Ватаным Татарстан

**КЕТГУТ** *и. ингл. махс.* Хирургиядә эчке җөйләрне тегәр өчен, вак терлек эчәкләреннән ясала торган махсус җеп. *Операция ясалган урынны тегү өчен иң кадерле нәрсәләрнең берсе – кетгут.* С.Шакир

**КЕТЕ́Р-КЕТЕР** *иярт.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса чәйнәгәндә, кимергәндә ишетелә торган җиңелчә шытырдау тавышларын белдерә. *Киртә буенда гына казыкка бәйләнгән бер яшь сарык кетер-кетер чәчәкле үлән кимереп йөри.* Ә.Еники. *[«Кыш бабай»] безнең сөенә-сөенә кетер-кетер китерүгә куанып, сорашканны да көтмәстән, көр тавыш белән сөйләп китте ---.* И.Салахов. --- *күселәр шагыйрьнең иртәгә дип хәстәрләп калдырган «шикәр, булкиларны... төнлә кетер-кетер китереп... ком итәргә» керешәләр.* Л.Хәмидуллин

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Кеткелдәп. *Ачъяңак кетер-кетер көлде. Тик күзе көлми иде.* Р.Зәйдулла. *Кетер-кетер кетердәтеп Көлеп куясың инде.* Ф.Дәүләтгәрәева

**КЕТЕРДӘВЕК** *с.* Кетердәп торган. *[Нәфисәнең] абыйларындагы кебек тәмле сөзмә, аның җиңгәсе пешергән кебек кетердәвек коймак бүтән беркемдә дә булмый иде.* Г.Бәширов

**КЕТЕРДӘВЕКЛЕ** *с.* Кетерди торган

**КЕТЕРДӘТҮ** *ф.* Кетер-кетер китерү. *Әмма нәфес – шайтан диләр бит, туюын туйсак та, күңел туймый, кесәләргә алдагы көннәргә дип яшереп куйган сохариларны да анда-санда «урлап» алып кетердәтәбез.* И.Салахов. *Кызарып, алсуланып торган бәлеш түгәрәген Сабира апа кетердәтеп кенә кисте дә бер читкә әйләндереп капла-ды.* Р.Низамиев. *– Әти, – диде Илүзә чәйне йотып җибәргәч, келиндер кетердәтеп.* Р.Мөхәммәтша

**Кетердәтә бирү** Бернигә карамастан кетердәтү

**Кетердәтә төшү** Берникадәр тагын да кетердәтү

**Кетердәтеп алу** Аз гына кетердәтү

**Кетердәтеп бетерү** Кетердәтүне тәмамлау

**Кетердәтеп тору** Хәзер кетердәтү; даими яки әледән-әле кетердәтү

**Кетердәтеп утыру** Шактый озак кетердәтү

**КЕТЕРДӘ́Ү** *ф.* **1.** Кетер-кетер иткән тавышларны хәтерләтеп җиңелчә шытырдау; кыштырдау. *Кетердәп тәмле пешкән кәтлите бар, Закускага дәхи кошлар ите бар.* Г.Тукай. *Таш юлдан кетердәп баручы арба тәгәрмәче көенә Хәлим үз тормышы, язмышы, киләчәге хакында уйлады.* Г.Гыйльманов.

*Мәрьям апа аның [бәлешнең] капкачын кисеп ачып җибәрүгә, йөзем белән аралашып мәмрәп пешкән дөге, ак майда кетердәп пешкән төче камыр исе бөтен өйгә таралды.* Д.Булатова

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл. к.* Кеткелдәү. *Нәсимә кетердәп көлеп җибәрде.* Ш.Камал

**Кетердәп китү** Азга гына кетердәү тавышы чыгару; кинәт кетердәү

**Кетердәп кую** Кисәк, бер мәртәбә кетердәү

**Кетердәп тору** Кетердәү хәлендә булу. *Бәлешне ашаганда мактап бетерә алмадылар, төбе, камыры кетердәп тора, диешеп, зур таба төбендә тик оятлык кына калдырдылар.* Г.Ибраһимов. *Башта ул кабартманы алып ашады (кабартма дөрестән дә тәмле иде, Илсөяр ярата торган – асты кетердәп тора торган) ---.* Г.Гобәй

**Кетерди бирү** Торган саен тагын да кетердәү; бернигә карамый кетердәү

**КЕТИ-КЕТИ** *иярт.* Кытыклану яки кытыклауны белдерә. *Яшь егет! Килче икәү уйнийк бераз кети-кети.* Г.Тукай. *Дулкын арты дулкын үтте киерелгән тәне буйлап, сыйпап башын, һәр тамыры белән кети-кети уйнап.* Р.Харис

**КЕТИ-КЕТИ́ ИТҮ** *ф.* Кытыклау, кытыклашу

**КЕТКЕЛДӘ́Ү** *ф.* **1.** Йомшак, ягымлы итеп өзек-өзек тавыш чыгарып көлү. *Вәли абзый йөзем суын эчкәннән соң, шаярып: – Ах, иблис хатын, моның эченә син колмак салгансың ахры, – дип кеткелдәде.* Ә.Фәйзи. *– Кара син аны! – дип кеткелди бабай.* Д.Булатова

**2.** *рәв. мәгъ.* Кеткелдәп. Йомшак, ягымлы итеп өзек-өзек тавыш чыгарып. *Мыеклы һич көтелмәгәндә, мыегын бөтерә төшеп, кеткелдәп көлеп куйды.* А.Расих

**Кеткелдәп алу** Бераз гына кеткелдәү

**Кеткелдәп тору** Даими яки әледәнәле кеткелдәү; кеткелдәү хәлендә булу

**Кеткелдәп яту** Хәзерге вакытта кеткелдәү

**Кеткелди башлау** Кеткелдәргә тотыну. *– Безнең якка каян килсеннәр алар! – дип кеткелди башлады, кулындагы озын кармак сабы төшеп китә язды.* Ф.Яхин

**Кеткелди бирү** Бернигә карамастан кеткелдәү

**Кеткелди төшү** Бернikaдәр тагын да кеткелдәү

**КЕТКЕЛДЕК** *с.* Гел, өзлексез кеткелдәп тора торган. *Бигрәк кеткелдек кыз*

**КЕТ-КЕТ** *иярт.* Җиңелчә өзек-өзек көлгәндә чыккан тавышны белдерә. *--- Шәфигулла, үз кәефен бер дә бозмыйча, йөз һәм күзләрендәге төчелеген бер дә киметмичә, татлы җавап бирде: – Чү, катын, чү, чү! Һәй, дурман баш син! – диде, кет-кет итеп төче көлеп җибәрде.* Ф.Әмирхан. *Галиәхмәт агай кет-кет көлеп куйды.* Ә.Дусайлы. *Вәликәй үзе кет-кет көлә, үзе улын тәртә аша атлатырга тырыша ---.* З.Зәйнуллин

**КЕФАЛЬ** *и. гр. зоол.* Кефальсыманнар отрядыннан юка, озынча гәүдәле, зур башлы диңгез балыгы. *Кара диңгездәге кефаль балыгын Каспий диңгезенә күчерделәр, һәм биредә ул бик нык үрчеп, промысел балыгына әйләнде.* Зоология

**КЕФИР** *и. рус* Сөткә махсус ачыткыч гөмбәчекләр салып оетылган туклыклы куе эчемлек. *[Идрис] кафеда бифштекс ашап, бер стакан кефир белән хушлангач, өченче каттагы бүлмәсенә күтәрелде.* А.Гыйләҗев

**КЕЧЕ** *с.* **1.** 1) Күләме зур булмаган, кечкенә; *киресе:* **зур**. *Бераздан кече капка тар гына булып ачылды, юан чылбыр аңа киң ачылырга ирек бирми иде.* Р.Батулла

2) Берәр кеше белән чагыштырганда ел исәбе буенча яшьрәк. *Апуш кыюсыз гына сәке йөзлегендә утыра. Аны хуҗабикә Зөһрә, аның өлкән кызы Сабира, кече кызы Сажидә җентекләп тикшерә.* Р.Батулла

3) Рәсми атамаларда: дәрәҗәсе, вазифасы буенча түбәнрәк булган. *Отставкадагы милиция майоры, ул вакыттагы кече лейтенант, университетның юридик факультетын бетереп эшкә килгән егет ---.* Ф.Яхин. *Шулай бервакыт кар тутырып чәй кайнатып эчим генә дигәндә, Әхәт янына кече лейтенант һәм аның иптәше килеп басты ---.* Р.Кадыйров

4) Кайбер атамалар һәм ялгызлык исемнәре составында: кечерәк күләмдә булган. *[Сәетзадә хәзрәт Гыймаев:] Ватан – ул абстракт төшенчә. Ә минә кече ватан – тәгаен нәрсә. Ул – туган нигез, туган авыл ---.* Ватаным Татарстан

**2.** *и. мәгъ.* Сабый, бала; гомумән кечкенә булу. *Олы, кече берләшеп, илгә хезмәт итәрбез, Берләшеп хезмәт итсәк, рәхәт гомер итәрбез.* Г.Камал. *Яшәр өчен бетмәс көч алырга Олысына һәм дә кечегә.* Ф.Яруллин

◊ **Кече күңелле** Башкаларга һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торучан, кешеләрне ихтирам итүчән, хөрмәт күрсәтүчән зат турында. *«Сәер кеше! – дип уйлана карчык аның [шагыйрь] артыннан. – Ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле ---».* Ә.Еники

**КЕЧЕ́ АТНА** *и. сөйл.* Пәнҗешәмбе, атнакич. *Аннан соң ул [карт], саташкан сымак итеп, үз пулатына бичура ияләнгәнлеген, кече атна көннәрендә кызы Әсманың өргә, кабереннән чыгып, тәрәзәләрне шакылдатып, ишегалдында йөргәнлеген сөйли башлады.* Ф.Әмирхан. *Безнең Риза һәр кече атна көнне кайтып куна иде.* Г.Исхакый

**КЕЧЕК** *с. иск. к.* **кечкенә**. *Синең дәрдең мәңа төште кечекдин, Газиз башым гариб булды гыйшыкдин. Бәне кечкенә мальчиктай кимсетеп, Олы итеп күрмәдең һич, и туганым.* Г.Кандалый

**КЕЧЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Кечелекле, ихтирамлы булу, кечелек күрсәтү. *Ана алдында кечеләнү*

2) *к.* **кечерәю** (*1 мәгъ.*)

**Кечеләнә бару** Акрынлап тагын да кечеләнү

**Кечеләнә тору** Торган саен кечеләнү

**Кечеләнә төшү** Берникадәр кечеләнү

**Кечеләнеп алу** Азга гына кечеләнү

**Кечеләнеп бетү** Бик нык, тәмам кечеләнү

**Кечеләнеп тору** Гел кечеләнү

**КЕЧЕЛЕК** *и.* 1) Дәрәҗә, хезмәт урыны, вазифа ягыннан түбәнрәк булу. *Кечелектән олы булган кеше һәркем каршында да мактаулы.* Ф.Бурнаш

2) Кече күңеллелек, ихтирамлылык. *Үзенә иң якын нәрсәләрнең, иң кадерле истәлекләрнең һәммәсе белән дә*

*берьюлы саубуллашкан кебек, кечелек белән башын иеп: – Хушыгыз! – диде [Нәфисә].* Г.Бәширов

**КЕЧЕЛЕКЛЕ** *с.* Ихтирамлы, юл куючан, түбәнчелекле. *Күбрәк татар балалары шикелле, Хәят та кечкенәдән ук үзеннән баерак кеше алдында кечелекле булырга өйрәтелгән иде.* Ф.Әмирхан. *Озатырга килүчеләрнең берсе – гаять кечелекле, тыйнак табигатьле, мөлаем һәм тәмле телле икенче мәхәллә имамы карт хәзрәттер.* З.Бигиев

**КЕЧЕРӘЙТКЕЧ** *с.* Нәрсәнең дә булса сурәтен кечерәйтеп күрсәтә торган. *Кечерәйткеч пыяла*

**КЕЧЕРӘЙТҮ** *ф.* 1) Билгеле бер нәрсәне күләм ягыннан киметү, кечкенәгә әйләндерү. *[Ак Король:] Аның Сихерчесе бар. Ул теләсә кемне кечерәйтә ала.* С.Гаффарова. *Зурларның гамәлләрен без, балалар, кечерәйтеп уйныйбыз шул.* Ф.Яхин

2) Нәрсәне дә булса киметү, аз калдыру

3) Акрынайту, көчен киметү, егәрен басу. *Газны кечерәйтү. Утны кечерәйтү*

4) *күч.* Берәр нәрсәнең әһәмиятен, бәясен һ.б.ш. киметү, төшерү. *Күпертеп яки кечерәйтеп сөйләү булмагандыр кебек минем үземә.* М.Хуҗин

**Кечерәйтә бару** Акрынлап кечерәйтү. *Ләкин мине кечерәйтә бару сизелгәндәй булды хатлардан: бер хаты – «Иптәш командир», икенчесе – «иптәш Баттал...», өченчесе «Салих...» диеп кенә башланган...* С.Баттал

**Кечерәйтә башлау** Кечерәйтергә тотыну. *Аллаһы биргән Казансу елгасының Кремльгә каршы уң як өлешен – казанлыларның җәен ял итә, су керә торган урынын күмә, су өсте мәйданын кечерәйтә башладылар.* Х.Арсланов

**Кечерәйтә бирү** Бернигә карамастан кечерәйтү

**Кечерәйтә тору** Әлегә, сөйләү вакытында кечерәйтү; гел кечерәйтү

**Кечерәйтә төшү** Тагын берникадәр кечерәйтү. *Галәү бабай, болай да кечкенә күзләрен кечерәйтә төшеп, озын буйлыга карап торды.* Г.Гобәй

**Кечерәйтеп алу** Тиз генә кечерәйтү

**Кечерәйтеп бетерү** Кечерәйтүне тәмамлау; барысын да кечерәйтү

**Кечерәйтеп тору** Кечерәйтү хәлендә булу; даими яки әледән-әле кечерәйтү

**КЕЧЕРӘЮ** *ф.* 1) Күләм, зурлык, үлчәм ягыннан кимү, кечкенәгә әйләнү; *киресе*: **зураю**. *Сирәкләнгән, кечерәйгән авыл, Тик зурайган «мәңгелекнең йорты» – Ындыр артындагы зираты...* Ш.Маннапов. *Югарыга күтәрелгән саен кечерәеп күренгән аксыл саргылт кояш яктысында, бер болытсыз чалт аяз күк йөзе астында иксез-чиксез дала җәелеп ята.* Н.Фәттах. *Ут бөҗрасы күзгә күренеп кечерәйде, кысылды.* Г.Гыйльманов

2) Сан ягыннан кимү, аз калу. *ЦСКАның проблемалары турында күп яздылар. Клуб бюджеты кечерәйде.* Ватаным Татарстан. *Дөрес, аның хезмәт хакы евро һәм долларга күчергәндә кечерәйде, чөнки фунт-стерлинг курсы түбән тәгәрәде.* Ватаным Татарстан

3) Акрынаю, көче кимү. *Йортта яктылык, җылылык кимеде, ул гүя таралды, кечерәйде.* Р.Габделхакова

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса әһәмияте, бәясе һ.б.ш. кимү, төшү. *[Шәмси] --- кечерәеп кенә агач арасына яшеренгән каенда да күз кабагы тарткан кадәре дә селкенү дә, хәрәкәтләнү дә күрә алмады.* Г.Исхакый. *Җир йөзендә яшәвемнең хәзер Кечерәйде асыл мәгънәсе...* Г.Рәхим. *Алтмышынчы, җитмешенче еллар белән чагыштырганда, бүгенге көндә әдәбият-сәнгатьнең җәмгыять һәм дәүләт мәйданында тоткан урыны шактый кечерәйде, тарайды кебек.* Р.Вәлиев

**Кечерәеп алу** Берникадәр вакытка гына кечерәю; тиз арада кечерәю

**Кечерәеп бетү** Бик нык, тәмам кечерәю; кечерәю тәмамлану. *Егет язуны кечерәеп беткәнче бөкләде дә Гәүһәриягә ыргытты.* Г.Әдһәм

**Кечерәеп калу** Ниндидер процесстан соң билгеле бер күләмдә кечерәю. *Ул юк арада взвод шактый ук кечерәеп калган.* Г.Бәширов. *Таза йортлар карчыкның иске өе сыман кечерәеп калган.* Л.Зөлкарнәй. *Бикә чыннан да төннең яртысын йокысыз уздырган иде ахрысы: болай да юка иреннәре аның тагын да ныграк кысылып, күзләре кечерәеп калган сыман иде.* Н.Фәттах

**Кечерәеп китү** Кинәт кечерәю; кечерәйгән кыяфәткә кереп үзгәрү. *Өстәл өстен бушатырга өлгермәгән Газизә апа, ничектер кечерәеп китеп, ишек төбенә барып баса.* И.Нуруллин

**Кечерәеп тору** Даими яки әледән-әле кечерәю; кечерәйгән хәлдә булу

**Кечерәя бару** Берникадәр кечерәю; торган саен тагын да кечерәю. *Аждаһа тиз генә бирешмәде, утлы теле белән аны ялап-ялап алды, аннары әкренләп чигенә, чигенгән саен кечерәя барды...* Әкият. *Тәлинкәләрдәге коймак өемнәре кечерәя барды ---.* М.Галәү. *Биегрәк менә барган саен Кечерәя бара кешеләр. Алар бары тормыш китабының Бер ноктасы гына төсләләр.* Ф.Яруллин

**Кечерәя башлау** Кечерәергә тотыну

**Кечерәя бирү** Бернигә карамый кечерәю

**Кечерәя төшү** Берникадәр кечерәю. *«Беренче театр» комедиясендәге башка образлар да матур эшләнгәннәр. Тик аларга караганда күп көчле эшләнгән Хәмзә бай тибы белән томаланып кына алар беркадәр кечерәя төшкәннәр.* М.Гали

**КЕЧЕ́ ТЕЛ** *и. анат.* Йомшак аңкауның арткы өлешендә йоткылыкны ачуябу өчен хезмәт итә торган әгъза

◊ **Кече телгә дә җитмәү** Ашамлыкэчемлек бик аз булу, җитми калу, туярлык булмау. --- *ул [алабута күмәче] олы телдән кече телгә дә җитмәде.* Ә.Фәйзи. **Кече телгә дә йокмау** *к.* **кече телгә дә җитмәү**. **Кече телгә дә тимәү** *к.* **кече телгә дә җитмәү**

**КЕЧЕ́ ЯК** *и.* Өйнең кечкенә ягы, кечкенәрәк бүлмәсе; кухня. *Зөһрә бикә кече яктан уклау алып чыгып, Габдулланы ястыклар арасыннан тартып алып кыйный башлады.* Р.Батулла

**КЕЧКЕНӘ** *с.* **1.** 1) Күләм, зурлык, үлчәм һ.б.ш. ягыннан зур булмаган. *[Гыйльфан абзый] Кечкенә капка янына килеп, зур бөҗраны капка тактасына бәрде.* Р.Батулла. *Ишеккә барып йитүе белән ишек ачылып, утыз яшьләр чамасында, кечкенә кара сакаллы матур гына кеше Казанның яңа мода җиләненнән, кечкенә бүректән килеп керә.*

Г.Исхакый. *Ул [Илдар Юзеев], кисәсеннән кечкенә кәгазь кисәге чыгарып, аны ашыкмыйча гына таслап безгә җиткерде.* Р.Сәгъди

2) Сан ягыннан күп булмаган, аз санлы. *Әле генә тавыш, шау-шу белән тулган мәйдан өстен Күчем, Уразай, Туйкә батырларның кыска, кырыс әмерләре күмеп китте. – Кечкенә гөруһларга бүленегез!* В.Имамов. *Татар халкында әле дә яшьләрнең әти-әниләре өйдә юк чакта кечкенә төркем булып кич утыруларын (хәзер инде егетләр катнашында) «аулак өй» дип атыйлар.* Татар энциклопедиясе

3) Кыска, тәбәнәк гәүдәле; карсак буйлы (кем, нәрсә). *Үзеннән зур бу томаннары бөркеп, пошкыра-пошкыра, табынга кечкенә җиз самавыр килеп утырды.* Ә.Фәйзи

4) Артык көчле булмаган (тавыш һ.б.ш.). *Лиза үзенең кечкенә, ләкин мәхәббәтле сопраносы белән бер романсның башын җырлап җибәрде.* Ф.Әмирхан

5) Мөһим, җитди булмаган, зур әһәмияткә ия түгел. *Никях ул, безнең халык уйлаганча, бер кечкенә эш түгел.* Г.Исхакый

6) Артык зыянлы, куркыныч булмаган. *«Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы?» – дип, Куян гаҗәпләнеп караган.* А.Алиш. *Әйттем: – Кечкенә генә авыру да тормышның чын йөзен күрергә ярдәм итә дип белми идем!* Ф.Яхин

7) Яшь, сабый; зур түгел. *Шул вакыт кечкенә Фатиха йөгереп керде.* Ә.Фәйзи. *Рөстәм әле бик кечкенә, аңа бары биш кенә.* А.Алиш. *Бер кечкенә бала, яфрак төсле Калтыранып, төелеп яшенә, Анасының итәк арасына Бөдрә чәчле башын яшерә.* М.Җәлил

8) *күч.* Җәмгыятьтә һәм хезмәттә билгеле түгел, артык зур урынга ия булмаган. --- *Ш. Камал нәкъ хезмәт иясе кешеләренең, җәберләнгән кечкенә геройларның күңел түрләрен дә күрә, таба белде.* Г.Халит

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* 1) Сабый, кечкенә бала, нарасый. *Бөгелмәдән Мәүлетдин Казан каласына, аннан Мәскәүгә китәргә дип чанага утырырга җыйналганда, хатыны аның киң күкрәгенә сыенып башын яшерде дә пышылдады: – Мәүлетдин! Безнең кечкенәбез булачак бит!* З.Зәйнуллин

2) 250 гр. сыешлы шешәгә салынган аракы турында. *Нишлим, биреп җибәрәм, я кечкенәне, я яртыны.* Л.-Х.Таналин

**КЕЧКЕНӘДӘН** *рәв.* Кечкенә вакыттан, яшьтән, балачактан. *И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.* Г.Тукай. *Күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулланың ике улы да кечкенәдән сәхнәдә, кеше күз алдында үсте.* Сәхнә

**КЕЧКЕНӘЛӘНҮ** *ф.* Кечерәю. *[Әтисе] Бүлеп алынган җирем кечкенәләнгән, үзең генә урап килерсең, дигән иде бит кичә.* Ф.Яруллин. *Туры ат бик кечкенәләнде.* М.Гафури

**Кечкенәләнә бару** Торган саен кечкенәләнү

**Кечкенәләнә башлау** Кечкенәләнүгә йөз тоту; кечкенәләнергә тотыну

**Кечкенәләнеп бару** Акрынлап кечкенәләнү

**Кечкенәләнеп бетү** Бик нык, тәмам кечкенәләнү

**КЕЧКЕНӘЛЕК** *и.* Кечкенә булу. *Шәйдулла күтәрелде. Сүз сорады һәм, күңеле тараеп китеп, премиянең кечкенәлегенә канәгатьсезлеген белдерде.* Ф.Яхин. *Карчык, болай да кечкенәлегенә карамастан, тагын да кечерәебрәк, шиңебрәк, бөгәрләнебрәк калды, йөзе агарып чыкты.* Р.Мөхәммәтша

**КЕЧКЕНТӘЙ** *с. диал. к.* **кечкенә**. *Тукай Хәбирнең арада чыккан кечкентәй бәрелешне уенга борып юкка чыгарырга теләгән сүзләрен тыңлап бетермәстән кузгалып китте.* И.Нуруллин. *– Кечкентәй генә куллары белән нинди матур чәчәкләрне нинди оста итеп ясый белә бит! – дип, Мәрфуга апа елмаеп, иркәләү карашы белән минем күзләремә туп-туры карады.* Ф.Әмирхан

**КЕЧТЕК** *с. диал. к.* **кечкенә**. *Әллибәлли-бәлли-бәү ...Куян кечтек, Аю дәү!* Р.Харис. *Кечкенә чакта һәммә кеше дә менә шундый кечтек кенә сәер була.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Беләсеңме, Назон, ак яулыклы Апалар бар безнең Карматтә; Билләһи дә, боек күңелләрен Балкытырга кечтек шәм җитә.* Идел

**КЕЧТЕКИ** *с. диал. к.* **кечкенә**. *[Наҗия:] Зинһар, бер кечтеки генә шигырь! Шигырь белән теләк теләгез әле миңа, ә?..* Г.Гыйльманов. *Үчти-үчти үчтеки, үсте китте кечтеки.* Р.Харис. *Что-то йөрәк брахлит... Кан куерды, ахры. Кечтеки генә сыекламый булмас.* Казан утлары

**КЕШ** *и. зоол.* **1.** 1) Сусарсыманнар семьялыгыннан көрән төстәге кыйммәтле мехлы кечкенә ерткыч җәнлек; *русчасы:* **соболь**. *[Эвенк] кыйммәтле кеш тиреләрен елкылдатып --- кайтып керә.* Казан утлары

2) Шул җәнлекнең тиресе, мехы

**2.** *с. мәгъ.* Шул мехтан тегелгән, эшләнгән. *Кеш бүрек. Кеш яка*

**КЕШӘН** *и.* Атның алгы аякларын тышаулап, икенче бер очы арткы аягына бәйләп куела торган озын бау. *Без дә кеше булырбыз, Атка кешән салырбыз.* Әйтем

**КЕШӘНЛЕ** *с.* Кешәнләгән, кешәнләп җибәрелгән. *Кешәнле атың – бар атың, Кешәнсез атың – юк атың.* Мәкаль

**КЕШӘНЛӘ́Ү** *ф.* Кешән белән бәйләү, кешән салу. *Йөремсәк атны кешәнлиләр.* Әйтем. *Кеше баласын кешәнләсәң дә тормас.* Мәкаль

**Кешәнләп кую** Кешәнләнгән итү

**КЕШЕ** *и.* 1) Хайваннардан аермалы буларак сөйләшү, фикерләү, корал җитештерү һәм аннан хезмәттә файдалана алу сәләтенә ия булган тере зат, адәм, кемсә. --- *Мөхәммәт Мәһдиев Чеховның «кеше һәр тарафтан да матур булырга тиеш» дигән таләбенә җавап биргән олы затларыбыздан иде.* Т.Галиуллин. *Кеше кайчан матур була? Кеше матур шулвакыт: иле өчен, халкы өчен яшәгәндә җан атып ---.* Р.Харис. *Егерме елга якын аягына баса алмыйча һаман утырып торган кешенең организмы таза була алмавы, әлбәттә, табигый.* Р.Әмирхан

2) *тарт. форм.* Билгеле бер уртак сыйфатларга ия булган, берәр төрле мохиттә, оешмада һ.б.ш. исәпләнгән зат, шәхес. *Мәскәү үзәгендәге квартирасы да чын иҗат кешесенә хас булган*

*җиһазлар белән җиһазландырылган иде*. Л.Хәмидуллин. *Өч бүлмә – җәннәт куанычы ул безнең заман кешесенә*. М.Юныс

3) Билгеле бер һөнәр, гомумән нинди дә булса эш белән шөгыльләнүче зат. *Мулла кешегә җәмәгатьсез тору шәригатькә хилаф бер нәрсә булса да, хәзрәт үзенә икенче юлдаш табуны һаман сузып-кичектереп килә*. Р.Әмирхан. *Ник бер кеше укытучыны тыңлап, аның карашын да матбугат чарасы аркылы җиткерсен?!* Мәгариф

4) Кардәшлек мөнәсәбәтләре, җенес һәм яшь бүленешләре буенча билгеле бер төркем. *Егет кеше – арысланга тиң кеше*. Мәкаль. *Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз*. Мәкаль. *Кыз кеше – мыскалга салынмаган ак ефәк*. Мәкаль

5) Югары әхлак һәм рухи кыйммәтләр гәүдәләнеше буларак шәхес. *Динсез идем, Шуның өчен дә бит Әткәй мескен кулын ташлады: – Бу имгәктән кеше чыкмас, – диде, – Иблис булыр, – дия башлады...* Һ.Такташ

6) Кемдер, берәрсе, кем дә булса; беркем. *Бу нурлы юл бит, шуның сихере берлән ясалган, кешеләрне алдап китерә торган юл бит*. Г.Исхакый. *--- Нурый карак, кеше суюда гаепләнеп, гомерлек каторгагамы, Себергәме озатылган. ---. Бала-чагалары юк икән, өйләре бөтенләй буш, кешесез калган*. Г.Ибраһимов

7) Икенче берәү, чит, ят адәм, гомумән, билгесез зат. *Кеше илендә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул!* Мәкаль. *Кулы, ят кешене күргәч тә, ни сәбәпледер, әнә револьверга үрелә...* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин ул сейфны ачып күрсәтмәделәр: эчендәге алтын байлыкларын чит-ят кешегә күрсәтергә ярамый, диделәр*. Л.Хәмидуллин

8) *куч*. Санау берәмлеге буларак кулланыла торган сүз. *Институтның тулай торагында, нигездә, биш-алты кешегә исәпләнгән бүлмәләр*. И.Салахов. *Унбиш-уналты милли-мәдәни, иҗтимагый оешма составында һәм 160 тан артык кеше катнашында үткәрелгән әлеге мәҗлескә рәис итеп нәкъ менә Фатих Әмирханның сайлануы бик гыйбрәтле*. Р.Әмирхан

9) *сөйл. куч*. Сөйгән яр, ир буласы яки дус егет. *[Риза:] --- аңар хат яздым. «Эш шулай, шулай, син минем күңелемә туласың, син разый булсаң, сорыйм, разый булмасаң, бер-бер теләп йөри торган кешең булса, сиңа разый түгел, дип ачык яз ---», – дидем*. Г.Исхакый. *Кияү буласы кеше әнисе остазбикә алдына мондыйрак таләп куя: – Әни, миңа Казанның иң матур кызын димләгез!* Р.Әмирхан

◊ **Кеше арасына керү** 1) Җәмгыятьтә, тормышта үз урыныңны табу, булдыру. *[Мөршидә Гөлчирәгә:] Кеше арасына кергәч, апаң артык булгандыр шул*. Т.Гыйззәт; 2) Дусларның араларын бозып, аларны үзара читләштереп, берсен үз ягына тарту. **Кеше аягы басмаган** Моңарчы кеше булмаган, кеше йөрми торган (урын, җир тур.). *Хат барып җитмәслек күгелҗем диңгез артыннан, алтын кояшны күмгән таулар сыртыннан, кош очып җитмәслек илләрдән, кеше аягы басмаган җирләрдән, кара болытлар арасындагы шәһәрдән чакырттылар, ди, алар шул остаНы*. А.Алиш. *Кеше аяк басмаган бу кара урманның очы да, кырые да юк иде шикелле*. Г.Әпсәләмов. *[Капитан:] Юлыбызда мондый гүзәл планета очравына сез барыгыз да шатланырсыз дип беләм. Без – кеше аягы басмаган яшел бишектә*. Р.Мөхәммәдиев. **Кеше аягы тимәгән** *к.* **кеше аягы басмаган** *Кеше аягы, ат тоягы тимәгән урыннарда кып-кызыл дала чәчәкләренең дуены*. Сөембикә. *Мал-туар түгел, кай җиренә кеше аягы да тимәгән бу хәтфә үләнгә басып күркәмлеген бозудан куркып туктап каласың*. Л.Ибраһим-Вәлиди. **Кеше аягы тыну** Кешеләр йөрүдән туктап, тулы тынлык урнашу (төн тур.). *Урамнарда кеше аягы тынган*. Г.Бәширов. *Кайбер төннәрдә кеше аягы тынгач, Микулай санитарканың «хәлен белергә» керә*. Д.Йосыпова. **Кеше басмаган** *к.* **кеше аягы басмаган** *Юлым якты диеп әйтә алмыйм, Минем алдан кемдер бармаган дип, Җирдә кеше басмаган Тузан бөртеге калган дип ---*. Ф.Яхин. **Кеше булу** 1) Югары әхлак һәм рухи сыйфатларга ия булу. *Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар!* Мәкаль. *Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше*. Г.Тукай. *Без – кешеләр, кайда яшәсәк, нинди дин тотсак та, кайсы телдә сөйләшсәк тә барыбер Кеше булып калырга тиеш*. Сөембикә*;* 2) Тормыш итәрлек, дөнья көтәрлек кеше булу; тормышка яраклы булу. *[Фазыйл] Галим булыр, зур кеше булыр ---*. Г.Ибраһимов. *– Үзегез ич, әти, бала чактан укыгыз, укыгыз дип үстердегез. – Дидек тә бит, укып кеше булсыннар дип үстерәсең инде аны*. Р.Мөхәммәдиев; 3) Өметсез дип саналган каты авырудан терелү, аякка басу; гомумән, хәл кереп, рәтләнеп, сәламәтләнеп китү. *Бер төймә дару йоткач, бөтенләй кеше булды*. Р.Зәйдулла. **Кешегә калу** *к.* **кеше кулына калу**. *Кешегә калган көн – таң атмаган төн*. Мәкаль. **Кешегә санамау** Ниндидер сәбәпләр аркасында кемгә дә булса түбәнсетеп, кимсетеп карау; аерым бер сәбәпне кемнең дә булса кимчелеге итеп күрү. *[Бай хатыннары] --- фәкыйрьләрне дисәң, аларны кешегә дә санамыйлар ---*. Г.Исхакый. *Азнакайда Чатыртауга менмәгән кешене кешегә санамыйлар*. Ватаным Татарстан. **Кешегә чыгару** Кемнең дә булса серен икенче берәүгә сөйләү. *[Сорур:] Әсма апа, мин сине бик якын күрәм. Бар серемне сөйлим инде. Зинһар, кешегә чыгармасана!* Г.Исхакый. **Кеше исәбенә яшәү** Кемнең дә булса акчасыннан яки әйберләреннән файдаланып, сорыкорт булып яшәү. **---** *кеше исәбенә рәхәт яшәргә омтылучылар очрап тора*. Кызыл таң. **Кеше итеп карау** Кемне дә булса санлау, аның белән исәпләшү, аны хөрмәт итү. *Бөтен кешеләр белән без кешегә кеше итеп карау турында сөйләшергә тиешбездер*. Т.Миңнуллин. **Кеше итеп санау** *к.* **кеше итеп карау**. **Кеше итү** 1) Кемгә дә булса җәмгыятьтә, тормышта үз урынын табарга ярдәм итү, тәрбияләү. *Кешене кеше иткән бер нәрсә – кешелеклелек!* М.Вәлиев. *Фазылҗан үзенең энесе Сабирҗан балаларын да үз янына алдырып укыта, эшкә өйрәтә, кеше итә*. Мәдәни җомга; 2) Каты авырудан

терелтеп аякка бастыру. **Кеше көлкесе итү** Кемне дә булса мәсхәрә итү, хурлыкка төшерү. **Кеше көлкесе ясау** *к.* **кеше көлкесе итү**. **Кеше кулына калу** 1) Авыру, гариплек яки картлык аркасында башкалар ярдәменә, тәрбиясенә мохтаҗ булу. *Хәтерлим мин дәү әнинең Ялварып йөрүләрен: «Кеше кулына калдырма, зинһар», – диюләрен.* И.Хәбибуллин. *Аена да түзәр, елына да... [Миләүшә] тик кеше кулына гына кала күрмәсен.* Сөембикә; 2) Башка берәүгә буйсынып яши башлап, үз иркеңне югалту; 3) Кемнең дә булса кулында булган мөлкәт, байлык чит бер кеше кулына, карамагына күчү. *Кибет тә кеше кулына калмады – каенанасын килене алыштырды.* Кызыл таң. **Кеше өстендә тору** Чит-ят кеше өендә яшәү. *Язмышың, тормышың юл белән бәйле булгач, төрле хәлләр була. Кеше өстендә дә торырга туры килгәли.* М.Хәсәнов. **Кеше өстендә яшәү** *к.* **кеше өстендә тору**. **Кеше рәтенә керү** 1) Үсеп, мөстәкыйль яши башлау; 2) *к.* **кеше арасына керү** (*1 мәгъ.*); 3) Авырудан терелү, аякка басу, савыгу. **Кеше сүзе** Нахак сүз, гайбәт. *Кеше сүзе кеше үтерә.* Мәкаль

**КЕШЕ́-КАРА** *и. сөйл.* Берәрсе, кемдер, кем дә булса. *Алла сакласын, кеше-кара ишетмәсен, әгәр ул әрсез хатынның паралич белән ятучы ире булганын да белеп алсалар?* Ф.Хөсни. *Узган атнада гараж артларын карап йөргәндә, тәмам аерылган икән бу, стенасы да бер ярты кирпеч калынлыгында гына, кеше-кара күргәнче рәтләргә кирәк --- дип уйлап куйган иде [Әгъдәс].* Р.Рахман

**КЕШЕЛӘ́РЧӘ** *рәв. к.* **кешечә**. *[Ханым шагыйрьгә:] Сез лаеклы кешеләрчә яшәү хөрмәтенә, Мин белештем фатир – ике бүлмә.* Ә.Баян. *Рифат муенына галстук тагып йөрүне мещанлыкка саный иде. Шулай да, дәрәҗә иясе кешеләрчә, ак якага галстук элүне үрнәк итәргә исәбендә юк түгел.* Ф.Яхин

**КЕШЕЛЕК** *и.* **1.** 1) Кешеләр, кешеләр җәмгыяте. *Тотып кала агач тамырлары һәм туктата таулар ишелүен. Ни коткарыр, иптәш Родари, Бүген Кешелекнең кешелеген?* Зөлфәт. *Айгөл Җәүдәтовнаның уй-кичерешләрендә генә түгел, хәтта гамәлләрендә дә кешеләрнең һәм, гомумән, кешелекнең һичбер эше юк иде.* Ф.Яхин

2) Кешегә хас төс-кыяфәт. *Туңып, күшегеп, тәмам кешелеген җуйган Хәйрүш көч-хәл белән станциягә килеп җитте.* М.Хәсәнов

3) Чын кеше булу, кешелеклелек, шәфкатьлелек сыйфатлары. *Кеше сиңа зарар итсен, син аңар файда ит! Менә кешелек шунда*! Г.Исхакый. *Кеше талап баеган, акча властеның түмен татып кешелеген җуйган Исмәгыйль гомумән мәхәббәт хисеннән мәхрүм.* И.Нуруллин. *[Ф.Әмирхан] --- кырыс шартларда да демократик идеалларына, кешелек намусына тап төшерми.* Р.Әмирхан

4) Кеше арасына чыкканда гына, кадергә генә кия торган кием. *Өйлеге юк кешелеген кияр, кешелеге юк кешенекен кияр.* Мәкаль. *Эш көнендә кешелеген кигән ял көнендә эш киемен кияр.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Күпмедер сандагы кешегә исәпләнгән, ... гә җитәрлек, ... дән торган, ... генә сыярлык. --- *өйгә кайтсалар, кечкенә генә кунак бүлмәсенә зур караватка ике кешелек урын хәзерләнгән, иртәгә юыныр өчен сулар, ап-ак сөлгеләр куелган таптылар.* Г.Исхакый. *Институтның тулай торагында нигездә биш-алты кешегә исәпләнгән бүлмәләр. Ә менә ике кешелеге берничә генә иде.* И.Салахов

◊ **Кешелектән китү** *к.* **кешелектән чыгу** (*2 мәгъ.*). *[Карт:] Бу кеше хәзер кешелектән киткән инде. Башкалар кайгысы юк моңарда. Акча кайгысы, мал кайгысы гына калган.* З.Зәйнуллин. *Кеше кадерен белгән заманмыни, Кешелектән киткән чаклары ---.* Ф.Яхин. **Кешелектән чыгу** 1) Гариплану, сәламәтлеккә зыян килү. *Ярым җимерек, кешелектән чыгарылган хәлдә килеп кергәнгә озак ятты, шуны анык белә [Аяз].* Л.Ибраһим-Вәлиди; 2) Кешегә хас сыйфатларны югалту. *Лаякыл исерек бу ике адәм заты, киресенчә, гайрәтне чигерерлек дәрәҗәдә кешелектән чыккан кебек тоелды миңа.* Г.Гыйльманов; 3) Нинди дә булса сәбәпләр аркасында ару, хәлсезләнү, кәеф төшү, эшкә булган дәрт сүрелү, кимү, сүнү. *Хәбибуллин бүлмәсенә кереп караватына ауды, чөнки үткән озын һәм үтә мәшәкатьле көн аны тәмам кешелектән чыгарган иде.* И.Хуҗин; 4) Нәрсә дә булса бозылу, җимерелү; яхшы сыйфатларын югалту. *Көзге ягъмурлы җилдә өйнең сылаганы изрәп, ул да йимерелде. Усал сыерлар, канауны йимереп, бакчага кереп йөргәнгә, түтәлләр, бакчалар да кешелектән чыкты.* Г.Исхакый

**КЕШЕЛЕКЛЕ** *с.* Шәфкатьле, мәрхәмәтле, ярдәмчел. *Зират мохитендә мал – бәясен, дан – кадерен, өстенлек көчен югалта. ---. Күңелдә кешелекле көч уяна.* М.Юныс. *Шагыйрьнең [Г.Тукайның] әсәрләре --- кешелекле, югары гражданлык хисләренә бай булуы белән укучыларны һәм шагыйрьләрне үзенә җәлеп итә.* М.Хәсәнов

**КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК** *и.* Кешелекле булу. *Бу кичнең кешелеклелек хисе уятучан сихәте карт хисапчыны кибеткә куып кертте, гаилә финансының дебет ягына зур зыян ясап, оныкка конфет алдыртты.* М.Юныс. *Татар повестеның иң матур традицияләрен дәвам итеп, язучы [Ф.Сафин] --- кеше һәм кешелеклелек, җәмгыять һәм кеше мөнәсәбәтләре бер заманда да үзгәрмәс-югалмас кыйммәтләр хакында уйлана.* Д.Заһидуллина

**КЕШЕЛЕКСЕЗ** *с.* Шәфкатьсез, мәрхәмәтсез, тупас. --- *[Шәрифулла абзый] да, телгә килеп, --- Казан байларына тел озайтып, гайбәтләренә төште: – Гаять кешелексез байлар...* З.Бигиев. *Хакимиятне кулларына төшергән коммунистларга М.Булгаковның «Собачье сердце» әсәрендә сурәтләнгән кешелексез Швондер, эттән кешегә әверелдергән, эчкече, бозык Шариков кебекләр --- аңлы затлардан кирәгрәк булалар.* Т.Галиуллин. *Я Аллаһу, юлларымны уртак кылма Кешелексез, ышанычсыз бәндә белән.* Ш.Җиһангирова

**КЕШЕЛЕКСЕЗЛЕК** *и.* Кешелексез булу. *Иван Грозный үзенең әхлаксыз тормышы һәм кешелексезлеге белән аерылып торган, ул төзегән террор*

*сәясәтеннән иң элек рус халкы үзе зур зыяннар күргән.* Р.Фәхретдинов

**КЕШЕ́-МАЗАР** *и. сөйл. к.* **кешекара**. *Шакып та, кычкырып та карады Камилә, әмма күз күреме җирдә кешемазар шәйләнмәде.* Г.Гыйльманов. *Тукталышта кеше-мазар да юк: вакыт соң.* Ә.Дусайлы

**КЕШЕ́-ФӘЛӘН** *и. сөйл. к.* **кешекара**. *Пароходта күтәренеп күчкән вакытта Фәтхерахман абзыйны әллә нинди бер уңайсызлык чолгап алгандай булды. Кеше-фәлән күрсә, аның дачаларга чыгуын гаепләр төсле иде.* К.Тинчурин. --- *кеше-фәлән килсә, чагыштырмача югарыдарак булган яр җимерелеп төшәргә дә күп сорамас.* Р.Мөхәммәдиев

**КЕШЕ́ЧӘ** *рәв.* 1) Кешегә хас булганча; кешеләр кебек, кешедәй. *Акыл әйтә: «Нәкъ кешечә яшәп, ул туктап калды: чиксез мәңгелекнең бер җирендә йокыга талды».* И.Юзеев. *[Комендант] Киресенчә, шатланган кебек әйтеп куйды: – Торсын соң... Хет бераз кешечә яшәп алыр...* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Тиешенчә яхшы итеп, адәмчә. *Кешечә озата да алмады кунакларын [Шамил абый].* Р.Мөхәммәдиев

**КЕШЛЕК** *и. сөйл. к.* **кешелек** (*4 мәгъ.*). *[Фәйрүзә] сандыкны туздырып киемнәрен алды, кешлеккә кия торган ике күлмәгенең бүген кайсысын кияргә белмичә, озак кына таптанып торды.* Г.Ахунов

**КЕШНӘ́Ү** *ф.* 1) Тавыш, аваз чыгару, кычкыру (ат тур.). *Агыйделнең аръягында калды кешнәп малкаем; Әй... калмады кешнәп малкаем, калды елап җанкаем.* Җыр. *Саф һава калтырап китеп, атның кешнәве тавышы колаклардан китәргә өлгерә алмады, авылның тагы бер тарафыннан җавап кешнәве килде.* Г.Исхакый. *Сугыш көне буе барган. ---. Кычкырган, ыңгырашкан тавышлар, тимергә тимер бәрелгән, атлар кешнәгән тавышлардан җиркүк тетрәп торган.* Н.Фәттах

2) *күч. сөйл.* Кычкырып, тотнаксыз итеп, ихахайлап көлү. *Нәрсә айгыр кебек кешнисең?* Г.Әпсәләмов. *Болгарлар укны алдылар, битекне укыдылар да ат кешнәгән кебек шаркылдап көлергә тотындылар.* Г.Исхакый

**Кешнәп алу** Бераз гына кешнәү. *Әллә кая еракта, озын, моңлы, әллә кемен сагынган, югалткан төсле итеп, ат кешнәп алды.* Һ.Такташ

**Кешнәп җибәрү** Кинәт кешнәү. *Ат та, бу матур көннең гади бер көн түгел икәнлеген белгән кеби, шул матурлыкның әллә нинди тулмаган җирен хис итеп, шуны тутырыр өчен кеби, бик матур итеп кешнәп җибәрде.* Г.Исхакый. *Ахрысы, сагынгандыр, мине күргә кешнәп үк җибәрде.* Г.Ибраһимов. *[Кашка] Кешнәп җибәрә, Улак янындагы ташка Дагасын бәрә.* Ф.Кәрим

**Кешнәп йөрү** Озак вакыт гел кешнәү. *Ике улым кире кайтмады, Кешнәп йөри кырда атлары ---.* М.Җәлил

**Кешнәп кую** Кинәт, аз гына кешнәү. *Ташбәкәл, иясе өчен пошынган сыман, кыска гына итеп кешнәп куйды ---.* Г.Исхакый. *Аның аты шунда кешнәп куйды, Чабып килде егет янына ---.* Ф.Яхин

**Кешнәп тору** Даими яки әледән-әле кешнәү; кешнәү хәлендә булу. *Ә бит минем башын күтәреп кешнәп торган фотоларым да бар!* Ф.Баттал

**КЕШТӘК** *и. фар.* Өске һәм эчке киемнәрнең тиешле урыннарын киңәйтү һ.б.ш. максатлар өчен тегелеп куела торган өчпочмак яки ромб формасындагы тукыма кисәге. *Кештәкнең [бер] ноктасы җиң очы юнәлешендә урнашырга тиеш.* Йорт эшләре. *Имештер, элекке заманда саескан хәзерге шикелле кара кештәкле, арттан яшел итәкле ак күлмәк кимәгән, башында каралы-яшелле түбәтәе дә булмаган.* Әкият

**КЕШТЕ́РТ-КЕШТЕРТ** *иярт.* Җиңелчә кыштырдау тавышын белдерә. *[Ат] кештерт-кештерт китереп, утлыктан печән ашап тора.* Н.Фәттах

**КИ** *терк. фар.* Иярченле кушма җөмләдә ачыклау мөнәсәбәтен белдерә. *Зира ул [фикер] иске хикмәтләр – кадим фәлсәфәләре, --- шул дәрәҗә тәрәкъкый итмештер ки, тәмамән яңа бер фәлсәфә вә җәдид бер мәсләк булмыштыр.* Ф.Кәрими. *Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.* Г.Тукай. *Галимнәребез, язучыларыбызның мактауга лаек хезмәтләре булса да, кызганыч ки, күп кенә шәхесләребезнең иҗаты, тормышы тәфсилләп өйрәнелмәгән.* Р.Батулла

**КИБАР** *и. гар.* **1.** 1) Зур, олы, өстен кешеләр. *Ул [Тукай] шул арада үзенең кайдадыр бер җирдә шундый зур рестораннардан беренә барып та, бөтен өстәл әтрафын әллә нинди кибарлар белән генә чуала торган кызлар коршап алганын сөйләде.* К.Бәкер

2) Горурлык, һавалылык, тәкәбберлек. *[Ай] артык матур вә хыялый төстә нурлы, ләкин бу нурда вә бу югарылыкта мөлаямәт вә иркәлектән бигрәк кибар катыш салкынлык бардыр шикелле тоела.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Һавалы, тәкәббер; олы. *Берлин кебек биек бер пайтәхетнең театросын вә нимсәләрнең кибар галәмен күрмәк арзусы илә бардык.* Ф.Кәрими

**КИБА́РАНӘ** *рәв. фар.* Эреләнеп, тәкәбберләнеп, һавалы рәвештә; горурланып. *Хәмдия бер креслога кибаранә генә утырган.* М.Фәйзи. *Кибаранә күтәреп баш, безнең таш-тау Селкенми дә, кузгалмый да тора сап-сау.* Г.Тукай

**КИБАРИ** *с. гар. иск.* Эре, тәкәббер, һавалы; горур. *Түрә --- озын буйлы, калынрак гәүдәле, ак сакаллы, мәһабәт вә кибари кыяфәтле.* Г.Ибраһимов

**КИБАРЛЫК** *и. иск. кит.* Эрелек, тәкәбберлек, олы сыманлык; горурлык. *Бай да бик яхшы беләдер монда йомышы барлыгын: «Ни кирәк?» дими, сорамый, ташламый кибарлыгын.* М.Гафури

**КИБӘК** *и.* **1.** 1) Башаклы игеннәрне һәм башка кайбер культураларны сукканда, чистартканда барлыкка килә торган калдыклар. *Орлык кибәксез булмый.* Әйтем. *Менә мин --- йомыркалар, кибәкләр, утыннар, саламнар, чүпрәкләр өчен судлашучы кеше калдыгы!* Г.Исхакый. *Әбүгалисина кибәкләр тирәсендә нидер эшләде: кибәкләр барысы да хәлвәгә әверелделәр.* К.Насыйри

2) *диал. к.* **кавык**

3) *эвф. к.* **кандала**. *«Кибәк» дисәң кибә, «кандала» дисәң кадала.* Ышану. *Йосыф муенынnan кибәк тот[ты].*

Г.Коләхмәтов. *Яттым йокларга әйлешәйле; тешләп алды кибәк бергәйле...* М.Шаһимәрдәнов

**2.** *с. мәгъ.* Кибәктән (*1 мәгъ.*) булган, шуннан ясалган. *Ерак түгел бер карт тары җилгәрә: җил миңа кибәкне очырып тора, мин шуларны тотып аркан ишә башладым. Бер-ике метр иштем дә: «Туктале, беркадәр төшкәч, күбрәк тә ишәрмен», – дип тотынганыем – өзелде китте минем кибәк арканым.* Әкият

◊ **Кибәк баш** Надан, аңгыра (кеше тур.*). Ит үзеннән кортлый, ди. Шуның күк, бу кибәк баш динчеләр үзләрен үзләре таптаганын аңламыйлар.* Г.Тукай. *Каравылчы карт, күз карашы белән аны озата калып, күңеленнән: «Бу мулла-мәзин халкы бигрәк кибәк баш инде!»* М.Галәү. **Кибәк башлы** *к.* **кибәк баш**. *Ишан образы, ул [Тукай] сурәтләгәнчә, олы кибән чалмалы, кибәк (ягъни чүп тутырылган) башлы, муенын бөгеп, күзен йомып утыручы буларак ачыла.* Ф.Яхин. **Кибәк очыру** Ялганлау, ялган кушып сөйләү

**КИБӘКЛӘНҮ** *ф.* Кибәклегә әйләнү, кибәк белән буталу, аралашу

**Кибәкләнә бару** Акрынлап кибәкләнү

**Кибәкләнә башлау** Кибәкләнергә тотыну

**Кибәкләнә төшү** Берникадәр кибәкләнү

**Кибәкләнеп бетү** Тәмам, ахыргача кибәкләнү

**Кибәкләнеп яту** Кибәкләнү хәлендә булу

**КИБӘН** *и.* Салам, печән һәм сугылмаган ашлыктан ачык һавада саклау өчен зур итеп салынган чүмәлә. *Кибән астында тычкан үлмәс, ир куенында кыз үлмәс.* Мәкаль. *[Ындырдагы] чүмәләләрдә, шундагы кибәннәрдә --- бунларның меңәр төрле планнары яшеренә башлады.* Г.Исхакый. *Туенып алабыз да зур кибән тирәли баш төртеп йоклыйбыз.* М.Кәрим

◊ **Кибән башы** Кыерчык (ипидә). *Шүрлектән бер бөтен ипине аласың да, күкрәккә терәп, бисмилла әйтеп, телеңне чыгарып, кибән башын кисеп аласың да, ашъяулыкка куясың.* Р.Батулла. *Анысына да үпкәләмәс иде Сәгыйрә, тик еш кына азык инде суынган була, ипинең дә күбрәк кибән башы эләгә (аны чәйнәрлек тешләре булса икән лә!).* Д.Йосыпова

**КИБӘНЛӘ́Ү** *ф.* Кибән кую, кибән итеп өю. *Кайбер колхозларда печәнне тозлап кибәнлиләр икән.* Ә.Еники

**Кибәнләп бетерү** Кибәнләүне тәмамлау

**Кибәнләп тору** Даими яки әледәнәле кибәнләү; хәзер кибәнләү

**Кибәнләп яту** *к.* **кибәнләп тору**

**Кибәнли башлау** Кибәнләргә тотыну

**КИБӘ́Н ҮЗӘГЕ** *и.* Кибәнне ныгытып тору өчен, аның уртасыннан җиргә кадала торган колга

**КИБЕГҮ** *ф.* 1) Бик нык тамак кибү, сусау, эчәсе килү. *[Исмәгыйль:] Чәй куй, кибектем бик каты.* З.Мәхмүди. *– Эй, нишлисең син?.. – Кыз энесенең кулындагы сок пакетын тартып алды ---. Әйтеп торам ич, өйгә кергәч эчәрсең, дип... – Ә мин кибектем...* М.Кәбиров

2) Үтә дә нык ябыгу. *[Тәзкирә:] Алай ашамый йөрсәң, бик тиз кибегерсең монда, җанкисәгем.* Н.Фәттах

3) *диал.* Нык кибү, коргаксу. *Июль башы. Менә инде ничәмә-ничә көннәр яңгыр күргән юк ---. Чирәмнәр суга кибеген, саргаеп маташа.* Сөембикә

**Кибегә бару** Акрынлап кибегү; акрынлап тагын да кибегү

**Кибегә башлау** Кибегү билгеләре сизелү

**Кибегә төшү** Берникадәр кибегү

**Кибегеп бетү** Бик нык кибегү

**Кибегеп тору** Гел кибегү; кибегү хәлендә булу

**Кибегеп яту** Әле, хәзерге вакытта кибегү

**КИБЕКТЕРҮ** *ф. сөйл.* Кемне дә булса төрле рухи газаплар белән борчып, җәберләп, йончытып ябыктыру. *Ачуым – ачу, кибектерәм әле мин аны, дип әйтеп әйтәдер, ди [Нәфисә].* Г.Бәширов

**Кибектерә төшү** Берникадәр кибектерү

**Кибектереп бетерү** Тәмам, бик нык кибектерү

**Кибектереп тору** Гел, даими рәвештә кибектерү

**КИБЕНҮ** *ф. сөйл.* Юешләнгән, чыланган өс-баш кибү яисә аны киптерү. *Бер чыланып, бер кибенеп Җиде суга таба баручы Сайдә үзенең уйларыннан үзе куркып китте.* Г.Гыйльманов

**Кибенә бару** Акрынлап кибенү; тагын да кибенү

**Кибенә төшү** Берникадәр кибенү

**Кибенеп алу** Тиз арада кибенү; берникадәр кибенү

**Кибенеп бетү** Кибенү тәмамлану; тәмам кибенү

**Кибенеп житү** *к.* **кибенеп бетү**

**Кибенеп тору** Даими яки әледән-әле кибенү; кибенү хәлендә булу

**Кибенеп яту** Кибенү хәлендә булу

**КИБЕР** *и. гар.* Тәкәбберлек, эрелек, артык горурлык. *Бу нинди игътибарсызлык! Матурлыктан туган бер киберме бу?* Ф.Әмирхан. *Ул бала вакытта ук аңардан кача, аның әллә нинди кибереннән, үзен каты, салкын һәм югары тотарга, баш булырга теләвеннән вә бөтен торышыннан җаны-тәне белән чиркана --- иде.* Г.Ибраһимов

**КИБЕРЛЕ** *с. иск.* Тәкәббер, эре, артык горур. *Җәлал --- күкрәгән, бөтен торышын киберле бер кыяфәткә китереп турылатты.* Г.Ибраһимов

**КИБЕРНЕ́ТИК** I *и. рус* Кибернетика белән шөгыльләнүче кеше

**КИБЕРНЕ́ТИК** II *с.* Кибернетикага мөнәсәбәтле, шуңа бәйләнешле; кибернетикага караган. *Яфракка тормыш суты ташучы «кан тамырлары»ның төгәл сурәтен, андагы үзгәрешләрне, матдәләр алмашын секундына меңәр исәпләү башкарган иң акыллы берәр кибернетик машинаның анык әйтеп бирә алганы бармы әле*? А.Хәлим

**КИБЕРНЕ́ТИКА** *и. гр. махс.* Машиналарда, тере организмнарда һәм җәмгыятьтә идарә итү һәм мәгълүматны тапшыру процессларының гомуми закончалыкларын өйрәнә торган фән. *Янәсе, компьютер, кибернетика заманында нинди ул дин! Моны кибернетиканың «к» хәрефен дә белмәгән кешеләр әйтә. Ә мин дингә мәдрәсәләрдә укып түгел, шул кибернетика аркылы килдем.* И.Әмирхан

**КИБЕТ** *и.* Товарлар ваклап сатыла торган сәүдә оешмасы һәм шулай сату өчен махсус яраклаштырылган бина. *Каладан, Габдулла байның йортыннан һәм кибетеннән алып кайткан акча белән мал Миңлебай Вафасына көчкуәт һәм ышаныч бирде.* М.Галәү. *Борынны ярып керә торган тозлы балык исе бу кибетләрдә нәрсә сатылганны аңлатып тора, һәм бу тозлы ис карта исе кебек үк эчне, карынны кытыклый, котырта, үрти иде.* Ә.Фәйзи. *[Бай:] --- бәлки, синең минем кибетемә пайга керергә дә ниятең булыр, урамнан кешеләр җыярга минем кибетем обжорный рәт түгел. Минем кибетем – магазин.* К.Тинчурин

**КИБЕТЧЕ** *и.* 1) Сатучы, кибеттә эшләүче кеше. *Кибетченең алмаларны: – Бик һәйбәт, свежийлар! – дип мактавына каршы Корбангали аның күзенә карап: – Шундый кирәк тә – вакыты шундый! – дип, авызын ерып көлеп куйды, гүя кибетче аның сөенеченә катнаша иде...* Ш.Камал. *Кара сакаллы бер кибетче аңа [Сөләйманга] байның бүлмәсен күрсәтте.* К.Тинчурин

2) Кибет тотучы (бай); шул кибеттә сату итүче кеше. *Вәсиләне Сатыш авылының кибетче Зариф малаена кияүгә биреп куйганнар.* Ф.Хөсни

**КИБЕТЧЕЛЕК** *и.* Кибетче вазифасы, кибетче хезмәте. *Кызының үзе кебек төшемле эштә булуын теләп кибетчелеккә укытты ---.* Мәдәни җомга

**КИБҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса юеш, дымлы нәрсәнең дымы бетеп корыга әйләнү. *Берәр фойеда яки подъездда озаграк тоткарлансам, минем плащ, әкияттәгедән дә тизрәк вакыт эчендә, омон солдатлары киеменә охшап кибә башлый.* Ә.Дусайлы

2) Тиешле дымлылыгы, юешлеге бетеп, бик нык кору. *--- [әбинең] күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә ---.* Ә.Еники. *Тәмәке тартканнан соң тамак кибә.* М.Кәбиров

3) Парга әйләнү (сыеклык, су тур.). *Инештә су кибә башлаган.* Н.Дәүли

4) Кору (үсемлекләр тур.). *Кызым гөлләр үстерә, Су сибә дә су сибә... «Су сипсәм үсәрләр! – ди. – Юкса тамыры кибә!»* Ф.Яхин

5) *күч.* Кемгә дә булса гашыйк тотып, шуннан газаплану. *Ике кыз – ике чибәр – Гыйшык утында кибәр.* Ф.Яхин

6) *күч. сөйл.* Авырудан, төрле рухи кичерешләрдән, авыр эштән һ.б.ш. ябыгу, кору. *Мәликә көннән-көн кипте, корыды, хәлсезләнә барды.* Г.Галиев

◊ **Кипкән балыкка әйләнү** Артык нык ябыгу. *Дүрт-биш көн эчендә [Вәли] үзе кипкән балыкка әйләнде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Кибә бару** Торган саен кибү

**Кибә башлау** Кибәргә тотыну

**Кибә тору** Алдан ук кибә башлау; билгеле бер вакытка кадәр кибү, кибеп кую

**Кибә төшү** Берникадәр күләмдә тагын да кибү

**Кибеп бетү** Тәмам кибү; ахыргача кибү. *[Габделбасыйр:] Диләфрүз белән гыйшык тотышабыз. Ул да саргаеп, кибеп бетте, мин дә, менә үзең күрәсең, көннән-көн саргаям, кибәм.* Ф.Әмирхан

**Кибеп житү** *к.* **кибеп бетү**. *Яңгырдан соң [Газинурның] кепкасы әле рәтләп кибеп тә җитмәгән иде.* Г.Әпсәләмов

**Кибеп килү** Акрынлап, аз-азлап кибү

**Кибеп тору** Кибү хәлендә булу, әле кибү

**Кибеп яту** *к.* **кибеп тору**

**КИГӘВЕН** *и.* Ике канатлы бөҗәкләр отрядыннан личинкалары хайван организмына тире капламы аша керә һәм анда үсә торган паразит бөҗәк. *Бүген көн әйбәт. Бөгәлчәннәр, кигәвеннәр дә борчымый. Кояш та артыгын кыздырмый.* Г.Хәсәнов. *Ярмөхәммәт үлән себеркесе белән атның ике бот арасын чаба, корсак асларыннан бөгәлчәннәрне куа, чебен-черки, кигәвеннәрне сыдырып төшерә.* Р.Батулла. *Кигәвен һәм чебеннәрдән качып шактый озак аунадым.* Ф.Яхин

**КИГЕЗҮ** *ф. к.* **кидерү**. *Таҗи белән Фәхри --- авыр тәрәт чиләгенең тишекле колакларына озын таяк кигезделәр дә шуның ярдәмендә аны иңнәренә күтәрделәр.* М.Галәү. *[Вахтёр:] Ишетмәдеңмени, ул артистка инде әллә кайчан «агач бушлат» кигезделәр ләбаса.* И.Салахов. *Ока елгасы буенда урнашкан хәрби лагерьда Габдрәхим Юсупов белән Җәүдәт Галиевкә кием кигезделәр.* З.Зәйнуллин

**КИГЕРҮ** *ф. к.* **кидерү**. *Көн саен ул аңа ап-ак чиста күлмәк кигерә.* М.Җәлил

**КИГИ** *и.* 1) Тәгәрмәч тырнагы. *[Үзле балчык] зур-зур кантарлары белән кубып, тәгәрмәчкә ябыша, тугымнар, кигиләр, калынаеп, резинадан эшләнгән төскә керәләр.* А.Гыйләҗев

2) Гомумән шуңа охшаш нәрсәләр турында

**КИДЕРҮ** *ф.* 1) Берәр кешегә нинди дә булса кием киярге ярдәм итү. *Күңелсезгә күлмәк кидермиләр.* Мәкаль. *Аш ашатты, үзе биреп су эчерде, Өстенә төрле-төрле тун кидерде ---.* Кол Гали. *Хәсрәү энесенең өстенә кызыл төстәге кытай ефәгеннән тегелгән күлмәк, ә Бәһрамга яшел күлмәк кидерде атакай Шахрай.* М.Хәбибуллин

2) Нәрсәне дә булса тышлык эченә тыгу, тышлык белән каплау, капланган итү. *Мендәргә тыш кидерү. Диванга чехол кидерү*

3) Эче божра сыман куыш әйберне нәрсәгә дә булса кертү, урнаштыру. *Ул [Тотыш] куенындагы янчыгыннан алтын йөзекне алды да анасының урта бармагына кидерде.* Н.Фәттах. *Ул [үгез суючы адәмгә охшаган таза бер ир] дәшми-тынмый гына тасманы минем култык асларыма тыкты, нindидер элмәк ясап башка кидерде, аннары, тарттырып, караватн башына бәйләде.* Ф.Яруллин

4) Нәрсәгә дә булса икенче нәрсәне асылган, эленгән хәлдә беркетү; тагу. *Берсе ике куллап арттан аның башын кысып тотты, үткер энә белән аның сул колагын тиште. «Алка кидерәләр», – дип уйлады Чәнси тыныч кына.* Н.Фәттах. *Тимерче Гаян абзый кыздырылган үткер тимер көпшә белән тишеп, үгезнең борынына алка кидерде ---. Р.Риян*

5) Нәрсәне дә булса икенче бер нәрсәгә (җепкә, энәгә, таякчыкка һ.б.ш.) кадап, чәнчеп беркетү, кертү. *Алар аны [итне] тимер шешкә кидереп утта кыздырачаклар ---.* Н.Фәттах

6) Утырту (кармакка җимне). *[Адий:] Яңа суалчан кидер. Тагын да зуррагы чиртсен!* М.Гыйләҗев

**Кидерә башлау** Кидерергә тотыну

**Кидереп алу** Тиз арада кидерү

**Кидереп бетерү** Кидерүне тәмамлау

**Кидереп карау** Кидерергә тырышу; кидереп чамалау

**Кидереп кую** *к.* **кидерелгән итү**. *Леонид Калинич куфайкасын салып урындык артына кидереп куйды*. З.Зәйнуллин

**Кидереп тору** Кидерү хәлендә булу. *Мөсафиров секретарьның кармагына суалчан гына кидереп торган.* И.Гази

**Кидереп яту** Әле хәзерге вакытта кидерү

**КИЕЗ** *и.* **1.** Йоннан басып эшләнгән тыгыз һәм калын тукыма. *Өйнең бөтен түрен иңләп, өстенә киез җәелгән зур сәке тора ---.* Ә.Еники. *Өйнең тәрәзәсе бер генә катлы, ишегендә киезләр, чыпталар да күптән алынып киемгә тотылганга, салкын иде.* Г.Ибраһимов. *Түрсәкегә буйлый калын киез җәелгән.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, ясалган, җитештерелгән, эшләнгән. *Ул [Бикмүш бабай] киез эшләпәсен чөйгә элде дә табын янына тезләнде.* Г.Гобәй. *Гәрәй казанын күтәреп барып җиткәндә, Намаҗан карт, биш билле кара тун, камалы бүрек, кыска куныч-лы киез ката киеп, күршесендәге мәчеттән кайтып килә иде.* Г.Ибраһимов. *Атчабарлар урамга килеп керү белән кайсы он, бәрәңге, кайсы балта, пычкы, киез итек чыгарып бирә.* М.Мәһдиев

**КИЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* Чуалту, басылдыру (чәч, йон һ.б.ш. тур.)

**Киезләндереп бетерү** Тәмам киезләндерү

**Киезләндереп тору** Даими яки әледән-әле киезләндерү; киезләндерү хәлендә булу

**КИЕЗЛӘНҮ** *ф.* Чуалып бетү, басылу (чәч, йон һ.б.ш. тур.). *[Салихның] кара чәчләре чуалып киезләнгән.* Г.Мөхәммәтшин

**Киезләнә башлау** Киезләнергә тотыну

**Киезләнеп бетү** Бик нык киезләнү; киезләнеп эштән чыгу, ярамас хәлгә килү. *Киезләнеп беткән каты мендәрдә ятса да, матур төш күрә Гәрәй.* А.Гыйләҗев

**Киезләнеп тору** Киезләнгән булу; киезләнгән кыяфәттә күренү

**КИЕЗЛӘТҮ** *к.* **киезләндерү**

**Киезләтеп бетерү** Бик нык киезләтү; киезләтүне тәмамлау

**Киезләтеп тору** Даими яисә әледән-әле киезләтү; киезләтү хәлендә булу

**КИЕЗЧЕ** *и.* Киез эшләүче, киез басучы кеше

**КИЕК** *и.* **1.** 1) Кыргый кош яки җәнлек. *Киекләр кешегә ышанмый, Көчлесе ыржая тешләргә.* Ш.Маннапов. *Урмандагы киекләр дә, судагы балыклар да, электрдан, газдан мәхрүм калган халыклар да!* М.Шаһимәрдәнов. *Яннарымда шуыша еланнар, ырылдашып йөри киекләр.* Ә.Дусайлы

**2.** *с. мәгъ.* Кыргый. *Яңгырларда, явымнарда, Давылларда-җилләрдә Киек казлар кыйгылдаша.* Х.Туфан

**КИЕК КА́З ЮЛЫ** *и. к.* **Каз юлы**. *Күк йөзендә көмеш ай тулы. Сызылып киткән Киек Каз Юлы.* З.Хөснетдинов. *Йөзне аз юды җылы яз тыны, Бугаздан буды черек баз дымы. Булырмы гүрем сөю-наз тулы, – Барасы юлым – Киек Каз Юлы...* Р.Закиров

**КИЕКЛЕ** *с.* Киекләре күп булган, киеккә бай (урман, кыр һ.б.ш.). *Тау битен япкан киекле урман.* Ш.Маннур

**КИЕЛГӘН** *с.* Яңа түгел, инде киюдә булган, таушалган. *Хатын-кызларының өстендә киелгән ситсы күлмәк белән сырган бишмәт, башларында искерә башлаган калфак, аякларында тула оек белән агач башмак.* М.Галәү

**КИЕМ** I *и.* 1) Тукымадан, күннән, мехтан һ.б.ш. материалдан тегелгән, эшләнгән һәм тәнне каплау яисә кию өчен хезмәт итә торган әйберләр җыелмасы. *Менә син иртә белән йокыдан уяндың да күзләреңне ачтың ---. Синең өс-баш киемнәрең урындыкка пөхтәләп җыеп куелган.* Н.Дәүли. *Камил тыңлады – кайтты. Китаплары янына киемнәрен дә салып кайттыкитте, кайтты-китте…* Р.Рахман. *Таң алдыннан киеменнән бензин исе аңкыган ир бәндәсе керде ---.* Н.Гыйматдинова

2) Пальто, бүрек, итек һ.б.ш. тыштан киелә торган җылы киемнәр; тышкы кием. *Өс киемен ашык-пошык чыклы чирәмгә ыргыткан.* Р.Харис

3) *күч. шигъ.* Гадәттә билгеле бер урынның, агачларның нинди дә булса төс белән каплануы турында әйтелә. *Көзге җилем син, яктылык күрмим, Моңсу табигать алтын киемнән.* А.Нәҗми

◊ **Кием калыбы** 1) Манекен; 2) *күч.* Кулыннан бер эш тә килми торган, киенеп-ясанып кына йөри торган кеше

**КИЕМ** II *и.* Бербөтен әйбер (комплект) тәшкил итә торган һәм бергә генә файдаланыла торган ике бер төсле һәм бер иш предметлар турында әйтелә; пар. *Ике чабата – бер кием.* Мәкаль. *Әтисеннән калган бер кием чабата бар иде, чормага менеп, Рәгыйдә шуны алып төште ---.* Р.Рахман

**КИЕМ-КИЛБӘТ** *җый. и.* Тышкы кыяфәт, өс-баш, киенү рәвеше. *Кәбир әфәнде --- буй-сыны, кием-килбәте, үзен тотуы, сөйләшүе белән шәкертләр һәм хәлфәләрнең исен китәрде.* Ә.Фәйзи

**КИЕМЛЕК** *и.* **1.** 1) Кием тегү өчен билгеләнгән тукыма. *Шуның өстенә, киткәндә 50 тәңкә акча һәм киемлекләр биреп җибәрделәр.* Г.Тукай. *--- мулламы, я бер бай сәүдәгәрдәнме, киемлекләр, бәгъзан азрак акча да килә иде шикелле.* Г.Кариев

2) Кием булу. *Үзе адәмлектән чыкканның киеме киемлектән чыгар.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Кием тегәргә яраклы, кием тегә торган. *Киемлек товар*

**КИЕМ-САЛЫМ** *җый. и.* Өс, баш, аяк киемнәре җыелмасы. *Хәзер сугыштан соң кием-салымы да юктыр, солдат иске-москысы булмаса.* И.Салахов. *Шагыйрь [Тукай] кием-салым мәсьәләсендә таләпчән түгел, гадирәк киенеп йөрүне ярата төшә иде.* И.Рәмиев

**КИЕМ-ТОТЫМ** *и. иск. к.* **кием-салым**. *[Капитан:] Ашау-эчү, киемтотым – бездә алар кечкенә мәсьәлә.* Ш.Камал

**КИЕМЧЕ** *и. иск.* Кием тегүче кеше. *Киемче яңа киемнәреңне китерде.* Г.Исхакый

**КИЕ́М ЭЛГЕЧ** *и.* Кием элəр өчен махсус урын яки җайланма. *Театр кием элгечтəн башлана, дилəр, ə фəн – китапханəдəн, андагы картотекалардан.* Р.Рахмани. *Ишектəн кергəч тə, сул якта фанер ширма. Ширма артында карават, юынгыч, кием элгеч.* И.Рəмиев

**КИЕНДЕРҮ** *ф.* 1) Кемгə дə булса киенергə ярдəм итү, кием кидерү. *[Анна Васильевна] --- һəркөнне йокыдан иренеп торган Шəмсигə: – Я əле, башкорт кантоны, рəхим итеп, үзеңезне киендерергə рөхсəт бирeңез əле, – дип, Алланың биргəн көнендə аның күлмəген-ыштанын алыштырды.* Г.Исхакый. *Ул арада Газизə апа Габдулланы киендереп, аның башына махсус үзе теккəн хəтфə кəлəпүшне киерткəн ---.* Ə.Фəйзи

2) Кемгə яки нəрсəгə дə булса охшатырга тырышып кием кидерү. --- *арада кайберəүлəрен ак фəрештəгə охшатып киендергəннəр.* М.Миначев. *Нурҗиһанны нəкъ авыл кызы итеп киендергəннəр.* Г.Бəширов

3) Кием белəн тəэмин итү, кием булдыру. *Кечкенə бала көннəремдə, һичбер эшкə ярамасам да, атам-анам мине киендереп асрап үстерделəр.* Дəрдемəнд

4) Матур кием белəн тəэмин итү, матур итеп йөртү. *Киендерсəң, киндер таягы да кияү була.* Мəкаль

**Киендерə бару** Акрынлап киендерү; тагын да киендерү

**Киендерə башлау** Киендерергə тотыну

**Киендерə тору** Нииндидер эш башланганчы киендерү

**Киендереп бетерү** Киендерүне тəмамлау; тулысынча киендерү. *Кайсы як [курчакны] алдан киендереп бетерə, шул төркем җиңүче дип табыла.* М.Бакиров

**Киендереп карау** Киендерергə тырышу; киендереп чамалау

**Киендереп кую** Алдан киендереп əзерлəү; гомумəн киендерү. *Киендереп куйгач, ике Бибинурны аерырлык та булмый.* Ватаным Татарстан

**Киендереп тору** Даими яки əледəнəле киендерү; киендерү процессында булу

**Киендереп чыгу** Барысын да ахырга кадəр киендерү

**Киендереп яту** Киендерү процессында булу

**КИЕНҮ** *ф.* 1) Берəр төрле кием кию. *Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым.* Г.Тукай. *Əни мич алдында чыж-пыж итеп нидер кыздыра калды, мин аннан-моннан киендем дə урамга чыктым.* Г.Ибраһимов. *Əткəй кайтырга җыена башлагач, тиз-тиз генə мин дə киендем.* Ш.Җиһангирова

2) Үзеңə кием булдыру, үзеңне кирəкле киемнəр белəн тəэмин итү. *Мунчадан соң костюм-чалбар, эшлəпə, ботинка сатып алып кияргə кушытылар. Барлы-юклы акчага киендем, малай, ни эшлисең бит.* Казан утлары. *«Хəзерге яшьлəр кулларына энə тотып, бəйлəп, тегеп утырмый, кыйммəтле кибетлəрдəн генə киенə», – диючелəр белəн килешеп бетмим.* Сабантуй

3) Матур, затлы киемнəр кию. – *Киендем əле, Минсылуттəй... – диде оялчан гына Гаяз. – Гирбаванный тутам Молотовтан алып кайткан иде бу киемнəрне...* А.Хəлим

4) *күч.* Берəр төрле нəрсə белəн капланy, өртелү (гадəттə агач, җир һ.б.ш. тур.). *Май айлары, Бөтен дөнья яшел киемнəргə киенгəн.* Һ.Такташ. *Җиңелчə суык, ак киемнəргə киенгəн агач-куаклар...* Дуслык

**Киенə бару** Акрынлап тагын да киенү

**Киенə башлау** Киенергə тотыну

**Киенə бирү** Бернигə карамастан киенү

**Киенə калу** Киенеп тоткарлану

**Киенə тору** Алдан ук киенə башлау; хəзер киенə торган булу

**Киенеп алу** Тиз арада киенү; яңа киемнəр алып, киемле булу

**Киенеп бетү** Тəмам, бик нык киенү; киенүне тəмамлау. *Киенеп беттем, чыгып китəсем генə калды, аягым атламый да атламый.* Ф.Хөсни. *Бу вакытта Мəрдəн абзый киенеп беткəн иде инде.* Г.Гобəй

**Киенеп җибəрү** Бик матур, ыспай, бай итеп киенгəн булу

**Киенеп житү** *к.* **киенеп бетү**

**Киенеп калу** *к.* **киенə калу**

**Киенеп карау** Киенергə тырышу; киенеп чамалау

**Киенеп кую** 1) Алдан киенеп, əзер булу; гомумəн киенү. *Җангир ваннага кереп китүгə, Мəрсинə тиз генə киенеп куйды ---.* Ə.Дусайлы

2) Бик күп киемнəр алу, бик матур киенү

**Киенеп тору** Киенү хəлендə булу; əле, хəзер киенү

**Киенеп яту** *к.* **киенеп тору**

**КИЕНҮ-ЯСАНУ** *ф.* Матур, купшы итеп киенү, бизəнү, купшылану. *Əсфан янына килгəндə, ул [Гөлчирə], гадəттəгечə, киенеп-ясанып, ай-кояштай балкып килə --- иде.* Ф.Хөсни. *Аларның [японнарның] алтмыш яшьлек хатын-кызлары янəшəңнəн киенеп-ясанып кəттə генə атлап үтсə, «бу нинди чибəр туташ икəн?» дип авыз суыңны корытып каласың.* Р.Мөхəммəдиев. *Инде бүлəклəрен барлап, киенеп-ясанып чыгып китəргə əзерлəнгəч тə, аһ-ваh килеп, əрле-бирле йөренде [Лиля] ---.* Сөембикə

**Киенеп-ясанып йөрү** Һəрвакыт киенгəн-ясанган булу

**Киенеп-ясанып яту** Киенү-ясану хəлендə булу. *Иртəн болар киенеп-ясанып ятканда, иң иске күлмəгемне кидем дə нидер эшлəп йөрим.* Мəдəни җомга

**КИЕРГЕ** *и.* 1) Чигү чиккəндə, тукыманы тарттырып куя торган рам формасындагы җайланма. *Тамбур киергелəрем бөгемле. Бөгелмəдəн килгəн түгелме?* Җыр. *[Апа] кечкенə киергесен тезенə куеп, кулъяулык чигə.* Г.Бəширов

2) Тиешле формага кертер өчен, нəфис мамык шəлне киерə торган кадаклы махсус кыса

3) *к.* **киергеч** (*2 мəгъ.*)

**КИЕРГЕЧ** *и.* 1) Нəрсəне дə булса җəеп, киереп кую өчен булган махсус җайланма. --- *Фəүзия киергечкə Зур кунычлар киертə.* Ш.Маннур

2) *махс.* Тиресе ярылмыйча салдырылып кына алына торган җəнлеклəрнең тирелəрен киереп киптерү өчен кулланыла торган ике аерылы агач. *Вəлинең йорт җиһазлары төрле мылтыклардан, төлке аулый торган флаглар, куян тиресе киергечлəреннəн тора иде.* Х.Госман

**КИЕРГЕЧЛӘ́Ү** *ф.* Нәрсәне дә булса киергегә тарту, киерү

**Киергечләп бетерү** Киергечләүне тәмамлау

**Киергечләп тору** Даими яки әледән-әле киергечләү; киергечләү хәлендә булу

**Киергечләп чыгу** Барысын да киергечләү

**КИЕРЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) Зур итеп ачылу, киңәю, кабару. *Әйтерсең лә киерелгән борын канатындагы миң – бөтен зәһәрнең, усаллык, ачу-шикнең анасы...* Д.Булатова

2) Бер үк төрле торышта, хәлдә озак булу аркасында оеган, арыган гәүдәне, аяк-кулны язу. *[Ялчы] Бер иснәде, сөякләрен шыгырдатып бер киерелде ---.* Г.Ибраһимов. *Карт ана бүре башын күтәрде, ал тәпиләрен сузып киерелде һәм ап-ак казык тешләрен күрсәтеп иснәде.* Ә.Дусайлы. *Ул [Илүзә] --- түшәктә килеш киерелде.* Идел

3) Нервлар киеренкеләнү. *Салихның киерелгән нервысы бераз бушанды.* Г.Минский

**2. киерелеп** *рәв. мәгъ.* 1) Бөтен көчкә. *Аның [Алмыш ханның] ярым йомык күз кабаклары киерелеп ачылды.* Н.Фәттах

2) Кыю рәвештә, батырланып, дәртләнеп. *Бер әйләнгәнче, карттан бер калышмый бардым. --- Болынның урталыгына җиткәч, киерелеп, бер-ике селтәдем ---.* Г.Ибраһимов

3) Үтә дә масаеп, һаваланып, горурланып. --- *ул [Хәкимҗан абзый] хәзер урамда йөргән вакытта да ашыкмыйча, киерелеп, олы сымак булып, байлар шикеллерәк итеп йөри башлады инде.* К.Тинчурин

**Киерелә биру** Бернигә карамый киерелү; акрынлап тагын да киерелү

**Киерелә төшү** Берникадәр тагын да киерелү

**Киерелеп алу** Кыска вакыт эчендә киерелү. *Ул [Җәмилә] --- тәмләп киерелеп алгандыр да кабат җылы юрганы астына чумгандыр.* Идел

**Киерелеп бару** Киерелү хәлендә булу; киерелеп хәрәкәт итү. *Барасы юл еракмы, якын микән – Киерелеп бара тора ак җилкән.* Ф.Яхин

**Киерелеп китү** Кинәт киерелү. *Тамак туйгач, --- күкрәкләр киерелеп китте, авызлар ерылды.* Г.Мирһади

**Киерелеп кую** *к.* **киерелеп алу**. *Зур сандык өстенә җәелгән йомшак түшәккә яткан Габдулла рәхәтләнеп бер киерелеп куйды.* Ә.Фәйзи

**Киерелеп тору** Киерелү хәлендә булу; даими яки әледән-әле киерелү. *Карлыгач-Сылу --- айгырына килеп кул салды, киерелеп, тулып торган калын җилкәсендәге зур кара ялыннан сөеп иркәләде.* Г.Ибраһимов

**КИЕРЕНКЕ** *с.* 1) Артык зур көч куюны, энергия сарыф итүне сорый торган; зур көч, игътибар таләп итә торган. *Бары күз төбендәге бер нечкә җеп кенә йокысыз сәгатьләр турында сөйли дә, күзләре зур, авыр, киеренке эш алып баруы хакында әйтеп торалар.* Р.Мирхәйдәров. *Ауга чыккан арыслан, мисал өчен, ачулы булмый, киеренке эш белән мәшгуль кеше нинди хәлдә булса, ул да бары шуны гына кичерә.* З.Мифтахов

2) Берәр төрле хәлдән чыгу юлын таләп иткән, чишелеш кирәк булган, авыр, кискен. *Нәкъ шул чакны, төшнең иң киеренке җирендә генә --- Микәй ниндидер шартлау авазыннан сискәнеп уянып китте.* Р.Мөхәммәдиев. *[Әхәт:] Ватандашлар! Туганнар! Ил өчен көрәш бик киеренке хәлдә, корал заводлары көне-төне эшләсәләр дә, корал җитешми ---.* Р.Кадыйров

3) Табигый булмаган, уңайсызлык тудыра торган, җитди. *Өй эчендә озак кына киеренке тынлык сакланды.* Н.Фәттах. *Шау-шу, елау-сыктау басылып, киеренке тынлык урнаша.* З.Зәйнуллин

4) *куч.* Бик тар, аз (вакыт тур.). *Җитмәсә, иң хәлиткеч, иң киеренке вакытта гына танкист Зарифулла бригадасындагы тракторлар бер-бер артлы ватыла тора икән!* М.Шаһимәрданов

**КИЕРЕНКЕЛӘ́НҮ** *ф.* Киеренке хәлгә килү. *Әмма Кытай белән --- үзара мөнәсәбәтләр яңадан киеренкеләнгән.* Р.Фәхретдинов. *Г.Гыйльманов, үз кыйссасының сюжетын төзегәндә, әнә шул әдәби-эстетик һәм психологик закончалыкларны да бик яхшы белеп эш итә. Нәтиҗәдә әсәрнең сюжеты тагын да киеренкеләнә, кырыслана ---.* Ф.Урманче

**Киеренкеләнә бару** Торган саен киеренкеләнү. *Бүлмәдә ялга, дәвалануырга килгән бу ханымнар арасында --- торган саен мөнәсәбәтләр киеренкеләнә барды.* Д.Каюмова

**Киеренкеләнә башлау** Киеренкеләнергә тотыну

**Киеренкеләнә төшү** Берникадәр киеренкеләнү

**Киеренкеләнеп китү** Кинәт киеренкеләнү. *Аның [Биләр щәһәрлегенең] беренче тапкыр 1164 елда телгә алынуы һич тә очраклы түгел, нәкъ менә шул чакларда халыкара хәлләр киеренкеләнеп китә ---.* Р.Фәхретдинов. *Такташ иҗаты тирәсендә бәхәсләрнең демократиягә, фикер төрлелегенә омтылыш чорында киеренкеләнеп китүе табигый.* Т.Галиуллин

**Киеренкеләнеп тору** Даими яки әледән-әле киеренкеләнү; әле киеренкеләнү

**КИЕРЕНКЕЛЕК** *и.* Киеренке булу. *Очучы аэродромнан шасси аерылып самолёт күтәрелә башлаган чакта бер киеренке мизгел кичерсә, икенче тапкыр ул киеренкелек аны тәгәрмәчләр җиргә тиеп йөгереп киткән чакта билән ала икән.* Р.Мөхәммәдиев. *Олы юлга текәлеп караган күзләр арыдылар, киеренкелек артты ---.* Р.Фәтхрахманов. *Күңел, хис киеренкелеген тагын да көчәйтеп җибәрә торган тагын бер сәбәп бар: ул да булса малайның бик аз вакытка – нибары бер генә сәгатькә – өйгә кергәнлеге мәгълүм була.* Әдәбият

**КИЕРМӘ** *с.* Бик зур итеп киерелгән. *Киермә кашлы, Киртек башлы.* Табышмак

**КИЕРТҮ** *ф. к.* **кидерү**. *Күңелсезгә күлмәк киертмиләр.* Мәкаль. *[Гариф:] Бабай һәйбәт кеше безнең... Теләсәң, күлмәк-ыштан да киертә!* Ш.Камал

**Киертеп кую** Киерткән булу. *Кыз --- үз бармагындагы йөзеген алып егеткә киертеп куя.* Әкият

**Киертеп тору** Даими яки әледән-әле киертү; әле киертү

**КИЕРҮ** *ф.* 1) Нык итеп тарттыру, тарту, сузу (җәя керешен). *Кем ул*

*«бетерәм дип, башыгызны» Киереп тарткан уклы җәясен?* И.Иксанова

2) Нәрсәне дә булса тартып, сузып, кырыйларыннан, читләреннән кая да булса беркетеп кую. --- *суелган тәкәләрнең тиресен киереп чормага элгән көннәр иде*. М.Мәһдиев. --- *кызлар киергеләрене киереп, балтыр чүпрәкләр челтәрли, якалар чигә башлагач, Сөннәтче бабайларда да хәл үзгәрә --- иде.* Г.Исхакый

3) Кабару; кабарту. *Нигә дип ашыгыйм икән Киергән булып җилкән?* Ф.Яхин

4) Зур итеп, киң итеп ачу. *Язу диган галәмәт тамырлардагы канның агышын тизләтә, борын тишекләрен киереп, үпкәләргә һава тула*. Ф.Яруллин. *Форточкадан кергән һаваны азсынып, тәрәзәсен киереп ачып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

5) Ике якка җәю, тырпайту. *Көрәшчеләр кебек, терсәкләрен киереп, алпан-тилпән атлаган була [Илгизәр]*. Г.Бәширов. *Ил дигәндә ничә ирләр үзен Утка салып җилкә киерде!* Ф.Яхин

6) Алга чыгару, сузу, калкыту (күкрәкне, аяк һ.б.ш.). *Албуга күкрәген киерде, аягына басты*. Н.Фәттах. *Тургай аларның игътибарын туплау өчен күкрәген киерде ---*. Ф.Садриев. *Ул, күкрәген кабыргалары шыгырдарлык киереп, берничә тапкыр тирән тын алган иде дә, башы әйләнеп, чайкалып китте ---*. Идел

7) *күч.* Киеренке хәлгә китерү, киеренкеләндерү. *Доктор, акыл җебен нык киергән хәлдә, Яшәү тамырын капшый ---*. М.Җәлил

8) *күч.* Яхшы табигатьле, киң күңелле булу

9) *күч.* Вакытны ничек тә булса үткәрү, тарту, сузу. *Бу бер көн менлага бик озын тоелды, һәрничек булса да шәһәрдә киереп, базарга, кибетләргә чыгып, көч-бәла илән бу көнне уздырды.* М.Акъегет

**Киерә бару** Һаман, бер-бер артлы киерү

**Киерә тору** Әле, хәзерге вакытта киерү

**Киерә төшү** Аз гына, берникадәр киерү

**Киереп йөрү** Гел, һәрвакыт киерү. *[Габдулла] камалы бүрек кидем, инде камалы тун гына киясе калды, дип, пуф-пуф итеп, корсагын киереп йөрде.* Ә.Фәйзи. *Әгәр дә крахмальный сорочка, ак перчатка һәм алмаз йөзекләр киеп, кулга бастон трость таянып, белмәгән нәрсәне беләмен диеп күкрәк киереп йөрү белән образованный булучылык табылса, бәлки Хәсәнша байбәтчәне образованный диеп әйтергә ярар иде.* Ш.Мөхәммәдев

**Киереп кую** Тиз арада яки алдан ук киерү. *Без чи тиреләрне киртәгә элеп киптергәндә киереп куяр өчен чөй очлый идек.* М.Гафури

**Киереп тору** Даими яки әледән-әле киерү процессында булу. *[Шәяхмәт:] – Я, син нәрсә, шамакай шикелле гурлаңны киереп торасың, авызыңа төкерим! – дип, Нургалинең юеш бугазыннан учлап тотты да төз лапаска таба этеп җибәрде.* М.Мәһдиев

**КИҖЕ** *и. һинд* 1) Буялган нечкә мамык җеп (элек Урта Азиядән кителгән)

2) *иск.* Кулдан эшкәртелгән тупас ефәк җеп (элек Кавказдан һәм Урта Азиядән алынган)

**КИҖЕЛӘП** *рәв.* Киҗе катып, киҗе аралаштырып. *Киҗеләп киндер сугу. Киҗеләп суккан сөлге*

**КИҖЕЛЕ** *с.* Киҗе кушып, киҗе катнаштырып сугылган. *Зур киҗеле кызыл чаршауларның берсен мич алды яныннан каршы стенага тартып, өйне түрдән ишеккә таба аркылы бүлделәр.* Г.Ибраһимов. *Ул арада өйдән җиңгәчәй белән Нигъмәтулла абзыкай киҗеле ашьяулыкка төргән ике зур төенчек күтәреп чыктылар.* Ә.Еники

**КИҖЕ-МАМЫК** *җый. и.* **1.** Читтән килгән мамык җепләр. *Нурый карт --- төпчек кызының тегү-чигүләре, киндерләре өчен кирәк җепне, җитенне, киҗе-мамыкны, буяуны, дебетне алып бирә торды.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Киҗе белән мамыктан тукылган. *Киҗе-мамык тукымаларны мөмкин кадәр яңарту өчен, серкә суы кулланыла.* Л.Мөхәммәт. *Чиновник борылыбрак утырды, һәм Әкрәм карыйга аның --- керле киҗе-мамык якасы белән кырылып-искереп беткән кара галстугы аермачык күренде.* М.Галәү

**КИЗ** *и.* Җәя керешендә ук койрыгын кую өчен махсус киртек

**КИЗӘК** I *и.* Ягулык буларак кулланыла торган кипкән сыер тизәге яки махсус калыпка салып кирпеч формасында киптерелгән сыер тизәге. --- *учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты.* Ә.Еники. *Бервакытны без, кызлар, далада капчык тутырып кизәк җыйганнан соң, авылга кайтышлый, мөгаллим нишли икән дип, шул калкулыкка күтәрелдек.* Ч.Айтматов. *«Аллага шөкер, кыш үтеп бара, көннәр җылынганчы көздән әзерләнгән кизәк тә җитәр», – дип уйлап куйды ул.* Ватаным Татарстан

**КИЗӘК** II *и. иск.* Чират, нәүбәт. *Шул вакытта Норадын әйтте: --- Әйт, Туктамыш! Беренче кизәктә (нәүбәттә) син атасыңмы, минме? Әйдә, син ат! Беренче кизәк синеке.* Дастан. *Яуда кизәк кылу – мәнем хокукымда.* В.Имамов

**КИЗӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Селтәнеп сугу өчен кулны күтәрү. *Кизәнеп сугып калыем, Йорт-казнасын алыем.* Дастан. *Болар нәрсәгәдер шаулашалар, хәлсез кулларын кизәнеп, бер-берен таптап, Гәрәйнең өстенә киләләр...* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Нәрсә белән дә булса янау, куркыту. *Атом белән кизәнү*

**2. кизәнеп** *рәв. мәгъ.* Каерылып, киерелеп, бар көчкә. *Шиһап агай өймәкәй тулы бидрәне тартып чыгарды да, аны тагы да югарырак күтәреп, яман кизәнеп, базга ыргытты.* М.Кәрим. *Фельдшер, кансыз бәндә, аның саен кизәнеп суга.* М.Мәһдиев. *Бар көченә бер кизәнеп сыдырды Кәрам атына.* Р.Харис

**Кизәнә бару** Торган саен кизәнү

**Кизәнә башлау** Кизәнергә тотыну. *Үзе һаман нидер акырына, таягы белән әле бер якка, әле атка, әле картка кизәнә башлый.* Г.Ибраһимов

**Кизәнә төшү** Берникадәр күләмдә тагын да кизәнү

**Кизәнеп алу** Кыска гына вакытка кизәнү. *Минем каршыга басып, бер кизәнеп алды хәтта, әмма ничектер сукмый калды...* Ә.Фазылҗанов. *Апа кеше*

*башын чайкый, куллары белән кизәнеп ала.* Идел

**Кизәнеп җибәрү** Кинәт кизәнү; кизәнгән булу. *Ул [робот] ташның авырлыгын чамалады да кизәнеп җибәрде.* А.Азимов

**Кизәнеп кую** Кисәк кенә кизәнү

**Кизәнеп тору** Даими яки әледән-әле кизәнү; әле кизәнү. *--- фашистларның башына утын тумраны белән суккандай беркөзлексез йодырыгы белән кизәнеп* торды. Р.Мөхәммәдиев

**Кизәнеп яту** Әле кизәнү. *Карыйм, пычак белән кизәнеп ята бу миңа.* Сөембикә

**КИЗИЛ** *и. бот. к.* **кызыл** II. *Җырлаучы төркемнең читенәрәк баскан бер кызның «кызыл» сүзен «кизил» дип җырлавы һәм, шуны әйткәндә, ерак түгел рәшәткә буенда үскән кизил агачы җимешләренә күз кырые белән генә карап алуы да тыңларга комачауламый ---.* С.Баттал

**КИЗЛӘ́Ү** *и.* Чишмә. *Кизләү кипсә, елга да кибә.* Мәкаль. *Тутасы кайта да сеңлесенә әйтә: – Бик тә кизләү суын эчәсем килә.* Әкият. *Кизләүгә суга төшкәндә, әтисе Нурҗан авыр күтәрми микән дип карап торыр иде.* А.Юнысова

**КИЗҮ** I *с.* **1.** *иск.* Дежурда, кизүдә торучы, дежур. *Кизү врач: «Сөйләшмәскә, сөйләндермәскә!» – дип, каткат кисәтсә дә, мин аның ут атып торган баш очына иелдем.* Г.Кашапов. *Хәзер инде ул [Галия] шәфкать туташларының, кизү табибларның күз карашыннан ук хәленең ничеклеген аңларга өйрәнеп бетте.* Д.Булатова. *– Менә сиңа кучтәнәч килгән, – ак яулыклы мөлаем апа – кизү санитардыр инде – сәке янындагы бәләкәй өстәлгә пакет куеп китте.* А.Юнысова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Дежурда, кизүдә торучы кеше. *[Рәфис] Байтак кына пошыргаланганнан соң, кизүгә шалтыратасы итте ---.* Б.Ислам. *Галиулла кизү, себеркесен күтәреп, тәһарәтханәгә йөгерде.* К.Тинчурин

2) Кыек килешләрдә: дежурлык, дежур тору. *Бермәлне Ләйлә төнге кизүдән соң ял итеп ята иде.* М.Кәбиров

**КИЗҮ** II *и.* 1) *сөйл.* Нинди дә булса авыруның нык таралуы; *русчасы:* **эпидемия.** *[Минһаҗ: Чебиләр] тәгәриләр диген, кизүдәнме, үләттәнме, әллә ачлыктанмы?* К.Тинчурин. *Русиядә дуңгыз кизүеннән 4 кеше үлгән ---. Табиблар, кизүдән саклануның иң ышанычлы юлы – вакцина, ди.* Шәһри Казан

2) Чираттагы авырту, өянәк. *--- «нервы расстроены» дигән докторларны һәр авыруны кизүдән диюче әбиләр белән тиңләштерә идем.* Г.Тукай

**КИЗУ́ КӨТҮ** *ф. иск.* Кизү булу; кизүлек эшен башкару, үтәү. *Мәдрәсәдә һәр көн бер шәкерт кизү көтә.* М.Гафури

**КИЗҮЛЕК** *и.* Кизүдә тору хезмәте, дежурлык. *Авыру янында шәфкать туташы, фельдшер --- өзлексез кизүлек итә.* Р.Әмирхан

**КИЗУ́ ТОРУ** *ф. к.* **кизү көтү**. *Койма өстендәге каравыл өйләрендә, манараларда, капка төпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде.* Н.Фәттах. *Икенче көнне кергәндә, Таһир әниләр телен өйрәнгән иде инде. – Төне буе утны сүндермәде, – диде кизү торган шәфкать туташы ---.* М.Кәбиров. *Үзенең балаларын да булышырга өндәде: табиблар булган улы, кызы һәм килене Габдрахман ага янында төнлә кизү тордылар ---.* А.Шамов

**КИЙ** *и. фр.* Бильярд таягы. *Заһид бит аңа бары бер генә тапкыр кийны тоттырды ---.* А.Расих. *Сөяк кебек ялтырап торган шома кийны буйдан-буйга гына түгел, очындагы бер тиен зурлыгындагы күненә кадәр мул итеп акбурлыйлар.* М.Хәсәнов

**КИКЕРЕК** *и.* Ашказаныннан авыз аркылы чыга торган газ (физиологик нормаль булмаган күренеш). *Әбелмәлих кикереп җибәрде. Бу кикерек белән мул гәүдәсе кәнәфигә тәмам тулышты.* М.Әмирханов

**КИКЕРҮ** *ф.* Ашказаныннан авыз аркылы газ чыгару. *Исерек тагын кикерә-кикерә җавап кайтарды: – Әйе, аны да алып кайттым, әбисе сагынгандыр, – диде.* Г.Галиев. *Иске татар шарт итеп кикерә дә: «Әлхәмделиллә!» – дип кычкырган була; әллә бичара мигъдәсе бозыклыкны бик зур нигъмәт дип беләме?* Г.Тукай

**КИКРИК** *и.* 1) Кайбер кошларның баш түбәләрендә була торган итләч үсенте. *Әтәчнең күрке – кикригә дә койрыгы.* Әйтем. *Бары тик олы кикрикле голланд әтәче генә --- кукраеп тавыш сала.* Ф.Яхин. *Чын әтәч менә нинди була икән ул! ---. Башын кыңгыр салганда, ут кызыл кикриге һәм алкалары селкенеп-тирбәлеп куя.* Р.Низамиев

2) *күч.* Тау сырты турында. *[Кавказда] томанны тишеп югарыга сузылган тау кикрикләрендә --- күзләрне камаштырып ак кар ята.* Г.Ахунов

3) *күч.* Кикриккә охшаган, формасы белән шуны хәтерләткән нәрсә. *Бүген... Ходаның кодрәте киң! – вак яңгыр сибәли, ыжгырып берсе өстенә берсе менеп өелгән ак кикрикләр шиңә, басыла.* А.Гыйләҗев

◊ **Кикриген кисү** *к.* **кикриген шиңдерү**. *Шундый [мактанчык] кешене очрата калса, шагыйрьнең күзендә саркастик чаткы пәйда була. Белеп тор, ул кешенең кикриген кисми калмый...* И.Рәмиев. **Кикриген төшерү** *к.* **кикриген шиңдерү**. *[Ата:] Кая, үзем, үзем салыйм әле сыртына шул бөҗырны, борынын бик чөймәсен, кикриген төшерим әле, – дип, Нурәхмәткә күз кысты.* Д.Каюмова. **Кикриген шиңдерү** 1) Кемнең яки нәрсәнең көчен, дәртен киметү; илһамын сүндерү. *--- Илһам дигән егетебез кикриген шиңдерергә – чынлыкны танырга мәҗбүр була ---.* Р.Кәрами. *--- «Әткәйгә әйтәм!» Менә шушы ике сүз шиңдерә дә куя иде әтәчләнеп сугышып яки телләшеп яткан кешенең кикриген.* Ш.Җиһангирова; 2) Тәнкыйтьләп яки куркытып, кемнең дә булса тәкәбберләнүен бетерү, масаюын киметү. *– Мин Сафатдин абзыйның кикриген шиңдерергә уйлаган идем, ә ул мине «бетереп» үк ташлады, – дип сүзен очлады Рәисә.* М.Шаһимәрданов. *--- [Мәхмүт Хөсәен] «Шым бул! Каршыңда унбиш фашист танкын бугазыннан чәйнәп өзгән фронтовик басып тора!» – дип, әлеге «иптәш-кардәш»нең бик тиз кикриген шиңдергән иде.* Шәһри Казан. **Кикрик катыру** Масаю, тәкәбберләнү. *Ә кукраерга дигәндә бала-чагасына кадәр кикриген*

*катырырга тора.* М.Кәрим. **Кикрик кызару** 1) Эшләр яхшы барып, зур канәгатьлек кичерү; риза булып яшәү. *[Сәйфи] колхоз димәде, колхоз өчен янып-көеп йөрмәде, үз кикриге кызаргач, аңа шул җитте.* Г.Бәширов; 2) Тәмам исерү. **Кикрик шиңү** 1) Кемнең яки нәрсәнең көче, дәрте кимү; илһамы сүнү. *Кәлимулла карт өчен хак сорарга килгән Гайнанның кикриге тиз шиңде.* Г.Гыйльманов. *Кикриге бик тиз шиңгән Сергеевның калтыранулы тавышы бу юлы бик мескенләнеп чыкты* ---. Р.Вәли; 2) Кемнең дә булса тәнкыйть яки куркыту аркасында тәкәбберләнүе бетү, масаюы кимү. *Сизеп торам, Айдар авыз ачарга да куркып калтырана, Җиһангирның да кикриге шиңгән.* Ф.Яхин.– *Кикрик шиңде алай, Каюм әфәнде, – диде Әхсән Байчурин.* И.Нуруллин

**КИКРИКҮК** *иярт.* Әтәч кычкырган тавышны белдерә. *Читәндә Әтәч: – Мин – биек, кикрикүк! – дип кычкырып утыра икән* ---. Ф.Яхин

**КИЛӘП** *и.* 1) Орчыктан махсус агачка чорнап, чуалмасын өчен бәйләм итеп уралган җеп. --- *Киләпкә салырга тотынды ул Кара йомгактагы уйларын.* Ә.Баюсов

2) Җеп үлчәү берәмлеге, өч метр чамасы. *Бер киләп җеп*

◊ **Киләбен чуалту** Кемнең дә булса уй-фикерен чуалту; кемнең дә булса уйфикере чуалу. *Бу караш Сөләйманның киләбен тагын да чуалтты.* К.Тинчурин. **Киләп сару** 1) Киләпкә җеп урау. *Авыл читендәге Гөлҗамал йон эрли, Киләп сара Гайфиләргә.* Н.Баян; 2) Ары-бире сугылып эшле-эшсез йөрү. *[Сугышчылар] Шулай киләп сарып, үз башларына маҗаралар эзләп, унбиш чакрымны унбиш көн уздылар.* Казан утлары. **Киләп сарып йөрү** *к.* **киләп сару** (*2 мәгъ.*). *Хәер, фатир белән бакча арасында киләп сарып йөрүе җәй саен дәвам итә аның [Фәритнең].* Ватаным Татарстан

**КИЛӘ́П АГАЧЫ** *и.* Җеп киләпләү өчен, бер башына ыргак, икенче башына аркылы таяк беркетеп эшләнгән, ярты метр чамасы озынлыгындагы махсус агач

**КИЛӘПЛӘ́Ү** *ф.* Җепне орчыктан киләпкә чорнап, чуалмасын өчен бәйләм итеп урау, киләп ясау

**Киләпләп алу** Берникадәр генә киләпләү

**Киләпләп бетерү** Барысын да киләпләү; киләпләүне тәмамлау

**Киләпләп йөрү** Киләпләү хәлендә булу. *Ә менә юкка урам киләпләп йөрүләрне, хәмер, тәмәке ише нәрсәләрне кабул итмәде [Рөстәм]* ---. Безнең гәҗит

**Киләпләп тору** Даими яки әледәнәле киләпләү; киләпләү хәлендә тору

**Киләпләп яту** Әле, хәзер киләпләү

**Киләпли бирү** Бернигә дә карамастан киләпләү

**Киләпли тору** Әлегә киләпләү

**КИЛӘСЕ** *с.* 1) Киләчәк, булачак (вакыт тур.). *Киләсе җәй, әгәр сугыш дәвам итсә, иң авыры булыр... Сугыш бетсә дә, алдагы җәй бик авыр булыр...* М.Мәһдиев. *Насыйп булса, тагы бер-ике имән багана алып, киләсе көзгә капканы яңадан эшләтергә --- исәплим.* Г.Ибраһимов. *Киләсе ел кайсыгыз гына булса да, һичкемнән сорамый, минем урынга ятсын!* Ш.Камал

2) Алда булачак (билгеле бер урын тур.). *--- карт поездга соңга кала һәм, киләсе станциядә куып җитәргә исәпләп, ак айгырын куа башлый.* Д.Заһидуллина

**КИЛӘЧӘК** *с.* **1.** 1) Киләсе, алга таба буласы; хәзергедән соң буласы (көннәр, айлар, еллар һ.б.ш.). *Нинди бәхетле! Мин үземнең киләчәк тормышымны күрәм.* Г.Кутуй. *Муса Җәлил --- изге теләкләрен, рухи-фәлсәфи эзләнүләрен нечкә тоемлы нәфис шигъри әсәрләрендә халкына, киләчәк буыннарга васыять итеп калдырган, киләчәк һәм үткән гасырларның бөек шагыйре.* Т.Галиуллин

2) Алда, моннан соң яшәячәк (кеше, буын һ.б.ш.). *Киләчәк буыннар өчен искиткәлә яхшы бер истәлек булыр ул [шәҗәрә]!* Ш.Мостафин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса алдагы тормышы, язмышы. *Газиз җирем, синең халкың яши Бәхет теләп киләчәгенә.* Р.Зәйнетдин. *Киләчәккә этәрердәй бер дәртле, куәтле рухта җырыбыз юк, гел төшенкелек, өметсезлек кенә анда чагыла.* М.Миначев. *Киләчәгең тагы да матур булсын.* В.Хәйдәрова

2) Киләсе, алда була торган (вакыт тур.). *Ялваралар алар Киләчәккә: «Тылсым куәсе бир халкыма: Суга төшкәч – суда батмасачы, Янмасачы – кергәч ялкынга!..»* Зөлфәт

3) *күч.* Алдагы көннәрдә булачак уңышлар; перспектива, карьера. *Киләчәгең алдан күренеп торган Укытучы булып уйный идең бит.* Р.Зәйнетдин

**КИЛӘЧӘ́К ЗАМАН** *и. лингв.* Сөйләнеп торган вакыттан соң булачак эш-хәлне, хәрәкәтне белдерә торган фигыль категориясе. *Тартык авазларга беткән фигыльнең билгеле киләчәк заманы*

**КИЛӘЧӘКЛЕ** *с.* 1) Киләчәге якты һәм матур булган. *Бер рәхәт вә тәмлене сөюче Ялкауны, вак кына ләззәтләр өчен әллә никадәр киләчәкле эшләрне бер якка куючыны күргәндә: «Бичара кеше! ---» – диясем килә.* Г.Тукай. *Гел кагылып, кимсетелеп һаман Яшәгәне өчен тилмереп, Җәндай күргән газиз халкымны син Киләчәкле итә күр берүк!* Зөлфәт. *Үткәне бар, бүгене бар Киләчәкле илемнең.* Казан утлары

2) *күч.* Өметле, сәләтле, перспективалы. *Киләчәкле яшь шагыйрь.* М.Гафури

**КИЛБӘТ** *и. гар.* Кыяфәт, буй-сын; тышкы күренеш. *Килбәте нинди, күләгәсе шундый.* Мәкаль. *Килбәте булгач кабахәт, уйладым: иблистер ул; Бу сасы ис, кем белә, шуннан чәчелгән истер ул.* Г.Тукай

**КИЛБӘТЛӘНЕП** *рәв. сир.* Масаеп, һаваланып. *[Яшь байлар] һәммәсе, үзалдына бертөрле эрелек белән, ложаларда яисә алгы рәт креслоларда килбәтләнеп утыралар.* Ш.Камал

**КИЛБӘТЛЕ** *с.* Килеш-килбәте бик матур булган; күркәм кыяфәтле; килешле. *Килбәтле кыз килен булгач күренер.* Мәкаль. *Байлар икәүсе дә – гәүдәгә бертигез, озын һәм пар аргамак кебек килбәтле, таза кешеләр.* М.Гафури. *Шунда торган Җантимер --- Туктамышның каршында Киңәше киң, килбәтле, Сүзе үткән би иде ---.* Дастан

**КИЛБӘТЛЕЛЕК** *и.* Килбәтле булу

**КИЛБӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Килешкилбәте ямьсез булган; кыяфәтсез, ки-

лешсез. *Больница киеме кешене гадәттә авыру итеп кенә түгел, килбәтсез итеп тә күрсәтә.* Ә.Еники. *Мәрсинә башта килбәтсез гәүдәсе белән балкып куйды, җәһәт кенә урыныннан сикереп торды.* Ә.Дусайлы. *Шайтан төкереге белән йөгертелгән пыяладагы килбәтсез чагылышыңа карап йөрәгеңне әрнетүдән ни мәгънә?!* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Дорфа, тупас, йогышсыз. *Килде дә ямьсез, килбәтсез урыннарны төзәтте. Тау кисәр эшлекле ул – тотынса, дөнья төзәтер.* Г.Тукай. *– Өйлән, – диде, – әмма кызны бик ямьсез дип әйтәләр, сөйләр сүзе килбәтсез!* Ф.Яхин

**2.** *кис. функ.* Бик нык, артык, гаять. *Һашимов, постка куелган кирәксез сакчыдай, килбәтсез зур аяклары белән идәнгә шап-шоп басып, әрле-бирле йөрде.* А.Алиш

**КИЛБӘТСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Килбәтсез булып китү, килбәтсезгә әйләнү; ямьсезләнү, кыяфәтсезләнү

**Килбәтсезләнә бару** Торган саен тагын да ныграк килбәтсезләнү

**Килбәтсезләнә төшү** Билгеле бер күләмдә килбәтсезләнү

**Килбәтсезләнеп алу** Аз гына вакытка килбәтсезләнү

**Килбәтсезләнеп бетү** Бик нык, тәмам килбәтсезләнү

**КИЛГӘ́Н-КИТКӘН** *с.* **1.** Килгәннәр һәм киткәннәр, килүче һәм китүчеләр, килеп-китеп йөрүчеләр. --- *[Археологлар] аның [Сөембикә манарасының] тимер юл вокзалы янында килгәнкиткән кешене сәламлап торуын «дәлилләп», җәмәгатьчелекне дә шуңа ышандырачаклар.* Идел

**2.** *җый. и.* Килгән һәм киткән кешеләр, килүче һәм китүчеләр, килеп-китеп йөрүче кешеләр. *[Казаклар] --- килгән-киткәнгә, кергән-чыкканга ара-тирә күз салып, төрле җирдә нәрсә хакындадыр акрын, сабыр тавыш белән сөйләшәләр.* Г.Ибраһимов. *[Галиулла:] Миндә әндери казнасы юк, тәккә, килгән-киткәнгә әрәм итәргә.* З.Зәйнуллин. *Килгән-киткән сезгә керде көндезләрдә-төннәрдә.* Р.Харис

**КИЛДӘ́-КИТТЕ** *с.* **1.** 1) *к.* **килделе-киттеле**. *Аларның [асрауларның] кайсы аңгыра, кайсы боек, кайсы «килде-китте»рәк булалар.* М.Гали. *Килде-китте көлке сүз сөйләүчеләрнең үзәк телевидениене басып алуы кайберәүләрдә ачыктан-ачык ризасызлык тудыра башлады инде.* Ватаным Татарстан

2) Начар, сыйфатсыз, аннан-моннан гына эшләнгән. *Ишек төбенә яки башка шундый килде-китте җиргә түгел, ә үзе белән бер түшәккә салды ул [Галимҗан] этне.* М.Кәбиров. *Нәтиҗәдә, Татарстан булгач, ниһаять, исем шәрифләрем дөрес язылган паспорт алам дип җан аткан кешенең кулына яңадан килде-китте документ тоттырдылар.* Р.Әмирхан

3) Дәрәҗәсе булмаган, ихтирамга, хөрмәткә лаек түгел. *Кунагы да бит аның килде-китте кеше түгел, бик хөрмәтле, бик газиз җан иясе.* Г.Минский

**2.** *и. мәгъ* 1) Ихтирамга, хөрмәткә лаек булмаган, вак кеше. *Бит әле миңа бер генә егетнең дә чын-чынлап гашыйк булганы юк! Кайбер килде-киттеләрне исәпләмәгәндә.* Н.Фәттах

2) Төптән уйланылмаган, мәгънәсез, ятышсыз сүзләр һ.б.ш. *Сеңелем килде-киттене сөйләргә яратканга, тәки алар белән гәпләшүендә була, үзе турында да, минем турыда да тезә генә.* Ш.Алпар

**3.** *рәв. мәгъ.* Начар, сыйфатсыз итеп. *Килде-китте эшләү*

**КИЛДЕЛЕ́-КИТТЕЛЕ** *с.* **1.** 1) Уйланылмаган, мәгънәсез, ятышсыз (сүзләр һ.б.ш.). *Илдар Илдарович (бик дулкынланып): Нигә сез миңа мондый килделе-киттеле сораулар бирәсез әле?* С.Гаффарова. *Шуңа ул [ЖКХ начальнигы] башыннан андый килделе-киттеле уйларны куып, фикерен йорт хакына туплады.* Казан утлары

2) Принципсыз, әле алай, әле болай сөйли, кылана торган кеше турында. *Туңгак алып аңардагы бу үзгәрешкә ышанырга да, ышанмаска да белмәде: Ябалак карт элегрәк бер дә андый килделе-киттеле түгел иде.* Н.Фәттах. *Менә Хөсәеннең олы кызы Фәхерниса ябык кына, зәһәр генә, килделе-киттеле бер хатын. Надан, вакчыл, гайбәтче, хорафатчыл.* И.Нуруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Мәгънәсез, ятышсыз итеп. *Җәмилә бу вакытта җан дустына мең рәхмәтле иде. Әмма Җантимернең килделе-киттеле сөйләве генә бәгырен кисте.* Ф.Яхин

**КИЛЕ** *и.* Эре бөртекле әйберләрне төеп ваклау өчен ясалган махсус савыт. *Килегә салып су төймиләр.* Мәкаль. *Сине ярма кебек Салып төйсәләр дә килегә, Барыбер син җылытырга тиеш Мичкә яккан җылы өйне дә.* М.Әгъләмов. *Маһруй карчык кечкенә җиз килегә кипкән үләннәр салып төя башлады, үзе мыгыр-мыгыр нидер укына.* Р.Батулла

**КИЛЕМ** *и. к.* **килер**

**КИЛЕМ-КИТЕМ** *җый. и.* 1) Килүчеләр һәм китүчеләр; кунак. *Тукай ялгызлыкны ярatканлыктан, Камилләр өендә тору аның табигатенә авыр булгандыр, чөнки алардагы килем-китем, чыр-чу, бала-чага, бигрәк тә хатын-кыз Тукайның изелүенә сәбәп була.* Ш.Каюмов. *Бу арада килем-китем күп булды.* Ф.Сафиуллина

2) Туу һәм үлү турында. *Мәңгелеккә килмәгән: җиргә килем-китем бар.* Г.Муллабаева

**КИЛЕМЛЕ** *с. диал. к.* **килерле**. *Балыкчылык кәсебенең иң газаплы һәм шуның белән бергә иң килемле дә булып саналган җылым тарту эше --- «Кызыл балыкчы» колхозында да оештырылачак.* Г.Минский

**КИЛЕН** *и.* 1) Улының яки энесенең хатыны. *Көзге катык, көмеш кашык – кызым белән киявемә; язгы катык, ярык кашык – улым белән киленемә.* Мәкаль. *[Мәхүп әби:] Дөресен әйтим, киленне башта яратмаган идем, хәзер күз иярләште. Нишлисең, урыс та бит, ахирәт, ата баласы...* А.Алиш. *Ат булгач, бер йөреп кайтыйм дип, әнкәй дә бармакчы иде, Сафа бабайның килене бәбәйләргә тора, шуңа булышырга кеше кирәк дип чакырдылар ---.* Г.Ибраһимов

2) Әле яңа гына кияүгә чыккан яшь хатын. *Таңда су алганда, яшь* киленнәр, *Туктап, таң җилләрен тыңларлар.* Һ.Такташ. *Яшь киленнәр утырып җеп эрлиләр ---.* С.Хәким. *Шул туфракта ата-бабаларының сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минҗиһан корткалар, шунда аның күз*

*алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр* ---. Ә.Еники

3) Өлкән буын кешеләренең яшь хатыннарга мөрәҗәгать итү сүзе. – *Ә, синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер! – диде карт, тукталып. Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле* ---. Ә.Еники

**КИЛЕНДӘШ** *и.* Ике туган ир-атның хатыннары. *Аналы-кызлы килендәшләр булгач, бергә яшәгән ике гаиләдә искиткеч татулык инде.* З.Зәйнуллин

**КИЛЕН-КҮНЧЕК** *җый. и.* Киленнәр, яшь киленнәр. *Яшь киленнең күз яше кибеп җитәр-җитмәс, киленкүнчек [Нәфисәне] бик тырышып кияүгә димли башлады.* Г.Бәширов

**КИЛЕНЛЕК** *и.* Килен булу. *[Земфира ханым:] Әти-әнисе төшеп калганнардан булмаган, уртача гына гаиләдән авыл кызы кирәк иде киленлеккә* ---. Шәһри Казан

**КИЛЕ́Н ТӨШЕРҮ** *ф. этн.* Кәләшне кияү йортына алып кайту. *[Гыйлаҗи:]* --- *җәй көне, печәнгә төшәр алдыннан, яшь тәкәләр өлгергәч, авылда кыз озату, килен төшерү көннәрендә [кунакка чакырам].* Г.Ибраһимов

**КИЛЕНЧӘК** *и.* Яшь килен. *Казакъның гадәте буенча, хәзер инде җегет ата-аналарыннан, өлкәннәрдән яшеренрәк, киленчәкләр аркылы, кызның куенында булырга хак алган* ---. Г.Ибраһимов

**КИЛЕР** *и.* 1) Табыш, файда. *Ризван да бит андый-мондый кеше түгел. Белеме дисәң – белемле, килере дисәң – килерле дигәндәй, эш кешесе.* Г.Минский

2) Акча, хезмәт хакы. *Эшең әйбәт, килерең бар.* А.Әхмәт

◊ **Килер җир** Акча табу мөмкинлеге. **Килер урын** *к.* **килер җир**

**КИЛЕРЛЕ** *с.* Килере булган, табышлы, төшемле, күп түләнә торган (эш һ.б.ш.)

**КИЛЕШ** I *и. Килү* фигыленнән ясалган исем. *Синең, яшьнәп, Дөньяга килешең иде. Минем, арып, Язмыш белән килешү иде...* Р.Фәйзуллин. *Министр белән очрашудан менә шундый каршылыклы уйларга бирелеп кайтып килешем иде.* А.Гәрәева. *Күңел түрләреңдә – илһам көче, Көйләр язып атлап килешең.* Р.Баһаветдинов

**КИЛЕШ** II *и.* Тышкы күренеш, кыяфәт. *Килешең, килбәтең, Биш гөрәнкә бишмәтең.* Н.Исәнбәт

◊ **Килешен китерү** Нәрсәне дә булса килештерү, формасын китерү, билгеле бер кыяфәткә кертү. *Егет тә килешен китергән: тар балаклы яшел чалбар киеп җибәргән.* М.Хәсәнов

**КИЛЕШ** III *бәйл.* Үзеннән алда килгән сүз белән бергә кемнең яки нәрсәнең нинди хәлдә, нинди рәвештә булуын аңлата. *[Сәрвәр] Кинәт, куркып, сүзсез катып калды, Үлгән килеш күреп танышын.* М.Җәлил. *Тик, Мич башында тун киеп яткан килеш, Әүхәди: – Ай-яй, малай, салкын!..* Һ.Такташ. *Баскан килеш эзлиләр, Яткан килеш эзлиләр.* Мөҗәһит

**КИЛЕШ** IV *и. лингв.* Татар телендә исемнәр, алмашлыклар, исем мәгънәсендә торган сыйфат, исем фигыль һәм сыйфат фигыль белән кулланылып, җөмләдә исемнәрнең башка җөмлә кисәкләренә бәйләнүен күрсәтә торган грамматик категория. *Килеш – сүз категорияләренең берсе.* Татар теле

**КИЛЕШЕНҮ** *ф.* Үзара сөйләшеп килешү, уртак бер фикергә килү. *Дүрт качакның башлыгы Чәнси иде. Теге якта ук килешенгәнчә, ирләрнең икесе дә берсүзсез аңа буйсынырга тиешләр.* Н.Фәттах. *Шулай итеп алдан килешенгән отпуск вакытым «чәлпәрәмә килде» – бер айга кичектерүләрен сорарга туры килде.* Р.Гаязетдин

**Килешенеп тору** Даими яки әледәнәле килешенү хәлендә булу

**КИЛЕШ-КИЛБӘТ** *җый. и. к.* **килбәт**. *Аһ, аның килеш-килбәте – Өлгереп җиткән җиләк. Бу җиләкне кабып йотмый Ничек түзәргә кирәк!* Ф.Яруллин. *Аның [Хамисәнең] йөзенә, гәүдәсенә, бөтен килеш-килбәтенә, атлап йөрүләренә кадәр, чын хатын-кыз гүзәллеге иңде.* Ә.Дусайлы

**КИЛЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) Килешеп торган, матур, җыйнак (кием һ.б.ш.). *Аның [Бикчәнтәевнең] өстендә гәүдәсенә сыланып торган, хаки төсендәге бик килешле өр-яңа китель.* И.Салахов. *[Сылуның] Кигән күлмәге дә бик килешле.* А.Хәйретдинова

2) Фикергә, сүз сөрешенә яки тирәяк мохиткә яраклы; урынлы (сүз һ.б.ш.). *Кәли дә* --- *бирәр сүз әйтергә уйлады, ләкин килешле сүз таба алмады булса кирәк, яңадан әкрен генә җыргә тезләнде.* Г.Гобәй

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Килешеп тора торган, матур итеп. *Өр-яңа ук булмаса да, шактый төзек тоелган йорт-җир гаҗәп күркәм һәм килешле күренә.* Г.Әдһәм

2) Оста, төзек итеп, игътибарны җәлеп итәрлек итеп (сөйләү һ.б.ш. тур.). *[Зыя] үзләрендә бала караучы булып торган Бәдри әбинең шома вә килешле рәвештә сөйләгән әкиятләрен бала чагында бик яратып тыңлый.* Г.Ибраһимов. *[Сүзлектә] «Комильфотность» төшенчәсе турында: «әдәп; мәҗлес әдәпләрен кыла белү, үзен һәр мәҗлестә кирәгенчә килешле рәвештә тота белү [диелә]».* Казан утлары

3) Әдәпле, тәртипле, күркәм. *Килешле итеп кенә, ул Өстәлгә ямыйямый: «Без сиңа иптәш түгел! – ди. – Абайлап сөйләш, абый». Җилкенеп җәйлы гына бу, Килешле генә дулап: «Без түгел, сиңа иптәш, – ди, – Тамбов бүресе, дурак!..».* Х.Туфан. *Тирә-якта* --- *килешле һәм акыллы уйнавы белән минем Алмачуарга тиңдәш булырлык бер колын күренми дә, ишетелми дә.* Г.Ибраһимов

**КИЛЕШЛИ** *рәв.* Килү уңаенда, юл уңаенда. --- *кыш көне мәктәптән кайтып килешли, сүздән сүз чыгып, бәхәсләшеп киттек.* Т.Миңнуллин. *Савыгырмын сыман җәйләремнән Көзләремә таба килешли* ---. Ф.Яхин. *Күңеле кителгән Хәсби түти кайтып килешли үк урамда туктый-туктый зарлана икән.* З.Зәйнуллин

**КИЛЕШСЕЗ** *с.* **1.** 1) Килешле булмаган, ямьсез, матур түгел. *Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу*! Г.Тукай. --- *ул [көймә], килешсез кара бер җанвар кебек, дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп китте.* Ш.Камал

2) Әдәпсез, тәртипсез, начар. *Юлларда килешсез тәртипсезлек хөкем сөрә.* Ф.Әмирхан. *Гүя әллә нинди бик килешсез бер эш, төзәтүгә мөмкин булмаган бер хатасы барлык зиһененә*

*килеп, кинәт борчыла башлады [Гариф].* Ш.Камал. *[Сатучы:] Килешсез сүзләрем өчен мин белексезне гафу әйләңез.* Н.Фәттах

**2.** *рәв. мәгъ.* Начар, ямьсез, дорфа итеп. *Гыйльмулла килешсез генә көлеп җибәрде.* Ш.Камал. *Көтелмәгән һөҗүмнән Руслан килешсез имгәкләп чалкан барып төште.* Ф.Мәснәвиева

**КИЛЕШСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Тәртипсезләнү, затсызлану; үзен әдәпсез, дорфа тоту

**Килешсезләнә бару** Акрынлап тагын да килешсезләнү

**Килешсезләнә тору** Берникадәр күләмдә тагын да килешсезләнү

**Килешсезләнеп йөрү** Килешсезләнү хәлендә булу. *Килешсезләнеп йөргәнче, әнә бүрегеңне җыештырып куй.* Ф.Әмирхан

**Килешсезләнеп тору** Даими яки әледән-әле килешсезләнү; килешсезләнү хәлендә булу

**КИЛЕШСЕЗЛЕК** *и.* 1) Килешсез булу, ямьсезлек, сыйфатсызлык. *[Корбангалинең] аягындагы киң башлы солдат итекләре, алама вә килешсезлекләренә карамыйча, һәрвакыт арулanып, сөртелеп йөртелгәнлеге --- аның бер оядагы кеше икәнлеген белдереп торалар иде.* Ш.Камал

2) Тәрбиясезлек, дорфалык, әдәпсезлек. *[Аю:] Әй, синдә ни өчен бөтенләй ит юк? Минемчә, бу кадәр арык булу бик килешсезлек бит.* Г.Тукай

**КИЛЕШТЕРҮ** I *ф.* 1) Ризалату, нинди дә булса фикергә күндерү. *Шул тирән ярасын кыбырсытып торучы, боз кыйпылчыгына әверелгән артыклык хисе, аны һич ташларга теләмәде. --- Һич теләмәсә дә, «Кем соң син? Бер бичара бит син!» дигән фикер белән килештерде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

2) Дуслаштыру, татуландыру. *[Сәгъди абзый] күп вакыт ул ике якны килештерергә, аларны бер-берсенә яхшы итеп күрсәтергә тырышты.* Ә.Фәйзи. *[Беренчесе:] Үбешик! Менә безне дә килештердең, Хуҗа! Менә рәхмәт!* Н.Исәнбәт. *Кич буе бәхәсләшеп чыктык. Тик бер яшьтән үк булган хыялыбыз гына үзебезне килештерде.* В.Ильясов

**Килештерә бару** Барысын да бер-бер артлы килештерү

**Килештереп йөрү** Гел, һәрвакыт килештерү

**Килештереп кую** Тиз арада килештерү

**Килештереп тору** Даими яки әледән-әле килештерү; хәзер килештерү процессында булу

**Килештереп утыру** *к.* **килештереп яту**

**Килештереп яту** Әле, хәзерге вакытта килештерү

**КИЛЕШТЕРҮ** II *ф.* **1.** 1) Бик килешле итеп, яхшы итеп эшләү, әйтү, урынлы итеп әйтү, булдыру. *[Сибгать:] Килештердең, Хәмзә. Молодец.* М.Фәйзи

2) Нәрсәнең дә булса формасын китерү, кыяфәтен булдыру. *Афзал --- каяндыр сары-шома таш алып, балтаны беләүләргә кереште. Белеп маташтырдымы, әллә юри килештердеме, Рахман бу кадәресен берничек тә төшенә алмады, агай балтасын җиренә җиткереп беләүли иде.* Ә.Дусайлы. *[Сабир] Кыяфәт-атлауларын үзгәртеп, үч алырга теләгән кешесенең йөрешен килештереп күрсәтә.* З.Зәйнуллин

3) Ошату, ярату, хуп күрү. *Дәян атакай, хак, сылу бикәнең кызларын ак төрекләргә биреп җибәрүен килештермәде ---.* М.Хәбибуллин. *[Сәгъди абзый] Габдулланы да сүзсез калдыруны килештермәде, ахры: – Син дә, малай актыгы, кем белән сөйләшкәнеңне белеп, артыңны чамалап сөйләшергә кирәк.* Ә.Фәйзи. *Юлдашының икеләнеп торуын болай гына үткәреп җибәрүне Изаел килештермәде һәм Ләмигадан бигрәк үзе өчен тырышып, әңгәмәне алга таба үстерде.* Р.Гаязетдин

**2. килештереп** *рәв. мәгъ.* Матурлап, матур итеп, җайлап, килешле итеп (сөйләү, язу, киенү һ.б.ш.). *Ул арада маймыл, ашыкмыйча, килештереп кенә конфетны кәгазеннән арчып, соңгысын бүлмә хуҗасына кире сузды.* Р.Мөхәммәдиев. *Шәмси мулла аларны [картларны] прошениегә килештереп терки барды.* Ш.Камал

**Килештерә бару** Акрынлап тагын да килештерү

**Килештерә башлау** Килештерергә тотыну

**Килештереп йөрү** Гел, һәрвакыт яки хәзер килештерү

**Килештереп кую** 1) Аз гына вакыт аралыгында килештерү; 2) Әле килештерү. *«Килештереп тә куя соң үзе! ---», – диеп уйлады «биюләреннән» эче поша башлаган ир-егет.* Р.Гаязетдин

**Килештереп тору** Даими яки әледән-әле килештерү; килештерү хәлендә булу

**КИЛЕШҮ** I *ф.* 1) Бергә тыныч яшәү, бер-береңне аңлау, янәшә яши алу. *Бер кешенең булган, ди, хатыны. ---. Бу кеше хатыны белән ничек тә килешә алмый икән.* С.Сүнчәләй

2) Дошманлашуны, талашуны туктатып, дуслашу, татулашу. *Кояш Яңгыр белән күп кычкырышкач, Бере-берсен яманларга тырышкач, – Татулашты, килештеләр ахырда Бу көннән сүз көрәштермәскә бер дә.* Г.Тукай

3) Солых төзү. *Иллә мәгәр утыз сигезенче елда Шәйгәрдән комиссарга да чират килеп җиткән. Әүвәл аны, ниндидер зур килешү төзегәндә, ил вәкиле итеп, Кремльдән Кытайга озатканнар.* В.Имамов

4) Кемнең дә булса фикеренә, тәкъдименә кушылу; шуңа риза булу, күнү. *[Салчак] Мыек чылгыен селкеткәләп, авызын кыйшайтып уйлангандай итеп торды да, кинәт кенә юашланып, килешеп: – Ярар, – диде. – Мин сиңа ачуланмыйм, син дә миңа ачуланма, тәгин углан.* Н.Фәттах. *Безгә, Валентин Васильевич белән баш кагып, килешүебезне белдереп утырудан башка чара калмаган иде кебек.* Р.Мөхәммәдиев

5) Нәрсәгә дә булса буйсыну, күнү; берәр төрле хәлгә карата түземлелек, чыдамлылык белән карый башлау. *Ахыр тора-бара күнектеләр, килештеләр, чөнки Бәһрам бәк алан һәм гот тарафларына яу йөреп, шактый табышлы булып кайтты.* М.Хәбибуллин. *Садыйк карт --- көннәрен эшсез үткәрү белән һич тә килешә алмый иде.* А.Алиш

6) Сатулашып, әйбернең бәясе турында ризалашу. *Байтак кына сатулашып, мулла да үгетләгәннән соң, ахырында ике йөз сумга килештеләр.* М.Галәү

7) Ярәшү; өйләндерү яки кызын бирү турында сөйләшеп кую, ризалашу. *[Хәлилгә атасы:] Зәйнәпкә күзеңне кыздырма, ул – килешкән кыз, алар бала чакта ук, аларның аталары кода булырбыз диеп килешкәннәр, Зәйнәп – Закирның булачак хатыны.* В.Ильясов

**Килешә бару** Торган саен барысы белән дә килешүне дәвам итү

**Килешеп бетү** Тәмам, тулысынча килешү. *Карышмадым: мондый постулатлар белән килешеп бетмәсәм дә, институттан «психолог» булып чыктым...* Җ.Юнысов

**Килешеп китү** Тора-бара килешү. *«Һы, бу колхозда фельдшер командалык итә икән! Бик кызык икән!» – дип озак сукранган хуҗа. Аннары килешеп киттек без аның белән.* А.Юнысова. *[Госман:] Минҗамал белән килешеп китмәсләрме дип алып килгән идем [Ризванны], синнән хәер-фатиха алмыйча, яучылык эшенә керешеп булмас.* Шәһри Казан

**Килешеп кую** Алдан ук килешү. *--- чит ыру кулындагы көтүлекләрдә мал ашату бәясен алдан килешеп куярга һәм түләргә кирәк ---.* З.Мифтахов. *Алар [балалар] бит бу бәйрәмне ел буе көтә, нәрсәләр алдырачакларын алдан ук үзара килешеп куялар.* Мәдәни җомга

**Килешеп тору** Даими яки әледәнәле килешү; килешү хәлендә булу

**КИЛЕШҮ** II *ф.* 1) Кемгә дә булса ятышлы, килешле булу (өс-баш киеме, бизәнү һ.б.ш. тур.). *Тавышың чишмә, телең тәмле, Бибиәсма, Итәкләрең дә килешкән – буй-буй тасма; ---.* Ш.Бабич

2) Тиң булу, туры килү, кулай булу. *Чибәр егетләргә чибәр кызлар килешә.* Г.Камал. *Бай һәм затлы традицион татар костюмына калфак бик тә килешкән.* Ялкын

3) Матур, төгәл, әйбәт булу; бар яктан килү. *Зөһрә матур судан кайта, Күлдән түгел – инештән; Бөгелми дә сыгылмый да, Бар җире дә килешкән.* Х.Мөҗәй

4) Әйбәт, яхшы сыйфатлы булу, тиешле дәрәҗәдә булу. – *Юк, юк, борчылмагыз, без ашыйбыз, ашларыгыз бик килешкән, – диде берничә тавыш берьюлы.* Г.Әпсәләмов

5) Урынлы булу, яхшы булу, ятышу, ярау (берәр төрле эш, хәрәкәт, сүз тур.). *[Карчык:] Кыз чагың – алтын чагың, ни әйтсәң шул килешә, ни кылсаң шул ярый...* Г.Ибраһимов. – *Алар уянмыйча, анда бару килешмәс, – диде сакчы ирләрнең берсе.* Н.Фәттах. *Ул [Валентин Васильевич] – арабызда иң өлкән кеше, аңарга шулай сөйләшү килешә.* Р.Мөхәммәдиев

6) Уңай тәэсир ясау, шифалы булу, ярдәм итү. *[Айбала:] – Чит илләрнең җир-суы килешкән булса кирәк, безнең Арысланыбыз киткәндә бала сыман иде, ике елда әбдән мыктый, тәвер җегет булып кайткан, – диде.* Г.Ибраһимов. *Кыш буенча тынчыган һавада бикләнеп торган шәкертләрнең авыру үпкәләренә Идел өстендәге язгы саф һава сөткә пешкән боткага атланмай килешкән төсле булды.* К.Тинчурин

◊ **Килешмәгән җир** *к.* **килешмәгән як**. **Килешмәгән эш** Ярамаган эш, начар эш. *Зөләйха абыстай исә мулласының шундый килешмәгән эше өчен кеше алдында кызарып җаны чыга.* Г.Ибраһимов. **Килешмәгән як** Кимчелекле як, кимчелек. *Үзең шундый чибәр, ыспай, тавышың да шундый матур. Синең берәр килешмәгән ягың бармы?* Р.Вәлиев

**Килешеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә килешү

**Килешеп тору** Килешле булу. *Калфаклары булмаганнар яулыкларын почмаклап, чөеп бәйләгәннәр, матур чигеш маңгай турында нәкъ калфак кебек килешеп тора.* Р.Батулла

**КИЛЕШҮ** III *и.* 1) Шартнамә

2) Солых. *Икенчесе --- Мәскәү белән килешү төзү ягында була.* Р.Фәхретдинов

**КИЛЕШҮЧӘН** *с.* Килешүгә бара торган, ризалашучан, күндәм, буйсынучан. *Ләбибнең көлүе – әче, мыскыллы, шәхесне юкка чыгаручан түгел, ә сыгылмалы, ипле, әмма һич кенә дә килешүчән булмаган көлү.* Г.Рәхим. *Шундый кавышу [мәхәббәткә нигезләнгән] – килешүчән, үзара ихтирамга нигезләнгән гаилә тормышының алшарты.* Я.Абдуллин. *[Банхуа:] – Басып керүем өчен ачуланма, – диде ул килешүчән бер ягымлылык белән.* – *Ашыгыч эш чыкты. Каганның... синең сеңелеңне күрәсе килә.* Н.Фәттах

**КИЛЕШҮЧӘНЛЕК** *и.* 1) Килешүчән булу, ризалашучанлык, күндәмлек. *Дөрес, күрше дәүләтләр арасында килешүчәнлеккә нигезләнгән гамәлләр дә байтак булган.* И.Хуҗин

2) Принципсызлык, аумакайлык. *Шагыйрь моны таркалу, ярашу, килешүчәнлек юлына борылу – указлы муллалар эзенә төшү кебегрәк кабул итә ---.* М.Гайнетдин

**КИЛЕ́ШЧӘ** *рәв. к.* **килеш** III. *Менә хәзер үк капкадан килеп чыгар, яисә менә хәзер ул, капка янына килеп, аннан чыгар-чыкмас кына килешчә карап тора башлар.* Ф.Әмирхан

**КИЛКИ** *и. сөйл. к.* **килька**. *Әйбәт идем дә соң... Песи бәхетен дә Тулы бирәлмәдем... Таш бүлмә дә подвал, «Китекәт» тә килки Булды күргәннәре...* З.Мифтахов

**КИЛМЕШӘК** *и.* Каян булса да килгән, чит кеше. *Ятасың боз кебек салкын түшәктә, Гүя син бу җиһанга килмешәк лә!* Г.Тукай. *--- үзен килмешәк итеп санаган ирнең әти-әнисенә, туганнарына, Курагач халкына: «Мин сезгә күрсәтермен әле!» – дип, йодрык төйнәп борылды ул [Фәзилә].* Г.Мирһади. *Кыш көннәрендә йорт ишегең ача алмый, аяклары бозга ябышып каткан сабыйга «юату» сүзе бер: «Кадалмас әле, килмешәк». Бу «килмешәк» – Тукай...* Ф.Бәшир

**КИЛО** *и. сөйл. к.* **килограмм**. *Бу килүемдә уханы азрак ашадым. Аның каравы өйгә алты кило балык алып кайттым.* Ә.Еники. *Кулга өч ай косилка-жнейкада эшләгәнгә 5 кило да 670 грамм арыш бирделәр.* З.Зәйнуллин. *Һәркайсы берәр кило гына балык тотса да, ике центнер кыйммәтле диетик ризык дигән сүз.* З.Мурсиев

**КИЛОВАТТ** *и. рус физ.* Электр тогы егәрлеген үлчи торган берәмлек: бер киловатта бер мең ватт була. *Тукай ул – шовинизм белән милләтчелек арасындагы миллион киловаттлы көчәнешкә куелган саклагыч, башкаларны яндырмас өчен үзе янган кеше.* Р.Батулла

**КИЛОВАТТ-СӘГАТЬ** *и. физ.* Егәрлеге бер киловатт булган токның бер сәгать эчендә эшләгән эшен үлчәү берәмлеге

**КИЛОГРАММ** *и. рус* Мең граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге. *Көч тә килограмм белән үлчәнә, масса да килограмм белән үлчәнә китап буенча.* З.Зәйнуллин. *[Мөдир:] Әгәр һәрберебез урлашса: берешәр литр сөт, берешәр килограмм он алып кайта башласа, бу кая китә?* М.Кәбиров. *Колхозда бер көн калмый эшләгәннәргә ничә килограмм ашлык бирделәр икән, хәтерләмим.* Татарстан яшьләре

**КИЛОГРАММЛАП** *рәв.* 1) Килограмм-килограмм итеп. *Эскерт янына үлчәүләр китереп, килограммлап санап бүлделәр саламны.* Татарстан яшьләре

2) Күпмедер килограмм чамасы, билгеле бер килограммга якын. *Колхоз уракка төшкән, беренче ашлык тапшырылган, ә ул [председатель], район җитәкчелегеннән яшереп, ачтан шешенгән колхозчыларга граммлап түгел, килограммлап ашлык тараткан!* Н.Фәттах

**КИЛОГРАММЛЫ** *с.* Бер яки берничә килограммга тигез булган. *18 яшькә кадәргеләр арасында 60 килограмм үлчәү авырлыгында Рәмис Минһаҗев 24 килограммлы герне 126 тапкыр күтәргәч, гер кулыннан ычкынып китә.* Ватаным Татарстан

**КИЛОЛАП** *рәв. к.* **килограммлап**. *Япон телевизорлары – икешәр бакча бәрәңге утыртып, аны утап, күмеп, көзен казып, җыеп, Уфа базарына илтеп, бидрәләп, килолап өф итеп сатудан килгән акча җимеше. Д.Булатова. [Госман хәзрәт:] Без – имам, мөфти, казыйлар – Русия, Татарстан өчен зур хезмәт куябыз. Ул эшне килолап та, тонналап та үлчәп булмый.* Мәдәни җомга

**КИЛОЛЫ** *с. к.* **килограммлы**. *Һәр сүзем башына бәрде, әйтерсең килолы гер.* Р.Харис. *Тарихтан сынау тапшырып чыккач, урамда очрады Габдрахман. Йөз кырык килолы бу әзмәвер иде Дәрҗәүндә дан!* М.Шаһимәрдәнов

**КИЛОМЕТР** *и. фр.* Мең метрга тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге. *Бу сопка тундра ягыннан болан мөгезе кебек тармакланып килә дә, Колыма ярларына ике-өч километр калганда, кинәт көньякка борыла.* И.Салахов. *Унике километр араны ничек йөгереп үтүен сизмичә дә кала ул.* М.Хәсәнов. *Минем белүемчә, ул ара ким дигәндә унбиш километр, ә минем отрядта нибары егерме ике генә кеше.* В.Нуруллин

**КИЛОМЕТРАЖ** *и. фр.* Километрлар белән үлчәнгән озынлык, ара. *[Миләүшә] трассага чыгып, төрле километражларда, төрле участокларда җәелгән асфальтлардан, махсус өтерге белән китеп, пробалар ала.* М.Хәсәнов

**КИЛОМЕТРЛАП** *рәв.* 1) Километр белән. *В.Патлай кулы аша үтеп таякка чорналган җепләрне километрлап үлчәү мөмкин булса, йөзләрчә, меңнәрчә чакрымнарга сузып булыр иде, мөгаен.* Шәһри Казан

2) Күпмедер километрга якын, километр чамасы. *[Әхәтне] унбиш километрлап узгач, артыннан килеп кире бордылар да, Сталинны ясап бетергәч кенә, кире озаттылар.* Казан утлары. *Караңгылык төшә башлагач, политрук Карпов шуышып килде. Ике километрлап артка чигендек.* Мәйдан

**КИЛҮ** *ф.* **1.** 1) Нинди дә булса транспортта яки җәяү хәрәкәт итеп, билгеле бер урынга якынаю яки барып җитү, барып керү. *Зур мәҗлескә бик күп кунак чакырылды, Чакырылган олуг бәкләр бар да килде ---.* Кол Гали. *Якшәмбе көнге әмердә татар кызына тәрәзә янына килү бөтенләй тыела иде. Ул урлап, качынып кына тәрәзә янына килде.* Ф.Әмирхан

2) Сөйләүче тарафына хәрәкәт итү. *Агыйделнең аръягыннан Атлар килә адымлап.* Җыр. *Ул университет коридоры буйлап миңа каршы килә иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ярты сәгать узды бугай. Кыз яңадан чыкты. Ул миңа таба килә.* З.Мәхмүди

3) Нинди дә булса тоташ масса, бербөтен агым булып хәрәкәт итү (болыт, су, һава һ.б.ш.). *Биек тауларга менәмсең, Болыт килә, күрәмсең.* Җыр. *Килә болыт кайчак, китә болыт, Бер тамчы да яңгыр сипмичә.* З.Нури

4) Боз, сал кебек әйберләр су буйлап хәрәкәт итү. *Агыйделне иңләп-буйлап саллар килә, Сал өстендә асыл кошлар сайрап килә.* М.Мәһдиев

5) Билгеле бер максат белән кая булса да бару. *Әхмәт җизни авыл советы рәисе булып эшли. --- Беркөнне эшкә килгәч, ул туп-туры почта начальнигы Мөхәммәт абзый янына кергән икән.* Б.Ислам. *Күңеле белән мәрхәмәтле керәшен карты иде Метрәй кордашы. Шуңа да аңа киңәшкә килде бүген [Нурулла].* Мәйдан. *Шушы елның сентябрь башында авылга бер укытучы кыз эшкә килде.* Мәдәни җомга

6) Нинди дә булса транспорт чаралары хәрәкәт итү. *Агыйделдән көймә килә Кылдан нечкә эз белән ---.* Җыр. *Тагы шунысы начар, каршы килгән машиналарның уты күзнең нурын өтеп-өтеп ала.* Р.Мөхәммәдиев

7) Күчмә кошлар җылы яктан кайту. *Яз килде, Язгы җыр булып, Канат кагып тургайлар килде.* Г.Латыйп. *Җылы яктан очып килде Сыерчыклар-кошкайлар.* Л.Лерон

8) Тиешле, билгеләнгән урынга барып җиту, тапшырылу (кая да булса җибәрелгән әйбер тур.). *Әти-әнисеннән дә хат килде. «Без нәрсә әйтик инде, кызым, абыеңнан сора», – дигәннәр.* Т.Миңнуллин. *Казан сәүдәсенә акчалары кергән чит шәһәр байларыннан, Казан губернасының эре алпавытларыннан Дьяченко исеменә котлау телеграммалары килде.* Ә.Фәйзи

9) Каян да булса билгеле бер урынга нәрсә дә булса китерелү, кайтарылу. *Завод коллективын хәзер ике генә нәрсә борчый: берсе – читтән киләчәк станоклар, икенчесе – тәрәзә пыялалары.* А.Расих

10) Табынга бирелү, куелу, китерелү (ашамлык, эчемлек һ.б.ш.). *Алар сөйләшеп торган арада аш килде. Аш – әлеге күптән түгел генә Николайның зарланганы – өйрә иде.* Ш.Камал

11) Авыз, күз һ.б.ш.дан бүленеп чыгу, агу (су, кан, яшь һ.б.ш. тур.). *Күзләремә яшь килде, – үзем өчен түгел, кашка байтал өчен.* Ф.Хөсни

12) Берәр урыннан таралу, чыгу, кая да булса үтеп керү (ис, төтен һ.б.ш.).

*Газизҗанның кулы коточкыч авыр, имән кайрысыдай кытыршы иде, аңардан туфрак, май һәм җир исе килә иде.* Ф.Садриев. – *Туктагыз әле, егетләр, – дип сүзгә кушылдым. – Монда бит без кызлар турында сөйләшергә җыелмадык. Тәмәке тарткан кешедән әшәке ис килә. Ә үзегез кызлар дигән буласыз, – дидем.* Ф.Яруллин

13) Билгеле бер тарафтан ишетелү (тавыш, җыр һ.б.ш. тур.). *Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман: «Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан».* Г.Тукай

14) Билгеле бер чыганакка тоташтырылу, файдаланугa бирелү (газ, ток, су тур.). *Быел сөенче: безнең авылга газ килде.* Өмет

15) Аерым бер вакыттан, билгеле бер чордан башланып дәвам итү (нәсел, гадәт һ.б.ш.). *Граф Шереметьев (Ширәхмәт) кебек байгуралар гына түгел, тарихчы Карамзин, язучы Куприн, язучы Радищев һәм башка күпләрнең шәҗәрәсе әнә шулай ерактан – татар нәселеннән килә.* М.Мәхмүтов

16) Якынлашу, башлану, җитү (ел, ел фасыллары, көн вакытлары тур.). *Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта; Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.* Г.Тукай. *[Мөсафир] бабай үләр алдыннан үзенә чакырды да миңа, бер уч тутырып, орлыклар бирде. Болар кызыллар иде, матурлар иде. – Яз килгәч, – диде, – боларны чәчәрсең!* Г.Ибраһимов

17) Алу, бирелү, түләнү (эш хакы, пенсия, пособие һ.б.ш. тур.). *[Сәгыйтьҗан:] Иң әүвәле Петербурда салыначак мәчетнең маясын туплап бетерергә кирәк, җәмәгать. Урыннардан җыела торган акча бик әкрен килә.* Ә.Фәйзи

18) Нинди дә булса фикер, план, уй һ.б.ш. барлыкка килү, туу (башта, күңелдә). *[Сәгыйтьҗанның] башына илһам булып килгән бүгенге уй аны баштанаяк биләп алган иде ---.* Ә.Фәйзи

19) Тиешле дәрәҗәгә җитү, яхшы сыйфатлы булу. *Мичебезнең төбе начар, нихәтле күп яксаң да, икмәкнең асты килми, бераз сүрәнрәк булгандыр ахры.* М.Гали

20) *Хәлгә* сүзе белән килеп, кем яки нәрсәнең дә булса башка бер сыйфатка күчүен, үзгәрүен, икенче бер халәткә керүен белдерә. *Кояш түбәнәйде, көн кичекте, һава көндезгедән әллә ничә дәрәҗә йомшарып, эчеп туйгысыз бер хәлгә килде.* Г.Ибраһимов. *Ул [хатын] каршылык күрсәтмәслек хәлгә килде.* М.Кәбиров

21) Кайбер юнәлеш килешендәге абстракт исемнәр янында килеп, әлеге исем белдергән нәрсәне аңлау, ачыклау, төшенүне белдерә. *Генри кинәт ныклы бер карарга килде дә костюмын кия башлады.* А.Тимергалин. --- *Габдуллин --- ныклы бер фикергә килеп: – Юк! Юк, господин прокурор! Ул кичне Габденнәсыр әфәнде өйдә юк иде, – дип җавап бирде.* З.Бигиев

22) Эш яки хәлнең башлануын белдерә. *«Казан мөхбире» соңгы номерында «Галимҗан мелланың мәдрәсәсеннән 81 шәкерт чыкты» дип язадыр, һәр җирдә шәкертләр хәрәкәткә килде.* Ш.Мөхәммәдев

23) Билгеле бер авырлыкта булу; (фәлән кадәр) тарту. *Кәбестә ун килограммнан артык килде.* Г.Ахунов

24) Үзеннән алда килгән чыгыш килешендәге исем (яки шул функциядәге сүз) белдергән сәбәп аркасында булу, туу. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә, аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.* Г.Тукай

25) *күч.* Бар яктан да камил, төгәл, җитеш булу. *«Авыл офыклары» газетасы баш мөхәррире Вазыйх абый Фатыйхов – бар яктан да килгән шәхес.* Безнең гәҗит

**2.** *ярд. ф. функ.* Хәл фигыльләр янында: 1) Билгеле бер предметка, урынга таба юнәлүне белдерә. *Рахман һөҗүмгә әзерләнде. Ләкин, дошман үзе пике ясап, туп-туры болайга таба ажгырып төшеп килә иде инде.* Ә.Дусайлы

2) Эш яки хәлнең дәвамлы рәвештә үсешен, эзлеклелеген, үзенең соңгы чигенә якынлашуын белдерә. *Кайный-кайный суның шулпага әйләнү өмете өзелгәч, Каюп бабай яңа гына яфрак ярып килгән карлыган сабакларыннан кечкенә пиннек сындырып, аны кайнап торган бидрәгә китереп тыкты ---.* М.Кәрим

3) Эш яки хәрәкәтнең үткәннән хәзергә күчүен белдерә. *Ә еллар яңаның җиңүен алып килделәр.* Һ.Такташ

4) Эш яки хәлнең әледән-әле, даими рәвештә кабатлануын белдерә. *Моңа кадәр ничек эшләп килгән булсам, моннан соң да шулай эшләрмен.* Ф.Хөсни

5) Эш яки хәрәкәтнең юл уңаенда эшләнүен, үтәлүен белдерә. *Керә килү. Ала килү*

6) *-асы* кушымчалы сыйфат фигыль белән килеп, берәр төрле теләк, омтылыш барлыгын белдерә. *Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә; Шул болыннарда ятасым, шунда аунаясым килә.* Г.Тукай. *Аңа бүген әллә нәрсә булган, Бер җырлыйсы килә, бер көлә, Бер онтылып, кинәт керфекләре Бер ноктага килеп төртелә...* Һ.Такташ. *Әллә нишләтә күңелне, үксеп елыйсы килә... Елау егет эшемени?! – Эх, бер җырлыйсы килә!..* Ф.Кәрим

7) Кайбер ияртемнәр белән килеп, фигыль ясый торган кушымчалар функциясен үти (мәс., *гөж килү – гөжелдәү, шау килү – шаулау* һ.б.ш.). *«Ияр вакыйгасы» белән иң элек Печән базары шау килде.* Ә.Фәйзи. *Эре яңгыр тамчылары якындагы мандарин агачы һәм платан яфракларына төшеп, берөзлексез шыбыр-шыбыр килә.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Килеп чыгу** 1) Эшнең нәтиҗәсе уңышлы булу, әйбәт тәмамлану; 2) Эшхәл, вакыйгалар билгеле бер юнәлеш алу, төс алу, ниндидер нәтиҗәгә китерү. *Аллаһы Тәгалә Вәлиулла хәзрәтнең рухын шат кылсын. --- Ни өчен болай килеп чыкты?* И.Фәиз

**Килә башлау** Килергә тотыну

**Килә тору** Даими яки әледән-әле килү; кемнән дә булса алдарак килү. *Хатларың гел килә торды – Үзең килмәгәнгәме.* Ф.Гаязов

**Килеп тору** Өзлексез, дәвамлы рәвештә гел килү; әледән-әле килү. *[Рафаэль:] – Хаты гына килеп торсын, егетләр, эш биюдән генә тормас, – диде ул, хатны кулына алгач та үз бүлмәләренә ашыгып.* Р.Мөхәммәдиев. *Мәдинәнең эше гел генә уңай килеп тора бит әле быел.* Мәдәни җомга

**Килеп яту** Килү хәлендә булу

**КИЛЬ** *и. голл. махс.* 1) Очу аппаратлары койрыгының бер өлеше

2) Судно корпусының аскы сырты

**КИЛЬВА́ТЕР** *и. голл. махс.* 1) Хәрәкәт итеп барган судно артыннан кала торган су агымы

2) *күч.* Бер юнәлеш, бер үк юл. *Бөтен коллективны бер кильватерга тезергә кирәк.* И.Гази

**КИ́ЛЬКА** *и. фин. зоол.* Сельдь балыклары семьялыгыннан булган вак балык; йомычка балык. *Биш-алты тачка йомычка балык – килька, сельдь, унбиш-егермеләп биреш, эре генә өч сазан чыкты.* Ш.Камал. *«Майдагы шпрот» консервларын әзерләү өчен, килька яки салака балыклары кулланыла.* Ватаным Татарстан

**КИ́ЛЬКИ** *и. фин. зоол. к.* **килька**. *Мин – консервланган томатлы кильки һәм арпа ярмасы катыштырылган «Завтрак туриста» ашап үскән буынның бер вәкиле.* Л.Лерон. *Вакыты-вакыты белән ашау ягы тақы-токыга калса да, ипи ягына кытлык юк үзе. Май белән дә ашыйбыз, чәй белән дә эчелә, кильки белән дә үтә...* Мәйдан

**КИМ** *рәв.* **1.** 1) Җитәрлек түгел, тиешле дәрәҗәдән аз. --- *3 айда Чаллы казнасының керемнәре тиешлесеннән беразга кимрәк булды.* Шәһри Чаллы

2) Начаррак булган, түбән. *Яхшы угыл атасын ярлылыгы өчен ким күрми.* Мәкаль. *Алай булса да, Аллага шөкер, агаларым яхшы иде, атамнан ким тәрбия кылмадылар.* Г.Исхакый. *[Мөнәвәрә:] Я, телеңә салынма, түгәрәк җирләреңнең барысы да килеңнәрнекеннән ким түгел, сине дә читкә куеп тормаслар.* З.Зәйнуллин

3) «Нәрсәләрнедер чагыштырганда азрак яки ниндидер күләмгә, микъдарга тулмаган» мәгънәсендә кулланыла. *Бәйрәмгә дә ерак калмады – ике атнадан да ким.* И.Салахов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җитәрлек булмаган, тиешенчә түгел, тиешле дәрәҗәсеннән аз булган. *Ким үлчәүле*

2) Күп нәрсәләрдән мәхрүм ителгән, кемгә дә булса тиң түгел дип саналган. *Килен кеше – ким кеше.* Мәкаль. *Тормышның бөтен шатлыгыннан мәхрүм ителгән, ким кеше итеп тойдым мин үземне.* Ә.Дусайлы

◊ **Ким дигәндә** *к.* **кимендә**. *Тумыртканың һәр өеннән ким дигәндә өч-дүрт бала кашык тотып умартачы йортына йөгерә.* М.Кәрим. *Олы таш юлларга чыгып җитәрлек түгел, зур елгалар – Нократ һәм Чулманның һәр икесенә ким дигәндә егермешәр чакрым ара.* Р.Мөхәммәдиев. **Ким куймау** Билгеле бер эшне тулы канәгатьләнү алырлык итеп, тиешеннән дә арттырып эшләү, башкару. --- *тураучылар үзләре дә ким куймыйлар, авызлары даим селкенә, күп вакыт иң симез локмаларны елт иттереп үзләре йоталар иде.* Г.Ибраһимов. *Башка тарафка озатылган җәза отрядлары да кимен куймадылар.* В.Имамов. *Тапладылар, таладылар. Эт кебек куймый кимен...* Э.Шәрифуллина. **Ким күрү** Түбәнсетеп карау, кимсетү; санга сукмау. *Һәрхәлдә, Иркәгөлгә матди яктан иптәшләреннән ким күренмәскә җитте [акча].* И.Ихсанова. *Кимсетәләр, ким күрәләр, әллә бәхетем юкка.* Җыр

**КИМӘК** *и. тар.* VIII–X гасырларда Көнбатыш Себернең Урта Иртеш буйларында яшәгән төрки кабиләләр берләшмәсе һәм шул берләшмәнең бер вәкиле. *Каханлыкның төп җирле халкы шулай ук төрки телле кабиләләр, инде безгә мәгълүм кыпчаклар белән кимәкләр булган.* Р.Фәхретдинов

**КИМВАЛ** *и. гр. муз.* Ике металл тәлинкәдән гыйбарәт музыка коралы

**КИМЕК** *и.* Җилек белән аралашкан йомшак сөяк. *Төше каплы, кимеге татлы.* Табышмак

**КИМЕНДӘ** *рәв.* Аз дигәндә, иң азы, минимум. *Сәгать саен литр кимендә.* М.Җәлил

**КИМЕРЧӘК** *и.* Кеше, хайван һ.б.ш. тере организмнар скелетының кайбер өлешләрен тәшкил итә торган тыгыз һәм каты тоташтыргыч тукыма. *Өч көннән урамда Мөбарәк күренде. Малайның борын кимерчәге ярыйсы ук күперенкеләнеп тора иде.* М.Шаһимәрдәнов. *Барлык умырткалыларның яралгылары скелеты кимерчәктән тора, үсеш алган саен, кимерчәк сөяк тукымасына әйләнә.* Биология

**КИМЕРҮ** *ф.* 1) Каты ризыкны тешләр белән ваклап, кырып ашау. *[Рабига:] Шушы ботны кимереп, чокырдан шулпасын йотып, минем күңел булырлык итеп сыйланып җибәр, яме.* М.Хуҗин. *Хатын-кыз ике тәүлек буена, төнгелеккә генә тын алып, гел ашау, нәрсәдер кимерү өстендә булды.* Д.Булатова

2) Нәрсәне дә булса тешләр белән кысып чәрдәкләү, ваклау, өзү. *Елтыр соры түшле, озын койрыклы кечкенә генә тычкан бер бодай камылын кимереп утыра иде.* Г.Гобәй

3) *күч.* Бимазалау, газаплау, борчу (уй, хис һ.б.ш. тур.). *Ямьле җәйнең мазасын черки-чебен китәрер, удал җегетнең йөрәген яман хатын кимерер.* Мәкаль. *Акын болай дип җавап биргән: «Үләнле җирдә мал симерер, үлекле җирдә мулла симерер, казакъның караңгы даласын муллалар килеп агартмаса, синең кебек наданнарның башын бет кимерер», – дигән.* Г.Ибраһимов. *Ә тоя идеме соң үзенең бәхетен? Йөрәкне астыртын гына, гел генә кимергән уйлар тулы бәхеткә ирек бирмәгәндер шул...* Д.Булатова

4) *күч.* Кем яки нәрсә исәбенә яшәү; урлашу. --- *дивана кимпер җенләнеп, картка таба кызулап килде дә: – Эт син! Байтүрәнең сөяген кимереп, йортны талыйсың! – дип кычкырынып, Азымбайның өстенә ташланды.* Г.Ибраһимов. *[Сөн] Иске май заводы урамының да ярты ихатасын ашап бетерде. Анысын да кимерсә, тагын кемне йотар?* В.Имамов

**Кимерә бару** Булган берсен рәттән кимерү

**Кимерә башлау** Кимерергә тотыну

**Кимерә бирү** Бернигә карамыйча кимерүне дәвам итү. *– Булмаса, үзем дә пешереп ашый беләм мин! – диде Габдрахман төксе рәвештә һәм ипиен тәмләп кенә кимерә бирде.* М.Шаһимәрдәнов

**Кимерә тору** Әлегә кимерү; нинди дә булса процесска кадәр кимерү. *Аш әзер булганчы, ипи кимерә тору*

**Кимерә төшү** Тагын берникадәр кимерү

**Кимереп алу** Берникадәр вакыт кимерү. *Еш кына теше белән кимереп*

*ала торган тырнаклары тигез итеп киселгәннәр.* З.Зәйнуллин

**Кимереп бетерү** Тәмам, тулысынча, беткәнче кимерү. *Үҗәт сержант тирән эчле ике тәлинкә токмачлы ашны чөмереп, чирек әтәчне тәмләп кимереп бетергәч, иптәше белән җәдәч сөяген аерды.* М.Шаһимәрдәнов

**Кимереп калу** Нindидер вакыйгадан соң яки нәрсәдер булганчы кимерү. *[Совхоз түрәләре] Үзара килешеп кенә, эскерткә ияләшкән комаклар сыман, җае чыкканда күбрәк кимереп калырга гына ашыгалар.* Д.Булатова

**Кимереп карау** Кимерергә тырышу

**Кимереп тору** Даими яки әледәнәле кимерү; әле, хәзерге вакытта кимерү. *Вакыйган, ике көн эшсезлек аркасында йөрәкләрне әкрен генә кимереп торган эч пошу артыннан эш көне гадәтчә бер бәйрәм кебек күңелле башланды.* Ш.Камал

**Кимереп яту** *сөйл.* Кимерү хәлендә булу; әле, хәзерге вакытта кимерү. *Күсе сыман астан гына кимереп ята белмәгән бу сантый, үзенә кызык тапкан.* В.Имамов

**КИМЕРҮЧЕ** *и. зоол.* 1) Озын һәм нык булган алгы тешләре белән үсемлек орлыгы, агач кайрысы һ.б.ш.ны кимереп тукланучы имезүче җәнлек (тиен, күсе һ.б.ш.). *[Бай дала киңлекләрендә] бөртекле ашлык белән тукланучы кимерүчеләр – йомраннар, дала сөркәсе (байбак), кыр тычканнары өстенлек итә.* Башлангыч география курсы

2) *күпл.* **кимерүчеләр**. Имезүчеләр классының иң күп санлы отряды; *русчасы:* **грызуны**. *Кимерүчеләр Антарктиданы санамаганда Җир шарының бар кыйтгаларында яшиләр*

**КИМЕТҮ** *ф.* 1) Күләм, зурлык, сан ягыннан ким итү, азайту, кечерәйтү. *Фатих Әмирхан, киеренкелекне киметер өчен, Тукайга якынрак килде.* Р.Батулла. *--- ревизиядән соң җитмәгән товар табылгач, әйтелгән сумманың бер өлешен киметтеләр, әмма калганы барыбер дә кызлар өстендә калды.* Мәдәни җомга

2) Кемне дә булса дәрәҗәсе, нинди дә булса сыйфаты һ.б.ш. ягыннан түбәнәйтү, кечерәйтү

**Киметә бару** Акрынлап киметү; тагын да берникадәр киметү

**Киметә башлау** Киметергә тотыну

**Киметә тору** Нindидер процесс башланганчы киметү

**Киметә төшү** Берникадәр, билгеле бер дәрәҗәдә киметү

**Киметеп бару** Акрынлап берникадәр киметү

**Киметеп кую** Алдан яки тиз арада киметү

**Киметеп тору** Даими яки әледәнәле киметү; киметү хәлендә булу

**КИМ ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Алдагы җөмләләрдән яки сүз сөрешеннән җиңел аңлашыла торган бер яки берничә кисәге төшереп калдырылган җөмлә. *Мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкләрнең булу-булмавына карап, җөмләләр тулы һәм ким җөмләләргә бүленә.* Татар теле

**КИМЛЕК** *и.* 1) Ким (*1 мәгъ.*) булу хәле, сыйфаты.

2) *к.* **кимчелек**. *Күңелеңне [яраткан кешеңнән дә] яхшы кеше юклыгына ышандырсаң, һичнинди кимлек тоймыйсың.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Түбәнлек, хурлык. *Гөлфаяз бик яхшы әни булырга тырышты. ---. Үзе дә, кызы да кимлек хисе кичермәсен өчен, бөтен барлыгы белән тырышты ул.* И.Ихсанова. *Әмма бер иш халыклар икенчеләрнең тарихын үзләренеке итүне бер дә кимлеккә һәм түбәнлеккә санамыйлар.* Ф.Яхин

**КИМЛЕК ДӘРӘҖӘСЕ** *и. лингв.* Предметтагы берәр билгенең гади дәрәҗәдәгедән кимрәк булуын белдерә торган асыл сыйфатлар формасы

**КИМО́ГРАФ** *и. гр.* 1) *мед.* Организмдагы төрле үзгәрешләрне теркәп бара торган җайланма, прибор (мәс., кан басымын, мускуллар кыскаруын һ.б.ш.)

2) Эксперименталь фонетикада авазларның әйтелешен язу җайланмасы, приборы. *Тирбәнеш дулкыннары кимограф (һава дулкыннарын махсус лентага язып бара) --- ярдәмендә яздырыла ---, ә бу авазның акустик составын, физик төзелешен билгеләргә ярдәм итә.* Тел белеменә кереш

**КИМОНО** *и. яп.* 1) Японнарда халатсыман киң җиңле милли кием

2) *махс.* Хатын-кыз күлмәгенең аерым бер фасон белән киселгән җиңе

**КИМПЕР** *и. фар.* Карчык, кортка. *Ханым дәхи ул туфракны алып, ярар, кимперем, дип, бераз заман саклап куйды.* Дастан. *--- дивана кимпер җенләнеп, картка таба кызулап килде дә: – Эт син! Байтүрәнең сөяген кимереп, йортны талыйсың! – дип кычкырынып, Азымбайның өстенә ташланды.* Г.Ибраһимов. *– Әнә кандай чибәр кимпер йөреп ята, авылда канча буш йортлар үксеп утыра, кайт та кил!.. – диде инде чишенеп тә өлгергән Иркен ага.* А.Хәлим

**КИМСЕНҮ** *ф.* 1) Үзеңне башкалардан начар дип уйлап, ким күрү; хурлану. *Үкенү, кимсенү, хәтта оялу аның [Гасыйм Сәләховичның] җанын борчыды да торды.* Ә.Еники. *Тимерҗан агай малае юклыкка бик кимсенә, ояла иде.* Д.Булатова. *Тумыштан гарип булганга, балачактан бирле кимсенеп үсте Рәйхана.* З.Зәйнуллин

2) Үзеңне кем тарафыннан булса да кимсетелгән дип уйлап гарьләнү; хурлану. *Күкрәгендә, беләгендә көч барлыгын тоя башлагач, ул [Тотыш], бер дә юктан кабынып китәргә генә торган ярсуына, кимсенүенә ирек биреп, үзен кыерсытучыларны еш кына тәпәләп тә ташлады.* Н.Фәттах

**Кимсенә бару** Торган саен кимсенү

**Кимсенә төшү** Берникадәр тагын да кимсенү

**Кимсенеп алу** Азга гына кимсенү

**Кимсенеп йөрү** Кимсенү хәлендә булу. *Зифа бигрәк тә каты торды. Югары уку укый алмавына үзенең гомер буена кимсенеп йөрүе дә җиткән.* Д.Булатова

**Кимсенеп тору** Даими яки әледәнәле кимсенү; кимсенү хәлендә булу

**Кимсенеп утыру** Кимсенү хәлендә булу. *[Фатих абый:] Кайтып китеп, син дөрес эшләдең. Кимсенеп утырма анда.* З.Зәйнуллин

**КИМСЕНҮЛЕ** *с.* Кимсенү төсмере булган, кимсенү чагылган, гарьләнүле (йөз, тавыш һ.б.ш.). *Тик, кара сакалың кайда да үзең белән, дигәндәй, хәерчелек үк булмаса да, мәңге җитмәүчелек,*

*кимсенүле юклыктан башы котыласы юк.* Д.Булатова

**КИМСЕТЕЛҮ** *ф.* Мыскыл ителү, читкә тибәрелү. *[Тукай] гаять гыйззәте нәфесле бер кеше иде ки, үзенә нинди дә булса бер яктан кимсетелеп карауны вә хәтта шул карау ихтималын гына да тәхәммел итә алмый иде.* Ф.Әмирхан. *Гел кагылып, кимсетелеп һаман Яшәгәне өчен тилмереп, Жандай күргән газиз халкымны син Киләчәкле итә күр берүк!* Зөлфәт. *Бу хакта олуг хан ишетә калса, җаны калтырап, кимсетелгән бәндәсен дәштерә, баштарак бүләк биреп ярлыкау үтенә, соңрак зиндан яисә чыбык суктыртып җәза кыла башлады.* Ф.Яхин

**Кимсетелә бару** Торган саен тагын да ныграк кимсетелү

**Кимсетелә тору** Акрынлап тагын да кимсетелү; берникадәр күләмдә кимсетелү

**Кимсетелеп бетү** Тәмам, бик нык кимсетелү. *Ләкин Аллаһ болай да кысрыкланып, кимсетелеп беткән татарга бу афәтне дә бирергә базмады.* Идел

**Кимсетелеп тору** Даими яки әледәнәле кимсетелү

**КИМСЕТҮ** *ф.* 1) Кемне дә булса ким күрү, җәберләү, санга санамау. *Әгәр кемдер минем милләтемне кимсетеп, аны йокларга мәҗбүр итә икән, мин кычкырачакмын, әгәр безнең милләтчеләребез бүтәннәрне кимсетергә маташып, без-без дип кенә милләтемне уятырга җыена икән, шулай ук кычкырачакмын.* Т.Миңнуллин. *Әмма Әлфияне урап узам. Аңа ачуым килә. Ничек алай минем бәхетемне, минем Сәлимәмне кимсетергә батырчылык иттең син, әй кызый!..* Ф.Яхин

2) Кемне дә булса мыскыллау, хурлау, яманлау. *Юләрне кимсетү – хәрәм, аңарга авыр сүз дә әйтергә ярамый, диләр. Имеш, казасы була.* Ф.Яхин. *Акчасы булганда – аракы, булмаганда спирт алып кайтты, кимсетү сүзләренә җавапсыз калырга тырышты [Ләйлә].* М.Кәбиров

**Кимсетә бару** Торган саен ныграк кимсетү

**Кимсетә башлау** Кимсетергә тотыну. --- *ни генә әйтмә, татар җиренә килеп, аның мал-мөлкәтенә хуҗа булгач, инде ул аны юри кимсетә башлый.* М.Миначев

**Кимсетә тору** Әле, хәзерге вакытта кимсетү

**Кимсетә төшү** Берникадәр тагын да кимсетү. --- *бер нәрсә күңелне кимсетә төште: ялтырап торган гарәп, фарсы һәм һинд киемнәре белән чагыштырганда, бу концертта татар костюмнарының хәерче хәлдә булуы күзгә ташланды.* Безнең гәҗит

**Кимсетеп алу** Аз гына кимсетү

**Кимсетеп килү** Даими кимсетү. *Бибизөһрә аркасында бозылышканнан соң, ул Галиәсгарны, урыны чыкса-чыкмаса, гел шулай сүзгә катнаштырып кимсетеп килде.* Ә.Фәйзи

**Кимсетеп тору** Кимсетү хәлендә булу, гел, һәрвакыт кимсетү. *Ләйләне ул [бианасы] күрәлмәде, әле авылдан булуын, әле милләтен искә алып, әле башка сәбәпләр табып, җае чыкса-чыкмаса да, төрлечә кимсетеп торды.* М.Кәбиров

**КИМСЕТҮЛЕ** *с.* **1.** Кимсетә торган; кимсетеп, түбәнсетеп карый торган. --- *үземнең тормыш юлымны хәтерләдем: «заочник» дигән бераз гына кимсетүле исемне күтәреп, шинель киеп, Болак буендагы педагогия институтында йөргәннәрем --- исемә төште.* М.Мәһдиев. *Кулларын баш астына куеп, түшәмгә текәлеп озак ятты инде [Тукай], ләкин балачагындагы кызыклы вакыйгалар да, кимсетүле хәлләр дә, аралашып-буталып, күз алдыннан чабышып кына уздылар.* М.Хуҗин

**2.** *рәв. мәгъ.* Кимсетеп, түбәнсетеп. *Кыз кимсетүле итеп: – Әллә ишетмисеңме, скорый [пароход] ич: җиле белән дә капландыра ул сине.* Г.Гобәй

**КИМҮ** *ф.* 1) Зурлык, күләм, сан һ.б.ш. ягыннан азаю, кечерәю. *Рамазан аеның беренче атнасында ук тәравих намазына йөрүчеләрнең саны бик нык кимеде.* М.Галәү. *[Камил:] Өч көн эчендә биш кадак кимедем.* Һ.Такташ. *Сер сөйләшер дуслар ерак хәзер, Кәндилләрдә мае кимегән.* Ф.Яхин.

2) Көче, куәте, дәрәҗәсе һ.б.ш. ягыннан азрак булып калу. *Әкренләп кояш сүнә барды, күк читенең бизәкләре куера, үзгәрә, алмашына барды; җирдәге төтеннәр кимеде, тавышлар тонykланды.* Н.Фәттах. *Илсөярдә курку кимеде кимүен, ләкин сәер бабай тагын да сәерләнә төште.* Г.Гобәй. *[Имченең] Фәриткә дә әзрәк файдасы тиде шикелле: тәненең уң ягы җилсенеп торуы сизелерлек кимеде.* З.Мифтахов

3) Әһәмияте, сыйфаты, тоткан урыны ягыннан түбәнәю, кечерәю (эшчәнлеге, кыйммәте һ.б.ш.). *Октябрьдан соң Г.Камалның иҗат эшчәнлеге кимемәде, киресенчә, көчәйде генә.* М.Гали

**Кими бару** Акрынлап кимү; торган саен тагын да кимү. *Ындырның бер башыннан икенче башынача тезелеп --- торган биек кибәннәр кими баралар.* Г.Ибраһимов. *Кешелек тә картаеп, аның да балалыгына хас ихлас сыйфатлары кими барамы?* Ш.Галиев

**Кими башлау** Кимергә тотыну. *Тора-бара кешенең аруыннанмы, аның эчке рухи көче кими башлап, ул инде түбәнрәк кимәлдә яшәүгә дә риза булуданмы?* М.Вәлиев

**Кими төшү** Тагын берникадәр кимү. *Укучылары беркадәр кими төшсә дә, татар әдәбияты әдәбият буларак бу елларда әллә ни оттырмады дип уйлыйм.* Р.Фәйзуллин

**Кимеп бару** Торган саен кимү; акрынлап берникадәр кимү. *Учтагы комның һәркөн саен кимеп баруы Фәниярны да, Илсөяне дә куркытмады.* Ф.Яруллин

**Кимеп бетү** Бик нык кимү; тәмам кимү. *Көн кичкә авышканда, юлаучылар да кимеп бетте.* Г.Әдһәм. *Хөкүмәт соңгы елларда гына, ветераннар кимеп беткәч кенә селкенә башлады.* Татарстан яшьләре

**Кимеп калу** Ниндидер тәэсирдән соң кимегән хәлдә булу. *Бер-беребезгә сыенышып капка төбендә озак утырабыз, өйгә керсәк, шатлыгыбыз кимеп калыр сыман.* Ф.Яруллин

**Кимеп китү** Соңгы арада кимү. *Сугыш вакытындагы доходлар да кимеп китте: инде бәрәңге сатып, кием алыштырып баеп булмый.* М.Мәһдиев

**Кимеп кую** Тиз арада кимү. *Сидектә тоз бер бөтен уннан биш процент*

*кына булырга тиеш. Ә минекендә бер бөтен уннан алтыга җитә язган. Ә менә минераль матдәләр йөздән бер процентка кимеп куйган әле.* Ф.Баттал

**КИМ-ХУР** *с.* **1.** 1) Башкаларга караганда начар, түбәнрәк хәлдә булган. *Менә бит әле каһәр төшкән лагерьда да ким-хур түгелмен.* Г.Фәхретдинов

2) Оятлы, хурлыклы булган, хурлыкка, оятка калган. *Әгәр ким-хур санамыйча, берәр юл җавап язарга мәрхәмәт кылсаң, шул таш астына иртәгә ун сәгатьтә куюыңны үтенеп калучы, күңел вә җаннан гашыйк Хисаметдин.* М.Акъегет

**2.** *и. мәгъ.* Һәртөрле оятлы, хурлыклы хәлләр. *Ул [карчык] әле тагын да яши алган булыр иде, ләкин якыннарын югалту, кешеләрдән күргән ким-хурлар әзсез генә узмаганнар иде.* А.Нәҗми

◊ **Ким-хур булу** 1) Башкаларга караганда түбәнрәк, начаррак хәлдә булу, яшәү. *Бездә яшәр Рәйхан, киендерербез, укытырбыз, ким-хур булмас.* Д.Каюмова; 2) Оятка, хурлыкка калу. *Ул [Җәмилә] бөтен нәрсәне кеше арасында «ким-хур булмау, йөз кызартмау» өчен генә эшли.* М.Гали. *– Юк ла инде, – дип канәгатьсезлек белдерде Вәлиулланы китерә килгән бригадир. – Ким-хур булмассың*! Ф.Яхин. **Ким-хур итү** Мыскыллау, мәсхәрәләү, кимсетү. *[Рәшидә:] Фәһим абыең әйтә, Рәхимҗан да үз улым кебек булыр, ким-хур итмәм, ди.* Сөембикә. **Ким-хур күрү** Түбәнсетеп, мыскыллап карау. *Малым бар дип, фәкыйрьне күрмә ким-хур, Сүзем кадерле дип, һич булма мәгъруր.* Г.Утыз Имәни

**КИМЧЕЛЕК** *и.* 1) Җитешсезлек, җитешсез як. *Хәзрәт үзенең гыйлемендә бер дә кимчелек күрми.* Ф.Кәрими. *Кая гына килеп кермәсен, падишаһ шунда кимчелек тапты ---.* В.Имамов. *Ул [Хәй Вахит] күп кенә кыска күләмле (бер-ике пәрдәле) сәхнә әсәрләре яза, аларда тормышыбызда урын алырга дәгъва кылган һәм кешеләрдә очраган аерым кимчелекләрне фаш итә.* Татар әдәбияты тарихы

2) *иск.* Нинди дә булса эштә, берәр төрле хәлдә һ.б.ш. зарар. *Азагы һәм әйбәт булмады: авылымызга солдатлар килеп тулып, тәрбиядә яшәгән вакытларында анлар халыкның бик күп мал-туарына кимчелек китерделәр ---.* М.Галәү. *Ул шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә, Бик каты ихлас белән чынлап ябышты дәрсенә ---.* Г.Тукай

3) *куч.* Мохтаҗлык, авырлык, җитмәүчелек. *Кимчелек күрми яшәү*

**КИМЧЕЛЕКЛЕ** *с.* Кимчелеге, җитешсезлеге булган. *Ничек кенә мактасаң да, демократиянең йомшак, кимчелекле яклары бар.* А.Тимергалин. *Гөлсинай аның өчен бердәнбер кимчелексез, камил гүзәл хатын-кыз иде.* А.Нәҗми

**КИНАЯ** *и. гар.* 1) Читләтеп әйтелгән, сүз; аллегория. *Чалның тапкырлы кинаясе мәҗлеснең хушына китте.* Г.Ибраһимов. *«Офицер чакта өйләнгән булсаң, шундый кыз алырга синең дә көчең җитә иде», – дигән киная иде бу.* М.Юныс

2) Нәрсәгә дә булса ишарә; ирония. *Мәҗлестәшләре аңар елмаеп карадылар да, киная белән мыскыллап: – Кая киттең? – диештеләр.* С.Сүнчәләй

**КИНАЯЛӘ́Ү** *ф.* 1) Турыдан-туры әйтмичә, нәрсәгәдер ишарә итеп, читләтеп сөйләү. *[Габделхәй] Кинаяләп, көйрыклап сөйләргә һәм үзен бик үткер күрсәтергә тырыша.* Ш.Камал. *– Нинди сөенче китерде инде сылу бикәмнең чапкыны миңа? – диде Бәһрам бәк, кинаяләп.* М.Хәбибуллин

2) Ирония белән әйтү, төрттерү. *Әйе, ул [Былбыл] да Зариф кинаяләп әйткән – «аннан бала табарга хыяллана» торган кызларның берсе.* А.Юнысова

**Кинаяләп кую** Берникадәр кинаяләү; аз вакыт кына кинаяләү. *Тукай да, Туфан да, Такташ та, Җәлил дә була алмадым, ди дә, «Роберт Миңнуллин булу да бик авыр әле монда» дип көрсенеп тә, шигърияттә үз биеклегенне яулау мәртәбәсенә кинаяләп тә куя шагыйрь.* Х.Назар

**Кинаяләп тору** Даими яки әледәнәле кинаяләү; кинаяләү хәлендә булу. *Халыкча шаярып, кинаяләп тормый гына әйтсәк: [ул] алынасы биеклекләр алынып, басыласы урыннар басылгач, --- кабат кайчандыр яуланган шушы биеклеккә әйләнеп кайткан урынбасар.* Җ.Дәрзаман. *Әмма Канәгатьнең әле кинаяләп торырга вакыты юк.* А.Хәлим

**КИНАЯЛЕ** *с.* 1) Читләтеп әйтелгән, читләтеп сөйләнгән; аллегорик. *Аның [Тукайның] нечкә кыллы лирикасы, камчылы сатирасы, кинаяле юморы, тәнкыйди эшчәнлеге, үткен публицистикасы – һәммәсе игътибар үзәгендә булырга тиеш.* Т.Галиуллин

2) Нәрсәгә дә булса ишарәләп әйтелгән; ироническ. *Кызның кинаяле бу сүзләреннән соң, минем тәмам җан тынычлыгым югалды.* М.Шаһимәрдәнов. *Малай торып басты. Йөзендәге кинаяле елмаю шунда ук юкка чыкты.* Н.Акмал. *Тукай тирәсендә базар хәерчесе кыяфәтендә уралып йөрүче Шәүлә бертуктаусыз җөтмәләр кора, эт шикелле иснәнә, кинаяле сүзләр сөйли ---.* Әдәбият

**КИНӘ** *и. фар.* 1) Үч саклау, үчегү; яшертен дошманлык. *Адәмиләр кинәсендин син сакланғыл...* Кол Гали. *Сөюне аяктан ега Көнләү, сүзләү, үч, кинә...* Э.Шәрифуллина. *Бергә булган ул елларга синдә каргыш, кинә... Тик шулай да, кавыштырган апрельгә тимә.* Р.Фәйзуллин

2) Үпкә, хәтер калу. *Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар, Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.* Дәрдемәнд. *Тик бу канәгатьләнүдә, тәм табуда, бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр, ихлас куану түгел, ниндидер салкын кинә, рәнҗү хакимлек итүен абайлаган кебек булдым.* Ш.Рәкыйпов. *Югыйсә бу игелекле, саф күңелле, һәрвакыт көләч абыйга бернинди үпкәм дә, кинәм дә юк иде.* Ә.Рәшит

3) Читләтеп әйтелгән сүз; аллегория. *Равил Фәйзуллин иҗатында кинәсе дә җитәрлек, инәсе дә бәгыреңне тишәрлек. --- «Җаныңныңваклыгын сылтама заманга» шигыренең исемендә үк кинәсе дә, инәсе дә күз уңында.* Т.Галиуллин

◊ **Кинә куу** *к.* **кинә тоту**. **Кинә саклау** *к.* **кинә тоту**. --- *Сүзгә мавыгып, озынгарак суза калсам, күңеленә авыр алмаса иде укучым, кинә сакламасын, кичерә генә күрсен иде.* К.Миңлебаев. *Әнә шундый кинә саклый белмәгән ха-*

*тыннарны минем җир йөзендә бүтән беркайда да күргәнем юк.* В.Астафьев.

**Кинә тоту** Яшерен дошманлык, эч кере саклау, ачу, үч саклау. *Әгәр дусларым вә юлдашларым күп булсын дисәң, кинә тотма.* К.Насыйри. *Яманнарның яманы – кинә тотмак.* Т.Ялчыгол. *Ул һаман миңа кинә тотып йөри, кинә сакларга яратмыйм мин.* Н.Исәнбәт

**КИНӘДАР** *и. фар. иск.* Яшерен үч алучы: үч алырга яратучы, кинә саклап йөрүче

**КИНӘЛЕ** *с.* 1) Кинә белдерелә торган, кинәсе булган. *Кинәле сөйләм «ярдәмгә килмәсә», җанны кем күргән дә аның ваклыгын яисә эрелеген кайсыбыз үлчәп караган дип тә дәгъвалап булыр иде.* Т.Галиуллин

2) *к.* **кинәчел**. *Кинәле кеше – энәле кеше.* Әйтем

**КИНӘНДЕРГЕЧ** *с.* Кинәндерә, куандыра, шатландыра торган, куандыргыч. *Кинәндергеч хәбәрләр*

**КИНӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Кемне дә булса шатландыру, куандыру. *Ләкин малай җиденче классны тәмамлауга --- артык укырга теләмәде. Әмма эш белән дә алай бик кинәндермәде.* Р.Төхфәтуллин. *Шулай да бу Мәрфуга килен эшләп кинәндерми, --- бер нәрсә ярамаса, хәзер тырт-мырт, тырт-мырт итә, үпкәләп, әче телләнә башлый.* Г.Ибраһимов

2) Берәр нәрсәгә булган зур ихтыяҗны канәгатьләндерү, тормышка ашыру. *«Рәхмәт! Рәхмәт [Советка]! Кинәндерделәр җиргә!» – дип сөйләнде [Гафият].* И.Гази

**Кинәндереп җибәрү** Көтмәгәндә кинәндерү. *Бу шатлыклы хәбәр барыбызны да кинәндереп җибәрде*

**Кинәндереп кую** Көтмәгәндә кинәндерү

**Кинәндереп тору** Даими рәвештә кинәндерү; шундый хәлдә тоту. *Дәртле уенның әле генә татыган рәхәте бөтен тәнемне биләп, үзалдына кинәндереп, күңелләрне җилкендереп тора.* Г.Бәширов

**КИНӘНЕЧ** *и.* Берәр нәрсәдән канәгать булганда, рәхәтлек тапканда барлыкка килгән куаныч, канәгатьлек хисе. *Бар аның сәләт, хәләл көч белән табылганы, шуңа кинәнеч, яшәү мәгънәсе канәгатьлеге биргәне.* Г.Хәсәнов

**КИНӘНЕЧЛЕ** *с. к.* **кинәндергеч**. *Туйның үзендә генә дә ниндидер сөенеч, кинәнечле тылсым бар.* Р.Камал

**КИНӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса канәгать булып куану; күптән көтелгән шатлыкка ирешү. *Апа хәзер берәүдән дә битен яшермичә, мактаганга кинәнеп, бөтенесенә елмаеп тора иде.* Г.Бәширов. *Хәлимә --- шул салмак, сабыр тавышны, күкрәгә түреннән килгән калын тавышны тыңлап кына кинәнер иде.* Л.Ихсанова

2) Нәрсәдәндер күңел хушлану, тулы рухи канәгатьлек алу, рәхәтлек хисе барлыкка килү. *[Җиһан тәтәй:] И, и-и күңелләләр дә булды Сабан туегыз. --- Рәхәтләнепләр дә карап йөрдек инде кинәнеп.* Г.Бәширов. *Кичке мәшәкатьләрен бетергәч, кулына берәр эш ала да шуларга карый-карый кинәнеп утыра.* Л.Ихсанова

3) Берәр нәрсәнең муллыгына ирешеп канәгать булу; тиенү. *Шәмгун карт --- ишетерлек итеп макташтыргалап ала: – Килен килгәннән бирле җылы суга кинәндем. Рәхмәт киленгә, – ди.* А.Шамов

**Кинәнеп китү** Көтмәгәндә кинәнү. *Берне атладым микән, икенеме, туктадым һәм кинәнеп киттем.* М.Әхмәтшина

**Кинәнеп кую** Кинәнгән хәлгә килү. *Айбиби йоклап яткан бала янына керде һәм, бала йөзендә Йосыф кахан төсмерләрен күреп кинәнеп куйды.* М.Хәбибуллин

**Кинәнеп тору** Даими яки регуляр рәвештә кинәнү; хәзер кинәнү хисе кичерү. *Ниһаять, ул оя-оя чикләвек куаклары үсеп утырган калкулык өстенә менеп җитте, күн курткасының төймәләрен ычкындырып һәм соры куян йоныннан бәйләнгән фуражкасын кулына тотып, коньяктан искән җылы җилгә кинәнеп торды.* А.Вергазов

**Кинәнә башлау** Кинәнергә тотыну

**КИНӘСЕЗ** *с.* Кинә тотмый торган, эчкерсез. *Битләрен җил кисеп, кояш өтеп бетергән тыгыз тәнле, яшьләренә күрә шактый таза күренгән, эчләре бер кәррә кинәсез, намуслары балта йөзе кебек туры булган бу абзыйларның бер төрле уйлап, икенче төрле сөйли торган кешеләр түгеллегенә иманым камил иде.* Н.Әхмәдиев

**КИНӘСЕЗЛЕК** *и.* Кинәсез булу; эчкерсезлек

**КИНӘТ** *рәв.* 1) Көтмәгәндә, искәрмәстән, кисәк; капыл. *Боларның берсе, һөҗүмнең кинәт, искәрмәстән ясалуы аркасында, үлем дәрәҗәсендә бик каты яралана.* Ш.Камал. *Ләкин, кинәт, һич тә уйламаганда яңалык туды.* А.Шамов. *Кинәт кычкырма әле, ансыз да эчләрем жу итеп тора.* Н.Исәнбәт. *Яңгыр, кинәт башланган кебек, кинәт туктады да.* Г.Әпсәләмов

2) Кисәк, көтмәгәндә, уйламаганда. *Аның кинәт үлеп китүенең сәбәбен йөрәк ярылудан күрделәр.* И.Хуҗин

3) Текә, кискен. *Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт бер борма ясап, авылның эченә керә язып кала.* Г.Ибраһимов

4) Берьюлы; бердән; дәррәү. *Ике авыл арасындагы үзәннән барганда, сискәндереп, баш очыннан гына кинәт выжт иттереп, кап-кара сыерчык көтүе үтте.* Г.Бәширов. *Җыр ничек кинәт башланган булса, шулай кинәт өзелде дә.* К.Нәҗми

**КИНӘТЛЕК** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса кинәт килеп чыгуы, кинәт булу хәле. *Һөҗүмнең кинәтлеге барысын да аптырашта калдырды.* Мирас

2) Дуамаллык, кызу канлылык, акылсыз тәвәккәллек. *Чынлап та бик яхшы кеше ул безнең Шамил. Кинәтлеге бар барын.* А.Гыйләҗев

**КИНӘТТӘН** *рәв. сөйл. к.* **кинәт**. *[Микәй] Як-ягына карангалап, байтак кына шулай торды да сөяп куйган колгалар өстеннән, кинәттән ук кебек атылып, лапас түбәсенә менеп тә китте.* Р.Мөхәммәдиев

2) Кинәтлек белән, һич көтмәгәндә. *Кинәттән һөҗүм итү*

**КИНӘЧЕ** *и.* Кинә тотучы, кинә куучы

**КИНӘЧЕЛ** *с.* Кинә тотучан, озак үч саклый торган. *Яман кеше – кинәчел.* Мәкаль

**КИНГСТОН** *и. ингл. махс.* Корабльнең су асты өлешендә судно эченә су

кертә торган клапан. *Озак эзли торгач, хыянәтче капитанны машина бүлегендә, пароходны батырырга теләп, кингстонны ачып маташкан җирендә таптык.* С.Сабиров

**КИНДЕР** *и.* **1.** 1) Сабагыннан сүс, пәҗе, орлыгыннан май алына торган берьеллык үлән үсемлек. *Игенчелектән, мәсәлән, җеп эрләү өчен киндер, җитен, ә терлекчелек һәм аучылыктан йон, тире-мех алганнар.* Р.Фәхретдинов. *Авыл халкы арыш, бодай, теш борчагы (чина), борчак, ясмык, солы, арпа, борай (бодайның бер төре), карабодай, тары, киндер һәм азрак җитен үстергәннәр.* И.Тимершин

2) Шул үсемлекнең орлыгы. *Күгәрченнәр киндер чүпли ишегалды чирәмдә.* Җыр. *Күз алдына --- куырылган киндер орлыгы, көнбагыш тараткан атасы килеп баса...* А.Хәлим

3) Шул үсемлек яки җитен сүсеннән эшләнгән тукыма. *Буй җиткән кызлар, сәке асты ачып, киндер станнары корып җибәрделәр, --- киндер сугарга керештеләр.* Ф.Хөсни. *Шәкүр карак киндер кигән, Бүгенгеләр – ак яка.* М.Саттаров

4) Рәсем төшерү өчен кулланыла торган шундый тукыма кисәге. *«Эретеп иркәли торган серле» күзләр хуҗасы гүзәл кыз һәм аның киндердәге рәсеме --- хисләрне кузгатырлык катлаулы структура һәм өслүб бердәмлеге тудыралар.* Т.Галиуллин. *Кулы нәрсәгәдер килеп бәрелде... Остаханә генә икән ләбаса бу, киндер генә...* Р.Харис

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *[Сәгъди абзый] --- үлгән улы Садриның күк киндер күлмәге белән бишмәтен алып, Габдуллага киертергә теләде.* Ә.Фәйзи

**КИНДЕРАШ** *и.* 1) *диал. к.* **киндер 1.** *Иске зиратны куаклыклар, кеше биеклегендәге алабута һәм киндераш баскан.* Я.Шәфыйков. *Ә янәшәдәге ташландык йорт ишегалдында икешәр метрдан ашып үскән наркотик киндераш урманы шаулый.* Ватаным Татарстан

2) Киндер орлыгы. *Киндердән киндер дә була, киндераш та була.* Мәкаль

**КИНДЕРӘ** *и.* Ишелгән нечкә бау. *[Карчык] --- улының оекларын, киндерә бәйләүләрен тагын бер кат кулы белән капшап, тикшереп чыга.* Ә.Фәйзи

**КИНДЕР ТУКМАКЛАУ** *ф. этн.* Яңа сугылган киндерне махсус тукмаклар белән кагып-сугып йомшарту (гадәттә яшь кызлар тарафыннан, өмә тәртибендә, уен-көлке белән башкарылган)

**КИНДЕРЧЕ** *и.* 1) Киндераш үстерүче кеше. *Мин киндерчеләрдән калам.* Р.Батулла

2) Киндер тукучы

3) *сөйл. к.* **киндер чыпчыгы**

**КИНДЕРЧЕЛЕК** *и.* Авыл хуҗалыгының киндер үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Колхоз киндерчелектән ел саен миллион сум чамасы доход ала.* Г.Галиев

**КИНДЕ́Р ЧЫПЧЫГЫ** *и.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан кечкенә генә сайрар кош; *русчасы:* **коноплянка**

**КИНЕМА́ТИК** *с. физ.* Кинематикада карала торган. *Кинематик хәрәкәт*

**КИНЕМА́ТИКА** *и. нем.* 1) *физ.* Механиканың җисемнәр хәрәкәтен геометрик яктан гына, ягъни хәрәкәтне тасвирлаучы ысулларны гына өйрәнә торган бүлеге

2) *күч.* Җисемнең идеаль шартларда хәрәкәтләнүе. *Төяүле арбаның кинематикасы*

**КИНЕМАТО́ГРАФ** *и. гр. махс.* 1) Яктылык сизүчәнлеге көчле булган тасмага хәрәкәттәге объектларны төшерә һәм аларны экранда күрсәтә торган аппарат. *Кинематограф лентасына алу өчен, сценарий язучыларның ярышы игълан ителә.* Казан утлары

2) *к.* **кинематография** (*1 мәгъ.*)

3) *к.* **кинематографист**. *«Алтын мөнбәр»нең еллык фестивале – күп кенә илләрнең кинематографларын, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләрен бергә җыю урыны да.* Ватаным Татарстан

4) *иск. к.* **кинотеатр**. *Көннәрдән бер көн Кәримевләр, әлбәттә, үзләре сизмичә булырга кирәк, кинематографларында «Мөхәммәт оҗмахы» дигән нәрсәне күрсәтмәкче булып игълан тараткannар.* Г.Тукай

**КИНЕМАТОГРА́ФИК** *с.* Кинематографка, кинематографиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Аста вагон тәгәрмәчләренең бик тиз әйләнгәне ишетелә, тәрәзә алдыннан кинематографик кызулык белән кырлар, таулар ялтырап үтеп тора.* Ш.Усманов

**КИНЕМАТОГРАФИСТ** *и. рус* Кинематография белгече, шул өлкәдә эшләүче кеше. *Кинематографистлар киңәшмәсе*

**КИНЕМАТОГРА́ФИЯ** *и. нем.* 1) Махсус аппарат ярдәмендә төшереп алынган сурәтләрне экранда яңадан күрсәтү аша җанлы чынбарлыкны чагылдыру сәнгате; кино сәнгате. *Әдәбият һәм музыка кебек сәнгать төрләренең тарихы гасырлар белән исәпләнсә, кинематографиянекен исә дистә еллар белән генә санарга туры килә.* Н.Юзиев

2) Мәдәниятнең кинофильмнар чыгару һәм аларны тамашачыларга күрсәтү белән шөгыльләнә торган тармагы, бүлеге. *Кинематография сәнгате*

**КИНЕСКОП** *и. ингл. тех.* Телеэкранда сурәт хасил итү өчен кулланыла торган электрон-нурлы көпшә. *Телевизорның яхшы эшләве кинескопка бәйле*

**КИНЕ́ТИК** *с. физ.* Җисемнәрнең хәрәкәт итүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Үзәк лабораториядә байтак кына матдәләрнең термохимик процесста кинетик үзгәрешен сыйфатлаган мәгълүматлар алынган иде.* Э.Касыймов

**КИНЕ́ТИКА** *и. нем. физ.* Теоретик механиканың динамиканы һәм статистиканы эченә алган төп бүлеге

**КИНҖӘ** *и.* Гаиләдә төпчек ир бала; төпчек бала

**КИНҖӘТӘЙ** *и.* 1) Гаиләдә иң соңгы малай

2) Иң кече угылга сөеп, иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе

**КИНО** *и. гр.* 1) *к.* **кинематография**. *Татар халкы тормышыннан куелган икенче фильм – «Койрыклы йолдыз» («Комета»). Аны 1929 елны Казанда «Көнчыгыш киносы»ның режиссёр В.Инкижинов җитәкчелегендәге ширкәте төшерә.* Н.Юзиев

2) *к.* **кинофильм**. *Нургали, райондагы зоотехниклар курсын ташлап, күрше-тирә авылларга кино куеп йөри башлаган иде.* М.Мәһдиев. *Караяр-*

*да тагын бер яңалык: кино тавышын тышка, авыл Советы бинасы каршындагы мәйданга чыгарганнар.* М.Юныс

3) *сөйл. к.* **кинотеатр**. *Театр, кино һәм клуб залларында утлар күптән сүнделәр.* Г.Минский. *Казанда VII Халыкара мөселман кинофестивале башланды ---, Казан кино залларында бәйгедән тыш программа әсәрләре күрсәтелә башлады.* Шәһри Казан

**КИНО-** *нем*. Кушма сүзләрдә «кино», «кинематографик» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *кинокадр, киногазета, кинотамашачы, кинохикәя, киночелтәр, киноартист, киноэкран, кинокамера* һ.б.ш.)

**КИНОАКТЁР** *и. рус* Кинофильмнарда уйнаучы артист. *Кызганыч ки, Татарстанда профессиональ киноактёрлар юк. Театр артистларына исә киногa төшкәндә театр сәхнәсеннән башка форматка күчү авыррак.* Шәһри Казан

**КИНОАКТРИ́СА** *и. рус* Кинофильмнарда уйнаучы хатын-кыз артист; артистка. *Кызның гәүдәсе электр суккандай тетрәп куйды, һәм ул, күзләрен йомган килеш, кулларын Стенлига сузды. ---. Киноактрисаларның ясалма хәрәкәтләрен күреп өйрәнгән Дино да исе китеп: «Ах!» – дип куйды...* А.Тимергалин

**КИНОАППАРАТ** *и. рус* Кинофильмнар төшерү һәм аларны күрсәтү аппараты. *Әйе, кино дигән могҗизаның авылга ямь керткән «дбижугыннан» кала икенче могҗизасы – елтыр киноаппараты белән ишек төбенә кунаклап алган киномеханик үзе була иде.* А.Хәлим

**КИНОАППАРАТУ́РА** *җый. и. рус* Кинематографиядә кулланыла торган (төшерә торган, проекцион, тавыш язгыч һ.б.ш.) төрле аппаратлар, машиналар, станоклар

**КИНОАТЕЛЬЕ** *и. рус* Кинофильмнар төшерү өчен җиһазландырылган махсус бина

**КИ́НОВАРЬ** *и. лат.* 1) Күкертле терекөмеш, кызыл төстәге минерал. *Киноварь ятмалары*

2) *хим.* Күкертле терекөмештән алынган минераль кызыл буяу

**КИНОДРАМАТУРГИ́Я** *җый. и. рус* Кинематография чаралары белән сурәтләп күрсәтү өчен язылган әдәби әсәрләр жанры

**КИНОЖУРНАЛ** *и. рус* Көндәлек тормыш вакыйгаларын чагылдырган аерым эпизодлар, сценаларны эченә алган кыска метражлы кинофильм. *Еш кына занятиеләрдә авыл хуҗалыгына багышланган киножурналлар күрсәтелде.* М.Хәсәнов

**КИНОИНДУСТРИ́Я** *и. рус* Кино сәнәгате; кинофильмнарны җитештерү һәм сату эше. *Киноиндустриядә көндәшлек*

**КИНОИНЖЕНЕР** *и. рус* Кино төшерү сәнәгатендә техник хезмәткәр. *Ә.Шәймәрданов Саба районының Сабабаш авылында дөньяга килә. Ленинград киноинженерлар институтын тәмамлаганнан соң, өч ел Казан кинохроникасы студиясендә эшли.* Мәдәни җомга

**КИНОИНСТИТУТ** *и. нем.-лат.* Киноның төрле өлкәсенә караган белгечләр әзерли торган югары уку йорты. *Ул [Г.Минский] 1934–1938 елларда киноинститутта сценарийлар язу буенча махсус белем ала.* Н.Юзиев

**КИНОКАДР** *и. рус* Кинога төшерелгән аерым бер сурәт (гадәттә ул тарихи әһәмияткә ия булганда атап әйтелә)

**КИНОКАРТИ́НА** *и. рус к.* **кинофильм**. *Гыйльми үзәк тарафыннан үткәрелгән киңәшмәләрдә (мәсәлән, 1928 елдагы киңәшмәдә) татар тормышын һәм көнкүрешен чагылдырган кинокартиналарның булмавын татар совет культурасының җитди бер кимчелеге буларак билгеләп үтәләр.* Н.Юзиев. *Мин әтиеңә язган хатларда үземнең нинди кинокартиналар карагаными язганмындыр, мөгаен. Шул картиналарның исемнәредер ул.* Сөембикә

**КИНОКЛУБ** *и. рус* Кино сәнгатен, кино сөючеләрне берләштерә торган ирекле иҗтимагый оешма. *[Балалар] өчен «Сәламәтлек», «Светофор», «Булачак солдат», «Без синең дусларың, табигать», «Мультфильмнар илендә» кебек киноклублар оештырылган.* Өмет

**КИНОКОМЕ́ДИЯ** *и. рус* Кино сәнгатенең бер жанры; көлкеле, кызык эчтәлекле кинофильм. *[Рамил Кыдрасов] «За двумя зайцами» кинокомедиясен караган булырга тиеш.* Мәдәни җомга

**КИНОКОМПА́НИЯ** *и. рус* Фильмнар җитештерү өчен, техник һәм башка чаралар белән тәэмин итә торган оешма

**КИНОКООПЕРАТИВ** *и. рус* Кинофильмнар җитештерү һәм кинофильмнар прокаты белән шөгыльләнә торган кооператив оешма. *Район кинокооперативы*

**КИНОЛАШТЫРУ** *ф.* Кайда да булса, билгеле бер урында кинотеатрлар, күчмә кинолар оештыру. *Авылларны кинолаштыру*

**Кинолаштырып бару** Акрынлап тиешле бар җирне дә кинолаштыру

**Кинолаштырып бетерү** Барысын да кинолаштыру; кинолаштыруны тәмамлау

**Кинолаштырып чыгу** Барысын да кинолаштыру

**КИНОЛЕ́НТА** *и. рус* 1) Кинофильмның аерым нөсхәсе

2) *сөйл.* Киноплёнка. *Кинолентасыннан тәмле ис килә, соңгы рәтләрдә, аппарат янында гына, мул итеп вазелин яккан, бит урталарын кызарткан кызлар утыра.* М.Мәһдиев

**КИНОЛИБРЕ́ТТО** *и. гр.-ит.* Музыка әсәренең (опера, оперетта һ.б.ш.) тулы тексты формасында төшерелгән кино. *[Г.Минский:] Безне күренекле совет режиссёры Николай Васильевич Грачёв укытты. Мин үзем шунда «Яңавыл кызы» исемле кинолибретто яздым.* Н.Юзиев

**КИНО́ЛОГ** *и. гр.* Кинология белгече

**КИНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Этләрнең токымнары, килеп чыгышы, аларны тәрбияләү үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән

**КИНОМАСТЕРСКОЙ** *и. рус сөйл.* 1) Кинематография өлкәсендә теоретик һәм практик белемнәр алуда беренче һөнәри уку йорты. *Мин Габдрахман ага Минский белән дә очрашып сөйләштем: – Кино белән мавыккан бер төркем яшьләр Казанда ачылган киномастерскойда укып йөрдек.* Н.Юзиев

2) Кинофильмнар төшерү һ.б.ш. өчен билгеләнгән һөнәрханә

**КИНОМЕХА́НИК** *и. рус* Кинофильмнар күрсәтү эшен башкаручы

механик. *Әнә бөтен авыл шул авызын ачса үпкәсе күренгән киномеханикның авызына гына карап тора бит. ---. Һәр малай апасын, һәр егет сеңлесен шушы киномеханикка гына кияүгә бирергә хыяллана.* А.Хәлим. *Ул [Нурми] атна-ун көн стажировка үтте дә киномеханик булып эшли башлады.* Гасырлар авазы

**КИНОМЕХА́НИКЛЫК** *и.* Киномеханик һөнәре. *[Нурми] берничә авылдашы киномеханиклыкка укырга китәргә рөхсәт сорап яза башлаган гаризасын, «армиягә җибәрүегезне сорыйм» дип төзәтте дә хәрби комиссарга тоттырды.* Гасырлар авазы

**КИНОМОНТАЖ** *и. нем.-фр.* Видео һәм аудиоматериалны монтажлау – башлангыч материалны яңадан эшкәртү процессы (нәтиҗәдә башка бербөтен материал барлыкка килә). *Пьесада драматик хәрәкәт диалог аша гына тормышка аша. ---. Диалогны киномонтаж тулыландыра* ---. Н.Юзиев

**КИНОНОВЕ́ЛЛА** *и. рус* Кыска сюжетлы кинофильм. *Мавыктыргыч кинуновеллалар*

**КИНООПЕРА́ТОР** *и. рус* Кинога төшерү эшен турыдан-туры башкаручы белгеч

**КИНООПЕРА́ТОРЛЫК** *и.* Кинооператор һөнәре. *Аның [Әлфәритнең] кинооператорлыкка укуы, күпләгән кинофильмнар төшерүдә катнашуы бушка китмәгән, ул картиналарында сюжетны оста кора.* Мәдәни җомга

**КИНОО́ЧЕРК** *и. рус* Документаль кино сәнгатенең бер жанры. *Баку киностудиясендә Г. Минскийның сценарийлары буенча нефтьчеләр турында берничә документаль киноочерк --- куела.* Н.Юзиев

**КИНОПАНОРА́МА** *и. нем.-гр.* Панорамалы кинофильмнар күрсәтә торган кинотеатр

**КИНОПЛЁНКА** *и. сөйл. рус* Кинематографиядә кинокартинаны төшерү яки бастыру өчен кулланыла торган яктылык сизүчән тасма; кинотасма. *Рәхимов Бакый Сибгатулла улы – Советлар Союзы Герое. 1938 елда Казан киноплёнка заводында слесарь булып эшли башлый.* Балтач энциклопедиясе

**КИНОПО́ВЕСТЬ** *и. рус* Чагыштырмача катлаулы сюжеты күптөрле вакыйгаларга корылган кино сәнгате әсәре. *Киноповесть комсомолец Гарифларның җиңүе --- белән тәмамлана.* Н.Юзиев

**КИНОПОРТРЕТ** *и. рус* Чынбарлыкта булган кешене кинематографик сурәтләү. *Танылган рәссамның кинопортреты*

**КИНОПОЭ́МА** *и. рус* Кино, телевизион фильмнарның әдәби нигезен тәшкил итә торган зур поэтик әсәр. *Әгәр безнең матбугатта да кинолибреттоларга яшел семафор ачылса һәм язучыларның киноны күздә тотып язылган әсәрләре – кинопоэмалары, сценарийлары басылып торса, язучылар кино сәнгатенә ныграк игътибарлы булырлар ---.* Н.Юзиев

**КИНОПРОИЗВО́ДСТВО** *и. рус* Кинофильмнар җитештерү, эшләү, булдыру сәнәгасе. *[«Камил» сценарие] --- кинопроизводствоның беренче дистанцияләрен, барьерларын җиңеп үтә.* Н.Юзиев

**КИНОПРОЕ́КТОР** *и. рус* Кинофильмнарны экранга күчерү максаты белән кулланыла торган җайланма, аппарат. *Әнә ул [киномеханик] --- кинопроекторыннан агылган нурлар көлтәсендә ниндидер серле кәтүкләр әйләндереп --- безне һушсыз итә.* А.Хәлим

**КИНОПРОКАТ** *и. рус* 1) Кинотеатрлар челтәрендә фильмнарны күпләп күрсәтү

2) Кинотеатрлар системасы

**КИНОРЕЖИССЁР** *и. рус* Фильмны куючы, кинокартина режиссёры. *Арадан берсе, министр иде булса кирәк, белдеклелеген күрсәтергә теләпме, сүз кыстырырга кирәк тапты тагы: – Менә ничек! Михалковның – кинорежиссёрның – замы булып эшлисезме?* Р.Мөхәммәдиев. *Иҗат баскычын кино сәнгатеннән башлап җибәргән кинорежиссёрның портфелендә сәхнә әсәрләре шактый җыйналган инде.* Ватаным Татарстан

**КИНОРЕКЛА́МА** *и. рус* Кинофильмның башында яки тәнәфес вакытында куелган реклама

**КИНОРО́ЛИК** *и. рус* Мәгълүмат, реклама һ.б.ш. эчтәлектәге кыска метражлы фильм. *Хроникага нигезләнгән кинороликлар*

**КИНОРОМАН** *и. рус* Кинематографик жанр; киң вакыйгаларны, күп геройларны үз эченә алган нәфис фильм. *Кинороман ике кисәктән тора*

**КИНО СӘНГАТЕ** *и.* Чынбарлыктагы вакыйгаларны реаль, уйдырма, яки мультипликация чаралары ярдәмендә кинога төшерү белән характерлана торган сәнгать төре. *Кино сәнгатенең үсеше, шул рәвешчә, татар әдәбияты һәм язучылары алдына яңа бурычлар, яңа эстетик таләпләр куя. Кино сәнгате халыкны гына түгел, язучыны да эстетик тәрбияләүдә актив катнаша.* Н.Юзиев

**КИНОСТУ́ДИЯ** *и. рус* Кинофильмнар төшерү, аларны чыгару белән шөгыльләнә торган предприятие (кинофильмның сценариен иҗат итүдән башлап фильмның күчермәсен алуга кадәр барлык эш шунда башкарыла). *Баку киностудиясендә Г. Минскийның сценарийлары буенча нефтьчеләр турында берничә документаль киноочерк --- куела.* Н.Юзиев. *Спектакль дәвамында видеокамера тотып хыялланып йөргән егетне өметле эшләре өчен киностудиягә чакыралар.* Сабантуй

**КИНОСЦЕНА́РИЙ** *и. рус* Кинофильм төшерүгә нигез итеп алына торган әдәби әсәр. *Җ.Фәйзи агада сакланган материаллар А.Шакировның әдәби эшчәнлеген дә ачыклыйлар. Анда --- «Салам Торханнар» исемле киносценарий кульязмасы һәм «Яшь карчык» исемле дүрт пәрдәлек пьесасы да бар.* Н.Юзиев

**КИНОТАСМА** *и.* 1) Кинематографиядә кинокартина төшерү өчен кулланыла торган яктылык сизүчән тасма, кинолента

2) *к.* **кинофильм**. «*Поэт на все времена» – татар шагыйре Һади Такташның тормышы һәм иҗаты турында публицистик-нәфис фильм. Аның шигырьләре кинотасманың нигезенә салынган.* Сәхнә

**КИНОТЕАТР** *и. рус* Халыкка кинофильмнар күрсәтү өчен махсус җиһазландырылган җәмәгать бинасы. *Язга таба шәһәр кинотеатрында яңа*

*фильмнар күрсәтә башладылар.* Г.Галиев. *Гайшә белән Самат өйләнешкән елны, бөтен Уралда беренчеләрдән булып, биредә табышлы кинотеатр ачылыр, аңа «Магнитка» дип исем бирерләр.* Ф.Бәйрәмова

**КИНОФЕСТИВАЛЬ** *и. рус* Төрле ил кинематографистлары арасында хезмәттәшлек урнаштыру, тәҗрибә уртаклашу, иң яхшы фильмнарны сайлап бүләкләү өчен үткәрелә торган тамаша, ярыш, кино сәнгате әсәрләренең смотры. *Халыкара мөселман кинофестивале Татарстан кино төшерүчеләрендә зур кызыксыну уята.* Мәдәни җомга

**КИНОФИКА́ЦИЯ** *и. рус к.* **кинолаштыру**

**КИНОФИЛЬМ** *и. рус* Экранда күрсәтелә торган кинематографик әсәр. *Чыннан да, ул Гөлсем апа күреп белгән, кинофильмнар, рәсемнәр аша таныш булган, сугышка кадәрге Мәскәү түгел иде.* Г.Гобәй. *Әгәр дә киләчәктә кем дә булса Шамил Усмановның легендар шәхесе турында --- кинофильм иҗат итәргә алына икән, менә бу трагик риваятькә нигезләнә ала.* Р.Мостафин

**КИНОЧЕЛТӘР** *и.* Кинофильмнарны кинотеатрларга махсус график нигезендә җибәрү белән шөгыльләнә торган оешма. *Район киночелтәре эшчәнлеген тәртипкә китерү*

**КИНОЧЫ** *и. сөйл.* Кинофильмнар күрсәтү эшендәге хезмәткәр, киномеханик

**КИҢ** *с.* **1.** 1) Иңе, аркылысы зур; *киресе*: **тар**. *Идел бит ул, тирән бит ул. Тирән бит ул, киң бит ул.* Җыр. *Ә түтәлләрдән киң генә сукмак, бакчаны буеннан-буена кисеп, иң түргә кадәр сузылып китә.* Ә.Еники. *Без идарә турындагы киң тыкрыктан икенче урамга чыктык.* Х.Сарьян

2) Җәйрәп яткан, күп урынны биләгән, иркен. *Иске Русия мәмләкәтендә, бөек Башкортстан туфрагында, Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирендә --- бер авыл бар.* Г.Ибраһимов. *Диңгез кебек иркен, киң болында Кызык та соң Сабан туенда.* Н.Исәнбәт. *Ырымбурны сулда калдырып, Тозтүбәгә чыктык, аннан инде бик ныклап киң дала башланды.* З.Зәйнуллин

3) Кысынкы булмаган, иркен. --- *чаптырып, Шибайның салам түбәле каралтылар белән әйләндерелгән киң, зур йортына керделәр.* Г.Ибраһимов. *Киң бүлмә. Киң ишегалды*

4) Иркен, кысып тормаган (өс һәм аяк киеменә карата). *Кайдан таптың бу бишмәтне? Бик тар. Киң, иркен кием кирәк мондый җирдә.* Г.Гобәй. *Нәкъ сураттәгечә киң ыштанлысы --- кыңгыравыклы бүреген салды да, җирән чәчен күрсәтеп, бил түбән иелеп алды.* Ә.Фәйзи. *Киң кунычлы зур итекләр, киндердән тегелгән гимнастёрка белән ул [реверанс] әллә ничек ямьсез чыкты.* Ш.Усманов

5) Өсте җәенке, яссыланып торган. *Киң агач савыт тулы катык, тигезләнеп, бавыр кебек каты оеган, пычак белән кис тә ал.* Г.Ибраһимов. *Киң, юка ташлар*

6) Аяк яки кул хәрәкәтләренең эре һәм салмак булуы белән аерылып торган. *Киң колач белән йөзү*

7) Бер нәрсә белән дә чикләнмәгән, тулы. *Октябрь революциясенә кадәр музыка татар культурасы үсешендә киң хокук белән файдалана алмады.* М.Җәлил. *Өмет тә киң, кесә дә тирән – акча гына аз.* Ф.Хөсни

8) Күләме белән зур, күп нәрсәләрне эченә алган, барлык. *Һади Такташ үз иҗатының башында ук, борынгы Шәрык әдәбиятын яхшы белүенә карамастан, киң халыкка аңлаешлы саф татар телендә язарга керешә.* Мәдәни җомга

9) Тирән, күпкырлы (белем һ.б.ш.). *Киң белеме, табигый зыялылыгы белән эшләгән даирәсендә дә зур абруй казана ул.* Мирас

10) Бөтен кеше өчен, күпчелек өчен билгеләнгән. *Безнең илебездә башлангыч һәм урта мәктәпләрнең киң тармагы булдырылган.* Мәдәни җомга

11) Җәенке, җәенкеләнеп торган. *[Шофёр] киң монгол битле, шадра йөзле кеше икән.* М.Мәһдиев. *Аның --- бераз кытайны хәтерләтә торган киң карасу йөзе, җәенке борыны --- күренү белән һәммә кешенең күзен тарттылар.* Г.Ибраһимов. *Әхмәтша абзый зур, киң учлары белән тезләренә таянып карангалап алды да янчыгын чыгарып тәмәке төрде.* И.Туктар. *Бабай белән оныгы – икесе дә олпат гәүдәле, киң күкрәкле, төптән юан чыккан зат иделәр.* З.Зәйнуллин

12) Бай эчтәлекле. *Хәдичәтти әнә шулай исемсез калды. Бу сүз – Хәдичәтти сүзе – башка хатыннарның исеменнән зуррак, киңрәк мәгънәдә иде.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Иркенләп, иркен һәм уңай булырлык итеп, рәхәтләнеп. *Ике кулы гүя ике канат иде аның шул мизгелдә: колачын киң җәеп трибунаның як-ягына таянган да менә-менә алга ыргылырга, очарга җыена диярсең.* Р.Мөхәммәдиев

2) Шактый, күп. *Тукай --- татар фольклор байлыгыннан шигъри иҗатында киң файдаланды.* Г.Нигъмәти. *«Октябрьгә кадәрге татар театры» дигән китапта безнең тарафтан Г.Исхакый пьесалары һәм аларның сәхнәгә куелу мәсьәләсе беренче тапкыр шактый киң яктыртылды.* Мирас

3) Күпләрне җәлеп итәрлек итеп, мулдан, зур масштабта. *Бикьярның күбе кебек, Шибай да көязләнергә, киңрәк торырга ярата иде.* Г.Ибраһимов

4) Тирәнтен, нык өйрәнеп, тулы килеш. *Бу хезмәт татар тел белемен киңрәк һәм тирәнтенрәк өйрәнү өстендә эшләүчеләргә бер кулланма булып хезмәт итәргә мөмкин.* В.Хангилдин. *Без Исхакыйны бөтен яклап, тулы килеш өйрәнергә тиешбез, тикшеренүләрне туктаусыз, тирәнрәк, киңрәк планда дәвам итәргә кирәк.* Мирас

◊ **Киң катлам** Күпчелек, масса; бик күпләр; бөтен халык. *Киң катлам укучы халык Тукай әсәрләрен ярата.* Н.Исәнбәт. *Киң катлам укучы өчен чыгарылган тарихи әсбапларда, дәреслекләрдә татар тарихы гел берьяклы яктыртылды.* Т.Галиуллин. **Киң колач алу** Берәр эш яки хәрәкәтнең зур көч алуы, киң таралуы. *Бездә 1905 елдан соң татар матбугаты киң колач алды.* Мирас. *Ватан сугышыннан соңгы дәвердә андый әдәби баганышлар киң колач алган иде.* Мәдәни җомга. **Киң колачлы** 1) Зур белемле, төрле

өлкәләрдә эш алып бара торган. *Мидхәт Кәримович киң колачлы галим иде, аның дистәләгән фәнни хезмәтләре бүген дә зур әһәмияткә ия.* И.Таһиров; 2) Масштаблы, үзенә күпләрне җәлеп иткән; 3) Күпьяклы; мәсьәләне һәрьяклап яктырткан. *Программада куелган киң колачлы, бөтен халык өчен мөһим һәм әһәмиятле мәсьәләләр халыкның дәртен уятып, йөрәгенә гайрәт өстәде.* Г.Әпсәләмов. **Киң күңелле** Юмарт, ачык табигатьле, кешеләргә яхшылык теләүче, олы җанлы, хөсетсез (кешегә карата). *Ай, кодагый! Бигрәкләр дә киң күңелле кеше икәнсез!* Ф.Яруллин. *Мидхәт Кәримович һәм шулай ук киң колачлы һәм киң күңелле галим З.И.Гыйльманов безнең Советның иң абруйлы членнары булдылар.* И.Таһиров. *Әйе, булдык без Арча якларында. Күрдек бу киң күңелле әйбәт кешеләрне.* Ф.Хөсни. **Киң сулыш белән** Бөтен күкрәк белән, тирән итеп. *Һәм ул аны [көйне] киң сулыш белән гаҗәп иркен, тирән, моңлы итеп җырлый белә иде.* Ә.Еники. **Киң урын алу** *к.* **киң колач алу**. *Мирфәйз Бабаҗанов репертуарында башка төрки, аерым алганда, казах халкының да җырлары киң урын алган булган.* Мәдәни җомга

**КИҢӘЕП** *рәв.* 1) Озаклап, иркенләп, тәфсилләп, ашыкмыйча, җайлап кына. *Жан бүген киңәеп шаяртырга теләми иде.* Ш.Рәкыйпов. *Ничектер, киңәеп сөйләргә җай килмәде.* Г.Ибраһимов

2) Бик күпләргә мәгълүм булып, таралып. *Әгәр ул хәбәр киңәеп таралса, нәрсә булыр?* Ш.Камал

**КИҢӘЕШ** *и.* Киңәю күренеше. *Матдәләрнең җылылыктан киңәеше*

**КИҢӘЙТЕЛҮ** *ф.* **1.** *төш. юн. к.* **киңәйтү**

**2. киңәйтелгән** *с. мәгъ.* Күләме, эчтәлеге белән гадәттәгедән зуррак, тулырак. --- *Гыйнвар ае азакларында «Казан утлары» журналы редколлегиянең киңәйтелгән утырышын үткәрде.* Т.Галиуллин. *Шушы кыска романның киңәйтелгән һәм тәфсилле варианты рәвешендәрәк языла башлаган, әмма төгәлләнми калган «Мулла бабай» романы турында да --- шушыларга охшаш фикерләр әйтергә мөмкин булыр иде.* И.Нуруллин

**Киңәйтелә бару** Торган саен ныграк киңәйтелү. *Ике кишәрлек уртасындагы ызан ел саен киңәйтелә бара*

**Киңәйтелә төшү** Тагын да бераз киңәйтелү

**Киңәйтелеп тору** Әледән-әле, гел киңәйтелү

**КИҢӘЙТКЕЧ** *и. махс.* Нәрсәне дә булса киңәйтә торган нәрсә (җайланма һ.б.). *Торбаларны киңәйткеч. Бораулау киңәйткече*

**КИҢӘЙТҮ** *ф.* **1.** 1) Киңлеккә арттыру, киңрәк итү, зурайту. --- *Мондагылар арба тәртәсен күтәреп ясалган күләнкене тагы бераз киңәйттеләр дә --- катык белән икмәк ашарга тотындылар.* Г.Ибраһимов. *Ул гаражны киңәйтү турында сүз кузгатты, әлеге машина да авылда торырга тиеш иде.* А.Гыйләҗев. *[Ибраһимов:] Менә карагыз, бу күппочмакны мин теләсә ничек киңәйтә һәм тарайта алам.* Җ.Тәрҗеман

2) Элек булганга җитмәгәнне өстәү, тулы иттерү, тулыландыру. *Итәк кыектан тора. Кыекны төзү ысулын аңласагыз, аны ничек итеп киңәйтүне һәм озайтуны тиз төшенерсез.* М.Мөхәммәт. *Кантун чагында Шибай ул тыкрыкны бикләтте дә, сигез сажиньны үзенә кушып, йортын киңәйтте.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Әдәбият-сәнгать әсәрләрендә эчтәлекне тирәнәйтү, баету. *Татар театры төзелеп эшли башлагач ук, Г.Камал [үзвәлгә] әсәрләрен сәхнәгә куярлык итеп яңадан киңәйтеп яза.* М.Гали

4) *күч.* Җәелдерү, тирәнәйтә төшү, көчәйтеп җибәрү. *Сәяси юл дөрес, эшләрне тагын да киңәйтү, тирәнәйтү кирәк.* Ш.Камал. *Киресенчә, киңәшмәдә тәнкыйть катгый рәвештә тыелган, ләкин кеше фикерен үстерергә, аны киңәйтергә, җәя төшәргә, тирәнәйтергә рөхсәт ителә.* А.Тимергалин

5) Көче, интенсивлыгы ягыннан зуррак итү, арттыру, үстерү. *Чит илләрдәге диңгезчеләрнең хокукларын яхшы белгән Исхак Исламов Россия матросларының хокукларын киңәйтү турында дәүләт органнарына язма тәкъдимнәр белән чыга.* Мәшһүр татар галимнәре. --- *Элекке заманда яшәгән тарихи шәхесләрнең биографияләре, төрле вакыйгалар белән танышу аның [Ш.Мәрҗанинең] дөньяга карашын киңәйтәләр.* Х.Хисмәтуллин

**2. киңәйтеп** *рәв. мәгъ.* 1) Нинди дә булса хәл яки хәбәрне арттырып, өстәп (сөйләү тур.). *Усал телләр [гайбәтне] тагын киңәйтеп, кабартып сөйли башладылар.* Г.Ибраһимов

**Киңәйтә бару** Торган саен ныграк киңәйтү. *Төрле төр чыганаклар белән эш башлап, әдәбият даирәсен торган саен киңәйтә барып, бер-бер артлы берничә тарихи-библиографик әсәр иҗат иткән.* Р.Әмирхан

**Киңәйтә башлау** Киңәйтергә тотыну

**Киңәйтеп бетерү** Бөтенләй, тәмам киңәйтү; бөтенләй киңәйгән хәлгә китерү

**Киңәйтә төшү** Беркадәр киңәйтү. *Су юлын киңәйтә төшеп, тагы берәр метр казыгач, --- электр кабеле суздылар.* А.Тимергалин

**Киңәйтеп җибәрү** Бераз киңәйгән хәлгә китерү. *Әгәр буегыз кечкенә булмаса, алты җөйле итәкне озынлыгының яртысыннан киңәйтеп җибәрергә мөмкин.* Л.Мөхәммәт. *Әнә шул никотин башта бик кыска вакыт эчендә баш миендә һәм башка органнарда кан тамырларын киңәйтеп җибәрә.* Безнең гәҗит

**Киңәйтеп җиткерү** Тиешле дәрәҗәгә китереп киңәйтү. *Чәчүлек мәйданны планга ярашлы рәвештә киңәйтеп җиткерү*

**Киңәйтеп кую** Тиз арада киңәйтелгән хәлгә китерү

**Киңәйтеп тору** Даими яки регуляр рәвештә киңәйтү эшен башкару

**КИҢӘШ** *и.* 1) Ничек эшләргә кирәклек турында үгет-нәсыйхәт, күрсәтмә, тәкъдим. *Киңәш сорасаң, атаңны белгәннән сора.* Мәкаль. *Бу чаклы күп киңәшләрдән соң Миңзифа әбинең башы шеште. Шул бетмәс-төкәнмәс киңәшләр йөге белән пешекче Зифа карчык «Хезмәт»кә килеп төште.* Г.Ибраһимов. *Инде карт кешенең биргән киңәшләрен өстән генә укып үтмәгез, Күңелегезгә алып бикләгез!* Һ.Такташ

2) Билгеле бер мәсьәлә буенча фикер алышу, киңәшү, киңәшләшү. *[Ма-*

*лайның] бу шуклыклары турында Алабугада укучы кызына хат язып, кызын киңәшкә чакырмыйча булдыра алмады.* Ф.Хөсни. *«Кызлар чумарлык, киленнәргә рәхәтләнеп кер чайкарлык булсын!» – диде ул киңәшкә җыелган идарә членнарына.* А.Гыйләҗев. *Судья аягүрә басты. – Суд киңәшкә чыга, – диде ул, папкасын ябып.* Ә.Еники

3) Киңәшләшеп хәл итә торган мәсьәлә, проблема. *Ә мин сиңа зур гына киңәш белән килдем.* Ш.Камал

4) *этн.* Хатын-кызларның туй табынына кем нәрсә пешереп, әзерләп алып килүен билгеләү өчен җыелып сөйләшүе. *Киңәш җыю. Киңәшкә бару*

◊ **Киңәш берегү** Үзара аңлашу, килешү. *Патшаларның киңәше берексен иде дә [тизрәк сугыш туктасын иде].* М.Гали. **Киңәш йөзеннән** Киңәш рәвешендә, киңәш итеп әйтелгән сүз хакында. *Мин аңа киңәш йөзеннән генә әйткән идем, үгет сатып түгел.* Н.Исәнбәт. **Киңәшкә килү** 1) Кеше киңәшен тыңлау. *Картлар киңәшкә килүчән була ул, Гөлсем сеңелем, хак сүз!* Ф.Бурнаш; 2) Бергә киңәшеп акыл табышып, үзара аңлашып бер фикергә килү. *Мөхәммәтҗан солдат һәммәсенең сүзен җөпләп торды да: – Күрше авыллар да шундый киңәшкә килгәннәр, ди: яздырмаска! – диде.* Г.Бәширов. **Киңәш кору** *к.* **киңәшләшү**. *Уралдан, Алатаудан үз илләре Караюргага кайтып җиткәнче, юл буенча Мәрхәбә белән Шәйхел киңәш корып килделәр.* Г.Ибраһимов. *Без, билгеле, киңәш корып, карар чыгарырга җыелмый идек.* Ә.Еники. **Киңәштән чыкмау** Бирелгән киңәш буенча гына эш итү, кеше киңәшен тоту. **Киңәш тоту** 1) Кемнең дә булса киңәше буенча эш итү, шуның киңәшен тыңлау; 2) *к.* **киңәшләшү**. *Гимназия советы, нишләргә белми аптырап, өч көн буе киңәш тотты.* Җ.Тәрҗеман

**КИҢӘШ ИТҮ** *ф.* 1) Киңәшләшү, уйлашу, киңәш сорау. *Мөдәррис үзе бу сәндерәләрнең кирәксезлеген сизсә дә, аларны алып ташлату өчен, бай белән киңәш итүнең уңаен таба алмый.* Ә.Фәйзи. *[Нурый карт:] --- хәзергә өзеп әйтә алмыйм, анасы белән сөйләшик, кардәш-ыруга да киңәш итим, – диде.* Г.Ибраһимов

2) Киңәш бирү, ни эшләргә кирәклеген әйтү. *Безнең Парашаның һәр яктан килгәнлеген: акыллы, матур, тыйнак булуын күреп алгандыр. Мин дә киңәш иттем.* Җ.Тәрҗеман. *Зурысы укый иде, сагыштан укый алмыйча, артка кала башлады. Укытучылар да, врачлар да киңәш итеп, бер кыш укытмый тоттым.* Х.Сарьян

**КИҢӘШЕ́НЧӘ** *рәв.* Кем дә булса киңәш иткәнчә. *Искәндәр, әтисе киңәшенчә, кармак җебен кулына урап, басмадан ярга сикерде.* Г.Минский

**КИҢӘШЛЕ** *с.* Киңәшеп эшләнгән. *Киңәшле йорт таркалмас.* Мәкаль. *Гәрчә мондый чаралар шактый гына казна чыгымнары таләп итсә дә, киңәшле эш таркалмас дигән фикердән чыгып тырышалар...* Безнең гәҗит

**КИҢӘШЛӘШҮ** *ф.* Кемнән дә булса киңәш сорау, берәр мәсьәлә буенча фикер алышу, киңәш тоту. --- *Кечкенә энеләре Шәйгәрдәнне чакырып, өчәү киңәшләштеләр дә, туй үтеп киткәнче, --- абзарда кизүләп каравыл торырга булдылар.* Г.Ибраһимов. *Киңәшләшәсе бик җитди сүзе булуын хәбәр итеп, Зәкия Мирсәетне бер читкә чакырып алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Киңәшләшә башлау** Киңәшләшергә тотыну. *Чакыруны кулга алуга, Мәскәүгә кайчан юлга чыгасыбыз, ничек киенәчәгебез хакында кызып-кызып киңәшләшә башладык.* Безнең гәҗит

**Киңәшләшеп алу** Кыска гына вакыт арасында киңәшләшү. *Хәмитшин абыйлар килеп җитү белән, көрешкәчниткәч, бераз әти гәүдәсенә карап торгач киңәшләшеп алдылар.* Х.Сарьян. *Тау өстенә менгәч, тагын бер кат киңәшләшеп алдым.* М.Усманов

**Киңәшләшеп тору** Даими яки регуляр рәвештә киңәшләшү. *Юлга нәрсә алу, ничек киенү турында киңәшләшеп торасы юк иде.* Г.Гобәй. *Телефоннан шылтыратып, данлыклы табиб Сәлма Габбасовна Вахитова белән киңәшләшеп торам.* Сөембикә

**КИҢӘШМӘ** *и.* Аерым бер мәсьәлә буенча киңәшләшү, фикер алышу максаты белән үткәрелә торган җыелыш. *Бусы киңәшмәнең гадәттәгечә беренче өлеше булды.* Р.Мөхәммәдиев. *Яушев абый өйдә юк, Уфага ниндидер киңәшмәгә киткән, диделәр.* Х.Сарьян. *Аның [бионика фәненең] тарихын бионикага багышланган гыйльми киңәшмәнең беренче утырышы булган көннән исәпли башлаганнар.* А.Тимергалин

**КИҢӘШСЕЗ** *рәв.* **1.** Киңәшмичә, киңәшләшмичә, киңәшмәстән. *Кодаларның күчтәнәчләрен күрсәтергә чыгарганда да, --- һичбер эш Мәрхәбәгә киңәшсез, Мәрхәбәнең ярдәменнән башка үтмәде.* Г.Ибраһимов. *[Сөембикә:] Үзе тапканын минем кулга алып кайтып тоттыра. Киңәшсез бер эш эшләми.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Киңәшмичә эшләнгән. *Киңәшсез эш үкенеч китерер.* Мәкаль

**КИҢӘШ-ТАБЫШ** *җый. и.* Һәртөрле киңәшүләр, сөйләшүләр. *Ул көнне көн буе йортта киңәш-табыш барды.* М.Мәһдиев. *Бик абруйлы кеше булган бабаебыз. Авыл халкы аның белән киңәш-табышка да йөргән.* Мәдәни җомга

◊ **Киңәш-табыш кору** *к.* **киңәш-табыш итү**. *Ир-ат, зур эш башкаргандагыдай, берсен-берсе бүлдереп киңәш-табыш корырга кереште.* Р.Мөхәммәдиев

**КИҢӘШ-ТАБЫШ ИТҮ** *ф.* Берәр эш я мәшәкать төшкәндә бергә киңәшеп акыл табышу, уйлашу. *Бу турыда әти белән киңәш-табыш итеп карыйм әле.* Ф.Әмирхан. *Хәзер сезгә килим әле, машина баскыч янында, барысын да сөйләшеп, киңәш-табыш итәрбез.* Т.Галиуллин. *Киңәш-табыш иткәннән соң, кыз автобус белән китәргә хәл кылды.* Р.Мөхәммәдиев

**КИҢӘШ-ТАБЫШЛАШУ** *ф.* Киңәш-табыш итү. *Миңа шулай, соңынтын сүз булмасын өчен, алдан киңәштабышлашып кую яхшырак.* С.Рафиков

**КИҢӘШ-ТАБЫШСЫЗ** *рәв. к.* **киңәшсез**. *Башта әнисен, киңәш-табышсыз, кешедән хат яздырып, өйнекен тышка чыгарганы өчен ачуланмакчы булды Халидә.* Ф.Хөсни

**КИҢӘШТӘШ** *и.* Киңәшләшә торган якын кеше. *Яннарыңда утырырмын, Киңәштәшең булырмын.*

Ә.Ерикәй. *Иң якын киңәштәшләрем, ярдәмчеләрем булган Галимҗан Нигъмәти белән Гомәр Гали Казанда сайланма җыентыгымны чыгарганнар икән ләбаса.* Х.Туфан

**КИҢӘШ-УҢАШ** *җый. и. к.* **киңәш-табыш**. --- *аерым тора башлагач, абзый кеше ни өчендер аңа үзенең эшгамәле турында бер дә сөйләмәс, элеккечә киңәш-уңаш итмәс булды.* Ә.Еники. *Бер заман киңәш-уңашлар, белешү, сорашулар туктады, икеләнүләр бетте, апайны ярәштеләр.* Г.Бәширов

**КИҢӘШҮ** *ф. к.* **киңәшләшү**. *Исеме табылыр, әнкәйләр белән дә киңәшербез, аларны исем туена чакырырбыз дип уйлады.* Г.Ибраһимов. *Сырга бикә белән киңәшмичә берни эшләргә тиеш түгеллеген белсә дә, ул, бар җаваплылыкны үз өстенә алып, кораллы кызларга боерыклар бирә башлады.* Н.Фәттах. *Гимназиядә нинди яңалык ишетәсең – теләсәң кайсы вакытта минем янга киңәшергә кер.* Җ.Тәрҗеман

**Киңәшә башлау** Киңәшергә тотыну. *Казан олуглары үзара җыелышып, урыслардан ничек сакланырга кирәклеге турында киңәшә башлады.* Һ.Атласи. *Туктадык та киңәшә башладык: – Сразы яланга килеп чыгарга ярамый.* Г.Мөхәммәтшин. *Вәзирләр киңәшә башладылар.* Р.Батулла

**Киңәшеп алу** Берара киңәшү, кыска вакыт аралыгында киңәшү. --- *алар килгәч, манараны ничек-ничек кисәргә дип каты гына киңәшеп алдылар да тиз-тиз чыгып та киттеләр.* Х.Сарьян. *Күршеләре карчыкның болай начарлана баруын күреп хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип, үзара киңәшеп тә алдылар.* Ә.Еники. *Председатель, өстәл аркылы сузылып, картлар белән нидер киңәшеп алды.* Г.Гобәй

**Киңәшеп карау** Тикшерү-белү максаты белән киңәшү. *Шулай да кем белән дә булса киңәшеп карарга булды.* Ф.Яхин. *– Ярар, мин хатын белән киңәшеп карыйм алайса, – дип, Сибгат ага кайтып китә.* Р.Батулла

**Киңәшеп тору** Һәрвакыт киңәшү. *Заманында зур вә исемле полководецлар санында йөргәнгә, ул, гарнизон полководецлары белән дә киңәшеп тормыйча, үзе белгән бинада калды.* М.Хәбибуллин

**КИҢӘШЧЕ** *и.* 1) Киңәш бирүче; консультант. *Киңәшчең олы кеше булсын.* Әйтем. *[Шәмси] Вә ярдәмчесе, киңәшчесе булмаганга, елап-елап намаз укучан, Алладан сораучан булды.* Г.Исхакый. *Ибраһимның иң якын киңәшчесе һәм рухи яктан арка таянычы абыйсы Фатих була.* Р.Әмирхан

2) Дәүләт хезмәтендәге югары вазифа һәм шул вазифага ия зат. *Смушкевич анда хәрби авиация министрлыгында баш киңәшче була, үзе турыдан-туры сугышларда катнаша һәм җитәкчелек итә.* И.Салахов. *Дәүләт киңәшчесе сүзен егерме ел дәверендә илебездә дә, гомумән, чит илләрдә дә милләтебезгә карата карашның тамырдан үзгәрүен ассызыклап йомгаклады.* Мәгърифәт

**КИҢӘЮ** *ф.* 1) Киң булып китү, киңгә әверелү; җәелү. *Башта кояш баешыннан гына чыккан болыт тиз арада киңәйде: --- берничә минут эчендә күк йөзен каплап алды.* Г.Ибраһимов. *Киңәйделәр безнең барган юллар, Тулыланды матур тойгылар.* Ә.Ерикәй. *Киң маңгае тоташ сөяк булып, бәрәңге тукмагы сыман таза очлы ике мөгез белән янга киңәйгән.* М.Мәһдиев

2) *физ.* Күләме арту. *Йөрәкнең стеналары тыгыз һәм эластик булганлыктан, артерияләр бу басымга чыдыйлар һәм тартылып киңәяләр.* Анатомия. *Очкын эләгүгә, теге газ гөлт итеп кабына да, киңәеп, поршеньны этә башлый.* А.Сафин. *Җисемнәрнең җылылыктан киңәюе*

3) Иркенәю, ачылып китү. *Әлиф яткач, урын киңәйде, теге алты малай да арага сыйды.* Г.Ибраһимов. *Тау башына чыксаң, дөнья тагын киңәя...* Г.Исхакый

4) Сан, микъдар, күләм, масштаб һ.б. ягыннан арту, үсү. --- *әллә ничә өлеш зур салам эскертләре баскычбаскыч булып күккә таба үрмәлиләр, озынаялар, киңәяләр, биегәя баралар.* Г.Ибраһимов. *Биек ярларның суга яткан күләгәләре торган саен киңәя һәм караңгылана бара.* Ә.Еники

5) *күч.* Җиңеләю, иркенәю (сулыш, тын тур.). *Егетнең күзләре ачылды, сулышлары киңәйде.* И.Туктар

6) *күч.* Иркенәю, рухи яки физик авырлыктан соң җиңеләю, рәхәтлек сизү. *Таң ату белән рух җиңеләя, күңел киңәя, йөрәкне әрнеткән авыр кайгылар үзеннән-үзе эриләр, таралып каядыр югалалар.* Г.Ибраһимов

7) Киңрәк таралу, киң массаны җәлеп итү, көчәю. *Революция үсәр, киңәер, – ул вакыт җир дә булыр, власть та булыр.* И.Гази

8) *күч.* Үсү, зураеп әһәмияте, көче арту, киң колач алу. *Илле алтыда тагы китереп бер авылны безгә куштылар. Колхоз киңәйгән, зурайган саен, миңа урын тарая барды.* Х.Сарьян. *Татар Ренессансының алтын дәвере – XX йөз башында татар теленең иҗтимагыйсоциаль вазифасы тагын да киңәя, ул яңа көч, куәт ала.* М.Хәсәнов

9) *күч.* Катлаулылану, җитди төс алу, зурга китү (эш, хәл, мәсьәлә һ.б.). *Бу мәсьәлә киңәеп, бервакыт Тимри мулланың --- урланган малны җыеп ятуы хакындагы хәбәр бөтен тирә-якта йөри башлаган.* Г.Ибраһимов. *Сүз --- кульъязмалар тирәсендә барырга тиеш иде. Әмма сүз сөреше шактый киңәйде, әңгәмә киеренке төс алды.* Т.Галиуллин. *Повестьның кысалары киңәя, тема-проблемалары катлаулана, ул күп геройлы, күп планлы әсәргә әйләнә.* Ф.Миңнуллин

10) *күч.* Иркенлек алу, иркенәю, үзе теләгәнчә яшәү. *Сабира дөнья селкетеп тиргәргә тотынды. --- Ләкин вакыт тар иде, киңәя алмады.* Г.Ибраһимов

11) Ныгу, чыныгу, тагы да куәтләнү. *Малайлар үсеп, ныгып, иңнәре киңәеп, егетләнеп, авылга каникулга кайттылар.* А.Гыйләҗев

**Киңәеп бетү** Бөтенләй киңәю, шундый хәлгә килү

**Киңәеп җитү** Тиешле дәрҗәгә килеп киңәю

**Киңәеп китү** Кинәт киңәю; кинәт шундый хәлгә килү. *Кыр эшләре башлануга, ярыш тирәнәйде, киңәеп китте.* Г.Бәширов. *Аның болай да тулы йөзе тагын да киңәеп, тулыланып китте.* А.Әхмәт. *Күкрәге җиңеләеп, сулышы киңәеп китте кызның.* А.Гыйләҗев

**Киңәеп тору** Киңәйгән хәлдә булу. *Атның тын юллары биш тиенлек ба-*

*кыр акча зурлыгы булып киңәеп торалар иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Киңәя бару** Торган саен ныграк киңәю. *Ул [Мәүлә] байтак вакытларга кадәр минем һаман киңәя барган офыгымда янган якты йолдыз иде.* А.Гыйләҗев. *Рус дәүләте күтәрелә, киңәя барган саен, аның кул астындагы рус булмаган халыкларның телләрен өйрәнүгә ихтыяҗ арта.* М.Ногман. *Моңа кадәр кимсетелеп, изелеп килгән күңеле алга атлаган саен яктыра, сулышлары киңәя барды.* И.Туктар

**Киңәя башлау** Киңәергә тотыну. *Аннары коридор киңәя башлый, бормаланып, әле уң якка, әле сул якка тайпыла, ниһаять, тагын да киңәеп, басып барырлык була.* Г.Гыйльманов. *Инде Европада да парсызлык галәмәте киңәя башлады – аның сәбәбе бер генә: холык.* Шәһри Казан

**Киңәя тору** Һаман киңәюен дәвам итү. *Гадәттә, күпчелегебезнең атааналары, әби-бабалары авыллардан булганга күрә, авыл җирлекләрендәге тереләр өчен төзелгән йортлар акрынлап кимүгә таба барса да, ахирәт йортларында «төзелеш» кайный, зират мәйданнары зурая, киңәя тора.* Шәһри Казан

**Киңәя төшү** Беркадәр киңәю, беркадәр киңәйгән хәлгә килү. *Ул хатынының сызылып киткән кара кашларына, чак кына киңәя төшкән килешле матур борынына, алсу битләренә --- иркәләп карады.* Р.Кәрами. *Тарлавык киңәя төшеп, як-якта чыршы, карагай урманы башланды.* Ш.Усманов. *Танымаслык иде Галәви. Йөзе кояшта янган, күкрәге дә киңәя төшкән.* Н.Дәүли

**КИҢӘЮЧӘН** *с. физ.* Киңәергә сәләтле. *Киңәючән җисем*

**КИҢӘЮЧӘНЛЕК** *и. физ.* Киңәючән булу. *Җисемнәрнең киңәючәнлеге. Сыеклыкларның киңәючәнлеге*

**КИҢЕ́НЧӘ** *рәв. сир.* Бөтен киңлегенә, төбенәчә; киң итеп. *Шәһәр думасының ишекләре киңенчә ачык, кешеләр кырмыска шикелле кайнаша.* Ш.Камал

**КИҢЛЕГЕ** *бәйл. к.* **киңлегендә, киңлегендәге**. *Бармак калынлыгы, ике уч киңлеге майлы түш итен алып --- утлы күмер өстендә тотасың.* М.Усманов. *Ә алда ике урам киңлеге боз җәелеп ята.* М.Әмир. *Бармак киңлеге тасма*

**КИҢЛЕГЕНДӘ** *бәйл.* Билгеле бер киңлеккә ия. *Бөтен тирә-якны күмеп киткән көрт, өйнең ишеге, стенасы буйлап ярты аршин киңлегендә бушлык калдыра икән.* Г.Ибраһимов

**КИҢЛЕГЕНДӘГЕ** *бәйл. к.* **киңлегендә**. *Ашның өстендә бармак киңлегендәге май бар*

**КИҢЛЕК** *и.* 1) Киң булу. *Яр Чаллы урамнарының киңлеге, заманча төзелгән мәдәният сарайлары белән сокландыра.* Р.Рахман. *Юлның киңлеге шул килеш кала бирә.* Безнең гәҗит

2) Берәр нәрсәнең аркылы үлчәме, иңе. *Күкнең киңлеге – кояш йөреше белән бер көнлек юл.* Әйтем. *Кайсы гына предметны алып карасак та, без аның өч үлчәнеше, ягъни озынлыгы, киңлеге, биеклеге булуын күрербез.* Җ.Тәрҗеман. *Авыл артындагы үзәнлеккә инде миналардан пехотага һәм танкларга каршы перекрытие ясалган, алтыҗиде метр чамасы киңлектә юлкоридор калдырылып, чигенүче гаскәр шул коридордан гына узарга тиеш иде.* М.Мәһдиев

3) Җәйрәп яктан иркен җир, гаять киң мәйдан. *Значок космик ачышларга, галәм киңлекләрен яулап алуга багышлап язылган, һәм анда 1957–1980 дигән саннар бар иде.* А.Тимергалин. *– Күрәсезме, – диде әнкәләре, – әнә анда, бик еракта, ап-ак киңлекләр аръягында ак калкулыклар башлана.* Р.Мөхәммәдиев. *Юлга таба салынып төшкән башаклар ара-тирә Хәнифәнең ялангач беләгенә ышкылып-ышкылып калалар, тирәякта киңлек, киңлек.* Ф.Хөсни

4) Ара, буш урын, ачыклык, пространство. *Кыю һәм горур, Җәеп кочагын, зәңгәр киңлектә оча яшь лачын.* З.Мансур. *Космик киңлекләрне үзләштерү*

5) *геогр.* Экватордан меридиан буенча (көньякка яки төньякка таба) градуслар белән үлчәнә торган ара. *Теләсә нинди ноктаның географик киңлеген карта яки глобустан табу өчен, аның кайсы параллельдә икәнен белергә кирәк.* Физик география. *Кыш көне мич якмыйча булмый: без бит урта киңлекләрдә яшибез.* А.Тимергалин

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса барлык сыйфатларының җыелмасы, асылы; тулылык, тирәнлек. *Бу бозык, кешелекләрен җуйган кара солдатларга кемлегебезне аңлатып бирә алмасак та, без бүген аларга булышырга әзер торуыбыз белән өстенлегебезне, күңелебез киңлеген раслыйбыз.* А.Гыйләҗев. *Биредә укыган чорда Ф.Әмирхан үзенең яшьтәшләреннән эрудициясе, карашының киңлеге --- белән аерылып тора.* Р.Әмирхан. *Мин Хәдичәмнең гүзәл рухи сыйфатларына – күңеленең сафлыгына, холкының киңлегенә, тыйнаклыгына сокланып яшәдем.* Мәдәни җомга

7) *күч.* Хөрлек, иркенлек. *Монда киңлек, монда җәннәт. Ни кирәкләр бар да бар.* Г.Камал. *Алар [композиторлар] үз халыкларының рухи дөньясын ачу аша иксез-чиксез рухи киңлекләргә чыгалар.* Т.Галиуллин

**КИҢЛӘП** *рәв. сир.* Киң итеп, җентекләп, бәйнә-бәйнә. *Гайшә Паларусовка (гаиләнең бөтен тарихын) болай киңләп сөйләмәде.* Г.Ибраһимов

**КИҢЧӘ** *с.* **1. 1)** Киңәйгән, киң генә, җәенке. *[Яков] буйга кечерәк, киңчә гәүдәле --- егет иде.* М.Әмир. *Киңчә битле өлкән сержант уртага чыкты.* М.Мәһдиев. *Ул урта буйлы, киң генә җилкәле, сыны нәкъ хәрбиләрнекечә төз, җыйнак, йөзе шома, кара тутлы, башкортныкына тартым киңчә-түгәрәк, ләкин борыны бик туры…* Ә.Еники

2) Таза гәүдәле, киң җилкәле. *Асаф иртәгесен военкомат коридорына килеп басачак кырган башлы кара егетләргә күз салды, --- сугышка кадәр егетләр буйлырак, киңчәрәк була иде, хәзер егетләр вакланды.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Киңрәк итеп, зуррак үлчәп. *Киемне киңчә кисү*

**КИҢЧЕЛ** *с. сөйл.* 1) Мулдан тотына торган, юмарт. *Киңчел хуҗабикә*

2) Җәенкеләнеп торган, җәенке. *Яфрак – гарәпчә вәрәкъ аталыр, ул – үләннең камылы тирәсендә һәм башында киңчел булып торган өлеше.* К.Насыйри

**КИҢЧЕЛЕК** *и.* Муллык, житенкелек, иркенлек. *Киңчелектә кимчелек*

*юк.* Мәкаль. *Киңчелек булмый тиңчелек булмый.* Мәкаль

**КИҢЧЕЛЛЕК** *и.* Киңчел булу

**КИОСК** *и. фар.* Әйберләр сату өчен зур булмаган махсус корылма. *Әмма шәһәр чиратны ярата инде. Анда чиратлар болай: иртән эшкә барганда киосктан гәзит-журнал алыр өчен, икенче бер киоскта трамвай талоны алыр өчен...* М.Мәһдиев. *Әнәс аны клуб чатындагы киоскта газета, журналлар караган булып көтеп ала.* С.Сабиров

**КИОСКЁР** *и. рус* Киоскта сату итүче

**КИОСКЫЧЫ** *и. к.* **киоскёр**

**КИП** I *и. рус сөйл.* 1) Берсе өстенә икенчесен салып, төргәк итеп бәйләнгән бер иш әйберләр. *Чыпта киплары. Кәгазь киплары*

2) Күпләп, төркемләп төрелгән әйберләрнең күләм-зурлык үлчәве; түк, бәйләм. *Ел саен Мәкәрҗәдән, Мәскәүдән йөзләп, ике йөзләп кип товар килә башлады.* Ш.Мөхәммәдев

3) *диал.* Печәннән яки саламнан шакмак рәвешендә прессланган түк

**КИП** II *и. диал.* Рәвеш, форма. *Татар календаре шул киптә басыла*

◊ **Кибе бетү** *диал.* Кыяфәте, килешкилбәте югалу. *Чалбарның кибе бетү*

**КИПАРИС** *и. гр. бот.* Кипарисчалар семьялыгыннан көньякта үсә торган, һәрвакыт яшел ылыслы хуш исле биек агач яки куак. *Бу мәңге яшел кипарислар, кактуслар арасында мәңге гомер итәрсең кебек тоела.* Н.Дәүли

**КИПАРИ́СЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Кипарис, туя, артыш, арча кебек ылыслы үсемлекләрне берләштерә торган бер семьялык. *Балавызсыман ак сызыклы ылыс ботакта өчәр-өчәр булып урнашкан. Бу – кипарисчалар семьялыгыннан булган артыш.* Н.Верзилин

**КИПКӘР** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, катнаш урманнарда, урман читләрендә үсә торган күпьеллык дару үләне; киез үләне; *русчасы:* **сушеница**

**КИП-КИҢ** *с. артык дәр. к.* **киң**

**КИПРӘН** *и.* 1) *тар.* Махсус чатыр тукымасы, тышлык. *Җир үп, аңлат, бу бәйрәм шәп корылмыш, һәм Өлкәргә гүя кипрән өртелмеш.* Котб

2) *диал.* Мендәр, ястык, юрган тышлыгы. *Кипрән тегү*

**КИПРӘНЛӘ́Ү** *ф. диал.* Мендәр, ястык кебек әйберләргә кипрән кидерү

**КИПРӘНЛЕ** *с. диал.* Кипрән кидерелгән. *Кипрәнле ястык*

**КИПТЕРГЕЧ** *и.* 1) Язу карасын үзенә сеңдерә, суыра торган махсус кәгазь. *Һәр дәфтәрнең эченә киптергеч куелган*

2) *махс.* Суны яки җиңел генә парга әверелүчән башка матдәне продукттан аеру өчен кулланыла торган җайланма, махсус камера

**КИПТЕРЕНҮ** *ф.* Чыланганнан, юешләнгәннән соң үз-үзеңне яисә киемеңне киптерү. *Кояшлы урында киптеренү*

**Киптеренеп алу** Бераз киптеренү, тиз генә киптеренү

**Киптеренеп утыру** Хәзер киптеренү

**КИПТЕРҮ** *и.* 1) Дымлы әйберләрнең дымын бетерү, коры хәлгә китерү. *Урындык ясыйсы каенны әти, күләгә урында өстен каплап, үз көненә елдан артык киптерде.* Г.Бәширов. *Гөлчирә апа бик җентекләп безнең ашауэчүләребез, --- яз-кыш юешләнеп кайтсак, кием-салымнарыбызны кайда киптерүебез турында бәйнә-бәйнә сораша башлады.* Р.Төхфәтуллин. *Идән такталарын үткән язда ук ярып, күләгәдә киптергәннәр.* Х.Сарьян

2) Озак саклансын өчен, үсемлек, җиләк-җимеш һ.б.ларның дымын, юешлеген махсус рәвештә бетерү, коры итү. *[Шәвәли карт] шунда чәчелгән тәмәкенең яхшысын сайлап, кояшта киптереп эшләде.* Г.Ибраһимов. *Ә без, Зөфәр абый белән икәү генә калып, көннәр буена печән кабартабыз, печән киптерәбез.* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин аны [сфагнум мүген] артык киптермәгез, чөнки артык киптергәндә, ул ваклана һәм дымны сеңдерми башлый.* Н.Верзилин

3) Сазлы урынны махсус җайланмалар ярдәмендә суын суыртып, корыту. *Тундра туфрагында авыл хуҗалыгы культураларын уңышлы үстерү өчен, туфракны киптерергә, җылләтергә һәм мәңге туң катлауның тәэсирен азайтырга кирәк.* А.Фатхуллин. *Казанның Яңа Савин районында сазчыкларны киптереп, күпкатлы йортлар төзеделәр.* Мәдәни җомга

4) Кирәкле дымнан мәхрүм итеп, артык дәрәҗәдә корыту, дымсызландыру. *Ишегалдына бер төркем яшьләр кайтып керде. – Әйдәгез, бакчага кертеп җиргә күмик, кояш чыккач, кыздырып, [гөлҗимеш куагының] тамырын киптермәсен, – диде берсе.* Л.Ихсанова. *Печән өстенең киң күңелле юмарт кояшы, Идел буе халкының киң тугайлардагы бетмәс-төкәнмәс печәнен киптереп арыганнан соң, баер якка авышкан иде.* Г.Бәширов

**Киптерә башлау** Киптерергә тотыну. *Ә, димәк, беренче үләннәрне җыеп, кыш өчен киптерә башларга да озак калмады.* Мәгариф

**Киптерә тору** Ниндидер процесс барышында яки процесс башланганчы киптерү

**Киптереп алу** Бераз киптерү, тизтиз киптерү

**Киптереп бетерү** Тәмам киптерү

**Киптереп кую** Киптереп, әзер хәлгә китерү

**Киптереп утыру** Озаклап киптерү. *Минем зур апаемның өлкән улы Заһир абый кайдадыр юешләнгән оекларын киптереп утыра иде.* Г.Бәширов

**КИПШЕНҮ** *ф.* 1) Бераз кибү, кибә төшү. *[Фидаил:] Чәчен алгач, җылы су салып торып башын юдым. Әзрәк кипшенсен инде дип, мич буенда бераз утырып торды.* Х.Сарьян

2) Тамак кибү, сусау. *Г.Батталов язучының кипшенгән, күм-күм булып күгәргән иреннәренә кашык белән су тамызып тора.* Р.Мостафин

3) Сурыгу, кипшерә төшү. *Аяк аслары тәмам кипшенеп, --- кешеләр инде бөтен язгы эшләрен бетергәч кенә, ике кызымны ияртеп, мин дә бакчага киттем.* Э.Шәрифуллина

4) *куч. сөйл.* Үтә ябыгу, корышу, арыклану. *Шулай бер ел узган, ике ел узган, ди. Ә кыз һаман газап утында янган да көйгән. Чыра кебек кипшенгән, ди.* Н.Дәүли

**Кипшенә башлау** Кипшенергә тотыну. *– Кайтырга вакыт, – диде Сары Пошлак, тиккә тезгән һәм кипшенә башлаган балыкларыннан бодай бөр-*

*текләрен сыпыргалап.* С.Гаффарова. *Ә инде берәр ышык җирдә кипшенә башласа, Марс манзарасы төшерелгән төсле фотоплёнка диярсең – кипкән бер җире яңа төскә керә башлый.* Р.Бәхтияр

**Кипшенеп бетү** Тәмам кипшенү. *Дөрес, баш бүрәнә ягында булыр, кипшенеп беткән мүккә терәлеп торыр.* Сөембикә

**Кипшенеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә кипшенү. *Ахыргача кипшенеп җитмәгән асфальт*

**Кипшенеп калу** Берәр вакыйгадан, тәэсирдән соң кипшенү. *Язучы [Г.Ибраһимов] бу вакытта да авыру, хәлсез була: --- тагын да ябыга, кечерәеп, кипшенеп кала.* Р.Мостафин

**Кипшенеп яту** *сөйл.* Кипшенгән хәлдә булу. *Үксүләрем яусын иде кипшенеп яткан болынга.* Р.Зәйдулла. *Анда яңа уңыш – гәрәбәдәй арыш кипшенеп ята.* С.Зыятдинова

**КИПШЕРТҮ** *ф. з.-сыз* Корып кибү турында. *Җәй-җәй инде: явымтөшемнән соң тиз җилли, тиз кипшертә.* С.Рәфыйков

**КИПШЕРҮ** *ф.* 1) Шактый кибү, дымы киму. *Менә озын сыйракның кипшергән иреннәре иксез-чиксез Рәсәйдә олысына-кечесенә яхшы таныш, кадерле исемне янә пышылдадылар.* Ш.Рәкыйпов. *[Гөләндәм:] Алай иренең бик кипшергән икән, нәрсә ялманып торасың, сал да эч үзеңә кирәкне.* Ф.Хөсни

2) Кибеп, үз хәленә кайту, сурыгу. *Юллар кипшергәч, походка чыгу*

3) *күч.* Ябыгу, бетәшү, хәлсезләнеп, кечерәеп калу. *Шушы кипшереп как сөяккә калган, тавышы да хәлсез генә булып чыга торган карт кайчандыр аю тоткан.* Н.Исәнбәт

4) *күч.* Саегу, бетүгә бару (акыл, рухи сыйфат һ.б.ш. тур.). *[Шагыйрьнең] Олыларча борчулы, ләкин балаларча шат бай күңеле сизелеп тора. Ул күңелләр берүк бай булсыннар иде! Кипшермәсеннәр иде!* М.Мәһдиев

**КИПШЕТҮ** *ф. з.-сыз сөйл.* Үзеннәнүзе кипшерү

**КИПШҮ** *ф. к.* **кипшенү** (*1 мәгъ.*). *Минем сулышларым кысылды, тез буыннарым калтыранды. Иреннәрем кипшеде.* Н.Дәүли. *[Сәлимә:] Рөстәм, шаяртма инде, бәгырь! Минем дә бит авызым кипшеде.* Ф.Яхин

**Кипшеп бару** Әкренләп кипшү. *Юл кипшеп бара*

**Кипшеп бетү** Тәмам, тулысынча кипшү, кипкән хәлгә килү. *Ул бит мине ярата, ярата, Илдархан абый. Белмисез генә, минсез саргаеп, кипшеп бетә ул.* Н.Исәнбәт

**Кипшеп китү** Тиз арада яки кинәттән кипшү; кинәттән кипшегән хәлгә килү. *Кояш чыккач, юл кипшеп китте*

**КИР** *и. иск.* **1.** 1) Мамонт (бозлавыкта сакланган мамонт түшкәсе)

2) *диал. фольк.* Гигант, гаять зур кеше

3) *с. мәгъ.* Караңгы коңгырт төс (мамонт төсе)

**2.** Шундый төсле. *Салават батыр ир булган, менгән аты кир булган.* Җыр. *Татар телендә утыздан артык ат төсмере аерымлана: ак, акбүз, бүртә, кир һ.б.* Р.Әхмәтьянов

**КИРАЛКАН** *рәв. диал. к.* **кираркан**

**КИРАРКАН** *рәв. диал.* Йөз белән югарыга карап, чалкан. *Суда кираркан ятып йөзү*

**КИРА́СА** *и. фр.* 1) Борынгы заманда сугышчыларның күкрәкләрен һәм аркаларын яраланудан, җәрәхәтләнүдән саклау өчен металл кием; көбә, көбә камзул

2) XX гасыр башларына кадәр Көнбатыш Европа һәм рус армияләрендә кайбер гвардия полкларының парад формасы

**КИРАСИР** *и. фр. тар.* 1) Көнбатыш Европа илләрендә һәм Россиядә гвардияче кавалерист

2) Элекке Россиядә һәм кайбер Көнбатыш Европа илләрендә парад формалары кирасадан гыйбарәт булган кавалерия полклары солдаты яки офицеры

**КИРА-ХАК** *и. гар.* Вакытлы файдалану бәясе, яллап тору, аренда бәясе. *Әхмәди бай --- бәлдәи Самардан бишалты чакрым җирдә кира-хак илә бер «дача» ялламыш иде.* З.Бигиев

**КИРӘГӘ** *и. тар.* 1) Төрки-татарда сугышчының тимердән эшләнгән баш киеме – очламның (шлемның) бер төре

2) Күчмә киез тирмәне киереп тора торган кабыргалык агачлар; тирмәнең түбәнге цилиндрик өлешен тәшкил иткән агач каркас. *Утыз ике умыртка, кырык кабырга.* Табышмак. *Җәгъфәр, --- өнен җуйган хәлдә, якындагы тирмә кирәгәсенә сыенды.* А.Расих

**КИРӘГЕНДӘ** *рәв.* Кирәк булганда, кирәк вакытта. *Зариф, Җәләлгә якын адәм булып, кирәгендә акча да алгалый, ярдәмгә мөрәҗәгать итә торган иде.* Г.Ибраһимов

**КИРӘГЕ́НЧӘ** *рәв.* 1) Кирәк булган кадәр, тиешенчә, тиешле дәрәҗәдә. *Ничек кенә булмасын, рөхсәт алынды, һәм Гафур аннан кирәгенчә файдаланды.* Г.Шәрипова. --- *Ул аяусыз көрәшнең серләренә бүген дә кирәгенчә төшенеп бетү җиңел түгел безгә.* М.Әмир. *Ә Мәрьяме аның кирәгенчә тигез, сабыр холыклы, аек акыллы хатын иде.* Ә.Еники

2) Нормаларга, таләпләргә туры килерлек итеп, дөрес итеп. *Яка кирәгенчә ятмаса, аның да урыны дөрес уелмаган дигән сүз.* Л.Мөхәммәт. *Хисаминың хатыны ачык күңелле һәм үзен кирәгенчә тота белә иде.* Г.Шәрипова

**КИРӘГҮ** *ф.* Кирәк булу, кирәге чыгу. *Кирәкмәгән киерге иртәгә кирәгер.* Мәкаль

**КИРӘК** *хәб. сүз.* **1.** 1) Нинди дә булса эш-шөгыльгә, тәртипкә карата билгеле бер теләк белдерү; зарурлык, таләп ителү. *Эндәшә батыр утынчы: – Сиңа миннән ни кирәк?* Г.Тукай. *Шатлыкларын ишеттерер өчен, Туган ягы кирәк кешегә.* Ф.Яруллин. *Ә тел өлкәсендә кандидатлар, докторлар бик кирәк, тел никадәр үзе кимесә, аның белән шөгыльләнүчеләр шулкадәр кирәгрәк.* М.Мәһдиев

2) *-ырга//-ергә, -рга//-ргә* формалы фигыльләр белән билгеле бер эш яки гамәлне башкару зарурлыгын, тиешлекне, мәҗбүрилек мәгънәсен белдерә. *Сезгә әһәмият бирергә кирәк, чөнки урынлы кулланылган сүз – ул мәгънә дә, --- матурлык та.* Г.Кутуй. *Үсемлекләр җыючыга зарарлы, агулы үсемлекләрдән сакланырга кирәк.* Н.Верзилин. *Шулай актык көчне җыеп булса да яшәргә кирәк, ярты елмы, бер елмы, әллә ниләр эшләп өлгерергә була бит әле.* З.Кадыйрова

3) *-са//-сә* формалы шарт фигыльләр белән килгәндә, анык раслый алмау, чамалап әйтү яисә шикне белдерә. *– Мондый чәчәнлекне начар биядән туган кара айгырлар гына әйтә белсә кирәк, – диде.* Г.Ибраһимов. *Теге ике кәҗә дә шул зифалыкка соклана иде булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу нәрсә аның ул вакытта «Тәрҗеман» газетасы теле тәэсирендәрәк язылып барган «Йолдыз» газетасында эшли башлавыннан килсә кирәк.* М.Гали

4) *-мак//-мәк* формалы фигыльләр белән: сорау алмашлыклары ярдәмендә ясалган фигыль сүзтезмәләрендә риторик сорауны белдерә. *Инде нишләмәк кирәк?*

**2.** *с. мәгъ. к.* **кирәкле**. *Миргали тормыш көймәсенең ничек итеп бүгенгә кадәр батмый йөрүен, нинди текә борылышларда да койрыкны кирәк якка борып өлгерә алуларын башыннан кичерде.* М.Әмир. *Әти сугышка киткәч, атыбыз Әхмәтша абзыйларда калды. Алар аны, үз атлары белән бергәттән, кирәк җирләренә җигәләр.* М.Әмир. *[Узучыларның] кайберләре исә, бик ашыгып --- кирәк нәрсәләрен сорыйлар да --- шундый ук ашыгычлык белән китеп баралар.* А.Шамов

**3.** *и. мәгъ.* 1) Ихтыяҗ, кирәк булган нәрсә. *Хатын-кыз күзәтүчәнрәк була, үзенә кирәген бик тиз эләктереп ала.* Т.Галиуллин. *Бу җөмләнең дә астына сызды [Сәлмән]. Тагын укыды – тагын сызды. – Күрәсең, башта гел кирәкләрен генә язганнар, – дип, башын кашып торды.* Х.Сарьян. *Кешелек дөньясы, гомум кирәкләрен җиткезер өчен, табигать белән көрәшергә, табигатьтән файдаланырга керешкән.* Мирас

2) Нинди дә булса эшкә кирәкле әйберләр, кирәк-ярак. *Өй кузгаткач, аның кирәге күп була икән.* Г.Ибраһимов. *Нәрсә генә юк келәттә: ризык дисеңме, дөнья кирәге дисеңме?* Г.Якупова. *Күрше-күлән юл кирәкләрен хәзерләште.* Г.Галиев

**4.** *терк. мәгъ.* Җөмләнең тиңдәш кисәкләре алдыннан кабатланып килеп, һәр очракта да бер үк хәрәкәт, бер үк бәяләмә булганлыгын белдерә. --- *Ул [Шиһабетдин Мәрҗани] илле ел соңгарак калып туган булса, шөбһәсез, кирәк фән кешесе, кирәк фикер кешесе буларак, ул әллә никадәр эш эшли алган булыр иде.* Ф.Әмирхан. *Кирәк черсен, кирәк торсын – ни ул тән? Чыдамсыз бер кием ул җанны өрткән!* Г.Тукай. *Трагедия жанры, әлбәттә, кирәк язучыдан, кирәк театр коллективыннан зур осталык, кыюлык таләп итә иде.* Казан утлары

◊ **Кирәге бар** «Бернинди дә кирәге юк» мәгънәсендә ирония белән әйтелә. **Кирәге бер тиен** 1) Хаҗәте юк, бөтенләй кирәксез, әһәмиятсез нәрсә. *Машина дип авыз суын корытып йөрүчеләрнең борыннарына чиртәсең түгелме син? Кирәге бер тиен, юләр сатма.* Г.Бәширов; 2) Кирәксез кешенең китүен теләгәндә әйтелә. *Китә бирсен, кирәге бер тиен.* Н.Исәнбәт. **Кирәгем исә егыл да үл** «Зарури хәл, берни дә эшләп булмый», «бернинди чара юк» мәгънәсендә. **Кирәгем иясе** *мыск.* Үзен бик кирәкле, әһәмиятле бер кеше дип санап, кәпрәеп, масаеп йөрүчедән көлеп әйтелә. **Кирәген алу** 1) Шелтә алу; 2) Кыйналу. **Кирәген бирү** 1) Кешене берәр гаебе өчен каты шелтәләү, тиргәү яки тәнкыйтьләү. *Ә калган балаларның кайберсе Хәлимнәрне кызганды, кайсы берсе: «Ну кирәкләрен бирә хәзер...» – дип кызык көтте.* Г.Гобәй; 2) Дөрес юлга кертү, акылга утырту. *Әби әйтә: – Өлкәннәрне, улым, тыңлап өйрән, – ди. – Тыңламаган өчен менә кирәгеңне бирәм, – ди.* Р.Миңнуллин. *Әни шулай да бөтенләй дәшми кала алмады: – Менә хәзер әтиегез кайтыр, – диде, – кирәгегезне бирер.* М.Әмир; 3) Җәфалау, интектерү. *Гомер буе дөнья кирәген бирсә дә, күңел бу котылгысыз мизгелне мөмкин кадәр кичектерергә тели иде.* Ә.Рәшитов; 4) Сугышта җиңү, өстен чыгу: (дошманны) тармар итү. *Дошман килсә кыркырга, Без бирербез кирәген!* М.Җәлил. *Сугыша Сталинград! --- Кирәген бирә немецның. Кыра фашистны Сталинград, тураклый.* Г.Бәширов; 5) Нинди дә булса эшне тырышып үтәү, уңышлы башкару. *Эшнең кирәген бирдек;* 6) Нәрсәдәндер тулы канәгатьләнү алу, ләззәт табу, рәхәтлек кичерү. *Йокының кирәген бирдек*; 7) Тәмам туйганчы, ныгытып ашау-эчү. *Карт, юрганга аяк бөкләп утырып, тавыкның да, майлы коймакның да кирәген бирде.* Г.Ибраһимов. *Пәрәмәчнең кирәген бирдек!* Н.Исәнбәт. **Кирәген үлчәп кенә сөйләшү** Сүзнең алдын-артын уйлап, сак сөйләшү. *Кирәген үлчәп кенә сөйләшүче сабыр холыклы кеше.* С.Рафиков. **Кирәге чыгу** Билгеле бер очракта ярап кую, кирәк булу. *Файда китерердәй эшне генә санга суга торган бәндәләр, бу «музей экспонатлары»н күргәч, мыек астыннан гына елмаеп, Габдерәшит картка: «Кирәге чыкмас инде боларның, абзый...» – дия иде.* А.Тимергалин. *[Әби:] Ярый әле үземнекен алып килгән идем, кирәге чыкты, үземә диган кәфенлеккә Хәлимәмне төреп озаттык.* З.Кадыйрова. **Кирәк бит** Көтелмәгән, гаҗәпләндерерлек бер хәл уңае белән туган хисне белдерү өчен әйтелә. *Кирәк бит, нәкъ эш кылынасы чакта, әтәч тәрәзә янындагы коймага менеп кычкырды да бүлде төшне, хәерсез.* Ш.Рәкыйпов

**КИРӘККӘ** *рәв.* Кирәк булганга, кирәк булганлыктан; нинди дә булса максат белән. *Минем бик кирәккә генә дип саклап калдырган шакмак ярым шикәрем бар.* Ф.Бурнаш. *Кайвакытларда Мәликә Рәүфәне дә орышкалап ташлый иде. Ләкин эш кулы кирәккә алганлыкны уйлагач, тынычлана.* А.Шамов. *Кирәккә чапкан кеше аны [печәнне] ярты көндә эш итеп чыга инде.* М.Мәһдиев

**КИРӘККӘ́-КИРӘКМӘСКӘ** *рәв. к.* **кирәкмәгәнгә**. *[Карт әсәй:] Безнең Таһирә җиңги кирәккә-кирәкмәскә яраклашып, телен бозып йөрмәде, ул үзенчә такылдады, без – үзебезчә.* Г.Якупова

**КИРӘ́К-КИРӘКМӘГӘН** *с.* **1.** Кирәк-кирәкмәс, файдасы булмаган, урынсыз. *Кирәк-кирәкмәгән сүзләр сөйләү. Кирәк-кирәкмәгән эшләрдә катнашу*

**2. кирәк-кирәкмәгәнгә** *рәв. мәгъ.* Бушка, тиккә, заяга. *Кирәк-кирәкмәгәнгә кереп-чыгып йөрү*

**3.** *и. мәгъ.* Урынсыз, мәгънәсез нәрсә. *Ул арада әнинең апасы чәчрәп чыгып иренә ташланды. – Кирәк-кирәкмәгәнне*

*кузгатып син утырасың! – дип тузынды.* Э.Шәрифуллина

**КИРӘ́К-КИРӘКМӘС** *с.* 1) Тиешле-тиешсез, урынсыз. *Кирәк-кирәкмәс урында сорау бирү*

2) Мәгънәсез, килешмәгән, рәтсез. *Галимә апа кирәк-кирәкмәс сүзләр әйтә.* М.Гафури

**КИРӘКЛЕ** *с.* 1) Кирәк була торган, кирәк булган, нәрсәгәдер яраклы. *Кирәкле барлык китапларны Юматша үзе табып алып кайта.* Г.Әпсәләмов. *Ашамлыклар әзерләгәндә, суган иң кирәкле тәмләткеч булып тора.* Татар халык ашлары. *Фәйзулла Хаясиевич --- тимер шкафка таба узды, аннан кирәкле эш кәгазьләре алырга ниятләде.* Ш.Рәкыйпов

2) Әһәмиятле, мөһим, файдалы, зур роль уйный торган. *Хәзер Алексей Лукич үзе дә икеле-микеле сөйләшә. Сәлахка кирәкле язуларны да бирми тора.* Г.Әпсәләмов. *Була җыелышлар, бәхәсле мәсьәләләр буенча чыгышлар ясыйм. Ә иң кирәкле сүзләрем соңыннан исемә төшә.* М.Әмир. *Мәрҗани дә, Хөсәен Фәезханов та үз мәмләкәтенең рәсми телен белүне иң кирәкле эшләрдән санадылар.* Х.Хисмәтуллин

3) Тиешле, билгеле яисә билгеләнгән. *Бик шәп балта остасы иде ул [Хәсән Сарьян]. Бөтен кирәкле кораллары да бар иде.* Ә.Еники. *Һәр өстәлгә нәкъ кирәкле ризык һәм нәкъ кирәк кадәр китерелде.* Г.Шәрипова

4) *күч.* Нинди дә булса эштә яки берәр мәсьәләне хәл итүдә файдасы тиярдәй, эшкә яраклы. *Кирәкле ташның авыры юк.* Әйтем. *Сигезне бетергән Айбулат шофёр-трактористлар курсына укырга китәргә җыенды. Колхозда иң кирәкле кешеләр иде алар.* З.Кадыйрова. *Флёра апа үзе дә танышкан чакта: – Мин – кирәкле кеше, ярдәмем тими калмас. Салым инспекциясендә эшлим, – дигән иде.* Шәһри Казан

5) *хәб. сүз мәгъ.* Файдалы булу, кыйммәтле булу. *Бу хезмәтләрнең әһәмияте әле дә кимемәячәк, алар халыкка бүген дә кирәкле.* Мәдәни җомга

◊ **Кирәкле кишер яфрагы** *ирон.* Кирәксез, әһәмиятсез, файдасыз кешегә карата әйтелә. *[Ризван:] Һу-һу, кара син! Бояр да әйтә, урман минеке, ди, син дә тагы. Каян килгән кирәкле кишер яфраклары!* Н.Исәнбәт. *Бу абзыйларның күбесе бит ялга чыкканчы зур урыннарда эшләгәннәр. Кирәкле кишер яфраклары булганнар.* Т.Галиуллин. **Кирәкле кылына басу** Кемнең дә булса йомшак ягын белеп, шуннан үз мәнфәгатьләрең өчен файдалану

**КИРӘКЛЕК** *и.* 1) Кирәк (кирәкле) булу; зарурлык, ихтыяҗ, хаҗәт. *Итәккә күпме метр тукыма кирәклеген белү өчен, итәк озынлыгын өчкә тапкырлыйбыз.* Л.Мөхәммәт. *Чынлап та, Мидхәтне нидер эшләтергә кирәклек үзеннән-үзе аңлашылып тора иде.* Ф.Хөсни. *Бар кешелек дөньясына Кирәклеген белдереп, Мәңге яшәр Тукаебыз, Елатып вә көлдереп.* Л.Шагыйрьҗан

2) Сарыф ителә, тотыла торган акча; чыгым. *[Әтисе улына:] Янымда синнән башка биш балам һәм карт атам бар. Шуларның өлешеннән аерып, сиңа кирәклек җибәреп торам.* Т.Биктимирова

3) Тиешлек. *[Профессор:] Мин инде, хөрмәтлем, кайчан нәрсә сөйләргә кирәклеген беләм... Һәм рәхим ит: отчёт әзер!..* Ш.Рәкыйпов. *Мәхмүт писарьга коры кул белән барырга ярамаганлыкны шактый ачык итеп ишарәләде. Әйе, бирергә кирәклеге ачык, анысын яхшы төшенде Габдулла абзый.* Ф.Хөсни. *[Ильяс:] – Гаяз, --- тор, күр тизрәк безнең авылның ямьлелеген ---. Күзеңне генә ачып кара, уянырга кирәклекне үзең үк аңларсың.* М.Әмир

4) Мөһимлек, әһәмиятлелек. *Мәрҗани «Вафиятел-әсляф...»та Кышкар авылы мулласы Исмәгыйль хәзрәт белән Хөсәен Фәезханов арасында булган бәхәсне, рус телен укыту кирәклеге турында Х.Фәезханов китергән дәлилләрне бик тәфсилләп яза.* Х.Хисмәтуллин. *Симпозиум төрки халыклар өчен «уртак» әлифба кабул итү кирәклеген таный.* Ә.Кәримуллин

**КИРӘКЛЕ́-КИРӘКМӘГӘН** *с. к.* **кирәкле-кирәксез**. *Ә мин, үҗәт адәм, тагын кирәкле-кирәкмәгән сораулар биреп маташам, табигый кызыксынуым алдында берүзем гаҗиз булып калам.* Ә.Рәшит

**КИРӘКЛЕ́-КИРӘКСЕЗ** *с.* 1) Теләсә нинди, мәгънәсез. *Кирәкле-кирәксез сүз сөйләү*

2) Вак-төяк, файдасыз. *Чолан эче кирәкле-кирәксез әйберләр белән тулган*

**КИРӘКЛЕ́-КИРӘКСЕЗГӘ** *рәв.* 1) Сәбәбе, нигезе булмыйча; юкка-барга. *Бигрәк тә Көнчыгыш вәкилләренә һич мөнәсәбәте булмаган Лукашевичның монда үзен хуҗадай хис итүе, кирәкле-кирәксезгә тыкшынуы канәгатьсезлек тудыра.* Р.Мөхәммәдиев

2) Максатсыз, кирәге булмаган килеш, тиккә. *Кирәкле-кирәксезгә өй белән лапас арасында йөрү*

**КИРӘКЛЕЛЕК** *и.* Кирәкле булу, зарурлык

**КИРӘ́КМӘГӘН** *с.* **1.** 1) Мәгънәсез, урынсыз, кирәкмәс. *Бу зур эшнең бер кулда булуы биш томның бөтенлекле булып чыгуына китерә, комментарийларда кирәкмәгән кабатлаулардан коткара.* Ф.Галиуллин. *– Юк, әни, бармыйм, – диде Рәүфә. – Кайбер хатыннар киләләр дә, эчне пошырып, кирәкмәгән сүзләр сөйлиләр.* А.Шамов

2) Чамасыз, кирәгеннән күпкә артык. *Житмәсә, хатыны кирәкмәгән матур.* Н.Исәнбәт

**2.** *и. мәгъ.* Кирәкмәс, урынсыз нәрсә. *Кире кирәкмәгәнне сөйләр.* Мәкаль

**КИРӘ́КМӘГӘНГӘ** *рәв.* Мәгънәсезгә, юкка, тиккә, тиешсезгә. *Аның дәрәҗәсендәге кешеләрнең хатыннары акчаны пачкалап туздырсалар, аның Раечкасы кирәкмәгәнгә артык бер тиенгә дә тими.* З.Кадыйрова. *Кызның кирәкмәгәнгә кысылып торуы Чәмәтнең ачуын гына китерде.* Х.Сарьян. *Хәтимә, өйгә кайтып керү белән, бер дә кирәкмәгәнгә кулына сөлге алды.* Г.Галиев

**КИРӘ́КМӘГӘНЧӘ** *рәв.* Исәпләп, уйлап җиткермичә. *Эшне кирәкмәгәнчә башлап җибәрү*

**КИРӘКМӘСКӘ** *рәв. к.* **кирәкмәгәнгә**. *Бер юньсезе кирәкмәскә баз казып куйган.* А.Алиш

◊ **Кирәкмәскә әйләнү** Исемен, дәрәҗәсен җую, үзенә илтифат бетү, авторитеты төшү. *[Әбием:] Килен, яшь вакытта улымны бик яраттың бит. Олыгая башлагач, нигә кирәкмәскә әйләнде соң ул?* Э.Шәрифуллина

**КИРӘКМӘСТӘН** *рәв. сөйл. к.* **кирәкмәгәнгә**. *Чәмәт кунак итүне, кунакка йөрешүне тиктомалдан расход чыгарып, бер кирәкмәстән кеше ашату дип уйлый иде.* Х.Сарьян

**КИРӘКСӘ́-КИРӘКМӘСӘ** *рәв.* Кирәк булмаганга, тикмәгә, юкка, тиктомалга. *Сәлмән Галләмов өстәл өстендә таралып яткан китап-дәфтәрләрен, кирәксә-кирәкмәсә йөрткән газет-журналларын малаеның иске портфеленә дыңгычлап тутырды.* Х.Сарьян. *Иялдәшә төшкәч, кирәксә-кирәкмәсә дә шул баскыч буенча менеп-төшеп йөрү минем өчен бик күңелле уен иде.* М.Әмир. *[Гыйлаҗ:] Фәйзулла малаеның кузгалып киткәнен карап торам ---. Тизлеккә салуының һич рәте юк, кирәксә-кирәкмәсә тормозга баскан була.* Р.Төхфәтуллин

**КИРӘКСЕЗ** *с.* 1) Кирәкмәгән, кирәге булмаган; әһәмиятсез. *Егетнең тел төбен сиздем. --- Китапта кирәксез урыннар да күп ул, дип кенә әйтәсе урынга, үзеңә уйларга куша.* Х.Сарьян. *Ни тырышуына карамастан, Юматша мәрхүмәнең табылган запискасының кем тарафыннан язылуын әле һаман ачыклый алганы юк иде. Мансур исә моны бөтенләй кирәксез эш дип карый, эзләшүдә катнашмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Художество әсәрләрен кирәксез детальләрнең күп булуы боза.* Ә.Исхак

2) Тиеш булмаган, урынсыз, нигезсез. *Юк, әләкмәде Жан. Шулай да Минск партия подполье комитеты аны кирәксез тәвәккәллекләр белән артык мавыкмаска, үзен сакларга кушты.* Ш.Рәкыйпов. *Хуҗа урыны белән кирәксез җиңеллек, диваналык күрсәтә.* М.Җәлил. *Анда [хикәядә] автор --- кунак көткәндәге кирәксез ыгы-зыгыларны, өзек-өзек картиналарда булса да, шактый тасвирлы күрсәтә алган.* М.Гайнуллин

3) Кирәклеге булмаган, урын гына алып торган, кирәгеннән артык. *Кирәксез кием. Кирәксез урын-җир. Кирәксез җиһаз*

4) Артык, кадере булмаган, кадерсез. *Нурый карт Шибайга кеше аша әйттерде: – Безнең алай кирәксез балабыз юк. Әгәр киреләсәләр, туры әйтсеннәр, бердәнбер кызыма минем өемдә урын җитәрлек.* Г.Ибраһимов

**КИРӘКСЕЗГӘ** *рәв.* 1) *к.* **кирәкмәгәнгә**. *Менә бит ул, көтеп-көтеп тә инде онытыла башлаган, инде кирәксезгә, әһәмиятсезгә әйләнә язган минутлар.* Л.Ихсанова. *Һәм мин бер нәтиҗәгә килдем. Кошларда очраклы бер генә хәрәкәт, кирәксезгә бер генә аваз да булмый.* М.Мәһдиев

2) Тиешсезгә, урынсыз. *Фәлән-фәлән кием астыннан кирәксезгә фәлән кием күренеп тора икән – моны җай белән генә әйтмичә калмыйлар.* М.Мәһдиев

**КИРӘКСЕЗЛЕК** *и.* Кирәк булмау, кирәк түгеллек. *Шул «йолдызлар» астында мәгърур тау-кыя кебек кайбер затлар – чын талантлы кешеләр – үз иҗатларының кирәксезлегенә кимсенеп гомер кичерергә мәҗбүрләр.* Казан утлары

**КИРӘКСЕНҮ** *ф.* 1) Кирәк дип табу, кирәк дип санау. *Аякларым оеп каткан: бераз гына йөрергә кирәксендем.* Г.Ибраһимов. *Бакчачы картны юату мөмкин түгел иде. Моны беребез дә кирәксенмәдек, әйдә, бушатсын хәсрәтен.* Ш.Рәкыйпов. *Бу риваять беркадәр төзәтмә кертүне кирәксенә.* И.Нуруллин

2) Нәрсәне дә булса көтеп алу һәм шуңа омтылу. *Кадерен белеп, тырышып укып, тәрҗемәче, инде бик кирәксенәләр икән, хәрби атташе булыр иде [егет].* Ш.Рәкыйпов. *Гомумән, безнең, кирәксенеп, теләп тапкан балаларыбыз туганнан алып нинди үрнәкләр күреп үсә соң?* Э.Шәрифуллина. *Тарих сабакларын тәкрарлап акыл алу юк, аны кирәксенмиләр дә. Хәтер югалган, күмелеп калган.* А.Гыйләҗев

3) Кемне дә булса юксыну, сагыну. *Күптән очрашмаган якын дустыңны кирәксенү*

**Кирәксенә башлау** Кирәксенергә тотыну. *Соңгы вакытта мәктәпләр аны кабат кирәксенә башлады.* Ватаным Татарстан

**Кирәксенеп йөрү** Озак вакыт яки күптәннән кирәксенү; кирәксенгән хәлдә булу

**Кирәксенеп кую** Кинәт кирәксенү

**Кирәксенеп тору** Һәрвакыт, гел кирәксенү

**КИРӘКТӘ** *рәв. к.* **кирәгендә**. *Давыл сүнәр, бәлки, йөрәктә. Ул табылмас, бәлки, кирәктә.* Һ.Такташ

**КИРӘ́КЧӘ** *рәв. сөйл. к.* **кирәгенчә**. *Үзеңне гадәти тотканда, вакыйгалар сиңа кирәкчә бара шул алар.* Ф.Яхин

**КИРӘК-ЯРАК** *җый. и.* Берәр төрле эш, шөгыль өчен кирәкле әйберләр, әсбаплар, кораллар һ.б. --- *Меңнәрчә чакрымнарда рельс сугышы башланып, фронтны вакытында кирәк-ярак белән тәэмин итү тукталса, кикрикләре тиз шиңәр [фашистларның].* Ш.Рәкыйпов. *Өсте салам белән капланган зур куыш алдында чиләкләр, пудовкалар, балталар, брезентлар һәм тагын әллә никадәрле шундый кирәк-яраклар ята.* М.Әмир

**КИРӘМӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Ислам динендә: кешеләр эшли алмый, изгеләр, әүлия затлар гына эшли ала торган эш; *к.* **кәрамәт**

2) *этн. миф.* Билгеле бер урынның хуҗасы булып исәпләнгән, табыныла торган илаһи көч, рух. *Кирәмәткә корбан чалу. Мари халкының Кирәмәт исеме белән бәйле ышанулары һәм йолалары*

3) Идел буе халыкларындагы мәҗүсилектә агачка табыну, аңа корбан китерү учагы // Мәҗүси келәү урыны, гадәттә изге агачлык

4) Берәр изге рухка корбанлык итеп билгеләнгән әйберләр (гадәттә алты өлештән торган һәм махсус урында сакланган)

5) *бот.* Элмәчәләр семьялыгыннан караманың ялан җирдә ялгыз үсә торган вак яфраклы төре; каез; *русчасы:* **вяз полевой**. *Әптери агай --- кыр уртасында, кирәмәт агачы янында куып җиткән теге егетне.* Г.Әпсәләмов

6) Табигый бәла-каза, һәлакәтләр. *Хәзер инде андый кирәмәтләр (корылык, ачлык һ.б.) бик аз очрый дала ягында.* Ш.Мөдәррис

7) Гаҗәпләнерлек, искитәрлек хәл, вакыйга; гадәти булмаган күренеш; могҗиза. *[Шикле кеше:] – Энем... Менә сиңа кирәк булса кирәмәт. [Яшь егет:] – Монда бер дә кирәмәт-мазар юк,*

*тотканнар да [Галимҗан белән Нәфисәне] өйләндергәннәр.* Ф.Бурнаш

**2.** *с. мәгъ.* Үзсүзле, холыксыз, кире беткән (кеше тур.)

◊ **Кирәмәте килү** Киреләнү, карышу, риза булмау. *Ни кирәмәте килгән тагы?* **Кирәмәте китү** Киреләнми башлау, киреләнүдән туктау. **Кирәмәтенә бару** *к.* **кирәмәте килү**

**КИРӘМӘТЛӘНҮ** *ф. диал.* Шомланып, борчылып ыгы-зыгы килү. *Бер дә юкка кирәмәтләнү*

**КИРӘМӘТЛЕ** *с.* 1) Нинди дә булса серле көчкә, үзлеккә ия булган. *Сафый абзый үзенең хикмәтле, кирәмәтле бакчасында кереп югалганчы чишмәне бер әйләнә.* М.Мәһдиев. *Кирәмәтле агач. Кирәмәтле урын*

2) Фаҗигале, аяныч (вакыйгалар тур.)

3) Үзенә бер сәер холыклы (кеше тур.)

**КИРӘМӘТЧЕ** *и.* Кирәмәткә (*2 мәгъ.*) табынучы

**КИРӘҮКӘ** *и. тар.* Меңнәрчә вак боҗралардан торган, күкрәк, иңбаш һәм терсәк турылары корыч пластинкалар белән ныгытылган көбә күлмәк, тимер җөббә; *русчасы:* **панцирь**. *Томан эченнән борынгы батырлар киемендә – башына бакрач, өстенә кирәүкә кигән берәү шәйләнә.* Н.Исәнбәт

**КИРӘЧ** *и. диал.* Корылманың, сыешлыкның ныклыгын тәэмин иткән агач яки тимер челтәр, каркас; сөлтәр

**КИРБАС** *и. гар.* Юка киҗе-мамык тукыма; бәз

**КИРЕ** *с.* **1.** 1) Тиешле яки төп тарафка каршы булган, каршы юнәлештәге. *Бер генә ут та күренми. Бөтенләй кире якка китеп бармыйлармы?* Г.Әпсәләмов. *Борылырга җайлы урын эзләп алга барганда, каршыбызга бер атлы килеп чыкты. – Кая китеп барасыз болай, кире якка?* М.Әмир

2) Берәр нәрсәнең уңай якка булмавын раслый торган; көткәнгә капма-каршы булган, капма-каршы эчтәлекле, тискәре. *Зифа карчык аны [Шәрифулланы] табын янына, көндезге ашка чакырды, әмма кире җавап алды.* А.Шамов. *Кире нәтиҗә*

3) Тискәре, начар; ямьсез. *Тәртипкә чакырырга кирәк андый кешеләрне. Башкаларга кире йогынты ясап куюлары бар.* С.Рәфыйков

4) Бозык, яман, тыелган. *Театр яктылыкка, нурга илтә, Кире юлга җибәрми, уңга илтә.* Г.Тукай

5) Уңай булмаган, нәрсәне дә булса хупламый торган, әһәмиятен танымый, инкяр итә торган. *Үзенең бу «күмәкләштерү»гә мөнәсәбәте нинди булгандыр, әтиебез бу хакта беркайчан да сүз катмады, уемча, шактый кире мөнәсәбәттә торгандыр дип беләм.* Р.Әмирхан

6) Кеше сүзен тыңламаучан, тыңлаусыз, кеше сүзенә карышучан; үҗәт. *Карт түзмәде, сәке кырыена төшеп, ачуыннан идәнгә типте. – Керәшендәй кире икәнсең! Ярар, тавышың тыгылсын!* Г.Бәширов

7) Әдәбият һәм сәнгатьтә: уңай булмаган, тискәре. *Әсәрдә бер якта бик әшәке, бик кире типлар, икенче якта бик иҗади уңган типлар бирү --- схемасы нык күзгә бәрелә.* М.Җәлил. *Кире образ*

8) Файдасы булмаган, нәтиҗәсез. *Кырмыска оясыдай кайнаган станция күренеп торсын. Шул фикерне бизмәнгә салып, уңай һәм кире якларын тәгаенләгәндә, станциядә тагын берәү күренде.* Ш.Рәкыйпов

9) *мат.* Берсенең артуы белән икенчесе кими торган. *Математика теле белән әйткәндә, монда кире пропорция: гыйльми дәрәҗәң ни кадәр түбән булса, эшләгән сәгатьләрең шул кадәр күп була, яки киресенчә.* Х.Сарьян. *Кире пропорциональ бәйләныш*

10) *мат., физ.* Нульдән түбән, минус тамгасы белән билгеләнгән

11) Йөз ягына каршы булган; эчке, сул, тыштан караганда күренми торган (киемгә карата). *Тунның кире ягын әйләндереп кию. Пальтолык тукыманың кире ягы*

12) Хат, телеграмма, посылка җибәрүченең үзенеке, җибәрүче затныкы. *Кире адрес: «Мәскәү» дигән, Аннан язган урамын.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Элекке, үтеп киткән, капма-каршы якка, барган юнәлештән артка борылып. *Гөлбану, мондый бәхетсезлеккә очраганга әрнеп, кире керде.* Г.Ибраһимов. *Колач җитмәс юан нарат бүрәнә тимер юл буйлап пычкылар арасына кереп китә, ә дигәнче, унлап-унбишләп тактага әверелеп, кире чыга.* М.Әмир. *Шау-шу кинәт тынды. Әхмәт кире борылып, тәрәзә янына барып басты.* Г.Бәширов

2) Яңадан, тагын, кабат. *Эшеңне кире сүттергәнгә гарьләнеп, үпкәләп утыруыңны --- беркем дә күрмәде шикелле.* Г.Бәширов. *Бер фикерне төгәлләр-төгәлләмәс икенчесенә, өченчесенә сикерде, аннан яңадан кире кайтты.* Г.Әпсәләмов. *Яңалифебезгә кире кайту безнең телебезне саклап калу, аның кулланылышын киңәйтүдә --- зур этәргеч булачак.* Ә.Кәримуллин

**3.** *бәйл. функ. диал.* Соң, ары. *Калган эш – төштән кире.* Мәкаль. *– Моннан кире сыер асрап булмас, – диде Фәрдәнә.* Казан утлары

◊ **Кире баштан** Яңадан, яңабаштан. *Дөрес текмәгәнсең, кире баштан сүтеп тек.* З.Бәшири. **Кире башы белән** Астын өскә әйләндереп. **Кире беткән** Үҗәт, үзсүзле, тискәре. *Мин – ярты дөньяны айкап чыккан кеше. Тик бездәге кадимнәр ише кире беткән томана башларны беркайда да очратмадым.* Г.Бәширов. *Ләкин Салих Батталны сез яхшы беләсез: ул төп кебек кире беткән бер кеше иде.* Р.Мостафин. **Кире бору** Кабул итмәү, үтенечне канәгатьләндермәү. *Булды, сорап килүче, артыннан йөрүчеләр булды, барысын кире борды, ярәшкән егетем бар, ди-ди көтте.* Р.Мөхәммәдиев. **Кире җибәрү** *к.* **кире бору**. *Ничә генә егет яучы җибәреп карамаган! Берсенә дә бармаган. Килгән берсен якты чырай, тәмле тел белән кире җибәрәдер иде, ди.* Г.Бәширов. **Кире кагу** 1) Кабул итмәү, нәрсәдән дә булса баш тарту. *Тютеев бары тик иремнән аерылган тәкъдирдә генә эшемдә калдырырга риза булды. Мин эшемне яратсам да, бу тәкъдимне нәфрәтләнеп кире кактым.* Г.Әпсәләмов. *– Сине тыңлау кызык, әлбәттә, – дидем мин. – Син сөйләгәннәрне кире кагу ансат түгел.* Г.Минский. *[Карчык:] – Аның үз эше бу. --- Нигә алмыйсыз, нигә кире кагасыз, – ди, – ничек итеп мин аны аңа кире алып кайтып күрсәтим, – ди, – үпкәләр бит.*

А.Шамов; 2) Инкяр итү, танымау. *Көр күңелле язучы [М.Мәһдиев] ике явызлыкны кире кага: ятимлек һәм ялгызлык.* Т.Галиуллин. *Заһир Габделваһапов ачыктан-ачык ике тылмач аркылы сөйләшә, боларның барлык таләпләрен дә кире кага.* Р.Әмирхан. *Ш.Мәрҗани Бохара мәдрәсәләренең тәртипләрен, андагы укыту формаларын кире кага, --- үзе кирәк дип тапкан фәннәрне укыта башлый.* Р.Хисмәтуллин; 3) Ризалык бирмәү, каршы килү. *Кызын сорап яучы җибәргән, атасы кире каккан.* Н.Исәнбәт. *[Солтан:] Әти, яратам мин Гамбәрне ---. Кире генә какмагыз. --- Күптән инде күңеленә хуш килгән кешене Юныс үзе дә кире кагарга теләми.* Г.Шәрипова; 4) Туктату, хәрәкәтен өзү, тоткарлау. *Безнең бурыч, авылда ныгып калып, --- дошманның барлык контратакаларын кире кагу.* И.Гази. *Теге як ярда каты бәрелеш бара. Безнекеләр ярсулы дүрт һөҗүмне кире какканнар.* Ш.Рәкыйпов. **Кире кайтару** 1) Үз сүзеңнән, фикереңнән баш тарту. *Кире кайтар, бәгърем, сүзләреңне Яндырма син мине утыңда.* Ф.Бурнаш; 2) Кабул итмәү, борып җибәрү, каршы килү. *Ел саен картка яучы җибәрәм. Юк бит, насыйп түгелме, көне җитмиме, карт, кемне генә яучы итсәм дә, кире кайтара.* Г.Ибраһимов. **Кире кайту** 1) Баштагы уеннан, сүзеннән баш тарту, ваз кичү. *Мин ул баштагы фикеремнән кире кайттым, сүзләремне кире алам.* Н.Исәнбәт; 2) Кабул ителмәү, кире кагылу. *Шуның өстенә, үзең дә ялгыз булгач, син инде теләсә кемгә башкода җибәрсәң дә, сүзең кире кайтыр дип шикләнмисең.* Г.Ибраһимов. **Кире какмаслык** Нык ышандыра торган, шикләнергә урын калдырмый торган. *Тикшерүченең фикеренчә, катыргы тышларына сургыч мөһер басылган шушы кенәгәләр кайсы Вәлиевнең Советлар Союзы Герое булуын һичкем кире какмаслык дәлилләр белән тәгаенләргә тиешләр иде.* Ш.Рәкыйпов. *Викториянең йөзенә тәвәккәллек чыкты: – Бар! Һич кире какмаслык дәлилләрем бар!* Ш.Рәкыйпов. **Кире килү** 1) Карышу, риза булмау; 2) Эш уңайга бармау, каршылык чыгып тору. *Чукыныплар китсен, эш бер кирегә китсә, гел кире килеп тора.* Н.Исәнбәт. *Ялның икенче көне дә адәм рәтле үтмәде, менә кичкә кергәч тә, гел кире килеп тора.* Р.Төхфәтуллин. **Кире китү** *к.* **кирегә китү**. *Фатих байның дөнья рәтен белмәве, эшенең кире китеп, тиз арада бөлгенлеккә төшүенә сәбәп булды.* Н.Исәнбәт. *Бер кире китсә, гел кире китә бит ул! --- Юк икән, бетмәгән икән Гыйльменисаның күрәселәре.* Ф.Хөсни. **Киресе килү** Киреләнү, тискәреләнү, киреләнгән чагы булу. **Кире сөрү** Булырга торган, көйләнгән эшне юк-бар сәбәп табып булдырмый калдыру. **Кире сүтү** *к.* **кире сөрү**. *Әнә бар бит берүзе күренмичә артта яшеренеп «рецензия» язып, кеше әсәрен юкка чыгарып, шуның гонорарына эчеп йөрүче алама татар. Шул адәм актыгы минем иҗатымны кире сүткән.* Г.Минский. **Кире уйлау** Баштагы уйдан кире кайту. *Ул курортка бармаска булган, кире уйлаган.* Казан утлары. **Кире ягы белән торган** Кәефсез, юньләп сөйләшми, сүз кабул итми торган кешегә карата. *Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, сөйлә, аңа карама, ул әле бүген кире ягы белән торган.* Г.Камал. **Кире яктан исү** Каршылык килеп чыгу, уңмау. *Кыш ничек тә үтәр, бер җәй, Алла боерса, урак-печән эшләсәк, көзгә кечкенә өй салырбыз, --- менә шулай акрынлап аякка басарбыз дип исәп йөрттеләр. Ләкин җил бераз кире яктан исеп куйды.* Г.Ибраһимов

**КИРЕГӘ** *рәв.* 1) Артка таба, кире якка. *Үзем дә сизмәстән, кирегә, сыртның артына чигендем.* М.Әмир. *Шулай да кирегә юл юк, анда салкын инеш, анда текә яр һәм анда ялгызлык.* Р.Мөхәммәдиев. *[Хуҗа кеше:] Мин бит беркайчан да пәнҗешәмбе белән җомга көнне кәкре юлда йөрмәдем. Кошлар кирегә таба очкан көнне андый кәсепкә чыкмадым.* Г.Бәширов. *Болак Казансуга коя торган булган, язгы ташу вакытында гына су, кирегә агып, Кабан күленә кергән.* Казан утлары

2) Кире яктан, кире тәртиптә. *Минһаҗетдин --- манжетларын җиңенә эләктермичә, кирегә, запонкалары белән эчкә киеп, чәчен су белән чылатып, хатынының тарагы белән тарап та җибәрде.* К.Тинчурин. *Җәләй ага минем авторефератны актарып чыкты, башта уңайга, аннан кирегә.* М.Мәһдиев

3) *куч.* Начар якка, яхшы якка түгел (үсеш, үзгәреш тур.). *Шул төннән минем башым сызлый башлады. --- Бер дә алга түгел – көн саен кирегә, көн саен кирегә. Атна дигәндә урынга яттым.* Х.Сарьян. *Без яңага таба юл тотабыз. Сез – кирегә таба.* Ә.Еники

◊ **Кирегә алу** 1) Начар мәгънәдә аңлау; 2) Уңай сүзне, уңай эшне кирегә әйләндерү, тискәрегә борып утыру. *Әнисенең кирле-мырлы сөйләшүе, гел кирегә алуы гаҗәпләндерде аны.* С.Рәфыйков. **Кирегә ишү** *к.* **кирегә сукалау**. *Шулай да бит кирегә ишсә язмыш, Үлеп китсә хатын күп тормый яңлыш.* Г.Тукай. **Кирегә каешып үскән** Тискәре, үзсүзле, үҗәт кеше турында. **Кирегә китү** 1) Начар якка үзгәрү; тукталып калу, дәвам итмәү, үсеш алмау (эш, тормыш тур.). *Әй, чукынсын ла бөтен дөньясы! Булмады инде... Бәхетең бер кирегә киткәч...* Г.Бәширов. *Булмады тормыш ул дигәнчә, булмады. Кырык беренче елның июненнән соң барысы да кирегә китте.* М.Мәһдиев; 2) Аң үсеше, сәяси яктан артта калу. *Искеләр [кадимчеләр] арасында көннән-көн яшьләргә карата реакция куәтләнә бара. Искеләр көннән-көн кирегә китә баралар.* Ф.Әмирхан; 3) Сәламәтлек начарлану, авыру көчәю. *Галимә апаның авыруы тагын да кирегә китте.* М.Гафури.– *Башта [даруның] бераз файдасы тигән кук була да тагын кирегә китә, – диде Мортаза бабай.* Г.Әпсәләмов. **Кирегә сукалау** Кемнеңдер фикеренә каршы төшү, уңай сүзне, уңай эшне кирегә әйләндерү, һәрнәрсәне тискәрегә борып утыру

**КИРЕДӘН** *рәв.* 1) Яңадан, яңабаштан. *Ашыга-кабалана ул [кәҗә бәтие] киредән бөдрә йонлылар төркеменә елыша төште һәм, башын игән булып, тын гына баруын белде.* Р.Мөхәммәдиев. *Тимерхан, җилләр уйнатып, Мөслимгә килде, --- барлык йомышларын йомышлап, киредән кайтырга чыккан иде.* Г.Ахунов

2) Кире яктан, кирегә, кире тәртиптә. *Моң үзе генә яши алмый, ул хәтер пәрдәләрен ачып, елларны киредән кайтара.* М.Галиев. *Сүзне киредән уку*

3) Артка таба, кире якка. *Хәйбулла бабай көтелмәгән сорау бирде: – Әллә соң, мөгаллим, камыты киредән кидертелгәнме? – диде.* Ф.Яхин

**КИРЕ́ ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Баш җөмләдә әйтелгән фикернең киресен белдергән (иярчен җөмлә тур.). *Бу төр кире җөмлә, инкяр формасын һәм сорау алмашлыгын алып, экспрессив сөйләмдә бик актив кулланыла.* Татар грамматикасы

**КИРЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Кирелек күрсәтү, каршы килү, кушканны тыңламау, карышу. *Тышкы яктан малайлар һаман кирелләнделәр, --- тыш яктан ишек бавын җибәрми тордылар.* Г.Ибраһимов. *Иванның болай кирелләнүен авыл халкы ошатмады.* Г.Бәширов

2) Каршы килү; кире кагу, кабул итмәү. *Ләкин авыру башка бер хирургка да риза булмагач, Мансурга артык кирелләнергә урын калмады.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Тормыш турында: һәрвакыт каршылыклы булып, авырлыклар килеп тору

**Кирелләнә бару** Торган саен тагын кирелләнү. *Башта матур сүзләр әйтәәйтә юатып карыйлар. Мин аның саен кирелләнә барам. Елыйм. Аннан соң орышалар.* Н.Дәүли

**Кирелләнә башлау** Кирелләнергә тотыну. *(Нурәхмәт:) Тагын кирелләнә башлады, Гөлҗиһан апа, аягын терәп каршы тора.* Т.Миңнуллин

**Кирелләнеп алу** Берара кирелләнү

**Кирелләнеп китү** Кинәттән кирелләнү

**Кирелләнеп кую** *к.* **кирелләнеп алу**. *--- Барый, урын җәелеп беткәч, балалар кебек кинәт бер кирелләнеп куйды.* Ф.Хөсни

**Кирелләнеп тору** Даими рәвештә, гел кирелләнү. *[Карт:] Баядан бирле кәҗә шикелле кирелләнеп торасың. Килешми егет кешегә.* Н.Дәүли. *Ләкин егет аны иңнәреннән кочып алган иде инде. Шәүрә кирелләнеп тормады.* Г.Бәширов

**КИРЕЛӘ́Ү** *ф.* 1) Уйлаганча, сөйләшкәнчә эшләмәскә булу, кире уйлау, ниятне үзгәртү, баштагы уйдан ваз кичү. *Нурый карт Шибайга кеше аша әйттерде. – Безнең алай кирәксез балабыз юк. Әгәр киреләсәләр, туры әйтсеннәр.* Г.Ибраһимов. *– Ярый, алайса, мин киттем, Габдулла. Вәгъдә бит инде? – Киреләгәнне көтәсеңме соң син, Билалетдин?* И.Нуруллин. *Ә Тукай үзе? Дуслары җыйналып кыскач, шагыйрь күнгәндәй була. Аннары кирели. Тагын күнә, тагын кирели... Нәтиҗәдә, бу эш, билгеле инде, булмый кала.* Казан утлары

2) Берәр нәрсәдә калышу, ким булу (чагыштырганда әйтелә). *Тик ала каз гына, нигәдер, киреләде: башка елларда тугыз-уннан һич ким чыгармаганны, быел оялмыйча ике бөртек биби иярпеп йөри.* Р.Төхфәтуллин

**КИРЕЛЕК** *и.* 1) Үзсүзлелек, тискәрелек, холыксызлык. *Ир ялынып үзенең апасы Фәтхиягә килде, ләкин бу гомерендә беренче тапкыр үзенең сүзендә, кирелегендә теше-тырнагы белән ябышып катты.* Г.Ибраһимов. *Ире эндәшмәгәч: – Каян килгән сиңа шулхәтле кирелек?.. Өйләнүнең ни авырлыгы бар инде сиңа, я? – диде хатын.* М.Галәү. *Гайнан --- Ризванның кирелегенә хәйран калып барды.* Г.Бәширов.

2) *күч.* Тотрыксызлык, өзлексез үзгәреп торучанлык; уңайсызлыклар. *Язның тискәрелегенә, җәйнең кирелегенә карамастан, борчак-баһадир бирешмәгән.* Социалистик Татарстан

**КИРЕСЕ** *и.* Нәрсәнең дә булса капма-каршысы. *[Асия:] --- Теге вакытта моңаеп утырган сары чәчәкләр турында сөйләп җаныма тигән идегез, бүген шуның нәкъ киресен сөйлисез. Нигә?* Г.Әпсәләмов. *Сәгъдетдин исә, хатынының нәкъ киресе буларак, юаш холыклы, аз сүзле, басымчак бер кеше иде.* Я.Зәнкиев. *--- Ак төсне ак иттереп тануы үзенә файда китермәячәген белгәч тә, күзен дә йоммас, бөтенләй киресен раслый башлар.* Ш.Рәкыйпов

**КИРЕСЕ́НЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Билгеле булганга капма-каршы төстә, бөтенләй башкача. *– Эшләр нәрсәдә? – дип кабатлады профессор, медсестрага кырыс итеп карап. --- – Кем үлә? – Берәү дә үлми, профессор, киресенчә, операция ясап өч көн үтүгә, бер карт палатадан рөхсәтсез чыгып китә.* Ш.Рәкыйпов

2) Нәрсәнең дә булса капма-каршысы, киресе буларак. *[Хәлфә:] Алайса киресенчә эшлибез, мулла кушканны тыңламаган өчен, алар сине яңакласын!* М.Әмир

**2.** *кер. сүз. мәгъ.* Әйткәнгә, уйлаганга, көткәнгә капма-каршы буларак. *Ана йөрәге Гөлбануга бертөрле дә юаныч әйтә белмәде, киресенчә, үзе йомшарды.* Г.Ибраһимов. *Ә кайберәүләр, киресенчә, үзләрен үзләре кимсетеп, «без – кечкенә кешеләр» дигән булып йөриләр.* Г.Әпсәләмов. *[Миргали:] Яхшы кешегә бервакытта да зыян эшләгәнем юк минем. Киресенчә, кешегә яхшылык эшләүдә дип беләм мин бу тормышның мәгънәсен.* М.Әмир

**КИРЕ́ ХӘЛ** *и. лингв.* Җөмләдә ияртүче кисәктән аңлашылганның киресен белдергән (иярчен кисәк тур.)

**КИРЕ́ ЯК** *и. диал.* Төньяк

**КИРЗА** *и. нем.* **1.** Төрле хуҗалык кирәк-яраклары, аяк киемнәре һ.б. әйберләр җитештерүдә файдаланыла торган сумалаланган тыгыз тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән яки ясалган. *--- зур кирза итекле, торнадай озын сыйраклы ефрейтор теләр-теләмәс кенә кулларын күтәрде.* Ш.Рәкыйпов. *Нури Арсланов совет-фин сугышы башлануга янә солдат шинеле кия, ничәмә-ничә еллар буе аяктан авыр кирза итек төшми.* Сөембикә

**КИРИ́ЛЛИЦА** *и. рус* IX йөз ахыры – X йөз башында көньяк, көнчыгыш һәм көнбатыш славян халыкларында кабул ителгән алфавитның берсе. *Әти гарәп имлясы белән дә, яңалиф белән дә, кириллица белән дә бердәй җиңел, заманча ярашлы итеп гамәл кылган педагогларның берсе булды.* Р.Әмирхан. *Татар теленең кириллицага корылган аксак графикасын төзәтү буенча фикер алышу башлангач, мин теләсәм-теләмәсәм дә эндәшми кала алмадым.* Ә.Кәримуллин

**КИРКА** *и.* Таш, боз һ.б.ш. каты тукымнарны вату, ваклау, казу өчен, агач сапка утыртылган, очлы озынча тимердән гыйбарәт эш коралы; кәйлә

**КИРЛЕ** *бәйл. диал.* Бирле, алып. *Иделдән кирле җәяү килү*

**КИРЛЕ́-БАШЛЫ** *рәв. сөйл.* Алдан артка; киресенчә итеп. *Апа минем кулдагы китапны тартып алды, бер ягыннан ачып та карады. – Җитмәсә тагын бисмилласын кирле-башлы тоткан! Куй хәзер үк!* Г.Бәширов

**КИРЛЕ́-МЫРЛЫ** *рәв.* **1.** *сөйл.* Теләсә ничек, ничек теләсә шулай. *Әнисенең кирле-мырлы сөйләшүе, гел кирегә алуы гаҗәпләндерде аны.* С.Рәфыйков. *Кирле-мырлы торуына да, вакыт-вакыт читләтүенә дә карамастан, ул да Габдулланы үзенчә яраткан икән ич.* И.Нуруллин

**2.** *с.* Үзсүзле, тискәре, үҗәт. *[Харис:] Менә шушы кирле-мырлы холкың үзең үскән саен азына төшеп, берзаман бөтен эшне, бар кешене дошман күрә башламассыңмы икән?* З.Вәли

**КИРМӘК** *и. диал.* Каен кабыгының туз астындагы катламы

**КИРМӘН** *и.* Дошманнан саклану өчен, махсус корылмалар белән һәрьяктан уратылып алынган ныгытма; кальга. *Таш кирмәннең эчендә Бикә ялгыз йорт тота.* Табышмак. *1723 елда Петр I әмере белән татар кирмәне өстендә барлыкка килгән һәм патшабикә хөрмәтенә Катеринбург исемен алган бу урыс каласы татарлар өчен чын мәгънәсендә җәһәннәмгә әйләнә.* Ф.Бәйрәмова. *Казан кирмәненә каршы якта, Казансу ярындагы каенлыкта ике-өч айга бер уздырыла ул кошлар җыены.* Идел

**КИРПЕЧ** *и.* **1.** 1) Үзле балчыкны ком белән су катнаштырып изеп, махсус калыпта сугып, яндырып эшләнгән төзелеш материалы. *Мәхмүт Кашгари сүзлегенә караганда, ул заманнарда ук инде төркиләр яндырылган кирпеч кулланганнар, кирпечне калыплар белән сукканнар ---. Болгар чоры кирпечләре еш кына квадрат формасына якын итеп сугылганнар һәм яндырылганнар.* А.Тимергалин. *Инде усак бүрәнәләрдән генә түгел, бу яклар өчен сирәк эләгә торган, чәере алынмаган нарат яисә кирпечтән үк җиткерәләр икән йортны.* Р.Мөхәммәдиев. *Өстәвенә, әнә быел шул ук Биршеденең аръяк яр буена тоташ кирпечтән зур пар тегермәне салып җибәрде.* М.Әмир

2) Шундый формада калыпка салып, пресслап һ.б. юллар белән эшләнгән әйбер. *Минем күземә икмәк миче ягындагы --- озынча дүрт кырлы бер кирпеч өеме чалынды.* З.Бәшири. *Кирпеч ипи. Кирпеч чәй* // Шундый формада кисеп киптерелгән нәрсә. *Торф кирпече. Тизәк кирпече*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый төзелеш материалыннан эшләнгән, салынган. *Без әлеге дә баягы кирпеч блоклар ясадык, җәй азагында бу җиңел эш тәмамланды.* А.Гыйләҗев. *Кирпеч йорт. Кирпеч койма*

2) *сөйл.* Уен кәртендә төшерелгән кызыл ромб һәм шундый кәрт; буби. *Кирпеч туз. Кирпеч король*

**КИРПЕЧЛӘП** *рәв.* Кирпеч формасында. *Кирпечләп киселгән торф. Кирпечләп сугылган тизәк*

**КИРПЕЧЛЕК** *с.* Кирпеч сугарга яраклы, кирпеч ясарга дип әзерләнгән. *Әзрәк тамак ялгап алганчы, кирпечлек балчык басылган була.* Г.Якупова

**КИРПЕЧЧЕ** *и.* Кирпеч сугучы. *Игенчегә явым кирәк, кирпеччегә аяз кирәк.* Мәкаль

**КИРТ** *и.* Берәр әйбернең өслегенә үткен әйбер белән кисеп яки уеп ясалган эз, сыр. *Мәннән абзый тагы бер чабуга, агач төбендә кырт киселгән кыек кирт пәйда булды. Мәннән абзый шул агач төбенә тезләнде дә шыңгырдап торган яңа пычкыны кирткә каршы якка куйды.* Г.Гобәй. *Нарат сумаласы кәүсәгә киртләр ясау юлы белән алына.* Н.Верзилин. *Көтүчеләрдә бер сыер – бер кирт, ике бозау – бер кирт, алты сарык бер кирт булыр.* Шура

**КИРТӘ** *и.* 1) Егып, ботакларыннан арындырылган, юан булмаган агач кәүсәсе, колга, чош. *Фатыйма һәм энесе Гаптерәй, икесе урманнан киртә алып кайтып, яңадан койма тоттылар.* З.Кадыйрова. *Элекке умарталыктан калган колга һәм киртәләр, инде ныклыкларын югалткан булсалар да, җәйга килеп тордылар.* Ф.Яхин. *Абзар артларында киртәдән үрәчәләп әвеннәр куелган.* М.Мәһдиев

2) Шундый агач кәүсәсеннән буй-буй тотып ясалган аралы койма. *Уңга да, сулга да юл бикле булгач, киртә аша сикереп, зират эченә кереп киттек.* М.Әмир. *Фәсхи балта тотып, үзенең баш йортын киртә белән әйләндереп маташа иде.* Г.Ибраһимов. *Кай турыдан узуыбызны да белерлек хәлдә түгелмен. Әһә, күземә утар киртәсе чалынды. Беләм: юл киртәгә барып терәлә дә кинәт сулга борыла.* Казан утлары

3) *хәрби* Дошманның алга баруын тоткарлау, юлын кисү өчен төзелгән каршылык кыры. *Безнең батальон танкка каршы киртәләр (корылма) төзеде.* Ә.Маликов

4) Ике стена арасына буйдан-буйга беркетелгән озын колга. *Күлмәкыштанны түшәм янына ук сузып куелган агач киртәгә элдем.* М.Әмир

5) Җанлы-җансыз нәрсәләрнең юлына төшеп, хәрәкәтләрен уңайсызлый, тоткарлый торган сәбәп; нинди дә булса комачау. *Ат --- әлегә ватылып өлгермәгән яңа боз киртә каршына килеп тукталды.* М.Әмир. *Шайтан таягының орлыклары һавада тыныч кына очып йөриләр; ләкин берәр киртәгә очрау белән орлык үзенең парашютыннан аерыла да җиргә төшә.* Кызыклы физика. *[Солтан:] Политиканың бөтен кабахәтлеге шунда: ул үзара шик тудыра, адәм балалары арасына шөбһә киртәсе сала.* А.Расих

6) *спорт* Барьер. *Беркөнне иртә торды да --- унбиш тапкыр киртә аша сикерде, турникта уйнады.* Г.Бәширов

7) Нәрсәнең дә булса чиге, ахыры. *Яхшылыкның киртәсе юк.* Г.Галиев

8) *диал.* Бурап эшләнмәгән һәртөрле абзар

9) *диал.* Хуҗалыкта терлек ябу өчен койма яки читән белән тотып алынган өсте ачык урын; карда

10) *күч.* Эштә, тормышта очраган каршылык, комачау, тоткарлык, һәртөрле чикли, тоткарлый торган сәбәп. *Ләкин монда һичкемнең күңеленә килә алмый торган бер киртә баш күтәрде: Фәтхия карчык дөньяга сыймый, дулый.* Г.Ибраһимов. *Әйтерсең алар арасында җимерелергә тиеш булып та*

*әле һаман җимерелми калган тагын ниндидер бер киртә бар иде.* Г.Әпсәләмов. *«Сәяси яктан ышанычсыз» хәзрәткә, мәгълүм инде, идарәче даирәләр, карагруһчылар тарафыннан гел киртәләр куелып килә.* Р.Әмирхан

11) *күч.* Үсешнең аерым бер моменты, чиге. *Еллар үткән саен, адәм баласы үзенең сабыйлык һәм үсмер елларына ешрак әйләнеп кайта торган була икән. Күрәсең, минем дә шул киртәгә якынлашып барган көннәремдер.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Киртәгә кермәгән** Аңлаешсыз, буталчык. *Әни аны көч-хәл белән тыеп, тынычландырып, урынына яткырды, шуннан әти берninди киртәгә кермәгән сүзләр сөйли башлады.* М.Әмир. **Киртәгә тагу** *тар.* Элек гаепле кешене киртәгә бәйләп куеп җәзалау. **Киртәдән чыгу** 1) Кабул ителгән тәртиптән, кагыйдәдән, чамадан чыгу. *Шулар өстенә тагын үзара көч сынашуларга, батырлык күрсәтүләргә бик зур урын бирелә. Бу мәсьәләдә киртәдән чыгулар да була.* М.Әмир; 2) Узыну, күп тәртипсезлекләр эшләү; 3) Арттырып җибәрү. **Киртә кору** Комачаулау, кешенең юлына аркылы төшү. *Күршем инде, билгеле, Киртә кора миңа һәр эштә.* М.Җәлил. **Киртә салу** *к.* **киртә кору**. *Жандармнар шефы А.П.Шуваловның бу күрсәтмәсе хезмәткә урнашу юлларында бик озак еллар буена хатын-кызларга киртә сала.* Т.Биктимирова. *Безнең юлга дошман кулы белән Адым саен киртә салына.* М.Җәлил. **Киртәгә керү** Бик камил, төгәл рәвештә булмаса да, беркадәр ярарлык хәлгә керү. *Нокталар да төртмимен, керсә ярар дип, киртәгә: Мин үзем сызганны бик яхшы таныйм дип, иртәгә.* Г.Тукай. *Киртәсенә керсә ярар, соңыннан эшсезлектә, тәдбирсезлектә гаепли алмаслык булса, җибәр.* М.Галәү. **Киртә сикерү** 1) *тар.* Дин алыштыру (бер диннән икенче дингә чыгуга карата әйтелә); 2) Буйсынмау, башбаштаклык күрсәтү, тыйнаксызлану. *Гыйльмениса --- артык киртә сикерүчеләр турында ишетеп, чирканганалап та куя: табыла бит бер нәфсесенә баш була алмаган кешеләр.* Ф.Хөсни

**КИРТӘБАШ** *и. этн.* Башка чыгучы гаиләгә ата йортыннан бирелә торган терлек (гадәттә ул сарык булган)

**КИРТӘК** *и. бор.* Кияү белән кәләшнең зөфаф кичәсе үткәрә торган бүлмәсе яисә махсус чатыры, өе

**КИРТӘЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **киртәләү** (*1 мәгъ.*). *Уң як күршебездә мәчет. Ике арада рәшәткә белән киртәләнгән зур гына бушлык.* М.Әмир. *Гаваньга керү юлы бер генә кораб та үтә алмаслык калын чылбыр белән киртәләнгән була.* Урта гасыр тарихы

2) Яктылык каймасы яки нур белән урап алыну, әйләндереп алыну. *Ай киртәләнсә – суыкка.* Әйтем

**КИРТӘЛӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **киртәләү**. *Әле үзе тере чакта Кашфулла, таш койманың арт ягыннан чирәм бүлеп, шуны зиратка кушып киртәләттe.* М.Кәрим

**КИРТӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Киртә белән урату, киртә белән әйләндереп алу, киртә тоту. *Алтынгуҗа агайның өе кара мунча кебек кечкенә иде. ---Каралты-кура түгел, киртәләп алынган ишегалды да юк.* М.Әмир. *Һәдия, чыбык-чабык куйгалап, киртәләп, аңа өй сыманрак урын җайлап бирде.* Г.Якупова

2) Алга таба хәрәкәт итүне читенләштерү, комачаулау. *Һаваларга ашып торган агачлар арасын тутырып, аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр.* А.Шамов. *[Урал күпере] дошманның юлын киртәләргә безгә ярдәм итте.* Ш.Камал

3) *диал.* Кипкән печәнне ике яктан тырма белән өеп чыгу, тезмәгә салу

4) *күч.* Үсеш, алга китешне тоткарлау, кыенлаштыру

5) *күч.* Хәрәкәтне тоткарлап тору, туктату, чикләү. *Сугыш сөреме киртәли Диңгездән искән җилне.* Г.Хуҗиев

6) *күч.* Һәртөрле бәла-казалардан саклау, иминлекне тәэмин итеп тору. *Бу дөньяда сине кем иркәли соң? Бәләләрдән сине кем киртәли соң?* Г.Тукай

7) *күч.* Чик кую; чикләү, тыю (теләк, хис, омтылышларны). *Бусы артык, бусы ярамый дип, Киртәләдек яшьлек хисләрен.* М.Җәлил

**Киртәләп алу** Киртәләгән хәлгә китерү. *Каберлекне ул күптән киртәләп алган иде. Кадерсез булмас инде балаларының сөякләре дә.* Г.Якупова

**Киртәләп кую** Тиз арада яки алдан киртәләнгән хәлгә китерү

**Киртәләп чыгу** Барысын да киртәләү; тулысынча киртәләү

**КИРТӘЛЕ** *с.* 1) Киртәләнеп алынган, киртә белән әйләндерелгән. *Киртәле кибәнгә мал кермәс.* Мәкаль

2) *күч.* Комачаулы, тоткарлыклы, каршылыклы

**КИРТӘЛЕК** *и.* **1.** 1) Киртә тоту өчен яраклы агач яки башка материал. *Һәдия, кереп-чыгып йөрергә дип куелган киртәлекләрне алып, чоланга чыкты.* Г.Якупова

2) Киртә белән әйләндереп алынган буш урын. *Урман аланында киртәлек белән әйләндереп алынган печән кибәннәре*

3) *күч.* Комачау, тоткарлау, каршылык. *Иркәлек – кеше юлында киртәлек.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Киртә тоту өчен яраклы. *Киртәлек агачлар әзерләү*

**КИРТЕК** *и.* **1.** 1) Киртелгән төш, кирт; киртеп ясалган билге. *Кешелек дөньясының ачыш-табышларын, тәҗрибәсен --- кирәк вакытта файдалану өчен төрле чорларда төрле халыклар төрле ысуллар кулланганнар. Әнә шундыйларның кайберләре – хәтергә төшерү өчен кулъяулык, җеп очын төйнәп кую, таякка киртек ясау кебекләре – әле дә сакланып калган.* Ә.Кәримуллин

2) *диал.* Шәл читендә яки якада формасы белән телне хәтерләткән тасма

3) *кимс.* Тинтәк, булдыксыз кеше

**2.** *с. мәгъ.* Почмаклап кисеп, уеп алынган. *Өстендә киртек якалы, арттан ерык чабулы купшы бишмәт.* М.Әмир

**КИРТЕКЛӘ́Ү** *ф. к.* **киртләү** (*1 мәгъ.*) *Үткен пәке белән таякны киртекләү*

**Киртекләп кую** Киртекләнгән хәлгә китерү. *Җитмәсә, әбисе былтыр җәй аның буен ишек яңагына билгеләп, пычак белән киртекләп куйган иде.* Д.Каюмова

**Киртекләп чыгу** Барысын да киртекләү

**Киртекли бару** Рәттән киртекләү

**КИРТЕЛҮ** *ф.* Киртекләр барлыкка килү

**Киртелеп бетү** Барысы да киртелү

**КИРТЕШ** *и.* **1.** 1) Мамонтның гаять зур азау теше; кырый, ян теше

2) *к.* **фил сөяге**

**2.** *с. мәгъ.* Мамонт тешеннән яки фил сөягеннән эшләнгән. *Киртеш кашык*

**КИРТКЕ** *и.* Нәрсәне дә булса киртү, киртеп вату өчен ясалган кискеч корал. *Корыч киртке*

**КИРТКЕЧ** *и.* Кирт яки тамга ясау өчен кулланыла торган махсус корал

**КИРТЛӘНҮ** *ф.* Кирт белән билгеләнү. *Киртләнгән агачларны кисү*

**КИРТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса киртләр ясап чыгу; киртек чабу. *Йөз еллык наратны киртләгәндә, 16 килограмм сумала алырга мөмкин.* Н.Верзилин. *Яшь кенә, таза гәүдәле ике чуваш егете наратны үткен, зур балта белән киртләделәр дә икенче ягыннан зур бер пычкы белән кисәргә тотындылар.* З.Бәшири

2) *күч.* Бер үк нәрсә турында еш-еш искә төшереп тору; кисәтү. *Бу җавап Мәхмүдкә шундый үтемле, инандырырлык булып тоела ки, ул аны гомер буе онытмыйча, балалар зиһененә дә киртләп калдыра.* Р.Әмирхан. *Шушы «тиеш түгел»не [өйдә бәбиләүне] безнең колакларга бик нык киртләделәр профессорлар.* Сөембикә

**Киртләп бару** Рәттән киртләү; киртләү эшен башкару. *Киселергә тиешле агачларны киртләп бару*

**Киртләп кую** Алдан киртләгән хәлгә китерү. *[Вахитов:] Хәтереңә киртләп куй: бу егет милләтнең генә түгел, җирнең астын-өскә әйләндерергә сәләтле.* Р.Мөхәммәдиев. *Хәтеремә киртләп куйдым: бу фикергә мин үзем, үз акылым белән килдем.* Г.Якупова

**Киртләп чыгу** Башыннан ахырына хәтле берәм-берәм киртләү. *«Кара, ничек көтелмәгәнчә киртләп чыккан. Шәп, шәп, шәп!» – дип, туктаусыз кабатлыйсың.* Э.Шәрифуллина

**КИРТЛӘЧ** *и.* **1.** 1) *геогр.* Тау битендә яки башка урыннарда табигый рәвештә барлыкка килгән баскычсыман урын; терраса. *Шушы төшенке киртләч үрге әрәмәлеккә хәтле өзелми.* Ш.Камал. *Аксубайдан шундый ерак җирдә, Кавказ сырты киртләчләрендә. Кем уйлаган шундый биеклектә Очрармын дип илдәшләремә.* Х.Туфан. *Мескен коралайлар көндез кояшта эреп, төнлә пычактай ялтырап туңган кар киртләчләрендә тояк-бәкәлләрен җәрәхәтләгәч, яхшы чаба алмыйлар шул.* Г.Якупова

2) Кайбер предметларның кырыена, читенә урнаштырылган вак тешсыман чыгынты. *Зур якаларда киртләчләр булганда, башта алар тегелә (киртләчләр дигәндә, яканың очы күздә тотыла), аннан соң яканың өске як җөе тегелә.* Л.Мөхәммәт. *Тәрәзә йөзлеге киртләчләре*

3) *диал.* Баскычтагы басма. *Өйалды киртләче*

**2.** *с. мәгъ.* 1) *к.* **киртләчле**. *Урамнарга март җилләре килгәч, Киртләч карлар тавын бетерә.* Ш.Маннур. *Ул арада тегеләр утырган арбаның бер тәгәрмәче киртләч урынга эләкте дә, арба капланып та төште.* Сөембикә

2) Үзендә киртләчләр булган, киртләчләнеп торган. --- *Бар да бертөрле, шул ук вакытта һәркайсы үзенчә матур өйләргә, киртләч коймаларга, сырлы капкаларга карады.* Г.Гобәй

3) Ызмалы, зигзаглы. *Бу төр яка [«матрос» яка] нигезе өстенә теләсә нинди киртләч яка ясый аласыз.* Л.Мөхәммәт

**КИРТЛӘ́Ч-КИРТЛӘЧ** *с.* **1.** Киртләчләнеп торган. *Имәннең мускуллы беләкләр шикелле юан ботаклы көчле кәүсәсе, киртләч-киртләч читле каты яфраклары бар.* Н.Верзилин. *Биек ярлар, агач коймалар буена җил-буран киртләч-киртләч кар көртләре өеп китте.* М.Галәү

**2.** *рәв. мәгъ.* Күп киртләчләр ясап. *Агачларның куе ябалдашлары киртләч-киртләч күтәрелгән яшел тауга охшый.* Г.Әпсәләмов. *[Любовь Васильевна] Чәчен ике яктан киртләч-киртләч ясап, башына берет киеп төшкән.* Х.Сарьян

**КИРТЛӘЧЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн.* **киртләчләү**. *Түрдә өстенә бер нәрсә дә җәелмәгән, --- үткен пәкеләр белән киртләчләнгән, сырланган иске өстәл.* А.Шамов

2) Киртләч рәвешенә керү, киртләч хасил итү; киртләч-киртләч булып тору. *Канбулаттан караганда бөтенләй өстебезгә авып килгән Җиргәнтауның Агыйделгә барып бәрелгән чите киртләчләнеп-киртләчләнеп күтәрелгән биек-биек кызыл ярга әйләнеп китә.* М.Әмир

**Киртләчләнеп бетү** Бөтенләй киртләчләнү; шундый хәлгә килү

**Киртләчләнеп тору** Киртләчләнгән хәлдә булу; киртләч булып күренү

**КИРТЛӘЧЛӘ́Ү** *ф.* Киртләчләр ясау, киртү. *Өй кыегын киртләчләп бизәү*

**КИРТЛӘЧЛЕ** *с.* 1) Үзендә киртләчләре булган, киртләчләнеп торган. *Киртләчле таулар*

2) Үтмәсләнеп беткән, кырыйлары кителгән (кисә торган коралларның йөзе тур.)

**КИРТЛЕ** *с.* Киртеге, киртләче булган. *Киртле яка*

**КИРТМӘ** I *и. диал.* 1) Камыр башы, мая камыр

2) Калган ипи камырыннан пешерелгән кечкенә ипи

**КИРТМӘ** II *и. диал.* Груша, армут

**КИРТМӘ** III *и. диал.* 1) Бура

2) Буралап эшләнгән чардуган

3) Киртек; *русчасы:* **зарубка**

**КИРТМӘЛӘ́Ү** *ф. диал.* Бура бурау, бура кую

**КИРТҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса урында кискеч корал белән кирт, уенты ясау. *Табагач сабын берничә җирдән киртү*

2) Почмаклап кисеп, уеп алу. *Яшь таналарның колагын киртү*

**Киртеп алу** *к.* **киртеп кую**

**Киртеп кую** Тиз генә итеп кирткән хәлгә китерү. *Доктор Ярашович коронкалар ясап киюемне һич белмәскә тиеш. Моны, Вика, киртеп куегыз. Бу хакта ләм-мим!* Ш.Рәкыйпов. *Айдар бу эшне шулай туктаусыз дәвам иттереп, фәнни хезмәт язуны уена киртеп куйды.* Х.Сарьян

**Киртеп тору** Даими яки регуляр рәвештә киртү

**КИРЧӘК** *и. иск.* 1) Факт, дөреслек, чынлык. *Кирчәкләрен генә әйтү*

2) Мәгълүмат, информация

**КИРЧЕГӘ** *и. диал.* Нәрсәнең дә булса тирәндә яткан үзенчәлеге, нинди

дә булса эшнең асыл сере; хикмәт, җай. *Һәр скважинаның үз кирчегәсе була – без әле шуны өйрәнеп бетмәгән.* Р.Төхфәтуллин. *Эшнең кирчегәсен белү*

**КИРЧЕГӘЙЛӘНҮ** *ф. диал.* Киреләнү, кирелеккә бару, көйсезләнү, капризлану

**КИРШӘН** *и. диал.* 1) Юкә агачыннан уеп ясалган тагарак

2) Тоткалы тагарак, ялгаш

**КИРҮ** *и. диал.* Төньяк. *Җил кирүдән булса – салкын көт.* Әйтем

**КИСАП** *и.* Киленең төйгече (гадәттә нәкъ уртасында учлап тотарлык билдәмәсе булган шактый авыр һәм нык металл яки агач кисәгеннән гыйбарәт). *Килесенә күрә кисабы.* Мәкаль. *Әнисә, ишегалдына барып кергәч, исәнләшепнитеп тормады, шунда яткан бер кисапны алып булыша да башлады.* З.Бәшири

**КИСӘК** I *и.* 1) Бөтеннән бүленгән бер өлеш. *Хәзрәт, секунд саен юкка чыга барган тавык кисәкләрен имән бармагы белән төрткәли-төрткәли --- сорап куйды.* К.Тинчурин. *Май алганыгыбызга ышану өчен, аңа кәгазь, мамык, чүпрәк яки филтә кисәген манып яндырып карыйбыз: май яна.* Н.Верзилин

2) Ватылып, сынып төшкән өлеш. *Ипле генә йөгереп барган җирдән, каршыма, аяк очыма ук дип әйтерлек, каткан балчык кисәге килеп төште.* Р.Мөхәммәдиев. *Мәрьям бәләкәй генә пыяла вазаның төбенә вак-вак кисәкләргә ватып салган шикәрне өстәлгә куя.* Ш.Камал. *Физика дәресендә шулай була: укытучы магнит кисәген ала да кәгазь астыннан металл уалчыкларына якын китерә. Тимер кисәкләре үрә басалар.* М.Мәһдиев

3) Нинди дә булса мәйданның, бинаның яки бүлмәнең аерым өлеше. *Тора-бара [Габдулла] «хөҗрә»дә яши башлаган. Хөҗрә дигәне исә – җәмәгать сәкесенең чаршау белән бүлеп алынган бер кисәге.* И.Нуруллин

4) Нәрсәнең дә булса (тукыма, күн, тире, такта һ.б.ш. әйберләрнең) файдаланудан артып калган кисентесе, корама. *[Микәй] Бераз хәл алырга исәпләп, көн кызуын җыйган кара калай кисәге өстенә кояшка арка куеп сузылып ятты.* Р.Мөхәммәдиев. *Язу өстәле һәм өстәл тирәсе язылып ташланган кәгазь кисәкләре белән тулган.* Г.Кутуй. *Аның костюмына карата галстугы, галстугына карата күкрәк кесәсеннән күренеп торган бер кисәк тукыма булыр.* М.Мәһдиев

5) Сындырып яки кисеп алган ипи һ.б.ш. ашамлык сыныгы, телем. *[Шәриф] менә, зарурат буенча, беренче мәртәбә буларак, балаларына һәм хатынына садакадан алган кисәкләрне ашатты.* М.Гафури. *Сания күкәйне икегә сындырып, зуррак кисәген энесенә бирде.* Г.Гобәй. *Фатыйма сөтне җәлләмәде, бер генә кисәк ипиен дә көчеге белән бүлеште.* З.Кадыйрова

6) Бер төрдән булган әйберләрнең берсе; нәрсәнең дә булса стандарт берәмлеге; пачка; данә. *[Зәйнулла хаҗи:] – Кем, Галиулла, --- агайның үзенә илле тиен садака, бер кисәк теге сабынны бир!.. – дип фәрман бирде.* К.Тинчурин. *[Немец] Пергаментка төргән өч кисәк нәрсә китереп, безнекеләрнең алдына салды.* Ә.Еники. *Олы урамнан Гаяз килеп чыкты, аның кулында капрон сетка, ә сеткада өчме-дүртме кисәк такта чәй күренеп тора.* Х.Сарьян

7) Беришле предметларның яки беришле массаның бер стандарт төргәге. *Минһаҗетдин прилавка өстеннән актык ситсы кисәген алып, шүрлеккә пөхтәләп куйды.* К.Тинчурин

8) Нинди дә булса бер күренешнең, вакыйганың, хәлнең состав өлеше. *Шәһәрдән шәһәргә йөк ташучыларның юл капчыкларына ияреп, заманының культура кисәкләре дә кайткан Җиргәнгә; календарь, китаплар кебек, Камил Мотыйгый тавышларын яңгыраткан граммофон тәлинкәләре кебек!* М.Әмир. *Һәрбер көн генә түгел, бәлки, һәрбер сәгать, һәрбер йөткерүнең аның гомереннән бер кисәген кубарып алганлыгын без генә түгел, ул [Г. Тукай] үзе дә белә вә аңлый иде.* Ф.Әмирхан

9) Бүлем, кечкенә кишәрлек, җир участогы. *Туры чыга алмасалар, тар гына булса да, бу кисәк җир үзебезнеке.* Ш.Рәкыйпов

10) Әсәрнең бер өлеше, бүлеге; бүлем. *Хәлим Искәндәревне тәҗрибәле педагог буларак таныткан, аның иҗатында иң күренекле урын тоткан хезмәте – «Белек йорты» (1912, 1913) исемле ике кисәктән торган хрестоматиясе.* М.Мәһдиев. *Билгеле булганча, Кырымда Г.Ибраһимов --- «Казакъ кызы» романын да редакцияли һәм әсәрнең икенче кисәге өстендә эшли.* Р.Мостафин. *Ике роман итеп уйланылган «Тукай» эпопеясының беренче кисәген [Ә.Фәйзи] 1947 елда яза башлаган.* Т.Галиуллин

11) *лингв.* Сүз яки сөйләмнең грамматик функциягә ия булган бер өлеше. *Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләнең иярчен кисәкләре. Тиңдәш кисәкләр*

12) Кемне яки нәрсәне дә булса мыскыллап, кимсетеп әйткәндә кулланыла торган тагылма сүз. *Без, малайлар, ир заты кисәкләре, ничек тә юл газабын ат белән кичтек.* Р.Төхфәтуллин. *Шуның өстенә квартирасы да шәптән түгел, Ягеднидәге авылча кара-каршы салынган кыйшык-мыйшык бер өй кисәгенең ярты ягыннан гыйбарәт иде.* Г.Гобәй. *Шушы юк кына хат кисәге өчен нигә тарткалашканнар егетләр? Аңламадым.* А.Гыйләҗев

13) Берәр зур күренешнең кечкенә генә өлеше, чаткысы, тамчысы. *Мәрхәбәнең сүзләре --- кызы Гөлбануның өстен каплаган киләчәк кара болытлар эчендә кечкенә генә бер якты кисәге ялтырап калгандай тоелды.* Г.Ибраһимов. *Рәхмәт сиңа, Акбиев, син миңа яшьлегемнең еракта күмелеп калган бер кисәген кайтарып, өстеннән пәрдәне ачып бирдең.* М.Мәһдиев

14) *тарт. форм.* Үзеннән алда килгән *җан, бәгырь* сүзләре белән берлектә, иркәләп, назлап мөрәҗәгать итү тәгъбире буларак кулланыла. *Гомерем булып, таш басмаса, Ташламам, җан кисәгем.* Җыр. *Хатны укып бетерүгә: – Илдарым, бәгырь кисәгем минем! – дип, җан ачысы белән кычкырып ишеккә ташландым.* Э.Шәрифуллина

**КИСӘК** II *рәв. сөйл.* Кинәт, көтмәгәндә. *Яңгыр, кисәк кенә башланган кебек, кисәк кенә узып та китте.* М.Галәү. *Кәҗә бәтиенә исә бу ошамады: дертләп китеп, кисәк кенә муенын читкә борды.* Р.Мөхәммәдиев. *Идән урта-*

*сына басып, урта бармагыңны борын очына куясың да, кисәк кенә хәрәкәт ясап, бер якка төртеп күрсәтәсең.* Э.Шәрифуллина

**КИСӘК-КОСАК** *җый. и. сөйл. к.* **кисәк-посак**. *Сания кисәк-косаклардан курчагына күлмәк текте.* Г.Гобәй. *[Уйлап табучы:] Тәгәрмәче шәп материалдан ясалган булса ие, ә бу нәрсә кисәк-косактан гына бит.* Я.Перельман

**КИСӘКЛӘНҮ** *ф.* Нәрсәнең дә булса кисәкләргә бүлгәләнүе яки кисәк-кисәк булып оешуы. *Арба юлындагы көчле яңгырдан ләмгә әйләнгән балчык икенче көнне яргаланып, кисәкләнеп каткан иде.* Татар иле

**Кисәкләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча кисәкләнү

**КИСӘКЛӘП** *рәв.* Кисәк-кисәк итеп, өлешләргә бүлеп. *Мин тиз генә --- кар базына чыгып, боз алып кердем. Шуны вак-вак кисәкләп йотса, туктый торган иде.* Х.Сарьян. *Кисәкләп сату*

**КИСӘКЛӘТӘ** *рәв.* 1) Кисәге белән. *– Эш белән генә ул чаклы мал таба алу – бик авыр хәл... Кисәкләтә алтын табып, хуҗаңа бирми калдыргансыңдыр, – диләр [миңа].* Г.Ибраһимов

2) Зур кисәкле килеш, вак кисәкләргә бүлгәләмичә. *Итне кисәкләтә сатып алу. Тукыманы кисәкләтә сатарга кую*

**КИСӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бөтен, тоташ әйберне вак кисәкләргә, өлешләргә бүлү. *Ит түшкәсен кисәкләү*

2) *сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса пычак, кылыч һ.б.ш. кораллар белән чапкалау, тураклау. *Снаряд алып бетермәгән корбаннарны алырга, үлмичә калган җәрәхәтлеләрне кылыч белән кисәкләргә дип килгән казаклар кире борылдылар.* Ш.Усманов

**Кисәкләп кую** Алдан кисәкләү; кисәкләнгән хәлгә китерү

**Кисәкләп чыгу** Бөтенесен дә кисәкләү; тулысынча кисәкләнгән хәлгә китерү

**Кисәкли бару** Барысын да рәттән кисәкләү

**Кисәкли тору** Даими рәвештә кисәкләү

**КИСӘКЛЕ** *с.* 1) Кисәкләргә, шакмакларга бүленгән, кисәк-кисәк итеп эшләнгән. *Кисәкле шикәр. Кисәкле сабын. Кисәкле сыр. Кисәкле тоз*

2) Берәмләп, данәләп сатыла торган. *Кисәкле товар. Кисәкле тукыма төргәкләре*

3) Бүлекләрдән, өлешләрдән торган. *Лифтта бездән башка бер генә кеше – ул елларда күп кисәкле романнары, сценарийлары белән шаулаган шанлы-шөһрәтле язучы, зур начальник – Георгий Марков.* М.Мәһдиев

**КИСӘ́К-ПОСАК** *җый. и. сөйл.* **1.** Билгеле бер эш процессында нәрсәдән дә булса артып калган кисәкләр

**2.** *с. мәгъ. к.* **калдык-постык**. *Ә чаналарда нәрсә генә юк! Күлмәк, иске бишмәт дисеңме; шәл, яулык, кисәк-посак парчалар дисеңме.* Н.Дәүли

**КИСӘКТӘН** *рәв. сөйл.* Кинәт, көтмәгәндә. *Йөрәктә кисәктән генә бер курку, сискәнү кебек хис кузгалып үтте.* Мирас

**КИСӘКЧӘ́** *и.* 1) Кечкенә кисәк. *Тамырчаның [җикән] кыздырылган кисәкчәләрен кофе итеп файдаланырга була.* Н.Верзилин. *Тукай халкы өчен яшәде, ул – халыкның бары тик кечкенә бер кисәкчәсе.* И.Нуруллин

2) *биол., физ.* Зәррә, атом төше, аерым өлеш

3) *лингв.* Аерым сүзләрне яки җөмләләрне төрле мәгънәви һәм модаль төсмерләр белән бизи торган ярдәмлек сүзләр (мәс., *һич, ни, исә, -мы//-ме* һ.б.). *Кисәкчә һәм ымлык сөйләүче кешенең тойгысын, әйтелгән сүзгә мөнәсәбәтен белдерәләр.* Татар грамматикасы. *Сорау кисәкчәсен алган хәбәр гадәттә үткән заманда килә.* Синтаксис

**КИСӘ́КЧӘ** *рәв.* Тулысынча түгел, өлешчә

**КИСӘКЧЕК** *и.* 1) Кечкенә кисәк, кисәкчә. *Донецк таулыгында ул [туфрак ясаучы] токымда комташ, известьташ һәм балчык сланецының кисәкчекләре күренә.* А.Фатхуллин. *Измәдә балчык кисәкчекләре күбрәк булган саен, аның үзлелеге һәм утыруы арта.* Төзү материаллары

2) *физ.* Материянең мөстәкыйль (дискрет) берәмлеге. *Молекулалар тагын да ваграк кисәкчекләрдән – атомнардан тора.* Физика. *Химик элементларның вак кисәкчекләре*

**КИСӘТМӘ** *и.* **1.** Шелтә, кисәтү. *– Дошманнарның ниятләрен белмәссең. Сиңа да мондый вакытта йокы калдырып урамда йөрергә киңәш бирмәс идем. Ярый ла безгә очрадың, – дип, Нәби аңа кисәтмә ясап алды.* К.Тинчурин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кисәтү характерындагы, кисәтүле. *Кисәтмә сигнал. Кисәтмә төс*

2) Алдан кисәтеп башкарылган. *Кисәтмә диктант*

**КИСӘТҮ** I *ф.* 1) Алдан белдерү, алдан хәбәр итү, искәртү. *Бу китап [«Мөстәфадел-әхбар»] үзенең тарихын оныткан, үткәненнән тәэсирләнүне күңеленнән чыгарган бу татарларга көтелмәгән бер кисәтү булды.* С.Кудаш. *Әнә бит, Гаяз Исхакый да «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дип кисәткән.* Ә.Рәшит. *Шул кеше көннәрдән бер көнне Разия апаның ишегең кага, пышылдап кына, ирегезне кулга алулары мөмкин, аң булып торыгыз, дип кисәтә.* Р.Әмирхан

2) Шелтәләү, шелтә белдерү. *[Жан:] Виктория Фёдоровна! Сезгә кисәтү белдерәм: бүтән беркайчан да мондый үзешчәнлек күрсәтмәскә!* Ш.Рәкыйпов

3) Нинди дә булса күңелсезлекне булдырмау өчен, алдан чарасын күрү. *Янгынны кисәтү. Су басуны кисәтү. Йогышлы авыруларны алдан кисәтү*

**Кисәтә башлау** Кисәтергә тотыну

**Кисәтеп килү** Күптәннән бирле, һәрдаим кисәтү

**Кисәтеп кую** Алдан искәртү; бер мәртәбә кисәтү. *Маякчы апа ике чыгуында да кисәтеп куйды: «Карагыз аны, колагыгызны борырмын!»* Г.Гобәй. *[Гыйният мулла:] Насыйп булса, өйгә кайткач түләрсез, дип кисәтеп куярга да онытмады.* М.Әмир. *– Беркемгә дә сөйлисе булма, ишетсен колагың!.. – дип, Кыям абзый Саҗидә апаны да, җиткән кызын да кисәтеп куйды.* Х.Сарьян

**Кисәтеп тору** Даими рәвештә кисәтү. *[Хәлфә] дәрес биргән вакытта берәр малайның --- күршесе белән сөйләшкәнен күрсә, кисәтеп тормый,*

*кулындагы дүрт кырлы правилосы белән шап итеп тегенең башына кундыра.* М.Әмир. *Тормыш шулай кисәтеп тора: борыныгызны салындырмагыз, җыр белән юатырмын, ди.* М.Мәһдиев

**Кисәтеп узу** Сүз уңаенда кисәтү

**Кисәтеп үтү** *к.* **кисәтеп узу**

**КИСӘТҮ** II *и.* 1) Шелтә; күрсәтмә. *Мин ун ел --- эшлим, бер тапкыр да кисәтү алганым юк.* Г.Ахунов. *[Чәмәт:] Вакытында дусларча кисәтү булсын. Ә ышануы – синең эш.* Х.Сарьян. *Алай гына да түгел, һәр ир кеше үзен – ата, һәр хатын ана дип хис итә, берәр ярамаган эш өстендә күрсә, баланы кисәтүне --- үзенең бурычы дип саный.* М.Әмир

2) Алдап хәбәр итү. *Ул да түгел, йөрәкне жу-у иттереп сузып-сузып, паровоз кычкыртып куя. Ниндидер шом, ниндидер кисәтү бар сыман шул авазда.* Р.Мөхәммәдиев. *Тик бу юлы ул [грузовик] малайлар янында туктап тормады ---, бераз әкренәя төшеп, кисәтү гудогы бирә-бирә, күпер аша чыгып китте.* Г.Гобәй. *Беренче кисәтү чажылдавын исәпләмәгәндә, тал чыбыгы нәкъ алты тапкыр сызгырып ала.* М.Мәһдиев

**КИСӘТҮЛЕ** *с.* 1) Кисәтүне, янауны белдергән. *Бу караш шул ук вакытта кисәтүле дә иде.* Г.Минский. *Сабый әбисенең кисәтүле тавышыннан шиңеп төште, авыр сулады.* Ф.Садриев. *Саҗидәнең колак төбендә Гафият хаҗиның карт хатыны әйткән кисәтүле сүзләре яңгырады.* М.Галәү

2) Нинди дә булса эш-гамәл турында алдан әйтеп куелган. *Кисәтүле диктант*

**КИСӘТҮСЕЗ** *рәв.* Кисәтмичә, көтмәгәндә, кинәттән. *Кисәтүсез кире керү. Кисәтүсез һөҗүм итү*

**КИСӘТҮЧӘН** *с. к.* **кисәтүле** (*1 мәгъ.*) *– Әбине юаттык юатуын да, – дип башлады врач, ничектер үтә җитди һәм кисәтүчән тон белән.* Ф.Хөсни

**КИСӘ́Ү** *и.* 1) Күмерләнеп янып торган яки янып сүнгән утын, агач кисәге. *Хуҗа хатын, янган мичтән учакка күмер, утлы кисәү тартып, бәрәңге пешерергә куя.* М.Мәһдиев. *Кайвакытта янган агач кисәүләре сынып төшә дә, чаткылар чәчелеп китә.* Ш.Усманов. *Учак әллә кайчан сүнгән. Аннан салкын көл белән сасы кисәү башлары гына калган.* Г.Бәширов

2) *к.* **кисәү агачы**. *Кисәү сабы озын булса, кулың көймәс.* Мәкаль. *Хәлим көлгә күмгән бәрәңгеләрнең көйгән исе чыга башлагач, кисәү алып, алгарак күчерде.* Г.Гобәй. *Мәликә, мич арасыннан кисәү алып, Рәүфәне туйганчы, ачуы басылганчы кыйнарга --- уйлаган иде.* А.Шамов

**КИСӘ́Ү АГАЧЫ** *и.* Мич күмерен болгату яки учакка тарту өчен, бер очын бөгеп, махсус җайланган, тоту өчен икенче башы агачка беркетелгән тимер таяк. *[Асылгәрәй:] Ә берсендә мин ул туңган ике катлы пыяланы кисәү агачы белән сугып ваттым.* З.Кадыйрова. *Әнисе кисәү агачы белән мич тарта башлады.* Р.Мөхәммәдиев. *[Габделкаюм:] Әби, син мине укырга өйрәткәндә ««ләм» кисәү агачы шикелле була» дип өйрәткән идең.* М.Гали

**КИСӘ́Ү ГӨМБӘСЕ** *и.* Башаклы үсемлекләрнең башагына ябышып үсә торган карасу шәмәхә төстәге йогышлы паразит гөмбә

**КИСӘҮЛӘНҮ** *ф. сир.* Кисәүгә (*1 мәгъ.*) әйләнү

**КИСӘ́Ү ТАЯГЫ** *и. к.* **кисәү агачы**

**КИСВӘ** *и. гар.* Кәгъбәнең диварларын каплап тора торган, гадәттә, кара ефәк япма. *Шул кисвәнең бер кисәген 2008 елның декабрендә Согуд Гәрәбстаны илчесе Татарстанга бүләк итте.* С.Сөнгатуллина. *Алты ай йөреп, Кәгъбәтулла өстенә ябыла торган кисвәнең бер кисәген алып кайткан.* Кызыл таң

**КИСЕК** *с.* **1.** 1) Кисеп алынган, кисеп кыскартылган. *Күз алдында каппкара чәчле --- кулына кисек мылтык тоткан бер бик усал бандит күренеп торды сыман.* Н.Дәүли

2) Киселгән; өзелгән. *Килгән юлым кисек, Ялгыйм икән ничек?* Э.Шәрифуллина

**2.** *и. мәгъ.* Кисенте, кисәк

**КИСЕКБАШ** I *и.* Татар халык риваятьләрендәге персонаж, иман өчен, ислам дине өчен гөнаһсызга җәберләнгән әүлия

**КИСЕКБАШ** II *и. зоол.* Балкараклар семьялыгыннан аркасында кешенең баш сөяге сыман саргылт төстәге сурәте булган, эңгер-меңгердә һәм төнлә оча торган эре күбәләкнең бер төре; *русчасы:* **мёртвая (адамова) голова**

**КИСЕКЛЕК** *и.* 1) Кисек булу. *Тәрәзә пыяласы өлгесенең кисеклеге күзгә чалынды*

2) *сөйл. к.* **кисентелек**

**КИСЕЛДЕК** *и.* Гарипләнү сәбәпле киселеп ташланган кул-аякның гәүдәдә калган өлеше; *русчасы:* **культя**. *Ул сикереп үк торды. Кул чугыдай гына калган ике балтыр киселдеген аяктай асылындырып, сәкесенә утырды.* Х.Сарьян

**КИСЕЛЕШ** *и.* 1) Нәрсәнеңдер киселү рәвеше, ничек киселгәнлеге. *Киселештә кыеклык арткан саен, киселгән җир ныграк озыная. Бу озынлыкны булдыру өчен, арт якта төп киңлеге киңрәк алына.* Л.Мөхәммәт. *Җиң төбе киселеше*

2) *к.* **кисем** (*1 мәгъ.*). *Цилиндрның аркылы киселеше*

**КИСЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **кисү**. *Менә чикмәннең ал тактасы булды, арт тактасы, аннары җиңнәре белән зур кайтарма якасы киселде.* Г.Бәширов. *Бу урманның вак агачлары киселәчәк икән.* Казан утлары. *Сандыкта, биш метрлап булыр, киселмәгән күлмәклек ята*

2) Кислота, известь эремәсе тиеп, яки көя һ.б.ш. корткычлар ашаудан тишкәләнеп бетү, кискәләнү. *Көя ашап киселгән тун*

3) Салкын һава, суык, җил һ.б. тәэсирендә тәннең кайбер өлешләре кызару. *Алар – биш кеше. Шәһәргә чыкканда, һәммәсе кырынган, җилгә киселеп, кояшта янган чиста йөзләреннән кырыс тазалык бәреп тора иде.* Х.Сарьян. *Үзе чын ир булган: буйга тартылган, иңнәре киңәйгән, йөзе җилдән каралган, киселгән.* Г.Әпсәләмов

4) Таушалу, теткәләнү, яраксыз хәлгә килү. *Чит-чите киселгән кәгазь битләре*

5) Нинди дә булса үткен корал белән җәрәхәтләнү. *Болынның урталыгына*

*җиткәч, киерелеп, бер-ике селтәдем дә, картның аяк янынннан кырып алып: – Киселәсең, кал артта! – дип тавыш бирдем.* Г.Ибраһимов. *Үсмер чакта печән чапканда, үлән сабакларына чорналган кәлтә, чалгыга киселеп, койрыгын өздерде.* Идел

6) Как-вак кисәкләргә туралу (бөтен, тоташ нәрсәләр тур.). *Фатыйманың өстәлдәге кабарып пешкән күмәчләрне, нечкә итеп киселгән токмачларны беренче күрүе иде.* З.Кадыйрова. *Өстәл өстенә телем-телем итеп киселгән бодай күмәче, ике чынаяк чокыры китереп куелды.* А.Шамов. *Аш китерелде, токмачы яшь кызлар кулы белән нечкә итеп киселгән.* М.Мәһдиев

7) *күч.* Бүленеп калу, аерылып калу, тоткарлану. *Алда, артта, уңда һәм сулында Киселсә дә юлым, күкрәгем ---. Көчсезләнеп, мин яшь түкмәдем.* М.Җәлил. *Кавдивизиянең йөгерек атлары баскан җирләрдә дошманның киселеп, изелеп ташланган хәрби бүлекләре, --- ватылган, җимерелгән станцияләре генә калды.* А.Шамов

8) *күч.* Өзелү, кинәт юкка чыгарылу; бетерелү. *Кешеләр сугыша, кан коя, Киселә меңнәрчә гомерләр.* М.Җәлил. *Кузьма дәдәй [сугышка] керү белән киселгән, ә менә меңгә бер бәхетле кеше – Фидаил абый кайтты.* Х.Сарьян. --- *Төннәрнең берсендә ул, отряд белән бергә, шәһәргә налёт ясады. Көтелмәгән бу һөҗүмнән дошман бик нык киселде.* Г.Кутуй

9) *күч.* Тукталу, өзелү, бетү (мөнәсәбәт, эш-хәрәкәт тур.). *Сүз, көлке киселде. Гарифулла элекке җитди хәленә кайтты.* Г.Минский. *Еллар үтте. Инде кайтыр чагы якынлашып килә иде. Менә бервакыт хәбәр-хәтер киселә.* Г.Ибраһимов. *Бу юлы сүзләре шул урында киселде.* М.Гафури

**2. киселеп** *рәв. мәгъ.* 1) Нык итеп, онытылмаслык булып. *Болай ваклап чәйнәп йоттырган нәрсә аның хәтеренә киселеп керде.* Г.Ибраһимов

2) Соң дәрәҗәдә, бик нык. --- *ит шулпасы исе борыныма ярып килеп кергәч кенә, мин үземнең иртәдән бирле ашамаудан киселеп ачыкканлыгымны сиздем.* Х.Сарьян

3) Аерым, аерылып, үзенә башка. *Кышын без дөньядан киселеп яшибез. Иң якын станция Камбарка булып, анысы да безгә җитмеш чакрым кире якта иде.* Х.Сарьян

4) Теге яки бу эшне эшләүдән туктап, тыелып. *Мин тагы нидер әйтмәкче булган идем – капыл киселеп уйга калдым.* Х.Сарьян

◊ **Киселеп йөрү** *ирон.* Кемгәдер бик тугры булгандай кыланып йөрүчегә карата әйтелә. *Дус булып киселеп йөргән була бит әле үзе, серләрен сөйләгән була.* Ш.Маннур. **Киселеп чыккан** 1) Бик үткен, чая. *Киселеп чыккан күзләр, күңелем аша кабынып, сөзә бөтен җир йөзен.* Н.Исәнбәт; 2) Үзенекен итүдә берни алдында да туктап тормаучы, үтә дә елгыр, тәҗрибәле

**Киселә бару** Рәттән киселү

**Киселә башлау** Киселергә тотыну. *[Әхмәди] озак йөрүдән читләре киселә башлаган сары конвертны кабаланып ачарга тотынды.* Г.Бәширов

**Киселеп бетү** Бөтенләй, тәмам киселү; бөтенләй киселгән хәлгә килү. *Ә Мәннан абзый, еккан агач киселеп бетеп, яңаны Хәлим белән егарга чират җиткәч, алай димәде.* Г.Гобәй. *Шулай йөгерә торгач, урам киселеп кенә бетеп --- үзәнлеккә төшеп китте.* Х.Сарьян

**Киселеп китү** Кинәттән, көтмәгәндә киселү

**Киселеп чыгу** Бөтенләй, тәмам киселү; тоташ киселгән хәлгә килү. *Кыз, мә дигәнне дә көтмичә, балтаны Хәлим кулыннан тартып алды. – Менә болай чабалар аны... Ботак бер селтәнүдә киселеп чыкты.* Г.Гобәй

**КИСЕМ** *и. мат.* 1) Предметны кисеп алган урында барлыкка килгән өслек. *Аркылы кисеме квадрат формасында булган авыр балканы, 30°лы почмак ясап авышкан яссылык буенча шудырып, машинадан төшерәләр.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. *Кәүсәнең өч кисеме тикшерелә: аркылы кисеме, радиаль кисеме, хорда буенче орынма кисеме.* Төзү материаллары

2) Телем, кисәк. *Гөмбә кисемнәре кипкәч, аны тирәләй кисеп алыгыз да гөмбәләрне гербарий битләренә ябыштырыгыз.* Н.Верзилин

**КИСЕМЛЕ** *с.* Билгеле бер формадагы кисеме булган. *Овал кисемле җисемнәр*

**КИСЕМТӘ** *и. мат.* 1) Билгеләнгән ике нокта арасындагы сызык. *Әгәр билгеле бер кисемтәдә җисем төрлечә хәрәкәт итсә, әлеге кисемтәне аерым кисәкләргә бүлеп, һәр кисәкне аерым карарга кирәк.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. *Кисемтә сызу*

2) Газета-журналлардан кисеп алынган аерым текстлар, мәкаләләр. *Журнал кисемтәләре*

**КИСЕНТЕ** *и.* 1) Әйбернең кисеп алынган бер өлеше. --- *мөдир терсәктән киселгән кул кисентесен Фирдүснең борын төбендә селки башлады.* Г.Ахунов. *Читән буена узган ел гына тирәк кисентеләре тезеп утырткан идем.* М.Әмир. *Бүрәнә кисентеләре. Такта кисентеләре*

2) *к.* **кисем**. *[Йосыф] өрәңге кисентесендәге тамчыларны күргәч, авыр гына сулап: – Бүген кискәннәр, – дип уйлады.* К.Нәҗми

3) Урманда агачлар киселгән урын, кисентек. *Бригадир анда-санда гына аударылмый калган наратлар белән чуарланган киң кисенте буйлап китеп барды.* Г.Әпсәләмов. *Аюхан көн дә урманга бара, барган саен теге урман кисентесе аша үтә, бер-ике агачны аты белән сөйрәтеп ачыклыкка чыгарып, чистартып китә.* Г.Якупова

4) Җиргә батып кергән тәгәрмәч эзеннән хасил булган чокыр-чакырлар. *Көзге пычракта бозылып калган урамнар, юллар бөтен казылмалары, кисенте вә чокырлары белән бер төн эчендә шакыраеп каталар.* Г.Бәширов

5) *тар.* Россиядә 1861 елгы крестьян реформалары вакытында алпавытлар тарафыннан крестьяннарның имана җирләреннән кисеп алынган участок

**КИСЕНТЕК** *и.* Киселгән урман урыны; ачык мәйдан; *русчасы:* **вырубка**. *Бик матур, һавасы саф булган кисентеккә кергәч, Зәки әкренрәк атлый башлады.* Х.Мөҗәй

**КИСЕНТЕЛЕ** *с.* 1) Үзендә кисентесе булган. *Кисентеле урман. Кисентеле кишәрлек*

2) *диал.* Казылмалы; сикәлтәле, тигезсез. *Кисентеле урман юлы*

**КИСЕНТЕЛЕК** *и.* **1.** 1) Кисәргә билгеләнгән урман. *Кисентелек чикләрен билгеләү*

2) Агачлары кисеп алынган урын

**2.** *с. мәгъ.* Кисәргә билгеләнгән

**КИСЕРКӘ** *и. диал.* Кәлтә елан

**КИСЕТ** *и. гар.* Чигүле тәмәке янчыгы. *Кайсы кисет чигә, кайсы йон эрли.* М.Шабай

**КИСЕШ** *и.* Суеш, сугыш, үтереш

**КИСЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **кисү**. *[Тикшерүче:] Соравым: манара кисешкән өчен, аңа берәрсенең янаганын ишетмәдегезме?* Х.Сарьян

2) Нәрсәләрнең дә булса үзара тоташуы һәм як-якка аерылып китүе. *Ике гасыр кисешкән чорда төрле дәрәҗәдәге хакимият хуҗаларының да психологиясе үзгәрде.* Казан утлары. *Урамнар кисешкән урыннарны үтүе кыенрак, анда танклар белән эш итә идек.* Гасырлар авазы

3) *мат.* Сызыклар һәм яссылыклар турында: уртак ноктада яисә уртак сызыкта очрашу. *Ике яссылык кисешүеннән барлыкка килгән почмак ике кырлы почмак дип атала.* Математика. *Кисешү ноктасы. Параллель сызыклар кисешмиләр*

4) *күч.* Бик каты талашу-сугышу, суешу

**КИСЕЯ** *и. рус* **1.** Киҗе-мамыктан эшләнгән үтә күренмәле җиңел тукыма. *Тәрәзә пәрдәләре ак бөздән яки кисеядән була.* К.Насыйри

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән яисә шуннан тегелгән. *Бай йорты тәрәзәләренең берсендә ашыгыч кына күтәрелгән кисея пәрдәнең күбектәй кабаруын ул искәрмәде.* Г.Шәрипова. *Ул көзге кебек шоп-шома су өсләре, ул кызларның кисея шарфы кебек җиңел ак томаннар.* Мирас

**КИСКӘ** *и.* 1) Кисеп аударылган агач кисентесе; юан түмәр. *Балта чапканчы кискә ял итә.* Мәкаль. *Кесмәс ярлары җимерелгәндә, сөяккә әйләнгән юан-юан агач кәүсәләре чыга, моны бездә кискә дип йөртәләр.* М.Мәһдиев. *Кыяфәте дә килеп тора: имән кискәседәй таза гәүдәле, кызыл йөзле, карчыга борынлы...* И.Нуруллин

2) *диал.* Кузла; утын кискәндә кулланыла торган стан

◊ **Кискә булып яту** Комачаулык итү, тоткарлау. *[Фатыйма бикә] Кызының олуг бәхетенә ирешү юлында кискә булып яткан Зыяның язмыш кулы илә алып ташлануына чыннан да куана иде.* Г.Ибраһимов. **Кискәдәй яту** *к.* **кискә булып яту**. *Гомумән, ул үзенә каршы төшкән, юлында кискәдәй яткан теләсә кем өстеннән яла-ифтира язудан чирканмый.* Х.Сарьян. **Кискә кебек** Эшкә авыр кузгала торган, инициативасыз (кеше)

**КИСКӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Күп кисәкләргә яки өлешләргә киселү

2) Күп урыннан, төрле төштән киселү, телгәләнү (бәрелү-сугылудан, җәрәхәтләнүдән, җилдән һ.б.ш.). *Иңбашы кылыч белән кискәләнгән*

**Кискәләнә бару** Рәттән кискәләнү; ныграк кискәләнү

**Кискәләнә төшү** Беркадәр, бераз кискәләнү

**Кискәләнеп бетү** Бөтенләй, тәмам кискәләнү, тәмам кискәләнгән (туракланган) хәлгә килү. *Тәгъзимә уң кулына карап алды. Чыннан да, аның кулы каралып, кискәләнеп беткән иде.* А.Расих. *Архивлар белән эш иткән кешеләр бер нәрсәгә хәйран кала: әлеге газета-журналлар туракланып, кискәләнеп беткән.* Ә.Рәшитов

**КИСКЕН** *с.* **1.** 1) Көчле тәэсир итә торган, ачы, үтә көчле (җилгә карата). *Яфраксыз агач башларындагы чыбыкларны кискен март җиле чайкалдырып тора.* Ш.Камал

2) Искәрмәстән, көтмәгәндә, бик тиз эшләнгән. *Әбүзәр абзый имән бармагы белән кискен-кискен ишарәләр ясап ала.* Г.Әпсәләмов. *Кинәт әсирләр арасында кискен бер хәрәкәт булып алды.* А.Расих

3) Капыл, кинәт булган. *1926 ел. Дипломат язмышында безгә төп сәбәпләре әлегә мәгълүм булмаган яңа кискен борылыш.* Р.Әмирхан. *Ләкин Миргали йөзендәге кискен үзгәреш Сабирны каушатты.* М.Камал

4) Авыр, кыен, катлаулы; хәлиткеч. *1942 елның кышында Сталинград янында бөек сугышның кискен борылышы булды.* Н.Фәттах. *Әлбәттә, мондый кискен заманда көрәш өермәсенә эләгеп киткән Мәлик кебекләр бер генә булмады.* Г.Минский. *Тел мәсьәләсе сәяси мөнәсәбәтләрдә иң кискен вакыйгаларга китерергә сәләтле.* Р.Хәкимов

5) Катгый, кырыс, анык, нык. *Һичбер сүзгә вакыт калдырмыйча, Кискен җавап кирәк бу юлы.* Ф.Бурнаш. *Мансуровның --- телефонга әйткән өзек-өзек кискен сүзләрендә, --- бөтенесендә сугышның авырлыгын искәртеп, үзенә күрә бер кырыслык бәреп тора иде.* Г.Бәширов. *[Кәшшаф:] – Булмас, кирәкми, кеше табарбыз, – диде кискен тавыш белән. – Ләкин эшкә чыгарга кирәк.* Р.Төхфәтуллин

6) Кырыс, яшәү өчен авыр, уңайсыз. *Себернең кискен үзгәрешле табигате*

7) Таләпчән, килешмәүчән. *Галимҗан Ибраһимов әйткәнчә, Мәрҗани ул заман мөселман кешесе телгә алырга да курыккан мәсьәләләрне күтәрә. Китап үз заманында ук кискен каршылыкка очрый.* Х.Хисмәтуллин. *Кискен тәнкыйть утына эләгү*

8) Әче, колакны яра торган. *– Я, охшамаганны сөйләмә инде, Гыйлаҗ, – диде Гөлзифа, шактый кискен тавыш белән.* Р.Төхфәтуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Катгый итеп, катгый рәвештә, категорик рәвештә. *Чиновник моны, тупас булмаса да, шундый кискен итеп әйтә, Искәндәр бәхәсләшеп торырга урын калмаганны төшенә.* Г.Гобәй. *Бүгенге көн минем холкымны кинәт һәм кискен, үтә дә кискен үзгәртте.* Г.Якупова

2) Кисәк, кинәт, тиз генә. *Кояш булса, җир йөзенә чыкмас, башкаларга көн күрсәтмәс дәрәҗәдә усалланып яшәүчеләр дә җитәрлек. Ләкин вакытлар үтү белән, бу иптәшләрнең тормышы кискен үзгәрә.* Э.Шәрифуллина. *Яңгура, аңа карамыйча гына, профессорга латинча диагнозын әйтте дә кискен итеп урыныннан торды.* Г.Әпсәләмов. *Миңа инде ул [эт] икенче мәртәбә кискен генә өреп куйды.* А.Шамов

3) Бик көчле, ачыктан-ачык. *[Гәрәйгә] моңарчы үлем бу кадәр якын килгәне, бу чаклы кискен сизелгәне юк иде.* Г.Ибраһимов. *Төннәр бигрәк тә авыр иде миңа, менә шунда инде мин ялгызлыгымны тагын да кискенрәк сизә торган идем.* А.Шамов

**КИСКЕНЛЕК** *и.* 1) Кискен булу. *Элек --- шуклыгы белән мәктәптә укытучыларның теңкәләренә тиеп беткән малай хәзер әнә баһадирларча киң җилкәле, нык ышаныч һәм кискенлек сизелеп торган хәрәкәтле егет булган.* Р.Төхфәтуллин. *Хатынның бу сүзләрендә кинәт туган бер кискенлек һәм горурлык ишетелә.* Г.Минский. *Дөнья күләмендә әле дә бөтен кискенлеге белән дәвам иткән --- ул аяусыз көрәшнең серләренә бүген дә кирәгенчә төшенеп бетү җиңел түгел безгә.* М.Әмир

2) Катгыйлык, кырыслык. *Яшь идеология, рух дөньясында барган көрәш кискенлеген Ә.Фәйзи «Флейталар» (1933) поэмасында чагылдыра.* Р.Зарипова. *Ул чакта мин боларны – Лененың тирәнлеген, фаҗигасенең кискенлеген аңлап бетермәдем.* А.Гыйләҗев

**КИСКЕНЛӘНҮ** *ф.* Кискен булып китү

**Кискенләнә бару** Торган саен ныграк кискенләнү

**Кискенләнә башлау** Кискенләнергә тотыну

**Кискенләнә төшү** Беркадәр, бераз кискенләнү

**Кискенләнеп китү** Кинәттән кискенләнү. *Ләкин соңгы елда хәлем кискенләнеп китте, һәм дару сатып алырга мәҗбүр булдым.* Хезмәт

**Кискенләнеп тору** Кискенләнгән хәлдә булу

**КИСКЕНЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Катлауландыру, киеренке хәлгә китерү. *Васыятькә тугрылык саклаган яшь мулла --- мәсьәләне баштан ук кискенләштерүне кулай күрмичә, бу эшнең ата-аналар ихтыярында икәненә басым ясый.* Р.Әмирхан. *[Гали Галиевич:] Кызыксынган кешеләр бар, димәк. Араларыгызны яңадан кискенләштерүчеләр бар. Соңыннан үзегез дә белерсез.* Х.Сарьян. *Күзгә күренеп үткән урыннарда бодайларның бер җирдә куе, бер җирдә сирәк булып күренеп калулары бу сорауны тагын да кискенләштерделәр.* М.Әмир

2) Көчәйтү, куәтләндерү. *[Газизә] гүя Мохтарның күңеленә килгән сорауны кискенләштерү өчен, әткәсенең [сүзләрен куәтләде].* Ш.Камал

**Кискенләштерә бару** Торган саен ныграк кискенләштерү

**Кискенләштереп бетерү** Бөтенләй (тәмам) кискенләштерү

**Кискенләштереп җибәрү** Тиз арада яки кинәттән кискенләштерү

**Кискенләштереп тору** Даими рәвештә кискенләштерү

**КИСКЕНЛӘШҮ** *ф.* 1) Катлаулырак, киеренкерәк төс алу, киеренкегә әйләнү. *Халыкара хәл кискенләшү. Сыйнфый көрәш кискенләшү*

2) Авыраю, кыенлашу, читенләшү. *[Мәхмүд абый] Үзен эзәрлекләнгән киек хәлендә күреп, тыенкы шом белән яши. Бу халәт торган саен кискенләшә.* Р.Әмирхан. *Ат тәмам ярсый, аның борын тишекләре киңәя, сулышы кискенләшә.* Г.Кашшаф. *Хроник чирләрнең кискенләшүе*

3) Үзара мөнәсәбәтләр кискен бозылу, начарлану

4) Кырыслану, артык җитдиләнү; беркадәр рәхимсезләнү. *Гаяз кинәт кызарды, кинәт агарды. Күзләре кисәк кискенләштеләр.* М.Әмир

5) Тәэсир итү көче арту. *[Сөләймановның] тыныч, сабыр гына сөйләгән сүзләре торган саен көчәя, кискенләшә, хәтта усаллана барган кебек иде.* Ә.Еники

**Кискенләшә бару** Торган саен ныграк кискенләшү. *Вакыт үзенекен иткән, казачий гаскәрнең үз эчендә дә каршылыклар кискенләшә барган.* И.Нуруллин. *Ләкин хәл сәгать саен, минут саен кискенләшә барды.* Г.Гобәй

**Кискенләшә башлау** Кискенләшүгә бару. *Тын юлы авырулары кыш башында кискенләшә башларга мөмкин.* Әлмәт таңнары

**Кискенләшә төшү** Беркадәр, бераз кискенләшү; тагы да кискенләшү. *Әминәнең тавышы кискенләшә төште.* Г.Минский

**Кискенләшеп китү** Кинәттән кискенләшү

**КИСКЕР** *с. диал.* Үткер, очлы, кисә торган. *Күрәннең кискер кыяклары. Тәнкисәр үсемлегенең кискер кыяклары*

**КИСКЕЧ** *и.* **1.** 1) Металл, таш һ.б.ш. каты әйберләрне кисү, эшкәртү өчен кулланыла торган корал; *русчасы:* **резец**. *[Азат:] – Нишләп булмасын, ә болар нәрсә? – дип, Чәмәт алдына исемнәрен әйтә-әйтә пычкысын, өтергесен, кискечен тезә башлады.* Х.Сарьян. **---** *Шкаф шүрлекләрендә һәртөрле никель савыт-саба, инструментлар күзгә чагыла: кыскычлар, кискечләр...* Г.Минский. *[Вәлетдин:] Күперне ел әйләнәсендә төзеп бетерергә диелгән: боз кискечләре корычтан эшләнәчәк.* М.Кәрим

2) *махс.* Машиналарның яки җайланмаларның кисә торган өлеше; чапкыч; *русчасы:* **резак**. *[«Казмаш» заводы] С-80 тракторына җайлап йөртелә торган куак кискечләр, тракторга запас частьлар эшләп чыгарган.* Г.Әпсәләмов. *Түмгәк кискеч*

**2.** *с. мәгъ.* Каты әйберләрне кисү өчен җайланган. *Кискеч төрән*

2) *анат.* Авызның алгы ягында урнашкан, тешләп алу өчен хезмәт иткән (тешләр тур.). *Өске һәм аскы казналыкларның алгы өлешендә 4 әр яссы кискеч тешләр була.* Анатомия. *Кеше азыкны кискеч һәм казык тешләр ярдәмендә тешләп ала.* Биология

**КИСКЕЧТАШ** *и.* Борынгы, беренчел җәмгыять кешеләре кулланган үткер кырлы таш кисәге

**КИСЛОРОД** *и. рус хим.* 1) Җирдәге организмнар тереклеге өчен беренче дәрәҗә әһәмияткә ия булган химик элемент

2) Шул элементның төссез, иссез газ хәлендәге торышы (техникада, медицинада киң кулланыла). *Сестралар кислород мендәрләре белән аның яныннан китмиләр, йөрәк даруларының иң көчлеләре бирелә.* Г.Әпсәләмов

**КИСЛОТА** *и. рус хим.* 1) Составында бик актив кушылма – гидроксид булган матдә. *Көлсыман туфрак ясалганда, беренчел һәм икенчел минераллар туктаусыз таркалалар. Аларның таркалуында органик кислоталар зур роль уйный.* А.Фаткуллин. *Һава парларында*

*газлар һәм каты матдәләр эрүе тоз, кислота катнашмаларын барлыкка китерә.* Төзү материаллары

2) Эреткечнең уңай корылган ионнарын бүлеп чыгара торган матдә. *Судагы эретмәләрдә күп кенә кислоталар әче тирәлек хасил итәләр һәм лакмусны кызыл төскә буйыйлар.* Р.Сәйфуллин, Г.Хисамиев. *Кислота белән селтеләр өс һәм аяк киемнәрен ашыйлар.* Химия

**КИСЛОТАЛАУ** *ф.* Кислота белән эшкәртү

**КИСЛОТАЛЫ** *с.* 1) Составында кислота булган. *Кислоталы сыекча. Кислоталы буяулар*

2) Кислота салынган, эчендә кислотасы булган. *Кислоталы канистр*

**КИСЛОТАЛЫЛЫК** *и.* Нәрсәнең дә булса составында кислота булу. *[Сазлыкта] Табылган әйберләрнең саклануына һава кермәү, сазлыкның кислоталылык дәрәҗәсе һәм шулай ук сфагнумның дезинфекцияләү тәэсире ярдәм иткән.* Н.Верзилин

**КИСМӘ** *с.* **1.** 1) Кисеп алына торган. *Кисмә әлифба. Кисмә хәрефләр*

2) Агачлары киселгән. *Менә шул кисмә урманны үтү белән кыр башлана.* Һ.Такташ

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **кисемтә** (*2 мәгъ.*) *Газета, журнал кисмәләре*

2) *диал.* Урманда агачлары киселгән озын тар ачыклык; урман ызаны; *русчасы:* **просека**

**КИСМӘК** *и.* Тар-тар такта кисәкләрен кыршаулар белән беркетеп яки юан агач түмәренең эчен уеп ясалган зур савыт. *[Мәликә апа] кисмәккә шабырдатып су салганда гына уйларыннан айнып киткәндәй булды.* Ә.Бикчәнтәева. *Төче кумәч дигәнебез кечерәк кисмәк капкачына ярарлык менә дигән такта иде.* М.Әмир. *Хуҗалар --- берсен-берсе бүлеп җавап бирә бардылар: – Әллә Казанда юк? Пожар сарае ич. – Кисмәкләре нәрсәгә? – Менә тагы!.. Пожар сүндерергә, – диде Фәрит.* Г.Гобәй

**КИСМӘКЧЕ** *и.* Кисмәк ясау остасы

**КИСМӘКЧЕЛЕК** *и.* Кисмәк ясау һөнәре, кисмәк ясау эше

**КИСМӘН** *и. зоол.* Агачны юл-юл ергачлап зарарлый торган коңгыз; *русчасы:* **дровосек**. *Кара кисмән*

**КИСТА** *и. гр. мед.* Тукымаларда һәм органнарда патологик процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган, сыекча яки боткасыман масса белән тулган куышлык

**КИСТӘН** *и. фар.* Таякның бер очына чылбыр яки каеш ярдәмендә тимер шар, гер һ.б.ш. авыр әйбер беркетелгән, икенче башында кулга кию өчен элмәге булган борынгы сугыш яки ау коралы. *Кистәннәр, каешка яки чылбырга тагылган 200–300 грамм авырлыктагы герләрдән гыйбарәт хәлдә, сугышчының коралы булып саналган.* И.Измайлов. *Гомәр кулындагы кистәннең калын башы берлән картның туры маңлаена төзәп селтәде.* Г.Ибраһимов. *Археологлар кистәннең бәргеч өлеше (тумары) сөяктән, тимердән, бронзадан ясалганнарын табалар.* А.Тимергалин

**КИСТЕРГЕЧ** *и.* Нәрсәне дә булса кистерә торган корал яисә деталь. *Сабан кистергече*

**КИСТЕРЕП** *рәв.* 1) Ачык итеп, өзеп. *Бермәлне мәхдүм әтисеннән, табигатькә, җәмгыятькә мөсавәт, ягъни тигезлек дигән нәрсә хасмы ул, дип сорап куя. Дәмолла хәзрәт улына кистереп җавап бирергә ашыкмый.* Р.Әмирхан. *– Миңа кешенең акчасы кирәкми, абыстай. Тормыш көтәрлек, дөньямны үзенеке кебек итеп тотарлык иптәш кирәк, – диде Тутыя, кистереп кенә.* Э.Шәрифуллина. *Сөйләшү җәйләнмасыннан ишетелгән яңгыравык тавыш иясе азрак сабыр итүне сорады һәм, өч-дүрт минут үтмәгәндер, хәрбиләргә хас булганча кистереп, тәгаенләп: – Бүләкләнүчеләр картотекасында андый Вәлиев бар, – диде.* Ш.Рәкыйпов

2) Нык яңгырап, аермачык булып (тавыш тур.). *Тишек чиләгенең суы агып беткәч, җиңеләйгән кое сиртмәсе авыр шыгырдап икенче якка авыша, коры агач тавышы салкын төн тынлыгын кистереп-кистереп, еракка яңгырый.* М.Мәһдиев

3) Кинәт, капыл. *Башыма кистереп кенә сызлау капты.* Х.Сарьян

**КИСТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **кисү**. *Шәмгун казна урманын урлады. Урлады түгел, делянкалап кистерде.* А.Шамов. *Башта ул Машаны танымады. --- калын толымнарын да кистергән.* Ш.Рәкыйпов. *Сәлимә сулагай ура икән. Керт-керт кенә кистереп, ул миңа таба урып килә.* Г.Бәширов

2) Орынма сугу, бәрү белән тиешле урынга юнәлтү (мәс., шарны, тупны бильярд, футбол, волейбол һ.б.ш. уеннарда)

3) Үтеп чыгу, аркылы чыгу. *Ташу безнең буага төртелү белән, агым әкренәйде. Без агымны туры кистермибез, түбәнгә таба чапрыш кистерәбез.* Х.Сарьян. *Әгәр елганы бу урыннан кистереп чыксаң, җәй көнендәге шикелле ындыр артлап кына кайтып булмый.* Казан утлары

4) *күч. сөйл.* Катгый бер фикергә, карарга килү; берәр мәсьәләне хәл итү

**Кистерә башлау** Кистерергә тотыну. *Мәктәпкә килүгә, бөтен кызлар кырылышып чәчен кистерә башлар әле сиңа карап, әйтте диярсең менә.* С.Гаффарова

**Кистерә төшү** Бераз кистерү

**Кистереп бетерү** Бөтенесен дә кистерү

**Кистереп калу** Берәр нәрсә булганчы кистерү эшен башкарырга өлгерү

**Кистереп килү** Билгеле бер вакыттан башлап даими рәвештә кистерү

**Кистереп кую** Алдан кистерү

**Кистереп тору** Даими рәвештә кистерү

**КИСҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса үткен корал белән өлешләргә, кисәкләргә бүлү, турау. *Тиз барып җиткән җегет, эшкә тотынган баргач ук, Кисә башлаган утынны балта берлән тук та тук.* Г.Тукай. *Шулай ук хәнҗәр белән, зур-зур телемнәр итеп, солдат ипиен кистеләр.* М.Әмир. *Бабай пычкыны кулына алып карады да сызгырып җибәрде: «Гали кылычы икән бу пычкы! Моның белән утын түгел, бәрәңге дә кисеп булмый».* Г.Әпсәләмов

2) Кыскарту (чәч, сакал һ.б.ш. тур.). *[Әнисе:] Нигә, балам, бу яулыгыңны бер дә салмыйсың, әллә толымнарыңны кистеңме?* З.Кадыйрова. *Яшьрәк хатыннар --- бер-берсенең колакларына пышылдыйлар: – Бусы чәчен кисмәгән икән, теге вакыт килгәне кискән иде*

*бит, тумачый, ә?* А.Шамов. *Искә төште: көз җитсә, йорт казлары сылу гәүдәләрен күтәрә алмасалар да очарга маташалар. --- Шуңа ул казларның канат очларын кисәләр.* Г.Якупова

3) Өс яки аяк киеме тегү өчен тукыма, күн яки мехны билгеле бер өлгедәге кисәкләргә бүлү. *Үлчәүсез кием кисмиләр.* Мәкаль. *Сафа абзый, сәке өстенә менеп, тезен чәнчеп утырды да чикмән кисте.* Г.Бәширов. *[Габделкәрим:] Тегүчегә дә бер кискәнче җиде кат үлчәргә кушалар, ә хирург җитмеш җиде тапкыр уйларга тиеш.* Г.Әпсәләмов

4) Кешенең кайсы да булса әгъзасының зарарланган өлешен операция юлы белән аерып алу. *Яшь доктор тәҗрибә өчен аның аягын шахта лазаретында ук кисәргә теләсә дә, Хәйрулла агай күнмәде.* К.Тинчурин. *Имгәнүчеләр бик күп иде. --- Кайберләренең хәтта аяк-кулларын кисәргә туры килде.* Г.Әпсәләмов

5) Тәнне үткен әйбер белән зарарлау, җәрәхәтләү. *[Мостафа:] Сугышта куркырга ярамый: кыюны пуля да алмый, кылыч та кисми.* Г.Кутуй. *[Фашистлар] Спирт белән [баланың] тәнен сөртәләр. Уеп-уеп тиресен кисәләр.* Ф.Кәрим

6) Берәр каты әйберне нинди дә булса кискеч корал белән вату, кисәкләргә ваклау. *Шахтёр егет күмер кисә, Кемнәр ала исәбен?* Җыр. – *Ташын да кистек, инәй, – дип көлде абый.* Х.Сарьян

7) Төзү материалы яки утын булачак агач хәзерләү. *Агач киссәң – озын кис, тимер киссәң – кыска кис.* Мәкаль. *Хәзер әтинең ул каены, ышкыганда, кискәндә, коры сөяк шикелле кетердәп тора.* Г.Бәширов. *Мифтах мәрхүм исән чагында Шәмгунга бик күп сука сукаладь, урак урды, әвен сукты, урман кисте.* А.Шамов

8) Нәрсәнедер бер өлешен бүлеп алып киметү. *Хәдичә җикереп җибәрде: – Үтмәде! Абзарыңнан сыерыңны җитәкләп алып чыгып киткән, бәрәңге бакчаңны кискән елларны оныттыңмыни?* Ф.Садриев. *Эш хакын кисү*

9) Нәрсәнедер икегә аерып узу, аркылы чыгу. *Кыш үз ямен алып килде: сызылып кына үткән беренче чана эзләре, үрләрне, үзәннәрне --- кисеп үткән чаңгы юллары...* Г.Гобәй. *Фатыйма елганы кисеп чыгып, өйләр шәүләсе күренә башлагач кына бик аруын тойды.* З.Кадыйрова. *[Әминә:] – Әллә куян инде? – Юлыбызны кисмәкче булган иде, юньсез!.. – Киссә ни булган?* Г.Минский

10) Каты басым ясап, тәндә эз калдыру, җәрәхәтләү (бау, киндерә һ.б.ш. тур.). *Яхшы атның башын нукта кисәр.* Мәкаль. *Чиләк бавы кулны кисә, кайта-кайта беләгем өзелеп төшеп калган кебек була.* Ф.Хөсни

11) Әчеттереп, яндырып авырттыру, әрнетү (җил, төтен, зарарлы парлар һ.б. тур.). *Суык җилләр йөзне кисте.* Г.Афзал. *Җаинәт җыр башлау белән бөтенләй үзгәрде: язгы көн кисүдән караеп тупасланган бите йомшарып, мөлаемланып китте.* Х.Сарьян

12) *күч.* Кыйнау, тукмау. *Тотындык без Шәле [егетләрен] кисәргә. Ватабыз үзләрен; аяк белән дә, кул белән дә изәбез үзләрен.* Ф.Сәйфи-Казанлы

13) *күч.* Кыру, юк итү. *Шундый кисәрбез, шундый кисәрбез ул каһәрләрне [фашистларны] без: җирдә тузаны да калмас.* Г.Кутуй. *Барысы-барысы өчен кисәсе иде менә хәзер автоматтан боргалап-боргалап [фашистларны]!* Ш.Рәкыйпов. *[Шәйхи:] Юк шул, иптәшкәй, борын төбендә казак кылычы торганда йоклый алмассың. Йоклый башлагач кына килеп кисәрләр.* Ш.Усманов

14) *күч.* Үтерү, яшәүдән туктату. *Нәкъ шушы бәйрәм көнне авылның гына түгел, ә районның алдынгы кешесе, коммунист Нуриазданов Нуриман иптәшнең гомерен кистеләр.* Х.Сарьян. *Мондагы [медицина учреждениесе] кечкенә генә гамьсезлекнең дә кемнең дә булса йөрәгенә салкын без булып барып кадалуы, кайберсенең хәтта гомерен кисүе дә мөмкин.* Г.Әпсәләмов

15) *күч.* Нинди дә булса эш-хәрәкәтнең, сүзнең барышын туктату, өзү. *Килбәтетдин бай көлкене нәкъ урта бер җиреннән кисеп, мәсьәләне дингә күчерергә теләп, Нигъмәтҗан абзыйның корсагына баш бармагы белән төртте.* Ф.Әмирхан. *Монда, саксызлык күрсәтеп, барыр юлыңны кисәргә, кайтыр юлыңдагы күперне җимерергә ярамый.* Я.Зәнкиев. *Мәхмүт --- учительгә рәнҗешле караш белән карады да сүзен кисте.* М.Гафури

16) *күч.* Нинди дә булса эшкә комачаулау, аркылы төшү. *Аулак бер җирдә әтинең юлын берничә коралль адәм кисә.* Р.Әмирхан. *Биям куш аяклап әле уңга сикерә, әле сулга чабып китмәкче була. Аның саен мин каршысына чыгып юлын кисәм. Мин, аны-моны уйламыйча, юл сабып кына китәргә итеп карадым. Юк, тагы кистеләр.* Х.Сарьян. *Без Вена шәһәренең тимер юл вокзалына һөҗүм итәргә, мөмкин булса, аны алырга, немецларның чигенү юлын кисәргә тиеш идек.* Гасырлар авазы

17) *күч.* Бетерү, юк итү (ышанычны, өметне һ.б.ны). *Матур тормыш, якты көн күрүдән Өметләрен тәмам кискәннәр.* М.Гафури. – *Я инде, Ләксәндер, ялындырма инде, яшьләрнең өметләрен кисмә инде! – дип, олырак яшьтәге агайлар да сүзгә кушылды.* Г.Ахунов

18) *күч.* Берәр нәрсә исәбенә нәрсәнедер күләм, сан, зурлык ягыннан киметү, азайту. *Нуриасма үзе пөхтәлекне яратты, тик бу йокыны кисү бәрабәренә эшләнде.* Ф.Садриев. *[Чәмәт:] Әгәр без бер Хәсәновныкын гына чыгарсак (ә аның сигез генә табак), «Гыйльми язмалар»ның күләмен кисәчәкләр.* Х.Сарьян. *Биш битлек текстның өч битен кискәннәр.* Ә.Кәримуллин

19) *күч.* Катгый рәвештә, артык бәхәсләшергә урын калдырмаслык итеп әйтү. *Ләкин карт аз гына да йомшармады; шундый ук рәхимсез, каты шелтә белән кисте. – Сиңа нигә фатиха тагын.* Г.Ибраһимов. *Ишек төбендә генә аның юлын секретарьның тимер тавышы кисте: – Ярамый: анда утырыш.* Х.Сарьян. – *Юк, мин сенсация артыннан кумыйм, – дип кисте язучы. – Сенсация сезгә кирәк булды ахрысы.* Казан утлары

20) *күч.* Бетерү, юкка чыгару. *Үз ризыгыңны үзең кисү*

21) *күч.* Җанны әрнетү; кайгы-хәсрәткә салу. *Үзәк өзгеч аваз, йөрәкләребезне кисеп, яңадан кабатлады: – Коткарыгыз!..* М.Әмир. *Кечке җиләс җил исә, Йөрәкне сагыш кисә.* Ә.Исхак.

*Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, – Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.* Г.Тукай

◊ **Кисәр карасы юк** Тоташ май гына булган симез ит турында. *Быел симерткән сугымыбыз шундый симез булып чыкты: бер дә кисәр карасы юк, чат май гына.* Н.Исәнбәт. **Кисеп ташлаган (кискән) тырнагына да тормау** Тиң булмаган, чагыштыргысыз дәрәҗәдә түбән булган. *[Кәрим:] Кара Гайфи безнең тарафтан көлкегә мисал итеп сөйләнерлек адәм түгел... Без аның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйбыз.* Г.Ибраһимов. *[Камил:] – Галиев тә мөдир булса, аннан... – Ә нигә? – Ул сезнең кисеп ташлаган тырнагыгызга да тормый бит!* Х.Сарьян. **Кискән дә каплаган** Тулы охшашлык турында

**Кисә бару** Барысын рәттән кисү

**Кисә башлау** Кисәргә керешү. *Техника куәте белән масайган кеше ---, гидростанция салам дип, йөз меңнәрчә гектар болыннарны су астында калдыра, урманнарны кисә башлады.* Г.Бәширов

**Кисә бирү** Кисүне дәвам итү. *Ләкин үгез кебек таза Җәмилгә үги әнисе ипи телемен бик юка итеп кисеп бирә икән.* М.Мәһдиев

**Кисә тору** Хәзерге вакытта, вакытлыча кисү. *Ибне адәм кисә торыр – урман халкы үсә торыр.* Мәкаль

**Кисеп алу** Беркадәр (бераз) кисү. *Күчермәне җиңелрәк төшерү өчен, өлгедә булган уйдырмаларның киңлекләрен кисеп алабыз. Әгәр кысаны кыектан кисеп алырга туры килсә, билгә кереш үткәрергә кирәк.* Л.Мөхәммәт. *Шактый тирән күмелгән икән, кәсен кисеп алып, көрәкне тирән батыргач кына, дымлы соры туфракта чынаяк тәтие елтырап күренде.* Г.Гобәй. *Корый башлагач, каенны авыл кешеләре кисеп алып, утынга мактәп мичендә яктылар.* Г.Ахунов

**Кисеп бетерү** Нәрсәне дә булса кисүне тәмамлау. *Ә кисеп бетергәч, бер сүз дә әйтмичә, Хәлимне арык күкрәгенә кысып, сөеп торды.* Г.Гобәй

**Кисеп ташлау** Бөтенләй кисү; тоташ кискән хәлгә китерү

**Кисеп тору** Даими рәвештә кисү; кисү эшен башкару. *[Фәрдәнә:] – Фронтовикларга тире бияләйләр тегәбез. --- Артельдән килгән бер апа белән Рәхимә җиңги кисеп тора, без тегәбез.* Г.Гобәй

**КИСҮЛЕК** *и. сөйл.* Кисәргә билгеләнгән урман кишәре

**КИТ** I *и. гр. зоол.* 1) Гәүдә төзелеше белән балыкка охшашлы, океаннарда яшәүче гаять зур имезүче хайван. *Яр буйлары тирәсендә яшәүчеләр балык тоталар, китлар һәм моржлар аулыйлар.* Урта гасырлар тарихы

2) *күч.* Нинди дә булса бер өлкәдә, тармакта дәрәҗәле булган абруйлы шәхес. *Фән китлары. Сәхнә китлары*

**КИТ** II *и. диал.* Арт, арт як. *Дөнья бер битен, бер китен күрсәтә.* Мәкаль

◊ **Киткә китү** Бозылу, таркалу, рәте китү

**КИТАБИ** *с. гар.* 1) Язма әдәби тел өчен генә хас, китапта кулланыла торган. *Әкият сүзе үзе дә – китаби хикәят (хикаять) сүзеннән үзгәргән вариант.* Р.Әхмәтьянов. *Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар – гыйлемгә, китаби сүзгә, уку-язуга хирыс халык.* Казан утлары

2) Дөньяны аңлатуы, йола-кагыйдәләре билгеле бер изге китап белән бәйләнгән, шуңа нигезләнгән. *Китаби диннәр – яһүдилек, христианлык һәм ислам*

**КИТА́ЙКА** I *и. рус* Киҗе-мамыктан эшләнгән бизәксез тукыма

**КИТА́ЙКА** II *и. рус* 1) Эссегә һәм салкынга чыдам алмагач сорты

2) Шул алмагачның вак җимешләре. *Китайка вареньесы*

**КИТАП** *и. гар.* 1) Нинди дә булса текстны эченә алган, битләре бер тәртипкә салынып төпләнгән басма (элек: кульязма) әсәр. *Китап – бер нәселнең икенче нәселгә калдырган мирасы.* Мәкаль. *Кызганычка каршы, ерак гасырлардан ул китапларның абсолют күпчелеге безгә килеп җитмәгән. Татар кульязма китабының тарихы гаять фаҗигале.* Ә.Кәримуллин. *Көннәрдән бер көнне әтинең китаплары арасында актарынганда, сәер бер шигырь җыентыгына юлыктым.* Ә.Фәйзи

2) Аерым басма итеп чыгарылган зур гына күләмле язма әсәр яки җыентык. *Казан ханлыгы чорында да, хәтта татарча басма китап барлыкка килгәч тә, бездә күчереп китап язу белән шөгыльләнүче осталар күп булуы тарихта яхшы билгеле.* Ә.Кәримуллин. *Халыкның хәтере – аның язма һәм басма китабында.* Тел – милләтнең сакчысы

3) Әдәби әсәрнең зур кисәге. *Романның беренче китабы шагыйрьнең бала чагыннан башлана.* Ә.Еники

4) *эвф.* Коръән яки бүтән изге язма. *Китап әйтә: үзеңнән түбәннәргә карап шөкер ит, югарыларга карап фикер ит.* Ш.Камал. *Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса, Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә, --- Шул вакытта мин кулыма китап алам, Аның изге сәхифәләрен актарам.* Г.Тукай

◊ **Китап кушмый** Нинди дә булса сүзнең яки гамәлнең кагыйдәгә, законга сыешмавын белдерә. *Алай өзгәләнергә ярамый, Зифа балам, китап кушмый.* Р.Хафизова. **Китап күтәрмәс сүз** *к.* **китапта язылмый торган сүз**. *Аннары Баһау тагы бер сүз әйтте: бу сүзне язсаң, китап күтәрмәс иде.* Г.Минский. **Китап сүзе** Китапта булган хикмәтле сүз; акыллы фикер. *Өйдә кеше күп булганга һәм китап сүзләре сөйләнгәнгә күрә, артык күңелсезлек хис ителмәгән кебек булды.* М.Гафури. *Әдәбият сөючеләр Тукай йортына бер изге җиргә килгәндәй аяк басалар: китап сүзе, гыйбрәтле сүз көтә аларны биредә.* Ә.Рәшит. *Татарлар гарәфәләрдә һәм бәйрәмнәрдә, җыеннарда һәм кичәләрдә чәчәнне түгел, ә «китап сүзе»н тыңлаганнар [«Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә» һ.б.ш. язма дастаннар].* Р.Әхмәтьянов. **Китапта язылмый торган сүз** Әйтергә оят, әдәпсез сүз. *Көтүче Кузьма --- [кәҗәләрне] бер дә китапта язылмый торган сүзләр белән сүгә.* Ш.Камал

**КИТАП БАСУЧЫЛЫК** *и.* Матбагачылык

**КИТАП КОРТЫ** *и.* 1) *зоол.* Иске кәгазьләр, китаплар арасында яши һәм шулар белән туклана торган бөҗәк

2) *күч.* Туктаусыз китап укучы яисә китаплар җыю белән артык мавыгучы кеше. *Өстәвенә үрти бит безне «китап корты» дип.* Ә.Рәшит

**КИТАП КӨЯСЕ** *и.* 1) *к.* Китап корты (*1 мәгъ.*)

2) Китапны кадерсез тотучы, китап әрәм итүче

**КИТАПЛЫК** *с.* Китапка җитәрлек, китапка сыярлык, китап күләмендә. *1918–1921 еллардагы сәяси мәхшәр, ачлык, ватандашлар сугышы --- Бу чор хикмәтләре, яза китсәң, үзе бер китаплык.* Р.Әмирхан. *Авылга су китертү, газ тарту артыннан чабулар – үзе бер китаплык.* Сөембикә

**КИТАПТАГЫ́ЧА** *рәв.* Китапта язылганча. *Мин сезне киенеп-ясанып бакчага чыккан яки театрга барган чагыгызда гына күргән һәм, китаптагыча, бер күрүдә гашыйк булып акылын җуйган кыз түгел.* М.Әмир

**КИТАПХАНӘ** *и. фар.* Төрле басма яки кулъязма китаплар тупланган махсус бина. *Түнтәр мәдрәсәсендә дә үз заманы өчен бай гына китапханә булган. Бу китапханә махсус бинада урнашкан.* М.Әхмәтҗанов

2) Китап-журналлардан, газеталардан файдалану өчен көйләнгән урын

3) Аерым бер кеше тарафыннан билгеле бер максат өчен сайлап тупланган китаплар җыелмасы

**КИТАПХАНӘЧЕ** *и.* 1) Китапханә (*2 мәгъ.*) хезмәткәре

2) Китапханәләр булдыру, китапханәләр оештыру өстендә эшләүче; китапханә белгече

**КИТА́ПЧА** *рәв.* **1.** Китапта язылганча; китап теле белән. *Ләис Зөлкарнәев сабыррак, басынкырак эш итә, --- аның фикер сөреше бераз китапчарак – аңа күбрәк зыялылык хас.* Ә.Рәшитов. *Акрын гына, ыспайлап кына кайсыбер тозлырак сүзләрне гарәпчәләп, фарсычалап кына китапча җибәрәләр.* К.Тинчурин

**2.** *с. мәгъ.* Китап теленә хас, китап стилендә булган. *Китапча сүзләргә абстракт лексиканың күпчелеге керә. Эш кәгазьләре һәм рәсми документларда теркәлгән сүзләр дә китапча сүзләргә керә.* Ф.Сафиуллина. *Хәлфә абыйның өсте-башы да чибәр, сүзе-өне дә, авыл егетләренеке кебек килде-китте, ордым-бәрдем түгел, китапча.* Г.Бәширов

**КИТАПЧА́** *и.* Букча, ранец

**КИТА́ПЧАЛАП** *рәв.* Китапта бирелгән кебек, китаптагы кебек итеп. *Кулыннан ни тотса, шул эш килүче зирәк акыллы бер колхозчы үз хуҗалыгын шулай оста итеп, --- китапчалап әйткәндә, рациональ итеп оештыра ала алган икән, моның ни гаебе --- бар?* Р.Төхфәтуллин

**КИТА́ПЧАЛАТЫП** *рәв.* Китаптагы кебек итеп. *Хәзрәтнең әле бер кодага, әле икенчесенә китапчалатып зерә дә мәзәк сүзләр әйтүе ишектән дә, ачык тәрәзәләрдән дә гел ишетелеп торды.* Г.Бәширов

**КИТАПЧЫ** *и.* 1) Китап җыючы

2) *иск.* Китап бастыручы, нашир. *Башта ул [«Шәрхе Габдулла»] кул белән язылып, күчерелеп йөртелсә дә, Казан китапчылары аны бастырып таратырга керешкәннәр.* М.Гафури. *Китапчылар сугыш бәетләре, дошман угыннан саклаучы догалар басып тараттылар.* К.Нәҗми

3) Китап белән сәүдә итүче, китап сатучы. *Юл буе борчылып бардым: «Айһай, бу пычракта чана сөйрәп йөрерме икән китапчы абзый?» Пычрак дип тормаган, китапчы агай килгән иде, рәхмәт төшкере!* Г.Бәширов

**КИТАПЧЫК** *и.* Зур булмаган, кечкенә китап. *Җәйгә чыккач, ат ашатырга барганда, икмәк сыныгы белән янәшә, куенымда берәр китапчык та була иде. Күбрәк укый торгач, миңа бу китапчыкта язылган чыпчык борыны тикле хикәяләр берничә катлы кебек тоела башлады.* Г.Бәширов. *Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның бәләкәй генә «Кыңгырау» исемле китапчыгы чыккан чак.* Ә.Рәшитов. *Г.Шәрәф яшь шагыйрьнең шигырьләр тупламын кабул итә дә, бер генә түгел, бәлки ике китапчык итеп, тиз арада басып чыгара.* И.Нуруллин

**КИТАПЧЫЛЫК** *и.* 1) Китаплар җыю белән мавыгу

2) Китап бастыру һәм китап сату эше. *Ошбу көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде.* Г.Камал

**КИТӘН** *и. гар.* **1.** Яхшы сыйфатлы җитен сүсеннән сугылган ак киндер тукыма. *Күлмәклеккә алдым ак китән, Еракларга, җаный, мин китәм.* Җыр. *Агы – китән, яшеле – суган, утырып солтан, кычкырып шайтан.* Табышмак. *Сугучы сугадыр китән.* К.Насыйри

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Китән күлмәк киштәдә, киндер күлмәк киртәдә.* Мәкаль. *Китән күлмәк тектердем һәр җомгада кияргә.* Җыр

**КИТӘРҮ** *ф.* 1) Берәр әйбер эченә сеңгән нәрсәне бетерү, нәрсәдән дә булса арындыру. *Күлмәктәге тапны китәрү*

2) Алдыру, алу, кырдыру (чәчне, сакал-мыекны). *Төпле белем алырга туры килмәгәнлектән, чәч-сакал китәрү ханәсендә кассир һәм кием бирүче булып эшләгән чагы да булган Нәфисәнең.* Р.Әмирхан. *Вә дәхи бала тугач берничә көннән соң, баланың чәчен китәреп, шул чәч авырлыгы алтын яки көмеш садака бирәләр.* К.Насыйри. *Карт сакал-мыегын бик тырышып китәргән.* Г.Мөхәммәтшин

3) Ямен җибәрү, бозу. *Бу кыз Илһамия атлы булып, матурлыгы белән дә иптәшләреннән аерылып тора иде. Зур, көчле куллары гына төс матурлыгын бераз китәрә сыман.* Х.Сарьян. *Бу «кызыл чалмалы» кеше белән көтмәгәндә очрашу профессорның кәефен китәрде.* Г.Әпсәләмов

4) Бар, булган нәрсәне юкка чыгару, юк итү. *Күңелдән китәрер өч нәрсә кайгы: яшел чирәм, гүзәл ярың, агар су.* Әйтем. *Зарарын китәрү*

**Китәреп бетерү** Тәмам, тулысынча китәрү; бөтенләй юкка чыгару

**Китәреп тору** Даими рәвештә китәрү

**КИТЕК** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәдән кителеп төшкән кыйпылчык, ярчык. *Искәндәр чынаяк китеген әле бер, әле икенче ягын әйләндереп карады.* Г.Гобәй. *Аның кулында тутыккан зур кайчы, каршысында зур көзгедән кителеп төшкән көзге китеге.* К.Тинчурин. *Бераздан соң мин үземнең балтыр итенә мина китеге тигәнен белдем.* А.Расих

2) Кителеп торган урын, уенты. *Ирен китеге*

3) *сөйл.* Берәр мәйданның, урынның почмакланып чыгып торган өлеше. *Басуның сөрелми калган китекләре*

4) *күч.* Кимчелек, җитешсезлек; нәрсәдер җитешмәү күренеше. *Җырның ертыгы юк, көйнең китеге юк.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* 1) Китеге (*2 мәгъ.*) булган, кителгән. *Сиртмәнең җиргә тиеп торган башы, үзенә тагылган --- борыны китек балта, тимер кыршау, тагын әллә нәрсәләрне шалдыр-шолдыр өстерәп, югары күтәрелде.* Г.Гобәй. *Рөстәм, үзенең дус малайларын алачыктагы китек ураклар, чалгы сыныклары белән коралландырып, кичке эңгердә пәри карарга барган иде.* К.Нәҗми

2) Почмаклап киселгән, почмаклап уеп алынган. *[Зыяның] өстендә китек якалы кыска бишмәт белән тар гына чалбар.* Х.Садри

3) *күч.* Кимчелеге булган, җитешмәгән. *Тик бер генә китек ягы бар Зәлия күңеленең: улына иптәш табып бирә алмады.* Г.Якупова

4) *күч.* Бөтен булмаган, канәгатьләндермәгән. *[Гыйльмениса:] – Юк, мин генә түгел мондый китек язмышка дучар булган кеше! – дип уйлап куйды.* Ф.Хөсни

**3.** *хәб. функ.* Кимчелекле, җитешсез ягы булган, канәгатьләнерлек түгел. *Чөнки әгәр лампа яндырсаң, Сабан туе тирәләрендә генә була торган бу үзалдына бер моңсу соры тынлык юкка чыгар да, бәйрәм куанычының кайсы ягыдыр китек булыр кебек иде.* Г.Бәширов. *Бу юлы Гали шаркылдап көлеп җибәрде. --- безнең колхоздагы хезмәт көненә тигән ипи, ахры. Әнә бит, бер чите китек.* Р.Төхфәтуллин. *Күңеле китекләргә сүздә сак бул, Каты бәрелә күрмә ялгызга.* Р.Фәйзуллин

◊ **Китек колак** Үр куяны. *Ләкин куян куян шул инде, эт ярга чыгып, эзгә төшкәнче, китек колактан җилләр искән иде.* Г.Гобәй. **Китек күңел** Түшенкелек, боеклык, үзен кимсетелгән итеп тою. *Хәер, кирәге генә юк. Сабыйларның нарасый күңелендә вакытсыз ачы гамь уятып, ананың болай да китек күңелен телгәләп йөргәнче, исе-хушы да булмавы мең артык!..* Р.Төхфәтуллин. *Шунда ук китек күңел үкенә дә башлый. Нигә авыру килеш, тыны буыла-буыла эшләде икән [әти]?* Г.Бәширов. *Әмма китек күңел бик кызык икән. Хәзер чайкалып түгелергә, хәзер уалып ватылырга тора.* Э.Шәрифуллина

**КИТЕК ИРЕН** *и. анат.* Кешеләрдә тумыштан килә торган физиологик җитешсезлек: өске иреннең читләре һәм урта өлеше кушылмау; *русчасы:* **заячья губа**

**КИТЕКЛӘНДЕРҮ** *ф.* Китекләр барлыкка китерү, китекләр хасил итү

**КИТЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Китек хәлгә килү, китекләр хасил булу

2) *күч.* Күңелсезләнү, боегу.

**Китекләнә бару** Торган саен ныграк китекләнү. *– Да-а, – дип сузды Кашшаф. Аның бая бакчага килеп керү белән туган соклану хисе, белмим, нигәдер, китекләнә бара иде...* Р.Төхфәтуллин

**Китекләнеп бетү** Бөтенләй китекләнү, тәмам китекләнгән хәлгә килү

**Китекләнеп калу** Нинди дер вакыйгадан соң китекләнгән хәлгә килү

**Китекләнеп кую** Кинәт кенә китекләнү. *Юл буе нинди ашкынулы күтәренке күңеле биредә, күп булса, ярты сәгать эчендә китекләнде дә куйды.* Р.Төхфәтуллин

**КИТЕКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса китек ясау, нәрсәнедер китеп алу, китеп төшерү

2) *күч.* Ямьсезләү, шыксызлау; шөкәтсез итеп күрсәтү. *Ишегалдына чыгуга, Кашшаф йорт-җирнең бөтенлеген китекләп торучы яртылаш җимерек бурабзарга игътибар итте.* Р.Төхфәтуллин

**Китекләп бетерү** Бөтенләй китекләү

**Китекләп кую** Китекләнгән хәлгә китерү

**Китекләп тору** Даими рәвештә китекләү

**Китекләп чыгу** Барысын да китекләү

**КИТЕКЛЕК** *и.* 1) Китек булу. *[Газизнең] борыны китеклек хәзер минем өчен әһәмиятен югалткан иде.* Ш.Камал

2) *күч.* Кимчелек, җитешсез як; чатаклык. *Минем бу бәхетлелек, үз-үземнән ризалык тойгымда ниндидер бер китеклек, җитешмәгәнлек сизелә башлады.* Ф.Әмирхан. *Ләкин дүрт хатынлы хаҗи семьясын хәтерләтүче «милләт» эчендәге бу китеклеккә сугыш еллары ямау салдылар.* К.Нәҗми

3) *күч.* Рухи төшенкелек; өметсезлек. *[Искәндәр Зәбирович:] Олы җан, олы җан икәнсез, Гөлсем ханым --- бала өчен иң аяныч күңел китеклеген – аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г.Гобәй. *Күңел китеклеген онытыр өчен, Әүхәди бөтен барлыгы белән эшкә чумарга керешә.* Ф.Яруллин

**КИТЕК-МИТЕК** *с. сөйл.* Нәрсәнең дә булса читләре берничә урыннан кыйпылып төшкән, тигез булмаган

**КИТЕЛМӘЛЕ** *с.* Китеп алына торган. *Кителмәле хәлвә. Кителмәле шикәр*

**КИТЕЛҮ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **китү** I

2) Китәргә туры килү (кинәт һәм уйламаганда). *Ял йортыннан инде шактый ерак кителгән иде.* Р.Мөхәммәдиев

**КИТЕЛҮ** II *ф.* 1) Ватылып, кыйпылып төшү, китекләр хасил булу. *Борыны кителгән чәйнек тә, саплары төшкән ике пар чынаяк та, кырык җирдән чатнап, калай тасмалар белән коршалып беткәннәр.* М.Әмир. *Әле артык калынаерга өлгермәгән боз, зур-зур кисәк булып, карап торуга җиңел генә кителә.* М.Әмир

2) Нәрсәнең дә булса читеннән бер өлеше кыйпылып төшү. *Таш йортларның штукатурлары кубып төшкән, почмаклары кителгән.* Г.Әпсәләмов. *Баракның түбәгә япкан шиферлары күп җирләреннән кителгән.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Яхшы гына, уңышлы гына бара торган җирдән кинәт начараеп китү, җимерелү (хәл, эш, тормыш-көнкүреш тур.). *Тып-түгәрәк бәхет бер яктан кителә, диләр... Халык арасында таралган әйтемдәге хакыйкать Кави белән Гөлҗиһанны урап узарга тиеш иде кебек.* Казан утлары

4) *күч.* Төшенкелеккә бирелү, кәеф китү. *Әнисе чыгып киткәч, Фатыйма иләс-миләс килеп, нигәдер, күңеле кителеп калды.* З.Кадыйрова. *Ажбулатовның айдай йөзе шундук кителеп төште.* Х.Сарьян. *Хәзер күңелем кителеп тора, юксынам үзен.* А.Сафин

**Кителә башлау** Кителергә тотыну. *Тырнакка эләксә, ул төссезләнә, калҗая һәм кителә башлый.* Сөембикә

**Кителеп бетү** Берничә урыннан кителү. *Чынаяк кителеп беткән. Балтаның йөзе кителеп беткән*

**Кителеп чыгу** Нәрсәнең да булса берәр җире тәмам кителү. *Уртасы уелган резин үкчә, хәтта унтының бер почмагы кителеп тә чыккан.* А.Расих

**КИ́ТЕЛЬ** *и. нем.* Утыртма якалы, бер якка гына каптырмалы итеп, хәрбиләр өчен тегелгән пиджак. *Яңа гына теккән яшькелт соры китель Искәндәрнең тәрбияләнгән яшь, зифа сыны өстендә шулкадәр килешле итеп торадыр иде...* К.Тинчурин. *Ә кояш исә, чиксез куанып, инспекторның погоннарында, фуражка кокардасында, китель төймәләрендә чагылды.* З.Хәким. *Армиядән яңа кайткан көннәре иде егетнең, өстендә әйбәт китель, кулында ялтырап торган гармонь иде.* Р.Төхфәтуллин

**КИТЕМ** *и. сөйл.* Берәр максат өчен тотыла, сарыф ителә торган нәрсә; чыгым. *Килемен баксаң – игез-игез; Китемен баксаң – сигез-сигез.* Н.Исәнбәт

**КИТЕРЕЛМӘ** *и.* Су ташкыны (агымы һ.б.) белән берәр урынга китерелеп ташланган нәрсә

**КИТЕРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **китерү**. *Һәр өстәлгә нәкъ кирәкле ризык һәм нәкъ кирәк кадәр китерелде.* Г.Шәрипова. *Аш китерелде, токмачы яшь кызлар кулы белән нечкә итеп киселгән.* М.Мәһдиев

2) Әйтеп, күрсәтеп үтелү. *Китерелгән фактлардан аңлашылганча, уңыш өчен көрәшнең Зәй якларында тиешле югарылыкта булмавы ачыкланды.* Татар иле

**КИТЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Кемне яки нәрсәне дә булса билгеле бер урынга алып килү, күчерү, ташу. *Госпитальгә тагы бик күп авыр яралыларны китерделәр.* Х.Камалов. *Әни бит ул әйтте, рәхмәт кенә әйтеп чык, диде. Кешегә су китереп, чалбар балакларын пычратып йөрергә кушмады.* Ф.Хөсни. *Икмәген дә алып кайтам, утынын да китерәм, бүтән вак-төяк хуҗалык эшләре дә минем җилкәдә.* М.Шабай

2) Берәр нәрсәне икенче бер әйбергә якынайту, якын кую. *Нух үз стаканына шыбырдатып аракы агызды да, ұртәлеп, авызына китерде.* Х.Сарьян. *Без аны суга якынрак китердек тә, астына яңа гына чапкан печән түшәп, өстенә күләнкәлек ясадык.* Г.Ибраһимов. *Әхтәм сумканы салмыйча гына корсак турысына китерде дә бусага бүрәнәсенә куеп ачты.* Казан утлары

3) Нәрсәнедер куып алып килү, хәрәкәтләнергә мәҗбүр итү (су, җил, давыл көче белән). *Күңелле генә салкынча җил исте, баш, миләрне рәхәтләндерә торган тәмле яңгыр исләре китерде.* Ш.Камал. *Әле генә булып алган хәл, бозлы яңгыр китергән кургаш болыттай, узып та китте.* Г.Минский

4) Нәрсәгә дә булса дучар итү. *Укымаган балаларның – ата-анага күпме зыян китерүләре, ил-күз алдында аларны рисвайлыкка төшерүләре һәркайсыбызга мәгълүм.* Х.Кәрим. *Халыкка кан кою, илгә хәерчелек, бөлгенлек китерә торган мондый империалистик сугышны долой!* М.Гали. *Мондый уйлар аның йөрәген өзеп алалар һәм еш кына күз яшен китерәләр.* А.Шамов

5) Тапшыру, ирештерү. *Сиңа миннән хәбәр китерсәләр, Муса үлгән инде, дисәләр...* М.Җәлил. *Полк командиры штабка килеп керү белән үк, [ул] аңа чиркәү башындагы күзәтче китергән мәгълүмат турында сөйләргә тотынды.* А.Шамов

6) *сөйл.* Дөньяга тудыру; бирү (җанлы һәм җансыз әйберләр тур.). *Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер.* Мәкаль. *Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.* Г.Тукай. *Шагыйрьләр мәгълүм өлгерлек белән революция китергән мөмкинлекләрне иҗатларында чагылдырырга алынып, поэзиягә яңа тема һәм яңа эчтәлек алып килделәр.* XX йөз башы татар прозасы

7) Юл күрсәтеп, юнәлеш биреп, кая да булса алып чыгу, илтү. *Бу сукмак безне туп-туры урман авызына китерде*

8) Фикерне, карашны куәтләү, ныгыту, дәлилләү өчен, нәрсәгә дә булса таяну, нигезләү. *Мондый цитаталарны күпләп китерергә мөмкин булыр иде.* Ә.Рәшит

9) Кайбер эш-хәл белдерә торган исем янында килгәндә, шул исемнән аңлашылган эш яки хәрәкәтне башкаруны, үтәүне аңлата. *Бик гади булганнар алар [җитештерү кораллары]. Я кул белән хәрәкәткә китергәннәр аны, я ишәкләр, үгезләр, атлар белән.* М.Мәһдиев // Шул исем белдергән эш-хәлгә дучар итүне, сәбәпче булуны, билгеле бер нәтиҗә бирүне аңлата. *Чөнки колхоз районның урта күрсәткечләренә өстәрлек әллә ни файда китермәгән кебек, зарар да китермәгәч, шул зарар китермәүне үзе бер файда дип карыйлар.* Г.Минский. *Шахтёрлар тормышыннан алып язылган бу әсәр шәхес драматизмына китергән сәбәпләрне бөтен тулылыгында аңларга ярдәм итә.* Ф.Бәширов. *Шушы фикере көч бирде Шәрифкә, кискен бер карарга китерде аны.* Г.Минский

10) Нәрсәгә дә булса теләк тудыру, хис-тойгы уяту. *[Баһау:] Доктор, анттыр әгәр, бүгеннән ары уема да китермәм мондый эшләрне.* Г.Минский. *Минем багып торуымны Китермидер уена: Йолдыз тулы күк-диңгездә Ай коена.* Л.Лерон. *Ул [ислам дине] – барыннан да бигрәк күңел пакьлеге. Кешелек җәмгыяте тудырган рухи кыйммәтләрне тану, иң изге эш-гамәлләргә иман китерү --- дә ул.* Ә.Рәшит

11) Баш яки төшем килештәге исем белән ниндидер теләкне, уй-тойгыны аңлата. *[Гаяз:] – Әлләниләр сөйләп, ачуымны китермә әле, яме, – диде ул. – Үзеңне үзең бетерәсең.* Х.Сарьян. *Йокы китерү*

12) *күч.* Нәрсәне дә булса хәтерләп, хәтерләтеп, тасвирлап сөйләү, телгә алу. *Үз халкыңның саф һәм керсез икәнен һәркемгә исбат итеп йөреп булмый. Синең хакыйкатьне юкка чыгарыр өчен, йөзләгән мәкальләр, җырлар, былиналар китерәчәкләр.* Ә.Рәшит

13) *күч.* Берәр әйберне бүләк рәвешендә бирү, нәрсәнедер бүләк итү. *Чәчәкләр китерегез миңа! Хуш исле чәчәкләр! Мин аларны күз алдымда җәелгән киң кырларга сибәрмен, шул кырларда мин аларны назлап, иркәләп үстерермен.* Ф.Әмирхан. *Кояш көлсен, язлар сиңа Кочак-кочак чәчәк китерсен.* Мәдәни җомга

14) *күч.* Тиешенчә итеп башкару, төгәл үтәү. *Җыр җырласаң, китереп җырла, Егет икәнлегең беленсен.* Җыр

15) *боер. ф. форм.* Кемгәдер ярдәм иткәндә, булышлык күрсәткәндә, «кая

әле, бир (бирче) әле» мәгънәсендә кулланыла. *Я, китер әле көндәлегеңне*

**2. китереп** *рәв. мәгъ. Сугу, бәрү, төшерү, салу* кебек сүзләр алдыннан килеп, эшнең тиз арада башкарылуын белдерә. *Басу капкасын чыгу белән, җирән айгырның сыртына берне китереп салган идем, айгырым дөлделдәй оча башлады.* Ә.Айдар

**3.** *ярд. ф. функ.* Кайбер сүз төркемнәре янында килеп, «итү» ярдәмче фигыль функциясен башкара. --- *Шул каһәр төшкән авылга һөҗүм итсәм, бөтен авылның астын-өскә китереп, һәммә кешеләрен әткәй алдында тез чүктереп гафу үтендерсәм... ---, шул чакта күңелем бераз басылыр иде әле!* Г.Ибраһимов. *Теге Харьков итчесенең эшләрен Мәскәвда пыран-заран китереп ташлаганыгызны мин бик яхшы хәтерлим.* А.Расих. *[Хәбибулла] беренче ирдән калган мал-мөлкәтне пыран-заран китерә башлады.* Ш.Хөсәенов

◊ **Китереп терәү** 1) Сүзне, фикер агышын, нинди дә булса эшне четерекле, буталчык җирендә туктату, бүлү. *[Шәңгәрәй] сүзне шуңа китереп терәде дә, үзе белә торып, юри хата фикер әйтте.* Г.Ибраһимов; 2) Көчле дәлилләр, фактлар белән кемнең дә булса мәгънәви позициясен тар-мар итү. **Китереп тоттыру** Үзе көч түкмичә, мәшәкатьләнмичә, кемдер әзерләп бирү. **Китереп чыгару** 1) Каядыр күмелеп яткан, онытылган әйберне алып күрсәтү; 2) Берәр хатирәне яки кузгатырга кирәк булмаган сүзне, үпкәне яңарту; 3) Берәр нәрсә эшләргә кирәклекне читләтеп, кинаяләп әйтү. --- *Әнинең килен рәхәте күрәсе бик килә торгандыр; моны турыдан-туры әйтеп бетермәсә дә, сүз җае белән бик нык китереп-китереп чыгара.* Г.Ибраһимов; 4) Көтелмәгән сүз яки хәл чыгару. *[Илдархан:] Нәрсә китереп чыгара тагын.* Н.Исәнбәт; 5) Ясау, тудыру, барлыкка китерү. *[Малай кардан], зуррак кисәкләрне кирпеч өйгән кебек өеп, солдатка охшаган бер фигура китереп чыгарды.* К.Нәҗми; 6) Нинди дә булса кирәкмәгән бер эш чыгару, килешмәгән, ярамаган нәрсә эшләп ташлау. *Вакыт-вакыт вак кына нәрсәләр белән дә үз тормышыбызны үзебез ямьсезлибез түгелмени? Юктан гына да яңа проблемалар китереп чыгарабыз түгелмени?* Ә.Рәшит

**Китерә башлау** Китерергә тотыну. *Авыз суларын китерә башлады, эх малай!* Ф.Дәүләтбаев

**Китерә төшү** Бераз китерү, китерүне дәвам итү

**Китереп бетерү** Китерү эшен тәмамлау

**Китереп җиткерү** Ниндидер эшкә, вакытка, моментка кадәр өлгереп китерү

**Китереп кую** Китерү эшен башкарып чыгу. *Аннары Равил кызны әлеге зәңгәр «Победа»сы белән җилтерәтеп кенә Укмаска илтеп, капка төпләренә үк китереп куйды.* В.Нуруллин

**Китереп тору** Гел, һаман китерү

**КИТЕШ** *и.* 1) Китү, китеп бару (процесс яисә хәрәкәт башлану). *Шушы китеш белән мин ике ел өйгә кайтмый йөрдем.* Ш.Камал. *– Мин кайтмыйм шул, – диде егет, каяндыр йөрәк төбеннән чыккан рәнҗүле тавыш белән, – кайтмыйм, апа! Кайтыш түгел, китеш минем...* Г.Минский

2) Үсеш, алга барыш, алгарыш. *Без укыган җәдит мәктәбе, әти-әниләр укыган иске мәдрәсәләр белән чагыштырганда, әлбәттә, бик зур алга китеш булган.* М.Әмир. *«Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны язудан максудым – милләтебезнең шул китешеннән үземнең разый түгеллегемне күрсәтеп, бу китешнең очы инкыйраз идекен белдерүдер.* Г.Исхакый. *Күп кешеле, зур, әмма берләшмәгән Европа илләренә Европаның алга китешеннән --- файда килерме?* Р.Әхмәтьянов

**КИТЕШЛИ** *рәв.* 1) Киткәндә, китеп барганда, юл уңаеннан, узышлый. *Абзый китешли әйтә куйды: – Утыз биш ел колхоз председателе булып эшләгән Галимҗан абыең булырмын мин, энекәш, – диде.* М.Мәһдиев. *Ул [солдат] Шәмсенур апаның таныш авылдашы булып, --- авылга китешли, җиде төн уртасында безгә килеп кергән.* Казан утлары

2) Китәр алдыннан, киткәндә. *Китешли саубуллашырга керү*

**КИТКЕЧ** *и.* Китек ясау коралы

**КИТМӘН** *и.* Җирне йомшарту, үсемлек төбенә туфрак өю һ.б. хезмәтләр өчен кулланыла торган, агач сапка туры почмак ясап утыртылган көрәк сыман үткен эш коралы. *Хәйләгә каршы хәйлә бар, китмәнгә каршы кәйлә бар.* Мәкаль. *Иртәдән башлап кичкә чаклы балта һәм пычкы, китмән һәм көрәк куллардан төшмәде.* Ш.Камал. *258 нче немец гренадёр полкы командирының боерыгында, чигенгәндә китмән, чалгы, көрәк кебек нәрсәләргә кадәр алып китәргә, диелгән иде бит.* Ш.Рәкыйпов

**КИТМӘНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Китмән белән эшкәртү; китмән белән эшләү. *[Авылда] Синә туктап тын алырга вакыт юк. --- Җәй җитсә – бәрәңгеңне ута, китмәнлә, күм, печән чап.* Ф.Садриев. *Бакча китмәнлисе, бәрәңге утыртасы бар. Бакча китмәнләргә Зәкәрҗанның әтисе дә, әнисе дә инде карт.* М.Мәһдиев

2) *күч. иск.* Үлгән кешене күмү, җирләү. *Киткән – кайта, китмәнләгән кайтмый.* Мәкаль

**Китмәнләп алу** Кыска вакыт аралыгында китмәнләү, тигез генә китмәнләү

**Китмәнләп кую** Тиз арада яки алдан ук китмәнләү

**Китмәнләп тору** Даими рәвештә яки әледән-әле китмәнләү

**Китмәнләп чыгу** Тулысынча китмәнләү. *Шуңа күрә ишле гаиләләргә уңайлы: кырмыска кебек килеп ябырылалар да тиз генә китмәнләп тә чыгалар өлешләрен.* Г.Якупова

**Китмәнли башлау** Китмәнләргә керешү

**КИТМӘНЧЕ** *и.* 1) Китмән белән җир эшкәртүче

2) *иск. эвф.* Кабер казучы

**КИ́ТСӘНӘ** *ы.* 1) Контекстта нинди интонация белән әйтелүенә карап, гаҗәпләнү, шатлану һ.б. төрле хисләрне белдерә. *Китсәнә, бу – дөрес хәбәрме?*

2) Аптырау, шелтәләү, ризасызлык һ.б. төрле хисләрне һәм кичерешләрне көчәйтеп бирә. *Шуннан соң инде Зәмзәмия --- «Әй, китсәнә, җизни, мине үртәмәсәң, мөгез чыгар дип уйлыйсыңмы әллә?» – дияр.* Г.Минский. *Китсәнә, җыен тузга язмаганны сөйләп торасың!*

**КИ́ТСЫМАННАР** *и. зоол.* Суда тереклек итүгә җайлашкан имезүчеләр отряды. *Китсыманнарның төп хәрәкәт органнары – койрык йөзгече һәм ишкәксыман алгы очлыклары.* Зоология

**КИТҮ** I *ф.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнеңдер яныннан читкә юнәлү, кузгалу (җәяү яки берәр төрле транспортта). *Әнисе аларны көтеп тормаган, киткән, лапас янындагы кече капкага җитеп бара иде.* Х.Сарьян. *[Мостафа:] – Я, нихәл, киттекме? – дип сорау бирде. – Киттек, – дидем мин.* Г.Кутуй. *Габдулла Җаек каласына киткәч, берничә елдан соң мин дә Бакуга нефть промыселларына эшләргә киттем.* Тукай турында замандашлары

2) Юнәлү, юнәлеш алу, бару. *Без тагын үз юлыбыз белән киттек.* Ф.Әмирхан. *Болын аша киткән сукмак*

3) Даими торган җиреннән башка урынга юнәлү. *Аккош китә гаң итеп, Исәнләшеп, моң итеп.* М.Укмасый. *Көзнең шушы кошлар җылы якка киткән, яфраклар коелган көннәрендә карт шулай боегып ала иде.* Г.Бәширов. *Кем уйлаган көзен киткән аккош Язын инде кире кайтмас диеп.* Г.Мөхәммәтшин // Калдыру, ташлау. *Ул [Гаяз Исхакый] киткәндә илдән күпләр киткән – Урысяһүд киткән меңәрләп. Ә татарлар кырда иген иккән... Татар китсә, киткән... берәмләп.* Л.Лерон

4) Бату, төпкә төшү. *[Тишелгән] кораб һаман батуында дәвам итә, әкренләп кенә су төбенә китә.* А.Алиш. *Аз гына җил чыгып, көймәне як-якка чайкалдыра башласа, аның тәннәре калтырана, су төбенә китеп, балык карынына эләгү куркуы аның йөзенә ачык укырлык дәрәҗәдә чыга иде.* Г.Ибраһимов

5) Нәрсәнең дә булса агып яки саркып чыгуы. *Терекөмеш исә буаны тишкән, хәзер аннан су китә. Борыннан кан китү. Күздән яшь китү*

6) Нәрсәнең дә булса зарарлы тәэсире, йогынтысы. *Эчке кан китүләрне кешенең тышкы кыяфәтеннән белеп була.* Биология. *Шеш мигә киткән. Тын юлына сөяк китү*

7) Билгеле бер физик торыш хәленнән хәрәкәткә килү, кузгалу. *Тик һаваны икегә ярып, колагыбызга шомлы бер аваз килеп керде. Димәк, иртәгә боз да китәчәк.* Х.Сарьян. *Бозлар китеп, елга өсте аз-маз арчылу белән, бай Стахеевлар --- пароходларын елгага төшерергә ашыктылар.* А.Расих. *Яз килер, карлар эрер, бозлар китәрләр. Тау битләре ачылыр*... Һ.Такташ

8) Саегу, сайга әйләнү, күләме кимү (елга, күл, кар һ.б. тур.). *Агыйделкәй киткән, суы кипкән.* Җыр. *Бишендә Хозыр Ильяс камчы селти, ягъни кар көнтөн китә.* Сынамыш

9) Каян да булса башлану, арырак сузылу. *Авылның аргы ягында әллә нинди яланнар китә.* Г.Ибраһимов. *Чокыр буйлап киткән тар сукмак белән --- берничә ел элек киселгән чаукалыкка барып чыктылар.* А.Таһиров. *Аннары тагын җиргә сеңеп барган вак-вак агач йортлар китә.* Г.Әпсәләмов

10) Башлану, интенсив рәвештә дәвам итү. *Башланды чистарыну, төзәтенү, --- чаршау, чыбылдык, күлмәкләр тегү, китте тазарыну-юыну, киенү-ясану.* Г.Бәширов. *Сәлимнең нәкъ каршысына сибелделәр болар. Китте үртәү, китте котырту.* Ф.Хөсни. *Клуб артына чыгып, китте сугыш, китте сугыш... Хәтерлисеңдер инде, иштек сезнең буынны ул көнне!* М.Галиев

11) Үтәлүнең, эшләнүнең вакыты дәвамлы булу, сузылу (дәвамлы эш-хәл, күренешләр тур.). *Безнең болай утырулар Китсен гомер буена.* Җыр. *Синсез үтә, тиңсез үтә Иртәләрем-кичләрем... Айга китсә, елга китсә, күпкә китсә нишләрем.* Х.Туфан. *Редакциядә эшли башлавыма өченче ай китте дигәндә, бүлек мөдире белән редактор чакырып алдылар.* Б.Камалов

12) Булып узу, булу, үткән фактка әйләнү (төрле хәлләр, вакыйгалар, табигать күренешләре һ.б.ш. тур.). *Гыйлем мөселманда, байлык мөселманда иде... Ул заманнар китте.* С.Шәкүров. *Ай арасында явымнар китә*

13) Берәр максат өчен тотылу, файдалануда булу. *Без кисә торган утынның күбесе хәрби паровозларны йөртергә китә.* Г.Гобәй. *Шунда киткән кыйммәтле ташларны --- Болакны матурлауга тотса, шәһәрдә һава яхшырыр иде.* Казан утлары

14) Сарыф ителү, тотылу, түгелү. *Тик ул һаман шуңа гаҗәпсенә: «Тапкан малым кая китә?» – ди.* М.Гафури. *Керосин күп китә дип, дәресләрен сыйныфларда хәзерләргә казый рөхсәт итми.* К.Тинчурин. *Бу айда акча күп китте*

15) Бер хәлдән икенче хәлгә күчү, алмашыну, торыш үзгәрү. *Кызның төсе киткән, сулышын көчкә-көчкә генә ала иде.* Ә.Шәмин

16) Берәр эшчәнлекне ташлап, башка гамәлгә күчү. *«Илдус быел солдатка китсә, какрас черегән өйгә генә кайтып керә икән», – дип уйлады Локман.* Х.Сарьян. *Ләкин бүгенге хәлләрдән соң эштән китү бөтенләй тормышка ашмас бер нәрсәгә әйләнде.* Идел. *Шаһгалиев заготзернога җирне үзе юллап алды, ләкин бүлә башлаганчы пенсиягә китте.* Казан утлары

17) Нинди дә булса хәлнең-халәтнең алмашынуы, онытылуы. *Китәр баштан кайгылар да, Әкрен-әкрен ага-ага.* Г.Тукай. *Ә Халидә апа күз алдымнан китми дә китми.* В.Нуруллин

18) Ялгышлык, хата җибәрелү, шуңа юл куелу. *Ләкин... ялган сукмактан киткән хак юлга керерме соң?!* Ә.Рәшит. *Инша язганда хата китү*

19) Кимү, азаю, бетү. *Көчем бар дип уйлама, Көчең китәр көн булыр. Янган тәмуг өстеннән Сыйрат үтәр көн булыр.* Дастан. *Картайгач, йөрәкнең хәле китү*

20) Бетү, юкка чыгу, юк булу. *Кул ярасы китәр, тел ярасы китмәс.* Мәкаль. *Китте хәсрәт, әләмнәр, Иркенләнде каләмнәр...* Г.Тукай. --- *Хәмидә миңа хәзер килеп чыкса, бөтен очрашуның яме китәр төсле тоелды аңа.* Х.Сарьян. *Алар әүвәлдә бик матур булганнар да, чукынгач, йөзләреннән иман нуры китеп, зәңгәрсу акланып калганнар.* Ф.Әмирхан

21) *сөйл.* Вафат булу, үлү, дөнья белән хушлашу. *Китте инде дөньядан бу милләтнең чын шагыйре.* Татар шигърияте: XX гасыр башы. *«Без китәрбез, сез каласыз!» – дип җырлармын, Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.* Г.Тукай. *Фәтхулла агай шәкертнең кулларын төзәтеп гәүдәсе буенча сузып*

*куйды. – Мескен, китәсең, ахры, – диде.* Ш.Камал

22) Традициягә әверелү, гадәткә керү. *Ул чакта солдатлар арасында мыек йөртү киткән иде.* Г.Әпсәләмов

23) *сөйл.* Модага керү, киң таралу. *Хәзер киң итәкләр киеп йөрү китте*

24) Еш, системалы рәвештә кабатланудан ихтыяҗга әверелү. *Мәнә синең дә шулай уянгач аунап ятуың гадәт булып китмәсен.* А.Әхмәт

25) *сөйл.* Юнәлеш килешендәге кайбер исемнәр белән килеп, шул исемнән аңлашылган берәр хәлгә күчүне аңлата. *Кулыңдагы биш бармагыңны гына кара син, бишесе биш төрле: берсе кәрлә имәндәй кыска ..., икенчесе сылу нараттай буйга киткән...* Г.Минский. *Эш судка киткән.* И.Гази. *Фёдоров, соң гына йокыга китсә дә, ул көнне иртә уянды.* А.Расих. *Мин төрле тавышларны тыңлап ята торгач йокыга киткәнмен.* М.Гафури

26) Кемнең дә булса мәсләген, юнәлешен, кәсебен һ.б.ны дәвам иттерүе. *– Ну вот, бик әйбәт булган! – дип, Шагалиев хуплап куйды. – Балта эшенә китүең ярый: ни әйтсәң дә, әткәң һөнәре бит!* Х.Сарьян. *– Мәнә нәрсә, энекәш, – диде кызыл чәчле хатын, --- комсомолга кергәч, әтиең юлыннан китмәссеңме соң син?* М.Мәһдиев

27) *сөйл.* Ычкыну. *Кулдан хакимлек китү*

28) *сөйл.* Кеше ихтыярыннан тыш башкарыла торган юнәлеш алу (эшләнәсе, башкарыласы эш-хәл һ.б.). *Шулай да бүген әллә һаваның кинәт ачылып корыга китүеннән, әллә инде энесе кайту шатлыгыннан [Таһир] иртәдән үк кәефләнеп аягына басты.* Х.Сарьян. *Эшләр хутка китте. Авыруның хәле уңайга китте*

29) Таралу, күпләргә мәгълүм булу. *Ата даны белән кыз китә, баса даны белән сүс китә.* Мәкаль. *Нефтьчеләрнең даны еракка китте*

30) Югалу, юкка чыгу, бетү. *Табигатьтән китсә китсен язлар, Тик син китмә минем күңелемнән.* Г.Мөхәммәтшин. *«И каләм!» шигырендә Тукай болай язды: «И каләм! Китсен газап, ит син безне шат».* М.Зәкиев. *Яуса карлар, туңса бозлар, Яз җитәр бер, боз китәр...* Ш.Бабич. --- *Әрем катыш арыш исе Китми бәгырьләреңнән.* Мәдәни җомга

31) Яшәүгә билгеләнгән вакытның кимүгә, тәмамлануга таба баруы, узу. *Һай, гомерләр үтте китте, кайда китте ул заман?..* Г.Тукай

32) Бозылу, чуалу, таркалу. *Бу җыр Шәяхмәтнең йөрәк бәгырьләрен телгәләде. Шул уңай белән гаиләдә рәт китте.* М.Мәһдиев. *Гаяз әле Халидә белән очрашырга әзер түгел, Халидә мәнә хәзер килеп чыкса, бөтен очрашуның яме китәр төсле тоелды аңа.* Х.Сарьян

**2. кит** *ы. функ.* 1) Гаҗәпләнүне, шикләнүне, ышанмауны белдерү өчен кулланыла. *[Шакир:] – Әллә врачка кирәктеме [духи]? – Кирәкте шул. Справканың срогын озайтмый ату. – Кит?! Нәрсә ди?* Г.Минский

2) Юк, кирәк түгел. *[Хәлифә:] Кит, кит, укыйммы соң, фалнамә кадәр фалнамәне синнән мыскыл иттереп торыр хәлем юк.* Р.Ишморат. *Гариф Хәмидәнең елаганын күреп: – Әллә елап йөри инде?.. Кит, юкка елама!.. Тапкан елар нәрсә! – диде.* М.Гафури

**3.** *ярд. ф. функ.* 1) Хәл фигыльләрнең *-ып (-еп), -п* формасы белән бәйләнештә килеп, аларның төп мәгънәсенә түбәндәге төсмерләр өсти: 1) юнәлешле яки нәтиҗәле хәрәкәт төсмере (башлыча хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән). *Ул иртә үк торып, эш булмас микән дип чыгып китте.* М.Гафури. *Пароход инде кузгалып киткән, баягыдай кыегая төшеп, борылып маташа иде.* Х.Сарьян. *Торып китү. Селкенеп китү. Узып китү*

2) Үзеннән алдагы хәл фигыльдән аңлашылган сыйфатка күчү, шул сыйфатка ия булуны белдерә. *Әминә шунда ук, дәртләнеп китеп, Шәрәфкә хат язарга утырды.* Г.Минский. *Кифая әбинең таш баскандай кысылган күкрәге җибәреп, иркенәеп китте.* Х.Сарьян. *Һәм кинәт яшәреп киткәндәй булды Гыйльмениса.* Ф.Хөсни

3) Төп фигыльдән аңлашылган эшкә дәвамлылык төсмере өсти. *Аста, як-якта, ярга терәп салынган кара мунчалар тезелеп киткән.* Г.Гобәй

4) Эш-хәлнең тиз һәм интенсив башкарылуын аңлата. *Су өсте күз нурын алырдай булып, ялтырап, яктырып китте.* Х.Сарьян. *Күпме йоклаганмындыр, кинәт уянып киттем.* Казан утлары

5) *Булып* ярдәмче фигыле белән килеп, эш-хәлнең дәвамлы төс алуын белдерә. *Ләкин көн дә шулай булып китсә, айлар буена шулай барса, мещан марҗалары синең мактануыңа эчтән кызганып, бичара дип карый башлаячаклар.* Г.Ибраһимов. *Ә инде шундый әңгәмәләр рухында тәрбияләнгән Галимәнең, һичшиксез, «Теләнче кызы»ндагы Сәгадәт кебек милләт хадимәсе булып китүенә шик юк.* XX йөз башы татар прозасы. *Берәүләр өчен дәвәт эш коралы, язу өчен кирәкле әйбер булса, икенчеләр өчен купшылык билгесе булып киткән.* Р.Әхмәтьянов

6) *шарт. ф. форм. -а/-ый* формалы хәл фигыль янында килеп, шул фигыльдән аңлашылган эш-хәлне дәвам иттерү мәгънәсен бирә. *Исәпли китсәң, бар да бер ноктага килеп җыела икән.* Казан утлары

◊ **Кит аннан** 1) Чынлапмы, шулаймы, дөресме (ис китү, хәйран калу, гаҗәпләнүне белдерә). *Кит аннан! Шулай ук дип әйттеләрме, кодагый!* Мирас; 2) Булмас, кирәк түгел (кискен рәвештә инкяр итүне, кире кагуны белдерә)

**Китә башлау** Китәргә керешү (тотыну). *Китә башлады бездән инде кошлар; Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.* Г.Тукай

**Китеп бару** Кинәт кенә китү. *Заготзернодан Уфага район үзәге аша көн саен автобус йөреп тора: кичтән килеп куна да иртән сәгать җидедә китеп бара иде.* Х.Сарьян. *Урамнан узучылар күрсә, гаҗәпсенеп, бертын карап торалар да, хәйран калудан тел шартлатып, үз юлларыннан китеп баралар.* Р.Мөхәммәдиев. *Гаяз Исхакый 1908 елның җәендә сөргеннән кача. Башта Петербургка килә, ә аннан Төркиягә китеп бара.* М.Хәсәнов

**Китеп калу** Берәр нәрсә булганчы китү

**Китеп йөрү** Берәр төрле максат белән озак вакытка кая да булса барып кайту. *Еракларга китеп йөрим дә мин,*

*Сагынып кайтам туган җиремне.* Ш.Маннур

**Китеп тору** Даими, регуляр рәвештә китү; беразга китү, билгеле бер вакытка китү. *– Хәзер! – дим мин, беркая да китми торырга кушкандай итеп, алар янына чыгам.* Ф.Хөсни

**КИТҮ** II *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса бер кырыен, почмагын, читен яки очын кыеп алу. *Әнә ул [әни], бозны ике як читләп өч-дүрт адым чамасы кискәч, атка каршы читеннән аны балта түтәсе белән сугып, китеп-китеп төшерә башлады.* М.Әмир. *Капка төбендә шырпы кабыннан китеп алынган чыра белән теш каезлап торган бу ир уртасы кешене Гыйлемхан танымады.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Кәефне җибәрү, күңелне төшерү. *«Иске йортлар юк» дигән уй [Рушания] күңеленең бер кырыен китте.* З.Кадыйрова. *Ләкин шулай да күп читләрен китеп-китеп алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Булачак киленне күргәч тә ошаттым. --- Тик кодалар гына бераз күңелне китте. Саранга охшыйлар.* М.Кәрим. *[Хатын:] Тик бер нәрсә күңелне китә: бүгенге көнгә кадәр аннан [ирдән] калган бурычларны түлим.* Сөембикә

**Китеп алу** Тиз генә яки бер өлешен генә китү. *[Бала] Бик җылый башласа, --- Шуннан [шикәрне] китеп алып, ипи белән имезлек чәйнәп каптырыгыз.* Ф.Хөсни

**Китеп тору** Даими рәвештә, һаман китү

**КИ́ТЧӘЛЕ** *ы. сөйл. к.* **китсәнә**. *Кызлары да, үзләре дә өйдә иде. Абый кайту хәбәрен әйткәч: «Китчәле!» – дип сораштыра башладылар.* Х.Сарьян

**КИ́ТЧЕ** *ы. к.* **китсәнә** (*1 мәгъ.*). *Хатын иренең исемен әйтеп тә өлгермәде, моңарчы тыныч кына тыңлап торучылар бердән хәрәкәткә килде: – Карагыз әле, Боряны әйтә ич бу! – Китче! Нишләп Боряны әйтсен?* Г.Минский. *[Егет:] – Тархан бабай! Рәхмәт инде сиңа, син булмасаң... – Ай-һай ла. Китче. Бер сүзне гелән-гел тукымаслар.* Г.Мөхәммәтшин

**КИЧ** *и.* **1.** 1) Тәүлекнең көн белән төн арасындагы бер мәле, караңгы төшә башлаган вакыт. *Кич якынлашуга карамастан, ябык ындыр эчендәге сугу машинасының туктарга исәбе юк әле.* Г.Әпсәләмов

2) *иск.* Кояш баеп, көн туганчы үткән вакыт; төн. *Кич... Җиделе лампа яна. Масра килене шәл бәйли. Дүрт кич бәйләсә – шәл уртасы. Һәр кич саен – бер чите... Тугызынчы кич – шәлнең читләрен уртага тегү.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса соңы, ахыры. *Игелекле эшнең киче юк.* Мәкаль

4) *күч. поэт.* Караңгылык, кайгы-хәсрәтле билгесезлек. *Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарың? Качан китәр кичең, килер нәһарың?* Г.Тукай

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кичен, кич булгач, кичке вакытта. *Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас.* Мәкаль. *Без дә ул көнне кич, докладтан соң, үзебезнең клубта концерт куйдык.* Х.Сарьян

2) Гадәттәгедән кичегеп, соң

◊ **Кичкә калу** Соңлау, соңга калу. **Кичкә калыну** *к.* **кичкә калу**. *[Фазылҗан абзый:] Районга эш белән килгән идем дә, кичкә калынды.* Р.Төхфәтуллин. **Кичкә каршы** Кич якынлашып килгәндә. *– Кичкә каршы юлга чыкмыйлар... Бергә утырып чәй дә эчмәдек бит әле, ашыкма, Гәрәй агай, – диде Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев. **Кичкә керү** Кич булу. *Кичкә керсәң, тәрәзә тирәсендә гел кыштыр-кыштыр егетләр кайнаша.* Г.Бәширов. **Кич утыру** *этн.* 1) Аулак йортка берәр төрле кул эше эшләп, күңел ачып утыру өчен җыелу. *Әти солдатта чакта, кышкы озын төннәрдә безнең өйдә кызлар җыелып кич утыра торган иде.* М.Әмир. *Кыр эшләре бераз җиңеләя башлау белән, кызлар, кич утырып, оекбашлар, бияләйләр бәйләргә тотындылар.* Г.Бәширов; 2) Кичләрен гаиләләр белән бергә җыелып, әңгәмә алып бару, сөхбәтләшү

**КИЧӘ** I *рәв.* 1) Үткән көнне, бу көннән элек булган көндә. *Ишеттем мин кичә: берәү җырлый Чын безнеңчә матур, милли көй.* Г.Тукай. *Кичә шәһәрдән бер аллә нинди китап алып кайттым.* Г.Исхакый. *Күрше кызы Хәдичә, --- Озак йөреп бакчада, Кичегеп кайтты кичә.* М.Җәлил

2) Бик күптәнге булмаган вакытка караган. *Кичә булса хат ташучы, Иртәгә мин – инженер!..* М.Җәлил

**КИЧӘ** II *и.* 1) Тәүлекнең кояш баеганнан соңгы өлеше, кич, ахшам. *Шаушулы көн үтеп, аның артыннан язның соң көннәрендә генә була торган йомшак, рәхәт һәм тын кичә килә.* Г.Ибраһимов. *Октябрь ае. Кичә салкын һәм җил иде.* Ш.Камал

2) Гадәттә, кичен, төнен уздырыла торган тантаналы мәҗлес яисә бәйрәм. *Сәхнә тарафыннан кичәне алып баручының көр тавышы яңгырады: – Бүгенге кичәнең олы кунагы – шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаевны чакырабыз сәхнәгә.* Р.Мөхәммәдиев. *Яңа ел кичәсен Лези белән үткәреп булмасмы дигән хыялым да бар иде, тик насыйп булмады.* А.Тимергалин

3) Электә: яшьләрнең нәрсәгә дә булса багышланган кичке уен-көлкеле мәҗлесе. *Безнең авылның сугыштан соңгы беренче кияве шәл бәйләү кичәсендә әнә шундый номер күрсәтте.* М.Мәһдиев. *Концерт беткәч, Яркәм абыйлар яшьләр кичәсе башлап җибәрделәр, апалар кичәдә калды, мин кайтып киттем.* Х.Сарьян

4) Нәрсәгә дә булса багышланган кичке җәмәгать җыелышы. *Партия һәм совет җитәкчеләре катнашында үткәрелгән кичә гадәттәгечә җай гына агып бара.* Р.Мостафин. *Атналыкның соңгы кичәсеннән Әстерханга кайтып барабыз. Кем белгән соң аны... Бу кичәдә Шундый тирән эзләр каласын...* Х.Туфан

5) *иск.* Төн, тәүлекнең дөм караңгы вакыты. *Ярканат – кичә кошы.* Әйтем. *Шагыйрь күңел күтәренкелеге, тирән ышаныч, пафос, матур, җиңел тел белән бу кичәне [«Кадер кич»] бер монументаль картина итеп сурәтли.* Н.Исмәгыйлев. *Гүя күк белән диңгез беренче сөю сәгатьләрен кичерәләр, --- тын кичәдә бер-беренә ташланалар, кушылалар.* Г.Ибраһимов

6) *дини* Үлгән кешене искә алу көне. *Мәрхүмнең җиде кичәсен уздыру. Кырык кичәсе*

**КИЧӘ-БҮГЕН** *рәв.* Кичә һәм бүген, соңгы бер-ике көн эчендә, күптән түгел,

әле генә. *Кичә-бүген парикмахерскаяда булган ахрысы, агара башлаган чәчен кыска итеп алдырган.* Г.Әпсәләмов

**КИЧӘ-БҮГЕНЛЕ** *рәв. к.* **кичәле-бүгенле**. *Гомумән алганда, мәктәп формасы турында әле кичә-бүгенле генә сүз башланмады.* Безнең гәҗит

**КИЧӘГЕ** *с.* 1) Кичә булган, булып үткән. *Кичәге тузан берлә буялып беткән яфраклар бүген зөмрүд кеби ямьяшел торалар.* Г.Исхакый. --- *Мунчадан кайтканда, өй тагын чибәрләнеп җыелган, сәкегә кичәгедән дә баерак, тәмлерәк, сыйлырак итеп чәй хәзерләнгән иде.* Г.Ибраһимов. *Мунчадан чыккач, кичәге тәртип белән диярлек, [кунак сыйлау] янә башланып китте.* Ф.Хөсни

2) *күч.* Инде булып үткән, элеккеге, күп еллар элекке. *Заман һәр көн башка заман, Казан һәр көн башка Казан, Ул кичәге Казан түгел, Үзгәрә бара һаман.* Н.Исәнбәт. *Былтыргыдан, кичәгедән бүген Янәшәрәк аңа гарасат.* Х.Туфан. *Кичәге купецлар – бүгенге толчокчылар, --- кичәге генераллар – бүгенге шарлатаннар, үзләрен «Рус Парижы» дип атыйлар.* Г.Гали

**КИЧӘГЕ-БҮГЕНГЕ** *с.* Соңгы арада гына булып үткән. *Яңа кергәннәр сүз чылбырына теләсә кай урыннан ялганалар, чөнки бөтен авыл, аның тарихы, кичәге-бүгенге хәлләр һәммәсенең күз алдында, барын да беләләр.* А.Гыйләҗев. *...Кичәге-бүгенге хәлләр башына капкан ахры.* Д.Булатова

**КИЧӘГЕ́ДӘЙ** *рәв. к.* **кичәгечә**. *Һәм шулчакта, әтисенең кул сырты белән күзен сөртә-сөртә, яр башында басып калуы менә кичәгедәй күз алдында иде.* Х.Сарьян

**КИЧӘГЕЛЕК** *и. сир.* Вакыты, заманы, кирәге узган нәрсә. *Һаман кичәгелек белән яшәү*

**КИЧӘ́ГЕНӘК** *рәв. сөйл. к.* **кичә** I. *Кичәгенәк кенә әле башка тормыш иде, сугыш законы хөкем сөргән тормыш иде.* Ә.Еники. *– Кичәгенәк бик яхшырды әле [баланың хәле]. Бүген кичкә таба шулай булды, – диде анасы.* Г.Кутуй. *Кичәгенәк Рабига түти Күпербашка китеп барадыр иде.* Р.Батулла

**КИЧӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* 1) Кичә булган шикелле, кичә булганча. *Иртәнге аштан соң ротаны, нәкъ кичәгечә, өйрәнү занятияләренә алып чыктылар.* М.Әмир. *Кичәгечә, бәрәңге бакчасын үтеп, сөйләшмичә, көймәгә утырдылар.* Х.Сарьян. *– Нихәлең бар, Мәрьям әби? – диде ул, кичәгечә бөтен йөзе белән елмаеп.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Әүвәлгечә, элеккечә, борынгыча. *Бүген кичәгечә яшәп булмый.* Ватаным Татарстан

**КИЧӘ́-КӨНДЕЗ** *рәв. иск.* Көнетөне. *Кичә-көндез ошбу җирдә, Тәңренең язмыш көне, Капчыгын тоткан, сорана җәй вә көз, яз, кыш көне.* Г.Тукай. *Әбүгалисина --- кичә-көндез гыйбадәт белән мәшгуль булды.* К.Насыйри

**КИЧӘЛЕ́-БҮГЕНЛЕ** *рәв.* Кичә һәм бүген; соңгы бер-ике көн эчендә. *Болар икесе кичәле-бүгенле, эш эчендә, яшь җиңгәләренә күңелләре белән бagландылар.* Г.Ибраһимов. *Кичәле-бүгенле чишә алмаган мәсьәләләрне Зөһрә тагын өйрәнеп карарга булды.* Г.Гыйльманов

**КИЧӘЮ** *ф. диал.* Кич җитү, кичкә таба йөз тоту. *Вакыт инде яхшы гына кичәйде, караңгы төшеп килә.* Шура

**КИЧЕГЕЛҮ** *ф. з.-сыз* Кичегергә туры килү

**КИЧЕГҮ** *ф.* 1) Кич якынлашу, кич җитү. *Көн кичеккән саен, болар ашыктылар --- икенче кечерәк кибәнне дә шулай ук матур, түгәрәк куеп, очлап бетерделәр.* Г.Ибраһимов

2) Тиешле вакыттан соңга калу. *Сәгать унда ул инде резин перчаткалар кигән кулларын терсәктән бөккән, авызына маска бәйләткән килеш, бер минут кичекмичә, операция өстәле янына килеп басты.* Г.Әпсәләмов. *Без кичеккәнбез, хәерсезне! Хатын утырасы поезд ярты сәгать элек кенә узып та киткән.* Г.Минский. *Мөхәммәт кичегергә ярамаганын, кызның начар бер нәрсәгә тарыганын аңлады.* Я.Зәнкиев

3) Тиешле сроктан артка калу, соңару. *Төп нигезгә кайтып баш орырга гел кичегә адәм баласы.* Г.Морат. *Кичегеп килгән яз*

**Кичегеп бару** Акрынлап кичегү. *Кояш түбәнәеп, көн кичегеп бара.* Мирас

**Кичегеп йөрү** Һәрвакыт кичегү, кичегеп килеп керү. *Бу ни хәл? Ике елдан бирле бер генә көнне дә, бер генә минутка да эшкә кичегеп йөргәнем юк иде, ә бүген?!* З.Бәшири

**КИЧЕГҮСЕЗ** *рәв.* Шунда ук, кичекмичә. *Кичегүсез килеп җитү*

**КИЧЕ́КМӘСТӘН** *рәв.* Билгеләнгән вакыттан һич тә кичекмичә: хәзер үк, тиз арада, тоткарлыксыз. *Кичекмәстән, хәзер үк эшкә тотынырга дигән нәтиҗәгә килде Гыйлемхан.* Р.Мөхәммәдиев. *Кичекмәстән икегә бүленеп, як-яктан һөҗүм итәргә кирәк иде.* Ш.Рәкыйпов. *– Авыруны хәзер үк хирургия бүлегенә күчерергә һәм кичекмәстән операция ясарга кирәк! – диде Мансур.* Г.Әпсәләмов

**КИЧЕ́КМИЧӘ** *рәв.* Тоткарсыз, бер җирдә тоткарланмыйча яки тоткарламыйча, үз вакытында. *Бизгәк һаман үз вакытыннан бер генә минутка да кичекмичә диярлек килә, килгән саен катырак калтырата иде.* М.Әмир. *[Кашшаф:] Ну, ярый алайса, Хөсәен абзый, барысын да шунда утырышта хәл итәрбез. Кичекмичә генә кил әле. Сәгать сигезгә.* Р.Төхфәтуллин

**КИЧЕКТЕРГЕСЕЗ** *с.* Кичектерергә ярамый торган, ашыгыч эшләнергә тиешле, ашыгыч. *Авыруга кичектергесез ярдәм күрсәтү*

**КИЧЕКТЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса билгеләнгән вакыттан соңгарак күчерү. *Карт мирза гадәттә иртән сәгать җидедә эчә торган чәен бүген сөекле улы хөрмәтенә унга кичектерде.* К.Тинчурин. *Алтынбай гаҗәп бер кызулык белән эшкә тотынды, бер көн кичектерми, кар яуганчы, яңа хуҗалыгын аякка бастыру эшенә керешә.* Г.Ибраһимов. *Ул елны укуларны гадәттәгечә беренче сентябрьдә башламыйча, бер айга кичектерделәр.* Г.Минский

2) Нинди дә булса процессның үтәлү, эшләнү яки тәмамлану вакытын сузу; тоткарлау

**Кичектерә төшү** Азга гына кичектерү

**Кичектереп килү** Күптәннән даими рәвештә кичектерү. *Сүзгә Ильяс кушылды: – Килгәннән бирле ветлечебница төзүне әлегә гел кичектереп киләләр.* М.Мәһдиев. *Закирны өйләндергәндә бирелгән өч йөз сумның яртысы каладан*

*бурычка алынган булган икән. Карт --- ничек тә хәзергәчә шуны түләми кичектереп килгән.* Г.Ибраһимов. *Мулла кешегә җәмәгатьсез тору шәригатькә хилаф бер нәрсә булса да, хәзрәт үзенә икенче юлдаш табуны һаман сузып, кичектереп килә.* Р.Әмирхан

**Кичектереп тору** Бераз вакытка кичектерү // Күп тапкыр кичектерү. *Ләкин бу көч һәр секунд саен рәхимсез якынлашкан гомуми параличны кичектереп торырга мөмкинлек бирә иде.* Г.Әпсәләмов. *Көтеп алынган бәхетле мизгелне беразга гына булса да кичектереп торырга ниятли идем әле.* Р.Мөхәммәдиев. *Сәгыйть Казакстан якларына барып урнашкач та --- Һәдия анда күчеп китүне һаман кичектерә торды.* М.Галиев

**КИЧЕЛҮ** *ф. сир. к.* **кичерелү**. *Ятканга бар да кичелә*

**КИЧЕН** *рәв.* Кич белән, кич булгач. *Йөрәгем яна минем, Яна көндез, яна кичен.* Ф.Кәрим

**КИЧЕН-КӨНДЕЗЕН** *рәв.* Кичен дә, көндезен дә, һәрвакыт. *Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем.* Г.Тукай

**КИЧЕНҮ** *ф.* 1) Бер көе яшәп яту, тормыш итү, көн күрү

2) Кыенлык белән көн итү, интегеп яшәү. *Мин үзем буржуй түгел, мин дә сезнең кебек үз кул көче белән яши торган, дәрестән, мөхәррирлектән килгән жалованье белән киченгән бер зыялы.* Г.Ибраһимов

**КИЧЕРГЕСЕЗ** *с.* Кичерелми торган. *Кичергесез хата. Кичергесез кыланыш. Кичергесез җинаять*

**КИЧЕРГЕСЕЗЛЕК** *и.* Кичергесез булу. *Җинаятьнең кичергесезлеге*

**КИЧЕРЕЛҮ** *ф.*1) *төш. юн. к.* **кичерү**. *Кичерелә һәм кичерелми торган хаталар*

2) *з.-сыз* Кичерергә туры килү

**КИЧЕРЕНЕШ** *и. к.* **кичереш**. *Без биредә персонаж телен формалаштыру, лирик кичеренешләрне сурәтләү, диалектизмнарны урынлы куллана белү кебек бер-ике моментка гына тукталабыз.* Л.Җәләй

**КИЧЕРЕНҮ** *ф. сир.* Бик тәэсирләнү, хисләнү. *Китаптан аерыла алмыйча артык кичеренеп укуыма борчылучы кешеләр дә булгалады.* Г.Бәширов

**КИЧЕРЕШ** *и.* 1) Нәрсәнеңдер тәэсиреннән туган көчле хис-тойгылар һәм шуңа бәйләнешле рухи халәт. *Кешенең камилләшкән тавышында аның рухи халәте, эмоциональ байлыгы, кичерешләр тирәнлеге һәм намусы да чагылыш таба.* М.Нигъмәтҗанов. *Һичбер сүзсез-нисез, ниндидер аңлашылмый торган юл белән алар бер-берсенең кичерешләрен аңлап, тоеп баралар.* Г.Бәширов. *Киленнәр сагынуы... Солдат сагынуы... Никадәр изге хисләр, пакь кичерешләр бу...* М.Мәһдиев

2) Көенеч, сагыш. *Хәсрәт-хәстәр ишле заманда кеше бер гамь, бер кичереш белән озак яши алмый, аңа бүтән мәшәкать, бүтән уй, бүтән кәеф кирәк.* М.Кәрим

**КИЧЕРЕШЛЕ** *с.* Нинди дә булса кичереш белән башкарыла яки күзәтелә торган. *Юк, җырның сүзләре авыр кичерешле түгел, җиңел һәм дәртле, көләч һәм якты булырга тиеш.* Э.Шәрифуллина

**КИЧЕРҮ** I *ф.* 1) Берәр җирдән чыгарга ярдәм итү, нинди дә булса урыннан үткәрү (гадәттә үтүе кыен булган урыннардан, елга, диңгез һ.б.ш.). *Димче диңгез кичерер.* Мәкаль. *Елга аша кичерү*

2) Нинди дә булса бер чорны яисә үзең өчен истәлекле саналган гомер дәверен яшәп үткәрү. *Дөрес, кыз алып тәмле көннәр кичергәндә, эштән бик вакытлы кайтып йөргән иде. Тик бу озакка бармады, бетте.* Х.Сарьян. *Шул ук намазлыкта бер уянып, бер калкып, ул төнне кичерде.* Г.Исхакый // Нәрсәне дә булса баштан үткәрү, күрү (тормыш хәлләренә карата). *Гөлбану бөтен бу газаплы эшләрне үз тәненнән, үз күңеленнән кичерде.* Г.Ибраһимов. *Бәхетле минутлар кичерү*

3) Искә төшерү, уй-фикер аша үткәрү, хәтердә барлау. *Бөтен утыз еллык каты тормышны башыннан кичереп, тик ялгыз – ул гына калды.* Г.Ибраһимов. *Кыска гына арада ниләр уйлап, ниләр кичерергә туры килмәде миңа. Әмма мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калды: бу – кешенең яшьлеге, кешенең мәхәббәте!* Ә.Еники. *Аның әйткән сүзләренең мәгънәсен тагын бер мәртәбә күңелемнән кичердем.* М.Юныс

4) Нинди дә булса бер рухи халәттә булып алу. *Күрмичә яшәргә дә сабыры җитмәс кебек тоелган йөрәк ничә еллык аерылыш газабын, кайгы һәм борчу тулы ялгызлык елларын кичерде.* К.Нәҗми. *Кеше җыр тыңлаганда, кайгы-хәсрәтне дә ничектер менә татлырак итеп кичерә.* Ә.Еники. *Һай, күптән, бик күптән андый курку хисен кичергәне юк иде бит.* Ф.Яхин

5) Нинди дә булса киеренке хәл эчендә булу, яшәү. *Бөтен Россия хәзер шундый кискен сыйнфый көрәш чорын кичерә.* Т.Гыйззәт. *Баштан кичкәннәре дә – бер аңар гына килгән түгел, бөтен ил белән күргән, кичергән кыенлыклар.* Р.Мөхәммәдиев

6) Һәртөрле тышкы тәэсирләрне җиңеп чыгу; шуңа түзү, чыдау. *Эссене авыр кичерү. Салкынны җиңел кичерү*

**Кичерә бару** Бер-бер артлы кичерү

**Кичерә башлау** Кичерергә тотыну. *Ә инде бераздан егетнең гаепсезлеге раслангач, ул вөҗдан газаплары кичерә башлый.* Ватаным Татарстан

**Кичереп алу** Әле, хәзерге вакытта кичерү. *Күптән түгел генә корылык чоры да кичереп алды үзе.* Безнең гәҗит

**Кичереп бару** Берәм-берәм кичерү. *Халисә онытылган хатирәләренең яңадан уянуын күңеленнән кичереп бара иде.* С.Рафиков

**Кичереп калу** Берәр нәрсә булганчы кичереп өлгерү. *Ташу башланганчы, машиналарны елга аша кичереп калу*

**Кичереп килү** Әллә кайчаннан бирле кичерү. *Җитмәсә тагын, гомергомергә күрше булып, тату гына көн кичереп киләбез үзебез.* Н.Яһудин

**Кичереп кую** Кичерү эшен алдан башкару. *Юлчыны елганың теге ягына кичереп кую*

**Кичереп тору** Даими яки регуляр рәвештә кичерү. *Кыз таныш булмаган кешеләр каршында уңайсызлык кичереп тора иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Туристларны елга аша кичереп тору*

**Кичереп яту** *сөйл.* Кичерү хәлендә, процессында булу. *Эшләгән кеше генә*

*аңлый торган вакыйгаларны кичереп ятасыз.* Татар заманы

**КИЧЕРҮ** II *ф.* 1) Бәхилләү, гафу итү. *Рәнҗетелгән яшьлек, Уртак сөю-хисләр Кичермәсләр безне, кичермәсләр.* Җыр. *Син аңардан барып гозер үтен, аягына егыл, ул сине кичерер.* К.Насыйри. *Әниләре Таибә абыстай килененең иренә баш бөкмичә шундый зур эшкә аяк чалуын һич аңларга да, кичерергә дә теләмәде.* Ә.Еники

2) Гөнаһларын йолу, ярлыкау. *Ул бик озак дога кылып: «Ярабби, карчыгымны гафу ит, гөнаһларыны кичер!» – дип, йөзене сыйпады.* Г.Исхакый. *– Ходай үзе күрә, бер кичермәсә, бер кичерер, – ди, – син миңа шул күрәзә карчыкның кайда торганын иплән өйрәт, – ди.* Г.Ибраһимов

3) *сөйл.* Исәптән чыгару, чигерү

**Кичереп бару** Даими яки регуляр рәвештә кичерү. *Үзеннән он, бәрәңге, ипи, крәчин алып торган кешеләрнең әҗәтләрен, әгәр мохтаҗлык аркасында вакытында түли алмасалар, Хәдичәтти гел кичереп (списать итеп) бара иде.* М.Мәһдиев

**Кичереп килү** Бик күп тапкырлар кичерү

**Кичереп тору** Һәрвакыт кичерү

**КИЧЕРҮ** III *и. сир.* Кичереш. *Халитов үз тибының психологик кичерүләрен әсәрдәге идеягә буйсындырып бирми.* М.Җәлил

**КИЧЕРҮ** IV *и.* Ярлыкау, гафу. *Тәүбәгә килеп, кичерү сорау*

**КИЧЕРҮЛЕ** *с.* Кичерә торган, кичерүне белдергән. *Кичерүле караш ташлау*

**КИЧ-ИРТӘ** *рәв. к.* **кич-иртән**. *Кич-иртә сизелерлек үк суыткалый башлады.* Г.Бәширов. *Яз айларын көткән кошлар сыман, Талпынадыр күңелем кич-иртә.* С.Сөләйманова

**КИЧ-ИРТӘН** *рәв.* Кичен һәм иртән; кичен дә, иртән дә. *Күңелем эзли сине кич-иртән, Мин сине көтәм, көтәм, көтәм.* Ә.Ерикәй. *Син киләсе юлдан күзем алмый, Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.* С.Хәким. *Йолдызларның кинәт атылуы Тынгы бирми миңа кич-иртән.* Р.Низамиев

**КИЧКӘ** *рәв.* Кич вакытындарак, кич белән, киченрәк, көн азагындарак. *Кичкә, көтүләр кайтыр вакытка, инде бу кечкенә өйнең кыегы утыртылды.* Г.Ибраһимов. *Төгәл һәм җентекле хәбәрне кичкә табарак Сәхиб солдат алып кайтты.* Ә.Фәйзи. *Зөһрәбану, агач сандык өстенә капланып, кичкә кадәр үкседе.* А.Гыйләҗев

◊ **Кичкә каршы** *к.* **кичкә таба(н)** --- *Һава саф, бөтен дөньяны кичкә каршы гына була торган бер рәхәт тынлык чолгый.* Г.Ибраһимов. **Кичкә таба(н)** Кич якынлашып килгәндә, кичкырын. *Һәм алар карт белән шулай килештеләр дә: иртәгә кичкә табан адвокат йортын барып карарга булдылар.* Ә.Еники. *Кичкә таба бер аксыл болыт коеп явып китте.* Г.Галиев

**КИЧКӘ́ЧӘ** *рәв.* Кичкә кадәр, кич җиткәнче. *Ә кояш иртәдән кичкәчә Чәчәкле балконны күзәтте...* Х.Туфан. *Фәсхи белән Алтынбай, таң иртәдән караңгы кичкәчә чабып, ике тәүлектә Исәнбикәне бетерделәр.* Г.Ибраһимов

**КИЧКЕ** *с.* **1.** 1) Кич (*1 мәгъ.*) була торган, кич вакытындагы, көн азагындагы. *Кичке азан! Кичке азан! Моңнар, уйлар килә синнән.* Г.Тукай. *Ул, башыннан эшләпәсен алып, йөзен кичке тау җиленә куеп, күзләрен дым каплаганчы, чиксез киңлекләргә карап торды.* Ә.Еники. *Кичке эңгердә бу очрашу бер сәгатьләр чамасыннан артмады.* А.Расих

2) Кич белән эшли, хәрәкәт итә, чыга торган һ.б.ш. *Син бүген кичке поезд белән китәрсең.* Һ.Такташ. *Гайнан, һаман да өметен өзәсе килмичә: – Кичке почта килгәндер бит инде? – диде.* Г.Бәширов. *[Сабир] кичке мәктәптә йөреп урта белем алды.* Казан утлары

3) Кичәләрдә, кичке мәҗлесләрдә киюю өчен билгеләнгән. *Арттагы машинадан алтын күзлекле бер ир белән урта яшьләрдәге бер ханым төште. Хатынның өстендә кичке күлмәк.* Г.Әпсәләмов. *[Сәгыйдә] Ашыга-ашыга үзенең кичке күлмәген алыштырды.* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ. к.* **кичке аш**. *[Андриан:] Их, үлеп ашыйсы килә. Кичкегә әнкәй нәрсә әзерләде икән? Ботка белән әйрәндер әле.* К.Латыйпов. *Дөрес, вакыты бик үк уңайлы түгел иде түгелен: төшке ашны инде ашадылар, ә кичкесенә шактый ерак иде әле.* Г.Шәрипова

◊ **Кичке күздә** Кич караңгы төшкән арада, эңгер-меңгернең күз күрер вакытында. *Мәрфуганы кичке күздә уенга чыкканда гына күреп калдым.* Н.Исәнбәт. **Кичке як** Төштән соңгы, кичкә таба барган вакыт. *Кичке якта гына печән кабартырга куштылар.* Ш.Маннур. *Приказчиклар кичке якта, балыкны ярты бәясенә булса да сатарга тырышып, урамнан узучыларга товарларын мактыйлар.* Җ.Тәрҗеман

**КИЧКЕ АШ** *и.* Кичен ашала торган соңгы ашау. *Бераздан --- кичке аш башлана.* М.Гали. --- *бүре гомере буе ач. Аңа беркем дә әбәт, кичке аш әзерләп тормый.* М.Мәһдиев. *Кайчагында, сүзләр белән мавыгып, Коля кичке аштан да мәхрүм калгалады.* Җ.Тәрҗеман

**КИЧКЕЛЕК** *и. к.* **кичке аш**. *– Без авылда күп вакыт кичкелекне тышта ашый идек, – дип сөйләп китте Гыймай.* Ф.Яруллин. *Иртән тору белән иртәнге аш турында кайгыртырга кирәк, кичкелекне ашагач, йокы вакыты килеп җитә.* М.Юныс

**КИЧКЕСЕН** *рәв. диал. к.* **кичен**. *Урман каравылчысы кичкесен [бу кешегә] түбән өйгә урын җәеп бирә.* Әкият

**КИЧКЕ УЕН** *и. этн.* Яшьләрнең, бергә җыелып, кичен үткәрелә торган җыр-биюле күмәк күңел ачуы. *Бибинурларга өч йорт аркылы гына яшәп яткан Мирзаһит аны кичке уеннан озата кайтты.* А.Гыйләҗев

**КИЧКЕ ЧӘЙ** *и.* Кичке аштан соң эчелә торган чәй. *Яшь килен кызарып ук китте, кичке чәй әзерләү бөтенләй аның хәтереннән үк чыккан иде.* Г.Ибраһимов

**КИ́ЧКЫРЫН** *рәв.* Кичкә таба, кичен, кич якынлашып килгәндә. *Кичкырын шау-гөр килеп авылга кайтып кергәндә, барысының да күңеле бик күтәренке иде.* И.Гази. *Ул арада кич җитеп, көтү кайтыр чак та якынлашты. Болай кичкырын җибәреп булмый ич инде кешене.* Ф.Хөсни. *Бик сагындым сине, бик сагындым; Күл буена кил син кичкырын.* З.Хәбибуллина

**КИЧЛӘП** *рәв. к.* **кичләтеп**. *Истә әле: бервакытны кичләп кенә кышкы юлда синең очка якынлаштык.* М.Җәлил

**КИЧЛӘТЕП** *рәв.* Кич җиткәч кенә, кич белән, соң гына. *[Сөнгать:] Кичләтеп кенә әллә кайдан кайта --- абзый?* М.Фәйзи. *Тыным белән тартып алырдай булып көттем әниемне, һәм ул кичләтеп кенә кайтып керде.* Г.Якупова

**КИЧЛӘТҮ** *ф. з.-сыз к.* **кичләү** (*1 мәгъ.*). *Алар бик озак утырдылар, алар чыкканда, инде көн кичләткән иде.* З.Кадыйрова. *Көн кичләтә. Шәһәр өстенә караңгылык пәрдәсе акрын гына җәелә.* А.Шамов

**КИЧЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кич җитү, кич якынлашу. *Һава тып-тын, көн яхшук кына кичләде.* С.Рәмиев. *Тик хөр күңелле иң ихлас адәм дә үз ихтыярында гына яши алмый. Еш кына аныңча туган көн аныңча кичләми, аныңча башланган гомер аныңча очланмый.* М.Кәрим

2) *иск.* Кайда да булса кич һәм төн уздыру, куну. *Фирдәвес күк, шул атауда алар кичли.* Аң. *Таһир мескен Зөһрә өчен Зинданнарда кичләгән; Башын кисәм дисәләр дә, Вәгъдәсеннән кичмәгән.* Җыр

**Кичләп китү** Кинәттән кичләү. *Мәшәкатькә чумып, көн кичләп киткәнен сизмирәк тә калды хатын.* М.Кәрим

**Кичләп тору** Хәзерге вакытта кичләү; берникадәр вакыт кичләү. *Килгән кунак бездә кичләп торырга уйлый*

**КИЧЛЕК** *с.* 1) Кичкә, кич вакытына җитәрлек, бер кичкә исәпләнгән. *Бер кичлек аш. Бер кичлек эш*

2) Бер кич (төн) куна торган. *Һичбер иманы, принцибы булмаган, --- җае туры килгәндә бер кичлек хатыннар белән кәеф-сафа корудан ары узмаган бу шакшы мәхлукны --- Яңгура үз юлыннан бөтенләй алып ташларга булды.* Г.Әпсәләмов

◊ **Кичлеге юк** Кичке аштан соң озак утыра алмау (йокы басу тур.)

**КИЧЛЕКТӘ** *рәв. диал. к* **кичкырын**. *Кичлектә гадәттәге бәйрәм, уенкөлке, җыр, бию, мәхәббәт.* Ә.Баян

**КИЧТӘН** *рәв.* 1) Кич белән, кичен. *Йокла, балам, йом күзең --- Кичтән йокың кала да, Егълап үтә көндезең.* Г.Тукай

2) Кичә кич белән, узган кич. *--- Моржа ачып, мичен якты. Ярый утыны кичтән кертелгән иде.* Г.Ибраһимов. *Ата-аналар балаларын аңа ияртеп җибәрергә тырышалар һәм кичтән белешеп тә куялар иде.* М.Мәһдиев. *Кайтуны шулай кичтән хәл иттек тә, таңнан торып, мин билетка киттем.* Х.Сарьян

3) Кичке вакытта ук, кич җитү белән. *– Кичтән үк килеп җит. – Ә гимназиядән ничек чыгарга? Тышкы ишекне кичтән бикләп куялар.* Җ.Тәрҗеман

**КИЧҮ** I *ф.* 1) Елганың бер ягыннан икенче ягына су аркылы чыгу. *Идел кичтем, дәрья гиздем, Җыйдым камыш тугайлардан, сазлыктан.* Г.Зәйнашева. *Озын сал, уралып барып, кинәт борылышны кичәм дигәндә, моңа каршы --- ак пароход килгәне күренде.* Г.Ибраһимов. *Үттек утлы давылларны, Кичтек зур елгаларны.* Ә.Ерикәй

2) Билгеле бер урын аша үтү, узу (ара, ераклык, ил чиге һ.б.). *Лизалар тора торган дачага бару өчен, татарлар күбрәк яши торган берничә урамнарны кичеп, шәһәр янындагы бер кырга чыгарга кирәк иде.* Ф.Әмирхан. *Безнең гимназиягә белем алырга Россиянең төрле почмакларыннан киләләр. Ат йөри алмаган җирне дөяләр белән кичәләр.* Җ.Тәрҗеман. *Барам, Сания! Кара-Ком чүлен җәяү кичәсе булса да, барыбер китәм!* Г.Бәширов

3) Нәрсә дә булса кичерү, баштан үткәрү (берәр төрле кыенлык, шатлык һ.б.ш.). *– Җәмәгать, монда хезмәткәрләре, – дип, сүзгә кушылды Туран Рыскулов. – Ерак барасы юк, үз башымнан кичкәнгә әйтәм.* Р.Мөхәммәдиев. *Җилйңгырлы пычрак юллары, чебен-черки газаплаган төннәре --- – барысы да баштан кичә.* М.Госманов

4) Вакытны, тормышны, гомерне һ.б. яшәп уздыру. *Шуны әйтергә телим: без, бәлки, уза да алмабыз ул күпер аша. Ә халкыбыз ул күперне иртәмесоңмы бер кичәргә тиештер бит?!* Р.Мөхәммәдиев. *Аның да тол калып яшәгән еллары ирле гомер кичкән чагы белән инде тигезләшеп килә.* Сөембикә. *Тынычлык менә шундый була икән... Сугыш кичмәгән булсаң, шушы матурлыкны күрә белер идең микән?* М.Мәһдиев

5) Үтү, узу (вакыт аралыгы, гомер һ.б.ш.). *Гасырлар кичте китте... кичте еллар! Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәуран...* Дәрдемәнд. *Көн артыннан көн кичеп, гомерең эш белән, мәшәкать белән чабып кына үткән бер заманда кеше язмышын каян белеп бетермәк кирәк!* Х.Сарьян. *Күр, гомере ничек кичә Иртәләр җитте исә...* Х.Туфан

6) Билгеле бер араны, аралыкны йөреп чыгу, гизү. *Бөек Уралның таулары арасында зур күлләр буена салынган заводларны, шахталарны кичтем.* Г.Ибраһимов

7) Күчеп китү, китеп бару, үтеп китү. *Кәрван кичәр – ут калыр, Халык кичәр – йорт калыр.* Мәкаль

8) Үтү, бетү (ниндидер хәл, авырлык һ.б.ш.). *Хәзрәт, Сөннәтче бабайны юатып: «Иншалла, кичәр, суык тигәндер», – дисә дә, күңеленнән, чыннан да, куркып китте.* Г.Исхакый. *Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван, Килеп кичте җиһандин канча илләр!..* Дәрдемәнд. *Тиздән бабам үзе дә бу дөньядан кичте шулай итеп моңын йөрәгемә салды да көен үзе белән мәңгегә алып китте.* Х.Сарьян

9) *сир. к.* **кичерү** (*2 мәгъ.*). *Сез килегез, якын дус итеп, Күп кайгылар кичкән анага.* М.Җәлил

10) *күч.* Кыска вакытка хәтергә килү, искә төшү. *Мәҗлес шундук тынып калды. Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте.* Ә.Еники

**КИЧҮ** II *и.* 1) Суның җәяүләп яки ат белән үтәрлек сай урыны; елга үткеле. *Кичү бирмәс елга юк, батыр җиңмәс дошман юк.* Мәкаль. *Утын төягән йөк белән котырып аккан кичү аркылы чыгып кара син.* М.Әмир. *Кичүдә машиналар хәрәкәте көчәйде.* Ш.Рәкыйпов

2) Елга аша икенче ярга чыгару өчен махсус җиһазландырылган урын. *Татарстан территориясендә тарихтан билгеле булган кичүләрдән Кама елгасында Саескан тавы кичүен һәм олуг кенәз Иванга язылган ярлыктан мәгълүм Чаллы кичүен күрсәтергә мөмкин.* А.Тимергалин. *Сәгать унберләрдә без Агыйдел кичүенә барып җиттек.* Х.Сарьян. *Инде мине дә юл өзегендә, мең газап чигеп, кичүләрдә батып үлә*

*язып, Казан тикле җиргә килергә мәҗбүр иттегез.* Җ.Тәрҗеман

3) Зур елгаларда мал эчәргә төшә торган сай урын; *русчасы*: **водопой**

4) Елга яки күл кырыенда басып су алыр һәм керләр чайкар өчен салынган кечкенә басма

5) Урам аша җәяүлеләр чыгар өчен эшләнгән үтеп йөрү урыны. *Каршыда урам аша җәяүлеләр чыгар өчен эшләнгән тамгалы кичү.* Казан утлары

**КИЧҮ** III *ф. иск.* 1) Гафу итү, кичерү. *Булса сезнең күңелегездә Әз генә шәфкать әгәр, – Кичегез!* Һ.Такташ. *[Муса:] – Гафифә, җаным! Мин бит сине җәберләдем, хаксызга рәнҗеттем, мин залим булдым... бер юлга кич, җаным, – диде.* Ш.Камал

2) Баш тарту, ваз кичү. *Дөньяда булган башка матурлардан Күз йомып, барчасыннан инде кичтем.* М.Гафури. *Дөнья малыннан кичү*

**КИЧҮЛЕ** *с.* Үзендә кичү (II) булган. *Елганың кичүле урынына килеп туктау*

**КИЧҮЛЕК** *и.* **1.** 1) Кичү (II) урыны һәм аның тирәсе. *Кичүлеккә җыелган атлы олаулар*

2) Кичү (II) итеп файдаланырлык урын

**2.** *с. мәгъ.* Кичү (II) итеп файдаланырлык; кичеп үтәрлек. *Кичүлек сайлык*

**КИЧҮСЕЗ** *с.* Үзендә кичү (II) булмаган. *Кичүсез елга булмас.* Әйтем

**КИШӘ** *и. диал.* Туку өчен әзерләнгән буй җебе үрмәсе

**КИШӘЛӘ́Ү** *ф. диал.* Туку процессында буй җепне буталмасын өчен үреп кую

**КИШӘНКЕ** I *и. диал. к.* **кәшәнкә**. *Чикләвекне ашар өчен дә, башта аны табарга, аның кабыгын ватарга, аннан кишәнкесен ачарга кирәк, аннан соң гына син аның төшен табасың, күрәсең һәм ашарлык таза булса, ашый аласың.* Н.Исәнбәт

**КИШӘНКЕ** II *диал. к.* **кишәрлек** (*2 мәгъ.*). *Бер кишәнке җир калды урасы*

**КИШӘҢГЕ** *и. диал.* Кәс, чирәмле җир. *Җирне кишәңге каплаган*

**КИШӘР** *и. диал.* Буйга сузылган тигез иңле җир мәйданчыгы; кишәрлек. *Сабан белән сөрелгән җир тасмасы кишәр аталган.* Р.Әхмәтьянов

**КИШӘРЛЕ** *с. диал.* Аерым кишәрләрдән торган. *Кишәрле җир мәйданы*

**КИШӘРЛЕК** *и.* 1) Эшкәртү (сөрү, чәчү, уру, чабу, утау һ.б.) өчен бүлеп алынган җир мәйданчыгы. *Сәфәргалин --- буш урындагы өй-баз чокырларын бульдозер белән тигезләтте; койма белән әйләндереп алып, бөтен кишәрлеккә каен аралаш яшь чыршы күчереп утырттырды.* А.Гыйләҗев. *Ә инде кишәрлекне җыеп бетереп әбәткә тукталгач, андыйлар: «Чәй! Чәй!» – дип, иң алдан йөгереп килеп җиттеләр.* Ф.Хөсни. *Ике кишәрлек чамасы утагач, төшке ашка кайтып киттек.* Г.Толымбай

2) Кыр эшләре эшләгәндә, бер кеше алып барырга тиешле җир участогы; алын. *Олыларның сөйләшүеннән Габдулла шуны белде: басуда Сабираның кишәрлеге җир уртасына туры килгән икән.* Ә.Фәйзи

3) Ниндидер максат (төзелеш, хуҗалык алып бару һ.б.ш.) өчен билгеләнгән җир мәйданы. *Казан шәһәре социаль яклау бүлекләре биргән мәгълүматлардан күренгәнчә, бүгенге көндә җир кишәрлеге алырга күп балалы 3771 гаилә чиратта тора.* Татарстан яшьләре

**КИШӘРЛЕКЛЕ** *с.* Кишәрлекләргә бүленгән, кишәрлекләргә аерылган. *Кишәрлекле җир мәйданы. Кишәрлекле болын*

**КИШӘРЛЕКЛӘП** *рәв.* 1) Кишәрлекләргә бүлгәләп. *[Чәчүдә] эшне кишәрлекләп-кишәрлекләп бүлеп эшләделәр.* Ф.Хөсни

2) *диал.* Төркем-төркем булып. *Кишәрлекләп тезелеп бару*

**КИШӘРЛЕКЛЕ-КЕШТӘКЛЕ** *с.* Төрле формадагы кишәрлекләргә бүлгәләнеп беткән. *Кайда иңе ун чабата буе, кайда биш-алты саженьлы кишәрлекле-кештәкле, ыштан балагыдай тар җирләр хәзер, йөзәр, меңәр гектары бергә кушылгач, --- матурланып киткәннәр.* Г.Бәширов

**КИШӘРЛЕКЛӘ́Ү** *ф.* Җир мәйданын кишәрлекләргә, кишәрләргә, өлешләргә бүлү

**Кишәрлекләп алу** Бер өлешен аерып кишәрлекләү

**Кишәрлекләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр кишәрлекләү

**КИШЕР** *и. фар.* **1.** 1) Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан яфраклары каурыйсыман телгәләнгән, кызгылт сары төстәге озынча юан тамыры булган бакча үсемлеге. *Югары очлар кишер чәчә, кыяр утырта, кара яздан парник ясап, тирес ташып чиләнәләр.* А.Гыйләҗев. *Чөнки яхшы белә: яшь председательнең үз бакчасында әлегә чөгендер дә, кишер дә, кыяр да, кабак та үстерелә.* М.Мәһдиев

2) Ашамлык әйбере буларак, шул үсемлекнең итләч тамыр өлеше. *Менә зәңгәр сырмалар кигән Карадуган малайлары – һәммәсе кишер ашый.* М.Мәһдиев. *Әхмәт көз көне аннан ярты капчык кишер, алты баш кәбестә алып кайткан иде.* Ш.Камал

**2.** *с. мәгъ. сөйл.* Шул үсемлекнең тамыр өлеше төсендәге. *Кишер сары*

**КИШЕР ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык үсемлекләр ыруына караган, коры болыннарда, куак араларында үсә торган, халык медицинасында сөякләр сызлаудан кулланыла торган үлән үсемлек: *русчасы*: **морковник**

**КИШЕРЛЕ** *с.* 1) Үзендә кишер үскән, кишер үстерелгән. *Кишерле түтәлләр*

2) Кишер салып пешерелгән, шуннан хәзерләнгән. *Кишерле аш. Кишерле бөккән. Кишерле салат*

**КИШМЕК** *и.* Чикләвекнең итләч оясы, кишәнке

**КИШМЕКЛӘ́Ү** *ф.* Чикләвекне кишәнкедән аерып алу

**Кишмекләп кую** Кишмекләнгән хәлгә китерү

**Кишмекләп чыгу** Билгеле бер вакыт аралыгында кишмекләү; бөтенесен дә кишмекләү

**КИШМИШ** *и.* 1) Төшсез вак җимешле виноград сорты

2) Вак сортлы виноград җимешләреннән киптереп әзерләнгән йөзем

**КИШТӘ** I *и.* 1) Савыт-саба, китап һ.б.ш. әйберләр кую өчен, стенага беркетеп, тактадан эшләнгән җайланма, шүрлек. *Икмәкләрне, абыстай кушуы буенча, киштәгә илтеп куйганнан соң,*

*Зөһрә апа әлеге бер тиенне абыстайның кулына илтеп төртте.* Ә.Фәйзи. *Кичке кояшның сүрән нуры кыйгачлап Коля бүлмәсенә төшкәндә, әлеге иске китаплар киштәдә тезелеп тора иде инде.* Җ.Тәрҗеман. *Шкаф киштәләрендә шыгрым тулы күн тышлы фолиант китаплар.* М.Юныс

2) Тимер юл вагонында әйберләр кую һәм йоклау өчен урын; сәндерә. *Вагонның киштә такталарыннан чи нарат чәере исе килеп тора.* Ш.Усманов. *Купега әйләнеп кердем, өске киштәгә менеп яттым да йокыга талдым.* Казан утлары. *Ә без Чайрушин белән югарыга, үзебезнең киштәләргә үрмәләдек.* Г.Ахунов

3) *күч.* Кемнәр, нинди кешеләр рәтендә, арасында саналу турында; даирә. *Иҗатларын таныган тәкъдирдә дә, җибәргән хаталары өчен, К.Тинчурин, Г.Камалларга да зыялылар киштәсендә урын табылмый.* Т.Галиуллин

**КИШТӘ** II *и. диал.* 1) Юан булмаган озын агач, колга. *[Хәерниса] аулак өйгә гармоньлы егет кертте. Бер керткәндә, бик әрсезләнә башлагач, егетне югары киштәгә аягыннан асып куеп, мәсхәрә кылу көлкесен ул башлады.* Г.Ибраһимов. *Печән кибәне салу ул болай. Аласың шоп-шома бер киштә. Гадәттә ул ак чыршы киштәсе була.* М.Мәһдиев

2) Түбә сыртыннан почмак ясап, йорт стенасына утыртып куела торган түбә терәге; бәпкә, кайчы. *Аннары карындыкка төреп бәпкә киштәсенә элеп сакланган каз түшкәсен Сабантуй көнне чормадан аласы.* М.Мәһдиев. *Давыл бәпкә-киштәләрне чыгырдатты, өй түрендәге топольнең ботакларын сындырып күккә каерды.* Казан утлары

3) Кышын адашмас өчен, юлның ике ягына утыртылган агачлар; маяк

4) *диал.* Кипкән печәнне җыеп ясаган тезем

5) *диал. к.* **күбә** I

6) *диал.* Бишек сиртмәсе, силә

**КИШТӘЛӘП** *рәв.* 1) Катлы-катлы итеп, берничә катлы киштәләр формасында, яруслап. *Киштәләп салынган әкәмәт урын икән ул театр. Бар киштәләре дә [халык белән] шыгрым тулы.* К.Нәҗми

2) Берсе өстенә берсен куеп, катлы-катлы итеп. *Тукыма тюкларын киштәләп өю*

**КИШТӘЛӘ́Ү** *ф. диал.* Чабылган печәнне ике яктан тырма белән өеп чыгу, **киштә** II (*4 мәгъ.*) ясау

**КИШТӘЛЕ** *с.* 1) Үзендә киштәсе булган, киштәләп эшләнгән. *Киштәле шкаф. Киштәле сейф*

2) Катлаулы, бер-бер эчле урнашкан. *«Тартмалы композиция» дип аталган бу алым дөнья әдәбиятында күптәннән мәгълүм. --- Беренче мәлдә аның [М.Мәһдиев] киштәле, новеллистик прозасын кабул итмәүчеләр дә булгандыр.* Т.Галиуллин

**КИШТӘЛЕК** *и.* **1.** Киштәгә яраклы такта яки колга. *Әптерүш машинасына, тегеннән-моннан кайтышлый, юк-юк та агачын, киштәлеген салып кайта.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* Киштә ясарга ярарлык. *Киштәлек сөян*

**КИЮ** *ф.* 1) Гәүдәнең берәр өлешен кием белән каплау. *Хөсәен --- озын казаки кими, бәлки, озынрак кына, татар киемчесе теккән пиджак киеп йөри.* Ф.Әмирхан. *Бусы да аның --- нәрсәнең кайда килешкәнен белә. Кияргә ашыкмый зат нәрсәне. Туемда кияргә торсын дип саклый.* Ф.Хөсни. *--- аякларында ботинка, ботинка өстеннән тагы галош кияләр; аларның хәтта кич ятканда кия торган эчке күлмәкләренә хәтле бар иде.* Х.Сарьян

2) Берәр әйберне эләктереп яки тагып, үзеңә беркетеп кую. *Фәхрисламның кәеф гадәттән тыш яхшы, шул уңайдан ул Ленар кыставы аркасында гына шәһәргә барып, мәҗбүри диярлек куйдырткан яңа теш казнасын да кигән иде. Ул аны ике генә очракта кия: өйгә кунак килгәндә һәм улы Ленар янына барганда.* М.Мәһдиев. *Судья күзлеген киеп бер кайнешкә, бер фоторәсемгә карады.* З.Мәхмүди

3) *күч.* Өсте нәрсә белән дә булса каплану, күмелү (гадәттә яфрак, чәчәкләр белән – үсемлекләр, җир тур.). *Йомшак нурлар сибә-сибә килә май. Яшел киемнәрен кия киң тугай.* Ә.Ерикәй

**Киеп алу** Тиз арада кию. *Габдуллага бу сөенеч өстенә сөенеч булды, ул яңа киемнәрен киеп алды. --- Сапый абзый, киез итекләрен салганнан соң, читекләрен киеп алды.* Ә.Фәйзи

**Киеп кую** *к.* **киеп алу**

**Киеп тору** Гел кию; хәзер кию процессында булу

**Кия башлау** Киярга керешү. *Инде ул ыштаннарны Америка, Аурупа илләрендә кия башладылар.* Р.Батулла. *Шуннан соң, бик озак чирләп ятканнан соң әле яңа гына аягына басып килә торган сырхау кебек, ниндидер бер авырлык, кыенлык белән яңадан чемоданына иелде, аны аска этеп куйды һәм шулай ук авыр хәрәкәтләнеп, әкрен генә, сүзсез генә костюмын кия башлады.* Н.Фәттах

**КИЮЛЕК** *с. сир.* Көн дә киелә торган. *Киюлек чалбар. Киюлек халат*

**КИЯ** *и.* 1) *этн. миф.* Үпкә, рәнҗеш рухы

2) *сөйл.* Үпкә, рәнҗеш хисе, күңел калу

3) Һәркемгә, һәрнәрсәгә хас берәр яхшы, хөрмәт ителерлек сыйфат

4) Ярамаган эш эшләп, шуның аркасында бәла-казага, зур зыянга дучар булу

◊ **Киясе килү** 1) Рәнҗү, хәтер калу, күңел кителү; 2) *к.* **кия** (*4 мәгъ.*)

**КИЯЛЕ** *с.* Тиз үпкәләүчән, рәнҗүчән. *Кияле бәндә көн күрмәс.* Мәкаль

**КИЯЛЕК** *и.* 1) Кия китерә, рәнҗетә торган нәрсә

2) *сөйл. к.* **кия** (*1 мәгъ.*)

3) Афәт, бәла-каза, зыян, зарар. *[Күрәзәче – Яңгурага:] Бөтен кыпчак, Болгар йортына киялек китердең.* Н.Исәнбәт. *[Дилә:] – Ә син тоттың да Себер баена ияреп китеп бардың. Баедыңмы соң? – Баедым. Байлыгымны төяп, Казанга кайттым, шуның киялеген күрәм хәзер.* Сөембикә

◊ **Киялеге килер (килмәсен)** 1) Кем дә булса артык рәнҗер дип, аңа ташлама ясаганда әйтелә торган сүз; 2) Икенче бер предметның яки күренешнең начар тәэсиренә эләгеп, шуннан зарар, зыян күрү; 3) «Монысыннан канәгать булмасаң, моннан да начаррагына тап булырсың» мәгънәсендә кулланыла. *Гыйбаш абзый туктап калды: – Сукранма, Бәшир абзый, киялеге килер, – диде. – Өлешеңә чыккан көмешең.* Г.Бәширов

**КИЯ́Ү** *и.* 1) Туй йоласында: өйләнеп йөргән егет, ир кеше. *Моның мәгънәсе шунда чыкты: гадәттә кияү үзенең аталары, кодалары белән бергә аерым чанада туйга килә дә, никах укылганчы, өндәүченең йортында берничә сәгать вакыт үткәрә.* Г.Ибраһимов

2) Барча нәсел-ырудагы өлкәннәр өчен: берәр туган тиешле хатынның ире. *[Хатыны – иренә:] Кияүне тынычлыкта калдыр, күзенә күренеп йөрисе булма!* Ә.Еники. *Әмма һәрбер баш миендә бер генә сорау бар иде: «Кияү» – ул кем? Ул нинди? Безнең авылның сугыштан соңгы беренче кияве ул – кем?* М.Мәһдиев

3) Атау һәм эндәшү сүзе буларак, ата һәм ана өчен кызның ире. *Картайдым инде, кияү, юклык изде.* Һ.Такташ

◊ **Кияүгә бирү** Йола буенча, кызны егет белән кавыштырып, ирле итү. **Кияүгә бару** *к.* **кияүгә чыгу**. *Юк, кая ди ул үз теләкләре белән кияүгә бару, хәтта дөнья йөзен бер күрергә зарыгып яшәгәннәр.* Ф.Яхин. **Кияүгә китү** *к.* **кияүгә чыгу**. **Кияүгә чыгу** Кемнең дә булса хатыны булу, ир белән яши башлау. *[Кодачадан] «Ә син кайчан кияүгә чыгасың?» – дип сорыйсым килде минем, ләкин тыелып калдым. «Әдәпсез», – дияр, гәрчә бөтен кайгысы кияүгә чыгу булса да.* Ә.Еники. *Тора-бара апалары кияүгә чыга башладылар, җизниләр килде, бүләкләр килде, кодалар булды.* А.Гыйләҗев. *Көннәрнең берендә Зөлхәбирә күрше Масра егетенә кияүгә чыккан дигән хәбәр таралды.* М.Мәһдиев

**КИЯ́Ү БҮЛМӘСЕ** *и. этн.* Кыз йортында кияү кертер өчен махсус җиһазландырылган бүлмә. *Бар, киленкәем, тиз, кияү бүлмәсен кара. Минем кулым тими, адәм алдында оятка калырлык була күрмәсен берүк!* Г.Ибраһимов

**КИЯ́Ү ЕГЕТЕ** *и. этн.* Кияүнең туй вакытында янында йөргән дус егете; *русчасы*: **шафер, дружка**. *Кияү ишек бавын тартып җибәрде. --- өйгә зур толыплы, кама читле бүрекле таза бер егет керде, аның белән бергә үк кияү егете, тагы берничә ир, берничә яшүсмер керде.* Г.Ибраһимов. *Гадәттә кияүне кияү егетләре алып килә.* Г.Бәширов. *Алдан – баш кияү егете, аңа тотынганы – кияү үзе, калганнары кияү егетләре. Шулай тезелешкәч, алар келәт ишегенә килделәр.* Ә.Еники

**КИЯҮДӘ** *рәв.* Кияүгә чыккан, тормышта. *Хәерниса авылда кияүдә иде, ире бик ашыкса да ---, китәргә көче җитмәде.* Г.Ибраһимов. *Дүрт кызым бар, икесе кияүдә*

**КИЯҮДӘГЕ** *с.* Кияүдә булган, кияүгә чыккан, ирдә саналган, ире булган. *– Хәзрәт, бу ни эш? Кияүдәге кызларга бер әйбер дә тимимени шулай? – диде.* Г.Ибраһимов

**КИЯ́Ү КАМЧЫСЫ** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан дүрткырлы озын сабагы ашарга яраклы, ал яки зәңгәр чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы*: **зопник клубненосный**. --- *Бәдретдин әйтә, моны башкортларда «кияү камчысы» дип йөртәләр, ди, чөнки очындагы менә шушы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул чынлап та чуклы камчыга охшап китә, ди.* Ә.Еники. *Юл читендә зәңгәр тубал булып кияү камчылары, зәңгәр күзләр, аклы-сарылы яулык бөркәнгән ромашкалар кала.* А.Гыйләҗев

**КИЯ́Ү КОЙМАГЫ** *и. этн.* Кыз белән кияү хөрмәтенә түгәрәк һәм матур итеп пешерелгән вак төче коймак. *Мунчадан соң кияү коймагы, чәй, кымыз белән сыйладылар.* Р.Батулла

**КИЯҮЛӘ́Ү** *ф. этн.* 1) Туйга кадәр ярәшелгән кыз янына барып йөрү. *Ак иделләрнең буенда Ак күгәрчен йөри җәяүләп. Син җаныйны алыр булсам, Өч ел йөрер идем кияүләп.* Җыр. *Җәй буе кияүләп, көз җитә башлагач та, Сәгыйдә хәзрәтеннән атна-ун көн аерылып торуларның авырлыгын бик нык сизенә башлады.* Г.Исхакый. *Бу аның соңгы кияүләве иде, атна-ун көннән киленнәр төшерү башланачак.* Г.Ибраһимов

2) Хөрмәт күрсәтү, хөрмәтләү. --- *бу сүзләр Хафиз байның бәгырен соңгы кисәгенә кадәр телгәләде. Ул мөртәтне ничек кияүләсен, ди, инде ул, кеше алларында нинди йөз белән күренсен икән инде.* Ф.Яхин

**Кияүләп йөрү** Кияүләү (*1 мәгъ.*) гамәлен башкару; кияүләү гамәлендә булу. *Бу юлы инде кияүләп йөрисе түгел иде: хәзрәтне чәйгә алып киләсе дә күз алдында никах кына укытасы.* М.Мәһдиев. *Озакламыйча, Шакир «колхоз йомышы белән барам» дип, айлар буе кияүләп йөргән яшь кәләшен алып та кайтты.* Р.Төхфәтуллин

**Кияүләп яту** *к.* **кияүләп йөрү**. *Туйлар шаулап уза, яшь мәзин кияүләп ята башлый.* И.Нуруллин

**КИЯҮЛЕ** *с.* 1) Кияве булган. *Кызлы кеше – кияүле.* Мәкаль

2) Кияүдә, ирдә булган; җефетле, җәмәгатьле. *Аның сеңлесе күптән кияүле инде*

**КИЯҮЛЕК** *с.* **1.** Кияүгә дип билгеләнгән, кияүгә дип алынган. *Кияүлек бүләк*

**2.** *и. мәгъ.* Кияү булу. *[Искәндәр:] Малайга кызыбызны бирергә күнгән булып, тик безгә кияүлеккә лаек булу һәм халык арасында йөзебезне аклау өчен дип, Казанга барып ике ел укып кайтуын шарт иттек.* М.Фәйзи. *Кияүлек вакытлары үтеп барган саен, Сәгыйдә мулласын ярата башлады.* Г.Исхакый

**КИЯ́Ү ПИЛМӘНЕ** *и. этн.* Итенә йомырка сытып, бик юка камырлы һәм вак итеп пешерелгән пилмән. *Вак-вак дисез, кияү пилмәне булганга вак алар.* Г.Галиева

**КЛА́ВЕ** *и. исп.* 1) Куба, Колумбия һ.б.ш. илләрдә таралган, каты агачтан эшләнгән ике таякчыктан гыйбарәт бәрмә уен коралы

2) Шул уен коралы ярдәмендә уйналган Латин Америкасы ритмы

**КЛАВЕСИ́Н** *и. фр. муз.* Фортепианога охшаган клавишлы-кыллы музыка уен коралы. *Яковкиннар квартирасында кемнеңдер клавесинда уйнаганы ишетелде.* Җ.Тәрҗеман. *Анна шунда ук утырган җиреннән торып, клавесин янына килде һәм бер дә ялындырмыйча уйнарга керешә.* Казан утлары

**КЛАВИАТУ́РА** *и. ит. муз.* 1) Клавишлы музыка коралларында клавишлар җыелмасы. *Аккордеон клавиатурасы. Фортепиано клавиатурасы*

2) Төрле җайланмаларда барлык клавишлар җыелмасы. *Йозакны ачу өчен, кулда ачкыч яки отмычка булу гына җитми; бәлки йозак механизмының клавиатурасы кайсы номерга яисә*

*кайсы хәрефкә куелырга тиеш икәнен белергә кирәк.* Ш.Усманов. *Компьютер клавиатурасы. Язу машинкасы клавиатурасы. Калькулятор клавиатурасы*

**КЛАВИКОРД** *и. фр. муз.* Электә кыллы-клавишлы уен коралы, фортепиано элгәрләреннән берсе

**КЛАВИР** *и. лат. муз.* 1) XVII–XVIII гасырларда барлык кыллы-клавишлы уен коралларының гомуми атамасы

2) Опера яки симфония партитурасының фортепианода башкару өчен әзерләнгән күчермәсе. *Бервакыт Муса Әминәдән «Севилья чәчтарашы» исемле операның клавирын күчереп бирүне сорый.* Х.Садрый. *Нәшриятыбыз тарихында Казанда беренче тапкыр тулысынча опера клавирлары дөнья күрде.* Р.Вәлиев

**КЛА́ВИШ** *и. лат. муз.* 1) Уен коралында бармак белән басу өчен төймә, пластинка. *Мөнирә рояль янына килде һәм --- клавишлардан озын бармакларын йөгертеп үтте.* Г.Әпсәләмов. *Гайдның гүзәл һәм бай сонатасын гүя --- клавесин янында утырган кыз үзе уйнамады, бәлки уйнау техникасын үзләштергән бармаклары гына клавишлар өстендә йөрде.* Ж.Тәрҗеман. *Менә аның озын, нечкә, хәтта нәфис бармаклары сары клавишлар буйлап йөгерәләр.* А.Тимергалин

2) Нindидер механизмнарны хәрәкәткә китерү яки мәгълүмат кертү өчен, бармак белән баса торган төймә, пластинка. *Түгәрәк шкала тирәсендә күпсанлы ваграк приборлар, аскы якта төрле кнопкалар һәм клавишлар.* А.Тимергалин

**КЛА́ВИША** *и. лат. кит. к.* **клавиш**. *Мансур клавишаларга ун бармагы белән тагын да ярсыбрак бәрә башлый.* Г.Әпсәләмов. *Бәлки, композиторларга да, вакыт-вакыт бармакларын клавишалардан алып, --- музыкабыз турында мәкаләләр, очерклар язарга кирәктер?..* Ж.Фәйзи. *Укытучы хатын зәңгәр бармаклары белән пианино клавишаларына баса да шулай җырлый.* М.Мәһдив

**КЛА́ВИШЛЫ** *с.* Клавишлары булган, клавишлар ярдәмендә уйнатыла, эшләтелә торган. *Фортепиано белән пианино клавишлы музыка коралларыннан саналалар*

**КЛАДОВОЙ** *и. рус* Ашамлык әйберләре, шулай ук товар, чимал һ.б.ш. кирәк-яракларны саклау урыны. *Бүген төнлә Низам байның кладовоеннан егерме йөк кызыл мал төяп алып киткәннәр.* К.Тинчурин. *Бүген, кладовойдан алты буханка ипи урлаган өчен, парторг Мещеряков аңа искәрмә ясый һәм болай ярамавын әйтә.* М.Яһудин

**КЛАДОВОЙЧЫ** *и.* Кладовой, склад эшчесе; кладовой мөдире. *– Һмм, – диде аңа симез җыерчыклары бүлтәеп-бүлтәеп торган юан муенлы кладовойчы.* Р.Төхфәтуллин. *Солыны безгә, киң авызлы бер тимер чиләкне тутырып, кладовойчы Шәмсетдин абзый биргән иде.* Татарстан яшьләре

**КЛАДОВЩИК** *и. рус к.* **кладовойчы**. *Биктимер: «Ялгыш үлчәргә, хәзер кладовщик синең элекке күршең кешесе түгел ич».* А.Алиш. *Кладовщиклар ничек тели, вакытны шулай куя.* Р.Батулла

**КЛАКСОН** *и. ингл. тех.* Транспорт чараларында тавыш сигналы бирә торган җайланманың һәм шундый сигналның элекке исеме. *Җәлил һәм беренче машинадагы Ибраһим берберсен сәламләп клаксонга бастылар, югары, кискен ике тавыш бергә кушылып, ерактагы тауларда кайтаваз булып яңгырады.* Р.Мирхәйдәров. *Урамнан извозчиклар, барабызлар, ара-тирә автомобильләр клаксоннарын кычкыртып уза.* Р.Батулла

**КЛА́ПАН** *и. нем.* 1) *тех.* Нинди дә булса механизмда пар, газ, сыеклык һ.б. үтә торган каналны каплау өчен махсус япкыч, каплавыч. *[Насостагы] дүрт чуен клапанның берсе яртылаш сынып төшкән.* Ш.Камал

2) Тынлы музыка коралларында уйнаганда һава агымының юнәлеш һәм көчен кирәгенчә җайга салу өчен кечкенә капкач

3) *анат.* Куыш органның нindидер юлны, тишекне томалый торган өлеше. *Һәр йөрәгалды белән карынчык тоташкан урында капкач рәвешендәге клапаннар бар.* Анатомия

**КЛА́ПАНЛЫ** *с.* Үзендә нинди дә булса клапаны булган; клапан ярдәмендә эшли торган. *Дөрес, әлеге исерткеч эчемлекне әзерләү өчен, су гына түгел, суны газлаштыра торган клапанлы шешә дә кирәк икән.* Татарстан яшьләре. *Клапанлы бүлгеч. Клапанлы насос*

**КЛАРНЕТ** *и. фр.* Агачтан бер башы киңәйтелеп эшләнгән курай шикелле тынлы музыка коралы. *Егерме сигез өлкән класс укучысы кларнетта марш уйнап баручы Пётр Балясников артыннан конференц-залга үтеп керәләр.* Ж.Тәрҗеман. *Арада берсенең – Гроздовскийның кулында кларнет чагылып китте.* Казан утлары

**КЛАРНЕТЧЫ** *и.* Кларнетта уйнаучы. *Чокырда курайчылар, эскрипкәчеләр, барабанчылар, кларнетчылар, флейтистлар, контрабасчылар һәм ике арфистка утыра.* Р.Батулла

**КЛАСС** *и. лат.* **1.** 1) Нинди дә булса уртак үзлеге, үзенчәлеге белән берләштерелгән предметлар, тикшерү яки өйрәнү объектлары төркеме

2) *биол.* Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы бүленешендә иң югары систематик категорияләрнең берсе. *Чәчәкле үсемлекләрнең иң зур төркемнәре булып класслар санала.* Ботаника. *Табигатьтә хайваннарның якын торган, охшаш семьялыкларын отрядка, отрядны – класска, классларны типка берләштерәләр. Имезүчеләр классы хордалылар тибы составына керә.* Биология

3) Социаль-экономик хәлләре, дөньяга карашлары, культура дәрәҗәләре буенча бериш кешеләр төркеме; сыйныф. *Монда халык бер-беренә каршы ике класска нык аерылышып җиткән.* Г.Ибраһимов

4) Берәр нисбәттән беришле яисә бер җәһәттән каралган нәрсәләр бүленешенең бүтәннәр белән тиң бер бүлеме. *Хисаплау машиналары класслары. Минерал класслары. Миноносецлар классы*

5) Иерархик бүленештә беренче, икенче, өченче һ.б. яисә югары, урта, түбән дип, кыйммәте һәм башка сыйфатлары буенча бериш нәрсәләрнең төркемнәрен билгеләгән сыйфат күрсәткече; разряд. *Беренче, икенче класс дип авыз ачасы да түгел: ике-өч көн элек сатылып беткән; өченче классы-*

*на да чак эләкте: соңгы ике билетны мин алдым.* Х.Сарьян. *Ханым, палубаны ташлап, беренче класслның салонына килеп керде.* Ә.Еники. *Бетонның ныклык буенча класслар шкаласы бетонның кысуга ныклыгы буенча элек кулланыла торган маркалар шкаласына туры килми.* Төзү материаллары

6) Мәктәп курсында бер баскыч. *Ул вакытта беркадәр реформалашкан мәдрәсәләрдә класска бүлү тәртибе менә шулай була торган иде: өч класс ибтидаи (башлангыч), дүрт класс рөшди (урта), өч класс уртадан югары – игъдади.* З.Бәшири. *Өлкән класстагылар гына беркадәр читтә, дәрәҗәләрен саклап, акыллы сүз сөйләшә иделәр.* Г.Әпсәләмов. *Залга өлкән класс укучылары кергәндә, түбән һәм уртанчы класслар инде рәт-рәт булып басканнар иде.* Җ.Тәрҗеман

7) Бер бүлмәдә укучы яки бер фәнне үтүче балалар төркеме. *Класста җиде малай – барысы да Николай исемле, шуңа күрә аларның һәркайсының кушаматы бар иде.* Җ.Тәрҗеман. *Бер үк вакытта музыка мәктәбенең фортепиано классын гел «бишле»гә тәмамлый.* Кызыл таң

8) Мәктәптә дәрес укытыла торган бүлмә, дәрес бүлмәсе. *Ибраһимов, тагын берсе кулын күтәрмәс микән дип, класс буйлап узды.* Җ.Тәрҗеман. *Компьютер классы менә диган: быел гына 11 компьютер кайтарылган, ә кәнәфиләрне үзләре эшләп тапкан акчага алганнар.* Ватаным Татарстан

9) *сөйл.* Нинди дә булса бер өлкәдә, эштә осталык, һөнәрнең югары сыйфаты. *Самолёт белән идарә итүдә югары класс күрсәтү*

10) Нәрсәнең дә булса урынын билгели торган сыйфат, дәрәҗә үлчәве. *Бетонның ныклык буенча класслар шкаласы*

**2.** *ы. мәгъ.* Шәп, әйбәт. *[Мостафа Ногман:] Карале, ыслушай. Кичә без Рөстәм Яхин белән бер романс иҗат иттек. Ну малай, класс инде.* М.Мәһдиев

**КЛА́ССИК** I *и. фр.* 1) Гомумхалык тарафыннан киң танылган, үрнәк булырлык әдәбият, сәнгать яисә фән эшлеклесе. *[Г.Камал] Октябрьдән соң да әдәби тәрҗемәчелек эшен дәвам иттереп, рус һәм Көнбатыш классикларының күп кенә әсәрләрен татарчага күчерде.* М.Гали. *Татарның миллионерларыннан берсе, Уралдагы алтын приисклары хуҗасы Закир Рәмиев (ул ук татар әдәбиятының классиклары җөмләсенә кергән күренекле шагыйрь Дәрдемәнд), шушы Җиргән авылында туган.* М.Әмир

2) Борынгы грек һәм латин телләре әдәбияты буенча белгеч

3) Сәнгатьтә классицизм тарафдары

**КЛАССИК** II *с. лат.* 1) Классиклар I (*1 мәгъ.*) тарафыннан иҗат ителгән; үрнәк булып танылган. *Студия классик операларның тулы пәрдәләре, аерым өзекләре өстендә эшләүне планга кертте.* М.Җәлил. *Классик комедия үрнәкләрен биргән Г.Камал әсәрләрендә Кариевның беренче чорга караган иҗат йөзе, --- типлар, алымнар аеруча чагылыш таба.* Һ.Мәхмүтов. *Шагыйрь [Ф.Кәрим] халык лирикасы, классик поэзия аша --- рухи дөньяны «тышка чыгарып» сынландыруга ирешә.* Т.Галиуллин

2) Атаклы, үрнәк булырлык, үрнәк булып торган. *Тукай тормышын өйрәнгәндә үк, Ибраһим классик әдип турында күп нәрсә белгән иде.* Р.Нуруллина. *Классик укытучылар – болар гел кеше баласын тәрбияләү турында гына сөйләшәләр, болар үз бәхетләре турында уйламыйлар да.* М.Мәһдиев

3) Борынгы грек һәм латин телләрен һәм әдәбиятларын өйрәнү белән характерлана торган. *Классик гимназия белемле, бик грамоталы егетнең квалификациясе заманы өчен җитеп ашкан булса да, көнчеләрнең казынулары аркасында --- урыныннан куалар.* Р.Әмирхан

4) Борынгы грек һәм римнар дөньясына караган. *Классик телләр*

5) *күч.* Бик характерлы, үзенчәлекле, типик. *Бу билгеләрнең кайсысы Күсия ханымда өстенлек ала торгандыр, әмма барысын бергә җыйгач, әлеге комсызлык диган нәрсәнең Күсия ханым йөзендә без классик үрнәген күрәбез.* Ә.Еники. --- *Хәмзә бай, Сираҗетдин, Әхмәтҗан кебек фанатик типларын сәхнәдә гәүдәләндерү өчен, К.Тинчурин әйткән ысулны куллану Кариев иҗатында классик мисал булып тора.* Һ.Мәхмүтов. *Жанр ягыннан «Тирән тамырлар» романы – детектив әсәрнең классик үрнәге.* Казан утлары

**КЛА́ССИКА** *җый. и. рус* Классиклар иҗат иткән өлге, үрнәк булырлык әсәрләр. *Бер кичне дөнья классикасын, икенче кичне рус классикасын, өченче көнне татар классикасын уйнасын симфоник оркестр.* Р.Вәлиев

**КЛА́ССИКАЛЫ** *с.* Классик әсәрләре булган, классик әсәрләр тудырган. *Әдәби традицияләр ягыннан да татар әдәбияты – шактый бай классикалы әдәбият.* Н.Юзиев

**КЛА́ССИК КӨРӘШ** *и.* Спорт көрәшенең халыклара төре, грек-рим көрәше

**КЛА́ССИКЛАРЧА** *рәв.* Классиклар кебек. *Сәхнәдә классикларча уйнау*

**КЛАССИФИКА́ТОР** *и. нем.* 1) Классификация белгече

2) *махс.* Билгеле бер тәртипкә салынган производство стандартлары белешмәлеге. *Җәмгатьчелек белән эшләүчеләр илкүләм эшчеләр һөнәрләре классификаторына да кертелгән.* Ватаным Татарстан

3) *тех.* Нәрсәне дә булса автоматик рәвештә төрләргә, классларга аера торган аппарат. *Гидравлик классификатор. Конуслы классификатор*

**КЛАССИФИКА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Төрдәш предметларны, күренешләрне яки төшенчәләрне аерым бер билгесе буенча классларга, бүлекләргә, бүлекчәләргә аеру, бүлү системасы. *В.Р.Вильямс классификациясенең нигезе итеп бербөтен бер туфрак ясалу процессын ала.* А.Фаткуллин. *Чәчәкле үсемлекләр классификациясе. Дөнья телләре классификациясе. Классификация ысуллары*

2) *к.* **классификацияләү**. *Туфрак классификациясе, беренчедән, туфракның географик таралу тәртибен, икенчедән, аның генезисын, физик-химик, биологик сыйфатын һәм җитештерү сыйфатын күрсәтергә тиеш.* Җир һәм туфрак

**КЛАССИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Классификация ясау, төркемләү, төркемнәргә аеру. *Г.Ибраһимов проза*

*әсәрләренә махсус бүлек багышлап, аларны классификацияләү --- аларның эчтәлеген ачу җәһәтеннән җитди уңышларга ирешә.* XX йөз башы татар әдәбияты. *Кара туфракларны ясалышы, үзлекләре һәм механик составы нигезендә классификацияләү.* Туфрак белеме. *Элементар кисәкчекләрне зурлыклары нигезендә классификацияләү. Классификацияләү алымнары. Минералларны классификацияләү*

**Классификацияләп алу** Тиз арада классификацияләү

**Классификацияләп кую** Классификацияләп, әзер хәлгә китерү

**Классификацияләп тору** Даими яки регуляр рәвештә классификацияләү. *Туплана торган материалны һәр атна классифицияләп тору*

**Классификацияләп чыгу** Барсын да классификацияләү. *Ул хатларны башта классификацияләп чыгасың.* Р.Миңнуллин

**КЛАССИЦИЗМ** *и. нем.* 1) XVII йөздән XIX йөзнең башларына кадәр сәнгатьтә һәм әдәбиятта антик үрнәкләргә ияреп иҗат итә торган, аның кануннарына нигезләнгән юнәлеш. *Уку йортының классицизм өслүбе шедеврларыннан саналган колонналы төп бинасы да шушы чорда төзелә.* Мәдәни җомга

2) Борынгы грек, латин телләрен, сәнгатен һ.б. өйрәнүгә нигезләнгән уку-укыту системасы

**КЛАССЛАП** *рәв.* 1) Класс белән бергә, класс-класс булып. *Без класслап-класслап бер я ике көнгә барабыз да кулдан килгән кадәр эшләп кайтабыз.* Х.Сарьян

2) Классларга бүлеп, классификация нигезендә

**КЛАССЛЫ** *с.* 1) Үз эшләре рәтендә башкалардан югары сыйфатлы булуы белән аерылып торган. *Эшелон уртасындагы классы вагоннан ике командир төшеп, станция начальнигы янына килделәр.* Ш.Усманов. *Югары классы чуен*

2) *күч.* Югары квалификациягә ия булган, хәзерлекле. *Бу Рөстәм Яхин музыкасының югары зәвыклы, талантлы булуы белән дә, югары классы башкаручы булуы белән дә бәйле иде.* Г.Ахунов

3) *сөйл.* Үзендә билгеле санда класслары булган. *Сигез классы мәктәп*

**КЛАССЛЫЛЫК** *и.* Сыйфатлы булу үзлеге, сыйфатлылык. *Бу якларда үстерелгән бодайның класслылыгы түбән, шул сәбәпле тартылган онның да сыйфаты кайтыш.* Кызыл таң

**КЛАССТАШ** *и.* Бергә, бер класста укыган кешеләрнең һәркайсы; сыйныфташ, шәрик. *Классташлары йөгерәчаба таралыштылар.* М.Хуҗин. *– Сезнең группага яңа укучы өстәлде, – дип, яңа классташыбызны иң арткы өстәлдә берүзе утырган Фәйрушин янына җибәрде.* Х.Сарьян

**КЛАССТАШЛЫК** *и.* Классташ булу хәле, күренеше. *Чөнки безнең халык классташлыкны хөрмәт итә, классташлык белән горурлана.* Ватаным Татарстан

**КЛЕ́ВЕР** *и. нем. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан чәчәкләре шарсыман формада булган, мал ашый торган үлән үсемлек; чалмабаш. *Урта һәм субтропик поясларда клеверның 200 ләп төре, элекке Союзда 70 ләп төре үсә.* Биология. *Шәйдулла атларга мичкә белән су ташый, клевер чабып, төяп кайта.* М.Мәһдиев. *Ә алмагач, чия араларына клевер, вика чәчтем, түтәл араларына да клевер.* Р.Төхфәтуллин

**КЛЕЁНКА** *и. рус* **1.** Махсус составлы җилем белән капланып, су үткәрмәслек итеп эшләнгән каты тукыма. *Дәфтәрне, кеше-кара күрмәсен дип, клеёнка астына яшереп куйдылар.* А.Гыйләҗев. *Клеёнка күбесенчә китап тышлыгы, өстәл җәймәсе кебек әйберләр ясауга китә.* Йорт эшләре

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән. *Полк писаре Бикләмишевка клеёнка папкага салынган кәгазьләр бирде.* К.Нәҗми

**КЛЕЁНКАЛАУ** *ф.* Клеёнка белән тышлау, клеёнка белән ябыштыру. *Ишекне клеёнкалау*

**Клеёнкалап алу** Тиз арада клеёнкаланган хәлгә китерү

**Клеёнкалап кую** Алдан яки тиз генә клеёнкаланган хәлгә китерү

**Клеёнкалап чыгу** Барсын да клеёнкалау. *Ишекләрне клеёнкалап чыгу*

**КЛЕЁНКАЛЫ** *с.* Клеёнка белән тышланган, клеёнка белән капланган; өстенә клеёнка ябылган. *Ике тәрәзә арасындагы буш урында өстенә кара түгелеп беткән, кырылган клеёнкалы өстәл тора.* А.Алиш

**КЛЕ́ЙСТЕР** *и. нем.* Крахмал яки оннан әзерләнә торган җилем. *Гөмбәнең кисеп алынган эшләпәсен клейстер яки башка төрле җилем сыланган кәгазь өстенә куеп карарга мөмкин.* Н.Верзилин. *Клейстер белән балчык кушу акшарның кайрыга яхшылап сеңүе өчен кирәк.* Ватаным Татарстан

**КЛЕ́ММА** *и. нем.* Чыбыкларны нәрсәгә дә булса тоташтыру өчен эшләнгән махсус кыстыргыч. *Клемма белән үткәргечне тоташтыру. Аккумулятор клеммасы*

**КЛЕПТОМАН** *и. гр.* Клептомания белән авыручы

**КЛЕПТОМА́НИЯ** *и. гр. мед.* Гел нәрсәдер урларга теләүдән, урлашмыйча тора алмаудан гыйбарәт психик авыру. *Мәхәббәтне эчкечелек, токсикомания, клептомания кебек чирләргә тиңлиләр.* Мәдәни җомга

**КЛЁПКА** *и. рус сөйл.* Кисмәк тактасы, мичкә тактасы

**КЛЕРИКАЛ** *и. фр.* Клерикализм тарафдары; клерикал партия әгъзасы. *Бу шигырь чыга-нитә калса, охранка да, татарның үз клерикаллары да шагыйрьнең башыннан сыйпамаган булырлар иде.* И.Нуруллин

**КЛЕРИКАЛИЗМ** *и. фр.* Җәмгыять тормышының мәдәни, сәяси һәм иҗтимагый өлкәләрендә чиркәүнең һәм руханиларның йогынтысын көчәйтүгә юнәлдерелгән сәяси агым

**КЛЕРИКАЛЬ** *с.* Клерикализмны яклый торган. *Уральск шәһәренең клерикаль даирәләре шәкертләрне котыртучы Г. Хәйруллинны онытып бетермәгән булалар әле.* Х.Гобәйдуллин

**КЛЕРК** *и. лат.* Инглиз теле таралган илләрдә офис хезмәткәре. *Үз хезмәтенә җитди мөнәсәбәте, төгәллеге белән ул [Резеда ханым] буржуа илләрдә мактанган клерклардан һич кенә дә кайтыш эшләми.* Т.Галиуллин

**КЛЕТЧА́ТКА** *и. рус биол.* Үсемлек күзәнәкләренең тышчаларын тәшкил

итә торган матдә; целлюлоза. *Аның нигезен целлюлозага яки клетчаткага якын матдә тәшкил итә.* Биология

**КЛЕТЬ** *и. рус* Шахта эченә төшеп-күтәрелеп йөрү өчен җайланма

**КЛЁШ** *и. фр.* **1.** Түбәнгә таба киңәеп киткән итәк яки балак өлгесе, тегелеше. *Теләсәгез, чалбар балагының киңлеген киң клёшка хәтле киңәйтеп була.* Л.Мөхәммәт

**2.** *с. мәгъ.* Шундый өлгедә тегелгән. *Тулы клёш итәк дүрт кыектан торганда бик матур килеп чыга.* Л.Мөхәммәт. *Пычранмас өчен, джинсы чалбарының клёш балакларын кайтарып куярга туры килде.* Д.Булатова

**КЛИЕНТ** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда хокук мөнәсәбәтләрендә үзенең яклаучысына-патронына бәйле булган ярымхокуклы граждан

2) Даими заказ биреп торучы зат, сатып алучы кеше. *[Бай] моның белән генә тынычланмыйча, үзеннән бурычка товар алучы күптәнге клиентлары белән дә ачуланышты.* М.Галәү

3) Нинди дә булса кәсәбә, сәүдә, кредит оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган кеше яки учреждение

4) Үз эшен алып баруны юриспруденция белгеченә тапшырган зат

**КЛИЕНТУ́РА** *и. җый. рус* Кемнең, нәрсәнең дә булса барлык клиентлары. *Бары татар клиентурасы арасында гына аның адвокатлык абруе әле бераз саклана иде.* М.Галәү

**КЛИ́ЗМА** *и. гр. мед.* 1) Дәвалау яки диагноз кую максаты белән туры эчәккә махсус сыеклык җибәрү

2) Туры эчәккә сыеклык җибәрү өчен махсус прибор

**КЛИ́МАКС** *и. гр. мед.* Җенес бизләренең эшчәнлеге үзгәрү сәбәпле, хатын-кызның җенси активлыгы кимү чоры; ырудан калу (гадәттә 45–55 яшьләр арасында була). *Гинекологик операцияләр, озакка сузылган стресс, җенси җитлегү чорында кичерелгән йогышлы чирләр климакс килүен тизләтә.* Ватаным Татарстан

**КЛИМАКТЕ́РИЙ** *и. гр. мед.* 1) Җенси функцияләрнең тукталу чоры; климакс

2) Климакс чорына бәйле үзгәрешләр. *Климактерий билгеләре*

**КЛИМАКТЕ́РИК** *с.* Климакска бәйле. *Климактерик чор*

**КЛИ́МАТ** *и. гр.* 1) Җирдәге аерым бер урынга хас булган, шул урынны географик яктан билгеләгән һава шартлары; билгеле бер урындагы һаваның күпьеллык режимы. *Начармы-яхшымы, мин – җир климаты буенча белгеч, һәм Кояш нурланышы минем төп профессиямә турыдан-туры бәйләнгән.* А.Тимергалин. *Кытайның көньягында субтропик климат, ул Көньяк Кытай диңгезе яры буенда тропик климатка якынлаша.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Җылы һәм салкын океан агымнары климатка бик нык тәэсир итәләр.* Физик география

2) *күч.* Вазгыять, нәрсәнеңдер торышы, кемгә яки нәрсәгә дә булса билгеле бер караш. *Иске карашлар һәм реакцион фикерләр утравына әйләнгән «Печән базары»нда хөкем сөргән әхлакый-рухи климатны Кисекбаш, Миңлебай, цирк көрәшчесе Карахмәт, Гали батыр, камчылы ишан кебек образлар ярдәмендә чагылдырып, Г.Тукай «Көфер почмагы каһарманнары»ның милләтне юкка чыгару чигенә китереп җиткерә язган гамәлләрен сурәтли.* Ф.Ханнанова. *Нәрсә генә эшләп карасам да, миңа карата «климаты» җылынмады.* Безнең гәҗит

**КЛИМА́ТИК** *с.* Аерым бер климатка караган, климат белән бәйле. *Җир шары төп биш климатик пояска бүленә: бер эссе, ике уртача, ике салкын пояс.* География. *Татарстан Республикасы уртача климатик пояста урнашкан, һәм ел яз, җәй, көз, кыш фасылларына бүленә.* Физик география. *Чәчәкләләр барлык климатик зоналарда һәм тропик урманнардан алып чүлләргә һәм тундрага кадәр төрле экологик шартларда үсәләр.* Биология

**КЛИМА́ТИК СЕЗОННАР** *и. геогр.* Һәр климатик пояска хас булган һәм берничә айга сузылган ел фасыллары

**КЛИ́МАТЛАШТЫРУ** *ф.* Яңа климат шартларына күнектерү. *Субтропик үсемлекләрне климатлаштыру*

**Климатлаштыра башлау** Климатлаштырырга тотыну

**Климатлаштыра тору** Климатлаштыруны дәвам итү

**КЛИ́МАТЛАШУ** *ф.* 1) Яңа климатка күнегү, шул климат шартларына җайлашу

2) *күч.* Таныш булмаган мохиткә, халәткә һ.б.ш. күнегү

**Климатлаша бару** Акрынлап климатлашу

**Климатлашып бетү** Бөтенләй климатлашу

**Климатлашып җитү** Тиешле дәрәҗәгә килеп климатлашу. *Рапс культурасы безнең шартларга климатлашып җитте*

**КЛИ́МАТ НОРМАСЫ** *и. геогр.* Климатның күпьеллык күзәтүләрдән чыгып алынган санча характеристикасы

**КЛИМАТОГРА́ММА** *и. геогр.* Ике төп климатик параметрның (гадәттә температура һәм явым-төшемнең) берберсенә нисбәтен чагылдыра торган диаграмма. *Климатограмма буенча Евразиянең климат типларын билгеләгез.* Материклар һәм океаннар географиясе

**КЛИМАТОГРА́ФИЯ** *и. геогр.* Климатологиянең төрле урыннардагы климат шартларын өйрәнү һәм тасвирлау белән шөгыльләнә торган бүлеге

**КЛИМАТО́ЛОГ** *и. фр.* Климатология белгече. *Миңа, климатолог кешегә, азмы-күпме якын тоелган бердәнбер китап шул иде бугай.* А.Тимергалин. *Климатологлар әйтүенчә, инерт система бер халәттән икенчегә күчкәндә, шундый кискен үзгәрешләр табигый күренеш икән.* Татарстан яшьләре

**КЛИМАТОЛО́ГИК** *с.* Климатологиягә караган, шуңа бәйләнешле. *Климатологик күзәтүләр*

**КЛИМАТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Метеорологиянең Җир шарында һәм аның аерым өлешләрендә төрле климат шартлары барлыкка килү үзенчәлекләренең сәбәбен ачыклый торган климат турындагы фән тармагы. *Мәскәү репродукция һәм климатология үзәгендә әйтүләренчә, атмосфера басымын «җайга салуга», циклоннарны буйсындыруга ук бәби туу кабат артачак, балалар берninди генетик тайпылышларсыз, сәламәт булып туачак.* Мәдәни җомга

**КЛИНДЕР** *и. нем.* Гадәттә төче камырдан бөҗрасыман итеп пешерелгән күмәч. *Конфетлар, клиндерләр,*

*прәннекләр белән аның үзенең тешләре череп беткән.* Г.Ибраһимов. *Кызым, мә, ал янчыкны, мә, тагын сиңа бишалты клиндер алдым.* Ф.Халиди. *Кош теле, кызыл эремчек, кәрәзле бал, сөтле чәй янына клиндер, конфет, алма, хөрмә кебек шәһәр күчтәнәчләре дә өстәлгәч, табын тагын да ямьләнеп китте.* Р.Низамиев

**КЛИ́НИК** *с.* 1) Клиникага бәйле; клиникага караган. *Клиник амбулатория*

2) Клиникада башкарыла торган, шунда үткәрелә торган. *Республика клиник (1 мәгъ.) хастаханәсенә бара торган юлда күп катлы йортлар төзергә тиешләр иде.* Безнең гәҗит. *Балаларда вакцинаны клиник (2 мәгъ.) сынау нәтиҗәсе 2 ноябрьдә билгеле булачак икән.* Ватаным Татарстан

**КЛИ́НИК ҮЛЕМ** *и. мед.* Организмда йөрәк эшчәнлеге, сулыш алу туктаганнан соң була торган тереклек белән үлем арасындагы күчеш чоры. *Клиник үлем белән чын үлем арасында хәлиткеч дүрт-биш минут вакыт бар. Шушы дүрт-биш минутта яшәү көче үлгән кешенең организмын бөтенләй ташлап өлгерми әле.* Г.Әпсәләмов

**КЛИ́НИКА** *и. гр. мед.* 1) Авыруларны дәвалау белән бергә студентларның практикасы да үтә торган, фәнни тикшеренүләр алып барыла торган дәвалау учреждениесе. *Күп тә үтмәде, клиниканың барлык хирурглары бүлек мөдире бүлмәсенә җыелды.* Г.Әпсәләмов

2) Авыру билгеләренең тулы картинасы, авыруның тышкы чагылышы

**КЛИНИЦИСТ** *и. ингл.* Клиникада дәвалау эшләре белән фәнни-тикшеренү эшләре дә алып баручы табиб

**КЛИ́НКЕР** *и. нем.* 1) Юлга түшәү өчен махсус файдаланыла торган бик каты, үтә нык итеп эшләнгән кирпеч. *Клинкерның сыйфаты аның химик һәм минераль составына, чимал сыйфатына, яндыру һәм суыту режимына бәйле.* Төзү материаллары

2) Цемент ясау процессында кулланыла торган яндырып укмаштырылган цемент комы. *Соңыннан цемент клинкеры шарлы тегермәндә гипс өстәп тарттырыла, онга әйләндерелә.* Төзү материаллары

**КЛИ́НКЕРЛАУ** *ф. махс.* Яндырып клинкерга әйләндерү. *Балчыктан ясалган әйберләрне клинкерлау*

**КЛИ́ПЕР** *и. голл. тар.* XIX гасыр ахырына кадәр гамәлдә йөргән тизйөрешле җилкәнле диңгез судносы

**КЛИ́РИНГ** *и. ингл. икът.* Якларның бер-берсенә булган дәгъваларын һәм йөкләмәләрен, кулга акча бирмичә, үз араларында исәп-хисап ясау системасы. *Халыкара исәп-хисапларда валюта клирингы файдаланыла, клирингның бу төренә башлыча милли валюталары иреклe алыштырыла алмаган илләр мөрәҗәгать итәләр.* Политэкономия

**КЛИШЕ** *и. фр.* 1) *махс.* Рәсем, сызым һ.б.ш.ларны күпләп кәгазьгә төшерер өчен, шуларның металл, агач һ.б.ш. материалга кабартып ясалган бастыру формасы. *Алай булырга ул ит түгел. Кургашын гына, клише гына бит.* Г.Тукай. *Җәен суда коенган балалар клишеларны табып алып, өйләренә алып кайта, ә ата-аналар өйдә күренгән бу яңа «уенчыкларга» игътибар итми калмый.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Еш кабатлана торган фикер шәкеле, таушалган, шаблон сүзләр тезмәсе. *«Аның гүзәллегенә кояш гашыйк» яки «йөзеннән ай көнләшә» кебек гыйбарәләр – фарсы-таҗик классик шигъриятенең иң таралган клишеларыннан.* Н.Хисамов. *Гариф абыйның [Г.Ахунов] һәр мәҗлестә кабатлый торган «көмеш билбауларын», «клише» җөмләләрен аның белән аралашып калу бәхетенә ирешкән кешеләр әле дә булса хәтерлиләр.* Казан утлары. *Эпик әсәрләрдә бер әсәрдән икенчесенә күчеп йөри торган этик формулалар, клишелар жанрның үзенчәлекле структура элементы булып торалар.* Татар халык иҗаты

**КЛИШЕЛАШУ** *ф. кит.* Калыплашу, клише формасында ныгып калу, урнашу

**Клишелашып бетү** Бөтенләй клишелашу

**КЛОА́КА** *и. лат.* 1) Борынгы Римда юынтык пычрак су агызу өчен җир асты каналы

2) *зоол.* Кайбер хайваннарның (җирсу хайваннарында, сөйрәлүчеләрдә, кошларда, кайбер имезүче хайваннарда) эчәклегендә урнашкан сидек һәм җенес юллары ачылу урыны; арт юл. *Юан эчәк белән нечкә эчәк арасында чик юк, туры эчәк клоакага ачыла.* Биология

**КЛО́УН** *и. ингл.* Көлкеле номерлар башкаручы цирк артисты; шамакай. *Исмәгыйльне музыкаль клоуннарның, гитара һәм мандолина уйнап, манежда йөрүләре бик мавыктыра.* Г.Ахунов. *Клоуны әллә нинләр кылана, егылган була, авызын чалыш-молыш китерә, күзләрен акайта – барын да эшли, тик ыштанын гына салмый инде.* Р.Батулла

**КЛОУНА́ДА** *и. рус* 1) Клоуннар тарафыннан башкарыла торган цирк номерлары. *– Акробатика, жонглёрлык, экселибр, фокус һәм клоунада төрләрен үстерәбез, – ди студия җитәкчесе, БДУның Бөре филиалы икенче курс студенты Владислав Крестьянов.* Кызыл таң

2) Шундый уенга охшаш мәзәк кыланышлар, шаяртулы уен-көлке. *Чын сөйләшүне клоунадага әйләндердегез.* А.Гыйләҗев. *«Шаян-шоу»ларны карыйм, клоунадага әйләнеп китә кайчагында.* Р.Вәлиев

**КЛО́УНЛАНУ** *ф.* Клоуннар кебек кылану, үзен клоуннарча тоту, шамакайлану. *Изаелның бу клоунланганын да Ләмига бик нык ошата.* Р.Гаязетдин

**КЛО́УНЛЫК** *и.* 1) Клоун һөнәре; клоун кәсебе, шөгыле. *Клоунлыкка түгел, сез аны һөнәргә әзерләргә тиеш!* Р.Батулла

2) *күч.* Җиңел акыллылык, җилбәзәклек

**КЛО́УНЧЫЛЫК** *и.* Клоуннарга хас кәмитчелек

**КЛУБ** *и. ингл.* 1) Бергә ял итү, күңел ачу, үзешчән түгәрәкләрдә, спортта катнашу өчен, уртак эш яки һөнәр кешеләрен берләштергән җәмәгать оешмасы. *Футбол клубы. Шахматчылар клубы*

2) Шул оешма урнашкан йорт, бина. *Клуб янында яшьләр җыйналган, уйныйлар, җырлыйлар.* Ә.Айдар. *Клубтан радиола тавышы ургылып чыкты – танцы башланды.* Х.Сарьян.

*1941 елның җәй башында авылда клуб төзергә керештеләр.* М.Мәһдиев

**КЛУ́МБА** *и. ингл.* Бакча гөлләре үстерү өчен, гадәттә калку итеп ясалган чәчәк түтәле; чәчәклек. *Шуңа ул кичләрен эштән кайткач, өй каршында клумбалар ясап, аларга төрле-төрле чәчәк орлыклары утыртып чыкты.* Р.Мөхәммәдиев. *Чәчәк клумбаларын да үзе теләгәнчә төзи, кыяр-помидорның да үзе теләгән урында үскәнен ярата.* Р.Рахман

**КНЕХТ** I *и. нем. тар.* Көнбатыш Европада (башлыча Германиядә, Австриядә) батрак

**КНЕХТ** II *и. голл. диңг.* Көймә, судно палубасында яки причалда трос, аркан бәйләп, уратып кую өчен махсус куш бүкән

**КНИ́КСЕН** *и. нем.* Көнбатыш культурасында сәламләү буларак кызларның аз гына чүгәләп алуы. *– Әйе, әтиемнең бердәнбер, ләкин бик иркә, бик тә капризлы кызы Даңгөл туташ булам, – диде дә, башта книксен чүкте, аннары кулын сузды ул.* А.Хәсәнов

**КНО́ПКА** *и. рус* 1) Кәгазь, тукыма кебек әйберләрне каты нәрсәгә беркетү өчен эшләнгән үткен очлы кыска кадакчык. *Нәсим урындыгына кнопка да куйма...* Г.Гыйльманов. *Ишек тупсаларын, тәрәзә рамнарын җентекләп карарга киңәш итә Хәмит абый: күгәргән кадак, кнопка ише әйберләр юкмы.* Ватаным Татарстан

2) Өстенә бармак белән басып электр чылбырын тоташтыру һәм төрле механизмнарны хәрәкәткә китерү өчен җайланган төймә. *Йозакны ачкач, ул ниндидер бер яшерен кнопкага басып алды, калын ишек шуннан соң үзе ачылып китте.* А.Тимергалин. *Бигрәк тә үткенрәге – балдыз сөйләде: – Анда, – диде, – эш бик җиңел, ак халат киеп, кнопкага басып кына утырам, көненә җиде сәгать эшлим.* М.Мәһдиев

3) *сөйл.* Ике кисәктән торып, берсе икенчесенә кереп берегә торган металл яки пластмасс каптырма

**КНО́ПКАЛАУ** *ф.* Кнопка белән (*1, 3 мәгъ.*) беркетеп кую

**Кнопкалап кую** Тиз арада яки алдан кнопкалау

**КНО́ПКАЛЫ** *с.* Кнопкасы булган; кнопкага басып хәрәкәткә китерә, эшләтелә торган. *Моңа кадәр элекке эш урынындагы бүлектә бердәнбер телефонга да якын килергә курыккан кешенең хәзер борын төбендә заманына күрә иң яхшы, кнопкалы затлы аппарат иде.* Ф.Яхин

**КНЯГИ́НЯ** *и. рус тар.* Князь хатыны. *Аның каравы әкияти легендаларга таянып, әллә кайдан мукшы княгинясы Нарчатканы уйлап тапканнар.* Ф.Бәйрәмова

**КНЯЗЬ** *и. рус тар.* 1) Борынгы рус феодаль дәүләтендә гаскәр яки аерым өлкә башлыгы. *Рус князьләреннән Даниил Романович Урда башкаласы Сарайга килгәч, Бату хан князьне христиан кануннарына каршы килә торган монгол йолаларын үтәүдән азат кылган.* Ф.Хуҗин

2) Шундый кешеләргә бирелгән, нәселдән нәселгә күчеп килә торган югары дәрәҗә. *Ай-вай мөхтәрәм затлар да инде, кызым. Аларның күңеленә кереп калырга тырыш, Акчуриннар бит, князьләр!* Ф.Яхин

3) *күч.* Элек Россиядә татарларга карата кимсетеп әйтелгән кушамат. *Тикшерүчеләр бертавыштан карарларын да әйтәләр: – Синең, князь, урының монда түгел, барагыңа кайт та җыен. Без сине, юлыңа акча һәм азыктөлек биреп, кире үз илеңә кайтарып җибәрәбез.* Ф.Хөсни. *«Без – татармыз» дигән мәкаләсендә Г.Ибраһимов болай дип яза: «Татарга “татар!” дигән өчен гафилрәк урысның таяк ашаштыруы яки “авызы кара кан белән юылуы” бик ерак ихтималлардан түгелдер. Шуның өчен дә алар “татар” дип эндәшмичә, “князь” диләр».* А.Гыйләҗев

**КНЯЗЬЛЕК** *и. тар.* 1) Князь тарафыннан идарә ителә торган феодаль дәүләт. *Л.Н.Гумилёв – аерым алганда, бернинди «татар-монгол иго»сы булмады, чынында татарлар Русияне ясак түләү бәрабәренә --- төрле вак князьлекләрне берләштерүдә этәргеч бирделәр дигән иманыннан чигенмәүче тарихчы.* Т.Галиуллин. *Идегәйнең бу җиңүе урыс князьлекләрен Литва-Польшага тулысынча буйсынудан коткарып-йолып кала.* Ф.Урманче

2) Кенәз титулы һәм хокукы

**КОАГУЛЯ́ЦИЯ** *и. фр. физ. хим.* Коллоид кисәкчекләрнең оеп укмашып катырак матдә хасил итү күренеше

**КОАГУЛЯ́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Коагуляция хәленә керү, оюу, укмашу

**Коагуляцияләнеп бетү** Бөтенләй (тәмам) коагуляцияләнү. *Эремәдәге матдәләр коагуляцияләнеп беткән*

**Коагуляцияләнеп җитү** Тиешле хәлгә килеп, бөтенләй коагуляцияләнү; шундый хәлгә килү

**КОАГУЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Коагуляция хәленә китерү. *Эремәне коагуляцияләү*

**Коагуляцияли башлау** Коагуляцияләргә тотыну

**КОАЛИЦИОН** *с.* Коалициягә бәйләнешле. *Ул Берлускони белән Берсанига, берләшеп, коалицион хөкүмәт төзергә киңәш бирә.* Шәһри Казан

**КОАЛИ́ЦИЯ** *и. лат. сәяси* Уртак максатларга ирешү өчен илләр, дәүләтләр арасында төзелгән килешү, берләшмә, союз. *Нугайлар Кырым ханы белән берлектә Мәскәүгә каршы сугыш ачмакчы булалар... Бу төрки илләрдә кяферләргә каршы билгеле бер коалиция төзү теләге туа.* Ф.Урманче

**КОБА** I *с.* Аксыл көрән, көрәнсу сары (хайван төсе тур.). *Коба сыер дигәне – безнең абзарда минем иң яраткан малым.* М.Кәрим. *Карап торган бер кыска аяклы, озын мөгезле, ак маңгайлы коба мөгезбикәне җигеп, алар утынга барырга җыендылар.* Д.Каюмова. *Коба бозау колынга иярә, тик аны куып җитә алмый, каерылып туктап кала.* М.Хуҗин

**КОБА** II *и иск.* Гадәттә түй буласы йортка тактадан матурлап эшләнгән капка

**КОБАГА** *и. диал.* Бәпкә таяна торган колакса башларына әйләндереп кагып чыгылган, махсус калын тактадан гыйбарәт җепсә (аның астыннан кәрниз башлана). *[Йорт салучылар], бәпкә утыртып, гәрничкә тотынган булганнар. Ләкин кобагасын гына сугып чыкканнар.* Х.Сарьян

**КОБАЕР** *и. башк.* Башкортларда гадәттә думбрага, сирәгрәк курайга

кушылып көйләп әйтелә торган кыска шигъри халык авыз иҗаты жанры. *[Урманов:] Син монда: «Ярлыларга таяныч, зарлыларга аяныч, яхшыларга шәфкать ул, явызларга дәһшәт ул», – дип, кобаер җырлап бирдең.* М.Кәрим. *Светлана Габдрахман кызы – районда гына түгел, республикада да билгеле кобаер иҗат итүче.* Кызыл таң. *Кобаер әйтү*

**КОБАЕРЧЫ** *и.* Кобаер әйтү остасы. *Башкорт хатын-кызлары җәмгыяте исеменнән котлаган, актрисаны ак инәй белән тиңләгән кобаерчы Розалия Солтангәрәеваның чыгышы --- аеруча мәгънәле булды.* Кызыл таң

**КОБА́ ҖЫРЫ** *и. этн.* Капка төбендә хуҗаларны мактау җыры. *Кодагыйга коба җыры.* Әйтем

**КОБА́ КЫЗЫЛ** *с.* Кызгылт көрән, көрәнсу җирән (хайван, кош-корт төсе тур.). *Коба кызыл чебеш. Коба кызыл көчек*

**КО́БАЛЬТ** *и. нем.* **1.** 1) Техникада һәм медицинада кулланыла торган көмешсу кызгылт төсле каты металл. *Кобальт җитешмәү терлекләрнең үсешен тоткарлый.* Биология. *Санберрида марганец, кобальт, көмеш, селен матдәләре табылган.* Татарстан яшьләре

2) Составында шул металл булган куе зәңгәр буяу. *Кобальт белән буялган фарфор*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул металлдан эшләнгән. *Кобальт калай*

2) Куе зәңгәр төстәге. *Кобальт бизәк*

**КО́БАЛЬТЛЫ** *с.* Составында кобальт булган. *Кобальтлы буяулар. Кобальтлы руда*

**КОБА ТАЛ** *и. бот.* Талчалар семьялыгыннан кәүсәсе (чыбыгы) кызгылт көрән төстәге тал; мурт тал; *русчасы*: **ракита, ива ломкая**. *Уртадагы озын буйлы Ат җилкәле Кобогыл, Комга беткән [үскән] коба тал Корык сайлар Кобогыл.* Дастан

**КОБА́ ТУРЫ** *с.* Бөтен тәне кызгылт көрән яки көрәнсу җирән, ялы һәм койрыгы кап-кара төстәге (ат тур.). *Монда күк атлар да, акбүзләр дә, кара туры, коба турылар да.* Н.Фәттах

**КО́БЗА** *и. муз. төрки* Украин халкының борынгы кыллы уен коралы; украин думбрасы

**КОБЗАРЬ** *и. укр.* Кобзага яки бандурага кушылып, думалар яки тарихи җырлар башкаручы украин халык җырчысы. *Тарас Шевченко – Украинаның бөек кобзаре*

**КО́БРА** *и. порт. зоол.* Аспидлар семьялыгыннан Африка һәм Көньяк Азиядә таралган бик агулы елан; күзлекле елан. *Кобралар куркыныч килгәндә гәүдәсенең алгы өлешен күтәреп, муеннарын киңәйтәләр: капюшон барлыкка китерәләр.* Зоология

**КОБУРА** *и. төрки* Пистолет, револьвер һ.б.ш. футляры. *Әти абыйны шул дәрәҗәдә тиргәде ки, моның «кобура, агач алтатар асып» кына түгел, гомумән сугышлы уеннарда катнашу теләге җилгә очты.* Р.Әмирхан. – *Ант ит! Алдашсаң атам! – ул билендәге наган кобурасына сугып куйды.* М.Кәрим

**КОБЫЗ** *и. к.* **кубыз**

**КОВБОЙ** *и. ингл.* Төньяк Америка далаларында атлы көтүче. *Анда ерак прериялардәге ковбой гитарасы чакыруларының кайтавазы һәм төнге паровозның ямансу сызгырулары ишетелә бугай.* Ә.Баян. *Ул гел америка ковбойларын хәтерләтте.* З.Кадыйрова

**КОВБО́ЙКА** *и. рус* Махсус өлге белән тегелгән шакмаклы ирләр күлмәге

**КОВЕРКОТ** *и. ингл.* **1.** Тышкы киемнәр тегүдә кием тышлыгы өчен кулланыла торган тыгыз тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Коверкот пальто. Коверкот костюм*

**КО́ДА** *и. ит.* 1) *муз.* Музыкаль пьесаның йомгаклау өлеше

2) *әд.* Сонет, рондо һ.б.ш. кебек поэтик жанрларга өстәп, кушып язылган тотрыклы формадагы шигырь юлы

**КОДА́** *и. монг.* 1) Өйләнешкән кыз белән егетнең, ир белән хатынның аталары һәм ир туганнары (бер-берсенә һәм башка туганнарына карата). *Иң элек кодаларның ашларын, туй күчтәнәчләрен мәҗлескә чыгарып күрсәтеләр ---. – Менә бусы Әфтах коданыкы.* Г.Ибраһимов. *Бу туй буласы йорт – җиңгәчәйнең әтиләре, ягъни кода бабайлар йорты. Кода бабайның өстендә ике генә сәдәпле ап-ак күлмәк, кара камзул.* Ә.Еники. *Тегенең «кода» дип эндәшүе бушка түгел иде. Баллыбанат ягыннан кайсыдыр кодаларына кода туры килә.* М.Кәрим

2) Өйләнәсе егет ягыннан кыз яучыларга барган ир кеше. *Кодалар килде капкага, кыз утырды кабага.* Мәкаль

**КОДА́ БӘЛЕШЕ** *и. этн.* Туй мәҗлесенең азагында чыгарыла торган бәлеш

**КОДАГЫЙ** *и. монг.* Өйләнешкән кыз белән егетнең, ир белән хатынның анасы яки өлкән хатын-кыз туганы (бер-берсенә һәм башка туганнарына карата). *Никях мәҗлесе дә шактый салкын үтте. Кодалар, кодагыйларны сыйлау да күркәм үтмәде.* Г.Исхакый. *Фәтхия кодагый белән Хәерниса кодагый, бу турыда сүз берләшкән кебек, бер уңайдан, бер якка таба сөрделәр.* Г.Ибраһимов. *Ә кыскасы шул: кодагыйлар бер-берсен ошаттылар, ошатмасалар, бергә кара-каршы утырып ике самавырны екканчы чәй эчә алмаслар иде!* А.Гыйләҗев

◊ **Кодагый ашы белән кунак сыйлау** Кеше сые, кеше күчтәнәче хисабына кемне дә булса сыйлау

**КОДА-КОДАГЫЙ** *җый. и.* 1) Кода белән кодагый һәм шуларга тиң булган кешеләр. *Берьюлы йомшарып киткән Фәтхия, үзенең мәҗлескә чакырылмаган кода-кодагыйлары өчен дип, бер ашъяулыкка пешкән итләр, кисәкле бәлешләр сала башлаган иде.* Г.Ибраһимов. *Ә кода-кодагыйларның шатланулары...* Г.Галиева. *Кияү белән кәләшне, яңа кода-кодагыйларны ашка алдылар.* Н.Көбәш

2) *күч. к.* **кода-кодагыйлык** (*2 мәгъ.*) *Әдәбият мәйданында кода-кодагый, дус-дошман дигән әйберне белми идек.* Э.Шәрифуллина

**КОДА-КОДАГЫЙЛЫК** *и.* 1) Кода һәм кодагый мөнәсәбәтендә булу хәле. *Батталлар токымы мин үскән авылдан күченеп киткән, әби-бабалар кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләрен өзмәгәннәр.* Л.Хәмидуллин

2) *күч.* Хезмәт урыныннан файдаланып, кардәш-ыруны, бер-береңне яклау күренеше, әшнәлек. *Сиңа иң якын торган ага-эне, туган-тумачаларың? Дус-ишләрең? Алар турында язу,*

*ничектер, үзенә күрә кода-кодагыйлык шикелле ярамый торган эш исәпләнгән.* М.Әмир. *Горком ягыннан торсаң, Вил үчләнәчәк, ә Вилне араласаң, горком кода-кодагыйлык, диячәк.* Х.Камалов. *Китте кода-кодагыйлык, энкечелек. Кем ничек булдыра, шулай таларга, йолкырга керештеләр.* Казан утлары

**КОДА-КОДАЧАЛЫК** *җый. и.* Кода һәм кодача мөнәсәбәтендә булу хәле. *Ул катлаулар һәртөрле туган-тумачалык, кода-кодачалык, уртак иман җепләре белән бер-берсенә нык итеп бәйләнеп беткәннәр.* М.Әмир

**КОДАЛАШУ** *ф.* 1) Бер-берсенә кода булып китү, кодалык мөнәсәбәтләренә керү. *Никахны 1921 елның гыйнварында җомга көн укыйлар, ике арада кунакка йөрешәләр, нәсел-нәсәп кодалаша.* Р.Әмирхан. *Яшьләр бер-берсен ошата. Никах, туй, кодалашу кебек йолалар үз тәртибе белән гамәлгә ашырыла.* Казан утлары

2) *күч. сөйл.* Берәр нәрсә белән артык мавыгып китү. *– Бабакай акбашлы белән кодалашты, имеш. Каян килгән изге кош! – дип пыр туздым.* З.Вәли

**Кодалашып бетү** Бөтенләй кодалашу, бөтенләй кодалашкан хәлгә килү

**Кодалашып калу** Берәр вакыйга булганчы кодалашкан хәлгә килү. *Алар исән вакытта кодалашып калдылар*

**Кодалашып кую** Алдан килешеп кодалашу

**КОДАЛА́У** *ф.* 1) Кыз сорату, яучылау. *Яшь киленгә шулчаклы ягымлы булып кыланды. --- Кыз баланы кемгә кодалаганын белә торып әйтмәгән, алдаган.* Ж.Тәрҗеман. *Кызны кодаларга барган ардаклы-хөрмәтле кешенең малае адәм ишетеп, адәм ышанмас явызлык кылды.* Ф.Мансуров

2) *этн.* Зур туй үткәч, махсус чакыру белән кияүнең ата-анасына кунакка бару

3) *күч. сөйл.* Нинди дә булса эш эшләргә үгетләү, кыстау. *Мәрхүм Хәсән Сарьян белән Җаманаклының 60 еллык юбилеена килгәч, мине эшкә башта ул кодалады.* Т.Галиуллин. *[Кави:] Кырык җиргә тарткалыйлар әле Гаязны. Гандәлиф РТСка ди, Сәйдәшев үзенә кодалый – төзелешкә.* Х.Сарьян. *Егетләрне җыеп, хәрби хезмәт турында әңгәмә үткәрә, булачак укытучыларны гаскәри тормышка кодалый.* Мәдәни җомга

**Кодалап йөрү** Күптәннән бирле кодалау; *этн.* зур туй үткәннән соң, махсус чакыру буенча, егетнең ата-анасына кунакка бару

**Кодалап карау** Булу-булмавын тикшерер өчен кодалау

**Кодалап тору** Кодалау юлында булу; кодалау эшен башкару

**Кодалый башлау** Кодаларга тотыну. *Мин дә бит әле сине үземә кодалый башламадым!* Р.Гаязетдин

**КОДАЛЫЙ** *рәв. диал.* Кода итеп, кода булып. *Туй үткәннән соң, каракаршы кодалый йөрешү. Кодалый килү*

**КОДАЛЫК** *и.* 1) Яучылык вазифасын үтәү, яучы булу. *Яше, карты, бүз баласы үләң, җыр әйтеп --- ике ыруг кодалыкка кул бирештеләр.* Г.Ибраһимов

2) Кода (*1 мәгъ.*) булу. *Ул Нурый белән Челем бабай арасында алай мәҗлескә чакырышып кодалык күрсәтү кебек хәлләрнең була алмавын ачык белә иде.* Г.Ибраһимов. *Ләкин аралашып яшәмәгәч, әлеге кодалык куян шулпасының шулпасыннан да сыеграк иде: ни тәме, ни төсе.* М.Кәрим

3) *диал.* Якын кода-кодагыйлар катнашында уздырыла торган мәҗлес

4) *күч. к.* **кода-кодагыйлык** (*2 мәгъ.*). *Боларның нәселләре әшнәлек-кодалык, блат белән яшәргә күнекмәгән иде.* Казан утлары

**КОДА́ ТӨШЕРҮ** *и. этн.* Зур туй узгач, кызның эти-әниләрен махсус кунакка чакыру

**КОДАЧА** *и. монг.* 1) Өйләнешкән кыз белән егетнең яки ир белән хатынның икенче якның ата-анасы һәм туганнарына карата кече хатын-кыз туганнар һәм аларга эндәшә торган сүз. *Хәзрәт, өйгә кайтышлый Әхмәттән Миңсылу кодачаның үзләрендә иканлеген ишеткәч, эшләпәсен бераз кыңгырайтып, купшылап куйды.* Ф.Әмирхан. *Бикъяр кодачаларыннан Хәернисаның Гөлбануга күңеле бик ятып киткән иде... Түзмәде, Фәтхия әбигә йөгереп барып, Хәерниса кодача белән Гөлбану арасындагы дуслыкны сөйләде.* Г.Ибраһимов. *Тагын бик куанышып безнең тирәдә бөтерелүче ике җиткән кыз – җиңәчәйнең сеңелләре – миңа кодачалар. Шушы кодачаларның кайсындыр кияүгә бирәләр – менә шуның туе булачак инде.* Ә.Еники

2) *диал.* Кызны кияү йортына озата баручы кызларның берсе. *Безгә кодачалар килгәннәр. Барысы да постау кигәннәр.* Җыр

◊ **Кодача булып утыру** Назланып, тәкәллефләнеп утыручы хатын-кызга карата әйтелә

**КОДАЧАЛЫЙ** *рәв. диал. сөйл.* Кодача булып

**КОДЕИН** *и. гр. фарм.* Авыртуны, ютәлне туктату өчен кулланыла торган кристаллсыман ак порошок; әфьюн мәгендә була торган алкалоид. *Кодеинны озак куллану наркоманлыкка китерә.* Биология

**КО́ДЕКС** *и. лат. махс.* 1) Билгеле бер өлкәгә карый торган законнарның системалаштырылган җыентыгы. *Гражданлык кодексы. Җинаять кодексы*

2) Кешенең җәмгыятьтә, тормышта үз-үзен тоту кагыйдәләре. *Шагыйрь [Сәйф Сараи] кеше гомеренең төрле яшенә яраклы акыллы гамәл һәм яшәү рәвешенең үзенә күрә бер кодексын эшләгән.* И.Хисамов

**КОДРӘТ** *и. гар.* 1) Зур, хәлиткеч көч. *Җыеп әйткәндә, татар мәдәни тормышында берникадәр җанланыш – «ренессанс чоры» шәйләнә. Кем кодрәте белән эшләнә бу борылыш – бу хакта әле берни дә белмибез диярлек.* А.Гыйләҗев. *Изге карт серле генә итеп җавап кайтара: «Я, әйтегез телләкләрегезне. Теләгәнегезне булдырырга минем кодрәтем бар».* И.Туктар. *Көчхәл белән, ниндидер серле могҗиза кодрәте белән исән калган биналарның шәүләләре. Сезнең барыгыз да минем күз алдымда.* М.Юныс

2) Сәләт, маһият, маһирлык. *Һәм, иң әһәмиятлесе, туристлар бюросында эшләүче агасы аркылы теләсә нинди дефицит язмаларны табу кодрәтенә ия.* А.Сафин. *Мине бу рәвешле яратучы Алланың кодрәтедер.* М.Гафури. *Калган өч йөз илле шәкертнең җылы аш ашарлык кодрәтләре булмаса да,*

*Нәбине санларга барыбер мәҗбүрләр иде.* К.Тинчурин

3) Булдыра алу, мөмкинлек. *Торма беркемдә юк, базарында бер! Бер сум тек бер сум! Базар бәяне үзе билгели, кодрәте зур.* А.Гыйләҗев. *Урамда буран. Гүяки җир йөзен генә түгел, кешеләрнең күңелләрен дә пакьләндерергә тели сыман. Әмма кодрәте генә җитми.* Ф.Яхин. *Алты дистәне алыштырган булуына карамастан, ул төз, җыйнак гәүдәсен дә, шәраб кодрәте белән бил алышырлык көчен дә саклаган.* Т.Галиуллин

4) Үзенә нык җәлеп итә торган көч, тәэсир, йогынты. *Бердән алар җырга йотылдылар, бары бер кодрәткә – бер исерткеч тойгыга буйсынган шикелле җырчыдан күзләрен аера алмыйча, аның һәр сүзен аңлап утырдылар.* Ә.Еники. *Ихтимал, Тимерхан морзаның кодрәтен, җанны сафландыра, күңелләргә пакьлек өсти ала торган куәсен шунда аңлагандыр.* Г.Ахунов

5) *күч.* Авторитет, дәрәҗә, абруй. *Шулай да әбинең кодрәте белән дәрәҗәсе искитмәле иде. Уллары-кызлары аның белән киңәшмичә бер генә зур эш тә кузгатмый диярлек.* Г.Бәширов

◊ **Кодрәт хәлвәсе** *дини* Мисырдан чыгып кырык ел чүлдә йөргән чакта Муса пәйгамбәрнең кавеменә күктән иңдерелгән ашамлык; мән; *русчасы:* **манна небесная**

**КОДРӘТЛЕ** *с.* 1) Зур кодрәткә, куәткә ия булган, көчле. *Ул [Мөхәммәд пәйгамбәр] кодрәтле Аллаһы бер генә, башка аллалар юк дип раслый, ә үзен Алла илчесе – аның пәйгамбәре дип атый.* Урта гасырлар тарихы. *Бу чорда, чыннан да, Византия яки Көнчыгыш Рим империясе кодрәтле һәм гаять зур дәүләт була.* Г.Дәүләтшин. *Шул чорларның иң кодрәтле хөкемдары Аксак Тимер һәм аның варисларының империясе белән Идегәй тыгыз, ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштырган.* Мирас

2) Егәрле, эш-хәрәкәт башкару сәләте зур булган. *Ниһаять, кече баҗа суд алдына баса. Шундый кодрәтле баҗасы булгач, ул үзен судта бик батыр тота.* Ә.Еники. *Сугышка кадәр ул районда бик кодрәтле райком секретаре эшләгән булган.* Мәдәни җомга

3) Тирән эз калдыра торган, мөһим, җитди. *Декларациянең кәгазь кисәге генә түгел, тормышыбызны үзгәртерлек кодрәтле көч – закон булуы кирәк.* Ә.Рәшит

**КОДРӘТЛЕЛЕК** *и.* Кодрәтле булу; кодрәт. *Мәгълүм булганча, ислам, кайбер башка диннәр кебек, рухи тормыш эшчәнлеген, идеологияне, мәдәниятне үз тәгълиматы белән шактый дәрәҗәдә яраклаштыра, шуның нәтиҗәсендә, этник, региональ аерымлыкларга карамастан, нигез төшенчәләр, моментлар туа (Алланың берлеге һәм кодрәтлелеге, тәмуг-җәннәт төшенчәләре һ.б.).* Мирас. *Моңа чаклы ул [патша] үзен җиңелмәс зат дип йөрде. Тиңсез кодрәтлелеге белән горурланды.* Н.Сәйяр

**КОДЫК** *и. диал.* Кое. *Төкермә кодыкка – үзең эчәрсең.* Мәкаль. *Колан кодыкка егылса, кыр бакасы колагына чыга имеш.* Мәкаль. *Икенче көнне киччә таба кодык янына тагын бер кәрван килеп туктады.* М.Галәү

◊ **Кодыкка җиткәнче кода** Үзенә кирәккәндә дуслык күрсәтеп, соңыннан оныта торган кеше

**КОДЫКХАНӘ** *и. иск.* Коелы бүлмә, бина. *Мондый кодыкханә, мәсәлән, Хуҗа Әхмәд Ясәви төрбәсендә бар.* А.Тимергалин

**КОДЫКЧЫ** *и. тар.* Сусыз җирләрдә су таба белүче. *Коралчыга ышанып юлга чыкма, кодыкчыга ышанып чүлгә чыкма.* Мәкаль

**КОЕ** *и.* 1) Җир астындагы сулы катламнан су алу өчен казылган тар һәм тирән чокыр. *Ул нефтьчеләрне яллап бакчасына кое ясатты, су аңа үзе килә.* М.Мәһдиев. *Сәләхетдиннән күрмәкче, алар да бакчага тирән кое казыдылар, коега да водопровод суы тутыралар.* А.Гыйләҗев. *Кое төбеннән караганда, йолдызлар көндез дә күренә имеш... Бу, әлбәттә, дөрес түгел.* А.Тимергалин

2) Төрле техник максатлар өчен казылган тирән чокыр, скважина. *Вахит, Гаделнең анасы белән бергә, якын-тирәдә пар бөркеп торган җылылык коеларын тикшерергә кереште.* Г.Гыйльманов. *Иң буталчык чорда Татарстан хөкүмәте, табышсыз эшләүче скважиналарга салымны бетереп, меңнәрчә нефть коеларын ябылудан саклап калды.* Ватаным Татарстан

◊ **Кое казу** Кешегә яманлык, начарлык эшләргә йөрү. *Кешегә кое казысаң, үзең буе казы.* Мәкаль. **Кое казып, үзе төшкән** Кешегә яманлык теләп, үзе бәлагә тарыган, үзе хур булган

**КОЕЛДЫК** *и.* Артык өлгерү, җилдавыл һ.б.ш. сәбәпләр аркасында коелган җиләк-җимеш, орлык. *Кырдагы иген коелдыгы зарарлы: аңа һәртөрле иген корты ияләшә.* Г.Хәсәнов

**КОЕЛМА** *и.* **1.** Махсус калыпка коелып ясалган әйбер. *Үзәк банкның җиде кат җир астында дип әйтелешле сейфларыннан миллион пизарралык алтын коелмалар алып чыгу үзе генә дә ни тора!* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Коелып эшләнгән. *Аннары ул [ышаныч хисе] бербөтен чуен коелма һәйкәлдәй гел мәгърур, гел буй җитмәс нәрсә түгел.* Ш.Рәкыйпов

**КОЕЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кою**

2) Үскән җиреннән күпләп йолкынып, өзелеп төшеп тору. *Алма чәчәге коела Таңда искән җил белән.* Җыр. *Җил исте, агачлар чайкалып китте, җиргә сары яфраклар коелды.* И.Салахов. *Әгәр дә мондый җәйланмалар булмаса, орлыклар, үзләрен үстергән үсемлекләр янына гына коелып, уңайсыз шартларда үсәрләр иде.* Е.Веселов

3) Бик вак кисәкләргә аерылып төшү, күпләп чәчелү, сибелү. *Кайдадыр пыяла коелды, түбә калайлары кызганыч тавыш белән чыңлап куйдылар.* А.Тимергалин. *Бүген әзрәк суытып җибәргәнгә, кояшлы һавадан вак-вак энҗе кебек ак кар чаткылары коела. Әйе, яумый, ә коела иде.* Г.Әпсәләмов. *Җир белән күк бер булып дерелди, блиндаж стеналарыннан балчык коела иде.* М.Мәһдиев

4) Табигый урыныннан кубып чыгу, күпләп төшү (теш тур.). *Гаиләсе, ике баласы бар, эшләми, хәле эшләрлек түгел, тешләре коела.* Ф.Бәйрәмова. *Үзем кебек картайган этемә шәһәрдән сөт ташыйм, тешләре коелган, ботка пешерәм.* Н.Гыйматдинова

5) Берәр урыннан туктаусыз агып тору, таму, яву (сыеклыклар, күз яше, яңгыр һ.б. тур.). *Бөртек-бөртек яшьләр коелды. Йөрәк әрнеде, күңел сыкрады.* Г.Исхакый. *Рухымның әллә кайчаннан бирле эзләп тә таба алмый йөргән теләге шул вакытта, шул караңгы төндә өзлексез коелган вак яңгырның шыбырдавы астында табылгандай тоела.* Г.Ибраһимов. *Мең елларга сузылган яулап алулар, буйсынулар, күз яшьләре, җиргә коелган, җирдә елга булып аккан каннар, зиндан газаплары...* Мирас

6) Мул булып бөркелү, җәелү (яктылык, нур һ.б.ш. тур.). *Өй каршындагы ак каеннарның бөдрә тармакларыннан мөлдерәп торган яшел нурлар коела.* Р.Мөхәммәдиев. *Август, матур вакыт. Төнге күктән йолдызлар коела торган вакыт.* Сөембикә

7) Коеп эшләнү. *Бакча капкасына каршы, көдрәләнеп үскән куаклар арасында чуен эскәмиядә җиздән коелган яшүсмер утырып тора иде.* Ш.Рәкыйпов. *Ачык муенында нечкә чылбырга беркетелгән, затлы металлдан коелган арслан башы ыржаеп тора.* Казан утлары // Корылу, төзелү, ясалу. *Аның тавык кермәслек итеп биек койма коелган бакчасы бар.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Каян да булса бер-бер артлы сикереп яки егылып төшү, төшеп калу (арбадан, чанадан һ.б.ш.). *Ак битле, елтыр күзле «чүлмәкләр» [малайлар] көлешә-көлешә чанадан коелдылар.* И.Гази. *Халык сискәнеп китте. Теге як халкы инешкә коелды: чыр-чу, елашкычкырыш.* М.Мәһдиев. *Кетәклектән, пырхылдашып, берәм-берәм тавыклар коелды.* Р.Мөхәммәдиев

9) *күч.* Яңгырап ишетелү. *Тургай җыры якты күк йөзеннән көмеш чыңнардай чылтыр-чылтыр коела иде.* Г.Бәширов. *Очып үтсеннәр иде алар [торналар] хәзер авыл өстеннән, дип телисең. Моңсу тавышлары яңадан җиргә коелсын иде.* А.Сафин

10) *күч.* Күпләп барлыкка килү, күпләп бирелү, әйтелү, яву (мәсьәләләр, тәкъдимнәр, сораулар). *Ул арада бу мактау сүзләре, кояшлы яңгыр кебек, көтмәгәндә генә минем өскә коела башлады.* Г.Бәширов

11) *күч.* Нинди дә булса эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә берәр төрле хәл хасил булу; берәр төрле халәт, күренеш барлыкка килү. *Аның [Галим абзыйның] таза-ныкъ тәненнән җитәрлек кадәр гайрәт, көч коелды. Ул шул гайрәт, көч аркасында, менә хәзер карт көнендә булса да, шулкадәр зур дәүләткә иреште.* Г.Исхакый

◊ **Коелып төшү** 1) Куркып китү, куркуга калу, өркү. *Рәшитнең әтисе, исе-акылы китеп, бер катка коелып төште.* А.Тимергалин. *Беркөн, бер дәрестә, институтны былтыр гына бетереп, беренче елын гына укыткан япь-яшь апага Фәйзәви үзенең мәкерле соравын бирмәсенме! Апабыз коелды да төште.* Х.Сарьян. *Коелып төшмәде Мирсәет, сездән курка торган күлмәк күптән тузган, дигән сыман, тәкъдим ителмәгән урындыкка ипле генә барып утырды.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Оялудан, уңайсызланудан һ.б.ш. сәбәпләрдән нишләргә белмәү, каушап, югалып калу. **Коелып иңү** *к.* **коелып төшү**. *Коелыплар иңде, мескенкәем, тиз генә кече якка кереп посты.* Ш.Маннур

**Коела бару** Торган саен ныграк коелу, бер-бер артлы коелу. *Юлда кайтканда, әнә шулай кыймылдый-кыймылдый, башаклар җиргә коела барганнар.* Р.Батулла. *Шул рәвешле, акрынлап оперативниклар күз уңаена эләккән гөнаһсыз бәндәләр «иләктән» коела бара, һәм анда бары ике кеше --- кала.* Мәдәни җомга

**Коела башлау** Коелырга тотыну. *Без, ачык авызлар, күгәрченнәрне күзәтәбез, ә күктән, искәрмәстән генә, парашютистлар коела башламасынмы!* Ф.Хөсни. *Бара-тора шуларның барысы берләшеп, зур, көчле, гөнаһсыз матур, нәзек бер хатын килеп басты, вә шуның авызыннан таза, батыр, матур музыка коела башлады.* Г.Исхакый. *Менә бервакыт арбадан көлтәләр коела башлый, колак төбендә җил сызгыра, як-якта нинди дер коры елга, чокырлар күзгә чалынып кала.* М.Галәү

**Коела тору** Һаман коелу, коелуын дәвам итү. *Яфраклар коела тора – себерә торалар.* Безнең гәҗит

**Коелып бару** *к.* **коела бару**. *Ул кагылып киткән ботаклардан җиргә тупыр-тупыр өлгергән алма коелып бара.* Р.Мөхәммәдиев. *Карасам, сурәттән миңа комы коелып бара торган бер адәм хәсрәт эчендә карап тора.* Ф.Яхин

**Коелып бетү** Бөтенләй, барысы да коелу; коелган хәлгә килү. *[Картның] тешләре коелып бетеп, эчкә батып калган авызының иреннәре калтырандылар.* Ф.Әмирхан. *Йорт уртасында, су эчендә утырган ялгыз карт каен әле һаман коелып бетәргә өлгермәгән ак-тык сирәк яфраклары белән кызганыч рәвештә шаулый башлый.* Г.Ибраһимов. *Талып кына калмады инде Бибинурның керфекләре, коелып бетте.* А.Гыйләҗев

**Коелып калу** Ниндидер бер вакыйгадан соң коелу. *Хатын --- яңа гына уянган, соңгы тапкыр ашаганда җәймәгә коелып калган икмәк валчыкларын чүпләп утырган баласына ишарәләде.* Г.Гобәй. *Чанадан печән коелып калган*

**Коелып китү** Кинәттән коелу; коелган хәлгә килү. *Бик көч берлән генә Шәүкәт: – Юк, – диде дә яше берлән коелып китте.* Г.Тукай. *Җил чыкты, агачлардан яфраклар коелып китте. Бара башлагач, кем ул, атам, дип әйтте дә, буыннарым коелып китте.* Һ.Такташ

**Коелып тору** Даими, регуляр рәвештә яки хәзер, әле коелу. *Ә җеннәр җимеш кортларыдай тупылдап коелып тора, коелып тора.* З.Мурсиев. *Түшәмендәге акшар кубып, идәнгә коелып тора.* Татарстан яшьләре

**КОЕЛЫК** *и. диал.* Суда бөтерелеп, кайнап ага торган урын; чоңгыл

**КОЕМ** *и.* Коеп ясалган металл әйбер

**КОЕМЧЫ** *и.* 1) Металлдан һ.б.ш. материаллардан коеп эшләнмәләр ясаучы

2) *тар.* Алтынчы, көмешче, зәргәр, ювелир. *Сөяркә тоткан коемчыга еш йөрер.* Мәкаль

**КОЕН** I *и. диал.* Коеп яуган көчле яңгыр. *Коеп коен койганда, коймадагы коелмадан коега коелдык коелды.* Р.Һади

**КОЕН** II *и. диал.* 1) Өерелеп өскә күтәрелгән көчле җил; өермә. *Коен эчендә калу*

2) Гадәттә, чүлләрдә була торган эссе һава өермәсе

**КОЕНДЫРУ** *ф.* 1) Суда юындыру. *Егет җырлый-җырлый мичкәсен чайкады, атын коендырды.* И.Туктар. *Бер-бер кардәш-кабилә кунакка килсә, ул бөтен гомерен шуларның баласы артыннан йөрергә сарыф итте: үзе йоклатты, үзе коендырды, үзе уйнатты.* Г.Исхакый

2) Кемнең дә булса өстенә шаулатып, күп итеп су кою. *Йөгердек өйләргә, алдык кем кечкенә чиләк, кем зур чүмеч, киттек чыгып очраган бер кешене коендырырга!* Г.Бәширов

3) Баштан аякка кадәр мул итеп юешләү, чылату

4) Баштанаяк пычрату, пычракка буяу. *Тузан --- ат аякларыннан, арба тәгәрмәчләреннән бөркелеп чыга да сине баштанаяк коендыра.* М.Гали

5) *күч.* Күп итеп бөркү, бөркелдерү. *Инде яз килгән, кояш җирне нурга коендыра.* Н.Дәүли

6) *күч.* Башлыча, исемнәр белән килгәндә, шул сүзләр белән белдергән эш-хәлнең берьюлы күп булып, интенсив башкарылуын белдерә. *Ул ярык, калын тавыш белән, уставта каралмаган зәһәр сүзләр белән безне коендыра.* А.Гыйләҗев. *--- кара айгыр сылу яшь атны көнче күз карашы белән коендырып, гайрәтле бер пошкыра да, матур сынын уйнатып, җилдәй очып кына узып китә.* Г.Бәширов

**Коендыра башлау** Коендырырга тотыну. *Басмачылар, һичтуктаусыз атып, Җаббар яшеренгән ташны пуля яңгырына коендыра башладылар.* Ш.Усманов. *Атларны буада коендыра башлау*

**Коендырып алу** Берара, кыска вакыт аралыгында коендыру

**Коендырып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә коендыру. *Баланы һәрвакыт коендырып тору*

**КОЕНУ** *ф.* 1) Су керү; суда йөзү. *Бүген көн буе эссе! Коенырга барырга бик шәп булыр иде.* Г.Исхакый. *Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм.* Г.Тукай

2) Баш аша үз-үзеңә су коеп юыну. *Юынып бетеп коенгач, икенче бүлмәгә чыктык.* И.Салахов. *Чишмә суы белән коену*

3) Юешләнү, чылану (мәс., яңгыр астында). *Рәхилә дә: «Тагын салкын суларда коенып, өшеп-туңып кайта инде», – дип уйлый-уйлый, әткәсенең аркасыннан сыйпап алды.* И.Туктар

4) *күч.* Нинди дә булса сибелеп, таралып тора торган әйбер эченә керү, күмелү. *Нигез туфрагында тавыклар коена.* И.Гази. *Юл тузанында, шапылдатып канат кага-кага, тавыклар коена.* М.Әмир // Нәрсә белән дә булса чолгап алыну, каплап алыну. *Урам яшеллеккә коенган*

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса кояш, ай һ.б.дан килгән яктылыкка, нурга чумуы, күмелү. *Күктә тулган ай, Бөтен авыл көмеш нурга коена.* М.Мәһдиев. *Таң нурлары чыкта коенган бер иртәдә тагы шул ук сукмак буйлап йөгереп киттем.* Р.Мөхәммәдиев. *Минем карап торуымны Китермидер уена, Йолдыз тулы күк-диңгездә Ай коена.* Л.Лерон

6) *күч.* Ләззәтләнү, рәхәтлек хисе кичерү, канәгатьлек алу. *Озак еллар дәвамында халык белән аралашып яшәргә өйрәнгән артист [Шәүкәт Биктимеров] ихтирам-хөрмәт нурларында коена.* Т.Галиуллин

**Коена башлау** Коенырга тотыну. *Олы кешеләр әйтә, күке тавышы ишетелә башлагач, аю да арт санын суга манчып ала. Шуннан соң безгә дә су коена башларга ярый икән.* Г.Бәширов

**Коенып алу** Берара (кыска вакыт аралыгында) коену. *Тирләүне басу өчен коенып алдык.* Г.Ибраһимов. *Кайберәүләр хәзер үк төнге диңгезне карарга барырга, хәтта су коенып алырга тәкъдим итеп карасалар да, Ләйлә белән Дилә каршы төштеләр.* Г.Тарханова. *Бераз яр буендагы куш каен ышыгында юангач, Сәйдә су коенып алырга булды.* Г.Гыйльманов

**Коенып тору** Даими яки регуляр рәвештә коену

**Коенып яту** *сөйл.* Сөйләм моментында, хәзер коену эшендә булу. *Без, узып барышлый, шул тузанда коенып яткан куян сыман берничә нәрсә очраттык.* А.Тимергалин. *Энем Госман белән су коенып яткан чакта, урман юлыннан бер җиңел машина килеп чыкты.* Җ.Юныс

**КОЕШ** *и.* Кою эше, кою хәле. *Кан коеш*

**КОЕШКАН** *и.* Иярне атның койрык төбенә таба тартып беркетә торган махсус бау, каеш. *Өзәңгесе өзмә алтын, Коешканы койма алтын, Нукталары сум алтын, Азулары бер карыш Аргымаклар бауда катты ла.* Дастан

**КОЖАН** *и. рус* Күн, брезент, клеёнка кебек су үткәрми торган материаллардан тегелгән плащ яки пальто. *Паларусов балавызлы киндер кожанын --- [чөйгә] элде.* Г.Ибраһимов. *Утыздан узган, кырыкка җитмәгән Дилә сылу гәүдәле, --- иңе нык, тәнгә тыгыз иде. Өстенә бишмәт кисә дә, кожан бөркәнсә дә, биле уелып торыр.* К.Кәримов. – *Әллә яңгыр һаман да ява-мы? – диде ул Шәмгун картның чыланган кожанын күреп алып.* А.Шамов

**КО́ЖАНКА** *и. рус сөйл. к.* **кожан**. *Берзаман, төн уртасында, --- өйгә күн кием (кожанка) кигән, --- кулларына маузерлар тоткан матрослар төркеме бәреп керә.* Р.Әмирхан

**КОЖИМИТ** *и. рус махс.* Ясалма күн

**КОЗА́У** *и.* Каездан, кайрыдан эшләнгән тартма яисә тырыс. *[Төлке:] Койрыгыма козау бәйләп, бәкегә тыгып тордым да, балыклар үзләре козауга кереп тулдылар.* Әкият. *Козауга җиләк җыю*

**КОЗГЫН** *и.* 1) Каргасыманнар семьялыгыннан каракучкыл каурыйлы, көчле томшыклы, аулак урыннарга оя ясый торган зур ерткыч кош. *Ике козгын сугышканда карга тук була.* Мәкаль. *Козгын чукый-чукый да ял итә.* Р.Батулла

2) *күч.* Ертлач, бик әрсез кеше. *[Алтынбай] арбадагыларның һәммәсенә ишетелерлек итеп: – Ни эшләп йөри монда бу козгын? – диде дә, үзе сикереп төшеп, шул чалмага таба йөгерде.* Г.Ибраһимов. *[Шәрифә:] – Миңа ул байгура ошамый. Бирмә, ташлама шул козгынның тырнагына, – дип пышылдады.* Ф.Яхин

**КОЗГЫНЛЫК** *и. сөйл.* 1) Ертлачлык, табыш күзәтү гадәте

2) *күч. сөйл.* Комсызлык, ачкүзлелек. *Аның козгынлыгы күпләргә билгеле*

**КОЗЫК** *и. диал.* Эрбет чикләвеге

**КОЗЫРЁК** *и. рус* Баш киемендә (бүрек, картуз, фуражка һ.б.ларда) маңгай өстенә очлаеп чыга торган ярымтүгәрәк чыгынты. *Дежур унтер-офицер Камәров каршысына килеп кулын козырёгына куйды.* А.Таһиров. *Заманына күрә модасына туры китереп куелган зур козырёгы озынаеп алга чыгып тора.* М.Әмир

**КОЗЫРЁКЛА́У** *ф.* **1.** Хәрби хезмәткәрләр арасында уң кулны баш киеменең чигә ягына күтәреп сәламләү

**2. козырёклап** *рәв. мәгъ.* Маңгай өстенә очлайтып чыгарып, козырёксыман итеп. *– Сөт ярата ул, сөт эчертерсең яме, кызым, – дип киңәш бирде яулыгын козырёклап бәйләгән рус карчыгы.* Г.Ахунов

**КО́ЗЫРЬ** *и.* 1) Ишек яки капка өстендәге япма, каплау; кузыр

2) Карта уены барышында иң зур саналган һәм теләсә кайсы картаны баса, яба ала торган карта төре. *– Козырь – капут! – диде генерал. – Мин пас инде! – диде адмирал.* Х.Туфан. *Козырь белән ябу. Козырь тузы белән йөрү*

3) *күч.* Бәхәстә көчле дәлил, көрәштә хәлиткеч фактор, чара

**КОЙГЫН** *и.* Коеп яуган яңгыр

**КОЙКА́** *и. кулин.* 1) Сугымның башаягының йомшак өлешләрен, шулай ук кимерчәкләрен озак кайнатып, төрле тәмләткечләр салып әзерләнә торган салкын ашамлык. *Койка әзерләү өчен, җилем матдәсенә бай баш-аяк ите алалар. Койка янына керән яисә горчица куялар.* Татар халык ашлары

2) *күч.* Беркадәр үтә күренмәле сыеклык сыман масса. *Әгәр дә шундый массаны саркытсаң, койка яки желе ясарга була.* Н.Верзилин

◊ **Койка баш** Чәчсез, пеләш башлы кешегә карата әйтелә

**КО́ЙКА** *и. рус* Бер яки ике кешелек гади төзелешле ятак. *«Татарстан» гостиницасының алты кешелек бүлмәсеннән койка алып урнашкач, --- Акком астына Җиһан дигән бер хатынны эзләп китте.* Ә.Еники. *Абый быел кышны больницаның салкын койкаларында үткәреп кайтты, инде кайчан күрешә алырбыз?..* Х.Сарьян. *Рушаниянең басып торыр хәле калмады ---, ишек төбендәге беренче койка башына ябышты.* З.Кадыйрова

**КОЙКАЛАНУ** *ф.* Койка рәвешенә керү, койка рәвешен алу. *Койкаланган масса. Кызыл карлыган желесы койкаланган*

**Койкалана бару** Торган саен ныграк койкалану. *Салкын урынга куйгач, куе шулпа койкалана бара*

**Койкаланып бетү** Тәмам койкаланган хәлгә килү. *Шулпа койкаланып бетте*

**Койкаланып җитү** Тиешле дәрәҗәгә килеп койкалану

**Койкаланып килү** *к.* **койкалана бару**

**КОЙКАЛЫК** *с.* **1.** Койка пешерү өчен әзерләнгән яисә шуның өчен яраклы. *Койкалык сыер баш-аягы*

**2.** *и. мәгъ.* Койка ясау өчен әзерләнгән шулпа

**КОЙКАСЫМАН** *с.* Койкага охшаш. *Тартылган лишайникны бер-ике сәгать буе кайнатсаң, ул --- әз генә гөмбә исе килеп торган койкасыман массага әйләнә.* Биология

**КОЙМА** I *и.* Нәрсәнедер уратып алган корылма; тоташ итеп ясалган киртә. *Барса, ике абый икесе дә урам якка койма коеп яталар.* Х.Сарьян. *Анда, дип әйтә, ди, тау өстендә дүрт почмаклы таш койма бар, имеш, --- бу койма эчендә тагы шундый бер таш койма бар, имеш...* Г.Ибраһимов. *Койма янына да барып килдем. Бүрәнә дип әйтерлек кыртыш такталардан тезгән бу койма борынгы шәһәр ныгытмаларын хәтерләтә.* А.Тимергалин

◊ **Койма колак** Әйткәнне аңлап, дикъкать белән тыңлый белүче кеше. *Койма колакка әйтсәң, коеп алыр.* Мәкаль

**КОЙМА** II *с.* Коеп ява торган, бик көчле. *Төньяк Сахалинда койма яңгырлар башланды.* Ә.Маликов

**КОЙМАК** *и.* 1) *кулин.* Сыек камырны кызган табага коеп, юка итеп пешерелгән ашамлык. *Ферма кызлары белән Гаҗилә җиңги көне буе өендә каз йолыкты, каз коймагы пешерде.* М.Мәһдиев. *Бакчадагы әлеге кечкенә өстәлдә майлы коймак белән ашык-пошык кына чәй эчтек.* Ә.Еники. *Төче коймак. Тары коймагы*

2) *сөйл.* Су өстендә хасил булган түгәрәк майлы (мазутлы) таплар. *Малай су өстендәге аллы-гөлле нефть «коймаклары»на карады.* И.Гази

3) *сөйл.* Су өстеннән яссы ташны чәпчетеп аткан вакытта барлыкка килгән вак дулкын боҗралары

◊ **Коймак ашау** Атылган яссы ташның су өстеннән, вак түгәрәк дулкыннар хасил итеп, берникадәр сикереп баруы турында. *[Морат:] – Аннан суга таш атып уйнадык, – диде. --- Ә, әйе, малайлар белән су керергә килгәч, Зифа апа да бар иде. Ул да атты. Аныкы коймак ашады, безнеке ашамады.* Г.Гобәй. **Коймак кою** 1) Коймак пешерү. *Тагын чәпчер инде дисәм, әни һич тә шау-шу күтәрмәде, хәтта коймак коеп, --- күрше хатыннарын чәйгә дә чакырды.* И.Салахов; 2) *к.* **коймак ашау**. *Юка гына шома ташны ыргытып җибәрәм, әллә ничә кат суга чәпәп очырам тегеңә. Ничә чәпәтсәң, шулкадәр «коймак» коясың.* Г.Якупова

**КОЙМА́К-КОЙМАК** *с.* Коймак формасын алган, шундый формада булган, түм-түгәрәк. *Кибетче Әсмабикәнең коймак-коймак битләре уртасына урнашкан песи борыны астындагы уймак авызы да елмайды.* А.Гыйләҗев

**КОЙМАКЛЫК** *с.* Коймак пешерергә билгеләнгән, коймак пешерергә җитәрлек. *Бер коймаклык он иләү*

**КОЙМАЛА́У** *ф.* Нәрсәне дә булса койма белән урату, әйләндереп алу, койма тоту. *Яшелчә бакчасын коймалау*

**Коймалап алу** Тиз арада коймаланган хәлгә китерү. *Йорт тирәсен коймалап алу*

**Коймалап бетерү** Бөтенләй коймалау, коймаланган хәлгә китерү

**Коймалап кую** Коймаланган хәлгә китерү. *– Бергәләшеп аның тирә-ягын коймалап куясы, матур итеп агачлар утыртасы гына калды, – ди Рамил Вәли улы.* Кызыл таң

**Коймалап чыгу** Бар яктан да коймалау

**КОЙНЕ** *и. гр.* Кардәш шивәләр катнашу нигезендә барлыкка килгән һәм шул шивә вәкилләре өчен аңлаешлы булган уртак тел. *Безнең тарихыбызга татар-кыпчак койнесы, төрки-болгар*

*койнесы билгеле.* А.Тимергалин. *Җыеп әйткәндә, Чүгүчәк һәм Алтайларда, бигрәк тә Голҗада үзенә күрә бер махсус төркичә сөйләш – койне барлыкка килгән иде.* М.Усманов

**КОЙРЫК** *и.* 1) Хайван гәүдәсенең төп өлешеннән артка чыгып торган хәрәкәтчән озынча үсенте. *Әгәр эзәрлекләүче хайван кәлтәне койрыгыннан эләктерә алса, кәлтә койрыгының бер өлешен өзеп кача.* Биология. *Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан --- койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган.* Г.Ибраһимов. *Акмаңгай кара борынын ботинкама тидереп алды да, койрыгын болгап дуслыгын белдергәч, ишек катына барып ятты.* А.Тимергалин // Кошларда гәүдәнең арткы өлешендә урнашкан бер учма каурыйлар. *Тукранның койрыгы да гәүдәгә терәк хезмәтен үти: койрыгының сыгылмалы каты каурыйлары белән ул агач кәүсәсенә бик нык терәлеп тора.* Зоология. *Әтәч койрыгы. Саескан койрыгы*

2) Төрле корылмаларның очлаеп торган арткы өлеше. *Автобус борын төпләреннән үк үтеп китмәсә дә, һәрхәлдә, болар аның «койрыгын» гына күреп калганнар, имеш.* Ф.Хөсни. *Корабның борт әйләнәсе чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган, койрык якта бер мәйданчык эшләнгән.* И.Салахов. *Ханым, --- палуба рәшәткәсенә таянып, койрыкта баручыларны күзәтергә кереште.* Ә.Еники. *Озын койрык булып сузылган вагоннарны сөйрәгән поездлар станциягә килеп-китеп кенә торалар.* С.Рафиков

3) Тәртип белән тезелгән сафларның соңгылары, ахыргылары. *Бер... ике... дүрт... биш. Койрыктан бишенче вагон. Нуруллин бишенче вагонга ук барып җитә алмас.* А.Шамов. *Көннең нәкъ менә шушы вакытларында биредә чират күп була. Без дә озын койрыкның артына килеп бастык.* Л.Ихсанова. *– Нәрсә бирәләр? – Шәһәр хатын-кызы моны чиратның койрыгына килеп басып, алдагы һәм үзеннән соң килеп баскан арттагы кеше белән «визуаль» контакт урнаштыргач --- кына сорый.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Чират. *Төшсәм, тукталышта бер такси да юк, җиңенә кызыл бәйләгән дежур кыз бар да, такси көтеп торучы байтак кына озын «койрык» бар.* Ф.Хөсни

5) *күч. сөйл.* Арттан калмый ияреп йөргән кеше. *Көн кичкә авышкач, Жан поездан төште. «Койрык» тагылмасын өчен, станция тирәсендә йөрештергәләгәч, Налибока урманына таба юнәлде.* Ш.Рәкыйпов

6) *күч. кимс.* Иярчен; куштан, ялагай кеше. *Һәрбер имам бездә койрык булган чакта, Койрык сүзе безгә бойрык булган чакта, --- Чыкты ахыр бездән дә бер бөтен кеше. Яхшы аңлап, тәкъдим итү читен кеше.* Г.Тукай. *Мифтах белән Гобәй – барыбер Мәхмүтнең койрыклары. Бая гына күрдең ич: ничек итеп этләр шикелле ырылдашалар.* Ш.Камал. *Ләкин [Хөсәенгә] «койрык» тагылганчы бу җирдән тизрәк ычкыну хәерлерәк иде.* А.Расих

7) *күч.* Эш-шөгыльнең үтәлеп бетмәгән, төгәлләнмәгән өлеше. *Ләкин иптәше аны аңламады. – Койрыгың калгач, ничек ял итәсең инде? – Җәй буе әзерләндем, – диде. – Ә син әзерләндеңме соң?* Х.Сарьян. *Мең рәхмәт аларга бу изгелекләре өчен, әниләрнең олы ярдәме белән сессияне бернинди койрыксыз тәмамладым.* Э.Шәрифуллина. *Туйның койрыгы һаман дәвам итә әле.* Казан утлары

8) Кишәрлекнең арты; артбакчаның аргы ягы. *Без шәһәр читендә торабыз, өйләребез бер үк урамда булмаса да, бакчаларыбыз койрыклары белән берберсенә чыгалар.* Ә.Еники

9) Ашлык җилгәргәндә, чистартканда аерылып чыга торган калдыклар; кибәк. *Фәйзулла старостаның тырышлыгы белән эре бөртекле яхшы арышны, яртылаш койрык кушып, начар арышка алмаштырдылар.* М.Галәү

10) *гади с.* Кешенең утыра торган әгъзасы; арт. *Валентин зур бияләй кулы белән минем кулны кысты да койрыгында шуып сәкедән төшеп китте.* И.Салахов. *Икенче цехта бөтенләй аяксызлар, койрыкларына утырып, ыргак белән мамык җептән оек, бияләй бәйлиләр.* Казан утлары

11) Кушамат, ләкаб; тагылма исем. *Көлкедән ничек тә котылырга кирәк иде, ничектер янәшә түзеп яшәргә, авылдан койрык булып килгән дошманлыкны онытып торырга иде.* А.Гыйләҗев

12) Нәрсәнеңдер аерылгысыз нәтиҗәләре, шаукымы

◊ **Койрыгы киселгән эт шикелле** *к.* **койрыгы пешкән мәчедәй**. *Камәретдин, койрыгы киселгән эт шикелле, очраган бер бала белән сугышмыйча калмый...* К.Тинчурин. **Койрыгы кыска** 1) Эләктереп, тотып булмый торган кешегә яки нәрсәгә карата. *Аны эләктерерләр иде, ул алданрак ычкына, югала, койрыгы кыска.* Н.Исәнбәт; 2) Шүрләү, курку, үз иркенчә эш итә алмау; 3) Кешенең белем-гыйлем багажы, акыл-зиһен ягы сайлыгы һәм эшне булдыра алмавы турында. **Койрыгы күренми** Очына чыгу озакка сузылган, нәтиҗәсе ерак булган эш турында. *Инде кар төшәр вакыт җитә, безнең әле иген җыю эшләренең койрыгы күренми.* Н.Исәнбәт. **Койрыгы кысылу** 1) Карьерасы барып чыкмау, хәрәкәт мәйданы калмау. *Җиңел генә диплом эләктермәкче иде дә, барып чыкмады, койрыгы кысылды.* Н.Исәнбәт; 2) Шүрләү, курку, үз иркенчә теләсә ни кыланмас булу. *[Нәдерша:] Сиздеңме, Шәйхи, акларның койрыклары кысыла башлады түгелме?* И.Туктар; 3) Экономик яктан кысылу, җәелә алмау. **Койрыгын бору** 1) Бик каты кисәтү, орышу, тәртипкә кертү. *Ул мутны тотып, койрыгын бик ныклап борырга кирәк.* Н.Исәнбәт; 2) Сүзеннән тану, икенче төрле сөйләү. *Мин аның мутлашуы хакында сүз кузгаткач, ул тиз генә койрыгын борды, имеш, ул дошманлык белән Фәйзериләр тараткан сүз генә.* Н.Исәнбәт. **Койрыгын кыска тоту** Башбаштакланырга ирек бирмәү, чарасын күрү. **Койрыгын төйнәп куйган** Бөтен хәстәрен күргән, эшне тәмамлаган. **Койрыгы текә тору** *сөйл.* Бирешмәү, үз фикерендә нык тору. **Койрыгы пешкән мәчедәй (төсле, кебек, шикелле)**. Кая керер урын тапмый, бәрелә-сугыла чабып йөрү, кая барырга белмәү. *Койрыгы пешкән мәче*

*төсле, кызлар тирәсендә синең йөгереп йөргәнеңне дә күрдем.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Фестивальнең ачылышына Спорт сараена билет сорап, койрыгы пешкән мәче кебек сырпаланып йөргәнем --- бик истә калган.* Ф.Хөсни. **Койрык бозга кату** Үз иркенчә хәрәкәт итәргә мөмкинчелеге калмау, берәр нәрсәгә бәйле булу. *Йортка кергән киявнең хәлен үзең беләсең, койрыгы бозга каткан аның.* Я.Вәли. **Койрык болгау** Куштанлану, ялагайлану. *Әләкчеләр, ялагайлар уңлап-суллап, Шеф алдында чабышалар койрык болгап.* Г.Афзал; 2) Фикерен ачык әйтмәү, хәйләләү, алдашу. **Койрык бору** *к.* **койрык болгау**. *Йөрмәче, Зыя Насыйр, син төрлечә койрык борып, Мәгънә чыкмый төрле байларга кереп йөгереп йөреп.* Ш.Бабич. **Койрыкка басу** 1) Арттан куып җитү, эзләп табу; 2) Кемне дә булса фаш итү, берәрсенең начарлыгын, усал ниятләрен ачып салу. *Менә син дөньялар, ә? Төлке Фәтхулланың да койрыгына басканнар бит, эләккән хәзер.* Н.Исәнбәт; 3) Чиратка басу. *Киләм шулай, кырмыска кебек халык. Почмакта балык биреп яталар. Мин дә тиз генә койрыкка бастым.* Н.Исәнбәт. **Койрыкка тагылу** Бер дә калмыйча арттан ияреп йөрү. **Койрыкны җыю (төйнәү)** Берәр ярамаган эшнең эзен яшерү, калдырмау. *Председатель койрыкны җыя белә.* Г.Толымбай. **Койрыкны кысу** Шүрләп, тыелып тору, тавыш-тын чыгармау. *Песи күргәч, күселәр койрыкларын кыстылар.* М.Җәлил. *Миңа --- каккан казык та тимәде. «Ничауа, үзеңнең дә башыңа җитәр көннәр килер әле!» – дип, мин ач бүредәй шыңшып койрыгымны кыстым.* Х.Сарьян. **Койрыкны сыртка салу** 1) Эшне бозу яки эшлисе килмәүдән читкә китү, җаваплылыктан качу, читләшү. *Диләрә дә врач булам диде, җиде ел укырга кирәклеген аңлагач, койрыкны сыртка салды.* А.Гыйләҗев; 2) Тиз генә, елгыр рәвештә качу. *Җәйге эссе көннәрнең берсендә, тора торгач, менә-менә койрыкны сыртка салып уенга чабарга дип торганда, әнисе тотты да йомыш кушты малайга.* Ф.Хөсни. **Койрыкта бару** Эштә, хәрәкәттә артка калу, соңгылар рәтендә бару. **Койрыкта булу** *к.* **койрыкта бару**. *Трибунага Хәләф сикереп менде: – Җитәр! Безнең алтынчы рота – сугышларда башкалар шикелле, бу эштә дә койрыкта булмас!* Ш.Усманов. **Койрыкта калу** *к.* **койрыкта бару**. **Койрык тагу** 1) Өйләнү; өстеңә йөк, мәшәкать алу; 2) Кешегә ихтирам белән, олылап мөрәҗәгәть иткәндә, исеме алдыннан әйтелә торган сүз кушу. *Авыл халкы да «Мәҗит хәлфә» дип, минем исемгә койрык тагып йөртә башладылар.* М.Гафури. **Койрыкта сөйрәлү** Барысыннан да артта бару, калышу, артка калу. *Ян Гус патриот була. Халыкка мөрәҗәгать итеп, ул: «Чехлар койрыкта сөйрәлмәскә, ә алда торырга тиеш», – ди.* Урта гасырлар тарихы. *Галиуллин белән ярты сәгать сөйләшүдән соң, мин районның ни өчен койрыкта сөйрәлүен, чәчү буенча да --- планның тутырылмау сәбәпләренә төшендем.* Г.Кутуй. **Койрык тыгу** Кирәкмәгән җиргә тыгылу, үзен кыстыру, төрле эшкә тыгылып, бутап йөрү. **Койрык чәнчү** Кайян да булса әйтмичә, сиздермичә генә китү; качып китү. *Таҗи абзыйны да үзләре янына чакырганнар иде, ул койрык чәнечте.* Ш.Маннур. *Прогулка көне шимбә көн иде, атнага ике ялга күчкән кешеләрнең койрык чәнчеп урамга чыккан көннәре иде.* Ф.Хөсни

**КОЙРЫКЛАНУ** *ф.* 1) Үзенә койрык үсү; койрык сыман нәрсә барлыкка килү

2) *күч.* Бер-бер артлы тезелеп, сузылып китү. *Сәмигулла аларның [кибетләрнең] кайсына бармасын, койрыкланып тезелгән озын-озын чиратлар күрде.* С.Рафиков

3) *күч.* Сүзнең, әңгәмәнең бер-бер артлы дәвам итеп торуы

**Койрыклана бару** Тагы да койрыклану. *Сүз койрыкланып барганда гына, өяздән килгән агитатор-организатор мәҗлесне ачык итеп игълан итте.* Һ.Такташ

**Койрыкланып бетү** Бөтенләй койрыклану

**Койрыкланып китү** Койрыкланган хәлгә килү; койрык булып күренү

**КОЙРЫКЛАП** *рәв. сөйл.* 1) Озын итеп, боргалап, сырлап, бизәкләп. *Документка койрыклап кул кую*

2) Булмаганны үзеңнән өстәп, арттырып

**КОЙРЫКЛЫ** *с.* Койрыгы булган. *Койрыклы җир-су хайваннары аяклары һәм койрыклары ярдәмендә гәүдәләрен дулкын сыман хәрәкәтләндереп йөриләр.* Биология. *Каралҗым болытлар төркеме арасыннан өчпочмак койрыклы ракеталар күренде.* Казан утлары

◊ **Койрыклы акча** Җиңел, тиз һәм күп табыла торган акча. *Ул абзый Рәсәй буйлап койрыклы акча эзләп йөри. Мондагы йорты, семьясы таралып бетте, анда китеп тә мантый алмады.* Н.Исәнбәт. **Койрыклы итек** Чабата. *Бер кат киндер ыштан, койрыклы итек (ягъни чабата), юка чикмән кигән крестьян зәмһәрир суыкта җәяүләп Казанга чыгып китә.* Казан утлары. **Койрыклы йолдыз** *астр.* Комета. *Койрыклы йолдызны тәнкыйть салкынрак каршы ала.* Н.Юзиев. *Декабрь аенда койрыклы йолдыз туса, бу ел елгаларда сулар күп булыр...* Татар халкының борынгы ырым-арбаулары һәм төрле фалнамәләре. **Койрыклы сүз** Читләтеп, кинаяләп әйтелгән сүз

**КОЙРЫКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Койрыгы булмаган, койрыгы булмый торган. *Безнең илдә койрыксыз җир-су хайваннарыннан гади күрән бакалар, гөберле бакалар һәм агач бакалары яши.* Биология

2) *күч.* Ышанычсыз, үз фикерендә нык тормаучан; аумакай. *Койрыксыз адәм*

3) *күч.* Кирәгеннән кыскарак (кием тур.). *[Зөләйха улы Зыяга:] Кайдан тапкансың шул җыен койрыксыз киемнәреңне.* Г.Ибраһимов

**2.** *күч. и. мәгъ.* Ярлы, фәкыйрь кеше, хәерче. *[Әни:] Ярата дип әйтеп, газиз балаңны йортсыз-җирсез бер койрыксызга тоттырып чыгарып булмый шул инде.* Г.Бәширов

**КОЙРЫКЧЫ** *и.* Көймәдә койрык тотучы; руль ишкәген тотучы. *Тик койрыкчы гына, күзләрен бер йолдызга текәп, урынында катып калган кебек, югалып утыра.* Г.Ибраһимов. *Көймәчеләрнең берсе: «Бу котылуның иң зур*

*сәбәбе койрыкчының гадәттән тыш маһирлыгында, шул тау-тау ишелеп килгән тулкыннар өстендә көймәне яннан суктырмый йөртә алуда», – диде.* Г.Ибраһимов

**КОЙТЫ** *с. монг. диал.* 1) Начар, әйбәт түгел. *Кыз яхшы төштә ярпая, койты төштә картая.* Мәкаль

2) Әшәке, усал. *Койты халык*

**КОК** *и. голл.* Корабта аш пешерүче, ашчы. *Ул ак алъяпкыч бәйләп, башына да ак берет кигән, кораблълардәге пешекче – кок диярсең.* А.Тимергалин. *– Иохим – флотта кок булып хезмәт иткән кеше, – дип сөйләнде профессор.* Казан утлары

**КО́КА** *и. исп. бот.* Калын яфракларыннан кокаин алына торган тропик куак

**КОКАИН** *и. исп.* Кока куагы яфракларыннан алына торган агулы кристаллик матдә – алкалоид. *Кокаин үзәк нерв системасын ярсыта һәм борчый, аны еш куллану наркоманлыкка китерә.* Биология

**КОКАИНЧЫ** *и.* Кокаин кулланучы наркоман

**КОКАИНЧЫЛЫК** *и.* Кокаин куллануга нигезләнгән наркомания

**КОКА́РДА** *и. фр.* Гадәттә, хәрби яисә бүтән профессиональ униформада баш киеменең маңгай өлешенә беркетелә торган махсус билге, значок. *Фашистлар белән сугышып йөр-йөр дә, әллә кем булып хәрби диңгез көчләрендә хезмәт итеп, кокардалар, алтын погоннар белән кайт та, лесхоз малайлары белән бәхәсләш...* М.Мәһдиев

**КОКА́РДАЛЫ** *с.* Кокарда беркетелгән, кокарда кадап куелган. --- *Исрафил атның яра кашкасын да, кокардалы күк читле фуражкасын да күзеннән югалтты.* Г.Ибраһимов

**КОКЕ́ТКА** *и. фр.* 1) Көяз, кыланчык хатын-кыз

2) Җиңел холыклы, җилбәзәк хатын-кыз

3) Хатын-кыз күлмәгенең билдән өске өлеше; кыска кыса. *Кокеткалар балалар күлмәкләре өчен дә бик кулай.* Л.Мөхәммәт. *Кокетканың өлгесен ясау*

**КО́КЛЮШ** *и. фр. мед.* Коклюш таякчыгы китереп чыгара һәм кешедән һавага төкерек тамчылары белән күчә торган йогышлы авыру; бума ютәл

**КО́КОН** *и. фр.* Күбәләк кортының курчаклык стадиясенә баруы дәвамында үз эченнән чыгарган җепләргә төренүеннән барлыкка килгән йомгак; кузы. *Ефәк коконы*

**КОКОС** *и. исп. бот.* 1) Каурыйсыман яфраклы, кәүсәсе күп божралы, бик эре җимешләр бирә торган җылы як агачы; пальманың бер төре

2) Шул агачның чикләвеге. *Кокос мае*

**КОКС** *и. нем.* Ташкүмер, нефть һәм башка углеродлы матдәләрне югары температурада һавасыз тирәлектә җылытканда хасил була торган каты көпшәк масса. *Кокс металлургиядә ягулык һәм кайтаргыч сыйфатында кулланыла.* Химия. *Кокс газыннан аерып алынган аммиактан аммоний сульфаты (ашлама) җитештерелә.* Химия

**КО́КСЛАНУ** *ф.* Кокска әверелү; кокска әверелә алу. *Кокслана торган ягулык*

**Кокслана бару** Торган саен ныграк кокслану

**Коксланып бетү** Бөтенләй кокслану; тулысынча коксланган хәлгә килү

**Коксланып житү** Тәмам коксланган хәлгә килү

**КО́КСЛАНУЧАН** *с.* Кокслана ала торган; кокслану хасиятенә ия булган. *Тиз коксланучан ташкүмер*

**КО́КСЛАУ** *ф.* Кокс булдыру максаты белән табигый ягулыкларны (мәс., ташкүмер, торф) һавасыз тирәлектә яндырып, корылай куып кокска әйләндерү

**Кокслап бетерү** Кокслауны тәмамлау

**Кокслап кую** Коксланган хәлгә китерү

**КОКТЕЙЛЬ** *и. ингл.* Тәмләткечләр салынган төрле эчемлекләрнең суытылган катнашмасы. *Алар ресторанда күп вакытта текила яисә текила кушып ясалган коктейль эчә.* Л.Әбүдәрова

**КОЛ** *и.* 1) *тар.* Тулысынча хокуксыз булган, үз хуҗасы – колбиләүченең милке саналган кеше. *Юлбашчылар һәм аларның якын туганнары зур терлек көтүләренә ия булалар, аларга әсир төшкән коллар хезмәт итә.* Урта гасырлар тарихы. *Идарә итү эшенә колларны катнаштырмыйлар. Колларның төп вазифасы – колбиләүченең боерыгын үтәү. Ә без үзебезнең коллыгыбызга ике куллап, теш-тырнак белән ябышканбыз.* М.Юныс. *Көннәр буе, айлар, еллар буе бу келәмне коллар тукыды.* Ә.Фәйзи

2) *дини* Кеше, бәндә; *киресе:* **раббы**. *Син кеби һәм ул теләнчеләр дә – Алланың колы; Кул суза, мискин! – бәхетсезлек вә ачлык аркылы.* Г.Тукай. *Җир йөзендәге барлык кешеләр – баймы алар, хәерчеме, мөселманмы, христианмы яки яһүдиме – һәммәсе дә Җиһандагы бер һәм бердәнбер Аллаһының коллары.* Татар мифологиясе. *Аллаһ үзенең яраткан колының ялваруын ишеткәндәй, изгелеген кылды да куйды.* А.Хәлим

3) *күч.* Икътисади, сәяси яктан тулысынча буйсынган, ирексез, хокуксыз кеше. *Мин тормышны, әхвәлне үзем теләгән якка борырлык куәтем бар дип уйласам да, вакыйгда әхвәлнең агымына кол икәнмен.* Г.Ибраһимов. *«Син монда кол, шуны онытма, Мирсәет, син кол... син кол... Җавап кайтара күрмә, син кол», – дип тынычландырырга тырышты ул үзен.* Р.Мөхәммәдиев

4) *күч.* Үзенең тормышын, язмышын нәрсәгәдер буйсындырган кеше. --- *Мин табигатьнең колы түгел. Мин беркайчан да кол булмаячакмын, ишетәсеңме?* А.Тимергалин. *Алдарга намусым бармый. Мин гомерем буе чынлыкның тугры колы булдым.* А.Гыйләҗев. *[Лёня:] Тәү очрашканда бичә кеше каушадымы – бетте. Моннан ары син – хаким, ул – колың.* М.Кәрим

◊ **Кол булу** Буйсыну, кол (*3 мәгъ.*) хәленә төшү. **Кол итү** 1) Кол хәленә төшерү; буйсындыру. *Кешеләрнең бер төркеме гавамны – маңгай тире, кул көче белән яши торган гавамны – үзенә кол итәргә, богауда тотарга тырыша.* Г.Коләхмәтов. *Бәдбәхет фашист, илбасарларча килеп, безнең кешеләрнең өйләренә ут төртә, үзләрен өйләргә бикләп яндыра, кол итә.* Ш.Рәкыйпов; 2) Үзенә тарту, җәлеп итү. *Тагы күргән төшендә ул теге Ләләне матур керфек астыннан бер каравы берлә патшаларны кол итә торган күзле ит-*

*тереп күрде.* Г.Исхакый. *Әмма шулчаклысы бәхәссез: сәхнәдән иңгән илаһи моң, көй, сүз матурлыгы, сөю хисе шагыйрьне иләсләндереп, үзенең колы итә.* Т.Галиуллин

**КОЛА** *с.* 1) Гәүдәсе аксыл сары, койрык-ялы кара төстәге (ат төсе тур.); *русчасы*: **саврасый**. *Миңлегалим өч җир тырмасын --- ике атка мичәү җепләре белән эләктергән дә үзе кола биясенең сыртына менәргә әзерләнеп маташа.* Г.Ибраһимов. *Кола мал тыңлаучан, сабыр, ә менә ак ат нечкә хисле, сизгер күңелле була.* М.Кәрим. *Чабышкысын елгыр кола бия янәшәсенә китереп бастырды Фәләхов.* Р.Мөхәммәдиев

2) Үзендә агачлар, куаклар үсмәгән һәм корылмалар да булмаган, киң, ачык (дала). *Кеше тормышы – кола яланда, үз тормышың – кара урманда.* Мәкаль. *[Шәйми:] Күк айгырдан колак кактык, хатын. --- Ят җирләрдә, кола яланда башын иеп, боегып калды.* М.Кәрим

**КОЛАВЫЗ** *и. иск.* 1) Юл күрсәтүче. *Колавыз булып юл башлап, Идегәй аны апкилде.* Дастан

2) *күч.* Җитәкче, остаз

**КОЛАГЫЗ** *и. иск. к.* **колавыз**. *Сөендек Тулусуповның колагызы Карамыш Мостафин үзенә Сөен-бикәнең анасы «кызым үтерелгән» дип сөйләгәнлеген безгә сөйләде.* Һ.Атласи

**КОЛАК** *и.* 1) Кешеләрдә һәм умырткалы хайваннарда ишетү органы булган парлы әгъза. *Сәгыйдә үзенең колагы белән кайнанасының тавышын ишетте.* Г.Исхакый. *Аның бер колагы сугыштан чукракланып кайткан иде. Кайсы колагы белән тыңлаган ул җирне – белмәссең.* М.Мәһдиев

2) Ишетү органының тыштан күренеп торган өлеше, тышкы колак. *[Куян] арт аякларына басып, озын колакларын алмаш-тилмәш уйнаклатып, --- Шәмсигә карап тора башлады.* Г.Бәширов. *Колак артында уч төбе кадәр миң белән туган балага Минҗан дип исем кушканнар.* М.Мәһдиев. *Аның колаклары иләмсез зур иде, һәм малайлар аңардан: «Бер колагын астына җәеп, икенче колагын өстенә ябынып ята икән», – дип көлә торганнар иде.* Ә.Еники

3) Ишетү сәләте. *Авылның иң читендәге фәкыйрь тирмәсенә кайтып аз гына утырган иде, аның үткен колагы төн ягыннан берничә атның дөп-дөп басып килгәнен ишетте.* Г.Ибраһимов

4) Баш киеменең ике ягыннан төшеп торган өлеше; колакчын. *[Киемнәрнең] барысында да канәфер төсендәге «ямаулар». Чалбарның тезләрендә, гимнастёрканың якаларында, бүрекнең колакларында.* И.Салахов. *Шулвакыт бүрек колакларын күтәреп бәйләгән, салкында битләре утлы күмердәй янган таза гына бер егет өйгә килеп керә.* М.Мәһдиев. --- *бүрегенең колакларын төшереп бәйләгән, якасын торгызган, билен тар каеш белән ныгытып буган.* Ә.Еники

5) Төрле нәрсәләрне тоту, элү, бору өчен беркетелгән җайланма; колак (*2 мәгъ.*) сыман чыгынты. *[Хәзрәт:] Чүлмәкче колакны каян теләсә шуннан чыгарыр, үзегезнеке булмаган дәүләткә кызыгып, дөнья артыннан куып йөрмәгез.* Ә.Фәйзи. *[Гөлбану] – Бу ни эш? Аны кая илтәсең? – дип, Закирның җиңенә, өлкән ак самавырның колагына тотынды.* Г.Ибраһимов. *Бәдретдин, кереп, самавырны алып чыкты, бу самавырның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.* Ә.Еники

6) Яңа гына шытып чыккан үсемлектә пар яфрак. *Углан – яшьтән, тары колактан беленер.* Мәкаль

7) *күч.* Айның яки кояшның ике ягында пәйда була торган парлы ярымтүгәрәк. *Көннең суык булуын шул ук кояш үзе әйтеп тора: аның ике ягында ике колак. Мондый чакта авыл җирендә: «Бүген кояшка да колак чыккан, ай-һай суык икән!» – диләр тәҗрибәле агайлар.* Ә.Еники

8) *күч.* Шәлдә, кашагада, пәрдә һ.б. шуның кебек әйберләрнең читендә асылынып торган тасма, чук. *Шәлнең зуры була, кечкенәсе була, аның колагы да төрле зурлыкта була.* Л.Мөхәммәт

◊ **Колагына аю баскан** *мыск.* Музыкага хиссез, моң һәм аһәң тоюдан мәхрүм кешегә карата әйтелә. *Һәм мин – җыр-музыка дигәндә колагыма аю баскан булса да, солист булырга алынам – мәктәп ишегалдында минем ялгыз чырылдавык тавышым яңгырый.* Ә.Рәшит. **Колагына да элмәү** Тыңламау, илтифат итмәү. *Ләкин Зөфәр әнисенең бу сүзләрен колагына да элергә теләмәде.* Ә.Еники. *Акыралар, бакыралар, бер сүзен колакларына элмиләр, үзе күрмәгәндә, артыннан мыскыллап көләләр, кыскасы, мескенкәйгә көн күрсәтмиләр иде.* Ә.Еники. *Илһамия үпкәләп тә карады, шелтәләде дә, ләкин Мансур боларның берсен дә колагына элмәде: әллә бар Илһамия, әллә юк.* Г.Әпсәләмов. **Колагына җиткерү** Нинди дә булса сүзне тапшыру, җиткерү. --- *менә шуның ләгыйнь малае, әлеге бөкре Шәрифҗан, капка төпләреннән Томанныйга кемнәр килгәнен күзәтеп тора икән дә икенче көнне хәлфәнең колагына җиткерә икән.* Ә.Еники. **Колагына кереп тә чыкмау** *к.* **колагына да элмәү**. **Колагын бору** 1) Җиңелчә җәза бирү турында. *Сиңа нәрсә булды? Ник турсайдың? --- Әллә хәлфә колагыңны бордымы?* Ә.Фәйзи. *Колакны борырга чамалыйдыр, нишлисең, бераз булды инде.* Г.Бәширов; 2) Каты орышу, ачулану; алдан ныгытып, кисәтеп кую. *Мәрьям апасының тавышы теге чактагыча, «болай йөрүеңне әниең белсә, колагыңны борыр иде боруын» дигәндәгечә, хәсрәтле иде.* Л.Ихсанова. **Колагын кайчылау** Сискәнеп, башын күтәреп колагын торгызу (ат тур.). *Сызгырып җибәргән тавышка җирән ат башын күтәреп колагын кайчылады.* Н.Исәнбәт. *Ямщик, дилбегәләрен селкеп, --- Һайт! – дип кычкырып куя. Атлар да колакларын кайчыландырып, пошкырапошкыра, алга җилдерәләр.* З.Бәшири. **Колагын кимерү** *к.* **колак итен ашау**. *Мәхүп аның колагын кимерә йорт киртәсе, урын турында: «Атаңа ни әйтим, рәтле кеше нигез кормас шушы урынга».* С.Кудаш. **Колагын колгага элеп утыру** *мыск.* Әйткәнне тыңламый, үз уе белән мәшгуль булу. *Сине, малай актыгы, эшкә өйрәтәләр, ә син колагыңны колгага элеп утырасың.* Т.Миңнуллин. **Колагыннан бату** Бик нык бурычка бату яки эшкә чуму. **Колагыңны кисеп, кулыңа тоттырыр** Бик усал, хәтәр кеше турында. **Колагы**

**очлы** Сизгер, бик тиз тотып ала торган. *Сиңа әйтәм, күрше, авызыңны чамалап ач, хәзрәтнең колагы очлы.* Г.Ахунов. **Колагы тору** Нык кызыксыну, уяулану. *Малайлар Мөнәвәр абзыйларының сәер гадәтләрен белеп бетергәннәр, шундук колаклары торды.* Ф.Хөсни. *Чәйшикәр дигәнне ишеткәч, карчыкның колаклары торды.* Ә.Еники. **Колак арттан җибәрү** Сүзне ишетсә дә, ишетмәмешкә салышу, игътибарга алмау. *Гыйльмановның бу юлы үзенә төбәлгән шактый җайсыз сүзләрне колак арттан җибәрүе Сәмигуллинга беркадәр гаҗәп тоелды.* Ш.Камал. **Колак асу** *к.* **колак салу**. *Аның сүзләренә колак аскан кеше юк.* К.Тинчурин. **Колак аша уздыру** *к.* **колак арттан җибәрү**. **Колак биреп тыңлау** Әйтелгән сүзне игътибар биреп, дикъкать белән тыңлау. **Колак итен ашау** 1) Бер сүзне кат-кат әйтеп йөдәтү, аптырату. --- *аның хатыны ничә айлардан бирле һәркөн: – Туныма тышлык ал, туныма тышлык ал, кеше күзенә күренерлегем калмады, хәерче кебек йөрим, – дип, моның колак итләрен ашый иде.* Г.Ибраһимов. *[Хирург:] Мин үзем моннан һич китмәс идем, хатын Ленинградка кайтыйк дип колак итен ашый.* Г.Әпсәләмов; 2) Кешенең гайбәтен сөйләү. **Колак итен кимерү** *к.* **колак итен ашау**. **Колак итен чәйнәү** *к.* **колак итен ашау**. *Аның бу бүләк мәсьәләсенә һич тә тыгыласы килми иде, ә тыгылса, Гайнүше икенче берәүнең туган көненә чаклы, һичшиксез, колак итен чәйнәячәк.* Ә.Еники. **Колак ишетмәгән** Яңа, ят, сәер, беркайчан да булмаган (хәбәр, эш һ.б. тур.). *Кайдан килеп тагылган бу колак ишетмәгән әкәмәт өстәмә безнең галантерейчы егеткә?* Ә.Еники. **Колак кагу** 1) Гыйбадәт кылучы мөселманның ике кулының баш бармаклары белән ике колагының йомшакларына орынуы; 2) Нәрсәдәндер мәхрүм булу, буш калу, кулдан ычкындыру. *Ул мине актык акчамнан колак кактырмакчы була. Моннан ничек тә сызарга кирәк.* Г.Камал. *Әгәр бу сүзләр ахун хәзрәткә барып җитә калса, Гайшәдән генә түгел, бөтенесеннән колак кагарга мөмкин.* Ә.Еники. *Кичен эшне тапшырганда, йомгагымны бракка чыгардылар. Нәтиҗәдә --- төшке ашта баландадан соң бирелә торган ярты чүмеч чумардан да колак кактым.* И.Салахов. **Колакка җитез** *к.* **колакка сак** (*2 мәгъ.*) *Сафа сүзгә саран булса да, колакка бик җитез иде.* А.Шамов. **Колакка ирешү** Берәүгә барып җитү, ишетелү (сүз, хәбәр һ.б.ш.). *Хәбәр тиз йөри. Күңелләрне шомландырып, безнең дә колакка иреште.* Х.Сарьян. **Колакка каты** Начар ишетә, ярым чукрак, саңгыраурак кешегә карата әйтелә. --- *Хәйрулланың әлеге колакка каты анасы, улыннан бернинди җавап ала алмагач, инде өченче тапкыр хат яздырырга килде.* Ә.Фәйзи. *Әби артык узынырга ирек бирмәсә дә, әйтерлек ачуыбызны китерә алмады: колакка катылыгы әйбәт иде.* М.Әмир. *Сине колакка бераз каты, диләр.* З.Нури. **Колакка керү** 1) Аз гына истә калу, саклану. *– Минә тиле… төн уртасында чәй эчеп алыйк имеш, – дип сукранган Сәләх тә җылы урыныннан сыдырылып төшәргә мәҗбүр булды. – Мәй дип әйтсәң, хет колакка керер ие.* Ф.Хөсни; 2) Ишетелү. *Хәер, тынлык дигәннең дә үз авазы бар икән – … кетәклектәге тавыкларның тигезлек сакларга теләп кузгалышып алуына кадәр колакка керә.* Р.Мөхәммәдиев. *Йокы аралаш ниндидер шау-шу колакка керде.* И.Салахов. *Кай арада пышылдашып китүләре дә колагыма керә: Әнә, әнә, Фатих Хөсни абый шушы була инде.* Ф.Хөсни. **Колакка киртү (киртләү)** 1) Бер әйтелгән сүзне яки кушылган эшне онытмас өчен ныклап хәтердә калдыру. --- *мин тагын Нуриман хөкеменә эләктем. Исән кайтсам, барыбер үтерәм дип, колагыма киртеп куйдым.* Х.Сарьян; 2) Бик нык кисәтеп кую. *[Милиция генералы:] «Халык депутаты» дигән төшенчә юк хәзер, колагыгызга киртләп куегыз, аларны «депутат» кына диләр.* Р.Мөхәммәдиев. *«Без тарихта эзлебез…» Тукай бу канатлы гыйбарә белән ата-бабаларының үткәне белән горурлануын, кемнәргәдер бу хакыйкатьне искә төшереп, колагына киртеп тору кирәклектән --- борчылуын әйтергә теләгән.* Т.Галиуллин. **Колакка сак** 1) Начар ишетүче. *Чын дөреслектә өчесенең дә телләрен бәйләгән уртак бер бәла: өчесе дә колакка саграклар икән.* Ф.Хөсни; 2) Сизгер, һәртөрле хәбәрне, сүзне бик тиз ишетүчән. *Моның тирәсендә бик артык ычкындыра күрмә, колакка сак.* Н.Исәнбәт. **Колакка салып кую** Онытмау, хәтердә тоту. *Ишеттеңме, нәрсә диде? Син аның ул сүзен колагыңа салып куй.* Н.Исәнбәт. **Колакка туку** Бер үк хәбәрне кат-кат әйтеп сеңдерү, һаман шуны кабатлап тору. *Тукыйлар колакка, укыйлар тарихын, тикшерергә төбен кушмыйлар. Аталар сөйли бабадан ишетеп, балалары шуны хушлыйлар.* С.Рәмиев. *Сиңа әйтәм, колакларыңа тукып кайтырлар, ул-бу чыгып бозылып китмәсен, заманаларны беләсең бит хәзер.* А.Шамов. *Иртән торгач ук, Гайнулла җизни белән Вәли абыйны чакыртып, колакларына тукып куйдылар.* Г.Бәширов. **Колакка чалыну** Ничектер, кайдадыр чак кына ишетелеп китү. *Никадәр эш белән мавыккан булмасын, болар да, әлбәттә, Сания ханымның колагына чалынды.* Ф.Хөсни. *Онытылып, рәхәтләнеп, елмаеп-көлеп сөйләште --- Тыңламыйм дисәң дә, колакка чалына ич инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин без капчыкта ята алмады. Бу сөйләшләр Шакирҗанның хатыны Миңленисаның колагына чалынды.* Г.Ибраһимов. *Ята торгач, араннан ап-ачык булып атның башак ашавы колакка чалынды.* Г.Бәширов. **Колакка элмәү** Әйткәнне бөтенләй тыңламау, ишетергә дә теләмәү. *Колагына да элмәде, мур кыргыры нәрсә!* И.Гази. *Колагына да элми, һич кенә туктый белми.* Ш.Галиев. *Бу сүзләре Гапсаттарга аталган иде, әмма ул аны колагына да элмәде.* Ф.Яхин. *Бер әйтеп карады Сәләхетдин Мирфатыйхка, ике кисәтте, тегеләр колакка да элмәделәр.* А.Гыйләҗев. **Колакка ят** Сәер, гадәттәгечә булмаган, гаҗәпләндерә торган. *Шулкадәр колакка ят иде ул ишетеп торган сүзләр – «әллә җен алыштырганмы аларны, Ходаем?!» дип, белгәннәрен дә укып карады Гөлмәрьям.* А.Гыйләҗев. **Колакка яту** Күңелгә ятышлы булу, күңелгә ошау, уңай

тәэсир итү (әйтелгән сүз, хәбәр һ.б.га карата). **Колакка ятышсыз** Ямьсез, тупас (сүз, хәбәр һ.б. тур.). *Ул сүзне [«ничава»] беренче ишетүем иде. Колакка ничектер ятышсыз булса да, шуның мәгънәсен беләсем килде.* Н.Сәфәров. *Югыйсә оланлар, яңа исем кушабыз дип, мәгънәсен уйлап тормый, сабыйларга колакка ятышсыз теләсә нәрсә тага бирәләр.* М.Кәрим. **Колакларны торгызу** 1) Әсәренү, сагаю, шомраю. *Йомран [ат] колакларын торгызып, тирә-якка карады.* А.Таһиров; 2) Игътибарны көчәйтү, бик нык кызыксыну. *Бу таныш көй һәм таныш сүзләрнең беренче юллары тыңлаучыларның колакларын торгызды.* Г.Әпсәләмов. **Колаклар торып басу** Берәр ят хәбәр я белдерү ишетүдән бик нык кызыксынып, игътибар белән тыңлый башлау. *Әчмән урманында күңелсезрәк нәмәрсә килеп чыккан, ди бит әле. Әчмән дигәч, билгеле инде, минем колаклар торып баса.* Ә.Баян. **Колаклар үрә тору** 1) Берәр төрле хәбәрдән, сүздән, көтелмәгән эш-хәлдән бик нык гаҗәпләнү, бик каты кызыксыну. *– Барыбыз да Мортазиннар тамырыннан шытып чыкканбыз, бабаларыбыз шул фамилияне йөртә иде безнең. – Кызның колаклары үрә торды.* А.Гыйләҗев. *Безнең колаклар үрә торды, эшнең зурлыгы тагын да арткан кебек булып китте.* М.Гафури; 2) Бик кызыксынып тыңлау. *Егетләрнең колаклары үрә торды, бусы ни тагын?* Ә.Еники. **Колакларына ышанмау** Көтелмәгән берәр нәрсәгә, хәбәргә чиктән тыш гаҗәпләнү. *Шәйхел колакларына ышанмады, кан аның башына йөгерде, ни әйтергә белми калды.* Г.Ибраһимов. **Колакны сасыту** Кирәкмәгән юк сүз сөйләп туйдырып бетерү. *«Ну, колакны сасыта», – дип уйлады Рәхим Саттар, үзе ялтырап торган күзләрен Шәфи Алмастан күчермәде.* Г.Әпсәләмов. **Колакны ярып керү** Бик көчле ишетелү (тавыш тур.). *Бу ялгыз, дөм сукыр тынлыкта теге бүлмәдә сөйләшкән һәр сүз колакны ярып керә иде.* Х.Сарьян. **Колак очына да элмәү** Ишетергә дә теләмәү, бөтенләй тыңламау, игътибар итмәү. *Авыл кызлары --- каты гына тешләп тә алгалыйлар иде. Гайнан исә андыйларны колак очына да элмәде.* Г.Бәширов. **Колак салу** 1) Игътибар белән тыңлау, киңәшкә игътибарлы булу. *Әлфия кечкенә кыз түгел, аның сүзенә дә колак салу ярый.* Ф.Яруллин. *Ул календарь биргән акыллы киңәшләргә бик чынлап колак сала.* М.Әмир. *Беренче сынауны Вак Дрей өйдә үткәрде. – Киб, колак салып тыңла һәм мыегыңа чорный бар, – диде ул роботка.* А.Тимергалин; 2) Ишетергә тырышу, тыңлап тору. *Зөфәр күпме колагын салып ятса да, аның сүзләрен аера алмады.* Ә.Еники; 3) Тыңлап карау. *Мин бераз барам да, атымны туктатып, тирә-якка колак салам.* Х.Сарьян; 4) Әйткәнне тыңлау, сүзнең эчке мәгънәсен аңларга тырышу. *[Таибә абыстай:] – Улым, абыең әйткәннәрне ишеттең инде, – диде ул җитди генә сүзен башлап. – Син яхшы гына колак салсаң иде.* Ә.Еники. *[Шәйдулла:] Син дә каты кыланма: кеше сүзенә колак сала бел.* М.Мәһдиев. *Параша аларның сүзенә колак салмый. Иван Лобачевскийның чибәрлегенә --- гашыйк булып өлгергән иде ул.* Җ.Тәрҗеман; 5) Игътибарны юнәлтү; кызыксыну. *Нина гайбәткә ышанмый торган хатын иде. Юк-бар сүзгә колак салмады.* Г.Ибраһимов. *Газетта Исхакыйның «Тормышмы бу?» романыннан өзекләр урнаштырылды, бу хәл газетаның да халык фикеренә колак сала башлавын күрсәтте.* Мирас; 6) Әйткәнчә эшләү, киңәшне тоту. *Юк, Шәрифә аларның сүзенә колак салмас, мәхәббәтеннән баш тартмас, шул кала шәкерте белән бергә булырлар.* Ф.Яхин. **Колак селкетмәү** Ишеткәнгә ис китмәү, әйткәннең тәэсире булмау. *Сүз сиңа да кагыла. Ә син, ишәк баласы төсле, колагыңны да селкетмисең. Сез ясарга тиеш ул мәйданны, сез!* Х.Сарьян. **Колак сөенчесе** *этн.* Кызны кияүгә бирергә ризалык булганнан соң, кыз һәм кияү егетенең ата-аналары арасында вәгъдәләшү билгесенә бирелә торган бүләкләр. *Шулкадәр күп мәһәр сорый торган булсалар, мин колак сөенчесе алырга риза түгел.* Г.Камал. *Шәмси разый булмас дип уйлаганнар булырга кирәк, моңарга белдермәенчә яучы җибәрделәр, моңарга белдермәенчә туй көнен билгеләделәр. Моңарга белдермәенчә колак сөенчесе алдылар.* Г.Исхакый. --- *Кызны вәгъдәләшеп, берничә микъдар мәһәр салып, кызны килешкәч, колак сөенчесе бирәләр.* К.Насыйри. **Колактан калу** Чукраклану, ишетмәс хәлдә булу. *Син аңа кычкырыбрак әйт, бабагыз инде колактан калган.* Н.Исәнбәт. **Колактан китмәү** Колакта берәр төрле тавыш тою, ишетелгәндәй, яңгырап торгандай булу. *Шул матур тавышны ишетер өчен, шул төшендә татыган ләззәтене яңартыр өчен, көзге алдына барып: – Хәдичә туташ, мин сине сөям! – диде.* Г.Исхакый. **Колактан колакка** Кешегә ишеттермичә, колакка гына пышылдап (сөйләшү, серләшү). *Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр. --- Нинди генә егеткә барырбыз, дип, Колактан колакка гына ла сөйлиләр.* Җыр. *Ай үтте, көн үтте. Шәмсинең марҗа белән торуы элгәре колактан колакка гайбәт иттереп кенә сөйләнде.* Г.Исхакый. *Алар --- күтәренке рух белән үзара колактан колакка нииндидер яшерен серләр турында серләшәләр.* К.Тинчурин. **Колактан язу** *к.* **колактан калу**. **Колак тондыргыч** Бик көчле (шау-шу, тавыш). *Кинәт Хәят шәһәр өстенә күтәрелгән колак тондыргыч гөрелтене ишетә башлады.* Ф.Әмирхан. *Кап-караңгы, бернәрсә дә күренми. Бары тик колак тондыргыч чебен мыжлавы ишетелә.* И.Салахов. *Йөрәкҗанов куык кебек кабара-бүртә башлады, аннары колак тондыргыч тавыш чыгарып, төтенсез генә шартлап ярылды.* А.Тимергалин. **Колак тондыру** Бик каты шаулау; гүләү; тавышлану. --- *зәһәр бензин исе белән күмеп, колак тондырып, берьюлы аллы-артлы мотоцикллар узды.* А.Гыйләҗев. **Колак тону** Көчле тавыштан яисә бәрелүдән ишетми (начар ишетә) башлау. --- *Гыйлемдар үз ролен менә дигән иттереп башкарды. Кул чабудан хәтта колаклар тонды.* Х.Сарьян. **Колак торгызу** 1) Берәр яктан кызыклы, әһәмиятле нәрсә хәбәр итеп, тыңлаучыда кызыксыну уяту. *Чү, сул як стенадан кемдер чиртә кебек. Әнә тагын, тук-тук. Колагымны торгызып*

*тыңлыйм.* И.Салахов. *– Син, банкир, фән тарихыннан да хәбәрдар икән әле, – диде ул аннары ---. – Мин колакларымны торгызыдым, – дип елмайгандай итте Альберт Линкольн.* А.Тимергалин; 2) Сагаю, сагаеп калу. *Абзарда кола бия зур улакта бутау ашый иде. Аяк тавышына колакларын торгызды.* Г.Ибраһимов. **Колак торгызырлык** 1) Аптырарлык, аптыраштa калдырырлык, гаҗәп. --- *халык арасында Коръән хафизны карт хәзрәттән соң мәхәлләгә имам итеп кую турында да сүзләр йөри башлады. Бу инде колакны торгызырлык хәбәр иде.* Ә.Еники. 2) Гаҗәеп, кызыклы, мавыктыргыч. **Колак төбенә менеп төшү** Яңаклау, кыйнау, сугу. --- *Тыңлап торучылар арасында булган Хуҗа абзый бу эшкә нокта куйган – Курай Назыймның колак төбенә менеп төшкән.* Р.Мөхәммәдиев. **Колак төбендә** Бик якында, янәшәдә, янында ук. --- *колак төбендә яңгыраган туп тавышы берничә секундка аның башын чуалткандай булды.* К.Тинчурин. *Кемдер колак төбендә генә кычкырып җибәрде: «Әй, Гумәр! Тор тизрәк, каласың бит!»* Г.Бәширов. *Нәкъ колак төбендә – юк, колак төбендә генә түгел, тагы да эчтәрәк, ми күзәнәкләре эчендә үк бугай – җавап ишетелде.* А.Тимергалин. *Колак төбендә мин аның «Әткәй!» дип пышылдаган куанычын ишетәм.* Ф.Хөсни. **Колак төбеннән** *к.* **колак төбендә**. *Теге көндә атылган кешеләрнең үлгән чакта әйткән сүзләре колак төбеннән яңгырап киткән төсле булдылар.* М.Гафури. **Колак чыгару** Ике нәфис яфрак җибәрү (үсемлекләр тур.). **Колак шомарту** Колакларны артка таба яткыру (ат тур.). *Җирән айгыр, башын кыңгырайтып, колакларын шомартып, бу нинди әкәмәт мал дигән сыман, үгезгә карап бара.* Ә.Айдар. **Колак шомрайту** *к.* **колак шомарту**. **Колак яныннан уздыру** Кирәксез яки артык әйтелгән сүзне ишетмәгән дә төсле яннан уздыру, йөрәккә авыр алмау. *Минем дә эшкә ярыйсым килә иде. – Әти, мин дә барыймчы, – дидем. Мин әйткәнне әти колак яныннан гына уздырды.* Г.Бәширов. *Минем бу сүзләрне дә колак яныннан уздырып, хатына сыймаган фикерен әйтеп калырга ашыкты.* Т.Галиуллин. *Сәлмән карт йортка буй бирмәс бу «малай актыгы»ның мондый сүзләрен башта колак яныннан игътибарсыз уздырырга тырышып йөрде.* Ф.Хөсни. **Колак яру** Бик көчле тавыш, аваз чыгару. *Бер килеп бәрелештеләр, тракторлар, моторлар өзмәс үкерде, металл ышкылган тавыш колакларны ярды.* А.Гыйләҗев

**КОЛА́К АЛКАСЫ** *и.* Колак йомшагына беркетелә, тагыла торган бизәнү әйбере. --- *әбиләрнең бер ише бизәнеп, колак алкалары тагып, беләзекләр киеп йөри башладылар.* А.Гыйләҗев. *Аның бабалары татар арасында бик үтемле булган, йөзек, беләзек, чулпы, колак алкасы --- ише әйберләр койганнар.* Г.Әпсәләмов

**КОЛА́К ИТЕ** *и. анат. к.* **колак йомшагы**

**КОЛА́К ЙОМШАГЫ** *и. анат.* Колак яфрагының аскы итләч өлеше. *[Камәрнең] бөдрәле чәче колак йомшагына җиткереп киселгән.* Г.Ибраһимов

**КОЛА́К КҮПЧЕГЕ** *и. к.* **колак мендәре**

**КОЛА́К МЕНДӘРЕ** *и.* Тышы чигелгән яки челтәр тотылган кечкенә мендәр; күпчек. *Боларның дүртесенә бер кечкенә колак мендәре белән иске кызыл юрганнан башка бернәрсәләре дә юк.* М.Гафури. *Ирексездән кулына диван өстендә яткан бер колак мендәрен алды.* Х.Сарьян

**КОЛА́К ПӘРДӘСЕ** *и. анат.* Тышкы колакны урта колактан аерып тора торган яры, элпә. *Кинәт кенә --- колак пәрдәсен зыңгылдатып, кыңгырау чылтырады.* Ж.Тәрҗеман. *Тавыш дулкыннары тышкы колакка бәрелеп, тышкы ишетү юлы аша узалар һәм колак пәрдәсенең тирбәнүен китереп чыгаралар.* Биология

**КОЛА́К ЭЛПӘСЕ** *и. анат. к.* **колак пәрдәсе**

**КОЛА́К ЯРЫСЫ** *и. анат. к.* **колак пәрдәсе**. *Колак ярысына килгән тавыш тирбәнешләре баш миенә барыбер электр импульслары рәвешендә тапшырыла.* А.Тимергалин

**КОЛА́К ЯФРАГЫ** *и.* Һавадагы тавыш тирбәнешләрен ишетү юлына юнәлдерергә ярдәм итә торган тышкы колак. *Кыз, колак яфракларына кадәр кызарып, сәер генә җиргә карады.* З.Бәшири. *Битен юганда, аның нәни генә колак яфрагында фирәзә кашлы алкасы селкенә.* Г.Бәширов

**КОЛАКА́Й** *и. сөйл.* 1) Зур колаклы кеше. *Колаксыз калганын күргәч, карак дуслары аңа Колакай дип өстәмә исем тактылар.* Р.Батулла

2) Чукрак

**КОЛАКБА́У** *и. диал. к.* **колакса** (*2 мәгъ.*). *Чабатага колакбау кую*

**КОЛАККА́-КОЛАК** *рәв.* Пышылдашып, башкаларга ишеттермичә генә. *[Мәстүрә белән Рәян] икәү колакка-колак сөйләшәләр.* Г.Коләхмәтов

**КОЛАКЛАНУ** *ф.* 1) Тирә-ягы яктылык белән уратылу, киртәләнү (айга, кояшка карата). *Ай колакланса, аягыңны ныгыт, көн колакланса, күрәгеңне ныгыт.* Мәкаль. *Ай колакланса, [көн] суыта.* Мәкаль. *[Әни:] – Бик тә суык бит, улым. Әнә кара әле, бүген кояш та колакланып чыккан. – Карасам, чынлап та шулай! --- Кояшның як-ягыннан, кызгылт сары булып, дәү-дәү колаклары тырпаеп тора.* Г.Бәширов

2) Шытып чыгып, ике яфрак җибәрү. *Кыяр үсентесе ике «колаклангач», әбием безгә яңгырдан соң «ат тоягы» җыйдыра.* Э.Шәрифуллина. *Кәбестә колаклану*

**Колакланып килү** Колаклануга юл тоту. *Ай колакланып килә*

**Колакланып тору** Колаклану хәлендә булу. *Зыкы суык көн. Халыкта сөйләнгәнчә, кояш та колакланып тора.* Р.Ишморатова

**КОЛАКЛА́У** *ф.* Савытка һ.б. нәрсәләргә колак (*5 мәгъ.*) ясау. *Чиләкне колаклау*

**Колаклап кую** Алдан яки тиз арада колаклау. *Чиләкне колаклап кую*

**Колаклап тору** Даими яки регуляр рәвештә колаклау. *Тимерче чиләк кебек савытларны колаклап тора*

**Колаклап чыгу** Барысын да колаклау

**КОЛАКЛЫ** *с.* 1) Билгеле бер формадагы колагы булган. *Гаҗилә җиңги*

*бәләкәй йомшак колаклы, җылы муенлы малай белән кухняда рәхәтләнеп сөйләште, аңа ботка пешерде.* М.Мәһдиев

2) Колагы зур булган кайбер хайваннар атамасы составында беренче сүз. *Колаклы маймыл*

3) *сөйл. к.* **колакчынлы**. *[Ногманның] колаклы бүрек астыннан кечкенә генә булып күренгән бите буенча борчак-борчак булып тир ага.* Р.Ильяс. *Безгә өр-яңа төрмә киемнәре: бушлат, гимнастёрка, чалбар, колаклы бүрек бирделәр.* И.Салахов

**КОЛАКСА** *и.* 1) Көймәдә ишкәк беркетелә торган урын; *русчасы*: **уключина**. *Ишкәкләр --- колаксаларыннан салдырылмаган килеш кенә көймә эченә төшерелгән иде.* Ш.Маннур

2) Чабатаның як-якларында киндерә үткәрә торган тишек

3) Бураның баш-башларында озын булып чыгып торган иң өске ике бүрәнә. *Бура бураганда, колакса калдыру*

4) *диал.* Хатын-кызлар кия торган тәңкәле калфак

5) *диал.* Бик зур колак алкасы. *Тамчы кебек эшләнгән колаксалары шәрә җилкәләренә үк тиеп тора.* Р.Рахман. *Чабата белән көмеш тәңкәле чәчүргечләр, уртасына зәңгәр таш утырткан ай колаксалар аңа бу гаилә узган ике төрле тормышны сөйли кебек иде.* Идел

6) *диал.* Чыгымчы атның күзен каплау өчен, йөгәнгә ике яклап тегелгән япма. *Атка колакса тегү*

**КОЛАКСАЛЫ** *с.* Колаксасы булган. *Колаксалы бура*

**КОЛАКСЫЗ** *с.* 1) Колагы юк, колагы булмаган; колагы төшкән. *Сукыр, аксак, тешсез, колаксыз хайваннарны корбанга чалу дөрес түгел.* Ватаным Татарстан. *Колаксыз чиләк. Колаксыз кәстрүл*

2) *сөйл.* Бөтенләй ишетми торган, саңгырау. *Күпме гомер калгандыр инде, моңа кадәр ишетмичә яшәдем, моннан соң да «колаксыз» килеш яшәрмен әле дип, Казанга барудан баш тарттым.* Ватаным Татарстан

**КОЛА́К ТӘҢКӘСЕ** *и. этн.* Туй чыгымнары өчен егет ягыннан кызның ата-анасына бирелә торган акча

**КОЛАКЧА** *и.* 1) *диал. к.* **колакчын**. *Өстенә ертык бишмәт, башына бер колакчасы өзелгән, бер колакчасы салынган бүрек кигән, --- чалышрак авызлы берәү килеп керде.* Г.Толымбай

2) *диал. к.* **колакса** (*5 мәгъ.*). *Колагыма таккан колакча Йөрсәм талпынадыр бер якка.* Җыр

3) *сөйл.* Күзлек сабы

**КОЛАКЧАЛЫ** *с. диал. к.* **колакчынлы**. *[Кичкырын безгә] башына кызыл йолдызлы колакчалы бүрек, өстенә шинель кигән берәү килеп керде.* Г.Толымбай

**КОЛАКЧЫК** *и.* 1) Кечкенә колак

2) *анат.* Йөрәк алды. *Колакчыклар кыскарганда, кан карынчыкларга килеп керә.* Анатомия

**КОЛАКЧЫН** *и.* **1.** 1) Баш киеменең (мәс., бүрекнең) колакны каплый торган махсус өлеше

2) *сөйл.* Колаклы бүрек. *Яңа колакчын булды дип, искесен утка якма.* Мәкаль. *Аягында Казанның әйбәт читеккәвеше, башында яңа колакчын иде.* Г.Ибраһимов

3) Радио, телефон кебек аппаратларда колакка киелә яки куела торган тыңлау приборы, наушник. *Гайнан, иң кырыйдагы кечкенә тәрәзәгә килеп, яшел яулыгы өстеннән башына телефон колакчыны элгән бер хатынга дәште.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* Колакчыны булган. --- *ә Зөфәр утны сүндерде дә, чишенеп --- толып җәйгән һәм зур колакчын мендәр салган идәнгә сузылды.* Ә.Еники. *Камерага атылып ике хәрби кеше керде. Башларында өр-яңа колакчын бүрекләр.* И.Салахов. *Ул колакчын бүреген салып, селеккәләп, буранда кунган карны авырулар өстенә чәчте.* Казан утлары

**КОЛАКЧЫНЛАП** *рәв.* Колакчын куеп. *Бүрекне колакчынлап тегү*

**КОЛАКЧЫНЛЫ** *с.* 1) Колакчыны булган, колакчынлап тегелгән. *Ишектән, үзе белән салкын өермә ияртеп, каеры тун кигән, колакчынлы бүреген төшергән өлкән яшьтәге агай килеп керде.* Р.Мөхәммәдиев. *Вилдан сыңар колакчынлы кешегә тиз генә папирос сузды. --- Председатель сыңар колакчынлы агайны әрләгән булды.* Г.Толымбай

2) Колакчын (*2 мәгъ.*) кигән. --- *болар тирәсендә шаулап йөргән колакчынлы казаклар, яшьләр, картлар нидер көтеп, сабырсызлык белән шаулашалар иде.* Г.Ибраһимов

**КОЛАН** *и. зоол.* Бәләкәй гәүдәле, зур башлы кыргый дала аты. *Атасы болан атмаганның баласы колан атмас.* Мәкаль. *Атның киеге – колан, кәҗәнең киеге – коралай.* Мәкаль

**КОЛАЧ** *и.* 1) Җәелгән ике кул очының арасы һәм шул аралыкка тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *«Э-эх!» дип бер киерелде дә, колачларын киң җәеп, имән ботаклары өстенә сузылып ятты.* Р.Мөхәммәдиев. *Сафа абзый ун колач озынлыктагы сумалалы чыбыркысы белән китереп сугуга --- атлар бөтенләй шаштылар.* Г.Бәширов. *[Насибулла абзый:] Анда бер нарат бар, ди, галимнәр шуның яшен белә алмыйлар, ди, юанлыгы сигез колач, ди.* М.Мәһдиев

2) Бер-берсенә тотынган ике кул арасы; кочак (якынча күләм). *Йөз яшәр наратлар шулкадәр юан: колач та җитми.* А.Тимергалин. *Мәктәпнең стеналары калын: метр гына җитми, колач кирәк.* Х.Сарьян. *Син агачның юанлыгына кара: ничә кеше колачы җитәр икән.* А.Расих

3) Кошларда, бөҗәкләрдә очу органы; канат. *Якыннан шул вакытта узды Лачын, җәеп, селкеп канат атлы колачын.* Г.Тукай. *Менә ул [торна] авыл читендәге башы көйгән каен турысында әйләнә башлады, Ахиярга аның колач кагуыннан чыккан һава тавышы ишетелде.* М.Мәһдиев

4) Билгеле бер вакыт эчендәге хәрәкәтнең киңлеге, зурлыгы, амплитуда. *Тавыш югары булган саен, тирбәнү ешлыгы зуррак була, ә тавышның көче тирбәнү колачы артуга бәйле.* Биология. *Тавыш дулкыннары өзлексез рәвештә көчле тәэсир иткәндә, колак пәрдәсе зур колач белән тирбәлә.* Анатомия

5) Зурлык, зур күләмлелек, масштаблылык. *Стадионның мәһабәтлеге, колачы, аеруча панорамасы ошады Мансурга.* Г.Әпсәләмов. *Кемнәрдер*

*мактаса, кызлар-егетләр арасында аны үртәүчеләр дә булды. Нияз Хисамовның «Исәнме, туган җир» картинасы күңелләрне үзенең мәһабәт колачы һәм лирик кайнарлыгы белән җәлеп итте.* И.Бәширов

6) *күч.* Нинди дә булса масштаблы эшнең, эшчәнлекнең күләме, зурлыгы. *Халык сугышы тулы колач алды.* Н.Коробков. *Чөнки бу эшләр тормышның бүгенге колачы белән чагыштырганда бик вак, әһәмиятсез иде.* Ф.Садриев. *Эшчәнлек киңлеге, киң җәелеш. Башка халыклардан үзгәлек, өстенлек хисе гаҗәеп әзлеклелек һәм колач белән таратылды.* Ә.Рәшит

7) 2,5 $м^3$ яки 4 $м^3$ га тигез утын үлчәү берәмлеге. *Вәлитдиннәрнең иңе-буе бер колач кына өйләре – безнең төп төягебез ул.* М.Кәрим

◊ **Колач алу** Еракларга җәелү, киң таралыш табу. *Ул көннәрдә матбугат битләрендә Сталинны Ленинның бердәнбер варисы, иң якын һәм ышанычлы көрәштәше итеп күрсәтү кампаниясе аеруча зур колач алган иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Болгар дәүләте төзелгәч (X–XI йөзләр), керамик материаллар һәм әйберләр эшләү киң колач алган.* Төзү материаллары. **Колач җәеп** 1) Ике кулны ике якка ташлап. *Ике кулы гүя ике канат иде аның шул мизгелдә, колачын киң җәеп трибунаның як-ягына таянган да, менә-менә алга ыргылырга, очарга җыена диярсең.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Шатланып, бик теләп, ихласлык күрсәтеп; 3) Иркенләп, тулы көчкә. --- *Еш кына егет шул нур эчендә колач җәеп йөзә --- һәм нәкъ шул мизгелдә уянып китә.* М.Мәһдиев. **Колач җәю** 1) Бар мөмкинлегенә киң җәелеп хәрәкәт итү. *Буйсынырга ләкин теләмәгәч, Идел ташып җәйгән колачын.* Н.Арсланов. *Культура революциясе --- бездә киң колач җәйде.* Г.Бәширов; 2) Таланты ачылу, шәхси табигый сәләтен киң җәелдерү. *Казанга килгәч, Тукайның шагыйрьлек таланты тагын да киң колач җәйде.* Н.Исәнбәт; 3) Нинди дә булса эшне киң планда алып бару, башкару. *Әхмәт байның капиталы Идел, Җаек буйларын, казак далаларын тарсынып, Германия базарларына да колачын җәя башлады.* К.Тинчурин. **Колач җитмәс** *к.* **колач җитмәслек**. *Колач җитмәс җәеннәр, төпкелдән чыгып, муеннарын сузып торалар.* М.Кәрим. **Колач җитмәслек** 1) Кочакка сыймый торган бик юан, зур диаметрлы. *Идрис чынлап та «аяклы энциклопедия» икән, аның мәгълүматына Әлфиянең генә колачы җитмәле түгел икән!* Х.Сарьян. *Колач җитмәслек әзмәвердәй агач, дөнья белән бәхилләшеп, бөтерелә-бөтерелә, гөрселдәп ауды.* М.Галиев. *Гаҗәеп зур ябалдашлы, колач җитмәслек юан нарат кына, җил-давылларның берсенә дә бирешмичә, горур басып тора.* Казан утлары; 2) Зур күләмле, масштаблы. *Мусаның яшьлек дуслары --- һәм гомумән авыл халкы яшь Мусаның кыю һәм колач җитмәслек эш алып баруын сокланып сөйлиләр.* Г.Кашшаф. **Колач салып (ташлап)** Бар көченә, колачын җәеп җибәреп, киң хәрәкәтләр белән. *Колач салып йөзеп киттек, Диңгезләр киң димәдек.* Р.Хәлиуллина. *Колач салып йөзгәненә, балыктай хәрәкәтләнгәненә сокланып-көнләшеп караган иптәшләре аны куып җитү турында хыяллана да алмыйлар хәтта.* Р.Әмирхан

**КОЛАЧА** *и.* **1.** Төрле үлчәмдәге шакмаклардан торган ала тукыма

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый тукымадан тегелгән яисә эшләнгән. *Колача юрган*

2) Аксыл җирән, кола төстәге. *Колача аттан йөк ауды, Куышны кая артармын [төярмен]?* Дастан. *[Аның] өстендә колача кызыл җилән.* Ф.Кәрими

**КОЛАЧЛА́У** *ф.* **1.** 1) Колач эченә алу, куллар белән бөтен колач җиткәнче кочаклау. *Ике кеше колачлый алмаслык имән. Кайбер токымнарның аерым кәүсәләре шактый юан була, 5–6 кеше дә аны чак кына колачлый.* Физик география

2) Колач (*1 мәгъ.*) белән үлчәү

3) Колач салып йөзү, кроль стиле белән йөзү. *Тегендә ирләрнең, киң колачлап, түгәрәк тирән ятуда йөзгәннәре күренде.* Г.Ибраһимов. *Дустым ай нурларыннан тукыган ялтыравыклы көмеш сукмак уртасыннан колачлап йөзеп бара иде.* М.Юныс

4) *күч.* Үз йогынтысы астына алу, үзенең эшчәнлек даирәсенә җәлеп итү. *Мин табигать кочагында яшим, аңа буйсынам, ләкин аны аң-гакылым белән колачлый алам.* А.Тимергалин. *Дөрес, идарә итү кыенлыклары аркасындамы, әллә башка сәбәптәнме, Аляскадан баш тартырга туры килә. Әмма колачлап булмастайны колачлау омтылышы югалмый.* Ә.Рәшит

**2. колачлап** *рәв. мәгъ.* Колач чамасында. *Канатларын җәйсәң, ун колачлап булыр, валлаһи...* Р.Батулла

**Колачлап бетерү** Тәмам колачлау, тулаем, барысын да колачлау. *Күрәсең, дөньялыкта һәммәсен дә колачлап бетереп булмый торгандыр.* Р.Фәйзуллин

**Колачлап тору** Колачланган хәл кичерү; колачланган хәлдә булу. *Егет имәнне колачлап тора иде*

**Колачлый бару** Торган саен ныграк колачлау. *Киресенчә, әлеге тискәре күренешләр яшәешне торган саен киңрәк колачлый барды.* Ф.Садриев

**КОЛАЧЛЫ** *с.* 1) Чиксез, гадәттән тыш, чамадан тыш зур

2) Тирән эчтәлекле, күп мәсьәләләрне эченә алган, күпьяклы. --- *Фаҗиганең ач күзенә карап язылган «Сөембикә»дән дә күркәмрәк рухлы, аңардан сәнгатьчә гүзәлрәк, олырак, колачлырак --- шигъри әсәрне хәтерләмим.* Т.Галиуллин. *Татар әдәбияты тарихында XX йөз башы нинди урын тота? Бу – бик колачлы сорау.* Н.Хисамов. *Югарыда аталган композиторларның колачлы һәм ялкынлы, сугышчан һәм тирән музыкасы хәзер дә дулкынландыра.* Казан утлары

3) Сәләтле, киң эрудициягә ия булган. *Нәҗип Җиһанов – техникум һәм консерватория аркылы системалы югары музыка белемен үзләштергән, зур культуралы, колачлы композитор.* Татарстан

4) *күч.* Масштаблы, зур күләмле. *Әсәрдә үзәк образ никадәр колачлы һәм масштаблы булса, аңа шулкадәр күбрәк «йөк» салып була.* Казан утлары

**КОЛАЧЛЫК** *с.* Колач (*1 мәгъ.*) озынлыгындагы, колачка сыярлык. *Тәкәләр, чыннан да, сокланырлык дәрәҗәдә мәһабәт иделәр: нечкә аяклар, ---*

*төрек кылычы кебек бөгелгән, бер-бер колачлык сырлы мөгезләр!* М.Усманов

**КОЛАЧЛЫЛЫК** *и.* Колачлы булу; зур күләмлелек, масштаблылык. *Һади Такташның һәртөрле вакыйгаларга мөнәсәбәте гаять киң масштаблы. Шундый киң колачлылыкның үрнәге – бөтендөнья әдәбият шедеврлары белән рәттән куелырдай «Җир уллары трагедиясе».* Мәдәни җомга

**КОЛАША** *и.* 1) Төрле хуҗалык эшләрендә кулланыла торган киң улак яки зур сай тагарак. *Ашлык киптерү колашасы*

2) Агачтан чокып ясалган тар һәм сай улак. *Ә кайчандыр шушы авыл егете Сәлмән күзәнәкләрен ачып тирәнәйткән, колаша куеп ныгыткан чишмә көмештәй саф суы белән ничәмә-ничә еллар буе Тормыш авылы халкының, меңнәрчә юлчыларның сусавын басты, аларга көч, куәт биреп акты.* А.Хәйретдинова

3) Мәет юа торган җайланма. *Акчурин агай башчылык итә иде. – Барыгыз, мәетне алып керегез. Ә синең, Нигъмәтулла бабай, колашаларыңниләрең әзерме?* Х.Сарьян

4) Кисеме ярымтүгәрәк булган яки шуны хәтерләткән һәртөрле сыешлык

**КОЛАШАЛАНДЫРУ** *ф.* Колаша формасына китерү, бераз калҗайту

**КОЛАШАЛАНУ** *ф.* Колаша рәвешенә килү, колаша формасын алу

**Колашалана төшү** Бераз колаша формасын алу

**Колашаланып бетү** Бөтенләй колашаланган хәлгә килү. *Озак суда ятудан агач такта колашаланып беткән*

**Колашаланып калу** Берәр эшхәлдән соң колашаланган хәлгә килү. *Яңгырдан соң фанер такта колашаланып калган*

**КОЛАШАЛЫ** *с.* 1) Үзендә колашасы булган. *Колашалы конвейер*

2) Колашасыман, колаша формасындагы

**КО́ЛБА** *и. нем.* Химик тәҗрибәләр үткәрү өчен кулланыла торган озын муенлы, кабарынкы формалы пыяла савыт

**КОЛБАСА** *и. рус* Эчәккә яки ясалма эчәк формасындагы яры тышчага тутырып махсус әзерләнгән казылык. *Гөлсылу кунагына үзе алып кергән колбасасы белән бәрәңге кыздырган*... Я.Зәнкиев

**КО́ЛБАЧЫКЛАР** *и. күпл. анат.* Күзнең челтәр катлавында төсләрне сизә торган нерв очлары; *русчасы:* **колбочки**

**КО́ЛБИЛӘҮЧЕ** *и.* Коллары булган, колларга хуҗа булган кеше. *Аристотель, колбиләүчелек җәмгыятенең аристократиясе вәкиле буларак, сәнгатьнең тәрбияви функциясен фәкать колбиләүчеләр өчен генә дип карый.* Нәфасәт. *Спартакның төп көчен колларын бөек күтәрелешкә, колбиләүчеләргә каршы сугышка оештыра белүендә күрә.* А.Әхмәт

**КОБИЛӘҮЧЕЛЕК** *и.* 1) Кобиләүче булу

2) Кол хезмәтеннән файдалануга корылган иҗтимагый-икътисади формация. *Колбиләүчелек строе кешелек җәмгыятенең үсешендә зарури этап булган.* Политэкономия

**КОДСИ** *с. гар.* Мөкатдәс, изге. *Рух өрдең син, халкың терегездең син, Гали күңлең чәчте кодси нур.* М.Фәйзи. *Ләкин шул ике ут эчендә янган минутта ул әллә нинди бер тәэсир белән Зыя кашында үзенең гаепле икәнен, ул кодси мөнәсәбәтнең өзелүенә үзе сәбәп булганлыгын хис итә дә --- күңеленә җиңелә.* Г.Ибраһимов. *Кодси хәдисләребезнең берсендә Аллаһыбыз әйткән сүзләр китерелә: «Яхшы гамәлләре өчен кешеләр һәр очракта да бүләкләнә».* Безнең гәҗит

**КОЛГА** *и.* 1) Гадәттә вертикаль утыртып куелган озын шома багана. *Мәйдан уртасында озын колга утырткannar, колга тирәсендә өсләренә яңа бишмәт кигән --- куштаннар тулгана иде.* М.Галәү. *Колга башында сөлгетастымал, метр-метр ситсылар, өрңа баш яулыклары җилдә җилфердиҗилфердi арып беткәннәр дә колгага уралып тынып калганнар.* Ф.Хөсни. *Мактанчык әтәч колгасын селкетеп канатларын шапылдатты да тагын шәрран ярды.* М.Мәһдиев

2) *спорт.* Сыгылмалы озын таяк формасындагы спорт снаряды. *Колга белән сикерү*

3) *диал.* Кое сиртмәсе

4) *диал.* Каба агачы

5) *диал.* Камыл

6) Түшәмгә якын итеп горизонталь урнаштырылган агач. *Колгада апамның кыек яулыгы-косынкасы эленеп тора.* Г.Якупова // *диал.* Киштә. --- *Габдулла кинәнеп кулын җәеп җибәрде, киерелеп алганда, колгадагы себеркеләргә орынды.* Ә.Гаффар

7) *күч. гади. с.* Нәзек, озын буйлы кеше турында. *Чабатачы кылый Хәбетдиннең өлкән кызы Колга Көмешбикәне егерме алты яшенә тикле соратучы да, юатучы да табылмады.* М.Кәрим

◊ **Колга буйлы** *к.* **колга** (*7 мәгъ.*). *– Безнең бөтенебезне үп, – ди колга буйлысы, – шуннан соң, бәлки, җибәрербез.* Ф.Шәфигуллин. *Озын шинель кигән колга буйлы вахтёр --- наряд кенәгәсенә карандаш белән билге ясап кычкыра.* И.Салахов

**КОЛГАЛАНУ** *ф.* 1) *диал.* Камыл җибәрү, камыллану. *Арыш колгалану*

2) *күч.* Кинәттән нәзек, озын булып китү; сузаю

**КОЛГАЛЫ** *с.* Озын таякка беркетелгән яки шул таякка сапланган. *Колгалы алма җыйгыч. Колгалы телевизор антеннасы*

**КОЛГАЛЫК** *и.* **1.** Колгага яраклы киртә, агач кәүсәләре

**2.** *с. мәгъ.* Колгага ярарлык. *Су алып килүгә, ир колгалык каен агачларын сөйрәп тә килә иде инде.* Г.Якупова

**КОЛГАСАР** *с.* Бик озын буйлы, нәзек (кеше тур.). *Аннары алар янына бер колгасар егет килде.* Г.Әпсәләмов

**КОЛГОТКИ** *и. чех* Аякларга сыланып торган, балаклары оекбаш белән бергә кушылган ыштан төре. *Надежда Николаевна исә сүзен дәвам итеп: – Хәзер менә Катюшабызга матур күлмәк, матур колготки кигертеп җибәрәчәкбез, – дип, алдан ук складтан алып куелган киемнәрне кызга кидерә башлады.* Ф.Яруллин

**КОЛЕНКОР** *и. фр.* **1.** Бик нык крахмалланган яки махсус состав белән туендырылган киҗе-мамык тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан эшләнгән яки тегелгән. *Коленкор башлык.*

*Коленкор тәрәзә пәрдәсе. Коленкор простыня*

**КОЛЕЯ** *и. рус* 1) Юлда тәгәрмәчләрдән барлыкка килгән тирән эз. *Тагын ун минуттан йомшак колеядан безнең машина ялгыз гына бара иде.* М.Мәһдиев

2) Тар рельслы юл

**КОЛИТ** *и. гр. мед.* Юан эчәкнең лайлалы тышчасы ялкынсыну

**КОЛИ́БРИ** *и. исп. зоол.* Керәшәсыманнар отрядыннан матур каурыйлы, озын томшыклы бик кечкенә кош; чебенкош. *Колибрилар баллы нектар һәм бөҗәкләр белән тукланалар.* Биология

**КОЛЛАГЕН** *и. гр. хим.* Күпкүзәнәкле организмнар тукымаларының (тире, кимерчәк, сөяк, сеңер һәм сеңерле бәйләвечләрнең) нигезен тәшкил итә торган аксымлы матдә. *Коллагеннан желатин җитештерелә.* Биология

**КОЛЛЕ́ГА** *и. лат.* 1) Эш, уку, профессия буенча иптәш; хезмәттәш. *Коллегам минем үз-үземне тотышымда явыз ниятнең сизелмәвен --- күргәч, тынычланды.* Т.Галиуллин. *Карташевский немец коллегаларны көч-хәл белән генә тынычландыра алды.* Ж.Тәрҗеман. *[Яңгура:] Рәхмәт сезгә, Әбүзәр Гиреевич. Коллегалар алдында сез мине күтәрдегез дә, канатландырдыгыз да.* Г.Әпсәләмов

2) Кәсептәш, һөнәрдәш. *Фотографның төшеме мин хыялланганча түгел. Казан тирәсендә минем коллегалар көненә иллешәрне сугалар.* Г.Мөхәммәтшин

**КОЛЛЕ́ГАЛЫК** *и.* Коллега булу

**КОЛЛЕГИАЛЬ** *с.* Бергәләп үзара киңәшү-килешү нигезендә башкарылган; бер төркем кешеләр тарафыннан алып барыла торган. *Аңа республиканың барлык хакимият органнары, предприятиеләргә керү, аларның коллегиаль органнары эшчәнлегендә катнашу чикләнми.* Ватаным Татарстан

**КОЛЛЕГИАЛЬЛЕК** *и.* Коллегиаль рәвештә хәл итү, эш башкару

**КОЛЛЕ́ГИЯ** *и. лат.* 1) Карар чыгару органы буларак вакытлыча билгеләнгән белгечләр төркеме. *Ниһаять, аны [Ибраһим Әмирханны] ТАССР Главсуды һәм Наркомюст коллегиясе әгъзасы итеп раслау турында карар кабул ителә.* Р.Әмирхан. *Кичә ул коллегия утырышыннан төнге уникенче яртыда гына кайтты.* А.Шамов. *Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе*

2) Киңәшләшү һәм идарә итү органы буларак кайбер профессия кешеләре берләшмәсе. *Казанда үткәрелгән Бөтенроссия мөселман укытучыларының съездында Татарстанда беренче гыйльми оешма – Гыйльми һәйәт (фәнни коллегия) сайланып, аның каршында төрле бүлекләр оеша.* В.Хаков. *Адвокатлар коллегиясе. Суд коллегиясе*

3) *тар.* Россиядә XVIII гасырда үзәк идарә. *Тышкы эшләр коллегиясе. Хәрби коллегия*

4) Көнбатыш Европа илләрендә һәм революциягә кадәр Россиядә кайбер уку йортларының бер төре

**КО́ЛЛЕДЖ** *и. ингл.* Бөекбритания, Америка һ.б.ш. кайбер илләрдә югары яки урта, хәзерге Россиядә бары урта белем бирә торган уку йорты. *Моннан биш-алты ел элек, колледжда укыган чакта, алар аерылмас дуслар иде. Колледжны тәмамлагач, аларның юллары аерылды.* А.Тимергалин. *Оренбургның мәшһүр сәүдәгәре Әхмәд Хөсәенов аеруча зиһенле шәкертләрне үз хисабына Төркиянең Бәйбурт шәһәрендәге махсус америкaн колледжына укырга җибәрә торган була.* Р.Әмирхан. *Бүген алар колледжда алдынгылар рәтендә.* Ватаным Татарстан

**КОЛЛЕЖ** *и. фр.* Франция, Бельгия кебек илләрдә урта белем бирә торган уку йорты

**КОЛЛЕКТИВ** *и. лат.* **1.** Уртак максатлар һәм уртак эшчәнлек нигезендә берләшкән кешеләр төркеме. *Ничектер тиз арада гына ул зур коллективның күзгә күренгән бер кешесе булды да китте.* А.Гыйләҗев. *Владимир Әлмәттә чакта бораулаучылар коллективы эчендә кайнап, аларның балалары белән аеруча дус булып яшәде.* Ә.Маликов. *Нәҗип дәмелла җитәкләгән кызлар мәктәп-мәдрәсәләрендә заманы өчен зур гына педагогик коллектив туплана.* Р.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Уртак, гомуми. *Коллектив йөкләмә. Коллектив шартнамә*

2) Күмәк көч белән башкарылган. *Һәм Хәлиулла, бичара, мондый коллектив һөҗүмгә түзә алмый, үкереп елап җибәрә һәм өенә кайтып китә.* М.Мәһдиев. *Безгә бүгенге сөйләшү нигезендә «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарына коллектив хат язарга кирәктер.* Мирас

**КОЛЛЕКТИВИЗА́ЦИЯ** *и. рус к.* **коллективлаштыру**. --- *Ә аннан Сталин «вак буржуаз» элемент дип саналган мужик агайны чынбарлыкта көчләп үткәрелгән коллективизация тәртәләре арасына җиккән заман бит бу.* Ә.Рәшит

**КОЛЛЕКТИВИЗМ** *и. рус* Шәхси мәнфәгатьләрне иҗтимагый мәнфәгатьләргә буйсындыруга нигезләнгән хезмәттәшлек, үзара ярдәмләшүчелек. --- *футбол уеннарында бердәмлек рухы, коллективизм сеңеп өлгергән малай актив рәвештә Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апа кысасыннан ычкынып маташа иде инде.* А.Гыйләҗев. *Гомумән, ул чорда аерымлыкны, кабатланмасны ачуга караганда, уртаклыкны, коллективизм сызыкларын эзләү мәртәбәлерәк саналды.* Т.Галиуллин

**КОЛЛЕКТИВЛАШТЫРУ** *ф.* Уртак милеккә әверелдерү, (аерым хуҗалыкларны) колхозлаштыру

**Коллективлаштыра башлау** Коллективлаштырырга тотыну

**Коллективлаштырып бетерү** Барысын да коллективлаштыру

**Коллективлаштырып тору** Даими, әледән-әле коллективлаштыру белән шөгыльләнү

**Коллективлаштырып чыгу** *к.* **коллективлаштырып бетерү**

**КОЛЛЕКТИВЛАШУ** *ф.* Коллектив булып оешу; колхозлашу. *Шәһәргә алар коллективлашу чорында тайганнар, тик анда да җирдә казынып, крестьяннарча тормыш итәләр.* В.Астафьев

**Коллективлашып алу** Тиз генә коллективлашкан хәлгә килү

**Коллективлашып бетү** Барысы да коллективлашу

**КОЛЛЕКТИВЛЫК** *и.* Коллектив белән эш итү күренеше; күмәклек, бердәмлек. *Коллективлык шартларында эш алып бару*

**КОЛЛЕКТИВЧЫ** *и.* 1) Коллектив өчен тырышучы

2) Коллективчылык тарафдары

**КОЛЛЕКТИВЧЫЛ** *с.* Коллективны яратучан, коллективка тиз ияләнүчән. *Коллективчыл кеше*

**КОЛЛЕКТИВЧЫЛЫК** *и.* 1) Коллектив белән яшәргә тырышу күренеше. *Кешеләрдә коллективчылык рухы – шулай ук ата-бабадан килгән матур омтылыш. Коллективчылыкның бик матур үрнәген безнең күрше Камәр түтидә күрергә була иде.* М.Мәһдиев

2) *к.* **коллективлык**

**КОЛЛЕ́КТОР** *и. лат.* 1) Нәрсәне дә булса җыю, туплау һәм бүлеп тарату белән шөгыльләнә торган оешма. *Китапханә коллекторы* // Тәрбиячесез калган балаларны балалар йортларына тарату учреждениесе

2) Нинди дә булса үрнәкләр, өлгеләр җыя, саклый һәм тасвирлап, тәртипкә салып баручы хезмәткәр

3) *тех.* Төрле торбалардан, каналлардан, юллыклардан килгән газ яисә сыеклыкларны җыеп, берәр якка җибәрү өчен төзелгән канал яки торба; җыйгыч торба. *Суыткыч коллектор. Яңгыр сулары коллекторы*

4) *тех.* Ток юнәлешен автомат рәвештә үзгәртеп торучы җайланма

**КОЛЛЕ́КТОРЛАР** *и. күпл. геол.* Куышлыклары нефть, газ һәм су белән тулган күзәнәкле яки чатнаган тау токымнары (комташ, известьташ һ.б.)

**КОЛЛЕКЦИОНЕР** *и. фр.* Нинди дә булса коллекция җыючы һәвәскәр. *Соңыннан мин коллекционерларның төрлесен күрдем, әйтик марка, борынгы сәгать, авторучка, зажигалка, фотоаппарат җыючылар.* М.Галиев

**КОЛЛЕКЦИОНЕРЛЫК** *и.* Коллекция җыюга һәвәскәрлек, коллекционер булу. *Коллекционерлык дәрте кузгалу. Коллекционерлык эше белән шөгыльләнү*

**КОЛЛЕ́КЦИЯ** *и. фр.* Бер төрдәге, бер иш нәрсәләрнең билгеле бер системада тупланган җыелмасы. *Аликның шактый ук күләмле коллекциясендә иң модалы ансамбльләр һәм җырчыларның тавышы язылган тәлинкәләр дә аз түгел түгелен.* А.Сафин. *[Врач:] – Менә бу коллекцияне карагыз әле, иптәшләр, – диде. Коллекция бик сәер иде: папирослар, сигаретлар, эрелевaклы трубкалар.* Г.Мөхәммәтшин. *Музейда аеруча мөһим экспонатлар арасында дөнья халыклары әлифбалары коллекциясе бар.* Мәдәни җомга

**КОЛЛЕ́КЦИЯЛӘҮ** *ф.* Коллекция җыю; коллекция итеп җыю. *Маркалар коллекцияләү. Открыткалар коллекцияләү*

**Коллекцияләп бару** Даими рәвештә коллекцияләү эше белән шөгыльләнү. *Күренекле шәхесләрнең портретларын коллекцияләп бару*

**Коллекцияләп килү** *к.* **коллекцияләп бару**

**Коллекцияли башлау** Коллекцияләргә тотыну

**КОЛЛЕ́КЦИЯЧЕ** *и. к.* **коллекционер**

**КОЛЛИ́ЗИЯ** *и лат.* 1) Яшәештә, тормышта һәм фикерләүдә хәл ителмәстәй булган каршылыклы хәл

2) *әд.* Әдәби әсәрдә сурәтләнгән характерларда чагылган теләк-омтылышларның, мәнфәгатьләрнең бәрелеше, шәхес белән тирәлек арасында яисә геройның үз күңелендә туган каршылык. *Ш.Камал әсәрләрендә яратып бирелгән коллизияләрнең бере – хыял белән хакыйкатьнең бәрелеше.* Г.Нигъмәти. *Әсәрнең нигезенә Кырым – Польша мөнәсәбәтләренә кагылышлы коллизия салынган.* Н.Хисамов. *Бәетләрнең бер өлешендә иҗтимагый тормыш белән бәйле коллизияләрне һәм социаль төсмерләрне күрү кыен түгел.* Татар халык иҗаты

2) *физ.* Көтелмәгән зур көч белән бәрелешү яки очрашу процессы

**КОЛЛО́ДИЙ** *и. гр.* Кайбер органик матдәләрне этил спиртында һәм эфирда эретеп ясала торган ябышкак эремә (медицинада яраларны ябыштыру өчен һәм фотографиядә кулланыла)

**КОЛЛО́ИД** *и. ингл. хим.* **1.** Эремәләрдә кристаллашмый һәм органик элпәләр аша да үтеп чыга алмый торган матдә (мәс., аксым, крахмал, җилем һ.б.ш.). *Коллоидлар химиясе*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый матдә үзлекләренә ия булган. *Үлчәмнәре буенча кисәкчек элементар, микроскопик --- коллоид төрләргә бүленә.* Химиядән күнегүләр китабы. *Туфракның өске катламы барлык коллоид матдәсен югалтканлыктан, аның механик төзелеше комсылга әверелә.* Җир һәм туфрак

2) Үзендә коллоидлар булган. *Коллоид кисәкчекләр газ, сыекча яки каты халәттә булырга мөмкин.* Химия. *Чистарту станцияләрендә суны каты фазадан йөзмә һәм коллоид кисәкчекләрдән арындырып чистарту*

**КОЛЛО́ИДЛЫ** *с. хим.* 1) Коллоиды булган. *Коллоидлы катнашма*

2) *к.* **коллоид** (*1 мәгъ.*)

**КОЛЛО́КВИУМ** *и. нем.* 1) Укытучы тарафыннан студентларның белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен оештырыла торган әңгәмә

2) Нинди дә булса докладлар ясап уздырылган киңәшмә. *Табигый ресурсларны саклау мәсьәләсенә багышланган коллоквиум*

**КОЛЛЫК** *и.* 1) Кол булу. *Коллыгыңа риза булмау*

2) Колбиләүчелеккә нигезләнгән иҗтимагый-сәяси корылыш. *Испаннар, колонияләрдә индеецларның җирләрен тартып алып, үзара бүлешәләр, җирле халык коллыкка төшерелә.* Урта гасырлар тарихы

3) *дини* Бәндәлек, бәндәчелек, Алланың колы булу сыйфаты

4) *күч.* Иҗтимагый һәм сәяси яктан бәйлелек, буйсынучанлык, мөстәкыйльсезлек. *Вахит «кяфер» коллыгында йөреп, --- укулар яңартып, бер авылга мулла булып, матур гына кызга өйләнүен уйлап, күңелен баса иде.* З.Һади. *Кем нәрсә турында гына язмасын, М.Мәһдиев кыйбласына тугрылыклы, халкыбызда ирекле яшәү рухын тергезү, аны коллык психологиясеннән арындыру, телен саклау өчен, мәгърифәтле, олы җанлы зыялылар кирәклекне үзәктә тота.* Т.Галиуллин. *--- Ә без, кешеләр, коллык-әсирлекнең теләсә нинди формасына каршы. Нәкышле коллык – барыбер коллык.* А.Тимергалин

5) *күч.* Бәйле булу хәле. *«Зыялы кешеләр рәтенә басу өчен, миңа үземнән коллыкны тамчылап чыгарырга туры килде», – дип язган Чехов.*

Т.Галиуллин. *Караңгылык, коллык, ярлылыклар безнең бабайларны изгәннәр.* И.Хәйруллин. *Төп максатларның берсе буларак, халкыбызга гасырлар дәвамында сеңдерелә килгән коллык, куркаклык психологиясен җиңү, яшьләрнең аң кимәлен үстерү торды.* Казан утлары

**КОЛМАК** *и.* 1) Киндерчәләр семьялыгыннан, кайбер культуралы төрләре сыра кайнатуда, икмәк пешерүдә, медицина һәм парфюмериядә кулланыла торган икеөйле үрмәле үсемлек. *--- Ярларында таллар, уем-уем зирек агачлары үсә, зирекләрне иркәләп колмаклар чорный, колмак араларында сандугачлар өзмәс сайрый.* А.Гыйләҗев. *Гаҗәп зур алсу роза чәчәкләре арасындагы колмак сабагыдай сыгылмалы яшел сызыклар аңа бормаланып беткән тоташ бер юлны хәтерләтә.* А.Сафин. *Егетнең тәне җилдән җитез, колмактан җиңел. Ә теле менә нигәдер авыр.* Г.Бәширов

2) Шул үсемлекнең нарат күркәсе сыман яшькелт сары төстәге чәчәге. *[Тракторчы:] Колмак салып, сарымсак салып ясалган сыра --- бар.* М.Гали. *--- Андагы җиләк-җимешне бетергәнче җыю мөмкин булмагандыр. Шомырт яки балан җыйсаң – чиләкләп, колмак дисәң – капчыклап...* М.Әмир. *Әдрән белән минем алда да колмак чүбе йөзеп йөргән кызгылт бал тора иде.* Х.Сарьян

**КОЛМАКЛЫ** *с.* Нәрсәгә дә булса ачыту яки тәм бирү өчен колмак кушылган. *Колмаклы эчемлек. Колмаклы сыра*

**КОЛМАКЛЫК** *и.* 1) Кыргый колмак күп үсә торган урын

2) Махсус колмак чәчелгән җир участогы. *Колмаклыкта эшләү*

**КОЛМАКЧЫ** *и.* 1) Колмак җыючы

2) Колмак үстерүче

**КОЛМАКЧЫЛЫК** *и.* Авыл хуҗалыгының колмак игү белән шөгыльләнә торган тармагы; колмак үстерү эше, шөгыле. *Колмакчылык белән шөгыльләнү. Колмакчылык бригадасы*

**КОЛОВОРОТ** *и. рус* Агач әйберләрне кул белән бораулап тишү өчен кулланыла торган эш коралы; әйләндермәле борау. *Кыршау астыннан түбәнрәк субайны коловорот белән аркылыга тишәләр дә гади тимер таяк яки эш коралы булган «лом» тыгалар.* М.Мәһдиев

**КОЛО́ДА** *и. рус* Уен карталарының тулы комплекты. *Белдерүдә Карахмәтнең, Геркулес сыйфатында чыгып, ике колода карта ертачагы әйтелгән.* И.Нуруллин. *Бикләмишев --- атлас карталар колодасыннан аерылып чалкан ятучы пиковая даманы үзенә таба тартты.* К.Нәҗми

**КОЛО́ДКА** *и. рус* 1) Аяк киемнәре теккәндә, эшләгәндә кулланыла торган, аяк табанына охшатып агачтан ясалган форма; аяк киеме калыбы

2) *махс.* Корыч һ.б. металларны эретеп коюда кулланыла торган форма

3) Ике аягы да булмаган кешенең куллары белән таянып хәрәкәт итүе өчен җайланган агач шакмак

4) Элекке заманда тоткыннарның, кулга алынган кешеләрнең аяк-кулларына яки муеннарына кидерә торган зур агач богау. *Картның муенына агач колодка киерткәннәр.* Г.Әпсәләмов

5) Күкрәккә орден тасмалары тагып йөртү өчен махсус эшләнгән планка. *Иван дәдәнең күкрәгендә орден-медаль колодкалары байтак, элемтәче булган.* М.Мәһдиев

6) Тормоз шкифы яки тәгәрмәч тугымы янына хәрәкәтне тоткарлау яки булдырмау өчен кыстырып куела торган, билгеле бер калыпта махсус эшләнгән агач яки тимер башмак

**КО́ЛОКОЛ** *и. рус сөйл.* Металлдан коеп зур конус рәвешендә ясалган, эченә асылган теле стенасына бәрелеп, яңгыравыклы тавыш барлыкка китерә торган зур кыңгырау; чаң. *Сторож колокол чукмарын нык кына иттереп ике тапкыр бәргәч тә, ялтыравыклы колокол тавышы моңлы гына озаеп чыңлап китте.* Ш.Камал. *Бөтен вокзал өстенә икене бәргән җиз колокол тавышы тарала.* Г.Минский

**КОЛОН** *и. лат. тар.* 1) Борынгы Рим империясендә эре җир биләүчедән арендага җир кишәрлеге алган кеше. *Яулап алынган илләрдә качкын коллар һәм колоннар элеккеге колбиләүчеләренә кире кайтарыла.* Урта гасырлар тарихы. *Эре утарлар Кече Азиядә генә сакланып кала, әмма алардагы коллар һәм колоннар саны кискен кими.* Мирас

2) Латин Америкасы илләрендә җир хуҗасына буйсынулы арендатор

**КОЛОНИАЛИЗМ** *и. сәяси* Икътисади һәм сәяси яктан көчсезрәк булган илләрне колония хәленә төшерү һәм шул хәлдә тоту сәясәте. *Колониализм мирасын бетерү*

**КОЛОНИАЛЬ** *с.* 1) Колониягә әверелдерелгән, колония хәлендәге. *Колониаль һәм ярымколониаль хәлдә яшәгән төрки телле халыклар арасында бу хәрәкәт [мәгърифәтчелек, азатлык идеяләре] исә бик зәгыйфь иде.* Х.Хисмәтуллин. *Колониаль илләр. Колониаль территорияләр. Колониаль биләмәләр*

2) Колониализмга караган, колониализмга бәйләнешле. *Колониаль яулап алу сугышларына катнашучы солдатлар да үзләренең кеше үтерүче, җимерүче икәнлекләрен аңлый алмаганнар.* М.Юныс. *Әмма патша самодержавиесенең колониаль политикасын тормышка ашыручылар Казан татарлары арасында барган бу прогрессив башлангычларны системалы рәвештә тыеп киләләр.* Октябрьгә кадәрге татар театры. *XV–XVI йөзләрдә колониаль сәясәттә үзенчәлекле юнәлеш барлыкка килде...* М.Зәкиев

3) Колонияләр биләүче. *Колониаль державалар*

4) Колонияләрдә җитештерелгән; колония территориясендә оештырылган. *Колониаль товарлар. Колониаль гаскәр*

**КОЛОНИЗА́ТОР** *и. сәяси* Колонияләр яулап алучы. *Хина агачының кабыгы тропик илләрне яулап алган бик күп колонизаторларның – голландиялеләрнең һәм инглизләрнең тормышларын коткарып калган.* Н.Верзилин. *Колонизаторларның барысы да беренче чиратта, үзләренә буйсындырылган халыкларның телләренә каршы көрәшкән.* Мәдәни җомга

2) Колонияләр белән идарә итүче яисә колониядә зур хуҗалык тотучы

3) Кеше яшәми торган, буш урыннарга күчеп утыручы; колонист (*1 мәгъ.*)

**КОЛОНИЗА́ТОРЛЫК** *и.* 1) Колонизатор булу. *Колонизаторлык омтылышлары*

2) Колонияләр белән идарә итү. *Колонизаторлык сәясәте*

**КОЛОНИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Чит илне басып алу һәм аны колониягә (*1 мәгъ.*) әйләндерү эше. *Әле генә хакимияткә килгән яңа хөкүмәт ханлыкны урыс колонизациясеннән ничек кенә булса да коткарып калырга тырыша.* Ф.Урманче

2) Буш яткан җирләрне хуҗалык ягыннан үзләштерү эше

**КОЛОНИЗА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. к.* **колонизацияләү**

**КОЛОНИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Колониягә әверелдерү. *Рус байларын Уралның, Себернең иксез-чиксез байлыклары кызыктыра. Ә Себерне колонизацияләү юллардан башка мөмкин булмый.* Казан утлары

2) Хуҗалык ягыннан үзләштерү

**Колонизацияләп бетерү** Бөтенләй, тулысынча колонизацияләү

**КОЛОНИСТ** *и. лат.* 1) Кеше яшәми торган урынга килеп яңа җир үзләштерүче. *Жюль Верннның «Серле утрау» исемле романындагы Линкольн утравында ялгыз яшәргә дучар ителгән колонистлар да --- бернәрсә белән дә авырмыйлар.* Н.Верзилин. *Голландиянең хорафатчыл колонистларына бик күп коточыргыч хәлләр кичерергә туры килгән.* Кызыклы физиология

2) Колониядә (*3 мәгъ.*) торучы (яшәүче). *Колонистлар Рәсәй туфрагына тамыр җибәргән якташларыннан --- һәрвакыт таяныч табалар иде.* К.Нәҗми

**КОЛОНИСТЛЫК** *и.* Колонист булу. *Колонистлыкның кыенлыклары*

**КОЛО́НИЯ** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Рим империясендә колоннар күчереп утыртылган җир, урын; колоннар яшәгән төбәк. *Борынгы Греция тарихы аерым шәһәр-дәүләтләр арасында, метрополияләр белән колонияләр арасында барган сугышлар белән тула.* Политэкономия

2) Икенче бер дәүләт тарафыннан басып алынган ил, аерым территория. *[Гафури] Европа империализмы тарафыннан таланучы Көнчыгыш колония халыкларының хәлләрен сурәтли.* М.Җәлил. *Алтынчы ай инде французларның Төньяк Африкадагы колонияләрен тоташтыру өчен ясалган Әлҗәзаир – Фас тимер юлы өзлексез гаскәр ташый.* Ш.Усманов. *Россия тарихында «колония», «яулап алу» кебек төшенчәләрне табу кыен; анда «яңа җирләрне үзләштерү», «кушу» кебек тәгъбирләргә өстенлек бирелә.* Ә.Рәшит

3) Икенче дәүләттән, илдән күчеп килгән кешеләр бергәләп яши торган урын (авыл, шәһәрчек, квартал). *Болгар дәүләтенең шәһәрләрендә хәтта кечкенә рус колонияләре дә була.* Казан утлары

4) Чит илдә яшәүче якташлар берләшмәсе. *Менә шундый борчулы, шомлы бер вакытта Финляндия татарларының аксакаллары бердәнбер хакыйкый юл сайлыйлар: ят илдәге якташларны берләштереп, мөстәкыйль дини-милли колония булып яшәргә хезмәт итүче җәмгыять коралар.* Казан утлары

5) Нинди дә булса бер ягы белән халык массасыннан аерылып торган кешеләр өчен махсус төзелгән торак урыны. *Махаулылар колониясе*

6) Җинаятьче-токтыннар яши һәм эшли торган кырыс режимлы урын. *Таныклыкта болай диелгән: мин, ягъни Гыйльман Кадыйр улы, 1920 нче елдан алып 1928 нче елга кадәр хезмәт колониясендә тәрбияләнгәнмен.* Н.Дәүли. *Хөкем карарын үтәү өчен, әдипне [Садри Җәләл] Ак диңгез – Балтыйк каналы төзелешенә, хезмәт колониясенә җибәрәләр.* Р.Мостафин. *Гомәрне ниндидер кырыс режимлы колониягәме, «хезмәт белән төзәтү» лагеренамы хөкем итәләр.* Р.Әмирхан

7) *биол.* Күпләп бер тирәгә тупланып, җыйналып үсә-яши торган үсемлек яки җанварлар төркеме (күче һ.б). *Ә хәзер колхозның амбары-келәте тулы, өйалды тулы икмәк, күселәр анда колония-колония булып яшиләр.* М.Мәһдиев. *Сөркә коры тау битләрендә, колонияләргә тупланып, тирән өннәрдә яши.* Зоология. *Тегермән астында, буа кырыендагы субайлар, тал тамырлары арасында сусарлар колония коралар.* Мирас

**КОЛО́НИЯЛЕ** *с.* 1) Колониясе (колонияләре) булган, колониягә ия. *Колонияле империяләр. Колонияле дәүләт*

2) Колония *(7 мәгъ.)* булып, бергә күпләп яши торган. *Колонияле гөмбәләр. Колонияле суүсемнәр*

**КОЛО́НИЯЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Колониягә әверелдерү; көчләп яулап алу. *Латин Америкасы илләрен колонияләштерү чоры. Көчсез илләрне колонияләштерү планы*

2) Яулап алынган яки буш яткан җир-биләмәләргә килеп утыру, аларны үзләштерү

**Колонияләштереп бару** Әкренләп, берсе артыннан берсен колонияләштерү

**Колонияләштереп бетерү** Барысын да колонияләштерү

**КОЛО́НИЯЧЕ** *и. к.* **колонизатор**. *Европа колониячеләре*

**КОЛО́НИЯЧЕЛЕК** *и. к.* **колонизаторлык**. *Колониячелеккә каршы күтәрелү*

**КОЛО́НКА** *и. рус* 1) Торбалардан килгән сыеклыкны агызып алу өчен эшләнгән торбасыман вертикаль җайланма. *Икенче кыз аңа: – Кулына бидрә тоттырасың да колонка юлын күрсәтәсең.* Х.Сарьян. *Мин әйтәм, әрәмәлекне сөреп ташлыйбыз икән, берьюлы ике куян атабыз: бердән, авылга колонкалар кертәбез, икенчедән, ырым-шырымнан котылабыз.* Г.Бәширов. *Колонка кырыенда туктап алдык, әти битен-кулларын юды.* Р.Низамиев

2) Суны газ яки электр энергиясе белән җылыту өчен эшләнгән җайланма. *Чырага ут төртеп газ колонкасын кабызып җибәрәсең дә, ярты сәгатьтән өең май кебек җылына.* Х.Ширмән

3) Автотранспортка ягулык бирү өчен ясалган махсус җайланма. *Бензин салырга дип, колонкалар тирәсенә машиналар тезелешеп киткән.* К.Кәримов

4) Газет-журналлардагы буй-буй текстлар; багана. *Җирле популяр интернет газеталарының берсендә танылган журналистның авторлык колонкасы әлеге мәкаләм өчен көтелмәгән сәбәп булды.* Татарстан

**КОЛО́ННА** *и. лат.* 1) Йорт архитектурасында терәү хезмәтен үтәгән төрле рәвештәге багана. *Болдыр баскычының*

*ике ягындагы йомры колонна сыман баганалар бу йортка үзенә күрә бер затлы үзенчәлек биреп тора иде.* Г.Бәширов. *Бу тирәдә күпчелеге ике-өч катлы өйләр булып, шулар эченнән институт бинасы гына берүзе калкып, фасадындагы колонналары үрә басып тора иде.* Х.Сарьян. *Колонналар өстендәге рим цифрлары бу бинаның унтугызынчы йөз азакларында корылуын әйтәләр.* Г.Әпсәләмов

2) Бер-бер артлы тезелгән кешеләр яисә хәрәкәттәге машиналар сафы. *Иң элек, озын һәм киң колонналарга тезелеп, тавыш-тынсыз, музыкасыз һәм җырсыз җәяүлеләр чыга башлады.* Г.Бәширов. *Колхозларга һәр ел урак өстендә, Уфаданмы, Эстәрлетамактанмы колоннасы белән машина килеп, иген ташырга ярдәм итәләр.* Х.Сарьян. *Алафузов заводы эшчеләре колонналары белән бергә шәһәр думасына Гафур да килде.* Г.Шәрипова

3) Бер-бер артлы тезелгән хәрби әсирләр, хезмәткәрләр, хәрби отрядлар сафы. *Ул колоннаның башында Тозтүбә отряды бара.* Ш.Усманов. *Якушев алдан үзе бара, кызу атлый, вакыт-вакыт колонна сузыла, арттагыларга усал команда яңгырый.* М.Мәһдиев. *Колонна артык зурайганга күрә, үз хәлләренә җитәрлек ышанмаган әсирләр, колонна туктауга карамастан, баруларын дәвам итеп, колония алдына ашыктылар.* А.Расих

**КОЛОННА́ДА** *и. фр. арх.* Колонналар (*1 мәгъ.*) тезмәсе, колонналар рәте. *Бу сарай үзенең фронтоннары һәм колоннадасы белән безнең Казан университеты фасадын хәтерләтә.* Г.Галиев

**КОЛО́ННАЛАП** *рәв.* Колонна рәвешендә, колонналар белән. *Баскыч, таш бинаның үзе кебек, борынгы стильдә колонналап салынган.* Казан утлары

**КОЛО́ННАЛЫ** *с.* Колонналар (*1 мәгъ.*) белән бизәлгән, колоннасы яки колонналары булган. *Оныгы Радик стадионга барышлый аны ак колонналы бинага кертеп калдырды.* М.Галиев. *Колонналы галереялар белән әйләндереп алынган кечкенә генә ишегалды монастырьның үзәге булып тора.* Урта гасырлар тарихы

**КОЛОНТИ́ТУЛ** *и. нем. махс.* Текстлы бит өстендә яисә астында китап, әсәр кебекләрнең авторы, параграф исеме һ.б.ш. мәгълүмат бирелә торган юл. *Аскы колонтитулдагы битләр нумерациясе*

**КОЛОНЦИ́ФРА** *и. нем. махс.* Китап, журнал һ.б.ш.ларның гадәттә колонтитулында урнаштырылган бит номеры. *Колонцифраларны битнең аскы ягында күрсәтү*

**КОЛОРА́ДО КОҢГЫЗЫ** *и. зоол.* Яфрагашарлар семьялыгыннан, гәүдәсе озынча түгәрәк, кабарынкы, кызгылт сарыга кара буйлар төшкән корткыч бөҗәк. *Дөньяда гел бәрәңге белән генә яши ала торган ике җан иясе бар: берсе аның – тулай торак буйдак-сазамаклары, икенчесе – колорадо коңгызы...* К.Кәримов. *Каршыга килгән җәяүле бер абзый аңлата: колхозның бәрәңге басуыннан авылга кайтучы коңгызлар бу, ди. Колорадо коңгызы.* М.Мәһдиев

**КОЛОРАТУР** *с. к.* **колоратуралы**. *«Җиләк җыйганда» – гаҗәеп матур дәртле көй, колоратур сопрано өчен осталык мәктәбе.* Х.Курбатов. *24 җыры язылган дискта җырчының [Р.Ваһапов] халыкчан башкару алымнары бик ачык күренә. Анда тартык авазлар янына сузык авазларны өстәп җырлау, колоратур алымнар бар.* Мәдәни җомга

**КОЛОРАТУ́РА** *и. ит. муз.* 1) Вокаль партиянең техник яктан үтәлеше; тавыш партиясен катлаулы булган калтыратулар, бизәкләр белән башкару

2) Шундый үтәлешкә сәләтле тавыш яки тавыш иясе

**КОЛОРАТУ́РАЛЫ** *с. муз.* Колоратурага ия булган. *Татарстанның атказанган артисткасы Мәбрүрә Рәхмәтуллина колоратуралы сопрано тавышы белән бик күпләрне сокландырган.* Мәдәни җомга

**КОЛОРИСТ** *и. лат.* 1) Колорит белгече, остасы

2) *махс.* Буяулар һәм тоннар белән тәэсирле итеп эш итә алучы белгеч

**КОЛОРИТ** *и. лат. кит.* 1) Сәнгать әсәрләрендә буяуларның, төсләрнең яисә авазларның барысы бергә тудырган гомуми тәэсир. *Колорит салуның бик тә зәвыклы остасы буларак, ул [В.Куделькин] Идел киңлекләренең шигъриятен җанга ятышлы итеп сурәтли белә.* Г.Ахунов

2) Нәрсәнең дә булса үзенчәлекле, үзенә генә хас билгеләр җыелмасы. *Тәрҗемәче китапның татарларга атап чыгарылуын күздә тотып, телендә ислам диненә бәйләнешле язма тел колоритын бирергә тырыша.* М.Ногман. *Котб таң атуны Низами сыман теге яки бу гаскәрнең җиңүе рәвешендә сынландырганда, аерым детальләргә төрки колорит бирә.* Н.Хисамов. *Иске Татар бистәсе Аурупа һәм Русия сәяхәтчеләрен аеруча Көнчыгыш колориты белән җәлеп итә.* Мәдәни җомга

**КОЛОРИТЛЫ** *с.* **1.** 1) Буяулар, төсләр яисә тоннар үзенчәлеге белән аерылып торган. *Сүз әсәрнең эчтәлегенә карап язылган декорацияләр, махсус тегелгән костюмнар, колоритлы гримнар турында бара.* Җ.Фәйзи. *Колоритлы картина*

2) Күзгә ташланган үзенчәлеге булган, оригинальлеге белән истә кала торган. *«Канатланыр чак»ның төп герое Хәлим түгел, Кафия. Әсәрнең иң җанлы, колоритлы образы әнә шул.* Г.Ахунов. *Кол Шәриф үзе күргән вакыйгаларның колоритлы эпизодларын теркәп калдыра.* Н.Хисамов

**2.** *рәв. мәгъ.* Үзенчәлекле рәвештә, тулы итеп. *Романда XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар һәм, гомумән, Рәсәй тормышы, төрле катлау кешеләре язмышы көнитеш детальләре аша шактый колоритлы һәм тулы сурәтләнә.* Т.Галиуллин

**КОЛОРИТЧЫ** *и. к.* **колорист**

**КОЛУН** *и. рус сөйл.* Кыен ярыла торган утынны яру өчен, йөзе чыгарылмаган бик авыр балта. *Сарайда ята колун балта. Түтәсе иңгән, күп сугудан; йөзе тынган, тутыгудан.* Р.Фәйзуллин

**КО́ЛТ-КОЛТ** *иярт. к.* **голт-голт** *Кызылармеец тәмле итеп су эчте, ә берсе, аның колт-колт итеп йотуын тыңлап --- сузылып яткан килеш, күктә ялтыраган йолдызларга текәлде.* А.Расих

**КОЛХОЗ** *и. рус* 1) Авыл хуҗалыгы эшләрен бергәләшеп алып бару өчен

башлыча XX гасырның 30 нчы елларында төзелгән күмәк хуҗалык. *[Газетада] «Интернациональная» колхозының шушы ике көн эчендә ун колхоз аша сикереп, районда бишенче урынга менүе әйтелгән.* Г.Бәширов. *Колхоз тормышын читләтеп үтә алмый язучы. --- М.Мәһдиев колхозларның яхшы якларын да күрә һәм сурәтли алган.* Т.Галиуллин. *Колхоз басуында инде эш төгәлләнгән, игеннәр амбарга, бәрәңгеләр базга кергән.* Казан утлары

2) Шундый хуҗалыкта эшләүче кешеләр коллективы, колхозчылар

**КОЛХОЗДАШ** *и.* Бер колхозда эшләүче-яшәүчеләрнең һәрберсе (берберсенә карата). *Колхоздашлар белән очрашу*

**КОЛХОЗЛАШТЫРУ** *ф.* Аерым крестьян хуҗалыкларын берләштереп колхоз төзү, колхоз оештыру. *Колхозлаштыру һәр җирдә янаулар, куркытулар белән алып барыла.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**Колхозлаштыра башлау** Колхозлаштырырга тотыну

**Колхозлаштырып бару** Эзлекле рәвештә колхозлаштыру эшен башкару

**Колхозлаштырып бетерү** Барысын да колхозлаштыру

**Колхозлаштырып килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә колхозлаштыру эшен башкару

**КОЛХОЗЛАШУ** I *ф.* Колхозга берләшү, колхоз булып оешу (крестьян хуҗалыклары тур.)

**Колхозлаша бару** Берәм-берәм барысы да колхозлашу

**Колхозлашып бетү** Барысы да колхозлашу

**КОЛХОЗЛАШУ** II *и. тар.* Колхозлар барлыкка килү, колхозлар оешу күренеше. *Янтимерләрнең күршесе, әле колхозлашуга тикле, ала биясен көн саен чыбыркы сабы белән тукмый иде.* М.Кәрим. *Әнә мәктәп янында зур бер йорт тора. Колхозлашуга хәтле бу йорт кулак Александрныкы булган.* К.Латыйпов. *Колхозлашу чорында да аңа таякның юан башы эләкте.* Н.Дәүли

**КОЛХОЗЧЫ** *и.* 1) Колхоз әгъзасы, колхозда эшләүче кеше. *Бер колхозчы игенчелек тарихында тиңе булмаган бодай үстергән.* Г.Бәширов. *Һәрхәлдә, ак киндер алъяпкыч ябып, киндер бияләй киеп, ат-арба белән йөргәне хәтердә [Миңлебайның]. Колхозчылардан бер колхозчы инде.* М.Мәһдиев

2) *тар.* Колхозлашу тарафдары

**КОЛЧЕДАН** *и. фр. геол.* Тимер, мышьяк, бакыр сульфидларыннан һәм күкертле катнашмалардан торган тау токымы. *Колчедан күкерт һәм сульфат кислотасы җитештерүдә, мышьяк, бакыр, тимер табуда төп чимал булып тора.* Кызыклы физиология. *Узган гасырның ахырында бакыр колчеданыннан бушаган майлы капчыкларны юган вакытта, колчедан бөртекләренең сабын күбеге белән өскә калкып чыкканын күргәннәр.* Кызыклы физика

**КОЛЧЕДАНЛЫ** *с.* Составында колчедан булган. *Колчеданлы ятмалар*

**КОЛЫН** *и.* 1) Елкы малының бер яше тулмаган баласы. *[Сафа бабай:] – Закир, бәхетең бар икән: башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды, сиңа алмачуар колын бирде, бу колын, ике агасы кебек, асыл сөякләрдән, – дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.* Г.Ибраһимов. *Болын буйларын яңгыратып, колыннар, кырыкмышлар кешнәп җибәрә.* Г.Бәширов

2) **колыным** *тарт. форм.* Гадәттә балаларга иркәләп дәшү сүзе. *Йөрәгемә чабып кердең Минем елгыр колыным.* Җыр. *Кайда син, колыным, күз нурым, бер эндәш, – үлеме, тереме?* Н.Фәттах. *Тансыгым, кай җирең авырта соң, кашкалы колыным, таем!* А.Хәсәнов

**КОЛЫНЛА́У** *ф.* Колын тудыру. *[Шапырай карт:] Нәрсә? Ишетмәдегезмени әле? Туры бия колынлады лабаса.* М.Хәсәнов

**Колынлап кую** Көтмәгәндә, тиз арада колын китерү

**Колынлап тору** Әледән-әле, гел колынлау

**КОЛЫНЛЫ** *с.* Колынлы булган; колыны белән йөргән. *Колынлы биягә кое суы да җитмәс.* Әйтем. *Атларның ачыкканнары, бигрәк тә колынлы бияләр, учактан әллә ни ерак китмичә, якын-тирәдә генә утлыйлар.* Х.Сарьян. *Ләкин малайлар алдаганнар икән, аннан колынлы бия җиккән бер кырлайчы, арган атын кыйнап, чак атлатып килеп ята.* Г.Ибраһимов

**КОЛЫНЧАК** *и.* 1) Колынны иркәләп атау сүзе. *Ат баласы – колынчак, билләрендә ыңгырчак.* Җыр. *Кыз – курчакка, малай колынчакка [тартыр].* Мәкаль

2) *күч. сөйл.* Яшьрәк малайларны иркәләп әйтү сүзе

**КОЛЫП** *и. гар.* 1) *тар.* Төрле кальга, кирмән һ.б.ш. ныгытмаларның ишекләрен, капкаларын ябып, бикләп кую өчен кулланыла торган махсус җайланма. *Кальга колыбы коллар кулында.* Мәкаль

2) Утлы коралда көпшә каналын ябу җайланмасы; затвор

**КОЛЬРА́БИ** *и. нем.* 1) *бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан, яфраклары һәм җимеше шалканга охшаган икееллык яшелчә культурасы; шалкан кәбестә

2) Ашамлык әйбере буларак, шул үсемлекнең итләч юан кучәне

**КОЛЬТ** *и. ингл.* Уйлап табучысы һәм җитештерүчесе исеме белән аталган махсус системалы револьвер (яки нинди дә булса башка төр ату коралы)

**КОЛЯ́СКА** *и. рус* 1) Кечкенә балаларны саф һавада йөртү, йоклату өчен көйләнгән махсус арба, балалар арбасы

2) Инвалидлар өчен махсус кечкенә арба. *Габделкадыйр инвалид коляскасына береккән өлкән туганын күтәрептөшереп йөртә, төрле ихтыяҗйомышларын үти.* Р.Әмирхан. *Кайвакыт картлар йортыннан берәр гарипгорабаны алып, коляска тәгәрәтеп йөртсәм, берсе дә бәйләнмәс иде дип тә уйлап куям.* Т.Галиуллин. *Июнь уртасында авылга кайткан идем. --- Миңа коляска, язу машинкасы, магнитофон бүләк иттеләр.* Ф.Яруллин

3) Мотоциклга бер ягыннан беркетелгән бер тәгәрмәчле ян тагылма, көймә. *Бервакыт ул Казанга барганда шул машинаның коляскасына мине дә утыртты.* Казан утлары

4) Өслеге ачыла һәм ябыла торган дүрт көпчәкле сиртмәле тарантас. *Ачык капкада юл коляскасы күренгәндә, Параша --- әле һаман кечкенә болдырда*

*басып тора иде.* Ж.Тәрҗеман. *Солтан талчыккан кыяфәттә коляскаңың сәхтиян артына авышты.* С.Шәрипова

**КОЛЯ́СКАЛЫ** *с.* Коляска тагылган, коляскасы булган. *Коляскалы мотоцикл*

**КОМ** I *и.* **1.** 1) Җир кабыгының өске өлешләрендә очрый торган каты минералларның вак кына бөртекләре. *Табигый ком төрле минераллар кергән көпшәк бөртекләр катнашмасыннан тора.* Төзү материаллары. *Әбүзәр абзый ком өстеннән бара. Ком таптакыр, әйтерсең асфальт.* Г.Әпсәләмов. *Тирә-якта кайнар сулыш өреп торган ком чүле. Урамда да аяк йөзеннән ком ярып йөриләр.* Х.Сарьян

2) Шул масса кебек итеп вакланган ясалма әйберләр. *Әни кара ипине шакмаклап кисте дә аның өстенә мул гына шикәр комы сипте.* Г.Бәширов

3) Кайбер ботаник һәм зоологик тезмә атамаларның беренче кисәге. *Ком солысы. Ком еланы*

**2.** *с. мәгъ. к.* **комлы**. *Гаяз Имай тыкрыгына борылды. Моннан ул басу юлы белән ком юлга менәчәк, ком юлдан заготзернога төшәчәк.* Х.Сарьян

◊ **Комга корылган** Тормышка ашыргысыз, төпле нигезе булмаган. *Әнисе дә, туганнары да алар мәхәббәтен нигезе комга корылган өметсез нәрсә дип санадылар.* Ш.Рәкыйпов. *Хәзер, апасы белән җизнәсе аерылышкач, Илһамия апасының фәлсәфәсе дә, бәхете дә комга корылган булганлыгын ачык күрә иде.* Г.Әпсәләмов. **Ком гарәбе** 1) Чүл гарәбе, бәдәви. *Берәүләр, аны хаҗдан кайтып килгәндә, теге ком гарәпләре акчасы өчен үтергәннәр, диләр икән.* Г.Ибраһимов; 2) Карасу йөзле, карасу тәнле, каратут кеше турында. *Авыл малайлары җәй буе инеш ярындагы комлыкта ятып, ком гарәбенә әйләнеп беткәннәр инде.* Татарстан яшьләре. **Комга сипкән су кебек** 1) Берәр нәрсәнең бәрәкәтсез юкка чыгуы, бетүе. *Байбәтчәгә ата байлыгы комга сипкән су кебек. Бер ел эчендә типтереп бетерде.* Ф.Сәйфи-Казанлы; 2) Бик тиз югалу, юкка чыгу турында. *Теге зур вакыйгалар булган көннәрдә төрле гаепләр аркасында арестовать ителгән солдатлар да комга сипкән су кебек югалдылар.* М.Гафури. **Комга терәлү** Эш бик нык авырлашу, авыр хәлдә калу. **Комга төшкән тамчы сымак** *к.* **комга сипкән су кебек**. **Комга утыру** *к.* **комга терәлү**. **Комга утырту** Авыр хәлдә калдыру. *Бер карт солдат аны шунда ук комга утыртты.* К.Нәҗми. **Комга язган** 1) Үтәлми торган, коры, ялган вәгъдә; 2) Онытылачак, җуелачак, озакка бармаган. *Яшьлектә укыганың – ташка язган, картайгач укыганың – комга язган.* Мәкаль. **Комнан аркан (бау) ишү (үрү)** Мәгънәсез, файдасыз эш белән шөгыльләнү яки эшсез тик йөрү. *Кызганычка каршы, кеше исәнлеге, аны саклау турында авыз суларын корытып сафсата сатарга яратсалар да, чынлыкта, хакимият дилбегәсен кулларында тоткан түрәләр, еш кына, комнан аркан үрүдән узмыйлар шул.* Т.Галиуллин. **Комнан ишелгән** Мәгънәсез, файдасыз, тормышка ашмый торган. **Ком тутырылган кебек** Авыр, күтәреп булгысыз. *Ком тутырылган кебек авырайган аяклары хәзер шундый җиңел атлый, әйтерсең Мансурның пар канаты бар.* Г.Әпсәләмов. **Комы коелу** 1) Курку, шүрләү. *Шулай дигән идем, комы коелды.* Н.Исәнбәт; 2) Картаеп көче бетү, хәлсезләнү, бетәшү. *Минем Мансур хәленә каласы килми. Мансур яшь әле, аның чәкәшергә көче бар, ә минем... комым коела инде.* Г.Әпсәләмов. *Хәерле булсын, бүгенге көн комы коелган карттан башланды.* Идел. *Ләкин чын ярату Байрашка хәләл җефете белән кырык ел бергә гомер иткәч кенә килде, комы коела башлагач, ягъни.* Казан утлары

**КОМ** II *рус* Кайбер кыскартылган кушма сүзләрдә «комитет» мәгънәсендәге компонент, мәс., *профком, райком, крайком, комбед* (ярлылар комитеты)

**КОМ-** I *рус* Кайбер кыскартылган кушма сүзләрдә «коммунистик» мәгънәсендәге беренче компонент (мәс., *компартия, комбригада, комвуз*)

**КОМ-** II *рус* Кайбер кыскартылган кушма сүзләрнең «командир», «командалык» мәгънәсендәге беренче компоненты, мәс., *комдив* (дивизия командиры), *комбат* (батальон командиры), *комсостав* (командирлар составы)

**КОМА́** *и. фар. тар.* Ханга яки аның якыннарына хезмәт итүче кол хатынкыз, кәнизәк

**КО́МА** *и. гр. мед.* Үзәк нерв системасы функцияләренең тирән зарарлануы нәтиҗәсендә аңны югалту, тышкы ярсытучыларга реакция булмау һ.б.ш. симптомнар белән характерлана торган яшәү белән үлем арасындагы халәт. *Шикәр чирле Мөкатдәс абый комада булып чыкты. --- мәктәп коесының насосын алыштырырга төшкәч, комага тарды.* Сөембикә. *Лилия моннан берничә ел элек, каты авырып, 20 көн комада ята.* Идел

**КО́М БУРАНЫ** *и.* Җил белән күтәрелеп, бөтерелеп йөргән ком өермәсе. *Бичара яшь агачны кояш яндыра, я бозлы яңгыр кәефен ала, я ком бураны килеп, җиргә чаклы бөгеп иелдереп китә.* Г.Тукай. *Олы юлдан атлар чаба, ком буранын туздырып.* Г.Камал. *Һаваларда ком бураны уйный, ком авызга, борынга, колакларга тула.* И.Гази

**КОМАГАЙ** *с. монг.* **1.** 1) Комсыз, ашап туймый торган, ашамсак. *Ашауэчүгә комагай кеше*

2) Туймас, канәгатьләнүне белми торган, ачкүз. *Аңгы иле алагай, Борнак иле комагай.* Әйтем. *Хәмдүневләр нәселләре белән әллә нинди комагай булып чыктылар.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* Комсыз кеше. *Комагайның борыны кырык көн алдан кычыта.* Мәкаль. *Комагайның корсагы тулмас.* Әйтем

**КОМАГАЙЛАНУ** *ф.* 1) Комагайга әверелү

2) Комагайлык күрсәтү, комсызлану

**Комагайлана бару** Торган саен ныграк комагайлану

**Комагайлана төшү** Беркадәр, бераз комагайлану

**Комагайланып бетү** Бөтенләй комагайлану, комагай хәленә килү

**Комагайланып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер комагайлану

**КОМАГАЙЛЫК** *и.* 1) Комагай булу

2) Комсызлык, хирыслык, ачкүзлек. *Комагайлык белән ашарга тотыну*

**КОМАЙ** *и.* 1) *миф.* Канатлы эт

2) Ау эте; бурзай

**КОМА́Й ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кыяклы үсемлекләр ыругыннан сазламыклы урыннарда үсә торган себеркәч чәчәкле күпьеллык терлек азыгы үләне; *русчасы:* **манник большой**

**КОМАК** *и. зоол.* 1) Азия һәм Африка ярымчүлләрендә, чүлләрдә яши торган, зурлыгы белән күселәрне хәтерләткән хайван; *русчасы:* **песчанка**. *Урта Азия республикаларында комакларның 8 төрен очратып була.* Зоология

2) *диал. к.* **күсе**. *Песи дә: – Гомерем буе хуҗага хезмәт иттем, өйдәге комакларны бетердем, алай да очраган бер җирдә тибә, мине кыйный, рәтләп ашатмый, шуның өчен мин үземә аерым тормыш башларга уйлыйм, – дигән.* Әкият. *Сайгак астыннан чыгып, шаулап йөрергә башлады Барча тычканнар, комаклар, ас вә әрлән, ләтчәләр.* Ш.Бабич. *Ашый-эчә, һәркем киенә, киләдер һәм кунагы, Туя сала-каласы димсең, тегермән комагы.* Татар шигърияте: XX гасыр башы

**КОМАЛАК** *и.* 1) *диал. к.* **колмак**

2) Куй тәкәсенең кипкән тизәге (күрәзәлек итүдә рәмел ташы урынына кулланылган). *Бу заманнарда бездә куй тәкәләре булмаганга, комалак урынына 41 ногыт борчагы яисә 41 вак таш кисәкләрен файдаланганнар.* М.Әхмәтҗанов. *Комалак белән багуда катгый таләпләр калыплашкан. Мәсәлән, комалак салучы исерткеч эчемлекләр белән эш итүче булмаска тиеш.* Татар халкының борынгы ырымарбаулары һәм төрле фалнамәләре

◊ **Комалак ачу** *к.* **комалак салу**. **Комалак салу** Комалак (*2 мәгъ.*) белән күрәзәлек итү. *Комалак салу турындагы борынгы беренче хәбәр-мәгълүмат XI гасырдан килгән. М.Кашгари сүзлегенә кереп калган «йат» сүзенә ясалган искәрмәдә ул ташлар белән күрәзәлек итү дип аңлатылган.* М.Әхмәтҗанов

**КОМАЛАКЧЫ** *и.* Комалак салып юраучы, күрәзәче

**КОМАН** *и. тар.* XI–XIII гасырларда Көньяк Дон – Идел далаларында яшәгән, төрки шивәләрнең берсендә сөйләшкән, кыпчаклар составындагы борынгы халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Цагаева бу атамаларның коман этнонимы белән бәйләнгән булуын бик күп мәгълүматлар белән дәлилли.* Х.Садри

**КОМА́НДА** I *и. лат.* 1) Уставта кабул ителгән формада телдән бирелә торган кыска боерык; әмер. *Командир, команда бирер өчен, өзәңгеләренә басып күтәрелә төште. Ләкин ул командасын биреп өлгермәде.* А.Шамов. *Ротаның старшинасы Долбышев --- аска карап кына команда бирә, өзлексез йөгертә.* Г.Ахунов. *Шунда Юматов абый да көзге җилдәй ачы тавышы белән: – Дүртәрләп тезелергә! Тезелү тәртибен беләсез! – дип команда бирде.* Х.Сарьян

2) Катгый әмер, боерык, күрсәтмә. *Аеруча басым белән, бар көченә кычкырып әйткәндә, Левитан тавышы бөтен илгә бирелгән илаһи бер команданы, хәтта йөзләгән туптан атыла торган салют бирүне хәтерләтә.* Н.Фәттах. *Ул да түгел, дәү әни я авылга йөгереп кайта, я күрше кишәрлеккә кереп команда бирергә дә өлгерә икән.* В.Астафьев. --- *Әнә шул тоткалардан тотып, бердәм команда белән «баба»ны күтәреп, субайның башына сугалар. Командалар, ни хикмәттер, рус телендә бирелә.* Мирас

3) Зур булмаган хәрби часть, отряд, рәсми дисциплина белән яши торган хәрби төркем. *Паровоз мөгрәп кенә бер кычкыртып алгач, команданы ерак юлга, көнчыгыш юнәлешенә таба алып китте.* Г.Ахунов. --- *Утыз-кырык кешелек команданың иярле атларга тарттырып бер тупны алып барганнары күренде.* Ш.Усманов. *Җәмәгать кырларын булдыру күп вакыт авылларга хәрби командалар җибәрү белән тормышка ашырылган.* С.Алишев

4) Нинди дә булса эшне, шөгыльне башкаручылар төркеме. *Пароходның командасы берничә минут эчендә баржаны ян буксирга алды.* Ш.Усманов. *Башка командалар килеп җиткәнче, Тимерханнарны хәрби комиссариат белән янәшә район клубына кертеп тутырдылар.* Г.Ахунов. *Программа белән студентларны куабыз, институт командасын Горький шәһәрендә үтәчәк ярышка әзерлибез.* Х.Сарьян

5) Бергә уйнаган спорт коллективы. *Быел кыш ун яшьлек малайлар составындагы хоккей командасы, Финляниягә барып, беренче урынны алып кайтты.* Р.Миңнуллин. *Алай гына да түгел әле, Резидә ханым авыл яшьләре арасында волейбол командасы туплап, аларны өйрәтеп, районга ярышка алып бара һәм һәрвакыт беренчелекне алып кайта.* З.Хәлиуллина

**КОМА́НДА** II *и. иск. сөйл.* Командир, башлык, баш кеше. *Тирече Вәли – элек тә команда, хәзер совет чорында да команда.* Г.Ибраһимов. *Борынборын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк урәтник, бака тимерче, чыпчык күмерче булып торган чагында, яшәгән, ди, әби белән бабай.* Р.Батулла

**КОМА́НДАДАШ** *и.* Кем белән дә булса бер үк командада булган кеше. *Командадаш дуслар*

**КОМА́НДАЛЫ** *с.* Командаларга бүленеп башкарыла торган. *Командалы уеннар. Командалы ярышлар*

**КОМА́НДАЛЫК** *и.* 1) Команда белән идарә итү, җитәкчелек. *Командалыкны үз кулыңа алу*

2) Командирлар даирәсе

3) Нинди дә булса эшнең башында тору, җитәкчелек итү. *Сталин вакытында --- теләсә нинди энтузиазм чаткыларын сүндерергә сәләтле, катгый кануннарга буйсындырылган административ командалык итү системасы төзелде.* Ә.Рәшит

**КОМАНДАН** *и. фр. иск.* Гаскәр башлыгы, командир; флот капитаны

**КОМАНДАРМ** *и. рус* Кораллы көчләрнең бер зур берләшмәсе – армия командующие

**КОМА́НДАЧЫЛЫК** *и.* Формаль, коры боерыклар бирү юлы белән генә эш итү ысулы. *Командачылыкка юл куймау*

**КОМАНДИР** *и. лат.* Хәрби частьнең, судноның башлыгы; хәрби команда өчен җаваплы кеше. *– Хәрби ячейкалар башында торырлык командирлар җитешми, – диде ул.* Ш.Рәкыйпов. *Кичә кич белән ул, Нуруллинны озаткач, полк командирын һәм полк комиссарын күргән.* А.Шамов. *Арттан командир:*

*«Сугышка хәзерләнергә!» – дип команда бирде.* А.Расих

2) *сөйл.* Нинди дә булса оешманың җитәкчесе, башлыгы

3) *сөйл.* Нинди дә булса эшне башлап йөрүче, шул эшне оештыручы кеше

**КОМАНДИРЛА́РЧА** *рәв.* Командирлар кебек, командирдан таләп итәлгәнчә. *Кинәт яңгыраган командирларча кискен, катгый тавыш Бакыйны сынын турайтып басарга мәҗбүр итте.* М.Маликова

**КОМАНДИРЛЫК** *и.* Командир булу, командир вазифасы. *Гафур шушы арада гына кызыллармеецлар арасында командирлыкка күтәрелгән бер егет иде.* Ш.Усманов

**КОМАНДИРО́ВКА** *и. рус* Эш урыныннан берәр максат белән кая да булса җибәрелү. --- *ишектә тагын бер шәкерт очрады. – Командировкага барам, Латыйп аганың фатихасын алырга килдем, – диде ул.* М.Мәһдиев. *Командировкадан кайткач, Хәлимә сәгатьләр буе китапханәдә утырып, китаплар актарды.* Л.Ихсанова

**КОМА́НДОВАНИЕ** *и. рус* Югары командирлар даирәсе, командалык. *Ак чехлар командованиесе шәһәрнең аклар кулына күчкәнен белдерә.* Ш.Усманов. *Беренче чиратта Кызыл Армия командирлары һәм политработниклар коткарыла. Чөнки алар немец командованиесенең боерыгы буенча шундук юк ителергә тиешләр.* Ш.Рәкыйпов

**КОМА́НДУЮЩИЙ** *с. рус* Зур гаскәри берләшмә башлыгы. *Командующий картада кулы белән йөртеп маршрут сызды.* Ш.Усманов. *Армия командующиеның бер генә сүзен ишетмәсә дә, Николай аның ни турында сөйләвен яхшы аңлады.* Ш.Рәкыйпов. *[Кәбир] сугыш елларында шофёр булган һәм ниндидер бер армиянең командующиен йөрткән.* Г.Әпсәләмов

**КОМАР** *и. гар.* **1.** 1) Отышлы уен, акчалы уен. *Андый атны комарга саламыни, дивана!* Р.Батулла

2) Азарт, тыелгысыз һәвәслек, нык мавыгучанлык. *Иң ярсыган чакта гына килә торган дүрт-биш катлап сүгенү комары старшина Хомичукны ярсытты.* М.Кәрим

3) Кызыксыну уяту, мавыктыручанлык. *Бу мәзәкнең комары юк*

**2.** *с. мәгъ.* Нинди дә булса эшкә, һөнәргә теләге, дәрте бик тә көчле булган. *И комар мин яшәү кызыгына.* Н.Арсланов

**3.** *хәб. функ.* Һәвәс, омтылучан, хирыс. *Ул балык тотарга бик комар*

**КОМАРЛАНУ** *ф.* Азартка бирелү, азартлану

**Комарланып китү** Соңгы арада комарлану

**КОМАРЛЫ** *с.* 1) Отышлы, акчалы. *Исерткеч эчемлекләр эчкән, комарлы уеннар уйнаган һәм алдалау белән шөгыльләнгән өчен, сугышчыларны иң авыр җәзага тартканнар.* Урта гасырлар тарихы. *Ирем үзе ниндидер комарлы уеннар белән мавыгып китте.* Мәдәни җомга

2) Бик дәртле, бик мавыгучан, бик һәвәс, азартлы. *Марс Шабаев белән Мирсәет безнең арада иң комарлы балыкчылар да иде.* Л.Хәмидуллин. *Беренчедән, ул – инде бүген-иртәгә закон сагына басасы яшь юрист, икенчедән, башкалардагы кызыксынучанлык дигән комарлы хис анда да бар.* К.Кәрим. *Эстрада кануннарын бөтен нечкәлекләре белән тоя торган комарлы юморист иде Фаил Шәфигуллин.* Казан утлары

**КОМАРЛЫК** *и.* 1) Бик нык мавыгучанлык; дәрт, азарт (мәс., спортта, уенда). *Көрәш комарлыгы*

2) *к.* **комарлылык** (*2 мәгъ.*). *Ә авылның башка ата этләре аңа [эткә] теш кайрап сагалаганнар: бүре исе, бүре комарлыгы сирпелгән барыбер Сарыкүзгә.* Г.Якупова

**КОМАРЛЫЛЫК** *и.* 1) Комарлы булу. *Отышлы уеннарга комарлылык*

2) Комсызлык, ачкүзлек, туймастай булу үзлеге

**КОМАРХАНӘ** *и. гар.-фар.* Комарлы уеннар уйнау урыны, комарлы уен йорты. *Дөньяда кайбер кешеләр рәхәтлекне вакытны бушка уздыра торган урыннарда, шатлыкны төнозын комарханәләрдә эзлиләр...* Р.Фәхреддин

**КОМАРЧЫ** *и.* Комарлы уеннарга бирелгән кеше, азартлы уеннар уйнаучы. *Комарчы исеректән койты.* Мәкаль

**КОМА́Ч** *и. гар.* **1.** 1) Куе кызыл төсле киҗе-мамык тукыма. *Тиз генә абзарга кердем дә, кырыкмышымны йөгәнләп алып, муенына кызыл комачка бәйләнгән кечкенә кыңгырау тактым.* М.Гали. *Йомышлы татарлар арасында сәүдәгәрләр күбәйгән, авылларда комач эшләү фабрикалары төзелгән.* С.Алишев. *Ике таяк сапка киерелгән комачны малайлар бик нык тотканнар. Ул комачка: «Беренче баскычлы Солы авылы башлангыч мәктәбе» дип сырлап-сырлап язып куелган.* В.Астафьев

2) Тукымалар, мануфактура; кызыл мал. *Лавкалар ачып, комачлар сата алмыйлар хәзер [байлар].* С.Рафиков. *Фәхретдин бабам сәүдәгәр булган, финнарда да йорттан-йортка кереп, комач, тукыма сатып йөргән.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый тукымадан тегелгән (киселгән). *Башындагы комач яулыгы, җил белән күпереп, ак канатлы күбәләк төсле фырылдап килә.* К.Нәҗми

2) Куе кызыл, җете кызыл. *Байрак йөртүче «Кызыл бөркетләр» дип язылган комач байракны күтәреп, егетләр алдына килеп басты.* И.Туктар. *Сандык төбеннән өр-яңа комач җәймә чыгарылып, өстәл өсләренә ябылды.* Г.Минский

◊ **Комач кебек кызару** Нык оялу, оялудан бик каты кызару. *Рәүфә, комач төсле кызарып, китәргә дә, китмәскә дә белми басып тора иде.* А.Шамов. *Гөлбану, хур булдым, адәм мәсхәрәсенә калдым бугай дип, комач кебек кызарды.* Г.Ибраһимов. *Шунда Гөлшәһидә аңа таба борылды. Танығач, комач кебек кызарды.* Г.Әпсәләмов. **Комач кебек (кып-)кызыл** *к.* **комач япкандай кызыл**. *Барсак, ни күзебез белән күрик: кып-кызыл комач кебек, бөтен җирне каплап алган җир җиләге.* М.Гали. **Комач япкандай кызыл** Җете кызыл, тоташ кызыл. *Июнь-июль айларында җир исә каен җиләге, җир җиләге белән комач япкандай кызыл булып капланып алына.* З.Бәшири

**КОМАЧА́У** *и.* 1) Нинди дә булса максатны, эшне, хәрәкәтне әкренәйтә, тоткарлый торган сәбәп; тоткарлык, киртә. *– Берәр комачау булгандыр, төшкәчә көтик әле, – дип уйлады [карт].* Г.Ибраһимов. *[Ишми:] Соң бит*

*хатынның бер комачавы да юк ла аның: кирәк икән, хезмәтче итеп калдырасың.* Г.Шәрипова. --- *бу зур академикның [Радлов], үзе Казанда яшәп тә, керәшеннән башка татар халкының дөньяда булуын күрмәмешкә салынуы татар тел-фольклор гыйлеменең үсүенә зур комачау булып төшә.* Н.Исәнбәт

2) Тиешле булганча эшләүне боза торган нәрсә, уңайсызлык

**КОМАЧА́У ИТҮ** *ф. к.* **комачаулау**. *Апрель ае беткәнче, колхоз басуында салам эскертләре яндырып йөрделәр. Кырда калган эскертләр җир сөргәндә комачау итәләр иде.* М.Мәһдиев. *Элеккечә тау башына җыелабыз, --- сугыш чорындагы түгәрәк уенга комачау итәбез, төрле этлекләр эшлибез.* Казан утлары. *Әмма боларның берсе дә көннәрдән бер көнне миңа гашыйк булырга комачау итмәде.* Мәдәни җомга

**КОМАЧАУЛА́У** *ф.* 1) Комачау, кыенлык тудыру; тоткарлык ясау. *Уйнаклап искән җил көймәгә алга барырга комачаулый.* Г.Гобәй. *[Гөлшәһидә:] – Укуымны дәвам иттерергә ниятем бар иде дә, булмас ахырысы. – Моңа нәрсә комачаулый соң?* Г.Әпсәләмов. *Гамбәр аңа нидер әйтергә теләгән кебек тоелды. Әмма һәр тапкырында ни дә булса комачаулады.* Г.Шәрипов

2) Борчу, тынычсызлау. *Үзем дулкынланам, миңа да чыгарга кирәк, әмма нәрсәдер комачаулый.* М.Мәһдиев

**Комачаулап алу** Берара, бераз вакыт эчендә комачаулау

**Комачаулап килү** Электән, күптәннән бирле комачаулау

**Комачаулап тору** Гел, һәрвакыт комачаулау. *Алдыбызда комачаулап торган келәт янып ишелде.* А.Расих

**Комачаулый төшү** Беркадәр, бераз комачаулау

**КОМАЧАУЛЫ** *с.* Үзендә комачаулар булган; комачаулап тора торган нәрсәләр белән бәйле, җайсыз, кыен. *Комачаулы юлга чыгу*

**КОМАЧАУЛЫК** *и.* Комачаулап торган нәрсә; комачау. *Күләгәдә озын булып үскән үләннәр, урын-урын аякка уралып, [атларга] бераз комачаулык ясыйлар.* Ш.Камал. *Типик булмаса да, музыкаль тәрбия эшенә комачаулык китерә торган кире фикерләрнең халкыбыз арасында әледән-әле ишетелүендә без, музыкантлар, үзебез дә гаепле бит.* Җ.Фәйзи. *Без бабайның эшенә бервакытта да комачаулык китерми идек.* Г.Гали

**КОМАЯК** *и.* Елга, күл буендагы чагыштырмача зур мәйданлы комлык; комлы яр буе. *Комаякта кызыну*

**КОМАЯКЛЫ** *с.* Комаяклары булган. *[Көймәче безгә] краяшта кызыныр һәм суга төшәр өчен дә уңайлы булган комаяклы җирләргә барырга юллар өйрәтте.* С.Кудаш

**КОМАЯ ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **комай үләне**

**КОМБАЙН** *и. ингл.* Бер үк вакытта берничә төрле авыл хуҗалыгы эшләрен башкара торган катлаулы агрегат. *Ә Илдарны әйтәсе дә юк – егетнең егете! Комбайнчылар курсын бетереп чыкты; быел җәен үзйөрешле комбайн штурвалына басарга тиеш.* Г.Гобәй. *Әткәң ул тракторын да, комбайнын да менә дигән итеп йөртә.* Л.Ихсанова

3) Төрле эш башкара торган машиналарны берләштергән катлаулы агрегат. *Кухня комбайны*

**КОМБАЙНЁР** *и. рус к.* **комбайнчы**. *Госпитальдән чыккач, комбайнёр шул хәлендә дә кыр корабын йөртергә өйрәнә.* Г.Гобәй

**КОМБА́ЙНЧЫ** *и.* Комбайн йөртүче. *Габдулла төрле атлы эшләрдә, урак өстендә ярдәмче комбайнчы булып эшләп йөрде. Хәзер өлкән комбайнчы икән.* Р.Төхфәтуллин

**КОМБАТ** *и. рус* 1) Батальон командиры. *Комбат бил каешын, гимнастёрка якасын төзәткәләде дә: – Чакыр бирегә, – диде.* Ш.Рәкыйпов

2) Батарея командиры

**КОМБЕД** *и. рус тар.* XX гасырның 20 нче елларында Совет хакимиятенең авыл җирлегендәге органы; ярлылар комитеты. *Унсигезенче елда авыл халкы тарафыннан комбед (ярлылар комитеты) рәисе итеп сайланган изге җан Шәяхмәт икенче улын артык иркә үстерә.* Т.Галиуллин

**КОМБЕДЧЫ** *и.* Комбед әгъзасы

**КОМБИАЗЫК** *и. а.х.* Төрле азыкны тиешле микъдарда бергә кушып ясаган терлек азыгы, катнаш азык; *русчасы:* **комбикорм**. *Чистайда комбиазык заводы төзелде.* Татарстан. *Тутыру тәрәзәсе янында, комбиазыкка кайнар су бирү өчен, ике форсунка куелган.* Терлекче-механизатор белешмәсе

**КОМБИЖИР** *и. рус кулин.* Төрле майлардан (үсемлек мае, терлекнең эч мае һ. б.) торган катнашма

**КОМБИНАТ** *и. лат.* 1) Бер-берсенә дәвамлы технологик процессларны бергәләп башкару өчен төзелгән эшханәләр берләшмәсе. *Сегежа – кечкенә генә эшче шәһәрчек, сугышка кадәр анда кәгазь комбинаты эшләгән.* Г.Әпсәләмов. *Без табигатьтән рәхимлекләр көтмәдек. Җирне харап итә торган әллә никадәр комбинатлар төзедек – урманнарны таладык, җир асты байлыкларын әрәм-шәрәм иттек.* Ә.Рәшитов. *Габдырхай ит комбинаты холодильнигында гап-гади грузчик булып эшли.* Н.Дәүли

2) Урындагы вак промышленность һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү эшханәләрен берләштергән оешма. *Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү комбинаты*

3) *пед.* Төрле баскычтагы уку йортларының практик эшкә өйрәтү базасы. *Укыту-производство комбинаты. Производствога өйрәтү комбинаты*

**КОМБИНАТО́Р** *с. лат.* Аерым өлешләрнең үзара урнашуына һәм барлыкка килгән комбинацияләргә нигезләнгән. *Комбинатор үзгәрешләр авазларның бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка киләләр.* Татар грамматикасы. *Математикада комбинатор анализ*

**КОМБИНА́ТОР** *и. лат.* Комбинацияләр ясарга оста кеше, комбинацияләр һәвәскәре, махинация остасы

**КОМБИНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Күбесенчә бер төрдән булган нәрсәләрнең билгеле бер тәртиптә урнашуы, берләшүе, кушылуы. *Татар телендә авазлар төрле комбинацияләрдә килеп, төрле-төрле төзелмәләр барлыкка китерә алалар.* Татар грамматикасы. *Цифрлардан комбинация оештыру. Төсләр комбинациясе*

2) *спорт* Җиңүгә, өстенлеккә ирешү өчен кулланылган уен, хәрәкәт

алымнары системасы. *Шахмат уенындагы комбинацияләр*

3) Хатын-кыз эчке күлмәгенең бер төре. *Алды челтәрләп эшләнгән ефәк комбинация*

4) Бер-берсенә туры китереп яраштырылган өлешләрдән торган предметларның тулы комплекты (мәс., кием, мебель һ.б.)

5) *икът.* Бер төрдәге предприятиеләрне берләштерү юлы белән җитештерүне концентрацияләү (бергә туплау) процессы

6) *күч.* Билгеле бер максатка ирешү өчен юнәлтелгән төрле мәкер-хәйлә һәм гадәти булмаган гамәлләр системасы, катлаулы план, махинация. *Артистларның хәлен бик яхшы аңлаган Тимершаһ Соловьёв --- бер комбинация уйлап чыгара: «Әгәр дә эстрадага чыгып җырласагыз, сезгә обед белән ужин бесплатно», – ди.* Октябрьгә кадәрге татар театры. *Сүз уңаеннан, соңгы атамада безнең героебызның исеме һәм фамилиясеннән кыскартылган комбинация җиңел шәйләнә.* Татарстан

**КОМБИНА́ЦИЯЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Максатка ярашлы комбинациягә китерү

2) *к.* **комбинацияләү**

**КОМБИНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Комбинация төзү. *Төрле төстәге чәчәкләрне комбинацияләп, букет эшләү. Шахмат уенында йөрешләрне комбинацияләү*

**Комбинацияләп бару** Рәттән комбинацияләү

**Комбинацияләп кую** Комбинацияләнгән хәлгә китерү

**Комбинацияләп тору** Даими рәвештә комбинацияләү

**Комбинацияли башлау** Комбинацияләргә тотыну

**КОМБИНА́ЦИЯЛЕ** *с.* 1) Комбинациядән (*1, 4, 6 мәгъ.)* гыйбарәт булган, комбинацияләрдән торган. *Комбинацияле сөрү агрегаты. Комбинацияле азык өләшкеч. Комбинацияле азык ваклагыч*

2) Комбинацияләр *(2, 5 мәгъ.)* кулланып эшләнгән. *Комбинацияле шахмат партиясе*

**КОМБИНА́ЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Комбинацияле булу. *Уенның [футбол] отышлы комбинацияләлеге күпләрдә соклану уятты.* Мәдәни җомга

**КОМБИСИ́ЛОС** *и. рус* Туклыклы һәм витаминга бай төрле үсемлекләр катнашмасыннан әзерләнгән терлек азыгы. *Комбисилос базы*

**КОМБИНЕЗОН** *и. фр.* Курткасы белән чалбары тоташ итеп тегелгән өс киеме. *Газинур, башкалар кебек үк, комбинезонының башлыгын артка ташлаган.* Г.Әпсәләмов. *Бронетранспортёрдан комбинезон кигән, күн бүрекле, якты чырайлы, нык гәүдәле берәү төште.* Ш.Рәкыйпов. *Балалар комбинезоны*

**КОМБРИГ** *и. рус* Бригада командиры. *Полк комбриг приказында күрсәтелгән вакыт эчендә үзенә билгеләнгән пунктка барып җитте.* А.Шамов. *Комбриг үзенең резервын да сугышка кертте, әмма кыя-тауны алып кына булмый.* Г.Әпсәләмов

**КОМГАН** *и.* Юыну өчен файдаланыла торган корсаклы һәм борынлы махсус су савыты. *Иртә-кичләрен мич буенда зур гына калай таз тора, аның янында комган. Юыну, коену эшләре шунда башкарыла.* М.Әмир. *Бусагадан атлауга, иң элек Мансурның күзенә җиз ләгән, зур корсаклы, кәкре борынлы комган, ак самавыр чалынды.* Г.Әпсәләмов. *Шуннан бай комганны ыргытып бәрде, комган мич кырыена бәреләп яньчелеп килде.* М.Галәү

**КОМГАНЛЫК** *и.* Комганнар куела торган махсус урын

**КОМЕДИАНТ** *и. ит.* 1) Театрда көлкеле рольләрне башкаручы, тамашачыларны көлдерүче артист

2) *күч.* Юк-бар сөйләнгәләп кеше көлдереп йөрүче кеше; шамакай

**КОМЕДИО́ГРАФ** *и.* Комедияләр иҗат итүче драматург

**КОМЕ́ДИЯ** *и. гр.* 1) Көлкеле сюжетка корылган яки бераз сатира белән сугарылган драма әсәре. *Комедиянең сатирик, юмористик төре театрны характерлаучы төп сыйфатлардан берсе булып китте.* Б.Гыйззәт. *«Беренче театр» комедиясе конкрет вакыйгаларга таянып, башлыча, Г.Камалның үз тормышыннан алып язылган.* Октябрьгә кадәрге татар театры. *«Бүләк өчен» комедиясе бәхетле гаилә кору юлындагы иске киртәләргә каршы чыга, ирекле саф мәхәббәт проблемасын күтәрә.* Һ.Мәхмүтов

2) *күч.* Көлкеле, кызыклы вакыйга, күренеш

3) *сөйл.* Тупас шаярту, әдәпсез кылаңыш

**КОМЕ́ДИЯЧЕ** *и. к.* **комедиограф**

**КОМЕ́ДИЯЧЕЛ** *с.* Комедия үзенчәлеге булган; комедиягә хас. *Хәмзә бай образын сәхнәдә беренче булып башкаручы – Г.Кариев. Аның комедиячел типларны гәүдәләндерүдәге сәләте башлап шушында ачыла.* Б.Гыйззәт. *Ячы карчыкның бүләк турындагы хәбәрне буташтырып әйтүе аркасында комедиячел ситуация куера.* И.Илялова. *«Беренче театр»да Хәмзә бай, «Банкрот»та Сираҗетдин --- – Кариевның комедиячел типтагы иң уңышлы сәхнә образлары.* Һ.Мәхмүтов

**КОМЕНДАНТ** *и. нем.* 1) Хәрби ныгытма яисә хәрби төбәк чикләрендәге гомуми тәртип өчен җаваплы кеше

2) Шул ук чикләрдәге хәрби хезмәткәрләрнең тәртибе өчен җаваплы хәрби башлык. *Шәһәр коменданты. Гарнизон коменданты. Лагерь коменданты*

3) Тимер юл, су, һава транспорты һ.б.ш. элемтә юлларында гаскәрнең, хәрбиләрнең һәм хәрби йөкләрнең дөрес хәрәкәт итүен күзәтеп торучы хезмәткәр

4) Нинди дә булса учреждениегә, оешмага караган йортның идарәчесе, йорт мөдире. *Бер атнадан соң тимер юл йортлары коменданты аларга өч көн эчендә квартираны бушатырга тәкъдим итә.* А.Шамов. *Комендант кызу-кызу гына атлап капкага таба узып барган җиреннән шып тукталды.* М.Әмир

**КОМЕНДАНТЛЫК** *и.* Комендант булу; комендант вазифасын үтәү, комендант хезмәте

**КОМЕНДАТУ́РА** *и. нем.* Комендант (*1, 2 мәгъ.*) җитәкчелегендә эшли торган учреждение

2) Шул учреждение урнашкан бина. *Комендатура ишегенә һәм тагын берничә җиргә зур-зур белдерүләр кадакланды.* М.Шабай

**КОМЕНДОР** *и. ингл.* Артиллерист матрос

**КОМЕ́ТА** *и. гр. астр.* Яктырткыч үзәге һәм тузан белән газдан торган койрыгы булган, эллиптик орбита буенча әйләнгән Кояш системасы объекты; койрыклы йолдыз. *Җирдән бу болытны кичерәк комета рәвешендә күзәтәчәкләр.* А.Тимергалин. *Кайбер кометаларны (мәсәлән, Галлей кометасын) Җирдән кыска вакыт дәверендә генә күзәтеп була.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы

**КО́МИ** *и.* 1) Фин-угор семьялыгының пермь телләрендә сөйләшүче, башлыча Коми республикасында яшәүче төп халыклар группасы атамасы һәм шул халыкның бер кешесе

2) Шул группага караган бер халыкның һәм аның теленең атамасы; коми-зырян

**КОМИЗМ** *и. гр.* Кешеләр катнашлыгы белән башкарылган эш-гамәлләрдә, вакыйгаларда булган көлкеле хәлләр; юмор. *Пьесада персонажлар саны киметелә – киеренкелек, драматизм йомшартыла, комизм көчәйтелә.* Һ.Мәхмүтов. *Комизм һәм драматизм театрга хас төп билгеләр иде, озак еллар тамашачының эстетик зәвыгы шул юнәлештә тәрбияләнде.* Октябрьгә кадәрге татар театры. *Сәйф Сараидагы комизмга үтергеч көлү түгел, ә инсанчының (гуманистның) дустанә елмаюы хас.* Н.Хисамов

**КО́МИК** *и. гр.* **1.** 1) Көлкеле, кәмит рольләрне башкаручы артист

2) Мәзәк сөйләргә яратучан, шаян, шук кеше

3) *иск.* Комедия әсәрләре язучы, комедияләр авторы

**2.** *с. мәгъ.* 1) Көлкеле, көлдерә торган, көлке уята торган. *Комедиянең үзәгендә кешенең тышкы кыяфәте, үзүзен тотышы белән эчке дөньясы арасындагы каршылык ята, шул нигездә комик ситуация, көлке туа, әмма мин бу төшенчәне ахыргача күз алдына китерә алмыйм, дим.* Т.Галиуллин. *1907–1912 елларда гына да Г.Кариев комик планда күпсанлы сәхнә образлары иҗат итте.* И.Илялова

2) Көлкеле рольләрне башкаруга бәйләнешле, комизмга караган. *Комик талант. Комик роль*

**КО́МИКЛАНУ** *ф.* Кәмитләнү, шамакайлану

**Комикланып йөрү** Гел комиклану

**КО́МИКЛАРЧА** *рәв.* Комикларга хас булганча; комиклар кебек

**КО́МИКЛЫК** *и.* Комик булу; көлкелек, мәзәкчелек

**КО́МИКС** *и. ингл.* Эзлекле рәсемнәр сериясе һәм кыска гына язулардан торган хикәя

**КОМИНТЕРН** *и. тар.* Коммунистик интернационал (Коммунистларның 1918–1944 еллардагы халыкара оешмасы)

**КОМИССАР** *и. лат.* 1) Хөкүмәт тарафыннан сәяси-административ яки хуҗалык эшләрен үтәргә аерым вәкаләтләр бирелгән югары дәрәҗәле эшлекле. *1921 елда Татарстан Республикасы Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы тарафыннан татар телен Татарстан территориясендә рус теле белән беррәттән бертигез хокукта йөртү турында декрет кабул ителә.* В.Хаков. *Җәүдәтнең әтисе элек көньяк өязләренең берсендә комиссар булып эшләгән иде.* Г.Бәширов

2) СССРда гражданнар сугышы елларында һәм аннан соңгы чорларда билгеле бер төбәккә яисә хуҗалык тармагына аерым вәкаләтләр белән вакытлыча җибәрелгән вәкил. *[Айбулатов:] Харис Абдрахманович – зур комиссар булган кеше! Аның турында фронт газеталары – русчасы да, татарчасы да күп яза.* Х.Сарьян

3) 1918–1942 елларда Кызыл Армиядә зуррак хәрби частька билгеләнә торган партия вәкиле; хәрби-сәяси хезмәткәр. *Сабирны Көнчыгыш фронтына – инде бу юлы Колчакка каршы озаталар. Ул анда полк комиссары хезмәтен үти.* А.Шамов. *Уфа белән Оренбург арасындагы олы юл өстендә утырганлыктан, безнең авыл аша әледән-әле узып торучы Кызыл гвардия отрядлары, төрле командирлар, комиссарлар --- күп була иде.* М.Әмир

**КОМИССАРИАТ** *и. фр.* 1) Советлар Союзында 1917–1946 елларда халык хуҗалыгының аерым тармагы белән идарә иткән үзәк орган. *Гыйльми һәйәтнең рәисе итеп Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариатында Г.Ибраһимов белән бергә эшләүче Мостафа Сөбхи билгеләнә.* В.Хаков. *1922 елда Татарстан җөмһүрияте Мәгариф комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәк тарафыннан, К.Насыйриның үлүенә 20 ел тулуга багышлап, бер мәҗмуга чыгарыла.* М.Гайнуллин

2) Гаскәри хезмәткә алу, хәрбиләрнең учётын алып бару һ.б.ш. белән шөгыльләнә торган җирле хәрби идарә органы. *[Егет] Хәрби комиссариат алдындагы зур карта янына килде дә Харьков шәһәрен эзли башлады.* Г.Гобәй

**КОМИССАРЛЫК** *и.* Комиссар булу; комиссар вазифасы, эше, хезмәте. *[Гыйләҗи:] Комиссарлыктан мине коткарырсыз да зур йортлар, зур күперләр салу эшенә җибәрерсез.* Г.Ибраһимов. *Сабир комиссарлык иткән полк Казан аркылы үтә.* А.Шамов. --- *Кави шул комиссарлык эшен 1928 елга кадәр дәвам итә.* З.Зәйнуллин

**КОМИССИОН** *с.* 1) Сәүдә эшендә арадашчы вазифасын үти торган, саткан бәядән процент алына торган. --- *Заһидә ханым әйтеп куйды: – Кәрим үзе алган савыт-саба, – диде. – Бераз акча юнәтсә, ул гел, антиквар, комиссион кибетләргә кереп, шундый борынгы савыт-саба алып кайта иде.* Р.Батулла

2) Арадашчылык итеп, сатуга алынган. *«Эш-йомыш» дигәннең «йомыш» ишеләре – биредәге комиссион продукт магазины аркылы саттыру өчен май, яшелчә тапшыру, кибетләрдән тегесен-монысын алгалау – әллә ни вакытны томмады.* Р.Төхфәтуллин

3) Шундый товарларга караган. *Комиссион бәяләр*

**КОМИССИОНЕР** *и. фр. икът.* Сәүдә эшендә арадашчы, комитент, җаваплылыкны үз өстенә алучы кеше, билгеле бер түләү хакына сәүдә йөкләмәләрен үтәүче. *Портка килеп туктаган көнне үк безнең корабка комиссионерлар – төрле кибет һәм фирма вәкилләре килә башлады.* Р.Мостафин

**КОМИССИОНЕРЛЫК** *и.* Сәүдә эшендә арадашчы булу; комиссионер вазифасы, эше. *Комиссионерлык белән шөгыльләнү*

**КОМИССИО́НКА** *и. рус сөйл.* Комиссион кибет. *Мондый буталчык вакытта аны тыңлап торсыннармыни? Кырык әйберләре кырык җирдә аунап ята. Артык-портыкларын комиссионкага илтәселәре бар.* Ф.Яруллин. *[Асыл:] Тукта, норка тунны... комиссионкага дидеңме?* Ә.Баян. *Кәрим Әбүбәкер Терегулов белән ярыша-ярыша комиссионкага йөри иде.* Р.Батулла

**КОМИ́ССИЯ** *и. лат.* 1) Берәр оешма карамагындагы махсус вәкаләтле кешеләрдән торган вакытлы орган. *Шунда ишек ачыла, һәм, Асия Мифтаховна артыннан ияреп, имтихан комиссиясе керә.* Ф.Яхин. *Ник ул әти бер дә атлы эштә эшләмәде икән? Гел ревизия комиссиясенең рәисе, склад мөдире һәм хуҗалыкның шуның ише вазифаларын үтәде.* Ә.Гаффар. *Менә, ниһаять, комиссия – бер яктан матрослар белән Берлин, икенче яктан комитет чиновниклары – пароход кабул итәргә килә.* И.Низамов

2) Һәрдаим, өзлексез рәвештә килеп чыга торган махсус мәсьәләләрне, проблемаларны хәл итә бару өчен төзелгән даими орган. *Хикмәт шунда: илдә Урта гасыр инквизициясе котырынган чорда ук, троцкист, солтангалиевче, җидегәнче, милләтче коммунист, прокуратура тикшерүчесе кулына килеп кергәнче, партия контроль комиссиясенең тегермәне аша үтәргә тиеш була.* Т.Галиуллин

3) Билгеле мәсьәлә, хәл буенча карар чыгару, тәкъдимнәр бирү хокукы булган оешма яки төркем. *Ләкин машина алу өчен, иң элек комиссия узарга кирәк.* Х.Ибраһим. *Әмма белеп торыгыз, монда әле байтак сораулар туар, аларны ачыклар өчен экспертлар комиссиясе кирәк.* Ф.Галиев

4) Алып сату белән шөгыльләнә торган оешманың товарларны карап, тикшереп кабул итә торган органы

5) Билгеле бер күләмдә акчалата түләү исәбенә башкарыла торган сатуалу системасы. *Әйберләрне комиссиягә тапшыру*

**КОМИ́ССИЯЛӘНҮ** *ф.* Махсус комиссия карары нигезендә хәрби хезмәттән азат ителү, запаска калдырылу. *Солдат хезмәтеннән комиссияләнү*

**КОМИ́ССИЯЛӘҮ** *ф.* Махсус комиссиянең карап тикшерүе нигезендә хәрби хезмәткә алынучыларның сәламәтлек ягыннан хезмәткә яраклылыгы турында нәтиҗә ясалу. *Призывникны комиссияләү*

**КОМИТЕНТ** *и. лат. финанс.* Комиссионерга үз исеменнән билгеле бер түләү хакына нинди дә булса сату-алу эшләре башкарырга җаваплылыкны үз өстенә алган кеше

**КОМИТЕТ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса эшкә җитәкчелек итү яисә иҗтимагый функцияләрне үтәү өчен сайлап куела торган, карар чыгару хокукы булган коллегиаль орган. *Судовой комитет секретаре Кармашов игъланнар тактасына еш кына газеталар элә, халыкара хәлләр, фронт яңалыклары турында белдереп тора.* С.Сабиров. *Ярлылар комитеты да байтак кешегә ярдәм күрсәткән иде, кырларны кысыр калдырмаска тырыштылар.* Я.Зәнкиев. *Иртәгә үк заводка, кадрлар бүлеге мөдире янына барам, аның белән сөйләшәм, киңәшәм, партия комитеты секретаре янына да кереп чыгам.* А.Шамов

2) Билгеле функцияләр үтәү, махсус чаралар үткәрү өчен төзелгән иҗтимагый яки дәүләт идарә органы. *Земский башкарма комитеты ничек кенә булса да станицада элекке атаман тәртипләрен саклап калырга тырыша иде.* И.Салахов. *Ләкин шундый җаваплы көннәрдә Казан комитеты меньшевиклар басымы астында ленинчыл «Вперёд» газетасын танудан баш тартты.* А.Расих

**КОМИТЕТЧЫ** *и. сөйл.* 1) Комитет әгъзасы. *Кире кайтып, комитетчылар белән тагын да катгыйрак сөйләшергә туры килде: «Флотилиягә яраклы судноларны иртәгә үк комитет утырышында раслатырга!» – диелде.* И.Низамов. *[Муса:] Безнең эше --- комитетчылар бу тирәдә йөрми. Хәрби алманнар күп очракта куркыныч түгел: --- безнең телне белмиләр.* Ш.Маннур. *[Меньшевикларны] яклап, элекке комитетчылардан берничә сакаллы адвокат кына такылдады.* А.Расих

2) Берәр комитет яклы кеше

**КО́МИЧА** *рәв.* **1.** Коми телендә. *Комича сөйләү*

**2.** *с. мәгъ.* Коми телендәге. *Комича китап*

**КОМКАЗЫГЫЧ** *и. зоол.* Комлы урыннарда оя ясап яши торган элпә канатлы бөҗәк; *русчасы:* **пескорой**

**КОМКАЗЫР** *и. зоол.* Минога личинкасы; *русчасы:* **пескоройка**

**КОМКОР** *и. рус тар.* Корпус командиры хезмәтенең кыскартылган исеме һәм Кызыл Армиянең югары команда составының бер хәрби дәрәҗәсе. *Аның җырын комкор Котовский үзе дә тыңлый иде. Кызыл галифе, кызыл фуражка кигән, ялтырап торган хром итеккә шпорлар таккан таза гәүдәле комкор үзе дә молдаван көйләрен бик матур итеп җырлый, бик кыстасалар, шпорларын шалтырата-шалтырата биеп тә китә иде.* С.Шакир. *Комкорның алгы сызыктан китүенә өч-дүрт сәгать үтмәде, әлеге җиңел танкларның икесе Баталов карамагына китерәп килеп тә җитте.* Ш.Рәкыйпов

**КОМКОРСАК** *и.* 1) *зоол.* Карпсымаңнар семьялыгыннан чагыштырмача зур башлы вак балык, ташбаш; *русчасы:* **пескарь**. *Комкорсак комлы суда булыр.* Мәкаль

2) *куч. сөйл.* Шаян, чая, шук, әрсез малай турында. *Разия чалбар балаклары манма су булган ике малайны – ике комкорсакны җитәкләп кайтты.* Г.Ахунов

**КОМЛАК** *и.* Ком белән капланган урын

**КОМЛАНУ** I *ф.* 1) Ком белән каплану. *Комланган яр*

2) Ком белән аралашып, буталып катнашу. *Суга барсаң, иртәрәк бар: кичкә калсаң – комлана.* Җыр. --- *камышлар, куе үләннәр – барысы да кайдадыр су астында калган; башка вакытта пыяладай үтә күренмәле чиста су комланган, болганчыкланган ---.* Н.Фәттах

**Комлана бару** Торган саен ныграк комлану

**Комланып бетү** Бөтенләй, тәмам комлану

**Комланып калу** Берәр моменттан, сәбәптән соң комланган хәлгә килү

**Комланып китү** Ниндидер моменттан соң комлану хәленә килү

**Комланып тору** Хәзерге вакытта яки гел, әледән-әле комлану хәлендә булу

**КОМЛАНУ** II *ф. сир.* Дулкынлану, тирбәнү. *Агыйделләр дулкынлана, Дулкынлана, комлана.* Җыр

**КОМЛАП** *рәв.* Ком ярдәмендә, ком кулланып, ком белән аралаштырып, ком катнаштырып. *[Яшь кызларның, яшь киленнәрнең] кайсы кое янында нидер чайкап-чайкап юа, кайсы рәшәткә буенда комлап, катыклап самавыр агарта.* Ә.Еники. *Капитанның беренче ярдәмчесе дәрәҗәсенә күтәрелгәнче, шактый озак беләк юанлыгы тимерчыбыктан үрелгән швартов арканын сөйрәргә, палубаны комлап юарга, трюм капкачлары ташырга туры килде.* Р.Вәлиев

**КОМЛЫ** *с.* 1) Эчендә, составында комы булган; комнан гыйбарәт, ком белән капланган. *Көймә комлы ярга килеп терәлде.* Э.Касыймов. *Алар бу вакытта елга тамагыннан еракта комлы яр буенда туктап торалар иде.* Н.Фәттах. *Төнлә сибәләп узган яңгыр комлы юлны чылатып өлгермәгән.* Р.Зарипова

2) Ком белән аралашып, буталып катнашкан. *Комлы җил белән уралып, бар хәлгә чабып, шәһәрнең бер читеннән эскадрон килеп чыга.* А.Шамов. *Зөлфияне Монголиянең комлы бураннары, барханнары, пычрак юрталары, сәяси тотнаксызлык мәсьәләләре борчымый.* Т.Галиуллин

3) Ком белән кызыл балчыктан торган (туфрак); *русчасы:* **супесчатый**

**КОМЛЫК** *и.* 1) Сулыкларның яр буенда ком белән капланган урын, пляж. *Биредә Канададан килгән туристлар ял итә икән. Яр буенда ак көймәләр, комлыкта ипле ятаклар...* М.Маликова. *Шушма комлыгында көнозын кеше өзелми.* Р.Хафизова

2) Балалар уйнау өчен ком салып ясалган урын. *Урамнан үтеп баручыларга, ишегалды комлыкларында тыныч кына уйнап утыручы балаларга урам этләренең һөҗүмнәре турында гел ишетеп торабыз.* Шәһри Казан

3) Ком чыгару урыны, карьер

**КОМЛЫ КӘГАЗЬ** *и.* Төелгән наждак катламы белән ябылган махсус кәгазь; наждаклы кәгазь. *Янәшәдә тагын 100×100 см лы пыяла такта. Ул комлы кәгазь белән ышкып, үтә күренмәслек хәлгә китерелгән.* З.Хисамов

**КОММАНДИТ** *с. фр. финанс.* Чикләнгән җаваплылыкка ия булган кеше

**КОММЕНТА́РИЙ** *и. лат.* 1) Берәр тамашага, документка, күренешкә аңлатма, ачыклама, искәрмә. *Г.Ибраһимовның «социалистик реализм» методына карата булган фикерен, ниһаять, М.Хәсәновның түбәндәге комментариеннан белә алабыз ---.* К.Гыйззәтов. *[Панов:] – Фронт хәлләрен белергә дә тоткыннарга җиткереп барырга кирәк. – Һәм шунда ук үз комментарийларыбызны да ясап барырга кирәк булыр, – диде Медведев, аңа өстәп.* Казан утлары

2) Берәр хезмәтнең, әсәрнең бәяләмәсен һәм аңлатмасын үз эченә керткән өстәмә ярдәмче текст, шәрех

◊ **Комментарийлар кирәк түгел** Аңлатуларсыз да аңлашыла. *Күрәсез, нәкъ бүгенге ситуация. Комментарийлар кирәк тә түгел. Әлеге сессиянең карарына күз салыйк.* Р.Миңнуллин

**КОММЕНТА́РИЙЛАУ** *ф.* Комментарий, ачыклама, аңлатмалар бирү. *Бу юлларны комментарийлап тору кирәкмәс.* Г.Гобәй

**КОММЕНТА́ТОР** *и. нем.* 1) Комментарийлар бирүче, шәрехләүче, аңлатма бирүче, шәрехче. *Комментатор тирәсенә елыш һәм ул тынып торган арада: «Борис! Сәлам!» – дип акыр!.. Шуннан чамаларбыз!* А.Гыйләҗев

2) Репортажны алып баручы, мөһим вакыйгаларны (спорт, иҗтимагый-сәяси һ.б.) матбугатта, радио-телевидениедә яктырткан журналист. *Юлаучылар журналистлар икән. --- Мәһабәт гәүдәлесе, аңлавымча, тышкы эшләр комментаторы.* С.Сөләйманова. *Таныш булыйк: мин – Сафия Нурхан, япон телевидениесе комментаторы.* И.Юзеев. *Комментатор булмәсе*

**КОММЕРСАНТ** *и. фр. махс.* Коммерция (сату-алу) белән шөгыльләнүче кеше; сәүдәгәр, алыпсатар. *Укымышым белән мин коммерсант.* Н.Исәнбәт. *Иске китапчыларга алмашка буржуаз-демократик юнәлештә эш итүче коммерсант китапчылар килде.* И.Рәмиев. *Әйдә, юлларны үзем түлим, кайтып килик инде, дисәм дә, коммерсант егет риза булмады.* Р.Сәгъди

**КОММЕРСАНТЛЫК** *и.* Коммерсант булу; коммерсант һөнәре, эше. *Әкрам бик тиз үзләштерде Коммерсантлык гадәтен.* Г.Насрый. --- *шәһәр идарәсе, Рус тарих җәмгыяте һәм башка уку йортлары, аерым галимнәр берничә ел --- искәрткән хәлдә, акча бәрабәренә китап биреп торуны коммерсантлык эше дип бәяли.* М.Галиев

**КОММЕ́РЦИЯ** *и. фр. икът.* 1) Сәүдә итү, сату итү, товар әйләнеше эшчәнлеге; тиҗарәт. *Хәзер ул медицина белән бәйле коммерция структурасында эшли.* Я.Шәфыйков. *Ләкин базар мөнәсәбәте, коммерция ул – котылгысыз бер күренештер, һәрхәлдә, якын киләчәктә шулай булачак.* Р.Миңнуллин

2) Табыш алуга юнәлгән эшчәнлек. --- *Радом спекулянтлары белән итәк астыннан гына коммерция ясарга да өлгерде.* Ш.Маннур

**КОММИВОЯЖЁР** *и. фр. махс.* 1) Сәүдә эшләрен, сәүдә оешмасы йомышларын төрле урыннарда юл йөреп башкаручы хезмәткәр. *Казанның татар байлары белән эш иткән сәүдә фирмаларының вәкилләре – коммивояжёрлар да шушы мөсафирханәләргә туктыйлар иде.* И.Рәмиев

2) Поезд, автобус кебек транспорт чараларында сәүдә итеп йөрүче, фирманың товар үрнәкләрен каталоглардан, прейскурантлардан күрсәтеп йөреп, заказлар җыю эшен башкаручы кеше; сәүдә эшләре белән шөгыльләнүче реклама агенты

**КОММОДОР** *и. ингл.* 1) Кайбер чит ил флотларында: вице-маршал һәм контр-адмирал дәрәҗәсе алдыннан килә торган югары офицер составының хәрби дәрәҗәсе

2) Конвой командиры

3) Пароход компаниясенең өлкән капитаны

4) Яхт-клубның президенты

**КОММУН** *и. иск. сөйл.* **1.** 1) *к.* **коммуна**. *[Миңлесылу:] Карт, сиңа әйтәм,*

*без дә язылыйк инде коммунга, Әхмүш тә язылды.* Һ.Такташ. *Коммун төзегәч, без монда да рәхәтләнеп эшләдек.* Г.Толымбай

2) Коммунист. *Галимҗан карт киявенең солдаттан коммун булып кайтуына риза түгел иде.* Г.Минский. *[Мәтәли:] – Нияз агай, син нигә бармыйсың? [Нияз:] – Мин коммун түгел бит.* Т.Гыйззәт

**2.** *с. мәгъ.* Коммунистлар яклы яисә үзе коммунист булган. *Безнең яшьтә чакта алар шундый коммун йөрәкле, шундый югары идеяле --- гражданин булганнар.* М.Әмир

**КОММУ́НА** *и. фр.* 1) Милек һәм хезмәт уртаклыгы нигезендә бергә яшәү өчен берләшкән кешеләр коллективы (XX гасырның 20 нче елларында СССРда социалистик яшәеш формасы дип исәпләнгән). *Күмәк хуҗалыкка тәҗрибә сыйфатында авыл кешеләрен коммуналар, артельләр оештырырга совет хөкүмәте үзе чакыра, бу юлга аяк баскан коллективларга теләгән урыннарыннан җир алырга мөмкинлек бирә, атлар-машиналар белән дә ярдәм күрсәтергә тырыша иде.* М.Әмир. *Совет властенең беренче елларында ярлы-урта хәлле крестьян хуҗалыкларын үстерүдә авыл хуҗалыгы кооперативлары зур роль уйнады. Алар – авыл хуҗалыгы коммуналары, сөтчелек ширкәтләре, терлекчелек ширкәтләре, он тарту буенча ширкәтләр һ.б.* Татарстанда терлекчелек

2) *тар.* Европаның кайбер илләрендә авыл яисә мәхәллә җәмгате, беренчел административ-территориаль берәмлек. *Ул шәһәрнең хәзер коммуна кулында икәнлеген, ләкин шул ук вакытта губернаторның да үз резиденциясендә яшәвен, заводларда дружиналар төзелүен, шәһәрдә халык милициясенең тәртип урнаштыруын сөйләде, ләкин гарнизондагы хәрби көчләрнең әле һаман коммуна ягына күчмәгәнлеген, анда бик ышанычлы иптәшләр эш алып барса да, әле тиешле нәтиҗәгә ирешеп булмаганлыгын хәбәр итте.* А.Расих

3) *иск. сөйл. к.* **коммунизм**. *Күмәкләшеп эшли-эшли Коммунага барабыз.* Җыр. *Һәр җырның кушымтасы икенче тапкыр кабатланганда, «татулык» сүзе «коммуна» белән алыштырыла. Ягъни чын мәгънәсендә татулык ул – коммунизм...* М.Әмир

4) *тар.* Урта гасырларда Көнбатыш Европа илләрендә: сеньордан ирекле идарә хокукын алган шәһәр общинасы

5) *тар.* Бөек француз революциясе вакытында (1789–1794): муниципаль үзидарә. *Бик озын сөйли торган егет иде ул. Һәр речен борынгы гасырлардан, коллар восстаниесеннән башлап, Париж коммунасы турында аерым туктап, бөтендөнья революциясе белән тәмамлый иде.* А.Шамов. *[Ул] Революциягә хәрби белгечләр кирәк, Париж коммунасында булган шикелле үк революцион офицерлар һәм генераллар кирәк, дигән уйны минем күңелдә ныгытты.* И.Низамов

**КОММУНА́ЛКА** *и. рус сөйл.* Шәһәр милкендә булган, шәһәр идарәсе тарафыннан билгеле бер торак мәйданы нормативлары буенча берничә гаиләгә бирелгән бер квартир. *Менә агач коммуналканың коридор ишегеннән бер төркем ир-егетләр белән хатын-кызлар килеп керде.* Җ.Дәрзаман. *Шәһәр халкы, байлардан калган йортларны вак кетәклекләргә бүлгәләп, шуларда тора бирде... Һичбер җае булмаганга һәм кысылып яшәгәнгә күрә, аларны «коммуналка» дип атыйлар иде.* Ә.Еники. *Карлен Татлян --- кичә генә әле ярым җимерек коммуналкаларда хезмәт хакын тартып-сузып ярым ач яшәүчеләрнең кеше ышанмаслык күтәрелешләре һәм шундый ук тизлек белән янә түбән тәгәрәүләренә күнегә бара иде.* Р.Мирхәйдәров

**КОММУНАЛЬ** I *с.* Коммуналарга *(2 мәгъ.)* бәйләнешле, коммуналарга караган. *Коммуналь сайлаулар*

**КОММУНАЛЬ** II *с.* Җирле хуҗалыкка (шәһәр, бистә, авыл һ.б.) караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Биредә Закир абый башта шәһәр коммуналь хуҗалыгында, аннары сәламәтлек саклау бүлегендә бухгалтер булып эшли.* Ш.Мостафин. *Иске янгын сараеннан әмәлләнгән бер бүлмәле, бәләкәй генә кухнялы коммуналь квартир кисәге таптым.* Ш.Маннур. *Коммуналь квартираның зур гына кухнясында, тагын өч семья белән янәшә, аларның да аерым өстәле, керосинкасы, чүп чиләге тора иде.* М.Маликова

**КОММУНАР** *и. фр. тар.* 1) Париж коммунасын оештыру һәм яклауда (1871 ел) катнашкан кеше; революционер. *Эйфель манарасын коммунарларга һәйкәл итәргә кирәк.* Г.Гали. *Коммунарлар истәлеге*

2) Коммуна әгъзасы, коммуначы. *Мәсәлән, коммунарлар ураза уңае белән дингә каршы кичәгә хәзерләнәләр, ә шул ук вакытта дошманнар, ифтар ашы җыеп, коммунага каршы көчләрне туплау эшенә керешәләр.* Ш.Камал. *Коммунарлар – безнең кешеләр бит алар. Алар – җирдә, тере кешеләр, безнең кебек үк реаль кешеләр.* Г.Бәширов. *Элек, коммунар эш яратмый, алар кәкрене тераәп йөрергә генә ярата, дип, коммунистлардан көләләр иде.* Г.Толымбай

**КОММУ́НАЧЫ** *и. тар.* Коммуна (*2 мәгъ.*) төзү яклы һәм коммуна әгъзасы булган кеше

**КОММУНИЗМ** *и. нем.* 1) Социалистик революциянең җиңүе һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру нәтиҗәсендә капитализмга алмашка килә торган югары иҗтимагый-сәяси формация. *Коммунизм дигән сүзне шунда башлап әти авызыннан ишеттем.* М.Әмир. *Тик менә кешенең гомере кыскарак. Синең белән мин коммунизмны, бәлки, күрә алмабыз.* С.Рафиков. *Тик безнең илдә генә хатын-кызлар тулы хокуклы булып, бәхетле, шатлыклы тормышта яшиләр, ирләр белән бертигез коммунизм төзүдә актив катнашалар.* Г.Иделле

2) Коммунистик җәмгыять төзү турында марксизм-ленинизм тәгълиматы, шундый хәрәкәтнең теоретик нигезләре. *Урта мәктәпләрдә, югары уку йортларында, аспирантура, докторантурада укыганда, политукуларда колагыбызга бер нәрсәне тукыдылар: «Фәнни коммунизм теориясе генә чын хакыйкать. Ә дин – кешеләр өчен әфьюн».* М.Әхмәтҗанов

**КОММУНИКА́БЕЛЬ** *с.* Кешеләр белән тиз контактка керүчән, җиңел аралашучан

**КОММУНИКАТИВ** *с.* Коммуникациягә (*1 мәгъ.*) караган, үзара аралашуга, хәбәрләшүгә, информация алышуга бәйләнешле. *Ләкин Кант, сәнгатьнең нинди дә булса максатка буйсынырга тиешлеген инкяр итсә дә, аның коммуникатив функциясен танырга мәҗбүр була.* К.Гыйззәтов. *Компонентларның һәр икесе дә мөһим, коммуникатив яктан актуаль кисәкләр булып торалар, һәм һәрберсе үзенчәлекле (автоном) бер хөкемне тәгъбир итәләр.* Г.Нәбиуллина. *Телнең коммуникатив функциясе аның танып белү функциясе белән тыгыз бәйләнгән.* Ф.Сафиуллина

**КОММУНИКАЦИОН** *с.* 1) Коммуникациягә (*1 мәгъ.*) караган. *Коммуникацион корылма*

2) *к.* **коммуникатив**

**КОММУНИКА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Аралашу, хәбәрләшү һәм элемтә юллары (каналлары). *Фронт коммуникациясенә әйләнгән бу юлны һәртөрле машиналар, йөк тарткычлар чокыр-чакырга әйләндереп бетергән.* Г.Минский. *Русия һәм БДБ илләре буйлап чәчелеп яшәгән халыкны гадәти коммуникация чаралары ярдәмендә бергә җыю бик кыен.* Р.Хәкимов. *Россия суд приставларының федераль хезмәте 50 сайт, форум, социаль челтәр һәм коммуникация программаларыннан торган исемлек төзегән.* Шәһри Казан

2) Шәһәр хуҗалыгының газ, су, җылылык һ.б. белән тәэмин итә торган корылмалары. *Шәһәрдә җир асты тулы коммуникация, эш күләме биреп булмый дип, кул гына селтәделәр.* З.Дәүләтов. *Коммуникацияләрне, җиһазлар һәм төзелмәләрне буяганда, хәбәрле (информацион) ишарә-искәртүле төсләр кулланыла.* Хезмәт иминлеге

3) Аралашу, аңлашу, хәбәрләшү, фикер һәм хис-тойгыларны белдерү. *Коммуникатив синтаксис җөмләдә тыңлаучы өчен алдан билгеле булган һәм яңа төшенчәне (актуаль кисәкләрне) аерырга тырыша һәм аралашу (коммуникация) процессында җөмләнең ролен билгеләргә омтыла.* М.Зәкиев. *Хәзерге заман коммуникациясе, бигрәк тә информатика фәне һәм информатика техникасының казанышлары нәтиҗәсендә, халыклар, дәүләтләр, континентлар арасындагы ераклыкны да сизми.* К.Гыйззәтов

**КОММУНИСТ** *и. лат.* 1) Коммунистлар партиясе әгъзасы. *Коммунист кеше туры сүзле, гадел булырга тиеш.* С.Рафиков. *Күзегезне ачып карагыз: коммунист түрәләр рәхәтләнеп халык җилкәсен кимерә, ял иткән арада трибунага чыгып тигезлек турында сөйли, якты киләчәктә бөтен халык шәп яшәр дип ышандыра.* Р.Зәйдулла. *Ләкин ул хәзер коммунист шагыйрь өчен бердәнбер юаныч, бердәнбер юл.* Ә.Давыдов

2) СССР да ВКП(б) һәм аның дәвамчысы булган КПСС әгъзасы

**КОММУНИ́СТИК** *с.* 1) Коммунизмга (*1 мәгъ.*) бәйле, коммунизмга караган. *Һәм мин моны элеккеге коммунистик тоталитарлык елларында да милләт язмышы турында үз сүзен курыкмыйча әйтә алган абруйлы әдипләребез әйтер дип көттем.* Җ.Дәрзаман

2) Теоретик коммунизм принципларына нигезләнгән яисә шуларны күз алдында тоткан. *Алар халык белән бергә матур киләчәккә – коммунистик җәмгыятькә бара.* А.Шамов. *Әмма бүген, илебездә төзеләчәк коммунистик җәмгыятьнең материаль-техник базасын салганда, киң колач белән азык-төлек программасын тормышка ашырганда, без үз-үзебездән җитештерелә торган бу продукция экономик яктан отышлымы, файдалымы дип сорарга да мәҗбүрбез.* А.Хәсәнов. *Яңа, коммунистик җәмгыять формалашу процессында аралашу һәм эшчәнлекнең яңа төре, гармонияле рәвештә җитлеккән кешенең яңа тибы барлыкка килә.* Матурлык нәрсәдә?

3) Коммунизм идеяләре белән сугарылган, коммунизм өчен көрәшүче. *Тик ул үзен барыбер җиңде: политбүлекне, коммунистик частьларны станция янындагы йортларга күчерде.* И.Низамов. *Әйе, сәвит мәктәбе, коммунистик тәрбия комганны, сөннәтне, намазны, никахны, иманны салып таптады гына түгел, яшь буыннан таптатты.* М.Маликова. *Илдә бүген «коммунистик идеалларны» теше-тырнагы белән яклаучыларның күбесе – урыслар.* Р.Зәйдулла

**КОММУНИСТЛА́РЧА** *рәв.* Коммунистлар кебек, коммунизм принципларын, идеяләрен тотып, шуларга хас булганча. *Шуңа күрә дә, иптәш Сабирҗанов, сезгә бүгенге мәсьәлә турында ныклап, коммунистларча уйларга киңәш итәбез...* Н.Акмал. *Ачык рәсми җыелышларда бары тик сәяси мәсьәләләр, коммунистларча гына эшләр карала.* Р.Вәлиев. *Коммунистларча эшләү, ә обывательләрчә яшәү – күренеп торган мәгънәсезлек.* Матурлык нәрсәдә?

**КОММУНИСТЛЫК** *и.* 1) Коммунист булу. --- *Балага исем сайлау мәсьәләсе ячейка әгъзаларына тапшырылгач, һәркем үзе изге санаган һәм коммунистлык өчен ярашлы саналган исемне мәгънәләрен сөйләп тәкъдим итә башладылар.* Ф.Әмирхан. --- *Без – коммунист.... Бездә – коммунистик иман... – Соң алайса, андый иманың да булгач, ник әллә кайчан кермәдең соң ул коммунистлыкка? – дип, янә сөаль бирде Майбәдәр.* Л.Лерон. *[Ифрат:] Ул сезгә беркайчан да хыянәт кылганы юк. Ышанмасагыз, башымны кисәргә бирәм. Коммунистлыгым белән ант итәм.* А.Расих

2) Коммунистларга хас сыйфатлар. *Бүген син икмәк өчен Ватаның каршында, сугышчы каршында коммунистлык намусың белән җавап бирәсең!* Г.Бәширов

**КОММУНХОЗ** *и. рус сөйл.* Коммуналь хуҗалык бүлеге. *Бүген бүлмәм өчен акча сорап, Коммунхоздан килеп керделәр.* Һ.Такташ. *Әхмәтша ул вакытта коммунхозда ниндидер начальник иде бугай.* М.Әмир

**КОММУТА́ТОР** *и. лат.* 1) *тех.* Коммуникация системасында электр тогы үтә торган линияләрне тоташтыру, өзү, күчерү, бүлү һ.б.ш. процессларны башкару приборы. *Бу вакыт арасында заводның төп һәм ярдәмчел цехлары, идарәнең җитәкчел бүлекләре һәм директор урынбасарлары коммутатор аша барысы бер телефон линиясенә тоташтырылып, директорның дирижёрлык тавышы астында көн*

*кадагы булып әверелгән мәсьәләләрне тикшерәләр, бәхәсләшәләр-тартышалар ---.* Э.Касыймов. *Коммутатор, 6–39 ны бирегез әле, гафу итегез, ялгыш әйттем, 5–13 не бирегез.* Р.Ильяс

2) Телефон элемтәсен эшләтү пункты. *[Телефонда] Гөлчирә түгел, ә коммутатордагы телефонистка Шәмсия [сөйләшә] иде.* Г.Әпсәләмов

**КОММУТА́ТОРЛЫ** *с.* Коммутаторы булган. *Коммутаторлы элемтә бүлеге*

**КОММУТА́ЦИЯ** *и. лат. тех.* 1) Махсус аппаратура ярдәмендә электр тогының өләшенүе, юнәлеше һәм сыйфаты белән максатчан идарә итү

2) *информ.* Хисаплау машиналарындагы мөһим элементлар арасындагы бәйләнешне эшләп чыгару

3) *лингв.* Тел берәмлекләренең формалары һәм аларның мәгънәләре арасында булган үзгәрешләрнең туры килүләрен теркәүгә нигезләнгән тикшерү методы

**КОММЮНИКЕ** *и. фр. сәяси* Дәүләтләр арасында алып барылган сөйләшүләр, килешүләр, ил эчендәге вакыйгалар, сугыш хәрәкәтләре һ.б. турында рәсми белдерү, рәсми хәбәр. *Шул ук гап-гади гариза, беркетмә, акт яисә указ, әмер, коммюнике һ.б. – болар барысы да жанрлар бит.* И.Низамов

**КОМОД** *и. фр.* Эчке кием һәм башка төрле вак-төяк әйберләр саклый торган тартмалы тәбәнәк шкаф. *[Алар] Шкафтагы китапларны туздырып ташладылар, урын-җирне, сандыкларны, кер саклана торган комод ящикларын актардылар.* А.Расих. *Комод өстендә берничә тузып беткән уенчык тора.* Ф.Галиев. *Буш арбаларга кием шкафы, комод, өстәл, урындыкише нәрсәләрне чыгарып төяп торалар, аласын алганнары китә бара.* Р.Фәтхетдинов

**КОМПАКТ** *рәв.* **1.** Тыгыз һәм бергә аерымланып урнашкан; аз урын алып торган, сибелмәгән-чәчелмәгән хәлдә. *Компакт яши торган халыклар. Компакт урнашкан булу*

**2.** *с. мәгъ. к.* **компактлы**

**КОМПАКТ ДИСК** *и. ингл.* Гадәттә 120 мм диаметрдагы даими (сөртелми торган) сигналлограммалы оптик диск. *Өстәвенә Рәшит Ваһаповның җырларыннан торган компакт дисклар, кассеталар чыкты.* Р.Миңнуллин

**КОМПАКТ КАССЕ́ТА** *и. ингл.* Магнитофон өчен зур булмаган ябык кассета

**КОМПА́КТЛЫ** *с.* **1.** 1) Тыгыз һәм җыйнак урнашкан. *Шәһәрнең, компактлы итеп, егерме биш мең кешегә генә салынуы миңа ошый.* Г.Ахунов. *Ниһаять, гаҗәеп объектлар – квазарлар, безнең Галактикадан гаять ерак урнашкан һәм ифрат зур микъдарда энергия таратучы компактлы җисемнәр дә – рентген нурлары чыгаралар.* Галәм. Җир. Кеше

2) Кыска, җыйнак. *Компактлы чыгыш*

**2.** *рәв. мәгъ.* Кыска, җыйнак итеп. *Компактлы сөйләп бирү*

**КОМПА́КТЛЫЛЫК** *и.* Компактлы булу

**КОМПА́НИЯ** *и. фр.* 1) Уртак сәүдәсе, кәсәбәләре, завод-фабрикалары һ.б. булган эшмәкәрләр оешмасы, фирма. *Тикшереп карасалар, документ дигәне ширкәтнең баржаларны үзе кебек үк компанияләргә, аерым хуҗаларга арендага биреп тору турында килешү кәгазьләре икән.* И.Низамов. *Җәүдәт заводның ничек төзелүе, «Фиат» дигән сүзнең Италиядәге Турин шәһәрендәге зур бер компания исеме икәнен, җиңел машинаның нинди булачагы, заводның елына ничә машина эшләп чыгарачагы һәм башка бик күп нәрсәләр турында үзенең белгәннәрен сөйләп бирде.* Р.Кәрами

2) Оешма башында торучының исеменә кушып әйткәндә шундый берләшмәдә катнашучыларга гомуми ишарә белдерә. *Мохтар [Габдуллага] сәүдә хезмәткәрләренең җыелышларына калмыйча йөрергә, Әхмәдиев һәм компаниясенең байлар файдасына хезмәт итүләрен һәрбер җыелышта ачып салырга тиешлекне әйтеп үтте.* Ш.Камал

3) Бергәләшеп вакытны уздырган, йөргән һәм бер-берсен яхшы белгән кешеләр төркеме. *Аларның сүзе буенча да, шаһитлар әйтүенчә дә, имеш, теге полковник ни өчендер бу компанияне туктатырга теләгән, ә извозчик атларны юри туп-туры аның өстенә куалаган икән.* З.Фәтхетдинов. *Алар ашамлык-эчемлекләр китерергә куштылар да, ял итәргә килгән шаулы компания төсле күренер өчен, көлешкән булып, сөйләшергә керештеләр.* Ә.Давыдов

**КОМПАНИЯЛӘП** *рәв.* Компания (*3 мәгъ.*) белән, компания булып. *Компанияләп кәеф ачарга Минзәлинский яратмый бугай.* К.Нәҗми

**КОМПАНИЯЧЕЛ** *с.* Компаниядә булырга яратучан, компаниягә тиз кереп китүчән, компаниягә тиз ияләшүчән. *[Әнисә Нуретдин кызы] Шул ук вакытта ул – бик аралашучан, кызык һәм компаниячел кеше ---.* Яшел Үзән

**КОМПАНЬОН** *и. фр.* 1) Нинди дә булса эштә, шөгыльдә кемгә дә булса компания тәшкил итүче кеше; мәҗлестәш, иптәш. – *Бу нәрсәгә син ничек карыйсың? – диде Феликс, шешәгә күрсәтеп. – Мин сиңа компаньон түгел. Тамчысы да ярамый.* М.Юныс. *«Компаньон»ының сатирик таланты инде һәркемгә билгеле.* И.Нуруллин

2) Сәүдә яки сәнәгать ширкәте әгъзасы. *Кайчандыр Бекхуҗаевларның компаньоны булган Коста аларга иске вексельләрне илтеп бирде ---.* Р.Мирхәйдәров

**КОМПАНЬОНЛЫК** *и.* 1) Компаньон (*1 мәгъ.*) булу, иптәшлек, юлдашлык

2) Компания *(1, 2 мәгъ.)*, ширкәт әгъзасы булу. *Бай үлде. [Габдрахманның] компаньонлык планнары, бай семья белән туган-тумача булу, йөрешү хыяллары юкка чыкты.* Ә.Фәйзи

**КОМПА́РТИЯ** *и. рус* Коммунистлар партиясе. *Компартиядән РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат – Татарстанның элеккеге вице-президенты Василий Лихачёв --- узарга мөмкин дип саный.* Безнең гәҗит

**КО́МПАС** *и. ит.* 1) Җир шарының дүрт ягын (көньяк, төньяк, көнчыгыш, көнбатыш) билгеләү өчен кулланыла торган махсус җайланма, прибор, кыйбланамә (һәрвакыт төньякны күрсәтә торган магниты – угы бар). *Иптәшләре адашмасыннар, кайту юлына таба кире борылмасыннар өчен, ул компасын гел алдында тота.* А.Алиш. *Аларны төз атарга, граната ташлар-*

*га, тимерчыбыклар кисәргә, пычрак җирдән түш белән шуышырга, суга керергә, карта һәм компас белән эш итәргә --- өйрәнергә мәҗбүр иттеләр.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Нинди дә булса эшкә юнәлеш, омтылыш бирә торган көч. *Һәр сатучы – кораб капитаны. Һәрберсенең дөрес компасы.* Р.Харис. *Белеп йөрми сәях, ә компасы – Ният аның, өмет – кыйбласы, Безгә әле ялга да туктыйсы, Төнгә кала-кала барасы...* Ф.Яхин

**КОМПЕНСА́ТОР** *и. лат. тех.* Нинди дә булса механизмнарның эш шартларын тигезләштерү, тиңләштерү, бертигез итү яки нәрсәнең дә булса аермасын үлчәү өчен билгеләнгән прибор, җайланма. *Предприятие Башкортстанда үзенең эшчәнлеген 2003 елда җәелдерә һәм башлап автомобиль сәнәгате өчен компенсаторлар, металлдан җиңсәләр, сильфоннар җитештерүгә керешә.* Кызыл таң

**КОМПЕНСАЦИОН** с. 1) Компенсациягә (*1 мәгъ.*) караган, шуңа бәйләнешле. *Хезмәт хакының база өлешеннән тыш, компенсацион һәм стимуллаштыру характерындагы өстәмәләр каралган.* Мәдәни җомга

2) Компенсация (*4 мәгъ.*) өчен хезмәт итә торган. *Компенсацион приборлар җыелмасы*

**КОМПЕНСА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нәрсә өчен дә булса түләү, бүләкләү яки нинди дә булса чыгымнарны каплау, кире кайтару эше һәм шул эш өчен билгеләнгән акча. *[Украина:] Татарның дегетенә буялып, урысның газын иснәп яшим икән, моның өчен миңа компенсация түләвегез тиешле!* Ф.Яхин. *Балтыйк буе республикалары совет «оккупациясе» чоры өчен компенсацияләр таләп итә.* Шәһри Казан. *Агымдагы елда хәзерге пенсия, пособиеләр, компенсацияләргә өстәмә материаль ярдәмне барысы 1,5 млн. кеше алачак.* Мирас

2) Өстәмә эш өчен закон нигезендә хезмәт хакыннан тыш түләнгән акча

3) *мед.* Организмда барлыкка килгән бик каты авырту акрынлап кимү, организмның элекке халәтенә кайту күренеше. *Бавыр чире компенсациясе*

4) *тех.* Төгәл механизмнарның ялгышсыз эшләвенә комачаулый торган тышкы тәэсирләрнең бетү күренеше

**КОМПЕНСАЦИЯЛӘ́Ү** *ф.* Компенсация ясау. *Пластик картадан читләр законсыз төстә акча урлаганда, банк клиентка бу сумманы компенсацияләргә тиеш.* Шәһри Казан

**Компенсацияләп бетерү** Компенсацияләүне төгәлләү

**Компенсацияләп килү** Күптәннән компенсацияләү эшен дәвам итү

**Компенсацияләп тору** Даими яки әледән-әле компенсацияләү

**Компенсацияли бару** Акрынлап берникадәр компенсацияләү

**Компенсацияли төшү** Тагын да компенсацияләү

**КОМПЕТЕНТЛЫ** *с.* 1) Нинди дә булса мәсьәләдән яхшы хәбәрдар, билгеле бер өлкәдә тирән белеме булган. *[Америкада] Фәндә, идарәдә, производствода, хезмәт күрсәтү өлкәсендә – һәркайда да югары квалификацияле, үз профессияләрен яратып сайлап алган компетентлы кешеләр эшли.* М.Мәхмүтов. *Компетентлы сәнгатькяр буларак, аның [Тукайның] урыс шигъриятендәге күренешләргә үз карашы бар.* Н.Хисамов. *«Техник контроль бүлеге»ндә компетентлы белгечләр эшләргә тиеш.* Р.Нуруллин

2) Төпле, ышандыргыч, авторитетлы; тирән хәбәрдарлыкка нигезләнгән. *[Һарут:] Сез монда нигә килдегез? Тәшерәмен исегезгә: тост кирәкми, җавап кирәк, компетентлы җавап сездән!* Р.Харис

3) Нинди дә булса эш, мәсьәлә буенча тиешле хокукка, вәкаләткә ия булган. *Компетентлы комиссия яраклы дип тапкан сценарийлар гына киностудиягә тапшырыла.* Ватаным Татарстан

**КОМПЕТЕНТЛЫК** *и.* Компетентлы булу; мәгълүматлылык; вәкаләтлелек. *Күргәнебезчә, «Техник контроль бүлеге»нең гимн текстын тикшерү компетентлыгы түбән булып чыккан.* Р.Нуруллин

**КОМПЕТЕНТЛЫЛЫК** *и. к.* **компетентлык**. *Хәзер беренче урынга компетентлылык, колачлы эш йөртә белү, мөстәкыйль рәвештә уйлый алу кебек асыл сыйфатлар чыга.* Казан

**КОМПЕТЕ́НЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Нинди дә булса өлкәдә, шулай ук билгеле бер мәсьәлә буенча яхшы хәбәрдарлык, белемлелек. *Җитәрлек компетенцияләре булмаган хәлдә операция ясаган булып, авыруны вакытыннан элек теге дөньяга озаттылар.* Г.Әпсәләмов

2) Берәр оешма яки урындагы кешенең нинди дә булса мәсьәлә буенча эш йөртүгә хокукы, вәкаләте. *Кесә телефонының төймәләре пипелдәде. «Сезнең очрак безнең компетенциягә керми... Тынычлык саклагыз. Иртән чыгарырлар».* Д.Булатова. *Вәкаләтле вәкил үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары --- һәм башка затлар белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыра.* Ватаным Татарстан

**КОМПЕТЕ́НЦИЯЛЕ** *с. к.* **компетентлы**. *Аларга шалтыратып, үзебезнең халкыбызның хәлен аңлатып бирә ала торган белемле, компетенцияле дежур кешеләр булсын иде радиотыңлаучылар арасында.* Безнең гәҗит

**КОМПИЛЯТИВ** *с.* Компиляциягә нигезләнгән, компиляция юлы белән төзелгән. *Закировны, өлкән буынга караган галимне, яшьләрнең компилятив фикерләр белән чыгыш ясаулары бөтенләй дә борчымады.* Ф.Яхин

**КОМПИЛЯ́ТОР** *и. нем. кит.* Компиляция белән шөгыльләнүче кеше; билгеле бер компилятив эш, хезмәт язган (төзегән) кеше

**КОМПИЛЯ́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Башка авторларның хезмәтләрен мөстәкыйль эшкәртмичә, аларның тикшеренүләрен күчереп алып нинди дә булса хезмәт, әсәр язу күренеше. *Бер акыллы кеше әйткән, ди: – Бер чыганактан күчерү – плагиат, икедән – компиляция, өч һәм аннан да күбрәктән күчерү – диссертация, – дигән.* Г.Гыйльманов

2) Шундый юл белән эшләнгән хезмәт, язма, әсәр; күчермә. *Галимнәрнең үзәккә алып бер генә мәсьәләне дә тикшерергә кыймаулары, утырышларны фикердә ныгып җитмәгән, фәнни*

*ачыштан компиляцияләрне аерыр хәлдә булмаган --- яшь фәнни хезмәткәрләрнең алып барулары --- гаҗәпкә калдырды.* Ф.Яхин

**КОМПИЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Компиляция ясау, компиляция белән шөгыльләнү

**Компиляцияләп тору** Даими яки әледән-әле компиляцияләү

**КО́МПЛЕКС** *и. ингл.* 1) Билгеле бер предмет, күренеш, эш-хәрәкәт, үзенчәлекләр җыелмасы. *[Гатауллин:] – Гариф Гафурович, сез нинди мәсьәләне чишү буенча эшлисез әле?.. – Сәнгатьтә комплекс проблемасы, – диде Гатауллин ---.* Ф.Яхин. *Һәр дәрес үз эченә физик күнегүләр комплексын, сулыш, бармак һәм күрү гимнастикаларын, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алган психологик уеннарны да ала.* Сабантуй

2) Халык хуҗалыгының үзара бәйле булган тармаклары җыелмасы, бергәлеге. *Татар телендәге китаплар тиражы арта ---. Бу уңайдан «Мәгариф» нәшрияты һәм Казанда нәшрият-полиграфия комплексы төзү турында ике мөһим карар кабул ителде.* Мирас. *Әлеге оешма [колхозара төзелеш оешмасы] --- «Коммунизмга» колхозында дуңгызчылык комплексы, Тымытык һәм Чалпыда мәдәният йортлары сала.* Маяк

3) Бер үк максатка юнәлдерелгән биналар, корылмалар төркеме. *Болгардагы Хан сарае комплексы 2013 нче елның июль башына төзелеп бетте.* Ш.Алпар. *1976 елны Кырлайда ачылган музей ике экспозициядән: мемориаль-көнкүреш һәм әдәби-нәфис комплекстан тора.* Р.Низамиев. *Көньяк-көнчыгыштан Кремльгә элекке Күчерү төрмәсе комплексы тоташа.* Мирас

**КО́МПЛЕКСЛАП** *рәв.* Комплекслы итеп; комплекслы рәвештә. *Ә.Кәримуллин --- Фәннәр академиясенең Дөнья культурасы тарихы буенча Гыйльми советының китапны комплекслап өйрәнү комиссиясе члены иде.* Совет Татарстаны язучылары

**КО́МПЛЕКСЛЫ** *с.* **1.** 1) Төрле предметларны, күренешләрне яки үзенчәлекләрне эченә алган. *Казан һәм Алабуга шәһәрләренең 1000 еллыгына әзерлек чорында мәдәни мирасны саклауга комплекслы якын килү үзен тулысынча аклады ---.* Р.Вәлиев. *Казан Кремле мәдәни мирасны саклау, аны өйрәнүгә комплекслы якын килү, саклап калу һәм реставрацияләү өлкәсендә Россия дәүләт мәдәни сәясәтенең бер ачык мисалы булып тора.* Мирас

2) Әтрафлы, һәрьяклы

3) Җитештерүнең төрле өлкәләрендә эшләүчеләрдән төзелгән бригада. *Егетнең тырышлыгын күреп, колхоз идарәсе аны комплекслы бригада бригадиры итеп билгели.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Төрле яктан, һәрьяклап, әтрафлы рәвештә

**КОМПЛЕКТ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса билгеле бер максатка хезмәт итә торган предметларның тулы җыелмасы (деталь, инструмент, әйбер кисәкләре). *Ошбу документта теркәлгәнчә, капитан Шибаевка ышанып, складтан --- унбиш комплект граната атучы җайланма һәм, ниһаять, «лимонка» тибындагы утыз граната чыгарылу турында язылган иде.* И.Хуҗин. *--- чиләк белән салкын су алып киләм, пробирка һәм колбаларны туңар-туңмас шул су белән юам, аннары 15–20 комплект җиһазлар һәм реактивлар әзерлим...* З.Мифтахов. *Җиде комплект медаль уйнатылды.* Сабантуй

2) Бербөтен тәшкил итә торган әйберләрнең тулаем җыелмасы; дирбия. *[Кыш бабай:] Машина, курчак комплекты, робот кебек уенчыклар «бүләк итәм».* Идел. *[Хат ташучының] --- уң җилкәсендә почта букчасы булса, сул ягында кер порошогы, юрган, мендәр, урын-җир комплекты, макароннар – саный китсәң, сатасы товарларның исәбе-хисабы юк.* Ватаным Татарстан

3) Инструкция яки штат нигезендә билгеле бер җиргә кабул ителә, нинди дә булса урынга урнаштырыла торган кешеләрнең тулы саны. *[Татар халык мәгариф институтында] безне: «Бик алган булыр идек тә, егетләр, комплект тулды шул», – дигән сүзләр белән каршыладылар.* Казан утлары

◊ **Комплектка тутыру** Билгеле бер әйберләрнең җитмәгән өлешләрен булдыру, тулыландыру, бербөтен итү

**КОМПЛЕ́КТЛАУ** *ф.* 1) Комплект җыю, комплект булдыру, комплект төзү, тиешле комплектка тутыру

2) Тиешле комплект белән тәэмин итү. *Тагылма коралларны басуга комплектлап чыгарырга планлаштыралар, вак-төяк мәшәкать белән паркка кайтып йөрисе булмый.* Ватаным Татарстан

**Комплектлап алу** Тиз арада комплектлау

**Комплектлап бару** Акрынлап барысын да комплектлау

**Комплектлап җиткерү** Барысын да комплект итү

**Комплектлап кую** Алдан комплектлау

**Комплектлап тору** Һәрвакыт комплектлау; даими яки әледән-әле комплектлау

**КОМПЛЕ́КТЛАШТЫРУ** *ф.* Тиешле нәрсәләр белән тәэмин итеп, комплект хәленә китерү. *Шул ук вакытта ФАП [фельдшер-акушерлык пункты] модулен ясау, комплектлаштыру, кирәкле урынга илтү һәм монтажлау конвееры булдырылган.* Маяк

**Комплектлаштырып бетерү** Тулысынча комплектлаштыру

**Комплектлаштырып кую** Алдан комплектлау; берникадәр вакытка комплектлаштыру

**Комплектлаштырып тору** Даими яки әледән-әле комплектлаштыру

**Комплектлаштырып чыгу** Барысын да комплектлаштыру

**Комплектлаштырып җиткерү** Тиешенчә комплектлаштыру

**КОМПЛЕ́КТЛЫ** *с.* 1) Комплектлап, комплект белән эшләнгән, җитештерелгән. *Комплектлы җиһаз*

2) Саннар янында килеп, «шул сан күрсәткәнчә комплекттан (*3 мәгъ.*) торган» мәгънәсен белдерә. *Ул елларда тулы комплектлы укчы батальон бишалты йөзләп сугышчыны берләштерә.* Л.Хәмидуллин

**КОМПЛЕ́КЦИЯ** *и. лат. кит.* Гәүдә, бөтен буй-сын, тән төзелеше

**КОМПЛИМЕНТ** *и. фр.* 1) Кемгә дә булса атап әйтелгән күңелгә ятышлы, ягымлы сүз; күңелгә ятышлы җавап сүзе. *Мин сезгә хәйран калам: кайдан алдыгыз сез ул тәмле телне, кайдан*

*килде сезгә ул кадәр комплиментлар?* М.Әмир. *Хатларның берсеннән башка һәммәсе комплиментлар белән генә тулы иделәр.* Ф.Әмирхан. *[Тукай:] Син, Ядкәр, комплиментларыңны барышняларга калдыр.* Р.Батулла

2) Чыгышы тәмамлангач яисә бик каты алкышлауларга җавап йөзеннән артистның тамашачыларга баш июе

**КОМПОЗИТ** *и. лат.* 1) *тех.* Химик төзелеше ягыннан нык аерылып торган матдәләрне кушып барлыкка китерелгән ясалма материал. *[Э. Галимов] Композит материаллар һәм саклагыч капламнар җитештергәндә, ресурсларны саклаучы экологик чиста технологияләрне гамәлгә кертә.* Татар энциклопедиясе

2) *лингв.* Кушма сүз

**КОМПОЗИ́ТОР** *и. лат.* Музыкаль әсәрләр иҗат итүче кеше; көйче. *Композиторлар союзы татар композиторларының иҗат активлыкларын күтәрергә, моның өчен аларның һәркайсы белән индивидуаль шөгыльләнеп, дөрес юнәлеш бирергә тиеш.* М.Җәлил. *Шагыйрь күңелендә яңа җырның, композитор күңелендә яңа көйнең иң беренче тапкыр ничек туа башлавын Газинур белми иде.* Г.Әпсәләмов. *14 ноябрь 18.30 сәгатьтә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында композитор --- Рәшит Кәлимуллинның юбилей кичәсе узачак.* Мәдәни җомга

**КОМПОЗИ́ТОРЛЫК** *и.* Композитор һөнәре, композитор булу. *Сүнчәләй композиторлык сәләтенә дә ия булган, шәхси архивында ул тудырган унлап көй-җырның ноталары саклана.* З.Рәмиев

**КОМПОЗИЦИОН** *с.* Композициягә (*1, 4 мәгъ.*) бәйләнешле. *Р. Харис, бер әсәрендә дә кабатланмаска тырышып, һәр шигыренә, поэмасына яңа композицион төзелеш, чишелеш, бетем эзли.* Т.Галиуллин. *Сөембикә манарасы һәм Спас капкаөсте манарасы шактый зур киңлекләрне үзара яраштыручы композицион төп идея, ориентир булып тора.* Мирас

**КОМПОЗИ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Әдәбият, сәнгать әсәрләрендә төп өлешләренең төзелеше, урнашу тәртибе һәм үзара нисбәте. --- *натюрмортны туйганчы карый идем. Кием-салым, каюта җиһазларыннан шушындый композиция төзү сирәк кешенең кулыннан киләдер.* М.Юныс. *Бу өченче басмада --- әдәби материаллар белән композициясе бөтенләй яңадан эшләнде.* Г.Ибраһимов. *«Әсма...» романы сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да игътибарга лаек. --- Утыз бүлектән торган бу әсәрнең композициясе дә үзенчәлекле.* М.Гайнуллин

2) Музыкаль әсәр. *Заманча музыкаль композицияләр ритмында башкарылган «Җырларым – хыялларым», «Ярым ай» --- кебек эстрада җырлары язучы [З. Хәким] иҗатының гаять тә үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итәләр.* Әдипләребез. *Милли музыка коралларында башкарылган музыкаль композицияләр бәйрәмгә тагын да ямь өстәде.* Өмет

3) Әдәби, музыкаль әсәрләрнең яки аларның кисәкләренең уртак тема, сюжет белән берләштерелгән тезмәсе. *Кичәдә укучылар тарихи эзләнүтикшеренү эшләрен тәкъдир иттеләр, әдәби-музыкаль композицияләр күрсәттеләр ---.* Маяк

4) Музыкаль әсәрләр төзү теориясе. *Консерваторияләрнең композиция классларын тәмамламаган, әмма җәүһәр-җырларын юмарт өләшкән талантларыбыз азмыни ---.* К.Йосыпов

**КОМПОЗИ́ЦИЯЛЕ** *с.* Бербөтен композиция (*1 мәгъ.*) тәшкил иткән, композициягә нигезләнгән. *Р.Харис иҗатында – лирик монологлардан торган ирекле композицияле лирик-фәлсәфи поэма да үстерелә.* Т.Галиуллин

**КОМПОНЕНТ** *и. лат.* Билгеле бер нәрсәнең состав өлеше, кисәге. *Берәмлекләргә киңәйтелгән аңлатмалар сүзлекнең Интернеттагы компонентында биреләчәк ---.* А.Тимергалин. *Халыкның катлаулы үсеш, үзгәреш чорларында татар булып формалашуына байтак этник компонентлар катнашкан.* Ф.Гарипова. *Драматургиядә бу стиль спектакльнең бөтен компонентларын, шул исәптән артистларның башкару үзенчәлекләрен дә билгели.* Г.Арсланов

**КОМПОНЕНТЛЫ** *с.* 1) Билгеле компонентлары булган, компонентлардан торган

2) Компонентларга бүлеп эшләнгән; компонентларның үзенчәлекләренә бәйле. *Компонентлы анализ*

**КОМПОСТ** *и. лат. а.х.* Төрле үсемлек, хайван тизәкләре черемәсен туфрак яисә торф белән катнаштырып ясалган органик ашлама. *Патиссонны түтәлләргә утыртып үстерергә кирәк. --- Түтәл уртасыннан буеннан-буена 30–40 см тирәнлектә канау казыйсы да шуңа тирес, я булмаса черегән үлән, компост тутырасы ---.* Ватаным Татарстан. *[Илгиз:] Җиргә бары тик өйдә әзерләнгән тирес һәм компост – тирес белән торф катнашмасы, органик ашлама кертәм.* Ирек мәйданы

**КОМПО́СТЕР** *и. фр. махс.* Билет, пломба һ.б.ш. тишеп яки кысып билге төшерү өчен кулланыла торган, келәшчә сыман яки башка формадагы прибор. *Халык белән шыгрым тулы троллейбус. Компостерга аркасы белән сөялеп, бер кыз басып тора.* Мәзәк. *--- ялган акча ясаучылар тишекләрне компостер белән төшерә.* Мәдәни җомга

**КОМПО́СТЕРЛАУ** *ф.* Компостер ярдәмендә билге төшерү

**Компостерлап алу** Тиз арада компостерлау

**Компостерлап бетерү** Барысын да компостерлау; компостерлауны тәмамлау

**Компостерлап кую** Компостерланган итү

**Компостерлап тору** Даими яки әледән-әле компостерлау

**Компостерлый бару** Рәттән компостерлау

**КОМПОТ** *и. фр.* 1) Төрле җиләк-җимешләрне шикәрле суда кайнатып ясалган татлы эчемлек. *Васфикамал каенатасы белән кече якта стаканнарга компот сала.* М.Мәһдиев. *Компотны кружкаларга бүлеп куясы да, егетләр утыргач, ботка китерәсе генә калды.* М.Юныс. *Компот чыгару өчен алма, хөрмә, слива кирәк ---.* Р.Мирхәйдәров

2) Шушы эчемлекне ясау өчен махсус киптереп әзерләнгән төрле җиләк-җимеш катнашмасы

**КОМПРЕСС** *и. фр. мед.* Дәвалау, авыртуны басу, киметү максаты белән, суда яки берәр төрле дарулы сыекчада юешләп, авырткан урынга куя торган чүпрәк, бәйләвеч. --- *Ана төнлә торып башына берничә мәртәбә компресс куйган булса кирәк...* А.Шамов. *[Әнкәй:] – Компресс куярга кирәк, бала ут яна, атасы! – дигән нәтиҗәгә килде һәм әткәйне ашыктырды. Муенны урап, калын һәм җылы компресс салдылар.* Ф.Яхин

**КОМПРЕ́ССИЯ** *и. лат. тех.* Тышкы көч тәэсире нәтиҗәсендә газ яки һава кысылу, тыгызлану күренеше

**КОМПРЕ́ССОР** *и. лат.* 1) *махс.* Һава, газ, парны басым астында кысу, тыгызлау машинасы. *[Абитуриент] Документларын теге егет әйтүе буенча «компрессор машиналары һәм җайланмалары» дигән белгечлеккә тапшыра.* Н.Вахитов. *График буенча беренче компрессорны сынау сентябрь башларында үткәрелергә тиеш булган.* Татарстан. *Заводны әле генә җир куеныннан чыккан газ белән тәэмин итү нефть промыселлары тирәсендә тезелгән компрессор станцияләренә (ГКС) беркетелде.* Идел

2) *мед.* Авыруларга операция ясау вакытында кан тамырын кысып тору өчен кулланыла торган махсус җайланма

**КОМПРЕ́ССОРЛЫ** *с.* Компрессоры булган, компрессорлардан торган. *Компрессорлы җайланмалар*

**КОМПРОМАТ** *и. рус* Кемнең дә булса яхшы исеменә, репутациясенә тап төшерү, аңа аяк чалу максаты белән җыелган мәгълүмат. *[Коста:] Анда [документларда] байтак эшкуарларга – республикадагы миллионерларга да, җинаятьчелек дөньясы белән идарә итүче олы агайларга да компромат тупланган ---.* Р.Мирхәйдәров. *Троцкий, Зиновьев, Каменевка каршы компромат акцияләрен оештыруның актив процессы бара торган була инде ---.* Мирас

**КОМПРОМИСС** *и. лат.* **1.** 1) Ике як та ташламаларга бару юлы белән ирешелгән килешү. *Тагын бер ликвидлы һәм ышанычлы чара: «Промсвязь банк»ның үз облигацияләре, тәвәккәллек белән ышанычлылык арасындагы компромисс.* Татарстан. *Үзара аңлашуга ирешү өчен, мин, мәсәлән, Болотная мәйданындагы вакыйгалардан соң оппозиция белән ил җитәкчелеге арасында арадашчы булырга әзер идем. Кызганычка каршы, ике як та компромисска әзер түгел иде.* Кызыл таң

2) *күч.* Гомумән, ташлама. *Ихтыяр көчең җитмәгән чакларда компромисс ясарга ашыгасың.* М.Юныс. *Тукайның шигъриятгә компромисска барганын, кемгәдер ярарга теләп яисә үзе өчен нниндидер файда күзәтеп шигырь язганын без белмибез ---.* И.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ. к.* **компромисслы**. --- *зур фикер төрлелекләре белән озакка сузылган бәхәсләрдән соң, компромисс формула табылып, соңыннан ул Татарстан Конституциясенә кертелде.* Мәдәни җомга

**КОМПРОМИССЛЫ** *с.* Ташламалы, ташламалардан торган; үзара ташламалар ясый торган. *[М.Шәймиев] кандидатура ике тапкыр инкяр ителгәннән соң, айлык килешterүләр кертүче төбәкләрдә башкарма хакимиятне формалаштыруның расланылган схемасын компромисслы дип бәяләде ---.* Ватаным Татарстан

**КОМПРОМИССЫЗ** *с.* **1.** Ташламасыз, ташламага, компромисска нигезләнмәгән. *Иртәгәсе көнне узачак пленумны уздырмавын телефоннан каткат «үтенгәннәр», ләкин Владимир Козлов – компромиссыз кеше, ризалашмаган.* Ирек мәйданы

**2.** *рәв. мәгъ.* Ташламасыз, компромиссыз рәвештә. *Урамнар да тыптын, паркларда да беркем «компромиссыз көрәшеп» йөрми, ичмаса бер «хат» та язмыйлар, күз буяу өчен дә...* З.Мифтахов. *Нәтиҗәдә дастанга [«Кыйссаи Йосыф»] варислыкны компромиссыз дәгъвалаучы үзбәк галимнәре дә хәзер тыныч күңел белән аны «татар ядкәре» дип атыйлар.* Ватаным Татарстан

**КОМПЬЮ́ТЕР** *и. ингл. информ.* Мәгълүматны барлыкка китерү, тапшыру-кабул итү, саклау һәм эшкәртү өчен билгеләнгән электрон хисаплау машинасы. *Унбишенче уен да уртакка төгәлләнгәч, директор компьютер экранында пәйда булган кызыллыаклы билгеләргә бакты ---.* М.Шаһимәрдәнов. *Теге чакта аптыраганнан гына кулына китап алган кешеләр бүген үзләренә башка шөгыль таптты – компьютер уеннары, интернет, кәрәзле телефон һ.б.* М.Кәбиров. *Компьютер уеннары бик күп: «Пасьянс», «Сапёр»дан алып катлаулы стратегияләргә кадәр.* Сабантуй

**КОМПЬЮ́ТЕРЛАШТЫРУ** *ф.* Икътисад, фән, белем бирү һ.б.ш. өлкәләргә компьютер техникасын кертү. *Массакүләм компьютерлаштыру соңгы исәптә яман нәтиҗәгә китерер төсле...* А.Тимергалин. *Иске цехта көрәк-чиләк, гади измә болгаткычлар кулланылса, яңасында инде компьютерлаштырылган линия эшли.* Т.Нәҗмиев

**Компьютерлаштыра бару** Акрынлап компьютерлаштыру

**Компьютерлаштыра башлау** Компьютерлаштырырга керешү

**Компьютерлаштырып бетерү** Барысын да компьютерлаштыру

**Компьютерлаштырып тору** Даими яки әледән-әле компьютерлаштыру

**КОМПЬЮ́ТЕРЛЫ** *с.* 1) Компьютеры булган, компьютерлар белән тәэмин ителгән. *Компьютерлы бүлмә*

2) Компьютерга караган, компьютер куллануга бәйле булган. – *Барыбер компьютерлы технологияләрдән читкә тайпылып булмый, – ди Рәүф Раиф улы.* Ватаным Татарстан

3) Компьютердан, гомумән электрон-хисаплау техникасыннан файдалана белүгә караган

**КОМПЬЮ́ТЕРЧЫ** *и. сөйл.* Компьютерны яхшы белүче, төзәтү һ.б.ш. белән шөгыльләнүче кеше. *Кем булыр бу бала? Балта остасы, компьютерчы, сәүдәгәр ---.* А.Хәлим. *Армиядән соң үзебезнең «Волга» авыл хуҗалыгында компьютерчы булып эшләдем.* А.Халит

**КОМСАР** *с. диал.* 1) Комлыгы булган; комлы

2) Ком төсендәге

**КОМСАРУ** *ф. сир.* Агарыну, ком төсенә керү

**Комсара төшү** Тагын да комсару

**Комсарып китү** Кинәт комсару; тагын да азрак комсару

**Комсарып тору** Даими яки әледән-әле комсару

**КОМСОМОЛ** *и. рус* 1) Коммунистик яшьләр оешмасы. *Мәктәптә комсомол һәм укучылар оешмасы учкомның да тәрбия роле зур иде.* Мирас

2) Коммунистик яшьләр берләшмәсе әгъзасы. *Мин комсомол түгел, Билетымны күптән инде сезгә тапшырдым.* Н.Баян. *Поповкада бер коммунист белән бер комсомолны тере килеш җиргә күмгәннәр.* А.Шамов. --- *– очлы күзле инспекторларның берсе минем кучкарда аунап яткан комсомол билетын күргән.* А.Гыйләҗев

**КОМСОМО́ЛЕЦ** *и. рус к.* **комсомол**. *Комсомолец Безгә сәлам укый, Йөрәкләргә үтә һәр сүзе: «Комсомолец – бөек исем, Ләкин Көч исемдә түгел, эшендә».* М.Җәлил. *Җыр туктауга, Талип бабай урыныннан торып, комсомолец Шаһбаз янына килде.* Г.Гобәй. *Хикәя китаплары укып кына, Тукай, Такташ шигырьләрен ятлап кына комсомолец булып бетеп булмый...* М.Әмир

**КОМСОМО́ЛИЯ** *җый. и. рус кит.* Комсомоллар, комсомол яшьләр. *Комсомолия, Синең әгъзаң бит мин...* Ф.Кәрим

**КОМСОМО́ЛКА** *и. рус* Коммунистик яшьләр берләшмәсе әгъзасы, хатын-кыз комсомол. *Макталучы – мактарлык кыз, Авыл кызы, үткен телле комсомолка Саҗидә.* Һ.Такташ. *Кичә җыелыш иде. Әсин, Сәрвәр, Комсомолка – Нигә килмәдең?* М.Җәлил. *Комсомолка Мөхтәрәмә үзе Теләп китә сугыш кырына.* Ә.Еники

**КОМСОМОЛЛА́РЧА** *рәв.* Комсомол кешегә хас булганча. *– Сезнеңчә, комсомолларча, [сыер] саварга алганыбыз юк шул! – дип, Гөлнарга чәпчергә маташа.* Ә.Айдар. *[Гөлзадә:] Әсин миңа киңәш бир, Рәшит, дусларча, комсомолларча.* Р.Ишморат

**КОМСОМОЛЛЫК** *и.* Комсомол булу; комсомол берләшмәсе әгъзасы булу. *[Шәфигулла агай:] Энгель товарищны менә комсомоллык дәрәҗәсенә ирешкәч тә әле буржуйлар үтерделәр.* Ф.Әмирхан. *[Адушкин:] Менә, дус кеше, эш нәрсәдә: сиңа бригадаң белән бүген төнге уникедән өченче сменага чыгарга туры килә. Кара, подкачать итмә, комсомоллык байрагын югары тот!* А.Алиш

**КОМСОМО́ЛЧА** *рәв.* Комсомолга хас булганча, комсомол кебек

**КОМСОРГ** *и. рус* Комсомол берләшмәсе әгъзасы булган яшьләрне оештыручы. *Сылу группада комсорг икән бит!* Г.Әдһәм. *Ахырдан, полк комсоргының соравы буенча, лейтенант Орлов взводны тезеп команда бирде: – Комсомол, бер адым алга!* Ә.Маликов

**КОМСОСТАВ** *и. рус хәрби* Командирлар составы. *Миңа ияреп кереп, кают-компаниянең ишеген бикләргә керешкәч кенә, Анастасия Аристарховнаның комсоставка аш биреп торучы буфетчы икәнлеген аңладым.* М.Юныс

**КОМСУ** *с.* Комлы, комы булган; составына беркадәр ком катнашкан. *Алай икән, Һәдия дә чит җирнең комсу туфрагына ятып калган икән дип уйлады Бакый.* М.Маликова. --- *комсу туфракларда ак әрем, чыбыксыман үлән, кыяклылар, ромашка --- үсә.* Россия географиясе

**КОМСЫЗ** *с.* **1.** 1) Үз мәнфәгатен генә кайгыртучы, үз файдасы өчен генә тырышучы, бик саран; ач күзле, туюны белми торган, туемсыз. *Ай комсыз! Көченнән килсә, бөтен урманын төяр иде бугай ---. Илләкомсыз, илләкансыз да инде буржуй дигәннәре.* Г.Бәширов. *Бүген никадәр гөнаһсыз чырай белән ятсалар да, терелеп чыккач, үзләренең шушы хәләтен онытып, явыз, мәкерле, комсыз бер ерткычка әверелачәк бәндәләр бит инде болар ---.* М.Кәбиров

2) Канәгатьләнә белми торган, үтә нәфесле. *Фашист шикелле комсыз, фашист шикелле ач күз, аның кебек чиктән ашкан азгын җанвар очратканым юк иде.* Г.Бәширов. *Сугыш бирән зәхмәте кебек комсыз бит.* К.Нәҗми

3) *күч.* Нәрсәгә дә булса ирешүгә, гомумән, нәрсәгә дә булса артык зур омтылышы, теләк-ихтыяҗы, хирыслыгы булган. *Буш хыялын, саташулы фик(е)рен Селкеп йөргән комсыз шагыйрьне Юлсыз искән җилгә сизгер милләт Үзенеке итеп танырмы?!* Р.Рахмани. *Шуңа бүтән якка түгел, әбелем алуга комсыз булды Ралиф.* Кызыл таң

4) *күч.* Шундый омтылыш, теләк белдерә торган (йөз, күз, караш тур.). *Кайда хәзер комсыз күзен ташлар Кипарислар үскән якларга.* Ф.Кәрим. *Учакта кызган куян итенә комсыз карашын төбәп, синең ризыгыңа кызышып торган иптәшеңне сугып үтерергә.* М.Кәбиров

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик нык омтылып, бөтен игътибарны биреп. *Тоткынлыкта хәзер мин... һәр көнне Көн чыгышын комсыз күзәтәм. Шигырь булып чыга үч ялкыны Яраланган лачын йөрәктән.* М.Җәлил

**3.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Комсызлар, бөтен йорт-җиребезне күтәреп китәр идегез бугай.* А.Шамов. *Ком тавында уйный Кадыйр, ясый ул әллә ниләр. «Комсыз түгел бит мин, нигә миңа Малайлар комсыз диләр?»* Ш.Галиев

**КОМСЫЗЛАНУ** *ф.* **1.** Комсызлык күрсәтү. *Ә аның саен теге комсыз халык комсызлана.* М.Галәү

**2. комсызланып** *рәв. мәгъ.* 1) Комсызлык (*1 мәгъ.*) белән. *Сыерлар комсызланып --- кызу-кызу бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүдән бушый алмадылар.* М.Галәү. *Тәүдә без комсызланып коштабакка дәррәү ташланабыз.* М.Кәрим. *Яңа туган бала сәгать саен ашарга сораган кебек, яшь журнал комсызланып материал таләп итә иде.* И.Нуруллин

2) *күч.* Киеренке игътибар белән, бик нык мавыгып, зур түземсезлек, кызыксыну күрсәтеп. *Актүш --- күмәчне ике аяк арасына кыстырып, комсызланып ашый башлады.* Г.Гобәй. *Рыжиков китүгә, мин комсызланып подшивканы актарырга тотындым.* Ә.Маликов. *Мин автобус көтәм, кабаланмыйм, Комсызланып карыйм як-якка.* З.Ишбирде

**Комсызлана бару** Торган саен комсызлану. *[Равил абый:] Нинди гафу үтенергә җыенсын, әле ул [ил] һаман да әрсезләнә, комсызлана, вәхшиләнә генә бара.* Казан утлары

**Комсызлана бирү** Бернигә дә карамыйча комсызлану. *[Хамисә] Яңа кеше белән кавышкан саен, ул сөю ләззәтенең тирәнәя баруын аңлады. Аның тәне комсызланганнан-комсызлана бирде.* Ә.Дусайлы

**Комсызлана төшү** Берникадәр тагын да комсызлану

**Комсызланып бетү** Бик нык, тәмам комсызлану

**Комсызланып китү** Тагын да комсызлану; берникадәр комсызлану. *[Хәкимнәр], шул яңа эшләренең тәмен белеп алгач, бигрәк комсызланып киттеләр.* М.Фәйзи

**Комсызланып тору** Даими яки әледән-әле комсызлану. *Байлык җыеп комсызланып торма, Коръән сүзен ешрак кабатла.* В.Ильясов

**КОМСЫЗЛЫК** *и.* 1) Комсызга, комсыз (*1 мәгъ.*) кешегә хас сыйфатлар. *Тормыш яхшырган саен, комсызлык арта.* М.Юныс. *Май сатучылар, [әлеге кешенең] комсызлыгына ачуланып, сүгенделәр, китә башладылар ---.* Г.Бәширов. *[Рәхим] зур-зур ике шакмак шикәр салынган чәйне аерым бер комсызлык белән эчеп җибәрә.* Ф.Әмирхан

2) Комсыз (*2 мәгъ.*) булу, хирыслык. *Нәфисә аның күзләрендәге бу борчулы комсызлыкны үзенең бөтен тәнендә сизеп уңайсызлана башлады.* Г.Бәширов

◊ **Комсызлык чире** Бик нык комсыз булу турында. --- *Бу комсызлык чиреннән үзе генә котыла алмый икән, аңа Нәфисәләр ярдәм итәргә тиеш түгел идеме соң?* Г.Бәширов

**КОМСЫЛ** *с. к.* **комсу**. *Комсыл туфрак*

**КОМТАШ** *и.* Ком һәм кызыл балчык катнашмасыннан торган утырма, тау токымы. *Әнә борынгылар арасында хәтта Гыйбадулла хаҗиның да һәйкәле комташтан гына булса, соңгы елларда күмелгәннәрнең рәсемнәре куелган, исемнәре мәрмәр, гранит ташларга уелган.* К.Йосыпов

**КОМФОРТ** *и. лат. кит.* Көнкүреш ихтыяҗлары өчен һәм гомумән тудырылган уңайлыклар. *Казан белән Арча арасында йөри торган пригородный поездны күз алдыгызга китерә торгансыздыр. Комфорт дигәннәре әллә ни түгел, әмма озынлыгы бар.* Ф.Хөсни. *Аска салырга төрле үлән-яфрак тутырылган «киез», одеял, мендәр бирәләр. Бу – инде менә ничә еллар күрмәгән рәхәтлек, комфорт!* И.Салахов. *Икенче тарафтан, роман-эссе авторы Мәһдиевнең --- комфорт ярату, иркәләнү кебек йомшаклыкларына да күз йоммый ---.* Р.Фәйзуллин

**КОМФОРТА́БЕЛЬЛЕ** *с.* Комфортлы, көнкүреш ихтыяҗлары өчен һәм, гомумән, артык комфорт белән аерылып тора торган, бик уңайлы. *Бездә хәзер олылардан калса гына – балаларга ---. Чөнки безнең үзебезгә комфортабельле шәп йортларда яшәргә кирәк, шәп санаторийларда дәваланырга --- кирәк һ.б. һ.б.* Р.Миңнуллин

**КОМФОРТА́БЕЛЬЛЕК** *и.* Комфортабельле булу. *Яңа тимер юл вокзалының комфортабельлеге*

**КОМФОРТЛЫ** *с. сөйл.* **1.** *к.* **комфортабельле**

**2.** *рәв. мәгъ.* Уңайлы шартларда, рәхәттә, комфорт белән. *Хәзер аның [Карленның] Мәскәүдә үзенчә яшәү рәвеше барлыкка килде дип әйтергә була, элек булмаган гадәтләре калкып чыкты, --- комфортлы яшәргә өйрәнде...* Р.Мирхәйдәров

**КОМФОРТЛЫЛЫК** *и.* Комфортлы булу; бик уңай шартлар. *Таләпләр катгый. Йорт бер ел эчендә төзелеп бетәргә, квадрат метрлары, комфортлылыгы һ.б. параметрлар комиссияне канәгатьләндерергә тиеш.* Авыл утлары

**КОМФОРТСЫЗ** *с.* Уңайлыклары булмаган, уңайсыз, комфорт тудырылмаган. *Диңгез кырыслыгына тизрәк күнексеннәр өчен [кубрик] шулай кысынкы, комфортсыз эшләнгән.* М.Юныс

**КОМЫК** *и.* Дагстан Республикасында яшәүче төрки халыкларның берсе; шул милләт кешесе. *Шагыйрь [Г.Тукай] үзенең иҗаты белән --- кыргыз, комык әдәби телләренә дә зур йогынты ясады.* В.Хаков. *[Шамил абый:] Татар теленә якын гагауз, комык телләре бар, аларны өйрәнү җиңел.* Кызыл таң

**КОМЫ́КЧА** *рәв.* **1.** Комык телендә. *Комыкча сөйләшү*

**2.** *с. мәгъ.* Комык телендә булган. *Комыкча сүз*

**3.** *и. мәгъ.* Комык теле. *Комыкчасы шома түгел*

**КОМЫРЫК** *и. диал.* 1) Тын урам, аулак тыкрык. *Җыйдылар комырыклардан Соңга калган халыкны.* Р.Әхмәтҗанов

2) Елганың агым көчле булмаган тирән урыны. *Бака да әйтер, имеш: ятыр җирем, умырыгым, комырыгым.* Әйтем. *[Малайлар] комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып, балык сөзәләр.* А.Гыйләҗев

**КОМЫЧ** *и.* 1) *сөйл. к.* **коймыч**

2) Кузна уенында ашык төре (койрык умырткасыннан ясалганы)

**КОН** I *и. рус* 1) Отышлы уеннарда акча яки шул акча бәрабәренә торырдай башка әйбер салына торган махсус урын. *Зурлары [карта уйныйлар]. Һәркайсының шырпы тартмасында, коннарында [кырыена дегет сыланган калай банкада] – кызыл таракан.* Г.Гобәй

2) Отышлы уен барышында махсус урынга җыелган акча. *Карта уйнаштыргалыйм. Этлекне дә белә башладым. Күз ачып йомганчы бер картаны икенче карта белән алыштырып куям. Күрсәләр – ипи шүрлегенә эләгә, күрмәсәләр – бөтен кон минеке.* Ф.Хөсни

3) Карта, шахмат һ.б.ш. уеннарның бер партиясе

4) Чүрәкәй, кузна һ.б.ш. уеннарда сага яки аткый төшәргә тиешле урын

**КОН** II *и. иск.* Тышкы кыяфәт; күрек, ямь (кешегә карата). *Адәм дисәң – коны юк, хайван дисәң – йоны юк.* Мәкаль. *Колда кон булмас, йөгерек атта сын булмас.* Мәкаль

**КОНАҖЫН** *и. монг.* Өч яшьлек теше мал (гадәттә бия тур.). *Бер конаҗын бияне бөтене белән ашап куйды.* Дастан

**КОНАН** *и. монг.* Өч яшьлек терлек (гадәттә ат). *Конан куйның койрыгын Ялгыз җигән сунарчы.* Табышмак

◊ **Конандай чабу** Күп чабу, чабулап йөрү

**КОНАР** *и. диал. к.* **кон** II

**КОНАРЛЫ** *с. иск.* Конары булган

**КОНАРЛАНУ** *ф. диал.* Конарлы булып китү; нурлану (йөз-кыяфәт тур.)

**КОНАРСЫЗ** *с. диал.* Кыяфәтсез, килешсез, ямьсез. *Әй конарсыз нәрсә, утырасың шунда лыгырдап, мин аны тагын безнең Гөлҗамалга бер-бер җирдән яучы булып килгәндер дип торам.* Г.Камал

**КОНВЕ́ЙЕР** *и. ингл.* 1) Җитештерелә торган эшләнмәләрне бер эшчедән

икенчесенә үзлексез күчереп тору яки йөк күчерү өчен билгеләнгән махсус җайланма. *Анда конвейер системасы тулысы белән тормышка уздырылды.* М.Галәү. *[Цехта] Эш конвейер системасы белән бара.* Ф.Кәрим

2) *күч.* Нәрсә дә булса җитештерүдә өзлексезлеккә ирешү күренеше

3) *жарг.* Сорау алучылары эзлекле рәвештә алмашынып, бер гаепләнүчедән озаклап, өзлексез сорау алу күренеше. *Нәкъ менә Маленков китеп барганнан соң, Солтангалиев җиде көнлек «конвейер»га бастырылып, һәммә нәрсәгә «тану күрсәтмәләре» бирә.* Мирас

◊ **Конвейер белән** Берөзлексез, тоткарлыксыз; бер-бер артлы. *Бер ел эчендә 200 ләп баш дуңгызны, атларны «юкка» чыгарып, сыер терлеге «конвейер» белән китеп бара.* Акчарлак

**КОНВЕ́ЙЕРЛАШТЫРУ** *ф.* Конвейер белән эшләү системасына күчү, конвейер ысулына күчерү

**Конвейерлаштыра бару** Акрынлап барысын да конвейерлаштыру

**Конвейерлаштыра төшү** Берникадәр тагын да конвейерлаштыру

**Конвейерлаштырып бетерү** Барысын да конвейерлаштыру; ахырга кадәр конвейерлаштыру

**Конвейерлаштырып карау** Конвейерлаштырырга тырышу

**Конвейерлаштырып тору** Даими яки әледән-әле конвейерлаштыру

**КОНВЕ́ЙЕРЧЫ** *и.* Конвейерны эшләтүче кеше

**КОНВЕ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) *физ.* Электр һәм җылылык корылмаларының хәрәкәт итә торган мохит (һава, пар яки сыеклык агымы) ярдәмендә күчерелүе. *Конвекция агымы*

2) *махс.* Диңгез, океан кебек тирән сулыкларда суның температурасы, тозлылыгы, тыгызлыгы үзгәрүгә бәйле рәвештә югарыдагы катлам белән түбәндәге катлам арасында су алмашыну күренеше

3) *махс.* Атмосфераның тигез җылынмавы сәбәпле, югарыгы катлам белән түбәнге катлам арасында һава алмашыну күренеше

**КОНВЕНТ** *и. лат.* Кайбер илләрдә закон чыгару хокукына ия булган, сайлап куелган махсус орган. *Милли конвент*

**КОНВЕНЦИОН** *с.* Конвенциягә караган, шуңа бәйләнешле. *Конвенцион тариф*

**КОНВЕ́НЦИЯ** *и. лат. сәяси* Нинди дә булса мәсьәлә турында халыкара килешү, шартнамә. *Шартнамә исә федератив мөнәсәбәтләрнең төрле рәвештә булырга мөмкин икәнен күрсәтә. Бу Россия тарафыннан кул куелган конвенцияләргә туры килә.* Казан

**КОНВЕРГЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) *махс.* Үзара бәйле булмаган төрле күренешләрнең билгеле үзенчәлекләре белән бер-берсенә охшашлыгы

2) *биол.* Кайбер кардәш булмаган организмнарда уртак шартларда яшәүгә җайлашу нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән тышкы яки эчке төзелеш охшашлыгы

**КОНВЕРСИОН** *с.* 1) Конверсиягә бәйләнешле, шуңа караган

2) *к.* **конверсияле**

**КОНВЕ́РСИЯ** *и. лат.* 1) *икът.* Алыштыру, үзгәртү, яңадан исәпләү күренеше. *Чит ил акчасына конверсия. Заём конверсиясе*

2) *икът.* Сәнәгать предприятиеләрен бер төр товар җитештерүдән икенче төр товар җитештерүгә күчерү күренеше. *Оборона сәнәгате конверсиясе*

3) *лингв.* Сүзнең нигезе яки аның формасы бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү юлы белән яңа сүз ясалу ысулы (мәс., *авыру бала – авыру янына бару, матур кыз – матур җырлау* һ.б.ш.)

**КОНВЕ́РСИЯЛЕ** *с. икът.* Конверсия ясалган

**КОНВЕ́РСИЯЛӘҮ** *ф.* Конверсия ясау

**Конверсияләп бетерү** Барысын да конверсияләү

**Конверсияләп килү** Тора-бара, акрынлап барысын да конверсияләү

**Конверсияләп тору** Даими яки әледән-әле конверсияләү

**Конверсияли бару** Эзлекле рәвештә конверсияләү

**Конверсияли төшү** Берникадәр конверсияләү

**КОНВЕРТ** *и. фр.* 1) Хат, документ һ.б.ш.ны салып кую яки почта аша кая да булса җибәрү максаты белән кулланыла торган, кәгазьдән дүрт почмаклап эшләнгән төрле зурлыктагы пакет. *Гәүһәр эшләпәсен, пальтосын салып бер якка куйды да, матур ридикюленнән зур конверт чыгарып, хатны алды.* Г.Ибраһимов. *Зәңгәр кәгазьгә алтын хәрефләр белән басылган аттестат конверт эчендә иде.* М.Юныс. *Бикбулатов, нечкә бармакларына кыстырып, конверт эченнән кыска гына язылган хатны тартып чыгарды.* А.Әхмәт

2) Күкрәк баласын төрү өчен дүртпочмаклап тегелгән одеял

**КОНВЕРТА́ЦИЯ** *и. икът.* Алыштыру, үзгәртү күренеше. *Чит ил акчасы конвертациясе*

**КОНВЕРТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. икът.* Акчаны, кыйммәтле кәгазьләрне кабул ителгән курс буенча алмаштыру

**Конвертацияләп бетерү** Барысын да конвертацияләү; конвертацияләүне тәмамлау

**Конвертацияләп тору** Даими яки әледән-әле конвертацияләү

**Конвертацияли бару** Акрынлап барысын да конвертацияләү

**КОНВЕРТЛА́У** *ф.* Нәрсәне дә булса конвертка (*1 мәгъ.)* салып кую. *Хатны конвертлап, адресын язды.* Ш.Камал

**Конвертлап бетерү** Барысын да конвертлау; конвертлауны тәмамлау

**Конвертлап тору** Даими яки әледән-әле конвертлау

**Конвертлый бару** Рәттән конвертлау

**КОНВЕРТЛЫ** *с.* Конвертта булган, конвертка салынган, конвертланган. *Шунда аның күзе төште Зәңгәр конвертлы хатка...* М.Җәлил

**КОНВОИР** *и. голл.* **1.** 1) *к.* **конвойчы**. *Аларның аяк-куллары өшегән, ачлыктан интеккәннәр алар, шулай да еламаганнар, конвоирларга ялвармаганнар.* Г.Гобәй

2) Суднолар төркемен яки аерым корабльне озатып бара торган сакчы судно яки самолёт

**2.** *с. мәгъ.* Конвой булып торучы, конвой эшен башкаручы. *Ул арада карцер ишеге дә ачылды, конвоир солдатлар куллары артка бәйләнгән Гыйльманов белән Егоричны алып чыктылар.* М.Гали

**КОНВОИРЛЫК** *и.* Конвоир хезмәте

**КОНВОИРЛЫК ИТҮ** *ф.* Конвоир вазифасын үтәү

**КОНВОЙ** *и. лат.* 1) Тоткыннарны, әсирләрне һ.б.ш.ны саклап, озата баручы кешеләр, короллы отряд. *Суд башланыр алдыннан, каты конвой астында аларны судка китерделәр.* М.Гали. *Баягы тавышлар – атулар --- конвойдан качкан тоткыннарны куу иде.* Г.Ибраһимов. *Таң беленеп килгәндә, тынычсыз полк, конвой сагы астында товар вагоннарына төялеп, билгесез якка җибәрелгән иде инде.* К.Нәҗми

2) Судноларны дошманнан саклап бара торган корабльләр яки самолётлар

3) Төрле суднолардан һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итүчеләрдән торган кәрван

**КОНВОЙЛА́У** *ф.* Конвой күзәтүе астында алып бару

**КОНВОЙЛЫ** *с.* Конвой сагы астында алып барыла торган, конвой сагы астында булган

**КОНВОЙЧЫ** *и.* Тоткыннарны, әсирләрне һ.б.ш. саклап озатучы, алып баручы кеше

**КОНВУЛЬСИВ** *с.* Конвульсия тибындагы, конвульсиягә охшаш

**КОНВУ́ЛЬСИЯ** *и. лат.* 1) *мед.* Көзән җыеру

2) *күч.* Куркыныч, ярсулы хәл; көчле чуалыш

**КОНВУ́ЛЬСИЯЛЕ** *с.* Конвульсия кебек, конвульсия белән булган

**КОНГЛОМЕРАТ** *и. лат.* 1) *кит.* Төрле әйберләрнең механик, тәртипсез, очраклы кушылмасы

2) *геол.* Төрле токымнарның кыйпылчыкларыннан гыйбарәт утырма тау токымы, цементланган чуерташлык

3) *икът.* Төрле тармакларга караган предприятиеләрнең монополистик берләшмәсе

**КОНГРЕСС** *и. лат.* 1) Әһәмиятле халыкара мәсьәләләр буенча үткәрелә торган зур җыелыш, корылтай. --- *1997 елда II Бөтендөнья татар конгрессы латинга кайту турында карар кабул иткән иде.* И.Таһиров

2) АКШ, Латин Америкасы илләренең күпчелегендә закон чыгара торган орган (парламент) атамасы. *АКШның ике мең галим эшләгән Конгресс китапханәсе һәм Төркиянең Милли китапханәсе белән дә эшлекле элемтә җайга салынган.* Р.Вәлиев

**КОНГРЕССМЕН** *и. ингл.* Конгресс (*2 мәгъ.*) әгъзасы

**КОНДЕНСАТ** *и. лат. физ.* Конденсация (*1 мәгъ.*) нәтиҗәсендә барлыкка килгән матдә

**КОНДЕНСА́ТОР** *и. лат. физ.* 1) Электр энергиясен туплаучы прибор

2) Кулланылышта булган парны суытып суга әйләндерү приборы

**КОНДЕНСАЦИОН** *с. мәгъ.* 1) Конденсация өчен билгеләнгән. *Конденсацион прибор*

2) Конденсация юлы белән табылган, җитештерелгән. *Конденсацион су*

**КОНДЕНСА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* 1) Бик каты тыгызлык, куелык, зур тупланыш. *Җылылык конденсациясе. Энергия конденсациясе*

2) Газ яки парның тыгызлануы, сыек яки кристаллик хәлгә килүе

**КОНДЕНСА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. махс.* 1) Оеп куеру

2) Тамчы булып утыру, суга әйләнү

**Конденсацияләнә бару** Акрынлап барысы да конденсацияләнү

**Конденсацияләнә төшү** Берникадәр күләмдә конденсацияләнү

**Конденсацияләнеп бетү** Тәмам конденсацияләнү

**Конденсацияләнеп тору** Даими яки әледән-әле конденсацияләнү

**КОНДЕНСА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Куерту, тыгызлау, туплау. *Җылылыкны конденсацияләү. Электрны конденсацияләү*

2) Газ яки парны тыгызлау, сыек хәлгә китерү

**Конденсацияләп бетерү** Тәмам конденсацияләү

**Конденсацияләп тору** Даими яки әледән-әле конденсацияләү

**Конденсацияли бару** Акрынлап барысын да конденсацияләү

**Конденсацияли төшү** Берникадәр күләмдә конденсацияләү

**КОНДИ́ТЕР** I *и. лат.* 1) Татлы ашамлыклар әзерләү остасы. *[Рафис Габделганиев:] --- һәр кеше җырчы-композитор булсынмы? Бу инде торт ясаткан һәркемгә кондитер булырга кирәк булып чыга бит.* Шәһри Казан

2) *иск.* Кондитер ашамлыклары белән сату-алу иткән кибет хуҗасы. *Кыска гына вакыт эчендә Сильвен 60 тартма шундый кәнфит саткан инде. Кондитер киләчәктә чикерткәле шоколад ашаучылар тагын да күбәер дип өметләнә* ---. Мәдәни җомга

3) *иск.* Кондитер ашамлыклары кибете. *Кондитердагы алучылар, сатучылар – һәммәсе дә, полицәләр берлән кергән кешеләр күргәч үк, бераз гаҗәпсенгәннәр иде.* Г.Исхакый

**КОНДИ́ТЕР** II *с.* Татлы ризыкларга һәм аларны әзерләүгә караган. *[Мөдир:] Бөркетләр, тыңлагыз... Кондитер әйберләре, фәлән хәтле, дөресме?* М.Шаһимәрдәнов. *Бодай исә төп ризык саналадыр ул. Ипидән тыш аннан ничә йөзләгән кондитер ашамлыклары да әзерләнә бит әле.* Ватаным Татарстан. --- *Татпотребсоюзның район кулланучылар җәмгыяте авыл халкы өчен 1,5 миллиард сумлык азык продукты җитештергән. Боларга икмәк, ипи ризыклары, казылык, кондитер товарлары, алкогольсез эчемлекләр һәм башкалар керә.* Шәһри Казан

**КОНДИ́ТЕРЛЫК** *и.* Кондитер I һөнәре. *[Ләмига:] Балалар йортыннан «чыккач» та бер училищега кондитерлыкка укырга керә ул [килен].* Р.Гаязетдин

**КОНДИЦИОН** *с. к.* **кондицияле**

**КОНДИЦИОНЕР** *и. лат.* Һаваны кондицияләү җайланмасы. *Вилла тоткан өчен налог, дача өчен тагын налог, машина өчен, телевизор, бензин, һава сафландыра торган кондиционер өчен, тагын әллә нәрсәләр өчен налог түлиләр алар.* М.Юныс

**КОНДИ́ЦИЯ** *и. лат. махс.* Нинди дә булса материалда, товарда булырга тиешле сыйфат, микъдар нормасы. *Аның зур суммага докторлык диссертациясе сырлап бирүче бер танышы бар* ---. *Хәзер аның янына керергә дә әйтергә, еллар буе эшләгәнемне кондициягә кертергә ярдәм ит, диярга.* Р.Мирхәйдәров. *Көньяк өлкәләрдәге күпчелек хуҗалыкларда орлыклар беренче класс кондициясенә җиткерелде.* Татарстан

**КОНДИ́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. махс.* Кондициялегә әйләнү

**Кондицияләнә бару** Акрынлап кондицияләнү

**Кондицияләнә төшү** Берникадәр кондицияләнү

**КОНДИ́ЦИЯЛӘҮ** *ф. махс.* 1) Тиешле, күрсәтелгән стандарт нигезендә төрле материал, продуктларның үзлеген, сыйфатын тикшерү, билгеләү, сынау

2) Нәрсәнең дә булса сыйфатын тагын да яхшырту максаты белән өстәмә эшкәртү, тиешле кондициягә җиткерү

**Кондицияләп бетерү** Барысын да кондицияләү

**Кондицияләп тору** Әле кондицияләү; даими яки әледән-әле кондицияләү

**Кондицияли бару** Рәттән кондицияләү

**Кондицияли төшү** Берникадәр кондицияләү

**КОНДИ́ЦИЯЛЕ** *с. махс.* Билгеле бер таләпләргә, тиешле стандартка җавап бирерлек; кондициягә җиткерелгән. *Һәрхәлдә, югары кондицияле орлыклар җитешмәве үзен нык сиздерә.* Ватаным Татарстан

**КОНДИ́ЦИЯЛЕЛЕК** *и. махс.* Кондицияле булу сыйфаты

**КОНДОМИНАТ** *и. лат. икът.* 1) Бер үк объект, йорт, күчемсез милеккә бердәм хуҗа булу

2) Бер үк территория белән берничә дәүләтнең бергә, уртак идарәсе

**КОНДОМИ́НИУМ** *и. лат. икът. к.* **кондоминат**

**КО́НДОР** *и. исп. зоол.* Грифлар отрядыннан үләксә белән туклана торган, башы-муены шәрә ерткыч кош

**КОНДОТЬЕР** *и. ит. тар.* Италиядә XIV–XVII гасырларда: нинди дә булса Европа дәүләте яки Рим Папасы хезмәтендәге ялланган хәрби отряд җитәкчесе. *Мәскәүнең Пушкин исемендәге музеена импрессионистларны карарга бардым да Пикассоның «Сукыр хәерче»сенә һәм кондотьер Гаттамелатаның атына гашыйк булып кайттым.* М.Юныс

**КОНДУ́КТОР** *и. лат.* 1) Поезд вагоннарында пассажирларга хезмәт күрсәтүче кеше. *[Абый:] Баш кондуктор свисток биреп поездны туктатмаса, мин калган идем.* А.Алиш. *Башка вагоннардагы кондукторлар байтактан тамбурга менеп басса да, ул барачак йомшак вагонныкы исә әле һаман соңга калучыларны көтә иде.* Р.Мирхәйдәров. *Билет тикшерүчеләр кергәндә, кондуктор безне туалетка биклэп куя.* Мирас

2) Шәһәр транспортында – автобус, трамвай, троллейбусларда билет сатучы, тәртип саклаучы хезмәткәр. *Каяндыр почмактан кондукторның тавышы ишетелде: – Арзан чакта билет алып калыгыз.* А.Гыйләҗев. *– Кайсы тукталыш икәнен дә белмисеңмени? – дип ачыклабрак китте кондуктор.* Р.Мөхәммәдиев

3) *махс.* Станокларда: инструмент белән эшкәртелә торган материал арасында үзара дөрес торышны тәэмин итә торган җайланма

**КОНДУ́КТОРЛЫК** *и.* Кондуктор (*1, 2 мәгъ.*) хезмәте, кондуктор эше

**КОНДЫЗ** *и. зоол.* **1.** 1) Кимерүчеләр отрядыннан булган кыйммәтле мехлы, коңгырт төстәге җир-су җәнлеге; *русчасы:* **бобр**. *Ахрысы, әүвәл кичне үк бер ят егетне кочаклап утырганын күргәч, уйлагандыр, дуңгызны кондыз итә алмам дип.* Ф.Халиди. *Киштәләрне сыгып төшкән төлке, кеш, ас, кондыз тиреләрен, тәпән-тәпән балларны, таудай өелгән ул күннәрне, савыт-сабаны, агач-ташны нишләтергә?* Н.Фәттах.

2) Шул җәнлекнең мехы; *русчасы*: **бобёр**. *Хатыннар туны һәм төрле материядән була. --- Якасына камчат яки кондыз куялар.* К.Насыйри. *Рәсәйдә кондыздан тегелгән туннар элек-электән югары бәяләнгән.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Шул җәнлек мехыннан тегелгән. *Өр-яңа чанадан өстенә кондыз якалы янут толып, башына һәйбәт камчат бүрек кигән бер кеше төшеп --- туп-туры сыйныф бүлмәсенә таба узды.* М.Галәү. *Чыннан да, театрга кондыз якалы тун кигән Тинчурин аю кебек алпан-тилпән атлап килеп керә.* Р.Батулла

**КОНДЫЗЛЫ** *с.* Кондызга бай, кондыз яхшы үрчи торган. *Балык дигәч, малайлар беравыздан кондызлы күл ягына тарталар ---.* Г.Ибраһимов

**КОНДЫ́З ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **өчьяфрак** (*2 мәгъ.*)

**КОНДЫРАК** *и. бот. диал. к.* **кындырак**

**КОНДЫРЛЫ** *и.* Елга һәм авыл исеме

◊ **Кондырлы кодача(сы)** Үзенә карата аеруча илтифат, аерым мөгамәлә таләп итүче, иркәләнергә, назланырга ярата торган кеше. *[Нурый Локманга:] Эшлә, кондырлы кодача булып утырма.* К.Нәҗми

**КО́НИК** *с. фр.* 1) Конуска (*1 мәгъ.*) караган, шуңа бәйләнешле

2) Конуска охшаган, шуңа охшаш; конустан (*2 мәгъ.*) гыйбарәт

**КО́НКА** *и. рус иск.* Атлы трамвай; шәһәрдә шундый трамвай йөри торган тимер юл; шул юлда йөри торган вагон. *Конкага җигелгән атлар җан авырттыргыч кызганыч --- тоелалар иде.* Г.Тукай

**КОНКИСТАДОР** *и. исп. тар.* XV–XVI гасыр ахырында Көньяк һәм Үзәк Американы яулап алырга килгән испан авантюристы. *«1680 елның 13 августында конкистадорлар талап җыйган 5,5 миллиард франклык алтынны трюмнарына төяп Испаниягә кайтып килүче «Санта-Крус» исемле кораб әле һаман... су астында ята...* М.Юныс

**КОНКЛАВ** *и. лат. кит.* Яңа Рим Папасын сайлау максаты белән үткәрелә торган кардиналлар җыелышы; шул җыелыш үткәрелә торган зал

**КОНКРЕТ** *с. лат.* **1.** 1) Анык, билгеле, төгәл; *киресе:* **абстракт**. *Булат сөйләгән конкрет моментлар аның йөрәгенә каты таш булып утырдылар.* Г.Ибраһимов. *Ләкин атның һәр хәрәкәте генә түгел, һәр аваз бирүенә тикле конкрет мәгънәгә ия булуын яхшы белгән Фәләхов шундук төшенде һәм таныл алды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Чын, реаль булган. *Боларын мин син әйтмәсәң дә беләм. Миңа конкрет фактлар кирәк.* М.Юныс

3) *лингв.* Сизү органнары ярдәмендә тоеп була торган нәрсәләрне белдергән (сүзләр). *Лексема --- сүзлек составының конкрет мәгънәгә һәм грамматик формаларга ия булган төп мәгънәви берәмлеге.* Татар теле. Лексикология

**2.** *и. мәгъ. сир.* Аныклык, конкретлык, конкрет форма. *Кави Нәҗминең*

*дә: абстракттан конкретка күчкән --- сугыш заманы --- картиналары язуда урынлы да, матур да булып төшәләр.* Г.Нигъмәти

**3.** *рәв. мәгъ.* Анык, билгеле итеп; ачык рәвештә. *Юк, сез конкрет әйтеп бирегез, ничек итеп каныга ул.* Ә.Еники. *Безнең яшь әдәбият һәм әдипләребезнең күп фәлсәфә сатучылык, конкрет яза белмәүчелек --- белән йөдәвен онытырга ярамый.* Г.Нигъмәти

◊ **Конкрет алганда** *кер. сүз.* Төгәл, дөрес, анык итеп әйткәндә; факт, мисал, дәлил белән күрсәткәндә. *Конкрет алганда, моны без --- Мәҗит Гафури поэмасына материал булган XIX йөз азагы һәм XX йөз башында Урал промышленность мәркәзләрендәге эшчеләр тормышы мисалында күрәбез.* Г.Нигъмәти

**КОНКРЕТЛАШТЫРУ** *ф.* Аныклау, ачыклау, конкретлык кертү. *Эчтәлекне тирәнәйтә төшәргә, образларны конкретлаштырырга --- артык эпизодларны кыскартырга кирәк.* М.Җәлил

**Конкретлаштыра бару** Акрынлап барысын да конкретлаштыру

**Конкретлаштыра килү** Электән конкретлаштыру

**Конкретлаштыра төшү** Берникадәр конкретлаштыру

**Конкретлаштырып бетерү** Барысын да конкретлаштыру яисә билгеле бер нәрсәне тәмам, тулысынча конкретлаштыру

**Конкретлаштырып җиткерү** Тәмам, тулысынча конкретлаштыру

**КОНКРЕТЛАШУ** *ф.* Аныклану, төгәлләнү, конкретлык барлыкка килү. *Аның теле тагын да шомарды, образлары тагын да конкретлаштылар.* М.Гали. *Инде сөйләшүнең темасы һаман тарая, конкретлаша иде.* М.Юныс

**Конкретлаша бару** Торган саен конкретлашу. *Шигырьләрдәге фикерләр, образлар, детальләр, алымнар торган саен конкретлаша бара.* Р.Харис

**Конкретлаша төшү** Берникадәр күләмдә конкретлашу

**Конкретлашып бетү** Тәмам конкретлашу

**Конкретлашып җитү** Конкретлашу ахыр чиккә җитү

**КОНКРЕТЛЫК** *и.* Конкрет булу. *Өйләнешүнең бөтен ягы нигә бүген үк (либреттоның шушы күренешендә үк) бөтен конкретлыгы белән хәл ителергә тиеш?* М.Җәлил

**КОНКУРЕНТ** *и. лат.* 1) Көндәш, кем белән дә булса конкуренция алып баручы. *Һәр икесенең дә базарда ялгызы гына каласы килә. Ягъни конкурентны алып ташларга кирәк.* К.Йосыпов

2) *иск.* Конкурста катнашучы кеше

**КОНКУРЕНТЛЫК** *и.* Ярышка, көрәшкә сәләтлелек; конкуренциягә каршы тора алучанлык

**КОНКУРЕ́НЦИЯ** *и. лат.* Билгеле бер өлкәдә яхшырак нәтиҗәләргә, өстенлеккә ирешү өчен ярыш, көрәш. *Цемент белән --- тимер баганалар, бетоннар конкуренциясе ул ташның ролен арткы планнарга өстери.* Г.Гобәй. *Буржуазия бер-берсе белән конкуренция ясап, чәчәкләр, бакчалар үстерү өчен, һәркайсы үзләренең дачаларына водокачкалар ясаганнар.* Ш.Камал. *Ике сәүдәгәр арасында конкуренция башлангач, Кропотницкий билетка бәяне киметкән.* М.Юныс

**КО́НКУРС** *и. лат.* 1) Нинди дә булса ярышта катнашучылар, тәкъдим ителгән эшләр арасыннан иң яхшысын, лаеклысын сайлап алу мөмкинлеге бирә торган ярыш. *[Эдик:] Мин бит кая керергә белмичә, җиңел конкурс эзләп йөрмим.* М.Юныс. *Өч ел рәттән сынау биреп карап та конкурстан үтә алмыйча йөргәннән соң, ниһаять, максатына ирешкән Мәскәү егете – группа старостасы тәкъдиме белән, беренче уку көнен билгеләп үтәргә булганнар иде.* В.Нуруллин. *Без беренче мәртәбә дәүләт заказы системасы буенча эшли башлаган 2002 елда нибары 20 ачык конкурс үткәрелсә, 2004 елда инде 104 ачык конкурс уздырылды* ---. Мирас

2) *махс.* Зур суммада бурычка кереп бөлгән кешенең эшен карар өчен, кредиторлар тарафыннан оештырылган җыелыш

**КОНКУРСАНТ** *и. рус* Конкурста катнашучы кеше (күпчелек очракта җыр-бию конкурсында). *Бишенче тапкыр «Йолдызлар фабрикасы» проекты үткәрелде, монысы конкурсантлар белән эшләүнең комплекслы булуы белән үзенчәлекле.* Кәеф ничек?

**КО́НКУРСЛЫ** *с.* Ярыш, конкурс нигезендә үткәрелә, алып барыла торган. *Әле яңа гына солдат формасын салган егет конкурслы имтиханнарны уңышлы тапшыра.* Татарстан

**КОННОТА́ЦИЯ** *и. лат. лингв.* Сүзнең төп, атау, денотатив мәгънәсен тулыландырып килә торган эмоциональ-экспрессивлыкка, стилистик төсмергә ия лексик мәгънә компоненты

**КОНОВАЛ** *и. рус сөйл.* 1) Махсус ветеринар белеме булмыйча гына атлар дәвалау белән шөгыльләнүче кеше; байтар. *[Хәйретдин карт җирән бияне] Әйзәдулла исемле мишәр коновалыннан бик зур өметләр белән дәвалатты.* Ш.Камал

2) *иск.* Ат печүче

**КОНОСА́МЕНТ** *и. фр. икът.* Йөк озатучыга йөкнең кабул ителгәнлеге турында бирелә торган документ. *Саф булмаган коносамент. Чартер коносамент*

**КОНСА́ЛТИНГ** *и. ингл. икът.* Финанс, икътисад, кәсәбә мәсьәләләре буенча профессиональ киңәш бирү системасы. *Консалтинг яңа оешмалар төзү барышында оештыру документлары пакетларын әзерләүдә кирәк булырга мөмкин. Консалтинг фирмалары киңәш бирү эшчәнлегенең төрле профильләре буенча специальләшкән булырга мөмкиннәр*

**КОНСЕ́НСУС** *и. лат. махс.* Фикер алышу һәм уртага салып сөйләшүләр нәтиҗәсендә бәхәсле мәсьәләләрдә уртак фикергә, карарга килү. *Инде менә өч сәгать үтте, һаман консенсуска килә алмыйбыз.* Ф.Баттал

**КОНСЕРВ** *и. рус кит. к.* **консервы**. *Сержант та дус булып өлгерде: Консерв һәм граната бирде.* Ф.Кәрим

**КОНСЕРВАНТ** *и. рус* Кайбер материалларның һәм азык продуктларының озак саклануын тәэмин итә торган матдә. *Күптән түгел дүрт төрбә табылды, һәм без аларны төрле консервантлар белән буяп, ачык һавада калдырдык.* Ватаным Татарстан

**КОНСЕРВАТИВ** *с.* 1) Искелек яклы, яңалык, алга китеш, прогресска

каршы (сәясәт, әдәбият, фәндә һ.б.ш.). *Казанның консерватив байларыннан һәм муллаларыннан байтак җәфа күргән Мөхәммәдзариф бервакытны энесе Мөхәммәднәҗип имамлык иткән Чистайга күчеп китәргә дә ниятләгән булган икән.* Р.Әмирхан. --- *«Асар»да тупланган материаллар, бездә элек бозып аңлатылганча, «чикләнгән, консерватив, файдасыз» нәрсәләр түгел, бәлки халык, ил тарихының реаль чынбарлыгын яктыртуга сәләтле, шуңа күрә өйрәнелүе зарур мәгълүматлардан гыйбарәт.* М.Госманов

2) *биол*. Тотрыклы

3) Операция кулланылмыйча алып барыла торган (дәвалау). *Бары тик консерватив дәвалау белән генә чикләнү чирнең тагын да ныграк кискенләшүенә китерә.* Өмет

**КОНСЕРВАТИВЛЫК** *и.* 1) Иске карашлылык, яңалыкка, прогресска каршы булучанлык. *[Габдулла Тукай] --- консервативлык һәм дини фанатизм, саранлык һәм дорфалык сыйфатларын мәсхәрә итә.* М.Хәсәнов. --- *журналистлык һәм революционерлык белән консервативлыкның синтезы, юлбашчылык сәләте – миңа да хас сыйфатлардыр.* Г.Акыш. *Белем бирү системасы бик консерватив, ул җәмгыятебездәге үзгәрешләргә тиз генә җавап биреп өлгерми. Бу консервативлыкка капма-каршылык хас.* Кызыл таң

2) *биол*. Тотрыклылык. *Нәселдәнлекнең консервативлыгы*

**КОНСЕРВАТИЗМ** *и. лат.* Консервативлык, консерватив карашлар. *Стильдә һәм телдә дә бу язучылар өчен консерватизм, халыктан һәм тормыштан качу төп сыйфатлардан булды.* М.Җәлил. *Аларның [язучыларның] әсәрләрендә әлеге идеологиянең төп үзенчәлекләре – бу чорда демократик идеалларга шактый ваемсызлык һәм консерватизмга симпатия ачык чагыла.* М.Гайнетдинов

**КОНСЕРВА́ТОР** *и. лат.* **1.** 1) Иске, консерватив карашлы кеше. *Ул үзе иске карашлы консерватор булса да, кем янында ничек эш кылырга кирәк икәнен белә.* Г.Нигъмәти

2) Бөекбритания һәм тагын кайбер илләрдә сәяси Консерватив партия әгъзасы. *Власть консерватор буржуалар кулында.* Г.Гали

**2.** *с. мәгъ. к.* **консерватив**. *1905 елгы революциядән соң Ишми ишан, ягъни Түнтәр авылының консерватор мулласы Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов, Бубый мәдрәсәсенә каршы юнәлгән карагруһчылар хәрәкәтенең җитәкчесе булып китә.* И.Нуруллин

**КОНСЕРВАТО́РИЯ** *и. лат.* Югары музыка мәктәбе. *Татар опера кадрларын чын күңелдән сөеп тәрбияләүчеләр Мәскәү консерваториясенең эре белгечләре, профессорлары, педагоглары булдылар.* М.Җәлил. *Лекциядән соң китапханәгә кереп, киләсе семинарга хәзерләнеп алдык та, Герцен урамына чыгып, консерваториягә юл тоттык.* М.Юныс. *Консерваторияләрнең композиция классларын тәмамламаган, әмма җәүһәр-җырларын юмарт өләшкән талантларыбыз азмыни ---.* К.Йосыпов

**КОНСЕРВА́ТОРЛЫК** *и. к.* **консервативлык** (*1 мәгъ.*). *Монда --- яңа типлар да аякка бастырылган – болар һәрбер яңалык хәрәкәте вакытында консерваторлык карашларын алга сөреп килгән картларның яшәрүе, Октябрь дулкыннары белән чайкалып, аларның да көрәш диңгезенә керүләре...* Г.Нигъмәти. *Дөрес, руханилар эшчәнлегенә консерваторлык, кинәт калкып чыккан, актив гамәл иткән яңалыкларга каршы булу, аларның юлларына аркылы яту сыйфаты да хас иде.* М.Госманов

**КОНСЕРВА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Озак вакыт зарар тимәсен өчен, төрле объектларны (азык-төлек, агач эшләнмәләр, тарихи һәйкәлләр һ.б.ш.) махсус эшкәртү юлы белән бозылудан, черүдән саклау ысулы. --- *экспертлар ике көн буе Болгарда йөреп, барысын да җентекләп караганнар, тикшергәннәр, объектларга реставрация һәм консервация ясау ысулларын, нигездә, уңай бәяләгәннәр* ---. Ватаным Татарстан

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса үсешен, эшен, хәрәкәтен вакытлыча туктатып тору хәле. *[А.Фадеев] Җәлил китабын чыгару буенча ашыгыч чаралар күрү, консервациядән алу кирәклеге турында сөйли.* Н.Юзиев

**КОНСЕРВА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. кит.* 1) Махсус эшкәртү, махсус шартлар тудыру юлы белән черүдән, бозылудан саклап калу. *Туганнар корпусын һәм Спасс соборы хәрабәләрен реставрацияләү һәм консервацияләүгә бәйләнешле рәвештә, мәдәни-агарту һәм туристлык-экскурсия функцияләре алгы планга чыгачак.* Мирас

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса үсешен, хәрәкәтен, эшен вакытлыча туктатып тору яисә гомумән туктату. *Халыкның традицион мәдәниятен консервацияләп булмый.* Ватаным Татарстан. *Бүген консервацияләнгән Карлыман заводының киләсе елда эшләп китәренә әлегә беркем дә гарантия бирми.* Кызыл таң

**Консервацияләп бару** Акрынлап барысын да консервацияләү

**Консервацияләп кую** Консервацияләнгән итү. *[Төзүче:] Йортны консервацияләргә ярамый, чөнки ул урнашкан мохитне консервацияләп кую мөмкин эш түгел: мохит җәмгыять, технологияләр, менталитет белән бергә үзгәрә.* Татарстан

**Консервацияләп тору** Әле, хәзер консервацияләү; даими яки әледән-әле консервацияләү

**Консервацияли башлау** Консервацияләргә керешү

**КОНСЕ́РВЛАУ** *ф.* Консерв ясау. *Бервакыт төшке аш вакытында Магнитогорск кешесе Виктор Дурманов консервланган мидияләр банкасын ачты.* Чаян. *Авыру [ботулизм] килеп чыгуның төп сәбәбе – өй шартларында консервланган ашамлыклар (яшелчә, җиләк-җимеш, гөмбәләр) ---, шулай ук туфрак белән пычранган ашамлык куллану.* Татар энциклопедиясе. *Алманы консервлап саклаганда, С витамины да тулысынча саклана диярлек.* Ватаным Татарстан

**Консервлап бару** Акрынлап барысын да консервлау

**Консервлап йөрү** Консервлау белән шөгыльләнү; әле, хәзерге вакытта консервлау. --- *музыкант Фуат Әбүбәкеров өенә кергәндә, ул яңа гына җыеп алган черри сортлы помидорларын консервлап йөри иде.* Шәһри Казан

**Консервлап кую** Алдан консервланган итү. *Язгы-җәйге чорда яшелчәҗимешне өзеп алгач ук ашыйбыз, ә кышкылыкка киптереп яки консервлап куябыз.* Өмет

**Консервлап тору** Әле, хәзер консервлау; даими яки әледән-әле консервлау

**КОНСЕ́РВЫ** *и. рус* Бозылудан, черүдән саклау максаты белән, герметик ябылулы банкаларга эшкәртелеп (тозлап, стерилизацияләп) тутырылган ашамлык. *Менә яшел чирәмдә былтырдан калган түп-түгәрәк учак урыны, менә кара янган таш, әнә куак төбендә консервы калае аунап ята.* Ә.Еники. *Завод кибетеннән, шулай ук яздырып, ипи, яшелчә, консервы ише ризык алып була.* Ә.Маликов

**КОНСИГНА́ЦИЯ** *и. лат. икът.* Товар хуҗасының товарларны, үз складына куеп сатсын өчен, арадашчы ролен үтәүче комиссионерга тапшыруы. *Кайвакыт консигнация мәҗбүри, әмма чигерелгән түләүне күздә тота*

**КОНСИ́ЛИУМ** *и. лат. мед.* Кыенлык килеп туган очракларда, авыруның чирен һәм аны дәвалау юлларын билгеләү өчен үткәрелә торган табиблар киңәшмәсе. *Егетләр, авыру янына җыелып консилиум үткәргән врачлар кебек, боларны тикшерергә һәм кайбер нәтиҗәләр ясарга керештеләр.* Г.Вафин. *Олы кызым Лилия, уртанчысы Зилә, улым Айдар, миңа әйтмичә генә, табиблар теле белән әйтсәк, консилиум җыйганнар.* В.Хәйдәрова. *[Мария Петровна:] Каюмова, --- бүген сезнең авыру буенча консилиум үткәрдек.* Мирас

**КОНСОЛИДА́ЦИЯ** *и. фр. кит. сәяси* 1) Консолидацияләнү эше; берләшү. *Соңгы елларда СССР дигән империя таркалып зилзилә башлангач, татарларның консолидация (оешу) процессы көчәйде.* К.Йосыпов

2) *икът.* Дәүләтнең кыска сроклы заемнарын озак сроклы итү финанс операциясе

**КОНСОЛИДА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) *кит.* Бергә туплау, ныгыту; хезмәт эшчәнлеген ныгыту максаты белән берләштерү. *Виртуальләштерү технологияләре һәм хисаплау ресурсларын консолидацияләү юлы белән гамәлдәге IT парктан тагын да нәтиҗәлерәк итеп файдаланырга --- мөмкинлек бирә.* Татарстан

2) *икът.* Дәүләтнең кыска вакытлы бурыч йөкләмәләрен озын сроклыга әйләндерү

**Консолидацияләп бетерү** Консолидацияләүне төгәлләү

**Консолидацияләп тору** Даими яки әледән-әле консолидацияләү

**Консолидацияли бару** Акрынлап барысын да консолидацияләү

**Консолидацияли төшү** Берникадәр күләмдә консолидацияләү

**КОНСОЛЬ** *и. ингл. махс.* 1) Стенадан горизонталь формада чыгып тора торган элемент (бер ягы белән ныклап беркетелгән терәк яки кронштейн)

2) Компьютер белән интерактив идарә итү җайланмасы (дисплей, клавиатура, тычкан)

3) Машина салонында магнитофон, тәмәке кабызу өчен махсус җайланма. *Салонда консоль, пыяла капкачлы панорама уңайлык тудыра, ә кояштан электр приводлы пәрдәчек саклый*

**КОНСОНАНС** *и. лат.* 1) *муз.* Берничә авазның аһәңлелеге, үзара ярашып яңгыравы; *киресе:* **диссонанс**

2) *әд.* Тулы булмаган рифманың рифмалаша торган сүзләрдә тартык авазлар гына аваздаш була һәм кабатлана торган төре

**КОНСОНАНТИЗМ** *и. лат. лингв.* Телнең тартык авазлар системасы. *Үзенең хезмәтләрендә Г.Ибраһимов, аваз һәм хәреф арасындагы мөнәсәбәтне ачыклап, вокализм (сузык авазлар системасы), консонантизм (тартык авазлар), иҗек һәм телдәге сингармонизм мәсьәләләренә шактый урын бирә, авазларның кулланылу үзенчәлекләрен тикшерә.* В.Хаков

**КОНСО́РЦИУМ** *и. лат. икът.* Эре банкларның, банкирларның зур финанс операцияләрен (заем яки акцияләр тарату һ.б.ш.) бергәләп башкару өчен төзегән монополистик берләшмәсе

**КОНСПЕКТ** *и. лат.* Нәрсәнең дә булса кыскача язма эчтәлеге. *Шушы китапчыкны, бигрәк тә аның әлеге томанлыклы өлешен, җентекләбрәк һәм кабатлап укудан һәм шушы нигездә конспект төзүдән башка чара юк.* Ш.Камал. *Без йөгерешеп аудиториягә кердек тә, конспектларыбызны җыеп, ишеккә ташландык.* М.Юныс. *Әүвәле иртәгәге лекцияләргә әзерләндем: укыдым, конспектлар яздым. Аннан «Мәхәббәт һәм өмет»кә тотындым.* И.Салахов

**КОНСПЕКТИВ** *с.* Конспект формасында, кыска, җыйнак. *Конспектив язмалар*

**КОНСПЕКТИВЛЫК** *и.* Җыйнаклык, кыскалык

**КОНСПЕ́КТЛАШТЫРУ** *ф.* Нәрсәне дә булса конспектлап чыгу. *Аның [Г.Ибраһимовның] чыгышын конспектлаштырган гади гарәп кешеләре өчен, бәлки, мондый сорауларның ул заманда бер әһәмияте дә булмагандыр ---.* Ә.Сибгатуллина

**Конспектлаштыра бару** Барысын да конспектлаштыру. *Укыган текстларыңны, материалларыңны конспектлаштырып бар.* Ватаным Татарстан

**Конспектлаштырып алу** Тиз генә конспектлаштыру; берникадәр конспектлаштыру

**Конспектлаштырып бетерү** Барысын да конспектлаштыру; конспектлаштыру эшен тәмамлау

**Конспектлаштырып килү** Конспектлаштыру эшен күптәннән дәвам итү

**Конспектлаштырып кую** Конспектлаштырып әзер итү; аз гына конспектлаштыру

**Конспектлаштырып чыгу** Барысын да, ахырына кадәр конспектлаштыру

**Конспектлаштырып тору** Әле конспектлаштыру; даими яки әледән-әле конспектлаштыру

**КОНСПЕ́КТЛАУ** *ф.* Конспект язу, конспект төзү. *Бу китапны укып чыгу һәм кирәк урыннарын конспектлау шактый күп вакыт сорый.* Г.Әпсәләмов

**Конспектлап алу** Берникадәр конспектлау

**Конспектлап бару** Акрынлап барысын да конспектлау. *Студентлар лекцияне тыңлап кына калмый, аның эчтәлеген конспектлап та бара.* Р.Зәйни

**Конспектлап бетерү** Конспектлауны тәмамлау; барысын да конспектлау

**Конспектлап куюю** Конспектлап әзер итү; өлешчә конспектлау

**Конспектлап тору** Даими яки әледән-әле конспектлау

**Конспектлап чыгу** Барысын да конспектлау

**Конспектлап яту** *сөйл.* Конспектлау процессында булу

**Конспектлый башлау** Конспектларга тотыну

**Конспектлый тору** Әлегә конспектлау

**КОНСПИРАТИВ** *с.* Конспирациягә караган, шуңа бәйләнешле; яшерен, яшертен. --- *даһи математиклар катлаулы, конспиратив юл белән табылган һәм иртәнге сынауда булачак мәсьәләләрне чишеп, тик исереп утыралар.* М.Юныс. – *Конспирация! – Опер солдатка текәлде. – Кара, бу конспиратив кәгазьләрнең барысын да бер битен дә калдырмыйча җыеп бәйлә!* И.Салахов

**КОНСПИРА́ТОР** *и. фр.* Конспирация остасы, конспирация юлы белән эш итүче кеше. *Көчле агитатор һәм оста конспиратор Муса кыен шартларда да дошманга каршы аяусыз көрәшче була.* Г.Иделле

**КОНСПИРА́ТОРЛЫК** *и.* Конспиратор булу. --- *конспираторлык осталыгына карамастан, охранканың дәү җәтмәсеннән котыла алмаган [Гаяз Исхакый].* И.Нуруллин

**КОНСПИРА́ЦИЯ** *и. фр.* Үзенең һәм үз әгъзаларының эшчәнлеген сер итеп саклау максаты белән, рәсми (легаль) булмаган оешмалар тарафыннан кулланыла торган методлар. *Аның --- эшләре яшьләрнең үзара утырышларына катнашу, татар эсерларының эшләренә булышлык итү, кайбер конспирация эшләрен алып барудан гыйбарәт.* Г.Нигъмәти. *Тангатаров --- сәяси партияләрнең конспирация мәктәбен үтмәгән, әлеккәндә [үзен] ничек тоту, ничек җавап бирү турында сабак алмаган иде.* Г.Ибраһимов. *Болар, бәлки, яшерен оешма өчен кирәкле кешеләр булганнардыр, Ходай белсен. Чөнки конспирация бик көчле ---.* Г.Фәхретдинов

**КОНСТАНТ** *с. лат. махс.* Тотрыклы, даими, үзгәрешсез

**КОНСТА́НТА** *и. лат. махс.* Даими зурлык (математика, физика һәм химиядә). *Авогадро константасы*

**КОНСТАТА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Нәрсәнең дә булса барлыгын билгеләү, әйтеп үтү эше. *[Хезмәттә] күренекле прозаиклар, шагыйрьләр --- иҗатының әһәмияте билгеләп үтелсә дә, бу эш ничектер артык тыйнак, констатация һәм гомуми характеристикалар рәвешендәрәк эшләнгән.* Казан утлары

**КОНСТАТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. кит.* Констатация ясау, нәрсәнең дә булса барлыгын ачыклап, билгеләп үтү

**КОНСТИТУТИВ** *с. кит.* Нәрсәнең дә булса нигезен тәшкил итә торган. *Конститутив үзенчәлекләр. Интонациянең конститутив, семантик, эмотив функцияләре*

**КОНСТИТУЦИОН** *с.* 1) Конституциягә караган, шуңа бәйләнешле. *Мәскәү, ниндидер «Конституцион тәртип»кә аркаланып, бер кулы белән чеченнәр илен хәрабәгә әйләндерер, икенче кулы белән аны төзәтү өчен акча биргән булыр ---.* Мәйдан. *Нинди демократия булсын бу? Чечняда конституцион тәртип урнаштырдыгыз бит әле, диләр безгә.* Ватаным Татарстан

2) Конституциягә корылган, шуңа нигезләнгән. --- *билгеле бер вакытта Тукайның беренче әсәрләрендә конституцион иллюзияләрнең һәм искергән әдәби традицияләрнең көчле генә басымы да сизелде.* Г.Халит. *Алар [делегатлар] конституцион монархияне яклыйлар, патшаның властен чикләү ягында.* И.Тимершин

**КОНСТИТУЦИОНАЛИЗМ** *и. лат. сәяси* Конституцион монархияне иң яхшы идарә системасы дип таныган сәяси агым

**КОНСТИТУЦИОНАЛИСТ** *и. лат. сәяси* Конституционализм тарафдары

**КОНСТИТУ́ЦИЯ** *и. лат. сәяси* Дәүләтнең төп законы. *Институт комсомол комитеты мине Казанка елгасы буендагы урамнарның берсенә яңа Сталин конституциясен, аның совет халкына биргән хокукларын танытырга, аңгәмәләр оештырырга билгеләгән.* И.Салахов. *Яңа Конституциягә кешене яклау өчен кирәкле барлык закон нормалары --- кертеләчәк.* Мирас. *Татарстан Республикасы Конституция суды төрле предприятие һәм физик затларның байтак дәгъвасын карап тикшерде.* Мирас

**КОНСТИТУ́ЦИЯЛЕ** *с.* 1) Конституциясе булган

2) *к.* **конституцион**. *Конституцияле монархияләрдә чын хакимлек парламент белән хөкүмәт кулында*

**КОНСТИТУ́ЦИЯЧЕЛ** *с.* Конституциягә корылган, шуңа нигезләнгән. *Узган елда республиканың иң югары дәүләт хакимияте органы буларак Югары Совет әзлекле төстә конституциячел вәкаләтләр үзләштерде.* Мирас

**КОНСТРУКТИВ** *с.* 1) *тех.* Конструкциягә караган, шуңа бәйләнешле. *Торак пунктларының бер-берсеннән урнашу аралыгы, ул чордагы транспорт агымының киеренкелеге күпчелек магистральләрнең һәм шәһәр урамнарының конструктив үзенчәлекләрен билгели.* Кызыл таң

2) *кит.* Нәрсәгә дә булса нигез була алырлык, төпле. *Әгәр дә элекке үзәк һәм бүгенге Россия парламенты безнең Декларацияне вакытында танысалар, республикабызның Россия бөтенлеген бозмый-нитми үз дәүләтчелеген нытуга юнәлдерелгән конструктив, демократик алымнарын аңлаган булсалар, референдумның да кирәге калмас иде.* Мирас

**КОНСТРУКТИВИЗМ** *и. нем.* XX йөз сәнгатендә иң чик формализмны һәм техницизмны алга сөрә һәм сәнгатьнең идеологик эчтәлеген танымый торган агым. *Хәзер искусствода конструктивизм агымы көчәю белән бөррәттән бу манараның да әһәмияте арта. Аны хәзер конструктивизм агымының гамәли мәктәбе --- диләр художниклар.* Г.Гобәй

**КОНСТРУКТИВИСТ** *и. нем.* Конструктивизм тарафдары

**КОНСТРУ́КТОР** *и. фр.* Билгеле бер нәрсәнең конструкциясен төзүче кеше. *[Конструктор Поздняковка] тиешле урыннарда үз конструкциясен тәкъдим итәргә бирәү дә комачауламый.*

Г.Әпсәләмов. *Корабны безгә баш конструктор үзе күрсәтә.* М.Юныс

**КОНСТРУ́КТОРЛЫК** *и.* Конструктор һөнәре; конструктор эше һәм вазифасы. *[Сәфәр] укырга кая кермәкче соң? Спутниклар конструкторлыгына булгач, Мәскәүгәдер инде.* М.Рафиков. *Әйтерсең лә ул [Рафаэль] заводтан яисә конструкторлык бюросыннан җибәрелгән белгеч иде алар өчен.* Р.Мөхәммәдиев. *1933 елның язынннан 1934 елның ахырынача С.Баттал һава көчләренең махсус конструкторлык бюросы янындагы сынау отрядында хезмәт итә.* Әдипләребез

**КОНСТРУКЦИОН** *с.* Конструкцияләр ясарга яраклы

**КОНСТРУ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса корылма, механизм һ.б.ш.ның корылышы, төзелеше, кисәкләренең үзара җайлашып урнашуы. --- *Алтын Урда дәверендәге дөрбә конструкцияләре XV–XVI йөзләрдәге Касыйм һәм Казан мавзолейларыннан шактый нык аерылганнар. Касыйм дөрбәләре XIV–XVI гасырлардан калган татар дөрбәләре корылмаларыннан үзләренең турыпочмаклы, озынча конструкциядә булулары белән үзенчәлекле.* М.Әхмәтҗанов. *[Автомобильгә] --- төрле конструкциядәге шиплы шиннарны да кулланырга ярамый.* Шәһри Казан

2) Катлаулы төзелешле корылма һәм аның аерым кисәкләре. *Дачаларның хуҗалары – шәһәрнең кирпеч заводы һәм тимер-бетон конструкцияләр комбинаты эшчеләре – --- шактый эш майтарып өлгерделәр.* Җ.Юнысов

3) *лингв.* Грамматик бәйләнеш ягыннан караганда сүзләрнең җөмләдә тезелү, урнашу тәртибе. *Иске әдәби телдә дә, Г.Тукай әсәрләрендә дә «исә» теркәгече фигыль формаларына ияреп килә ---. Бу конструкция «Кыйссаи Йосыф»тан башлап XX йөз башына кадәр актив кулланылып килә ---.* Д.Рамазанова. *«Малтабар», «дантабар» һ.б.ш. кебек табигый яңгырашы бу формадагы, конструкциядәге лексик берәмлекләр бүген дә актив яши алганын күрсәтә.* И.Хуҗин

**КОНСТРУ́КЦИЯЛӘҮ** *ф.* Нәрсәнең дә булса конструкциясен төзү. *Иштуган диплом эше итеп автостанок конструкцияләргә уйлый иде.* Г.Әпсәләмов

**Конструкцияләп бетерү** Барысын да конструкцияләү; конструкцияләү эшен тәмамлау

**Конструкцияләп кую** Конструкцияләп әзер итү

**Конструкцияләп тору** Даими яки әледән-әле конструкцияләү

**Конструкцияли бару** Акрынлап барысын да конструкцияләү

**КО́НСУЛ** *и. лат.* 1) Икенче бер илнең нинди дә булса төбәгендә үз иленең һәм аның гражданнарының хокукларын, сәяси мәнфәгатьләрен яклый һәм вәкиллек итә торган хөкүмәт вәкиле; дипломат. *Спектакльне бүген Александровскидагы япон консулы белән аның хатыны да караячак дип, безне кисәтеп куйдылар.* Ә.Маликов. *Безне каршы алган консул Богомолов ачык чырайлы адәм иде.* Г.Фәхретдинов

2) *тар.* Борынгы Римда сайлаулы югары хезмәт урыннарындагы кеше титулы; шул титулны йөртүче кеше. *Тиздән ул [Красс] сенатка менәр. Консул булыр.* Н.Исәнбәт

3) *тар.* Франциядә консуллык (*4 мәгъ.*) чорында югары башкарма власть үз кулында булган кеше; шул титулны йөртүче кеше

**КО́НСУЛЛЫК** *и.* 1) Консул вазифасы, хезмәте. *Соңрак ул [Шаһимәрдән Ибраһимов] гарәп илләрендә дә консуллык вазифасын үти.* Л.Хәмидуллин. *Реза Багбаг Кондори үзенең консуллык вазифаларын үтәячәк округ Татарстан, Башкортстан --- Чиләбе өлкәләрен үз эченә ала.* Казан утлары

2) Икенче бер дәүләтнең нинди дә булса төбәгендә башка бер дәүләтнең консул җитәкчелегендәге вәкиллеге; шул вәкиллек урнашкан бина. *[Капитан:] Кичә консуллыктан килгән вәкил алып биргән билет белән килдек.* М.Юныс. *Поляк Иванны тәрҗемәче итеп алып, Марсельдән Дижонга, аннан Парижга барып, совет консуллыгын эзләргә тотындык.* Г.Фәхретдинов. *Новороссийск белән Владивостокта шәрәфле (дип әйтик инде) консуллыклар бар.* Сөембикә

3) *тар.* Борынгы Римның Республика чорында консулның идарә вакыты. *Цицерон консуллыгы*

4) *тар.* Франциядә: Наполеон Бонапарт борылышыннан (1799 елның 9 ноябре) башлап империя игълан ителгәнгә кадәр (1804 ел) булган чор

**КОНСУЛХАНӘ** *и. к.* **консуллык** (*2 мәгъ.*)

**КО́НСУЛЬСТВО** *и. рус к.* **консуллык** (*2 мәгъ.*). *Франциядә СССР үзәге шул йортта урнаша. Икенче бер кварталда зур, яхшы, чиста йортта безнең генеральный консульство җирләшә.* Г.Гали

**КОНСУЛЬТАНТ** *и. лат.* Консультация (*1 мәгъ.*), киңәш бирүче кеше. *Болардан тыш театрның художество составыннан балетмейстер ассистенты иптәш Карыйны --- һәм вокаль консультанты Загревскаяны алырга кирәк.* М.Җәлил. *[Мансур Хәсәнов] аерым докторлык диссертацияләренең гыйльми консультанты --- була.* Мирас

**КОНСУЛЬТАНТЛЫК** *и.* Консультация бирү эше. *[Җәгъфәрнең] тагын берничә урында консультантлык эшләре дә бар иде.* Г.Әпсәләмов

**КОНСУЛЬТАТИВ** *с.* Киңәш бирү, фикер алышу характерындагы. *Бәяне --- МСОП (Халыкара табигатьне саклау берлеге) кебек консультатив оешмаларның тәҗрибәле галимнәре бирә.* Татарстан

**КОНСУЛЬТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса сорау, мәсьәлә буенча белгеч киңәше, күрсәтмәсе. *Минем белән бергә мәдрәсәдә укучы Габдулла Харис, үзенең язган шигырьләрен укып консультация алу өчен, Тукайның номерына баргалый иде.* М.Галәү. *«Галиябану» либреттосы --- тиешле консультация белән авторына кайтарылды.* М.Җәлил. *Шәриф ага Камалның яшь әдипләрнең үсүе турында борчылып сөйләүләре, аларның аерым әсәрләре турында язып биргән тирән эчтәлекле консультацияләре бүген дә хәтеремдә ---.* Х.Хәйри

2) Укытучының укучыларга предметны үзләштерүдә өстәмә ярдәме; шундый ярдәм күрсәтү белән махсус дәрес. *Канифә карчык аша укытучыга үзенең*

*гозерен җиткерде: укытучы хатын студент кызга бер-ике генә консультация үткәрә алмас иде микән?* Н.Көбәш

3) Нинди дә булса сорау, мәсьәлә буенча белгечләр киңәшмәсе. *Шушы елның 12–15 августында Мәскәүдә Татарстан һәм Россиянең вәкаләтле вәкилләре арасындагы консультацияләрнең беренче этабы уңышлы тәгәлләнү факты ышанычны көчәйтә.* Мирас

4) Аерым сорау, мәсьәлә буенча белгечләр киңәш, күрсәтмәләр бирә торган учреждение. *Шәриф ага Камал бик тыйнак, сүзен кешегә сеңдереп һәм шул ук вакытта үлчәп кенә, үз итеп сөйләүче, самими һәм туры кеше иде. --- яшь язучыларның консультация бюросында һәм соңгарак нәшриятның әдәби бүлеге мөдире булып эшләгән елларда бик яхшы күрдем мин моны.* Х.Хәйри. *Йөкле булуымны әйтеп, уколлардан баш тартам. Табиб мине дәваханәгә барырга, хатын-кызлар консультациясенә исәпкә басарга үгетли.* Идел

**КОНСУМА́ЦИЯ** *и. фр.* Ресторан, казино һ.б.ш. күңел ачу урыннарында зур акча чыгымнарына ирешү өчен махсус ялланган кызларның килүчеләр белән аралашуы. *Консумация ярдәмендә казино, ресторданнарның кереме арта*

**КОНСЬЕРЖ** *и. лат.* Ишек сакчысы, швейцар. *Кайсы фатирга икәнлегемне әйткәч, подъездга керү белән каршы алучы консьерж әбекәй кәефсез генә: «Җыештыручымы?» – дип куйды.* Кызыл таң

**КОНСЫЗ** *с.* 1) Кыяфәтсез, котсыз, шыксыз. *[Ана үрдәк:] Дөрест, бераз шәкелсезрәк --- ул йомырка эчендә озаграк ятты, шуның өчен бераз башкаларга караганда консызрак булгандыр.* Ф.Әмирхан

2) *сөйл.* Тәрбиясез, оятсыз, әдәпсез; дорфа, кырыс. *Юләр, --- консыз, җирәнгеч, кешелекнең бөтен яхшы сыйфатларыннан мәхрүм булган ике муллага – Ишми Мөбарәк белән Такырҗан Хәсәнгә ләгънәт соңында ләгънәт булсын.* Г.Тукай. *Минем икмәк вә тоз хакын белә алмады бу консыз.* М.Галәү. *Ире дә бер мәхлук, консыз бәндә инде, тик шуңа да карамастан саф татар авылында хатынын үз дененә кертмән.* Ш.Алпар

**КОНСЫЗЛЫК** *и.* Консыз булу

**КОНТАКТ** I *и. лат.* 1) *тех.* Электр чылбырында үткәргечләрнең тыгыз тоташуы; шулар тоташкан урын. *Ул [Сафа абый] минем кулымнан радиоалгычымны алды да, кычкырткалап, дулкыннарын тикшереп карады, батареясының урынын ачып: – Менә кара, энем, контактлары начар, шуңа тигез эшләми әйберең, – диде.* Н.Каштанов

2) *күч.* Тыгыз элемтәдә булып, үзара килешеп, ярдәмләшеп эшләү. *Кешеләр белән беренче контакт вакытында алынып, Акыл үзәге хәтеренә салынган информация буенча кеше хромосомалары ясалып, күзәнәкләр эченә кертелде.* З.Мифтахов. *Контакт үзәк өчен җиһазлар, видеокүзәтү камералары, санлы радио элемтәсе терминаллары сатып алынган.* Мәдәни җомга

3) *күч. сөйл.* Якыннан торып аралашу, бергә булу хәле. *Контакт булдыру*

**КОНТАКТ** II *с.* Турыдан-туры тоташа, тәэсир итә торган. *Контакт линзалар*

**КОНТА́КТЛЫ** *с.* 1) *тех.* Контакты (*1 мәгъ.*) булган. *Җиз контактлы приборлар*

2) Аралашучан; контактка тиз керә белүчән; рәсми, шәхси мөнәсәбәтләрне саклый белүче (кеше). *Рәсим Низамов – тамашачы белән контактлы җырчы.* А.Юнысова

3) Бәйләнешкә керү мөмкинлеге булган, элемтәгә керү күздә тотылган. *Контактлы тапшыру. Контактлы телевидение*

4) Ике якның турыдан-туры тыгыз элемтәсе, бәйләнеше белән алып барылган. *Контактлы спорт төрләре*

5) *к.* **контакт** II. *Шөкер, хәзер андый мыскыл ителүләрдән котылу юллары берничә төрле: берсе – заманча, матур күзлек алу, икенчесе – контактлы линзалар, өченчесе – күзгә операция ясату...* Шәһри Казан

**КОНТА́КТЛЫЛЫК** *и.* Аралашуга сәләтлелек; һәртөрле мөнәсәбәтләр. *Контактлылык – характерның искиткеч гүзәл ягы*

**КОНТА́КТСЫЗ 1.** *с.* Контакттан тыш, контакттан башка гына булган. *--- скважиналы контактсыз инфракызыл термометриянең геофизик аппаратлы методик комплексын эшләгән һәм гамәлгә керткән --- өчен бер төркем белгечләргә Дәүләт бүләкләре тапшырылды.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Контактка кермичә, турыдан-туры бәйләнешсез

**КОНТАМИНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Тасвирлаганда, ике яки берничә вакытны, вакыйганы бутау

2) *лингв.* Үзара охшаш ике форма, сүз яки тәгъбир берләшүеннән яңа форма, мәгънә яки тәгъбир барлыкка килү күренеше. *Ләкин бу чыганакта ап-ачык итеп мажарлар дип әйтелгән кайбер язмаларда, дөрес, «башҗар» төре дә очрый, ләкин моны баш хәрефләрнең контаминациясе, ягъни яңгырашка ярашып алышынуы гына дип карарга кирәк ---.* Р.Фәхретдинов

**КОНТЕ́ЙНЕР** *и. ингл.* 1) *махс.* Йөк автомобильләрендә, тимер юл платформаларында, су юлы транспортында товар йөртү өчен кулланыла торган зур әрҗә. *[Айсылу] Кооператив фатирын тапшырып --- әйберләрен контейнерга тутырып озатты, һәм үзе поезд белән шул калага кайтып төште.* Мәйдан

2) Космик корабльдә фәнни аппаратура урнаштырыла торган бүлек

3) Нәрсә дә булса салып йөртү, саклау өчен махсус тартма, әрҗә. *Каттан катка сузылган торба буйлап контейнерга ташлагач, ничектер күңеле җиңеләеп калгандай тоелды [Рөстәмнең].* М.Кәбиров

**КОНТЕ́ЙНЕРЛЫ** *с.* Контейнерларга төялгән, контейнерга салып йөртелә торган. *Перспективалы транспорт каркасы Чистай, Түбән Кама һәм Зөя янында логистика үзәкләре төзүне күздә тота, алар контейнерлы йөк ташуларны оптимальләштерү белән шөгыльләнәчәк.* Мәдәни җомга

**КОНТЕКСТ** *и. лат.* 1) Текстның мәгънә ягыннан бөтен һәм үзен тәшкил итә торган фразаның мәгънәсен ачып бирә торган өлеше. *Алар авторның соңгы еллардагы күзәтү-уйланулары белән баетылып, яңа китап контекстында үз урынын алган һәм, китапның арка умырткасын тәшкил итеп, аңа яңа үзенчәлекле яңгыраш өстәгән.*

К.Йосыпов. *Бүгенге шигъриятебезне башка әдәби традицияләр контекстында карау да – бик өлгергән мәсьәлә.* Р.Харис. *Термин сүзләр тәрҗемә ителми, әмма контекстта кулланганда, татар теленә хас аффикслар кабул итә.* Мирас

2) *күч.* Нинди дә булса күренешләрне, фактларны аңлатканда, билгеле бер әйбернең бер бөтен булып каралуы. *Мөнәсәбәтләр контексты*

**КОНТЕКСТУАЛЬ** *с.* Контекстка бәйләнешле, контекстта гына аңлашыла торган (мәгънә һ.б.ш.). *Контекстуаль исемләшү*

**КОНТИНГЕНТ** *и. лат.* 1) *кит.* Нинди дә булса мәнфәгатьләрдән чыгып берләшкән коллектив, учреждение, оешма, армия һ.б.ш.ның составы, аның карамагында булган барлык кешеләр. *Соңгы елларда югары уку йортларында укучы яшьләр контингенты, аларның белем дәрәҗәсе бик нык үзгәрде.* Р.Вәлиев. *[Профильле мәктәпләргә] --- балаларны сәләтләре буенча җыймыйлар, яшәү урыны буенча туплана укучылар контингенты.* Ватаным Татарстан

2) *махс.* Билгеле бер максатлардан чыгып нәрсәгә дә булса куелган чик, норма. *Төзелеш материаллары контингенты*

**КОНТИНЕНТ** *и. лат. геогр.* Коры җирнең океан белән әйләндереп алынган төп өлешләреннән берсе; материк, кыйтга. *Без, суыткычлы трюмнарга зәйтүн мае төяп, Австралиянең Аделаида портына барабыз. Җир шарының безгә капма-каршы ягы, башка континент, башка дөнья.* М.Юныс. *Континентлар төрле, тик алар да Даирәләр белән бүленә, Кайда – таулар, кайда күле генә Аерым бер дөнья күренә.* Ф.Яхин

**КОНТИНЕНТАЛЬ** *с.* 1) Континентта булган, континентка урнашкан, шуңа хас. *Әлбәттә, Болгар дәүләтенең уңышлары, континенталь абруе күрше славян, хәзәр кабиләләрендә көнчелек тудыра.* И.Әмирхан

2) Диңгездән бик еракта урнашкан, җәе коры, эссе, кышы салкын булган (климат)

**КОНТИНЕ́НТАРА** *с.* Континентлар арасында файдаланыла, башкарыла торган. --- *татарлар әле Чыңгыз хан эпохасына кадәр үк югары культуралы шәһәрләр төзегәннәр, континентара сәүдә алып барганнар, елга флоты, металл эшкәртү, җир эшкәртеп төрле продукция алуны булдырганнар.* И.Хуҗин

**КОНТО́РА** *и. нем.* Күпчелек очракта хуҗалык һәм финанс эшләре белән бәйләнешле мөстәкыйль учреждение яки предприятиеләрнең административ-канцелярия бүлекләренең гомуми атамасы; шундый бүлек, учреждение урнашкан бина. *Контораның ишеге төбендә агач болдырның өченче катына басып кораллы солдат тора.* Г.Ибраһимов. *Алар, ачык капкадан фабрика ишегалдына кереп, контора тирәсенә барып туктадылар.* М.Гали. *МТС конторасында Айсылу шактый озак торды.* Г.Бәширов

**КОНТО́РА ӨСТӘЛЕ** *и. иск.* Язу өстәле. *Бары контора өстәле шикелле бер өстәл тугрысына гына татар вә рус мөхәррирләреннән бәгъзыларының рәсемнәре эленгән: Тукай сурәте зур кулда...* Ф.Әмирхан

**КОНТО́РКА** *и. рус* 1) *сөйл.* Контора урнашкан кечкенә генә бүлмә. *Газинур үзе почтальон килә торган вакытларда конторкага барырга бер дә вакыт таба алмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Күп тә үтмәде, ерактан пароходның килгәне күренеп, болар да нәрсәләрен алып, пристаньга конторкага кереп, пароход килгәнен карап тора башладылар.* Мирас

2) Биек урындыкка утырып яки аягүрә эшләү өчен кыек, сөзәк такталы биек язу өстәле. *Әхтәм байның түбәнге этажы пулатта, контор ишекне кергәч, ишекнең ике ягында ике конторка, янә түрдә бер конторка, ул конторкада Закир утырыр ---.* Ф.Халиди

**КОНТОРЧЫ** *и. иск.* Контора хезмәткәре. *Аның [Әхмәт Исхакның] әтисе Габдулла абзый ---, малае Әхмәт туганда, сәүдәгәр Галиевләрнең күн аяк киемнәре фирмасында конторчы булып эшли торган була.* Әдипләребез

**КОНТО́РЩИК** *и. сөйл. к.* **конторчы**. *Беркөнне Айсылу җиңги безнең утарга килеп, конторщик Дорофейны председатель --- итеп сайлатты.* Т.Гыйззәт. *Габдулланың якын иптәшләреннән приказчик, бер конторщик билгеләнгән вакыттан элегрәк килеп чыктылар.* Ш.Камал. *Контора булдымы – аңа конторщик кирәк. Анысы да табыла. Ә ул конторщик... Габдулла Тукаев.* И.Нуруллин

**КОНТО́РЩИКЛЫК** *и.* Конторщик булу, конторщик хезмәте. *Габдулланың конторщиклык эшчәнлеген аның түбәндәге җавап хатыннан беләбез: «Мөхтәрәм әфәндем! --- Уральск шәһәрендә Мөхәммәдкамил әл-Мотыйгый-Төхфәтуллин өчен конторщик Габдулла Тукаев».* И.Нуруллин. *Сүз арасында әйтеп узыйм: бу юлларны язучы ул чагында «Амур»да конторщиклык хезмәтен башкара иде.* И.Рәми

**КОНТР-** *лат.* Кушма сүзнең икенче кисәгеннән аңлашылган мәгънәгә актив каршылык күрсәтүне белдерә торган беренче компонент (мәс., *контркөч, контрчара*)

**КОНТР** *и. сөйл.* **1.** *к.* **контра**. *Аларның [лозунгларның] кайберсен «контр»лар алып ташлый.* Ә.Маликов. *[Ирбулат:] Колхозчы контр булмый, ә контрның колхозчы исеменә яшеренеп йөрүе бик мөмкин.* Р.Ишморат

**2.** *с. мәгъ.* Инкыйлапка каршы булган. – *Контр буржуалар үзләренең бу эшләренә кайбер алданган ярлыларны да җыгалар, – ди.* Г.Ибраһимов

**3.** *рәв.* Каршы, кире. *[Минһаҗ:] Контр сөйлисең, Үтәш бабай, әссәламегаләйкем. [Үтәш:] Контр түгел, туры сүз.* К.Тинчурин

**КО́НТРА** *и. ит. тар.* *Контрреволюционер* сүзеннән; XX гасырның 20 нче елларында «контрреволюционер», «Советларга каршы кеше» кебек мәгънәләрдә йөргән жаргон сүз. *[Тикшерүче:] --- синең кебек контраларны юк итеп бетерү – безнең изге бурыч.* Г.Тарханова

**КОНТРАБА́НДА** *и. ит.* 1) Тыелган яки пошлина салынган товарларны, кыйммәтле әйберләрне дәүләт чиге аша яшертен чыгару яки кертү. *Контрабанда белән шөгыльләнүчеләргә Казахстан белән Урта Азиянең, Әфганстанның якынлыгы да бик ярдәм итә.* Кызыл таң

2) Шундый юл белән чыгарылган яки кертелгән товар, кыйммәтле әйберләр. *Әлбәттә, Аксай ханы Мәхму-*

*товка йөз мең доллар чыгарып та сала алган булыр иде, контрабанда валютасы җитәрлек ---.* Р.Мирхәйдәров

3) *куч.* Нинди дә булса тыелган эшләрне, караш-фикерләрне яшерен рәвештә үткәрү; шулай үткәрелгән фикерләр һ.б.ш.

**КОНТРАБАНДИСТ** *и. ит.-рус* Контрабанда (*1 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче. *Монда борылдылар калкудан. Контрабандист эреде томанда.* Р.Хисмәтуллин. *Соңга таба контрабандистлар аша даими транспорт булдырдык.* Казан утлары

**КОНТРАБАС** *и. ит.* Зур скрипкага охшаган, иң түбән яңгырашлы кыллы музыка уен коралы. *Дөрес, училище оркестрына язылып, альтта, контрабаста ару гына уйнарга өйрәнде [Әнис].* Ә.Хәсәнов. *Ансамбль үсә, бүген аның составында 13 кеше бар. Баян, фортепиано, ксилофон, балалайка, контрабас --- һәм гитара кебек инструментларда уйныйлар.* Өмет

**КОНТРАГЕНТ** *и. лат. махс.* Шартнамә нигезендә үз өстенә нинди дә булса йөкләмәләр алган кеше яки оешма

**КОНТР-АДМИРАЛ** *и. фр.* Беренче (кече) хәрби адмирал дәрәҗәсе; шул дәрәҗәне йөртүче кеше. *[Октябрьский] Утыз биш яшендә ук контр-адмирал дәрәҗәсен алган.* В.Имамов. *Сталинград сугышында үзеннән лаеклы өлеш керткән контр-адмирал Д.Рогачёв безнең Яшел Үзән каласында яши, вафат булгач, шунда ук җирләнә дә.* Шәһри Казан

**КОНТРАКТ** *и. лат.* Якларның үзара йөкләмә алуына бәйле рәвештә төзелгән килешү, шартнамә. *Анда ул шактый озак торып, кич белән генә чыкты: контракт кәгазе аның кесәсендә иде.* И.Гази

**КОНТРА́КТЛЫ** *с.* Контракт нигезендәге, контрактта каралган. *[Карарда] Татарстан Республикасының югары һәм урта профессиональ белемле белгечләрне максатчан контрактлы әзерләү һәм ул белгечләрне эшкә урнаштыру канун нигезендә беркетелде.* Мирас

**КОНТРАКТАНТ** *и. фр. махс.* Контракт нигезендә үз өстенә нинди дә булса йөкләмә алган кеше яки оешма

**КОНТРАКТАЦИОН** *с.* Контрактациягә караган, шуңа бәйләнешле

**КОНТРАКТА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Билгеле срокларга һәм билгеле шартларда нәрсә дә булса алу яки файдалану турында контракт төзү эше

2) Контрактлар нигезендә авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү системасы һәм шуның конкрет чарасы

**КОНТРАКТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Контрактация үткәрү; контрактлар төзеп, билгеле бер затка атап, билгеләп, тәгаенләп кую

**Контрактацияләп бару** Бер-бер артлы контрактацияләү

**Контрактацияләп бетерү** Барысын да контрактацияләү

**Контрактацияләп тору** Даими яки әледән-әле контрактацияләү; әле, хәзерге вакытта контрактацияләү

**КОНТРА́ЛЬТО** *и. ит. муз.* Бик түбән (калын) җырчы хатын-кыз тавышы; шундый тавышлы хатын-кыз. *Басынкы контральто белән, хискә сугарылып, ягымлы тенор чыгарган моңлы көй йөрәкне ләззәтле итеп тибрәтә.* М.Юныс

**КОНТРАМА́РКА** *и. фр.* Театрга, кинога һ.б.ш.га бушлай, түләүсез керү хокукы бирә торган талон. *[Артист Адамантов] «Мин җырлагач, бик каты кул чабарсың», – дип, берәүгә контрамарка биргән ---.* И.Нуруллин

**КОНТРАПУНКТ** *и. нем. муз.* 1) Бер үк вакытта яңгырый торган берничә мөстәкыйль көйне, тавышны гармоник бөтенгә берләштерү сәнгате; полифония. *Хәбир, мелодик сәләте булуга карамастан, форма белән логиканы тоймый, гармониядән аксый, контрапунктны аңламый.* Ш.Хөсәенов

2) Күптавышлылык тибы буларак полифонияне өйрәнү фәне

**КОНТРАРГУМЕНТ** *и. рус* Нәрсәгә дә булса каршы юнәлдерелгән аргумент, дәлил. *Татарстан большевиклары исә, Г.Исхакыйның төпле фикерләре белән контраргументлар аша көрәшү урынына, башка юл сайлыйлар.* Мирас

**КОНТРАСТ** *и. фр.* **1.** 1) Кискен аерылып торган, бик ачык капма-каршылык. *Ә менә шат, уенчак Камилә Мәрьямнең контрасты рәвешендә бирелгән.* Г.Нигъмәти. *Тукай авылның фәкыйрьлегенә көенә. Картинаны ул кәеф-сафа чигүче байга контраст рәвешендә тасвирлый ---.* Н.Хисамов. *--- кыйссаның башыннан ахырына хәтле үтә дә зур урын алып торган капма-каршылык, кычкырып торган контраст: ак һәм кара; яхшылык һәм явызлык ---.* Ф.Урманче

2) Рәсем сәнгате, фотода: буяуларның төсендә кискен аерма

**2.** *с. мәгъ. к.* **контрастлы**. *[Аяз Гыйләҗев] тормышка үз карашы, әдәбиҗат эшенә үз мөнәсәбәте булган, контраст бизәкләр белән эш итә --- торган, җитлеккән язучы ---.* Р.Мостафин. *Изге татар авылы академиясен тәмамлап, власть тирәсенә керә башлагач, мин дөньяда контраст төсләр яшәвенә төшендем.* Р.Мөхәммәдиев

**КОНТРАСТЛЫ** *с.* 1) Кискен капма-каршылыклы; капма-каршылык тудыра торган. *Бер-берсен күрмичә ярты минут та яши алмаучы бу ике матрос һәр нәрсәнең контрастлы якларын, һәр фикернең капма-каршылыгын табалар иде.* М.Юныс

2) Рәсем сәнгатендә, фотода: буяуларның төсендә кискен аерма булган. *Сирәк очрый торган мондый [кара җирлеккә] чиккән әйберләр бүген дә сокландыра, чем-кара җирлек җете төсләрнең контрастлы матурлыгын көчәйтеп тора.* Казан

**КОНТРАСТЛЫК** *и.* Контраст булу сыйфаты. *«Төнге гөлләр» шигырендә --- автор [Зөлфәт] Кеше йөрәгенең җылысы белән Галәм җанының салкынлыгы контрастлыгын тудыра ---.* Ф.Сафин. *Аның [Г.Ибраһимовның] әсәрләренә вакыйгаларның киеренкелеге, психологик драматиклык һәм характерлар контрастлыгы хас.* М.Хәсәнов

**КОНТРАСТЛЫЛЫК** *и.* Капма-каршылык, зур аерма. *Алтын Урда сәнгатенә --- яссы рельефка салмак күчүче вак һәм эре бизәкләрнең контрастлылыгы характерлы.* Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова

**КОНТРАТА́КА** *и. фр.* Дошман һөҗүменә каршы җавап атака; атакага каршы атака. *Немец диган кабахәт җан ике контратака арасында да тынычлык бирми: я артиллериядән,*

*я миномёттан өзлексез атып тора.* И.Гази. *Ул көнне безнең частьлар --- яхшылап урнашырга да өлгермәделәр, фашистлар бер-бер артлы контратакага ташландылар.* А.Әхмәт

**КОНТРАТА́КАЛАУ** *ф.* Контратака ясау, контратакага бару. – *Безгә ашыгырга кирәк, – диде Урманов. – Финнар контратакалыйлар.* Г.Әпсәләмов

**Контратакалап калу** Контратака ясарга өлгерү

**Контратакалап тору** Әле, хәзер контратакалау; даими яки әледән-әле контратакалау

**КОНТРАФАКТ** *и. ингл.* Законлы булмаган; автор хокукларын бозып житештерелгән һәм сатылган товар. *РФ Гражданлык кодексының 1252, 1255, 1263 нче маддәләре буенча контрафакт носительләр әйләнештән алынырга һәм компенсациясез юк ителергә тиеш.* Маяк

**КОНТРАФА́КТЛЫ** *с.* Законлы булмаган; автор хокукларын бозып житештерелгән һәм сатылган. *Тикшерү барышында полиция хезмәткәрләре DVD дискларын сатып алды. Нәтиҗәдә контрафактлы хәзерләү билгеләре булган дисклар сату фактлары ачыкланды.* Маяк

**КОНТРАФА́КЦИЯ** *и. фр.* Хезмәт эшчәнлеген икенче кеше исеме белән алып бару, товарларны җитештерүдә һәм сатуда башкаларның патентын законсыз рәвештә куллану, шулай ук танылган фирмаларның товар билгесен үз товарыңа законсыз рәвештә урнаштыру

**КО́НТРАЧЫЛЫК** *и. тар.* Совет властена каршылык

**КОНТРИБУ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Җиңүче дәүләт файдасына җиңелгән дәүләттән түләтелә торган салым. *Моңардан тыш, ул заманда әле Мәскәү Казанга салым түләп торган. --- Кызганычка каршы, бу контрибуциянең, дөресрәге йолымның күләме төгәл күрсәтелмәгән.* Р.Фәхретдинов

2) Басып алынган җирләрдә халыктан акчалата яки әйберләтә җыела торган салым. *Тагын төшләр… Тагын буржуйларның күз алдына куркыныч сүзләр өермәсе килеп баса: Комендант… Комиссар… Ревком… Конфискация… Контрибуция.* К.Нәҗми

**КО́НТРЛАНУ** *ф. тар.* Контр булу, контрга әйләнү

**Контрлана бару** Акрынлап контрлану

**Контрлана төшү** Берникадәр контрлану

**Контрланып бару** Тора-бара контрлану

**Контрланып йөрү** Озак вакыт дәвамында контрлану. *[Гали] Колчак ягында ирекле агитатор булып, контрланып йөри.* Г.Ибраһимов

**Контрланып куюу** Кинәт контрлану

**КО́НТРЛЫК** *и. тар.* Контр булу. *Коммунист булган кеше шул ук вакытта бездән председательнең контрлыгы, взятка алуы турында документлар сорарга тиешле иде.* Һ.Такташ

**КОНТРМИ́НА** *и. хәрби* Оборона корылмаларына якын юлларны дошман минёрларыннан саклау өчен куелган мина. --- *Ул [Г.Утыз-Имәни] бу сәясәткә «контрмина» булдыру юлына баса.* М.Гайнетдин

**КОНТРНАСТУПЛЕ́НИЕ** *и. рус к.* **контрһөҗүм**. *[Генерал:] Узган ел маршал Шапошников киңәш иткәнчә, безгә яздан ук оборона тотып, немецны туктатып, аннан соң гына контрнаступлениегә күчәргә кирәк иде.* З.Зәйнуллин

**КОНТРОЛЁР** *и. фр.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса тикшерү, контроль ясау белән шөгыльләнүче хезмәткәр. – *Ышанмагыз, иптәш милиционер. Алар беренче мәртәбә билетның контрольсез ягын ерттырып, бер билет белән ике тапкыр кереп йөриләр, – диде контролёр кыз.* М.Юныс. --- *[контролёр кыз:] Бабай, бу бала-чага билеты ич.* Б.Ислам

2) Җитештерү барышында нәрсәнең дә булса эшенә контроль ясау өчен билгеләнгән җайланма, әсбап. *Телне өйрәнгәндә --- теге яки бу артикуляция шактый озак үзләштерелә, колак контролёр хезмәтен үти, ә колак авазны бик үк төгәл аерып җиткерә алмый.* Ф.Сафиуллина

**КОНТРОЛЁРЛЫК** *и.* Контролёр хезмәте

**КОНТРО́ЛЛЕР** *и. ингл. махс.* Электр двигательләренең эшен җайга сала, көйли торган прибор

**КОНТРОЛЬ** *и. нем.* **1.** 1) Тикшерү максаты белән күзәтү; тикшерү; күзәтчелек. *Профсоюз председателе докладын бик әйбәт сөйләде. «Тикшерәбез дә контрольдә тотабыз».* М.Юныс. *1736 елгы фәрманнан соң хөкүмәт рөхсәте һәм контроле белән килгән татарлар башка исемнәр белән аталып йөртелә башлыйлар ---.* Д.Рамазанова. *Француз группасы белән бергә безнең взвод төп автомагистральне контрольгә алды.* Казан утлары

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса эшчәнлеген тикшерә торган оешма

3) *к.* **контролёр**. *Кинәт әйләнсәм, ни күрим: ике кондуктор, бер күз карашы белән ашарга торгандай ачулы йөзле контроль, безне ике яктан кысып алганнар.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тикшерә торган, тикшерү, күзәтчелек хокукы булган, шундый хокук бирелгән. *Контроль пост*

2) Тикшерү, күзәтчелек итү өчен билгеләнгән. *Аңа бер кочак контроль эшләр, программалар килеп төште.* А.Гыйләҗев. *Безнең дивизия разведкасының бурычы – батальон сугыш алып барган арада дошман тылына үтү һәм контроль «тел» алып чыгу.* Ә.Айдар. --- *һәрбер урта махсус мәдәният һәм сәнгать уку йортына максатчан кабул итүнең контроль саннарын билгеләп, Мәдәният министрлыгы бернечә ел дәвамында бу проблеманы мөстәкыйль хәл итәргә тырышып карады.* Мирас

**КОНТРО́ЛЬЛӘҮ** *ф.* Контроль ясау, контрольлек эшен башкару; тикшереп күзәтү юлы белән уяулыкны тәэмин итү

**Контрольләп бетерү** Барысын да контрольләү; тәмам, ахыргача контрольләү. --- *җитәкчеләр ярдәменнән башка бу кадәр мәйданны контрольләп бетерү мөмкин түгел.* Маяк

**Контрольләп тору** Даими яки әледән-әле контрольләү

**Контрольли төшү** Берникадәр контрольләү; контрольне билгеле бер күләмдә арттыру

**КОНТРОЛЬЛЕК** *и.* Контрольдә тоту, тикшерү-күзәтү эше. *Наркотик-*

*ларга нәтиҗәле контрольлек һәм кешеләрнең бу афәткә ияләшүенә каршы чаралар эзләү халыкара дәрәҗәдә алып барыла.* Ватаным Татарстан

**КОНТРОЛЬЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Контрольдә тоту. *[Мәгърифәт] Үзең төзегән, утына-суына үзең түләгән, тәрбияви эшкә үзең контрольлек иткән мәктәптә.* А.Хәлим

**КОНТРОЛЬЧЕ** *и.* Контрольләүче; контроль ясап торучы кеше; *к.* **контролёр**. --- *базар шартларында дәүләт икътисади процессларны көйләүче һәм контрольче буларак чыгыш ясый.* Кызыл таң

**КОНТРПАР** *и. тех.* Машинаны туктату максаты белән пар машинасының цилиндрына җибәрелә торган пар. *Паровоз, контрпар чыгарып, тормоз бирде.* Ш.Усманов

**КОНТРРАЗВЕ́ДКА** *и. рус* Дошман разведкасына, шпионаж, диверсиягә һ.б.ш.га каршы көрәш өчен билгеләнгән махсус оешма. *Әйтик, «Russія» романын язганда (ул «Татарский удар» исеме белән дөнья күрде), мин разведкага, контрразведкага һәм диверсион эшчәнлеккә --- багышланган исәпсез-хисапсыз материал эшкәрттем ---.* Идел

**КОНТРРАЗВЕ́ДКАЧЫ** *и.* Контрразведкада эшләүче кеше

**КОНТРРАЗВЕ́ДЧИК** *и. лат.-рус к.* **контрразведкачы**

**КОНТРРЕВОЛЮЦИОН** *с.* Инкыйлапка дошман, аңа каршы куелган, юнәлтелгән. *Контрреволюцион корткычлык монда да үзенең ерткыч тырнагын батырырга омтыла.* Ш.Камал. *Искәндәр, контрреволюцион эше ачылып, кулга алынды.* Г.Нигъмәти. *Бу факт, контрреволюцион татар буржуазиясенең йөзен фаш итү өчен, искиткеч бай, кызыклы материал булып тора.* М.Җәлил

**КОНТРРЕВОЛЮЦИОНЕР** *и. рус* Контрреволюцион хәрәкәттә катнашучы, контрреволюция яклы кеше. *Беренче, ул – контрреволюционер, кулак, --- авыл кулакларын развёрсткадан саклый, дезертирлар асрап ята, аларда сыйланып йөри.* Һ.Такташ

**КОНТРРЕВОЛЮЦИОНЕРЛЫК** *и.* Контрреволюционер булу. *Без аны [председательне] контрреволюционерлыкта, взятка алучылыкта гаепләдек.* Һ.Такташ. *Т.Бәдигыйны, чыгышы белән руханилар нәселеннән булуы сәбәпле, контрреволюционерлыкта һәм тәрбия эшен җимерүдә гаепләп, өлкә комитеты президиумы карары белән 1935 елның 7 мартында эшеннән алалар.* Мәгариф

**КОНТРРЕВОЛЮ́ЦИЯ** *җый. и. фр.* Халыкның бер катламының инкыйлапка кадәр булган тәртипләрне кайтару, үзләренең мәнфәгатьләрен һәм хокукларын саклап калу өчен, инкыйлапка каршы алып барган көрәше. *Кушма Штатлар президенты Вильсон Россиядәге контрреволюциягә 12 миллион доллар бурычка акча бирде.* И.Гази. *1905 нче ел революциясе вакытлыча җиңелде. Контрреволюция өстенлек алды.* Г.Кашшаф. *В.И. Ленин җитәкчелегендәге Коммунистлар фиркасе контрреволюциягә каршы көчләр туплый башлый.* З.Зәйнуллин

**КОНТРРЕВОЛЮ́ЦИЯЧЕ** *и. к.* **контрреволюционер**. --- *Контрреволюцияче, ак эмиграцияче тарафыннан җибәрелгән тәбрик телеграммасын үзем өчен тәбрик түгел, хурлык табам...* М.Гали

**КОНТРУДАР** *и. рус к.* **контрһөҗүм**. *11 августта Богодухов янындагы немецлар беренче контрудар ясыйлар.* З.Зәйнуллин

**КОНТРХӘРӘКӘТ** *и.* Хәрәкәткә каршы хәрәкәт. *[Герасимов] бөтен контрхәрәкәтнең, контратакаларның һәммәсенең дә иң кечкенә тармакларынача үзе турыдан-туры җитәкчелек итәргә тотынды.* Г.Ибраһимов

**КОНТРҺӨҖҮМ** *и.* Дошман һөҗүме тукталганнан соң үткәрелә торган каршы һөҗүм. *Фронтта безнең гаскәрләрнең контрһөҗүме дәвам итә иде әле.* Г.Әпсәләмов. --- *[гаскәрләр] дошманның контрһөҗүмгә күчә башлаганын күреп, туктап, үзләре үк оборонага күчә башлаганнар иде инде.* З.Зәйнуллин. *17 август таңында ук полк сугышчылары, кысылып килгән дошман боҗрасына тоташырга ирек бирмәс өчен, соңгы контрһөҗүмгә күтәрелделәр.* Л.Хәмидуллин

**КОНТРЧАРА** *и.* Җавап буларак эшләнгән каршы, контр чара. *Лагерь комитеты да контрчаралар күрә башлады.* Н.Дәүли

**КОНТУ́ЖЕН** *с. рус сөйл.* Контузиягә дучар ителгән, контузияле. *Әтиләре – сугыштан контужен кайткан Тимерҗан агай – малае юклыкка бик кимсенә, ояла иде.* Д.Булатова

**КОНТУ́ЖЕН БУЛУ** *ф. сөйл.* Контузияләнү. *Ул нык контужен булып, миенә дә зарар килә.* Ш.Камал. *«Сугышта контужен булса да, бу кияүнең ике аягы да сау-сәламәт, үз урынында бит», – дип тынычландырырга тырышты Надияне әнисе.* Идел

**КОНТУ́ЗИЯ** *и. лат. мед.* Организмның тыштан җәрәхәт алмый гына өлешчә яки тулысынча эчке зарарлануы, имгәнүе, зәгыйфьләнүе (снаряд, бомба шартлау һ.б.ш. нәтиҗәсендә). *– Контузия зәхмәте бу, – диде ул, акланырга теләгәндәй акрын тавыш белән.* Ә.Еники. *Соңыннан белдем, сугышта контузия алган икән ул.* Т.Миңнуллин

**КОНТУ́ЗИЯЛӘНҮ** *ф.* Контузия алу. *[Гали Динмөхәммәтов] --- 1917 елның февраль башларында контузияләнә.* Җ.Юныс. *Аннары кем госпитальгә эләгә, кем бөтенләй туфрак астына күмелә; яраланып, контузияләнеп, тоткынлыкка төшкәннәр дә аз түгел.* Г.Гыйльманов. *Мин – гади рядовой солдат, сибиряк, ветеринар, дидем, фронтка да ветеринар буларак җибәрелдем, әсирлеккә дә яраланган, контузияләнгән хәлдә төштем, дидем.* Казан утлары

**КОНТУ́ЗИЯЛӘҮ** *ф.* Контузиягә дучар итү. *Сугышның контузияли торган тавышлары нинди дә булса көй-музыкага урын калдырмый.* Ватаным Татарстан

**КОНТУ́ЗИЯЛЕ** *с.* Контузияләнгән, контузия алган. --- *артиллерист Ә.Галиев, чолганышта калып, контузияле хәлдә дошман кулына әсир төшә ---.* Совет Татарстаны язучылары

**КО́НТУР** *и. фр.* Предметның тышкы формасын чагылдырган сызымы, предметның график сурәте. *[Хәзер трассада] булачак автостраданың контурларын күрергә була.* М.Мәхмүтов.

*[Генерал] --- график сызымнар белән хәрби операциянең булачак контурларын төшерә башлый.* З.Зәйнуллин

**КО́НТУРЛЫ** *с.* Контурдан гына гыйбарәт булган, контурлары гына күрсәтелгән. *Контурлы карта. Контурлы сызык*

**КО́НУС** *и. гр. мат.* **1.** 1) Турыпочмаклы өчпочмакның бер катеты тирәсендә әйләнүенең нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән геометрик җисем. *Конусның күләмен исәпләү*

2) Формалары белән шундый җисемгә охшаш предметлар. *Алдыбызда өскә таба очлаеп калыккан һәм иң очына кызыл йолдыз беркетелгән конус рәвешендәге зур һәйкәл-обелиск басып калды.* Ф.Хөсни. *Кибетче апа, килькине «Социалистик Татарстан» гәҗитеннән конус ясап, шуңа тутырып үлчәде ---.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* Конус формасындагы, конуслы. *Конус эшләпә. Конус төбә*

**КО́НУСЛЫ** *с.* Конус формасындагы, коник

**КОНФЕДЕРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса оешмаларның берләшмәсе, союзы. *[Вахит Хаков] 1994 елдан алып, Австралиядәге «Җир шарында гуманизм һәм гаделлек өчен» халыкара рыцарьлар конфедерациясе әгъзасы.* Мәйдан

2) Үз суверенлыкларын саклаган дәүләтләрнең берләшмәсе. *Кайбер дәүләтләр, шул исәптән бүгенге бәйсез дәүләтләр дә, конфедерация принципларында --- көн күрәләр.* Мирас

**КОНФЕРАНС** *и. фр. театр* Сәхнә чыгышларын, концерт программаларын алып бару белән бәйле эстрада жанры; шул жанрга караган чыгышларның тексты. *Сайлап алу туры яшь буенча өч төркем арасында 3 номинация буенча узды: вокал, сөйләм иҗаты һәм конферанс, рәсем иҗаты.* Маяк

**КОНФЕРАНСЬЕ** *и. фр. театр* Концерт программаларын алып баручы, кайчакта концерт номерлары арасындагы пауза вакытында тамашачыларны үз номерлары белән җәлеп итүче артист. *[Фуат] --- мильон шөгыль тапкан: декан, диктор, конферансье, тәнкыйтьче дә, депутат та.* Р.Харис. *Конферансье егет аңа урындык тәкъдим итте, бик җитез кыланып, алдына гармунын да китереп куйды.* Г.Әдһәм

**КОНФЕРЕНЦ-ЗАЛ** *и. нем.* Тантаналы утырышлар, конференцияләр залы. *Гыйльми үзәкнең конференцзалында, мәрмәр коридорларында: «Борынгы Кытай иероглифларына күз салсаң...», «Санскрит язмаларына караганда...», «Борынгы Мисыр папирусларында...» дигән сүзләр яңгырап торды.* Г.Афзал

**КОНФЕРЕ́НЦИЯ** *и. лат.* Нинди дә булса мәсьәләләрне хәл итү, фикер алышу максаты белән, дәүләтләр, иҗтимагый, фәнни һ.б.ш. оешмалар вәкилләренең җыелышы, киңәшмәсе. *Залдагы халыкның күбесе өчен аның исеме съездлар, конференцияләр буенча мәгълүм иде.* Г.Ибраһимов. *Ничәмә-ничә симпозиумнар, фәнни конференцияләр, каты бәхәсләр булды, ялкынлы фәнни нотыклар сөйләнде.* Г.Афзал. *Конференция көннәре якынлашкан саен, Вәлишинның бизнес һәм коммерциясе чәчәккә бөреләнеп кенә калмыйча, мул җимеш тә бирәчәге ачык гәүдәләнә иде.* Ф.Яхин

**КОНФЕССИОНАЛЬ** *с.* Билгеле бер диндә булу, билгеле бер дин тоту белән бәйле булган. *Мөселман конфессиональ мәктәпләрендә, традицион саналган фәннәрдән тыш, шәкертләрен ул [Ш.Мәрҗани] Көнчыгышның мәшһүр фикер ияләре һәм шагыйрьләре калдырган бай мирас белән таныштыра ---.* Я.Абдуллин

**КОНФЕ́ССИЯ** *и. лат.* Билгеле бер дин, билгеле бер диндә булу. *Рус колонизаторлары --- татар халкының бер өлешен христиан диненә күчерделәр. Бер милләт эчендә шулай ике конфессия барлыкка килде.* Мирас

**КОНФЕТ** *и. лат.* Кечкенә, шакмак һ.б.ш. формадагы татлы кондитер эшләнмәсе. *Ирләр хатын-кызларны чиктән тыш конфет ярата дип уйлыйлар.* Ш.Камал. *Аннан соң --- ашамлык төрелгән ашъяулык чишелеп табынга җәелде, аның өстенә юача, чикләвек, көнбагыш, чуклы конфетлар куелды.* Ә.Фәйзи

**КОНФЕТЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Кыланчыклану, кылану; *к.* **кәнфитләнү**. *Конфетланучы халыкны җенем сөйми.* Г.Әпсәләмов

2) Кемгә дә булса артык игътибар күрсәтү, аның көен көйләү, төчеләнү. *Күрәләтә кызыл еланнар белән конфетланганбыз икән.* Ш.Камал

**Конфетланып алу** Азга гына конфетлану

**Конфетланып бетү** Бик нык, тәмам конфетлану

**Конфетланып кую** Аз гына конфетлану

**Конфетланып тору** Даими яки әледән-әле конфетлану; әле, хәзерге вакытта конфетлану

**КОНФЕТЛАП** *рәв.* Конфет белән, конфет ашап, конфет кабып. *Чәй эчерәбез үзеңә Баллап, майлап, конфетлап.* М.Гафури

**КОНФЕТЛЫ** *с.* 1) Конфеты булган. *20 конфетлы тартма*

2) *куч.* Төче, ялагай, җитди булмаган

◊ **Конфетлы уйнау** Шаярып сөйләшү, җитди булмау. *[Вахитов:] Сез – бик бормакай кеше. Без бит сезнең белән конфетлы уйнамыйбыз.* Н.Исәнбәт

**КОНФЕТТИ** *и. ит.* Маскарадларда, балларда күңел ачучылар бер-берсенең өстенә һ.б.ш. сибә торган төрле төстәге вак кәгазь һ.б.ш. түгәрәкләр. *Шәрык клубында үткәрелгән әдәби кичәләрнең берсендә Зәйтүнә атлы «фәрештә» Габдулла өстенә конфетти сибә.* З.Мансуров

**КОНФИГУРА́ЦИЯ** *җый. и. нем. кит.* 1) Нәрсәнең дә булса тышкы күренеше, сурәте. *Ул кайбер детальләрнең конфигурацияләрен үзгәртү турында берничә тәкъдим керткән.* Г.Әпсәләмов

2) Нинди дә булса предметларның үзара яраклашып урнашуы

3) *информ.* Компьютерның программа һәм аппарат чаралары җыелмасы, тупламы. *Кайвакыт конфигурация дип компьютерның аппарат өлешен, «тимерен» генә аңлыйлар*

**КОНФИГУРА́ЦИЯЛЕ** *с.* 1) Аерым бер конфигурациягә ия булган

2) Конфигурациясе үзенчәлекле булган

**КОНФИДЕНЦИАЛЬ** *с. кит.* Яшерен, башкалар белергә тиеш булмаган.

*Совет иерархиясендә күпкә күренеклерәк урыннар биләгән Үзәк Комитет әгъзалары --- Сталинга шәхси конфиденциаль куштанлану белән тулы хатлар юллыйлар ---.* Мирас

**КОНФИСКА́ЦИЯ** *и. лат.* Кемнең дә булса акчасын, мөлкәтен дәүләт файдасына көчләп тартып алу. *Колхоз эшләгәненә түләмәгәнне хуҗаларга әйтми генә конфискация итү.* З.Зәйнуллин

**КОНФИСКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Конфискация ясау, конфискация үткәрү

**Конфискацияләп бару** Рәттән барысын да конфискацияләү

**Конфискацияләп бетерү** Конфискацияләүне тәмамлау; барысын да конфискацияләү

**Конфискацияләп тору** Хәзерге вакытта конфискацияләү; даими яки әледән-әле конфискацияләү

**Конфискацияли бару** Әзлекле рәвештә конфискацияләү

**Конфискацияли бирү** Бернигә карамый конфискацияләү

**КОНФИТЮР** *и. фр.* Куе джем төре. *--- кибеттә конфитюр, хәлвә, крендель исе – баш әйләндергеч ис.* М.Мәһдиев

**КОНФЛИКТ** *и. лат.* 1) Капма-каршы якларның, фикерләрнең, көчләрнең бәрелеше; җитди капма-каршылык, бик каты, кискен бәхәс. *[Галия:] Адашып йөри бит ул! Аның күңеле белән бу дөнья арасында бик зур конфликт бар.* З.Хәким. *Конфликт иске: кара көчләр белән ак көчләрнең бәрелеше.* Л.Шагыйрьҗан. *Конфликт комиссиясе эшне озакка сузарга теләмәде.* Х.Госман

2) Кайвакыт кораллы бәрелешкә китерә торган халыкара мөнәсәбәтләрдәге кискенлек, киеренкелек. *Хәрби конфликт*

3) *әд.* Әдәби әсәр сюжетының нигезе буларак персонажлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең капма-каршылыгы. *Моңа мисал итеп «Шайтан ялчысы – Хәмидә», «Вокзал вә мөсафирләр» --- дигән бүлекләрне күрсәтергә мөмкин. Конфликт искелек белән яңалык, явызлык белән яхшылык бәрелешенә нигезләнгән.* М.Гайнуллин. *Бу әсәр [«Рәшә»] уңай һәм кире геройлар конфликты турында түгел, ә катлаулы, каршылыклы күңел дөньясы, кешенең шактый яшерен дә, серле дә булган эчке дөньясы турында.* Әдәбият

**КОНФЛИ́КТЛЫ** *с. кит.* Бәхәсле, каршылыклы. *БДБ киңлекләрендә кайбер конфликтлы хәлләргә кагылышлы ике яклы мөһим очрашулар булачак.* Ватаным Татарстан

**КОНФЛИ́КТЧЫЛ** *с. кит.* Конфликтка тиз керә торган, гаугалы

**КОНФО́РКА** *и. голл.* 1) Күмер салу һәм чәйнек кую өчен самавыр күмерлегенең өстенә кидереп утыртыла торган махсус челтәр җайланма

2) Плитәдә аш-су пешерү, кайнату савытларын утырту өчен махсус түгәрәк тишек. *Кухня яныннан үтеп киткәндә күз төшереп калдым. Дүрт конфорка да дөрләп яна: берсендә шулпа, берсендә ботка, берсендә чәй кайный, дүртенчесендә – шприцлар.* К.Кәримов. *Газ конфоркалары, плитәләр һәм кулдан ясалган җылыткычлар турында әйтеп тә торасы түгел.* Яшел үзән

3) Шул тишеккә куела торган тимер түгәрәкләр

**КОНФУЗ** *и. лат. кит.* Оятка калу хәле, оятлы булу; уңайсыз хәл. *Конфуз гына түгел инде монда – алга таба реклама бирүченең кемне өстен күрәчәге дә ап-ачык...* З.Мифтахов

**КОНЦЕНТРАТ** *и. лат.* **1.** 1) Прессланган, киптерелгән, тиз һәм җиңел әзерләнә торган продукт. *[Солдат] Тары концентратыннан сыек кына итеп пешерелгән ярты котелок ашны күз ачып йомганчы сыпырып куй[ды].* Ш.Маннур. *Без шунда, кырда, балык концентраты белән борчак концентратыннан аш пешереп ашадык.* М.Әмир

2) *а.х.* Туклыклы матдәләргә баетылган терлек азыгы (түп, көрпә һ.б.ш.). *Күпме еллар эшләп, хуҗалыкларда сөтебикәләрне фураж, концентрат һәм башка төр азык белән җитәрлек күләмдә тәэмин итүләрен сирәк күрдем дияргә була.* Ватаным Татарстан

3) *махс.* Казылма байлыкны баету нәтиҗәсендә барлыкка килгән продукт

4) Чималны куертудан, баетудан соң барлыкка килгән продукт, матдә. *Әлеге утраудагы 277 өч яшьлек балага беренче ике атнада төрле ясалма буяулар һәм Е 211 концентраты кушылган сок эчергәннәр.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Витамин һ.б.ш. матдәләргә баетылган, концентрацияләнгән (мал азыгы һ.б.ш.). *Гөләндәм [сыерларга] күбрәк концентрат азыклар бирергә кирәклеген куәтләде.* С.Рафиков

**КОНЦЕНТРАЦИОН** *с.* 1) Бергә туплый, җыя торган; бергә тупланган

2) *тар.* Сәяси тоткыннарны, хәрби әсирләрне ябып тоту өчен ясалган. *Илемне концентрацион лагерьлар чолгап алды.* Г.Минский

**КОНЦЕНТРА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Бөтен, бар булган яки бик күп нәрсәнең бер урынга җыйналуы, тупланышы. *Искәндәрне канга батырганчы кыйнап, концентрация лагерена үзе шикелле «кире беткән» берничә совет солдаты янына илтеп ташлыйлар.* Г.Гобәй

2) *хим.* Билгеле күләмдәге эремәдә эретелгән матдәнең микъдары, куелыгы. *Эремәдә тозлар концентрациясе*

**КОНЦЕНТРА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **концентрацияләү**. *--- маллар аранга кертелгәч, концентрацияләнгән азык та 30 проценттан артмаска тиеш.* Ватаным Татарстан

**Концентрацияләнә бару** Акрынлап концентрацияләнү

**Концентрацияләнә төшү** Бернигәдәр күләмдә, тагын да концентрацияләнү

**Концентрацияләнеп бетү** Тәмам, ахырга кадәр концентрацияләнү

**Концентрацияләнеп тору** Даими яки әледән-әле концентрацияләнү; әле, хәзерге вакытта концентрацияләнү

**КОНЦЕНТРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Бөтен, барлык булган яки бик күп әйберне бер урынга җыйнау, туплау. *Терлекчелекне специальләштерү, концентрацияләү, хуҗалыкара кооперацияне үстерү кебек яңа баскычка күтәрелдек.* Яшәү яме

2) *хим.* Нинди дә булса эремәне куерту, куеландыру, тулыландыру

3) *махс.* Баету (казылма байлыкларны, руданы)

**Концентрацияләп бетерү** Бик нык концентрацияләү

**Концентрацияләп тору** Даими яки әледән-әле концентрацияләү; әле, хәзерге вакытта концентрацияләү

**Концентрацияли бару** Акрынлап концентрацияләү

**Концентрацияли төшү** Берникадәр концентрацияләү

**КОНЦЕНТРА́ЦИЯЛЕ** *с.* Билгеле процентларда, билгеле күләмдә концентрациягә ия булган. *Наркотик матдәнең концентрациясе 66 процентны тәшкил иткән. Татарстанда әлегә мондый югары концентрацияле наркотик матдә белән тоткарланучылар булмаган.* Ватаным Татарстан

**КОНЦЕ́НТРИК** *с. мат.* 1) Уртак үзәге булган. *Гомуми үзәккә ия ике әйләнә концентрик әйләнәләр дип атала.* Математика

2) *әд.* Бер конфликт тирәсенә оешкан. *Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасы – поэтик әсәр, концентрик фабулага корылган.* Э.Губаева

**КОНЦЕПТ-КАР** *и. ингл.* Техник-технологик эшләнеш, дизайн яки башка күрсәткечләре ягыннан элекке модельләрдән кискен аерылып торган автомобиль

**КОНЦЕПТУАЛЬ** *с.* Нинди дә булса концепциягә нигезләнгән; өр-яңа концепцияне үз эченә алган, шуның белән мөһим булган. *Форумда әһәмиятле документ – «Татарлар һәм ислам дөньясы: хәрәкәт итү һәм үсешнең концептуаль нигезләре» дигән концепция кабул ителергә тиеш.* Мәдәни җомга

**КОНЦЕПТУАЛЬЛЕК** *и.* Концептуаль булу. *Төрле жанр һәм стильдәге материалларны автор шәхесенең зурлыгы, галим буларак дөньяга, яшәүхәятыбызга карашының киңлеге һәм концептуальлеге --- туплап тора.* К.Йосыпов

**КОНЦЕ́ПЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Теге яки бу күренешкә карата үзара бәйләнгән һәм берсеннән икенчесе туа торган карашлар системасы: нинди дә булса күренешне аңлау-аңлату ысулы. *--- вульгар социологизм концепциясе Тукай иҗаты тирәсендә дә әдәбитәнкыйди фикер көрәшен кискенләштереп җибәрә.* Т.Гыйләҗев. *Россия Федерациясенең милли концепциясен язучыларның берсе дә, конференцияләрне оештыручы, фәнни докладларны аерым җыентык итеп бастырып чыгарырга юл ачучы кеше дә – Мансур Хәсәнов.* Мирас

2) Язманың, әсәрнең төп фикере, идеясе. *Безнең фикеребезчә, аның [мәкаләнең] төп концепциясе дә дөреслеккә туры килми булса кирәк.* Ф.Урманче

**КОНЦЕРН** *и. ингл.* Монополистик берләшмәләрнең бер формасы буларак, гомуми финанс контрольлегенә нигезләнгән күпсанлы сәүдә-сәнәгать предприятиеләре берләшмәсе. *Әле бик күп еллар элек Фарбер концерны бу тауларны тишеп аммиак чыгарган.* Н.Дәүли

**КОНЦЕРТ** *и. ит.* 1) Билгеле бер программа нигезендә музыкаль әсәрләрне һ.б.ш. номерларны халык алдында башкару. *Орган тавышы тынды. Концерт тыңлаучылар урыннарыннан кузгалдылар.* М.Юныс

2) Бер генә (сирәгрәк берничә) музыка уен коралында оркестрга кушылып башкару өчен язылган зур музыкаль әсәр. *Н.Җиһанов консерваториядә укыган елларында --- берничә фуга, сонатина, концерт, квартет һәм, ниһаять, беренче симфониясен яза.* М.Җәлил

**КОНЦЕРТ-ТАМАША** *и.* Концерт, төрле уен-көлке белән зур бәйрәм. *Очрашу «Сабыйга» журналында басылган әсәрләр буенча төзелгән концерт-тамаша белән тәгәлләнде.* Мирас

**КОНЦЕРТИ́НА** *и. ингл. муз.* Алты кырлы кечкенә гармун формасында музыка уен коралы

**КОНЦЕРТИ́НО** *и. ингл. муз.* Концерт (*2 мәгъ.*) тибындагы, ләкин җиңелрәк башкарыла торган һәм кечерәк күләмле музыкаль әсәр

**КОНЦЕРТМЕ́ЙСТЕР** *и. нем. махс.* 1) Оркестрда башкаручылар (беренче скрипкачы, беренче альтчы) төркеменең җитәкчесе

2) Симфоник яки опера оркестрының солисты

3) Җырчылар белән партияләрне өйрәнүче пианист-аккомпаниатор. *1941 елның ахырында Рөстәм Яхин Казанга кайта, Татарстан радиосында концертмейстер булып эшли башлый.* Казан утлары

**КОНЦЕ́ССИОН** *с.* 1) Концессиягә (*1 мәгъ.*) караган, шуңа мөнәсәбәте булган

2) Концессия (*1 мәгъ.*) нигезендә яшәп килгән

**КОНЦЕССИОНЕР** *и. нем.* Концессия иясе, концессиясе булган, концессия алган кеше

**КОНЦЕ́ССИЯ** *и. лат.* 1) Хөкүмәт карамагындагы табигый байлыкларны, предприятие һ.б.ш. хуҗалык корылмаларын билгеле бер вакытка файдалануга бирү турында шартнамә, килешү. *Беркөнне ул [Син-Дян] япон концессиясе карамагындагы күмер шахтасы тирәсендә дә күзгә чалынган.* Ә.Маликов

2) Шундый шартнамә, килешү нигезендә оешкан, барлыкка килгән предприятие

**КОНЦЛА́ГЕРЬ** *и. рус* Тоталитар һәм авторитар режимлы дәүләтләрдә сәяси тоткыннарны яки сугыш вакытында әсирләрне тоту һәм күпләп үтерү урыны. *[Җырны] бер концлагерь да, бер богау да тота алмый.* Н.Исәнбәт

**КОНЦЛА́ГЕРЬЧЫ** *и.* 1) Концлагерь оештыручы, концлагерь сакчысы

2) *сөйл.* Концлагерьдагы кеше; концлагерьда булып чыккан яисә анда тотылган кеше

**КОНЪЮНКТИ́ВА** *и. лат. анат.* Күз алмасының алгы өлешен һәм күз кабакларының эчке өслеген каплап торган лайлалы яры

**КОНЪЮНКТИВИТ** *и. лат. мед.* Конъюнктиваның ялкынсынуы. *Күз авырулары арасында иң киң таралганы – конъюнктивит.* Сабантуй

**КОНЪЮНКТУР** *с.* 1) Конъюнктурага бәйләнешле, шуңа карап эшләнгән

2) Вакытлы гына, тиз арада үтә торган

**КОНЪЮНКТУ́РА** *и. лат.* 1) *кит.* Иҗтимагый тормышның нинди дә булса өлкәсендә барлыкка килгән хәл, шарт. *Яшь автор [үз әсәрендә] --- иҗат интеллигенциясе арасында конъюнктурага карап эш итүче, карьера артыннан куучы типларны фаш итү, чын иҗат атмосферасы өчен көрәш проблемаларын куярга тели.* М.Әмир

2) *икът.* Товарлыклы хуҗалыкның торышын чагылдырган билгеләр

(бәяләр хәрәкәте, кыйммәтле кәгазьләр курсы, товарны эшләп чыгару күләме) җыелмасы. *Хуҗалык конъюнктурасы*

**КОНЪЮНКТУ́РАЧЫ** *и. кит.* 1) Конъюнктурага, вакытлы тәэсир, йогынтыларга бирелеп эш итүче кеше

2) Теге яки бу конъюнктурадан (*1 мәгъ.*) чыгып, үз-үзен тотышын бик тиз үзгәртүчән принципсыз кеше

**КОНЬКИ** *и. рус сөйл.* Бозда шуар өчен аяк киеменә беркетелгән тар металл табан; тимераяк. *Чаналарның, чаңгыларның, конькиларның шәпләрен сайлап алырга чыккан малайлар анда да үз эшләрен шулай ук тизрәк бетерергә ашыгалар иде.* А.Алиш

**КОНЬКИЧЫ** *и. сөйл.* Конькида шуучы; конькида шуу спорты белән шөгыльләнүче. *[Альбомның] икенче битендә конькичылар Жукова белән Гончаренко.* Г.Мөхәммәтшин

**КОНЬЯК** *и. фр.* Виноград шәрабен куып, шуны озак саклау нәтиҗәсендә алынган югары градуслы исерткеч эчемлек. *Ирләрнең бер өлеше утырып та, аяк өсте дә, сыра, коньяк, аракы тәмен татыйлар.* Ш.Камал. *Яңа ел бәйрәмнәре якынлашып килгәндә... өстәлгә коньяк та, лимон да менеп кунаклаган.* Чаян

**КО́НЮХ** *и. рус сөйл.* Ат карау, ат асрау белән шөгыльләнүче эшче. *Хуҗасы үлгәннән бирле [ат] үзен беркемгә иярләтми. Ул шундый чыгымчыланды, үзен караучы конюхны да тибеп үтерде.* Мирас

**КО́НЮХЛЫК** *и. сөйл.* Конюх эше, конюх булу

**КОҢГЫЗ** *и. зоол.* 1) Элпә канаты өстендә каты хитин канатлары булган бөҗәк; *русчасы:* **жук**. *Коңгыз башын аска таба ия алса да, төрле якка бора алмый.* Биология. Хайваннар. *Су коңгызлары да шулай эшли.* Табигать белеме. *Яр буйларында ялтыравыклы коңгызлар очып йөрде.* Диңгез тирәнлегендә. *Урман кошлары --- кабык астында һәм үзагачта тереклек итүче мыеклач коңгызлар, кабык коңгызлары, юкәр коңгызларының личинкалары белән тукланалар.* Биология

2) **коңгызлар** *күпл. зоол.* Катыканатлылар, бөҗәкләр классының йомшак япмалы корсак өлешен һәм икенче пар элпә канатларын өске каты канатлар каплап торган, туфрак ясаучы, санитар, ерткыч, үсемлекләрне серкәләндерүче бөҗәкләр отряды

**КОҢГЫЛДА́У** *ф.* Саңгыраурак каңгылдау. *Эстон кызы бу җирләрдә барган авыр сугышлар турында сөйләгәндә, нарат башында берөзлексез козгын очынгалады. Оча-куна коңгылдады.* М.Мәһдиев. *Әткәй сугышта – Хаты юк күптән. Козгын, коңгылдап, Очрама бүтән.* Ш.Галиев

**Коңгылдап алу** Кинәт, кыска вакыт коңгылдау

**Коңгылдап җибәрү** Кинәт коңгылдау

**Коңгылдап кую** Кисәк, бер мәртәбә коңгылдау. *Нәрсәдер әйтергә теләгән [челән] үз телендә коңгылдап та куйган.* Ә.Баян. *Шунда каракош, очып йөреп, аның каршысына агачка кунды да коңгылдап куйды.* Ф.Яхин

**Коңгылдый башлау** Коңгылдарга тотыну

**КОҢГЫЛДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **коңгылдау**

2) *күч.* Шаулашу, гөрләшү, шау-гөр килү. *Коңгылдашкан күп яманга хур булдым.* Мәкаль

**КОҢГЫР** *с.* 1)*к.* **коңгырт** (*1, 2 мәгъ.*). *Күлдә йөргән коңгыр каз чүл кадерен белмидер, чүлдә йөргән дуадак күл кадерен белмидер.* Мәкаль. *Коңгыр чәч өстендә маңгай турына киелгән кеч-кенә, ак энҗеле калфак язның матур чәчәге кебек сокландыгыч күренә.* Г.Ибраһимов. *Студент гади генә, ләкин килешле киенгән, ябык кына битле, коңгыр чәчле, яңа гына мыек чыга башлаган егет иде.* Ф.Әмирхан

2) *диал. к.* **коңгыз**

**КОҢГЫРЛЫК** *и. к.* **коңгыртлык**. *Хәят күзләргә дә билгеле бер төс бирергә тырышып караса да, булдыра алмады: алар коңгырлык белән чемкаралык арасында билгесез килеш калдылар.* Ф.Әмирхан

**КОҢГЫРТ** *с.* 1) Көрән, карасу көрән төстәге (гадәттә, күзләр, сакалмыек, чәч, төкләр тур.). *Коңгырт атка атланган нииндидер казак капка төбенә килеп туктады.* А.Таһиров. *Чагылдыра күзне таң яктысы, Җилләр тарый коңгырт чәчләрне. Белмим, әллә хисләр ташкангамы, Ирексездән күзләр яшьләнде.* М.Җәлил. *Картның озынча битенә, коңгырт күзләренә, ирен кырыйларына күз салып, егет аның кәефен чамаларга тырышты.* Г.Бәширов

2) Кара тутлы, кояшта кызган (кеше тәне тур.). *Кабилә башы, шулай итеп, бердәнбер улыннан язды, хәзер аның Гулана атлы җиткән кызы гына калды. Әйе, кояшта янган коңгырт тәнле, озын кара чәчле, кара күзле Гулана...* Р.Фәхретдинов. *Карасалар – үткен күзле, коңгырт битле бу кыз Ташлытауның иң чибәр кызларыннан берсе икән.* М.Мәһдиев

3) Башка бер төскә коңгырт төсмер кушылуын белдерә. *Күзләрендәге коңгырт яшел матур төсләр, нечкә кашлары, куе сары чәченең иңбашына төшеп җитәр-җитмәс бөдрәләнеп кире кайтарылуы Дәрҗияне көяз ханым итеп күрсәтәләр иде.* Г.Бәширов. *Әфхәтнең коңгырт соры күзләреннән тәүге каен суыдай үтә күренмәле, кристалл төсле саф шарлар тәгәрәсә дә, мондый очракта акырыш, бакырыш, тавыш белән елау кабул ителмәгән.* Т.Галиуллин. *Йоннары елык-елык килеп торган коңгырт кара төстәге җитез чәшкеләр, йомры озынча гәүдәләрен туптай атылдырып, әле челтәргә үрмәләп менәләр, әле эчке якка уелган түгәрәк тишеккә кереп югалалар иде.* А.Вергазов

4) *күч.* Басынкы, берникадәр карлыккан (кеше тавышы тур.). *Кычкырып җырларга ярамый. Альшуллер әкрен, коңгырт тавыш белән «Дунай аръягы» көен суза.* А.Таһиров. *Шул чак Гәүһәршад бикә, кинәт аягүрә басып, кулларын киң колачлап, күзен түшәмгә текәп, шомлы, коңгырт тавыш белән кычкырды ---.* Р.Батулла

**КОҢГЫРТЛАНУ** *ф.* Коңгырт төскә керү. *Нык үзгәрдем, бәлки, хәзер Хис тә бераз сүрелгәндер; Сары чәчем коңгыртланды, Күз карашым кырысланды.* Р.Закиров

**Коңгыртлана бару** Торган саен коңгыртрак булу

**Коңгыртлана башлау** Коңгырт төс билгеләре күренү. *Нәфисә кояш белән*

*язгы җилдә коңгыртлана башлаган битен һәм маңгаен яулык чите белән сөрткәләп алды.* Г.Бәширов

**Коңгыртлана төшү** Бераз коңгырт төс керү

**Коңгыртланып бетү** Бик нык коңгыртлану

**Коңгыртланып килү** Акрынлап, азазлап коңгыртлану

**Коңгыртланып китү** Кинәт коңгыртлану

**КОҢГЫРТЛЫК** *и.* 1) Коңгырт булу. *Күзләрнең коңгыртлыгы*

2) Коңгырт төс, төсмер

**КО́ҢК-КОҢК** *иярт.* Коңгылдаган тавыш чыгаруны белдерә. *Аз йоклагандырмы, күп йоклагандырмы, шул матур тавышларга ниндидер ямьсез, шомлы аваз килеп кушылгач кына, Алып Бәргән күзен ачты. – Коңк, ко-оңк! – дип, нидер коңгылдый иде.* Р.Батулла

**КООПЕРАТИВ** *и. нем.* **1.** 1) *сөйл.* XX гасырның 80 нче еллары башында барлыкка килгән, киң кулланыш товарлары җитештерү һәм сату, төрле хезмәт күрсәтү һ.б.ш. өлкәләрдә эшли торган, дәүләт предприятиеләреннән аермалы буларак, хосусый нигездәге предприятие. *Кооперативлар оештыру. Кием тегү кооперативы*

2) *к.* **кооперация** (*2 мәгъ.*). *Ашлыгымны бастырдым, хәйран уңган ашлыгым, Хәзер илтәм кооперативка Ашлыгымның артыгын.* М.Җәлил. *Сул якта – яшел чирәм һәм вак куаклар каплаган кечкенә утрау. Бакчачылык кооперативында бүленеп бирелә торган дүрт сотый җир зурлыгы гына.* М.Юныс

3) *иск. сөйл. к.* **кооперация** (*3 мәгъ.*). *Кәҗә нихәтле көчле бакырса, аның иясенә кооперативтан шул хәтле күп товар алырга мөмкин була имеш.* Ш.Камал. *Госман инде әнисе бирәр йомыш белән күршегә кергәндер, я кооперативка чыгып киткәндер дип уйлады.* А.Шамов. *Казан кооперативында Саталар алтын-көмеш; Гармунчының мәхәббәте артык була биш өлеш.* К.Йосыпов

**2.** *с. мәгъ.* Кооперативка караган, кооперативлаштырылган. *Колхозларда һәм совхозларда җитештерү мөнәсәбәтләрен шул юнәлештә үзгәртергә кирәк. Аларны кооператив нигезгә күчерү һәм башлангыч хезмәт коллективларына мөстәкыйльлек бирү --- максатка ярашлы.* Мирас

**КООПЕРАТИВЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Кооперация (*1, 2 мәгъ.*) нигезендә берләштерү. *Сөтчелек хуҗалыгын кооперативлаштыру*

2) Кооперациядә (*2 мәгъ.*) катнашуга җәлеп итү

**Кооперативлаштыра бару** Акрынлап рәттән кооперативлаштыру

**Кооперативлаштырып бару** Кооперативлаштыруны акрынлап арттыру

**Кооперативлаштырып бетерү** Барысын да кооперативлаштыру; кооперативлаштыруны гомумән тәмамлау

**КООПЕРАТИВЛАШУ** *ф.* Кооперативларга берләшү, оешу

**Кооперативлаша бару** Акрынлап кооперативлашу

**Кооперативлашып бару** Кооперативлашуны акрынлап арттыру; акрынлап барысы да кооперативлашу

**Кооперативлашып бетү** Барысы да кооперативлашу; гомумән кооперативлашуны тәмамлау

**КООПЕРАТИВЧЫ** *и. к.* **кооператор**. *Тукыз авылыннан Тоболга Нури Кутков дигән кооперативчы килгән икән.* Ш.Маннур

**КООПЕРАТИВЧЫЛЫК** *и.* Сәүдә кооперативларын оештыру эше

**КООПЕРА́ТОР** *и. ингл.* 1) Кооперация (*2 мәгъ.*) өлкәсендә эшләүче хезмәткәр, кооперация эшчесе. *Янәсе, Кашпировскийлардан һәм шуның сымак үрчегән җыен әтрәк-мәтрәк кооператорлардан кай җирең ким?* Н.Хәсәнов

2) Сәүдә кооперациясендә эшләүче кеше. *Мин сезне кооператор Мортаза иптәшкә төшерермен. Аларның өйләре иркенрәк.* К.Нәҗми

3) Кооператив оештырган кеше, эшмәкәр

**КООПЕРА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Хезмәт оештыруның бер үк төрле эш барышында яки шул эшнең үзара бәйләнгән башка процессларында күп кешеләрнең бергәләп эшләүләренә корылган формасы. *Татарстан белән Россия аеруча тыгыз мөнәсәбәтләрдә булдылар һәм булачаклар. Бу аларның географик урнашуына, ягъни җирләрнең янәшәлегенә һәм җитештерү кооперациясенең югары дәрәҗәдә булуына бәйле.* Мирас

2) Үз әгъзаларының матди чараларына оешкан, төзелгән хуҗалык, сәүдә һ.б.ш. төркемнәр берләшмәсе. *Һөнәр кооперациясе*

3) *сөйл.* Кооперация (*2 мәгъ.*) кибете. *Кооперациядә товарлар юк, табып бирергә булыш әле, дигән идем, нигә әйткәнемә үкендем.* Т.Гыйззәт

**КООПЕРАЦИЯЛӘШТЕРҮ** *ф. к.* **кооперативлаштыру**

**Кооперацияләштерә бару** Акрынлап барысын да кооперацияләштерү; берникадәр күләмдә тагын да кооперацияләштерү

**Кооперацияләштереп алу** Берникадәр вакытка гына кооперацияләштерү

**Кооперацияләштереп бетерү** Барысын да кооперацияләштерү; кооперацияләштерүне тәмамлау

**Кооперацияләштереп тору** Хәзерге вакытта кооперацияләштерү

**КООПЕРАЦИЯЛӘШҮ** *ф.* Кооперация нигезендә берләшү

**Кооперацияләшә бару** Акрынлап барысы да кооперацияләшү; берникадәр күләмдә тагын да кооперацияләшү

**Кооперацияләшә төшү** Билгеле бер күләмдә генә кооперацияләшү

**Кооперацияләшеп алу** Берникадәр вакытка гына кооперацияләшү

**Кооперацияләшеп бетү** Барысы да кооперацияләшү; кооперацияләшү тәмамлану

**КООПТА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Яңа сайлаулар үткәрмичә, нинди дә булса сайланып куелган органны яңа эшчеләр белән тулыландыру

**КООПТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Кооптация үткәрү. *Күп тә узмады, РСДРПның кооптацияләү юлы белән торгызылган һәм тулыландырылган яңа комитеты эшли башлады.* А.Расих

**Кооптацияләп алу** Тиз арада кооптацияләү

**Кооптацияләп бару** Һәр очракта һаман кооптацияләү

**Кооптацияләп тору** Даими яки әледән-әле кооптацияләү

**КООРДИНАТ** *и. лат.* 1) *мат.* Ноктаның урынын белдерә торган зурлык

2) *геогр.* Ноктаның яссылыкта яки киңлектәге торышын билгели торган зурлык. *Сәяхәт башлыгы, берни дәшмәстән, ягулыкның күпме калганын һәм ракетаның координатларын күрсәтә торган автоматны эшкә кушты.* А.Тимергалин. *Сез безгә заводыгызның төгәл координатын эшләп бирегез. Бүген кич үк безнең егетләр барып бомбага тотарлар.* Г.Гобәй

3) *сөйл.* Кемнең дә булса урнашкан, торган урыны турында мәгълүмат

**КООРДИНА́ТА** *и. лат. к.* **координат**. *Ике үзгәрешле тигезләмәнең графигы дип, координаталары тигезләмәне дөрес тигезлеккә әйләндерүче координата яссылыгының нокталары күплеге атала.* Алгебра

**КООРДИНАЦИОН** *с.* Координациягә караган, шуңа бәйләнешле. *Координацион бәйләнешләр*

**КООРДИНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Билгеле координатлары буенча берәр ноктаның, төбәкнең һ.б. урынын билгеләү күренеше

2) Ярашканлык, килешкәнлек. *Хәрәкәтләр координациясе*

3) *күч.* Танышу-белешү

**КООРДИНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Нинди дә булса күренеш, хәрәкәтләрне яраклаштыру, килештерү. --- *СССР Фәннәр академиясенең союздаш республикаларның академияләре эшчәнлеген координацияләү комиссиясенең җаваплы секретаре Николай Пшерков ---.* Мирас

**Координацияләп алу** Берникадәр вакыт координацияләү

**Координацияләп тору** Даими координацияләү

**КООРДИНА́ЦИЯЛЕ** *с.* 1) Координация белән бәйле

2) Координациягә хас, координациягә караган

**КОПАЛ** *и. мекс. махс.* Лак җитештерүдә кулланыла торган бик каты табигый казылма сумала

**КОПЁР** *и. нем. махс.* 1) Җиргә субай кагып кертү өчен махсус механик җайланма. *Дамбадан бик аз вакытка гына төзелештәге пар копёрының челтәрле башнясы һәм биек эстакаданың бер өлеше күренеп алды.* Г.Әпсәләмов. *Копёр да, дизель чүкеч тә суднолар килеп туктаячак корыч стенаны төзү белән китерелгәннәр.* Г.Әпсәләмов

2) Шахта өстендә күтәргеч урнаштыру өчен юнәлтелгән махсус техник корылма

**КОПИ́ЛКА** *и. рус сөйл.* Акча җыю, саклау өчен, тар авызлы бикләнә торган тартма, савыт һ.б.ш. *[Кошчыклар] үзләре кечкенә, авызлары зур. [Бөҗәкләрнең] чыккан бере, копилкага салган көмеш акча кебек, төшә дә китә.* Г.Гобәй

**КОПИРАЙТ** *и. ингл.* 1) Авторлык хокукы. *Яңа китабыңны бастыру өчен копирайт алу*

2) Шул хокукны белдерә торган махсус билге (©)

**КОПИ́РКА** *и. рус сөйл. к.* **копировка**

**КОПИРО́ВКА** *и. рус сөйл.* Язу, сызым кебек нәрсәләрнең күчермәсен алу, төшерү өчен кулланыла торган махсус кәгазь

**КО́ПИЯ** *и. нем. сөйл. к.* **күчермә**. *Язышкан булсагыз, сездә аның копиясе булырга кирәк.* А.Шамов. *Бу протоколдан Камали агай копия алдырып... мөфти хәзрәткә җибәргән, диләр.* Ш.Мөхәммәдев. *Ул шөбһәсез авыл бае малае Гали уйнаган рольнең копиясен диярлек уйнаган булыр иде.* Г.Нигъмәти. *Кирәк бит, охшаса да охшый икән кеше кешегә: Әминәнең коеп куйган копиясе.* Т.Миңнуллин

**КО́П-КОРЫ** *с. артык. дәр. к.* **коры**; бик тә коры. *Яз җиткән булуга карамастан иртәнге суыкта аяк асты коп-коры, айгыр җилдертә, аягы җиргә тияр-тимәс оча.* И.Гази. *Үлә язып су эчәсе килә, иреннәр коп-коры.* Ә.Маликов

**КО́ПРА** *и. малаял.* Кокос чикләвегенең кокос мае алына торган төше. *Копра җитештерүдә Яңа Гвинея... алда тора.* Чит илләрнең экономик географиясе

**КОПШАҢГЫ** *и. диал.* 1) *зоол.* Тирестә яшәп, тизәк белән туенучы ялтыравык яшел хитинлы зур коңгыз; тирес коңгызы, гуңгыйк; *русчасы:* **жук-навозник**. *Копшаңгы: – Хуш, сау булыгыз, мин Һиндстанга киттем, – дип очкан икән дә, тик юлда ат тизәге күргәч, шунда кунып калган, имеш.* Мәкаль. *Копшаңгы юлда йөрсә, аяз булыр.* Сынамыш

2) *күч.* Орышу, ачулану, кимсетү сүзләре буларак кулланыла. *[Алмаз Эсмеральдага:] Җитәр! Туктыйсыңмы, юкмы син, копшаңгы!* Н.Исәнбәт

**КОПЫ** *и. к.* **копы бүрек**

**КОПЫ БҮРЕК** *и.* Колакчынсыз бүрекнең бер төре; очлы киң бүрек

**КОР** I *и.* 1) *иск.* Чак, вакыт

2) Даирә, мохит, төркем

**КОР** II *и. зоол.* Суерның бер төре

**КОРАБ** *и. к.* **корабль**. *Диңгезне ерып, кораб һаман алга бара.* А.Алиш. *Баш очыннан һава кораблары Тасма сузып китә еракка.* Г.Афзал

**КОРАБЛЬ** *и. фр.* 1) Зур диңгез судносы. *Ул ерак Боз диңгезендә зур-зур корабльләр йөртә.* Д.Аппакова. *Менә монда, безнең Яңа бистә янында, зур порт, корабльләр, күрәсеңме әнә...* Р.Ишморат

2) Зур куәтле очу аппараты. *Галәм киңлекләрен айкап, кеше аягы басмаган планеталар эзләп йөрүче нинди корабль, нинди кешеләр соң болар? --- Бу корабль галәм пиратларыныкы.* Р.Мөхәммәдиев

3) *күч.* Гомумән, куәтле, зур машина, транспорт. *Комбайн – басу корабле*

4) *күч.* Нинди дә булса зур эшчәнлек өлкәсе, зур оешма. *Академик Мансур Хәсәнов – фән корабле капитаны.* Мирас

**КОРАК** *и.* 1) Утын итеп файдаланыла торган коры үлән сабагы (алабута, тигәнәк һ.б.ш. сабаклары)

2) *бот.* Юан, куыш сабаклы, киң яфраклы үлән. *Корама җыеп ил иткән, корак җыеп көн иткән.* Мәкаль

3) *а.х.* Мамык үсемлегенең мамыгы алынгач калган буш кузагы

**КОРАЛ** *и.* 1) Һөҗүм итү һәм саклану өчен кулланыла торган махсус әйбер, җайланма. *Ниһаять, ир уртасы булып җиткәндә килде шундый вакыт: ул зур уллары белән бергә, кулына корал алып, Бөек Ватан сугышына китте.* Г.Бәширов. *Сабир абзый тынсыз тора. --- – Менә үз кешеңне фашистлар үтергәнне шулай карап тор әле син! Ә бит бездә корал, граната.*

М.Мәһдиев. *[Сөембикә:] Аларның яңа кораллары бар, чит илдән китерткән көчле туплары бар, дарылары, кургашлары җитәрлек.* Г.Гыйльманов

2) Кемнең дә булса хәрби көче, гаскәре турында. *Рус коралының һәм рухының бөеклеген пропагандаларга тырышучы рус елъязмачылары үзләре дә Мәскәүнең олы кенәзләре белән сугышта татарларның куркусызлыгына сокланырга мәҗбүр булганнар.* Р.Фәхретдинов. *Биредә, Идел ярлары буенда, Германия коралының 1939–1941 еллардагы җиңү даны чәлпәрәмә килә.* Шәһри Казан

3) Нинди дә булса шөгыль, эш вакытында кулланыла торган җайланма, инструмент. *Неандертальләр – беренче аучылар; тупас һәм бик гади хезмәт кораллары – чапкычлар, кыргычлар, таш пычаклар белән эш иткәннәр ---* Р.Фәхретдинов. *Георгий плитә белән ике арада әйләнде: эш коралларын кайнатты, урын-җиргә дезинфекция ясады.* И.Салахов. *[Ясәви] Кабаланмый гына эш коралларын барлар, үз дәрәҗәсен белеп кенә фатирдан фатирга йөрер.* Ә.Дусайлы

4) Көй чыгару, башкару өчен эшләнгән махсус инструмент. *Хрусталь чыңы, электр-музыка коралларының космик моңы, кошлар сайравы бергә кушылып, әкияти гүзәл яңгыраш алалар.* Р.Харис. *Кубыз... Уйлап карасаң, халык бу уен коралын табигатьтән күчереп ясаган икән.* М.Хуҗин. *--- Гарәп, фарсы, төрек телләре. Бу телләр аңа музыка коралларының җанлы авазлары булып ишетелделәр.* А.Нәҗми

5) *күч.* Гомумән, нинди дә булса куркыныч янаганда зыян салучыдан саклану чарасы буларак кулланыла торган әйбер. *Учындагы отвёртканы бар көченә кысып, ул [Җәүһәрия] һөҗүмгә әзерләнде. --- Юк! Ул җиңел генә бирелмәячәк! Учындагы коралын эшкә җигәр, тырнар, тешләр, өзгәләр... Әмма бирелмәс!* Г.Әдһәм

6) *күч.* Нәрсәгә дә булса ирешү алымы, чарасы. *Анам биргән туган тел, Атам биргән корал тел.* Мәкаль. *Юма тел белән куштанлык аны --- бал-май эчендә йөздерде. Сәйфи күп тапкырлар сыналган бу коралны хәзер тагын бер мәртәбә эшкә җигеп карамакчы булды.* Г.Бәширов. *Бу «политик акция» барып чыккан тәкъдирдә, фашистлар халыкны партизаннарга каршы кую өчен үтемле «пропаганда коралы» алачаклар...* Мирас

◊ **Коралга тотыну** Корал белән көрәшкә күтәрелү, кораллану. *[Пётр Алексеевич:] Ох, әфәнделәр, мондагы халык бик кара һәм кыргый. Алар арасында халык санын алуны оештыру һич мөмкин эш түгел. Бу турыда хәбәр чыгуга ук, барча ир-ат коралга тотыначак ---.* В.Имамов. *– Мин синнән төгәл сан сорыйм – син калтырап төшәсең. Мин борылып синең йөзеңә карыйм – син коралга тотынасың, – диде Албуга шелтә белән.* Н.Фәттах. **Коралга ябышу** *к.* **коралга тотыну**. *[Сәет:] Ниятегез янә мөселманнар каны коюда идеме, әфәнделәр? --- Барып чыкмас! ---. Хөррият хакына без коралга ябыштык.* В.Имамов. *Халык ярсуыннан коралга ябышкан. Кораллы халык, акча даулап, кораллы буржуйлар белән атышкан!* М.Шаһимәрдәнов. **Корал итү** Кем яки нәрсәне дә булса билгеле бер максатта файдалану. *Һиммәтең итсәң корал, Шөбһәсез галиб булырсың.* М.Гафури. **Корал (көче) белән** Көч кулланып, хәрби көч, сугыш көче белән. *Ярты-йорты белемле, хакимияткә корал көче белән килгән канкойгыч большевиклар Русия белән «җитәкчелек» итә башлыйлар.* З.Зәйнуллин. *Ә бит корал көче ярдәмендә кылынган каһарманлык табигый дип саналганда, кеше күңелендә ясалган батырлыкны төрлечә кабул итүчеләр дә юк түгел.* Мирас. **Корал күтәрү** 1) Корал белән янау, куркыту, һөҗүм итү. *[Исәнтәй:] Син... кунак... Минем өемдә, минем ашымны ашап, миңа каршы корал күтәрәсеңмени?!* Н.Фәттах; 2) Баш күтәрү, корал тотып көрәшкә күтәрелү, сугыш башлау. *[Сәхипгәрәй:] Әфәнделәр, әгәр дә Хәрби шура председателен 24 сәгать эчендә азат итмиләр икән, без коралга ябышырга мәҗбүр булачакбыз. [Барысы:] Корал күтәрергә кирәк...* К.Тинчурин. *Әмма шулчак артта Күчем батырның усал әмере яңгырады: – Корал күтәрәсе булмагыз, кылычларыгызны кынга!* В.Имамов. **Корал ташлау** 1) Корал тотып каршылык күрсәтүне, сугыш хәрәкәтләрен туктату. *Дөресрәге, сөннәр аны [Банлу Чжаоны] камап алдылар һәм корал ташлап кул күтәрергә мәҗбүр иттеләр.* Н.Фәттах. *Минск янында уратып алынган кызыл гаскәрләр, каршылык күрсәтмичә, коралларын ташлап, немецларга әсирлеккә биреләләр.* З.Зәйнуллин. *Кайсыдыр бер яралының: «Хыянәт!» – дип иләмсез ачыргаланып кычкыруы булды, әле генә стена һәм капка тирәсендә йөргән сакчылар, коралларын ташлап, урам буйлап йөгерешә-кача башлады.* В.Имамов; 2) Кискен ризасызлык белдерү йөзеннән коралсызлану. *[Һөҗүмгә] көчләп җибәрә башласалар, һичбер атышсызнисез, бөтен часть белән корал ташларга кирәк.* М.Гали

**КОРАЛ ЙӨРТҮЧЕ** *и. тар.* Урта гасырларда: алыпның хәрби коралларын йөртүче яшь гаскәри; кучты

**КОРАЛАЙ** *и.* 1) Кыр кәҗәсе; *русчасы*: **косуля**. *Атның киеге – колан, кәҗәнең киеге – коралай.* Мәкаль. *Тулы айдай нур йөзле, Коралайдай саф күзле, Шикәр, балдай сүзле Күзекәдәй сылу кыз – Я синеке, я минеке!* Дастан

2) Искечә ай исеме (ноябрь-декабрь урталарына туры килә). *Коралай килми – кыш җитми, коралай китми – яз җитми.* Сынамыш

**КОРАЛДАШ** *и.* **1.** 1) Сугыш кырында кем белән дә булса бергә булган, солдатта бергә хезмәт иткән кеше, хәрби хезмәттәш. *Коралдашларым горнизонга кайтып кергәндә, поэмам төгәлләнгән, аны инде Казанга җибәрергә дә өлгергән идем...* Ә.Маликов. *Коралдашлар яу кырында! Кайда соң мин? Кем мин сиңа, ятиммени? Әйт, Туган ил!* Р.Саттар. *[Батыр командирның] --- коралдашларын гына түгел, илбасарларны да шаккаттырган рухи батырлык күрсәтүен аңларбыз.* Мирас

2) Сугышчының иң якын ярдәмчесе. *Җыр – яугирнең тугры юлдашы да, коралдашы да, киңәшчесе дә.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* Сугыш кырында кем белән дә булса бергә булган, солдатта бергә хезмәт иткән яки итүче. *[Воен-*

*ком:] Бу – мәңге төзәлмәс яра: безнең сугышта башларын салган коралдаш дусларыбыз.* Ф.Хөсни

**КОРАЛДАШЛЫК** *и.* Коралдаш булу. *Һәммәбезне бергә кушты Коралдашлык, сафташлык, Бу җиңүгә сез дә, дуслар, Һәммәгез дә катнашты.* Ә.Фәйзи

**КОРАЛЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Кораллар, сугыш өчен кирәк булган хәрби кирәк-ярак, дирбияләр белән тәэмин итү

2) Нинди дә булса эшчәнлек, хезмәт төре өчен кирәк булган корал, җайланма, дирбияләр белән тәэмин итү. *Ярый әле яңа хуҗалар басу-кырларга, фермасына-башкасына ышанычлы сакчылар куйды, аларны баштанаяк коралландырып, яхшы машиналарга утыртты.* Ф.Яхин. *Казанда да, махсуслаштырылган техника белән коралландырып, 10–15 кешелек бригада оештырырга була лабаса!* Шәһри Казан

3) *күч.* Төрле белем, мәгълүмат белән таныштыру, үзләштерүне тәэмин итү. *Имеш, без дә курс бетереп, студент булып чыкканбыз. Имеш, безне дә мәгыйшәт берлән көрәшергә коралландырып чыгарганнар!* Г.Тукай

**Коралландыра бару** Акрынлап барысын да коралландыру

**Коралландыра башлау** Коралландырырга тотыну. *Инде бераздан Тукай үзе дә аны яңа идеяләр белән коралландыра башлый һәм бик зур рухи терәгенә әверелә.* Р.Рахман

**Коралландыра төшү** Берникадәр күләмдә тагын да коралландыру

**Коралландырып алу** Азга гына коралландыру

**Коралландырып бетерү** Барысын да коралландыру; коралландыруны тәмамлау

**Коралландырып тору** Даими яки әледән-әле коралландыру; әле, хәзерге вакытта коралландыру

**КОРАЛЛАНУ** *ф.* 1) Корал, хәрби кирәк-ярак, дирбияләр белән тәэмин ителү. *Ныгытма төзү, кораллану урынына рязанлыларның бала-чага шикелле икона белән азапланулары минем ачуымны китерә иде.* М.Юныс. *Сөнчә киенгән, сөнчә коралланган егермеләп ирнең барысы да атларыннан төшеп, җәяүләп, шулай ук кунаклар каршысына килделәр ---.* Н.Фәттах. *[Ураков:] Минем кул астында баштанаяк коралланган ике мең кешелек көчне бастырырлык гаскәр юк.* В.Имамов

2) Һөҗүм итү яки саклану өчен кулга корал алу, корал булдыру. *Тимерчыбык катып үрелгән камчылар белән коралланган егерме биш атлы кеше өчен җәяүле җиде бәндәне җиңү бәрәңге ашаудан да җиңел иде, билгеле.* М.Галәү. *Авылдашлар, кем ни эләктерә ала, шуның белән коралланганнар иде.* З.Хәким. *Каяндыр бер солдат йөгереп чыкты да мылтыклар, сөңгеләр белән коралланган бик күп җегетләр янына килеп кычкырды: «Ура, ура, иптәшләр! Без җиңдек!..»* Г.Ибраһимов

3) Өндәп, боерып көрәшкә чакырганда, кулга корал алып көрәшкә чыгу, күтәрелү. *...Шулай, эшчем, кораллан, бар сугышка.* М.Җәлил

4) Билгеле бер эшчәнлек, хезмәт төре өчен кирәк булган корал, җайланма, дирбияләр белән тәэмин ителү. *--- диктофон, блокнот һәм каләм белән коралланып, җыелган бер кочак сорауларым белән, Әбүзәр әфәндене эзләп, Чирмешән кулланучылар җәмгыятенә юл тоттым.* Шәһри Казан

5) Нинди дә булса эшчәнлек, хезмәт төре башкару өчен кулга эш коралы алу. *--- көрәк, кыргычлар белән коралланып, трамвай, автобус юлларына сибелгән эшчеләре --- кечкенә шәһәрчеккә ниндидер бер мөһимлек төсмере кертәләр иде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

6) *күч.* Төрле белем, мәгълүматлар белән танышу, аларны үзләштерү. *Бәлки, ул [Гатауллин] яшьлектәге юләрлеккә хас беркатлылык белән агымга каршы йөзгәндәге кебек, килешмәүчәнлек белән коралланып, шул ялган табигыйлекне кабул итәргә генә теләмидер?* Ф.Яхин. *--- Алиш иптәш байтак кына тәҗрибәләр аркасында балалар телен нык кына үзләштерсә дә, ул әле балалар әдәбиятын специфик сюжетлаштыру белән йомшак коралланган.* Ф.Кәрим. *Милли азатлык идеясе белән коралланган яшьләр бүген мең, иртәгә миллион булса...* Р.Рахман

7) *күч. шаярт.* Билгеле бер максат белән (каршы якны куркыту, шаярту һ.б.ш.) алдан ук берәр чара булдырып, әзерләп кую. *Фәниянең сабыр канаты сынды. Тәүфикъның чираттагы оҗмахыннан әйләнеп кайтуын ул чынлап та ишек төбендә уклау һәм саплы таба белән коралланып каршы алды.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Кораллана бару** Акрынлап тулысынча кораллану. *Колхоз техника белән дә кораллана барган.* Гасырлар авазы

**Кораллана башлау** Коралланырга керешү. *Китә хәзерлек: балталар, кендекләр, герләр белән кораллана башлыйлар ---.* Ә.Фәйзи

**Кораллана төшү** Тагын берникадәр, аз гына күләмдә булса да кораллану

**Коралланып алу** Тиз генә кораллану. *Печән базарындагы төрле вакыйгалар һәм кызыкларга хирыс әһле ислам, мәсьәләнең үзәген бик тиз аңлап, таяк, таш, сыңар кәвеш шикелле нәрсәләр белән бик тиз арада коралланып алып, күсегә каршы чыктылар.* К.Тинчурин

**Коралланып бетү** Тәмам бик нык кораллану; кораллану тәмамлану

**Коралланып йөрү** Коралланган булу. *[Мортаза бай:] Хәзер һәркем яхшы коралланып йөри...* М.Галәү

**Коралланып тору** Хәзер коралланган булу; даими яки әледән-әле кораллану

**Коралланып яту** *сөйл.* Кораллану процессында булу. *Янәсе, Татарстан – сепаратизм, ваһһабизм, терроризм үзәге, меңләгән кеше урманнарда коралланып ята, дип гәзитләрдә язалар, телевизордан, радиодан сөйлиләр.* Мәдәни җомга

**КОРАЛЛЫ** *с.* 1) Коралы булган, коралланган. *Җәбер күрдем гүзәл алдакчылардан, Золым күрдем кораллы сакчылардан.* Г.Утыз Имәни. *Атасы аңа быел беренче тапкыр ышанып эш йөкләде: кыш көне ул, этләр җигеп, кораллы йөз ир белән, илле йөк мал белән төн кешеләренә сату-алуга барды.* Н.Фәттах. *Ташка баштанаяк дикъкать биреп караганнан соң, гасырлар сулышын кичергән рәсемнең кораллы сугышчы икәнен ачыклады ---.* Мирас

2) Кулга корал алып, корал тотып башкарыла торган; сугыш-бәрелеш белән үтә торган. *Кичә Мисырда хәрбиләр белән кораллы бәрелеш нәтиҗәсендә «Братья мусульмане» төркеменең 42 тарафдары һәлак булган ---.* Ватаным Татарстан

**КОРАЛЛЫ КӨЧЛӘР** *и.* Армия, гаскәр. *Русия Кораллы көчләрен эшче-крестьян армиясе дип йөртә башладылар.* Н.Вахитов

**КОРАЛСЫЗ** *с.* **1.** Кораллanмаган, коралы булмаган. *Болын уртасында түгәрәкләнеп тезелеп утырган йөзләрчә ак өйләр арасында кораллы, коралсыз кешеләр кайнашты.* Н.Фәттах. *--- [карт учитель] коралсыз халыкны атлы казаклар кургаш ядрә һәм сөңге белән каршы алуларын --- дулкынланып сөйләп бирде.* Ә.Фәйзи

**2.** *рәв. мәгъ.* Коралдан башка. *Үз хокукларыбызны коралсыз яулап алу буенча мөхтәрәм Махатма Ганди тәгълиматы үрнәк була ала.* И.Әмирхан

**КОРАЛСЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Коралсыз калдыру, көч белән кемнең дә булса коралын ташлату, алу. *[Разведка начальнигы:] Безнең союзниклар – Англия һәм Америка – --- Тын океандагы уртак дошманны баштанаяк тар-мар итү, коралсызландыру өчен булышлык сорап, совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать иттеләр.* Ә.Маликов. *--- дистәгә якын сугышчы дакоталарны чолгап алдылар, шаулаша-шаулаша коралсызландырдылар, барысын да агач кәүсәләренә бәйләп куйдылар.* И.Хуҗин. *Ямгырчы би шулай ук яр астындагы акбүреләрне дә коралсызландырды, каекларны, кешеләрне сак астына алды.* Н.Фәттах

2) Кемнең дә булса коралланy мөмкинлекләрен киметү, кыскарту; бөтенләй коралсыз калдыру. *Ә кызыллар Каретник дивизиясен коралсызландыра алмыйлар.* З.Зәйнуллин

3) Кемнең, нәрсәнең дә булса карамагындагы коралларны алып кую, коралланy чараларыннан мәхрүм итү

4) *күч.* Кемнеңдер көрәшкә булган омтылышын юкка чыгару, нәрсә өчен дә булса көрәшү мөмкинлеген бетерү

5) *күч.* Кемнеңдер нәрсәгә дә булса каршы тору теләген бетерү. *Мин һаман баш тартам. «Әгәр дә без сезгә аспирантурада укырга тәкъдим итсәк?» – ди. Шушы сүзләре белән коралсызландырды ул мине, чөнки, чыннан да, укуымны дәвам итәсем килә иде.* М.Мәхмүтов

**Коралсызландыра бару** Акрынлап коралсызландыру

**Коралсызландыра башлау** Коралсызландырырга керешү

**Коралсызландыра төшү** Тагын берникадәр, аз гына күләмдә булса да коралсызландыру

**Коралсызландырып бетерү** Бөтенләй коралсызландыру; коралсызландыруны тәмамлау

**Коралсызландырып тору** Хәзерге вакытта коралсызландыру; даими яки әледән-әле коралсызландыру

**КОРАЛСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Коралсыз калу, коралдан мәхрүм булу. *Армияне реформалау инде 20 елдан артык дәвам итә, һәм аның очы-кырые әле һаман күренми. Бу чорда ул, бер кат коралсызланып, инде яңадан кораллана башлады.* Мәдәни җомга

2) Хәрби коралны кая да булса тапшыру, ташлау (шул рәвешле хәрби көч кулланудан, нинди дә булса каршылык күрсәтүдән һ.б.ш. баш тарту)

3) *күч.* Билгеле бер эш-хәрәкәт өчен кирәкле идея, ярдәм һ.б.ш.дан мәхрүм калу

**Коралсызлана бару** Акрынлап коралсызлану

**Коралсызлана төшү** Тагын берникадәр коралсызлану

**Коралсызланып бетү** Тәмам бик нык коралсызлану; коралсызлану тәмамлану

**КОРАЛСЫЗЛЫК** *и.* Коралсыз булу, коралдан мәхрүм ителгән булу

**КОРАЛЧЫ** *и.* Корал ясаучы эшче, оста. *Кремль тавының ышыгында, Болак елгасы буенда күнчеләр бистәсе булган. Ерак түгел генә тимерчеләр, чүлмәкчеләр, коралчылар һәм башка төрле һөнәр ияләре яши торган бистәләр тезелеп киткән.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Бу эш [җир эшләре] өчен Мәскәү белән Новгородтан тимерчеләр, Вологдадан балта осталары, Туладан коралчылар, ә Казаннан штукатурчылар китергәннәр.* Ватаным Татарстан

**КОРАЛ-ЯРАК** *җый. и.* Һәртөрле сугыш кораллары. *Бу, чынлап та, коралярак төзәтүче оста, җор сүзле Ваня Рябчиков иде.* Казан утлары

**КОРАМА** *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса (тукыма, тире һ.б.ш.) файдаланудан артып калган кисентек, вак кисәк. *Корама җыеп ил иткән, корак җыеп көн иткән.* Мәкаль. *[Габдулланың] Өстендә яшел хәтфә кырыйлы җиңсез камзул, башында төрле төстәге корамалардан тегелгән чуклы кәләпүш.* Г.Гыйззәтуллина

2) Шундый кисентекләрдән тегелгән япма, җәймә. *Хәсри карчык сандык өстенә җәелгән кораманы алып дүрткә бөкләде.* Г.Гали

3) *сир.* Калдык-постык, вак-төяк материалдан ясалган, зур булмаган корылма (өй, киоск, ларёк). *Иудәйдәге консул Агриппа --- храм диварларыннан да биегрәк итеп корама күтәрттерә һәм шуннан торып храмда барган хәлләрне күзәтергә тели.* М.Хәбибуллин

4) *күч.* Эчтәлеге ярлы булып, аннан-моннан гына иҗат ителгән әсәр. *Галиәхмәтнең шигырьләрен мин сокланып укыдым. Соңгы вакытта татар шигърияtendә коры информациягә, хәбәргә корылган шигъри корамалардан арыдым.* Мирас. *--- тавышка иярүләр аркасында мәгънәсез сүз корамаларыннан торган табышмаклар да очрый: «Лып-лып ихыл, шрихыл да шрифыл...»* Н.Исәнбәт

**2.** *с. мәгъ.* 1) Артып калган вак кисәкләрдән эшләнгән. *Һәр кеше үзенә тигән җиргә берничә таяклап бүлепбүлеп чәчелгәнлектән, иген басулары нәкъ корама юрган шәкелен алып торалар.* М.Фәйзи. *Карый түргә менеп, төрле чүпрәк кисәкләреннән җыеп тегелгән корама көрпә өстенә утырды.* М.Галәү. *Мөтәч Хәмитенең Бикәсе дә корама юрганга төрелгән имчәк баласын күкрәгенә кыскан килеш арба янәшәсеннән атлый ---.* З.Зәйнуллин

2) *күч.* Иске. *Ишегалдына аяк бастык. Мин корама машинамны кабызып җибәрдем.* М.Шаһимәрданов

3) *күч.* Таркау, берләшмәгән. *III меңьеллыкта Россия әүвәлге куәтенә ябышып ятучы корама империя булыр микән, әллә --- көчле федератив дәүләт булыр микән – бусы тулысынча тарих сабакларын ни дәрәҗәдә үзләштерүгә бәйле.* Мирас

4) *күч.* Алынма сүзләр, чит тел элементлары белән чуарланган (телнең саф булмавына ишарә итеп әйтелә). *Корама телдәге шигырьләре күренгәләсә дә, --- Тукай хәзер, нигездә, саф татар телендә яза башлый.* И.Нуруллин. *– Инде мондый проект ошамаса, Гаспралы теле сезгә артык корама тоелса, – дидем мин, – татар теле бар, сезгә мәгълүмдер, ЮНЕСКО тарафыннан ул дөньядагы ундүрт тел арасына кергән.* Р.Зәйдулла. *Чуар, корама телле вәкил артыннан хурлап-мыскыллап кычкырдылар, әче-әче итеп сызгырдылар...* М.Шаһимәрдәнов

**КОРАМАЛА́У** *ф.* 1) Корамаларны (*1 мәгъ.*) үзара ялгап тегү. **---** *башымда да мине Өчилегә кире йибәрер алдыннан әнинең, миңа сагынмалык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.* Г.Тукай

2) Аннан-моннан гына вак-төякләрдән оештырып ясау. *Акбурлы такталардан гына корамаланган вакытлы вокзал бүген бигрәк тә иләмсез күренә иде.* Ш.Маннур

3) Корама (*2 мәгъ.*) белән ябып кую

4) *күч.* Тупаслану, алынма сүзләр, чит тел элементлары белән чуарлану (тел тур.). *Теле корамаланган, аны сафландырырлык авылы бетүгә йөз тоткан әдәбият турында фаразларга да куркам.* Шәһри Казан

5) *диал.* Каплап, ябып, әйләндереп алу. *Бу материаллардан теккән һәр нәрсә – төрле каплар, киез паласлар, ат япмалары да кун өстенә шакмаклап, я өчпочмаклап, яки бүтәнчә бизәкләр белән корамаланган.* Мәдәни җомга

**Корамалап бару** Акрынлап барысын да корамалау

**Корамалап бетерү** Барысын да корамалау; корамалауны төгәлләү

**Корамалап кую** Корамаланган итү. *Димка ак киндер белән корамалап куелган куыш янына йөгерде.* Н.Фәттах

**Корамалап тору** Хәзер корамалау; даими яки әледән-әле корамалау

**Корамалый бару** Акрынлап барысын да корамалау

**КОРАМАЛЫ** *с.* 1) Корамалардан эшләнгән. *Агач сандык өстендә сәләмәләнгән корамалы юрган.* А.Алиш. *--- кул тегермәннәре һәм чабаталар, талканнар һәм корамалы юрганнар һәрдаим камиллеккә, иркенлеккә, яктыга омтылучы халыкларның символы була алмый.* Кызыл таң

2) *күч.* Таркау, берләшмәгән

**КОРАМАЛЫК** *и.* 1) Тукымадан кием-салым теккәндә киселгән, соңыннан корама тегәргә яраклы кисәкләр; кыенты

2) *күч.* Мәгънәсезлек, бернинди мәгънә белдермәүчәнлек. *Сәнгать үзенчәлекләренә килгәндә, табышмакларда --- тавышка иярүләр, корамалык, аллитерация һәм башкаларның тоткан урыннарын күрсәтергә була.* Н.Исәнбәт

**КОРАМТА** *и. диал.* Ат җигү дирбиясе. *Фазлый складтан Тимеркүкнең [атның] яхшы корамталарын чыгарды.* Х.Госман

**КОРАН** *и. диал.* Козгынның кечерәк төре; дала козгыны, кара козгын

**КОРА́У** *ф. диал. к.* **корамалау**. *Корап сырган иске юрган төсле Чуарланган дөнья картасы.* Н.Арсланов

**КОРАШТЫРУ** *ф. сөйл. к.* **корамалау** (*1, 2 мәгъ.*). *Уңышсыз әсәрләрем бардыр, тик берсе дә халтура өчен язылмады. Югыйсә, тагын мактанам, пьеса кораштыру миңа бик җиңел.* Т.Миңнуллин. *Безнең йортлардан – мәктәп, сарайларыбыздан колхоз келәтләрен, ат сарайларын кораштырып, колхоз ясадылар.* А.Хәлим

**Кораштыра бару** Акрынлап барысын да кораштыру

**Кораштырып алу** Тиз генә кораштыру

**Кораштырып бетерү** Барысын да кораштыру; гомумән, тәмам кораштыру

**Кораштырып тору** Хәзерге вакытта кораштыру; даими яки әледән-әле кораштыру

**Кораштырып яту** Әле кораштыру

**КОРАЧ** *с. диал.* Су җыелмый торган, калкурак. *Авыл урамнарының корач битләренә яшелле-кызыллы каз үләне тибә башлаган.* К.Тинчурин

**КОРБАН** I *и. гар.* 1) Илаһ буларак кабул ителгән яки илаһи көченә ышанылган бер барлыкка багышлап суела торган хайван. *Корбанга чалынган хайваннар – иң бәхетле хайваннар алар ---.* Ф.Әмирхан. *Байлар нәфел корбаны дип бер сарык чалдылар.* Ә.Фәйзи. *Хәзер бөтен тирә-яктан корбаннар суеп, нәзер, садакалар биреп, каберен зиярәт итәләр...* Ш.Камал

2) Кемнең дә булса аерым бер теләкләрен канәгатьләндерү максаты белән үләргә, газапланырга һ.б. нинди дә булса җәза-җәбер күрергә тиешле җан иясе. *Митричев, атып егачак иң беренче корбанын эзләгәндәй, зәһәрләнеп ялтыраган күзләрен кыскан килеш, тешләрен шыкырдатып, пулемётның көпшәсен уңнан сулга, аннары сулдан уңга боргалый башлады.* Г.Бәширов. *Теге куян үзеннән көчлерәкләрне сөзәргә теләсә, буйвол мөгезе белән сөзә алмый, корбаннарын куып тотарга уйласа, антилопа аякларын күтәреп йөгерә алмый.* Чаян

3) Аерым бер бәхетсезлек яки афәт, сугыш аркасында җәбер-газап күргән яисә һәлак булган кеше. *Комсыз Сивашка озакламыйча тагын бер корбан бирергә туры килде.* Г.Бәширов. *[Гөләндәм:] Иргә чыгу белән табигый таләпләргә баш ияргә, гаилә төзелешенең корбаны булырга туры килә.* Т.Гыйззәт. *Шаһтимер булсаң – бик куанып, башка берәү булсаң, аңа булган мәхәббәтемне корбан итеп, мин сиңа булам.* М.Фәйзи. *Мал, җир өчен мең-мең җаннар корбан була...* Г.Камал

4) Кемнең яки нәрсәнең дә булса файдасы яисә башкалар бәхете өчен шәхси мәнфәгатьләрдән ирекле рәвештә баш тарту, үз-үзеңне куркыныч, һәлакәт астына кую гамәле. *Ә бит кызыл балыклар сай тарлыкларга уылдык чәчү, нәсел калдыру өчен күтәрелә. Үзләре шунда корбан булалар.* Ә.Маликов

◊ **Корбан бирү** *к.* **корбан итү**. **Корбан булу** Билгеле бер иҗтимагый эш,

нинди дә булса идея өчен һәлак булу, үлү. *Башка милләт әһеленең Казан ханлыгының яшәргә тиешлегенә ышанып һәм фәнни дәлилләп язуы өчен корбан булуы, фаҗигасен сизенә торып та бу фидакярлеккә баруы – башкарак гамәл.* Т.Галиуллин. *Язучы Ш.Мостафинның эзләнү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, 104 татар язучысының 31 е корбан була.* Ф.Хәсәнова. **Корбан итү** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса файдасы, мәнфәгате өчен үзен кызганмау, үлем куркынычы астына кую, һәлак итү. *Сарайларын ташлап шагыйрь Байрон Җылы эзләп йөргән җанына, Җырларын һәм үзен корбан иткән Юнаннарның ирек давына.* Ш.Маннур. *Әгәр мөмкин була торган булса, мин менә шунда, синең әниеңне күрер өчен, үз җанымны корбан итәр идем.* Г.Гобәй. *--- хатыннар үзләрен корбан итеп булса да дөньяны коткарып калырга тиеш.* Р.Батулла; 2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса файдасы, мәнфәгате, хакы өчен нәрсәдән дә булса баш тарту, нәрсәне дә булса кызганмый сарыф итү. *Чөнки бу вакытта ул [Сәгадәт] инде үзен татар милләтенең киләчәге, аның чәчәк атуы өчен корбан итәргә әзер торган милләтпәрвәр кебек интеллектуаль югарылыкка күтәрелгән була.* Мирас; 3) Оттыру, бирү (уенда). **Корбан кылу** *к.* **корбан итү**. *Булдыра алса, бөтен дөньяны үз рәхәтенә корбан кылыр иде.* Г.Исхакый. **Корбан тәкәсе** Кемнеңдер гаепле эше, гамәле өчен җавап бирүче, җәза алучы зат. *Андрейның һәрдаим аңардан корбан тәкәсе ясавы әүвәле күпләргә ошаса, рәхәтлек бирсә дә, инде ахырга таба теңкәләренә дә тия башлады.* Ф.Яхин. *Дусларыгыз, хакимият башында утырсалар да, дилбегәне үз кулларында тота алмадылар, ике дә уйламый сезне корбан тәкәсе итәргә әзерләр.* Р.Мирхәйдәров

**КОРБАН** II *и. зоол. к.* **корбан балыгы**. *--- Димгә батырылган челтәр капчык эчендә агач көрәк киңлеге ике корбан ласпылдап ята иде...* М.Кәрим

**КОРБАН АЕ** *и.* Мөселман календаренда зөлхиҗҗә аеның халык телендәге атамасы (шул айда Корбан бәйрәме). *Китабыбыз Коръән Кәримдә --- Аллаһы Тәгаләнең: «Мин таң белән ант итәм. Мин ун төн белән ант итәм...» – дигән сүзләре бар. Галимнәр бу ун төн турында: «Зөлхиҗҗә, ягъни корбан аеның ун көнедер», – диләр.* Өмет

**КОРБАН БАЛЫГЫ** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан киң, яссы гәүдәле, төче суларда яши торган балык; *русчасы:* **лещ**. *Саплы агач соскыдан да озынрак алтын сары корбан балыгы үлән өстенә чыгып ятты.* М.Кәрим. *Уралтау елгаларында нинди генә балыкларны очратмыйбыз – чуртаны, алабугасы, кызылканаты, корбан балыгы, кызыл балык ---.* Ф.Бәйрәмова. *Азов диңгезе корбан балыгы (лещ) --- вак балыкларга бик бай.* Физик география

**КОРБАН БӘЙРӘМЕ** *и. дини* Ислам динендә зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә корбан чалып үткәрелә торган дини бәйрәм; Ураза бәйрәме белән беррәттән мөселманнарның иң зур бәйрәмнәре. *Бичырман керәшеннәр Корбан бәйрәмен дә, Ураза бәйрәмен дә тоталар, ураза тотмасалар да.* Ф.Баязитова. *Безнең бөтенебезне бергә җыеп, Корбан бәйрәменә сыер сатып алып, корбан чалырга дигән фикер иң беренче аның башына килде.* Идел

**КОРБАН ГАЕТЕ** *и. дини к.* **Корбан бәйрәме**. *Корбан гаете көнне Гөләнвәр Сәгъди абзыйларга керде һәм --- Габдулланы үзләренә алып чыгып китте.* Ә.Фәйзи. *Ураза аенда, корбан гаетләрендә Нәҗмине аштан калдырмыйлар.* Р.Батулла. *Хәтта төрмә надзирателенең аны дини бәйрәм – Корбан гаете белән котлавы да Муса әфәнденең күңелен тынычландыра алмый.* Мирас

**КОРБАНЛЫК** *и.* Корбанга I (*1 мәгъ.*) билгеләнгән мал. *Калган корбаннарның акчасы белем алучы шәкертләр яшәгән тулай торакларга --- җибәрелә. Бу акчага алынган корбанлыклар иясләре исеменә багышлап чалына.* Ватаным Татарстан

**КОРБАНСЫЗ** *с.* **1.** Корбаны булмаган. *Сугыш корбансыз булмый.* Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* Корбан бирмичә

**КОРГАК** *с.* **1.** 1) Корыган, кипкән, кибә торган. *...Тезләнеп ул коргак камышка Көн-төн яңгыр ялвара – Яумый, Күкләр баткан каргышка.* Кызыл таң

2) Коры, яңгырсыз. *Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коргак була.* Сынамыш

**2.** *и. мәгъ.* Коры һава. *Сабанчы яңгыр тели, юлаучы – коргак.* Мәкаль

**КОРГАКСУ** *ф.* 1) Кору, кибү, кипшенү. *Шунда ук янгын сарае, ат абзарлары, күгәргән кул насослары, коргаксыган мичкәләре...* А.Гыйләҗев. *Ничә еллар буе коргаксыдык. Җир хуҗасын сөрдек еракларга.* Зөлфәт. *Идән такталары коргаксыган. Шыгырдатмас өчен стена буеннан барам.* М.Юныс

2) *күч.* Ярлыланып, бушап калу. *Сугыш төтенне дә үлчәүгә салырга өйрәтте. Төтенгә коргаксыган шундый чакларда берәрсенә тәмәке посылкасы килсә, солдат семьясы өчен ул зур бәйрәмгә әйләнә.* Ә.Маликов

3) *күч.* Рухи ярлылану. *Минем дә коргаксу куркынычы яный башлаган татар җыры бакчасының бер генә түтәленә булса да су сибәсем, җырчәчәкләрне булдыра алганча кадерлисем килә.* К.Йосыпов

**Коргаксый бару** Акрынлап коргаксу. *Шәҗәрәнең тамырлары Сау, шөкер, исән-аман. Ябалдашы гына менә Коргаксый бара һаман.* Г.Морат

**Коргаксый башлау** Коргаксырга тотыну. *Табигатьтән читкәрәк китсәң, тойгылар коргаксый башлый.* М.Юныс

**Коргаксый төшү** Берникадәр күләмдә тагын да коргаксу

**Коргаксып бару** Акрынлап тагын да коргаксу. *Явым ике атнага сузылды. Коргаксып, кибеп барган инеш су белән тулып, ярлар ишелеп төште, буаларны ерып алып китте, күперне җимерде, кош-кортны агызды.* Ә.Фәйзи

**Коргаксып бетү** Бик нык, тәмам коргаксу. *Коргаксып бетәбез дигәндә, консерваториянең беренче курс студенты Филүс Каһиров кебек җырчы чыксын әле каршыңа!* А.Юнысова. *[Фоатның] аякларында коргаксып беткән сандали.* М.Әмир. *Дөрес, һәммәсе дә элеккечә кебек: шул ук коргаксып беткән мичкәләр, шул ук кыек-мыек тәгәрмәчле ташландык арбалар.* М.Шабай

**Коргаксып җитү** Коргаксуның ахыр чигенә җиткән булу; тәмам коргаксу

**Коргаксып калу** Коргаксыган хәлгә килү. *Ул көнне Зөлфәт тантана итте. --- Иҗатында – суынган учак көленнән бәрәңге кәлҗемәсе эзләргә күнеккәннәр күз алдында карсакланып, сай фикерләре коргаксып калды.* М.Галиев. --- *гасырлар буе татар теленә үз милкедәй булып кергән 30 меңләп терминны чыгарып түккәннән соң, телебез коргаксып калды.* М.Әхмәтҗанов

**Коргаксып кую** Кинәт коргаксу. *Яшәү яме бераз тонykланса, я коргаксып куйса язарым, Дәрдемәнд күк, мин базарга чыгам, урап кайтам Чехов базарын.* Р.Харис

**Коргаксып утыру** Әле, хәзерге вакытта коргаксу. *Корылыктан һәм су юклыктан авыллар коргаксып утыра.* Шәһри Казан

**Коргаксып яту** Шактый вакыт коргаксу. *Уйнамадым дип әйтмим, уйнадым, эшсез торып коргаксып ятмадым.* Акчарлак

**КОРГАКСЫК** *с.* 1) Кипшенгән, дымсыз, коры. *Җире – коргаксык, Кулы – коры капчык.* Мәкаль

2) Коргаксып какшаган, коргаксыган

3) Үсеп утырган килеш кипкән

**КОРГАКСЫЛ** *с.* 1) Суы, дымы чагыштырмача аз булган; ярым коры, кипкән

2) *күч.* Бик чандыр, ябык (кеше, кеше әгъзалары һ.б.ш. тур.). *Костя --- карчыкны сәке өстенә илтеп яткырды, коргаксыл кулларыннан, итсезләнгән битендә тырпайган аксыл алмаларыннан үпте.* Р.Рахман

**КОРГАКСЫНУ** *ф.* 1) Бик нык, артык нык кибү

2) Кибеп кечерәю, кибү аркасында какшау. *Коргаксынган ат арбасы*

3) *күч.* Бик нык кимү, такыраю, ярлылану. *Нинди замана бу, кара чордай Кешеләре шаша коргаксынып ---.* Ф.Яхин

**Коргаксына бару** Торган саен ныграк коргаксыну

**Коргаксына башлау** Коргаксынырга керешү

**Коргаксына төшү** Берникадәр коргаксыну

**Коргаксынып бетү** Бик нык, тәмам коргаксыну

**Коргаксынып җитү** Ахыр чиккә җитеп коргаксыну

**КОРГАКСЫТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **коргаксу**. *Вөҗданга таянмыйча, белемгә, сафлыкка һәм Кояшка омтылмыйча иҗат итү музыкабызны да, әдәбиятыбыз, сәнгатебез һәм фәлсәфәбезне дә гарипли, милли агачыбызның сутын коргаксыта.* Р.Зарипов

**Коргаксыта бару** Акрынлап барысын да коргаксыту

**Коргаксыта төшү** Берникадәр коргаксыту

**Коргаксытып алу** Тиз арада гына, кыска гына вакытка коргаксыту

**Коргаксытып җиткерү** Ахыр чиккә җиткереп, бик нык коргаксыту

**Коргаксытып тору** Хәзерге вакытта коргаксыту; даими яки әледән-әле коргаксыту

**КОРГА́У** *ф. иск.* Яклау, саклау, кайгырту. *Тургай яңгыр яуса баласын коргый.* Мәкаль

**Коргап тору** Өзлексез, даими коргау; әле, хәзерге вакытта коргау

**Коргый төшү** Берникадәр коргау

**КОРГЫЛДА́У** *ф. к.* **кургылдау**

**КОРГЫЧ** *и.* 1) Корма кору өчен кирәк-ярак әсбаплар (таяк, тукыма һ.б.ш.)

2) *диал.* Калын пәрдә, штор. --- *түшәме акшарлана, ковролин, тәрәзә коргычлар, гардиннар сатып алына.* Мишәр дөньясы

**КОРД** *и. фр. махс.* **1.** 1) Калын, нык итеп эшләнгән киҗе-мамык җеп

2) Шундый җептән тукылып, резин белән катырылып эшләнгән тукыма. *Кордтан автомобиль шиннары, олтаннар ясыйлар*

3) Бизәге белән шундый тукымага охшаган, буй-буй вак сырлы йон һ.б.ш. тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шундый җептән эшләнгән, тукылган, тегелгән

**КО́РДА** *и. гр. махс.* Атларны түгәрәк буенча куып йөртү өчен билгеләнгән озын бау, тезген

**КОРДАШ** *и.* 1) Бер корга (*2 мәгъ.*) кергән кешеләрнең берсе

2) Яшь аермалары артык зур булмаган ике кешенең берсе; чордаш. *Картларның өеннән кеше өзелмәде. Күршеләр, туган-тумачалар, кордашлар, авылдашлар – берсе дә калмады.* Г.Гыйльманов. *[Әнкәй] Бу дөньяга --- җорлыгы белән кордашларының михнәтле тормышын җиңеләйтергә, безне багарга килгән дә, мәңгелек йортына кайткан.* К.Йосыпов

3) *диал.* Яшьтәш. *[Айтуган карт] өйдә ятып тарыккан булса кирәк, аның үз кордашлары янында иркенләбрәк сөйләшәсе килә иде.* Г.Бәширов. *Үземнең кордашлар – «кырык беренчеләр» дә аксакаллар яшенә җитте.* Р.Гаташ. *Хәзрәт белән килгән кеше кордашлар кебек күренә иде, бу әфәндегә илле яшьләр чамасы булыр.* Р.Батулла

**КОРДАШЛЫК** *и.* 1) Кордаш булу; яшьтәшлек

2) Дуслык, ахирәтлек

**КОРДЕБАЛЕТ** *и. фр. махс.* Күмәк биюләрне башкаручы балет артистлары төркеме. --- *Айсылуны М.Җәлил исемендәге театрга эшкә алдылар. Башта ул кордебалетта биеде. Аннары аңа корифей дәрәҗәсен бирделәр.* Мәдәни җомга

**КОРДОН** *и. фр.* 1) Киртәләп, тоткарлап торучылар яки чик буе сакчылары отряды. *Полиция кордоны*

2) Чик буе сакчылары яки каравылчылар урнашкан, яшәгән урын. *1794 елны Идел елгасында булган казачи кордоннарны һәм кордон постларын Ахтубәгә, Ахтубәдән теркәп Большой үзенга күчерергә указ чыга.* В.Ильясов

3) *күч.* Нинди дә булса эшчәнлеккә, хәрәкәткә каршы чара; киртә, тоткарлык. *Ирек килде, шатлык килде, Кордоннарны җимереп мәңгегә.* М.Максуд

**КОРЕАН** *и.* Ясалма таш; заманча төзелеш-бизәлеш материалы

**КОРЕЙ** *и. сөйл. к.* **кореяле**. *Утраулда үзен хуҗа итеп сизгән корей хатыны башланган кавыннан ике телем кыеп алды да безгә сузды...* Ә.Маликов

**КОРЕ́ЙЧА** *рәв.* Корея телендә

**КОРЕ́ЯЛЕ** *и.* Кореядә яшәүче кеше. *Кореяле кайсыдыр кесәсеннән җитез генә коньяк шешәсе тартып чыгарды: – Риза булсаң, уңыш өчен бер шешә эчәбез дә таралышабыз.* Р.Мирхәйдәров. *Ул йортта кытайга да,*

*кореялегә дә тартым бер карт япа-ялгыз яши икән.* Ә.Маликов

**КОРЕШОК** *и. рус* Квитанция кенәгәләрендә: төп битнең квитанцияне ертып, кисеп алганнан соң калган өлеше. *Ниһаять, без дә юньлерәк квартирлы булабыз бугай. Ордерның яртысын, ягъни корешогын бирделәр.* Ф.Яруллин

**КОРИАНДР** *и. лат. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан җимешләреннән эфир мае җитештерелә торган берьеллык үлән үсемлек (яшь үсемлекләре һәм кипкән җимешләре аш тәмләткеч буларак та кулланыла)

**КОРИДОР** *и. лат.* 1) Квартирның, бинаның аерым өлешләрен тоташтыра торган озын тар аралык. *Марҗа асрау коридор буенча, чәй дирбиясе күтәреп, җәһәт кенә аш бүлмәсенә таба бара; коридорның аргы башында җиде-сигез яшьлек бер ир бала, ду килеп, кулга өйрәнгән куян баласын куып йөри ---.* Ф.Әмирхан. *Коридорда 16 гаилә яшибез һәм барыбыз да бер кухнядан файдаланабыз, суны мичкәләрдә атлар белән китерәләр.* Мирас. --- *Алексей Фролов аңлатуынча, кайбер элеккеге тулай торакларны техник хәле буенча торак йортка кертү бик авыр. Бу бигрәк тә коридор системасы буенча төзелгән торакларга кагыла.* Ватаным Татарстан

2) Ике яктан нәрсә белән булса да аерылган, чикләнгән озын тар аралык. *Икенче караганда куе томан аның эченнән тәбәнәк тар коридор ясап барган шикелле.* Г.Бәширов. *Дүрт йөз метр киңлектәге ачык коридор – нейтраль зона аша күпме шуышканбыздыр, әйтүе кыен.* Ә.Маликов

**КОРИДО́РЩИК** *и. рус иск.* Кунакханәләрдә: уртак коридорда хезмәт итүче, номерларны күзәтеп торучы кеше. --- *шундагы коридорщикка берникадәр әйберләр алырга кушып, егерме тиен бирү вәгъдәсе берлән самавыр сорадык.* Г.Исхакый

**КОРИФЕЙ** *и. гр.* 1) Борынгы грек трагедияләрендә хор җитәкчесе

2) *театр* Кордебалетның әйдәп баручы биючесе. --- *Айсылуны М.Җәлил исемендәге театрга эшкә алдылар. Башта ул кордебалетта биеде. Аннары аңа корифей дәрәҗәсен бирделәр.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Нинди дә булса өлкәдә атаклы, күренекле шәхес. --- *хәтта рус әдәбиятының корифейлары Ш.Камалны белә, аның иҗатына югары бәя бирә.* И.Нуруллин. *Татар әдәбиятында милли шигъриятебезнең күренекле корифейлары Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, С.Хәким, Х.Туфан, И.Юзеевның лаеклы шәкерте --- Равил Фәйзуллин олуг шагыйрь булып күңелгә ныклап урнашты.* Шәһри Казан

**КО́РК-КОРК** *иярт. к.* **корык-корык**. *Чирле иде ул, корк-корк йөткерә.* Г.Ахунов

**КОР-КОР** *иярт.* Ана күркә, торна, каракош һ.б.ш. кайбер кошлар кычкырган тавышка охшаган авазларны белдерә. *Кор-кор килеп кара козгын чукый Иреклемен дигән уемны.* Казан утлары

**КОР-КОР ИТҮ** *ф.* Кор-кор иткән тавыш чыгару

**КОРКЫЛДА́У** *ф.* 1) Кор-кор итү, кор-кор дигән авазлар чыгару. *[Тавык] Һаман кабарынып, туктаусыз коркылдап, тирә-ягына ялт-йолт каранып кына тора.* Ә.Еники. *Ак торнаны атып үтергәч, торналар тау өстендә, кызганыч тавышлар белән коркылдап, бик озак очып йөриләр.* Н.Әхмәдиев

2) *күч. гади с.* Лыгырдау, кызыл сүзләр сөйләп маташу

**Коркылдап алу** Берникадәр коркылдау

**Коркылдап кую** Бер тапкыр коркылдау. *Пәри туе кебек дөбер-шатырдан бөтен әрәмәлек гөр килә, куркудан уянган кош-корт коркылдап куя.* С.Сабиров

**Коркылдап тору** Әле коркылдау; даими яки әледән-әле коркылдау. *Шома дуңгыз баласы шикелле баштанаяк ялтыраган килеш коркылдап торган әллә кемнәрдән «куркаклар, лодырьлар» исемен ишет!* Ш.Камал

**КОРМА** I *с. сөйл.* Кем яки нәрсә белән булса да бер иш, тиң булган. *Шулай бер көн Миңсылу, тагын байтак үзебез шикелле бер корма вак кызлар җыелыштык.* Г.Лотфи

**КОРМА** II Кушма сүзләрдә «корылма» мәгънәсендәге икенче компонент (мәс., *янкорма, өскорма*)

**КОРМАЛА́У** *ф. диал.* Бөтен җирен каплап, томалап, әйләндереп урап алу, төреп бетерү

**Кормалап алу** Берникадәр кормалау

**Кормалап бетерү** Тәмам, тулысынча кормалау. *Яулык-яулык болытлар көньяк күген кормалап бетергән.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Кормалап кую** Кормаланган итү. *Аннан-моннан кормалап куелган биналарга урнашкан 11 котельный һәм «пыяла вата» туннарын киеп, җир өстендә сузылып ятучы магистраль җылылык үткәргечләре – илгә 170 миллион тонна кара алтын озаткан Баулының бүгенге йөзен билгеләүче күренешләрнең берсе шул.* Ватаным Татарстан

**КОРНЕТ** I *и. фр. хәрби* 1) Инкыйлапка кадәрге рус армиясендә: атлы һәм чик буе гаскәрләрендә кече офицер дәрәҗәсе; шул дәрәҗәдәге кеше

2) Кайбер илләрнең армияләрендә хәрби дәрәҗә. *Корнет Уэльс Гыйрак яки Әфганстанга командировка турында әле Сэндхерст хәрби училищесында укыган чорда ук хыяллана башлаган.* Мәдәни җомга

**КОРНЕТ** II *и. ит. муз.* Быргыга охшаш тынлы җиз уен кораллы. *Колакка корнетта уйналган «Катюша» яңгырады.* Х.Мөҗәй

**КОРНЕТЧЫ** *и. муз.* Корнетта уйнаучы музыкант

**КОРОЛЕ́ВА** *и. рус* 1) Хатын-кыз король; патшабикә. *Уильям туганнарын да онытмаган. Ул әтисе һәм әбисе – королева Елизавета II нең резиденцияләре өстеннән очып үткән.* Ватаным Татарстан. *192 дәүләтнең 19 ы белән хатын-кызлар идарә итә, ягъни хакимияттә иң зур кәнәфиләрдә утыралар. Алар арасында Бөекбритания һәм Дания королевалары --- бар.* Шәһри Казан

2) Король хатыны. *Король белән бергә сугыш барышын күзәткән королева чигенә башлаган солдатларны үзе һөҗүмгә алып киткән. Король янәшәсендәге королева шахматка шулай килеп кергән...* С.Сөләйманова

3) Шахмат уенында иң көчле фигура булып саналган вәзирнең (ферзьнең) икенче төрле атамасы. *Бәп-бәләкәй Айратны җиңмәскә соң! Ә сораулар*

*ява тора. Сынап та, кызыксынып та: – Апай, нишләп шахматта королева корольдән шәбрәк йөри?* С.Сөләйманова

4) *сөйл.* Үзенең матурлыгы, буйсыны белән аерылып торган хатын-кыз. *Имтихан билгеләре түбәндәгечә: --- Хатынны королева итеп киендерә белү – дүрт.* М.Бакиров. *«Безнең апай...», «Королева...» Мәскүрә турында бит бу!* С.Сөләйманова

5) *күч.* Нинди дә булса бер өлкәдә югары уңышларга ирешкән, уңай сыйфаты белән бик нык аерылып торган хатын-кыз. *Әлеге триумф өчен барлык кызларыбызга, тренерларга рәхмәт белдерәбез һәм синхрон йөзү «королевалары»на спортта, тормышларында яңа матур җиңүләр һәм казанышлар телибез!* Ватаным Татарстан. *Шулай дигәч, сап-сары чәчәкләрдән үрелгән тәкыяны чәчләренә утыртып куя. – Әйтерсең болын королевасы, шулай килешә, – ди Гөлшат, соклануын яшерә алмыйча.* Э.Хаббанова

**КОРОЛЬ** *и. герм.* 1) Кайбер дәүләтләрдә монарх титулы; шул титулга ия кеше. *Дөньяның иң зур филателистларыннан булган Англия короленең дүрт миллионлап маркалардан торган коллекциясен сугыш вакытында үзләрендә саклап торып сугыштан соң исән-сау Англиягә кайтарулары белән немецлар әле дә булса мактаналар.* Г.Гобәй. *--- Англия короленең икенче хатыны Макдональд Англия тәхетенә наследник китерергә йөргән елларда, мин пароход борынында тәмәке тартып бара идем.* Һ.Такташ. *Соңра хан янына киттеләр дә: король белән килеш, әмма син падишаһ белән (Иван Грозный морад) килешмә, ул (Иван) мөселман йортын һәм немецларны (Ливония морад) алды...*Г.Гобәйдуллин

2) Карта уенында дәрәҗә буенча туздан соң килгән карта; башына таҗ кигән сакаллы ир кеше сурәте төшерелгән уен картасы. *Валет нәрсә, әле аның корольләре дә, тузлары да бар…* Р.Мирхәйдәров. *Уйнаучыларның «туз», «валет», «король», «дам» дигән сүзләрен ачык ишетсә дә, уенны һичничек аңлый алмый Мөбарәк.* М.Шаһимәрданов. *[Мөхәммәтҗан:] Тә-әк, крест тузлары, корольләре безнең татар дамаларын ярата, диләр...* А.Әхмәтгалиева

3) Шахмат уенында төп фигура, шаһ. *Әһә, мин уйнаганга йөрдең, шах корольгә, әһә, ә мат сиңа.* А.Алиш

4) *күч.* Сәнәгать, сәүдә һ.б.ш. өлкәне үз кулында тота торган кеше турында. *Базар корольләре! Шарлатаннар! Череп беткән сыра кортлары!* Һ.Такташ. *(Печән базары почмагы олылары) бу көнге көфер почмагы корольләре бармы?* Ф.Әмирхан. *– Хәзерге Эйфель хуҗаларыннан – автомобиль корольләреннән үч алыр көн килер! – Менә болар да өстәләләр?* Г.Гобәй

5) *күч. сөйл.* Сәләтлелеге, йөз матурлыгы һ.б.ш. сыйфатлары белән башкалардан кискен аерылып торган кеше турында. *Рәфгать – футбол короле.* Б.Камалов

**КОРОЛЬЛЕК** *и.* 1) Король тарафыннан идарә ителә торган монархик дәүләт. *Исланд, скандинав һәм герман халыкларының эпик традицияләре нигезен һун яулары нәтиҗәсендә 437 елда Бургунд корольлегенең юкка чыгарылуы --- кебек зур тарихи вакыйгалар тәшкил итә.* Ф.Урманче

2) Король вазифасы, хезмәте. *Корольлек итү*

**КОРО́НКА** *и. рус анат.* 1) Тешнең күренеп торган өске өлеше. *Тешләр коронкадан, муентыктан һәм тамырдан торалар.* Анатомия

2) Кайбер очракларда, бозыла башлаган тешне дәвалап, аны саклау өчен кидерелә торган металл, металлокерамика яки пластмасс тышча. *Илвир Гөлсылуны --- ике алтын коронка куйдырган таза гына егеттән сорап белде.* М.Шаһимәрданов. *--- энемнең, елмаеп җибәрсә, алдагы алтын коронкалары ыржаеп утыра.* Шәһри Казан

**КОРПОРАТИВ** *с.* **1.** 1) Аерым бер компаниягә, бер фирмага караган корпорация белән чикләнгән. *Зур дәүләт кечкенә проблемаларны хәл итә алмый: тегендә-монда сугыш чыга, чиновниклар шәхси, корпоратив мәнфәгатьләрдә тоткарланалар.* И.Заһидуллин. *Руслан [ТАИФта] корпоратив идарә буенча урынбасар булып эшли ---.* Татарстан

2) Күмәк. *--- балалар бакчасына, мәктәпләргә генә түгел, зур-зур абзыйлар, апалар җыелган корпоратив кичәләргә дә килә Кыш бабай.* Безнең гәҗит

**2.** *и. мәгъ.* Бер фирма, оешма һ.б.ш. хезмәткәрләренең бергә ял итү чарасы, бер коллективның бәйрәм кичәсе, мәҗлесе. *Безнең корпоративка килгән тәкәббер байбичәдән, мескен, тавышы гәүдәсеннән ерак китә алмаган хәчтерүш кенә калган иде.* Шәһри Казан

**КОРПОРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Һөнәр яки катлау мәнфәгатьләре уртаклыгыннан чыгып берләшкән җәмгыять, оешма, кешеләр төркеме

2) Зур хуҗалык берләшмәсенең бер төре: менеджерлар идарә итә торган акционерлар берләшмәсе. *Соңгы көннәрдә Казанда дөнья күләмендә эш итүче АКШ корпорациясенең татарча билбордлары пәйда булды.* Ватаным Татарстан. *«Cirque du Soleil» – бөтен дөньяга танылган цирк. --- Бүген ул дөньяда иң көчле цирк корпорациясе санала: аның капиталы бер миллиард доллардан да артып киткән.* Сабантуй

**КО́РПУС** *и. лат.* 1) Бер урынга, якын-тирәгә салынган берничә зур бинаның берсе; шулай ук бинаның аерылып торган зур бер өлеше. *Урам буйлап салынып, бөтен бер кварталга сузылып киткән завод корпуслары бу караңгы, яңгырлы төндә матур булып балкыйлар иде.* Г.Әпсәләмов. *Июнь ахырына госпиталь корпуслары бушап калды.* Ә.Маликов. *Каршыда карцер корпусының бер як стенасына бастырыптерәп куйган табутлар.* И.Салахов

2) Нинди дә булса механизм, җайланма, аппарат һ.б.ш. тышын, тышчасын, нәрсәнең дә булса нигезен тәшкил иткән деталь. *Бомба эченә дым үтмәсен һәм температурасы кинәт үзгәрмәсен өчен, корпусы эченә биш атмосфералы гелий газы тутыралар.* З.Зәйнуллин

3) Судноның тышчасын тәшкил иткән өлеше, каркас. *«Виктория», очып килгән уңайга, борыны белән катерның кабыргасына төрттерде. Мондый көчле бәрдерүдән көймәнең корпусы гөрселдәп куйды.* И.Хуҗин. *1948 елда җир тетрәгәндә, корабль тагын да*

*өскәрәк калыккан, дип тә сөйлиләр. Бу мизгелдә тирә-якны яктылык чорнап ала, ә көймәнең корпусы икегә ярыла.* Кызыл таң

4) Берничә дивизия яки бригаданы үз эченә алган зур гаскәри берләшмә. *Орловның йөзе кырыс, уйчан. Сахалин корпусы командованиесе йөкләгән җаваплылык аның көчен, энергиясен чикли, тоткарлыйдыр төсле.* Ә.Маликов. *Полк командирының кабинетыннан чыгу белән, кире очучылыкка кайтаруларын сорап, корпус командиры исеменә рапорт яздым.* М.Юныс. *Лифляндиядән генерал Левенгаупт уналты мең кешелек корпус белән үзенең короле артыннан кузгалгач, аңа Пётр Рәсәйгә ялланган немец генералы Боур командалыгындагы илле меңлек армияне каршы куйды.* В.Имамов

5) Белгечлекләре, рәсми яки хезмәттәге дәрәҗәләре бер төрле булган кешеләр төркеме. --- *газетларда һәм депутатлар корпусында, кооператорларның баш әйләндергеч уңышлары турында шапырыну өчен, күпләп акча җыярга керештеләр.* Р.Мирхәйдәров. *1916 елдагы экспедицион корпусның бер татар солдаты үзенең чит илләрдә күргәннәрен көндәлек итеп язып барган булган.* Мирас

6) *иск.* Ябык типтагы хәрби урта мәктәпләрнең атамасы составында кулланыла. *Патша Николай I әмере буенча 9 яшьлек Җәмәлетдинне Мәскәүнең беренче кадетлар корпусының яшьләр бүлегенә озатып җибәрәләр ---.* Д.Гарифуллин

7) Типография эшендә: 10 пункт үлчәвендәге хәреф

8) *лингв.* Күпсанлы текстлар җыелмасы нигезендә төзелгән һәм электрон формада саклана торган сүзлек-белешмә. *Татар теленең электрон корпусы*

**КО́РПУСЛЫ** *с.* 1) Корпусы (*1 мәгъ.*) булган, шуның эченә урнаштырылган. *Вакыт үтә. Стенадагы җиз корпуслы, СОС биргәнне тыңлар өчен, өч белән дүрт һәм тугыз белән ун арасы кызылга буялган циферблатлы диңгез сәгате кебек: тек, тек, тек ---.* М.Юныс

2) Эченә әйберләр урнаштырып кую, саклау өчен билгеләнгән (буфет, шкаф, комод, сервант һ.б.ш. тур.). *[Рәсим] Кибетләргә кереп карап, таныш-белешләреннән сораштырып, корпуслы җиһаз ясау серләренә төшенә.* Ирек мәйданы

3) *лингв.* Корпуслар (*1 мәгъ.*) төзү, анализлау һәм файдалану белән шөгыльләнә торган (фән). *Соңгы елларда тел белемендә корпуслардан файдаланып телне өйрәнә торган яңа фән – корпуслы лингвистика (корпусная лингвистика) барлыкка килде*

**КОРПУ́СКУЛА** *и. лат. физ.* Классик, типик физикада: матдәнең бик вак кисәкчәсе

**КОРПУСКУЛЯР** *с. лат. физ.* Корпускулаларга хас, шуларга караган

**КОРРЕКТ** *с.* Дөрес, урынлы

**КОРРЕКТИВ** *и. к.* **корректива**. *Аппаратураның да кайбер узелларына коррективлар кертергә туры килер.* Г.Иделле. *Һиндстан халкы, тарихның күп тармакларына төзәтмә керткән кебек, моңа да корректив кертте: бодай күмәче (һинд телендә «чапати») азатлык яулап алган Һиндстан халкының горурлыгына әйләнде.* М.Мәһдиев

**КОРРЕКТИ́ВА** *и. лат. кит.* Өлешчә төзәтү, дөресләү, үзгәреш кертү эше

**КОРРЕ́КТЛАУ** *ф.* Беркадәр төзәтү; азрак төзәтмә ясау

**Корректлап алу** Берникадәр корректлау

**Корректлап бетерү** Корректлауны тәмамлау; барысын да корректлау

**Корректлап тору** Әле, хәзерге вакытта корректлау; даими яки әледәнәле корректлау

**Корректлап чыгу** Барысын да корректлау

**КОРРЕКТИРО́ВКА** *и. рус* 1) *хәрби* Максималь төгәллегенә һәм нәтиҗәсенә ирешү максаты белән, артиллерия утының юнәлешенә кертелгән төзәтмәләр яки үзгәртүләр. *Елга буендагы өйләрне артиллерия утына корректировка бирү өчен күзәтү пунктлары иттек.* Казан утлары

2) *күч.* Билгеле бер эшчәнлеккә, берәр хәлгә, торышка һ.б.ш. төзәтмәләр яки үзгәртүләр кертү күренеше. *Кешенең тормыш коруы – космоска чыгу. Старт дөрес алынса – программа үтәлә; старт начар алынса – бернинди центр корректировка ясый алмый.* М.Мәһдиев

**КОРРЕКТИРО́ВЩИК** *и. рус* Корректировка ясаучы кеше. *Хәсән һәрбер үтелгән километр саен бу кешенең немец корректировщигы икәненә ышана бара иде.* А.Расих

**КОРРЕ́КТЛЫ** *с.* **1.** 1) Ягымлы һәм тәрбияле, итагатьле. *[Хатип ага Госманның] --- авторитарлыгы, шулай әйтергә мөмкин булса, шактый корректлы, ягъни вульгарлашмаган авторитарлык иде.* М.Госманов

2) Дөрес, урынлы. --- *безнең ул берлекне, имеш тә, кайсыдыр бер югары түрә ошатмаган икән, милли нигездә оешма төзү корректлы түгел, дигән икән...* З.Мифтахов

**2.** *рәв. мәгъ.* Дөрес, урынлы итеп. *Әкрәмнең күршесе казакъ Жолдасның (И.Гомәров) сәхнәгә чыгуын тамашачы гел алкыш белән каршы ала. Болай якын итү очраклы түгел, образ, «сәяси корректлы» эшләнүе белән бергә, милли казакъ холкының төрле якларын исәпкә алып, бик көлке хәлгә китерелгән.* Сәхнә

**КОРРЕ́КТЛЫЛЫК** *и.* Корректлы булу

**КОРРЕ́КТОР** *и. лат. махс.* Корректураны укучы һәм төзәтүче нәшрият яки типография хезмәткәре. *Редактор да, секретарь да, корректор да, экспедитор да үзем булам, икешәр, өчәр көн өйгә кунарга кайтмыйча, көне-төне шунда эшләп уздырам.* М.Галәү. *Газета корректорлары минем исем-фамилиямне шулкадәр бозганнар иде.* А.Шамов. *[З.Бәшири] Кәримов-Хөсәеновларның матбагасында корректор --- булып эшли.* Казан утлары

**КОРРЕ́КТОРЛЫК** *и.* Корректор вазифасы, хезмәте. *Редакция һәм типография атмосферасында үзен никадәр генә рәхәт хис итмәсен, корректорлык вазифасын һәм бүтән эшләрне ничаклы теләп башкармасын, Габдулланың төп эше (үзе дә шулай санаган булса кирәк) – әдәби иҗат һәм публицистика.* И.Нуруллин. *[Тәскирә Мөхәммәдиева:] Гәзит эше белән азмы-күпме таныш идем. Шуңа «кара эш» дип тормадым, корректорлыктан башладым.* Кызыл таң

**КОРРЕКТУ́РА** *и. лат.* 1) Типографик набордан чыккан оттисктагы хаталарны төзәтү эше. *Ул һәр көн типографиядә сигез сәгатьлек корректура хезмәтеннән калган бөтен вакытын шул дәресләренә бирә.* Г.Ибраһимов

2) Кулъязма яки оригиналы белән чагыштырып төзәтү өчен, типографик набордан кире кайтарылган оттиск. *Нашир һәм редактор кеше Тукайны корректура карар өчен генә чакырмаган, әлбәттә.* И.Нуруллин. *Корректура нигезендә текстны басмага киткәнче үк төзәтеп эшләү газета-журналлар үсеше дәверендә тулысынча хәл ителгән дияргә була.* Ф.Яхин

3) Нәрсәгә дә булса гомумән үзгәрешләр, төзәтүләр кертү. *Без барасы юллардагы соңгы үзгәрешләр. Шуларны карталарга күчереп, корректура ясарга кирәк иде.* М.Юныс

**КОРРЕ́КЦИЯ** *и. нем.* 1) *махс.* Төзәтү, дөресләү, төзәтмәләр кертү. *LASIK ысулы белән ясала торган күзгә эксимерлазер коррекция бүгенге көндә күзнең күрүен яхшырта торган иң заманча һәм нәтиҗәле ысуллардан санала.* Шәһри Казан

2) *тех.* Файдалану, эксплуатация шартларының үзгәрүеннән чыгып, үлчәү приборлары, идарә итү аппаратларының эш-хәрәкәтенә төзәтмә, үзгәртүләр кертү күренеше

**КОРРЕ́КЦИЯЛӘҮ** *ф. махс.* Коррекция ясау. --- *радионавигация приборларын карарга, карталарны коррекцияләргә, экипажга эш хакын хисаплап чыгарырга, касса отчётын төзергә кирәк.* М.Юныс

**Коррекцияләп алу** Берникадәр коррекцияләү; билгеле бер вакыт аралыгында коррекцияләү

**Коррекцияләп бару** Рәттән барысын да коррекцияләү

**Коррекцияләп тору** Даими яки әледән-әле коррекцияләү

**Коррекцияли бару** Акрынлап барысын да коррекцияләү

**Коррекцияли бирү** Бернигә карамастан коррекцияләү

**Коррекцияли төшү** Коррекцияләүне акрынлап арттыру

**КОРРЕКЦИОН** *с.* Төзәтүгә, коррекциягә караган, шуңа бәйле. --- *Президентның, ни өчен кичке, коррекцион мәктәпләрдәге сыйныф җитәкчеләре тиешле акчаларын ала алмый, дигән соравына мәгариф министры Андрей Фурсенко дәлилле җавап бирә алмады.* Мәгариф

**КОРРЕЛЯТИВ** *с. кит.* Бәйләнеше булган, мөнәсәбәттәш, тиңләштерергә (чагыштырырга) мөмкин булган, тиңләштерерлек. *Коррелятив төшенчәләр*

**КОРРЕЛЯЦИОН** *с. кит. к.* **корреляцияле**

**КОРРЕЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* Бәйләнеш, нисбәт, үзара мөнәсәбәт

**КОРРЕЛЯ́ЦИЯЛЕ** *с. кит.* Корреляциягә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *[Г.Бариев] Корреляцияле сикерешләр моделен (Бариев моделен) тәкъдим итә һәм төгәл чишә.* Татар энциклопедиясе

**КОРРЕСПОНДЕНТ** *и. лат.* 1) Газета, журнал, радио һәм телевидениедә корреспонденцияләр авторы. *Газета корреспонденты үзебезнең эшче-хәбәрчеләр бригадасы белән бергәләп, фабриканың цехларын җентекләп тикшерделәр...* Ш.Камал. *Шулай аларның кайсысы корреспондент, кайсысы спортсмен булып киләләр дә шпионлык итеп йөриләр.* Т.Гыйззәт

2) Кем белән дә булса хат язышып, хәбәрләшеп торучы кеше. *[Екатерина] чит илдәге үзенең корреспондентларына («укымышлы» патшабикә Европаның күренекле шәхесләре белән хат алышып торуны бик яраткан) «фетнәнең тәмам бастырылуы» турында шундук хәбәр юллый.* В.Имамов

3) *икът.* Аерым бер төбәктә үзенә тиң икенче бер оешманың шул оешма исәбенә мәнфәгатьләрен чагылдыра һәм финанс йөкләмәләрен үти торган банк яки финанс оешмасы. *Корреспондент шартнамәсе*

**КОРРЕСПОНДЕНТЛЫК** *и.* **1.** Корреспондент (*1 мәгъ.*) хезмәте, вазифасы

**2.** *с. мәгъ.* Банкның эчке опрацияләре өчен билгеләнгән счёты. *Татарстан банкларына килгәндә, аларның корреспондентлык счётларындагы иреклe акчалары ел башында да, җәен дә 9–13 миллиард сум тирәсе булды.* Ватаным Татарстан

**КОРРЕСПОНДЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Аерым кешеләр яки оешмалар арасында почта аша язышу, хәбәрләшү эше. *Миңа әле генә килгән икенче корреспонденция – Төркиядә чыга торган «Кардәш әдәбиятлар» журналының 20 нче саны.* Ә.Кәримуллин. *Моңарчы гражданнарның хат алышканын тикшерү, корреспонденциянең эчтәлеген ачыклау оператив-эзләү эше вакытында гына, бары тик суд карары нигезендә мөмкин иде.* Ватаным Татарстан

2) *җый. и.* Почта-телеграф аркылы җибәрелгән әйберләр (хатлар, телеграммалар, бандерольләр һ.б.ш.). *Корреспонденциянең вакытында барып җитмәве өчен, «Почта России» оешмасы күп тапкырлар тәнкыйтьләнде ---.* Ватаным Татарстан

3) Газета, журнал, радио, телевидениегә агымдагы вакыйгалар турында каян да булса җибәрелгән хәбәрләр, мәгълүмат. – *Корреспонденциянең авторы әйтелми, – диде Гайкин, ирен кырыен кыймылдатып.* Г.Ахунов

**КОРРОЗИОН** *с. к.* **коррозияле**

**КОРРО́ЗИЯ** *и. лат.* 1) *хим.* Тирәяк мохитнең химик яки электрохимик тәэсире нәтиҗәсе буларак металларның таркалуы, ашалуы. *[Декоратив калпакның] Цинк йөгертелгән, полимер белән капланган металлдан эшләнгәннәре аеруча яхшы. Андыйлары коррозиягә бирешми, тутыкмый.* Ирек мәйданы

2) *геол.* Суның химик тәэсире нәтиҗәсендә тау токымнарының таркалуы

**КОРРО́ЗИЯЛЕ** *с.* Тутыккан, коррозиягә дучар ителгән, коррозиягә бирешкән. *Гафаров җитәкчелегендә --- озак вакытлар коррозияле тирәлекләрдә була торган технологик җиһазларның, торба үткәргечләрнең ышанычлы һәм куркынычсыз эшләвен --- тәэмин итү системасы тәкъдим ителә.* Татар энциклопедиясе

**КОРРУПЦИОНЕР** *и. лат.* Коррупциягә катнашкан кеше. *Илдә бурлар, коррупционерлар --- намуссызлыкны дәрәҗәгә санап ятканда, халыкка хезмәт итәргә өндәү үзе дә – утопия.* Р.Хәкимов. *[Халык] чиновникларның*

*хезмәт хаклары зур булмаса да, бай яшәүләрен дә беләә, --- коррупционерлар алдында законның көчсез икәнлеген дә белә.* Ватаным Татарстан

**КОРРУ́ПЦИЯ** *и. лат. кит.* Сәясәт эшлеклеләренең, урындагы кешеләрнең акчага сатылучанлыгы; үзләренең хезмәт дәрәҗәләрен, эш урынында булган хокукларын шәхси байлык туплау өчен файдалануга корылган җинаять; идарә итү органнарында чиновникларның ришвәт алып, эш урыныннан законсыз файдалануы; ришвәтчелек, сатлыклык. --- *бу уңайдан коррупция проблемасын да искә алу урынлы.* Ватаным Татарстан

**КОРРУ́ПЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Коррупциягә бирелгәнлек. *Дөньяның 180 иле арасында коррупциялелек дәрәҗәсе буенча Мьянма, Сомали һәм Гыйрак иң беренче урыннарны алды.* Авыл утлары

**КОРРУ́ПЦИЯЛЕ** *с.* Коррупция үтеп кергән, сатлык, сатылган, сатып алынган. *Эчке эшләр министрлыгының 34 хезмәткәре быел коррупциядә катнашканлыклары аркасында хөкем ителгән. Хокук саклау оешмалары иң коррупцияле оешма дип табылган.* Безнең гәҗит

**КОРСА́ГАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Моллюскларның бер классы; әкәмтөкәмнәр. *Корсагаяклылар, яки әкәмтөкәмнәр – моллюскларның 90 меңләп төрен берләштергән иң зур класс.* Биология

**КОРСАЖ** *и. фр.* 1) Хатын-кыз күлмәгенең муеннан билгә кадәрге өлеше

2) Итәкнең киң, каты билбавы

**КОРСАК** *и.* 1) Кеше һәм хайваннарда: ашказаны, бавыр, эчәкләр, талак һ.б.ш. органнар урнашкан урын; эч. *Бу бала бөтенләй ялангач, корсагы зур, аяклары кыска, кәкре ---.* Г.Ибраһимов. *[Сирай] Алга чыгып торган тезе белән Ярулланың корсагына тибә.* М.Фәйзи. *Кичә Ибрай белән икәү, корсакларны ачып, әллә ничаклы кояшта кыздырып карадык.* М.Кәрим

2) Гәүдәнең аркага капма-каршы ягы. --- *яшел чирәмнәргә корсаклары берлә сузылып ятып --- иске хатирәләрене яңарта торган агайлар --- бу мәнзарәне тагы матурлата, аңар тагы күбрәк мәгънә бирә иде.* Г.Исхакый. *Ул, корсагына яткан да, муенын сузып, кыектагы күгәрченнәргә таба елыша.* И.Гази

3) Кайбер предметларның кабарып чыгып торган урта бер урыны (самавыр, мичкә, кибән һ.б.ш.). *Кибетнең шүрлекләрендә эреле-ваклы таш чынаяклар, тирән һәм сай тәлинкәләр, юан корсаклы, нечкә билле купшы вазалар...* Ә.Фәйзи. *Төргәк эченнән корсагы яньчелеп эчкә баткан, бераз шадраланган иске фляга килеп чыкты.* Ә.Маликов. *Барып керсәк, зуринәй, аксаклап-туксаклап, кечкенә корсаклы самавырны куеп җибәрә иде.* К.Йосыпов

4) *сөйл.* Ашказаны, карын. *Өченче көн инде Хәлифәнең Корсагында бүре концерты, Хатыннары дисәң? – Сорама да; Шундый хәлләр, Бохар шәкерте.* Һ.Такташ. *Бии торгач, корсактагы ашаган ипиләр дә коелып бетте.* Г.Камал. *Корсак тулгач тынычланып, шпал өстенә сузылып яттым.* И.Салахов

5) *сөйл.* Ана карынындагы бала; авыр, көмән. *Инде әнисе, безнең өйгә килеп, кызының миннән корсагы булуы турында балавыз да сыгып алды.* Ш.Алпар. *[Гөлчирә:] Аннары шуны да белеп торыгыз: минем аңардан дүрт айлык корсагым бар ---.* Ф.Хөсни. *Хатын симез булгач, баштарак игътибар да итмәгәнмен: бер ай яшәргә дә өлгермәдек әле, ә аның инде корсагы борынына җитеп килә икән.* Идел

6) *күч. сөйл.* Бик зур корсаклы, юан кешегә карата мыскыллау сүзе буларак әйтелә. *Аристократ-сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар --- Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак ---.* Г.Тукай. *Таныш кешеләр. Теге шар корсак белән баш табиб түгелме?* А.Зәки

7) *күч. сөйл.* Күпчелек очракта *зур, юан* сүзләре белән кулланылып, «бай, колбиләүче, аристоркрат» кебек мәгънәләрдә мыскыллап әйтелә. *Җамалый карт җырләре ярлы халык кулына күчкән бөтен байларга, зур корсакларга каршы көрәшүчеләрнең берсе иде...* Һ.Такташ. *Тагы шул юан корсак байларга, надан хәлфәләргә ышанабызмы?* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Ашау, ашауга, ризыкка булган ихтыяҗ. *Сыер дигәнең бик ахмак нәрсә бит ул, яхшылыкны белми, аңарга ашарга гына булсын; корсак өчен кырык мәртәбә үләргә әзер.* Һ.Такташ

◊ **Корсак ачу** *диал.* Ашыйсы килү. *[Әсгать:] Әтием әйтә, борын-борын заманда бер патша дала буйлап сыбай китеп бара икән, ди. Бара торгач, моның корсагы ачкан.* М.Кәрим. *[Нәнәй:] Корсагың ачкандыр инде, шул гомер йокы симертеп ни.* Д.Булатова. **Корсакка калу** Балага узу; авырлы, көмәнле булу. *[Анна Васильевна] --- икенче мәртәбә корсакка калгач, ул хәзер инде Шәмсигә әйтүне кирәк тә тапмады.* Г.Исхакый. *Эш беткәч, Рәйсә: «Мин корсакка калдым», – дип «сөенеч алды».* Ш.Алпар. **Корсакка узу** *к.* **корсакка калу**. *Кәләш корсакка узды. Көннән-көн юаная башлады.* М.Әмир. *Шунысы шәп: ул корсакка узмау җаен белеп эш итә, акыллы кыз.* Ш.Алпар. **Корсак киерү** Масаю, мактану, һавалану. – *Камалы бүрек кидем, инде камалы тун гына киясе калды, – дип, «пуф, пуф!» итеп корсагын киереп йөрде.* Ә.Фәйзи. --- *корсагын киереп, эре-эре атлап бакчаның икенче почмагына йөгерде.* К.Нәҗми. *Ә менә көннәр буена корсак киереп өендә яткан Сабирда әнә акча белән буа буарлык!* Ф.Яхин. **Корсак колы** Гел ашау турында, байлык туплау турында гына кайгыртып яшәүче кеше. *Мондый корсак коллары бер читтә калдылар.* Г.Ибраһимов. *Ахирәте шигърият таганында атына, анда исә ашау-эчү мәсьәләләре – «корсак коллары»на хас нәрсә дип тәнкыйтьләнә иде.* Н.Гыйматдинова. *[Хәзрәт] күп ашауны, тәмлетамаклыкны, корсак колы булуны зур түбәнлек саный ---.* Р.Әмирхан. **Корсак күтәрү** Корсаклы (*2 мәгъ.*), йөкле булу, балага узу турында. *[Люда:] Син нәрсә ачык авызланып йөрдең? Башкалар әнә чип-чистамыни? Берсе дә корсак күтәрми.* Ф.Мәснәвиева. **Корсак симертү** *гади с. к.* **корсак үстерү**. *Милләтеңне белмәсләр, Гыйлләтене күрмәсләр; Җилкә, корсак симертеп Тик ятырлар тидия.* Г.Тукай. *Әгәр фәлән мулла, тәүбә-әстәгыфируллаһ, нәфе-*

*сен тыя алмый: авыл буйлап бәлеш-тән-бәлешкә корсак симертеп йөри --- икән, ул болай да халык теленә кергә, ә Габделҗаббарның төртмә теленнән Аллам үзе сакласын...* Идел. **Корсакта бүре концерты** *к.* **корсакта бүреләр улау**. *Өченче көн инде Хәлифәнең Корсагында бүре концерты.* Һ.Такташ. **Корсакта бүреләр улау** Бик нык ашыйсы килү. *Бәлкем, аның корсагында бүреләр улыйдыр.* Э.Касыймов. **Корсак туйдыру** 1) Ашауга булган ихтыяҗны канәгатьләндерү; ашау. *Имез, ана, имез! Син, үзеңнең имчәгеңнән аккан хәләл сөтләрең берлә, эш эшләп тамак туйдырачак, эш эшләп, әллә никадәр әрәмтамакларның корсакларын туйдырачак балаңны имез!* Г.Исхакый; 2) Билгеле бер һөнәр, кәсепнең яшәү чыганагы була алуы турында. *[Җаббар:] Ул музыкаң, ул рәсемең белән ни чыгарасың? Ул корсак туйдырамы?* Г.Ибраһимов. **Корсак тутыру** *гади с.* 1) Бик күп, туйганчы, гарык булганчы ашау. *Хакыңны ал хөр вакта, Берләшеп кал форсатта, Форсат бирмә корсакка: Корсак тулмас һич чакта.* Ш.Бабич. *Бары тик хәйлә дә алдау, үз корсакларын тутыру гына.* Т.Гыйззәт. *Корсагын тутырырга чирек кадак как кирәк.* Г.Коләхмәтов; 2) Йөклелекнең соңгы стадиясенә җитеп, корсак (*5 мәгъ.*) бик зур булу турында. *[Карчык:] Өстеңнән йөреп иреңнән корсак тутырган бер әшәке хатынның тумаган баласын кызганып, үзеңнекеләрне ятим итмәкче буласың түгелме?* Ш.Җиһангирова. **Корсак төшерү** Бала төшерү; аборт. *Аннары үзен, энисе белән минем эни район больницасына алып барып, корсагын төшерткәннәр.* Ш.Алпар. **Корсак үстерү** *гади с.* 1) Юанаю, симерү. *[Түрәләр] Гомер буе халык җилкәсендә утырып, менә моның кадәр корсак үстерәләр дә: «Корсак астын күптән күргәнем юк, күрсәгез сәлам әйтегез», – дип йөриләр.* М.Кәбиров. *– Габдрахман абзый, мин сине бик хөрмәт итә идем... әле дә ул уемнан кайтканым юк! – дип башлады Сафатдинның алагаем калынаеп, корсак үстереп җибәргән рәис кияве.* М.Шаһимәрданов; 2) Баю. *Туры кәсептән алай кеше корсак үстерә алмый.* Г.Ибраһимов. **Корсак шиңү** *гади с.* 1) Ябыгу. *[Мәхлукулла бай] --- корсагы шиңүдән куркып, андаен нәрсәләр артыннан йөреп башын агарттырмаска тырыша иде.* Г.Тукай. *Әй, фәлән бай! --- Корсагың шиңгән, төсең беткән... Ничек булды болай?* М.Гафури. *[Гәрәй Рәхимнең] Югары Совет ашханәсендә тукланып, матур гына түгәрәкләнеп килгән корсагы кадакка эләккән футбол тубы сыман шиңгән.* М.Галиев; 2) *ирон.* Ярлылану

**КОРСАК ТИФЫ** *и.* Югары температура, көчле баш авырту, эч китү кебек билгеләре булган йогышлы авыру. *Бер фельдшер, нигәдер, кешене корсак тифыннан тозлы кыяр алып кала дигән «даһи» карарга килгән.* Ватаным Татарстан. *Җылы якларда, гадәттә, корсак тифы һәм гепатит А чире киң таралган.* Кәеф ничек?

**КОРСАКЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) *шаярт.* Балага узу, авырга узу, корсакка калу, йөккә узу, йөккә калу

2) Симерү, корсак үстерү

3) Корсак төсле булып, алга табан кабарып чыгып тору. *Юлның ике кырыеннан бик оста куелган арыш кибәненең корсагы шикелле корсакланып чыккан куе матур яшел яфраклар белән агачлар тезелеп киткән.* М.Гали

**Корсаклана бару** Акрынлап корсаклану

**Корсаклана төшү** Берникадәр тагын да корсаклану

**Корсакланып бетү** Бик ямьсез булып, бик нык корсаклану

**Корсакланып тору** Корсак төсле чыгып тору

**КОРСАКЛЫ** *с. сөйл.* 1) Зур, юан корсагы булган. *И калын корсаклы бай, корсаклы һәм «инсафлы» бай. Ай буенча ач торып, ачлар хәлен сизденме, әй?* Ш.Бабич. *Күп бала-чагалы башка кешеләрнең дәү корсаклы, шешенгән битле балалары ризык өмет итеп кулга карап торганын күрсәм, йөрәкләрем телгәләнә иде.* Мирас

2) Авыры, көмәне булган; йөкле. *Әйе, ул корсаклы... Менә бераздан соң аның сары гына, йомшак кына бер баласы була, юк, аныкы түгел, Аннаныкы.* Г.Исхакый. *Чөнки Җәмилә күптән корсаклы (авырлы) ---.* М.Гали. *Малайның эшкә кулы ятып торганлыгын шәйләп алган икән ич Шахразыйның дәү корсаклы (көмәнле) килене дә.* М.Шаһимәрданов

**КОРСАР** *и. ит. иск.* 1) Диңгез юлбасары, пират

2) Юлбасарлар судносы

**КОРСЕТ** *и. фр.* 1) Билне, гәүдәне тартып торып, матур күрсәтсен өчен киелә торган киң тыгыз билбау. *«Ком сәгате»н хәтерләтүче буй-сын. --- Димәк, иң нәфис фигура дигән сүз бу. Әлеге буй-сынга ия булучыларга корсетлы күлмәк сайларга киңәш итеlә.* Кәеф ничек?

2) Дәвалау максаты белән кулланыла торган каты бандаж (умыртка сөяге авырткан яки кәкрәя башлаган вакытта киелә). *Автокреслосыз йөрүдән күп очракта балалар интегә. Аларга бер ай хастаханәдә ятарга, аннан соң корсет киеп йөрергә туры килә.* Шәһри Казан

**КОРТ** I *и.* 1) *зоол.* Озынча гәүдәсе белән боргаланып яки бер җыерылып, бер сузылып хәрәкәт итә торган умырткасыз тереклек иясе; бөҗәкләрнең курчакка әйләнер алдыннан булган бер стадиясе – бик хәрәкәтчән һәм күп ашаучан личинка; *русчасы:* **гусеница**. *Төшемә карт имән кәүсәсе буенча үрмәләгән дүрт күбәләк корты белән шуларны куып баручы чаян керде әле.* Ә.Гаффар. *Шурик сызлана-сызлана борылып караса, җирдән, ашыгып, кәбестә күбәләге корты юлны аркылы чыгып бара.* Х.Ширмән. *Ә иң шаккатырганы шул булды: героебыз үз фатирында махсус савытларда кошлар өчен кортлар үрчетә ---.* Ватаным Татарстан

2) *сөйл.* Умырткасыз яки аяксыз, яисә бик вак аяклары булган кечкенә гәүдәле, күпчелек очракта азык-төлектә һ.б.ш. хасил булып, аларга зарар китерә торган хайваннарның гомуми атамасы; гомумән, вак паразит бөҗәк. *Шома чырайларында мәсхәрәле елмаю уйнатып, җыелган халыкка җирәнеп карыйлар. Ни тели бу тирес кортлары?* Р.Зәйдулла

3) Элпәканатлылар отрядыннан чәчәк нектары һәм серкә җыеп, нектарыннан бал, серкәсеннән чыршын

эшләп чыгара торган бөҗәк; бал корты. *Әнә күрәсезме, кара гына, шома гына бер эшче корт өй тирәсендә әйләнә: өйгә керергә исәбе ---.* А.Алиш. *Бабай, бабай, корт чакты!.. Акырмале шулчаклы! Корт чаккандыр бик белеп, Йөрмә бакчага кереп ---.* Мөҗәһит. *Умартада яшәүче кортлар умарта авызы янына берничә каравылчы куя, ә алар исә очып килгән һәр кортны күздән кичерә, исни.* Ватаным Татарстан

4) Яфрагашар коңгызлар семьялыгыннан бәрәңге, томат, баклажан, сирәк кенә тәмәке яфраклары белән туклана, авыл хуҗалыгына зур зыян китерә торган бөҗәк; бәрәңге корты; колорадо коңгызы (гадәттә канат ярмаганнары тур.). *Бәрәңгене корт басса, хуҗа аларны чүпли?* М.Шаһимәрдәнов. *--- җәй буе урталай бөкләнеп чүбен чистарт, корты белән көрәш, көзен кәкрәеп чүплән кертеп бушат та, килосын ике сум илле тиеннән «талап» китүчеләрне зар-интизар белән көтеп алып, шуларга капчыгы-ние белән бүләк итеп җибәр!* Авыл утлары

5) *күч.* Кеше хисабына көн күрүче, әрәмтамак, паразит. *– Октябрятлар оешмасы – большевистик сәяси оешма, анда кулак көчекләренә, мәчет кортларына урын юк, – диде директор, укытучыга мөрәҗәгать итеп, – бу мәсьәләне тиз арада хәл итегез.* Казан утлары

6) *күч. сөйл.* Нинди дә булса эш белән артык мавыккан, бик еш шул эш белән мәшгуль булган кешегә карата көлеп, мыскыллап яисә шаяртып әйтелә. *[Әйшә:] Акча санаучы берәүгә бирерләр дә... Шунда акча кортлары үрчетеп гомерем үтәр.* Т.Миңнуллин. *Мирныйның маршал Жуков урамына урашкан китапханәсеннән дә, җәй көне булуга карамастан, балалар өзелеп тормаган. --- Хәбәрчебез шундый «китап кортлары»н, ягъни китап сөюче балаларны – --- рәсемгә төшереп алды.* Яшел Үзән

7) *күч.* Борчылу, икеләнү, шикләнү, газаплану кебек хисләр; шундый халәт турында. *Корыт җирдән языкның кортларын син, Очыр җилгә аларның йортларын син ---.* С.Рәмиев. *Шушы көннән, бер үк вакытта сөенечле һәм көенечле көннән башлап, Мәхмутовның күңеленә шик корты белән бергә курку керде ---.* Р.Мирхәйдәров. *– Ә тәнне-җанны корт басса, аларны ничек чүпләргә? --- – Җандагы кортларны чүпләр өчен кирәк дин!* М.Шаһимәрдәнов

◊ **Корт кимерү** Нәрсә өчендер яки билгеле бер сәбәпләр аркасында борчылу, хафалану һ.б.ш. хисләргә бирелү турында. *Мәзиннең башына яңа бер уй төште, аны комсызлык корты кимерә башлады.* М.Галәү. *Сөйгәнемнең җанын көнчелек корты кимергән кебек тоелып, бер төнне үз теләгем белән, җаным-тәнем белән яратып хатыны булдым.* Кәеф ничек?

**КОРТ** II *и. махс.* Ачыган сөтне сүрән утта кызыл төскә кергәнче озаклап кайнатып әзерләнгән ризык; кызыл эремчек. *[Айбала] Тукалның кушуы буенча, тирмәдән әле кибеп бетмәгән кортларны кояшка чыгарды, --- берничә көн буенча җыелган сөттән эремчек кайната башлады.* Г.Ибраһимов. *Шарлыкны чыккач, аларның азыклары бөтенләй бетте. Барлык булган ризыклары – таш кебек булып каткан алты баш кипкән корт калды.* З.Зәйнуллин. *Каймагын аертып, эремчек ясап, чебиләргә ашата, кайберәүләр эремчектән корт кайната башлаган.* Ватаным Татарстан

**КОРТ** III *и. ингл. спорт* Теннис уены өчен махсус мәйданчык. *Өч корттан торган комплекс «Газпром – балаларга» программасы нигезендә сафка бастырылган иде.* Мәдәни җомга

**КОРТ АЕРУ** *ф.* Яңа күч ясап, ана корт янына җыелу һәм төп умартадан аерылып чыгу; бала аеру. *--- тәҗрибәле умартачы тиздән корт аеру процессы башланачагын аңлый.* Ватаным Татарстан

**КОРТ АНАСЫ** *и. зоол.* Озынча корсаклы иң зур умарта корты; ана корт. *Чиләкләргә бал алып, корт анасын күче белән тубалга җыеп, дуслар Карлы тавы буена киткәннәр.* Риваять. *– Корт анасы үзенең тышкы кыяфәте белән үк аерылып тора, – дип аңлата һәвәскәр умартачы.* Ватаным Татарстан

**КОРТ АКЧАСЫ** *и. этн. эвф.* Кияү егет ягыннан килгән кунаклар яки кияүнең туганнары тарафыннан, үзләре бүләкләнгәннән соң, тәлинкәгә яисә подноска җавап итеп салынган акча

**КОРТАШАР** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан гәүдәгә зур булмаган, вак бөҗәкләр белән туклана торган сайрар кош; *русчасы:* **щур**. *Артыш җиләген --- төньяктан кайткан чәрелдәвек, карабүрек, корташар ярата.* Г.Хәсәнов

**КОРТБАШ** *и. этн.* Күз тимәсен өчен, сабый балаларның баш киеменә тагып куела торган әкәм-төкәм кабырчыгы. *Сәҗидә апасы үз кулы белән тегеп куйган корт башы бөтен авылда бер аның кәләпүшендә генә иде.* Ә.Фәйзи. *Бала чакта кызларга ситсыдан такыя ясаганнар. Аның маңгай өлешенә вак тәңкәләр, төймәләр һәм корт башлары тегелгән була.* Р.Мөхәммәдова

**КО́РТИК** *и. рус* Хәрби Диңгез Флоты офицерлары бил каешларына тагып йөри торган кыска хәнҗәр формасындагы салкын корал. *Иң башта билгә тагып йөри торган офицер кортигы күземә ташланды. Кынысыннан чыгарып, кортикның йөзен тикшереп карадым.* М.Юныс

**КОРТКА** *и. сөйл. к.* **карчык**. *Алла сакласын, кем, кортка, сыерыгызның хәле яман.* К.Тинчурин. *Янә илле тәңкә куша ир. Кортка исә тагын иллелек таләп итә.* М.Шаһимәрдәнов

**КОРТКЫЧ** *и.* **1.** 1) Игеннәргә, урман-бакча байлыкларына, хуҗалыккөнкүреш әйберләренә зарар китерә торган җәнлек, бөҗәк һ.б.ш. *Эт, шаян һаулап, тычкан өстенә сикерде һәм инде оясына килеп җиткән корткычны борыны белән җиңел генә төртеп җибәрде.* Г.Гобәй

2) *күч.* Халыкка, дәүләткә зарар китерә, зыян сала, начарлык эшли торган кеше. *Гитлер – җиһан корткыч – аның саен ярсуын арттырды.* Г.Гобәй. *Еллар үткәннән соң Сафия аша Лутовның гаебе фаш ителеп, корткычлар кулга алыналар.* Г.Нигъмәти. *Ул арада Казаннан тагын вәкилләр килеп тулды. «Район оешмаларында корткычлар утыра, хәзер үк аппаратны алардан тазартырга кирәк, менә исемлек», – диделәр.* И.Салахов

3) *күч. сөйл.* Нәрсәгә дә булса зарар китерүче, зыян салучы кеше (гадәттә көлеп, шаяртып әйтелә). *Таптама бодайны, корткыч!* Г.Гобәй

**2.** *с. мәгъ.* 1) Зарарлы, зарар китерә, зыян сала торган (җәнлек, бөҗәк һ.б.ш.). *Ә ул иген корткыч кортларны Чүпләп йөрер синең артыңнан.* М.Гафури. *[Кәкрүшкә:] Урманны корткыч бөҗәкләрдән саклыйм...* Р.Харис

2) *күч.* Халыкка, дәүләткә зарар китерә, зыян сала, начарлык эшли торган (кеше тур.). *Прологта поручик Кудрявцев ролендә күренеп үткән Лутов әсәрдә үзәк тресттан килгән корткыч инженер итеп гәүдәләндерелгән.* Г.Нигъмәти

**КОРТКЫЧЛЫК** *и.* Зыян салу, зарар китерүгә юнәлтелгән җинаятьчел эшчәнлек. --- *Искәндәр бер заводтан куыла, икенчесеннән дә кысрыклана, ул үзе дә корткычлык эшен көчәйтә, үзенең --- гаебен ачардай кешеләрнең авызын акча белән каплый.* Г.Нигъмәти. *Бу тактага аның корткычлыгы --- кара дегет белән язылган.* Ф.Кәрим. *[Гомәр Гали:] Юк, бу һич мөмкин түгел. Монда бер корткычлык бар.* И.Салахов

**КОРТЛА́У** *ф.* 1) Үзендә кортлар барлыкка килү. *Елына бер балтыраган ашамаган кешенең эче кортлар, имеш.* Әйтем. *Ит үзеннән кортлый, ди. Шуның күк, бу кибәк баш динчеләр үзләрен үзләре таптаганын аңламыйлар.* Г.Тукай

2) *этн. эвф.* Кияү йортында туйның икенче көнендә туйда кергән бүләкләрне карау; бирнә багу

**Кортлап бетү** Бик нык кортлау; барысы да кортлау. *Өлгергәнче [алманың] яртысы кортлап бетәчәк.* И.Гази. *Түтәлләрне әниләре Тикшерсәләр – Кортлап беткән андагы бар Яшелчәләр!* Ә.Исхак

**Кортлап йөрү** Кортлаган халәттә булу; әле, хәзер кортлау. *Утырдың да син дә үзең теләп Ятлар арбасына, ялгышып; Язмышыңа сылтап, йөрдең кортлап, Кара йөзләр белән ярашып.* Р.Сафин

**Кортлап тору** Даими яисә әледәнәле кортлау; кортлаган халәттә булу. *Кортлап торган кап-кара сазлы су эчендә тәүлек буе лычкылдап йөз-йөз дә, чыккач утырып кибенерлек бер коры урының булмасын*! Ә.Фәйзи. *Авыз сулары корып, күчтәнәчне «кортлап» торган без тоткыннарга Алкин староста әүвәле берәм-берәм сохарины, бавырсакны өләшеп чыкты ---.* И.Салахов

**Кортлап яту** Кортлау процессында булу. --- *анда көнкүреш калдыклары белән рәттән хайван үләксәләре дә, күмелмичә, шул килеш сасып, кортлап яталар.* Бөгелмә авазы

**Кортлый бару** Тагын да кортлау; акрынлап кортлау. *Корылык булгангамы – игеннәр кортлый бара*

**Кортлый башлау** Кортлары барлыкка килү. *Тояк арасы ярылып, кортлый башлаган.* Т.Гыйззәт. *Китап корты була торгач, үзең дә кортлый башладыңмыни?* Ф.Баттал

**Кортлый бирү** Тагын да кортлау; бернигә карамый кортлау

**Кортлый төшү** Бераз кортлау; тагын да берникадәр күләмдә кортлау. *Кортлый төшкән бәрәңге бакчасы*

**КОРТЛЫ** I *с.* 1) Кортлаган, корт төшкән. *Кызыл алманың эче кортлы булучан.* Әйтем. *Кортлы алмалар шакшок коелдылар.* И.Гази

2) *күч. сөйл.* Тик тора белми торган, кыбырсык (кеше тур.). *Бер кортлы кәҗә бөтен читәнне җимергән.* Мәкаль. *Чәчәкләрне алар шиңдермәсен, Бәйләм-бәйләм, өем эче – бәйрәм! Иштең, ахры, күңел каланчасын, Кортлы җаным тәмам кечерәйгән.* Ф.Яхин

**КОРТЛЫ** II *с.* Корт II кушылган, корт белән катнаштырылып ясалган. *Гөлгенә түти, менә монда улыма дип алып килгән вак бәлешләр, юачалар, төшләр, чәкчәкләр, кортлы майлар бар.* М.Гали. *Яңа гына мичтән җылынып чыккан вак бәлешләр, юачалар, кәлҗемәләр, салкыннан кергән кортлы май белән кәрәзле бал да килеп утырдылар.* М.Галәү. *Чәй янына куела торган балан, эремчек бәлешләре, баллы паштет, кортлы сумсалар, чәкчәк, бавырсак, кош теле шикелле татлы ризыклар өчен бодай онын җиз иләктән генә илиләр.* Г.Галиева

**КОРТЛЫГАН** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан көпшәсе эчендә һәрвакыт бер үк төрле кара корт була торган үлән үсемлек; аю көпшәсе; *русчасы:* **борец жёлтый**, **аконит**

**КОРТ ТӨШҮ** *ф. к.* **кортлау**. *Көз көне, быел уҗымга корт төшкәнлек сәбәпле, кырдагы арышларга карап йөрәк кенә әрни иде.* К.Тинчурин

**КОРТЧА** *и. зоол.* Авыл хуҗалыгы культураларына зур зыян китерә торган бөҗәк; *русчасы:* **червец**

**КОРТЧЫ** *и.* Умартачы. *Иртәнге якта гына кортчылар умарталарны карабодай басуына күчергәннәр иде. Менә бит...* М.Мәһдиев

**КОРТЧЫЛЫК** *и.* Умартачылык. --- *чуаш, мари, удмурт, мордва халыкларының бабалары күбрәк урман, аучылык, балыкчылык, кортчылык белән шөгыльләнгән.* М.Әхмәтҗанов. *Ул [Рашат] үзе ирешкән уңышларның серен башкаларга да ача, вакытын, көчен кызганмыйча, кортчылык белән шөгыльләнергә теләүче кешеләргә яңа корт гаиләләре аерып бирә.* Ватаным Татарстан

**КОРУ** I *ф.* 1) Тиешле юешлеге, дымлылыгы бетеп, артык нык кибү, бик корыга әйләнү. *Җәйнең матур яшелләгеннән соң, каралып, корып, тәмуг идәне төсенә әйләнгән кара пычрак җир йөзе яңа яуган кырпак кар белән ак ефәккә чолгангандай матур сыйфат алган...* Г.Ибраһимов. *Хуҗаның теле корып, авызы кипкәч, Уйлады хәл җыярга саф су эчеп.* М.Гали

2) Парга әйләнү, кибү (дым, сыеклык, су тур.). *Шуның аркасында Кызыл таш, Куянлык, Күлбаш сазлыклары корый.* К.Тинчурин

3) Сулу, тереклек итүдән туктау (үсемлекләр тур.). *Сабагыннан өзелеп җиргә төшкән яфрак кебек корып кипкәнен...* М.Гали. *Җил шыр ялангач кыр буенча чаба, юлында очраган шәрә куаклар арасында сызгыра, корыган үләннәрне һавага күтәрә.* Г.Әпсәләмов. *[Чәнси:] Үлән йолкырга, корыган ботак-сатак җыярга кирәк.* Н.Фәттах

4) *күч.* Авырудан, авыр эштән, төрле рухи кичерешләрдән ябыгу, саргаю. *Житмәсә, улы һәм килене хәсрәтеннән Мәүлиха да бик тиз сыгылып төште: кипте, корды.* М.Шаһимәрдәнов

5) *күч.* Авыру, паралич сугу аркасында, кешенең кул, аяк һ.б.ш. әгъзалары

хәрәкәтләнүдән туктау, тереклек көчен югалту. *Хәзер халык Майшәкәрнең үзеннән көлә инде: «Башта Әлфиягә ялган гаеп такты, аннары каргады; гөнаһысы, каргышы үзенә төште: кулы корыды, авызы кыегайды...».* М.Шаһимәрдәнов. *[Хәзрәт:] Манараларны кискән, чиркәүләрне бетергән кешеләргә нәрсә булганын ишетеп, укып торабыз. Кемнеңдер кулы корыган, кемдер аяксыз калган яисә башка бер бәлагә юлыккан.* Ватаным Татарстан

6) *күч.* Үлеп бетү, юкка чыгу, онытылу, югалу. *Әле ярый атам безне алып китеп коткарып калган. Әгәр дә шулай булмаса, нәселебез тамырдан корый иде бит...* И.Хуҗин. *Соңрак ул [Сталин] «кушканны үтәүче»ләрнең үзләренә дә чират җиткән, чират җитмәгәннәрен халык каргышы, милләт нәфрәте куып җиткән, нәселләре корыган, юкка чыккан.* Ф.Бәйрәмова. *Аллаһы Тәгалә кушканнарны мулла үтәмәсә, аның муллалыгы корый, ә мулла кушканнарны халык үтәми башласа, шул халыкның тамыры корырга тотыначак!* М.Шаһимәрдәнов

7) *күч. сөйл.* Бетү, юкка чыгу. *[Шамил:] Беркөнне каравылчы өендә бу сөйләнеп утыра. Хәзерге заманда укырлык шагыйрьләр юк, ди. Калмады берәү дә, ди. Талантлар корыды, ди.* Мәйдан

8) *күч. сөйл.* Сүнү, сүрелү. *[Карт:] Яшьләр киләчәккә һәрвакыт зур ышаныч белән карыйлар. Өметегез корымасын!* И.Хуҗин

**Корый башлау** Корырга тотыну. *[Тирәкнең] зур баз казыганда күп кенә тамырларын кистеләр, шуннан корый башлады.* Ә.Еники

**Корый төшү** Тагын бераз кору

**Корып бетү** Бик нык кору; ахырга кадәр кору; корып юкка чыгу. *[Фатыйма] үзе дә кибеп, корып беткән инде.* Г.Камал. *Бернәрсә дә юк монда, хәтта таллар, Ак каеннар корып беткәннәр.* Ә.Ерикәй. *Муен тамырларым корып бетте, Бер минут та рәхәт тормадым.* Җыр

**Корып калу** Корыган хәлгә килү. *[Әтисе Рәмиләгә:] Агачларыбыз авырый, яфраклары саргая, үзе корып кала.* З.Әхмәров

**Корып тору** Кору хәлендә булу; даими яки әледән-әле кору

**КОРУ** II *ф.* **1.** 1) Төзү, салу; торгызу. *Омтыладыр Адәм Җир йөзендә Бәхет сарайлары корырга.* И.Юзеев. *– Гөлләр, – диде Газинур, аның ялтырап торган күзләренә карап. – Димәк, безнең колхозда чынлап та электростанция корып була?* Г.Әпсәләмов. *Кырыс табигатьле дала шартларында шәһәрләр кору, иген игү мөмкин булмый.* Н.Фәттах // Ясау, төзү. *Хатын-кыз өйне корып йөргәндә, Сарсымбай үзе әле яңа килеп җиткән маллар – бияләр, куйлар, сыерлар арасында иде.* Г.Ибраһимов. *Син кыр булсаң, кырга килеп, матур чатыр корырмын.* Ә.Ерикәй. *Моңарчы палатка корып та яшәгән чак булды.* Г.Ахунов

2) Ясау, эшләү. *Күке оя кормас.* Мәкаль. *Тузды микәнни кыя да, кошлар кормый оя.* Ф.Яруллин. *Кабер тирәсенә агач утыртып, чардуган корганнар иде.* Г.Бәширов. *Ул [үрмәкүч] аны [пәрәвезне] үзенә торак һәм ау ятьмәсе кору өчен файдалана.* Биология. Хайваннар

3) Булдыру, барлыкка китерү, нигез салу, оештыру (дәүләт, оешма һ.б.ш. тур.). *[Фазыйл] да калышмаска тырыша бугай – әллә нинди оешмалар корып, төрек-татар байрагы дип, дин, милләт өчен бергә барыйк, аерылмыйк, дип лаф ора.* Г.Ибраһимов. *Корыр идем анда [утрауда] үз илемне, «Гаделлек!» дип язып нигезенә. Яманлыкны тамыры белән йолкып Батырыр идем Үлем диңгезенә.* Ф.Яруллин. *Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә, авыр безгә, авыр синсез тору. Бер егылгач, авыр икән тору һәм яңадан дәүләтеңне кору.* Р.Ягъфәров

4) Оештыру, күрсәтү, тәкъдим итү. *Әмма бер көн Әлмәнең сандык-сәхнәдә корган тамашасы хуҗабикәнең җен ачуларын чыгарды.* С.Лашманчы. *Ресторандагы вакыйганың импровизацияле тамашага корылган булу ихтималын да күз уңыннан ычкындырмый [командир].* Безнең мирас

5) Булдыру, башлап җибәрү. *[Хафиз:] Әгәр син миңа чыксаң, без шундый бәхетле тормыш корырбыз, Гөлзадә.* Р.Ишморат. *Җимерсәң иде шуларның Дөньясын пыр туздырып!.. Эх, гомер итсәң иде бер, Үзеңчә тормыш корып!* Х.Туфан. *Шунысы кызык: загссыз гаилә корган ирләрнең 70 проценты, ә хатын-кызларның бары тик 10 проценты гына үзләрен иркле дип саный.* Акчарлак

6) Билгеле бер материал нигезендә иҗат итү. *Тәнкыйть язган шагыйрь, беренче карашка, өстән-өстән, әмма характерлы якларны сайлап, бөтенлек тойгысы тудыра, гомумиләштерә, үз хис дөньясына корып сурәтли, аның тәнкыйть мәкаләсе аерылып тора.* Ш.Галиев

7) Берәр нәрсәгә таяну, нигезләнү; иҗат итү. *[Дума члены:] – Русиянең идарәи мәшрутасы (конституциягә шарт ителгән) нинди әсаска корылган? – дип сорады.* А.Таһиров. *Татар теленең имласын камилләштерү, латин графикасы нигезендә кору, ул графикага кире кайтуның ролен аның тарафдарлары да, дошманнары да яхшы аңлый.* Ә.Кәримуллин. *Әледән-әле сүзлекләр, яңа технологияләргә корылган дәреслекләр эшләнә.* Мәгърифәт

8) Планлаштыру, башкару. *Шул безнең Гәүһәрнең дә тәртәсен уңга бордырырга план кора, бугай...* Г.Ибраһимов. *Кайдадыр яңгыр ява булса кирәк, йомшак кына гөлдерәү ишетелеп ала. Мондый вакытта киләчәккә план кору уңай.* М.Мәһдиев

9) Җыю, үткәрү (мәҗлес, туй, уен, әңгәмә һ.б.ш. тур.). *Октябрь бәйрәмендә, бик шәп мәҗлес корып, электән калган бу шыксыз тапны бәйрәм сые белән бөтенләй юып ташлаганнар.* Г.Бәширов. *Ә мин инде чаңгыларда түгел, Акбүз атта гүя элдерәм. Токмач кисеп, якты табын корып Көтеп тора мине бергенәм.* Р.Низамиев

10) Уйлап чыгару, оештыру. *...Ярлы өйләр пычак кайрыйлар, Ак сарайлар ашыгып хәйлә кора.* Х.Туфан. *Ялкыннары сиңа тимәсен дип, юлларыңа кордым мең киртә.* Ф.Яруллин. *Нинди генә фәлсәфә корсак та, без төп сәбәпне урап үтәлмибез.* Мирас

11) Каплау, ябу, ышыклау. *Дөрес, тәрәзә пәрдәләрен үтүкләп корды, ак-*

*бурга крахмал кушып агартты, гомумән, адәм карарлыгы калмаган өебезне ялт иттерде.* Ф.Мансуров. *Бүлмәнең бер чатын аш ягы иттереп чолан ясаган, аны пәрдә белән корып куйган.* Ахир. *Син телдәдең Якты көннәр, таңнар атуын. Теләмәдең мескен милләтеңнең Пәрдә корып йоклап ятуын.* З.Мөхәммәтшин

12) Ясау, эшкә яраклы хәлгә китерү. *[Солтан:] Мин алты тиен сорадым. Ул бишкә менде. Шуңа килешеп, мин ике парна арасында Гыйрфан байның ындырында машина кордым.* Г.Ибраһимов

13) Яраклаштыру, көйләү. *[Солдатлар] сорап та тормыйлар, үзләренең контроль аппаратларын кыр телефонына корып, «кыр телефоннарын өзеп йөрүче шпион» тотканнарын белдерәләр.* А.Таһиров

**2.** *ярд. ф. функ.* Абстракт исемнәр янында тезмә фигыль составында: шул исемнән аңлашылган эшне башкару. *Патша азса, бөтен илгә килә афәт, Халык азса, патша башы була харап. Иле нинди булса, патшасы да шундый, Надан патша белән бәхет корып булмый.* Котадгу билик. *Ә Шәвәли кызының «нифтече» егет белән кәеф-сафа коруы турында өйдән өйгә яман сүз таралды.* Г.Ахунов. *Ни ул Тимерхан белән кара-каршы утырып сөйләшми, ни ул киңәш кормый, ни сүзгә колак салмый.* М.Мәһдиев. *«Москвич» телефоннан еракта, ниндидер җитди кыяфәтле кешеләр белән гәп кора, аңа комачауларга базмаслар, миңа калса, шылтыратырга мөмкин...* Р.Мирхәйдәров

**Кора башлау** Корырга керешү. --- *ул [Мөхәммәтхан] үзе генә калган вакытларда, җанашы Фәхерниса хакында төрле уйларга чумып, өйләнү турында планнар кора башлады.* К.Тинчурин. *Бу ике кешедән, ничек кенә, кайда гына туры килмәсен, үч алырга уйлады ул. [Һашимов] Хәзер шуңа планнар да кора башлады.* А.Алиш

**Кора тору** Башка бер эш-гамәлгә кадәр яки шул башкарылган арада кору

**Корып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә кору. *Алар килгәнче, Шәяхмәт белән икесе генә киңәш корып алдылар.* М.Мәһдиев. *Барган көнне төнгә хәтле унике кешелек зур палатка корып алдык.* А.Таһиров

**Корып ату** Бик тиз кору. *Иптәшләр чатыр корып аттылар да учак ягарга тотындылар.*

**Корып бетерү** Тулысынча корылган хәлгә китерү. *Алай-болай корып бетергәч, яр буена утырдык та тәмләп кенә «Фетяска» дигән шәраб белән сыйланабыз.* Т.Миңнуллин

**Корып бетү** *сөйл. к.* **корып бетерү**. *Муллалар үз мәхәлләсендә ничә кыз биреләчәген, ничә килен ярәшеләчәген күптән санап куеп, ничаклы никах вә садака акчасы керүен әллә кайчаннан хисаплап, тумаган балага бишекләр корып беткәннәр иде.* Г.Ибраһимов

**Корып җибәрү** Тиз арада яки кинәттән кору. *Шәп-шәрә урынга тормыш корып җибәрүе бик авырга килсә дә, Тимери рәнҗемәде.* Г.Бәширов. *Фәндиләнең тормыш корып җибәрүе, өстәвенә иренең дә ипле-итагатьле кеше булуы сәүдә эшендәге башлыкларга кулай булып чыкты.* Г.Ахунов. *Көн дими, төн дими, ун ел буена урман төпләгән, соңыннан шунда нигез корып җибәргән.* Г.Әпсәләмов

**Корып карау** Булу-булмавын тикшерү-сынау өчен кору

**Корып кую** Тиз генә кору яки алдан кору. *Ботак-сатактан, салам-куралардан торган ояларны һәрбер агач ботаклары саен һәм көн саен яңадан-яңаны корып куеп була.* В.Имамов. *Ашап-эчеп яңалыкларны сөйләшеп алгач, әнкәсе Зиннурга сәелханәдә урын җәйде, чебен-черки бимазаламасын өчен, чатыр корып куйды.* Я.Зәнкиев. *Югыйсә мин үземчә бер план да корып куйдым инде.* Г.Галиев

**Корып тору** Даими кору; кору белән мәшгуль булу. *Байтак кына вакыт матур гәп корып тордык.* А.Хәсәнов. *Нишләсен солдат?! Озак план корып торырга вакыты да юк әле аның. Ә «тел»не бу төндә алырга кирәк.* Шәһри Казан

**Корып чыгу** Бер-бер артлы барысын да кору

**Корып яту** *сөйл.* Кору процессында булу. *Хәзер үк инде алар авыл читендә такта щитлардан берьюлы әллә ничә барак корып яталар.* Ф.Латыйфи. *Син белмисеңдер әле, монда бит Казавиастрой, Казмаштрой, Казвагонстрой корып яталар.* К.Миңлебаев. *Чуен коючы оста Бәкер белән Яван Фатий яңа ташаткыч корып яталар.* М.Хәбибуллин

**КОРУ** III *ф.* 1) Берәр төрле коралны заряд (снаряд, патрон) куеп, киереп, тартып һ.б.ш. юл белән хәзерлек хәленә китерү. *Пулемёт патрон тезелгән озын киндер тасманы тешләп алган, автомат рәвештә атарга көйләп, корып куелган иде инде.* М.Әмир. *Ул унатарын яңадан корды, бу юлы аягына ипләбрәк баскан хәлдә, кулын ышанычлырак тотарга тырышып һәм яман да үҗәтләнеп, күнегүен кабатлады.* Т.Әйди. *Ибрай әллә нишләп китте: моңарчы йокыга талыр алдыннан, аннары уянгач, ул беркавым уендамы, хыялындамы, өнендәме шалт та шолт итеп винтовка кора ---.* Ә.Гаффар

2) Нәрсәне дә булса көйләп, эш башкарырга әзерләп кую. *Радиалгычны кыска дулкынга корып хәбәрләр тыңлау*

3) Электр энергиясе туплау

**Кора башлау** Корырга керешү. *Бүре дисәң – бәләкәй, дип сөйләнә-сөйләнә, бабай мылтыгын кора башлаган.* Р.Батулла

**Кора тору** Башка бер эш-гамәлгә кадәр яки шул башкарылган арада кору

**Корып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә кору

**Корып ату** Бик тиз кору

**Корып бетерү** Тулысынча корылган хәлгә китерү

**Корып җибәрү** Тиз арада яки кинәттән кору

**Корып карау** Булу-булмавын тикшерү-сынау өчен кору

**Корып кую** Тиз генә кору яки алдан кору

**Корып тору** Даими кору; кору белән шөгыльләнү

**Корып чыгу** Бер-бер артлы барысын да кору

**КОРУЛЫ** I *с.* Корып, ябып куелган (пәрдә, чаршау тур.). *Өй эче ярыйсы яктырган, пәрдәләре корулы тәрәзәләр зәңгәрсу...* Ф.Мансуров

**КОРУЛЫ** II *с.* Корылган, заряд куелган (ату кораллары тур.). *Эчке Россия белән Себер арасында елкы сәүдәсе йөртүчеләргә ялланып, көзге суык яңгырларда, караңгы төннәрдә мал саклап, корулы мылтыгын төзәп, ат өстендә якты таңнар көтеп үткәрә...* Г.Ибраһимов. *Диңгезчеләр бушлаты һәм бескозырка кигән берәү ишек төбендәге корулы пулемёт артына ташланып, кисәтми-нитми, ярсып-ярсып атарга тотынды.* Ш.Шәйдуллин

**КОРУНД** *и. тамил* **1.** Алюминий окисеннан торган, кызыл якут, зәңгәр якут, топаз кебек төрләре булган бик каты минерал. *Шомарту өчен бөртекле абразив − корунд, карбокорунд яки тузандай алмаз кисәкчекләре кулланыла.* Төзү материаллары

**2.** *с. мәгъ.* Шул минералдан ясалган, шул минерал куеп эшләнгән. *Корунд инә озак вакытлар эшли алсын өчен, адаптерны пластинкага салмак кына төшерергә, уйнатудан туктаган вакытларда адаптерны тоткыч терәкләргә куярга кирәк.* Файдалы киңәшләр

**КОРЧАҢГЫ** *и.* **1.** 1) Корчаңгы бете тирегә үтеп керү сәбәпле, тәндә кычыту һәм куыклы тимгелләр барлыкка килү белән үтә торган йогышлы авыру. *Курамшин корчаңгыны бетерү өчен бармак та селкетмәгән ---.* Г.Ахунов. *Корчаңгы авыруын китереп чыгаручы корчаңгы талпаны да кеше өчен бик куркыныч.* Биология. Хайваннар. *Иртәгә Илмасны госпитальгә салалар, корчаңгы йоктырып кайткан.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Шундый авырулы кеше яисә хайван

3) *күч. гади сөйл.* Юньсез, булдыксыз, әшәке кеше. *Әй корчаңгы, алай кочаклыйлармыни аны.* А.Хәмзин

**2.** *с. мәгъ.* Шул авыру белән авырый торган. --- *җәй уртасы җитсә дә, [маллар] Якты-Күлдәге кебек симереп җитмәгәннәр, кайбер тайлар әле һаман да ябагаларын коеп, матурланып китә алмаганнар. Ара-тирә корчаңгы атлар да күренә.* Г.Ибраһимов. *Үрәтник, кигәвен куган корчаңгы ат кебек кыбырсып, ярсып, билендәге кәкре кылычын тартып алды, күзләрен акайтып кычкырды ---.* Ш.Шәйдуллин. – *Урыс малы дип, урысча атап йөртмәбез инде, үзебезчә булыр, – диде ул, корчаңгы сыерның маңгай уртасын кашый-кашый, каршы чыккан Вәрәкыяга елмаеп ---.* Р.Рахман

◊ **Корчаңгы тел** *гади с.* Күп сөйләргә яратучы кеше

**КОРЧАҢГЫ́ БЕТЕ** *и. зоол.* Кеше һәм хайван тәнендә корчаңгы авыруы барлыкка китерә торган паразит бөҗәк; *русчасы*: **чесоточный зудень**

**КОРЧАҢГЫ́ ТАЛПАНЫ** *и. зоол. к.* **корчаңгы бете**. *Корчаңгы талпаннары кешедән кешегә җиңел күчә.* Биология. Хайваннар. *Корчаңгы талпанының 20 ләп төре билгеле.* Сәламәт яшәү нигезләре

**КОРЧУ** *с. диал.* Вакчыл, бәйләнчек. *Холыксыз карт корчу булыр.* Мәкаль

**КОРША́У** I *и.* 1) Юка нечкә агач яки металлдан бөгеп эшләнгән бөҗра. *Ул шәрә тәненә тире алъяпкыч бәйли, җитү чәчле башына алюмин коршау киеп куя, авызына үзе ясаган төрепкәсен каба.* Т.Мөбарәков. *Хәзер ул өч зур һәм тугыз кечерәк өлешкә бүленгән хәлдә һәм көмеш коршау белән беркетелгән.* Инсан һәм дин

2) Мичкәгә, кисмәккә һ.б.ш.га кидереп, такталарын беркетү өчен бөгеп ясалган металл яки агач бөҗра. *Анда ике малай тәгәрмәч коршавы тәгәрәтеп килә иделәр, маңгайга-маңгай чәкәштеләр.* Ф.Яхин

3) *спорт* Пластмассадан, тимердән бөҗра формасында бөгеп ясалган спорт (гимнастика) снаряды. *Туп, коршау белән төрле хәрәкәтләр ясаган моржның һәр чыгышы көчле алкышларга күмелде.* Кызыл таң. *Коршау әйләндерү*

4) Тыгыз итеп кысып торган нәрсә, бәйләвеч. *Күзләрем яралы аякларыма төште. Алар пөхтә итеп, ап-ак бинт белән бәйләп куелган иде. Башымда да ниндидер коршау бар, ул да кысып бәйләнгән булып чыкты.* Г.Гыйльманов

5) Күзгә чәч төшмәсен өчен дугасыман формадагы хатын-кыз аксессуары

6) *күч.* Богау. *Богауларны киертергә, Теләгәнчә биетергә Уйлаган шаһлар Киде үзләре коршаулар.* Г.Камал. *[Гыйззелбәнат:] Арабызда синең күкрәгеңдә алтын тәрең, икона каршында чукынуларың, өстәвенә хатынлы булуың минем күңелемне дә, җанымны да тимер коршауда тотты. Сез дә шундый ук коршау кысанында булгансыз икән.* Г.Галиева

7) *күч.* Камалыш. *Коршау эчендә калу*

◊ **Коршау арасына кертү** Тәртипкә салу. **Коршау ату** *иск.* Бөлү, банкротлыкка чыгу. **Коршау сугу** Коршау кидерү, коршаулау. **Коршау сугып йөрү** Булмастай, мәгънәсез эш белән йөрү; эшсез вакыт уздыру. *Ераклардан Килгән зур минонос Мина куеп камый «Рәсәй»не. «Диңгез юлын коршап җиңәрбез!», – дип, Коршау сугып йөри крейсер.* Х.Туфан

**КОРША́У** II *ф.* 1) *к.* **коршаулау** (*1 мәгъ.*)

2) Нәрсә белән дә булса әйләндереп, тотып алу; чолгап алу, бәйләү. *Өй янында чебиләр өчен, иске читәннәр белән коршап, ялан ясадык.* А.Хәлим

3) *диал.* Чолгап алу, камап алу. *Ташландык нигезне агачлар коршаган*

4) *диал.* Япма ябу (киртә, салам һ.б. белән)

5) *диал.* Тышлау. *Фанер белән коршау*

**Коршап алу** Бар яклап та коршау; коршалган хәлгә китерү

**Коршап бетерү** Тулысынча, тәмам коршау

**Коршап килү** Билгеле бер вакыт дәвамында акрынлап коршау

**Коршап кую** Коршалган хәлгә китереп җиткерү

**Коршап тору** Даими рәвештә, вакыты-вакыты белән коршау

**Коршап чыгу** Һәрберсен, барысын да коршау

**Коршый бару** Эзлекле рәвештә, бер-бер артлы коршау

**КОРШАУЛА́У** *ф.* 1) Коршау кидерү, коршау салу, коршау сугу, коршау тарттыру. *Мичкәләре агач коршау белән коршаулау*

2) Каплап алу, басып китү. *Кап-кара кар коршаулаган кырдан Нәрсә эзлим соң мин? Сере ни? Артка карыйм – ара шундый ерак һәм алда да берни күренми.* Р.Зәйдулла

3) *диал. к.* **коршау** II (*2 мәгъ.*)

4) *күч.* Борчу

5) *күч.* Буйсындыру (уй-фикерләр, хәрәкәтләр тур.)

6) *күч. сөйл.* Юк-бар белән мәшгуль булу

**Коршаулап алу** Тиз арада коршаулау; коршауланган хәлгә китерү. *Ул завод биләмәсе исә биек таш койма белән коршаулап алынган иде.* Л.Хәмидуллин

**Коршаулап бетерү** Тулысынча, барысын да коршаулау

**Коршаулап кую** Коршауланган хәлгә китереп әзерләү

**Коршаулап ташлау** Тиз арада коршаулау

**Коршаулап тору** Һәрдаим, әледән-әле коршаулау

**Коршаулап чыгу** Башыннан ахырына, берәм-берәм коршаулау

**Коршаулый башлау** Коршаулауга керешү

**КОРШАУЛЫ** *с.* 1) Коршауланган. *Тимер белән коршаулы, өч урыннан йозакланган сандыгы икмәккә алыштырып алган метрлы тауар белән лык тулы иде.* Ш.Янбаев

2) *диал. к.* **корулы** I

**КОРШАУЛЫК** *и.* **1.** Коршауга яраклы яки кирәкле материал

**2.** *с. мәгъ.* Коршау ясау өчен билгеләнгән

**КОРШАУСЫЗ** *с.* Коршавы булмаган, коршау белән ныгытылмаган (мичкә, кисмәк, тәгәрмәч һ.б. тур.)

**КОРШАУЧЫ** *и. сөйл.* Коршау куючы яки коршау белән сәүдә итүче

**КОРЪӘН** *и. гар.* Мөселманнарның ислам дине кануннары турындагы изге китабы. *Кәгъбәтуллада бөтен җир йөзеннән җыелган хаҗилар Коръән укыйлар.* Ф.Әмирхан. *[Хөсәен:] Сиңа тагы яңалык әйтә алам: мөфти хәзрәтләренең егерме биш еллык юбилеенда үзенең гүзәл баритон тавышы белән Камил Мотыйгый әфәнде Коръән укыган.* А.Расих. *Яшен яшьниме соң, күк күкриме, Коръән сүрәсеме соң көйли? – Сәмруг канатыдай киң ачылган Китап Синең җаныңны сөйли.* Ә.Гаффар

**КОРЪӘ́НЕ КӘРИМ** *и. гар. кит. к.* **Коръән**. *Коръәне Кәримдә ятимнәргә карата булган хакларны үтәү кирәклеге турында әйтелә*

**КОРЪӘ́Н ЧЫГУ** *ф.* Берәүнең рухына багышлап, Коръәнне тулысынча укып чыгу; хәтем кылу. *Чәй эчкәндә, Вәли үзенең күпме Коръән чыгуын, --- кемгә ашка йөрүләрен сөйләде.* А.Таһиров. *Борһанетдин сугыш елларында бик изге эш эшләде: сугышта үлеп калганнарга Коръән чыкты, үлем-җитем килгән чакларда безгә ни эшләргә икәнен аңлатып бирде.* Г.Ахунов. *--- хатыны Шәрифәнең каберe нурлансынга, Коръән чыгуны авыл абыстаена йөкләп, озакка тукталмастан китеп тә барды.* Ф.Яхин

**КОРЪӘНХАФИЗ** *и. гар.* Коръәнне яттан белгән кеше. *Ул укуга гадәттән тыш сәләтлелек күрсәтә, коръәнхафиз булып җитешә.* М.Гайнетдинов. *Бу кешенең исеме «Ала күз Хафиз», үзе коръәнхафиз һәм мулла булган.* Казан утлары

**КОРЫ** *с.* **1.** 1) Юешләнмәгән, чыланмаган, су-дым үтмәгән. *Суда юынып алды, Өсте коры калды.* Табышмак. *Коры мүктә эз калмый.* Г.Әпсәләмов. *Аның киемендә бер саплам коры җеп тә калмаган иде бугай.* Г.Гыйльманов

2) Суы беткән, суы югалган (елга, коe һ.б.ш.). *Коры чокыр аркылы салынган күпердән узган чагында, клуб янында кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышларын ишетте.* Г.Әпсәләмов. *Авылны кап урталай телеп, сай гына коры елга үтә.* А.Гыйләҗев. *Мин яшен тизлеге белән клуб артындагы коры елгага, үзәнлеккә атылдым.* Р.Низамиев

3) Корып кипкән, утын итеп ягу өчен әзер. *Коры утын белән чи дә яна.* Мәкаль. *Шунда миңа [кешеләрнең] берсе әйтте: – Син үзеңне шулкадәр бердәнбер, бик кирәкле кеше дип белдеңме әллә? Синнән ут алгач та... Учакларыбызда коры утын булмаса, учак тергезә алыр идекме? – диде.* Ф.Яхин. *Кешеләрнең елан, ерткыч күп дип сөйли торган куркыныч урманнарга Зөһрәне, коры утыннар җыярга, юри җибәрә икән үги анасы.* Балачак аланы

4) Дым тартмаган, дым үтмәгән, дымыкмаган; дымга ярлы. *Ә урмансыз, ялангач кырларда кар һәм яңгыр сулары берьюлы елгаларга агып төшәләр дә кырларга җәеләләр һәм уңдырышлы җирләрнең бик күп яхшы туфрагын юып китәләр, кырларда коры, уңдырышсыз кызыл балчык кала ---.* Дөньяда ниләр бар. *Зәмзәм чишмәсе, менә ничә гасырлар инде, шушы эссе, коры урында да кипмичә, миллионлаган халыкны сугарып, дәвалап тора.* Мәдәни җомга

5) Составында су парлары бик аз булган, дымлы түгел. *Казармаларга җитәр алдыннан, безне җылы, коры казармаларга кертәләр, шунда бераз гына булса да иркенләп чишенеп ял итәрбез дип уйлаган идек, ләкин ул булмады.* А.Таһиров. *Коры һава тирене ялкынсыта, эчәсене китерә.* Кызыклар дөньясында

6) Юеш, пычрак түгел (җир, туфрак тур.). *Коры урын бер дә юк Безнең капка төбендә. Ярсып ага гөрләвек, Бик киң булып бүген дә.* Балачак аланы. *Аяк асты коры, урманга чыгарга була*

7) Явымсыз, яңгырсыз. *Көннәр коры чакта Данис авылга кайтып йөрде.* Ә.Моталлапов. *Коеп яуган муссон яңгырлары декабрь аенда туктап тора, шуңа күрә ул «чагыштырмача» коры, турист сезоны санала.* В.Юныс

8) Ачы, зыкы (кышкы салкын тур.). *Март аеның хикмәте: көндез бераз йомшартса, төннәрен коры суыкта куыра.* Ш.Шәйдуллин. *Декабрьнең коры ачы җиле Өскә өеп болыт китерде ---.* Х.Рахман. *Яңа елда яңа кар Җемелдәр дә елкылдар. Агачлар көмеш кенә – Торсын шул килеш кенә! Коры суык урамда Кайсы айда? Гыйнварда.* Н.Каштан

9) Үз дымы кояш яки ут җылысында кибеп беткән. *Керт-керт коры печән кимерә башлаган айгыр Бибинурны таныды ---.* А.Гыйләҗев. *Кайберләре, көзге җил агач ботакларыннан йолкып-йолкып алган коры яфраклар сыман, кыштыр-кыштыр арлы-бирле талпындылар, тик билгеле бер фикергә оешып бетә, укмаша алмыйча тузгып, чәчелеп беттеләр.* Ә.Гаффар. *Фәсхиләрнең лапас түбәсендәге коры печән өстендә күккә карап ятабыз.* Г.Сабитов

10) Корыган, үсүдән туктаган, яфраклары коелып беткән (үсемлек тур.). *Гусеницалар коры ботак яки яфрак рәвешенә кереп, бик исле сыекча бүлеп чыгарып, куркыту позасын алып, ефәк*

*җептән кисәк төшеп, дошманнардан саклана алалар.* Биология. Хайваннар. *Шулвакыт Шалпан колак ерактан йөгереп килеп сикерим дигәндә генә, агач төбе өстендәге кәкре коры чыбык кинәт кузгалып, яртылаш үрә торды. --- Ул чыбык түгел, агулы кара Елан икән.* Балачак аланы

11) Майлылыгы, дымлылыгы тиешле дәрәҗәдә булмаган. *Бит тиресе коры булганда, битне каты су белән юмаска, түбән температурадан (салкын һавадан, салкын судан) сакланырга һәм сабын белән еш юынмаска кирәк.* Йорт эшләре

12) Киптерелгән, концентрат хәлендәге, сусыл булмаган (терлек азыгы тур.). *Коры ашатуга күчү күп урында кул хезмәтенә кире кайтуга этәрсә, бирелдә, киресенчә, механикалаштырудан баш тартырга җыенмыйлар.* Ватаным Татарстан

13) Өлгергән (орлык, ашлык, иген тур.)

14) Күк күкрәүсез һәм яңгырсыз була торган (яшен тур.). *Гыйззәтуллин теге коры яшен чатнаган вакытта авызын ачып калган иде, берничә секунд буе шуны яба алмыйча катып торды.* М.Мәһдиев

15) *күч.* Гади, гадәти, примитив. *Быелга кадәр Михаилның Хәятка мөнәсәбәте коры дуслык кына иде.* Ф.Әмирхан. *Мин, чыннан да, гарәпләрнең яшәү ысулларын, Шәрык кешесенә хас үзенчәлекле психологиясен аңларга тырышам. Коры кызыксыну түгел бу.* В.Юныс. *Тик хикмәт шунда: ана теленә кагылган барлык эшчәнлек телнең коры төзелешен өйрәнү белән катгый чикләнде.* Мәдәни җомга

16) *күч.* Туклыклылыгы тиешле дәрәҗәдә булмаган (итсез-майсыз, сөтсез-шикәрсез аш-су тур.). *Ә тана ите ярап куйды! Бөтенләй бүтәнчә эшли башлады печәнчеләр. «Коры» аш ашаган көннәрдә кайбер печәнчеләрнең покосны я бик тар алып, яисә күрер күзгә киң алып та, астын чи калдырып чабуларына эчем пошып кисәтү ясагач: – Теләсә ни әйт, прсидәтел, әмма үтерсәң дә, шушыннан әйбәтрәк итеп чаба алмыйм! – дип әрепләшүчеләр дә бетте ---.* В.Нуруллин. *Түбеннән коры аш горчицасы эшлиләр, аннан аш тәмләткеч һәм горчичник ясыйлар.* Ботаника // Ашсыз, җылы ашамлыкларсыз. *--- икенче эләксәң – карцерга: юеш, караңгы, пычрак идәнле, кандалалы бүлмәгә, берничә көнгә коры икмәк белән суга ябып биклиләр.* Г.Ибраһимов. *Үз-үзегезне тәртипкә китерергә, ярты тәүлеклек коры паёк әзерләп алырга.* Ә.Гаффар

17) *күч.* Сусыллыгы, майлылыгы тиешле дәрәҗәдә булмаган. *Әгәр бавыр кирәгеннән артык кыздырылса, паштет сусыллыгын югалта: коры була.* Йорт эшләре

18) *күч.* Буш, эчтәлексез; дәлилләнмәгән. *Кем дә булса сезне мактар, бәлки, Матур мактап, Коры сүз сөйләр. Ләкин, Үзегез белән әрни-әрни, Минем кебек сезне кем сөя?* Х.Туфан. *Аларның башта гына коры сүзгә һушлары китә.* Р.Зәйдулла. *Билгеле, ул сораулар коры сорау гына булмыйча, яшь йөрәкнең нечкә кылларын чиртте.* Ф.Мансуров

19) *күч.* Үзе генә зур нәтиҗә, канәгатьләнү бирми торган («бары», «тик», «гына» мәгънәсендә). *Коры протест*

20) *күч.* Буш, бернәрсәсе дә булмаган, эченә берни салынмаган. *Ул кайтып җиткәч күрә: анда коры ялан гына калган – дошман явы килеп бөтенесен кырып-талап киткән.* Р.Фәхретдинов. *Коры капчык*

21) *күч.* Буш, өстенә берни түшәлмәгән, җәелмәгән; берни эләктерелмәгән. *Икенче көннәрдә кич булды исә, санитар килеп аның матрасын алып куя башлады. Яшь музыкант Ванёк коры тактада бөгәрләнеп ята.* А.Таһиров. *Украинадан килгән егет сөйләве буенча, кайчакта балык коры кармакка да эләгә.* В.Юныс

22) *күч.* Инструмент, эш коралларын кулланмаган, кул көче белән генә башкарылган. – *Садыйк абый, яңа метчиклар бармы? – Әй, юк шул, акыллым, ясаганнар әлегә беткән, шунда ничек булса да рәтләп тор инде... – Урлап бетерәләр дә, аннан коры кул белән эшлә! – дип куйды берсе.* А.Алиш

23) *күч.* Сурәтләү-тасвирлау чараларына ярлы, художестволы түгел, декларатив характердагы. *Коры сүздән пылау булмас, дөгесе-мае булмаса.* Мәкаль

24) *күч.* Катлауландырылмаган. *Гаилә хакында минем фикерем коры гына: --- син аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, --- һәркемгә өйләнү тиеш.* Г.Тукай. *Илһамның бабасы «коры» Шакир гына түгел, Мөхәммәтшакир исемле булган.* Мәдәни җомга

25) *күч.* Буш, нигезсез, файдасыз. *Көрәшләрдә ныгыган һәм мөстәкыйльлек өчен көрәшен ил эчендә дә, читтә – мөһаҗирлектә дә дәвам иттергән төрки-татар халкы дәүләтле булырга һәрчак әзер, ул коры хыялыйлыктан ерак тора.* Г.Исхакый

26) *күч.* Каты күңелле, кырыс, усал. *Монысы коры коданы бөтенләй чыгырдан чыгарды.* М.Мәһдиев. *[Галимҗан Алмачуарга:] Тиздән аерылышабыз. Мин әле сине сагынып та саргаячакмын. Мине усал кеше, коры холыклы, диләр.* С.Поварисов

27) *күч.* Усал, таләпчән. *Бармасыем кана, персидәтелебез Миңнулла – бик коры кеше, вакытында килеп җитмәсәң, сөт аертырга килгән картларны көттереп торсаң, ыштыраф салырга да күп сорамый.* Г.Ахунов. *Яшьли коры холыклы булдым.* Р.Батулла

28) *күч.* Хиссез, җансыз; рәсми төсмерле. *Закон сакчысының җавабы коры һәм кискен булды---.* Г.Ахунов

**2.** *и. мәгъ.* Диңгезгә, сулыкка капмакаршы буларак җир. *Төркия дә, диңгез көче зәгыйфь булса да, корыдан сакланыр өчен, ул да үзенең ярларына гаскәр тутырды, аларны ныгытырга тотынды.* Г.Исхакый. *Галәү карт --- кайчандыр борын заманнарда «Барса килмәс»нең [утрау] корыга якын ягы туңып, Азай казакларының кыш көне боз аркылы утрауга кереп утыруларын --- сөйләде.* А.Таһиров. *Су кандаласы (водомерка) һәрвакыт су өстендә тереклек итә, беркайчан да суга чуммый һәм корыга да чыкмый.* Кызыклы физиология

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Явым-төшемсез, яңгырсыз. *Көн кызу, җәй коры килә, имеш!* З.Мәхмүди. *Көннәр коры тора*

2) Түләүсез, бушлай, бернәрсәсез. *Гүргә кергән кире чыкмас, өйгә кергән*

*коры чыкмас.* Мәкаль. *Инде тәүлеккә якын корсак буп-буш – «корыга» эшли бит.* И.Салахов

3) Берни кушмыйча, өстәмичә. *Кытайлар һәм японнар чәйне коры килеш эчәргә ярата.* Юлдаш

4) Хиссез, җансыз; усал итеп. *Хәят, Әминәнең тезенә төртеп, күзләре белән Галине күрсәтте дә: – Без белешмәсәк тә, белешүче табылган әле, – диде, һәм үзе коры гына елмайды.* Ф.Әмирхан. *Биек якалы толып кигән кода дигәне, өйгә кереп, коры гына сәлам бирде.* М.Мәһдиев. *Тыштан караганда, архитектура сызымнары кебек корырак, шактый кырыс күренә Мәрьям ---.* М.Маликова

5) Кырыс рәвештә, аяусыз

6) Ачы итеп. *Җан коры гына сызланды; аның әллә нәрсәсен кисеп алганнар шикелле иде.* Ф.Әмирхан

**4.** *кис. мәгъ.* Бары, тик, бары тик, гына. *Елан бит. Коры елан гына түгел, үз теләгенә ирешер өчен агуларын яшереп, «фирештә» сурәтенә кереп торган, сине шулай астыртын чага торган матур елан бит!* Г.Ибраһимов. *Боярның аның көлтәсе бетмәс, бояр эшен ни хәтле тырышып эшләсәң дә, коры «молотчина»дан башка нәрсә ишетә алмассың.* А.Таһиров

◊ **Корыга китү** Озак вакытлар яңгыр яумыйча тору. *– Корыга китте бит әле, Габделхәй, – диде Дәүләтгәрәй абзый, күккә карап.* Н.Фәттах. *Яңа ай чалкан яткан икән, көннәр корыга китәргәдер, күрәсең.* Г.Хөсәенов. **Корыга (селкенеп) йөрү** Эшсез, максатсыз йөрү; нәтиҗәсе булмау. **Коры җеп бөртеге дә калмау** Бик нык юешләнү. *Ә инде күктән яңгыр «чиләкләп коя» башласа, коры җеп бөртегең дә калмый.* Дөньяда ниләр бар. **Коры җиргә ташланган (балык) кебек** Үз стихиясендә булмау турында. *Ләкин класста ул давылда корабы ватылып коры җиргә ташланган диңгез юлбасары кебек утыра.* М.Мәһдиев. **Коры исәп** Хоккей, футбол һ.б.ш. спорт төрләрендә уенның бер яки һәр ике якның да бер генә очко да җыя алмыйча тәмамлануы. *Уфалылар үз бозында коры исәп белән отылырга теләмәде.* Кызыл таң. **Коры кабык** 1) *к.* **коры куык**; 2) Бик ябык кеше. *Синең каршыңда коры кабык кына басып тора...* М.Маликова. **Коры калу** Мәхрүм калу, буш калу. *Тел дигән дәрья бар. Төбендә энҗе-мәрҗән бар. Белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр.* Мәкаль. *Су котырынса – яман котырына, өлгерсәң, өлгереп каласың, өлгермәсәң, коры каласың.* М.Әмирханов. *Кияү чыкмас, коры калырмын дип белдеңме?* А.Гыйләҗев. **Коры кибәк** *к.* **коры куык**. *Зурлыгына, акылына карап Или язмыш адәм баласын. Коры кибәк булсаң, эшләр харап: Җил уңайга төшеп каласың.* Р.Низамиев. **Коры кул белән** 1) Бернәрсәсез, буш. *Бүген Бибинурны күреп, тыкрыктан чыкмыйча яшеренеп маташа, димәк, коры кул белән кайтып килә.* А.Гыйләҗев. *Тулы бер дәүләт иясе булган патша, хаким дә, үлсә, коры кул белән торып кала.* С.Лашманчы; 2) Нәтиҗәсез, максатка ирешмичә. **Коры кул белән калу** *к.* **коры калу**. *Хәер, озакламый башланачак Ташаяк ярминкәсендә үзенең коры кул белән калмаячагына бик яхшы ышана иде ул.* Ф.Латыйфи. **Коры куллы** Таләпчән, үзе дигәнчә һәм тиз эшли торган. *Фиданиясе аны, аз сүзле, бик коры куллы кеше, ди.* И.Сираҗи. **Коры куык** 1) Мактанчык, үз сүзендә тормый торган кеше; 2) Буш сүз, әһәмиятсез нәрсә. *Троя кешеләрен агач ат белән алдалап, черек төп башына утыртып калдырганнары кебек, гомере буена «якты киләчәк» дигән коры куык белән туендырып тордылар ич.* Ә.Гаффар. **Коры мунчала белән юу (уу, ышку)** Алдау; берни эшләмичә, сүз белән генә юмалау. *План өчен ул безгә берни дә бирмәде, коры мунчала белән юу гына булды бит ул.* С.Сабиров. **Корыны бушка аудару** Эшсез йөрү. *Торып тор, бу соң корыны бушка аудару түгелме?* Г.Ахунов. *Мин дустымның Гани абыйсын борчуы корыны бушка аудару гына булыр, политик редакциягә мине инде якын да җибәрмәячәкләр дип уйладым.* Г.Тавлин. *[Гыйлемхан:] – --- Үзем пенсионер. [Нәҗип:] – Ә-ә, – дип, һава иснәп куйды хуҗа кеше, төс-кыяфәтенә «әллә кем түгелсең икән әле...» дигән бер мәгънә чыгарып. – Җил сугарып, корыны бушка аударып йөрү инде, алайса?..* Р.Мөхәммәдиев. **Корыны бушка әйләндерү** *к.* **корыны бушка аудару**. *Бистәнең чигенә җитеп киләләр, тик әлегә корыны бушка әйләндерү генә.* М.Әмирханов. **Коры сөяк** Бик ябык. *[Хатынның] йөзе балавыздай сары, бөтен тәне юнып алган төсле коры сөяк.* В.Имамов. *Барысы да ябыклар, хәлсезләр. Коры сөяк тә тире.* Н.Фәттах. **Коры сөяккә калу** Бик нык ябыгу. *Зыятдин коры сөяккә генә калган.* З.Хәким. *Йөзе җитди, һаман сөйли, Авыз ачарга да бирми: – Бак әле, – ди, – минем өскә, Калдым коры сөяк, тире. Белмим, адәм рәвешенә Керә алырмынмы кире?..* Р.Хисмәт. **Коры такылдык** *к.* **коры куык**. **Коры таякка калдыру** Буш итү. *«Атаң исән чакта, мин бөтен Сөн илен үз кулымда тоттым, син каган булгач, миңа сигез мең өй бирдең дә коры таякка калдырдың» – диде [анасы].* Н.Фәттах. **Коры тоту** 1) Таләпчән булу; кызганып тормау, аямау. *Ул башта эшчеләрне коры тотмакчы булды: ник намаз укымыйлар, ник акча уйныйлар, ник эчәләр? Өсләренә күкләр күкрәтә иде.* Ш.Камал. *Мөгаллим коры тотты. Габделхәкимгә ат җигәргә кушып, бик тиз әйләнеп киләчәген әйтеп чыгып китте.* С.Поварисов. *Кызның әтисе динен, телен оныткан мөртәт булса да, кендекне төен белән бәйләп кую ихтыяҗын коры тотты.* Т.Галиуллин; 2) Тиз эшләү. *Көлтәчеләр эшне коры тоттылар, икешәр көлтәне берьюлы эскерткә ыргыталар.* А.Таһиров. *Рушад мәсьәләне бик коры тотты.* М.Мәһдиев. **Коры чыгу** Кыен хәлдән югалтусыз котылу. *– Ни эшлибез? – дип, хатынына текәлде Бәйрәмгали. Чөнки белә, хатын башлы аның, теләсә нинди хәлдән коры чыга белә.* Р.Мөхәммәдиев. **Коры шалтыравык** *к.* **коры куык**. *Минем бик зур кимчелем бар: мин тормышны һәм безнең киләчәкне шактый тирән итеп аңлый белмәм, мин тар фикерле дә, вак та, коры шалтыравык кына кеше дә түгел.* Г.Бәширов. **Коры шәүләгә калу** *к.* **коры сөяккә калу**. *Ана кеше газиз баласына бер тапкыр күз салу белән*

*барысын да төшенгәндәй булды. --- Кай арада йөзенә сары суккан да коры шәүләгә калып өлгергән диген син аны. Эх-х, балакай!* М.Хәсәнов

**КОРЫ БОЗ** *и. хим.* Углеродның икеле окисе, углекислый газның басым астында каты хәлгә китерелгән төре. *--- иданнәрне, дивар, түшәмне яктылык сибеп торучы тыгыз пәрдә белән томалап, агып торган коры бозны хәтерләткән зәңгәрсу төтен акрын гына шуышып чыга һәм бөтерелеп күтәрелә башлады...* Т.Кәримов

**КОРЫБОТАК** *и. эвф.* 1) Чуан, сызлавык. *Чуан дисәң юаная, корыботак дисәң – корый.* Әйтем

2) *күч. сөйл.* Гаиләсез, баласыз кеше

**КОРЫГА** *рәв. сөйл.* Юкка, файдасыз, нигезсез. *Корыга йөрү. Корыга мактану*

**КОРЫ ҖИЛ** *и.* Чүл, дала ягыннан исә торган кайнар җил; *русчасы:* **суховей**. *Җир өстендә тузанлы коры җил исә, төньяктан кара-корыч болытлар безгә табан килә.* М.Мәһдиев

**КОРЫ ҖИР** *и.* Җир шары өслегенең судан башка өлеше. *Ул вакытларда Япониянең коры җир гаскәре һәм диңгез флоты зәгыйфь булганга, сугышып алган җирләрен ирексездән Кытайга кайтарырга мәҗбүр булды.* Г.Тукай. *Елдан елга, гасырдан гасырга су шулай океаннан коры җиргә, коры җирдән океанга әйләнеп йөри.* Дөньяда ниләр бар. *Тереклекнең байлыгы ягыннан ул бары коры җирдәге дымлы тропик урманнан гына калыша.* Табигать белеме

**КОРЫК** *и.* 1) Көтүдәге берәр терлекне, чабып барган атны яки кыргый хайванны муеныннан эләктереп тотып алу өчен кулланыла торган, очына элмәкле бау беркетелгән колга. *Кулына корыклар күтәреп, Шәяхмәт белән бергә кайткан озынча буйлы, ябыграк, ләкин нык гәүдәле кеше Нәгыймәнең ире Садыйк иде.* Г.Ибраһимов. *Сәгыйть йокысыннан торып чыкканда, җылкычы алама, гүпесен – баш астына, корыгын янына куеп, тирән йокыга киткән иде.* А.Таһиров

2) Колга, озын киртә. *Өстерәлеп йөри торган нәрсә [җил-давыл] килеп җитәрәк, [Таз] ни булса, шул булыр дип сикереп тора да, корык белән кизәнеп суга да. Корык белән сугуы була, моның янына килеп төшә озын чәчле бер хатын.* Әкият

3) *иск.* Борын заманда: сугышларда дошманны ат өстеннән егып әсирлеккә алу өчен кулланылган бер башы элмәкле бау. *Корал юкта корык та корал.* Мәкаль

◊ **Корык салу** 1) Бугалак салу; үтерү, буып үтерү; 2) Дошманны аулау. *Әҗәл туры килмәсә, Азраел корык салмаса, Әле дә булса, Туктамыш, Синнән калыр картыңмын!* Дастан. **Корык ташлау** *к.* **корык салу**. *Чирүле күлгә килгәндә, Кадыйрбирде солтанның Посулы яткан чирүе, Корык ташлап артыннан, Җанбайны егып атыннан --- Чатырына апкилде.* Дастан

**КОРЫК-КОРЫК** *иярт.* Каты йөткергәндә чыккан тавышны белдерә. *--- дымлы төннәрдә ютәл бумасы белән интеккән Җәмилә карчык, комганын тотып, корык-корык ютәлләп, тәрәзәгә тия язып үтеп китә.* А.Гыйләҗев

**КОРЫКЛА́У** *ф.* Берәр терлекне, чабып барган атны яки кыргый хайванны корык ярдәмендә муеныннан эләктереп тотып алу. *Ак башлы, кара бишмәтле хатыннар шуннан [бәйләүдән] ерак түгел йөргән бияләрне корыклап китерәләр дә савып йөриләр.* Г.Ибраһимов

**КОРЫКЧЫ** *и. иск.* Корык белән ат тотучы, мал аулаучы. *Тар җирдә тамаша булма, киң җирдә корыкчы булма.* Мәкаль

**КОРЫЛАЙ** *рәв.* Коры (*1 мәгъ.*), юешләнгәнче, юешләтмичә. *Орлыкларны корылай агулау*

2) Коры (*17 мәгъ.*) килеш, бернәрсәсез (ашау-эчү тур.). *Корылай ашаганда, бер-ике кабасың да – вәссәлам.* Ә.Гаффар

**КОРЫЛАНУ** *ф.* 1) Корыга, яңгырсызга китү; дым киму. *Климат корылана, үсемлекләргә бай сазлыклы урыннар кими.* Биология

2) Коры булып китү, кибү. *Буялган чәчләрне каты су белән юганнан соң, чәчләр корылана, терелеген югалта.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Таләпчәнлек күрсәтү, каты куллылану. *Асылов бердән корыланды, Мәүлиха апага да кырыс, ямьсез тавыш белән эндәште.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Салкын, рәсми төс алу; хисләргә ярлылану, игътибар азаю. *Шул сөйләшүдән соң, аның миңа булган мөнәсәбәте сизелерлек салкынайды, сөйләшүе тагын да корыланды.* М.Вәли-Барҗылы

**Корылана бару** Торган саен корылану. *Миңлегаязның талканы корылана гына барды.* Р.Мөхәммәдиев. *«Сухой закон» көннән-көн корылана бара.* К.Кәримов. *Диңгездән ераклашкан саен, климат корылана бара.* Материклар һәм океаннар географиясе

**Корылана башлау** Корылану ягына үзгәреш сизелү

**Корылана төшү** Бераз корылану. *Пермь чорында климат корылана төшкән.* Биология

**Корыланып бетү** Тәмам корылану, корыланган хәлгә килү

**Корыланып калу** Нинди дә булса вакыйгадан соң корыланган хәлгә килү

**Корыланып китү** Бераз корылану. *Эсселектән һава корыланып китте*

**Корыланып тору** Һаман, даими корылану

**КОРЫЛАТА** *рәв.* 1) Коры (*1 мәгъ.*) килеш

2) *күч. сөйл.* Спиртлы эчемлек кулланмыйча. *Гадәттә, берне салу белән тел ачылып китә, уртак сүз табыла, бер-береңне җиңелрәк аңлый башлыйсың. Ә болай, корылата, валлаһи, мин үземне ничек тотарга белмим.* М.Юныс

**КОРЫЛДА́У** *ф.* 1) Торнаның үзенә хас тавыш белән кычкыруы, торкылдавы

2) Кайбер кошларның «ко-ко-ко» кебегрәк билгеле бер тавыш чыгаруы. *Күркә корылдау*

3) *күч.* Тупас, калын тавыш белән сөйләү

**Корылдап алу** Берара корылдау

**Корылдап йөрү** Әледән-әле, даими корылдау

**Корылдап кую** Кинәт бер тапкыр корылдау. *Әтәч корылдап куйды*

**Корылдап тору** Һәрдаим, әледән-әле корылдау

**Корылдый башлау** Корылдарга тотыну

**Корылдый бирү** Корылдавын дәвам итү. *Күркәләр корылдый бирә*

**КОРЫЛМА** I *и.* 1) Төзелгән, төзелә торган бина, хуҗалык яки техник объектлар. *Мавзолей тибындагы бу кирпеч корылма халыкта «Тамерлан манарасы» дип йөртелә.* Ф.Яхин. *БМ-13 корылмасына кагылышлы һәр мәгълүмат хәрби сер булып калырга тиеш.* С.Лашманчы. *Гидроэнергетика башкаларга караганда чистарак санала. Ләкин аңа бәйләнгән гидротехник корылмалар, бигрәк тә биек плотиналар (буалар) һәм сусаклагычлар, еш кына экологик тигезләнешнең башка төрле бозылуларына китерә.* География // Төзелгән, ясалган берәр нәрсә. *Кремль йолдызлары. Бу инде кабатланмас корылмалар.* Кызыклар дөньясында. *Шушы юл белән Ленинградта (хәзер Петербург) иске бакча корылмаларын, Псковта биек манара төбендә күмелеп калган яшерен керү юлын һәм башка тарихи истәлекләрне табалар.* Кызыклар дөньясында

2) *хәрби* Дошманның алга баруын тоткарлау, юлын кисү өчен булдырылган каршылык, киртә

3) Берәр механизм яки аның состав өлеше, яисә өлешләре. *Урамны иңләп бер комбайн туктаган, алгы корылмалары кара балчыклы юл йомшагына сеңгән.* М.Мәһдиев. *Билгесез кеше тимер юл вокзалы территориясендә шартлаткыч корылма куелуы турында хәбәр иткән.* Ватаным Татарстан

**КОРЫЛМА** II *и.* 1) Нинди дә булса предметта барлыкка килгән электр егәрлеге

2) *к.* **заряд** (*2 мәгъ.*). *Электр корылмалары ике төрле: уңай һәм тискәре булалар ---.* Дөньяда ниләр бар. *Якыннан тәэсир итешү теориясе буенча, бу үзара тәэсир болай була: һәр корылма электр кыры хасил итә, һәр корылманың электр кыры икенче корылмага тәэсир итә.* Физика. *Кислородның электротискәрелеге водородныкына караганда югарырак булганлыктан, уңай корылмалар водород атомы янына туплана.* Гомуми биология

**КОРЫЛТАЙ** *и. монг.* Дәүләт яисә аерым өлкә күләмендә үткәрелә торган җыен, съезд. *СССРның төрле почмакларында – республикаларда, өлкәләрдә – язучыларның корылтай-съездлары үтә, җирле оешмалар төзелә ---.* Р.Фәйзуллин. *Менә корылтай булыр, чык та сөйлә!* В.Имамов. *Хәтерлим әле: 1989 елда Татар иҗтимагый үзәгенең I корылтаен азан белән башлап җибәрдек.* Р.Ягъфәров

**КОРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кору** III

2) *күч.* Көч, энергия туплау; дәртләнү, илһамлану. *Мин Еники тылсымыннан яңабаштан корылам; ак һәм кара клавишларга кагылып дәрт алган аһәңсаз шикелле, --- палитрасындагы буяулар кушылмасының муллыгына инанган рәссам шикелле...* М.Галиев

**КОРЫЛУЛЫ** *с. сөйл. к.* **корулы 2.** *Корылулы ау мылтыгы*

**КОРЫЛЫ** *рәв.* Коры *(17 мәгъ.)* килеш, буш, бернәрсә дә салмыйча, өстәмичә (ашау-эчү тур.). *Бибинур: – Гайфулла, син чәйне лимонсыз яратмыйсың да бит... Әйдә инде, бу юлы ничек тә корылы гына эчәрсең...* Ш.Камал

**КОРЫЛЫК** *и.* 1) Коры булу; дымланмаганлык, юешләнмәгәнлек. *Снарядларның корылыгын тәэмин итү*

2) Озак вакытка сузылган яңгырсызлык, явымсызлык һәм шуның аркасында һавада дымның бетүе, җирнең кибүе, үсемлекләрнең көюе, коруы. *Электә корылык вакытларында өлкән яшьтәге авыл кешеләренең Алладан яңгыр сорап, каберлекләргә барып төрле догалар укып йөрү йоласы бар иде.* М.Абдрахманов. *Авылда кайда гына барсаң да, кемне генә күрсәң дә, һәммәсе шул корылыктан, басуда игеннәр, үләннәр көюдән, ачлык куркынычыннан зарланалар иде.* М.Гали. *Игеннәргә корылыктан шактый зыян килгән икән, шулай да аларга да яңгырның файдасы тиде, тәмам корып-янып бетүдән сакланып калдылар.* Ф.Яхин

3) Тиредә дымлылыкның җитешмәве. *--- азыкта А витамины җитмәү тиренең корылыгын арттырырга һәм чәч коелуга сәбәпче булырга мөмкин.* Йорт эшләре

4) *күч. сөйл.* Кырыс һәм каты күңелле булу; таләпчәнлек, салкынлык, рәсмилек. *Моның түбәнлеген, моның корылыгын үзем үк тоям, ләкин гаҗизмен, сүз таба алмыйм, адәм теле аның хиссиятеннән бик ярлы.* Г.Ибраһимов. *Гаязның бу корылыгы Зояны тагын ныграк каушатты.* М.Әмир. *Хәзер инде аның тавышындагы корылык һәм сагаю беткән иде.* Г.Әпсәләмов

**КОРЫЛЫКЛЫ** *с.* Коры, дымсыз, яңгырсыз (һава торышы, климат тур.). *Җирнең иң корылыклы районнарын чүлләр били.* Табигать белеме. *Бик күп һиндлар йогышлы авырулардан һәм корылыклы елларда иген булмау аркасында ачлыктан үләләр иде.* Чит илләрнең экономик географиясе

**КОРЫЛЫШ** *и.* 1) Төзелү, оешу, нигез салыну. *Сафа Гәрәй хан әнә шулай уйлап, имән диварларны эчке-тышкы яктан карап, сокланып та, горурланып та йөрде. Чыннан да, мәһабәт корылыш иде бу.* Р.Батулла. *Дөрес, гигант төзелештә, илебез мактанычы булачак бөек корылышта, чиста куллы, чиста күңелле кешеләр эшләргә тиеш.* Р.Вәлиев

2) Дәүләтнең, аерым структураларының төзелеше. *«Җепшетү чоры» сәяси корылышка үзгәреш китерә алмады.* Ә.Баян. *Чөнки алар Русиядәге унитар корылыштан туйганнар һәм тарихи процесстан читтә калулары белән моннан ары килешеп яшәргә теләмәделәр.* Р.Хәкимов

3) Структура, композиция (әдәби әсәр тур.). *Әдәби әсәрнең мәгънә юнәлеше, идеясе, эчтәлеге, корылышы, --- башка сыйфатлар хакында шәкертләр начар сөйләми.* С.Поварисов. *Әсәр үзенең эчтәлеге, корылышы һәм гомумән бөтен рухы белән тормыш дәреслеген, тәрбия китабын хәтерләтә ---.* Х.Миңнегулов

**КОРЫЛЫШЛЫ** *с.* Билгеле рәвештә, формада корылган, төзелгән. *Габдулланың алды әллә нинди аңлаешсыз гаҗәп корылышлы тартмалар, серле котыйчыклар белән тулды.* Ә.Фәйзи

**КОРЫМ** *и.* 1) Ягулыкның янып бетмәгән газ өлешеннән калган, әйберләрнең өслегендә кунык хасил итә

торган кара төстәге майлы продукт. *Корым карасы китәр, намус карасы китмәс.* Мәкаль. *Караңгы төшеп өйгә кайтканда, әби түр башында утырган да, колак артларына җеп белән эләктергән күзлеген кигән дә, чынаяк астлыгында ак май белән корымны бергә изеп маташа.* Г.Исхакый. *Син хатының Өммегөлсемгә әйт: морҗасының корымын ешрак чистартып торсын.* Г.Әпсәләмов

2) *типогр.* Типографиядә куллану өчен махсус эшләнгән кара буяу

◊ **Корым ягу** 1) Ялган сөйләү, пычрату, хурлау; 2) Хурлык китерү, оятка калдыру. *– Ни генә әйтим инде мин сиңа, Ибраһим, – ди бабасы, – бөтен нәселнең битенә корым ягтың бит син моның белән.* Г.Гобәй

**КОРЫМБАШ** *и. а. х.* Үсемлекләрдә, аеруча бөртеклеләрдә була торган гөмбә авыруы; кисәү гөмбәсе; *русчасы:* **головня**

**КОРЫМЛАНУ** *ф.* 1) Корымга буялу, корым куну. *Төн буе янып корымланган лампа куыгына үрелгән генә иде, баш түбәсендә ялт итеп электр лампасы кабынды, янә сүнде, тагын кабынды.* Ш.Шәйдуллин. *[Ментәйн] --- сөннәрнең изге корымлалары тирәли әйләнеп чыкты, эченә керде, игътибарсыз гына җир идәнгә, корымланган бүрәнәләргә күз төшереп алды.* Н.Фәттах. *Кара мунчада аклы киемнәр тиз корымлана – юынганнан соң, диварга таянырга ярамый.* Р.Батулла

2) *к.* **корымлау** (*1 мәгъ.*)

**Корымлана бару** Аз-азлап, торган саен корымлану. *Корымлана барган күңелебезне арындырасы килә.* Татарстан яшьләре

**Корымлана башлау** Бераз корым куну

**Корымлана төшү** Тагын да корымлану

**Корымланып бетү** Бик нык, тулысынча корымлану. *Галәү бабай шырпы сызды да корымланып беткән унлы лампаны кабызды ---.* Г.Гобәй. *Кичтән кәсебебез уңмады. Бөтен ризыгыбыз әле тонып та өлгермәгән су астында йөзә иде. --- тышы корымланып беткән бәләкәй бидрәне тутырып су кайнаттык.* М.Кәрим. *Камерада тагын тынлык урнашты. Түшәмдәге корымланып беткән лампочка кызарып кына яна.* И.Салахов

**Корымланып йөрү** Даими, еш кына корымга буялган булу. *[Габдуллаҗан:] Тимерче кебек корымланып йөрмәсәң ярамас дип куркасыңмыни, чүпрәк баш!* К.Тинчурин

**Корымланып калу** Нindидер бер сәбәптән корымланган хәлгә килү

**Корымланып китү** Кинәттән корымлану, шундый хәлгә килү

**Корымланып тору** Әледән-әле корымланган хәлгә килү

**КОРЫМЛА́У** *ф.* 1) Корым, төтен чыгару

2) Корым кушу, корым бутау

3) Корым белән буяу, каралту

4) *күч.* Ялгыштыру, бутау. *Кызның салкынлыгы аның акылын корымлый, хәтерен ала торды.* Ф.Яхин

**Корымлап тору** Әледән-әле корым белән каплану

**Корымлап чыгу** 1) Билгеле бер вакыт дәвамында корымлау. *Төн буе корымлап чыгар инде, аны Каралтып, Күкрәгемдә дөрләгән шәм!* Н.Акмал

2) Рәттән барысын да корымлау

**Корымлый башлау** Корымлау билгеләре күренү

**КОРЫМЛЫ** *с.* 1) Корымга, төтенгә буялган, корым сеңгән. *Менә ул бер кулы белән корымлы, җылы морҗага тотынып, икенчесе белән кояштан күзләрен ышыклап, кырлар өстенә карады.* И.Гази. *– Озаграк йоклап җибәргәнбез шул, хәлфә абый, – диде кизү малай, корымлы бармаклары белән башын кашып.* М.Гафури // Корым катыш. *Аның эченнән балтыр чүпрәгенең очлары күренеп тора. Яшел чапанның бер җире ямь-яшел, бер җире капкара булып корымлы майга буялган...* Г.Исхакый

2) *күч.* Намусны каралта, пычрата торган (сүз, гайбәт тур.)

**КОРЫМЛЫК** *и.* Мичнең төтен юлында корым җыелсын өчен калдырылган урын

**КОРЫ-МОРДЫ** *җый. диал. и. к.* **коры-сары**. *Бәләкәй чана тартып бара икән урманга, аннан чыбык-чыбык, коры-морды гына төяп кайта ала.* С.Поварисов

**КОРЫН** *и. монг.* 1) *тар.* Элеккеге күчмә халыкларда яшь һәм җенес буенча аерымланган төркемнәрнең бергәләп ашавы

2) *күч.* Җыен, корылтай

3) *күч. диал.* Аш вакыты. *Төшке корын*

**КОРЫ-САРЫ** *җый. и.* 1) Корыган ботак, чыбык-чабык, вак-төяк утын. *Алар икесенә кечкенә-кечкенә биш балык тоттылар һәм тирә-яктагы коры-сарыны җыеп ясалган учак өстенә үзләре белән алып чыккан калай савытта шул балыкларны пешерергә куйдылар.* Ә.Фәйзи. *Куштанрак малайлар, утка коры-сары өстәгән булып, гел учак тирәсендә әйләнәләр.* И.Гази

2) Сыек булмаган ашамлыклар. *[Фарукҗан] Сәгатенә күз салгач, ашыгып киенде, солдат гадәтенчә, елдам гына юынды һәм кичәге чәен җылытып, коры-сары капкалады ---.* Т.Әйди. *Күршеләрендә торучы Исламия апа әйтә, ашаганнары кыты-мыты, коры-сары иде, чәй эчәләр дә чәй эчәләр иде, ди.* Т.Миңнуллин

**КОРЫ СЫЗЛАУ** *и. сөйл.* Ревматизм. *Яз көне кинәттән генә минем аяклар авырта башлады. Безнең якта аны коры сызлау диләр.* Т.Миңнуллин

**КОРЫТ** *и. кулин.* 1) *тар.* Әчегән сөтне, катыкны сөзеп, киптереп ясалган кисәкле каты ашамлык. *[Акъәби] Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, шомыртын, эремчеген, корытын да шулар өчен киптереп куя.* Ә.Еники. *Каймак корыты әзерләү*

2) Сөтне озак кайнатып ясала торган кызгылт сары төстәге коры эремчек; кызыл эремчек; *к.* **корт** II. *Бәйрәм табынында милли ризыкларның барысы да бар иде: бишбармак, казылык, коймак, чәкчәк, бавырсак, тутырылган каз, кыстыбый, әйрән, корыт, кымыз һәм башкалар.* Кызыл таң. *Таулы-урманлы бу төбәк кымыз, ат ите, корыт, казы һ.б. экологик таза азык-төлек, авыл хуҗалыгы туризмы, халык кәсепчелеген үстерүгә булышлык итә.* Өмет

**КОРЫТУ** *ф.* 1) Сөртеп, киптереп коры (*1 мәгъ.*) итү. *Хәзер тәнне корытып сөртик.* М.Юныс. – *Алай... – дип сузды башлык, тирләгән маңгаен кулъяулык белән корытып.* Р.Зарипов

2) Эчендәге суын яки башка төрле сыекчасын агызып, салып бетерү. *Шимбә көнне, мунча чабынып кайтканнан соң, самавырны корытканчы чәй эчкәч, --- Бибинур урынны гадәттәгедән киңрәк җәйде.* А.Гыйләҗев

3) Яңгыр булмау, су сипмәү, дым җитмәү сәбәпле үсемлекләрне коры (*5 мәгъ.*) хәлгә китерү. *Су сибәргә килгән хатыннар --- әрекмәннәр белән яшелчәләрне ябып чыктылар. Варифә апаның чираты икән. Ул тагын мыгырданды: – Ходаем, корытыйм дисә, кыраусыз да корыта. Алладан качып булмый инде ул...* А.Алиш

4) Җан иясен, аның органнарын яшәүдән, тереклек итүдән туктату. *Кичә чәчәген имеп корыткан корт Бүген үрмәләп алмасына бара. Аңлашыла бара, җәмәгать, Барысы да аңлашыла бара.* Н.Акмал

5) *күч.* Бөлгенлеккә төшерү, талап, хәерчелеккә китерү. *Мәрхүм булмаса да, инде күптән Мәхрүм ул улдан, оныктан: Нәсел тамырын ул йолкып төптән, Үз токымын үзе корыткан.* Р.Закиров

6) *күч.* Бетерү, юк итү, юкка чыгару; үтерү. *Шуның өчен, эшче халык бу бәладан котылыр өчен, эшсез калып, баласы-чагасы берлән ачка үлүдән үзен саклар өчен, бу эшнең төбен корытырга тырышырга кирәк.* Г.Исхакый. *Юк, корыта алмый икән ясалма химия тере табигатьне.* А.Хәлим. *Ризасызлык күрсәткән очракта, түләүле сугышчылар баш күтәрүчеләрнең нәсел-нәсәбен корыту гына түгел, йорт-җирләренең көлен күккә очыра.* Ватаным Татарстан

7) *з.-сыз* Коры һава урнашу, коры көннәр китү. *Җәй урталарына шактый корыта башлады*

**Корыта бару** Бер-бер артлы корыту; торган саен ныграк корыту

**Корыта башлау** Корытырга керешү; корыту билгеләре күренү. *Австралиядә буйволлар бик нык үрчеп, бөтен үсемлек дөньясын корыта башлагач, ил хөкүмәте аларны күпләп ауларга рөхсәт бирә.* Ватаным Татарстан

**Корыта төшү** Бераз корыту

**Корытып алу** Тиз генә корыту. *Морза түбәтәен салып, зур кулъяулыгы белән чәчсез башын корытып алды.* М.Әмирханов. *[Ул] Ап-ак кулъяулыгы белән күз төпләрен, юешләнгән битләрен корытып алды.* Р.Зарипов. *--- ул яшьле керфекләрен корытып алды да арткы рәтләрнең берсенә кереп утырды.* Ф.Әһлиуллина

**Корытып бетерү** Тулысынча корыту, бик коры итү. *Аларның тормышта тамыры тирән әле, кешеләрдәге иске гадәтләр белән нык бәйләнгән, димәк, аларны корытып бетерер өчен дә әле күпме вакыт һәм көч кирәк булачак.* Ә.Еники. *Сөрелгән җирдән язын-көзен агып төшкән туфрак дилбегә җитмәс тирәнлектәге инешне саектырды гына түгел, бүгенге көнгә тәмам корытып бетерде.* Р.Зарипов

**Корытып кую** Тиз генә коры итү, корыган хәлгә китерү. *Шаһбаз итәк чабуы белән маңгаен корытып куйды да өстәлдәге кымыз чәркәсен кулына алды.* М.Әмирханов

**Корытып җибәрү** Кинәттән корыту

**Корытып ташлау** Тиз арада тулысынча корыту. *Әгәр дә, корт, моннан китмәсәң, нәселең-җәвереңнең белән корытып ташлармын!* Ф.Бәйрәмова

**Корытып тору** Дәвамлы рәвештә, өзлексез яки әледән-әле корыту

**Корытып чыгу** Башыннан ахырына кадәр корыту

**Корытып яту** *сөйл.* Корыту процессында булу. *Югары белемле агроном, ә менә мелиораторлар чакырып, чишмәләрне корытып ятасыз.* Т.Миңнуллин

**КОРЫЧ** *и.* **1.** 1) Тимернең углерод һәм кайбер башка төр катнашмалар белән кушылган эретмәсе, көмеш сыман аксыл аеруча каты металл. *Тимер булып тимер бөгелде, Корыч булып корыч тетелде.* Г.Бәширов. *[Мәүлә:] Карап тотмасаң, корыч та тутыга. [Хөрмәтулла:] Тутыкса да, корыч булып кала, кәлҗемәгә әйләнми.* А.Гыйләҗев. *[Батисфераның] стенасы корычтан коелган, аның калынлыгы өч сантиметр.* Диңгез тирәнлегендә

2) Корычтан эшләнгән деталь, әйбер. *Чакма корычы*

3) *күч.* Тормышта чыныккан, нык, чыдам кеше турында. *Сынап карады бик күпләр Ул корычның ныклыгын Һәм аларга кагылуның Нинди куркынычлыгын!* Ә.Исхак

**2.** *с. мәгъ.* 1) Корычтан эшләнгән. *Бер дә бер көнне йорт хуҗасы үзенең этен ияртеп, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән.* А.Алиш. *Дуласа да, дүрттән ишелгән айгыр кылы бирешерлек түгел, ныклы. Кармагы да – чын корыч кармак. Сатуныкы.* М.Кәрим. *1986 елда Сент-Луис шәһәрендәге өермә вакытында нарат таяк 1 сантиметр калынлыгындагы корыч плитәне ансат кына тишеп чыккан.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* Нык, чыдам. *Синең даһилыгың нуры белән Гөл бакчасы итте ул илен Һәм җил үтмәс корыч дивар белән Әйләндереп алды ул чиген.* Ш.Маннур

3) *күч.* Аеруча нык; җиңелмәс, сынатмас (кеше, холык һ.б.ш. тур.). *Какшатырга корыч сафыбызны Дошманнарга бирмә юл бер дә.* Ә.Исхак. *Ләкин Хөрмәтулла абзаңның йөрәге алай тиз генә җеберлек итеп коелмаган. Корыч аның йөрәге!* А.Гыйләҗев. *Сары медальгә корыч Нәфисәнең күз яше тамды.* Казан утлары

4) *күч.* Колакны ярып торган, ямьсез (тавыш тур.). *Шыгырдап, каршыдагы үлем камерасының ишеге ачылды. Корыч тавыш чыңлап китте. Мөгаен, ашыгып кергәндә, штыклар берберсенә сугылдылар.* И.Салахов

◊ **Корыч айгыр** Трактор. *Корыч айгырга боегырга ирек бирмәде Гамилә.* Ш.Мостафин. *Ни булганын сорап маташмадым, болай да бөтенесе аңлашылды: минем корыч айгырдан егылган.* Ф.Яруллин. **Корыч аргамак** Автомашина, трактор һ.б.ш. техника турында. *Корыч аргамаклар белән Төзелешне буйлыймын. Җырдан туймаган шикелле, Эш-хезмәттән туймыймын.* К.Латыйп. **Корыч ат** *к.* **корыч аргамак**. *Кошлар җитмәс җир иде, Җилләр үтмәс ил иде, Корыч атлар китерде Октябрьнең сабагы!* З.Бәшири. *Әмма корыч атыңа саласы ягулыкның*

*сыйфатын белеп торсаң комачау итмәс иде.* Ватаным Татарстан. **Корыч йөрәкле** Батыр, кыю, курку белмәс. **Корыч кош** Самолёт. *Кызлар белән дус булган, ди, Хезмәткә әзер торган, ди, Зур бер корыч кош.* Ә.Исхак. *Көн саен авыл өстеннән һава яңгыратып корыч кошлар оча.* Г.Кутуй. **Корыч лачын** *к.* **корыч кош**

**КОРЫЧА** *с.* Бераз коры, хиссез. *Хәят җавап бирмәде, ләкин күзләренә чыккан салкынча һәм корыча ут аның да туганымы сүзләренә ышана икәнен күрсәтә иде.* Ф.Әмирхан

**КОРЫЧАГАЧ** *и. бот.* Зәйтүнчәләр семьялыгыннан булган тар, вак яфраклы, үзәге бик каты агач; дардар агачы; *русчасы:* **ясень**. *Тау итәгендәге яшь корычагач биләмәсен кар валы белән әйләндермәкчеләр.* М.Рафиков. *[Тылсымлы таякка] өрәңге, корычагач, карама, кизил агачы да ярый.* Кызыклар дөньясында. *Әгәр якын-тирәдә имән, өрәңге, корычагач, шомырт кебек яфраклы токым агачлар үсә икән, мондый җирдә җимеш агачлары да әйбәт үсә.* Юлдаш

**КОРЫЧ-БЕТОН** *с.* Корыч һәм бетоннан эшләнгән. *Пленар утырышларда сөйләнгән докладлар – --- КДАТУ доценты Фәрит Җамалиевнең «Корыч-бетон төзелмәләрне статик һәм циклик йөкләмгә хисаплау проблемасы» тыңлаучыларда зур кызыксыну уяттылар.* Фән һәм тел

**КОРЫ ЧЕРЕК** *и.* Тамыразыкларда була торган, чиләнмичә черүдән гыйбарәт авыру. *Кисеп утыртканда, коры черек авыруы арта.* Ватаным Татарстан. *Фузариозны, икенче төрле әйткәндә, коры черек авыруын ничек танырга соң?* Байрак

**КОРЫЧЛАНУ** *ф.* 1) Корыч хәленә килү; корычка әверелү (чуен, тимер тур.)

2) *күч.* Ныгу, чыныгу; нык, чыдам, түзем булып китү. *Әйтерсең җәһәннәм утларында кайналып, корычланып чыккан бер егет – менә шулай күренде миңа Шаһбаз дустым.* Г.Ибраһимов. *Шулай яши шагыйрь, рухландырып Илдәшләрен тирә-ягында. Ялкыннарда җаны корычланды, Ул бөгелмәс кыен чагында!* Р.Вәлиева

**Корычлана бару** Торган саен ныграк корычлану. *Ибраһим элеккечә ипле, әмма инде торган саен корычлана барган җитди тавыш белән үгетләвен белде ---.* В.Имамов

**Корычлана төшү** Бераз, тагы да корычлану

**Корычланып җитү** Тулысынча корычлану

**Корычланып бетү** Тәмам корычлану. *Күрер идең: Корычланып, кырысланып беттем, – Еллар мине шулай иттеләр. Чәчләргә чал кертеп уза торган Читен хәлләр баштан үттеләр.* Х.Туфан

**КОРЫЧЛЫК** *и.* Ныклык. *Заман безнең үзәкләрдән үтте, Назламады рәхәт тынычлык та. Корал биреп, походларда йөртте. Ярап куйды кайчак корычлык та.* И.Юзеев

**КОРЫ́ЧТАЙ** *рәв.* 1) Корыч кебек, корычка охшаш

2) *күч.* Нык, какшамас булып. --- *Рәсәйнең үзәк өлешендә корычтай нык берләшмә барлыкка килер иде ---.* Ф.Гарипова. *Нужа икмәген шактый кимергән, әмма авырлыкларны сыгылмыйча җиңеп, корычтай чыныккан Закуанга бервакыт кояш ныграк елмая, дөнья яктыргандай тоела башлый.* Өмет

3) *күч.* Кискен итеп, колакны тырнап. *Тавышы элеккечә корычтай яңгырап чыга алмады, ишетелгән сүзләре дә авыр килде ---.* Г.Ибраһимов

**КОРЫЧЧЫ** *и.* Корыч кою остасы, корыч әйберләр ясаучы. *Аның олысыкечесе – һөнәр остасы: берсе – корыччы, икенчесе – алтын-көмешче.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**КОРЫЧ ЮЛ** *и.* 1) *иск.* Тимер юл

2) Рельс. *Поезд --- төнне ярып алга чапты; вагоннар әле як-якка селкенде, әле кинәт аска ыргылды, состав менә-менә корыч юллардан чыгып китәр дә берәр җирдә мәтәлер сыман тоела иде.* Р.Мирхәйдәров

**КОРЫШКАК** *с. сөйл.* Чирләшкә, ябык. *Корышкак бала*

**КОРЫШТЫРУ** *ф.* 1) Вак-төяк, юкбар нәрсәләрдән аннан-моннан төзү, әмәлләп кую. *Теге чактагы егетләрнең берсе – хәзер инде ир уртасы булып баручы Габделәхәт – читәннән корыштырган һәм сыер тизәге белән сыланган сыер фермасы янында тәмәке төреп торганда, Рауза килеп чыкты.* Ф.Баттал // Төрле кисәкләрне, әһәмиятсез нәрсәләрне бербөтен итеп берләштерү. *[Председатель] Бура эченә иске молотилкадан калган тимер-томырлардан әллә ниләр корыштырды.* Т.Миңнуллин

2) Җыйнау, җыйнакландыру

3) Ачытып авырту. *Башта кеше бу турыда уңайсызлый торган кысылутарсыну сизә, аннары бу хис урыныннан сызлап, чәнчеп яки корыштырып авырту башлана.* Йорт эшләре

**Корыштыра башлау** Корыштырырга керешү

**Корыштыра төшү** Бераз корыштыру

**Корыштырып бетерү** Тулысынча корыштыру

**Корыштырып кую** Алдан корыштырып, әзер хәлгә китерү

**Корыштырып яту** Күпмедер вакыт дәвамында корыштыру эше белән шөгыльләнү

**КОРЫШУ** *ф.* 1) Сулу, шиңү. *Чәчәк төсле гомерем, чәчәк тә бит карлы җилдән шиңеп корыша.* М.Җәлил. *Бу гаҗәеп бер күренеш иде: яшел төсен югалтып корышкан, сарыларга «сабышкан» яфрак, берни дә аңларга өлгермичә, нәкъ төштәге кебек үзенең соңгы очышында тирбәлә ---.* Т.Кәримов

2) Картлыктан, ачлыктан яки авырудан бик нык ябыгу, тәннең тулылыгы, турылыгы югалу. *Мин караватка якынрак килдем һәм күренгән кешенең ятлыгыннан аптырап калдым: бу – кипкән, корышкан һәм сукырайган бер карт иде.* Ф.Әмирхан. *Авырыйсыңмы – димәк, гөнаһың бар. Җәза итеп Тәңре җибәргән. «Череп кат!» диюче үзе корыша, үз каргышын алып бер бәндә.* Р.Фәйзуллин. *[Карт:] Кем син, Нәфисәгә охшаган зат? Тәне корышып каткан булса да, җаны әүвәлгечә калган Васил диган теге самими егетне эзләп, әллә күктән төштеңме?* Г.Әдһәм

3) Авыру нәтиҗәсендә аяк яки кулның коруы, тартышуы, эшкә ярамый башлавы. *Бөтен буыннары корышып, һич йөри алмыйча, эшли алмыйча бик*

*күп җәфа чиккәннәр болар.* Г.Баширов. *Тышын таракан кимергән Коръәнне карчык озак актарды, бер аятен гарәпчә мыгырданып, корышкан бармагы белән йөртеп чыкты да тамак кырып тезде ---.* М.Мәһдиев. *Таныш йорт та күренде: «Өйдә генә булса ярар иде!» – дип телдә корышкан иреннәр.* Ватаным Татарстан // Гомумән, гәүдәнең тартылуы, җыерылуы. *Корышкан һәм сукырайган карт*

4) Кору, кибүдән җыерылу, бөтәрләнү, йомарлану. *Ул бер уч шакмакны чәчеп җибәреп, берсен-берсенә чиртеп тидерә дә, аларны яңадан корышып беткән кулына җыя бара ---.* М.Галәү

5) *күч.* Мескенләнеп калу. *Туган җирем, синнән Аерылмаган чакта мин әле Әйбәт кенә, көч табыла миндә, Ә аерылсам, бетәм, корышам.* Х.Камалов

**Корыша бару** Торган саен ныграк корышу

**Корыша башлау** Корышу билгеләре күренү

**Корыша төшү** Бераз корышу

**Корышып бетү** Бик нык корышу. *Бөкерәеп, корышып беткән бер карчык баскыч алды себереп йөри.* Т.Миңнуллин. *Куллары белән җиргә таянып калырга телде, тик аны бу гына коткармады: җылыда озак торып корышып беткән чөгендер төсле гәүдәсе ярдан аска табан тәгәрәде.* Н.Әхмәдиев

**Корышып калу** Соңгы арада яки ниндидер бер вакыйгадан соң корышкан хәлгә килү. *Элек тә әллә ни итләч кеше түгел, яшьләргә ничек тә ярарга тырышып, ул тәмам корышып калды.* Ф.Хөсни

**Корышып китү** Көтмәгәндә корышу

**Корышып яту** *сөйл.* Озак вакытлардан бирле корышу

**КОРЯК** *и.* Камчатка крае составына кергән Коряк округында яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Төньяк халыклары – чукча, коряк һәм башка милләтләр – эчеп кырыла.* Татарстан яшьләре. *Аз язулы телләргә язулары Октябрь күтәрелешеннән соң гына барлыкка килгән телләр керә: абхаз, абазин, чукот, коряк, чечен, башкорт, ингуш һ.б.* Фән һәм тел

**КОРЯ́КЧА** *рәв.* **1.** 1) Коряк телендә. *Корякча укый-яза белү*

2) Корякларча, коряк халкындагыча. *Корякча биеп күрсәтү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Коряк телендәге. *Корякча дәреслек*

2) Корякләрдагы шикелле. *Корякча туй йоласы*

**КОСА́ТКА** *и. лат. зоол.* Дельфиннар семьялыгыннан, диңгез һәм океаннарда яшәүче, каралы-аклы төстәге ерткыч имезүче хайван

**КОСЕ́КАНС** *и. лат. мат.* Тригонометрик функция: өстәмә почмак секансы. *Кемдә шәфкать булыр, кемдә намус. Алан-йолан карыйм як-якка. Харап кына итте косеканс, Сыер булып басты аякка.* Г.Афзал

**КОСИ́ЛКА** *и. рус* Печән, үлән чабу машинасы. *Косилканың тәртәсе дуга белән күтәрелеп куелган, аңа камытлар, дилбегәләр эленгән.* М.Фәйзи. *Бары немец утарларында гына косилка тавышы ишетелгәләде – анда ашлык чалгыга эләгерлек булган дип сөйләделәр.* Ә.Еники. --- *Зөлфикарь – яшен ташы белән бер, һәрнәрсәгә өлгерә: алтынчыда укыганда ук, трактор йөртергә өйрәнде, җәен косилка белән печән чапты ---.* Ш.Янбаев

**КО́СИНУС** *и. лат. мат.* Тригонометрик функция: өстәмә почмак синусы. *Монда косинус функциясенең җөп булуы, синус функциясенең так булуы исәпкә алынды.* Комплекс үзгәрешле функцияләре теориясе нигезләре

**КОСМЕ́ТИК** I *с.* 1) Косметикага караган. *Битне юганда сабын гына түгел, махсус гельләр, күбекләр (мусслар), косметик сөтләр дә кулланалар.* Матур буласың килсә. *6–9 көнлек сорыкорт личинкалары гомогенаты косметик максатларда файдаланыла.* Татар балы. *Косметик максатларда лимон, кишер, керән, кыяр, фасоль еш кулланыла.* Юлдаш

2) Җиңелчә, өстән-өстән генә эшләнгән. *Рәсәйдә патша, генсек каршылаганда, урамнарны шулай чиста итеп себерәләр, коймаларны буйыйлар, йортларга косметик ремонт ясыйлар.* М.Юныс. *Һәйкәлләрнең күпчелеге ничек бар, шулай калды (косметик ремонтны, ягъни буявын яңартуны исәпкә алмаганда).* Ватаным Татарстан

**КОСМЕ́ТИК** II *и.* 1) *к.* **косметолог**

2) Косметика белән сату итүче. *Косметик булып эшләү*

**КОСМЕ́ТИКА** *и. гр.* 1) Гигиена һәм нәфислек, кайчакта дәвалау өчен, тән тиресен, чәчләрне тәрбияләү чаралары. *Нефтьне эшкәрткәндә алына торган минераль майлар (мәс., вазелин) косметика өчен ярамый.* Йорт эшләре. *Биш мең «яшел» акча даими рәвештә кыйммәтле әйберләр сатып алырга гына түгел, көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, үзеңне кием-салым, аяк киеме, косметика һәм азык-төлек белән тәэмин итәргә --- җитә.* Татарстан. *[40 тан соң] сезнең косметикада төп урынны җыерчыкларга каршы крем алып торырга тиеш.* Юлдаш

2) Бизәнү, биткә, тәнгә ясалма матурлык бирү әйберләре. *Косметика, сеңлем, сиңа Тәкъдим итеп «көдрә»сен, Чәчләреңне көйдерергә Өлгермәгән, күрәсең.* Х.Туфан. *Косметика җитештерүчеләрнең үз эшләнмәләре составына синтетик кушылмалар өстәве экологлар өчен сер түгел.* Юлдаш

3) Шул әйберләрне ясау һәм куллану сәнгате. *Косметика гүзәлләре урам тулы, ә мондый чәч кемдә бар?!* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Ясалмалык. – *Карга күзен карга чукымый... – Заман үзгәрде бит, так что... – Тышкы яктан гына, косметика бары.* Х.Камалов

**КОСМЕТИ́ЧКА** *и. рус* Гадәттә хатын-кызларның бизәнү әйберләрен салу өчен эшләнгән кечкенә янчык. *Юл чыгымнарына диелгән вак-төякләр косметичка белән бергә иңбашына асылган бәйрәм сумкасына бикләнде.* К.Кәримов. *Алар [японнар] таракан канатыннан зиннәтле хатын-кызлар сумкасы – косметичка, пудра һәм күзлек савытлары ясап сата башлаганнар.* Юлдаш

**КОСМЕТО́ЛОГ** *и. фр.* Косметология белгече. *Ну, иң әүвәл косметологка күренми булмастыр.* Р.Гаффар. *Тәҗрибәле косметолог кебек Керешә ул иҗат эшенә. Кызыл йолдыз кадый шунда әүвәл Сабыемның нәфис*

*түшенә.* Ф.Шәех. *Үз вакытында дөрес тәрбия күргән тән тиресе картаймый да, матурлыгын да югалтмый, диләр косметологлар.* Юлдаш

**КОСМЕТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның дәвалау косметикасы өлкәсендәге мәсьәләләрне өйрәнә торган бүлеге. *Еш кына яшьләр үз өстенә җаваплылык алырга теләми, алар дерматология, стоматология, косметология кебек акчалы белгечлекләрне сайлый.* Кызыл таң. *Тәндәге шул җөйләрне косметология ярдәмендә берәр ничек бетереп булмыймы?* Безнең гәҗит

**КОСМЕ́Я** *и. лат. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан катмарлы чәчәк ата торган берьеллык үсемлек, бакча гөле. *Георгин (Dahlia), цинния (Zinnia), рудбекия (Rudbeckia), гайлярдия (Gaillardia), бәрхет гөл (Tagetes), космея (Cosmos), кореопсис (Coreopsis) төрләрен бакча гөлләре итеп үстерәләр.* Ботаника

**КО́СМИК** *с.* 1) Космос, галәм күләмендәге; космоска бәйләнешле, космоста була торган. *Сызгыру, гүләү һәм шартлау рәвешендә ишетелгән космик тавышлар мәгънәле сүзләр, җөмләләр булып ирешә башлагач, Мөхәммәт мондагы һәр җисемнең тере икәнен аңлады.* З.Максуди. *Кораб космик чиксезлектә йөзгән Җир шарын хәтерләтә.* М.Юныс. *Ә атмосферада янып бетмичә, Җиргә төшкән космик җисемнәр метеоритлар дип атала.* Табигать белеме

2) Космостан килә торган. *Атмосферада атом төшләре, космик нурлар белән тәэсир итешеп, ирекле нейтроннар бүлеп чыгаралар.* Физика

3) Космоска оча торган. *Бу планетага [Сатурнга] космик аппарат берничә ел оча.* Табигать белеме. *Космик корабта радиациянең кайбер төрләреннән сакланып була, әмма бөтенесеннән дә түгел.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Бик тиз, бик зур, грандиоз, гигант. *Ара якынайган саен, адымнар кечерәя, ә йөрәк тибеше космик тизлек белән арта барды, арка буйлап салкын тир елгалары акты.* Ф.Бәллүр. *Техник прогрессның космик адымнар белән алга китүе, --- ил эчендәге миграция --- – болар һәммәсе дә бер телдән икенче телгә сүз керүен туктаусыз ихтыяҗ итә.* Х.Сарьян. *Минем Гаклым һәр яфракта Танып югалмас жирәбә, Таш һәм космик гасырларның Үлемсез бирләгән таба.* А.Хәлим

**КО́СМИК ТАШ** *и.* Метеорит. *Аларның [кратерларның] күпчелеге – Ай өслегенә метеоритлар (космик ташлар) төшеп бәрелү нәтиҗәсе.* Табигать белеме

**КОСМО-** *гр.* Кушма сүзләрнең беренче компоненты: 1) Космоска, космологиягә мөнәсәбәтле: *космофизика, космофизик, космохимия, космохимик* һ.б.ш.

2) Космонавтика фәненә мөнәсәбәтле: *космомедицина, космопсихология* һ.б.ш.

3) Космоска очуга, кешенең космоста булуына мөнәсәбәтле: *космоинженер, космопорт* һ.б.ш.

**КОСМОГО́НИК** *с.* Космогониягә мөнәсәбәтле. *Геометрик орнаментлар кырым татарларының космогоник карашларын чагылдырганнар.* Г.Гобәйдуллин. *Космогоник символлар иң борынгы символлардан санала.* Г.Гыйльманов. *Ләкин Кант үзенең космогоник тәгълиматыннан эзлекле материалистик һәм атеистик йомгаклар чыгара алмаган.* Философия

**КОСМОГО́НИЯ** *и. гр.* Астрономиядә күк җисемнәренең барлыкка килүен һәм үсешен, гомумән, Кояш системасының барлыкка килүен өйрәнә торган бүлек. *Ислам диненең космогония фәне өчен Коперник белән Галилей кирәкмәгән: аларның фикерләре баштан ук гадәти булган.* Г.Гобәйдуллин. *Кыскасы, адәм затының кояшка мәхәббәте мәңгелек һәм иксез-чиксез, ләкин мәхәббәтне космогония, күк җисемнәре белән генә чикләү дөрес булмас иде.* М.Әхмәтҗанов

**КОСМО́ГРАФ** *и. гр.* Космография өлкәсендә эшләүче белгеч

**КОСМОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Галәмнең тасвирламасы һәм аңлатмасы (мәс., йолдызларның, йолдызлыкларның исемнәре). *Их син, юләр, --- аякларым дип ятасың, төкер аякларыңа, --- латин белән космографиядән [икеле] алма.* Ф.Әмирхан. --- *Без хәзер үсемлекләр, хайваннар, мәгъдәннәр, техника, космография, җәгърафия, математика һәм тел турында халык атамаларын җыю баскычындабыз.* Г.Ибраһимов. *Бу космография – күк йөзендәге җисемнәрне, гомумән, күк йөзен тасвирлау фәне.* Татар милли педагогикасы

**КОСМОДРОМ** *и. рус* Космик корабларны һәм космик аппаратларны очышка җибәрү өчен махсус җиһазландырылган мәйдан. *Бу моңны космодромнан адәм баласы бөек батырлык эшләргә күккә күтәрелгәндә, бөек солдат, Ватан сугышы Герое – полководецка җитмеш-сиксән тулган көндә, --- опера һәм балет театрына җыйганда уйнарга кирәк.* М.Мәһдиев. *Баһадур белән бергә тын өйгә төрле техника, радиоаппатуралар кереп тулды, аның бүлмәсе космодромны хәтерләтә башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Космодромга бардым да, Билет кына алдым да, Очтым киттем биеккә, Очтым зәңгәр киңлеккә.* Э.Мөэминова

**КОСМОЛЁТ** *и. рус к.* **космоплан**

**КОСМО́ЛОГ** *и. рус* Космология фәне белән шөгыльләнүче галим. *Космологларның күзәтүләре*

**КОСМОЛО́ГИК** *с.* Космологиягә бәйләнешле. *[Искәндәр Сөмбелгә:] Космологик теорияләрең белән Хәмитнең башын катырма әле.* Р.Вәлиев

**КОСМОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Астрономиянең бер тармагы буларак, галәмнең барлыкка килүен һәм үсеш закончалыкларын өйрәнә торган фән. *Моны түбәндәге бер рубрика – космография вә космология даирәсе мисалында күрсәтергә мөмкин.* Р.Әхмәтьянов. *Бу чорда кибернетика, бионика, космология һ. б. кебек яңа фәннәр барлыкка килде.* Философия

**КОСМОНАВТ** *и. рус* Космоска, галәмгә очучы. *Без бит куркып торырга Түгел малай-шалайлар. Шулай да космонавт булу Авыр икән, малайлар!* Р.Миңнуллин. *Данлыклы очучы-космонавт Юрий Гагаринга кадәр алтмышынчы еллар башында бөтен дөньяны шаулаткан --- татар егете һәм ул җитәкләгән экипаж хакында сезнең укыганыгыз-ишеткәнегез бармы ---?*

Ш.Мостафин. *Космик корабльләр орбитага чыкканда, космонавтларның вестибуляр аппаратына авырлык арту бик көчле тәэсир ясый.* Биология

**КОСМОНА́ВТИКА** *и. рус* Космоска очуларны теоретик һәм гамәли яктан өйрәнә торган фән. *Кара син нинди техника, космонавтика, астронавтика.* Т.Миңнуллин. *Йолдызлары коелган илебез космонавтика көнен утыз бишенче тапкыр бәйрәм иткән чакларда, әлеге кырык сигез классташ очрашу үткәрергә теләде.* К.Кәримов. *Икенче дустым Борис Терёхин --- озак еллар буена космонавтика өлкәсендә иминлекне тәэмин итүче галимнәр һәм инженерлар төркемен җитәкләде.* К.Шакиров

**КОСМОНАВТЛЫК** *и.* Космонавт булу; космонавтлар шөгыле. *Космонавт булмаган әле Әтием дә, бабам да. Космонавтлыкка аларның Берсе дә укымаган.* Р.Миңнуллин. *Эш хакы да кирәк түгел, Машинага тартмый күңел. Космонавтлыкка кучәм: Галәмгә, Айга очам!* Р.Вәлиева

**КОСМО́НИМ** *и. гр.* Күк җисемнәренең гомуми фәнни атамасы. *А.В.Суперанская, космик киңлекләрнең иксез-чиксез булуын истә тотып, «космоним» терминын гомумирәк, «үз эченә галактика, йолдызлар җыелмасы, томанлыклар, йолдызлыкларны җыйган термин» дип атый.* Фән һәм тел

**КОСМОНИ́МИКА** *и. гр.* Ономастика фәненең космостагы төрле зоналар, күк җисемнәре атамаларын өйрәнә торган тармагы. *Бу китапта лингвоархеологиянең антропонимика, топонимика, зоонимика, космонимика өлкәләрендә тикшеренү нәтиҗәләре бирелә.* М.Зәкиев

**КОСМОПЛАН** *и. рус* Үз двигательләренең егәрлеге хисабына яки арадаш ракета яисә, шундый махсус очкыч ярдәмендә җирдән күтәрелеп китеп, турыдан-туры космоска чыга торган орбиталь кораб

**КОСМОПОЛИТ** *и. фр.* **1.** 1) Космополитизм тарафдары. *Космополит түгел. Шөкер, халкым да бар, ил дә, Ватан да.* Р.Фәйзуллин. *Милли чикләнгәнлек дип сөйләнүче татарлар – космополитлар койрыгына ябышкан тигәнәкләр ул.* Т.Миңнуллин. *Шовинистлар үтә нечкә хәзер. Космополит, ай-яй, модада!* А.Хәлим

2) Патриотизмның әһәмиятен, кирәклеген танымаучы кеше. *Космополит түгел, патриот мин, Нигә китим башка Галәмгә? «Венера»быз яки «Кояш»ыбыз Бу «Галәмдә» безнең юк әллә?* Х.Туфан. *Пабло Неруда – космик масштабтагы җир шагыйре. Ләкин ул космополит түгел. Ул – һәркайда үз халкының, җиренең улы.* А.Хәлим

3) Җир шарының күпчелек почмакларында очрый торган үсемлек яки хайван

**2.** *с. мәгъ. биол.* Җир шарының күпчелек өлешендә яшәү, үсү өчен махсус шартлар таләп итми торган (үсемлекләр, хайваннар тур.). *Эндемиклардан аермалы буларак космополит төрләр бик зур территорияләргә таралган.* Биология. Хайваннар. *Ул [гади бөркет канаты] – Җир шарының барлык өлкәләрендә киң таралган космополит үсемлек.* Ботаника

**КОСМОПОЛИТИЗМ** *и. гр.* 1) Гомумкешелек мәнфәгатьләрен һәм кыйммәтләрен аерым милләт яки дәүләт мәнфәгатьләреннән өстен кую карашлары һәм сәясәте. *«Космополитизм позициясендә торучылар фикеренчә, – ди С.Максуди, – сугышларны булдырмау өчен милләтләрнең милли хисләрен сүндерергә, аларны юкка чыгарырга, кешелек җәмгыятен һичнинди миллиятсез массага әйләндерергә кирәк».* Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман

2) Милләтләрнең мөстәкыйль яшәвен, дәүләт төзүен, милли патриотик традицияләрне һәм милли мәдәниятне кире кага торган идеология. --- *илленче еллар башында «космополитизм» белән көрәш башлангач, болгар экспонатлары бөтенләй юкка чыкты.* М.Юныс. *Әлбәттә, бүгенге яшьләребезгә заманның төссезлек, нәселсезлек, ырусызлык, милләтсезлек, космополитизм чире йога бара.* Т.Миңнуллин. *Коммунистик идеология хакимлек иткән чорда сүз сәнгатендә миллилекне күрсәтү натурализм дип бәяләнде, нindидер милли төсмерләрдән азат булган космополитизмга ирешү идеал булып саналды.* Ф.Галимуллин

**КОСМОПОЛИ́ТИК** *с.* 1) Космополитизмга мөнәсәбәтле. *Иң әүвәл театр бетә, музыка, рәсем һәм башка сәнгатьләр дә, табигый сулен югалтып, космополитик дәрьяда эри, югала...* Р.Фәйзуллин. *Җирдәге кырмыскалар биеклеге туйдырса, галәми киңлекләргә чыгып китәм, туган тел кысаларына, үги булып, әллә нинди космополитик сүзләр килеп керә.* М.Галиев. *Истә калырлык та түгел, әллә нинди сынык-ватык һәм милли төсмерсез, космополитик көйләр басып алган эстраданы.* Ватаным Татарстан

2) Киң таралган, яхшы үсә, үрчи торган (үсемлекләр, хайваннар тур.). *Семьялыкка [элмәчәләр семьялыгы] 18 ыруг һәм космополитик таралган 200 гә якын агаччыл төр керә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КОСМОПОЛИТЛЫК** *и.* Космополитизм идеяләрен яклау, аларны куәтләү, космополит булу. *Бу илләрдә космополитлык һәм яңача фикерләү процессы кызурак темплар белән бара.* К.Гыйззәтов. *Аннары [Н.Нәҗми] икенче бер шигырендә татарның космополитлыгы өчен, Татарстаннан читтә яшәгән 80 процент татарның телен югалтуына әрнеп болай яза ---.* М.Кәримов. *Космополитлык – күпмедер дәрәҗәдә бөтен халыкларга да хас нәрсә.* Татарстан яшьләре

**КО́СМОС** *и. гр.* 1) Җир һәм башка күк җисемнәренең атмосфера чикләре тышындагы, чагыштырмача буш галәм киңлеге. *Радио сүзе дөрес тә инде, әнә бит, космостан да хәбәр итеп торалар, ди...* Г.Гыйльманов. *Тик Фәхрәзи, космос белән элемтәгә керү өчен, гади кеше аңыннан чыгып, миен нindидер башка халәткә корырга өйрәнергә тиеш.* З.Мурсиев

2) Барча галәм, җиһан, дөнья. *Безнең чорда космоска ракета очырту да, атом төшен аерып алу да катлаулы түгел.* М.Юныс. – *Әллә космоска җибәрәләрме? – дип, егет сүзен шаяртуга борды кыз.* Ә.Моталлапов. *Брежнев торгынлыгы елларында без космоска очтык, фәнне үстердек, БАМ*

*төзедек һәм дөньяда үз урыныбызны били идек.* Татарстан яшьләре

**КОСМОҮЗӘК** *и.* Космик үзәк

**КОСМОЭНЕРГЕ́ТИК** *и. гр.* Космоэнергетика өлкәсендәге белгеч. *Гусейн Абушев Мәскәүдә танылган космоэнергетик Эмиль Багировта белем алган, Казанга килгәч, медицина академиясен тәмамлаган.* Кәеф ничек?

**КОСМОЭНЕРГЕ́ТИКА** *и. гр.* Оператор белән энергиянең тышкы кырларының үзара бәйләнеше һәм психик эшчәнлек хисабына шул энергия белән идарә итүгә нигезләнгән тикшеренү юнәлеше

**КОСТА-РИ́КАЛЫ** *и.* Коста-Рика Республикасында яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Коста-рикалылар үзләрен иң бәхетле халык дип санныйлар икән*

**КОСТЁЛ** *и. пол.* Католиклар чиркәвенең полякча исеме. *Аларның аргы ягында кечкенә авыл, авыл кырыенда бер имение янында кызыл кирпечтән ясалган костёл да бар.* А.Таһиров. *Костёл буенда өсте гөмбәзләп ябылган сәхнә сыман корылма.* Х.Камалов. *Рим Папасы Иоанн Павел II ярдәме белән Казанга Изге Ана иконасы кайтарылганнан соң, костёл төзү көнүзәк мәсьәләгә әйләнде.* Й.Шәрапова

**КОСТЁР** I *и. рус сөйл.* Ачык урында янып торган утын, чыбык-чабык өеме, учак. *Бөдрәләнеп костёр яна.* Ә.Ерикәй. *Кичләрен киң болында костёрлар кабынды.* Г.Гобәй. *Костёр янып бетә; аның соңгы төтене җәелеп кенә югары күтәрелми, еракка күренми тарала.* Н.Абдулкәримова

**КОСТЁР** II *и. рус бот. к.* **кындырак**. *Бары тик 500 гектар орлык өчен (100 гектар люцерна, 400 гектар ут үлән (костёр)) һәм 200 гектар чамасы малларга яшел килеш ваклатып ашату өчен калдырылды.* Әлки хәбәрләре. *Уңышын җыеп алгач, костёр басуын да яңартачакбыз, «картайган» басуда өмет аз.* Кызыл таң

**КОСТЫЛЬ** *и. рус сөйл.* 1) Култык таягы. *Дин кулындагы үзенең таянып йөри торган агач костыле белән сукмакчы булып, Газимачукка кизәнгән иде.* Ш.Камал. «*Врачларга костыль белән кизәндем», – дип сөйләгән соңыннан әнигә [әти].* Туганайлар

2) *махс.* Рельсны шпалларга беркетү өчен эшләнгән махсус юан очлы кадак. *Хәзер рельслар, шпаллар тирәсендә су кебек ару балласт шпаллар, шөрепләр, костыльләр яңартылганнар, вагон сикерми, төз бара.* Г.Гали

3) Самолётның койрык терәге. *Сапны тагын тарта төштем – самолётның койрык астындагы костыле һәм ике тәгәрмәче белән йомшак кына итеп җиргә тигәнен сиздем.* С.Баттал

**КОСТЫРГЫЧ** *с.* **1.** 1) Костыра торган, ашаганны кире чыгарта торган. *Тирләткеч, костыргыч һәм басымны төшерә торган сапониннар бар.* Урман аптекасы. *Кайбер рецептлар ярдәмендә авыруда костыргыч рефлекс барлыкка килә.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Бик тәмсез; бик ямьсез, зәвыксыз; җирәнгеч. *Аның фикеренчә, Сталинга карата әйтелгән һәр яман сүз көлке һәм костыргыч.* Безнең гәҗит

**2.** *и. мәгъ.* Ашказанын юдыручистарту максаты белән, шулай ук агулануга каршы эчелә торган дару, сыекча. *Аның [костыргыч тамырның] тамырларында ютәлне йомшарткыч, костыргыч, эч йомшарткыч буларак кулланыла торган эмитин һәм башка алкалоидлар бар.* Ботаника

**КОСТЫРГЫЧ ТАМЫР** *и. бот.* Мареначалар семьялыгыннан, нәзек сабаклы, киң шома яфраклы, ак төстәге көпшәсыман вак чәчәкле куак үсемлек; медицинада тамыры костыра һәм кайырта торган дару буларак кулланыла; *русчасы:* **ипекакуана**, **рвотный корень**. *Ипекакуана, яки костыргыч тамыр (Cephaelis ipecacuanha) – мөһим дару үләне.* Ботаника

**КОСТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **косу**. *Костырырга омтылып карадым, аңын югалткан хәлдә булгач, ашказанын зонд белән юдырырга батырчылык итмәдем ---.* Г.Галиев. *Көчле кислота яки селте белән агуланганда [кешене] костырырга ярамый.* Йорт эшләре

2) Ашаган-эчкәнне кире чыгаруга китерү. *Бу дару костыра*

3) *з.-сыз* Ирексездән, үзлегеннән косу. *Укшыта, ачлыктан кабыргаларга ябышкан эчләр суырыла. Баштарак костыра иде, акрынлап иялнде бугай [Шакир].* В.Гали. *Мондый очрак була калса, эч авырта, күңел болгана, костыра, температура күтәрелә, калтырата, йөрәк тибеше ешая, көзән җыера.* Татарстан яшьләре

4) *күч. туп.* Үзләштергәнне кире кайтарып алу, тартып алу. *Бик күпләрне, бирән корсак, кабып йоткан идең, Костырырлар йотканыңны, тотса Мәскәүләр якаң!* Ә.Исхак. *Халыктан җыйган йомыркаларын костырырга кирәк оятсызның!* Ә.Фәйзи. *Ул аңа яхшылык эшләвен һәрчак тәкрарлый, бригада эшенә каршы килүләрен шуның белән җиңә. Моны халыкта, яхшылык эшли дә шуны костыра, диләр.* Х.Камалов

5) *күч.* Начар тәэсир итү; тискәре фикер калдыру (кеше тур.). *Үз-үзен тотышы костыра*

**Костыра башлау** Костырырга тотыну. *Ашаганнан соң авыруны укшыта, костыра башлады*

**Костырып бетерү** Тулысынча костыру

**Костырып җибәрү** Кинәт кенә ирексездән костыру

**Костырып тору** Әледән-әле, өзлексез костыру

**КОСТЮМ** *и. фр.* 1) Ирләр өчен чалбар-пиджак, кайвакыт жилеттан, хатын-кызлар өчен жакет, итәк яки чалбардан торган кием-салым комплекты. *Зәвык белән тегелгән костюмның күкрәк турысыннан – ак ефәк кофточка өстеннән сузылып төшкән кызыл галстук кызның күрекле йөзенә матур җитдилек биргән.* К.Тинчурин. *Әле хәзер генә өметләнеп ялкынланып янган күзләрен каршындагы сәкедә утырган шакмаклы костюмлы, кызыл ефәк яулыклы хатынга текәде.* А.Шамов. *Әйе, бу костюмны Газиз киңәшмәдән киеп кайткан иде.* Г.Бәширов

2) Махсус шөгыль, профессия өчен кием. *Әүкәтнең суга чумган минутыннан файдаланып, Мәрьям, чуар сарафанын салып, су коену костюмын киеп ала.* М.Маликова. *Һәм ул, башлык белән җиңел спорт костюмы – трико гына кигән ялан куллы солдат, таяклары белән берөзлексез этенеп, алга*

*баруын дәвам итте.* Р.Кәрами. *Тулы водолаз костюмы, калын броня диярлек авыр панцирь кияргәме?* Диңгез тирәнлегендә

3) *сөйл.* Пиджак. *Шунда чирәмлектән урын сайлап, Самат җиргә костюмын җәя башлады.* Г.Гыйльманов. *Габдрахман агайның өстендә кара костюм, башында кара бәрхет кәләпүш.* С.Сабиров. *Бу костюмны ире Илсур күптән түгел генә Чехиядән алып кайткан иде.* Чаян

4) Билгеле бер социаль катлау, чор, этнос кешеләренә хас киемнәр. *Изү яки хәситә кебек салына торган бизәү элементлары костюмга бәйрәм төсмере өсти һәм аның затлылыгын арттыра.* Гомер агачы. *Кием-салым авторлары «Прет-а-порте», «Делюкс» һәм «Милли костюм» номинацияләрендә көч сынашты.* Ватаным Татарстан

5) Театрчылык эшендә кирәк булган һәртөрле сәхнә киеме. *Сәхнә мәйданын файдалану, костюмнар сайлау, тавыш һәм музыка бизәлеше, бутафория һәм реквизит мәсьәләләрен хәл итүдә беренчел принциплар нинди?* М.Арсланов. *--- Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар» (1937), «Бишбүләк» (1938) спектакльләренә, Н.Җиһановның «Качкын» (1940) операсына декорацияләр һәм костюмнар эшли художник.* Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел

**КОСТЮМЕР** *и. фр.* Театрда костюмнар өчен җаваплы кеше. *Сукырлар театры бит без, ә мин – аның режиссёры да, артисты да, суфлёры да, билет сатучысы да, костюмеры да.* Х.Сарьян. *[Ул] Ленинград театрының элеккеге костюмеры тегеп биргән смокингын да алып, бәйрәм көннәренә (юк, Мартукка түгел!) Актүбәгә кайтып китте.* Р.Мирхәйдәров

**КОСТЮМ-КҮЛМӘК** *и. к.* **костюм** (*1 мәгъ.*). *Билаловны каптёркага чакырсалар, ни күрә: алдында моданың соңгы зәвыгы белән тегелгән костюм-күлмәктән киенгән фырт егет басып тора.* С.Шәрипов

**КОСТЮМЛЫК** *с.* **1.** 1) Костюм тегәргә яраклы, җитәрлек. *Галләм абзый сандыкны актарып, аннан улына дип аталып та тектерергә өлгерә алмый калган костюмлык материалны эзләп тапты ---.* Ш.Бикчурин. *Орден белән бергә аңа костюмлык сукно, бурка, җигүле ат, гаиләсе өчен бүләкләр бирелә.* М.Ибраһимов. *Ахыр чиктә 6 төрдә костюмлык һәм 6 төрдә пәлтәлек тукымалар җитештерелә.* Шәһри Казан

2) Костюм тегү, сатып алу өчен билгеләнгән. *Костюмлык акча*

**2.** *и. мәгъ.* Костюм тегү өчен алынган яки әзерләп куелган тукыма. *Тиз арада сандыклар актарыла башлый, чөнки Равилә кайтуга дип күлмәклек яки костюмлык махсус алынган була.* Ф.Яруллин. *Кече лейтенант Баязитовның әйтүе буенча, баш кеше, өйгә кайтучыларга бүләк итеп бирелә торган товардан бер кешелек үлчәм (костюмлык) ала һәм аны биш литр спиртка алыштыра.* М.Яһудин

**КОСТЮМ-ЧАЛБАР** *и. к.* **костюм** (*1 мәгъ.*). *Онытып җибәргәнмен икән: сиңа Илгиз абый костюм-чалбар бүләк иткән дигәннәр иде ---.* Ф.Яруллин. *Костюм-чалбарларын алыштырып, юынып, өстәл янына килгәндә, Хәят кайнар өчпочмаклар китереп куйды.* Ф.Садриев. *Борынына ис кერә башлагач, үзенә яңа костюм-чалбар алып бирүне сорый бу бәндә.* Чаян

**КОСТЮМ-ЮБКА** *и. к.* **костюм** (*1 мәгъ.*). *Хатын эре шакмаклы материядән теккән костюм-юбкадан, лаклы туфлидән иде.* Х.Камалов. *Җем-җем итеп торган алкалар, муенсалар, искиткеч затлы костюм-юбка аны кинофильмнардагы чит ил аксөякләреннән ким күрсәтми иде.* Фән һәм тел

**КОСУ** I *ф.* **1.** 1) Ашаган-эчкәнне кире чыгару. *Аның күңеле бик каты болганып, косасы килә башлаган иде.* Ф.Әмирхан. *Мин кечкенә мәгарә эчендәге бүре балаларын карап тормадым, кан күреп күңелем болгана, косасым килә башлаган иде.* Г.Тавлин

2) Эчтәгене авыздан чыгару, төкерү (кан тур.). *Мин, зинданда кан косып яткан иптәшемне коткарыр өчен, бер тиен акча да тота алмыйммы?* Г.Ибраһимов. *Канын космады бу юлы юаш карт, канын йотты, җиңе белән иренен сөртте ---.* А.Гыйләҗев. *Түшәк өстендә кан косып яткан вакытта, әнә беркемгә дә аның һәм аңа да һичкемнең кирәге юк иде.* В.Имамов

3) *күч.* Җирәнү, кабул итмәү. *Менә бездә бер карагруһлар гәзитәсенең сүзләрене ишетсәң, үзең дә косарсың.* Г.Тукай. *--- гафу итегез, майлы күзләрдән косасы килә.* Т.Галиуллин

4) *күч.* Башкалардан талап җыйган нәрсәләрне кире кайтарырга мәҗбүр булу турында

5) *күч.* Күпләп чыгару. *Гыйфритләрем оҗмахтагы затлы җиләк-җимеш агачларын гариплә ганнәр, көмеш сулы күлләрдә йөзгән алтын кошларны, үрдәкләрне ботарлаганнар. Әйтәм аны макмырдан тилмергән вакытларында алтын косып йөрделәр!* З.Мәһмүди. *[Автобус] Ахылдап-ухылдап, ишекләрен ачты. Бер кочак кешене косып чыгарды да ике кочакны суырып алды.* Ж.Юныс

6) *күч.* Тимергә тиеп торган нәрсәгә тимер тутыгы чыгу. *Озак торса, җиләк салган савыт косарга мөмкин*

7) *күч.* Башак чыгару. *Ә янәшәдә, күз күреме җитмәс офыкларга тартылып, арыш дулкынлана. Димәк, арыш баш коса.* А.Хәлим

**2. косарсың** *ы. мәгъ.* Җирәндергеч, шакшы, чиксез әшәке. *Косарсың бу кыланышларыннан!*

**Коса башлау** Косу билгеләре күренү. *Күбесе коса башлый, кайберләре һуштан язып егыла ---.* Р. Батулла

**Коса язу** Чак космый калу. *Дару эчкәннән соң, авыру коса язды*

**Косып алу** Бераз косу. *Машина туктагач, бала косып алды*

**Косып бетерү** Барысын да, ахырга кадәр косу. *Ашаганын косып бетерде*

**Косып җибәрү** Кинәт косу. *Кизәнеп чабарга иткәндә, әлеге кыз куркуыннан косып җибәрә.* Әкият. *[Илсөяр] беркөнне сыйныфта утырганда, күңеле болганып косып җибәрде.* Р.Хәбибуллина. *Ул арада эчем актарылып, ургып косып җибәрдем.* Г.Галиев

**Косып йөрү** Даими, еш, әледәнәле косу. *Эшләр өчен шартлар начар бит, Алия Фәргатовна. Янында косып йөрсәләр, дикъкать тарала шул ул...* М.Маликова

**Косып кую** Көтмәгәндә, кинәттән косу. *Җиңел машина эчендәге сасы искә, тавышка тешне кысып түзеп, өстемә косып куймасалар гына ярар иде дип борчылып бара торгач, изрәп киткәнмен.* Татарстан яшьләре

**Косып ташлау** *сөйл.* Кинәт косу. *Тик йомырканың көч-хәл белән чәйнәп йотылган өч-дүрте дә берничә минуттан, өелеп, бугазына килде, һәм ул аларны косып ташламыйча булдыра алмады.* Р.Рахман

**Косып тору** Һәрвакыт, өзлексез косу

**Косып чыгу** Билгеле бер вакытны косып үткәрү. --- *эчкән савыты шакшы булдымы, бала төне буе косып чыкты.* А.Гыйләҗев

**Косып яту** *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта косу; шактый вакыттан бирле косу. *[Зариф абзый:] Ни булсын, бер эчеп кайтуында подвал баскычыннан мәтәлеп төшкән. Хәзер кан косып ята икән...* Ә.Еники. *Өйрәнчек бомба ташлау алты йөз метр биеклектән иде. Өч йөз метрга күтәрелеп җиткәндә, инде без, алты курсант, идәндә тәгәрәшеп косып ята идек.* М.Юныс. *Тәне кызышып, башы әйләнеп, косып ятканда, бакча яныннан узып баручы, күреп, фельдшерны чакырган, рәхмәт төшкере.* Татарстан яшьләре

**КОСУ** II *и.* Ашказаныннан азык калдыкларын кире чыгару процессы. *Косуы туктаганчы, башка һичнәрсә каптырырга ярамый, диде [доктор].* Г.Ибраһимов. *Күп очракларда кеше организмына пычрак һава тәэсиренең билгеләре булып баш авырту, колак «шаулау», сулыш авыраю, косу, хәлсезлек, эш сәләте киму тора.* Сәламәт яшәү нигезләре. *Укшу, көнгә биш-алты мәртәбә косу, тора алмыйча яту – менә шул була инде җиңелчә токсикоз.* Сөембикә

**КОСУР** *и. гар. иск. кит.* Кимчелек, җитешсез як. *Моның сәбәбе, бәгъзе кешеләр безнең димагымызның (миебезнең) шундый косур (кимчелек) берлән яратылуыннан дисәләр дә, минемчә, монда да эшкә өйрәнмәгәнлекемезнең бик күп зарары бардыр.* Г.Исхакый

**КОСЫК** *и.* Косып чыгарылган нәрсә. *Өйләре кап-караңгы, косык исе белән сасыган.* М.Гафури. *[Ионыч] йокымсырый иде, айныды, карлыккан ямьсез тавыш белән, косык исе чәчеп, Нәҗипкә ябырылды.* А.Гыйләҗев. *Әгәр дә [агуланган] кешенең хәле авыр булса, косыгыннан тончыкмасын өчен, башын кырыйга боралар.* Йорт эшләре

**КОСЫК ДАРУЫ** *и. к.* **костыргыч 2**

**КОСЫ́НКА** *и. рус сөйл.* Өчпочмаклы кечкенә яулык, кыекча. *Нажия кыска жакетын киеп, матур бизәкле ефәк косынкасын бәйләгән чакта, Майпәрвәз ханым аңа сокланып карап тора.* Ә.Еники. *[Мәрзиянең] чәчләре чуалган, косынкасын кулына тоткан иде.* Г.Ахунов. *Егетләр кыска козырёклы кепканы кырын салганнар, кызлар өч читле яулык бәйләгән – косынка дип атала.* Т.Миңнуллин

**КОСЯК** *и. рус махс.* Балыкларның, гадәттә, үрчү чорында өер булып тупланганлыгы; көс. *Бер көнне яр кырына чехонь көтүе (косяк) килде.* Р.Батулла

**КОТ** *и.* 1) *миф.* Тәннән аерылып китә ала дип уйланылган җан; рух. (*Фәләннең) коты чыккан, Кил коты, кил коты! Күгәрчен күк гөрләп кил! Кыр казы күк тезелеп кил! Ак җилен күк савылып кил! Кил коты, кил коты!* Ф.Урманчеев. *Һәркемнең үз коты бар. Алай гынамы, һәр нәрсәнең, һәр төбәкнең, кала-авылларның үз коты бар, диләр.* Г.Хөсәенов

2) Шайтан кагылмасын, зәхмәт тимәсен дип яки башка максат белән янда йөртү өчен койдырып эшләнгән «җан» сурәте. *Бу сүзләрне тыңлап илбик шат булды, Кулларын күтәреп, бер дога кылды. Әйтте: – И, ярдәмле, кот кылган иям, Сыгылган көнемдә сыгынган иям.* Й.Баласагуни

3) Нур, ямь; матурлык. *Тауда ятып тай баккан, Кырда ятып куй баккан, Елкычыдан би булган, Түрәң булган Кобогыл Өрәңгедән каты икән; Килбәте синнән киң икән, Коты синнән котлы икән.* Дастан. *Өй эчендә кот калмаган, китаплар чәчелгән, Дивангәринең бизәкле артыш таягы урталай сынган, өй хуҗасыз, ятимлек төсе өй түренә менеп утырган.* Р.Батулла

4) *иск.* Бәхет, уңыш; файда. *Ни ди, ишет, танылган кеше, Бәхет-коты белән дан алган кеше: «Кемең белән дәүләт ярашса килеп, Башын күккә тигерер, югары кылып».* Й.Баласагуни. *Тирә-якта кармак салган малайлар, кот эзләп, я Ишбайга, я Былыуга, я Димгә китте. Без калдык.* М.Кәрим

5) *иск. филос.* Табигатьтәге дүрт стихиянең җыелма исеме (җир, су, ут, һава)

◊ **Кот ботка җиту** *к.* **кот очу**. *Буржуйларның коты ботына җиткән, куркуларыннан тимер капкаларын эчтән имән бүрәнә белән терәтеп куйганнар.* Н.Әхмәдиев. **Кот ботка йөгерү** *к.* **кот очу**. *Нәзкәйнең коты ботына йөгергән. Йөгерер шул! Өеңә урыс кереп чукынсын да, әллә нәрсәләр дип урыс телендә сөйләсен дә, кылычын өстәвенә шапылдатсын.* З.Зәйнуллин. **Кот ботка төшү** *к.* **кот очу**. *Үлемҗитем дигән сүзләрне ишетә алмыйм, «ашыгыч ярдәм» сызгыртып үтә башласа, котым ботыма төшә.* А.Гыйләҗев. *Котым ботыма төшеп җиткәндер, куркуымнан чинап җибәрдем.* Ф.Яхин. **Кот бугазга килү** *к.* **кот очу**. **Кот калмау** *к.* **кот очу**. *Ничә сөйләсәң дә, дала яклары – мәкерле як шул, бүген кырау төшәме әллә дип котым калмаган иде, ярый әле таң алдыннан җил исеп куйды ---.* М.Шабай. *Бездәге офицерлар тузынышып чыктылар берзаман, котым калмады.* А.Гыйләҗев. *Болай да тәндә кот әсәребез калмаган, ә теге шайтан туп-туры безгә якынлаша бара, тояклары белән җирне актара, пошкыра, тагын әллә нәрсәләр эшли.* Ф.Яхин. **Кот качу** Бәхет китү, тынычлык бетү. *Кайнап торган, күкрәп торган авылдан кот качты.* Р.Батулла. **Кот китү** *к.* **кот качу**. *Кот киткәндер рух язуын үзгәрткәч ---.* Р.Гаташ. **Кот кошы** Бәхет алып килүче берәр кеше яки нәрсә; гомумән, бәхет символы. *Тугры бул – ташламас сине кот кошың. Тугры юлдан йөрсәң, төнгә калмассың.* Й.Баласагуни. **Кот куну** 1) Бәхет килү. *Колхозда эшләп кот кунган кешене күрмәдем мин ул вакытта.* Т.Миңнуллин. *Безнең йортка нигә кот кунмый, дисәм, бухгалтер-экономист җитмәгән икән...* Р.Вәлиев. *Гел шулай уңып торсын, тәнеңә ит, җаныңа кот*

*кунсын...* Г.Гыйльманов; 2) Ямьләнеп китү. *Өйгә кот куну.* **Кот очарлык** Бик куркыныч. *Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я өрәкме, нәрсә бу? Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!* Г.Тукай. *Галимнәр кәрәзле телефоннарның зыяны турында кот очарлык нәтиҗә чыгарган.* Ватаным Татарстан. **Кот очу** Бик нык курку. *Самолёт тәрәзәсеннән котым очып карыйм: бер төркем артисткалар каршы алырга килгәннәр.* Г.Әпсәләмов. *Бермәл таң яктырып килгәндә, баш очында гына гөп-гөп итеп ике тапкыр мылтык аттылар. Без, кот очып, сикерешеп тордык.* М.Кәрим. *Әмма берничә рәт кызны түшәкләре янында күреп, коты очты җиңги кешенең.* С.Лашманчы. **Кот очыру** *к.* **котын алу**. *Шомлы аваз кабат яңгырап, тагын котын очырды.* К.Тәхау. **Кот табанга төшү** *к.* **кот очу**. **Кот тубыкка төшү** *к.* **кот очу**. **Кот урынына утыру** Тынычлану. *Кем булырга мөмкин бу? Таныш, бик таныш тавыш иде ул! Тәнемә җан кайтты. Котым урынына утырды.* Ф.Яхин. **Кот үкчәгә төшү** *к.* **кот очу**. *Курку хисе берәүләрнең котын үкчәләренә төшерә, бүтәннәрне тиңсез каһарманлыкка өнди, шуңа ирештерә.* Ә.Гаффар. **Кот чыгу** *к.* **кот очу**. *Чалгыга киселермен дип, ул Бибинур чапканда да әллә каян читтән генә коты чыгып карап тора.* А.Гыйләҗев. *Кинәт мин куркып, котым чыгып, ләмгә ныграк сыендым.* Ф.Бәйрәмова. *Әллә бер-бер бәхетсезлеккә юлыгып куйдыңмы дип котым чыкты.* Я.Зәнкиев. **Коты култык астында** Бик куркак кеше турында. **Котын алу** Бик нык куркыту. *[Мескен генә авылларның] йөзьяшәр имәннәре елдан-елга мәгърурлана, колач җитмәслек кәүсәләре, бүрәнә-бүрәнә ботаклары белән котны алып, җилдавылдан курыкмыйча, һаман үсә дә үсә, ныгый да ныгый.* Ф.Яхин. *[Мостафа] Килеп бераз торгач та, тегенең [Заһидулланың] котын ала башлыйм: – Хәзер кайтып китәм, – дим.* М.Кәрим. *Крокодил! Җир йөзендәге барча тереклекияләренең котын алып торган, гаять зур, бик гайрәтле һәм рәхимсез ерткыч бу.* Кызыклар дөньясында. **Котын качыру** *к.* **котын алу**. *Инде хәзер, үзенең шундый булуына карамастан, янган йортының котын качырып, әллә кем рәвешендә һаман бушны бушка аударуында.* Ф.Мансуров. **Кот чыгарырлык** *к.* **кот очарлык**. *Ул төтен, ул төтен! – Алып та булмый тын! Көпчәкләр дөберди, Чыгарырлык котың.* Г.Тукай

**КОТАЙТКЫЧ** *с.* Бәхетле итә торган

**КОТАНАЙ** *и.* 1) Иске төрки мәҗүсилектә кот кую, күрәзәлек итү кебек эшләр белән шөгыльләнүче карчык

2) Убырлы карчык, ямьсез хатын. *Кайгыга бирелсәң, әни әйткәндәй, котанайга әверелерсең, убырлы карчык булырсың да калырсың...* М.Хуҗин

**КОТА́НГЕНС** *и. лат. мат.* Тригонометрик функция: өстәмә почмак тангенсы

**КОТА́Ю** *ф. сөйл.* 1) Тазарып, матурланып китү (мәс., авырудан соң); ямь керү. *Гётега тиң бер язучы әйткән: – Матурлыктан дөнья котаер!* Р.Тойгын

2) Тиенү, нәрсәнең дә булса җитәрлек булуы турында. *Пычакчы пычакка котаймас.* Мәкаль. *Гомере буе яллanып эшләп, әти котая алмады.* Т.Миңнуллин. *Сабак биреп Сабак алалмаган Милләтләрнең кайсы котайды?* М.Әгъләмов

3) Мактану. *Чыннан да, моның белән котаерга буладыр. Өч мең сум, ди бит...* Ф.Мансуров

**Котаеп бару** Торган саен күбрәк котаю

**Котаеп бетү** Тәмам котаю

**Котаеп китү** Тиз арада, көтмәгәндә котаю

**КОТЕЛОК** *и. рус* 1) Гадәттә гаскәриләр куллана торган тоткалы кечкенә металл савыт, аш савыты. *Низами тәмле буларын чыгарып торган алюмин котелокны аның каршысына китереп куйды. – Йөз граммны да исәнлеккә җибәрәбезме әллә?* Г.Әпсәләмов. *Берәүләр, котелокларын тотып, кайнар суга йөгерделәр, икенчеләр су алып кайткан паровоз янында билдән чишенеп юынырга, төртешеп, су чәчрәтергә тотындылар.* М.Мәһдиев. *Ләкин котелокта ботка түгел, шулпа гына.* Дөньяда ниләр бар

2) Шундый савыт рәвешендә эшләнгән түгәрәк өсле, тар читле каты эшләпә

**КОТЕ́ЛЬНЫЙ** *и. рус* Пар казаннары куелган бина. *Безнең Мәснәви шахтада котельныйда янган түгелме?* А.Гыйләҗев. *Щитлы йортлар салынган урамда үзәкләштерелгән котельный була, ир-ат утын әзерләп иза чикми, хатын-кыз – мич ягып.* М.Мәһдиев. *Салынып бетмәгән котельный бинасы бар иде, шуны ашыктырып төзетә башладылар.* Х.Камалов

**КОТЕ́ЛЬНЯ** *и. рус к.* **котельный**. *Лаештан Казанга кадәр 40 чакрымлы су торбалары сузарга, насос станцияләре чылбыры төзергә, котельнялар, юллар салырга, җиһазлар алырга, кешеләр ялларга кирәк булыр иде.* Татарстан. *Терлекчеләр йорты, котельня санаулы минутлар эчендә янып, көлгә әйләнде.* Ватаным Татарстан

**КО́ТИК** *и. рус зоол.* **1.** 1) Колаклы тюленьнәр семьялыгына караган кыйммәтле мехлы, ишкәк аяклы имезүче хайван; диңгез мәчесе. *XX гасыр башында котиклар юкка чыгу алдында була*

2) Шул хайван тиресеннән эшләнгән мех

**2.** *с. мәгъ.* Шундый мехтан тегелгән. *Әле генә котик манто алдың түгелме?* Т.Гыйззәт. *Аягына ак фетр ботылар, өстенә кара котик манто кигән хатын универмаг тирәсендә күзегезгә чагылып калса, алданмассыз, Күсия ханым булыр ул!* Ә.Еники

**КОТИЛЬОН** *и. фр.* Франциядә барлыкка килгән, берничә мөстәкыйль бию һәм уеннан торган бал биюе

**КОТИРО́ВКА** *и. фр. финанс.* 1) Кыйммәтле кәгазьләргә биржа бәясе кую. *Газетаның алдагы санында котировка, индекс, ликвидность турында, биржаларда, фонд базарларында кемнәрнең һәм ничек акцияләрен сату-алулары --- хакында язарбыз.* Татарстан яшьләре

2) Биржада кыйммәтле кәгазьләр яки товарлар әйләнеше. *«Мин көн саен котировкаларны көтәм, акчаларым күпмегә артканын тикшереп барам,*

*үпкәләмә, кайта алмыйм», – диде [Илгизәр].* Р.Сәгъди

**КОТКАРУ** I *ф.* 1) Нинди дә булса авыр, хәтәр яисә исәнлегенә, бөтенлегенә куркыныч янаган хәлдән чыгару, котылдыру, саклап калу; нормаль хәлгә китерү. *Ул --- Шәйхулла дустының аны Житомир янындагы каты бер сугышта ничек итеп үлемнән коткарып калуы турында бик тәмләп һәм тәфсилләп сөйләргә керешә.* А.Шамов. *Дошман бомбалары яуган чакта, Җир коткара мине үлемнән.* Ә.Ерикәй. *Макай төнен йоклаган – Акбай аны саклаган. Макай батмый чак калган – Акбай аны коткарган.* И.Юзеев

2) Уңайсыз, кыен хәлдән чыгу мөмкинлеге бирү, юлын күрсәтү. *Ярый әле бу сөйкемле туташ мине уңайсызлыктан коткарды.* Ш.Камал. *Айсылу: – Безне тагын бер кыенлыктан коткардың, Гөлсем, – диде.* Г.Бәширов. *Төн карасы аларны коткарды.* И.Гази

3) Әсирлек, тоткынлыктан азат итү. *Ярый, риза, ләкин әләгә-нитә калсам, коткару сездән.* Ш.Камал. *Әйе, әйе, ул хәзер әтисен дә, үзен дә коткара ала бит.* Г.Гобәй. *Тоткын туганнарны коткарырга Кызыл байрак алып без килдек.* Ә.Ерикәй

4) Эләккән яки кысылган урыннан тартып алу, ычкындыру, арындыру. *– Сау булыгыз! – дип, кулларын минем учларымэченнән коткарырга тырышкан сыман итте.* Ф.Әмирхан

**Коткара башлау** Коткарырга керешү

**Коткарып бетерү** Тулысынча коткару. *Ләкин мондый юллар белән генә дә балаларны хәерчелектән, авыр шартлардан коткарып бетереп булмый.* Э.Шәрифуллина

**Коткарып калу** Үз вакытында, кирәк моментта коткару. *Аннары, ике чирләшкә кешенең кан алыштыруы гына аларны коткарып кала алыр иде микән? Юк, әлбәттә.* Г.Гыйльманов. *Без бүтәннәр күргәнне тоя белергә тиеш, бары шул гына безне мескенлектән коткарып калачак, дияр ул.* М.Маликова. *Ахун дөрес аңлады: аларның шушы дәһшәтле утны сүндерер өчен бар нәрсәне эшләргә әзер торуларын да, --- иген басуы белән салам өемнәрен генә түгел, алайларны да бәладән коткарып калу кирәклекне – барысын-барысын да...* Ф.Яхин

**Коткарып килү** Даими, электән үк коткару. *Әнисе аны гел коткарып килде.* Г.Ахунов. *Шәфкатьсезлек җиле йөзләремә Килеп бәрелгәндә, тынны өтеп, Мине бары шул коткарып килде, Кайнар дулкыннарны читкә этеп.* Ф.Яруллин. *Ә бит, киресенчә, сез, миңа шартлар тудырып, мине коткарып киләсез.* Т.Миңнуллин

**Коткарып тору** Вакытлыча коткару. *Менә шушы тойгы аны рюмкага үрелүдән шушы минутка кадәр коткарып торды, әмма Бәкернең әлеге әйткән сүзләре аның бу батырлыгын җимерергә бер сәбәп булды.* Ф.Садриев

**КОТКАРУ** II *и.* Табигый бәла-каза, хәвеф-хәтәр, үлем һ.б.ш.дан саклап калуга бәйле эшчәнлек. *Илгә корылык килеп, ачлык янаганда яңгыр теләү, тиз таралган үлем чиреннән коткару сорау зур бер тамаша --- булган.* Мәдәни җомга. *Ә җәй буена коткару хезмәте 60 кешене үлемнән алып калган.* Татарстан яшьләре. *Күл уртасында боз ярылып, суга баткан кешене бәладән йолып калырга коткару хезмәте егетләре никадәр генә ашыксалар да өлгермәскә мөмкиннәр.* Шәһри Казан

**КОТКАРУЧЫ** *и.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса коткарган кеше, саклап калучы. *Ләкин мин харап булмадым, каяндыр, минем бәхетктә, коткаручы килеп чыкты.* А.Шамов

2) *махс.* Коткару хезмәтендә эшләүче; коткару эшләрен оештыручы белгеч. *Коткаручы һөнәре иң куркыныч һәм җаваплы хезмәтләрдән санала. Коткаручылар төркеме.*

3) Азат итүче. *Җыенда авыл халкы үзләрен аклар кулыннан коткаручы Озын Хөсәенне күреп шатланды.* Һ.Такташ. *Безне бәйдән коткаручы – без генә.* Н.Исәнбәт

**КОТ-КОН** *җый. и.* Төс, чырай, кыяфәт. *Коты-коны калмаган, танырлык түгел бу кешене!*

**КОТКУ** *ф. диал. к.* **котырту** (*2 мәгъ.*)

**Коткып тору** Даими, һәрвакыт котку

**КОТКЫ** *и.* **1.** 1) Кешеләрне, аларның игътибарын нәрсәгә дә булса җәлеп итү максаты белән, ясалма рәвештә артык дулкынландыру, алар арасына таркалыш кертү, ажиотаж булдыру. *Мәхдүм коткысы белән эшләнгән эш булды бу, Сәгыйтьҗан абзый!* Ә.Фәйзи. *Мондый үпкә-хәтер калуларның төбендә шул ук Хафизулла, бигрәк тә Җиһангир хәзрәт коткысы ятуын да яхшы аңлый иде Гарифулла.* Г.Мөхәммәтшин. *Әле дә ярый зимагур Халәфнең карта коткысы озакка бармады, бер хәйлә генә булып чыкты.* Ф.Яхин

2) Кешеләрне аеруча дулкынландыра торган, алар арасында шик, курку, ризасызлык уята торган ялган хәбәр, авантюристик идея һ.б.ш. *Сөйләде инсан коткару юлларын, Нинди коткы, вәсвәсә һәм шом барын.* Ш.Бабич. *Кем өйрәтте коткы таратырга, фетнә борчасы?!* К.Нәҗми. *Мондый коткы – дошман ягыннан, кулак чыгара мондый төтенне.* Ф.Кәрим. *Матбугатта басылган мәсьәләләр җыентыгында колхозга каршы коткы язганнармыни?* В.Юныс

**2**. *с. мәгъ.* Курку, шик, ажиотаж булдыра торган. *Синдә дә коткы сүз икән!..* Р.Харис

◊ **Коткы башы** Коткы таратучы кеше. **Коткы боткасы пешерү** *к.* **коткы салу**. *Болар барысы да Казанның аксөякләреннән булып, Казанда чакларында коткы боткасы пешереп ятканнар ---.* Һ.Атласи. **Коткыга бирелү** Курку, шикләнү. *Язмышлар сүтмәслек үрелгән. Бәхетле яшәргә гомергә Мин – синңа, син миңа бирелгән. Тугры бул, алданма, бул түзем, Хур була коткыга бирелгән.* Р.Хисамиев. *Талибулла, исеңә кил, шайтан коткысына бирeләсең!* Х.Камалов. **Коткы салу** Гадәттә, явыз ният белән, аеруча тәэсир итәрлек ялган хәбәр таратып, таркалыш кертергә маташу, шик кузгату, курку уяту. *Мин, янәсе, үзебезнең авылныкы булмаган [членнарыбызга] каршы Мостафага коткы салып маташканмын.* Ш.Камал. *Кемгә мал бирергә, --- дошман арасына ничек коткы салырга. Һәммәсен уйлаштылар.* Г.Ибраһимов. *Кем анда залга коткы салды, Сөйләгәндә район вәкиле?* Ш.Маннур. **Коткы тарату** *к.* **коткы салу**. *Нәгыйм, губкомга буйсынмаска*

*өндәп, иптәшләр арасында коткы таратып маташты.* Ш.Камал. *Лаф оралар, коткы тараталар, Бармак янап Совет йортына.* Ә.Ерикәй. *Янәсе, качкыннарның тиздән илне басарга килүләре турында яман телләр шактый коткы таратканнар.* Ф.Бурнаш

**КОТКЫЛЫ** *с.* Коткыга нигезләнгән, коткы сала торган. *Әтиең авырып, синә авылыңа китәргә туры килгәч, күңелемә ниндидер коткылы хис: «Шушы очрактан файдаланып кал, кызый», – дип пышылдаган кебек тоелды.* Ф.Яруллин. *Әй күңелем, коткылы вәсвәсәләрдән иләс-миләсләнмәсәң икән.* Г.Хөсәенов. *Бервакыт Фәтхулла хәзрәткә бик кәттә кыяфәтле мәркәз журналисты коткылы сорау бирмәсенме ---.* А.Тимергалин

**КОТКЫНАМӘ** *и. иск.* Берәр хәрәкәткә өндәп, коткы сүзләре язылган кәгазь; хат

**КОТКЫЧЫ** *и.* 1) Коткы таратучы. *Монда юк-бар коткычылар керә. Шуңа күрә каравыл куйдык.* Г.Ибраһимов. *1546 елны Казан коткычылары, тагы Сафа Гәрәйне тәхеттән төшереп, Мәскәү курчагы Шаһ Галине хан итеп куялар.* Ф.Бәйрәмова. *Юнусовны – әхлаксыз, көнче, коткычы, Габделвәһаповны намуслы, тугрылыклы хезмәт кешесе дип бәяләп, алар җирле түрәдән кискен чара күрүдән баш тартуын үтенә.* Р.Әмирхан

2) Кемне дә булса берәр хәбәр яки идея белән мавыктырырга, үзенең тарафдары итәргә тырышучы

**КОТКЫЧЫЛЫК** *и.* Коткы салу, коткы тарату эше. *Шуның нәтиҗәсендә шовинистик рухтагы коткычылыкка каршы көрәшү читенләшә.* Т.Миңнуллин

**КОТЛА́У** I *ф.* 1) Рәсми рәвештә тәбрикләү; нинди дә булса вакыйга уңае белән (бәйрәм, туган көн һ.б.) кемнең дә булса шатлыгын, уңышын уртаклашу, тәбрикләү. *Хөснулла, хатыны Бибиҗамалны да бәйрәм белән котлап, өстәл башында урын алды.* Ш.Камал. *Политрук Исмаев, өй саен кереп, Октябрьнең өчьеллыгы белән котлап йөрде, сугышчыларга тылдан килгән бүләкләрне өләште.* Г.Бәширов. *[Гайшә] Кереп, сеңлесен кияүгә чыгуы белән котлаган, бүләкләр дә биргән икәнне күршеләреннән генә ишеттеләр.* Л-Х.Таналин

2) *этн.* Кемнең дә булса тормышында берәр шатлыклы вакыйгага атап, бүләк алып килү (бирү) һәм шуның уңае белән оештырылган сыйМәҗлестә катнашу. *Өй котлап, менә мин дә сиңа хәлдә барынча әз-мәз нәрсә китергән булдым, ди.* Г.Ибраһимов. *Анысы шулай, тик менә, әти, бүген, ызба котлап, сыер китереп бәйләделәр бит әле нужага.* Ф.Бурнаш

3) *сөйл.* Хуплау, яхшы дип табу. *Патриотик теләкләр күрсәтүеңне, әткәй, мин дә котлыйм.* Т.Гыйззәт. *Бу башлангыч адымны без котлап каршыларга --- тиешбез.* М.Җәлил. *Котлый бар да җәйге төнне, Бер тонып, бер яктырып!* Н.Исәнбәт. *Менә бу фикереңне котлыйм.* Р.Ишморат

**Котлап алу** Тиз арада котлау. *Минтимер Шәрипович барчабызны да бәйрәм белән котлап алгач, халык арасына качып торган мине күрде дә: «Менә монда Алмаз Хәмзин дә бар икән», – диде.* А.Хәмзин

**Котлап калу** Ниндидер вакытка яки вакыйгага кадәр котлап өлгерү

**Котлап килү** Билгеле бер вакыт дәвамында даими котлау. *Яңа туган таңны котлап киләм, Кулларымны сузып, Авырлыклар, сабырлыклар белән – Яшәү барыбер кызык!* И.Юзеев

**Котлап китү** Сүз уңаенда котлау. *Безнең гимназиядә югары күрсәткечләргә ирешкән бихисап спортчылар исәпләнә, аларны да котлап киттеләр.* Хезмәт даны

**Котлап кую** Алдан котлау. *Кая, алдан ук котлап куйыйм әле.* Р.Мирхәйдәров. *Элекке чик сакчыларын һәм армиядә шофёр булып хезмәт иткәннәрне якынлашып килгән һөнәри бәйрәмнәре белән алдан ук котлап куябыз.* Туган як

**Котлап тору** Даими котлау. *Мәктәптә Илүзә өчен иң бәхетле көннәрнең берсе булгандыр бүген: укытучылары да, сыйныфташлары да котлап кына тордылар.* Р.Мөхәммәтша

**Котлап узу** Нинди булса вакыйга уңае белән котлап, бүләк тапшыру, хөрмәт күрсәтү; тиз арада тоташтан котлау

**Котлап үтү** *к.* **котлап узу**

**Котлап чыгу** Һәммәсен котлау. *Шуңа күрә указны укыгач ук, барысын да телефон аша ихлас күңелдән котлап чыктым.* Т.Миңнуллин. *Парадта катнашучыларны котлап чыккач, ул дәүләт җитәкчеләре басып торган мавзолейга күтәрелде.* Г.Шакиров

**Котлап яту** *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта котлау. *Гыйльмия: «Ах оятсыз... Ах җирбит... Үлгән әтисен бәйрәм белән котлап ята... Адресы үзгәрсә дә, күңеле бер дә тоймый микәнни аның?»* А.Гыйләҗев

**Котлый башлау** Котларга керешү. *Тәнәфестә үк авторны күпләр котлый башладылар.* Ф.Яхин

**КОТЛА́У** II *и.* Тәбрик. *Шул ук вакытта аңа ак эмигрант Гаяз Исхаков та котлау телеграммасы җибәрә.* М.Гафури. *Бу котлау мине борчыган мәсьәләгә ачыклык кертә бугай.* Ә.Еники. *Акбабайны котлау электән килгән йола иде.* М.Кәбиров

**КОТЛА́У КӘГАЗЕ** *и.* Нинди дә булса вакыйга уңае белән котлап, тәбрикләп языла торган язу, открытка. *Әһә, искә төште: шул заманнарның котлау кәгазьләре, ягъни открыткалары, җылы итеп кулдан язган хатлары җитми икән.* Шәһри Казан

**КОТЛАУЧЫ** *и.* Котлау сүзе әйтүче. *Егет, котлаучыларга җавап бирү өчен, урыныннан торды.* А.Шамов. *Шулай итеп, туган көнеңдә сине чынлап котлаучы да юк.* М.Маликова. *Алсуның туган көненә ерак-ераклардан чәчәк бәйләмнәре җибәрүче дә, юри генә шылтыратып котлаучы да булмады: Таһир өйләнгән!* Сөембикә

**КОТЛЕТ** *и. фр. кулин.* Тарттырган ит яки балыкны, шулай ук бәрәңге измәсен түгәрәк яисә озынча формада кыздырып яки парда пешереп әзерләнгән ашамлык. *Аның ашаганын сәгатьләп тышта салкында көтеп торсам да, миңа бер котлет та чыгарып ашатканнары юк.* М.Гафури. *Кош итеннән котлет ясаганда сөт өсте яки сөт кушсаң, котлет кабарып һәм тәмле булып пешә.* Юлдаш

**КОТЛОВАН** *и. рус* Берәр корылманың фундаментын салу өчен эшләнгән

зур чокыр. *Тамбовтан, --- Себердән килгән эшчеләр аның корпусларын салганнар, котлованнар казыганнар ---.* Г.Әпсәләмов. *Асылгәрәй карт, олы уллары Гыйлемгәрәй һәм Сәгыйть белән бергә, ирләр төркемендә җир казырга бара, алар көрәк һәм кәйлә белән уникешәр сәгать котлован казыйлар.* Ф.Бәйрәмова. *Килеп төшүебезнең икенче көнендә үк ир-атны, имчәк баласы булмаган хатын-кызны көрәк, кәйлә тоттырып, котлован казырга җибәрделәр.* К.Шагали

**КОТЛЫ** *с.* 1) Матур, ямьле, ягымлы. *И һиммәт иясе, бар котлы урын, Шуны сорар асыл ир үлмәс борын.* Й.Баласагуни. *Йорт-җирләре бик котлы*

2) Бәхетле, күңелле, шатлык белән тулган. *Җәйләү салган котлы йорт.* Идегәй. *Һәм Үгделмеш әйтте: – И, котлы илбик, Сездән тияр илгә – халыкка белек.* Й.Баласагуни

◊ **Котлы булсын!** Нинди дә булса яхшы вакыйга уңае белән котлап әйтелә торган изге теләк сүзләре. *[Биремҗан әкә:] --- сарманнар белән караайгырларның кода булып кушылулары дошманның йөрәгенә ут салыр, башыннан акылын алыр, кодалык котлы булсын! – диде.* Г.Ибраһимов. *Вәгъдәләшү котлы-мөбарәк булсын, шатлык, бәхет эчендә яшь кәләш белән бергәбергә гомер итегез!* Ш.Бабич. *Әнием дә бик сөенде, Кочаклап алып сөйде. Котлы булсын кәләпүшең, Бигрәк килешә, диде!* Р.Вәлиева

**КОТЛЫК** *и.* 1) Уңыш, бәхет, шатлык һ.б. китерә торган кеше яки нәрсә. *Кыз үссә – кытлык, ул үссә – котлык.* Мәкаль. *Кунак бер көн кунса – котлык, ике көн кунса – кытлык.* Мәкаль

2) *этн.* Котлау бүләге яисә котлау нияте белән әйтелә торган яхшы сүз, изге теләк. *Котлыкны тапшыру*

**КОТО́МКА** *и. рус* Аркага асып йөри торган юл капчыгы. *Соры шинель, яньчелгән фуражка, изелгән папаха, котомкалар, винтовкалар, патронташлар ишелеп ята.* Ш.Камал. *Хәлим котомкасын Фазылга бирде дә Нәҗипне аркасына күтәрде.* Г.Гобәй. *Гарәфи абзый баш астына салган котомкасын җайлый да буленгән сүзен дәвам итә.* Г.Әпсәләмов

**КОТО́МКАЛЫ** *с.* Аркасына котомка аскан (кеше тур.)

**КО́ТОЧКЫЧ** *с.* **1.** 1) Бик тә куркыныч, хәтәр; дәһшәтле. *Коточкыч тавыш белән күк күкрәп җибәрә.* Г.Ибраһимов. *Чынлап та, коточкыч шартлау яңгырады, --- Хәсәнбай бөтенләе белән төтен пәрдәсе астында калды, һәм ул төтен озак вакыт таралмыйча торды.* М.Кәбиров

2) Ямьсез. *Күрәсең, бу минутта минем төсем коточкыч булган булса кирәк.* А.Шамов. *Мин барысы өчен дә Аны, тик Аны гаепләдем. Ни өчен әле ул мине – коточкыч бер кешене яратырга булган?* А.Әхмәтгалиева

3) Бик көчле, каты. *Бераздан коточкыч буран кузгала.* А.Алиш. *Ат, боргычланган иренenең коточкыч әрнүеннән аңын җуйган кебек, кинәт тынычланып калды.* Г.Әпсәләмов

4) Бик яхшы. *Коточкыч хәтер үзендә: тарихчы белергә тиешле йөзләрчә исемнәрне һәм даталарны ул күңелдән генә әйтә дә бирә.* Ә.Еники

5) Бик зур, чиктән ашкан, күтәрә алмастай, әйтеп бетерә алмаслык. *Бер көн эчендә бер-бер артлы ишелеп төшкән коточкыч яңалыкларга, шулай итеп, тагын бер яңалык өстәлде.* Н.Фәттах. *[Камәрия Талиягә:] Никадәр гөнаһсыз җаннарны харап иттең... Иреңә коточкыч борчу, хурлык китереп, йөрәген җәрәхәтләдең.* Г.Галиева

6) Бик авыр тәэсир итә торган (сүзләр тур.). *[Райбашкарма председателе Галиуллин:] – Үз яныма торырга кермәссең бит, – дип, коточкыч сүзләр тезеп китте.* Г.Кутуй. *Ничек әйтә алды икән карты шундый коточкыч сүзләрне?* Н.Фәттах

7) Бик начар, бик яман, тискәре; бик тәэсирле. *Газеталардан сугышның кайнар сулышы бәрелеп тора, фашистларның коточкыч ерткычлыгы, алар коллыгына дучар булган совет кешеләренең башыннан узган дәһшәтле вакыйгалар күз алдына килә.* Г.Бәширов. *Тора-бара мин инде боларның барысына да шулкадәр ияләштем, үземнең дә шушы коточкыч дөньяда коточкыч кеше икәнлегемә шулкадәр ышандым.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *кис. мәгъ.* Бик тә, гаять, үтә, артык. *Шуннан, улым, коточкыч зур балык өскә килеп чыкты да кармакны өзеп ычкынды.* Т.Гыйззәт. *Бу коточкыч авыр сугыштан соң, Бу сагынычлы озак елдан соң, Туган җиреӊ түбәләрен күргәч, Таш булсаң да, дустым, еларсың.* Ш.Маннур. *Кайда коточкыч тирән бер су ага... Шунда мин ташлыйм бәгырьнең валчыгын... Нинди көч бар соң шуңардан башкага?!* Ф.Бурнаш. *Аннан соң аның ире коточкыч көнче булып чыкты.* Ә.Фәйзи

**КО́ТОЧЫРГЫЧ** *с.* **1.** *к.* **коточкыч 1.** (*1–7 мәгъ.*). *Йөзе агарган, күзләрендә башка һичбер вакыт булмаган ут вә куәт яна, кулларының калтыравы арта; бөтен торышына коточыргыч бер төс чыгып, таный алмаслык бер кыяфәт ала, ләкин үзе урыныннан кузгала алмый.* Г.Ибраһимов. *Мин бу коточыргыч бакчадан чыгарга, бу коточыргыч зәһәр сүзле карчыктан котылырга ашыктым – чыгып киттем.* Ф.Әмирхан. *Ләкин без бу юлы карчык белән берни дә эшли алмадык, ни өчен дисәң, аның күзләре нинди дер коточыргыч ут белән тулган иде, нәрсәдер әйтергә җыена иде ул.* Н.Нотфуллина

**2.** *и. мәгъ.* Куркыныч нәрсә, фильм. *Ул гел шул коточыргычларны карый.* Х.Ибраһимов

**3.** *рәв. мәгъ.* Куркыныч итеп. *Янгын сараеның эче ашлык суккандагы кебек дөп-дөп иткән, мышнаган, сүгенгән, коточыргыч итеп чинап, акырып җибәргән тавышлар белән тулды.* Р.Батулла

**4.** *кис. мәгъ.* Бик тә, гаять. *Ул коточыргыч авыр ачлык елның тирән, куркыныч фаҗигасен әйтеп бирергә адәм теле җитәчәк түгел!* Г.Ибраһимов. *Икенче көнне коточыргыч яман хәбәр таралгач, Сафа Гәрәй ханның күңеленә кара шом иңде ---.* Р.Батулла. *Көтелмичә килеп чыккан коточыргыч яман вакыйга кызлары Сәкинәдән аларны тагы да ныграк аерды.* Л.-Х.Таналин

**КОТСЫЗ** *с.* **1.** 1) Авыр тәэсир итә торган, күңелсез. *Монда һәр нәрсә, һәр күренеш әллә нинди котсыз, салкын кебек.* Л-Х.Таналин. *--- динамиклардан котсыз тавыш яңгырады. Юк, тавыш үзе матур иде, әлбәттә,*

*әмма мәгънәсен аңлау белән котсызга әйләнде.* М.Кәбиров. *Өенә бер дә керәсе килми, чөнки котсыз аның өе.* В.Нуруллин

2) Ямьсез. *Менә Рәмзия ханым да өстендәге котсыз халатын гәүдәсенә сыланганчы урап, билен фланель билбавы белән шундый кысып бәйләгән ---.* Ә.Еники. *Шул ук вакытта барлык почмаклардан, --- котсыз күзләрен зур ачып, мохтаҗлык һәм ярлылык карап тора иде.* Н.Фәттах. *Бибинур күпме мәшәкать чигеп яшәсә дә, битләре алай котсыз түгел, күзеннән зәңгәрлеге, иреннән елмаю качмады.* А.Гыйләҗев

3) Авыр, катлаулы. *Котсыз еллар артта калды кебек.* Р.Зәйдулла

4) Авыр, күңелсез, мәгънәсез. *Дөнья ул кадәр үк котсыз түгел иде.* М.Кәбиров

5) Рәхимсез, җансыз. *Менә Газиз Гобәйдуллин. Татарлардан беренче тарихчы-профессорның хезмәтләреннән яңа, яшь буын татар халкының каһарманлыгын, үткән юлын өйрәнер. Әмма аның яшь гомерен система дип аталган котсыз кылыч кыяр.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ямьсез, кыяфәтсез итеп. *Аның [Хөсәеннең] авызы кыегайды, паралич суккан кешедәй котсыз итеп утыргычка утырды.* А.Таһиров. *Сәхи абзыйның бик котсыз кикереп, «әлхәмделилла» диюен генә хәбәр итте.* А.Расих. *Шул озын буйлы, яшьлек бөркелеп торган, үзенең котсыз тоелган аяк-кулларына урын таба алмаган егет аңа самимилеге һәм --- киң күңеллеге белән дә бик тиз ошап өлгерде.* Ф.Яхин

2) Тәртипсез, ямьсез итеп. *Котсыз яшәп, Җирнең котын алучыга Ачы каргыш төшсен!* Зөлфәт

**3.** *кис. мәгъ.* Бик, гаять. *Авыл юлына борылып керүгә, егетне атлы милиционер туктатты. «Ерактан кайтасыңмы?» – дип сорады ул, котсыз коры.* А.Гыйләҗев. *Күл котсыз зур, яр буйларында корыган саргылт камыш бамбук үсентеләрен хәтерләтә.* М.Вәлиева. *Бер читтәрәк теге котсыз кара эт кенә Зөһрә ягына төбәлеп карап тора.* Г.Гыйльманов

◊ **Котсыз куян** Куркак, юктан коты очкан кеше, бичара. *Их син, котсыз куян!* Ш.Маннур. **Котсыз нәрсә** Кыяфәте качкан, чырае сытылган кеше; кыяфәтсез, шыксыз нәрсә. *Нишләп йөри бу монда, котсыз нәрсә?*

**КОТСЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* Котсыз, шыксыз итү, котсыз итеп күрсәтү; ямьсезләү. *Шәһәр үзәгендәге җимерек йортлар бөтен тирәк-якны котсызландыра*

**Котсызландырып бетерү** Тәмам, тулысынча котсызландыру

**Котсызландырып тору** Әле, хәзер котсызландыру. *Искергән каралтыкура ишегалдын котсызландырып тора*

**КОТСЫЗЛАНУ** I *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **котсызлау**. *Төсләр сынды суык уйсуларда, Котсызланды сары сусар иле.* Г.Афзал

2) Ямьсезләнү, ямьсез төс алу. *Көзен авыл урамнары котсызлана*

**Котсызлана бару** Торган саен күбрәк котсызлану

**Котсызлана төшү** Бераз котсызлану

**Котсызланып бетү** Бик ямьсезләнү; тәмам котсызлану

**Котсызланып калу** Ниндидер бер гамәлдән котсыз хәлгә килү. *Горурлык югалды, чыдамлык, түземлек бетте; әле бер-ике көн [Фәриданең] төшендә генә ямьләнә башлаган --- дала, кешеләр – барысы да яңадан ямьсезләнеп, котсызланып калды.* Н.Фәттах. *Тумбочка мәет чыккан өй кебек караңгыланып, котсызланып калды.* В.Нуриев. *Авыл ничектер моңаеп, котсызланып калды.* Ә.Рәшит

**Котсызланып китү** Кинәт котсызлану

**КОТСЫЗЛАНУ** II *и.* Бер-береңне ихтирам итмәү, начар мөгамәләдә булу. *Хәер, ул --- кешеләрнең котсызлануын таш-бетон арасында, пластмасс, пыяла катырылган җилемгә чолганып яшәүдән дип уйлый иде.* Р.Зәйдулла

**КОТСЫЗЛА́У** *ф.* Ямьсезләү, шыксызлау

**Котсызлап бетерү** Ахырга кадәр, тәмам котсызлау

**Котсызлап тору** Һәрвакыт, гел котсыз, ямьсез итү. *Кайчан койма ясатасыз, ди. Бөтен авылны котсызлап тора, ди.* Ф.Мансуров

**Котсызлап җибәрү** Бераз котсызлау

**КОТСЫЗЛЫК** *и.* 1) Ямьсезлек (тышкы кыяфәт, күренеш тур.). *Өстәвенә юл өстендә очраган авылларның котсызлыгы күңелгә тия.* Т.Миңнуллин

2) Ямьсез, әшәке кыланыш

**КОТТЕДЖ** *и. ингл.* Шәһәр үзәгеннән читтәрәк салынган, бер гаиләгә исәпләнгән ике-өч катлы зур хосусый торак йорт. *Ярлы илдә киенү үзе генә дә зур бәхет санала, чөнки хосусый яхта тотарга, коттедж салдырырга безнең илдә иң бай саналган кешеләрнең дә кулыннан килми.* М.Юныс. *Һәм ул авыр гына атлап коттеджга таба китте.* Р.Зәйдулла. *Ә янәшәдә генә өеп күтәрелгән, ныгытылган яр өстендә коттеджларның биниһая зур ике корылмасы калкып тора.* Татарстан

**КО́ТЧЫККЫЧ** *с. сөйл.* **1.** *к.* **коточкыч 1.** (*1–7 мәгъ.*). *Көнчелеге котчыккыч. Йорттагы мәче баласын да иркәләп сыпырырга ярамый иде.* М.Мәһдиев. *Анакаем котчыккыч хатасын аңлаудан тәмам гаҗиз булды.* Р.Батулла. *Хатын-кыз психикасының бу дәрәҗәдә бозылуы, аңнардагы котчыккыч үзгәрешләр, әлбәттә, тиктомалдан гына түгел.* Татарстан яшьләре

**2.** *кис. мәгъ. к.* **коточкыч 2**. *Бу бичара тычкан дөньядан бик иртә китте. --- Котчыккыч аяныч, котчыккыч үкенеч.* Р.Батулла

**3.** *рәв. мәгъ.* Куркыныч итеп. *Озак та үтми, әлеге җил-давыл бер җирдә бөтерелеп, котчыккыч булып өерелеп-өерелеп тора да бер биек тау башына барып туктый.* Әкият

**КОТЫ́Й** *и. диал. к.* **котыйчык**

**КОТЫ́Й СУЫГЫ** *и. сөйл.* Нык, зәһәр салкын. --- *Өшегән шул җаның, өшегән. Өшегән җаныңнан җаныма Бәрелде котыйлар суыгы.* Ш.Җиһангирова. *Килә китәсе әллә кайларга: Кыргый тауларга, шомлы тайгага. Үтәсе килә котый суыгын, Экваторны һәм чүлләр кызуын.* Ф.Солтан

**КОТЫ́ЙЧЫК** *и.* 1) Гадәттә, агачтан кырып ясала торган түгәрәк кисемле һәм капкачлы кечерәк савыт, гомумән, тартма, шкатулка. *Кечкенә генә котыйчык, әйләнәсе кара күз.* Табышмак. *Анары ул түр шкафтагы котыйчыктан*

*дәфтәр битенә язылган хатны алып укып китәр иде ---.* Б.Камалов

2) *иск.* Кот (*2 мәгъ.*) салып тота торган кечкенә савыт

3) *к.* **кот** (*2 мәгъ.*). *Камәреннән алтын зынҗырлы котыйчык асылынган хакимнең башында зур чалма, чалма маңгаенда асылташлы мөштек, мөштеккә кара ләкләк каурые кадалган.* Р.Батулла

**КОТЧЫК** *и. диал. к.* **котыйчык** (*1 мәгъ.*)

**КОТЫЛГЫСЫЗ** *с.* Котылырга мөмкин булмаган, һичшиксез булачак. **---** *хатын-кыз, яшүсмер һәм олыкарыны сугышның котылгысыз кыенлыкларына каршы кыюлык белән җитәкләп барырга, фронтка күп итеп икмәк җитештереп бирергә кирәк иде.* Г.Бәширов. *Ераклашу, ераклашу... Шулай ук бу – котылгысыз бер күренеш микәнни?! Хәтта үз балаңнан да!* Ә.Еники. *Шаховский котылгысыз үлем булып килгән торпеда юлыннан көймәне икенче якка борып өлгерә ---.* Г.Әпсәләмов

**КОТЫЛГЫСЫЗЛЫК** *и.* Котылу мөмкинлеге булмау, чарасызлык. *Иртәгесе таңның һичшиксез атуына ышанган кебек, үлемнең дә бер көнне килеп җитәсенә инанып, аннан курыкмыйча яшәргә кирәк икән. Әнә шул инану котылгысызлыкны бераз җиңеләйтеп җибәрә шикелле.* С.Зыялы

**КОТЫЛДЫРГЫЧ** *с. сир.* **1.** Котылу биргән, котылу китергән. *Котылдыргыч карар*

**2.** *и. мәгъ.* Котылыш, котылуга ярдәм иткән сәбәп, чара. *Яман авыруга каршы котылдыргыч*

**КОТЫЛДЫРУ** *ф.* 1) Коткару. *Безнең фамилияне хурлыктан шушы хәйлә генә котылдырачак бит.* М.Фәйзи. *Кумәчче Галәвинең этен тотып алып китәләр дигәндә генә, көчкә, сызгырып котылдырып калдык.* Г.Камал

2) Эләккән җирдән тартып алу, ычкындыру, азат итү. *Хөршит --- җитез генә хәрәкәт белән кулын минем учымнан котылдырды.* Ф.Әмирхан

**КОТЫЛУ** I *ф.* 1) Авыр хәлдән, бәла-казадан чыгу юлын табу. *Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән.* Г.Тукай. *Беләм, хәтер, язсам гына бераз Котылалам синең җәбердән.* Х.Туфан. *[Мәрьям абыстай:] --- ниндидер бер саташулы төштән котылырга теләгәндәй, ихтыярсыз башын чайкап куйды һәм авырайган күз кабакларын ачты.* Акчарлак

2) Сәламәтләнү. *Күз тию ---- – берничек тә аңлатып булмастай магик халәт. Димәк, аннан котылу өчен дә төрле могҗизалы, тылсымлы алымнарга мөрәҗәгать итәргә кирәк.* Ф.Урманчеев. *Базилик чәе --- ашказаны һәм эчәк җәрәхәтеннән, эч күбүдән, газ җыелудан котылырга булыша.* Мәгърифәт

3) Табигый бәла-каза һәм башка һәлакәт, афәт вакытында исән калу, үзеңне саклап калу. *Ике тәүлек чамасы, бугай, дошман тылында йөргәннән соң, көтмәгәндә финнарның разведкасына туры килдек. Сугышсыз гына котылырга мөмкин түгел иде.* Г.Әпсәләмов. *Фазыл Ризван абыйсының язгы ташуда суда акканын исенә төшерде. Ничек котылгандыр?* Ф.Яхин

4) Эләккән җирдән качу, ычкыну; азат булу. *Татарны каптырган капкын Тимердән хәтәррәк: Аннан котылыр өченгә, Сәяси акыл кирәк.* Н.Әхмәдиев. *Әсирлектән котылганнарның кырык өче тылга китүдән баш тартты.* З.Зәйнуллин. *[Шәфи:] Әйткән иде Нургали карт. Нигә аны тыңламадым икән? Ничек котылырга? Үтерәләр дип кычкырсаң, берәү дә йөгереп чыкмаячак.* З.Мәхмүди

5) Исән калу. *Халык телендә бу төр үрдәкләрне чумгаклар дип атыйлар, яралана-нитә калса, алар, аучы кулына төшмәс өчен, чумып котылып кала, ди.* К.Кәримов. *--- кан һәм үлем үзәненнән әсирлеккә эләгеп кенә котылган --- егет монда гомерлек ярын – минем булачак әниемне очрата.* Мәдәни җомга

6) Авырлыкны җиңү, мәсьәләне хәл итү. *--- бер атна дигәндә, без бу яңа урынга, яңа өйгә бөтенләй торырга да күчтек – күпер башындагы чүплектән мәңгегә-мәңгегә котылдык.* Г.Ибраһимов. *--- һәркемнең баш миен бер генә уй борчый: кая барырга? Чукынудан ничекләр итеп котылырга?* С.Зыялы. *Киндер, мәк үсентеләрен юк итеп кенә бу афәттән котылу мөмкин түгелдер, чөнки наркотиклар чит илләрдән агылып тора.* Татарстан яшьләре

7) Көтелгәннән аермалы буларак, кечкенә җәза яки аз чыгым белән чикләнү. *Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу семьяның мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.* Г.Тукай. *Мин аңа батрак урынына ничәмә-ничә еллар эшләгәннән соң, буш кул белән башка чыгармакчы. Ничек җиңел генә котылмакчы була.* З.Зәйнуллин

8) Тормыш авырлыкларыннан качу, авырудан арынуның бер ысулы буларак, үлемне өстен күрү. *Авыл җитәкчесе итеп сайланган җыен әтрәкәләм, ярлы-ябагай дин әһелләренә теш кайрый башлады. Контрибуция салалар, сөрген белән куркыталар. Хәлимнең атасы үлеп котылды котылуын.* Г.Бәширов

9) Кул селтәү, проблеманы хәл итүдән читләшү, качу. *Соңга таба җизни безгә бернечә бакыр тиен бирү белән котылып кала башлады.* Безнең гәҗит

10) Төрле сәбәпләр аркасында хәрби хезмәткә алынмау. *Алтын булгач, докторын да --- сатып алып була икән шул: ике мең тотканнар, диләр... --- Гали «шәһәргә» барып каралды, – ахрысы, бөтенләйгә котылды...* Г.Ибраһимов. *Солдаттан исән-сау котылып калсам, ябышып чыгарга да вәгъдә биргән иде [Нәфисә].* А.Шамов. *Монда тап-таза, аяк-кулы исән яшь егетләр җиңел генә хәрби хезмәттән котылып кала.* Безнең гәҗит

11) *эвф.* Исән-сау бала табу, бозаулау, колынлау һ.б. турында. *[Миңҗамал:] Хәмит Бикәсенең бишенче баладан котылганына ай да юк – өзлегермен дип курка, бармый.* З.Зәйнуллин

12) *иск.* Тынычлыкта яшәү. *Баш китсә, аяк котылмас.* Мәкаль

**Котыла бару** *к.* **котылып бару**

**Котылып бару** Авыр хәлләрдән һәрвакыт котылу; тәмам котылуга якынаю. *Шөкер, анысыннан котылып кына барабыз дигәндә, таш булып иңнәребезне тагын шом басты.* М.Галиев

**Котылып бетү** Тулысынча котылу. *Күпме еллар буенча җыела килгән аянычлы хаталардан да һаман әле ко-*

*тылып бетә алмыйбыз ---.* Ә.Еники. *--- алынмаларның кушымчаларын төрлечә язу бәласеннән «Казан утлары» кебек үзләренә нык таләпчән басмалар да котылып бетә алмый әле.* И.Низамов. *--- бәлки, шуңа да татар прозасының публицистик характердагы өстәмәләрдән котылып бетә алганы юк әле.* Д.Заһидуллина

**Котылып җитү** *к.* **котылып бетү**. *Аның теле дә гарәпчәдән, фарсычадан бөтенләй котылып җитә алмады.* Г.Ибраһимов. *Үлемнән мин котылып та җитмәдем, шәт...* Р.Харис. *Ләкин барыбер күңел тетрәнүләреннән котылып җитә алмаган иде әле ул...* Г.Гыйльманов

**Котылып калу** Бәла-каза, кайгы тимичә, зур зыян күрмичә котылу; котылырга өлгерү, вакытында котылу. *--- Маһруйның әйткән сүзләрен дә, кичергән хәлләрен дә – барсын да инкяр итсәң, Маһруйның бар сөйләгәннәре низам-закон каршында расланмыйча һәм кабул ителмичә, синең котылып калачагың шөбһәсез.* З.Бигиев. *Унике кешедән бары тик берсе көчкә котылып калды.* С.Сабиров. *– Тиран дигән сүз кадими хәлфәләрне күздә тота, бу шәкерт җырлары һич тә патшага каршы язылмаган! – дигәч, Җамал Вәлиди котылып кала.* Р.Батулла

**Котылып килү** 1) Билгеле бер вакытка кадәр даими котылу. *Иң кыен хәлләрдән дә моңарчы җиңел котылып килгән.* А.Гыйләҗев

2) Котылу процессында булу. *Ул икенче инфарктан чак-чак котылып килә.* А.Хәлим. *Бөтен дөньясы авырудан котылып килгән чак бит.* Г.Гыйльманов

**Котылып тору** Һәрвакыт, даими котылу; вакытлыча котылу. *– Уйларга кирәк, – дигән җавап белән котылып тормакчы булды [егет].* Ә.Моталлапов. *Теге хатын да, бүгенгә булса да котылып торыйм дип, ахры, акчасын бирүгә, тизрәк бу тирәдән китәргә ашыкты.* Р.Сәгъди. *Бүген 1 Май аланында җыр бәйрәме ич. Күңел ачарбыз, мамыктан да котылып торырбыз.* Г.Мөхәммәтшин

**Котылып кую** Алдан ук котылу, көтмәгәндә котылу. *Профессор да, эшләрен төгәлләп, озата йөрүчеләреннән шома гына котылып куйган иде.* Т.Галиуллин

**КОТЫЛУ** II *и.* Авыр хәлдән чыгу юлы, котылыш. *Әгәр милләтемез шул юл берлә китсә, ике йөз елдан соң булмаса да, бер вакытны инкыйраздан котылу ихтималы юктыр.* Г.Исхакый. *Хәйдәр болай гына котылуына бик шат иде.* Г.Бәширов. *Туган авылы, туган колхозы тегендә чагында Хәмдия өчен --- барлык михнәтләрдән котылу урыны булып тоела торган иде.* Н.Фәттах

**КОТЫЛМАС** *с.* Котыла алмый торган. *Яшь җылкы үзен котылмас әсир кебек хис кылды, ләкин тынычлана алмады.* Г.Ибраһимов

**КОТЫЛМАСЛЫК** *с.* **1.** Котыла алмый торган. *--- бу хатынның туры юлдан чыгып шәһвәтләр дәрьясына атылуы, ахырында вөҗдан газабыннан, үкенүдән котылмаслык бер гөнаһка төшүе һичбер мөмкин түгелдер.* Г.Бубый

**2.** *рәв. мәгъ.* Котыла алмаслык итеп. *Хәзер бу су анасын ябып куялар бик нык иттереп, котылмаслык иттереп.* С.Гыйләҗетдинов

**КОТЫЛЫШ** *и.* Бәла-казадан котылу юлы. *Шулай итмәгәндә, янә дә шушындый кара яу килә калса, котылышка һич өмет юк – Казан кяфер кулына күчәчәк.* Р.Батулла

**КОТЫП** *и. гар.* **1.** 1) Җир шары (һәм башка планеталар) күчәренең шар өслеге белән кисешкән ике шартлы ноктасының берсе; полюс. *Чү, күләгә! Нур бөркегән кояш Кергән кебек булды болытка, Түгел, Амундсенның дирижабле Очып бара Төньяк котыпка...* Ф.Кәрим. *Ильич булыр җирнең һәр чигендә, Котыпларда, сахра, тауларда ---.* И.Шәфиев

2) Шуның төньякта урнашканы, төньяк полюс. *Әгәр шушы Күктау булмаса, Мәскәү дә, экватор да, котып та гап-гади географик төшенчәләр булып кына калырлар иде.* А.Гыйләҗев. *--- Себер өчен монысы да гаҗәп түгел, чөнки котып белән чүл арасында ята бит ул, монда җәй көне кар яварга, ә кыш көне яңгыр коеп китәргә дә мөмкин.* Ф.Бәйрәмова

3) Гомумән, шул урын тирәлегендәге мәйдан; төньяк. *Безне хаҗга алып барам, ди бит, ә үзе, бәдбәхет, --- безне әллә нинди зәмһәрир салкыннары булган җирләргә, котып якларына алып киткән!* А.Расих. *Кыш ияртеп, котып якларыннан Килә кошлар – карабүрекләр ---.* Ә.Баян. *Бар да пардан... – Ап-ак кардан Кырлар юрган ябынган. Салкын җилләр Әкрен генә Исә котып ягыннан.* Җ.Тәрҗеман

4) *иск. күч.* Нindidер бер өлкәдә зур уңышларга ирешеп танылу алган абруйлы кеше. *Үзе яшәгән дәвернең котыбы булу*

5) *күч.* Капма-каршы якларның берсе. *Мондый кыю тәвәккәллек тиз арада халыкны социаль яктан ике котыпка аерды да куйды.* Ә.Еники. *«Мөгаллим» һәм «Мөгаллимә» – әлеге фаҗиганең ике котыбы.* М.Гайнетдинов

6) *күч.* Салкын урын; салкынлык. *– Тагын котып эчендә кыш чыгасыз инде. – Ха-ха-ха! – дип кешнәп кычкырды --- [Тимерҗан].* В.Имамов. *Тора-бара бу йорт котыпка әйләнгәндәй тоелды.* Р.Мулланурова. *Ил кодрәте – кылган догабызда, Кыйбла тарафына йөз тотып... Изге дога... намаз вакытында Эри йөрәктәге мең котып.* Ф.Гыйззәтуллина

**2.** *с. мәгъ.* Котыпка **1.** (*1 мәгъ.*) бәйле. *[Бату хан:] --- Минем Урдам котып яктан, туң даладан алып Каф тауларына, Кырын Атауга хәтле сузылачак.* В.Имамов. *Алар [таулар] Зәйтуганны котып яктан искән салкын җилләрдән саклап торалар кебек.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Котып кебек** Бик салкын. *Котып кебек суык дәрьясында Ничек кенә яшәп калырга?* Л.Шәех. **Котып салкынлыгы** *к.* **котып салкыны**. *Үзем сораган ихлас кыңәшкә син әйткән боздай салкын сүзләрне ишеткәч, --- бөтен тәнемә котып салкынлыгы иңде!* М.Вәли-Барҗылы. **Котып салкыны** Үтә салкын һава, ачы, зәмһәрир суык. *Чүпрә саткан өчен тотып япканны, андый кыланмышлар өчен утырталар да утырталар инде... һәм аның [Заһидәнең] бәгыренә, котып салкыны булып өерелеп, утыз җиденче елларның шаукымы бәреп кергәндәй булды.*

М.Маликова. *Гамирның күз күреме тарайганнан-тарайды, колакларында бертуктаусыз су шаулады, котып салкыны бөтен тәнен биләп алды.* Х.Ширмән. *Өйдә котып салкыны: мичкә ягылмаган, ашарга пешерелмәгән.* Ватаным Татарстан

**КОТЫП БАЛКЫШЫ** *и.* Төньякта атмосфераның югары катлауларында атом һәм молекулаларның корылган кисәкчекләр белән бәйләнешкә керү нәтиҗәсендә барлыкка килгән газларның яктылык нурлары булып таралу күренеше; *русчасы:* **полярное сияние**. *Галим үзе өчен яңа тоелган «ак төн» дигән сүзне дәфтәренә төртеп куйды. Аннары ул котып балкышы белән кызыксынды.* А.Тимергалин

**КОТЫП ЙОЛДЫЗЫ** *и.* Алтын казык, Тимер казык йолдызы. *Скандинавиядә Котып йолдызы – космосның кендеге.* Ф.Урманче. *Котып йолдызы төрки халыкларда күккә кагылган «тимер казык» итеп күз алдына китерелгән ---.* М.Бакиров. *Юнәлеш табарга ярдәм иткәнгә, остазларны һәм шәехләрне Шәрыктә Котып йолдызы белән чагыштырганнар.* Фән һәм тел

**КОТЫПЧЫ** *и.* Котыпка оештырылган фәнни һ.б.ш. экспедицияләрдә, сәяхәтләрдә катнашучы; шунда эшләүче

**КОТЫРМА** *с.* Котырып, ярсып торган. *Котырма җил. Котырма буран*

**КОТЫРТКЫЧ** *с.* Котыртуга корылган, ниндидер гамәлгә этәрә торган. *Килми торгач күп заман җиргә җасус, Иңмәгәч җиргә котырткыч зур тавыш, Бик тынычлап бәндәләр, --- Башлаганнар көн күрергә эш белән, Тир түгәргә, ил төзергә эш белән.* М.Җәлил. *Моны карап яту күңел котырткыч караклык, исерткеч бер хыянәт сыман иде ---.* М.Мәһдиев. *Язгы кояшның дәрт котырткыч нурлары аны уятмасын дип, ир тәрәзә пәрдәсен тартып куйды.* Р.Батулла

**КОТЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **котыру**. *Кирәккә-кирәкмәскә кортларны төтен белән котыртмаска, корт бәйләнә башласа – чәбәләнмәскә.* М.Мәһдиев

2) Кешеләрне хәйләле юллар белән бер-берсенә каршы өндәү яки берәр эш-гамәлгә этәрү, тарту, мавыктыру. *Ягъкубка хат язарга котырттыңмы?* З.Бигиев. *Эшчеләрне эш ташларга котырта дип, завод хуҗасы аны үзе полициягә тотып биргән.* Ә.Фәйзи. *Шайтан котырта Шамилне: – Алдыңда – телевизор. Кулга китап алмасаң да, Рәхәттә гомер узар.* И.Юзеев

3) Үртәү, үчекләү. *Аюның үкерү тавышы бу «җанвар»ны котырта иде, котыртып кына калмыйча, аның кыргый холкын үртәп, урамга чакыра иде.* Г.Гыйльманов

4) Җәлеп итү. *Галина вак-вак атлап, фарфор савыт алып керде, бүлмәгә, ашказанын котыртып, пилмән исе таралды.* А.Гыйләҗев. *Күп тә үтмәде, теге як бүлмәдән табада май чыжылдавы ишетелә, ашказанын котыртып, тәмле исләр дә килә башлады.* М.Хәсәнов

**Котырта тору** Башка эш-хәл барган арада котырту. *Шер-Хан аның саен яшь бүреләрне котырта торды.* Р.Киплинг

**Котырта төшү** Тагын да котырту. *Учына гына сыеп бетмәгән «мәхәббәт алмалары» Гайфулланың нәфесен котырта гына төште.* Ф.Яруллин

**Котыртып алу** Берара, бераз котырту. *Авыл Советы секретаре инде мине ике мәртәбә котыртып алды.* Н.Фәттах

**Котыртып җибәрү** Көтмәгәндә бераз котырту. *Кемдер кирәк бит халыкны котыртып җибәрергә.* А.Хәмзин. *Түр башына менеп кунаклаган каенагайның боерыкка охшаш күрсәтмәсе Кәшифәне котыртып җибәрде.* К.Тимбикова

**Котыртып җиткерү** Бик нык котырту. *[Кызлар] --- баштарак ул «чирәм җырләр», «дала җырләр» турында ишетергә дә теләмәгән Фәридәне дә котыртып җиткерделәр, башын әйләндерделәр, һәм ул, яраткан эшен --- ташлап, менә монда килде.* Н.Фәттах

**Котыртып йөрү** *к.* **котыртып тору**. *Айрат төшкә кадәр гел үзен котыртып йөргән эчтәге шайтанга бирешмәгән иде, төштән соң яшел сандык тирәсендә ешрак бөтерелә башлады.* Ф.Яруллин

**Котыртып кую** Алдан ук котырту. *Егет сыйныфташларын яңа килгән укучы кызга каршы котыртып куйган икән*

**Котыртып тору** Даими, һәрвакыт котырту. *Әти чыгып кулымнан мылтыкны алды да, корал шундый куркыныч нәрсә ул, ат, ат, дип, һаман котыртып кына тора, диде...* М.Маликова. *Адәм баласы нәфесенең чиге юк, чөнки аны Иблис мәлгунь һәрвакыт котыртып тора ---.* В.Юныс. *Яшь угланны гел котыртып торган тыелгысыз көчтән башка тагын икенче бер нәрсә дә бар иде.* Н.Фәттах

**Котыртып яту** *к.* **котыртып тору**. *Бу Дәүләт карт, Таулы ярда Сабан туе була дип, гәзиткә язып, бөтен дөньяга таралган авылдашларны котыртып ята.* Г.Зәйнашева. *Аны партоешма секретаре котыртып ята икән, дип өстәмәкче иде дә, вакытында тыелып, сүзләрен үзендә калдырды.* Т.Галиуллин

**КОТЫРТУЧЫ** *и.* Берәр кеше яки хайванны хәйләле юллар белән нинди дә булса эш-гамәлгә этәрүче, мавыктыручы. *Ярты сәгатьләп тартышкач, үгез котыртучының хәле кими башлады бит, бер-ике мәртәбә сөрлегеп тә алды.* Н.Әхмәдиев. *Аның белән элеккечә үк уйнарга, шаярырга яратсалар да, хәзер ялгышып та аны котыртучы юк иде инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу мәзһәпчеләрне котыртучы – инглизләр, әфәндем.* Р.Батулла

**КОТЫРТЫК** *и. сөйл. к.* **коткы 1.** *Әллә анасы котыртыгы белән, әллә каннан килә, әллә үзе дә сизмәстән, Исмәгыйль абыйларына нәфрәтле булып үсте.* Р.Батулла

**КОТЫРУ** I *ф.* **1.** 1) Психик контрольне югалту, аек акылдан, тыныч халәттән чыгу, ярсу, дулау кебек билгеләре булган авыруга дучар булу. *Котырган бүре кебек дөньяны шаулаттым.* Й.Баласагуни. *--- Сабира апайның иДәннән сәкегә котырган шикелле йөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның урактан «җенләнеп» авырып кайтканын белдем.* Г.Тукай. *Ә инде аның [Мәрсинәнең] ир-ат халкын читкә тибәреп торган --- тумыштан җыерчыклы тар маңгаена һәм котырган этнеке шикелле куркыныч күзләренә Тәңре гаепле түгел.* Ә.Дусайлы

2) Гадәттә, тискәре хисләргә бирелеп дулау, ярсыну, кычкыру. – *Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең, – диләр.* Г.Тукай. *Ир котырган иде.* М.Кәбиров

3) Көчле теләк белән эшләү, мавыгу; омтылу, ашкыну. *Зөбәрҗәт: Алтынкөмеш, байлык диеп Котырма, Галибаба! Җыен юк-бар белән өйне тутырма, Юләр-баба! Ай, Ю-ләр ба-ба!* Ш.Фәрхетдинов. *Йөрәк, котырма, Тузма, шашынма, Ял ит утыр да, Утыр акылга. Түгелсең инде Егет яшендә.* И.Юзеев

4) Уңу, күпләп үсү. *Бәрәңге утыртмыйлар, ындырларын бакра белән билчән басты, шепкән котырды.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Инсафлылыкны, тәртипне оныту. *Сәймән: «Китәселәр китсен, Фаягөл. Куанычка булсын. Монда калганнарның кадере арта. Бүген бигрәкләр дә якын күренәсең әле, сипкеллем». Фаягөл: «Әй әле, котырма».* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Иркенләп, бирелеп уйнау. *Өмә дигәнең рәхәт инде, валлаһи! Бу бер дә эш түгел – уен да көлке, шаяру да котыру...* Г.Ибраһимов. *Улыгыз гел уйнасын, Берегез дә тыймасын! Кисен, тисен, тотынсын, Килсен, көлсен, утырсын, Япсын, ятсын, котырсын...* Р.Миңнуллин. *Син, улым, артык котырма, Сеңелеңә дә тимә. Әтиең бер тузып китсә, Я чыгар җилле давыл, Я килер зур зилзилә.* Ф.Тарханова

7) *күч.* Буш сүз сөйләү, ахмаклык күрсәтү. – *Минем өйләнәсем килә, патша кызын алам, – ди [малай]. Атасы әйтә: – Котырма, патша безгә кызын бирәме соң?* Әкият. *[Баграт:] – Котырма. Соңыннан үкенерсең. Университетны бетерү белән сине аспирантурада калдырачаклар. Акыллы кеше шундый перспективаны зимагурлыкка алыштырамыни?* М.Юныс

8) *күч.* Киң колач белән, ургылып хәрәкәт итү. *Быел да кар эчләрендә сулар гөрләп кабынды; Идел бозлары быел да койрыгы тигез булмаган очыргыдай котырдылар; елгалар быел да очындылар.* Г.Толымбай. *Киң аланга чыгу белән, ике зур күл арасында коточкыч янгын котыруын күрделәр, һавага кара кue төтен күтәрелә.* Г.Әпсәләмов. *Юк, мин батмыйм, диңгез! Улларымны Бирмим сиңа, котыр-котырма!* Зөлфәт

9) *күч.* Торган саен дәһшәтлерәк булу. *Рәттән ике тәүлек яңгыр явып, бүген иртә белән бигрәк котырган, урамнар ап-ак суга әйләнеп, аяк атларга да хәл калмаган иде ---.* Г.Ибраһимов. *Тәлгатьне кырык өченче елның март бураннары котырган чакта, колхоз малларына ялан эскертләреннән печән ташыганда ат тибеп үтерде.* З.Зәйнуллин

**2. котырып** *рәв. мәгъ.* 1) Бик тиз, ярсулы рәвештә. *Җил котырып исә, очучы чыпчыкларны да, кечкенә кошчыкларны да үзе белән ияртеп алып китә.* А.Алиш

2) Бик яхшы, шәп, мул итеп. *Кемгә зур шатлык килми?! --- Аларның тавышларында яшел үләннәрнең, ягымлы чәчәкләрнең шаулавы гөрли; аларның сикеренүләрендә котырып үсәчәк ашлыклар хәле очына --- .* Г.Толымбай. *Читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәпкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына, аңа Миңлебай карт очрый.* Ә.Еники. *[Фәридун абзый] Келәт артында котырып үскән әрекмәннең зур яфрагын өзеп алып коштабак өстенә яба да Галимә кулына тоттыра.* В.Юныс

3) Бик нык. *Шеф абый минем котырып шатлануымнан елмаеп куйды.* Ф.Яруллин. *Өйдәгеләре котырып эчте, аннары бергәләшеп сугыштылар.* Яңарыш

4) Дәртләнеп; кызу итеп. *Җәүдәтнең энесе бик каты кычкырды, әнисе, аны кочаклаган килеш, ничектер котырып биешкән бик күп аяклар арасына барып төште.* Г.Бәширов. *Фатыйма Заһит котырып үпкән урыннарда эз калгандыр дип курыкканлыктан халатына чат ябышты.* Ф.Яруллин

5) Катгый, кискен рәвештә. *XX йөз башы татар тормышында барган ашкынып яңару хәрәкәте искенең котырып каршы торуын сындырырга, җиңәргә омтылган.* Мәдәни җомга

◊ **Котырган акча** Зур акча. *Кыскасы, зур акчалар, дөресрәге, котырган акчалар әйләнгән җирләрдә була ул.* Р.Мирхәйдәров. *Котырган акчалар белән эш итмәвең күренеп тора лабаса!* Р.Гаязетдин. **Котырган сыер сөте** Аракы. *Үзләре, җәй чыккан саен берәр аулаграк җирдә ике-өч яки күбрәк кеше берләшеп, «котырган сыер сөте»ннән авыз итүне чит күрмиләр.* Г.Тавлин. **Котырган үгез сөте** *к.* **котырган сыер сөте**. **Котырган эт** Чамасыз явыз, усал кеше. *[Солтан:] Ничек кенә булса да, Фазыйлны күрергә, аның аркылы Гыйлаҗины бу котырган этләр авызыннан коткарырга кирәк.* Г.Ибраһимов. **Котырган эт кебек** Ярсу белән, үтә усаллык белән. *Күрәсез, каланың үз зимагурлары да, эшсезлектән кемгә бәйләнергә белмичә, котырган этләр кебек кыланып йөриләр.* С.Кудаш. *Башы белән буразна катысына барып төшкән корбанын шундук, котырган эт кебек талый, таптый, изә башлады: – Минә сиңа! Минә сиңа! Безнең авылда бүтән җырламассың!* А.Хәлим. *Ул җитезрәк булып чыкты: ике атлауда аяк чалып екты да, котырган эт кебек ырылдап, очлы тырнакларын муеныма батырды.* З.Мәхмүди. **Котырган эт төсле** *к.* **котырган эт кебек**. **Котырган эт шикелле** *к.* **котырган эт кебек**. *Падишаһ, гаять гайрәтеннән котырган эт шикелле, урт итен чәйнәп урыныннан торды, янә утырды. Әбелхарис мыек астыннан тик көлеп торыр иде.* К.Насыйри

**Котыра бару** Торган саен ныграк котыру. – *Юха елан! – дип акырды Ричард, аның саен котыра барып.* З.Мәхмүди. *Җитмәсә, ютәл дигән ләгыйнь котырганнан котыра бара.* Р.Батулла. *Буран торган саен котыра барды.* Г.Галиев

**Котыра башлау** Котырырга тотыну. *Баракларда, чын мәгънәсендә, тиф котыра башлады, моннан исән калу мөмкин түгел иде, чөнки ач бетләр бу зәхмәтне кешедән кешегә таратып йөрделәр.* Ф.Бәйрәмова. *Кичкә таба җәяүле буран ныклап котыра башлады.* Р.Батулла. *Черки котыра башлады.* Г.Гыйльманов

**Котыра бирү** Туктамыйча, һаман котыру; тагын да ныграк котыру.

*Кар-буран котыра бирде. Эт, аның саен котыра биреп, хәзер үк ботарлап атарга теләгәндәй, Микәйнең өстенә үк ыргыла башлады.* Р.Мөхәммәдиев

**Котыра тору** Бернигә карамастан котыру

**Котыра төшү** Бераз котыру; тагын да ныграк котыру. *Дәресләр беткәндә, буран тагын да котыра төште.* Т.Миңнуллин

**Котырып алу** Берникадәр вакыт котыру. *Трибунага менеп акыл сата, Яманатың илгә очыра. Теләр иде, бәлки, тагын бер кат Җир селкетеп котырып алырга?* Ә.Баян. *Юлдан яздырса бураны, котырып алса җиле, Телсез, маяксыз түгел юл, тик түгел Тукай җире.* Ә.Исхаков. *Розаның шунда нәфесе котырып алды.* Ф.Яхин

**Котырып бару** Торган саен котыру. *Хәзер бигрәк инде эт кебек котырып баралар, ерткычлар...* Г.Ибраһимов

**Котырып бетү** Бик нык котыру, кычкыру

**Котырып җитү** Тәмам котыру. *Әмма Фәрит котырып җиткән иде инде, ул дөп-дөп күкрәгенә сугарга тотынды: – Минме кеше көлдерәм, минме?* Г.Бәширов

**Котырып йөрү** Һәрвакыт усал, ярсу булу, дулап йөрү; ургылып хәрәкәт итү. *[Зыя] биюне яратмый, такмаклар да аңа бер дә ошамый. Әмма, әмма дөнья туздырып, котырып йөргән малайларны да җиңеп, туктатып, тирә-якны үзенең моңлы сөкүнәтенә чумдырган озын көйләр башланса, ул дөньясын оныта, --- әллә нинди әкият галәмнәренә кереп китә.* Г.Ибраһимов. *Урамда көз башланды. Тупыл яфракларын әле монда, әле анда сипкәләп, котырып йөрделәр аның җилләре.* Ф.Яхин

**Котырып китү** Кинәт котыру, тиз арада ярсыган хәлгә килү. *Бик әйбәт эш түгел бит, күңелдәген кешегә сөйләп кенә йөрмисең, комсомол кешегә килешми, диләр, югыйсә күңелдә исерек уйлар котырып китә.* М.Әмир. *Бөтен күңелемне ярсытып, әллә ниткән бер әшәкелегем котырып китте!* М.Хәсәнов. *Аның үчегеннән котырып китеп, таяк кебек нечкә, чандыр, ябык бер малай, – исеме Дамир, аста сикергәләнеп торган да маймыл җитезлеге белән менгән дә киткән.* И.Гази

**Котырып тору** Котыру процессында булу. *Мин туганмын карлы декабрьнең Буран котырып торган мәлендә. Шуңаргадыр менә гомерем буе Җылы эзлим яз да, җәен дә.* Ә.Баян

**Котырып узу** Берара котыру да тыну, басылу. *Хәтерләсәгез, быел июнь аенда республиканың берничә районында, шул исәптән Актанышта да, давыл котырып узды.* Татарстан яшьләре

**Котырып чыгу** Бик нык котыру. *Һаваның ләтафәт һәм сафлыгы, күк йөзенең зәңгәр хәтфә төсле мөлаем матурлыгы, күптән түгел генә котырып чыккан каралҗым диңгезнең күксел сәдәп төсенә кереп, күзләрне рәхәтләндерә-рәхәтләндерә йомшак кына тирбәнеп ятуы --- бу дөньяның көндәлек хакыйкатенә охшамый, зиһеннәрдәге хыялый оҗмахларны аңдыра иде.* Ш.Камал

**КОТЫРУ** II *и.* **1.** 1) *мед. к.* **котыру авыруы**. *Котыру билгеләре булган кыргый җәнлекләргә юлыгу белән катлаулы хәл килеп туганда, --- коткаручыларны чакырырга кирәк.* Сабан таңнары. *Тукай районында соңгы җиде ай эчендә хайваннар арасында алты котыру очрагы теркәлгән.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Ярсу, дулау. *Мулланың мондый котыруы аңа бер дә көтелмәгән эш иде.* Г.Ибраһимов. *Шау-шу, кычкырыш, шашкынлык бөтен өйне, йортны басты. Барган саен тагын яманрак котыру төсенә керде ---.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Көчле агымлы. *Каридел бик котыру елга икән – чистый эт булдык...* Х.Сарьян

**КОТЫРУ АВЫРУЫ** *и. мед.* Гадәттә, авыру хайван тешләү нәтиҗәсендә кешеләргә, аеруча хайваннарга йогып, нерв системасы зарарлану, баш мие ялкынсыну белән характерлана торган вируслы авыру. *[Логинов:] Әйе, иптәшләр, Холмогорның хәле бик җитди, аңарда котыру авыруы.* Т.Гыйззәт. *Котыру авыруының шундый хасияте бар икән: вегетация чоры, ягъни башлангыч дәвер үтеп китсә, беркемне коткарып, саклап калып булмый икән.* А.Гыйләҗев. *XVII гасырның 80 нче елларында француз галиме Луи Пастер котыру авыруына каршы вакцина уйлап таба.* Ватаным Татарстан

**КОТЫРУЧАН** *с.* Тиз ярсып китүчән. *Мәдинә ханымны иң пошындырганы да асылда шул иде. Мондый чакта хатын-кыз мин-минлегә кайчак бик яман котыручан була.* Г.Әпсәләмов

**КОТЫРУЧАНЛЫК** *и.* Котыручан булу

**КОТЫРУ ЧИРЕ** *и. к.* **котыру авыруы**. *Шөкер, кешеләр арасында котыру чире эләктерүчеләр булмаган.* Ватаным Татарстан. *Күп еллар асраган, дусты дип санаган эт тә, котыру чирен йоктырып, хуҗасына ябышырга мөмкин.* Шәһри Казан

**КОТЫРЫК** *и. сөйл.* **1.** 1) Коткы, котырту. *Әгәр син, агаларың котырыгы белән безне ата-ана итми башласаң, алар шикелле башбаштакланып, үзең белгәнчә йөрсәң, безгә кайгыбыздан үләргә генә кала.* Ф.Әмирхан. *[Гали (ялынып):] Зинһар, дим, Мәгъруфә, хаталык белән, шайтан котырыгы белән генә...* М.Фәйзи. *Мансур да Ленинградтан җибәргән бер хатында, ак финнарның империалистлар котырыгы буенча башлаган авантюралары тар-мар итәлү белән үк ялга кайтачагын язган иде.* Г.Әпсәләмов

2) *к.* **котыру авыруы**

3) Котыру авыруы өянәге. *Котырыгы башлану*

**2.** *с. мәгъ.* Дәрт тулы, ашкынулы, ташып торган. *Гаязның соңыннан басылган бөтен хикәя, романнары, пьесалары аның киң шашкын, котырык хыяллы һәм тасвирының күренешле (картиналы), җиңел алынмалы булуын күрсәтәләр.* Г.Сәгъди

**КОТЫРЫНКЫ** *с.* Бик көчле, ярсу, гадәттән тыш көчле. *Патша заманындагы сәясәт совет чорында аеруча астыртын һәм котырынкы төс алып дәвам итте.* Р.Миңнуллин. *Иртәгесен котырынкы чабыш дәвам итте. Ходайбирде төркеме элеккечә койрыкта сөйрәлде.* Б.Рафиков. *Җир белән күк тоташып, коточкыч зур тизлектә әйләнә башлады, һәм мин, шул котырынкы өермәгә кушылып, күккә менеп*

*киткәндәй булганымны гына хәтерлим.* Ф.Латыйфи

**КОТЫРЫНКЫЛЫК** *и.* Котырынкы булу; ярсулык. --- *тотнаксыз балада котырынкылык галәмәтләре күрмәгән табибларны җавапка тартырга нигез бар кебек монда.* Мәдәни җомга

**КОТЫРЫНУ** *ф.* **1.** 1) *кайт. юн. к.* **котыру**. *Җир йөзендә сугыш бара, үлем котырына.* Г.Ахунов. *Гасыр башындагы капиталның ярсып котырынган чаклары...* М.Әгъләмов. *Мин бары тик Тилләхаҗиевны күз алдына китердем. Синең ни әйткәнеңне ишетсә, нишләр иде икән? Вәт котырыныр иде.* Р.Мирхәйдәров

2) Үзеннән-үзе, сәбәпсез котыру. *Мәгърур башың имәдең аңа, Явызлыкны күрсәң каршыңда, Җырладың син ирек җырларын Котырынган тиран алдында.* Х.Туфан. *Сәлимәнең куркудан коты очты. Котырынган ир яныннан ничек тә чыгып качарга кирәк иде.* С.Зыялы. *Ак аю сыман болытлар томалый авыл күген. Бөтерелә тышта өермә, Котырына буран бүген.* Х.Туфан

**2. котырынып** *рәв. мәгъ.* 1) Ярсып. *Галимнең йөрәге котырынып, ачу һәм көнләшү белән тибә башлады.* Г.Әпсәләмов

2) Бик нык. *Сыза кипшергән, читчитләренә котырынып үлән калыккан, уентык-уентык булып кузгалак тишелеп чыккан ---.* А.Гыйләҗев. *Соң сәгатьтә дулкын шашты, Котырынып җил исте.* Р.Фәйзуллин

3) Дәртләнеп, бик нык теләп. *[Вәли:] Бервакыт хатын «бик матур була» дигәч, котырынып, шушы мыегымны карага буяган идем.* Г.Камал

**Котырына бару** Торган саен тагын да ныграк котырыну

**Котырына башлау** Котырынырга тотыну. *Бер-ике минуттан ниләр буласын уйлап, Гаделҗанның тагын йөрәге котырына башлады.* Аманулла. *Чуалмак мәсьәләсе онытыла төшкәч, Варис тагын хәттин ашып котырына башлады.* Р.Батулла. *Әллә җеннәре килешмәде, әллә ханым хаталанудан үзалдына котырына башлады – болар хакында ул уйлый алмады.* Ф.Яхин

**Котырынып алу** Кыска гына вакытта, бераз котырыну. *Һава көненә кырыкка төрләнә: я яңгыр, я юеш кар ява, я шакырдатып туңдырып куя, я февраль бураннары котырынып ала.* Ә.Сафиуллин. *Тыныч, сабыр Гатаулла улының чыгырдан чыгып, котырынып алуының бүлмәдәшләре генә белә торган янә бер сәбәбе бар иде.* Т.Галиуллин

**Котырынып йөрү** Һәрвакыт, даими котырыну. – *Киребеткән карт дурак!* – *диде Сәрви.* – *Партийный кеше бер син генә түгел, синнән башка бер кеше дә болай котырынып йөрми.* Ф.Әмирхан

**Котырынып китү** Кинәт, тиз арада котырган, ярсыган хәлгә килү. *Степанов котырынып китә: – Син нәрсә эшләгәнеңне беләсеңме? – Мин үлемгә әзер, – ди төшенкелеккә бирелгән Саша Долинов.* Безнең мирас

**Котырынып яту** Хәзер котырыну. *Күрше бүлмәдән кычкырышкан тавышлар килә. Җитәкчеләре котырынып ята, ахрысы*

**Котырынып тору** Даими, туктаусыз, әледән-әле яки хәзерге моментта котырыну. *Бу атаманың үзенә күрә дөреслеге бар: көз көне, кыш көннәрендә ул ачулы күркәдәй туктаусыз кабарынып, котырынып тора.* М.Юныс

**КО́ФЕ** *и. ингл.* 1) Мареначалар семьялыгының бер ыругы һәм шуңа караган куак исеме. *Латин Америкасында күбрәк кофеның аеруча тәмле «арабика» сорты, ә Африка һәм Азиядә «робуста» сорты үстерелә ---.* География. *Кофе агачлары плантацияләрдә башка агачлар күләгәсендә үсәләр һәм ел буена җимеш бирәләр.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Кофе агачы елына нибары дүрт йөз граммнан кило ярымга кадәр генә әзер уңыш бирә.* Сөембикә

2) Шул үсемлекнең орлыгы. *Латин Америкасы илләре чит илләргә авыл хуҗалыгы продуктлары (--- кофе, шикәр, тәмәке, банан) һәм тау промышленносте продукцияләре (нефть, төсле металлар ---) чыгаралар.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Илдә [Эфиопиядә] кофе җитештерү, бигрәк тә кыргый агачлардан кофе җыю, зур урын алып тора.* Материклар һәм океаннар географиясе

3) Шул орлыктан кайнатып яисә кайнаган суга болгатып эчү өчен ясалган он. *Кибеттә кофены үлчәп тә саталар*

4) Шул оннан әзерләнгән кайнар эчемлек. *Буфет өстәлләре һәммәсе сырып алынган. Хатын-кызлар кофе, шоколад, пирожныйлардан авыз итәләр.* Ш.Камал. *Зөһрә апа улын беренче җаваплы рейска ныклап әзерләде: өс-башын кат-кат тикшерде, --- куе кофе кайнатып, аны термоска тутырды, бер савытка тавык боты, өрек, йөзем төйнәде.* А.Гыйләҗев. *Кит балыгы күздән югалгач, капитан кофе кайнатты, карталар саклана торган өстәл тартмасыннан печенье табып алды.* М.Юныс. *Кофе – туклыклы эчемлекләрнең берсе, ул 5000 ел дәвамында өзлексез кулланылып килә.* Юлдаш

**КОФЕ-БРЕЙК** *и. ингл.* Гадәттә, конференция, семинарлар вакытында җиңелчә генә ашап, чәй яки кофе эчеп алу өчен ясала торган кыска тәнәфес. *Очрашу ахырында катнашучыларга кофе-брейк оештырылды*

**КОФЕВА́РКА** *и. рус к.* **кофекайнаткыч**. *Ә сумкадагы әйберләрнең исемлеге даими: үтүк, сәгать, кофеварка, кипятильник, электробритва, фотоаппарат, аракы.* В.Юныс. *Машина ясаучыларга бүләккә яңа навигатор, кесә телефонын куя торган җайланма, автомобиль чәйнеге яки кофеварка яхшы булыр.* Шәһри Казан

**КОФЕИН** *и. нем.* 1) Кофе орлыгы, чәй яфрагы һ.б. кайбер үсемлекләрдә була торган матдә; медицинада ярсыткыч, ягъни наркотик сыйфатында кулланыла. *Йоклар алдыннан күп ашарга, составында кофеин булган яки исерткеч эчемлекләр эчәргә киңәш ителми.* Шәһри Казан. --- *кофеин организмның тулаем эшчәнлеген, нерв һәм кан тамырлары системасын, баш миендәге кан әйләнешен яхшырта, бронхларны киңәйтә.* Юлдаш

2) Составында төп өлешне шундый матдә тәшкил иткән дәвалау препараты. – *Римма, капитанга өч доза кофеин, тизрәк!* – *дип боерды баш врач.* Х.Камалов. *Туктаусыз кофеин эчүдән йөземә сары коелды.* З.Мәхмүди. *Дүрт*

*сәгатькә бер кофеин уколы салып тордым.* Г.Галиев

**КОФЕИНЛЫ** *с.* Составында кофеин булган. *Тетрациклин төркемендәге антибиотикларны, кофеинлы препаратларны (аскофен, цитрамон, каффетин) сөт, кефир, эремчек кулланганда эчмиләр, чөнки дару тәэсир итмәячәк.* Мәдәни җомга

**КОФЕ́ЙНИК** *и. рус* 1) *к.* **кофекайнаткыч**. *[Уотсон:] – Минем ни белән мәшгуль икәнемне каян белдегез әле? Аттта да күзегез бармы әллә сезнең?! – Анысы юк югын, ләкин минем алда ялтыратып чистартылган кофейник тора, – дип җавап бирде ул [Холмс].* К.Дойль

2) Әзер кофены табынга бирү өчен зуррак чәйнек формасындагы чынаяк савыт. *Китәргә җыенганда, Инга, сумкасыннан алып, хуҗаларга нәфис нәкышләр белән эшләнгән чәйнеккә охшаш кофейник бүләк итте.* Х.Камалов

**КОФЕ́ЙНЯ** *и. рус* Кофе, чәй, татлы ризыклар тәкъдим итә торган кечкенә ресторан, кафе

**КО́ФЕКАЙНАТКЫЧ** *и.* Кофе кайнату өчен тимер яки фарфордан эшләнгән махсус савыт, чәйнек. *Бәйгедә җиңгәннәргә кофекайнаткыч бүләк иттеләр*

**КО́ФЕТАРТКЫЧ** *и.* Кофе тарту җайланмасы, кофе тегермәне. *Кипкән кызыл миләш һәм гөлҗимешне 1:1 өлеш алып, кофетарткыч аша чыгарырга кирәк.* Кәеф ничек?

**КО́ФЕЯРГЫЧ** *и. к.* **кофетарткыч**

**КОФР** *и. фр.* Берничә бүлеге булган сандык; чехол. *«Алтылы»ның багажнигыннан сәхнә күлмәкләре кидерелгән кофр белән озын каешлы сәяхәт сумкасын алган арада «Газель» куып җитте.* К.Кәримов. *Мәскәүдән фотоаппаратура өчен бер мең сумга кофр алып кайткан идем.* Татарстан яшьләре

**КО́ФТА** *и. пол.* Билгә кадәр яки аннан бераз озынрак була торган, бәйләнгән яки тегелгән өс киеме. *Кофтасында алтын җепләр.* М.Юныс. *Аның чәчләре күпертелеп ясалган, өстендә чытыр ак кофта, кара затлы юбка, аягында кара ялтыравыклы туфлиләр иде.* М.Мәһдиев. *Кофта изүе дә кирәгеннән артык ачык шикелле, ач күзләр шунда төбәлгәндер шикелле...* А.Әхмәтгалиева

**КОЧАК** *и.* 1) Алга сузылган ике кул белән күкрәк арасы. *Игенсез басуны чүп-үлән басадыр, Игелексез күңелне яулыйдыр яманлык... Кояштай нурлы йөз кочаклар ачадыр, Елмаю кодрәте калалар алырлык.* Ә.Гадел. *Бөтен назым белән урап алып Эретер идем аны [чибәрне] кочагымда.* Ф.Яруллин. *[Гыйлемхан:] Түзмәде, тулышкан күзләрен күрсәтүдән уңайсызланып, аны уң кулы белән кочагына алды. Кочагына алды алуын, әмма абайламады: әллә апасын, әллә бушлыкны кочаклады.* Р.Мөхәммәдиев

2) Шул арага сыешлы якынча күләммикъдар берәмлеге. *Кулында бер кочак сары тюльпаннар.* М.Маликова. *Бер көнне ул елга яры буена, менә шушы турга, бер кочак тал үсентеләре алып килә һәм куаклык утырта.* Г.Гыйльманов. *[Алчын:] Әле Кояш уянганчы ук, якындагы урманнан ике кочак коры ботаклар җыеп килде.* Р.Фәизов

3) *күч.* Куен. *Синнән [сагынудан] качам, сине онытырга тырышам. Әмма... Әмма үзем тагын-тагын кочагыңа – кайнар, назлы, гөләп куагы төсле гүзәл, чәнечкеле кочагыңа омтылам.* И.Салахов. *Җылы өйдә өшеп ятам, Бетеп бара җылылык. Ә бит күпме кыз җылынды Кочагыма сыеныпп.* Ф.Яруллин. *Ник аерасың, әй язмыш, Аерылмас чакларымда? Гомерлеккә калдырсаңчы Кайнар кочакларында.* Р.Вәлиева

4) *күч.* Яхшылык, хозурлык яисә яманлык, начарлыкны туплаган тирәлек, мохит. *Кызылком чүле талгын гына тымызык төн кочагына кереп бара иде.* Т.Әйди. *Яр читеннән тын гына, ипле генә йөзеп барган көймәнең кинәт, туксан градуска борылып, шаулы диңгез уртасына, дулкыннар кочагына ташланганыдай булды бу [Гыйлемхан].* Р.Мөхәммәдиев. *Офык артыннан йөзен ачкан кояш нурлары кочагында Чирүле күл зәңгәрсу-яшькелт төс белән балкый иде ---.* М.Әмирханов

5) *күч.* Тәэсир, йогынты (йокы, гипноз тур.). *Ул әле йокысы кочагыннан, бүген күргән төшләре тәэсиреннән чыннан да айнып бетмәгән --- иде кебек.* Т.Әйди. *Минем назларымнан Гүзәл уянды да, күзләрен ачмыйча, йокының тәмле кочагыннан чыгарга ашыкмыйча гына рәхәтләнеп киеределе.* Карам

◊ **Кочагыннан чыгу** Берәр нәрсәдән көчкә котылу. **Кочак белән** Күп итеп. *Ул мөхәннәс әйтте: «Ни хәлем булсын, авырулар вә афәтләр кочак белән керә, чеметемләп чыга» ---.* К.Насыйри. *Төшендә ул һәрвакыт Хөснетдиновны җиңә, кызыл айгырның йомшак ялыннан сыйпап, үз аранына алып кайта, хуш исле сусыл тукранбашны кочагы белән, мул итеп улагына сала.* А.Гыйләҗев. **Кочак җәеп** Бик теләп, яратып, үз итеп. *Бирегә аны, дөрестән дә, ачык йөз белән, кочак җәеп каршы алдылар.* Р.Вәли. *Мәскәүгә дә, Ыстанбулга да китмә, Ләбиб, Актанышың һәрчак көтә кочак җәеп.* Л.Лерон. *Ә «детдом»нан чыккан 16–17 яшьлек үсмерне кем, кайда кочак җәеп көтеп тора?* Татарстан яшьләре. **Кочакка алу** 1) Кочаклау. *Соңгы сүзләрен әйткәндә, ананың тавышы шундый да зарлы, шундый да инәнгеч иде. Мәрвәрнең үзәкләре телгәләнде. Ул җәһәт кенә йөгереп килеп, әнисенең хәлсез --- гәүдәсен кочагына алырга мәҗбүр булды.* М.Хәсәнов. *Егет [Михман] түзмәде, Фатыйманы киң кочагына алды, кайнар тыны белән аның яңагын өттереп, башын әйләндерде.* З.Кадыйрова; 2) Үз итеп, яратып каршылау, күтәреп алу. *[С.Хәким] кайбер шагыйрьләр төсле җырчыларны кочакка алмый, кулларын үпми, купшы мәдхияләр әйтми. Әмма аннан гына җылылык, ихласлык тойгысы кимеми ---.* Т.Галиуллин. **Кочакка керү** Нәкъ уртасына, үзәгенә керү, эләгү

**КОЧАКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Куллар белән уратып алып кысу, кочу, иркәләү. *– Солтан, синең якташ килгән, тор! – дияргә өлгерә алмадылар, мин, атылып барып, дустым Шаһбазны кочакладым.* Г.Ибраһимов. *Карт, хәвефләнеп, улының башын кочаклады.* М.Мәһдиев. *Дисбе-дисбе көннәремне санап, Карлы чыршыларны кочаклап, Мин декабрь белән саубуллашам... Ак йолдызлар тула кочакка.* Р.Низамиев

2) Кочакка сыймас әйберләрне кочкандай, кулларны ян-якка җәеп, шуларга күкрәк белән сыену. *Бакча безнең ил, Алтын безнең җир, Җиргә тезләнеп, Чәчәк өздем мин. Менә шул чакта җирне кочаклап Үбәсем килде, – Сыймый кочакка.* Б.Рәхмәт. *Минме синең уйларыңда көймәгәнме? Сине күзләп эзләреңнән йөрмәгәнме? Ә беркөнне мине чиксез бәхет басты: Егылдым да кочакладым күләгәңне.* Т.Миңнуллин. *Ул [Таһир] янәшә торган ике каберне кочаклап елады.* М.Кәбиров

3) Кочакка алып күтәрү. *Агач арасында биек булып тыгыз үскән үләнне йолкып, кочаклап, куыш эченә китереп салдылар.* Г.Якупова

4) Күкрәккә, түшкә, култык астына кысып тоту. *Ул Улибаева янына килеп утырды, кулындагы себеркесен кочаклады.* М.Мәһдиев. *Салих гармунын кочаклаган килеш басып тора бирде.* М.Латыйфуллин

5) *күч.* Үз эченә алу, колачлау (табигать күренешләре тур.). *Ә безне инде, аю баласыдай, Кочаклады калын тайгалар.* Ш.Маннур

**2. кочаклап** *рәв. мәгъ.* Шатланып. *[Карлыгач] Шуларны бетереп, үзенең кул эшен алырга гына торганда, шатлыгыннан кая басарга белмичә, Айбала килеп керде дә кызны кочаклап үбә башлады.* Г.Ибраһимов. *Дөрес, алар безне кочаклап каршыларга тормыйлар.* М.Юныс

**Кочаклап алу** Тиз генә кочаклау. *Килеп керү белән Баграт мине кочаклап алды.* М.Юныс. *Ул арада Сәет Мөршидә апаны кочаклап алды.* Т.Миңнуллин. *[Кош:] Әллә кайдан гына килеп чыкты да, гүяки күләгәсе белән кочаклап алды.* Ф.Яхин

**Кочаклап кую** Көтмәгәндә кочаклау

**Кочаклап тору** 1) Кочаклаган хәлдә булу

2) Әледән-әле кочаклау

**Кочаклап чыгу** Барысын да бербер артлы кочаклау. *Нәфигулла абзый, рәхмәтләр укый-укый, балаларны кочаклап чыкты.* З.Зәйнуллин

**Кочаклый башлау** Кочакларга керешү

**Кочаклый бирү** Бернигә карамый кочаклау. *– Ярый алайса, – дигән Аждаһа, – әгәр синең гомереңкадерле түгел икән, каеныңны кочаклый бир.* Ф.Яруллин

**Кочаклый төшү** Ныграк, кысыбрак кочаклау

**КОЧАКЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **кочаклау**. *[Солтан:] Шул ашлык сукканда, эскерт башыннан кочаклашып бергә егылганнан бирле, безнең арада ниндидер бер нечкә ефәк җеп сузылган кебек булды.* Г.Ибраһимов. *Менә ул хәзер аның янына килер, торыр, ата белән ул кочаклашырлар.* М.Мәһдиев. *Яшьләр кочаклашып агач арасына кереп югалырга өлгермәделәр, аның янына игезәк сыңары Зөһрәбану килеп басты.* А.Гыйләҗев

2) Ике яки берничә кешенең берәр кул белән генә бер-берсенең җилкәсеннән яки биленнән алуы. *Егетләр, җилкәләреннән тотынышып, кочаклашып биеделәр*

3) *күч. сир.* Кушылу (җансыз әйберләр тур.). *Җилем суы --- шул матур тугайларның иң матур җирендә Агыйдел белән кочаклаша.* М.Гафури

**Кочаклаша башлау** Кочаклашырга тотыну

**Кочаклашып алу** Тиз арада бер мәртәбә кочаклашу

**Кочаклашып кую** Көтмәгәндә бер мәртәбә кочаклашу

**КОЧЕГАР** *и. рус* Пар казаннарын карап, эшләтеп торучы эшче. *Әле узган ел гына сез таккан эчкече кочегар, траптан егылып, кулын сындыргач, профсоюз каршында җавап бирдем.* М.Юныс. *Яңа кочегар дигәннәре Фәгыйләгә шикле күренгән әлеге тузгый чәчле егет икән.* С.Сабиров. *Әнә теге клубта кочегар булып эшләгән, пенсиягә дә бик картаеп чыккан Иван дәдәй инде.* Р.Фәизов

**КОЧЕГА́РКА** *и. рус* Пар казаннары, мичләр урнаштырылган бина. *Ә җәйге кызу көндә кочегарка ул – тәмуг, бигрәк тә манёвр чорларында эссе.* А.Таһиров. *Эшләрен тәмамлагач, алар юеш киемнәрен кочегаркага төшереп элделәр дә җылынырга ашханәгә керделәр.* М.Юныс. *--- контроль-уткәрү пунктыпостларын карыйм, ашханә залларына күз салам, слесарь-сантехник эшен дә башкарам дигәч, кочегарка биналарын кереп әйләнәм.* Н.Хәсәнов

**КОЧЕГА́РЛЫК** *и.* Кочегар һөнәре, эше. *Җәһәннәм турындагы әкиятне кочегарлыкта эшләгән кеше язган булырга тиеш.* М.Юныс

**КОЧ-КОЧ** *ы. диал.* Кәҗә чакыруны белдерә

**КОЧУ** *ф.* 1) *к.* **кочаклау** (*1 мәгъ.*). *[Аю:] «Нишләп юлымда торасың?» – Бүрене болгап аткан. «Сине уважаю!» – диеп, Керпене кочып яткан.* И.Юзеев. *Иген аша кемдер кемне Чакырган икән, Кемдер кемне кочкан икән, Шул гаеп микән?* А.Хәлим. *Амантай, үзенә-үзе хисап бирмәстән, күкрәгенә килеп капланган якын кешесен кочып алды да һаман бер үк сүзләрен кабатлады.* Т.Әйди

2) Ике яки сыңар кул белән уратып алып кочаклау; сөю. *Фатыйма әбисенең иңеннән кочып алды, юатмакчы булды, тик нинди сүзләр тапмак кирәк?* З.Кадыйрова. *– Колакта гел музыка гына яңгырый, дөньяда бер генә кыз калды: ул – минем Рая, Раечкам, – дип, [Александр Иванович] хатыны кырына күчеп утырды, аны иңбашыннан кочып, чигәсеннән үпте.* З.Кадыйрова. *– Рәхмәт сиңа, кызым! – дип кочып үпте әнисе Зөлфияне.* Г.Сабитов

4) *күч.* Иңләп алу. *Кыйблага таба Торналар оча. Тауларны кара: Болытлар коча.* С.Сүнчәләй. *Күк күгәрчен очадыр, Зәңгәр күкне кочадыр. Минем улым бәү-бәү итә, Йолдызларда очадыр.* Ә.Гадел

3) *күч.* Үз эченә алу, үзенеке итү (табигать, үлем һ.б. тур.)

**Коча бару** Бер-бер артлы, рәттән кочу

**Коча башлау** Кочарга керешү

**Коча бирү** Һаман кочу, кочудан туктамау. *Бу очракта Луиза үз стихиясендә яши. --- Ни генә дисәк тә, очсыз-кырыйсыз Күк бит ул. Шигъри рухы кочаклый алганча коча бирсен, «рәхмәт юлы»ннан Җиргә дә төшәр әле.* З.Мансуров

**Коча тору** Бернигә карамый кочу. *Дулкыннарың бер-бер артлы ярны коча*

*торсын, Бәлки, яңа җыр китерер тугызынчы дулкын?* Р.Гаташ

**Коча төшү** Ныграк кочу. *Үзе дә мине ныграк коча төште.* А.Хәсәнов. *Кайтып җитәрәк сөекле ханым йокымсырады, һәм ире аны, биленнән коча төшеп, икенче катка сөйрәде.* Р.Зарипов

**Кочып алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә кочу. *Күлмәк сәдәбен каптыра алмыйча азапланган әнисе арык куллары белән улын кочып алды.* А.Гыйләҗев. – *Кая, кызыма хәер бирим әле... Бала елмайды. Әбекәенең муеныннан кочып алды.* Ф.Җамалетдинова. *--- ник бер кочып алып, чал сакал баскан битеннән суырып үпмәдем икән дип, хәтта бүген дә бик үкенәм.* А.Хәсәнов

**Кочып тору** Һәрвакыт, әледән-әле кочу

**КОЧУ-ҮБҮ** *ф.* Кочаклау, үбү, бик нык ярату. *Балаларның балалары балдан Татлы икәннәрен беләбез. Алдыбызга алып, кочып-үбеп, татлылардан татлы, диябез.* Р.Сафин. *Милли идея эзлибез икән, безгә битләребезне Россия флагы төсенә буяп, эчеп-исереп, урамда очраган бер кешене кочып-үбеп йөрергә түгел, иң беренче чиратта, үз асылыбызны сакларга, үткәндәге әйбәт үрнәкләрне яңадан торгызырга, камилләштерергә генә кирәк.* Ватаным Татарстан

**КОШ** *и.* 1) Тәне каурый, йон белән капланган, томшыгы һәм канатлары булган умырткалы хайван. *Язлар җитте, Кошлар килде, Сау кайттыңмы, тургаем!* Х.Туфан. *Йоклый авыл. Рәхәт тынлык. Бары кошлар серләшә.* Р.Мөхәммәт. *Кыскамы ул, аллә бик озынмы, Эшең сыйсын тик бер гомергә. Өметләнмик күбәләк я кош булып, Бу дөньяга кабат килергә.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Сөйгән яр (хатын-кыз тур.). *Кычкырамын яңлыш, уйламыйча: «Килче, кошым, былбыл кошым, – дим. – Килче, үбим ап-ак кулларыңнан, Килче, зинһар, «кызыл түшем»! – дим.* М.Җәлил. *Алтын кошым – мәңге сүнмәс моңың, Мин мондамын, ә син кайдасың? Оя кордың күңелем түрләренә Бәхет серен белеп, файдасын.* Р.Баһаветдинов

3) *күч. сөйл. ирон.* Кеше (холкы, характеры, җәмгыятьтәге дәрәҗәсенә карап бирелгән бәя). *Мин нинди кош икән дип аптырап торам, үзебезнең кранчы кыз икән ләбаса!..* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Очкыч

◊ **Кош бураны** Ашкыну, талпыну (кешенең кичерешләре тур.). *Йөрәгемә кереп оя кордың, Кыйбла итеп шушы тарафны. Сагыну-сагышларым – кош бураны. Мәхәббәтем талмас канатлы.* Р.Багаутдинов. **Кош йокысы** Сак йокы. **Кош кебек очу** Бик тиз хәрәкәтләнү. *[Юныс карт] Йөрәге түзмәде: «Фиу!» – дип өзәңгеләрен какты, атын әйдәде дә, кош кебек очып, бая килеп әйләнгәннәрнең каршысына барып чыкты ---.* Г.Ибраһимов. **Кош кунмый торган** *к.* **кош очмаслык**. **Кош очмас** *к.* **кош очып җитмәс(лек)**. **Кош очмаслык** Бик көчле, үтә кырыс, зәһәр (салкын, буран тур.). *Кош очмаслык салкыннар хәзер сирәк күзәтелә.* **Кош очып җитмәс(лек)** Бик ерак. *Чуен чүлмәк авызы тар, Пешә солдат ашлары; Кошлар очып җитмәс җиргә Китә солдат башлары.* Җыр. – *Кош очып җитмәслек илләрдән --- минем илемә – Капкорсак патша җиренә килгән осталар остасы Бикзирәк, минем сезгә сүзем бар әзрәк, – дип әйтте, ди, Капкорсак патша.* А.Алиш. **Коштай очу** *к.* **кош кебек очу**. **Кош тоткандай** Бик шатланып, үзен бәхетле сизеп. *Кайберәүләрне аяклары гел шунда каерып торды: мыштым гына кереп киттеләр дә кош тоткандай очынып чыктылар.* Р.Мөхәммәдиев. *Киртә башына үрмәләп менгән Бибиҗамал, әткәсен күрүгә, сөенеченнән кош тоткандай: – Әткәй, кара әле, мин кайда мендем! – [диде] ---.* Ф.Сафин. *Дәрестән кайтканда, беренче эшем итеп капкабызга беркетелгән почта тартмасын актарам, эчендә хат булса, кош тоткандай, өйгә керү белән, йотлыга-йотлыга укырга керешәм.* Г.Галиев. **Кош тоткан диярсең** *к.* **кош тоткандай**. *[Шакир] Кош тоткан диярсең – авызы колагына җиткәнче ерылган.* Ә.Гаффар. *Бу хәлгә хәтта хисапчы Разия дә игътибар итте: – Кара, кара бу аксак шайтанны, кош тоткан диярсең.* Н.Әхмәдиев. **Кош тоттыру** Алдау, юкны вәгъдә итү

**КОШБА́У** *и. этн.* Бер кисәгән икенчесенә казның бот сөяге ярдәмендә тоташтырып, туку станогының өске өлешенә беркетеп куела торган бау; тарттырып беркетелгән җепләр рамы һәм ике тәбәлдерек шул бауга бәйләнә

**КО́ШБИГЕ** *и. тар.* Бохара ханлыгында баш вәзир дәрәҗәсендәге кеше

**КОШЕНИЛЬ** *и. фр. зоол.* 1) Кокцидлылар отрядыннан җете кызыл төстәге каты кабыклы вак бөҗәк. *Кармин Әрмәнстан, Азәрбайҗан һәм Польшада тереклек итүче кошениль исемле бөҗәктән ясала. Бер кило кармин ясау өчен, 150 мең данә кошениль кирәк.* Шәһри Казан

2) Шул бөҗәк кабыгыннан алына торган буяу матдәсе (кармин буявын ясаганда кушыла)

**КО́ШЁВКА** *и. рус* Артка ике кеше аркасын терәп утырырлык, алда ат тоту өчен урын көйләнгән көймәле чана; кашавай. *Чаналарның берсе җиңел кошёвка, икенчесе киң үрәчәле гади чана иде...* Ә.Еники. – *Әйдә, Зиннур абый, тизрәк кошёвкага утыр, астыгызга печән дә җәйдем, – дип, шатлыклы йөз белән каршы алды аны Әхмәдүш.* Я.Зәнкиев. *Матур язларның берсендә Гөлсем карчык яшәгән йорт турысына шәп бер кошёвка килеп туктады.* Р.Рахман

**КОШ ИКМӘГЕ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан, аскы өлешендә утырма эллипссыман яфраклары булган, өскә таба ботакланучан туры сабаклы, вак ак чәчәкле, түгәрәк кузаклы, саргылт яшел төстәге берьеллык үлән үсемлек; дару ясау өчен дә файдаланыла; *русчасы:* **ярутка полевая**

**КОШ-КОРТ** *җый. и.* 1) Һәртөрле кошлар, вак хайваннар. *Кырыс тавыш урмандагы бөтен кош-кортны урыныннан кузгатты.* М.Мәһдиев. *Булмаганны. Сөләйман пәйгамбәрмени ул, кошкорт телен белештерергә?* Ф.Яхин

2) Йорт кошлары. *[Сәрбиназ:] Җылыткан ризык эчемә ярамый шул. Тавыкларыңа сибәрсең. Кош-корт асрыйсыңдыр бит?* А.Гыйләҗев. *Сыерны бетерсәләр дә, кош-корт, вак мал җитәрлек.* Ә.Моталлапов

**КОШКУНМАС** *и. бот. к.* **кошкунмас агач**. *Кайбер культуралы һәм кыргый кыяклыларны зарарлый торган тутык гөмбәләрнең икенче хуҗасы булып кошкунмас (Frangula) тора.* Ботаника. *Кошкунмас Рәсәйнең бөтен Европа өлешендә, Көнбатыш Себердә, шулай ук Урта Азиядә һәм Кавказда таралган.* Юлдаш

**КОШКУНМАС АГАЧ** *и. бот.* Кошкунмасчалар семьялыгыннан, биеклеге 3 м, сирәк кенә 8 м га җиткән, күп ботаклы, ботаклары чәнечкеле, эллипссыман яфраклы, вак саргылт яшел чәчәкле, шарсыман кара сусыл җимешле куак яки зур булмаган агач; эт шомырты, бүре шомырты; *русчасы:* **жостер слабительный**

**КОШКУНМА́СЧАЛАР** *и. күпл.* Икеөлешлеләр семьялыгыннан, каршыдаш эллипссыман бөтен яфраклы, вак саргылт яшел чәчәкле, кайбер төрләренең ашарга яраклы җимешләре булган, дәвалау, бизәү һ.б.ш. максатларда кулланылган куак яки зур булмаган агач кебек үсемлекләрне белдерә торган атама; *русчасы:* **крушиновые**

**КО́Ш ӨЛЕШЕ** *и. этн. иск.* Басуда, урмыйча, кош-кортка калдырылган ашлык. *Кош өлеше калдырган фәкыйрьгә гошер бирмәсә дә ярый.* Мәкаль. --- *Ярар, җитте. Калганнары – кошлар өлеше. Язга кадәр озак бит әле.* Р.Мулланурова

**КО́Ш САЛУ** *ф. иск. к.* **кош чөю**

**КО́Ш СӨТЧЕСЕ** *и. бот.* Әспечәләр семьялыгыннан яфраклары тамыр яны таралгысы ясап үскән, ак яки саргылт чәчәкле суганчалы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **птицемлечник**

**КОШТАБАК** *и.* 1) Берәр литр чамасы сыйдырышлы (агач яки калай) тәлинкә. *Малайлар, коштабакны күтәреп, ишегалдына йөгерделәр.* Г.Ахунов. *Хабул туганнары белән бер коштабактан ашарга гадәтләнгән иде.* С.Лашманчы. *...Туй кызганнан-кызды. Һәркем хәленнән килгәнчә яшел коштабакка акча салды.* Б.Ислам

2) *диал.* Аш тәлинкәсе

3) *диал.* Форфор яки эмаль табак

**КО́Ш ТЕЛЕ** *и. кулин.* **1.** 1) Ак оннан йомыркага басып, юка итеп җәелгән камырны өчпочмак яки ромб формасында озынча итеп кисеп, майда кыздырыла һәм чәй янына куела торган ашамлык. *Мидхәтнең Әнисәсе – җиңел гәүдәле, ачык-күләч хатын – җил-җил атлап, өстәлгә самавыр китереп утырта, кош теле, бал, каймак, коймак куя.* Р.Мулланурова. *Бәби ашына дип чәкчәк, кош теле, сумсалар да пешергән идем.* Күңел ачыйк бергәләп

2) Сәер, таныш булмаган тел, сөйләш. *Кош теле күк матур исемең, Рио де Жанейро, Тик үзең ямьсез әле син, Рио де Жанейро.* Х.Туфан

**2.** *с. мәгъ.* Кечкенә генә (хат тур.). *Йомыш дип, кечтек кенә, кош теле хәтле генә хат кисәге язып бирмәссеңме, дигән идем.* А.Гыйләҗев

◊ **Кош теледәй** Кечкенә. *Моңарчы күз авыруы белән солдаттан калып килгән Хәкимулла да, машинкада басылган кош теледәй кәгазьне кулына тоткач, әле аның чын мәгънәсенә төшенмәде.* М.Мәһдиев. *Дистә еллар дәвамына газиз анага кош теледәй хат язып сала белмәгән балалардан нинди тәрбия?..* Р.Мөхәммәдиев. *Баштарак кош теледәй генә ике хаты килгән иде, аннары килмәс булды.* Г.Гыйльманов. **Кош теле кадәр** *к.* **кош теледәй**. *Зарыгып көткән чираттагы хатым килеп җитте. Кош теле кадәр генә дип булмастыр монысын.* Җ.Дәрзаманов. *Шул кичтә сәхнә артында миңа кош теле кадәр генә язу кисәге тоттырдылар.* Р.Рахман. *Газизә әби аннан кош теле кадәр генә булса да хәбәр көтте.* Безнең гәҗит

**КО́Ш ЧӨЮ** *ф.* Бөркет, лачын, шоңкар кебек кулга ияләштерелгән кайбер ерткыч кошлар ярдәмендә ауга йөрү. *Азамат ир Туктамыш – Акбүз аты астында, Лачыны ияр кашында, Чирүле күлдә кош чөеп Дәүран сөргән хан булды.* Дастан. *Һәрхәлдә, кош чөю (ерткыч кошларны кулга өйрәтеп, шулар белән ауга йөрү) гадәте борынгы аучылыкта түгел, Урта гасырларда гына уйлап чыгарылган булса кирәк.* Р.Әхмәтьянов

**КО́Ш ЧӨЮЧЕ** *и. тар.* Ханнарның ау кошлары өчен җаваплы хезмәтчесе

**КОШЧЫ** *и.* 1) Кош караучы. *Әллә соң кошчылар юньләп тәрбияләмиләр микән дип, аптырагач, сыер савудан алып, бер сукраныбрак йөри торган хатын урынына үземнең Сәкинәне дә куеп караган идем.* В.Нуруллин

2) *тар. иск. к.* **кош чөюче**. *Туктамыш ханның кошчысы Котлыкыя, ханнан яшерен рәвештә, аның могҗизалы кошы булган лачынның ике йомыркасын Шаһ Тимергә (Аксак Тимергә) бүләк итә ---.* Ф.Урманчеев

**КОШЧЫЛЫК** *и.* Авыл хуҗалыгының кош-корт үрчетү тармагы. *Анда справка Түбән Кама шәһәрендә яшәүче, кошчылык фабрикасында эшләүче Халяпова Хәдичәгә бирелгән дип язылган иде.* Т.Галиуллин. *Кошчылык фабрикаларының беришеләре – тавык йомыркасы алуга, икенче берләре тавык ите алуга көйләнгән.* Биология. Хайваннар

**КО́Ш ЯСМЫГЫ** *и. бот.* Сандалчалар семьялыгыннан ярымпаразит күпьеллык үлән үсемлек; чыпчык чикләвеге; *русчасы:* **ленец**

**КОЭФФИЦИЕНТ** *и. лат. мат.* 1) Алгебраик аңлатмада билгесез зурлык тапкырлана торган сан яки хәреф; тапкырлагыч. *Әгәр f(x) күпбуынының тискәре коэффициентлары булмаса, бу формуланы куллана алмыйбыз.* Күпбуыннар. *Экспертлар әйтүенчә, коэффициент бишкә җитсә, җәмгыять хокукый булудан туктый, мондый илдә яшәү бик тә кыенга әйләнә.* Татарстан яшьләре

2) *физ.* Физик җисемнең аерым бер үзенчәлеген, мәс., сыгылмалылыгын, ышкылу көчен һ.б.ны билгели торган зурлык. *Чана белән юл арасындагы ышкылу коэффициенты 0,15, тартма белән чана арасында – 0,5.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. *Пропорциональлек коэффициенты h ны Планк константасы дип атыйлар ---.* Физика

3) *күч.* Нәтиҗәлелек күрсәткече

**КОЭФФИЦИЕНТЛЫ** *с.* Коэффициенты булган, коэффициенты кулланылган. *Иң зур уртак бүлүчесе D(x), ә иң кечкенә уртак кабатлысы K(x) булган реаль коэффициентлы ике күпбуын табыгыз.* Күпбуыннар

**КОЮ** *ф.* 1) Вак, коры, сибелүчән нәрсәләрне күпләп төшерү, чәчү, тарату.

*Ак чәчәген коя шомыртларым, Түзеп торып күпме чыдасын, Гөнаһларга кереп каралганчы, Аклыкларын җил алсын.* Б.Рәхимова. *Күзләр бәйле... Сизәм, язгы шомырт Чәчәк коя егыласы төшкә...* Зөлфәт. *Ул хайваннарның яшәү рәвешен, үз-үзләрен тотышын, яшәү тирәлеген, --- йон коюларын һәм туклануларын тасвирлый.* Биология

2) Гадәттә, саксызлык аркасында төшереп җибәрү. *Таң җилләре Арыш башларыннан Чык бөртеген коеп искәндә --- Фашист пиратлары Илебезнең Гадел тынычлыгын боздылар.* В.Мифтахов

3) Махсус төрле якка сибеп, чәчеп җибәрү. *Малай, үләннәрдәге чыкны коеп бетерергә теләгәндәй, камылларга селтәнде.* Г.Гыйльманов

4) Сыеклыкны бушату, күпләп салу; югарыдан агызу. *Цемент койдыру өчен тампонажчылар килде, тимер юл вагоны чаклы махсус агрегатлар кырык биш минут эчендә җир астына сиксән тонна цемент койды.* Г.Ахунов. *[Шәрифулла:] – Әйдә, утыр! Син, брат, минем команданы тыңларга тиешсең! – һәм чәшкәне тутырып аракы коя.* Ә.Еники. *Кара озын чәчле, йөзен куе сакал баскан егет касәләргә шампан койды, ниндидер тост әйтте.* Р.Зәйдулла

5) Билгеле бер сулыкка агып төшү, кушылу. *Инеш, Аюкөйдергән елгасы белән бер үк юнәлештә агып, Чирмешән елгасына коя икән.* Әкият. *Чишмә, агып төшеп, Кытай җирендәге Зайсан күленнән башланган олпат Иртешкә коя.* Я.Зәнкиев. *Елга коя торган урыннарда 2–3 чакрым тирәлектә аларның [болгарларның] яшәү урыннары да табылды.* Мәдәни җомга

6) Күп итеп, көчле һәм өзлексез яву. *Әлеге карт чын мәгънәсендә күрәзәче булып чыга: нәкъ ул кисәткәнчә, күп тә үтми, бер көн һәм бер төн зәһәр яңгыр коя.* Ф.Урманче. *Декабрьнең салкын йолдызларын Коя буран, чәчә, тарата! Ә авылның көмеш иңнәренә Төн буена калын кар ята...* Р.Низамиев. *Таң атты, яңгыр әүвәлгечә бертуктамый коя да коя.* Дөньяда ниләр бар

7) Рудаларны эретеп, шулардан чуен, корыч, бакыр һ.б. металл алу. *Бурычы гаять тә кәттә илченең: серле калага үтеп керергә, ничеккенәләр булса да чуен кою серен ачарга, һич югы чуен коючыны урлап, Өргәнечкә алып кайтырга.* М.Хәбибуллин. *Хәзер эшкә яраксыз станоклар, искергән рельслар – тузган нәрсәләрнең барысы металлургия заводларына яңадан кою өчен җибәрелә.* Дөньяда ниләр бар

8) Эретелгән металл, пластмасс кебекләрне сыек килеш калыпларга агызып, әйберләр яисә аларның детальләрен ясау. *Бу акыллы баш [М.Фазлуллин] --- типографиядә дә яңа хәрефләр коярга --- дигән «тирән» дәлилләрен китерә.* Ә.Кәримуллин. *Ул, литерларны коя торган машинадан тыш, хәрефләрне җыю һәм аерым юллар итеп беркетү җаен уйлап таба.* М.Вәлиев. *Бер-берсенә төгәл охшаш ямьләнү әйберләрен мин беркайчан да коймадым.* М.Хуҗин

9) Төзү, кору, салу. *Тату туганнар таштан койма койганнар.* Мәкаль. *Җир беткән дип торам бит. Текә яр. Төпсез чокыр, дөмегәсең генә. Малтуар төшмәскә койма койганнар.* Ф.Садриев. *Кадак булмаган вакытта тимерчыбыкны төзәйтеп, турап, койма койдылар, терлек-туарны кертмәделәр, дип искә ала аксакаллар.* Ватаным Татарстан

10) Сыек массаны киптереп, нәрсә дә булса ясау (ризык тур.) *Алмадан үзегез үк как коя аласыз.* Ватаным Татарстан

11) Ике яктан, мәс., читән белән ныгытылган аралыкка балчык измәсен агызып тутыру (койма ясау тур.). *Хәзер аңа койма коюдан ни мәгънә?* В.Нуруллин

12) *күч.* Нәрсәләрне булса да (күпләп) вату, аудару, җимерү. *Чүлмәкләрне чәлпәрәмә коеп төшерә колга... Баганадагы әтәчне малай төшергән кулга!* Н.Сафина. *«Зачистка» ясарга килгән спецназ талап-кыйнап киткән үзен [картның]. Өстәвенә автомат түтәсе белән авызындагы бөтен тешен коеп төшергәннәр.* З.Мәхмүди

13) *күч.* Күп сөйләү, күп итеп теләк теләү. *Ирләр --- Гаян белән Гөлфаяга мондый очракта телдән төшми торган теләкләрен, иң акыллы киңәшләрен коярга тотындылар.* Ә.Дусайлы

14) *күч.* Мул итеп сибү, чәчү

◊ **Коеп куйган (кебек, төсле)** 1) Бик охшаш, бер калыптан эшләнгән кебек. *Кирәк бит, охшаса да охшый икән кешегә, Әминәнең коеп куйган копиясе.* Т.Миңнуллин; 2) Бик матур. *Әннә белән Фатыймадан башка да аларга килеп йөрүче кызлар байтак иде. Барысы да коеп куйган төсле матурлар, җитезләр, шаяннар иде.* А.Алиш. *Русчаны яхшы белә, буй-сыны коеп куйган, төрекчәне аңлый [Сабир].* Р.Шәфигуллин. *Ай-һай, булса да булыр икән коеп куйган матурлык. Бу чабышкының табигатьтә сирәк очрый торган затлы токымнан булуы әллә каян күренеп тора иде.* Г.Тарханова; 3) Билгеле бер калыпны алган, билгеле бер юнәлештә генә эшли торган. *Син яшьтәш тә, замандаш та булып, Дөнья буйлап җырлап йөрисең. Дөрес әйткәнсең шул, Әйе, Тукай, Коеп куйган гына түгелсең...* И.Юзеев. *С.Рәмиевкә җибәргән хатларының берсендә Тукай үзенә, гаять бер кыюлык белән, төгәл характеристика биргән: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит».* И.Нуруллин. *Һии-ии, Гайфуллин, коеп куйган писер бит бу.* Г.Афзал; 4) Чын. *Утыз алты яшьлек коеп куйган ир-егет! Матур киенгән. Карашында кырыслык та, мөлаемлык та бар [Галимҗан Ибраһимов].* С.Поварисов. *Кестутис – коеп куйган воевода.* М.Әмирханов. **Коеп куйгандай** *к.* **коеп куйган (кебек, төсле)**. *Халык әкиятләредәй җыйнак, коеп куйгандай төгәл, тапкыр алар [А.Алиш әкиятләре].* Сабантуй. **Коеп куйган коймак кебек** Бар яктан да килешкән, күңелгә хуш килгән нәрсә турында. *Сүзләр хисле дә, мәгънәле дә, сурәтле дә. Халыкча әйтсәк, коеп куйган коймак кебек. Бер төере дә юк. Тотып ашыйсы килә хәтта.* С.Поварисов. **Коеп кую** Матур, җыйнак итеп эшләү. --- *Г.Бәширов Нәфисәне сайлап ала да, искечәрәк әйтсәк, мөбарәк исемне мөшәррәф итеп, гүзәл бер хатынның әдәби һәйкәлен коеп куя.* Х.Сарьян. *Гомумән, эшләгән эшен коеп куя иде әни.* Т.Миңнуллин. *Менә шул татар чабатасын Бәгърем абзагыз коеп кына куя.* А.Хә-

лим. **Коеп куеп** Дөрес, матур итеп. *Татарчаны коеп куеп сөйләшә, шуның белән татар егетләрен үзенә карата бeлә иде.* Г.Ахунов

**Коеп алу** Тиз арада, аз гына кою. *Нәкъ менә кыз яткан урынга яңгыр коеп алган.* Сабантуй

**Коеп бетерү** Тулысынча, барысын да кою. *Әнә шулай шәһәр ябагасын коеп бетергәч, яшеллек җарияләре мине, уйларыңнан чистарынып ал дип, көл буена алып киләләр.* М.Галиев. *Картайган каздай калтырый, туңа кешем: күңел мамыгын коеп бетергән...* Ш.Галиев. *Узган атнада, сорау алу вакытында, ул Кафилнең бөтен тешен коеп бетерде.* З.Мәхмүди

**Коеп җибәрү** Кинәттән кою

**Коеп китү** Көтмәгәндә тиз генә кою

**Коеп кую** Алдан ук коелган хәлгә китереп әзерләү

**Коеп тору** Даими, туктаусыз кою; бер-бер артлы кою. *Шул ук нефтьчеләребезнең хезмәтен ал: күз ачкысыз буран диме, җәйге челлә диме, өстән коеп тора диме ---.* М.Хәсәнов. *Совет чынбарлыгы аларны уртак калыпка салып коеп кына торды, аларның «өлкән туган»ның һәр гамәлен алкышларга әзер торган психологиясен төгәл алгоритмнар ярдәмендә формалаштырды.* А.Хәлим

**Коеп чыгу** Барысын да тоташтан кою; билгеле бер вакыт дәвамында кою. *Тинтәк хатын буза чыгарып кына калмыйча, иң элек, күсәк алып, өйнең барлык тәрәзәләрен коеп чыга ---.* М.Хәсәнов. *Яңгыр кичтән үк сибәли башлаган иде, төне буе коеп чыкты.* Р.Сибат

**Коя башлау** Коярга тотыну. *Куе кара болытлар эченнән, гөрләтеп, эре тамчылы салкын яңгыр коя башлый.* Г.Ибраһимов. – *Мәшәкатьләнәсең бит, Газизә... – диде Гариф һәм, йомшак кына челтерәп комга сугылып торган дулкын кисәкләреннән кулы белән алып, битенә су коя башлады.* Ш.Камал

**Коя бирү** Коюын дәвам итү, һаман да кою. *Ә урамда яңгыр коя бирде, кич иңеп килә торды.* Ф.Яхин. --- *Марс касәгә чәйне коя бирде.* В.Ильясов

**Коя тору** *к.* **коеп тору** *Чиләкләп коя торгач, юл җиңеләйде.* Р.Батулла

**КОЮХАНӘ** *и.* Кою эшләрен башкару өчен махсус бина. *1813 елдан башлап университет типографиясе янында гарәп хәрефе коюханәсе (словолитня) эшкә керешә.* Россиядә беренче төрки-татар басмасы (Пётр I нең 1722 елгы манифесты)

**КОЮЧЫ** *и.* 1) Коемчы. *Бездә атаклы сынчылар, коючылар да бар бит.* Н.Фәттах

2) Эреткән металлдан коеп төрле эшләнмәләр ясау белән шөгыльләнүче эшче; *русчасы:* **литейщик**. *Металл коючы үзе теләгән яхшы сыйфатлы корыч алу өчен, шулай ук кулындагы бөтен мөмкинлекләрдән файдалана.* Г.Бәширов

**КОЮЧЫЛЫК** *и.* 1) Металлдан коеп җиһазлар һәм бизәнү әйберләре эшләүгә бәйле борынгыдан килгән шөгыль. *Татарларда коючылык киң таралган була. Гадәттә, бизәнү әйберләре – җиз тәңкәләр, балдак, йөзек һ.б. эшләнгән*

2) Кою сәнгате

**КОЯШ** *и.* 1) *астр.* Җир һәм башка күк җисемнәре: планеталар, аларның иярченнәре, астероид, метеорит һ.б.ш. белән бергә бер система тәшкил иткән һәм шул системаның үзәге булган бердәнбер йолдыз. *Аурупа фәне ачканчыга кадәр, Җирнең түгәрәк булуын һәм Кояш тирәли әйләнгәнен Галилейга, Колумбка кадәр, Коръәннән чыгып, Сәйф Сараи әйткән иде инде...* Р.Батулла. *Безнең Кояш системасы да кайчандыр шушы рәвештә галәмдә яшәгән, аны һичнәрсә борчымаган.* Ф.Яхин. *Җирнең кечкенә космик җисем, Кояш системасының бер өлеше булуын сез инде беләсез.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) Җир өчен яктылык һәм җылылык чыганагы булган күк җисеме. *Кояш чыкты, Көзге яфракларга Алтын төсле нурлар сибелде.* Х.Туфан. *Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә: «Кояш бата, Айлар калка, Бик ямансу шул чакта...».* Ә.Еники. *Онытылмаслык булып тоелса да, Сөйгән ярлар хәтта онытыла. Әйтерсең лә безнең күңелебездә Бик еш кына кояш тотыла.* Ф.Яруллин

3) Шул җисемнән тарала торган нур, яктылык, җылылык. *Тәрәзәдән кояш төшеп тора*

4) *күч.* Иң якын һәм иң кадерле кеше, сөйгән яр. *Дидем: «Нурлы кояшым, мин мәхәббәт вәгъдәсен бозсам, Ходай үзе җәза бирсен, яшендәй каһәрен салсын. Кусаң читкә, алырмын яктылык мин кем карашыннан?»* М.Җәлил. *Якты кояшым минем! Рушанна, бер үбимче үзеңне, рөхсәтме?* А.Гыйләҗев. *Кояшым, күз нурым! Онып җирдә бозлар барын, Болытлар барын онып, Елмаеп тор яннарымда, Алтын Кояшым булып.* Ф.Зыятдинова

5) *күч. шигъ.* Иң якын, иң кадерле, тормыш өчен иң кирәк булган нәрсә чыганагы. *Гаделлек кояшы. Өмет кояшы*

6) *күч. сөйл.* Кояш төсендәге түгәрәк нәрсәләр (коймак, көнбагыш тур.). *Алсу-саргылт нәни «кояш»лар зәңгәр читле тәлинкәгә әллә никадәр өелгән инде.* Г.Әдһәм

◊ **Кояш алу** *к.* **кояш ашау** (*1 мәгъ.*). **Кояш ашау** 1) Кояш нурлары тәэсирендә әйбернең төсе уңу. *Өстендәге кояш ашаган җиләнендә дә зыялылык нуры бөтенләй үк сүнеп бетмәгән.* С.Поварисов; 2) Кызыну. *Аларның каршысына яулыгын артка чөереп бәйләгән, битен, беләкләрен кояш ашаган, озын керфекле яшь кенә бер кыз килеп басты.* Г.Бәширов. *Картның җыерчыклар яргалаган, кояш ашаган, җил кискән йөзе бакырга охшап тора.* М.Хәсәнов; 3) Кар эрү турында. **Кояш кебек (төсле, шикелле)** Көләч йөзле, мөлаем. *Әтиең-әниең шушы йомыкый малайга кояш кебек кызыбызны бирмибез дигәч, мин сине урлап качтым.* М.Хуҗин. *Кояш кебек эшлекле ярдәмчесе булган кешене кем җиңә алсын?* Ә.Баян. **Кояш колаклану** Әйләнәсендә нур алкасы чагылу. **Кояш сугу** Кояшта озак булудан бик нык баш авырту, укшыту, кайвакыт һуштан язу. *Кояш сукмадымы икән мине?* А.Гыйләҗев. *– Бабай, минем баш ник авырта икән? – Ай олан, сиңа бит кояш суккан. Айяй да каты суккан, – диде бабасы ---.* В.Нуриев. **Кояшы баю (бату)** Иркен яшәү, эшләү, иҗат итү мөмкинлекләре бетү. *Шул хәлендә дә торып утырырга*

*көч тапкан, инде гомер кояшы баеп барганда, авыру сөягенә музыкадан дәва сораган кешенең сүзләре Әнвәрне тетрәтеп кенә калмады, анда сырхауга карата соклану да тудырды.* Шәһри Казан. *Әмма семит цивилизациясенең дә инде кояшы баеп бара.* Мәдәни җомга

**КОЯ́Ш БАЕШЫ** *и. сөйл.* 1) Көнбатыш. --- *пар ат Гыйрфан байның Себердән кайткан кызы белән Фазыйлны хәзер колхоз үзәгенә әйләнгән Гыйрфан бай йортыннан кояш баешы ягына таба алып чыгып китте...* Г.Ибраһимов. *Кайдадыр кояш баешта, кыялы ярлар янында, олуг Чулман үзенең бөек туганын очратырга тиеш.* Н.Фәттах. *Кайтып килә Кояш баешыннан, Тиле романтикасын озаткан. Ачу-нәфрәт белән чынбарлыкка Каршы барып, туры сүз әйткән.* И.Юзеев

2) Кояшның офык артына китү мизгеле һәм рәвеше. *Кояш баешын күзәтү*

**КОЯ́Ш БАТЫШЫ** *и. сөйл. к.* **кояш баешы**. *Кояш батышына киткәнеңә атна үтте, ләкин синнән хат килгәне юк.* С.Баттал

**КОЯШБАЛЫК** *и. зоол. к.* **айбалык**. *Менә бу кечкенә балыкчыклар – кояш балыкның балалары, биш йөз метр тирәнлектә яшиләр.* Диңгез тирәнлегендә

**КОЯ́Ш ИҢЕШЕ** *и. к.* **кояш баешы**. *Кояш иңешенә карап тору*

**КОЯ́Ш ТОРГЫНЛЫГЫ** *и.* Кояш Җир эклиптикасының иң төньяктагы яки иң көньяктагы ноктасы аша узгандагы вакыт. *Анысын 22 нче июньнән – җәйге кояш торгынлыгы көненнән исәплиләр.* Н.Максимов. *Күк сферасында Кәҗәмөгез тропигы − кышкы Кояш торгынлыгы көннәрендә Кояш зенитта тора торган параллель, ул күк экваторыннан 230 27' почмак белән аерыла.* Фән һәм тел

**КОЯ́Ш ЧЫГЫШЫ** *и. сөйл.* 1) Көнчыгыш. *Кояш чыгышыннан берәү килә, Оныткан ул Күккә ашуны. Ул каһкаһә белән усал көлә, Кемнәргәдер бик тә ачулы.* И.Юзеев. *Кояш чыгышы яктан Кояш баеш якка, Кара болыт кебек, Дәһшәт килеп ята.* Г.Афзал

2) Кояшның офык артыннан калыккан мизгеле; таң ату рәвеше. *Таңны атыру өчен, ярга чыгып, кояш чыгышына карап йөгерердәй булдым.* А.Яһудин

**КОЯШЛЫ** *с.* 1) Аяз, кояш яктыртып торган. *Кояшлы матур көндә бала-чаганы өйдә тотып буламы?* С.Поварисов. *Май аеның бар җиһанны нурга төргән кояшлы бер көнендә авыл йөзләгән кунак кабул итте.* Мәгърифәт

2) Кояш балкып торган көннәре күп булган. *Кояшлы җәй башы, шимбә көн, загс тирәсендә бизәлгән машиналар тора ---.* М.Маликова. *Кытайны үткәч, кояшлы аяз һава да бетте.* В.Юныс

3) *күч.* Бәхетле, җитенкеле. *Бигрәк тә безнең хәзерге кояшлы, аяз дәвер шулкадәр әйбәт, күңелле! – Яз гына инде хәзер.* Х.Туфан

**КОЯШСЫЗ** *с.* Кояш булмаган, болытлы. *Кояшсыз, чәчәксез соры ноябрь ае. Зур югалтулар күп булды бу көздә.* Г.Афзал. *Сөюсез бит яшәү – кояшсыз көн, Сөюсез бит язлар яз түгел.* Р.Вәлиева

**КОЯ́ШСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Төче сулыкларда яшәүче, гәүдәләре кояшка охшаш иң гади төзелешле организмнар семьялыгы. *Кояшсыманнарның күбесенең тәне кояшны хәтерләтә, ләкин аларның минераль скелетлары юк.* Биология. Хайваннар

**КОЯ́ШТЫР** *ы.* Ант итеп ышандырганда кояшны таныклыкка чакырып әйтелә торган сүз. *Авыл малайлары да аналарының берәр нәрсәсен сыптырып тотылгач: – Кояштыр, алмадым, – диләр, кояшны якасыннан тотып шаһитлеккә өстериләр.* Һ.Такташ. *[Нургаян:] Халидә, бу синдер? [Халидә:] Артыңда да күзең бардыр синең, кояштыр. [Нургаян:] Аяк тавышыңнан таныдым.* А.Гыйләҗев. *Ипинең чыраен күрмим, кояштыр, менәтерә, мин алмадым.* Р.Батулла

**КӨБӘ** *и. тар.* Вак металл боҗраларны бер-берсенә кидереп эшләнгән борынгы сугыш киеме. *...Ишек төбендәге сакчылар тимер көбәләрдән һәм булат кылычлардан...* Ф.Бәйрәмова. *Илбәк үз алдында көбә кигән җайдакны күреп алды.* Р.Зәйдулла

**КӨБӘ КИЕМ** *и. к.* **көбә**. *Ибне Рустә, болгарлар атка атланып йөриләр, көбә киеm кияләр һәм баштанаяк коралланганнар, дип язып калдырган.* Р.Фәхретдинов

**КӨБӘ КҮЛМӘК** *и. к.* **көбә**

**КӨБӘК** *и.* 1) Ату коралларының көпшә формасындагы пуля яки снарядны билгеле бер ноктага юнәлтә торган өлеше; көпшә. *Алдарак басып торган немец автомат көбәген идәнгә каратып борды.* З.Зәйнуллин. *Каравылчы йөкне аркасыннан тырпаеп торган мылтык көбәге белән бергә этәреп чыгаргандай этәреп урман авызына чыгарды да чананы Мерәс ягына каратып борып куйды.* А.Хәлим

2) *диал. к.* **күбәк**

**КӨБӘКЛЕ** *с.* Көбәге булган. *Аучыларга, бүре бар, дип әйт кенә син, берберсен уздырып, күгәргән куш көбәкле мылтыкларын эре ядрәләр белән корып, чаба-чаба авыл читенә барып та җиттеләр.* А.Гыйләҗев

**КӨБЕЛӘ** *и. зоол.* Борчакка зарар китерә торган кечкенә паразит бөҗәк; борчак бете, гөблә

**КӨБРӘ** *и. диал. бот. к.* **кәзберә**

**КӨДРӘ** *с. сөйл. рус* Бөдрә, бөдрәләнеп торган, бөдрә булып, чорналып үскән. *Икебез дә көдрә кара чәчле, төз гәүдәле, өстебездә ыспай гына костюм-чалбар, күлмәк-галстук, аягыбызда зур түрәләр кия торган импортный ботинка.* З.Мәхмүди

**КӨДРӘЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл.* Бөдрәләтү, бөдрәләндерү, бөдрә итү

**Көдрәләндереп бетерү** Барысын да көдрәләндерү; көдрәләндерүне тәмамлау

**Көдрәләндереп йөрү** Һәрвакыт көдрәләндергән хәлдә булу

**Көдрәләндереп тору** Даими яки әледән-әле көдрәләндерү

**КӨДРӘЛӘНҮ** *ф. сөйл. төш. юн. к.* **көдрәләү**

**Көдрәләнә башлау** Көдрәләнергә керешү

**Көдрәләнеп бетү** Бик нык көдрәләнү

**Көдрәләнеп җитү** Тәмам, тулысынча көдрәләнү

**Көдрәләнеп калу** Нindидер тәэсирдән соң көдрәләнү

**Көдрәләнеп тору** Көдрәләнгән хәлдә булу

**КӨДРӘЛӘТҮ** *ф. сөйл.* Чәчне бөдрәләтү, бөдрә итү (гадәттә чәчтарашханәдә)

**Көдрәләтеп алу** Тиз генә көдрәләтү

**Көдрәләтеп бетерү** Барысын да, тулысынча көдрәләтү; көдрәләтүне тәмамлау

**Көдрәләтеп тору** Һәрвакыт яисә әледән-әле көдрәләтү

**КӨДРӘЛӘҮ** *ф. сөйл.* Бөдрәләү, бөдрә итү (чәчне)

**Көдрәләп бетерү** Барысын да, тулысынча көдрәләү; көдрәләүне тәмамлау

**Көдрәләп кую** Алдан ук көдрәләү, көдрә итеп әзерләү; тиз генә көдрәләү

**Көдрәләп тору** Көдрәләү хәлендә булу; даими яисә әледән-әле көдрәләү

**Көдрәли төшү** Тагын да көдрәләү

**КӨДРӘЮ** *ф. диал.* Кукыраю, этәчләнү. *Егетләр, кызлар алдына килеп, тыпыр-тыпыр биеп, бармак шартлатып көдрәеп торалар.* А.Гыйләҗев

**КӨЕ** *бәйл. к.* **көенчә**. *Каз-үрдәкләрне суярга да көн юк, туңдырмаган көе, мал-туарны уҗымга чыгарып булмый.* М.Мәһдиев. *Фира кайтканда, әнисе ишегалдында иде, кызын күрми дә, танымый да кебек, эндәшми, шәл бөркәнгән көе, тирән карга бата-чума йөри.* Х.Камалов

**КӨЕК** *и.* 1) Билгеле бер әйбер яки матдә янганнан, көйгәннән соң барлыкка килгән калдык яисә аның көйгән урыны. *Башкалар кергәндә, өйдә әллә нинди көек исе, май исе чыккан иде.* Г.Ибраһимов. *Аяк астында Украинаның эссе кояшы һәм көзге җиле белән киптерелгән үлән сабаклары кыштырдады, аклар ягыннан битләргә дары исе, көек исе килеп бәрелде.* Г.Бәширов. *Чолыклыкка көек исе таралырга өлгермәде, Габделрахман кабат килеп җитте.* Җ.Рәхимов

2) *күч.* Кайгы, хәсрәт, күңелсезлек. *Юк, кирәкми, язмыймын, эчтә көек; күңелем боек! Ник боекмаска: тәмам ертык оек, шиблет кыек ---.* Ш.Бабич. *Анасына көек булыр өчен генә туган, күрәсең.* Г.Ибраһимов

**КӨЕКЛЕ** *с. иск. диал.* Кайгыхәсрәте булган, борчулы. *Көек ашаган көекле булыр.* Мәкаль

**КӨЕЛТЕ** *и.* 1) *зоол.* Арыш чыпчыгысыманнар семьялыгыннан озын аяклы һәм озын томшыклы, зур булмаган саз кошы; *русчасы:* **кулик**. *Һәрбер көелте үз сазлыгын мактый.* Мәкаль

2) Кошларның моңсу, кызганыч тавышы. *Аккошларның көелтеләре*

**КӨЕНӘ** *бәйл. к.* **көенчә**. --- *Язу-сызу белмәгән көенә Сәфәргалиләрнең шул дәрәҗәгә менүенә шатланалар...* М.Гафури. *Гайнетдин абзый өенә кайтып ишекне байтак вакыт дөбердәткәч кенә, хатыны аягөсте ярым йокылы көенә ишек ачты.* Ш.Камал. *Коңгырт чәчле кыз телефонда сөйләшә торган көенә башын чайкап куя ---.* Г.Бәширов

**КӨЕНДЕРҮ** *ф. диал.* Кайгыга, борчуга салу, кайгы-хәсрәт китерү. *Гаилә эчендә иренә юлдаш вә һәрнәрсәдә сердәш булган хатын өчен, дөрес сүз белән булса да, ирен көендерү килешерме?* Р.Фәхреддин

**КӨЕНЕЧ** *и.* Кайгы-хәсрәт, сагыш, борчылу. *Бу инде үпкәләү, көенеч күз яшьләре түгел иде.* Ш.Камал. *Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас булып, икенче яктан, язмышы бик авыр, тарихының соңгы сәхифәләре баштанаяк көенеч вә хәсрәт илә тулыдыр.* Г.Ибраһимов. *Исәпләсәң исең китәр: күпне күргәнбез икән, сөенечләрең, көенечләрең хәтер катламнарына түшәлеп калган.* Ш.Галиев

◊ **Көенечкә каршы** *кер. сүз. к.* **кызганычка каршы**. – *Әйе, көенечкә каршы, бандитны качыргансыз! – диде Фәтхи ---.* Ш.Камал

**КӨЕНЕЧЛЕ** *с.* Кайгылы, хәсрәтле булган, борчулы. *Миеннән көенечле уй үтте, балаларым, балаларым дип, күпме газап чикте.* Г.Ибраһимов. *Габдрахман абзый, төлке койрыгыдай йөнтәс мыегын сыпырып, көенечле тавыш белән әйтте ---.* Д.Галимов

**КӨЕНҮ** *ф.* Кайгыру, хәсрәтләнү; бик нык борчылу. *Әмма бер кабынган утның һаман да көйрисен,ниһаять, 1764 елда янә ялкынланып, шуңа көенәкөенә тагы ике ел яшәгәннән соң, туксан бер яшендә үлеп китәсен --- белми әле ул.* Җ.Рәхимов. *Хәтта ул үз баласының абруе өчен генә дә көенми, сугыштагы ирләрен онытып, азыптузып йөрүче хатыннарның барысын да күралмый, алар Хәдичә түтинең иң явыз дошманнары иде.* Г.Бәширов. *Ул инде әнисе өчен сөенә белә, аның өчен чын күңеленнән көенә белә.* Г.Гобәй

**КӨЕНҮЧӘН** *с.* Төрле борчуларга, кайгы-хәсрәткә тиз бирелүчән

**КӨЕНЧӘ** *бәйл.* Үзеннән алда килгән сүз белдергән рәвештә, хәлдә. *Эчте дә эчте салкын суны, тирле көенчә!* Дәрдемәнд. *Аның сөйгәне Гәүһәр туташны җанлы көенчә күз алдына китереп бастырдым ---.* Г.Ибраһимов. *Кырык градус суыкта да шул көенчә йөри бирә.* Д.Галимов

**КӨЕНЧЕК** *и. диал. к.* **көенеч**. --- *ул [Мәрьям] да шатлык белән көенчек, өмит белән шөбһә вә үкенүнең әле бер яктан, әле икенче яктан туктаусыз агымына ятып, матди хәяттан аерыла, эзләгәнен мәңге таба алмас шикелле бер тойгы сизә иде.* Г.Ибраһимов

**КӨҖӘЛӘ** *и. бот.* Логанийчалар семьялыгыннан тропикларда үсә торган куак яки агач үсемлек; костыргыч чикләвек; *русчасы:* **чилибуха**

**КӨЗ** *и.* 1) Җәй белән кыш арасында булган, үз эченә сентябрь, октябрь, ноябрь айларын алган дүрт ел фасылының берсе. *Тышта инде тәмам көз булып, төннәрен ап-ак кырау төшүгә карамастан, тәрәзә төпләрендә гөлләр пәйда булды.* Җ.Рәхимов. *Аңа гармун тавышы берничек тә тәэсир итми. Бу чың аның колагында кырык икенче елның көзеннән бирле яңгырап тора...* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса ахырга якынлашкан чоры; картаю, сулу вакыты. *Мин болай идеммени соң, Мин болай идеммени?! Сары яфраклы сабырлык Көзенә килдеммени?* М.Галиев. *Иртәнге көзге каршында көзе җиткән ир сурәте; чәрдәкләнгән йөзенә сулышыннан томан төшә.* М.Галиев. *Нигә шулай соңлап килдең, сөю, Гомерләрнең көзе җиткәндә?* З.Сираева

**КӨЗӘН** *и.* Сусарлар семьялыгыннан кыйммәтле мехлы кечерәк кенә ерткыч җәнлек; *русчасы:* **хорёк**. *Яфраклар да бетте, кешеләр агачларның кайрысына ябыштылар, тирә-якта бөтен агачлар*

*шәрәләнеп калгач, этләр, мәчеләр, тиеннәр, көзәннәр, күселәр, бакалар, чикерткәләр, суалчаннар белән тукландылар ---.* М.Кәбиров

**КӨЗӘ́Н ҖЫЕРУ** I *ф.* Үзеннән-үзе мускуллар, гадәттә очлыкларда, киерелү, кыскару, тартышу. *Салкын суда озак булгангамы, [Гадиләнең] аякларын көзән җыера башлый.* Ф.Яруллин

**КӨЗӘН ҖЫЕРУ** II *и.* Мускулларның үзеннән-үзе авыртып тартылуы. *Көзән җыеру көннәр буе аягөсте басып торган һөнәр ияләре – сатучылар, чәчтарашханә хезмәткәрләренең «профессиональ» чире санала.* Ватаным Татарстан

**КӨЗӘН ТАРТУ** I *ф. к.* **көзән җыеру** I

**КӨЗӘН ТАРТУ** II *и. к.* **көзән җыеру** II

**КӨЗГӘ** *рәв.* Көзен, көз көне, көзгә таба, көз җиткәч. *«Җир-мазар алсак, палатка куеп булса да җәйне үткәрер идек, көзгә кадәр вакыт бар, ни булса да куыш әтмәлләрбез!» – дип сөйләштеләр Нәҗип белән Наилә.* А.Гыйләҗев. *[Наил:] Сиңа әле көзгә генә мәктәпкә барасы.* Ф.Зыятдинов

**КӨЗГӘ́ЧӘ** *рәв.* Көзгә хәтле, көзгә кадәр; көз башланганчы. *Көзгәчә сабыр итик ---.* Г.Ибраһимов

**КӨЗГЕ** I *и.* 1) Үзенең алдындагы барлык нәрсәләрне чагылдыра торган шома пыяла яки металл өслеге булган предмет. *Хатын, тиз генә яулыгыны салып ташлап, көзге өстәленә барып, өстәлдән калфак алып, көзгегә барып каранып, ишеккә таба китә.* Г.Исхакый. *Көненә өч-дүрт күлмәк алыштыру, сәгатьләр буена көзге каршында утыру, энҗе-мәрҗәннәр, бриллиантлар тагу җәфаларын бер Алла да үзе генә белә Елизавета.* Җ.Рәхимов. *Ул әле дә булса көзге каршына баскан көйгә ашыкмый-кабаланмый гына чәчен таравын белә.* Д.Галимов

2) *күч.* Билгеле бер процессларның, күренешләрнең чагылышы. *Беркөн килеп, шәхес йөзтүбән ава да, хакыйкать көзгесе каршында ялангач иҗатың торып кала.* М.Галиев

3) *күч.* Нәрсәне дә булса ачыкларга, белергә ярдәм итә торган чара. *Укый-яза белү – тормышыңны Ачып күрсәтүче көзге ул.* М.Гафури

4) *күч.* Берәр нәрсәнең тигез өслеге. *Буа көзгесе мәйданы*

**КӨЗГЕ** II *с.* 1) Көзгә хас, көз көне була торган; көзен башкарыла торган. *Узган ел мәдрәсәдә сабак тыңлаган шәкертләрнең «май чүлмәгенең эче» турындагы сүзләре дә эзсез калмаган бугай, бу көзге көннәрдә иләүдән-иләүгә «Карышбаш» һәм «Батырша мулла» дигән хәбәрләр йөри, алар сүз-хат җитәрлек барлык вилаятьләргә барып ирешә иде.* Җ.Рәхимов

2) Көз айларында үсә яисә өлгерә торган. Көз көне җәелә торган. *Көзге бодай*

3) Көз сезоны, көз фасылы өчен билгеләнгән. *[Шагыйрьнең] көзге пальто өстенә җәйге пальтосы да була иде.* И.Рәмиев

◊ **Көзге әтәч** Бәйләнчек һәм сугышучан, бик һавалы яшүсмер. **Көзге чебеш** Нычып, чыныгып җитмәгән яшүсмер. *Ә мин, хәзер унберне тутырып килә торган олы малай, шул көзге чебешләр арасында утыр имеш.* Ш.Маннур

**КӨЗГЕ-КЫШКЫ** *с.* Көзен һәм кышын була торган, шул вакытларда уза торган

**КӨЗГЕЛӘНҮ** *ф.* Көзге төсле ялтырау, көзге кебек шомага әйләнү

**Көзгеләнә төшү** Тагын да көзгеләнү

**Көзгеләнеп калу** Нindидер тәэсирдән соң көзге кебек шомага әйләнү

**Көзгеләнеп китү** Көзге хәленә килү. *Балалар көне буе чаңгы, чана, тимераякта боз өстендә уйнадылар, боз каткан елга өсте хәтта көзгеләнеп китте*

**Көзгеләнеп тору** Көзге кебек хәлдә булу

**КӨЗГЕЛЕ** *с.* Көзгесе булган, көзгеләп, көзге куеп эшләнгән. *Көзгеле гальванометр*

**КӨЗГЕЛЕК** *с. сөйл. к.* **көзлек**

**КӨЗГЕЛЕКТӘ** *рәв. сөйл. к.* **көзен**

**КӨЗГЕ́ЧӘ** *рәв.* Көз көнедәй, көз кебек, көздәгедәй. *Көзгечә салкын җил*

**КӨЗГЕЧЕ** *и.* Көзге ясау белән шөгыльләнүче, көзге ясаучы оста, көзге коючы

**КӨЗДӘ** *рәв.* Көз көне, көзен, көз җиткәч. *Язда булса – яшеллек һәм чәчәкләрнең хуш исе, көздә булса – туклык, муллык һәм һәркайда эш исе.* М.Җәлил

**КӨЗДӘН** *рәв.* Көзен ук, көз вакытында ук. *Казанга мәдрәсәгә барганчы, әтисе аны, алдагы көздән Зөягә җибәреп, берәр кыш тагын русча укытырга уйлаган иде, ләкин киресенчә булып чыкты.* М.Гали. *Әнисе көнозын мәктәптә, абые да быел көздән укырга керде ---.* Г.Гобәй. *Бригадасын ныгыту өчен, ул көздән ниләр генә эшләмәде.* Г.Бәширов

**КӨЗЕН** *рәв.* Көз айларында, көз вакытында, көз көне. *Җил көзен очраган берәүнең борынына тузан тыгып йөридер иде, хәзер инде һөнәрен үзгәрткән---.* Һ.Такташ. *Көзен дә, кышын да басуда кунып булмый торгандыр, кайтып керергә бер куыш кирәктер бит миңа.* Г.Бәширов. *Көзен фриц язган хатынына: – Кыш килгәч тә кайтып җитәм, – дип. – Көз бик пычрак була бу якларда, Сугышуы авыр икән, – дип.* Ә.Ерикәй

**КӨЗЛӘ́Ү** *ф.* Көзне үткәрү; көз буе яту

**КӨЗЛЕК** *с.* Көзен куллану өчен билгеләнгән, көзен кирәкле

**КӨЗЛЕКТӘ** *рәв. к.* **көзен**. *Тик, иптәш, көзлектә каз бәлешенә дәшәрсеңме?* Г.Бәширов

**КӨЗЛИ** *рәв. сөйл. к.* **көзен**. *Кышлый һәм көзли колхоз үз колхозчыларына икмәк, он, ашлык бирә.* Кама ягы

**КӨЙ** I *и. кыт.* 1) Авазларның (тоннарның) эзлекле тәртибеннән гыйбарәт музыкаль бербөтен. *Ә алар [музыкантлар], ярарга тырышып, дәртләнә-дәртләнә әрмән көйләрен сыздыралар.* З.Мәхмүди. *Кемдер яңа йокыдан уянган, әле бөтенләй ачылып җитмәгән тавышы белән озын көйгә салып: «Агыйделкәй алкын, суы салкын, Тулкыннары кага салларга...» – дип суздь.* Г.Ибраһимов. *Көйгә салып йөрәк моңнарымны Нинди-нинди җырлар тезмәдем, – Гыйшык тоту аннан мең мәртәбә Кыен икән, шуны белмәдем.* Ш.Мөдәррис

2) Билгеле бер музыкаль әсәр. *Гармунчы аның саен җәһәтрәк бию көйләрен тартып җибәрә. Аяклар торган*

*саен ныграк баса.* Р.Мөхәммәдиев. *Тукай ашханәгә юынырга төшкән вакытларда, ашханә буена җырлап йөри, биредә ул «Мөхәммәдия» укымый, ә татарның милли көйләрен: «Кара урман», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» көйләрен җырлый иде.* Ш.Каюмов

3) Нәрсә дә булса чыгарган аһәңле тавыш. *Әһә! Әнә өянкенең су өстенә асылынып төшкән чуклары дулкын өсләренә тиеп китәләр дә бер серле көй чыгаралар... Чың-чың... чың-чыңчың...* Г.Гыйльманов

◊ **Көен җырлау** Берәр эштә кемнең дә булса карашын үткәрү; кемнең дә булса эшен яклау

**КӨЙ** II *и. кыт.* Җай, тәртип, бер уңай. *Аның көенә туктап-туктап барды, ул утырып ял иткәндә көтеп алды.* Г.Гобәй. *Тормышыбызны бер көйгә җайлап җибәрсәк тә, без яңа теләкләр һәм бурычлар белән янып яшибез.* Ә.Еники

◊ **Көе килү** Җае килү, кәефе килү, кәеф булу. *Үзеңне нык сыйларлар: безнең карт, көе килгәндә, бик юмарт кеше.* Г.Ибраһимов. **Көе киту** Бозылу, эшнең рәте бетү. *Шулай да бу Мәрфуга килен эшләп кинәндерми, көе килгәндә бик әйбәтләп булышкалый, бер нәрсә ярамаса --- үпкәли, әче теллеләнә башлый.* Г.Ибраһимов. **Көен көйләү** Кәефен табу, күңелен күрү. *Кемнең җырын җырласаң, шуның көен көйләрсең.* Мәкаль. *Ярамыйны мондый «ярамый» бер дә бер заманны түйдырып, гарык итеп бетергән дә, әйткән, ди, бу: – Мин Ярамыйм икән, әнә урам буйлап Ярый килә. Аңа бөтен нәрсә ярый. Шуның көен көйләп торыгыз инде, алайса, – дигәч, әллә кая киткән дә барган.* Ә.Гаффар. **Көен күрү** *к.* **күңелен күрү**. **Көенә тору** Кемгә дә булса каршы килмәү, ул дигәнчә эшләү. **Көйгә килү** Җайлану, яхшыга әйләнү (кешенең үз-үзен тотышы, тәртибе тур.). *Николай үзенең заборын беррәттән дүрт мәртәбә санаткач кына азрак тынычланды, юкса һич ипкә-көйгә килми.* Ш.Камал. **Көйгә китерү** Нинди дә булса эшне башкарырга күндерү, ризалату; яхшыга әйләндерү. **Көйгә бастыру** *к.* **көйгә китерү**

**КӨЙГӘ** *бәйл. к.* **көенчә**. *Яратса, шул көйгә яратыр, ератмаса чукынып китсен: мин, аңа ярыйм дип, үзем өчен бер тиен чыгым ясамам, купшыланмам.* Г.Ибраһимов. *--- һәм шул бәхетсез көйгә, бүтән кешеләрдән калышмыйча атлап килдем.* Ф.Хөсни. *Күңелен никадәр беркетеп торырга теләсә дә, ахрысы түзә алмады, намазын укый торган көйгә, учак ягына борынын сузып иснәштерә башлады.* Г.Бәширов

**КӨЙГӘЛӘК** *с. сөйл. к.* **көенүчән**

**КӨЙГӘНӘК** *с. диал. к.* **көйгәләк**

**КӨЙДӘ** *бәйл. к.* **көенчә**. *Мин ул сүзнең мәгънәсен аңламасам да, бөтен көйдә отып калдым.* М.Гафури. *Озын буен тагын да күтәреп, шкафка яны белән сөялгән көйдә тора бирә.* Г.Ибраһимов

**КӨЙДЕРГЕЧ** *с.* 1) Көйдереп, яндырып ала торган. *Башкаланы дәһшәтле сугыш күкрәве дерелдәтми, канонадалар тынган, сугыш җәһәннәменең көйдергеч ялкыны башкала күгендәге соры болытларда чагылмый иде.* Г.Гобәй. *Егет, я син бу әлегә тетрәнеп кенә торган ут шәүләсеннән качып кит һәм аны онытып өлгер, я син аның көйдергеч ялкынында көл булырга әзер тор!* Ә.Фәйзи. *Харара җиле көйдергеч кызу һава белән вак борычтай әче тузан алып килә.* М.Юныс

2) *күч.* Бик көчле, ачы (хис тур.). *Шушындый минутларда, яңа туган балаларның бишекләренә бомбалар ташларга хәзерләнүче фашистларга, сугыш уты кабызучыларга нинди көйдергеч нәфрәт кабынмый да, нинди ярсу тумый!?* Г.Әпсәләмов

**КӨЙДЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса тышкы ягын, чит-читләрен яки очларын каралганчы яндыру, күмерләндерү. *Ут телләре аның [Ильясның] бияләен көйдереп, беләзек турын ялап әчеттергәнгә, кинәт читкә тайпылып, таяк-фәлән юкмы дип эзләнде.* Ә.Баян. *Кабер өстендәге тактага көйдереп түбәндәге сүзләр язылган иде: 1943 ел, 21 апрель.* А.Расих

2) Киптерү, корыту. *Йөзе җил, яңгыр белән әйтерсең көйдерелгән.* Г.Ибраһимов. *Ул киптергән суны, көйдергән иген кырларын.* М.Җәлил

3) Кыздыру, эсселәтү (кояш нурлары, эссе һава тур.). *Талип бабай кояшка карап, сүзен икенчегә борды: – Ай, битеңне капларга бер кисәк болыт! Шулкадәр көйдермәсәң...* Г.Гобәй. *Ниһаять, ул үзенең күз теккән ноктасына барып ирешә дә, аннан мөтәкәбиранә бер сыйфат белән дөньяга карап, бөтен табигатьне утына, яктысына күмә, яндыра, көйдерә һәм нурландыра.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Авыру яки башка сәбәпләр аркасында тән бик кайнар булу. *Кулын тотып караган идем, корт чаккандай кире тартып алдым. Пешерде генә түгел, көйдерде.* Н.Әхмәдиев

5) *күч.* Кайгыга салу, хәсрәтләндерү; борчу. *Ә хәзер, хәзер алар утлы күмер кебек минем тәнемне көйдерәләр.* Р.Ишморат. *Тик юлдашының шыңшуы бәгырен көйдерә иде.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Начар якка үзгәртү, үзенең тискәре тәэсирен калдыру. *Сугыш җәһәннәменең ялкыны бер ел дигәндә авылны шәһәргә караганда да рәхимсезрәк итеп көйдерергә өлгергән, авыл өстенә җәелгән сөрем исен чәчәк исләре генә томаларлык түгел иде.* Г.Гобәй

7) *күч.* Бик каты тәнкыйтьләү. *Байларны, казый һәм хәлфәләрне фаш итүгә, мәдрәсәдәге һәм хәзрәт семьясындагы җиренгеч якларны сатира уты аша көйдерүгә юнәлдергән.* М.Җәлил

**Көйдерә башлау** Көйдерергә тотыну. *Соңгы айларда башын, йөрәген кайнаткан зәһәрләр тагын аның бөтен тәненә таралып, көйдерә башлады.* Г.Ибраһимов

**Көйдерә бирү** Бернигә дә карамый, һаман көйдерү. *Кояш төшлеккә менә, һава көйдергәннән-көйдерә бирә.* Г.Ибраһимов

**Көйдереп алу** Тиз арада гына көйдерү. *Ялкын кебек көйдереп ала торган Усал җилләр биткә өрделәр.* Ә.Ерикәй. *Ачы хәсрәт аның тынын буган, күз яшьләрен көйдереп алган, әгәр елый башласа да, күзләреннән яшь урынына кан тамар иде.* Г.Бәширов

**Көйдереп кую** Азрак, берникадәр күләмдә көйдерү. *Тик алтын сары салам түбәне бераз көйдереп --- куйды.* Г.Ибраһимов

**Көйдереп ташлау** Ачу, ярсу белән тулысынча көйдерү; бик тиз көйдерү. *--- менә күрерсез, бодайлары тишелеп тә чыкмас, шундук кояш көйдереп ташлар, диделәр ---.* Н.Фәттах

**Көйдереп тору** Бертуктаусыз, гел, даими көйдерү; хәзерге вакытта көйдерү. *Тагын бер уй аның күңелен көйдереп, җанын бимазалап тора.* Т.Галиуллин

**Көйдереп узу** Узышлый көйдерү. *«Берсе җанымны теге дөньяга алып китсә, икенчесе сары йортка тапшырыр» кебегрәк ямьсез уйлар өермәсе миен көйдереп узды.* Т.Галиуллин

**Көйдереп үтү** *к.* **көйдереп узу**. *Сөембикә аның тавышын һич тә таный алмады, әллә Баллы Төбәктән әнисе килгәнме дигән уй аның миен көйдереп үтте.* Ф.Садриев

**КӨЙЛӘГЕЧ** *и. махс.* Нәрсәне дә булса көйләү, җайга салу, рәтләү приборы; регулятор

**КӨЙЛӘМ** *с. әд.* Көйләп укыла, әйтелә торган. *Такташ көйләм шигыреннән сөйләм шигыренә күчү, шигырьдә табигыйлек мәсьәләләрен куйган иде.* Х.Госман

**КӨЙЛӘНҮ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **көйләү** II (*1–2 мәгъ.*). *Сыекчаны әзерләп бетереп, ике көпчәкле арбага көйләнгән кисмәккә салгач, кисмәкне труба аша арба артындагы күп тишекле улакка тоташтырып бирде.* Г.Гобәй. *Бер читтәрәк – су эчәр өчен махсус көйләнгән, югарыга су ургып тора торган кран.* Р.Ишморат

2) Тәртипкә килү, җайлану, үз эзенә төшү (тормыш, эш һ.б. тур.). *Хәйләкәр төлкенең эшләре бик шәп көйләнә ---.* А.Алиш. *Бу агроном чибәр генә көйләнгән тормышының тынычлыгын бозмыйча, матур гына итеп яшәргә яратучан --- бер кеше иде.* Г.Бәширов. *Бара-тора, яшь йөрәкләрендәге ялкынлы, дәртле һәм берникадәр җиллебуранлы мәхәббәтләре бер-берсенә гадиләшү көче белән гаделләшкәч, тормышлары көйләнде.* Г.Минский

3) *сөйл.* Җайлашу, күнегү. «*Ана теле» дип тикмәгә әйтмиләр – карында чакта ук шул аһәңгә көйләнә бала.* Ш.Галиев

**Көйләнеп бетү** Тәмам көйләнү, бар да көйләнү. *Бөтенесе дә көйләнеп беткәч, Нәфисә ---, байталны тезгеннән тотып, бодай өстенә җитәкли башлады.* Г.Бәширов

**Көйләнеп китү** Билгеле бер вакыттан соң көйләнү; көйләнгән хәлгә килү. *Шулай итеп, эшләр тагын көйләнеп китә иде.* Г.Бәширов

**КӨЙЛӘНҮ** II *ф. төш. юн. к.* **көйләү** I. *Тышта ерак-еракларда, караңгылык артындагы яссылыкларда, гүяки һаман үткер, ничә матур аваз белән көйләнгән пионерлар җыры ишетелгән кебек була.* Ш.Камал

**КӨЙЛӘ́П-ЧӨЙЛӘП** *рәв.* Төрле сүзләр белән юатып. *[Сәфәр:] Безне көйләп-чөйләп тынычландырып, кайтарып җибәрделәр.* Ә.Фәйзи

**КӨЙЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Нindидер бер көйне башкару, бер көй(гә) җырлау. *Авыл һаман үзенең тирән вә тыныч йокысында; тик сирәк кенә кайдадыр берәү ачы сызгырып җибәрә, кемдер өзек кенә җыр көйли дә музыка тартып куя.* Г.Ибраһимов. *--- Тукай бәетен сагышлап, кызганып көйлиләр – елап җибәрермен сыман: миңа да бик җәл.* Ш.Галиев. *Күп тә үтмәде, нindидер күңелле җыр көйли-көйли, ишектән колхоз рәисе Рифкать Сәлимович килеп керде.* Г.Гыйльманов

2) Музыкаль авазлар чыгарып, сүзсез нindи дә булса бер көй сузу. *Җырлап тудым, җырлый-җырлый үләрмен мин, Кабердә дә әкрен генә көйләрмен мин.* Ә.Ерикәй. *Зөмәрә биегән кебек селкенгәләп керә, «Әпипә»гә көйли-көйли, бүлмә аша үтә башлый.* А.Әхмәт. *[Зөфәр] Үзалдына нindидер көй көйли, вакыт-вакыт җырның сүзләрен дә кушып китә.* Р.Мөхәммәдиев

3) Сайрау. *--- яфраклар арасына яшеренгән кошчыклар адәмнәр аңламый торган җырларын көйлиләр дә, бөтен бу юл тамчылы нур һәм резедаларның тормышларына бер серлелек бирә иде.* Ф.Әмирхан

4) Нindи дә булса көйгә охшаш авазлар, тавышлар чыгару (җансыз әйберләр тур.). *Исә җил авыр кайгылы: Куркыныч көйләрне көйли ул, Дәһшәтле серләрен-тарихын, Бу җирнең кайгысын сөйли ул.* Һ.Такташ

5) Көйгә салу. *[Китап] үзе бер генә табак чамасы булып, көйләп язылган иде.* М.Гафури

6) *иск.* Сөйләү, сурәтләү (шигырьләрдә). *[Такташ] авыл турында, аның хезмәт ияләре эченнән диварында Ленин рәсемен асраучы советчы Шәхми картлары үсеп чыгуын көйләде.* Г.Нигъмәти

**Көйләп алу** Кыска гына вакыт эчендә көйләү. *Хәйрүш «Галиябану»ны көйләп ала.* А.Алиш

**Көйләп бирү** Көйләп күрсәтү. *– Менә кара! – Газинур көйнең яңа бәет көеннән аерыла торган урыннарына басым ясап көйләп бирде.* Г.Әпсәләмов

**Көйләп җибәрү** Көйли башлау. *– Думбрам да бүген ак таң беленеп, кайгылы кара үлем хәбәре йөрәгемне яралаганнан бирле телдән тукталды, аның бер моңлык әйтергә исәбе юк түгел иде, – диде дә --- моңланып, халык җырларыннан берен көйләп җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Бара-бара да көйләп җибәргән була, гәүдәсен туры тотарга, аякларын нык басарга тырыша.* Г.Гобәй. *Аның үзеннән-үзе җырлап торган яңгыравык тавыш белән таягын болгый-болгый көйләп җибәрүе, чыннан да, нindидер тантана уята иде.* Г.Бәширов

**Көйләп йөрү** Һәрвакыт яки кат-кат көйләү. *Кулына думбра тотып, өйдән-өйгә көйләп йөри икән.* Г.Ибраһимов. *Авыл малайлары, җыйналып, Кәҗә Хәмитнең артыннан йөри, аның җырлаган җырларын һәр җирдә кызык итеп көйләп йөри иделәр.* Ш.Камал. *Авыз эченнән генә көйләп йөргән яңа җырын безнең өчен, киләчәк буыннар өчен акка төшереп калдырасы бар бит аның.* Г.Гыйльманов

**Көйләп килү** Күптәннән бирле көйләү. *[Минтимер Шәймиев:] Шуңа күрә дә без федераль үзәк белән мөнәсәбәтләребезне махсус шартнамә ярдәмендә көйләп килдек.* Ватаным Татарстан

**Көйләп кую** Аз гына, кыска гына итеп көйләү. *Әкрен генә «Шат күңелле яшьләр»не көйләп куя.* Г.Гобәй. *Матур, моңлы тавышы белән акрын гына көйләп куя.* Г.Ибраһимов

**Көйләп тору** Әледән-әле яисә даими рәвештә көйләү; көйләү хәлендә булу. *Ахыр гомер мәңге өстегездә Мәрсияләр көйләп торырмын.* Ш.Бабич. --- *сөйләнә-сөйләнә, җил бәргәли башлаган тәрәзәне ябып куйды, нindидер музыка көйләп торган репродукторны ычкындырып җибәрде.* Г.Бәширов. *[Ана] Үкенә икән, елый икән. Шул ана көйләп тора сыман да, тик әнкәй тавышы ич?* Ш.Галиев

**Көйли башлау** Көйләргә тотыну. *Ул йомшак кына тамак кырып ала да иң моңлы бер җырны сайлап көйли башлый.* Г.Гыйльманов

**Көйли бирү** Бернигә дә карамастан көйләүне дәвам итү. *Сабый әле һаман, әнисенең хафага төшкәнен аңламыйча, кулын чәбәкләп көйли бирде ---.* Г.Гобәй

**Көйли төшү** Бераз көйләбрәк әйтү, сөйләү. *Ул бераз җитдиләнеп китте һәм бераз көйли төште. – Егет кеше уйлый да уйлый, уйларының очына чыга алмый, – диде.* Г.Бәширов

**КӨЙЛӘ́Ү** II *ф.* 1) Кору, рәтләү, җайлау (механизмны һ.б.). *Оялды Илсөяр, уңайсызланды, ә пулемётын тачанкага көйли-көйли елмаеп карап торган Өметбаев белән күзгә-күз очрашкач, кызарып, башын түбән иде.* Г.Гобәй. *Иртән камыт бавын көйләгән карт Кич утырып тарих өйрәнә!* З.Мансур

2) Тәртипкә китерү, рәткә салу, рәтләү, җайлау (эшне һ.б.). *Юк, утыз өч яшькәчә тормышын көйли алмаган Нәҗипкә әрәм мондый затлы мал!* А.Гыйләҗев. – *Сания! – диде. – Бу әбине хәзер үк Байрашевага алып бар. Әйт үзенә: әбине бүтән йөртмәсен, бөтен эшен көйләп, акчасын бүлеп үз кулына биреп җибәрсен!* Г.Бәширов. *– Борчылма, мулла, эшне көйләрбез, ил имамыннан налог түләтмәбез, – диде.* А.Шамов

3) Оештыру, җайга салу, башлап җибәрү. *[Мәхмүзә:] Хәзер инде, Ишнияз бабай, колхоз эшен машинага көйләде ич, ә син ат дигән буласың.* Р.Ишморат. *Әтәч ул – могҗизалы кош: ерак Африкадан килсә дә, әүвәлге туган ягы көйләгән вакыт белән яши, таңда кычкыруы да, көндез аваз салуы да шундагыча.* Ш.Галиев

4) *диал.* Әзерләү, җәю (мәс., урынҗирне). *Кайсылары биек итеп печән тутырган тарантаста урын көйли башладылар.* Г.Бәширов

5) *куч.* Күңелен табу, кадерләү, күңелен күрү. *Үзе көн-төн эшләгәч, аңа эшсез яткан хатынын назлау да, көйләү дә торган саен авырга килә башлады.* Ә.Еники

6) Юату, юмалау. *Сафия абыстай аны шулай көйли-көйли урынына илтеп яткырды, ләкин Хәкимҗан абзый һаман тынычлана алмый иде әле.* А.Шамов. *Шуңа күрә мөдәррис тә, хәлфәләр дә мәдрәсәгә әледән-әле улбу юкмы дип килеп йөри торган полицейский Ряховны һәрвакыт, мәдрәсәдә тынычлык, борчылырга урын юк дип, көйләп озаталар иде.* Ә.Фәйзи. *Искәндәр Маратны көйләп кергәч, яңадан эшкә чума.* Г.Гобәй

**Көйләп алу** Тиз генә, озакка сузмыйча гына көйләү. *Тапёр белән чак кына көйләп алырсыз.* Ш.Камал. *Винтовкаларын көйләп алдылар.* М.Гафури

**Көйләп бирү** Кем өчендер көйләү эшен башкарып чыгу. *Әйе, кичә ниндидер бер чибәр хатын аңа урын көйләп бирде бит.* Г.Бәширов

**Көйләп җибәрү** Көйләүне башлау; тагын да көйләү. *Үзара ярыш дигәнен дә көйләп җибәрәсе булыр, агитаторга әйтермен.* Г.Бәширов. *Быел молотилкабыз электр көче белән эшләде, фермада салам кискеч машинаны да электрга көйләп җибәрдек.* Ә.Еники

**Көйләп кую** Алдан ук көйләнгән итү. *Аңарчы бөтенесен көйләп куярга кирәк.* Г.Бәширов. *Бүген иртән яңа камытларга Баулар көйләп куйды яхшылап.* З.Мансур

**Көйләп тору** Гел яки әледән-әле көйләү. *Аны гына көйләп тора торган гаҗәп матур хур кызлары күренәләр.* Ф.Әмирхан

**Көйли башлау** Көйләргә тотыну. *Ат абзарлары тирәсендә тимер ходлы арбаларны көйли башладылар, дугаларга кыңгыраулар тактылар.* М.Мәһдиев

**Көйли төшү** Тагын бераз көйләү

**КӨЙЛЕ** I *с.* 1) Аһәңле, музыкаль яңгырашлы. *Хвалыннан килгән Шәймәрдан исемле мишәр шәкерте беркөнне: – Кая, мин дә бер җыр әйтеп бирим, – дип, «Шиповой колюса» дигән бер озын көйле җыр җырлап бирде.* Ә.Фәйзи. *Аның йомшак, көйле тавышында, матур итеп кеткелдәп көлүендә яхшылык аңкылып торган...* А.Шамов

2) Көйләп, билгеле бер көйгә салып укыла торган. *Г.Камалның ул еллардагы беренче шигырьләре күбрәк иске көйле дини китаплар стилендә язылганнар.* М.Гали

**КӨЙЛЕ** II *с.* Тәртипкә салынган, җайлы, уңайлы; тәртипле. *Давыл башланганның икенче көнендә кичкырын Гариф белән солдат Шәрәфи картка барырга дип чыгып киткәч, барактагы иптәшләре: «Безнең артельщикның эше көйле...» – дигән булып, Гариф турысында бераз гайбәт җыйсам да, ул гайбәт – хаксызлык эше.* Ш.Камал

**КӨЙЛЕЛЕК** *и.* 1) Көйле (I) булу. *Җырның көйлелеге*

2) Көйгә ятышлы булу, аһәңле булу үзенчәлеге. *Барыннан да элек, классик поэзия нигезендә яткан көйлелекнең акрынлап булса да декламация интонациясе белән аралашуы --- сизелде.* Г.Халит

**КӨЙМӘ** I *и.* 1) Су өстендә йөзә торган зур булмаган судно, кәмә. *Ләкин мине Жорның балыгыннан да бигрәк көймәләре, көймәләреннән дә бигрәк моторлары сокландыра.* М.Әмир. *Үзе [Нариман] кармаклар тезелгән озын капрон җепне әкрен генә су төбеннән тартып, көймә төбенә тәгәрмәчләп җыярга кереште.* Г.Мөхәммәтшин. *Шатыр-шотыр килеп, аллы-артлы куышып, моторлы көймәләр кайтты.* А.Гыйләҗев

2) Кайбер тезмә исемнәр составында хәрби судноларны белдерә. *Шаховскийның су асты көймәсе исән-сау килеш базага кайтып җитте.* Г.Әпсәләмов. *Кызылларның канонер көймәсе һәм биш гади судно күренгәч, туптан бер тапкыр аталар да, артиллеристлар качып бетә.* Ватаным Татарстан

3) *иск.* Пароход. *Югарыдан килә торган бик озын трубалы, ике якта бик зур тәгәрмәчле зур кара көймә күренде. Аның трубасыннан очкын белән катыш кара төтен чыгып бара иде.* М.Гали

4) *иск.* Дүрт тәгәрмәчле, рессорларга утыртылган һәм бар ягы да ябык булган арба; экипаж. *Аңа күз яше арасыннан караңгы төннәр, зур кара көймәгә җигелгән зур кара атлар, Сабирның, шул көймәгә курыкмыйча утырып, әллә нинди караңгы, билгесез дөньяга кереп китеп югалулары берәм-берәм күз алдына килә.* Г.Ибраһимов

5) Кеше утырту яки йөк йөртү өчен, мотоциклга беркетелгән тәгәрмәчле җайланма; люлька, коляска. *Көймәле мотоцикл биредәге немецларга зур яссы термослар белән аш китерә икән.* Х.Камалов. *Көймәсез мотоцикл, мотороллер һәм мопед йөртү стажы бер елдан ким булган кешеләргә пассажирлар утырту тыела.* Социалистик Татарстан

6) Әйбер ташый торган кечкенә арбачык. *Үзе, күл буена кире кайтып, ашъяулыкка төрелгән ризыкларны җыештырып алды, аларны арба көймәсенә аннан-моннан ыргытты, сыңар кулы белән тәртәне әләктереп, Рузилә янына чапты.* А.Гыйләҗев

◊ **Көймә комга терәлү** Эш кыенлашу; авыр хәлдә калу. *«Әһә, – дим эчемнән генә, – бу бичараның да көймәсе комга терәлгән икән!»* Ә.Еники. *Инде ел беткәндә, көймәң комга терәлдемени?* Э.Касыймов

**КӨЙМӘ** II *и.* Өскә таба кабарынкы итеп салынган түшәм яки стеналарны, терәкләрне тоташтыра торган дугасыман түшәмә. *Миңнур картның --- миче бозылды: башта ул бик каты төтенләп газаплады, аннары аның көймәсе дөбердәп ишелеп төште.* А.Шамов. *Озак утыргач, өчле лампа яктысында күзләрне йокы баскач кына, багу, юрау башлана, гәзит яки иске китап битләрен алалар да караңгы мич алдында шуны яндыралар, аның ялкыныннан мич көймәсендәге корымга ут үрли ---.* М.Мәһдиев

**КӨЙМӘДӘШ** *и. сир.* Көймәдәге юлдаш; бер көймәдә утырып барган кешеләрнең берсе. *Көймәдәшләремә шундук бу сәгатьнең үзем белгән тарихын сөйләп бирдем.* М.Әмир

**КӨЙМӘЛӘП** *рәв.* Берәр бина яисә корылмага көймә II формасын биреп, түбәсен көймә II рәвешенә китереп. *Бу вокзал чиксез зур итеп көймәләп эшләнеп, башын пыяла белән япкан лабазга охшый.* Г.Гали. *--- беренче катның көймәләп эшләнгән аркасы җанның тәннән аерылуын күрсәтүче символ булса кирәк ---.* Р.Сафин. *Стена шундый тигез, ак известь җөйләре туп-туры, ә түшәм, ныклык өчен, мич шикелле көймәләп эшләнгән.* А.Тимергалин

**КӨЙМӘЛЕ** *с.* 1) Көймә II рәвешле. *Диварларың таштан бит, түшәмең дә көймәле.* А.Гыйләҗев. *Аның [мәчетнең] сигез кырлы гөмбәзе, тәрәзәләренең көймәле бизәлеше Идел буе һәм Урта Азия калаларындагы таш мәчетләрне хәтерләтә.* Мирас

2) Көймәсе булган. *Көймәле арбага утырып карау теләге, чынлап та, бик көчле булгандыр без малай-шалайларның.* Казан утлары

**КӨЙМӘЧЕ** *и.* Кешеләрне көймә белән елга, күл аша чыгарып кәсеп итүче. *Шуңа күрә дә келәй, ямаулыклар көймәчеләрнең һәрчак кул астында.* Р.Фәйзуллин. *Бераздан бернинди явызлык көтмәгән Санька янына өрлектәй өч көймәче килеп керде.* Ф.Латыйфи. *Көймәче һаман да шул иске кеше икән, безне таныды.* Г.Рәхим

**КӨЙРӘК** *с. сөйл.* Авырлыкларга тиз бирешә торган; борчылучан, тынгысыз. *Көйрәк үзен бетерер, сабыр эшен бетерер.* Мәкаль. --- *Гөлбикә апа, Мөэзкирнең каты кара чәчләреннән сыйпый-сыйпый, һаман иркәләде: – Көйрәк шул син, улым!.. Үземә охшагансың...* А.Гыйләҗев. *Гүзәл көздә калыр көйрәк җаным, Октябрем – бакый юлдашым.* Л.Шәех

**КӨЙРӘКЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Янып чыгу. *Лампа филтәсе көйрәкләнү*

2) *күч.* Борчылу, хафалану, артык кайгыру. *[Мансур:] Артык көйрәкләнүем өчен, үземә дә оят булып китте.* Казан утлары

**Көйрәкләнә бару** Тагын да ныграк көйрәкләнү

**Көйрәкләнеп бетү** Тәмам көйрәкләнү

**КӨЙРӘТТЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **көйрәтү** (*2 мәгъ.*). *[Илдус:] Көйрәттерегез әле, дим [папиросны].* Д.Аппакова

**КӨЙРӘТҮ** *ф.* 1) Мичтә, учакта һ.б. ут яндырып җибәрү. *Баласын да тирбәтә, Мичләрен дә көйрәтә, Укый торган кызының Дәресен дә өйрәтә.* Г.Афзал

2) Утлы күмердән, янып торган тәмәкедән, папиростан ут алып яисә шырпы белән кабызу. *Ул төннәр буе утырып сөйләргә ярата. Сабир абзый мичтән күмер алып тәмәкесен көйрәтә.* М.Мәһдиев

3) Тарту. *Кода бабай киткәч, Нигъмәтулла абзыкай ---, җиргә чүгәләп, учына яшереп кенә тәмәке көйрәтергә тотынды.* Ә.Еники. *Өйдә тәмәке көйрәтү гадәте булмаса да, Надыйр, капшанып, шырпы, сигарет эзләп азаплана...* Р.Мулланурова

4) *күч.* Пар, бу, төтен чыгару. *Кардан ачылып өлгергән җир, тирән-тирән итеп сулагандай, ак пар көйрәтә башлый, ә язгы уйнак җил җирнең бу дымлы сулышын авыллар өстенә алып китә...* Ә.Еники

5) *күч.* Хис тудыру. *Кыскасы, ничек тә әлеге чаткыны йөрәгемдә кабындырып, көйрәтеп җибәрергә тырышам...* Ә.Еники. *Көйрәтсәң дә сөю очкыннарын Йөрәгемдә әле кайвакыт ---.* Р.Рахмани

**Көйрәтә башлау** Көйрәтергә тотыну. *Бу юлы лампаның филтәсен басып куйдык та бер-бер артлы тәмәке көйрәтә башладык.* Р.Вәлиев. *Алар авыз-борыннарын каплаган ак битлекләрен салып аттылар, урман читенә чүгәләп, тәмәке көйрәтә башладылар.* Ф.Бәйрәмова

**Көйрәтә бирү** Бернигә дә карамый көйрәтү; көйрәтүне дәвам итү

**Көйрәтеп алу** Тиз арада көйрәтү. *– Безнең урыста эшнең башы итеп махра көйрәтеп алу гадәте бар, – диде ул [Степан Семёныч] көлемсерәп.* Б.Камалов

**Көйрәтеп җибәрү** *к.* **көйрәтә башлау**. *Көйрәтеп җибәргәч, Әхмәди, яңадан Шәмси янына тезләнеп, тагын тыңларга тотынды.* Г.Бәширов. *Кайчандыр авыл кызлары арасында усаллыгы, җитезлеге һәм чаялыгы белән Ирдәүкә кушаматы алган Гөлфирә, куркуыннан тынычлана алмыйча, --- сигаретына ут көйрәтеп җибәрде ---.* Г.Кашапов

**Көйрәтеп тору** Көйрәтү эшен башкару

**КӨЙРӘ́Ү** *ф.* 1) Пыскып утырган җиреннән яңадан яна башлау; утлы күмергә әйләнеп яну. *Кич җиткәндә генә кояш чыкты – Нурлары сынган, үзе көлдә көйрәгән күмер сыман.* Р.Харис. *Кызарып көйрәгән күмергә өреп, чыра башына ут кабызды.* Г.Галиев. *Уйсулыкта җем-җем учак көйри, Көтү ята урман буенда.* Г.Афзал

2) Һавага таралу, агылу, бүленеп чыгу (яктылык, пар һ.б.ш.). *Абзар кыегының нәкъ сырты өстеннән генә пар сыман яктылык көйри, ә кыек читендәге саламнардан тамчылар, ычкынып киткән берсе чаткы шикелле кабынып, җиргә тамалар.* Ә.Еники

3) Кызудан, эсселектән кибеп кору (үсемлекләр һ.б.). *Тәннәрендә кургаш саклый алар. Ул агачлар утта көйрәгән.* Р.Вәлиев. *Үләннәр көйри далада ---.* Н.Нотфуллина. *Көйрәгән чәчәкләргә, үләннәргә карап таң калды Вәсилә.* Казан утлары

4) *куч. сөйл.* Сусау; бик нык эчәсе килү. *Ул [Бәгърем] үңәчләренә кадәр көйрәп сусаган иде.* А.Хәлим

5) *күч.* Сызлану, әрнү. *Эчтән янды [Мәдинә], эч-бавыры көйрәп, кара сөрем булды.* Г.Якупова. *Рәхмәт сезгә, сугыш ялкынында Көйрәп үскән газиз балалар.* Р.Вәлиева. *Намусы саф, әмма йөрәкне әллә ни тырный, күңел түрендә әллә ни көйри.* М.Хәбибуллин

6) *күч.* Нинди дә булса хис белән яну. *Разияның күңелендә әллә кайда яшеренеп, көйрәп яткан чаткы кабынып китә ---.* Г.Ибраһимов. *Ялкыны да, төтене дә юк иде әле ул көнләүнең, иллә Туйбикәнең җиткән углын күргәч, өстәвенә кызы һаман аның янына ашкынгач, күңел күгендәге пыскып торган көнләү галәмәте әкрен генә көйрәргә тотынды.* М.Хәбибуллин. *Мәхәббәт утларында «көйрәп» яшисез.* Сөембикә

**Көйрәп бетү** Тәмам көйрәү. *Тәмәке көйрәп бетә дигәндә, телефон янә шылтырады.* М.Галиев

**Көйрәп тору** Озак вакыт дәвамында көйрәү; сөйләү моментында көйрәү. *Бераздан [өй] тоташ күмергә әйләнде. Кып-кызыл булып, байтак вакыт көйрәп торды.* А.Расих. *Аң белән аңлаган да кебек буласың, ләкин күңел үзенекен итә: сүнми дә, сүрелми дә, пыскып кына йөрәк маен сызып, көйрәп тора.* Х.Камалов

**Көйрәп утыру** *сөйл. к.* **көйрәп тору**. *Инеш буендагы талларга хәтле яфракларын коеп, сусызлыктан көйрәп утыралар.* К.Нәҗми

**Көйрәп яту** *сөйл.* Акрын гына көйрәү, озак көйрәү. *Көйрәп яткан утка бензин сибеп Дөрләткәндәй булды бу караш.* М.Җәлил. *Чабатаның башы көйрәп ята, «Ут төрткәннәр, мәйтәм, мин янам!»* Ш.Маннур. *Утлы күмер өстендә көйрәп яткан хатның зәңгәр ялкынына текәлеп, Нәфисә озак уйланды.* Г.Бәширов

**Көйри башлау** Көйрәргә тотыну. *Шулардан, ахрысы, егетнең күзләрендә яшәү нуры көйри башлаган кебек иде.* Х.Камалов

**Көйри бирү** Көйрәве дәвам итү

**Көйри төшү** Бераз көйрәү

**КӨЙСЕЗ** I *с.* **1.** 1) Аһәңсез, моңсыз, начар көйле. *Көйсез җырчылар һәм көйсез җырлар белән тулган эстрадада моң төшенчәсенә урын бетеп бара ---.* Ватаным Татарстан

2) Җырлау сәләте булмаган. *Көйсез җырчы*

3) *иск.* Көйгә, музыкага салынмаган. *Кич белән кайчак укыйлар, тыңлыйсың төрле китап. Кайсысы көйсез була һәм кайсысы көйле китап.* Г.Тукай

**2.** *рәв. мәгъ.* Күңелгә ятышсыз; көйсез итеп. *Һәркемдә язуга һәвәс артып китте, кайсы көйләп, кайсы көйсез генә язарга тотындылар.* Г.Камал

**КӨЙСЕЗ** II *с.* **1.** 1) *сөйл.* Канәгатьләнерлек булмаган, мәшәкатьле. *[Эшнең] монысы көйсез һәм мәшәкатьле, шунлыктан Устьеда гомерен акча төшереп уздыручылар аңа якын да килми, төшемлерәген эзли.* Э.Касыймов. *Үзең дә беләсең, хәлебез бик көйсез, Нәфисә, бик, бик!* Г.Бәширов

2) Ипсез, җайсыз, уңайсыз. *Сабанның көйсез булуы --- эшне чиксез авырлатты.* М.Гафури. *Анда, ишегалдының урта бер җирендәге эскәмияләрдә, гадәттәгечә, яшь-кыркын тупланган, кулларында көйсез гитара зеңгелди.* Г.Кашапов

3) *сөйл.* Тәртибе булмаган, тәртипкә салынмаган; җайланмаган. *Өнсез чагы әле чатырымның, Көйсез мәле әле көемнең.* Г.Морат. *Безнең тормыш-көнкүреш бик көйсез иде әле ул вакытларда.* Идел

4) *күч.* Начар холыклы, үҗәт; капризлы, көйләгәнне ярата торган. *Көйсез кияү кебек көйсезләнеп, ул [Мотаһар] яңадан басмакка басты.* А.Хәлим. *Әллә ничек менә, шул кечкенә ияк аның җитди йөзенә көйсез, үпкәләүчән бала чырае биреп тора кебек.* Ә.Еники. *Көйсез кешеләр көе бу.* Р.Вәлиев. *Ә без, хатын-кызлар, үзегез беләсез, көйсез халык, һәркайсыбызга аерым игътибар кирәк.* Сөембикә

5) Күңелгә ятышсыз, тупас, мәгънәсез, бәйләнешсез. --- *Китапларда ипсез, көйсез, моңсыз сүзләр ташкыны агыла ---.* М.Вәлиев

6) Билгеле бер вакытта яисә ниндидер сәбәпләр аркасында кешеләр өчен күпмедер кимчелекле, мәшәкатьле булып күренгән (тоелган, кабул ителгән). *Ә балык дигәнең үзенә күрә генә түгел, бик көйсез мәхлук: чиртми генә.* М.Әмир. *Авыруның төрлесе бар: карты, ямьсезе, көйсезе...* М.Маликова. *Бер эретә, бер катыра... Көйсез апрель айлары.* Р.Рахмани

**2.** *рәв. мәгъ.* Күңелсез кыяфәттә, кәефсез рәвештә. --- *[Рабига:] Нәрсә булды, тагын төне буе йокламадың мәллә, бигрәк көйсез күренәсең ---?* Казан утлары

◊ **Көйсез кодагый** Үзен көйләгәнне, кадерләгәнне, бар теләкләрен дә үтәп торганны ярата торган кешегә карата әйтелә. *Көйсез кодагый булма әле, хатын.* Р.Вәлиев. **Көйсез кияү** *к.* **көйсез кодагый**

**КӨЙСЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн.* 1) *к.* **көйсезләнү**

2) Ярсыту, ачуны китерү, кәефне төшерү. *Бу нәрсәләр Хәятның башын соң дәрәҗәдә авырттырдылар һәм нервларын тиз төзәлмәслек итеп көйсезләндерделәр.* Ф.Әмирхан

**Көйсезләндереп алу** Тиз арада һәм бераз гына көйсезләндерү

**Көйсезләндереп бетерү** Тәмам көйсезләндерү; бик нык көйсезләндерү

**Көйсезләндереп тору** Һәрдаим, еш көйсезләндерү

**КӨЙСЕЗЛӘНҮ** I *ф.* Көе китү, аһәңлелеге бозылу (музыкаль инструментлар тур.)

**КӨЙСЕЗЛӘНҮ** II *ф.* 1) Җае китү, бозылу (эш, хәл һ.б.). *Табигатьнең көйсезләнүенә иләшеп беттек инде.* Ватаным Татарстан

2) Бозылу, ватылу (техника, механизмнар һ.б. тур.). *Комбайн көйсезләнмәсә, бер атна эчендә эшне бетерәбез без, егетләр.* Казан утлары

3) Үз вазифаларын, эшчәнлеген тиешле дәрәҗәдә, гадәттәге кебек башкара алмау. *Нишли, ничегрәк «тота» ул [йөрәк] үзен – тәндәге тере җан? Көйсезләнмиме, ялгышмыймы, хәрәкәт итүе ничегрәк?* Ә.Еники

4) Нигезсез теләк белдерү яисә сәбәпле-сәбәпсез бик күп һәм еш елау; тәртипсез булу (балалар тур.). *Машкага көйсезләнергә һәм нянясы белән сугышырга киңәш итмим: тукмап ташлавым бар үзен.* Я.Винецкий

5) Борчылу, нервлану, холыксызлану. *Нидер яшерәләр, ахры, болар [егетләр], көйсезләнә башладылар.* Казан утлары

6) *күч.* Холыксызлану, кәефсез булу, капризлану. *Ул [Чибәркәева] инде килгән көннәрдәге кебек минут саен көйсезләнми, шик-шөбһәләрен бөтен палатага кычкырып әйтми, елаулары да кими төште.* Г.Әпсәләмов. *Шуның өстенә, Рәмзия аңардан [Гасыйм Сәләховичтан] унбер яшькә кечерәк, табигый инде, ул көйсезләнергә ярата ---.* Ә.Еники. *Шуннан бирле малаема әллә ни булды. Үземә каршы әйтә. Киреләнә, көйсезләнә.* Ф.Яруллин

**Көйсезләнә бару** Торган саен ныграк көйсезләнү; тагын да берникадәр көйсезләнү

**Көйсезләнә башлау** Көйсезләнергә керешү. *Ләкин озак та үтми, Нәҗия «көйсезләнә» башлый.* Ә.Еники

**Көйсезләнә төшү** Беркадәр көйсезләнү

**Көйсезләнеп бетү** Бөтенләй көйсезләнү

**Көйсезләнеп калу** Нindидер сәбәптән көйсезләнү

**Көйсезләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә көйсезләнү

**Көйсезләнеп куя** Вакыт-вакыт, сирәк кенә көйсезләнү. *Тик Нәсимә түти белән Миңсылу гына бераз көйсезләнеп куялар.* Ш.Камал

**Көйсезләнеп тору** Озак вакыт дәвамында көйсезләнгән хәлдә булу. *Нәүмизә мунчага Алып Бәргән белән бармыйм дип көйсезләнеп торган булган иде дә, хуҗа хатын бик чая нәмәстәкәй булып чыкты...* Р.Батулла. *Эш шунда: өч яшь ярымлык кызыбыз соңгы араларда көйсезләнеп тора.* Г.Нурлы

**КӨЙСЕЗЛӘНҮЧӘН** *с.* 1) Еш, һәрвакыт көйсезләнә торган. *Көйсезләнүчән бала*

2) Кәефсезләнү, сәбәпсез елау, кычкыру һ.б.

**КӨЙСЕЗЛӘ́Ү** I *ф.* Көен I җибәрү, бозу

**Көйсезләп бетерү** Тәмам көйсезләү

**КӨЙСЕЗЛӘ́Ү** II *ф.* 1) Җаен җибәрү, бозу (эшнең, механизмнарның)

2) Борчу, комачаулау. *Әмма Заһир авылда калганнарының тормышларын шактый көйсезләде.* С.Зыялы. *[Самат:] Көйсезләп йөрим инде мин сине, Гадилә апа ---.* Казан утлары

**КӨЙСЕЗЛЕК** I *и.* 1) Көйсез I (*1 мәгъ.*) булу; көе начар булу (җырның, музыканың)

2) Көе киткән булу, көйләнмәгәнлек (музыкаль инструментлар тур.)

**КӨЙСЕЗЛЕК** II *и.* 1) Җайланмаган булу, көйсез II (*2 мәгъ.*) булу. *Йорттан йортка күчеп йөрү мәшәкатьләре, көйсезлекләр тәмам ардырды Тәнзиләне ---.* Казан утлары

2) Авырлык, борчу, өстәмә мәшәкать. *Беренче көйсезлек таныклыкта иде: анда «Маркс исемендәге әртил әгъзасы Тугашев Тәбрик Фәрхетдинович» дип язганнар иде.* Ә.Баян. *Ул [Кәүсәрия] тормыштагы төрле көйсезлекләрне җиңел үткәрә ---.* М.Маликова

3) *күч.* Үҗәтлек, үзсүзлелек, кирелек. *Бу аның тарафыннан гади бер көйсезлек кенә түгел иде.* Ш.Камал. *Ул баштарак моңа әллә ни игътибар да итмәде, кызларда була торган бер көйсезлек кенәдер дип уйлады.* Н.Фәттах

**КӨЙЧЕ** *и. сөйл.* Көй иҗат итүче; композитор. *Аның [Мотаһарның] бары тик үз күңелендәге сагышны, үз йөзендәге җимереклекне, җанындагы моңга сусауны галибанә сурәтләрлек, аңлатырлык, моңга-сынга, көйгә-җыруга салырлык бирәр әдип, бирәр көйче, бирәр сынчы бар микән бүгенге Казанда?* А.Хәлим. *Махсус җыр текстлары язмасам да, җырчы, көйче дусларым мөрәҗәгать иткәндә, очрактан файдаланып калырга тырышам.* Мәдәни җомга

**КӨЙШӘНҮ** *ф. диал.* Кыймылдау, бик әкрен хәрәкәтләнү яисә хәрәкәтсез диярлек булу. *Заһир карт идәндә һаман шул кыяфәтсез рәвештә көйшәнеп яткан Фәтхигә күз ташлап ала: «Әстәгъфирулла тәүбә!»* Т.Мөбарәков

**КӨЙШӘҮ** *ф. диал. к.* **күшәү**. *Аксыл-соргылт төстәге озын торыклы сыерлар анда хәтта хөкүмәт учреждениеләре районындагы скверларда көйшәп йөриләр.* М.Мәһдиев. *Өстәлемдә мөгезле кара мәче көйшәп утыра.* Р.Гаффар

**Көйшәп тору** Озак вакыт дәвамында көйшәү. *Бер кырыйдарак киртәгә бәйләгән зур гына алпавыт аты печән көйшәп тора, тагын да читтәрәк икеөч баш кара сарык күренә.* Г.Бәширов. *Ул [бозау] әле көйшәп торган әнисе янына килеп, арт сикертеп китеп бара, әле юкә артына чыгып ямьсез бер әйләнә ясый да кычкырмакчы була ---.* М.Мәһдиев

**КӨЛ** *и.* 1) Нәрсә дә булса янганнан соң барлыкка килгән аксыл соры төстәге тузансыман минераль калдык. *Хәзрәт кулына сигара көле сала торган бер тарелка тотып кергән иде.* Ф.Әмирхан. *Мәдрәсә мичендә кыштан калган шактый көл өелеп ята икән, мәнә шул көлне иләктән үткәреп, бер кечерәк капчыкка тутырган да күрше авыл базарына күтәреп киткән шәкерт.* Ә.Еники. *Учактагы көлләр тузгып куйды.* Г.Мөхәммәтшин

2) Утын һ.б янып беткәндә хасил була торган кайнар тузансыман калдык; утлы күмер. *Көлгә күмгән бәрәңгеләренең көйгән исе чыга башлагач, кисәү алып, алгарак күчерде.* Г.Гобәй. *[Көткәнбез] бәрәңгенең учак көлләрендә Күмер төсле булып янганын.* Р.Рахман. *Баягыча тагын ут ягып, көлгә бәрәңге күмәбез.* Г.Гобәй

3) Төсне белдереп килгәндә: аксыл соры, соргылт. *Тынлыкны өстәлнең каршы ягында утыручы, какча йөзле, маңгайга таба өчпочмакланып төшкән көл төсендәге чәчле агай бүлде.* Р.Вәлиев. *Иске клуб янышнан узганда, бер яктан кара джиплар, икенче яктан көл төсендәге «БМВ»лар килеп туктады.* И.Сәйфуллин. *Һәм аның [Зариф абзыйның] ябыгудан көл төсле булып яңак сөякләренә ябышкан битләре нурланып, хәтта сулышлары киңәеп китте.* З.Фәйзи

◊ **Көл булу** Юкка чыгу, бетү; үлү, һәлак булу. *Гөлбакчалар түзмәс, көл булыр.* Н.Исәнбәт. *Ачыктан-ачык сугышсак, син көл булачаксың.* Р.Батулла. *Бер минутта шартлый туплар, Яшь гомерләр көл була.* Ә.Ерикәй. **Көл булып күккә очу** *к.* **көле күккә очу**. *Низам бай йорты-җире белән көл булып күккә очар – анда да Сәрби Галимҗанга булмас.* Ф.Бурнаш. *Хөтбәләр, хәдисләр, тагын әллә нәрсәләр көл булып күккә очкан шикелле булдылар.* А.Шамов. **Көлгә әверелү** Тулысынча янып бетү. *Мәһабәт мәчетләр, кәрвансарайлар, төрбәләр янып көлгә әвереләләр, җимереләләр.* Р.Батулла. **Көлгә әйләндерү** *к.* **көл итү**. *Председатель чалгы сабын икегә-өчкә сындырып күлгә тондырды, иелеп тырманы алды, аны көлгә әйләндерде.* А.Гыйләҗев. **Көлгә әйләнү** 1) Тәмам янып бетү; 2) Зур кайгы, борчу, авыр хисләр тәэсирендә сәламәтлек какшау, яисә рухи яктан изелү, бирешү. *Йөрәкләре көлгә әйләнер иде аларның.* А.Шамов. **Көлгә калу** *к.* **көлгә әйләнү**. *Мәдинә дә янып көлгә калды ул янгында.* Г.Якупова. **Көлгә очу** Юкка чыгып әрәм булу. *Бар тырышлыкларым көлгә очты.* Ялкын. **Көлдә аунау** Ярлы булып, фәкыйрьлектә яшәү; кеше ярдәменнән башка, үз көннәрен үзләре күрү. *[Байтирәк:] Барыгыз, көлдә аунап көнегезне күрегез.* Т.Гыйззәт. **Көлдән төймә төю** Бар эшкә дә оста булу. *Болай булса, үсә төшкәч, көлдән төймә дә төяр [улым].* З.Бәшири. **Көле күккә очу** Юкка чыгу, бетү; җимерелү. *Көлләре күккә очкан күпме штрафник-сугышчы хәбәрсез югалды дип игълан ителде.* К.Латыйп. *Фашистларның көле күккә очты Үти алмый явыз теләген.* Ш.Маннур. **Көлен күккә очыру** 1) Яндыру. *Йортыңның көлен күккә очырган имансызны нишләп гафу иттең син?* Н.Гыйматдинова; 2) Юк итү. *Порт-Артурны көлен күккә очырып, бөтенләй ваттырып, харап итеп бетергәннәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Бир син миңа үземнең торпедный аппаратымны, бир син миңа автомат, граната, күрсәт син миңа цельне – мин аның көлен күккә очырам.* М.Мәһдиев; 3) Бик нык сүгү, тәнкыйтьләү. **Көл итеп күккә очыру** *к.* **көлен күккә очыру**. *Җир йөзен каплап, ташып килгән Наполеон яуларын Бер өрүдә көл итеп күккә очырган дөнья бу!* Ә.Исхак. **Көл итү** Юк итү, юкка чыгару, бетерү. *Әйдәгез, явызлар оясын Көл итеп күтәрик һавага.* М.Җәлил. *Хур итәргә тели сөйгәнеңне, Көл итәргә тели йортыңны.* Ш.Маннур. *Алар Чулман илен көл итте.* Р.Батулла. **Көл йоттыру** Кемне дә булса алдау; алдап начар әйбер сату, бирү. **Көл кебек агару** Куркудан, борчылудан яисә авыру сәбәпле йөзнең, тәннең ап-ак булып агарып китүе. *Чырае көл кебек агарган Ләксәндернең берме-икеме кабыргасы сынган, егетләрнең битләре сыдырылган, кулы-аягы каймыккан, әмма --- үләр дәрәҗәгә җитеп яраланган кеше юк иде.* Г.Ахунов. **Көл кебек булу** *к.* **көл кебек агару**. --- *егетнең төсе көл кебек булган, иреннәре күгәргән.* А.Таһиров. **Көл киселү** *к.* **көл кебек булу**

**КӨЛӘЧ** *с.* **1.** 1) Елмаюлы, ягымлы, шатлыклы (йөз, күз һ.б. тур.). --- *Табигате белән көләч, якты йөзле, татлы сүзле, бер күрүдә кешеләрнең күңел түрендә урын ала торган кеше.* Г.Ахунов. *Ишектән көләч йөзле чибәр бала килеп керүгә, бүлмә эче яктырып киткәндәй булды.* Г.Нурлы. *Әбиеңнең изге күңелле кеше икәнлеген көләч йөзләре үк әйтеп тора бит!* Казан утлары

2) Ачык йөзле, мөлаем, шатлыклы кыяфәтле (кеше тур.). *Бәхете һәм шатлыгы ташып торган көләч егетнең сурәтенә текәлгән килеш, бер мизгелгә тын калдык.* Э.Касыймов. *Кияү тиешле абый түгәрәк ак битле, зур соры күзле, көләч, сөйкемле генә бер егет иде.* Ә.Еники

3) *күч.* Бик матур булып күренгән, үзенә тартып торган, күңелгә рәхәтлек биргән әйберләргә карата әйтелә. --- *Хәтердә калганнар буенча мине иң нык гаҗәпләндергәне кояш иде. Ул җылы, көләч, якты, серле!* Р.Низамиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Шатланып; матур итеп. *Күрәсең, бу апа да каршысында көләч елмаеп, баш иеп торган картның кемлеген һәм каян килгәнлеген аермачык белгәндер.* Э.Касыймов. *Берсеннән-берсе матурлар, кояшка көләч елмаешалар, куанычларымны арттыралар [җир җиләкләре].* Н.Хәсәнов

**КӨЛӘЧЛӘНҮ** *ф.* 1) Ягымлылану, йөздә елмаю, мөлаемлык барлыкка килү. *Ул көнне Тимерханның язгы җилдә ярылып кубалакланган, күптәннән елмаю белмәгән бите көләчләнеп яктырган иде.* М.Мәһдиев. *Ире дә күзгә күренеп үзгәрде: иң элек аның йөзе көләчләнде, шуннан бу аның күзләренә күчте, иреннәре ярым ачылып, тешләре елтырый башлады.* Ф.Бүләков

2) Матураю. *Күрәсез, соңгы елларда Казан-башкаланың йөзе матурайган кебек, китапларыбызның да тышкы кыяфәте көләчләнде.* М.Вәлиев

**Көләчләнеп китү** Көләч була башлау; тагын да бераз көләчләнү. *Васильев көлемсерәгәндәй итте, йөзе көләчләнеп киткәндәй булды.* А.Вергазов

**КӨЛӘЧЛЕК** *и.* 1) Ягымлылык, мөлаемлык; көләч, ачык йөзле булу. *Шагыйрәнең назлы тавышы бер дә үзгәрмәгән, һәр сүзеннән көләчлек бөркелә иде.* М.Маликова. *Егетнең чыраенда көләчлек сызыклары бетеп торды, җитдиләнеп китте, мин шаярып әйтмим дигән кебек иде ул.* Х.Камалов. *Рухын изгәннәр, ихтыярын шактый сындырганнар егетнең. Йөзеннән көләчлек качкан.* Т.Галиуллин

2) Позитивлык, оптимистлык; яктылык. *Бөтен кыяфәтенә, иҗатына көләчлек, шаянлык чыккан шагыйрьләр дә, мин генә калмыйм дигәндәй, кирәгеннән артык моңлана башлады.* Л.Лерон. --- *автор тагын да бер максатны күздә тоткан, билгеле. Ул да булса, әсәрдәге юмор көчен, көләчлек хөрлеген*

*арттыру.* А.Әхмәдуллин. *Бу кайгыдан соң ул үзен каты чирдән терелгән кебек сизде, йөзе сулып калды, күзләрендәге көләчлек сүнде.* Р.Хәбибуллина

**КӨЛДЕРДӘ́Ү** *ф. диал. к.* **келтерәү**. *--- Чиләк эченә тутырылган вак-төяк уенчыклар юл буе көлдердәделәр.* Идел

**КӨЛДЕРГЕЧ** *с.* **1.** Көлдерә торган, көлкеле. *Марсельнең юморы теләсә кем чыгарып, теләсә кем сәхнәдән чәчә торган очсызлы көлдергеч түгеллеген дә аңлыйм.* Т.Миңнуллин. *Моны күреп торган Фәгыйлә, Тукайның дүрт кенә юллык көлдергеч шигырен хәтерләп, авыз эченнән кабатлый ---.* С.Сабиров. *Мисаллар арасында көлдергеч шигырьләрнең булуы тыңлаучыларның хушына килде.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Мәзәк. *Юл буе көлдергечләр сөйләп эчне катырып бетерде Әхмәтсафа.* Казан утлары

**КӨЛДЕРГЕЧЛЕК** *и. иск.* Көлдергеч булу; комиклык. *[Шигырьдә] уйландырырлык тирәнлек тә юк, көлдергечлек ягы да цирк клоуннарыныкына караганда бик түбән, бик тупас һәм чәйнәлгән әйберләрдән гыйбарәт иде.* Ш.Камал

**КӨЛДЕРҮ** *ф.* Көлү китереп чыгару. *Су буенда яланөс йөреп, бөтен халыкны көлдергән, имеш, кебек нәрсәләрне ишеттерәләр.* М.Гафури. *Аннары хыялы йөгерек бирәү, мәчет үзе җыламый, ә мәчетне япкан чакта чыга алмый калган карт мәзин җылап утыра, дип тә безне көлдерә.* Ә.Еники. *Хөсәенов та сүзен көлдерү өчен әйтмәде, җаны ачытып әйтте.* Г.Ахунов

**Көлдерә башлау** Көлдерергә тотыну

**Көлдереп алу** Бераз гына көлдерү. *Мин туктагач, Фәрит мәзәк сөйләп көлдереп алды.* Р.Вәлиев. *Тормыш дәвам итәр янып-балкып, Я көлдереп алыр, елатып...* Г.Сәгыйров

**Көлдереп бетерү** Бик нык көлдерү. *Аш янында доктор, үзенең яшь врач чагында практикада йөргән вакытларын сөйләп, яшьләрне көлдереп бетерде.* И.Гази. *[Миңнехан абый] Кечтек кенә сүзләрне дә кызыкка әйләндереп, эчеңне катырганчы көлдереп бетерә иде.* Г.Сәгыйров

**Көлдереп тору** Даими көлдерү

**КӨЛЕМСӘ** *с.* **1.** *диал. к.* **көлемсәр**. *--- кызмача кунаклар аның талчыбыктай сыгылмалы зифа буена, кызарып пешкән чия төсле тулы канлы көлемсә иреннәренә комсыз күзләре белән йотардай булып карап утыралар.* С.Сабиров. *Көлемсә тавышлы әлеге кыз абыйсыннан нидер сорады да йөгереп тә китте.* Ялкын

**2.** *рәв. мәгъ.* Көлеп карап, елмаеп. *[Лиза] Миңа сез дип түгел, син дип эндәшә, көлемсә карап сөйләшә торган булып китте.* С.Сабиров

**КӨЛЕМСӘР** *с.* Елмаюлы; шатлык-куанычны чагылдырган. *Әйе, Сибгат ага, үзе әйтмешли, көлемсәр иде, шул сөйкемле елмаюы белән һаман күз алдында тора.* Л.Шагыйрьҗан. *Табигатьнең кодрәте белән адәм баласының якты хисләре, көлемсәр холкы, уңганлыгы, кулының осталыгы бергә үрелгәч, нинди гүзәллек хасил булган!* М.Маликова. *Нинди генә көлемсәр холыклы кеше булмасын, әгәр шыр тиле түгел икән, ул тик торганда бер сәбәпсез көлеп җибәрмәс.* И.Низамов

**КӨЛЕМСӘРЛЕК** *и.* Көлемсәр булу, елмаючанлык, көләчлек. *Тавышларың, көлемсәрлегең, зәңгәрсу күзләрең, аксыл ефәк чәчләрең шулчаклы таныш.* Ә.Баян

**КӨЛЕМСЕРӘ́Ү** I *ф.* 1) Бераз елмаю; җиңел генә елмаю. *– Быел Фәнияне дә үзебез белән алып барабыз, – диде егетләрнең икенчесе, табынчы кызга җылы көлемсерәп.* Ә.Еники. *Хәйран калдык: каршыбызда иягенә таянып һәм чак кына көлемсерәп, җанлы полиглот үзе утыра икән ләбаса!..* Э.Касыймов

2) Берәр кешенең елмайган сыман итеп, нәрсәгә дә булса яисә кемгә дә булса тойгы, хис, карашын белдерүе. *Әмма күршесе текәлебрәк караса, мөгаен, бу көлемсерәүнең теш сызлаганда чырай сытуга охшавын чамалар иде.* Б.Камалов. *Сөләйманов көлемсерәп, баш чайкап тора.* Г.Ахунов. *Боларны күз алдыннан кичергәч, Сәлим кешеләрнең шулкадәр дә ышанучан булуына көлемсерәү катыш уфтанып куйды.* Ф.Латыйпов

**Көлемсерәп алу** Аз гына һәм тиз генә көлемсерәү

**Көлемсерәп кую** Аз гына яисә бер тапкыр көлемсерәү. *Җиңгәчәсе ирексездән көлемсерәп куйды.* Ә.Еники. *Корбан көлемсерәп куйды.* Б.Камалов. *Мансур Хуҗиевич, шуны да аңламыйсыңмыни дигән кебек, борынын мышкылдатып, көлемсерәп куйды.* М.Маликова

**Көлемсерәп тору** Озак вакыт көлемсерәү. *Шәүрә, егетнең шулай кинәт кенә кабынып китеп дөрләп яна торган гадәте барын абайлап, көлемсерәп тора иде.* Г.Бәширов. *Оланнар бу хәлне, чынлап та, уен гына итеп кабул иттеләр бугай, хәтта көлемсерәбрәк торалар иде.* М.Хәбибуллин

**Көлемсери бирү** Көлемсерәүне дәвам итү. *– Рәсем училищесынамыни?.. – диде, ниһаять, профессор, үзе көлемсери биреп минем бер рәсемгә карап тора башлады.* Гөлшәһидә

**Көлемсери төшү** Тагы да ныграк көлемсерәү. *Гарәфи абзый, көлемсери төшеп, башын чайкады. – Җавапны син таба беләсең, Газинур.* Г.Әпсәләмов. *– Хәтәр җиңел үтте көн, – диде Зәмзәмия, көлемсери төшеп.* Ә.Моталлапов

**КӨЛЕМСЕРӘ́Ү** II *и.* Йөзнең елмайган хәле, елмаю мимикасы. *Харис моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, тик аның уйчан ак чыраенда ниндидер сызлану аша боек көлемсерәү чагылып киткәндәй булды.* Ә.Еники. *– Ун-унбиш минуттан таман гына буласы, – диде кара кашлы кеше. Аның йөзенә татлы көлемсерәү җәелде.* Ф.Шәфигуллин. *Һәм егетнең бу сүзләрендә җиңелчә көлемсерәү сизелде.* М.Маликова

**КӨЛЕНЕЧ** *с.* **1.** *диал.* Көлкеле. *Бичара Мостафа исә туп-туры үзенең учына салып, йөзенә сөрткәнлеге җәһәтле, кыяфәте гаять көленеч бер хәлдә иде.* Ф.Кәрими. *Бер басуга карыйм, бер – үземә, --- Ачы көленеч хәлем күренә.* Ш.Маннур. *Бигрәк көленеч әйберләр сөйли әбиең, кайдан барысы да исеңдә калган диген?!* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Көлке булып; кызык булып. *Ул вакыттагы кыяфәтем укучылар өчен бик көленеч булып тоелгандыр инде...* Мәгърифәт

**КӨЛЕНЕЧЛЕ** *с. диал.* Көлкеле, көлдерә торган. *Чеховның көлкесе –*

*һәр күңелле кәефне белдергән фәкать көленечле нәрсәләрне генә күрсәтүдән гыйбарәт көлке.* Г.Нигъмәти

**КӨЛЕШ** *и.* 1) Күмәкләп яңгыратып көлү. *Бераздан ачулы, усал авазлар күңелле шау-шу, гомум көлеш белән алышынды.* Ф.Шәфигуллин. *Мәзәкләр оятсызрак булган саен, көлеш көчәя.* Ф.Яруллин. *Китте көлеш, чыр-чу килеп тәңкә җыю, һәм халык бу тамашага янә гөрләп кул чапты.* М.Хәбибуллин

2) Көлү рәвеше. *Ул көлеш, йөрешләре – Хәйран кыланмышлары [түрәләрнең].* Р.Рахмани. *Һич оныта алмыйм шул чибәркәйнең көлешләрен дип, шактый хыялланып йөрде әле Габделнур.* Идел

**КӨЛЕШҮ** *ф.* Күмәкләп көлү, бергәләшеп көлү. *Барыбыз да көлешүдән туктап, моннан соң саграк булу турында бер-беребезнең исенә төшерештек.* М.Әмир. *Ләйлә чыгып киткәч, Зөһрә белән Гайфулла бер-берсенә карашып көлешергә тотындылар.* Ф.Яруллин. *Кирәк түгел тәрҗемәче – Көлешәбез бер телдә без!* Р.Миңнуллин

**Көлешә башлау** Көлешергә тотыну. *Моны күреп, астагы ирләр шаркылдашып көлешә башладылар.* Ф.Бәйрәмова

**Көлешә бирү** Бернигә карамый көлешү

**Көлешеп алу** Кыска вакыт эчендә көлешү. *Барысы да, иптәшләренең хәтерен калдырмаска тырышкандай, аңа карап, тыелып кына көлешеп алдылар.* Ә.Еники. *Халык тагын көлешеп алды.* А.Хәлим

**Көлешеп кую** Берничә кешенең аратирә көлүе. *Егетләр, кызыйның телдәрлеген ошатып, көлешеп куйдылар.* Г.Бәширов. *Кемнәрдер мыдыр-мыдыр сөйләшә, ара-тирә көлешеп тә куялар, ләкин йокының кочагы шул кадәр татлы, уянасы, хәтерне-аңны кузгатасы килми.* А.Гыйләҗев

**Көлешеп тору** Әле, хәзер көлешү. *Дәррәү күтәрелеп көлешеп кенә торганда, Камил белән Ризван килеп чыкмасыннармы!* Г.Бәширов. *Тынгысыз уйның очы яңа күршеләргә, дөресрәге, аларның ишек төбендә күмәкләшеп көлешеп торган минутларына килеп тоташты.* М.Маликова

**КӨЛКЕ** *с.* **1.** 1) Көлдерә торган, сатирик, юмористик. *Сүз биредә шундый көлкерәк бер әкәмәт вакыйга турында барачак.* Ә.Еники. *Шуңа күрә аның [шамакайның] җитди әйткән сүзләре дә көлке булып ишетелә икән.* Р.Батулла

2) Мәзәк, сәер. *Кайчагында [Фәтхелислам] җитди күренергә тырышса да, сүзе-кыланышы барыбер көлке килеп чыга иде.* Ә.Еники. *Кала буйлап хатынын эзләп чапкан ирдән дә көлке һәм көчсез адәм дөньяда бар микән?* М.Маликова. *Монысы да – шулай ук, көлкерәк фамилия.* В.Шугаев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Көлдерә торган кызыклы күренеш, вакыйга, хәл. – *Ха! – диде егет, башын чөя биреп. – Көлке!.. Өйдә пенсионерлар да ял итми хәзер.* Ә.Еники. *Сыңар керфек какмаган төнге шәһәргә минем өзгәләнү-бәргәләнүләрем көлке югыйсә.* Н.Гыйматдинова. – *Көлмәгез! – диде ул, катгый тавыш белән. – Бу көлке түгел.* Р.Батулла

2) Көлү, көлешү. *Һәм бу хәлдән чыгар өчен, миңа да кычкырып көләргә – юри көлкегә әйләндерергә кирәк иде дә бит, тик минем – сантыйның – шуңа да тапкырлыгым җитмәде.* Ә.Еники. *Валерка – көндәлек тормышта юктан да көлке чыгарып эчеңне катыручы, әле егерме яшьлек кенә егет.* А.Хәсәнов

3) *иск. кит.* Кечкенә күләмле юмористик яки сатирик әсәр; комедия. *«Көлке – диде ул [Бабич], – кешене рәхәтләндерә, күңелне ача, эч пошуны баса, ---, ялыккан кешеләрне җиңеләйтеп җибәрә».* Г.Гыйльманов. *Икенче пьеса – «Хат болгатты!» исемендә бер пәрдәлек көлкедер.* Ф.Әмирхан. *«Яшен» исемле көлке журналының тарихы бик кызыклы аның ---.* Казан утлары

◊ **Көлкегә алу** Җитдигә санамау, кимсетү, көлү. *Әгәр алар минем эшчәнлегемне көлкегә алып, иҗат үҗәтлегемне киметергә-кимсетергә, торабара юкка чыгарырга теләсә, шул максат белән тәнкыйтьләгән булса, болар минем дуслар түгел.* Мәдәни җомга. **Көлкегә әйләндерү** *к.* **көлкегә бору** *Моның иң җайлы чарасы – белдекле булып күренергә тырышу, һәр яңалыкны көлкегә әйләндерү.* Б.Рафиков. **Көлкегә бору** Берәр сүз яисә эш, хәлне көлкегә әйләндерү. *Көлкегә бора да куя сүзне: «Мин укып йөргән арада я сугыш бетеп куяр ---», – ди [Фәрит].* З.Зәйнуллин. **Көлкегә калдыру** Көлү объектына әйләндерү, уңайсыз хәлдә калдыру. *Кайвакыт ярату аркасында башкарылган эшләр дә иясен я көлкегә калдыра, я көтелмәгән бер хәл китереп чыгара.* Р.Рахман. *Шулай да бервакыт калдырдык көлкегә.* Х.Халиков. **Көлкегә калу** Уңайсыз хәлдә калу, оятлы булу. *Чынлап җавап бирергә керешсәң, көлкегә калуың бар.* М.Әмир. *Ул [Идрис] үзенең көлкегә калу ихтималының бик зур икәнлеген аңлады.* А.Гыйләҗев. *Минем көлкегә калуым аңа [Һаҗәргә] ошагандыр ахрысы, ә, бәлки, әле эченнән генә «шәп иттеләр!» дип кинәнеп тә куйгандыр.* Ә.Еники. **Көлкегә күтәрү** *к.* **көлкегә калдыру**. **Көлке итү** Көлкегә әйләндерү; чынга алмау. *Көлке итеп пәйгамбәрләр сүзен, Бозыклыкка алар бирелгән...* Р.Рахмани. *«Тәрәкъкый» газите мәдрәсәләргә ислах турында юл күрсәтүдән бигрәк, алардагы җитешсезлекләрдән көлә, хәлфә һәм мөдәррисләрне көлке итеп күрсәтә иде.* Фатих Әмирхан турында истәлекләр. **Көлке капчыгы** 1) Бик күп кызыклар, мәзәкләр белүче һәм аларны сөйләргә яратучы кеше. --- *Чынлап та, көлке капчыгы бит синең ул дустың.* Ялкын; 2) Мәзәкләр тупланмасы. --- *Көрәкләрне алмашка килүчеләргә бирдек тә бераз хәл-әхвәл алырга дип чокыр кырыена тезелешеп утырган гына идек, менә шул Йосыф дигән егетебез, тешен ялтыратып, көлке капчыгының авызын чишеп тә җибәрде ---.* Р.Вәлиев

**КӨЛКЕЛЕ** *с.* Көлдерә торган, көлке уята торган. *Мин сиңа шундый да кызыклы, шундый да көлкеле китап-журналлар күрсәтер идем, аннары бергәләп уйнар да идек, ә!* Э.Касыймов. *Ә мондый чакта инде берәрсенең тел очыннан көлкеле, мәзәк сүз чыгуын көт тә тор.* Р.Вәлиев. *Хәер, без дә мәгънәсез һәм көлкеле уен уйныйбыз түгелме соң?!* Т.Миңнуллин

**КӨЛКЕЛЕЛЕК** *и.* 1) Көлкеле булу. *Төп мәгънәсендә кулланылып, әле бу, әле теге төркемгә караган сүзләрдән җыелган тиңдәш кисәкләр яки стилистик*

*җитешсезлекне күрсәтә, яки сөйләмгә көлкелелек бирү максатын күздә тота.* Х.Курбатов

2) Комиклык. *Бу пьесада көлкелелек тулып ята үзе ---.* Казан утлары

**КӨЛКЕНЕЧ** *с. сир. к.* **көлкеле**. *Ә без алдыбызда аерым клоун, көлкенеч, кәмит бер картны күрдек.* М.Җәлил

**КӨЛКЕНЕЧЛЕ** *с. к.* **көлкенеч**. *--- Исенә төшергән саен һәм кызганычлы, һәм көлкенечле тойгыларга бирелә иде [Фәтхи].* Ш.Камал

**КӨЛ-КҮМЕР** *и. җый.* Көл һәм күмер кебек калдыклар. *Хәзер чирәмне дә, аның бала чагы эзләрен дә көл-күмер, тузан-туфрак басып киткән.* А.Гыйләҗев. *Мич ягып, төтене-сөреме, көлекүмере белән иза чигәсе юк, пар казаны көйләрләр.* Б.Камалов. *Бу чокырда бик күп тимер-томыр, көл-күмер, ташкирпеч ватыклары табылды.* Ф.Хуҗин

**КӨЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса янып бетеп көлгә әверелүе. *Учак күмерләре аксылланып көлләнә башлады.* Г.Мөхәммәтшин

2) Көлгә буялу

**Көлләнә бару** Торган саен ныграк көлләнү

**Көлләнә башлау** Көлләнүгә табан бару

**Көлләнеп бетү** Бик нык көлләнү

**КӨЛЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса көлгә бутау, көл белән катнаштыру. *Әй, көлләү цехын көлләделәр дә соң!* А.Алиш. *Комлап, көлләп, сабынлап, Әби табаны юа, Әйбер-караны юа, Аннан идәнне юа.* Р.Вәлиева

2) *махс.* Йонын койдыру өчен, тирегә известь кушып көл сибү. *Залда ут кабынуга, көлләү цехында эшләүчеләрнең дә битләренә кызыллык йөгерә.* А.Алиш

**Көлләп алу** Бераз көлләү; тиз арада һәм бер тапкыр көлләү

**Көлләп бетерү** Барысын да көлләү

**Көлләп тору** Сөйләү моментында көлләү; даими, еш көлләү

**КӨЛЛЕ** I *с.* Көл белән аралашкан, көл кушылган, көле булган. *Көлле пумала күтәргән шадра хатын бии-бии килә.* И.Гази. *Без кичергән еллар иңсәсендә Кала фәкать көлле күмерләр.* Ч.Мусин

**КӨЛЛЕ** II *с. гар. иск.* Барлык, бөтен; барысы, һәммәсе. *[Бабай:] Бу җыелып чыгуыгызның бөтен җәфасы, көлле мәшәкате сиңа гына төшәр.* А.Алиш. *Ләкин никадәр тырышсам да, доганың гарәпчә сүзләрен исемә төшерә алмадым, күңелдән генә үзебезчә теләргә керештем: – Ярабби, Габдулла абыйны көлле азаплардан азат ит.* Г.Бәширов

**КӨЛЛЕК** *и.* 1) Хуҗалыкта яисә башка берәр җирдә махсус көл түгә торган урын; көл җыя торган тартма, әрҗә. *Көллек тирәсендә йөргән тавыкларын күргәч, Мәрфуга әби дөньясын онытып, аксаклый-аксаклый шунда йөгерде.* Казан утлары

2) Көл җыю өчен мич авызындагы кечкенә култык. *Без барып кергәндә, Мансур алгы яктагы мичнең көллеген чистарта иде ---.* Сөембикә

3) *техн.* Мич учагының рәшәткә астындагы көл җыела торган җайланмасы

4) Тәмәке төпчекләрен һәм көлен салу өчен махсус кечкенә генә савыт. *Язу өстәле янында матур гына сөйләшеп утырганда, Сәйдәшнең күзе өстәл өстендәге көллеккә төшә.* Р.Батулла. *[Зөбәрҗәт:] Әй, сез, унбишенче номерга көллек чыгарыгыз.* Д.Салихов. *Мәрмәр ташыннан ясалган бу көллек кырыена авызын зур ачкан карга сыны да беркетелгән иде.* Р.Низамиев

5) Самавырның аскы өлешендә көл коелыр өчен урын

6) *махс.* Тире көлләү өчен махсус чан, зур мичкә

7) *махс.* Тире көлләгәндә кулланыла торган известь һәм көл кушылмасы

**КӨЛЛЕЛЕК** *и. махс.* Нинди дә булса ягулыкта яисә туфракта көлнең дәрәҗәсе, күләме

**КӨЛЛИЯТ** *и. гар.* Махсус урта, урта һөнәри яки гомуми урта белем бирә торган уку йорты. *Шуннан соң атна-ун көн үттеме икән, миңа үзем эшләгән көллият йомышы белән калага барырга туры килде.* Р.Фәизов. *Көллиятем, син – Казанда Шөһрәтле, изге урын ---.* Э.Шәрифуллина. *Арча тагын безнең аңыбызда – данлыклы педагогика көллияте, халкыбызның милли йөзен билгеләүче бер бизәге – атаклы Арча читекләре дә.* Сөембикә

**КӨЛСУ** *с.* 1) Көл төсендәге; аксыл соры. *Мортаза аның дулкынланып иңенә төшкән көлсу чәчләренә, --- кояшта каралган нечкә беләкләренә сокланып карады.* М.Маликова. *Тын урамда янган бензин исе калдырып, көлсу төстәге машина җиңел генә кузгалып китте һәм озакламый күздән югалды.* Н.Фәттах

2) *махс.* Ылыслы һәм ылыслы-яфраклы урманнарның карбонатсыз токымнарында барлыкка килгән аксыл төстәге туфрак; шундый туфрак катнашкан булу. *Орлыклар борынлап чыкканчы көннәр җылы торды, бу исә көлсу туфрак өчен мөһим шартларның берсе иде.* Г.Ахунов. *Карт, төпчеген тапталган көлсу туфракка ташлап, аягы белән баскалап куйды.* М.Маликова. *Кара туфрак, көлсу туфрак, соры туфрак – бер басу.* Р.Фәйзуллин

**КӨЛСУЛАНУ** *ф.* Көлсу төскә керү. *Фәйзулласының каратут йөзе көлсуланып агарып чыкты, ирен читләрендә күбекләр пәйда булды.* Н.Хәсәнов. *Чәч учмасы, ут капкандай, Көлсуланып агара.* М.Галиев

**Көлсуланып бетү** Тулаем көлсу төскә керү

**Көлсуланып тору** Көлсу булып күренү

**КӨЛСЫМАН** *с.* Көл төсле. *Кояш баеганнан соң алсуланып калган елга өстен көлсыман төссез томанга охшаган элпә каплады.* М.Хәсәнов

**КӨЛТӘ** *и.* 1) Урылган игеннең бер бәйләм итеп җыеп бәйләнгән сабаклары. *Җәмил солдат сугышка тикле катлаулы сугу машинасына көлтә тыгып тора.* Г.Ахунов. *Чөнки әле эскертләргә дә салынмаган, сирәк-мирәк өелеп-өелеп куелган юеш көлтәләргә генә ышыкланган идек.* М.Садри. *Эштән кайткан атка бер көлтә солы ул – бәхет!* Р.Батулла

2) Бер бәйләм итеп җыелган үсемлекләр, чәчәкләр. *--- Клара, бер эш булсын дип, чәчәкләр көлтәсен кәнәфигә таратып салды да яңадан тигезләп, матурлап җыйды.* Ә.Еники

3) *күч.* Ниндидер бер чыганактан таралган бик көчле нур, очкын, ут ташкыны. *Ялкын сулап торган күк йөзе, төтеннәргә уралган офыклар, тоташтан миналанган кырлар, ут көлтәләре*

*чәчкән мина шартлаулары, сугышчан иптәшләреңнең кыелган җаннары...* Г.Ахунов. *Ул [Фәрит], яна-яна, үзен урап узып баручы «Тигр»га ташланды, утлы тере көлтә кебек йөгереп барып, артыннан менеп китте.* З.Зәйнуллин

◊ **Көлтә койрык** Төлке. *Оя хуҗалары чыр-чу килеп икәүләшеп төлкегә ташланды, көлтә койрык сыпырту ягын карады.* Г.Якупова. **Көлтә койрыклы** Койрыгының йоннары күпереп торган. *Ач карынлы бүреләр һәм көлтә койрыклы төлкеләр янына барып чыккан керпе баласы.* Әкият. **Көлтә шикелле аву** Бик каты егылу, гәүдә белән барып төшү

**КӨЛТӘ АРБАСЫ** *и. а.х.* Көлтә ташу өчен махсус арба; *русчасы:* **сноповозка**

**КӨЛТӘ́ БАВЫ** *и.* Көлтә бәйләү өчен, гадәттә ашлык сабакларыннан яки чи чыбыктан ясалган бау; *русчасы:* **перевясло**. *Сөмбел! Син, акыллым, Йолдыз белән минем уң ягыма бас! Көлтә бавы кисәрсең, көлтә биреп торырсың...* Г.Бәширов. *--- уракчы хатыннар яулыкларын артка чөеп бит юалар, көлтә бавы чылаталар, өстикәгә су тутыралар.* М.Мәһдиев. *Аталары Зәйнулла кичтән үк Сәйфуллага: – Иртәгә иртүк төшеп, тугайда көлтә бавына күрән урыгыз, ике көнгә җитәрлек булсын.* З.Зәйнуллин

**КӨЛТӘ́ БӘЙЛӘГЕЧ** *и. а.х., тех.* Ашлыкны үзе урып, үзе көлтә итеп бәйли торган авыл хуҗалыгы машинасы; *русчасы:* **сноповязалка**

**КӨЛТӘ́ БИРГЕЧ** *и. а.х., тех.* Ашлыкны урып, көлтә итеп бәйли торган авыл хуҗалыгы машинасы

**КӨЛТӘ́ ТИГЕЗЛӘГЕЧ** *и. а.х., тех.* Көлтә бәйләгеч машинада сабакларны тигезләп тора торган махсус деталь

**КӨЛТӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* Көлтә рәвешенә китерү, көлтә итеп бәйләү, җыю

**Көлтәләндереп алу** Аз гына көлтәләндерү

**Көлтәләндереп бетерү** Барысын да көлтәләндерү

**Көлтәләндереп җибәрү** Бераз, берникадәр көлтәләндерү

**Көлтәләндереп кую** Алдан көлтәләндерү, көлтәләнгән хәлгә китерү. *--- Чәчләрен яңадан бер кат ипләп кенә көлтәләндереп куйды [Хәят].* Ф.Әмирхан

**КӨЛТӘЛӘНҮ** *ф.* Көлтә сыман булып сузылу, көлтә сыман рәвеш алу (нур, очкын һ.б.ш.). *[Сәлим] фонарьның көлтәләнеп алга сузылган яктысы белән бөтен бүлмәне капшап чыкты.* Г.Гобәй. *Көлтәләнеп үскән кара әрем уртасыннан тырпаеп торган торба башы – әйтерсең лә балачак бәйрәмнәренең яшел чыршысы!* К.Кәримов. *--- бизәкле шәл астыннан саргылт чәчләре көлтәләнеп чыгып торган урта яшьләрдәге хатын яңа күршесен бик үк дусларча булмаган хәрәкәт белән читкәрәк этте ---.* Г.Мөхәммәтшин

**Көлтәләнә башлау** Көлтәләнүгә табан үзгәрү

**Көлтәләнеп бетү** Барысы да көлтәләнү

**Көлтәләнеп тору** Көлтә рәвешендә булу

**КӨЛТӘЛӘП** *рәв.* 1) Аерым көлтәләр (*1, 2 мәгъ.*) белән, көлтәләргә аерып. *--- киртә буендагы тарыларын бергәләп барып уралар, аны кыш буена, аяз көннәрдә кием җәеп кенә, көлтәләп сугалар: шулай рәхәт кенә яшиләр икән.* Г.Бәширов. *Шуннан соң беренче кишәрлекнең арпасын бик кадерләп җыеп, көлтәләп һәм көлтәләрне ишәк сыртына салып, калага алып киттеләр.* Н.Фәттах. *Урмаган игенне саҗинлап бүлегез, урганын – көлтәләп.* З.Зәйнуллин

2) Көлтә (*3 мәгъ.*) рәвешендә. *Ул аны еш-еш суыра, авызыннан көлтәләп чыккан төтенне, тынгысыз черкиләрне ачуланып куган кебек, кулы белән әледән-әле таратып тора.* Г.Әпсәләмов. *Алачыкның ике тәрәзәсе дә уймак кына, кояш нуры көлтәләп төшә, бөтен почмакларга барып та җитми.* Г.Якупова

3) *куч.* Күпләп. *--- шигырьләремтакмакларым район гәҗитендә әледән-әле бертөрмләп тә, көлтәләп тә басыла башлады.* И.Юзеев

**КӨЛТӘЛӘ́Ү** *ф.* Көлтә итеп бәйләү, көлтәләр ясау. *Ачык авызын ябып, чыбык көлтәләргә кереште [Баемас].* Р.Батулла. *Һәм менә һич тә уйламаганда-көтмәгәндә, ул кызны мулла ишегалдында кызлар белән салам көлтәләп йөргән хәлдә очрата.* Ф.Хатипов

**Көлтәләп бару** Рәттән, берсен дә калдырмыйча рәттән көлтәләү

**Көлтәләп бетерү** Көлтәләүне төгәлләү

**Көлтәләп килү** Әкренләп көлтәләү

**Көлтәләп кую** Алдан көлтәләү; көлтәләгән хәлгә китерү

**Көлтәләп тору** Сөйләгән моментта көлтәләү; даими көлтәләү. *Көлтә дип, искерәк гадәт буенча әйтәм, ул чакта ашлыкны көлтәләп торырга вакыт җитмәгәч, чабып кына өяләр иде.* Ә.Баян

**Көлтәләп чыгу** Барысын да көлтәләү

**Көлтәли башлау** Көлтәләргә керешү

**КӨЛТӘЧЕ** *и.* 1) Көлтә бәйләүче. *Көлтәче җырына кушыла елгалар.* Ә.Ерикәй

2) Көлтә ташучы. *Шушы вакытта басу капкасында беренче көлтәче күренде: ул тау кадәр итеп төягән, һәм аты көчкә-көчкә тартып килә.* И.Гази. *Анда эш кайный: көлтәче егетләрнең күбесе үзләренең көнлекче икәнлекләрен бөтенләй онытканнар, җан-фәрман көлтәләрне биек эскертләрнең башына тондыралар ---.* А.Таһиров

**КӨЛТӘЮ** *ф. диал. к.* **кылтаю**. *[Назыйм:] Көлтәеп йөрмә әле, карчык, каршымда, әле бер көлмәгеңне киясең, әле икенчесен, ничек арымыйсың ---.* Казан утлары

**КӨЛ-ТУЗАН** *и.* Көл катыш тузан. *Хәрабәләр эченнән, көл-тузан, таш өемнәре арасыннан миналар тартып чыгаручы, мәкерле дошман мең төрле хәйлә белән яшереп калдырган миналарны табып, меңләгән ватандашларын коткаручы бу Шакиров үлемне җиңәргә кайда өйрәнгән икән?* М.Садри

**КӨЛҮ** *ф.* **1.** 1) Шатлану, канәгатьләнү һ.б. нәтиҗәсендә өзек-өзек кыска авазлар чыгару. *Арадан берсе кызык сүз әйтсә, калганнары көтүләре белән бергә кушылып көләләр.* М.Әмир. *Камай шундук көлүдән туктады, гәрчә тавышы чыкмаса да, Сәлим хан моны тегенең җитдиләнеп киткәнен чыраеннан чамалады.* М.Хәбибуллин

2) Кешене мәсхәрәләү, мыскыллау. *Николай Максимовичның үртәп көлүләрен ишетә башлагач, ул [Ханзафаров] шаккатты, кызарынды, бүртенде, --- өлкә комитетына шалтыратам, жалу бирәм, дип чәпчеде.* Г.Әпсәләмов. *Ташла шул кешедән көлүеңне.* Р.Вәлиев. *Тик бу – Хисмәтулланың эчкерсез мәхәббәтеннән оятсыз рәвештә көлү булачак лабаса!* Ә. Моталлапов

3) Кире мөнәсәбәт күрсәтү, түбәнсетеп карау, тәнкыйть итү. *Үзләре [әти, әни] бит алар – гомер буе искелектән көлеп, шуны хурлап килгән кешеләр...* Ә.Еники

4) *күч.* Шатлык, күңеллелек белдерү; канәгатьләнү белдерү (күзләр, йөз тур.). *Авызы көлә, күзләре көлә, борын астындагы бармак бите кадәр мыегына хәтле көлә.* Б.Камалов. *Аның [Әминәнең] йомшак иреннәрен, көлеп торган күзләрен күргәч, күпмедер вакытка авыр уйлардан һәм әнисенең түзеп булмаслык карашыннан котылдым.* Р.Вәлиев

5) *күч.* Яктырту, нур сибү; мөлаем, елмаюлы булып күренү (кояш һ.б. тур.). *Шүрләп кенә эчкә кергән идек, – Каршылады көлеп каеннар ---.* Р.Рахмани

**2.** *и. мәгъ.* Шатлану, канәгатьләнү хисләре тәэсирендә барлыкка килгән өзек-өзек авазлар. *Бүген бит һәр өйдә диярлек мәҗлес, шатлык, җыр, көлү, бию.* Г.Әпсәләмов. *Гаҗәп иде бу көлү, нәрсәгә охшатырга да белмим мин аны...* Ә.Еники. *Көлү безне дуслаштыра, Көлү безне берләштерә.* Р.Миңнуллин

◊ **Көлеп карау** Санга сукмау; түбәнсетү, кимсетү. *Әнә синең хатынга элек бездә көлеп кенә карыйлар иде.* Р.Вәлиев. **Көлеп тору** Бик матур булып, игътибарны җәлеп итеп, ялт итеп тору. *--- Анда үрнәкле тәртип, көлеп торган чисталык булсын...* Ә.Еники. **Көлеп эч кату** Тыела алмыйча, бик каты көлү. *Кызык сүзләреннән көлеп эчебез ката иде.* Г.Мөхәммәтшин. **Көлсәң көл, еласаң ела** «Кызык та, кызганыч та» дигән мәгънәдә

**Көлә башлау** Көләргә тотыну. *Эт белән песинең җир сукаларга җигелгәнен күреп торган тау карап-карап торган да түзмәгән, шаркылдап көлә башлаган.* Әкият. *Аның койрыксыз Коранһышын күрүгә, мәйдан халкы шырык-шырык көлә башлады.* Р.Батулла

**Көлә бирү** Бернигә карамый көлүен дәвам итү

**Көлә тору** Башка эш-хәл барышында яки алдан көлү. --- *шул ук халыкның акыллырак өлеше күк күкрәтеп дигәндәй көлә торды.* Ф.Баттал

**Көлә төшү** Бераз көлгән кебек итү. *Зыя, көлә төшеп, үз тарафыннан протест ясады: – Егетләр, күпме эчкәнсездер, ансын белмим; ләкин гонаһка мине катыштырмагыз ---.* Г.Ибраһимов

**Көлеп алу** Аз гына көлү. – *Юнганың кем икәнен беләсездер? Ул бит – яшь матрос дигән сүз. – Келтерәп кенә көлеп алды [Дина Павловна].* Г.Ахунов. *Гөлмәрфуга түти кеткелдәп көлеп алды.* А.Хәлим. *Гөлфия хихылдап көлеп алды да сүзен дәвам итте.* Ф.Яруллин

**Көлеп җибәрү** Кинәттән көлә башлау. --- *Данифка бу кызык тоелды, ул ачылып китте, көлеп җибәрде.* М.Маликова. *Бу юлы инде Мәхмүткә кушылып мин дә көлеп җибәрдем...* М.Әмир. *Казый Нисбахны байгышка охшатты да көлеп җибәрде.* М.Хәбибуллин

**Көлеп кую** Сирәк-сирәк яки бер тапкыр көлү. *Менә хәзер дә ул [абзыкай] җырын әнә шулай әллә кайларгача җәелеп китәрлек итеп сузып бетерде дә, үзе дә шуңардан әсәрләнеп булса кирәк, кәефләнеп бер көлеп куйды.* Ә.Еники. *Тимерхан абзый – алтмыш биш яшьлек өлкән кеше – кеткелдәп кенә көлеп куя.* Г.Ахунов. *Үзләре [Чәчкә белән Миләүшә], нindidер сер биргәндәй, каш астыннан гына көлеп куялар.* Ф.Яруллин

**Көлеп тору** Сөйләү моментында көлү; һәрвакыт, еш көлү, бертуктаусыз көлү. *Пётр Петрович инде җиденче унны тутырса да, һаман көлеп кенә тора.* М.Әмир. *Зөһрә исә: «Менә мондарак, менә тегендәрәк китте бугай», – дип, җизнәсен тинтерәтүдән кызык табып, эчтән генә көлеп торды.* Ф.Яруллин. *Көлеп тора, үзе дәшми [әтиең].* Ә.Галиев

**Көлеп утыру** Көлгән хәлдә булу; башкаларның фикерләрен җитдигә санамыйча яисә ышанмыйча кабул итү, күпмедер дәрәҗәдә кире мөнәсәбәттә булу. *[Нәзирә:] – Мин синең белән чынлап сөйләшәм, Һәнүс абый, ә син миннән көлеп утырасың, – диде ул һәм иңбашларын калтыратып елап җибәрде.* Ф.Шәфигуллин. *Беләм, мыек астыннан гына көлеп утырасыз инде сез.* М.Әмир

**КӨЛЧӘ** *и.* Әче камырдан пешерелгән камыр ризыгы; кабартма (элек көлдә пешерелгән). *Төенчек эченнән зур гына йөзем тәлгәше, бодай көлчәсе, бер йомарлам эремчек, сөт савыты күренеп тора иде.* Н.Фәттах. *Шикәрем дә бар, әче камырдан көлчә дә пешергән идем.* Н.Кәримова. *Ә инде без кайтуга, әбекәйнең яңа ипие мичтән чыгарылган, мендәр өстенә икенче ягы белән әйләндереп тезелгән, күпереп пешкән көлчәсе майлап, табак түбәсеннән итеп өеп куелган, мунчасы ягылган була иде.* Э.Шәрифуллина

**КӨМӘН** *и. фар.* Карындагы бала, йөклелек. *[Мирсәлим:] Көмәнеңне төшертергә бирәр атна вакыт кирәк шул сиңа!* Н.Гыйматдинова. *Шул ук «Волга»да көмәндә чагында алып барган малайны хәзер инде дөньяга чыккан чагында алып та кайтырга кирәктер бит инде, иншалла!..* А.Хәлим. *[Алсылу:] Җирдә адәм рәтле кеше беткәч, җыен гарип-горабадан Буйга узып көмән үстерүдән чиркана тән.* Ә.Баян

**КӨМӘНЛЕ** *с.* Авырлы, йөкле; балага узган. *Кайнанасы өеннән куып чыгарганда, Шәмсия өченче балага көмәнле була.* Т.Галиуллин. *Аңардан [ишектән] ерак түгел үскән агач ягында бер ир белән көмәнле хатын сөйләшеп торалар.* Ф.Гайнуллин. *Лотфулла белән чапты [Күкчәчәк], Лотфулладан көмәнле дидем, шундый түбәнлекләргә кадәр төштем.* Н.Гыйматдинова

**КӨМЕШ** *и.* **1.** 1) Аксыл соры төстәге ялтырап торган кыйммәтле металл. *Көмештән шуның өчен акча ясадылар, чөнки көмеш – ышанычлы, бәһале товар.* Г.Тукай. *Әллә көмеш булуына шикләнәләр инде, әллә кыйммәтсенәләр, --- тотып-тотып карыйлар, әмма сатып алмыйлар.* Ф.Шәфигуллин. *Сакланып калган әйберләр арасында көмештән эшләнгән чигә алкасы һәм бакырдан эшләнгән шалтыравык асма бизәк чылбырлары бар иде.* Ф.Хуҗин

2) Элек шундый металлдан коеп ясалган вак акча. --- *Егерме тиен көмеш һавага очып китте, кыз иелеп аны эзләп алды, касса алдындагы хатыннар бер-берсенә карашып баш чайкадылар.* А.Гыйләҗев. *Бик нык рәнҗегән Фирдәүси мунчага бара, анда җимеш суы эчә һәм барлык көмешне мунчачы белән тәмле «фук» сатучыга бүлеп бирә...* Җ.Ильясов. *– Кәҗә өч көмеш тора! – дип такмаклый икән үзе [Зарифат].* Р.Батулла

3) Шундый металлдан ясалган бизәнү әйберләре. *Анда тик кыйммәтле нәрсәләр генә сатыла: алтын да көмеш, бриллиант та якут.* Э.Касыймов

4) *күч.* Үзенең төсе яки ялтыравы белән көмешне хәтерләткән, аксыл соры төстәге әйберләр. *Агачларда – алтын, чәчтә – көмеш, Кышларымны гына, Язларымны гына, Җәйләремне булмый туктатып.* Х.Мөдәррисова

5) *күч.* Ходай язган, насыйп булган кеше, әйбер. *Берзаман әллә кайсы яктан, аның [Алмакай-Алмабикәнең] өлешенә көмеш булып, Хәлекәй-Хәлиулла килеп төшкән.* Г.Якупова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый металл кушып ясалган; көмеш **1.** (*1 мәгъ.*) йөгертелгән. *Гата класс ишеген япмаган көе үк көмеш портсигарын чыгарып яхшы папирос алды, хикмәтле зажигалка белән ялт итеп кабызды ---.* М.Мәһдиев. *Ул [Әхнәф], көмеш кашык белән өстәлгә шакы-шокы суккалап, шактый вакыт торды.* Ф.Садриев

2) Шундый металлдан ясалган (акча тур.). *Җиңгәчәйнең өстендә киң итәкле озын кәшимир зәңгәр күлмәк, яшел камзул, башында көмеш тәңкәле тар гына калфак ---.* Ә.Еники. *Аның [Миңлеасиянең] көмеш тәңкәләр сибелгәндәй яңгыравыклы тавыш белән рәхәтләнеп көлеп җибәрүләре – барысы, барысы Тимерхан абзыйның күз алдыннан узып киттеләр.* Г.Ахунов. *Көмеш тәңкәләр белән бизәлгән ук савытларында һәр олан үзе теләгән төскә буяган уклар.* М.Хәбибуллин

3) *күч.* Төсе яки ялтыравы белән шундый металлны хәтерләткән, аксыл соры. *Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле җилфердәшәләр...* Ә.Еники. *Уңда да, сулда да, артта да, алда да, өметләрне канатландырып, көмеш балыклар сикерешә.* М.Әмир. *Җемелдәтеп җиргә яткан көмеш чыкны, Көнчыгышта, Алып батыр калканыдай Матурланып, түм-түгәрәк кояш чыкты.* Ш.Мөдәррис

4) *күч.* Агарган, чал. *Зәйтүнә ерактан ук аның ике чигәсеннән сузылып киткән көмеш тасмаларны күреп алды.* М.Маликова. *Беләм нигә чәчкә чал төшкәнне, Нигә көмеш сакал үсүен.* М.Садри. *Көмеш чәчле әнкәем бу, Ак яулыгы кулында.* Х.Әюп

5) *күч.* Яңгыравык, яңгырап торган, ачык тонлы (тавыш тур.). *Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа: аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана.* Ә.Еники. *Ул кичтә Тәбрия, мандолинаның көмеш чыңына кушылып, шактый җырлар җырлады.* М.Маликова

6) *күч.* Нихаклашу кебек берәр вакыйганың 25 еллыгы белән бәйле. *Укучылар белән уртак фикердә яши башлаганга чирек гасырдан артык – көмеш туй үтеп тә киткән.* Ш.Галиев. *– Газинур белән Миңсылу көмеш туйларына чакырганнар иде, затлырак бүләк аласы булыр инде ---, – дип сүз башлады хатыны.* Татарстан яшьләре

**КӨМЕШ-АЛТЫН** *җый. и. сөйл.* **1.** 1) Көмеш һәм алтын кебек затлы металлар. *Мимарлар-мөһәндисләр сарайлар, мәчетләр кора, һөнәрчеләр көмеш-алтын, җәүһәр-энҗеләрдән бизәнү әйберләре, рәссамнар гүзәл сәнгать әсәрләре иҗат итә.* Р.Батулла

2) Алтын-көмештән ясалган әйберләр. *Көмеш-алтынга кызыгу*

**2.** *с. мәгъ.* Алтыннан һәм көмештән ясалган. *Шуннан солдат әйтә: – Мин сиңа көмеш-алтын акчалар бирәм бит, чакма ташы нәрсәгә кирәк сиңа? – ди.* Әкият

**КӨМЕШКӘ** *и. рус сөйл.* Өй шартларында ясалган исерткеч эчемлек; самогон. *Борька стаканга тутырып көмешкә салды да миңа сузды.* И.Сирматов. *Ике катлы соры бина эчендә нинди генә күңелсезлекләр вә хәтәр хәлләр булып үтмәде: урлашу, янау, яшеренеп көмешкә эчү, авыз-борыннар канату...* К.Латыйп. *Битләрен дә кыл баскан бу аю кебек йөнтәс адәмзаттан сасы көмешкә исе килеп бәрелде.* А.Хәлим

**КӨМЕШКӘЧЕ** *и.* Көмешкә кайнатучы

**КӨМЕШЛӘНҮ** *ф. төш. юн.* 1) *к.* **көмешләү**. *Моның өчен көмеш хуз хәзерләмәк кирәк: биш йөз өлеш йодистый калий, меӊ өлеш су. Ун минутта, күп булса утыз минутта көмешләнеп бетәдер һәм бик һәйбәт буладыр.* К.Насыйри

2) *күч.* Чәч агару, чалару. *Аларның [таныш-белешләремнең] --- битләрендә җыерчыклар тирәнәйгән, чәчләре көмешләнгән, күзләре эчкәрәк бата төшеп, күп нәрсәләрнең серен белгәндәй, җитди, сабыр карыйлар.* Ә.Еники

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса аксыл соры төскә кереп, чаларып торуы. *Әле кичә генә зәңгәрләнеп агып яткан елга, һавалар кинәт кенә суытып җибәргәнлектән, ашыга-ашыга көмешләнә, агымы талгынлана ---.* А.Хәлим. *Ачык тәрәзәдән томырылып диярлек бер-бер артлы ике ак күбәләк килеп керделәр дә --- ачык тәрәзәгә түгел, икенчесенең кояш яктысында көмешләнгән пыяласына бәрелделәр.* Г.Кашапов

**Көмешләнә башлау** Көмешләнү билгеләре сизелү. *Көмешләнә башлаган коңгырт-кара чәчләрен ясалма бөдрәләткән Алия, кыюланып, уң кулына тотып кергән эштән китү турындагы гаризасын --- өстәлгә куйды.* М.Шаһимәрдәнов. *Шулай да аларның [мыекларның] карадан көмешләнә башлаганлыгын аңлау кыен түгел.* С.Поварисов

**Көмешләнә төшү** Тагын да бераз көмешләнү. --- *кайчандыр соргылт булып та, хәзер төсен югалткан күзләре тагын да эчкәрәк яшеренгән һәм сирәк, йомшак чәчләре тагын да ныграк көмешләнә төшкән шикелле күренде.* Н.Фәттах

**Көмешләнеп бару** Акрынлап, азазлап көмешләнү

**Көмешләнеп бетү** Тәмам көмешләнү. *Барып җитсәләр, ак сакалы тезенә җиткән, чәчләре көмешләнеп беткән, аркасы бөкрәйгән, куллары кәкрәйгән*

*бер бабайны очраттылар, ди, алар.* А.Алиш

**Көмешләнеп калу** Көмешләнгән (чаларган) хәлгә килү. *[Гөлфирә] Шунда аларның [чәчләре] элеккегә караганда яртылаш диярлек көмешләнеп калуына игътибар итте, тик, ирен борчымас өчен, бу турыда бер сүз дә әйтмәде.* Ә.Сафиуллин

**Көмешләнеп килү** Көмешләнүгә таба бару. *Олыгаеп, чәчләре көмешләнеп килгән промысел җитәкчесе Евгений Иванович дөньяда барысын да күргән тәҗрибәле кеше иде.* Ә.Сәлах

**Көмешләнеп китү** Кинәт, ниндидер сәбәптән көмешләнү. *Сәүбәннең зәңгәр күзләре дә бераз ачылып, ачыкланып, хәтта көмешләнеп киткән.* Г.Гыйльманов

**Көмешләнеп тору** Көмешләнгән хәлдә булу. *Чигәләрендә ак чәчләре көмешләнеп тора.* Х.Камалов

**КӨМЕШЛӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **көмешләү**

**КӨМЕШЛӘ́Ү** *ф.* 1) Көмеш белән каплау, көмеш йөгертү; көмешкә ману. *Көмешләп эшләнгән бу затлы балдакны миңа мәрхүм ирем бүләк иткән иде.* Сөембикә

2) *күч.* Көмеш төсенә кертү; агарту, чаларту. *Кояш нурлары көмешләгән апак су өстендә тирбәлеп утырган көймәләрнең кара силуэтлары искиткеч бер манзара иде.* А.Гыйләҗев

**Көмешләп бетерү** Тулысынча, бөтен җирен көмешләү

**Көмешләп тору** Даими, һәрвакыт көмешләү

**Көмешләп чыгу** Һәрберсен аерым-аерым көмешләү

**Көмешли башлау** Көмешләргә тотыну

**Көмешли төшү** Тагын да бераз көмешләү

**КӨМЕШЛЕ** *с.* 1) Көмештән ясалган; составында көмеш булган. *Беркөнне ул [Рәхим] Орликны җиңел чанага җигеп алды, мәктәптән сорап торып, дугага көмешле кыңгырау такты, --- сөйгән кызын алмага чыгып китте.* Җ.Мостафин. *Тәңкә салсаң, алырлар, ә суда көмеш булу сәламәтлек өчен кирәк: көмешле су бозылмый.* Ш.Галиев

2) Көмешкә манылган яки көмеш өлешләре дә булган. --- *алдындагы өстәлдә сулы графин янында торган көмешле җиз кыңгырауны шалтыратып, Фәхретдин Гыйльмановның үтерелүе турындагы эшне тикшерү башланачагын белдерде.* Р.Гайфуллина

**КӨМЕШСУ** *с.* Ялтырап торган аксыл соры; көмеш төсенә охшаган. *Саф, көмешсу тамчыларда, Мәймүнәнең күңел күгеn яктыртырга теләгәндәй, офыкка тәгәрәгән кояшның мәрхәмәтле нурлары чагыла иде.* Н.Хәсәнов. *Давыт үлән арасыннан көмешсу әрем баш тарткан турга килеп басты* ---. М.Галиев

**КӨМЕ́ШТӘЙ** *с.* **1.** 1) Көмеш шикелле, көмешкә охшаган, аксыл соры. *Көмештәй мех*

2) *күч.* Яңгыравык, чыңлап торган; колакка ятышлы (тавыш тур.). *Берёзкига гомерендә бер генә тапкыр булса да килеп киткән кеше --- шушы көнгә чаклы көмештәй саф авазын саклап калган кыңгырауны инде беркайчан да оныта алмас.* В.Тельпугов. *Көмештәй аваз белән кешнәп җибәрдеме, күктәге фәрештәләргә чаклы очып барган җиреннән тукталадыр.* Р.Низамиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Көмешсу төскә кереп. *Мәчеткә ул [Коръәнхафиз] кара казаки өстеннән көмештәй елык-елык уйнаклаган атлас чапан, башына кара чуклы зәңгәр фәскә җыйнак кына итеп чорнаган ак чалма киеп бара.* Ә.Еники. *Кичке шәфәкъ яктысында аның [Дарья әбинең] кулындагы биш энәләре генә, күзлегенә тиям-тиям дигәндәй, көмештәй елык-елык ялтырый иде.* В.Тельпугов. *Аны [Мөнир абыйны] каршына утырткач, Сөембикә аптырап китте: туганнан туган абыйсы шактый картаеп, ябыгып киткән, чәчләре коелмаса да көмештәй чаларган, кашлары гына кап-кара килеш иде.* Ф.Садриев

2) Яңгырап, чылтырап. *Көмештәй яңгыраган тавышка уянып киттем* ---. М.Гали

**КӨМЕ́ШСЫМАН** *с.* Көмеш төсле; аксыл соры. *Менә көмешсыман канатлы ак самолёт килеп чыга.* А.Гыйләҗев. *Әгәр дә сезгә Кама урман хуҗалыгында булырга туры килсә, --- юлның ике ягына утыртылган көмешсыман чыршыларга игътибар итүегезне сорар идем.* М.Хәсәнов. *Пәрдә артыннан көмешсыман савытлар --- тотып, юантык бер апа килеп чыкты* ---. М.Мәһдиев

**КӨМЕШЧЕ** *и.* Көмештән коеп төрле әйберләр ясаучы яисә әйберләрне көмешләүче оста. – *Мине көмешче кызыксындыра шул, – диде Үрбәт.* М.Әмирханов. *Итекчеләр юк, көмешчеләр юк, тегүчеләр, сәгать осталары, пыяла куючылар, калайчылар юк.* И.Сирматов. *Кызны 1895 елда хәзерге Татарстанның Саба районы Теneки авылы көмешчесе Галәветдин үзенә хатынлыкка алып китә.* Татарстан

**КӨМЕШЧЕЛЕК** *и.* Көмешләү яисә көмештән әйберләр ясау һөнәре. *Сабада элек-электән көмешчелек һөнәре булган.* Ш.Галиев. *Китапханәләр яна, мәчетләр җимерелә, көмешчелек, җәүһәрчелек корый...* Р.Батулла

**КӨН** *и.* 1) Тәүлекнең бер өлеше, кояш чыкканнан алып баеганчы вакыт; *киресе*: **төн**. *Көн сүрән, караңгы, көз фасылындагыча вак яңгыр сибәли.* И.Нуруллин. *Көн җылы, кояшлы иде.* Р.Вәлиев. *Әллә көн азагында адәм баласына тагын да авыррак микән?* Н.Гыйматдинова

2) Бер тәүлек. *Вакыйгалар берберсен кысрыклый, эшләр берсе өстенә берсе өстәлә, һәр яңа көн белән ни дә булса туа, ни дә булса арта бара.* Ә.Еники. *Ике көн үткәч тә, дүрт-биш көннән дә, бер айдан да килмәде әле ул кыюлык миңа.* Р.Вәлиев

3) Айның яки атнаның аерым бер өлеше; календарь дата. *Якшәмбе көн булгач, бирегә дә халык шактый күп килгән.* Ә.Еники. *Шимбә көн кич чәй эчеп бетергәч, уйланып утырган Сәйфуллага: – Син, кияү, вакыт табып, тиз генә Төхфәт баҗаңа барып кил әле, – диде.* З.Зәйнуллин

4) Ел фасылына бәйле билгеле бер вакыт. *Җәй генә түгел, кыш көне дә буш тора бу гараж.* Ф.Яруллин. --- *[Гомәрнең] әтисе – шактый бай оста Ибраһим – җәй көне ял итәр өчен, йорт һәм бакча сатып алган иде.* Җ.Ильясов. *Мәдрәсәдә укулар көз көн-*

*нәрендә кар явар алдыннан башланган, язга чыккач, ташу аккан чакларда тукталган.* Ф.Гарипова

5) Нинди дә булса бәйрәм яисә вакыйга белән бәйле дата. *[Динислам:] Туган көнең белән, Мәдинә-Гөлмәдинә.* Г.Якупова. *Укытучылар көне. Белем көне*

6) *күпл.* Әдәбият, сәнгать өлкәсендәге вакыйгаларга яисә аерым бер датага, язучылар һ.б. иҗатына багышланган һәм берничә көн дәвам иткән зур чара. *Москвага татар әдәбияты көннәре уздырырга килдек.* М.Әмир. *Журналның бу бәйрәме матбугат битләрендә, әдәбият көннәрендә, иҗат кичәләрендә һәм бүтән әдәби чараларда ел буе диярлек дәвам итте.* Р.Фәйзуллин

7) *күпл.* Билгеле бер вакыт, чор яисә вакыт аралыгы. *Хәтердә калган ул авыр да, күңелле дә көннәрне уйлап, Зөбәйдә арба тарта, үзе елмая.* З.Зәйнуллин. *– Кадерле әнкәем, җанкисәккәем! – диде чүл кызы Нәүризә. – Гөлстан халкының иң кара көннәре башланды.* Р.Батулла

8) Кояш яктылыгы, кояш җылысы. *Тезем-тезем тәрәзәләр Көнгә куйган йөзен.* К.Булатова. *Ул [ана] сәламәт вакытындагыча айнык тере булып ачылган күзләре белән көн яктысына карап ята.* Ә.Еники. *Тәрәзәмнән кергән көн яктысы сүнеп бара.* А.Шамов. *Үзең белән көн яктысын түгел, Алып киталмыйсың чырасын да.* Х.Әюп

9) Кояшлы як. *Ферма артындагы көнгә караган тау бите, пыяла вагы сибелгәндәй, күз явын алып, бертуктаусыз җем-җем уйнаклап тора...* Ә.Еники

10) *күч.* Гомер. *Ул [Әбу Рәйхан Бируни] инде үзенең көннәре санаулы икәнен тоя, әмма үзе кабызган гыйлем утын кем дәвам иттерәсен генә белми иде.* Җ.Ильясов

11) *күч.* Тормыш, яшәеш. *– Бүгеннән башлап үз көннәрен үзләре күрсен, бездән фатиха, – диде [Хәнифә].* З.Зәйнуллин. *Минем өчен тагын якты көннәр башланды.* Р.Низамиев. *Озын сүзнең кыскасы шул, балалар: көн озын, гомер кыска, гөнаһлардан арынып, матур итеп яши башларга вакыт.* Ф.Яруллин

12) Бәхетле, яхшы тормыш. *Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.* Мәкаль. *Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр; тун күрмәгән тун күрсә, кага-кага туздырыр.* Мәкаль

13) *күч.* Һава торышы. *– Көннәр бозылганчы урып җыю эшләрен төгәллисе иде бит, егетләр, – дип кул биреште безнең белән бригадир Салих.* Казан утлары

◊ **Көн ачылу** Яктыру, аязу. *Көн ачылгач кына китәрсез инде, эшегез бик ашыгыч булмаса.* Казан утлары. **Көн бетү** 1) Авыр хәлгә калу, яшәргә мөмкинлек калмау. *[Коръәнхафиз:] Бел, синең кебек ахуннарга көн бетте хәзер...* Ә.Еники. *Менә шул чакта Казанның хуҗалары без булырбыз, ә байларга һәм генералларга көн бетәчәк!* Я.Винецкий; 2) Урын калмау, кирәге бетү. *Йорт тоткасына тәмам көн беткән икән бу нигездә.* Мәдәни җомга. **Көн бирмәү** *к.* **көн күрсәтмәү**. **Көн булмау** Яхшы, тыныч тормышта яшәргә, иркенләп эшләргә мөмкинлек булмау. *Көн булмады инде ул мескенгә.* Казан утлары. **Көн булу** Һава торышы әйбәт булу. *Көн барда ташырга тырыша халык [печәнне].* З.Зәйнуллин. **Көнгә чыгару** 1) Тотылмый яткан нинди дә булса әйберләрне, киемнәрне куллана, кия башлау. *Үз сандыгымда күпме бирнә чүпрәкләрем тасланган килеш ята... Көнгә чыгарырга сәбәбе генә юк!..* А.Хәлим; 2) Фаш итү. **Көнен көнгә катып** Һәрвакыт, бертуктаусыз; көнтөн. *Көнен көнгә катып эшләүчеләр дә хәерче хәлендә яши әле, башкаларны әйтәсе дә юк.* М.Гафури. **Көнең төшү** Йомыш төшү, ягъни кемнән дә булса әйбер, ярдәм сорарга мәҗбүр булу. **Көн дә бәйрәм, көн дә туй** «Рәхәт яшәү» мәгънәсендә. *Ә сезнең – көн дә бәйрәм, көн дә туй.* Р.Вәлиев. *Клуб мөдире агай үзенең башы дәүмәлле олы йозагын күтәреп килеп керде: «Көн дә бәйрәм, көн дә туй булмый ул», – дип сөйләнә-сөйләнә, яшьләрне куып дигәндәй чыгарды да ишекне шартлап бикләп кайтып китте.* Г.Якупова. **Көн итү** Яшәү, тормыш алып бару. *Яңартылган йортларда көн итәчәк кешеләр Урманцевның тырышлыгы турында белмәячәк тә.* М.Маликова. *Мәхәббәт ул туйда гына кирәк. Ә соңыннан кешеләрне уртак тормыш, бергәләп көн итү, балалар үстерү дә бер-берсенә бәйли.* Ә.Еники. *Яшьләрнең дә заманча көн итәселәре килә.* Б.Камалов. **Көн кадагына сугу** Нинди дә булса эшне бик кирәкле вакытта башкару. *Повестьларында да тискәре образлар аша бүгенге көннең әхлакый мәсьәләләре күтәрелә, көн кадагына суга торган гыйбрәтле хәлләр тасвирлана.* Казан утлары. **Көн калмау** *к.* **көн бетү**. *Безгә дә көн калмады.* Р.Батулла. **Көн кебек** *к.* **көн кебек ачык**. *Әйткәнемнең кадере, үземнең болай да булмаган кадерем кимеячәге генә көн кебек.* Р.Рахман. *Шул ук вакытта икесе дә [Хәят белән Миңзаһит] ул дөньяны нәкъ менә үзләре тудырганны аңлыйлар, аны кабул да итә алмыйлар, аңардан котылу да юк, шуннан чыга алмыйча һәлак булачаклары да көн кебек иде.* Ф.Садриев. **Көн кебек ачык** Үзеннән-үзе аңлашыла; бик яхшы билгеле. *Монда кызгануның мәгънәсезлеге көн кебек ачык.* М.Маликова. *Ә ачыкларга кирәк, һәрхәлдә, яңа начальник аның [Шәймәрдан агай] өчен көн кебек ачык булырга тиеш.* Ә.Еники. *Андый тамашага Габделбәр Гафуровның түзмәсе көн кебек ачык иде.* Б.Камалов. **Көн килү** Уңыш елмаю, җиңеллек килү, мөмкинлек ачылу. *– Мочтак хатынына гына сыер саварга димәгән, безгә дә көн килде, – дип, Шәмсия бии-бии сөенде.* Р.Батулла. **Көн кичереш** Тормыш алып бару. **Көн кичерү** *к.* **көн күрү**. *Элек балалар гел туган нигез тирәсендә тупланып яшәүне хуп күрә иделәр, бер-беренә ярдәмләшеп көн кичерделәр.* Ә.Моталлапов. **Көн кичкә авышу** Кич җитеп килү. *Менә без, көн кичкә авыша башлаган булса да, әле бөтен көченә янган җәй кояшы астында ялтырап яткан Идел өсте буйлап түбән таба очабыз.* М.Әмир. *Көн кичкә авышып килә иде, укытучылар бүлмәсенә дәфтәр тикшерергә, план төзергә җыела башладылар ---.* М.Мәһдиев. **Көн күзе йомылу** Кич җитү; караңгылану, караңгы төшү. *--- Көн күзе йомылганчы җырларлар иде.* Х.Кәрим. **Көн күзлеге** Көн таләбе. *Көн күзлегеннән караганда искә алырлык та вакыйга түгел.* И.Сирматов.

**Көн күрмәү** 1) Көн яктылыгы күрмичә яшәү; күпмедер вакытниндидер сәбәпләр аркасында караңгыда яшәргә, вакыт үткәрергә мәҗбүр булу. *Бахыркайлар [казлар], оя басып, көн күрми утырып ни, әзрәк әллә диваналананалар?* Г.Якупова; 2) Яхшы тормыш күрмәү. **Көн күрсәтмәү** Тыныч кына яшәргә, эшләргә һ.б. мөмкинлек бирмәү; хәлен, тормышын кыенлаштыру. *[Балалар] акыралар, бакыралар, бер сүзен колакларына элмиләр, үзе күрмәгәндә, артыннан мыскыллап көләләр, кыскасы, мескенкәйгә көн күрсәтмиләр иде.* Ә.Еники. *– Түзәрлегем калмады! – диде ул. – Хатын көн күрсәтми, хыянәт итә.* Р.Батулла. **Көн күрү** 1) Тормыш алып бару, яшәү, гомер итү. *Һәлак булган солдатның өлкән улына һәрнәрсә бик авырлык белән бирелде, үз көчең белән көн күрүнең ачы, тозлы тәмен ул бик иртә татыды.* М.Маликова. *Үз көнемне үзем күрдем.* Г.Ахунов. *Киек кошларның тормышы шулай дәвам итәр, ә минә мин озатасы өч кешенең язмышлары ничегрәк булыр, чит-ят җирләрдә алар ничегрәк көн күрер?..* К.Латыйп; 2) Берәр төрле кәсеп, һөнәр белән яшәү өчен акча эшләү; яшәешне тәэмин итү. *Җәтмәгә эләккән балыкларны, җитмәсә шундый сирәк очрый торган гына түгел, безнең кебек хәләл кәсеп белән көн күрүче кешеләрнең төшенә дә керми торган эре, матур, тере чөгәләрне кире суга җибәрү!* М.Әмир. *Җәй буе үз вакытын дачасында, шәһәр ыгы-зыгысын тоймыйча, саф һава сулап, кишер, суган үстереп көн күрүче ветераннарның нәфрәтен аңларга була, билгеле.* Мәдәни җомга; 3) Уңышка, максатка ирешеп, әйбәт яши башлау; тормышлар җайланып китү. *Шулай бит ул, берәү үлә, берәү көн күрә дигәндәй, кайчак кеше үзе дә сизмәстән кинәт кенә максатына ирешеп куя.* Ә.Еники. **Көннәрдән бер көн(не)** Бервакыт. *Шулай көннәрдән бер көнне минем янга Фәхри карт килеп чыкты.* Ә.Еники. *--- бу дуслык көннәрдән бер көнне бозыла ---.* Н.Фәттах. **Көннәре санаулы** Вакыты чикле. **Көннәрне авыштыру** *к.* **көн күрү**. *--- Болар шуның белән алай-болай итеп көннәрен авыштырып баралар икән, ди.* Әкият. **Көннәрнең берендә** *к.* **көннәрдән бер көн(не)**. *Көннәрнең берендә партадашым Сәйфүш белән без дә киногa качып керергә уйладык.* Р.Низамиев. *Көннәрнең берендә үз хәлебезгә читтәнрәк торып күз ташлаган идек тә хәйранга калдык...* М.Зарипов. **Көнне төнгә ялгап** Ял итмичә, көне-төне. *--- Миңлеәхмәт көнне төнгә ялгап үзе дә эшләде, бригададагы халыкны да эшләтә белде.* З.Зәйнуллин. **Көннеке көнгә бетү** Шул ук көнне бетү, икенче көнгә калмау (азык, акча, эш һ.б.ш.). *--- [Салам] көннеке көнгә бетеп бара, бер дә запас әзерләп булмый.* А.Расих. **Көннеке көнгә җиту** Шул көнне табылган, кергән нәрсә җитәрлек булу, кытлык булмау; гомумән, урта хәлле тормыш булу. *Көннеке көнгә җитеп баргач, аларга күпләп утын әзерләүнең хаҗәте юк иде.* Ф.Яруллин. **Көннекен көнгә җиткерү** Кытлык, тарлык күрмәү; гомумән, урта хәлле тормышлы булу. *Минем хезмәт хакы белән көннекен көнгә җиткерү бик җиңелләрдән түгел, һаман кемгәдер баш иярга, чарасын табарга туры килә.* Юлдаш. **Көннекен көнгә ялгау** Һәр көнгә бик авырлык белән ризык, акча һ.б. җиткерү (авыр тормыш алып бару тур.). *Югыйсә бүлешер маллары да юк: ике гаилә дә көннекен көнгә чак ялгап, гомер учагын сүндерми сакларга тырыша.* Р.Мулланурова. *Фронттан яраланып, эштән чыгып кайткан ир-ат та көннекен-көнгә ялгый алмый азаплана.* Ә.Хәсәнов. **Көннең көн буе** Көн дәвамында, озак вакыт. *Көннең көн буе йөрсә дә, район хуҗалыкларын карап, эт булып арыса да, ул [Усманов] Казанга кайтып китә --- иде.* Г.Ахунов. **Көннең көн буена** *к.* **көннең көн буе**. *Нәтиҗәдә, көннең көн буена утырып оешкан әгъзалары язылып, киеренкеләнгән нервлары тынычланып, ятуга эреп китә торган булды.* Г.Гобәй. **Көн өсте** Бер көн эчендә, көн дәвамында, көнендә. *– Һи, йөрүмени бу! – диде [карчык]. – Көн өстенә килеп китәбез без Куандыкка.* Ә.Еники. **Көн сүнү** *к.* **көн кичкә авышу**. *Чынлап та, кышкы көн сүнеп бара иде инде.* Ә.Еники. **Көн сүрелү** *к.* **көн кичкә авышу**. *Ниһаять, көн сүрелгәч, Сания белән Зиннурны берсекөнгә Зиреклебашка кунакка чакырып, юлга чыктылар.* Ә.Еники. **Көн туу** 1) Кояш чыгу; яктыра башлау. *Көн туса, алар авылына барырга җай эзли башлыйм.* Ф.Яруллин. *Көн туса – яу, яу булса – төн!* Р.Батулла; 2) Яңа чор (тормыш) башлану. *80 еллык тарих катламнары артыннан яңа көн туып килә.* Мәдәни җомга. **Көн уртасы** Төш вакыты, кояш төшлектә булган вакыт. **Көн үзәге** 1) *к.* **көн уртасы**. *Атна уртасы, көн үзәге булганга вагонда кеше аз иде.* И.Сирматов. **Көн үзәгендәге** Тиз арада хәл ителергә тиешле; актуаль. *Кадрларны авылда калдыру – көн үзәгендәге катлаулы проблема.* И.Низамов. **Көн чырае** Яхшы мөнәсәбәт, якты йөз. *Аңа [Фәһимәгә] якты көн чырае күрсәтмәделәр инде.* Н.Гыйматдинова. **Көн юк** *к.* **көн булмау**. *Хәерчегә нишләсәң дә көн юк.* Ф.Садриев. **Көн яктысын күрмим** Нәрсәнең дә булса дөреслегенә, үз сүзләренең хаклыгына ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе

**КӨ́НАРАЛАШ** *рәв.* Бер көн үткән саен; бер көн аша. *Минә ул [Гасыйм Сәләхович] көнаралаш диярлек килә, китә, ә Рәмзиянең бер генә тапкыр да аның үз хәле турында сорашканы юк.* Ә.Еники. *Ә ул [Фәһимә] исә, көнаралаш шалтыратып, теңкәгә тиеп, нервыны ашап тора.* Ф.Шәфигуллин. *Сүзне уенга борырга, Хәмитнең көнаралаш табылып торган борчуларын бүгенге сүз үзәгенә алмаска иде аның исәбе.* Р.Вәлиев

**КӨНБАГЫШ** *и.* 1) Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан орлыклары тәлинкә сыман түгәрәк нигез-ояга урнашкан, җимешләреннән май алына торган, озын сабаклы, эре сары чәчәкле үсемлек. *Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, көнбагыш сабаклары арасыннан чыгуга, безгә таба якынлашып килгән бер марҗа түтәен күреп алдык.* Ә.Еники. *Тормышны, ирекне, кешеләрне нык сагынгангамы, кояшка тартылган көнбагыштай сезгә омтылган идем.* Р.Низамиев

2) Әлеге үсемлекнең май алына һәм киптереп яки кыздырып ашала торган

кабыклы орлыгы, җимеше. *Өлкәннәр кодасы яки баҗасы белән очрашып, «сәй» (яки «мәй») эчеп чыгар өчен, ә яшь-җилкенчәкләр исә көнбагыш ярып йөрер өчен генә булса да килә.* Ә.Еники. *Капкачыларга рәхәт, яннарында чуалган малайларның учыннан көнбагыш алып, чарт-чорт шуны яралар.* А.Гыйләҗев

**КӨ́НБАТЫШ** *и.* **1.** 1) Дөньяның дүрт ягының берсе: көнчыгышка капма-каршы булган, ягъни кояш баткан як; мәгъриб. *Көнбатышка таба безнең эшелон кузгалып киткәч, сулышым иркенәйгәндәй булды...* К.Латыйп. *Сугыш көнбатышта да, көнчыгышта да безнең гаскәрләрнең җиңүе белән бетте.* Г.Ахунов. *Палатага кояш нуры төшми: тәрәзәләр көнбатышка караган.* М.Маликова

2) Европаның шул өлешендә урнашкан илләре. *Көнбатышның азат халыклары Карый безгә һаман шикләнеп.* И.Гыйләҗев. *Боларның [белем һәм технологияләрнең] барысын да Көнбатышта – Япониядә, Тайваньда, Сингапурда табарга мөмкин.* Р.Хәкимов

**2.** *с. мәгъ.* Берәр географик территориянең кояш батышы өлешендә урнашкан. *Көнбатыш Себер*

**КӨНГӘ́-КӨН** *рәв.* Бер көнгә бер көн исәбе белән. *– Бер дә борчылма, көнгә-көн итеп исәпләрбез, – диде Мәрфуга, җиңгәсенең аптырашта калуын күреп.* Мәдәни җомга

**КӨНГӘ́ЧӘ** *рәв.* 1) Билгеле бер көнгә кадәр. *Мин, шушы көнгәчә әле беркемне дә сөймәгән, бер генә егеттән дә чын мәхәббәт сүзе ишетмәгән --- кыз, кинәт иргә чыгу ихтималы алдында торып калдым.* Ә.Еники. *Соң көнгәчә – шушы бәйге. Соң көнгәчә – тантана!* Л.Зөлкарнәев

2) Нинди дә булса бер вакытка кадәр, берәр моментка чаклы. *Өстәвенә анда мин тәрбияләгән балет осталарыннан шушы көнгәчә котлаулар, тәбрикләүләр килеп тора.* Н.Юлтыева. *Алар [авыл халкы] язган истәлекләр буыннан-буынга күчеп, безнең көннәргәчә килеп җиткән.* Казан утлары

**КӨНГЕ** *с.* 1) Нindидер бер көнгә караган; билгеле бер көндәге. *Кичәге көнге кебек кенә түгел бүген, балык шәп каба.* Ә.Еники. *Теге көнге шикелле, соңыннан Роза берәр нәрсә сизеп алса?* В.Нуруллин. *Рәмиз күңелендә ул көнге хатирәләр яңара.* Ф.Яруллин

2) *диал.* Көндезге. *Көнге эшләреңне Сөенеп сөйли-сөйли, Иңнәремә кулың салганда, Сине шундый кысып кочар идем, Әгәр дә бу Иптәшлекне вату булмаса.* Х.Туфан

**КӨНГЕРӘ** *и. ингл.* **1.** Сумкалылар семьялыгыннан, арткы аяклары озын, алгы аяклары кыска булган, баласын сумкасында йөртә һәм ике аякта сикереп йөри торган имезүче хайван. *Көнгерә кебек түмгәктән түмгәккә сикердек.* Х.Камалов. *Түшендәге пальто төймәсен ычкындырып, елтыр күзле бәләкәй этне куенына урнаштырган кеше килә – әйтерсең лә көнгерә!* Ш.Галиев. *Ишек төбендәге оясыннан көнгерә күз карашы белән озатып калды.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Көнгерә тиресеннән ясалган; көнгерә мехыннан тегелгән. *Шул [Байгилде] әйткән: «Пугачауның башы кылыч астында, уң кулы богауда. Сул кулын кискәнгә – бер йөгерек ат белән бер көнгерә тун», – дигән.* Г.Бәширов. *Улы бүләк иткән көнгерә бишмәтен киеп, Габдулла абзый түбән якка таба атлады ---.* Казан утлары

**КӨНДӘГЕ** *с.* 1) Көн саен кабатлана торган; һәрвакыттагы; гадәттәге. *Алгы бүлмәдә утыручы лаборант кыз көндәге тәртип буенча бүген дә яңа газитәләрне аның өстәленә кертеп куйган иде.* Ә.Еники. *Зәйтүнә зарыгып, ут йотып торса да, көтү бүген көндәгедән күп соңгарып кайтты.* А.Гыйләҗев. *Гафур бабай белән урманга баргандa, тәмле йокыдан аерылуның беренче чирканчыгын алган Таһирҗан йокларга көндәгедән иртәрәк ятты.* З.Фәйзи

2) Нинди дә булса сүздән соң килеп, эш яки хәлнең шул сүз белән тәгъбир ителгән конкрет бер вакытка караганын белдерә. *Шул көндәге бөек яктылык һәм бу хәерсез төн...* Ә.Баян. *[Равил:] Рәнҗемисеңдер бит теге көндәгеләр өчен...* Н.Гыйматдинова

**КӨНДӘГЕ́ДӘЙ** *рәв. к.* **көндәгечә**. *Көндәгедәй шатлык алып килә Һәм шатлыгын җәеп туа таң...* Ф.Кәрим. *Сибгатулла бүген артельгә көндәгедәй соңгарак калып барды.* Ә.Исхак. *Ул көнне әни мине көндәгедәй иртәрәк уятты.* Г.Бәширов

**КӨНДӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* Гадәттәгечә; һәр көндәге шикелле, башка көндәгедән аерылмаган. *Һәм, көндәгечә, бу кинода билетлар бөтен сеансларга да сатылып беткән иде.* Ә.Еники. *Концерт дигәнебез көндәгечә башланды.* И.Нуруллин. *--- Көндәгечә менә бүген дә, Кырык эшен ташлап кырык якка, Мине, Рәйсә, синнән башка Озатмады шулай беркем дә.* Р.Закиров

**КӨНДӘЛЕК** I *и.* 1) Берәр кешенең үз тормышы, кичерешләре яисә үзе өчен мөһим тоелган вакыйгаларны теркәп барган язмалары; шул көндәлек язмалар тупланган дәфтәр. *Ә менә бөтенләй әһәмиятсезгә саналып, көндәлеккә язарга да кирәк табылмаган вакыйгалар энәсеннән җебенә кадәр гомер буе саклананалар.* М.Әмир. *Анда синең көндәлегең бардыр, шуны укыйм әле дип сезгә кергән идем, әниең эзләде-эзләде, таба алмады.* Ф.Яруллин. *Ул [Галимҗан абый] гомере буе диярлек көндәлекләр яза, үзенең туган төбәген өйрәнә.* Сөембикә

2) Мәктәптә билгеләр кую һәм өйгә бирелгән эшләрне язып бару өчен хезмәт итә торган махсус дәфтәр. *Әйтмичә генә өйдән чыгып китүләр, кичләрен соң кайтулар, көндәлегендә моңарчы булмаган өчлеләрнең күренә башлавы аны [Сөембикәне] бик борчый иде.* Ф.Садриев. *– Тырышкан таба ул, ташка кадак кага ул! – дип шаярта хәзер Тимербай, көндәлегендәге бишле билгесен күрсәтеп.* Мәдәни җомга

3) Көндәлек эшләрне, очрашуларны һ.б. планлаштырыр өчен алдан теркәп, билгеләп куя торган махсус калын дәфтәр, блокнот

4) Еш кулланыла, һәрвакыт мөрәҗәгать ителә, укыла, карала торган, ягъни һәрвакыт өстәлдә яисә кул астында тора торган китап, басма, җыентык һ.б. *Быелгы календаребызны да язучыга да, югары уку йорты шәкертләренә дә,*

*бакча үстерүчеләргә дә, авыруларга да кирәкле, файдалы көндәлек, бер кулланма булсын дип тырыштык.* Татар мөселман календаре

**КӨНДӘЛЕК** II *с.* 1) Һәркөнне кабатлана торган, һәр көн саен була яки башкарыла торган. *Берлинга! Элек безнең бөтен армиянең сугышчан лозунгысы булган бу сүз хәзер гади солдатның көндәлек сүзенә әверелде.* Ш.Мөдәррис. *Көндәлек эштә, алар белән очрашканда, бергәләп колхозларга чыкканда, Тимерхан алардан [белгечләрдән] өйрәнә, агротехника һәм зоотехния буенча элементар кагыйдәләрне төшенә башлый.* Г.Ахунов. *Китап укуга һәм язу эшләренә күп вакыт сарыф итү белән беррәттән, Муса [Җәлил] көндәлек дәресләрен дә вакытында әзерләргә өлгерә.* Казан утлары

2) Һәр көн кулланыла, киелә торган. *И.Рәми һәм француз галимнәренең бу хезмәтләре – минем көндәлек өстәл китапларым.* М.Мәһдиев. *Аннары йорт арасында кия торган көндәлек һәм эш киемнәрен әзерләде [Рәхимә түти].* З.Фәйзи

3) Һәр көн чыгарыла, басыла торган. *Көндәлек газеталарны исә ил халкының 24 проценты гына укый.* Р.Фәйзуллин. *Беренче шигырьләрем көндәлек матбугатта 1960 елда чыга башлады.* Ф.Яруллин. *Көндәлек гәҗитләрне карап-укып барган кеше бик күп яңалыклардан хәбәрдар була ---.* Ватаным Татарстан

4) Гадәттәге, гадәти; башкаларыннан бернәрсә белән дә аерылып тормаган. *Дөрес, көндәлек гади тормыш үзенең моңарчы хөкем сөргән тәртип-низамы, дине-шәригате белән искечә һаман бара иде әле.* Ә.Еники. *Үз фикереңне төгәл, дөрес итеп әйтә һәм яза белү, аларны көндәлек аралашуда уңышлы файдалану кешенең интеллектын билгели.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘР** *к.* **көндәлек** I (*1 мәгъ.*). *Мин баламның көндәлек дәфтәрен язудан, язылганын укудан рәхәтлек таба идем.* Г.Кутуй. *Күрәсең, ул [А.Алиш] көндәлек дәфтәре алып барган, нәсерләр дә язган.* Р.Мостафин. *Чаллыярдагы ыгы-зыгы шулкадәр көчле булды, язмыш Гаярны дулкыннарның шундый биек өркәчләренә утыртып йөздерде ки, вакыйгаларны көндәлек дәфтәре битләренә күчереп барырга вакытны бөтенләй диярлек калдырмады.* Г.Кашапов

**КӨНДӘШ** *и.* **1.** 1) Берничә хатыны булган ирнең хатыннары бер-берсенә карата шулай аталалар. *Гайшә көндәш бала китерә алмый икән.* Р.Мулланурова. *Көндәш белән яшәү бер Хәлимәдән генә калмаган.* Ф.Сафин. *Тимерче хатыннары көндәш булып яшәмәгәннәр, ә ике якын дус, ахирәт булып, бергәләшеп тату дөнья көткәннәр.* З.Зәйнуллин

2) Бер үк ир-егетне яисә хатын-кызны яратучы яки аңа ниндидер дәрәҗәдә мөнәсәбәттә булган ике кеше (бер-берсенә карата). *Көндәшемне өзгәләп ташларлык булып, ишекне кискен генә ачтым.* А.Шамов. *Көндәш җөмләсен төгәлләп өлгермәде, Күкчәчәк ыржайган бикәнең авызына вак бәрәңге кыстырды: – Безнең исемнәрне гайбәткә буяма, яме?!* Н.Гыйматдинова

3) Спорт уеннарында һәм ярышларында бер-берсе белән көч сынашучы спортчы яисә команданың берсе. *Шахмат тактасы артына утырсам да, көндәшем спорт мастеры ук булмаса, беренче разрядлыларга гына биреште юк.* А.Хәсәнов. *Шуңа да көндәшләр капкасына даими туп кертүчеләр арасында уенчыларыбыз алдынгы булмау куркыныч түгел.* Шәһри Казан

4) Нинди дә булса бәхәстә, ярышта каршы якта булган һәм кемнән дә булса өстен чыгарга омтылучы, җиңеп чыгарга тырышучы икенче берәү. *Тубыкбай сизелер-сизелмәс кенә билен уйнатып алды, кенәз кысып китерергә теләгән сынын бушата төште һәм үз чиратында көндәшенең касыгына йодрыгын кадады.* М.Хәбибуллин. *Әлҗаманның төрле ягын капшап караганнан соң, алып Бәргән, кинәт аска кереп, көндәшенең билен шатырдатып тотып алды да, «һек» иткән тавыш чыгарып, дошманын һавага чөйде.* Р.Батулла

5) Бер үк кулланучыга исәпләнгән һәм бер-берсенә конкурент булган товарлар, җитештерү чаралары һ.б.ш.ның берсе. --- *Үзебездә җитештерелгән комбайнның бәясе чит илдәге «көндәшеннән» күпкә очсыз.* Ватаным Татарстан

6) Үзе белән бер юнәлештә, өлкәдә эшләгән, хезмәт куйган һәм аңа конкурент булган һөнәр иясе. *[Идрис:] Нигә йотар икән? Мин аның көндәше түгел, эштә дә аның урынына үрмәләргә җыенмыйм.* А.Гыйләҗев. *Үзеңнән көчлеләр арасыннан ул көндәшләрне эзләргә һәм шулардан ким җырламаска дигән максат куеп иҗат итәргә кирәк.* З.Сәхәбиева. *Сәхнәдәге көндәшләренә дә үзе белгәннәрне өйрәтүдән авырсынмады [Шәфика Котдусова].* Мәдәни җомга

7) Көнләшүче; кемгә дә булса аяк чалырга, начарлык эшләргә теләүче; дошман. *Чит айгырны байталга якын җибәрмәс өчен, көндәшләрниләр генә кыланмый монда.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Көнләшү нәтиҗәсендә кемгә яисә нәрсәгә дә булса начар мөнәсәбәттә булган. *Көндәш хатын шымчы булыр.* Әйтем. *Көндәш командадан барыбер җиңдермәбез дип башладылар бу уенны футболчылар.* Шәһри Казан

**КӨНДӘШЛЕ** *с.* Көндәше (*1–2 мәгъ.*) булган. *Усак яфрагы көндәшле хатыннар шикелле: җилсез көндә дә кыймылдап тора.* Әйтем. *Көндәшле бичара серен, кайгы-борчуларын тагын кемгә сөйләсен инде ---.* Казан утлары

**КӨНДӘШЛЕК** *и.* 1) Көндәш булып яшәү; кемгә дә булса көндәш булу. *Һай, яман да икән көндәшлек хәлләре.* М.Әмирханов. *Әле дус йөрсәләр дә, заманында көндәшлек рәхәт булмагандыр.* Г.Якупова

2) Кешеләр, оешмалар, илләр һ.б. арасындагы үзара ярышу, өстен чыгарга омтылу; конкуренция, конкурентлык, конкурент булу. --- *карачыларның һәркайсы үз ягын каера башлады, биләр арасында астыртын көндәшлек тамырланды.* Ф.Латыйфи. *Ә бию сәнгатендә Фәйзигә тиңләшерлек тә, аның белән көндәшлек итүче артистлар да булмый.* Ф.Фәтхи. *Читтән кертелгән азык-төлек товарлары белән көндәшлек (конкурентлык) итәргә хәзерләнмәгән җирле җитештерүчеләргә базарда үз урыннарын табу һәм бу*

*урыннарны саклап калу кыенлаша.* Ватаныбыз тарихы

**КӨНДЕЗ** *рәв.* **1.** Иртә белән кич арасындагы вакытта. *Хәят чәй куйды, ашарга көндез пешергән пилмәнне кайнарлады.* Ф.Садриев. *Алар [Булатлар] өчен чыршы бәйрәме көндез булды.* Х.Бәдигый

**2.** *и. мәгъ.* Иртә белән кич арасындагы вакыт. *Июньнең башы, ап-ачык кояшлы көннең көндезе.* Ф.Әмирхан

◊ **Көндез чыра яндырып эзләү** Бик нык, бөтен җирдән, бөтен дөньяны актарып эзләү; эзләмәгән җирне калдырмау. --- *Тамара Сергеевна кебек кешене бит ул [Петя] көндез чыра яндырып эзләсә дә яңадан табачак түгел!* Ә.Еники. *Хәзерге заманда бу салам түбәле, җиргә сеңеп беткән кырык тирәүле каралты-кураны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табалмассың.* Р.Батулла

**КӨНДЕЗГЕ** *с.* 1) Иртә белән кич арасындагы; көн уртасындагы. *Төнлә дә көндезге кебек якты шәһәрдә үскән кыз бала ничек караңгыдан чирканмый икән?* Н.Гыйматдинова. *Көндезге эсседә борчылган сыерлар хәзер кадалып ашыйлар, бу көтүлеккә төшкәннәренә өч көн, үлән әйбәт, күпереп тора.* А.Гыйләҗев. *Көндезге сәгать уннар тирәсе.* Г.Мөхәммәтшин

2) Көндез башкарыла торган. *Көндезгесен җәмгыять үзе карый иде, ягъни сез дигән сүз.* М.Маликова

3) Көндез кулланыла, киелә, тотыла һ.б. торган. *Хатын икенче бүлмәгә кереп, Заһит биреп җибәргән алтын әйберләрне тиз генә диван астына тыкты да, йокы күлмәген кияргә дип, көндезге киемнәрен салды.* Ф.Яруллин

4) Көндез уяу булган, көндез хәрәкәттә булган (хайваннар һәм бөҗәкләр тур.). *Акбарның ул тирәдән узып барышлый искәргәне бар: аннан көндезге тилгәннәр, төнге ябалаклар эзләнмичә, тукталмыйча, ары таба узалар да китәләр иде.* Ә.Гаффар. *Г.Петров мәгълүматлары буенча, 2005 елда Татарстан территориясендә көндезге тәңкәканатлыларның 143 төре билгеләнгән.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

5) Уку йортларында даими, һәр көнне һәм гадәттә көндез укуга корылган. *Мин педагогия институтына барып кергәч, ул анда читтән торып укуыннан көндезге укуга күчте.* М.Маликова. --- *студент чагында ук фәнни эшкә керешү, аннан көндезге аспирантурада уку һәм кандидатлык диссертациясе яклау – фәнгә килүнең иң сыналган һәм нәтиҗәле юлы.* Х.Миңнегулов. *Институтта көндезге һәм читтән торып уку бүлекләре бар.* Э.Шәрифуллина

**КӨНДЕЗГЕ АШ** *и.* 1) Көн уртасындагы, төш, өйлә вакытындагы ашау. *Бәрәңге кәтмәнләвемнең рәте булмаса да, көндезге ашка чаклы өйгә кереп күренеп йөрмәдем.* И.Сирматов. --- *Бер көнне көндезге ашка кайткач, ул [Хәмзә абый] авылдан бөтенләй исереп килде.* Н.Булатов

2) Шул вакытка әзерләнә торган ризык, ашамлык. *Вәли кайтып кергәндә, Мәрьямбикә өстәлгә көндезге ашны әзерләп, ашъяулыклар яба, тәлинкә, кашык, пычак, чәнечке, борыч, серкә, икмәк китереп йөри иде.* Р.Гайфуллина. *Көндезге ашны әзерләгәч кенә чыгармын мин юлга, дип әйткән иде бит апа.* Казан утлары

**КӨНДЕЗГЕЛЕК** *и. сөйл.* **1.** Көндез кулланыла, файдаланыла торган нәрсә; көндезгә билгеләнгән, көндезгә каралган нәрсә. *Көндезгелекне ашап, бераз уйнаганнан соң, куыш эчендә йоклап калган иде улы, кичкә – юк.* З.Зәйнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Көндез кулланыла, файдаланыла торган; көндезгә билгеләнгән. *Менә атларга көндезгелек салам төйим дә аннары кайтырбыз...* Г.Бәширов

**КӨНДЕЗЕН** *рәв. к.* **көндез**. *Иртән дә яуды [яңгыр], кичен дә яуды, көндезен дә, төнлә дә туктап тормады.* Г.Ахунов. *Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек.* Ә.Еники. *Көн саен кич яшен дә яңгыр, көндезен кояш.* Җ.Ильясов

**КӨНДЕЗЛӘРЕН** *рәв.* Һәрвакыт көндез. *Көндезләрен эш, төннәрен китап өстендә утыру.* М.Маликова. *Көндезләрен түзә лә ул, ә менә төннәрен!..* А.Хәлим. *Көндезләрен җилсез-аяз, ә төннәрен җылы яңгыр явып үтә.* Ә.Еники

**КӨНДИ́Н-КӨН** *рәв. иск. к.* **көннән-көн**. *Көндин-көн үскән, ди, ул батыр.* Әкият. *Андин соң Түләк берлә кызның көндин-көн мәхәббәтләре артыграк булды.* Дастан. *Рәхмәт, Алла разый булсын, гомереңез озын улыб, дәүләтеңез вә бәхетеңез көндин-көнгә зиядә улсын.* Г.Тукай

**КӨНЕ́-СӘГАТЕ** *и.* 1) Тиешле вакыты, үз вакыты. --- *Көне-сәгате җиткәч әйтермен.* Ватаным Татарстан

2) Билгеле бер вакыт. *Көненә-сәгатенә, кәефе-мәнфәгатьләренә карап, ул [Мотаһар] бу күптән таныш, дистә еллар буе тапталган, мең-миллион тапкыр йөрелгән аралыктан төрле рәвештә --- үтә ала.* А.Хәлим

◊ **Көне-сәгате белән** Бик тиз, кичекмәстән, шунда ук. *Тукай комитетының карарын мин көне-сәгате белән үк белдем.* Ә.Еники. *Бу вакыйганы көне-сәгате белән хәтердә калдырырга кирәк.* А.Хәлим. --- *Сүз әти-әниләргә көне-сәгате белән ирешә.* Ватаным Татарстан

**КӨНЕ́-ТӨНЕ** *рәв.* Берөзлексез, бертуктаусыз; озак вакыт дәвамында. *Гыймай көне-төне рамнар ясап картайса да, моның кадәр байлык туплый алмас.* Ф.Яруллин. *Көне-төне селкенми дә бер урында яту никадәр генә түйдырмасын, эчке сызлавы адәм түзәрлек булса, Габбани ыңгырашмады.* Ә.Галиев. *Радиодан, телевизордан көне-төне шалтыраганнары да җиткән.* Р.Вәлиев

**КӨНЕ́Н-ТӨНЕН** *рәв. к.* **көне-төне**. --- *Зенит туплар улый-күкри көнен-төнен.* Ш.Мөдәррис. *Ни өчен дигәндә, укуга Фәләхтән ныграк бирелгәннәр, көнен-төнен дәреслек өстендә утырган укучылар да бар иде алар классында.* В.Нуруллин. *Улының хәл ителмәгән язмышы балык кылчыгы кебек аның бугазына килеп кадалды, көнен-төнен сызлатып тора башлады.* А.Гыйләҗев

◊ **Көнне-төнне белмичә** Бик нык бирелеп, ял итмичә, үз-үзен аямыйча эшләү, ни беләндер шөгыльләнү һ.б. турында. *Син көнне-төнне белмичә тырышып эшлә-эшлә дә, синең хезмәтеңне зурлап, сине Геройга тәкъдим итсеннәр дә, шул чакта сине күралмый, синнән*

*көнләшә торган берәү килеп чыгып бөтен эшеңне бутап бетерсен дә – шуңа түзеп торып кара син!* В.Нуруллин

**КӨНЕНӘ** *рәв.* Бер көн эчендә, көн дәвамында. *Ә Андрюшиннар – олысы булсын, кечесе булсын – тозлы балыкны көненә биш тапкыр ашасалар да туймыйлар ---.* М.Әмир. *Әнә аш өенең тәрәзәләре ачык, ишеге ачык, мичен көненә икешәр ягудан тәмугка әйләнгән эсседә хатын-кыз кайнаша.* Ә.Еники

**КӨНЕНДӘ** *рәв.* 1) Шул ук көнне. *Мөселманнар мәетне көнендә җирлиләр.* М.Маликова. *Группабызның кызлары да тәртиплеләр, хәер, биредә тәртипсезләнергә ирек куймыйлар, директорыбызның талканы коры, андыйларны мәктәптән куу турында көнендә үк боерык яздырып элдерә.* Г.Галиев

2) Алдан билгеләнгән көнне; тиешле вакытта. *Ниләр күрсәм дә мин юл йөргәнемдә, Төгәл йөрдем, төгәл килдем, көнендә.* Котб

3) Нәкъ шул вакытта. *Архитекторлар һәм сынчылар ул әмерне көнендә үк гамәлгә ашырып куйдылар.* Ф.Баттал

**КӨНҖӘЛӘ** *и.* **1.** 1) Кул белән йон эрләү өчен агачтан ясалган җайланма (бер-берсенә туры почмак ясап беркетелгән ике агач кисәгенең горизонталь өлеше – утыру, ә вертикаль өлеше йон бәйләп кую өчен кулланылган); каба. *Безнең якта йонны бәйләп куеп эрли торган җайланмага көнҗәлә диләр.* Х.Сарьян. *Йон эрли... көнҗәлә итеп Урындыкның аягын.* Р.Гаташ

2) Эрләр өчен әзерләнгән йон, сүс, мамык. *Көнҗәлә дип, эрләр өчен бәйләп куелган йонның үзенә әйтәләр.* Х.Сарьян. *Аннан, иелә биреп, башын какты: кабадагы көнҗәләгә охшап тузгыган чәчләреннән энҗе тир бөртекләре сибелде.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кабадагы йон кебек, шуңа охшаган. *Зәйтүнә аларны [тилгәннәрне] куркытып, бер башына көнҗәлә сүс бәйләгән таягын болгый...* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Тузгып, күпереп, кабарып торган. *[Асия:] Ә бит монда кайчандыр кап-кара көнҗәлә чәч иде.* Г.Ахунов. *Биек нарат башында, аучыларга мыскыллы карап, көнҗәлә койрыклы тиен ботактан ботакка сикерә.* Г.Әпсәләмов. *Һич таракка буйсынмыйча, йондай күпереп торган чәчкә дә көнҗәлә чәч диләр.* Х.Сарьян

◊ **Көнҗәлә баш** Чәчләре күпереп, тузып торган хатын-кызга кимсетеп әйтү сүзе

**КӨНҖӘЛӘ́ДӘЙ** *с.* Тузган, таралмаган. *Көнҗәләдәй чәч*

**КӨНҖӘЛӘ́ ТАЯГЫ** *и. к.* **көнҗәлә** **1.** (*1 мәгъ.*). *Ә көнҗәләне бәйләп куйган җайланмага каба диләр. Халык телендә көнҗәлә таягы дигәне дә бар.* Х.Сарьян

**КӨНҖЕТ** *и. бот.* Көнҗетчәләр семьялыгыннан, Африка һәм Азиянең тропикларында таралган, культуралы төре көньякта игеп үстерелә һәм орлыгыннан май алына торган үләнчел үсемлек. *Өстенә кыздырылган сипкел-сипкел көнҗет орлыклары сибелгән андый пәканд [ипи] айлар буенча бозылмый.* Т.Нәбиуллин. *Үзе кайнар, үзе бераз кызарып пешкән, өстендә сипкел-сипкел кыздырылган көнҗет орлыклары, үзе ак, күпереп тора, ә исе, исе – һушларыңны алырлык!* Р.Мирхәйдәров

**КӨНҖЕТЛЕ** *с.* Көнҗет кушылган, сибелгән, составында көнҗет булган. *Көнҗетле икмәк*

**КӨНҖЕТЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Җылы яклардагы кайбер икеөлешле үсемлекләрне эченә алган семьялык

**КӨ́НИТЕШ** *и. к.* **көнкүреш** (*1 мәгъ.*). *Егетләргә ресторан бусагасы тормышы белән җылы саубуллашып, үзгә көнитеш юлына чыгу сәгате җиткән иде.* Т.Галиуллин. *Кешенең робот рәвешендәге мәгънәсез көнитеше турындагы идея җәяүле уйланулары аша бирелә.* Г.Гайнуллина

**КӨ́НКҮРЕШ** *и.* 1) Билгеле бер кеше, халык, катлау һ.б. яшәешенә хас гадәтләр, үзенчәлекләр, яшәү рәвеше. *Көнкүрештәге үз-үзен тотышы Әмирхан абыйның иҗатына да хас.* Т.Миңнуллин. *Ләкин [Гасыйм Сәлахович] үзе дә сизә: нәрсәнедер белеп җиткерми, аңлап җиткерми... Әйтик, кешеләрнең көнкүрешләрен...* Ә.Еники. *– Анда күп нәрсәләр бар, – дип башлады Ласхай һәм Өскит иленең кануннары, кешеләре, аларның тормышы, көнкүреше турында сокланып сөйләде.* Р.Батулла

2) Тормыш, яшәеш, көн күрү хәле. *Икенчедән, үз көнкүреше белән артык мавыгып киткән кеше халык ихтыяҗын күрми башлый.* Ә.Еники. *Әйе, ул [Илдус] – булдыклы ир, көнкүреше төзек-камил иде.* Н.Гыйматдинова. *Клара аларның көнкүреш хәлләре белән дә, читләтеп кенә булса да, кызыксынып карады.* Ә.Еники

**КӨНЛӘП** *рәв.* 1) Бер көнгә исәпләнгән хәтле; бер көн дәвамында. *Менә синдә ялкау йокылары Сәгать түгел, көнләп сузыла.* М.Җәлил

2) Билгеле көн дәвамында; сөйләмдә күрсәтелгән көн чамасында. *Атна-ун көнләп укыгач, безнең курсны бөтенләе белән колхозга бәрәңге алырга озаттылар.* Э.Касыймов

◊ **Көнләп түгел, сәгатьләп** Бик тиз; кызу темплар белән. *Бу малай айлап түгел, көнләп түгел, сәгатьләп үскән, ди.* Әкият. *Шул унбиш ел чамасы вакыт эчендә шәһәр көнләп түгел, сәгатьләп үсте.* Р.Сабиров. --- *Симезләр армиясе бөтен дөньяда көнләп түгел, сәгатьләп арта.* Мәдәни җомга

**КӨНЛӘШЕ́РДӘЙ** *с.* **1.** Көнләшерлек. --- *Җир шарында бәхетле чор тормышының бәхетле баласы булып туу үзе үк күпләр көнләшердәй вакыйга түгелме соң?* М.Вәлиев. *Биш йөз ел буена татарны бетерә алмыйча интеккәннән соң, Рәсәй туфрагында Иблис көнләшердәй ике шәхес пәйда булды: Ленин белән Сталин.* Р.Батулла. *Ай көнләшердәй кыз иде, Үзе дә шуны белде.* Ә.Баян

**2.** *рәв. мәгъ.* Көнләшердәй итеп

**КӨНЛӘШЕРЛЕК** *с.* **1.** Сокланырлык, кызыгырлык булган. *Әлмәт театры артистлары белән спектакль куймаган режиссёр бик сирәктер, әлмәтлеләргә бу яктан да көнләшерлек.* Сәхнә. *Миргалим Харисовның колачы матур мәгънәсендә көнләшерлек.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Сокланырлык итеп

**КӨНЛӘШТЕРЕРЛЕК** *с.* **1**. Соклану, кызыгу тудыра торган

**2.** *рәв. мәгъ.* Сокландырырлык. *Иң оста нәкыш төшерүчеләрне дә көн-*

*ләштерерлек итеп эшли [Дәүран].* М.Хәбибуллин

**КӨНЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Кемдә дә булса көнләшү хисе уяту. *Ара-тирә көнләштерә дә бел, бик үсенеп китмәсен ул, куркыбрак та торсын.* Ә.Еники. *Сезне көнләштерер өчен шулай иттек.* Ш.Камал

2) Нәрсә (кем) дә булса зур кызыксыну, соклану уяту. *Табигатьнең искиткеч серлелеге аңарда [Нәфисәдә] табигать көченә ихтирам уята, аны дулкынландыра, хәтта көнләштерә иде.* Г.Бәширов

**Көнләштерә төшү** Тагын да ныграк көнләштерү

**Көнләштереп алу** Бераз гына көнләштерү

**Көнләштереп бетерү** Тәмам көнләштерү; барысын да көнләштерү

**Көнләштереп йөрү** Шактый вакыт көнләштерү; даими, еш көнләштерү

**Көнләштереп тору** Даими, еш көнләштерү

**КӨНЛӘШҮ** *ф.* **1.** 1) Яраткан, кадерле булган кешеңнең мәхәббәттәге тугрылыгына, хисләренең, мөнәсәбәтләренең сафлыгына шикләнеп карау. *Көнләшүем дә бүтәннәрнекенә охшамаган, үземне эчтән кимерә-кимерә газаплый идем.* Н.Гыйматдинова. *Кайчагында көнләшү хисе күңел тәрәзәләренә чиртеп куйса да, бу шомлы шикләнүләрне җәһәт-җәһәт куарга тырышам.* Ә.Моталлапов. *Үзе [хатын] юкта көнләшүдән буылам.* Р.Батулла

2) Башкаларның өстенлегенә, уңышына, мөмкинлегенә яисә әйберенә кызыгу һәм шуны ук теләү. *Аның [Әнвәр Давыдовның] шулай рухланып укуын күреп-ишетеп, мөгаен, артистың да көнләшер иде.* К.Миңлебаев. *Кызыйлар кала кызыгып, энекәшләр – көнләшеп!* Р.Миңнуллин. *Әллә каян беленеп тора: безнең бәхеттән көнләшәләр.* Ә.Баян

3) Кешеләрнең өстенлеген, уңышын, шатлыгын, әйбәт тормышын һ.б. күреп гарьләнү, кара көнчелек хисе белән яну, ул кешегә аяк чалырга, комачауларга теләү. *Мактап сөйләүчеләр күп булган кебек, көнләшүдән аның [Кәримнең] уңышларын юкка чыгарырга тырышып сөйләнүчеләр дә булмады түгел.* Ә.Еники. *[Сәгыйть:] Теге сатучыларга әйтмә, юкса көнләшү китәчәк.* Ф.Яруллин

**2.** *и. мәгъ.* Кемнең дә булса матди яки рухи яктан өстенлеген яки башкаларга мөнәсәбәтен күргәч (белгәч) туган кызыгу, соклану яки, киресенчә, күралмау хисе. *Гүя хатынының бу байлыклары бер дә аның өчен түгел иде. Хәтта көнләшү дә кузгалмады аңарда: кузгалырга иренде, ахрысы.* Ә.Еники

◊ **Көнләшү корты** Көнләшү хисенең тынычлыкны алып, һәрвакыт күңелне бимазалап торуы хакында. *Миләүшәнең күңелендә көнләшү корты кузгалды. Хәер, бу көнләшү генә түгел, Әлфреднең сүзләре аның горурлыгына ук барып кадалды.* Ф.Яруллин

**Көнләшә башлау** Көнләшергә тотыну. *Ярый, яшь хатын бала тапкач, карт хатын көнләшә башлый.* Әкият. *Зәйтүнә Насретдинова күзләрендә кинәт көнләшә башлау чаткылары чагылып алды: – О-о!.. Хәтта Киров театрының үзенә-ә!* Р.Вәли

**Көнләшеп алу** Бераз, кыска вакыт аралыгында көнләшү. *Күңеле белән ул [Хәнәфи агай] атларның шундый язмышына көнләшеп алды.* Җ.Мостафин

**Көнләшеп йөрү** Еш, һәрвакыт көнләшү. *Аның [Сыртакның] осталыгыннан көнләшеп йөрүче сунарчыларга сөенечтер бу җиңелү, сөенеч кенә түгел, бәйрәм булгандыр.* Р.Батулла. *Эзлә, тап шул бәхетне, ә кеше бәхетенә кызыгып, көнләшеп йөрмә, аның бәхетен тартып алырга да тырышма.* Р.Вәлиев

**Көнләшеп кую** Кыска гына вакыт, аз гына көнләшү; бер тапкыр көнләшү. *Теге мут җан хатын янында шундаен сырпалана иде ки, вәзир көнләшеп куйгандай булды.* М.Хәбибуллин. *Айзат Нурбакның Тамарага тутырыптутырып каравын, Тамараның да аңа ничектер уңайсызланган, бераз оялган шикелле елмаебрак күз салуын күреп, «ну тиз дә дуслаша соң кешеләр» дип көнләшеп куйды.* Г.Мөхәммәтшин. *Дөресен әйтим, мин алардан көнләшеп тә куйдым.* А.Хәлим

**КӨНЛӘШҮЛЕ** *с.* Көнләшү катыш. *Килен китүне күреп калганда, һәркем көнләшүле яшәреп кала.* М.Галиев

**КӨНЛӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **көнләшү**. *Егет чагында миннән көнләп, Әскәр белән сугышканые – кулы яман да каты аның.* Ф.Шәфигуллин. *Юк, бу тансыклавы хатынны сагынудан түгел иде, хәтта көнләүдән дә түгел, хатынның бала табып үстерә башлагач кына яхшы якка үзгәрүеннән гаҗәпләнү тойгысы гына иде.* М.Хәбибуллин. *– Бу хатынны көнләсәң дә ярый, – дигән уфтану белән, үзенә язмаган беренче мәхәббәте артыннан сокланып карап калды Хисмәтулла.* Ә. Моталлапов

**Көнләп йөрү** Озак вакыт дәвамында көнләү. *Сәлимәнең еллар буе көнләп йөрүен ул каян белсен.* Казан утлары

**Көнләп кую** Кыска вакыт аралыгында, бер тапкыр көнләү

**КӨНЛЕК** I *с.* 1) Бер көнгә билгеләнгән, билгеләп куелган. *Блоклар өстендә нәкъ унбиш минут эшлибез – бу безнең көнлек норма.* Ә.Сәлах. *Без төшенеп җиткәнче, «Комбайнчы Һади Абзалов, көнлек нормасын 120% үтәп, беренче урында бара» дип язылган, казыкка аркылы беркетелгән тактаны минем кулыма, «Комбайнчы Гимаз Кашапов ике көн рәттән көнлек нормасын 110% ка үтәде» дип язылганын Фоат абый кулына тоттырды.* Г.Галиев. *Дөрес, көнлек норманы үтәми калган юк югын.* Р.Вәлиев

2) Сөйләмдә күрсәтелгән көн исәбенә җитәрлек, шул вакыт исәбенә билгеләнгән. *Бүген кич эштән кайткач, капчыкларыбыздагы бәрәңгеләребезне чамалап карадык: бик кысып ашаганда да, җиде-сигез көнлек кенә калып бара икән.* Г.Галиев. *Болгар халкының кайберсе, йола куша дип, әле булса мәет янына өч көнлек ризык куя.* М.Хәбибуллин. *Үзең үлгәч тә өч көнлек эш кала, диләр бит.* Ә. Моталлапов

3) Бер көн эчендә булган, бер көндә башкарылган яки башкарыла торган. *Миңа көнлек эшләргә ялланып йөрүдән башка чара калмады.* Г.Галиев // Сөйләмдә күрсәтелгән көн кадәр дәвам иткән яки итә торган, шул кадәр көннәргә сузылган. *Өске Кирмәнгә бер көнлек юл калды.* М.Хәбибуллин. *Алып та киттеләр, Иваново өлкәсенең Гороховец лагерьларында ике көнлек хәрби*

*әзерлеген пулемётчы булып эшли башлап, миномётчы булып тәмамлаганнан соң, --- Мотаһарны һәм аның кебек иреннәннән ана сөте дә кипмәгән өч йөз селәгәй малайны сугышка да ыргыттылар.* А.Хәлим

4) Бер көн эчендә җыелган, тупланган яки җыела, туплана торган; эшләп алынган яки алына торган. *Кәримә менә шул сыерның көнлек сөтен беренче айда ук унике литрга җиткерде.* Ә.Еники. *Боларның фәкыйрьрәкләре, көнлек хезмәт берлән яши торганнары балаларын-чагаларын ерак йирләргә мәктәпкә җибәреп йөртә алмыйлар, киемнәре булмый.* Г.Исхакый. *Үзенең көнлек керемен – ике тәңкә акчасын биреп, ул аны коткарган.* С.Алишев // Бер көн эчендә тотыла, туздырыла, сарыф ителә торган. *Минем көнлек расходым 20 тиеннән узганы юк.* Г.Кутуй

5) Гомер көннәре турында, ягъни яше тулмаган баланың (хайван, кошкортларның һ.б.) ничә көн тутырган булуы. *Сорап та тормады, кая, ничек тотыйм кызымны дип уйлап та бирмәде, биләүдәге ике көнлек кызын күтәреп алды да идән буйлап биеп тә китте.* Ә.Галиев. *Ике баласы өстенә өч көнлек сабыен калдырып, ять-яшь килеш кара гүргә керә ул.* Т.Нәҗмиев

6) Кыска гомерле, тиз үтүчән, вакытлы. *Шунысы да бар: аның җырлары бер көнлек кенә түгел.* Р.Миңнуллин. *Көнлек шатлыкларның арасында Ул югалды, кабат чыкмады.* М.Әгъләмов

**КӨНЛЕК** II *и.* 1) Эш көне исәбеннән түләнә торган вакытлы яки сезонлы эш. *Әнкәем Нурый хаҗиларда көнлектә йөри.* Г.Толымбай. *Директор Шәмсетдиновны квартирага үзенә алган, инспектор Хәмитовны «көнлеккә» салып чират төзегән иде.* М.Мәһдиев. *Үзләре көнлеккә, атлары көрчеккә калсын!..* А.Хәлим

2) *сир.* Үлгән кешене искә алу көне, искә алу йоласы (өчесе, җидесе, кырыгы тур.). *Ибраһим абыйның җиде көнлеге бүген, халык шунда агыла.* Казан утлары

**КӨНЛЕК ДӘФТӘР** *и. к.* **көндәлек** I (*1 мәгъ.*). *[Нуруллин:] Аның менә көнлек дәфтәрләре, хатлары, бер бик кадерле рәсеме Көньяк фронтында минем кулда калган.* А.Шамов. *Аннары ул көнлек дәфтәрен язарга утырды.* А.Алиш

**КӨНЛЕКЛӘП** *рәв.* 1) Эш көне исәбеннән, көнләп. *– Хуш, – ди бай, – ничек түли, айлыклапмы, көнлекләпме?* Г.Әпсәләмов. *Ул Нурый картларга көнлекләп эшкә баргалый иде.* Г.Ибраһимов. *Юк, имеш, көнлекләп түләми, бетереп түли, син дә аңа бетереп эшлә.* Ә.Фәйзи

2) Көнлек итеп, бер көнгә җитәрлек итеп. *[Рашат:] Син аны [горурлыкны] токмач басарга он алып кергән кебек, сарайдан көнлекләп алып керәсеңме?* Ф.Садриев. *Ә мин 50 сум стипендияне, ай буена җиткерү өчен, көнлекләп бүлеп куям.* Безнең гәҗит

**КӨНЛЕКЛЕ** *с.* Эш көне исәбеннән түләнә торган, көнләп башкарыла торган. *Шул кайгы-хәсрәт илә бернichә вакытлар уздырганнан соңра, беркөн «илһам» иләме ни берләдер кылт итеп күңеленә Бохарадагы бер кәвешчедә көнлекле хезмәт итүче икедән бер угылы – мәхдүме хәтеренә төшмеш.* Г.Камал. *Кызчык чагында күрше-тирәнең бозауларын көтә, үсә төшкәч, әтисенә ияреп, көнлекле эшкә йөри, ә кышларын апалары белән бергә Казан байларына читек кайый.* Ә.Еники

**КӨНЛЕКЧЕ** *и.* **1.** Эш көне исәбеннән түләү шарты белән эшкә алынган кеше. *Ә монда яллаган көнлекчеләр төшкәчә ат көтеп өйдә яттылар.* Г.Ибраһимов. *Һич булмый икән, көнлекче булып, утын ярып йөреп булса да, тамагыбызны туйдыра алырбыз әле.* Г.Кутуй

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җитди булмаган, кыска вакытлы. *Көнлекче иҗат ясин укылмыйча гына Вакыт каберенә күмелә.* М.Галиев

2) Бүгенге көн белән генә яши торган, эшли торган. *Х.Туфан белән С.Хәким көнлекче шагыйрьләргә каршы көрәштеләр.* М.Вәли-Барҗылы

**КӨНЛЕКЧЕЛЕК** *и.* Көнлекләп (*1 мәгъ.*) эшләү. *--- Әбиемнең күп еллары көнлекчелектә үткән.* Сөембикә

**КӨННӘ́Н-КӨН** *рәв.* Торган саен, вакыт узган саен. *Шагыйрь дә, хикәяче дә, сатирик та булып Фаил Шәфигуллин күз алдыбызда үсте, көннән-көн яңарды, олыгайды.* Н.Арсланов. *--- Әдәбият – энә белән кое казу, әдәбият – кеше күңелен тәрбияләү, әдәбият – кешеләрне яхшы булырга, көннән-көн яхшырак була баруга этәрү коралы.* Ф.Хөсни. *Кәтиб Хафиз өчен шул көннән алып китаплар дөньясындагы хәлләр киңәя барды, сарайда булып торган хәлләр көннән-көн тарая барды.* М.Хәбибуллин

**КӨННӘ́Н-КӨНГӘ** *рәв. к.* **көннән-көн**. *Болай дип Ходайга ялваруы бары тик үз хәленең көннән-көнгә начарая баруыннан гына, сабый гомере өчен куркудан гына иде.* М.Кәбиров. *Яшь бала көннән-көнгә алга бара ул, сәламәт кенә була күрсен.* Казан утлары

**КӨННЕКЕ́Н-КӨНГӘ** *рәв.* Көн саен, һәр көнне. *Гәзитләрне көннекенкөнгә ябыштырып барырга шәһәр хакимиятенең акчасы юк иде, күрәсең.* А.Хәлим. *Кемгә күпме акча тиеш икәнемне көннекен-көнгә язып бардым ---.* Казан утлары

**КӨ́НОЗЫН** *рәв.* Көн дәвамында; көн буе. *Инде утыз елга якын, һәркөнне таңнан торып, көнозын болын-кырда йөрим, алай да табигатьне күреп туйганым, аның серләрен аңлап бетерә алганым юк әле.* З.Фәйзи. *Кояш көнозын кыздырган иде, юл тузанының кайнарлыгы ботинка табаны астыннан бәреп тора.* Р.Низамиев. *Үзем көнозын мәктәптә, ирем дә җаваплы урыннарда эшләде.* Сөембикә

**КӨ́НОЗЫНГА** *рәв. сөйл. к.* **көнозын**. *[Әмир:] Беләсеңме, менә көн кичкә авышып килә, әле мин көнозынга җылы сүзләрне беренче тапкыр синнән ишеттем.* М.Хуҗин

**КӨ́НОЗЫНЧА** *рәв. сөйл. к.* **көнозын**

**КӨ́Н-ТӨН** *рәв. к.* **көне-төне**. *Әнем бик авыр кичергән, көн-төн елаган, мескенкәем.* Ә.Баян. *Көн-төн бергә эшлибез үзебез!* Ә.Еники. *Рушад эшкә чумган, көн-төн китаплар белән.* М.Мәһдиев. *Бизәк төшерүчеләр көнтөн эшли, ташчылар мунча салырга күчтеләр.* М.Хәбибуллин

◊ **Көнне-төнне белмәү** Ял күрмичә күп эшләү турында. *Көнне-төнне бел-*

*ми эшләүчеләрне махсус эзләп җыйганнар диярсең!* Мәгърифәт

**КӨННӘР-ТӨННӘР** *и. купл. кит. сир.* Озак вакыт; гомер. *Шушы хәлләрдән соң Кояш ничә мәртәбә күз йомып, Ай ничә тапкыр җир йөзенә карап каш сикертте, ягъни байтак көннәр-төннәр узды.* Р.Батулла. *Әйтәм, имеш: күпме еллар Бүлешмәгән серләребез, Көннәр-төннәр сөйләшсәк тә Бетмәс кебек сүзләребез.* Ф.Чанышева

**КӨ́НҮЗӘК** *с.* Билгеле бер вакыт өчен бик әһәмиятле булган; мөһим; актуаль. *Кайбер көнүзәк мәсьәләләр көннең үзедәй үлүчән.* Г.Морат. *Илбаш үз чыгышында иң әүвәл көнүзәк мәсьәләләргә, шул исәптән әдипләрне нәкъ менә бүген борчыган проблемаларга басым ясады.* Мәдәни җомга

**КӨНЧЕ** *с.* **1.** 1) Яраткан кешесенең тугрылыгыннан яки хисләренең, мөнәсәбәтләренең сафлыгыннан шикләнүче, көнләшүче. *[Сәриянең] ире бик тә вакчыл, үтә чыккан көнче, кире беткән бер бәндә булып чыкты.* М.Зарипов. *Давыдов гаиләтормышында яман көнче булса да, иҗат мәсьәләсендә көнләшә белмәде бугай.* К.Миңлебаев

2) Кешеләрнең уңышын, өстенлеген күреп гарьләнүче, бәхетенә аяк чалырга яисә шул кешедән өстен чыгарга теләүче. *Шулай итеп, кешеләр мәкерле Пумбадан – галәм серләрен, комсыз, көнче Думпастан – йолдызларны азат иткәннәр.* Р.Батулла. *Беркемгә билгесез чатырчы, күр дә тор, көнче күршеләренең күз алдында күккә күтәрелер әле...* Җ.Ильясов

3) Көнләшүле; көнләшүне белдергән. *Яки вакчыл, көнче кеше, үзен һәммә кешедән дә дәү итеп уйлап та, берни дә белмәгән кеше, ничек итеп бөек идеяләр турында яза белсен?* Г.Бәширов. *Егеткәем, сез бик көнче кеше булырга охшыйсыз.* Т.Галиуллин. *Мөхетдинов көнче хатын-кызны бер дә өнәми иде.* Х.Камалов

4) *иск.* Дошман булган. *Күп тә үтми, батырлар яткан ак тирмәне көнче яу чолгап алды.* Әкият. --- *Көнче яуга көенеч китердегез.* М.Җәлил

**2.** *и. мәгъ.* Көнләшә торган кеше. *Кешесе ул түгел, көнчеләрдән түгел, явызлык эсти белмәс, кулыннан килгән киңәшен бирер, акыллы сүзен әйтер [Нуретдин абзый].* Ә.Еники. *Көнчеләр әләге буенча патша Ән-Нуман аны зинданга ябарга һәм буып үтерергә боерган.* Җ.Ильясов. *Кит бар моннан, көнче, күземә күренмә!* Казан утлары

◊ **Көнче күбәләк** Бик нык көнләшүчән кеше. *Минем көнче күбәләгем, минем кыю карчыгам, сез – бербөтен!.. Миннән бүтән кем сезнең көчкә чыдар?!* Р.Харис. – *Сәбәпсез көнләшү – гөнаһ,* – *диде хуҗа хатын.* – *Димәк, көнче күбәләк икәнсез...* Ф.Җамалетдинова

**КӨНЧЕЛ** *с. к.* **көнче**. *Күпме еллар үткән, күпме сулар аккан, көнчел кешегә дә тынычланырлык вакыт булган инде.* Ә.Моталлапов. *[Фазыл:] Ай-яй усал син, Гөлбану, көнчел!* Р.Ишморат. --- *Имам дигәннәре көнчел, явыз бер карт икән.* Р.Мулланурова

**КӨНЧЕЛЕК** *и.* 1) Якын кешеңнең тугрылыгыннан яки мәхәббәтеннән шикләнү хисе. *Көнчелек кычкырта аны шулай.* К.Нәҗми. *Нәфисә аның [Зиннәтнең] болай көнчелеген җиңә алмыйча бусарынуына кыенсынып карап торды.* Г.Бәширов

2) Кешеләрнең өстенлеген, уңышын күралмыйча, гарьләнеп көнләшү хисе. --- *Көнчелектән бу, көнчелектән! Алар аны үзләреннән рәхәтрәк яшәгәне өчен яратмыйлар.* Ә.Еники. *Көнчелек, алдау, хәйләкәрлек, ялагайлык, икейөзлелек, тупаслык, комсызлык һәм башкалар, башкалар – максатка ирешү өчен табигый чаралар.* Ә.Баян. *Дөнья артыннан куу, көнчелек кешеләрне упкынга илтә.* Р.Батулла

◊ **Көнчелеккә көч килү** Көнләшү хисе уяну. **Көнчелек килү** Көнләшү хисе туу. *Кешенең яхшы эшенә көнчелегең килсә, аңардан уздырып эшлә.* Мәкаль. **Көнчелек корты** Кеше күңелен борчып, тынгы бирми торган хис. *Ул авторларның кайберләрен көнчелек корты кимерә, кайберәүләре минем әсәрдә тәнкыйтьләнгән иде.* Г.Бәширов. *Дөресен генә әйткәндә, көнчелек корты төште аның бәгыренә.* Р.Батулла. **Көнчелек тамыры** Көнчелекне китереп чыгарган сәбәпләр. **Көнчелек уты** Көнчелек хисе, көнчелек тойгысы. *[Дамир] кочак-кочак розалар күтәреп бүлмәбезгә килеп кергәндә, күп кенә кызларның күзендә көнчелек уты кабына иде.* Ф.Яруллин. *Шул сәгать көнчелек уты йөрәген яндырып, җәлладка әмер кыйлды: «Кис шул ярамаган угланның башын!» – диде.* К.Насыйри

**КӨНЧЕЛЕКЛЕ** *с.* Көнләшүле; көнләшү хисләре булган. *Хәзер инде алар [Нургали белән Миңсылу] олыгаеп баралар, элекке кебек күзгә-күз карашып кына да тормыйлар, шулай да тынгысыз, көнчелекле яратышуларының һич кимегәне юк иде.* Ә.Еники

**КӨНЧЕЛЛЕК** *и.* Кеше характерындагы көнчел булу сыйфаты. *Көньяк кешеләрендә була торган кара көнчеллек, күкрәктә икмәк пешерә торган мичтәге ялкын кебек дөрләп, кайнар төтен белән бергә Гомәрнең башына китереп сукты---.* Җ.Ильясов. *Тырышлыгы да, көнчеллеге дә бар иде [Исхакның].* Ә.Моталлапов

**КӨ́НЧЫГЫШ** *и.* **1.** 1) Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның көнбатышка каршы булган, кояш чыккан ягы; мәшрикъ. *Көнчыгыштан көнбатышка, көнбатыштан көнчыгышка киткән эшелоннарны ишек ярыгыннан күреп кенә түгел, ә санап-барлап барамын.* К.Латыйп

2) Европага карата шул тарафта урнашкан илләр. *Урта гасыр мәзһәбләреннән оеган Көнчыгыш тирән йокыда хәзер.* Р.Хәкимов. *Күрер күзгә зур көнчыгыш шәһәренең тормышы шундый.* Җ.Ильясов. --- *Көнчыгышта технологияләр уйлап табылмый, фәнни ачышлар ясалмый.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Европага карата шул тарафта урнашкан, шул тарафтагы, шуларга мөнәсәбәтле. *Көнчыгыш Азия*

**КӨ́НЬЯК** *и.* **1.** 1) Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның төньякка каршы ягы. *Җилләр ашыгып-ашыгып авылның төньягыннан көньягына суык күчереп йөри---.* К.Кәримов

2) Җылы климат полосасы, җылы як. *Ул [Гадил] язмыштан күпне таләп итми, көньякларда шукланып йөргәне дә юк иде.* М.Маликова. *Көньякка күченеп китүче очар кошлар да ашыкмыйлар.* Ә.Галиев. *Бүрек колакчыннарын*

*төшерү дә ярдәм итми көньякның җылы, иркә кояшында үскән малайларга.* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* Нинди дә булса җирнең, торак урынның (авылның, шәһәрнең, илнең һ.б.) кояшлы ягына караган; көньяктагы. *Көньяк Урал сыртларына сыенган төпкел башкорт төбәге Айтуганга заман җиле килеп кагылган гына иде әле.* Г.Якупова

**КӨ́НЬЯК-КӨНБАТЫШ** *и.* **1.** Горизонтның көньяк белән көнбатыш урталыгындагы ягы һәм шул яктагы урын. *Баюга авышкан март кояшы көньяк-көнбатышка караган тәрәзәләрдән бүлмә эченә бер тутырып карады.* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* Шул якта, шул тарафта урнашкан, шул якныкы булган. *Ә Сталинград һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларының Хәрби Советлары Сталинның әҗәл боерыгын сугыш лозунгысына әверелдерделәр.* К.Латыйп. *Борынгы Алабуга шәһәрлеге --- хәзерге шәһәрнең көньяк-көнбатыш чигендә, Каманың кушылдыгы Тойманың уң ягында урнашкан.* Ф.Хуҗин

**КӨ́НЬЯК-КӨНЧЫГЫШ** *и.* **1.** Горизонтның көньяк белән көнчыгыш уртасындагы ягы һәм шул яктагы урын. *Төньяк-көнбатыш тарафтагы чикләрне кан кушу белән ныгыткач, Сәлим хан көньяк-көнчыгыш тарафына игътибар итте һәм күрде: төрки халыклар белән чикләнгәнгәме, бөтенләй сакланмый диярлек икән ул яклар.* М.Хәбибуллин. *Бангладешның көньяк-көнчыгышындагы бер авылда бик тә үзенчәлекле агач үсә.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Шул якта урнашкан, шул якныкы булган. *Кытайдагы хәлләр, Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге мөһим вакыйгалар да мәҗмугадан читтә калмый.* Х.Миңнегулов

**КӨ́НЬЯКТАГЫ** *с.* 1) Берәр урынның көньягында урнашкан. *Норлатны бүген журналистлар арасында хәтта Татарстанның көньяктагы башкаласы дип әйткәннәрен дә ишеткән бар.* Х.Вәлиәхмәтов. *Җәй урталарында ул Болгар йортның көньяктагы чигенәчә барып җитә дә көнчыгышка таба борыла иде.* Н.Фәттах. *Тегеләр – көньяктагылар да ышанмады...* Я.Винецкий

2) Җылы яктагы. *Ә менә ул көньяктагы санаторийларда сезнең эшчеләрегез дә ял итә аламы?* Р. Миңнуллин. *Көньяктагы һава, диңгез шавы --- бик сагындырган Әнисәне.* Татарстан яшьләре

**КӨНЬЯШӘР** *и. зоол.* Көнлекчеләр отрядыннан бер-ике көн генә яшәүче канатлы бөҗәк; бер көнлек күбәләк; *русчасы:* **подёнка**

**КӨҢ** *и. иск.* Кол кәнизәк, кол хатынкыз. *Кызны асрый алмаган – көң итәр, улны асрый алмаган – кол итәр.* Әйтем

**КӨҢГЕ́Р-КАҢГЫР** *рәв. диал.* Бер көе, бер килеш; уртача, ярыйсы гына. *Көңгер-каңгыр яшәп яту*

**КӨПӘ́-КӨНДЕЗ** *рәв.* 1) Көн үзәгендә, якты вакытта. *Көпә-көндез булса да, ни өчендер, сәбәбен аңлата алмыйм, мин шүрләп куйдым.* Р.Батулла

2) *күч. сөйл.* Ачыктан-ачык, кеше күзе алдында, яшермичә, тартынмыйча. *Кафеның бинасын көпә-көндез кем иренмәсә шул талап ятуга бик җаны көйгән Җәүһәрия милиция начальнигына хат язган иде.* М.Маликова. *Көпә-көндез, халык алдында күрәләтә талыйлар...* Б.Камалов. --- *[Берәү] баемакчы читләр исәбеннән, Көпә-көндез талап ятим, толлар хакын.* Р.Рахмани

**КӨПЕ** *и.* Сарык йонынннан сырып тегелгән бишмәт; кыска тунга охшаш кием. *Бер картның унике улы бар: Өчесе сары көпе кия, Өчесе яшел күлмәк кия, Өчесе сары чикмән кия, Өчесе ак тун кия.* Табышмак. *Кулларына камчылар тоткан, көннең кызулыгына карамастан зур итек, көпе, колакчын кигән дүрт казакъ килеп керде.* Г.Ибраһимов

**КӨПКӘ** *и.* Яшь малларны кышлату өчен җир асты абзары. *Ятимнең эче җиде катлы, Сигезенчесе бозау көпкәсе.* Мәкаль

**КӨПЛӘ́Ү** *ф. диал.* Тышлау (төрле материал белән)

**Көпләп бетерү** Барысын да көпләү, ахыргача көпләү

**Көпләп кую** Алдан яки тиз генә көпләү. *Яңаны алып кайтканнар дип торам, Фәнилә иске диваннарын бик оста итеп көпләп куйган икән.* Казан утлары

**Көпләп тору** Хәзерге вакытта көпләү

**Көпли башлау** Көпләргә керешү

**КӨПЧӘК** *и.* 1) Тәгәрмәч; үз күчәрендә әйләнеп, транспорт чараларын хәрәкәткә китерү өчен хезмәт итә торган түгәрәк җайланма. *Мин арбаның дүрт көпчәгенең дүрт үлчәүдәлеген күреп, башкорт абыйга карап: – Ник алдадың, арбаң бик начар ич... – дидем.* Г.Исхакый. *Биек тауга менеп бара бер атлы... Көпчәкләр сөйрәлә бер-бер артлы...* А.Гыйләҗев. *Равил кулын уа-уа кереп утырды: – Боз ява, валлаһи. Юл артык изелгән, көпчәкләр тарталмас, ахрысы.* Н.Гыйматдинова

2) Төрле механизмнарда хәрәкәт барлыкка китерә яки аны тапшыра торган түгәрәк җайланма. *Миномётның көпшәсе белән прицелы – егерме, көпшә куела торган тактасы – унал-ты, көпчәкләре белән лафеты егерме --- кила тарткан мөлкәтне җилкәләрегезгә йөкләгез дә, әйдәгез --- марш-бросокка!..* А.Хәлим

3) *күч.* Бер урында гына тормыйча, һәрвакыт үзгәрә, алга бара торган нәрсәләргә карата әйтелә (мәс., ел, вакыт, гомер). *Ничек кызу әйләнә гомернең бу зур көпчәге – ел дигәнең.* Ә.Еники

**КӨПЧӘКЛЕ** *с.* Көпчәге булган; көпчәк ярдәмендә хәрәкәт итә торган. *Шул көнне кичкә таба райүзәк ягыннан килүче брезент түбәле, киң көпчәкле батыр «ГАЗ-7» машинасы күпергә җиткәндә генә шып туктады.* Ә.Еники. *Бүген санитаркалар аны [Әбүзәр абзыйны], резина көпчәкле арбага утыртып, ваннага алып киттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Менә берзаманны көпчәкле файтунга утырып, мулла белән Тинчурин кайтып төшә.* Р.Батулла

**КӨПЧӘК ТЕШЕ** *и. махс.* Агач көпчәктә бүкәнне һәм тугымны тоташтыра торган агач яки металл таяк; киги

**КӨПЧӘКЧЕ** *и.* Көпчәк (*1 мәгъ.*) ясаучы оста

**КӨПШӘ** *и.* 1) Кайбер үсемлекләрнең турыга үскән эче куыш сабагы. *Күбәләк курай көпшәсе эченә кереп кунаклаган.* Р.Батулла. *Әрәмәлектән балтырган көпшәсе, какы җыеп чыкканда, яшь әти белән әни чишмә буенда сөйләшкән балаларының сүзенә колак салды.* А.Хәйретдинова

2) *бот.* Ботаникага караган кайбер кушма терминнарның икенче компоненты буларак кулланыла. *Тимгелле түндербашның халык телендә дистәдән артык исеме бар: тимгелле агу уты, елан көпшәсе, сасыкай...* Ватаным Татарстан. *Яшь кортлар, яфрак кимерүче коңгыз һәм кисмәннәрнең вак личинкаларына каршы – елан көпшәсе (түндербаш).* Кәеф ничек?

3) *анат.* Куыш эчле озынча формадагы әгъза яки әгъзаның бер өлеше. *Авыз куышлыгының арткы өлешендә йоткылык урнашкан, аның өске өлешенә йоткылыкны урта колак куышлыгы белән тоташтыручы борын юллары һәм евстахий көпшәсе (ишетү көпшәсе) ачыла---.* Биология. *Әлеге авыру тиз арада операция үткәрүне таләп итә, яралгы үсеп, көпшә шартларга һәм көчле эчке кан китүләр булырга мөмкин.* Сөембикә

4) Түгәрәк куыш эчле озынча предмет; сыеклык, газ, пар һ.б. үткәрү өчен кулланыла торган нечкә торба; шланг. *Төнлә үк чыккан юу машиналары эшләрен бетереп өлгермәгәннәр, әле анда, әле монда асфальтка, гөл түтәлләренә юан көпшәләрдән шабырдатып су коялар.* М.Маликова. *Мичнең өске ягында кайнавы җитешкән сыекчаны икенче бүлеккә үткәрә торган юан гына көпшә иде.* К.Латыйп

5) Берәр җайланманың нәзек торбачык формасындагы элементы, аерым бер детале. *Тартмадан тимер көпшәләрне, тәгәрмәчләрне, утыргычны чыгарып, кәгазьләрен укып, җыярга, гарипне тимер караватыннан күтәреп алып, арбага җайлап утыртырга туры килде.* М.Маликова

6) *махс.* Озын нәзек цилиндр формасындагы прибор, җайланма. *Элек җылы нурлар сирпеп торган матур зәңгәр күзләр, кызарып, лазер көпшәсе шикелле зәһәр нурлар чәчәргә тора.* Ж.Дәрзаман. *Табибә ханым көпшә куеп, башта минем йөрәк тибешен, үпкәне тыңлады, аннары күз-колакларны тикшерде ---.* К.Латыйп

7) Ату коралының пуляга яки снарядка юнәлеш бирә торган торбасыман өлеше. *Ике кулы белән түшәгенә таянып, артка каерыла биреп утырган хәзрәт, ап-ак иреннәрен кыймылдатып, күзен дә йоммыйча наган көпшәсенә карап тора...* Ә.Еники. *Посттан кайткач винтовкасын чистартмаган көе ятып йоклаган иде [Гата], эченә яңгыр төшкән икән – ике-өч сәгать эчендә көпшә «чәчәк аткан» булып чыкты.* М.Мәһдиев. **---** *[Каравылчының] аркасыннан һаман да шул мылтыгының көпшәсе тырпайган.* А.Хәлим

◊ **Көпшәгә китү** Төпләнергә тиеш булып та, төпләнмичә сабак җибәрү (шалкан, кишер, чөгендер кебек үсемлекләр тур.). **Көпшәгә утыру** Сабак җибәрү, сабаклану. *Куаклanганнан соң берникадәр вакыт үткәч, сабаклары үсә башлый – үсемлек көпшәгә утыра.* Ботаника. *Бодайлар көпшәгә утырган иде инде ул вакытта, шуны онытма ---.* Казан утлары

**КӨПШӘК** *с.* 1) Күпереп торган, бөртекләнеп, ярмаланып, таралып торган. *Кортлекләр көпшәк кар астына чумалар.* Д.Гайнетдинова. *Көпшәк кар болытлары тоташ таулар сымак.* Н.Хәсәнов. *Бораунын бүгенге көпшәк катламга килеп керүе һәм котырынып аска төшүе Сергейның дөньясын оныттырып җибәрде.* Ш.Бикчурин

2) Тыгызлыгын югалткан, бик йомшак, шәлперәйгән (мускуллар, тән һ.б. тур.). *Көпшәк булгангамы, Зәмзәмиянең тәннәре кабармыйча, корт чаккан урыннарга кызыл төерләр генә калыккан иде.* З.Фәйзи. *Әмма Наилә борынгыча, аристократларча ап-ак, көпшәк һәм ясалмарак чибәр.* В.Нуруллин. *Беләсеңме, нигә шулай тиз арыйсың син? Көпшәк тәнле булганга!* Г.Бәширов

3) Йомшарган (яшелчә һ.б. тур.). *Көпшәк кыяр. Көпшәк кишер*

4) *махс.* Күзәнәкле, тишек-тошыклары булган. *Балта осталары саласы бүрәнәнең кайсы ягы төньяк котыпка, кайсы ягы көньякка карап үскәненә игътибар иткәннәр, көньякка карап үскән көпшәк ягын эчкә калдырып дөрес эшләгәннәр.* Т.Нәҗмиев. *Яшәгән гомернең, мөгаен, күбрәк өлеше әнә шул кимегән көпшәк бозлардай файдасызга югала торгандыр.* А.Вергазов. *Әле дә ярый җиңелчә генә чыгып киткәнмен, сумкамны алмаганмын, боз, җебегән шикәр кебек, бик көпшәк, ялучан.* Т.Кәримов

5) *күч.* Әдәбилектән ерак торган, җитешсез яклары, кимчелекләре күп булган; йомшак (әсәр тур.). *Бик күп шигырьләр озын һәм көпшәк булганга күрә, яшьләр шигърияте укучыларда ризасызлык тудыра башлаган иде.* М.Вәлиев. *Әлегә эшләнеп бетмәгән, ачкычы табылмаган көпшәк, йомшак шигырьләре дә очрый.* Л.Шәех. *Гомумән, әлеге Конгресс татар түрәләренең режиссёрлыгында куелган көпшәк спектакль сыман тәэсир калдырды.* Р.Зәйдулла

**КӨПШӘКЛӘНДЕРҮ** *ф.* Көрәк, тырма һ.б ярдәмендә яки башка юл белән туфракны, җирне көпшәк хәлгә китерү, йомшарту

**Көпшәкләндерә бару** Аз-азлап, акрынлап көпшәкләндерү; артыннан ук көпшәкләндерү

**Көпшәкләндерә төшү** Тагын да бераз көпшәкләндерү

**Көпшәкләндереп бетерү** Көпшәкләндерүне төгәлләү

**Көпшәкләндереп җибәрү** Бераз көпшәкләндерү

**Көпшәкләндереп чыгу** Барысын да көпшәкләндерү

**КӨПШӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Йомшару, көпшәк хәлгә килү (туфрак, кар һ.б. тур.). *Гашыйк ир көпшәкләнгән язгы кар кебек икән: кояш әз генә елмайса да, җебеп эри.* Н.Гыйматдинова. *Өчдүрт квадрат метр кар тоташ иңеп, төшеп утыра. Димәк, көпшәкләнеп эрегән.* Ш.Галиев

2) Тыгызлыгын, сыгылмалылыгын югалту, шәлперәю. *Үрдәк сусыз яшәми, сусыз аның тиресе көпшәкләнә, эчәкләре кибә.* Н.Гыйматдинова

3) Йомшару, пәжү, тыгызлыгын югалту (яшелчә тур.)

**Көпшәкләнә бару** Торган саен күбрәк көпшәклəнү

**Көпшәкләнә башлау** Көпшәклек билгеләре барлыкка килү

**Көпшәкләнә төшү** Тагын да бераз көпшәкләнү

**Көпшәкләнеп бетү** Тәмам көпшәкләнү. *Карбызлар көпшәкләнеп бетәр дип көтмәдек.* Г.Кутуй

**КӨПШӘКЛӘТҮ** *ф.* Көпшәк хәлгә китерү

**КӨПШӘКЛӘ́Ү** *ф. к.* **көпшәклә́тү**

**КӨПШӘКЛЕК** *и.* 1) Көпшәк (*1 мәгъ.*) булу. *Карның көпшәклеге*

2) Көпшәк (*4 мәгъ.*) булу. --- *Мәнә каян килеп туа [шигырьләрдәге] күңелсез бертөрлелек, еш очрый торган көпшәклек!* М.Вәлиев

**КӨПШӘЛӘНҮ** *ф.* Көпшәгә әйләнү, көпшә хасил итү (кайбер үсемлекләр тур.)

**Көпшәләнә башлау** Көпшәләнүгә табан үзгәрү

**Көпшәләнеп бетү** Тәмам көпшәләнү

**Көпшәләнеп җитү** Көпшә рәвешен алу

**КӨПШӘЛЕ** *с.* 1) Көпшәсыман, трубкасыман; куыш эчле

2) Көпшә (*1 мәгъ.*) җибәрә торган, көпшәгә китә торган, көпшәсе була торган. *Көпшәле суган*

3) Көпшәсе булган (ату коралы). *Алтынчәчкә аның күзләре ике көпшәле мылтык булып күренде, алардан ут чәчелгәндәй булды...* М.Маликова. *Февраль хезмәт хакыннан ике көпшәле мылтык алырмын дип тора идем дә, --- булмас ахры.* Ф.Шәфигуллин. *Баржаның иркен палубасында озын көпшәле туплар, пулемётлар, кораллы матрослар.* С.Сабиров

**КӨПШӘЧЕЛ** *с. бот.* Эче куыш сабаклы; көпшәле

**КӨР** *с.* **1.** 1) Симез, таза; арык булмаган (терлек тур.). *Шул чакта малларны картына, яшенә, көренә, арыгына аерып, рацион төзеп ашата башлаган булабыз.* Ә.Еники. *Ике баш [сарык], безнекеләрне ул кадәр симез дип мактана алмыйм. Шулай да көрләр.* А.Хәлим // Таза, сәламәт; арык булмаган (кеше, гадәттә, балалар тур.). *Бу гарипнең балачагын белүчеләр аның бик көр һәм алмадай матур бала булуын сөйлиләр.* Г.Минский

2) Симез, мае күп булган, яхшы (ит тур.)

3) Яхшы үскән, әйбәт, шәп; мул уңыш бирә торган. *Быел игеннәр көр*

4) *сөйл.* Уңдырышлы, файдалы матдәләргә бай. *Көр туфрак*

5) *сөйл.* Бай, мул, әйбәт, җитеш. *Түбән Шырдыклы авылы бик бай, бик көр тормышлы иде заманында.* Р.Батулла

6) Яхшы; күтәренке, шатлыклы (кәеф, күңел һ.б. тур.). *Шунлыктан картлыгыңны бик тыныч, көр күңел белән үткәрергә хаклы син (Тимерхан).* Г.Ахунов. – *Күңелләр көр, җаннар тынычмы? – Әһлиулла, гадәтенчә, бик тәмләп, җиренә җиткереп сораштыра башлады.* Б.Камалов. *Шатлыктан «ура» кычкырасым килә: күңел көр, рух күтәренке.* К.Латыйп

7) Көчле яңгырашлы; яңгыравык, ачык (тавыш, аваз һ.б.). *Шул чакта моңарчы елмаеп кына утырган начальник үзенең көр тавышы белән салмак кына әйтеп салмасынмы: – Син, Шәймәрдан абзый, безнең секретарьны нигә аерып калдырасың әле?* Ә.Еники. *[Габделбәрнең] әле генә гөбедән чыккандай көр, тупас тавышы киселеп калды.* Б.Камалов. *Председательнең көр, матур тавышы буш бүлмәдә яңгырап ишетелә иде.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Симез, көчле итеп (*1 мәгъ.*). *Бу – аның [Миңлегәрәйнең] төп кәсебе, атларын һәрвакыт таза, көр тота, ә көз җитеп, беренче кар төшкәч, шул атларның берәрсен иярләп, төлке, бүре сугарга да чыгып китә.* Ә.Еники

2) Мул тормышта. *Ул илнең халкы көр яшәгән, хөр яшәгән, мул яшәгән.* Р.Батулла

3) Яңгырап, көчле булып. *[Баян баһадир:] – Тавышы көр чыга бу оланның, әллә сәфәр арасында йөзбаш итәбезме үзен? – диде янәшәсендә барган вәзиргә.* М.Хәбибуллин

**КӨРӘГӘ** *и. диал.* 1) Бал, кымыз һ.б. эчәтә торган кечкенә мичкә

2) Табынга бал, кымыз кебек эчемлекләрне салып куя торган савыт. *Көрәгәсен өстәлендә куйды, яңадан дүртаякланып, караватастындагы уылдыкны китереп чыгарды [Мотаһар].* А.Хәлим. *Әлеге хуҗа бер көрәгә көмешкәне эчеп бетерә дә, көрәгәсен тутырып, иң олы кунакка бирә.* Р.Батулла

3) Әчетелгән бал. *Көрәгә булса, кунакның күңеле булыр.* Мәкаль

**КӨРӘГӘЧЕ** *и. иск.* 1) Табынга көрәгәдән эче бал яисә кымыз салып бирүче кеше

2) *диал.* Мәҗлесне алып баручы; табын башлыгы

**КӨРӘЙТҮ** *и.* Көр булсын өчен ашатып симертү. *Мал-туарны көзен көрәйтү*

**Көрәйтә башлау** Көрәйтергә керешү

**Көрәйтә төшү** Бераз көрәйтү, тагы да көрәйтү

**КӨРӘК** *и.* 1) Җир казу, кар көрәү һ.б.ш. эшләр башкару өчен хезмәт итә торган, киң яссы очлы, озын саплы корал. *Бозаулар абзары, аңардан ары сарыклар белән дуңгызлар абзары тирәсендә дә чиләк күтәргән, көрәк тоткан шәүләләр чуалалар.* Ә.Еники. *Икенче көнне көрәк алып барып, бәләкәчне чишмә чокыры янына җирләдек.* Р.Вәлиев. *Көрәк сабына таянып, ул [Бәгъремә] бер омтылыш белән чокырдан сикереп чыкты.* А.Хәлим

2) Тирәнлек үлчәү берәмлеге; көрәкнең җир казый торган өлеше тирәнлегендә. *Кара туфрак катламын да үтеп, кызыл балчыкка җиткәч, берәр көрәк алганнан соң туктаса да була [Бәгърем].* А.Хәлим

3) Көрәккә сыешлы нәрсә; бер көрәк күләмендә нәрсәдер. – *Тагын берәр көрәк туфрак сал да, алып китәм чиләкне, – дип, абый кызулатмаса, песи баласына тагын күпме карап торган булыр идем икән, белмим.* Казан утлары

◊ **Көрәк оны** *иск.* Тегермәндә ашлык тарттырган өчен, тегермәнчегә яки тегермән тоткан оешмага билгеле бер күләмдә бүлеп бирелә торган он. *Шуңа күрә карт, «көрәк оны» гына җитмәгәч, язын-җәен нәрәтә белән балык аулап, кышын җәнлеккә капкын куеп, авылның исемле сунарчысы да булып яшәде.* Ә.Еники. **Көрәк сакал** Бөтен бит киңлеген каплап алган зур һәм киң сакал. **Көрәк сакаллы** Зур һәм киң сакалга ия (кеше). *Караса, ишек артында орырга дип балтасын күтәргән көрәк сакаллы бер карт басып тора, күзләре акайган, йөзе кыйшайган.* Г.Әпсәләмов. *Уртадагы вагоннарның берсеннән --- көрәк сакаллы баш кондуктор, поезд туктар-туктамас, егетләрчә генә си-*

*кереп төшеп кала һәм, халыкны ерып, вокзал бинасына эре генә кереп китә...* Ә.Еники

**КӨРӘКБОРЫН** *и. зоол.* Мәрсин балыклар семьялыгына кергән, төче сулыкларда очрый торган һәм борыны көрәк формасын хәтерләткән балык төре; *русчасы*: **лопатонос**

**КӨРӘКЛӘП** *рәв.* Көрәк(ләр) белән. *Көрәкләп ташу. Көрәкләп чыгару*

**КӨРӘКЛЕ** *с.* Көрәк белән эшли торган (эш)

**КӨРӘК-СӘНӘК** *җый. и.* Көрәк һәм сәнәк кебек хуҗалыкта кирәкле эш кораллары. *Шунда ук көрәк-сәнәкләрен ташлап ---, туннарын киеп, тизрәк мәдрәсәгә элдерәләр [шәкертләр].* Ә.Еники. *Көрәк-сәнәктән гайре коралы булмаган карт-коры хәлсезләгән чамалады да (үзе сабанга җигелсенмени?) тасма тел Лотфулланың тәбесенә аягын кыстырды.* Н.Гыйматдинова

**КӨРӘ́КТӘЙ** *с. куч.* Көрәк зурлыгында; көрәкне хәтерләтә торган. *Зөһрә суга иреннәрен генә тидерде дә, җизнәсенең көрәктәй учына башын салып, күзләрен йомды.* Ф.Яруллин. *Мәнә билемнән уратырга җыенгандай, көрәктәй зур кулларын өскә күтәрде [Равил].* Н.Гыйматдинова

**КӨРӘКЧЕ** *и.* 1) Көрәк белән эшләүче

2) Көрәкләр ясаучы; көрәкләр әзерләп сатучы

**КӨРӘЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **көрәү**. *Гөлсем апа юл аша чыкты да көрәлмәгән тротуар буйлап ашыга-ашыга китеп барды һәм өч-дүрт өй буен үтүгә, кинәт туктап калды.* Г.Гобәй. *Абзар түбәләре көрәлгән, анда юкагач таякта зырылдап бәләкәй җил тегермәне әйләнеп утыра иде.* М.Мәһдиев

**Көрәлеп бетү** Бөтенләй, барысы да көрәлү

**КӨРӘН** *с.* **1.** Коңгырт, коңгырт төстәге; каһвә төсендәге. *Көрәнгә әйләнгән ак аю кебек чумар да китәр, пылт итеп калкып та чыгар.* М.Әмир. *Мәнә шофёрлары аларның зур булмаган көрән чемоданнарын һәм кара букчаларын күтәреп алды да, ашыкмыйча гына дебаркадерга таба атладылар.* Э.Касыймов. *[Гармунчының] башында чиккән көрән кәләпүш.* И.Нуруллин

**2.** *и. мәгъ.* Көрән буяу; көрән төс. *Апа көрәнгә манган иде бит ул күлмәген дип, серне чишеп ташламасынмы шунда Асия.* Казан утлары

**КӨРӘНӘЮ** *ф. к.* **көрәнләнү**

**Көрәнәя бару** Торган саен ныграк көрәнәю

**Көрәнәя башлау** Төсе көрәнгә табан үзгәрү

**Көрәнәеп китү** Сизелерлек көрәнәю

**КӨРӘН КҮМЕР** *и.* Түбән сортлы ташкүмер; соры күмер

**КӨРӘНЛӘНҮ** *ф.* 1) Көрән төскә керү, көрән төс алу

2) Көрәнгә охшаган булу; көрән булып күренү. *Фаина Наумовнаның урман-далада яшәгәнлеге йөзенә чыккан, анда-санда эре сипкелле йөзен җил кискән, ялангач беләкләре дә көрәнләнеп, юкарып калганнар ---.* А.Гыйләҗев

**Көрәнләнә башлау** Көрәнгә табан үзгәрү

**Көрәнләнә төшү** Тагын берникадәр көрәнләнү

**Көрәнләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй көрәнләнү

**Көрәнләнеп җитү** Ахыргача көрәнләнү

**Көрәнләнеп калу** Ни сәбәпледер, нәрсәнең дә булса тәэсире нәтиҗәсендә көрән төскә керү

**Көрәнләнеп китү** Кисәк көрәнләнү

**Көрәнләнеп тору** Көрән төстә булып күренү; һәрвакыт, даими, еш көрәнләнү. *Тик уртада Симетбаш юлының көрәнләнеп торган юл сызыгы ярылып кала.* Ә.Фәйзи

**КӨРӘНСУ** *с.* 1) Сыек көрән, беркадәр көрән. *Сакландымы икән аның кара каймалы якты күзләре, нурда югандай бик чиста көрәнсу йөзе, җиргә тияр-тимәс кенә йөргән камыштай нечкә, зифа гәүдәсе?* Ә.Еники. *Әнә көрәнсу күзләрендә дә нindидер сәер чаткылар чагылып китте ләбаса...* Э.Касыймов. *Һәм шагыйрәнең бәйләгән көрәнсу күлмәгенә сокланып карап торды [Нурҗиһан].* М.Маликова

2) Башка бер төскә сыек көрән төсмер кушылуны белдерә. *Хәмитнең кул аркасы күз алдында көрәнсу кызыл булып шешеп чыкты.* З.Фәйзи. *Нурҗиһан утырган көрәнсу саргылт өстәл түр тәрәзә төбенә терәп куелган.* М.Маликова. *Гипсланган кулын муенына аскан, түп-түгәрәк йөзле, бөдрәләнеп торган көрәнсу саргылт чәчле бу кыз баштарак әлләни күзгә-башка чалынмады.* В.Нуриев

**КӨРӘПӘЛӘ** *и.* Өс киеменә тоташтырып тегелгән башлык; капюшон. *Килен, ишек катындагы агач чөйдә эленеп торган ирләр кожанын алып, җиңнәрен киеп тормыйча гына, көрәпәләсеннән башына элде дә берни дәшми чыгып китте.* М.Әмир

**КӨРӘ́Ү** *ф.* Кар, кар көрте һ.б.ш. нәрсәләрне көрәк белән алып яки казып читкә ташлау. *Беләсеңме, нигә [җәяү йөргәндә] шулай тиз арыйсың син? --- Эшләми үскәнгә. Җир сөрмәгән, урман кисмәгән, кар көрәмәгән син.* Г.Бәширов. *--- йокы алдыннан берәр физик эш эшләп кирәргә гадәтләнде: кар көрәде, утын ярды яки чаңгыда йөрде.* Г.Гобәй. *Борһан эшнең ничек булачагын белгән иде булса кирәк, капка төпләрен көрәгән, капкасының аратасын алган иде.* М.Мәһдиев

◊ **Көрәп алу** Берәр нәрсәне күпләп кулга төшерү, күпләп үзләштерү. *Төпчекләре Хисмәт – адвокат. Дөрес булса, адвокатлар хәзер акчаны көрәп ала, имеш.* Ф.Яруллин. *– Шахтёр, димәк, – дип җанланып китте хуҗа кеше. – --- Шахтёрлар акчаны көрәп ала, диләр шул...* Р.Мөхәммәдиев. *Җүнле булса, ул шимбә көнне дә шул земснарядына китеп олакмас иде, безнең белән ял итәр, көймәләрдә йөрер иде, начальник булып, акчаны көрәп алыр иде...* Г.Ахунов. **Көрәп китерү** *к.* **көрәп алу**. *Горурланмаслык та түгел шул, чөнки ире аның дәрәҗәле кеше... Иң мөһиме, акчаны Күсия ханымга көрәп китерә.* Ә.Еники

**Көрәп алу** Бик тиз, кыска вакыт эчендә көрәү, бераз көрәү. *Ишегалдын көрәп алу*

**Көрәп бетерү** Бернәрсә дә калдырмыйча, бөтенесен көрәү

**Көрәп карау** Көрәү нәтиҗәсен сынау

**Көрәп килү** Эзлекле рәвештә, тоташтан көрәү

**Көрәп кую** Алдан ук көрәү, көрәргә өлгерү. *Сабира болдырдан капкага*

*бара торган юлны күрәп тә куйган инде.* Ә.Еники

**Көрәп тору** Һәрвакыт, еш көрәү; хәзерге моментта көрәү. *Вафа зур агач көрәк белән кар көрәп тора иде.* М.Галәү

**Көрәп чыгу** Бөтенесен, барысын көрәү

**Көри башлау** Көрәргә керешү. *Ә мин, җан ачуым белән тегеләр янына барып, кар көри башладым.* В.Нуруллин

**КӨРӘШ** *и.* 1) Ике кешенең, көч кулланып, бер-берсен егарга, җиңәргә тырышуы; көч сынаш. *Көрәш законы каты бит; я сине ега, я син аны егасың.* Р.Ишморат. *Менә көрәш башланды. Беренче булып көрәшкә балалар чыкты.* М.Галәү

2) *спорт* Билгеле бер кагыйдәләр нигезендә көч һәм җитезлекне сынау максаты белән оештырыла торган спорт уенының бер төре. *Икенче якта, бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар. Монда көрәш барадыр.* Г.Ибраһимов. *Гатият абзый шул елны Сабантуй көрәшен эшләпә астыннан гына карап торган, уртага кереп, элеккеге гадәт буенча кысылып-катышып йөрмәгән.* М.Мәһдиев. *Испаннарның корридасына чүлмәк вату, татарча көрәш (чын дөресе бил алыш) яки, киресенчә, Сабан туена коррида элементларын кертеп карагыз – нәрсә килеп чыгар икән?* Д.Асылов

3) Гомумән, нинди дә булса спорт ярышы. *Җиңел атлетчылар көрәше. Ишкәкчеләр көрәше*

4) *филос.* Капма-каршылыклар бәрелеше (җәмгыятьтә, табигатьтә һ.б.). *[Булат] мәсьәләнең принципиаль ягына күчеп озак сөйләде. Бөтен тарих – сыйныфлар көрәшенең тарихы, дип нигезләде.* Г.Ибраһимов. *Табигатьнең иркен күкрәгендә мәңге көрәш, Мәңге хәрәкәт, Мәңге туу, Мәңге артып тору белән бергә үлем-һәлакәт.* Һ.Такташ. *Революцияне --- җанлы иҗтимагый көчләрнең көрәше дип карарга кирәк.* Г.Нигъмәти

5) Капма-каршы позициядә торучы төркемнәрнең, юнәлешләрнең бер максат өчен алып барган актив эшчәнлеге; үзара бәрелеше. *Азатлык көрәшенең гыйбрәтле моментлары аеруча тәфсилле итеп, аның [С.Алишевның] «Казан җиңелгәч, татар халкының хәле» дигән мәкаләсендә яктыртылган иде.* Р.Әмирхан. *Сөембикә заманнарында --- Казанда ике төркем түрәләрнең үзара каршылыклары, көрәше, ызгыш-талашы киңәя вә тирәнәя барды.* Ф.Урманче. *Аның [Хәдичәнең] йөз мең сум бирнәсе бар. Менә шул бирнә өчен Хәдичә тирәсендә «көрәш» бара. Бу көрәштә кайсы «ерткыч» җиңеп чыкса, Хәдичә дә шуңа булачак.* М.Гайнуллин

6) Дәүләтләр, армияләр арасында барган сугыш. *Рәссамның, партизаннар белән бер сафта торып, дошманга каршы көрәш алып баруы бөтен дөньяга таралды.* Г.Кутуй. *Әйбәт, әдәпле егетләр Гыйльмулла, Нуриәхмәт, Шәһидулла, Галиәхмәт агач бүкәндә утырып үстеләр дә Ватан азатлыгы өчен көрәшкә чыгып киттеләр һәм шул көрәштә башларын салдылар.* М.Мәһдиев. *Дуслары да, кордашлары да күп булган аның. Тик аларның күбесе төрлесе төрле җирдә, канлы көрәшләрдә ятып калганнар: Халхин-Голда, Фин кампаниясендә...* Казан утлары

7) Өстен, алдын чыгу өчен ярыш, узыш; өстенлек өчен тартыш. *1905 елның көзендә дөньяга килсә дә [«Нур» гәзите], аны гамәлгә кую өчен көрәшнең башы 1891 елга ук карый.* Р.Әмирхан. *Кешелек дөньясы, гомум кирәкләрен җиткезер өчен, табигать белән көрәшергә, табигатьтән файдаланырга керешкән. Инде бу ихтыяҗ аркасында кешеләрнең үз араларында тартыш, көрәш, узыш башланган.* Мирас. *Бу – геройның тормыш юлы, асылда кыенлыклар белән көрәш юлы, яхшылыкның явызлык белән көрәше. Көрәштә геройның позициясе иң сабый чакның бер вакыйгасын сурәтләгәндә ачыклана.* Татарстан

8) Алга куелган берәр төрле максатка ирешү өчен алып барылган актив эшчәнлек; шөгыль. *Мәктәпкә Әсәдуллин дигән бер егет килде һәм, авылда кушаматның бик киң таралганына шаккатып, мәктәптә кушаматка каршы көрәш ачты...* М.Мәһдиев. *Фин хатыннары табигатьне ясалма чүптән саклау юлында көрәш алып баралар.* М.Юныс. *Эчкечелек белән көрәшү, дигән хәбәр башкаладан килде... Тик бу көрәш, башкаладагыга караганда, ике яки бер ярымга катырак иде.* Н.Измайлова

9) Берәр иҗтимагый, әдәби, мәдәни хәрәкәт барган өлкә, тармак. *Милли азатлык, мөстәкыйльлек өчен көрәштә беренче җиңүчеләр Литва, Латвия, Эстония булды.* Ә.Кәримуллин. *Рафаэль Мостафин – патриот-шагыйрь Муса Җәлил исемен, иҗатын халыкка кайтаруга зур өлеш керткән, аның тормыш һәм көрәш юлын эзлекле өйрәнгән эзтабар-язучы.* Казан утлары. *Анда [киңәшмәдә] патша министры татар халкына каршы көрәшнең өч юлын тәкъдим итә. Шуларның берсе – «инородецларның» уку-укыту эшен тәртипкә салу.* Мәдәни җомга

10) *күч.* Көчле хисләр, омтылышлар, эчке кичерешләр бәрелеше. *Үзең дә сизә булгансың, Разия иркәм, минем эчемдә күп заманнардан бирле көрәш килә.* Г.Ибраһимов. *Бары тик бик сирәк вакытларда гына Гәүһәр ирендә ниндидер тирән эчке көрәш барганлыгын сизә.* Г.Әпсәләмов

11) *күч.* Бәхәс, үзара әйтеш. *[Мирсәет Солтангалиев] Шәхси тормышындагы катлаулылыкларны аерым хәлләрдә, әйтик, Троцкий белән шахмат уйнаганда фикер көрәшен бирүдәге... осталыгы шуларның кайберләре генә.* Р.Мөхәммәдиев. *Сүз көрәше озакка сузылды.* Мирас

**КӨРӘШЛЕ** *с.* Көрәш белән тулы; көрәш дәрте белән сугарылган. *Шагыйрь [Равил Фәйзуллин] 1988 елда язылган бу шигырендә үткән көрәшле елларга күз ташлый, аларны янә күңеленнән кичерә.* Казан утлары

**КӨРӘШ-СУГЫШ** *и.* Сугыш, дау; канкоеш. *Картка үз гомерендә көрәш-сугышларны күп күрергә туры килде.* Казан утлары

**КӨРӘШ-ТАЛАШ** *и. сөйл.* Аерым төркемнәрнең, юнәлешләрнең яки шәхесләрнең бәрелеше. *Көрәш-талаш эчендә кайнап, тагын бер көн узды.* Казан утлары. *Үзара көрәш-талаш озак дәвам итте*

**КӨРӘШТӘШ** *и.* Нинди дә булса бер максат өчен бергә көрәшүче. *Ул [Зәкәрия карт] көрәштәшләре Ибраһим белән Исмәгыйльнең «Поле чудес» бандитлары тарафыннан атып үтерелүе хакында белмәве белән бәхетле иде.* Г.Гыйльманов. *Хезмәтне тулаем укып чыксаң, билгеле бер күләмдә XX йөз башы әдәби тәнкыйтьчеләре, әдипнең дуслары, танышлары, көрәштәшләре белән дә очрашасың.* Ф.Ибраһимова. *Музей оештырган бу очрашуларда Җәлилнең көрәштәшләре Рушат Хисаметдинов, Фәрит Солтанбәков, --- Альберт Җәлилов --- һәм башкалар булдылар.* Казан утлары

**КӨРӘШҮ** *ф.* 1) Бер-береңне куллар белән тотып егарга тырышу, җиңәргә омтылу. *Урамда, пыр тузып, малайлар көрәшә. Җиңел генә бирешмәсен. Көрәшсен, актык көченә кадәр, бөтенләй хәлдән тайганчы көрәшсен, дәрманы тәмам беткәнче көрәшсен...* К.Миңлебаев. *Урман буенда озак булдык. Йөгерештек, сикерештек, көрәштек, мәтәлчек атып аунадык, сикерешле уйнадык.* М.Кәрим

2) Билгеле бер кагыйдәләр нигезендә, көч һәм җитезлекне сынау өчен, бер-береңне арка белән җиргә салырга тырышу. *Хафиз – уналты яшьтә чагында Сабан туенда батырлар белән көрәшеп... бүләк алган егет.* К.Тинчурин. *Теге дәү [кеше] озак көрәште, әле бер, әле икенче малайны алып атып карады, әмма җиңелде.* И.Салахов

3) Нинди дә булса максатка ирешү өчен актив эшчәнлек алып бару. *Татар халкына, кайда гына яшәсә дә, үзенең дәүләтчелеген булдырырга омтылырга, иманлы татар булып сакланып калу өчен көрәшергә кирәк.* Ф.Бәйрәмова. *...Сафин эченнән: «Әле минем көрәшер мөмкинлегем бетмәгән, бирешмәскә генә кирәк!» – дип уйлады.* Казан утлары

4) *юг.* Кан кою, сугышу, сугышта катнашу. *Татар халкы Карасакал, Батырша һ.б. күтәрелешләрендә зур каһарманлыклар кылып, ирек өчен үзен аямыйча көрәшкән.* Р.Әмирханов

5) Дәүләтләр, армияләр, иҗтимагый сыйныфлар турында: корал белән сугышу. *Без барыбыз да: очучылар һәм танкистлар, флотчылар һәм артиллеристлар, кораллы һәм коралсыз партизаннар – барыбыз да каһарманнарча көрәштек.* Г.Кутуй. *Бу вакытта революцион авыл, бербөтен булып, алпавытларга каршы көрәшә.* Г.Нигъмәти. *Бер генә минут элек алар дүртәү иделәр. Көрәшергә, соңгы тамчы канга кадәр фашистларга каршы торырга әзер иделәр.* М.Юныс

6) Кыйнашу, сугышу. *Мәдинә белән ун минуттан артык өзлексез, бөтен көченнән куеп көрәшкән бандитның дәрманы шактый шиңгән иде, ахрысы.* Ш.Камал

7) Берәр зыян, зарар китерә торган нәрсәне юкка чыгару, бетерү өчен актив эшчәнлек алып бару. *Манара – авылның хуҗасы иде. Дингә каршы көрәшәбез дип, авыл халкының сәнгать әсәрен юк итүне вәхшилек дип атамыйча нишлисең?* М.Мәһдиев. *Ялган поэзия, ясалма поэзия һаман да яши... Яши, чөнки аның белән бер генә тәнкыйтьченең дә чынлап торып көрәшкәне юк.* Казан утлары

8) *күч.* Тартышу, даулашу, таләп итү. *Бу бәхет өчен ничек көрәшергә кирәк? Әйе шул, бәхет өчен тартышырга, даулашырга кирәк, диләр.* Г.Әпсәләмов

**Көрәшә башлау** Көрәшергә керешү

**Көрәшеп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә көрәшү

**Көрәшеп килү** Күп еллардан бирле көрәшү

**Көрәшеп карау** Көрәштә үзен сынау, көрәшү тәҗрибәсе алу. *[Галимҗан Шәрәф] Пантюркизмда гаепләүләрне дә кире кага. Ул, тенденциягә каршы һәрвакыт, бигрәк тә әдәбият һәм тел белеме өлкәсендә көрәшеп килдем, дип кабатлый.* Татарстан

**Көрәшеп тору** Һәрвакыт, гел көрәшү; көрәшкән хәлдә булу

**КӨРӘШҮ-АЛЫШУ** *ф.* Төрлечә көрәшү, көч сынашу. *Эш көтеп торган ярлылар, салкынлыкка чыдый алмыйча, әрле-бирле йөгерәләр, бер-берсе белән көрәшеп-алышып та киткән булалар.* М.Гафури

**КӨРӘШЧӘ** *и. диал. к.* **керәшә**. *Әле генә [Мәрьям] карап торган урыннар яр кырыендагы көрәшчә оялары кебек кенә булып күренә.* Г.Бәширов

**КӨРӘШЧЕ** *и.* **1.** 1) Сабан туенда көрәштә катнашкан батыр. *Бүген Сабан туе. Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр.* Г.Ибраһимов. *Авылда эш эшләп гомер иткән, бөтен тирә-якта атаклы көрәшче булган Вафаның көч-куәте күп иде әле.* М.Галәү. *--- гомер-гомергә атаклы көрәшче исемен йөрткән Нәркис бабайның кызыксынуы үтә көчле: көрәшче егетләрнең бил сөлгеләре тартылып-тартылып килгән саен, ак сакал очлары дерт-дерт итеп куя.* Н.Хәсәнов

2) Спорт уенының бер төре булган көрәш белән шөгыльләнүче, шул ярышта катнашучы; гомумән спорт көрәше белән шөгыльләнүче. *Мин дә көрәшкә йөргән идем дә, тренер әйтте, хәлең юк, синнән көрәшче чыкмый, диде.* Д.Салихов

3) Берәр максат өчен көрәшүче, шул көрәштә актив катнашучы. *Халыкның мөстәкыйльлек заманыннан чылбыр булып килгән көрәшчеләр элитасы (мирзалар, тарханнар белән сәедләр) гамәлдә юкка чыгарыла... Әмма татар халкы үз арасыннан яңа каһарманнар чыгара.* Р.Әмирхан. *Гаяз Исхакый иҗатка, Тукаебыз кебек үк, иртә килә һәм үзен талантлы язучы, үз кыйбласын тапкан көрәшче итеп таныта.* Мәдәни җомга

4) Инкыйлапта яки сугышта катнашучы. --- *1918 елның 15 августында Әстерханда танылган кызыл көрәшче Касыйм Туйбактин үтерелә.* Ф.Галимуллин. *Иҗтимагый фикерләр белән халкына мөрәҗәгать итүче, милләт язмышын кайгыртучы лирик герой гыйсъянчы герой, көрәшче булып җитешә.* Д.Заһидуллина

**2.** *с. мәгъ.* 1) Көрәшүче, көрәшә торган. *Симаев белән Җәлил бер-берсен хөрмәт итәләр һәм туганнарча яраталар. Җәлил турында сүз чыкса, Симаевның фикере бер генә: «Ул – саф күңелле, иленә тугрылыклы көрәшче шагыйрь».* Р.Мостафин

2) Актив эшчәнлек алып бара торган, максатчан. *Бәлки, сугышчан шагыйрь дә түгелдер, әмма аның көрәшче шагыйрь булуы бәхәссез!* Р.Рахмани. *Көрәшче шагыйрь [Р.Фәйзуллин], яңа*

*чор килгәч тә, үз шигъри фәлсәфәсенә тугры калды.* Казан утлары

**КӨРӘШЧЕЛЕК** *и. кит.* Ирек сөючәнлек, каһарманлык, ныклык, кыюлык. *Тукай Ямашевның көрәшчелеген, революционерлыгын да шәхси сыйфатлары призмасы аркылы күтәреп бәяли.* И.Нуруллин. *Көрәшчелек фәлсәфәсе Равил Фәйзуллин иҗатының башыннан алып ахырына кадәр кызыл җеп, төп лейтмотив булып уза.* Казан утлары

**КӨРӘЮ** *ф.* 1) Көр, симез хәлгә килү, симерү (терлек тур.). *Көтүдә йөргәч, мал-туар көрәйде*

2) Тулылану, түгәрәкләнү, тазару, ит куну, симерү (кеше тур.). *Бикчәнтәй агай, кызың бик көрәйгән икән.* Т.Гыйззәт

3) *күч.* Ачык яңгырау, ишетелү дәрәҗәсе көчәю; ныгу (тавыш тур.). *Тәүлек артыннан тәүлек уза. Карга балаларының да канатлары ныгый, тавышлары көрәя.* М.Кәрим. *Икенче җәйдә сугыш вакытында калкып чыккан егетләрне дә уенга ала башладылар. Уенның тавышы көрәйде.* М.Мәһдиев. *Әле генә язгы җил белән, --- аккошлар белән серләшкән нечкә күңелле хисчән шагыйрь мондый темага кергәндә кинәт кенә куәтләнеп китә, тавышы көрәя.* Казан утлары

4) *күч.* Яхшы, мул тормышта аякка басу, хәлләнү, куәтләнү. *Шәһәрләр чәчәк атты, авыллар көрәйде, сәүдә гөрли.* Р.Батулла

**Көрәеп җитү** Тәмам көргә әйләнү, симерү

**Көрәеп китү** Соңгы вакытта көрәю, кинәт көр хәлгә килү. *Ала каз, чыннан да, бик үзгәрде... Аңа дәрт керде, ул көрәеп, матурланып китте.* Ә.Еники. *[Сафура:] Шәһәр икмәге килешкән үзеңә. Кара, нинди матурланып, көрәеп киткәнсең.* Т.Гыйззәт

**Көрәя бару** Акрынлап, көннән-көн көрәю, көрлеге арта бару

**Көрәя башлау** Көрәю билгеләре барлыкка килү

**Көрәя төшү** Беркадәр көрәю, бераз көр хәлгә килү

**КӨРГЕЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Самавырның күмерен үрләтү өчен, торбасыннан берәр нәрсә белән өрдерү

**КӨРД** *и.* Гыйракта, Иранда, Төркиядә, өлешчә Россиянең көньягында яши торган, теле иран телләре семьялыгына кергән халык атамасы; шул халыкның аерым бер кешесе. *Биредә буй-буйлы, ак, кара, җәй өчен – киҗе-мамыктан, көрдләр, гарәп, сәлҗук, чегәннәр өчен – йоннан, күренекле кешеләр өчен хәтта ефәктән чатырлар тегәләр.* Җ.Ильясов

**КӨРДӘШҮ** *ф. сир.* Элеккеге кайбер күмәк уеннарда, ике төркемгә бүленү өчен, уенга катнашучылар, үзләренә яшерен исем кушып, уенны оештыручы алдына килү. *Бу көрдәшкәндә, уйнаучыларның үзләренә кушып килгән кушамат исемнәре, гадәттә, бик шигъри, ишле-кушлы сүзләрдән гыйбарәт була.* Н.Исәнбәт

**КӨ́РДЧӘ** *рәв.* Көрд телендә. *Көрдчә сөйләшү*

**КӨРЕ** *и.* Туку станында буй җепне күтәрү-төшерү өчен җеп элмәкләр беркетелгән махсус кыса; җепле кылыч; *русча:* **нитченка**. *Биш көре белән сугылып, озын чук салындырган киң сөлгеләр юкмы?* Г.Ибраһимов. *Һәм көреләр парлап биеп тора, һап та һоп дип, кылыч кул чаба.* Ш.Маннур

**КӨРЕ́ КҮЗЕ** *и. этн.* Көредә буй җепләр үткәрү өчен хезмәт итә торган җеп элмәк

**КӨРЕ́ КЫЛЫЧЫ** *и. этн. к.* **көре**

**КӨРЕЛЕ** *с.* Көре ярдәмендә тукылган. *Моңа түбәндәге нәрсәләр керә: чүпләм сөлгеләр, көндәлек бит сөрткеч тастымаллар, зур сәкенең бер башыннан икенче башына җитәрлек көреле чүпләм.* Казан утлары

**КӨРЕНДЕ** *и.* Диңгез, елга һ.б. сулык өстендә чыгынтыланып, кырлыкырлы, тигезсез булып туңган боз

**КӨРЕНДЕЛӘП** *рәв.* Тигез булмаган катламнар белән; чыгынтылы булып. *Камада боз көренделәп каткан*

**КӨРЕЧ** *и. бот. к.* **корычагач**

**КӨРҖӘ** *и. диал.* Кечкенә балаларга яратып әйтелә торган сүз. *И, көрҗә, сөйләгән буласың бит*

**КӨРКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Көрт-көрт иткән авазлар чыгарып кычкыру (көртлекләр, күркәләр һ.б. кошлар тур.)

**КӨРЛЕК** *и.* 1) Көр (*1 мәгъ.*) булу, симезлек дәрәҗәсе. *Сез тапшырган малларның көрлеге һәрвакыт уртадан түбән була.* Ә.Еники. *Ул мал-туарларының күплеге һәм аларның көрлеге белән дә макталып телгә алына.* А.Әхмәт

2) Симезлек. *Итнең көрлеге*

3) Уңдырышлылык. *Көр туфрак*

4) Күтәренкелек; шатлыклы, яхшы кәеф. *Сәхнәдә – гүзәллек, янда – гүзәллек, дөньяда – иминлек, күңелдә – көрлек...* М.Әмир. *Сугыштан соңгы туклык, тынычлык, күңел көрлеге, иң беренче чиратта, гыйшык-мәхәббәт мәсьәләсен «тиешле югарылыкка күтәрде».* М.Мәһдиев. *Шул Асия-Миңлеасия барлык уеннарны оештыручы, үзе иң алдан уртага чыгып биюче, җиңеллеге, сүзгә тапкырлыгы, күңел көрлеге белән авыл яшьләрен кузгатучы булып чыкты.* Г.Ахунов

5) Хәллелек, бай, мул тормыш. *Көрлеккә түзмәсәң, хурлыкка түзәрсең.* Мәкаль

◊ **Көрлек тибү** *диал.* 1) Энергия ташып тору; 2) Булган акчаның, байлыкның кадерен белмичә, кирәкмәгәнгә сарыф итү; мул тормыштан азыну

**КӨРМӘК** *и.* Тотлыга торган, сүзләрне ачык итеп әйтә алмаучы

◊ **Көрмәк тел** 1) Тотлыга торган кеше; 2) Мәгънәсез, аңлашылмый торган сөйләм

**КӨРМӘКЛӘНҮ** *ф.* Дулкынлану, курку, аптырап, югалып калу һ.б. сәбәпләр аркасында яки исерткеч эчемлекләр тәэсирендә сүз әйтә алмыйча тору, тотлыгу. *[Ата] сүзен ничек дәвам итәргә белмәде, теле көрмәкләнде, җан җылысы табылмады.* Н.Хәсәнов. *– Анда бит, анда... – Нурсөянең теле көрмәкләнә иде. – Анда... Гыймран абзаң акылга җиңеләйгән.* Н.Гыйматдинова. *Вәзир Исхак кичтән эчкән эчемлектән әле булса айнып җитмәгән, теле көрмәкләнмәсә дә, исерек иде.* М.Хәбибуллин

**Көрмәкләнә башлау** Көрмәкләнергә тотыну. *– Дөрес әйтәсең, иптәш Бәдертдин Әсәйский, – ди атаман, көрмәкләнә башлаган телен көчкә әйләндереп.* Н.Әхмәдиев

**Көрмәкләнеп тору** Әледән-әле яки хәзерге вакытта көрмәкләнү. *Моның белән шаккаттыра алмагач, үзен урыс*

*булуда гаепләргә теләмәгәндәй: – Әллә нигә телем көрмәкләнеп тора, – дигән сүз ычкындырды.* Ф.Яхин

**Көрмәкләнеп бетү** Тәмам көрмәкләнү. *Аягында көчкә басып торган, теле көрмәкләнеп беткән --- бер яшь кенә егетне иптәшләре: «Братан, успокойся!» – дия-дия, көч-хәл белән өстерәп алып чыгып китте.* Шәһри Казан

**КӨРМӘКЛӘ́Ү** *ф.* Махсус элмәк, төен ясау; шундый төен ясап бәйләү. *Хатыныңны хөрмәтлә, тезгенен кулга көрмәклә.* Мәкаль. *Серне чишә бит бу, бетерә башны, хурлык бавы белән көрмәкли.* Ш.Маннур

**Көрмәкләп кую** Көрмәкләп әзер итү

**КӨРМӘКЛӘШҮ** *ф.* 1) Билләрдән алышып көрәшү; әүмәкләшү; сугышу, көч сынашу. *Гариф хәлфә вакытында без дәрес бетәр-бетмәс ду килеп урыныбыздан куба идек тә, ишек төбенә ташланып, өерелешеп-көрмәкләшеп, букчалар белән сугышып, мәдрәсәне тузанга батыргач кына чыгып китә торган идек.* Ә.Еники. *Ике арада якалашу, көрмәкләшү башлангач, халык арасыннан чыгарылган Мәхмүди, кемдер йодрык кундырган чигәсен ышкыйышкый, нишләргә белмичә, бер як читтә басып тора ---.* Ә.Фәйзи. *Командалар регби уенындагы кебек унарлап өелешәләр, көрмәкләшәләр, туп капка янына таба бөтенләй тәгәрәми, я бер кырыйга чыга, я икенче янга кача.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Ярышу, берсен-берсе уздырырга тырышу. *Картта ике көч сугыша, көрмәкләшеп көрәшә башлады.* А.Хәлим

**Көрмәкләшә башлау** Көрмәкләшергә тотыну

**Көрмәкләшеп бетү** Көрмәкләшүгә кадәр барып җитү; нык көрмәкләшү

**Көрмәкләшеп тору** Гел, әледән-әле яки хәзер көрмәкләшү

**КӨРМӘКЛЕ** *с.* Теле көрмәкләнә торган (кеше тур.). *Күреклегә күз иярер, көрмәклегә сүз иярер.* Мәкаль

**КӨРМӘЛӘНҮ** *ф. диал. к.* **көрмәкләнү**. *– Матурлар бит, Таҗи Хаҗиевич, әйеме? – Ә-әйе, – диде мөдир, теле көрмәләнеп.* М.Сәлим

**КӨРМӘЛЕ** *с.* Өсте капланган, ябык. *[Бибикамал] Читән чыбыктан үргән көрмәле йомшак тарантаска ун яшьлек улы Хәмзәне дә алган иде, атнадан артык кунакта булдылар алар.* Т.Нәбиуллин

**КӨРМӘЛҮ** *ф. сөйл. к.* **көрмәкләнү**. *Чишмә сулары дулкынланган, тулганган, Агышларыннан тынып, теле көрмәлгән.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *– Кызым? – диде Камиләттәй, теле көрмәлеп.* Н.Фәттах

**Көрмәлә башлау** Көрмәлүгә табан бару

**Көрмәлеп бетү** Бик нык көрмәлү. *[Хәмдүнә:] Телең көрмәлеп беткән бит инде.* М.Кәбиров

**КӨРМӘ́Ү** *ф. к.* **көрмәкләү**

**КӨРМӘШҮ** *ф. диал. к.* **көрмәкләнү**

**КӨРПӘ** I *и.* **1.** 1) Яңа туган сарык бәрәне

2) Бәрән тиресеннән эшләнгән мех, илтер

3) Дөя, сарык йоны, мамык һ.б. кушып сырылган һәм ятканда яисә утырганда аска җәелә торган кечкенә түшәк. *Дөрес, аны чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар; юынганда кулына комганнан җылы су салып тордылар; астына йомшак көрпә салып түргә утырттылар...* Ә.Еники. *Җәгъфәр озакламый тирмәгә кереп көрпәгә сузылып ятачак һәм Кустанайдан алып кайткан Казан газеталарын укый башлаячак.* А.Расих

**2.** *с. мәгъ.* 1) Көрпәдән (*2 мәгъ.*) тегелгән. *Күркәмгә күз иярә, көрпә тунга чүп иярә.* Мәкаль

2) *күч.* Йомшак, нәфис. *Күтәр чәчкәйләрең, күтәр кабагың, Күренсен күзләрең, көрпә яңагың.* Дәрдемәнд

**КӨРПӘ** II *и.* 1) Ашлык бөртекләренең он итеп тарттырганнан соң калган һәм вак кабыклардан, тышчалардан гыйбарәт булган чүбе (онны иләгәндә, гадәттә, иләк өстендә кала). *Бәлки әле, көрпәсеннән тавыкларга боламык та пешереп бирәләрдер.* Ф.Яруллин. *Нургали аларга тәмле печән, көрпә, чөгендер бирәсе урында, юкның сәбәпләрен аңлатып, акыл сатып тора алмый.* Ә.Еники. *Андагы йон аралары әни иләктән он иләгәч җыелып калган көрпә кебек тузанлы икән.* Ә.Галиев

2) *диал.* Ярма. *Шуңа күрә, бик хәлсезләнеп китмәсен дип, үзебезнең авыздан өзеп булса да, аңа да бәрәңгесеннән дә, көрпәсеннән дә өлеш чыгарып килдек.* Р.Вәлиева

3) *неол.* Металл, агач һ.б. өстен кырып эшкәрткәндә барлыкка килгән вак бөртекләр, чүп; эшкәртү калдыгы

◊ **Көрпә кушу** Нәрсә дә булса сөйләгән вакытта бераз арттырып, ялганлап яисә үзеннән өстәп, булган хәлне тыңлаучыга күпмедер дәрәҗәдә үзгәртеп тәкъдим итү, җиткерү. **Көрпә баш** *тирг.* «Аңгыра, башсыз, тинтәк» дигән мәгънәдә берәр кешегә карата әйтелә

**КӨРПӘ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан 5–10 см биеклегендәге берьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **крупка**

**КӨРПӘЧӘ** *и. к.* **көрпә** I (*3 мәгъ.*). *Урындыкта ул эшләгән көрпәчәләр, оныкларында күңел җылысын кушып бәйләгән оекбашлар, жилетлар дисеңме...* Ватаным Татарстан

**КӨРСЕНҮ** *ф.* Нинди дә булса хисне (кайгы, борчу, сагыш һ.б.) белдереп, озын һәм тирән итеп сулап кую. *Бала чагын, егет вакытларын, каз өмәләрен, туйларын, җыеннарын, ярминкәләрен – барысын да кызык итеп, тәмле итеп, көрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде [бабасы].* Ә.Еники. *Бүген ул [Әбүзәр абый] таркау: әле шат сыман, әле уйга чума, онытыла, аска карый, көрсенә.* Г.Әпсәләмов. *– Фатыйма дип көрсенмә, син үзең мине коллыкка саттың, – диде бер тавыш.* Ф.Яруллин

**Көрсенеп алу** Кисәк кенә бер яисә берничә тапкыр көрсенү. *Профессор ике кулы белән башын кысып өстәлгә таянды, берничә тапкыр бик тирән итеп көрсенеп алды.* Г.Әпсәләмов. *Әткәй гәҗит укый. Вакыт-вакыт Көрсенгәләп ала.* Г.Морат. *– Алга таба да алдынгылыкны саклап калып булырмы ---. – Ландыш ханым тирән итеп көрсенеп ала.* Сөембикә

**Көрсенеп кую** Бер тапкыр көрсенү. *Ул [Тимерхан] үзе дә сизмәстән сәер генә көрсенеп куйды: – Инде менә шул*

*кадәренә дә канәгать...* Г.Ахунов. *Көлештеләр, ә җиңгәчәсе: «Һи, заманнар, картлары да балалар төсле булган», – дип, бер көрсенеп куйды.* Ә.Еники. *Мотыйк озак итеп башын селкеп торды-торды да көрсенеп куйды.* Р.Вәлиев

**Көрсенеп йөрү** Анда-санда көрсенү

**КӨРСИ** *и. гар.* 1) Терсәк куя торган култыксалары булган биек, киң һәм җайлы урындык, кәнәфи. *Тик Чикерткә генә йомшак көрсигә тәмам баткандай кузгалмыйча утырып кала.* Ә.Еники. *Ләкин председатель бу хәлдән тиз котылды, кулын каршысындагы көрсигә ишарәләп кенә сузгандай итеп: – Исәнмесез, утырыгыз, – диде.* М.Маликова

2) *иск.* Теләсә нинди утыргыч. *Аларның кайберләре янында мөдәррисләре тәбәнәк кенә бер көрсигә аякларын бөкләп утырып, тирә-юньнәрендә идәнгә утырган шәкердләргә дәрес әйтәләр.* Х.Миңнегулов. *– Патшалар көрсиеннән бер дә ким булмады бит бу, – дип сөенде Илгиз, үз эшенә үзе сокланып.* Казан утлары

3) *иск.* Мәдрәсәләрдә парта хезмәтен үтәгән тәбәнәк өстәл. *Көрси исемендә йөргән бу әйбер партаның пародиясе булса да, укучылар һәм укытучылар үзләрен бәхеткә ирешкән дип саныйлар, чөнки кадими мәктәптә мондый әйберләрнең исе дә юк.* Казан утлары

**КӨРТ** *и.* Җил себереп ясаган кар өеме. *Кышкы җилләр, тырыша торгач, эскертләр әйләнәсенә шактый калын итеп көрт салганнар.* Ә.Еники. *Агачлар гына түгел, юл кырыена өелгән тау-тау кар көртләре --- – барысы-барысы аның каршына йөгерәләр, аның кочагына керергә ашыгалар кебек.* Р.Вәлиев. *Тыкрык аша көрт ерып, синең янга килү әллә рәхәт дип беләсеңме?* З.Зәйнуллин

**КӨРТИ** *и.* Өс киеме астыннан кию өчен сырып тегелгән яки мехтан эшләнгән җиңсез кием. *Әнкәмнән калган мамык, плүш көртидән бер мендәрчек сыман нәрсә әмәлләгән идем.* Р.Рахман. *Тун астыннан көрти киярга ярата иде безнең әткәй.* Сөембикә

**КӨРТЛЕ** *с.* Көрт баскан. *Авылның көртле юллары машинасын чөеп-чөеп җибәргәндә, йөзе бозылды, тешләре кысылды.* Ф.Яруллин. *Клуб алдында моторлар гөрләп тора: театр машинасын көртле, таулы юллардан озатып куясы бар.* Ш.Галиев. *Бу җырны әтием Кайбыч урамнарының көртле юлларын ерып килгәндә җырлаган икән.* Р.Рахман

**КӨРТЛЕК** *и.* Тавыксыманнар отрядыннан, ите ашарга яраклы булган шактый зур кыргый кош; урман тавыгы. *Нибары өч-дүрт куяным, сигез тиенем, биш көртлегем, бер карт бүрем калды.* Р.Батулла. *Дөрес, ул чакта көртлек, кыр тавыгы юк иде, әгәр алар да булса, дөньясын умыра идек!* А.Гыйләҗев. *Урманда көртлекләр, төлке, куяннар җитәрлек, диләр.* Р.Низамиев

**КӨРТМӘЛЕ** *и. бот. диал.* Мүк җиләге; *русчасы:* **клюква**. *[Мәдинә] Чабылмый калган озын үлән арасында алланып күренгән көртмәлегә үрелде.* Г.Якупова

**КӨРТМӘЛЕК** *и. бот. диал.* 1) Кара җиләк; *русчасы:* **черника**

2) Нарат җиләге; *русчасы*: **брусника**

**КӨРҮГ** *и. бор.* Күзәтче, шымчы, дошман тылын күзәтүче

**КӨРЧЕК** *и.* 1) Чүрәкәй уенында җиргә сызылган түгәрәк яки шул түгәрәк хезмәтен үтәгән таш. *Ничек уйласам да, бөтен уйлар Туктап кала көрчек ташында.* Ш.Маннур

2) Балалар уенында нинди дә булса чикне билгеләгән сызык. *Йөгерү, качу өчен бер сызык киртәсе (көрчек) билгелиләр дә сукыр тәкәне сызык читенә илтеп, аякларын иркен итеп бастырып куялар.* Татар халык уеннары: Кабыргалы-камчылы. *Сәлимә көрчекнең икенче ягына чыкты дип, шунда ук әләкләргә дә тотынды малайлар.* Ялкын

3) Нәрсәнең дә булса соңгы чиге, ахыры. *Гафу ит, мондый хәстәрлегем гомеремдә беренче мәртәбә. Көрчек якынаю галәмәтедер.* Н.Нәҗми

◊ **Көрчеккә терәлү** Аптырап калу, нишләргә дә белмәү; чарасыз калу. *Биктимер абзыйның да быел эше көрчеккә терәлде.* Г.Толымбай. *Эшләвен эшлибез инде анысы, ял иткән юк, тик менә атсыз калгач, эшләр көрчеккә терәлә.* Казан утлары

**КӨС** *и. диал.* Вак балык, маймыч. *Салих көсләрне әрли-әрли кармагына суалчан кигезде.* Г.Мөхәммәтшин

**КӨСӘМЧЕ** *и. иск. диал.* Биләмдә күп йөрергә яратучы; биләмче. *Көсәмче хатын*

**КӨСӘНҮ** *ф. иск.* 1) Теләү, сорау, өмет итү. *Тимәсне көсәнүдән файда юк.* Мәкаль. *Авыр сулап бабай көсәнде, Тәңре, коткар, үзең ярдәм бир, дип, Күзен күккә таба күтәрде.* Г.Сөнгати

2) Аш сайлау, талымлау

**КӨСМӘН** *и. бор.* Зур ишкәк, көймәдә койрык ишкәге. *Бу турыда Агыйдел бик каты ага – салдагылар бөтен көчләрен көсмәнгә салдылар, юкса, сайга килеп утыруы мөмкин иде. Койрык көсмәнен берүзе тоткан иң таза кеше Раббани абый иде.* Х.Сарьян

**КӨСТӘНҮ** *ф. иск. к.* **көсәнү** (*1 мәгъ.*). *Көстәнеп күп егъладым күңелем тулып.* Г.Кандалый

**КӨТӘРГӘ** *рәв. сөйл.* Бурычка, әҗәткә, соңыннан түләп кайтару шарты белән (бирәчәк яки алачак акча, әйбер һ.б.ш.). *Ул чордагы татар сәүдә буржуазиясе арасында Москва фабрикантларыннан көтәргә күпләп мал алып, соңыннан «шартлаган» булып банкротлык игълан итү --- бик модадагы әйбер иде.* М.Гали. *Карале, көтәргә он-фәлән сорап килүче булса, закладсыз бер кашык та бирәсе булма.* И.Гази

**КӨТӘСЕГӘ** *рәв. диал. к.* **көтәргә**. *Әхмәтсафа агай өязләрдә кибет ачып, --- бәгъзы өяздәге сәүдәгәрләргә көтәсегә дә Мәскәү малын сата торган булды.* Ш.Мөхәммәдев

**КӨТӘЧӘККӘ** *рәв. сөйл. к.* **көтәргә**. *Орлыгың аз булса, көтәчәккә бирермен.* М.Җәлил

**КӨТЕК** *с. сөйл.* 1) Кимчелекле, тулы булмаган, җитешсезлекләре күп булган, өтек. *Көтек проект*

2) *кимс.* Озын булмаган, кыска. *Аяк-куллары көтек, муены озын гарип ир аренада эт булып уйнады.* М.Кәрим. *Арбада галәмәт олы башлы, кыска гына гәүдәле, көтек аяк-куллы өч яшьләр чамасындагы шыр ялангач ир бала ята.* Мирас. *Аның өстендә көтек бишмәт*

3) Очланып тормаган. *[Бәк Бәкичнең] ирене өстендә көтек кенә мыек,*

*каш нечкәртелгән.* Х.Кәрим. *Көтек башлы каләм*

**КӨТЕКЛЕК** *и.* Кимчелекләре, житешсезлекләре күп булу. *Проектның көтеклеге*

**КӨТЕЛГӘН** *с.* 1) Алдан билгеле булган, булуына ышанылган; булуы фаразланган. *Әмма тормыш көтелмәгән һәм көтелгән кайгы-хәсрәтләрен алга чыгарып куйды.* М.Мәһдиев. *Шәрифәдән көтелгән җавап алынгач, Нәгыйм-мулла тынычланып калды.* Идел

2) Көтеп алынган. *Күптән көтелгән беренче сентябрь көне дә үтеп китте.* Г.Әпсәләмов

**КӨТЕ́ЛМӘГӘН** *с.* 1) Кинәт килеп чыккан, алдан билгеле булмаган, һич уйламаганда булган, барлыкка килгән. *Фашистлар, көтелмәгән һөҗүмнән каушап, кача башлыйлар.* К.Нәҗми. *Бу көтелмәгән очрашу Гәүһәрнең күңелен айкарга җитә калды.* Г.Әпсәләмов. *Исән көенә Казан урамнарында күренүе [Х.Туфанның] күпләр өчен көтелмәгән һәм сәер күренеш була.* Казан утлары

2) Беркем дә көтмәгән, очраклы. *Әмма килүче бөтенләй көтелмәгән кунак булып чыкты.* Г.Әпсәләмов

3) Сирәк була торган, гадәттәгедән аерылып торган. *Көтелмәгән эпитетлар, сынландырулар, ашкын хисле, саба җилле гүзәл әкият тулып тора аның [Марсель Гали] туган якка багышланган нәсерләрендә.* Г.Ахунов

4) Тиешле җирлексез, нигезсез, сәбәпсез барлыкка килгән, очраклы. *Ул кисәк кенә Баһавига арты белән борылды, көтелмәгән игътибарсызлык күрсәтеп, кунакка сүз дәшмәстән, башта лампаның филтәсен чеметеп тазартты.* А.Расих. *Алдан бу хәлләр турында белгәч, Ленар өчен көтелмәгән удар булмый инде.* Казан утлары

**КӨТЕ́ЛМӘГӘНДӘ** *рәв. к.* **көтмәгәндә**

**КӨТЕ́ЛМӘГӘНЧӘ** *рәв. к.* **көтмәгәнчә**. *Ләкин алар Диләфрүз әйткән урамда очрашмадылар. Бар да көтелмәгәнчә килеп чыкты.* Г.Әпсәләмов

**КӨТЕ́ЛМӘСТӘН** *рәв. к.* **көтмәгәндә**. *Бу шулкадәр көтелмәстән, уйламастан һәм шулкадәр табигый әйтелде ки, Рәхилә, ихтыярсыз, янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды.* Ә.Еники

**КӨТЕПХАНӘ** *и. иск.* 1) *к.* **китапханә**. *Соңра мин дә тиз генә көтепханәмә барып, Крыловның әсәрен табып, «Күке илә Әтәч кыйссасы»ны янә бер кат укып чыктым да тирән бер фикергә талдым.* Г.Тукай. --- *Әлеге көтепханәнең гыйбрәтле язмышы археографик мирасыбызны үлемнән коткару юлындагы Вахиди эшчәнлеген фәнни дөрес бәяләргә ярдәм итә.* М.Госманов. *Болар бабаларын каршы алырга бигрәк дәрт белән хәзерләнәләр һәм аталарының көтепханәсендә XX гасыр башына даир ни кадәр китаплар булса, шуны укып чыгарга тырышалар иде.* Ф.Әмирхан

2) Китап нәшрияты

3) Китап сату ширкәте

**КӨТЕПХАНӘЧЕ** *и. иск. к.* **китапханәче**. *Аннары рус теле һәм әдәбияты кабинетында көтепханәче булып эшләвем дә үсүемә аз ярдәм итмәде.* Г.Кутуй

**КӨТЕШЛИ** *рәв. сир.* Көтеп торганда, көткән чакта. *Суд барган вакытта Нәгыймә, баласы авырганны ишетеп кайтканнан соң, аптекада дару ясалганны көтешли, Шәрәфиләр өенә килеп, мәҗлестә утыра.* Г.Нигъмәти

**КӨТКӘ́НЧӘ** *рәв.* Теләгәнчә, өмет иткәнчә. *Ләкин аның ахыргы нәтиҗәсе көткәнчә куанычлы булырмы?* Т.Әйди

**КӨ́ТМӘГӘНДӘ** *рәв.* 1) Һич уйламаганда, кинәт. *Көтмәгәндә килеп төшкән үги килен бөтен мәҗлес вакытында гаҗәп дәрәҗәдә кирәкле кул булып китте.* Г.Ибраһимов. *Инде менә китүенә дүрт ел узгач, алдан хәбәр итеп тормыйча, көтмәгәндә генә [Сабир] үзе дә кайтып төште.* Ә.Еники. *Шуннан соң, ничектер бер дә көтмәгәндә, көне-төне ишеп-ишеп кар яуды, бөтен җир акка төрелде.* Г.Әпсәләмов

2) Сизмәгәндә, абайламаганда. *Көтмәгәндә күреп аласым, качып калган урынын беләсем килә тегенең.* Р.Мөхәммәдиев

**КӨТМӘ́ГӘНДӘ-УЙЛА́МАГАНДА** *рәв. к.* **көтмәгәндә**. *Бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда елгыр бия башын югары чөеп кешнәп җибәрде.* Р.Мөхәммәдиев. *Юлыктым мин быел бер чәчкәгә, Көтмәгәндә-уйламаганда...* Х.Туфан

**КӨ́ТМӘГӘНЧӘ** *рәв.* Алдан уйланылмаганча, уйламаганча. *Ләкин бу эш гел көтмәгәнчә тәмамланды.* Идел

**КӨТҮ** I *ф.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса килүен саклап тору, каршы алырга, очрашырга әзер булып тору. *Син кайларда йөрисең икән? Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...* Җыр. *Монда киләсе икәнегезне ишеткәч тә, әллә нишләп сабырсызланып көттем мин сезне.* Ф.Әмирхан. --- *Хәлсез тавыш белән: – Трамвай көтәм, – дип өстәдем. – Көтмәгез, трамвай тиз булмас, кайдадыр авария.* Ә.Еники

2) Берәр нәрсәнең булуына исәп тотып, ышанып тору. *Алда безне сыный торган әллә ниләр булыр әле дип, өмет катыш көтә идек без, һәм безнең сабый күңелләр ялгышмады: безне кырык беренче елның июне айныны.* М.Мәһдиев. *Хат килгәнне зарыгып көтү*

3) Берәр теләгән нәрсәнең киләчәктә булуына ышанып тору, өмет итү. *Безнең авыл җирендә ни булсын, менә шәһәрдән кайткан кешеләрдән көтәбез инде яңа хәбәрләрне.* М.Әмир. *Кешенең иң зур, көчле хисләреннән берсе – алдан сизү, көтү. Кеше әле үзенең нәрсә көткәнен белми, ләкин күңеле өзгәләнә инде, тыпырчына.* М.Мәһдиев

4) Берәр кешенең килүенә (кайтуына) ышанып вакыт уздыру. *Егетем көтә, әти-әнием көтә – бар да көтә, ә мин, селкенүдән туктаган маятник шикелле, ни ары, ни бире!* Ә.Еники. *Бәдри дә киткәч, авыл кемнедер югалткан сыман ятим калды. Аны гел көттеләр.* М.Мәһдиев. *Бибинур апа үзләренең бәләкәй бүлмәсенә яз кояшы төсле яктылык, нур алып керәсе сабыйны бөтен күңеле белән көтте.* Г.Ахунов

5) Нәрсәнең дә булса әзер хәлгә килүен, җитешүен, өлгерүен карап-күзәтеп тору. *Мунча булганын көтеп тормаска булдым.* Казан утлары. *Аш өлгергәнне көтү*

6) Табигатьтә булган берәр күренешнең булуын, шуның тормышка ашуын саклап вакыт уздыру. *Латыйфа карчык җәйне бик сабырсызлык белән көтте.*

Х.Садри. *Язны бигрәк тә балалар сагынып көтәләр.* Г.Әпсәләмов

7) Берәр төрле эшнең яки процессның вакыты, срогы килеп җитүен саклап вакыт үткәрү. *Ай түгел, атна түгел, бер көн, бер сәгать көтәргә дә ирек бирмәделәр.* Г.Ибраһимов. *Гәүһәр икенче көнне көтә-көтә алҗып бетте.* Г.Әпсәләмов

8) *Дөнья, тормыш* сүзләре белән килеп, «алып бару» мәгънәсен белдерә. *Өч малае төрлесе төрле җирдә дөнья көтә, ди.* М.Кәрим. *Аның бит бердәнбер кызын дәрәҗәле, исемле, әмма, шуның белән бергә, тормыш көтүнең рәтен-җаен белгән хөррәк кешегә бирәсе килә иде...* Ә.Еники. *Ялгыз башың белән дөнья көтүләре бик читен шул.* Г.Әпсәләмов

9) Уйлау, гөман кылу, ничек буласын чамалау. *Уймак кадәр шул кечкенә генә тычканнан мондый чинауны кем көткән?* Җ.Юныс

10) Берәр нәрсәне алдан белеп, шуңа әзер булу. *Василий үзе дә офицердан берниндә изгелек көтми иде.* Ә.Еники

11) Терлекне кырда, болында һ.б.ш. урыннарда карап йөртеп ашату. *Атадан ятим калган угыл ел үсәсен көн үсә, буй җиткерә һәм, күп тә үтми, атасының малларын көтә башлый.* М.Хәбибуллин. *...Ноябрьнең сигезендә кар яуды да, ат көтүне туктатырга туры килде.* В.Нуруллин

12) Берәр эшне үтәү. *Мәдрәсәдә һәр көн бер шәкерт кизү көтә.* М.Гафури

◊ **Көтә-көтә көт (көтек) булу** Көтә-көтә алҗып бетү, озак көтеп торудан гарык булу. *Мәрьям иреннән хат көтә-көтә көтек булды.* Идел. *Ул ир дигән нәрсәләрне көтә-көтә көтек булып бетәрсең.* Г.Камал. *Мин көтә-көтә көт булгач, Гөлгыйзар адресы белән хат яздым.* Г.Исхакый. *Ул [Гәүһәр] өенә ашыга... Җәгъфәре инде көтә-көтә көтек булгандыр.* Г.Әпсәләмов. **Көтеп кенә тору** Форсаттан бик тиз файдалану. *– Күпләр шундый костюм тектерерләр әле, – диде кухнядан чыгып килгән Гөлназ. – Безнең яшьләр яхшыны көтеп кенә торалар.* Ә.Әпсәләмов. **Көтеп яту** Берни эшләмичә, кешедән көтү; мәсьәләнең үзлегеннән чишелгәнен көтү. *Неужели тегеннән кайтканнарын көтеп ятарга туры килер?* Х.Камалов. **Көтмәгән җирдә(н)** Һич көтмәгәндә, һич уйламаганда, кинәт. *Ник хәзер [бай абзый] күңелең боек? Әллә һичбер көтмәгән җирдән сату тукталдымы?* М.Гафури

**Көтә башлау** Көтәргә керешү. *[Хөсәен карт] сыерчык килгәнне көтә башлый.* Г.Газиз

**Көтә бирү** Бернигә карамыйча, һаман көтү

**Көтә төшү** Тагы да бераз көтү

**Көтеп алу** Кемнең яки нәрсәнең дә булса килгәнен (булганын) көтеп, күрүгә ирешү. *Ә минә аларның өченчесе – Ибраһим ага Салахов – ул көнне дә көтеп алды.* Г.Ахунов. *Шул кичәдән соң Тукайның үзен күрмәсә дә, аның турындагы хәбәрләрне аерым бер кызыксыну белән тыңлый, зарыгып көтеп ала торган булды Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев. *Якшәмбе. Мәктәп балаларының көтеп алган кадерле көне: таң тишегеннән торып, мәктәпкә барасы юк.* В.Нуруллин

**Көтеп җиткерү** Ахыргача көтү, көтүенең нәтиҗәсен күрү. *Хәер, башыңда булса да, барыбер аның килгәнен көтеп җиткерә алмыйча дөнья куясы икән безнең сыман гади халыкка.* Э.Фатыйхова

**Көтеп йөрү** Көтеп торган хәлдә булу, озак көтү. *Була шундый хәл: беркайчан да үзең ишетмәгән, ләкин бар булып тоелган гаҗәеп матур көйнең бер килеп ишетелүен көтеп йөрисең.* Ә.Еники. *Зифа буйлы, шомырт күзле бу кызга сокланмаган кеше авылда юк иде. Менә хәзер ул инде, чирләп, үлем көтеп йөри.* М.Мәһдиев. *Мөхәммәт абый миннән егерме еллар әнә шул шигырьне көтеп йөргән, ә мин, вәгъдәсез, язмаганмын...* Р.Харис

**Көтеп калу** Калган җирдә көтү. *Сездән тиз арада җавап көтеп калам, аның уңай булачагына ышанам.* А.Галимов

**Көтеп карау** Билгеле бер вакыт дәвамында көтү

**Көтеп тору** Көтү хәлендә булу; әлегә көтү. *Бу шундый җанга якын таныш тавышы кызның йөрәгенә төште... ул бары шул нечкә тавышның ишетелүен генә көтеп йөри торган булды.* Ә.Еники. *Сәгать җиде туларга егерме минутта мин басу капкасы төбенә барып көтеп торырмын, яме!* В.Нуруллин. *Ә өйгә кайтуга, аны өрҗыңа эшләр көтеп тора.* Ф.Яруллин

**Көтеп утыру** Сөйләү моментында көтү хәлендә булу. – *Нәфисә көтеп утыра утыруын да, – диләр имеш, – ай-һай, авыл кызына өйләнер төсле күренми ул егет!* Г.Бәширов. *Гыйльмениса апа мичтән чыккан бәрәңгегә су бөркә, --- көтеп утырасың – йортта тантаналы иминлек.* М.Мәһдиев

**Көтеп яту** *сөйл.* Шактый озак вакыт көтү. *Элеккеге кебек... берәр яки ярты көнгә ял биреп ала торган яңгырлар беткән. Шулайдыр, чөнки елгалар, күлләр, урманнар бетте, --- болытны Атлантик океаннан көтеп ятабыз.* М.Мәһдиев. --- *Синең күзең төшкән кыз сиңа пока отказ бирә... йокламый ул. Син нәрсә әйтеп узарсың дип көтеп ята ул.* Казан утлары

**Көтә башлау** Көтәргә керешү. --- *Маһруй, авылга китмичә, Пеләтәндә (Казанның бер төбәге) бер карчыкның өенә урнашып, бала туар көнне көтә башлады.* З.Бигиев. *Асавкадан Раушания исемле кызга өйләнеп дөнья көтә башладылар.* Өмет

**Көтә бирү** Бернигә карамый көтүен дәвам итү. *Малай көтә бирде.* Р.Мөхәммәдиев

**Көтә тору** Башка эш-гамәл барышында көтү

**КӨТҮ** II *и.* 1) Болында, кырда һ.б.ш. урыннарда бергә көтелә, ашатып йөртелә торган терлек төркеме. *Болай да сирәкләнеп калган көтү бөтенләй чыгудан туктады.* Г.Гыйльманов. *Уҗым катыгы аеруча тәмле. Монысы көз көне, җир туңдыргач, сыер көтүе уҗым басуында йөргәндә була.* М.Мәһдиев. *Көтү чираты, ниһаять, безнең капкага җитте.* М.Галиев

2) Бер тирәгә тупланып торган хайваннар, җәнлекләр, кошлар төркеме. *Ат колакларын торгызган, пошкыра. Әттә генәсе! Каршыга бер көтү бүре килә!* Г.Әпсәләмов. *Һавада сыерчыклар көтүе күренә.* А.Алиш

3) *сөйл.* Бергә җыелып торган кешеләр төркеме. *Дежур сестра килеп керде: – Кыен булса да, коридорга чыкмыйча булмас сиңа, Нәҗметдинов, бер көтү кеше килгән анда. «Нәкъ бер көтү! Бу кадәр күп туганнарын күргәч, анакай һушыннан язачак» --- – дигән уй йөгереп үтте башыннан.* С.Шәрипова. *– Анда кызлар күп, чәчкәләр белән чыгарлар, – дип, бер көтү йөгәнсез кызны колоннаның алдына бастырды.* И.Салахов

4) *кимс.* Явыз максатлар белән нинди дә булса төркемгә оешкан кешеләр даирәсе; өер; банда, шайка. *Фашистлар көтүе. Наркоманнар көтүе*

5) *сир.* Өем, күч. *Кырда февраль җиле өермәләр кузгатып йөри. Бер тынып кала, бер яңадан сызгыра-сызгыра кар көтүләрен куып алып китә.* Н.Дәүли

◊ **Көтү башы** Көтүне ияртеп, көтү башында йөри торган хайван. *Кырга чыксаң, көтү башы кәҗә булыр.* Әйтем. *Көтү башы дип атап йөртә торган берничә сыер бар: карт, зур, мәһабәт, могтәбәр хайваннар --- алга чыгып юлбашчылык кылалар.* Г.Ибраһимов

**КӨТЎ-КӨТҮ** *рәв.* **1.** Төркем-төркем булып, берничә төркем хасил итеп. *...Яз көне шахталардан авылларына иген эшенә дип кайткан ярлы халык --- кире көтү-көтү булып шахталарга, фабрика-заводларга тарала башладылар.* К.Тинчурин

**2.** *с. мәгъ.* Күпсанлы, ишле. *Болай да байлар җитәрлек иде Җиргән татарлары арасында. Тире-яры белән сәүдә итүчеләр, көтү-көтү аяклы мал куучылар, итчеләр...* М.Әмир. *Юныс карт --- көтү-көтү малларны ничек урлап куып алып киткәнен сөйләде.* Г.Ибраһимов

**КӨТҮЛЕК** *и.* 1) Алан, болын һ.б.ш. кебек көтү йөртә торган җир; утлау, утлавык. *Кесмәс елгасы өзгәләнеп кипкән, механизаторлар, яр буенда культуралы көтүлек өчен су алырга дип, трубаларны кая каптырырга белмичә йөриләр.* М.Мәһдиев. *Берәү дә аны [кырны] көтүлектән башка әмәл өчен файдаланмаган.* К.Нәҗми

2) Терлекне көтүдә ашату өчен файдаланыла торган, үләнчел үсемлекләр үскән авыл хуҗалыгы җирләре. *[Тундрада] Көтүлекләр җәй көне мүклишай тундрасында, ә кыш урманлы тундрада урнаша.* А.Фаткуллин

**КӨТҮЧЕ** *и.* 1) Көтүне болынга, кырга һ.б.ш. урыннарга алып чыгып, саклап, ашатып йөртүче кеше. *Көтүчесе нинди, көтүе шундый.* Мәкаль. *– Мин, – диде, – сүз сөйли белмим. Мин – көтүче. Менә мин егерме ел инде колхоз көтүен көтәм.* М.Мәһдиев. *Ул [әти] көтүче, ә мин аның ярдәмчесе генә.* Казан утлары

2) *к.* **көтү башы**. *Бары тик [атларның] үз араларыннан иң сылу, иң йөгерек, иң җитез җирән кашка гына көтүче хезмәтен үти икән.* А.Алиш

3) Кайбер күмәк уеннарда уенны алып баручы. *Йөгерешле, качышлы һәм башка шуның шикелле күмәк уеннарда күп вакытта балаларга арадан берсен көтүче итеп сайларга туры килә.* Н.Исәнбәт

**КӨТҮЧЕ́ БИШТӘРЕ** *и. бот. к.* **көтүче сумкасы**

**КӨТҮЧЕ́ БЫРГЫСЫ** *и. муз.* Агачтан ясалган халык музыка уен коралы

**КӨТҮЧЕ́ КОШЛАР** *и. күпл. зоол.* Торнасыманнар отрядындагы кошлар семьялыгына караган, болын-сазлыкларда, сай күлләрдә үсемлек һәм бөҗәкләр белән тукланып яшәүче кыска койрыклы кошлар (су тавыгы, камыш тавыгы, кечкенә кугыч һ.б.)

**КӨТҮЧЕ́ КУБЫЗЫ** *и. бот.* Көтүче кубызычалар семьялыгыннан, үләнле сазлыкларда, сай сулыкларда үсә торган ак чәчәкле, агулы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **частуха**. *Көтүче кубызы бөҗәкләр ярдәмендә серкәләнә.* Ботаника

**КӨТҮЧЕ́ КУБЫЗЫЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Бөтен җир йөзендә таралган, йөзләп төрне берләштергән берөлешле күпьеллык үлән үсемлекләр семьялыгы

**КӨТҮЧЕЛЕК** *и.* Көтүче булып эшләү, көтүче хезмәте. *Көтүче 23 яшьләр чамасында, шат күңелле, уенчак бер егет улып, көтүчелек кыла иде. Ошбу көтүчелек хезмәтендә дә иреклe булуны сөя.* З.Һади. *Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган.* Г.Кутуй. *Ул елларда көтүчелек иң түбән һөнәр исәпләнә иде, --- ягъни кулыннан башка берниндi дә эш килмәгән кеше генә көтүче була дип карыйлар иде.* М.Әмир

**КӨТҮЧЕ́ СУМКАСЫ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан ак чәчәкле, җимеше биштәргә охшаган кечкенә элпәле кузакчыктан гыйбарәт дару үсемлеге; *русчасы:* **пастушья сумка**. *Көтүче сумкасына үзеннән һәм читтән серкәләнү хас.* Ботаника

**КӨФЕР** *и. гар. дини* **1.** Ислам дине кануннарына буйсынмау; Аллага ышанмау, Алланы инкяр итү, танымау, хурлау. *Уразада гошер бирмәү Зур гөнаһ бит, көфер бит.* М.Җәлил

**2.** *с. мәгъ.* Алланы танымаудан гыйбарәт; гөнаһлы. *Арада шундый бер мәзәге бар: «Башларына мондый көфер сорау бирүчеләрне салып суктыру өчен, Алла, имештер, урманда чыбык кисеп яткан».* Г.Гобәй

◊ **Көфер мөһере сугу (басу)** Нинди дә булса темага сүз алып барганда, сүзне кирегә таба борып утыру. *Синең бар эшең, ахыры, шул, кешегә көфер пичәте басып утыру гына булырга кирәк.* Г.Камал. **Көфер пичәте сугу (басу)** *к.* **көфер мөһере сугу (басу)**. **Көфер почмагы** 1) *тар.* Инкыйлапка кадәр Казанда, Печән базары мәчете янында, кадимче динчеләрнең, сәүдәгәрләрнең һәртөрле яңалыкны һәм яңалыкны яклаучы кешеләрне сүгеп, тиргәп тору урыны. *[Тукай:] Рамазанов җәнапларының «Болгар» номерыннан качтым, туйдым Печән базарының кырыктартмачы Хафизларыннан, көфер почмагыннан.* А.Расих. *Хәмит абзый бик зур төгәллек белән Тукайның бүлмә номерын... Гайнан ишан мөритләренең кием формасын, Мөхәммәтҗан Хафизның көфер почмагында шкафын – барысын да төп-төгәл сөйли.* М.Мәһдиев; 2) *куч.* Кешеләрдән кимчелек табып, көлеп, гайбәт сатып тору урыны; гайбәт почмагы. *Һәрбер танцы залының үзенә күрә «көфер почмагы» була. Анда башкаларны күзәтүдән тәм табучы кызлар җыела.* Ш.Хөсәенов. **Көфер сүз** 1) *дини* Аллага, дингә каршы сүз. *[Хафиз:] Көфер сүз сөйлисең, Бибиҗиһан, тәкъдире язылганга*

*ышанмыйсыңмы әллә син?* Ә.Фәйзи. *Фәйрүзә аның Алладан өркүен искә төшерепме, юри кычкырып укыды: – Юктырсың ла, Алла! – Чү, ниткән көфер сүз? – дип каушап китте Хәйбүш.* К.Нәҗми; 2) Әшәке, начар сүз. *Кызның агасы артларыннан төрле көфер сүзләр илә ләгънәтләр укып калды.* Ш.Мөхәммәдев

**КӨФЕРЛЕК** *и. гар. дини* 1) Аллага, дингә ышанмау; исламнан, аның кануннарыннан читләшү. *Көферлек төшенчәсе потларга табыну, Аллаһны санга сукмау, намаздан баш тарту, сихерчелек, күрәзәчелек, эчкечелек, отышлы уеннар, хак юлдан яздыра торган эшләр, үз-үзеңә кул салу һ.б.ны үз эченә ала.* Татар энциклопедиясе

2) *күч.* Вәгъдәдә тормау, антыңа хыянәт итү; начар эш, ярамаган гамәл. *Дөньяда шушындый җаһиллек тә, мөкатдәс саналган бөтен тойгыларны аяк астына таптап мыскыллый торган шушындый көферлек тә булуы мөмкинме?* Ш.Маннур

◊ **Көферлегем житте** «Тәкъдирдән узып сөйләшүемнең афәте тиде, хур булдым» дигән мәгънәдә

**КӨФЕРЛӘНҮ** *ф. дини* 1) Алланы инкяр итү (танымау), Аллага каршы сүз әйтү

2) Берәр гөнаһлы эш эшләү

**КӨФРИЯТ** *и. гар. иск. дини к.* **көферлек**. *Муллаларны «элеп алып селкеп салуы», аннан соң үзенең «көфрияты», әллә нинди тарихлары-вакыйгалары белән дә тирә-якны шаулатуы Зыяныниндидер бер каһарман сыман итеп күрсәтәләр иде.* Г.Ибраһимов

**КӨФУ** *и. фар. иск.* Тиң, тиңдәш, пар. *Мин шуның белән тиң вә аңа көфу микәнни? – дигән уйлар күңеленнән китте.* М.Гафури

**КӨХЕЛ** *и. гар. иск.* Сөрмә. *[Әбүгалисина:] Сиңа мин бер чара күрсәтә алам. Күрәмсең бу тузан сөрмәсен? Көхел дигән әйбер.* Н.Исәнбәт

**КӨҺӘР** *и. фар. иск.* Гәүһәр. *Ике якты көһәр – ике якты гәүһәр*

**КӨЧ** *и.* **1.** 1) Тереклек иясенең физик эш, хәрәкәт башкару сәләте; гайрәт; кешенең яки хайванның физик энергиясе. *Урта буйлы, бик төз, җыйнак, тыгыз гәүдәле, көч үзендә яман булырга тиеш, беләкләрендәге таш-тай мускуллары буын-буын калкып тора.* Ә.Еники. *Тамак туйдыру өчен башкарылган эшләр никадәр күп физик көч таләп итсә, шуның кадәр үк рухи, эстетик ләззәт бирә.* М.Мәһдиев. *Таш кисү ничек авыр булмасын, тәндәге икенче көч үзенекен итә: котырына, куркыта, шомландыра. Шушы котырган көчне чыгармыйча торып тынычлана алмастыр ул, мөгаен.* Ф.Яруллин

2) Тумыштан килгән яшәү сәләте; яшәү инстинкты. *Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр Керфек очларыңнан тамалар?* Һ.Такташ. *Табигать законының көчеме, семья тормышын сагынумы, ләкин, ни генә булмасын, өйләнәсе килү теләге көннән-көн ныграк йота барды.* Ә.Еники. *Ниндидер бер инстинкт – ул аңламаган, аңа таныш булмаган, шул ук вакытта аңа буйсынмаучы, аның өстеннән хакимлек итүче көч – аны тагын һәм тагын шул кызга карарга мәҗбүр итте.* Ш.Хөсәенов

3) Куелган максатка ирешү өчен сарыф ителгән энергия, актив тырышлык. *Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым, Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.* Г.Тукай. *Мәгърифәтчелек идеяләре белән рухланган бу чор язучылары --- бөтен көчләрен халыкны агарту эшенә багышлыйлар.* М.Гайнуллин. *...Шушы хәтле матурлыктан шәһәр уртасына күчәргә башыңа тай типмәгәндер бит? Күпме көчең керде шушы йортка.* Мәдәни җомга

4) Кемнең яки нәрсәнең дә булса эш-хәрәкәт башкару сәләте, энергиясе, егәрлеге. *Аталардан калган, ай, яшь бала күкрәк көче белән мал таба.* Җыр. *Көч капкадан керсә, гаделлек ишектән чыгар; көч ишектән керсә, гаделлек тишектән чыгар.* Мәкаль. *Бәла килсә, күрү көче кулдан китәр.* М.Кашгари. *Әлбәттә, Илдарга эләккән булыр иде. Көчләре бер чама булса да, --- [ят] малай бик җитез һәм чамасыз кыю иде.* Г.Гобәй

5) Кодрәт, куәт, егәр. *[Хан] Мин үз кул астымдагы теләсә нинди колымның гомерен кыскарта алам, ә озайтырга көчем юк.* Әкият. *Кеше, индивидуум, никадәр генә көчкә ия шәхес булса да, җәмгыятьтән башка яши дә, бернәрсә эшли дә алмый.* М.Хәсәнов. *Юкка гына баш тартасың минем тәкъдимнән. Татар капиталы көч җыя башлады, безгә дә нәкъ көч җыяр вакыт хәзер.* С.Шәрипова

6) Хәл, дәрман, егәр; үз вазифасын үтәү сәләте. *Картайдым, көчем юк эш эшләргә. Мин картайдым, --- көчтән калдым.* Н.Исәнбәт. *Ашны икмәк белән ашасаң, көчең артыр.* И.Гази. *Авыр эш эшләгән саен безне дәртләндереп торучылар бар: көч чыкмыйча, көч керми. Ә көчле буласы килә!* М.Мәһдиев

7) Нәрсәнең дә булса файдалы, уңай ягы, өстенлек. *Ул кешене яшәртә һәм яңартып җибәрә торган хезмәтнең гаҗәеп бу хасиятен, шушы көченең серен тагын да тирәнрәк аңлый башлый.* Г.Бәширов

8) Ныклык, нык булу хәле. *Гәүһәр, иренең ат кебек пошкырынып юынуын яратып бетермәсә дә, бүген моңа игътибар итмәде, киресенчә, иренең тавышлануында ниндидер көч сизде.* Г.Әпсәләмов

9) Хиснең, акылның чагылу дәрәҗәсе. *Ачу, нәфрәт дулкынының көче астында тыела алмый каласың.* Ф.Кәрим. *Бу хыялый тормышны Әсма карчык үзе тудырган, үзе ясаган иде. Түзеп булмады, хәер, мин монда әлеге хыялый көч тәэсирендә идем ---.* М.Мәһдиев. *Акылның һәм тәрбиянең хәлиткеч көченә ышану, кеше характеры формалашуда җәмгыять һәм тирәлекнең тәэсирен күрсәтү мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятының төп нигезе булып тора.* М.Гайнуллин

10) Ышаныч, өмет. *Әсәрләрдәге башкаларга үрнәк булып торган геройлар шәригать кануннары буенча яши, һәм бу аларга көч, ышаныч, таянычтерәк булып тора.* Мәдәни җомга

11) Аерым сыйфатларга ия булган кешеләр төркеме яки аерым шәхес. *Әдәбиятка яшь көчләр килә. Социаль-мәдәни көчләр*

12) Рәсмилек, гамәлдә булу. *– Көч, хокук саклау органнары үз республикабыз карамагында булырга тиеш, –*

*дип нык торучы без – депутатлар – дүртәү-бишәү генә булдык.* Ватаным Татарстан. *[Халыкларның] Үзбилгеләнү хокукы дөньякүләм тарихи тәраккыять тенденциясен чагылдыра һәм халыкара гамәлләрдә реаль көчкә ия.* Мәдәни җомга. *Закон үз көчендә калды*

13) Нинди дә булса җисемнең, матдәнең һ.б.ш.ларның берәр эш башкарырга яки эш башкара торган энергиянең чыганагы булырга сәләте; егәр. *Кешеләрнең хезмәтен җиңеләйткән һәм хезмәтнең бәрәкәтен арттырган электр көче бөтен эш тармагына үтеп керсен.* Ә.Еники. *Дөньяның тегерменнәре күп төрле... Бар җил көченнән дә зырылдап әйләнә торганнары, бар су агымы килеп бәрелгәч кенә шаулап эшли башлаганнары.* Ф.Бәйрәмова. *Атом көчен һәм коралын уйлап таптылар, менә кеше холкының, кеше психикасының серләренә ахырынача төшенү өчен бик күп тырышасы бар әле.* В.Нуруллин

14) Берәр эш-күренешнең чагылыш дәрәҗәсе, интенсивлыгы. *[Кинәт туктаган поезд] вагоннарының буферлары бер-берсенә зур көч белән бәрелделәр.* К.Нәҗми. *Тавыш көче. Яктылык көче. Шартлау көче*

15) Хезмәт. *Кеше көченнән файдалану*

16) Берәр төрле иҗтимагый күренешнең, мәс., җәмгыятьнең, илнең куәте. *--- Бу рәхимсез кыш менә дигән бик күп имән урманнарын харап итте. Аларны алыштыру кыен, җирнең җитештерү көчләре, күрәсең, фәкыйрьләнә.* М.Мәһдиев

17) Нәрсәдер башкарырга сәләтле эшче куллар, кешеләр. *Гражданнар сугышы беткәч, эшсез калган меңнәрчә ак рус генерал, полковниклары, дөньяның төрле ягына таралып, һәр алучыга үзләренең кылыч көчләрен сата башладылар.* Ш.Усманов. *Сугыш беткән елда авылга «Оргнабор» дигән оешмадан әледән-әле вәкилләр килгәли башлады. Көньяк Сахалин, Амур буе өлкәләрендәге колхоз-совхозларга эшче көчләр җыйдылар.* М.Мәһдиев

18) Берәр төрле энергиянең, эшчәнлекнең чыганагын тәшкил иткән матди башлангыч. *Дальтон законын онытасың. Табигатьтәге бар хәрәкәт тә нинди дә булса бер көч катнашлыгыннан башка була алмый.* Җ.Фәйзи. *Дөньяда кешелек җәмгыятенең яшәвенә зур зарар сала торган кыргый көчләр бар: су басу, вулканнар ату, җир тетрәү, корылык, янгын, сугышлар.* М.Мәһдиев. *Китап ул яңа иҗтимагый көчләрне ныгытуга булышкан; шул ук Китап әлеге көчләр тудырган тәхетләрне челпәрәмә китереп җимерешкән дә.* М.Госманов

19) *куч. күпл.* Гаскәр, армия, хәрби частьләр. *Кулыбызда булган разведка хәбәрләренә караганда, Тозтүбәдә Дутовның зур көчләре җыелган.* Ш.Усманов. *Фашистларның, аңнарына килеп, зуррак көч белән чыгып, урманны айкарга --- тотынулары мөмкин.* А.Шамов. *Тигезсез сугышта --- казанлыларның көчләре бөтенләй какшый, сугышны дәвам иттерергә берничнди дә мөмкинлекләре калмый.* Р.Әмирхан

**2.** *хәб. функ.* Авыр, кыен; читен. *Бала начар булса – ата-анага көч.* Мәкаль. *Каты торсаң – җанга көч, Йомшак торсаң – чинга көч.* Мәкаль. *Аяз гына булса – айга көч, Болыт та булса – көнгә көч; Кая барсаң да бер кояш, Күбәләктәй газиз җанга көч.* Җыр

◊ **Көч алышу** Көрәшү, тырышу. *Җәмгыятькә тиенлек файда китермичә, хакыйкать турында чат саен сафсата саткан саламторханнар белән көч алышуга күпме хәләл көч сарыф ителә, күпме изге җаннар юкка чыга.* Т.Галиуллин. **Көч бирү** 1) Дәрт, илһам бирү, рухландыру, дәртләндерү. *Фронт дуслыгы ул бит ай-вай ничек, ул синең яшәвеңә көч бирә, тормышыңны матурлый.* Г.Әпсәләмов; 2) Куәтләү, дөреслеген раслау (сүзнең, фикернең һ.б.). *Баланың белеме булып та, фикере таркаулыгын аңлаган укытучы аңа «әйе, әйе» дип көч бирә.* Мәгърифәт. **Көч булу** Артык көч түгелү, мәшәкате зур булу. *Оренбуркайларның үре биек, Ат юрттырып менсәм – көч була ---.* Җыр. *[Малай:] – Юк инде, Рәдиф, өч тапкыр барып карадың – җитте! Өчтән ары көч була ул.* В.Нуруллин. **Көчен аямау** Үзен кызганмау, җәлләмәү; нык тырышу. *Үзем өчен генә түгел, сугыштагы ирем, фашистлар үтергән анам өчен дә көчемне аямый эшләргә сүз бирдем.* Г.Бәширов. **Көченә керү** Рәсмиләшү, закон көчен алу, законлашу. *Карар шунда ук бөтен галәм алдында көченә керергә тиеш.* М.Кәрим. *1980 елның июненнән хайваннар дөньясын саклау һәм аннан файдалану турындагы Закон көченә керде.* Биология. **Көч җиткән кадәр (кадәренчә)** Мөмкин булган кадәр, булдыра алганча. *Гәүһәр көче җиткән кадәренчә балаларны ялганламаска, туры сөйләргә өйрәтте.* Г.Әпсәләмов. **Көч җиткәнче** *к.* **көч җиткән кадәр**. *Кеше бер дә трай типми, ул яши, башкалар кебек эшли, тирә-ягында кайнап торган тормышка да көче җиткәнче катнаша кебек...* Г.Әпсәләмов. **Көч җитү** Берәр нәрсәне эшләргә хәлдән килү, булдыра алу; эшли алу. *Нәрсәдер сизенгән сыман, Гәүһәрнең бу хатны мәктәптә укырга көче җитмәде.* Г.Әпсәләмов. *Чанны аркан белән тартып югары мендерергә ирләрнең генә көче җитмәде.* Ш.Камал. **Көч килү** 1) Чамадан тыш күп эшләү аркасында организмга зарар килү; берәр әгъза авырту. *Күтәрмә, билеңә көч килмәсен;* 2) Авырга, кыенга туры килү. *Юк, Бибинур апа уйлаганча булмады бу. Әниеңнән оекбашны бер сорарга була, ике, әмма... өчкә китсә, көч килә шул инде...* Г.Ахунов; 3) Хурлану, гарьләнү. *Көнчелегенә көч килде Мәрьямнең. --- кул-аякларына барлык көчен салып, егетне ул куа чыкты.* Г.Ахунов. **Көч китерү** Авыр эштән берәр әгъзага зыян китерү. *Сәгъди абзый, дөньясын җиткерим дип, әнә Габдрахман байга йөк ташыганда аягына көч китерде һәм гомер буена аксап калды.* Ә.Фәйзи. **Көч кую** 1) Күп эшләү, күп энергия сарыф итү. *Дөрес, Сәйфулла аңа кан кардәше түгел, әмма ул бик якын дустының --- авылда яңа тормыш төзү өчен күп көч куйган, каты авырудан соң үлгән дусты Шәрифулланың улы иде.* Ә.Еники. *Хәмит ага Ярми күптомлыкның проспектын төзүгә, ә соңрак әкиятләрнең ике китабын әзерләүгә күп көч куйды.* И.Надиров. *Киң колачлы галим һәм оештыручы буларак, Тәлгать Галиуллин Алабуга педагогика*

*институтында да зур көч куйган.* Мәдәни җомга; 2) Тырышу. *Шигырь бит ул бик күп көч куеп озак вакытлар эшләү нәтиҗәсендә генә чын сәнгать үрнәге булу дәрәҗәсенә ирешә ала.* Т.Гыйззәт. **Көч салу** *к.* **көч кую**. *Ихтимал, аңа, Мәйпәрвәз ханымга, кияүне «чын семья кешесе» итәр өчен күп көч салырга, зур осталык күрсәтергә туры килер.* Ә.Еники. **Көчтән калу** Көч бетү, хәл бетү, әлсерәү, бетерешү. *[Хан:] Мин картайдым, --- көчтән калдым.* Н.Исәнбәт. **Көчтән килү** Хәлдән килү, башкарып чыгарга көч җитү. *Юк, ул эш минем көчтән килми, өстемә ала алмыйм. Әгәр минем көчемнән килсә, мин төрек кардәшләребезне кулыма күтәреп, Ататөрек мавзолее тавына алып менәр идем дә бөтен дөньяга күрсәтер идем.* Г.Ахунов. **Көчтән таю** *к.* **көчтән калу**. **Көчтән тыш** Мөмкин булганнан да артык. *Көчтән тыш көчәнмә, билең сынар.* Мәкаль. **Көчтән язу** *к.* **көчтән калу**. **Көч түгү** 1) Теләккә, максатка ирешү өчен энергия сарыф итү. *Яшьлеге аркасындамы, ул чакта Яңгураз дуслар эзләүгә артык көч түкмәде.* Т.Әйди. *Гарифә апа үзенең Габдрахманын җиңел алмады, көрәшеп, көч түгеп, энергия сарыф итеп, башка кызлардан аралап, яулап алды.* М.Мәһдиев. *[Халыкның] беришләре тирә-як байларга көч түккән, яисә ераккарак китеп эшләп кайткан.* И.Нуруллин; 2) Билгеле бер эшне ихлас күңел белән башкару, үтәү

**КӨЧӘЙТЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **көчәйтү**. *Ләкин безнең халыкта төш күрүнең мәгънәсе ике чорда ике тапкыр көчәйтелеп, куәт алган.* М.Мәһдиев

**КӨЧӘЙТКЕЧ** I *и. тех.* Электрон лампалар яки ярымүткәргечле триодлар ярдәмендә электр тогын яки аның көчәнешен арттыру җайланмасы. *Алгычның түбән ешлык көчәйткече нормаль эшли.* А.Тимергалин. *Лампалы көчәйткеч. Югары ешлыклы көчәйткеч. Егәрлек көчәйткече*

**КӨЧӘЙТКЕЧ** II *с. лингв.* Үзләре ялганып килгән сүзгә көчәйтү төсмере бирә торган. *Көчәйткеч кисәкчә*

**КӨЧӘЙТҮ** *ф.* 1) Дәрәҗәсен, көчен, интенсивлыгын, куәтен арттыру; зуррак итү, үстерү. *Президентларының үз культураларына да, дөньядагы барлык культураларга да якты күз белән каравы, мәдәни бәйләнешләрне көчәйтергә теләве аларны сөендерә.* Г.Гобәй. *--- теге яки бу вакыйгаларның кайсы моментын көчәйтү һәм, гомумән, стиль, тел, сюжет, образ турында шактый тулы итеп сөйләште.* К.Нәҗми

2) Нинди дә булса эш-хәрәкәтнең, процессның башкарылу көчен арттыру, зуррак итү, күбәйтү. *Чөнки каршы әйтелгән сүз, аталарының ачуын арттырып, буранны гына көчәйтәчәк.* Г.Ибраһимов. *Чишмәләр үзләре минем Учларыма су салды. Су салды алар яшәргә Көчәйтеп тик сусауны.* С.Хәким. *Стенадагы репродукторның тавышын көчәйттеләр.* Р.Ишморатова

3) Нинди дә булса эш-хәрәкәтне башкарырга ярдәм итү; үстерү. *Үткән ел Солтан, балаларның русча сөйләү телләрен көчәйтер өчен, рус драма түгәрәгенә оештырган иде.* Г.Кутуй. *Ләкин нинди генә җырны алма, ул, барыннан элек, кеше күңелендә тормышка мәхәббәт уята, кешедә яшисе килү теләген көчәйтә.* Ә.Еники

4) Нәрсәнең дә булса чагылыш дәрәҗәсен арттыру, интенсивлыгын үстерү, гамәлдәге көчен арттыру. *...Менә шушы горурлану хисе аның газаплы һәм ләззәтле мәхәббәтен тагын да көчәйтә иде.* Н.Измайлова. *Бу әсәрләр миңа, ничектер, якын, сердәш. Бәлки, аны язучының да минем төсле мәхбүс булуы тәэсирне көчәйткәндер.* И.Салахов. *Риторик сорау яки эндәшләр шигъри фикерне көчәйтүгә хезмәт итәсе урынга, йомшартуга хезмәт итә.* Н.Хисамов

**Көчәйтә бару** Торган саен көчле хәлгә китерү, көчен акрынлап арттыру

**Көчәйтә башлау** Көчәйтү ягына җибәрү

**Көчәйтә төшү** Тагы да бераз көчәйтү, көчен арттыру. *Кичәдән бирле бертуктаусыз сибәләп торган вак яңгыр профессорның күңелендәге моңсулык хисен тагын да көчәйтә төште.* Тәмуг чәчәге

**Көчәйтеп алу** Тиз-тиз генә, кыска вакытка көчәйтү. *Вакыт-вакыт бакчачылар алмагачны шулай көчәйтеп алалар бит әле, ашлыйлар.* М.Мәһдиев

**Көчәйтеп җибәрү** Кисәк көчәйтү. *Дөньяга таләпне үз-үзенә таләп белән бергә кую, соңгысын хәтта көчәйтеп җибәрү лирик геройдагы егетлек сыйфатын чагылдыра.* Н.Хисамов. *Бу сүзләр Сабир абзыйның түземсезлеген тагын да көчәйтеп җибәрделәр.* Ә.Еники. *Илебездә XX гасырның азагында барган үзгәртеп корулар татар халкында мәдәни мирасы белән кызыксынуны тагын да көчәйтеп җибәрде.* Гасырлар авазы

**Көчәйтеп карау** Көчәйтү юлын сынау

**Көчәйтеп кую** Кисәк, уйламаганда көчәйтү

**Көчәйтеп тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле көчәйтү

**КӨЧӘНЕШ** *и. физ.* Электр корылмасы хәрәкәт иткән вакытта электр энергиясенең көчен билгели торган зурлык. *Электр көчәнешен даими тоту өчен, төгәл стабилизатор сатып алдым.* А.Тимергалин. *Батареяның бушану дәрәҗәсен, шулай ук көчәнеш зурлыгы буенча нагрузканы сәнәк белән дә белеп була.* Механизаторлар белешмәсе. *Фазаара көчәнеш. Механик көчәнеш*

**КӨЧӘНЕШЛЕ** *с. физ.* Көчәнеше булган; билгеле көчәнештәге. *Югары көчәнешле*

**КӨЧӘНЕШЛЕЛЕК** *и. физ.* Җисем корылмаларының тыгызлыгына пропорциональ булган электромагнит кырының характеристикасы. *Электр кырының көчәнешлелеге. Магнит кыры көчәнешлелеге*

**КӨЧӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Бар көчкә бөрәр эш-хәрәкәт башкарырга тырышу яки эш башкару өчен күп көч салу. *Күпме генә көчәнмәсен, егет болытны иңнәреннән алып ташлый алмый.* Ф.Ярullин. *Шуннан соң җизнәсе Наилне күтәреп алды да, кечкенә баланы «үчтеки» иткәндәй, көчәнеп-көчәнеп югары чөя башлады.* Ә.Еники

2) *күч.* Гайре табигый тырышу, үзен көчләп мәҗбүр итү. *Конституциянең татарча текстын тәнкыйтьләп итеп көчәнү дә – сыныкка сылтау.* И.Низамов. *Мин әллә нишләдем. Зиһенем бет-*

*те дә куйды, ишеткәнемне көчәнеп тә аңламый торам – нәрсә диде соң ул?* Ә.Еники

**2. көчәнеп** *рәв. мәгъ.* 1) Ихтыярына каршы килеп, мәҗбүри. *Көчәнеп елмаю. Көчәнеп көлү*

2) Авырлык белән, кыенлык белән, зур тырышлык куеп. *Көчәнеп уку. Көчәнеп эшләү*

**Көчәнә башлау** Көчәнергә тотыну

**Көчәнә төшү** Бераз гына көчәнү; тагын да ныграк көчәнү

**Көчәнеп алу** Аз вакыт аралыгында көчәнү

**Көчәнеп карау** Көчәнүне сынау

**Көчәнеп кую** Көчәнгән хәлгә килү

**Көчәнеп тору** Әледән-әле яки билгеле бер вакыт дәвамында көчәнү

**КӨЧӘЮ** *ф.* 1) Көч-куәте арту, ныгу, көчлегә әйләнү. *Фирма үсте, көчәйде.* Казан утлары

2) Эш-хәрәкәтнең интенсивлык дәрәҗәсе арту, процесс көчлегә әйләнеп китү, интенсивлашу. *Мәгълүм булганча, империалистик сугыш елларында демократ язучыларны патша чиновниклары эзәрлекләве тагын да көчәя.* М.Гайнуллин. *Урманда җил көчәйгән иде.* А.Расих. *Ату көчәйде, каядыр гөрселди, ухылдый, шап иттереп тә куя – без «ләхәүлә»не укып, тыңлап кына ятабыз.* Ә.Еники. *Җилле-давыллы февраль килде. Сорау алулар көчәйде.* И.Салахов

3) Нинди дә булса процессның чагылыш дәрәҗәсе арту. *Аның авыруы бетү урынына көннән-көн көчәйде генә.* М.Әмир. *Миндә исә вәсвәсә тагы да көчәйде: – Иптәш председатель, әгәр без ике пар аяк белән шул арыш басуын ярып кайтып китсәк, икмәккә зыян тиярме? – дидем.* М.Мәһдиев. *Галимҗан Ибраһимовның үпкә туберкулёзы көннән-көн көчәеп, ул йөри алмаслык хәлгә килә.* Казан утлары

4) *күч.* Тирәнәю, ныгу. *Рәуф белән әнкәсе арасында туган салкынлык вакыт үткән саен көчәйде.* Г.Иделле. *Үпкәсе көчәйгән Луизаның турсайган иреннәре бәлшәйде.* А.Гыйләҗев. *Көрәш тагын да кыза, көчәя, җәелә бара. Ватаннары, милләтләре белән элемтәләр өзелгәч, аларда ниндидер гарьләнү хисе көчәйгәндер.* Мәдәни җомга

**Көчәеп алу** Кыска вакытка гына көчәю

**Көчәеп килү** Акрынлап көчәю

**Көчәеп китү** Соңгы вакытта сизелерлек көчәю. *Бикмөхәммәдевләр фирмасы элек-электән районның бөтен сырьё базарына хөкем йөртә торган булып, сугыш елларында бигрәк тә көчәеп китте.* Ш.Камал. *Андый шатлыклы көнне, әйтик, коймак пешерелә торган көнне, аның ул гадәте бигрәк тә көчәеп киткән, күрәсең.* Ф.Хөсни. *Минем йөрәгемдә аңа карата зур хиснең кечкенә чаткысы бар кебек иде һәм якыная, белә төшкәч, көчәеп, ялкынланып китәргә тиеш кебек иде.* Ә.Еники

**Көчәеп кую** Кисәк, уйламаганда көчәю

**Көчәеп тору** Әледән-әле көчәю

**Көчәя бару** Көннән-көн күбрәк көчәю, көче көннән-көн арту. *Шаһзадәнең гыйшык уты көннән-көн көчәя барды.* К.Насыйри. *Арестантлар арасындагы тынычсызлык инде ай башыннан ук кузгалган иде. Бәйрәм якынлашкан саен, ул көчәя барды.* И.Салахов. *Ә теге гөрелте туктамый, аның саен көчәя бара.* Р.Мөхәммәдиев

**Көчәя башлау** Көчәюгә табан бару

**Көчәя төшү** Тагы да көчәю. *Докторлар килеп киткәннән соң, карчыкка игътибар һәм тәрбия тагын да көчәя төште.* Ә.Еники

**КӨЧ-БӘЛА** *и. к.* **көч-хәл**

◊ **Көч-бәла белән** *к.* **көч-хәл белән**. *Көч-бәла белән кул арбасын тартып китердек.* М.Галәү. *Бу бер көн менлага бик озын тоелды, һичничек булса да шәһәрдә йөреп, базарга, кибетләргә чыгып, көч-бәла илән бу көнне уздырды.* М.Акъегет

**КӨЧ-ГАЙРӘТ** *җый. и. к.* **көч-дәрман**. *– Мирсәет! Билеңне бирмә, Мирсәет! Аяк чалырга маташма. Аяк чалдырма! – дип, көч-гайрәт өстәп торалар.* Р.Мөхәммәдиев

**КӨЧ-ДӘРМАН** *җый. и.* Көч, гайрәт, куәт; сәләт. *Минем алтмыш биш яшьлек чал икәнлегемне онытма, арган-талган, өметсезләнгән сырхау мизгелләремдә көч-дәрман өстә, ярабби!* А.Гыйләҗев

**КӨЧ-ЕГӘР** *җый. и. к.* **көч-куәт**. *Тазалык-саулык булганда, беләгеңдә көч-егәр ташып торганда, монда да дөнья җимертеп яшәргә була бит.* М.Галәү

**КӨЧ-ЕГӘРЛЕК** *җый. и. к.* **көч-куәт**. *Мондый көч-егәрлек һәм тәвәккәллек, хәтта үҗәтлек, моңа кадәр булса да, бары тик соңгы Ватан сугышында, немец илбасарларына каршы сугышып йөргәндә генә шулай аермачык һәм максатлы булгандыр.* Г.Гыйльманов

**КӨЧКӘ** *рәв.* 1) Бик зур авырлык белән, көч-хәл белән, кыенлык белән. *Сөләйман ---, авыруларга эчерер өчен куелган чиләк эченнән тимер чүмечне алып, шуның белән көчкә ишеккә кага башлады.* К.Тинчурин

2) Эш-хәрәкәтнең тулы башкарылмавын белдерә: чак-чак кына, аз гына күләмдә, бик аз итеп. *Тавышы көчкә ишетелә*

**КӨЧКӘ-КӨЧКӘ** *рәв. к.* **көчкә**. *Мөхәммәтхан көчкә-көчкә генә авыру аякларын өстерәп, күкрәгендәге авырудан, ачудан, гарьлектән буыла язып, кибет алдындагы баганага сөялде.* К.Тинчурин

**КӨЧ-КОДРӘТ** *җый. и. к.* **көч-куәт**. *Сыгылып төшмичә яши-эшли алыр өчен, кайчагында кешегә үзебезнең җыр – гади халык җыры да искиткеч зур көч-кодрәт бирә икән.* Ә.Еники. *Авыр хәсрәт килгән чакларда да бөгелеп төшмәскә тырыштык. Хода Тәгалә көч-кодрәт бирде безгә.* Г.Шәрипова. *Мәһабәт гәүдәле егетнең аяксыз калып гомер кичерүләрен уйламый мөмкин түгел бит. Менә кайчан кирәк адәм баласына рухи көч-кодрәт!* Мәдәни җомга

**КӨЧ-КУӘТ** *җый. и.* Көч, куәт, гайрәт. *Ләкин син, Сталинград, безнең көч-куәтебезне якты чагылдыргандай бирешмәдең, һәм син, батыр шәһәр, җиңеп чыктың!* Г.Кутуй. *Яңача эшли башларга көч-куәт тә, гайрәт тә калмады.* А.Гыйләҗев. *Габдулла байның йортыннан һәм кибетеннән алып кайткан акча белән мал Миңлебай Вафасына көч-куәт һәм ышаныч бирде.* М.Галәү

**КӨЧЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **көчләү**

2) Көч җыю, көч туплау. *Русиянең төрле халыкларыннан тупланган аның*

*алае айлар буе хәзерләнде, көчләнде.* Г.Исхакый. *Үзән елганың киң ятуларында су белән рәхәтләнгәннән соң, һәммәсе яңарып, көчләнеп, арбалар янына килделәр.* Г.Ибраһимов. *Бөек эшләр ул бик тиз эшләнми. Үгез дә үсеп җитми көчләнми.* Ә.Синугыл-Куганаклы

3) *сөйл.* Билгеле бер эшне көч салып башкару, үтәү. *Мин торырга, күземне ачарга көчләнәм.* Ш.Әхмәдиев. *Табынга тилмереп көтелгән чәй урынына кайнар пәрәмәч килде. Кунаклар тагын азаплап көчләнделәр.* М.Галәү

4) *сөйл.* Ясалма тырышу, теләртеләмәс кенә эшләү. *Ире аны яратмыйча, көчләнеп торырга мәҗбүр булган.* Ә.Еники

5) *сир.* Уяну, барлыкка килү, көчәю, үсү. *Нинди шәфкать! Өстенә баксаң, күңелләр нечкәрә, мондый хәл күргәч, күңелләрдә мәхәббәт көчләнә.* Г.Тукай

6) Нәрсәне булса да белү, аның асылына төшенү. *Гали әллә ни әйтергә теләгән кебек булды да әйтмәде, чыраен үзгәртте, гүя нишләргәдер көчләнә иде: еларгамы, көләргәме --- – үзе дә белми.* Ш.Камал

**2. көчләнеп**. *рәв. мәгъ.* Мәҗбүри рәвештә, ирексезләп. *Йөзе аның бу минутта эчке газабын көчләнеп басарга тырышкандай киеренке, җитди, хәтта берникадәр усал да иде.* Ә.Еники. *[Балалар] аңлый башлагач кына көчләнеп «әни» дип йөрсәләр дә, аны һәрвакыт икенче дәрәҗә әни иттереп йөрүдән котыла алмадылар.* Г.Исхакый

**КӨЧЛӘП** *рәв.* 1) Көч кулланып, ирексезләп, мәҗбүри рәвештә. *Биш гасыр элек үк көчләп чукындыру, телдәниманнан яздыру һөҗүменә юлыккан татар халкы үз фаҗигале язмышына аек караш ташлап, аннан олуг гыйбрәт алырга тиеш.* Р.Әмирхан. *Бабасы да моны белергә тиеш иде ләбаса. Без аңардан баланы көчләп алмадык.* Ә.Фәйзи. *Бер үк вакытта мөселманнарны православие диненә көчләп күчерү дә дәвам иткәч, «новокрещёные» дигән билгеләмә шул чорларда килеп чыккандыр инде...* Казан утлары

2) Ирексезләп, ризалыгын алмыйча, мәҗбүри рәвештә. *Революциягә кадәр яшьләрне көчләп өйләндергәннәр, кияүгә биргәннәр, дип сөйләнүләр әле дә яши. Ләкин, принципта, бу фикер белән килешү авыр.* М.Әхмәтҗанов. *Ул болай дигән: – Без көчләп бирүчеләр түгел. Зөһрә чыга икән, һичшиксез, яратып чыгарга тиеш.* Ә.Еники

3) *сир.* Бернинди буш урын калдырмыйча, тыгызлап. *Буш түгел букча, [шәкертләр] китергәннәр аны көчләп төяп.* Г.Тукай

◊ **Көчләп тагу** Кешегә мәҗбүри йөкләмә йөкләү. *– Гәүһәр, мин сиңа үз карашымны көчләп тагарга уйламыйм, – диде Галимҗан абзый уйчан гына.* Г.Әпсәләмов. *Үз аналарын үзләре карамыйча, кардәшләренә көчләп такмакчы булалар.* Казан утлары

**КӨЧЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кемне дә булса берәр нәрсә эшләргә мәҗбүр итү, ирексезләү, үз ихтыярына куймау. *[Немец офицеры:] Без көчләмибез, без сезнең ихтыярыгызга куябыз.* Ә.Еники. --- *Әллә апаның булдыра алмаслыгын белеп, аны пианино уйнарга көчләмәделәр.* Ф.Яруллин. *Соңгы көннәремдә генә үз өстемә яңа гөнаһ аласым килми, кызымны көчләмәячәкмен, үзе теләгәнчә эшләсен.* С.Шәрипова

2) Үзеңне ирексезләп берәр нәрсәгә мәҗбүр итү. *Шулай да булса, ул аны [Габдулланы] сөя алмый, үзен көчләсә дә сөя алмаячак.* Г.Исхакый. *Ләкин күпме генә үземне көчләсәм дә, көйләсәм дә тоймый идем мин аның кабынуын, тоймый идем.* Ә.Еники. *Кеше тормышта шәхси гадәт-холкына бәрабәр хәрәкәт итә, киресенчә булса, ул үз-үзен көчләүгә кайтып кала.* Т.Галиуллин

3) Көч кулланып, җенси мөнәсәбәткә керергә мәҗбүр итү. *Кыз үзенең кайгылы серен --- апасы Миңнисага сөйләгән. Авыл егете аулак өйдә көчләде, шуннан балага уздым, дип әйткән.* Г.Ибраһимов. *Ул да булмый, унлап хатын: «Безне көчләде», – дип, Миңнәхмәт өстеннән волостька язу илтәләр.* Г.Толымбай

**КӨЧЛЕ** *с.* **1.** 1) Физик көче зур булган, таза, нык. *Хәйбулла көчле калын бармаклары белән чуклы янчыкның төбеннән махорка чеметеп алды.* Ш.Камал. *Рауза бер генә секунд Әхмәтнең йөзенә карады да көчле кулы белән аның кулын кысты.* Ш.Усманов. *Бераздан боларга инде олыгая башлаган, теге, тыныч елларда чын егетләрнең көчле кулларын тотып уеннар уйнаган кызлар да кушылдылар.* М.Мәһдиев

2) Зур физик энергиягә ия булган, егәрле. *Телисең икән самолётка утырасың. Бик шәп җиһазланган ул көчле һава кошлары сине --- әллә кайларга илтеп куялар.* Г.Бәширов. *Аның [Ахиярның] гармунындагы бакалар кадәр көчле, моңлы басларны минем беркайчан да ишеткәнем булмады.* М.Мәһдиев. *Бездә җирләрне җидешәр-сигезәр төрәнле сабаннар таккан бик көчле тракторлар сөрә.* Г.Галиев

3) Тәвәккәл, нык ихтыярлы. *Кылыч белән түгел, турылык һәм Чынлык белән көчле кешеләр.* М.Җәлил. *Көчле рух, таза кул, киң күкрәк Кайсы якта булса, шунда хасият күбрәк.* К.Камал. *Шагыйрь [Ә.Баян] уткән һәм бүгенге хәлләр турындагы уйларын тетрәндергеч вакыйгалар аша, көчле рухлы, фидакарь геройлар мөнәсәбәтләрендә гаять тәэсирле итеп бәян итә.* Мәдәни җомга

4) Эрудицияле, бик сәләтле. *Шунда аның иртәге дәресе өчен өстәмә планы туа, үзенең көчле яклары да, көчсез яклары да күренә.* Г.Әпсәләмов. *Бармы Гомәрдә көчле интеллект, киң караш?* И.Нуруллин. *Ш.Мәрҗани яшәгән чорда Казан университеты тюркология буенча көчле гыйльми кадрларга бай була.* Х.Хисмәтуллин

5) Иҗтимагый көче һәм икътисади мөмкинлеге зур булган, куәтле. *Еш кына гаиләне дәүләт белән чагыштыралар* ---. *Шуңа күрә нык, таза гаиләләрдән генә көчле дәүләт төзелә, дип әйтәләр дә инде.* М.Әхмәтҗанов. *Тарихка иң көчле дәүләт булып кереп калган Рим империясе дә 510 ел гына яшәгән.* Мәдәни җомга

6) Сан ягыннан күп, зур, ишле. *– Дошман көчле десант төшереп, тимер бөҗра булып шәһәр өстенә килә булырга кирәк, – диюгә, Хаҗи атка атланып, бөтен көчкә чаптырып, полк штабына китте.* К.Тинчурин. *Борынгы дәверләрдән поши --- изге хайван булып исәпләнгән, болгар бабаларыбызда поши культы көчле булган.* Татар мифлары

7) Чагылыш дәрәҗәсе зур булган, интенсив. *Көчле шартлау дулкыны аны [түбәдә сакта торучыны] җиргә бәреп төшергән.* Т.Гыйззәт. *Ләкин машина кузгалып китүгә, засадага поскан фашистлар көчле ут ачалар.* К.Нәҗми. *Моратның әтисе Искәндәр Зәбирович Алпаров --- берничә тапкыр мина давылы, көчле артиллерия уты астына туры килсә дә исән калган иде.* Г.Гобәй

8) Яхшы коралланган, сугышка нык сәләтле. *Көчле гаскәр. Көчле ныгытма*

9) Төзәлмәс, каты. *Берәүнең өендә көчле авыру булса – алар турысында да җырламыйлар.* М.Мәһдиев

10) Тәэсир көче зур булган, нык тәэсир итә торган. *Күрдем хәзер: һич нәрсә тиң түгел, Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел.* Г.Тукай. *Әмма алсу эре чәчәкле шәльяулыгы белән бөтен аркасын-җилкәсен каплаган Гыйльменисаттинең, урындык яртысын гына алып, ы-ы килеп Йосыф кыйссасын укыгандагы кебек көчле тәэсирне бер җирдә дә алмадым.* М.Мәһдиев

11) Көче, тәэсире белән гадәтидән артык, ташып торган; тирән, зур (хисләр тур.). *Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка булган көчле гыйшкы турында.* Һ.Такташ. *Бер минутка ул иренен тешләп, бер ноктага караган хәлдә, әллә нинди көчле уйга талды.* Ә.Фәйзи. *Сөю тойгысы никадәр көчле булган саен, аның нәфрәте дә шулкадәр көчәя.* А.Хәлим

12) Исбатлау көче зур, ышандыргыч. *[Г.Тукай] Фольклорны феодаль крепостнойлык калдыкларына каршы көрәштә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г.Нигъмәти. *Ибраһим ага [Салахов] «Йөрәктәге яралар» исемле язмасында моңа бик көчле мисал китерә.* Г.Ахунов. *Ш.Мәрҗани: «Һәр эштә асыл – хәләллек, дөреслек; нәрсәне дә булса харам дип әйтү өчен көчле дәлил кирәк», – диде.* Г.Хисмәтуллин

13) *күч.* Нык тәэсир итә торган, тәэсир итү көче зур булган. *Әмма Кәшфинең көчле градуслы эчемлекне үз гомерендә беренче эчүе иде.* М.Мәһдиев. *Көчле аракы. Көчле сыра. Көчле серкә*

14) Йогынты ясау сәләте зур, тиз дәвалау үзлегенә ия булган. *Көчле укол. Көчле дару*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Каты, нык, тоярлык итеп. *Көчле сугу. Кыз белән егет берберсен көчле яраталар. Егетнең тавышы көчле яңгырый*

2) Зур тизлек белән, ярсып, шашынып. *Язгы ташкын көчле ага*

3) Тиешенчә, яхшы итеп, әйбәтләп. *Мәкалә көчле язылган*

**3.** *и. мәгъ.* 1) Физик яктан таза, чыдам кеше. *Ләкин без – сугыш чоры малайлары: --- безне, иң көчлеләре дип, ике курстан сайлап алып, көлтә бирергә куштылар.* Х.Сарьян

2) Нык ихтыярлы кеше турында. *Көчле белән көрәшмә.* Мәкаль. *Әйдә җырлыйк мазлум милләтләрнең Көчләрдән күргән хурлыгын.* М.Гафури. *--- Аларның каршыларына ак чәчле бер карчык килеп чыга да, ике кулын алга сузып: – Әй акыллы картлар! Көчләр көчсезләргә җәбер иткәндә булышасыз... Күрмисезме, бу бичара хатын ничек калтырый.* М.Гайнуллин

◊ **Көчле як** Кемнең яки нәрсәнең дә булса кыйммәтле бер сыйфаты (үзенчәлеге). **Көчленеке замана** Кем көчле, көчкә таянып эш итә, шул рәхәт яши торгач чор (вакыт)

**КӨЧЛЕК** *и. кит.* Көчләү, ирексезләү, мәҗбүр итү. --- *Көчлек көчсезгә тигермәс зыян. Бүре берлә куй бергә су эчәр, үрдәк белән карчыга бергә очар.* Мөхәммәдьяр. *[Кыям абзый:] Кызым. --- Үзең беләсең, монда инде бернинди дә көчлек юк. Кыз бала гел ата-ана кырында тормый, вакыты җиткәч, шулай китә инде ул.* Х.Сарьян

◊ **Көчлек белән** Зур көч куеп, мәҗбүриләп. *[Хезмәтче хатын] киткәч тә, бик көчлек белән урынымнан торып чишенә башладым.* Ш.Камал. *Бүген дә карт ишек төбендәге калын таякка, чөйдәге каеш чыбыркыга берничә күз төшереп алды; ләкин үзен көчлек белән тыйды.* Г.Ибраһимов. *Иҗек укуның авырлыгына чыдый алмыйча, бик күп балалар берничә көннән үк мәктәпне ташлап качарга мәҗбүр булалар. Аларны аталары, көчлек белән җитәкләп мәктәпкә китереп, мулла кулына тапшыра.* М.Гафури

**КӨЧЛЕЛЕК** *и.* 1) Зур физик көчкә ия булу. *Менә-менә, барыбызның да көчле буласыбыз килә. Тик көчлелекнең нинди икәнлеген генә белеп бетермибез.* Ф.Яруллин. *Кайчандыр ул үзе дә шулай уйлый иде бит. Көчлелекнең, урамда сугышып, башкалардан өскә чыгу гына түгел икәнлеген аңлатырга кирәк иде.* Казан утлары

2) Зур көч, кодрәт, куәтлелек дәрәҗәсе. *Берсе – татар музыка тәсбихының бисмилласы, икенчесе – театрыбыздагы искелекне дер селкетеп алган тугыз балл көчлелегендәге дулкын, дип куйды.* Ш.Рахманкулов. *Ә инде алдынгы милләт буласыбыз килә икән, шунысын да үзләштерик: милләтнең көчлелеге – һәрберебезнең көчлелегендә, милләтнең уңганлыгы – һәрберебез уңганлыгында.* Шәһри Казан. *Дәүләтнең көчлелеге. Армиянең көчлелеге*

3) Эш-хәрәкәтнең, хис-тойгыларның чагылышы көчле булу. *Мәхәббәтнең көчлелеге. Нәфрәтнең көчлелеге*

**КӨЧ-СӘЛӘТ** *җый. и.* Осталык, сәләт, булдыра алу сыйфаты. *Завод корпусларын төзегәндә, әтинең көч-сәләте бик тә ярап куя: ул бетоннан фундамент сала, гаять авыр эштә була.* К.Миңлебаев. *Шактый зур көч-сәләтен әйбәт булып күренергә сарыф иткән андый тәти егетләрнең тыйнаклыгы вакытлыча гына икәнен, ныклы аякка баскач, бөтенләй икенче рәвешкә керәсен алар әле уена да китерә алмыйлар күрәсең.* Татарстан

**КӨЧСЕЗ** *с.* **1.** 1) Көче беткән яки бик аз булган, хәлсез, егәрсез. *Көчсез куллар. Авыру, көчсез кешеләр. Көчсез мускуллар*

2) Кимчелекле, җитешсез, йомшак. *Сай эчтәлекле, сәнгатьлелек ягыннан көчсез булган текстлар, әлбәттә, матур музыкаль яңгыраш тудыра алмыйлар.* Җ.Фәйзи. *Балалар бар да таныш, якын, үз. Аларның көчле һәм көчсез яклары да билгеле...* Г.Әпсәләмов

3) Чагылыш дәрәҗәсе зур булмаган, сизелер-сизелмәс, зәгыйфь. *Көчсез тавыш, сюитадагы төп мелодия бу бүлектә акрын һәм көчсез. Аны гөрләвекле, дулкынлы яңа музыка баса.* М.Җәлил. *[Миңниса җиңгинең] бу төртмәле сүзләре баягыча көчле, бәлки үзсүзләнеп әйтелмәгән көчсез*

*каршылык кыла иде.* Ә.Фәйзи. *Анасы --- кулы белән изәп, нәрсәдер кычкырды. Ләкин хәлсез ананың көчсез тавышын әтәч тавышлары каплады.* К.Тинчурин

4) Тәэсир итү көче, куәте түбән булган, йомшак. *Электр лампасының көчсез саргылт нурлары зур палата эчен күңелсез генә яктырта.* Ш.Усманов. *Көчсез аракы. Көчсез эремә. Көчсез кислота*

5) Ярлы, тормышы тәэмин ителмәгән. *Көчсез хуҗалык*

**2.** *и. мәгъ. күпл.* 1) Физик яктан егәрсез, хәлсез кеше. *Мәхәббәтнең бик тылсымлы көче бар: ул һәркемне тигезли. Картларны яшәртә, ямьсезне матурлый, көчсезне көчле итә.* Ф.Ярullин. *Тормыш өзлексез көрәштән гыйбарәт: көчлеләр ега, көчсезләр егыла.* Казан утлары

2) Җенси мөнәсәбәткә кирәргә сәләтсез. --- *Имансызларның сәҗдәгә утыруларыннан, ырудан калган көчсезләрнең мәхәббәт уены уйнауларыннан ни мәгънә?* М.Кәрим

**КӨЧСЕЗӘЮ** *ф. сөйл. к.* **көчсезләнү**. *Аның бу шатлыгы алдында теге шомлы хәбәрдән туган кайгы-хафасы кечерәйде, көчсезәйде.* Г.Минский

**КӨЧСЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Көчсез итү, көчсезгә әйләндерү

2) Тәэсир итү мөмкинлеген киметү, куәтен киметү. *Ниһаять, иртә балкыган таң, ачылганнан-ачыла барып, өй эчендәге ут яктысын бөтенләй көчсезләндергәч, Гөлниса кунагына урын җәйде.* Г.Минский. *Агуны көчсезләндерү. Рентген нурларын көчсезләндерү*

**Көчсезләндерә башлау** Көчсезләндерергә керешү

**Көчсезләндерә бару** Көчсезләндерүне дәвам итү

**Көчсезләндерә төшү** Тагы да бераз көчсезләндерү

**Көчсезләндереп тору** Бертуктаусыз, һаман көчсезләндерү

**КӨЧСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Көчсезгә әйләнү, хәлсезләнү, хәл бетү; көчне югалту. *Сәер ләззәттән хәлем китә. Буыннарымның көчсезләнүен тоям.* Э.Шәрифуллина. *Каты авырудан соң организм көчсезләнгән*

2) Икътисади һәм хәрби куәте, көче кимү (дәүләт, җәмгыять һ.б. тур.). *Империалистик сугышлар империалистларның үзара көчсезләнүен китереп чыгаралар.* Яңа тарих. *Көнбатыш Рим империясендә күп шәһәрләр җимерелә... башкалары исә көчсезләнә.* Урта гасырлар тарихы. *Илнең куәте көчсезләнү*

**Көчсезләнә бару** Акрынлап көчсезлеге арту, көннән-көн ныграк көчсезләнү

**Көчсезләнә башлау** Көчсезлек билгеләре күренү

**Көчсезләнә төшү** Тагы да бераз көчсезләнү

**Көчсезләнеп бетү** Тулысынча көчсезләнү

**Көчсезләнеп калу** Вакытлыча яки өлешчә көчсезләнү, нинди дер сәбәптән соң көчсезләнү

**Көчсезләнеп китү** Берара көчсезләнү

**КӨЧСЕЗЛЕК** *и.* 1) Көч булмау яки аз булу дәрәҗәсе

2) Берәр төрле эш башкарырга сәләте яки мөмкинлеге булмаудан килеп туган чарасызлык, гаҗизлек. *Һәрвакыт өмет берлән өметсезлек арасында торып, аның күңелен көчсезлек, зәгыйфьлек кебек бер хис биләде.* Г.Исхакый. *Рәүфәнең тавышында инде әчке елау, ялвару һәм үзенең көчсезлеген сизү бар иде.* А.Шамов. *Көчсезлектән, сеңлесенә ниндидер йогынты ясый алмавыннан үзе дә гаҗиз иде ул.* А.Расих

3) *мед.* Импотенция, җенси сәләтсезлек. *[Җансаттаров:] Котүгә барып «Холмогор»ны карадыгызмы? [Малтабаров:] Карадым. Һичшиксез, аңарда импотенция. Ягъни җенси көчсезлек.* Т.Гыйззәт

4) *күч.* Йомшак як, йомшаклык; кимчелекле як. *Сүз тотмау – көчсезлек һәм гамьсезлек билгесе.* Җ.Фәйзи. *Күрсәтә алдымы соң ул көчен? Төптәнрәк уйлап карасаң, киресенчә, үзенең көчсезлеген генә күрсәткәндер.* М.Хәсәнов. *Менә --- нәрсә җитми бүген хатын-кызга. Хатын-кызның бит көче – көчсезлегендә.* Шәһри Казан

**КӨЧ-ХӘЛ** *җый. и.* **1.** Егәр, физик мөмкинлек; хәл

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **көчкә** (*1 мәгъ.*). *Калын карагай бүрәнәләр, көч-хәл күтәрәбез... Әле генә күтәреп куйган бүрәнәне тагын көч-хәл күтәреп җиргә салабыз.* И.Салахов

◊ **Көч-хәл белән** 1) Кыенлык, авырлык белән, барлык көчне куеп. *Аны битенә салкын су бөркеп, дару иснәтеп, көч-хәл белән аңына китерделәр.* М.Гали. *Көч-хәл белән эзләп таптык ямьсез, ташландык хәлгә килгән бинаны.* Т.Галиуллин. *Саммит түтәй тормышын көч-хәл белән генә алып бара торган бер тол хатын иде.* Ж.Верн; 2) Көчкә, чак-чак кына. *[Малай] берсендә егылып китәм дигәндә генә, көч-хәл белән каршындагы ботакка тотынып өлгерде.* Р.Низамиев. *Хөсәен абзый ---, минем Рәшит бабайны да --- шул ачлык-ялангачлык дөньясында югалтып, көч-хәл белән туган якларга кайтып егылган.* Казан утлары

**КӨЧ-ЯРДӘМ** *җый. и.* Ярдәм, булышлык. *Мин дә көч-ярдәм бирермен, әйдә, иптәш, кузгалыйк. Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.* Г.Тукай

**КӨЧЕК** *и.* 1) Эт баласы. *Тиз генә торып йөгерәсең дә --- капкадан керүгә рәхәтләнеп бер ычкынасың, анасын аучы атып үтергән көчек кебек күккә карап елап җибәрәсең.* М.Мәһдиев. *Шунда әнисе чак кына башын күтәрде, һәм сары йонлы бу ата көчек – киң маңгайлы нык-таза көчек – җиргә мәтәлеп төште.* А.Хәсәнов

2) *күч. кимс.* Балага яки яшь кешегә карата кимсетеп әйтү сүзе. *Мәрдән, бу – сиңа актык әйтү! Ил пычратып ятма! Марҗаң белән көчегеңне ал да тай моннан!* Г.Гобәй

3) *күч. сөйл. кимс.* Арттан калмый ияреп йөргән кешегә карата әйтелә

**КӨШ** *ы.* Кош-кортны куганда әйтелә торган сүз

**КӨШӘ** *ы. к.* **көш**

**КӨШЕЛ** *и.* Ындырда сугылган ашлык өеме. *Көшелне икенче якка күчереп карыйбыз. Алай да рәте юк. Булмаса, өйгә алып кайткач, иләк аркылы үткәреп карарбыз инде, дибез.* М.Гали

**КӨШЕЛ ИЛӘГЕ** *и.* Ашлык иләү өчен зур иләк; *русчасы:* **грохот**

**КӨШКЕ** *с. диал.* Иркә, назлы. *И, ул инде элек-электән көшке кеше*

**КӨШКЕЛӘНҮ** *ф. диал.* Иркәләнү, назлану. *Көшке кешегә көшкеләнергә бер сылтау гына булсын*

**Көшкеләнә төшү** Бераз көшкеләнү; тагы да көшкеләнү

**Көшкеләнеп китү** Соңгы вакытта көшкеләнү

**Көшкеләнеп тору** Хәзерге моментта көшкеләнү

**КӨШ-КӨШ** *ы. к.* **көш**

**КӨЮ** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса читчите яну, кырые күмерләнү. *Тик биек морҗа белән күмерләнеп кара көйгән баганалар һавага сузылып утырып калалар.* Г.Ибраһимов. *Бу – хәтердә калсын өчен әйтелә, димәк, ипине фәлән сәгать, фәлән минуттан аласы: йөзе көймәсен...* М.Мәһдиев

2) Дым җитмәү сәбәпле шиңү, кору. *Үләннәр көйгән, яфраклар саргайган. Эш бит менә ничек тора иде: --- кырык җиденче елның коры җәе. Засуха. Халык нервный – бөтен җир көя.* М.Мәһдиев. *Авылда кайда гына барсаң да, кемне генә күрсәң дә, һәммәсе шул корылыктан, басуда игеннәр, үләннәр көюдән, ачлык куркынычыннан зарланалар иде.* М.Гали. *Ахыргы чиктә, игеннәр көя башлагач, бер көнне боларның авылына бер карт хәерче килгән, ди.* Мирас

3) Кызу, эссе хәлгә килү. *Суга төште – сүнмәде, Утка керде – көймәде.* Х.Туфан

4) Бик нык эчәсе килү, сусау. *Без, кояштан, сусаудан көеп, һаман арба асларында әлсерәп ятабыз.* Г.Ибраһимов

5) *диал.* Элеккеге көчен югалту; сулу, ябыгып калу

6) *диал.* Күгәрү, күк төскә керү, күк төс алу. *Кызу кояш астында барган эш белән арып яндылар, иреннәре көйде, авызлары кипте.* Г.Ибраһимов

**Көеп бетү** Бөтенләй, тәмам көю. *Халык күккә карап, һаман яңгыр көтте; саргая башлаган игеннәр, үләннәр тәмам эштән чыгып, янып, көеп беттеләр, ләкин яңгыр яумады.* М.Гали. *Менә ул чирәме көеп беткән тузанлы җиргә кәрәк очы белән сызгалый башлады.* И.Гази

**Көеп йөрү** Озак вакытлар дәвамында көю

**Көеп китү** Бераз көю. *Мич капкачын ачып, ипиләргә күз салырга кирәк: ипинең йөзе килгәнме? Көеп китәрлек булса, мич капкачын ачып, ипигә бераз хәл кертәсе.* М.Мәһдиев. *Мин нигә бу тынчу камерада? Күкчәтау даласы хәзер шау чәчәктәдер. Ә мин? Кинәт бит алмаларым көеп китте, кайнар яшь коела.* И.Салахов

**Көеп чыгу** Тулысынча көйгән хәлгә килү. *Кинәт бөтен өйгә гөлт итеп ут кабына, тәрәзә пыялалары чылтырап коела, яшьтинең чәчләре, кашлары, керфекләре көеп чыга, бите пешә...* Г.Рәхим. *Гәүһәр боларны ишек ярыгыннан ишетеп торды һәм гарьлегеннән [кара] көеп чыкты.* Г.Әпсәләмов

**Көя язу** Чак кына көйми калу. *Көя язып каралган бәрәңге кабыгы астыннан иң тәмлесе – алсуланып торган юка гына кетердәвеге килеп чыкты.* Г.Бәширов

**Көеп яту** Озак вакыт көйгән хәлдә булу. *Көнозын кояш астында көеп яткан түбә калае күңелле шыбырдый иде.* Г.Ибраһимов

**Көя бару** Акрынлап көю. *Көн кызганнан-кыза, күк көйгәннән-көя бара.* Г.Ибраһимов

**Көя башлау** Көяргә тотыну. *Кирсан тәмәкесен мыеклары чытырдап көя башлаганга кадәр тартып бетерде.* Ш.Усманов

**Көя төшү** Тагы да бераз көю

**КӨЮ** II *ф.* 1) Кайгыру, көенү, хәсрәтләнү. *Әйтсәм телем көя, әйтмәсәм, җаным көя.* Әйтем. *Бу нәкъ әтиләрчә, үз баласын сөйгән, баласының иминлеге өчен борчылып көйгән әтиләрчә итеп ярсу иде.* Г.Минский. *Бабасы Габдулланың кайтуына кинәнмәде дә, көймәде дә.* Ә.Фәйзи

2) Борчылу, кайгыру. *Түгәрәк чишмә, салкын су, Эчтем җаным көйгәнгә.* Җыр. *Ярым ятлар белән уртак, янамын да көямен.* М.Фәйзи

3) *куч.* Бик көчле хискә бирелү, яну. *Тик менә мәхәббәттән генә бәхете булмады аның. Дөрес, ул бер кабат сөйде, сөйде һәм гомергә көйде.* Н.Дәүли. *– И Гәүһәр апа, – дип җавап бирде Миләүшә, – күп көйдем дә, көяселәрем дә җитәрлек әле.* Г.Әпсәләмов

4) Югалу; һәлак булу. *Ә... яшьтәшләренең күпмесе шул сугыш утында көеп, көлгә-туфракка әйләнеп, ерак җирләрдә ятып калды?* Т.Әйди

**Көеп йөрү** Озак вакыт көю

**Көеп тору** Көю хәле кичерү

**КӨЯ** I *и.* 1) Тәңкәканатлылар отрядыннан, корты йон әйберләрне, ашлык бөртекләрен һәм үсемлекләрне зарарлый торган кечкенә күбәләк. *Кайчакларны аның вәгъдәсе хәтта әллә ничә елга сузыла, йонны чормада көя турап бетерә.* Г.Бәширов. *Аларны [тиреләрне] алганда яхшы танып-белеп алырга, шунда ук, эчендә көя ашаганнары бар дип, күбрәк скидка белән алырга кирәк. Саткан вакытта, көя ашаган кәҗә тиреләрен, керосин вә скипидар белән майлап, яхшы тире хисабына сдавать итә белергә кирәк.* Ш.Мөхәммәдев. *Иптәшенең күзе елтырый, башында велюр эшләпә, анысын да, пальтосын да көя ермачлаган.* М.Мәһдиев

2) *куч.* Эчтән борчып тора торган кайгы-сагыш хисе. *Ул шөбһәне тизрәк бетерә алмаганга, күңелендә әллә нинди бер исемсез эшпошыргыч нәрсә җирләште, әллә нинди күрелмәгән бер көя аның тынычлыгын ашый башлады.* Г.Исхакый. *Йөрәктә соңыннан озак еллар буе мине газаплаячак бер сәер ачыну көясе кузгалганны сизеп, башым иелә.* Ә.Баян

**КӨЯ** II *и. диал.* Бал кортлары кереп-чыгып йөрү өчен ясалган умарта тишеге

**КӨЯЗ** *с.* **1.** 1) Купшы, ыспай киенергә яратучан. *Бикьярлар – бик көяз, бик гайбәтчел халык.* Г.Ибраһимов. *Үзе [Фарук] галәмәт көяз, үзе искиткеч рәхимле бәндә иде.* К.Миңлебаев

2) Чибәр, матур, купшы. *Фарук абый, гәүдәгә бераз калыштрак булса да, гаҗәеп зур көчкә ия, төскә-биткә чибәр генә, мин белгәндә инде каратут йөзле шадра бер көяз егет иде.* К.Миңлебаев. *Алар [егетләр] әнә шул кызлар өчен, мыекларына порак оны кунган Пауал абзый, аның көяз гүзәл Зинасы --- өчен көрәшеп, ерак туфракларда башларын салдылар.* М.Мәһдиев

3) Күрер күзгә аерылып торган, матур булып үскән. *Аның [Хәдичәттинең] кабере очында бик көяз каен агачы бар.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* Фырт, купшы кеше. *Көяз туңмас калтырар, сөякләре шалтырар.* Әйтем

**3.** *рәв. мәгъ.* Купшы итеп, матурлап, ыспайлап, килешле итеп. *Көяз киенгән егет*

◊ **Көяз күбәләк** Иркә, җилбәзәк, назлы (гадәттә кызларга карата). *Нәрсә кирәк икән бу көяз күбәләккә? Нигә аның кара күләгәсен күрүгә җаным өшеп китте?* А.Гыйләҗев

**КӨЯЗЛӘНҮ** *ф.* Киенү-ясану, купшылану, фыртлану. *Һәрчак ыспайланырга, көязләнергә, назланырга яратучы сеңлесе Гайшә дә Сөембикә апасындагы үзгәрешкә игътибар итте.* М.Хәбибуллин

**Көязләнә бару** Көннән-көн көязләгән арттыру

**Көязләнә төшү** Бераз көязләнү; көязләнү хәлендә булу

**КӨЯЗЛЕК** *и.* 1) Купшылык, бизәнергә-ясанырга яратучанлык, фыртлык

2) Көяз кыланыш. *[Хан] шунда ук Алтынчәчкә табан әйләнеп, аерым бер масаю һәм көязлек белән, муенсаны, җәүһәрне аңа тәкъдим итә.* М.Җәлил

3) Ыспайлык, матур сынлылык. *--- Канат сыман җилдә җилфердәгән ялларымы, сыртның дәвамы сыман дугайланып үрә баскан койрыгымы --- Чемпионның исеме генә түгел, килешкилбәте һәр хәрәкәтенә кадәр мәһабәт көязлектән гыйбарәт иде.* Р.Мөхәммәдиев

**КӨЯЗ ТУРГАЙ** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан җете чуар төсле, томшыгында кызыл бөҗрасы булган кечкенә урман кошы; *русчасы:* **щегол**

**КӨЯЛӘК** *с. диал.* Юкка-барга борчылучан, тынгысыз. *Көяләк кеше*

◊ **Көяләк җан** Борчылучан, көяләнүчән кеше турында

**КӨЯЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Борчылу, тынычсызлану; пошыну. *Ул салкынча кулын Нуриасманың маңгаена куйды. – Төшемә кермәдең: әле яшисең, ә калганына көяләнмә.* Ф.Садриев. *Алпамша [кәҗәнең кушаматы] минем юашлыгны белә, шуңа күрә артык көяләнми дә.* М.Галиев. *Утар алдында Коләхмәт карт председательгә үртәлеп көяләнде, эчке яктагы үгезләргә карап тирән көрсенде.* Мирас

**Көяләнә башлау** Көяләнүе күренү

**Көяләнә төшү** Бераз көяләнү

**Көяләнеп тору** Әледән-әле көяләнү

**КӨЯЛӘНҮЧӘН** *с. сөйл.* Борчылучан, хәвефләнү хисенә тиз бирелүчән. *Көяләнүчән кеше*

**КӨЯЛӘ́Ү** I *ф.* Мех яки йоннан эшләнгән әйберләргә көя төшү, көяләр барлыкка килү. *Мамык шәл көяләгән. Тиреләр көяләгән*

**Көяләп бетү** Тәмам көяләнгән хәлгә килү, бөтен җире көяләү

**Көяли башлау** Бераз көяләү

**КӨЯЛӘ́Ү** II *ф.* Бурсу, дымланып күгәрү; басылып, кызып черү (салам, печән һ.б.ш.). *Хуҗа хатын, өелеп куелган көлтәләр янына килеп, бер башакны учына салып уды да иснәп карады: «Надя, кара әле, көяли башлаган».* Н.Дәүли

**Көяләп бетү** Бөтен җире көяләү

**Көяли төшү** Бераз гына көяләү

**КӨЯЛЕК** *и. иск.* 1) Берәр эшкә комачаулык, каршылык, тискәре нәтиҗә

2) Зыян, каза

◊ **Көялек килү** Берәр эшнең киресе, капма-каршысы килеп чыгу. *Сукранма, Бәшир абзый, көялеге килер. Өлешеңә чыккан көмешең.* Г.Бәширов. **Көялек күрү** Зыянга, казага дучар булу. *– Син нәрсә эшлисең? – дип, үз-үземне белештермичә кычкырып җибәрдем. – Шул ятимнәрнең ризыгы ничек тамагыңнан үтә? Белеп тор, моның әле син көялеген күрәчәксең.* Ф.Яруллин

**КӨЯНТӘ** *и.* 1) Чиләк, кәрзин кебек нәрсәләрне асып йөртү өчен очларында киртләче яки тимер ыргаклары булган, җилкәгә салына торган, махсус бөгеп ясалган озын иңсәле агач җайланма. *Каршыңа буш чиләкле көянтә аскан кеше очраса – юлың (яисә ниятең) уңмый.* Юрамыш. *Яр буенда калды көянтәсе, Көянтәне тапты тик әнкәсе.* Татар мифлары. *Җырлап килә көянтәгә асылган чиләкләрең. Ник әйтмисең, бармы әллә сөйкемле сөякләрең?* Р.Гәрәй

2) Саннардан соң килеп, көянтә (*1 мәгъ.*) белән ташылган нәрсәнең санын, күләмен белдерә. *Үзе көн саен кер юа, --- аннан көненә җиде-сигез көянтә су алып кайта икән.* М.Мәһдиев. *Маллары күп булган кешеләр, көненә унар көянтә су алып менәбез, дип сөйлиләр...* В.Нуруллин. *Безнең терлек алай күп түгел: бер сыер да ике баш сарык. Шулай да дүрт көянтә су китә көненә.* Казан утлары

3) *махс.* Төрле механизмнарда, үлчәүдә кулланыла торган рычаг; иңсә

◊ **Көянтә буе** Көянтә озынлыгы кадәр. *Кешеләр җиләккә кояш чыгып көянтә буе күтәрелгәч китәләр, Мәрфугатти исә кояш чыкканчы кызу-кызу атлап китеп бара...* М.Мәһдиев. **Көянтә буе ара** Бик якын, ерак булмаган ара. *Чиләкләрем – Сак белән Сок: Көянтә буе ара, Еракмыни очрашырга көянтә буе ара?! Чиләкләрем ник соң Сак-Сок сыман «Сыкранып бара»?* Р.Хәлиуллина. **Көянтә йоткан** *мыск.* Гәүдәсе белән алга таба иелеп, бөкрәеп йөри торган кешегә карата әйтелә

**КӨЯНТӘЛӘП** *рәв.* Көянтәгә асып, көянтә белән. *Бизәкле пар бидрәсен көянтәләп, Кече инәем судан кайтты.* М.Кәрим

**КӨЯНТӘ ЙОЛДЫЗ** *и.* Зодиак йолдызлыкларының (элеккеге Болгар-Казан календаре буенча йолдызларның урнашуы белән көянтәне хәтерләткән 12 йолдызлыкның) берсе; *русчасы:* **весы**

**КӨЯНТӘЛЕ** *с.* 1) Көянтәсе (*1 мәгъ.*) булган, көянтә аскан. *Көянтәле кызлар*

2) Көянтәсе (*3 мәгъ.*) булган. *Арба тәртәсенә асып куелган көянтәле үлчәүдә үлчәнеп, конфет, прәннек, көнбагыш кебек нәрсәләр сатыла.* И.Нуруллин

**КӨЯНТӘЛЕК** *с.* Көянтәгә яраклы. *Ул, көянтәлек агач эзләп йөри торгач, моңар хәтле таныш булмаган имәнлеккә килеп чыкты.* К.Нәҗми

**КӨЯНТӘ́СЫМАН** *с.* Көянтәгә охшаш, көянтә формасында эшләнгән, ясалган. *Ике рәт колонналар тезеп, көянтәсыман ярым түгәрәк формада эшләнгән матур капка алдында бераз гына чират та бар иде.* Ә.Еники

**КӨЯНТӘ-ЧИЛӘК** *җый. и.* Су ташу кирәк-ярагы буларак көянтә һәм чиләкләр. *Кеше алдыннан буш көянтә-чиләк белән үтәргә ярамый: аңа уңышсызлык килә.* Юрамыш. *--- купшы булуы өстенә, Зөбәйдә бик җитез, уңган да булып чыкты. Аның кулына эләккән савыт-саба елкылдап калыр, суга барса, көянтә-чиләге урамны яктыртып торыр.* Н.Измайлова. *Әнә тыкрыктан минем әни төшеп килә. Көянтә-чиләк аскан, кулында төенчек.* М.Галиев

**КӨЯНТӘ-ЧИЛӘКЛЕ** *с.* Көянтә-чиләк аскан яки элгән. *Алачык буеннан җиңел-җиңел генә, әдәпле генә атлап, көянтә-чиләкле кызлар, яшь киленнәр узып китә.* А.Шамов

**КӨЯ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругыннан зарарлы бөҗәкләргә каршы кулланыла торган үлән; борча үләне; *русчасы:* **пиретриум**. *[Көя үләне] ---, кубесенчә, көньякта һәм таулы төбәкләрдә үсә.* Биология

**КӨЯ́ ЧӘЧӘГЕ** *и. бот. к.* **көя үләне**

**КРАБ** *и. голл. зоол.* Югары төзелешле унаяклылар отрядыннан, чагыштырмача зур гәүдәле диңгез кысласы (күп төрләре затлы ризык буларак файдаланыла). *Миногалар, омарлар, краблар, елан балыклар алырга вәкилләр Балтыйк буена, Калининградка ашыкты.* А.Гыйләҗев. *Аулау төрләре хайван төркемнәре яки аларның тереклек эшчәнлеге продуктларына карап аерыла, мәсәлән, кыйммәтле мех өчен аулау, балыкчылык, урман умартачылыгы, краблар --- тоту.* Биология. Хайваннар. *Крабның балалары үзләренең аналарына бөтенләй охшамыйлар.* Диңгез тирәнлегендә

**КРА́ГИ** *и. голл.* 1) Күн яки кирза итекнең ялганмалы куныч өлеше

2) Перчатканың киң һәм озын беләзеге. *«Эфси» маркалы (бу – чагыштырмача арзан бәяле фирма, диләр) экипировка бәяләре болайрак: --- бияләйләр (краги) – 790, --- сумнан башлана.* Татарстан яшьләре

**КРАКС** *и. лат. зоол.* Карарак төстәге эре каурыйлы, кыска канатлы, кабарынкы томшыклы тавыксыман кошлар семьялыгы һәм шуңа караган кош. *Отрядта алты семьялык: озын аяклылар яки чүп тавыклары, кракслар, кыргавыллар, көртлекләр, мисыр тавыклары һәм күркәләр.* Биология. Хайваннар

**КРАЙ** *и. рус* 1) Россия Федерациясендә (элеккеге СССРда, РСФСРда) эре административ территориаль берәмлек. *Аларның вәкаләтләре Президент вәкилләренә, край һәм өлкәләрнең билгеләп яки сайлап куелган хакимият башлыкларына күчә.* Россия XX гасырда. *Иске Икшермә дигәннән, элек бер өлеше Томск губернасына кергән Красноярск краенда районыбызның Иске Икшермә, Сатыш, Тимершык, Килдебәк исемнәрен йөрткән торак пунктлары барлыгын белә идек.* Т.Нәҗмиев. *Белгечләр билгеләп үткәнчә, Алтай краенда яшәүчеләр галәм тематикасы белән бәйле тиңдәшсез материаллар саклый.* Ватаным Татарстан

2) Билгеле бер географик өлкә, регион. *Спорт белән шөгыльләнәм, парашют белән сикерәм һәм 17 июльнең ул край вакыты белән кичке сәгать тугызлар тирәсендә кинәт билгесезлеккә очам.* Ф.Яруллин

3) *сир.* Туган як, туган төбәк, җир

**КРАЙКОМ** *и. рус иск.* СССРда коммунистлар партиясенең край (*1 мәгъ.*) комитеты. *Гыйнвар аенда минем «Башмагым», «Наёмщик», «Ташкыннар» трилогиясен рус теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгару мәсьәләсен хәл кылган идек. Бу турыда крайком секретаре иптәш Батыевның Мәскәүгә язган хаты да Сезгә билгеле.* Т.Гыйззәт. *Указ шул көнне үк басылып чыкты. Яман да шәп банкетны крайком үз өстенә алды.* Р.Батулла. *Бу үтә дә яшерен боерыкны компартияләргә, крайком, окружком, шәһәр комитетлары һәм райком бюролары әгъзаларына җибәрү өчен --- куллар куелган.* З.Зәйнуллин

**КРАН** I *и. нем.* Авыр йөкләрне күтәртеп төяү, бушату, якын арага күчерү хезмәтен үти торган техник җайланма, механизм. *Ул [Русаков] боцманга кычкырды: – Әллә тилерделәр инде? Монда ике кранга урын җитми, бу ахмаклар өчне куялар.* М.Юныс. *Менә кранның борыны тукталып калды, аннан салынган ыргакка торбадан сузылган тросның элмәген элделәр.* М.Маликова. *Кичләрен, тын су өстенә төн пәрдәсе иңгәч, яр өстендәге завод тәрәзәләрендә, биек кран башларында утлар җемелди ---.* С.Сабиров

2) Шундый механизм урнаштырылган автомобиль. *Йокыга китә алмый борсаланып яткан төнне урталайга ярып, поездлар текелдәп үтте, --- краннар ары-бире шуышып гүелдәде, --- кайдадыр илереп-илереп гармун җылады, җылады да завод, ТЭЦ сасысыннан тончыгып туктады.* А.Гыйләҗев

**КРАН** II *и. голл. тех.* 1) Резервуар, зур савыт яки үткәргеч торбадан кирәгенчә сыеклык яисә газ бушату, агызу өчен борып ачыла-ябыла торган җайланма. *Кранны ябу өчен, аның бөкесен агымга аркылы борырга кирәк.* Гидравлика

2) Үткәргеч торбадагы сыеклык яки газны тоткарлау, аның агымын көйләү яисә бушату хезмәтен башкара торган ачулы-ябулы җайланма. *– Сукач, ишетәсеңме? Буфетка кайнар су килми, кранны ач! – диде Шмаков.* М.Юныс. *Краннан су тамып тора, Күп чакта агып тора. Әнием и борган була, И булыштырган була. Тик кран җаен таба: Тама да һаман ага!* Р.Миңнуллин. *[Искәндәр] Иренеп кенә кранны борды – тагын җылы су юк. Савыт-саба юмаска сәбәп чыгуына сөенгәндәй, теләр-теләмәс кенә сукранып, кранны ябып куйды.* Р.Вәлиев

3) Су торбасының ачулы-ябулы җайланма урнаштырылган башы. *Ул [Ринат], күнегүләрен ясагач, кран астында бил тиңентен юынып керде.* Н.Хәсәнов. *Башны кран астына куеп салкын суда тотам да имтиханга китәм.* И.Салахов. *Салих, өч стакан табып, кран астында юа башлый.* Р.Мингалим, Э.Яһудин

**КРАНБА́ЛКА** *и. голл. тех.* Заводларда, ремонт цехларында биеклектәге аркылы тимер балкага урнаштырылган тәгәрмәчле платформасы кул көче яки электр ярдәмендә хәрәкәткә килә торган күтәртү кранының бер төре. *Чыңгыз, зур чүмечкә тутырып алынган сыек металлны кранбалка*

*ярдәмендә күтәртеп, идәннән идарә итә-итә, цехның аргы башына таба хәрәкәтләндерде.* Н.Хәсәнов

**КРАНЧЫ** *и.* Кранда I (*1 мәгъ.*) эшләүче, кран белән идарә итүче. *Төнге алтынчылар, кранчылар, шапшак слесарьлар белән янәшәдә синең рәсемең эленеп торсынмы?* А.Гыйләҗев. *Пыяла кабинадан башларын тыгып, кранчылар үзара бераз чәпчеп тә алдылар.* М.Юныс. *Ир дигәнем төзелештә инженер иде, үзем – кранчы.* К.Тимбикова

**КРА́ТЕР** *и. гр.* 1) Вулкан түбәсендә лава бәреп чыга торган уенты. *Эт хуҗасының күлмәгенә янар тау рәсеме төшкән. Кара ефәккә ясалган зәңгәр янар тауның кратерыннан кызыл ут көлтәсе күтәрелә.* М.Юныс. *Вулкан-«сызлавык»ның үзәгенә – кратерга кадәр әле тагын чакрымнан артык менәсе бар.* Р.Фәйзуллин

2) Калкулыктагы уенты. *Кратер эчендә һәм аның якын-тирәсендә никельле тимер метеорит кыйпылчыклары табылды.* Фән һәм тел

**КРА́ТЕРЛЫ** *с.* Кратеры булган. *Айның өслеге кратерлы булуы мәгълүм*

**КРАХМАЛ** *и. нем.* 1) Үсемлекләрдә барлыкка килә торган вак бөртекле онсыл матдә, углеводларның бер төре. *Ташлытау станциясе җирнең үзәге икән ---. Көзге пычракта утыз алты пот бәрәңге заданиесен шундагы крахмал заводына илтеп тапшырасы.* М.Мәһдиев. *Крахмал һәм гликоген организмда күзәнәкләрнең тереклеге өчен энергия чыганагы ролен үти.* Гомуми биология. *Башка абагалардан аермалы буларак, бөркет канаты озын шуышма тамырчалы, анда крахмал туплана.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *сөйл.* Туңган яки бозылган бәрәңгене киптереп ясалган ашамлык. *Бер чиләк чи бәрәңгедән кило-кило ярым сыйфатлы крахмал чыга икән*

**КРАХМАЛЛАНУ** *ф.* 1) *төш юн. к.* **крахмаллау**. *Мөнирә башына крахмалланган ак башлык кигән олы гына бер хирургны күз алдына китерде.* Г.Әпсәләмов. *Мөмкинлегем булганда, мин аңа кучтәнәчләр, крахмалланган ак якалар, манжетлар җибәрдем.* Фатих Әмирхан турында истәлекләр

2) Крахмалга әверелү

3) Үзендә крахмал барлыкка килү, туплану. *Бәрәңгенең крахмалланып черегәнен чүпләүчеләргә өйләренә бирә тордылар.* М.Мәһдиев

**Крахмаллана башлау** Крахмал туплану билгеләре күренү

**Крахмаллана төшү** Бераз крахмаллану

**Крахмалланып бетү** Бик нык крахмаллану

**Крахмалланып җитү** Тәмам, тулысынча крахмаллану

**КРАХМАЛЛА́У** *ф.* Тукымага, киҗемамык җептән бәйләнгән нәрсәләргә крахмал сеңдереп тыгызландыру. *Ксения Сәйдәшнең ак күлмәген, якаларын, бигрәк тә алмаш-тилмәшкә кия торган ак күбәләк бантикларын крахмаллап юа, үтүкләп бирә.* Р.Низамиев

**Крахмаллап алу** Тиз генә крахмаллау

**Крахмаллап бетерү** Тулысынча крахмаллау

**Крахмаллап җибәрү** Аз гына крахмал сеңдерү

**Крахмаллап кую** Алдан ук крахмаллау, күптән крахмалланган хәлгә китерү. *Аш урынын җыеп, юылган савыт-сабаны сөртим дип тастымалга баксам, ни күзем белән күрим, крахмаллап куйган ап-ак салфеткаларымның карар җире дә калмаган – чат корым.* К.Тимбикова

**Крахмаллап тору** Даими крахмаллау

**Крахмаллап чыгу** Барысын да берבер артлы крахмаллау

**Крахмаллый башлау** Крахмалларга керешү

**Крахмаллый төшү** Бераз крахмаллау

**КРАХМАЛЛЫ** *с.* 1) Үзендә крахмал булган (барлыкка килгән, җыйналган). *Ул [бүлбеле кымызлык] – кыргый төре билгеле булмаган борынгы культура, аның крахмаллы бүлбеләре Андның биек таулы районнары, Колумбия, Боливия һәм Чили илләрендә бәрәңге культурасы белән ярыша.* Ботаника. *Аксымлы һәм крахмаллы ризыкларны бергә ашаганда, алар авырдан үзләштерелә.* Татарстан яшьләре

2) Үзенә крахмал сеңдерелгән. *Шәһәрнең крахмаллы күлмәкләрен салып ташлап, Анна Васильевна хәзерләп куйган җәйге җиңел күлмәкне киенеп, аякка чәпелдәвек киеп, терраска хәзерләнгән чәй янына килеп утыргач кына, чын да үзен-үзе дачада итеп хис итте.* Г.Исхакый. *Сафин үзе ак кар шикелле крахмаллы якалар өстеннән ут шикелле кызыл ефәк галстук бәйләгән, өстән торып гомуми тәртипне караштыра.* Ш.Камал. *Нәзек озын буй, инглиз сукносыннан тегелгән, үзенә ятышкан зәңгәрсу кара костюм, крахмаллы утыртма яка, затлы ефәк галстук, дулкын-дулкын кара чәч, ак йөз, кара каш, туры борын вә җәя иреннәр Кәбир күз алдында мәңгегә сакланыр.* Р.Батулла

◊ **Крахмаллы яка** Хакимият вәкиле. *Крахмаллы яка тәкерек чәчте: – Ломовойлар өчен түгел бу зал! – Цензор булып Ильминский дәште: – Нигә кирәк сиңа газет-журнал?* Г.Афзал

**КРАХМАЛЛЫЛЫК** *и.* Крахмал микъдары, крахмаллы булу дәрәҗәсе. *Бөртекле культуралар арасында кукуруз крахмаллылык ягыннан беренче урында тора*

**КРЕВЕ́ТКА** *и. фр. зоол.* Унаяклы кыслалар отрядыннан, ашарга яраклы вак кына диңгез хайваны. *Су төпләренә ябышкан суүсемнәрдән тыш, биредә матур кабырчыклы төрле-төрле моллюсклар, актиния, ялгыз кысла, креветкалар --- яши.* Табигать белеме. *Теләсә нәрсә әзерләргә мөмкин: бозау ите, балык, үрдәк, күркә, кысла, креветка, омар, кыздырган бака боты.* В.Юныс. *Тирәндә яшәүче креветкаларның авызы янында махсус бизләре бар, куркыныч янаганда, аннан яктырткыч болыт чыга.* Кызыклы физиология

**КРЕ́ДИТ** *и. лат. финанс.* Исәп-хисап кенәгәсенең чыгымнар языла торган бите, бүлеге; киресе: **дебет**. *Монда инде төрле җиргә сибелгән саннар бергә җыелалар. Дебет булып бер якка, кредит булып икенче якка тезеләшәләр.* Т.Миңнуллин. *Дебет – синең саваплы эшләрең, кредит – начарлык-*

*ларың. Үткәндә кылган кырын эшләреңне кире кайтып төзәтеп булмый.* Х.Камалов

**КРЕДИ́Т** *и. фр. финанс.* 1) Шартнамә нигезендә билгеле бер вакытка кичектереп, тигез өлешләп яки процент исәбенә арттырып түләнә торган акчалата яки әйберләтә бурыч. *Минем валюталарым Швейцария банкында саклана, кредит ачуларын сорап радиограмма җибәрдем, әле җавап килеп җитмәде, дип ялганлаган иде, югыйсә.* М.Юныс. *Хәзер кредит бирүдә саклык банкының өлеше кими бара.* Ватаным Татарстан

2) Билгеле бер максатка бирелгән һәм күпмедер вакыт дәвамында файдаланган өчен процент исәбенә суммасын арттырып түләнә торган акча. *Бу төнне ире Миләүшәне акчалата кредит алырга кирәкле кәгазьләр җыя башларга күндерде.* Г.Исхакова. *Шәхси хуҗалык төзүгә бирелгән кредит*

**КРЕДИ́Т АЛУЧЫ** *и.* Шартнамә нигезендә билгеле бер максат белән чикләнгән вакытка банктан акча алып торучы; *русчасы:* **заёмщик**. *Кредит алучылар арасында эре ширкәтләр – нефть, металлургия, күмер чыгару, төзелеш компанияләре дә җитәрлек.* Ватаным Татарстан. *Авыл хуҗалыгы тармагында эшли торган банкның кредит алучылар саны арткаdebannan-арта бара*

**КРЕДИ́ТКА** *и. рус сөйл.* Кредит картасы. *Товар өчен кредитка белән түләү*

**КРЕДИТЛА́У** *ф.* Өлешләп кире түләү шарты белән билгеле бер вакытка процент алу исәбенә яки процентсыз бурычка акча биреп тору, товар сату. *Банклар бер-берсен кредитлый алмый җәфалана.* Ватаным Татарстан. *Мәсәлән, узган ел банк 2006 ел белән чагыштырганда 89 процентка күбрәк кредитлаган, һәм бу – Русиядәге банкларның уртача күрсәткеченнән шактый югары сан.* Татарстан яшьләре

**Кредитлап алу** Кыска вакыт эчендә кредитлау

**Кредитлап килү** Билгеле бер вакыт дәвамында даими кредитлау. *Банк шулай ук Русия территориясендә урнашкан филиаллары аша илнең күпчелек төбәкләрендә кече һәм урта бизнесны да даими рәвештә кредитлап килгән һәм килә.* Татарстан яшьләре

**Кредитлый башлау** Кредит бирергә керешү. *Банклар хосусый торак төзү тармагын кредитлый башладылар*

**КРЕДИТОР** *и. лат. финанс.* Кредит, ягъни бурычка акча яисә товар биреп торган зат яки оешма. *Болай да булгалый: бер татар икенче татарга күптәннән бирергә тиешле акчасын бирмичә йөри; менә кредитор акча алучы артыннан үзенең кешесен җибәрә дә: «Әбелгаффар, син кайчаннан бирле әҗәтеңне түләргә вәгъдә итәсең, ә бирмисең?» – диярга куша.* Рим.Вәлиев

**КРЕДИТОРЛЫК** *и. финанс.* Кредитор булу; кредиторга бәйле булу. *Кредиторлык һәм дебеторлык бурычының пропорциональ булмаган үсеше*

**КРЕДИТ-ФИНАНС** *с.* Кредит һәм финанс эшләренә мөнәсәбәтле. *Банк – эре финанс-кредит оешмасы. Кредит-финанс учреждениеләре аша фермерларга микрокредит бирү эшен җайга салу*

**КРЕ́ДО** *и. лат.* Тоткан юл, мәсләк, кыйбла; шәхси караш. *Аларда – шагыйрьнең кредосы, ышанычы, кыйбласы, көндәлек шатлыгы...* Р.Гаташ. *Кредога, безнеңчә әйтсәк, инануга кагылмый инде бу сүзләрем.* Ф.Баттал

**КРЕ́ЙСЕР** *и. голл.* Озын юллар йөрүгә исәпләнгән һәм мөстәкыйль бурычлар башкара ала торган сугыш корабы. *Кая алар, минем беренче килүемдә күргән крейсерлар, миноносецлар, торпеда катерлары һәм су асты көймәләре?* М.Юныс. *Рейдта тып-тын гына, зубр, як үгезе кебек авыр чайкалып, бер-ике крейсер тора – якын килеп кара!* М.Мәһдиев. *Әйе, сез су асты көймәсендә дә, крейсер яки торпеда катерларында да булмассыз.* Р.Кәрами

**КРЕ́КЕР** *и. ингл.* Коры, гадәттә баллы булмаган печенье. *Әби «Чупс» китергән, Апа – «Крекер» чит илдән. Туңдырма алган икән Дәү әтисе дә иртән.* Л.Шәех

**КРЕ́КИНГ** *и. ингл. махс.* Ягулык мае, химия сәнәгате өчен чимал алу максаты белән нефтьне төрле состав өлешләренә таркатып эшкәртү. *Крекинг процессында радикалларның берсе водород атомын аерып җибәрә, ә икенчесе китереп куя.* Химия. *Каталитик крекинг – катализаторлар кулланып, мотор ягулыкларының чыгуын арттыру максаты белән, югары температурада нефтьне эшкәртү процессы ул.* Тирә-юнь мохитне саклау

**КРЕ́КИНГЛАУ** *ф. махс.* Нефтьне кудырып, аның кирәкле состав өлешләрен аерып алу

**Крекинглый башлау** Крекинг эшенә керешү

**КРЕМ** *и. фр.* 1) Май, йомырка, каймак һәм шикәр комы кебек ашамлыкларны туглап эшләнгән измә. *Кремны болай ясыйбыз: йомырка агын куе итеп күбекләндерәбез, әкренләп шикәр комы белән крахмал өстибез.* Малайларга-кызларга: «тәмле» киңәшләр

2) Бит, тән, кул, аякларга сөртү өчен, косметика буларак һәм дәвалану максаты белән кулланыла торган май. *Наилә озаклап көзге каршысында бөтерелә, тәненең төрле җирләренә ислемайлар, кремнар, лосьоннар сөртә.* А.Гыйләҗев. *Аланга ислемай исе, крем, одеколон исе тарала, яшьләр Язтургайга китәргә җыеналар.* Ш.Бикчурин. *Әгәр биткә вак кара бетчәләр (нокталар төсендә) чыкса, нинди дә булса майлы кремнар һәм майлар сөртергә ярамый.* Йорт эшләре

3) Аяк киемнәрен матурлату, ярылудан саклау өчен махсус май. *Чүпрәк ботинкамны ике көн кремга батырып, аннары җиде кат тирем чыкканчы коры сукно белән ышкып кына ялтыраткан идем.* Ф.Яруллин. *Егет киосктан аяк киеме чистарта торган крем алды.* Р.Кәрами

**КРЕМАТО́РИЙ** *и. нем.* Мәет яндыру миче булган махсус бина. *Назимов тәрәзә янына китте, крематорий торбасындагы ялкынга карап тора башлады.* Г.Әпсәләмов. *Язгы кояш крематорий морҗасыннан ургып чыккан кара төтен артына кереп качкан бер мәлдә, кичке аштан кайтып килешли, Абдуллин полицай киемендәге берәүнең --- зәгыйфь әсирне кыйнавына игътибар итте.* Я.Зәнкиев

**КРЕМА́ЦИЯ** *и. лат.* Мәетләрне махсус бинада урнаштырылган мичтә

яндыру. *Без кремация урынына якынлашканда, ярда җиде учак яна иде.* Ә.Рәшит. *Англиядән кайтартылган кремация мичендә берьюлы 200 кило биокалдык сыя.* Татарстан яшьләре

**КРЕМА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Мәетне яндыру. *Без, көймәләргә утырып, югары агымына таба йөзәбез. Анда, өстәрәк, яр буйлатып, мәетләрне кремацияләү урыны.* Ә.Рәшит. *Сүз дә юк, мөселман кануннары буенча, үлгәннәрнең җәсәден кремацияләү, ягъни яндыру, язык эш санала.* Шәһри Казан

**КРЕМЕНЬ** *и. рус* 1) Кристалл структуралы минерал, аеруча нык таш; чакматаш, ут ташы. *Кайнар чишмәләрдән ерак урыннар да суынып каты хәлгә килгән, кремень белән капланып алынган ---.* Дөньяда ниләр бар

2) *сөйл. күч.* Нык, көчле ихтыярлы кеше. *Ә Батя – кремень, чакматаш! Аннан кирәкмәгән сүзне тискида кысып чыгара алмыйсың.* А.Хәсәнов

**КРЕМЛА́У** *ф.* 1) Крем ягу, сөртү, сылау (ашамлыкка яки тирегә)

2) Крем белән майлау, крем ышку (аяк киеменә). *Бутыйларны кремлап, чистартып, киптереп тә азапланырга кирәкми.* Татарстан яшьләре

**Кремлап алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә кремлау

**Кремлап җибәрү** Бераз, берникадәр кремлау

**Кремлап кую** Алдан ук яки тиз арада кремланган хәлгә китерү. *Кремлап куярга кремише нәрсә юк иде, абый аларны көнбагыш мае белән майлап куйды.* Ф.Яруллин. *Бакчага баргач, чүп савытына ыргытырмын әле дип йөргән иске ботинканы да кремлап, тазартып куйган бу [кыз].* Ф.Хәбибуллин

**КРЕМЛЬ** *и.* 1) Алтын Урда чорындагы төрки-татар шәһәрләрендә, XIV гасырдан алып Россиянең борынгы зур шәһәрләрендә, гадәттә, яр буена, калкурак урынга төзелгән эчке ныгытма; кирмән, кальга. *Тиздән Кремль курантлы даң-доң итеп унике тапкыр сугар да, Советлар Союзы гимны яңгырар.* И.Салахов. *Казан суы ярында иң югары төштә, таш каланың ак күңеле булып, чал кремль тора.* Ф.Мансуров. *Хәзерге Кремль территориясендә Казан ханлыгы, Алтын Урда һәм Болгар чорларыннан калган бер генә бина да сакланмаган.* Ф.Хуҗин

2) *күч.* Хөкүмәт (Россия хөкүмәтенең Мәскәү Кремлендә эш йөртүеннән). *Кремль кушканны үтәп, Әфганстан дигән тыныч илгә басып керделәр, аны пыран-заран китерделәр – бары шул.* Татарстан яшьләре

**КРЕМНЕЗЁМ** *и. гр. хим.* 1) Кремний белән кислород кушылмасы; табигатьтә кварц, кремний, опал формасында очрый. *Үсемлекнең яфраклары һәм сабаклары каты, тыгыз, чөнки аларда да кремнезём күп.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Бу төркемгә кергән иң түбән төзелешлеләрнең күпчелегендә эчке скелет бар, ул радиаль типта төзелгән һәм кремнезём яки стронций сульфатыннан тора.* Биология

2) Силикат чималы

**КРЕМНЕЗЁМЛЫ** *с.* Составында кремнезём булган. *Юка гына балчыклы бурташ катламы астында төрле дәрәҗәдә кремнезёмлы, урыны-урыны белән кремнийлы --- мергел катламы ята.* Фән һәм тел

**КРЕ́МНИЙ** *и. гр. хим.* Табигатьтә ком, кара соры тимердәй ялтыраган кристалл формасында очрый торган, тау токымнары составына кергән төп химик элементлардан берсе. *Кремний – кислородтан кала Җир кабыгында иң күп таралган элемент.* Химия. *Кремний атомында электроннарның энергия баскычларына ничек урнашуын энергетик диаграммада күрсәтегез.* Физика. *Бодяганың тәне күпсанлы күзәнәкләрдән тора һәм эчке скелет ролен башкара торган нечкә кремний энәләр белән капланган.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КРЕ́МНИЙЛЫ** *с.* 1) Составында кремний булган. *Кремнийлы комташта кварц комы сулы комташ белән берегә, һәм опал минералы барлыкка килә.* Төзү материаллары. *Мәсәлән, кремнийлы ярымүткәргечләрдән торган бүгенге компьютерларыбызның барысы да графенлыга әйләнәчәк.* Ватаным Татарстан

2) Комташлы

**КРЕМ-СО́ДА** *и. рус* Татлы, газлы салкын эчемлек төре. *Крем-сода сусауны баса торган эчемлек түгел*

**КРЕН** *и. голл.* Очкыч, кораб яисә көймәнең хәрәкәт вакытында янтаюы. *--- инструктор самолётны үзе шулай янтайткан икән. Чөнки, самолётны янтайтып, тиешле дәрәҗәдә крен ясап кына дөрес борылып була.* С.Баттал

**КРЕ́НДЕЛЬ** *и. нем.* Гадәттә, төче камырдан бөҗра сыман итеп пешерелгән күмәч. *Бер-ике урында күпереп пешкән ак күмәч, кызарып пешкән крендельләр сата торган төрекләр дә күренәләр.* А.Таһиров. *Чөнки аның [Газизнең] кибетендә тоз, керосин, шырпы, чәйшикәр генә түгел, шәкертләрнең авызларыннан сулар китерә торган бал, монпасье, чикләвек, крендель шикелле әйберләр дә тулып ята---.* Ш.Камал. *Без, Галиәкбәр әфәнденең язу-сызу өстәле артында сөйләшә-сөйләшә, крендель белән чәй эчтек.* Т.Мөбарәков

**КРЕНДИЛ** *и. нем. сөйл. к.* **крендель**. *Крендилне бик тиз ялт итеп куябыз, уртадагы тишеге генә кала.* Ф.Яруллин

**КРЕОЗОТ** *и. гр.* Агачны яисә ташкүмерне корылай кудыртудан чыккан куе, яман исле агулы матдә, деготь төбе. *– Менә бу шадра эзләре шул шпалдагы креозот кисеп кергәннән, – дип, ул, сакал төкләрен шыкырдатып, яңагын сыйпап алды.* М.Галиев. *[Һарун картның], уйлап карасаң, әллә ашау җитмәүдән, әллә шул шпал мае – креозот исенә укшып-укшып егылган чаклары да әз булмады югыйсә.* Л.Хәмидуллин

**КРЕОЛ** *и. исп.* Латин Америкасында башлыча Европадан француз, испан, португал чыгышлы беренче күчеп килүчеләрдән, әмма канында җирле халыклар катнашы да булган ак тәнле кеше. *Ак тәнле халыкны Европадан бик күптән күчеп утыручылар (испаннар, португаллар) нәселенә – креолларга һәм соңгы вакытларда күчеп килүчеләргә аерып йөртәләр.* Чит илләрнең экономик географиясе. *– Бетәбезмени алайса? – дигән сорауга креол җавап бирмәде, нindидер бөтен нәрсәгә карата*

*битарафлык белдергән күзләре йомылды.* И.Хуҗин

**КРЕП** *и. фр.* 1) Өсте кытыршы итеп тукылган юка йон яисә ефәк тукыма. *Мондый бәйләнешләр нигезендә барлыкка килгән сүзләр шактый күп: крепдешин (кытай крепы, кытай ефәге); одеколон (фр.) – Кёльн суы; ессентуки – су һәм ул чыга торган урын ---.* Ф.Сафиуллина

2) Шулай эшләнгән тукыма атамаларының беренче кисәге. --- *Габбас ни өчендер: – Мәдинәнең дә теге креп-жоржет күлмәге һаман да тузмый икән бит, – дип әйтә куйды.* Р.Рахман. *Ул төшендә дә креп-жоржетлар, нейлоннар, перлоннар, лавсаннар гына күрә торгандыр.* Г.Афзал. *Файдешин, креп-сатин, креп-флоксише тукымаларны бөтенләй юмаска, бәлки химик юл белән генә чистартырга кирәк ---.* Йорт эшләре

**КРЕПДЕШИН** *и. фр.* **1.** Тыгыз тукылган сыйфатлы юка ефәк тукыма. *Итәкне, җиң очларын һ.б. детальләрне дә үтүкләгәндә шулай ук серкәле су белән чылатырга тәкъдим ителә, чөнки кайбер тукымалар сыланып тормаучан була, мәсәлән, крепдешин, шифон һ.б.* Йорт эшләре

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *[Ханымның] Өстендә яшел крепдешин күлмәк, ак йоннан бәйләнгән калын кофта.* Ф.Латыйфи. --- *күршесе Вәдүтнең хатыны Гөлбәһар да үзләренең яшелчә бакчаларына карачкы куйган икән. Зәңгәр күлмәк кидертеп. Сәгыйтьнең солдат киемен көтеп-көтеп тә киелмәгән, тузмаган-туздырылмаган крепдешин күлмәген.* Ә.Гаффар

**КРЕПОСТНИК** *и. рус тар.* 1) Россиядә колбиләүчелек системасы тарафдары, шундый системаны саклап калу өчен көрәшкән зат

2) Алпавыт, бояр. *Ул заманнардагы техника – авыл хуҗалыгының ярым натуральный формасы – алпавыт-крепостник, шунардан аерылып җитмәгән вак һөнәрче, Шәрык белән сәүдә мөнәсәбәте, шуның аркылы Бохара-Төркестанның бездәге идеологиягә тәэсире, феодализм хәрабәсе...* Г.Ибраһимов. *Без кеме соң җирнең? Хуҗалары! Барысын да санап, я, узыйк: «Крепостной крепостник та, Крәстиян һәм дә... колхозник!»* Зөлфәт

3) *күч.* Реакцион сәясәтче

**КРЕПОСТНИКЛЫК** *и.* 1) Крепостник (*1, 2 мәгъ.*) булу. *Күрәсез, Тукай солтан деспотизмы астында яшәгән халыкның политик һәм экономик изелүен күрсәтү белән бергә, Россиядәге самодержавиечыл-крепостниклык строен да камчылый.* И.Нуруллин

2) *күч.* Реакционерлык

**КРЕПОСТНОЙ** *с. рус* **1.** 1) Крестьянның шәхесенә, мөлкәтенә һәм хезмәтенә алпавыт ия булу хокукына нигезләнгән

2) Алпавытка буйсынган, аның кул астындагы (кешеләр тур.). *Шәрифә: «Анысы дөрес, Зәкәрия Адамович, шулай да мин аңлый алмыйм, ничек итеп крепостной крестьяннарсыз торырга да, ничек итеп дворяннар үз хуҗалыкларын алып барырлар?»* Т.Гыйззәт. *Крепостной крестьяннар алпавыткка эшләүдән һәм оброк түләүдән баш тартканнар.* Татарстан тарихы. --- *ул чакта Кабанов дигән ат өйрәтүче бер талантлы крепостной крестьян яшәгән.* Дөньяда ниләр бар

**2.** *и. мәгъ.* Алпавыт кул астындагы зат, чуракол. *Үзе каты куллы старшина буларак, крестьяннарны изеп, җәфалап үз эшләрен эшләтүгә карамастан, аларның крепостной булмауларын яклап чыга.* С.Алишев. *Алкышлардан туган ялгышлардан Догасын онытып, тулган ай Оеп йоклый... Улларына охшап, Аең да кол – шул ук крепостной.* А.Хәлим

**КРЕПОСТНОЙЛЫК** *и.* Кол биләүгә нигезләнгән иҗтимагый төзелеш. *«Крестьянлык крепостнойлык түгел!» Дигән оста телләр җитәрлек.* Зөлфәт. *Күршедәге Урман асты Чурачыгы чуваш авылы да аңарда крепостнойлыкта булган, дип сөйлиләр иде.* Р.Зәйдулла. *Крепостнойлыкның таркалуы һәм капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе сәүдә эшенең алга китүенә ярдәм иткән.* Татарстан тарихы

**КРЕ́ПОСТЬ** *и. рус* 1) *сөйл.* Ныгытма, кальга. – *Крепость – крепость инде ул. Аны алыр өчен бернечә корпус кирәк, – ди ефрейтор.* А.Таһиров. *Бабасында бер атна кунак булганнан соң, Иннокентий пар ат җигелгән бричкага яшь бичәсен утыртып, аның бирнәләрен төяп, үзе яшәгән Гродно крепостена алып кайтып китте.* З.Зәйнуллин. *Халтаев яшәгән ихатага килеп җитәрәк ул туктап калды, милиция башлыгы йорты чын мәгънәсендә алып булмаслык крепостьны хәтерләтә иде.* Р.Мирхәйдәров

2) *тар.* Патша Россиясендә ныгытылган төрмә

**КРЕ́СЛО** *и. рус* 1) Гадәттә, култыклы, аркасы биек йомшак утыргыч; кәнәфи. *Ишекне бикләп, ачкычын кесәсенә салды, йомшак креслога утырды да миңа текәлеп карады---.* Г.Ибраһимов. --- *ул [Искәндәр] ак чехол белән өсләре ябылган йомшак креслога – Мәрьямбикәгә каршы утырып, --- йөрәгендәге каушау, уңайсызлыкны никадәр басарга тырышса да, булдыра алмады.* К.Тинчурин. *Каршымдагы камыш креслога чумып утырган кеше бик кечкенә, бик ябык бит, билләһи!* И.Салахов

2) *күч. сөйл.* Дәрәҗәле урын. – *Кресло өчен куркасыздыр инде. – Вәзыйх, эчтән шүрләп, шулай диде.* Х.Камалов

**КРЕ́СЛО-КАРАВАТ** *и.* Җәеп, таратып куйгач, караватбуларак та кулланылган кресло. *Авансценага ап-ак кресло-караватт тәгәрәтеп Гөлчирә керә.* А.Гыйләҗев

**КРЕСС-САЛАТ** *и. лат.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан яфраклары минераль матдәләргә, витаминнарга бай үлән үсемлек. *Кавказда зур мәйданнарда чәчүле кандала үләне яки кресс-салат (Lepidium sativum) үстерелә.* Ботаника. *Ачык грунтка әнис, кресс-салат, бөтнек, майоран һәм газон үләне чәчәргә була.* Мәдәни җомга

**КРЕСТЬЯН** *и. рус* Төп эше җир эшкәртү, иген игү, мал асрау булган авыл кешесе. *Эшче һәм ярлы крестьян власте сугышны тизрәк туктатырга мөмкин икәнлекне --- аңлатырга тырышып карады, ләкин булмады ---.* Ш.Камал. *Менә татар әдәбиятының ерак тарихын җанландыручы, бүгенгесен үстерү өчен армый-талмый эшләүче*

*галимнәр Галимҗан Нигъмәти, Сәләх Атнагулов та ярлы крестьян гаиләсеннән.* И.Салахов. *Ләкин ничек кенә кызса да, бераз суынгач, әни үзенең крестьян хатыны икәнен исенә төшерә, өйдә барыбер әти сүзе сүз була.* М.Маликова

**КРЕСТЬЯНЛЫК** *и.* 1) Крестьян булу. *Крестьянлыктан килә торган йомшак як*

2) Крестьян сыйныфы. *Ләкин Сәгъди абзый табигате белән саран түгел --- иде. Тик азмы-күпме акча чыгар алдыннан бераз гына сыкранып алу аның икенче табигатеннән – крестьянлык табигатеннән килеп туган бер гадәт иде.* Ә.Фәйзи

**КРЕСТЬЯ́НЧА** *рәв.* Крестьян кебек, крестьянга хас булганча; аңа охшатып. *Сафуш, әлбәттә, моны [«эх, мылтык булган булса!» дигән сүзләрне] чынлап та көртлек атасы килүдән түгел, шундый вакытны: «Эх, шулай итәсе калган, болай итәсе калган», – дип, крестьянча файдасыз үкенү гадәте буенча гына әйтте.* Ә.Фәйзи

**КРЕТИН** *и. нем.* 1) Кретинизм аркасында гадәттән тыш бәләкәй буйлы булган кеше

2) *күч. тирг. туп.* Акылсыз кеше. *[Хаммат:] Авызыңны чамалап ач, кретин!* Р.Батулла. *– Кретин! – дип кычкырды аңа хатын, кисәк кенә кулына сугып.* Х.Ибраһимов. *[Ольга:] – Идиот син, кретин! [Мөхәммәт:] – Нәрсәнәрсә?! [Ольга:] – Шуның өстенә куркак!* Р.Сибат

**КРЕТИНИЗМ** *и. нем. мед.* Калкансыман бизнең гормоны җитешмәүдән була торган физик (гәүдә төзелешендә пропорция сакланмый) һәм акыл зәгыйфьлеге. *Йод җитешмәү аркасында, бик күп кешеләр кретинизм белән авырый*

**КРИ́ЗИС** *и. гр.* 1) Нәрсәнең дә булса яшәешендә, үсешендә авыр, еш кына һәлакәтле тоткарлану хәле, шундый вазгыять. --- *табигатьне һәм телне катастрофага китереп җиткергән экология кризисы; идарә эшенә үзенең туган теленә дошман кешеләрне сайлап утыртуларның яман нәтиҗәсен дә онытырга ярамый.* М.Юныс. *Бүгенге авыл – безгә канат куйган авыл кичергән кризис турында без – өч йөздән артык язучы – барыбыз да беләбез.* А.Хәлим. --- *Илдар Хөсни Әлмәттә милициядә хезмәт итте, рухи кризистан чыга алмыйча, вакытсыз арабыздан китеп барды.* Г.Гыйльманов

2) *икът.* Икътисадта: булган товар белән ихтыяҗ арасындагы тәңгәллек бозылу. *Нинди юбилей, ди, ул кризис вакытында?!* Т.Миңнуллин. *Кризис башланган 2008 елда бу тармак тәмам кредитка баткан, ә әзер йортлар базары тәмам тулган булып чыкты.* Татарстан. *Кризис күп кенә фирмаларның ябылуына китерде, кайбер предприятиеләр кризисны сылтау итеп эш урыннарын кыскарта, хезмәт хаклары күзгә күренеп азая, яки аны тоткарлык белән генә бирәләр.* Ватаным Татарстан

**КРИ́ЗИСЛЫ** *с.* Кризис килеп чыккан, кризис кичерә торган. *«Исәнме, йөрәк» китабы, әйтерсең, күп кенә яшь шагыйрьләр өчен кризислы хәлдән котылу юлын күрсәтү иде.* М.Вәли-Барҗылы. *Хәлбуки нормаль хәлендә чакта ил белән идарә итү өчен икътисади, сәяси, юридик, идеологик һәм башка чаралар да артыгы белән җитә, һәм бары тик кризислы әхвәлдә генә яки хокук тәртибен бозучы аерым мәрдәннәргә карата гына дәүләт көчләү юлына баса.* Р.Хәкимов. *Уйлап карасаң, Россиянең бүгенге көнге кризислы хәлен, аның сәбәпләрен, Россиянең киләчәген синергетика аңлата аламы соң?* Философия

**КРИМИНАЛ** *и. лат.* Җинаять, җинаятьчелек. *«Умырзая»дагы криминал өчен дә мине гаепләргә җыенасыңмы?* Т.Галиуллин. *«Кем үтергәнен белер өчен дә киләләр. Әмма мин криминал белән бәйләнмим ---», – ди ул [Таһир Хәйдәров]---.* Сөембикә. *Бу закончалыкны исәпкә алмау яшь буынны ялгыш юнәлешкә кертеп, эчүчелеккә, наркоманлыкка, фахишәлеккә, криминалга һәм башка шушындый --- җинаятьчел юлларны сайлауга китерә.* Философия

**КРИМИНАЛИСТ** *и. лат.* Криминалистика белгече. *Калада яшәсә, криминалист белгечләргә тиз генә барып килер иде, маҗаралы детектив әсәрдә яки фильмда алар, тәмәке төпчегенә карап, кем тартуын, ни өчен тартуын, --- иң мөһиме, кайда яшәвен әйтеп бирәләр.* Р.Мирхәйдәров. *Криминалист кергәндә, Бәхтияров офицер киемнәрен граждан костюмга алыштырып өлгергән, көзгегә каранып басып тора иде.* М.Насыйбуллин

**КРИМИНАЛИ́СТИК** *с.* Криминалистикага бәйле. *Укучының бу «криминалистик эше»н, иң шәп ясалган карточкалар белән бергә, мәктәп стенасындагы тактага – күргәзмәгә ябыштырып та куялар.* М.Маликова. *Криминалистик экспертиза нәтиҗәләре җинаятьченең эзенә төшәргә ярдәм иткән*

**КРИМИНАЛИ́СТИКА** *и. лат.* Хокук фәненең җинаятьләрне тикшерү алымнарын, ысулларын, аларның исбатламаларын өйрәнә торган тармагы. *Ул криминалистика фәнен бераз өйрәндем, ди, бездә андый белгеч юк бит.* И.Сәйфуллин. *Криминалистика буенча практика үткәндә, аларны шәһәр фотолабораториясенә алып баралар.* М.Маликова. --- *елмаюын сакларга тырышып, криминалистика өлкәсендәге яңа техник казанышлар турындагы плакаттан аерылгач, кулындагы эбонит таягын Ансарга төбәде.* К.Кәримов

**КРИМИНАЛЬ** *с.* Җинаятьчелеккә бәйле. --- *Радио-телевидение, газета-журнал кебек информация чаралары, нигездә, нәкъ менә кеше күңелендә тискәре эмоция тудыра торган экстремаль, криминаль яңалыклар, хәбәрләр тарату белән мәшгуль.* Р.Миңнуллин. *Казандагы криминаль төркемнәр өчен «стрелка»ның урыны да мәгълүм: Столбище урманындагы ташландык полигон.* Г.Гыйльманов. *Бу процесс зур масштабка ия булган криминаль төркемнәрнең көчәюенә, дәүләтара террорлыкның киңәя баруына китерә.* Философия

**КРИМИНО́ЛОГ** *и. гр.* Криминология белгече. *Итальян криминологы Чезаре Ломброзо (1835–1909) даһилыкны нормаль кешегә хас сыйфат түгел дип исбат итәргә тырышкан.* К.Гыйззәтов

**КРИМИНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Җинаятьчелекне хокукый һәм социологик яссы-

лыкта (аның сәбәпләрен, шартларын, җинаятьчел төркемнәрне, җинаятьчеләрнең шәхесләрен, җинаять кылуны кисәтү юлларын һ.б.ш.ны) өйрәнә торган фән тармагы. *Криминология фәне югарылыгыннан караганда, һәр этносның үзенчәлекләре бар. Криминология һәм җинаять җәзасын үтәтү кафедрасы*

**КРИМПЛЕН** *и. ингл.* **1.** Синтетик җепселләрдән эшләнгән бөгәрләнми торган тукыма. *– Кримплен ертылмый ул, тишелеп туза, – диде Әлфия.* С.Зыялы

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Үзең доцент хатыны, ә үзеңнең кримплен күлмәгең дә юк.* М.Мәһдиев. *Ә хәзер аның өстендә шундый затлы кримплен костюм, аякларында биек үкчәле (унике сантиметр!) итальян туфлие... һәм болар барысы да аңа шундый килешеп тора ---.* В.Нуруллин. *– Минә шундый инде безнең Линар! – дип, Алтынчәчкә карап, ачык шәмәхә төсле кримплен күлмәгенә чак сыйган күкрәкләрен дерелдәтеп көлеп алды Мөһимә.* М.Маликова

**КРИПТОГРА́ММА** *и. гр.* Шартлы билгеләре (хәрефләр, аларның укылышы) аерым төркем кешеләргә генә билгеле булган язу. *[Әти:] Әйе, бик кызык. Мондый сүзләр криптограмма дип атала.* Р.Сибат

**КРИПТОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Криптограмма кулланып язу

2) Шартлы билгеләр белән язу кагыйдәләре. *Физик криптографиягә бәйле тикшеренүләр*

**КРИПТОМОНА́ДАЛАР** *и. күпл. лат. зоол.* Сулыкларда очрый торган ике мыекчалы, хәрәкәтчән микроскопик беркүзәнәклеләр, суүсемнәр. *Криптомонадалар тәнендә хлорофилл бар.* Кызыклы физиология. *[Пирофитсыманнарның] аеруча киң таралган вәкиле – криптомонада ыругы (Cryptomonas).* Ботаника

**КРИПТОН** *и. гр.* Затлы газлар төркеменә караган төссез, иссез химик элемент. *Таләпләренә карасаң, аларның да яшәргә теләгәнен аңларга була: --- һавага биек торбалар аша криптон дигән газны чыгаруны туктатырга ---.* Татарстан яшьләре. *Криптон 1898 елда Рамзай һәм Траверс тарафыннан ачыла*

**КРИСТАЛЛ** *и. гр.* **1.** 1) Молекулалары билгеле бер тәртиптә төзелеп, һәрвакыт даими формадагы каты җисем кисәкләре хасил итә торган химик матдә. *Борынгы платформалар, җыерчыклы тау өлкәләре, үзәк океаник сыртларның торышы, --- материкларда кристалл токымнарының калкымнары «Җир кабыгының төзелеше» дигән тематик картада күрсәтелгән.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Кыш көне бик югарыда каурыйсыман болытлар йөри. Ул болытлар бик күп, бик күп боз кристалларыннан тора. Кристаллар, бер-берләренә берегеп, кар бөртекләре хасил итә.* Салават күпере. *Шуңа күрә кристаллны гигант молекула дип карарга була.* Гомуми химия: мәсьәләләр һәм күнегүләр

2) *күч.* Көчле, чыныккан, үз карашларында нык торган кеше. *Мин аны [Җәгъфәрне] бары кристаллга әйләнгән, ташка, матдәгә әйләнгән татарлык, аның вөҗданы, дим...* Г.Гобәйдуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кристалл хәлендәге, кристаллдан торган. *Кристалл челтәрнең нигезендә элементар кристалл күзәнәге ята.* Физика. *Юкса эретеп ябыштырганда, кристалл канифоль белән эшләү бик күп тоткарлыклар тудыра ---.* Х.Камалов. *Әлеге сыек кристалл экранлы телевизорларның калынлыгы нибары 1 сантиметр гына.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Үз карашларында нык торган, чыныккан; чиста, намуслы (кеше тур.). *Һич арттырып әйтмим, кристалл кебек кеше.* Г.Тавлин. *Агу тулы кара йөрәк була, Сатлык йөрәк була – буш йөрәк; Тимер йөрәк, кристалл йөрәк була, Батыр йөрәк була – куш йөрәк.* Г.Афзал

**КРИСТАЛЛАШТЫРУ** *ф.* Кристаллга әверелдерү, шундый хәлгә китерү. *Химик технологиядә сыекчаны болгату гидромеханик процессларны (эмульсия ясау, дисперсияләү, гомогенлаштыру), масса алыштыру процессларын (эретү, экстракцияләү, кристаллаштыру һәм абсорбция) --- уздыру өчен кулланыла.* Химик технологиянең гидромеханик процесслары

**Кристаллаштыра бару** Рәттән, азазлап кристаллаштыру

**Кристаллаштыра башлау** Кристаллаштырырга тотыну

**Кристаллаштырып җиткерү** Тәмам кристаллашкан хәлгә китерү

**КРИСТАЛЛАШУ** *ф.* 1) Җисемнәрнең сыеклык, газ, коллоид халәтеннән кристалл халәтенә күчүе. *Караңгы кәрәзләрдә азык запасы тизрәк кристаллаша, бу – бал кортларының көчсезләнүенә һәм кышлаганда үлүенә китерә.* Татар балы

2) *күч.* Билгеле бер тотрыклы форма алу; формалашу. *Син – тирән белемле, югары профессияле, кристаллашкан гыйльми көч.* М.Җәлил. *Минә Тукай лирикасының җитлегеп кристаллашкан дәвереннән бер үрнәк: «Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, – Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын ---».* Н.Хисамов. *--- хис һәм акыл көче бергә кристаллашкан шигърияттә шагыйрь, теләсә нинди тарихи фактны үз җаны аша үткәреп, укучы җанына, аңына иңдерергә тиеш.* Фән һәм тел

3) *күч.* Бик ныгу, чыныгу. *Тарихта Вакыттан кристаллашкан Исем генә кала.* Р.Фәйзуллин. *Шагыйрь йөрәгендә тормыш каршылыклары көчәйгән саен, шагыйрь «кристаллаша».* Р.Фәтхрахманов

**Кристаллаша бару** Аз-азлап, торган саен күбрәк, ныграк кристаллашу

**Кристаллаша башлау** Кристалл хәленә күчү билгеләре күренү

**Кристаллашып бетү** Тәмам кристаллашу, шундый хәлгә килү

**Кристаллашып җитү** Тулысынча кристалл хәленә күчү

**КРИСТАЛЛАШУЧАН** *с. физ.* Кристаллаша ала торган, кристалл рәвешенә керә ала торган. *Кристаллашучан сыекча*

**КРИСТАЛЛИЗА́ТОР** *и. лат.* Химик кушылмаларны суытып кристалл хәленә китерү аппараты. *Предприятиенең продуктлар цехында кристаллизатор куелачак*

**КРИСТА́ЛЛИК** I *и. рус к.* **кристаллчык**. *Билгеле бер температурага кадәр суытылган сыеклыкта бик кечкенә кристалликлар --- (ионнар, атомнар, молекулалар) өлкәсе – кристаллашу үзәге барлыкка килә.* Физика

**КРИСТА́ЛЛИК** II *с.* Кристалл хәлендәге. *Бу нәрсә, разведчиклар кристаллик фундаментка килеп төртелделәр түгелме?* Ш.Бикчурин. *Кристаллик күкерт җиңел эретелә: бу аның кристаллик челтәре молекуляр булырга тиешлеген раслый.* Химия. *Кристаллик рәшәткә хасил булганда, электроннарның энергиясе үзгәрә ---.* Даими ток законнары

**КРИСТАЛЛО́ГРАФ** *и. фр.* Кристаллография белгече. *Француз кристаллографы О.Браве күрсәтүе буенча (1848 ел), элементар кристалл күзәнәге кабыргаларының озынлыкларына һәм юнәлешләренә карап, кристалл челтәрнең 14 төре булырга мөмкин.* Физика

**КРИСТАЛЛОГРА́ФИК** *с.* Кристаллография фәненә, аның тикшерү алымнарына бәйле. *Кристалларның кристаллографик системалар (сингонияләр) буенча классификациясе элементар күзәнәкне тасвирлаган параллелепипед формаларының аерым очракларына нигезләнә.* Физика

**КРИСТАЛЛОГРА́ФИЯ** *и. фр.* Кристалларның барлыкка килүен, төзелешен өйрәнә торган фән. *Кристалларның төзелешен кристаллография фәне өйрәнә.* Физика

**КРИСТАЛЛЫ** *и.* Кристаллары булган; кристалл шәкелендәге. *Электронлы микроскопия юка кристаллы массаларны өйрәнү өчен кулланыла.* Төзү материаллары

**КРИСТАЛЛЫК** *и.* Кристалл булу. *Кристаллык торышы*

**КРИСТАЛЛЧЫК** *и.* Аерым бер тәртиптә урнашкан һәм үзара бик нык бәйләнгән кристалл кисәкчекләренең бер бөртеге. *Ул болытлар чыннан да боз кристаллчыкларыннан тора, шулай булгач, күктә бозлар агымы башланган, дию дә дөрес.* Ф.Ибраһимова

**КРИТЕ́РИЙ** *и. гр.* Нәрсәне дә булса объектив, төпле бәяләү өчен сайланган билге, сыйфат. *Тарихилык критерие кешенең эш кораллары ярдәмендә шул коралларны туктаусыз җитештерә килүенә нигезләнә.* Ә.Баян. *Ләкин дөньяда «өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше» дигән критерий да барлыгын онытмаска кирәк.* Р.Харис. *Нәтиҗәдә, базарда нәрсә тәкъдим ителсә, шуны күздән кичерәбез, карарны бердәнбер, шулай ук ялган критерийга – әйбернең бәясенә карап кабул итәбез.* Татарстан

**КРИ́ТИК** I *с.* 1) Кискен үзгәрешкә китерә торган. *Андый кисемдәге параметрларны критик параметр диләр.* Техника термодинамикасы. *Автокамилләшүгә сәләтле бүгенге роботлар, ниндидер бер критик чикне узып, кешегә якынлаша, адәмиләшә башламады микән хәзер?* А.Тимергалин

2) Авыр, катлаулы; куркыныч, кискен. *– Давай, чалбарыңны төшер, –* диде доктор, *явызрак күренергә тырышып. – Әдәбият ләчтитен кирәгеннән артык сатканга күрә, гемоглобинның критик ноктага җиткән инде.* М.Юныс. *--- сугыш чорында адәм баласы килеп эләккән критик, кискен ситуацияләрдә алар кешенең кем икәнен, нинди икәнен ныклап белергә ярдәм итә.* М.Вәли-Барҗылы. *Балалар үсешенең критик периодларында нерв, иммун һәм репродуктив системаларның зарарлы факторларны сизүчәнлеге тагын да югарырак.* Сәламәт яшәү нигезләре

**КРИ́ТИК** II *с.* **1.** Тәнкыйть күзлегеннән чыгып әйтелгән яки язылган; тәнкыйтьле. *Бу анализ әсәрдәге уңышлы һәм кимчелекле якларны ачып бирә, башлап язучылар биредә күп кенә нәрсәгә төшенә алалар: әсәрне критик күзлектән чыгып укырга өйрәнәләр һәм язачак әсәрләре өчен үзләренә сабак алалар.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Тәнкыйть күзлегеннән чыгып. *Алар шулай ук балаларны күзәтүчәнлеккә, игътибарлылыкка, критик уйлау һәм мөмкин булган реаль вакыйгаларны уйдырмалардан аера белергә өйрәтә.* Тәрбия теориясе һәм методикасы

**КРИ́ТИК** III *и. фр.* Тәнкыйтьче. *Ул критик, бичара, һичкемнең вә һичнәрсәнең яхшы тарафын күрә алмый.* Г.Камал

**КРИ́ТИК РЕАЛИЗМ** *и.* Әдәбиятта һәм сәнгатьтә тормышны тәнкыйть күзлегеннән чыгып дөрес чагылдыруны метод итеп алган алым. *Язучы үзе яшәгән җәмгыятьне я сюрреализм, я критик реализм, я романтизм --- методына таянып яктырткан. Ләкин метод булдымы, ул – ниндидер чик билгеләү.* Ф.Яруллин. *Мин үзем исә кайчандыр соцреализм, критик реализм, романтизм дигән нәрсәләрне әдәбият дәресләрендә укысам да, аларның ни икәнен аңламадым, бүген дә аңламыйм ---.* Т.Миңнуллин

**КРИ́ТИКА** *и. гр.* Тәнкыйть. *Минем чуттан аракы эчеп, миңа ук критика чәпәп торасың...* А.Яһудин. *Минем белән эшләгәндә, бик әтәчләнә идең бит. Каршыңа бастырып критика ясый идең.* Т.Миңнуллин

**КРОКЕТ** *и. фр.* Агач шарны агач чүкеч белән бәреп кечкенә капкага кертүдән гыйбарәт уен, шартаяк уены. *Крокетны тигез җирдәге мәйданда уйныйлар, мәйданның кәзе алынган булырга тиеш.* Файдалы киңәшләр. *Кымыз дачасында Фатих Сәйфи-Казанлы, мин, миңа кунакка килгән иптәш кызым Камәр ---, ял итүчеләрдән тагын бер-ике кеше мәйданчыкта крокет уйный идек.* Кызыл таң

**КРОКЕТЧЫ** *и.* Крокет уйнаучы

**КРОКИРО́ВКА** *и. рус* Крокет уенында үз шарың белән икенче – билгеләнгән шарны бәрү. *Төрле команда «юлбасарлары» бер-берсенә крокировка ясый алалар, һәм шуның өчен аларга ике тапкыр сугу хокукы бирелә.* Файдалы киңәшләр

**КРО́КУС** *и. лат. бот.* Сусынчалар семьялыгына караган күпьеллык үлән үсемлек, зәгъфран. *Крокус, роза, лилия, туй чәчәген (гладиолус) яратып үстерә ул [Резидә].* Заман сулышы

**КРОКОДИЛ** *и. гр.* Ян-яклардан кысылып килгән озын койрыклы, җәенке танаулы, гәүдәсе каты япма белән капланган сөйрәлүче ерткыч хайван; тимсах. *Җәннәт булгач, анда куе тропик урманнар, фил, крокодил һәм зур-зур еланнар яши торган джунгли да булырга тиештер.* Р.Мөхәммәдиев. *Сихри агачлар күләгәсендә, мәрмәр читле искит-*

*кеч буаларда зур-зур крокодиллар ята.* Кызыклар дөньясында. *Крокодилларда ул [йөрәк] дүрт камералы.* Биология

◊ **Крокодил күз яше** Риялы үкенү, ясалма кызгану; икейөзлелек (корбанын ашап бетергәннән соң, крокодилның күзләре, янәсе, яшь белән тула дип ышанудан). – *Хатын-кыз күз яше ул – крокодил күз яше инде. Чамала... – Канатланып һавада очып йөргән иде, хатын җылавы аны җиргә өстерәп төшерде.* Х.Камалов. *Алга таба табигатьне ярату, комбинат эшчеләренең армый-талмый хезмәт итүләре, кыскасы, крокодил күз яшьләре, төче сүзләр тезелеп киткән иде.* Р.Мирхәйдәров. *Ә китап укымыйлар дип крокодил күз яшьләре түгү исә, гомумән, тешкә тия.* Татарстан яшьләре

**КРО́ЛИК** *и. пол. зоол.* 1) Куяннар семьялыгыннан гадәти куяннарга караганда кечерәк колаклы, соры төстәге имезүче хайван. *Хәзерге вакытта Австралия материгында кеше алып килгән, кыргыйлашкан кроликлар очрый.* Биология. Хайваннар. *Шул ук механизмнан күп кенә хайваннар: кроликлар, вальдшнеплар, балыклар да файдаланалар ---.* Кызыклы физиология. *Ата Кролик, уңай вакыт табып, сүз башлады: – Син кем?* Р.Батулла

2) Шул хайванның ите. *Кролик пешеп җиткәч, кәстрүлдән алырга, өлешләп бүлеп тәлинкәләргә салырга һәм өстенә кролик пешкән шулпада әзерләнгән ак соус сибәргә кирәк.* Йорт эшләре

**КРОН** I *и. гр.* Хромлы сары минераль буяу. *Сары крон (хромлы минераль буяу) белән ультрамарин (ачык зәңгәр төстәге буяу) кушылмасы матур яшел төс бирә.* Яшь натуралистларга

**КРОН** II *и. гр. к.* **крона**. *Дәүләт аның фатир һәм коммуналь чыгымнарын тулысынча түли һәм шуның өстенә аена ким дигәндә өч мең швед кроны бирә.* В.Юныс

**КРО́НА** *и. гр.* Европаның кайбер илләрендә (Исландия, Дания, Чехия, Словакия, Эстония, Швеция, Норвегия һ.б.) төрле елларда кулланышта йөргән яки йөри торган төп акча берәмлеге (исеме тәңкә акчага төшерелгән таҗ сурәтенә бәйләп аңлатыла)

**КРОНГЛАС** *и. нем. тех.* Оптик приборлар өчен махсус пыяла

**КРОНШТЕЙН** *и. нем. тех.* Нәрсәне дә булса (балкон, шүрлек һ.б.ш.) диварга, баганага һ.б.ш. перпендикуляр рәвештә беркетү өчен эшләнгән һәм аскы ягында ныгыткан кыек таякчыгы булган җайланма. *Ул [бра] төрле якка әйләнә торган кронштейнга утыртылган булса, өстәл артында эшләп утыру уңайлы булачак.* Өегез ямьле булсын

**КРОСС** *и. ингл. спорт* Спорт йөгереше яки ярыш (чаңгыда, велосипедта, мотоциклда һ.б.ш. узышу). *Һәрбер ярыш – безнең мәктәп даны, Җиңүчеләр булыйк кросста.* Җ.Тәрҗеман

**КРОССВОРД** *и. ингл.* Шакмакларга бүленгән фигурага хәрефләр язып, горизонтальдә дә, вертикальдә дә аерым сүзләр китереп чыгарудан гыйбарәт булган табышмак-уен. *Берәүләр кофта бәйли, икенчеләр мода турында гәп сата, кроссворд һәм ребус чишүчеләр бар ---.* Ф.Баттал

**КРО́ССИНГ** *и. ингл. спорт* Ярыш вакытында уза торган автомашинаның тизлеген аның траекториясен кистереп тоткарлау белән характерлана торган узыш төре

**КРОССО́ВКА** *и. рус сөйл.* Йомшак табанлы спорт аяк киеме. *[Әтил] аягына оекбашларын һәм кроссовкаларын киде.* Ф.Бәйрәмова

**КРОХОБОР** *и. рус сөйл. кимс.* Җыен вак-төяк җыючы бик саран кеше. – *Бирмим! --- Үземә дә бер генә ыштук калды. – Төнге әңгәмәдәшнең штук дигән сүзе йөрәккә штык булып кадалды --- Крохобор! Тәмәке корты!* З.Мәхмүди. --- *Швейко, җәһәннәмгә бар дигәндәй, мыгырданып, тик утырды. – Мескен крохобор бит син, – дип куйды Каменский азактан.* С.Шәрипов

**КРУ́ЖКА** *и. рус* Стакан формасындагы тоткалы биек савыт (гадәттә 200 гр – 1 кг сыешлы була). *Мин ак калай кружкадан иреннәремне пешерәпешерә җиләкле кайнар чәй эчтем.* Ф.Яхин. *Һич кенә дә авыл тормышына охшамаган кырыс тәртибе ---, тимер кашык, кружкалары – һәммәсе аның өчен үзгә бер яшәеш иде.* Т.Галиуллин. *Компотны кружкаларга бүлеп куясы да, егетләр утыргач, ботка китерәсе генә калды.* М.Юныс

**КРУИЗ** *и. ингл.* Диңгез сәяхәте. *Хәзер Европа буенча круизга документлар тутырып йөри, ә анда, кордон артына, бик тә ышанычлыларны гына җибәрәләр.* Р.Мирхәйдәров

**КРУПЧА́ТКА** *и. рус* Иң югары сортлы ак он. *[Тегермән] --- олау-олау кереп торган гәрәбәдәй бодайны тартып чыгара... Тартканы да биткә кершән итеп сөртерлек ап-ак он – крупчатка!* Ә.Еники

**КРУПЬЕ** *и. фр.* Уен йортларында уен барышын күзәтеп торучы, ставкалар кабул итеп, уенчыларга отышларын бирүче кеше. *Крупьелар күренми. Килгән бөтен халык уен автоматлары артында.* Мәдәни җомга

**КРУ́ШНИК** *и. рус к.* **крючник**. *Анда Үткән чорда калган өйләрдә Күбрәге ватык кешеләр --- Тузган крушниклар, Ямщиклар яшиләр.* Х.Туфан. --- *Х. Туфан, исемсез һәм дәгъвасыз хәлдә, әдәбиятның иң авыр йөген «Туфанчалап» күтәрешергә – батрак крушнигы булырга әзер язмыш белән шигъриятебезгә килеп керә.* М.Гайнетдинов

**КРУ́ШНИКЛЫК** *и.* Крушник булу, крушник кәсебе

**КРЫЖО́ВНИК** *и. рус* 1) Крыжовникчалар семьялыгыннан ачкылтым татлы җимешле, чәнечкеләре булган куак үсемлек; актикән. *Крыжовник картайган, шулай да энәләрен тырпайткан, якын китерми, янәсе.* Ф.Тарханова. *Крыжовник бер утырткач егерме елга кадәр үсә.* Өегез ямьле булсын

2) Шул үсемлекнең җимеше. *Чыннан да, крыжовник йонлы карлыган булудан битәр бозау күзенә охшаган икән ләбаса.* Р.Батулла. *[Ленар:] Клара, кара, әй, синең бу крыжовник согың чын тел ачкычы булган бит. Әйбәт чыккан ул!* А.Хәсәнов. *Ягъни кешедән көнләшеп яшәүче кеше – бәхетсез. Бу кешеләр, мөгаен, үз гомерләрендә бер тапкыр да беренче кырау белән крыжовник вареньесына әйләнгән бәрәңге сабагы исен кояшлы иртәдә иснәмәгәннәр.* М.Мәһдиев

**КРЫЖО́ВНИКЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Крыжовник, карлыган кебек

икеөлешле үсемлекләрне берләштерә торган бер семьялык

**КРЮ́ЧНИК** *и. рус* Аркага асылган махсус җайланма белән пароход яки баржалардан йөк ташучы кеше. *Заманында, Мәкәрҗәдә крючник булып йөргән чакларда, Мәрфуга әбиеңне хәйран калдырырлык бүләкләр алып кайта идем.* С.Сабиров

**КРЮШОН** *и. фр.* 1) *иск.* Кечкенә күкшин, савыт. *--- кытай бәллүреннән ясалган кыйммәтле савыт-саба, табаклар, әллә нинди шейкерлар, крюшоннар, рюмкалар – берсенең дә бәяләмә хаклары куптарылмаган ---.* А.Хәлим

2) Исерткеч эчемлек: йөземнән җитештерелгән ак шәрабның ром, ликёр яки коньяк белән кушылмасы. *Крюшон – романтик кичәләр эчемлеге*

3) Татлы салкын куассыман эчемлек, җимеш суы

**КСЕНОН** *и. гр.* Химик элемент: электротехникада һәм медицинада кулланыла торган инерт газларның берсе. *Ксенон кушылмалары*

**КСЕНОНЛЫ** *с.* Ксеноны булган, ксенон белән эшләнгән. *Ксенонлы наркоз киләчәктә федераль программа буенча киң кулланылышка керeп китсә, бәясе дә бермә-бер арзанаюы ихтимал.* Ватаным Татарстан

**КСЕРОФОРМ** *и. гр.* Ярага яки пешкән урынга сибү өчен кулланыла торган, суда да, спиртта да эремәүчән сары висмут һәм бром кушылмасыннан гыйбарәт порошок

**КСЕНОФОБ** *и. гр.* Чит ил, чит милләт кешеләренә, чит ил әйберләренә дошманлык белән караучы кеше

**КСЕНОФО́БИЯ** *и. гр.* Чит ил, икенче раса, башка милләт кешеләрен күралмау белән характерлана торган психик авыру, нормадан тайпылыш. *Бу безнең ксенофобиягә каршы йөреш булды.* Безнең гәҗит

**КСЕ́РОКС** *и. ингл.* Күчермә алу аппараты. *Теләсә нинди почеркны, кулдан язылган төп нөхсәнең ксерокстан чыгарылган икенче-өченче копияләрен дә танырга өйрәтә ул редакция эше.* Мәгърифәт

**КСЕ́РОКСЛАУ** *ф.* Күчермә, копия алу

**Ксерокслап бетерү** Ксерокслауны тәмамлау

**Ксерокслый башлау** Ксерокслларга керешү

**КСЁНДЗ** *и. пол.* Полякларда һәм литвалыларда католик рухани башлыгы. *Байның аның миллионеры да, бояры да, ксёндзы да, шулар рәтеннән побы да бергә каералар.* А.Таһиров

**КСИЛИТ** *и. гр.* Шикәр чире белән авыручылар тарафыннан шикәр урынына кулланыла торган төссез кристаллар формасындагы баллы матдә

**КСИЛО-** *гр.* Агачка бәйлелекне, агачтан ясалганлыкны аңлата торган алкушымча

**КСИЛО́ГРАФ** *и. рус* Ксилография белгече; агачка чокып рәсем яисә сурәт төшерү остасы

**КСИЛОГРА́ФИК** *с.* 1) Ксилография юлы, шул ысул белән эшләнгән. *Кореяда ксилографик калыптан беренче текстлар басыла.* М.Вәлиев

2) Ксилографиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган

**КСИЛОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Агачка чокып рәсем төшерү сәнгате. *Фәнни басмалардагы гарәп текстлары ксилография ысулы белән эшләнгән.* Казан утлары

2) Агачка чокып ясалган рәсем яки хәрефләр төшермәсе

**КСИЛОЛ** *и. гр. хим.* Эреткеч, интермедиат, авиация ягулыгы. *Ксилол – химия сәнәгате продукты*

**КСИЛОЛИТ** *и. гр. хим.* Составына агач чүбе, асбест кергән ясалма төзелеш материалы. *Ксилолит идән тактасы, койма һ.б.ш. ясауда кулланыла*

**КСИЛОФОН** *и. гр. муз.* 3–4 рәттән торган, махсус сайланган агач пластинкаларга ике агач таякчык белән сугып уйнала торган музыка уен коралы. *[Айдаров] еш кына радиода һәм эстрадада, үзешчән сәнгать коллективларында солист-инструменталист буларак чыгыш ясый: ксилофонда уйный.* Казан

**КУ** I *с.* 1) Бик нык корыган, агарып кипкән (агач, үлән). *Кола-ала [байрак] торыр, Ку агачтан май тамар.* Х.Мәхмүтов

2) Эче буш, коры; шүре шикелле. *Бура торып калган бернәрсәсез: Нәкъ җилеген алган ку сөяк.* М.Гафури

**КУ** II *и.* Черек каен төпләрендә үсә торган каты гөмбәнең киптерелгәне, кипкән мәшкә, кау (чакма белән ут кабызу өчен кулланыла). *Чакмадан атылып чыккан очкыннардан әлеге ку пыскып яна башлады.* М.Госманов. *[Келәмче кыз] Курҗыныннан – күн янчыгыннан – чакма таш алды, чакма чагып, оста-җитез генә куга ут төшерде.* Р.Батулла

◊ **Ку баш** *хупл.* Баласыз, баласы булмаган (күпчелек очракта, ир-атларга карата әйтелә)

**КУА** *с. к.* **коба**. – *Ә! – дип, һаман бирешмәскә тырышты ул. – Безнең куа сыер ике бозау китерде. Икене, икене!* А.Гыйләҗев. *«Минем кызым кияү күргән нәрсәме» дигәндәй, кунакларны ятсынмасмы инде бу чорсыз... – диди, куа сыерын ишегалдына чыгарды.* Г.Бәширов

**КУАК** *и.* 1) Агачларның, үсемлекләрнең төптән үк диярлек ботакларга тармакланган тәбәнәгрәк төрләре. *Шунда ук агачлар төбеннән гөлҗимеш куаклары сузылып китә.* Д.Галимов. *Кура җиләге куакларында яңа үргеннәр күренә башлагач, аларның иң көчлеләрен сайлап алалар.* Өегез ямьле булсын

2) Гомумән, чагыштырмача зур булмаган, тәбәнәк агачлар төркеме. *Холодильник янындагы тәрәзне аяк белән бәреп төшердем дә андагы затлы ризыкларны үләннәр, куаклар арасына ыргыта башладым.* Т.Галиуллин. *Парк, сквер, аллеялардагы элек ямьяшел булып утырган агачлар, декоратив куаклар... корып төшкән, кибеп беткән.* Ә.Сәлах. *Җил шыр ялангач кыр буенча чаба, юлында очраган шәрә куаклар арасында сызгыра, корыган үләннәрне һавага күтәрә.* Г.Әпсәләмов

**КУА́ККИСКЕЧ** *и.* Куакларны тигезләү, матурлау өчен махсус корал; *русчасы:* **кусторез**. *Куаккискеч машина*

**КУАКЛАНУ** *ф.* Куак рәвешенә кереп үсү; ботак яки тармак җибәрү, тармаклану. *[Карт] --- куакланып өлгергән һәм, инде менә мең тапкырлар әйтелгәнчә, яшел дәрья булып шаулый башлаган иген басуы буйлата атлап китте.* Ә.Баян. *Иртә чәчелгән арпалар үсешләренең куаклану фазасын кичерә-*

*ләр, бодай чәчкәндә куелык та, тирәнлек тә сакланган.* Авыл утлары

**Куаклана бару** Акрынлап куаклану, тагын да куаклана төшү

**Куаклана башлау** Куаклану процессы башлану

**Куакланып бетү** Бик нык куаклану; тәмам куакка әйләнү

**Куакланып калу** Нинди дә булса агачның гадәти үсү процессы тукталып, куак формасына керүе, шул формада үсүе тукталу. *Яшь чагында ук очы сынган шомырт агачы төрле якка ботаклар чыгарып, зур булып үсә алмыйча куакланып калды*

**Куакланып килү** Куак формасына керә бару. *Яңа утырткан карлыган инде бик матур булып куакланып килә*

**КУАКЛЫ** *с.* Куак, вак агачлары булган, куаклардан торган. *– Закир абый, бу мин, – ди Ваня, чаңны селкетмәскә тырышып. – Карагыз әле, сезгә күренәме: куаклы юлдан бер төркем атлылар килеп чыкты.* Д.Галимов. *--- Наил мәктәп юлыннан куаклы сукмакка борылды.* К.Кәримов. *Тиздән бодай басуы да бетеп, вак куаклы, үләнле тау итәге башланды.* Х.Сарьян

**КУАКЛЫК** *и.* Куаклардан торган, куаклар үсә торган урын, әрәмә. *Вак куаклыклар, тигәнәк, чытырман баскан ямь-яшел утрау.* Р.Фәизов. *Юл буенда тал агачлары, сирәк-мирәк тәбәнәк каеннар, куаклыклар күзгә чалына, өзлексез кошлар сайрый.* Р.Кәрами

**КУАКЧЫК** *и.* Кечкенә куак. *Малай юл кырыенда үскән куакчыкны, куакчыктагы нәни чүлмәкчекләрне күреп туктап калды.* Р.Батулла

**КУАЛ** *и. диал.* Үсеп утырган җирендә (аумыйча) кипкән, корыган агач, урман

**КУАЛА́У** *ф.* 1) Куып алып бару, билгеле бер юнәлештә барырга мәҗбүр итү. *Астан күтәрелгән су ике елганың да бозларын туктаусыз алга куалый.* К.Йосыпов

2) Кызурак, җитезрәк атларга мәҗбүр итү (җигелгән яки атланган атны һ.б.ш.). *Бер-ике көннән, пар алашаларын куалап, тегеләр дә килеп җитте.* Әкият. *Атны куалыйсы, тизрәк авылга кайтып җитәсе килде малайның.* Г.Исхакова. *Шуңа да ул [абзый] арык аткаен-малкаен куалый. Чөнки алда – Ушили таулары.* К.Йосыпов

3) Көчләп кая да булса барырга мәҗбүр итү, кая да булса җибәрү. *[Патша хөкүмәте халыкны талады,] Суярга алып барган куйлар кебек, Көтү-көтү сугышка --- куалады.* Ш.Мөхәммәдев

4) Куу, куып җибәрү, үз яныңнан китәргә мәҗбүр итү. *Бер урман буена барып җиткәч, аю белән бүреләрне дә җибәрде, пәрине дә яныннан куалады, бер башы гына калды.* Әкият. *Шулай да байлык артмады. Әти барыбер үземне бер казыксыз куалап чыгарды ---.* Г.Толымбай. *Алар килеп җиткәнче, бәхетле Габделхәй ат янына якынлашты, --- тәнендәге кигәвеннәрне куалады.* Н.Фәттах

5) Кемне, нәрсәне дә булса тоту максаты белән артыннан чабу, йөгерү. *Җан-фәрман йөгерә бер мамонт, Аккара күрмичә йөгерә бер тынга!.. Әйтерсең ниндидер күренмәс явыз көч Куалый мамонтның артыннан.* Л.Лерон. *Аяз Актүш белән куе печән арасында аунаклашып уйнады, күбәләк куалады, кигәвен тотты.* Д.Каюмова

**Куалап җитү** Куалап башкалар белән тигезләшү (ярышта һ.б.ш.). *Галиәкбәр абзый үзе дә, хатыны да бик еш хәлемне белә башладылар. Артта калган дәресләрдән куалап җитү өчен, үземә ярдәмгә иң яхшы студентларны беркеттеләр.* Г.Кутуй

**Куалап йөрү** Куалау хәлендә булу. *Шигърият артыннан куалап йөрмиләр, ул үзе килә.* Г.Тарханова

**Куалап тору** Гел, туктаусыз куалау яисә әледән-әле, ара-тирә куалау. *Сакчы солдатның әледән-әле куалап торуына карамастан, алар, ярсулы бер үҗәтлек белән, һаман капкага якынрак килергә тырышалар.* М.Галәү. *Тирләрен җиңнәре белән генә сөртеп алалар да ут өертүләрен дәвам итәләр. Берберсен ашыктыралар, куалап торалар, җитмәсә.* Ф.Баттал. *--- кешеләрне гел йортларга гына куалап торган бураннар да шәһәр урамнарына ниндидер шомлы тынлык, алдагыч иминлек тойгысы иңдерде.* В.Имамов

**Куалый башлау** Куаларга тотыну. *--- Илһам хан атын тагы да куалый башлады.* М.Хәбибуллин. *Рифның сабыр йөрәге, кинәт тибешен кызулатып, бөтен кан әйләнешен бил тирәсенә куалый башлады ---.* К.Кәримов

**Куалый төшү** Тагын да куалау. *--- ирекне алтын бәһасенә сатып алды дияргә була, – диде әмир Хаҗи, атын куалый төшеп.* М.Хәбибуллин

**КУАЛАУЧЫ** *и.* Көтү, мал-туар һ.б.ш. куучы. *Атларны куалаучы карт мыекларын сыпырып куйды.* Р.Гаязетдин

**КУАН** *с. диал.* Эссе һәм җилле (көн тур.)

**КУАНДЫРГЫЧ** *с.* Куану хисе бирә торган, сөенечле, шатлыклы. *Ә тегеләр, аның куандыргыч җавабын сабырсызлык белән көтеп, күзенә карап торалар.* Г.Минский. *Аның шушы сүзләре кинәт хушланган аш әһеленә иң төпле һәм куандыргыч дәлилләр дип табылдылар.* Ф.Яхин

**КУАНДЫРУ** *ф.* Куаныч, канәгатьлек, шатлык хисе тудыру; шатландыру. *Алар барысы да мактау сүзләре, тынычландыру, куандыру сүзләре генә әйтергә тырыштылар.* Н.Фәттах

**Куандыра бару** Акрынлап тагын да, берникадәр күләмдә куандыру

**Куандыра төшү** Берникадәр куандыру

**Куандырып тору** Әле куандыру; даими рәвештә яки әледән-әле куандыру. *--- якты кояш, меңәрләгән чакрым арадан үзенең җылы энергиясен җибәреп, яктысы белән Рәйханны куандырып тора.* Д.Каюмова

**Куандырып җибәрү** Кинәт куандыру, көтмәгәндә куандыру

**Куандырып яту** Куандыру хәлендә булу

**КУАНУ** I *ф.* ) Шатлану, сөенү, шатлык, канәгатьлек хисләре тою. *Нәфисә бу сорауга куанып, зәңгәрсу кыска бишмәтенең эчке кесәсеннән коңгырт тышлы кечерәк кенә куен дәфтәрен чыгарды.* Г.Бәширов. *– Чын могҗиза бит бу, дусларым! – дип сөйләнде ул, куануыннан нишләргә дә белмичә.* Р.Фәизов. *Әгәр бер тычкан тотса, аны олы бәхет вә дәүләт саный иде. Һәм ничә көн куанып, аны теш даруыдай*

*газиз тотып, аз-аз гына ашый иде.* Татар халык иҗаты

2) Дәртләнү (казларның аталану чорында була торган хәле). *Ашамаган каз куанмый.* Мәкаль

**Куанып алу** Берникадәр вакыт куану. *Айсылу, колхоз идарәсенә таба барган карт-карчыклар төркемен күреп, тагын бер куанып алды.* Г.Бәширов

**Куанып бетү** Бик нык куану. *Хәйдәр исә балаларның ачык йөзендә тирән ышаныч һәм якты өмет балкуын күреп куанып бетә алмый иде.* Г.Бәширов

**Куанып йөрү** Куану халәтендә булу. *Ул-бу юкмы икән дисең, төштә яхшырак күрсәң дә, көне буе куанып йөрисең.* Г.Бәширов. *Яки кәефе күтәренке булганда, үзалдына нидер көйләп, куанып йөри.* Әдәбият

**Куанып китү** Берәр сәбәп чыгып кинәт кенә куану. *Килде заман, инде шатлан, курай, Ямьле тавышың илгә яңрасын. Куанып китсен урман, сайра, тугай, Бүз тургайлар кушып сайрасын!* Ш.Бабич

**Куанып кую** Азга гына куану. *Әмма сержантның тавышы калтыравыннан, --- артисткаларның һәм сугышчының маңгаеннан үбеп, кулын каты итеп кысуыннан аларның иске танышлар икәнен төшенде һәм, Газинурны күптән белгәнлектән, аның бәхетенә куанып куйды.* Г.Әпсәләмов

**Куанып тору** Даими яисә әледәнәле куану

**Куанып җибәрү** Кисәк куану

**Куанып утыру** Куану хәлендә булу. *Габдулланың бүгенге күтәренке күңелен алар икесе дә үзләренчә аңлап, баланы юаттык, дип уйладылар һәм куанып утырдылар.* Ә.Фәйзи

**КУАНУ** II *и.* Куаныч, шатлык. *Куанудан шунда еладым, Шомырт ботакларын кочаклап.* Ф.Кәрим

**КУАНЫЧ** *и.* Шатлык, сөенеч. *«Кызыллар!» – Куанычымнан агачта булуымны онытканмын, чак кына мәтәлеп төшмәдем.* Д.Галимов. *Йөзү эшендә... саф һава, дөнья күрү куанычы, экзотика, романтика, кешенең дәрәҗәсен күтәрә торган авыр, җаваплы эш.* М.Юныс

**КУАНЫЧЛЫ** *с.* 1) Шатлыклы, сөенечле. *Бу еллар Казан ханлыгының иң куанычлы еллары булып, ул урыс боендырыгыннан котылган, тынычлаган иде.* Һ.Атласи. *Бу куанычлы хәлнең каян туганын ачыклау өчен, билгеле, фәнни тикшерү уздырырга кирәк булыр иде.* М.Юныс

2) Шатланган, куанган. *Чәй катында елмая куанычлы әткәсе.* Г.Тукай

**КУАНЫЧЛЫК** *и. ялг.* куаныч. *Аталы-аналы ике карчыга бер тау башында урын тота иделәр. Вә дәрәҗәләренә карап лаек кәсеп итеп, куанычлыкта гомер итә иделәр.* Татар халык иҗаты. *Февраль инкыйлабын Русиядә изелгән бөтен халыклар бик шатлык, куанычлык белән каршы алган ---.* Гасырлар авазы

**КУАНЫЧЛЫЛЫК** *и. к.* **куаныч**

**КУАНЫЧСЫЗ** *с.* **1.** Шатлыксыз, бернинди шатлыгы, сөенече булмаган. *Куанычсыз саннар һәм Зәңгәр төндә, йомшак карга басып, Сары Хисмәт кайта эшеннән.* Ш.Маннур

**2.** *рәв. мәгъ.* Шатлыгы, сөенече, куанычы булмыйча. *Әһә, хәзер башлана: кеше балалары балага охшаганнар, әллә кайчан өйләнгәннәр, оныклар тудырганнар һәм башка охшаш сүзләр дип, Шайбаков куанычсыз гына уйлап алды ---.* В.Исламетдин

**КУАНЫЧСЫЗЛЫК** *и.* Сөенече, шатлыгы, куанычы булмау

**КУАНЫШУ** *ф. урт. юн.* 1) Бергәләшеп куану, шатлану, шатланышу. *Шәһадәтнамәне ана кеше дә, Шакирҗан да, Габделхәким дә кат-кат тотып, әйләндереп карый-карый куаныштылар.* С.Поварисов. *Тавыклар да: «Шулай!» – дигән булып, Куанышып җырлап җибәрде.* Ш.Маннур

2) Дәртләнү, дәртләнешү (казларның аталану чорындагы хәле). *Ишегалдында казлар куаныша*

**КУАРУ** *ф. диал.* 1) Аксыллану, бераз агару, аксыл соры төскә керү

2) Агару (чәч һ.б.ш. тур.)

**КУАС** *и. рус к.* **квас**. *Мулла-мөәззин белән катышкач, куас, сыра пешерү затсызлык була инде.* Г.Исхакый

**КУӘ** *и. гар. иск. юг.* 1) Эшне эшли белү, башкара алу сәләте; талант. *Бик күп нәрсәләргә көче җитсә дә, кызны малайга әверелдерү куәсеннән мәхрүм иде Заһит Рәхмәтуллович.* Ф.Садриев. *Эштә иҗади куәсегезне тормышка ашыру кирәк – сезне һичшиксез бәяләрләр.* Мәдәни җомга

2) Көч, куәт. *Тәннәренә җылылык иңеп, аракы куәсе миләргә менеп җиткәч, дөнья, район, авыл хәлләре турында гәп корып җибәрәләр.* Т.Галиуллин

**КУӘТ** *и. гар. кит.* 1) Физик эшхәрәкәт ясау сәләте, эш башкара алу мөмкинлеге; гайрәт, көч. *Төрки-татар дөньясында Тәңре кылычы атадан балага, баладан оныкка тапшырылып, көч, куәт, батырлык, гадел хакимият символына әверелә.* Ф.Урманче. *Менә бит, адәм баласының таланты, кодрәте нинди зур, куәте ничек көчле, диләр алар.* М.Маликова. *Әнә Илфат нинди нык үсмер булып бара, куәт дисәң куәте бар, буйга-сынга да күз тимәсен диярлек ---.* Б.Камалов

2) Иҗтимагый күренешнең, илнең, җәмгыятьнең көче, дәрәҗәсе. *Сәбәбен дә аңлаган бу ил куәтенең, һәр болгарның (татарның) хан белән тигез дәрәҗәдә ил иминлеге өчен җаваплылык хисе тоюын да абайлаган [Чыңгыз хан].* Ф.Баттал. *Лас-Вегас куәтләре бу чыгымны гына рәхәтләнеп күтәрә ала.* М.Юныс. *Идел бассейны үзе үк Казан ягында икътисади куәтне арттыруга ярдәм итүче, өстенлекле көндәшлек алып баручы мөһим фактор булып тора.* Татарстан

3) Кораллы көчләр. *Ил сагына баскан «куәт»ләрне Кулланмаска – тантаналы вәгъдә!* Р.Низамиев. *Монда бүген ике гадел, тугры куәт, Хыянәтсез ике сакчы тора.* Ш.Мөдәррис. *Аурупада Америкаyның ПРО системасын җәелдерүенә бәйле рәвештә дәүләтнең оборона куәтен --- ныгыту буенча чаралар системасы билгеләнде.* Мәдәни җомга

4) Җитештерү объектлары (заводлар, машиналар, техник корылмалар тур.). *Бу тиклем техник куәтләр Җир-анабызга, аның табигатенә зур зыяннар салу, табигатьтә сакланырга тиешле тигезлекләрне даими бозу бәрабәренә яулана.* Р.Фәизов. *Татарстан хөкүмәте, Мәскәүдән капиталь ремонт өчен бүленә торган акчаны ике тапкыр күбрәк алып, төзелеш куәтлә-*

*рен һәм белгечләрен саклап калмакчы.* Ватаным Татарстан

5) Эш-хәрәкәтнең, күренешнең көче. *Баярак аз гына да кымшанмый утырган агачлар үзләренә искиткеч куәт белән ябырылган җилгә каршы торырга азапланалар ---.* Г.Кашапов. *Бу яшеннәрнең куәтен, күк күкрәүләр дөбердәгәнен адәм баласы акылы белән колачлый да алмый.* Кызыклар дөньясында. *Бу хәл Кура-Сиво җылы агымының куәте кимү белән аңлатыла.* Кызыклы ихтиология

6) Берәр күренешнең йогынты ясау көче, тәэссораты. *«Тимер маршы» исә үзенең куәте, көче берлә Тимергалинең астын-өскә китерә.* Г.Исхакый // *сөйл.* Тәэсир итү көче, катылыгы. *[Кымызның] Әчкелтемрәк куәте борынны да ярып чыкты, ә каймагы тамак төбенә дә ягылып калды.* Ә.Еники

7) Егәрлек. *Андый батареяның куәте өч Днепрогэстан артып китә!* Кызыклар дөньясында

8) Эшләп чыгару, җитештерә алу сәләте. – *Күренеп торган шушы факелларда янган газның куәте генә дә бәләкәйрәк бер шәһәрне җылытып гөл итәрлек,* – дип ачыклап бирде. А.Гыйләҗев. *Балык терминалларының куәте үзебезнең территориаль суларда тотылган балыкны да тулысынча кертеп бетерергә мөмкинлек бирми.* Мәдәни җомга // Эшләү сәләте, булдыклылык, белем дәрәҗәсе. *Үзем теләгән нәрсәләрне тәрҗемәгә куәтем җитсә дә, ни бирсәләр аны тәрҗемә итәргә үземдә икътидар хис итми идем.* Г.Тукай

9) Үсеш, алгарыш. *Аның шигырьләре һәм поэмалары, соңгы елларда аеруча зур куәт алган прозасы тормыштагы урының, кыйблаң турында уйландыра.* М.Вәлиев

10) *күч.* Рухи сәләт, рухи көч. *Өзеп кенә бер якка хәл итәрлек тә куәте юк иде [Мортазинның].* В.Имамов. *Гаеп, үпкә белдерү түгел, каршы әйтерлек куәте дә юк.* В.Имамов

11) *күч.* Дәрт

◊ **Куәт бирү** 1) *к.* **куәт кертү**. *Алла куәт бирсен!* 2) Дәрт бирү, җилкендерү. *Тәкетдин карт, бәйләүчеләргә куәт биреп, туктаусыз тәкелдәде.* А.Хәлим. *Өйдән чыккан кунакларның бер ише биюгә кушыла, кайсылары биючеләргә куәт биреп кул чабып тора.* Т.Миңнуллин. **Куәт кертү** Көч бирү

**КУӘТ-КОДРӘТ** *и. гар.* Көч, хәлдән килү. *Каганның Болгарга күзе кызган. Куәте-кодрәте җитсә, бер кабуда йотар иде.* М.Хәбибуллин

**КУӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Көч бирү, куәт кертү. *Саф, ачык һавада хәрәкәт итү аның [баланың] эчендәге ашларны үзгәртеп, бәдәнен куәтләндерер.* Х.Сарьян

2) *күч. сөйл.* Үстерү, көчәйтү; арттыру. *Аннан [төрмәдән] исән-сау чыкканнан соң, ул көрәшен тагын да куәтләндерә.* Р.Батулла

**Куәтләндерә бару** Торган саен ныграк куәтләндерү. *[Сөйләм] Ритмы һәм тизлеген, көчен куәтләндерә барып, соңыннан акрынлап киметәбез.* Г.Нуриев

**Куәтләндерә башлау** Куәтләндерергә керешү

**Куәтләндерә бирү** Бернәрсәне игътибарга алмыйча куәтләндерүен дәвам итү

**Куәтләндерә төшү** Тагын да куәтләндерү. *Ә соңгы елларда тормышыбызда башланып киткән яңарыш хәрәкәте исә Әмирхан Еники исеме һәм әдип иҗаты кузгаткан андый уйфикерләр агымын тагын да көчәйтә, куәтләндерә төшә.* М.Вәли-Барҗылы

**Куәтләндереп алу** Бераз, кыска вакытка куәтләндерү

**Куәтләндереп җибәрү** Куәтләнүгә этәргеч бирү; бераз куәтләндерү. *Шул рәвешле, әйтемнәрнең иҗтимагый-эстетик функциясе турында, ул – нигездә, тел бизәге, берәүнең сүзен, фикерен көчәйтеп, куәтләндереп җибәрү өчен кулланыла, дип әйтергә мөмкин.* Ф.Урманче

**Куәтләндереп тору** Даими куәтләндерү

**КУӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) Физик яктан көчәю, ныгу. *Күрешкәч, Рәсим Хәбирнең кулы шактый ныгыган, куәтләнгән булуын сизде ---.* Ф.Шәфигуллин

2) Тагын да көчәю, зуррак көчкә ия булу, интенсивлашу (эш, хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Агым каршылык очраганда аеруча куәтләнә бит ул.* К.Тимбикова

**Куәтләнә бару** Торган саен куәтләнү, куәте акрынлап арту. *Искеләр [кадимчеләр] арасында көннән-көн яшьләргә карата реакция куәтләнә бара.* Ф.Әмирхан. *Буран һаман куәтләнгәннән-куәтләнә бара.* С.Җәләл. *Революция дулкыннары аның саен куәтләнә бара.* И.Нуруллин

**Куәтләнә башлау** Куәтләнүе сизелү, күренү, куәтләнергә тотыну. *Моның шулай булуына Сүзге сөенде генә, чөнки Себер иле күзгә күренеп ныгый, куәтләнә башлаган, элеккеге таркаулыкның, мескенлекнең инде эзе дә калмаган иде.* Ф.Бәйрәмова

**Куәтләнә төшү** Тагын да куәтләнү. *Сәгадәтнең вөҗдан газабы, казармага «үз ишләре» янына кайтып кергәч, тагын да куәтләнә төшә.* Ф.Габидуллина

**Куәтләнеп алу** Бераз, кыска вакытка куәтләнү

**Куәтләнеп калу** Нинди дә булса сәбәптән, вакыттан соң куәтләнү. *Иван III вакытында рус дәүләте шактый ныгып, киңәеп, куәтләнеп калды.* М.Әмирханов

**Куәтләнеп килү** Акрынлап куәт җыю. *Җәмгыятебезнең ыгы-зыгылы, демократиянең куәтләнеп килгән еллары.* Р.Вәлиев

**Куәтләнеп китү** Көтмәгәндә, кинәт куәтләнү. *Бу минутта тагын да көчәеп, куәтләнеп киткән хакыйкать Галиянең күзләрен томалады ---.* Р.Низамиев. *Мондый хәлләр соңрак, 28–29 нчы еллардан башлап, кинәт куәтләнеп китте.* Ә.Еники

**КУӘТЛӘТҮ** *ф. сөйл. к.* **куәтләндерү**

**Куәтләтеп алу** Бераз куәтләтү

**Куәтләтеп кую** Алдан ук куәтләтү

**Куәтләтеп тору** Әледән-әле яисә даими куәтләтү

**КУӘТЛӘҮ** *ф.* 1) Теге яки бу фикерне, сүзне, тәкъдимне һ.б.ны яклау; хуплау. *Аны хатыны куәтләде.* Х.Сарьян. *Бүлек начальнигы, аның фикерен куәтләп, үзалдына гына әйтеп куйды.* Р.Ишморатова. *Кайсыгыз ячейка оештыруны куәтли?* Корыч ничек чыныкты

2) Нигезләү, дөреслеген күрсәтү, дөреслегенә ышандыру, дәлилләү. *--- авылның искелеген шәҗәрә ярдәме белән дә куәтли.* С.Алишев. *--- татар*

*эстрадасына хезмәт итүчеләр арасында махсус белем алмаган җырчыларның саны арта бару әлеге карашның дөреслеген күпмедер күләмдә куәтли кебек.* К.Миңнуллин

3) Нинди дә булса бер эш-хәрәкәтне башкаруда ярдәм итеп хуплау; җилкендерү, куәт бирү. *Малай, тегесенең җырын куәтләп: ох! ох! ох! дип ухылдап утыра иде.* Г.Бәширов

4) Үстерү, арттыру. *Хис сюжетын куәтләп, автор вакыйга сюжетын да матур итеп чикләп куя.* А.Яхин

5) *сөйл.* Көчәйтү. *Күңелдә туган йорт белән очрашу кирәклеген куәтләгән саен, ыгы-зыгылы шәһәр тормышы томан артына яшеренә, югала барды.* Казан утлары

**Куәтләп алу** Барысы бердәм куәтләү, дәррәү хуплау

**Куәтләп җибәрү** 1) Кәтмәгәндә куәтләү, хуплавын белдерү. – *Чынлап та! Бөтен кан тамырларына йөгерде!.. – дип, минем сүзне абый да куәтләп җибәрде.* Х.Сарьян. *Галимҗан да аның сүзләрен куәтләп җибәрде.* З.Бәшири

2) Куәтләнүгә этәргеч бирү. – *Әйе! – җырга Булат кушылып, куәтләп җибәрде.* Т.Таһиров

**Куәтләп китү** Сүз арасында куәтләү

**Куәтләп кую** Куәтләүне белдерү. – *Иманнардәй озын гомерле булырга язсын безгә! – дип, Басыйр Бариевич аны куәтләп куя.* А.Гыйләҗев

**Куәтләп тору** Әледән-әле, даими куәтләү. *Дәүләт үзе [өй салуны] куәтләп тора, акчасын бирә, материалын бирә.* Ә.Еники. *Патшага бу ошый, җансакчысын хәтта куәтләп тора.* М.Хәбибуллин. *Әмма рәссамнарны, һәрдаим экспозицияләр оештырып, һаман куәтләп тору мәслихәт ---.* Мәдәни җомга

**Куәтли бару** Һәрберсен, булган берсен куәтләү. *--- мин аның фикерләрен куәтли бардым.* М.Әмир

**Куәтли бирү** Куәтләвен дәвам итү. *Саҗидә сүзен куәтли бирде: – Гомергә баласыз каласың килмәсә, өйләнергә кирәк...* М.Галәү

**Куәтли башлау** Куәтләргә тотыну. *Аның фикере белән килешмичә, берәр сорау бирсәң: «Тукта!» – дип, үз сүзен куәтли башлый.* Татарстан яшьләре

**Куәтли төшү** Бераз куәт бирү; тагын да куәтләү. *Зыяның соңгы еллардагы эшләре аның бу өметен куәтли төшеп, тик Собраниедән имтихан кылынып чыгуы гына аның җанын бик дулкынландырды.* Г.Ибраһимов

**КУӘТЛЕ** *с.* 1) Зур физик көчкә ия булган, көчле. *Менә ялантән Гыйззәт, куәтле беләкләрен күпертеп, теге япьлекә белән үгез каршына килде ---.* М.Мәһдиев. *Синнән рөхсәт сорап килмәгән, синнән рөхсәт сорап китмәгән хис, әлбәттә, ризалыгыңны көтеп маташмас: буаны ерган куәтле ташкын сыман җаныңа ургылыр.* Н.Гыйматдинова

2) Иҗтимагый яки икътисади куәте, көче зур булган. *Олы Россия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары да илнең караңгы почмакларында яшәгән халыкларның кайбер караңгы катлауларына баштарак менә шулай булып тоелды.* Г.Ибраһимов. *Нинди бай як бу Себер дигәнең, нинди куәтле як.* Казан утлары

3) Зур егәрлекле. *ТЭЦыбыз бертөрле гидростанцияләрдән дә куәтлерәк безнең.* М.Зарипов. *Синең кулда – кешеләр, куәтле техника.* М.Мәһдиев. *Әлеге куәтле комбайнда агалы-энеле Мансуровлар эшлисе!* Б.Камалов. *Куәтле электр бушануы белән сине һуштан яздырып, хуҗаларны ярдәмгә чакырган.* А.Тимергалин

4) Җитештерүчәнлеге зур булган. *Проект буенча тугызар катлы йорт торгызып куйган кешенең әлегә кадәр шундый куәтле комбинатны җитәкләве гаҗәпләндерә...* Г.Кашапов. *КамАЗның тимерчелек заводы кебек куәтле предприятие бу тармакта юк иде әле ---.* Казан утлары

5) Интенсив; гайрәтле, көчле. *Еллар үтү белән акыл утырып зиһен арткач, Тукай таланты бөтенләй яңа яклары белән ачылды, куәтле дулкыннары хисләрне генә түгел, акылны да әллә кая алып киткән зур диңгезгә әверелде.* Х.Сарьян. *Япония галимнәре, әле тегеләр кире кайтып киткәнче үк, бу көзгегә куәтле лазер нуры җибәрәләр.* Кызыклар дөньясында. *Табигать көчләренең энергетикасы гаять куәтле булганлыктан, аны озакка сузылачак мөһим эшләргә сарыф итү сорала.* Мәдәни җомга // Куркыныч. *Мин үземне куәтле ташкынга эләккән бер бөҗәк хәлендә хис иттем.* А.Тимергалин

6) Сизү органнарына тәэсир итә торган, нык сизелә, күренә торган; көчле. *[Габдулланың] Көйнең борылышларына, түбәнлегенә яки югарылыгына, тавышның куәтле яки зәгыйфь булуына ишарәләп дирижёрлык итүе дә табигый килеп чыкты ---.* И.Нуруллин. *Кояш баеды, ләкин куәтле ал төс җир астыннан балкыган кебек ---.* М.Вәлиев // *сөйл.* Көчле тәэсир итә торган; зәһәр, каты. *АКШта яшәүчеләрнең 10 проценты гына куәтле исерткеч эчемлекләр куллана.* Мәдәни җомга

7) Зур, көчле. *Көлтаяк инде инеш буена төшеп, куәтле маңгаен инеш ярына терәгән иде.* М.Мәһдиев

8) Авыр, зур физик көч сорый торган. *Куәтле эштән, кушаяк тибеп йөзүдән тән бераз гына рәхәтлек кичереп алҗыган, ял сорый, ашказаны ризык сорый иде.* М.Мәһдиев

9) Көчле, сизелеп торган (хис-кичереш тур.). *Хәятта хатын-кызның бер бүлегендә бик куәтле була торган көнләшү тойгысы аз иде.* Ф.Әмирхан

**КУӘТЛЕЛЕК** *и.* Куәтле булу; көчлелек, гайрәтлелек. *Ике сүз берраттән, бер сүз кебек тоташ итеп әйтелсә, боларның берсендә булган басым икенчесенә шактый тәэсир итә, ягъни берсенең басымында булган куәтлелек икенчесенең басымын зәгыйфьләндерә.* Җ.Вәлиди

**КУӘТСЕЗ** *с.* 1) Физик яктан көчсез, көче аз булган. *Бу тавышлар диңгез буена җәелеп, карт дулкыннарны яшь итте, куәтсезгә көч бирде, куркакларга гайрәт бирде.* Г.Коләхмәтов

2) Тәэсир итү көче аз булган, айныган, көче кимегән; көчсез; гайрәтсез. *Сәмәрия хихылдап: – Агуың куәтсез икән, менәтерәк мин исән, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Куәтсез керән. Куәтсез серкә*

3) *сөйл.* Ышандырмый торган, ышандыру көче булмаган, нигезсез. *Куәтсез дәлилләр*

**КУӘТСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Физик яктан көчсезләнү, куәт бетү; хәл китү

2) Көче, куәте кимү, бетү (табигый күренешләр тур.). *Давыл куәтсезләнү*

3) Организмга тәэсир итү көче бетү, айну. *Керән куәтсезләнү*

**Куәтсезләнә бару** Торган саен куәте кимү. *[Кояш] Шулай үткән бер минутта түбәнәя, куәтсезләнә барып, ниһаять, бөтенләй югала: ак була, бетә.* Г. Ибраһимов

**Куәтсезләнә төшү** Бераз куәтсезләнү

**Куәтсезләнеп калу** Билгеле бер моменттан, сәбәптән соң куәтен югалту

**Куәтсезләнеп китү** Искәрмәстән, көтмәгәндә кинәт куәтсезләнү

**КУӘТСЕЗЛЕК** *и.* 1) Физик көчсезлек, көче аз булу. *[Җәгъфәр] --- үзенең ялгызлыгын, куәтсезлеген хис итеп елый иде.* Ф.Әмирхан. *Мускулларның куәтсезлеге*

2) Көчсезлек, тәэсир көче булмау

**КУБ** *и. гр.* 1) *мат.* Геометрик җисем – һәр ягы квадрат булган төзек алтыпочмак. *Кристаллның структурасы – кырые үзәкләштерелгән куб.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

2) Күләм үлчәү берәмлеге: **кубсантиметр** – иңе, буе һәм биеклеге 1 см; **кубметр** – иңе, буе һәм биеклеге 1 метр һ.б.ш.

3) *сөйл.* Иңе, буе һәм биеклеге бер метр булган күләм үлчәү берәмлеге; кубометр. *[Бетон салу] стенага хәтле --- Алтыбызга туксан куб була.* Ш.Маннур

4) *мат.* Нинди дә булса санның үз-үзенә ике мәртәбә кабатланган тапкырчыгышы, дәрәҗәгә күтәрелгән (дәрәҗәләнгән) санның яки хәрефле билгеләмәнең өченче дәрәҗәсе: $a^2b^3$ (*a* квадрат, *b* куб)

5) Тамырның өченче дәрәҗә билгесе

6) Сыеклыкны кайнату яки саклау өчен хезмәт итә торган зур савыт. *Мәктәп ишегалдында --- зур ашханә. Анда һәрвакыт куб кайнап тора, теләгән чагыңда чәйне эчә бир.* З.Бәшири. *[Солдатлардан] берәү: – Монда кайнар су табып буламы? – дип сорады. – Юк, куб кайнатучы эшчене үтерделәр.* Ш.Усманов

**КУБАЛАК** I *и.* Умарта түбәсе астына куелган яссы такта

**КУБАЛАК** II *с.* 1) Яргаланып, тиресе, тышчасы купкан, купкаланган. *Кубалак борынлы Хәнәфи карт үзе белән киң җилкәле, берсеннән-берсе таза өч чалгычы егет ала килгән иде.* М.Рәфыйков

2) Купкан, купкаланган кисәкләре асылынып торган

**КУБАЛАКЛАНУ** *ф.* Яргаланып кубу, кубалаклар хасил булу, вак-вак кисәкләр булып куба башлау; кубып, кисәкләр асылынып тору (тышча, тире һ.б.ш., гомумән, нәрсәнең дә булса өслеге тур.). *Ул көнне Тимерханның язгы җилдә ярылып кубалакланган, күптәннән елмаю белмәгән бите көләчләнеп яктырган иде.* М.Мәһдиев. *Боларның барысы, шулай ук битне яхшы корытып сөртмәү дә тиренең кубалаклануына һәм яргалануына сәбәп була ---.* Өегез ямьле булсын. *Әгәр бит-кулны начар сөртсәң, тирене җил ашый: кибә, кубалаклана һәм хәтта ярыла.* Өмет

**Кубалаклана бару** Акрынлап кубалаклану; кубалакланганнан-кубаклану

**Кубалаклана башлау** Кубалакланырга тотыну

**Кубалакланып бетү** Бик нык кубалаклану, тәмам кубалаклану

**Кубалакланып тору** Гел кубалаклану процессында булу; әледән-әле кубалаклану

**КУ́БАЛЫ** *и.* Куба иле кешесе. *Кичә кубалылар безне үзләренә чакырды.* Р.Мостафин

**КУБА́НКА** *и. рус* **1.** 1) Бәрән тиресеннән тегелгән яссы түбәле, тирән эчле колаксыз бүрек. *[Ләлә] ак маскхалатын салган, аның башында кызыл түбәле соры кубанка, өстендә сырган чалбар, шундый ук сырган телогрейка.* Г.Әпсәләмов. *[Хазбулатның] өстендә --- бөрмә билле черкеска, башында иң яхшы бөдрә бәрән тиресеннән тегелгән кубанка.* Р.Ильяс

2) *а.х.* Бодайның югары сыйфатлы бер сорты. *--- богдайның дәхи төрләре күптер, хәтта 150 ләп төре бар, диләр. Бу җирдә кулланылганы ошбулардыр: сандо-мирка, саксонка, гирка, арнаутка, кубанка, билаторка.* К.Насыйри

**2.** *с. мәгъ.* Кубанка (*1 мәгъ.*) формасында тегелгән. *[Хафизның] башында кубанка бүрек, өстендә кожан иде.* Г.Галиев

**КУБАРУ** *ф.* 1) Ябышкан, нык береккән нәрсәне аерып алу, җирлегеннән аеру, куптару. *Гайфулла, искергән шиферларын кубарып, өй түбәсен ак калай белән япты.* Ф.Яруллин. *Электр чаңының үкерүеннән битәр, күз алдында кабынып киткән ут көлтәсе караваттан кубарып, салкын палубага томырды.* М.Юныс. *«Уфада Габдулла Тукай хөрмәтенә куелган истәлек тактасын кубарып ыргытканнар!» дигән хәбәр булды.* Ф.Нәкыйпов

2) Куптару, күтәрү, чыгару (тузан, давыл һ.б.ш.). *Акларның җәяүлеләре, атлылары тузан кубарып монда таба чабалар.* Г.Бәширов

3) *күч.* Кузгату (уй, хисләрне). *Кондаков егет күңелендә нинди уйлар кубарганын сизенде.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Нинди дә булса эшне булдыру, эш кузгату, майтару. *Менә әйтер күк: «Юк, булмый Пычагым да кубарып...»* С.Хәким

5) *күч. жарг.* Каеру, күп итеп алу, күпләп бирергә мәҗбүр итү (акча һ.б.ш.). *«Шәһәргә даныңны чыгарам» дип куркытып, егетеңнән --- шактый гына кубарган идем.* Г.Камал

**Кубарып алу** Берникадәр вакыт кубару; кубарып үзеңнеке итү, үзеңдә булдыру. *Кригер [патша рәсеме астына ябыштырган кәгазьне] кубарып ала да укый.* Т.Гыйззәт. *Стенага беркетелгән бер агачны кәйлә белән кубарып алуы булды, калганнары үзләреннән-үзләре чыкты.* Г.Хисамов. *Казанны кубарып алып киткәннәр.* Г.Рәфикый

**Кубарып ату** Тиз генә барысын да кубару

**Кубарып бетерү** Ахырга кадәр кубару, барын да кубару

**Кубарып йөрү** Кубару хәлендә булу. *--- Сәләхиләргә барып: – Аның шулпасы да булырга тиеш, нигә миңа шулпасын бирмәдегез?! – дип дау кубарып йөргән.* Ф.Хөсни

**Кубарып кую** Азрак кубару яки алдан ук кубарган хәлгә китерү

**Кубарып ташлау** Кискенлек белән кубару. *Давыл кайсыдыр өйнеңме, сарайныңмы түбәсен кубарып ташлады.*

Г.Әпсәләмов. *Хакыйкатьне эзләүчеләр бар икән әле дөньяда, һәм мин ышанам: хаклыкны нинди генә авыр таш белән бастырып куйма, аны кубарып ташлардай көчләләр, гайрәтлеләр табылыр.* Ф.Яруллин

**Кубарып яту** Кубару хәлендә булу

**КУБАРЧЫК** *и. диал.* Яргаланып, кубалакланып төп җирлегеннән аерылган кисәк, кисәкчә

**КУБАРЧЫКЛАНУ** *к.* **кубалаклану**. *Батыргали агайның борыны өшеп, тиресе кубарчыкланып кутырлаудан чыкмый торган иде.* Ш.Мөхәммәдев

**Кубарчыклана бару** Акрынлап тагын да кубарчыклану

**Кубарчыкланып бетү** Бик нык, тулысынча кубарчыклану; тәмам кубарчыклану

**Кубарчыкланып китү** Кинәт кубарчыклану; тагын да кубарчыклану

**Кубарчыкланып чыгу** Тулысынча кубарчыклану

**КУБАРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кубару**. *Күргәнең бар микән: урмандагы төбе-тамыры белән кубарылган карт агач куенында үскән зифа, яшь агачны да үзе белән бергә аудара.* Р.Низамиев

2) Күтәрелү. *Халык дәррәү кубарылды. Мине арбам-нием белән күтәреп алалар дип торам.* Д.Галимов. *Улым, мәетләрнең рухыннан курык, килеңнең атасына вәгъдә биргәнеңне онытма, сүзеңне таптасаң, тыныч яткан кабереннән дә кубарылыр, кем белән дә, кайда да бәхетле була алмассың.* Р.Рахман

3) *дини* Кыямәт көнендә кабердән терелеп чыгу (үлгән кешеләр тур.). *Ул көндә хак булган кубарылу өчен кычкырган тавышны бар да ишетерләр, ошбу көн – каберләрдән чыгу көнедер.* Ногмани

◊ **Кубарылу көне** Кыямәт көне. *Аллаһы Тәгалә әйтә: «Аллаһ китабында әйтелгәнчә, кубарыласы көнгә кадәр кабердә яттыгыз, менә бүген – каберләрдән кубарылу көнедер».* Ногмани

**Кубарыла бару** Акрынлап тагын да кубарылу

**Кубарылып бетү** Бик нык кубарылу, ахыргача кубарылу

**Кубарылып китү** Кисәк кенә кубарылу

**Кубарылып тору** Һәрвакыт яисә әледән-әле кубарылу

**Кубарылып чыгу** Кубарылу хәлендә булу; әле, хәзер кубарылу. *Суккан саен, сугылучының тәненнән чәчрәп кан һәм ит кубарылып чыга иде.* М.Гали

**КУБАТУ́РА** *и. нем.* Нәрсәнең дә булса кубометрлар белән үлчәнә торган күләме. *Әни, шушы фатирыбыз кай җире белән начар? Кубатурасы да әйбәт, бакчасы да бар.* Ә.Фәйзи

**КУБИЗМ** *и. фр.* Сынлы сәнгатьтә: XX гасырның беренче яртысында формалашып, реаль чынбарлыктагы әйберләрне геометрик фигуралар белән сурәтләүне яклый торган модернистик агым. *Шул шакмакларның берсе янына икенчесе ничек куелганга карап кына, хатынның тезләрен кочаклап утырганын чамаларга була. Нәрсә бу: кубизм дигән стильнең чагылышы гынамы, әллә югыйсә рәссамның бу образга үз мөнәсәбәтен белдерүеме?* М.Маликова. *Художниклар арасында кубизм дигән агым килеп чыккан. Кешеләрнең гәүдәсен, бите шакмакларга бүлеп ясаудан гыйбарәт икән кубизм дигәннәре.* И.Гази

**КУ́БИК** I *с. мат.* Кубка охшаган, куб төсле. *Гади кубик структуралы кристаллда координаталар күчәрләрендәге x = 2, y = 1, z = 1 нокталары аша үтүче атомнар яссылыгының Миллер индекслары ---.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

**КУ́БИК** II *и. рус* 1) Балалар уенчыгы – төрле рәсемнәр, сүзләр, фигуралар төзү өчен, куб формасындагы зур булмаган агач яки пластмасс фигура, шакмак. *Ул кирпечләр нәкъ кубиклар кебек.* А.Алиш. *Бу кубик белән кыска гына вакыт эчендә бөтен дөнья мавыкты, бөтен дөнья халкы шул кубикны боргалады.* Г.Рәхим

2) Кубсантиметр (сыеклык үлчәү берәмлеге). *Безнең, доктор әфәнде, бер кубик та каныбыз юк.* Т.Гыйззәт. *«Бер кубик камфара», – дигән сүзләр ишетелеп кала миңа.* Ә.Айдар

3) *тар.* 1943 нче елга кадәр Совет армиясендә урта комсоставның квадрат формасында булган хәрби дәрәҗә билгесенең көнкүрештәге атамасы. *Әле кичә генә петлицаларына кече лейтенант кубигы таккан бу егетләр станциягә таба юл тоттылар.* Л.Ихсанова. *Өстәл артында ябык кына, сорырак битле бер бәндә утыра иде. Кызыл петлицасында бер кубигы бар.* З.Зәйнуллин

4) *күч.* Кубик формасындагы нәрсә. *Абыйлар кубиклардан биек-биек йортлар салалар.* А.Гыйләҗев

**КУ́БОК** *и. рус* Спорт ярышларында җиңүчеләргә приз буларак тапшырыла торган, кыйммәтле материалдан эшләнгән савыт – ваза. *Гагарин кубогы уңаеннан уздырылган ярышларның берсен дә калдырмыйча карадык. Әти «спорт» дәфтәренә әлеге ярышны үзгәртеп «Татарин кубогы» дип язып куйган ---.* Ватаным Татарстан

**КУБОМЕТР** *и. рус* Иңе, буе, биеклеге берәр метр булган күләм үлчәү берәмлеге; кубметр. *Шәһәрнең су ресурсларына еллык ихтыяҗы 8 миллион кубометр булса, әлегәчә эшләп килгән суалгычлардан ул 6,5 миллион кубометр гына алды.* Кызыл таң

**КУ́БРИК** *и. голл.* Судноның аскы палубасы, судно командасы өчен торак бүлмә. *Ә кубрикта практикантлар яшәргә тиеш. Диңгез кырыслыгына тизрәк күнексеннәр өчен, шулай кысынкы, комфортсыз эшләнгән.* М.Юныс

**КУБУ** *ф.* 1) Ябышкан, берекән урыныннан аерылу, аерылып төшү. *Илһам, өстәлдәге зур лупаны алып, аның аша картинага, аеруча буявы купкан урыннарга бик җентекләп карап торды.* Р.Фәизов. *Купкан урыннары булмаган эмальле яки алюминий кәстрүлгә бер стакан су, бер чеметем тоз салып утка утырталар.* Өегез ямьле булсын

2) Кубалаклану һәм вакланып коелу. *Баланың сөягеннән итләре аерылып, тереләй тиреләре кубып, бик газапланып үлгән, аның кычкырган тавышы урамнарга ишетелеп торган...* Ф.Бәйрәмова

3) *сөйл.* Кузгалу, тору, күтәрелү (утырган яки яткан урыннан). *– Мин бирүзем түгел, гадәтемчә, гел синең белән, – дип шаяртты Рәйхан, урыныннан кубып, аларга таба атлады.* Д.Каюмова

4) Кинәт кузгалу, хәрәкәт итә башлау, туктап, басып торган урыннан китү. *Күп малайлар һәм яшьләр дөр кубып [мәчеттән] чыгып киттеләр.* Г.Газиз

5) Кая да булса китү, кузгалу, күтәрелү. *Күмәкләшеп шәһәргә купканда, мирас җебен юлда югалтмадыкмы без, минем замандашлар?* К.Йосыпов. *Илнең асыл ир-егетләре яу кырында ятып калганнар, аларның аналары, хатыннары, балалары, дәррәү урыннарыннан кубып, дошманнан качып киткән.* М.Маликова

6) *сөйл.* Очып китү. *Каз купса, үрдәк күлгә ия булыр.* Мәкаль

7) Башлану, чыгу, күтәрелү (җил, буран, давыл тур.). *Бервакыт буран купты.* Г.Ибраһимов. *Давыл кубар тиздән, көчле давыл.* А.Алиш

8) *күч.* Күтәрелү, кинәт башланып китү (тавыш, шау-шу, гаугa һ.б.ш.). *Тылмачның соңгы җөмләләрен ишетүгә, ялландагы халыкның түземлеге сынды. Төрле якта ризасызлык, дәгъва, кычкырыш купты.* В.Имамов

9) Сугыш, фетнә һ.б.ш. башлану турында. *Халык дәррәү кубып, шаулашагөҗләшә ишеккә ташланды.* М.Галәү. *Атыш куба калса, иң беренче булып, якты җиһан белән сез хушлашырсыз.* В.Имамов

10) Көрәшкә күтәрелү, яуга чыгу. *Кеше бит ул – акыллы зат. Бер алышта җиңәм дип, барысы бергә купмады.* К.Йосыпов

**Куба бару** Акрынлап тагын да кубу; кубу арта бару

**Куба башлау** Кубарга тотыну. *Әмма күп тә үтми, идәннең буявы куба башлый, бигрәк тә сайгак аралары ямьсезләнеп кала.* Өегез ямьле булсын

**Кубып бетү** Бик нык кубу; кубу тәмамлану

**Кубып китү** Кинәт кубу; кубу хәлендә булу, гомумән кубу. *[Итекнең] берсенең балтыры ертыла төшкән, икенчесенең олтаны кубып киткән.* Ш.Камал

**Кубып тору** Әледән-әле кубу

**Кубып чыгу** Тулысынча кубу

**КУБЫЗ** *и.* 1) Дугасыман бөгелгән тимерчыбыкка 6–9 см озынлыгындагы юка гына җиз яки корыч тел беркетеleп, авызга куеп чиртеп уйный торган кечкенә музыка уен коралы (озынлыгы 7–10 см.). *Кинәт кенә шәрә агач ботаклары кубыз теледәй булып тоелды* Биюшкә. М.Хуҗин. *Борын-борын заманда, кешеләр әле агачка, ташка табынган чорда, бер адәм аудан кайтышлый тимердән ясалган бер хикмәтле әйбер табып ала. Бу әйберне хатынына алып кайтып бирә. Хатыны бу тимерне әйләндереп-әйләндереп карый да, бер дә рәтенә төшенмәгәч, авызына каба. Калтырап торган тел сыман бер нәрсәсенә чиртә дә өрә башлый. Шуннан көй чыга. Баксаң, бу кубыз икән.* М.Мәһдиев. *Барабан каксалар, барабан артыннан; Кубыз тартсалар, кубыз артыннан.* Н.Исәнбәт

2) Скрипка шикелле борынгы кыллы уен коралы. *Минем ерак бабаларым, яуга китәр алдыннан, соңгы мәҗлестә бәгырьләрне эретә торган саз моңын, кубыз киңәшләрен тыңлаганнар.* М.Юныс. *Бу – синдәме, шигърият, сүз пәйгамбәре тарафыннан сайланган кандаш, аңдаш, моңдаш сүзләрнең илаһи бердәмлеге: думбра, кубыз, саз, гөслә кыллары чиртеп, тормыш-хәят хакында тәүлекләр буена кабатланмыйча җыру әйткән чәчәннәрнең тиңдәшсез тапкырлыгы?* М.Галиев. *Элеккедән татар халкының төп уен кораллары түбәндәгеләр булган: сорнай (мөгездән ясаган түй быргысы – өрмә уен коралы, түйлар аннан башка узмаган), барабан, дандалай, шөлдерләр, саз (саз камышы курае), кылкубыз, кубыз (кыллы һәм өрмә, әле дә кулланылышта) ---.* Сөембикә

◊ **Кубызына бию** *ирон.* Кемнең дә булса теләге, кушуы, өндәвенә сукырларча ияреп эш итү, ихтыярсыз буйсыну. *Ул гына түгел, аларның кайберләре Болгар тарихын өйрәнү безнең өчен зарарлы, бу, янәсе, Сталин кубызына бию --- дип тә чыктылар.* Ә.Кәримуллин. *Шуны уйнап җибәрүе була, ире шатлыгыннан бии башлый. Әнә шул заманнан бирле ирләр хатыннарның кубызларына биилар, ди.* М.Мәһдиев

**КУБЫЗЧЫ** *и.* 1) Кубыз чиртү остасы, кубыз уйнаучы. *Кубызчы чалды чәң төн йокламыйча. Утыргач таңга чаклы ошбу хәлдә, Кинәт купты тавыш иртәнге мәлдә.* Котб

2) *күч. сөйл.* Кемне дә булса үз кубызына биетүче, кемгәдер үз фикерен, мәсләген тагучы. *Татар буржуазиясенең күптәнге кубызчысы, реакцион «мөселман иттифакы»н оештыручы бу кеше [Муса Бигиев] Октябрь тантанасыннан соң бөтен зәһәрен пролетариат диктатурасына юнәлтте.* К.Фасеев

**КУБЫК** *с.* Яргаланып, кубалакланып беткән, кубып-кубып тора торган. *Кубык борынлы шул малайның бездән алдарак мәйданга ыргылуы белән һич килешәсе килми.* Р.Төхфәтуллин

**КУБЫЛГЫ** *с. диал.* 1) Әле бер, әле икенче урыны ялык-йолык итеп, төсе үзгәреп күренә торган (кайбер тукымалар тур.)

2) Үзгәреп торучан, дулкынлы. *Кубылгы көй. Кубылгы тавыш*

**КУВА́ЛДА** *и. рус* Зур кул чүкече. *Авылдашлар, кем ни эләктерә ала, шуның белән коралланганнар иде. Монда сәнәк, күсәк, табагач, балта, пычак, таяк һәм хәтта кувалда кебек кораллар күренде.* З.Хәким

**КУВШИН** *и. к.* **кукшин**. *Бала коендырганда, --- уң кул ягына өстәлгә яки урындыкка сабын, коендыру өчен, кувшинга салып, бер литр чамасы су әзерләргә.* Өегез ямьле булсын

**КУГА** *и.* 1) *бот.* Кугачалар семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. *Куганың Татарстан Республикасында 10 төре бар.* Татар энциклопедиясе

2) Сазлыклы урыннарда, су буйларында үсә һәм тәлгәшле чәчәк ата торган кыяк үлән; күл камышы

3) Су өстендә җыелган төрле үлән калдыклары

**КУГАЛЫ́П ҮЛӘН** *и. бот.* Кугачалар семьялыгыннан күпьеллык саз үсемлекләре ыругы. *Татарстан Республикасында 2 төре: саз кугалып үләне – сазлыкларда; диңгез кугалып үләне Әлки, Мөслим районнарының дымлы, тозлак болыннарында, торфлы сазлыкларда үсә.* Татар энциклопедиясе

**КУГАЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Яфраклары күбесенчә тамыр таралгысында

чиратлашып бер-яки ике-өч рәт булып үсә торган, бер яки күпьеллык тамырчалы үләнчел үсемлекләр семьялыгы. *Кугачаларның чәчәкләре ике җенесле.* Татар энциклопедиясе

**КУ́ ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Агачларда паразит рәвештә үсә торган гөмбә; *русчасы*: **трутовик, трутник**. *Ашказанында сок бүленеп чыгу кимеп, гастрит авыруы күзәтелсә, ку гөмбәсен кулланалар.* Сәламәт яшәү нигезләре

**КУГУАР** *и. ингл. зоол.* Мәчесыманнар семьялыгыннан Төньяк һәм Көньяк Америкада яши торган зур кыргый мәче; пума

**КУГЫН** *и.* 1) Качкан кешене тоту максаты белән эзәрлекләп куу

2) Куучылар, эзәрлекләүчеләр төркеме. *Карт тегеләр артыннан кугын чыгара.* Әкият. *[Ш.Бабич] артыннан кугын куып бик озак йөгергән кеше төсле шабыр тиргә баткан, тәмам әлсерәгән иде.* С.Әдһәмова. *Беркемне дә тоталмады Волостьның кугыны да.* С.Баттал

3) Бүрәнәләрне сал ясамыйча гына агызу, транспортлау эше

4) Гадәттә, атка атландырып, ашыгыч йомыш, хәбәр белән җибәрелгән кеше

**КУДЫРГЫЧ** *и. тех.* Кудыру, торба буйлап икенче бер урынга җибәрү, транспортлау өчен насос сыман махсус җайланма, агрегат. --- *Электростанция, такта яру өчен механикалаштырган цех, су кудыргыч башня һәм эшчеләр өчен 50 урынлы тулай торак төзеп файдалануга тапшыралар.* Мәдәни җомга

**КУДЫРТУ** *ф. йөкл. юн.* 1) *к.* **кудыру**

2) Кудыргыч ярдәмендә сыеклык яки газны торбалар аша бер урыннан икенче урынга күчерү, агызу. *[Владимир Путин] Бу килешүне имзалау белән Русиянең Европа көньягына газ кудырту юнәлешендә Сербия иң алдынгы газ җибәрү юлы булып тора.* Ватаным Татарстан

**КУДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **куу**. *Тоткыннарны җәберләүче, төрмә инвентарен читкә сатып ятучы бер надзирательне эшеннән кудырта һәм төрмәгә яптыра.* М.Акмулла

2) Билгеле бер матдәне югары температурада тотып, аның составындагы сыеклыкларны, газны һ.б.ш. аерып чыгару юлы белән эшкәртү, кирәкле матдә ясау

**Кудыра башлау** Кудырырга тотыну

**Кудырып бетерү** Барысын да кудыру, кудыруны тәмамлау

**Кудырып килү** Торган саен тагын да кудыру

**Кудырып тору** Һәрвакыт яисә әледән-әле кудыру

**КУЕ** *с.* 1) Үзара, берсенә икенчесе бик якын, тыгыз, еш урнашкан; *киресе*: **сирәк**. *Икесе дә эссе көндә, куе тузанлы шәһәр һавасында табигатьләре бозылган алучыларның кыланышларына, капризларына ярый-ярый әлсерәделәр, арыдылар.* Г.Исхакый. *Бөтен битенә утлы күмер чаткыларыдай чәчелгән куе сипкелләргә күнегәсе бар.* Т.Галиуллин. *Куе яңгыр пәрдәсе аша каршы як басуларны да, авылны да күрү мөмкин түгел.* Г.Гыйльманов

2) Күп булып кабарып, күпереп торган, еш һәм тыгыз урнашкан, калын (чәч, керфек, үлән һ.б.ш.). *Юлның ике кырыеннан бик оста куелган арыш кибәненең корсагы шикелле корсакланып чыккан куе матур яшел яфраклар белән агачлар тезелеп киткән.* М.Гали

3) Нәрсә дә булса өстәп, салып, кушып куертылган, саф сыеклык халәтен шактый югалткан (сыекча, измә); *киресе*: **сыек**. *Юылган стена кипкәч, барлык ярыкларны куе шпаклёвка белән сылыйлар.* Өегез ямьле булсын

4) Тыгыз, яктылык үткәрми торган (газсыман әйберләр тур.). *Өнсез-тынсыз калган халык кинәт кенә дөбер-шатыр иткән тавыштан дерт итеп калды – кай арададыр күк йөзен куе кара болытлар өере каплап алган.* Н.Мусин

5) Төп төстән караңгырак булган, җетерәк; *киресе*: **сыек**, **ачык**. *Ашъяулыкның куе кызыл җирлегенә әнкәй егерме бизәк төшергән.* К.Йосыпов. *Куе яшел агачта аларны [чыршы күркәсен] әллә каян шәйлисең.* Р.Кәрами. *[Эре җимешле күгәннең] җимешләре уртача зурлыкта (8–10 г), түгәрәк, куе зәңгәр төстә.* Өегез ямьле булсын

6) Майлы, майның өлеше күп булган. *Аның [финнең] куе каймак берлән бирелгән каһвәсе телләрне йоттырды.* Г.Исхакый. *Фән болай дип әйтә: сөтле сыер үстерәсең килсә, бозауга яшь чагында мөмкин хәтле күп итеп куе сөт эчерт, ди.* Ә.Еники. *Эремчек белән каймакны яки куе сөт өсте белән яңа чүпрәне бертигез өлешләрдә туглап та биткә сөртә торган май ясарга мөмкин.* Өегез ямьле булсын

7) Тәме нык беленә торган, организмга тәэсире көчле булган, каты. *Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән куе чәй китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде.* Ә.Еники

◊ **Куе су** Малларга эчерү өчен он болгатып әзерләнгән туклыклы сыекча, ашлы су. *Яратам да соң шул йонлач Сарбайны. --- Аңа куе су, шулпа бирәм.* Г.Лотфи

**КУЕЛАНУ** *ф.* Куеру, куе булып китү. *Ләкин бераздан сораныл йөрүчеләр тагын да куеланды.* М.Мәһдиев. *Нәфисә шуны искәрде: урманның эченәрәк кергән саен, агачлар куеланды, биегрәк була барды, өстәге кояш ерагайды...* Г.Гыйльманов

**Куелана бару** Акрынлап тагын да куелану

**Куелана башлау** Куеланырга тотыну

**Куелана төшү** Тагын бераз куелану

**Куеланып бетү** Бик нык куелану, тәмам куелану

**Куеланып калу** Кинәт кенә куелану

**Куеланып килү** *к.* **куелана бару**

**Куеланып китү** Соңгы арада куелану. *Бу алмаларның берсен өзеп ашап карагач, егеткә мөгез үсә, урман да куеланып китә, аждаһа кыяфәтенә керә.* Х.Гатина. *Күркәмлеге белән барыбызның да ушын алып торган бу гөл, артык куеланып киткән очракта, гел генә эштә, иҗатта булган кешене дә диван белән телевизордан ары китмәгән ялкау «өй тавыгы» на әйләндерә икән.* Ватаным Татарстан

**КУЕЛАТУ** *ф. сөйл.* Куерту

**Куелата төшү** Тагын да берникадәр күләмдә куелату. *Өндәү рәвешендә китерелгән сүзләр, сорау җөмләләр --- Туфан шигырьләренең декламациячелек төсен куелата төшәләр.* Г.Нигъмәти

**КУЕЛМА** *с.* Куелган; бер алып, бер куеп йөртергә мөмкин булган, даими беркетелмәгән. *Куелма тешләр*

**КУЕЛМАЛЫ** *с. к.* **куелма**. *Берничә контейнерлы җиһазда махсус куелмалы швабралар урнаштырыла.* Безнең гәҗит

**КУЕЛЫК** *и.* 1) Куе булу. *Буяу өстәгән саен, бер җирне буяп карарга кирәк. Әгәр шул төс канәгатьләндерсә, тиешле куелыкка җиткәнче, эремәгә 20 процентлы терлек җилеме өстиләр.* Өегез ямьле булсын

2) Ешлык, урманның ерып йөри алмаслык куе урыны; чытырман. *Кучкар мөгезе куелык, Куелыктан куелык; Тәкә мөгезе түгәрәк, Түгәрәктән түгәрәк.* Х.Мәхмүтов

**КУЕЛЫШ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса куелу тәртибе, торышы, куелу үзенчәлеге. *Бәя кую комиссиясе хуҗалыкларда техниканың саклауга куелышына уңай бәя бирде.* Саба таңнары

2) Спектакльнең һ.б.ш. бер яки берничә мәртәбә аерым формада куелуы. *Без барлык театрларга йөрдек, балет-операларның русча һәм татарча куелышларын карый идек.* Мәдәни җомга. *Әлбәттә, журналистлар арасында «Яшь йөрәкләр»нең элекке куелышларын хәтерләүчеләр юк иде бугай.* Безнең гәҗит. *Бу куелыштагы спектакль күбрәк җыр-биюгә корылган.* Шәһри Казан

**КУЕН** *и.* 1) *к.* **кочак** (*1 мәгъ.*). *Сарбай юеш борынын хуҗасының куенына тыкты ---.* М.Хуҗин. *Ул [песи баласы] әнисе тирәсендә сырпалана, иркәләнә, ә кичләрен аның куенына кереп йоклый икән.* А.Алиш. *Аның бәхете Нурбәкнең кайнар куенында ярала да, тышка чыгарырга ярамыйча, икесенең арасында тарала, бер-берсенә сеңә.* К.Йосыпов

2) Күкрәк. *[Марат], уенны онытып, башын әнисенең куенына төртә.* Г.Гобәй

3) Кием белән күкрәк яки шул турыдагы тышкы кием белән эчке кием арасы. *Куенга бер кисәк икмәк белән берничә бәрәңгене кыстырып, тагын чыгып чабабыз.* Г.Ибраһимов. *Миңнурый, куеныннан чиккән яулык чыгарып, оялып кына Газинурга сузды.* Г.Әпсәләмов

4) *күч.* Ятакта бергә булу. *Шул ук вакыт һавадан бер дию патшасы пәйда булып, моның куенындагы хатынын күтәреп алып китте.* Әкият

5) *күч. шигъ. к.* **кочак** (*7 мәгъ.*). *Мәңгелек – яшәү уенының юаныч куены.* М.Галиев

6) *күч.* Җирнең эче, җир асты. *Җәмиләне кара каберга – мәрхәмәтле җир куенына илтеп күмделәр.* М.Гафури

◊ **Куенда елан асрау** Ниндидер начар кеше белән эш итү, аңа артык нык ышану, үзеңә бик якынайту. *Куеныңда елан асрап та шуны белмичә булмаган кебек, сезнең дә алтын ятканны белмәвегез мөмкин түгел.* Г.Хисамов. **Куенына керү** *Егет, кыз, кияү, кәләш* сүзләре янында: өйләнешеп, беренче төнне үткәрү. *Кияү кешенең кәләше янына килүе яңа горефләр белән үрелгән ике төрле традицион йола белән бәйле: 1) кызны язылышырга алып бару, кичен аның ягында үткәреләчәк туй мәҗлесендә катнашу һәм бабасы йортында калып кыз куенына керү ---.* М.Бакиров. *Бүген аны [айгырны] кыз куенына керәсе кияүдән дә болайрак төзәндергәннәр иде.* Н.Фәттах

**КУЕ́Н ДӘФТӘРЕ** *и.* Һәртөрле кирәкле мәгълүмат, эшләнәчәк эш, фикерләрне теркәп бару максаты белән янда йөртелә торган кечерәк дәфтәр, блокнот. *Ул көн хәтердә: яшереп кенә язган шигырьләремә бәреп керә алар, куен дәфтәремә күчә.* Р.Низамиев

**КУЕ́Н КЕСӘ(СЕ)** *и.* Күкрәк турына, киемнең эчке ягына салынган кесә. *Куен кесәсенә керү белән бармакларыма – рәхәтлек, тәнемә кайнарлык тарала.* Р.Низамиев

**КУЕ́Н СӘГАТЕ** *и.* Кесә сәгате. *[Сабира] күлмәк кесәсеннән куен сәгате чыгара.* М.Җәлил

**КУЕНТЫК** *и.* Куенга (*1 мәгъ.*) охшаш урын. *Яфраклар куентыкларында үскән бүлбечекләр дә җиргә коелалар.* Ботаника

**КУЕРТКЫЧ** *и. к.* **конденсатор**

**КУЕРТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **куеру**. 1) Сыеклыкны нәрсә дә булса өстәп яки башка төрле юл белән куерак хәлгә китерү, куе массага әйләндерү, куеландыру

2) Болганчык хәлгә китерү (суны), болганчыкландыру

3) *күч.* Көчәйтү, арттыру, интенсивлаштыру (тәэсир көчен һ.б.ш.). *Ул аңа йогынтысын тагын да куертты*

4) *күч.* Нәрсәне дә булса зурга җибәрү, катлауландыру; кирәгеннән артык җитдиләндерү. *Сәгыйдә улы белән сүз куертуны янә дә кирәксез санады.* Г.Хисамов

**Куерта бару** Акрынлап куерту

**Куерта төшү** Берникадәр куерту

**Куертып бетерү** Барысын да куерту; тәмам, ахыргача куерту

**Куертып җибәрү** Тагын да куерту. *Җиһангир бу полиция катнаштыру моментын тагы куертып җибәрде.* Г.Ибраһимов

**Куертып тору** Әле яки гел, һәрвакыт куерту

**КУЕРУ** *ф.* 1) Куелану; куелык, ешлык хасил итү (агач, куаклар тур.). *Ябалдашның үзгә артык куерса, аны сирәклиләр.* Өегез ямьле булсын

2) Калын, тыгыз булып үсү, күпереп торган хәлгә җитү (чәч, үлән һ.б.ш. тур.). *Бүреләрнең, төлкеләрнең йонналары куерды.* Г.Әпсәләмов. *[Айсылуның] өске иренендәге сизелер-сизелмәс кенә кара төкләре тагын да куера төшкән иде.* Г.Бәширов

3) Куе массага әверелү, ката башлау (сыеклык тур.). *Әлеге катнашманы, иләк аша чыгарып, куерганчы утта тотарга.* Серле календарь

4) Болгану, болганчык хәлгә керү. *«Парча» суларың да куермыйча, уймакланып ишелеп аксыннар.* Һ.Такташ

5) Куе (*3 мәгъ.*), үтә күренмәслек хәлгә җитү, тагы да тыгызлану. *Басу ягыннан күренгән болытлар кургашланып куера башладылар.* Г.Минский

6) *күч.* Һава составының начарлануы, кислородка ярлылануы. *Сестра, монда һава бик куерып китте әле. Әллә --- идәнне сөрттереп аласыңмы?* А.Шамов

7) *күч.* Ныгу, көчәю (сүз, әңгәмә һ.б. тур.). *Туй көнендә таралган начар-пычрак гайбәт куерып җәелә --- башлады.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Җитдигә әйләнү, зурга китү (берәр эш яки вакыйга). *Вакыйгалар куерды. Хәзер Арибах өчен Тогрылны үтергән Туктай ир тиеш була, нишлисең, канун шундый.* Казан утлары

9) *күч. сөйл. сир.* Йокыга ою, йокы халәтенә керә башлау. *Сәмигулла абзый*

*үзе йоклап китәр алдыннан, куерып кына ята торган карчыгын уятып: – Чәйне ничә кадак алсам ярар икән? – дип сорады.* Ф.Әмирхан

**Куера бару** Торган саен куеру. *Түбән очтагы гармун тавышы Гамбәриянең күңеленә һаман тирәнрәк үтә торды, тирәнгә төшкән саен, үкенечле уйлар куера барды.* К.Тимбикова

**Куера башлау** Куерырга тотыну. *Беркөнне төштән соң күк йөзе куера башлады.* Р.Кәрами. *Копенгагенда Король театрында хәлләр куера башлады.* Р.Батулла. *Авылына якынлашкан саен, кызның бит алмаларына кунган кызыллык куера башлады.* З.Хөснияр

**Куера төшү** Билгеле бер күләмдә куеру. *Караңгылык куера төшкәч, отряд, бөтен көчен бергә туплап, чолганышны өзде ---.* Г.Әпсәләмов

**Куерып алу** Аз гына вакытка куеру. *Ильясны озата чыкканда, аны [Зәйнәпне] күреп калганнар икән. Авылда сүз куерып алды.* К.Тимбикова

**Куерып бетү** Бик нык куеру; куеруның җитәрлек, кирәкле дәрәҗәгә җитүе

**Куерып китү** Көтмәгәндә, кинәт куеру. *Аерым артистлар турында сүз куерып китте.* М.Әмир. *Тарихи вакыйгалар ул кышны куерып китте.* Ә.Еники

**Куерып җитү** *к.* **куерып бетү**. *Кичке эңгер-меңгер куерып җиткән иде инде.* Г.Гобәй

**КУЕРЫК** *с.* **1.** 1) Шактый болганчык; болганган, пычрак. *Куерык суның акканы яхшы.* Мәкаль

2) Куертылган, болгатылган

**2.** *и. мәгъ.* 1) Спирт, шикәр, сыра һ.б.ш. җитештергәндәге калдык; *русчасы*: **барда**

2) Куерып укмашкан әйбер, оешып каткан нәрсә. *Җәрәхәттән агып чыккан кан куерык хасил итә.* Анатомия

**КУЗ** *и.* Утлы күмер. *Чын шагыйрь, Иман биеклегеннән торып, дәверләр аръягына сүз йомгагын чөя алган икән, аны дәвер ызаннарында кузы калган учак көле арасыннан Вакыт кайтып күтәреп ала да мәңгелек бишегенә сала.* М.Галиев. *Риф һәм Фәрәһия Мусиннар, тимер чиләктә куз йөрткән сыман, өйдән-өйгә йөреп, китапка җан өрештеләр.* К.Йосыпов

**КУЗ КҮМЕР** *и. к.* **куз**

**КУЗА** *и.* 1) Аяк һәм өс киемнәренең металлдан эшләнгән өлешләре (каптырма, үкчәлек һ.б.ш.)

2) Агачтан эшләнгән җиһазга куелган яссы металл пластинка, бизәк

**КУЗАК** *и. бот.* Кайбер үсемлек орлыкларының озынча тар кабыгы, җимешлеге. *Күрше Сафа бабай әйтә, бер кузакта уналты борчак булса, ул инде бик уңган була, ди.* Г.Ибраһимов. *Урман янындагы --- борчакны матур көннәрдә яшел дип җыеп алмаганнар иде, хәзер кузакларын җәеп үрә дә башлаган.* А.Шамов. *Заводтан чыкканда да, колаклары кызыл борыч кузагы кебек яна иде.* Г.Әпсәләмов

**КУЗАКЛАНУ** *ф.* Кузаклар барлыкка килү; кузак чыгару

**Кузаклана бару** Акрынлап кузаклану

**Кузаклана башлау** Кузаклары барлыкка килү. *Җәй башында кычыткан шулпасы белән тамак алдасак, рәхәт, җылы җәй уртасында безне кызыктырып, борчак кузаклана башлады.* Ватаным Татарстан

**Кузакланып бетү** Бик нык кузаклану, тәмам кузаклану. *Инде бөтенләй кузакланып беткән – сырга кебек сабакны сыгып утырталар.* Г.Ибраһимов

**Кузакланып килү** *к.* **кузаклана бару**

**Кузакланып тору** Кузак рәвешендә булу; әле кузаклану

**КУЗАКЛЫ** *с.* 1) Кузагы булган. *Быелдан кузаклы, кыяклы һәм бөртекле культуралар катнашмасыннан силос салуны арттырачаклар.* Кызыл таң

2) Орлыклары кузак эченә урнашкан; шул хәлендә кулланыла торган. *Диетик аш әзерләү өчен, 100 грамм сельдерей тамыры, укроп, петрушка, базилик, тоз, 250 шәр грамм кишер, кузаклы фасоль --- алына.* Тәмлетамак

**КУЗАК(ЛЫ) БОРЫЧ** *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан, орлыгы грушага охшаш җимешлеккә (кузакка) урнашкан берьеллык үсемлек; *к.* **кызыл борыч**. *Аның спиртлы дуләнә һәм кузаклы борыч төнәтмәләрен җитештерү буенча законга каршы гамәле --- телевизор аша бөтен илгә күрсәтелсә дә, Самара прокуратурасы җинаять эше кузгатудан баш тартты.* Ватаным Татарстан. *Кызганычка каршы, умырткаара дискысына үләннәрдән ясалган дару эчеп кенә тәэсир итеп булмый. --- Мәсәлән, сирень, кузаклы борыч төнәтмәләрен кулланалар.* Өмет

**КУЗАКЛЫЛАР** *и. күпл. бот.* Борчак, җир чикләвеге, борыч, ясмык кебек үсемлекләрне берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **бобовые**. *Е витамины шытып чыккан арыш орлыгы, кузаклылар, салат, яшел суган, бавыр, йомырка сарысы, кукуруз, зәйтүн һәм соя майларында бар.* Шәһри Казан

**КУЗАКЧА** *и.* Кәбестәсыманнарның уртадан элпә белән аерылган, һәр орлыкка аерым буынтыклы кузагы. *Торма, кәбестә, шәббуйның кузакчалары тышкы күренешләре белән кузакка охшыйлар.* Ботаника

**КУЗАЛАК** *и.* Ике тәгәрмәчле ат арбасы

**КУЗАЛА́К АРБА** *и. к.* **кузалак**. *Мокыт абый, кузалак арба җигеп, бабасына килгән.* Мәзәк

**КУЗАЛА́У** I *ф.* Куза куеп, куза белән бизәп эшләү

**Кузалап чыгу** Барысын да кузалау; ахырга кадәр кузалау

**КУЗАЛА́У** II *ф. диал.* Тәгәрәп бару

**КУЗГАЛАК** *и.* Карабодайчалар семьялыгыннан ашарга яраклы озынча яфраклы, тәме ачкылтым күпьеллык үлән үсемлек. *Шулай булса да, бу урманның гөрләп утыруы, бигрәк тә аның язгы кузгалагы, --- күзгә чикләвекләре минем күңелемне ул урманга тарталар.* Г.Ибраһимов. *Битләре алланганчы икмәк белән кузгалак шулпасы ашадылар.* И.Гази. *Моңарчы Талипның саклап килгән биш-алты шакмак шикәрен суырып, кузгалак чәйнәп, ара-тирә җиләк чүпләп килделәр.* Ә.Еники

**КУЗГАЛАКЛЫ** *с.* Үзендә кузгалагы булган; үзендә кузгалак үскән

**КУЗГАЛАКЛЫК** *и.* Күпләп кузгалак үскән урын

**КУЗГАЛУ** *ф.* 1) Тик тору хәленнән чыгу, хәрәкәтләнә башлау; кыймылдау. *Тән арган, кул-аяк кузгалырга теләми, ләкин ми ачык, якты, күңел шат.* Г.Ибраһимов. *Аның инде кул һәм аякла-*

*ры сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле түбән тарталар ---.* Ш.Камал

2) Утырган яки яткан урыннан тору яки торып китү. *Түбәнге табындагыларның күбесе кузгалып, чыгар ягын карый башлады.* Г.Ибраһимов. *Сестра, урыныннан кузгалмый гына сузылып, башка үләннәрдән зур булып, аерылып үсеп торган ат кузгалагын сындырып алды ---.* А.Шамов. *Сәкесе өстендә Шәриф яткан җиреннән чак-чак кузгалып торып утырды.* М.Гафури

3) Кая да булса юнәлү, китү, юлга чыгу. --- *Зур кораб акрын гына юлга кузгалды.* А.Алиш. *Ул арада берәүнең: «Тыпру! Кузгалсаң туктый алмыйсың, туктасаң кузгала алмыйсың!» – дип, атын әрләве ишетелде.* И.Гази

4) Йокыдан тору, төнге тынлыктан соң хәрәкәт итә башлау, эшкә тотыну. *Ул кояш белән бергә кузгала, Күрәген ала, җиңен сызгана.* М.Җәлил. *Бригада приказы буенча полк озакламый кузгалырга тиеш ---.* А.Шамов

5) Авыруның кабат башланып китүе, кинәт көчәюе; өянәк тоту. *– Бүген, – ди, – анакайның мигрене кузгалды.* Г.Ибраһимов. *Бүсеремнең кизүе кузгалды.* Т.Гыйззәт

6) Нинди дә булса эш башлау, эшкә тотыну. *Таңнан уракка кузгаласыз икән...* Г.Гыйльманов. *Эшче халык кузгалсын, Беләкләрен сызгансын ---.* Ш.Бабич. *Шикләнерлек нәрсә булмаса, тагын кузгалып китәләр.* И.Гази

7) *сөйл.* Урыныннан чыгу, таю. *Буын кузгалу*

8) *күч.* Ачу, нәфрәт, мәхәббәт һ.б.ш. кебек хис яки уй, фикер туу, барлыкка килү. *Хайвани дәрте котырып кузгалган кызмача ир кулыннан ычкыну алай ансат түгел иде [Гайниягә].* Ф.Хөсни. *Бу вакытта Әминәнең күңелендә бик куәтле усаллык кузгалган иде: йөзе күгелҗем төскә керде.* Ф.Әмирхан. *Кичә кич күңел төбендә кузгалган ачы моң тагын да яманрак чыңлый башлады.* Г.Гыйльманов

9) *күч.* Күтәрелү, кинәт башланып, көчәеп китү (җил, давыл, буран һ.б.ш. тур.). *Тышта җил, буран дөньяның астын өскә китерерлек булып кузгалган, дулый.* Ш.Камал. *Бөтенләй --- кызганнар, ди. Бииләр, җырлашалар, тузганнар, ди. Бу сүздән бакчачылар тамырында Җәһәннәм ташкыннары кузгалган, ди.* Ш.Бабич

10) Ташу; елгаларда боз китү. *Бүген таңда урман ташуы да кузгалыр.* Г.Бәширов. *Тулуы җитте ау диңгезенең, Боз кузгалыр, диләр, тиз көннән.* Г.Халит

11) *күч.* Талаш, шау-шу башлану. --- *комендантның әмерне санга сукмавына каршы ул [Хованский] ярсып кузгалды.* В.Имамов

12) *күч.* Көн тәртибенә куелу, төп мәсьәлә итеп күтәрелү. «*Чулпан» колхозының ун еллык бәйрәмен үткәрү мәсьәләсе үзеннән-үзе кузгалды.* Г.Галиев

13) *күч.* Ирек, бәйсезлек һ.б.ш. даулап көрәшкә күтәрелү; баш күтәрү. *«Кузгал, уян, ләгънәт ителгән Коллар һәм ачлар дөньясы».* Һ.Такташ. *Яңа кампания кузгалган саен, яңа лозунглар барлыкка килә.* Ә.Маликов

14) *күч.* Бәхәсле яки үтәлеше катлаулы булган мәсьәлә турында сүз башлану. *Иң ахырда кузгала бер мәсьәлә, Бар хыял, уйлар шуңарга ташлана.* Ш.Бабич

**Кузгала бару** Акрынлап кузгалу; бер-бер артлы кузгалу

**Кузгала башлау** Кузгалырга тотыну. *Әни авыл ягына шигәеп күз салды да урыныннан кузгала башлады ---.* Г.Бәширов. *Акмаңгай баштарак Хәмиттән качып китәргә тырыша иде, әмма тора-бара аның йөрәгендә үгезлек ярсуы кузгала башлады.* Ф.Яруллин. *Василий акрын гына урыныннан кузгала башлады.* Н.Нотфуллина

**Кузгалып килү** Акрынлап кузгалу. *Көнбатыш яктан җил кузгалып килә, янгын бик озакка сузылачак иде.* В.Имамов

**Кузгалып китү** Кузгалып хәрәкәт итү; кинәт кузгалу. *Якуб аякларын арба кырыеннан салындырып утыргач, арба кузгалып китте: таш җәйгән урам буенча дөбер-дөбер китеп бардылар.* И.Гази. *Озакламый поезд кузгалып китте.* А.Шамов. *Автобус та шуны гына көткән кебек кузгалып китте.* Г.Минский

**Кузгалып кую** Аз гына кузгалу. *Моңарчы битараф бер чырай белән тыңлап кына утырган Идият абзый кузгалып куйды ---.* Ш.Камал

**КУЗГАЛЫШ** *и.* 1) Кузгалу, урыннан тору, хәрәкәтләнү эше. *Боларның тузынуыннан киң далага чәчелгән бөтен көтүдә бер кузгалыш булды.* Г.Ибраһимов

2) Хәрәкәт. *Гомумән, машина төзелеше тармагындагы уңай кузгалыш Татарстанның киләчәген билгеләячәк, дип белдерде Президент.* Ватаным Татарстан

3) Баш күтәрү; фетнә. *Сезнең хакны даулар өчен бу кузгалыш; Һәркемгә, һәрнәрсәгә, һәр тугрыда.* Г.Тукай

**КУЗГАЛЫШУ** *ф. урт. юн.* Кузгалу, хәрәкәт итә башлау. *Без икебез дә урынарыбыздан кузгалыштык та, үзебез дә белмичә, бер-беребезгә каршы килештек.* Ф.Әмирхан

**КУЗГАТКЫЧ** *с.* **1.** Кузгатып җибәрә торган; хәрәкәткә китерә, җанландыра торган, яки берәр эш яисә хәлне башлап җибәрә торган. *[Тикшерүче] берничә яктан кузгаткыч сорау биреп, картның сүз тегермәнен әйләндереп җибәрде.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кузгатып җибәрә торган нәрсә

**КУЗГАНУ** *ф. диал.* Атлыгу, дәртләнү, канатлану. *Кузганып, тиешле эшне эшләп куя иде.* М.Гали

**КУЗГАТУ** *ф.* 1) Тик торыш хәленнән чыгару, хәрәкәтләндерү, кыймылдату. *Шул минутта ук паровоз, гудок бирмичә генә, эшелонны бердән кузгатты.* Ш.Усманов. *Паровоз тагы әкрен генә кычкыртып куйды да кузгалды һәм беренче вагонны, буферын шалтыратып, урыныннан кузгатты.* Г.Гобәй

2) Утырган яки яткан урыныннан күтәрү, торгызу. *Ялгызлыктан газапланган Илсөяр тәрәзә төбендә кояш нурларында гамьсез мырлап яткан песине кереп кузгатты.* Г.Гобәй

3) Хәрәкәт иттерә, йөртә башлау. *Барыбер кояш көләр дә Кузгатыр бар бозларың ---.* Н.Исәнбәт

4) Күчерү, бер урыннан икенче урынга кую яки торышын үзгәртү. *Дәрес китаплары башка китаплар белән аралаш булганлыктан, аларны алыр өчен, Хәсәнгә корзиндагы бөтен*

*китапларны кузгатырга туры килде.* Ф.Әмирхан

5) Уяту, йокыдан торгызу. *Барактагы егетләрне дә Исак гадәттәгедән иртәрәк кузгатты.* Ш.Камал

6) Эшкә күтәрү, оештыру. *Яшьләрне эшкә кузгату*

7) Чир көчәюгә, кинәт авырта башлауга сәбәпче булу. *Я тагын өянәгемне кузгатырсың.* Р.Ишморат

8) *күч.* Берәр хис, физик яисә рухи халәт хасил итү. *Күкрәтеп, гүләп, сайрап, өзелеп Килде, курай, уйнар мизгелең, Якты уйлар салып дәртен кузгат, Күккә ашыр йөрәкләр сизгерен.* Ш.Бабич. *Чү... Ни эшләтәм әле... Уй кибәген Җилгәрергә дигән башымны? Ник кузгатам күкрәгемне баскан Ваемсызлык дигән ташымны?* М.Галиев. *Ә кыз чыннан да матур бит. Сүнеп барган теләкләрне уятырлык, дәртләрне кузгатырлык матур.* Р.Рахман

9) *күч.* Билгеле бер мәсьәләне күтәрү, тикшерүгә кую, берәр нәрсә турында сөйли башлау. --- *платёж артыннан платёж килә дә тора, бүген ул турда сүз кузгату җайсыз.* Ш.Мөхәммәдев. --- *Казанга кайткач, шушы ук теманы кузгатып, СССР Фәннәр академиясенең союздаш республикаларның академияләре эшчәнлеген координацияләү комиссиясенең җаваплы секретаре Николай Пшерков белән телефон аша сөйләшә.* Мирас

10) *күч.* Суд эше башлау, суд тикшерүенә бирү. *[Шәрип] тагы ике фәкыйрьгә унар пот арыш, берәр сум акча бирде дә Гыйззәтнең бер хатасы турында эш кузгаттырды ---.* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Берәр зур эш башлау, эшкә тотыну. *[Нурый карт:] Менә хәзер өй кузгатырга торам, җир-урман алдым.* Г.Ибраһимов

**Кузгата башлау** Кузгатырга тотыну. *Әгәр нидер кузгата башласа, шунда ук: – Кәримәне абыйга белә торып алдырткансыз әле, анда ни карадыгыз! – дип, авыз-телләрне томалап куя торган булып китте.* Ф.Яхин. *Соңгы араларда Илсур гел үлем турында сүз кузгата башлады.* Безнең гәҗит

**Кузгатып бетерү** Барысын да кузгату; кузгатуны тәмамлау

**Кузгатып йөрү** Кузгату халәтендә булу. *[Мостафа:] Каюм абзый интересный бер эш кузгатып йөри әле.* Ш.Камал

**Кузгатып карау** Булу-булмавын белер өчен кузгату

**Кузгатып кую** Тиз генә кузгату. *Чөнки РФ прокуратурасы карамагындагы Тикшерү комитетының Казан бүлеге Җинаять кодексының «Вазифаи вәкаләтләрне явыз максатта куллану» дигән коррупция маддәсе буенча эш кузгатып куя.* Безнең гәҗит

**Кузгатып җибәрү** Тик торыш хәленнән чыгару; кинәт кузгату. *Фәхриҗамалның әлеге уңайсыз тойгыларын яңадан кузгатып җибәрделәр.* Ш.Камал. *Ничектер, аның шундый тирән тойгыларны кузгатып җибәрә торган ниндидер бер серле ягы бар иде.* Г.Бәширов

**Кузгатып тору** Әледән-әле яки гел кузгату. *Дөрес, яшь киленнең сылулыгы, килеш-килбәте хакында хатын-кыз артык сүз кузгатып тормады, бу кадәресен һәркайсы үзе генә хәтер сандыгына салып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**КУЗГАТУЧЫ** *и. сир.* Инициатор, башлап җибәрүче, башлаучы

**КУЗГА́У** *ф. диал. к.* **кузгату**

**КУЗЛА** *и. рус* 1) Арба яки чананың алгы өлешендә ат тотучы утыру өчен махсус ясалган урын. *Хәлим кара лаклы зур тарантас кузласына утырган.* Г.Гобәй

2) Утын кискәндә кулланыла торган, аяклары бер-берсенә аркылы сугылган борыс формасындагы җайланма. *[Газинур] биек кузлаларга аркылы салынган бүрәнә өстенә сикереп менде.* Г.Әпсәләмов. *Ишегалдында ике малайның, кузлага салып, озын пычкы белән әрдәнә тураганнарын күрдем.* Г.Галиев

3) *спорт* Төрле гимнастик күнегүләр өчен ясалган махсус җайланма. *Тик коңгырт күн белән тышланган, җитмәсә җене сөймәгән хайван исеме белән аталган кузланы (козёлны) сикереп чыга алмыйча иза чикте. Илләм йөгереп килә, гәүдәсен куллары белән этеп җибәрә һәм... шып итеп кузланың биленә утыра.* Т.Галиуллин

4) Берничә мылтыкны штыгы белән югары каратып бер-берсенә сөяп куйган пирамида

**КУЗЛА́ ҖӨЕ** *и.* Уң ягы кузла аягы кебек (Х ка охшаш аркылы-торкылы җепләрдән торган), сул ягы атлатып җөйләнгән ике параллель сызыктан гыйбарәт булган чигү җөе (күбесенчә, сыпылмаган ертыкны типчү яки әдепне беркетү өчен кулланыла). *Астарны кесәлекнең тискәре ягына салып күклиләр, кесәлекнең кисек кырыен астарга таба бөклиләр, аннары күкләп кузла җөе белән тегеп чыгалар.* Өегез ямьле булсын

**КУЗЛЫК** *и.* Утлы күмерне, кузны җыеп өеп кую өчен мич алдында махсус урын; мич култыгы

**КУЗНА** *и.* 1) *анат.* Сарык, кәҗә, ат, сыер кебек хайваннарда ашык сөяге, бәкәл сөяге (балаларның җәй көне ачык һавадагы уенында кулланыла). *Шагыйрь кайсы вакытта идарәханәгә кесәсенә кузна тутырып килә.* Ф.Әмирхан. *Алгы якта [Фәрит] кузналар санап маташа иде.* Ш.Камал

2) Шул сөяк белән уйнала торган уен

**КУЗНАЛЫ** *и.* Кузна уены. *Ду килеп, тиргәшә-талаша, кузналы уйныйбыз.* Ш.Маннур. *Ул бай баласы кебек киенә, бай гаиләсе белән бер табактан ашый, урамда яшьтәшләре белән кузналы, качышлы уйный.* Р.Батулла

**КУЗОВ** *и. рус < төрки* Йөк машинасының кешеләр утырту һәм йөк төяү әрҗәсе, козау. *МТС директоры Зәйнуллин, шофёр кабинасына утырмыйча, кунаклар янына кузовка урнашты.* Г.Минский

**КУЗЫ** I *и.* Әстерхан чикләвеге. *Эчтәлекләре ягыннан коман табышмакларын түбәндәге тематик төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин: --- Үсемлекләр һәм җиләк-җимеш: камыш, камыш башы, кавын, кузы.* Х.Мәхмүтов

**КУЗЫ** II *и.* Курчак сүрүе, тышчасы, пәрәвезе; *русчасы*: **кокон**. *Кортлар куак төбендә яки үләндә ефәк пәрәвез кузыларда курчакланалар. Июль-август айларында кузылардан күбәләкләр чыга.* Җиләк-җимеш

**КУЗЫ** III *и. к.* **кузый**

**КУЗЫЙ** *и.* Бәрән, сарык бәтие. *Кыз кочмаган ирнең җаны тыныч, кузгалак ашамаган кузый тыныч.* Мәкаль. *Дөя*

*җуйса колынын, Иртә-көндез иңридер, Куй югалтса кузыйсын, Иртә-көндез мөгридер.* М.Җәлил

**КУЗЫЙЛА́У** *ф.* Кузый, бәрән тудыру; бәрәнләү (сарык тур.)

**Кузыйлап тору** Кузыйлау хәлендә булу яки гел, елдан-ел кузыйлау

**КУЗЫР** *и.* 1) Өстән ышыклап тора торган махсус урын, кыекча. *Лампа кузыры. Ишек өстендәге кузыр*

2) Күш, бөркәү, көймә (элек арба-чана өстенә куелган)

3) *сөйл. к.* **козырь**

**КУЗЫ́ ЧИКЛӘВЕГЕ** *и. к.* **кузы** I. *Агарган чәчне --- яшел кузы чикләвеге кабыгыннан ясалган төнәтмә белән юарга була.* Өегез ямьле булсын

**КУЙ** *и.* 1) Койрык буе тирәсендә күпләп май җыела торган сарык токымы. *Югалган куйның койрыгы зур булыр.* Мәкаль. *Ул күрә куй койрыгын да: «Нинди шешкән!» – дип куя.* Г.Тукай

2) Гомумән сарык. *Бүре мескен куйны ертып, өзгәләп, үзенең табигый ач күзлеге илә ашый башлады.* Г.Тукай. *Тере куйны ботыннан тотып кимерерлек дәрәҗәгә җитеп ачыккач та, фин ашханәсенә кереп, фин ысулынча ачык өстәлдә ашадылар.* Г.Исхакый

**КУЙЧЫ** *и.* Куй көтүче. *[Арысланбайның Карлыгач-Сылуны урлап кайтуын] башта ялчы хатын белде. Ул, куркып, хәйран калып, куйчыга сөйләде.* Г.Ибраһимов

**КУЙЧЫЛЫК** *и.* Сарык асраучылык

**КУК** *с. диал.* Кукрайган, масайган, күкрәген киергән. *Үзе – юк, үзе – кук.* Мәкаль. *Сез мине борынын һавага чөеп, бүксәне киереп атлаучы кук егет итеп күз алдыгызга китерә күрмәгез тагын.* Р.Төхфәтуллин

◊ **Кук итеп** Кукраеп, күкрәк киереп. *Ачык ишектән өйгә, биш-алтылап тавык ияртеп, кук итеп әтәч килеп кергән.* Мәзәк

**КУКАЛ** *и. сөйл.* Украин кешесе; хохол. *Ул үз гомерендә чит дошман илләрдән, бигрәк тә казак җәйләвенә утырган кукаллардан, көтү-көтү малларны ничек урлап, куып алып киткәнен, югалган асыл малларны караклардан ничек табып алганын көлке һәм куркыныч итеп сөйләде.* Г.Ибраһимов

**КУКАР** *и. иск.* Агач эшенә, агач белән эш итүгә бик оста кеше; *русчасы:* **столяр**

**КУКАРЧЫЛЫК** *и. иск.* Агач эшләре

**КУКИШ** *и. сөйл. к.* **кәҗә тоягы**. *--- [Гайнулла хаҗи] ышанып тапшырып торган барлык акчасын, малын, йорт-җирен үз исеменә яздырта да аңа [Әхмәтсафага] кукиш кенә күрсәтә.* М.Гайнетдинов

**КУКРАЮ** *ф.* Үз-үзеңне әллә кемгә кую, масаю, борын күтәрү. *Шулай кукраеп йөргән-йөргән дә, ди, бу [әтәч] – биек койма башына менеп кунаклаган, ди.* Әкият. *Ләкин кыз алганда, кукраеп, кодагый булып түрдә утырасың, кодагый, кодачаларның ашларыны, бик яхшы булган дип, яратмаганны күрсәтеп тора торган төсле мактыйсың.* Г.Исхакый

**Кукрая бару** Торган саен кукраю

**Кукрая бирү** Бернигә карамый кукраю

**Кукрая төшү** Берникадәр кукраю

**Кукраеп йөрү** Әле яки һәрвакыт кукраю. *Әмирҗанга погоннар белән озак кукраеп йөрергә, Садыйк хаҗига Әмирҗан өстенә карап озак шатланырга туры килмәде.* Ш.Камал

**Кукраеп тору** Кукраю хәлендә булу

**Кукраеп утыру** *к.* **кукраеп тору**. *«Мин кем!» дигән сыман, бер әтәч кукраеп утыра.* И.Гази

**КУКСИН** *с. нем. диал.* Зәңгәрсу кызыл, фуксия чәчәге төсендә булган

**КУКУРУЗ** *и. лат.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан чәкән формасындагы эре орлыклары ашарга яраклы булган, юан озын сабаклы, кыяк яфраклы берьеллык үлән үсемлек; маис, кәгъбә бодае. *Мал азыгы өчен кукуруз, чөгендер, люцерна, рапс, тукранбаш һәм башкалар чәчелә.* К.Йосыпов

2) Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. Ул *бик кызыктыргыч сап-сары төстә һәм бик тәмледер сыман тоелган кукуруз боткасы иде.* Ш.Маннур

**КУКУРУ́ЗНИК** *и. рус сөйл.* Кечкенә (салонына 12 пассажир сыешлы) самолёт. *--- кукурузник урманга җитәрәк биеклеген арттырды да, яңа гына күкрәп үткән яшенле яңгырдан соң таралган татлы һавадан ләззәтләнеп утыручы агачларның тынлыгын бозып, үкерә-үкерә ары табан очып китте.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**КУКУРУЗЧЫ** *и.* Кукуруз үстерүче, кукуруз үстерү остасы

**КУКУРУЗЧЫЛЫК** *и.* Кукуруз үстерү, кукуруз игү эше

**КУКЫР** *с. диал.* Мактанчыграк, һаваланырга яратучан

**КУКЫРАЮ** *ф. к.* **кукраю.** *--- ишек төбендәге баскычта муенына автомат аскан немец солдаты кукыраеп басып тора.* Ф.Абдуллин. *[Гайфи] Тагын бер тапкыр тын алгач, ул кукыраеп кычкыра ук башлады ---.* М.Мәһдиев. *– Сезне түгел, сезнең ханыгызны да мин катауга кертмәдем, – диде би, кукыраеп, тупас кына.* Н.Фәттах

**КУКШИН** *и. к.* **күкшин**. *Әбинең бер кулында кукшины, икенче кулында, култык астында, кечкенә генә төен кисәге.* Г.Гали. *Дулкынлануын яшерергә тырыша, киръәксә-киръәкмәсә дә кукшиннан касәгә агызып су йоткалый.* Р.Батулла

**КУЛ** I *и.* **1.** 1) Кешенең иңсәсеннән алып бармак очларына кадәр булган өске очлыгының һәр икесе. *Кеше гомере бигрәк нәзберек шул: «Кыймылдыймы йөрәк... кан... куллар?» Тып-тын гына агып ята гомер, Кеше гомере – догалы еллар...* М.Галиев

2) Шул әгъзаның беләзектән алып бармак очларына кадәр өлеше, чугы. *Кулдан килгәндә, кулларыңны у, Кулдан килмәсә, кулларыңны ю.* Ә.Синугыл-Куганаклы

3) Нинди дә булса эшне башкаручыны «шул кеше» дип уйлау, гөманлау турында. *Инде менә бүген шундый әйбәт, чуклы башлы сөлге югалган икән, Хәтирә кулы булмыйча, кемнең кулы булсын?* Г.Минский

4) Берәр эшне башлап җибәрүче яки шуны башкаручының шул эш барышына яки эш нәтиҗәсенә йогынтысы (ышануларга нигезләнгән). *Кияүгә чыгарга җыенучы кызлар, синең кулың җиңел, синнән әйбер алган киленнәр кире әйләнеп кайтмыйлар дип, ашъяулыгын, тастымалын аңардан [Мәгъдәниядән] алалар иде.* Ф.Яруллин. *– Синең кулың*

*җиңел булды, эш табылырга тора әле, Исхак абзый, – диде Кирам.* Г.Галиев

5) Язу рәвеше. *Әнә бит аның язуы, аның кулы!* Г.Гыйльманов

6) Нәрсәне дә булса иҗат итү, булдыру-тудыру рәвеше; шәхси осталык чагылышы

7) Ихтыяр, карамак. *Ярларыгыз безнең кулда – Милициягә киңәш ит.* Җыр. *Балаларыгыз кеше кулында үссәләр, сезгә әйләнеп тә карамаслар.* Г.Тукай

8) *күч.* Як, тараф, юнәлеш (гадәттә *уң* һәм *сул* аныклагычлары белән кулланыла). *Төн ягына караган ишектән кергәч уң кулда, түргә якын, сандыкларга тезәп, байбичәнең үзе өчен ятак куйдылар ---.* Г.Ибраһимов. *Рөстәм, сул кулда күренгән югарылыкка менеп, «Москва» гостиницасы колонналарының берсенә сөялде.* Г.Кутуй

9) *күч.* Кешенең нинди дә булса эшчәнлеге, шөгыленең коралы, чарасы һәм шулай ук берәр анык эш күрсәткече. «*Тормышымда телгә алырлык вакыйгалар булмады» дип яза торганы --- илдәге зур вакыйгаларны үз кулы белән тудыручы иң гади совет һәм партия эшчесе иде.* Г.Бәширов. *Әлеге мәкалә --- иҗат интеллигенциясенең кулына идеология богаулары кидерергә маташуның нинди күңелсез нәтиҗәләргә китерүен этрафлы итеп, дәлилләп исбатлады.* Ә.Сәхапов. *Бу рөхсәт ителми, чөнки эшче куллар колхозда да җитми иде.* Идел

10) *күч.* Иялек, хуҗа булу. *Чөнки шул көннәрдә төрмәгә җибәрерләр дип уйлаганга, боларның кулларыннан тиз котылырмын дип өметләнә идем.* Г.Исхакый. *Ни генә әйтмә, төннәрен колхозның бар байлыгы аның кулына күчә.* Ф.Яруллин. *Донбас капкасының ачкычлары безнең кулда [бит].* И.Гази

11) *күч. кыек килеш форм.* Хакимлек, власть; биләүчелек. *Петроградта Совет большевиклар кулына күчкән.* И.Гази

12) *күч. у.-в. килешендә* Кулга алынган булу, тоткынлыкта булу турында. *Сашкасы да, кулак Латыйбы да кулда хәзер.* А.Расих

13) *күч. сөйл. кыек килеш форм.* Берәмләп сатучылар даирәсе (зур сәүдә системасына каршы куелып әйтелә). *--- халык күбрәк сөтне кулдан алырга тыраша.* Кәеф ничек?

14) *күч.* Нарасый баланы беләкләргә утыртып (яткырып) йөртү турында. *[Сабый] Кулга килгәч, бер дә ятсынмыйча, аның колак алкалары, ак беретындагы фил брошкасы белән уйнап торды.* Г.Гобәй

15) *күч.* Хатын-кызның кияүгә (тормышка) чыгарга ризалыгы. *Наташабызның матурлыгыннан «башы әйләнгән» немец аңа үз йөрәген тәкъдим итеп, кулын сорады.* Кызыл таң

16) *хәрби* Фланг, канат. *Уң кул урар, сул кул турар, урта кул ук атар.* Мәкаль. *[Хан:] Мәхмүд, син уң кулга баш булачаксың.* Г.Исхакый. *Минем кешелек иравыл, өч меңлек уң кул белән ул тиз арада кузгалып китеп, сал-күпердән чыга башларга уйлады.* Н.Фәттах

**2. кулдан** *рәв. мәгъ.* 1) Һич кичектермәстән һәм турыдан-туры (түләү, расписка бирү һ.б.ш. тур.). *[Шәкертләр] --- идарәнең куйган тәртибе буенча яшәргә кулдан язу бирсеннәр!* Г.Ибраһимов

2) **кулдан**, **кул белән** Борынгы примитив кораллар белән яки кул көче ярдәмендә генә (машина белән эшләүгә каршы куелып әйтелә). *Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.* Ә.Еники. *[Йортларның] Әллә тәрәзәләре, әллә кулдан бәйләнгән челтәрләре, әллә чигүле пәрдәсе – нәрсәседер үзенә тартты.* Ә.Дусайлы

3) Басмыйча, каләм-карандаш белән генә язып. *Каюм Насыйри кулы белән язып алынган татар халык әкиятләрендә дә халык теленең сафлыгына сокланасың ---.* Г.Бәширов

◊ **Кул алу** Дуслык билгесе итеп сузылган кулны кабул итеп кысу; күрешү, саубуллашу. *Шушы булыр безнең иптәшләрчә Күрешеп кул алу.* М.Җәлил. **Кул арасына керү** Йорт эшендә олыларга ярдәм итә, булыша башлау (үсмер балалар тур.). **Кул асты йомышы** Вактөяк йомышлар. *Аның вафатыннан соң, дөрес күңелле, тыңлаучан әдәм дип, Гыймадины Габдулла ишан үзенә кул асты йомышына алды.* Р.Шакиров. **Кул астына алу** 1) Үз җаваплылыгыңа алу (башкару, үтәү өчен). *Уракчылар кул асларына алган кишәрлекләрен уралар.* М.Гали; 2) Хакимлекне, җитәкчелекне яки берәр кешене, группаны һ.б.ш. үз карамагыңа алу. *Кардәшебез, җан күршебез чирмеш халкын тәмам кул астына җыйдылар.* М.Хәбибуллин. **Кул астына керү** *к.* **кул арасына керү**. *Унбер-унике яшь тирәсе булгандыр миңа. Кул астына керә башладым.* Т.Галиуллин. *Хатыным-кугәрченем, гомере озын булгыры, ел саен бер малай табып торды. Рәхмәт аңа, хәзер барысы да кул астына керә башладылар.* М.Хәбибуллин. **Кул астына туры килү** Ашыкканда яки кызган вакытта, ярсыган чагында кул җитәрлек, тотарлык урында булу. *Безнең әткәй кызу канлы иде, ул кызган чагында кул астына эләкмәвең хәерле.* Идел. **Кул астына эләгү** *к.* **кул астына туры килү**. **Кул астында** 1) Җитәкчелегендә, карамагында. *--- Шагыйрь Уфага кайтып төшә һәм остазы кул астында чыга торган «Ирек» газетасында языша башлый.* Г.Гыйльманов. *Әти балта остасы булып, бала чагымда аның кул астында эшкә өйрәнгән кеше идем.* Ф.Яхин. *Алар, ниһаять, көчле хан кул астында тыныч яшәргә телиләр.* М.Хәбибуллин; 2) Якын урында, тиз генә алырлык җирдә. *Нәрсә теләсәм яки кул астында нинди ризык туры килсә, шуны ашап яшәдем.* Ф.Баттал. *Суыткычның кул астында, ягъни кухняда булуы җайлы.* Өегез ямьле булсын. **Кул баглау** Кулларның терсәктән түбәнге өлешен күкрәк өстендә берберсенә чалыштырып, бер кул чугы белән икенче кулның юан беләген тотарлык итеп (яки тотып) тору – хезмәткә хәзерлек билгесе. *Вә Әбүгалисина дәхи фәсахәт вә бәлягать белән дога вә сәна әйтеп, кул баглап торганда, падишаһ бер мәртәбә гыйбрәт күзе белән карады, күрде ---.* К.Насыйри. **Кул бару** Берәр эшәке, начар яки күңел теләмәгән эшне эшли алу турында. *Кушканны гына гел үтәгәнгә, Бүген кул бармый гел бүтәннәргә.* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Кул белән алып ташлагандай** Авырту-газаплар тиз генә һәм бөтенләйгә тәмамлану турында. *Мин,*

*вөҗдан газабының кул белән алып ташлагандай кинәт югалуына бик нык шатланып, иркен суладым.* А.Шамов. **Кул белән хөкем итү** *к.* **кул хөкеме**. **Кул бирү** 1) Күрешү, саубуллашу, килешү яки дуслык билгесе итеп, кешегә кулны сузу. *Бир кулыңны, дөнья синсез һич миңа!* С.Сүнчәләй; 2) Ярдәм итү. *Халык ләкин сиңа иткән үзенең хөкмене бозмас, Егылганнарга кул бирмәс, батып барганга җеп сузмас.* Г.Тукай; 3) Атаклы ишан белән вакыт-вакыт күрешеп, аның күрсәтмәләрен һәм фатихасын алу. *Бу мулла --- Күнтәй авылының бер суфие белән Зәйнулла хәзрәткә кул биреп кайтырга бара.* М.Гафури. **Кул бирешү** *к.* **кул бирү**. *Шулай булганда гына гомерлеккә дип кул бирешергә ярый.* Б.Камалов. *Кул бирешеп алдылар, Күзләрдә үч яндырып.* Х.Туфан. **Кулга алгысыз** Иске, сәләмә, пычрак һ.б.ш. нәрсәләр турында. *Сәләмә генә дә түгел, шул кулга алгысыз чүпрәк-чапрак арасында адәми зат гәүдәсе дә ауный бугай.* Ж.Рәхимов. **Кулга алу** Арест салу, ирегеннән мәхрүм итү. *Кулга алыныр алдыннан гына ул көлтә төягән чытыр арбасына күршесендәге тол хатынны утыртып кайткан.* А.Гыйләҗев; 2) Үзеңнеке итү; хуҗа, ия булу. *Елена Глинская кенәз Овчина-Оболонский белән якынаеп китә, ә теге, үз чиратында, олан кенәзнең карачларын һәм киңәшчеләрен берәм-берәм кулга ала.* М.Хәбибуллин; 3) Үз хисләреңне тезгенләү, үз-үзеңә баш булу. *Әһә, дим эчтән генә, шушы сәгатьтән кулга ала башлыйм үзеңне.* Ф.Баттал. --- *Самат бу сораудан селкенеп китте, ләкин үзен бик тиз кулга алды.* Г.Гыйльманов. *Эшче халык кузгалсын, Беләкләрен сызгансын, Теләкләрен кулга алсын, Кирәкләрен эзләсен.* Ш.Бабич. **Кулга ияләшү** Кешеләрдән өрекми, курыкмый башлау. *Бер профессор аларга: «Урам этләрен ашаткалыйсыз бит, кулга ияләшкән берәрсен тәҗрибә уздыру өчен алып килегез әле», – дигән.* Р.Гыйлемханов. *Ул [Лариса] үзенең агачтан бик нәфис итеп уелгандай бармагы белән кай тарафка ишарәләсә, ягымлы елмайган егет шул тарафка атлап китәр иде. Кулга ияләшкән филмени!* М.Маликова. **Кулга керәм дип тору** Әзер булу; җае килү. *Ә монда, ачуым да бер килмәгәе, кулларына керәм дип торган әйберне ычкындыралар.* И.Сирматов. **Кулга керү** 1) Хосусый милек саналу, берәүнең файдалану мөмкинлеге булу. *Ярлы кеше, кулына ярым акча керсә, ярдан сикерә.* Мәкаль. *Кунакка барышлый, Җәүдәт көтмәгәндә кулга килеп кергән бүләккә куанып та куйды.* А.Хәлим. *Минем кулга кергән туп җанланып киткән сыман булды.* Р.Сафин; 2) Буйсыну, кемнең дә булса кул астында булу. **Кулга өйрәнү** *к.* **кулга ияләшү**. *Марҗа асрау коридор буенча, чәй дирбиясы күтәреп, җәһәт кенә аш бүлмәсенә таба бара; коридорның аргы башында җиде-сигез яшьлек бер ир бала, ду килеп, кулга өйрәнгән куян баласын куып йөри ---.* Ф.Әмирхан. **Кулга өйрәтү** Ияләштерү, кушканнарны яисә синең фикерләреңне тыңлап эшләргә җайлаштыру. --- *Митрополит аларга патшага тиярга кушмады, кулга өйрәттең, син үз эшең, үз йөгең башкардың инде дип, Сильвестрны юатты...* М.Хәбибуллин. **Кулга тапшыру** Кемнеңдер иркенә кую. *Ахыр чиктә Кирмән татарларының гайрәтен кайтармас өчен аны, бик ихтимал, рухани атакайлар кулына тапшыралар.* М.Хәбибуллин. **Кулга төшерү** 1) Ничек тә төрле юллар белән ия булу; 2) Сугышып яки хәйлә-мәкер белән алу; 3) Әсир, тоткын итү, пленга төшерү; 4) Яр, хәләл җефет итү. *Шәп булыр кулга төшерсәм Мин Фатыйманы әгәр...* Һ.Такташ. **Кулга төшү** 1) Хәйлә-мәкер яисә кемнеңдер тырышлыгы нәтиҗәсендә берәүнең карамагына керү. *Монда кызыллар кулына төшкән шәһәрдә калып булмас.* Ф.Латыйфи. *Борынгы китаплар да кулга төште;* 2) Әсирлеккә, тоткынлыкка эләгү. *Ләкин тигезсез бер көрәштә Сарман, яраланып, хан кулына төшә.* Г.Гыйльманов. **Кулга эләгү** 1) Тотылу. *[Пермский:] Аның әле сәнәкчеләр дигәне бар икән. ... Алары кулына эләксәң, Алла сакласын!* Н.Исәнбәт. *[Хәлил:] Кулына эләксәң, күрсәтер ул.* А.Гыйләҗев. *Ул имансыз минем кулга эләксәме...* Г.Мөхәммәтшин; 2) *к.* **кулга керү** (*1 мәгъ.*). *Аннары Шаяхмәт абзый, шунысы да бар бит әле аның: мал кем кулына эләгә...* М.Галиев. *Болай гына, очраклык белән Бер шигырең кулга эләкте.* К.Булатова. **Кулда барда** Мөлкәт, хакимият булганда. *Кулда барда файдалану.* **Кулда булу** Файдаланырга, кулланырга мөмкинлек булу, кемдер яисә нәрсәдер белән идарә итү. *Бит ханбикә булуга, Казан мәркәзе аның кулында булачак.* М.Хәбибуллин. **Кулда гына йөртү** Кадер-хөрмәт күрсәтү. *«Мин бит духтыр, курыкма, – ди, – терелтербез... Җәйгә сине кулда гына йөртербез!»* Р.Рахмани. **Кулдан килгән кадәр** Хәлдән килгәнчә, мөмкин кадәрле. *[Җангали]: Кулымнан килгән кадәр мин сиңа булышырмын, ясавыл.* М.Хәбибуллин. **Кулдан килү** Булдыра, эшли алу. *Авызындагы теленә бакма, кулыннан килер эшенә бак.* Мәкаль. *Аннан килеп тегермәнчелек тә һәркемнең кулыннан килә торган эш түгел бит әле ул.* Г.Якупова. *[Җангали:] Әйт, нинди шарт, кулымнан килә торган булса, таш яуса да үтәрем.* М.Хәбибуллин. *Әйе, безнең әтинең кулыннан килмәгән эше юк.* Ф.Яруллин. **Кулдан китү** 1) Форсат, мөмкинлек ычкыну, югалту; 2) Мөстәкыйль тормыш итә башлау, үз көнен үзе күрү. – *Кара әле, карт, Маратыбыз нинди сабыйның сабые иде! Кичә карасам – үскән икән ул, и үскән! – Күз генә тия күрмәсен... – кулдан китте, аллага шөкер...* Г.Гыйльманов; 3) Соңгы юлга озату. *Әнисен үзегез беләсез, сезнең кулдан китте.* Ф.Хөсни. **Кулдан кичү** *к.* **кулдан үтү**. **Кулдан тартып алу** Чит кешенең малмөлкәтен, сөйгәнен тырышлык-уңганлык яисә хәйлә-мәкер белән үзеңнеке итү. *[Мороз:] Чибәр хатының, Василий, чибәр. Тикмәгә генә кеше кулыннан тартып алмагансың икән.* М.Хәбибуллин. **Кулдан тоту** *к.* **кулны тоту**. *Сине уйласам, и тормыш, җаным җырлар ыргыта, Тик халкыма сузган чакта, кемнәрдер кулдан тота.* А.Хәлим. **Кулдан төшермәү** Кадерләү, бик тәрбияләү, карау. *Онык туса, кулдан төшермәбез.* К.Кәримов. **Кулдан төшмәү** Озак вакытлар бер корал белән

эшләү. **Кулдан узу** *к.* **кулдан үтү**. *Мөхәммәдьяр кулыннан борынгы грек философларының китаплары да узды: Демокрит, Әфләтун, Аристотель, Птоломей, Архимед, Эвклид хезмәтләре белән аз-маз таныш.* М.Хәбибуллин. **Кулдан үтү** 1) Эшләү, башкарып чыгу. *Мин берсене беләм: урыс кенәзенә ярлыкмы булсын, поляк падишаһына әмерме булсын, фарсы шаһына фәрманмы булсын – һәммәсе аның кулыннан үтә иде.* Г.Исхакый. *Эзе калсын керсез намусыңның, Ни үтсә дә синең кулыңнан.* М.Җәлил. **---** *аннан соң [Агасире] баһадир каршына өелгән коралларга ымлады. – Болар барысы да минем кулдан узды, баһадир.* М.Хәбибуллин; 2) Өйрәнү, үзләштерү (китаплар, кулъязмалар һ.б.ш. тур.); 3) Берәрсе тарафыннан үтерелү. *Фәхринең кем кулыннан үтүе турында күңелләрдә шөбһә бик кайный иде.* Г.Ибраһимов; 4) Файдалануда булу (женси теләкләрне канәгатьләндерү тур.). **Кулдан ычкыну** 1) Югалу. *Калмады, ычкынды кулдан алтын дәвер, белмәдек, Белмәдек туганда, җаннар кол буласын белмәдек.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Момент кулдан ычкынган.* Х.Камалов. *Яшь гомер ике килми. Вакыт кулдан ычкына!* Р.Мулланурова; 2) Буйсынудан чыгу; әсирлектән котылу. *Василий, мәсәлән, бертуктаусыз немецлар кулыннан ычкыну турында уйлана.* Ә.Еники. *Сөйләш, энем, үткәзеп сөйләш. Югыйсә кулдан ычкына бит.* Н.Гыйматдинова. **Кулдан ычкындыру** Югалту. *Борынгыча – байларча эш йөртеп килгән татар сәүдә капиталы чәй монополиясен кулдан ычкындыра.* И.Рәмиев. *Егетне кулдан ычкындырмаска иде, бик булдыклы күренә.* М.Ахметшина. **Кулдан эш китү** Стресс, күңелсез яки шатлыклы хәбәрдән эшли алмау. *Ай, ул җанның яшертен генә сызланып сыктаулары, тән гайрәтен басарга теләп уфылдаулары; аһ, ул йөрәккәйнең тозакка эләккән кош сыман тыпырчынуы, боегуы, җырлыйсы килгән җырының бугазына басып эндәшми калулары, кулдан эш китүләре...* Ә.Гаффар. *Ә бала чирләсә, кулдан эш китә.* Р.Мулланурова. **Кулдан эш төшү** *к.* **кулдан эш китү**. *Тукталдым да тынып калдым. Бу нинди мизгел, ниткән? Нидән аяклар атламый? Ник кулдан эшем төшкән?* Н.Сафина. **Кулда тоту** 1) Буйсындырып тору, хакимлек итү. *Әйтик, Василий Шуйский кенәз Дума башында утырса, Иван Телепнев килгән илчеләрне кабул итте, кыскасы, хакимиятне үз кулында тотты.* М.Хәбибуллин. *Мин Муравьёв штабында махсус элемтә бүлеген кулда тоттым.* Ш.Шәйдуллин. *Феодаллар аларны [крестьяннарны] король ярдәменнән башка да кулда тота алалар.* Урта гасырлар тарихы; 2) Хисләрне йөгәнләп тору, тышка чыгармау, үз-үзеңне контрольдә тоту. *Үзеңне кулда тота белергә дә кирәк!* **Кул җае** Берәр (гадәттә физик) эшне булдыра алу, шуңа өйрәнү мөмкинлеге. --- *Кул җаен сынап караган Әүвәл үз йортыннан ул.* С.Хәким. **Кул җитү** 1) Эшләргә өлгерә алу. *КГБ архивларына үтеп кереп җыелма документларны өйрәнергә кулым җитмәде, теләгем дә юк иде.* А.Гыйләҗев; 2) *к.* **кул бару**. *Ничек итеп --- кеше малын таларга кулыгыз җитә!* И.Гази. **Кул җылыту** 1) Алдау-йолдаулы, шикле яки аеруча үзенчәлекле эшләрне башкаруда тәҗрибә туплау. *Мәрхабә, мондый эшләрдә [кызны кияү каршыларга әзерләүдә] бик күп кул җылыткан хатын кебек, ике сандыкны берьюлы ачып ташлады да кочагы-кочагы белән әйләндерә башлады.* Г.Ибраһимов; 2) Шикле юллар белән мал табу. *Бик күпләр ул сугышта кул җылытып кына калмадылар, зур капитал тупладылар.* Т.Галиуллин; 3) Кыйнау, сугу. *Халык гөж килә. Һәрберсенең кул җылытып алырга теләге зур күренә.* Х.Кәрим. **Кул калу** Берәр эшне эшләгәннән кулга (гомумән сәламәтлеккә) зыян килмәгәнне белдергәндә кулланыла. *Кулалмашка кул талмас, эшләгәннән кул калмас.* Мәкаль. **Кул карату** Кул сызыкларын багучыдан бактырып күрәзәләтү. *Кызганычка каршы, бүгенге көндә дә чегәннәрдән кул каратучылар очрый әле.* Социалистик Татарстан. **Кул кору** *к.* **кул калу**. **Кул кору** *к.* **кул калу**. **Кул кушыру** 1) Кулларыңны (бармак араларына бармакларны кертеп) бер-берсенә тоттыру (хөрмәт белән тыңлау билгесе); 2) Бернәрсә дә эшләмичә (чарасын күрмичә), битараф булып тору турында. *Инде шул фронтовик баласын, әнисез дә калган гөнаһсыз нарасыйның бөтенләйгә күзләрен йомганын кул кушырып көтеп торыйкмы?* Ф.Хөсни. *Чыннан да, болай өй кошына әверелеп кул кушырып утырсаң, берәү дә китереп бирмәс.* М.Хәсәнов. *Авыл җирендә пенсионер да кул кушырып утырмый.* Б.Камалов. **Кул кую** 1) Документ, хат яки башка берәр язманың, картинаның һ.б.ш. мәгънәсе өчен җаваплылык, шаһитлык, ризалык яки истәлек билгесе итеп имзаңны язу. *Ниндидер актлар төзеп кул куйдырмакчылар иде дә, «мин бернәрсә белмим, беркемне күрмәдем, монда кем дә юк» дип куып чыгардым үзләрен.* Т.Галиуллин. *Шартнамә исә федератив мөнәсәбәтләрнең төрле рәвештә булырга мөмкин икәнен күрсәтә. Бу Россия тарафыннан кул куелган конвенцияләргә туры килә.* Казан; 2) Раслау, ризалык, канәгатьлек белдерү. *Рәмзия Илфатның ата була белүенә эчтән кул куеп утырды.* Б.Камалов. **Кул күтәрелү** *к.* **кул бару**. **Кул кыздыру** *к.* **кул кызу**. --- *татар кухнясының чиксез мөмкинлекләрен эшкә җигәрдәй уңган аш пешерүчеләр берберсен уздырырга тырышып кул кыздырадыр.* М.Галиев. **Кул кызу** Эшкә бик нык бирелеп, дәртләнеп китү; нинди дә булса эшне эшлисе килеп тору. *Бу оста – әйткән эшне ялтыратып эшләп куя, бер кулы кызгач, әйтмәгәнен үзе күреп тә эшли иде.* Ф.Хөсни. **Кул кыска** Нинди дә булса эшне эшләргә ирек булмау, рөхсәт ителмәү, көч җитмәү турында. *[Рөстәм:] Я, егетләр, авылны бик кысмыйсызмы? [Госманов:] Кысар идек тә, кул кыскарак. Бик кысарга ирек бирмиләр.* Һ.Такташ. **Кул кысу** Күрешү, саубуллашу, дуслашу яки тәбрикләү билгесе итеп, кешенең кул чугын учлап кысу. *Кыз елмайды, егетнең кулларын кысты.* Г.Ибраһимов. **Кул кычыту** Берәр нәрсә эшләп ташларга яки берәрсен кыйнарга ашкынып, ярсып тору. *[Хәйдәр:] Хыял бу, туган. Әйтергә кирәк, йөгәнсез фантазия! Кул кычыту бәласе.* Г.Бәширов. **Кул**

**көче** Физик хезмәт. *Кул көче белән яшәүче икенче бер гаилә – Дамир һәм Зәйнәп Мәгъсүмовлар.* Кәеф ничек? **Кул күтәрү** 1) Дини йола буенча: дога укыганда, кулларны уч ягы белән биткә якын тоту. *Менә карчыклар, хәерле юл теләп, кул да күтәрделәр.* Г.Бәширов; 2) Сугарга әзерләнү, кизәнү; сугу. *Бәхәсләшеп, дуслык дигән изге Чиктән узып китеп, Кул күтәрде икәү берберсенә Кинәт кызып китеп.* И.Юзеев. *Адәм затына кул күтәргән кеше генә куркак була.* М.Хәбибуллин; 3) Җәмәгать урыннарында сөйләргә, җавап бирергә һ.б.ш. теләк белдерү. *– Солтанъяр бабай, минем дә сорау бар иде, – дип кул күтәрде ---.* З.Мурсиев; 4) Уң кулны баштан югарырак күтәрү юлы белән тавыш бирү, берәр карарга һ.б.ш. ризалык белдерү. *Минем тәкъдимгә егермеләп кеше кул күтәрде.* Ш.Камал. *Раифов Әхмәтне классның стена газетасына хурлап язарга дип кул күтәрдек.* Г.Мөхәммәтшин. **Кулларын җәю** Чарасызлыкны, мөмкин түгеллекне, аптырау яки гаҗәпләнүне белдереп, кулларны як-якка җәеп җибәрү хәрәкәте. *Ветсанитар Галләм абзыйдан сорасаң, ул да кулларын гына җәя.* Ә.Еники. *Кулларны җәяргә юк – эшләргә кирәк!* Идел. **Кулны кире кагу** Тормышка чыгу турындагы тәкъдимне кабул итмәү. *Егетнең кулын кире кагу.* **Кулны кисәргә бирәм** Үзе бик нык ышанганда, башкаларны да ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе. *Кулымны кисәргә бирәм! Төзүче, бетончы, балта остасы да аннан ким алмый.* Ш.Бикчурин. **Кулны күкрәккә кую** 1) Түбәнчелек күрсәтү, гафу үтенү билгесе; 2) Чын ихлас күңелдән һәм ышанычлы итеп әйтү турында. *Кулны күкрәккә куеп әйтәм, барысы да син дигәнчә эшләнде.* **Кулны сорау** Тормышка чыгарга тәкъдим ясау. *Тагын аның төсле бер егет бар. --- Минем кулымны сорап йөри.* Ф.Яхин. *Монысы кызлар колагына: төшеңдә чәчәк аткан розалар күрсәң, тиздән кулыңны сораячаклар.* Г.Гыйльманов. **Кулны тоту** Эшләргә комачаулау, эшкә тоткарлык ясау. **Кулны тою** *к.* **кулда тоту** (*2 мәгъ.*). *Остаздан башка кем суксын – Кулны булмый тоеп.* М.Әгъләмов. **Кул озайту** 1) Йодрык кулланып мөгамәлә итү, ору-сугу. *Никадәр кул озайтсалар да, күңелендәге изге йолдызны сүндерергә теләсәләр дә, шагыйрь аның сүнмәгәнен белдерә.* Г.Кашшаф; 2) Һөҗүм итү. *Озайттылар миңа кул төрле мәлгунь көч, кара көчләр.* Г.Тукай; 3) *к.* **кулы озын булу**. **Кул остасы** Кул көче белән башкарыла торган нинди дә булса бер эшкә бик оста кеше. *[Госман] Груздевка шалтыратып, берәр юньлерәк һәм төплерәк кул остасы җибәрүен үтенде.* Э.Касыймов. **Кул очы** Вак-төяк чыгымнар, кесә чыгымнары. *Акчасын Мәрхабә үзе бирә. Монысын инде – кул очына калдырган тиеннәреннән; югыйсә эшләп алганын тулысы белән әнисенә китереп тапшыра.* Г.Әпсәләмов. **Кул пычрату** Үтә вак, көчсез дошманны кыйнау турында әйтелә. *[Әхмәди:] Кулларымны пычратасым килми. Сугып екмыйм.* Ә.Бикчәнтәева. **Кул салу** 1) Берәр нәрсәгә ия булырга омтылу; талау. *Әүвәл Казанга атасы Иван Өченче кул сала, шуңа әтәчләнүедер.* М.Хәбибуллин; 2) Урлау, законсыз үзләштерү. *Хөкүмәт милкенә кул салу*; 3) Һөҗүм итү, җәберләү. *Ә мин Аллага шөкер кылам, кешегә кул салганым булмады, әйе, хатын-кыздан башка. Аларга кул салырга ярый, чөнки аларның яртысын шайтан яраткан.* М.Хәбибуллин; 4) Хатын-кызларны көчләргә омтылу. *[Хаҗия Гыйлемдарга:] Инде үз асравыңа кул салу кебек түбәнлеккә барып җиткәнсең.* Т.Гыйззәт; 5) Җинаятьчел рәвештә үтерү. *Миңа үлем җәзасы чыгарыгыз. Үзем җиренә җиткерермен. Болай гына үз-үземә кул сала алмыйм.* Ш.Маннур; 6) Берәр эшкә тотыну, шуңа көч кую. *Әни, табигый хәленә төшеп, гадәттәге эшли торган эшләренә кул сала башлады.* М.Гафури. **Кул селкү** 1) Билгеле бер юнәлешкә каратып кул чугын җилпү – күрергә теләмәү, баш тарту яки инкяр итү билгесе. *– Кирәкми, кирәкми! – диде Ирнәс кулын селтәп. – Безгә киләчәктә эш күп булачак әле.* Р.Фәизов; 2) Өмет өзү; бөтенләйгә араны өзү. *Утка чыксын бөтен дөньясы дип, Кул селтәдем хәзер барыннан.* Н.Исәнбәт; 3) Бөтенләй баш тарту. *Бикмөхәммәт --- эшкә барудан бөтенләй кулын селтәгән.* Г.Насрый. **Кул селтәү** *к.* **кул селкү**. *«Яры-ый, маэмай димәгәннәр бит әле...» дип кул селтәү үз битеңә үзең төкерү була.* Х.Сарьян. **[Кулга] кул сугу** 1) *к.* **кул чабу**. *Бер егет гармонь уйный, Шәриф бии, кул сугу, сызгыру, дәртле хәрәкәтләр.* М.Фәйзи; 2) Килешү, үзара ризалашу билгесе итеп, шапылдатып, бербереңнең кулын кысу. *Өйгә кереп сөйләшик тә кулга кул сугышыйк, булмаса.* Х.Сарьян. **Кул сузу** 1) *к.* **кул бирү** (*1, 2 мәгъ.*) *Мин Имәлинең яныма килүен көтмәдем, үзем башлап кулымны суздым.* М.Әмир; 2) *к.* **кул озайту** (*1, 2 мәгъ.*). *[Әтиемнең] әнигә кул сузганын, ягъни аны сугу, кыйнау дәрәҗәсенә җиткәнен күргәнем булмады.* М.Гафури; 3) *к.* **кул салу** (*1, 2, 4 мәгъ.*). *Көчле көчсезгә кул сузмасын, арыслан дәвәнең муенын өзмәсен, эт төлкенең тунын ертмасын --- дип боерган, дигән.* Әкият. --- *Мәскәү кенәзе Казанны алса, Әстерханга кул сузар ---.* М.Хәбибуллин; 4) Үз кулы белән башкарырга, берәр эштә катнашырга омтылу. *Пычак-пәке кайраулар, утын ваклауларны әйтмим дә. Авыл җирендә теләсә кайсы малай җиде-сигез яшендә андый эшләргә кул суза бит инде.* Э.Касыймов. **Кул сузымы** Бик якын ара. *Сәхнәдән кул сузымы ераклыкта тамашачы утыра.* И.Рәмиев. **Кул сырты белән дога кылу** Бәддога кылу. *Алар [руханилар] мәчеттә безгә каршы кул сырты белән дога кылсалар, --- безнең кулда башка чаралар табылыр.* Г.Ибраһимов. **Кул тарту** *сир.* Баш тарту. *Безнең Аю батыр сугыштан да кул тартмас иде, ни чара, аяклар ауга чорналган.* Г.Тукай. **Кул тидерү** 1) Җәзалау яки куркыту максаты белән ору-сугу. *Тагын да Фәрхиягә кул тидерәсе булсаң, җаныңны алырмын, бел дә тор шуны.* Ш.Камал; 2) Нәрсәне дә булса эшли, эшкәртә башлау. *Кул тидерә, күңел сала торгач, кошчылык фермасының эшләре рәтләнә башлады.* С.Рафиков. **Кул тимәгән** 1) Файдаланыла, эшкәртелә башламаган (һәртөрле табигый байлыклар тур.). *Әнә бит, сәфәргә җыенган чагы, алда аны кул тимәгән*

*икенче бер дөнья көтеп тора*... Р.Низамиев; 2) Тотыла, сарыф ителә башламаган. *Кул тимәгән запаслар*; 3) Гыйффәтле, саф (хатын-кыз тур.). *Кеше куллары тимәгән Ярлар таба аласыңмы?* Җыр. **Кул тию** 1) Чистартылу, тазартылу. *Өстәл өстендә консервлар, бушап калган тәлинкәләр, хатын-кызлар кулы тимәгән бер кофейник тора.* А.Шамов; 2) Ремонтлану, төзәтелү, эшкәртелү турында. *Тир түкмәгән ир ир түгел, Кул тимәгән җир җир түгел.* Ә.Синугыл-Куганаклы; 3) Тикшерелү яки яхшыртылу, редакцияләнү турында. *Аңа [романга] әдипнең революциядән соңгы иҗат кулы да тигән.* Г.Нигъмәти; 4) *к.* **кул җитү** (*1 мәгъ.*). *Гариза – сукно астында. Кул тими әле һаман.* З.Мансур. **Кул тыгу** Эшкә эзләүсез-сораусыз катнашу (гадәттә әрсез һәм начар кеше тур.). *Бәдри мулла --- вак бурыч оешмаларына кул тыгарга тырыша.* Х.Кәрим. **Кул уйнау** 1) Бик җитез эшләү, эштә осталык һәм җитезлек күрсәтү. *Эшләгәннең кулы уйный, эшләмәгәннең күзе уйный.* Мәкаль; 2) Берәр шикле эштә кемнең дә булса актив катнашлыгы булу. *Яхшы ирләр кул уйнатмый, Хатынны да кыйнап атмый.* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Кул уңае** Эшләргә, эшкәртергә җайлы торыш. *[Шәрифулла] кирпечләрне кырып, чистартып, кул уңаена тәртипләп өеп куйды.* А.Шамов. **Кул хезмәте** *к.* **кул көче**. *Кул хезмәте ысуллары борынгыларның рухын милләткә сеңдерә дип саныйлар японнар.* Безнең юл. **Кул хөкеме** Судсызнисез (гадәттә йодрык белән) җәзалау турында. *Бүген аларның [Закир белән Галимәнең] икесен ике урынга куеп, каравыл куегыз, кул белән хөкем итүче булмасын!* М.Гафури. **Кул һөнәре** *к.* **кул эше** (*1 мәгъ.*). *--- яшь мулла хатынын кул һөнәренә өйрәтә башлагач, боларның кадере артты.* Г.Исхакый. **Кул чабу** Алкышлау. *--- Ә мин һаман шигырь дыңгырдатам һәм --- үземә үзем кул чабам.* Л.Лерон. *Руслар чын күңелдән кул чаптылар.* М.Мәһдиев; 2) Кул чапканга охшаган тавыш чыгару турында. *Ширәмәтовлар йортының ташландык коесында җил елый, ә төсе уңган кызыл әләм, шуны котыртып, шапы-шопы кул чаба.* Ә.Гаффар. **Кулы авыр** Берәү башлаган эшнең уңышлы тәмамланмавы турында. *Аның белән барып булмый, кулы авыр.* **Кулы белән эшләү** Берәр эш-гамәлне икенче берәүдән эшләтү яки ул башкарган кебек итү. *Син инде, Лександр, ил башында сабый кенәз утыра дип уйлыйсыңдыр, хаталанма, тәхеттә кенәгинә Елена Глинская утыра, ул хакимлек итә хәзер, һәммә нәрсә аның кулы белән эшләнә.* М.Хәбибуллин. **Кулы каты** Усал (кеше тур.). **Кулы коргыры** *к.* **кулы корысын**. **Кулы корысын (корышсын)** *карг.* Кулы эшкә яраксыз хәлгә килсен, хәрәкәтсез калсын, дип теләү. *«Кулы корысын иде хәерсезнең», – дип өзгәләнгән иде [Мария Семёновна].* Б.Камалов. *Иң әйбәтен кискән, кулы коргыры.* Ф.Яруллин. **Кулы кулга иярми** *к.* **кулы кулга йокмый**. *Булды, чиләге тулды инде. Аның җиләкме-фәләнме, чикләвекме җыйганда кулы кулга иярми дә йокмый: әллә мизгел, әллә кан агымы кебек, вакытны тоймыйча эшли дә эшли.* Ә.Гаффар. **Кулы кулга йокмый** Бик җитез һәм оста эшли. *Килен үзе дә җиңнәрен сызганып алган, итәк кыстырулы, кулы кулга йокмый.* Ф.Хөсни. *Тегермән сүтүчеләрнең куллары кулга йокмый башлады.* Ә.Гаффар. **Кулына калу** Яшәү ихтыяҗлары белән кемгәдер бәйле булу; кемнеңдер тәрбиясендә булу. *Өметбай әнә шулай Гөлчибәр карчык кулына калды.* Д.Бүләков. **Кулына карау** *к.* **кулына калу**. **Кулына шайтан төкергән** Бик оста, бик булдыклы. **Кулын куеп китмәгән** Кемлеге билгесез (гадәттә начар эш эшләүче тур.). **Кулын кыскарту** Каршы төшү, билгеле бер эшкә тотынмаслык, бармаслык итү, юл куймау, мөмкинлекләрне чикләү. *Кулларын кыскартырга кирәк андыйларның, хәләл көч белән яшәргә өйрәнсеннәр.* Б.Камалов. **Кулын чишү** Чиксез мөмкинлекләр бирү. *Хәзер исә болар юк, Җангали хан хәтта каракларның да кулларын чиште.* М.Хәбибуллин. **Кулы озын булу** 1) Урлашу, караклык итү; 2) Сугышырга ярату; 3) Мөмкинлекләре киң булу. **Кулы тар** Акча азлык, мөмкинлек юклык. **Кулы ябышып тору** *к.* **кулы ятышлы**. *Мөдәррис исә бер атна эчендә шигырь сөйләр өчен сәхнәле итеп, иркен сарай корып куйган. Кыяфәт тә элеккечә, кулы коралга ябышып тора каһәрнең.* М.Галиев. *Малайның сбруйга кулы ябышып торганлыгын күреп, Корбангали абзый эченнән генә куана ---.* Ф.Хөсни. **Кулы ятышлы** Оста, булдыклы. **Кул эше** 1) Хатын-кызларның бәйләү, тегү, чигү кебек вак йорт эшләре. *Балкон һәм лоджияләр табигатьтән ераклаша барган шәһәр кешесенә гөлләр үстерергә, өйдән чыкмыйча гына һава суларга, китап я кул эше белән гөлләр арасында утырырга өстәмә мөмкинлек бирә.* Өегез ямьле булсын; 2) Шундый эш предметы. *Хатын-кыз, нәкъ авылдагыча, кул эшләрен күтәреп, күрше-күләнгә утырмага йөри.* А.Расих; 3) Кул эше белән хәзерләнгән төрле әйберләр. *[профессор Фукс:] --- Мин татар хатын-кызларының кул эшләрен бик яратам инде, җиңги.* М.Гали. **Кул ябышу** 1) Берәр эшне (гадәттә физик хезмәт өлкәсендә) аеруча оста, җитез башкару; 2) Аерым берәр эшкә сәләтле булу; 3) Гомумән эшли алу. **Кул ягу** 1) Үтерергә омтылу; кул күтәрү. *– Бүреләр --- Сарыкларга кул якмыйча тик йөриләр.* М.Гафури; 2) Нәрсәгә дә булса ия булырга омтылу, кул сузу. *Хәзер, совет вакытында, әллә ниткән буржуй алтыннарына кул ягып, башны җәфага саламыни кеше.* Ш.Камал. **Кул яту** *к.* **кул ябышу**. *Күзәтеп йөрим: кулыгыз ята.* А.Гыйләҗев. *Ярый әле фрау Крюгер һәммәсенә үзе оста икән, арбайтерның андый эшләргә кулы ятмавына гаҗәпләнмәде ---* Т.Әйди. *Кәрим Төмәндә туган, кулы эшкә ята башлагач, атасы һөнәренә ия булган.* И.Салахов

**КУЛ** II *и. диал.* 1) Инешле ерынты, сулы сыза. *Болар [өч елга] кушылалар да ул җиргә чаклы кечкенә кул гына булып агып яткан Өзән елганы берьюлы зурайтып җибәрәләр.* Г.Ибраһимов. *Кул термины татар гидронимиясендә инешле ерынты, сулы сыза мәгънәсендә йөри.* Ф.Гарипова

2) *диал.* Үзән; чокыр

**КУЛ** III *с.* 1) Лаеклы, яраклы. *Түбән яктан берәү менә, Бөрлегәннән кызыл*

*тун тышы; Килгәннән бирле карап торам, Сез икән безгә кул кеше.* Җыр

2) Җайлы, уңай, кулай. *[Хакның] Яртысын акчалата биргәч, [сәүдәгәрләр], әлбәттә, үзләренә кул булмаган, үтмәс товарны алмыйлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Кулак өчен гаҗәп кул кеше инде. Шундый бөкре башлы түрәләр.* Һ.Такташ

**КУЛАВЫЗ** *и.* 1) Таныш булмаган яки үтүе авыр җирдә (кичү, үткел, батлакыкта) юл күрсәтүче. *Кулавызсыз юлга кергән юлдан язар.* Мәкаль. *Шуннан соң картка эт ышанычлы кулавыз булды.* М.Хуҗин

2) *күч.* Дини остаз; рухи җитәкче

3) *күч.* Гид

4) *күч.* Арадашчы. *Кыз, кымыз, кубыз – шайтанга өч кулавыз.* Мәкаль

5) *күч.* Белешмәлек

**КУЛАВЫЗЛЫК** *и.* Кулавыз эше, хезмәте. *Эт тырнакларын хуҗасының киемнәренә батырып карышты, кулавызлык вазифасын үтәргә теләмәде.* М.Хуҗин

**КУЛАГАЙ** *и. диал.* **1.** Ришвәтче. *Кулагайга акча төртү*

**2.** *с. мәгъ.* Ришвәт алучы

**КУЛАЗА́К АРБА** *и.* 1) *к.* **кузалак**

2) *диал.* Бүрәнә тарттыра торган гадәттә ике тәгәрмәчле арба. *Шул егет кулазак арбага ат җигеп урманга барган була.* Әкият. *Уракчылар кайтып китүгә, дыңгыр-дыңгыр килеп, кулазак арбага мичкә салган өлкән ат караучы Әхмәт абзый төшә.* М.Мәһдиев. *Акчулпан: – Бүген кулазак арбага җикмә әле, – дип каршы төште.* М.Хуҗин

**КУЛАЙ** *с.* **1.** 1) Уңайлы, җайлы. *Көн бөркү, ә тимер, ни әйтсәң дә, салкынча, күктән иңгән шикелле, авылга көтмәгән-нитмәгәндә аеруча мөһим эшләр буенча өлкән тикшерүче килеп төшкәндә, ут йөгергән арт санының суытырга бигрәк тә кулай инде.* Ә.Гаффар. *Юашлык дөнья көтү өчен кулай булмаган, күрәсең.* М.Юныс

2) Җайлы, отышлы. *Болай эшләү агитаторларга да бик кулай күренде.* Ф.Яруллин

3) Лаеклы. *Без арба белән тартып кайткан Перкунас абыйга да Зөлхәбирә апа кулай эш тапты.* А.Хәсәнов

4) Әйбәт, яраклы. *Митрополитка Иван Дүртенче кулай, кулга ияләшкән, аның сүзен карусыз үти вә тыңлый иде.* М.Хәбибуллин. *Бюрократлар акыл һәм талант иясенә караганда ялагай һәм кулай бәндәләрне тизрәк күтәрәләр ---.* В.Имамов. *Бөтен рухи халәтең, теләгең, омтылышың белән син – безгә булышырга иң кулай кеше.* Т.Әйди

**2.** *рәв. мәгъ.* Җайлы, уңайлы; отышлы. *Бандитларга бик кулай килеп чыга бит.* Н.Дәүли

**КУЛАЙЛАШТЫРУ** *ф.* Кулай итү, җайлаштыру. *Үзенә күрә мөхтәсибәт кантуры сыман нәмәстәкәй дә, җомга намазларын үткәрү өчен гыйбадәт йорты да кебек куышыбыз булыр диеп, колхозның ат алачыгындагы җимерек өен кулайлаштырган идек.* А.Хәлим

**Кулайлаштыра бару** Торган саен ныграк кулайлаштыру

**Кулайлаштыра башлау** Кулайлаштырырга тотыну

**Кулайлаштыра төшү** Бераз кулайлаштыру

**Кулайлаштырып бетерү** Тулысынча кулайлаштыру

**Кулайлаштырып карау** Кулайлаштырырга омтылу

**Кулайлаштырып кую** Алдан кулайлаштыру

**КУЛАК** *и. төрки тар.* 1) Ялчылар, хезмәтчеләр тотучы авыл бае; байгура. *Ләкин ясаклы крестьяннан чыккан кулак та аристократия белән вак йомышлыдан саналмады ---.* Г.Гобәйдуллин

2) Совет хакимияте тарафыннан, сыйнфый дошман дип аталып, юкка чыгарылган хәлле крестьян катлавы һәм шул катлауның бер вәкиле. *«Колхоз җитәкчесе була торып, кулак калдыгы Зыятдин кызына өйләнгән» дип, еллар буе күземне ачырмадылар...* Р.Вәлиев. *Кулакларны куганда да, Югары авыллар үз араларыннан таза тормышлы крестьяннарны читкә сөрергә ирек бирмәгәннәр.* А.Гыйләҗев

**КУЛАКЛЫК** *и. тар.* Кулакларга хас сыйфатлар; кулак булу

**КУЛАЛМАШ** *рәв.* **1.** *к.* **кулалмашка**

**2.** *и. мәгъ.* Бергә ярдәмләшеп эшләүче кеше. *Әнә шул мең бәла белән тапкан ризыгыңны ялгыз гына ашау юк, чөнки син бүген тапсаң, кулалмашың иртәгә нидер юнәтә.* А.Гыйләҗев

**КУЛАЛМАШКА** *рәв.* 1) Икәүләп эшли торган эштә: парга. *Кулалмашка кул талмас, эшләгәннән кул калмас.* Мәкаль. *Нәби, Хөсәен кордашы белән кулалмашка эшли-эшли, --- бу өйне әйбәт кенә торырлык хәлгә китергән иде инде.* Р.Төхфәтуллин

2) Ярдәмгә. *Тормыш аек, шулкадәрле аек: кулалмашка компьютерлар килде...* Р.Низамиев

3) Бер эш көненә бер эш көне түләү шарты белән эшләшеп. *Кулалмашка көтү көтешү*

**КУ́ЛАРА** *рәв.* 1) Төп эштән тыш тагын башка эштә. *Монда мин кулара гына эшлим*

2) *сөйл.* Вакыт-вакыт. *Кулара безгә дә килеп китә инде ул*

◊ **Куларага керү** Ярдәм итү. *Шамил куларага керә дә башлаган икән инде: Иртештән су алып менде.* Я.Зәнкиев

**КУЛАРБА** *и.* Йөкне кул белән тартып ташу өчен җайлаштырылган ике тәгәрмәчле кечерәк арба. *Куларбамны тартып узган чакта, Бөкрәеп, алга сузылып, Икешәр дә өчәр машиналы Күршеләрем кала кызыгып.* И.Юзеев. *Керә куларба тартканы, Иңгә зур биштәр асканы... Утырган, ауган, басканы: Гел юлда язмыш вокзалы!* Р.Рахмани

**КУ́Л АРБАСЫ** *и. к.* **куларба**. *Чыклы чәчәкләр чабып, печән итеп киптерер өчен, кул арбасы белән алып кайтырга түгел, ә күрше кызы Зөлфиягә такыя үрер өчен алып кайтырга сусаган идем.* Ә.Гаффар. *Кул арбасын икәүләп тартып, юл буе сөйләшеп бардык.* Р.Фәизов. *Өч малай окоптан бәләкәй кул арбасы сыман ике тәгәрмәчле бер нәмәрсә тартып чыгардылар.* З.Зәйнуллин

**КУЛАСА** *и. рус диал.* 1) Су агымының көче белән әйләнә торган махсус тәгәрмәч, зур чарык. *Пароход борылып китәр өчен артка чигәргә тиеш иде – гөжләтеп куласасын әйләндереп җибәрде.* Х.Сарьян. *Малай чакта тегермән куласасына ябышкан малай мин.* М.Галиев. *Барлык тирә-як авыллар белә: Тәтерләр арба, чана ясыйлар,*

*шомырттан бик матур итеп тарантас үрәләр, су тегермәненә коры куласалар ясыйлар.* З.Зәйнуллин

2) Калаклы тәгәрмәч, калаклы вал. *...Вакыт миннән зур уяулык сорый! – Стеналар зыңлый, таңнар зыңлый: «Мәртәбәгә заман юл ачса... Кояш сүнмәс, яшәү сүнмәс дигән, Киләчәккә юл өзелмәс!» – дигән Ышанычым – гигант куласа!* Ф.Гыйззәтуллина. *[Мәүлет] --- биш-алты көн дигәндә куласа күчәренә каеш тарттырып станок ясады, пычкы көйләп куйды һәм бүрәнәләрне дә тарттырып куйды.* Ш.Бикчурин. *Шулай да, нинди җил иссә дә, аларның берәр төрле куласаны әйләндереп җибәрүе хәерлерәк түгелме?* Мәдәни җомга

**КУЛ-АЯК** *җый. и.* 1) *к.* **аяк-кул**. *Ай бәбекәчем, рәхмәт төшкере, мине болай зурлаганың өчен мәңге рәхәт яшә, кул-аякларың сызлаусыз булсын.* Ю.Әминов. *Аның бөтен тәне авыраеп, башы томаланып тора һәм кул-аяклар хәлсез яналар.* Ә.Еники. *Кулы-аягы исән таза ир кеше хәер сорарга тиеш түгел.* Р.Батулла

2) *биол.* Кайбер хайваннарда үзгәргән очлыклар. *Ярым маймылларда ботакны кочаклап тотуга җайлашкан җитез озын кул-аяк бар.* Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы

◊ **Кул-аягы белән каршы** Берәр нәрсәне кискен кабул итмәү. *Әнинең кул-аягы белән каршы килүенә карамастан, Габбани иртәнге чәйдән соң ук баз казырга кереште.* Ә.Галиев

**КУ́Л БАЛАСЫ** *и. диал.* Яшь бала

**КУЛБАШ** *и.* 1) Беләк калак сөягенә тоташкан урын. *– Миңа бәхет! – диде «Промстрой» начальнигы, күршесенең кулбашына дусларча кагылып.* Ф.Абдуллин. *Әтисе, буш йөгәнне нишләтергә белмәгәндәй, әле кулбашына сала, әле балтырларына бәргәләп, йөгәндәге ак тәңкәләрне чылтырата.* Ә.Баян. *Гүя аны ул [Разыя] гына коткара ала: аның кулбашларында канатлары бар!* А.Хәлим

2) Киемнәрнең кулбаш турысы. *Кофтаның кулбашын ерту*

**КУЛ-БАШ** *җый. и.* Баш һәм куллар. *Вахил мулла кулын-башын юа, үзе чәйнекне кыздырып чәйне сала...* Г.Исхакый

**КУ́Л БАШЛАУ** *ф. иск.* Сугышта гаскәрнең бер өлешен атакага күтәрү. *Туй башлаудан кул башлау җиңел.* Мәкаль

**КУЛБАШЛЫЛАР** *и. биол.* Умырткасыз хайваннар классы. *Алар эчәккуышлы, энә тиреле хайваннар, моллюсклар, кулбашлылар, суалчаннар, буынтыклы хайваннар булганнар.* Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы

**КУЛ-БИТ** *и. җый.* Куллар һәм бит. *Озак йөрде ул: кул-битләрен канатып, әрәмәлекләрне айкады; бата-чума, сазлыклар кичте...* Г.Гыйльманов. *Иван Телепнёв хезмәтчесе керткән табакта кул-битен юды да Фёдорның иңбашыннан алып сөлгегә сөртенде һәм күзге каршына барып басты.* М.Хәбибуллин. *Кул-битне генә түгел, тез тиңентен аякларны да юып җибәргәч, арулар онытылып китте.* И.Сирматов

**КУЛГА́-КУЛ** *рәв.* Бер-берсенең кулыннан тотышкан хәлдә. *Ә сул яктагы мәгъшуклар кулга-кул тотынышканнар, һәм бу фани дөньяда аларның гаме юк.* А.Тимергалин. *Шуңа да карамастан бер-берсен яхшы белгән уртак язмышлы безнең халыкларыбыз киләчәккә – коммунизм капкаларына кулга-кул киләләр иде.* Т.Миңнуллин

◊ **Кулга-кул биреп** *к.* **кулга-кул тотынышып**. **Кулга-кул тотынып** *к.* **кулга-кул тотынышып**. *Бораулаучы белән нефть чыгаручы кулга-кул тотынып эшләмәсә, хезмәтнең кызыгы да юк кебек.* Җ.Рәхимов. **Кулга-кул тотынышып** 1) Дусларча; килешеп. *Олан кенәз тәрбиячесе Сильвестер белән кулга-кул тотынышып яшиләр, имеш.* М.Хәбибуллин; 2) Бергә. *Бәхет белән хыял кулга-кул тотынышып йөри ул.* Р.Вәлиев. *Без тормыш диңгезен кулга-кул тотынышып кичик...* А.Тимергалин

**КУЛДА́Н-КУЛГА** *рәв.* Бер кешедән икенчесенә, өченчесенә, башкаларга күчеп; әле берсенә, әле икенчесенә күчеп. *Үзе исән чагында [Габделҗаббар Кандалый] шигырьләре язма килеш кулдан-кулга йөри.* И.Бәхтиев. *Ак чехлар белән кызыллар арасында барган тарткалашта авыл биш тапкыр кулдан-кулга күчкән.* Г.Гыйльманов

**КУЛДАШ** *и. сир.* 1) Аркадаш, ярдәмче; партнёр. *Арифә машиналары белән маташучы кулдашларын борчып тормады...* Р.Мирхәйдәров. *Реклама ялгыз түгел, аның кулдашлары бар: әйбер кирәклегенә иманып өлгергән күршең, хатының, балаларың.* М.Юныс

2) Мәсләктәш, фикердәш. *Яңа эш башлаганда, кулдашлар кирәк*

**КУЛДАШЛЫК** *и. сир.* Кулдаш булу. *Берәрсен кулдашлыкка алу*

**КУ́ЛЕР** *и. инг.* Зур савыттан су алу җайланмасы. *Бүлмәдә кулер, вентилятор, кондиционер һ.б. бар*

**КУ́ЛИ** *и. тамил* 1) Көнчыгыш Азиядәге кайбер илләрдә: кул арбасына яисә өч тәгәрмәчле велосипедка җигелеп, йөк яки пассажир ташучы кара эшче. *Кули булып йөрү*

2) Авыр кара эштә эшләүче

**КУЛИНАР** *и. рус* Кулинария остасы; аш-су белгече. *Җиңгәсенә «атказанган кулинар» дигән исем һич тә юкка гына бирелмәгән.* Р.Төхфәтуллин. *[Аның кызы] «Бәхетле» ширкәтенең кондитер цехы начальнигы, кулинарларның төбәкара ассоциациясе әгъзасы, --- Франция кулинарлар академиясе дипломанты.* Т.Нәҗмиев. *Кулинарлар, бу моллюсклардан 100 төрле ашамлык әзерләргә мөмкин, диләр.* Ә.Халидов

**КУЛИНА́РИЯ** *и. лат.* 1) Аш-су әзерләү осталыгы, аш-су әзерләү сәнгате. *Парфюмериядә һәм кулинариядә очрый торган бөтен исләр тулган анда [урманда].* М.Мәһдиев. *Татар кулинариясендә сөтне куерту, әчетүоету, кайнату ысуллары кулланыла.* Табында сөт ризыклары

2) Әзер ризыклар һәм ярымфабрикатлар сатыла торган кибет

**КУЛИ́СА** *и. фр.* 1) *театр* Театраль декорациянең сәхнәдә ян-якларга бербер артлы урнаштырылган яссы өлешләре. *Мин кулиса артында оештыру эшләре белән тыз-быз киләм, һәммә нәрсә үзем теләгәнчә башкарылсын дип борчылам.* М.Сәлимҗанов

2) *муз.* Бакыр тынлы музыка кораллары тавышының югарылыгын үзгәртү-көйләү өчен кулланыла торган өлеше

◊ **Кулиса артында** Халыкка белдерелмәгән, яшертен, матбугатта чагылыш тапмаган

**КУЛИЧ** *и. гр.* Православие бәйрәме Пасхага сөткә-майга изеп пешерелә торган, биек, түгәрәк формадагы баллы икмәк. *Кулич пешерү*

**КУЛКАНАТЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Алгы очлыклары канатларга әверелгән, төнлә актив тереклек алып бара торган имезүчеләр отряды; *русчасы:* **рукокрылые**. *Кулканатлылар бөтен җир шарына таралганнар.* Биология. *Кулканатлыларга очар этләр һәм яркацатлар кирә*

**КУ́Л КӨРӘШЕ** *и. спорт* Армрестлинг. *Әгәр 1993 елда Балтачта узган «Нәүрүз» бәйрәмендә кул көрәшенә чыгып карамаса, Әлфия ханым Зыятдинова да үзенең дөньяда иң көчле хатын-кыз булуын белми калыр иде.* Акчарлак

**КУЛКУБЫЗ** *и.* Скрипка төре. *Кулкубыз тартсаң – көй чыга, бүрәнә тартсаң – өй чыга.* Мәкаль

**КУЛЛАГАЧ** *и. диал.* Гадәттә кабер, изге чишмә һ.б. өстенә куелган агач яки хач, тәре баганасы

**КУЛЛАМА** *и. этн.* Терлекнең майлы түш итенә,йөрәк, бавыр-бөерләрен, эчәк-карталарын өстәп пешерелә торган һәм, вак кына итеп тураганнан соң, шулпада шакмаклап киселгән токмач белән аралаштырып кайнатып, парландырып алудан гыйбарәт милли ашамлык. *Дөньяда кулламадан да тәмле аш юктыр дип ышана идем мин малай чакларда.* М.Әмир. *Безнең әти ашлысулы кеше булганга, безнең әнинең кабартмасы, коймагы, кыстыбые, бәлеше, кулламасы данлыклы булганга, кунактан өзелеп тормый идек ---.* С.Поварисов

**КУЛЛАНМА** *и.* **1.** 1) Инструкция, күрсәтмәләр җыелмасы; ярдәмлек. *Аның [Г.Т.Таһирҗановның] «Тарихтан – әдәбиятка» дип аталган хезмәте (1979) – безнең теманы ачу өчен кирәкле кулланма.* Ф.Гарипова. *Кулланучыга КМ ПБ эшләнмәләренең эш принципларын һәм дөрес файдалануны аңарга мөмкинлек бирәчәк интерактив техник кулланмалар булдырыла.* Татарстан

2) Белем бирү, уку-укыту эшендә ярдәмлек итеп куллану өчен басма хезмәт. *Әсәрнең бигрәк тә беренче һәм икенче баблары, Мөхәммәд һәм беренче хәлифләр тарихын өйрәнү өчен, элекке татар мәдрәсәләрендә шәкертләргә дәреслек, мөгаллимнәргә кулланма хезмәтен үтәгән.* С.Вахиди. *Аларның кайберләрен ул 1967 елны студентларның практик дәресләре өчен чыгарылган кулланмада бастыра.* М.Госманов. *[И.Бәширова] «Гомуми тел гыйлеме һәм татар стилистикасының теоретик нигезләре» дигән темалар буенча методологик кулланмалар яза.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ярдәмлек буларак кулланыла торган, күрсәтмәләр туплаган. *Китап сөючеләргә төрле темадагы әдәби басмалар да, кулланма дәреслекләр дә, сувенирлар белән бергә мөселман киемнәре дә тәкъдим итәләр әлеге кибеттә.* Мәдәни җомга

2) Көнкүрештә еш кулланыла торган. *Кулланма әсбаплар*

3) Кулланырга яраклы

**КУЛЛАНУ** I *ф.* Эштә, нинди дә булса максатларда файдалану. *Даут Сөнгатович ферзь гамбитыннан башлады, шулаймы?! Каро-Канн саклануын кулланды, шулаймы?* М.Галиев. *Ул каратэ алымы кулланып, мине асфальтка атып бәрде...* Г.Гыйльманов. *Җәзаларның нинди төрләрен генә кулланмаганнар утызынчы елларда.* А.Гыйләҗев

◊ **Куллану кәрзине** Кешегә яшәр өчен беренче чиратта кирәк булган барлык нәрсәләрнең минималь бәяләре суммасы. *Росстат мәгълүматлары буенча, куллану кәрзиненең бер айлык минималь бәясе Мәскәүдә 1819,6 сум, Татарстанда 1277,8 сум тәшкил итә.* Мәдәни җомга

**Куллана бару** Булган нәрсәләрне эштә, билгеле бер максатларда эзлекле рәвештә куллану

**Куллана башлау** Кулланырга тотыну. *Ул бу тәгъбирне шулхәтле яратып куллана башлады ки, хәтта көннәрдән бер көнне яраткан нәни оныгы артык шаяра башлагач, аңа да гадәте буенча: «Утыртам мин сине!» – дип ычкындырган имеш.* Р.Мирхәйдәров

**Куллана килү** Шушы вакытка кадәр даими куллану. *Кулъязмаларны куллана килү*

**Куллана төшү** Тагы да бераз куллану

**Кулланып бетерү** Тулысынча, барысын да куллану. *Буяуларны кулланып бетерү*

**Кулланып бетү** *к.* **кулланып бетерү**. *Барлык мөмкинлекләр дә кулланып беткәнме?* И.Низамов

**Кулланып карау** Нәрсәне дә булса сынау өчен куллану; кулланырга омтылу

**Кулланып тору** Әледән-әле, һәрвакыт куллану; әлегә, вакытлыча гына куллану

**КУЛЛАНУ** II *и.* Нәрсәдән дә булса файдалану процессы. *Булган статистика базасын тагын да тирәнрәк анализлау шуны күрсәтә: 2005 елга әлеге төбәкләр белән «Халык куллануы товарлары» һәм «Азык-төлек товарлары» буенча – уңай, ә «Сәнәгать товарлары» төркеме буенча тискәре сальдога ия.* Татарстан

**КУЛЛАНУДАГЫ** *с. сир. к.* **кулланыштагы**. *Куллланудагы товар*

**КУЛЛАНУЧЫ** *и.* Җитештерелгән товарны куллана торган зат. *Күп кенә очракларда җир асты суларын кулланучыга уңайлы, якын урында чыгарырга мөмкин.* Татарстан. *Тарифларның иң зур һәм иң түбән чикләре мәгълүматларыннан чыгып, кулланучылар төркемнәре буенча электр һәм җылылык энергиясенә тарифлар булдырылды.* Идел

**КУЛЛАНЫЛУЧАН** *с.* Гадәттә еш кулланыла торган; үтемле булган. *Кулланылучан товарлар*

**КУЛЛАНЫЛУЧАНЛЫК** *с. к.* **кулланыш**. *Товарларның кулланылучанлыгы ихтыяҗ белән билгеләнә.* Татарстан

**КУЛЛАНЫЛЫШ** *и.* 1) Куллану ешлыгы. *Көнбатыш Европада Урта гасырларда бик күп төрле акчалар кулланылышта йөри торган булган.* Кызыклар дөньясында

2) Нәрсәнең дә булса эш-процесста кулланылуы. *Чыннан да, компьютерлар, электрон хисаплау җайланмалары мәгариф системасында киң кулланылыш алды...* Мәгърифәт

**КУЛЛАНЫШ** *и. к.* **кулланылыш**. *Кулланыштан чыккан акча кебек Ята хәзер алар [яфраклар] юлларда.* Ф.Яруллин. *Моннан берничә дистә*

*еллар элек «милли идея» дигән төшенчә фәнни кулланышыбызда булмады дип әйтсәк, ялгышмабыз кебек.* К.Гыйззәтов. *Алар күләмнәре буенча зур түгел, экономияле, гади, кулланышка тиз кереп китәләр һәм илебезнең төрле төбәкләрендә теләсә нинди шартларда файдаланыла алалар.* Татарстан

**КУЛЛАНЫШЛЫ** *с.* 1) Кулланыла торган. *Инде бит дөнья бер кулланылышлы шприцларга күчте.* Ф.Яруллин

2) Кулланырга яраклы. *Кулланылышлы кулъязмалар*

3) Куллану өчен уңай, җайлы

4) Иң еш кулланыла торган. *Кулланылышлы товарлар*

**КУЛЛАНЫШСЫЗ** *с.* **1.** 1) Кулланылмый торган, кулланыш тапмаган. *Кулланылышсыз мәгълүматлар*

2) Кулланырга җайсыз, уңайсыз

**2.** *рәв. мәгъ.* Кулланылмыйча. *Кулланышсыз яту*

**КУЛЛАНЫШТАГЫ** *с. к.* **кулланышлы**. *Көндәлек кулланыштагы су эчәргә ярамас дәрәҗәдә пычранган.* И.Әмирханов

**КУЛЛАП** *рәв.* 1) Сыңар (бер) яки ике кул белән. *Карчык ике куллап яулыгын рәтли дә җиңел генә бер көрсенеп куя ---.* Ә.Еники. *Габделхәмит, каты ыңгырашып, ике куллап башын тотты.* С.Зыялы

2) Кул биреп. *Ике куллап көрешү*

**КУЛЛЫ** *с.* 1) Кулы яки кулга охшаш органы, әгъзасы булган. *Сигез куллы сигез якка юллы.* Табышмак

2) *күч.* Ярдәмчесе булган. *Уллы ата – куллы ата.* Мәкаль

**КУЛЛЫ́-АЯКЛЫ** *с. күч.* Саусәламәт, бөтен (гадәттә кеше тур.). *Куллы-аяклы үзең, шөкер итәргә кирәк*

**КУЛЛЫК** *и. диал.* 1) *к.* **җиңсә**. *Ак куллык янында өстәл өстендәге таплы ашъяулык оялып китте.* Г.Исхакый

2) Хатын-кыз күлмәкләрендә, свитерларда һ.б.ш. җиңне кыска итеп калдырып, беләзектән терсәккә яки беләккә кадәрен салып куярга мөмкин итеп эшләнгән өлеше. *Хәзер киемнәрне яңадан куллыклар белән тегәләр.* Татарстан яшьләре

**КУЛОН** I *и. фр.* Бер яки берничә кыйммәтле таштан яки затлы металлдан ясалган, муенга тагыла торган бизәнү әйбере. *Соңрак томар сүзе «бизәк, бизәнү өчен асылган кулон, медальон» мәгънәсен алган (буй томар, путемар).* Р.Әхмәтьянов. *Алтын кулоннарга, медальоннарга татарча итеп эскизлар эшләдем.* Мәгърифәт

**КУЛОН** II *и. фр. физ.* Электр тогы микъдарын үлчәү берәмлеге. *Фарадей законнарыннан, электролиз вакытында бер валентлы матдәнең бер грамм-атомын аерып чыгару өчен, электролит аша 965000 кулон электр корылмалары уздырырга кирәк дигән нәтиҗә чыга.* Физика курсы

**КУ́Л ПЫЧКЫСЫ** *и.* Бер кул белән генә эшләтелә торган кечкенә пычкы. *Аңарга кечкенә кул пычкысы эләккән иде. Кисә башлау белән, ул кипкән ботакка эләкте дә зыңлап китте.* Ф.Яруллин

**КУЛСА** *и.* 1) Кыска рычаг яки рычаглар системасыннан торган механизм

2) Шундый механизм белән идарә итү өчен тотка. *Бәхетне бер умырып томар идек, Тик кайда соң аның кулсасы?* Р.Идиятуллин

**КУ́Л СУГЫШЫ** *и.* 1) Ату коралыннан башка яки, гомумән, бернинди коралсыз сугыш, көрәш. *Окоп эчендә сапёр көрәге белән кул сугышы оештыру, тревога белән чыгып йөгерү, төн үткәнче кырык-илле километр араны марш-бросок белән үтү.* З.Зәйнуллин

2) Күңел ачуның йодрык белән сугышудан гыйбарәт булган бер төре

**КУЛСЫЗ** *с.* 1) Кулы булмаган, чулак. *Ике кабере бар... Үзе яши әле! Тыныч кына ятмый түшәгендә. Ыргыталмый калган гранатасын кулсыз кулы эзли төшләрендә...* М.Галиев. *Кулсыз солдат яшенә тыгылып сөйләвен дәвам итте.* М.Юныс. *[Галләметдин] Кулсыз җиңен киң солдат каешына кыстырып куйган, уң кулына ике башы да ачыла торган тимер ручка тоткан.* Г.Кашапов

2) Кулы, имгәнү, сызлау, авырту сәбәпле, эшкә яраксыз булган. *Кулсыз әле мин, эшли алмыйм*

◊ **Кулсыз итү** *к.* **кулсыз калдыру**. **Кулсыз калу** 1) Ярдәмчесез, булышчысыз калу. *Улым шәһәргә укырга киткәч, хуҗалык эшендә кулсыз калдым*; 2) Авыр хезмәт яки башка сәбәп белән кулларның эшләрлек көче калмау, кулларның көче алыну. **Кулсыз калдыру** 1) Ярдәмчесез, булышчысыз калдыру; 2) Авыр эш эшләтеп яки башка бер юл белән кемнең дә булса кулларын эшли алмаслык хәлгә китерү

**КУЛСЫ́З-АЯКСЫЗ** *с.* **1.** Кулы да, аягы да булмаган. *Кулсыз-аяксыз ирләргә дә асылынырга гына торалар иде алар.* Ф.Баттал. *Күзләрен шардай тәгәрәтеп, кулсыз-аяксыз, телсез һәм буынсыз булып ята...* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кулсыз, аяксыз килеш. – *Кулсыз-аяксыз кайтса да риза булыр идек әле, – диделәр.* К.Тимбикова

2) Ярдәмчесез. *Балалар да киткәч, тәмам кулсыз-аяксыз калдым*

**КУЛСЫЗЛЫК** *и.* 1) Кулсыз булу. *Гариплек, сукырлык, аяксызлык, кулсызлык, саңгыраулык темаларын олыдан куптарырга бер генә татар иҗатчысы да җөрьәт итмәде шикелле.* Р.Батулла

2) Ярдәм итәргә кеше булмау. *Кулсызлык эшне вакытында төгәлләргә комачаулый*

**КУЛТАМГА** *и.* 1) *тар.* Имза урынына йөргән, имза функциясен үтәгән тамга. *«Гел шагыйрь була күрче...» Зөлфәт култамгасы.* Р.Әхмәтҗан. *Култамга үрнәкләре*

2) Имза. *Прокурорның якыннан аралашкан кешеләре әлеге хәрефләрнең аның имзасы, култамгасы икәнен яхшы беләләр иде.* Р.Мирхәйдәров. *Сирәк кунаклар ядкәренә үз култамгасын да куйдырдылар [Җәүдәттән].* А.Хәлим. *[Илфак Ибраһимов та] Беренче урынбасарыбызга «Тәлгат Габдрахмановичка» дип култамгасын салып, китабын бүләк иткән әле менә.* Т.Нәҗмиев

**КУЛТАЯК** *и.* Гадәттә таянып йөрү өчен махсус кыска таяк. *Ә менә сул як күршеләре Мөхтәрәм абзый – култаягы сыман кыска, минсиңайтим.* А.Хәлим

**КУЛТЫК** *и.* **1.** 1) Беләкнең югарыгы өлеше белән ян арасы. *Ике карбыз бер култыкка сыймас.* Әйтем

2) Куен. *Кочагымда ап-ак хризантемалар! Култыгымда син...* А.Гыйләҗев

3) Култыкка (*1 мәгъ.*) кыстырып ташырлык әйбернең күләме. *Харис бер*

*култык арыш саламы алып кереп, аны салкын суда юып бирде.* К.Кәримов

4) *күч.* Үсемлектә: сабак белән кәүсә арасының иң түбәнге өлеше; култыкча. *Култык бөресе*

5) *күч.* Берәр нәрсәгә ясалган уенты. *Чүлмәк тә чүлмәк сары май Мич култыгында эридер.* Җыр

6) Төп мәйданнан читтәрәк торган җир; ышык урын. *Анда бер ямьле, җыйнак култыкта сыйлану, мөгаен, күңеллерәк булыр.* Т.Әйди

7) *махс.* Сулыкларның коры җиргә уелып кергән өлеше. *Уңда исә диңгез һәм диңгез култыклары булырга тиешле якта, әле яшеллеген җуймаган урман белән капланган тәбәнәк калкулыклар сузылып китә.* Н.Фәттах. *Җилнең кар исе аңкып торган салкын сулышы култыкны уратып алган кызыл таллыкны, камышларны шаулатты ---.* М.Хәсәнов. *Диңгез култыгының камышлары – Чишмәңнең нәкъ сыкрау тавышлары.* Ә.Синугыл-Куганаклы

8) Урман читеннән эчкәрәк кереп торган агачсыз җир. *Урман култыгы*

9) *күч. к.* **култыкса** I

**2.** *с. мәгъ.* Якын, чын. *Монда да олы сүз култык дустыбызның авызыннан чыккач, шым калып тыннарны кыстык.* Ф.Яхин

**КУЛТЫ́К АСТЫ** *и. к.* **култык** (*1 мәгъ.*). *[Әхмәдиша] Култык астына кереп оялаган папкасын якындагы бер табуретка өстенә ташлады да ванна бүлмәсенең ишеген ачты.* Ф.Баттал. *Алар --- аяусыз төстә кытыкларга, акыртып көлдеререгә тотынды. Култык аслары да, кабыргалары да, табаннары да калмады.* Ә.Гаффар

◊ **Култык астында үсү** Якланган-сакланган булу. *«Барсын, дөнья күреп кайтыр, – диде уллары, – юкса синең култык астында гына үсеп иркәләнеп бетте».* Ф.Яруллин. **Култык астында яшәү** *к.* **култык астында үсү**

**КУЛТЫ́К-КУЛТЫК** *с.* Рәттән берничә култык (*5–8 мәгъ.*) рәвешендәге. *Култык-култык урманнар*

**КУЛТЫКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **култыклау**

2) Уем барлыкка килү; култык сыман эчкә кереп тору

**Култыклана бару** Торган саен ныграк култыклану

**Култыклана башлау** Култыкланырга тотыну

**Култыклана төшү** Бераз култыклану

**Култыкланып бетү** Бик күп култыклар барлыкка килү

**Култыкланып тору** Култык булып күренү

**КУЛТЫКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Култыктан тоту; беләктән үзенең беләге белән эләктерү. *[Фатыйма] Хатыныңны култыклап мәҗлескә барасыңмы, юкмы?* Х.Вахит. *Майор хатынын култыклап китеп барды.* Р.Кәрами

2) Култыкка (*1 мәгъ.*) кыстыру

**2. култыклап** *рәв. мәгъ.* Бергәләп, берлектә. *Кеше биредән бәхетен култыклап чыга.* Х.Вахит

**Култыклап алу** Тиз генә култыклау. *Егылып китүчеләрне култыклап алалар.* А.Гыйләҗев. *– Димәк, монда да тәхет бүлешү бара, Җангали хан, – диде ясавыл һәм Җангали ханны култыклап алды.* М.Хәбибуллин. *Бауман буйлап барам шулай, култыклап алмасынмы берәү.* Ф.Баттал

**КУЛТЫКЛЫ** *с.* Култыкланып торган. *Агыйдел буйлары иңсәле, Иңсәле җирләре култыклы.* Җыр. *Ул ял итә торган култыклы урында балык шәп каба.* Ф.Яхин

**КУЛТЫКСА** *и.* 1) Балкон, баскыч, нинди дә булса махсус мәйданчык кырыена тотынырлык, таянырлык итеп буйга беркетелгән әйбер; кизә. *Ул, баскыч култыксасына таянып, күзләрен йомган килеш, шактый ара басып торды.* Р.Вәлиев. *Иң якында, култыкса аша иелеп, пулемётын безгә төбәп, ике солдат басып тора.* А.Гыйләҗев

2) Диван, кресло, кайбер урындыкларның махсус эшләнгән, таянып, кулны куеп утырырга мөмкин булган уң һәм сул яклары. *Олуг хан, илченең кабалануын ошатмыйча, Феофанга күз төшереп алды, тәхет култыксасына кулларын куйды.* М.Хәбибуллин

3) *сир.* Култык таягы. *Култыкса белән йөрү*

**КУЛТЫ́К ТАЯГЫ** *и.* Аяксыз яки аягы гарипләнгән, имгәнгән кешеләргә йөрү өчен, култыкка (*1 мәгъ.*) җиткән һәм аркылы терәлгече булган махсус таяк. *Гомергә болай култык таягына калмас, яшь тән төзәлер, аягына бер басар әле, Алла боерган булса.* Ф.Хөсни. *[Вәдүт карт] --- култык таякларын меңсигез йөз туксан өченче елгы винтовка урынына уйнаклатып алды.* Ә.Гаффар. *Госпитальдәге яралы солдатларның култык таяклары да шулай шыгыр-шыгыр итә.* Р.Ишморатова

**КУЛТЫКЧА** *и. бот. к.* **култык 1.** (*4 мәгъ.*)

**КУЛТЫРАК** *и. этн.* 1) XIX гасырга кадәр: хатын-кыз җиләненең бик озын җиңе

2) Хатын-кыз бөркәнчегендә: аркага кайтарылып тегелгән бизәк рәвешендәге ялган җиң

**КУЛТЫРМАЧ** *и. этн.* 1) *к.* **култырак** (*2 мәгъ.*)

2) Погон яки погонсыман бизәк. *Култырмачлар тегү*

**КУЛУАР** *и. фр.* **1.** 1) Кайбер иҗтимагый биналарда (парламент, театрда) төп, зур залга тоташкан ябык коридор, кечерәк зал. *Кулуарда сөйләшү*

2) Рәсми булмаган очрашулар

**2.** *с. мәгъ.* Рәсми булмаган. *Болары, нигездә, кулуар сөйләшүләрдә.* Р.Фәйзуллин

**КУЛЧАТЫР** *и. неол.* Зонтик. *Кулчатырлар чәчәк атты берәм-берәм.* Г.Сәлим. *Әгәр сез кулчатырыгыздан озак файдаланмаган булсагыз, аны вакыт-вакыт ачып карарга һәм җылы душ астында берничә минут тотарга киңәш итәбез.* Идел. *[Яңгыр ява башлагач] Халык таралышмады, кулчатырлар астында бәйгеләрне тамаша кылуын дәвам итте.* Мәдәни җомга

**КУЛЪЮГЫЧ** *и.* Бит-кулларны юу өчен суны кирәкле күләмдә генә агызып була торган махсус савыт. *Номерыбызны ачып кердек. Ике карават. Кечкенә генә өстәл, шкаф һәм кулъюгыч.* М.Юныс. *Тараканга көч керде: Кызурак йөгерде. Кулъюгыч кранына Менеп тә ул өлгерде.* Г.Исхакова. *Кулъюгычлары да җайлы гына икән.* Казан утлары

**КУЛЪЯЗМА** *и.* **1.** 1) Кулдан язылган текст. *Кулъязмалар янмый, дип*

*сөйлиләр, Нәрсә генә икән яна соң... Кулъязмалар да бит төрле була, Начарлары ничек янмасын?* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Киңәш-табыш итеп, кулъязма белән өстән-өстән генә танышкач, мәрхүм үзе «Хатирәләр» дип атаган төргәкне Мюнхенга, «Азатлык» радиосында татар-башкорт редакциясенең баш мөхәррире Гариф Солтан әфәндегә юллыйлар.* А.Гыйләҗев. *Кулъязмаларны бер дә игътибар белән карамыйсыз.* М.Галиев

2) Текстның оригиналы. *Текстны кулъязма белән чагыштыру*

**2.** *с. мәгъ.* Кулдан язылган. *Бу – кулъязма журнал иде.* Ә.Гаффар. *Быелның февраль аеннан бирле Татарстанның халык фронты карамагында Хоцей берүзе диярлек «Марксист» исемле кулъязма журнал чыгарып килә.* Идел

**КУЛЪЯЗУ** *и.* Кулдан язу рәвеше, почерк. *– Равил, сәлам! – дип язган иде ул үзенең хәттатларныкыдай тигез һәм матур кулъязуы белән.* И.Хуҗин

**КУЛЪЯУЛЫК** *и.* Кул-битне сөртеп алу өчен махсус кечкенә тукыма кисәге. *Килеп чыкты чиккән кулъяулык авылдагы иске сандыктан...* И.Юзеев. *[Күзлекле] --- аннары кесәсеннән дүрткә бөкләнгән ап-ак кулъяулык алды да бармак очларын сөртте.* М.Мәһдиев. *Диларә, башын читкә борып, кулъяулыгы белән күзләрен сөртергә тотынды.* З.Садыйков

**КУЛЫШ** *и.* Иректе күләмдәге салым

**КУ́ЛЬМАН** *и. нем.* Вертикаль яки бераз авыш урнаштырылган сызым тактасы. *Ә эчтәрәк, кульманнар артыннан, чалбар балаклары яки биек үкчәле ыспай туфлиләр генә күренә иде ---.* М.Маликова

**КУЛЬМИНАЦИОН** *с.* Кульминациягә җиткән, үсешенең иң югары ноктасындагы. *Орденны нәрсә өчен бирүләре турында сөйләгәндә, Закирҗан кызып китте һәм хикәянең иң кульминацион ноктасында калай кружка төбендәге спиртны су кушмый гына йотты...* М.Мәһдиев. *Дәреслек-хрестоматиядәге өлешләре беренче сюжет сызыгының төенләнешен (йолык туе – вакыйгалар үстерелешенең бер аралыгын, Казаяклар килү – кульминацион ноктаны, Алмыш хан таләбенә Тотышның каршы чыгуы һәм чишелешне, Тотышның җиңелеп, әсир төшүе) хасил итәләр.* Д.Заһидуллина

**КУЛЬМИНА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) *астр.* Күк җисеменең меридиан турысыннан үтү моменты. *Кульминация ноктасы*

2) *күч.* Вакыйгалар үсешенең иң киеренке, иң югары ноктасы. *Вакыйгалар шундый үсеш алган: күз алдында – кульминациясе!* Л.Шагыйрьҗан. *Музыка кульминациягә күтәрелә, Зәкәрия аңа җыр белән кушыла.* Х.Вахит. *Сюжет турында сөйләгәндә, төенләнеш, кульминация, чишелеш кебек төшенчәләр нәкъ менә әсәр төзелешен аңларга ярдәм итә.* Д.Заһидуллина

**КУЛЬТ** *и. лат.* 1) Дини табыну һәм шуңа бәйле дини йолалар. *Төрки халыклар дастаннарында да Канатлы Елан-Сазаган культы эзләре сакланып калган.* С.Шәмси. *Угызлардагы су культына (Су тәңре) килгәндә, Ибне Фадлан аларның суга кагылудан саклануларын һәм үзләре күргәндә башкаларны да бу эштән тыюларын әйтә.* Татар әдәбияты тарихы

2) Хөрмәткә, олылауга лаек кем яки нәрсәдер. *Әйе, географик термин – моның өчен культ.* М.Мәһдиев. *Шагыйрь әсәрнең төп кыйммәтен аның хикмәтле булуында күрсә дә, хикмәтлелек халык авыз иҗатында гыйбрәтле сүз әйтү, фикер – сүз культы белән генә чикләнми.* И.Юзеев. *--- өлкәннәр культы аңа гомеренең соңгы елларына кадәр хас булды кебек.* Р.Зәйдулла

3) *күч.* Кешегә яки нәрсәгә дә булса табыну, Алла урынына күрү; шуның белән чиктән тыш мавыгу. *Һәр заманның яман чире була: Туберкулёзлары, тифлары... Саф җаннарны кырган шәхес культы, Йоткан нәфес культы типлары.* Л.Лерон. *Шәхес культын күпме генә сүкмә, Качып булмый культтан: Ул һәр чорда акыл иясенең Бугазыннан тоткан.* М.Әгъләмов

**КУЛЬТ-** *лат.* Кушма сүзләрнең «культурага бәйләнешле» мәгънәсендәге кыскартып алынган беренче кисәге (мәс., *культпоход, культтовар* һ.б.)

**КУЛЬТЛЫ** *с.* Шәхес культы хөкем сөргән. *Аһ, теге чор – культлы, шомлы чор – Балаларны ничек имгәткән.* Х.Туфан

**КУЛЬТИВА́ТОР** *и. фр.* Сөрелгән туфракның өске катламын йомшарту, җирне чүп үләннәрдән арындыру һәм минераль ашламалар белән тукландыру өчен кулланыла торган авыл хуҗалыгы машинасы. *Бер культиватор Нарат чокырында җиргә сеңеп бара. Исәпкә бар, санга юк...* Ф.Баттал. *Сабан-чәчкеч җитми, культиваторлар җыелып бетмәгән, тырмалар шулай ук...* Н.Фәттах. *Бүгенге көндә завод илнең аграр тармагында бик зур ихтыяҗга ия булган, өр-яңа модельле, энәле-роторлы яссы төрәнле КПИР 3,6 культиваторы эшләп чыгаруны җайга салды.* Татарстан

**КУЛЬТИВАЦИОН** *с.* Культивациягә бәйләнешле. *Культивацион биналарның түбәләрен пыялалап эшләү аркасында, үсемлекләр яктылыктан да файдалана алалар.* Яшелчәчелек

**КУЛЬТИВА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Сөрелгән җирне культиваторлар белән йомшарту эше. *[Кыр эшләре] Көйле генә барды быел, инде тирә-күршеләр дә, «Таң» колхозы да дым каплады, тырма, культивация дә бетеп килә, кайбер басуларда чәчүне дә башлап җибәргәннәр инде.* Р.Фәизов

2) *к.* **культиватор**. *Тагы бер тәүлектән иген чәчеләсе басуга культивация кереп китте.* Х.Камалов

**КУЛЬТИВА́ЦИЯЛӘҮ** I *ф.* 1) Культивация ясау. *Туфракны яз эшкәртү көз сөрелгән мәйданны тырмалаудан һәм кабат сөрүдән яки башта культивацияләп, аннары тырмалаудан гыйбарәт.* Яшелчәчелек

2) Үстерү, махсус карап үстерү

3) Хуп күрү, таралуына булышлык итү. *Яхшы сыйфатларны культивацияләү*

**Культивацияләп бетерү** Ахыргача, беткәнче культивацияләү

**Культивацияләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр культивацияләү

**Культивацияли башлау** Культивацияләргә тотыну

**КУЛЬТИВА́ЦИЯЛӘҮ** II *и. к.* **культивация**. *Сугарулы участокларда, буразналап сугарганда, культивация-*

*ләүдән соң буразналар сызалар һәм рассаданы буразна янтыгының төбенәрәк утырталар.* Яшелчәчелек

**КУЛЬТИВА́ЦИЯЛЕ** *с.* Культивацияләнгән. *Культивацияле җирләр*

**КУЛЬТУ́РА** *и лат.* 1) Кешеләр тормышында, үзара мөнәсәбәтләрдә, тудырган материаль һәм рухи кыйммәтләрдә чагыла торган, кешенең иҗади мөмкинлекләре, җәмгыятьнең билгеле бер тарихи үсеш дәрәҗәсе. *Әдәбиятлар тарихында шундый әсәрләр бар ки, исемнәрен телгә алу белән, аларны иҗат иткән халыкларның рухи культура дәрәҗәсе, эстетик идеал югарылыгы күз алдына баса.* Татар әдәбияты тарихы. *Материаль культура*

2) Берәр өлкәдәге иң югары казанышлар дәрәҗәсе. *Тыңла син, Мәскәүдә укымаганың күренеп тора, тыңлый белү культурасына өйрәнергә кирәк.* М.Галиев. *Сәяси культура көндәшеңнең җиңеп чыгуын таный белү сәләтенә дә бәйле.* Татарстан

3) Аерым тарихи дәверләр, халыклар, милләтләр характеристикасы. *Урыслардан телебез, динебез, килеп чыгышыбыз һәм культурабыз – күп ягыбыз белән аерылабыз.* Т.Әйди. *Сезнең шул турыда – милли культурабызның киләчәге турында уйлап караганыгыз бармы?* М.Мәһдиев. *Болгар шул вакыттагы культураның аерым яклары турында сөйли.* Татар әдәбияты тарихы

4) Тарихи этник-локаль берләшмәнең материаль калдыклары җыелмасы. *Икенче төрле итеп әйтсәк, шушы кабиләләр яшәгән төбәкләрдә Салтау культурасы үсеп чыга ---.* Казан утлары. *Имәнкискә археологик культурасы*

5) Махсус игеп үстерелә торган үсемлек, микроорганизм. *Борчагын, арышын, уҗым бодаен җыеп алдык дип тә бетерә алмыйсың, соңгы культуралар өлгерә.* Б.Камалов. *Элеккечә бердәнбер культура булган мамыкка түләү хакы тиеннәр белән исәпләнә, бай табигатьле, ипиле яклар бөлгенлеккә төшә бара.* Г.Мирхәйдәров. *Нурлатка килгән аграр белгечләр фикеренчә, басулардагы сабан культураларыннан мул уңыш көтелә.* Татарстан

6) Мәдәниятлелек, укыганлык, гыйлем. *Культурага омтылу*

**КУЛЬТУ́РАЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Культуралы итү. *[Галимнәр] Урта Азиядәге халыкларны культуралаштыруда --- бик зур роль уйнаганнар.* СССР тарихы

2) Авыл хуҗалыгы культуралары үстерү өчен яраклы хәлгә китерү, уңдырышлыга әйләндерү. *Зирек агачы, күрән, нарат үләннәре үсә торган җирләр, культуралаштырганнан соң гына, бакча өчен яраклы хәлгә килә.* Иң шәп календарь. *Кара туфраклы булмаган зоналы районнарда сөрү катлавын кимендә 20–22 сантиметрга кадәр тирәнәйтергә һәм культуралаштырырга тәкъдим ителә.* Яшелчәчелек

3) Игеп үстерелә торган үсемлеккә, аерым бер төр культурага әйләндерү. *[Баклажан] Беренче булып Һиндстанда культурлаштырыла, аннан башка илләргә дә тарала.* Ботаника. *Хәзер чабыр үләнен культуралаштыралар, яңа сортларын чыгаралар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**Культуралаштыра бару** Даими һәм эзлекле рәвештә культуралаштыру

**Культуралаштыра башлау** Культуралаштырырга керешү

**Культуралаштырып бетерү** Тулысынча культуралаштыру

**КУЛЬТУ́РАЛАШУ** *ф.* 1) Культуралы булып китү, мәдәниятлегә әверелү

2) Культуралаштырылганга әйләнү

**Культуралаша бару** Эзлекле рәвештә культуралашу

**Культуралаша башлау** Культуралашырга керешү

**Культуралашып бетү** Тулысынча культуралашу

**Культуралашып килү** Акрынлап культуралашу

**КУЛЬТУ́РАЛЫ** *с.* **1.** 1) Иҗтимагый һәм рухи тормыш өлкәсендә югары казанышлары булган, шуларга таянган (милләт, халык, ил һ.б.ш. тур.). *Культуралы әдәбият үзенең һәр күренешен, һәр яңа әсәрен барлап, тикшереп, аларга бәя я диагноз куеп барырга тиеш.* Р.Харис. *Алар Мисыр, Сурия кебек бай культуралы илләрдә җаваплы һәм җитди урыннарда эшләгәннәр.* Татар әдәбияты тарихы

2) Мәдәниятле, тәртипле, әхлаклы (кеше тур.). *Яшьтәш үзенә культуралы, интеллигентларча мөнәсәбәт таләп итә башлады.* М.Мәһдиев. *[Эсмеральда] Ай... Айдар абый, акылыңа кил! Үзең син шундый культуралы, шундый вөҗданлы кеше, шундый тупас рәвештә...* Н.Исәнбәт. *Болар өстенә ил халкы хезмәт сөючән, югары культуралы һәм табигый байлыклардан да бик оста, чын хуҗаларча файдалана.* Кызыклар дөньясында

3) Белемле, алга киткән; сәләтле (кеше тур.). *Минем сезне культуралы, белемле кешеләр итеп күрәсем килә.* М.Мәһдиев. *Мондагы һәйкәлләрне күрер өчен, культуралы затлар, акчаларын, вакытларын кызганмыйча, әллә нинди ерак илләрдән киләләр.* М.Юныс

4) Мәдәни, тәртипле, культура урнашкан (учреждение, предприятие һ.б. тур.). *Культуралы зур-зур шәһәрләрдә егетләр, ирләр ак оекбаш белән кара туфли кия башладылар.* М.Мәһдиев

5) Авыл хуҗалыгы культурасы булган, игеп үстерелә торган. *Культуралы үсемлекләр*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әдәп-әхлак, культура кагыйдәләренә ярашлы рәвештә. *Үзеңне культуралы тоту*

2) Мода буенча; килештереп. *Хәмит абзый үзе бик культуралы киенә, борын астында нәкъ рафинад шикәр шакмагы зурлыгында мыек йөртә, башында һәрвакыт кызыл плюш өсле тупый бүрек, чалбары үтүкләнгән була...* М.Мәһдиев. *Өстәл тирәсендә пөхтә һәм культуралы итеп киенгән, кирәк булса дип кесә дәфтәрләрен алып куйган җитди эш кешеләре утыра иде.* М.Вәлиев

**КУЛЬТУ́РАЛЫЛЫК** *и.* 1) Культуралы булу, мәдәниятлелек, мәдәни үсеш югарылыгы

2) Әдәплелек, тәрбиялелек, интеллигентлык. *Хәлимә өчен культуралылык билгесе – үткәннәрдән, шул исәптән рухи кыйммәтләрдән дә баш тартып, бүгенге белән генә яшәү.* Ә.Закирҗанов. *Белемлелек – хәзерге мәгънәсендә ул культуралылык, дөньяны киң танып белү, үз-үзеңә зур таләпчәнлек.* В.Байдерин

**КУЛЬТУ́РАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Җитештерү, иҗтимагый, рухи тормыш өлкәсендәге

казанышлары булмаган, үсеше артта калган. *Бу халык культурасыз, ярымхайван дәрәҗәсендә.* Ф.Галимуллин

2) Әдәпсез, инсафсыз. *Культурасыз кеше*

3) Начар әзерлекле, белемсез, эрудициясез. *Син – моңсыз, культурасыз бәндә.* З. Хәким

**2.** *рәв. мәгъ.* Культурадан башка. *Культурасыз көн күрү*

**КУЛЬТУ́РАСЫЗЛЫК** *и.* 1) Культурасыз булу, мәдәниятсезлек

2) Әдәпсезлек, тәрбиясезлек; наданлык. *[Рәхилә:] Китап битен бөкләү – культурасызлык галәмәте.* Х.Вахит

**КУЛЬТУ́РАЧЫ** *и. иск.* Культура кертүче, культурага өндәүче кеше

**КУЛЬТУ́РАЧЫЛЫК** *и. иск.* Культура пропагандалау эше

**КУЛЬТУРИЗМ** *и. ингл.* Мускулатураны үстерү өчен махсус физик күнегүләр системасы. *Культуризм конкурслары хатын-кыз чибәрлеге буенча төрле дәрәҗәдә уздырыла торган ярышларга шактый бирешә.* К.Гыйззәтов

**КУЛЬТУ́РНИК** *и. рус иск.* 1) *к.* **культурачы**. *Алай ни – культурник булырга ярамый.* Т.Гыйззәт

2) Ял вакытында (ял йортлары, санаторий, хосусый пляж һ.б.ш.ларда) уеннар, җыр-биюләр оештыручы кеше

**КУЛЬТУ́РНИКЛЫК** *и.* Культурник эше

**КУЛЬТУРО́ЛОГ** *и. лат.-гр* Культурологияне өйрәнүче галим. *Мәдәниятнең бербөтенлеге мәсьәләләре буенча культурологлар һәм фәлсәфәчеләрнең хезмәтләре дә файдаланылды.* И.Тарханов. *Алман культурологы Освальд Шпенглер «Аурупа киче» китабында Көнбатыш Аурупа мәдәниятен «Фауст мәдәнияте» дип атый.* И.Вәлиулла. *Симпозиумда сәнгать белгечләре, тарихчылар, культурологлар, фольклорчы галимнәр, рәссамнар, гамәли бизәү сәнгате осталары катнашты.* Мәдәни җомга

**КУЛЬТУРОЛО́ГИК** *с.* Культурологиягә караган. *Әмма әлеге китаплар белән җентекләп танышкач, ул кулланмаларда культурологик метод өстенлек итүе ачык күренә.* Мәгърифәт

**КУЛЬТУРОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Халыкларның мәдәниятен, аның рухи үсешен, халык тормышындагы ролен өйрәнә торган фән. *Ә укытучы исә үз фәнен генә түгел, кардәш фәннәрне дә: педагогика, психология, философия, культурология, экономиканы белергә һәм сәнгатьнең күп төрләре белән таныш булырга тиеш.* Р.Юсупов

**КУ́Л ЯССУЫ** *и.* 1) Яссы һәм туры хәлдәге кул чугы. *Фәхри, гадәтенчә, кул яссуы белән югарыдан түбәнгә һаваны кисте.* Г.Ибраһимов

2) Уч киңлеге; уч киңлеге кадәр озынлык үлчәме. *Ныклык өчен кирәгәләрнең югары ягыннан кул яссуы киңлегендә җеп белән уратып, моның очларын ишекнең таянычларына китереп бәйләделәр.* Г.Ибраһимов. *Әле бер кул яссуы гына күтәрелгән кояш нурлары җир өстен кып-кызыл төскә күмгән.* Д.Каюмова

**КУМАРИН** *и. фр.* Күп кенә үсемлекләр составында булган, парфюмериядә, сабын кайнатуда, эчемлекләр, кондитер әйберләре житештерүдә кулланыла торган хуш исле матдә. *Кумариннар һәм фурокумариннар үсемлекләрдә чиста хәлдә яки шикәрле калдык белән гликозидлар хәлендә була.* Урман аптекасы. *Балтырган согында табигый кушылма – фотодинамик актив кумарин бар.* Мәдәни җомга

**КУ́МЖА** *и. фин зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан, төче сулыкларда яши, көмеш сыман ялтырап торган тиресенә кара таплар төшкән кыйммәтле промысел балыгы. *[Балык] Кумжа балыгыныкы шикелле таплы булып, сырттан түшкә таба ул таплар кими бара.* В.Сабунаев

**КУМИР** *и. бор. слав.* 1) Пот, мәҗүсилек илаһы сыны

2) *күч.* Соклану, табыну предметы. *Танылган әдип, татар яшьләренең кумиры Г.Ибраһимовның мәдрәсәдә әдәбият укытуы «Галия» шәкертләренең әдәби кыйблалары ачыклануында, талантлары формалашуында хәлиткеч роль уйнаган, әлбәттә.* М.Гайнетдинов. *Үзәгемә үтте ялган кумир, йөрәгемдә яна утлы күмер.* Л.Шагыйрьҗан. *[Яшүсмерләр] Үзләренең кумирларына – кино һәм эстрада йолдызларына охшар өчен, ультрашәмәхә нурлар астында күмергә әйләнергә дә әзер.* Мәдәни җомга

**КУМКВАТ** *и. кыт. бот.* Рутачалар семьялыгыннан мәңге яшел, сабагы вак чәнечкеле куак үсемлек һәм шуның әфлисун төсендәге кечкенә җимеше; япон апельсины; вак мандарин. *Кумкват сатып алу*

**КУМТА** *и.* Тартма; букча. *Кумта эчендә кеше, Җырлау-сөйләүдә эше.* Табышмак. *Ниһаять, ул [Кадерҗан] тышына патша сурәтләре ябыштырылган, кайчандыр хәлле, бик тә хәлле булган ерак бабаларына акча кумтасы булып хезмәт иткән катыргы тартма китереп чыгарды ---.* А.Хәлим. *Яшь бәрән ите тиз пеште, хәстәрле егетләрнең кумталарыннан саба-саба кымыз килеп чыкты, как ит, табикмәк табылды, шулар дастарханга тезелгәч, харап матур табын булды.* З.Мурсиев

**КУМУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Иминиятләштерелгән объектларның чикләнгән пространствода (складта, пристаньда) туплануы

2) *мед.* Организмда озак чыгарыла яки таркала торган дару препаратларының туплануы, һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, даруларның тәэсире арту. *Бу күренеш тупланыш (кумуляция) дип атала.* Химик матдәләрнең агулылыгы

3) Шартлау энергиясенең билгеле бер юнәлештә концентрацияләнүе

**КУНА** *и.* **1.** Ипи әвәләү, токмач басу, кисү һ.б.ш. камыр эшләре өчен махсус такта. *Кулы белмәгән куна сайлаган.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ. күч.* Киң. *Алтынчы бригадага эләктем, бригадирым куна җилкәле, калын имән кискәседәй гәүдәле, көр үгез муенлы.* А.Гыйләҗев

**КУНА́ ТАКТА(СЫ)** *и. к.* **куна 1.** *Күкрәк куна такта кебек киң габаритлы күренә.* М.Галиев. *Табак урынына ул [Сафура апа] өсте ашъяулык белән ябулы куна тактасы күтәреп килә түгелме?* Р.Хафизова. *Куна тактасы өчен кешегә керү уңайсыз.* Р.Төхфәтуллин. *Вакыт-вакыт тынып калган Сәгыйдә камырын куна тактасына җәеп салды.* Н.Хәсәнов

**КУНАК** *и.* **1.** 1) Үткәрелә торган мәҗлескә, бәйрәмгә, очрашуга һ.б.ш.

махсус чакыру, йола яки сөйләшү-килешү буенча бирәр гаиләгә, илгә килгән һәм, гадәт таләбенчә, хөрмәт күрсәтелергә тиешле зат. *Хатыны Тәнзилә, кунакка хәерле иртә теләп, җәһәт кенә аш өенә кереп китте.* Г.Бәширов. *Кунакның шәбрәге килде исә, рәхим итсен!..* А.Гыйләҗев

2) *кыек килеш форм.* Кунаклау II, кунаклап йөрү күренеше. *Әкият геройларына ияреп, бала шаян Шүрәле, уңган убырлы карчык янына кунакка бара.* Таңчулпан. *Сөмбелә хәзер җитәкчеләрнең кунакка чакыруларын кул кушырып көтеп ятмый, бәйрәмнәрне үзе эзли, исләренә төшереп шалтыраткалап тора.* К.Кәримов

3) *диал. эвф.* Кизү чире

**2.** *с. мәгъ.* Кунак (*1 мәгъ.*) булып килгән. *Кунак кеше*

◊ **Кунак итү** Чакырылган, килгән кешегә сый-хөрмәт күрсәтү. **Кунак йөрү** Берничә кешедә (илдә) кунак булу. *Без бөек Владимир белән килешү ясадык: кан коешып шаярмаска, беребездән беребез ясак җыймаска, сәүдәне тыймаска, ил илгә кунак йөрергә.* Р.Харис. **Кунакка килдең мәллә?!** «Тик утырма, эшлә» мәгънәсендә әйтелә. **Кунак сые** Тәмле, затлы мул ризык. *Безнең өчен гади ризык кына түгел, кунак сые иде бу.* М.Әмир. **Кунак төшерү** Кунак чакыру, кабул итү. **Кунак төшү** Чакырулы яки бик кадерле, көтелгән кунак килү. *Тик кайвакыт күңеленә чит-ят уйлар килеп, әллә кунак төшәргәме дип тә ниятләргә теләге җанлана икән.* Ф.Яхин. **Кунак уздыру** Кунак мәҗлесе ясау

**КУНА́К БҮЛМӘСЕ** *и.* Өйдә, квартирада кунак кабул итү, ял итү өчен зуррак бүлмә. *[Люкс номерында] Өч йокы бүлмәсе, дүрт ванна бүлмәсе, рояль куелган бик зур кунак бүлмәсе, берьюлы илле кеше ашап чыгарлык ашханә... һәм кунакка кирәк булырдай күптөрле вактөякләр!* Кызыклар дөньясында

**КУНА́К ЙОРТЫ** *и. к.* **кунакханә**. *Кунак йорты салдырабыз. Бассейны, саунасы белән.* Н.Гыйматдинова

**КУНА́К-КУНАК** *рәв.* Бер-береңә кунак йөрешеп, бер-берең белән кунак алышып. *Вакыт күп тә, гомер кыска икән, Кунак-кунак булып йөрергә.* Ф.Яруллин

◊ **Кунак-кунак уйнау** Бер-береңбелән кунак алышу, үзара кунак йөрешү. *Ул көнне ул [Сәгадәт] кызлар белән кунак-кунак та уйный иде.* Г.Исхакый

**КУНАКЛА́У** I *ф.* 1) Берәр биегрәк урынга очып менеп утыру (кошлар тур.). *Чылтыр чишмәләргә эндәш кенә – Телләреңә былбыл кунаклар!* Зөлфәт. *Тисә дә берсенә генә тиясе таш меңләгән чыпчыкларга шом сала – дәррәү күтәрелеп очалар, аннары, каршындагы лапас түбәсенә кунаклап, бабамның кабат оеп китүен көтәләр.* Ф.Баттал

2) Биегрәк урынга менеп утыру (гадәттә кеше тур.). *Аннан соң ияргә Гөлчәчәк менеп кунаклады.* З.Хөснияр

3) Гомумән утыру. *Кайвакыт Нәсимнең ашыйсы килми, бары тик әтисеннән аерылырга теләмәгәнгә генә, өстәл янына кунаклый иде.* Н.Әхмәдиев. *Әйдә, шушында кунаклап җылын.* Г.Тавлин

4) Урнашу. *Тәмте тавы башында, авылдан аерыла төшеп, күркә кебек җилгәрәк кунаклаган ялгыз өйдән итәген ыштан бөрмәсенә кыстырган бер пумала баш килеп чыкмасынмы!* Ф.Хөсни. *Өстәлгә һәйбәтләп тозга ярып пешерелгән ярка-ярка ярмалы бәрәңге куелды, бу бөркеп, моңлы көй сузып торган самавыр килеп кунаклады.* М.Хәсәнов. *Кояш нәкъ безнең баш өстенә менеп кунаклаган да тик тора, кадаклап куйган диярсең.* Р.Хафизова

**Кунаклап алу** Тиз генә кунаклау. *Сәкесенә кунаклап алган Сәгъдәт күк йөзен күздән кичерде.* А.Хәлим

**Кунаклап бетү** Барысы да кунаклау

**Кунаклый башлау** Кунакларга тотыну

**КУНАКЛА́У** II *ф. сир.* Бераз кунак булу. *Ул синең яныңда озак кунакламас.* Н.Гыйматдинова

**Кунаклап алу** Кыска гына вакыт арасында кунак булып тору

**Кунаклап йөрү** Билгеле бер вакыт дәвамында кунак булу

**Кунаклап тору** Еш, әледән-әле кунаклау

**КУНАКЛЫ** *с.* Кунаклары булган, кунак(лар) чакырган. *Кунаклы йорт – хөрмәтле йорт.* Мәкаль

**КУНАКЛЫЙ** *рәв. сир.* Кунак булып, кунак итеп

**КУНАКЛЫК** *и.* **1.** Кунак булу, кунакның хокуклары, бурычлары, кунак булу вакыты. *Иптәшенең хәзерге кунаклыгы – солдаттан кайтышы иде.* Ш.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Кунак өчен билгеләнгән. *Кунаклык сыйлар*

**КУНА́К ӨЕ** *и. к.* **кунакханә**. *Ул тирәләрдә бүген – туристик базалар, кепинглар, кунак өйләре, палатка шәһәрләре, автопансионатлар...* М.Мәхмүтов

**КУНА́К-САНАК** *и. җый. к.* **кунак-төшем**. *Һич кенәләр дә кунак-санак белән маташасым килми.* А.Хәлим

**КУНА́К-ТӨНӘК** *и. җый. к.* **кунак-төшем**

**КУНА́К-ТӨШЕМ** *и. җый.* Һәртөрле кунаклар һәм килгән-киткән кешеләр. *Халык бәйрәмнәрдә, кунак-төшемнәрдә, үлем-китемнәрдә генә кешелеккә кия торган кием-салымына тотынды.* Ә.Гаффар. *Ниһаять, туй, кунак-төшем, әби-бабай, кода-кодагый.* Ф.Баттал. *Менә ике ел тоташтан, бездә кунак-төшем булганда, хәләл җефетем ул төн, ул таңны исенә төшерә.* Э.Касыймов

**КУНАКХАНӘ** *и.* 1) *этн.* Кунак-төшемне кундыру, ял иттерү өчен махсус өй яисә бүлмә

2) Читтән килгәннәргә вакытлыча яшәү өчен түләүле торак. *Кунакханә бүлмәсенә очраклы гына туры килгән бу өч кеше әлегә юньләп танышырга да өлгермәгәннәр иде.* М.Галиев. *Ул арада Кара Күзлек «Казан» кунакханәсенең ишек төбендәге чәй өстәле янында тукталгандай итте, сатучы егет белән нидер сөйләшеп тә алды сыман.* Ф.Баттал

**КУНАКЧЫЛ** *с.* Килгән кунакны яхшы каршылый, сыйлый торган, кунак чакырырга яратучан. *Кунакчыл йортта кунак бар.* Мәкаль. *Әни минем – бик тә ачык йөзле, кунакчыл кеше.* Н.Шәрифуллин. *Кунакчыл өй гел кешеле, Бик белмәс аның ишеге.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**КУНАКЧЫЛЛЫК** *и.* Кунакчыл булу. *Бәйрәмнәрдә авыл гөрләп тора,*

*Төрле яктан җыела кунаклар... Кунакчыллык кайнарлыгы белән Табаларда бии коймаклар.* М.Әгъләмов. *Кунакчыллык кагыйдәләре буенча мондый чакыру Сәет бәй тарафыннан ясалырга тиеш кебек.* Т.Галиуллин. *Бу шигырьләрдә кунакчыллыкка да шундый ук зур игътибар бирелә; кунакчыллык соңгырак чор төрки әдәбият ядкәрләрендә дә, халык иҗаты әсәрләрендә дә мактала.* Татар әдәбияты тарихы

**КУНА́К ЯГЫ** *и. этн. к.* **кунак бүлмәсе**. *Кунак ягына үтүгә, кунакларны сәкегә утыртуга, тамашачы Сираҗи уч төбендәге янчыкны сикертеп алды...* М.Хәбибуллин

**КУНА́-ТӨНӘ** *рәв. к.* **кунып-төнеп**. *Без монда күпме чиләнәбез. Куна-төнә ятабыз.* Ф.Яруллин

**КУНЫ́П-ТӨНЕП** *рәв.* 1) Берничә тәүлек буе. *Ләкин хикмәт шунда, соңгы төннәрне анда кунып-төнеп йөрүче булмаган.* М.Маликова

2) Шактый озак булып, көндез дә булып, кунарга да калып. *Гайнан хәзер монда кунып-төнеп эшләргә тиеш булачак.* Г.Бәширов

**КУНАЧА́** I *и.* Йортта кош-корт (башлыча тавыклар) менеп кунакласын өчен махсус куелган горизонталь киртә. *Куначасы да юк, аңа чебен дә кунмый.* Әйтем. *[Сәхия:] Тавыклар күптән куначада инде, әтәчкә дә вакыт, күрәсең.* Д.Салихов. *Тавыклар ялындыра, ялкауланып куначаларында мескенли бирә.* Ф.Садриев

**КУНАЧА́** II *и. диал.* Ак бүлмә; кыз бүлмәсе. *Йөрерсең, анакай, йөрерсең, Буш куначага керерсең; Буш куначада мин булмам, Сары май кебек эрерсең.* Җыр

**КУНА́ЧА** *рәв.* Кунарга дип, кунарга уйлап. *Бабай әйтте, иртәгә Аюга барабыз, диде. Кунача барабыз, диде.* С.Зыялы

**КУНГАК** *и. диал.* Бал кортлары килеп куну, очып китү өчен умарта авызына куелган тактачык, бусага

**КУНГ-ФУ** *и. кыт.* Дошманның авырту үзәкләренә куллар һәм аяклар белән кинәт сугудан һәм дошманның үз энергиясен үзенә каршы кулланудан гыйбарәт үз-үзеңне саклау-яклау өчен кытай системасы. *Кунг-фу укытучысы булып кинода уйнарга тәкъдим ясалгач та, Ли бик теләп риза була.* Кызыклар дөньясында

**КУНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **куну**

2) *күч. гади с.* Кинәт каты итеп сугу. *[Харис] Шундый кундырды, Фикъряәт тәгәрәп китте.* М.Хәсәнов. *Әгәр ул Василий чыраенда санга санамау шикелле берәр нәрсәнең чаткысын гына сизеп калса да, перчаткасын салып тормастан, «мужик»ның ияк астына берне кундырыр иде.* Ә.Еники. *Урыслардан бере сүзгә-сүз килеп, гел юк өчен бандеровчының яңагына берне кундырган икән.* А.Гыйләҗев

**Кундыра язу** Чак кына кундырмый калу

**Кундырып алу** Бик тиз кундыру. *Гомәр, үз гадәтенчә, аның муен тамырына берне кундырып алды.* Җ.Ильясов. *Иртәгә сәхнәдә Исмәгыйльгә ризалату өчен «кызым»ны бәргәләп аласы урында, Гөлчәчәккә чынлап торып берне кундырып алам әле.* Г.Галиева

**Кундырып калу** Кундырырга өлгерү. *Бакчага үтешли, пружиналы тар ишек шап итеп Кашшафның аркасына кундырып калды.* Р.Төхфәтуллин

**Кундырып кую** Көтмәгәндә кундыру; бер тапкыр кундыру

**Кундырып тору** Әледән-әле, еш кундыру

**Кундырып чыгу** Барысына да бер-бер артлы кундыру. *Балаларының җилкәсенә берәм-берәм кундырып та чыга – барыбер файдасыз.* Ә.Баян

**КУНСТКА́МЕРА** *и. нем.* 1) XVI–XVII гасырларда сирәк очрый торган төрле тарихи, мәдәни, фәнни характердагы нәрсәләрнең коллекциясе һәм аларны саклау урыны. *Соңыннан җыелган халык алдында Пётр кызның канлы башын тотып бара, иреннәреннән үбә һәм башны кунсткамерада сакларга боера.* Х.Камалов

2) *күч. сөйл.* Бик куркыныч җир

**КУНУ** I *ф.* 1) Очып килеп, берәр урынга утыру. *Язгы кар сулары Челтерәп акмаган, Узучы кошлар да Кунар җир тапмаган.* И.Юзеев. *Сандугач бер ботактан икенчесенә куна, әле ерагая, әле якыная.* Э.Касыймов

2) Нәрсәнең дә булса өслегенә ябышу, утыру, эләгеп калу (тузан, дым, кар бөртекчекләре тур.). *Яшь бәпкә үләннәренә Зәңгәр дым кунды.* Р.Вәлиева. *Кар иреннәргә төшеп эри, муеннарга тула, керфекләргә куна.* Р.Вәлиев

3) Үсеп чыга башлау. *Шул минутта роза чәчәгенең сабагына энәләр куна, ә кактус чәчәге роза чәчәген хәтерләтә башлый.* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Барлыкка килү, булу. *Ә инде сөягемә кот кунсын, атлы-тунлы, тукбөтен яшим дисең икән, рәхим ит, анысы да үз ихтыярыңда, юлы бер – намуслы хезмәт.* М.Хәсәнов. *Күз буташтырмый буявын, алтынлый бар дөньясын! Кешелек йөзенә генә күз буявы кунмасын!* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Аның иреннәренә елмаю кунды.* Г.Гыйльманов

**Куна башлау** Куну билгеләре күренү. *Тәрәзә төбенә тузан куна башлаган*

**Кунып тору** Даими, әледән-әле куну; кунган хәлдә булу. *Кемнәрнеңдер капкасына Бәхет кошы кунып тора.* Ф.Яруллин. *Казык саен әнә чыпчыклар кунып тора.* Н.Дәүли

**КУНУ** II *ф.* 1) Төн үткәрү, йоклау. *Әтине беләсең ич инде, кыш җиттеме, атналар буе бүре аулый, өйгә дә кайтмый, кая куна, ни ашыйдыр.* Ә.Гадел. *Юк, башта әле ул урманда адашып йөрде, аннан әллә нинди куркыныч зиратка килеп чыкты, аннан сазга батты, аннан тауга менде һәм, төн кунарга дип, тау куышына керде.* Ф.Бәйрәмова. *[Бабай] Кичә өендә кунмаган.* Г.Гыйльманов

2) *сөйл.* Бергә төн үткәрү (егет белән кыз, бер гаилә төземәгән ир белән хатын тур.)

◊ **Куна ятып** Көн-төн, даими, өенә кайтмыйча. *Канәгатьнең ике абзасы да печәндә. --- Куна ятып эшлиләр.* А.Хәлим

**Кунып йөрү** Шактый вакыттан бирле куну, еш кына куну. *[Мөдәррис] Өйрәледә бер кич, Боткалыда ике кич кунып йөриме?* А.Хәлим. *Атна буе вокзалда кунып йөрдем.* Ф.Яруллин

**Кунып чыгу** Бер мәртәбә куну. *Якты Күл керәшеннәре безнең авылда туктап ял итәләр. Еш кына кичтән килеп кунып та чыгалар.* И.Сирматов

**Кунып яту** *к.* **кунып йөрү**; даими, озак вакытлар куну. *Без хәзер, күрше рус авылында укыганнар, дүртенчеләр, бишенчеләр шикелле, кеше сәндерәсендә кунып ятмыйбыз – көн саен кайтып йөри идек ---.* Х.Сарьян. *– Кыстасалар да, иртәгә дә анда кунып ятмагыз, төш авышуга кайтырга чыгыгыз, – дип калды әнкәй.* И.Сирматов. *Ничектер җайсыз бит һаман-һаман кешедә кунып яту.* Ф.Шәфигуллин

**КУНУ-ТӨНҮ** *ф.* Һәрвакыт, даими куну

**КУН-ФУ** *и. кыт. к.* **кунг-фу**

**КУНШЫ** *и. диал.* 1) Очраклы юлдаш

2) *диал.* Күрше. *Үзеңне яхшы дип белсәң, кунышыңны фәрештә дип бел.* Мәкаль

3) *диал.* Әңгәмәдәш

**КУНЫК** *и.* Әйбернең өслегендә хасил булган, аңа ябышкан коры матдә катламы. *Әлеге гамәл [механик агарту] йомшак һәм каты теш кунычыгын кырып алу, тешне фтор-лак белән каплаудан гыйбарәт.* Сөембикә. *Куныкны бетерү өчен, мондый әйберләрне сабын күбеге өстәлгән нашатырь эремәсендә тоталар.* Серле календарь. *Кайчагында колактан бүленеп чыккан нәрсә эремчексыман масса, йомшак куник рәвешендә була.* Иң шәп календарь

**КУНЫКЛА́У** *ф.* Кунык хасил булу

**Куныклый башлау** Куныкларга тотыну

**Куныклый бирү** Куныклавын һаман да дәвам итү

**Куныклый төшү** Бераз куныклау

**КУНЫКЛЫ** *с.* Өслегендә кунык хасил булган. *Аеруча ул аның [балыкның] тәңкәләре арасыннан төртеп чыккан --- пычрак куныклы чал төкләренә шаккатты.* Ә.Гаффар. *[Ирганың] Җимешләре карасу зәңгәр төстә, күгелҗем куныклы, кара җиләк җимешенә караганда эрерәк.* Ботаника

**КУНЫЛУ** *ф. з.-сыз* Кунарга туры килү. *Туганнарда кунылу*

**КУНЫЧ** *и.* 1) Аяк киеменең балтырны каплый торган өлеше. *Йодрыклар йомарлана, яңак сөякләре шыгырдый, итек кунычларында йокымсыраган хәнҗәрләр көнгә чыгып ялтырый.* А.Гыйләҗев. *[Илгиз] Күнитеге кунычына кечкенә сары флаг урап тыккан.* Б.Камалов. *Аякларында ботинка һәм балтырын кыскан күн кунич.* М.Юныс

2) Бияләйнең, перчатканың беләзек турысы һәм беләзектән югарырак өлеше. *Бияләй кунычы*

**КУНЫЧЛЫ** *с.* Кунычы булган. *Аягында, Шумбутский әйткәнчә, җылы кунычлы, биек үкчәле чит ил ботинкасы.* М.Насыйбуллин. *Җитмәсә, күрше карчыгының озын кунычлы бутые да юк икән, Камәр карчык аңа бер кичне Саимәдән калган бутыйны ыргытты.* М.Мәһдиев

**КУПАЙ** *с.* Мактанчык; мактанырга ярата торган. *Купай кешенең калпагы да калай.* Мәкаль. *Үз урманында чупай да купай.* Мәкаль

**КУПАЙЛАНУ** *ф.* Мактану; масаю. *Малай һәрвакыт купайлана*

**Купайлана башлау** Купайланырга тотыну

**Купайланып алу** Берара купайлану

**Купайланып йөрү** Даими рәвештә купайлану

**Купайланып тору** Әле, хәзерге вакытта купайлану; еш, әледән-әле купайлану

**КУПАЙЛЫК** *и.* Мактанчыклык. *Купайлык кешене бизәми*

**КУПА́ЛЬНИК** *и. рус* 1) Су коенганда, кызынганда кия торган махсус кием, костюм. *Юеш купальниктан пляжда йөрмәгез яки комда ятып тормагыз, югыйсә билсез калуыгыз бар.* Иң шәп календарь. *Спорт киемен – спорт белән шөгыльләнгәндә, табигатькә чыкканда, купальникны – су коенганда, купшы күлмәкне кичә-бәйрәмнәрдә кию урынлы.* Мәгърифәт

2) Кайбер спорт төрләрендә, мәс., гимнастикада киелә торган форма

**КУПАЮ** *ф. к.* **купайлану**. *Купай – корыга масайган, купайган кеше.* Н.Исәнбәт

**Купаеп алу** *к.* **купайланып алу**. *Аларга мактау да, туйда гадәти саналган купаеп алу да кирәкми, алар йола үти, тырышулары кыз бала хакына, әйдә, аның күңеле кителмәсен ---.* Р.Камалов

**Купаеп йөрү** *к.* **купайланып йөрү**

**Купаеп китү** Кинәт купая башлау. *– Хәзергесе турында уйларга кирәк, – диде Таһия, кинәт купаеп киткәндәй.* Х.Камалов

**Купаеп тору** *к.* **купайланып тору**

**Купая башлау** Купаерга тотыну

**Купая бирү** Һаман да купаю, купаюны дәвам итү

**Купая төшү** Тагы да купаю

**КУПЕ** *и. фр.* 1) Пассажир вагоннарында аерым бүлмә. *Ул купеда купкан ыгы-зыгыга да, хатынының үчекләп әйткән сүзләренә дә битараф калды.* М.Маликова. *Купе почмагында рәхәт оеп утырган Мотыйгулла, монда мин дә бар дигәндәй, иренеп кенә сүзгә кушылды.* Р.Вәлиев

2) Җиңел автомобильләрдә: ике ишекле ябык кузов; шундый кузовлы машина

**КУПЕЦ** *и. тар.* Патша Россиясендә: бай сәүдәгәр, зур сәүдә предприятиесе хуҗасы. *Урамга купецлар туктаган, Кызыллы яулык алыгыз; Без ашаган, без эчкәнгә Риза-бәхил булып калыгыз.* Җыр. *Аларның уллары, теләсәләр, сәүдәгәр (купец) сословиесенә языла алалар; ләкин моның өчен 500 сумнан да ким булмаган капиталлары булу шарт.* Г.Гобәйдуллин. *Илчелегендә йөз кеше, кырыгы – рус купецлары ---.* Р.Харис

**КУПЕЦЛА́РЧА** *рәв.* Купецларга хас булганча, купецлар кебек. *Купецларча фикер йөртү*

**КУПЕЦЛЫК** *и.* Купец дәрәҗәсе. *Мәсәлән, 1803 елда Сая авылының Хәлил Галиев дигән ясаклы татары 2020 сум (рәсми) капитал объявить итеп, 3 нче гильдия купецлыкка чыкты.* Г.Гобәйдуллин

**КУПЛЕТ** *и. фр.* 1) Шигырь яки җырда аерым строфа. *Иң аска, хәрефләрне балаларча бөтерә-бөтерә, тигез юллар белән бер куплет шигырь язып куйган.* Р.Вәлиев. *Көйләп язылган «Ахырзаман» китабындагы һәр куплет шушы сүзләр белән тәмамлана.* Х.Сарьян. *[Табындагылар] «Сарман» белән «Шахта»ның бер-ике куплетын җырладылар да тагын тынып калдылар.* М.Маликова

2) Көнүзәк мәсьәләләрне күтәргән сатирик яки юмористик кыска җыр, такмак. *Әпсәләм уйнап җибәрә. Нурсәнә куплетлар җырлый.* Х.Вахит

**КУПЛЕТЧЫ** *и.* 1) Куплетлар чыгаручы

2) Куплетлар башкаручы. *Куплетчылар ярышы*

**КУПОН** *и. фр.* 1) Кыйммәтле кәгазьләрнең (облигация һәм акцияләрнең) хак, кыйммәт язылган һәм дивидендлар яки процентлар алганда кисеп калдырыла торган өлеше. *Купоннар белән эшләү*

2) Урыны күрсәтелмәгән театр билеты

3) *неол.* Сәүдә итү яисә хезмәт күрсәтү фирмасы эшләп чыгарган, ташлама яки өстенлек бирә торган кәгазь. *Купондагы адресыгыз һәм исем-фамилиягез редакция өчен генә.* Акчарлак

◊ **Купоннар кисү** 1) Банкка салынган акчадан килеп торган процентлар исәбенә яшәү. *Купоннар кисү хисабына яшәү*

2) Түбән бәядән сату, ташламалар бирү. *Кибетләр купоннар кисәргә чакыра.* Татарстан яшьләре

**КУПОРОС** *и. фр. хим.* Күкерт кислотасы тозларының атамасы. *Уңыш сакланачак подвалда күгәрек гөмбәсе үрчемәсен өчен, яхшылап җилләткәннән соң, кайнар суда бакыр яки тимер купоросы эретеп, --- подвал эчен эшкәртәләр.* Мәдәни җомга. *Бу авыруны бетерү өчен, үткән елгы үсемлек калдыкларын җыеп яндырырга һәм бакыр купоросы эремәсе белән зарарсызландырырга кирәк.* Иң шәп календарь

**КУПРИТ** *и. лат.* Кыйммәтле һәм сирәк очрый торган кызыл бакыр рудасы, минерал. *Составында массача а) 2,5 % халькопирит CuFeS2; б) 3 % борнит CuFeS4; в) 2,5 % куприт Cu2O; г) 3 % халькозин Cu2S булганда, мәгъдән бакырга бай мәгъдәннәргә керәме, әллә бакырга ярлы мәгъдәнгәме?* Г.Хисамиев

**КУПТАРУ** *ф.* 1) Ябышкан, берекккән нәрсәләрне аеру. *Чатта «Болгар», баскыч, сары идән – Куптарсалар, кабат басалмам.* С.Хәким. *Сусыз җирләргә басканда бозга ябышкан табаннарын чатырдатып куптарып ала.* М.Әмир. *Ләкин кызның аяклары җиргә кадакланган төсле: куптарып булмый.* Н.Гыйматдинова

2) Берәр нәрсәнең өслегендәге катламын аерып алу. *Зәһәр кәрләчнең яшел яфрагын өзеп алып тышчасын куптаралар һәм сөял өстенә бәйлиләр.* Мәдәни җомга

3) Туздыру, өермәләндерү. *Беркем башка менми. Тузан куптармый. Укытучылар белән укучылар бер-берсе өчен өзелеп торалар.* А.Хәлим. *Ул теге Монголия ягыннан, кар катыш ком бураны куптарып, җил исә.* З.Зәйнуллин

4) *күч.* Мавыктырган нәрсәдән аерып алу. *Габрахман кызын тәрәзәдән куптарып алды.* М.Юныс

5) *күч.* Аеру, торгызу. *Аллам сакласын, тыныч яткан җиреннән куптарырсың ---.* А.Хәлим

**Куптара башлау** Куптарырга тотыну. – *Ул минем туган көнем хөрмәтенә җырларга тиеш! – дип, комиссар буза куптара башлады бит.* Р.Батулла

**Куптара бирү** Һаман да куптаруын дәвам итү

**Куптара килү** Күптәннән бирле куптаруын дәвам итү. *Аның «Татарстан яшьләре», «Безнең гәҗит», «Звезда Поволжья» газеталарында, «Казан утлары», «Идел» журналларында басылган мәкаләләре җәмәгатьчелектә тирән кызыксыну, еш кына шау-шу да куптара килде һәм килә.* Шәһри Казан

**Куптара төшү** Бераз куптару

**Куптарып ату** Ачу белән яисә көтмәгәндә, тиз куптару

**Куптарып бетерү** Барысын да, тоташ куптару

**Куптарып ташлау** *к.* **куптарып ату**. *Ләкин акылым, фикерем белән мин аны бик тиз куптарып ташладым.* Р.Гали

**Куптарып чыгу** Башыннан ахырына кадәр куптару

**КУПШАК** *с.* Куба башлаган, урыны-урыны белән купкан, купкаланган

**КУПШАКЛЫ** *с.* Купшак урыннары булган. *[Заһир] Үзе елмая, купшаклы иреннәре колагына җиткән ---.* Р.Төхфәтуллин

**КУПШАКЛАНУ** *ф.* 1) Купшакка әйләнү. --- *Павлюхин тирәсендәге биш катлы йортлар арасына кысылган ике катлы, акшары купшакланган, тәрәзә пыялаларын вакыт җиле каралткан йортта яши икән врач.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **кубалаклану**. *Кечкенә гармунның буяулары искереп беткән, купшакланган, хәтта урыны-урыны белән куба ук башлаган.* М.Әмирханов. *[Гыйльфанның] Кояшта купшакланган битендә әнә күзләре генә елтырый.* Ф.Латыйфи. *Хәсән ---, аягының төзәлә башлап купшакланган җәрәхәтен куптарып, туфрак сипте.* М.Юныс

**Купшаклана бару** Торган саен ныграк купшаклану

**Купшаклана башлау** Купшакланырга тотыну

**Купшаклана төшү** Бераз купшаклану

**Купшакланып бетү** Бөтенләй, тулысынча купшаклану. *Кояшта янган, купшакланып беткән тәннәрне иркәләп, Ык аръягыннан салмак, җиләс җил исә.* Ф.Латыйфи. *Аннан соң туфракны чәчеп җибәрде дә, сузылып ятып, --- купшакланып беткән җирне үпте.* М.Кәбиров

**Купшакланып калу** Купшаклык сыйфаты бетмәү, купшакланган хәлгә килү

**Купшакланып китү** Бераз купшаклану

**Купшакланып тору** Әле, хәзерге вакытта купшаклану. *Агарта белмәсәң, мич тә купшакланып тик тора.* Г.Нәбиуллин

**Купшакланып чыгу** Нык купшаклану

**КУПШУ** *ф.* Бераз купкалау, азрак купшаклану

**Купшый бару** Купшу процессы дәвам итү, һаман да купшу

**Купшый башлау** Купшырга тотыну

**Купшый төшү** Бераз купшу

**Купшып тору** Әле, хәзерге вакытта купшыган булу

**Купшып чыгу** Купшыган хәлгә килү

**КУПШЫ** *с.* **1.** 1) Матур; нәфис; нәзакәтле. *Аның кайнар сулы кружкага үрелүе дә --- нәзакәтле һәм купшы иде.* А.Гыйләҗев. *Учлап-учлап шигырь өләшәләр, Һәрбер кулда – купшы гөлләмә.* Р.Зәйдулла

2) Матур киенгән, бизәнгән, төзәтенгән; матур, ыспай киенергә ярата торган. *Кибет янына сабыр, акыл-*

*лы карашлы, бик үк купшы булмаган, әмма чиста киенгән кешеләр җыелды.* Җ.Ильясов

3) Бик матур итеп тегелгән, ясалган (кием-салым тур.)

4) *күч.* Тышкы бизәкләргә бай. *Яраткан укытучыбызның үлемен «геройлык» дип аталган купшы сүз берничек тә каплый алмый.* М.Юныс. *Миндар ялындырып тормады, купшы шигырьләр тыңлаудан шулай ансат кына котылуына сөенә-сөенә чыгып китте.* Р.Габделхакова. *Мин монда җөмлә матурлау, сүзләрне купшы һәм яңгыравыклы итү, әсәрләрен чуарларга һәм чибәрләргә яратучы кайберәүләр шикелле тышкы бизәкләр һәм башка шундый хикмәтләр эзләү белән мавыкмадым...* Н.Макиавелли

5) Югары класслы. *Үтә купшы кытай рецептларында фритюрда кыздырылган сөлек бирәләр, һәм ул бик кыйммәт тора.* Иң шәп календарь

**2.** *и. мәгъ.* Ыспай, көяз кеше

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Пөхтә, матур, зәвык белән. *Ул да Алманиягә хезмәт итә, әмма болай купшы киенү түгел, матрос бушлаты сыман ниндидер калын, тупас постау курткадан ары китә алмый иде.* Т.Әйди

2) Матур, ыспай итеп. *Апайлар купшы атлап үтеп киттеләр, кәрзиннәрендә – ап-ак челтәрләр, сөлге-тастымаллар.* Г.Якупова. *Нинди купшы булып алмагачлар чәчәк аткан.* Ә.Баян

**КУПШЫЛ** *и. зоол.* Тау чыпчыгысыманнар семьялыгыннан, ачык төсләрдәге чуар каурыйлы кош; *русчасы:* **щегол**. *Урманда йөрсәң, купшыл, карабүрек, миләш чыпчыкларын еш очратасың.* К.Тәхау

**КУПШЫЛАНУ** *ф.* Матурлану; купшы булып китү. *Усаклар, шомыртлар карасу кызыл яфраклары белән купшыланып утыра.* К.Тәхау. *Зәйтүнә ---, әнисенең мәһәр калфагын чәченә әле тегеләй, әле болай кадап, купшыланып маташты.* Ф.Хөсни. *Менә сиңа егет солтаны! Купшыланып туйгач, утыргыч аркылы үрелеп, кызга сүз куша ---.* Р.Мулланурова

**Купшылана бару** Торган саен ныграк купшылану. *Универсиаданы каршылап, башкалабыз көннән-көн матурлана, купшылана бара, ләкин тышкы матурлык белән генә җиңү яулап булмаганын, ә ныклы әзерлек кирәклеген барыбыз да аңлыйбыз.* Биектау хәбәрләре

**Купшылана башлау** Купшыланырга тотыну

**Купшылана бирү** Купшылануын һаман дәвам итү

**Купшылана төшү** Бераз купшылану; тагын да купшылану

**Купшыланып алу** Тиз арада яки кыска вакытка купшылану

**Купшыланып калу** Нинди дә булса вакыттан, сәбәптән, вакыйгадан соң купшыланган хәлгә килү

**Купшыланып китү** Күзгә күренеп, сизелерлек купшылану. *Ул, чыннан да, ямьләнеп, күпереп, купшыланып киткән.* Ф.Яхин. *Шул рәвешле, алар тагын да купшыланып киттеләр.* Шәһри Казан

**КУПШЫЛА́У** *ф.* Матурлау; купшы итү. *Чигүле алъяпкычлары, калфак сымаграк итеп, купшылап яулык чөюләре, көянтәне сыңар иңбашка гына салып суга йөрүләре Өчтатар кызларының?* Г.Якупова

**Купшылап җибәрү** Бераз купшылау

**Купшылап тору** Һәрвакыт, гел купшылау

**Купшылап чыгу** Барысын да, башыннан ахырына кадәр купшылау

**Купшылый төшү** Бераз купшылау; тагын да купшылау

**КУПШЫЛЫК** *и.* 1) Купшы булу, матурлык. *Тупылларда җиңел шаулау, купшылык бар талларда.* Г.Ибушев. *Матурлыгы, купшылыгы һәм ефәктәй елкылдап, кулга тоткач агып торуы белән кешнең кышкы мехына бу дөньяда тиңнәр юк.* Кызыклар дөньясында

2) Көязлек; бизәнергә, матур киенергә яратучанлык. *Артык купшылыкны яратмау*

**КУПЫ** *и. диал.* Кечкенә агач табак. *Купы өстендә купы.* Табышмак

**КУПЫРАЮ** *ф. диал.* Мактану; эреләнү. *Җәвәһирәсе дә мин рәис бичәсе дип купыраеп йөрмәде, кирәк икән бәрәңгесен, кирәк икән чөгендерен эшкәртте.* А.Хәлим

**КУПЮР** *и. к.* **купюра**. *Идәндә егерме биш, илле һәм ун сумлык купюр төргәкләре аралашып, тәгәрәшеп ята башладылар.* Г.Кашапов

**КУПЮ́РА** *и. фр.* Бәясе күрсәтелгән акча билеты, акция, облигация яки башка кыйммәтле кәгазь. *Шул уңайдан, ЦРУның дәлилләп соравын искә алып, АКШ хөкүмәте бөтен дөньяда әйләнештә йөри торган иске йөз долларлык купюраларны иң якын арада җыеп алу һәм аларны --- яңа долларларга алыштыру турында карар кабул итәчәк.* Р.Мирхәйдәров. *Ялган акча ясаучылар күбәеп китте ахры, соңгы ярты ел эчендә шундый 600 купюра табылган.* Акчарлак

**КУР** *и. диал.* 1) Ут саклау өчен калдырылган утлы күмер, куз

2) Әчетке, камырбаш. *Камыр курына күрә.* Мәкаль. *Карчыгы онны иләп, каймакка басып кур ясый.* Әкият

3) Катык оеткысы

4) *күч.* Берәр нәрсәнең кузгатып, кабызып җибәрүчесе, орлыгы, чаткысы

5) *күч.* Капитал, туплама. *Кур җыю*

**КУРА** I *и.* 1) Каты сабаклы үләнчел үсемлек. *Хәдичә апа, чәнечкеле куралардан шәрә беләкләрен тырнатып, ике арадагы койма янына килде.* М.Маликова. *Качышлы уйнарга чакыра әрекмән, кычыткан, куралар.* Казан утлары

2) Кипкән сабак. *Кеше өстендә бүрәнә дә җиңел, үз өстеңдә кура да авыр.* Мәкаль. *Абынды ул, егылды ул, Һуштан язган күк булды, Ләкин, кура кыштырдауга, Тагын торып юк булды.* Ш.Маннур. *Бик таныш бу көзнең «Әлифба»сы, Куралар да җирдә, камыллар.* Э.Мостафин

3) Кура җиләге. *Стенада – мәтрүшкә, имән яфрагы, кура яфрагы катыш бәйләнгән каен миллекләре.* М.Мәһдиев. *[Зәйнәп] Кураны кайтарып та карый, иелеп тә җыя, матур чүгәләп тә; кайсы җиләкне каба. Киерелеп, тартылып, эчтәрәгенә үрелә.* Ә.Гаффар. *Кура һәм кара бөрлегән яфрагында алыштыргысыз аминокислоталар бар, ә алардан башка организм үсә һәм яши алмый.* Мәдәни җомга

**КУРА** II *и.* **1.** 1) *тар.* Камыштан, нечкә агачтан ясалган койма

2) Йортның терлек-туар, кош-корт өчен абзар, кетәклекне киртәләп алган өлеше; ишегалды. *Балтасыз, тактасыз кура корып булмый.* Мәкаль. *Ырсытдин белән Абдрахман курадан бергә чыктылар.* Я.Зәнкиев. --- *Рәйсә, бәбәй артыннан бәбәй табып, кураны бала-чага белән тутырып ташлады.* Р.Батулла

3) *диал.* Балчык белән сылап эшләнгән читән абзар. *Мал абзары, кош курасы, утын чиңлегенә кадәр җитлекле иде.* В.Имамов. *Әле, көтү җәйләүдә чакта, әзрәк ял итсә булмыймы, ферма курасын ремонтлап азаплана [этием].* Г.Якупова

**2.** *с. мәгъ.* Тал чыбыгы, яшь нарат, камыш һ.б.ш.дан ясалган. --- *Гөлфия, бәрәңге бураэнасы аша йөгереп узып, кура койма арасыннан үтте һәм Чирмешән буена килеп чыкты.* Р.Айзатуллин

**КУРАБЬЕ** *и. фр. < гар.* Төче камырдан пешерелә торган татлы камыр азыгы. *Без, тирләп-пешеп чәй эчә-эчә, Василий Губа пешергән курабье белән хушланып, бәйрәм итеп утырабыз.* А.Гыйләҗев

**КУРАВЫЧ** *и. тар. к.* **караваш**. *Ишәккә йөгән орып качыр булмас, куравычка тун кидереп хатын булмас.* Мәкаль

**КУРА́ ҖИЛӘГЕ** *и. бот.* 1) Рубус ыругыннан, розачәчәклеләр семьялыгыннан, тамырлары күпьеллык, ә өске сабак өлеше икееллык ярымкуакчыл үсемлек; *русчасы:* **малина**. *Кура җиләкләре дә чәчәк аткан!*

2) Шул үсемлекнең җимеше. *Вакыты үткәч, кура җиләге җыярга барма.* Мәкаль. *Хәер монда аның ише очраклы кешеләр – печән чабучыдыр, утын кисүчедер, җир җиләге, кура җиләге, чикләвектер җыючылар гына килеп чыга.* Ә.Гаффар

3) *күч. к.* **кура җиләге кебек**. *Хатын үтә әгълә, нәкъ пешеп җиткән кура җиләге икән.* А.Гыйләҗев

◊ **Кура җиләге кебек** Сәламәт, чибәр (хатын-кыз тур.)

**КУРАҖИЛӘК** *и. к.* **кура җиләге**. *Үзебезнең Степанга барам да кара карлыган, кызыл карлыган, кураҗиләк куагы алып кайтам ---.* И.Гази

**КУРАЗ** *и. фар. диал.* Әтәч. *Бер куразны җиде кеше суймый.* Мәкаль

**КУРАЙ** *и.* 1) *к.* **курай үләне**. *Ул тирә-якка күз йөгертеп, ягарга әйбер эзли башлады, якында гына коры курай сабаклары, койма койганнан калган вактөяк йомычкалар күреп сөенде.* А.Гыйләҗев. *Дөньяларны иңли-иңли Иркен сулап җил исә. Бәсле курай көпшәләре Җем-җем итә, җил тисә.* Ф.Әһлия

2) Үләнчел үсемлекләрнең кипкән, корыган сабагы. *Иртә генә торам, юлга чыгам, Курай кисеп алам камыштан.* Г.Зәйнашева. *Үзе сөйли, үзе курай купшасы эзли икән егет.* Г.Якупова. *Кыбырсык гамь йортка кергән урманга; Эчке сызлау иңри күзгә курайда.* Р.Рахмани

3) Көпшәле үсемлекләрнең сабагыннан ясала торган тынлы музыка коралы. *Уйна, курай, үзәкләрне өздер, курай, Яман уйларым булганда биздер, курай...* М.Әгъләмов. *Ханзадәләр тартып курай уйнаган, Курай көен тыңлап, кошлар моңланган.* Ә. Синугыл-Куганаклы. *...Ә тормыш – көтүче курае, Көйли көй көтүләр җаена.* Сөләйман

4) Гомумән, тынлы уен коралы

◊ **Кураена бию** Берәүнең кушканын үтәп тору, аның ихтыярына буйсыну. *Ниткән оешма булсын инде ул! Байларның сакчы эте Әхмәдиев кураена биегән оешма хезмәткәрләрне химая итсен, имеш.* Ш.Камал

**КУРА́Й ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан, куыш сабаклы, каурыйсыман яфраклы үләнчел үсемлек; шома көпшә; *русчасы:* **дудник**. *Дару чималына дарулык курай үләненең чәчәк атмый торганнарының тамырлары белән бергә тамырчаларын әзерлиләр.* Урман аптекасы. *Курай үләнен аппетиты начарайган балаларга ашар алдыннан эчерәләр.* Мәгърифәт

**КУРАЙ-КУБЫЗ** *җый. и.* Курай һәм кубыз кебек уен кораллары. *Киң сулышлы газиз халкым Гомерендә дәшмәгән, Курай-кубыз, сорнай уйнап Җырлыйҗырлый яшәгән.* Ф.Әһлия

**КУРАЙЛА́У** *ф. сир.* Курайда уйнау. *Атаклы курайчыларның «Ашказар»ын курайлаганда, ул да сизмәенчә «васвас» дип алды.* Г.Исхакый

**КУРАЙЛЫК** *и.* Куралар күп булып үскән урын. *[Юлчы бабай] Әллә инде экияттән Идел йортка юл ала, Зәңгәр күлле тугайларга, Курайлыкка юнәлә.* Ф.Әһлия

**КУРАЙЧЫ** *и.* Курайда уйнаучы. *Ә курайга кушылып һәрвакыт Котлыяр мулла җырлый торган иде, һичшиксез, курайчыга тиң җырчы иде ул.* Ә.Еники. *Егет хәйран оста курайчы, ди.* Г.Якупова. *Тик бу юлы сандугачларны исерткән, ак күлмәкле каен кызларын биеткән курайчының тыны кысылды.* И.Ихсанов

**КУРАЛАНУ** *ф.* Үләнчел үсемлекләрнең сабагы кату, агачлану

**Куралана башлау** Кураланырга тотыну

**Куралана төшү** Бераз куралану

**Кураланып бару** Акрынлап, азлапазлап куралану

**Кураланып бетү** Тулысынча куралану, кура хәленә килү

**КУРАЛА́У** *ф.* Кура II (*1 мәгъ.*) белән әйләндереп алу

**Куралап алу** Тиз генә куралау

**Куралап бетерү** Ахыргача, беткәнче куралау

**Куралап кую** Куралаган хәлгә китереп калдыру

**Куралап чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр куралау

**Куралый башлау** Куралларга тотыну

**КУРАЛЫ** *с.* 1) Куралар I (*1 мәгъ.*) каплаган, кура үскән

2) Арасында кура II (*1 мәгъ.*) булган, кура белән аерылган

**КУРАЛЫК** *и.* **1.** 1) Кура җиләге (куагы) күп үскән урын. *Күрәле, куе куралык каплаган мәйданчыкка күтәрелде бу.* М.Хәсәнов. *[Ибрай] Борылса күрде: читтәрәк бер куралык булып, ул шуның соңгы җиләкләрен учына чупли дә башлаган.* Ә.Гаффар

2) Кура үләне күп үскән урын

**2.** *с. мәгъ.* Кура ясау өчен яраклы

**КУРАНТ** *и. фр.* Манараларга куела яки бүлмәләрдә урнаштырыла торган көйле зур сәгать. *Ак кремль, кабынып китә Вакыт – курантларның алсу авазы.* М.Галиев. *Күңелләрне җилкен-*

*дереп, курантлар сукты.* Р.Хафизова. *Яңа ел курантлары дыңгырдата башлаганчы, чаптырып кына чыгып керергә җәә өлгерәсең, җәә юк.* Р.Гаффар

**КУРА́ТОР** *и. лат.* 1) Билгеле бер нәрсәне даими күзәтүче, караучы зат. *Хәлбуки гайбәт группаның кураторы, философия укытучысы Алия Фәргатовнаның да колагына барып ирешкән иде инде.* М.Маликова. *Миңа баштагы дәвердә бу эшнең кураторы булырга туры килде.* Казан утлары. *Сәлимҗановка даими рәвештә театр һәм аның күпсанлы идеологик кураторлары арасында ниндидер буфер хезмәтен үтәргә туры килүен әйтеп торасы да юк.* Татарстан

2) *икът.* Бурычлы кеше өстеннән күзәтүчелек итүче зат

3) *мед.* Клиникада яткан авыруларны күзәтүче медик

**КУРАТАЛ** *и бот.* Курайчалар семьялыгыннан, озын туры сабаклы, шәмәхә ал чәчәкле, артык дымы озынча яфраклары өстенә аерылып чыгып, күз яше кебек агып төшә торган, сазлыкларда, елга-күл буйларында таралган үлән үсемлек; *русчасы*: **дербенник иволистный**

**КУРА-ХУҖАЛЫК** *җый. и.* Йортҗир, хуҗалык. *Ул чакта ике кура-хуҗалык арасында тәбәнәк кенә, утырган эт биеклеге генә читән иде.* А.Гыйләҗев

**КУРАЧ** *с.* 1) *диал.* Кыска буйлы. *Мөхәммәт янына елышкан курач кына бер адәм: – Падишабыз аттан төшсә дә, иярдән төшмәскә ниятли бугай! – дип сүз катса да, ул эндәшмәде, кызыксынып алгарак узды.* Я.Зәнкиев. *Курач буйлы, дыңгычлап тутырылган ат казылыгы кебек тыгыз гәүдәле, коңгырт чәчле бүлек мөдире, кара күн кәнәфиеннән күтәрелеп, Вильсурга саф татар телендә мөрәҗәгать итте: «Сезнең белән танышуыма шатмын».* Т.Галиуллин. *Харис дип исем тагып куйдылар үзенә. Буйга курачрак булса да...* М.Галиев

2) Кечкенә, тар һәм кыска (киемсалым тур.). *Иңнәре бик тар, җиңнәре курач иде халатның.* Л.Гыйззәтуллина

**КУРАЧЛАНУ** *ф.* 1) Бөрешү, бәләкәйләнү, тәбәнәкләнү; ябыгу. *Күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаепләрне куркудан дер-дер калтырап тагын да курачланган малай өстенә өяләр генә.* А.Гыйләҗев

2) Кечерәю, кыскару (кием-салым тур.). *Җитмәсә, элек төзелгән ферма торaклары, мастерскойлар да искерде, үсмер балага теккән кием курачланган кебек, замана таләпләрен күтәрә алмый башладылар.* Ф.Садриев

**Курачлана бару** Торган саен ныграк курачлану

**Курачлана төшү** Бераз курачлану

**Курачланып бетү** Тәмам, бик нык курачлану

**Курачланып калу** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң курачланган хәлгә килү. *Кечерәеп, курачланып калган Николайны ташлап китә алмады ул [Гәрәй].* А.Гыйләҗев

**Курачланып китү** Бераз курачлану; көтмәгәндә курачлану

**КУРГАВЫЛ** *и. тар.* 1) Югары катлам вәкилен саклаучылар төркеме

2) Шәхси сакчы; җан сакчысы. *Кургавыллар яллау*

**КУРГАВЫЛЛА́У** *ф.* Билгеле бер затны саклау, коргау. *Хуҗаны кургавыллау*

**Кургавыллап тору** Даими кургавыллау

**Кургавыллап йөрү** Һәр җирдә, һәрвакыт кургавыллау

**КУРГАН** *и.* 1) Борынгылар үзләренең үлгән башлыклары, баһадирлар истәлегенә өеп калдырган калкулык. *Курганнар... Курганнар өстендә – зиратлар, Зиратлар өстендә – кылганнар, Туфракка әйләнгән ир-атлар Кайчандыр изгелек кылганнар...* И.Юзеев. *Тәҗрибәле табиб шикелле, йөрәгенә кереп курганның, алтын балдак табып алды археолог.* М.Галиев. *Тарихчы археологлар бу якларда да борынгы курганнар тапканнар ---.* Ф.Бәйрәмова

2) Кальга, кирмән дивары. *Ялгыз агач урман булмас, ялгыз кирпеч курган булмас.* Мәкаль. *Кереп курганга шундый якты йөзле, тезеп китте Бануга мондый сүзне.* Нәваи

3) *этн.* Тигез җирдә балчык стена белән әйләндереп алынган утар

**КУРГАШ** *и.* **1.** 1) Зәңгәрсу соры төстәге йомшак, чүкелүчән авыр металл. *Кургашны ялкын эретә, күңелне яхшылык эретә.* Мәкаль. *Таш коймалар тышкы яктан бакыр белән, эчке яктан кургаш белән капланган.* Н.Фәттах. *Кургаш, иң беренче чиратта, кече яшьтәге баланың психикасына тискәре йогынты ясый.* Иң шәп календарь. *Марганец, кургаш, терекөмеш һәм башка кайбер металларның тозлары периферик нервларны һәм үзәк нерв системасын зарарлый.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

2) Пуля. *Бер ялгыш хәрәкәт, күңелләренә хуш килмәгән сүз булсын – кургаш кисәгенә куышыннан очып чыгу өчен җитә калачак.* Т.Галиуллин. *Сугыш чорында күпме газиз күкрәкләргә тигән кургаш кебек, исән күкрәкләргә дә тиеп-сызлап үткән бер чорда, әти кайгысы да салкын сулар югандай онытылды.* Х.Сарьян. *Үтсәм дә мин кургаш яңгырларын, Сыкранырга туган җырым юк!* Ш.Мөдәррис. *Приказны үтәмәсәң, сиңа да, миңа да – тугыз грамм кургаш!!!* Р.Кадыйров

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кургаштан **1.** (*1 мәгъ.*) яки кургаш кушып эшләнгән. *Кургаш табут, аннан сезгә кабык. Ил ирләре, дәшми тормагыз!* Н.Сафина. *Һәркөн иртән шул ук уй белән йокыдан уяналар, тиз-тиз киенәләр, күңелне биздереп бетергән, кургаш ядрәдәй тере борай боткасын, тешкә ябыша торган чи ипине һәм тозлы балыкны ашыйлар ---.* Г.Ахунов. *Төн буе кургаш торбаларда җыелып торган суда бик күп агулы матдәләр туплана икән.* Иң шәп календарь

2) Төсе кургаш **1.** (*1 мәгъ.*) шикелле булган, шуңа охшаган

3) *күч.* Авыр. *Олуг Хаким кургаш болыттай авыр күз кабакларын түбән төшерде дә язмыштан да ачырак, гүрдән дә салкынрак уй уйлый башлады.* Ә.Гаффар. *Бер усал сүз, бер туры сүз, бер кургаш сүз саклыйм йөрәктә. Бер авыр сүз – Хаксыз әйтелгән сүз – Кургаш булып килде кай яктан?* И.Юзеев

**КУРГАШЛАНУ** *ф.* 1) Кургаш кушылу

2) *күч.* Караңгылану, кургаш төсенә керү

3) *күч.* Авыраю. *Күз кабаклары кургашлану*

**Кургашлана бару** Торган саен ныграк кургашлану

**Кургашлана башлау** Кургашланырга тотыну

**Кургашлана төшү** Бераз кургашлану; тагы да кургашлану

**Кургашланып бетү** Тәмам, бик нык кургашлану

**Кургашланып тору** Әле, хәзерге вакытта кургашлану

**КУРГАШЛА́У** *ф.* 1) Кургаш кушу; кургаш белән ямау

2) Кургаш белән пичәт сугу, мөһерләү

**Кургашлап бетерү** Тәмам, тулысынча кургашлау

**Кургашлап кую** Тиз арада кургашлау

**Кургашлап тору** Даими яки әледәнәле кургашлау

**Кургашлап чыгу** Барысын да, ахырга кадәр кургашлау

**КУРГАШЛЫ** *с.* 1) Составында кургаш булган. *Компресс өчен Буров сыекчасы яки кургашлы примочка ярый ---.* Иң шәп календарь

2) Кургашланган

**КУРГАШЫН** *и.* **1.** *к.* **кургаш 1.** *Рәсимнең авызы кипте, теле кургашын кисәгедәй авыраеп калды.* Ф.Шәфигуллин. *Әйтерсең минем бөтен әгъзаларымны кургашын белән коендырдылар.* Ф.Яруллин. *Ә «Кара күмер» кушаматлы үгезнең киң маңгаен чәрдәкләгән кургашынның минем күкрәкне теткәләве ихтимал түгел идеме?* Ә.Гаффар

**2.** *с. мәгъ. к.* **кургаш 2.** *Кургашын шарларны шалтыратып --- салучылар да юк түгел иде.* А.Әхмәт. *Әрҗәләрне күтәреп ташыган кешеләр дә кургашын хәрефтер дип уйлый.* А.Тимергалин

◊ **Кургашын кәгазьгә төреп куйган сыман** Манма су. *Өсте-башы кургашын кәгазьгә төреп куйган сыман иде.* Казан утлары

**КУРГЫ** *и. диал.* Металл кыздыру өчен махсус учак; тимерче миче

**КУРҖЫН** *и. фар.* Ат, ишәк һ.б. аркасына салып йөртү өчен, авызлары бер-берсенә каратылган ике зур кисәдән (тәйдән) гыйбарәт капчык. *Бер курҗынга тултырып алтын биреп, Карчыкны ахыр алдап орды, диде.* Дастан. *Авыл җиренә чыгып, көзге, тасма, борыч, чәй һ.б. белән сәүдә итүче вак сәүдәгәр --- үзенең товарларын ике кесәле капчыкка – артмакка яки ике ялпак кәрзингә, карнашага (курҗынга) тутырып, атның савырына – ияр артына ике яклап аскан.* Р.Әхмәтьянов

**КУ́РИЯ** *и. лат. сәяси* Кайбер сайлау системаларында сайлаучыларның мөлкәт, милли һ.б. үзенчәлекләре буенча төркеме. *Казан ханлыгы монарх эшчәнлегенә феодаль курия һәм феодаллар съездлары ярдәмендә юнәлеш биргән феодаль монархия була.* Б.Хәмидуллин

**КУРКАК** *с.* **1.** Курка торган; кыю түгел, өркәк, шүрләүчән. *Күрсәтәм мин кемнең куркак икәнен.* Р.Хафизова

**2.** *и. мәгъ.* Кыюсыз, өркәк кеше. *Суга чумып кына батыр булсалар, җирдә бер куркак та калмас иде!* Р.Хафизова. *Сугышырга батыр шашмый, Сугышуны куркак башлый.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ә шулай да батырлар бер үлә, Һәркөн җаны чыга куркакның.* Ф.Яруллин

◊ **Куркак җан** Бик куркак, ышанычсыз кеше. *Куркаклыктай юк дөньяда хурлык, Куркак җанны һәрчак фашлагыз!* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Заманы шул: куркак җаннар Намус сатып батырлана.* Ф.Яруллин. *Әх, куркак җан, сугыш төтененнән Котың чыгып артка качтың син.* Ш.Мөдәррис. **Куркак куян** Һәрнәрсәдән курка торган кеше. *Руслан Даулатович ---, үзенең куркак куян түгел икәнлеген расларга теләгәндәй, «Булышыйм!» дип, әүвәл кухня якка да кергән иде, профессор итагатьле генә кире какты.* З.Хөснияр

**КУРКАКЛАНУ** *ф.* Куркак булып китү. *Куркакланган карга куләгәгә кунмас.* Мәкаль

**Куркаклана бару** Торган саен ныграк куркаклану

**Куркакланып бетү** Тәмам куркакка әйләнү

**Куркакланып китү** Соңгы вакытта куркаклану

**Куркакланып тору** Әле, хәзерге вакытта куркаклану

**КУРКАКЛА́РЧА** *рәв.* Куркаклар шикелле. *Тегеләр көлеп калдылар. Бераз киткәч, Тәүгиз болай куркакларча качуына, тегеләргә «сдача» бирмәвенә бик каты гарьләнүеннән нишләргә белмәде.* Х.Камалов

**КУРКАКЛЫК** *и.* Куркак булу, өркәклек. *Куркаклар һичкайчан булалмый азат, Куркаклык – милләткә гомерлек газап.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Куркаклыкны гафу итә алмас, Чыраеңа бәреп әйтер халык.* Р.Әхмәтҗанов. *Үлем – мәгънәсезлек, көчсезлек, куркаклык дип уйлыйм мин.* Р.Вәлиев

**КУРКА́-КУРКА** *рәв.* 1) Һәрвакыт куркып

2) Бик сак. *Ул янә курка-курка гына эш бүлмәсенә чыкты ---.* З.Хөснетдинов. *Курка-курка гына тавыш бирдем.* А.Гыйләҗев

**КУРКАЧ** *с.* 1) *к.* **куркак**

2) Курыкканлыгы күренеп торган

**КУРКУ** I *ф.* 1) Берәр нәрсә алдында көчсезлек, ярдәмсезлек кебек уйхисләр кичерү. *Ә гөнаһтан курка белү кирәк, Кача белү кирәк гөнаһтан.* К.Булатова. *Курка икән, димәк ки, үзенең хак түгеллеген чамалый.* А.Гыйләҗев. *Батыр була алмый батыр, Курыкмаса әгәр – башсызланып башын сала Батырлыкка кадәр.* М.Әгъләмов

2) Билгеле бер нәрсәдән шикләнү, сагаю, борчылу. *Кот очу, курку, шөлләү кебек хисләр юк иде күңелдә.* Т.Галиуллин. *Малайлар, сулыш та алмыйча, ни буласын көтәләр. Миңнәхмәт бабай куркырмы, юкмы?* Р.Хафизова

3) Билгеле бер эшкә алынырга кыюлык җитмәү, батырчылык күрсәтмәү. *Курыксаң, әйтмә сүзеңне, Әйтсәң, кыю тот үзеңне.* Ә.Синугыл-Куганаклы

4) Билгеле бер шартларда чыдамау (үсемлекләр һ.б.ш. тур.). *Помидор үсентесе язгы кыраудан курка*

◊ **Курка торган (куркыр) күлмәк тузган** Һич тә курыкмауны белдерә. *[Җәмилә:] Җангали ханнан курка торган күлмәгеңне туздырдың түгелме инде, Сөембикә ахирәтем?* М.Хәбибуллин. **Курыкканга куш күренү** Бик каты куркудан нәрсәдер чынбарлыктан артыграк тоелу. *[Кенәз] Берара үтүгә, артына әйләнеп карады, курыкканга куш күрендеме, аның артыннан кемдер килә кебек иде.* М.Хәбибуллин

**Курка калу** Бераз куркуга төшү, шикләнү. *Кәримә курка калды, аяк буыннары капылт йомшарып, тез астының хәле киткәндәй булды.* З.Хөснияр. *Мин тагын да ныграк курка калдым.* Ф.Яхин. *Кинәт каршыма [поши] килеп чыккач, мин дә курка калдым.* М.Хәбибуллин. *Бирeдә сорашынсам, курка калган дип уйлаулары бар.* Р.Төхфәтуллин

**Курка төшү** Бераз курку. *Солтан, курка төшеп, Зиннурның җыерчыклы кабаклары арасында хәйләкәр ялтыраган соры күзләренә карады.* А.Расих

**Куркып бетү** Бик каты курку, тәмам куркуга бирешү. *Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышы елларында төрле серле кораллар куллану ихтималыннан куркып беткән солдатлар күктә очкан пәрәвезне агулый торган матдәләрнең бер төре дип кабул иткәннәр.* Кызыклар дөньясында

**Куркып йөрү** Озак вакытлардан бирле курку. *Түрәләрдән курку, судтан курку Ана сөте белән сеңгән кебек. Адәм балалары бу дөньяга Куркып йөрер өчен килгән кебек.* Г.Афзал. *Сүз кату түгел, туры карарга да куркып йөрим мин аңа.* Г.Гыйльманов

**Куркып калу** Ниндидер сәбәптән соң курка торганга әйләнү. *Дәррәү кабынган авыру ханымнан куркып калган врач кыз ачкыч тишегенә сыярлык булып бөрешеп калды.* М.Галиев. *Кичер, әнкәй! Өметеңне Синең аклый алмадым. Куркып калдым. Бүреләрдән Сине яклый алмадым.* Ф.Яруллин. *Кайбер егетләр мондый чакта югалып, хәтта куркып кала.* М.Маликова

**Куркып китү** Кинәт, көтмәгәндә курку. *Аның тагы йөрәге куркып китте.* Г.Исхакый. *[Фәрхинур] Әйтмәгән идем, әйтим: синең белән сәхнәдә уйнаганда, кинәт кенә мин сине танымый башлыйм: бөтенләй бүтән буласың да алдыма килә башлыйсың. Валлаһи, куркып китәм.* Н.Исәнбәт. *Куркып киттем. Әмма Фазыйлә апа мине ничектер йомшак һәм җылы итеп кочты ки, мин эредем.* Ф.Яхин

**Куркып кую** Аз гына вакытка, бераз гына курку хисе тою. *[Чикерткә] Әллә ташлап качтымы дип, бик борчылып куркып та куя.* Ә.Еники. *«Ә шушында батсам?» – дип куркып куя ул.* М.Мәһдиев. *«Хәлсезлектән бөтенләй арындым шикелле тоелган иде бит», – дип куркып куйды ул [Разия].* М.Юныс

**Куркып тору** Гел курку; күпмедер вакыт курку; әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда курку кичерү. *– Дөрест, гыйлем шәп инде үзендә: бөтен тирәяк мулласы үзеннән куркып тора, – диде дә, мужик та зур иттереп сулады.* Г.Исхакый. *Кенәгинә каршына җилтерәтеп китерелүнең сәбәбен белмәгән Федот агарынып калган, әле берсенә, әле икенчесенә мөрәҗәгать итмәкче, әмма кыймый, авызын ачарга куркып тора иде.* М.Хәбибуллин. *«Үзем дә шуннан куркып торам әле», – дип, Бүре Госманы авылга таба китеп барды.* И.Сирматов

**Куркып утыру** *к.* **куркып тору**. *[Әнисә:] Нишли алар анда? [Кәримҗан:] Куркып утыралар.* А.Гыйләҗев. *--- Мөдир абзый селкенергә дә куркып утыра иде.* И.Сирматов

**Куркып яту** *к.* **куркып тору**

**КУРКУ** II *и.* Берәр нәрсә алдында көчсез, ярдәмсез булудан, я шулай дип уйлаудан, шикләнүдән туган рухи-физиологик халәт. *Минем күңелемдә әллә нинди курку, үз-үзенең гаебен белү хисе уянды.* Г.Исхакый. *Канга гына түгел, җанга сеңгән Курку, үз-үзеңә цензорлык.* И.Юзеев. *Шул мәхшәрләр исеңдәме, Мөҗәй? Курку безне, ай-һай, талкыды!* Зөлфәт

◊ **Курку белмәс** Бернидән дә курыкмый торган, йөрәкле; батыр. **Куркуга бату** Бик каты курку. **Куркуга бирелү** Курку хисе кичерү. **Куркуга калу** *к.* **куркуга бирелү.** *Елена Глинская кайчан уйлана-уйлана да тәмам куркуга кала.* М.Хәбибуллин. **Куркуга салу** Куркыту; күңелгә шом салу. *Бөек кенәгинәнең бу фәрманы боярларны куркуга салды.* М.Хәбибуллин. **Куркуга төшү** *к.* **куркуга бирелү.** *Моны һич тә көтмәгән фашистлар куркуга төшкәннәр ---.* Р.Мостафин. **Курыкканга – куш** *к.* **куш күренү**. *Бәлки, ул кадәр озак та булмагандыр, «курыкканга – куш, койрыгы белән биш» дигәндәй, каршы яклар бер-берсен сыныйлар иде.* Г.Ахунов. *Курыкканга – куш дигәнең шушы була торгандыр, мөгаен.* М.Әмирханов

**КУРКУЛЫ** *с.* Курку катыш; курку күренеп, беленеп торган. *Кызның тавышы куркулы.* З.Хөснияр. *– Нәрсә булды, әни? – диде Сөмбел, әнисенең куркулы йөзен күргәч.* Ф.Яруллин. *Тик шофёр егет күккә таба таш яуган бу манзараны күрә алмый: куркулы күзләре әкрен генә йомылалар.* Р.Гыйззәтуллин

**КУРКУЛЫК** *и.* 1) Ышану буенча: кешенең нәрсәдән, кемнән куркып авыруын белү максаты белән эретелгән кургаштан коела торган кот. *Куркулык койдыру*

2) Нәрсәдән дә булса куркып калу халәте. *Төннәр буе саташа, куркулыгы кузгала торган булып китте.* Ф.Яхин

**КУРКУМА** *и. лат. бот.* 1) Имбирчәләр семьялыгыннан, тропик Азиядә, Төньяк Австралиядә, тропик Африкада үсә торган, тамыры һәм сабаклары эфир майларына, буяуга бай булган күпьеллык үләнчел үсемлек

2) *кулин.* Шул үсемлекнең тамырыннан ясала торган кызылсу соргылт төстәге хуш исле ачы аш тәмләткеч. *Баш мие өчен корица, имбир, куркума файдалы.* Татарстан яшьләре

**КУРКУСЫЗ** *с.* **1.** Курыкмый торган, курку белмәс. *Ул үзен Алла каршында гына зәгыйфь һәм гөнаһлы дип саный икән, ә шул чорның иҗтимагый-социаль тормышында ул – гаять көчле рухлы, батыр җанлы, куркусыз шагыйрь.* Н.Юзиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Курыкмыйча. *Чәмәт инде куркусыз төп мәсьәләгә күчте.* Х.Сарьян

**КУРКУСЫЗЛЫК** *и.* Курыкмаучанлык, кыюлык сыйфаты. *Шуны гына көтеп торган Шүрәле Фирүзә бер аяк табаны тиклем алга таба атлады да, шул хәрәкәтен һичкемнән курыкмас җан икәнлеген, үтә дә куркусызлык галәмәте дигәнне аңлатып, сүзгә кереште...* Ә.Гаффаров. *Аның [Чураевның] кеше ышанмаслык батырлыгы һәм куркусызлыгы турында күптән инде легендалар йөри.* Р.Мирхәйдәров

**КУРКУЧАН** *с.* Курка торган. *Олкән голиафлар бик сак һәм куркучан,*

*аларга якынаеп булмый.* Кызыклар дөньясында

**КУРКУ-ШӨБҺӘ** *и. к.* **курку** II. *Курку-шөбһә басты Күктерәрне: кем – дошман, кем соң дусты аның?!* Л.Шагыйрьҗан

**КУРКЫЛЫК** *и. диал.* Кошларны куркыту максаты белән бакчага куела торган карачкы. *Куркылык кую*

**КУРКЫН** *и. диал. к.* **курку** II

**КУРКЫНДЫРУ** *ф.* 1) Куркыту

2) *з.-сыз* Куркырга мәҗбүр булу

**Куркындырып бетерү** Һәммәсен, тәмам куркындыру

**Куркындырып җибәрү** Кинәт яки бераз куркындыру

**Куркындырып кую** Алдан ук куркындыру

**КУРКЫНУ** *ф.* 1) Көтмәгәндә, билгесез сәбәптән курку

2) Куркуга бирелү. *Шәвәлиев аңа куркынып карады.* Ф.Садриев

**Куркынып калу** Көтмәгәндә куркуга бату. *[Хөсәен] Куркынып калды. Әле моңарчы булмаган бер авырту иде бу.* А.Расих. *Ваһимның ярсуы чиктән ашып килә иде, хәтта Моназыйр аңа каршы сүз әйтергә куркынып калды.* М.Хуҗин

**Куркынып китү** Кинәттән курку. – *Нишлисең, абзый? – дидем. Шунда агаем аптырый: Куркынып киткән төсе, куллар да дер-дер калтырый.* Г.Тукай. *Аңа күз салуга Җәмилә куркынып китте: хатынның йөзе күгәреп чыккан, күзләре йомык иде.* М.Маликова

**КУРКЫНЫЧ** *с.* **1.** Куркыта торган; хәвефле; хәтәр; шомлы. *Шахтада янгын! Коточкыч куркыныч хәл!..* А.Гыйләҗев. *Балачакның бүрегә бәйле куркыныч төннәре, дәһшәтле кичләре, әкиятләре күп булды.* М.Мәһдиев. *...Парсегян аның өчен бик куркыныч кеше иде.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *рәв. мәгъ.* Куркытып, хәвефле, шомлы итеп. – *Әтием, агачлар нигә шулай куркыныч шаулый ул? – ди яшел күлмәкле кызым.* Р.Бәшәр

**3.** *и. мәгъ.* 1) Сәламәтлеккә, гомергә янаган, нәрсәне дә булса юкка чыгару ихтималы булган нәрсә. --- *җинаятьчел дөньяга һәм эшкуар даирәләргә реаль куркыныч ясый...* Р.Мирхәйдәров

2) Куркынычлык. *Үзләренең нинди куркыныч астында йоклауларын алар сизмәделәр.* Ә.Баян. *Ләкин кейсны хуҗасына кайтарып бирмичә ярамый, бирмәсәгез, тормышыгызны куркыныч астына куясыз була.* Р.Мирхәйдәров

**4.** *хәб. сүз мәгъ.* Хәвефле, куркыныч булуны хәбәр итә. *Таң яктысында аңа алай ук куркыныч түгел иде инде.* Р.Хафизова

**КУРКЫНЫЧЛАНУ** *ф.* Куркыныч булып китү, куркынычка әйләнү

**Куркынычлана бару** Торган саен куркынычрак булу

**Куркынычланып китү** Көтмәгәндә яки бераз куркынычлану

**КУРКЫНЫЧЛЫ** *с.* **1.** 1) Куркыта торган. *Сәгыйдә, бик куркынычлы ямьсез төшеннән уянып китеп, төш булуына шатланган кебек, фонарьны көтмәенчә дә чыгып китте.* Г.Исхакый. *Азык-төлек бәяләре күтәрелә баруның халык өчен тагын бер куркынычлы ягы бар: һәркем дә кыйммәт бәягә ризык сатып ала алмаячак.* Мәдәни җомга

2) Зарар китерә торган. *Куркынычлы җил-давыл. Олы шатлык, олы кайгы – бер үлчәүнең ике очы; Чиктән ашып китсә ташып, икесе дә куркынычлы.* Г.Сәгыйров

3) Зарарлы, хәвефле. *Шунысы күптән билгеле: җир тетрәү алдыннан күпчелек җанварлар куркынычлы урынны ташлап китәләр.* Кызыклар дөньясында

**2.** *рәв. мәгъ.* Куркыныч итеп. *Ыжжыж итеп сызгырып, тәрәзә капкачаларын шакылдата, моржалардан кереп, озын иттереп сузып, моңлы, куркынычлы улый --- торган кышкы җилнең тавышына уянып киттем.* Г.Исхакый

**КУРКЫНЫЧЛЫК** *и. к.* **куркыныч** (*3 мәгъ.*)

**КУРКЫНЫЧЛЫЛЫК** *и. к.* **куркыныч** (*3 мәгъ.*). *Сатирик комедия андый геройларны төзәтми, ә рәхимсез рәвештә аларны фаш итә, аларның асылын күрсәтә, алар кылган гамәлләрнең сәбәбен һәм куркынычлылыгын аңлата.* Г.Каюмова

**КУРКЫНЫЧСЫЗ** *с.* Куркыныч булмаган, хәвеф-хәтәрсез; борчылырлык түгел

**КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК** *и.* Иминлек; тынычлык; хәвефсезлек. *Ләкин үз вакытында аның «Үтә яшерен» мөһере сугылган ике хезмәте белән танышып өлгергән Ю.В.Андропов ярдәм кулы суза: ул Вашингтонга АКШтагы совет миссиясенең куркынычсызлык хезмәтен җитәкләргә җибәрелә.* Р.Мирхәйдәров. *Бу күрсәтмәдә авыл халкы хисабына янгын куркынычсызлыгын көчәйтү буенча кайбер чаралар каралган булган.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Яңа двигатель экономиялелек, ышанычлылык, файдалы эш коэффициенты һәм экологик куркынычсызлык буенча югары характеристикага ия.* Татарстан

**КУРКЫТКЫЧ** *с.* **1.** Куркыта торган, куркыныч

**2.** *и. мәгъ.* Карачкы, куркылык

**КУРКЫТУ** *ф.* 1) Курку, шом салу, курку халәтенә китерү; шүрләтү. *Ялынып та, куркытып та хатлар яздым.* Т.Миңнуллин

2) Янау

3) Өркетү, качарга мәҗбүр итү

**Куркытып алу** Көтмәгәндә куркыту

**Куркытып бетерү** Бик каты куркыту. *Бөтен чебешләремне куркытып бетерде, хәерсез!* Т.Миңнуллин. *Бүлбе үзе – усал, каты куллы, бик кырыс кеше. Хатынын куркытып бетергән.* Р.Батулла

**Куркытып кую** Алдан куркыту. *[Сабира:] Куркытып куй син аны.* Э.Яһудин

**Куркытып тору** Әледән-әле куркыту; һәрвакыт курку халәтендә тоту. *Панченко куркытып торса да, үзебездә хисапчы булып эшләгән кыз белән ишектән чыгып барышлый үбештек.* Т.Миңнуллин. *Яңгырлар әледән-әле куркытып торганда, бу хәтәр нәрсә иде.* Ф.Садриев

**Куркытып килү** Даими куркыту. *Мине, шөһрәтлебез, хәрби киемдәге хатын-кыз һәрчак куркытып килә.* М.Хәбибуллин

**КУРКЫШ** *и. сир.* Курку. *Шулчак Сөмбелгә әллә ни булган, куркышыннан агарынып киткән дә: «Курай очыннан кан тама», – дип һушын югалткан.* Т.Якупова

**КУРЛЫК** *с.* **1.** 1) Курга, маяга калдырылган. *Курлык камыр*

2) Үрчемгә калдырылган. *Курлык терлек*

**2.** *и. мәгъ.* Камыр башы. *Курлык калдыру*

**КУРМАЧ** *и.* 1) Кыздырылган бодай

2) Терлекнең эч маен эреткәннән соңгы калдык, сызык

**КУРНОС** *с. рус сөйл.* 1) Почык (борын тур.). *Мин бер матур кызны беләм, яшерен сөеп йөрим. Кара күзе өчен сөям, курнос борынын сөймим.* Р.Гаташ. *Гәүдәгә таза, киң җилкәле, шома битле, курнос борынлы, әмма куш иякле, шуңа күрә үзенә бер төрле ягымлы күренә [ яралы].* Х.Камалов. *Курнос борынының яфраклары дерелдәп куйганда, Нагаевның карт йөрәге әллә нишләп китә, шайтан алгыры!* Р.Зәйдулла

2) Почык борынлы

**КУРОК** *и. рус* Тәте. *Без ант иттек: куроклардан Кулны алмабыз, Бөтен дошман берләшсә дә, Җиңми калмабыз.* Ф.Кәрим. *Тәмам ачуыма тигәч, бер попугайны прицелга алып, курокка бастым.* М.Юныс

**КУРОРТ** *и. нем.* 1) Дәвалану өчен шифалы шартлары (климат, минераль чыганаклар һ.б.) булган урын. *Ташкент янындагы курорттан ерак түгел месхет төрекләренең яшәве билгеле.* Р.Мирхәйдәров. *Әле менә бүген генә, курортка путёвка алырга баргач, бик тә матур, акыллы бер кыз күрдем.* Ф.Баттал

2) Ял итү урыны. *Менә, ичмасам, хәзер сине курорт кешесе дияргә була.* Н.Исәнбәт

3) *күч.* Хәвефсез яшәү өчен бөтен шартлары да булган урын. *Төрмә – алар өчен курорт, төрмәдә утырган меңнәрчә вак-төяк кесә караклары, өй басучылар – бер сүз белән әйткәндә, «шушера» – әнә шул бурлык аристократиясенә һич карышусыз хезмәт күрсәтә...* А.Гыйләҗев

**КУРО́РТ-САНАТОРИЙ** *җый. и.* Төрле дәвалану, ял итү урыннары. *Курорт-санаторийларга да Саматов белән бергә йөрде Рәмзи ---.* К.Латыйп

**КУРОРТОЛО́ГИЯ** *и. нем.-гр.* Табигатьнең шифалы факторларын, аларның сәламәт һәм авыру организмга тәэсирен, ул факторларны дәвалау, профилактикада куллану мөмкинлекләрен өйрәнә торган медицина тармагы. *Курортология белән кызыксыну*

**КУРОРТОТЕРАПИ́Я** *и. нем.-гр. мед.* Курортта аның шифалы табигый факторларына нигезләнеп үткәрелә торган дәвалау чаралары комплексы. *Курортотерапия үткәрү*

**КУРОРТЧЫ** *и.* 1) Курортта дәваланучы, ял итүче. *Быел курортчылар куак төбе саен бит!* А.Хәлим

2) Ял итәргә йөрергә яратучы кеше. *Гомергә курортчы булдыгыз!*

**КУРПЫ** *и.* **1.** 1) Төптән тамырланып үскән үсемлек

2) Агач төбеннән үсеп чыккан үсентеләр

3) Чабып алганнан соң үскән яшь үлән. *Ары киттек сутлы сукмак буйлап, Сугылдык та урман йортына... Сарут борын төрткән аланнарда Тәгәрәдек яшел курпыга.* М.Әгъләмов. *Чабылган печән урынына шытып чыккан яшел йомшак курпы өстендә атның сылу гәүдәсе еракта ук күренеп тора.* М.Юныс

4) *күч. сөйл.* Яшь буын, балалар, оныклар

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чабылган-урылганнан соң үсеп чыккан. *Чая Гөлфинур курпы үлән өстендә зыр-зыр әйләнүен белде ---.* А.Вергазов

2) Яшь буыннан булган

**КУРПЫЛАНУ** *ф.* Курпылар үсеп чыгу

**Курпылана бару** Курпылар торган саен күбрәк үсеп чыгу

**Курпылана башлау** Курпыланырга керешү

**Курпыланып китү** Бераз, берникадәр курпылану

**Курпыланып килү** Акрынлап курпылар чыгарга әзерләнү, курпылар чыга башлау

**КУРПЫЛЫ** *с.* Курпылары булган, курпы белән капланган

**КУРС** I *и. нем.* 1) Хәрәкәт юнәлеше. *Тәрәкъкыят айнытырмы, юкмы Русьны, Диңгез бер купса, югалта кораб курсны.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Габдрахман, өске палубага менеп, төп компас күрсәткән курсны карап төште.* М.Юныс

2) Маршрут. *Тауларга курс тоту*

3) *күч.* Мәсләк; кыйбла

4) Иҗтимагый, сәяси тормыш юнәлеше. *Ил демократиягә, базар икътисадына курс алды.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Авылны күчерергә йөрүенә югарыдан каршылык юк, киресенчә, хуплап торалар, чөнки ул чорда гомуми курс шундый.* В.Нуруллин

5) *икът.* Кыйммәтле кәгазьләрнең (сум, валюта, евро, акция, облигацияләрнең) сатылу-алыну бәясе. *Әйтерсең лә Курсы төшкән акча монда көн. Берәү... алтау... Ай, янчыгы менә Бупбуш калган, Ә алынган нәрсәң – уннан бер.* Х.Туфан. *Долларның рәсми курсы – бер сум, итәк астыннан бер доллар илле сум тора.* М.Юныс. *Бераз үзгәрешләр кичерсә дә [валюта], бу курс шактый озак сакланган.* Кызыклар дөньясында

**КУРС** II *и. нем.* 1) Дәвалану, дәвалану процедураларының бер циклы. *Шунысын да әйтим: дәвалану курсын үтеп чыккач, хәрби өйрәнүләргә озатам мин сине.* Б.Камалов. *Анда әлеге кыйммәтле эчемлекне куллануга нигезләнгән шәхси дәвалау курсы билгеләнә.* Идел

2) Нинди дә булса бер фәнне яки аның тармагын укыту өчен билгеләнгән вакыт. *Ул [Галя] берөзлексез французча өйрәнә, стенография курсында читтән торып укый...* М.Мәһдиев. *Таллин шәһәрендә, «Таллингаз»да эшләү өчен, этләрне кыска сроклы курсларда укыталар.* Кызыклар дөньясында

3) Фәнни дисциплинаның систематик эчтәлеге һәм аның тексты. *IX–XI сыйныфлар курсы әдәбият тарихын өйрәнүгә багышлана.* Д.Заһидуллина

4) Югары яки махсус уку йортларында укуның бер еллык баскычы. *Ирина исә быел дүртенче курсны бетерә, ул студентларның төзелеш отряды белән китәчәк.* Б.Камалов. *Бу темалар әлегә сер, курс эшләре әзерләнеп беткәч тә, аның хакында кешеләргә белдерергә ярамый.* З.Хөснияр. *Без үзара әүвәлге курстан бирле белешеп йөрдек-йөрдек тә, өченче уку елы башында*

*якынаеп, бишенченең ахырында туй ясадык.* Ф.Яхин

5) *сир.* Төрле дисциплиналар буенча уку-укытулар оештырыла торган югары яки махсус уку йорты. *Юкса техникумдыр, курстыр кебек җирләрдә, укытучылар әйтмешли, «менә дигән төпле белем алган», диплом күтәреп кайткан кешеләр.* Ф.Латыйфи

**КУРСАНТ** *и. рус* 1) Курсларда II (*2 мәгъ.*) укучы. *Ишек төбендә курсантлар җыелышкан*

2) Хәрби училищеда белем һәм тәрбия алучы. *Монда Хәрби диңгез училищесы курсантлары волейбол уйныйлар иде.* М.Мәһдиев. *Ул үзе курсант булса да, аны штабка чакыртып, аратирә эш кушалар иде.* Г.Ахунов. *Хәзер үк безгә килеп җит, кәләшнең башын бер курсант әйләндергән.* Ф.Яруллин

**КУРСИВ** *и. типогр.* **1.** Кульязма хәрефләргә охшаш шрифт. *Параграфтан курсив белән язылган сүзләрне табыгыз һәм аларның әһәмиятен аңлатыгыз.* Биология: хайваннар

**2.** *с. мәгъ.* Кульязма хәрефләргә охшаш шрифттагы. *Курсив хәрефләр куллану*

**КУРСИ́СТКА** *и рус тар.* Патша Россиясендә махсус хатын-кыз курсларында укучы. *Без икемез дә бер кызны: бер татар кызыны, бер татар курсисткасыны көтәбез.* Г.Исхакый. *Петербурдан кайтучы курсистка өчен хас ягылган мунчага кереп чыккач, гаилә җыйналып, күңелле гөрләшәгөрләшә чәй эчәләр.* А.Расих

**КУРСОР** *и. ингл. информ.* Дисплей экранында чираттагы операция башкарылачак билге яки позицияне чыгару урынын күрсәтә торган күчерелмә тамга

**КУРСТАШ** *и.* Кем белән булса да бер курста укыган кеше. *Ул чактагы студент Зөлфәт дежурлыкны курсташы Мөдәррис Әгъләмовка тапшырган.* М.Галиев. *Алай да мин замандашларыма, курсташларыма рәхмәтлемен, яман сүз әйтмәгәннәр, карага, ялганга буямаганнар.* А.Гыйләҗев. *Бәлки, курсташларың арасыннан «текә» бизнесменнар чыккандыр.* К.Кәримов

**КУРТ** *рәв. диал.* Тиз, җитез, елгыр. *Соңыннан [Сәфәргали] карчыгына, малаена берьюлы курт кына әйтеп куйды: «Нәрсә алырмын, нәрсә сатармын – кайткач күрерсез».* Ф.Хөсни

**КУРТАЖ** *и. фр.* Биржа килешүләрендә арадашчылык өчен брокерга сатучы һәм сатып алучы биргән акчалата бүләк, әҗер

**КУ́РТКА** *и. пол.* Гадәттә ябык изүле җылы кыска өс киеме. *[Сәрия] Рәгыйдәнеке булырга тиешле кыска куртканы үзе киде.* Ә.Баян. *Күпмедер вакыттан соң эт тиресеннән тегелгән унтый, җылы куртка, казах бүреге кигән аучыларны кара «Волга» шәһәр читенә алып чыкты.* М.Галиев

**КУРЧАК** *и.* **1.** 1) Шаманчылыкта изге яисә явыз рухлар кереп утыра дип уйланылган сыннарның берсе. *Ә Казага сыенып көн күргән, мәҗүсилектән чыгып та бетмәгән, курчакка табынучы ар, чирмеш, мукшы, башкорт, чуваш нишләр?!* Ф.Латыйфи

2) Кеше сурәтендә ясалган бала уенчыгы. *Курчак дулкыннар өстендә тирбәлә-тирбәлә агып китә.* Р.Хафизова

3) Манекен. *Галимнәр һәм инженерлар башта нәкъ кеше гәүдәсенә охшатып манекен, ягъни курчаклар ясыйлар.* Кызыклар дөньясында

4) Һәйкәл, сын. *Димәк, татар әдипләре әнә шул гипс, бронза курчакка баш орып, шуннан куркып, шуңа ярашып яшәгәннәр.* А.Гыйләҗев

5) *зоол.* Тулы әверелешле бөҗәкләрнең индивидуаль үсешендәге личинкадан соңгы стадиясе. *Дөрес әйтә, мин үз дөньяма яшеренеп барам булса кирәк, күбәләк курчагына әверелеп киткән кебек.* Ф.Яхин. *Май коңгызының курчагы тышкы яктан олы бөҗәккә охшый.* Биология: хайваннар. *Бәлә күбәләкләр һәм бүтән бөҗәкләрдә генә түгел, ә башлыча аларның кортларында һәм курчакларында. Менә болары инде – зур тамаклылар.* Кызыклар дөньясында

6) *күч.* Мөстәкыйльлеге булмаган, берәүнең теләк-ихтыярына буйсынган кеше, кешеләр төркеме, дәүләт. *Бер ише кешеләр, җан саклауны, хәвеф-хәтәрсез яшәүне бөек идеаллар хакына дигән сылтау белән аклап, ихтыярсыз курчакка, обывательгә әверелде.* Ә.Еники. *Әйтик, Җангали хан – Василий кенәзнең курчагыдыр.* М.Хәбибуллин. *Шулай да бу кискен хәлләр кешене курчакка әйләндерә шул.* Х.Камалов

7) *күч.* Уйлый белми торган, хистойгылары булмаган кеше

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кечкенә һәм пөхтә. *Бу курчак бүлмәгә аяк басуым белән үк өстемдәге киемнең күплеген, аягымдагы итегемнең тузанлылыгын сизеп алдым.* А.Шамов

2) Бик матур. *Курчак кыз, сөйләш әле минем белән? Кызым, акыллым?* А.Гыйләҗев

3) Мөстәкыйльлеге булмаган, буйсынган, башка берәү ихтыярындагы. *Ул чакта оккупантлар тарафыннан оештырылган курчак мәхкәмә бәйсез илнең легитим җитәкчесен хөкем итте.* Мәдәни җомга

4) Уйный торган, уенчык. *Шәһәр баласы курчак аюлардан, тоз күзле куяннардан бик тиз туя һәм, кызык эзләп, уенчыкларын ботарлап ташлый.* Ф.Яруллин

◊ **Курчак кебек (төсле)** 1) Матур; пөхтә. *Ул, әтисе уйлаганча, «китап карап», авыл куштаннары берлә бер булып халыкны талап, бот күтәреп, эшләмәенчә, сугым кебек ашап ятуны, өйләнгән булып курчак төсле шылтыравыклы атларга утырып, кияү булып барып, бер танымаган, белмәгән кыз берлән бер келәткә бикләнеп ятуны шулкадәр мәгънәсез эш таба иде.* Г.Исхакый. *Безнең ертык, юеш, кылка киемнәребез арасында ул курчак кебек.* Ә.Гаффар; 2) Тиешенчә, яхшы итеп. *Тракторына сукасын да, печән чапкычын да курчак кебек итеп үзе ясап куйды.* Р.Гаффар; 3) Чибәр, бик матур. *Чибәр, курчак кебек матур кыз...* З.Хөснияр. *Мин сине эшләтмичә, өйдә курчак кебек киендереп утыртырмын дип вәгъдә бирдем – киресенчә килеп чыкты.* Р.Юнысова. *Саргылт чәчең тузган маңгаеңа, Курчак кебек җыйнак буй-сының; Оялчанлык, әзрәк кирелегең... Күзең сөйли нидер юксынып...* Р.Рахмани. **Курчак кебек (күк) сикертү** Үз ихтыярына буйсындыру. *Ә боларның җепләрен бер учка җыя алмыйм. Җыйсам, курчак күк сикертер идем үзләрен!* А.Гыйләҗев. **Курчак туе** *тар.* Бер сәбәпсез ясала торган мәҗлес. **Курчак уены** Җитди

булмаган эш. *Тора-бара черчетлар мондый курчак уенын да уйнап тормаслар, чөнки аның мәгънәсезлеген күрәләр: юләр түгел бит.* Г.Әпсәләмов. *Ул бит бу уенны курчак уены кебек иттереп кенә, вакытлыча гына диеп санаган иде.* Х.Хәмидулла. **Курчак уены яшеннән чыгу** Үскән булу. *Әмма азга гына дип башлаган уены сәгатьләргә сузыла да, әнисе я апасы күреп алып орышалар үзен: – Син инде курчак уены яшеннән чыккан!* Ф.Яхин

**КУРЧАКҖАН** *и.* **1.** Куркак, буйсындырылган кеше

**2.** *с. мәгъ.* Куркак, бүтәннәр ихтыяры белән эш итә торган. *Бүген әнә шул гүзәл вә сылу кызны ниндидер хатынша һәм курчакҗан Җангали кулына илтеп тапшырсынмы?!* М.Хәбибуллин

**КУРЧА́К-КУРЧАК** *и.* Курчаклар белән уйнау

◊ **Курчак-курчак уйнау** Җитди булмаган эш белән шөгыльләнү. *Сезнең белән курчак-курчак уйныйсы гына калды!* К.Тимбикова

**КУРЧАКЛАНУ** *ф. зоол.* Курчакка (*5 мәгъ.*) әверелү. *Курчакланыр алдыннан һәрбер гусеница үзенә куйган ботакка үрмәләп менә ---.* Биология: хайваннар. *Тагын 25–28 көн үткәч, личинкалар курчакланалар һәм яңа буын үрчем бирәләр ---.* Яшелчәчелек

**Курчакланып бару** Курчакка әверелә башлау

**Курчакланып җитү** Тулысынча курчакланган булу

**Курчакланып килү** Акрынлап курчаклану

**КУРЧАКЛЫ** *с.* **1.** 1) Курчагы булган. *Курчаклы кыз*

2) Курчаклар белән башкарыла торган. *Курчаклы тамаша*

**2.** *и. мәгъ.* Курчак уены. *Балалар ни өчен курчаклы уйный?* Ф.Яруллин. *Син бала чагыңдагы кебек курчаклы уйнавыңны дәвам итәсең.* М.Юныс. *Ул чакта әле кызларым курчаклы уйный белми иде...* Ш.Җиһангирова

**КУРЧАКЛЫК** *и.* 1) Курчак (*6 мәгъ.*) булу хәле. *Ятлар синнән ят тел, ят җыр ятлаттырып, Тырыштылар чыгармаска курчаклыктан.* Ә.Баян

2) Ясалмалык

**КУРЫЛДА́У** *ф. к.* **кургылдау**. *Бакча буенда, төрле якка сибелгән чебиләрен җыя алмыйча, кабарынган чуар тавык курылдап йөри.* Г.Бәширов

**КУРЫН** *и.* Бер кеше балык тота торган кечкенә елым

**КУРЫС** *и. угор* Каезланмаган, юкәдән тоташ суеп алынган кабык (караллы түбәсен ябу өчен кулланылган). *Курыстан өзәңге дә әмәлләдем.* М.Әмир. *Юкәләрне каезлаган ыруым Чабаталар кигән курыстан...* Р.Әхмәтҗан. *Бермәлне кемгәдер «минем әни үги бит» дигәне өчен Карлыгачны шартлатып курыс белән каезладымы [Алмабикә]?* А.Хәлим

**КУРЬЕР** *и. пол.* 1) Оешмаларда һ.б.ш.да эш кәгазьләре ташучы хезмәткәр. --- *Фәтхелислам – студент, ә мин – китап кибетендә курьер булып эшләүче.* Ә.Еники. *Үзегез кул куегыз да курьер белән җибәрегез.* М.Маликова. *Курьерлар, хат ташучылар бушлай таратып йөри торган реклама өеме иде бу.* К.Кәримов

2) Зур араларга ашыгыч йомышлар белән җибәрелә торган хезмәткәр. *Паровозның бу үкерүе куркынган поляк курьерларын һәм дипломатларын купеларындагы йомшак диваннардан торгызды.* Корыч ничек чыныкты // Йомышчы. *Җыелышка дисәң дә, бер синең арттан курьер йөгертергә туры килә.* Ф.Абдуллин

3) *күч.* Берәүнең ихтыярына буйсынган кеше, йомышчы. *Безнең җылы табын тирәсендә Иблиснең бер «курьеры» йөри.* Х.Туфан

**КУСАР** *и. рус диал.* Чыра пычагы

**КУСТ** *и. рус сөйл.* Аерым группалар, оешмалар берләшмәсе; вакытлы төркем

**КУСТАРЬ** *и. рус* **1.** 1) Вак һөнәрче. *Революциягә кадәр Казан губернасы промышленносте авыл хуҗалыгы чималын эшкәртүче 198 кустарь һәм ярымкустарь предприятиедән гыйбарәт булган.* Казан утлары

2) *күч.* Түбән сыйфатлы эш башкаручы. *Модернизм кустарьларының Алласы да, ватаны да күп...* Х.Туфан

3) Ялгыз, башкалардан аерылган кеше. ... *Ә үзем... (Ни әйтергә белми, Терәлеп калам, туктап.) Мин дә... одиночка... – Кустарь? – Түгел... әйе... Кустарьрак... бунтарь...* Ә.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* Гади ысуллар белән эшләнелгән. *Вьетнамның үзендә вак кустарь промышленность кына калган.* Казан утлары

**КУСТАРЬЛА́РЧА** *рәв.* 1) Кустарьларга хас булганча. *Кустарьларча эшләү*

2) *күч. сөйл.* Түбән сыйфатлы, кимчелекле. *Кустарьларча ясалган әйберләр*

**КУСТАРЬЛЫК** *и. к.* **кустарьчылык**. *Иң әүвәл булганын әрәм-шәрәм итмичә, кечкенә булса да, үз эшеңне башлап җибәрү хаҗәт: вак бизнеска тормышта туклану, вак сәүдәгәрлек, һөнәр, кустарьлык өлкәләрендә очыкырые күренмәгән мөмкинлекләр бар бит.* Ә.Борһанов

**КУСТАРЬЧЫЛЫК** *и.* 1) Кустарьлар эше. *Яңа бистә кешеләренең баштагы төп кәсебе – кустарьчылык.* И.Нуруллин

2) *күч.* Начар оештырылган, бик гади ысуллар белән башкарылган эш

**КУТАН** *и. этн.* 1) Казахстанда һәм Себердә: ябусыз, түбәсез зур абзар. *Кутанда куй кырылса, кутыр кәҗә баш булыр.* Мәкаль

2) *диал.* Балчык абзар, балчык кура

**КУТИ́КУЛА** *и. лат.* 1) Күп кенә үсемлекләрнең җир өсте органнарын каплап торган майлы матдә. *Тышча өслегендә кутикула катламы булырга мөмкин.* Ботаника

2) Күп кенә умырткасыз хайваннарның тире өсте ярысы. *Планариядән аермалы буларак, җитлеккән бавыр имгеч суалчанның тәнендә вак төкләр булмый, һәм аны кутикула саклый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КУТЫР** *и.* **1.** 1) Яра өстендә каткан каннан гыйбарәт катлам. *Бөтен баш түбәсен каплаган әлеге кутырны күргәч, Асылбикәнең үз тәне пешеп киткәндәй булды.* Р.Вәлиев. *– Кызлар ничек матурлаган үзеңне, – диде Мостафин, битендәге кутырларга ымлап.* Х.Камалов. *Коточкыч күренеш. Йөзен кутыр баскан. Кашы да, керфекләре дә юк.* Җ.Ильясов

2) Үсемлектә, хайваннарда һәм кешедә очрый торган авыру. *Кутыр чыгу*

3) *күч.* Кайры яки таш өстенә чыккан гөмбә

4) *күч.* Үзәккә үткән, хәтергә кереп калган күренеш. *Бәрәкәтле дә, аяусыз да Казагыстан күкрәгендә кутыр булып яткан исәпсез-сансыз лагерьлар, ил кадерен белмәгән, читтән килеп тулган килмешәкләр, ярты дөнья күген каплаган биек-биек коймалар --- үз эшен үтәгән иде инде...* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Авыру. *Сукыр атка кутыр ат иярер.* Мәкаль

◊ **Кутыры азу** *к.* **кутыры кызу**. **Кутыры кызу** Нәфес кузгалу, мавыгу, теләк уяну. *Юк, аның бүрәнә сатасы килеп тормый – сораучысы булган өчен генә кутыры кызган иде.* Х.Сарьян

**КУТЫРЛА́У** *ф.* Кутыр барлыкка килү, кутыр чыгу. *[Ирбулатның] Ярты башы пеләшләнгән, хәтта кутырлаган ---.* Ф.Баттал. *Йомшак ләмнән атлап йөргәндә, шундагы суда утырып, аларның аяклары кутырлый.* Кызыклар дөньясында

**Кутырлап бетү** Тоташ һәм күп булып кутырлау. *Аның тәпиләре ярылып, кутырлап беткән иде.* И.Гази

**Кутырлап чыгу** Нинди дә булса сәбәптән кутырлаган хәлгә килү

**КУТЫРЛЫ** *с.* Кутырланган, өстендә кутыры булган. *Тәнендә – тимер кайнатудан калган кутырлы җөйләр, каткан буяу тамчылары.* М.Юныс

**КУТЫР-ЧАТЫР** *рәв.* Бик каты кутырлап. *Тузудан чуклана башлаган ыштан балагы эченнән чыгып торган тәпие кутыр-чатыр чебиләп, тәмам каешланып каткан иде.* М.Хәсәнов

**КУТЮРЬЕ** *и. фр.* Югары сыйфатлы нәфис киемнәр һәм аңа аксессуарлар иҗат итүче модельер. *Аның ире атаклы кутюрье Кристиан Лакруада эшли, ниндидер югары урында тора.* Р.Мирхәйдәров. *Аларны да [курчакларны] кутюрьелар Джанни Версаче, Жан-Поль Готье, Кристиан Диор киендерә.* Шәһри Казан

**КУУ** *ф.* 1) Хәрәкәткә китерү, хәрәкәтләнергә мәҗбүр итү. *Ку әле, җил, болыт көтүләрен, Тау башлары күренә башласын.* Х.Туфан. *Кайчакларда, нәкъ шул вакыт төньяктан көчле җил исеп, култыктагы һәм болыннардагы суны диңгезгә куа.* К.Меркульева

2) Билгеле бер урыннан китәргә мәҗбүр итү. *Уйлар синнән сорап килмиләр, син куганга карап китмиләр.* Б.Камалов. *Җангали хан үзе теләп китмәгән булса, аны Казаннан берәү дә кумады.* М.Хәбибуллин

3) Иректән мәхрүм итеп, туган, торган җирләрдән китәргә мәҗбүрләү, сөрү, сөргенгә озату. *Әйе, әйе, анысы да хак сүз: сине, Хөсәен, җиденче ел азагында ук сөргенгә куганнар дигән сүз булды.* А.Расих

4) Эштән азат итү, дәрәҗәдән төшерү. *Эштән куар өчен артыгы белән җиткән, бик фәтва.* Т.Галиуллин. *– Кешене эштән куу булды түгелме соң бу? – диде ул [Зуфирә], Вадимга борылып.* М.Маликова. *Гомеремдә түрәләргә койрык болгый белмәдем ---. Эштән кусалар куарлар.* Ф.Латыйфи. *Начальник шуны гына көткәндәй котырыныплырга тотынган, статья буенча куам, дигән.* Татарстан яшьләре

5) Алдарак баручының артыннан җиту, тоту, аны узып китү өчен хәрәкәт тизлеген арттыру. *Сунарчы далага аксак куян алырманга бармый, чын сунарчы бүре куа, һич югы төлке аулый.* М.Хәбибуллин. *Менә бу җайдак кыргый җәнлек куып бара ...* Г.Гыйльманов

6) Куышлы уйнаганда, качучыны тоту максаты белән артыннан йөгерү. *Күрде, төшенде: бит болар Куышлы уйныйлар! Берсе кача, берсе куа – Һич туктап тормыйлар.* Р.Рахмани

7) Качучыны эзәрлекләү. *Тик тапмады «Канатлы»ны – Сөекле юлдашкаен. Ул хәзер дә эзли аны, Акларны куган саен.* Ш.Маннур. *Күреп калдым ул явызның Качып киткәнен, Куган идем дә артыннан, Ләкин җитмәдем.* А.Алиш. *Моны ишеткәч, Рөстәм нишләргә белми. Тагы аларны куып Мәскәүгә барыргамы?* С.Җәләл

8) Хәрәкәтләнү тизлеген арттырырга мәҗбүр итү. *Ачуын һәм ярсуын басарга тырышып куа ул атны.* Ә.Баян. *Кичләр саен машинаңның Кабинасын юа идек. Матур кызлы авылларга Машинаны куа идек.* Ф.Яруллин. *--- җитез «атлар» чаба, ай-һайлап, юкә дилбегәне кулларыннан ычкындырмаска тырышып, чыбыркылы «кучерлар» куа, ә алар артыннан нечкә генә тавыш: миһаһайлап, артта калмаска тырышып, «колыннар» ияргән.* З.Зәйнулин

9) Тарату, таркату (җыен, төркем һ.б. тур.). *Россияне үз кулында тоткан бөек император ике Думаны куды, өченчесен дә, дүртенчесен дә куар.* Р.Ишморат

10) Күбрәк, сыйфатлырак эшләүне, ни дә булса башкаруны таләп итү. *Сәгатем генә түгел, минутларым да шыплап төелгән – үземне үзем куу өстенә, --- атнаның алты көнендә мине тренерым куа.* Х.Сарьян. *Өй арасында, үз ындырыңда эш бетеп тормый. Әмма төп эш колхозда. Бугазыңа ябышып куалар.* А.Гыйләҗев

11) Ерак җирләрдән йөртеп алып кайту (автомобиль тур.). *Машина куу*

12) *сир.* Тузгыту (чәч тур.). *Каршы искән җил минем озын кара чәчләремне кирегә куа...* Ф.Бәйрәмова

13) Терлекне көтүгә чыгару. *Иртән әтәч кычкырганга уянып, малларны көтүгә кумагач, кич аларны капка төбенә чыгып каршы алмагач, нинди тормыш ди ул?!* Р.Вәлиев. *Ул инде урамда адашмыйча йөри ала, көтү куа, кибеткә бара, су ташый.* Г.Гыйльманов

14) *тех.* Сыеклык яки газны торбалар, каналлар буйлап басым ярдәмендә күчерү. *Болгарлар үзләре дә биек ташпулат торгыза, күпер суга, керамиксыман көпшәләр буйлап су куа ---.* М.Мәхмүтов. *Ә йөзгечләре, вентилятор кебек, бертуктаусыз эшләп тора, шулай итеп уылдыкка чиста су куа.* К.Меркульева. *Йөрәк ритмик рәвештә тибеп тора һәм канны тәннең баш өлешенә куа.* Биология: хайваннар

15) Сыек катнашмаларны яки каты матдәне югары температурада төрле компонентларга (фракцияләргә) аеру. *Җирле халык бу үләннән сыра куа, дару әзерли, хәтта тире эшкәртү өчен сыеклык та ала.* Кызыклар дөньясында. *Нефть куу*

16) Организмнан чыгарып ташлау. *Калийга бай кыяр согы кан басымын нормальләштерә, аппетитны яхшыр-*

*та, эчне йомшарта, үт куа, бөер ташларын эретә.* Мәдәни җомга

17) Уйнаганда шарларны сугып тәгәрәтеп йөртү. *Клуб ишекләре ачык, үсмерләр шалт та шолт бильярд куа, кинолар көн саен күрсәтелә ---.* А.Гыйләҗев

18) *күч.* Электән килгәнне дәвам итү. *Ирмәк куган – бәлагә, хезмәт куган – казнага.* Мәкаль. *Анастасия дә шуны куа, ятак ягына берәүне дә кертми.* М.Хәбибуллин. *Хәер, Эдуард үзе дә элекке гадәтен куып бәхәсләшмәде.* Н.Гыйматдинова. *Испаниядәге искиткеч кыю мотодорларның бичара үгезне кызыл чүпрәк күрсәтеп ярсытулары борынгы заманнан калган гадәтне куу гына.* Кызыклар дөньясында

19) *күч.* Акыл, белем, камиллек һ.б. сыйфатлар буенча үсеш дәрәҗәләре югарырак булганнар белән тиңләшергә тырышу. *Уңганнар артыннан куу*

20) *күч.* Билгеле бер яшькә якынлашу. *Әйтерсең бу хатын кырыктан узмаган, ә бу ир иллене кумый.* Г.Якупова

21) *күч.* Нинди дә булса максат куеп тырышып йөрү. *Кем ул анда изге бер кыйбласыз яшәмәкче узып бар дөньядан, байлык арты байлык кына куып? – Җаны фәкыйрь килеш, рухы – надан.* Л.Шагыйрьҗан. *И Гарәпша дус, дөньяга бүген килмәгәнсеңдер, һәммәбез план артыннан куа ---.* Идел

**Куа башлау** Куарга тотыну. *– Эшләрем бар, базарга, Печән базарына барамын, – диде һәм хезмәтчене куа башлады.* З.Бигиев

**Куа бирү** Кууны дәвам итү. *Туктамышны куа бир.* Дастан

**Куа йөрү** Туктаусыз куу. *Халык: «Дөньялыкта кылган гөнаһ адәм баласын теге дөньяда да куа йөрер», – ди ич.* М.Хәбибуллин

**Куа килү** Туктаусыз эзәрлекләү. *Арттан мышнаган, чыштырдаган тавышлар куа килә.* Ф.Баттал. *Артларыннан куа килгән гаскәриләр аларның үле гәүдәләрен генә тапканнар.* Ф.Яхин. *Куа килә заман тәгәрмәче! Алга куйган иблис сыбызгысын: Абын... тор, чап – өлгер я тиз юл сап, Кеше диеп тормас: сытылырсың!* Р.Рахмани

**Куа китү** *к.* **куып китү**. *Анлар артыннан кулларыны киртә ясаган пар куа китте.* Г.Исхакый. *Куа киттек фрицны.* Ш.Рәкыйпов

**Куа төшү** Тагы да ныграк куу. *– Атларны куа төшәргә кирәк, өлгермәмез, – диде һәм дә күзе белән төтен чыга торган йирдән манара эзли башлады.* Г.Исхакый

**Куа тору** Бертуктаусыз куу; билгеле бер вакыт куу. *Әй куа, әй куа, куа торгач, Төлке, койма аркылы сикереп, урманга кача.* Әкият. *Беркем артыңнан куып тормый.* Ә.Гаффар. *[Хәлил:] Кумый тор мине. Чак кына баш-күз алыйм.* А.Гыйләҗев

**Куып бару** Дәвамлы рәвештә куу. *Наполеонны куып барып, поляк җирен, Немец җирен азат иткән полк бит ул.* Ш.Мөдәррис. *[Хәтер] Эзәрлекләп күпме куып барыр? Ничәвебез туктап уйга калыр... Уй төбендә, белмим, нәрсә табар...* Р.Рахмани. *Ул абзый алтмышны куып бара бит.* Ф.Садриев

**Куып бетерү** Бөтенесен дә, барысын да куу. *Күкне болыт баскан иде, җил чыгып, аларны кайсын кая куып бетерде.* А.Алиш. *– Аңа чыдыйлармы соң, вак айгырларны шунда ук куып бетергән, – ди...* Ә.Еники

**Куып җибәрү** Китәргә мәҗбүр итү. *Куәтле вә гайрәтле хан Казанга килә һәм Шаһгали ханны куып җибәрә.* М.Хәбибуллин

**Куып җитү** Куып тоту, артыннан җитешү. *Аяк астында шыгырдый торган карларны үтә-үтә, тар урамнан зур урамга чыккач кына, Хәмитнең иске иптәше Сәгыйть куып йитте.* Г.Исхакый. *Ә бүреләр, бу икәүне Куып җитәргә теләп, Көн-төн чапканнар ---.* И.Юзеев. *Искәндәрнең аны куып җитәсе, нидер әйтәсе, һич югы акланасы килде, илле кузгалган җирдән туктап калды.* М.Хәбибуллин

**Куып йөрү** *к.* **куа йөрү**. *Шуннан Шомат малае әйтә моңа: «Бүре абый, әллә син дә Муллагали күргән нәмәне куып йөрдең --- ?» – ди.* И.Сирматов

**Куып килү** Якынлашу, якыная бару. *[Хатыннар] Яшь ягыннан гомер уртасын куып килсәләр дә, һәр икесе яңа җиткән үсмер кызлар төсле киенгән.* В.Имамов

**Куып китү** Кинәт куа башлау. *Самат та сикереп торды, кызны куып китте.* Г.Гыйльманов. *[Көчек] Үрдәкне куып китә, Казларны куып китә, Артыграк кызып китә – Тукталмый, узып китә!* Ш.Галиев

**Куып тору** Бертуктаусыз куу. *Шулай үзләрен куып торгач, апа белән җизни кеше: «Туган якка кайтып калуыбыз хәерле», – дип кайтып төштеләр.* З.Фәйзи

**КУУЗИКА** *и. эстон а.х. к.* **куузику**. *Баштан чит язулар белән чуарланган кием киеп «мальборо»лар көйрәтер дәрәҗәгә җиткәнче кем тиле бәрән ашаткан, ул ни шалкан, ни чөгендер – куузика башларга?* Ә.Гаффар

**КУУЗИКУ** *и. эстон а.х.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан тамыразык буларак кулланыла торган икееллык үсемлек; азык шалканы; турнепс

**КУФА́ЙКА** *и. рус сөйл.* Сырма. *[Зиннурның] Өстендә яңа куфайка, сырган чалбар, башында тышлаган бүрек.* З.Зәйнуллин. *Ул [әти] кулындагы очсызлы тәмәкесен кайраклан-ган куфайкасына гына басып сүндерә.* Р.Рахман

**КУ́ХНЯ** *и. нем.* 1) Аш-су бүлмәсе; аш-су әзерләү, ашау өчен махсус бүлмә, өй. *Кухняны зәңгәр май исе басты.* М.Мәһдиев. *Әби инде кухняда: мич ягып йөри.* Х.Сарьян. *Дүрт бүлмәле фатирлары бар. Кухнясы, кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе...* Г.Гыйльманов

2) *сөйл.* Аш-су бүлмәсендәге табак-савыт, ярма һ.б. урнаштыру өчен шкаф. *Кухня урнаштыру*

3) Гаскәри частьларда, туристик группаларда, экспедицияләрдә һ.б.ш. аш әзерләү әсбаплары һәм ашчылар йөри торган махсус транспорт. *Бераздан соң тагын су бирделәр, бу юлы инде флягаларны тутырып, поход кухнясында тәмле исләр аңкытып, ботка пеште.* Х.Ширмән. *Бу полкның кыр кухнясы да булып, мескен сигез солдатка туйганчы кайнар аш ашаттылар.* Р.Кадыйров

4) Милли ашамлыклар, аш-су. *[Марсель Сәлимҗановның] Яраткан ризыклары – татар кухнясы.* Т.Нәҗмиев. *Әле кичә генә иң популяр юнәлешләр*

*булып япон һәм кытай кухнясы санала иде.* Татарстан

5) Яңа туган балаларга сөтле ризыклар әзерләү һәм тарату белән шөгыльләнә торган учреждение. *Баланы үзегезгә алгач, сөт кухнясыннан стерилизованный сөт алырсыз.* Ф.Хөсни. *Хәзер әниләр яңа туган сабыйлары белән «8 Март» тукталышындагы кухняга барып йөрергә мәҗбүр.* Сабантуй

6) *күч.* Тар, чикләнгән тирәлек. *Милләт җанын җылытамы Зилзиләле заман җиле... Кемдер килеп җиңнән тарта: – Татар теле – кухня теле.* Г.Садә

7) *күч.* Нәрсәнең дә булса нигезе, асылы, күпчелеккә билгеле булмаган яклары, ясалышы, әзерләнеше. *Икенчедән, ул яңа партия пешеп чыккан кухняның эчендә булды.* И.Нуруллин. *Телевидение кухнясы*

**КУ́ЧЕР** *и. нем.* 1) Җигүле ат белән идарә итүче, дилбегә тотучы кеше. *Юк, моны элекке заманда толып яки чикмән киеп чана башына утырган, почта станциясендә кайнар борщ ашап чыккан кызыл битле кучер җырлагандыр.* М.Мәһдиев. *Кузлада утырган зур якалы чикмән кигән кучерга ныклап әйтелгән: атларны атлатып кына алып барырга, юыртуга күчмәскә!* З.Зәйнуллин. *Кучер, борылмыйча гына, авыз эченнән нидер мыгырданып дилбегә какты ---.* М.Галиев. *Кучерның исе киткән, сүзен әйтер хәле юк.* Н.Ихсанов

2) Тарантасның алгы ягында атны әйдәүче өчен махсус урын. *Шуларны кучер астындагы печәнгә әйбәтләп яшергәч, [Клара белән Рәхмәт], утырышып, авылдан чыгып киттеләр.* Ә.Еники. *Кучерда утырган кара сакаллы абзый атын өйнең нәкъ баскычы төбенә китереп туктатты.* Ә.Еники

3) *сир. күч.* Әйдаман

**КУ́ЧЕРЛЫК** *и.* 1) Кучер эше

2) *сир. к.* **кучер** (*2 мәгъ.*)

**КУЧКАР** I *и.* 1) *иск.* Янып торган чыраны кую өчен, гадәттә тәкә яки болан мөгезеннән эшләнгән махсус җайланма. *[Нурмый] Яңадан кучкарларны, өстәл, урындык асларын капшап чыкты.* Ф.Шәфигуллин

2) *иск.* Мич кашагасы өстендә әйбер кую өчен махсус мәйданчык. *Интегеп кенә башымны күтәрсәм, кучкарда ут яна – җиделе лампа кысып кына куелган.* Х.Сарьян. *Шул арада кучкардан бүлмә ачкычын алып, миңа күзен кысып, ул өйалдына чыкты.* М.Мәһдиев. *--- Язилә апа турында халык, кучкардан шырпы алырга урындык куеп менә икән, дип сөйлиләр иде.* Ф.Шәфигуллин

**КУЧКАР** II *и.* **1.** 1) Печтерелмәгән сарык тәкәсе. *Айгыр куйсаң, өнледән куй, кучкар куйсаң, йонлыдан куй.* Мәкаль. *– Нәрсә, сарык яхшы мал идеме соң? – дип кызыксынды пассажир ---. – Әйе! Чын кара кучкар иде.* Р.Мирхәйдәров

2) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган, шул исемдәге йолдызлык. *Инде таныш булган Җидегән йолдыз, Кучкар, Кәҗәмөгез, Укчы йолдызлыклары күренә башлады.* Р.Закиров

3) Зодиак системасына керә торган шул исемдәге йолдызлык тамгасы

4) Кояш календарена караган унике айдан торган йолдызлыкның беренче (көн белән төннең язгы тигезләнешенә мөнәсәбәтле) ае исеме; 21 марттан 20 апрельгә хәтле булган чор. *Көнбатышта гороскоп – Кәҗәмөгездән, төркиләрдә Кучкардан башлана.* Р.Сафин

5) Кояш шул йолдызлыкта чакта туган кеше

6) *иск.* Дусты өчен үзен корбан итәргә дә әзер кеше. *Дусыңны коткар, ул сиңа булыр кучкар.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Печтерелмәгән (тәкә тур.). *Өй атында кашка тәкә, Куш мөгезле кучкар тәкә.* Табышмак

**КУЧКЫЛ** *с.* **1.** Карасу, каралҗым. *Ләкин бала кош кинәт юан башын күтәрә, кучкыл томшыгын киң ача да ялт итеп җимне тартып алганга охшый.* К.Тәхау. *Дим өсте көзгедәй типтигез, кучкыл зәңгәр, талларның күләгәләре яткан, мин, суны чупылдатмаска тырышып, әкрен генә ишәм, җыр мине еракка-еракка алып китә.* Ә.Еники. *Уң аяк кәкрәеп каткан, бер миллиметр язылмый, кызыл кучкыл төскә керә башлаган.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* Карасу төс

**КУЧКЫЛЛАНУ** *ф.* Кучкыл төскә керү, карасулану. *Рувим Михайлович кара кызыл кучкылланган аякны тотып карау белән ах итте.* Х.Камалов. *[Ташлыяр елгасы] --- ындыр артларына сырышып, куе кучкылланып үскән таллар арасына кергәч, беразга күздән югалып та тора.* А.Гыйләҗев. *Хәерлегә генә була күрсен... Кучкылланып, даулап, тугарылып, Ялтыратып утлы камчыларын, Ил өстенә килә кара болыт!* Зөлфәт

**Кучкыллана төшү** Бераз кучкыл төскә керү

**Кучкылланып бару** Торган саен кучкыл төскә керү

**Кучкылланып китү** Көтмәгәндә, кинәт кучкыллану

**Кучкылланып тору** Әле, хәзер кучкыл төстә булу

**КУЧКЫЛЛЫ** *с.* 1) Бераз карасу булган. *Баш өстендә кучкыллы зәңгәр күк.* Ф.Сафин

2) Каралҗым төс кергән (кызынган кеше тур.)

**КУЧТЫ** *и.* 1) *тар.* Алпарның (рыцарьның) атын һәм коралын карауч ир-егет. *Кучтыга сүз кушу*

2) *диал.* Дус (үзеннән яшьрәкләргә карата әйтелә)

3) **кучтым** *диал. тарт. форм.* Туганкай, энекәш

**КУШ** I *с.* 1) Ике. *Бермәлгә Гази, үзен ничегрәк тотарга белмәгән кеше сыман, аптырабрак калды. Әмма озакка түгел, шундук карчыкка таба атлап, куш кулын сузды.* М.Хәсәнов. *[Ул] --- чуеннан куш йодрык хәтле ит калҗасын бакрач белән сөзеп алып, тәлинкәмә китереп тә салды.* А.Гыйләҗев. *Язгы ачлык китереп кыскач, әтисенең куш көпшәле мылтыгын сатты ул.* Б.Камалов

2) Пар ителгән, бергә куелган. *Куш дәреснең беренче сәгате бетәргә тагын ун минут бар иде ---.* Х.Сарьян. *Малайлар мәж килеп атына торган турникта буш, куш бөҗралар җансыз асылынып торалар.* Я.Зәнкиев

3) Икесе бер төптән үсеп чыккан. *Куш каен өчен кайгырып кайтып, авылга килеп керү сөенече ул көткәнгә караганда кимрәк булды.* Я.Зәнкиев. *Сукмак буендагы куш каенда талпына-талпына саескан чүкерди.* Ш.Шәйдуллин

4) Береккән. *Әнисе дә сизде бугай, юаткандай итте: – Куш кендекмени үзегез, ә?* Г.Якупова

5) Бөтеннең ике тигез өлеше булган; ике бердәй кисәктән, өлештән, предметтан торган. *Яңа Шәрип арасындагы тигез кырга энә бурына ошаганрак куш канатлы кечкенә генә аэроплан төшеп утырды.* Ә.Еники

6) Икегә аерылып торган. *Киң битле, юан муенлы, зур авызлы, куш иякле, урта буйдан тәбәнәгрәк таза гәүдәле бу кешенең күзләре тары бөртекләре төсле астыртын ялтырый иде.* Х.Камалов

7) *астр.* Уртак авырлык үзәге тирәсендә әйләнә торган йолдызлар. *Куш йолдызлар тәртипсез рәвештә төрле якка таба хәрәкәт итәләр.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

8) *лингв.* Компонентлары үзара тезүле юл белән бәйләнгән кушма сүз. *Куш сүзләрнең компонентлары үзара тигез хокуклылар, тезүле бәйләнеш белән бәйләнгәннәр, грамматик яктан бер-берсенә бәйле түгелләр.* Татар грамматикасы

◊ **Куш бугаз** *гади с.* Бер дә юкка кычкыручы кеше. *[Морат:] Ну кушбугаз Мөжәйнең ипи шүрлеген җимерәм кайткач...* Э.Яһудин. **Куш йөрәкле** Батыр, кыю. **Куш куллап** Бик теләп, шатланып. *Куш куллап риза булу.* **Куш күренү** Зур, куркыныч булып күренү; *к.* **курыкканга куш күренү**

**КУШ** II *и. рус сөйл.* Зур акча. *Куш эләктерү*

**КУШАВАЗ** *и. махс.* Фольклор әсәренең бәетләргә якын жанры

**КУШАК** *и.* Киң билбау. *Кодес бәге Йосыфны шәп кунак итте, асыл халат, йөгерек ат бүләк итте, алтынланган кушак бәйләтте ---.* Кол Гали. *Ефәк кушак билеңдә, Көмеш балта кулыңда, Зифа буйлы бер чыршы Үсеп тора юлыңда.* М.Җәлил

**КУШАМАТ** *и.* 1) Кешегә берәр сыйфаты нигезендә яисә нинди дә булса вакыйга уңаеннан, гадәттә мәзәк өчен бирелгән икенче исем. *Юкка тагалармы авылда кушаматны?* А.Гыйләҗев. *Аннары Саматның авылда үз кушаматы бар.* Г.Гыйльманов. *Кызның әтисе Ислам абый аңа шул чагында «кияү» кушаматы да тагып калдырган иде.* Казан утлары // Билгеле бер сыйфатлары буенча бер төркем кешеләргә бирелгән исем. *[Искиткеч сәләтле балаларга] Франциядә «тефлон» дигән кушамат такканнар, чөнки индиго балаларга без күнеккән стереотиплар бөтенләй «ябышмый».* Мәдәни җомга

2) Төп исем-фамилияне яшерү максаты белән алынган икенче исем, псевдоним. *1909 нчы елның җәендә Галимҗан Ибраһимов, Казанга килеп, вакытлы матбугат битләрендә «Габди» дигән кушамат астында бик актив рәвештә басыла башлады.* А.Расих. *Мәкалә астына ул шулай да үз исемен куймады – кушамат уйлап тапты.* Т.Әйди. *Язучының беренче һәм икенче әдәби кушаматлары аның Болгарда туып, Сарайда иҗат иткәнлеген аңлаталар. Өченчесе авторның кемгәдер бәйләнгәнлегенә ишарә ясый.* Татар әдәбияты тарихы

3) Хайван, кош-корт исеме. *Безнең кәҗәнең кушаматы – Алпамша.* М.Галиев. *Журналистлар Зур Абый дигән кушамат таккан хайванны реабилитацияләү 3 елга сузылган.* Мәдәни җомга

**КУШАНУ** *ф. иск.* Тагу, асу

**КУШАЯК** *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан Евразия, Төньяк Африка, Төньяк Америка далаларында һәм чүлләрендә яшәүче, ике аякта чабарга һәм сикерергә җайлашкан зур булмаган имезүче хайван; тавышкан; *русчасы:* **тушканчик**. *Монда ябалак белән мәче, кушаяк белән көнгерә арасында кайбер галимнәр тарафыннан табыла торган билгеле охшашлыкларны күрсәтеп була.* Хайваннар турында очерклар. *Чүл хайваннарының күбесе: антилопалар, йомраннар, ком тычканнары, кушаяклар, ташбакалар гомумән су эчмичә яки бик озак сусыз яши алалар.* Кызыклы физиология. *Ачык урыннарда яши торган имезүче хайваннар арасында сикереп йөрүче формалар сирәк түгел; мәсәлән, безнең далаларда яшәүче кушаяклар ---.* Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы

**КУ́ШАЯКЛАП** *рәв.* 1) Арткы яки алгы аякларын бердән ташлап (хайваннарның чабуы, сикерүе, тибүе тур.). *Бүренең шул бер мизгелгә туктап торуы җитә: кушаяклап томырылган алмачуарын үрә торгызып, аның өстенә киң күкрәкле алпавыт үзе сикереп төшә.* Ә.Гаффар. *Бәхетеңә кушаяклап керпе типсә, ятасың инде ялгыз угаланып.* Н.Гыйматдинова

2) Ике аякны бергә куеп (кешенең сикерүе тур.)

3) *күч. к.* **куш куллап**

**КУ́ШАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Кимерүчеләр отрядының койрыгы үзеннән озын, койрык очы йөнтәс, арткы аяклары алгыларыннан озынрак булган имезүчеләр семьялыгы; *русчасы:* **тушканчиковые**. --- *Татарстанда кондызлар (семьялыкта бердәнбер ыруг), тиенсыманнар, йоклачсыманнар, тычкансыман кимерүчеләр (мышовковые), кушаяклылар (зур кушаяк), әрләнсыманнар, тычканнар семьялыклары вәкилләре яши.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КУШӘ** *и.* Туку станы. *Анай кәбәм, кушә коргансың, Анда бөгелеп ниләр тукырсың?* Җыр

**КУШБАШ** *и. зоол.* Карплар семьялыгына караган, йомры чабаклар ыругыннан төче суларда яши торган озынча гәүдәле һәм киң башлы балык. *Карп балыклары да (чабак, кушбаш, корбан балыгы) шактый озак (8–15 ел) яшиләр.* Кызыклы ихтиология. *Озак вакытка урнаштырылган мондый җимлек вак балыклар белән тукланучы кушбаш, судак, алабуганы да үз тирәсендә тота.* Серле календарь

**КУШЕ́ТКА** *и фр.* Аркасы булмаган, бер як башы бераз күтәрелгән зур булмаган диван. *Җиделе лампа кабызган пунктта кичен, ак җәймәләр белән капланган кушеткага утырып, бер кеше эчен уа-уа көлә иде.* Я.Зәнкиев. *Фельдшер белән икәүләшеп, аны кушеткага яткырдылар.* Н.Гыйматдинова

**КУШ ИТҮ** *ф.* Арттыру, күбәйтү

**КУ́ШКАНАТЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Бөҗәкләр классының озынборыннар, өндәмәсләр, чебеннәр, кигәвеннәр һ.б. төрләрне (барлыгы 120000 төр) берләштергән бер отряды

**КУШКАПКА** *и.* Ике якка ачылып китә торган капка. *Авыл янындагы*

*кушкапкадан кергәч, уң кулда түбәсе шифер белән ябылган ике катлы кирпеч бина.* Б.Камалов

**КУШКОЛАК** *с. сөйл.* Зур колаклы

**КУШКӨБӘК** *и.* Ике көпшәле ау мылтыгы

**КУШКЫ** *и. диал. иск.* Күп җәпле, күп очлы камчы

**КУШЛАВЫК** *и. сөйл.* Куыш урын

**КУШЛАНУ** *ф.* Ике булып күренү, икегә әйләнү

**Кушланып алу** Тиз арада, азга гына ике булып күренү

**Кушланып китү** Көтмәгәндә, кинәт икегә әйләнү

**КУШЛА́У** *ф.* 1) Бергә, янәшә китереп кую (гадәттә учлар, куллар тур.)

2) Парлау. *Кушлап, кушлап тагарга Куш төймәкәй кирәк, туганый; Кушлап, кушлап сыктарга Үз инәкәй кирәк, туганый.* Җыр

**КУШМА** I *с.* 1) Берничә матдә кушып ясалган, составында берничә матдә булган

2) Берләшкән, бер дәүләт, оешма хасил иткән. *Америка Кушма Штатлары байрагында ак һәм кызыл тасмалар чиратлаша.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Кушма Штатларның төрле районнарыннан 4500 дән артык кеше тикшерү үтә.* Кызыклар дөньясында

3) *лингв.* Ике яки берничә тамырдан торган. *Татар телендә кушма сүзләрнең байтак өлешен тезмә сүзләр тәшкил итә.* Татар грамматикасы. *Кушма сүзләрдә нечкә һәм калын иҗекләр очрый: төнбоек, чимал...* Ф.Сафиуллина

4) *лингв.* Үзара ияртүле яки тезүле яисә ике юл белән дә бәйләнгән ике яки берничә җөмләдән торган. *Кушма җөмләләр гади җөмләләргә караганда соңрак барлыкка килгәннәр.* Ф.Сафиуллина. *Кушма җөмлә төзи торган аерым җөмләләрнең үзләренә генә караган субъектлары һәм предикатлары булырга тиеш.* М.Зәкиев

**КУШМА** II *и. диал.* 1) Буй тактачыклардан ясалган савыт, чиләк

2) Сал агызганда бергә беркетелгән агачлар рәте. *Анысы дөрес. И бер-ике кушмадан сал да кимемәс иде.* Х.Сарьян

**КУШМАЛЫК** *и.* 1) Кушылган булу. *Күп очракта кушма җөмләнең кушмалыгы бик ачык күренеп тора ---.* М.Зәкиев

2) Аккомпанемент

**КУШМЕТАЛЛ** *и. махс.* Бер-берсе белән тоташкан, термик киңәю коэффициентлары төрле булган ике металл яки эретмә; биметалл

**КУШМЫНЧАК** *и. диал.* Аерылмыйча гел бергә йөргән кешеләр, дуслар, агылый белән тагылый

**КУШОРЛЫК** *и.* Кыяклылар семьялыгыннан кыргый үсемлек; бодайның бер төре; кыр борае, чын борай

**КУШСУЗЫК** *и. лингв.* Дифтонг

**КУШТАБЫН** *и. диал.* Өйдә идәнгә җәеп әзерләнгән зур табын

**КУШТАН** *с.* **1.** 1) Ялагай, тәлинкә тотучы. *Куштан песи баласы менеп утырды диярсең.* Т.Галиуллин

2) Артык төче мөгамәләле; кыланчык (хатын-кызлар тур.)

3) Бала итәкле, шундый фасонлы. *Куштан итәкле күлмәк*

**2.** *и. мәгъ.* 1) *иск.* Революциягә кадәр: татар авылларында власть вәкилләре белән арадашлык итүче кеше

2) *иск.* Колхозлаштыру чорына кадәр: кулак (*2 мәгъ.*) яклы кеше. *Отряд хуҗалары башлыча һәр җирдә кулаклардан, рецидивистлардан, элеккеге армиянең түбән чинлы куштаннарыннан тора.* Ш.Шәйдуллин

**КУШТАНЛАНУ** *ф.* 1) Ялагайлану, тәлинкә тоту. *Әхмәдиша карт, имансызлардан куркып, куштанланып елмайса да, юеш борынлы малайларны кешегә санамый.* Т.Галиуллин. --- *Берлиннан килгән татар эшлеклеләренең аңа куштанланып сөйләшүеннән бер нәтиҗә чыгарды: дәрәҗәле кош икән!* Т.Әйди. *[Старшина] Мамакка нәрсәдер сөйләп куштанлана, бер күзен кысып-кысып алгалый.* Х.Камалов

2) Чытлыклану, төчеләнү (хатын-кыз тур.)

**Куштанлана төшү** Бераз куштанлану

**Куштанланып йөрү** Гел, еш кына куштанлану. *Әнә шуңа күрә, ярый, китеп баруы яхшы булды әле, бер дә әллә кем түгел әле, ир-ат алдында кылтаеп куштанланып йөрүдән башканы белми иде, котылдым, ичмаса, дип куанган иде Ханәфи.* В.Нуруллин

**КУШТАНЛЫ** *с.* Бәби итәкле. *[Музейда пыяла астында] Ефәк чуклы ак шәл, куштанлы җиңле кызгылт сары кофта, очында буй-буй ике ак каймалы шәмәхә итәк, бизәкләр чигелгән ак алъяпкыч.* Т.Әйди

**КУШТАНЛЫК** *и.* 1) Ялагайлык, ярарга тырышучанлык. *Әнә шул куштанлыгын өнәп бетермим мин аның.* Р.Низамиев. *Куштанлыкта хыянәт орлыгы бар!* Х.Камалов. *Куштанлыгы да бар: начальство авылга килгән чакларында тиешенчә каршы алып, тиешенчә кунак итеп җибәрә белә [Ханәфи].* В.Нуруллин

2) Төчелек, чытлыклык (хатын-кыз тур.)

**КУШТОЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Имезүчеләр классының аякларында бармаклары җөп санда булган (2 яки 4), калын тояклы хайваннар отряды; 150 ләп төрне берләштерә; партояклылар

**КУШТЫРНАК** *и. лингв.* Цитаталарны, персонаж сүзләрен, әсәр, китап, журнал исемнәрен һ.б.ш.ларны аерып күрсәтү өчен махсус билге («...»). *Тәэк, килеп чыга болай... Син – куштырнаклар эченә алына, дигәндә – арты өтер, аяктан соң – сызык...* М.Галиев. *Тыныш билгеләрен болай төркемләү гамәли яктан бик уңай түгел, чөнки җәяләр һәм куштырнаклар бу бүленештән читтә кала.* М.Зәкиев

**КУШУ** I *ф.* 1) Төрле матдәләрне бергә катнаштыру, аралаштыру. *Әллә умарта балы да кушкан инде [шәрабка]?* Р.Бәшәр

2) Бер итү, бербөтен итеп берләштерү. *[Зөлкарнәй:] Лабораторияне ябарга түгел, ә кушарга.* Х.Вахит. *Биш колхозны бергә кушып, бер колхоз ясаганнар.* Х.Сарьян. *Йөрәкләрне кушты йөрәкләргә, Бер түгәрәк итте милли көй.* Р.Рахмани

3) Яулап алу, үз составына кертү (дәүләт, территория, биләмәләр тур.). *Үз дәүләтенә яңа биләмәләр кушса һәм дәүләтен катнашка әйләндерсә, нәселдән килгән падишаһка да җиңел булмый.* Н.Макиавелли. *Әмма [аларның] төп бурычлары көнчыгыш чикләрен саклау һәм Казахстан белән Урта*

*Азияне Рәсәйгә кушу өчен плацдарм була.* И.Сирматов

4) Өстәп әйтү, язу. *Сүзләренә кирәк-сә-кирәкмәсә дә «лар», «ләр» кушып, күплектә сөйләргә ярата ул.* М.Хәсәнов. *Шуңа күрә без кеше исеменә кушып, абый дибез, апа дибез.* Х.Сарьян. *«З» кушып сөйләшү безнең авылда кыланчыклык санала ---.* М.Маликова

5) Нәрсәгә дә булса өстәп бирү. *Бер сыерыбызга кышлык азык булды дип әйтергә ярамаса да, саламга кушып салырлык кына бар иде.* А.Яхин

6) Бер төркем кешеләр, хайваннар янына яңа кешеләр, хайваннар китерү, санын арттыру

7) Ияртү. --- *Шәех Игәнәй килеп керде һәм беренче сүз итеп: «Сәлим хан Олуг Мөхәммәт сәүдәгәре Садакка Төн илләренә чыгарга ярлык бирде, сак кирәкмәс, мин аңа үземнең бер мөридемне кушып җибәрәм», – диде.* М.Хәбибуллин

8) *биол.* Аталандыру // Яңа төр үсемлекләр чыгару, ялгау. *Груша агачына кушу, ялгау өчен, шул алмагачның бер ботагын яисә бөресен кисеп алып, груша агачына ялгарга мөмкин.* Дөньяда ниләр бар

9) Тоташтыру; кабызу. *Әле иртәгә Корбан гаете дигән көнне, бәйрәм алды концерты буладыр дип, телевизорны кушкан идем, бара бер нәрсә – «Юмор-шоу».* Татарстан яшьләре. *Пенсильвания университеты профессоры Дуглас Смит исә нерв җепселләренә электрод кушып, аны үстерү методикасын эшләде.* Мәдәни җомга

10) *мат.* Ике яки берничә санга кергән берәмлекләрнең суммасын табу. *Икегә икене кушкач – дүрт, икене икегә тапкырлагач – дүрт.* Р.Вәлиев. *Аерым очракларда андый системаларны алыштырып кую ысулы белән яки тигезләмәләрне кушу ысулы белән чишеп була.* Алгебра. *Торгын дулкын* $S_1$ *белән* $S_2$ *не кушып табыла.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

11) Тоташтыру, терәтеп кую. *Түр башында берничә өстәлне кушып урнашкан, араларында кызык өчен булса да бер ир заты да булмаган хатын-кызлар төркеме бәйрәм итеп ята.* Т.Галиуллин. *Бераздан шуңа [мәчеткә] кушып, таштан тагын бер бина торгызганнар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

12) Аралаштыру, арасына кертеп җибәрү, кыстыру. *Зәңгәр лә ыштан, зәңгәр ыштан, Аның арасына ак кушкан.* Җыр

13) Әйтү, телгә алу. *Борылып китеп кенә бармакчы идем, җыр башлангач, монсына кем исемен кушып җырлarлар икән дип кенә тукталып калдым.* И.Сирматов

14) *сир.* Ашарга бирү, алдына ашарга кую (малларга). *Аны [атны] лапаска кертеп тугарып, бәсләнгән тирләрен сөртеп печәнгә куштык, ат дилбегәсенкамытын өйгә алып кердек.* Х.Сарьян

15) *куч. сөйл.* Кавыштыру, өйләндерү, башлы-күзле итү. *Безне генә Ходай сөеп кушкан, Аермасын иде лә бер дошман.* Җыр

**Куша башлау** Кушарга тотыну

**Кушып бару** Даими яисә билгеле бер тәртиптә кушу. *Җырга салып хат җибәрәм, Дәфтәр битем шакмаклы. Арасына кушып барам Башка килгән такмакны.* Л.Шагыйрьҗан

**Кушып бетерү** Яраса-ярамаса да әллә ниләр кушу

**Кушып җибәрү** Тиз генә кушу. *Инсаф музыка кушып җибәрде.* Г.Нурлы. *Әмир урыныннан җәһәт торды да телевизорны кушып җибәрде.* М.Хуҗин

**Кушып кую** Кушылган хәлгә китерү

**Кушып тору** Әле, хәзерге вакытта кушу

**КУШУ** II *и.* 1) Ике яки берничә санга кергән берәмлекләрнең суммасын берләштерүдән гыйбарәт арифметик гамәл. *Күпме аңлатырга була: сезнең бурычыгыз кушу да, тапкырлау да түгел, ә алу һәм бүлү.* Р.Вәлиев

2) Шул гамәлне язуда белдергән махсус билге; плюс (+)

**КУШУ** III *ф.* 1) Кемгә дә булса берәр эш эшләргә боеру, әмер бирү. *Ул яшь натуралистларга юлда очраган һәммә нәрсәгә игътибарлы булырга куша иде.* М.Кәримов. *[Ренат] Мин кушам, боерам!* Х.Вахит. *Йөрәгемә куштым башка сине яратмаска! Синең зәңгәр күзләрең дип җан атмаска.* Р.Вәлиева

2) Берәр нәрсә эшләргә тәкъдим итү; әйтү. *Хәзрәт, ым кагып кына, Иргалигә дә чишенергә кушты.* М.Хәсәнов. *Мин аңа гөлләрне җиргә куярга куштым.* Г.Гыйльманов. *[Тәзкирә:] Әгәр бик үҗәтләнә икән, тот та бүген аңа бөтенләй күренмә. [Әбүзәр:] Качарга кушасыңмы?* А.Гыйләҗев

3) Күрсәтү, билгеләү

4) Таләп итү. *Инде дә даһи вә үлемсез Мөхәммәд галәйһиәссәлам биш вакыт намазны безгә фарыз итеп калдырган икән, шәригать кушканга буйсынмый булмас.* М.Хәсәнов. *Тимерханнар да алардан курыкмый, шикләнми, тик алар тыйнак, алар үзләрен устав кушканча тоталар.* Г.Ахунов. *– Без, алайса, закон кушканча эшләрбез! – диде Дәүләтша әкә ашыгып.* Я.Зәнкиев

5) Хокук бирү, рөхсәт итү

6) Язу, насыйп итү (теләкне белдерә). *Һәм дә шундый булып калырга Ходай кушсын берүк.* М.Хәсәнов

**Кушып бетерү** Барысын да кушу

**Кушып җибәрү** Кемдер аркылы кушу; тиз генә кушу

**Кушып тору** Даими рәвештә кушу. *Тик һаман бернәрсә тоткарлый: үги әнисе, минуты да булмаслык итеп, эш кушып тора.* З.Фәйзи

**Кушып чыгу** Һәммәсен дә кушу

**КУШУ** IV *и.* Боерык, әмер, тәкъдим. *Кемнеңдер кушуы буенча*

**КУШУ** V *ф.* Исем бирү, исем кую. *Балаңа чәчәк исеме куш, кыз булса да, малай булса да.* Г.Гыйльманов. *Малайга матур һәм җыйнак Әбелфатыйх Гомәр дигән исем куштылар.* Җ.Ильясов

**КУШУ́-АЛУ** *ф.* Кушу һәм алу. *Кушу-алу җөмлә төзүгә караганда күп җиңел минем өчен.* М.Хуҗин

**КУШУЧ** *и.* 1) Түгәрәкләп янәшә куелган ике уч. *Кушучыңны күкрәгеңә куеп, Кире борыл яшәү ягына.* К.Булатова

2) Шундый ике учка алынган сибелүчән, чәчелүчән әйбернең микъдары. *– Борының кычытмадымы? – дип, Гази кесәсенә дә бер кушуч чикләвек салды [Рәхимҗан].* М.Хәсәнов

**КУШУЧЛАП** *рәв.* 1) Кушуч белән, кушучка алып. *Тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: көшеләңнән кушучлап бөртек*

*алу, аның хуш исен тою бөтен арұталуларны юк итә дә куя.* М.Хәсәнов. *Бункердан гөжләп аккан бөртекләрне кушучлап бер исним әле ---.* Б.Камалов

2) *куч. сөйл.* Күп итеп. *Сипкәндәй кушучлап, чәчте ул очкыннар... Кешеләр кычкырды!.. Ә җаннар очтылар.* Л.Лерон. *Төпле акыл дигән хәзинәне һәркемгә дә кушучлап өләшмәгәннәр.* Б.Камалов. *Күрәсеңдер ич! Күкләрдән Ходай Кушучлап сибә өмет бөртеген.* Р.Идиятуллин

**КУ́ШЪЯКТЫЛЫ** *с.* Ике яктан яки аслы-өсле ике рәт тәрәзәдән яктылык кергән (биналар тур.)

**КУ́ШЪЯУЛЫК** *и.* Ике кат итеп ябына алырлык зур яулык; бөркәнчек

**КУШЫЛГАК** *и.* Нәселдәнлек билгеләре төрлечә булган организмнарны кушылдырудан, ягъни гибридлаштырудан туган организм; гибрид. *Моннан тыш тагы илебезнең күп кенә районнарында заанен токымлы кәҗәләр белән җирле кәҗәләр кушылгаклары таралган ---.* Йорт эшләре

**КУШЫЛДЫК** I *и.* 1) Икенче елгага коя торган елга. *XVI йөздә Болак – Казан елгасының табигый ермак рәвешендәге сул кушылдыгы.* Ф.Гарипова

2) *к.* **кушылма** (*1, 3 мәгъ*). *Кешеләр алдында син тагын да балкысын өчен, затлы металлдагы вак кушылдыклар күк, сафлыгыңны-пакьлегеңне киметә торган барлык кимчелекләреңне көйдерер идем, яндырыр идем.* Ш.Рәкыйпов

**КУШЫЛДЫК** II *и. к.* **кушылгак**

**КУШЫЛМА** *и.* 1) Ике яки берничә нәрсәне кушудан барлыкка килгән катнашма. *Башка төсләр шуларның [ак һәм караның] төрлечә кушылмасыннан хасил була.* Т.Галиуллин. *«Ир-ат» сүзе исә «ир» белән «ат» кушылмасыннан гыйбарәт.* Ф.Шәфигуллин. *Светлана Червонная --- ислам гамәли бизәү сәнгатенең классик традицияләрен иҗади эшкәртеп ясалган абстракциянең берлегендә күрә һәм, нәкъ шушы кушылма аны танытты, ди.* Мәдәни җомга

2) Билгеле бер нәрсәләрнең янәшә килүе, янәшә куелуы. *Ак-караның кушылмасы – олы бер сер имди, Рәсемкыйссаң шул серләрне танытыр ---.* Сөләйман

3) Бер яки берничә элемент атомнарының төрлечә бәйләнеше нәтиҗәсендә хасил булган матдә. *Туфрак та химик юл белән эшкәртелә, кучмә комнар бетерелә, атмосфера һәм күлләр дә фторлы кушылмалардан арындырыла, ясалма сулыклар төзелә.* А.Тимергалин. *[Мотор эшләгәндә] Газга куе кушылма бирергә ярамый ---.* Х.Госман. *Нефть чиста гына булмый, аның составында йөзләрчә төрле зарарлы кушылмалар була.* М.Зарипов

4) *к.* **кушылгак**. *Безгә кеше организмының ясалма интеллект белән, робот белән кушылмасы бүген коточкыч бер азман булып тоелса да, иртәгә андый кибернетик организмнарның – «киборг»ларның чынга ашуы мөмкин түгелмени?* А.Тимергалин. *Татарстанда туган күренекле химик А.Арбузов фосфор-органик кушылмалар өлкәсендә ачышлар ясый.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Бронза – нигездә, шул ук бакыр ул, тик аны эреткәндә төрле кушылмалар гына (мәсәлән, кургаш катнашмасы) өстәгәннәр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**КУШЫЛМАУЧАНЛЫК** *и. махс.* Бер нәрсәнең икенчесе белән кушыла алмавы

**КУШЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кушу**. *Шул сагыш-моң килеп сарыла да Каеннарның яшел иңенә, Әкрен генә кыйсса сөйли миңа, Кушылып талгын шәфәкъ җиленә.* Ф.Яруллин

2) Ике яки берничә нәрсә аралашу, катышу

3) Тоташу, бербөтен булу. *Йөзе чытыккамы, чем-кара кашлары бергә кушылган.* М.Хәсәнов

4) Берәр төркемгә (кешегә) килеп катнашу. *Ничек кенә булса да үзебезнең берәр частьны очратып, шуңа кушылырга кирәк иде.* Ә.Еники. *Ике кызылармееңц кушылган боларга, чигенгән вакытта.* З.Зәйнуллин. *Халык агымына кушылып фойега чыктым.* М.Хәсәнов

5) Өйләнешү, кавышу. *Бергә-бергә кушылып яшик мәллә, ди икән бу...* М.Мәһдиев. *«Кушылыйк без, мин сиңа тугры хатын булырмын», – диде [Шәгъбикә].* Я.Зәнкиев. *Бу җырны, зур мәҗлесләрдә гел шулай, быел кушылачак яңа парлар башлап җырлый икән.* Ә.Галиев

6) Берәр фикер белән ризалашу; килешү. *Мин дә бу фикергә кушылам*

7) *сөйл.* Уртаклашу; теләктәшлек күрсәтү. *Кыз да бу мәзәк егеткә кушылып рәхәтләнеп көлә.* М.Хәсәнов

8) Сүзгә, җырга, уенга һ.б. катнашу. *Сүзгә Иргали абый да кушылды.* М.Хәсәнов. *Концертка килүчеләр аягүрә басып, җырчыга кушылдылар.* К.Тимбикова. *Җырладылар яшь егетләр, Кушылды кызлар; Күкрәкләрендә балкыды Алтын йолдызлар.* Г.Насрый

9) Икенче бер елгага кою, агу. *Әнә шул Иртеш һәм Тобол елгалары кушылган урыннан ерак та түгел Тобол шәһәре урнашкан.* Я.Зәнкиев. *Борынгы Чулман белән Ак Идел килеп кушылган бер кыйтга.* Х.Сарьян. *Бөтен бугаз, аның Мәрмәрә диңгезенә барып кушыла торган ягына чаклы уч төбендәгедәй күренә.* И.Нуруллин

10) Яулап алыну, берәр дәүләтнең составына кертелү. *Габбасилар идарә иткән чорда хәлифәлеккә Сицилия, Кипр, Крит утраулары һәм Италиянең көньяк өлеше генә кушыла.* Тарих

11) Кан катышу. *Монда [Урта Идел һәм Урал буйларында] төрле этник төркемнәр очрашып кушылганнар яки бер-берсен алмаштыру процесслары кичергәннәр.* Ф.Гарипова. *Хәтта тамырлары төрки булган чуаш, шор ишеләре дә татар белән кушылса, балалары – урыс!* И.Сирматов. *Бу вакытта болгарлар кыпчаклар белән ныклап кушылган булалар инде.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

12) *махс.* Реакциягә керү, берләшү (матдәләр тур.)

13) Өстәлү. *Ләкин Калатаудагы төзелеш, аның өстенә көнбатышка таба сузыла торган объектлары да кушылгач, аның тамагына да төер тыгылды.* Г.Кашапов

**Кушыла бара** Торган саен күбрәк кушылу. *Талгын гына агылган скрипка көенә бер-бер артлы Динә һәм Рафаэль Латыйповлар кушыла барды.* А.Нәҗми

**Кушыла башлау** Кушылырга тотыну

**Кушыла төшү** Бераз кушылу

**Кушыла тору** Эзлекле рәвештә бер-бер артлы кушылу. *Килмешәкләр атау халкы белән аралаша, аңа кушыла торганнар.* М.Юныс

**Кушылып алу** Кыска вакытка кушылу. *Мәхмүт ага да башын күтәреп, шатлыклы гүләүләргә үзенең гөрелдәве белән кушылып алды.* М.Гали

**Кушылып бетү** Тулысынча кушылу, тәмам кушылу. *[Козгын] --- тавышсыз-тынсыз гына кузгалды да, торган саен кечерәя барып, күздән югалды, төпсез караңгылык белән кушылып бетте.* Ә.Гаффар. *Тегермән тартканда, ашлыкка тегесе-бусы кушылып бетә.* Ф.Шәфигуллин. *Мискидәге май инде боламыкка әйләнде, аерым-аерым йомарланган кисәкләр инде бергә кушылып бетте.* Н.Фәттах

**Кушылып китү** Акрынлап, бер-бер артлы кушылу. *Алдагы гасырга да кыю атлап кергән бу олуг затларга, вакытын белеп кенә, Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, Ю.Әминев кебек зирәк каләм осталары кушылып китте.* А.Гыйләҗев. *Җырның соңгы өлешенә ул кушылып китте, аңа якынрак торган кешеләр иярде.* Ә.Гаффар. *Харитонов операциянең уңышлы чыгуына иман китергән иде булса кирәк, тыныч күңел белән дөнья сүзләренә кушылып китте.* Х.Камалов

**Кушылып тору** Әледән-әле, даими кушылу

**КУШЫЛУЧЫ** *и. мат.* Арифметик гамәлдә: берәр сан (зурлык) белән кушыла торган сан (зурлык). *($a_n$) арифметик прогрессиянең беренче n буыны суммасын $S_n$ дип тамгалыйк һәм бу сумманы ике мәртәбә: беренче очракта кушылучыларның номерлары арта бару тәртибендә, ә икенче очракта кими бару тәртибендә урнаштырып языйк.* Алгебра

**КУШЫМ** *с. сөйл. к.* **кушымта 2**

**КУШЫМТА** *и.* **1.** 1) Өстәлгән, өстәп бирелгән нәрсә, өстәмә. *Законга кушымта итеп, өч мең ярым термин һәм техник атаманы эченә алган исемлек бирелгән.* Иң шәп календарь. *«Татар рекламасы һәм матбугат» дигән теманы без берничә ел элек кушымтабызда башлап җибәреп, шундый материалны даими тәкъдим итеп киләбез.* Мәдәни җомга

2) *махс.* Җырда, шигырьдә һ.б.ш. һәр куплеттан соң кабатлана торган строфа. *[Кара мыеклы белән Нигъмәтулла абзыкай] Һәр җыр артыннан, күңелләрне дәртләндереп, берәр кушымта әйтеп куялар...* Ә.Еники. *Җырның кушымтасын таза, калын күкрәкле җиңгәчи күтәреп алды.* М.Мәһдиев. *Әле бер, әле икенче яктан җыр ишетелә, кушымта рәвешендә генә хәтәррәк сүзләр дә өстәлә.* К.Кәримов

3) *күч.* Чит, теге яки бу әйбернең үз асылын тәшкил итмәгән нәрсә. *Әгәр дә син туплый торган кешеләр арасына ят кушымталар кереп ояласа, ахырдан аларны аралап алу гаять кыен булачак.* Г.Кашапов

**2.** *с. мәгъ.* Өстәлгән, өстәп бирелгән

**КУШЫМЧА** *и. лингв.* 1) Нигез составында булмаган, морфологик һәм синтаксик бәйләнешләрне тәэмин итә торган морфема. *Әле генә сез күплек кушымчаларының гыйльми табигатен дөрес аңламавыгызны күрсәттегез.* Х.Сарьян. *«Дә» кушымчасының бөтен тирәнлеген, мәгънәсен Сабир гына аңлады.* М.Мәһдиев. *Телнең үзенең кушымчалары күп вакытта үзләренең табигатен лексик берәмлек буларак югалткан мөстәкыйль сүзләрдән килеп чыкканнар.* Татар грамматикасы

2) Суффикс. *Мәсәлән, формант методына таянып үткәрелә торган анализ гидронимик нигезне, гидронимнар ясауда киң кулланыла торган сүз ясаучы кушымчаларны (гидронимик формантларны) һәм алкушымчаларны (префикслар) аерып карарга мөмкинлек бирә.* Ф.Гарипова

**КУШЫМЛЫК** *и. диал. к.* **кушымта** (*2 мәгъ.*)

**КУШЫ́П ЯЛГАУ** *и. биол.* Янәшә үсеп утырган ике үсемлекне төпләрендә килеш ялгау ысулы; янәшә ялгау, аблактировка

**КУШЫРУ** *ф.* 1) Кулларны яки аякларны берсе өстенә икенчесен китереп кую. *Тукай кулларын кушырып, сыкранып йөзен чытты, бүлмәсендә арлы-бирле йөренергә тотынды.* А.Расих. *Чыннан да, мунча нигезендә, тезләрен туп-туры кушырып, күптәнге, әллә кайчангы Әсхәдулла абзый утыра иде.* М.Мәһдиев. *Кәүсәрия килгән икән, кулларын күкрәгенә кушырып бөрешкәнен генә күреп калдым.* Ә.Гаффар

2) Кулларны күкрәк каршысына китереп, учларны бер-берсенә тидерү (кайбер халыкларда сәламләү билгесе буларак та кулланыла)

**Кушырып кую** Кушырган хәлдә тоту

**КУЫ́ГАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Кайбер төрләре үсемлекләр арасында вирус, гөмбә авыруларын тарата, авыл хуҗалыгына зарар китерә торган бөҗәкләр отряды; трипслар

**КУЫК** *и.* 1) Сыеклыкта басым нәтиҗәсендә барлыкка килә торган, берәр төрле газ тулы үтә күренмәле шар. *Аннан [кер юу машинасыннан], ачык читлектән азат ителгән кошлар кебек, эреле-ваклы дистәләгән сабын куыгы очып чыкты.* Ә.Гаффар. *Минә ул [Сәяр] эчендә терекөмеш кебек һава куыклары уйнап торган шәраблы фужерын өстәлгә куйды да сул кулын югары күтәрде.* М.Галиев

2) Тән пешү яки ышкылу нәтиҗәсендә тиредә барлыкка килә торган сулы кабарчык. *[Шәңгәрәй малаеның] Пешкән җире кызарган, бер-ике куык кабарып чыккан.* А.Тимергалин

3) *биол.* Кайбер тереклек ияләрендә эченә һава, сыеклык тулган әгъза. *Касык куыгына кундырганнан соң, ул тынсыз катып калды.* А.Хәлим. *Су басымы колак пәрдәсен ерту белән генә чикләнми, буыннарны катыра, бәвел куыгын эштән чыгара.* М.Юныс. *Балыклар үзләренең йөзү куыкларын да сулау өчен файдаланалар.* В.Сабунаев

4) Лампа пыяласы. *Ишекне шундый итеп япты ки, керосины бетә башлаган асылмалы лампаның ялкыны куыгыннан атылып чыга язды.* М.Хәсәнов. *Шактый корымланган җиделе лампа куыгына аның төкерек тамчылары тиеп чыжылдады.* Ә.Гаффар. *[Хәй Габидуллин] Төн буе янып корымланган лампа куыгына үрелгән иде, баш түбәсендә ялт итеп электр лампасы кабынды ---.* Ш.Шәйдуллин

5) Тәнне җылыту яисә салкынайту максаты белән эченә су яки боз

тутырыла торган резин капчык. *[Боз кисәкләре тутырылган] Куык астына икегә бөкләнгән сөлге куярга.* Файдалы киңәшләр

6) *сөйл.* Шар. *[Сәетнең] Үпкә кытыклары килеп, иптәш кызлары янында куна калгандыр дигән хыялы каз куыгы кеби шартлады.* Т.Галиуллин. *Әллә аллы-кызыллы куыклар таккан машина гына алганнармы?* А.Гыйләҗев

7) *күч. сөйл.* Ялган; кабартылган, күпертелгән сүз (хәбәр)

◊ **Куыгы шиңү** 1) Хәле бетү, дәрте бетү; 2) Кәефе бозылу, тәкәбберлек бетү. «*Кулларын селтәп тотынган иде дә, куыгы тиз шиңде», – диде [Камил].* Х.Сарьян. **Куык очыру** 1) Корыга мактану. *Теленнән, борыныннан Очырта куыкны [Самат]: – Шулай, – ди, – һәр кышны Җи...ңәм мин су...ыкны...* Г.Нәбиуллин. *Андый сатлык җаннар нәсел-нәсәбе белән куык очырырга ифрат яраталар.* Ш.Рәкыйпов; 2) Ялганлау. *Хәзер инде бар иптәшләр Сөйләшәләр чын-чыннан: – Ул, бер кызны коткардым дип, Куык кына очырган.* Г.Нәбиуллин

**КУЫ́К АБАГА** *и. бот.* Чын абагачалар семьялыгыннан урманлы тау битләрендә, чокырларда үсә торган тәбәнәк күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **пузырник**

**КУЫ́К ГӨМБӘ** *и. бот.* Гастромицетлар группасыннан, кипкәч, эче кара коңгырт тузанга әйләнә торган шар сыман базидиаль гөмбә; *русчасы:* **дождевик**. *Димәк, яңгыр башмагы куык гөмбә исемле дә икән.* К.Тәхау. *Яшь вакытларында куык гөмбәләр – йомшак кына сусыл итле ак шарчыклар.* Робинзон эзләреннән

**КУЫКЛАНУ** *ф.* Куыклар (*1–2 мәгъ.*) барлыкка килү

**Куыклана башлау** Куыкланырга тотыну

**Куыкланып бетү** Күп санда куыклар барлыкка килү; нык куыклану. *Аның өсте манма су, куллары пешеп куыкланып беткән.* Г.Әпсәләмов

**Куыкланып тору** Куыкланган хәлдә булу

**КУЫКЛЫ** *с.* 1) Куыгы булган // Куыкланып торган. *Берлинский жёлтый [салат сортының] яфраклары түгәрәк, куыклы һәм бөрмәле.* Яшелчәчелек

2) Пыяла. *Туфайлов өйгә кайтып, куыклы лампага ут элдерде ---.* Х.Камалов. *Хәтта куыклы лампаның да теле дерелдәп алды.* М.Әмирханов. *Куыклы лампа уты астында ниндидер кәгазьләр актарып утыра иде Ильяс Алкин.* М.Мөхәммәдиев

**КУЫКЛЫ́ ҮЛӘН** *и. бот.* Яфраклары арасында эче куыш куыклары булган, судагы вак организмнар, планктон, маймычлар белән туена торган үлән. *Балыкларны ашый торган үсемлекләр дә бар. Менә куыклы үлән.* Кызыклы ихтиология

**КУЫ́К УТЫ** *и. бот. к.* **куык яфрак**

**КУЫКЧЫЛ** *с.* Куык рәвешендәге. *Эхинококк дигән тасма суалчан куыкчыл стадиясендә куыкларының эре (бала башы зурлыгында) булуы белән аерыла ---.* Биология: хайваннар. *Яфрак өстендә кабарынкы, куыкчыл урыннар күренә.* Яшелчәчелек

**КУЫК ЯФРАК** *и. бот.* Куыкутычалар семьялыгыннан бөҗәкләр белән туклана торган күпьеллык үсемлек. *Бу – куыкутычалар семьялыгыннан куык яфраклар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КУЫЛ** *и.* Агач кәүсәсендәге зур куыш

**КУЫЛМА** *и. махс.* Югары температурада тотып, состав кисәкләргә аерылган матдә

**КУЫЛА́-СӨРЕЛӘ** *рәв. сөйл.* Чыгарга, китәргә тупас рәвештә мәҗбүр ителеп. *Куыла-сөрелә гомер итү*

**КУЫРДАК** *и. сөйл. к.* **куырма**. *Куырдак ашау*

**КУЫРДЫК** *и. сөйл. к.* **куырма**. *Аналарына әйтәләр инде болар: – Без урманга китәбез, син мичне бик кызу итеп як та, безнең кайтуга, бу солдатны куырдык ит, – диләр.* Әкият. *Моңарчы Сөмбеләнең урман аланын күргәне дә, учак күмерендә пешкән куырдыклардан, кош итләреннән, билдәмәләрдән авыз иткәне дә юк.* А.Гыйләҗев. *Тик ни гаҗәп, үтәме ике-өч сәгать вакыт – мин тәмләп кенә куырдык, итле аш ашап утырам.* Мәгърифәт

**КУЫРМА** *и.* Кыздырылган ит. *Куырманы сыер, сарык, ат һәм кош итләреннән дә әзерлиләр.* Серле календарь

**КУЫРМАЧ** *и.* Бүрттереп табада кыздырылган бөртекле ашлык я борчак. *[Кузы Көрпә:] Әни, куырмач ашыйсым килде, куырмач куыр, – ди.* Дастан

**КУЫРУ** *ф.* 1) Азыкны кыздырып әзерләү. *Куырган кальмарны кызчык бик ярата.* Г.Сәгыйров. *Ул арада өстәлгә самавыр килде. Зиннур абый, тиз һәм тәмле булсын дип, күкәй тәбәсе куырган икән ---.* Я.Зәнкиев. *Хәнифәттәй тәрәзәсе башта буран арасыннан куырган борчак кебек кенә саргаеп күренгән иде, тора-бара ачыкланды, яктырды.* Ф.Шәфигуллин

2) Киптерү, корыту, шиңдерү. *Иртә чыккан чәчәкләрне салкын куыра.* У.Шекспир

3) Тәнгә бик эссе яисә бик салкын һава килеп бәрелү, кисәк көчле тәэсир итү. *Ә тышта тыныңны куыра торган суык.* А.Хәсәнов. *Ул тавыш әллә ничек шунда, сугыш кырыннан килгәндәй тоела, бәлки, чыннан да, тын куыра торган җил ул тавышларны монда сугыш кырыннан ук алып киләдер.* М.Мәһдиев. *Тәрәзәләрдә калын боз тора, Салкын битне өтә, куыра.* Г.Рәхим

4) Өтү, өтеп алу (ялкын тур.). *Кыз, ике мәртәбә ялкын теле куырган Аятел Көрсиен кочаклап, урамда калды.* Н.Гыйматдинова

5) Авызны, иренне бөрештерү, ачыттыру. *Хөрмәнең кайбер төре авызны куыра*

6) Җыеру, бөрештерү, бөгәрләү, йомарлау (гәүдәне). *Икенчедән, мин кайбер җилкәсен куырып, погон ялтыратып йөрүчеләрдән дә кайбер автобиографик моментларны онытмауларын сорар идем.* М.Мәһдиев // Җыйнау, эчкә тартып җыеру. *Күрәсеңме, әнә ул [чәүкә баласы] Тик бер аякта тора, Ә икенче тәпиен Корыштыра, куыра.* Ш.Маннур

7) *күч. сөйл.* Ашыктыру, ашыгырга кушу. *Кытыр-кытыр безнемени, Ул үз-үзен куырды.* Г.Сәлим. *[Нургата:] Тукта, син алай бик куырма әле, Рәхмәтулла абый.* Х.Вахит

8) *күч. сөйл.* Таләп итү. *Ахры, ул служебада бер тыловик утыра, тылдан*

*китмәс өчен тырышамы, әллә үзе бар эшне җиренә җиткереп эшләргә яратучымы? Бик яман куыра...* Х.Камалов

9) *күч.* Тиргәү. *Бу юлы бик каты куырды аны Бичарин.* Ф.Шәфигуллин. *Идрисовның мондый кызу куыра торган кешеләрне очратканы бар иде, тел кайтарудан тыелды.* Х.Камалов

10) *күч.* Кыйнау. *Килеп җитә патша монда. – Кем ваткан? – дип дулый ул да. – Ә-ә, Чулпанмы?.. Суктырырга! Чыбык белән куырырга!..* Ш.Маннур

**Куыра башлау** Куырырга тотыну. *[Балыкны] Көзгә сөзеп куыра да башлыйбыз, рәхим итегез!* Ә.Еники. *Кояш югарырак күтәрелгәч, чүл өсте күмергә утырткан табадай кызачак һәм мескен баланы куыра башлаячак.* М.Юныс. *«Я, сөйлә инде, зарыктырма!» – дип, Габдулла иптәшен куыра башлады.* Ә.Фәйзи

**Куыра бирү** Бернигә карамыйча куыруын дәвам итү. *Ләкин Мөхсиновның йомшар исәбе күренми, ул «әтисе белән гомер иткән» картны куыра бирә.* Ф.Хөсни

**Куыра төшү** Тагын да бераз куыру

**Куырып алу** Кискен рәвештә куыру. *Шәмәхә төн. Якты урам. Куырып ала апрель җиле.* М.Галиев. *Тун төймәләрем ычкынып беткән, кызган канны салкын һава куырып алды.* Ә.Гаффар. *Ә салкынлык ким дигәндә кырык градус. Әгәренки җил дә булса, иреннәреңне куырып алыр иде.* Ә.Галиев

**Куырып бетерү** Бөтенесен куыру; тәмам, бик нык куыру

**Куырып җибәрү** Бераз куыру. *Сулы чанга салып, тозын җебетеп куырып җибәрсәләр, безгә бата...* С.Шәрипов

**Куырып кую** Көтмәгәндә, кинәт куыру; алдан куырып әзер итү. --- *төш дигәнне арыш оныннан да куырып куялар.* Г.Бәширов

**Куырып ташлау** Кинәт куыру. *Май суыклары чәчәкне куырып ташлады.* И.Гази

**КУЫРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **куыру** (*1–2 мәгъ.*)

2) Утта кызып, ашарлык хәлгә килү. --- *токмач, күмәч, пәрәмәч һәм төрекчәдәге кавырмач вә боламач кебек аш исемнәре – һәммәсе аш дигән сүзнең төрле сүзләргә кушылуыннан хасил булган булырга тиеш, чөнки без умачның уылып, куырмачның куырылып (төрекчә «кавырылып») ясалганлыгын беләбез.* Җ.Вәлиди

3) Бөрешү, корышу; беркадәр кибү. *Вакыты узганлыктан, җир җиләге кояшта бераз куырылган.* М.Гали. *Су гөлләре чумды су астына, Куырылды дөнья – җилләр кайнар.* Зөлфәт

4) Бөрешү; бөгәрләнү, йомарланып килү. *Ишекне ачып караңгылыкка чыкканда гына, клуб миче кырында зәңгәр сырмасының ян кесәләренә кулларын тыгып куырылып утырган Гаделиянең күзләре белән очраша.* М.Мәһдиев. *Мин бер кырыйда куырылып басып торам ---.* М.Галиев. *Шәфкать туташының шприцын күрүгә куырылган бала әкренләп язылა башлады.* Ф.Яруллин

5) Кискен тәэсир иткән эссегә яки салкынга каршы реакция бирү (тән тур.)

6) Йомарлану, бөгәрләнү, җыерчыклар барлыкка килү (кием, тукымалар тур.). *Өстендәге бөтен киеменең бертөрле куырылып, җыерылып торуы сәбәпле, хәзрәтебезнең кыяфәте көлдермәслек түгел иде.* Ф.Әмирхан

7) *күч.* Курку. --- *Сөмбеләнең йөрәге куырылды: өч тамашачы утыра, ә керү ишеге ябык: чаршавына чаклы корылган.* К.Кәримов

8) *күч.* Авырлык күрү, михнәт чигү, югалту кичерү. *Бар халыклар куырыла Кыраулар төшкән чакта.* Зөлфәт. *Өч көн буе кышкы урман эчендә, эзсез-сукмаксыз, азыксыз-сусыз куырылганнан соң, бер авылга тап булып, урам очындагы йорт тәрәзәсен шакыдылар алар.* А.Хәлим

**Куырыла төшү** Бераз куырылу. *Иртәнге салкын белән өшеп куырыла төшкән тәннәр әллә нинди җылылыкны искә төшергән кебек чымырдап киттеләр.* М.Гафури. *Гаепләнүче баскан җирендә куырыла төште.* Г.Ибраһимов

**Куырылып алу** Беразга кинәт куырылу. *Трубканы куйгач, ул [Фаина Наумовна], эре-эре сипкелләр чәчелгән кыска буынлы беләген өстәлгә куеп, туңган кеше сыман куырылып алды.* А.Гыйләҗев

**Куырылып бетү** Бик нык куырылган хәлгә килү. *Сулда җил уңаена сөрлеккән солы, кара башын җиргә төрткән тары, саргаеп, куырылып беткән ясмык җирләре җәелеп китте.* И.Гази. *Япан кырда яшеннәргә Каршы торган агач булып Кичтем язмыш-җәйләремне, Ахыр беттем куырылып.* Р.Рахман

**Куырылып калу** Нинди дә булса сәбәптән, вакыттан соң кинәт куырылу. *Чапкын булып барган Балак, Әтилгә керүгә үк, өстенә кайнар су койгандай куырылып калды.* В.Имамов. *Гыйззелмөлек куырылып калды. Кем чакырган аларны, сарайга кем керткән?!* Җ.Ильясов. *[Рәсимә түтинең] Гәүдәсе әбиләрнеке кебек куырылып калган.* З.Фәйзи

**Куырылып килү** Берәр нәрсәнең көчле тәэсирендә көтмәгәндә куырылу. *[Ловыгин] Саранланмыйча, кызына да сыптырды, анысы куырылып килде, төенчеккә төйнәлде, чарылдап кычкырып җибәрде.* А.Иванов. *Әнисе белән сөйләшкән хатынның йөзен күрүгә, кыз куырылып килде.* З.Хөснияр. *Аның газап тулы күзләрен күргәч, куырылып килдем.* Ф.Шәфигуллин

**Куырылып китү** Кинәт куырылу. *Һәм [Иван Дүртенче] үз уеннан үзе куркынып, куырылып китте.* М.Хәбибуллин

**Куырылып кую** Аз гына вакыт эчендә кинәт куырылу. *Бакый өшеп киткәндәй куырылып куйды.* М.Галиев

**Куырылып төшү** Тәмам, бик нык куырылу, бөрешеп бетү. *Хәтта моны көн саен ишетеп торган солдат апа да – ул да – ирексездән куырылып төшә.* Ә.Еники. *Муенына тамып, инде үзәгенә үткән көз тымызыгыннан куырылып төшкән, сорыланып кечерәйгән берсе култык астына кыстырган папкасын караңгыланган җиргә төшереп җибәрде ---.* С.Гаффарова

**КУЫШ** I *и.* **1.** 1) Нинди дә булса предметта эчкә кереп торган, томаламый ясалган ачыклык, бушлык, буш урын; куышлык. *Габделхәй минем әнинең мич куышына акча куеп торганын күреп калган да шуны чәлдергән икән.* М.Әмир. *[Гаделша абзый] Аннары*

*тире бияләйләрен мич куышына тыкты, шарфын муенынынан сүтте, тунын тиз-тиз элгечкә элде, итекләрен салырга иелде.* Р.Ишморатова

2) Тау, җир катламнарын эчкә таба казып, уеп ясалган, яисә җир катламнары формалашканда барлыкка килгән бушлык. *Әнкәйләр чүлмәк тапкан урыннан 80–90 метрлар көньяктарак элеккеге заманнарда зур гына тау куышы булган.* И.Сирматов. *Куышның авызы кечкенә генә, анда мүкәләп диярлек керәсе икән.* Ә.Гаффар. *Ә биек ярга ул [ондатра] куыш казып кера, бу куышның керү юлы су астында кала, киң оя өскә урнаша.* Кызыклар дөньясында

3) Агач кәүсәсенең үзагачы черегән урында барлыкка килгән бушлык. *Хәзер аны – әлеге яшеннең нарасый бер чаткысын – имән куышына ябып куйдылар.* Ә.Гаффар. *Бүкән куышыннан яшерелгән алтыннар чәчелеп китә.* Н.Хәсәнов. *Әйе, нәкъ шулай, югарыдагы агач куышыннан тәмле ис килә.* Кызыклар дөньясында

4) Киртәләре таган сыман яисә дүрткел итеп куелган, өсте кәс, кайры, кабык, чыбык-чабык, печән, салам һ.б.ш.лар белән ябылган ышык урын. *Төн кундык без урман куышында. Безнең яшел куыш өстеннән, Кыштыр-кыштыр тиеп ябалдашка, Җәйге яшел җилләр истеләр.* Зөлфәт. *Куышыбызга яңгыр яварга тотынды. --- Куыш астыннан чыктык та, ашыга-кабалана яңа ботаклар сындырып, әнинең баш очына җәяргә керештек.* Ә.Гаффар. *Печәннән куышлар корып, бер айга якын шунда яши идек.* М.Вәлиев

5) Гомумән, вакытлыча сыенырлык, яшеренерлек, кунарлык урын. *Бары тик икебез генә сыярлык куыш түшәмендәге өч боз сөңгесен җил йөрсенгә стенада махсус калдырылган тишекләрдән кергән ай нуры яктырта иде.* Ә.Гаффар

6) Яшәү урыны, торак. *Гаделша картның куышы чыннан да борылыш артында гына булган.* М.Хәсәнов. *Хәзер улы белән яшәргә аларга бер куыш кирәк.* Я.Зәнкиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эче буш. *Син, изге Байкал, Дулкынлан, чайкал, Югалт көймәне Ерак-еракка, Куыш ярларга, Дошмансыз якка.* Ш.Маннур. *Бүген Казан уртасы куыш күмәчне хәтерләтә ---.* Татарстан. *Куыш эчле «каландр» дигән беләзекләр, ташын яки ташның урынын күчереп була торган йөзекләр дә яшьләр модасына керә.* Татарстан

2) Үзагачы череп, бушлык, тишек хасил булган. *Ә эче куыш агач очрамасмы?* А.Тимергалин. *Затлы-затлы ишекләре, Боздай салкын күзләре... Анкетадай буш сүзләре, Куыш агач үзләре.* Р.Рахмани

◊ **Куыш карбыз тибү** Эшсез йөрү, буш йөрү

**КУЫШ** II *и. к.* **куышлы**. *Иң әүвәл бишташ, аның артыннан әйләнбәйлән, аның артыннан куыш уеннары, берсе артлы берсе, биш вакыт намаз кеби, аллы-артлы үтәлә генә бара иде.* Г.Исхакый. *Гөж килеп кырлар, басулар тормыш җырын җырлыйлар; Шаулы уҗымнар өстендә җилләр куыш уйныйлар.* Г.Сәгыйров. *Без, малайлар, өянке артларыннан гына качып киләбез дә таш атып су чәчрәтәбез. Китә чыр-чу, китә куыш.* М.Галиев

**КУЫ́Ш-КУЫШ** *и. к.* **куышлы**. *Кунак малайлар белән күңелле итеп куыш-куыш уйнадык.* Р.Төхфәтуллин

**КУЫШЛАНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **куышлау**

2) Куышлык ясау, куыш итеп кую. *Бервакыт хәзрәт ике йодрыгын куышландырып тотты да, картинаны шулар аркылы карый-карый, җәһәтләп, артына чигә башлады.* Ф.Әмирхан

**Куышландырып кую** Алдан ук куышландырып калдыру

**Куышландырып яту** Әле, хәзерге вакытта куышландыру

**КУЫШЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **куышлау**

2) Куышлык барлыкка килү, куышлык ясалу. *[Тозлы кыярының] Бер чакта да уртасы куышланмас, җебемәс, болай да тәмләп ашарга була, теләсәң, салатка куш ---.* А.Гыйләҗев

**Куышлана бару** Торган саен ныграк куышлану. *Баш тирәсендәге кар, эреп, куышлана бара.* Р.Батулла

**Куышлана төшү** Тагын да бераз куышлану

**Куышланып китү** Аз гына, ниндидер сәбәптән бераз куышлану

**Куышланып тору** Әле, хәзер куышланган хәлдә булу

**Куышланып чыгу** Тәмам куышлану

**КУЫШЛА́У** *ф.* Куышлык ясау, куыш итеп ясау

**Куышлап бетерү** Куыш ясауны тәмамлау; бик нык куышлау, бик күп куышлар ясау

**КУЫШЛЫ** I *с.* 1) Эче куыш булган. *Куышлы имәнне яшен бүтән бер дә сукмый, буш чикләвекне бүтән аҗаган алмый.* Ә.Гаффар. *Куышлы агач тирәсендә хайваннар эшчәнлегенең нинди төрләрен билгеләргә була?* Биология: хайваннар

2) Эченә куышлар ясалган. *Байкалларны кичте юллар Куышлы таулар аша.* Ш.Маннур

**КУЫШЛЫ** II *и.* Катнашучылардан берсенең башкаларны куып тотудан гыйбарәт балалар уены. *Әнә чем-кара күзле, түп-түгәрәк йөзле бер малай бабасы белән куышлы уйный.* Р.Төхфәтуллин. *Көн караңгыланган, урамда, куышлы уйнагандай, реклама утлары сикерешә.* М.Зарипов. *Кояш чирәм өсләрендә Куышлы уйный иде; Болыт шәүләсеннән качып, Үртәүдән туймый иде.* Р.Рахмани

**КУЫШЛЫК** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса эчендәге буш урын, бушлык. *Теш куышлыгы*

2) *махс.* Тереклек организмында булган бушлык яки төрле әгъзалар урнашкан урын. *– Моны хәзер дә кабатларга әзермен, – дидем мин, кызган телемне корыган авыз куышлыгында көчкә әйләндереп.* Р.Төхфәтуллин. *[Кортлар] Җыелган нектарны махсус бал капчыгында алып кайталар. Букчага охшаган бу куышлык кортның корсак алдына урнашкан.* Кызыклар дөньясында. *Гөмбәләр белән йогышлану очракларының күбесе элек колак куышлыгына операция ясаткан кешеләрдә була.* Иң шәп календарь

3) *к.* **куыш**. *Мондый урыннарда ул тишкән куышлыклар тулып ята.* Кызыклар дөньясында. *Кабилә куышлыкта йоклаган чагында учак сүнәргә тиеш түгел.* Дөньяда ниләр бар

**КУЫШУ** *ф.* Бер-береңне узарга яки тотарга тырышып йөгерү, чабу; йөгерешү. *Бер агач артыннан икенчесенә йөгереп кача-кача озак куыштылар [алар].* А.Иванов. *Диңгез өстендә үзара куышып, шашынып йөгерешкән ак яллы яшькелт дулкыннар ару-талуны белми шаулыйлар да шаулыйлар.* М.Юныс. *Җилләр белән әүмәкләшеп тәгәриләр, куышалар, көрәшәләр яшь малайлар.* Р.Фәйзуллин // Атта һ.б.ш. җигүле хайваннарда бер-береңне узарга тырышып, ярышып чабу, чабышу

**Куыша тору** Озак вакыт, бертуктаусыз куышу. *Куыша торгач, алар Чалмыя елгасының иң текә, иң биек ярына килеп җиттеләр, һәм Убырлы аска очты.* Ф.Садриев

**Куышып йөрү** Әле, хәзер, сөйләү моментында куышу. *Күңелләре көр: ирләр төркем-төркем булып гәп сата, көлә, тәмәке көйрәтә, хатын-кыз заты да бар, алар тирәли бала-чага куышып йөри.* Ә.Гаффар. *Диңгез өстендә ак яллы дулкыннар куышып йөри.* М.Юныс

**КУЮ** *ф.* **1.** 1) Әйберне нинди дә булса бер урынга, җиргә урнаштыру. --- *Флүн трубкасын куйганчы, тегесе чаптырып килеп тә җитә.* И.Сирматов. *[Фаягөл:] Соң, куйыйк берәр музыкальный центр.* Т.Миңнуллин. *Башны куям ап-ак төшләр күргән якты сердәш – ялгыз мендәргә.* Н.Гамбәр

2) Нинди дә булса торышка, рәвешкә китерү. *Цехның тәрәзәләре бик өстә, баскыч куйсаң гына менеп җитәрлек урында иде, ишекләрне ут чолгап алган.* А.Расих

3) Нәрсәне дә булса берәр нәрсәгә янәшә, якын китерү. *Җилләр телен белгән Лорка үзе килеп чыгар кебек борылыштан. Гитараның күкрәгенә кулын куеп башлар җырын яңабаштан.* М.Галиев. *Мин колагымны куеп тыңлап карадым.* Ф.Яруллин. *Кулларын каш өстенә куеп, безне хатыннар, карчыклар карап кала.* Р.Төхфәтуллин

4) Берәр позициягә урнаштыру (сугышта, яу кырында). *Бер көнне авыл кырыена пулемёт ноктэлары куяр өчен солдатлардан кар өйдерттеләр.* Р.Кадыйров

5) Нәрсәне дә булса бер әйбергә, предметка беркетү, беркетеп ясау. *[Зур апам] --- муенына иңбашларын каплап торган зур челтәр яка куеп, аны алдан коңгыздай зур брошка белән каптырып куйган.* Х.Сарьян. *Итекчеләр юк, көмешчеләр юк, тегүчеләр, сәгать осталары, пыяла куючылар, калайчылар юк.* И.Сирматов

6) *сөйл.* Төзү, кору, ясау. *Үзләренә үзләре куйган һәйкәлләр таш һәйкәлләрдән кадерлерәктер дә әле.* И.Сирматов

7) Өю, өеп ясау (кибән, эскерт, чүмәлә һ.б. тур.). *Сугылган саламны каккалап чүмәләгә өюче, чүмәләләрне озатып торучы хатыннар, эскерт куючы ирләр бер-берсен алыштыра.* И.Сирматов. *Көрнәләләр шунда печән чабалар. Зур-зур кибәннәр куялар.* К.Хәмзин

8) Хезмәткә билгеләү. *Әйтик, мөдир урыны бер ел түгел, ике ел буш торса да, ректорга һичкем – ни кандидат, ни доктор: «Мине мөдир итеп куюыгызны үтенәм» дип гариза язып керми.* Х.Сарьян. *– Капитанның политик ярдәмчесе – помполит өстәлергә тиеш. – Кемне куячаклары билгеле түгелме әле?* М.Юныс. *Әнәснең уңганлыгы, булдыклылыгы йөзендә чагылгандыр, мөгаен, аны мастер итеп куялар.* Идел // Исәпкә кертү. *Янычарны казна хисабына куй.* Р.Батулла

9) *сөйл.* Комарлы уеннарда: акчаны билгеле бер күләмдә банкка, уенга кертү

10) Ашамлык яки эчемлекне кайнау, пешү, ою һ.б.ш. өчен әзерләп калдыру. *Жалоба юк, значит, Фатиха түтәй көмешкә куймый.* И.Сирматов. *Хөсәен кухняга чыгып, керосинкага чәшке белән су куеп керде.* А.Расих. *«Чәй куярга кирәк», – дип уйлады Җиһан.* Ф.Латыйпов

11) Ясау, беркетеп урнаштыру. *Аңа инде теш куйганнар, ул элеккечә, яшь вакытындагыча, әттәтерләнеп сөйләшә, ашыга, җөмләне вата, боза иде.* М.Мәһдиев

12) Бирү (азык тур.). *Кышын кошларга азык кую*

13) Язу, язуда күрсәтү. *Мәктәптә исә сүзләрне әдәбиләштереп, кагыйдә буенча язарга кушалар иде. Кайда «з», кайда «д» куярга белми аптырап бетәсең.* М.Маликова. *[Йосыф Исхакович:] Бүгенге числоны, айны куярга онытмагыз.* Д.Салихов. *Битекче, тагын бер хат яз, минем тамганы куй!* М.Хәбибуллин

14) Язуда тыныш билгеләрен куллану. *Беренчесендә мин тыныш билгеләре куймыйм, икенчесендә – куям.* Х.Сарьян. *Беләсең, бер сүзгә төртке куйсаң, әшәке сүзгә әйләнә.* Х.Камалов

15) Салу, утырту (чәчәкләр тур.). *Бәлки, хәзер бөтен ил аның каберенә чәчәкләр куядыр.* И.Сирматов. *Туган көнеңдер инде: күп итеп чәчәк куйганнар, чүлмәкләре белән шиңмичә утыралар иде.* Х.Сарьян

16) Тамашачы алдында чыгыш ясау. *Без дә ул көнне кич, докладтан соң, үзебезнең клубта концерт куйдык.* Х.Сарьян. *Алар кич клубта концерт куярга тиеш булганнар да, телевизорчылар кассеталарын онытып калдырган төсле, болар да синтезаторларын --- күрше колхозда онытып калдырганнар икән.* И.Сирматов

17) Бәясен билгеләү, хакын күрсәтү. *Аңа хакны бик түбән куясыз.* Кызыклар дөньясында

18) Бәяләү, өстен яки түбән дип табу. *Ә менә Маринаны мин форма һәм фикер бердәмлегенең көче ягыннан хәзерге күп ир шагыйрьләрдән өстен куям.* С.Сөләйманова

19) Кулланылган баллар системасындагы билге белән бәяләү, шул билгене язуда күрсәтү. *Инде дәрескә «бишле куярга» дип язып куйган протоколчы кызның да кулыннан ручкасы төшеп китте.* Х.Сарьян. *Укытучылар алар син председатель дип тормаслар, белмәсәң, акыртып икеле куярлар.* Ф.Яруллин

20) Берәр төрле мәсьәлә күтәрү, күтәреп чыгу. *Мин башта декан белән сөйләшәм, аннан мәсьәләне ректорат алдына куярбыз.* Х.Сарьян

21) Бурычлар һ.б.ш. билгеләү, йөкләмәләр алу. *Императорга шарт куям, илче: хан кызын аңа алып бирсәм, император миңа Боспор Херсонесны бүләк итәр ---.* М.Хәбибуллин. *«Гаилә бәйләнешләренең нык булыр-*

*га тиешлегән кырыс нормалар белән расларга», «бу – бик җитди һәм изге эш» – менә ул [Наполеон] куйган кайбер таләпләр.* Кызыклар дөньясында

22) Оештыру; урнаштыру; билгеләү (тәртип һ.б.ш. тур.). *Яңа позициягә барырга ике сәгать вакыт куйдылар.* Х.Камалов. *Ник дигәндә, килмешәк хәзер үз таләпләрен куя ---.* Кызыклар дөньясында

23) Билгеләү; ачыклау. *Артемий мәсьәләне дөрес куя: балаларның гаебе юк.* А.Иванов

24) Нәрсәне дә булса хәл итәргә тәкъдим итү. *Тавышка куям, миннән кала һәркем каршы.* Ә.Гаффар

25) Калдыру (ихтыяр, ирек, теләк тур.). *[Немец офицеры:] Без көчләмибез, без сезнең ихтыярыгызга куябыз.* Ә.Еники. *Ләкин олы юлга чыккач, бахбайларны үз көенә куябыз да, мин Җәзилә янына күчеп утырам.* Х.Сарьян

26) Әйтү. *Әнкәй, күз карашын алардан яшереп, менә күрше әбиеңнәргә кара кәгазь килде бит әле, дип куйды.* И.Сирматов

27) Физик, рухи көч бирү, хезмәт кертү. *Мин үземнән әйтәм: күп тырышлык куйган гына алга барала.* Г.Сәгыйров. *Яралылар килә торды, алар бар көчләрен куеп дәваладылар ---.* Х.Камалов. *Һәм [бурсык] бөтен көчен куеп үз-үзен яклый, куркыныч итеп ысылдый, ерткычны тешләп алырга тора, ә үзе һаман саен оясына таба чигенә.* Кызыклар дөньясында

28) Бирү, күрсәтү, ирешү (уңыш, рекорд тур.). *[Егетләр:] Нәгыйм абый, стена ягыннан тышаулауны тәмамладык, безнең звено тагаен рекорд куймагае.* Х.Мөхәммәтшин. *Күргәнегезчә, кошлар нинди генә рекордлар куймыйлар!* Кызыклар дөньясында

29) Тәкъдим итү, бирү. *Юл кую*

30) Исемләү. *Безнең ил корабларына, кагыйдә буларак, тарихта эз калдырган күренекле шәхесләр --- исемнәрен куялар.* М.Юныс

31) Җибәрү, кушу (көй, музыка, магнитофон һ.б.ш. тур.). *Музыка кую*

32) Әдәби әсәрне экранлаштыру яки сәхнәләштерү. *«Куючы режиссёры булса, мин аңа мең сценарий язып тотыра алам!» – дип әйтүче язу остасы да, «Яхшы сценарий булса, фильм төшерүнең бернәрсәсе юк», – дигән режиссёр да һөнәрләренә кәсеп итеп караучылар гына.* Мәдәни җомга

33) Өлгерү, чит итмәү. *Зангир исә ординарец вазифасын да куймый, барысына да җитешә.* Х.Камалов

34) Эшне тапшыру, билгеләү, кушу. *Бәхәс дигәндә Камилне куй инде – сикереп тә төште.* Х.Сарьян

35) Санау, уйлау. *Хатын, үзен зурга куеп, мине начар билгеләренә укыган --- малай итеп күрә иде.* Х.Камалов

36) Гадәттә дәвалау максаты белән организмга сыеклык кертү. *Людовик XIII не әкренләп мышьяк белән агулап үтергәннәр, дәвалыйбыз дигән булып, клизма куйганда да мышьяк кушарга онытмаганнар.* Мәдәни җомга. *Система кую*

37) **куй, ку́йчы, ку́егыз** *боерык ф. форм.* Тукта, ташла, оныт. *Тик син түгел... Куй, үпкәләмә, Тотнаклы бул. Ак җаныңны сакла.* Г.Сәлим. *[Ырсытдин:] Куйчы... кунак дип, үзебезнең ялчыбыз Мөхәммәт кагылган иде.* Я.Зәнкиев. *Әмирханның киңәшләре истә: милләт кызы, сәхнә – синең эш. Куй, шауласын «көфер почмаклары» ---.* Р.Әхмәтҗанов. *[Мирхас:] «Бу ахмаклыгыгызны куегыз», – диде.* Х.Камалов

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Эш яки хәлнең тиз, кинәт башкарылуын белдерә. *Шул уңай белән ул Заһидә турында да уйланып куйды.* Ә.Еники. *Бәлки, тулай торак биреп куюлары да бар.* Х.Сарьян. *Ә минем күкрәгемдәге йөрәк, кемдер боз кисәге белән орынгандай, кысылыпкысылып куйды.* Ә.Гаффар

2) Эшнең нәтиҗәле булуын, төгәлләнүен белдерә. *Пәрдәләрне тартып куйгач, искә төшереп, бер мендәрне бусага төбенә ташлыйм.* Ә.Гаффар

3) Эш яки хәлнең сизелер-сизелмәс яки кыска гына вакыт аралыгында бер тапкыр башкарылуын белдерә. *Әле ул елмаеп та куйды кебек.* Н.Дәүли. *Су уртасында берәр балык сыртын елтыратып чумып куя.* Ә.Еники

**Куеп бару** *к.* **куя бару**. *[Туктар:] Соң бит, ваткан саен куеп та барам...* Х.Ибраһим

**Куеп бетерү** Тулысынча кую; барысын да кую

**Куеп җибәрү** Тиз генә кую. *Фатыйма апа самавырын куеп җибәрә, әчәсем килсә-килмәсә дә, кыстый-кыстый чәй эчерә.* Х.Сарьян. *[Марҗа апай] --- үзен орыша-орыша, тиз генә самавыр куеп җибәрде.* А.Хәсәнов. *[Назыйм] Графиннан бәләкәй чәйнеккә су агызып, электр белән генә чәй куеп җибәрде.* М.Вәлиев

**Куеп йөрү** Төрле урыннарда кую; күпләп кую. *Мин бит районда концертлар куеп йөргәндә, Тукай шигырьләрен ятлап йөрдем.* Х.Сарьян

**Куеп тору** Даими, әледән-әле кую; әле, хәзер, сөйләү моментында кую. *Дөрес, аларга биредә төрле урыннарга азык куеп торалар.* Кызыклар дөньясында // Билгеле бер вакытка кадәр калдыру, вакытлыча тимәү. *– Алкаң ычкынды, – дим мин. – Куеп тор, соңыннан.* Ә.Гаффар. *Зирәк егет икәнсең. Куеп тор, дим, кагылма!* А.Гыйләҗев

**Куеп чыгу** Тоташтан, бер-бер артлы кую; һәрберсенә кую. *Нокталарын, өтерләрен дә үз урыннарына куеп чыксаң – шаккатарлык.* Н.Дәүли. *Кыш бабай һәр тәртипле балага чыршы төбенә уенчыклар куеп чыккан.* Сабантуй

**Куеп яту** *сөйл.* Хәзерге вакытта кую. *Хәзер анда станоклар куеп яталар әнә...* М.Вәлиев. *Кара әле, Рамазан энем, колхоз-совхоз театрына яшь артистлар кирәк. «Галиябану»ны куеп яталар.* Б.Камалов

**Куя бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы кую. *Берсе артыннан берсен дәфтәрләрне төзәтеп, читкә куя бара.* Г.Исхакый

**Куя башлау** Куярга тотыну. *Мин Алла дип исәрә дә кеше, җаны үз-үзенә күпләп һәйкәл куя башлый.* М.Галиев

**Куя килү** Электән үк, системалы рәвештә кую

**Куя тору** Әледән-әле кую. *Әмма кайгы ничек кенә зур булмасын, тормыш дәвам итә һәм үзенең яңадан-яңа таләпләрен алга куя тора.* Мәдәни җомга // Алдан кую. *[Сафиулла:] Бар, чәеңне куя тор.* Ә.Гаффар

**КУЯН** *и.* **1.** 1) Шул исемдәге семьялык барлыкка китергән, кыска койрык-

лы, озын колаклы, арт аяклары алгысыннан озынрак һәм көчлерәк булып, сикереп чабуга көйләнгән имезүче кечерәк җәнлек. *Әкрен барган – куян артыннан җиткән, шәп барган – сыер артыннан җитмәгән.* Мәкаль. *Күчәндә утырган кәбестә башларыннан кызыл күзле көрән куян карап тора иде.* Ә.Гаффар. *Дөрес, аның рәсемнәрендәге куяннар кәҗә бәтиенә, ташбакалар кырмыска түмгәгенә охшашлы булып чыгалар.* Ф.Яруллин

2) *сөйл.* Йорт куяны, кролик. *Куян фермалары, каз-үрдәк фермалары, тавык фермалары оештыру да алга килеп басты.* Г.Ахунов. *Саматов дачасында тавыклар һәм куяннар белән мәшгуль булды.* К.Латыйп. *Куян асрауга тоткан чыгымнарны каплау бер хәер, зур керем алу турында хыялланып йөри [директор].* Р.Мулланурова

3) *күч. сөйл.* Куркак зат. *Колхозның айгыры бар иде. Шуны бер ир-ат та тыя алмый иде. Мал докторы Нурҗамал шуның муеныннан бер генә сыйпый, тегесе куян булып кала иде.* Т.Миңнуллин

4) *күч. сөйл.* Билетсыз пассажир. *Ул поездларның кондукторлары, кисәктән генә әллә кайдан пәйда булып, безне – «куяннарны» – куып төшерәләр иде.* Ә.Рәшит

5) *күч.* Нурны йотмый торган шома өслектән төшкән чагылыш, кояш, ут һ.б.дан кайтырылган яктылык нурлары. *Түшәмнәрдә «куян» бии, Кояш чакыра тышка.* М.Әгъләмов

**2.** *с. мәгъ.* Куян тиресеннән тегелгән. *Куян бүрек, төлке бүрек, кемнәр бүре бүректән; йолкып алып атты буран, кызыгып йөргән күптән.* М.Галиев. *«Милициягә?» – диде абзый, инде кулына кучкән куян бүреген туктаусыз изгәләп.* А.Хәлим. *[Фазыйр] Аның өстеннән тагын киндер белән тышланган зур куян бияләйләр кигән.* З.Зәйнуллин

◊ **Куян балтасы** Бәләкәй балта, кечкенә балта. **Куянга койрык кую** Кирәкмәгән эш белән шөгыльләнү. **Куян җан** Куркак кеше. – *Шулкадәр дә куян җан булырсың икән, – диде Фазылҗан абзый ---.* Р.Төхфәтуллин. **Куян җанлы** *к.* **куян җан**. **Куян йөрәк** *к.* **куян җан**. *Кызларга – куян йөрәкләргә – шул гына кирәк, алар, каравыл кычкырырга әзер булып, урыннарыннан ук торып бастылар.* А.Хәсәнов. *Кирәкми, потлары бер тиен ул куян йөрәкләрнең, бармыйм яннарына.* Г.Тавлин. **Куян йөрәкле** *к.* **куян җан**. *Беләсеңме, иптәш партийный секретарь, җир йөзендә йөз ел куян йөрәкле булып яшәгәнче, бер ел арслан йөрәкле булып яшәвең әйбәт.* Г.Ахунов. **Куян каны кебек** Бик куе чәй турында. *Куян каны кебек куе, кайнар чәй белән шул төстәге «Ак ләкләк» коньягын каплап, Сәет, үз хәл-әхвәле турында бәян итеп, сүзен «ярдәм сорап килдем, гафу ит» дип төгәлләде.* Т.Галиуллин. **Куян койрыгын тоттыру** Алдау. **Куян колагы калу** Бернәрсә дә калмау. **Куян күчтәнәче** Урманнан, кырдан яки берәр сәфәрдән кайткач, кечкенә балаларга бүләк дип бирелә торган, гадәттә алып киткән ашамлыкның кире алып кайткан бер өлеше. *Үзең берәр нәрсә уйлап тап инде шунда малайга куян күчтәнәченә.* В.Нуруллин. *Әтиләре каян да булса ераграк юлдан кайтса, алар йөгереп килеп итеген салдыралар да, аның күзенә карап, «куян күчтәнәче» көтеп торалар иде. Ул бер-ике сынык ипи була.* Р.Кәрами

**Куян шулпасының шулпасы** Бер нәрсәнең икенчесенә формасы белән генә якын килүе, эчтәлекләрендә уртаклык булмау. *Хуҗа Насретдин аны куян шулпасының шулпасы дигән.* Ә.Гаффар. *Открыткалардагы фотокүчермәләр куян шулпасының шулпасы гына ич.* Ш.Рәкыйпов

**КУЯ́Н БУЫНЫ** *и. бот. к.* **куян йоны**

**КУЯ́Н ЕЛЫ** *и.* Төрки халыкларда һәр елы бер аерым хайван исеме белән аталган борынгы унике еллык циклда дүртенче ел. *Куян елы килсә, суык була.* Сынамыш. *Бу – куян елының тормыш итү өчен бик үк җайлы булмаганлыгы турында сөйләмиме икән?* Ф.Сафиуллина

**КУЯ́Н ИРЕН** *и. мед.* Кешенең өске ирене икегә аерылып тору, читләре һәм урта өлеше кушылмаудан гыйбарәт тумыштан килгән җитешсезлек; *к.* **китек ирен**

**КУЯ́Н ЙОНЫ** *и. бот.* Кугачалар семьялыгыннан шуышма яки кыска тамырчалы, көрән яки яшькелт чәчәкле күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **ожика**

**КУЯ́Н КӘБЕСТӘСЕ** *и. бот.* Кантибәрчәләр семьялыгыннан калын, итләч сусыл яфраклы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **заячья капуста**. *Кәрләч белән бергә щи, шулай ук салат һәм винегрет әзерләү өчен, куян кәбестәсен дә файдаланырга мөмкин.* Робинзон эзләреннән. *Комсу туфраклы нарат урманнарында, коры куаклыкларда куян кәбестәсе очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Куян кәбестәсенең яфракларын төеп, башлы суганны уып, сөялгә ябу да файдалы.* Мәдәни җомга

**КУЯ́Н КӘРЕШКӘСЕ** *и. бот.* Күбәләкчәчәклеләр семьялыгыннан, терлек азыгы итеп кулланыла торган күпьеллык кузаклы баллы үсемлек; *русчасы:* **вика полевая**

**КУЯ́Н КОЛАГЫ** *и. бот.* Кыргый нәүрүзчәләр семьялыгыннан яфрагы өч аерчалы, сабак очына урнашкан ялгыз чәчәкле күпьеллык үләнчел үсемлек; урман какысы; *русчасы:* **дряква**. *Куян колагын элек-электән, күз тиюдән саклау өчен, йорт янына утыртканнар һәм, сизгерлекне уятырга, түшәк янына куйганнар.* Безнең гәҗит

**КУЯ́Н КУЗГАЛАГЫ** *и. бот.* Карабодайчалар семьялыгыннан өч йөрәкчек сыман яфраклы, урманда үсә торган үләнчел үсемлек; *русчасы:* **щавель туполистный**. *Куян кузгалагыннан әчкелтем салкынча эчемлекләр әзерләргә була.* Робинзон эзләреннән. *Куян кузгалагының сыек яшел төстә өч бүлемле яфраклары тукранбаш яфракларына охшыйлар.* Дөньяда ниләр бар

**КУЯ́Н КУЫШ** *и. этн.* Куышып уйнаудан гыйбарәт балалар уены. *Шәһәр балалары хәзер, теле чыккач та, үзе кебек татар мөселман балалары берлән бергәләшеп ат-ат, куян куыш уеннары уйный алмый.* Г.Исхакый. *Сүз ахырында шундый җырсыз-сүзсез татар халык уеннарыннан кайбер миңа мәгълүм булганнарының исемен бирәм. Менә алар: туп уйнау, куян куыш.* Н.Исәнбәт

**КУЯ́Н КҮЗЕ** *и. бот.* Астрачалар семьялыгыннан зур сары кәрзингә тупланган чәчәкле, тоташ читле яфраклы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **девясил германский**

**КУЯНЛЫ** *и. этн. к.* **куян куыш**. *Балачакта аның нәрсә икәнен белмичә, куянлы уйнаганда без дә шуны [санамышны] такылдап йөри идек.* Р.Ягъфәров

**КУЯ́Н СОЛЫСЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан себеркәч чәчәк төркемле, тар озын яфраклы чүп үләне

**КУЯН СӨЯК** *и. бот.* Күбәләкчәчәклеләр семьялыгыннан кузаклы үсемлек; *русчасы:* **гороховник**

**КУЯ́НСЫМАННАР** *җый. и. зоол.* Үсемлекләр белән туклана торган, үткен тешле җәнлекләрнең дүрт семьялыгын (шул исәптән чыелдык җәнлекләр һәм куяннарны) берләштергән имезүче хайваннар отряды. *Андый хайваннар (кимерүчеләр һәм куянсыманнар) азыкны кискеч тешләре белән кимереп өзәләр дә урт тешләре белән яхшылап чәйниләр.* Биология: хайваннар

**КУЯ́Н ТАЛЫ** *и. диал. бот.* Астрачалар семьялыгыннан, аксыл төстәге, көчле исле ачы үлән; исле әрем

**КУЯ́Н ТУБЫГЫ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан, сары чәчәкле, каурый сыман яфраклы үләнчел үсемлек, гәзнич; *русчасы*: **пастернак**. *Төрле урынга сибелгән юа, каз тәпие, куян тубыгы, балтырган, шома көпшә кебек тәмле үләннәр дөнья байлыгы булып күренә иде безгә.* М.Әмир. *Ашка бер-бер артлы гәрәнкә (брюква), кишер, сельдерей, куян тубыгы һәм иң соңыннан бәрәңге салырга [кирәк].* Серле календарь

**КУЯ́Н ТУКРАНБАШЫ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, зур чатыр чәчәк төркемле, баллы агулы үсемлек; *русчасы:* **вязель**

**КУЯ́НЧА** *рәв.* 1) Куян кебек. *Куянча сикерү*

2) *күч.* Куркып. *Берияләр илне имгәткәндә, Син куянча читкә шылмадың ---.* Х.Туфан

**КУЯНЧЫ** *и. сөйл.* 1) Йорт куяннарын үрчетү белән шөгыльләнүче кеше

2) Куян аулаучы. *Куянчыларның җавабы бер инде: «Әйе, аттык бер куянны».* Т.Миңнуллин

**КУЯНЧЫЛЫК** *и.* 1) Йорт куяннары үрчетү эше. *Куянчылык алтмышынчы елларда тагын бер тапкыр аваз биреп алды ---.* М.Мәһдиев

2) Йорт куяннары асрау белән шөгыльләнә торган хуҗалык тармагы. *Куянчылыкта эшләү*

**КҮӘС** *и. рус* Камыр әчетә торган савыт (гадәттә агачтан була). *Карчык --- күәс янына килде. Камыр да матур булып кабарган икән!* М.Шаһимәрдәнов. --- *[мине] күршеләргә коймак табасына, ипи саласы булса, күәс камырына кертәләр.* Г.Сабитов. *Кая барып сугылырга белмичә чоланга чыкты, аннан буш күәс күтәреп керде.* А.Гыйләҗев

◊ **Күәс төбе** Күәс төбендә ачыткы өчен калдырылган камыр. *Мөнә, Гөлҗамал абыстай, бу – хәер икмәге, күәс төбен сиңа дип атап әвәләгән идем.* М.Гали. **Күәс төбен кагу** Бөтен эч серен сөйләп бирү

**КҮӘ́С-КҮӘС** *с.* Күәс чиләге кадәр, күәс чиләге кебек зур. *Сыерлар шул ук, пуф та пуф кайталар, күәс-күәс җиленнәр як-якка чайкала.* А.Гыйләҗев

**КҮӘ́С ЧИЛӘГЕ** *и. к.* **күәс**. *Хатын күәс чиләгенең төбенә җылы су сала, ипи калагы диган хикмәтле агач калак белән электән күәс төбендә калган ачы камырны туглап җанландыра.* М.Мәһдиев

◊ **Күәс чиләге тулу** Бала туу вакыты җитү. *Ләкин табибларның Саимә янында озак кайнашырга мөмкинчелеге юк, икенче өстәлдәге Зәйтүнәнең, кем әйтмешли, күәс чиләге тулып ашкан иде.* Г.Галиева

**КҮБАВЫЗ** *и. зоол.* Имүчеләр классыннан паразит суалчан; *русчасы:* **многоуст**

**КҮБАЯК** *и. зоол.* Буынтыгаяклылардан гәүдәсе суалчанны хәтерләткән, күп аяклы бөҗәк; карышлавык; *русчасы:* **многоножка**

**КҮБАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Буынтыгаяклылар тибына керүче, озынча гәүдәләре буынтыкларга бүленгән бөҗәкләр. *[Буынтыгаяклыларда] буынтык саен диярлек пар аяк, барлыгы 170 кә җитә һәм күбрәк тә булырга мөмкин.* Зоология

**КҮБӘ** *и.* **1.** 1) Сәнәк белән бер күтәреп алырлык итеп әзерләп куелган печән яки салам өеме. *Алып чыккан күбәләрем сирәгәеп бара икән инде, шунда пөхтә генә таратылган рәтләр арасында утырып калган бер кочак печәнгә күз төште.* Р.Мөхәммәдиев. *Печән күбәләре, киртә агачлары, бүрәнәләр, хәтта буралар да актарылып-актарылып аккан ташкын кочагында калган.* Н.Әхмәдиев. *Без, хатын-кызлар, тырма белән җыеп, покосларны күбәгә салабыз.* М.Галиев

2) *күч.* Берәр чыганактан таралган бик көчле нур, очкын, ут һ.б. турында. *Шулчак янымда гына гөлт итеп ут күбәсе кабынып сүнә. Күбәнең бер очкыны минем күкрәгемне өтеп ала.* М.Кәрим

**2.** *с. мәгъ. диал.* Вак, пыскак. *Күбә яңгыр сибәләп тора.* И.Гази

**КҮБӘЙТҮ** *ф.* Берәр предметның санын, микъдарын арттыру, ишәйтү, күп итү. *Ул Мәскәүдән --- килгән телеграмманы, күбәйтеп басып, полкларга җибәрергә боерык бирде.* Ш.Рәкыйпов. *Радиодан көне-төне корал күбәйтү, ызгышлар, сугыш турында сөйлиләр.* М.Юныс. *Килешегез, алтынны яу белән түгел, сату-алу белән күбәйтү кулайрак.* Р.Зәйдулла

**Күбәйтә бару** Тора-бара арттыру, күбәйтү. *Бер елны да аның уңышы зарарланмады, кыярына шадра тап төшмәде, елдан-ел әмәлен күбәйтә барып, ул үз эшенең остасына әйләнде.* А.Гыйләҗев

**Күбәйтә бирү** Бернигә дә карамыйча күбәйтү

**Күбәйтә төшү** Тагын да беркадәр, бераз күбәйтү

**Күбәйтеп алу** Күбәйгән хәлгә китерү

**Күбәйтеп бетерү** Ахыргача, беткәнче күбәйтү

**Күбәйтеп кую** Алдан ук күбәйтү

**Күбәйтеп тору** Әледән-әле яки даими күбәйтү

**Күбәйтеп чыгу** Берсен дә калдырмыйча, барысын да, бөтенесен дә күбәйтү

**КҮБӘК** *и.* Чабагач сабы. *Чабагач күбәге, бозлы җиргә бәрелеп, ике җирдән дә өзгәләнде дә чыкты.* Г.Толымбай

**КҮБӘЛӘК** *и.* **1.** 1) Тәңкәканатлылар отрядыннан ике якта да төрле төстәге тузанчасыман матдә белән капланган канатлары булган бөҗәк. *Агач ботагыннан нәзек җеп сузып, кызу-кызу үрмәкүч төшеп килә. Хәзер ул күбәләкне эләктереп алачак.* М.Галиев. *Купшы күбәләкләр көннең-көн буена чәчәктән чәчәккә кунып, аның таҗчыкларының иң татлы суын – нектарын эчәләр.* Дөньяда ниләр бар. *Күбәләкләрнең шактый төрләре эңгер-меңгердә һәм төнлә оча. Болар – төнге күбәләкләр, мәсәлән, көяләр.* Биология

2) *куч. сөйл.* Бант рәвешендәге галстук. *Нәфис соры постаудан кофтаитәк киеп, ак якасына килешеп торган тасма күбәләк тагып килсә дә, кызыкай бөтән гимназистка, курсисткаларга охшап бетмәгән иде.* Т.Әйди. *Янәшәсендә үк көязләнеп басып торган, әледән-әле муенына таккан күбәләгән --- төзәтү белән мәшгуль юлдашына карап елмайды.* Р.Мөхәммәдиев

3) *куч. ирк.* **күбәләгем**. *Ул да, мине сагынганда, күбәләгем, түгәрәгем, асыл кошым, сандугачым, җырлап җибәрә микән?* Җыр. *– Я, синең исемең ничек? – Алмас! – диде малай, авызын тутырып, батыр гына. – Ә синеке, күбәләгем?* Ә.Еники

4) *куч.* Фахишә. *Майор дигән кеше --- Алинәне дә «күбәләк»ләрнең берсе дип уйлады бугай.* Х.Ширмән. *[Азат]: Аның белән тагын бер кыз да бар. [Энҗе]: Берәр төнге күбәләк булмасын тагын!* Х.Ибраһим

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күбәләк (*1.1) мәгъ.*) формасындагы. *Башында кыңгыр салган кара кәләпүш, өстендә, нәкъ Хикмәйнеке төсле, тройка костюм, катыргы якалы ак күлмәк, күбәләк галстук.* Г.Әпсәләмов

2) Йомшак, эре бөртекле (кар тур.). *Ул киткәндә, талпынып-талпынып күбәләк кар ява иде.* М.Кәрим

◊ **Күбәләк гомере** Нәрсәнең дә булса бик кыска вакытлы булуы турында. *Зөһрәгөл арыган, рухсыз тавыш белән: – Тиеш? – дип кайтарып сорады. – Ихтимал. Тик кызлар гомере күбәләк гомередәй кыска.* Т.Әйди. **Күбәләк күңел** Тиз гашыйк булучан. *Яшь йөрәк күп җилкенде, күбәләк күңел күп чәчәкләр тирәсендә очынды, ләкин Һаҗәр килде – шуның белән башкалар һәммәсе югалды.* Г.Ибраһимов

**КҮБӘЛӘ́К-КҮБӘЛӘК** *с. к.* **күбәләк 2.** (*2 мәгъ.*). *Игенчеләргә февраль үзе дә булыша: күбәләк-күбәләк тоташ кар ява, әйтерсең күк йөзе тишелгән.* К.Тәхау

**КҮБӘЛӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Күбәләк кортыннан, үсеп, күбәләккә әйләнү

2) Күбәләк рәвеше алу, күбәләк сыман булу. *Көн бераз җылыта төшкән, җил дә туктаган, карны да себертми, [кар] күбәләкләнеп кенә ява башлаган.* Х.Кәрим

**КҮБӘЛӘ́К ЧӘЧӘК** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, чәчәкләре күбәләккә охшаган үләнчел үсемлек; *русчасы:* **мотыльковый цветок**

**КҮБӘЛӘ́КЧӘЧӘКЛЕЛӘР** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, чәчәкләре күбәләккә охшаган үсемлекләр ассемьялыгы; еш кына аерым семьялык итеп карала; *русчасы*: **мотыльковые**. *Күбәләкчәчәклеләр арасында берьеллык һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, агач һәм куаклар бар.* Ботаника. *Күбәләкчәчәклеләр семьялыгына кергән барлык үсемлекләрнең дә җимеше – кузак.* Биология

**КҮБӘЛӘ́Ү** *ф.* Чабылган печәнне күбәләргә өю, сәнәк белән күтәреп алырлык итеп өеп-өеп кую. *Урман аланында киерелеп печән чабарсың, без малайлар белән печән әйләндерербез, күбәләрбез, чүмәлә куярбыз.* А.Гыйләҗев

**Күбәләп бару** Барысын да, берсе артыннан берсен, булган кадәресен күбәләү

**Күбәләп бетерү** Барысын да, бөтенесен дә, ахыргача, беткәнче күбәләү

**Күбәләп тору** Хәзер күбәләү; гел күбәләү

**Күбәләп чыгу** Һәрберсен берәмберәм, берсе артыннан берсен күбәләү

**Күбәли башлау** Күбәләргә керешү

**КҮБӘ́Ү** *рәв.* **1.** Күп булып. *Хәйдәр аларны кискен җаваплар белән кайтаргач, күбәү җыелып килеп, чигенүне сорадылар.* Ш.Усманов

**2.** *хәб. функ.* Күп, күп санда. *«Сез күбәү бит, матурым. Бөтенегез барыбер минем кочагыма сыймас. Ә гарем ачарга рөхсәт итмәсләр», – дигән иде ул.* Ф.Яруллин. *– Дөрес әйтәсең, – диде аңа Бөек Остаз. – Без күбәү. Тик без күзгә-башка күренмибез.* Ә.Гаффар. *Килеп тукталуы булды, аңардан халык агыла башлады. Этешми-төртешми генә чыгалар, әмма бик күбәүләр.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮБӘҮЛӘШЕП** *рәв.* Күп булып, күбәү булып. *Күбәүләшеп җыелу*

**КҮБӘЮ** *ф.* 1) Саны, микъдары яки күләме, зурлыгы ягыннан арту, ишәю. *Хәзер безнең дуслар күбәйде.* Ф.Яруллин. *Исеңдәме икән: сугыш елларында безнең якларда бүре күбәйде.* М.Юныс. *[Саматның] рәис булып сайлангач, эше шактый күбәйде ---.* Г.Галиева

2) *сөйл.* Көчәю; арту; зураю. *Аның өстенә көннән-көн һөҗүм вә сүз күбәя.* М.Гафури

**Күбәеп бару** Даими рәвештә күбәю. *Гимназиядә татар кызлары күзгә күренер дәрәҗәдә күбәеп баралар.* Ф.Әмирхан. *--- бозыклыклар хәзер тормышта шактый күбәеп бара.* Ф.Яруллин

**Күбәеп килү** Акрынлап күбәю. *Акчалы кешеләр күбәеп килә, кемдер бура ала, кемдер түбәлек шифер кайтарта.* Ф.Яруллин

**Күбәеп китү** Кинәт күбәю. *Боерык бирүчеләр артык күбәеп киткән очракта, бу хәлдән ярыйсы гына файдаланып та була.* М.Юныс. *– Гайнан, мин полковник Карбозов янына киттем. Таныш-белешләр күбәеп китте. Ярдәм сорамыйча булмас... – дип, майор җитез генә урыныннан купты.* М.Насыйбуллин. *Мактаучылар күбәеп китте: – Коеп куйган үзе!* Ә.Моталлапов

**Күбәя бару** Торган саен күбәю. *Шуның өчен --- алар арасында төрле авырулар күбәя бара иде.* Г.Исхакый. *Рәмзи үртәвендә дә күпмедер хаклык барын тойгач, табышмакның чишелү вариантлары күбәя баруын чамалады.* Т.Әйди. *Кеше ихтыяры белән тереклек барлыкка килә торган сулыклар да күбәя бара.* А.Муранов

**Күбәя башлау** Күбәю билгеләре сизелү. *Әти әйтә: «Хәзер партияне таратучылар күбәя башлады, Горбачёвтан башлап», – ди.* Р.Вәлиев.

*...Аннан соң әтинең эше күбәя башлады.* Х.Ширмән

**Күбәя тору** Аз-азлап, бертуктаусыз күбәю. *Серле затны күрүчеләр һаман күбәя тора.* А.Муранов

**Күбәя төшү** Беркадәр, бераз арту, күбәю. *Тавыш бирдем --- Илемнең көчкуәте күбәя төшсен өчен.* Ә.Ерикәй

**КҮБЕ** *и. к.* **күбесе**. *Иң күбе – бармак башы зурлыгында җир җиләкләре.* Г.Ибраһимов. *Үз гомеремдә читтә иң күбе алты кич кунган мин малай, ул кышның февралендә өч атна чит авылда, үз өемә кайтмыйча яшәдем.* М.Мәһдиев. *Иң күбе – ул сине кызганыр, ә Сәхиягә кызганучы кирәкме?* Ф.Яруллин

**КҮБЕК** I *и.* **1.** 1) Җил тәэсирендә дулкынланганда яисә ташкын булып акканда, су өстендә барлыкка килә торган һава куыклары. *Ә давыл бөтен пычракны, башка файдасыз нәрсәләрне астан өскә чыгарып ата, болгата. Өскә күбек калка.* Г.Ахунов. *[Сиваштагы] күбек буразнасы полкның барасы юлын кисеп тә чыкты, сугышчыларның аягына су бәрелә башлады.* Г.Бәширов. *Сыртларында ак күбекләр кайнатып, бер-бер артлы тәгәрәп килгән дулкыннар баржаларның бортларына бәрелә, палубаларга сикерә.* С.Сабиров

2) Берәр төрле сыеклыкны болгатканда яисә кайнатканда, күбекләнеп, өрелеп өскә чыккан җиңел масса. *Минем сыра күбеген өрә-өрә тәмләп эчкәнне бер читтә сабыр гына көтеп тордылар.* Ә.Еники. *Бер урында ак алъяпкычлы кыз кайнап утырган зур казан өстеннән күбек ала.* М.Әмир. *Монда авыз тутырып ашарга ипи җитми, булганы да саргылт күбек кебек бәрәкәтсез иде.* М.Маликова

3) Суда эреп, күбекләнгән сабын эремәсе. *Исле сабын үзенең ак, йомшак күбекләре белән Солтанның битләрен, муеннарын, колак эчләрен иркәләп юа.* Г.Ибраһимов

4) Авыр йөк тартудан яки кызу чабып йөрүдән атлардан бүленеп чыга торган, ак булып күпергән тир яки селәгәй. *...Канатлы атлар. Ярсып чаба ак күбектә...* Н.Арсланов. *Ат тиргә батты: камыт-ыңгырчак асларыннан ак күбекләр чыкты.* Х.Садри. *Ат җайдакны тыңларга теләмәде, авызлыгын чәйни-чәйни күбек чәчеп читкә сикерде.* Р.Мөхәммәдиев

5) Бик күп сөйләгәндә яки кайбер хроник авырулар вакытында кешенең авызыннан килә торган куыклы бүлентек. *– Әле син безнең авылларны алдарга тотындыңмы? – дип кычкырды ул, авызыннан күбекләр килеп.* Н.Измайлова. *Мин әйтәм, бетте баш, моның бумасы килде инде, дим... Авызына күбекләр чыгарган, үзе, бер күзен генә ачып, миңа карый.* А.Расих. *Аны [эпилепсияне], ихтимал, һәркайсыгызның күргәне бардыр: кеше егыла, аның тәне тартыша башлый, авызыннан күбек килә...* Серләр һәм могҗизалар

6) *куч.* Бик ак һәм матур булып күренгән нәрсә турында. *Ак күбеккә баткан чия бакчалары*

7) *куч.* Аумакай, башкалар сүзенә тиз бирелә торган, үз фикере булмаган, принципсыз кешеләр. *Җыелышта «күбекнең» төп өлешен өлкән буын ир-ат халкы тәшкил итте, иң усал-миһербансыз сүзләр шулар авызыннан чыкты.* Т.Галиуллин. *Халык дулкыны белән бергә, әлбәттә, күбек тә күтәрелеп, экстремизм да җанланып алды.* Ә.Рәшитов

**2.** *с. мәгъ.* Йомшак, күпереп торган. *Атылып-бәрелеп тамбурга чыгуыбыз булды, күзләребез чагылды: перрон ап-ак, беренче күбек кар төшкән.* И.Салахов

◊ **Күбеккә бату** Бик нык тирләү (ат тур.). *Күбеккә баткан җирән атларын чыбыркылап, кыргый тавыш белән сөрән салып, басу капкасыннан кораллы отряд килеп керде.* К.Нәҗми. *Күбеккә баткан иярле ике ат көтелгән хәбәрчеләрнең дә килеп җиткәнен белдереп тора иде.* Ш.Усманов. *Ак күбеккә баткан юргалар Карлы юлдан ярсып чабалар.* Р.Миңнуллин. **Күбеккә төшү** *к.* **күбеккә бату**. *Ак күбеккә төшкән атның урман юлыннан чабып килгәнен күреп, Мөнирә аның каршына чыкты.* Ф.Хөсни

**КҮБЕК** II *и.* Туглап күпертелгән йомырка агына шикәр оны кушып пешерелгән ашамлык. *Күбекне сүрән духовкада 1,5–2 сәгать пешерәләр.* Татар халык ашлары

**КҮБЕК** III *и. диал.* Күпертеп бәйләнгән озын чуклы ефәк шәл

**КҮБЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Күбек барлыкка килү; күбек хасил булу. *Шаулый буа, арыктан су бәргәләнеп түбәнгә төшә, мең нурлы тамчы булып чәчри, күбекләнә, кайный, ярсый.* А.Гыйләҗев. *[Йомырка агын] Машина яки кул белән 18–20 минут күбекләнгәнче күпертергә, аннары болгата-болгата җайлап кына шикәр комы һәм ванилин өстәргә.* Татар халык ашлары

2) Авыздан күбек бүлеп чыгару. *[Атларның] авызлары күбекләнгән, өсләрендәге тир яңа бераз ката башлаган, үзләре салмак кына атлыйлар.* Г.Ибраһимов. *Салкын җилле көн булуга карамастан, атлар бик нык тирләгән, авызлары күбекләнгән, өсләреннән пар күтәрелә.* А.Шамов. *Егетнең киеменә сыймаган корыч беләкләре хәрәкәтләнәләр, ирен читләре күбекләнә.* А.Гыйләҗев

3) Бик нык кайнарлату аркасында пар ясалу, кайнау (сыеклык тур.). *Самавырның суы кайнап, күбекләнеп тора*

**Күбекләнә төшү** Тагы да бераз күбекләнү

**Күбекләнеп алу** Кыска вакыт арасында күбекләнү

**Күбекләнеп бетү** Тулысынча күбекләнү, тәмам күбекләнү

**Күбекләнеп тору** Һәрвакыт күбекләнү; хәзерге вакытта күбекләнгән булу. *...Быжҗыр-быжҗыр күбекләнеп торган тирән су итек кунычын күмә башлый.* Ш.Маннур. *Тагы бер мәртәбә йотып алгач, күбекләнеп торган кымыз тулы стаканын читкәрәк куеп, --- урыныннан торды ул.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮБЕКЛЕ БӨҖӘКЛӘР** *и. биол.* Суыручы бөҗәкләр семьялыгыннан, озынлыгы 3–10 мм булган, үсемлек суты белән тукланучы көрән яки яшькелт төстәге бөҗәкләр. *Күбекле бөҗәкләр личинкалары үсемлекләрдә махсус бизләр бүлеп чыгарган күбекле лайла эчендә яши. --- Алар каен җилләге, иртә өлгерә торган кәбестәгә зарар китерә.* Биология

**КҮБЕКТАШ** *и.* Катып калган вулканик күбектән гыйбарәт тау токымы; пемза

**КҮБЕ́НГӘНЧЕ** *рәв. гади с.* Туйганчы, гарык булганчы. *Шулай да минем бу беренче килүем шактый уңышлы чыкты: ике көн яр буенда ятып, иртәкич күбенгәнче уха ашап, үзем белән өйгә дә бер өч кило балык алып кайттым.* Ә.Еники

**КҮБЕНҮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса су, дым тәэсиреннән кабарып күләме арту; бүртү. *Судагы бүрәнә күбенгән*

2) Күп ашаудан яки бүртә торган азык ашаудан эч күбү. *[Аш ашап] эч күбенә, ә чыгып берәр сәгать чаңгы шуугa Щукарь агай алашасы кебек шиңә дә кала иде.* Г.Гобәй. *Борчак ашап күбенү*

3) *күч.* Рәхәт тормышта, муллыкта, байлыкта яшәү. *Башкорт картлары Шибайны: «Бу килмешәк татар безнең башкорт каны белән күбенә», – дип, шелтәләп әйтүдән курыкмадылар.* Г.Ибраһимов. *Байлар эшче һәм ярлыларның каннарын эчә-эчә күбенеп, дөньяның асты өскә килгәч, --- мин кызыл сугышчыларның берсе булып киттем.* Г.Толымбай

**Күбенә башлау** Күбенергә тотыну

**Күбенә төшү** Тагы да бераз күбенү

**Күбенә язу** Чак күбенми калу. *Ашый-ашый күбенә яза, кесәләренә тутыра...* Татарстан яшьләре

**Күбенеп бетү** Тәмам күбенү

**Күбенеп яту** Күпмедер вакыт күбенгән хәлдә булып тору

**КҮБЕСЕ** *и.* Кемнәрнең яки нәрсәләрнең дә булса күп өлеше, күпчелеге. *Мостафин Өфенең, аның үз сүзе белән әйткәндә, «асыл затларын», «аксөякләрен» төсенә карап белгән, бик күбесенең исем-фамилияләрен һәм кушаматларын хәтерли торган булган.* М.Кәрим. *Русиядә булган урыс кенәзләре һәм алпавытларының, дворяннарының күбесе, крестьяннарыннан яки җир-суларыннан һәм дөньяда тоткан урынnaрыннан аерыласы килмичә чукынган мөселман мирзаларының бер өлеше икәнлекләре мәгълүм.* Р.Фәхретдинов. *Ә менә Мөдһиш Иван Казанны алганнан соң, мөселман мәчетләре урынында кирпеч өемнәре генә кала, күбесе исә махсус рәвештә җир белән тигезләнә.* Р.Әмирхан

**КҮБЕСЕ́НЧӘ** *рәв.* 1) Күбрәк, башлыча, нигездә; күп өлештә. *Бер генә нәрсә ачык: хәзер аларның язмышы күбесенчә Миңнегөлгә бәйле.* Р.Айзатуллин. *Ат караклары сукмагы күбесенчә Урал тавының Урта сырты аша узган.* З.Зәйнуллин

2) Күп вакытта, күп очракта. *Һәм ни өчен язучыларыбыз бүгенге көннең әхлакый эзләнүләрендә, күбесенчә, негатив якларны гына басым ясап күрсәтәләр?* А.Сункишев. *Наратбашлар күбесенчә дымлы әче туфраклы урыннарда үсә.* Ботаника. *Сазанак --- мәңге яшел вак куак, кайчакта биеклеге 1 м га җитә, әмма күбесенчә 20–30 см дан артмый.* Урман аптекасы

**КҮ́БИҖЕКЛЕ** *с. лингв.* Берничә иҗектән торган, берничә иҗектән ясалган. *Күбиҗекле сүзләр*

**КҮБРӘК** *рәв.* 1) *чаг. дәр. к.* **күп**. *Актүш, камчылар күбрәк төшкән саен, күбрәк ярсыды.* Г.Гобәй. *Безнең мөнәсәбәтләрне син бөтен өй эчебезгә карaганда да күбрәк беләсең.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Югыйсә ул вакытының күбрәк өлешен бөтенләй башка нәрсәләргә багышлый --- иде.* Т.Әйди

2) *к.* **күбесенчә**. *Югары Шырдан халкы күбрәк ямщик чабып, я читкә йөреп кәсепләнеп килгәннәр.* М.Гали. *Лиза сүзгә аз катыша, күбрәк тыңлап утыра иде.* Ф.Әмирхан

**КҮ́БУКЛАДЛЫ** *с. махс.* Берничә укладтан торган. *Күбукладлы экономика яшәгән шартларда, дәүләт промышленностеның вак товар крестьян хуҗалыгы белән сәүдә элемтәсе котылгысыз --- иде.* КПСС тарихы

**КҮ́БУРЫНЛЫ** *с.* 1) *мат.* Берничә цифрдан торган, берничә цифр билгесен үз эченә алган, берничә цифрдан гыйбарәт. *Күбурынлы саннарны кушуның разрядлап эшләнгәнен хәтердә тотарга кирәк.* Арифметика

2) Утыра торган урыннары күп булган. *Күбурынлы самолёт*

**КҮБҮ** *ф. к.* **күбенү** (*2, 3 мәгъ.*). *Ләкин ул алып кайткан шешәләрдәге сыекчаны суыргач, баланың эче еш күбеп авырта иде.* М.Маликова. *– Минемчә, алар теге яки бу гарнизонда үзләренең йогынтысы хөкем сөргән зона булдырырга тырышалар, шулаймы, Мозаев? – Әмма чечен дәшмәде, күпкән аскы иренен генә ялаштырды ---.* С.Шәрипов. *Гел эчәсем килмәсә дә, бер чәшке ни җылы, ни салкын кайнаган су эчтем. Эч күпсә күбә инде, анысына гына түзәрмен.* Р.Кәрами

**Күбә бару** Торган саен ныграк күбү. *Бармагымнан йөзекне --- чыгара алмыйча иза чиктем. --- бармагым күбеп, йөзегем кысыла гына бара иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Күбә башлау** Күбү билгеләре сизелү

**Күбеп тору** Күпкән хәлдә булу; күпкән булып күренү. *Кичә кич Фәритe шундый суырып үпкән: иреннәре бүген дә матур гына күбеп тора.* Г.Мөхәммәтшин

**Күбеп чыгу** Бик нык күбү, күпкән урыннар барлыкка килү. *Җиһангир тиз генә күлмәген салдырырга булышты һәм, Ахунның тәне аннан да, моннан да күбеп чыкканын күргәч, шаклар катты.* Н.Хәсәнов. *Ике араны [шахтада] берничә рәт әйләнгәнче, минем баш берничә җирдән күбеп чыкты.* М.Гафури. *Аның маңгаена тирдән чыланган бөдрәләре ябышкан, тешләгәннән иреннәре күбеп чыккан иде.* М.Маликова

**КҮ́БҮЛЧӘМЛЕ** *с. физ.* Үлчәме берничә булган. *Күбүлчәмле төсле сурәт*

**КҮ́БҮЛЧӘНЕШЛЕ** *с. физ. к.* **күбүлчәмле**

**КҮГАГАЧ** *и. бот.* Каенчалар семьялыгыннан, дымлы, известьле туфракта үсә торган агачлар, сирәк кенә куаклар ыругы; киң таралган төрләре гади күгагач, көнчыгыш күгагачы; *русчасы:* **граб**. *Күгагачның куе ябалдашы баш очымда җилбер-җилбер килә иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Катнаш урманнарда корычагач (ясень), күгагач (граб) үсә.* Дөнья кисәкләре географиясе. *Европаның көнбатышында климат йомшаграк, һәм биредә имәнле каенлыклар, имәнле күгагач (граб) урманнары һәм бук (кара каен) урманнары өстенлек итә.* Башлангыч география курсы

**КҮГӘЛ** *и. зоол.* Кыр үрдәгенең бер төре. *Караңгы иде, тик дөньяга таралган тымызык күлдә күгәлләр, суналар гына чумышып уйныйлар, алтын канатлы бөркет күтәрелгәнче шаярышып калырга телиләр иде.* Р.Зәйдулла

**КҮГӘН** I *и.* Ишек, капка һ.б.ш.ларны ачып ябу өчен, ыргакка яки шарнирга утыртып эшләнгән металл планкадан гыйбарәт җайланма. *Такта ишекнең астагы күгәне ватылып чыкты.* М.Мәһдиев. *Чыннан да, бу изелеп беткән бер иске күн чемодан иде. Капкачы ачык, бер генә күгәндә эленеп тора.* Ф.Галиев. *--- капка үзеннән-үзе ачылып китте. Аның баганасы күгән ягына ауган, ябылган хәлдә терәү белән генә тотып була икән.* Ф.Садриев

**КҮГӘН** II *и. бот.* 1) Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан ашарга яраклы күгелҗем җимешләр бирә торган чәнечкеле куак; дала әлүчәсе, кыргый слива; *русчасы*: **тёрн**. *Күгән җиләк чәчәк ата, Акка күмеп тирәкне.* М.Маликова. *Безнең көнчыгыш районнарда дала чиясеннән башка тагын сирәк кенә дала сливасы яки күгән очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Агуланганда яки ашказаны эшләмәгәндә, 50 грамм күгән агачы (терновник) чәчәген 1 литр суга салып кайнаталар һәм шуны чәй урынына эчәләр.* Ватаным Татарстан

2) Шул куакның җимеше. *Монда кызыл карлыган, күгән, күк җиләк, нарат җиләге, шикша үсә ---.* А.Мифтахетдинов

**КҮГӘНӘ** *и. диал. к.* **күгән** II. *Алмагач, чия, күгәнә чәчәкләре арасыннан саркып чыккан төтен Кәрәмнең борынын кытыклады.* Ф.Садриев

**КҮГӘНЛЕК** *и.* Күгән күп үскән урын, күгән куаклыклары. *Әрәмә читендәге чиялек белән күгәнлеккә дә көтү керттеләр.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮГӘРЕК** *и.* **1.** 1) Тиешле дымлылык һәм температура булганда органик матдәләрдә һәм предметларда барлыкка килгән соргылт күк яки саргылт соры төсле кунык. *Вареньеда, бозыла башлаган алма яки апельсиндагы күгелҗем-яшел төстәге күгәрек әләсе – пенициллның споралар барлыкка килү стадиясе ул.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Күгәрекләр дә гөмбәләргә керә. Аларның кайберләре шулкадәр кечкенәләр, шуңа күрә микроскоп аша карап кына күрергә була.* Ботаника

2) Тәндә бәрелүдән, сугылудан һ.б.ш. механик тәэсирләрдән күгәреп чыккан урын. *Хатынның ире алдында бернинди гаебе булмаса да, күз төбендәге күгәрекләр яңарып кына тора.* Мәгърифәт

3) *диал.* Тутык

4) *күч.* Тормышта борчыган, комачаулаган, туйдырган нәрсәләр. *Хәзер пролетариат, халыкның алдынгы көрәшчесе буларак, үзенең оешмасын ныгытырга, интеллигентлар оппортунизмының һәртөрле күгәреген үзенең өстеннән кырып ташларга --- тиеш.* В.Ленин

**2.** *с. мәгъ.* Күк төсле. *Илсөяр --- портретның аскы өлешендә ниндидер күгәрек таплар барлыкка килгәнлеген күрде.* Ф.Яруллин. *Арырак, камышлар эчендә, күгәрек саз суы күренә иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮГӘРЕК ГӨМБӘ** *и. биол. к.* **күгәрек 1.** (*1 мәгъ.*). *Ашамлыкларда һәм туфракта күгәрек гөмбәләрнең башка төрләре дә үсә.* Биология. *Чималдагы микроорганизмнар, бигрәк тә күгәрек гөмбәчекләре саклаалар һәм дым белән җылылык тәэсире астында тиз үрчи башлыйлар.* Урман аптекасы

**КҮГӘРЕНҮ** *ф.* 1) Төрле яки бөтен җире күк төскә керү, күк төс алу; күгәрү (тән тур.). *Аның кырынмаган чырае сулып җыерчыкланган, ираннәре күгәренгән иде. Вакытсыз картайган иде балакай...* М.Маликова

2) Ачуланудан, нәфрәтләнүдән һ.б.ш. хисләрдән бит төсе нык үзгәрү, бозылу. *Тегеләр, ачудан күгәренеп, бердәм рәвештә Хәйретдин агайны тетеп ташларга җыенганнар иде бугай ---.* А.Гыйләҗев

**Күгәренеп бетү** Тулысынча, бөтенләй күгәренү

**Күгәренеп китү** Кинәт күгәренү. *Күгәренеп китте Гөлсем апа, куллары калтыранды.* Г.Гобәй

**Күгәренеп чыгу** Тулысынча күгәренү. *Мидхәт кулындагы чиләкне күрүгә, аның сирәк керфекле күксел күзләре зур булып ачылды, йөзе күгәренеп чыкты.* М.Маликова

**КҮГӘРҮ** *ф.* 1) Күк төс алу, күк төскә керү. *Мин кат-кат башымны селектем: «Кирәкми, кирәкми», – дидем, күгәргән иреннәремне чак тибрәтеп.* Ә.Еники. *Яңа ел алдыннан авылга Әлфред килде, аның инде күгәргән, тырналган урыннары беткән, ул тәмам элекке хәленә кайткан иде.* Ф.Яруллин. *--- абыйсы, йөгереп барып, сандыкны ачып карады. Карады да катып калды. Аның йөзе бер агарды, бер күгәрде.* Н.Әхмәдиев

2) Дымлылыктан, җылыдан һ.б.ш. сәбәпләрдән нәрсәдә дә булса күгәрек барлыкка килү. *Завод кибетендә ите – сөрсегән, бәрәңгесе – өшегән, оны күгәргән була.* Г.Әпсәләмов. *Алар полиэтилен капчыкка күгәргән арышны да, бодайны да тутыра барганнар иде.* Ф.Садриев. *--- ачлыктан --- нибары ике кеше вафат булган. Алары да, әйтелгән сүзгә колак салмыйча, күгәргән башак онын кулланудан килеп чыккан.* Г.Сәгыйров

3) *диал.* Тутыгу. *Эретеп ябыштырып эшләнгән металл чардуган. Тимерләре инде күгәргән.* М.Мәһдиев. *Зыятдин карт тал башындагы каргалар карсылдашуын шомланып тыңлады, яргыч ишеген шыгырдатып япты, сушилканың күгәргән йозагын тотып карады.* Р.Вәлиев. *Алтын дип йөргәнем бакыр икән. Күгәргән бакыр!* М.Насыйбуллин

4) *күч.* Тормыштан артта калу, илкөн хәлләреннән хәбәрдар булмау. *Талантлы һәм перспективалы спортсменның Язкилдедә күгәреп ятырга калуына һич тә ышанасы килмәде аның!* А.Гыйләҗев

5) *күч. сөйл.* Ваемсызлану, рухи ярлылану. *Мондый бөдрә язларда кемнең генә йөрәге дәртләнмәс икән. Нигез ташы белән бергә күгәреп каткан, мүкләнгән йөрәкләр генә дәртләнмәсә дәртләнмәсләр.* А.Шамов. *[Карт солдат:] Ачлы-туклы салкын окопларда ята-ята, безнең йөрәкләргә йон үсеп, күгәреп бетте инде.* М.Гали

◊ **Күгәргән калай** Булдыксыз, кыюсыз, пешмәгән кешегә карата әйтелә. *Күгәргән калай түгеллегемне расларга кирәк иде. Киттем җырчылар әзерли торган җиргә.* Ф.Яруллин. *Аларны күрү Нәҗип ише күгәргән калайга түгел, Вафа Сафич кебек ышанычлы затка да насыйп булмаячак.* А.Гыйләҗев.

**Күгәреп беткән** Карлыккан (тавыш тур.). *Озын йонлы карт этләр үзләренең күгәреп беткән тавышлары белән өрергә тотындылар.* С.Җәләл

**Күгәрә бару** Торган саен ныграк, күбрәк күгәрү

**Күгәрә башлау** Аз гына күгәрү. *Фураж да, солы да юк икән атларга, күгәрә башлаган салам белән җан саклап торалар икән бичаралар.* А.Гыйләҗев

**Күгәрә төшү** Беркадәр, бераз күгәрү. *[Бай:] Монда бер кибетчедән күгәрә төшкән он алган идек, шуны сезгә җибәрдек.* Ш.Мөхәммәдев

**Күгәреп бару** Әкренләп күгәрү

**Күгәреп бетү** Тулысынча, бөтенләй күгәрү. *Авыруның уч төпләре канап, күгәреп беткән ---.* Ф.Садриев. *Тимерчыбык чыдамас. Күгәреп беткәндер инде ул.* Р.Вәлиев. --- *Туктар, сәнәгенә кадалудан куркып, тырмаша-тырмаша печән арасыннан чыкканда, баш түбәсенә шалт итеп күгәреп беткән калай чәйнек килеп төште.* Х.Ибраһим

**Күгәреп калу** Ниндидер бер эш, сәбәптән күгәрү, күгәргән хәлгә килү. *...Зәнфирә юри үпкәләгән булып читкә атлады, Ирек аның беләгеннән тотты. – Җибәр, авырттырасың, беркөнне дә күгәреп калган.* Ф.Садриев

**Күгәреп китү** Тиз арада яки кинәт кенә күгәрү. *Юк шул, гафу итә алмый аның улыннан ун яшькә олы булуын. Шуны исенә төшерсә, агу эчкәндәй, чырае сытылып, бер агарып, бер күгәреп китә.* Г.Якупова

**Күгәреп тору** Күгәргән булып күренү. *Ахрысы, сакал-мыек бик күе үсмәкчедер, нык кырылса да, [Шаһбазның] яңаклары, мыек урыннары бераз күгәреп торалар.* Г.Ибраһимов. *Аның яртылаш чал төшкән чәчләре, җыерчыкланып, күгәребрәк торган күз төпләре, маңгаендагы сырлар күп борчулар кичергәнен, җитәрлек ял күрмәгәнен әйтеп тора иде.* З.Фәйзуллин

**Күгәреп чыгу** *к.* **күгәреп калу**. *Ул һәммәсен аңлады, бәлки әле артыгын да уйлагандыр. Юка иреннәре күгәреп чыкты, йөзенә көл төсе керде, күз бәбәкләре кара бәрхет төсен алды.* М.Маликова. *[Ир кешенең] күпергән өске ирененнән кан саркый, уң күз төбе уч төбе кадәр күгәреп чыккан.* Ф.Галиев. *Сугыш алдыннан гына салып кергән яңа нарат йортның почмаклары да дымланып күгәреп чыккан әнә.* Г.Әдһәм

**Күгәреп яту** Озак вакытлар дәвамында күгәргән хәлдә тору. *Анда тик күгәреп яткан диңгез шикелле сахра гына күренә.* Г.Тукай

**КҮГӘРЧЕН** *и.* 1) Күгәрченсыманнар отрядыннан, дөньяның барлык җирләрендә диярлек таралган, гадәттә, соргылт күк яки ак төстәге кош. *Хәзергә тынып торсалар да, өй түбәләрендә, кәрниздәге ояларында – күгәрченнәр. Алар иртәгә яңадан гөрләшә башлар.*Ә.Баян. *Айлар, еллар үтте, --- яланнарны ягы-ягы белән сарут басты, хәтта, авылда күгәрченнәр кимеп, каргалар ишәеп киттеләр.* Ә.Еники. *Хатын-кыз, ду кубып, күгәрчен балалары сыман, аның тирәсендә бөтерелә башлый.* Р.Вәлиев

2) **күгәрченем**, **күгәрченкәем** *күч. ирк.* Күбесенчә хатын-кызларга иркәләп әйтү сүзе: «сөеклем», «кадерлем» мәгънәсендә. *– Бу – минем сөекле хатыным Эльзаны көтә, – дип күрсәтте Гата бизәлгән караватны. – Шул күгәрченем кайтканчы, Гата абыең идәндә шинель җәеп йоклаячак.* М.Мәһдиев. *Тәмәке тартырга чыккан идем, официантка читкәрәк әйдәде. Харап буласың, күгәрченкәем, бәйләнмә шул проституткага, дигән була.* С.Шәрипов. *Машина --- иркен ишегалдына керде, милиционерлар, төшеп, кызлар утырган ишекне ачтылар. – Я, күгәрченкәйләр, төшегез, килеп җиттек, – диде аларны озата килгәне.* Х.Ширмән

◊ **Күгәрченнәр кебек** Бик дус яшәү, бик тату (яшәү). *[Гайнулланың] унөч ел бергә күгәрчен кебек гөрләшеп гомер иткән Саҗидәсен күрәсе килде.* А.Әхмәт. **Күгәрченнәр кебек гөрләшеп** *к.* **күгәрченнәр кебек**. *Ул бит Әскәй кырларында иген игеп, мал-туар асрап, гаилә корып, хатыны, балачагалары белән күгәрчендәй гөрләшеп яшисе кеше иде.* Н.Әхмәдиев. **Күгәрчен кебек (күгәрчендәй) гөрләү** Җай гына, бик ягымлы итеп сөйләү. *Староста гаҗәеп чибәр, һәркем белән күгәрчендәй гөрләп сөйләшә ---.* Ф.Садриев. *Торалар болар икесе шулай сөйләшеп, елмаешалар, күгәрчен кебек гөрләшәләр.* Ф.Галиев. **Күгәрчен сөте генә булмау** Җитешлекне, муллыкны, байлыкны яки табынның бик бай әзерләнгәнлеген белдергәндә кулланыла. *Өч-дүрт җирдә базар, аннары Ага базар үзе ни тора. Анда күгәрчен сөте генә булмаса булмыйдыр.* М.Хәбибуллин. **Күгәрчен сөте дә булу** *к.* **күгәрчен сөте генә булмау**. *Аның чемоданында, хет ышан, хет ышанма, валлаһи дип әйтәм, күгәрчен сөте дә булгандыр.* Г.Мөхәммәтшин. **Күгәрчен теле кадәр** Зурлыгы, күләме, үлчәме бик кечкенә булган. *...Үтте бер атна, үтте өч атна, --- әмма аңардан күгәрчен теле кадәр дә хат кисәге килмәде ---.* Э.Касыймов

**КҮГӘРЧЕ́Н БҮРЕГЕ** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан ачык төстәге эре чәчәкләре куышлыгына чук яки башаксыман чәчәкләре урнашкан берьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **марьянник**

**КҮГӘРЧЕ́Н КЕТӘГЕ** *и.* 1) Өй яки сарай түбәсендә, чарлагында күгәрченнәр өчен ясала торган кетәк, оя

2) *күч.* Бик кечкенә бина. *Укыган чагымда, ул шыксыз бинаны күгәрчен кетәге дип кенә йөри идем.* Р.-Н.Гүнтәкин

3) *күч. сөйл.* Театрда иң югарыдагы ярус

**КҮГӘРЧЕ́Н КОШЛАР** *и. зоол. күпл.* Күгәрченсыманнар отрядына караган, кыска муенлы, йомшак мамыклы, озын очлы канатлы кошларның бер семьялыгы; *русчасы:* **голубиные**

**КҮГӘРЧЕ́Н КҮЗЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан урманнарда, болын, сазлык, далаларда чүп үләне буларак очрый, кечкенә генә күк чәчәкләр ата торган үләнчел үсемлек; гөлкәй чәчәк; *русчасы:* **незабудка**. *Язның иртә чәчәкләрен казаяк, энҗе чәчәк, тузганак, күгәрчен күзе алыштырды.* К.Тәхау. *Үләнчел үсемлекләр дә аз түгел, монда казаяклар, күгәрчен күзе, яраннар һәм башка төрле үсемлекләр үсә.* Биология. *Бик матур поляр мәкләре, күгәрчен күзе, алтын туй үләне, күкчәчәкләр төньяктагы шәһәр һәм посёлок бакчаларын бизиләр.* Ботаника

**КҮГӘРЧЕ́Н СӨТЕ** *и.* 1) *бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, күк яки ал чәчәк ата торган үсемлек; испәрәк; *русчасы:* **живокость**; **шпорник**

2) *күч. сөйл. сир.* Аракы, спиртлы эчемлек. --- *Мөбәрәкша карт --- астан бер шешә сузды. – Моның нәрсәсен яшереп торасың инде, төбендә генә калган лабаса! – диде Мәүлия. – Күгәрчен сөте аз булганга кадерле ул, җитмәгән тагын! – диде карт.* Ә.Гаффар

3) *күч. сөйл.* Бик сирәк очрый торган әйбер турында. *Анда Сорочига кердем мин кайтышлый, җылан мөгезе белән күгәрчен сөте дә табарга була.* М.Мәһдиев. *– Нәрсә кирәк чибәр ханымга? – диде ул четердәп ---. – Күгәрчен сөте дә табып бирә алам.* Р.Зәйдулла

**КҮГӘРЧЕНСЫМАННАР** *и. зоол. күпл.* Үсемлекләр белән туклана торган, күбесенчә ачык төстәге мамыклы һәм шадра күгәрченнәр асотрядына кергән кошлар классының бер отряды; *русчасы:* **голубеобразные**

**КҮГӘРЧЕ́Н ТӘПИЕ** *и. бот.* Канәфер чәчәге төре; *русчасы:* **гвоздика Андржеевского**

**КҮГӘРЧЕНЧЕ** *и.* Күгәрченнәр асраучы кеше

**КҮГЕЛ** *с. диал.* Караҗиләк. *Аш ашалып беткәч, тагы күгел сыман каралып тора торган кара җиләктән ясаган кесәл күтәреп кайтты.* Г.Исхакый

**КҮГЕЛҖЕМ** *с.* 1) Беркадәр күк, көлсу күк. *Шушы биеклек өстеннән кайсы якка гына карасаң да, җәелеп яткан аксыл иген кырлары, яшел үзәннәр, күгелҗем урманнар --- күренә иде.* Ә.Еники. *Иртән торганда, йөзе талчыккан, күз төпләренә күгелҗем күләгәләр яткан иде.* С.Шәмси. *Күпердән өстәрәк Агыйделгә кушылган пычрак байтак арпаны күгелҗем итеп, тонык ... туңдырмый ята икән.* С.Шәрипов

2) Кайбер зоологик һәм ботаник терминнарның состав кисәге. *Күгелҗем суүсемнәр. Күгелҗем акчарлак*

3) Башка бер төскә берникадәр күк төсмер кушылуын белдерә. *Харис аның плащ җиңеннән тырпаеп чыккан кулларына карады да имәнеп китте: йодрыклары күгелҗем кызыл тукмак кебек, тырнаксыз бармаклары кәкрәеп каткан.* М.Маликова. --- *Ибрай Зәкуанов сарык суйган, аны лапас өрлегенә бәйләнгән тияккә асып тунаган, күгелҗем миләүшә төсендәге эчәкләрен озынча тагаракка савып төшергән ---.* Ә.Гаффар. *Тәбәнәк кенә, каратутлы какча йөзле бу кешенең күз төпләренә, арганлык галәмәте булып, күгелҗем сары күләгәләр яткан ---.* А.Гыйләҗев

**КҮГЕЛҖЕМЛӘНҮ** *ф.* 1) Күгелҗем төскә керү, күгелҗем төс алу. --- *врач: «Кызым, иң авыр кайгы көтә сине. Әниеңнең йөзе күгелҗемләнде, җир тарта аны», – дигән иде.* К.Тимбикова. *Аның бите-йөзе бурлаттай кызарган, муен тамырлары исә күгелҗемләнеп бүртеп чыккан иде.* Э.Касыймов. *Антонина Андреевнаның йөзе бер күгелҗемләнеп кызарды, бер көлсу төскә керде ---.* Г.Галиев

2) Күгелҗемләнеп күренү. *Чирәм буйлап күгелҗемләнгән самавыр төтеннәре дә хәзер күренми.* К.Нәҗми. *Машина, күгелҗемләнеп, каракучкылланып яткан Алка күлне урап, үзәк усадьбага керде.* И.Салахов

**Күгелҗемләнә башлау** Аз гына күгелҗемләнү

**Күгелҗемләнә бару** Торган саен ныграк күгелҗемләнү

**Күгелҗемләнә төшү** Беркадәр, бераз күгелҗемләнү

**Күгелҗемләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча күгелҗемләнү

**Күгелҗемләнеп калу** Нindидер сәбәпләр аркасында күгелҗемләнү. *Мәхмүтнең --- йөзе дә күгелҗемләнеп калган.* К.Тимбикова. *Инә, җеп белән булашкан арада, егеткә күз төшереп алам, ул отыры агара бара, --- күгелҗемләнеп калган иреннәре дерелдәп тора.* Г.Галиев

**Күгелҗемләнеп китү** Кинәт күгелҗемләнү. *Ерактагы кара урман, ничектер, күгелҗемләнеп, яшәреп китте.* Г.Гобәй

**Күгелҗемләнеп тору** Күгелҗемләнгән хәлдә булу; күгелҗем булып күренү. *– Әнә теге полосадан, – дип, еракта күгелҗемләнеп торган агачлыкка ымлады Вәлишин.* М.Маликова. *Якында гына биек Кавказ таулары күгелҗемләнеп тора.* Ә.Галиев. *Фәридәнең --- җепсел кан тамырлары исә үтә күренмәле нәфис тиресе астыннан күгелҗемләнеп бүртеп торалар иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮГЕЛҖЕМ УРМАН КҮГӘРЧЕНЕ** *и. зоол.* Күгәрченсыманнар отрядының күгәрчен кошлар семьялыгыннан, күк күгәрченгә охшаган, кыска муенлы, тыгыз тәнле, томшыгы ак яки саргылт, томшык төбе балавызсыман йомшак тиреле, озын очлы канатлы кош; *русчасы:* **клинтух**

**КҮГЕЛҖЕМ УТ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан, сабагы буйбуй эзле, юан һәм ботаклы, биеклеге 2 м га җитә торган күпьеллык үсемлек; күгелҗем үлән; *русчасы:* **лазурник**

**КҮҖӘ** *и.* Киптерелгән бодайны киледә төеп яисә башка юл белән ваклап, казанда яки чуенда пешерелгән сыек ботка. *Катык, әйрән, эремчек, күҗә белән төрле-төрле савытлар, зур-зур казаннар шунда ук урын алдылар.* Г.Ибраһимов

**КҮЗ** *и.* 1) Күрү әгъзасы. *Кояш саргайды, --- тән кычыта, аяклар сызлый, карт-корының күзе эчкә батты.* М.Мәһдиев. *Баканың күзләре килбәтсез булып калкып тора, сулыш алганда тамак астындагы тиресе сулкылдый.* М.Юныс. *Күрән күзен кысып, карт ерактагы урманга карап тора башлады.* Ә.Гаффар

2) Күрү сәләте. *Мактанып әйтүем түгел, әмма минем бу мәсьәләдә күзем үткер, шуңа күрә башта ук чамалап алдым* ---. Ф.Галиев. *Ата белән ул акрын гына сәүдә рәтләре арасыннан атлыйлар. Күзләре үткен, колаклары сизгер.* Ф.Латыйфи. *Юк-барны уйлама син, Биктимер энем. Күз юк дип, кул салындырып утырып булмый. Сукыр Суфыйны гына исеңә төшер.* З.Зәйнуллин

3) Күз карашы. *Вася гармун каешларын рәтләп «заигрыш» бирде дә, күзләрен читкә борып, клуб эченә моң сипте.* М.Мәһдиев. *Самат кызларга шоколадларын, Зәйтүнәгә бүләк яулыгын бирде. Ә үзенең күзләре гел Аниядә иде.* Г.Галиева. *Як-ягыма каранып, гадәттәгечә, Гөлнәзирәне эзләдем. Күз карашларыбыз очрашкач, ул ирексездән елмаеп куйды.* Х.Ибраһим

4) *сөйл.* Икмәкнең, сырның һ.б.ш.ларның киселгән җирендә күренеп торган вак кына тишекләр, күзәнәкләр. *Тәлинкәдә – кояш, Тастымалда – икмәк, Телем күзләренә нур тулган.* Р.Фәйзуллин

5) Оек, бияләй һ.б.ш. бәйләгән нәрсәләрдә бәйләмнең җептән гыйбарәт элмәге. *Мамык шәл инде тузган, юкарып беткән, күзе киткән урыннары да шактый күренә.* Г.Әдһәм. *Табан түбәндәгечә бәйләнә: 2 кырыйда да 26 шар күзне калдырырга, уң якта 10 күзне уңнан бәйләргә дә 11нчесен икене бергә уң белән алырга.* Сөембикә. *Башлыкны бәйли башлаганда 70 күз җыябыз.* Ирек мәйданы

6) Буйлык (буй җепләр) үремендә бер төен (туку станында). *Сул кулда кылыч шуа, уң кулда соса йөри. Хатыннарның һәр сүзен, җәтмәнең һәр күзен җөпләп, төеннәр төйнәлеп бара.* Ә.Гаффар

7) Энәнең җеп саплау тишеге. *Энә күзе*

8) Кул тегермәненең өске ташында ашлык сала торган тишек. *Гомре тегермән тарткан, күзенә [бөртек] сала алмаган.* Әйтем

9) Нинди дә булса әйберләрдәге махсус кечкенә тишек. *Ачкыч күзе. Төймә күзе*

10) Ишеккә беркетелгән җайланма; **күзчек** (*2 мәгъ.*). *Дагалы итекләре белән таш идәннән шак-шок басып килгән берәү ул утырган камера ишеге төбендә кинәт туктап калды. – Әй син! – дип, үз-үзен белештермичә кычкырып җибәрде Мирсәет һәм күз тишеккә бармагын төбәде.* Р.Мөхәммәдиев. *Рәнис ---, урталай бөкләнгән хатны кулына тоткан килеш, ишектәге күзгә текәлде һәм җиңел сулап куйды, әлегә Хәмзә үзе генә килгән иде.* Җ.Дәрзаман. *[Надзиратель] Кеше-кара күренмиме дигәндәй, як-ягына күз сала. Аннары янә ишек күзенә каплана.* Н.Хәсәнов

11) *сөйл.* Тәрәзә өлгесе. *Әбелкарәмнәр йортының күзләре йомык.* М.Юныс. *[Сыйныф бүлмәсенә] идән җәйгәннәр дә, тәрәзәләрен киңәйтә төшеп, берничә күз пыяла куйганнар.* Р.-Н.Гүнтәкин

12) *сөйл. к.* **күзчә** (*2 мәгъ.*). Бәрәңге күзе // Бәрәңгенең күзчәләрен кисеп алып әзерләнгән орлык. *Аннары бәрәңге күзләре дә хәзерләргә кирәк.* Социалистик Татарстан

13) *сөйл. иск.* Карта уенында картадагы билгеләрнең оту өчен кирәк булган саны. *Кайбер солдатлар күзенә бер тиен генә салып уйнасалар да, бер сәгатьтә 75 тиеннәрен калдырып, читкә китеп утырдылар.* М.Гали

14) *тарт. форм.* Берәр нәрсәнең нәкъ уртасы. *Аяк астындагы язгы күлләвекләрнең күзенә тояк белән басып, су чәчрәтеп, теркелдәп кенә кайтабыз шулай.* Р.Низамиев. *Конвойдагы солдатлар, итекләре белән суның күзенә басып, чәпелдәтеп атлап чыктылар.* М.Кәрим. *Ходай кичерсен, көн күзендә чишмәмә килдемдер.* Н.Гыйматдинова

15) Суның туңып өлгермәгән урыны яки боз эреп су өсте ачылган урын. *Күлләр күзе күптән томаланган, Хәбәр алдым искән җилләрдән.* Б.Сөләйманов. *Җылы якларга китәргә ашыкмаган кыр үрдәкләре шунда – елга күзләрендә йөзәләр.* К.Тәхау // Ниндидер өслектә боз эреп ачылган урын. *Мин юрганга аякларымны ныгытып төрәм дә тәрәзә бозын ялыйм, нәни генә күз ясап, сезнең кайтканны көтәм.* А.Гыйләҗев. *Искәндәр, аптырагач, боз каткан ишек пыяласын сулышы белән өреп җылыта башлады. Пыялада түгәрәк күз ясалды ---.* Р.Вәлиев

16) *сөйл.* Пешерелгән ботканың уртасына май салу өчен ясалган чокыр. *Ботка күзе*

17) *тарт. форм.* Берәр нәрсәнең тәэсире иң көчле булган урын, җир. *Җил күзенә куелган утлы күмер кыза гына.* Г.Әпсәләмов. *Өйне сап-сары балавыздай юып чыгара, мендәр-ястыкларны әйләндерә-әйләндерә мәрхәмәтле кояш күзендә киптерә ---.* А.Гыйләҗев. *Кәнизәк китергән комганнан битенбашын юып, йонлы сөлге белән сөртенгәч, ул Көн күзенә чыкты, тезләнеп Көнне сәламләде.* Р.Зәйдулла

18) **күзем** *сөйл. ирк.* Кадерлем, сөеклем, күзалмам. *[Мостафа:] «Анам, җаным, күзем...» – дип, акырып-акырып елый.* Ш.Камал

19) *күч. сөйл.* Караш, фикер; билгеле бер мөнәсәбәт. *Баштарак моңа түбән күз белән караган, үзе белән бер класста укыган укучылар да аны арага алырга тырыша башлыйлар.* М.Гали. *Син, акташкаем, госел коенып, тәһарәт яңарттым да эш бетте, фәрештәгә әйләндем, ил күзендә абруйлыларның да абруйлысы булдым, дип фикер йөртәмсең?* Б.Камалов

20) *күч.* Кемнең дә булса игътибары, күзәтеп, карап торуы турында. *Минем бу хәлемне иң элек әнием сизенде. Ана күзеннән яшеренеп буламыни?* Ә.Еники. *Әле менә, Алла боерса, киләсе язга бер көнне көтүгә чыгарырмын. Бөтен таналарның күзе синдә генә булыр.* М.Мәһдиев. *Рәмзия ниләр уйлый торгандыр, анысы караңгы, Мөнирҗан исә көпә-көндез урамнан янәшә атлауларыннан да уңайсызлана, әйтерсең авылның күзе аларда гына.* Н.Әхмәдиев

21) *күч. сөйл. к.* **күзәтчелек** (*1–2 мәгъ.*). *Тукта, ниләр кыланып ята икән, --- дигәндер. Күз җибәрим янына, тыныч кына ятмасын, дип хафалангандыр.* Ш.Маннур. *Кайсы чакларда --- ат сатуны туктата Рәвил. Шайкасын каладан чыгарып җибәреп, полиция, жандармнар күзеннән яшереп куя.* З.Зәйнуллин. *Сания апаның икенче оныгы – Наилнең улы Руслан да – әбисе күзеннән читтә --- үсә менә.* А.Әхмәтгалиева

22) *күч.* Нәрсәнең дә булса янып торган сигнал уты. *--- шофёрның үз муенындагы кызыл шарфы белән машинаның яшел күзен шоссседан күренеп тормаслык итеп тәмам томаладык без.* М.Вәли

◊ **Күз агы белән карау** Күрәсе килмичә, яратмыйча яки ачу белән карау. *Әнә кичә генә планёркада комбат автомобиль ротасы командиры Труновка, нигә су ташыгыч һаман эшләми, дигәч, Карповичка күзенең агы белән генә карап, сылтау тапты ---.* С.Шәрипов. *Хәлимовның күзләре тагын кискенрәк кысылды, озын ак кашлары борын өстенә кадәр сузылды, йөзен юри читкә борып, күзенең агы белән генә аңа карап тора башлады.* Р.Айзатуллин. *– Әйт дөресен, Мойше, – дип, күзенең агы белән карады Чуртан, – табышны кем җыйды?* М.Насыйбуллин. **Күз агы кадалу** Күңел төшү, гашыйк

булу. – *Ашамый-эчми, яфрак күек саргаеп кибә, бәпкәчемнең сиңа күз агы кадалган, кызым, – диде.* Н.Гыйматдинова. **Күз агы кебек саклау** *к.* **күз карасы кебек саклау**. **Күз агым** Иң якын, кадерле, сөекле кешегә иркәләп әйтү сүзе. *[Габдулла:] Син, Закир, миңа менә шушы күз агым – бердәнбер кызым Галия кебек үк кадерлесең!* Ак юл. **Күз алакаю** *гади с. к.* **күз алару** (*1 мәгъ.*). *[Сиражетдин:] Болай булганда үзләренең дә күзләре алакаер. Биргәнне тизрәк алып калырга тырышырлар.* Г.Камал. **Күз алалану** *к.* **күз тону**. *--- йөзләрчә тамашачыны үзенең һәр сүзенә, һәр ымына ышандырып, буйсындырып торган артист Кәлимә янында мескенгә әйләнде, алаланган күзләре берни күрмәс булды ---.* К.Тимбикова. **Күз алару** 1) Көчле теләк барлыкка килү, нәрсәне дә булса кулга төшерергә теләү. *Акчаны күргәч, хатынның күзләре аларды, төшемме, өнемме дип, кире чигенде.* Г.Ибраһимов; 2) Артык нык куркудан күзләр зур булып ачылу. *[Сарыклар] ишегалдында ят кеше басып торганны күргәч, --- күзләрен ахмакларча алартып, мәгънәсез рәвештә акыра башладылар.* М.Мәһдиев. *Саяф аны җилтерәтеп аягына бастырды да яңагына чалтыратып җибәрде. – Юләр! Фәрхунә салмак кына башын күтәрде, аның күзләре аларган иде.* М.Хуҗин. **Күз алгысыз** Күзне, карашны аерып ала алмаслык матур күренеш турында. **Күз алды әлҗе-мөлҗе килү** *к.* **күз алды караңгылану**. *Альфредның күз аллары әлҗе-мөлҗе килде, аның беркайчан да бу дәрәҗәдә ачыкканы юк иде әле.* Ф.Садриев. *Хөсәен мине туп кебек өскә чөя дә лап итеп җиргә килеп төштем дигәндә генә тотып ала. Минем чәчләрем тузгый, күз алларым әлҗе-мөлҗе килә, һәм мин чәрелдәп кычкырып җибәрә торган идем.* Р.-Н.Гынтәкин. **Күз алды караңгылану** Хәлсезлектән, ачлыктан яки көчле дулкынланудан вакытлыча ачык күрү сәләтен югалту, әйләнә-тирә караңгы булып күренү. *Ирек җан көченә тырышты, бөтен җиреннән тир акты, --- вакыт-вакыт эсседәнме, тамак кибүдәнме, чайкалып, күз аллары караңгыланып китте.* Ф.Садриев. *Юл пычрак иде, машина эзеннән бара алмыйча, Гөлкәй берничә тапкыр таеп егылды. Хәле бетте, күз аллары караңгыланды.* Х.Ширмән. *Ул куаклар арасыннан килеп чыгуга, минем күз алларым караңгыланып китте.* Ф.Галиев. **Күз алдына бастыру** *к.* **күз алдына китерү**. *Шулай да вакыйганың ничек булганын бергәләп күз алдына бастырып карыйк әле.* Ф.Галиев. **Күз алдына килеп басу** *к.* **күз алдына килү**. *Күпмедер вакыт узгач, кызның моңлы җыры ишетелә. --- Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса.* Ә.Еники. **Күз алдына килү** Күзаллауда, уйда, хыялда барлыкка килү; искә төшү. *Әмма каһәр төшкән бу портрет, уйламаска тырышкан саен, күз алдына ешрак килде.* Ф.Яруллин. *Күз алдына берсеннән-берсе шыксыз, җан өшеткеч, йөрәк әрнеткеч күренешләр килде ---.* М.Хәсәнов. *Күз алдына һаман Галәй килде.* Р.Зәйдулла. **Күз алдына китерү** Фикердә-уйда, хыялда образлар барлыкка китерү, кемнедер яки нәрсәнедер гәүдәләндерү. *Зеелов калкулыклары да таныш икән. Дөрес, монда хәзер ватык танклар, үле гәүдәләр --- булмаса да, Хәйдәров, академиядә Берлин операциясен җентекләп өйрәнүе буенча, аның күптәнге чын рәвешен күз алдына китерде.* Т.Таһиров. *Кәримә артсыз урындыкка килеп утырды, шушы келәттә төн кунган Исламны күз алдына китерергә тырышты.* С.Шәмси. *Йөрәге шулай урыныннан кузгалган чакларда, ул тизрәк икенче бер күренешне күз алдына китерергә тырыша...* М.Хәсәнов. **Күз алдында** 1) Кемнең дә булса алдында, каршысында, кемдер карап, күреп торганда. *Гүя шушы такмакны гына көтеп торган, бүректәй болыт, колакчыннарын җыеп, күз алдында кечерәйде ---.* Ф.Латыйфи. *Ә менә хәзер, минем күз алдында диярлек, әлеге күл буйлары бөтенләй бетте.* С.Шәмси. *Камыр малай әллә эреп таралды, әллә яңа зат булып яралды: милиционер күз алдында юк булды.* Х.Ибраһим; 2) Сизелеп, сизелерлек булып. *[Ләмига түтәй:] Күз алдында үзгәрде бит малай, әтисе кайткач танымас та инде.* Г.Гобәй; 3) *к.* **күзгә карап**; 4) Үзе барда, үз алдында. *[Касыйм]: --- Барысы да минем күз алдында узды: бишьеллык планнар, коммунизм төзүләр, перестройкалар, ниһаять, авылның бүгенге фаҗигаләре.* З.Хәким. *Сөләй аның фикере белән килешмәде. – Юк инде, күз алдында кычкыртып алдасыннар да, ничек ачуың килмәсен!..* Н.Хәсәнов; 5) Кемнең дә булса күзаллавында. *[Газизов:] Күз алдымда бары шул цифрлар гына йөрде.* А.Шамов. **Күз алдында әйләнү** *к.* **күз алдыннан китмәү**. *Нигә ул бертуктаусыз такылдап, кыска итәкләрен җилфердәтеп күз алдында әйләнә?* Ә.Еники. **Күз алдында йолдызлар уйнау** *к.* **күздән (күзгә) ут күренү**. **Күз алдында калу** *к.* **күз алдыннан китмәү**. *Шул фильмның бер эпизоды күз алдымда калган.* М.Юныс. **Күз алдында тору** *к.* **күз алдыннан китмәү**. *Менә шушы күренеш искиткеч гүзәл һәм беркайчан кабатланмас сәнгать әсәре булып, әле һаман Булатның күз алдында тора.* М.Вәли. *Ә Рухия менә хәзер дә әле аерымачык тере булып, нечкә билле, озын толымлы булып, җитез һәм чибәр булып Равилнең күз алдында басып тора.* В.Нуруллин. **Күз алдында тоту** *к.* **күздә тоту**. *Кошлар очышы турында сөйләгәндә, мин кешенең күңел матурлыгы ачылуын, җанының биеккә омтылуын күз алдында тоттым.* Ф.Яруллин. *«Иң якын кешеләремне генә уйларга вакыт тимәде». Иң якын дигәндә, ул туачак сабыйны да күз алдында тота иде.* М.Маликова. *Соңгы вакытларда бүлмәләренә чәй эчәргә я Чулпан, я күрше кызлары --- кереп йөри башлаганнар иде. Күрәсең, Фаягөл шуларны күз алдында тота.* Х.Ширмән. **Күз алдыннан китмәү** Истән чыкмау, һәрвакыт istә-хәтердә булу; уйда-фикердә булу. *Үзебезнең өй кешеләре, бигрәк тә әни күз алдыннан китми.* М.Гафури. **Күз алдыннан кичерү** *к.* **күз алдыннан уздыру**. *Нурислам, Атау Зыятдинның тормыш юлын берьюлы күз алдыннан кичерергә теләгәндәй, инеш аръягына карап уйга чумып торды.* Р.Вәлиев. *...Җәвидә бу уй-*

*ланып калган мизгелләрдә Хәлимов белән ничек «дуслашып» китүләрен күз алдыннан кичерде.* Р.Айзатуллин. **Күз алдыннан кичү** *к.* **күз алдыннан узу**. **Күз алдыннан уздыру** Бер-бер артлы күз алдына, хәтергә китерү. *Студентларны күз алдымнан уздырып торам.* М.Юныс. **Күз алдыннан узу** Бер-бер артлы күз алдына, хәтергә килү. **Күз алдыннан үткәрү** *к.* **күз алдыннан уздыру**. *Кызның йөзен күрүгә, Хәдичә үзенең Габтелхәй белән булган беренче төннәрен күз алдыннан үткәрде.* Г.Галиева. *Шактый еллар үткәч кенә, Фаягөл аның үлгән хәбәрен ишетте, Гөлсем әнисенең яхшылыкларын тагын бер кат күз алдыннан үткәреп, бушаганчы елады...* А.Әхмәтгалиева. **Күз алдыннан үтү** *к.* **күз алдыннан узу**. *Кассетадагы күренешләр Миләүшәнең күз алдыннан йөгереп үтте ---.* Ф.Яруллин. *Заһирның күз алдыннан пәрдә ачылулар, Галиянең дулкынланып аны көтү, очрашу картиналары, су буе сәхнәләре үтте.* Т.Таһиров. *Моңа хәтле булган сәер һәм табышмактагыдай аңлаешсыз вакыйгалар аңа тынгы бирми, маҗаралы кино күренешләре шикелле, алар берәм-берәм күз алдыннан йөгереп үтә башлады.* Ф.Латыйфи. **Күз алды томалану** *к.* **күз алды караңгылану**. *Лесниковның чигәләре күперде, күз аллары томаланды ---.* С.Шәрипов. *Мәрьям абыстай улының бөтен сыны күренеп барган вагон ишегенә йотылып карый. Ләкин аның күз аллары томалана.* Ә.Еники. *Хәзер менә баш авырта, күз аллары томалана.* Ф.Яруллин. **Күз алды чуарлану** *к.* **күз алды караңгылану**. *Башта мин бик нык каушадым. Күз алдым чуарланды.* М.Гафури. **Күз алды яктыру** Уй-фикерләре ачылу; фикерле, уйлый алу халәтенә килү. *Кинәт Санькаsuccessfulның күз аллары яктырып китте. Мәчетнең дүрт манарасы дөньяның дүрт тарафына юл күрсәтә түгелме соң?!* Ф.Латыйфи. *Ни галәмәт, шул әфсен-төфсеннән соң баш авыртуы басыла, күз аллары яктырып китә торган иде.* Р.Мулланурова. *– Ярабби, алан исе килә... Бал исе, чәчәк исе!.. – Сәвиләнең күз аллары яктырды.* Н.Гыйматдинова. **Күз аллары әлҗе-мөлҗе килү** *к.* **күз(ләр) әлҗе-мөлҗе килү**. **Күз алларын томалау** Дөньяга дөрес, реаль караш булдырырга мөмкинлек бирмәү. *[Нәфисә:] Дин сөреме бездә кайберәүләрнең әле шушы көнгә кадәр күз алларын томалап тора.* Г.Бәширов. **Күз алмам** *к.* **күзалмам**. *Гомерлеккә китү түгел, Боекмачы, күз алмам.* Р.Миңнуллин. *Хәзер дә күз алмам, күз нурым минем ир җаным.* Н.Гыйматдинова. **Күз алмастай** Бик чибәр; бик матур, күркәм. *--- Бикәнең битләре алсуланып яна, борын очларына кунган --- сипкелләре бикәнең йөзен тагын да хозурлатып, күз алмастай итәләр.* М.Хәбибуллин. **Күз алмасыдай саклау** *к.* **күз карасы кебек саклау**. *[Сара:] --- Күз алмасыдай саклап яшәде [Сәгыйдулла гармунны].* Ә.Гаффар. *Күрдегез инде, мин --- мәхәббәтемне таптым... Шуңа күрә ул миңа бик кадерле, күз алмасыдай саклыйм мин аны...* Ә.Еники. **Күзне ала алмау** Бик сокланып, яратып карау. *Булачак кәләшенә чиксез гашыйк булган Камырҗан аңардан күзен ала алмады.* Х.Ибраһим. *– Чукынгыры, истән чыккан икән, – диде ул, балдызын теләр-теләмәс кенә кочагыннан ычкындырып. Ләкин күзен аңардан ала алмады.* Ф.Яруллин. **Күзне алмау** Кемгә яки нәрсәгә дә булса озак итеп, игътибар белән карап тору. *– Карап-карап торам да, гел Евграф Евграфович чалымнарын күрәм мин бу шайтанда! – диде малайдан бер генә минутка да күзен алмаган Борһан.* Х.Ибраһим. **Күз алмашу** Күз бик үк дөрес, ачык күрми башлау, күз ялгышу. *Ул арада караңгылык төшеп, урман эчендә күз алмаша башлаган.* Г.Рәхим. **Күз алышу** Кем белән дә булса сүзсез генә карашу, карашып алу. *[Гайнетдинов] --- крестьяннар, хатыннар, кызыл гаскәрләр белән күз алышты.* Г.Ибраһимов. **Күз алышыну** 1) *к.* **күз алмашу**. *Ярым караңгы кухня аша узганда, күзе алышыныпмы, --- бер күз ташлауда ул Тәбриядәге үзгәрешне абайлап ала алмады кебек.* М.Маликова; 2) *к.* **күз тону** (*2 мәгъ.*). *Айнур аны күрми. Йөзе кыйшаган, күзләре алышынган.* Ф.Бәйрәмова. **Күз артында** Үзе югында, үзе катнашмаганда (сөйләү, тиргәү һ.б.). *--- Габделбәр явызның янә безнең күз артында гына койрыгын боруы кебек моментлар – үләсе тизрәк үлсен, бетәсе тизрәк бетсен, дип ашыгу галәмәтедер.* Х.Сарьян. **Күз астында** Кем дә булса карап, күреп торган вакытта; күзәтү астында. *Без аны, үзенә кул салмасын дип, бик каты күз астында тотабыз.* Х.Сарьян. **Күз ату** 1) Кинәт карау, карап алу; күз төшерү. *Зәнфирә белән Роза кычкырып көлде, чырык-чырык килеп, кем беләндер үртәште, --- әмма Ирек ягына күз дә атмады.* Ф.Садриев. *Кәефе нигә бозылганын үзе дә аңламыйча, Билалов КИП аша пилорама ягына күз атты.* С.Шәрипов. *Атилланың кызга сокланулы күз атуын тотып алган шымчылар әлеге кыз турында әнәсеннән җебенә кадәр белеп, түкми-чәчми аңа җиткерделәр.* Р.Зәйдулла; 2) *к.* **күз төшерү; күз салу**. *Ләкин бу беренче саташуларым, балалыкларым, юләрлекләрем, оялып күз атуларым, --- инде беркайчан да кабатланмас, кабатланмас шул!* Х.Ибраһим. *Аңа күз атучы егетләр арасында җыр-биюгә осталар, --- колы булырга әзерләр дә күп иде.* Р.Айзатуллин. *Акйолдызлар, Аййолдызлар һәм башка йолдызлар, сокланып, хәйран калып күз ата сиңа.* М.Кәрим. **Күз атып йөрү** Кемне дә булса яратып йөрү, кемгәдер гыйшык тоту. *Ул чакта яшерен күз атып йөргән кызы Гөлфия дә, укытучысы Нурия апа да аңа математика факультетына керергә киңәш бирделәр.* Р.Айзатуллин. *Кем белә, авылда күз атып йөргән берәр ярлы-ябагай кызыгып куеп, эшне бозуы да бар.* Ф.Яхин. **Күз ачарга да бирмәү** Бик каты кыстау; ашыктыру, кызулату. **Күз ачарлык (та) түгел** *к.* **күз ачкысыз**. *[Әхмәдулла:] Ай-яй буран, станциядән чыгып бераз киткәч тә шундый күтәрелде, күз ачарлык та түгел, көчкә килеп җиттем.* А.Шамов. **Күз ачкысыз** Бик көчле, бик каты (буран, кар һ.б.ш. тур.). *--- Казанның Яңа бистәсендә --- яңгыр яуса, тездән пычрак, коры айларда күз ачкысыз.* Ш.Рәкыйпов. *Бөтен дөньяны кар баскан, күз ачкысыз буран, кар көртләре; шулай да кайдадыр яз*

*сулышы сизелә ---.* Г.Әпсәләмов. *Чиләкләп яңгыр яуганда да, күз ачкысыз кышкы буранда да ул район үзәгеннән почта ташый иде.* И.Юзеев. **Күз ачмаслык** *к.* **күз ачкысыз**. **Күз ачмый** Ялсыз; туктаусыз. *Күз ачмый эшлибез менә. Һаҗәр кызулый. Тәмәке дә тарткан юк иде әле.* К.Тимбикова. **Күз ачу** Туу, дөньяга килү. *Мин – чыра яктысында күз ачкан бәндәмен.* М.Кәрим. **Күз ачылу** Берәр нәрсәне аңлый башлау, дөреслекне төшенү, тану. *Кешенең күзе кайчан ачыла? Тугандамы, дөньяның матурлыгына, зурлыгына хәйран калып гаҗәпләнгән чактамы, әллә йөрәгенә мәхәббәт уты бәреп кереп сулышларын кыса башлагандамы?* Ф.Яруллин. *– Таисия Ивановна, гафу, сез ялганчы түгел! Хәзер күзем ачылды ---, – дип, Шамбутский Комзинаны туктатмакчы булды.* М.Насыйбуллин. *– Сез аңламадыгыз мине... Мин үзем дә дөм-сукыр булганмын... Менә күзем ачылды хәзер... Ачылды, [– диде Фәрдәнә].* Х.Сарьян. **Күз ачып йомган арада** *к.* **күз ачып йомганчы**. *Гайфулла --- күз ачып йомган арада --- ымсындыргыч сихри көч ташып торган гәүдәне кукрәгенә кысты.* Ф.Яруллин. *Тормышның кануны шундый инде: бер ел эчендә генә түгел, күз ачып йомган арада да дөньядагы барлык җанлы-җансыз нәрсә күпмегәдер үзгәреп өлгерә.* Ә.Еники. *Сөембикә күз ачып йомган арада Миңзаһитның алдыннан шуып төшеп, колготкиларына үрелде.* Ф.Садриев. **Күз ачып йомганчы** Бик тиз арада; кинәт. *Бер малайның бил каешын сорап алды да шуны бишкә ярып телде, күз ачып йомганчы бишле камчы үреп --- куйды.* М.Мәһдиев. *Берничә ир тагын өй эченә кереп китте. Күз ачып йомганчы карчыкны күтәреп тә чыктылар.* С.Шәмси. *Мин машина бүлегенә шалтыраттым. Берәр хәтәр хәл булды дип аңладылар, күрәсең, күз ачып йомганчы йөгереп менеп тә җиттеләр.* М.Юныс. **Күз ачып, күз йомганчы** *к.* **күз ачып йомганчы**. **Күз ачып, күз йомылмау** *к.* **күз ачып йомганчы**. *Күз ачып күз йомылмады, арба яшел урман эченә кереп чумды.* Г.Исхакый. **Күз ачырмау** Кемне дә булса бик нык әрләү, битәрләү, тиргәү. *Сәмиминә текәлеп карап торды да: «Син кукурузны монда кыстырма, яме?» – диде. Күз дә ачырмый бу.* Т.Таһиров. *Эштә халык күз ачырмый. «Шакир кода, туйлар ничек узды?» – дип көләләр.* Р.Айзатуллин. *Җәннәт, зәһәр, шуны сизеп алган, ул Хәернисадан мыскыллап көлеп, күзен ачырмый башлады.* Г.Әпсәләмов. **Күз аша үтү** Кемнеңдер тикшерүенә тап булу. *Ул – хуҗа, базарның абруе ---. Ерак Көнчыгыш тайгасыннан урланып монда килгән кыйммәтле кеш тиреләре дә, сусар, җофар мехлары, үз төбәгебездәге вак-төяк җәнлек тиреләре дә иң әүвәл аның күзе аша үтә.* А.Гыйләҗев. **Күз әлҗе-мөлҗе килү** Берәр хәлдән күз аллары чуарлану, күз аллары караңгыланып-томаланып китү. *Аракыдан күзләре әлҗе-мөлҗе килә башлаган Сәет, ярым пышылдап, Афзалга болай диде: ---.* Ф.Яруллин. *Кояшның кызды-руына чама юк, эссе тыгыз һава күкрәкне кыса, күзләр әлҗе-мөлҗе килә иде.* Р.Зәйдулла. *Бар тәне кызыша, башы әйләнә, колаклары шаулый, күзләре әлҗе-мөлҗе килә иде аның.* Т.Әйди. **Күз әсәрләнү** Нинди дә булса хәбәрдән, хатирәдән, хисләрдән яисә эчке киеренкелектән күзләр зур булып ачылу. *Әгәр дә кодрәтеннән килсә, ул [Галкин] Хажины әллә нишләтергә дә әзер ---. Күзләре әсәрләнгән, тешләре кысылган.* М.Хәсәнов. **Күз бәйләнү** Караңгылану, эңгер-меңгер вакыт җитү. *Җиде чакрымдагы Зиреклебашка караңгы төшеп, тәмам күз бәйләнгәч кайтып җиттеләр.* Ә.Еники. *Кичке тугызда китапханәдән чыктым. --- Күз бәйләнгән чак.* М.Юныс. *Инде тәмам күз бәйләнгәч, йөрәгендә кузгалган давыл басыла төшкәч, Билал яңадан өйләре янына әйләнеп килде...* М.Вәли. **Күз бәйләү** *к.* **күз буу**. **Күз белән айкау** *к.* **күз белән сөзү**. *Исендә әле: ул бик озак исәңгерәп торды, күзләре белән мәҗлесне айкады: кем өчен, кем өчен?* Р.Зәйдулла. *Прокурор --- күзләре белән кунакларны айкап чыкты, әмма Халитов күренмәде.* Р.Мирхәйдәров. **Күз белән ашау** *к.* **күз белән капшау**. *--- мин резервтагы батальонда «Яшь солдат курсы»н үтә идем. Шул чакта ефрейтор Мудрецов, командир каршында торганда, аны «күз белән ашарга кирәк» дип өйрәтә иде.* М.Юныс. *Әнисе белән янәшә урнашкан Әсма Гөлчирәне күзләре белән ашардай булып утырды.* Х.Сафина. **Күз белән бораулау** Дикъкать белән карау, бик җентекләп карау. *Нишләп яшел күзләре белән һаман Сәвиләне бораулый? Кием үлчәме алганда тегүче дә болай тикшермидер.* Н.Гыйматдинова. *Үземнең рентген аппараты булып тумаганыма уфтанып, тагын да халатны күзем белән бораулап киттем.* Р.Кәрами. **Күз белән капшау** Бик бирелеп, игътибар белән карау. *Кайнананың күзенә күренер хәл юк, күзе белән корсакны капшый башлый.* Ф.Яруллин. *Бер алдыма, бер артыма чыгып, мине күзе белән баштанаяк капшап карады.* М.Кәрим. *«Кияүдә микән, ир дигән кемсәсе нindирәк бәндә икән?» – дип, күзе белән генә ишегалдын капшады.* Н.Гыйматдинова. **Күз белән каш арасында** Бик якында. *Авылында, каласында һәр кешедән сора: Күз белән каш арасында Курку басып тора.* Г.Афзал. **Күз белән сөзү** Кемне яки нәрсәне дә булса бик җентекләп карау, бик нык карау. *Тагын күпме эшлисем бар икән дип, караңгыда эшләгән мәйданны күзләре белән сөзеп азапланмаячак...* Ф.Хөсни. *Бөтен өй эчен күз белән сөзеп чыктык.* Г.Кашшаф. **Күз белән тишү** *к.* **күз белән бораулау**. *Дамир, күзе белән тишәрдәй булып, Галимнең киң җилкәсен бораулады.* Н.Гыйматдинова. **Күз бетәштерү** *к.* **күз бетерү**. *Төннәр буе күз бетәштереп китап өстендә утырыр.* Г.Ахунов. **Күз бетәшү** *к.* **күз бетү**. **Күз бетерү** Күзнең күрү сәләтен бик нык киметү, күзне бозу. *Абыйларыңның ярман сугышында шәһит китүе кайгысыннан әниеңнең чәчләре бүздәй агарды, инде хәзер сине сагынып яшь коя, күзен бетерә.* Т.Әйди. *[Равилнең әнисе:] «Күз бетереп, шул шайтан сабагын укып утырганчы, чабата ясап сатсаң, мең мәртәбә әйбәтрәк булыры!» – дип, гел сукранып тора.* В.Нуруллин. **Күз бетү** Күзнең күрү сәләте бик нык киму, күз бозылу. *Еламасана,*

*әни, мин киткәнгә, Күз генәең бетәр яшь белән.* Җыр. **Күз бозу** *к.* **күз бетерү**. *Панкратов укудан туктап, Коля янына килде. – Җитәдер инде? Берни күреп булмый, күз бозудан ни мәгънә, – диде.* Җ.Тәрҗеман. *Бүлмәгездә караңгы, караңгыда күзегезне бозасыз бит, диеп кисәтү ясаган кызга карап елмайды --- егет.* Йолдыз. **Күз булмау** Күзәтүче, караучы булмау. *Зәйтүн, үзенә күз булмаганнан файдаланып, чолан идәненнән өч литрлы банка белән җиләк вареньесы алып керде ---.* А.Гыйләҗев. **Күз буу** 1) Сихерләү; 2) Гипнозлау, гипнозга дучар итү. *--- аның [Алиның] егерме дүрт яшьлек улы безгә әйләнмәле станокта --- юеш балчыктан, күз буган кебек, сокландргыч матур чәйнек ясап күрсәтте.* М.Галиев; 3) Ялганлау, алдау. *Кайбер сатучылар күз буарга да оста булалар бит...* М.Юныс. *Өч мең сум акча күз алдында эреп юкка да чыкты. Ничек шулай күз буарга өйрәнгән диген син аны.* Х.Ибраһим. *Мин бит Булатыңны үтерергә җыенган идем. Зур акчалар күзне буды, аңны томалады.* Н.Гыйматдинова. **Күз буучы** 1) Сихерче. *[Әхмәт:] Җиде кат җир астында елан йөргәнне сизүче, күз буучы, кешенең киләчәген күрүче мин буламын.* Д.Аппакова; 2) Гипнозчы; 3) Аферист, махинатор. *Спирит сеанслар, күз буучылар, явыз убырлар, сихерчеләр турында ишетеп кенә белгән участковыйның бу сәер күренештән тез буыннары калтырады.* Х.Ибраһим. **Күз буяу** Алдау, кемнән дә булса дөреслекне яшерү; юкны бар итеп күрсәтү. *Үз гомереңне күз буяуга әрәм итү ифрат та аяныч, әлбәттә.* Ф.Садриев. *Тәҗрибәле диңгезче эшли дә белә, кирәк чакта күз буярга да ифрат оста.* М.Юныс. *Әле менә безнең армия немецларны пыр туздырып куарга тотынгач, [союзниклар] күз буяр өчен генә дигәндәй, кыймылдый башлаган булдылар.* Ә.Еники. **Күз буяучы** Алдакчы, ялганчы, юкны бар дип күрсәтүче. *– Бер кочаклап, бөтен йорт-җиремә хуҗа булмакчы икәнсең! --- «Өйләнәм», имеш. Күз буяучы! – [диде Таешова].* М.Насыйбуллин. **Күзгә ак-кара күренмәү** 1) Бернәрсәгә дә игътибар итмәү. *Гомумән, ул соңгы көннәрдә телдән калды, күзенә ак-кара күренмәс булды.* М.Хәсәнов. *Җәмилә апа: «Кызым, хәерлегә булсын, күзеңә ак-кара күренми бугай», – диде.* Т.Таһиров; 2) Начар белән яхшыны аермау, бернәрсә дә аңламау. *[Әпипәнең] күзенә ак-кара күренми, --- әллә нинди бер нәмәрсәгә ияреп читкә китәргә йөри.* Г.Бәширов; 3) Бик каты ачудан яки куркудан ни эшләгәнне аңламау, берни белән исәпләшмәү. *Күзенә ак-кара күренмәгән Мөнирҗан, кулына эләккән беренче әрҗә белән, Рәмзиягә кул сузучы адәм актыгына орды.* Н.Әхмәдиев. **Күзгә ак төшү** Күрмәмешкә, сизмәмешкә, белмәмешкә салыну. *– Судьяның уң кулына алтын төртсәң, күзенә ак төшә, шуны оныттыңмы әллә, балдыз? – диде Фәйзулла, ачы көлемсерәп.* Г.Әпсәләмов. **Күзгә ат тоягы күренү** Каты бәрелү-сугылудан күз алдында ялт-йолт утлар уйнаган кебек булу. *Ә мин --- баскан урынымда бер әйләнеп чыгарга өлгердем микән, син борын төбенә шундый итеп ямадың: күзгә ат тояклары күренде.* М.Галиев. **Күзгә бәрелү** 1) Күзгә күренү; игътибарны үзенә җәлеп итү. *Гаҗәп, Фәния белән Гүзәл арасындагы охшашлыклар күзгә бәрелеп тора икән ләбаса: икесендә дә түп-түгәрәк йөз, сап-сары чәч, сөрмәле зәп-зәңгәр күзләр, төз аяклар.* Г.Галиева. *Биредә һәрнәрсә --- «Мине күрәсеңме?!» дигәндәй чекерәеп, күзгә бәрелеп тора ---.* С.Шәмси. *Үтә күренмәле нейлон аша хатынның һәр әгъзасы «карагыз, мин монда» дип кычкырып, күзгә бәрелеп тора.* М.Юныс; 2) Ачык сизелү, беленү. *Күзгә бәрелеп тормаган нәрсәне хәтер тизрәк оныта.* Ф.Яруллин. *--- Алтын Урда ханының олуг хан Гүйәккә буйсынмавы күзгә бәрелергә тиеш түгел.* М.Хәбибуллин. *Әмма, читтән караганда, Сәрвәрнең батырлыгы күзгә бик тиз бәрелә.* К.Тимбикова. **Күзгә бәреп** 1) Ачыктан-ачык, турыдан-туры; тартынмыйча (әйтү, сөйләү). *Ә менә Баракчи хатын... Ул – Гүйәк хан тарафдары, күзгә бәреп әйтмәсә дә, аны яклый.* М.Хәбибуллин. *[Зөфәр:] Җырларга санап утырма инде, әти! Әйтәсеңне боргаланмый гына, күзгә бәреп әйт тә бир...* Җ.Дәрзаман. *Беркемнең дә яхшы ягын күрми, дөрес дип, күзгә бәреп әйтүчән.* Ш.Галиев; 2) Ачыктан-ачык, берни яшермичә (яшәү тур.). *Безнең халык шулай, шәп итеп, күзгә бәреп яшәргә ярата.* М.Мәһдиев. **Күзгә йокы кермәү** Йоклый алмау, йокысызлыктан интегү. *Йокы керми күзгә төннәр буе, Ничәнче көн инде кич-иртән Ак мендәргә башым куйдым исә, Бала елаганны ишетәм.* М.Әгъләмов. *Ә башында уйлары тубалга япкан күч кебек. Бөтенесен тәртипкә салып, бер җепкә тезмичә, күзгә йокы керәсе юк.* Ф.Галиев. *Саимә --- әйләнде-тулганды, тәрәзә челтәре аркылы кергән ай нурларыннан качып та карады, күзенә йокы кермәде.* Г.Галиева. **Күзгә йокы тулу** *к.* **күзгә йокы элену**. *Мин дә көттем-көттем дә, күзгә йокы тулгач, аудым.* Н.Гыйматдинова. **Күзгә йокы тыгылу** *к.* **күзгә йокы элену**. *Шәмси акыртын гына кәнәфигә утырды. --- аның күзенә йокы тыгылды.* Г.Исхакый. **Күзгә йокы элену** Йокы килү. *Күзгә туктаусыз йокы элenә. Утырып, ял итеп алганда да ярар иде.* Сөембикә. **Күзгә карап алдау** *к.* **күзгә карап җан сату**. *[Кунаклар:] Күзгә карап алдалыйсың.* А.Алиш. **Күзгә карап җан сату** Ачыктан-ачык алдау, алдалау, оятсызларча ялганлау; хәрәмләшү. *[Рамай:] Их, Сабир абзый, күзгә карап җан сатучылар, дип әйтәләр иде сезне, дөрес икән.* Т.Гыйззәт. **Күзгә карап тану** Күрәләтә, булганның киресен раслау. **Күзгә карап тору** Кемгә яки нәрсәгә дә булса буйсыну, бәйле булу; кемнең дә булса көенә, җаена тору. *Карале, малай, һаман бер стипендия күзенә карап утырмассың бит инде.* Җ.Дәрзаман. **Күзгә карап ялганлау** *к.* **күзгә карап җан сату**. *– Алаймыни? Нинди вөҗдансыз ялганлау, күзгә карап ялганлау, чытырдатып ялганлау!.. – дип уйлады да мәсьәләне дәвам иттермәкче булды.* Ф.Әмирхан. **Күзгә карап яту** *к.* **күзгә карап тору**. *«Ну артист, – дип уйлады Гайфулла, – шәһәрдә дә Кәбирчигенең күзенә карап ятмыйдыр бу. --- Авылда чакта Хафиз белән дә араларында нидер булган, дип сөйләгәннәр ие».* Ф.Яруллин. **Күзгә карап яшәү** 1) Тату,

дус, бер-берсен аңлап, яратып, хөрмәт итеп яшәү. *Бер-берләренең күзләренә генә карашып яшиләр.* Ф.Яруллин; 2) *к.* **күзгә карап тору**. *Самат та, өйләнгәннән соң үзгәргәннән-үзгәреп, --- үз фикерен әйтә торган ир-егет урынына хатын күзенә карап --- яши торган бозауга әйләнде.* З.Зәйнуллин. *Мәгънәсез икән, үсмәсен ир! Эшләсен, мал тапсын, ләкин үсмәсен. Бер хәлдә, күземә карап кына яшәсен.* А.Гыйләҗев. **Күзгә каратып тоту** Кемне дә булса үзенә каратып тоту, буйсындырып тоту. **Күзгә кереп тору** 1) Үткен, чая булу. *Бер дә шәһәрдән килгән димәссең үзен [кунак кызын]... Әмма авылныкы да түгел, бөтенләй башка – күзеңә кереп, чәчрәп тора, дигән уйлар бер-бер артлы йөгереште хуҗа хатын күңеленнән.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Күренеп, беленеп тору. *Авыл кешесенең байлыгы, ярлылыгы, уңганлыгы, ялкаулыгы ихатасының бөтен ноктасыннан күзгә кереп, кычкырып тора.* А.Гыйләҗев. **Күзгә керерлек булып** Бик нык йотылып, текәлеп (карау, тыңлау). **Күзгә керердәй булып** *к.* **күзгә керерлек булып**. *Бизәнеп-ыспайланып чыгып киткән Харрас Солтания янына барып кергәндер, тегесе, күзенә кереп китәрдәй булып, Харраска карап чекерәеп утырадыр.* К.Тимбикова. **Күзгә көл сибү** *к.* **күзгә төтен җибәрү**. *[Шүрәле:] Син, егет, күзгә көл сибәргә яратасың кебек.* Д.Аппакова. **Күзгә көя булу** Берәр кешенең яки берәр нәрсәнең күңелгә начар тәэсир итүе, кәефне бозуы турында. *Мәйданнан халык таралышканда, Фарукҗанның бер кырыйда Тураев, Аксолтановлар белән сөйләшеп торуы исә бигрәк тә аның күзенә көя булды.* Т.Әйди. **Күзгә күзне кую** Кара-каршы утыру. *[Зөһрә:] Күзгә күзем куеп, тын утырып Барлык серләремне сөйләрмен.* Ф.Бурнаш. **Күзгә күзне терәү** Кара-каршы тору. *--- шулай берсе тәрәзәдә, икенчесе урамда күзгә күзне терәп торгач, Вәзиләнең «ничек булды соң?» дип сорыйсы килде ---.* А.Гыйләҗев. **Күзгә күренеп** Күз алдында; сизелеп, беленеп. *Шушы көннән институтта тормыш күзгә күренеп үзгәрде.* Ф.Яруллин. *Соңгы көннәрдә тулай торак күзгә күренеп җанланды, киләсе студентлар килеп беткән, бүлмәләренә урнашканнар иде инде.* Х.Ширмән. *Мөҗипнең азык запасы күзгә күренеп кимеде.* Х.Ибраһим. *...Йөзе агарып, бәләген канлы чүпрәк белән урап кайткан көннән бирле иренең күзгә күренеп үзгәрүен, үз эченә бикләнүен, --- күргән саен, Гөлйөземнең үзәге өзелә ---.* Ф.Латыйфи. **Күзгә күренерлек** Сизелерлек, беленерлек; игътибарга лаек. *[Гамбәр]: Минем хет күзгә күренерлек эшләрем бар – тотып карарга мөмкин.* З.Хәким. *--- шуның өстенә электән сак-лык ашлык-фәлән дә булмаганга күрә, безнең тормышның матди ягы да күзгә күренерлек рәвештә түбән китте.* М.Гафури. **Күзгә күренү** 1) Кемгә дә булса очрау. *– Менә шәп булган, – диде карт, инде байтактан күзгә күренмәгән кызы килеп чыгуга сөенеп, --- кызын өйгә чакырды.* С.Шәмси. *Искәндәр белән Сөмбел өйләнешкәч, Рүдәл бөтенләй күзгә күренмәс булды.* Р.Вәлиев. *– Күзеңә хатының җен булып күренгәндер, күбрәк йөр әле янына! – диючеләр дә булды.* Х.Ибраһим; 2) Ялгыш күренү; 3) Нинди дә булса әсәрнең яки тулы бер китапның басылып чыгуы, дөнья күрүе. *Ошбу көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде.* Г.Камал. **Күзгә кырып салырга да** *к.* **күзгә кырып салырлык**. *Ул үзе тапкан малга үзе хуҗа икәнен, алканы Хәй Фәләхинең күзенә кырып салырга да бирмәячәген расларга тырышты.* К.Тимбикова. **Күзгә кырып салырлык** Аз гына да, азрак та; бөтенләй. *Авылда күзгә кырып салырлык та яшьләр калмады, барысы шәһәргә качып бетте.* Р.Вәлиев. *Заманында тавышларыннан каланча селкенеп, калаен зең итеп торган авылда ир заты дигәннәр күзгә кырып салырлык кына калган иде.* Н.Әхмәдиев. **Күзгә ташлану** Бик ачык күренү, игътибарны җәлеп итеп тору. *Якыная төшкәч күрәм: иң түр почмактагы кечерәк кенә өстәл янында өч кыз утыра. Алларында ике шампан шешәсе ---. Шоколад һәм кыйммәтле сигара савыты да күзгә ташлана.* М.Вәли. *Утларны кабызып җибәргәч, өйнең иркенлеге шундук күзгә ташланды.* Ф.Яруллин. *Гади, бераз кырысрак диңгез тормышыннан соң мондагы яшәүнең үзгәлеге аеруча күзгә ташлана.* М.Юныс. **Күзгә ташланырлык** Игътибар итәрлек, күзгә күренерлек. *--- Хак Тәгалә диннең тәгълиматларында күзгә ташланырлык хаталар күргән иде.* М.Хәбибуллин. **Күзгә текәлү** Текәлеп карау, күзгә дикъкать белән карау. *Егет минем күзләремә текәлде.* Ә.Еники. *Яшькелт утлар яңадан Гөлкәйнең күзләренә текәлделәр.* Х.Ширмән. *Ул ---, башын бераз кыңгыр салып, эчкерсез бер елмаю белән күзләремә текәлде.* Г.Галиева. *Абыйлар бар, энеләрем... Алар да әнә әтинең күзенә текәлгәннәр.* Р.Мөхәммәдиев. **Күзгә терәп әйтү** *к.* **күзгә бәреп әйтү**. *Бу юлы, димәк, батырлар табылган, Маликның күзенә терәп әйткәннәр.* И.Гази. **Күзгә терәп сөйләү** *к.* **күзгә бәреп әйтү**. *[Йөзлебикә] Сәйфинең эчеп йөрүләрен күзенә терәп сөйләп китте.* Г.Бәширов. **Күзгә терәү сугу** Бик авыр, кыен, уңайсыз хәлгә калдыру. **Күзгә төбәлү** *к.* **күзгә текәлү**. *Хәтерлим, мин шунда каушап тирәюнемә карандым, нишләргә кушасыз дигән сымак, укытучының күзләренә төбәлдем.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзгә төртелү** *к.* **күзгә бәрелү**. *Аксолтанов бераз уйланып торгач: – Ә син, җанкисәккәем, нигә шундый уйга килдең әле? – дип елмайды. – Һәр нәрсә күзгә төртелеп тормый ул.* Т.Әйди. *Милләтләр белән санлашмау һәрнәрсәдә күзгә төртелә.* Сөембикә. **Күзгә төртсәң күренмәс(лек)** Бик нык караңгы, дөм караңгы. *Тышта күзгә төртсәң дә берни күренмәслек караңгы.* Н.Әхмәдиев. *Фомичёв тәрәзәгә күз төшереп ала: анда күзгә төртсәң күренмәслек караңгы, җил улый.* Ф.Галиев. *Җилле-яңгырлы көннәре, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төннәре белән көз дә килеп җитте.* М.Хәсәнов. *Төшсә, су төбе кап-караңгы, күзгә төртсәң күренмәслек бер хәлгә килгән, ди.* Әкият. **Күзгә төртү** Әйтеп тору, гаеп итеп күрсәтү. *Тапланган биография белән командалык итү гаять кыен. Санга сукмыйлар. --- Биографияңне күзгә төртәләр.* Х.Камалов. **Күзгә төтен җибәрү** Алдау,

ялганлау. *Мөгаен, ул, юлдашына караганда, эшне төплерәк беләдер. Тегесенең күзгә төтен җибәрүе бар.* Г.Әпсәләмов. *[Таштимер:] Сез күзгә төтен җибәрмичә, анығын гына әйтегез: үзегез кемгә хезмәт кыласысз: Фәйзулла Хуҗаев гөруһынамы, әллә...* Т.Әйди. *Ә Сәкинә Бариевна --- авыруларны битәрли: – Кем янына килдегез, аңгыра сарыклар?! Шарлатан бит ул, күзгә төтен җибәрүче!* Н.Гыйматдинова. **Күзгә төтен өрү** *к.* **күзгә төтен җибәрү**. *– Теге --- каләм әһеленә әйт, авылдан үкчәсен ялтыратсын. – Аның үз авылы. – Күзгә төтен өрмә, Галиев!* Н.Гыйматдинова. **Күзгә тузан булып керү** *к.* **күзгә черки булып керү**. *Ә хәзер кызлар артык кыюлар, күзгә тузан булып керәләр ---.* З.Кадыйрова. **Күзгә туры карап** 1) Ачыктан-ачык, дөресен. *Мактау сүзе азрак булса да, хакыйкатьне күзгә туры карап әйткәч, --- ачы тәнкыйть тә йөрәккә таш булып ятмады...* Р.Вәлиев. *Ашаганым – балмай, кигәнем – ефәк-атлас. Ә үзем гомер буе кеше күзенә туры карарга куркып яшим.* Г.Мөхәммәтшин; 2) Тыныч намус белән, оялмыйча, үзен хаклы санап. *Хәзер инде мин бу мөхтәрәм затның күзләренә туры карап сөйләшә алам.* Г.Галиева. **Күзгә чагылу** *к.* **күзгә чалыну**. *Якыннан аның йөзе бик чиста, тик кечкенә колакларыннан түбән яңак сөяге читендә ак мамык күзгә чагыла.* Ә.Еники. **Күзгә чалыну** 1) Күзгә күренеп алу. *Гайфулла --- кире кереп китәргә торганда, тегермән ягыннан килүче бер шәүлә күзенә чалынды.* Ф.Яруллин. *Арырак ул райкомның идеология секретаре Шәвәлиевне --- таныды. Өстәлдән читтә – стена буйлап тезелгән урындыкларда – тагын әллә кемнәр күзгә чалынды.* Ф.Садриев; 2) Сизелү, беленү. *Мин аны, ул үзгәрешне, иң элек үземдә хис итәм: кеше күзенә чалынырлык яңа сыйфатларга баемасам да, һәрхәлдә, бер елга картайдым мин...* Ә.Еники. **Күзгә чәчрәп керү** Әрсезләнү, чик-чаманы белмәү; кемнәрнеңдер игътибарын җәлеп итәргә омтылу. *Табыш, мал белән кайтсамы, уһу, туктатырсың син аны: хатын-кыз күзенә чәчрәп керергә генә тора ир-ат!* А.Гыйләҗев. *Ләкин матурлыгы, бүтәннәр сыман күзгә чәчрәп кермәгәнлектән, башта күренми – соңыннан гына ачылып китә торган икән.* Х.Сарьян. **Күзгә черки булып кадалу** Әрсезләнү, оятсызлану. *--- мин – Казанга фанер чемодан күтәреп килеп кергән кеше. --- Сездәйләр ягына борылып карарга оят кебек. --- Хәзерге акылым булсамы? Бөтенесенең күзенә черки булып кадалыр идем.* К.Тимбикова. **Күзгә чүп булып керү** Комачаулау, борчу, эчне пошыру. *Ай Аллам, шул портрет күзеңә чүп булып керде инде. Нинди генә сүз башлама шуның белән тәмамлыйсың.* Ф.Яруллин. *Мин аның күзенә чүп булып керәчәкмен, йөрәгенә үтмәс пычак булып кадалачакмын...* Р.Габделхакова. **Күзгә эләгү** *к.* **күзгә чалыну**. *Абыстай [Җәләлне], исерек булып, халык күзенә генә эләкмәсә ярар иде инде, дип елап-елап, төн буена башын мендәргә куймый чыкты.* Г.Ибраһимов. **Күзгә эләрлек** Игътибарга алырлык, кызыксынырлык. *– Ишекне дә бикләмәгәнмен бит әле, – дип икеләнде юлдашы. – Нәрсәң бар инде күзгә эләрлек? Элегрәк монда ишекне бикләп йөргән кеше сирәк булган.* С.Шәрипов. **Күзгә яшь терәлү** *к.* **күзгә яшь тыгылу**. *[Җамалый агайның] күзләренә яшьләр терәлде.* Һ.Такташ. **Күзгә яшь тыгылу** Елап җибәрерлек хәлгә җитү. *Санькaның күзләренә яшь тыгылды. Авыртудан яисә үкенечтән түгел, ә бугазына төер булып тыгылган җәлләү, әтисен кызгану хисеннән туган яшьләр иде бу.* Ф.Латыйфи. *Мин аның [Гөлнәзирәнең] колагына ягымлы сүзләр пышылдыйм. Күзләремә яшь килеп тыгыла...* Х.Ибраһим. *Үзен әллә нинди сынауларга әзерләгән тоткын да, прәннек биргәч, йомшап төшә, күзенә яшь тыгыла.* Р.Зәйдулла. **Күз дә йоммыйча** 1) Икеләнмичә, курыкмыйча. *– Юк, мин ишетмәдем, – диде Рамазанов, күзен дә йоммыйча.* Ф.Садриев. *Зөлфия күзен дә йоммады: – Йогышлы авыруга охшаган бу! – диде.* Х.Ибраһим; 2) Тартынмыйча, оялмыйча. *[Кече лейтенант:] – Киленегезне ничәү кыйнадыгыз? – диде. – Нишләп без кыйныйк аны? – диде карчык, күзен дә йоммыйча.* Ш.Максудова. **Күз дә каш урынына күрү** Бик кадерләү; бик кадерле дип санау. **Күз дә каш урынына тоту** *к.* **күз дә каш урынына күрү**. **Күздә май бетү** Күзләр нурсызлану, төссезләнү. *Кешеләр аны – Әхтәмҗанны күзәттеләр: нечкә, үтәкүренмәле хәлсез куллар; тән тиресе саргылт, күзләрдә май беткән.* М.Мәһдиев. **Күздән җую** Югалту. *Егетләр, без аларны киләчәктә дә күздән җуймаска тырышыйк. Шикле танышлар!* Т.Әйди. **Күздән кичерү** 1) Җентекләп карап чыгу. *Карт, тәмәкесен суыра-суыра, --- күрше йортларның карлы түбәләрен күздән кичерде.* С.Шәмси. *– Хуш, авылым... – дип гаҗәпләнеп үз эченнән кабатлады Зыятдин карт һәм, бу сүзләрнең мәгънәсенә әле генә төшенгәндәй, бөтен авылны күздән кичереп чыкты.* Р.Вәлиев. *Илһам каршы арбага гипнозга тартылган кебек текәлгән сеңлесен тагы бер кат күздән кичерде.* Х.Ширмән; 2) Хәтердә искә төшерү. *Алда торган эшләрне тагын бер кат күздән кичереп чыктылыр, планнарны ачыкладылар.* М.Насыйбуллин. **Күздән (күзгә) очкын күренү** *к.* **күздән (күзгә) ут күренү**. **Күздән очкыннар сибү** Тирән кичерешләр, хисләр чагылышы буларак, күзләр бик нык ялтырау. *Нәфисә дә, аңа очып кунарга теләгәндәй, кулларын йодрыклады, күзеннән зәһәр очкыннар сипте.* Ф.Садриев. *Рамилнең күзеннән зәһәр очкыннар чәчри иде.* Н.Гыйматдинова. **Күздән очкыннар чәчрәү** *к.* **күздән (күзгә) ут күренү**. *Әлфреднең колак төбенә нидер белән бик шәпләп тондырдылар. --- Ул, күзләреннән чәчрәп чыккан очкыннар тарала төшкәч, өстенә ябырылучыларны --- сугып очыра башлады.* Ф.Яруллин. **Күздән очкыннар чәчү** *к.* **күздән очкыннар сибү**. *Әлфирә берничә секунд күзләреннән очкыннар чәчеп торгач, башын иеп, палаткага кереп китте...* Ф.Шәфигуллин. **Күздән сагыш кою** Моңлану, хәсрәтләнү, борчылу. *– Безнең әни үз гомерендә бер сәгать ял итмеме икән? – дип, күзләреннән сагыш коеп сөйләде ул ---.* М.Мәһдиев. **Күздән төшерү** Берәр кешенең кем каршында булса да абруен, дәрәҗәсен төшерү,

яхшы атын юкка чыгару. *[Шөҗәг:] Аны юлдан яздырмыйча, аны байның күзеннән төшермичә туктамам.* Г.Камал. **Күздән төшү** 1) Дәрәҗә, абруй төшү. *Хәзер Зиннәтнең Айсылу каршында күздән төшәсе килми иде.* Г.Бәширов. *Мәгәр бер тапкыр күздән төшеп, телгә эләккән адәм тиз генә ычкына алмый ---.* М.Кәрим; 2) Игътибардан читтә калу; онытылу. *Күп эчкән күздән төшәр.* Мәкаль. *Губернаторлар, байлар, түрәләр күздән төшеп, түрдән тәгәрәгәч, урамга «Кәҗә төбәге»н яңадан ябыштырырга маташучылар да булган бугай.* М.Кәрим. **Күздән уздыру** *к.* **күздән кичерү**. *Борһан --- кинаяле караш белән Мәдинәнең --- төртеп торган тулы күкрәкләренең тарантас сикерткән саен тетрәп куюларын кабат күздән уздырды.* М.Хәсәнов. **Күздән (күзгә) ут күренү** Каты бәрелүсугылу һ.б.ш. физик тәэсирләрдән күз алдында очкыннар чәчрәгән кебек булу. *Сабак белмәгән шәкертләрне укыткан хәлфәләр күздән утлар күренгәнче яңаклап та куялар.* М.Гафури. **Күздән ут чәчрәү** *к.* **күздән (күзгә) ут күренү**. *Ул --- өстәл артыннан иләп кенә торды да, искәрмәстән, йодрыгы белән минем чырайга кундырды. Күзләремнән утлар чәчрәде ---.* Ф.Галиев. *Тикшерүче яшен тизлегендә урыныннан торды һәм Мәҗитнең яңагына уңлы-суллы сугып алды. Мәҗитнең күзләреннән утлар чәчрәде.* Г.Әпсәләмов. **Күздән ут чәчү** *к.* **күздән очкыннар сибү**. *– Ни җитмидер сиңа, аңламыйм, – дип тезеп китте ул, күзләреннән ут чәчеп.* Р.Зәйдулла. **Күздән үткәрү** *к.* **күздән кичерү**. *Ул безне шулай, чалкан яткан килеш, бер генә бөртек җиребезне дә калдырмыйча күзеннән үткәрә башлады.* Х.Сарьян. *Мин --- былтыр укыган сабакларны күздән үткәрә --- башладым.* М.Гафури. **Күздән читтә калмау** Күрелү, игътибар ителү. *Саимәнең бу торышы тәҗрибәле «Беренче» күзеннән читтә калмады, билгеле.* Г.Галиева. *Ырудашларының Иләмәнне агырлавы, олуг күрүе аның күзеннән читтә калмады.* Р.Зәйдулла. **Күздән ычкындырмау** Даими рәвештә күзәтеп тору. *--- мин карчыга баласыдай бик сак, бик уяу утырам, егетнең бер сүзен дә, бер хәрәкәтен дә күздән ычкындырмыйм.* Ә.Еники. *Шул көннән кыз аны күздән ычкындырмады, – алар арасында сүзсез сөйләшү башланып китте.* С.Шәмси. *Үзем биим, ә үзем «аны» да күздән ычкындырмыйм.* Г.Әдһәм. *[Айсылу]: Хәзер һәрберегез үз урынына! Карагыз аны, бер секундка да Альберт булмәсен күздән ычкындырмагыз.* Ф.Яруллин. **Күздән югалу** Кемнең яки нәрсәнең дә булса күренми башлавы, юкка чыгуы. *Чалгы тавышы әкренләп тоныкланды, печән пакусы күзгә күренеп ерагайдыерагайды да бөтенләй күздән югалды.* Р.Вәлиев. *Миләүшә, Әлфред күздән югалуга, душтан төренеп чыккан җәймәсен сүтеп, йомшак урын өстенә ауды.* Ф.Яруллин. *Каңгылдап очкан кыр казлары, иркен яланнар, туплауга төшеп килгән елкы көтүе --- күздән югалды.* М.Юныс. **Күздән юк булу** *к.* **күздән югалу**. **Күздән яздырмау** Гел янында булу, һәрвакыт күзәтеп тору. *Кәләше, киресенчә, аның янында бөтерелә, бер алдына, бер артына төшеп тора, бер минутка да күзеннән яздырмый.* Р.Хәбибуллина. **Күздән язу** 1) Ераклашу, читкә китү һ.б. аркасында күзәтеп, карап торган әйбер күренми башлау, югалу. *Митрәй сәүдәгәр, --- бары тик урам чатына җитеп, тегеләр борылып күздән язгач кына, әкрен генә өенә таба атлады.* М.Хәбибуллин; 2) Сукыраю. *Өйгә кергәч, Галина миңа аңлатып бирде: – Әнием бомба шартлаудан шулай күздән язды.* М.Кәрим. **Күздә очкын кабыну** *к.* **күздә ут (чаткысы) кабыну**. *Арслановның күзләрендә зәһәр очкыннар кабынды, ул, мыскыл иткән кебек күзләрен кысып, Шәвәлиевкә: – Җибәрделәр?! – дип кычкырды.* Ф.Садриев. **Күздә очкын сүнү** *к.* **күздә ут сүнү**. *Аның йөзе тагын уйчанланды, күзләрендәге очкын сүнеп юкка чыкты ---.* Р.Вәлиев. **Күздә очкын уйнау** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. *Кинәт яшәреп, чибәрләнеп китте Кәримә, күзләрендә очкын уйный, йөзеннән бәхетле елмаю китми ---.* С.Шәмси. *Бит урталары аның әнистәй пешеп чыга, күзләрендә очкын уйный, ә сылу гәүдәсе үзеннән-үзе уйнап тора.* Ә.Еники. **Күздә очкын ялтырау** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. **Күздә очкын яну** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. **Күздә тоту** 1) Берәр төрле ният, максат белән эш итү, исәп итү. *Мондый кешене район җитәкчеләре дә күреп алганнар, күздә тотканнар булса кирәк.* Ф.Хөсни. *Айсылуның күздә тоткан кешесе – Тимергали карт – шушы иде инде.* Г.Бәширов. *Мунча да ягылган. Каен себеркесенең дә мәтрүшкә, бөтнек, юкә һәм имән ботаклары кушып бәйләнгәне, былтыргысы, быелгы май аеныкы... Ләкин кунак «себерке» дигәндә аларның берсен дә күздә тотмады.* Ф.Садриев; 2) Игътибарга алу, исәпкә алу. *Ибраһимовның төпченүе тикшерүдә катнашучыларны ныграк уйланырга мәҗбүр итте. – Әйе, мөмкин, – диде Сәйдәшев. – Без бу юраманы да күздә тотабыз.* М.Насыйбуллин. *Кеше галәмгә тәэсир итү мөмкинлеге алыр, аны үзләштерә башлар, практика, халык хуҗалыгы интересларын күздә тотып өйрәнергә керешер.* Галәмгә юл. **Күздә ут сүнү** Күңелсез хәлләрдән, кичерешләрдән күзләр нурсызланып калу. **Күздә ут (чаткысы) кабыну** Нәрсәдәндер шатлану яки, киресенчә, нәфрәтләнү чагылышы. *Гитлер дигән сүзне ишетүгә, Шәрифулланың күзләрендә хәтәр бер ут кабына ---.* Ә.Еники. **Күздә ут (чаткысы) уйнау** Тирән кичерешләрдән, хисләрдән күз карашы җанланып китү. **Күздә чаткы кабыну** *к.* **күздә ут (чаткысы) кабыну**. *Кордашлар бер егерме елларын ташлаган кебек булдылар, хәрәкәтләре дә җитезләнде, күзләрендә чаткылар кабынды.* А.Тимергалин. **Күздә чүп булып тору** Комачаулап, борчып торган кеше яисә уңайсыз эш турында. *[Хәйретдин:] Китсеннәр алар, күздә чүп булып тормасыннар.* Х.Кәрим. **Күздә эленеп тору** *к.* **күз алдында тору** (*1 мәгъ.*). *Анда ул тагы ире күзендә эленеп торачак, ә аңа күзсез дә, колаксыз да урын кирәк.* Х.Сарьян. **Күз дүрт булу** Гаҗәпләнүдән, көтелмәгән шатлыктан яки куркудан күзләр зур булып ачылу. *Менә малайның күзләре дүрт булган, үзе чак-чак тын ала. – Әти! Безгә Оленька килде, аны алып керергә*

*ярыймы?* М.Мәһдиев. – *Аның беренчел исеме Шәйхулла, фамилиясе Заһруллин булганын да беләсеңме? – Хәйбулланың күзе дүрт булды.* К.Тимбикова. **Күзе атылып чыгарга тору** Куркудан күзләр зур итеп ачылу турында. *Шулай да [Мәрьямнең] куркуыннан йөрәге ярыларга, күзләре атылып чыгарга тора шикелле иде.* Г.Ибраһимов. **Күзе ачык** Аңлы, белемле. *Күзе ачык кеше ач калмый.* Мәкаль. *Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр, Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр.* Г.Тукай. *Келәм юкта чыпта яхшы, укымышлы төркестанлылар җитмәгәндә, күзе ачык татар да әйбәт.* Т.Әйди. **Күзе әйтеп тору** Күз карашыннан беленеп, сизелеп тору; күздә чагылу. **Күзе дә йөзе** Сүз барган кешеләрнең үзләре алдында, ачыктан-ачык. **Күзе җете** Яхшы күрә. *Менә син, сәламәтлеге Ходайга шөкер, күзе җете, --- колагы да сак, армый да диярлек, бар да элеккечә калды ---.* А.Гыйләҗев. **Күзе каты** Хорафат карашлар буенча: бәхетсезлек, начарлык, авыру китерә торган магик көчкә ия күзләр турында. *Күзем каты булмый иде, тефү, күз тимәсен.* Т.Гыйзэзт. *[Мөхтәр:] Күзең каты булып, күз тигезсәң... [Дилбәр:] Минем күзем каты түгел.* З.Хәким. --- *Алилуева иренә мөрәҗәгать итеп ала: – Зинһар алай карама, күз тигерерсең. Күзең каты синең!* Р.Мөхәммәдиев. **Күзе күкерт чәчрәтү** *к.* **күздән очкыннар сибү**. *Чыннан да, Нурихан Нуриевичның йөзе ярсулы, кашлары кабарынкы, күзләре күкерт чәчрәтә иде.* Шатлыклы кайгы. **Күзе маңгаена менү** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Каменскийның күзе маңгаена менә язды. Бу юлы ул чынлап гафу үтенде, алай килеп чыгар дип уйламаган идем, диде.* С.Шәрипов. *Ничек бәрәңге әрчүемне күргәч, Гөлмисалның күзе маңгаена менде ---.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Яшерен синдикат хуҗасы сәгатенә карап алды һәм гаҗәпләнүдән күзе маңгаена менде ---.* Р.Мирхәйдәров. **Күземә күренмә** 1) «Чыгып кит, күз алдымда торма» мәгънәсендә. – *Кит моннан! – дип, җан ачысы белән кинәт кычкырып җибәрде ул. – Кит моннан! Күземә күренмә!* Р.Вәлиев. *Я, җитте сезгә, күзге әтәчләр. --- Туганлашу хакына берне җибәрәсез дә аннан күземә күренмәгез!* Ф.Латыйфи. – *Бар, кайтып кит, алайса! Күземә күренмә! – Ирек утырды да, беләкләрен өстәлгә куеп, башын салды.* Ф.Садриев; 2) Кемнең дә булса борчып йөрмәвен үтенү. *Һәрхәлдә, ул, гомерендә беренче тапкыр диярлек ир хокукы белән файдаланып, хатынына: – Кияүне тынычлыкта калдыр, күзенә күренеп йөрисе булма! – дип, бик нык кисәтеп куйды.* Ә.Еники. *Мин аңлаешлы әйттем: кирпечсез күземә күренмисез.* Р.Айзатуллин. **Күземнән югал** *гади с. к.* **күземә күренмә** (*1 мәгъ.*). *Күземнән югал! Эзең булмасын, әрсез алабай! – дип, инде тәмам чыгырыннан чыгып --- кычкыра башлады кибет мөдире.* Г.Ахунов. – *Күралмыйм мин сине, күралмыйм. Берегезне дә күралмыйм. Күземнән югалыгыз! – Миләүшә бу сүзләрне аяк тибә-тибә кычкырды.* Ф.Яруллин. *Батый хан да аңа елмайды, әмма бикәсе артында карачы карчыкны күреп, күземнән югал, дип кул селтәде.* М.Хәбибуллин. **Күзем чәчрәп чыксын** *гади с.* Сөйләгәннең дөреслегенә ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе. *Әнә Булат, Хәмдиягә үч итеп, авылның иң чибәренә өйләнәм, дип әйтә, ди. --- Мәрфуга әбинең үзеннән ишеттем, менә күзем чәчрәп чыксын!* Т.Таһиров. – *Кит аннан! – Көтелмәгән хәбәрдән мулла малаеның күзләре шакмакланып чыкты. – Икмәктер! – диген! --- – Алдасам, күзләрем чәчрәп чыксын! – диген.* Н.Әхмәдиев. *Генерал белән кунган бар! Шампан белән аягымны юдырттым... Хак, алдасам, күзем чәчрәп чыксын!* А.Гыйләҗев. **Күзенә йотылу** Кемнең дә булса күзенә бик нык текәлеп карау. *Гаепләнүчеләр прокурорның күзенә йотылдылар.* Г.Ибраһимов. **Күзенә керү** Интектерү, аптырату. *Ай азагында ул чираттагы корбанына барып, үзенең мул яшәве, тәмле ашавы белән мактаначак, күзенә кереп, тегенең бурычлы җанын уч төбендә дер селкетәчәк.* А.Гыйләҗев. **Күзенә кылчык булып кадалу** Нинди дә булса күңелсез эш-хәлне кемнең дә булса гел исенә төшереп тору, оныттырмау. *Крестьянның яшәр чуты калмаган, әллә кая китеп олага идем, шул председательнең күзенә кадалган кылчык булыйм дип кенә монда ятам.* А.Гыйләҗев. **Күзенә кылчык кадалгыры** *шелт.* Кемне дә булса орышканда, тиргәгәндә әйтелә. *Әрәм итте өряңа машинаны, күзенә кылчык кадалгыры!* Р.Вәлиев. **Күзен дә йоммау** *к.* **күзен дә йоммыйча**. **Күзен дә йоммыйча** 1) Уңайсызланмыйча, оятсызларча. *Минме алдашам? Карале моны ---! Күзен дә йоммыйча, акны кара дип тора бит, ә, бәдбәхет!* Г.Ахунов. – *Әни-маем, ул хәер сорый, бирмәгәч җылый, – диде Җәннәт, күзен дә йоммыйча.* Г.Әпсәләмов. *Димәк, әгәр Азат Ходайкуловка җавап тотарга туры килсә, күзен дә йоммыйча: «Хатыны өчен үч алырга дип прокурор ялла-ды», – диячәк.* Р.Мирхәйдәров; 2) Бик җиңел генә. *Теләсә нинди эшне коеп эшли. Синең белән мин булдыра алмаганны күзен дә йоммыйча әмәлләп бирә бит ул әшнә.* К.Тимбикова; 3) Ике дә уйламыйча, уйлап та тормыйча. *Олы кызымның туена дип, абыеңа да сиздерми җыйган акчам бар ---. Күземне дә йоммыйча, һич җәлләмичә бирәм.* К.Тимбикова. **Күзендә мәчеләр сикерешү** *к.* **күзендә мәче тояклары уйнау**. – *Мин югында бик дәртлеләр белән эш иткәнсең ахыры. – Юкны сөйләмә әле, – диде сылу. Үзенең күзендә мәчеләр сикерешә иде.* Р.Зәйдулла. **Күзендә мәче тояклары уйнау** Дәрте ташып торган, мут, азгын кеше турында. *[Гыйззәтнең] куәте чиктән ашкан хатыны – кыйгач кашлы, күзләрендә мәче тояклары уйнап торган егерме яшьлек Нөзәһәтнең өйдәге агач караватта ялгыз ятуының сәбәпләрен һич тә халыкара-политик хәлләргә мөнәсәбәтле итеп уйлап карыйсы килми иде.* М.Мәһдиев. **Күзендә шайтан тояклары уйнау** *к.* **күзендә мәче тояклары уйнау**. *Лизаның --- йөргән егете, белгәнемчә, юк, чөнки бар вакытын-көчен укуга бирә, ләкин кайчакта күзләрендә шайтан тояклары уйнап киткәли...* Х.Ширмән. **Күзеннән ут уйнату** Тирән кичерешләрен, хисләрен, гадәттә ачуны һ.б.ш.ны чырайда, күздә чагылдыру. *Кыз, кинәт селкенеп, Фәхригә борылды,*

*күзеннән ут уйнатып, зәһәр белән җавап бирде.* Г.Ибраһимов. **Күзеннән ут чәчү** *к.* **күзеннән ут уйнату**. **Күзен төшерү** Кемнең дә булса игътибарын җәлеп итү. *«Тавышны мәдрәсәдән тышка чыгару» дигән сүз «бу мәдрәсәгә полициянең күзен төшерү» дигән сүз иде.* Ә.Фәйзи. **Күзен чыгару** Аптырату, җәфалау, интектерү. *Аллаһе Тәгалә хатынга әйткән, имеш: эштән сине азат итәм, әмма бала белән күзеңне чыгарам...* М.Мәһдиев. **Күзең чыкканмы (чыктымы әллә)** *гади сөйл. шелт.* «Күрмисеңме?», «күзең юкмы?» мәгънәсендә кулланыла. *Ул көнозын хыял канатында очты. Хәтта каршысына килеп чыккан Рәшитне дә чак таптамады. – Өскә менәсең бит, күзең чыктымы әллә? – дип, рәис аны битәрләгәндәй итте.* Р.Шәрипова. *Синең күзең чыккан идеме? Өйләнгәнче нәрсә карадың?* Х.Сафина. **Күзең чыккыры** *гади сөйл. шелт.* Кемне дә булса орышканда, тиргәгәндә кулланыла. *[Мәликә:] Ялгыш, имеш, ялгыш! Күзең тишелеп чыккыры нәрсә!.. Болай булганда, бөтен нәрсәләрне ватып, кырып бетерерсең син.* А.Шамов. **Күзең чыкмагындыр бит** *к.* **күзең чыкканмы (чыктымы әллә)**. *Берзаман ревизор килеп төшәр дә кәгазьләребезгә күз салу белән әйтер: «Һай Аллам, ишәк түгелдер бит сез? --- Бу кадәр башбаштаклыкны күрмәскә күзегез чыкмагандыр бит?» – дияр.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзе очлы** Тиз төшенүчән, тиз күреп (аңлап, белеп) ала торган. *Шөкер, балалар өйдә юк чак булды. Аларның күзе бик очлы. Сәндерәдәген генә түгел, күңелдәгесен дә күрәләр.* Ф.Яруллин. *[Сәрбиназ:] Гәрәй Мингалиевичнең күзе бик очлы. Кешенең тышындагысын гына түгел, эчендәгесен дә күрә.* Г.Шакирова. *Нәрсә, аларныкы шәбрәк, матуррак идеме? Шәбрәкләрне таный беләсең, ул якка күзең очлы синең.* Г.Галиева. **Күз ертып** Бик иртә уянып. *Шулай да без тик ятмыйбыз, җиң сызганып әзерләнәбез: сабанга киткәндәге сыман күз ертып торабыз да китапка тотынабыз ---.* Х.Сарьян. *Килеп төшкәннең икенче көнендә үк, таңнан күз ертып, башкалар белән бергә урманга агач тамгаларга чыкты.* Х.Сафина. **Күзе сукыр** Игътибарсыз, илтифатсыз. *Яшьлекнең күзе дөм сукыр икән шул.* Н.Гыйматдинова. *Кая карый бу авыл егетләре, күзләре сукырдыр аларның.* З.Кадыйрова. **Күзе тоз булу** Шаккату, ис китү; бик нык гаҗәпләнү. *Туй бүләге итеп фатир бирәбез. Кода-кодагыйның күзе тоз булсын!* М.Маликова. **Күзе томанлы** Күргәнне тиз генә төшенә, аңлый алмый торган. *Картлыкның күзе томанлы булса да, ул башкаларга мөһим булганны да күрә белә.* А.Гыйләҗев. **Күзе урынында түгел** Артык нык гаҗәпләнүдән, куркудан күзләр зур булып ачылу. *Өлкә комитетының утырышлар залына кергәндә, Арслановны инструктор Хисаметдинов каршы алды. Аның күзе урынында түгел иде.* Ф.Садриев. **Күзе ут булып кабыну** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. *– Кит моннан, ялагай! – Фирдәснең иреннәре мәсхәрәле чалшайды, күзе ут булып кабынды.* Г.Ахунов. **Күзе ут булып ялтырау** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. **Күзе ут булып яну** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. **Күзе ут уйнау** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. **Күзе үткен** *к.* **күзе очлы**. *Шул инде, яшьлекнең күзе үткен булса да, ул, гадәттә, үзе эзләгәнне генә күрә.* А.Гыйләҗев. *Төлке Тимер бинең колагы сак, күзе үткен, кулы озын иде.* Р.Зәйдулла. *Бәхтияров, --- өч-дүрт фоторәсем алып, игътибар белән карарга кереште. – Күзе үткен егетнең, сержант Әхәтовны әйтәм, – дип, Борһановка мөрәҗәгать итте.* М.Насыйбуллин. **Күзе үткер** *к.* **күзе очлы**. *Мактанып әйтүем түгел, әмма минем бу мәсьәләдә күзем үткер, шуңа күрә башта ук чамалап алдым ---.* Ф.Галиев. **Күзе чыккан** Берәр эштә зур тәҗрибә туплаган; бик нык остарган. *[Баһау], киңәш-табыш сорап, минем кебек колхоз эшендә күзе чыккан кешеләргә бармый.* А.Расих. **Күзе чыккан нәрсә** *гади с. шелт. к.* **күзе сукыр**. *Ай Алла, харап булдык. Күзләре чыккан нәрсәләр бу табынга тишек эскәтер җәйгәннәр.* Г.Камал. **Күзе шакмак булу** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Миңлегөл чытлыкны да дәшәргә кирәк, күрсен, күргәч күзе шакмак булсын!* А.Гыйләҗев. *Лотфиның күзләре шакмак булды, ул имән бармагын чигәсе янында уйнатып алды ---.* Ф.Латыйфи. *Кайтып кергәч, Рәшатның исерек күзләре шакмак булды. – Вот ты даёшь! – диде ул сызгырып.* Ф.Садриев. **Күзе шакмаклану** *к.* **күз шар(дай) булу**. *– Кит аннан! – Көтелмәгән хәбәрдән мулла малаеның күзләре шакмакланып чыкты.* Н.Әхмәдиев. *Сөембикәнең йөзенә --- аптырау билгеләре чыкты, аннары ул аптырау ачу белән алышынды. Аның күзләре ямьсез булып шакмакланды.* Ф.Садриев. *Сәрби апаның яшькелт күзләре шакмакланып, сирәк кашлары маңгаена менде. – Сигез мең дисеңме? Булмаганны...* А.Вергазов. **Күзе шараю** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Дәлия ишекне киң ачып керде дә, черт итеп, эчтән бикләде. Ирхәт моны көтмәгәндер, күзләре шараеп, телсез калды ---.* М.Хуҗин. **Күзе шар(дай) булу** Куркудан, гаҗәпләнүдән, ачудан, көчле дулкынланудан һ.б.ш. хисләрдән күзләр зур булып ачылу. *Мине күргәч, күзләре шар булды, өннәре алынды...* М.Хәсәнов. *Мондый сүзне ишеткәч, Баһаветдин агайның күзләре шардай булды.* Н.Фәттах. *Шимбә көнне иртән иртүк каенанам белән кызыма зур-зур акчалар бирдем, күзләре шар булды.* М.Насыйбуллин. **Күзе юк** Караңгы булу; күренмәү. *Көзге төннең күзе юк, алай да ул ишегалдында әрле-бирле йөри башлагач, күрше хатыны – әрем тел Сажидә: – Бәй, безнең очка килен төшкән икән бит! – дип кычкырды.* А.Гыйләҗев. **Күз җебетү** Елау. *Ә болай, дәфтәр пычратып, күз җебетеп утыру – юләрлек.* Т.Таһиров. **Күз җитмәгән** 1) *к.* **күз җитмәслек**; 2) Карап тору, күзәтү мөмкин булмаган. *Кызны читтән – Гөлбикә апаның күзе җитмәгән җирдән табарга кирәк иде.* А.Гыйләҗев. **Күз җитмәслек** Ерак; күз күреме җитмәслек, күреп булмаслык. *Җеннәрнең өйләре күз җитмәслек биек була торгандыр.* Г.Тукай. **Күз җитү** 1) Алдан күрә алу, алдан күреп, белеп тору. *Мирзаның күзе җитмәгән, акылы ирешмәгән, кулы тимәгән кабахәтлекләрнең барысы Иргали кулы белән эшләнә.* Ф.Бурнаш; 2) Ышану, инану.

*[Аксаби:] Аның Әнисәне тәрбияләп үстерә алуына күзем җитми.* З.Бәшири. **Күз җылыну** Нәрсәгә дә булса уңай мөнәсәбәт күрсәтү, караш йомшару. *– О-о! – Муафикъның күзләре тагын да җылынып китте, «әниеңнең карынында вакытта ук синнән өмет чыгачагын сиздем мин» дигән кебегрәк карый башлады.* Р.Зәйдулла. **Күз зинасы кылу** Күз карашы белән җенси теләкне белдерү. *[Шофёр] Мөршиднең оятсызланып күз зинасы кылып торуын сизеп бугай: «Һу-у! Кара син аны?» – диде ---.* К.Тимбикова. **Күз ике булу** *к.* **күз дүрт булу**. **–** *Директорның күзе ике булды! – Өч булмадымы тагын?!* Х.Ибраһим. **Күз ияләшү** 1) Караңгыда кешеләрне, әйберләрне күрә, аера башлау; караңгыда күрергә күз җайлашу, күнегү. *Мирфатыйх та бүген ап-аек иде, күзе ияләшеп, Хәйретдин агайның түрендә кичәге дошманын танып алгач, тагын да ныграк айныды ---.* А.Гыйләҗев. *Күз ияләшкәнче баз эченә карап торам да, чүп коелмасын өчен кружканы аска каратып, баскычтан төшә башлыйм.* М.Галиев; 2) Күнегеп бетү, өйрәнеп җитү; күзгә ят булып күренмәү. *Берберсенә күз ияләшә төшкәч, очрашу үз сукмагын тапты тагын.* А.Гыйләҗев. **Күз иярмәс(лек)** Бик тиз. *Ул күз иярмәс тизлек белән өскә күтәрелде ---.* Р.Вәлиев. *Саранцев, көндәшен уң кулыннан тартып китереп, күз иярмәс тизлек белән аягыннан эләктерде дә өскә чөйде.* Ф.Галиев. *Әни --- күз иярмәс җитезлек белән чеметеп кенә [җиләкне] өзә дә эмаль чиләккә сала.* Ә.Гаффар. **Күз (дә) иярмәү** Бик тиз хәрәкәт итү, эшләү турында. *Ирек текстны әйтеп торды, машинисткаының кулына күз дә иярми, ул аны егерме минутта басып та бетерде.* Ф.Садриев. *Ул --- кызу-кызу арканын ишәргә тотынды. Кулларына күз иярми.* М.Кәрим. *Сәриянең кулларына күз иярми: җитез генә токмачын кисеп, ялт кына бәрәңгесен дә әрчеп куйды.* Г.Әдһәм. **Күз йомдыру** Алдау. **Күз йоммау** Бер дә йокламау. *Төннең калган өлешен каенанам квартирасында күз дә йоммый үткәрдем.* М.Насыйбуллин. **Күз йому** 1) Аңлы рәвештә, белә торып игътибар итмәү; күрмәгән булу, күрмәмешкә салыну. *[Әбелхарис] --- сеңлесенең кайбер хәтәр адымнарына күз йома иде.* Г.Әпсәләмов. *Күз йомсын, дип, тыкшынмасын арага, Алтын төртте Гөлзар сакчы агага.* Ә.Фирдәүси. *Мин ник ялганга күрәләтә күз йомыйм соң әле?* Т.Әйди; 2) Тәвәккәлләү. *Ә өченче көнне иртәнге сигездә үк торды да күз йомып Заһидка шалтыратты.* А.Расих. **Күз йомып алу** Йоклап алу, черем итеп алу. *Җыелышка вакыт иртәрәк әле. Азрак күз йомып алырга мөмкин.* Ш.Камал. **Күз йомып тору** Эндәшмәү, игътибар итмәү; түзү. *[Гариф:] Безгә күзләребезне йомып торырга ярамас. Ак бандитларның ояларын туздырырга кирәк.* Ш.Камал. **Күз йөртү** Берәр кешене яки әйберне өстән-өстән генә карау, тиз генә карап чыгу. *Искәндәр купедагы картларга тагын бер кат күз йөртеп чыкты.* Р.Вәлиев. *Асыл --- таныш өянкеләр, йортлар буенча күз йөртеп, үз нигезенә килеп җитте.* М.Хәсәнов. *Ул бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты.* Р.Айзатуллин. **Күз йөгертү** *к.* **күз йөртү**. *Чөнки институтта әдәбияттан имтиханнар биргәндә, ул мена дигән әсәрләрне күз генә йөгертеп уза алды, аларны тәмләп, чын ләззәт алып укырга вакыт җитми иде.* М.Вәли. *Мөршид үз участогыннан шактый еракка китеп баскан сакчыларга күз йөгертеп алды ---.* К.Тимбикова. **Күз кабагы тарту** *к.* **күз тарту**. *Алтын алка авыр тарта, Алты мыскалдин артса; Шул җанымны күрер булсам, Уң күз кабагым тарта.* Җыр. **Күз кайту** Күрү сәләте кимү, күзләр начарлану. *Карчык, бөтенләй үк сукыр булмаса да, күзе кайткан кеше булса кирәк.* Әкият. **Күз калайлану** 1) Күзләргә усаллык, явызлык билгеләре чыгу. *Хәер, табут күтәргән төркемдә күзләре калайланган егетләр күп иде.* Ф.Яруллин; 2) Хиссез, битараф, салкын кешегә әверелү. *Аның кыяфәтеннән көлеп үләрсең: кашлары салынып төшкән, күз кабаклары да кысылып беткән, күзләре калайланган.* И.Тургенев. **Күз калмау** 1) Күзләр ару, күзләр талчыгу. *Әй җырлады инде, мескен [радио дигән нәмәстәкәй], әй җырлады! Елап күзкәйләрем калмады.* Т.Таһиров; 2) Күп уку, елау һ.б.ш. сәбәпләр аркасында күзләрнең күрү сәләте кимү. **Күз камаштыргыч (камашырлык)** Сокландыргыч, бик матур. *Чәчәкләр шундый күп, шундый төрле: күзләрең камашырлык.* Ф.Яруллин. *Буләкләр арасында күз камаштыргыч күн букчам бар, аны сыйпап кую үзе бер рәхәтлек китерә торган иде миңа.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күз камашу** *к.* **күз чагылу**. *Әле менә бүген Нәфисәнең арт урамнан кәҗә куып кайтканын күрдем дә матурлыгыннан күзләрем камашты.* Ф.Яруллин. *Урман аланы ямьле: Матур чәчәкләр үскән. Күзләрне камаштыра, Җиләкләре дә пешкән.* Ә.Яһүдин. **Күз каплау** Ришвәт биреп, җайлап, үз ягына аудару. *– Милиция сизмиме? – Кереме аларның күзен капларга гына җитә.* Ф.Садриев. **Күз карам** «Якыным, кадерлем, бердәнберем» мәгънәсендә кулланыла. *Туачак газиз оныгыбыз, күз карабыз, матур итеп, «дәү әти», «дәү әни» дип эндәшерме безгә ---?* Мәдәни җомга. **Күз карасы булу** Кемнеңдер яки нәрсәнеңдер эшкә яраксыз, гамәлсез булуы. *[Мингазиз:] Хәзер җибәрәм мин аны... (Сәгать янына килә.) --- Йөрми бит, каһәр! Их! Бетерәм! Җимерәм хәзер! Тормасын күз карасы булып...* Х.Ибраһим. **Күз карасыдай саклау** *к.* **күз карасы кебек саклау**. *– Бу тамганы күз карасыдай гына түгел, җаныңнан да кадерләбрәк сакларсың, – диде базарбашы, аның муенына тәңкәне асып.* Ф.Латыйфи. **Күз карасы кебек** Бик кадерле, бик якын. *Юк, юк, Мөхәммәт бабай, кешенең күз карасы кебек әйберен ничек курыкмыйча юлга аласың, ди.* Ф.Яруллин. *Шул ук вакытта итекләрен күрәләтә ярдыру да бик кызганыч иде аңа: алары да әтисеннән калган һәм күз карасы кебек итеп саклап кия торган итекләр иде.* В.Нуруллин. **Күз карасы кебек саклау** Бик кадерләп саклау. *Без --- сезгә җирдәге һәммә нәрсәне мирас итеп калдырган идек. Сез аларның барчасын да күз карасы кебек саклараыз --- дип уйлаган идек.* Р.Вәлиев. **---** *бездә эшләүгә бәйле бөтен нәрсәне күз караң кебек сакла.*

Ф.Галиев. *Язга минем бары тик бер китабым, күз карасы кебек сакланган бердәнбер китабым калды.* Г.Сабитов. **Күз карасын түгеп карау** Бик нык бирелеп, йотылып карау. **Күз карашка** Тышкы кыяфәтенә караганда. *[Хаҗи:] Юкса, күз карашка бер дә алай яшь кебек күренми иде.* Ш.Камал. **Күз көеге** Кемнең яки нәрсәнең дә булса кирәксез, артык булуын белдерә. *Сизеп торабыз, аның үзенә без «күз көеге», «җан көеге» генә.* Ш.Маннур. *[Рәхимә:] Бар әле, бар, кер әле, күз көеге булып торма каршымда, нәрсә дип әле мин синең алдыңда акланып торырга тиеш.* Х.Ибраһим. *Шул минутта аның җанында ботакка карата үчлек хисе калкып чыкты, һәм ул күз көеге булып яткан ботакның сыртына пычкысын зәһәрләнеп сызды.* Н.Хәсәнов. **Күз кунарлык** Матур; күңелгә хуш килерлек. *Шуңа күрә аңа йортсыз-җирсез сәрхушләр ияләнеп киткән иде ---, кайчакта хәтта күз кунарлык дип тапкан картиналарны да үзләре белән алып китәләр.* М.Маликова. *Мөгаен, Беләрев белән Шәрәфә үскән авылда күз кунарлык, яшүсмерләрне кызыктырырлык башка һөнәр иясе булмаганга шулай килеп чыккандыр.* К.Тимбикова. **Күз кушыру** *диал.* Төбәлеп карау. **Күз күгәрү** 1) Кемне яки нәрсәне дә булса түземсезләнеп, зарыгып көтү. *Кухняда пәрәмәчләр көя, көтә-көтә кунакларның күзе күгәрде.* Р.Вәлиев. *– Сабанга төшкәндә, --- бүтән эшкә кушмабыз, укырга керергә әзерләнерсең, диден. – Җиһаншин абый сугышта беләктән өзелгән кулын селкеп куйды. – Шушы вакыттан әзерләнә башласаң, дивана, күзең күгәрер!..* Х.Сарьян. *– [Степанны] төгәл дисез дә бит, берәр ресторанга юлыкса, – Зәйнулла, сул күзен кысып, телен шартлатып куйды, – көтә-көтә күзләрең күгәрер.* М.Насыйбуллин; 2) Ару, талчыгу. *Зур авыл ул, бер башыннан икенче башына чыга-чыга күзең күгәрер.* Ф.Яруллин. *Мәкаләне укып чыкканчы, Шәвәлиевнең күзләре күгәрде.* Ф.Садриев. **Күз күмергә әйләнү** Зарыгып бетү, озак көтү. **Күз күмерләнеп яну** *к.* **күз яну**. *Рабига һаман чибәр, әйеме? Күзләре күмерләнеп яна, әйеме?* Н.Гыйматдинова. **Күз күнегү** Кемгә яки нәрсәгә дә булса ияләшү, җайлашу. *Тау башына менеп туктагач, ул ирексездән аска, Аксыргак авылының күз күнеккән чуар нокталарына һәм --- буага карады.* А.Гыйләҗев. *Кунакханәнең салкын, шыксыз бүлмәләренә дә күз күнекте.* А.Әхмәтгалиева. **Күз күргән** Электән таныш булган, белгән. *Күз күргән, таныган кеше төсле күренәсең, нихәл, ни эшләп йөрисең?* Г.Камал. *Автоинспекциядә минем күз күргән кешеләр анда.* В.Нуруллин. *--- дәүләт комиссиясендә күз күргәннәрдән кемнәр булыр икән?* К.Тимбикова. **Күз күргән якка** Теләсә кайсы якка, юлны сайлап тормыйча. *[Карт:] Атыңны эләктерер дә күзе күргән якка сызар.* Ш.Камал. **Күз күрер** Нишләргә кирәклеге алда, вакыты җиткәч билгеле булыр, ачыкланыр. *Юк-юк, ул да ошатыр бу урынны. Ә ошатмаса? Ул чагында күз күрер.* Н.Әхмәдиев. *Эшнең асылын аңлагач кына, бер гаепсез Зотовны әрләде дә тынычланды: «Ярар, иртән күз күрер, бригадага шалтыратмый тор...»* С.Шәрипов. *– Ә син үзең кайда яшәмәкче буласың? – Аны-сын күз күрер. – Күз күрер дә күз күрер! – Зыятдин карт ачуын Ихтыярга кучерде.* Р.Вәлиев. **Күз күрмәгән** Сөйләүче кеше өчен чит, таныш булмаган. *Каядыр чит авылда, күз күрмәгән кешенең берәр фаҗига аркасында үлүен сөйләсәләр дә: «И, мескен», – дип елап ала иде.* М.Галиев. *Ә Шамил үзе Нәсимәгә карап шаяртқан була: – Төн уртасында әллә нинди күз күрмәгән адәмнәрне ияртеп йөрисең син, Нәсимә!* М.Вәли. *Дала һавасы төрле-төрле авазлардан тулышып таша сыман: тургайлар өздереп сайрый, чикерткәләр чырылдый, күз күрмәгән бөҗәкләрнең безләве ишетелә.* Р.Зәйдулла. **Күз күрмәгән, колак ишетмәгән** Искиткеч; гадәттән тыш; моңарчы күрелмәгән һәм ишетелмәгән; бөтенләй таныш булмаган. *Урман кулчасы буйлап югары менүгә, йомшак болытлар сине өсләренә утыртырлар да күз күрмәгән, колак ишетмәгән якка алып китәрләр төсле.* Ф.Яруллин. *[Әҗем] Югалып торыр да күз күрмәгән, колак ишетмәгән ят мал белән базар теленә керер.* Ф.Латыйфи. *Соңгы арада төннәр буе саташып чыгам, әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән җан ияләреннән качып, шулардан котылырга маташып, бастырылып бетәм.* Р.Вәлиев. **Күз күрмәслек, колак ишетмәслек** Ерак (ара, җир). *[Гали:] Бабаем, остазым, күз күрмәслек, колак ишетмәслек җиргә китәбез бит без.* Д.Аппакова. **Күз күрсә дә, кул җитми** Нәрсәне дә булса эшләргә кирәклеген белә торып, аны үтәргә вакыт булмау. **Күз кызу** Нәрсәгә дә булса кызыгу, аңа ирешергә омтылу. *Әмирләрнең үз машиналары булачак. «Жигули!» --- Их, малайларның күзләре кызар инде.* Р.Зәйдулла. *Авыл халкының күзен кыздырып, урам буйлап узарбыз.* Р.Вәлиев. *Бер дә башканыкына түгел, Мозаффарның картинасына күзе кызган бит әле.* М.Маликова. **Күз кыры белән карау** *к.* **күз кырые белән карау**. *Ул күз кыры белән генә алдында яткан икмәккә карап алды.* Р.Зәйдулла. **Күз кырые белән карау** Илтифатсызлык күрсәтеп, битарафлык белән, теләмичә карау, күзәтү; сиздермәскә тырышып карап алу; яратмыйча карау. *Начальник күз кырые белән генә миңа карап алды да өстәл читендәге кара төймәгә басты.* М.Юныс. *Яздым да --- Гөлнәзирәнең күз кырые белән генә минем якка борылып каравын, җавап бирүен көттем.* Х.Ибраһим. **Күз кырыен төшерү** *к.* **күз кырые белән карау**. *Фельдфебель аларның аякларына күз кырыен гына төшерде.* М.Гали. **Күз кысу** Нинди дә булса билге яки ишарә буларак, күз кабагын хәрәкәткә китерү. *--- мин әле автобусларына да күпвакыт түләми йөрим. Яшьрәк шоферлар булса, күз кыскалап алам да урындыкка посам.* Ф.Яруллин. *Урынбасар аңа күз кысып, башкаларныкын багарга ишарә ясаса да, кыз үҗәт булып чыкты.* Х.Ибраһим. *Ул Саимәгә таба ым белән ишарәләп, серле генә итеп Саматка күз кысты.* Г.Галиева. **Күзләр белән ашау** Тартынмыйча, оялмыйча, туп-туры карау; йотылып карау. **Күзләр биешү** *к.* **күзләр уйнау**. *Үзенең көн саен утырып ашый торган өстәленә карагач, Мөнирҗанның күзләре*

*биеште: булары аңкып торган тары боткасы һәм майда кыздырылган ипи телемнәре авызыннан сулар китерде.* Н.Әхмәдиев. **Күзләренә пәрдә кору** Ап-ачык беленеп, күренеп торган нәрсәне күрмәмешкә, белмәмешкә салыну. *Нурсөя генә, Гыймранга тугрылык саклап, күзләренә пәрдә корды менә.* Н.Гыйматдинова. **Күзләр зәһәрләнү** Күз карашы усаллану. *Гыйльметдин Харисович --- сикереп торды, йөзе агарды, күзләре зәһәрләнде.* Н.Дәүли. **Күзләр мәңгегә йомылу** *юг.* Үлү, вафат булу. *Ләкин искиткеч хәл: аның күзләре мәңгегә йомылмаган икән.* Г.Бәширов. **Күзләр очрашу** Күз карашлары туры килү. *Әлфис һаман, шул ук урында басып, Гөлкәй артыннан карап тора, кымшанмый да. Күзләре очраштылар.* Х.Ширмән. **Күзләр ут чәчү** Кемнең дә булса чаялыгы, шатлыгы-куанычы күзләреннән бөркелеп тору. *Фәрдәнәгә игътибар итми мөмкин түгел иде: шомырттай күзләре ут чәчә, теле телгә йокмый.* А.Вергазов. **Күз майлану** Караш уйнаклау; мутлану. *– Мин сиңа өстәл тактасы аркылы өч тапкыр коры кул белән сугармын, шуңа чыдый алсаң, кыз синеке, – дигән. Моны ишеткәч, хәзрәтнең күзләре майланган.* Әкият. *Кайчан карама – капка төпләрендә җигүле ат торыр, ә Сәмигулланың күзе майланган, эше җайланган булыр иде.* Ф.Яруллин. **Күз маңгайга менү** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Галимәрдәннең күзе маңгаена менде. Менә сиңа мә! Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас бу хәлгә!* Х.Ибраһим. *Кара инде бу велосипедны: руленнән тотмасаң да бара икән. Күргән малайларның күзләре маңгаена менде.* Н.Әхмәдиев. *Кәримә бу сәер тавыш тәэсиреннән айнырга да өлгермәгән иде әле, өйгә күзләре маңгаена менгән Әскәр Шәехович килеп керде.* К.Тимбикова. **Күз маңгайга сикереп менү** *к.* **күз шар (дай) булу**. *Каяндыр килеп кергән сәләмә генә киемле яшь бер килмешәк егетнең болай кискен җавап бирүенә шаккатып калган иде булса кирәк, Эшләпәнең күзләре маңгаена ук сикереп менде.* В.Нуруллин. **Күз маңгайга сикерү** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Раббани лап итеп урындыкка утырды, кулы белән күкрәген умырды, авызы ачылды, күзләре маңгаена сикерде.* Г.Әпсәләмов. **Күз мутлану** Хисләр уяну, шаянлану, шаянга әйләнү. *Кырый урамнарга бастымы, Шәмсетдиннең күзе мутлана.* Г.Бәширов. **Күз начарлану** Күзләрнең күрү сәләте кимү. **Күзне аера алмау** *к.* **күзне алмау**. *--- гудок тавышы аның йөрәгенә төшә, һәм ул, сихерләнгән кеше шикелле, поездан күзләрен аера алмый.* Ә.Еники. **Күзне акайту** *гади с.* Гаҗәпләнүдән, ачуланудан һ.б.ш. лардан күзләрне зур итеп ачу. *– Ха-ха, кара әле бу акыллы башны! – Витя Петровичка борылды. Тегесе беренче тапкыр күргәндәй күзләрен акайтып Шаманга текәлде.* Р.Зәйдулла. *– Лыгырдама юкны, Мойше, – диде Чуртан, күзен акайтып.* М.Насыйбуллин. **Күзне ала алмау** *к.* **күзне алмау**. *Ә өйгә кайтып үзләренә [егетләргә] чәй эчергәндә, аңардан күзләремне ала алмадым.* Т.Таһиров. **Күзне аларту** *к.* **күзне акайту**. *Арсланов ялт сикереп торды, дөпелдәтеп идәнгә типте һәм күзләрен алартып төкерек чәчте ---.* Ф.Садриев. *Җаббаровның төсе үзгәрде, һәм ул күзләрен алартып хатынына төбәлде ---.* М.Шаһимәрдәнов. *Сабит хатынга күзен алартып карады да, билетларны вак-вак кисәкләргә ерткалап, почмактагы чиләккә илтеп сипте.* А.Гыйләҗев. **Күзне алмау** Өзлексез озак карап тору. *Алдымда яп-яшь юкәләр, төз матур каеннар тора. Алардан күзне алып булмый!* М.Вәли. *– Мин дөрес әйттем, – диде Комзин, тикшерүчедән күзен алмыйча.* М.Насыйбуллин. **Күзне алу** Кемгә яисә нәрсәгә дә булса караудан туктау. *Ялчы Йолкымбай кымыздан күзен алды, чөнки өметләнү файдасыз иде.* Г.Ибраһимов. **Күзне ачу** 1) Йокыдан уяну. *Ничек йоклап киткәндер, Владимир Ильич хәтерләми, күзен ачканда, тышта инде яктырган, җил басылган иде.* Г.Әпсәләмов. *...Ул күзен ачканда, кояш юкәләр өстенә үк күтәрелгән, көн җылытып җибәргән иде.* А.Вергазов; 2) Кемгә дә булса берәр нәрсә турында дөреслекне ачу, нәрсәнең дә булса чын асылын ачып салу. *Күзебезне киеребрәк ачсак, бер нәрсәне күрербез, хан: Гүйәк хан безнең кан дошманыбызга әверелеп бара.* М.Хәбибуллин. *Рәхмәт, сез минем күземне ачтыгыз. Хәзер мин генерал булганчы укыячакмын.* М.Юныс. *Менә шул кечкенә генә ятим малай күземне ачты, ашкынып авылга кайтасым, энемне күрәсем --- килде.* Р.Габделхакова. **Күзне ачып йөрү** Карап йөрү, бик абай булу, саклану. *[Гәрәй]: Карагыз аны, моннан соң күзегезне ачыбрак йөрегез. Бәлки, каен янудa теге монтёрның гаебе бардыр.* Г.Шакирова. **Күзне ачып карау** Игътибар белән, дикъкать белән карау. *Әнә чана башында ята торган теге нәмәстәкәйне күрәсеңме?.. Юк, күрәм, дип кенә утырма, күзеңне ачып, ипләбрәк кара әле син аны!* В.Нуруллин. **Күзне ачырмау** Интектерү, йөдәтү, аптырату; сүз әйтергә дә ирек калдырмау. *Безне дә авылдан куа яздылар. Картымны – Мировой Әптелмән малае, мине – Карышкан кызы дип, күзебезне ачырмадылар.* Г.Әпсәләмов. *Әтисе --- яшь чакта шәһәрдә дә укыган. Илшат бу турыда малайларга әйтми. «Алдыйсың», – дип, күзне дә ачырмаслар аннары.* Р.Зәйдулла. *– Алай итмә, ач кайтаргансың дип, күзне дә ачырмаслар, [– диде әни].* М.Галиев. **Күзне гарешкә терәп** Аллага сыенып, Аллага ялварып; зур өмет белән. *[Вахит], күкрәк кесәсенә тегеп куйган догалыкларны алып, күзләрен гарешкә терәп укый торган иде.* М.Гафури. **Күзне ерта торган** Ачык, җете, күзгә бәрелеп торган. *--- алар Карл Маркс урамыннан үтеп барганда, күзне ерта торган яшькелт сары курткасына эре итеп «ДПС» дип язылган кеше аклы-каралы таягын сузган иде.* М.Маликова. **Күзне йокы алмау** Йоклый алмау. *Ул кичне мин, күземне йокы ала алмый, төне буе борсаланып яттым.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзне йокы басу** Бик нык йоклыйсы килү, йокы төшү. *Байкучатов ---, күзләрен йокы баса башлагач, урыныннан торып, оеган тәнен бөгелә-сыгыла язып алды ---.* Т.Әйди. *Тәслимә түти моңаеп, мавыгып, озак һәм күп итеп эрләде. Ниһаять, күзләрен йокы баса башлады.* М.Шаһимәрдәнов. *Күзебезне йокы баса*

*башласа, комнан мендәр ясап, кочаклашып йоклыйбыз.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзне калайландыру** *к.* **күзне тозландыру**. *Карчык, күзен калайландырып, тагын шул элекке сүзен сөйли башлады*. Г.Толымбай. **Күзне камаштыру** *к.* **күзне чагылдыру**. *Челтәр бизәк тотылган өй кыекларына, аклыгы белән күзне камаштырган икешәр, хәтта өчәр катлы ташпулатларга, чат саен диярлек күккә ашкынган нечкә манараларга сокланып озак йөрде Санька*. Ф.Латыйфи. *Чыңгыз күзләрне камаштырып янган ут нокталарга карамыйча, кою участогына таба атлады.* Н.Хәсәнов. **Күзне кан алу** *к.* **күзне кан басу**. *Кашның каралган чагы, Күзне кан алган чагы; Җырларбыз да, еларбыз да, Йөрәкнең янган чагы*. Җыр. **Күзне кан басу** Каты ачудан салкын канлылыкны югалту, нык ярсу, аек акыл белән эш итә алмау. *Житү чәчле егетләрнең күзен кан баскан, авызларында тәмәке иде.* М.Мәһдиев. *Әле күптән түгел генә кочаклашып үбешкән, араларыннан җил дә үтмәслек тоелган туганнарны алыштырып куйдылар диярсең: берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә бәхәсләшергә тотындылар, битләре кызарып чыкты, күзләрен кан басты*. Ф.Латыйфи. *Менә хәзер Гыйматдин абый шул турыда сүз кузгалткач, яшь ирнең --- күзләрен кан басты ---*. М.Шаһимәрдәнов. **Күзне каплау** Чынбарлыкны танырга, эш-хәлгә реаль карарга комачаулау. *Бер-бер артлы туган уллары, иренең комсыз тырышлыгы, юлда очраган киртәләрне эзлекле җиңә баруы аның күзен ал пәрдә белән каплады*. А.Гыйләҗев. **Күзне кису** *к.* **күзгә бәрелү**. *Саесканнар, Нәҗипнең күзен кискән үзгәрешләргә куанышкан сыман, үзара чыкыр-чыкыр киләләр иде.* А.Гыйләҗев. **Күзне күгәртеп** Озак. *Хәниф картлар кызларын күзләрен күгәртеп көтсәләр дә, яшь гаилә туп-туры Мөниржаннарга кайтып төште*. Н.Әхмәдиев. **Күзне күзгә текәп** Берберсенә карашып. **Күзне күзгә терәп** *к.* **күзне күзгә текәп**. *Бик озак торгач карашып, Күзне күзгә нык терәп, Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»* Г.Тукай. *Күзне күзгә терәп күпме торганбыздыр, берчакны бу, берни дә булмаган төсле, уен-көлке белән кушып әйтеп ташлый.* Ф.Хөсни. **Күзне күзгә төбәп** *к.* **күзне күзгә текәп**. **Күзне күтәрү** Туры карау. *Берничә көн Әсма Кәбиргә күзен күтәреп карамады.* Х.Сафина. *Хәзрәт туп-туры иттереп Сәгыйдәгә карарга батырчылык кылмаса да, Сәгыйдә һаман шул көләч йөз, һаман шул хәтфә тавыш белән: «Исәнме, хәзрәт?» – дигәч, ул акыртын гына күзен күтәрде.* Г.Исхакый. **Күзне кыздыру** Нәрсәгә булса да ия булырга теләк уяту, кызыктыру; нәрсә дә булса күңелне үзенә тарту, җәлеп итү. *Хәлим мәктәптә кесәсеннән чыгарган саен балаларның күзләрен кыздыра торган бик матур авторучкасын иптәшенә сузды.* Г.Гобәй. **Күзне кызыктыру** *к.* **күзне кыздыру**. **Күзне кытыклау** Җилкендерү, ярсыту. *Кәлимә --- күзне кытыклаучан ялтыравык дулкыннарга, алланып, инде баерга җыенган кояшка карап торды.* К.Тимбикова. **Күзне майландырып** Күз карашы белән нинди дә булса көчле теләкне, хисне чагылдырып. --- *балдызы, Бүләкне Гайфулланың кулына тоттырып: – Мә, рәхәтләнеп сөй инде кызыңны! Күзеңне майландырып карап торуларыңны күрмәде дип беләсеңме әллә? – диде.* Ф.Яруллин. --- *ул --- урындык аркасына авышкан Нурзифаның күзләренә текәлде. Ник болай күзләрен майландырып карый, нәрсәгә ишарәли?* М.Маликова. *Кәримә аңлады инде: Хәй Фәләхинең күз майландырып караулары әллә нинди астыртын ниятләр белән булмаган.* К.Тимбикова. **Күзне мөлдерәтеп** Ымсынып, ялварып, зур теләк, түземсезлек һ.б.ш. хисләр белән. *Ул ЦК секретаре, күзен мөлдерәтеп, шуны тыңлап утырсынмыни?* Ф.Садриев. *Сәвилә институттан кайтканда, бусага төбендә ике-өч, --- тагын да соңрак утыз-кырык җан иясе күзен мөлдерәтеп көтәр --- иде.* Н.Гыйматдинова. *Дамиры да, коридорда Гөлүсәне очраткан саен, күзен мөлдерәтеп, кызның артыннан карап кала ---*. Х.Ширмән. **Күзнең бер чите белән карау** *к.* **күз кырые белән карау**. *Филимонов кәгазьне алды, сүзен һич туктамастан, күзенең бер чите белән генә карады.* Г.Ибраһимов. **Күзнең нуры сүнү** Яшәү дәрте сүнү, нәрсәдәндер өмет сүрелү. *Ул тагын, чалгы очы тиеп киткән чәчәк сыман, киселде дә төште, күзләренең нуры сүнде, йөзе сулды, хәле китте.* К.Тимбикова. **Күзне очландырып** *к.* **күзне майландырып**. *Нигә күзен очландырып карый ул Сәвиләгә? Нәрсә тапкан?* Н.Гыйматдинова. **Күзне сөрәйтеп** Мәгънәсез караш белән карап. *Мин үземне кая куярга урын тапмадым. Ник бу сүзләрне ул сөйли, ә мин күземне сөрәйтеп утырам?* Г.Мөхәммәтшин. **Күзне сукырайту** Күңелең төшкән кеше яки әйбер турында гына уйлап, башкаларга игътибар итмичә йөрү. *Дөрес, җиде хатынга законлы өйләнеп, тугызы белән өйләнмичә генә яшәгән кешеләр, мәхәббәт күзне сукырайта, диләр.* Ф.Яруллин. **Күзне талдырганчы** Бик озак; озак итеп. *Күк зәңгәрлегенә күзләрне талдырганчы карап яткач, чатыр кора башладык.* Р.Вәлиев. **Күзне тасрайтып** Әрсезләнеп, киреләнеп, оятсызланып һ.б.ш. хисләр чагылдырып. --- *шикле егетләр --- Фәндиләгә күзләрен тасрайтып, ашардай булып карап узалар.* Г.Ахунов. *Зәмзәмбикә ---, син дә монда идеңмени әле дигән сыман, күзләрен тасрайтып, бер мәлгә текәлеп карап торды ---*. М.Хәсәнов. *Балалар, сез нәстә күзегезне тасрайттыгыз әле, утырыгыз табынга, утыр!* Н.Гыйматдинова. **Күзне тәреләндерү** Әрсезләнү, киреләнү. *Чукынып кына китсәң ие, энем Әлфәт! --- Инде котылдым бугай дип кенә барадырыем, тәки күзеңне тәреләндереп килеп җиттең бит, ә!* В.Нуруллин. **Күзне терәү** *к.* **күз текәү** (*1 мәгъ.*). *Кергән минуттан башлап залның төньягындагы калкуга, кызыл постаулы өстәлгә, әгъзаларга, бигрәк тә зур буйлы, ябык йөзле рәис Бигановка күзләрен терәде дә шуннан аерылмады.* Г.Ибраһимов. **Күзне тоз(дай итү)** *к.* **күзне тозландыру**. *Ансамбль җитәкчеләре унбиш көн Мәскәүдә укып яткан икән каһәрнең, шуңа күрә генә унбиш көн буена күзен тоздай итеп өйдә утырган икән.* Г.Мөхәммәтшин. *Келәмен кочаклап, күзен тоз итеп*

*көтеп тора бугай!* А.Гыйләҗев. **Күзне тозландыру** Нык теләү, тирән хисне күзләрдә чагылдыру. *Мин булачак ирем янына кунакка киләм, ә ул, авызына су капкандай, бер сүзсез күзен тозландырып карап тора.* Р.Вәлиев. *Ул да миңа: «Юкка көчәнәсең, барыбер сереңне беләм бит!..» – дигәндәй, күзләрен тозландырып карап тора иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзне томалау** 1) Алдау, ялганлау. *Өстенә шикаять арты шикаять яуса яуды, әмма Гайнан Ибраһимов ашыкмады. --- тузга язмаган вәгъдәләр биреп, башлыкларының күзен томаларга да маташмады.* М.Насыйбуллин; 2) *к.* **күзне сукырайту**. *Әнә шул тышкы сыйфатлардан күзем томаланды. Шулар белән исерүемне ярату бу дип алдандым.* Ә.Еники. *Әллә инде әзрәк томан бар, әллә матурлыгы күзләрне томалый дип уйлады Җәннәт.* Г.Әпсәләмов. **Күзне тондыру** Күзне акайту. *Идел буйларында кан эчәргә Дошман килә, күзен тондырып.* Ә.Ерикәй. **Күзне төбәү** *к.* **күз текәү**. *Алпамша бөтенләй башка... «Нигә җүләрләнәсең, килешми болай», – диген шикелле мыскыллы күзләрен төбәгән.* М.Галиев. **Күзне тутырып** *к.* **күзне мөлдерәтеп**. *Аннан залга чыктым. Бу юлы Нәҗип, күзләрен тутырып карап, мине каршы алды.* Ә.Еники. *Алар клубтан чыгып киткәндә, Фәриданең күзләрен тутырып карап калуын күреп, Саимә бераз уңайсызланды.* Г.Галиева. – *Кара, кара, – диде яңа кергән Газизә, аңа күзен тутырып карап һәм чигенә-чигенә.* Ә.Гаффар. **Күзне түгәрәкләндерү** Шаккату; гаҗәпләнү. *Рамазан хәләл җефетенә күзләрен түгәрәкләндереп карап: – Алар бит оптовой, – диде.* Г.Әпсәләмов. **Күзне тырнап** Бик иртә торып, кояш белән бергә уянып. *Кояш ярты сүәм күтәрелде исә күзен тырнап килеп җиткән Зиннәт тә иссезтынсыз.* Н.Гыйматдинова. **Күзне уйнату** Берәр төрле көчле хисне, теләкне һ.б.ны белдереп, күзләрне ялтырату; мутлану. *Җәннәт, --- шатланган булып: – Белми дә торам, бездә кунак бар икән, – диде һәм, шайтани күзләрен уйнатып, кунакка алсу кулын сузды.* Г.Әпсәләмов. *Мөршид, иренен турсайтып, күзен уйнатып, икенче иңбашын бүлтәйтте.* К.Тимбикова. --- *күзләрен уйнатып, кулларын селти-селти, тантаналы тавыш белән үзенең итәгенә төшмәгән утлы күмерләрне туздырудан --- ул бары тик ләззәт кенә алды.* Ф.Садриев. **Күзне ут итү** Кызыктыру. --- *Рөстәмгә өч тәгәрмәчле велосипед сатып алдылар, сала малайларының күзен ут итеп, --- кыңгырау чылтыратып йөрсен әле бер!* А.Гыйләҗев. **Күзне чагылдыру** 1) Бик матур, сокландыргыч нәрсәнең нык тәэсир итүе турында. *Бер дә тотылмаган, күзне чагылдырырлык ак яулык чыгарып, маңгаена тидергәләп алуга, тирәюньгә бик нәфис, бик тәмле хушбуй исе җәелде.* Г.Гобәй; 2) Ис китәрү, шаккатыру. *Урта кул Мәскәү сәүдәгәрләренә хас кәперәюгә, кергән кешенең күзен чагылдыруга исәпләнгән, --- бай җиһазлы бүлмәләрнең ишекләрен каерып ача килеп, Җәннәт иң зур бүлмә каршында туктады.* Г.Әпсәләмов. **Күзне чагырайту** *к.* **күзне чекрәйтү**. --- *аны күргән бер кеше, әллә аптырап, әллә көнләшүдән, артына әйләнеп, урам уртасында күзен чагырайтып калыр иде.* Х.Сарьян. **Күзне чекрәйтү** Нәрсәгәдер бик зур игътибар белән, әрсезләнеп, кыенсынмыйча карау. *Батыр әкә эшеннән туктап күзен чекрәйтте.* Н.Гыйматдинова. *Урамда кеше-фәлән күренми. --- Нәрсә эзли бу малай, дип, күзләрен чекрәйтеп карап торырлар иде.* Р.Зәйдулла. *Дустым ---, миңа теге дөньядан кайткан адәмгә карагандай, күзен чекрәйтеп карап торды ---.* Г.Мөхәммәтшин. **Күзне чекрәйтү** 1) Нинди дә булса өмет яки теләк белән текәлеп, төбәлеп карау. – *Кара, кара... оялмыйча, күзләрен челәйтеп, туптуры миңа карап тора бит әле, кабахәт! – диде ул кабатлап.* М.Шаһимәрданов. *Иң кызыгы да шул: төркем эчендә мөдир белән Зәйниләргә килгән ширантай инженер да күзен челәйтеп басып тора.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) *к.* **күзне чекрәйтү**. *Мин почмакта, телемне чыгарып, күземне челәйтеп, ертылган җиңемне җөйләп утыра идем.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзне читкә алу** *к.* **күзне читкә күчерү**. *Ул һәрдаим үзендә Адиләнең карашын сизә башлады. Ләкин карашлар очрашса, кыз, кызарып, күзләрен читкә ала.* Р.Зәйдулла. **Күзне читкә бору** *к.* **күзне читкә күчерү**. *Мөршид күзләрен читкә борды. – Әйттем бит: былтыр үлгән тавыкның быел исен чыгарып, сораштырып торма!* К.Тимбикова. *Алекси апа битемнән сөеп, мәгънәле генә елмаеп куйды. Ничектер каушап-уңайсызланып, күземне читкә бордым.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күзне читкә күчерү** Нәрсә өчендер кыенсынып, карашын читкә бору. *Авыр тынлыкны күтәрә алмады Сәет, күзләрен читкә күчерде, карашы бүлмә эчендәге җиһазлардан, түшәм, тәрәзә буйларыннан йөгереп узды.* Ф.Латыйфи. **Күзне шакмак итү** *к.* **күзне шар (дай) итү**. – *Яле, хатын, чыршы бәйрәме уздырып күзләрен шакмак итик әле таныш-белешнең, – диде Госман Галиев үзен каршы алган Гөлзифа ханымга.* М.Мәһдиев. **Күзне шар(дай) итү** 1) Күзләрне бик зур итеп ачу (кызыксынудан, гаҗәпләнүдән һ.б.ш. хәлләрдән). *[Курчак:] Күзегезне шар итеп, Юк вакытны бар итеп, Менә монда карагыз.* М.Җәлил. *Иң башта, аны күрүгә, ишек янындагы кечкенә аралыкта кер юып яткан Света күзләрен шардай итеп тураеп басты.* М.Вәли; 2) Бик нык гаҗәпләнү. **Күзне шар кебек ачу** *к.* **күзне шар(дай) итү**. *Тегесе башта аңышып ук җитмичә, ахрысы, берничә адым атлады, аннары күзләрен шар кебек киереп ачты ---.* М.Вәли. *Шәмси коты очып уяныл китте. Сизәр-сизмәс: – Анна, – дип куйды. Үзенең дә күзе шар кебек ачылды.* Г.Исхакый. **Күзне шарландыру** *к.* **күзне шар(дай) итү**. *Ярты сәгатьләп касса каршындагы чиратта торганнан соң, тәрәзәчек аша паспортын бирде һәм: – Зинһар, Мәскәүгә, иң якын рейска, – дип үтенде. Кассир гаҗәпләнүдән күзләрен шарландырды.* Р.Мирхәйдәров. *«Сине күммәделәрмени?!» – дип, күзләрен шарландырып тик ята чыпчыгым.* Н.Гыйматдинова. **Күзне (ут) яндыру** Кызыктыру, көнләштерү. --- *Газиз абый сөлектәй озын гәүдәсе, ияк урталары чокырланып торган чибәр йөзе, --- матур хәрби киеме белән йолдыздай*

*ялтырап, авыл малайларының күзен ут яндырды да --- китеп тә барды.* Х.Сарьян. *Синең орденыңны мин тагып чыгып малайларның күзен яндырырмын.* Ф.Яруллин. *[Һарун:] Бишмәтеңне әйтәм, үзеңә ничек килешеп тора. --- Акчаны җәлләмәдем инде, әйдә, егет кызлар күзен яндырырлык итеп киенсен, дидем.* А.Вергазов. **Күзне учларга яшерү** *к.* **күзне яшерү**. *Күзләремне учларыма яшереп чыгып киттем.* Ә.Баян. **Күзне яшерү** Тартынудын, оялудан кеше күзенә карамау. *Кыз, күзләрен яшереп, читкә борылды.* Ф.Яруллин. *Помполит Чоломбижко да --- дәшмәде. Күтәрелеп карарга базмыйча, күзен яшерде.* М.Юныс. *Батырлыгы хакында сөйләшү чамадан арта башласа, Сәрвәр, күзләрен синнән яшереп, читкә карап елмайгандай итә ---.* К.Тимбикова. **Күз нуры кебек** Үтә дә якын, үтә дә кадерле. *Аксак Йосыфның күз нуры кебек күргән бердәнбер кызы Мөнәвәрә --- Харис абыйга гашыйк булып акылыннан шашты.* М.Юныс. **Күз нурым** *к.* **күз алмам**. *Бәгырем, бәгырем, күз нурым! Нигә алай дисең, нигә елыйсың?* Ә.Еники. *Аның икенче хәсрәте – бердәнбер улы, күз нуры Туктар.* Х.Ибраһим. *Җиде бөртек бит сез, күз нурларым.* М.Насыйбуллин. **Күз нурын түгү** Күзләр белән бик җентекләп, тырышып карап эшләү, бик озак карап тору. – *Убырдан өйрәнгән үлән серләрен китап итеп язам. – Күз нурыңны түгепме?* Н.Гыйматдинова. *Асламчылардан сатып алган әйберләре белән әнине ул, күз нурларын түктереп, көн-төн утырткан.* Ф.Мансуров. **Күз очкынлану** Тирән хис, теләк һ.б.ш.ларның чагылышы буларак, күзләр ялтырау. *Искәндәрнең күзләре очкынланып китте. – Ә мин соң! Ә мин соң! Минме? Мин хәзер...* М.Мәһдиев. *– Туйдым шушы каһәр суккан наряд төзүдән. --- Үткән айда сез әйткәнчә тутырган идем, чак-чак тукмамадылар. --- – Билаловның күзләре очкынланды.* С.Шәрипов. *Ул чакларда Вафин унҗиде яшьлек егетләр кебек яшәрә, аның күзләре очкынлана ---.* Ф.Садриев. **Күз очы белән карау** *к.* **күз кырые белән карау**. *Лиза еш-еш күз очлары белән артист баскан почмакка карап ала.* Ф.Әмирхан. **Күз очы белән күрү** *к.* **күз кырые белән карау**. *Илбактының кыяр-кыймас кына үзенә якынлашуын күзенең очы белән күреп, Атилла туктады.* Р.Зәйдулла. **Күз очыннан ычкынмау** Игътибар үзәгендә булу, читтә калмау. *Ул оста итеп азга да канәгать булган чырай чыгара, әмма шул ук вакытта бер генә нәрсә дә аның күз очыннан ычкынмый.* Р.Мирхәйдәров. **Күз өйрәнү** *к.* **күз ияләшү**. **Күз өстендә(ге) (кара) каш** Бик кадерле һәм күңелгә якын кеше яки нәрсә турында. *Заманында күз өстендә каш идең бит син!* Г.Бәширов. *Гармун уйный белгән егетне кызлар күз өстендә кара каш урынына гына йөртәләр.* Н.Әхмәдиев. *Мәхмүт! Группабызның күз өстендәге кашы, бөтен кызларны сокландырырлык егет.* К.Тимбикова. *Азалияне күз өстендәге каш итеп үстердек.* Шәһри Казан. **Күз пыялалану** *к.* **күз томалану**. *Шунысын гына әйтәм: нибары сигез класс кына укыган, күзе пыялаланган, шапшак, исерек буяучы Зоя синнән-миннән күбрәк белә икән.* К.Тимбикова. *Тәминдар ишегалдында ниндидер уй корып йөри... Нәрсә майтармакчы ул? Күзләре пыялаланган...* Н.Гыйматдинова. **Күз салу** 1) Карау, карап алу. *Кемгә генә күз салма, бәрәңге ашап үскән гап-гади җир кызы булып чыга.* Ф.Яруллин. *Капитан, күперчекнең сул як канатына чыгып, пароходны тотып торучы бауларга күз салды.* М.Юныс. *Алтын Урда тарафына күз салырга да кыймый яшәгән Хулагу, Мәңгү хан ярдәмендә, Алгы Азияне яулау сылтавы белән, тычкан елында яу кузгала.* М.Хәбибуллин; 2) Нәрсәгә дә булса игътибар итү; аны тикшереп карау. *Яткын җырләрне үзләштерү шаукымы --- узган иде, шуңа күрәме, аръяктагы бу урынга кызыгучы да, күз салучы да табылмады ---.* А.Гыйләҗев. *Инде бишенче елның бирге ягына чыгып, Галимҗан Ибраһим иҗатына күз салыйк.* Г.Нигъмәти; 3) Ошату, ярату. *Менә сиңа Мәдинә... Гомер ир-атка күз салмаган кыз.* М.Галиев. *Рухия белән сөйләшербез, аңлашырбыз дип өметләнә иде. Шуңа күрә ул --- авылларында да, анна-ры Казанда университетта укыган елларында да бер кызга да күз салмады.* В.Нуруллин. *Мансур Ибраһимович ---, әллә инде Гөлкәйне яратмыйча, башка берәүгә күз салды микән?* Х.Ширмән. **Күз сирпү** Күзнең кырые белән генә яисә тиз генә карап алу. *Зөһрә ханым елмаеп, миңа хәйләкәр генә күз сирпеп куйды.* Ә.Еники. *Вафинга каршы утыручы Әхнәф Шәрифуллин, башын ишеккә таба борып, Иреккә җиңелчә генә күз сирпеп алды* ---. Ф.Садриев. *Хәбир абый, мин синең үзеңне чакырмакчы идем [кунакка]. --- Озакка түгел, күз сирпеп кенә чыгарсың.* Р.Вәлиев. **Күз суын түгү** *к.* **күз нурын түгү**. **Күз сүнү** Күзләрнең нурсызланып, өметсезлек белән каравы. *Һаҗәрнең --- йөзе агарынган, һәрчак ялкынланып торган күзләре сүнеп калган.* К.Тимбикова. *Берәү әле үлмәгән иде. --- Чәчләре тузып калган, күзләре сүнмәгән.* Ш.Рәкыйпов. **Күз талганчы** Озак итеп. *Карамаган булсаң да, миңа: «Әйе шул, Мәхмүт, күзем талганчы тәрәзәдән китә алмадым ---», – дип язуыңны сорар идем.* К.Тимбикова. *Түбән Кама урманнарын, Зәй, Кама болыннарын, --- түгәрәк күлләрен күзләр талганчы карыйсы --- калган.* Р.Вәлиев. *Туганнар, сөешеп туймастай булып, күзләре талганчы бер-берсенә карашып тордылар.* Ф.Латыйфи. **Күз талдырып** *к.* **күз талганчы**. **Күз тарту** Хорафат карашлар буенча: киләчәктә буласы берәр төрле хәлне белдерү билгесе дип санала. *Гөлфия --- берничә көн шул сөйләшүдән калган авыр тәэсирләрдән айный алмый йөрде: эче пошты, үзен кая куярга белми интекте, уң күзе тартты.* Р.Айзатуллин. **Күз тасраю** *к.* **күздә ут (чаткысы) уйнау**. *Төркемдәге ирләрнең аяклары ихтыярсыздан сәхнәгә якынрак атлады, күзләре тасрайды, иреннәре юешләнеп, авызлары ерылды.* М.Маликова. **Күз ташлау** 1) *к.* **күз төшерү** (*1 мәгъ.*). *Мин күз ташладым: томалып үскән үләне кендектән, ә чалгылары «түгызлы» иде.* М.Мәһдиев. *Зөһрә, өйгә күз ташлап алды да: – Әйбәт яшисез, молодцы, – дип, апаларының тормышларын хуплавын белдерде.* Ф.Яруллин. --- *еракка күз ташласаң,*

*сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә.* Ә.Еники; 2) Кемне дә булса ошату, ярату, аңа күз төшерү. --- *кыз үзе дә сизмәстән Зөлкамалга: «Әнә ул кара мыеклы, кылыч борынлы чибәркәй минеке булыр, аңа күз ташлама», – дип әйтеп ташламасынмы!* Р.Рахман. **Күз тәгәрәү** Аска табан карау. *Малайларның күз җиргә тәгәрәгән, тузанлы битләреннән кара тир ага.* А.Гыйләҗев. **Күз тегү** *к.* **күз текәү**. *Шәмси бик җентекләп урманга күзен текте.* Г.Исхакый. *Әмма Фарукҗан --- юл буендагы биек, ерактан караганда җиргә кадап куелган каз каурыен хәтерләткән байтирәкләргә күз теғеп озак онытылмады ---.* Т.Әйди. *[Ярулла] нәфрәт тулы, үч алу уты белән янган күзләрен казакъ егетенә тегәде ---.* З.Зәйнуллин. **Күз текәп** Өмет тотып, карап торып, зур игътибар белән. *Күз текәп торган ике атны бирәм, бигайбә, туганнар, шулар белән озатырлар, гаеп итеш булмасын.* А.Әхмәтгалиева. *Ә тол калып, мең хәсрәт белән күз текәп үстергән бердәнберең юньсез булып чыкса нишләрсең?* А.Гыйләҗев. **Күз текәү** 1) Төбәлү, туп-туры карау. *Елгага таба күзләрне текәп, тын калдым.* Р.Вәлиев. *Тилмереп ул күзләренә күз текәде.* Кол Гали. *Ул ике күзен тагы Сәгыйдәгә текәде.* Г.Исхакый. Озак итеп бер нәрсәгә карап тору. *Тикшерүче чүгәләп шул эзгә күз текәде.* Ф.Галиев; 2) Ышанып карау, өмет белән карау. *Бөтен дөнья йөзе бу көннәрдә Күз текәгән Мәскәүгә табан.* М.Гафури. **Күз терәп** Нәрсә дә булса өмет итеп; ышанып. *Башка барыр һич урын юк Бу хатынга, күз терәп.* М.Гафури. **Күз тигезү** Күзектерү. *[Мөхтәр:] Күзең каты булып, күз тигезсәң...* З.Хәким. **Күз тидерү** *к.* **күз тигезү**. *Мин, аңа сокланып карап: «Моннан да матур булса, аңа күз тидерәчәкләр ---», – дидем.* Ф.Яруллин. **Күз тимәсен** Хорафат карашлар буенча «кемне яки нәрсәне дә булса мактаудан, сокланып караудан аларга зарар килмәсен, начар булмасын» дигән мәгънәне аңлата. *– Һай, күзләрем генә тимәсен, – диде өлкән килен, – бигрәкләр дә оста кисәсең инде токмачны.* Ф.Яруллин. *[Габделбар абыйсы:] – Сөбханалла, Рәмзия, күз тимәсен үзеңә... Кара син бу чибәрлегеңне, буй-сыныңны, – дип, кызның бер үзенә, бер көзгедәге чагылышына сокланып карап торды.* С.Шәмси. *Бүз бала Җәгъфәр дә сөлектәй егет булып җитешеп бара. Күз генә тимәсен!* Ф.Латыйфи. **Күз тию** Күзегү. *Хөрмә төшләренең бер өлешен качырларга күз тимәс өчен кигезә торган муенчак төймәләре белән аралаштырып җепкә тездем дә муеныма киеп куйдым ---.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күз тия күрмәсен** *к.* **күз тимәсен**. *Машалла! Күз генә тия күрмәсен, алтын алма булып җиткән икән!* Ә.Еники. *«Ну, хатының да хатының. Күз генә тия күрмәсен, моны кайлардан таптың, бәхетеңне берүк югалтма», – диләр.* Ф.Садриев. **Күз томалану** *к.* **күз тону** (*2 мәгъ.*). *Әнә шул тышкы сыйфатлардан күзем томаланды, шулар белән исерүемне ярату дип алдандым.* Ә.Еники. *Сине күргәч, аның күзе томаланды.* Ф.Яруллин. **Күз тону** 1) Гаҗәпләнүдән, куркудан һ.б.ш.лардан күз аллары караңгылану, күз күрмәс хәлгә килү. *Уйлары төрле якка чәчелгән, теле көрмәкләнгән, күзе, тиле кешенеке сыман, тонган иде.* А.Гыйләҗев. *– Син, энем, милиция булсаң, милиция бул, чибәр яшь катынны күрдем дигәченнән дә күзең тонмасын, – [диде Маһибәдәр].* Ш.Максудова. *Машина йөрткәндә туп-туры карап йөр, юкса, чибәр кызлар күрсәң, күзең тона.* Сөембикә; 2) Күзгә берни дә күренмәү, күзгә ак-кара күренмәү. *Күрше хатыны әйтә, әнә без бер елны шулай [бозауны] чыгарган идек, капкабыз ачык булган, урамга ук чыгып китте, чак алып кердек, күзләре тонган, ди.* М.Мәһдиев. *– [Ирем] шушысы шул, – дип җөпләде аны Гаҗилә. – Күрмисеңмени: салмыш. Күзе тонган.* Ә.Гаффар. *Директорның күзләре тонган, тешләре кысылган, ә йодрыклары сугышырга җыенган калай әтәчнеке кебек йомарланган иде.* М.Шаһимәрдәнов; 3) *к.* **күз күгәрү**. *Сине кайтара алмый күз тонды.* С.Кудаш. **Күз тору** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Аны ишеткәч, безнең әбиләрнең күзләре торды, куркыша башладылар.* М.Гали. **Күз тоту** 1) Нәрсәгәдер ният, исәп тоту; берәр нәрсәне алдан чамалау. *Ә бабайның күз тотып йөргән участогы да бар икән.* Ә.Еники; 2) Күңел төшү, ошату. *Хәйдәр күз тотып йөридер, ди, көн дә шуның янында буладыр, ди.* Г.Бәширов. **Күз төбәп** *к.* **күз терәп**. *Аның күз төбәп кайткан якыннары әнә шулар иде.* Ә.Еники. *Ул вакытта аларның күз төбәп торган Ванялары Себер колониясендә тәрбияләнүче «Чекушка» кушаматлы угрыга әйләнгән була инде.* М.Насыйбуллин. **Күз төрткесез** Берни дә күрмәслек. *[Ярми:] Салгандыр, шельма! Күз төрткесез караңгыда пычрак ерып йөрмәсә.* Ә.Гаффар. **Күз төшерү** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса карау, карап алу. *Аны-моны караштыргач, әни миңа күз төшереп алды да, гүя болай гына сорап куйды.* Ә.Еники. *[Егет:] – Кирәксә-кирәкмәсә дә кеше сүзен бишкә бүлеп утырганчы, бераз газета-журналларга күз төшергәләсәгез яхшырак булыр иде, – диде.* М.Хәсәнов. *Саимә янәшәдәге буш караватка күз төшерде.* Г.Галиева; 2) Игътибар итү. *Җизни чит-ят хатын-кызга күз төшермиме?* Ф.Яруллин. **Күз төшмәслек** Күзгә ташланмый торган, ышанычлы (урын). *Мәрьям абыстай [портсигарны] һәркемгә бер тапкыр күрсәтеп чыкканнан соң, бу затлы әйберне каядыр, һич кеше күзе төшмәслек җиргә яшереп куя.* Ә.Еники. **Күз төшү** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса игътибар итү, күреп алу. *Мин инде трамвайны көтмичә китеп бармакчы идем, шул чакта сезгә күзем төште...* Ә.Еники. *Шулчак Сафураның күрше тәрәзәдәге утка күзе төште.* Х.Ибраһим. *Әлбәттә, кызлардан алдарак чишенеп куйды Билал һәм кулларын уа-уа кухня ягына таба узса – өстәлгә күзе төшеп, шаклар катты!* М.Вәли; 2) Күңелгә ошау; гашыйк булу, ярата башлау. *Тузганак башлы Миңсылуның да бу юеш танауга, нигәдер, күзе төшмәде.* Ф.Яруллин. *Авыру әнисен саклап кияүгә чыкмыйча калган Миңнурыйга күзе төшеп йөргән аның [Мөбарәкшаның].* М.Мәһдиев. *Аннары бит яшь чакта, бер күзең төшкәч, кешене ничек тә матур итеп*

*күрергә тырышасың*. Ә.Еники. **Күз туйганчы карау** Озак итеп, күңел булганчы карау. *Ул инде, әлбәттә, аны сөймәячәк, иркәләмәячәк, тик күзләре туйганчы карап кына калачак иде.* М.Маликова. *Әмма Зөләйха апа үзенең бөркетенә күз туйганчы карарга да, күрше-колан арасында әз-мәз мактанып, горурланып калырга да өлгермәде.* Г.Мөхәммәтшин. **Күз туймау** Нәрсәдер җитәрлек булмау яки, күп булса да, канәгать булмау. *Мәҗлес таралды, үзе туйса да, күзе туймаганнар оркестр уйнап торган зур залга үттеләр.* Р.Мирхәйдәров. **Күз түбәгә мену** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Хәбәр, чынлап да, шаккатырлык иде. Малайларның күзләре түбәгә менде.* М.Кәрим. **Күз түгәрәкләнү** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Директорның кысынкы күзләре түгәрәкләнеп китте. Бу фәрештәдән ул һич тә мондый сүз көтмәгән иде.* Ф.Яруллин. *– Молчок! – Әзһарның күзләре яшелләнеп китте, иреннәре калтырый, күзләре түгәрәкләнә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Гариза укыган саен, аның күзләре түгәрәкләнә барды.* Ф.Садриев. **Күз тышта калу** Тыштан өйгә кергәч, беркадәр күз алды караңгыланып тору. *Күз тышта калган иде – кергән мәлгә берни күреп булмады.* Г.Ахунов. *Көчле кояш нурлары астында күзне камәштереп ялтырап яткан карга карап булмый, әбиебез әйтмешли, күзләр тышта кала.* Г.Сәгыйров. **Күз угы** Кемгә яисә нәрсәгә дә булса төбәлгән күз карашы. *Татар да, безнең күз укларын хис итеп булырга кирәк, күзләрен газетадан алып, әүвәл кызга, аннан соң миңа карап куйды.* Ф.Әмирхан. **Күз угы белән тишү** Төбәлеп карау. --- *Сәмария ахирәтенең колагында җемелдәгән алкаларны күз угы белән тишкәләп: – Яраган инде, – диде.* Н.Гыйматдинова. **Күз угында тоту** Игътибар үзәгендә тоту. *Имамнар гына түгел, Йосыф кахан яһүдләре дә аның һәр адымын күз угында тоталар.* М.Хәбибуллин. *Валя да аны гел күз угында тотты, егетнең итәгенә төшкән икмәк валчыгын сыпырып алды* ---. Җ.Дәрзаман. **Күз уйнаклау** *к.* **күз уйнау**. --- *берсе әдәпле кешегә охшаган, икенчесе итагатьсезрәк, ахры. Күзләре уйнаклап тора, сирәк кенә елмаеп ала.* С.Шәрипов. *Пани --- долларлар чыгарды. – Мин түли, – дип елмайды ул, аның елмаюында серлелек сизелде. – Мин сез бурыч... – Карышсам да, пани ирек куймады, күзләре уйнаклап, зәһәрләнеп алды хәтта.* М.Хуҗин. **Күз уйнау** 1) *к.* **күз ялтырау**. *Ә беркөнне, шулай ук шахта ягыннан кайтып, Хәерnisаларга кунакка килгән Әсхәбкамал исемле мут, хәтәр бер кызны (күзләре уйнап торган, имеш) тотып алып бер чәй чокыры портвейн эчерткәннәр* ---. М.Мәһдиев; 2) Нәрсәне дә булса нык теләү, нәрсәгә дә булса кызыгу. *Акчасы булганның кулы уйный, булмаганның күзе уйный.* Мәкаль. **Күз уңына алу** Күзәтү; игътибарга алу. *Ничек кенә булмасын, бу кеше хәзергә шикleләр исемлегендә кала бирде, күз уңына алынды...* Ә.Сафиуллин. **Күз уңына эләгү** Игътибарга алыну, күзәтелеп тору. *Иң беренче чиратта, җенси характердагы җинаятьләр кылырга сәләтле дип, хокук саклау органнары күз уңына эләккән, бигрәк тә хөкем ителгән ир-егетләр тикшерелә.* Мәдәни җомга. **Күз уңында булу** Игътибар үзәгендә булу. *Нигә һәркемнең --- күз уңында буласы, ишләренең уйлары белән идарә итәсе килә?* Р.Зәйдулла. **Күз уңында тору** *к.* **күз уңында булу**. *Әллә юан Машкадан баш тартканга, әллә кибет директорының гел күз уңында торганга, аны тиздән экспедитор итеп куйдылар.* Х.Ибраһим. **Күз уңында тоту** 1) Күзәтү; истә, игътибарда тоту. *План – бер хикмәт, аны үтәү – икенче мәсьәлә, ә үтәлешне тикшерү, күз уңында тоту – иң кирәклесе.* С.Шәрипов. *Габдерәшит 1881 елда яңадан Истанбулга әйләнеп килгәч, бәйсезлеген беркайчан да җуймаган, кардәш төрки халыклар, кабиләләр мәнфәгатен дә күз уңында тотарга тырышкан төрек җәмгыятенең алдынгы өлеше белән танышырга омтыла.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Сүз дә юк, чит илдәге яңалыклар белән дә танышып барабыз, җитештерү һәм сыйфатка караган технологияләрне күз уңында тотабыз.* Р.Мирхәйдәров; 2) Нәрсәнеңдер булу-булмау ихтималын телдән әйтмичә генә фараз итү, исәпләү; күздә тоту. **Күз уңыннан җибәрү** *к.* **күз уңыннан ычкындыру**. *Иртәгәсен Харис хатынын күз уңыннан җибәрмәде.* Ә.Моталлапов. **Күз уңыннан җуймау** Онытмау, истән чыгармау; игътибар үзәгендә тоту. *Ләкин Билал үзенең уң ягындагы фәрештәне бер генә мизгелгә дә күз уңыннан җуймый, кыз аның ягына карамаса да, һәр хәрәкәтен күреп, һәр сулышын тоеп утыра.* М.Вәли. **Күз уңыннан төшермәү** *к.* **күз уңыннан җуймау**. *Хәтта исем кушканда да, кеше исемен тел һәм сөйләм берәмлеге дип карап, аның бүтәннәргә ничек тәэсир итәчәген күз уңыннан төшермәскә кирәклеген кисәтә Сарьян.* И.Низамов. **Күз уңыннан үткәрү** *к.* **күз алдыннан уздыру**. **Күз уңыннан читтә калмау** *к.* **күз уңыннан җуймау**. *Ләкин монда да беркемнең сыңар сүзе, кыек карашы, ымыишарәсе аның күз уңыннан читтә калмады.* Р.Зәйдулла. **Күз уңыннан ычкындыру** Онyту, истән чыгару; игътибар итмәү. *[Айсылу:] Әйе, бераз һавада йөреп кайтабыз. Син Альбертны күз уңыннан ычкындырма.* Ф.Яруллин. *Тәртипсезлекләр көчәя анда. --- ул ротага быелгы чыгарылыштан кадровый офицер сораячакбыз, ә хәзергә бу ротаны күз уңыннан ычкындырырга ярамый.* С.Шәрипов. *Казанга Шаһгали белән юнәләсе Фёдор Карповка әйтеп куярга кирәк, дип уйлады патша, бу огланны күз уңыннан ычкындырмасын.* Р.Зәйдулла. **Күз уңыннан югалу** Кем яки нәрсә дә булса кинәттән юкка чыгу. *Номердагы күршесе иртәнге телефон трубкасына ябышкан хәлдә башлап җибәрә, клиентларның адреслары һәм телефоннары язылган калын дәфтәр көннәр буе язу өстәлендә ята, ул бары тик кунаклар килгәндә генә күз уңыннан югала.* Р.Мирхәйдәров. **Күз ут булу** Берәр төрле көчле теләк, хис чагылышы буларак, карашның җанланып, дәртләнеп китүе. *Кәмран мәктәпкә чынлап та килгән булган. Әгәр шәрикташләрем арасында ялган гыйшкыма ышанмаучылар бар икән, менә, мин әйтәм, күзләре ут булсын хәзер үзләренең.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күз ут кебек яну**

Көчле теләк, хисне белдереп, күзләр бик нык ялтырау. **Күз уттай яну** *к.* **күз ут кебек яну**. *Валлаһи, гашыйк булгансың, Күзләрең уттай яна.* М.Җәлил. **Күз ут шикелле яну** *к.* **күз ут кебек яну**. **Күз үлчәве белән** *к.* **күз чамасы белән**. *[Алтын] бит күз үлчәве белән казанга салына торган бәрәңге түгел.* Ш.Камал. **Күз үлчәме** Берәр озынлыкны, зурлыкны, ераклыкны күз белән билгеләү, күз белән чамалау. **Күз үткенлеге югалу** Күзнең күрү сәләте начарлану. *А витамины җитешмәве күзнең үткенлеге югалуга, үсешнең тоткарлануына --- китерә.* Урман аптекасы. **Күз чагылу** Нәрсәгә дә булса бик нык соклану мәгънәсендә әйтелә. *Ирек, бар байлыгын – кечкенә сумкасын тотып урамга чыккач, дөньяның аклыгына күзе чагылып, һушсыз калып торды.* Р.Вәлиев. **Күз чалшаю** Күз кылыйлану. *--- таң атканда, мөәзиннән ачкыч алып, мәчет эчендәге баланы табып алып кайтсалар – аның бер күзе чалшайган.* М.Мәһдиев. **Күз чамасы белән** Күз белән чамалап. *Хәзер мин карандаш тота белү өстенә әйберләрнең пропорциясен күз чамасы белән чамалап ала белергә тиешмен.* Гөлшәһидә. **Күз чаткылану** *к.* **күзләр җылыну**. *– Минем йөрәккә дә чират тимәсме, дим шул. – Лейтенантның күзләре чаткыланып китте.* Х.Камалов. **Күз чекерәйтү** Әрсезләнеп карау. *Каршыларында Мостафин кадәр Мостафинның хатыны басып торгач, әйтергә тиешләр ләбаса! Юк, хәерсезләр, әйтмиләр, песнәк күргән ата мәчедәй, күзләрен чекерәйтеп тик карап торалар...* Ә.Еники. *Көне буе күзен чекерәйтеп үз фамилиясеннән күзен алалмыйча яткач, фән белән шөгыльләнүен дәвам итәсе килде.* Х.Ибраһим. **Күз чекерәю** Акаю, караштa усаллык, әрсезлек чагылу. *Аның сөйкемле йөзе бүген яшелле-зәңгәрле төс алды: уймак авызы турсайды, күзләре ачулы чекерәйде...* Г.Иделле. **Күз челәйтү** Көнләшү, күпсенү. *Ә Гафият абзагыз? Әллә ул берәүнекеннән дә күпсенмиме? Кая инде күпсенмәү! Гафият булсын да кешенекенә күз челәйтмәсен, имеш.* И.Гази. **Күз чите белән карау** *к.* **күз кырые белән карау**. **Күз читен төшерү** *к.* **күз кырые белән карау**. **Күз чыга язу** Бик озак көтү яки нәрсәне дә булса эзләү. *[Ирбулат:] Болай да Сабир абый справкасын эзләп күзем чыга язды.* Р.Ишморат. **Күз шар кебек ачылу** *к.* **күз шар(дай) булу**. **Күз шарланып китү** *к.* **күз шар(дай) булу**. *Моны күргәч, Ибраһимның күзләре шарланып китә.* Г.Гобәй. **Күз эленү** 1) Йокы басу, йоклыйсы килү. *Хафиз байның --- юлда шактый араларны йоклап кайтуы сәбәпле, күзләре эленергә уйламый иделәр булса кирәк.* Ф.Яхин. *Чалы кошы, ят инде син, ят. Әнә бит арудан күзләрең эленгән, тәмам йокы баскан үзеңне.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) Караңгылану, караңгы төшү. *Күктән җиргә кара айгыр төште. Күз эленде.* Р.Зәйдулла. **Күз юлы** Чәч аермасы, чәчне як-якка аерып торган эз. *Сәвиянең яңаклары алсу, кара күзләре көләч, ак маңгай өстеннән күз юлы ачып үрелгән чәчен баш очына урап куйган.* Р.Хәбибуллина. **Күз явын алу** Үзенең матурлыгы белән бик нык аерылып, үзенә җәлеп итеп торган әйбер турында. *Өстәл өсте күз явын алып тора: кечкенә графин, нечкә саплы рюмка, --- бар да нинди тәртип белән куелган.* Ә.Еники. **Күз явын алырдай** *к.* **күз явын алырлык**. *Каеннар күз явыңны алырдай яшел шәлләрен сары шәлгә алыштырган ---.* Г.Ахунов. **Күз явын алырлык** Бик матур, бик шәп. *Ә бит гади халык арасында да күз явын алырлык гүзәлләр --- күп булгандыр.* Ф.Яруллин. *Секретарьның өстендә куе зәңгәр төстәге һәйбәт костюм. --- күз явын алырлык ап-ак челтәрле кофтасының изүләре аз гына ачык.* М.Хәсәнов. *Шаһбаз, --- билгеле, үзен дә онытмады: күз явын алырлык кара лакированный туфли алып киде.* Х.Ибраһим. **Күз яздыру** Кемнәндер качарга омтылып, юлны махсус бутау. *Рәзил, олылардан күз яздырып, балыкка сыпыру ягын карады.* Ф.Яруллин. *Болак күперен чыгуга, «чуарбаш», тегеләр малайны почта киоскысы янында калдырып, билет сата торган кассага керә. Ләкин ул моны бу юлы да күз яздыру өчен генә эшли булса кирәк.* М.Насыйбуллин. *Бүген качарга дип карар кылган өч әсир, --- эт кебек күзәтеп торган немец солдатларыннан күз яздырып, --- торба эченә кереп йомылдылар.* М.Галиев. **Күз язмау** *к.* **күздән ычкындырмау**. *Бәлане Байкучатов чыгаруы ихтимал, аңардан менә күз язмау әһәмиятлерәк.* Т.Әйди. **Күз ял итәрлек** Матур, ямьле. *Урам Эзи юлы шикелле үк изелеп, җебеп, чокырланып беткән. Күз ял итәрлек янбакчалар да, миләш, шомырт, сәрви куаклары арасында балкып утырган умарталар да юк.* А.Гыйләҗев. **Күз ялтырау** Берәр төрле көчле хисне, теләкне һ.б.ларны белдереп, күзләр нык җанлану. *Нурзифаның тавышында --- үзен дә әңгәмәдәшеннән өстен кую чагылды. Моны тоеп алган Хәнәфинең күзләре хәтәр ялтырап алды.* М.Маликова. *Тикшерүченең кулында өр-яңа йөзәрлекләр кыштырдап тора иде. Җинаятьченең күзләре ялтырап алды да сүнде.* М.Насыйбуллин. *Ара-тирә авылдан-авылга коткы таратып йөрүче ниндидер кешеләр килә. Үзләренең күзләре ялтырый, сөлгене башка катлы-катлы урaганга, муеннары неп-нечкә күренә.* Р.Зәйдулла. **Күз яну** 1) Нинди дә булса хистән караш очкынланып китү. *Торабара Гайсә дәрте ташып, күзләре хәтәр янып торган бу хатын өчен иратның яше-карты, матуры-ямьсезе дигән төшенчәнең юклыгын аңлады.* Ф.Садриев. *– Әйдә, без аны сагалап торабыз да уктан алабыз, – диде Бәркә хан ---. Габдулла оланның тәмам күзләре яна башлады ---.* М.Хәбибуллин. *Фәнни конференциядә чыгыш ясаганда, күзләреңнең ничек янганын мин бик яхшы хәтерлим!* Г.Шакирова; 2) Нинди дә булса омтылыш барлыкка килү, теләк уяну; кызыгу. *Хикмәйләр матур гына особнякта тора икән. Җәннәтнең күзләре янып китте.* Г.Әпсәләмов. *Басуга якыная төшсәләр, сыерларның күзе яна башлый, аларга сарыклары да ияреpгә генә тора.* Н.Әхмәдиев. *– Ә нигә бармаска инде?! – дип чәпченде Шәмсенур. Бүләк аласын сизгән хатынның күзләре уттай яна иде.* Х.Ибраһим. **Күз ятьмәсе** Кеше күз алды, күзәтү, игътибар. *Күз ятьмәсендә чәбәләнеп яшәве бер дә рәхәт түгел*

*икән.* Н.Гыйматдинова. **Күз яше агызу** *к.* **күз яше түгү**. *Сүз әйтер хәл юк, күз яшеңне агызырга тотынасың. Ни булды сиңа?* Г.Галиева. *Королеваң бик шәп булганга, кичә күз яшьләреңне агызып утырдыңмы?* Ф.Яруллин. **Күз яше аралаш** Күзгә яшьләр тулып; елау катыш. **Күз яше белән** Елап, яшь аралаш. *Бөтен төнне ире турында, үткән гомере турында кайгылы уйлар белән, күз яше белән кичерде.* Г.Ибраһимов. **Күз яше катыш** *к.* **күз яше аралаш**. *Ләкин элекке заманнардагы кебек күз яше катыш шатлык бер дә булмады.* Г.Ибраһимов. *Сәгыйдә (күз яше аралаш): – Рәхмәт, Сөләйман абый, – диде.* Һ.Такташ. **Күз яшенә буылу** Каты елаудан сүз әйтә алмыйча тору; туктаусыз күз яшьләре агызу. *[Фәнис:] Ә әни... (Күз яшенә буылып.) Ә әни минем – чын кеше, чын...* Х.Ибраһим. **Күз яшенә төелү** *к.* **күз яшенә буылу**. *Җиргә иелеп, Ул томанга нидер сөйли, Күз яшенә төелеп.* М.Җәлил. **Күз яшенә тыгылу** *к.* **күз яшенә буылу. Күз яшен түктерү** Кемне дә булса газапхәсрәт чиктерү, интектерү. **Күз яше тоту** *к.* **күз яше төшү**. **Күз яшерү** Туры карамау, күзгә карамау. *Бусагачы аңа гаҗәпләнеп карады да, күзләрен яшереп: – Һәрвакыттагыча, тәкъсир... – дип мыгырдады.* Р.Зәйдулла. **Күз яше төшү** Хорафат карашлар буенча: кемнеңдер каргавы яки рәнҗүе сәбәпле бәла, бәхетсезлек килү. *[Миңнулла] Шишковка хатыны һәм балалары белән хушлашырга кушты. --- [Григорий Петрович:] – Әллә калдырасыңмы, энекәш, балалары бик кызганыч бит, күз яшьләре төшәр, – диде.* В.Нуруллин. **Күз яше түгү** Күз яше белән елау. *Кайгымны эчемә җыеп яшәдем. Шул гомер эчендә күпме күз яше түккәнемне бер үзем генә беләм.* Х.Ибраһим. *Әле дә хәтерендә җиңгинең --- бер як күкрәгенә сабыен, икенчесенә үлем хәбәре китергән хатны кысып күз яше түккәннәре...* М.Шаһимәрданов

**КҮЗ АГАЧЫ** *и. иск.* Туку станында буй җепнең (буйлыкның) очын беркетү өчен хезмәт итә торган җайланма

**КҮЗ АГЫ** *и. анат.* Күз алмасының ак тышчасы. *Мужҗәннең кыяфәте чынлап та әйбәт түгел. Йокы күрмәгәнгә, күзенең агына хәтле балавыз кебек саргайган иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮЗ-АКЫЛ** *җый. и.* Күрү һәм фикер йөртү сәләте. *– Нинди Кифая булсын, ди, ул сиңа? --- Апа дип сөйләш! – диде әти. – Әйтми генә торыйм әле! – дидем мин киреләнеп. Әрнү-үртәлү хисләре күз-акылны томалаган чак иде.* Р.Габделхакова

**КҮ́ЗАЛЛАУ** I *ф.* 1) *махс.* Элек кичергәннәрне, баштан үткәннәрне аңда, хәтердә яңадан торгызу, күз алдына китерү. *Кайчакларда ул сагынуны котсыз кыяфәтле, караңгы чырайлы, Шүрәледәй куркыныч зат итеп күзалларга тырыша.* Ф.Җамалетдинова. *Мирза сөйгәнен хәзер дә элекке кыяфәттә күзаллый.* Ә.Моталлапов

2) Берәр нәрсәне беркадәр аңлау, төшенү. *Х.Сарьян туган телнең барлык нечкәлекләрен оста сиземли, сүзлек байлыгын күзаллый, телнең эчке механизмын хәрәкәткә китерүче бөтен нечкәлекләрне күрә белә.* Ф.Сафиуллина. *Җанны мин эчтә, күкрәк турысында, офыкка барып тоташкан зәңгәр күге, чишмәсе, --- инеше булган олы бер дөнья итеп күзаллыйм.* М.Галиев. *Ә төсләр балкышы халыкның матурлыкны бәйрәм дәрәҗәсендә күзаллавын аңлата.* Сөембикә

**КҮ́ЗАЛЛАУ** II *и.* 1) Фикердә-уйда, хыялда барлыкка килгән, күңелдә гәүдәләндерелгән образлар, фаразлар. *Галәм төзелеше турындагы хәзерге күзаллаулар акрынлык белән формалашканнар.* Табигать белеме. *Специфик булмаган тынычсызлаучылар китереп чыгарган тойгылар предмет турында ялгыш күзаллау тудыра алмыйлар.* Анатомия

2) Берәр нәрсәгә карата билгеле мөнәсәбәт, караш. *Иманым камил, күзаллаулар төрлечә булса да, иң соңгы нәтиҗә уртактыр: безнең өчен Тукай шагыйрь генә түгел, аның инсанлыгына изгелек сыйфатлары да салынган ---.* Сөембикә

**КҮ́З АЛМАСЫ** *и. анат.* 1) Баш сөягенең күз чокырларына урнашкан, шар формасындагы күрү әгъзасы. *Ә беркөнне кинәт кенә аппетит бетә, ул арада күз алмасында сары төс сизелә ---.* М.Мәһдиев. *Күз алмалары атылып чыгар дәрәҗәгә җитеп киерелде, йөрәк ярсып-ярсып типте.* Р.Вәлиев. *Аның [Ибрайның] күз алмасындагы дымсулык кипкән иде инде.* Ә.Гаффар

2) *ирк.* Берәр кешегә карата иркәләп әйтелә торган, «җаным», «бәгърем», «сөеклем» мәгънәсендәге мөрәҗәгать сүзе. *Шул көннәрнең якты хатирәсе, кайнар мәхәббәте җимеше булып, менә шушы күз алмасы, бәгырь пәрәсе – нәни кызы дөньяга килде.* Х.Сафина. *[Хатын:] Күзалмам, үзеңне саклый күр, сабыйларың өчен, сине сагынып сөюче --- иптәшең өчен саклый күр.* А.Шамов

◊ **Күз алмаларын уйнату** *к.* **күзне уйнату**. *Хатын аңа җавап бирмәде. Күз алмаларын уйнатып: – Сез Караталдан ахры? – диде.* А.Гыйләҗев

**КҮ́ЗАЧКЫСЫЗ** *с.* Күзләрне ачарга ирек бирми торган, көчле. *Кара буран, күзачкысыз җил котырган көн була бу!* А.Гыйләҗев

**КҮЗӘ** *и. к.* **кужә**. Төелгән тарыдан яисә бодай ярмасыннан пешерелгән ботка

**КҮЗӘЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **күзләү** I. *Җомагыл тәрәзә төбенә утырган да үзенең нуры сүнеп бара торган коңгыр күзе белән әледән-әле Гөлсемне күзәли.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**КҮЗӘНӘ** *и.* Чәчкечтә орлыкларны рәт-рәт итеп чәчеп бару өчен хезмәт итә торган җайланма. *[Сапай карт:] Машина өчен орлыкны аеруча нык иләргә кирәк, менә мин карап бардым, машинаның күзәнәсенә бер солы эләккән, аны чәчүче күрми.* М.Җәлил

**КҮЗӘНӘК** *и.* 1) Нинди дә булса предметның эчендә булган вак куыкчык, кечкенә бушлык. *Бу каекның авырлыгы 200–250 кг тирәсе, су өстендә җиңел йөзә. Ләкин тора-бара камыш күзәнәкләренә су сеңеп, 8–10 айдан ул яраксызга чыга.* А.Муранов. *Менә аның тирән кунычлы кун калошлары күзәнәкле бозга баттылар.* К.Нәҗми // Икмәк эчендә барлыкка килгән кечкенә куык, бушлык. *Шүрлектән күпереп пешкән ярты ипи үзенең эрелеваклы күзәнәкләре белән карап утыра иде.* Г.Гобәй

2) Бал кәрәзендәге оячык, тишек, күзчек. *Күзәнәкләрдәге сыек бал, суырту көченә каршы тора алмыйча, машина стенасына сибелә.* А.Алиш. *Умартага куелган кәрәзләргә бал тутырылып, кортлар кәрәзнең югарыгы өлешендәге күзәнәкләрен пичәтли башлау белән, аларны суырту өчен алырга кирәк.* Умартачылык

3) Җептән бәйләнгән әйбердәге элмәк. *Минә бу йомшак перчаткаларның матур күзәнәкләренә яшь киленнәрнең нинди генә теләкләре бәйләнмәгән.* Г.Бәширов. *Күлмәк бәйлим бүләккә, Батыр сугышчы өчен, Салып һәр күзәнәккә Йөрәгемнең җылысын.* Ә.Исхак

4) Бәрәңге күзчәсе. *Фермага барышлый, урау булса да, бәрәңге күзәнәге кисүчеләр янына туктадык.* Л.Ихсанова

5) *биол.* Терек организм төзелешенең цитоплазмадан, төштән һәм тышчадан гыйбарәт төп структур берәмлеге. *--- мин пәрдәле, паласлы, телевизорлы, нарат исе килеп торган салкынча өйне бөтен күзәнәгем белән тоеп, кабул итеп, диванга чумдым.* М.Мәһдиев. *Мондый әшәкелекне озак карасаң, күзләр аша кереп, барлык күзәнәкләреңә сеңәр.* Ф.Яруллин. *Ирекнең бөтен гәүдәсе рәхәт изри иде, әйтерсең гәүдәсенең һәр күзәнәге татлы йокыга талган.* Ф.Садриев

6) *тех.* Механизмда нинди дә булса деталь куела торган тишек, уем. *Комбайн сәнәге күзәнәгеннән атылып чыгу*

**КҮЗӘНӘКЛӘ́Ү** *ф.* Күзәнәк ясау, күзәнәкләр хасил итү. *[Гөлүсәнең] өстендә йөзенә иш килә торган, эре күзәнәкләп бәйләнгән сыек зәңгәрсу төстәге йон күлмәк.* М.Хәсәнов

**КҮЗӘНӘКЛЕ** *с.* Күзәнәкләре булган, күзәнәкләрдән торган. **---** *әгәр бу ипи уңышлы – күзәнәкле, ачкылтым --- чыкса, димәк, күәс төбендә аның «нәселен» калдырырга кирәк.* М.Мәһдиев. *Хлорелладан тыш, --- бүлмә үсемлекләренең балчык чүлмәк стеналарында бер күзәнәкле башка төр суүсемнәр дә шактый еш очрый.* Ботаника. *Күзәнәкле бетон заводы турысындагы тимер юл аша чыккач, Айзат машинасын уңга – элеватор тавына таба борды.* Язмышлар яңарганда

**КҮЗӘНӘКЛЕЛӘР** *и. күпл. биол.* Күзәнәкчел төзелешле организмнар. *Алар төшсез һәм тышчасыз булып, гади аксым төерчекләреннән торганнар. Болар күзәнәклеләргә кадәр организмнар булганнар.* Биология

**КҮЗӘНӘКЧЕЛ** *с. биол.* Организмы күзәнәкләрдән торган, күзәнәкләрдән гыйбарәт. *Бу охшашлык теләсә кайсы чәчәкле үсемлекнең күзәнәкчел төзелешле булуында һәм һәрберсенең бер үк төрле органнары: тамыр, яфрак --- булуда күренә.* Кызыклар дөньясында. *Үсемлекләрнең барлык органнары күзәнәкләрдән тора. Димәк, үсемлек күзәнәкчел төзелешле була ---.* Биология. *Орлыкның яралгы тамырчыгы да, үсеп җиткән үсемлекнең тамыры да, башка органнар кебек үк, күзәнәкчел төзелешле була.* Ботаника

**КҮЗӘТ** *и.* Дозор; күзәтчеләр отряды. *Күзәт җибәрү*

**КҮЗӘТЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **күзәтү** (*1–6 мәгъ.*). *Мичурин, киресенчә, бер-берсенә ерак булган үсемлек төрләре һәм токымнары арасында гади шартларда күзәтелгән кушылмаучанлыкны җиңү өстендә эшләде.* А.Бахарев, П.Яковлев

2) Күренү, беленү, сизелү, аңлашылу. *Нинди дә булса конкрет тарихи фактның чагылуы күзәтелми.* М.Җәлил. *Һәрбер тип эчендә (мәсәлән, хордалыларда) күзәтелә торган гәүдә төзелешенең һәм яралгы үсешенең охшашлыгы, бу типның барлык вәкилләренең чыгышлары уртак булганлыгын --- күрсәтә.* Дарвинизм нигезләре

3) Булу, булып тору. *Быел су басулар еш күзәтелә*

**Күзәтелә башлау** Нәрсәнеңдер билгеләре күренергә тотыну, сизелү. *Бу процесс озак вакытларга туктап торганнан соң, 1980–1990 елларда татар милләтенең яңарышы башлану белән яңадан күзәтелә башлады ---.* Д.Исхаков. *Хәзер компьютер, Интернет заманы, кешенең калын-калын китаплар укырга вакыты юк дип, әдәби әсәрләр иҗат итүдә кыскалыкка өстенлек бирү күзәтелә башлады.* Р.Харис

**Күзәтелеп килү** Күптәннән күзәтелү, күзәтелүен хәзергәчә дәвам итү. *Моңа чаклы телләр ике формада күзәтелеп килде.* Фән һәм тел

**Күзәтелеп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле күзәтелү. *Моңа охшаш хәлләр шулай ук Россиянең башка почмакларында да даими күзәтелеп тора.* Шәһри Казан

**КҮЗӘТЕШ** *и. кит.* Нәрсәне дә булса игътибар белән карау, тикшерү, күзәтү. *Урыны белән бу сагышлы хыялга чолганган күзәтешләр, үткенләшә төшеп, социаль протест дәрәҗәсенә дә күтәреләләр.* Г.Нигъмәти

**КҮЗӘТҮ** I *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне, яисә берәр эш-хәрәкәтне җентекләп карау, карап тору, күздән кичерү. *Күңелем һич тыныч түгел, юктан да борчылып, куркып тора, әйтерсең минә бүлмәмә кемдер кергән дә яшеренеп кенә мине күзәтә.* Ә.Еники. *Ул җизнәсе киткән якка карап көлде: «Ачулан әйдә, ачулан. Ярсыган аю гайрәтлерәк була», – дип, читтән генә күзәтте.* Ф.Яруллин. *Паромда су аркылы чыкканда, Алма гел авыл кешеләрен күзәтте.* Р.Рахман

2) Кемне яки нәрсәне дә булса читтән карап-тикшереп, аның барлыгын-юклыгын, үзенчәлеген, ни эшләвен һ.б.ларны ачыклау, билгеләү. *Гордов күзәтү пунктына борылып кайтты, чирек сәгать буена кулыннан бинокльне төшермәде.* Ш.Рәкыйпов. *Ярый, мөмкин кадәр, кулдан килгәнчә күзәтермен, тик кабатлап әйтәм: мин Гөлкәйнең язмышы өчен җаваплы түгел.* Х.Ширмән. *[Сәет] чит мәмләкәтләрдә йөргәндә дә, шушы Казанда да ул үзен кемдер күзәткәнне, кирәк чакта гына ярдәм кулы сузылганны тоеп яши иде ---.* Ф.Латыйфи

3) Берәр кешене фаш итү, тоту өчен, аны сагалап-тикшереп, карап йөрү. *Мине --- җиде тәүлеккә гауптвахтага ябу белән чикләнделәр. Шушы көннән соң минем һәр адымымны күзәтү башланды.* Ф.Яруллин. *Зәйнулла сәвальгә сорау белән җавап кайтарды: – Зайцевны үзенә белдермичә күзәтү астына алуга ничек карыйсың?* М.Насыйбуллин. *Үз акылы белән масайган профессор Лобачевский артыннан бүгенге көннән башлап күзәтү оештырырга кушты...* Җ.Тәрҗеман

4) *күч.* Кемне дә булса караутәрбияләү, аның турында кайгырту. *– Авыру әлегә аңсыз, без аны күзәтәбез, син, агай-эне, тавышланма, яме, – диде [табиб].* Н.Гыйматдинова

5) *күч.* Берәр нәрсәне булдыру турында алдан кайгырту, нәрсәгә дә булса ирешү өчен эш алып бару. *Киләчәктә шундый күңелсезлекләр булмауны күзәтергә кирәк.* Ф.Бурнаш

6) *күч.* Тикшерү, өйрәнү. *Автор аларның һәммәсенең тормыш юлын күзәтә, укучыларга индивидуаль язмышларын күрсәтеп бирә.* Ф.Галимуллин. *– Без сине бик озак күзәттек, сынадык, – дигән иде Нургали ага.* Ф.Латыйфи. *Совет галимнәре бу сәер күлне берничә ел күзәтәләр һәм сернең төбенә төшенәләр.* А.Муранов

**Күзәтә бару** *к.* **күзәтеп бару**

**Күзәтә башлау** Күзәтергә керешү. *[Ул] тавыш чыгармыйча, абзар ягын күзәтә башлады ---.* Ф.Садриев. *Чулпан бөтенләй күңелсезләнеп калды, миңа аркасы белән борылып, --- янында бөтерелгән парларны күзәтә башлады.* Х.Ширмән

**Күзәтә бирү** Бернәрсәгә карамастан күзәтүне дәвам итү. *– Минем исемем Марат, атамның исеме Әмир. Мөрәҗәгать итү өчен – Марат Әмирович, – диде ул, укучыларны күзәтә биреп.* З.Фәйзуллин

**Күзәтә тору** Билгеле бер вакыт дәвамында күзәтү. *Мин, шул яфракларны кызыксынып күзәтә торгач, су төбендә алтын тәңкәле берничә балык күреп алдым.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Күзәтеп бару** Даими рәвештә күзәтү. *Тагын шуны да исегезгә төшереп куябыз: изге теләктән чыгып бирелгән бу сигнал уңае белән сезнең нинди чаралар күрүегезне бик яхшылап күзәтеп барачакбыз.* В.Нуруллин. *Ләкин ул, барыннан да бигрәк, политиканы күзәтеп бара һәм бәхәсләшергә ярата.* Җ.Тәрҗеман

**Күзәтеп бетерү** Барысын да, берсен дә калдырмыйча күзәтү. *Монда кырмыска оясы кебек. Шундый шартларда бөтен кеше артыннан күзәтеп бетереп булмый.* Ирек мәйданы

**Күзәтеп йөрү** Даими рәвештә, һәрвакыт күзәтү. *Ул күзәтеп йөри торгач, беркөнне Таһирның бакчага кергәнен күреп, --- падишаһка кайтып сөйләгән, ди.* Әзләнүләр, уйланулар, табышлар

**Күзәтеп калу** Күзәтергә өлгерү

**Күзәтеп килү** Билгеле бер вакыттан башлап күзәтүне даими рәвештә дәвам итү. *– Мин сезне күптәннән күзәтеп киләм, – дип үгетләвен дәвам итте физик.* Җ.Тәрҗеман. *Гаяз Исхакый белән Галимҗан Ибраһимовны --- вакытлы матбугат сәхифәләрендә чыгып торган мәкаләләре аша да байтактан күзәтеп килә идем.* Р.Мөхәммәдиев

**Күзәтеп тору** Һәрвакыт, гел күзәтү, әледән-әле күзәтү. --- *Нөзәһәт аны, бакча башындагы каенга сөялеп, август төнендә күзәтеп торды ---.* М.Мәһдиев. *Ихтыяр Нурисламның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды.* Р.Вәлиев. *Нургали аганың тавышы көчәйгәннәнкөчәя барды, аның һәр хәрәкәтен тылсымлангандай күзәтеп торган Сәеткә, үзе белән базарбашы түгел, ниндидер илаһи зат сөйләшәдер кебек тоела башлады.* Ф.Латыйфи

**Күзәтеп чыгу** Барысын да, бөтенесен дә бер-бер артлы күзәтү. *Урыс патшасы сөзеп кенә илчеләрне күзәтеп чыкты.* Р.Зәйдулла. *Берничә урауда сейфтагы акчаларны үзенекенә күчереп бетерде дә, кабинетын игътибар белән күзәтеп чыкканнан соң, аска төшеп китте ---.* Р.Мирхәйдәров. *Аякларына басып, ишек борысына сөялгәч, җентекләп өй эчен күзәтеп чыкты.* Р.Мөхәммәдиев

**Күзәтеп яту** *сөйл.* Озак вакыт дәвамында күзәтү. *Иленә килгән фаҗигане тыныч кына күзәтеп ята торган бәндә түгел ул.* Ә.Моталлапов

**КҮЗӘТҮ** II *и.* 1) Бер-берсе белән бәйләнгән нәрсәләр (фактлар, вакыйгалар, күренешләр һ.б.) турында язма, кыскача белдерү. *Парижда минем дөнья сәяхәте вакытында язып ташланган математик этюдымны һәм кайбер күзәтүләремне басып чыгардылар.* Җ.Тәрҗеман. *Бакуда иртәгесен чыгасы газеталар инде кичтән үк басыла башлый. Ул, шуларның беренче нөсхәләрен кулга төшереп, кичен күзәтү хәзерли.* Р.Мөхәммәдиев. *Бер көн үткәч, Казан радиосының матбугат күзәтүендә Саттаров мәкаләсенең дөнья күрүен хәбәр иттеләр.* Ф.Садриев

2) Фәнни тикшеренүнең бер ысулы. *Ул да Марат шикелле үк нурланыш ешлыгының җан ияләренә, терек һәм терек булмаган табигатькә тәэсирен өйрәнә. Кызыклы гына күзәтүләре дә бар.* Ф.Латыйфи. *Табигатьне өйрәнү методларының яки ысулларның берсе – күзәтү.* Табигать белеме

**КҮЗӘТҮЧӘН** *с.* Һәркемгә, һәрнәрсәгә җентекләп караучан, игътибарлы. *Исламгали агай – күзәтүчән, шәһәрләрдә, больницаларда күп йөргән, --- Сәламәтлек саклау министрлыгы тирәсендә күп тапкыр булган кеше – белә, күрә иде.* М.Мәһдиев. *Шәвәли бик күзәтүчән малай икән: һәммәсен дөрес тасвирлаган.* Ф.Яруллин. *Хәйдәргали агай, шактый ук коры кеше булуына да карамастан, күзәтүчән һәм төптән уйлап эш итәргә күнеккән.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮЗӘТҮЧӘНЛЕК** *и.* Күзәтүчән, игътибарлы булу. *Яр өстендә кайнашкан халыкны күзәтеп тору хәерлерәк сыман тоелды аңа. Бәлки, рәссамлык кызыксынуы, күзәтүчәнлеге дә шуңа этәргәндер.* Ә.Моталлапов. *Ул биремнәр сезгә яңа материалларны үзләштерергә, күзәтүчәнлегегезне, --- иҗади эшләү сәләтегезне арттырырга ярдәм итәр.* Табигать белеме

**КҮЗӘТҮЧЕ** *и.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү эше белән шөгыльләнүче. *Юк шул, аңламадылар кызлар Ташлыяр егетләренең хәлен: күз сирпемәделәр, ә үзләрен күзәтүчеләрдән тартынып-нитеп тормыйча, кайсы өеп куйган бүрәнә өстенә елышты, кайсы --- коры бәрәңге сабагына ауды.* А.Вергазов. *Башына тәкәрлек йомыркасы кебек чуар кепка, өстенә шәмәхә төстәге куртка кигән Чекушкин ул көнне күзәтүче өчен тамгалы агач, әзер мишень иде.* М.Насыйбуллин. *Бөтенләй күзәтүчесез, хуҗасыз калган тегермәннәрне бала-чага уен җире итте ---.* Р.Рахман

2) Разведка эшен башкаручы хезмәткәр, разведка агенты. *Күзәтүчеләребез аның тегендә – Колчак ягында, шәп каһарман булып, телләрдә йөргәнен хәбәр иттеләр.* Г.Ибраһимов

3) Газета-журналда, радио-телевидениедә күзәтү ясаучы

**КҮЗӘТЧЕ** *и.* **1.** 1) Каршы як турында мәгълүматлар җыю өчен җибәрелгән хәрби хезмәткәр, разведкачы. *Күзәтчеләрдән алынган хәбәрләргә караганда, Капитоновка станицасында ике меңләп казак җыелган.* Ш.Усманов

2) *хәрби* Фронтта дошман урнашкан җирне ерактан күз белән күзәтүче хәрби хезмәткәр. *Одинцов дигән егетебез утыра иде нарат башында. Күзәтче булып. Дошман бик якын иде.* Н.Акмал. *Полк командиры штабка килеп керү белән ук, [ул] аңа чиркәү башындагы күзәтче китергән мәгълүмат турында сөйләргә тотынды.* А.Шамов

3) Кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү, тикшерү белән шөгыльләнүче. *Тик бу серле күзәтчеләрнең кем икәнен беркем дә белми иде әле.* Г.Сабитов. *Каравылчы штатын кыскарттылар, барлык кибетләр төнгелеккә күзәтчесез калды.* Ә.Моталлапов. *Натуралистның үткен күзләре тәҗрибәсез күзәтче өчен күренмәслек булган --- үзгәрешләрне күрә.* А.Бахарев, П.Яковлев

4) *к.* **күзәтүче** (*3 мәгъ.*). *Ә менә «Польша» журналы. Анна исемле күзәтче әнә нәрсә ди: «Хатын-кызларның һәрберсе диярлек сары чәчле булырга тели».* А.Мифтахетдинов

5) *иск. к.* **күзәтүче** (*1 мәгъ.*). *Күп тә үтмәс, башка капкалар өстендә дә күзәтчеләрнең үткен күзе яңа кәрваннарны күрер, Идел өстеннән Казансуга борылучы көймәләрне абайлар.* Ф.Латыйфи

**2.** *с. мәгъ.* Разведка белән шөгыльләнүче, разведкага җибәрелгән. *Күзәтче отряд дошманның Капшап кайткач йөрәген, Барып күккә очырабыз Аның соңгы тирәген.* М.Җәлил

**КҮЗӘТЧЕЛЕК** *и.* 1) Күзәтү, тикшерү, сынау эше. *Кара йөзле, усал күзле, бик йөрәкле. Йосыфка шул күзәтчелек кылды инде.* Кол Гали. *Юкка гына Җиһангир яшьрәк чагында холыксыз Гариф абыйсыннан шикләнеп, хәтта аның артыннан күзәтчелек итеп --- йөрде.* Н.Хәсәнов. *Рафикъ күзәтчелектән ычкынды.* Ә.Моталлапов

2) Рәсми күзәтү-тикшерү эше белән шөгыльләнүче орган. *Әйе, вакыт шундый, партия линиясе шундый. Эчке эшләргә партия күзәтчелеген формализмга әйләндерергә хакыбыз юк.* Ә.Баян. *Премьер-министр Р.Миңнеханов Идел буе Ростехнадзор идарәсе күзәтчелегендә торган предприятие һәм оешмаларда сәнәгать, энергетика һәм экология иминлеге мәсьәләләренә багышланган киңәшмәдә катнашты.* Мәдәни җомга. *Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин --- Кырым-Сарай картлар һәм инвалидлар интернат-йортында өлкәннәр белән очрашты, шушында ук интернат-йортның күзәтчелек советы утырышында катнашты.* Мәгърифәт

3) Берәр эшнең башкарылуын күзәтү; надзор эше. *Районда йөз иллелән артык сәүдә ноктасы бар ---. Без --- аларны күзәтчелектә гел генә тотып тора алабызмы соң?* Ә.Моталлапов

4) Каршы як турында мәгълүматлар җыю, күзәтү-тикшерү эше. – *Сине күзәтчелек итәргә күрше абзаң тарттымы? – Кыз эндәшмәде.* Т.Әйди

**КҮЗӘ́Ү** *ф. диал.* Карау. *Күзәми очкан кош кунарга агач тапмас.* Мәкаль

**КҮЗ-БАШ** *җый. и.* Баш һәм күзләр. *Кая эләксәм дә, чәмләнеп аяусыз сугышам мәгәр: танау канамый, күз-баш күгәрми калган чак сирәк була.* М.Кәрим. *Бирсә дә бирер икән Ходай Тәгалә киленнең явызын: күзен-башын кан итеп кыйнавы җитмәгән, суд ишек төпләрендә йөртмәкче булып милициягә барган.* Ш.Максудова

◊ **Күз-баш алу** Нинди дә булса бер хәлдән соң тормыш беркадәр җайлану, рәтләнү. **Күзгә-башка бәрелеп торган** Күренеп, беленеп торган; ачык, анык. *Марат үзен газаплаган шушы сәер халәтне аңлый алмый. Бер карасаң, күзгә-башка бәрелеп торган җитди сәбәбе дә юк.* Ф.Латыйфи. **Күзгә-башка күренмәү** Кемнең дә булса очрамавы, күренеп йөрмәве, күзгә чалынмавы турында. *Сейфны, андагы яшерен документларны тапшырганнан соң аның редакциядә күзгә-башка күренгәне юк иде.* Ф.Садриев. *Таштугайдан кайтканнан бирле күзгә-башка күренгәне юк, өеннән чыкмый.* Н.Фәттах. **Күзгә-башка чалынмау** *к.* **күзгә-башка күренмәү**. *Ул хәтта күршесенең күзгә-башка чалынмавына да игътибар итмәде.* Н.Әхмәдиев. *Әмма Мөхәммәт бабай, нишләптер, соңгы вакытта күзгә-башка сирәк чалынды.* Ф.Яруллин. **Күз-баш томалану** Берни белән кызыксынмау, бар нәрсәгә битараф булу. *Хәзергеләрнең генә ул күзе-башы «мал» дип, «акча» дип томаланган.* А.Әхмәтгалиева. **Күз-баш томалау** *сир. к.* **күз-баш томалану**. *Ничекләр болай күз-баш томалап яшәргә мөмкин, җә?* Н.Гыйматдинова. **Күзе-башы акаю** Күзенә ак-кара күренмәү, нәрсәгә дә булса җитди игътибар итәрлек хәлдә булмау. *Тимерханнар башлы-күзле булган заманнарда егетҗилән дә, кыз-кыркын да, күзе-башы акаеп, теләсә кемне гомер юлдашы итми иде.* Г.Ахунов. *Ишек киләсен тибеп очырып, күзе-башы акайган Шәрәф килеп керде.* Н.Гыйматдинова. **Күзе-башы алакаю** *к.* **күзе-башы акаю**. *[Мәгъри:] Аларның да шул, сезнеке шикелле, күзе-башы алакайган бер асраулары бар.* Г.Камал. **Күзе-башы алару** *к.* **күзе-башы акаю**. – *Әни! – диде Мәһди. – Син минем семья тормышыма тыгылудан туктыйсыңмы, юкмы, кәнсә кәнис?! – Чү, чү, балам, нигә шул тамаша кыланасың? Күзең-башың аларган!* Ш.Максудова. **Күзе-башы бернәрсә күрмәү** *к.* **күзе-башы алакаю**. **Күзе-башы тону** *к.* **күзе-башы акаю**. *Храмовның кабинетын көч-хәл белән эзләп тапты. Күзе-башы тонган иде егетнең.* А.Гыйләҗев. *Ә Нәсимә: «Басмада Су анасы утыра, җитмәсә, чәчен тарап!» – дип, күзе-башы тонып кайтып керде.* М.Хәбибуллин. *Әле ярый, Илдус килеп җитте. Күзе-башы тонган, аяклары кырыкмыш тайныкы кебек биеп кенә тора.* Д.Галимов. **Күзен-башын әйләндерү** 1) Кемнең дә булса фикерен чуалту; 2) Кемне дә булса һәртөрле юллар белән үзенә карату. *Дөрес, болардан сак булырга, берсе белән дә аралашмаска, бигрәк тә теге чибәркәйдән ерак торырга кирәк: сизми дә калырсың, күзне-башны әйләндереп ташлар да...* М.Шаһимәрдәнов

**КҮ́З БӘЙЛӘШ** *и.* Уйнаучыларның берсе, күзе бәйләнгән килеш, башкаларны тотудан гыйбарәт уен. – *Хәзер балалар качышлы уйнамый, – диде Бибинур таркау гына. – Мин дә шаккатам аңа! Качышлы уйнамыйлар, тычкан салыш бетте, күз бәйләш тә онытылды...* А.Гыйләҗев. – *Без аны аю белән күз бәйләш уйнарга өйрәтәбез! – Шкулин шырык-шырык көлде.* А.Мифтахетдинов

**КҮЗГӘ́-КҮЗ** *рәв.* 1) Икәүдән-икәү генә; башкалар булмаганда, башкалар юк чакта. *Хуҗа хатын шул вакытта хуш исле арыш оны белән күзгә-күз ялгыз кала.* М.Мәһдиев. – *Әх, – мәйтәм, – әле кумәк хуҗалыгыгыз белән социализм милеген бүлешеп ятасызмыни? – Шул сылтау белән колхоз рәисен, бригадирны кулга алып, күзгә-күз сорау алу үткәрдем.* Ә.Гаффар. *Күзгә-күз җитди сөйләшүдән туган кайнарлык әле сүрелеп җитмәгән иде.* Н.Хәсәнов

2) Кара-каршы. *Ләкин Зөбәрҗәтнең ата-ана киңәшен тотар хәле калмаган иде; күзгә-күз утырып сөйләшмичә аңлый алмаслар дип, --- Эстәрлегә кайтып китте.* Х.Сарьян. *Сүбәдәй дошман белән күзгә-күз туры килмәде диярлек, аны һәрчак --- сакладылар, күкрәкләре белән капладылар.* М.Хәбибуллин. *Егетнең каршысына ук утырып, куллары авыртудан аның ничек өзгәләнүен күзәтеп барасы килгән иде аның. Күзгә-күз утырып, аның йөзендәге һәр үзгәрешне тоеп, туйганчы, күңел булганчы күзәтәсе...* Р.Мөхәммәдиев

3) Йөзгә-йөз, турыдан-туры, маңгайга-маңгай. --- *ут эченә үзе кереп, үлем белән күзгә-күз бер генә тапкыр булса да очрашкан кеше беркайчан да кеше медален такмас...* М.Мәһдиев. *Мин сине әнә шундый курку, икеләнүләр белән көттем, Айгөл. Ләкин безгә күзгә-күз очрашып сөйләшергә язмаган икән.* Ф.Яруллин. *Аларның икесен күзгә-күз очраштырып, телефоннан булган сөйләшүгә нокта куясы килде Ирекнең.* Ф.Садриев

◊ **Күзгә-күз карау** *к.* **күзгә-күз карашу**. *Тикшерү эшләре түгәрәкләнергә бер-ике көн кала, мин бу картны, күзгә-күз карап сөйләшер өчен, авыл советына чакырттым.* Ф.Галиев. *Тик бүре, шактый вакыт күзгә-күз карап торганнан соң, борынын чыршы ботаклары арасыннан алды, тын гына шуышып, караңгыда юк булды.* Х.Ширмән. **Күзгә-күз карашу** Бер-берсенә текәлеп карау, күзләрен бер-беренә текәп тору. *Гаяз белән күзгә-күз карашып, аптырашта калдык.* М.Әмир. *Бераздан ишек ачылды, аннан Тимер Буганың исен җибәргән кыз күренде. --- Бик озак күзгә-күз карашып тордылар.* Р.Зәйдулла. **Күзгә-күз карашып яшәү** Бик тату, дус яшәү. *Күзгә-күз карашып кына Яши идек парлашып, Бик ялгыштың, җанкисәгем, Мәхәббәттә адашып.* Г.Зәйнашева. **Күзгә-күз терәп** Бер-берсенә текәлеп карап. --- *шулай берсе тәрәзәдә, икенчесе урамда күзгә күзне терәп торгач, Вәзиләнең «ничек булды соң?» дип сорыйсы килде.* А.Гыйләҗев. *Тагын күпмедер күзгә-күз терәп тын утырдылар.* Р.Айзатуллин

**КҮЗДӘЙ** *рәв. диал. к.* **күздән**. *Аңа ияргәннәр һәркайчан савытларын [җиләк белән] күздәй тутырып кайталар.* Г.Ибраһимов

**КҮЗДӘН** *рәв. сөйл.* Мөлдерәмә. *Кранны борып карады, тамчы су юк торбаларда. Чормага менеп ярым айга борынын тыкса, күрә, Мирфатыйхларның бөтен савыт-сабалары күздән тулы ---.* А.Гыйләҗев

**КҮЗЕГҮ** *ф.* 1) Хорафатлар буенча: кемнең дә булса көнләшеп яки сокланып каравы нәтиҗәсендә чирләп китү, бәхетсезлеккә юлыгу; күз тию

2) Күзгә чалынып йөрү. *Ләкин Булатов өстәл яныннан чыкты да, аларның икесен дә килештермәкче булган кебек: – Син, энекәем, – диде Инсафка, – китсәң кит, китмәсәң, җөрмә авылда кешегә күзегеп.* Н.Фәттах

3) *куч. сөйл.* Мактаганнан соң нәрсә дә булса начарлану

**КҮЗЕКТЕРҮ** *ф.* 1) Кемнең дә булса көнләшеп яки сокланып каравы сәбәпле кемне дә булса авыруга (чиргә), бәхетсезлеккә дучар итү; күз тидерү

2) *куч. сөйл.* Берәр нәрсәнең мактаганнан соң начарлануы турында әйтелә

**КҮЗЕЛДЕРЕК** *и. к.* **күзлек** (*2 мәгъ.*)

**КҮЗЕННӘН** *рәв. сөйл. к.* **күздән**. *Янчурин, --- серванттан кызыл аракы алып, Сөембикәнең каршындагы бокалны күзеннән тутырып куйды.* Ф.Садриев

**КҮЗИКМӘК** *и. этн.* 1) Төче камырдан юка гына итеп җәеп, табада пешерелгән ашамлык. *Бәрәңгене арчып пешерә, төя, шуны күзикмәккә җәя дә, урталай бөкләп, табага салып, майда чыжылдата.* М.Мәһдиев. *Бетәсе түгел: кыстыбый, диләр, өчпочмак, гөбәдия, диләр, катык, күзикмәк, коймак – тагы нәрсәләр. Бөтен авыл ризыгын ашап бетереп буламыни?* Ә.Баян

2) *к.* **кыстыбый** (*1 мәгъ.*). *Ул да түгел, әтиләре тагын берәр нәрсәне искә төшерә: – Кыстыбый пешерсәң иде, әни... Тик әбиләре аны, никтер, «күзикмәк» ди.* Г.Шәрәфи. *Менә сиңа чәкчәк, күзикмәк!..* Ш.Рәкыйпов

**КҮ́З КАБАГЫ** *и. анат.* Умырткалыларда күз алмасын алгы яктан каплап тора торган тире җыерчасы. *Гомергә кояш нурын күрмәгәндәй ап-ак чырайлы егет авырлык белән күз кабакларын күтәрде ---.* Т.Галиуллин. *Ихтыяр, аның шешенке күз кабакларына, күмгәкләнә башлаган йөзенә --- карап, беркавым тын торды.* Р.Вәлиев. *Сүзсез генә чәй эчтеләр дә, шешенгән күз кабакларын салкын су белән юып, Рәмзия кибетенә китте.* Н.Әхмәдиев

**КҮ́З КАРАСЫ** *и.* 1) *анат.* Күз алмасының мөгез катлавы аша кергән яктылык нурларын күз эченә үткәрүне җайлый торган тишем; бәбәк. *Мин аның якты башын үземә тартам, аның алдына чүгәлим, һәм без бер-беребезнең күзләренә карыйбыз. Мин – аның күз карасында, ул – минекендә.* Р.Кутуй. *Тилебәрән үсемлеге белән агуланганда, баш авырта башлый, --- кеше бик нык тынычсызлана, күз карасы зурая, авыз кибә.* Ботаника

2) *куч.* «Бик кадерле, бик якын кеше» мәгънәсен белдерә. *[Вәзир:] Кичер минем күзем карасын, Аяу кирәк ата баласын.* Ф.Бурнаш

**КҮЗ-КАШ** *җый. и.* Күзләр һәм кашлар. *Сәкинә --- башын күккә чөеп җибәргән, чәчләр су күбеге төсле кабарганнар, күзен-кашын ясаган ---.*

А.Гыйләҗев. *Ирегем бетеп үземә охшаган икән! Күзе-кашы гына түгел, авыз-борыннарына тикле, колакларына тикле нәкъ минеке.* В.Нуруллин. *Ул, иркен сулыш алып, сынын турайта төште, иңбашына аскан нәни сумкадан көзге чыгарып, күзләрен-кашларын төзәтенергә кереште.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Күзен-кашын җимерү** Ризасызлык, үпкә белдергәндә, күз-кашларның табигый торышы бозылып, ямьсез итеп карау. *– Ә башка колхозларда кем төзи? – Хәлимов күзен-кашын җимереп аңа карады.* Р.Айзатуллин. *– Син, Әскәр Шәехович, – диде ул күзен-кашын җимереп, – барысын да аңлап бетерергә тырышасыңмы?* К.Тимбикова. **Күзен-кашын сыту** *к.* **күзен-кашын җимерү**. *Ишек нәни генә шыгырдауга, Сабит, күзен-кашын сытып, аңа туктарга куша.* А.Гыйләҗев. **Күз-каш уйнату** Берәр төрле хисне, теләкне һ.б.ларны белдереп, күзләрне кыскалау, кашларны сикертү. *Юк, аның үзен түгел, ә, бәлки, иренең читтә булачагын, күз-каш уйнатачагын уйлап көнли иде.* Н.Акмал

**КҮЗ-КОЛАК** *җый. и.* 1) Күзләр һәм колаклар. *Фәйзинең --- битенә сирәк вак тамчылар төшеп кытыклый, күзколакны кычыттыра, әмма баш астына салган кулларны аласы, кыймылдыйсы килми иде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Күзәтүче, шымчы. *– Мин дәүләт иминлеген саклыйм, сез дә халыкның күзе-колагы, – дип, сүзен дәвам итте Йөзлебаев.* Ф.Садриев. *Ханның һәр җирдә күз-колагы барын һәммә кеше белеп торырга тиеш.* Р.Зәйдулла. *Ул тиктормас халыкка мизгел саен күзколак кирәк, көндезләрен генә түгел, төнге йокыларына хәтле саклыйсы.* Р.Габделхакова

◊ **Күз-колак булу** Берәр кешене яки нәрсәне күзәтү астында тоту, эшхәрәкәтләрен күзәтеп-саклап, тикшереп тору. *--- Хәмитнең хатыны --- кышка Рәшидә апаны шәһәргә чакыра икән. Бала-чагага, кухняга хуҗа, күз-колак кирәк, ди.* М.Мәһдиев. *Авыл булгач, аның казы-тавыгы, ишегалдында Акбае, арканда бозавы бар – туйдырырга, эчертергә, барысына да күз-колак булып торырга кирәк.* С.Шәмси. *Нигә җыелдыгыз монда, бездельники! Күзколак булып тормасаң, көне буе челем көйрәтер идегез!* М.Юныс. **Күз-колак иттерү** Кемне дә булса нәрсәнедер күзәтү, кемнеңдер эш-гамәлләрен тикшерү эшенә җәлеп итү. *Кенәгәне писарь кулыннан алганчы, Билаловның башына бер уй йөгерде: «Күз-колак иттергәндә килештерер иде бу. --- Органнарда түләүле яки түләүсез шымчы булып китсә... Йөрер бит язмышларны җимереп!»* С.Шәрипов. **Күз-колакны үткен тоту** Сак булу, сизгер булу. *Һәм ул моннан соң үз кул астындагы кешеләренә карата күз-колакны үткен тотарга кирәклеген аңлап кайтты.* К.Нәҗми. **Күз-колаксыз калу** Җитәкчесез, күзәтчесез калу. *[Подполковник:] – Рәхмәт сиңа! Хәвефле хәтәр мәлдә күз-колаксыз калган полкны бәладән коткардың, – диде.* М.Кәрим. **Күз-колак юкта** Кеше күрмәгәндә, кеше юк чакта. *Гамирның, --- кайберәүләрнең якыннарын, яңа зиратка илтмичә, күз-колак юкта кабер казытып, шушында гына күмүе турында ишеткәне --- бар иде.* З.Фәйзуллин

**КҮЗ-КУЛ** *җый. и.* Күзләр һәм куллар. *--- Макаров пистолетыннан ансат кына атырмын димә. Үзенә күрә прицелын көйләп, күз-кулыңа күнекмә үткәрмәсәң, биш-алты адымдагы түңгәкне чәпүе дә авыр.* С.Шәрипов

**КҮ́З-КҮЗ** *с.* **1.** Күзгә охшаш түгәрәкләре булган, күзле; күзләрдән торган; күзләр хасил иткән. *Аннары килеп, бу адәмнең күз-күз тишекле свитер кигәнлеген --- дә өстәргә кирәк.* Ф.Садриев. *Күз-күз күләгәләр Җиһангир кулы өстендә биешә, качыш уены уйныйлар сыман.* Н.Хәсәнов. *Менә известняк кисәгендә күз-күз булып зәңгәр целестин оялары ялтырый.* Җ.Тәрҗеман

**2.** *рәв. мәгъ.* Күзләр хасил итеп, күз кебек тишекләр рәвешендә. *Аңына килгәндә, ул баш өстендәге ботак урыннары күз-күз булып торган агач түшәм күрде ---.* Ф.Галиев

**КҮ́З КҮРЕМЕ** *и.* 1) Күрү, күз белән кабул итү мөмкинлеге. *Киң басма янында колач җитмәслек юан кәүсәле, күз күреме җитмәслек куе ябалдашлы чинар агачы үсә ---.* М.Маликова. *Әле мәшһүр Урал тауларын уза гына башладылар, алда – күз күреме җитмәслек тигезлекләр, сазлыклар, урманнар.* Х.Ширмән

2) Күз белән күрә алырлык ара, караш белән колачлый алырлык җир. *--- ул әле балконнан күренеп торган, борчулары басылган Яңа Ташлыяр авылына, күз күреме колачлый алган кадәр җиргә җәелгән басуларга, әле өстәл тирәсендә түгәрәкләнеп утырган балаларына карап, шатлыгын яшерә алмый --- иде.* Р.Вәлиев. *Тыгыз һәм куе яңгыр пәрдәсе тирә-якны томалап алды, күз күреме ераклыкта бер генә нәрсәне дә абайлап булмаслык әңгермеңгер урнашты.* Ф.Латыйфи

3) Чама, гади күз белән билгеләнгән үлчәм. *Мондагы тире җыючы да, тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка дигәндәй, күз күреме белән генә кабул итә.* Социалистик Татарстан

4) *күч.* Шәхеснең күзаллаулары, дөньяга карашлары. *Балачакны, --- орчык эрләп утырган ана җырын хәтерләтте бу моң. Еракларга алып китте, күз күремен киңәйтте, дан-дәрәҗәдән, --- мөһимрәк нәрсәләр барын искә төшерде.* М.Маликова

**КҮЗЛӘВЕК** *и. диал.* 1) Кечкенә инеш, чишмә, кизләү, чыганак

2) Бозның тишелгән урыны; бәке авызы. *Боз хәрәкәткә килгән, күзләвекләр күренә башлаган иде.* А.Мифтахетдинов

**КҮЗЛӘ́Ү** I *ф.* 1) *сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса җентекләп карау; күзәтеп тикшерү. *Бу чакта Карпович, пыяласы җиңелчә караләтылган күзлеге аша, мөгаен, ротаны күзләгәндер.* С.Шәрипов. *Бүре --- таңга кадәр печән өстендә утырып чыккан ялгыз кәҗә бәтиен күзләп, авыз суын корытты.* Р.Мөхәммәдиев. *--- ят бер кеше --- тирә-юньне күзләп, ашыга-ашыга атлый.* М.Галиев

2) Күңелгә охшаган затны яки берәр әйберне эзләп, күзәтеп сайлау. *Киленлеккә кыз күзләгәндә, аналар гаҗәп таләпчән була.* Г.Әпсәләмов. *Билал --- Шамил белән вак-төяк сүз алышкан чагында да, беркемгә сиздермичә, гел*

*Гөләемне күзли ---.* М.Вәли. *Ә егетләрнең эше мәгълүм инде: кызлар күзләү – кайсы чибәр дә кайсы кыйгач кашлы...* А.Вергазов

3) *сөйл.* Нәрсәдер хакында кайгырту, аны булдырырга тырышу яки берәр максатка ирешергә тырышу. *Үз файдасын гына күзләп, эшчене эткә дә хисап кылмаган байның тәлинкәсен ялаучы доверенный бу эшне сизгәч тә Искәндәр байга җиткерде.* Ш.Мөхәммәдев

**Күзләп алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында күзләү. *Зөфәр йорт тирәсен күзләп алды.* Ә.Галиев

**Күзләп йөрү** Озак вакыт дәвамында күзләү

**Күзләп тору** Әледән-әле яки хәзерге вакытта күзәтү. *[Лиза] Тәрәзәдән тышны күзләп тора иде ---.* Г.Әдһәм. *Мишель, --- миңа карта кирәк, дип әйтеп чыккандыр да, әнә шул бүлмәгә посып, безне күзләп торадыр.* Р.-Н.Гүнтекин

**Күзләп чыгу** Берәм-берәм һәрберсен күзләү. *Урамда җан иясе-фәлән күренми. Беренче булып Хәмдияләр ихатасын күзләп чыктым.* Т.Таһиров

**Күзли башлау** Күзләргә тотыну. *Төркемдәш кызларны, таныш-белешләрне күзли башладым.* Х.Ширмән

**Күзли бирү** Бернигә дә карамый күзләүне дәвам итү

**КҮЗЛӘ́Ү** II *ф. махс.* Кыргый җимеш агачына культуралы агач бөресен ялгау

**Күзләп бетерү** Булган берсен күзләү

**Күзләп тору** Һәрвакыт, гел, әледәнәле күзләү

**КҮЗЛӘ́Ү** III *ф.* 1) Энә күзенә җеп кидерү; саплау. *Шул инәне күзләп, төймә тагып кара.* Р.Ханнанов

2) Төзәү. *Шулвакыт Кара Мәргән аңар күзләп атып та җибәрде.* Ак юл

**Күзләп кую** Алдан ук яки тиз арада күзләү

**КҮЗЛӘШТЕРҮ** *ф.* Үзләре күргән, ишеткән, белгән нәрсә турында ике кеше ике төрле сөйләгән вакытта, хакыйкатьне ачыклау өчен, аларны берберсе белән очраштырып сөйләтү; кара-каршы китерү

**КҮЗЛЕ** *с.* 1) Күзләре (төрле мәгънәдә) булган. *Зайцев --- эзләгәнен тиз тапты: бер почмакта «яшел күзле» такси тора иде.* М.Насыйбуллин. *Хәер, --- бу корымлы казан кебек түгәрәк битле, пәке белән уеп җибәргәндәй кысык күзле, җәлпәк танаулы дала кешесен беркем дә ялчылыкка да, чура итеп тә алырга теләмәде.* Р.Зәйдулла. *Түшәмнән чекерәеп карарга тырыша торган тоныкк күзле лампалар да минем рухымны яктыртмый.* Ф.Җамалетдинова

2) Күзләре күрә торган, күрү сәләтен җуймаган. *Аннан соң Якуп Сәйфи --- грифель тактасына язганны да гаҗәпләнеп карап торды. Күзле кешегә безнең укуны, язуны карап торуы кызык, күрәсең.* Э.Касыймов. *Күзле чакта да кешеләрнең чабата ясаганын карап утырып кына да исләрем китә иде.* З.Зәйнуллин

◊ **Күзле багана** *к.* **күзле бүкән**. **Күзле бүкән** 1) Аңгыра кеше. *Дусты туганнарына очына-очына Казан, институт турында, уку турында сөйләгәндә, Гөлкәй кирәкмәгән күзле бүкән булып утырмас бит инде.* Х.Ширмән. *Билет, төрле китап-әсбап белән тулы өстәл янында күзле бүкәннән болай фырт утырган профессор абзый үз эше белән мәшгуль иде.* Х.Ибраһим. *Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк: ул күзле бүкәнне очрату түгел, исемен дә ишетәсем килми минем ---.* М.Насыйбуллин; 2) Артык битараф, игътибарсыз, хиссез, пошмас кеше. *Их мин, күзле бүкән! Төлкенең капкынга эләккәнен ник башта ук күрмәгәнмен икән?* Н.Әхмәдиев. *Әллә уйлар белән мавыгып, әллә артык көчле каушаганга күрә, күзле бүкән булып катканмын да калганмын.* Ә.Баян; 3) Хәрәкәтләнергә, эшләргә мөмкинлеге булмаган яки теләмәгән кеше. *Алтмышта күзле бүкән кебек кымшанмый ятулары читен миңә.* Г.Әпсәләмов. **Күзле сукыр** Нәрсәне дә булса аңламаган, төшенмәгән яки гомумән надан кеше. *Ә без, ди [Миңлевәли], муллалар артыннан күзле сукыр булып бара алмыйбыз инде, ди.* М.Фәйзи

**КҮ́ЗЛЕ-БАШЛЫ** *с.* 1) Күзе, башы булган

2) *күч.* Гаиләле; хатынлы яки ирле булган. *Газизә тормышының яңа нигезен корырга, башкалар кебек үк күзле-башлы хатын булырга өметләнде.* Н.Дәүли

◊ **Күзле-башлы булу** Гаилә кору, өйләнү яки кияүгә чыгу; хатынлы яисә ирле булу. *Әбелхарисның өйләнергә җыенуын ишеткәч, Исмәт бай үзе килеп: – Әбелхарис энем, егет кешегә иртәме-соңмы күзле-башлы булырга кирәк --- – диде.* Г.Әпсәләмов. *Бер буйдаклыкка өйрәнсәң, йөри бирәсең ул шулай. Вакытында күзле-башлы булырга кирәк.* Р.Зәйдулла. **Күзле-башлы итү** Өйләндерү яисә кияүгә бирү. *Шунысы бик тә сөенечле булды: Айтуталар ике балаларын – ике бәгырь җимешләрен күзле-башлы иттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Әллә үзебез исән-сау чакта, сине башлы-күзле итү безнең өчен куаныч түгелме!* Ф.Хөсни

**КҮЗЛЕК** *и.* 1) Күзнең күрү сәләте кимегәндә яисә күзне көчле яктылыктан, зарарланудан саклау өчен киелә торган, ике күз турысында да пыяласы булган оптик әсбап. *Күзлеге өстеннән бик дикъкать белән карап каршы алды бу мине, кулы белән генә урын күрсәтте.* Ә.Еники. *Затлы товар: чын күннән сумкалар, перчаткалар, дипломат, күзлек савытлары.* М.Мәһдиев. *Алтын кысалы күзлек кигән озын буйлы егет килеп керде.* М.Галиев

2) Өркәк атка читкә карарга комачаулау өчен йөгәнгә беркетеп эшләнгән каплавыч; күзелдерек. *Йөгән күзлеге*

3) *күч.* Берәр мәсьәләгә караш, фикер, тоткан позиция, бәяләү ноктасы. *--- әмма сезнең язмыш мине, төзелеш ветераны буларак та, дөнья күргән кеше күзлегеннән караганда да, шактый борчый.* Р.Вәлиев. *– Хисаметдинов аларга бәйләнмәгән иде, – диде Ирек аптырап. – Причём монда бәйләнмәгән! Нинди күзлектән карыйсың бит.* Ф.Садриев. *– Тарихи материализм күзлегеннән сез моңа ничек карыйсыз? – дип сорап куйды ул, Мәгъсүмнең бушый башлаган костюм төймәсенә күрсәтеп.* Х.Ибраһим

4) *диал.* Умартачының битен корткылар чагудан саклау өчен, юка мамык тукымадан, тюльдән яисә нечкә тимерчыбыктан челтәрләп ясалган җайланма, битлек. *[Умарта бакчасындагы] кабыктан ясалган куыш, аның тирәсендәге коры умарталар, читлек,*

*күзлек, тубал кебек нәрсәләргә без иярәшеп беткән идек.* М.Гафури

5) *сөйл. к.* **күз** (*10 мәгъ.*). *Күзлекнең тимер капкачы ачылды. --- Надзиратель ---, шалтыр-шолтыр китереп, тимер ишекнең йозакларын ачарга кереште.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮЗЛЕКЛЕ** *с.* Күзлек кигән, күзлек киеп йөри торган. *Тукталышта алгы ишектән өлкән яшьтәге бер ир керде: калын күзлекле, мәһабәт борынлы, зур портфель тоткан.* М.Мәһдиев. *Рафаэль дигәннәре кырык яшьләр тирәсендәге күзлекле бер адәм иде.* С.Шәмси. *Менә бүлмәгә укытучыбыз Риф Мөхәммәтҗанов --- зыялылыгы әллә кайдан күренеп торган, ыспай, какча гәүдәле, күзлекле Хәсән Сарьянны ияртеп алып керде.* Г.Садә

**КҮЗЛЕКЛЕ АЮ** *и. зоол.* Аюлар семьялыгыннан, кара яки кара-көрән мехлы, күз тирәли ак яки саргылт алкалары булган аю; *русчасы:* **очковый медведь**

**КҮЗЛЕКЛЕ ЕЛАН** *и. зоол.* Аспидчалар семьялыгыннан, озынлыгы – 1,6–2 м, муенының арка ягында күзлек сыман бизәге булган, үтә зәһәр агулы елан; *русчасы:* **очковая змея**, **кобра индийская**. *Җәгъфәр, батырчылык итеп, бу күзлекле еландай үзен гипнозлап йотарга җыенган хатыннан китәчәк иде.* А.Расих

**КҮЗЛЕ ТӘБӘ** *и. к.* **күз тәбә**. *Чаттан борылуга, кечкенә кафеның кечкенә генә вывескасы күренүгә, --- профессорның да ашказаны биш-алты йомыркадан ак майда кыздырылган күзле тәбәне кабул итәргә әзерләнде.* К.Тинчурин

**КҮЗЛЕ́ ҮЛӘН** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, чәчәк төркеменең тышчасы ачык төсләрдәге яфракчыклардан гыйбарәт булган үсемлек; *русчасы:* **бессмертник**

**КҮЗЛУТ** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, сабагы дүрт кырлы, шәмәхә кызыл чәчәкле берьеллык үлән; *русчасы:* **пикульник**; **жабрей**. *Кабинасында бер кочак хуш исле кыр чәчкәләре булырга тиеш иде аның: ромашкалар, ипи чәчәкләре, куккүзләр, күзлутлар.* А.Гыйләҗев. *Зәңгәр чәчәк, эт какысы, кыр тормасы, билчән, күзлут --- һәм башка шундый чүп үләннәр хәзер агротехникадан артта калган хуҗалыкларда гына очрыйлар.* Умартачылык

**КҮЗМӘ́-КҮЗ** *рәв. сөйл. к.* **күзгә-күз**. *Кирәк булса, мин яшьләрнең үзләре белән күзмә-күз һәм ныграк сөйләшермен.* Ш.Камал

◊ **Күзмә-күз карашу** *к.* **күзгә-күз карашу**. *Көн буена икәү кара-каршы, күзмә-күз карашып утыралар да икән, берсе уйнап, берсе җырлап гомер уткәрәләр икән.* Г.Ибраһимов

**КҮЗСЕЗ** *с. сөйл.* 1) Бер яки ике күзе дә булмаган

2) Сукыр, күзе күрми торган, күрү сәләтен югалткан. *[Дустым белән] --- мотоциклда --- бәрелдек ---. Дустым үлде, мин күзсез калдым.* Р.Мингалим. *[Митрәй:] – Гәрәй дус, мин синең кызың югалган дип ишеттем. Хакмы шул? – Хак, Митрәй, хак. Анасы тәмам күзсез калды инде.* М.Хәбибуллин. *[Г.Камалның] инсценировкаларыннан бары тик «Күзсез мастерлар» дигән әсәр генә басылган.* М.Гали

**КҮЗСЕНДЕРҮ** *ф. к.* **күзектерү**

**Күзсендереп бетерү** Бөтенләй күзсендерү. *[Нәфига әби:] Алма кебек балаларыгызны җыен яман күзләргә күрсәтеп күзсендереп бетерәсез.* М.Әмир

**КҮЗСЕНҮ** *ф. к.* **күзегү**. *Күзләрең күзсенмәсен, мин сокланып туймыйм карап.* Ш.Бабич

**КҮЗ ТӘБӘ** *и.* Йомырканың агы белән сарысын тугламыйча гына кыздырган табага салып пешерелгән ашамлык. *[Трактирчы:] Теләсәгез, йомыркадан күз тәбә салып бирергә була.* М.Гали

**КҮ́З ТӨБЕ** *и. анат.* 1) Күзләрнең аскы кабагы яны. *Иреннәре агарган, күз төпләре уелган, ә үзе [Зөһрә ханым] күңелсез, боек иде.* Ә.Еники. *Иртән торганда, йөзе талчыккан, күз төпләрендә күгелҗем күләгәләр яткан иде.* С.Шәмси. *Харрас Шәмгуновичның йокысыз күзләре кызарып яшьләнгән, күз төпләреннән зәңгәрсу капчыклар асылынып төшкән ---.* Р.Вәлиев

2) Күз уемының борын янында тоташкан урыны. *Күз төпләренә эрен җыелу – коньюктивит авыруы билгесе.* Кеше анатомиясе һәм физиологиясе

**КҮЗУТ** *и. диал. бот. к.* **күзлут**

**КҮ́З УТЫ** *и. диал. бот. к.* **күз үләне**

**КҮЗҮЛӘН** *и. диал. бот. к.* **күз үләне**

**КҮ́З ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан, ап-ак, сары, кызыл төстәге чәчәкле берьеллык болын үләне; *русчасы*: **очанка лекарственная**

**КҮЗЧӘ** *и.* 1) Икенче бер агачка ялгау өчен, культуралы җимеш агачыннан кисеп алынган бөре. *Ялгау өчен алынган культуралы сортның күзчә яки чыбыкчасын ялгам --- дип атыйлар.* Ботаника. *Мичурин бер ярым кадаклы Антоновка алмагачының берьеллык чәчкене күзчәләрен өчьеллык кыргый груша ябалдашына ялгаган.* Дарвинизм нигезләре. *Утыртмалык дип тамырланган чыбыкчадан яки ялганмага ялганган күзчә яки чыбыкчадан үстерелгән үсемлекләрне атыйлар.* Биология

2) Бәрәңге бөресе, бәрәңге өстендә шытым бирә торган урын. *Бәрәңгене күзчәләрдән үрчеткәндә, бөреләрне бүлбенең йомшагы белән кисеп алырга --- кирәк.* Ботаника. *Бәрәңге бүлбесен карагыз. Аның өстендәге чокырчыкларда 2 шәр – 3 әр булып урнашкан бөреләр, ягъни күзчәләр күрерсез.* Биология. *Бөреле күзчәләр бүлбенең баш (оч) дип йөртелгән өлешендә күбрәк була.* Дарвинизм нигезләре

**КҮЗЧЕК** *и.* 1) *биол.* Түбән төзелешле җан ияләренең тәнендә үк җайлашып үскән, төзелеше белән чын күз булып җитмәгән күрү органнары. *Хламидомонаданың кечкенә кызыл «күзчеге» – кызыл төстәге тәнчеге, күзәнәк сыекчасы тулган зур вакуолясы һәм хәрәкәтле ике кечкенә вакуолясы бар.* Ботаника

2) Тышкы якны карау өчен, ишеккә беркетелгән җайланма. *[Гөлфия] азрак вакыт узгач, хәл алып, ишек төбенә барды, «күзчек»тән карады.* Р.Айзатуллин

**КҮ́З ЧОКЫРЫ** *и. анат.* Баш сөягендә күз алмасы урнашкан уентык. *Наиләнең күз чокырларында ут уйнады: «Кыланма! Беләсең!»– дип кычкырды ул аяусызланып.* А.Гыйләҗев. *Фонарь тотып килгән ирнең --- тирләгән*

*киң маңгаена киез эшләпәсе кырыннан кара күләгә кунды, күз чокырлары тирәнәеп, борыны озынаеп китте кебек.* Ә.Гаффар. *Баласын юындырган вакытта, күз чокырына җыелган яше пылт-пылт итеп табактагы суга тамды.* Р.Зәйдулла

**КҮ́З ЯШЕ** *и.* 1) *биол.* Күз алмасын эчтән чылатып торган, шулай итеп аны кибүдән саклаган сыекча

2) Кайбер физиологик халәтләр яки психологик кичерешләр вакытында күз бизләре бүлеп чыгара торган төссез, беркадәр тозлы сыекча. *Саимәнең бу сөйкемсез сөякне тизрәк чыгарып җибәрәсе, ялгыз калып, күз яшьләренә ирек бирәсе килде.* Г.Галиева. *Яр буена килеп, сагышына түзә алмыйча үксеп-үксеп елаган кызыйның күз яшьләре төшкән урында үскән ул беренче мәртәбә.* Г.Гыйльманов. *Сафура: – И Асылбикә апам, --- нишләп син минем янымда калмыйсың? – дип, күз яше белән әкрен генә елады.* Ш.Максудова

**КҮК** I *и.* 1) Җирдән югарыга караганда гөмбәз сыман булып күренә торган һава киңлеге. – *Синеңчә бәхет нәрсә, җизни? – диде Зөһрә, күктәге зәңгәрлеккә карап яткан хәлдә.* Ф.Яруллин. *Эссе, тынчу көн. Күктә ялтырап аҗаганнар уйнап ала.* Х.Ибраһим. *Күкне урталай кисеп, коточкыч калын япьле яшен ялтырады ---.* Х.Ширмән

2) Җирне чолгап алган галәм пространствосы. *Җирнең, күктәге башка яктырткычлар кебек үк, күк җисеме булуы --- беленде.* Астрономия

3) Планетаара галәм киңлеге, космос. *Күк җисеме җиргә килеп бәрелүдән булган шартлауны берничә водород бомбасы көченә тиңләргә мөмкин.* А.Муранов. *Асторономия – күк җисемнәре турындагы фән.* Астрономия. *Безнең планетабыз – иксез-чиксез галәмнең бер кисәге, бихисап күп күк җисемнәренең берсе.* Табигать белеме

4) Биеклек. *Составның нәкъ уртасында авызын күккә күтәреп торган ике туп.* Ш.Усманов. *Аяз төннәрдә ач бүреләрнең күккә карап улаганнарын ишетәм.* Г.Ибраһимов

5) *сөйл.* Илаһи көчләр. *Без икебез дә – язмышның үги балалары! Ерак күк безнең аһ-зарларга колак салмый.* Г.Ибраһимов. *Синең монда булуыңны, табынымны бизәп утыруыңны күкләр тарафыннан җибәрелгән бер бүләк дип куанып утырам.* Н.Әхмәдиев. *Яңа динне кабул итеп өлгермәгән кешеләр, Тәңредән яхшылык теләп, шул имән төбендә үгез чалалар иде, инде аларны Күк белән тоташтырып торучы бу мәңгелек --- агач, кисәүгә әверелеп, яңгыр астында пыскып ята.* Р.Зәйдулла

6) *күч.* Дини карашлар буенча: югарыда фәрештәләр яши торган урын. *Хур кызларына күктәге фәрештәләр энҗе-мәрҗәннәр сипкән.* Ф.Яруллин

7) *күч. шигъ.* Билгеле бер мәдәни һәм социаль-тарихи үзенчәлекләрдән гыйбарәт кешелек җәмгыяте. *Мең өч йөз еллар Шәрык күген Каплап торган тәрәт чүпрәген яндырабыз бүген.* Һ.Такташ

8) *күч.* Кешенең эчке кичерешләре белән тудырылган дөньясы. *[Гәрәй:] Их, Айсылу! Нишләттең син мине? Күгемнең бер чите кителде бит бүген.* Ф.Яруллин. *--- без дүртебез дә киләчәктә бәхетле булачагыбызга ышандык, тормыш күгебездә, елмаеп-көлеп, кояш балкып торачагына ышандык.* М.Шаһимәрдәнов. *Шул ук мәлдә аның күз алдында Убәдәй каханның ничек якты дөньяны ташлап китү мизгеле хәтер күген ачып җибәрде.* М.Хәбибуллин

◊ **Күк белән каплану** *к.* **күк белән ябылу**. **Күк белән ябылу** Берәр нәрсәнең түбәсе ябылмаганны аңлата. **Күк бите** *к.* **күк йөзе**. *Көн батышына таба күк битеннән әкрен-әкрен пәрдә тартыла.* М.Җәлил. **Күк гөмбәзе** *к.* **күк йөзе**. *Күк йөзе чип-чиста, зәңгәр, күк гөмбәзе бик биек, анда-санда тилгәннәр күренә ---.* М.Мәһдиев. *Күк гөмбәзен кыңгырау итеп тагын бер тапкыр кагыйммы җырымны?* Ә.Гаффар. *Күк гөмбәзе тоташ кара болыт эчендә, акрын гына көзге салкын яңгыр сибәли.* Р.Айзатуллин. **Күк итәге** Күкнең горизонт сызыгы өстендәге өлеше, офык. *Инде күк итәкләре шактый агарган.* А.Шамов. **Күк ияләре** Илаһи көчләр. *Кеше илаһи затлар белән сөйләшә, үзенә ярлыкау сорый, мәрхәмәтле күк ияләреннән ярдәм көтә.* Ф.Латыйфи. **Күк йөзе** Күк I (*1 мәгъ*). *Күк йөзе акрын гына агарганнан-агара һәм төпсезләнә бара...* Ә.Еники. *Ә көзге яңгыр исә туктыйсы итмәде: тишек иләктән аккан кебек, күк йөзе җиргә су койды.* М.Мәһдиев. *Күк йөзе зәп-зәңгәр, уч төбе хәтле дә болыт юк.* М.Хәбибуллин. **Күк кабагы ачылу** *к.* **күк капусы ачылу**. **Күк кавузы ачылу** *к.* **күкнең төбе тишелү**. *Күк кавузын ачканнармыни – һавадан су ишелә.* Батулла. **Күк капугы ачылу** *к.* **күк капусы ачылу**. *Күк капугы ачылганын күргән бер башкорт дога кылган: «Ярабби! Иртәгә бер телем ак күмәч белән май ашасам иде!»* Г.Тукай. **Күк капусы ачылу** 1) Дини ышануларга күрә, Кадер кичәсендә караңгы күк йөзендә күзләрне камаштырырлык якты ярык барлыкка килү (шуңа шаһит булган кешенең теләгән бөтен теләкләре кабул була дип санала). *Миңзаһитка күк капусы ачылгандай булды.* Ф.Садриев. *Әкиятләрдә сөйләнә торган күк капусы ачылгандай, бар дөньясы сихри нурга, илаһи бер якты моңга күмелеп калды.* Г.Шәрәфи; 2) Бәхет-шатлыкларга, уңышлы эш-гамәлләргә юл ачылу, мөмкинлек туу. *Хикмәйнең башкодасын карышканныкылар борып кайтарганын ишеткәч, Раббаниның күк капусы ачылгандай булды.* Г.Әпсәләмов. *«Казан!» дигәнне ишеткәч тә башы әйләнеп киткәндәй булды Мирсәетнең. --- Килсә дә килә икән бәхет дигәнең. Менә бит, күк капусы ачылган диярсең...* Р.Мөхәммәдиев. **Күккә ашу** 1) Бик биек булу; һавага, югарыга табан юнәлгән булу. *Менә бераздан манара эчендә балта тавышы яңгырады, манара ыңгырашты, аның күккә ашкан алюмин ае чайкалып куйгандай булды.* М.Мәһдиев. *--- егетләр --- урмандагы күккә ашкан зифа агачны екканда кызганып та, өйгә алып кайткач, аңа --- утын итеп караган --- агай кебек --- сөйләргә тотындылар.* Р.Вәлиев. *Юл буенда кечкенә алан. Уртасында ике бөдрә каен, озынрагы туп-туры булып күккә ашкан, ә икенчесе, аңа сыенып, чукларын салындырып утыра.* Т.Таһиров; 2) Рухлар дөньясына, югарыга

күтәрелү (берәр изге тур.). *Мөхәммәд пәйгамбәр үлгәч, имеш, җиденче күнендә күккә ашкан.* М.Мәһдиев. *--- кайда гына, нинди генә эштә эшләсә дә, һичберкайчан әти-әниләрен, төп нигезне Ирек ташламас, пәйгамбәр булып күкләргә ашса да, аларга барлык эшләрендә ярдәм итәр ---.* Ф.Садриев. *– Күккә ашкан, Тәңре үзе алган! – дип сөйләнде корткалар. – Бигрәк изге бала иде шул.* Р.Зәйдулла; 3) Көтелмәгән көчле куаныч, шатлык кебек хисләр кичерү. *– Әйттем бит мин сезгә, минем әти мировой, дип! – Камырҗан сөенеченнән күккә ашарга да әзер, аның шатлыгы эченә сыймый иде.* Х.Ибраһим. **Күккә карап йөрү** Бер эшсез, шөгыльсез йөрү. *Ә Хәйринең йөрәге, ике кулын артка куеп, берниди максатсыз, ашыкмыйча-кабаланмыйча күккә карап йөрүгә түзә торган түгел иде.* Ф.Садриев. **Күккә күтәрелү** *к.* **күккә ашу**. *Ханның җаны саз кылыннан агылган моңнар тәэсирендә әле күкләргә күтәрелгән, әле җирләргә төшкән.* Ф.Яруллин. **Күккә күтәрү** 1) Кирәгеннән артык, чамадан тыш мактау. *Сине күккә күтәреп мактады ул.* Р.Вәлиев; 2) Куандыру, рәхәт, ләззәт бирү. *Нининдер сәер, моңарчы кичерелмәгән халәт кызның күңелен күкләргә күтәрде.* Г.Галиева. *Тик шушы көннәрдә генә булган бер вакыйга Бибинурны тагын бер кат күккә күтәрде.* Х.Ибраһим. **Күккә мену** *к.* **күкнең җиденче катына мену**. *Ә ул чакта... Ул чакта кыз күккә менде!* Г.Әдһәм. **Күккә очыру** Юк итү, юкка чыгару; җимерү. *Кайчандыр ул бомба ясаган булган, шуны сынап караганда, күршесенең сараен күккә очырган.* Ф.Галиев. *Шулай һәр ике якның хәрби запасларын күккә очырсак, сугышырлык рәтләре калмаячак.* Ш.Рәкыйпов. **Күккә сикерү** 1) *к.* **күкнең җиденче катына мену**. *Хатны Әминәнең әнисе язган. --- Иң мөһиме: риза! Күккә сикердек ул көнне.* Р.Вәлиев; 2) Артык кылану, узыну. *Нәсимәне авылда гадел булуы өчен хөрмәт итәләр, чөнки ул тормышның җелеген суырып алырга җыенмый, кем әйткәндәй, күккә сикерми, барына риза булып яши белә.* М.Шаһимәрдәнов. *Яшьтән иркә үсмәгәч, мастерларның каты сүзләренә дә артык исе китмәде. Мактасалар да, күккә сикермәде.* И.Гази. **Күккә сузылу** *к.* **күккә ашу** (*1 мәгъ.*). *Анда-санда нәзек сыйраклы кое сиртмәләре күккә сузылган.* Х.Сафина. **Күккә терәлү** *к.* **күккә ашу** (*1 мәгъ.*). *Шулвакыт аның күз алдына --- манаралары сөңге булып күккә терәлгән таш мәчетләр килде.* Р.Зәйдулла. **Күккә үрелү** *к.* **күккә ашу** (*1 мәгъ.*). *Эчке шәһәрдә – хан сарае, биек манаралы мәһабәт мәчетләр, манаралар белән узышып күккә үрелгән юан тирәк агачлары.* Ф.Латыйфи. **Күккә чөю** *к.* **күккә күтәрү** (*1 мәгъ.*). *Ә юк, Божедомов политхезмәткәр язмышын күккә чөеп данламады бит.* С.Шәрипов. *Алай куркырлык булгач, яклый торган кешеңне яхшылап белмәгәч, халык алдында күккә чөеп мактамаска иде, иптәш Сәйфетдинова.* Р.Айзатуллин. *Самат Фәридәне шулкадәр күкләргә чөеп мактар дип көтмәгән иде ул.* Г.Галиева. **Күк көймәсе** Күкнең күренә торган өлеше; күк гөмбәзе. *Төсе уңа төшкән күк көймәсе тагын да биегәйде һәм ачыкланды.* Г.Бәширов. **Күк күкрәтү** 1) Бик зур эшләр башкару; дан-шөһрәткә ия булу. *Минем дус та, күкләр күкрәтеп, Күрсәтәдер илнең ныклыгын.* М.Җәлил; 2) Бик зур җанлылык уяту, шау-гөр китерү. *Күк күкрәтеп Гөрлә, Москва!* Ә.Ерикәй; 3) Шау-шу күтәреп ачулану, тиргәү. *Ул башта эшчеләрне коры тотмакчы булды. --- Өсләрендә күкләр күкрәтә иде.* Ш.Камал. **Күкнең җиденче каты ачылу** *к.* **күк капусы ачылу** (*2 мәгъ.*). *Кайбер кызларның сөйләвенә караганда, мондый төндә күкләрнең җиденче каты ачыла, һәм сөйгәнең күк баскычлары буйлап сине югарыга алып менеп китә.* Ф.Яруллин. **Күкнең җиденче катына күтәрү** *к.* **күккә күтәрү** (*2 мәгъ.*). *Шушы рәхәт җылылык, кызының йомшак сулышы, сизелер-сизелмәс кенә типкән йөрәк тибеше Саимәне күкнең җиденче катына күтәргән.* Г.Галиева. **Күкнең җиденче катына менгерү** Бик нык куандыру, шатландыру; рәхәтлек тойгысы бирү. *Үзенең бөеклеген тою, шул хис белән исереп йөрү кызны күкләрнең җиденче катына менгерә иде.* Ф.Яруллин. **Күкнең җиденче катында (булу, йөзү)** Бик нык куану, сөенү, шатлану, рәхәтлек халәте кичерү. *Гайсә күкнең җиденче катында йөзде. Бу – адәм әйтеп, адәм ышанмаслык хәл иде.* Ф.Садриев. *Нәзирә белән без дә шул хәлдә идек. Үзебез сөйләшмибез, әмма күңелләребез, кем әйтмешли, күкнең җиденче катында.* Җ.Тәрҗеман. *Фәрди сиздe: Зифа да үзен күкнең җиденче катындагы кебек хис итә иде.* Сөембикә. **Күкнең төбе тишелү** Көчле яңгыр яки кар яву. *– Ява, – диде Айрат. – Эре яңгыр тиз туктаучан да – туктамый: күкнең төбе тишелгән.* Г.Мөхәммәтшин. **Күктән алынган** Уйдырма. *Аңа бер-ике көн җитә: тынычлап кәгазьләрне тәртипкә китерергә һәм идарәнең ике еллык хисабыннан «күктән алынган» фамилияләргә хезмәт хакы түләнгән серле ведомостьне алырга да Ташкентка, ә, бәлкем, Мәскәүгәдер, китеп югалырга.* Р.Мирхәйдәров. **Күктән җибәрелү** *к.* **күктән иңү**. *Нәкъ шундый көннәрнең берсендә мине сезнең авылга алма төяргә җибәрделәр. Бу, мөгаен, күктән җибәрелгән ярдәм булгандыр.* Ф.Яруллин. **Күктән җиргә төшү** Нининдер әйбергә, эш-шөгыльгә, вакыйгага аек акыл белән, реаль карый башлау, аңлап якын килү. *Шуңа күрә ата кеше дә уйлый: тозларгамы аңа баласын, әллә, егет эшчән, тырыш, намуслы, ата-анасы да ипле күренсә, күктән җиргә төшәргәме?* Т.Әйди. **Күктән иңү** 1) Дини карашлар буенча: Алладан килү, Алладан җибәрелү. *--- яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне --- сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте.* Ә.Еники; 2) Һич көтелмәгән җирдән килеп чыгу, пәйда булу. *--- ул көтүче зур бер музыкант булырга кирәк; ул быргы аңар күктән иңгән булырга кирәк: андый матур тавышны мин әле гомерем эчендә әүвәлге мәртәбә ишетәм.* Ф.Әмирхан. *Күктән иңгәндәй пәйда булган бу егет нәрсәсе беләндер Рәхимгә ошады.* А.Вергазов. **Күктән йолдыз чүпли торган** Уңган,

булдыклы. *Малайны заводның һөнәр училищесына укырга кертте. Күктән йолдыз чүпли торган булмаса да,ипле иде, ярыйсы гына укып, әйбәт кенә фрезеровщик булып чыкты.* М.Маликова. **Күктән көткәнне җирдә очрату** *к.* **күктән көткәнне җирдә табу**. *Әмма хәзер Бохара компартиясенә нигез салган шушы кешеләр белән бер-ике авыз сүз алышу аның өчен күктән көткәнне җирдә очрату бәрабәрендә иде.* Т.Әйди. **Күктән көткәнне җирдә табу** Уйламаганда, көтмәгәндә хыялдагы теләкнең тормышка ашуы. **Күктән көтү** Нәрсәнең дә булса үзлегеннән барлыкка килүенә, гамәлгә ашуына өмет тоту. *[Акбирдин:] Кандырга без суны күктән көтмибез, җирдән эзлибез.* К.Тинчурин. **Күктән төшкәнне көтү** *к.* **күктән көтү**. **Күктән сөрелгән** Дәргяһтан сөрелгән. *Ут белән күктән сөрелгән бер усал шайтан кеби, Сөрдисә мәҗлестән, ул дингә сыенган Мостафа.* Г.Тукай. **Күктән төшү** 1) *к.* **күктән иңү**. *Мәлс Нәфисәгә соклanып карап торды. Бу күркәм гөлчәчәк, күктән төшкән алиһәдәй бу зат анықы бит!* Ф.Садриев. *Ә сиңа, сеңлем, бәхет күктән төшкән. Берүзеңә бер бүлмәле фатир.* Ф.Яруллин. *Пашаның олы кызы Нәримә ханым: – Ай, Ихсан, син мондамыни? Күктән төшмәгәнсеңдер ич? – дип әсәренгәндәй итте.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) Тирә-якта барган күренешләрне, булган хәлләрне аңламау, төшенмәү турында. *Рәмзиянең йөзенә елмаю чыкты: – Сез, абзый кеше, әллә күктән төштегезме? Кайдан килеп авыл кибетендә ит булсын?* Н.Әхмәдиев. *Балалар исә алар күңеленең нечкәлеген аңлап бетерми. Әйтерсең күктән төшкәннәр...* Р.Мулланурова; 3) Бушлай, хезмәт куймыйча бирелү, җиңел генә табылу; 4) Зинадан туу, уйнаштан туу; никахсыз туу. *[Бибкәй:] Берәүләрнең баласы бар икән. Ирсез көе күктән генә төшкән бала шулай газиз була инде ул.* М.Фәйзи. **Күктән эзләгәнне җирдән биру** *к.* **күктән көткәнне җирдә табу**. *Миңнурыйга әкәмәт шәп туй күлмәге таптым, искиткеч! Күктән эзләгәнне җирдән бирде, дигән кебек булды бу.* Ф.Латыйфи. **Күктән яву** *к.* **күктән төшү** (*3 мәгъ.*). *– Баллар, майлар күктән яумый шул, – диде Ләйлә, ирен яклап.* Ф.Яруллин. **Күк терәве** Озын буйлы кешегә карата әйтелә. *Әй, сөйләмә шуны, күк терәве.* И.Гази. **Күк чатыры** *к.* **күк көймәсе**. *Баш очларында гына йолдыз атылды: күк чатыры буйлап кадалып төште.* И.Гази. **Күк чите** *и. к.* **күк итәге**. *--- еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә.* Ә.Еники

**КҮК** II *с.* 1) Ачык зәңгәр, күк I (*1 мәгъ.*) төсендә булган. *--- кияүнең үзен дә буш итмәделәр: күп түгел, әмма шулай да, кыз бүләге итеп, аңа яхшы хром итек белән күк бостон костюм бирделәр.* Ә.Еники. *Күкчәчәкнең кәрзин кырыендагы бүрәнкәсыман чәчәкләре күк төстә була.* Ботаника

2) Зәңгәрсу соры. *Күк күгәрчен гөрлидер, Гөлләр чәчәк атканда.* Җыр. *Күк томан*

3) *диал.* Аксыл соры (ат төсе тур.). *Ул арада Нәфисәнең күк атын җиккән Мыек Шәмсетдин килеп туктады.* Г.Бәширов. *--- кичке җиләстә без, олы инәем белән икәү генә, күк алашаны җигеп, Сайран авылына аның кияүдәге өлкән кызына --- кунакка барачакбыз.* М.Кәрим

4) Салкыннан, бәрелүдән һ.б.ш. тышкы тәэсирләрдән тәннең кайсы да булса урынында барлыкка килгән (төс тур.); күгәрек төсендә булган. *[Шәкертнең] чәче җиту, яңак сөякләре чыккан, иреннәре күк, күзләре ачык көе хәрәкәтсез ята, үзе җиңел генә һаман сулый иде.* Ш.Камал

5) *диал.* Яшел. *Аларның күпчелеге, чалмасын салып куеп, түбәтәйдән генә калган һәм кәефләнеп күк чәй эчә иде.* Т.Әйди. *Үзбәк, казах, кыргыздан кушылган бер гаиләдә, түгәрәк табында, ястык өстендә аяк бөкләп, күк чәй, кара чәй эчтек.* И.Юзеев

6) Башка бер төскә күк төс яки төсмер кушылуын белдерә. *Авыл булып утырган күк-сары, сары-кызгылт --- төстәге юрталар уртасында Сүбәдәй баһадирның уң кулы – Күнбай бәк юртасы.* М.Хәбибуллин. *Чәчәкләре күкшәмәхә төсендә, кайчакта кызгылт яки ак, югарыдагы яфракларының куентыкларында тезмә такыялар булып урнашканнар.* Урман аптекасы

7) *сөйл. сир.* Өсте җыеп алынган яки сепаратта каймагы аертылган, майсыз (сөт). *Гайшәнең ничә елга бер килгән әнкәсен сыйларга каты арыш икмәге белән өсте алынган күк сөттән башка әйбере дә юк иде.* Г.Ибраһимов

**КҮК** III *бәйл.* Кебек, шикелле, сыман. *Сәхнәдәге биючеләр кисәк кенә әйнып киткән күк булдылар.* М.Мәһдиев. *Хисмәт бүген, җиңгән сугышчы күк, Күкрәгенә шатлык яшергән.* Ш.Маннур. *Аның кош сайравы күк нәфис тавышы ерак урман артындагы сунарчыга ничек ирешсен инде?* К.Тимбикова

**КҮК АЛА** *с.* Ак һәм күк төсләрдән торган (ат төсе тур.). *Минем атым күк ала, Акрын басып күп ала.* Җыр

**КҮКӘЙ** *и.* 1) Йомырка. *Өч йөз күкәйдән өч йөз чебеш чыга. Алар үсеп җиткәч, үзләре күкәй сала башлый.* Ф.Яруллин. *Мөнирҗан бер уңайдан кетәклеккә дә күз төшерде. Титибикәләр бүген дә тырышкан: алты күкәй салганнар.* Н.Әхмәдиев. *Апа --- өстәл уртасына чыжылдап торган күкәй тәбәсе китереп куйды.* Г.Мөхәммәтшин

2) *биол.* Югары төзелешле тереклек ияләрендә: ана җенес күзәнәге; *русчасы:* **яйцеклетка**. *Аталанган күкәйдән эшче корт яки ана корт чыгуы личинкаларны ничек ашатуга бәйле.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Күкәй һәм сперматозоид – бертөрле булмаган шартларда үскән ике организмның тереклек эшчәнлеге продуктлары.* Анатомия

3) *биол.* Ана бөҗәкләр сала торган шундый ук күзәнәк. *Авыру кеше, гадәттә, аеруча балалар, бу урынны кашып, тырнак астына бабасыр күкәйләрен эләктерә ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Ана корт җәй буена күкәй сала ---.* Биология. *Канны суырганнан соң, озынборыннарда күкәй өлгерү процессы башлана.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

4) *биол.* Ата җенес күзәнәкләре ясала торган парлы җенес бизе һәм кешедә,

хайваннарда була торган эчке секреция органы. *Вышкадан чыгып китеп бара иде. – Нишләп кермәде ул? – дип сорады Ирек. – Керсә, аны монда күкәеннән асалар, – диде --- Рәсүл.* Ф.Садриев

◊ **Күкәй баш** Аңгыра, тинтәк, тирәнтен уйлауга сәләтсез кеше. *Нәрәт дип, сүзеңне аста калдырмакчы мәллә син, күкәй баш!* Н.Гыйматдинова. **Күкәй күз** 1) Күз алмасының гадәттәгедән алгарак чыгып торуы; акаеп торган күз, зур күз; шундый күзле кеше. *[Ибрай:] Чумара Садрыйның күкәй күз Галимәсе кебекләргә калса, артыңа әйләнеп карамый өч көн тоташ йөгер.* М.Фәйзи; 2) Ап-ачык күренеп торган нәрсәне дә күрмәгән кеше турында. **Күкәй салган этәч кебек** Берәр нәрсә эшләргә, башкарырга ашкынып тору; кыбырсу. *– Күкәй салган этәч кебек йөрисең, ни булды соң сиңа? – диде Солтания.* М.Галиев. **Күкәй эчендәге сары кебек** 1) Кадерле кеше яки әйберне кадерләү, саклау турында; 2) Тормыш авырлыкларын күрмичә яшәү турында. *--- үзебез дә, колхозыбыз тернәкләнгәч, күкәй эчендәге сары кебек тора башладык.* Ә.Еники. *«Башка чыгып» тора башлагач кына, усал кайнана әйткән «күкәй эчендәге сары кебек» дигән сүзләрнең мәгънәсен аңлады университет белемле килен.* Г.Әдһәм

**КҮКӘЙАШАР** *и. зоол.* Элпәканатлылар отрядыннан, башка бөҗәкләрнең күкәйләре эченә күкәй сала торган паразит бөҗәк; *русчасы:* **яйцеед**

**КҮКӘ́Й КҮЗӘНӘК** *и. биол. к.* **күкәй** (*2 мәгъ.*). *Мүкнең башка сабакчыклары очындагы кечкенә колбачыкларга охшаган төерләрдә эре йомры күзәнәкләр үсә. Алар күкәй күзәнәк дип атала. Сперматозоидлар кебек, күкәй күзәнәкләрне дә бары тик микроскоп ярдәмендә генә күреп була.* Ботаника. *Чәчәкле үсемлекләрдә ата гаметалар – спермийлар – бик вак була. Ана гаметалар – күкәй күзәнәкләр – спермийларга караганда шактый эре.* Биология

**КҮКӘЙЛЕК** *и. биол.* Хатын-кызларда катнаш секрецияле парлы җенес бизләре

**КҮКӘЙСАЛГЫЧ** *и. зоол.* Кайбер бөҗәкләрнең һәм балыкларның ана затларында күкәй салу өчен хезмәт итә торган тышкы җенес әгъзасы; *русчасы:* **яйцеклад**

**КҮКӘЙЧЕ** *и.* Күкәй белән сату итүче кеше. *Аның --- икенче хатынлыкка күрше Түбән авылдан вак сәүдәгәр, күкәйче Гариф кызы --- Фатиманы алып кайтуын Хәбибрахман карт бер дә, бер дә өнәмәгән!* А.Гыйләҗев

**КҮКБАШ** *и. бот.* 1) Ләләчәләр семьялыгыннан чуар чәчәкле үсемлек; *русчасы:* **рябчик**. *Күкбаш артыннан ук көмеш сулы тугайлар янындагы уйдыкларда --- балтырганнар өлгерә.* А.Гыйләҗев. *--- бервакыт Фалих аңа аксыл зәңгәр күкбаш, ала миләүшә, --- тагын бик күп төрле чәчәкләр һәм ак ромашкалар бүләк иткән иде.* Р.Кәрами

2) *диал.* Күкчәчәк. *Миңа ул туктады, үрелеп күкбаш чәчкәләренә кагылды, әмма өзмәде ---.* М.Хәбибуллин

**КҮК БИЛЧӘН** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, вак чәчәкләре себеркәч булып тупланган чүп үләне; *русчасы*: **осот**

**КҮК БӨРЛЕГӘН** *и. бот. диал.* Кара бөрлегән

**КҮ́КБҮЗ** *с.* Ат төсе: аксыл соры. *Их, эченнән алыптай җен чыксын иде дә: «Я, кодрәтле хуҗам, сиңа нәмә кирәк? Акбүз ат кирәкме? Күкбүз атмы?» – дисен иде.* А.Тимергалин. *Җаның булса, уян, сикереп күкбүз атка мен!* М.Гафури

**КҮ́КБҮЗАТ** *и.* 1) Аксыл соры төстәге ат

2) Тимерказык янындагы йолдызлык; кече җидегән, чүмеч йолдыз. *Акбүзат йолдыз, Күкбүзат йолдыз, Тимерказык бер ялгыз.* Мәкаль

**КҮКГӨМБӘ** *и. бот.* Коры, кабарынкы, аксыл яки саргылт көрән төстәге, кагылганда күк төскә керә торган эшләпәле, ашарга яраклы сирәк гөмбә; *русчасы*: **синяк**

**КҮКЕ** *и.* 1) Күкесыманнар отрядыннан йомыркаларын башка кошлар оясына сала, көзен көньякка китә торган урман кошы; кәккүк. *Җир өстеннән йомшак җылы бәреп тора, шул кояш нурында күбәләкләр шаяра, урман эченнән күке тавышы ишетелә.* Г.Бәширов. *Ата-баба сандугач, карлыгач, күке, тургай, кыр казы белән серләшеп гомер кичергән.* М.Мәһдиев. *Кайдадыр еракта-еракта, урманның иң куе җирендә, күке кычкырган авазлар ишетелеп куйгандай була.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүче кеше. *Тәки бер күке булды инде ул Әүхәди, авыл саен бер хатыны, авыл саен бер бала аның.* Татар иле

3) *күч.* Тапкач та баласын ташлап калдырган хатын-кыз. *Үз әнисе булган кеше баланы ташлап китми ул ---. Берәүгә дә бирмибез Гөлнурны! Кирәк булса, бугазын өзеп җибәрәм мин ул күкенең!* К.Тимбикова. *– Таш бәгырь син, Вәли! Бишектә углың елап ятадыр, өеңә кайтыр идең. – Углым?! Минекеләр шәһәрдә, әнкә! Ә теге сабый – күкенеке.* Н.Гыйматдинова

◊ **Күке баш** *сөйл.* Хәтерсез, онытучан кеше турында. **Күке йомыркасы эчү** Нәрсәнеңдер сәбәбен аңламау, зиһен чуалып китү. *– Ни өчен миңа мондый яхшылык, Әлми абый? --- Аңламыйм. – Син, атаң башы, күке йомыркасы эчтеңме әллә?! – дип кычкырып җибәрде Әлми.* Г.Әпсәләмов

**КҮКЕБАШ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан иртә язда ук күк һәм миләүшә төсендәге чәчәкләр ата торган үлән үсемлек; баллы ботка, бал үләне; *русчасы*: **медуница**. *Урман аланнарында умырзая, күкебаш, зәңгәр келәнчел борын төртте.* К.Тәхау. *Язгы урманда күкебаш ерактан ук күренеп тора, аның чәчәкләре эре булмаса да, ачык төстә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КҮКЕ́ ҖИТЕНЕ** *и. бот.* Дымлы урыннарда үсә торган, мүкләрнең сабаклы һәм яфраклы төрләренә караган, киң таралган күпьеллык үсемлек; *русчасы*: **кукушкин лён**. *Күке җитене һәм башка мүкләр сабаклы һәм яфраклы булулары белән суүсемнәрдән, гөмбәләрдән --- аерылып тора.* Умартачылык. *Монда [урманда] чын мүкләрнең бик күп төрләрен күрергә була. Алар арасында күке җитене һәм ешрак нарат урманнарында очрый торган птилиум ыругыннан матур мүк – птилиумтәвә кош кауры*е. Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы.

*Туфракны тоташ яшел келәм кебек каплап, күке җитене йомшак яшел мүкләрне кысрыклый.* Ботаника

**КҮКЕЛДӘҮ** *ф. сөйл.* Кәк-күк, кәк-күк дип кычкыру. *Күке күкелдәмичә майның яме булмый, диләр.* К.Тәхау. *--- сәгатьнең эченнән баш тыгып күкелдәгән кош малайны шаккатырган иде.* М.Мәһдиев. *Күкеләр тагын бер-берсен уздырып күкелдәргә керешә.* Г.Сабитов

**Күкелдәп кую** Бер генә тапкыр күкелдәү; әллә нигә бер күкелдәү. *Июнь ахырларында күп кошлар сайраудан туктый. Ара-тирә күке генә күкелдәп куя.* К.Тәхау

**Күкелдәп җибәрү** Кинәт күкелдәү

**Күкелдәп тору** Һәрвакыт, гел, әледән-әле күкелдәү

**Күкелди башлау** Күкелдәргә тотыну. *Баш очында күке күкелди башлады*

**КҮКЕЛЕ** *с.* 1) Күкеләр булган, күке яши торган

2) Билгеле бер вакытны күке кебек кычкырган тавыш белән белдерә торган (сәгать). *Әти-әнисен бик тә, бик тә көткәндә, инде ике атна тула дигәндә, Исламгали агайның өендә инде телевизор, күкеле сәгать --- ватылган --- иде.* М.Мәһдиев. *Шунда аның [Мөнирҗанның] күкеле сәгатькә күзе төште.* Н.Әхмәдиев. *Кинәт күкеле сәгать – әниләренең туй бүләге кычкыра башлады ---.* Р.Айзатуллин

**КҮКЕРТ** *и.* **1.** Сары яки соры төстәге тиз кабынып китәргә сәләтле химик элемент (сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында, хәрби эштә һәм медицинада кулланыла). *Мин дә, уйламыйчарак әйтеп, дустымның йөрәк ярасына тоз гына түгел, күкерт кислотасы сиптем.* М.Юныс. *Берәүләр, Гыйлемҗан озак торса, дары урынына [алтатарга] шырпы күкерте генә салырга кирәк, диделәр.* М.Мәһдиев. *Әледән-әле су өстенә тирәннән сумала һәм күкерт кисәкләре калка.* А.Муранов

**2.** *с. мәгъ.* Күкерт **1.** төсендә булган, шуның төсен хәтерләтә торган. *Дегеттән чыккан сыман күкерт-кара йөзле, бүрәнәдәй юан муенлы --- карт --- ишеккә таба юнәлде.* А.Хәлим

◊ **Күкерт кебек дөрләү** *к.* **күкерт кебек кабыну**. **Күкерт кебек кабыну** Бик тиз ачулана башлау, бик тиз ярсып чыгу. *Берни булды исә, күкерт кебек кабынып китә дә хәзер куллары белән уйнарга керешә.* Т.Гыйззәт. *Күкерт кебек кабынып китә торган Тимерхан лапастан алып чыккан сәнәкне ачу белән җиргә кадады.* Р.Вәлиев. **Күкерт сыман дөрләү** *к.* **күкерт кебек кабыну**. *– Кияүгә?! – Сәрхуш күкерт сыман дөрләде. – Башыма тай типкән мәллә минем?!* Н.Гыйматдинова. **Күкерт сыман кабыну** *к.* **күкерт кебек кабыну**. *– Ю-у-ук, – дип, көтмәгәндә кинәт җанланып, кулларын бутый-бутый сөйләргә кереште Вәлиди. Күкерт сыман кабынды.* Р.Мөхәммәдиев. **Күкерттәй кабыну** *к.* **күкерт кебек кабыну**. *Кәлимулла абый өенә күкерттәй кабынып кайтып керде.* М.Шаһимәрдәнов

**КҮКЕРТЛӘНҮ** *ф.* Күкерткә әйләнү; күкерткә манылу, күкерт белән каплану

**Күкертләнә башлау** Күкертләнергә тотыну

**Күкертләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча күкертләнү

**КҮКЕ́РТЛӘ́Ү** *ф.* Күкерт белән эшкәртү; күкерткә ману, күкерт белән каплау

**Күкертләп бетерү** Тулысынча күкертләү

**Күкертләп чыгу** Һәрберсен, булган берен күкертләү

**Күкертли башлау** Күкертләргә керешү

**КҮКЕРТЛЕ** *с.* Химик составында күкерт булган; күкерт кушылган. *– Санаторийга, курортка җибәрергә кирәк, күкертле сулар, ләмнәр, бәлки, файда бирер, – диде ул соңыннан.* Ф.Яруллин. *Аяклары авырганга күрә, аңар [дәү әнигә] шушы көннәрдә күкертле сулар белән дәваланырга барырга кирәк иде.* Ф.Әмирхан. *Оренбург далаларында кымыз эчеп, күкертле суларда коенып дәвалану нәтиҗәсендә, аның сәламәтлеге әйбәтләнеп китте.* Җ.Тәрҗеман

**КҮКЕ́РТ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Плаунчалар семьялыгыннан, мүкле, ылыслы урманнарда, дымлы, кайчак сазлы җирдә үсә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **плаун, баранец обыкновенный**

**КҮКЕ́ САБЫНЫ** *и. бот. к.* **күке үләне**

**КҮКЕ́СЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* 120 ләп кош төрен берләштерә торган бер отряд; *русчасы:* **кукушкообразные**

**КҮКЕ́ ТӨКЕРЕГЕ** *и.* 1) Боҗрасыман ефәк кортының агач ботакларына салган күкәйләреннән гыйбарәт боҗра. *Арматура чыбыклары юка ак боз белән капланганнар иде. Күке төкерege кебек өзек-өзек урыннары да бар.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Бик аз, күләме, микъдары ягыннан бик кечкенә нәрсә. *[Хезмәт хакы] Күке төкереге инде, чәй-шикәргә дә җитми.* Социалистик Татарстан

**КҮКЕ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан, утчәчәк ыругыннан, сабагында селәгәйгә охшаш күбекле, ал һәм ак чәчәк ата торган күпьеллык үсемлек; сабын чәчәк; *русчасы:* **кукушкин цвет**. *Канәферчәләрнең чыпчык җилеменә охшаган башка төрләре дә бар: мәсәлән, сазлы болыннарда үсүче нәфис алсу төстәге, салынкы чәчәкле күке үләне ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КҮКЕ́ ЯШЕ** *и. бот.* Сәхләбчәләр семьялыгыннан, туры сабаклы, тоташ яки бармаксыман аерчалы бүлбеле үсемлек һәм шул үсемлекнең чәчәге; төертамыр, сәхләб; *русчасы:* **кукушкины слёзки**. *Күке яше, тавык үләне яздагы кебек шау чәчәктә.* К.Тәхау. *Ә күке яше? Аны төнгә тулысы белән салкын суга салу тиешле. Нинди нәфис, ә үзе салкыннан курыкмый.* А.Мифтахетдинов

**КҮКҖИЛӘК** *и. бот.* Арчанчалар семьялыгыннан, күксел кара төстәге җиләк бирә торган кечкенә куак һәм аның җиләге; торна җиләге; *русчасы*: **голубика**. *Монда кызыл карлыган, күгән, күкҗиләк, нарат җиләге, шикша үсә ---.* А.Мифтахетдинов. *Сазлыкта үсә торган кечкенә куаклардан һәм үләнчел үсемлекләрнең (--- күкҗиләк, сазанак, мүк җиләге, күрән) аз сандагы төрләреннән яңа бергәлек барлыкка килә.* Биология. *Тундрада төньяк боланнары көтелә, җиләк үсемлекләреннән саз җиләге, күкҗиләк --- җимешләре өлгерә.* Ботаника

**КҮК-ҖИР** *җый. и.* Күк һәм җир; күк һәм җирдәге барлык нәрсәләр. *«У-у, – диде урманны урап килгән кайтаваз, – у-у!» Күк-җир дә Тәминдар өчен өзгәләнә иде.* Н.Гыйматдинова

**КҮККАНАТ** *и. зоол. к.* **күкшә**

**КҮ́К КАРГА** *и. зоол.* Ракшасыманнар отрядыннан, гәүдә озынлыгы 34 см га кадәр зурлыктагы, күк төстәге кош; *русчасы*: **сизоворонка, ракша**

**КҮККҮЗ** *и. к.* **күкчәчәк**. *Кабинасында бер кочак хуш исле кыр чәчкәләре булырга тиеш иде аның: ромашкалар, ипи чәчәкләре, күккүзләр, күзлутлар.* А.Гыйләҗев

**КҮК-КҮ** *иярт. к.* **кәк-күк**. *Хәзер урманда, иртәдән алып кичкә кадәр, «күк-кү, күк-кү» дигән тавыш яңгырый.* К.Тәхау. *Кинәт ерактан килгән «күк-кү, күк-кү» авазы аны тораташ хәленнән чыгарды.* Х.Сафина. *Мине берәү дә, «бәләкәч кызчыгым!» дип, түшәмгә чөя-чөя сөймәде, күк-кү иттермәде ---.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тегәргә уңайлы булсын өчен яки тегелә торган әйберне кидереп үлчәп карарга әзерләгәндә, аның кисәкләрен энәне эре-эре атлатып тегеп беркетү; типчү. *Ике кисәк тукыманы, сул якларын эчкә каратып, берсе өстенә икенчесен салыгыз, энәләр белән беркетеп күкләгез.* Көнкүреш хезмәте. *Ике катлы тасманы башта ике ягыннан да күклиләр һәм каеп чыгалар ---.* Йорт эшләре

2) Энәне эре-эре атлатып тегеп, җөй буен билгеләү

**Күкләп бетерү** Тулысынча күкләү

**Күкләп кую** Тиз арада, тиз генә күкләү

**Күкләп чыгу** *к.* **күкләп бетерү**

**Күкли башлау** Күкләргә тотыну

**Күкли бирү** Бернигә дә карамыйча күкләүне дәвам итү

**КҮКЛЕ** *с.* 1) Күк төсле, күк төсмерле яки күк төс катнашкан. *Һәм ул ут чиксез матур: күкле, кызыллы, аклы, ди.* Г.Тукай. *Күкле күлмәк*

2) Катлаулы төсне белдергәндә: күк белән башка нинди дер төсләр аралашкан. *Ак бүре --- [егетне] алып барып, өстенә күкле-яшелле мүк үсеп беткән таш янына китереп: – Менә бу нәрсә, син танышсыңмы? – дип күрсәтте.* Әкият. *Бу сүзләрне ишеткәч, директор Заһир абый көнчелегеннән күкле-зәңгәрле булган, ди, имеш.* М.Шаһимәрдәнов. *Үз колакларына үзе дә ышанмаган Габишевның йөзендә күкле-кызыллы тимгелләр барлыкка килде...* Ә.Баян

**КҮКЛЕК** *и.* Күк төстә булу; күк төс. *Һаваның күклеген каплап, су буенда ком бураны күтәрелде.* Заман – Татарстан. *Диңгезнең күклеге*

**КҮКЛЕ-ЯШЕЛЛЕ** *с.* 1) Күк белән яшел катыш; күк һәм яшел төсләрне эченә алган. *Күкле-яшелле дулкыннар ярга түшәлгән тимер-бетон плитәләр өстенә ярсып үрлиләр ---.* Шатлыклы кайгы

2) *күч.* Артык югары тон белән әйтелгән, ямьсез, чыелдык. *Янындагы егермеләп малайның күкле-яшелле тавышлары белән кычкырып, чинап җибәргәненнән Ярулланың аты кискен итеп читкә тартылды.* З.Зәйнуллин. *– Син нәрсә, мөртәт, безне мыскыл итәргә чакырдыңмы? – дип кычкырды ул күкле-яшелле тавыш белән.* Г.Сабитов. *Кинәт өйдән Сабирәттәйнең күклеяшелле тавышы ишетелә.* М.Галиев

3) *сөйл.* Нинди дә булса күңелсез сәбәптән бик нык бозылган, төсе киткән (йөз, караш). *Күкле-яшелле чырай*

**КҮКРӘК** *и.* 1) Гәүдәнең муеннан алып корсакка кадәр булган өлеше. *Мостафин, сөенеп, Нәҗиясен бер кулы белән күкрәгенә кыса.* Ә.Еники. *Сөләйманов кулындагы ботак кисәген бер читкә ташлады, күтәрелә төшеп, кулларын күкрәгенә кушырды.* Ф.Галиев

2) Гәүдәнең үпкә, йөрәк урнашкан өлеше. *Рәхмәтулла абзый кыз янына килеп чүгәләде. Күкрәгенә колагын куеп тыңлап торды.* Ф.Яруллин. *Әтисе эндәшмәде. --- Сулыш алганда күкрәге ямьсез ачы сызгырып куйды.* Р.Зәйдулла. *--- кибеп яткан печәнне кузгалткандагы, башны әйләндерә торган хуш исне, шифалы һаваны күкрәк тулганчы эчкә аласы, --- сагышлы уйларыннан беркадәргә арынып яшисе килә иде аның.* С.Шәмси

3) Хатын-кыз гәүдәсенең өске өлешендә калкып торган сөт бизләре; түш. *Зөһрәнең изүләре ачык. Бала имгәндә, сөт тамганмы – ул күкрәкләрен сөртәсөртә төшә.* Ф.Яруллин. *Саимәнең --- бала имезгән вакыттагыча имчәкләре чеметкәләгәндәй булды. Әйтерсең лә күкрәкләренә шаулап сөт төшә. Ул үзе дә сизмәстән күкрәкләрен капшап алды.* Г.Галиева. *Хатыны Хәят – таза гәүдәле түгәрәк хатын – олы күкрәкләрен мыймылдата-мыймылдата чыгып, өстәл әзерләргә кереште.* Ф.Садриев

4) Киемдә кеше гәүдәсенең өске өлешенә туры килгән урын, киемнең алдагы өске өлеше. *Кайберәүләр медальләрне өч, ун, егерме сумга сатып алалар һәм тугызынчы май көнне, күкрәкләренә тагып, урамга чыгалар икән.* М.Мәһдиев. *Көн батышы ягында рум легионнары тезелгән, анда --- көбәләренең күкрәк тимерендә арыслан башы төшерелгән алтын тәңкәләрен ялтыратып, бөркет каурыйлары кадалган өслем кигән легатлар балбал сыннары кебек катып калган...* Р.Зәйдулла // Киемнең өске өлешендә булган урын. *Аның өстендә бик гади генә итеп тегелгән, ачык изүле, кыска җиңле яшел күлмәк иде. Күкрәге өстендәге кечкенә кесәсенә ак ефәк кулъяулыгын төртеп кенә куйган...* Ә.Еники. *Машинкадан чыккан алты-җиде юллык кәгазьне мин күкрәк кесәмә тыктым.* М.Мәһдиев. *Мотыйк күкрәк кесәсеннән иллелек суырып чыгарды.* Р.Вәлиев

5) *к.* **күкрәкчә** (*1 мәгъ.*). *--- абыстай да Гөлйөзем әбигә «үлгән кызым өлеше» дип, чиккән күкрәкне төртә иде.* Г.Исхакый

6) *күч.* Кичерешләрнең, хисләрнең һ.б.ның шартлы билгесе; күңел. *Түгәрәк күл буен мин буйладым, күкрәгемнән ташкач уйларым.* Ф.Бурнаш. *Бик күп төн йокыларын качырган көнчелек уты [Сәлимнең] күкрәгендә яңа бер көч белән кабынды.* Г.Әпсәләмов

7) *күч.* Табигатьтә нинди дә булса бер урынның өсте, өслеге, өске өлеше. *Бу шаудан без бер мәгънә тотып алгандай, аңлагандай булдык: Җир шары күкрәк киереп бер сулыш алырга әзерләнә, күпме вакытка булыр, әмма Җир шары үзенең күкрәгенә снарядлар, бомбалар төшермичә туктап ял итәргә әзерләнә ---.* М.Мәһдиев. *Бирәсен*

*бирде инде ул, карт үзе исән чагында бераз ял итеп, тын алсын җиркәй, күкрәгендә үскән печәннең салмак кына тибрәнүеннән иркәләнсен әле бер...* С.Шәмси

8) *күч.* Берәр нәрсәнең алгы өлеше. *Күк дулкыннар әнә шулай бер-бер артлы ерактан, зәп-зәңгәр киңлекләр аръягыннан --- баш калкыталар һәм, зәңгәр канатларын җәеп кагына-кагына, --- туп-туры мәңгелек ташлы ярларга һәм теплоходлар күкрәгенә ыргыла торалар.* Ә.Баян

◊ **Күкрәк авазы** Әрнүле тавыш. *Айдар сызлануына түзә алмыйча күкрәк авазы белән ыңгырашты да җан бирде.* Татар иле. **Күкрәк белән каршы тору** *югь.* 1) Бөтен көч белән каршы тору, барлык көчне биреп көрәшү. *Милләт өчен җан бирәчәк каһарманнарга да аяк чалмак эстәдекләрендә каләмебез вә күкрәгебез илә каршы торабыз.* Г.Тукай; 2) Җитди бәхәсләшү, үз сүзен бирмәү. **Күкрәк белән саклау** Кемне яки нәрсәне дә булса яклап, саклап, батырларча сугышу. *[Каюм:] Авылның һәммә ярлы һәм урта хәлле крестьяннары үзләренең Совет властен күкрәкләре белән саклаячакларына нык ышанабыз.* Ш.Камал. *Ташлап киттем тыныч иҗатымны Миңа бәхет биргән Туган илне Күкрәк белән саклап калырга.* Ә.Ерикәй. **Күкрәк белән яклау** *к.* **күкрәк белән саклау**. **Күкрәк кагып** 1) Үз-үзенең күкрәгенә куллар белән бәрә-бәрә. *– Сәндерәгә ничек меним? – диде ул, як-ягына каранып. – Баскычың күренми. – Гайфулла, күкрәк кагып: – Мин баскычка ярамыйммыни? – диде дә балдызын күтәреп алды.* Ф.Яруллин; 2) Әйткән фикерләренә ышандырырга тырышып, мактанып, масаеп. *Савыт-саба куеп --- йөргән Гөлзаһира да сүзгә кушылды: – Ә «Кәҗә»гә ничек җан керде ул чакларда! Күкрәк кагып йөрде бит, мөртәт!* Т.Таһиров. *[Габдулла:] Миңа шушы ярым җимерек өемә бер такта гына кагып куйсам да, җаным җиңеләеп китә. Үзем өчен эшлим дип, күкрәк кагып куям.* Ф.Яруллин. **Күкрәккә күкрәк килү** Кем беләндер үзара каршылыкка керү. *Шулай да әлегә кадәр бояр балалары белән күкрәккә күкрәк килеп алышка чыккан юк ---.* М.Кәрим. **Күкрәккә май яккандай булу** Куану, сөенү. *Мин, бу ни хәл тагы дип аптырап, аның йөзенә бактым. Баксам – күкрәгемә май яккандай булды: мөдиремнең күзләрендә мөлдерәмә яшь иде.* Х.Сарьян. **Күкрәккә тау аугандай** Нәрсәнең дә булса күңелгә бик авыр, бик каты тәэсир итүе турында. *Саимә --- үзен хастаханәдә ятарлык авыруга санамаганлыктан, докторның хәбәре күкрәгенә тау аугандай авыр тәэсир итте.* Г.Галиева. **Күкрәк киереп** 1) Үпкәләргә тулы, тирән сулыш алып, бөтен көч белән сулап. *Җәвидә хисләрен яшереп маташмады, авызын зур ачып, күкрәген киереп сулады.* Р.Айзатуллин. *--- Хәйдәровның башы әйләнеп киткәндәй булды. – Яратам шушы вакытны! – Ул, күкрәген киереп, рәхәтләнеп тирән сулыш алды.* Т.Таһиров; 2) Барлык көч-куәтне биреп, бөтен сәләтне җигеп. *Чалгысын янап бетергәч, --- карт --- үзенә генә билгеле борынгы сүзләр пышылдап, күкрәк киереп селтәп җибәрде.* С.Шәмси. *[Трунов] тайга җилләренә каршы ничәмә ел күкрәк киереп йөргән шул...* С.Шәрипов. *Өйалды ишеге тагын күгәненнән кубарлык булып ачыла, Сабирәттәй, мул күкрәген киереп, тагын чәлдер-чөлдер [килә башлый].* М.Галиев; 3) Горур, үз көченә үзе ышанып; үзенең хаклы булуын дәлилләп. *– Төрмәдә черисең килсә, сук әйдә, – диде Зөһрә, күкрәк киереп.* Ф.Яруллин. *--- Батый ханга --- яңа сарайда күкрәк киереп утырырга гына иде, бирегә килүгә янә сәясәткә кереп китте.* М.Хәбибуллин. *Парлыларны күргән саен, --- ул: «Башкалар күкрәк киереп ир хатыны булып йөри, ә миңа сөйгәнем белән кеше күзенә күренергә дә ярамый», – дип кимсенә иде.* М.Маликова. **Күкрәк киерү** Артык масаю, һавалану; мактану. *Шундый адәмне дә шаккаттыргач, без тагын да күкрәкне киердек инде.* Р.Зәйдулла. *– Ихтыярны кызык иттеләр, – дип кеткелдәде Нурислам. – Азрак кына башын күтәрә, күкрәген киерә башлаган иде, тоттылар да цемент чокырына ыргыттылар...* Р.Вәлиев. **Күкрәк көче белән** Үз куллары белән эшләп, үз тырышлыгы белән. *Атадан бала яшьләй калса, Күкрәк көчләре белән, абау, бәгърем, мал таба.* Җыр. *Чекушкин --- өйгә кайтты исә, рәхим ит, өстәл тулы ризык-нигъмәт, ата-ананың күкрәк көче белән табылган икмәк, --- улларына һәр нәрсә җитеш.* М.Насыйбуллин. **Күкрәкне мәче тырнау** Күңелдә борчу, шик туу. *Тынычланып басылгачниткәч, абзый кинәт күкрәгенең бер почмагын мәче тырнавын аерымачык сизә башлады: картның күңелендә, Акбалыкка барып, хәтфә кәләпүшен тиктомалга ташлап калдыруына үкенү хисе купкан иде.* Э.Касыймов. **Күкрәк сугу** *к.* **күкрәк кагу**. *СССР диган бөек илнең барлык төбәкләрендә, миллионнарча кешеләрне җыеп, әлеге «гениаль» китаплар турында күкрәк суга-суга сөйлиләр ---.* Ф.Садриев. *– Кәнишне, яла! – диде Гапонин, күкрәгенә сугып. – Мин Ибраһимовны беренче күрәм.* М.Насыйбуллин. **Күкрәк сызылу** Кайгыру, күңел әрнү, көенү. *Уйлыйм, оча күңелем, ялкынлана, Кызулана йөрәк ташкыны, Күкрәккәем сызыла.* М.Җәлил. **Күкрәк тавышы** Яңгыравыклы калын тавыш. *Ирек, йөзенә берни чыгармыйча, күкрәк тавышы белән генә көлгәндәй итте.* Ф.Садриев. *--- аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.* Ә.Еники. *– Әлфирә?! – диде ул күкрәк тавышы белән һәм, шулчаклы озак сөйләшмичә утыруы өчен, эчтән генә үз-үзен шелтәләде.* Ф.Шәфигуллин. **Күкрәктән чыккан тавыш** *к.* **күкрәк тавышы**. *– Нигә, Илшат? – Гүзәл күкрәктән чыккан эчке тавыш белән шулай диде.* Ф.Яруллин. **Күкрәк төю** *к.* **күкрәк кагу**. *– Ә мин, ләкин миңа мин, – ул йодрыгы белән күкрәгенә төйде, тавышын кинәт куәтләтеп җибәрде, – миңа мин бик яхшы аңлыйм!* К.Тимбикова. **Күкрәк тутырып** Үпкәләргә һава тулганчы. *Миләүшә ишеккә якын килеп, күкрәген тутырып саф һава сулады ---.* М.Мәһдиев. *Бераздан --- һавага пешкән ит исе күтәрелачәк. Миңа шул чакта инде син күкрәк тутырып сулыш алуның чын тәмен татыйсың.* М.Кәрим

**КҮКРӘ́К АВЫЗЫ** *и. анат.* Күкрәк читлегендәге иң өске кабырганың күкрәк сөягенә тоташкан өлеше. *Мин түктергән күз яшьләре, мин койган каннар менә монда, күкрәк авызына килеп тыгылган.* М.Кәрим

**КҮКРӘ́К АВЫРУЫ** *и. сөйл.* Үпкә авыруы, туберкулёз. *Моисей Соломонович каты авырып китә. Күкрәк авыруы көчәя.* Җ.Фәйзи

**КҮКРӘ́К БАКАСЫ** *и. сөйл.* Йөрәк чире, ишемия авыруының клиник формасы; стенокардия. *Карчыгы байтактан күкрәк бакасыннан үлгәнгә, Хәбибрахман абзый тәмамысы берьялгызы калган...* А.Гыйләҗев. *Йөрәк астмасы, күкрәк бакасы, гипертония --- һәм башка төрле авырулар белән җәфаланучы --- кешеләргә карап шуларны уйладым.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮКРӘ́К ЗӘХМӘТЕ** *и. сөйл. к.* **күкрәк авыруы**. *Менә шул Әхмәтҗан нәкъ синең кебек күкрәк зәхмәте белән авырып ятты.* А.Шамов

**КҮКРӘ́К КУЫШЛЫГЫ** *и. анат.* Тән куышлыгының тышча (плевра) белән капланган сулыш юллары, үпкә, үңәч, йөрәк, бугаз бизе, кан тамырлары, нервлар урнашкан (кешеләрдә) өске яки (имезүчеләрдә) алгы өлеше. *Асылның йөрәге кысылды, чәнчеште, күкрәк куышлыгыннан ниндидер иң газиз нәрсәсе өзелеп төшкәндәй булды.* М.Хәсәнов

**КҮКРӘ́К СӨЯГЕ** *и. анат.* Күкрәк читлегендәге алгы яктан кабыргалар тоташкан тар һәм яссы сөяк; *русчасы*: **грудина**. *Өч-дүрт метр узуга минем инде тын буылган, күкрәк сөяге ияккә менеп-төшеп йөри башлаган иде.* М.Мәһдиев. *Яшәгән көннәр авырлыгын картайган кешеләр генә белә, бу авырлык рәхимсез, --- аның басымы астында умыртка сөяге көянтәгә әверелә, --- күкрәк сөяге сиздермичә эчкә суырыла.* Р.Зәйдулла

**КҮКРӘ́К ХАСТАЛЫГЫ** *и. к.* **күкрәк авыруы**. *[Апам] күкрәк хасталыгы белән вафат булды.* М.Гафури

**КҮКРӘКЧӘ** *и.* 1) *этн.* Хатын-кызларның күлмәк өстеннән күкрәккә тагыла торган, чигү, мәрҗән, тәңкә кебекләр белән матурланган бизәнү әйбере. *Мулла кияүгә ике пар күлмәкыштан, --- каен анага намазлык, күкрәкчә, күлмәклек --- бирелде.* Г.Исхакый. *Берсеннән-берсе чибәр биш кыз борынгы керәшен күлмәкләре киеп, --- мәрҗән тезелгән яка, күкрәкчәләр тагып, атлаган саен чеңләп-чылтырап, кухнядан бүлмәгә аш-су ташып йөрделәр.* Х.Сарьян. *Татар хатын-кызларының борынгы киеменә хас нәрсә – күкрәкчә.* Г.Мөхәмәдова

2) Алъяпкычның күкрәкне каплый торган өлеше. *Тик бүрәнә өстенә баскан Гыйсьми генә, ике кулын алъяпкыч күкрәкчәсенә тыккан килеш, --- тын гына карап тора иде.* А.Шамов. *Нәфисә күкрәкчәсенә яшерелгән төенчекне Хәлимәнең кулына сузды.* Мәдәни җомга

3) Бюстгалтер, лиф. *Сөембикә колготкидан гына, күкрәкчәсен эләктереп маташа иде.* Ф.Садриев. *Хатны ул [Гайния] кат-кат укыды. Аерыласы килмичә, бөкләп, аны күкрәкчәсе эченә тыкты.* Н.Әхмәдиев. *Сафин --- тәрәзә төбеннән Гөлфиянең сәгатен, идәннән күкрәкчәсен алды, ---.* Р.Айзатуллин

4) *этн.* Татар хатын-кызларының, күкрәкне каплау өчен, күлмәк эченнән киелә торган, чигелгән яисә бүтән төстәге тукыма белән бизәлгән эчке кием

5) *махс.* Борынгы заманда һәм Урта гасырларда: күкрәкне саклау өчен киелә торган сугыш киеме, панцирь. *Күкрәкне бронза пластинкалардан эшләнгән күкрәкчә саклаган.* Борынгы заманнар тарихы

6) Гомумән гәүдәнең күкрәк турысындагы күренеп, аерылып торган берәр билге. *Елгалар ташыр алдыннан, сиртмә койрыклы, кара түгәрәк күкрәкчә «киган» чәперчек тә кайтты.* К.Тәхау

**КҮКРӘКЧЕН** *и. тар.* Борынгы заманда сугышта күкрәкне саклау өчен кулланыла торган кечкенә калкан яки көбәсыман сугыш киеме

**КҮКРӘ́К ЧИРЕ** *и. сөйл. к.* **күкрәк авыруы**. *Атасы үлгәннән соң, үзеннән кече өч сеңелесен, күкрәк чире белән кан төкергән анасын тәрбияләү өчен, башын Кәүҗиякнең кара бае Габдрахманга тоташтан биш елга саткан.* М.Хәсәнов

**КҮКРӘ́К ЧИТЛЕГЕ** *и. анат.* Кешедә, сөйрәлүчеләрдә, кошларда һәм имезүчеләрдә сөяк системасының умырткалардан, кабыргалардан, күкрәк сөягеннән гыйбарәт өлеше (диафрагма белән аерылып, күкрәк куышлыгын барлыкка китерә). *Күкрәк читлегеннән йөрәк былбыл булып очып чыга да кызның иңнәренә кунып сайрый.* Ф.Яруллин. *Кыз буыла-буыла ютәлләргә тотынды, күкрәк читлеген түзә алмаслык авырту биләп алды...* Х.Ширмән. *Шатлык белән тулган йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгарга теләгәндәй талпына ---.* Ф.Латыйфи

**КҮКРӘНҮ** *ф.* Гөр-гөр килү, шаулау, гөрләү. *Салмак кына тирән эрелек белән Ак самолёт килә күкрәнеп.* Ш.Маннур

**КҮКРӘТҮ** *ф.* Шаулату; гөрләтү. *Бу сүзләр өй эчен күкрәтте.* Ирек мәйданы

**Күкрәтеп алу** Бераз, кыска вакытка күкрәтү

**Күкрәтеп җибәрү** Кинәт күкрәтү. --- *Сания нәзек-көчсез бармаклары белән пианиноның аклы-каралы тешләренә китереп басуга, күкле-яшелле авазлар бөтен өйне күкрәтеп җибәрде.* М.Галиев

**КҮКРӘ́Ү** I *ф.* **1.** 1) Гөрелтеле көчле тавыш чыгару. *Яңгыр, гадәттә, төштән соң килеп гөрелдәп күкрәп ява, яки кичтән күк йөзе мөлдерәп тула да төн уртасында ява башлый.* М.Мәһдиев. *Туктаусыз күк күкри, күкрәү авазлары, тора-бара тоташтан дәһшәтле гөрелтегә әверелеп, өзеп-өзеп улаган мотор тавышын күмеп китә.* Г.Сабитов

2) Яңгырау, яңгырау барлыкка китерү. *Габдулланың күз алдына җиз быргыдан күкрәп чыккан тавыш белән тамак кыра торган зур галим килеп басты.* Ә.Фәйзи. *Гасырлар артыннан килгән күкрәү авазына охшатып, иске сәгать суга башлагач кына, яңадан аңына килгәндәй булды.* Р.Вәлиев. *Алдындагы кызын Мәһәрим --- баш өстенә күтәрде: – Хушлашыйк, вакыт, – диде. Аның көр тавышы мәйдан өстеннән күкрәп үтте.* М.Кәрим

3) *куч.* Гөрләп үсү, шаулап үсү. *Чәчәкләр күкрәрләр, --- карлар эрер.* Һ.Такташ. *Эссе чүлләр күкрәп торган*

*яшел кырларга, гөл бакчаларына әйләнер.* Р.Ишморат

4) *куч.* Танылу, шөһрәт яулау. *Яшь вакытта яшьнәдем, көчле вакытта күкрәдем.* Г.Тукай. *Күкрәп яшә, дустым!*

**2. күкрәп** *рәв. мәгъ.* 1) Бик яхшы, шәп булып, мул булып. *Күз күреме җитмәслек, очына-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәшеп үләннәр үскәннәр.* А.Алиш. *Очы-кырые күренмәгән бу күкрәп үскән иген шулкадәр якын, хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә.* Ә.Еники. *Сез бит яхшы беләсез: колхоздагы һәр нәрсәдә аның йөрәк кайнарлыгы утыра. Күкрәп үсүче игеннәрендә дә, техника дип аталган тимер-томырларында да...* Ф.Садриев

2) Шау-гөр килеп. *Кешенең табигате гел үзгәреп тора: «бер давыллап ала, бер тына», әле яшьлеге күкрәп узган туган ягын сагына ---.* И.Юзеев. *Күп учаклар янып сүнгәч, күп гомерләр күкрәп тынгач, очраштык без аның белән.* М.Кәрим

◊ **Күкрәп торган** Көче ташып торган, гайрәтле. *Өч хәерче колхозны берләштереп ясалган, җиде авылны үз эченә алган, --- бу хуҗалыкны кеше рәтенә кертү өчен, Гайсә үз гомеренең күкрәп торган елларын корбан итте.* Ф.Садриев

**Күкрәп җибәрү** Кинәт күкрәү

**Күкрәп кую** Кинәт күкрәү, бер тапкыр күкрәү

**Күкрәп тору** Әледән-әле күкрәү; озак вакыт дәвамында күкрәү

**Күкри башлау** Күкрәргә тотыну

**КҮКРӘ́Ү** II *и.* Гөрелтеле көчле тавыш; саңгырау шартлау тавышы. *Зал күкрәүне хәтерләткән көчле алкышларга күмелде.* Т.Таһиров. *Син бит кәеф кешесе – язгы яңгыр. Крашың, күкрәвең, яңгырларың мул була да тиз алмашына.* Ә.Баян. *Тегеләрнең моңарчы сүлпән аткан пушкалары да дәррәү телгә килде. Жирне тоташ күкрәү тетрәтә.* М.Кәрим

**КҮКРӘҮЛЕ** *с.* Күк күкрәп ява торган. *Җир йөзен сафландыргыч давыллы, күкрәүле яңгыр киләсен алдан ук сизенеп, черек агач куышын эзләгән ябалак.* К.Нәҗми

**КҮКРӘҮСЕЗ** *с.***1.** Күкрәми торган, тавышсыз. *Өй тирәли күкрәүсез яшен уйнап йөргән төннәрне сәер яктылыкта агач ботаклары чәнечкеле тутык тимерчыбыктай күренеп китә.* Х.Сарьян

**2.** *рәв. мәгъ.* Тавышсыз, тын гына. *Ләйлә ире белән килешергә теләмәде. --- Бәхәс, офыкта ялтыраган яшендәй, күкрәүсез сүнде.* Ф.Яруллин

**КҮКСАГЫЗ** *и. бот.* Тузганаклар ыругыннан, табигый каучук бирә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **кок-сагыз**. *Билчән утап, күксагыз төбе каезлап тәмам сөяллләнгән, кер бәләгедәй саллы кул иде безнең әнинең кулы.* Г.Сабитов

**КҮКСӘ́Ү** *ф. диал.* **1.** Ютәлләү (авыру вакытында)

**2.** *и. мәгъ.* 1) Астма, чахотка, коклюш һ.б. ютәл чирләре. *Декан булып озак яшәмәде Захарчук, күксәү чиренә юлыгып, --- мәңгелеккә сәфәр кылды.* А.Гыйләҗев

2) Ютәл авырулы кеше. *Фидаил абый, яралары өстенә күксәүгә әйләнеп, кәкшәеп, әкрен генә сыза барды ---.* Х.Сарьян

**Күксәп тору** Әледән-әле күксәү; озак вакыт дәвамында күксәү

**Күкси башлау** Күксәргә тотыну

**КҮКСЕЛ** *с.* 1) Күк төскә тартым, күгелҗем, берникадәр күк; күк төс төсмерләнгән. *Күк йөзе күксел бәрхеткә охшаган йомшак бер тонык төскә керде ---.* Ә.Еники. *Битенә кунган өянке йонын сирпегән уңайдан, Дамирның күксел ак перчаткасы болар торган юлның уң ягына ишарәләде.* С.Шәрипов. --- *Булатҗан мосафир кара чикмән киндерәсен чишеп җибәрде, керләнгән күксел тәнен, муенына таккан тәресен күрсәтте.* М.Хәбибуллин

2) Башка бер төскә берникадәр күк төсмер кушылуын белдерә. *Бүген секретарь кыз чәчен күксел зәңгәр төскә буяп килгән.* М.Юныс. *Бу яктылык артындагы кап-кара басу, юл буендагы кап-кара зелпе куагы юка гына күксел кара пәрдә аша күренә кебек.* Р.Төхфәтуллин. *Плащлар төрле төстә булса да, диңгез буендагы чуерташлар кебек, бергә килгәч, тоташ бертөсле – күксел соры булып тоелалар.* М.Маликова

**КҮКСЕЛЛӘНҮ** *ф.* Күксел төскә керү, күксел булу. *Краснов ике куллап тегенең кулларын бугазыннан алмакчы булып тырыша. Тыны кысылудан «кырк-кырк» итеп сулышын рәтли. Битләре күкселләнде.* Х.Камалов. *Бәке Чаган бозы өстендәге күкселләнеп яткан кар уртасында караеп, чумгылланып тора.* Ә.Фәйзи. *Директорның маңгаендагы җыерчыклар тирәнәя төшәләр, карашы еракта күкселләнеп күренгән урманга төбәлде.* Ш.Рәкыйпов

**Күкселләнә бару** Торган саен ныграк күкселләнү

**Күкселләнә башлау** Аз гына күкселләнү

**Күкселләнә төшү** Тагын да бераз, берникадәр күкселләнү

**Күкселләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча күкселләнү

**Күкселләнеп китү** Кинәт күкселләнү

**Күкселләнеп тору** Күкселләнгән хәлдә булу; күксел булып күренү. *Егет, ямансулап, ерак та түгел тын гына агып яткан Иделгә, аръякта күкселләнеп, күңелләрне алгысытып торган урманнарга карады.* Р.Зәйдулла. *Егетнең сул яңагында тирән яра җөе күкселләнеп тора.* Г.Мөхәммәтшин. *Максимыч офыкта, өрфия пәрдәгә төренеп, күкселләнеп торган тауларга карап, беразга тынып калды ---.* Ш.Рәкыйпов

**Күкселләнеп чыгу** Нинди дер бер эш, сәбәптән күкселләнү, күкселләнгән хәлгә килү

**КҮКСЕЛЛЕК** *и.* 1) Күксел булу

2) Күксел төс. *Күңелгә, дөньяга ниндидер җиңел күкселлек тула...* Ә.Баян. *Арада буйга кайтышрак сакау Ахунның каратут тәнендә генә яман күкселлек ачык сизелми.* Н.Хәсәнов. *Билетларны кесәгә салып, культура йортының таш баскычыннан төшеп килгәндә, кояш офык күкселлегенә яртылаш чумган иде.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮКСУ** *с. к.* **күксел**

**КҮК СУСЫН** *и. бот.* Сусынчалар семьялыгыннан, кылыч сыман эре кыяклы һәм күк, шәмәхә һ.б. төсләрдәге эре матур чәчәкле күпьеллык үлән

үсемлек; *русчасы*: **касатик германский**, **ирис**

**КҮКСҮ** *ф.* 1) Күгәрү; күгәрек барлыкка килеп, ачы тәм керү (ашлык, он һ.б.ш. тур.). *Совхоз җитәкчеләре --- аларның ул тораклары күксегән яки җил уйнарлык тишек-тошыклы --- булуларын ишетергә дә теләмиләр*. Г.Тавлин. *Чокырда бик дымлы, күксегән үлән исе килә иде*. Ф.Галиев. *Мин менә шушыны [махорканы] тартам. Ә бу сезнең сигаретлар, гафу ит, алар күксегән мүк кенә*. Ф.Садриев

2) *күч.* Нәрсәгә дә булса мөкиббән китү яки нинди дә булса эштә аптырап калу, ни эшләргә белмәү. *Тора-бара ачуым да кабара: нәрсәгә әле мин, Урта гасыр туташлары төсле, сузан каенга карап күксеп утырам?!* А.Гыйләҗев

**Күксеп бетү** Тулысынча күксү, бөтенләй күксү. *Амбардан күксеп беткән арыш исе килеп тора.* В.Астафьев

**Күкси башлау** Аз гына күксү

**КҮК ТАРАКАН** *и. диал.* Кыргаяк

**КҮКТАШ** *и.* Бакырны күкерт кислотасында эреткәндә барлыкка килә торган күк төстәге тоз; бакыр купоросы. *Бордо сыекчасын түбәндәгечә хәзерлиләр: 1 килограмм бакыр купоросын (күкташны) 50 литр су салынган агач яки чүлмәк савытта эретәләр*. Яшелчәчелек

**КҮКТЕРӘР** *с. неол.* Үтә биек, бик күп катлы. *Берләшкән Гарәп Әмирлегендә төзелә торган «Бурҗ Дубай» («Дубай каланчасы») дип атала торган күктерәр йорт (небоскрёб) 630 метрга җитте.* Мәдәни җомга. *Көнбатышның үзендә дә хәл бик җиңел түгел: анда, кризисның бер чагылышы булып, банкирлар күктерәр йортлардан җиргә сикерәләр.* Ватаным Татарстан

**КҮ-КҮ** *иярт. к.* **кәк-күк**. *Ә мәгънәсез кәккүк, мактанып, Тик лыкылдый, үзенә таң калып: Бер белгәне «күкү» аның.* М.Җәлил

**КҮКФАРЫЗ** *и. рус иск.* Күкташ. *Үземне көзгедән карыйдыр идем дә колакларымның күкфарыз күк икәнен белә идем.* Г.Газиз

**КҮКЧӘЧӘК** *и. бот.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан, күбрәк уҗым басуларында очрый торган ачык күк чәчәкле үлән; арыш чәчәге, төймәбаш; *русчасы*: **василёк**. *Ә күктән борчак басуына иксез-чиксез кояш нуры агыла, бу нурга --- чыдый алмыйча бүртенеп чәчәк аткан билчәннәр, баллы куәтләр, күкчәчәкләрдән дөньяга затлы конфет исе таралган ---.* М.Мәһдиев. *Җиләк җыя-җыя, күкчәчәк һәм алабута үсеп утырган арыш кыры читенә җиткәч, без балан куагы күләгәсендә ял итәргә утырдык.* Ә.Гаффар. *Бик матур поляр мәкләре, күгәрчен күз, алтын түй үләне, күкчәчәкләр төньяктагы шәһәр һәм посёлок бакчаларын бизиләр*. Биология

**КҮКЧӘЧКӘ** *и. диал. к.* **күкчәчәк**. *Күкрәп утырган күкчәчкә арасындагы кечкенә өстәл тирәсенә утырыштык.* М.Әмир

**КҮКЧЕЛ** *с. диал.* Беркадәр басынкы, карлыккан тавышны хәтерләткән (тавыш тур.). *Олуг чаң тавышы озаеп торган хәлдә туктап тора. Ул тавыш үзе күкчел.* Ш.Камал

**КҮКШӘ** *и. зоол.* 1) Карга кошлар семьялыгыннан гәүдәсе күксел коңгырт, башы куе көрән, канатлары һәм койрыгы җирән төсле кечкенә кош; *русчасы:* **кукша**. *Урманда «крә-крә» дип кычкырган күкшәләр --- күренә.* К.Тәхау. *Күкшә – кызгылт төстәге кошчык. Ак канатларында зәңгәр таплар күренә. Башында бүреге дә бар*. Н.Сладков

2) Карга кошлар семьялыгыннан, урманда яши, кышын җылы якка китә торган кош, урман саесканы; *русчасы:* **сойка**. *Күкшәләр бик куркаклар; аларның ачык чуар каурыйлары ачык урыннарда тилгәннәрнең һәм башка ерткыч кошларның күзенә ташлана*. Робинзон эзләреннән

**КҮКШӘКОШ** *и. сөйл. к.* **күкшә** (*1 мәгъ.*). *Күкшәкош, кызылтүш, миләш чыпчыгы бик еш килде хәзер урманнан.* Г.Гобәй

**КҮКШЕЛ** *с. диал. к.* **күксел**. *Агыйдел күперенә кергәндә, Уфа тавы, ярты күкне каплаган күкшел болыт төсле, каршыга килеп басты.* Х.Сарьян. *Бер әби күкшел тамырлары беленеп торган ябык куллары белән үзенең кечкенә төенен чишә алмый азаплана иде.* Г.Сабитов

**КҮКШЕЛЛӘНҮ** *ф. диал. к.* **күкселләнү**. *Дамирның йөзе, иреннәре күкшелләнде, ул, күкрәген тотып, үзенә урын таба алмыйча, әрле-бирле йөри иде.* Ф.Садриев

**Күкшелләнеп тору** Күкшелләнгән хәлдә булу. *Аның йокысызлыктан күз төпләре күкшелләнеп тора, йөзе агарып калган иде.* Ф.Садриев

**Күкшелләнеп чыгу** Тулысынча һәм тиз арада күкшелләнү. *Аның [Арслановның] чырае күкшелләнеп чыкты, иреннәре, куллары калтыранды*. Ф.Садриев

**КҮКШИН** *и.* Өскә таба тараеп менгән, гадәттә тоткалы һәм борынлы чүлмәк. *[Дәүләтьяров белән Якуп] иртән, пристаньга чыгып, биш йөз сумга бер күкшин кызарганчы кайнаган сөт алып кerделәр.* И.Гази

**КҮК ЮТӘЛ** *и.* Буылып-буылып йөткерүдән гыйбарәт, балаларда була торган йогышлы авыру, бума ютәл; *русчасы:* **коклюш**

**КҮЛ** I *и.* 1) Бөтен яктан да ярлар белән уратылып алынган табигый сулык. *Күлнең суы салкын иде, күрәсең, төптә чишмәсе булгандыр ---.* Ф.Яруллин. *Су өстеннән башта күл чикерткәсе ермачлап үтте ---.* С.Шәрипов. *Янибызда гына зур, матур һәм шактый тирән күл дә җәйрәп ята иде безнең!* М.Вәли

2) Су түгелеп, җыелып барлыкка килгән кечкенә сулык; күлдәвек. *Бу ташкыннан торып Калды бераз су. Күрер күзгә бу су – Бер кечкенә күл.* М.Гафури

**КҮЛ** II *и. рус* Гадәттә тупас материалдан тегелгән зур капчык. *Җилкәдәге унар потлы күлләр, Үч иткән күк, җиргә тарталар.* Ш.Маннур

**КҮЛӘГӘ** *и.* **1.** 1) Бер яктан яктыртылган предметның икенче ягында барлыкка килгән караңгы чагылышы. *Көмеш шәмдәлдәге ялгыз шәм ялкыны намазлык өстендәге ак шәүлә хәрәкәтеннән тирбәлеп-тирбәлеп куя, диварларда күләгә булып бии.* Ф.Латыйфи. *Шул вакыт ерактан машина уты айкалып алды, песинең күләгәсе, зураеп, абзар стенасына ыргытылды.* М.Галиев

2) Кояш яки ай яктырткан вакытта, Җир өстендәге предметларның икенче ягында барлыкка килгән караңгы чагылышы (бу чагылыш кояш, ай югары

чакта – кыска, түбән чакта озын була). *Кулымдагы путёвка буенча шәһәр читендәге «Дулкын» санаториена килеп җиткәндә, күләгәләр озынаеп, көндезге эсселек шактый сүрелгән иде инде.* Ә.Еники. *Баш пешәрлек эссе көн, авылда тынлык, этләр, телләрен чыгарып, капка күләгәсендә яталар.* М.Мәһдиев. *Үз күләгәсен узарга теләп, тау битеннән чабып үтте Микәй.* Р.Мөхәммәдиев

3) Нәрсә белән дә булса капланып, кояш нурларыннан сакланган урын, аралык. *Моннан да зуррак бәхет бармы икән тагын бу дөньяда дип ятасың рәхәтләнеп шулай җәйге урман эчендә, өеңнең салкынча рәхәт күләгәсендә.* М.Вәли. *Яз көннәрендә мин шунда чыгып, өянке күләгәсендә берьялгызым утырырга яратам.* Г.Сабитов. *Күләгәгә килеп кергәч, тыннар иркенәеп китте.* М.Кәрим

4) Караңгыда ачык күренмәгән берәр нәрсә шәүләсе; карачкы. *Җиргә кара күләгә сикереп төште һәм, эһ дигәнче, кызны, бөтәрләп, икенче күләгәнең аяк астына ыргытты, арбага сикерде.* Ф.Латыйфи. *Кичке тынлыкта йокымсыраган агачлар арасында куе күләгәләр, кара күзле шәүләләргә әйләнеп, мине уратып алырлар кебек.* М.Галиев

5) *махс.* Рәсемдә, картинада кешенең яки предметның иң аз яктыртылган өлеше. *--- ул сурәтләрне җанландырып күрсәтә торган яктылык һәм күләгәләр чагылышы, сурәтләрнең кайчан һәм кемнәр тарафыннан ясалуы билгеле булмау – галимнәр дөньясында бик зур кызыксыну уятты.* А.Муранов

6) *күч.* Кешенең рухи хәле, сагышның, кайгы-хәсрәтнең һ.б.ш.ларның йөздә, күздә чагылышы. *Әлфирәнең йөзеннән әле һаман да мыскыллы елмаю күләгәсе китмәгән иде.* Ф.Шәфигуллин. *Аның шаяртып кабатлана-кабатлана сорашуын әле генә аңлаган югары оч малаеның йөзенә күләгә төшә.* М.Галиев. *Елмаюын елмайды, әмма кара күзләрендә барыбер гарьләнү күләгәсе чагылып куйды аның.* А.Вергазов

7) *күч.* Берәр нәрсәнең тискәре чагылышы, начар ягы. *Турысын әйткәндә, Һаҗәр – минем үткәндәге косарлык дәрәҗәдәге мөртәтлегем күләгәсе бит.* Г.Тавлин

8) *күч.* Берәр кешенең холык-фигыльләрен кабатлаучы, аңа сукырларча иярүче. *Миңа калса, Гәрәй, теге холуй минем байлыгым аркасында Натальяга өйләнергә йөри. --- Холуй да холуй инде үзе, Святослав кенәзнең күләгәсе дияргә була.* М.Хәбибуллин

9) *күч.* Кемнең дә булса яклавы, ярдәме. *--- ә Мәрхабә яшь шул әле, үскәндә абызы күләгәсендә үсте, берәр гаеп булса, апасын кисәтәләр иде, ә Мәрхабәгә иркәләнергә генә кала иде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* Кояш нурларыннан сакланган; ышык. *Уләннәрдәге чыклар да бик кызык: кояш төшкән урында алан өсте көзге кырау төшкән кебек ап-ак, ә күләгә җирдә куе зәңгәр.* Г.Сабитов

◊ **Күләгәгә әверелү** к. **күләгәгә әйләнү** (*2 мәгъ.*). *Ул адәм --- тора-бара Йосыфымның тәмам күләгәсенә әверелде, киленкәем, күләгәсенә.* М.Хәбибуллин. **Күләгәгә әйләнү** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса әһәмияте, кирәклеге бетү. *«--- Әллә мин аның өчен бер күләгәгә әйләнеп бараммы?» – дигән уйлар белән, Гайфулласының кече яктан чыкканын көтте.* Ф.Яруллин; 2) Кемнеңдер артыннан калмый йөрү; 3) Һәр очракта да кемгәдер ошарга тырышу. **Күләгә йөгерү** Йөздә ризасызлык, канәгатьсезлек билгесе чагылып алу. *Шубаринның йөзенә күләгә йөгергәндәй булды, әмма ул үзен бик тиз кулга алды.* Р.Мирхәйдәров. **Күләгәдәге икътисад** Икътисади эшчәнлекнең рәсми статистикада исәпләнмәгән һәм табыштан салым түләмичә алып барылган төрләре. *Әгәр кайчан да булса мине күләгәдәге икътисадны оештыруда гаепләп чыксалар, мин, мөгаен, сазлыкка бу адәмнәрне дә өстерәрмен.* Р.Мирхәйдәров. *Кайбер икътисадчылар әйткәнчә, «күләгәдәге» икътисад белән җитәкчелек итү өчен, сәясәтне, кадрлар мәсьәләсен бик нечкә тоемларга кирәк.* Казан утлары. **Күләгәдә калдыру** 1) Игътибарга алмау, әһәмият бирмәү; арткы планда калдыру. *Кадетлар министрлыгы --- Думаның яраксызлыгын күләгәдә калдыра.* В.Ленин; 2) Кемнән яки нәрсәдән дә булса өстен чыгу. *[Хәмдия:] Берәүгә хасланган мәхәббәтемне дә күләгәдә калдырырлык, күңелемне кол иткән көем бар.* М.Фәйзи. *Минем гөлчәчәк кырым Гарлемның (чәчәкләр үстерә торган шәһәрнең) гасырлар буенча килгән --- шөһрәтен күләгәдә калдырыр.* Ф.Әмирхан. **Күләгәдә калу** Игътибардан читтә калу. *Сумкасы белән бергә югалган кыйммәтле кәгазьләре, документлары өчен генә кайгырмады – дәрәҗәсен югалтып, күләгәдә калудан курыкты ул.* Х.Ибраһим. *Теге вакытта, дәлилләр җитмәү сәбәпле, җинаятьче күләгәдә калды.* М.Насыйбуллин. *Егетләр, без аларны киләчәктә дә күздән җуймаска тырышыйк. Шикле танышлар! Әмма үзебез күләгәдә калырга өйрәник.* Т.Әйди. **Күләгә кебек** 1) Тавышсыз-тынсыз, бернинди тавыш чыгармыйча. *Шулвакыт Ирек күләгә кебек тавыш-тынсыз гына үзенең уң ягына бер кешенең килеп басуын сизде ---.* Ф.Садриев; 2) Артыннан бер дә калмыйча, аерылмыйча, ияреп. *[Хатын-кызның] күләгә кебек һаман артларыннан килүен күзәткәч, Амантай түзмәде, капылт кына борылды да туп-туры тегенең каршысына килеп басты.* Т.Әйди; 3) Һәрнәрсәгә битараф булып, күңел бирмичә. **Күләгә кебек иярү** к. **күләгәгә әйләнү** (*2 мәгъ.*). *Күләгә кебек ияреп, Янымда йөрде үлем.* Ә.Ерикәй. **Күләгә куну** 1) Йөзгә ризасызлык, канәгатьсезлек, күңелсезлек билгесе чыгу. *Ярхәм --- «Кайтты, ахры!» дип шатланып, урыныннан сикереп торган иде дә, өй түрендә басып торган, борыны яньчелгән Әдһәмне күреп, йөзенә күләгә кунды.* А.Вергазов; 2) Кемнеңдер гөрләп торган тормышы бозылу. *Габбасовны эштән алгач, алар йортына да күләгә кунды.* Татар иле. **Күләгәсе генә калган** Ябыккан. **Күләгәсе күмелеп тормау** Кая да булса китеп озак тормау, тиз әйләнеп кайту. *Гайрәтулла ул кая барса, шунда алтын тавына юлыга, китеп күләгәсе күмелеп тормады, әнә ничек баеп кайтты.* Ф.Хөсни. **Күләгә ташлау** *к.* **күләгә төшерү**. **Күләгә төсле** *к.* **күләгә кебек**. *Тиздән туегыз булыр-*

*га тора. --- Ә син, хыялый кешедәй, тәмам сүнеп, күләгә төсле йөрисең.* Ә.Еники. **Күләгә төшерү** Кемнең дә булса исемен таплау. *– Ярар, ул хатын-кызны ачыклап, комиссарга күләгә төшермик, – диде Симиниев.* Т.Әйди. *Бу турыда сөйләп, аның сабыйларча шатланып та, дәртләнеп тә йөргән көннәренә күләгә төшерәсем килмәде.* Г.Галиева. *Үч иткән кебек, шул ук Саттар Хәбирәсе белән аның арасында күләгә төшерерлек бер хәл дә булып алды.* М.Хәсәнов. **Күләгә төшү** 1) Кемнең дә булса исеме таплану. *Аңлашылмас нәрсә түгел: Денис Иванович өстенә күләгә төшә, дигән сүз бу.* Ә.Баян. *Хан, бүгенге хәл – гадәти булмаган хәл, гадел хөкем ит. --- Сезгә дә күләгәсе төшмәс, халык та канәгать калыр.* М.Хәбибуллин. *--- егет аның янында әз генә утырып чыкса да, аларның исеме ил теленә керер, --- имеш-мимеш сүз таралыр, кыз намусына күләгә төшәр иде.* М.Маликова; 2) Күңелсез хәл килеп чыгу, кәеф бозылу. *Эстетика дәресе – кызлар өчен зур бәйрәм. Шул бәйрәмгә күләгә төшәр дип, Илүзәнең башына да килмәгән иде.* А.Вергазов. **Күләгә эчендә калдыру** *к.* **күләгәдә калдыру** (*2 мәгъ.*). *Жандарм ротмистрының --- ишекләргә каравыл солдат куеп, озын төн буенча тентү ясавы шәкерт революциясе турындагы гайбәтләрне күләгә эчендә калдырды.* Г.Ибраһимов

**КҮЛӘГӘ́ДӘЙ** *с.* **1.** 1) Тавыштынсыз, бөтенләй тын

2) Бик ябык, хәлсез

**2.** *рәв. мәгъ.* Тавышланмыйча, бер тавыш та чыгармыйча. *Нәфисәнең иптәшләре, кыяр-кыймас бригадирларына караштырып, күләгәдәй тын торалар.* Г.Бәширов

**КҮЛӘГӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Күләгә барлыкка китерү, күләгә ясау; нәрсә белән дә булса ышыклау, каплау. *Баш өстендә алтын зонтик күләгәли.* Г.Тукай. *Һәр яңа көн туды исә, чалт аяз күктә сарык тиресе хәтле генә бер болыт кояш турысына тап килә дә бөтен Тау ягын күләгәли.* Ә.Баян. *Урамда җылы, якты, тик бу икәүнең күңеленә кереп оялаган шомлы караңгылык дөнья ямен күләгәләгән иде.* М.Маликова

2) *күч. сөйл.* Начар итү, начар итеп күрсәтү; таплау, пычрату

**Күләгәләп тору** Күләгә хасил иткән хәлдә булу. *Учарланып үскән карама агачы, безне кояшка пешермичә, өстебездә күләгәләп тора.* Ф.Хөсни. *--- зур-зур агачларның --- ботаклары --- безнең юлыбызны күләгәләп --- торган --- койманы үткәндә, без тын гына, сөйләшми генә бардык.* Ф.Әмирхан

**Күләгәле төшү** Бераз, беркадәр күләгәләү

**КҮЛӘГӘЛЕ** *с.* 1) Күләгә төшкән, күләгәләнеп торган; кояшның туры нурларыннан ышыкланган. *--- аларның йорты күләгәле якта иде.* Р.Вәлиев. *Иркен иген кырлары, хозур күләгәле бакчалары, матур-матур утарлары белән күз явын ала торган үзәннәре дә бар лабаса бу җир йөзенең.* Т.Әйди. *Кояшлы ачык урында үсә торган үсемлекләр күләгәле урманда очрамый.* Ботаника

2) *күч.* Тулы булмаган, начар, тискәре, кимчелекле. *Бу колхозның --- аеруча кырчылык тармагы буенча эчпошыргыч күләгәле яклары бар иде.* М.Шабай. *Аннары минем үткән тормыш юлым да... шактый ук күләгәле.* М.Хәсәнов. *Хыялга ашмаслык күләгәле бәхетем артыннан йөгерәм дә йөгерәм мин...* Х.Ибраһим

3) *күч.* Борчулы, тынычсыз, хафалы. *Мин шуны сизәм: бу бәхетле минутлар артында аңлаешсыз күләгәле көннәр ята төсле.* А.Вергазов

4) *күч.* Яшерен. *Дүрт ел эчендә аның дошман дигәне дә күңелнең күләгәле бер почмагына кереп урнашкан була бит.* М.Маликова

**КҮЛӘГӘЛЕК** *и. к.* **күләгә** (*2 мәгъ.*). *Җәйнең иң кызу чакларында да аның төбендә салкынча күләгәлек була.* Г.Ибраһимов

**КҮЛӘГӘЛЕЛЕК** *и.* Күләгәле булу

**КҮЛӘМ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса куб берәмлекләр белән үлчәнә торган зурлыгы. *Табигатьтәге төрле күренешләрнең нәкъ әнә шул кәкре сызыкларга буйсынган булуы ачыклана: --- газ күләменең басымга бәйлелеге гипербола белән билгеләнә ---.* Җ.Тәрҗеман. *Турыпочмаклар белән сызылган цилиндрларның күләмнәре суммасы AB дугасы белән сызылган күләмгә якынча гына тигез була.* Югары математика нигезләре. *--- Вавилон, Һиндстан һәм Кытай халыклары да каналлар үткәргәннәр, зур-зур биналар төзегәннәр, төрле савытларның күләмен билгеләгәннәр ---.* Фән һәм тел

2) Нәрсәнең дә булса гомуми зурлыгы. *Ул китап, күләме белән тәнкыйть күзенә чалыныр дәрәҗәдә булмаса да, --- үзенчәлекле бер яшь каләм борын төрткәнен хәбәр итте.* Х.Сарьян. *Ул диңгезләр үзләре дә соңыннан һәм күләмнәре, һәм формалары ягыннан кат-кат үзгәрешләргә дучар булганнар.* А.Муранов

3) Нәрсәнең дә булса гомуми микъдары. *Әгәр дә бу эшне Бакый ага теләгәнчә һәм бик озакка сузмыйча башкарып чыга алсалар, бу хезмәттә катнашкан һәрбер кеше бер айлык хезмәт хакы күләмендә премия алачакларын да әйтергә онытмадым.* Г.Галиева. *Алимент күләмен арттыруны сорап судка бирермен.* Ә.Моталлапов. *Кайбер урыннарда явым-төшемнең күләме ел әйләнәсендә 100–120 мм дан артмый.* Ботаника

4) Берәр төрле күренеш, эшчәнлек һ.б.ш.ның җәелү дәрәҗәсе, колачы, масштабы. *Октябрьдан соң --- киң күләмдә халык әдәбиятына да --- иркенләп үсәргә юл ачылды.* М.Җәлил. *Фронт штабы киң күләмдә һөҗүм башлау планын төзеде.* Ш.Усманов // Нәрсәнең дә булса сферасы. *Аеруча мөһим чаралар тоташ факультет күләмендә үткәрелә иде.* Ф.Миңнегулова. *Ә Мостай ага Кәрим – шуның өстенә дәүләт эшлеклесе дә, илебез күләмендә башкарылган барлык изге эшләрнең үзәгендә торучы ил агасы да...* И.Юзеев. *Ул бөтен галәм күләмендә иң бөек казаныш --- булыр иде!* Ф.Латыйфи

**КҮЛӘМЛЕ** *с.* 1) Билгеле күләмдәге. *Моның өчен, әйткәнемчә, миналарның көчлесе һәм бәләкәй күләмлесе кирәк.* Ш.Рәкыйпов. *Сарьян --- рецензия-тәкъдимнәр, кечерәк күләмле мәкаләләр язуга күчте.* Л.Хәмидуллин. *1946–1947 елларда мин «Моңлы җыр тавышы» --- исемле зур күләмле сәхнә әсәре яздым ---.* И.Юзеев

2) Күләме, микъдары зур булган. *Шушы күләмле биш әсәрнең нәкъ өчесе, бәхеткә, бүгенге авылның бүгенге кешеләре турында булып чыкты.* Х.Сарьян. *Юл төенчекләре күләмле күренсә дә, авырга охшамаган: җилтерәтеп күтәреп киләләр.* Ә.Моталлапов

**КҮЛӘ́МЧӘ** *с. махс.* Төгәл бер күләмдә алып билгеләнгән, шул күләм өчен дөрес сайланган. *Күләмчә авырлык ул – бер куб метр җисемнең килограммнар белән алынган авырлыгы.* Физика

**КҮЛӘНКӘ** *и. диал.* Кояштан, кояш нурларыннан ышыкланган урын, күләгәләнгән пространство. *Төшсен әзрәк, дип, күләнкә безгә дә.* Г.Тукай. *Байтак себергәч, хәл алыр өчен, --- койма буендагы эскәмиягә барып күләнкәгә утырды.* Ш.Мөхәммәдев

**КҮЛӘТКӘ** *и. диал. к.* **күләгә** (*1–3 мәгъ.*). *[Ул] Гәүдәгә таза түгелдер ахры, күләткәсе малайларныкы шикелле генә тоела.* Ш.Маннур

**КҮЛБУГА** *и. зоол.* Челәннәр семьялыгыннан үкергән тавыш чыгара торган саз яки елга кошы; *русчасы:* **выпь**. *Тик ара-тирә мәче башлы ябалак кычкырып куя да, сазлыктан күлбуга тавышы килә.* Х.Сафина

**КҮЛБУГАЛАР** *и. күпл. зоол.* Ләкләксыманнар отрядына кергән челәннәр семьялыгының бер ыругы (камышлыкка оя корып, көндез яшеренеп, төнлә ауга чыга торган кошлар); *русчасы:* **выпи**

**КҮЛДӘВЕК** *и.* Кар эрегәннән яки яңгыр яуганнан соң җыелып калган су. *Бака тагын кычкырып куйды. Ул капка янындагы күлдәвек читендә моңаеп утыра.* М.Юныс. *Анда-санда, төрле зурлыктагы көзге ватыкларына охшап, күлдәвекләр ялтырый.* Р.Вәлиев. *Инде капка асларыннан чыгып, чишмәдән агып төшкән су күлдәвегендә быкырдашкан каз-үрдәк авазлары ишетелгәләде.* Ә.Гаффар

**КҮЛДӘМӘ** *и. сөйл.* Нindидер сәбәп белән су җыелып барлыкка килгән кечкенә сулык; күлдәвек. *Аннары инде озын шлангны тәрәзә аша үткәреп, кранга ялгадылар, бакча мәйданы күлдәмә булганчы төннең төн буе су агыздылар.* М.Хәсәнов

**КҮЛЕК** *и. диал.* Камыштан һ.б.ш.лардан үреп ясалган сумка

**КҮЛ-ЕЛГА** *җый. и.* Күлләр һәм елгалар. *Олы күл-елга магистралендә диңгез кораблары йөри, каналлар аша алар янәшәдәге Миссисипи, Огайо, Оттава, Гудзон елгаларына чыгалар.* А.Муранов

**КҮЛЕМ** *и. диал.* 1) Көндезге ял (кыр эшләрендә). *Энекәш, энем урынына – апай, әнине – инәй, ярчыкны – ярпылчык, ипине – әпи, әбәтне күлем дип әйтү һәм башкалар игътибарны җәлеп итә, колакны иркәли.* Ф.Галимуллин

2) Кыр эшләренең кайсы да булса төрен башкарганда бүлеп алынган җир мәйданы; кишәрлек. *[Мостафа:] Безгә бүген шушы күлемне [урып] бетерергә кирәк.* Ш.Камал

**КҮЛЛӘВЕК** *и. к.* **күлдәвек**. *Җылы күлләвекләрне айкап йөрүләргә ни җитә!* А.Тимергалин. *Аяк астындагы язгы күлләвекләрнең күзенә тояк белән басып, су чәчрәтеп, теркелдәп кенә кайтабыз шулай.* Р.Низамиев. *Юлларда, көзгедәй булып, эреле-ваклы күлләвекләр җәйрәп ята.* М.Шаһимәрдәнов

**КҮЛЛЕК** *и.* Зур булмаган сулык. *Сарнакыйган дигән сазлыкта күллек бар ---.* Әкият

**КҮЛМӘК** *и.* Эчке һәм тышкы кием буларак кулланыла торган, юка тукымадан тегелгән әйбер; ирләр өчен ул өске өлештән генә гыйбарәт булса, хатын-кызларныкына итәк тә өстәлә. *Илгизәр галстук астындагы күлмәк төймәсен ычкындырды.* Н.Хәсәнов. *Анда ---- хатын-кыз тасвирланган иде. Ул ике кулын баш астына салган да, йөзен тамашачыга борып, чалкан яткан, ефәк күлмәге нәфис тәненә сыланып тора.* М.Маликова. *Ишектә күлмәген чалбары эченә тыгарга да өлгермәгән килеш Назыйм күренде.* Р.Айзатуллин

2) *диал.* Ана карынындагы баланың тышчасы

◊ **Күлмәк белән туган** *к.* **күлмәктә туган**. *Ярый әле үзе исән калган. Күлмәк белән туган икән...* Җ.Дәрзаман. **Күлмәккә сыймау** Ачу, үпкә һ.б.ш. хисләрдән бик нык борчылу, үрсәләнү. *Төннең кап-кара сыңар күзенә охшаган күл «Нишләп йөрисең?» дигән сыман сәерсенеп карый, ә ул ачуыннан өрелеп тулган, күлмәгенә сыймый иде.* Н.Гыйматдинова. *Сөенече күлмәгенә сыймыйдыр шул, кыз сораган иде бит.* М.Маликова. **Күлмәккә сыя алмау** *к.* **күлмәккә сыймау**. *Мохтар һаман да күлмәгенә сыя алмыйча алга баруында булды.* Ф.Галиев. **Күлмәктә туган** Эше уңа торган, бәхетле кеше турында әйтелә

**КҮЛМӘК-ИТӘК** *җый. и. сөйл.* Күлмәкләр һәм итәкләр, гомумән, хатын-кыз киеме. *Ә хатын-кызлар үз якларында яулыкларын, күлмәк-итәкләрен сыйпаштыргалап, кибетләрдә ни күргәннәрен, ни юнәткәннәрен, бәяләрне сөйләп бетерә алмый алҗыды.* Ә.Гаффар

**КҮЛМӘК-КОСТЮМ** *җый. и. сөйл.* Күлмәк, пиджак, чалбар кебек киемнәр. *Кияү белән кәләшкә күлмәк-костюм тектерү, балдаклар алу, ике якка бирешәсе бүләкләрне юнәтү – күңелле мәшәкатьләрнең очы-кырые юк сыман.* М.Маликова

**КҮЛМӘК-КҮНЧЕК** *җый. и. сөйл.* Күлмәк, эчке күлмәк һ.б.ш киемнәр. *[Гафифә] үзенең бик вак: күлмәк-күнчек, кершән-иннек интереслары белән --- көлке халәттә күрсәтелә.* Ф.Әмирхан. *Хатыннар, кап-кара пычрак агып торган баудагы күлмәк-күнчекләре тирәсендә йөгерә-йөгерә, яман тавыш белән улап ук җибәрделәр.* А.Вергазов

**КҮЛМӘКЛЕК** *и.* **1.** Күлмәк тегәргә яраклы тукыма; күлмәк тегү өчен билгеләнгән тукыма, материал. *Ул Һаҗәр апасына күлмәклек, әтисенә җылы свитер сатып алган иде.* Н.Хәсәнов. *Карт җиңгәчәсенә ул яшел сатин күлмәклек белән ак батист яулык бирде ---.* Ә.Еники. *«Әминә апакаем, менә сиңа нәни генә бүләк», – дип, Минзукның хатынына күлмәклек төртеп маташа.* Р.Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күлмәк тегү өчен билгеләнгән, күлмәк тегәргә яраклы; күлмәккә җитәрлек. *Кыз --- яңадан бер күлмәклек ситса ала да, исәнләшеп, чыгып китә бу.* Әкият. *Күлмәклек ситсыга мохтаҗ студентларның исемлеге төзелгән.* Җ.Фәйзи. *Ялгызлыгына ка-*

*рамастан, утыз ел буе тырыш хезмәт итүен искә алып, каравылчы Зиятдинованы бер күлмәклек штапель белән бүләклим.* М.Мәһдиев

2) Күлмәк тегәр өчен тукыма, материал сатып алырлык. *Әтисе аның, может, чыннан да военкомдыр. Бер күлмәклек кенә акча юнәтер.* Т.Галиуллин

**КҮЛМӘК-МАЙКА** *җый. и.* Һәртөрле күлмәк һәм майкалар. *Күлмәк-майкаларын җәеп, шуның өстеннән үткәннәрдер дә чирәмлеккә чыкканнардыр.* А.Тимергалин

**КҮЛМӘК-ЧАЛБАР** *җый. и. к.* **күлмәк-ыштан**. *Күлмәк-чалбар суга манып алган шикелле юеш.* М.Юныс. *Ул нафталин исе бөркеп торган күлмәк-чалбар киеп алган, башында өр-яңа кәләпүш, аякларында киертелгән күн читек.* Р.Вәлиев. *Санька --- көймәдә ауный-ауный пычранып беткән өс-башын салып ташлады, чиста күлмәк-чалбар --- киде ---.* Ф.Латыйфи

**КҮЛМӘКЧӘН** *рәв.* Өске кием киеп тормыйча, күлмәк кигән килеш кенә. *Тыштан күлмәкчән генә кергән Галияне Җәмилә борчулы сүзләр белән каршы алды ---.* Т.Таһиров. *Кулындагы камчысы белән, акрын гына иттереп, Рәвил Ярулланың күлмәкчән аркасына шаяртып суккан ---.* З.Зәйнуллин. *Тик ул бүлмәгә кергәндә, карт галим күлмәкчән генә физик күнегүләр эшләп ята иде.* А.Вергазов

**КҮЛМӘК-ЫШТАН** *җый. и.* Киемнең һәр төре, күлмәкләр һәм ыштаннар. *Сәмигулла, чиста күлмәк-ыштаннарын култык астына кыстырып, мунчага китәргә торганда, аларга күршесе Хөрмәтулла карт килеп керде.* Ф.Яруллин. *Хатын-кыз бит сиңа ашарга пешерә, күлмәк-ыштаныңны юа.* М.Мәһдиев. *Дәү энисеннән курчакларына күлмәк-ыштаннар тектереп, шулар белән мәш килеп уйнап йөргән Газизәгә дә инде биш яшь тулды.* Х.Ибраһим

**КҮЛМӘК-ЫШТАНЛЫК** *и.* Күлмәк һәм ыштан тегү өчен тукыма, материал яки шуны алырлык акча. *Минем сүзем ялган чыкмасын инде, карт, син күлмәк-ыштанлык алып кайт.* Г.Исхакый. *Бу көннәрдә күкәй сатып, күлмәк-ыштанлыкка гына булса да акча ясап йөргән --- Хәләфчик --- сөекле дустының кулына узган елгы апрель санын тоттырырга өлгергән иде.* Х.Ибраһим

**КҮЛЧӘ** *и. рус диал.* Бөҗра, алка. *Насосның поршенендагы күн тәгәрмәчләрне бастырып тора торган яссы бер күлчә кырыеннан бөтенләй яньчелгән.* Ш.Камал

**КҮМ-** *кис.* Кайбер сыйфатлар белән артыклык дәрәҗәсе ясый. *Башын күтәреп караса – каршысында күм-күк күзле Серёжа Аксаков басып тора.* Җ.Тәрҗеман. – *Кем... кем өйрәтте сине турыдан-туры капитанга керергә? – Деркач кызарды, күм-күмгәк булды.* М.Юныс. *--- кулым күм-күк таплар белән бизәлгән, тырналып-киселеп беткән була ---.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮМӘ** *и. диал. этн.* Кечкенә балаларны йөртү өчен өсте каплаулы, ике көпчәкле, агачтан ясалган бәләкәй арба. *Арба артларына күмәләр таккан уракчылар безне узып китәләр иде.* С.Җәләл. *Менә юлсыз-нисез җирдән, күмәсен тартып, бер яшь хатын чаба. Күмәсендә ике улы утырган.* Т.Нәбиуллин

**КҮМӘК** *с.* **1.** 1) Берләштерелгән. *Атларны күмәк хуҗалыкларга талап ала торган вакытларда кайтып төшә Баһау.* Г.Ахунов. *Замана егете буларак, аны башта шофёр булу кызыксындыра, күмәк хуҗалык рәисе Тәлха Сәйдәшевкә бу турыда һич икеләнмичә әйтә.* Ф.Галимуллин. *«Кешеләрне батраклыкка ялладың» дип сүгә күмәк хуҗалык рәисе.* Н.Гыйматдинова

2) Күп кешеләр белән бергәләшеп башкарыла, үтәлә торган. *Яшьләрнең күмәк кул чабуы астында кулыннан таягын ычкындырмаган Байтирәк абзый чүгә-чүгә бии ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу такмаклар аңа ошады, күңеле күтәрелеп китте, тик ул, күмәк биюдән кызып, Шкулин берәр юләрлек эшләмәсен дип шикләнде.* А.Мифтахетдинов. *Күмәк җырның кайтавазы магистраль буйлап очты, сопкадан сопкага сугылды.* С.Шәрипов

3) Күпсанлы, күп. *Күмәк хезмәтчеләр [бал кортлары] барысы да тәрәзгә ташлана.* А.Алиш

4) Күп кеше өчен бер, уртак. *Ялгыз калса, сүгенә дә, кычкыра да алмас, күмәк бердәмлекнең нинди көч икәнен аңласын әле...* М.Галиев. *Каминга каршы яктагы диварга зур рам – Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Нәби Дәүли, Нури Арслановның күмәк портреты эленгән.* М.Маликова. *Чабак елгасы ярындагы авылларда гына түгел, бөтен күрше-тирә районнарда да беренче күмәк бакча – колхоз бакчасы була бу.* Г.Мөхәммәтшин

5) Бер колллектив өчен кабул ителгән; җитәкчелек һәм хезмәткәрләр арасында төзелгән. *[Фазлый:] Эш хакын арттыру мәсьәләсе күмәк договорларны яңарту мәсьәләсенә бәйләнгән икәнлеге профсоюз членына мәгълүм булырга тиеш.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Бергәләп, бергәләшеп; күмәкләп. *Мәктәптә җыр дәресе атнага бер керә иде, --- укытучы апа --- күмәк җырлата иде.* М.Мәһдиев. *Дада, сез хаклы бу очракта, марш булгач, ул бит күмәк башкарылырга тиеш.* Р.Мөхәммәдиев. *--- Хатим Миннебаеч --- уртага чыкты һәм күмәк кул чабулар астында Зиләнең ике бит очыннан үбеп алырга да онытмады.* М.Галиев

**3.** *хәб. сүз функ.* Күп, күбәү. *Алар – күмәк. Мин әле яңа гына килгән берәү булганга күрә, сүзне озынга җибәрергә курыктым.* М.Гафури. *Күбәләкләр күмәкләр. Бигрәк шаян кунаклар.* Н.Исәнбәт

**4.** *и. мәгъ. сөйл.* Нинди дә булса максат белән оешкан кешеләр төркеме, коллектив. *Шул күмәктә яңа карашлы, яңа уйлы кешеләр туалар.* М.Җәлил

**КҮМӘКЛӘНҮ** *ф.* Күмәккә әйләнү. *Соңыннан, инде ялгыз өй күмәкләнеп авыл хәленә килгәч тә, элек, башта тагылган исем сакланып калган.* Ш.Камал

**Күмәкләнә башлау** Күмәкләнүгә табан бару

**Күмәкләнеп бетү** Тәмам күмәкләнгән хәлгә килү; бөтенләй, тәмам күмәкләнү

**КҮМӘКЛӘП** *рәв.* Бергәләп, бергә тупланып. *Константин Никифоровичның бар теләге үз тирәсенә батыр кешеләр туплап, тоткыннарның күмәкләп лагерьдан качуын оештыру*

*икән.* Ә.Галиев. *– Ярдәмнән ташламаслар. Ул яктан икеләнәсе юк, – ди Беслан ышаныч белән. – Бездә андый эшләр күмәкләп башкарыла...* Ә.Моталлапов. *Ә бездә --- меңләгән халык стадионга җыела иде дә күмәкләп җырлый иде.* А.Мифтахетдинов

**КҮМӘКЛӘШЕП** *рәв. к.* **күмәкләп**. *Ялтырап торган калай түбәле йортларда яшәүче ике як күршесе, үз бакчаларын сукалаганда, карчыкныкын да әйләндереп ташлыйлар, күмәкләшеп, бәрәңгесен дә утыртып бирәләр.* С.Шәмси. *Күмәкләшеп ашаганнан соң, Хәния өстәл өстен җыештырырга керешә ---.* Н.Хәсәнов. *Дусларым, әйдәгез, бертавыштан, күмәкләшеп кабатлагыз әле минем арттан.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮМӘКЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Бергә туплау, берләштерү, күмәк итү. *Аннан [балалар] кошчыкларны бүлешеп алдылар. --- Кошчыкларга ялгыз-ялгыз күңелсез иде. – Әйдәгез, күмәкләштерәбез, – диде Фәрит.* Г.Гобәй

2) Вак крестьян хуҗалыкларын колхозларга берләштерү. *Илебезне индустрияләштерү, шулай ук авыл хуҗалыгын күмәкләштерү нигезендә яңабаштан кору эшендә химия промышленносте зур урын тота.* Ш.Камал

**Күмәкләштерә башлау** Күмәкләштерергә керешү

**Күмәкләштереп бетерү** Тулысынча, ахыргача күмәкләштерү; күмәкләшкән хәлгә китерү

**Күмәкләштереп чыгу** Булган берсен күмәкләштерү

**КҮМӘКЛӘШҮ** *ф.* 1) Бергә туплану, берләшү; бер оешкан төркем (коллектив) хасил итү. *[Бал кортлары], көтүләре белән бергәләшеп, җиң сызганып, күмәкләшеп эшкә ашыгалар.* А.Алиш

2) Колхозларга берләшү (вак крестьян хуҗалыклары тур.)

**Күмәкләшә башлау** Күмәкләшергә тотыну

**Күмәкләшеп бетү** Тулысынча, бөтенләй, тәмам күмәкләшү

**Күмәкләшеп кую** Тиз арада күмәкләшкән хәлгә килү

**КҮМӘКЛЕК** *и.* **1.** Бергәлек, күмәк эш итү (хезмәттә, көнкүрештә, ялда һ.б.). *Күмәклектә – хәрәкәт, күпчелектә бәрәкәт бар...* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ. иск. лингв.* Бер төрдән булган предметлар өчен уртак булган; уртаклык (исем). *Исемнәр ялгызлык һәм уртаклык (күмәклек) дигән ике төркемгә бүленәләр ---.* Татар грамматикасы. *Исемдә предметлык мәгънәсе үз эченә күп төрле төшенчәләрне туплый: --- ялгызлык һәм уртаклык (күмәклек) исемнәр була.* Татар теле морфологиясе

**КҮМӘКЧЕ** *и.* Күмәкләшү яклы кеше, күмәкләшү тарафдары

**КҮМӘКЧЕЛЕК** *и.* Күмәкләшүне хуплау, күмәкләшү яклы караш

**КҮМӘРТӘ** *и.* Күпләп сатыла торган әйберләр күләме, санлы микъдары. *Ирләр оекбашының бер күмәртәсе (ягъни 10 пары) 300 сум булгач, берсе бигрәк очсызга төшә түгелме соң?* Татар иле

**КҮМӘРТӘЛӘП** *рәв.* Күп микъдарда, күпләп; зур партияләр белән (сату яки алу һ.б. тур.). *Алар чималны күмәртәләп кабул итүче сәүдәгәрләргә тапшыралар яисә турыдан-туры фабрикага һәм заводларга озаталар.* А.Сункишев

**КҮМӘЧ** *и.* 1) Май, йомырка, шикәр һ.б.ш.ларны кушып әзерләнгән камырдан пешерелә торган ашамлык. *Ул кай вакытлар мич ягып күмәч сала, кыстыбый пешерә --- иде.* Г.Исхакый. *Без станция ларёгыннан әле генә сатып алган бер тәбикмәк, черек бәрәңге күмәчен ашап утырабыз.* М.Мәһдиев. *Ятимне кызганалар, бер йорттан да буш чыгармыйлар диярлек, муенына асылган чүпрәк букчасына алабута күмәче, көлчә, бәрәңге, хәллерәкләре бәрәр кукәй дә сала иде.* Р.Айзатуллин

2) *сөйл.* Ак оннан пешерелгән икмәк, ипи. *Тукта, моңар карап торырга ярамас, ичмасам, ак оннан бераз күмәч кабартып куйыйм ---.* Г.Исхакый. *Тегерменче Зәки кызы! Бодай оныннан пешерелгән күмәчне сыер теле хәтле кисеп, каймакка мана-мана умырадыр әле.* Ф.Яруллин. *Безне --- ак күмәч, --- пыяла савытка салынган тоз белән --- каршы алалар да җырлаталар, биетәләр.* М.Мәһдиев

◊ **Күмәче көлгә төшү** 1) Төшенкелеккә бирелеп, күңелсезләнеп, боегып йөрү; 2) Ялганы тотылып, уңайсыз хәлдә калу

**КҮМӘЧЛӘП** *рәв.* Күмәч белән, күмәч ашап (чәй эчү тур.). *Мин хәзер чәй китертәм, бер-икешәр стакан күмәчләп чәй эчәбез.* Ш.Камал

**КҮМӘЧЛЕК** *с.* 1) Күмәч пешерергә яраклы; күмәч пешерергә җитәрлек. *Күмәчлек он. Бер күмәчлек чүпрә*

2) Күмәч алырлык, күмәч алырга җитәрлек. *Күмәчлек акчасы юк-югын. Ләкин куенында бер кыерчык икмәге бар.* И.Гази

**КҮМӘЧ-ТӘМӘЧ** *җый. и.* Күмәч кебек камыр ашамлыклары, төрле күмәчләр

**КҮМӘЧЧЕ** *и.* Икмәк, күмәч пешерүче яки шуның белән сату итүче. *Бохара әмире ишеткән икән: иң тәмле күмәчне Сәмәрканд ханының күмәччесе пешерә икән.* М.Мәһдиев. *Фёдор Алексеевич унбер яшеннән күмәчче ярдәмчесе булган.* Ш.Рәкыйпов. *Доктор бәй, Дөлдөл өчен борчылмагыз. Шулай ук күмәччедән акча да алып калырмын.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮМГӘКЛӘНҮ** *ф. диал.* Салкыннан, бәрелүдән һ.б.ш.лардан күк төскә керү. *Төнлеге ачык тирмәнең уртасында --- бер ир-ат чалкан ята, сары йөзендә канлы яра эзләре, күз төпләре күмгәкләнеп шешкән, күлмәк изүләре аерылган – бөтен кыяфәте аның күптән түгел генә кыйналып ташлануы хакында сөйли иде.* Т.Әйди

**Күмгәкләнә башлау** Аз гына күмгәкләнү. *Ихтыяр, аның шешенке күз кабакларына, күмгәкләнә башлаган йөзенә --- карап, беркавым тын торды.* Р.Вәлиев

**Күмгәкләнеп бетү** Бөтенләй күмгәкләнү

**Күмгәкләнеп чыгу** Тулысынча һәм тиз арада күмгәкләнү

**КҮМГЕЧ** *и.* Үсемлекләрнең төбен йомшарту, күпертү өчен җайлап эшләнгән авыл хуҗалыгы коралы; *русчасы:* **окучник**. *Культиватор күмгече*

**КҮМЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **күмү** *(1–7 мәгъ.). Иске чүплектә чокырга күмелгән җирдән әллә никадәр бодай чыкты.* Г.Бәширов. *Окоптагы кызылармеец куркудан акыра-акыра каядыр*

*качмакчы булып ыргылды һәм, танк чылбыры астына эләгеп, балчыкка күмелде...* Х.Камалов. *Ниндидер олуг хөкемдар күмелгән кабер булырга тиеш.* Ф.Латыйфи

2) Нинди дә булса сыек яисә көпшәк массага бату, чуму, кереп бетү. *Челтәрле күпер астында Ак чиләгем күмелде.* Җыр. *Тәбрия --- туктап калды, ул арада аны арттан дулкын бәреп екты, башыннан каплады. Ул торды, --- ләкин тагын егылды, тагын күмелде.* М.Маликова. *Пароход дуен катламы астына күмелгән булса кирәк.* А.Муранов

3) Берәр затның яки предметның өсте нәрсә белән дә булса каплану, өстенә берәр нәрсә куну. *Әнә хезмәтче: киң җилкәле, зур сакаллы, бөтен җире онга күмелгән бер бабай.* Г.Ибраһимов

4) Кар, балчык, ком һ.б.ш. астында калу. *Кар астында күмелеп калган яшел уҗымны яз җилләре килеп ачкан кебек, яз хәтердә күмелеп яткан истәлекләрне өскә калкытып чыгара.* Ф.Яруллин. *Яртылаш карга күмелгән киртә казыклары бу мизгелдә аңа коткаручы кешеләрдән дә якынрак булып тоелды.* М.Галиев. *Җәе генәме соң, кышын әйт син, бөтен дөнья акка күмелә.* Р.Габделхакова

5) Күп предметлар белән каплап алыну, чолгап алыну. *Тау астына күмелгән авылның кызгылт шәфәкъ нурына манчылган төтен баганалары гына шәйләнә иде.* М.Галиев. *Әле күптән түгел генә халык белән тулып, гөрләп торган урамнар кирпеч, пыяла ватыклары белән күмелеп, бакчалар кара күмергә әйләнде.* Ә.Галиев

6) Агачлар, куаклар, чәчәкләр белән каплану. *Быелгы җиңү язын да шау чәчәккә күмелеп каршы алды ул [шомырт].* Ф.Яруллин. *Алма бакчасына күмелеп утырган өйләр башланды.* М.Галиев. *Ноябрь башында ачык террасада чәчәккә күмелгән гөлләр күләгәсендә --- гәпләшеп утыруның үзенә бер рәхәтлеге була.* Р.Мөхәммәдиев

7) Йөзнең, битнең берәр нәрсә белән каплануы турында. *Аның болай сөйләве, тирә-яны йонга күмелгән киң һәм көләч йөзенең рәхәтләнеп китүе Шәрәфи картка ошады.* Ш.Камал

8) Берәр нәрсә ябыну, нәрсә белән дә булса өсне каплау; нәрсәдер арасына посу. *Митингтан соң Газинур авыл читендә, корыган бәрәңге сабакларына күмелеп, төнге секретта ята иде.* Г.Әпсәләмов. *Мулла --- зур толыбының якалары эченә күмелде.* Г.Ибраһимов

9) *күч.* Нинди дә булса әйберләр бик күп булып, шулар белән шөгыльләнү. *Фаяз --- берничә көн дәреслекләргә, лекцияләр язылган дәфтәрләренә күмелеп утырды.* С.Шәмси. *Һәлакәттән соң беренче атнада станция хуҗалары җирле халыкны «бернинди нурланыш та юк» дип тынычландырырга маташса да, тиздән компания миллионышар долларлык дәгъваларга күмелә.* Мәдәни җомга

10) Нәрсәнең дә булса караңгылык яки яктылык белән чолганып алынуы. *Диңгез буенда очрашуга хәтле, яктылыкка күмелгән зур залдагы халык каршына --- чыгып баскан --- йомшак тавышлы шагыйрә белән бер карашып алу булды бит әле.* М.Маликова. *Кинәт бөтен дөнья нурга күмелде диярсең!* Г.Әдһәм. *Класс бүлмәсе акрын-акрын караңгыга күмелде.* Җ.Тәрҗеман

11) Төтен, томан һ.б.ш. белән каплап алыну. *Бая гына үзенең коры һәм җылы һавасы, он исе белән ямь биреп торган өй эче яшел тәмәке төтененә күмелде.* Г.Минский

12) *күч.* Тавыш, шау-шу белән тулу. *Парк, төрле төсләрдәге утларга чумып, бала-чага чыр-чуына күмелеп, гөрләп тора.* Р.Вәлиев. *Аудитория шаушуга күмелде.* Ф.Садриев. *Зал күкрәүне хәтерләткән көчле алкышларга күмелде.* Т.Таһиров

13) *күч.* Ераклашып яки берәр нәрсә эченә, арасына, артына кереп күренмәс булу, күздән югалу. *Ниһаять, кояш Сарай тавы артыннан күз кысып алды да бөтенләй күмелде.* М.Галиев. *Өлфәт төркеме дә урманга кереп күмелде.* А.Тимергалин. *[Кәрим абзый] --- ике кулы белән аралап, куе арыш арасына керде. – Һәй, кызым, карале, машина күмелерлек бит.* Г.Сабитов

14) *күч.* Зур байлыкка, акчага, зиннәтле әйберләргә ия булу, нәрсәнедер күп итеп кулга төшерү. *Күз карашларында шул алтыннар, ефәкләр эченә күмелгән шат йөрүчеләр арасына барырга теләсәләр дә, үзләрен аңа хаклы күрмиләрдер.* Г.Ибраһимов. *Әнә шулай итеп, байлыкка күмелгән, алтынга чумган Парижның --- кыз-хатыннарны шундый юллар белән икмәк табарга мәҗбүр итүе ачык факт булып кала.* Г.Гали

15) *күч.* Данга, шөһрәткә ия булу, мактал. *Яу булып килә авылга Безнең армия – Җырларда данга күмелгән Кавалерия.* Ф.Кәрим. *Бер күлнең исеме дә шулхәтле киң җәелеп, данга күмелмәгән.* А.Муранов

16) *күч.* Берәр төрле хискә, кичерешкә тулысынча бирелү, дучар булу. *Ул әллә нинди уйларга күмелеп дәшмитынмый гына барган җиреннән дертләп уянып китә.* Ф.Хөсни. *Таһирның йөрәге шатлык хисенә күмелде.* Г.Мөхәммәтшин

17) *күч.* Ыгы-зыгы, тынычсызлык, мәшәкатькә чуму. *Дөнья мәшәкатьләренә күмелеп яшәсәк тә, мәрхүм вакытвакыт искә төшә иде ---.* Ә.Еники. *Яңа көн туып, Николай яңа мәшәкатьләргә күмелде.* Җ.Тәрҗеман. *Прокурор башаягы белән эшкә күмелде: көннәр буе тау кадәр өелгән кәгазьләр арасында казынды.* Р.Мирхәйдәров

**Күмелә бару** Торган саен ныграк күмелү

**Күмелә башлау** Аз гына күмелү

**Күмелә төшү** Бераз, беркадәр күмелү

**Күмелеп алу** Тизгә генә, кыска вакытка гына күмелү. *Төн кочагына кереп барган шәһәр бер генә мизгелгә, күз ачып йомганчыга гына караңгылыкка күмелеп алды.* Ф.Латыйфи

**Күмелеп бетү** Бөтенләй, тәмам күмелү. *Гөлйөзем әби җомгага кадәр күмелеп бетеп, хәзрәтләр Сөннәтче бабайның өендә актык фатиханы да кылдылар.* Г.Исхакый. *Без борчак чәчелгән җирдән барабыз икән, яңгыр булмаганлыктан, чәчкән җир җилләгән, борчак күмелеп бетмәгән.* М.Мәһдиев

**Күмелеп калу** Ниндидер вакыйгадан соң күмелү. *Күпләрнең исемнәре архив тузаннарында күмелеп калган, ---.* И.Юзеев. *Ирләр чит җирләрдә*

*күмелеп калыр өчен дөньяга киләләр.* М.Мәһдиев. *Күмелеп калган болыннарга, анда-санда калкып чыккан утрауларга --- сыкранып карап барудан кәефе кырылды ---.* Ә.Моталлапов

**Күмелеп килү** *к.* **күмелә бару**

**Күмелеп тору** Күптәннән күмелгән хәлдә булу; хәзерге вакытта күмелгән хәлдә булу

**Күмелеп утыру** *к.* **күмелеп тору**. *Бер көнне көтү каршыларга дип капка төбенә чыгып баскан хатыннар Гаффә карчыкның кычытканга күмелеп утырган өеннән төтен чыгуын күреп алдылар.* С.Шәмси. *Франциядә, Париждан егерме чакрымнар чамасы көньякта, бакча һәм гөлләргә күмелеп утырган шәһәрчек ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Урман яисә чәчәккә күмелеп утырган болын буйлап ашыкмыйча гына үтегез.* Ботаника

**Күмелеп яту** *к. сөйл.* **күмелеп утыру**. *[Хөппеҗиһан], боегып, аһ-зарга күмелеп ята.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮМЕР** *и.* **1.** 1) Ташка әйләнгән үсемлек калдыгыннан гыйбарәт, казып табыла торган янучан каты матдә. *Шахталарга син төшәрсең, Жырлап күмер кисәрсең.* Жыр. *Язучылык эше --- белән чагыштырганда, урман кисү, шахтада күмер чыгару пүчтәк кенә.* Ф.Яруллин. *Ерактан ыргытканда күмер, мич авызына эләкмичә, палубага коелып бетә.* М.Юныс

2) Агач янып, көлгә әйләнгәнче сүнгән яки сүндерелгән, кабат ягулык итеп кулланыла торган кара төстәге калдык. *Самавырны тиз кайната Кызыл миләш күмере.* Җыр. *Аларны мин иртәгәсен бик әйбәтләп юып, пот ярымлы күмер үтүге белән үтүкләп җибәрдем.* Ф.Яруллин // Янып, куз хәленә килгән агач кисәге. *Сәбиләнең генә тавышы чыкмый, ул һаман сүзгә кушылмыйча, утлы күмергә карап онытылып утыра иде.* Р.Вәлиев. *Бу минутларда сарыклар кутанда тыныч кына күши, --- учактагы күмерләр сүрән генә көйри ---.* Т.Әйди. *[Егет] --- ике уйлап тора торганга охшамаган, әнә самавырга су салганын, кыскыч белән аның торбасына утлы күмер тутырганын гына карап тору да җитә.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күмердән ясалган, күмер ярдәмендә эшли торган. *Күмер фильтр. Күмер электрод*

2) Шомырт кара, чем кара төстәге. *Озын нечкә буйлы, очлы борынлы, күмер күзле егет сүзгә артык катнашмый ---.* Р.Габделхакова

◊ **Күмергә әйләнү** 1) Юкка чыгу, бетү. *Яшь кыз Сәрмәдия саткан якта --- күп нәрсә күмергә әйләнгән.* Ә.Моталлапов. *--- анда Әфганстан сәүдәгәре Габделшөкерхан мал-мөлкәтенең тулысынча көлгә, күмергә әйләнүе тәүлекнең калган өлешен тоташ ыгы-зыгыга күмде.* Т.Әйди; 2) Авыр рухи газаплар кичерү. *Җавапсыз мәхәббәтеннән янар, көяр, күмергә әйләнер, әмма дустына хыянәт итмәс!* Г.Әдһәм. **Күмергә калу** *к.* **күмергә әйләнү** (*2 мәгъ.*). *Яна йөрәк, яна йөрәк, Күмергә кала инде; Йөрәгемнең янулары Гомергә кала инде.* Жыр. **Күмер итү** Юкка чыгару, юк итү. *Без торгызган матур сарайларны Җиргә екты, күмер итте ул.* З.Мансур. **Күмер карагы** *иск.* Октябрь революциясенә кадәр мәдрәсәдә укучы шәкертләрне карагруһчылар шулай атаганнар. *[Шкафчы – шәкертләргә:] Итәкләрегезгә абынып егылмагыз! Һи, күмер каралары!* Г.Камал. **Күмер төшү** Утын янып кузга әйләнү, утлы күмер булу. *[Таба ипиен] мичне тартыр алдыннан, күмер төшкәч пешерәләр.* Ф.Яруллин. *Мин чәй куеп киләм, күмер төшкәндер...* Р.Мөхәммәдиев

**КҮМЕР БАЗЫ** *и. иск.* Агач яндырып, күпләп күмер әзерләү өчен, урман авызына казып, мич урынына файдаланылган зур чокыр. *Садыкай абзый, күмер базыннан кайткач, ысланган киемен алыштырмыйча, беркайчан да табынга утырмый иде.* Яңарыш

**КҮМЕР КИСЛОТАСЫ** *и. хим.* Углекислый газны суда эретеп ясалган кислота

**КҮМЕРЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса яндырып, күмергә әйләндерү. *Шырпыны күмерләндереп, соры стенага ясады матрос Ленин рәсемен.* Г.Гобәй

2) *куч.* Күгәртү, кара яндыру; күгәргәнче, кара янганчы сугу, кыйнау

**Күмерләндереп бетерү** Яндыру, тулысынча күмергә әйләндерү

**Күмерләндереп чыгару** Нык күмерләндерү. *Миңлегайшә абыстай, ике малаен өстереп, абзарында кыйнатты үземне. --- тәнем-битемне күмерләндереп чыгардылар ---.* Н.Гыйматдинова

**КҮМЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса янып, бөтенләй күмергә әйләнү; күмер булу. *Күмерләнгән өйнең тупсасында Аунап ята ана гәүдәсе.* М.Җәлил. *Шәмнең филтәсе күмерләнеп, факел сыман көйрәде ---.* Ж.Тәрҗеман. *Уртадагы ике-өч аратасы кайчандыр янып күмерләнгән --- баскычтан Ирек икенче катка күтәрелде.* Ф.Садриев

2) Нәрсәнеңдер чите яну, чит-чите көйрәү. *Учак көлендә кызарып, күмерләнеп пешкән кайнар бәрәңгене --- малайлар да үлеп ярата.* Г.Сабитов. *Рабига күмерләнгән бәрәңгеләрне таяк белән чирәмгә куалады.* Н.Гыйматдинова. *Чыбыклар гөлт итеп кабындылар да кара төскә керделәр, төтенләп, бөгелә-сыгыла, чытыр-чытыр килеп яна башладылар, күмерләнгән очлары өскә күтәрелде.* И.Тургенев

3) *махс.* Агачның һавасыз һәм утсыз таркалуы нәтиҗәсендә, ташкүмер барлыкка килү. *Ташкүмер --- агачларның җир астында һавасыз таркалуыннан һәм күмерләнүеннән барлыкка килгән.* Химия

**Күмерләнә башлау** Аз гына күмерләнү

**Күмерләнә төшү** Бераз күмерләнгән хәлгә килү; беркадәр, бераз күмерләнү

**Күмерләнеп бетү** Бөтенләй, тәмам күмерләнү. *Маратның [коймагы] исә кечерәк тә, яньчек тә, ә берсенең асты күмерләнеп беткән иде.* Г.Гобәй

**Күмерләнеп җитү** *к.* **күмерләнеп бетү**

**Күмерләнеп калу** Берәр тәэсирдән соң күмергә әйләнү; күмер хәленә килү. *Янгын иртә белән генә тынды. Берничә йортның стенасы күмерләнеп калды.* Х.Сафина

**Күмерләнеп килү** Янып бетүгә бару

**КҮМЕРЛЕ** *с.* 1) Күмер төялгән, күмер тутырылган, күмере булган. *Эшчеләр һаман да клетка белән шахтага*

*төшеп тора, күмерле вагонеткалар менеп тора.* Ш.Камал

2) Күмергә буялган, күмергә пычранган. *[Гөлчирә:] Әти, минем кулым күмерле, арбасы белән [баланы] минем янга керт әле.* Т.Гыйззәт

**КҮМЕРЛЕК** *и.* 1) Самавырның эчендәге күмер яки чыра тутырып яндыра торган торбасы. *Шул тирәдә торучы каравылчы бабайдан --- самавыр алып, коры-сары чыбык-чабык белән кайнаталар. Хуш ис, тәмле ис чыксын өчен, күмерлеккә лимон кабыгы ташлыйлар.* И.Рәмиев

2) Күмер җыя (саклый) торган урын

**КҮМЕ́Р ЯНДЫРУ** *ф. тар.* Һаваны аз гына кертеп яки бөтенләй кертмичә, агач яндырып, агач күмере әзерләү. *Бу авылның бөтен кәсебе урман кисү икән. Җәйгә чыгу белән, агач кисеп, күмер яндырырга (әлбәттә, завод өчен) китәләр имеш.* М.Гафури

**КҮМЕ́Р ЯНДЫРУЧЫ** *и. тар.* Агач күмере әзерләү белән шөгыльләнүче. *--- итек басучылар, тире иләүчеләр, күмер яндыручылар, --- кыскасы, кемнәр генә булмаган да, кемнәр гомер кичми безнең Югары авылда!* А.Гыйләҗев. *Юлда күмер яндыручылар янында кунып, икенче көнне төштән соң [заводка] барып кердек.* М.Гафури

**КҮМЕРЧЕ** *и.* Күмер сатучы, күмер сату белән кәсеп итүче кеше. *Күмерченең – күмере, итекченең итеге юк.* Әйтем. *Әхмәтнең --- хәзер итчеләрнең, утынчыларның, күмерчеләрнең концертларыннан бик яхшы хәбәре бар.* Г.Камал

**КҮМҮ** *ф.* 1) Чокыр казып, шул чокырга нәрсәне дә булса салып, өстен туфрак белән каплау. *Камил төшеп һәлак булган чүмечтәге металлны детальгә коймадылар, стена кырыендагы җиргә күмделәр.* Н.Хәсәнов

2) Җир, туфрак һ.б. астында калдыру. *[Егетне] Бер көнне күкертле ваннага чумдыралар, икенче көнгә ләмгә күмәләр.* Ф.Яруллин. *Иң хәтәре шул булды: янәшәдәге иң тәмле сулы саналган коены, өске бурасын сүтеп, түбәдән төшкән тирес һәм балчык белән күмеп, җир белән тигезләп киттеләр.* М.Галиев. *Сәгыйдә --- тәпиләрен, яр комына күмеп уйнагандай, бодай бөртекләренә күмде.* Н.Хәсәнов

3) Пешерү өчен, утлы көл эченә салу. *Дөньяда иң тәмле ризык нәрсә? --- бу хакта Галәү бабай ---: – Көлгә күмеп пешергән бәрәңге, – дияр.* Г.Сабитов. *Таганга чәйнек асабыз, көлгә бәрәңге күмәбез.* М.Кәрим. *Буа буылып беткән кичне ярда учак ягып, шул учакка бәрәңге күмеп, «буаны саклап», аның янында кунабыз.* З.Зәйнуллин

4) Мәетне кабергә салып, өстен туфрак катламы белән каплау; җирләү, дәфен итү. *[Сөннәтче бабайны] үзе казыган кабергә иртәгесен бөтен авыл җыелып күмде.* Г.Исхакый. --- *Мәскәүнең бер заводында эшләүче татар агае, хатыны үлгәч, «мин – дин дошманы, хатынымны яңача күмәм» дип белдергән ---.* М.Мәһдиев. *Татар гадәте буенча мәетне шул ук көнне күмәләр.* Г.Ахунов

5) Нәрсә белән дә булса каплап, басып китү (су, кар һ.б.ш.). *Зыкы суыкларда урманнан ач-ялангач килеш утын тартып ташулар, тирләп-пешеп, кар күмеп киткән эскертне ачу --- Маһиянең үпкәсен кабартып, аны түшәккә екты.* Н.Хәсәнов. *Бу көнне егет урамда суык кыш булуын да, урмандагы куян сукмакларын кар белән күмеп, ачы җил дулавын да бөтенләй онытткан иде.* Г.Мөхәммәтшин

6) Берәр нәрсәне бөтен яктан каплау; уратып алу. *Хәтерлисеңме, Сәбилә, туй мәҗлесе көнне мин сине кыр чәчәкләренә күмгән идем.* Р.Вәлиев. *Тау башын куе озын үлән каплаган булыр. Чак кына иелсәң, ул безне бөтенләй күмәчәк.* М.Кәрим // Нәрсәнең дә булса икенче бер әйберне каплап китүе. *Әллә уйлый туган илнең гөл юлларын, Яфрак күмгән, балкып көлгән күл буйларын.* Н.Исәнбәт. *Карт утырткан үрмә гөлләр, койма-диварларга сарыла-сарыла, йортны чәчәккә күмде.* Г.Әдһәм

7) Нәрсәне дә булса караңгылык яки яктылык, нурлар белән чолгап алу. *Иртәгә аны үтерсәләр, дөньяны нурга күмгән кояш та, --- шушы сылу кыз да – барысы-барысы калачак бит!* Ш.Рәкыйпов. *Күктә бар дөньяны көмеш нурга күмеп ай йөзә.* Р.Габделхакова. *Тиздән, тирә-юньне яктылыкка күмеп, фаралар ялт итеп кабынып киттеләр.* Р.Төхфәтуллин

8) *диал.* Культуралы үсемлек тирәсенә йомшартылган туфрак өю. *Бәрәңге күмү*

9) *күч.* Нәрсә белән дә булса кирәгеннән артык тәэмин итү. *Чиле-пешле шигырьләрне, поэмаларны бер-бер артлы язып, редакцияләрне, нәшриятларны күмеп ташлар идем.* Ф.Яруллин

10) *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне бик күпләп бирү, җибәрү; кемне дә булса берәр нәрсә белән баету. *[Хисами:] Мин сине акчага күмәрмен һәм шулар өстенә тагы әткәйдән бер имана җир дә бирдертермен.* Г.Минский. *Сөенде Заль, тетрәнә янә җаны, Бүләкләргә күмде ул арачыны.* Ә.Фирдәүси. *Флора ханымны чәчкәләргә күмделәр һәм җилкәсенә кәҗә мамыгыннан бәйләнгән зур ак шарф салдылар.* Г.Галиева // Шатлыкка, бәхеткә, данга һ.б.ш.ларга ия итү яки авырлыкларны оныттыру. *Шатлыкка күмдең бүген син Әткәңне, әнкәңне дә.* С.Хәким. *Онега заводы эшчеләреннән төзелгән --- партизаннар отряды ул сугышларда аеруча зур ныклык һәм батырлыклар күрсәтеп, үзен мәңгелек данга күмде.* А.Муранов

11) *күч.* Берәр нәрсәнең көчен, тәэсирен киметү, сүрелдерү, арткы планда калдыру. *Күңеленә кереп оялаган ризасызлык тойгысын әнә шулай эш белән күмәргә теләде.* Ж.Тәрҗеман

12) *күч.* Тавыш, шау-шу белән каплап, чолгап алу. *Культура йорты янында җыйналган кешеләр аны алкышка күмделәр.* Г.Тавлин. *Бүлмәне җәелеп, тугарылып көлгән калын тавыш күмеп китте ---.* Ф.Латыйфи. --- *анда Әфганстан сәүдәгәре Габделшөкерхан мал-мөлкәтенең тулысынча көлгә, күмергә әйләнүе тәүлекнең калган өлешен тоташ ыгы-зыгыга күмде.* Т.Әйди // Берәр тавышны ишетелмәслек итү, көче ягыннан аны узып китү. – *Университетта нидер шартлады! – дип кычкырды шофёр, гөрелтене күмәргә тырышып һәм, тешләрен кысып, бар көченә тормозга басты.* Ф.Латыйфи. *Гудок тавышын да күмеп кычкырган*

*аның тавышына әнисе йөгереп чыкты.* М.Галиев. *Поезд тәрәзәләреннән, ахры, тәгәрмәч дыкылдауларын күмеп, әлеге моң тарала.* Т.Әйди

13) *куч.* Бик күпләп сораулар яудыру, бик күп сүзләр әйтү. *Аны телдән дә, язма рәвештә дә сораулар белән күмделәр.* М.Мәһдиев. *Башта Фатыйма ападан гына сораштылар, аннары үземне сорауга күмделәр.* Р.Габделхакова. *[Муса Нургалине] үзенчә ярты-лаш үзбәкчәләп, сүз белән күмеп ташлады.* Ә.Еники. *Машинаны такыр юлга чыгаргач, Коля мине сораулар белән күмеп ташлады.* Г.Сабитов

14) *куч. сөйл.* Берәр эшне, күренешне һ.б.ларны юкка чыгару, бозу, харап итү. *[Өндәмәләрдә] болай язылган: «Халыкка чылбыр коючылар, җиңү тантанасын бик иртә үткәрәсез. Бөек Рус революциясен күмәргә бик иртә тотындыгыз».* К.Нәҗми

15) *куч.* Кемне дә булса авыр хәлдә калдыру, авыр хәлгә кую. *Ивановны яклап, Бинаров чыкты. --- Ивановның барча гаепләрне өстенә алуын – яшермәвен әйтте. Ивановны күмә бит бу юләр, дип, моның сүзләреннән көлү өзелмәде.* Г.Ибраһимов // Юк итү, юкка чыгару. *Дерпт уку-укыту округы попечителе Клингер эштән азат итүләрен сорый, сәбәп итеп үзенә тапшырылган университетны күмүдә катнашасы килмәвен күрсәтә.* Җ.Тәрҗеман

**Күмә бару** Берәм-берәм, булган берен күмү, әкренләп күмү. *Кулларына акча керсә, алар аны чуен чүлмәккә салып, --- тирән итеп чокыр казып, җиргә күмә бардылар.* Ф.Яруллин. *Рәхимсез вакытның бөтен нәрсәне үзгәртә, юа, күмә баруын --- ачынып уйлаган Айдар бу минутта беркемне дә тыңламый --- иде.* М.Галиев. *Үпкәләргә тиеш иде Зөһрәгөл, әмма ул хәзер күңелендәге үпкә хисләрен мин-минлек, Фарукҗанны үзенә каратасы килү тойгысы күмә баруын сизде.* Т.Әйди

**Күмә башлау** Күмү эшенә керешү. *--- Гамир тиз генә табут капкачын ябып менде дә каберне күмә дә башлады.* З.Фәйзуллин

**Күмә тору** *к.* **күмә бару**. *Эшнең яңалары искеләрен күмә тора.* Т.Әйди

**Күмә төшү** Тагын да бераз, беркадәр күмү. *Бүре бугазлаган колын калдыкларын күмүчеләр янына килеп: «Күмә төшегез, этләр казып чыгарырлык булмасын», – дип кычкырды Сәетҗан.* Татар иле

**Күмеп бару** *к.* **күмә бару**. *Бу сибелгән су тамчылары шунда ук чәчәкләргә әверелеп, Ай өстен сихри матурлыкка күмеп бара.* Ф.Яруллин. *Онега тирәләрендә яшәгән борынгы кешеләрнең, дини йола үти торган гыйбадәтханәләреннән тыш, үз ыруларының үлгән кешеләрен күмеп бара торган каберлекләре дә булган.* А.Муранов

**Күмеп бетерү** Бөтенләй, тулысынча күмү. *Берничә көн карлар күмеп бетергән кышлакларны, инде тибенергә көчләре бетеп барган җылкыларны --- карап, кояш күк буйлап йөрмәлде дә --- барлык галәмне ныклап җылытырга тотынды.* З.Зәйнуллин. *--- ун көн элек кенә никельле карават сатып алган идем, аны, курчак ятагына охшатып, челтәрләргә күмеп бетергән идем.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Күмеп бетергәч, өмете өзелде ахры. Хәле беткәндәй, кабер өстенә башын куеп ятты.* Г.Сабитов

**Күмеп китү** Тора-бара күмелгән хәлгә алу. *Кешеләр, иртүк торып, сукмак ердылар, абзар-сарай ишекләрен күмеп киткән карны көрәделәр, инешчишмәләрдәге бәкеләрне ачтылар.* К.Тәхау. *Тормышның вак-төяк мәшәкате башкалар турындагы уйларыңны күмеп китә.* Ф.Яруллин. *Коркачык заготзерносында быел хәлләр харап икән: иген тавы станцияне күмеп киткән.* М.Мәһдиев

**Күмеп кую** Тиз арада яки алдан күмү. *Менә үлем сәгате җитүен сизеп, Арей, биек тау итәгендә урын сайлап, савытын шунда күмеп куйган ---.* А.Муранов. *Шуннан соң, орлыклы үсемлекләрнең язгы сортларыннан – алмагачтан, грушадан һ.б.дан алган орлыкларны, элек яхшы итеп юылган һәм кыздырып суытылган елга комына күмеп куялар.* А.Бахарев, П.Яковлев

**Күмеп ташлау** Тиз-тиз күмү. *Арбаның төбеннән корырак көлтәләрне тартып чыгардым да, иң элек, дер-дер калтыраган картны шулар белән күмеп ташладым.* Г.Ибраһимов. *--- Гыйльметдин карт аны төрле буяулар, пумалалар, кәгазьләр белән күмеп ташлады.* Ф.Яруллин. *Сарай кешеләре авырганда, табиб --- янында һәрчак әнә шул улы Ислам булыр иде – Айбибине бер мәлгә генә хис ташкынына күмеп ташлаган егет.* М.Хәбибуллин

**КҮМХУҖ** *и. иск.* Күмәк хуҗалык – авыл хуҗалыгы эшләрен коллектив белән алып бару өчен, башлыча, XX гасырның 30 нчы елларында төзелгән социалистик хуҗалык. *Нәкъ шул чакны, машинасына утырып, күмхуҗ рәисе Касыймов та кайтып җитте.* Х.Ибраһим. *Күмхуҗлар төзелә башлаганчы ук, авыл ярлылары белән берләшеп, тегермәннәрне Җиһаншадан тартып алдылар да бар халыкныкы иттеләр.* Р.Рахман

**КҮН** I *и.* **1.** Махсус ысул белән эшкәртелгән (иләнгән) хайван тиресе. *Шуның өстенә исләр: ат исе, камыт күне, яңа чапкан печән, --- лаклатып алган тальян исе – болар барысы – музыка, ис, чуар төсләр – кешене табигый халәтеннән күпмегәдер аерып ала ---.* М.Мәһдиев. *Гадәттә урыс сәүдәгәрләре Казанда болгари күн эзли, --- көмеш савыт-саба, алка, йөзек, беләзек ала ---.* Ф.Латыйфи. *Каршы алучыга ияреп килгән ирләр йомшак сары күннән ясалган зур чемоданнарны купе эченнән алып чыктылар.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шуңардан ясалган, шул материалдан тегелгән. *Шул чакта мин үземнән ерак түгел бер хәрби кешенең күн итекләрен шыгыр-шыгыр басып, әрле-бирле йөргәнен шәйләп алдым.* Ә.Еники. *Баш астына салынган киндер капчыкның төнлә үткен пәке белән ярылган булуы да, аннан сыңар күн чүәкнең урланган булуы да --- мине кызыксындырмады, борчымады.* М.Мәһдиев. *Укытучы килешле күн пальтодан, партком секретарьлары гына кия торган каракүл бүректән иде.* Х.Ширмән

2) Шул материал белән тышланган, капланган. *Сангурский киң күн диванга җәелеп утырган.* Ш.Усманов

**КҮН** II *и.* 1) Борынгы акча

2) Металл акчаның герб төшерелгән ягы. *[Акча] ике яклы: аның бардыр*

*иләк һәм күн ягы.* Г.Тукай. --- *көмеш акчаны бертуктаусыз чөеп торуын белә ул: акча биш, ун тапкыр иләк ягы белән төшә, әмма күн барыбер чыгачак ---.* В.Леви

**КҮНӘК** *и.* 1) *иск.* Тар авызлы капчык сыман зур күн савыт, турсык. *Яңгырым яу, явып тор, Мичкә белән ташып тор, Күнәк белән коеп тор.* Такмак. *Алла колы Котлы Шәңгәрәй Болгар ханы казнасына түлисе ясак: --- ярты батман туң май, бер күнәк сары май ---.* А.Тимергалин

2) *диал.* Тырыс (каен тузыннан эшләнгән савыт)

**КҮНӘ СУЫ** *и. иск.* Терекөмеш сыекчасы. *Бәгъзе бер усал кияүләр балаларга, кәгазьгә төреп, бер тиенне күнә суына манып, 20 тиен сурәтендә бирәләр.* Г.Тукай

**КҮНӘЯК** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан зәңгәр чәчәкле үлән үсемлек; фәрештә чәчәге, һиндыба

2) Шул үсемлекнең кофега кушыла яки үзе генә кулланыла торган киптерелгән тамыры

**КҮНДӘМ** с. **1.** Тыңлаучан, карусыз, буйсынучан, кушканны эшли торган. *Ә соңга таба шул көчле бәндәләрне сүзсез, күндәм коллар селкеп ташлаганнар.* М.Юныс. *[Геворгның] куллары төрле эшкә бара шул, үзе талымсыз, үзе күндәм.* С.Шәрипов. *Ә минә беренче секретарь булып алгач, күндәм Миңзаһитка әллә ни булды ---.* Ф.Садриев

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Күндәм өндәмсез эшләр.* Әйтем

**3.** *рәв. мәгъ.* Карышмыйча. *Фаруkжан күндәм генә аңа иярде.* Т.Әйди. *--- мотор күндәм генә эшли башлауга, Хәйдәр бар көченә педальгә басты ---.* А.Гыйләҗев

**КҮНДӘМЛӘНҮ** *ф.* Тыңлаучанга, буйсынучанга әйләнү, кушканны эшли торган булу. *Чәүчәләк кызга биш тәүлеккә карцерда утыру җитәр, ул аннан күндәмләнеп, ихтыяры сынып чыгар.* М.Маликова

**Күндәмләнеп калу** Нindидер вакыйгадан, тәэсирдән соң күндәмләнү. *Өчәүләп матур гына яшәп ятканда, Мөнибем, газиз иркәем, салгаларга өйрәнеп китте. Гаҗәбе шул: мин тагын да күндәмләнеп калдым.* Мәгърифәт

**КҮНДӘМЛЕК** *и.* Күндәм булу. *Минә шунда кешеләрнең күндәмлегенә ул [Зөфәр Шәрипович] хәйран калды.* Ф.Садриев. --- *карт чыдамлыгы, күндәмлеге белән баштагы вакытларда Амантайны таң калдыра иде.* Т.Әйди. *Сөләйнең бу юлы да күндәмлеге җиңде: үз эшләре кырылып ятса да, күршесенә каршы килә алмады.* Н.Хәсәнов

**КҮНДЕРҮ** I *ф.* 1) Кемне дә булса үтенеп, сорап, берәр нәрсә эшләргә ризалату. *Шуны бик нык исеңдә тот: Шакирыңны, ай-ваена куймыйча, күндер!* Ә.Еники. *Юк, минем көчемнән килми, Рафисны инде күндердем, Чаллыга күчеп китәбез.* М.Мәһдиев. *Айбиби ничекләр булса да каханны күндерер дип уйлыйм мин.* М.Хәбибуллин

2) *сөйл.* Өйрәтү, күнектерү, гадәтләндерү. *Хаҗи агай --- эшкә күндерде, сабыр, нык булырга өйрәтте.* Ш.Рәкыйпов. *Минә мондый тинтәкләргә сөйләгез, өйрәтегез. Тазалыкка, чисталыкка күндерегез, әйтегез.* М.Җәлил. *Моңарчы бик тә җитди булган, инде ике-өч бозау тудырып, аларны тәүфикъка күндергән сыер елга үрenә, ерак һәм куе урман чиксезлегенә томырылды ---.* Ә.Баян

3) Буйсындыру. *Күнче күнне күндерер.* Әйтем

**Күндереп кую** Алдан ук күндерү. *– Булмаса, берсекөнгә кайтып китәрсең, тотмам, – дип, Любовь Васильевна кичә кичтән үк мине бүгенгә китми торырга күндереп куйган иде.* Х.Сарьян

**КҮНДЕРҮ** II *ф. кит.* 1) Берәр максат белән кая да булса җибәрү. *Төрекмән ханы илә сугыш башлангач, атам мине гаскәр башы кылып, бик күп гаскәр илә сугышка күндерде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Сүзләр белән үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, сәлам, хәбәр җибәрү. *– Сәлам күндерде дисең инде алайса? – дип кабатлады Җиһанша.* Р.Рахман. *[Клёпаның] әнисе зур постта, җаваплы эштә, аңа сәлам генә күндергәләде ---.* С.Шәрипов. *Иң элек әлеге мәҗлестә катнашучыларга фиркадәшләре исеменнән сәлам күндерде.* Р.Мөхәммәдиев

3) *күч. диал.* Ашау. *Балалар калын-калын телемнәрне эләктереп, тоз сипteләр. Эре-эре ярмалы бәрәңгеләрне күндерергә керештеләр.* М.Әмир

**Күндереп тору** Әледән-әле, аратирә күндерү

**КҮНЕ** *с. иск. к.* **күндәм**. *Күне кеше, «күл яна!» дигәч тә, иләк белән су алып йөгергән, ди.* Н.Исәнбәт

**КҮНЕГҮ** I *ф.* 1) Берәр төрле эшкә өйрәнү, нинди дә булса бер эшне башкарырга күнекмә алу. *Балта белән эшләп күнеккән кулның гайрәте нык иде, бармакларымны өзә язды хәтта.* Г.Байбурин

2) Гадәтләнү, ияләшү, өйрәнү. *Безнең татар ирләре --- үзләре солтан булып, хатынны олтан итеп яшәргә күнеккәннәр.* Х.Ширмән. *Картның сәер гамәлләренә инде күнеккән булсалар да, дачада печән чабып киптерү алар өчен үзенә күрә бер тамаша иде ахрысы.* С.Шәмси. *--- мәхәббәт романтикадан гадәти якынлыкка, бер-береңә күнегүгә әверелә ---.* Ф.Миңнегулова

3) Җайлашу, яраклашу (сизү органнары тур.). *Атның ян бармаклары кечерәеп, өченче бармагы бик нык үсеп киткән. Бу хәл --- эре хайванның өченче бармагының күбрәк эшләвеннән һәм күбрәк күнегүеннән килеп чыккан.* Дарвинизм нигезләре

**Күнегә бару** Торган саен ныграк күнегү. *Акрынлап кыр тавышларына күнегә бардылар.* А.Гыйләҗев. *Бал корты угыдай авырттырып, йөрәк түренә барып кадала торган мондый битәрләүләргә әкренләп күнегә барды Дамир ---.* Ф.Мәҗитов. *Шулай мактәп тормышына күнегә барып әйбәт кенә эшләп ятканда, --- мине көтмәгәндә район хастаханәсенә чакырып алдылар.* Г.Галиев

**Күнегә башлау** Күнегергә тотыну. *Гамир ялгызлыкка, шушы шартларга күнегә, яраклаша гына башлаган иде – яңа күңелсезлекләр китте.* З.Фәйзуллин. *Инде гырлавына күнегә башлаган идем, берзаман теге гырламый да, гыжламый да башлады ---.* Р.Хәбибуллина. *– Галимҗанга ат җигәргә кушарбыз. Эш көне дә булыр, эшкә дә күнегә башлар, – дип куйды.* Язмышлар яңарганда

**Күнегә килү** Электән үк, акрынлап, тора-бара күнегү. *Аяксызның – чатанлыгына, кулсызның – чулаклыгына, ятимнең – ятимлегенә, хәсрәтленең хәсрәтенә акрынлап күнегә киләбез.* М.Кәрим. *Кәриманең эшкә күнегеп кенә килә торган чагы иде.* К.Тимбикова

**Күнегә тору** Алдан ук күнегү, өйрәнә башлау. *Әгәр үзең күз төшерергә тиешле тиңеңнең кем икәнен ачыклый алмыйча --- йөргән булсаң, авылдашларың кемгә игътибар итәргә, аннары күнегә торырга --- кирәклекне бик оста күрсәтеп бирәләр.* Ә.Баян. *--- бер остага ярдәмче булып, күрше авылга бура бурарга киттем. Куллар күнегә торсын, үземә дә бурыйсы булыр.* Ф.Яруллин. *--- мунча өлгергәч, хәләлемне алдан кертеп җибәрдем. Андагы шартларга күнегә торсын, --- янәсе.* М.Шаһимәрдәнов

**Күнегә төшү** Беркадәр, бераз күнегү. *Кыз ат өстендә утыруга күнегә төште.* А.Шамов. *Кышка кергәч, карт бераз тынычлана, ялгызлыгына күнегә төште.* С.Шәмси. *Әлеге киеренкелеккә күнегә төшкән Микәй як-ягына да күз салырга өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев

**Күнегеп бару** Торган саен ныграк күнегү. *Илдус, гадәттәгечә, башын гына кага ул ---. Кайчакта бу – Рифкатнең ачуын да китерә, ләкин ул моңа күнегеп бара.* Р.Вәлиев. *– Бәясе бер ярты, – дигән, төшерергә күнегеп барган Миңлегали, ике дә уйлап тормастан.* Р.Мөхәммәдиев. *Бер-беребезгә авырлык белән генә күнегеп барганда, ишек шакыдылар.* М.Галиев

**Күнегеп бетү** Бөтенләй, тәмам күнегү. *Әти-әнисенең әйткәләшүенә күптән күнегеп беткән Рамилә, тү-тү-тү дип, уенчык машинасын тәгәрәтеп юана иде.* М.Маликова. *--- Анфиса Егоровна --- ялгызлыкка күнегеп беткән.* Ф.Галиев. *Болар Сафин өчен яңалык түгел, күнегеп беткән, бернинди конкрет гаепләрлек сүз ычкындырмады әле.* Р.Айзатуллин

**Күнегеп җитү** Тиешле дәрәҗәгә җитеп, тәмам күнегү. *Дөрес, куллары әле әүвәлгечә җитез хәрәкәтләнми, станокка күнегеп җитмәгән, кирәкле кораллар да кул астында юк, эш урыны да җайсыз сыман.* Г.Әпсәләмов. *Эшкә тәмам күнегеп җиткән идем инде.* М.Юныс. *Эш тәртибенә дә күнегеп җиткән иде инде ул практика вакытында.* Ф.Вәлиәхмәтов

**Күнегеп килү** *к.* Күнегә башлау, бераз күнегү. *Хәзер бизәкле нотыкларга ул күнегеп килә, ул гынамы, күңеле тели сыман.* М.Хәбибуллин. *Менә икенче тәүлек инде колаклар, борынгы Греция ишкәкчеләренеке кебек үк, бер ритмга – тимер рельсларга бәрелгән көпчәкләр тавышына күнегеп киләләр ---.* Х.Ширмән. *Бу хәлгә күнегеп кенә килгәндә, ничектер, күзе төшеп, Айдар оя төбәсенә кайтып кунган ялгыз сыерчыкны күреп алды.* Г.Шәрәфи

**Күнегеп китү** Соңгы арада күнегү. *Ул хәтта үзе дә, хыялы белән генә булса да, шушы чит-ят язмышларга кереп, кушылып яшәргә, шул хыялый яшәүдән тәм һәм ямь табарга, мәгънә алырга күнегеп китте.* Г.Гыйльманов. *Ул тиздән Хуҗа кушаматына үзе дә күнегеп китте.* М.Юныс. *– Зинһар мине аңларга тырыш, – дип, ирен йомшак кына көйләп, һәрнәрсәне үзенчә хәл итәргә күнегеп китте.* Г.Галиева

**КҮНЕГҮ** II *и.* 1) Нәрсәгә дә булса өйрәнү яки үзенең күнекмәләрен камилләштерү, ныгыту максаты белән, берәр кеше тарафыннан башкарылган хәрәкәтләр. *Ул ---, кулын ышанычлырак тотарга тырышып һәм яман да үҗәтләнеп, күнегүен кабатлады.* Т.Әйди. *Гимнастлар, спортзалдан чыкмыйча, катлаулы күнегүләр ясадылар.* Ф.Яруллин. *Көн-төн укы, эшлә, хәзерлән, үзеңә үзең дәресләр үткәрергә өйрәнеп, күнегүләр үткәр.* З.Зәйнуллин

2) *махс.* Нинди дә булса күнекмәләрне ныгыту, камилләштерү, тулыландыру максатыннан үтәлә торган бирем төре. *Күнегүләр дәрестә үткән грамматик материалны үзләштерү һәм ныгытуда зур роль уйныйлар.* Д.Тумашева. *Уйнау техникасын камилләштерү өчен, сез иске күнегүләрне дә онытмаска тиешсез.* Ә.Еники. *Өйгә бирелгән күнегүләр*

**КҮНЕККӘНЛЕК** *и.* Нәрсәгә дә булса күнеккән булу, өйрәнгән булу. *Аның винтовканы тотуында да, патроннарны сумкасына тыгуында да ниндидер сәләтлелек, осталык, күнеккәнлек бар иде.* А.Шамов

**КҮНЕКМӘ** *и.* Берәр максатчан эшхәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән осталык, сәләт, нәрсәне дә булса эшли белү тәҗрибәсе. *Тик менә... тугызлы чалгы белән авыр покос салып барыр өчен шактый күнекмә кирәк бит!* М.Мәһдиев. *Тормыш тарафыннан җәберләнгән бу югары белемлеләр бик тиз арада хезмәт күнекмәләре алып, соң чиккәчә тырышып эшли башлыйлар.* Р.Мирхәйдәров. *Гамир белән Толя килеп кергәндә, күнекмәләрдән соң трусиктан гына калып юынып алган Марат каты сөлге белән ышкып-ышкып тәннәрен корыта иде.* З.Фәйзуллин

**КҮНЕКТЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса өйрәтү. *Гөлсем апа балаларын ять-яшьтән эшкә күнектерде.* Г.Гобәй. *Кулны күнектерергә кирәк! Лаф орып кына немецны җиңеп булмый, брат!* Х.Камалов

2) Системалы рәвештә күнегүләр ясап чыныктыру; гадәтләндерү. *Моннан соң кулын көн дә күнектерәчәк ул, көн дә!* Т.Әйди

3) Билгеле шартларга, берәр эшкә ияләштерү, гадәтләндерү. *Кызганычка каршы, Мичурин ул вакытта үсемлекләрне климатка күнектерү дигән ялган фән белән мавыгып китә.* А.Бахарев, П.Яковлев

**Күнектерә башлау** Күнектерергә тотыну; аз гына күнектерү

**Күнектереп бетерү** Тәмам, бөтенләй күнектерү. *Сезне, Гайсә Батталович, мактауга шулкадәр күнектереп бетергәннәр ---.* Ф.Садриев

**Күнектереп карау** Күнектерергә тырышу

**Күнектереп тору** Әледән-әле яки даими күнектерү

**КҮНИТЕК** *и.* Күннән тегелгән итек. *Генерал солдатның күнитеген кызыл крем белән чистартуын күрә.* Ирек мәйданы

**КҮНКАНАТЛАР** *и. күпл. зоол.* Кулканатлылар отрядының ярканатлар ыругы; *русчасы*: **кожаны**

**КҮНЛЕК** *и. махс.* Кайбер тропик агачларның кайрысыннан алына һәм

чиркәүдә гыйбадәт вакытында яндырыла торган саргылт яисә кызгылт төстәге хуш исле сумала; *русчасы:* **ладан**

**КҮНҮ** *ф.* 1) Риза булу, ризалык бирү. *Имам хәзрәтләре, Карлыгачны шул ук көнне кумәргә, дигәч, Сүбәдәй бер карусыз күнде.* М.Хәбибуллин. *Әнсар аның калуына каршы килеп, әнисе белән куркытып караса да, Рузалия күнмәде.* Х.Ибраһим. *– Мин синең ил белән килгәнлегеңне беләм, – дип сүз башлады Атилла. – Барлык таләпләремә күнәчәгең дә миңа билгеле.* Р.Зәйдулла

2) Гадәтләнү, ияләшү. *Сугыш чыканда инде әти үлеменә дүрт ел гомер узып, күңелләр дә ятимлеккә күнгән иде.* Х.Сарьян. *Ул инде әлеге халәтенә шулкадәр күнгән, җыелышка килгәч үк ян бүлмәгә уза ---.* М.Мәһдиев. *Яши-яши күнәсеңдер инде бер-береңә.* Р.Габделхакова

3) Нәрсәгә дә булса күнегү. *Биек икән, күнгән аяклар да Сер бирергә теләр төслеләр.* Ш.Маннур

4) Нәрсәгәдер җайлашу (сизү, күрү, ишетү органнары тур.). *Урамнар җиде-сигез катлы өйләр тезеп эшләнгән ящикларга охшый. Күз тиз күнә.* Г.Гали

**Күнә бару** Торган саен ныграк күнү. *Еллар үтте. Мин дә инде акрынлап тормышның җәберенә күнә бардым.* М.Мәһдиев

**Күнә башлау** Аз гына, бераз күнү. *Инде эшкә күнә башлаган куллар кулга йокмыйлар.* Г.Гобәй

**Күнеп бетү** Тәмам, бөтенләй күнү. *Гадәтемә күнеп беткән картәсәем дә аптырап калды: – Нурия, колынкаем, нишләвең бу?* Г.Якупова

**Күнеп җитү** *к.* **күнеп бетү**. *Военком янына Хәерниса ул елны ике тапкыр барды. Полковник инде күнеп тә җиткән, егетләрне чакыртырга булган иде.* М.Мәһдиев. *Тик әле кияү, ир булырга да өлгермәгән, бу төшенчәләргә күңеле түгел, колагы да күнеп җитмәгән Гарифка «әти» сүзе чит, ят иде.* К.Тимбикова

**Күнеп килү** Соңгы вакытта күнү

**Күнеп тору** Беразга күнү; түзү, карышмау. *Кыз язмышына күнеп торырга уйламый – тарткалаша башлый.* Мәдәни җомга

**КҮНЧЕ** *и.* Күн иләүче; күн эшендә эшләүче; күн сатучы. *Мисырда оста тукучылар, күнчеләр һәм башка һөнәрчеләр килеп чыккан.* Борынгы заман тарихы. *Казан күнчеләре*

**КҮНЧЕЛЕК** *и.* Күн иләү, күн эшкәртү тармагы. *Күнчелектә эшләү*

**КҮНЬЯ** *и. гар.* Кемгә дә булса улының (сирәгрәк кызының) исеме буенча бирелгән һәм ирләр өчен *әбү*, хатыннар өчен *өмме* дип башлана торган хөрмәтле кушамат. *Әбү Хәнифә күньясе белән танылган бөек галимнең асыл исеме Ногман булган*

**КҮҢЕЛ** *и.* 1) Кешенең эчке рухи дөньясы; аның хис-тойгылары, кичерешләре. *Дамирны кызның күңелендә кузгалган хисләр өермәсе урап алгандай булды.* Ф.Яруллин. *Гаҗәп икән ул күңел дигән нәрсә: үзе менә шушы Рухиядән берәр хәбәр килмәсме дип, егерме ел буена туктаусыз көтеп, өметләнеп йөрде.* В.Нуруллин. *Беренчесендә ул – хатын һәм... ана да булачак бит әле. Ә икенчесендә ул бүгеннән – табиб. Бу ике дөньяны бер күңелгә сыйдыру мөмкин микән?* М.Маликова

2) Аерым шәхескә хас рухи үзенчәлекләр. *[Чжу картның] күңел кичерешләрен чагылдырып, --- яңаклары эчкә батып кергән саргылт йөзе тимгелләнеп кызара бара.* А.Шамов. *Җитәр, Өлфәт, әйдә, туктатыйк бу хактагы сүзне. Никтер күңелем ышанмый төсле минем сиңа.* В.Нуруллин. *– Алла бәхетеңне бирсен, Әсма! Күңелең тыныч булсын, шатлыгың зур булсын! – Гыйззәт шул сүзләрдән соң кунаклар янына әйләнеп керде.* Х.Сафина

3) Кичерешләр, хис-тойгылар чыганагы. --- *композиторлар әле генә күңелләреннән кайнап чыккан көйләрен Дамирларның пианиноларында чиртterә.* Ф.Яруллин. *Профессор күңелендә ихтыярсыздан кузгалган көнләшү хисен тыярга тырышты ---.* М.Маликова. *Я аны башка берәү эләктерәчәк, я аның күңелендә бөреләнә башлаган хисләр, ачылып җитмичә, мәңгегә йомылачак.* Р.Кәрами

4) Сиземләү сәләте, интуиция. *[Варламовның] күңеле сизенде: Карповичның яраннары, куштаннары, сүз кушкандай, дәррәү каршы.* С.Шәрипов. *Миңзаһитның күңеле сизенә, монда нәрсә дә булса бар: бу [Рашат] я эчә, я хатын-кызга туздыра акчасын ---.* Ф.Садриев. *Әмма бу яңгынга бер Гөлчирә генә гаепле булмавын ул күңеле белән тоя иде.* Х.Сафина

5) Фикер, уй; аң. *Кулымда каләм, ә күңелем әллә кайларда.* Җ.Тәрҗеман. *Аннары бераз тын утыргач, үз күңелендәген әйтеп салды: – Әсманы әйтәм, булышыр микән миңа?* Х.Сафина. *«Әллә хатын сизенде микән?» – дигән шик йөгереп үтте Гайфулланың күңеленнән.* Ф.Яруллин. *Күңелдә буылып торган үпкә сүзләрен ирекқә чыгарасы, --- елый-елый аңа барысын да сөйлисе килә.* Р.Вәлиев

6) Зиһен, хәтер. *Сезнең исемегезне күңелебездә Шушы көнгә чаклы сакладык.* М.Гафури. *Инде карт кешенең биргән киңәшләрен Өстән генә укып үтмәгез, Күңелегезгә алып бикләгез!* Һ.Такташ

7) Кәеф, рух. *Нәкъ шушы көн Һидият бик төшенке күңел белән кайтты.* Ш.Камал. *Малайлар шешәдәге затлы эчемлекне уртлап-уртлап киткәлиләр. Һәрберсенең күңеле көр.* Ф.Яруллин. *Бүген укытучының күңеле аеруча күтәренке: Мәскәүдә өченче дәреслеге басылып чыккан, бер нөсхәсе аңа килеп тә җитте.* М.Маликова

8) Мәхәббәт, сөю, ярату хисе. *Назыйм тәүфикълы, инсафлы, сабыр. Күңеле гел синдә, Гөлфия кызым.* Р.Айзатуллин. *Мин дә менә ялгыз башым. Сугышта чакта сизелми иде, ә хәзер җан түзми. Күңелем гел синдә.* Х.Сафина. *Тик күзе анда булса да, күңеле башкада иде.* Инешләр Иделгә кушыла

◊ **Күңел авыраю** Авыр уй-хисләр барлыкка килү. *Мин бу чагыштырулар белән асла килешмәсәм дә, әңгәмә азагында күңелем авырайды.* А.Гыйләҗев. **Күңел агачы** *к.* **күңел күге**. --- *бу егетнең күңел агачына мәхәббәт дигән кош кунган икән!..* А.Гыйләҗев. **Күңел азу** Бозык уй-фикерләр, хисләр туу. *[Габдулла:] Аларның үкертеп йөргәннәрен күреп күңеле азгандыр.* М.Фәйзи. **Күңел азыгы** Күңелне күтәрү, юату өчен кирәк булган нәрсә, чара; рухи

азык. *[М.Горький әсәрендә] капитализм шартларында --- эшчегә аз гына күңел азыгы булырлык нәрсәләрнең дә җитәрлек булмавы бик матур итеп, оста гәүдәләндерелеп күрсәтелгән.* Г.Нигъмәти. **Күңел ак булу** Уй-хисләр, теләкләр саф булу. *[Акын:] Күңелең ак булса, йөрәгеңдә илгә мәхәббәт кипмәсә, син, телсез булсаң да, бүген кайгы җырын көйләрсең.* Г.Ибраһимов. **Күңел аклыгы** Эчкерсезлек, самимилек. *Ул гөлләрнең яфракчыгын дәфтәрем арасында сакласам, сезнең күңел аклыгыгызны исә ядкәр итеп йөрәгемдә саклармын.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңел актарылу** Уй-фикерләр чуалу, буталу; борчу-хәсрәт туу. *– Әсманы үзеннән сорамый гына сиңа ярәштеләр. Ә аның сине күрәсе дә килми. – Шул минутта Низамның күңеле актарылып ташлангандай булды.* Х.Сафина. **Күңел алгысу** *диал. к.* **күңел ашкыну**. *Күңеле алгысып, күз төбе дымланган Сәвилә әрем өзеп капты.* Н.Гыйматдинова. *Шул өметем дә өзелгәннән соң, сезнең авылдан бөтенләй китеп барырга карар кылгач, күңелем алгысып, хискә бирелеп киткәнмен икән – аннан гына дөнья җимерелмәгәндер бит.* В.Нуруллин. *Ничек тә җебеп төшмәскә, тешләрен кысып тынычланырга теләсә дә, эче поша, күңеле алгысый иде.* З.Вәли. **Күңел ату** Берәр кешегә мәхәббәт төшү, аны ярата башлау; күз төшү. *Ә менә кичләр буе янында бөтерелсәк тә, Зөфәр абыйның кемгәдер күңел атуын башыбызга да китереп карамаганбыз.* Р.Мөхәммәдиев. **Күңел ачкычы** 1) Кешене нинди дә булса максатка юнәлдерү өчен берәр төрле юл, алым, ысул, чара. *[Айсылу:] Ярышны кабындырып җибәрү өчен, колхозчының күңел ачкычын табарга кирәк.* Г.Бәширов; 2) Күңел ачу чарасы, юлы. *[Хафиз:] Күңел ачаргамыни? --- Фазыл, алай булса, чыгар әле күңел ачкычын [аракыны].* Р.Ишморат. *Мәзәк – күңел ачкычы, табышмак – зиһен ачкычы.* Мәкаль. **Күңел ачлыгы** Күңел ачарга, күңеллеләнергә мөмкинлек булмау. *Хәят кызлык вакытын күңел ачлыгы белән үткәрде.* Ф.Әмирхан. **Күңел ачу** Вакытны күңелле итеп үткәрү, хозурлану, юану. *Акыл сатарга, кешене сүгәргә яраткан Мәлгунов --- тиргәгән кешесе белән соңыннан утырып күңел ачарга да бик маһир адәм иде.* Х.Ибраһим. *Күңел ачу уеннарын һәм концерт программасын төзүне Саматка тапшырдылар.* Г.Галиева. *Җыр-бию, күңел ачу таңга кадәр дәвам итте.* Ф.Садриев. **Күңел ачыклыгы** Эчкерсез, яхшы мөгамәлә; эчкерсез мөнәсәбәт. *Бабай өйләнде. Балаларга башта, бабайның күңел ачыклыгы тәэсире белән, бу эш хуш тоелды.* Ш.Камал. **Күңел ачылу** Яхшы кәеф барлыкка килү, кәеф яхшыру. *Бербер артлы маскалар керде, аларны күргәч, Зәнфирәнең күңеле кабат ачылып китте.* Ф.Садриев. *Күп тә уйлап тормый, ике тиенлек чия, өч тиенлек калач алып кердем дә арба өстенә кырын ятып ашап алдым. Күңел ачылып китте.* М.Гафури. *Әнкәй урын өстендә ята бит, Нурислам. «Күңелең ачылыр» дип чыгарып җибәргән булса да, ни йөрәккәем белән уенда йөрим?* А.Әхмәтгалиева. **Күңел аша уздыру** *к.* **күңелдән кичерү**. *Хәтер капчыгын селеккәләп, монда – бу заводка килеп кергән көннәрен исенә төшерергә тотынды, аннары тагын да ераккарак чигенеп, укыган елларын, Кукмарасын, әтиәнисен күңеле аша уздырды.* Э.Касыймов. **Күңел аша үткәрү** *к.* **күңелдән кичерү**. **Күңел ашкыну** Нәрсәгә дә булса бик нык омтылу, нәрсәне дә булса бик нык теләү. *Фәнни түгәрәкләргә йөрү, концертларда катнашу да аз тоела, күңел каядыр ашкына иде.* М.Маликова. *Әлбәттә, кыз һич икеләнмичә апаларында куна калган булыр иде, тик бүген аның күңеле нәрсәгәдер ашкынды.* Ф.Яруллин. *Чакрым араларны кыскартсаң иде лә! --- Нигә бу хәтле күңел ашкына икән?* Н.Гыйматдинова. **Күңел әрнү** Чиктән тыш борчылу. **Күңел баглау** *иск. к.* **күңел беркетү**. *Сәңа шөйлә күңел баглар, күздин чишмәләр чаглар.* Г.Кандалый. *Менә шунлыктан ул әлегә халыкка фаш ителмәгән могҗизалы китапларга соңгы вакытларда игътибар күзен салды, күңелен баглады.* Ф.Яхин. **Күңел байлыгы** Кешегә хас уй-тойгылар, хисләр, эчке дөнья. *Мин тагын Разияны якларга керешәм: аның әле бик яшь булуын, шуңа күрә чәчелүен, күңел байлыгын ваклап әрәм итүен --- сөйлим.* И.Гази. **Күңел бакчасы** *к.* **күңел дәрьясы**. *Элегрәк аның күңел бакчасы Илүзә өчен ачык иде. Ә хәзер гөлбакчаның капкалары ябылган, йозаклары бикләнгән.* М.Маликова. **Күңел бармау** Теләмәү, теләк булмау, риза булмау. *[Хәйретдин:] Ай, анасы, бер генә дә күңелем бармый бит бу эшкә. Ничек итеп үз балаңны үзең кара урманда адаштырып калдырырга кирәк?!* А.Әхмәт. **Күңел басылу** Борчылулы халәттән арыну, бимазалы уйхисләрнең юкка чыгуы; җан тынычлыгы урнашу. *[Шәмсинең] аны барып тапмаенча күңеле басылмады.* Г.Исхакый. *Иләндәге сулар җыелып беткәндә, аның күңеле басылган, җанындагы давыл тынган иде.* Ф.Яруллин. *Әби никадәр тынычландырырга теләсә дә, минем күңел басылмады.* Н.Хәсәнов. **Күңел баю** Кешенең эчке дөньясы, рухи халәте тулылану. *--- Аның китүенә бер ай вакыт узды, дөньям үзгәрмәде, күңелем баемады.* Р.Вәлиев. **Күңел беркетү** 1) Берәр төрле эш-хәрәкәт башкарырга ниятләү, берәр нәрсәне эшләргә булу; нинди дә булса бер карарга килү. *Шул карарны биргәннән соң, китәргә күңел беркетеп, форсат көтә башладым.* М.Гафури. *Комсомолия, синең әгъзаң бит мин, Сиңа гына беркеткәнмен бөтен күңелемне.* Ф.Кәрим. *Бүген исә Бөтен дөньяда тынычлык саклау фондына дип җыйган унсигез меңсум акчасын илтеп тапшырырга дип күңел беркеткән иде.* Ә.Баян; 2) *к.* **күңел салу**. *Сафирә --- теге чакта күмер китереп киткән Галләм малае Таҗига күңелен беркетте.* М.Шаһимәрданов. **Күңел бер урында тормау** *к.* **күңел ашкыну**. *Авылга кайткач, күңел бер урында тормый. Барысын да тизрәк күреп чыгасы килә.* Р.Мөхәммәдиев. **Күңел биздергеч** Биздерә торган, сөйкемсез; ямьсез, шыксыз. *[Низамның] тырпаеп торган каты кызгылт чәче, болганчык төссез күзләре, итләч бите, аю сыман чайкалып авыр атлап йөрүләре күңел биздергеч булып тоелды.* Х.Сафина. **Күңел бизү** Берәр нәрсәдән тую, суыну, бизү;

нәрсәне булса дә яратмый башлау. *Минем малайлар ел буена бер хат та язмыйлар. Тәмам күңелләре бездә ахрысы.* Р.Вәлиев. *Җаны ничек кенә әрнемәсен, күпме генә егеткә рәнҗеп, --- кешеләрдән күңеле бизеп йөрмәсен, барыбер яшәргә --- кирәк иде.* С.Шәмси. *Ни хикмәттер, Сафураның Мәһдидән күңеле бизмәде.* Ш.Максудова. **Күңел бикләрен чишү** *к.* **күңел капкасын ачу**. *Моң аның күңел бикләрен чишеп, ябык капкаларын ачып җибәрде дә саф җил, нур булып бәреп кергәндәй булды.* М.Маликова. **Күңел бирү** Чын күңелдән тырышу, берәр эшне бик тырышып башкару. *Хәернисага монда күңел биреп өйрәнәсе нәрсә бар.* Г.Әпсәләмов. *Уенга мавыккан балалары, аны күргәч, --- бер-берсен әләкләшергә тотынды, тик әни кешенең үзләренә күңел бирмәвенә үпкәләп, бик тиз кире борылдылар.* Т.Әйди. *Ул --- нык эчә, төрле купецлар, завод хуҗалары белән әшнәләшә, хезмәтен күңел биреп башкармый.* Җ.Тәрҗеман. **Күңел боегу** *к.* **күңел төшү** (*4 мәгъ.*). *Ә син тик торганда, дуамалланып, уракны биргәнсең дә чыгаргансың. Шуңа күңелем боегып китте.* Г.Мөхәммәтшин. *Бая гына очынган күңел кинәт кенә боеккан иде.* Н.Гыйматдинова. **Күңел бозлану** Дәрт, рух сүнү, дөньядан бизү. *Бер мәхәббәтнең газабын, михнәтен сизгән кеше, Бер сөеп арган вә җөмлә нәрсәдән бизгән кеше – Күңле бозланган кешедер.* Г.Тукай. **Күңел бозылу** Кәеф китү, яхшы кәеф юкка чыгу; рух төшү, борчылу. *Әллә якты җәй көннәре үтеп, караңгы көз көннәре якынлаганга күңелең бозылдымы?* Г.Тукай. *Күземә яшь килде, янымдагы --- балаларга: «Китсен, күңелем бозылды», – дидем.* Г.Ибраһимов. **Күңел болгану** 1) Косасы килү. *Мин хәзер диңгездә, иркенлектә, саф диңгез һавасын сулап яшәгәндә, көн саен диярлек баш әйләнүен, күңел болгануын сизәм.* М.Юныс. *Кич җитүгә аның башы авыртырга тотына, күңеле болгана, кан басымы күтәрелә ---.* Ф.Садриев. *Гөлчирәнең --- чигәләрен кысып башы сызлады, күңеле болганды.* Х.Сафина; 2) Җирәнү хисе кичерү, чиркану. *[Йосыф:] Абый урынында мин булсам, бу сүзеңнән әллә кайчан күңелем болгана башлаган булыр иде.* Ф.Әмирхан. **Күңел болгаткыч** Җирәнгеч, чирканыч; күңел кайтара торган, начар тәэсир уята торган. *«Мине кире кертерсез микән...» ише күңел болгаткыч сүзләрен балаларга да әйткән бит әле.* Татарстан яшьләре. **Күңел борлыгу** *диал. к.* **күңел борчылу**. *Нәҗип мунча мичен томалап, салкын-кайнар суларны әвештәвеш китереп көйләп чыккач, күңеле борлыгып, инеш буйларын тагын бер урады.* А.Гыйләҗев. **Күңел борчылу** Берәр нәрсә турында хәвефләнеп уйлану, борчылу. *[Гариф Газизгә:] Минем күңелем борчыла, мин сине бит чынлап яратам.* Ш.Камал. **Күңел булу** 1) Канәгатьлек, канәгатьләнү хисе кичерү. *– Күңелең булдымы инде? – диде Гайфулла, сынауны сынатмый үткәннән соң.* Ф.Яруллин. *Ветеран --- киленне мактый-мактый, рәхәтләнеп, күңеле булганчы тукланды.* Х.Ибраһим. *[Гөлчирә:] – Кулларың алтын, Нәфисә, синең! – диде. Кызның күңеле булды.* Х.Сафина; 2) Кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. *Заһир мактый-мактый кымыз эчте, казылыктан авыз итте. Ә инде бишбармак та килгәч, бөтенләй күңеле булды.* Т.Таһиров. *Җыр тәмамлангач та, күңелләре булып, һәммәсе дәррәү кул чабарга керештеләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Тырыша торгач, ике тапкыр тидерде, шуңа чиксез күңеле булып, як-ягына каранып куйды.* Х.Камалов. **Күңел бушап калу** *к.* **күңел бушау**. *Күңелем бушап калды. Яңадан туган кебек булдым.* Р.Вәлиев. *Арсаң да, берәрсе авыр сүз әйтсә дә – бер җырлап җибәрсәң, бөтен күңелең бушап кала.* Х.Сафина. **Күңел бушанып калу** *к.* **күңел бушау**. *Дулкынланып, ашыгып сөйләде, гүя тормышын тиз-тиз сөйләп чыкса, үзенең дә күңеле бушанып калыр кебек иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңел бушату** Эчне пошырган, борчыган кайгы-сагышларны кемгәдер сөйләү, кем беләндер бүлешү. *Аз гына кәефең булмадымы, монда кил. Сөйләшербез, күңел бушатырбыз.* Р.Вәлиев. *Кеше, күңелен бушатса, җиңеләеп кала, диләр.* Ә.Еники. *Шәрәфәнең --- иң көчле дип санаган бер ир-ат заты янына барып, күңелен бушатасы килә.* К.Тимбикова. **Күңел бушау** Эч пошудан, борчылудан, кайгы-сагышлардан арыну. *Гөлчирә өйгә соң гына кайтты. Күңеле бераз бушаган, бераз тынычланган иде.* Х.Сафина. *Сиңа хат язсам, бөтен кайгыларым тарала, күңелләрем бушый, рәхәт булып китә.* Р.Кәрами. **Күңел бушлыгы** Һәрнәрсәгә битарафлык, омтылыш булмау; рухи торгынлык. *Кышын мин әле һаман да язу өстәле янына утыра алмадым. Күңел бушлыгы сизелде.* М.Мәһдиев. **Күңел вәсвәсәгә бирелү** Вәсвәсәләнү, коткыга бирелү. *Синең белән булганда, дөрес, күңел вәсвәсәгә бирелми.* Ф.Яруллин. **Күңел газабы** Борчылу, авыр рухи кичерешләр. *[Харис:] Аптыраудан, исемә төшмәүгә гаҗәпләнүдән һәм туып килгән күңел газабыннан телем дә әйләнмәде.* А.Шамов. **Күңел газаплану** Күңелдә тынычлык булмау, борчылу хисе кичерү. *Күңеле газаплана башлый аның: «Нигә тидем шул чебен тимәс чер итәр малай актыгына?»* И.Гази. **Күңел гариплеге** Күңел кителгән булу, рухи төшенкелек. *Инде кабат ул туктаусыз газапланулардан, йөрәк януларыннан мине аерып алырдай, күңел гариплеген, мәхәббәтнең каерылган канатларын төзәтердәй кеше табылыр микән?!* Р.Кәрами. **Күңел гасабилану** *к.* **күңел газаплану**. *Ә шулай да кызның уйлары борчулы, күңеле гасабилана.* Р.Кәрами. **Күңелгә авыр алу** Берәр хәбәрдән яки сүздән рәнҗү, аны бик авыр кабул итү. *Чуар тавыкны тавык димәсәң, Җамал әбинең хәтере калып, бу сүзне улы Гата да күңеленә авыр алыр.* А.Алиш. *Эшегез болай барса, күңелегезгә авыр алмагыз, сезнең хәлләр шәптән түгел.* Г.Бәширов. **Күңелгә авыр булу** Борчылырга, газапланырга туры килү. *[Хәдичә:] Шул кеше озату кебек кыен нәрсә юк. Бигрәк күңелгә авыр була.* М.Гафури. **Күңелгә авыр тоелу** Канәгатьсезлек туу, күңелне борчу; ошамау. *[Хаҗи:] Тик әнә кәләпүш кимәгәнсең, энем. Әнә инде ул эшең күңелгә авыррак тоела шул.* Ш.Камал. **Күңелгә беркетү** Истә, хәтердә калдыру. *--- ул Гадилне бер генә минутка да исеннән чыгармый, --- эченнән гел аның*

*белән киңәшеп-сөйләшеп йөри, аңа әйтермен дип, вак-төяккә кадәр күңеленә беркетеп куя иде.* М.Маликова. --- *мин, иреккә чыгу белән иң башта шул Косовны күрергә дип, күңелгә беркетеп куйдым.* Ф.Галиев. --- *Миңнулла, әгәр исәнимин кайта алсам, иң элек әти-әнине, аннары Зәйнәп-сылуны күреп сөйләшер идем дип, күңеленә беркетеп куйган иде.* В.Нуруллин. **Күңелгә вәсвәсә салу** Шикләндерү, шөбһәләндерү, вәсвәсәләндерү; котырту. *Бу учактагы ут сүнмәсен өчен, Иблис бар көченә тырыша: әле Зөһрәнең, әле Гайфулланың күңеленә вәсвәсә сала.* Ф.Яруллин. **Күңелгә дәва булу** Нәрсәнең дә булса күңелсезлекне, бәхетсезлекне, борчу-хәсрәтне җиңеләйтүе, оныттыруы. *Шәфыйкның сөюе күңеленә дәва булсын, балам.* Х.Сафина. **Күңелгә дәрт өстәү** Ашкындыру, илһамландыру, рухи куәт, көч өстәү. *Ә мулла: – Кара, кара, Касыйм ничек бара. Валлаһи, Касыйм ота, – дип, икенче яктан Гыйззәт күңеленә дәрт өсти.* Х.Сафина. **Күңелгә жылы йөгерү** *к.* **күңелгә жылы керү**. *Матусов тикшерүченең үзгәрүен абайлап алды, күңеленә жылы йөгерде.* М.Насыйбуллин. *Төпчеген уйлагач, ана күңеленә жылы йөгерде.* А.Гыйләҗев. **Күңелгә жылы иңү** *к.* **күңелгә жылы керү**. *Хәзрәт сүзләреннәнме, әтисе мөлаем елмаеп куйды. Мирсәетнең күңеленә жылы иңде, димәк, җәза куркыныч булмаячак.* Р.Мөхәммәдиев. **Күңелгә жылы керү** Шикләнү яки борчылу хисләре юкка чыгу; өмет уяну. *Егетнең күңеленә жылы керде. Мәрхәбәнең җавабын: «Мин каршы түгел, үзең теләсәң ни эшлә», – дип аңлады.* Г.Ибраһимов. **Күңелгә жылылык салу** Өметләндерү, шик-шөбһәләрне юкка чыгару. *Шушы кагылып алу һәр икесенең күңеленә жылылык, йомшаклык салды.* Ф.Яруллин. **Күңелгә жылы нур иңү** *к.* **күңелгә жылы керү**. *Бер аймы, ай ярыммы узгач, бөдрә чәчле, үткен коңгырт күзле бу татар малаеннан күңелгә жылы нур иңгәне сизелә башлады.* А.Гыйләҗев. **Күңелгә кадалу** Авыр тәэсир итү, рухи газап барлыкка китерү. --- *Гөлнараның куркыныч тәҗрибәләрен Наилә үзенчә кабул итте, ышанып ук бетмәде, мәгәр бер уй, бер тойгы күңелгә очлы ук булып, китмәскә кадалды.* А.Гыйләҗев. **Күңелгә кара болыт сару** Күңелсезләнү; кайгылы, сагышлы уйлар биләү. *Әбисе белән сөйләшкәч, күңелгә кара болыт сарды.* Н.Гыйматдинова. **Күңелгә кәгъбә булу** Яктылык бирү, үрнәк булу; яратылу, сөелү. *[Шаһтимер:] Ил балалары күңеленә кәгъбә булган данлы кыз шундый хөрмәтсезлекләр күрәме?* М.Фәйзи. **Күңелгә кәгъбә итү** Ярату, сөю; табыну. *[Мавия:] Ул сине шунда тәү мәртәбә күрде. Һәм шул көннән алып күңеленә кәгъбә итте.* М.Фәйзи. **Күңелгә керү** Игътибарны, зиһенне биләү. *Шагыйранә җанлы ул сәер кызыкай --- мәңге онытылмаслык булып, Әнсарның күңеленә кереп калган...* Х.Ибраһим. **Күңелгә килү** Искә төшү, хәтергә килү. *Башта, нинди карарга килергә белмичә шикләнеп йөргән чакларында, Андреевның әйткәннәре теге яки бу рәвештә Мостафин күңеленә килгәләгән иде.* Ә.Еники. *Нинди дә булса авыр, чуалчык мәсьәләне чишә алмыйча ятса, шулчак йокы белән уяу арасында зиһене ашыгып-ашыгып эшкә тотына, --- җавап үзеннән-үзе күңелгә килә.* А.Гыйләҗев. *Коелып төшмәде Сәкинә, --- бер дә алай шаккатмыйча гына: – Күңелгә килгән нәрсә алга килми калмый шул, – диде дә кече якка кереп китте.* В.Нуруллин. **Күңелгә киртләп кую** *к.* **күңелгә беркетү**. *Хан кызны Хәзәр каганына тотыклыкка җибәрмәс өчен, тизрәк иргә бирү ягын караячак, шуңа күрә, соңрак бу турыда сүз кузгатырга кирәк булыр дип, би күңеленә киртләп куйды.* Р.Зәйдулла. **Күңелгә китерү** Уйга китерү, уйлау, уйлап карау. *Зөфәрнең уйчан карашындагы тирәнлек, жылылык үзенә тартты, күрәсең. Зөфәр бу турыда күңеленә дә китермәде, әлбәттә.* Ә.Галиев. *Менә минем гомерем узды, туным тузды инде, әмма мондый нотыкларны сөйләү түгел, аларны күңелемә дә китереп караганым юк.* В.Астафьев. **Күңелгә корт керү** *к.* **күңелдә шик (шөбһә, шом) туу**. *Гайфулланың күңеленә бер корт керсә, туктап кала торганнардан түгел.* Ф.Яруллин. *Зөлфәгә алдагы көннәре хакында алай хафаланырлык, кайгырырлык түгел иде. Шулай да кызның гомерендә беренче тапкыр күңеленә корт кергән --- иде.* Э.Касыймов. **Күңелгә коткы салу** *к.* **күңелгә вәсвәсә салу**. **Күңелгә курку керү** Курку хисе барлыкка килү. **Күңелгә куләгә төшерү** Шикләндерү, шөбһәләндерү. *Бәлкем, бу хакта бөтенләй дәшмәскәдер, изге вә тугры хезмәт иткән егет күңеленә күләгә төшереп, гөнаһка батуың бар.* М.Хәбибуллин. **Күңелгә курку төшү** *к.* **күңелгә курку керү**. *Җиңгидән бу сүзләрне ишеткәч, минем күңелгә курку төште.* М.Гали. **Күңелгә кырау төшү** *к.* **күңел сыну, күңел кырылу**. *Чәчәкле гомер таңында Дилбәр күңеленә кырау төшүнең нигә кирәге бар иде?* Н.Хәсәнов. **Күңелгә (сары) май булып яту** Яхшы, күтәренке хис уяту, кәефне күтәрү. *Бу хәбәр Гайфулланың күңеленә сары май булып ятты.* Ф.Яруллин. *Бүген, җанын кая куярга белмичә, поликлиникадагы ахирәте янына сугылган иде, ишеткән яңалыгы күңеленә сары май булып ятты ---.* Г.Әдһәм. *«Әфәнде» дигәнне ошатты булса кирәк, кечкенә гәүдәле кешеләрнең зур буласы, дәрәҗәле күренәсе килә бит. --- Сары май булып ятты күңеленә.* Р.Мөхәммәдиев. **Күңелгә (сары) май сылау** Шатландыру, рухландыру, тынычландыру. *Утеп барышлый сугылган Зөлфирә дә күңелгә сары май сылады.* Н.Гыйматдинова. **Күңелгә (якты) нур булып иңү** Өмет тудыру, ышаныч уяту. *Сугыштан соңгы караңгы һәм фәкыйрь елларда аның җырлары әнә шулай халык күңеленә якты нур булып иңделәр ---.* Р.Хәбибуллина. **Күңелгә ошау** 1) Уңай тәэсир калдыру. *[Старшина:] Син полковник күңеленә ошап калгансың, ул үзенә сине ездовой итеп алмакчы була.* Ә.Айдар; 2) Кемнең дә булса зәвыгына, уйтеләкләренә туры килү. *Ресторанда меню актарып утырам: күңелемә ошардай аш эзлим.* Т.Миңнуллин. **Күңелгә (кереп) оялау** *к.* **күңелгә кереп утыру**. *«Ходайдан күркәм сабырлык һәм татулык сорагыз». Бу сүзләр Наиләнең күңеленә кереп ояладе...* А.Гыйләҗев. *Күңеленә кереп оялаган риза-*

*сызлык тойгысын әнә шулай эш белән кумәргә теләде.* Ж.Тәрҗеман. *Миләүшә[нең] --- өмете акланмагач, юлда кайтканда күңеленә кереп оялаган шатлыгының бер почмагы кителеп төшкәндәй булды.* Ф.Яруллин. **Күңелгә рәхәтлек бирү** Канәгатьлек хисе тудыру. *Әбисенең мичтә пешергән алсу йөзле коймаклары, --- – бөтенесе Хәмзәне икенче бер мохиткә күчереп, күңеленә ниндидер рәхәтлек бирә иде.* Ф.Яруллин. **Күңелгә салу** 1) Хәтергә алу, истә калдыру. *Егет боларның барысын да күңеленә салып кайтып китә.* Әкият. *«Монда бер хикмәт бар», – дип күңелгә салып куйдым.* Ф.Яруллин. *Кайчандыр миңа әнием күп нәрсәләр аңлаткан иде дә бит, яшьлек белән күңелемә салмаганмын.* З.Кадыйрова; 2) Искәртү, хәтергә сеңдерү. *Шул вакыт, Ходай күңелемә салгандыр инде, баягы нәрсә йөрәгенә тимәдеме икән дип, авызына сөт салырга уйладым.* Г.Ибраһимов. **Күңелгә сеңдерү** Истә калдыру, хәтердә калдыру. *Кызлар кайбер егетләрнең дуамаллыгын түгел, Ватан хакына кылынган батырлыкны күңелләренә сеңдерергә тиешләр.* Ш.Рәкыйпов. *Киләчәк елларга чыкканда без артка борылып карыйбыз һәм шул чишмәләрне авыз итеп, челтерәүләрен күңелгә сеңдереп, алга китәбез.* И.Юзеев. *Музыка дәресендә барлык ата-аналар да укытучы әйткәнне язып баралар, Рәкыйбә карчык та --- барысын да күңеленә сеңдерә бара иде.* М.Галиев. **Күңелгә сеңү** Онытылмаслык булып хәтердә, истә калу. *--- ул --- үзе генә түгел, туып-үскән җире дә якты булып, ягымлы булып, чәчәкле булып күңелемә сеңеп калды...* Ә.Еники. *Зур көрәк сакаллы, дәү таза гәүдәле бер рус карты белән булган әнә шундый аңлашылмау күңеленә аеруча нык сеңеп калды Миңнулланың.* В.Нуруллин. *Миңсафның --- кайтып та, күңелләргә май булып сеңәрдәй җылы сүз катканы юк.* Х.Сарьян. **Күңелгә таракан керү** Шикләнү, шомлану, шөбһәләнү. *Өйләренә таралышып, һәр кеше үзенең уе белән икәү генә калгач, күңелләргә тагын таракан керде: төнлә белән авылга ут салмагайлары.* И.Гази. **Күңелгә таш булу** *к.* **күңелгә таш яту**. **Күңелгә таш булып төшү** *к.* **күңелгә таш яту**. **Күңелгә таш булып утыру** *к.* **күңелгә таш яту**. *Ә инде аның әйткәннәре күңелгә таш булып утырды.* З.Вәли. **Күңелгә таш яту** Җанга авыр тәэсир итү. *Сираҗи яныннан чыккач, аның ашыйсы да, эчәсе дә килмәде, күңеленә ниндидер авыр таш ятты.* Ф.Садриев. **Күңелгә тезү** Хәтердә калдыру, истә калдыру. *Фәридун Фазлыев үз кайгысына баткан булса да, Нәҗипнең һәр сүзен ишетте, сүзләрен уйга әйләндереп, күңеленә тезә барды.* А.Гыйләҗев. **Күңелгә тию** Начар тәэсир калдыру, ошамау. *«Теге малаең» дигән сүз Сәгыйрьнең күңеленә тиде.* М.Галиев. *Касыймның бу сүзләре Солтанның күңеленә тиде.* Х.Сафина. *Сезнең дә урыс сүзләре кыстырып сөйләшүегез күңелемә тия ---.* Н.Гыйматдинова. **Күңелгә тоз салу** Бик нык кәефне җибәрү. *Бүген минә икеләнеп калуы да шуңардан иде: тагын шулай төрпә каршыласа, яралы йөрәккә, нигезсез рәнҗетелгән күңелгә тагын тоз салса?* Х.Сафина. **Күңелгә төер утыру** Рәнҗү, канәгатьсезлек хисе калу. *Әмма очрашу минутлары кыска, бик тиз үтеп китәләр, --- саубуллашу вакыты килеп җитә, әйтергә дип әзерләнгән сүзләр күңелгә төер булып утырып кала иде.* М.Маликова. **Күңелгә (уй) төшү** 1) Ниндидер уй-фикер туу. *Фәйзәви дә борчылгач, егетләр, минем күңелгә дә уй төште әле...* Х.Сарьян; 2) Хәтергә килү, искә төшү. *Уралны үткәндә, күңелгә әллә нәрсәләр төшә.* М.Гафури. **Күңелгә уелу** Хәтердә, истә калу. *Башындагы күн картузы, пианино клавишларына охшаган тешләре һәм шүре балаклы кара чалбары гына күңелгә уелып калды.* Шатлыклы кайгы. **Күңелгә урнашу** *к.* **күңелгә керү**. *«Мокамай» безнең дә балачагыбыз булып, мәңгелеккә күңелгә урнашып калган икән...* И.Юзеев. **Күңелгә урын тапмау** Борчылу, тынычсызлану. *Көне буе күңелемә урын тапмый, бер эшкә кулым бармый аптырап йөрдем.* Р.Габделхакова. **Күңелгә утлы күмер булып төшү** Нинди дә булса көчле хис, тәэсир калдыру. *Зәйтүнә белә иде бит бу сүзләрне, күптән белә, ләкин нигә алар бүген болай тантаналы яңгырaганда күңелгә утлы күмер булыр төште соң әле?* М.Маликова. **Күңелгә ут салу** 1) Борчу уяту, уйланырга мәҗбүр итү. *Әмма безнең күңелгә дә ут салып өлгерде: Касыйм белән икебезгә, ике дә уйламастан, укытучы булырга киңәш итте.* Х.Сарьян. *Доктор аның күзләрен озак кына карагач, --- егетнең күңеленә ут салды: – Сиңа, егетем, Одессага барырга кирәк.* Э.Касыймов; 2) Мәхәббәт хисе уяту, үзенә гашыйк итү. *Хан кызы безнең улыбызның күңеленә ут салган булса?* М.Хәбибуллин. **Күңелгә утыртту** *к.* **күңелгә беркетү**. *[Гыйлаҗи] баштан ук күңеленә утыртып куйды.* Г.Ибраһимов. **Күңелгә кереп утыру** Мәхәббәтен яулау, оныта алмаслык булып истә калу, хәтергә уелу. *Үзенең чая гомерен таудан ага торган шарлавык төсле тиз һәм шаулап уздырган бу йөрәкле егет минем күңелгә дә әнә шулай нык булып утырып калды.* Ф.Хөсни. *Бер очратты тукталышта, ике очратты, --- өченчесендә егетнең аңа төбәлгән тирән карашы кызыйның бөтен тынычлыгын алып, күңеленә кереп утырды.* С.Шәмси. **Күңелгә ут ягу** *к.* **күңелгә ут салу**. **Күңелгә үтеп керү** Бик көчле тәэсир калдыру. *Гайсә хәйләкәр иде, бу кешенең күңеленә үтеп кергәнлеген аңлады ---.* Ф.Садриев. *Чөнки андагы кешеләр язмышы күңелләргә үтеп керә: «тагы ни була, тагы ни була?» дип, мавыктырып-иярте алып китәләр.* Х.Сарьян. *[Рухия] Равилнең шулай дәртле итеп, бөтен кешенең күңеленә үтеп керерлек итеп уйнавына куанып, --- елмаеп кына утыра.* В.Нуруллин. *Гайшәнең баш очында биш почмаклы йолдыз уелган ак таш тора, язуы да күңелгә үтеп керерлек.* А.Гыйләҗев. **Күңелгә хуш килү** *к.* **күңелгә (сары) май булып яту**. *Миңсылуның күлмәге һәм туфлиләре өчен борчылуы Тимерҗанның күңеленә хуш килде.* Ф.Яруллин. *Латифа карчыкның ап-ак күлмәк киеп, --- ак яулык бөркәнеп керүе дә Сафураның күңеленә хуш килде.* Ш.Максудова. *Киелүен киелгән, ләкин йомшак аслы, кара күннән җиренә җиткереп тегелгән бу читек*

*юньле генә иде әле, ул Сәгыйдулла күңеленә хуш килде.* Х.Сафина. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) йөгерү** *к.* **күңелгә шик (шом, шөбһә) килү**. *Алты бала табып бу хәлне күрмәгән ана нишләргә белмәде, күңеленә шом йөгерде.* Г.Галиева. *Беркөнне Михаил Максимович кунаклары белән теге матур чәчәкләр үсеп утырган куентыкта басып тора иде. Аягөсте булуларын күргәч, күңелгә шом йөгерде.* Ш.Рәкыйпов. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) керү** *к.* **күңелгә шик (шом, шөбһә) килү**. *Унбер булды, унике тулды – Вәли кайтмады. --- Тора-бара күңеленә шом керде.* Г.Әпсәләмов. *– Кайдан беләсең? – дип сорады ашыгып Җәвидә. Шунда ук күңеленә шик керде.* Р.Айзатуллин. *Фатыйха бер мәлгә каушап киткән иде дә, ләкин күңеленә кергән шомны тиз басып, үзе дә көтмәстән: – Җәләл, төя икмәгеңне, үзем илтәм! – диде.* Х.Сафина. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) килү** Шикләнү, хәвефләнү, куркып калу. *Күңелгә шом килә: гүя, [дулкыннар] менә-менә тагы бер-ике тапкыр ыргып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр.* Г.Ибраһимов. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) салу** Куркыту, борчу. *Тик менә бәреп яуган яңгыры һәм ерып уза алмаслык пычрагы күңелгә шик сала.* З.Вәли. *Гариплек күңелемә шом сала минем.* Р.Вәлиев. *Һәрвакыт сабыр Ләйләнең болай ярсуы Гайфулланың күңеленә шом салды.* Ф.Яруллин. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) төшү** *к.* **күңелгә шик (шом, шөбһә) килү**. *Хатынының күңеленә шик төшә дә Сәлимовтан ирен таптыра башлый.* Р.Вәлиев. *Минем янга килгәләп йөрсәң, --- апамның күңеленә шик төшә башлар.* Ф.Яруллин. **Күңелгә эз салу** Хатирә, истәлек калдыру. *Әмма бер кич Һаҗәр күңеленә тирән уелып, һич онытылмас эз салып калдырды.* К.Тимбикова. **Күңелгә юаныч бирү** *к.* **күңелне юату**. *[Хатның] һәр юлыннан, һәр сүзеннән күңелгә юаныч бирә торган, шатлык урнаштыра торган мәгънә чыгардылар.* А.Шамов. **Күңелгә якын алу** Нәрсәгә дә булса бик зур игътибар бирү, бик зур теләктәшлек күрсәтү; нинди дә булса хәлне бик тирән кичерү. *Башкалар яшәячәк йортлар өчен, бүтәннәр таптаячак урамнар өчен --- янып-көеп йөрүе. Күңелгә артык якын алырга да кирәкмидер, бәлки?* М.Маликова. **Күңелгә якын** Кадерле. *Җылыга тилмергән бу дөньяга тиздән кояшлы көннәр киләчәген уйлый карчык, ул көннәр, бәлки, аның да җанын җылытыр, күңеленә якын авазлар ишетелер ---.* С.Шәмси. **Күңелгә якынаю** Тагы да күбрәк ошату, якын итү. *Такташ каләме аркылы бөтен татар дөньясына билгеле булган Сыркыды авылы, үзен күргәч, күңелгә тагын да якынайды.* И.Юзеев. **Күңелгә якын итү** Ошату, үз итү, якын дип санау. *Хәтта Рәмилә булып Рәмилә дә үзе кебек үк зур күзлекле, чандыр озын буйлы егетне күңеленә якын итте.* Х.Ширмән. *Кайвакыт күңелең якын иткән кешегә читтән генә сокланып карыйсың, аңа якынаясы --- килә.* Ф.Яруллин. **Күңелгә яра салу** Рухи газап, борчу тудыру. *Ул аны гафу итәргә дә, аның өчен гомерен бирергә дә әзер иде. Тик нишлисең, күңелгә салган яра тирән иде ---.* Х.Сафина. **Күңелгә ярау** *к.* **күңелгә яту**. *Андук Гыйлемдарның бу хатыны күңелемә ярады.* Н.Гыйматдинова. **Күңелгә ярып салу** Төшендереп сөйләү, җентекләп аңлату. *Әле җыелышта [Газизнең] сөйләгән сүзләрен ишетеп хәйран калып утырдым... Күңелгә ярып сала.* М.Гафури. **Күңелгә яту** Ошау; уй-теләкләргә туры килү. *Тик Нәфисә белән безнең анда көн саен барган гражданнар сугышы синең күңелеңә ятмас.* Ф.Садриев. *Я, әйтегезче, кыз кешенең күңеленә ятарлык, йөрәген талпындырырлык нәрсә генә ишеттем соң мин?..* Ә.Еники. *Кешеләр күп нәрсәгә күнектеләр, җырның да моңлысы, фаҗигалесе ныграк күңелгә ятучан булып китте бит.* М.Кәрим. **Күңелгә ятымлы** *к.* **күңелгә ятышлы**. **Күңелгә ятышлы** Җанга якын, ошый торган. *Аннан соң --- борынгы исемнәрне искә төшерделәр, әмма күңелгә ятышлы, яңгыравыклы заманча татар исеме тел очына килмәде.* Х.Ибраһим. *Күңеленә ятышлы егетләрдән аерылып, япа-ялгыз каласы килмәгәннәнме, әллә ихлас күңелдән ярдәм итмәкче булыпмы, Головин ышандырырлык итеп ялгап китте.* М.Насыйбуллин. *Әнинең тавышы тыныч, күңелгә ятышлы.* Ә.Гаффар. **Күңел даруы** 1) Берәр күңелсезлекне, бәхетсезлекне кичерергә яки онытырга ярдәм итә торган чара. *Интектерде мине айлар буе Эчем пошуы, йөрәк януы. Кирәк иде миңа, тәннән бигрәк, Җан даруы, күңел даруы.* М.Җәлил; 2) *ирон.* Аракы, спиртлы эчемлек. *Гөлбикә --- бер шешә күңел даруын алъяпкычы астына яшереп урамга чыкты.* Р.Ишморатова. **Күңелдә бәйрәм булу** Шатлык хисе барлыкка килү, шатлану, сөену. *Тимеринең күңелендә бәйрәм иде.* Г.Бәширов. **Күңелдә боз арттыру** Җан газабын көчәйтү. *Иртәгәләр туды, алар эзсез-өнсез, җылы язда күңелләрдәге бозны арттырып үтә тордылар.* А.Гыйләҗев. **Күңелдәген түгү** Авыр уйларны, серләрне кем белән дә булса уртаклашу, бүлешү. *Хатын --- сөйли дә сөйли. --- ире килгәнче, күңелендәген түгеп калырга ашыга сыман.* К.Тимбикова. **Күңелдә йөртү** Нәрсәне дә булса хәтердә саклау, истә тоту, онытмау. *[Рания]: Болыннарны, урманнарны, чишмә буйларын һәрвакыт күңелебездә йөртербез.* З.Хәким. **Күңелдә калдыру** Искә, хәтергә сеңдерү. *Аның асрарга алган үксез бала икәнлеген белгәч тә, Мохтар аны-моны уйламаган, картның яисә карчыкның якыннарыннан берәр фәкыйрь кешенең баласыдыр дип күңелендә калдырган иде.* Ш.Камал. *Бу кычкырышу Фатыйманың күңелендә авыр тойгылар калдырды.* З.Кадыйрова. **Күңелдә калу** Истә, хәтердә калу; онытылмау. *Сөекле хезмәтчебез Хөсәен белән Истанбулга килүебез дә күңелемдә калган...* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңелдә касмак яту** *к.* **күңелдә төен (булып) калу**. *Бәлкем, күңелендә касмак ятадыр.* И.Салахов. **Күңелдән алып (кырып) ташлау** Нәрсәнедер уй-фикердән чыгарып ташлау; игътибар итми башлау. *Ләкин Нәфисә уяна гына башлаган бу яңа өметне дә күңеленнән кырып ташлады.* Г.Бәширов. **Күңелдән китмәү** Һәрвакыт истә булу, онытылмау. *Бер нәрсә шикне арттырып, борчып, күңеленнән китмәде.* А.Гыйләҗев. *Фиранын га-*

*җәеп чыдам булуы Алексейның күңеленнән һич кенә дә китмәде.* Х.Камалов. *Теге вакытта Хисаметдиновның әйткән сүзләре аның күңеленнән китмәде.* Ф.Садриев. **Күңелдән кичерү** 1) Үткәннәрне яңабаштан бер-бер артлы искә төшерү, хәтердә яңарту. *Үзе шул арада бүген аңа сөйләгәннәрен күңеленнән кичерә, мие аша сөзә бирде.* Р.Айзатуллин. *Үткән тормышын күңеленнән кабат-кабат кичереп, Илсөяр озак ятты.* Ф.Яруллин; 2) Уйлау, искә алу. *Вәзилә --- Түбән авылдагы мәктәп коллективын кат-кат күңеленнән кичерде.* А.Гыйләҗев. *Ә кичләрен --- алар икәүләп булачак очышның барлык этапларын тагын бер кат күңелләреннән кичерәләр.* Галәмгә юл. **Күңелдән кичү** 1) Бер-бер артлы хәтергә килү, искә төшү. *Кичәге гөнаһлы кызыгулар, төнге вәсвәсәләр күңелдән кичкәч, Сабит җиңеләеп, чистарып калган иде.* А.Гыйләҗев; 2) Хис-тойгылар, уй-фикерләр бер-бер артлы барлыкка килү. **Күңелдән өзелү** Йөрәктән чыгу, чын күңелдән әйтелү. *Сүз ул күктән төшмәгән, кеше күңеленнән өзелеп төшкән.* Р.Вәлиев. **Күңелдән сызып ташлау** *к.* **күңелдән алып (кырып) ташлау**. *Ә минем аны мәңгегә онытасым, күңелемнән бөтенләй сызып ташлыйсым килә иде.* А.Гыйләҗев. **Күңелдән ташып чыгу** Бик көчле, шатлыклы хис-тойгыларны, кичерешләрне һ.б.ш.ларны эчтә генә саклый алмау, яшерә белмәү. *[Дәүләтшин] бүген чиксез бәхетле иде һәм күңеленнән ташып чыккан шатлыгын кем белән булса да уртаклашасы килде аның.* И.Гази. **Күңелдән уздыру** *к.* **күңелдән кичерү**. **Күңелдән узу** *к.* **күңелдән кичү**. **Күңелдән үткәрү** *к.* **күңелдән кичерү**. *«Анда нинди үзгәрешләр бар икән?» – дип, үзенә ярдәм кулы сузарлык кешеләрне күңеленнән үткәрде.* Р.Мирхәйдәров. **Күңелдән үтү** *к.* **күңелдән кичү**. *Саимәнең күңеленнән шундый уйлар үтте.* Г.Галиева. **Күңелдән чыгару** Оныту, истән, хәтердән чыгару; уйламаска, онытырга тырышу. *Шулай да ул бәбәйгә узу өметен күңеленнән чыгармады.* Г.Галиева. **Күңелдән чыгарып ташлау** *к.* **күңелдән чыгару**. *Кинәт бөтен зиһенен бер йодрыкка җыйнап, кызга дәште һәм аркасыннан кочып алды: – Күңелеңнән чыгарып ташла син аны, Рауза, оныт!..* Р.Мөхәммәдиев. *Ничә тапкыр Касыймны күңеленнән чыгарып ташларга теләде, ничә тапкыр үзен эт итеп әрләде, --- күпме эченнән битәрләде.* Х.Сафина. *Ә теге хыянәтче кыз – Рухия турында бүтән беркайчан да уйламаска, аны күңеленнән бөтенләй чыгарып ташларга --- карар кылды.* В.Нуруллин. **Күңелдән чыгарып ыргыту** *к.* **күңелдән чыгару**. *[Гали] моннан биш ел элек булган шомлы вакыйганы күңеленнән чыгарып ыргытырга теләи.* М.Гафури. **Күңелдән чыгу** Онытылу, истән, хәтердән чыгу. *Әлеге әйбер аның күңеленнән чыкмады, ул моны өзмичә туктамаячак иде.* Ф.Садриев. *Дәресләрдә дә ире турындагы уйлар күңеленнән чыкмады.* Р.Айзатуллин. **Күңелдән югалу** *к.* **күңелдән чыгу**. **Күңелдән юылу** *к.* **күңелдән чыгу**. *Башка сүзләрне дә, мәҗлесне дә томанлы хәтерли Сәет. Кем ни әйткән, нәрсә белән сыйлаганнар, --- күңелдән юылган.* Ф.Латыйфи. **Күңелдән ялкын бөркелү** Артык дулкынлану; шатлыктан яки борчылудан туган көчле кичерешләр кичерү. *«Уф!» – диде хатын, өзгәләнгән күңелдән кайнар ялкын бөркелеп, иреннән пешерде.* Н.Гыйматдинова. **Күңелдә өмет чаткысы кабыну** Нәрсәгә дә булса ышаныч, өмет барлыкка килү. *Матусовның күңелендә өмет чаткысы кабынды.* М.Насыйбуллин. *Күңелендә өмет чаткысы кабынган Рабига: – Акыллым, – диде, – Габдерәхим тагын берәү белән никахланам дисә, син ризалашыр идеңме?* Н.Гыйматдинова. **Күңел дәрьясы** Хис-тойгылар, кичерешләр, эчке дөнья. *Таһирҗан югалгач, кызның күңел дәрьясы шулкадәр үзгәрде.* Г.Әдһәм. **Күңелдә саклау** *к.* **күңелдә йөртү**. *Уф, кызам шул, газиз җаным. --- Ышан, бу сереңне дә күңелемдә саклармын.* Н.Гыйматдинова. **Күңелдә таш эремәү** Ниндидер ямьсез сүздән, эш-хәлдән соң барлыкка килгән хисне онытмау, хәтердә саклау. *Кызның кискен җавабыннан Фаяз аңлады: күңелендәге таш һаман эремәгән.* С.Шәмси. **Күңелдә төен (булып) калу** Нинди дә булса сөйләшүдән, вакыйгадан соң авыр тойгы, хис уяну. *[Сәйфетдин карт:] Рәнҗеп чыкма инде, күңелеңдә төен булып калмасын.* Г.Бәширов. **Күңелдә төер калдыру** Үпкәләтү, рәнҗетү. *Теге көнне күңелдә төер калдырдың син.* Ф.Садриев. **Күңелдә уелып калу** Хәтердә, истә онытылмаслык булып урнашу. *Кат-кат кабатлагач кына, хәтергә сеңеп, әнисенең соңгы сүзләре буларак, күңелдә уелып калды.* Г.Әдһәм. *--- минем күңелдә ул вакытлардан тагын ике хатирә ачык булып уелып калган.* Р.Вәлиев. *Равилнең уйлары күңелендә мәңгегә уелып калган мәктәп елларына янә әйләнеп кайтты.* В.Нуруллин. **Күңелдә ут уйнау** Көчле кичерешләргә дучар булу сәбәпле бик нык шатлану яки борчылу. *Башка көннәрне --- алдагы көннәргә планнар яза, я булмаса газит-журналлар караштыра торган иде, бүген берсенә дә кулы ятмады, күңелендә ут уйнады.* Р.Айзатуллин. **Күңел дәфтәре** Хәтер. *Иске бу такмак, сабый вакытымда күп такмакланган Такмагым булганга, күңел дәфтәрендә сакланган.* Г.Тукай. *Мөхтәрәм профессор, хатын-кыз мәсьәләсе буенча докторлык диссертациясе якларлык ук кеше булмаса да, --- күңел дәфтәренең яшерен битләренә шактый матур сәхифәләр язган кеше иде.* Ф.Яруллин. *Баксаң, аның [Ибраһим Газиның] күңел дәфтәрендә энҗе бөртекләредәй миниатюралар да бар икән.* Б.Камалов. **Күңелдә шик (шөбһә, шом) тудыру** Шикләндерү, шик-шөбһә барлыкка китерү. *Аның сүзләре минем күңелдә шөбһә тудырдылар.* Ш.Усманов. **Күңелдә шик (шөбһә, шом) туу** Шикләнү, шик-шөбһә барлыкка килү. *Күңелендә шик туды тууын, әмма сиздермәде.* Ә.Моталлапов. **Күңелдә эз калдыру** *к.* **күңелдә калдыру**. *Хатын-кызларның кайберләре күңелендә тирән эз калдырган: тиз генә искә төшәләр, ә беришләре исә шундук онытылган ---.* Р.Кәрами. **Күңелдә (авыр) юшкын калдыру** *к.* **күңелдә төер калдыру**. *Бу хәл Ирекнең күңелендә берничек тә аңлата алмастай авыр юшкын калдырды...* Ф.Садриев. **Күңелдә яңарту**

Кабат, яңадан искә төшерү. *Аннары Халитов сүз алды, ул Лариса белән булган фаҗигане тагын бер кат күңелләрдә яңартты ---.* Р.Мирхәйдәров. **Күңел диңгезе** *к.* **күңел дәрьясы**. *Юкса, бая карашлар кисешкәндә, аның күңел диңгезе дә чайкалып алды бит.* Ф.Яруллин. **Күңел дөньясы** *к.* **күңел дәрьясы**. *Шул көннән башлап, Хәернисаның күңел дөньясы бөтенләй үзгәрде.* Г.Әпсәләмов. *Кодрәтеннән килгән очракта да Сәвилә Тәминдарның күңел дөньясына тыкшынмас иде.* Н.Гыйматдинова. *Нәтиҗәдә, геройларның күңел дөньясы тулырак ачыла, романда карашлар конфликты калкурак сурәтләнә ---.* Р.Фәтхрахманов. **Күңел дулкынлану** Тынычлык югалу, ашкынулы тынычсызлану. *Йөрәк тибеше икеләтәөчләтә ешайды, тамырларда кан агышы кызуланды, күңеле диңгездәй дулкынланды.* Ф.Яруллин. **Күңеле ачык** Хис-тойгыларга, сүзгә һ.б.ларга әзер. *Назга, йомшак сүзгә күңеле ачык.* Ф.Яруллин. **Күңеле белән** Аң белән түгел. *Тик күңеле белән Касыймны кызгана иде ул.* Х.Сафина. *Равил күңеле белән бабасы сугышкан җирләрне әллә ничә тапкыр урады инде.* Н.Әхмәдиев. **Күңеле белән дә, тәне белән дә** Бөтенләй, бөтен барлыгы белән. *[Газизов:] Мин аның үз-үзен тотуына, миңа күңеле белән дә, тәне белән дә хыянәт итмәвенә ышана идем.* А.Шамов. **Күңеле иркен** Һәркемгә игътибарлы, кечелекле булу. *[Саимә:] Кәефем килде әле Гришага. Беребезне дә онытмый. Хәтере нык аның. Күңеле иркен.* К.Нәҗми. **Күңеле каты** Шәфкатьсез, рәхимсез. *Кыз, көрсенеп, авыр сулап куйды: – Болай карап торышка әйбәт кенә кебек үзе. Тик ниндидер коры кеше ул. Күңеле каты.* Ж.Дәрзаман. **Күңеле керле** Эчтән ниндидер начарлык, усаллык уйлап йөрүче. *Чөнки күңеле керле иде аның бүген, гаебен танырга көче җитмәгәч, тормышының көйсезлеген беренче очраган кешесенә --- йөкләп җибәрергә тырышты ул.* А.Гыйләҗев. **Күңеле киң** *к.* **күңеле иркен**. **Күңеле китек** Кайсы яктан да булса кимсетелгән, рәнҗетелгән булу. *Кешедән җыйган кием-салымны, авылдан килгән азык-төлекне сакларга да урын бар. Рәхим итегез, тормышы ким, күңеле китек мескен-бичаралар!* М.Маликова. *[Рәис:] Гөлнур, мин аларга барысын да әйтеп бетермәдем әле. --- Ни дисәң дә, балалар йортында үскәннәр бит алар, күңелләре китек.* Ф.Галиев. *Чит мин сезгә, чит, ә читнең күңеле китек була аның.* Р.Вәлиев. **Күңеле кителү** Кемдер тарафыннан урынсыз рәнҗетелү. *Рушания, кире килеп яхшы иткәнсең, бик күңелем кителеп калган иде шулай кинәт китүеңә.* З.Кадыйрова. **Күңеле көйсез** Кәефсез. *Бәхете булмады аның, шуңа күрә генә күңеле көйсез.* А.Гыйләҗев. **Күңеле көр** Канәгать, шатлыклы булу турында. *Егетләрнең күңелләре көр, әниләренең ачы бал мичкәсенә төшеп чыкканнар.* З.Кадыйрова. **Күңелен авызлыклау** Начар уй-фикерләрдән, эш-хәлләрдән арыну; нәфесне тыю. *Клёпа җиңелчә уйлап, күңелен авызлыклый алмады, гомерен куркыныч астына куйды...* С.Шәрипов. **Күңелен агарту** Аңлы-белемле итү; рухи баету. *Димәк, син хезмәт итү өчен килгәнсең? Мәгърифәт өчен, авыл балаларының күңелен агарту өчен, шулаймы?* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңелен алу** Кемдә дә булса үзенә карата яхшы мөнәсәбәт уяту; гашыйк итү. *[Мәрхәбә] үги каенананың күңелен алырга, туры үзенең килендек, кардәшлек тойгыларын күрсәтергә ашыкты.* Г.Ибраһимов. **Күңелен аудару** *к.* **күңелен алу**. *[Әбелхарис:] Тик мин ханның гына күңелен табыйм. Киткән данны кире кайтарыйм. Ничек аның күңелен аударыйм?* Н.Исәнбәт. **Күңелен ачу** 1) Кемнең дә булса кәефен күтәрү; кайгы-хәсрәтен таратырга ярдәм итү. *[Сәфәр:] Гөлнур әнә бик серле, тылсымлы кызга охшаган. Шуның күңелен ачып, серен белсәң иде ул.* Ф.Галиев. *Ул аны гафу итәргә дә, аның өчен гомерен бирергә дә әзер иде. Тик нишлисең, күңелгә салган яра тирән иде, тел тибрәтеп күңелен ачарга аның көче җитмәде.* Х.Сафина; 2) Серен сөйләү. *Ә мин аларны һаман дус санап йөргәнмен, --- аларга бар серләремне, күңелемне ачканмын.* Р.Вәлиев. *[Безнең татар] елый-елый мендәрен чылатып бетерер, тешләп иреннәрен канатыр, ә ир-атка күңелен ачып салмас!..* С.Шәмси. **Күңеленә ачкыч табу** Кемнең дә булса эчке дөньясына үтеп керә алу. *Нишләргә? Киребеткән «ханым»ның күңеленә ачкычны ничек табарга?* М.Маликова. **Күңелен бәйләү** Кемне дә булса үзенә карату. *Хәлил дә йокламаган: бөтен тирә-юнь егетләре күз тотып торган кызның күңелен бәйләп өлгергән.* М.Фәйзи. **Күңелен бирү** *к.* **күңел бирү**. *Илдус эшне ашыкмыйча, бөтен күңелен биреп, җиренә җиткереп эшли ---.* З.Кадыйрова. *Аксубай якларыннан килгән гади бер мишәр кызы өчен, шушы урыс хатыны ник бөтен күңелен биреп чабып йөрде икән?* Ирек мәйданы. **Күңелен бушату** Үз эчендәге авыр уйлардан арыну. *Ялгызы гына калып күңелен бушатасы --- килә иде.* Ф.Яруллин. *Гайшә белән бөтен күңел серләрен ачып, ачыктан-ачык сөйләшә алса да, Габдуллаҗан янында ул бүгенге көнгә кадәр каушый, борчыла, ире янынан бер чакта да күңелен бушатып китә алганы юк.* А.Гыйләҗев. **Күңелен күрү** Берәр юл белән кешенең кәефен күтәрү, канәгатьлек хисе уяту. *Культорг Әхәт абыйның күңелен күрәсе килә.* Ф.Яруллин. *Кызлар белән таныштың исә, аларның күңелләрен күрер өчен, дискотекага, киногa, ресторанга бармыйча котылып булмый.* Х.Ибраһим. *Күңелен күреп, җанын тынычландырып куйсаң, синең өчен --- бөтен нужаны берүзе тартырга әзер бит хатыннар.* К.Тимбикова. **Күңелен күтәрү** *к.* **күңелен күрү**. *Алтынчәч кич укуга бармады. Болай да ул анда күңелен күтәрү өчен генә йөри иде.* М.Маликова. *Һаҗәрнең күңелен күтәрү, күңелен күрү өчен хәзерләнгән сүзләр югалалар да калалар.* М.Хәсәнов. *Кәримә кайтып, карт белән карчыкны гел юатып, күңелләрен күтәреп тора.* С.Шәмси. **Күңелен кыру** Кешенең кәефен бозу, канәгатьсезлек хисе уяту; үпкәләтү, рәнҗетү. **Күңелен кытыклау** Йөрәкне, күңелне тәэсирләндерү, җилкендерү, җиңелчә генә ярсыту; хис уяту. *Оялудан куе озын керфекләре дерелдәп куйды, матур чия ирennәрен тешләде. Боларның барысы да яшь табибның күңелен кытыклады.* З.Кадый-

рова. **Күңелен сындыру** *к.* **күңелен кыру**. *Фатыйма Акбикә инәйнең күңелен сындырмас өчен генә ризалашты.* З.Кадыйрова. **Күңеле сынык** *к.* **күңеле китек**. **Күңелен табу** *к.* **күңелен күрү**. *Бераз вакытлар торгач, --- Заятүләк, аның күңелене табар өчен, түбәндәге җырларны әйтте ---.* Дастан. *Фарукҗанның --- әллә кемнәргә каршы көрәшергә гайрәте дә, елгырлыгы да бик җитә, ә менә Зөһрәгөлгә дуслык кулын сузарга, хәтта күңелен табар өчен генә аның хәлен сорашырга да ашыкмады.* Т.Әйди. *Сизеп торам: инде миңа да сүзгә катнашырга, ничек булса да Ирекнең күңелен табарга, үз ягыма тартып карарга кирәк.* В.Нуруллин. **Күңелен үстерү** Яхшы кәеф барлыкка китерү, шатландыру. *– Булдырасың, булдырасың! – дия-дия көч-куәт биреп, күңелен үстереп торды.* А.Тимергалин. **Күңелен яралау** Кемгә дә булса борчу, кайгы, рухи газап китерү. *Яңа гына табылган энесенең күңелен яралыйсы килмәсә дә, җаваптан котылырлык түгел иде.* Р.Хәбибуллина. **Күңелен ярып салу** Эчендәге уй-фикерләрне сөйләү. *Сөйләвен тыңлаганда, һич тә андый тәэсир калмый, ул үзенең уй-хыялларын әйтә, үз күңелен ярып сала кебек тоела бит.* К.Тимбикова. **Күңелен яулау** *к.* **күңелен алу**. *Мәсхүдә ханым беренче дәресеннән үк балаларның күңелен яулап өлгерде.* Мәгърифәт. **Күңеленңне киң тот** Әзер бул, өмет ит, исәп тот. *[Илдар:] Күңеленңне киң тот, халык сиңа [эш] тапшырырга чамалап тора.* Г.Гобәй. **Күңеле суыну** Яратмый башлау, бизү. **Күңеле тар** Көнчелекле, хөсетле. *Күңеле тар, саран кеше, күпме алтын-көмеш җыйса да, --- чын рәхәтне татый алмаячак.* К.Тимбикова. *– Күңелең тар бугай, апа. – Хатын бозлы суга чумгандай туңды-өшеде.* Н.Гыйматдинова. **Күңеле төзек** *иск.* Яхшы уйда булган, игелекле, яхшы. *Күңеле төзек адәм яхшы эшкә булышудан һич тартынмас.* Шура. **Күңеле туры** Намуслы, гадел. *Талканы коры булуга карама, күңеле туры ул кешенең.* Р.Вәлиев. **Күңел жу (шу) итү** Бик нык курку, шүрләп калу. *Тик кинәттән китте күңелем жу итеп. Җир дә җир. Сөргән кара җир!* Н.Исәнбәт. *[Зөһрә:] Мин тегендә барырга дип чыксам, капка төбенә атлар килеп туктады. --- Күңелем шу итеп китте.* Г.Ибраһимов. **Күңел җәрәхәте** *к.* **күңел ярасы**. **Күңел җәрәхәте алу** *к.* **күңел яралану**. *--- Гордов --- Совет властен торгызу өчен көрәшеп йөргәндә, гомер буена төзәлмәс күңел җәрәхәте алып калды.* Ш.Рәкыйпов. **Күңел җебе чишелү** Берәр яшерен, сер булган нәрсәне ачыктан-ачык сөйләп бирү; үзенең хәлен, уй-ниятләрен тулысынча сөйләү. *Нәни капчык бавы белән бергә Айзатның, ни өчендер, моңарчы төенләнеп торган күңел җебе дә чишелеп киткәндәй булды.* Язмышлар яңарганда. **Күңел җебе (җепләре) өзелү** Өмет, ышаныч калмау. *Рушания озата чыкмады, чөнки күңел җепләре менә өзеләм дип тора.* З.Кадыйрова. **Күңел җилкенсенү** *к.* **күңел җилкенү**. *Инде хәзер яз: карлар эри, гөрләвекләр ташып ага, күңелләр җилкенсенеп ала!* Х.Ибраһим. **Күңел җилкенү** Нинди дә булса теләк уяну, якты өмет-хыяллар барлыкка килү. *Тагын ниләр сөйләшкәннәрдер, хәтердә калмаган. Ә менә күңеле җилкенүе, өмет чаткылары уянуы онытылмый.* С.Шәрипов. *Аның күңеле җилкенә, ул очып китәрдәй булып йөри иде.* Э.Касыймов. *Эшләр болай тәгәрәсә, озакламый илгә кайтырлар, Ходай кушса... Гордовның да күңеле җилкенеп куйды.* Ш.Рәкыйпов. **Күңел җиңеләю** Эчке борчылулар юкка чыгу, тынычланып калу. *Ул картның авыр адымнары артыннан нәфрәт тулы күзләре белән карап калды. Иң гаҗәбе, аның күңеле җиңеләйде ---.* Сөембикә. **Күңел җитү** 1) Кирәк дип табу, тиешле дип санау. *Үзең --- аз булса да, күңелең җиткәнчә ярдәм кылырсың.* Ш.Мөхәммәдев; 2) Ышану. *Бу атның мендерүләренә күңелем җитми.* Г.Ибраһимов. **Күңел җылылыгын салу** Кемне дә булса ярату, кайгырту; кемгә дә булса яхшы мөнәсәбәт күрсәтү. *Күңел җылылыгын шуңа [кызы Энҗегә] салды да аның киңәше белән авылга кайтып, бикле ишекне ачты.* М.Мәһдиев. **Күңел җылыну** 1) Кәеф күтәрелү. *Сый-нигъмәт татлы --- булса да, күңелләр җылынып җитмәде, чөнки биредәге дүрт кеше арасына нindидер бер киеренкелек кереп оялагандай иде.* М.Маликова; 2) Өмет уяну. **Күңел җылысы** Эчкерсезлек белән, якын итеп карау; яхшы мөнәсәбәт. *Урта яшьләрдәге акушерка Тәбриягә күңел җылысын мул бирде.* М.Маликова. *Саимә бала табу белән, барлык назын, күңел җылысын нарасыена кучерде.* Г.Галиева. *Әлегә безнең шәһәрдә күңел җылысы табар җир икәү генә: эш һәм өй.* Р.Вәлиев. **Күңел иләсләнү** Җиңел уйлар барлыкка килү, хисләр уяну, җилкенү. *Күңелләрем иләсләнсә, әй, әйләнәм сабыйга!* Н.Измайлова. **Күңел ишеген ябу** Яшерен серләрне, эчтәге уй-фикерләрне читләргә сөйләмәү, башкалар белән бүлешмәү. *--- Мәгъдән абыйсы да: – Буразнадан читкә киттек бугай... – дип, бая гына төбенә хәтле ачып куелган күңел ишекләрен яба төшүне кирәк тапты.* Язмышлар яңарганда. **Күңел йогышу** *к.* **күңел яту**. *[Лутов:] Ләкин бу халыкка [егетнең] күңеле йогышып бетми бугай.* Ш.Камал. **Күңел йозагы бикле (булу)** Эчке дөньяга читләрне кертмәү; серләре, уйлары белән бүлешмәү турында. *Ә Дилбәрнең күңел йозагы бикле килеш калды.* А.Әхмәтгалиева. **Күңел йолдызы** Җанга якын кеше; мәхәббәт йолдызы. *Кайда мин, дуслар, хәзер? Аh, кайда күңелем йолдызы?* Н.Исәнбәт. **Күңел йомшару** Хисләргә бирелеп бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү, дулкынлану; хисләр нечкәрү. *– Зурлавың өчен рәхмәт инде, балакай. Игелек күр! – Күңеле йомшарудан карчыкның тавышы үзгәрде.* Н.Хисамов. *Нәрсә көтәсең, Вәсилә, әйтәсе сүзеңне әйт! Нигә күңелең йомшарды?* Н.Гыйматдинова. **Күңел йомшау** *к.* **күңел йомшару**. *Мин үземне хәзер бу хәзрәткә бөтенләй буйсынган кебек хис иттем, күңелем йомшап, күземнән яшь килде.* М.Гафури. *Моңа кадәр күңеле йомшау түгел, пышылдап сөйләшә дә белмәгән әтисенең шулай кинәт җебеп төшүе Ихтыярның җанын актарып ташлагандай булды.* Р.Вәлиев. **Күңел кабул итмәү** *к.* **күңел күтәрмәү**. *Синнән башка бүтәннәрне Күңелем кабул итмидер.* Җыр. **Күңел кабул күрмәү**

*к.* **күңел күтәрмәү**. **Күңел кайтаргыч** *к.* **күңел биздергеч**. *Шушы күңел кайтаргыч күренешне күзәтеп торган тикшерүченең башына уй килде ---.* Ф.Галиев. *Күңел кайтаргыч күренеш.* Г.Гобәй. *Картның көләргә маташуы күңел кайтаргыч иде.* А.Әхмәтгалиева. *Ул шундый сөйкемсез, күңел кайтаргыч булып тоелды ки, Тәбрия кулын сузгач, Гадил ихтыярсыздан артка тайпылды.* М.Маликова. **Күңел кайтару** Биздерү, туйдыру; каршы фикер уяту; яратмаслык булу, ошамау. *Бу хәл бригаданың үсешенә ярдәм итми, киресенчә, бораулаучыларның күңелен кайтара иде.* Г.Ахунов. *Хәер, егетнең төсебите дә, кием-салымы да күңел кайтарырлык түгел: башына кепка, өстенә кыска тужурка, аягына кун итек кигән.* А.Шамов. **Күңел кайту** *к.* **күңел бизү**. *Халык арасына ыргылган ачык күңелле Бибинурның кеше белән исәнләшергә дә иренгән, үз сукмагыннан гына атлап йөрергә күнеккән төнтек Касыймнан күңеле кайта башлады.* Х.Ибраһим. *Рәхим бар нәрсәдән күңеле кайтып, үҗәтләнеп югла омтылды.* А.Вергазов. *Ул бит Абдулла минем йөземне күрер дә, күңеле кайтып, башка берәүгә кызыгыр дип уйлый...* Э.Касыймов. **Күңел калу** Үпкәләү, рәнҗү; хәтер калу. *Юк инде, Касыймга башка бармыйм. Җәләлнең күңеле калыр.* Х.Сафина. **Күңел канатландыргыч** Яхшы хис, омтылыш барлыкка китерә торган, дәртләндергеч. *Күңел канатландыргыч итеп әйтелгән бу сүзләрнең яшерен мәгънәсен Гөлчирә аңлап бетермәде.* Х.Сафина. **Күңел канатлану** *шигъ.* Нинди дә булса берәр яхшы хис, омтылыш барлыкка килү, дәртләнү, рухлану. *Тик бер теләк: сөю дәрте белән Канатланса иде күңелләр.* М.Җәлил. **Күңел капкасына туп кертү** *окказ.* Күңеленә үтеп керү, күңелен яулау. *Анда [Лужникида] ярыш ничек бетсә дә беткәндер, әмма монда борынгы химиклар посёлогында, Фуатның күңел капкасына, искәрмәстән куәтле бәреп, бер тупны керткәннәр иде...* Э.Касыймов. **Күңел капкасын ачу** Шәхси серләрне ачу, эч серләрен кешегә сөйләү. *Күңел капкасын ачып, кешеләргә үзен күрсәтергә яратмый иде Мирвәли.* А.Гыйләҗев. *Күңелләрнең капкалары әле киереп ачылмаган, эчке киеренкелек бетеп җитмәгән иде.* Ф.Яруллин. *Бал-бузаның телләрне чишүен, күңел капкаларын шәрран ачып җибәрү сәләтен ул яхшы белә иде.* Р.Зәйдулла. **Күңел капкасын бикләү** *к.* **күңел ишеген ябу**. *Ә Зиннәтулла кинәт кенә «саңгырауланды». Аның «кияү» сүзенә күңел капкасы бикләнеп маташа иде.* Н.Гыйматдинова. **Күңел капчыгын селкү** *к.* **күңел капчыгын чишү**. *Беткән баш беткән, Себер киткән, диде дә Рәнис, һич тартынмыйча, күңел капчыгын төбеннән тотып селкергә булды.* Ж.Дәрзаман. **Күңел капчыгын чишү** Эч серләрен ачу, эч серләрен сөйләү. *Улы күңел капчыгын чишәргә ашыкмады, анасының төпчеңүләрен --- икенче якка борып җибәрде.* Ш.Хөсәенов. **Күңел каралу** Тәрбиясезләнү, тупаслану. *Элек заманнарда [алар], туры юлдан чыгып, күңелләре каралып, ата-бабаларына ияреп, тәмам хайван булып җиткән вакытларында, араларыннан берсе туры юлны табып, аларны туры юлга өндәмештер.* З.Һади. **Күңел карышу** *к.* **күңел тартмау**. *Чәчкәнең күңеле карышты, ләкин якыннарының кыставына каршы тора алмады.* Ф.Яруллин. **Күңел кату** Җан тупаслану, шәфкатьсезләнү; хиссезләнү. *Ирен җиңә алмагач: «Бармасаң, сорамасаң – тормыйм, аерылышабыз!» – дип кычкырды. Нәҗипнең күңеле портландцемент белән ныгытылып каткан иде.* А.Гыйләҗев. *Юк, ул елый алмый, аның күңеле каткан ---.* Р.Вәлиев. *--- Мөршидкәй шул рәвешле --- Казаннан ерак түгел бер колониягә килеп эләкте. Зиһеннәре чуалган, күңеле таштай каткан иде.* К.Тимбикова. **Күңел килү** *к.* **күңел төшү** (*1 мәгъ.*). *Тагын әйт аңа: куп уйламасын, Күңле килгәнгә кияүгә барсын.* Җыр. **Күңел киңәю** *диал. к.* **күңел булу**. *Кызның күңеле киңәйде. «Нигә печән җыюдан качтың», – дип, берсе дә бәйләнмәгәч, яңадан барып җыярга өметләнде.* Г.Ибраһимов. **Күңел киң булу** Кешеләргә карата ярдәмчел, кайгыртучан, игътибарлы булу. *[Шәйхел:] Күңел киң булса, урын тарлыгыннан курыкмыйм мин.* Г.Ибраһимов. **Күңел киселү** *к.* **күңел кителү**. *Әмма очраша алмауларыннан, егетнең алдавыннан күңеле киселде, күзләренә яшь тулды, төне буе йоклый алмады.* Ф.Яхин. **Күңел китеге ямалу** Канәгатьсезлек, ризасызлык хисе бетү. *Өй эченә ансын-монсын алгаласам, хатынның да күңел китеге ямалыр иде.* Г.Мөхәммәтшин. **Күңел китек булу** Рухи канәгатьсезлек кичерү, нәрсәдәндер риза булмау. *Хәйдәрнең газапланулары сүрелеп, хисләре суына төшсә дә, Мәрьямне барыбер оныта алмады, күңеле һаман китек булып кала бирде.* Язмышлар яңарганда. **Күңел китеклеге** Нәрсәдәндер өмет сүрелү; кайсы яктан да булса башкалардан ким булу. *[Искәндәр:] Бала өчен иң аяныч күңел китеклеген – аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г.Гобәй. **Күңел кителү** Хәтер калу. *Их әни, әни! Син исән булсаң, күңел болай кителмәс иде.* Н.Хәсәнов. *Бер генә ел калган иде тик кавышырга, Татлы хыяллар юкка чыкты, күңел кителде, Сугыш ачы хәсрәт китерде.* Н.Арсланов. *--- бер малайның: «Яшь килен апайның кәнфите тәмле. Үзе әлләкем түгел икән...» – дип әйткәнен ишетеп күңеле кителсә дә, ишетмәмешкә салышты.* Г.Галиева. **Күңел киту** 1) *к.* **күңел кырылу**; 2) *к.* **күңел төшү**. *[Габдулла:] Нәрсә син ул хәтле тирән уйга чумып киттең? Корбангали агайның оҗмахтагы хур кызларына күңелең киттеме әллә?* Ш.Камал. **Күңел кичермәү** Гафу итмәү. *Синең болай байгыш кебек кимсетелгән булып йөрүеңне күңел кичерми.* А.Гыйләҗев. **Күңел котырыгы** Азгын, тотнаксыз, бозык хис. *Ялкаулык илә күңел котырыгы артыннан йөрмәк адәм угылын авыру итәр.* Шура. **Күңел кошы** 1) Кемнең дә булса ратканы, сөеклесе. *Менә ул, кайчандыр --- төн йокыларын качырган, мәңге сүнмәс утларга салган, хәзер инде тормышыннан мәңгегә югалган күңел кошы – Гөлүсә!* Ж.Дәрзаман. *Күңел кошымның мине алдаганы юк әле.* Ф.Яруллин; 2) Рух, дәрт турында. *Хәлсезлек белән рәхәтлек икесе бергә килеп кушылгач, күңел*

*кошы күккә күтәрелеп очып китә икән.* Р.Вәлиев. --- *аның күңел кошы ашкынулы хисләр белән атна буе күкнең иң биек ноктасында кагынудан башлап, әкертен-әкертен түбәнәя --- торды.* Ә.Баян. *Тик үз күңелендә мондый чакларда булырга тиешле очынуны гына тоймады: күңел кошы, никтер, канат какмады.* Сөембикә. **Күңел кояшы** *к.* **күңел йолдызы**. *Асыл кошым, сандугачым, Син бит күңелем кояшы.* Җыр. **Күңел күзгесе** 1) Җан; зиһен. *Бу кадер кич – елда бер кич, барча кичләр изгесе, Пакьләнер таптан бүген мөэмин күңелләр күзгесе.* Г.Тукай; 2) Рухи чагылыш. *Холык ул, энем, кешенең күңел күзгесе.* М.Насыйбуллин. **Күңел күрлеге** Рухи күтәренкелек, яхшы кәеф. *Асия-Миңлеасия барлык уеннарны оештыручы, --- күңел күрлеге белән авыл яшьләрен кузгатучы булып чыкты.* Г.Ахунов. **Күңел кузгалу** Әсәрләнү, тәэсирләнү; хисләр уяну. *Борынына яз исе килеп кергәч, картның да күңеле кузгалды.* С.Шәмси. *Бер дә юкка гына күңеле кузгалудан кинәт сулпәнләнеп калган Һаҗәр егеткә ачуланып карады.* К.Тимбикова. *Элекке елларны бәйрәм булса, күңелләр үзеннән-үзе кузгала, сөенеч ташып торгандай була иде.* Х.Сафина. **Күңел курку** Шүрләү; шөбһәләнү. *[Мәрфуга:] Әллә нигә күңелем куркып тора.* А.Алиш. **Күңел куркыну** *к.* **күңел курку**. *Бакчадагы карт агачлар да әллә нинди шомлы тавыш белән караңгы төндә шауларга тотыналар. Күңел куркына, эч нидәндер шикләнә.* Г.Ибраһимов. **Күңел кушканча** Намус, вөҗдан таләп иткәнчә. *Ашыктырма, Бакир, барыбер күңелем кушканча эшлим мин.* Н.Гыйматдинова. **Күңел кую** *к.* **күңел бирү**. *Тик никадәр күңел куймасын, Рәйхана җитәкләгән участокта, юк дигәндә дә, эчпошыргыч күңелсезлекләр чыгып тора.* Р.Ишморатова. *Гимназиядән чыккач, [Гали] сабын эшенә бигрәк күңел куеп керешә.* Ш.Мөхәммәдев. *Ахирәтемнең исеме Мөнәввәр. --- Элек берәүгә күңел куеп чыккан булса да, бәхете бик кыска булды.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңел күбәләге** Сөю, ярату хисе. *Күңел күбәләгең андыйга бер кунса, тиз генә ычкына алмассың.* М.Маликова. **Күңел күге** *шигъ.* Кешенең эчке дөньясы, рухи халәте. --- *Сөмбел генә шул көннән соң басынкыланып калды, аның күңел күгендәге кайсыдыр бер тәрәзәсе Искәндәр өчен инде ябык иде...* Р.Вәлиев. *Илшатның күңел күген болыт басты.* Ф.Яруллин. *Чынлап та, тәэминатчы булып Гаффар эшкә керешкәннән бирле, Әсхәт Лотфиевич өчен дөньяның яме югалды кебек ---, күңел күге өстендә авыр, салмак кара болытлар йөзеп йөри.* М.Шаһимәрдәнов. **Күңел күге аязу** Кайгы-хәсрәттән, күңелсез хисләрдән арыну. *Тәбрия --- үзендәге үзгәрешне бик тиз сизде. Җаны тынычлангандай булды, күңел күге аязып китте.* М.Маликова. *Кара болыт үтеп киткәннән соң, күк йөзе аяза барган кебек, Газинурның да күңел күге әкренләп аяза барды.* Г.Әпсәләмов. **Күңел күзе** Тирә-юньне күрә белү, тоемлау, аңлау сәләте; интуиция. *Алай да минем күңелем күзе ул урынны һаман элеккечә күрә икән, нигә ышанмаска, ди, әле?* Ә.Гаффар. *Күңел күзе беләнрәк карасаң, бу сихри моң белән инеш буйлары тулгандыр ---.* М.Хәсәнов. *[Айсылу:] Мине беркем дә рәнҗетмәде. Мин үзем теләсә кемне рәнҗетә алам. [Гәрәй:] Юк инде, үскәнем, бездә дә күңел күзе бар.* Г.Шакирова. **Күңел күккә менү** *к.* **күңел күтәрелү**. *Атлы кеше – канатлы кош. Сезгә карап, минем күңел күккә менә.* Ә.Баян. **Күңел күпере** Хәтер, зиһен. *Өенә кайтканда, күңел күпере аша бик күп авылдашларын уздырып чыкты ул.* Ф.Яруллин. **Күңел күтәрелү** Кәеф яхшыру; шатлану. *Зөбәйдә әби белән шулай сөйләшеп утыргач, мин бөтенләй тынычланам. Күңелем күтәрелә.* Ф.Яруллин. *Кәбирнең үзеннән-үзе күңеле күтәрелде, бөтен тәненә нindидер бер талгын дулкын җәелде ---.* Х.Сафина. *Егетләрнең дә күңелләре күтәрелде, Җамали абзый дип кенә торалар.* И.Гази. **Күңел күтәренкелеге** Яхшы кәеф, күтәренке рух. *Экрандагы күңел күтәренкелеге ак халатлы ике кызга да акрынлап күчә барды.* Г.Әдһәм. *Гает көнне --- күңел күтәренкелеге аеруча сизелеп тора ---.* Г.Әпсәләмов. **Күңел күтәрмәү** Риза булмау; каршы килү. *Шәһәргә килгәч, берәр тәмле нәрсә ашамый китүне күңел күтәрә алмады.* М.Гафури. **Күңел кыбырсу** Җилкенү, ашкыну. *Получка кесәмә керү белән, күңел кыбырсый да башлады.* М.Юныс. **Күңел кызыгу** Теләк уяну; кызыксыну барлыкка килү. *[Илнең] һәр почмагын аерым-аерым Күрер өчен күңел кызыга.* М.Гафури. **Күңел кыйналу** Җан әрнү, газап хисе кичерү, борчылу. *[Гафиятулла:] Кеше аркылы ишеткән сүзгә күңел кыйнала. Колактан кергән салкын сүз йөрәккә барып җиткәнче боз була.* Г.Әпсәләмов. **Күңел кыллары** *шигъ.* Кешенең хисләре, эчке дөньясы. *Мин җаным-тәнем белән синең дә миңа битараф түгеллегеңне, күңелеңнең ниндидер кыллары минем күңел кылларына килеп тоташканлыгын --- тоюдан рәхәтлек кичереп кайттым.* Ф.Яруллин. *[Ирек:] Минем күңел кылларында кабат бер генә былбыл да сайрамаячак!..* Ф.Садриев. *Абыстаемнан качып кына күңел кылларыңа үзем чиертермен, яме?* Н.Гыйматдинова. **Күңел кымырҗау** Борчылу, тынычсызлану. *Иреккә чыкканнан бирле ел буе күрешмәгән Чуртанны шәраблар белән тулы өстәл янында күрүгә, Соседкинның күңеле кымырҗап китте.* М.Насыйбуллин. **Күңел кымыржу** *к.* **күңел кымырҗау**. *Бу кеше янәшәсендә чакта аның күңеле кымырҗып, әллә нинди ләззәтле тойгылар кичерә иде.* Ф.Садриев. **Күңел кырылу** Кәеф китү, тынычлык бозылу. *Бу барысы өчен дә куанычлы хәбәр иде. Шулай да кызны күрә алмавына Фаязның күңеле кырылды ---.* С.Шәмси. **Күңел кыршавы бушану** *к.* **күңел бушау**. *Һәм менә иренең сүзләре, әкренләп, күңелнең кыршавын бушандыргандай итте, алгысытып җибәрде.* М.Маликова. **Күңел кыткылдау** *к.* **күңел кытыклану**. *– Киттек! – диде очрашу шатлыгыннан күңеле кыткылдый башлаган Юра.* Ф.Вәлиәхмәтов. **Күңел кытыклану** Әсәрләнү, нинди дә булса эш-хәрәкәтне тизрәк башкарасы килү, нәрсәгәдер ашкыну. *Гөлбикә белән Гөлмәрьямнең дә адымнары җиңел, --- йөрәкләр беренче тапкыр*

*дөп-дөп тибә, күңел кытыклана, гел көләсе килеп тора.* А.Гыйләҗев. *Болындагылар аның тавышын ерактан ук ишеткәннәр; йөзләрендә елмаю балкыган, күңелләре кытыклана башлаган.* Э.Касыймов. *Болай булгач чикми булмый артка таба, Йөрәк яна, күңел һаман кытыклана.* М.Гафури. **Күңелләр якынаю** Мәхәббәт, ярату хисе туу. *Яшен белән яшен кисешкән кебек, бу карашлар ике йөрәкне тоташтырырга өлгерде. Күңелләр якынайды.* Ф.Яруллин. **Күңелне аздыру** Нәрсәнеңдер бозык уй-фикерләргә этәрүе. *[Ләлә:] Әгәр бу йөрешегез күңелемне аздырырга маташу булса, туры гына чыгып китүегез тиешлекне белдерәм.* М.Фәйзи. *Сабит тавышсыз гына Самвел белән Гургенны каргарга кереште: «Әйтмәгән килеш монда да табын хәстәрләгәннәр. Кеше котыртып ---. Күңелне аздырып! Кунак ханымның килен икәнен беләләр ич! Ахмаклар!»* А.Гыйләҗев. **Күңелне актару** 1) Узганнардан кайбер вакыйгаларны искә төшереп, хәтер барлау; 2) Серен белергә тырышу. *[Габдулла:] Мин сиңа ышанмыйм. Син, нәрсәнедер төшендем дигән булып, минем күңелне актарырга кергәнсеңдер.* Ф.Яруллин; 3) Борчу, тынгысызлау. *Капка ярыгыннан моны карап калган хатын-кыз елап ала, күңелнең әллә кай төшләрен актарып ташлый бу тавыш.* М.Мәһдиев. *Ә инде бераз олыгаеп, яшең кырыкларга якынлашып килгәндә, үзгәңне өздереп, күңелләреңне актарып, милли каның уяна башлар ---.* Мәдәни җомга. **Күңелне алгысыту** Җилкендерү, ашкындыру, дәртләндерү. *Кыз шат, иртәгә юлга чыгасы – аны бөтенләй күрмәгән-белмәгән дөнья көтә. Шул аның күңелен алгысыта.* Р.Зәйдулла. *Мидхәт шул Ленизасына өйләнеп куйса, безнең өчен хәерлегә булыр мөгаен. Күзгә-башка чалынып йөрмәс, ныклап аягына басарга өлгермәгән кыз баланың күңелен алгысытмас ичмаса!* М.Маликова. **Күңелне аулау** Кемне дә булса үзенә гашыйк итәргә, үзенә каратырга тырышу. *[Нәгыймә:] Шәмси миңа исле сабыннар җибәрткән иде, кибетче Хәйбулла улы кәнфитләр китерткән иде. Имеш, шуның белән минем күңелемне аулыйлар.* Г.Ибраһимов. *[Гөлчирә:] Сорама, җиңги, тасма телләре белән күңелемне аулады.* Т.Гыйззәт. **Күңелне ачу** 1) *к.* **күңелен ачу**. *Уен-көлке белән күңелне ачарбыз.* М.Җәлил; 2) *к.* **күңелен бушату**. *– Кил, – дип инәлеп чакырып калды Галия. – Сиңа күңелемне ачар идем бер.* Н.Гыйматдинова. **Күңелне ашкындыру** *к.* **күңелне дәртләндерү**. *Аныкы шикелле, минем йөрәгемне кытыклый торган сын, аныкы шикелле, минем күңелемне ашкындыра торган адымнар җир йөзендә Алядан башка кемдә булырга мөмкин!* Ф.Әмирхан. **Күңелне әрнетү** Ачындыру, канәгатьсезлек уяту, авыр хисләр тудыру; бик авыр тәэсир итү. *Ә менә Казанда туып үскән Баталовның онытылуы күңелне әрнетә.* Ш.Рәкыйпов. *Бу уй Әлифәнең күңелен әрнетте дә әрнетте.* М.Маликова. **Күңелне әсир итү** Үзенә карату, гашыйк итү. *Яшь, сылу кызларның күңелләрен әсир итү өчен вакытын да, акчасын да кызганмаган егеткә бүгенге очрашу да гадәти булып күренде.* Х.Ибраһим. *Яшь артистларның бик мәзәк киемнәре, уены тамашачыларның күңелен әсир итте.* Җ.Тәрҗеман. **Күңелне басу** Тынычландыру, юату. *Хуҗа дарыгильзаларын диванга җәеп салган. – Күңел басар өчен генә кыландырам шунда, – дигән булды ул.* С.Шәрипов. *Хәйри күңелен басар өчен агач бакчасына чыкты ---.* Ф.Садриев. *Шулай уйлаган иде ул, шул рәвешле үч алып, күңелен басарга теләгән иде.* М.Маликова. *Ничек кенә итеп түпәләсәң дә, ничек кенә итеп кырсаң да, каһәрләнгән бу дошманнан күңелне басарлык итеп үч алынмас кебек.* Ф.Кәрим. **Күңелне беркетү** Уртак фикергә килү. --- *мунча алар өчен юыну, чабыну урыны гына түгел, икесе ике җирдә хезмәт кылалар, теләгән минутларда гел-гел очрашып булмый, ә мунча – аларның сер алыша торган, планнарны барлап, күңелләрне беркетеп куя торган яшерен эш булмәсе дә.* А.Гыйләҗев. **Күңелне бииздерү** Берәр нәрсә туйдыру, биздерү; күңелне кайтару, яратмаслык итү. *Талиповны һич аңлый алмадым. Бригадирлар, белгечләр берәр эшлекле тәкъдим кертсә, асылына төшмичә ачуланып ташлый, кешенең күңелен биздерә иде.* Р.Айзатуллин. *Күңелне биздереп бетергән бу свитер, мех итекләр киеп күпме йөрергә мөмкин!* А.Мифтахетдинов. **Күңелне бикләү** Төшенкелеккә бирелү, беркем белән дә аралашасы килмәү. *Яраткан кешем үлде минем. Бөтен тормышыма кара пәрдә ябып, күңелемнең ишек-тәрәзәләрен бикләп китте ул.* Н.Гыйматдинова. **Күңелне белү** *к.* **күңелгә (кереп) утыру**. *Сүз, ни өчендер, күңелләрен белгән, көн дәвамында икесе дә кабат-кабат әйләнеп кайткан нәрсәләргә күчә алмады.* С.Шәмси. *Егет озак икеләнеп тормады, --- кайбер нәрсәләрне Әминевнең үзеннән сорап ачыкларга һәм, --- шуларга таянып, күңелен белгән һәлакәтне яңабаштан тикшерү өчен рөхсәт сорарга тели иде ул.* Т.Әйди. *Айсылу аның бөтен йөрәген, күңелен белэп алды, бу хис шундый көчле: егет үзен исереп киткәндәй тойды.* Р.Хәбибуллина. **Күңелне бимазалау** Нәрсә дә булса борчу, тынычсызлау. *Күңелең бимазалый башласа, тагын менеп утыр идең вакыт поездына.* Р.Вәлиев. *Эшкә китәр алдыннан, Флүр Сәхбиевич Гөлмирәнең соңгы хатын китап киштәсеннән алып укыды да, күңелен бимазалап тормасын --- өчен, аны ерткалап ташлады.* Р.Кәрами. **Күңелне бозу** Кәефне җибәрү. *Бала күңелен бозып, шул яшендә ташлап китәргә булгач, кулыңа күтәреп аласы да юк иде!* К.Тимбикова. **Күңелне боектыру** *к.* **күңелне төшерү**. *Шулай да аның идарәдә булмавы Нургалинең күңелен шактый боектырып җибәрде.* Ә.Еники. **Күңелне болгандыру** Ачуны китерү, начар тәэсир ясау. **Күңелне болгату** *к.* **күңелне болгандыру**. *Ике шәрә гәүдәнең салам өстендә... әүмәкләшүе күңелен болгатты.* Н.Гыйматдинова. **Күңелне болыт каплау** Кәеф бозылу, башка күңелсез уйлар килү. *Ләкин күңелне салынкы болыт каплаган, яңгыр тиз генә үтәр сыман күренми, ә җан бу йорттан ераклашырга ашкына иде.* М.Маликова. **Күңелне борчу** Нәрсәнеңдер уйдан-истән чыкмыйча бимазалап торуы. **Күңелне борчу алу**

*к.* **күңелне борчу**. *Касыймның иртәдән бирле бер валчык капканы юк иде, шулай да тамагыннан ризык үтмәде. --- күңелен борчу алган иде аның.* Х.Сафина. **Күңелне дәртләндерү** Ниндидер сәбәптән рухның күтәрелеп китүе. *Ялкын өсти кайнар йөрәккә бу [медаль], Дәртләндерә һаман күңелне.* З.Мансур. **Күңелне җәлеп итү** *к.* **күңелне тарту**. *[Ильяс:] Класста укыган чагында ук күңелемне җәлеп иткән ул малайга бәхетләр теләүче дус мин.* М.Фәйзи. **Күңелне җилкендерү** 1) Дәртләндерү, рухландыру. *Ул исләр, борынны рәхәт кытыклап кына калмыйча, эчкә, тәннең бөтен күзәнәкләренә үтеп кереп, күңелләрне җилкендерә.* В.Нуруллин. *Рылеевның колактан колакка йөреп күңелләрне җилкендергән атаклы шигыре хәтергә төште ---.* Җ.Тәрҗеман; 2) Җылы хисләр уяту, якты өмет тудыру. **Күңелне җилкетү** *к.* **күңелне җилкендерү**. *Кояшның беренче нурлары белән һавага күтәрелгән сабан тургаеның чишмә суыдай челтерәп аккан җыры күңелләрне җилкетә.* И.Гази. *Үзенең арзанлы ситса күлмәге, йомшак-ягымлы карашы, татар кызларына хас мөлаем-сабыр тыйнаклыгы белән ул Сабитның күңелен җилкетеп алды.* А.Гыйләҗев. **Күңелне җилсендерү** *к.* **күңелне җилкендерү**. *Шыксыз, моңсу көз болуга карамастан, бүген көн җылы һәм кояшлы, шуның өстенә әле җанны иркәләп, күңелләрне җилсендереп, чиксез хыялый киңлекләргә чакыра сыман.* Х.Ибраһим. **Күңелне җиңеләйтү** Авыр уйларны тарату. *Җамал әбисенең аны бүлдермичә генә тыңлавы, аны хуплаган сыман ияк кагып куюлары Тәнзиләнең күңелен җиңеләйтеп җибәрде.* А.Гыйләҗев. **Күңелне җирсетү** Ымсындыру, өметләндерү. *Ризыкка язмаган икән бу алмалар, күңелне җирсетеп, авызга су китереп аллана башланганда гына, --- бала-чагалар җыйнаулашып килгәннәр дә әнисләрнең сыңарын да калдырмыйча ашап бетергәннәр.* А.Гыйләҗев. **Күңелне җылыту** *к.* **күңелне эретү**. *Көтмәгәндә, --- Зөлфия: «Әт-ти!» – дип кычкырды. Бу тавыш Ринатның суына башлаган күңелен бердәм җылытып, рәхәтләндереп җибәрде.* Н.Хәсәнов. *Хәленнән килсә, ул аны хәзер кысып кочаклар да каткан күңелен җылытыр, тынычландырыр, юатыр иде.* З.Кадыйрова. *Хатыныннан мине якынрак күрүе күңелне тагын җылыта кебек.* Ә.Баян. **Күңелне изрәтү** *к.* **күңелне йомшарту**. *Түр яктан агылып чыккан җыр моңы Ихтыярның да күңелен изрәткән иде ---.* Р.Вәлиев. **Күңелне изү** Ниндидер авыр уй-хисләрнең җанны борчып, җәфалап торуы. *Әлегә янәшә басып торсалар да, аерылу авырлыгы күңелне изә башлаган, ләкин үзләре моны сиздермәскә тырышалар, күтәренке тавыш белән шаярышалар иде.* М.Маликова. **Күңелне иләсләндерү** *к.* **күңелне кузгату**. *Сылуның көлүе дә башка кызларныкына охшамаган: колакны иркәли, күңелне иләсләндерә.* Г.Әдһәм. **Күңелне иләс-миләс китерү** *к.* **күңелне кузгату**. *[Солдатлар], --- мостовой ташларына гөрс-гөрс басып, кулларын киң селтәп, дәртле җыр белән кешеләрнең күңелләрен иләс-миләс китереп, Кремльгә таба узып киттеләр.* И.Гази. **Күңелне имрәтү** Тынычландыру. *Бигрәк тә җирән бияне алырга тотылган егерме биш сум турында ләм-мим дип сүз кузгатмавы Ишмайны тагын шатландырды, аның күңелен имрәтеп җибәрде.* Ш.Камал. **Күңелне йомшарту** 1) Җылы хис уяту, дулкынландыру. *Әйе, аның тавышында, кыяфәтендә күңелне йомшарта торган ниндидер бер көч бар иде.* М.Маликова. *Энесенең кучтәнәчләре бөтенләй аның күңелен йомшартып җибәрде.* З.Фәйзи; 2) Ачуны басу, бәхилләү хисе уяту. *Бу бүләкләр белән картның рәнҗүле күңелен йомшартырга, туй арасында тавыш чыгармау җаен карарга теләде.* Г.Ибраһимов. **Күңелне йомшату** *к.* **күңелне йомшарту**. **Күңелне кайтару** Гайрәтне чигерү; кәефне бозу. *Аның мине үбүләре күңелне кайтара иде.* Х.Камалов. *[Хөрмәтулла:] Бүген дә үзе белән сөйләшергә дип сүз башлаган идем, күңелне кайтарды.* Т.Гыйззәт. **Күңелне калдыру** Үпкәләтү, рәнҗетү, хәтерне калдыру. *[Җәмилә:] Алай олы кешенең күңелен калдырмыйлар аны.* Г.Камал. **Күңелне канатландыру** Дәртләндерү, илһамландыру. *Шатлык күңелне канатландыра.* **Күңелне каралту** Берәр кеше хакында нахак яки начар сүз тарату. *Кем аңа минем күңелемне каралтып, әшәке итеп күрсәткән?!* Н.Гыйматдинова. **Күңелне (корт) кимерү** Җанны нәрсәдер борчып тору. *Тик алай булып чыкмады, озакка бармады ул тынычлык, Фаязның күңелен кабат төрле уйлар, шик-шөбһәләр кимерә башлады ---.* С.Шәмси. *Чәчәргә җир җитмәде, сеңелем. Орлык артып калды. Күңелне корт кимерә. Язы нинди бит!..* Х.Сафина. *Күңелеңне корт кимерә башласа, ай-һай, Билалов, күпкә чыдарсыңмы?* С.Шәрипов. **Күңелне китү** Нәрсәнеңдер яки кемнеңдер ризасызлык хисе уятуы. *Булачак киленне күргәч тә ошаттым. --- Тик кодалар гына бераз күңелне китте.* М.Кәрим. *Син беркемгә дә зыян салмадың, беркемнең күңелен китмәдең.* М.Маликова. *Ә мин аның күңелен китәм, аның өлешен эчәм, үз баламның бәхетен урлап эчәм.* Г.Мөхәммәтшин. **Күңелне корыту** Уй-хисләрне юк итү; хиссез, ваемсызга әйләндерү. *Җәүдәт, ичмасам, син дөньяга кырылып йөрмә, нәфрәт җүнле хис түгел, ул күңелне корыта.* Н.Гыйматдинова. **Күңелне котырту** *к.* **күңелне ымсындыру**. *Тик миңа яман эшнең әллә нинди караңгы, маҗаралы ягы күңелемне котыртты.* Ф.Яруллин. **Күңелне көйдерү** *к.* **күңелне өтү**. *Вагон эчендә җырны икенче бер кыз күтәреп алды ---. Кинәт кенә Ихтыярның күңелен ут көйдереп алгандай булды.* Р.Вәлиев. **Күңелне кузгату** Кешедә берәр уй-теләк уяту; берәр төрле хис барлыкка китерү. *«Яз җиткәч, каен түмәреннән су тама!» дип арттырса да, бүтән җәһәттә картның уйлары күңелне кузгатырлык иде.* А.Гыйләҗев. *Картина сугыш беткән чорга багышланган иде: басу юлыннан пилотка, гимнастёрка, кирза итекләр кигән берничә ир-ат килә, авылдан аларга каршы бала-чага, хатын-кыз йөгерә. Ничектер, күңелне кузгатты бу күренеш.* М.Маликова. *Мәдинә апа башын Сафуан абыйның иңенә куеп елый башлады. – Күңелемне кузгаттың да... китеп бардың...* М.Галиев.

**Күңелне куркыту** Курку хисе барлыкка китерү. *Әллә кайдан һичвзлексез ишетелеп торган мылтык тавышы, бер әкренәеп, бер куәтләнеп, куркынган күңелне тагын да ныграк куркыта.* Ш.Усманов. **Күңелне күрү** *к.* **күңелен күрү**. **Күңелне күтәрү** *к.* **күңелне күрү**. *Абыйсы Баязит, утыз биш яшьләрендәге җор табигатьле, шаян сүзле кеше, алар йортына кайтса, баш өстенә җыелган болытларны таратып, күңелләрне күтәреп китә.* Ш.Максудова. **Күңелне табу** *к.* **күңелен күрү**. **Күңелне кыйнау** Җанны газаплау. *Бу хакта уйлау Сөембикәнең күңелен кыйнады, җанын әрнетте, аның үзен төн йокысыз итте.* Н.Акмал. **Күңелне кымырҗыту** Беркадәр борчу уяту, беразуйландыру. *Һәркемнең күңелен кымырҗытып торган нәрсәләрне күзгатып җибәрергә шул җитә калды.* М.Шабай. **Күңелне кыру** *к.* **күңелне бозу**. *Шушы көнгә хәтле егеттә күңелен кырган бер генә сыйфат та күргәне юк әле аның.* С.Шәмси. *Нәҗипнең баядан бирле күңелен кырып торган шиге көчәйде.* А.Гыйләҗев. *Фәкать Гадилнең күңелен артык кырырга ярамаганын аңлап кына, кычкырып елаудан тыела ---.* М.Маликова. **Күңелне кытыкландыру** *к.* **күңелне кытыклау**. **Күңелне кытыклау** Тәэсирләндерү, әсәрләндерү, җиңелчә ярсыту; берәр хис уяту. *«Берәр бәндә, чүлмәккә салып, алтын-көмеш күмеп куймадымы икән» дигән уй аның күңелен кытыклап куйды.* Н.Дәүли. *«Икәүдән-икәү генә калгач ни булыр?..» кебек сораулар, күңелне кытыклап, уйны бөтенләй башка юнәлешкә алып китте.* К.Тимбикова. *Бабасы тагын сугышның икенче вакыйгаларына кереп китмәкче иде, тик Хәмзә баядан бирле күңелен кытыклап торган сорауны бир[де] ---.* Ф.Яруллин; 2) Борчу, тынычсызлау. *--- Әхәтов: «Осталар нишләтергә белерләр, кайгырма, өең имән бармагы күк булыр», – дип, Абдулланы тынычландырып үткән иде үтүен, алай да күңелне нидер кытыклый да тора иде...* Э.Касыймов. *Зөфәрнең --- артык түземлеге калмады, пышылдап, күңелен кытыклап торган сорауны бирде ---.* Ә.Галиев. *Сөенчалинның ул хакта ишеткәне юк иде, үзенең наданлыгын белдертәсе килмәде, шулай да беләсе килү аның күңелен кытыклады.* Х.Камалов. **Күңелне моңландыру** Моңсу хис уяту, сагышландыру. *Бу күренеш аның күңелен моңландыра.* Ш.Камал. **Күңелне нечкәртү** *к.* **күңелне йомшарту**. *Бөек Иделнең киң күкрәге белән озак-озак итеп тын алуы, ничектер, күңелне нечкәртә, таң нурыдай якты уйлар туа иде.* Г.Бәширов. *Скрипка кылын чиртеп алгач та шулай була: ялгыз аваз, йөрәгеңә үтеп кереп, кинәт күңелне нечкәртеп җибәрә ---.* С.Шәмси. **Күңелне ныгыту** *к.* **күңел(гә) беркетү**. *Иртәгәсен дәү әни көне буе үзенең күңелен ныгытты, дәү әти аның янында басып торган кук сөйләнде.* В.Астафьев. **Күңелнең иң нечкә кыллары** *шигъ.* Иң тирән хисләр турында. *Нәфисәнең дәртле җыры, яшь мәхәббәтнең иркә һәм тирән тойгыларыдай, күңелләрнең иң нечкә кылларын чиертәчиертә, зал эчендә тибрәнә башлады.* Г.Бәширов. **Күңелнең кәгъбәсе** 1) Яраткан, гашыйк булган, мәхәббәт төшкән, сөйгән кеше. *[Мавия:] Син кызлар күңеленең кәгъбәсе икәнеңне белмисең. Син сөймәсәң дә, кызлар сине сөя.* М.Фәйзи; 2) Кемнең дә булса уйхисләрен тарткан нәрсә. *Башкала – күңелемнең кәгъбәсе.* **Күңелне очындыру** *к.* **күңелне дәртләндерү**. *Бөтен шушы чуар күренеш Гафиятнең күңелен тагын очындырып җибәрде: «Бөтен ил белән кузгалдык, хәерле сәгатьтә булсын!» – дип уйлады ул.* И.Гази. **Күңелне өзү** Җанны бимазалау. *Шәһәрчекнең кайсы почмагындадыр бер эт җанны талап улый да улый, шомлы тавышы белән күңелне өзеп-өзеп ала.* Х.Камалов. **Күңелне өтү** Тетрәндерү. *Күңелен өтеп алган уйлардан котылу өчен, Гөлчирә --- җитен көлтәләрен ---, суга кереп, берәм-берәм ярга чыгара башлады.* Х.Сафина. **Күңелне өшетү** Хиссезләндерү, дәртсезләндерү. *--- картаю галәмәте һәркемгә төрлечә, һәркемгә үзенчә генә килә. Я сиздерми килә, я кинәт сиздереп, күңелне өшетеп, бәгырьне суытып та куя.* А.Гыйләҗев. **Күңелне пакьләндерү** *к.* **күңелне сафландыру**. **Күңелне песиләр тырнау** Көнчелек уяну. *Күңелне песиләр тырный башлады. Бу ничек була инде? Минем бер ымлавым кыз-кыркын халкын шаштыра торган иде бит.* Г.Мөхәммәтшин. **Күңелне рәнҗетү** Үпкәләтү; хәтер калдыру. *Бәхетем, диме? Ни сөйли инде тагы?! Нигәдер бу сүзләр күңелне рәнҗетми бит әле...* Н.Гыйматдинова. **Күңелне рәхәтләндерү** Канәгатьлек хисе уяту, яхшы тәэсир итү. *Дымлы кара туфрак, күңелне рәхәтләндереп, тәмле ис аңкытып, актарыла башлады.* И.Гази. **Күңелне сагыш биләү** *к.* **күңелне сагыш урау**. *Шуннан соң көнозын кулы эшкә ятмады, күңелен моңсу бер сагыш биләде.* Х.Сафина. **Күңелне сагыш урау** Кемне яки нәрсәне дә булса сагынудан, юксынудан моңаю, сагышлану, җан әрнү. *Ә моннан берничә ел элек хатыны үлде, ятим калган картның күңелен сагыш урады...* Х.Сафина. **Күңелне саклау** Үпкәләтмәскә тырышу, хәтерне саклау. *[Зәйнәп:] Ашасаң, безнең өйдә сүз әйтүче юк та, ана-кайның күңелен саклап, без инде ашамыйбыз.* Ф.Әмирхан. **Күңелне сафландыру** Авыр уй-хисләрдән арыну; әхлакый сафлыкка ирешү. *Дуслык кешенең күңелен сафландыра, димәк, ул кешенең барлык башка хисләрен нәфисли.* Г.Әпсәләмов. **Күңелне сафлау** *к.* **күңелне сафландыру**. *Тап вә кердән, пычранудан бу күңелне сафлый ул [вөҗдан].* М.Гафури. **Күңелне селкетү** Әсәрләндерү, тәэсирләндерү; көчле хисләр, тойгылар уяту. *Утыз җиденче еллар кышындамы, авылга колхоз-совхоз театры дигән игелекле коллективлар килеп, әллә нинди хикмәтле пьесалар куеп, халык күңелен дер селкетеп киткәләделәр.* М.Мәһдиев. **Күңелне сихәтләндерү** Кайгылы, борчулы уйларны бетерү, юкка чыгару; җанны тынычландыру. *[Газизнең киемнәрен] сыйпаштыру гына да ана кешенең сагыну һәм юксынудан яраланып беткән күңелен сихәтләндереп җибәрә иде.* Г.Бәширов. **Күңелне соры томан басу** Аңлаешсызлык, билгесезлек халәте биләп алу. *Өстәвенә, чыннан да узган төнне аның күзенә йокы кермәгән, шун-*

*лыктан ул тәмам миңгерәүләнгән, күңелен соры томан басып алган иде...* Э.Касыймов. **Күңелне суындыру** Кемнәндер яки нәрсәдәндер бизү; өметне өзү. *Әни кеше аны әче балдан өзмәде, күңелен суындырмады.* Р.Айзатуллин. **Күңелне суыту** *к.* **күңелне суындыру**. *– Ай, күз нурым, укыган өчен түләргә кирәк. Кайдан акча табарбыз? – диде әнисе. Вәли шулай да күңелен суытмады.* Инешләр Иделгә кушыла. **Күңелне сүрелдерү** *к.* **күңелне суындыру**. *Әгәр Урманцевны якыннан белсә, гаепкыегын табар, Тәбриянең күңелен сүрелдерергә тырышыр иде ---.* М.Маликова. **Күңелне сызлату** Борчу, тынычсызлау; авыр хисләр, сагыш уяту. *Аның --- күптән күңелен сызлаткан, «их, шушыларны әйтергә!» дип йөргән фикерләре күп иде.* Ф.Садриев. *Өстемдә кара тап булып, күңелемне сызлатып торган теге шелтәдән котылырга да өлгермәдем, аннан да яманрак хәлгә дучар булдым.* В.Нуруллин. **Күңелне сыкрату** Җанны әрнетү; борчылдыру. *--- төзелеш тавышына кушылып, күңелләрне сыкратып, күрше бүлмәдән моңлы җыр агыла да агыла...* Р.Вәлиев. **Күңелне сындыру** Үпкәләтү, рәнҗетү; хәтерне калдыру. *[Байтүрә:] Картны рәнҗеткән, күңелен сындырган чагым аз [булмады].* Г.Ибраһимов. *Ирекнең инде монда яңа дуслары бар, ул аны юри генә, күңелен сындырмас өчен, кыенсынганнан гына чакыргандыр кебек тоелды.* Ф.Садриев. **Күңелне таптау** Рәнҗетү, якты хисләрне сүндерү. *Хыянәт шул рәвешле килә микәнни ул? Дөньяны караңгылыкка чумырып, күңелне таптап...* Н.Гыйматдинова. **Күңелне тарту** Игътибарны җәлеп итү, кызыксыну уяту, кызыксындыру. *Мохтар бу малайда күңелне үзенә тартырлык һичбер хасият тапмый.* Ш.Камал. **Күңелне ташыту** Әрнү-ярсуларның тышка бәреп чыгуына сәбәпче булу. *Шушы соңгы сүз Фирдиянең күңелен ташытты, йөрәгенә пычак булып кадалды.* Р.Кәрами. *Бер үк вакытта Гөлгенә бу сүзләре белән Хәлимнең тулган күңелен ташытты.* Г.Гобәй. **Күңелне тәртипкә салу** Үз хисләрең, тойгыларыңны аңларга тырышу; үз-үзеңне кулга алу. *Аның зәгыйфь акылы шулай итеп күңелен тәртипкә салырга тырыша.* Р.Вәлиев. **Күңелне телгәләү** *к.* **күңелне телү**. *Кайгыдан ераклашырга тырышып, Канаштан Арчага кучкач тә, инде моңа җиде ай вакыт узса да, шушысы кинәт кенә күз алдына килә дә күңелне телгәли.* Ирек мәйданы. **Күңелне телү** Бик нык борчу. **Күңелне тетрәтү** Хисләргә бик нык тәэсир итү; бик нык дулкынландыру. *Тар окопта киң сулышлы, күңелләрне тетрәтерлек, нәфис үрелгән, халыкчан гади җырлар туа.* И.Юзеев. *--- кешеләргә рәнҗемичә генә, инде аргы яктагы агачлыкка сәфәр кылырга күңеленнән әзерләнгән Нөзһәт җиңгинең күңелен тагын бер тапкыр тетрәтеп алдылар.* М.Мәһдиев. **Күңелне тибрәтү** *шигъ.* Дулкынландыру; рухландыру. *Бу сүзләр солдатларның күңелләрен шундый бер гаҗәп көч белән тибрәтеп җибәрделәр.* К.Нәҗми. **Күңелне төшенкеләндерү** *к.* **күңелне төшерү**. **Күңелне төшерү** 1) Өметсезләндерү; моңсуландыру, сагышландыру; 2) Моңсулану, күңелсезләнү. *Тәбриянең сораулы карашыннан башын иеп: «Мин бүген килә алмасам, күңелеңне төшермә», – дип өстәде.* М.Маликова. *– Күңелеңне төшермә, – диде Мирсәет, аның күзләренә туры текәлеп. – Казандагы иптәшләрдән дә уңайсызланма, аңларлар...* Р.Мөхәммәдиев. **Күңелне тутыру** 1) *к.* **күңелне йомшарту**. *Аның күзләрендә елтырый башлаган яшьләре минем дә күңелемне тутырдылар, бугазыма яшь тыгылды.* Ф.Әмирхан; 2) Нинди дә булса хис-тойгы биләп алу. *Яткач та бик арыган кешенең йомшак һәм уңайлы урынга сузылганда хис итә торган бер рәхәтлек тойгысы аның күңелен тутырды.* Ш.Камал. **Күңелне тынычландыру** Эчтәге борчуларны юкка чыгару. *[Гарәфи:] Күңелне тынычландырыр өчен чыгып утырдым әле.* Г.Әпсәләмов. **Күңелне тырнау** Борчылу хисе уяту, борчу. *– Анысы минеке, – диде Хәнәфи теш арасыннан. Егетләргә аның рәсеме ошамаганы сизелә, бу аның күңелен тырный иде.* М.Маликова. *– Ләкин, үзең чамалыйсыңдыр, кызлар гыйшкын кире каккан-ны гафу итә алмыйлар, – дип, Сәгъди абзый күңелен тырнап торган фикерен әйтми кала алмады.* Г.Галиева. *Өйләнешәбез дә, еллар буе күңелне тырнап килгән мәхәббәт газапларыннан арынып, калган гомерне тыныч, бәхетле үткәрәчәкбез.* Р.Айзатуллин. **Күңелне укшыту** Гайрәтне чигерү. *Бу ялвару күңелне укшыта иде.* Н.Гыйматдинова. **Күңелне урау** *к.* **күңелне чорнау**. *Ә аның җаны тыныч түгел, күңелен шик-шөбһә урап алган...* Р.Мөхәммәдиев. **Күңелне утырту** Төп карарга килү, үз-үзеңне җиңү. *Ә Наилә Хәбировна сүзен дәвам итте: – Башта күңеле тартмыйча, соңыннан бу эштән аерыла алмаган күпме кызларны беләм мин. --- Менә шул: юләрләнеп йөрмә, күңелеңне утырт та эшкә тотын.* А.Вергазов. *Әмма колхоз төзелгәч, күмәк эшкә күңелен утыртып җиткерә алмый.* Ф.Галимуллин. **Күңелне уяту** *к.* **күңелне кузгату**. *Аның күңелен уятасы, күңелен музыка тыңлар өчен әзерлисе килә иде Искәндәрнең.* Р.Вәлиев. **Күңелне үртәү** Җанга тию, ачуны китерү. *Җырның моңы, сүзләре генә түгел, ә шофёр егетнең --- артык кычкырып җырлавы җанына барып кагыла, болай да тынычсыз күңелен үрти иде.* Р.Вәлиев. **Күңелне үстерү** Нинди дә булса эш-хәрәкәткә дәртләндерү; рухландыру. *Торган саен киңрәк җәелә барган революцион хәрәкәттә подпольечыларның аңа да ныклап таяна башлаулары Гордовның күңелен үстереп җибәрде ---.* Ш.Рәкыйпов. *Бүләкләрне биреп кенә торалар, значоклары да калмый. --- Анысы ярый, күңелне үстерә белгәч.* Н.Хәсәнов. **Күңелне хушландыру** Җанга ятышлы булу, кәефне күтәрү; көч өстәү. *– Чәеңнең хуш исе бөтен бүлмәгә таралды. --- Тик сүзләрең нинди булыр бит, безнең күңелне хушландырырмы, юкмы, – дип көлде Бәхтияров.* М.Насыйбуллин. *--- оның кисәгемне уттан коткарчы, я бер Аллам! Күзләренә нур иңдер, күңелләрен хушландыр.* Н.Гыйматдинова. **Күңелне чайпалдыру** *к.* **күңелне үртәү**. *Мәдинә карчыкның алдын-артын уйламыйча, турыдан бәреп әйтелгән сүзләре Зөләйха апайның болай да тулып ташырга*

*торган күңелен чайпалдырып җибәрде*. Г.Мөхәммәтшин. **Күңелне чемету** *к.* **күңелне кытыклау**. --- *бүгенге җыр, караңгы төндә тын далада яңгыраган җыр, --- күңелне чеметепчеметеп ала, сулык-сулык китерә иде*. Р.Вәлиев. *«Быел тагын су буенда корсак кыздырып, җәй буе ятар инде», – дигән уй күңелен чеметеп алды*. Ф.Яруллин. **Күңел нечкәрү** *к.* **күңел ташу**. *Бу минутта Нургалинең дә күңеле нечкәреп китте, ничектер, күзләре дымланды, тамак төбе кымырҗып куйды*. Ә.Еники. *– Рәхмәт инде, – диде күңеле нечкәргән Мидхәт*. М.Мликова. *Ул төнне искә төшерсә, Булат менә хәзер дә, күп еллардан соң да, әллә нишләп китә: күңеле нечкәрә, җанына сагышлы моң тула*. М.Вәли. **Күңелне чорнау** Ниндидер уй-хисләр биләп алу. *Мәңгелек алдында күпләрнең күңелен икеләнү, каушау чорный торган була*. А.Гыйләҗев. **Күңелне шаштыру** Бик көчле хисләрне уяту; җилкендерү. *«Мин бүген яшәмим әле, мин алга карыйм, сине дә үзем белән матур киләчәккә, беркем танымаган ләззәт дөньясына дәшәм!» – дип, күңелен шаштырган җан шушымы?* А.Гыйләҗев. **Күңелне шик кимерү** Шөбһәләнү, шомлану, икеләнү, җанны шик тырнап тору. *Гомердә булмаганны, Атилланың күңелен шик кимерә, дошманга ташланырга җөрьәт итми тора, икеләнә иде*. Р.Зәйдулла. **Күңелне шом басу** Шомлану, шөбһәләнү. *Рәшидә дөм караңгылыкта, тынлыкта калды. Күңелен шом басты*. М.Маликова. *– Саумы, агай? Хәлләр имин генәме? – дигән булдым. Күңелемне кинәт шом басты*. М.Кәрим. **Күңелне шомландыру** Нәрсәнеңдер куркытуы, шикләндерүе. *Аларның мәгърур кыяфәте Зәйтүнәнең күңелен шомландырып җибәрде: бу даһиларга тиңләшү – табиб булу – гади адәм баласы өчен мөмкин эш микән?* М.Маликова. **Күңелне ымсындыру** Игътибарны җәлеп итү, кызыктыру. *Гүзәл гөлләр үпкәләмәсен өчен, аларның башларыннан сыйпап китәсең. Әле тегесе, әле монысы күңелеңне ымсындыра*. Ф.Яруллин. *Нәфисә сиңа кияүгә чыкмас, безнең буш өебезгә килергә риза булмас ---. Кыз күңелен ымсындырып йөрмә*. Х.Сафина. *Ә еракта – күңелне ымсындырган урман-болыннар!* Н.Гыйматдинова. **Күңелне эретү** *к.* **күңелне йомшарту**. --- *Зәнфирәгә матур-матур тостлар да әйтелде, күмәк җырлар да җырланды, тик аларның берсе дә аның күңелен эретә алмады*. Ф.Садриев. *Фаязның балаларча сөенүе Рәмзиянең дә күңелен эретеп җибәрде*. С.Шәмси. *Узган ел безнең бәйрәмдә күңелне эретте карчыгым: миңа җылы башмаклар бүләк итте*. Шатлыклы кайгы. **Күңелне юату** Кайгы-сагышларны тарату, авыр кичерешләрне, уйларны оныттыру, кәефне күтәрү. *Бик тырыша, хәлфә биргән дәресләрне су кебек эчкәнче ятлый, шулай итеп күңелне юата идем*. М.Гафури. *Һәм иркәләп җылы сүзләр белән Ул Алсуның күңелен юатты*. М.Җәлил. *Ничек кенә күңелеңне юатырга тырышма, ялгыз, барыбер, ялгыз инде*. Р.Вәлиев. **Күңелне яктырту** Шатлык, канәгатьлек хисләре барлыкка китерү. *«Фатыйх мине чынлап та бик яратадыр ахры», – дигән уй күңелен яктыртып җибәрде*. Ф.Яруллин. *Гадилнең гап-гади сүзләре дә аның кичерешләрен бөтенләй үзгәртеп, күңелен яктыртып җибәрде*. М.Маликова. **Күңелне ярсыту** 1) Кешедә нинди дә булса хисләр уяту; теләк яки омтылыш барлыкка китерү. *Бик күпләрнең күңелләрен ярсыткан ул, Биегәндә, бәйрәмнәрнең күрке булып, Егетләрнең иң шәпләрен алҗыткан ул*. Ф.Бурнаш; 2) Борчылдыру, борчылу хисе уяту. *[Садыйк:] Янымда синең булмавың гына күңелне ярсыта*. Г.Ибраһимов. **Күңелне яулау** *к.* **күңелне әсир итү**. *Телефоннан сөйләшкәндә ук күңелемә үтә дә хуш килгән олпат рәссам-сынчы бу юлы үзенең бөтен торышы, күргән һәр кешене сокландырырлык матур саклануы белән күңелемне яулады*. Г.Галиева. *Константин Никифорович Куличенко Зөфәрнең күңелен бик тиз яулап алды*. Ә.Галиев. *[Ләйлә:] Тормышта, чынбарлыкта сәнгать – күз явын алырдай, күңелне яулардай ямьле ялган*. З.Хәким. **Күңел нурлану** Күңелендәге серләр, һәркемгә күренеп тормаган хисләр. *Юк, шәһәргә китсен, мине шунда күтеп торсын. Шулай диеп уйладым. Күңелем нурланып китте*. Ф.Яхин. **Күңел пәрдәсе** *к.* **күңел күге**. *Шашкын куышу башлаганчы, аз гына булса да аналарның күңел пәрдәсен күтәреп карыйк*. А.Гыйләҗев. **Күңел офыгы** Хисләр дөньясы, уйфикерләр колачы. *Сине күл буенда ялангач күргәндәге халәтнең бер очкыны гына да күңел офыгы өстеннән очып үтмәде*. Ф.Яруллин. **Күңел очыну** Дәртләнү, рухлану. *Бая гына очынган күңел кинәт кенә боеккан иде*. Н.Гыйматдинова. *Күңел дигәнең, күпме генә оялтма, һаман очына*. Н.Гыйматдинова. **Күңел өзгеч** Авыр кичерешләр тудыра торган. *Аһ, матур соң ул кояшның күңлем өзгеч моң чагы: Ул – оялчан кыз йөзедәй бер кызыл утнур шары*. Н.Исәнбәт. **Күңел өчен генә** Кемнең дә булса кәефен җибәрмәс өчен, кемне дә булса тынычландыру өчен. *Шунда ир, күңел өчен генә: – Кая җыендың соң, Вәсилә апасы? – дип сораса, --- сытылып-сытылып елар иде ул*. Н.Гыйматдинова. *Күңел өчен генә булса да, ник берсе очрап сәлам бирсен!* Җ.Дәрзаман. **Күңел өшеткеч** Авыр тәэсир итә торган. *[Шәрәфи картның] ялангач аяк үкчәләре арттан, әллә нишләп, бик килешсез һәм дә күңел өшеткеч булып күренә иделәр*. Ш.Камал. **Күңел өшү** *к.* **күңел туңу**. *Хәер, таза-сау кешегә тыштагы салкын салкынмыни ул? Күңелең өшемәгән булсын!..* Э.Касыймов. **Күңел почмагы** *к.* **күңел** (*2 мәгъ.*). *Әмма күңелемнең бер почмагында искә төшкән саен әрни-сызлый торган җәрәхәт уелып калды*. А.Тимергалин. *Күңеленең бер почмагында, җанын борчып, сөйгәне белән яңадан кавыша алуына шик туды ---*. Р.Хәбибуллина. **Күңел почмаклану** Канәгатьлек хисе туу; җан тынычлану. *Җаны саф кешегә бу дөньядан күңел гаебе белән китү авыр. Ул яктан да эше төгәлләнде Бибинурның, күңеле почмакланды*. А.Гыйләҗев. **Күңел пошаманга төшү** *к.* **күңел пошыну**. *Хатынның бит мускуллары тартышып куйды, күңеле пошаманга төште*. Р.Айзатуллин. **Күңел пошу** *к.* **күңел пошыну**. **Күңел пошыну**

Нәрсәнең дә булса җанны бимазалап, борчып торуы турында. *Күңел пошына, ашкына һәм гаҗәп тынычсызлана.* Ф.Әмирхан. **Күңел рәнҗү** Канәгатьсезлек хисе туу, үпкәләү. *Рәгыя җиңгәсенә дә, кылый күз картка да аның күңеле рәнҗеде.* Г.Ибраһимов. *[Шүрәле:] Минем күңелем рәнҗеде. Ә күңел ярасы төзәлми.* С.Яһүдин. **Күңел рәхәтләнү** Канәгатьлек хисе уяну; күңелне якты уйлар биләү. *Аның күңеле бик рәхәтләнеп китте: --- мәктәп белән бергә, бөтен авыл аңар караган, аны көтә, кирәксенәләр, бик кирәк, бик мөкатдәс нәрсә – яктылык, нур сорыйлар.* Ш.Камал. **Күңел сабагы** *иск.* Ятлый торган, күңелдән белергә тиешле бирем, сабак. *Кичке ястүдән соң хәзрәт мәдрәсәдә балаларның күңел сабагын тыңлатканда, Сәгыйдә остазбикә --- хәзрәт кайтуга мунча хәзерләп куя.* Г.Исхакый. **Күңел сабырсызлану** *к.* **күңел кыбырсу**. *Шул рәвешле, ике-өч көн үтте дигәндә, Һаҗәрнең бөтен сораулары ачыкланган, күңеле сабырсызланып Гарифны көтә иде инде.* К.Тимбикова. **Күңел савыты** Яшерен уйлар, хисләр саклап торган урын буларак күңел. *Бөтен хикмәт тыелуда шул: күңел савытындагы җенне чыгармау.* Ш.Галиев. **Күңел савыты ташу** *к.* **күңел ташу** (*2 мәгъ.*). *Чит-ятларга кем түгелә, ди. Күңел савытың ташыса да, дәшмә инде.* Н.Гыйматдинова. **Күңел салу** 1) Ярата, сөя башлау; ошату. *«А-ах, менә ничек! Бу сары чебеш тә күңелен Урманцевка салган икән бит!» – дип уйлады Камилә гаҗәпләнеп.* М.Маликова. *Унбиш-уналты яшендә мал-мөлкәтле гаиләләрдән яучылар килә башлый, ләкин кыз, төрле сәбәпләр табып, һәммәсен дә кире кагып тора. Чөнки аның күңел салган бүтән кешесе булган.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) *к.* **күңел кую**. *Бу исә Фәндиләгә бик ошый, ул, шунлыктан микән, эшкә бөтен күңелен сала ---.* Г.Ахунов. **Күңел сандыгы** *к.* **күңел савыты**. *Шул гомерләр күңел сандыгыңа бикләп йөрткән серләрең минем өчен хәзер сер түгел инде, улым.* Җ.Дәрзаман. *Утыра торгач, әби күңел сандыгын актара торды.* Д.Гайнетдинова. **Күңел сандыгына салу** Уй-хисләрне тирәнгә яшерү, эчке тойгыларны башкаларга сиздермәү. *Кунаклары алдында читенсенгән Валериан Леопольдович дәшмәде, түзде, күршесенең җикеренүләрен күңеленең кара сандыгына салып куйды.* А.Гыйләҗев. **Күңел сандыгын ачу** *к.* **күңел капкасын ачу**. *Ачасы иде ымсындырып торган шул күңел сандыгын.* Н.Гыйматдинова. **Күңел сафлану** Начар уй-хисләр юкка чыгу. *[Нәфисә:] Ничектер, күңелем тагын да сафланган, уйларым тагын да кыюлана төшкән кебек.* Г.Бәширов. *Авылдашларның да, азан тавышы ишетеп, күңеле сафланыр дигән идем ---.* Н.Гыйматдинова. **Күңел сафлыгы** Уй-хисләрнең садәлеге; эчкерсезлек. **Күңел серен ачу** *к.* **күңел капкасын ачу**. *Гайшә белән бөтен күңел серләрен ачып, ачыктан-ачык сөйләшә алса да, Габдуллаҗан янында ул бүгенге көнгә кадәр каушый, борчыла, ире яныннан бер чакта да күңелен бушатып китә алганы юк.* А.Гыйләҗев. **Күңел сөенү** *к.* **күңел шатлану**. *Әйтик әле, җырлыйк әле Баламишкин көенә; Күләгәләрен күрсәм дә Күңелләрем сөенә.* Җыр. *Шуны күреп эшчеләрнең, директорның күңеле сөенде.* М.Җәлил. **Күңел суыну** 1) Берәр нәрсәдән бизү, тәмам тую. *Безнең элек ярышларда катнашкан бер кыз бар, ләкин соңгы вакытта яхшы нәтиҗәләр күрсәтми. Әллә күңеле суынды, әллә олыгая башлады.* Р.Кәрами; 2) Яратмый башлау, сөйми башлау. *Болай да иләс-миләсрәк күңеле Равилдән мәңгегә суыначак! Ә Равил аның күңеле суынуын һич теләми.* В.Нуруллин. *Кызның йомры, тыгыз күкрәкләре, нечкә биле һаман күз алдында тора. Күңеле суынып китсә дә, ул тынычлана алмады.* А.Мифтахетдинов. **Күңел сүрелү** Кәеф китү; гайрәт чигү. *Башкалар сүзенә карап, Күңелең сүрелмәсен.* Җыр. *Кызның кинәт күңеле сүрелеп, йөзендәге матурлык балкышы тоныкланып китте, дымсу кара күзләре уйчанланып калды ---.* В.Нуруллин. *9 Май көнне кулына бер пачка карабодай ярмасы, бер ярты аракы китереп тоттыргач, картның күңеле сүрелде.* Х.Ибраһим. **Күңел сызлану** *к.* **күңел сызу**. *Кәмранны бер мәгънәсезгә тилмертүем өчен күңелем сызланды ---.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңел сызлау** *к.* **күңел сызу**. **Күңел сызу** Борчылу, хәсрәтләнү; нәрсәнеңдер җанны тырнап торуы. *Мәрхабәнең күңеле сыза, Вәли аны көннән-көн ныграк ярата, тик нәрсәдер аның җанын бәйләгән кебек.* Г.Әпсәләмов. **Күңел сыкрану** *к.* **күңел сызу**. **Күңел сыкрау** *к.* **күңел сызу**. *Киредән университетка кайтып җиткәч, күңеле сыкрап, моннан ары Григорий Ивановичның өенә барып йөри алмаячагы турында уйлады.* Җ.Тәрҗеман. *Әсма яшьләр уены була торган җиргә китте. Күңеле сулкылдап сыкрый иде аның.* Х.Сафина. **Күңел сыну** 1) Нәрсәдәндер өмет өзелү; хәтер калу, үпкәләү. *Тарлыклардан күптән! Күптән! Күңелем сынган.* Г.Тукай. *Әгәр менә хәзер үк Сәйфулла килеп кермәсә, бик кадерле бер нәрсәсен югалтыр, гомергә күңеле сынып калыр төсле тоелды аңа.* Ә.Еники; 2) Кече күңелләләнү, хисләр нечкәрү. *Бу кадәр дә үчләшер икән кеше! Картайгач йомшармы, күңеле сынармы дигән идем, юк, тэрәлгән дә каткан...* Р.Вәлиев. **Күңел сынык булу** *к.* **күңел китек булу**. *Халык шул хәтле яратты үзен, ул килмәсә, бөтенесенең күңеле сынык була иде.* Э.Касыймов. **Күңел сыю** Үз итү, ярату. *Юкса ул әйтер иде: күңел сыйган җир – дөньяда иң матур, иң якты урын ул, дияр иде.* Н.Гыйматдинова. **Күңел талпыну** Нәрсәгә дә булса омтылу, ашкыну, берәр нәрсә эшләргә теләк барлыкка килү. *Көннәр тагын да матурлана төште. Күңел тагын да талпына башлады.* М.Гафури. **Күңел тараю** Үзең турында гына уйлау. *Нурсөянең күңеле нур да үтмәслек дәрәҗәдә тарайды шул!* Н.Гыйматдинова. **Күңел тарту** Теләү, теләк булу. --- *Мостафин район җитәкчеләре белән --- кунакка йөрешеп китүдән аеруча саклана, --- нигәдер, күңеле тартмый ---.* Ә.Еники. --- *Фәкать күңеле тартканга, аның янында җанга ял алганга гына ул аны озаткалап йөрде.* М.Маликова. *Озын сүзнең кыскасы шул: күңел тартмаса да, тавыш-гауга чыгарып ташлап китә алмадым.* Р.Мөхәммәдиев. **Күңел**

**тартылу** *к.* **күңел тарту**. *Шуңа күңел --- җил-яңгыр тидермәгән бәхетле көннәргә тартыламыни?* Н.Гыйматдинова. *...Университетны тәмамлагач, Дамирга Уфада калырга да мөмкинлек бар иде. Тик күңеле туган ягына нык рак тартылды.* С.Шәрипов. *Тик минә минем күңел дә сиңа тартыла шул.* Х.Сафина. **Күңел тарыгу** Авырсыну, кыенсыну; пошыгу. *[Нәфисә], бу басынкы тынлыкка күңеле тарыгып: «Әнкәй, син өйдәме?» – диде.* Г.Бәширов. **Күңел ташу** 1) Нинди дә булса хисләрнең тышкы чагылышы. *Аның бу сүзләре шундый ялкынлы булып чыктылар, күпләрнең күңелләре ташыды, күзләренә яшь килде.* Г.Ибраһимов; 2) Бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү, дулкынлану. *Мәлик Рәйян карар кылды, күңле ташып: «Мәмләкәтем сиңа лаек», – диде имди.* Кол Гали. *[Мосье Пьер Фор:] Тик аның [Кристиананың] күңеле ташып китте, шуның өчен генә абайламый калды ул.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Күңел тәрәзәсе** *к.* **күңел күге**. *[Гәрәй:] Просто без күп вакыт кешегә кеше итеп карый белмибез. Күңел тәрәзәләребез тимер капкачлы.* Г.Шакирова. *--- Гөләндәмнең күңел тәрәзәсе ачык иде.* Ә.Гаффар. **Күңел тезгене бушау** *к.* **күңел йомшару**. *Нинди гайрәтле көй! Нинди кодрәтле моң! Күзләргә яшь саркыса саркыр, әмма күңел тезгене бушамас...* С.Шәрипов. **Күңел теләү** *к.* **күңелгә ошау**. *[Шәмсекамәр:] 19 яшемә җитеп --- берәүне дә сөйгәнем, сөя алганым юк, --- күңел теләгән кеше очрар микән?* А.Әхмәт. **Күңел тетелү** Борчылу, хафалану, тынычсызлану. *Алайса нигә тетеләсең, күңел?! Нигә битараф кына: «Ачуланмыйм», – димисең?!* Н.Гыйматдинова. **Күңел тетрәү** Ниндидер авыр уйлар кичерү. *Күңеле тетрәп куйды аның: әнкәсе тәрәзә төбендә утыра, күзләре юлда иде.* Инешләр Иделгә кушыла. **Күңел төбе** *к.* **күңел түре**. *Илсөяр шулай дип үзен юатырга тырышса да, күңел төбендәге бер уй киресен әйтә ---.* Ф.Яруллин. *Тик, нишләптер, беркөн Батталовка карата туган шиге һаман күңеленнән китмәде, ул, болганчык суның ләме пычрак чиләк төбенә утырган кебек, аның күңел төбенә ятты.* Ф.Садриев. *Хатын-кыз аһ-уһ килде, аңламасалар да, бу сүзләрнең тирән мәгънәсен үзләренчә сиземләп, күңел төпләренә салып куйдылар.* Р.Зәйдулла. **Күңел төбендә** *к.* **күңел түрендә**. **Күңел төпкеле** *к.* **күңел түре**. *Сабит туктаусыз икеләнә иде әле: иртәсе дә килә Сөмбеләне, күңеленең төпкелен ниндидер корт та кимерә...* А.Гыйләҗев. **Күңел төпкелендә** *к.* **күңел түрендә**. *Күңел төпкелендә, иңрәп, үзәк өзгеч үкенү баш калкытты.* К.Тимбикова. *Күңел төпкелендә оялаган куркыныч һәм ләззәтле уй иде ул.* Н.Гыйматдинова. **Күңел төшү** 1) Күңелгә ошау; ярата башлау, сөя башлау. *Күзем төшсә, күңелем төшми Синнән башка бүтәнгә.* Җыр. *[Байтирәк:] Аларның күңеле тегә кызларга төшкән, сезгә хыянәт итәргә телиләр.* Т.Гыйззәт; 2) Нәрсәне дә булса теләү. *[Сәхип карчык күчтәнәчне] үзенең сандыгының төбенә үк салып бикләп, күңеле төшкән саен әзләп-әзләп кыш буе капкалап тота.* М.Гали; 3) Өметсезлеккә бирелү, өметсезләнү. *Күңел төшерерлек бик күп авырлыклар күрүгә карамастан, [Җәүдәттән] тора-бара --- көр күңелле, тере бер кеше калкып чыкты.* Г.Бәширов. *Тау төшкән саен, кешенең күңеле дә төшә, аңа шул ук агачлар да, шул ук үләннәр дә --- таныш булып күренә.* Р.Вәлиев; 4) Кәеф кырылу, кәефсезләнү. *Кызның шундый азгын зат булып чыкканына күңеле төшеп, Габделфәрт шактый вакыт сөйләшмичә торды.* Х.Ибраһим. *Бу төнне Рауза йокларга ятмады, хәтта еларлык та хәле калмыйча, караватында утырды – аның шулхәтле күңеле төшкән иде.* Ги де Мопассан. **Күңел тулу** *к.* **күңел ташу** (*1 мәгъ.*). *Зөһрә ханым сүзеннән туктады, күңеле тулып, бугазына төер килде шикелле ---.* Ә.Еники. *--- ул иң элек кесәсеннән дәү генә кульяулык тартып чыгарды. --- Менә-менә күңеле тулып китәр дә елап ук җибәрер...* Х.Ибраһим. *Бу күренештән Саимәнең күңеле тулды, күзләре яшьләнде.* Г.Галиева. **Күңел тулы булмау** Берәр нәрсә җитмәгән кебек булу, канәгатьсезлек хисе кичерү. *Ләкин әти дигән нәрсә... ул булмагач, күңел монда барыбер тулы булмаячак.* Ә.Баян. **Күңел тулып түгелү** Нинди дә булса сәбәпләрдән күз яше белән елау. *Колашага салынган мәетне машина әрҗәсеннән төшергән чакта, Сафураның күңеле янә дә тулып түгелде.* Ш.Максудова. **Күңел тулышу** *к.* **күңел ташу** (*1 мәгъ.*). *Күңеле тулышып, бертын сөйләвеннән туктап торды урманчы.* Р.Мөхәммәдиев. *Коля аска карап басып тора, үпкәләүдән, рәнҗүдән күңеле тулган иде.* Җ.Тәрҗеман. **Күңел туңу** Хисләр сүрелү. *Шунысы бик гаҗәп: Нәфисә исенә төшү белән, Зиннәт туңып калган күңеленең язгы боз кебек акрын-акрын эри баруын тоя башлады.* Г.Бәширов. **Күңел тупаслану** Битарафлану, игътибарсызлану; каты бәгырьлегә әйләнү. *Кешеләр белән эшләү, гомумән, авыр. Күңелләр бер тупаслана, бер нечкәрә.* Сөембикә. **Күңел түгәрәкләнү** Берәр нәрсәдән канәгать булу, канәгатьлек хисе кичерү. *Сөйлә дә сөйлә дип җаныңны ашый бит, ә! Халидә иде аның исеме. --- Я, күңелеңнең почмаклары түгәрәкләндеме, бала?* Н.Гыйматдинова. *Укучылар да, укытучылар да канәгать булды. Директорның да күңеле түгәрәкләнде ---.* Д.Гайнетдинова. **Күңел түгелү** *к.* **күңел ташу** (*1 мәгъ.*). *Җәгъфәрнең күңеле түгелергә генә тора иде.* Г.Галиев. **Күңел түзмәү** 1) Сабырсызлану; хисләрне тыя алмау. *Кинотеатр яныннан үткәндә, минем күңел түзмәде, ризалык-мазар сорап тормыйча, Әминәне җитәкләп алып кереп киттем.* Р.Вәлиев; 2) Нәрсәгә дә булса бик нык омтылу, ашкыну. *Хәлдән таеп егылсак та алҗып, Күңел түзми, йөрәк ашкына.* Ш.Маннур. **Күңел түре** 1) Шәхес өчен иң мөһим һәм иң тирәндәге уй-хисләр. *Эченә төшкән әлеге шом, кара пошаман, нәкъ шыксыз җан иясе кебек, күңел түренә үрмәли.* М.Хәсәнов. *Бүлдермәде Нәҗип, --- хатынның --- сүзләре --- катлам-катлам булып, аның күңел түренә тыгызланып утырдылар.* А.Гыйләҗев; 2) Хәтер. *Ул Маркс теориясен күңел түренә сала, аны гомергә онытмаслык итеп ятлый.* Г.Әпсәләмов. **Күңел түрендә** Иң мөһим һәм

иң тирәндәге уй-хисләр янәшәсендә. *Бары тик кайдадыр, күңел түрендә генә әйтеп-аңлатып булмый торган үпкәләү һәм аптырау --- катыш бер хис туып килә.* Р.Вәлиев. *Күңел түрендә Бибинур үзен Зөһрәбану алдында гаепле саный иде.* А.Гыйләҗев. *Ата кешенең --- бер генә тапкыр да хәл-әхвәл белешмәве, кызым дип күңел хакы өчен дә ым салмавы --- күңел түрендә баш калкытырга маташкан вак-төяк яктылыкны да күмеп китә иде.* Ирек мәйданы. **Күңел түрендәге** Иң тирән, иң самими, кадерле. *[Айсылу:] Сез – бик әйбәт кеше, Гәрәй Миргалиевич, ләкин... [Гәрәй:] Ләкин хисләрнең нечкәлеген тоярлык, күңел түрендәге чәчәкләрне күрерлек түгел, дисезме?* Г.Шакирова. *Арага җил кергән шикелле, күңел түрендәген әйтү авыр иде.* М.Маликова. **Күңел түреннән** Йөрәгеннән, чын күңеленнән. *Искәндәр күңел түреннән күтәрелеп килгән өмет хисе белән стена сәгатенә таба борылды.* Р.Вәлиев. *Хәй Фәләхинең сүзләре дә бүген күңел түреннән чыкмый, кыланмышлары да нәкъ артистларныкы кебек.* К.Тимбикова. **Күңел тынгысызлану** *к.* **күңел тынычсызлану**. *...Авылга якынлашкан саен, йөрәгем ныграк тибә, күңел тынгысызлана.* Р.Габделхакова. **Күңел тынычлану** Борчулардан, хафалардан, кайгы-хәсрәтләрдән арыну. *Ниһаять, болар да бала сөю бәхетенә ирешә, --- инде күңелләре тынычланыр дип, хат килүгә үк бүләкләр ала башлады.* Ф.Яруллин. *Җәләлнең дә күңеле тынычланды: ашлыгы тайгада бик шәп яшерелгән, юлсукмакларны кар каплады.* Х.Сафина. *Ул миңа: «Курыкма, курыкма, егет, син ят илдә түгел, бирегә үз кешеләр яши», – дип әйтә иде сыман. Күңелем тынычланды.* Н.Дәүли. **Күңел тынычлыгын алу** Тынгылык бирмәү, җанны бимазалау. *Әмма бүген башына һични керерлек түгел, Раузаның шулай соңаруы күңел тынычлыгын алды.* Р.Мөхәммәдиев. **Күңел тынычлыгын җую** Тынычлыгы бетү, тынгы булмау. *Иван Петрович та күңел тынычлыгын җуйды.* Ф.Вәлиәхмәтов. **Күңел тынычлыгы табу** *к.* **күңел тынычлану**. *Юньсез иреннән бәхетнең чыраен да күрмәгән Рәхимәне инде, ниһаять, күңел тынычлыгы табып яшәрмен дигәндә генә, икенче хәсрәт килеп тапты.* Х.Ибраһим. **Күңел тынычсызлану** Борчылу, җанга тынгылык булмау. *Вахитның күңеле тынычсызлана, йөрәге тибә, үзен бик авыр, куркыныч җирдә торган кебек хис итә иде.* М.Гафури. **Күңел уалу** Рәнҗү, үпкәләү. --- *«Картлар рәнҗер. --- Картлар күңеле уалырга гына тора», – диде Нәҗип, тавышы йомшарып, юашланып чыкты.* А.Гыйләҗев. **Күңел уйнау** Ашкыну, җилкенү. *Күңеле уйнаган Фарукҗан әнә шундый уйлар эчендә яна.* Т.Әйди. *Әмирханның күңеле уйный иде ахрысы. Гел сөйләнде, сүзен һаман кинаяләп тә, шаярткалап та әйтә торды.* Н.Акмал. *Күз аллары томалана, башлары әйләнеп, күңелләре уйный башласа, беразга гына күләгәгә кереп торды.* А.Хәлим. **Күңел уйнаклау** *к.* **күңел уйнау**. *Бүген күңел уйнаклый.* А.Мифтахетдинов. **Күңел (үз) урынына утыру** *к.* **күңел тынычлану**. *...Акрынлап күңеле үз урынына утыргач, Мостафин шул ук көзне бабасы симертеп суйган атның яртысына пай кертеп, аңа да кушылды.* Ә.Еники. *Чынлап та, абыйлар китеп күңел утырыр-утырмастан, Хәвадис абый уку белән җенләнә башлады.* Х.Сарьян. *Озатырга чыккан җәмәгате, газизе Гөлйөземне маңгаеннан үпкәндә җаны тынычланган, күңеле исә урынына утырган иде инде.* Ф.Латыйфи. **Күңел (үз) урынында түгел** Нәрсә турында да булса уйлану, борчылу, тынычлыкны югалту турында. *Малайга нindидер зур уй төшкән, малайның күңеле урынында түгел.* Г.Бәширов. **Күңел (үз) урыныннан кубу** Берәр нәрсә турында уйлый, борчыла башлау. *Өч айга Мәскәүгә китәсе булганга, Нурисламның күңеле урыныннан купкан иде, ул Сәбилә өчен борчыла ---.* Р.Вәлиев. **Күңел утыру** Тынычланып калу. *Урнаштылар, ләкин Мирвәлинең күңеле утырмады. Ары-бире мәгънәсезгә сугылып көннәрен үткәрде ул, --- яшереп кенә эчә башлады.* А.Гыйләҗев. *Күңелең утырса, бәлки, безне дә күрә башларсың.* Р.Вәлиев. *Инде --- күңеле утыра башлаган иде, тагын зиһене таралып төште.* Ф.Яхин. **Күңел үртәлү** Гасабилану; җан борчылу. *Хәмит сөйли дә сөйли, ул сөйләгән саен, Искәндәрнең колаклары томалана бара, күңеле һаман саен ныграк үртәлә.* Р.Вәлиев. **Күңел үсү** *к.* **күңел күтәрелү**. *Үз алларында кызыл комиссар Толмачёвны күргән сугышчыларның күңеле үсә ---.* Ш.Рәкыйпов. *Якыннарының бу йомшак якларыннан Атилла еш кына файдалана да, аларга әледән-әле асылташлар белән бизәлгән әйберләр бүләк итә, тегеләрнең күңеле үсеп китүен мыек астыннан елмаеп күзәтергә ярата ---.* Р.Зәйдулла. *Тик бу җиңү егеткә бер шатлык та китермәде, күңеле үсмәде аның.* Г.Әдһәм. **Күңел хакы өчен** *к.* **күңел өчен генә**. *Ата кешенең --- бер генә тапкыр да хәл-әхвәл белешмәве, кызым дип күңел хакы өчен дә ым салмавы --- күңел түрендә баш калкытырга маташкан вак-төяк яктылыкны да күмеп китә иде.* Ирек мәйданы. **Күңел хушлану** Рух күтәрелү, канәгатьлек хисе барлыкка килү. *Илсөярнең бу сүзләрдән күңеле хушланып, Җәүһәргә ризалык бирде.* Ф.Яруллин. *Кызның озын аяклы, төз сынлы, нечкә билле икәнен күргәч, Гадилнең күңеле бик тә хушланды.* М.Маликова. **Күңел чисталыгы** *к.* **күңел сафлыгы**. *Күңел чисталыгы, мәхәббәттә сафлык, илгә тугрылык дигән үлчәүләрне алып салып карасаң – җырлар ачыла да бетә!* Ф.Яруллин. *Әй язмыш, Хәлимәмне әйтәм, --- исерек ир белән ызгышып, күңел чисталыгы турында --- уйларга вакыты булмады.* З.Кадыйрова. **Күңел читлеге** *к.* **күңел сандыгы**. *Күңел читлегендә яшеренеп яткан нindидер талпыну, нindидер сер менә-менә тышка бәреп чыгар сыман тоелды.* Т.Нәбиуллин. **Күңел чыдамау** *к.* **күңел түзмәү**. **Күңел шатлану** Эчтән шатлану, сөенү. *Ләкин үзе алданса да, күңеле шатланды.* Г.Әпсәләмов. **Күңел шатлыгы** Рухи күтәренкелек. *Була шундый халәтләр: кайвакыт берәүне чын күңелдән сөясең, --- мөнәсәбәтеңне кемгә дә булса сөйләү сиңа күңел шатлыгы, җан рәхәте бирә.* Г.Ибраһимов. **Күңел шәмнәрен кабызу** Үткәннәрне, күңелдә сакланган якты

хатирәләрне искә алу. *Сулда, өч бүлмә аша, аларның уртак кухнялары, үзбәктаҗиклардан төнге ябалаклар кайвакыт анда пылау пешерәләр, аулакта үз телләрендә сөйләшеп, күңел шәмнәрен кабызалар.* А.Гыйләҗев. **Күңел шикләнү** Нәрсәгәдер бик үк ышанып бетмәү. *Коелып ук төшмәде Сәкинә, --- бер дә алай шаккатмыйча гына: – Болай соңаргач, күңелем шикләнгән иде аны, тәки шул аксак шайтан янында булгансың икән! – диде дә кече якка кереп китте.* В.Нуруллин. **Күңел шомлану** *к.* **күңел тынычсызлану**. *Телеграмма аласы көнне күңел шомланып, йөрәк сыкрый башлаган иде, хатынга нидер булган төсле...* Инешләр Иделгә кушыла. **Күңел ымсыну** *к.* **күңел төшү** (*2 мәгъ.*). **Күңел эрү** Әлегә кадәр җанны бимазалап торган хисләрнең нинди дә булса сәбәптән соң таралуы, юкка чыгуы. *Әтием: «Кызым, хәлләрең ничек?» – дип, килеп хәлем белсә, күңелем эрер, бар үпкәм онытылыр иде дә бит.* Р.Габделхакова. --- *бөтен дөньяны балкытып, Рухия интернаттан килеп чыгуга, сары май күк эри дә китә Равилнең күңеле.* В.Нуруллин. *Рәхмәт ишеткән солдатларның вагоннан күңелләре эреп чыкты.* С.Шәрипов. **Күңел юану** Нәрсә белән дер мавыгу. **Күңел юанычы** *к.* **күңел юаткычы**. *Һәркемнең бер күңел юанычы була.* Р.Вәлиев. **Күңел юаткычы** Кайгысагышларны оныттыра, борчуларны баса торган сәбәп. *Ә Равил --- күңел юаткычы булып хезмәт итеп килгән иң якын дусты аккордеонын шул сәгатендә үк Йосыф абыйның иске велосипедына алмаштырып кайтты.* В.Нуруллин. *Кәбире дә, кара, нинди явыз: арттан чыгып, күңел юаткыч бер сүз әйтсә, теле корыр иде микәнни?* Х.Сафина. **Күңел юату** Үз-үзен тынычландыру; борчуларны, кайгыларны оныттыру. *«Шөкер, хат Гайфулла кулына эләкмәде». Ләйлә күңелен шулай дип юатты.* Ф.Яруллин. **Күңел юксыну** Нәрсәнедер югалткандай булу, зарыгу. *[Гаяз:] Шулай да нәрсәдер җитми иде, шулай да күңел нәрсәнедер юксына иде.* М.Әмир. *Үзем синнән башка Тора алмыйм: күңел юксына.* З.Мансур. **Күңел язылу** Күңелсез уй-фикерләрнең таралып китүе; яхшы кәеф барлыкка килү. *Яңа тормыш башлыйк, коргаксыган күңелләр язылсын.* М.Хәсәнов. --- *Галия Идрисовна да, терелеп, яңадан мәктәпкә килде. Өстән авыр йөк төшкән кебек җиңеләеп, күңелләр язылып киткәндәй булды.* Инешләр Иделгә кушыла. **Күңел яктыру** Шатлык, канәгатьлек хисләре барлыкка килү. *Кыз якынайган саен, күңеле яктырганы, кәефе яхшырганы тыштан караганда күренми-сизелми.* М.Маликова. *Ә ни өчен ул халык ят булсын, ди, аңа? Профессорның күңеле кинәт яктырып, йөзе ачылып китте.* Җ.Тәрҗеман. **Күңел якын итү** *к.* **күңелгә ошау**. **Күңел ялыгу** Нәрсәдән булса да тую, ару. *Караңгы, бик иләмсез һәм озын төннән күңел ялыга...* М.Гафури. **Күңел, янып, көлгә әйләнү** Әрнүле уй-хисләрдән, борчылулардан соң күңел кату, салкынаю, хиссезләнү. --- *инде Касыйм белән араны тәмам өздем дип уйлаган чаклары байтак булды. Тик янып көлгә әйләнгән күңел чатында һәр тапкыр бер чаткы калган булып чыга, кечкенә генә хатирә дә шуны үрләтеп җибәрә иде.* Х.Сафина. **Күңел яралану** Нинди дә булса сәбәптән кайгы, сагыш, хәсрәт, ачыну хисе барлыкка килү. *Күңеле яраланган, җанын тынгысызлык биләгән Сәгыйдәнең йөрәге кысылып-кысылып килде.* Н.Хәсәнов. **Күңел ярасы** Нәрсәгә дә булса хәтер калу, йөрәк әрнү. *Их, күңел ярасын да шулай дача шикелле артта калдырып китеп булса иде!* Җ.Тәрҗеман. *Ирекнең күңел ярасы акрынлап онытылды, Сөембикәгә булган рәнҗеше кимеде ---.* Ф.Садриев. *Күңел ярасын ачып салган Һаҗәр тагын бер үксеп куйды.* К.Тимбикова. **Күңел ярасына тоз сибү** Кем беләндер булган күңелсез хәл яки вакыйганы аңлы рәвештә аның исенә төшерү. *Шулай көйләнер төсле тоелганда, озын телләр, кайсы көнләп, кайберләре үч итеп, карчыкның күңел ярасына тагын тоз сибә башладылар.* Г.Бәширов. **Күңел ярасын ачу** Эчтәге уй-хисләрне, борчу-хәсрәтне кем белән дә булса уртаклашу. *Баязит абый аларның хыянәтен авыр кичерде, әмма бер чакта да, беркемгә дә күңел ярасын ачып күрсәтмәде ---.* **Күңел ярларына юшкын утыру** Эчке рухи нәзакәтлелек югалу, холык тупаслану. *Тыюлар озаккарак китсә, күңел ярларына юшкын утыра. Ул юшкын әкрен-әкрен җаныңны баса башлый.* Ф.Яруллин. **Күңел ярсу** Бик нык әсәрләнү; кызып китү, ярсу. *[Халикъ:] Әллә нәрсә булмады булуын, Ишмөхәммәт, әмма ләкин бик күңел ярсып китте.* Ш.Камал. **Күңел яту** (күбрәк юклык формасында кулланыла) Ошату, ярату, теләү. *Әйе. Соклана идем, баш ияргә әзер идем, әмма күңелем ятмый иде, чөнки еш кына ул миңа, шул максатларына ирешер өчен, теләсә нинди әшәкелеккә барыр төсле күренә иде.* Ә.Еники. *Әлбәттә, кызның кылларын тартып караучылар әле дә юк түгел. Тик берсенә дә Кәриманең күңеле ятмый.* С.Шәмси. *Бу балконга никтер аның күңеле ятып җитмәде.* Ф.Яруллин

**КҮҢЕЛДӘН** *рәв.* 1) Яттан, хәтердән. *Ул Казан гимназиясендә укып чыккан шагыйрь Державинның шигырьләрен күңелдән сөйләде ---.* Җ.Тәрҗеман. *Һәммә сүзләрен күңелдән белеп бетте.* Г.Ибраһимов. *– Уку гына түгел, кайберләрен күңелдән беләм инде, – дип, канатланып, мактанып куймасынмы малай.* Р.Мөхәммәдиев

2) Язмыйча. *Кушылучыларның урыннарын алыштыру, билгеле, күңелдән эшләнә.* Арифметика. *Күңелдән исәпләү*

**КҮҢЕЛДӘШ** *и.* Уртак серләре булган кеше. *Фикердәштән, күңелдәштән туа дус.* Ш.Галиев

**КҮҢЕЛЕННӘН** *рәв.* Эченнән, уеннан; уйда, аңда. *Гайшә дәшмәде. Күңеленнән ул, әлбәттә, минем белән риза иде.* Г.Кашшаф. *Әни кеше сизмиме соң? Сизенә иде бугай ул Миңнулланың Зәйнәпне ятратканын. Һәм моның шулай булуын күңеленнән хуплый да иде бугай.* В.Нуруллин. *Нәҗип дәшмәде, күңеленнән генә кемнәргә күпме бурычы булуын санап барды.* А.Гыйләҗев

**КҮҢЕЛЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл. к.* **күңеллеләндерү**. *Моның өстенә эшчеләрнең эштән бушаган вакытларында тау буена җыелып уйнаулары, гармун*

*тартып биюләре дә күңелләндерә торган иде.* М.Гафури

**Күңелләндереп җибәрү** Кинәт күңелләндерү, җанлылык, ямь өстәү

**КҮҢЕЛЛӘНҮ** *ф. сөйл. к.* **күңелләләнү**. *Моңардан соң һәр икесе күңелләнеп, авыр сүзне дә җиңел генә кузгатып җибәрделәр.* Х.Сарьян. *Табын салмак кына күңелләнеп көч ала бара.* З.Зәйнуллин

**Күңелләнә бару** Торган саен ныграк күңелләнү

**Күңелләнә бирү** Бернәрсәгә карамастан күңелләнүне дәвам итү

**Күңелләнә төшү** Бераз, беркадәр күңелләнү

**Күңелләнеп алу** Бер ара күңелләнү, кыска гына арага күңелләнү

**Күңелләнеп китү** Берәр этәргеч бирерлек вакыйгадан, билгеле бер вакыттан соң күңелләнү

**КҮҢЕЛЛЕ** I *с.* **1.** 1) Шат рухлы, көр табигатьле. *[Сәлимә:] Безнең әни бик күңелле карчык булып бара.* Ф.Әмирхан. *Алсу – күңелле кыз*

2) Шат; кәефле. *Кайчандыр үзенең беркатлы, күңелле табигате белән арткурага ямь биреп торучы --- бу акыллы кызны Нәсимә беренче күрүдән үк ошаткан иде.* К.Нәҗми

3) Шатлыклы; кәефне күтәрә торган. *Ял вакытларында алар үзләре эшләгән җирдән күпме бодай чыгарга тиешлеге --- турында күңелле әңгәмәгә кереп китә торганнар иде.* Г.Бәширов. *Күңелле күренеш*

4) Яхшы тәэсир итә торган. *Минһаҗ --- кайвакытта күңелле вакыйгалар сөйләп ташлый ---.* М.Гафури. *Күңелле истәлекләр калдыру*

5) Кәеф күтәренкелеген чагылдырган, шатлыкны белдергән. --- *Фатыйма апа әле моннан бер атна элек Миассарының: «...Тиздән сугыш бетә --- Алла боерса», – дип язган күңелле хатын алган иде.* К.Тимбикова. *Күңелле, мавыктыргыч хезмәтнең болай тиз тәмамлануына Гарифулла көрсенеп куйды.* Э.Касыймов

6) Кайбер сыйфатлар янында килеп, «кешенең эчке дөньясы, характеры шундый» дигән мәгънәне белдерә. *Рәнҗетелгән кеше киң күңелле була алмый.* Ф.Яруллин. *Июль кичендә шундый алгысак күңелле ике егет остаханәдә дуслары белән очрашып, сөйләшеп утырдылар.* М.Маликова. *Ни өчен табигать я булмаса Тәңре шушындый гаделсезлекне эшләгән соң? Пакь күңелләрне ак итеп, кара күңеллеләрне кара итеп булмый микәнни?* Ф.Садриев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шатлык белән, яхшы кәеф белән, кәефләнеп. *Дамирның уйларын бүлдереп, беләгендәге кызыл чүпрәккә ак белән «Дежурный ярдәмчесе» дип язылган повязкасын тартып куйды да, Силушкин күңелле генә эндәште ---.* С.Шәрипов. *Биктимер --- күңелле итеп, бөтен йөзен балкытып елмайды ---.* З.Зәйнуллин. *– Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, яңа геометриягә таянып, әлбәттә хәл итәрбез, – дип, сүзне күңелле генә очлап куйды Хәлфин.* Җ.Тәрҗеман

2) Яхшы, кызыклы; шәп. *Кыз, Таһир эчемлек салган рюмканы иреннәренә чак кына тигезеп, вак-вак йотымнар белән эчте. Таһирга күңеллерәк булып китте.* Н.Акмал. *Самолёт моторы күңелле генә гүли башлады.* М.Насыйбуллин. *Берничә минуттан аланда, күңелле чытырдап һәм төтәсләп, учак яна иде.* А.Тимергалин

3) Һәр тарафтан канәгать булып. *Таң атып, агач башында төн үткәргән кошлар күңелле чөкердәшә башлагач кына, Закир үзенең Разиясын озатып куя.* И.Гази

**3.** *хәб. функ.* 1) Шатлык, тулы канәгатьлек хисләре кичерү турында. *Яшәү тәмле, яшәү күңелле.* М.Җәлил. *Урманда нинди күңелле!*

2) Кызыклы, яхшы. *Гыйшык – дөрләп күтәрелгән ялкын ул, аңа читтән карау гына күңелле.* М.Маликова

**КҮҢЕЛЛЕ** II *и. иск.* Сугышка үз теләге белән язылып киткән кеше; ирекле. *Нишлиләр безнең күңелләләр, Ни хәлдә гаскәрең?* Ф.Бурнаш. *Күңелле булып язылган милиция [хезмәткәрләре] арасында «Мөхәммәдия» шәкертләреннән Ибраһим Килдиев, Закир Закиров --- һәм башкалар булганлыгын күрәбез.* Казан утлары

**КҮҢЕЛЛЕК** *и. сөйл.* Җан азыгы, рухи канәгатьлек өчен булган нәрсә. *Туемлык түгел, күңеллек.* Мәкаль

**КҮҢЕЛЛЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* Ямьләндерү, кәефне күтәреп җибәрү. *Моның өстенә эшчеләрнең эштән бушаган вакытларында тау буена җыелып уйнаулары, гармонь тартып биюләре дә күңеллеләндерә торган иде.* М.Гафури. *Әтисенең шаярып сөйләшүе аны тагын да күңеллеләндерде.* Ш.Камал

**Күңеллеләндереп җибәрү** Кинәт күңеллеләндерү, ямь өстәү

**КҮҢЕЛЛЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Күңел ачылу, кәеф күтәрелү; шатлану. --- *Мәрфуга абыстайның: «Исән кайттыңмы, карт? Сатулар яхшы булдымы?» – диюенә дә: «Аллага шөкер», – дип, күңеллеләнеп җавап бирде.* Г.Исхакый. *Соңгы елларда шул авылны, аның кешеләрен өзлексез уйлап, нечкә күңелләнеп, реаль тормыштан аерылды түгелме?* Т.Таһиров. *Кунаклар күңеллеләнгәннәр иде инде ---.* Д.Гайнетдинова

2) Ямьләнү, матурлану, күңеллегә әйләнү. *Бакчалар бик күңеллеләнде, кара карлыган котырып уңды, яфраклары да күренми шомлыкның, билләһи.* А.Гыйләҗев

**Күңеллеләнә бирү** Бернәрсәгә карамастан күңеллеләнүне дәвам итү

**Күңеллеләнә төшү** Бераз, беркадәр күңеллеләнү

**Күңеллеләнеп алу** Берара күңеллеләнү

**Күңеллеләнеп китү** Нинди дә булса сәбәптән яки билгеле бер вакыттан соң күңеллеләнү. *Ул моннан соң тагын да татлырак сүзләр килеп чыгуны өмет итеп, күңеллеләнеп китте.* Г.Бәширов. *– Бигрәк күңелсез яшисез. – Менә бит син кайткач күңеллеләнеп китте, – диде Гайфулла, балдызының ни теләвен аңлый башлап.* Ф.Яруллин. *Икесе дә әллә кайларда калган истәлекләрдән күңеллеләнеп китәләр.* З.Зәйнуллин

**КҮҢЕЛЛЕЛЕК** *и.* 1) Ямьлелек, җанга рәхәтлек. *Әллә нигә бер килгән бәйрәмнәрдә генә я Финляндиягә барып, я Кронштадт кебек җирләргә пароходта йөреп килеп, җәйнең матурлыгы, яшь тормышның ачык һавада күңеллелеген күреп --- кайттылар.* Г.Исхакый. *Аннары алар Әмирләр группасы белән бергә Яңа ел каршыладылар. Әй, ул чактагы күңеллелек!* Р.Ишморатова

2) Рух күтәренкелеге, яхшы кәеф; шатлык. *Лариса магнитофон кабызды, бүлмәгә тагын да ямь, күңеллелек өстәп, музыка уйнады...* М.Вәли. *Гадәттә яңгыр яуганда була торган күңеллелек юкка чыкты, бу юлы ул газапка әйләнде.* Г.Иделле

3) *сөйл.* Рәхәтлек, ямь. *Бик күп уйный, наян ул; Күңеллелек, көлкеләр таба әллә каян ул.* Г.Тукай. *Курайлы елга буенда җиләк-җимеш җыю да печән өсте белән бер вакыткарак туры килә. Бусы инде – үзе бер күңеллелек.* Г.Галиев

4) Кайбер кушма сыйфатлар составында килеп, кешенең эчке дөньясы, характеры үзенчәлеген белдерә. *Кайбер кешеләрдәге тар күңеллелек саескаңнардан килә икән.* М.Мәһдиев. *Тәүге очрашуда ук Хәятнең үтә дә ачык күңеллелеге һәм беркатлылыгы хәйран калдырды.* Ф.Садриев. *Рәхмәт инде киң күңеллелегегез өчен.* Ф.Яруллин

**КҮҢЕЛСЕЗ** *с.* **1.** 1) Кәефсез, борчулы, сагышлы (кеше тур.). *[Шәмсия:] Улым, Марат, син нигәдер күңелсез, әллә берәр җирең авыртамы?* Т.Гыйззәт. *Иреннәре агарган, күз төпләре уелган, ә үзе [Зөһрә ханым] күңелсез, боек иде.* Ә.Еники

2) Борчылуга сәбәп булган, кәефсезлеккә китергән. *Хантимер дә бүтән күңелсез әңгәмәне ялгамады ---.* Н.Гыйматдинова. *Шулай уйлап, Касыйм ага йокларга ятты һәм, күп тә үтми, карчыгы белән булган күңелсез сөйләшүне онытты.* Р.Кәрами. *Татлы хыял дәрьясына чумып киткән Атабаев алдына һич көтелмәстән бу ямьсез хатынның килеп чыгуы аны яңадан күңелсез, ямьсез бер хәлгә төшерде.* Г.Иделле

3) Борчулы, хәвефле, сагышлы; шатлыксыз. *Председательнең күңелсез уйларын бүлеп, ак телефон зыңгылдады.* М.Маликова. *Иң беренче булып күңелсез хәбәр белән Зөлфирә килде ---.* Р.Хәбибуллина. *Миндә гел күңелсез хәлләр генә, бала.* Н.Гыйматдинова. *Берсеннән-берсе күңелсезрәк, моңсурак көннәр белән тагын бер атна вакыт узды.* З.Биишева

4) Ямьсез, күңелгә ятышсыз. *Нинди шыксыз, күңелсез җирләр, дисең.* Г.Кашшаф. *Миңа ул бөтенләй ошамый. Нindидер күңелсез кеше.* Тигез гомер итегез!

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кайгылы рәвештә, борчылып. *Күңелсез үткән балалык дәвере аны рухи түбәнләтмәде.* Г.Ибраһимов. *– Җә, җә, – диде хат ташучы, күңелсез генә.* Н.Гыйматдинова. *– М-да, мин сезне нәкъ шул хакта искәртергә теләгән идем, – диде комбат, күңелсез генә.* С.Шәрипов

2) Ямансу, моңсу, нәрсәдер җитмәгән кебек. *Синсез миңа бик күңелсез булыр инде...* Г.Кашшаф. *Бушап калган зур бинада ялгыз көн уздыру нинди күңелсез булыр иде.* Ә.Еники. *Безгә бит ирләрнең яратуларын раслап торуы кирәк. Шунсыз күңелсез.* Ф.Яруллин

**3.** *и. мәгъ.* Кәефсез, борчулы, нәрсәдәндер риза булмаган кеше. *Менә шул Чалы кошы Кәмран бәйнең кулын кабул кылмаган. Нишлисең бит, күңелсезгә күлмәк кигертеп булмый...* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮҢЕЛСЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кәефне җибәрү, борчуга салу, хәсрәтне көчәйтү. *Ә бүген, киресенчә, аның чырае гадәттәгедән караңгы, сукыр лампа сөреме аның йөзенә төшеп, чыраен тагын да күңелсезләндерә ---.* Ә.Баян. *Иң яхшы укучыларыннан аерылу [укытучыны] беразга күңелсезләндерде.* А.Әхмәт

**Күңелсезләндерә бару** Торган саен ныграк күңелсезләндерү

**Күңелсезләндерә төшү** Бераз, беркадәр күңелсезләндерү

**Күңелсезләндереп тору** Даими, һәрвакыт күңелсезләндерү

**КҮҢЕЛСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Кәеф китү; кайгыру, хәсрәтләнү; борчылу. *Ямансу булса да күңелсезләнмәдек: күрәләтә үлемгә түгел, --- ә тыныч вакытның солдат хезмәтенә китәләр.* Х.Сарьян. *– Бар инде, – диде Мила. – Күңелсезләнмә. Мин гел сине уйлармын.* А.Мифтахетдинов. *Хәйретдин --- урманга чыгып киткән иртәне генә: – Күңелсезләнмә! Шундый чибәр кыз боегып утырырга тиеш түгел, – диде.* Х.Сафина

**Күңелсезләнә бару** Торган саен ныграк күңелсезләнү. *Шулай да, каралырга вакыт якынлашкан саен, Гайшә күңелсезләнә барды.* Г.Кашшаф. *Әмма йөргән саен Тәнзиләнең күңелсезләнә баруы, ап-ачык беленеп торган таркаулыгы, урынлы-урынсыз биргән сораулары --- Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәтне дә хәйранга калдырды.* А.Гыйләҗев

**Күңелсезләнә башлау** Күңелсезлек билгеләре барлыкка килү. *Укулар бетеп, ял вакыты килгәч, күңелсезләнә башладым.* М.Әмир

**Күңелсезләнә төшү** Тагын да күбрәк күңелсезләнү. *Соңгы елларда --- үз кабыгына кереп бикләнгән Фәрхетдин, Тәбрик белән сөйләшкәч, бигрәк тә күңелсезләнә төшкән, бөтенләй сөйләшмәс булган.* Ә.Баян

**Күңелсезләнеп йөрү** Күптәннән, шактый вакыт күңелсезләнү. *Бу сөйләшүдән соң, ул гел диярлек күңелсезләнеп йөрде.* Ә.Еники. *Тик соңгы көннәрне генә, никтер, күңелсезләнеп, моңсуланып йөри Кәримә.* С.Шәмси

**Күңелсезләнеп калу** Нинди дә булса вакыйгадан соң кинәт күңелсезләнү. *Күңелсезләнеп калган ир теләр-теләмәс кенә буйсынды аңа.* К.Тимбикова. *Өйгә кайтмаганына инде үкенә үк башлаган Рузалия, тәмам күңелсезләнеп, боегып калган иде.* Х.Ибраһим. *Аһ, юкка сорадым мин! Чулпан бөтенләй күңелсезләнеп калды, миңа аркасы белән борылып, --- янында бөтерелгән парларны күзәтә башлады.* Х.Ширмән

**Күңелсезләнеп китү** Нindидер сәбәп аркасында кинәттән күңелсезләнү. *Петрович, күңелсезләнеп китеп ---: – Революция язмышы хәл ителгән бу көннәрдә безнең җиңүне теләгән бер генә кеше дә авырырга тиеш түгел! – диде.* В.Нуруллин. *Һич кенә сөйләшергә форсат юк дип уйлап, Саимә бөтенләй күңелсезләнеп китте.* Г.Галиева. *Это верно, дип пичәт чәпәп куя торган иде ул һәм, ни өчендер, үзе дә күңелсезләнеп китә иде...* М.Шаһимәрданов

**Күңелсезләнеп тору** Шушы арада күңелсез булу. *Күңелсез?! Әйттегез сүз, Габделлатыйф абзый... Күңелсезләнеп торырга вакыты булмаячак аның.* С.Шәмси

**Күңелсезләнеп кую** Кинәт күңелсезләнү. --- *соңгы атнада Чулпан мәктәптән чыккач та, кемнедер эзләгәндәй, уңга-сулга карап ала, кирәкле*

*кешесен тапмагач, күңелсезләнеп куйгандай була ---.* Х.Ширмән

**Күңелсезләнеп утыру** Шактый вакыт дәвамында күңелсезләнү. «*Күңелсезләнеп утырырга ирек бирмиләр монда», – дип, үзләренчә тынычландыргандай да иттеләр коллегаларым.* Шәһри Казан

**КҮҢЕЛСЕЗЛӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **күңелсезләндерү**. --- *иренең туйдан соң ук китеп баруы һәм Илдусның монда якында гына булуы аны ике ут арасында яшәргә мәҗбүр итә, тормышын күңелсезли иде.* Р.Кәрами

**Күңелсезләп бетерү** Тәмам күңелсезләү, бөтенләй күңелсезләү

**Күңелсезләп тору** Даими, һәрвакыт күңелсезләү

**КҮҢЕЛСЕЗЛЕК** *и.* 1) Рухи төшенкелек, кәефсезлек. *Ничек кенә авыр булмасын, Тәнзиләмне ничек кенә көчле сагынмыйм, беренче атналарда күңелсезлеккә бирелмәскә тырыштым.* З.Вәли

2) Кайгы, сагыш, хәсрәт, моңсулык. *Зәйнәп моны күргәч, җаны өзелә язып, күңелсезлек сәбәбен сорады.* М.Гафури. *Һаҗәр, Гариф сүзләрендә коточкыч күңелсезлек сизенеп, юан гына бер төп башына лыпылдап утырды.* К.Тимбикова

3) Җанны борчый торган вакыйга; кешене авыр тәэсирләргә дучар итә торган вазгыять. *Эштә күңелсезлекләр чыгып тора инде ул.* Ф.Яруллин. *Сөенеч белән хатны укый башлады, ләкин күңелсезлеккә килеп төртелде.* Х.Камалов. *Кәеф шәп булганда, зуррак күңелсезлек тә җиңел үтә.* Ш.Галиев

4) Ямьсезлек, шыксызлык. *Әнвәр беренче тапкыр бүлмәсенең күңелсезлеген күреп ояллды, ләкин Лариса стенага түгел, ян яктагы иске диванга караган иде.* М.Маликова. *Тышта яктырып килә, ә аның тирә-ягында караңгылык, күңелсезлек хөкем сөрә.* Җ.Тәрҗеман

**КҮҢЕЛЧӘК** *и. сөйл.* 1) Игелекле, ярдәмчел, эчкерсез кеше. *Юк, Лена бик күңелчәк, бик шат кыз иде ул чакта!..* А.Гыйләҗев

2) Кәеф-сафа корырга яратучан, җиңел холыклы кеше. *Улың күңелчәк булса – атының бәхетсезлеге, кызың күңелчәк булса – башының бәхетсезлеге.* Мәкаль

**КҮП** *рәв.* **1.** 1) Шактый санда, байтак санда; саны ягыннан аз түгел, ишле; *киресе*: **аз**. *Дуслары һәм укучылары күп иде аның...* Г.Садә. *Ул алып кайткан дәфтәрне Өлфәт: --- – Быел күп калмады инде, дүртенчедә башлармын, – дип, ераккарак җыеп куйды.* Г.Сабитов. *Дәвам итүче үзгәрүчәнлек һәм сайлап үткәрелә торган затларның саны күп булу ясалма сайланышка ярдәм итә.* Дарвинизм нигезләре

2) Микъдары ягыннан гадәттәгедән артык яки артыграк. *Сукырлар – гаҗәп кызык халык, бөтенләй бүтән дөнья, аларга көн дә бер, төн дә бер, дип, мавыктыргыч итеп, күп тапкырлар сөйләгәне бар иде аның.* М.Галиев. *Болар аркасында килгән зыян каравылчы тоткан чыгымга караганда күп тапкыр ким.* Ә.Моталлапов

3) Чамадан тыш, тиешеннән артык. *Күп хыялландым инде мин матур тормыш, олы бәхет турында.* Ф.Яруллин. *Аннан, барысы да иркен сулыш алгач, бу хакта күп сөйләнеп йөрмәскә булдылар.* Н.Хәсәнов. *Бик үткен һәм күп сөйләшүчән булгач, Равил аны алдагы рәтләрнең берсендә утыра булырга тиеш дип уйлаган иде ---.* В.Нуруллин

4) Шактый озак. *Чит җирләрдә бик күп йөрдем, Белә алмадым хәлеңне.* Җыр. *Мирза гомеренең күп өлешен Азиядә үткәрде.* Ә.Моталлапов. *Кырлы стаканга салынган су кайнап чыксын өчен күп кирәкми.* Р.Мөхәммәдиев

5) Бик, нык, ифрат дәрәҗәдә. *Кунак, кымыздан авыз итә биреп, ерак җирләрдә бу йортны сагынып күп кайгырганын сөйләде.* Г.Ибраһимов

6) *сөйл.* Сыйфатлар алдыннан килеп, билгенең артык булуын белдерә. *Ул мин сөйләгәнгә караганда бик күп матуррак иде.* А.Шамов. *Тормыш юлы кыска булды, дөрес, Иҗат чоры аннан күп кыска.* З.Мансур

**2.** *с. мәгъ.* 1) Саны ягыннан шактый, ишле. *Ләкин әдәбият укытучыбызның дәресне күңелле итеп алып баруы аркасында, күп кенә әсәрләр белән танышырга өлгергән идем.* Г.Камал

2) Зур, шактый зур (микъдары, күләме һ.б.ш. яклары). *Ләкин имгәнгәннән соң озак вакыт үткән, шунлыктан, исән калган нерв күзәнәкләрен кабат эшләтә башлау өчен, күп тырышлык куярга кирәк булачак.* Ф.Яруллин. *Бүлеккә Фәриданең дә бик күп ярдәме тиде*

3) *-лы* кушымчалы исемнәр алдыннан килә һәм «берничә» яисә «саны ягыннан шактый» дигән мәгънәне аңлатып, кушма сүз ясый. *Шул хәтлек күп санда төзелгән җилкәнле, күп ишкәкле, палубалы, пушкалар куярга җайланган кораблар кая булганнар соң?* З.Зәйнуллин. *Гүзәлия Шакирова Азнакай шәһәренең яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү оешмасында хезмәт куйган.* Ирек мәйданы

**3.** *хәб. функ.* Күплекне, күп булуны белдерә. *Чибәрләр күп, Җан сөйгәнем бер генә.* З.Мансур. *Сөт, кабак, бәрәңге, әтәчтән башка да мактанырлык нәрсәләр күп әле авылымда.* И.Юзеев

**4. күпләр** *и. мәгъ.* Күп кешеләр. *Алай санасаң, күпләр күпләргә бурычлы инде. --- Алар да түләргә тиеш.* Р.Айзатуллин. *Дуслары һәм укучылары күп иде аның... Дөресен әйтик, аларның да күпләре Сарьян кебек бакый дөньяга күчте, сирәгәйде.* Г.Садә. *Нәҗмиев күпләр белән кул биреп күреште ---.* Ф.Садриев

◊ **Күп беләмлек** (**дәгъвасы**, **чире**) Кемнең дә булса үзен бик белдекле санавы. *Бигрәк тә аның артык иркәләнүләре, мактанчыклыгы һәм бөтен кешедән күп беләмлек дәгъвасында булуы Хөснуллага һич тә ошамый иде.* Ш.Камал. **Күп булса** Иң күп дип исәпләгәндә, иң күп дигәндә. *Күп булса ике метр чамасы ара булгандыр, шылт иткән аваз да юк, тик утырабыз.* Р.Мөхәммәдиев. **Күп дигәндә** *к.* **күп булса**. *Бу [фәнни] нигез – әле гектарыннан күп дигәндә утыз центнер ашлык чыккан җирләрдән иллене, алтмышны үстерү дигән сүз.* Х.Сарьян. **Күпкә китү** Арту, артып китү, чамадан чыгу. *Туган көннәр, төрле бәйрәмнәр күпкә китә башлады.* Ә.Моталлапов. *Кыстаулар күпкә китә башлагач, ул яңак астындагы бизләрен тотып: – Минем ангина бизләрем бар, әчкелтем нәрсәләрне яратмый, –*

*диде.* Ф.Яруллин. *Сүз болай да күпкә киткән иде.* Х.Сарьян. **Күпне белү** Нәрсә белән дә булса кирәгеннән артык кызыксыну. *Аның бу торышы миңа: «Юк инде, күпне белсәгез, тиз картаясыз!» – дип әйтә иде кебек.* Ә.Еники. **Күпне кичерү** *к.* **күпне күрү**. *Үз гомерендә күпне кичергән Хикмәт бик тетрәндергеч минутларда да йөрәген таш белән бастырырга күнеккән ---.* М.Галиев. **Күпне куу** Күп нәрсәләргә ия булырга омтылу яки нинди дә булса максатка ирешергә тырышу. *Күпне куган кешенең эше һич бетмәс.* Мәкаль. **Күпне күргән** 1) Күпне кичергән, тормыш тәҗрибәсе зур булган. *Март ишектән бактырыр, сәнәк-көрәк яктырыр, диләр күпне күргән картлар.* К.Тәхау. *Күпне күргән Хикмәтулла өчен менә шушы минуттагы җанга якын тынлык --- артык бәхет булып тоела иде.* М.Галиев. *Күпне күргән кеше булуына карамастан, директорны әлеге сорау уңайсыз хәлдә калдыра язды.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Таушалган, тузган; иске. *Күпне күргән, җил-яңгырда төсләре уңып беткән вагоннарга төяделәр дә аларны Мәскәү – Смоленск юнәлешенә таба алып киттеләр.* Р.Низамиев. **Күпне күргән, күпне кичергән** *к.* **күпне күргән** (*2 мәгъ.*). *Ул сөйли, ә син күпне күргән, күпне кичергән бу тылсым иясенең авызына карыйсың да аның сихри сөйләме артыннан иярәсең.* И.Юзеев. **Күпне күрү** Бөтен ваклыкларга, әһәмияте булмаган нәрсәләргә дә игътибар итү. *– Маңгай бөдрәләрең күлмәк ямауларың, чабата мыекларың белән бик пар килгән. – Сәкинә Сәхиягә берәр нәрсә белән тондыра. – Күпне күрсәң, мә сиңа!* Ф.Яруллин. **Күп сорамау** Уйламыйча, үзе теләгәнчә эшләү. *Мин, мөгезсез сыер кебек, алдын-артын уйламыйча, үз советыбызга барырга да күп сорамас идем, азактан ни буласын белгән юк ич.* К.Тимбикова. *[Дөнья дигәнең] карышып, тезгенен тарткалый башласаң, бер читкә селтәп, авызборыныңны җимерергә дә күп сорамый икән кайчакта.* В.Нуруллин. **Күп сулар агу** Күп вакыт узу. *[Банаев:] Яшермим: ул вакыт мин чехлар яклы идем... Ләкин, әфәндем, аннан бирле күп сулар акты.* Г.Ибраһимов. **Күп сүзле** Күп сөйли торган, сөйләмчәк. *Марина Викторовна күп сүзле, шат күңелле кеше күренә.* Ф.Яруллин. **Күптән түгел** Әле генә, моннан аз гына вакыт элек. *Күптән түгел Г.Ахуновның «Хуҗалар» исемле яңа әсәре басылып чыкты.* Х.Сарьян. *Күптән түгел генә аның яңа повесте – «Бер ананың биш улы» басылып чыккан иде.* М.Галиев. *--- священник – яшь кенә юаш егет – күптән түгел семинарий бетергән булса кирәк, кунак бүлмәсенең ишеге төбендәге урындык читенә генә утырган.* И.Тургенев. **Күп тә үтми** Тиздән, тиз арада; озакламый. *Шуннан, күп тә үтми, яраланган Гарәфине яңадан авылына кайтарып җибәрәләр.* Г.Әпсәләмов. *Күп тә үтмәс, ана тургай оя корыр.* К.Тәхау. **Күп тә үтмәде** *к.* **күп тә үтми**. *Күп тә үтмәде, самолётларга тагылган ефәк арканны сузып, планерларга беркеттеләр.* М.Галиев. *Күп тә үтмәде, берничә малай йортлар идарәсеннән озын баскыч сөйрәп китерделәр.* Ф.Яруллин. *Күп тә үтмәде, әнисе урынга егылды.* Г.Әдһәм. **Күп уйлап тормау** Озак уйлап тормыйча, шунда ук, икеләнмичә эш итү. *Күп уйлап тормый, агач башына менеп китә.* М.Фәйзи. **Күп чәйнәлгән** Бик күп сөйләнеп, бик күп мәртәбәләр кулланылып, үзенең тәэсирлелеген югалткан (тәгъбир, сүз, фикер һ.б. тур.). **Күп яшә!** Берәр тантанада, мәҗлестә һ.б.ш. очракларда озын гомер теләүне белдерә. *[Бураш:] Рәхмәт, егет, күп яшә!* М.Җәлил

**КҮП-** *кис. диал.* Кайбер сыйфатлар белән артыклык дәрәҗәсе ясый. *Кәрим яклы булып ялган шаһитлык биргән иярченнәренең йөзләре күп-күмгәк булып, тораташ булып каттылар.* Г.Камал. *Аның ярасы күп-күмгәк булып беленеп торса да, хәзер караңгыда бернәрсә дә күренми иде.* А.Шамов. *[Чечекәй әби:] Ят, ял ит. Күп-күмгәк булып өшеп беткәнсең ич.* Т.Таһиров

**КҮ́ПБАЛАЛЫ** *с.* Балалары күп булган, ишле, күп балага ия. *Аларның элитасында һәрвакыт полигамия күзәтелә: күчмәннәр, кагыйдә буларак, күпхатынлы һәм күпбалалы булганнар.* Чын мирас. *Күпбалалы гаилә*

**КҮ́ПБАСКЫЧЛЫ** с. 1) Баскычлары күп булган

2) Берничә стадиядән гыйбарәт булган. *Күп баскычлы сайлау системасы*

**КҮ́ПБАСУЛЫ** *с. а.х.* Чәчү культураларының урынын ел саен бер басудан икенче басуга күчереп чәчүгә нигезләнгән. *Күп басулы киң кырларда --- Яңа тормыш чәчәк атты.* М.Җәлил. *Күп басулы чәчү әйләнеше*

**КҮ́ПБАСУЛЫЛЫК** *и. а.х.* Игеннәрне берничә басуга чиратлаштырып чәчүгә нигезләнгән чәчү әйләнеше

**КҮ́ПБИТЛЕ** *с.* Битләре күп булган. *Өй подъездындагы җимерек почта әрҗәләренең кыйшайган авызларына ара-тирә кемнәрдер белдерүләр белән тулган күпбитле гәҗитләр кыстырып киткәлиләр.* Татарстан яшьләре

**КҮ́ПБУЫН** *и.* 1) *мат.* Берничә бербуынның суммасын тәшкил иткән алгебраик аңлатма. *Ньютон биномы формуласы күпбуынны дәрәҗәгә күтәрергә мөмкинлек бирә.* Алгебра

2) *физ., тех.* Берничә буыннан гыйбарәт (аппарат, җайланма)

**КҮ́ПБУЫНЛЫ** *с.* 1) *мат.* Берничә бербуынның алгебраик суммасыннан торган. *Күпбуынлы алгебраик аңлатма*

2) *физ., тех.* Буыннары күп булган (җайланма, аппарат һ.б.ш. тур.). *Күпбуынлы тезмә ракеталар, К.Э.Циолковский алдан әйткәнчә, хәзер бездә һәм чит илләрдә зур тизлек белән һәм гаять ерак араларга очалар.* Космик ракеталар. *Күпбуынлы вал*

**КҮ́ПВАКЫТ** *рәв.* Еш кына, күп очракта. *--- мин әле автобусларына да күпвакыт түләми йөрим.* Ф.Яруллин. *Төрле язмыш, төрле хәлләрне ишеткәләргә туры килә, аларны күпвакыт артык кызыксынмыйча, --- тыңларга кирәк булган өчен генә тыңлыйсың.* Ш.Җиһангирова

**КҮ́ПДИНЛЕ** *с.* Күп диннән торган; күп диннәр булган. *Ул гына да түгел, күпмилләтле һәм күпдинле илдә ошбу проблемаларның тулысынча чишелеше сәяси системаны модернизацияләүнең нигезенә салынырга тиеш.* Мәдәни җомга

**КҮПЕ́К БАЛЫГЫ** *и. иск.* Акула

**КҮПЕР** *и.* 1) Елга, чокыр, тимер юл һ.б.ш. аша үтеп йөрү өчен, шулар өстеннән салынган корылма. *Авыл читендәге күпергә килеп кергәндә генә, татлы уйлар тозагыннан ычкынып, чынбарлыкка кайтып төште кыз.* С.Шәмси. *Әни көтүне күпергә кадәр озатыша төшә.* М.Галиев. *Аксуны икегә бүлеп аккан елга ярларын асылмалы күпер тоташтыра.* Г.Әдһәм

2) Яр буенда пароходка, паромга керү, көймәләр туктау өчен ясалган корылма. *[Пароходка] Керә торган күпердә ыгы-зыгы көчәйде.* Ә.Моталлапов. *Паром туктый торган күпердә, кулына кармак сабы тотып, Салих утыра.* Г.Мөхәммәтшин

3) Су читендә кер чайкау өчен, такта яисә бүрәнәләрдән ясалган киң басма

4) Ремонт яки төзү эшләре алып бару өчен, бина стеналары тирәли такталардан ясалган мәйданчык (төзелеш басмасы). *Ул буш вакытларда төзелеш басмаларының иң югары күперенә менәргә, шуннан торып тирә-юньгә карарга ярата.* А.Шамов

5) *тех.* Автомашинада, тракторда һәм шундый машиналарда шассиның көчне дифференциалдан ике тәгәрмәчкә күчерү механизмы урнашкан өлеше. *Арткы күпер корпусыннан майны корпус төбендәге магнит бөкеле тишектән агызып алалар.* Тракторлар. *Алгы күпер*

6) *спорт* Җиңел атлетикада учларга (яки башка) таянып һәм үкчәләрне җиргә терәп, гәүдәне өскә дугаландырудан гыйбарәт гимнастик фигура

7) *махс.* Ясалма тешләрне казнага беркетә торган җайланма, планка

8) *анат.* Баш миенең озынча ми белән урта ми арасына урнашкан өлеше. *Озынча мидән югарырак, аңардан ачык рәвештә аркылы буразна белән аерылган күпер ята.* Анатомия

9) *күч.* Сөйләнелә яисә языла торган фикерләр арасындагы логик бәйләнеш, эзлекле күчеш

10) *күч.* Кешенең эчке кичерешләре белән тудырылган дөньясы. --- *вакыт-вакыт, балдызының беркем башына килмәгән кыланышлары Гайфулланың хәтер күпере аша үтеп, йөрәген кысылып куярга мәҗбүр итә иде.* Ф.Яруллин

◊ **Күпер башында күчәр башлары эләгешкән** Ерак туганнарга яки бөтенләй ят кешеләргә карата әйтелә. **Күпер башында тәртә очлары орынган** *к.* **күпер башында күчәр башлары эләгешкән**. **Күперләр җимерелү** Мөнәсәбәтләр өзелү. *Ләкин дөнья һичбер вакыт син теләгәнчә генә бармый. --- я сөйгәнеңнең кочагына атылам дигәндә генә, күперләр җимерелеп, билгесезлеккә ташланасың.* Ф.Яруллин. *Фәрдәнә белән синең арадагы күперләр җимерелде.* Ә.Гаффар. **Күперләр җимерү** *к.* **күперләр яндыру**. *Үткәнгә илтүче күперләрне җимереп ташлавына сөенә.* Ф.Яруллин. **Күперләр яндыру** 1) Тәвәккәлләү, җитди карарга килү; 2) Артка чигенергә, фикерне үзгәртергә мөмкинлек калдырмау. *[Зайцев] Артка чигенмәс өчен, әшәкелек юлындагы күперләрне яндыргандай булды.* М.Насыйбуллин. *[Дина:] Ә безнең чигенер өчен күперләр яндырылган.* М.Мәһдиев

**КҮПЕРЕЛЕП** *рәв.* Үсемлек яки игеннәрнең бик яхшы булып, тиз, мул үсүе турында. *Төрле матур чәчәкләр җәй саен күперелеп үсәләр.* Ак юл

**КҮПЕРЕЛҮ** *ф.* Котырып үсү, мул булу

**КҮПЕРЕНКЕ** *с.* 1) Күпереп торган, кабарынкы, кабарып торган. *[Кояшның] зәңгәрсу ак нурлары якты тасмалар булып күккә сузылган, һавада тын гына тирбәлеп йоклап ятучы күперенке ак болыт канатларын алтынга манган иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Төнлә кар явып узган, күрәсең, күперенке көртләр өстенә кер кунып өлгермәгән әле.* М.Маликова // Кабарып торган, куе (чәч, йон, мамык һ.б.ш. тур.). *Беренче тапкыр больница тәрәзәсеннән хәлсез генә кул болгап, күперенке мыек астыннан елмайган көненнән башлап, кайтырына ышанып көттем.* М.Галиев. *Калын иреннәр, зәңгәрсу зур күзләр, күперенке чәчләр, болай сөйкемле генә үзе.* С.Шәрипов. *--- карсак төлке йомраннан азрак зуррак, --- аның күперенке коерыгы бар иде.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Нәзакәтле дип саналган яки төче сүзләр белән чуарланган; купшы (сөйләм һ.б.ш. тур.). *Аннары күперенке сүзләр белән маташырга теләк тә юк иде.* А.Шамов. *[Шагыйрьнең] сүзләре дә шигырьләре сыман хиссез, күперенке иде.* Х.Сарьян

**КҮПЕРЕНҮ** *ф.* 1) Дымнан, җылыдан һ.б.ш. күренешләрдән кабару, кабарынкы хәлгә килү. *Тәрәзәдән яз җылысы белән күперенгән дымлы җир исе, тал бәпчекләренең төчкелт исе бәреп тора иде.* Г.Бәширов

2) Күбеккә әйләнеп күтәрелү. *Күперенгән дулкын*

3) Кабару, күперү (чәч, мамык һ.б.ш. тур.). *Әйтерсең урман өстенә бриллиант тузаны яуган, бөтен җир --- утта яна: мамыктай күперенеп, тәңкәләнеп каткан кар өстеннән кояш нурлары кире чәчриләр – һич туры карап булырлык түгел.* И.Юзеев

4) Төкләрен, йоннарын, каурыйларын күпертү (кошлар яки хайваннар тур.). *Күркә күперенгән*

5) Тазару, симерү. --- *икенче бер малай урамга тачка ясап чыккан, --- аркылы тактасына үзенең ике-өч яшьлек ыштансыз энесен, аш ашап, сөт эчеп күперенгән корсаклы, юеш борынлы малайны да утырткан ---.* М.Мәһдиев

6) *күч. сөйл.* Ачулану, усаллану. *Ирләр шул арада, калай әтәчләр кебек күперенеп, кызып-кызып бәхәсләшергә тотындылар.* К.Тимбикова

**Күперенә бару** Торган саен ныграк күперенү. *Олаучым, үлем алдындагы кеше кебек, сулышын еш-еш ала һәм, бәлане миннән күрергә теләгәндәй, минуттан минутка миңа сүзсез генә күперенә барган кебек иде.* Ф.Хөсни

**Күперенә башлау** Күперенергә тотыну. *[Фәрхи карчык:] Күперенә башласаң, бер дә юкка каз куыгы шикелле күперенәсең дә китәсең.* Ш.Камал

**Күперенә төшү** Бераз, беркадәр күперенү; тагын да ныграк күперенү

**Күперенеп китү** Кинәт күперү

**Күперенеп тору** Күпергән хәлдә булу. *[Атның ялын], башкалар кебек, бөтенләй бетертмәдем: бер чирек кадәрлерәк калдырып, үзеннән-үзе күперенеп тора торган иттем, төзәттердем.* Г.Ибраһимов. *[Хәят] үз-үзләреннән күперенеп тора торган*

*--- чәчләрен тараганда, Лиза дача хәлләрен сөйли торды.* Ф.Әмирхан

**КҮПЕРМӘ** *и. к.* **күпертмә** (*1 мәгъ.*). *Гөлҗиһан күпермә иңбашлы, тар билле, киң итәкле алсу асыл күлмәктән иде.* А.Расих

**КҮПЕРТЕК** *с. к.* **күперенке**. – *Бисмиллаһир-рахманир-рахим, – дип, Рәшидә абыстай Талмудны кулына алды, күпертек иреннәре белән үпкәндәй итте ---.* М.Хәбибуллин

**КҮПЕРТКЕЧ** *и.* Йомырка, каймак һ.б.ш.ны күпертү өчен кулланыла торган агач калак, таякчык, туглагыч. *[Чәлпәк пешерү өчен] йомырканың сарысын агыннан аерып алып, шикәр комы кушарга һәм агач кашык яки махсус күперткеч белән туглап күпертергә кирәк.* Халык ашлары

**КҮПЕРТМӘ** *и.* 1) Хатын-кыз күлмәге һәм алъяпкычының иңбашларына бөрдереп тегеп куелган, канатсыман булып күпереп торган тукыма кисәге, бизәк. *Ызан буйларында күпереп үскән чәчәктәй, юл тулы халык: җиңел чабаталы, бәбәй итәкле апалар, күпертмә иңсәле күлмәк кигән кызлар ---.* Х.Сарьян

2) Хатын-кызларның гәүдә төзелешен тулырак күрсәтү өчен, эчке киемгә өстәп тегелгән эшләнмә. *Тормышлары бик үк мулдан булмаса да, кызый матур булып тулды, башка кызлар куеп йөри торган ясалма мамык күпертмәләр бер җиренә дә кирәк булмады.* М.Мәһдиев

3) Хатын-кыз күлмәгендә челтәрдән яки җиңел тукыма кисәгеннән ясалган бөрмә

4) Куе итеп тугланган төче камырдан, табага салып, мичтә пешерелә торган азык

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күпереп торган, кабарып торган, кабарынкы. *Бу озын торыклы, күпертмә савырлы атлар аңа бик тә, бик тә таныш иде.* Р.Зәйдулла

2) Күпертелгән, арттырылган. *Атласов белән икесе каяндыр алган күпертмә санны [аның] йөкләмә итеп күрсәтүе Садыйковны тетрәтеп җибәрде.* С.Рафиков

**КҮПЕРТҮ** *ф.* 1) Чи йомырка, йомшак камыр һ.б.ш. нәрсәләрне туглыйтуглый күбеккә әйләндереп кабарту. *Йомырка агын тәмам күбек хәленә килгәнче туглагыч белән күпертергә, --- шуңа шикәр оны яки шикәр комы салырга.* Йорт эшләре. *Помадка йомырка агын күбекләнгәнче күпертеп һәм аны чикләвек, шикәр пудрасы белән туглап ясала.* Тәмле тамак

2) Күбекләндерү. *Ишектән Хәмзә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән.* Г.Камал. *Зур-зур дулкыннар, ак кикрикләрен күпертеп, бер-бер артлы йөгерешеп киләләр ---.* Г.Сабитов

3) Көпшәкләндерү, көпшәк хәлгә китерү; кабарту (туфракны һ.б.ш.ларны). *Яңгырый мотор җырлары, Күпертә җирне сабан.* З.Мансур

4) Кабарту, кабарынкы хәлгә китерү. *Сәгыйдә --- түшәкне кабартты, ястыкны күпертте, --- юрганны ачты ---.* Г.Исхакый. *--- бүлмә тактасы буенда күпертеп, пөхтәләп җыештырылган иске генә тимер карават.* Ә.Еники

5) *күч.* Бәяләрне кирәгеннән артык күтәрү. *Үз товарларын күпертелгән бәяләр белән саткан монополияләр шул ук вакытта крестьян хуҗалыкларыннан продуктларны чиктән тыш түбән бәяләр --- [белән] сатып алалар.* Политэкономия

6) Арттыру, күбәйтү. *Зур авызын ачып, йомшак йонлы канатларын җәеп азапланган кошчыкның кыяфәте күңелдәге шомны тагын да күпертте.* М.Маликова. – *Чыннан да, егетләр, артыграк күпертү китте бездә. – Барысын да ал да гөл итеп күрсәтергә бик ярата башладылар.* Р.Төхфәтуллин

7) *күч.* Берәр хәлне, күренешне чынбарлыктагыдан арттырып, чамадан тыш зур итеп күрсәтү. *Сүзләрендә шактый гына күпертү булса да, рәсемдә, чынлап та, Гыйлемхан сипләгән җыйнак кына, гадәти генә авыл өе иде.* Р.Мөхәммәдиев. *--- юклы-барлы уңышларны күпертеп язылган докладтан соң, күңел ачу өлеше башланды.* С.Шәрипов. *Дамирә күперткән: монда шаһинә дә, шаһ та юк, монда һәммәсе дә – гап-гади артист.* Н.Гыйматдинова

**Күпертә төшү** Бераз, беркадәр күпертү

**Күпертеп алу** Тиз арада күпертү. *[Әнисә] Җиләкнең татлысын гына җыя, газда күпертеп кенә ала.* М.Маликова

**Күпертеп җибәрү** Тагын да ныграк күпертү. – *Хатын, ни булды сиңа, ник җенләнәсең? – дип, кабарган ачуын тагын да күпертеп җибәрде.* З.Кадыйрова

**Күпертеп кую** Күпергән хәлгә китерү. *Фәридә күпертеп куйган чал чәчле башын иеп уйга калды.* М.Маликова

**Күпертеп тору** Күпергән хәлдә тоту

**Күпертеп чыгу** Берәм-берәм, һәрберсен аерым-аерым күпертү

**КҮПЕРТҮЛЕ** *с.* 1) Күпертеп куелган, күпертмәле

2) *күч.* Чамадан арттырып җибәрелгән. *Фәйзулла Хаҗиевич --- басынкы ханымга күпертүле мактау сүзләре әйтә, аның кәефен күтәрмәк була.* Ш.Рәкыйпов

**КҮПЕРҮ** *ф.* 1) Күбекләнеп күтәрелү, кабару. *Менә тагаракка сыймыйча ак күбекләр күперә.* Г.Әпсәләмов

2) Әчүдән күләме зураю, кабарып чыгу, күтәрелү (камыр, катык һ.б.). *Иртәнге якта йокыдан уянып, хатын да, ир дә рәхәтләнеп тыңлап ята, мич башына куелган күәс чиләгендәге камыр сулыш ала, яши, күперә.* М.Мәһдиев

3) Нәрсәнең дә булса туглаганнан күләме арту. *Пешкән әзер массага элек сөзеп куелган мук җиләге салып, куе күбеккә әйләнгәнче туглагыч белән күпертергә, масса күпереп ике өлеш арткач, аны вазаларга салырга ---.* Йорт эшләре. *Каймакка шикәр оны салып, күпергәнче тугларга.* Тәмле тамак

4) Көпшәкләнү; кабарып йомшару. *Вак соры яңгырдан җир туя, күперә.* М.Мәһдиев

5) Пешкән вакытта кабару, кабарган хәлгә килү (ипи, коймак һ.б. тур.). *Ул арада таба ипие күпереп пешә дә башлый ---.* Ф.Яруллин. *Коймак пешергәндә, күмернең кирәге дә юк, коймак матур булып күпереп пешсен өчен, өстән ялкын гына кирәк.* М.Мәһдиев. *Чигелгән ак ашъяулык өстендә ---, күпереп пешкән ап-ак икмәк, майда пешерелгән чәй токмачы ---.* Р.Мөхәммәдиев

6) *сөйл.* Тулылану, симерү, тазару. *Ни өчен берәүләр корсак киерәләр, кабаралар, күперәләр дә, ни сәбәпле*

*икенчеләр ачлыктан каталар, үләләр?* Г.Тукай. *Гарәфи абзыйның маңгай өстендәге чәче коелып беткән булса да, яңаклары бодай кабартмасы кебек күпереп тора.* Г.Әпсәләмов

7) Кабару, кабарып тору. *Безнең йорт каршысындагы урам ялт итеп себерелгән булыр, анда куе яшел чирәм, хәтта --- хәтфәдәй күпергән алма үләне, бәпкә үләне үскән булыр.* Г.Ахунов. *Лесниковның чигәләре күперде, күз аллары томаланды, ---.* С.Шәрипов. *Чүпрәле камыр ризыклары яки составында чүпрә булган эчемлекләр куллану да эч күперүгә китерә.* Ирек мәйданы

8) Йоннарын кабарту, тырпайту. *Кайсы чакта күперсә дә, тиз шиңә бит теге, ишегалдындагы ата күркә.* Г.Тукай

9) Нәрсәнең дә булса (кием, җилкән һ.б.ш.ның) җилдән кабаруы. *Көннәрнең берендә базар халкы Кари әфәндене велосипедка атланган хәлдә күрделәр: аның зәңгәр җөббәсенең киң җиңнәре җил белән күпергәннәр.* Ф.Әмирхан

10) Шешү, ялкынсыну. *Моңа әллә ничә төштән каршы тавыш бирделәр: – Суык тиюе бар. – Ютәл эләктермәгәе. – Үпкәсе күпермәсме соң?* Ә.Гаффар

11) *күч.* Арту, зураю (гайбәт, хәбәр, начар сүз һ.б.). *Имеш-мимешләр торган саен күперде, әллә кайчан хәтердән төшкән сүзләр яңадан калкып чыкты.* А.Тимергалин // Арту, күбәю. *Кеше баеды, кесәдә акча күперә, ә ул һаман шул – ахмак.* Р.Зәйдулла. *Винтер укуыннан туктый, уйлары янә күперә ---.* А.Мифтахетдинов

12) **күпереп** *рәв. мәгъ. сөйл. к.* **күперелеп**. *Ызан буйларында күпереп үскән чәчәктәй, юл тулы халык ---.* Х.Сарьян. *Урманнар түбәндәрәк башлана, ә күл буендагы болыннарда, затлы келәм сыман, сусыл яшел үлән күпереп үсә.* А.Муранов

**Күперә бару** Торган саен ныграк күперү. *Гайбәт, күпергәннән-күперә барып, бистәгә бик тиз таралып өлгерде.* Г.Гобәй

**Күперә тору** Күперүне дәвам итү. *Баш күперә тора, бераздан мич башындагы җилпучта он да җылына ---.* М.Мәһдиев

**Күперә төшү** Бераз, беркадәр күперү

**Күпереп китү** Нindидер сәбәпләр аркасында кинәт күперү. *Бер атна эчендә танымаслык булып көрәйде үзе [эт]. Йоннары күпереп китте.* Г.Сабитов

**Күпереп тору** Күпергән хәлдә булу. *Ул йон чистартылган, язылган була, шуңа күрә күпереп, таралып тора.* Х.Сарьян. *Бервакыт, иренең пинжәген чистартканда, күпереп торган кесәсенә ялгыш кулы тиеп китмәсә, һаман аны-моны искәрми яшәр иде бәлки.* Ф.Яруллин. *Алар да җырлый: чип-чиста туннарын --- сандыктан чыгарганнар, --- муеннарда сарык йоныннан бәйләнгән, кичә генә мунчада юып киптерелгән, күпереп торган ак күбек шарфлар ---.* М.Мәһдиев

**Күпереп чыгу** Тәмам күперү. *Яңагым сизелерлек күпереп чыккан, шешкәне күземә үк күренеп тора ---.* Г.Сәгыйров

**КҮПЕРЧЕ** *и.* Күпер салучы, күперләр салу эшен башкаручы кеше

**КҮПЕРЧЕК** *и.* 1) *кеч. форм. к.* **күпер** (*1, 2, 3, 7 мәгъ.*). *Ул җен ачуы белән мәетнең казналыгын вата-җимерә, алтын тешләрне, металл күперчеге белән йолкып алып, кабер өстендә торган Ромага бирде.* З.Фәйзуллин

2) Корабльләрдә, кайбер машиналарда күзәтү, идарә итү өчен мәйданчык. *Капитан, күперчекнең сул як канатына чыгып, пароходны тотып торучы бауларга күз салды.* М.Юныс. *Фәргать --- төзелешкә җиткәч, кран юлы шпалларына басып барды-барды да --- кран күперчегенә күтәрелде ---.* Н.Хәсәнов. *Әти биек комбайн күперчегендә штурвал тотып бара.* М.Галиев

3) *спорт* Сикерү басмасы, трамплин. *Суга сикерү күперчеге*

**КҮ́ПКАНАТЛЫЛАР** *и. зоол.* Озын (бәләксыман) тәнле, аркаларында күпсанлы төркемнәр булып урнашкан кылчыксыман йөзгечләре булган балыклар төре; *русчасы*: **многопёрообразные**. *Күпканатлылар тропик Африкадагы төче сулыкларда яшиләр.* Дарвинизм нигезләре

**КҮ́ПКАТЛАМЛЫ** *с.* Катламнары күп булган, күп катламнардан торган. *Хәзерге заман кешесе өчен мәхәббәтне саклап калу – аңа өстәмә итеп ярашу сыйфатларына ия булу дигән сүз; мөгаен, мәхәббәт бүген шушы күпкатламлы кушылманың өлеше буларак кына яшәп кала ала торгандыр...* Тигез гомер итегез!

**КҮ́ПКАТЛЫ** *с.* Күп каттан торган, күп каттан хасил булган. *Рөстәм Миңнеханов залдагы архитекторларга --- мөрәҗәгать итеп: «Татарстан тиз төзелә торган күпкатлы һәм шәхси йортларның заманча технологияләренә мохтаҗ», – диде.* Ватаным Татарстан

**КҮПКӘ** *рәв. сөйл.* 1) Озак вакытка, озакка. *Монда үткән бер матур көн Онытылмас күпкә кадәр.* Ш.Маннур. *Акча күпкә җитмәү*

2) Шактый. *Мондый шартлаткыч эшне дә күпкә ансатлаштыра, куркынычсызрак та.* М.Маликова. *Шундый бер кызыклы закончалык та мәгълүм булган: иске китаплар хәзергеләреннән күпкә яхшырак саклана.* Мәдәни җомга

**КҮ́ПКВАРТИРЛЫ** *с.* Берничә яки күп квартирдан гыйбарәт. *Күпквартирлы йортлар эксплуатациягә тапшырылды*

**КҮ́ПКҮЗӘНӘКЛЕ** *с.* Күпсанлы күзәнәкләрдән торган организмнарга, җәнлекләргә, үсемлекләргә һәм гөмбәләргә карата әйтелә. *Кайбер галимнәр күрсәтүенчә, протерозойда төрле бактерияләр белән күпкүзәнәкле су үсемнәр киң таралган.* А.Фаткуллин. *Иң борынгы чор күпкүзәнәкле хайваннарның булмавы белән характерлана.* Дарвинизм нигезләре

**КҮ́ПКҮЗӘНӘКЛЕЛӘР** *и. күпл. зоол.* Тәннәре күпсанлы күзәнәкләрдән барлыкка килгән тукыма һәм әгъзалардан торган организмнар (үсемлекләр, гөмбәләр, хайваннар); *русчасы:* **многоклеточные**

**КҮ́ПКЫЙММӘТЛЕ** *с. мат.* Берничә цифрны үз эченә алган, берничә цифрдан гыйбарәт. *Кире тригонометрик функцияләр – күпкыйммәтле функцияләр.* Югары математика нигезләре

**КҮ́ПКЫЙММӘТЛЕЛЕК** *и. мат.* Күпкыйммәтле булу. *Кире тригонометрик функцияләрнең графиклары аларның күпкыйммәтлелеген аерымачык*

*күрсәтәләр.* Югары математика нигезләре. *Санның күпкыймммәтлелеге*

**КҮ́ПКЫРЛЫ** *с.* 1) *махс.* Берничә кыры (ягы) булган, берничә кырдан (яктан) торган. *Күпкырлы игәү. Күпкырлы геометрик фигура*

2) Бер ноктада кисешүче берничә яссылык тарафыннан барлыкка китерелгән. *Әгәр күпкырлы почмакның барлык кырларын яссылык белән кистерсәк, кисемдә күппочмак килеп чыга.* Геометрия

3) *күч.* Күп төрле тармакларга караган, күп төрле якларны үзенә алган, төрле үзенчәлекләре булган. *Сез – һәркайда кирәк кеше, кабул итәрләр. Күпкырлы талант иясе өстенә шагыйрь дә икәнсез әле...* Ә.Моталлапов. *Эх! Нигә мин шундый күпкырлы икән?..* Җ.Фәйзи. *Бер сүз белән әйткәндә, күпкырлы сәләтле кеше иде.* М.Зәкәриева

**КҮ́ПКЫРЛЫК** *и. мат.* Барлык яктан да яссы күппочмаклар белән чикләнгән геометрик җисем. *Күпкырлыкның бер ноктадан чыккан кырлары күпкырлы почмак төзиләр.* Геометрия. *Төзек күпкырлык*

**КҮ́ПКЫРЛЫЛЫК** *и.* Күпкырлы (*2 мәгъ.*) булу. *Иҗатның күпкырлылыгы*

**КҮПЛӘП** *рәв.* 1) Бик күп санда яки бик күп микъдарда. *Әмма мине иң борчыганы: Барлас матур-матур сүзләрне, тәгъбирләрне күпләп исраф итә.* Х.Сарьян. --- *китаплар икенче көнне шкафтан юкка чыктылар. Моның абыйсы эше икәнен белгәнгә, үч итеп, тагын күпләп алып кайтты.* Ф.Яруллин. *Татарлар күпләп яши торган төбәктә торганнар алар.* Ә.Моталлапов

2) *махс.* Зур партияләр белән, күп микъдарда, күмәртәләп (товарларны алу һәм сату тур.). *Сәүдәне белә Казан халкы! Рекламалары кычкырып тора, ихтыярсыз кесәңне капшарсың. Күпләп кызыл мал сәүдәсе...* Г.Әпсәләмов. *Шәвәлиев колхоз-совхозлардан күпләп ит алучы җитәкчеләрнең исемлеген Вафинның алдына китереп салды.* Ф.Садриев. *Тик менә яшергән җирдән игенне базарга ничек апчыгарга, шуңа һич акылым җитми, каян табаргадыр күпләп сатып алучыны?* Х.Сафина

**КҮПЛӘТӘ** *рәв. к.* **күпләп** (*2 мәгъ.*). *Ә икенчесе үзенең җире җитәрлек булуы өстенә, 48 дисәтинә җирне чагыштыргысыз арзанга, дисәтинәсен 3,55 сумга күпләтә «сатып ала».* В.Ленин

**КҮПЛЕК** *и.* 1) Күп булу; нәрсәнең дә булса саны бер генә булмау. *Эшнең күплегеннән киленнең зарлануы да колакка кермәде.* Г.Исхакый. *Хәер, эш китапның күплегендәмени: түшәме биек булып та, өйрәсе сыек булмактан ни файда!..* Х.Сарьян. *Бүген ул үзенә игътибарлы карашлар артык күплектәнме, эчтән балкып киткән.* М.Галиев

2) Нәрсәнең дә булса муллыгы, микъдар ягыннан күп булуы, ишлелеге. *Каберләр өстендәге мәрмәр истәлек һәйкәлләр, кемнеңдер кемгәдер якын мөнәсәбәте төсендә, акчасы күплектән генә куелганлыгын кычкырып тормый ---.* Ш.Рәкыйпов. *Арал суының аеруча үтә күренмәле булуы һәм анда кислородның чагыштырмача күплеге әнә шуннан килә икән.* А.Муранов

3) *лингв.* Предмет һәм күренешләрнең ике яки аннан артык булуын белдергән грамматик категория. *Ә бүген минем әйтәсе сүз башка: язучыларыбыз нигәдер күплек кушымчасы белән артык мавыга башладылар.* Х.Сарьян. *– Сөйләгез, сөйлә, мин шаяртам гына, – диде Хәлимов та җитдиләнеп. – Сез, – ул беренче тапкыр шулай күплек санда аңа дәште, – моны ничек бәялисез?* Р.Айзатуллин. *– Өч прәннек бирегез тагын, – дидем, аныңча күплек санда эндәшеп.* М.Галиев

**КҮ́ПМАНДАТЛЫ** *с.* Сайлау системасына нигезләнгән дәүләт органы туплауда катнашучы сәяси төркемнәргә (партияләргә) бирелгән хокукый документ төре турында. *Күпмандатлы сайлау системасы*

**КҮ́ПМӘГЪНӘЛЕ** *с. лингв.* Күп мәгънәгә ия, берничә мәгънәсе булган. *Татар лексикологиясе дәреслекләрендә сүзнең бермәгънәледән күпмәгънәле булып әверелү ысулларын аңлату, асылда, рус теле лексикология дәреслекләрендә язылган фикерләрне кабатлау нигезендә бара.* И.Бәширова. *Баш килеш --- – күпмәгънәле килеш һәм шактый еш туры объект мәгънәсен, ияләк мөнәсәбәтен һ.б. мөнәсәбәтләрне белдерә ала.* Татар теле морфологиясе. *Омонимнарны күпмәгънәле сүзләр белән бутарга ярамый.* Хәзерге татар әдәби теле

**КҮ́ПМӘГЪНӘЛЕЛЕК** *и.* Күпмәгънәле булу, берничә мәгънәне эченә алу. *Совет цензурасы шартларында --- укучыга чынлыкны җиткерү бурычы намуслы художниктан --- сайланган сүзләрнең кинаяле күпмәгънәлелеген, фикерне укучы күңелендә дәвам итәрлек тирән итеп салуны таләп итә иде.* Р.Фәтхрахманов. --- *хәзерге татар телендә бер үк сүзнең үзара бәйле булган берничә лексик мәгънә белдерә алу мөмкинлеге полисемия, күпмәгънәлелек --- дигән исемнәр белән атала.* И.Бәширова. *Сүзнең, төп мәгънә белән беррәттән, өстәмә мәгънәләргә ия булуы аның күпмәгънәлелеге дип атала.* Хәзерге татар әдәби теле

**КҮ́ПМЕ** *а.* **1.** 1) Предметларның яки затларның саны, микъдары турындагы сорауны белдерә. *Әйттем мин сиңа, тырышма ул кадәр, бетермә үзеңне, дип... Безгә, карт белән карчыкка, күпме кирәк соң?* С.Шәмси. *Карале, кияү, синең Шайтан калаң астына күпме кеше сыя ала?* М.Хәбибуллин. *Аның бит әле ата-анасы, туган-тумачасы да бар дигәндәй, беләсеңме, күпме кешенең тынычлыгы качачак?* Р.Мөхәммәдиев

2) *сөйл.* Вакыт турында: озакмы, никадәр, ничә сәгать? *Ә Гатауллин күпме ята инде?* Ф.Яруллин. *Көтәм, көтәм. Күпме дисез, шулай көтәргә риза...* Р.Мөхәммәдиев. *Бу халәт күпме дәвам иткәндер – ул белми.* Ф.Латыйфи

3) *сөйл.* Ни бәя, ни хак? *Бу юлы инде берәүнең дә машинасын туктатып, аннан: «Күпме?» – дип сорарга башына килмәс.* М.Маликова. *[Сафура:] Бәяләрен күпме куярсың икән?* Т.Гыйззәт // Акча турында: никадәр, ничә сум? *– Хезмәт хаклары ничек соң? --- Күпме аласың шулай да? – дип, төпченүен дәвам итте ул һаман.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул, Фәниярның шагыйрь икәнлеген белгәч, иң беренче итеп: «Күпме аласың? – дип сорады. – Пенсияң күпме?»* Ф.Яруллин. *Лениза акчаны янында кирәк кадәр генә йөртә иде.*

*– Күпме бирим икән? – дип сорады.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Гадәттә, тойгылы җөмләләр составында килеп, берәр нәрсәнең күп санда яисә микъдарда булуын белдерә. *Киләчәктә казу эшләрен менә кайда җәелдереп җибәрәсе иде – борынгы кешеләр тормышына кагылышлы күпме яңа табылдыклар бүләк итә алыр иде бу урын!* А.Сункишев. *Рәхмәт сезгә! Күпме ашлыкны коткарып калдыгыз!* Г.Сабитов. *Үзләре авылда яшәп, бөтен гаиләсе белән производствода эшләгән, күпчелектә карт әнисе аркасында бәрәңге бакчасы белән мал-туарын тоткан акыллы крестьяннар күпме хәзер!* Х.Сарьян // *Әллә, менә, әнә* кебек сүзләр янында килеп, алар ачыклаган сүзнең мәгънәсен тагын да көчәйтә төшә. *[Госманов:] Йортыңда әллә күпме тирелләрең бар.* Һ.Такташ // *Сәхнәләрдә, нәкъ чын шикелле итеп, күпме үлдек, күпме терелдек?* Р.Фәйзуллин. Шактый, бик күп; берничә мәртәбә. *Шуны саклап кала алмаганына соңыннан күпме үкенде Әнсар.* Х.Ибраһим

2) Билгесез вакытны белдерә: никадәр. *Күпме йоклаганны белмим, безне уяттылар.* Г.Исхакый. *Күпме дәвам иткәндер бу хәл, тик бераздан гына ул үзенә төбәлгән бер пистолет, ике автомат көпшәсен күреп алды.* Ә.Еники. *Күпме йоклаганмындыр – белмим, кинәт кемдер мине төрткәли башлады.* Ә.Айдар

3) Берәр нәрсәнең билгесез, чама белән әйткән микъдарын белдерә. *Гадәттән тыш гади әйтә халык, ләкин шуңа күпме мәгънә, күпме тирәнлек, күпме моң салып әйтә.* Г.Ахунов. *«Акча кирәк булганда тартынма, миннән сора, күпме сорасаң да бирермен», – дип борчак сиптергән бәндә, баксаң, үзе --- кешеләрдән акча сыгып алучы икән...* Ә.Нигъмәтуллина. *Ул карлы кичләрнең кәгазьгә сыя алмаган күпме хатирәләре кем белән дә бүлешеп булмый торган сагынуга әйләнеп калгандыр...* М.Галиев

**3.** *бәйл. функ.* Иярчен тәмамлык, иярчен күләм һәм аергыч җөмләләрдә мөнәсәбәтле сүзләр составында бер җөмләне икенче җөмләгә бәйли торган чара буларак кулланыла: *Ләкин ишек төбендәгеләр, кулларына тигән савытта күпме шулпа бар, һәммәсен эчеп бетерергә тырыштылар.* Г.Ибраһимов. *Кем күпме укый, шулкадәр күп белә*

◊ **Күпме дә булса** Беркадәр; билгеле бер санда, микъдарда. *Ләкин бу китапта күпме дә булса үзенең катнашы барлыгын ул берәүгә дә әйтмәде.* Ә.Фәйзи. **Күпме кирәк** 1) Җитәрлек дәрәҗәдә, теләгәнчә; кирәк кадәр; 2) Бик нык, бик каты (кыйнау һ.б.). *Ала да, колагыннан тотып, уңлап-суллап, күпме кирәк!* А.Шамов

**КҮ́ПМЕ-АЗМЫ** *рәв. сир.* Беркадәр, бераз, билгесез үткән вакыт турында. *Күпме-азмы ятканнан соң, ул йокыга талган кебек булды.* Ә.Еники

**КҮ́ПМЕГӘ** *а.* 1) Ни хакка, ни бәягә? *Юл буенда ул, күрше авылның тегермән осталарына кереп, күпмегә эшләп бирүләрен сөйләште.* Г.Исхакый. *Фарукҗан бу көннәрдә мамыкның, киптерелгән җимешләрнең чын бәясен иптәшләреннән сорашып, җирен уртагыннан файдаландырган байның авылдашларын күпмегә алдавын анykларга омтылды.* Т.Әйди. *Чыгым барыбер күбәя инде, Харис ---. Кием-салымның гына да күпмегә төшүен үзең беләсең.* Ә.Моталлапов

2) Никадәр вакытка, никадәргә, озаккамы? *Тынсыз калган бу рәхәт минутлар күпмегә кадәр сузылгандыр, юл буеннан чатыр чабып килгән ат тавышы ишетелде.* М.Мәһдиев. *Бу гарьлекле «уен» күпмегә сузылган булыр иде.* М.Галиев. *Тагы күпмегә сузылган булыр иде икән бу халәт, белмим.* Р.Мөхәммәдиев

3) Берәр нәрсәнең күп санда яисә микъдары зур булуын белдерә. *Мәдрәсәдә укыганда да, бу повестьтагы кебек, йөз шәкертнең берсе булмаган, ул алардан әллә күпмегә күтәрелеп торган.* Х.Сарьян. *Менә шуннан инде ул ананың кайгысы күпмегә артуын үзең чамалап кара.* Г.Байбурин

**КҮ́ПМЕГӘДЕР** *а.* Күләме, срогы билгеле булмаганны белдерә: никадәргә, никадәр вакытка. --- *принципиаль көрәш, чөнки берсенеке җиңсә – үсешнең кинәт алга китүе хәл ителә; икенчесенеке җиңсә – үсешнең күпмегәдер тоткарлануы бар.* Х.Сарьян. *Шуның өстенә исләр: ат исе, камыт күне, яңа чапкан печән, --- лаклатып алган тальян исе – болар барысы – музыка, ис, чуар төсләр – кешене табигый халәтеннән күпмегәдер аерып ала ---.* М.Мәһдиев

**КҮ́ПМЕДӘН** *а.* 1) *к.* **күпмегә** (*1 мәгъ.*). *Күпмедән сатканлыгын хәбәр итсен.* К.Нәҗми

2) Нинди исәп белән, нинди исәптән чыгып? *[Председатель:] Син ул бодаеңны күпмедән чәчмәкче буласың соң?* Г.Бәширов

**КҮ́ПМЕДЕР** *а.* **1.** Санның, күләмнең билгесезләгән аңлата. --- *һәр телнең сүзлек составында күпмедер өлешне читтән кергән сүзләр тәшкил итә.* Х.Сарьян. *Күпмедер акча бирергә уйлыйлар бугай.* Ф.Яруллин. *Бу татлы сүзләр Инсиянең аракы сөреме белән томаланган күңеленә күпмедер рәхәтлек өстәде.* Ә.Моталлапов

**2.** *рәв. мәгъ.* Билгесез вакыт турында. *Күпмедер вакыт исәңгерәп яткач, урамга чыккалый башладым.* Ф.Яруллин. *Фәнис, эчендә кайнарга керешкән ярсуын кинәт кенә тышка чыгарып түгәргә кыенсынып, ни әйтергә белмичә, күпмедер вакыт тавыш-тынсыз басып торды.* Ә.Моталлапов. *Саимә --- күпмедер вакытка югалып калды.* Г.Галиева

**КҮ́ПМЕЛӘП** *а.* Нәрсәнеңдер күләмен яки зурлыгын чама белән билгеләү. *Докладлар күпмеләп булыр икән?*

**КҮ́ПМЕЛЕК 1.** *и.* Кемнәрнең яки нәрсәләрнең күпме булуы, сан исәбе турында. *Товарларны барлап чыкмыйча, җитмәүчелекнең күпмелеген белеп булмый бит әле.* Ә.Моталлапов

**2.** *а. сөйл.* 1) Нәрсәнең дә булса бәясен яки гомуми күләмен ачыклау соравы буларак кулланыла. *Барлыгы күпмелек нәрсә алдыгыз?* Г.Ибраһимов

2) Ничә яшьтә; ничә яшь тулган? *Аның кызы күпмелек?*

**КҮ́ПМЕҢЛЕК** *с.* Саны күп меңнәрдән торган, берничә меңне эченә алган. *Бүген исә монда 67 крәстиән хуҗалыгы эшли, аларның күпмеңлек терлек*

*көтүләре плутоний даласында утлап йөри.* Мәдәни җомга

**КҮ́ПМЕСЕ** *а.* Нindидер бер күплекнең аерым өлешләре. *Ә хәзер ул җимешләрнең күпмесе җиргә коелган.* Ф.Яруллин

**КҮ́ПМЕШӘР** *а.* Нәрсәне дә булса бүлгәндә, өләшкәндә, һәркемгә туры килгән күләмне ачыклау соравы буларак әйтелә. *Ринат булачак премияне истә тотып җавап бирде: – Тәккә генә булмас... – Якимовка җан кереп китте. – Күпмешәр? – Ун.* Н.Хәсәнов

**КҮ́ПМИЛЛӘТЛЕ** *с.* Күп милләттән, халыктан торган; күп милләттән, халыктан гыйбарәт. *Бөек Ватан сугышы вакытында безнең күпмилләтле совет солдатлары, дошман өстенә һөҗүм белән барганда, --- «ура» сүзен «бу – татар сүзе» дип кычкырмасалар...* Х.Сарьян. *Дәүләт Киңәшчесе, Русия Федерациясен демократик юлдан үстерү шартларында күпмилләтле республикада --- төптән уйланылган дәүләт милли сәясәтен эшләү бик кирәк дип исәпли.* Ватаным Татарстан. *Ул гына да түгел, күпмилләтле һәм күпдинле илдә ошбу проблемаларның тулысынча чишелеше сәяси системаны модернизацияләүнең нигезенә салынырга тиеш.* Мәдәни җомга

**КҮ́ПМИЛЛӘТЛЕЛЕК** *и.* Күп милләтле булу. *Ул борынгы гасырларда ук нигез салынган тарихи традицияләрне дәвам итә, күпмилләтлелек безнең илебезнең төп сәяси һәм мәдәни традицияләре нигезен тәшкил итә.* Чын мирас

**КҮ́ПМИЛЛИОНЛЫ** *с.* Саны, микъдары берничә миллион булган. *Көньяк-Көнчыгыш Азиянең күпмиллионлы халкы күченер өчен урын эзләргә тиеш булачак – Бангкок, Калькутта, Шанхайга, шулай ук, су басу куркынычы яный.* Мәдәни җомга

**КҮП НОКТА** *и. лингв.* 1) Рәттән куелган өч нокта рәвешендәге тыныш билгесе. *«Сугышта йөри, диләр...» кебек юллардан соң куелган күп нокта, шагыйрь язмышындагы кайбер вакыйгалар аның эчтәлеген безгә башкача да ача.* Р.Рахман

2) Текстта сүзләр төшереп калдырылган урынны билгели торган нокталар рәте. *Сүгенү сүзе урынына күп нокталар куюю да закон бозу булып саналачак.* Татарстан яшьләре

**КҮППОЧМАК** *и. мат.* Сынык сызык белән дүрттән артык почмак ясап уратып алынган геометрик фигура. *Күппочмак моделе, аршын һәм зур циркуль күтәреп, Ибраһимов керде.* Җ.Тәрҗеман. *Әйләнәнең озынлыгы, аңа камаулы яки аны камаучы күппочмакның яклары санын чикләмәгән рәвештә арттырганда, күппочмакның үзгәрешле периметры омтылган чикләмә дип карала.* Югары математика нигезләре

**КҮ́ППОЧМАКЛЫ** *с. мат.* Почмаклары дүрттән артык булган. --- *тәләсә нинди күппочмаклы фигураны өчпочмакларга бүлгәләргә мөмкин.* Җ.Тәрҗеман

**КҮ́ПСАНЛЫ** *с.* Берәр төрле предметларның яисә затларның күп саныннан гыйбарәт. *Мангуллар – күпсанлы --- сугышларда чыныккан халык.* М.Хәбибуллин. *Ул кешеләр, разъездга төшкәч, ике як урманның күпсанлы караңгы сукмакларына кереп югалалар ---.* М.Мәһдиев. *Бүген дә үзенең күпсанлы иярченнәрне белән чирләләрне карый-карый, профессор күршемдә яткан Сашка абыйга килеп терәлде.* Г.Сәгыйров

**КҮПСЕНҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне яки берәр төрле эшне кирәгеннән артык дип санау (исәпләү). *[Хәерниса җиңги:] – Монысын бигрәк тә ярата идем, --- дип яшь койды. – Шулай, Ходай күпсенгәндер инде.* М.Мәһдиев. *[Сәлимә апа:] Ба, ниткән эш, ди, ул? Сезне монда кем күпсенә?* Н.Хәсәнов. *Дәмдинов счёт кәгазен кулына ала да, күпсенеп, кашларын уйнатып тора.* Х.Ибраһим

2) Кемнеңдер өстен ягыннан көнләшү. *Үз күңелендә аның һичбер вакыт көнчелек, башкалар байлыгын күпсенү дигән нәрсә булмады.* Ф.Яруллин. *Өйле-җирле иткән колхозыңа да хәләл көчеңне кызгангач, син кем буласың инде? Шуны йөзләренә бәреп әйткәч, «Алай күпсенгәч, салдырмаска идең», – дип, авызыңны томаларга да күп сорамыйлар ---.* Ф.Садриев. *[Фәнис:] Танышканнан бирле миндә торасың. [Зарема:] Күпсенәсеңме*? Х.Ибраһим

**Күпсенә башлау** Күпсенергә тотыну

**Күпсенеп йөрү** Озак вакытлар дәвамында күпсенү

**Күпсенеп тору** Әлеге вакытта күпсенү

**КҮ́ПСЕРИЯЛЕ** *с.* Серияләре күп булган, күп сериядән торган. *Мәсәлән, «күпсерияле» дигәнне мин башта, үзебезнең «күпсенү» дигән сүз кебек, тамырын «күпсер» дип укый башлыйм.* Х.Сарьян

**КҮ́ПСҮЗЛЕ** *с.* Күп сөйләшергә яратучы, күп сөйләшүче. *Яңа дустым күпсүзле булып чыкты*

**КҮ́ПСҮЗЛЕЛЕК** *и.* Күпсүзле булу. *Хәй Фәләхи йомгаклауга кучкәч, күпсүзлелектән тәмам талчыгып беткән кешеләр игътибарлырак була башлады.* К.Тимбикова

**КҮ́ПТАВЫШЛЫ** *с. муз.* Җырны яки инструменталь әсәрне бер үк вакытта берничә тавыш белән башкарудан гыйбарәт булган; полифоник. *Шундый күптавышлы көйнең бер өлеше уйналгач, Тимербулат туктарга уйлаган иде.* К.Нәҗми

**КҮ́ПТАВЫШЛЫЛЫК** *и. муз.* Күп тавышлы булу, полифония

**КҮ́ПТАРМАКЛЫ** *с.* Берничә юнәлештә эш алып бара торган. *Күл бассейнында болыннар, көтүлекләр бик күп, монда күптармаклы авыл хуҗалыгы да нык үскән.* А.Муранов. *Гүзәлия Шакирова Азнакай шәһәренең яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү оешмасында хезмәт куйган.* Ирек мәйданы

**КҮПТӘН** *рәв.* 1) Моннан күп элек, әллә кайчан. --- *мөгаллименә: «Нигә соң һәр халыкның үз кыйбласы?» – дип әйтәсе килгән иде. --- Ә бүген әйтер иде, тик ул еллар күптән үткән инде.* М.Хәбибуллин. *Тычканның бу гадәтен белгән бакчачылар күптән инде алмагач төпләренә җепшек кар өептаптап, аны боздай катырып куйдылар ---.* К.Тәхау. *Зиратка кереп тә булмый торгандыр, күптән кар баскан инде аны.* Р.Мөхәммәдиев

2) Әллә кайчаннан бирле, элек үк. *Мин төрмәнең начарлыгын, аның кызыгырлык җир түгел иканлеген бик күптән белә идем.* Г.Исхакый. *Мин аңа*

*күптән инде кымырҗып торган соравымны бирәм: – Сафуан абый, сине очучылыктан төшерделәрмени?* М.Галиев. *Аннары ул аспирантка кул сузды: – Уз, уз, бик әйбәт иткәнсең, күптән көтә идем.* К.Тимерханов

**КҮПТӘНГЕ** *с.* 1) Хәзерге вакыттан күп элек булган, әллә кайчангы. *Бу вакытта Гайниҗамалның күңеле ераkларга, үзенең башыннан үткән, күптәнге яктылы-караңгылы, шатлыклы-кайгылы хәлләргә карап очадыр иде.* Ш.Камал

2) Күптәннән килгән, озак вакытлар буенча дәвам иткән; иске. *Кайда гына чыгыш ясасак та, ял итүчеләр дә, хәрбиләр дә, эшчеләр дә безне күптәнге танышлары кебек каршыладылар.* И.Юзеев. *Син ул ашлыкның ничек чәчелгәнен дә, ничек үскәнен дә, ничек урылганын да белмисең бит. Чөнки син – врач, анысы да күптәнге.* Ф.Садриев. *Телевизорда күптәнге сериалның дәвамы бара.* Ф.Яруллин

**КҮПТӘН-КҮП** *рәв. сөйл.* Бик күп. *Халыкларның сәламнәре --- Килеп тора һәр көн күптән-күп.* Ш.Маннур

**КҮПТӘННӘН** *рәв. к.* **күптән**. *Бит ул Исламны күптәннән белә, тик игътибар гына итмәде.* М.Хәбибуллин. *Баскыч төбен күптәннән саклыйсыңмы?* Ә.Моталлапов. *Шагыйранә җанлы ул сәер кызыкай инде күптәннән дөньяда юк ---.* Х.Ибраһим. *Егет Себер сазлыкларында мондый «йотучы» урыннарның очравын күптәннән белә иде.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮ́ПТЕЛЛЕ** *с.* Берничә телдә алып барыла торган; берничә телне эченә алган. *Күптелле сүзлек*

**КҮПТЕРМӘ** *и.* Борчак, ясмык яки тары онын йомырка, сөт кушып болгатып, табага салып пешерелгән ашамлык. *Күптермәнең камыры коймак камырыннан бераз куерак була, һәм ул төче камырдан пешерелә.* Халык ашлары

**КҮПТЕРҮ** *ф.* 1) *к.* **күбендерү** (*1 мәгъ.*). *Шалкан эч күптерә, талкан бил нығыта.* Мәкаль

2) *сөйл.* Шештерү, кабарту, кабартып чыгару. *Аннары әтәчләрнең түшләрен күптергәнче кычыткан белән чабып, барысының да канатларын йолкып җибәргәннәр.* М.Гали

**Күптерә башлау** Күбенгән, кабарган билгеләре күренү

**Күптереп бетерү** Тулысынча, бөтенләй күптерү

**Күптереп җибәрү** Кинәт күптерү

**КҮПТЕРҮЧӘН** *с.* Күптерә торган. *[Сәмигулла:] Чәй, яхшы пешеп җитмәсә, эчне күптерүчән була.* Ф.Әмирхан

**КҮПТИ́Н-КҮП** *рәв. иск. к.* **күптән-күп**. *Татарчалап күптин-күп сәлам белдергән хат шешәдә, күл суы белән җир асты елгасына кушылып, еракка агып китә иде.* Н.Хәсәнов

**КҮ́ПТИРАЖЛЫ** *с.* Тиражы зур булган. --- *кыз --- тәрәзә төбеннән трестның бер генә битле күптиражлы газетасын алып килеп, --- Флүр Сәхбиевич каршына салды.* Р.Кәрами

**КҮ́ПТОМЛЫ** *с.* Күп томнан гыйбарәт. *Күптомлы сүзлек*

**КҮ́ПТОМЛЫК** *и.* Күп томнан гыйбарәт басма. *Шулай ук биредә М.Гафуриның элекке елларда дөнья күргән күптомлыкларына төрле сәбәпләр аркасында керми калган кайбер шигырь һәм поэмалары урын алды.* Казан утлары. *Табылган материаллар тулысы белән киләчәктә күптомлыкларда биреләчәк.* Чын мирас

**КҮ́ПТӨРЛЕ** *с.* Төрле-төрле, әллә ничә төрле. *К.Насыйри бу китабына татар халык иҗатының күптөрле жанрларыннан үрнәкләр җыя ---.* М.Мәһдиев. *Зөфәр Шәрипович кочагы белән газета-журнал алды, анда язылганнарга ияреп, --- күптөрле тәкъдимнәр әйтте ---.* Ф.Садриев. *Галәм дөньясы гаять күптөрле, аңа бихисап күк җисемнәре һәм аларның системалары керә.* Табигать белеме

**КҮ́ПТӨРЛЕЛЕК** *и. кит.* Берничә төрдән гыйбарәт булу. *Табигать белеме дәресләрендә табигатьнең гаҗәеп күптөрлелеге турында --- бик күп мәгълүмат алырсыз.* Табигать белеме. *Дарвин, культуралы үсемлек һәм йорт хайваннарының һәрбер төренә караган сорт һәм токымнарның күптөрлелеге ясалма сайланышның төрле юнәлеше аркасында билгеләрнең аерылуыннан килә, дип аңлатты.* Дарвинизм нигезләре

**КҮ́ПФАЗАЛЫ** *с. махс.* Берничә фазадан торган. *Күпфазалы ток системасы*

**КҮ́ПФАТИРЛЫ** *с. к.* **күпквартирлы**. *Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауның быелгы сметасы, алдагылары кебек үк, дүрт өлештән тора.* Мәдәни җомга

**КҮ́ПФИГУРАЛЫ** *с.* Фигуралары күп булган, берничә фигуралы. *Мисалга, күпфигуралы дивар бизәге – «Нурлы Казан» панносын алыйк.* Чын мирас

**КҮ́ПХАТЫНЛЫ** *с.* Берничә хатыны булган. *Аларның элитасында һәрвакыт полигамия күзәтелә: күчмәннәр, кагыйдә буларак, күпхатынлы һәм күпбалалы булганнар.* Чын мирас

**КҮ́ПХАТЫНЛЫЛЫК** *и.* Күп хатынлы булу; полигамия. *Сөләйман пәйгамбәр исә күпхатынлылыкка чарасыздан бара: күп кенә асыл егетләре орыш кырында ятып калгач, тол калган хатыннарны үз учагына алырга мәҗбүр була.* М.Хәбибуллин

**КҮПЧЕК** *и.* Кечкенә мендәр. *Түр башына муллага утырырга салам күпчек куйганнар.* Әкият.--- *яңа килгән балаларны ---, сабакка өйрәнә башлагач, идәнгә көрпәгә кучерәбез. Бай балаларының күпчекләре дә бар.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮПЧЕЛЕК** *и.* 1) Нәрсәләрнең дә булса зур өлеше, күп саны. *Укыган елларны җәйге каникулның күпчелек өлешен ата-бабаларының туган җирендә үткәргән.* Ә.Моталлапов. *Күпчелек очракта кыз үзен урлатырга риза булып, бу турыда ата-аналары белеп тора; кайбер очракта кызны чын-чынлап урлыйлар...* Х.Ширмән. *Ашлыкның күпчелек өлеше ябык өсләкләр астында һәм складларда саклана.* Ф.Садриев

2) *сөйл.* Халык массасы. *Ул үзен күпчелектән өстен санап, борын чөеп, һаваланып йөрмәдемени?* А.Гыйләҗев. *Кумәклектә – хәрәкәт, күпчелектә бәрәкәт бар...* А.Тимергалин. *Мондагы күпчелек индеецлар --- үз хуҗалыкларында җитештергән белән генә көн күрәләр.* А.Муранов

**КҮПЧҮ** *ф. сөйл.* 1) Артык нык әчү (камыр, катык һ.б. тур.). *Камыр күпчү*

2) Кабару, күбү

**Күпчеп бетү** Бөтенләй, тәмам күпчү. *Ике авыл арасындагы шул бака ефәге белән капланып, күпчеп беткән бу күлдән бер елны бизгәк чире тарала.* К.Нәҗми. *Күпчеп беткән катык бар анысы, тавыкларга җим болгатырга дип тотканы...* М.Галиев. *Сәлахетдин малае эчә! Күпчеп, көеп беткән инде.* А.Гыйләҗев

**Күпчеп утыру** Шактый вакыттан бирле күпчегән хәлдә булу

**Күпчеп чыгу** Күпчегән хәлгә килү

**КҮПШЕК** *с. диал. к.* **көпшәк**. *Фидан ихтыярсыз үзенең күпшек тәнен карап кичте: ул бервакытта да бу кыз төсле булмады.* Х.Сарьян

**КҮ́ПЬЕЛЛЫК** *с.* 1) Күп еллар буена дәвам иткән, күп еллар барган. *Ялгыз килештән дә үзенең күпьеллык хыялын тормышка ашыра алмыйча йөрде.* Ә.Моталлапов. *Тундрада җылылык бик аз, туфракны күпьеллык туңлык каплаган.* Табигать белеме. *Күпьеллык сынаулар туфракны реактив плутонийга шулкадәр баеткан ки, террорчыларга пычранган җирне атом бомбасы эченә тутырасы гына калган.* Мәдәни җомга

2) *бот.* Берничә ел яши торган, күп еллар буена үсә торган (үсемлекләр тур.). *Күпьеллык мәкне декоратив үсемлек итеп үстерәләр.* Йорт эшләре. *Яфраклы урмандагы күпьеллык үләнчел үсемлекләрнең чәчәк атуы – язның өченче билгесе.* Ботаника. *Чүп үләннәр арасында берьеллык, икееллык һәм күпьеллык үсемлекләр була.* Яшелчәчелек

**КҮ́ПЬЯКЛЫ** *с.* 1) *махс.* Яклары күп булган. *Күпьяклы призма*

2) *күч.* Күпкырлы, күп тармаклы. *Шундый кешеләр бар, алар өчен төгәл, катлаулы һәм күпьяклы режим саклау – үзенә күрә бер хобби.* В.Леви. *Иҗтимагый-гуманитар фәннәр өлкәсендәге күпьяклы эшчәнлеге белән культура төзелешенә үзеннән өлеш кертүче мондый милли институтлар Советлар Союзындагы барлык автономияле республикаларда да бар.* И.Надиров

**КҮРА́ЛМАУ** *ф. сөйл.* Берәр кешегә яки берәр нәрсәгә карата яратмау, нәфрәт хисе кичерү. *[Зәйнәп:] Җитте! --- Нинди китү, ди, ул, нинди тору? Мин бит сине күралмыйм!* Х.Ибраһим. *--- күралмыйм мин аны. Ул мине эзәрлекли, миннән көлә, интектерә, җәзалый.* Ф.Яруллин. *Ул, кызның күзләренә карап: – Мине шулкадәр күралмас булдыңмыни? – дип сорады.* С.Шәмси

**Күралмый башлау** Күралмау дәрәҗәсенә җитү

**КҮРА́ЛМАУЧЫЛЫК** *и.* Күралмау хисе. *Шуннан бирле ике арада берберсен күралмаучылык туды.* Н.Хәсәнов. *Гөлкәй --- күңелендәге мәхәббәтен күралмаучанлык белән алыштырырга тиеш.* Х.Ширмән

**КҮРӘ** *бәйл. сүз* 1) Берәр нәрсәгә ярашлы рәвештә, шуңа туры китереп; карата. *Соравына күрә җавабы.* Әйтем. *Чиләгенә күрә капкачы.* Әйтем. *Яшенә күрә шуклыкның чигенә чыккан бу малай мәзәккә дә бик сәләтле иде.* Г.Гобәй

2) Фигыльләрдән соң килеп, «шул фигыль белдергән эш-хәл сәбәпле», «шуның аркасында» дигән мәгънәне аңлата. *Ишеккә каршы эленеп торганга күрә, бүлмәгә кергән һәркемнең күзе иң элек шуңа [рәсемгә] төшә.* М.Маликова. *Көпшәк токымнар аркылы диңгез суы саркып торганга күрә, су монда диңгез суы белән бертигез ---.* А.Муранов

3) Гадәттә *сөйләү, әйтү* кебек сүзләр янында килеп, «кемнең дә булса сөйләвенә, кемнең дә булса әйтүенә караганда» дигән мәгънәләрне белдерә. *[Салихның] сөйләвенә күрә, бөтен эше офицер тотуда булган.* Ш.Усманов

4) Туры килгәнчә, буенча, каралганча. *Хәнәфи мәзһәбенә күрә, гореф-гадәт ислам дине нигезләренә хилафлык китермәсә, аны файдаланырга мөмкин, дигән гыйбарә бар.* Р.Мөхәммәтшин

**КҮРӘГӘ** *и.* Киптерелгән төшсез өрек җимеше. *Бары тик шуннан соң гына Мирзанур, сәкегә куеп торган төенчеген чишеп, бер яулык һәм кәгазьгә төрелгән күрәгә, киптерелгән алыча, алма, тагын бераз йөзем сузды: – Менә болары – улың Фазыл күчтәнәчләре.* Н.Әхмәдиев. *Эремчеккә он, йомырка, күрәгә, шикәр комы, тоз салып, яхшылап болгатырга.* Ирек мәйданы

**КҮРӘЗӘ** *и.* 1) Күрәзәләү шөгыле, гамәле. *Әллә соң күрәзә итә торган сәләте бар инде шуның [Ларисаның]?* М.Маликова. *– Күрәзә итеп утырма, болай да яратам мин сине, – диде Кәбир.* Х.Сафина

2) Күрәзәче. *Хан бу сәер кешегә игътибар итә. Күрәзәгә аның һәм үзенең сакалына ымлап күрсәтә.* Н.Исәнбәт. *Әллә күрәзә инде минем бу Олы инәем!* М.Кәрим. *Шушы юрау кәефемне бозып җибәрде. «Ярый, күз күрер, – дип юанырга тырышам. – Мин бит күрәзә түгел алдан белергә».* М.Юныс

**КҮРӘЗӘЛӘ́Ү** *ф.* Фараз кылу, гөман итү; алдан күрү. *Нәдерша кызга тагын төбәлеп карады, нинди яңалык көтелүен уйланып белергә тырышты. Әмма моны күрәзәләү мөмкин түгел икән, ---.* М.Хуҗин

**КҮРӘЗӘЛЕК** *и.* 1) Нинди дә булса гайре табигый сәләт яки тылсымлы алымнар белән киләчәкне күрү, билгеләү. *[Шәйхулла:] Күрәзәлегең бик күңелгә ятышлы чыкты. Күпме хак бирим?* Д.Аппакова. *Табор белән сату итәләр, алдап-йолдап күрәзәлек итәләр.* С.Шәрипов. *Шул балага кесәмдәге вак акчаны чыгарып биргән идем, анасы рәхмәтләр укып, бушлай күрәзәлек итәм, дип ябышты, ди.* М.Маликова

2) *күч.* Алдан күрү, фаразлау. *--- акыл һәм күрәзәлек бар сездә – миңа кияүгә чыкмаячаксыз.* М.Хуҗин. *– Менә әйттем ич, мине дә дәштерәчәк, – диде Зөлхидә, юртадан чыкканда. – Күрәзәлегең бар, хак, – диде Кол Гали ---.* М.Хәбибуллин. *Бикмулла үзенең күрәзәлеге белән мактанмыйча булдыра алмады.* Ә.Еники

**КҮРӘЗӘЧЕ** *и.* Күрәзәлек (*1 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче; күрәзәлек итүче. *Ул үзен хатын-кыз психологиясен шәп белүче күрәзәчегә саный алмый алуын.* Ә.Моталлапов. *Әллә чыннан да күрәзәче сәләте бармы бу кызыкайда?* М.Маликова. *Шул Сухадулда Әким исемле бер күрәзәче чуаш карты бар икән.* З.Зәйнуллин

**КҮРӘЗӘЧЕЛЕК** *и. сөйл. к.* **күрәзәлек** (*1 мәгъ.*). *Әнисе үзендә булган тылсымлы көч, күрәзәчелек, дәвалау көче, гади кеше аңламаслык әйберләрне кем белән уртаклашсын, кемгә сөйләсен.* З.Кадыйрова. *Харисов аның бу минут-*

*та үзе куйган проблемалар хакында уйлавына шикләнмәде. Дөрес күрәзәчелек иткән булып чыкты.* Р.Айзатуллин

**КҮРӘ́ КАРАУ** *и. мед.* **1.** Күз күременең үткенлеге кимү, ерактан ачык күрмәү белән үзенчәлекле күз кимчелеге; *русчасы:* **близорукость**. *[Аяз:] Мин бит күрә карау, миндә тавык күзе.* Г.Бәширов. *Балалар еш кына караңгылы-яктылы вакытта, кайчакта трамвайда --- барганда укыйлар. Болар бар да күзгә артык көч китерә һәм ерактан күрә алмауны (күрә карауны) китереп чыгара.* Анатомия

**2.** *с. мәгъ.* Ерактан начар күрә торган. *Сакалбаебыз кайвакытларда мине кулымнан тотып тәрәзә янына алып килер иде дә күрә карау күзләрен миңа озак кына текәп торганнан соң: «Сөбханалла! ---» – дияр иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КҮРӘ́ КАРАУЧЫ** *и.* Ерактан начар күрүче. *Бик еракка карап барсаң гына адашмаска мөмкин – күрә караучы булсаң... дип уйлады Муса.* Г.Әпсәләмов

**КҮРӘ́-КҮРЕШКӘ** *рәв. сөйл. к.* **күрә-күрештән**. *Күрә-күрешкә кызны ошату*

**КҮРӘ́-КҮРЕШТӘН** *рәв. сөйл.* Беренче мәртәбә очрашудан ук, тәүге күрешүдән үк. *Минем белән тәкәллефле генә күрешсә дә, күрә-күрештән үк ул миңа ошамады.* Г.Рәхим

**КҮРӘЛӘТӘ** *рәв.* 1) Күрә торып, аңлы рәвештә, белгән килеш. *Мин алдан вәгъдә өләшмим, күрәләтә үземне андый кыен хәлгә дә куя алмыйм.* Р.Айзатуллин. *--- алар күрәләтә, аңлы рәвештә безнең юлга аркылы төшә, шулай итеп беразга гына булса да авылымның гомерен озайтам дип уйлый.* Р.Вәлиев. *Прокурор белән телгә килгән: «Нишлисез сез?.. Күрәләтә торып кешене харап итмәкче буласызмы?» – дип, вышкада булган хәлне сөйләп биргән.* М.Хәсәнов

2) Ачыктан-ачык, турыдан-туры; бер дә тартынмыйча, күзгә карап. *Гайсә Батталович миңа күпме пычрак атты – мин барысын да күтәрәм. Ә менә мин аңа ташланды дигәне – күрәләтә ялган!* Ф.Садриев. *Мансур Ибраһимович, профессорның күрәләтә ымсынулы карашын чамалап, сүзне тизрәк икенчегә борды.* Х.Ширмән. *Шунысы бар: күрәләтә халыкны талаучы сәүдәгәрләр белән базар тулы.* Ә.Моталлапов

**КҮРӘ́МСЕҢ** *кер. сүз сөйл. к.* **күрәсең**. *Карибулла шуларны аңлый торган кеше түгел, күрәмсең.* Э.Касыймов

**КҮРӘН** *и.* Күрәнчәләр семьялыгыннан, сазда үсә торган тар, озын кыяклы күпьеллык үлән; *русчасы:* **осока**. *Карабүрекләр --- кычыткан, күрән, алабута, тигәнәк орлыкларын яратып ашыйлар.* К.Тәхау. *Бер өлешләләр классына барлык игелә торган һәм кыргый кыяклылар, күрәннәр, лалә чәчәкләләр керә.* Биология. *Тундраның мүклелишайниклы үсемлекләр берлегендә --- үләнчел үсемлекләрдән күрән, кыяклылар һәм башка үләннәр очрый.* Ботаника

**КҮРӘНӘК** *и. диал.* Нинди дә булса бер үрнәк яки гыйбрәтле сабак. *Күргәннән күрәнәк ал.* Мәкаль

**КҮРӘНЧӘЛӘР** *и. бот.* Күрән, камыш һ.б.ш. үсемлекләр кергән бер өлешле күпьеллык үләнчел үсемлекләр семьясы; *русчасы:* **осоковые**. *Бу кәс кыяклылар белән күрәнчәләрнең берберенә кушылып үскән тамыр һәм тамырчаларыннан тора.* Ботаника. *Күрәнчәләргә шулай ук үр сазламыкларында үсә торган җиңсәле мамыкбаш та керә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КҮРӘСЕ** *и. сөйл. к.* **күрәчәк**. *[Хәдичә түти:] Бар икән күрәселәрем. --- Бу кадәр рәнҗетүең өчен берүк телең корсын!* Г.Бәширов

**КҮРӘ́СЕҢ** *кер. сүз* Ахрысы, булса кирәк, бугай. *Күрәсез, боларда бернинди дә матурлау юк – һәркем әйтә алган гап-гади сүзләр.* Х.Сарьян. *Фәнияр --- мотоциклымның сыңар көпчәге кайда төшеп калды икән соң дип гаҗәпләнә, күрәсең.* Ф.Яруллин. *Күрәсең, күңелендәге шул хыялын вакытлыча гына булса да тормышка ашкандай хис итмәкче булыптыр, Равилне чын укытучылар шикелле итеп укытырга тырыша ул.* В.Нуруллин

**КҮРӘЧӘК** *и.* Кичерергә, күрергә тиеш булган нәрсә; тәкъдир, язмыш. *«Уф! – дип куйды Сәет. – Бәла агач башыннан йөрми... Күрәчәгең булса...»* Ф.Латыйфи. *Шундый сәяхәтләрнең берсендә ул [малай], Исламгали агайның күрәчәгенә каршы, Япониягә барып чыккан ---.* М.Мәһдиев. *Алдагы көндә күрәчәкләр нәкъ менә шушы кичтән башланды да.* М.Маликова

**КҮРГӘЗМӘ** *и.* **1.** 1) Билгеле принциптан чыгып тупланган һәм халыкка танышу өчен ачык булган иҗат, сәнгать әсәрләре, тарихи яки архаик предметлар җыелмасы. *Имеш, аның портретын бик зур залга күргәзмәгә куйганнар.* Ф.Яруллин. *Җиденче класста чакта «Имән белән ак каен» дигән рәсемемне Мәскәүгә балалар иҗаты күргәзмәсенә җибәрделәр.* Җ.Тәржеман. *Шушы залда ук аның иҗат күргәзмәсе үткәрелде.* Ә.Моталлапов

2) Шундый әйберләр куелган бина

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кешеләргә (халыкка) үрнәк итеп күрсәтү өчен оештырылган. *«Коммунизм юлы» дип аталган, исеме җисеменә тап килә торган күргәзмәгә, колхозның рәисе булырга бик теләсә дә, Әхсән Сахапович Хәлиуллин килә алмаячак.* А.Гыйләҗев

2) Бөтен кешеләргә гыйбрәт, сабак булсын өчен оештырылган. *Шуннан соң, авылда ук күргәзмә суд булып, Шакирның зур өен хатыны белән баласына алып бирделәр.* Р.Төхфәтуллин

3) *сөйл. к.* **күрсәтмә** (*2 мәгъ.*). *Халык, бигрәк тә хатын-кыз, музей экспонаты караган кебек, берәм-берәм кабина тәрәзәсенә килде: эчтә күргәзмә әсбап булып Мәликә утыра иде.* М.Мәһдиев. *Кинәнде укытучылар, --- сөенде укучылар! Ишекләр очып кына ачылды, пыялалар һәрвакыт бөтен, --- күргәзмә әсбапларның барысы ремонтланган ---.* А.Гыйләҗев. *Сездән алты мең акча кирәк булачак. Авыл урамнарына күргәзмә материаллар эшләтү өчен.* Ф.Садриев

**КҮРГӘЗМӘЛЕ** *с. сөйл. к.* **күрсәтмәле**. *Күргәзмәле дәресләр*

**КҮРГӘЗМӘЛЕЛЕК** *и. сөйл. к.* **күрсәтмәлелек**. *Бу мисал күргәзмәлелек өчен китерелде.* Х.Госман

**КҮРГӘЗҮ** *ф. к.* **күрсәтү**. *Батырның батырлыгын чәй эчеп утырган чагында*

*күргәзеп булмый.* Һ.Такташ. *Бу караш, настроениеләрне ул «Җир уллары»ндагы Кабилдә, Газазилдә аеруча тулы күргәздe.* Г.Нигъмәти

**Күргәзә алу** Күргәзергә мөмкинлек булу

**Күргәзә бару** Һәммәсен, булган берсен күргәзү

**Күргәзә башлау** Күргәзергә тотыну

**Күргәзә тору** Башка эш-гамәлдән алда күргәзү

**Күргәзеп алу** Кыска вакыт аралыгында, тиз генә күргәзү

**Күргәзеп бару** *к.* **күргәзә бару**

**Күргәзеп бетерү** Бөтенесен дә, барысын да күргәзү

**Күргәзеп йөрү** Күргәзү эше белән шөгыльләнү, нәрсәдер күргәзү белән мәшгуль булу

**Күргәзеп калу** Нәрсәне дә булса үз вакытында күргәзергә өлгерү

**Күргәзеп китү** Нәрсәне дә булса эш яки сүз барышында күргәзү. *Мине аклап, шул ук алган шигырьләрдән башка мисал китерергә кирәкми. Үземне аклау өчен, аларны монда күргәзеп китү кирәкми.* Һ.Такташ

**Күргәзеп тору** Әледән-әле яки даими күргәзү. *59 җитмәсә, аттан хәтәррәк дулап күрсәткән үгез үзенең тәүфикълы була алуын күргәзеп тора икән әле.* Ә.Баян

**Күргәзеп үтү** *к.* **күргәзеп китү**

**КҮРГӘ́Н-БЕЛГӘН** *с.* **1.** Таныш булган, күреп белгән, баштан кичкән. *Кайчагында мин үземнең күргән-белгән төрле әйберләр турында сөйләп, аның дикъкатен җәлеп итәргә тырышам.* Ш.Камал

**2.** *и. мәгъ.* 1) Күреп белгән, таныш кеше. *– Күргән-белгәннәргә сәлам күндер, – диде карчык.* Мәдәни җомга

2) Таныш булган нәрсә; күреп белгән эш-вакыйга. *--- нәрсәдән башларга бу истәлекләрне? Үткәннең кайсы баскычлары, күргән-белгән, --- укучыларга кызык булыр икән --- ?* Т.Галиуллин

**КҮРГӘНЕ́-КҮРМӘГӘНЕ** *и.* Нинди дә булса хәл-вакыйга хакында күреп яки ишетеп кенә белүчеләргә карата әйтелә. *Көпә-көндез авыл урамына килеп кергән төлке бөтен кешене кузгатты, күргәне-күрмәгәне – барысы да бу хакта үз фаразын әйтергә ашыкты.* Татар иле

◊ **Күргәне-күрмәгәне шул булсын** Нәрсә дә булса бирүче яки алучының гаделсезлегенә рәнҗеп әйтелә. *Хәлим тапкан бодайны малайның күз алдында себереп алдылар, әйдә, күргәнкүрмәгәннәре шул булсын.* И.Гази

**КҮРЕК** I *и.* 1) Матурлык, хозурлык, ямь; чибәрлек, гүзәллек. *Ишектән кергәч – күрек уза, түргә менгәч – холык уза.* Мәкаль

2) *тарт. форм.* **күрке**. Кем белән дә булса горурлануга сәбәпче; нәрсәнең дә булса матурлыгы. *Ә Шәрифулланың Сәйфулласы?--- ил күрке булырлык егет түгелме?!* Ә.Еники. *Манара – авылның хуҗасы, күрке иде.* М.Мәһдиев. *Агач – шәһәр күрке, һаваны сафландыручы.* К.Тәхау

**КҮРЕК** II *и.* 1) Мех, йоны белән эшкәртелгән хайван тиресе. *Күрек кигән күркәм булыр.* Мәкаль

2) Һава өрдерү өчен тиредән эшләнгән җайланма (тимерчелектә, пыяла житештерүдә һ.б.ларда кулланыла). *Шул мичкә һава өрдерү өчен күрекне механик үзе эшләдe.* Җ.Тәрҗеман. *Күрек белән өрдертелгән һава күмерне дөрләтеп яндыра.* М.Юныс. *Галикәй чынаягын тубырлы-тубырлы биш бармагы өстенә утыртып, тимерче күрeге кук өрә-өрә, рәхәтләнеп, шопырдатып эчте ---.* А.Гыйләҗев

3) Кайбер уен коралларында һава ярдәмендә музыкаль тавыш барлыкка китерү өчен тартылып сузыла торган сырлы җайланма. *Ул гармун күрeге өстенә башын кыңгыр сала да уйнап җибәрә.* Р.Вәлиев. *Заһир гармун күрекләрен тартып җибәрде.* Т.Таһиров

**КҮРЕК** III *и. диал.* 1) Күпләп әзерләнгән күмерне тутыру өчен, тал чыбыгыннан үреп ясалган бик зур кәрзин. *Элек арбага яки чанага утыртылган зур-зур күрекләрдәге күмерне авыл саен сатып йөриләр иде.* Яңарыш

2) Абзардагы тиресне басуга чыгару өчен кулланылган үтә зур кәрзин

**КҮРЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Матур, гүзәл, чибәр. *Бәгыремә кысып, бу кич бер сөярмен Һәм күрекле йөзең туя бер күрермен.* Кол Гали. *Ямаулы бит белән кемнең иң күрекле урыннарда утырасы килсен?!* Ф.Яруллин. *Әлбәттә, ул могҗизаларның иң күреклесе – әнә шул Севан күле!* А.Муранов

2) Мех белән бизәлгән, мехы булган

3) Һава өрдерү өчен тиредән эшләнгән җайланмасы булган, шундый җайланмалы

4) Күреге II (*3 мәгъ.*) булган, шул күрек ярдәмендә музыкаль тавыш барлыкка китерә торган

**2.** *и. мәгъ.* Матур, чибәр кеше. *Күреклегә күмер кабы да килешә.* Мәкаль

**КҮРЕКСЕЗ** *с.* **1.** Матур булмаган, матур түгел, ямьсез; чибәр булмаган. *Бакча каравылчысы – без күлеп йөргән, ямьсез генә, күрер күзгә күрексез генә тол хатын.* И.Юзеев. *Күрексез генә адәм дә, кияүгә әйләнгәч, купшылана да китә.* М.Кәрим. *Кыскасы, ибтидаи мәктәпнең күрексез укытучысы мыштым калды.* Р.-Н.Гүнтәкин

**2.** *и. мәгъ.* Матур булмаган, ямьсез кеше. *Күрексез – бизәнер.* Әйтем

**КҮРЕКСЕЗЛЕК** *и.* Күрексез, ямьсез булу. *Хәзер менә элгечләрдәге күлмәкләрне актаргалап карый башлагач, аларның күрексезлегенә, төсләренең ямьсез алалыгына хәйран калды.* М.Маликова

**КҮРЕКЧЕ** *и. иск.* Мехчы, мех эшкәртүче; мех белән сәүдә итүче. *Төлке никадәр качса да, барыр җире күрекче кибетендәдер.* Мәкаль

**КҮРЕ́ЛМӘГӘН** *ф.* **1.** *Күрелү* фигыленнән ясалган сыйфат фигыльнең юклык формасы

**2.** *с. мәгъ.* Сирәк очрый торган; гадәттән тыш булган. *Аның көтүлекләрендә моңа кадәр күрелмәгән яхшы нәселле эре терлекләр барлыкка килде.* Г.Бәширов. *Моңарчы һич күрелмәгән матурлык*

**КҮРЕМ** I *и. иск. к.* **күрәзә**

**КҮРЕМ** II *и. физиол.* Женси яктан өлгергән хатын-кызларда ай саен аналыктан кан килү; айлык, хәез, менструация. *Бәй, кайчан гына, әллә нишләп күремем юк, балага уздым ахры, дип шәбәеп йөргән иең түгелме!* М.Хәбибуллин. *Кайбер хатын-кызның күреме аз, дәвамлылыгы да 3 көн булырга мөм-*

*кин ---.* Сөембикә. *Әмма эчең авыртса, күрем бик аз булса яки, киресенчә --- булса, махсус табибка күренергә, киңәшләшергә кирәк.* Ирек мәйданы

**КҮРЕМЛӘҮ** *ф. сөйл.* Багу, күрәзәлек итү, фал ачу. *[Мулла:] Агай садаканы бер тиенләп кенә суза, әллә без өшкерү, күремләү эшенә чыгыйкмы икән?* Әкият

**КҮРЕМЛЕК** *и.* Фәкать карар өчен генә куелган әйбер (күбрәк ашамлыклар тур.). *Туемлык түгел, күремлек кенә.* Әйтем

**КҮРЕМСЕЗ** *с. диал.* Кемнедер күралмаучы, аңа нәфрәт белән караучы

**КҮРЕМСЕЗЛӘНҮ** *ф. диал.* Нинди дә булса сәбәп белән кемнедер күралмау, кемгә дә булса нәфрәт хисе кичерү. *Аның ярсуына көчсез ирләр көчле, нык кешеләрне очраткач була торган күремсезләнү, нәфрәт кушылды.* А.Гыйләҗев

**КҮРЕМСЕЗЛЕК** *и. диал.* Күралмаучылык. *Безнең буын байлыктан дошманлык, карунлык, мещанлык, күремсезлек түгел, нәкъ шуларның киресен – туганлык һәм матурлык тойгылары тәрбияләү юлын эзләп табарга тиеш.* А.Гыйләҗев

**КҮРЕМЧЕ** *и. иск.* Багучы, күрәзәче. *Күремчегә барма, башыңа кайгы алма.* Мәкаль

**КҮРЕМЧЕЛЕК** *и. к.* **күрәзәлек** (*1 мәгъ.*). *Ялкау, мескен, зур ялган күремчелеккә бирелә, Күремчелеккә бирелгән кеше үз эшенә иренә.* Я.Емельянов

**КҮРЕНГЕЧ** *и. иск.* Билет. *Без тиз генә бардык та, ике тәңкә егермешәр тиенгә күренгечләр алып, [поездга] утырдык.* Шура

**КҮРЕНДЕК** *и. этн.* Кыз куенына кергән вакытта, беренче мәртәбә күрешкәндә, кияүнең кызга бирә торган акчасы яки бүләге

**КҮРЕНЕКЛЕ** *с.* 1) Атаклы, танылган, дан казанган. *Совет прозасының күренекле вәкилләре --- психологик осталык белән фәлсәфи анализлау юнәлешендә иҗат итәләр ---.* Х.Сарьян. *Семинарда аның ике пьесасы тикшерелде, күренекле драматурглар уңай фикерләр әйттеләр.* Ф.Садриев. *Ничәмә йөз еллар буена --- күренекле геометрларның күңеленә шом салган бишенче постулат һаман чишелмәгән көе... Чишеп тә булмас, ахры.* Җ.Тәрҗеман

2) Әһәмиятле, мөһим, төп. *Үзенең күренекле гыйльми хезмәтләре өчен --- И.В.Мичурин Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.* А.Бахарев, П.Яковлев

3) *диал.* Күренеп торган, күзгә бәрелеп торган. *Күз алдында, күренекле урында зур такта тора.* Һ.Такташ // Ихтирам иләре, хөрмәтле кешеләр өчен билгеләнгән. *Иң күренекле урында поплар белән муллалар [утыра], алар тирәсендә, аягүрә басып, рус, татар, мукшы авыл байлары [тора].* Г.Ибраһимов

**КҮРЕНЕШ** *и.* 1) Күренү, күренеп тору рәвеше. *Хәсән каралган җәймәсенең читләрен күренмәслек итеп одеял белән каплады да, кроватенең читтән күренешен карар өчен, өчдүрт адым артка чикте.* Ф.Әмирхан

2) Кешенең тышкы кыяфәте; рухи һәм физик халәтнең йөздә, кыяфәттә чагылышы. *Чөнки болар кешене киеменә һәм тышкы күренешенә карап хөкем кылалар.* Ш.Мөхәммәдев

3) Күз белән күзәтелә торган тамаша; табигатьтә тирә-як картинасы; манзара. *Совет власте елларында гына монда геологлар киләләр һәм, кояш нурлары уйнаган су өстендә аккошлар сыман йөзгән бозларны күреп, бу күренешкә хәйран калалар.* А.Муранов. *Менеп җиткәч, безнең күз алдыбызда искиткеч матур һәм мәһабәт күренеш ачылды.* Ә.Еники

4) Табигать картиналарының рәсеме, пейзаж. *Шүрлектән югары стенада Рафаэльнең «Сикстинская мадонна» картинасыннан алып аерым-аерым эшләнгән биш күренеш эленеп тора.* Ә.Еники

5) Берәр төрле көчнең, эш-хәрәкәтнең чагылышы, гәүдәләнеше, нәтиҗәсе. *Татар операсы илебездәге бөтен милләт халыкларының дуслыгы, туганлыгы, бердәмлеге нигезендә, шул туганлыкның чәчәк ату күренеше булып барлыкка килде.* М.Җәлил. *Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды.* М.Гали. *Физик күренешләргә җылылык, механик, яктылык, тавыш, электр һәм магнит күренешләрен кертәләр.* Табигать белеме

6) Вакыйга, хәл, берәр очрак. *Эчүчелекнең --- җәмгыятькә зарарын тормышчан картиналарда сурәтләп биреп, әдәби әсәр белән шушы ямьсез күренешкә каршы көрәшкә чыгып, автор бик файдалы эш башкарган.* Ф.Галимуллин. *Син моның карашы үзгәргән икән дип борчылма, юк, карашым үзгәрмәде, әмма мондагы кайбер күренешләр башкачарак уйларга мәҗбүр итә.* Ф.Яруллин. *Зөфәр Шәрипович --- халыкның күптән ачуын китергән күренешләрне шактый кыю тәнкыйтьләде ---.* Ф.Садриев

7) *әд.* Пьесадагы (спектакльдәге) актның (пәрдәнең) яки картинаның бер үк катнашучылар уйный торган өлеше. *«Безнең шәһәрнең серләре»ндәге биш күренеш арасында үзенең художество ягыннан эшләнүе һәм мастерларча бирелүе белән «Печән базары» күренеше, һичшиксез, иң югары урынны тота.* М.Гали

8) Аерым кадр (сурәт, рәсем). *Кассетадагы күренешләр Миләүшәнең күз алдыннан йөгереп үтте ---.* Ф.Яруллин

9) *этн.* Беренче тапкыр очрашканда, кияүнең кызга бирә торган бүләге яки акча; күрендек. *Кияү белән кыз күрешә дә, [кияү] кызның кулына акча сала; моны «күренеш» диләр. Ул бирелгән акчаны күренеш акчасы диләр.* К.Насыйри

10) *лингв. иск.* Төр категориясе, рус тел белемендә «вид» дип йөртелә. *Телебездә мәгълүм бер төрдәге теләсә нинди фигыльләрдән, үзенә аерым фигыльләр кушып, фигыль күренешләре (виды) ясау бар.* Г.Алпаров

**КҮРЕНЕШСЕЗ** *с.* Матур булмаган, ямьсез, шыксыз, кыяфәтсез. *Бай кызларына күренешсез генә, нәсел-нәсәпсез генә кавалер белән лихачка утырып йөрү килешми.* Ф.Әмирхан

**КҮРЕНМӘ** *с. махс.* Күренә торган, күреп була торган. *Яктырткычларның күренмә хәрәкәтләре*

**КҮРЕНМӘС** *с.* Күренми торган. *--- Сәбилә егетләрне күренмәс җепләр*

*белән урыннарына бәйләп куйган да үзе теләгәнчә хәрәкәтләндерә ---*. Р.Вәлиев

**КҮРЕНҮ** *ф.* **1.** 1) Күз белән кабул ителү, карап сизелү, танылу, караганда күзгә чалыну. *Март бетеп килгәндә, тургайлар да күренде.* К.Тәхау. *--- бөтен тау битен каплап киткән урман да, инде карасу яшел төс иңеп, ачык күренә иде.* Х.Сарьян. *Ул да булмый, бакча ягыннан кулына бер учлам кычыткан, урак тоткан әти күренә.* Р.Мөхәммәдиев

2) Очрау, табылу. *[Язучының] урыны белән [Гейненың] стилистик чараларын куллануы да күренгәли.* Г.Нигъмәти

3) Килеп чыгу, килеп чыгып күзгә ташлану. *Томан пәрдәсе таралып, Одесса ярлары күренде.* М.Юныс. *Тик соңгы бер-ике көндә генә ул ни өчендер күренмәгән иде.* Э.Касыймов

4) Басылу, дөньяга чыгу (әсәрләр тур.). *Гафурның [Коләхмәтовның] хәзергәчә матбугатта күренгән оригиналь әдәби әсәрләре шулар булып, моннан башка аның «Әбүҗәһел» дигән пьесасы басылып ятканда --- полиция тарафыннан [конфискацияләнгән] булган.* Г.Нигъмәти

5) Билгеле бер үзенчәлеге белән аерылып тору, күзгә ташлану. *Беренче көнне сиздермәскә тырышып чыдап барса да, иртәгесен Гөлсәйдәнең йөзендә борчылу билгеләре күренде.* Ф.Яруллин. *Культуралы кәбестә кыргый кәбестәгә караганда үзгәрүчәнрәк. Шул ук хәл хайваннарда да күренә.* Дарвинизм нигезләре

6) Сизелү, тоелу. *Бер – гөлгә, бер сиңа карыйм, Син матур күренәсең.* Җыр. *--- мин аларны кызгансам, алар мине кызганган кебек булып күренәләр иде.* М.Гафури. *Түзмәде, тагын шакыды. Бигрәкләр тансык һәм моңлы күренде эчтән ишетелгән тавыш.* М.Хәбибуллин. *Бу минутта аңа Фәүрия үтә якын, үтә ягымлы күренде.* Ф.Яруллин

7) *сөйл.* Нәрсәне дә булса ачыклау өчен тикшерелү, белгечкә мөрәҗәгать итү. *Сугыштан соң байтак еллар үткәч, Абдулла бер докторга барып күренде.* Э.Касыймов. *Ул хатынының йокымсыраулы, аптыраулы йөзенә карап: «Бәлки, сиңа табибка күренергә кирәктер, матурым», – диде.* Ф.Яруллин. *Барган көнне Ирек, врачка күренеп, Яшьләр үзәгенә берүзе бер бүлмәгә урнаша алды.* Ф.Садриев

**2. күренә** (**ки**), **күренеп тора** (**ки**) *з.-сыз хәб. функ.* Аңлашыла, сизелә. *Күренә, бер бәрәңгедә генә үсмәгән бу кыз, авыр кара эш аны аркылыга җәймәгән.* Ә.Еники. *Күренеп тора ки, [агайның] безгә баш буласы килә, әмма кызның карашында әллә нинди бер илтифатсызлык сизелә.* Ф.Әмирхан

**Күренә бару** Торган саен күбрәк күренү

**Күренә башлау** Бер-бер хәлдән соң күзләргә башкача булып күренергә тотыну яки күләмле, күпсаны нәрсәнең берникадәр өлеше күзгә күренергә тотыну, күренү билгеләре барлыкка килү. *Агачлар арасында дошман солдатлары күренә башлады инде.* Г.Әпсәләмов. *Баскыч буенча өскә менеп килгән кешенең бераздан киң читле ак эшләпәсе, елкылдык зәңгәрсу крепдешин күлмәк итәге, җиңнәре, кулбашы күренә башлады.* Н.Фәттах. *Күзгә һәр түмгәк – төлке, һәр куак бүре булып күренә башлады.* Җ.Дәрзаман

**Күренә төшү** Тагын да ныграк күренү

**Күренеп алу** Берара, кыска вакытка, аз гына күренү. *Кыска гына бер мизгелдә Равилнең күзенә хәтта салават күпере күренеп алды.* Н.Әхмәдиев. *Күршеләрдән Марс Шабаев кердә, композиторлар Фасил Әхмәтов белән Мирсәет Яруллин да күренеп алалар.* Г.Ахунов. *Баскыч ишегендә алъяпкычлы, почмаклап яулык япкан бер яшь хатын күренеп алды ---*. Ә.Гаффар

**Күренеп калу** Азга гына күренергә өлгерү. *Нух әсәрнең беренче битләрендә үк шыксыз тәэсир калдыра, әшнәсе Зәкиев белән нindидер серле, астыртын кешеләр булып күренеп кала.* Ф.Галимуллин. *Еракта Сикертән басуы күренеп калды.* М.Мәһдиев. *Аның башындагы яшел яулык почмагы гына күренеп калды.* Ф.Яруллин

**Күренеп китү** *к.* **күренеп алу**. *Өй тирәли күкрәүсез яшен уйнап йөргән төннәрне --- агач ботаклары чәнечкеле тутык тимерчыбыктай күренеп китә.* Х.Сарьян. *– Кайвакыт яр сызыгы күренеп китә, – диде капитан, башын күтәреп.* М.Юныс. *Ашыгып сөйләүдән аның сары йөзенә сизелер-сизелмәс кенә кызыллык йөгерде, моңсу күзләрендә хәлсез очкыннар күренеп китте.* Р.Вәлиев

**Күренеп куюю** Кыска вакыт эчендә күренү, кинәт күренү

**Күренеп тору** Күренгән хәлдә булу. *Минә бүлмәгә укытучыбыз Риф Мөхәммәтҗанов --- зыялылыгы әллә кайдан күренеп торган, ыспай, какча гәүдәле, күзлекле Хәсән Сарьянны ияртеп алып керде.* Г.Садә. *Беренче генә тотуың түгеллеге күренеп тора.* Ф.Яруллин. *Күренеп тора: һәр боерыгын карусыз үтәргә торучылар белән идарә итү аңа рәхәт иде ---*. М.Галиев. *Күлнең бу өлешендәге суның үтә күренмәлелеге әйбәтрәк: төбе алты-җиде метрдан күренеп тора.* А.Муранов

**КҮРЕНҮЧӘНЛЕК** *и. махс.* Берәр җисемнең күренү үзлеге, күренү мөмкинлеге. *Атмосфераның күренүчәнлеге*

**КҮРЕШҮ** I *ф.* 1) Бер-береңне күрү, очрашу, бергә туры килү. *Лариса күрше кафедрага Дәүләтшин кул астына күчкәннән бирле, аның белән сирәк күрешелә.* М.Маликова. *Сәләхи белән без Сабантуй саен күрешәбез ---*. М.Мәһдиев. *– Исәнлектә күрешик, – диде ул, ике кулын сузып. Зөфәр аларны бераз вакыт кысып торды да ишекне ачты.* Ә.Галиев

2) Кем белән дә булса очрашкач, исәнләшү йөзеннән куллар кысышу. *Нәҗмиев күпләр белән кул биреп күреште ---*. Ф.Садриев. *Кызу-кызу атлап, капитан янына килеп тә җитте, --- кул биреп күреште ---*. М.Мәһдиев. *Митрәй аның белән кушкуллап күреште ---. Ике куллап күрешкән чакта, картның таягы төшеп китте.* Н.Әхмәдиев // Очрашканда, нинди дә булса ишарә, ым, хәрәкәт белән исәнләшү. *Соңра Шәрифулла абыйсы белән үбешеп күрешә һәм кискен генә борылып --- юлга таба атлый.* Ә.Еники. *[Мәрфуга:] Күз очыннан гына күрештек.* Ш.Камал // Кем белән дә булса беренче мәртәбә очрашкач, танышу максаты белән аның кулын кысу. *--- коңгырт бөтеркә чәчле чибәр генә бу егет үзен, Казан универ-*

*ситетында укучы студент Шәүкәт, дип күреште ---*. Э.Касыймов

3) Аерылышканда саубуллашу йөзеннән куллар кысышу. *Ул бик якын кеше кебек, баягы сүзләрне кабатлап, минем белән күрешеп: – Ишет, бүгеннән Троицкига кит! – дип, үз юлына китте...* М.Гафури

4) Вакытны бергә уздыру. *Аннары ул тулай торакка хәтле озатты. «Иртәгә тагын күрешәбез, яме, чибәркәй?» – диде.* Н.Гыйматдинова. *[Фаяз белән Рәмзия] күрешсеннәр, сөйләшсеннәр, бәлки, берәр нәтиҗәгә килерләр дип фикер йөртте ике карчык.* С.Шәмси

**Күрешә башлау** Күрешергә керешү. *Айрат белән Алсу ешрак күрешә башлады.* Ф.Яруллин

**Күрешеп алу** Бер тапкыр күрешү. *Коридорда күренүем булды, Миша, авызын ерып, каршыма килеп чыкты, күрешеп алу белән беренче соравы: «Ну как, друг, готовился?» – булды.* Г.Галиев

**Күрешеп йөрү** Шактый вакыт дәвамында очрашып тору. *Бер айга якын көн дә күрешеп йөрүгә карамастан, Мирза өчен кыз ачылып бетмәгән сер сандыгы булып калды.* Ә.Моталлапов

**Күрешеп тору** Даими күрешү яки хәзерге моментта күрешү. *Сизми дә калганмын, без Сәкинә белән бер-беребезгә карашып, күрешеп торганда, Фәхретдин абзый да шунда кереп утырган булган икән.* В.Нуруллин

**Күрешеп чыгу** Булган һәрбер кеше белән күрешү. *[Ирек] беренченең ишек төбендә торучы бюро әгъзалары белән берәм-берәм күрешеп чыкты.* Ф.Садриев. *Бәйрәм җыенында Хикмәт, чыраендагы үтеп керә алмаслык корыч сабырлыгын ачмый гына, авылдашлары белән күрешеп чыкты ---*. М.Галиев. *Гөлсем апа озата керүче күршеколан белән кул кысышып күрешеп чыкты.* Г.Гобәй

**КҮРЕШҮ** II *и.* 1) Очрашу, бергә булган вакыт. *Күрешүнең чынга ашмасын икесе дә чамалыйлар иде.* Ә.Моталлапов. *Әллә инде беренче күрешүдә үк үзен артык өнәмичә --- каршы алгангамы, --- Ихтыяр беренче атнада директор янына зур эше төшмәгәндә кермәскә тырышты.* Р.Вәлиев

2) Хастаханәдә, ябык уку йортында, төрмәдә һ.б.ш. урыннарда булган кеше белән очрашу, аны күрү. *Төрмәдә утырган улы белән күрешү ана күңелендә авыр яра калдырды.* Юлдаш

**КҮРКӘ** *и. рус* 1) Фазаннар семьялыгыннан, ит өчен үстерелә торган зур йорт кошы. *[Маһибәдәр кайнана] Я күркәләргә әчетке болгатып бирмәгәнсең, --- я сарыкларның йонын тигез итеп алмагансың, дип бәйләнә...* Ш.Максудова. *Урамга арты белән карап торган бай ихатасы тирәсендә --- тавыклар кытаклый, йоннары коелып беткән күркәләр гөлдерәшә.* И.Тургенев. *Сыер, бозау, 13 баш сарык, шуның кадәр үк бәти, каз, тавык, күркә асрыйлар.* Ирек мәйданы

2) Күркә ите. *Көзгә туй итәрбез дә симез-симез үрдәкләрне, күркә түшкәләрен күтәреп шәһәргә китәрбез!* А.Гыйләҗев. *Ниләр генә юк иде анда: тутырган тавык, каклаган каз, --- күркә шулпасы, пылау, кабартма, --- эремчек ---*. Шатлыклы кайгы

3) Ылыслы агачларның тәңкәчекләр белән капланган озынча түгәрәк яисә йомырка сыман булып укмашып үскән орлык чәкәне (кәшәнкәсе). *Тиен дә буранннан тәмам гаҗиз булды, көн яктысына чыгасы, --- нарат һәм чыршы күркәләре орлыкларыннан авыз итәсе килә аның.* К.Тәхау. *Яз көне наратның яшь ботакчыкларында кечкенә күркәләр күрергә мөмкин. --- Күркәләр кабырчыклардан тора.* Биология. *Яз көне, бөреләр ачыла һәм яшь ылыслар үсә башлаган вакытта, карагайда күп санда күркәләр барлыкка килә.* Ботаника

◊ **Күркә булып кабарыну** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *– Син, тинтәк баш, безне уйладыңмы соң? – Гөлфия күркә булып кабарды, кызарып чыкты.* Р.Айзатуллин. **Күркәдәй кабару** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *Генерал үзенә каршы килгәнгә күнекмәгән. --- Йөзе күркәдәй кабарып һәм кызарып чыкты ---*. Р.Мөхәммәдиев. *Ул, Әкрәмнең тел төбендә үзе өчен бик үк күңелле булмаган нәрсә ятуын сизенеп, күркәдәй кабарынып китте.* Г.Мөхәммәтшин. **Күркәдәй кабарыну** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *Элекке генераллар алтын ялтыравыгы белән күзне камаштыра, таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабарынган кыяфәте белән тыныңны куыра иде.* Г.Бәширов. *– Нигә күркәдәй кабарындың, Рәмзис? – дип сорады ул, уң кулы белән егетнең аркасыннан кагып.* Инешләр Иделгә кушыла. **Күркә кебек кабару** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *Кичә ул күркә кебек кабарып көн азагынача утырды ---*. Р.Айзатуллин. **Күркә кебек кабарыну** Усаллану яки масаю, эреләнү. *Рәхим күркә кебек кабарынды. – Сез нәрсә барыгыз да миннән допрос ала башладыгыз?* А.Вергазов. *Нәрсә болай күркә кебек кабарынып йөрисең, матурым?* Т.Галиуллин. **Күркә кебек кукраю** *к.* **күркә кебек кабарыну**. **Күркә күк кабарыну** *к.* **күркә кебек кабарыну** *--- әти, ашавын онытып, әнигә карап ала, әни исә күркә күк кабарынып утырган да миңа күз төшергәли.* А.Гыйләҗев. **Күркәсе кабару** Үпкәләү. *[Илдусның] «Шырпы кабы» дигәнгә бераз күркәсе кабарды бугай аның.* Р.Вәлиев. **Күркә төсле кабарыну** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *Унтер --- күркә төсле кабарынып, тоткыннарны берәм-берәм өстәл янына китереп, --- һәркайсының аркасына номер суга башлады.* Ә.Галиев. **Күркә төсле кукраю** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *[Нургали] Шәйдуллиннан күркә төсле кукраеп, югарыдан түбәнгә карап сөйләүне көтмәгән иде.* Ә.Еники. **Күркә урынына кабару** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *Сәхипгәрәйне үпкәләтәсе килми аның, болай да әнә күрмәс борын ук күркә урынына кабарына, кызарына.* М.Хәбибуллин. **Күркә шикелле кабарыну** *к.* **күркә кебек кабарыну**. *Шул вакыт калҗайган өйалды ишеге җиде тавышка шыгырдап ачыла, Сабирәттәй баскычка чыгып, нәкъ тегермәнче Сафа абзыйның күркәсе шикелле кабарынып, чәлдер-чөлдер килә башлый.* М.Галиев

**КҮРКӘМ** *с.* **1.** 1) Күзгә матур, чибәр күренә торган, үзенең матурлыгы белән аерылып торган. *Бер ахирәте шундый саф уйлы, төскә-башка күркәм, тәрбияле иде.* С.Шәрипов. *--- буйга артык калку булмасалар да, төскә-биткә күркәм, исемнәре-чабы чыкмаган*

*Гыйльфан агайның төпчекләре егерме бердә дә ата йортында иделәр.* А.Гыйләҗев. *Иң гаҗәбе шунда: бу күркәм бинаны әллә каян килгән төзүчеләр түгел, ә колхоз осталары үз куллары белән салганнар.* Ф.Садриев

2) Уңай сыйфатларга яки яхшы үзлекләргә ия, хуплауга лаек булган, әйбәт, матур. *Ул аңа буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән чын ирегет булып күренде.* Ә.Еники. *Яшәгән җиреңне чистартып, пакьләндереп тору – иң күркәм, изге эш!* М.Юныс. *Ул яңа җан иясе синең белән миннән иң күркәм сыйфатларны үзенә туплап дөньяга килер.* Ф.Яруллин

3) Уңай тәэсир калдыра торган, яхшы. *Кыйссаның хәтимәсе язылмаган иде, каләмен кулга алуга, көтмәгәндә, берсе артыннан берсе иң кирәк күркәм сүзләр коела башлады.* М.Хәбибуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Яхшы, шәп. *[Ишан:] Китап киңәш белән эш күргәнне күркәм таба.* К.Тинчурин. *[Бәдри:] Күркәм итеп тәмамларга насыйп булсын.* М.Фәйзи. --- *түр өстәлдә утыручылар --- гаҗәп күркәм итеп утыра беләләр.* М.Юныс

**КҮРКӘМЛӘНҮ** *ф.* 1) Матурлану, ямьләнү

2) Яхшы яктан танылу. *Аннан соңра бер ир чыкты – гыйлем тавы, Аның белән күркәмләнде ислам даны.* Кол Гали

**Күркәмләнә бару** Торган саен ныграк матурлану, күркәмләнү. *Якуб, мәсәлән, образ буларак башта игътибарны җәлеп итмәсә дә, соңрак байый һәм күркәмләнә бара.* И.Нуруллин

**Күркәмләнеп калу** Берәр эшсәбәптән соң күркәмләнү. *Әти исә миңа: – Борчылма, улым, рәтен белеп киссәң, урман кимеми ул. Тагын да чистарып, күркәмләнеп кала әле җитмәсә, – диде.* Г.Мөхәммәтшин

**Күркәмләнеп китү** Кинәт матурлану, күркәмләнү

**КҮРКӘМЛӘ́Ү** *ф.* Матурлау, ямьләндерү. *Соңгы еллар практикасы шул бәйрәмнәрне күркәмли, эчтәлеклерәк итә.* З.Нури

**КҮРКӘМЛЕК** *и.* Күркәм булу, матур булу. *Ә бит гади халык арасында да --- күркәмлеге белән теләсә кайсы патша сараен бизәп торырлык чибәрләр күп булгандыр.* Ф.Яруллин. --- *оста куллы җиңгиләр җиһазлаган авыл өйләрендә генә була торган күркәмлек, ямь бар иде бу өйдә ---.* М.Маликова. *Һәрнәрсәдә табигать биргән күркәмлек, һәрнәрсәдә хозурлык.* Х.Ширмән

**КҮРКӘ-ТАВЫК** *җый. и.* Күркә, тавык кебек йорт кошлары. *Бер ишан хәзрәт симерттем күркә-тавык ашатып.* Г.Тукай

**КҮРКӘТАНАУ** *и. бот. диал.* Иенке шалфей, тәмлекәй

**КҮР-КҮР** *ы.* Күркәләрне чакыру сүзе

**КҮРМӘСЛӘНДЕРҮ** *ф.* Күрмәс хәлгә китерү. *Күңел күзен күрмәсләндерү*

**КҮРМӘСЛӘНҮ** *ф.* Күрмәскә әйләнү

**КҮРМЕШ** *и.* 1) Күргән, баштан кичкән нәрсәләр

2) *к.* **күрәчәк**. – *Күрмешем булган инде, мәхлук, сиңа чыгып башымны бәйләдем, – дип сөйләнә-сөйләнә үкседе ул.* Р.Айзатуллин

◊ **Күрмешне күрү** Авырлыклар, кыенлыклар кичерү. *Әйе, Хәммәди агай – күрмешне күргән кеше безнең.* Н.Исәнбәт

**КҮ́РМИ** *с. иск.* Ятлый торган, күңелдән белергә тиешле (бирем, сабак). *[Гомәр:] Җәгърафия дә укытмыйлар, туган телне дә. Гел күрми сабак кына.* Г.Бәширов

**КҮРСӘТЕЛЕШ** *и.* Әдәби әсәрдәге сурәтләү, тасвирлаулар. *Образның әсәрдә күрсәтелеше*

**КҮРСӘТКЕЧ** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсә үсешенең, барышының чагылышы, билгесе, сыйфаты. *Подразделениесе яңа елга шәп күрсәткечләр белән аяк баса ---.* С.Шәрипов. *Укучыларыбызның кайберләре чирек буена фәннәрне икелегә генә үзләштерәләр ---. Ә күрсәткечләребез гел туксан тугыз проценттан түбән төшми.* Г.Тавлин. *Отчётта һәр савымчыга уникешәр сыер дип язылган. Ә чынында нәрсә?.. Шулай алдашуыбызга да карамастан, күрсәткечләребез гаять түбән.* М.Хәсәнов

2) Нинди дә булса хезмәт яки процесс нәтиҗәләренең цифрларда, графику сызымнарда чагылышы. *Эш барышында боларның барысы да төрле күрсәткечләр, таблицалар ясарга --- тотыла иде.* А.Мифтахетдинов. *Аңа аһ та ваһ итүләр кирәкми, ә бәлки төгәл исәпләнгән саннар, --- сыйфат күрсәткечләре кирәк.* Галәмгә юл. *Югары белем баскычына куеп караганда, Казан губернасында руслар арасында ул түбәндәге күрсәткечләр белән тасвирлана: ир-атлар – 2,51 процент, хатын-кызлар – 1,86 процент.* Сөембикә

3) Берәр нәрсәне күрсәтү өчен хезмәт итә торган предмет (мәс., маяк) // Нинди дә булса җайланманың юнәлеш угы. *Приборның күрсәткече тизлекнең артуын яки кимүен күрсәтеп, күтәрелеп яки төшеп йөргәндә, аңа беркетелгән каләм дә күтәрелә.* Физика // Нинди дә булса шартлы мәгънәне белдергән тамга, билге. *Авыруларга йөрер өчен маршрутлар билгеләнгән; сукмак кырыйларына утыртылган юл күрсәткечләрендә беренче, икенче, өченче маршрут дип язылган.* Г.Әпсәләмов. – *Мин гаепле түгел, юл күрсәткечләре гаепле, – диде Мөбарәк Таһирович, аларның үз итеп көлемсерәүләренә. – Юл күрсәткечләре өскә эленгән, ә аста халык йөри.* М.Маликова. *Юл буендагы күрсәткечләргә якын-тирәдәге авылларның исемнәре язылган.* Р.Кәрами

4) Белешмә китап үзе яки китаптагы белешмә исемлек. *Алфавит күрсәткече. Кушымчалар күрсәткече. Сыйфатлар күрсәткече*

5) *мат.* Бирелгән санны яки аңлатманы нинди дәрәҗәгә күтәрүне белдерә торган цифр яки хәреф. *Дәрәҗә күрсәткече бөтен булган функция.* Югары математика нигезләре

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нинди дә булса күренешнең чагылыш дәрәҗәсен күрсәтә, билгели торган. *Приборның күрсәткеч угы*

2) Юнәлешне күрсәтү өчен хезмәт иткән. --- *Галия апа кулындагы күрсәткеч таягын Рәдифкә төбәде дә: – Син шартлаттыңмы? – дип, җан ачуы белән кычкырып куйды.* В.Нуруллин. *Күрсәткеч таягым Австрия кырыена очып куна.* М.Галиев. *Укытучы апа кулына күрсәткеч таягын тотып керә*

*иде дә Җир шарын әле тегеләйгә, әле болайга әйләндереп сөйләргә тотына иде.* Р.Вәлиев

**КҮРСӘТКЕЧ БАРМАК** *и.* Баш һәм урта бармаклар арасындагы бармак; имән бармак, шәһадәт бармагы. *Менә ул торып басты. Күрсәткеч бармагын ике каш арасына төртеп, бер мәлгә сүзсез торды, аудиториягә күз төшерде.* Г.Садә

**КҮРСӘТМӘ** *и.* **1.** 1) Ничек эш итәргә кирәклекне өйрәткән киңәш, аңлатма. *Карчыгына күрсәтмәләр биреп бетергәч, Сәмигулла, күршесенә зарлана-зарлана, ишегалдына чыкты.* Ф.Яруллин. *Без каравылчы штатын өстән җиткерелгән күрсәтмә нигезендә кыскарттык.* Ә.Моталлапов. *Инструктор кемнәрнедер күрә, аларга нәрсәдер әйтә, икенчеләренә күрсәтмә бирә, өченчеләрен тирги.* Ф.Садриев

2) Үз күзләре белән күргәнне сөйләп бирү; таныклык. *Безнең кулда Советлар Союзы Герое исеменә дәгъва белдерүче Вәлиевнең үз күрсәтмәләренә нигезләнгән --- өч мәгълүмат бар ---.* Ш.Рәкыйпов. *--- ул барлык шаһитларның күрсәтмәләрен җентекләп карап чыккан, бирәчәк сорауларын кабат исенә төшергән.* Ф.Вәлиәхмәтов. *Сораулар һәм җаваплар ана кеше өчен шушының белән гомумән тәмамланды. --- күрсәтмәләре гел дөрес булды малайның.* Ә.Баян

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күрсәтмәлелек өчен хезмәт итә торган. *Укытучы артыннан карт сторож математикага бәйләнешле инструментлар һәм күрсәтмә әсбаплар салынган кәрзин күтәреп кертте.* Җ.Тәрҗеман. *Күрсәтмә әсбаплар бүлмәсенең ишеге шыгырдап куйды.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) *спорт* Мәҗбүри программадан тыш, иҗади әзерләнгән. *Ул арада тимераякта шуучыларның күрсәтмә чыгышлары тәмамланып, экранда «Спортлото» шарларын әйләндерә башладылар.* Язмышлар яңарганда

**КҮРСӘТМӘЛЕ** *с.* Өйрәнелә торган предметларны, аларның модельләрен, схемаларын һ.б.ш.ларны күрсәтүгә нигезләнгән. *Сезнең фәнни һәм бик кыйммәтле хезмәтегез --- шулкадәр күрсәтмәле һәм ышандырырлык формада бирелгән ---.* А.Бахарев, П.Яковлев

**КҮРСӘТМӘЛЕЛЕК** *и.* Предметларны, аларның модельләрен, схемаларын күрсәтеп өйрәнүгә нигезләнгән алым, ысул

**КҮРСӘТҮ** I *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса күренә торган хәлгә китерү; карарга тәкъдим итү; карап күрергә мөмкинлек бирү. *Инде Силушкинга --- тоныкк кына күрсәткән телевидение тапшыруларын карау сизелерлек чикләнде.* С.Шәрипов. *– Мә, кара, күр --- – дип, Мирсәеткә ике фоторәсем сузды. Әтисе белән әнисен күрсәтә дисәң, болар алай өлкән күренми.* Р.Мөхәммәдиев. *Малай рәсемне иптәшләренә күрсәткән.* Җ.Дәрзаман // Карап күрергә бирү, тәкъдим итү (документ һ.б.ш.ларны). *– Сез кемнәр? Каян килдегез? – Тегеләр мандатларын күрсәттеләр.* Ш.Рәкыйпов

2) Яктырып торган яки шома өслектә кеше яки әйбер шәүләсенең чагылдырылуы. *Әллә дөрес күрсәтмиме дип, җиңе белән көзгене сөртеп карый, ап-ак көзгеләре, дөп-дөресне күрсәтә.* А.Гыйләҗев

3) Кешеләр карап күрсен өчен, берәр төрле эш-хәрәкәт башкару, нәрсәне дә булса демонстрацияләү. *Мөбин гомер буе мөгез чыгарып яшәде, тик кенә торганда, бөтен кеше күз алдында кипкән сыер тизәге ашап күрсәтү кирәкме, --- – барысын да эшли ала иде.* М.Мәһдиев. *Баксаң, ул үз тирәсенә коеп куйган «артистлар» җыйган икән ич. Уйнап та күрсәтәләр бит әнә.* Р.Мөхәммәдиев. *Әлмәт театры Болынкырда аның пьесасының премьерасын күрсәтте.* Ф.Садриев

4) Кемне дә булса әйләнә-тирә белән тиешле аңлатмалар биреп таныштыру. *ГЭС башлыгы, кунакның теләгенә буйсынып, аңа зыр әйләнеп торган кече генераторны күрсәтте, аның куәтен әйтте ---.* Э.Касыймов. *Тәрәзәдән күренеп калган авылларны, станцияләрне күрсәтә-күрсәтә, юл буе таныштырып, сөйләп кайтты.* Н.Акмал

5) Кемнең дә булса игътибарын берәр кешегә яки берәр нәрсәгә юнәлдерү. *Райкомның эшләгән эшен дә күрсәтергә онытма ---.* Ф.Садриев. *--- шушы мин күрсәткән олы юлдан ерак китмәгез, ул сезгә алга бару өчен яхшы маяк булачак.* Ә.Галиев

6) Тәкъдим итү. *Күзлеге өстеннән бик дикъкать белән карап каршы алды бу мине, кулы белән генә урын күрсәтте.* Ә.Еники. *Мәдинә апа бала имезеп утыра иде. Ымлап кына урындык күрсәтте.* Ф.Яруллин. *[Суфия апа] аннары арткы рәттәге бер буш партаны күрсәтеп, Равилгә шунда утырырга кушты.* В.Нуруллин

7) Кемне яки нәрсәне дә булса билгеле яктан кабул итәргә этәрү, фикер тудыру. *[Солтангалиев:] Аны үз милләттәшләре алдында явыз большевик, дошман кеше итеп күрсәтү кемгә кирәк икән?* Р.Мөхәммәдиев. *Бу күлмәк аның артык ябык та түгел, тулылыгы да сизелмәгән сыгылмалы гәүдәсен бик сылу итеп күрсәтте.* Р.Кәрами // Кемнең яисә нәрсәнең дә булса үзенчәлеген, сыйфатын чагылдыру. *Хәзерге заманда һәркем үзен үзе күрсәтергә тиеш.* Ф.Яруллин. *--- кызының төрле эшләргә катнашасы, кеше арасына кереп, эш күрсәтәсе килә иде.* С.Шәмси. *Табигать тискәре якларын күрсәтә башладымы, тракторның да киреләнә торган гадәте бар аның.* Р.Төхфәтуллин

8) Кешеләргә үзеңнең башкалардан аерылып торган нинди дә булса сыйфатыңны, хәлеңне белдерү, сиздерү. *[Вадим] Ике көн дә узмады, күрсәтте егетлеген.* Ә.Моталлапов. *Паниев, әйдәле, күрсәт осталыгыңны!* Ш.Рәкыйпов. *--- ул безнең идеология бүлегендә шактый вакыт инструктор булып эшли, үзен бары тик яхшы яктан гына күрсәтте.* Ф.Садриев // Нинди дә булса мөнәсәбәтне белдерү, чагылдыру. *Хатынына игътибарлылык күрсәтә, һәрдаим ярдәм итәргә тырыша.* Ә.Моталлапов. *Таһирны терелтү өчен һәрберсе җаннарын ярып бирердәй туганчыллык күрсәтә.* Ф.Галимуллин. *Әгәр дә берәрсе сиңа якты йөз күрсәтә икән, белеп тор: димәк, аңа синнән нидер кирәк ---.* Р.Вәлиев

9) Сәнгать әсәрендә кайсыдыр образны гәүдәләндерү, чагылдыру, сурәтләү. *Атказанган артист Х.Сәлимҗанов*

*халыкның зирәклеген, тапкырлыгын, кыюлыгын, җитезлеген Байтирәк образында шактый тулы күрсәтте.* М.Җәлил

10) Исбатлау, дәлилләү. *Син әле үзеңнең бүтәннәр сүзен кабатлаучы попугай түгел икәнеңне, сандугач икәнеңне, үз тавышың, үз көең барлыгын күрсәтерсең.* Җ.Тәржеман. *Анысы сезнең эш түгел, атакай; Матрёшкага кем колы икәнен күрсәтермен әле.* И.Тургенев

11) Ничек эш итәргә кирәклеген өйрәтү, аңлату. --- *әллә нинди катлаулы тигезләмәләр белән мәсьәлә чишеп күрсәткәндә, ул яңа бер планета ачкан кебек, бәхетле халәткә безне дә алып керә, мавыктыра белә иде.* М.Галиев. *Нишләргә икәнен үсмергә таяклы кеше күрсәтеп, өйрәтеп бирә.* К.Латыйп

12) Нәрсәне дә булса шартлы билгеләр белән чагылдыру, билгеләү. --- *күл суының биеклеге ничек үзгәртеп торуын күрсәтә торган график төзик ---.* А.Муранов. *Инфляциянең үсүен график юл белән күрсәтү*

13) Белдерү, билгеләү (төрле приборларның температура, басым, юнәлеш һ.б.ш.ны белдерүе тур.). *[Компастагы] стрелканың кара төскә буялган очы һәрвакыт төньякны, буялмаган очы көньякны күрсәтә.* Физик география

14) Нәрсәне дә булса ачыклау өчен, башка бер кешегә мөрәҗәгать итү (күбрәк авырулар тур.). *Ул да бер туганын хастаханәгә йөртә иде, кызымны күрсәтергә булышмассыңмы, дип, үзем анннан үтендем.* Ирек мәйданы

15) Сайлаулы органнарга кемне дә булса тәкъдим итү. *Беренче мәсьәлә – авыл советына председатель сайлау. Кандидатлар күрсәтүегезне сорыйм.* Һ.Такташ

16) Нәрсәнең дә булса нәтиҗәсе ачыклану; мәгълүм булу. *Бераздан соң хуҗа кешенең бу астыртын эше нәтиҗәләрен дә күрсәтте.* Р.Төхфәтуллин. *Безнең элек ярышларда катнашкан бер кыз бар, ләкин соңгы вакытта яхшы нәтиҗәләр күрсәтми.* Р.Кәрами. *Рамазанов --- колхоз экономикасын бөтен ваклыкларына кадәр белүен күрсәтте.* Ф.Садриев

17) Таныклык бирү

18) *сөйл.* Кирәген бирү, нык итеп шелтәләү; үч алу. *[Ата кеше:] Ну, ярар. Синеңчә булсын. Ну, бирермен әле мин, күрсәтермен...* М.Мәһдиев. *Болай йөрсәң, күрсәтермен әле мин сиңа.* Ф.Яруллин

19) Бирү, тәэмин итү. *Миңзаһит ---, укуын тәмамлап кайткач та, аңа акча күрсәтмәде, бик кирәк чакларда ---гына сәмән ыргытты.* Ф.Садриев

20) Абстракт исемнәр янында килеп, шул сыйфатка, үзлеккә ия булуны исбатлауны белдерә. --- *минем әле кешеләргә, җиргә яхшылык эшлисем бар, игелек күрсәтәсем бар ---.* М.Мәһдиев. --- *Шәвәлиевкә яңадан Сонялар да, Саниялар дә, Хәлимәләр дә, Кәримәләр дә кадер-хөрмәт күрсәттеләр.* Ф.Садриев

**2.** *ярд. ф. функ.* Нинди дә булса эшхәрәкәтне кемгәдер җиткерү, аңлату йөзеннән башкару, үтәү. *Бу очрашуда ул миңа үзенең әсирлектә язган бик яхшы патриотик шигырьләрен, хәтта бер поэмасын да яттан укып күрсәтте.* И.Юзеев. *«Кәк-тәк тавышым юк? – дип дөнья кубардым. --- Ышанмасагыз, тагын берне җырлап күрсәтәм».* Ф.Яруллин. *Сабит энесенә сүз катмады, чыгарып та җибәрмәде, димәк, ул бу спектакльне Нәҗип өчен дә уйнап күрсәтте.* А.Гыйләҗев

**Күрсәтә бару** Һәммәсен, булган берсен күрсәтү

**Күрсәтә башлау** Күрсәтергә тотыну. *Хәтта хатын-кызларга карата бозык ирләргә хас әрсезлекләр дә күрсәтә башлады ул.* З.Фәйзуллин. *Малай үзенең йөзенә-битенә, күзләренә, чәчләренә төртеп күрсәтә башлады.* Г.Гыйльманов. *Әмма заманалар узып, рус дәүләте прогресска йөз тотып, алга бару юлына чыккач, мондый изоляция сәясәте үзенең тискәре ягын да күрсәтә башлады.* А.Әхмәдуллин

**Күрсәтә тору** Башка эш-гамәлдән алда күрсәтү

**Күрсәтеп алу** Кыска вакыт аралыгында, тиз генә күрсәтү

**Күрсәтеп бару** *к.* **күрсәтә бару**

**Күрсәтеп бетерү** Бөтенесен дә, барысын да күрсәтү. *Әти кешенең әле төзү эше бетмәгән иде, холкы тагы да начарланды, тәмам үзен күрсәтеп бетерде.* М.Мәһдиев

**Күрсәтеп йөрү** Күрсәтү эше белән шөгыльләнү, гел, һәрвакыт күрсәтү

**Күрсәтеп калу** Нәрсәне дә булса үз вакытында күрсәтергә өлгерү. *Исән чакта эш күрсәтеп калырга кирәк, эш!* Р.Вәлиев

**Күрсәтеп карау** Күрсәтергә тырышу. *Әмә әни... --- Сызламаган җирем юк, ди. Врачларга да күрсәтеп караган идем үзен.* В.Нуруллин

**Күрсәтеп китү** Нәрсәне дә булса эш яки сүз барышында күрсәтү

**Күрсәтеп кую** Нәрсәне дә булса күренгән хәлгә китерү; алдан күрсәтү

**Күрсәтеп тору** Әледән-әле яки даими күрсәтү; хәзерге вакытта күрсәтү. *Ул иртәне кояш сүлпән күтәрелде, нәрсәдәндер күңеле бизгәндәй, байтак вакыт болыт арасыннан читен генә күрсәтеп торды ---.* С.Шәмси. --- *дошман көчле. --- дошман ягыннан өзлексез явып торган пуля һәм снарядларның көннән-көн арта баруы да шуны күрсәтеп тора иде.* В.Нуруллин. *Көне буе әллә нинди авыр эшләрне эшләсә эшләр, әмма тикшерүче каршында ярты сәгать тә утырмас – аның бөтен кыяфәте әнә шуны күрсәтеп тора иде.* Ф.Вәлиәхмәтов

**Күрсәтеп үтү** *к.* **күрсәтеп китү**. *Дарвин организмнарның тереклек шартлары шушы сорт яки токымда кеше өчен кирәкле сыйфатларны үстерүгә ярдәм итәрлек булуының бик әһәмиятле икәнлеген аерым күрсәтеп үтә.* Дарвинизм нигезләре

**КҮРСӘТҮ** II *и.* 1) *сөйл.* Күрсәтмә. *[Мостафа:] Мондый эшләр Цеканың күрсәтүе буенча эшләнә.* Ш.Камал

2) Шаһитлык; берәр вакыйга турында шунда булган кешенең мәгълүматы. *[Рәхим:] Атаңны аттылар, абыеңны яптылар, докторны да, следовательне дә ялган күрсәтүләре өчен утырттылар.* Һ.Такташ

**КҮРҮ** *ф.* **1.** 1) Күз белән карап кабул итү, карап сизү. *Хәрәм ата исә башын түбән иген дә атлый да атлый, берәүне дә күрми, күрергә дә теләми сыман.* М.Хәбибуллин. *Аны күккә алып*

*менәргә тиешле очучы ---, Зәйтүнәне күрүгә, җилдә каралган йөзен чытып куйды.* М.Маликова

2) Очрату. *Җиңел, хәрәкәтчән, тере гәүдәле Ләйләне, беренче күрүдә, кырыкка җитеп килә торган хатындыр бу, кафедра җитәкчеседер дип, һичкем әйтә алмас иде.* М.Маликова. *Гөлфия аны беренче тапкыр МТС конторасында күрде.* Р.Төхфәтуллин. *Анда [Казанда] мөһим йомышлары, күрәсе кешеләре бар.* Ә.Моталлапов

3) Күз белән карап кабул итү сәләтенә ия булу. *Якуп Сәйфи белән Шәүкәт сәхнәдәге үзгәрешләрне --- аңлатып барырга тырыштылар, тик тумыштан ук күрү сәләтеннән мәхрүм булган кешегә аларның аңлатуы --- музыка сөйләгәнне катлауландыра гына иде.* Э.Касыймов. *Гел кимсенә иде ул начар күрүе аркасында, ничә еллар буе «Дүрткүз» дигән кушамат тагып йөрде!* М.Маликова

4) Аңлау, төшенү; сизү, белү. *Бу надан студенттан эш чыкмаганын күргәч, мин икенче ягымдагы утыргычка таба әйләндем.* Ф.Әмирхан. *Ышаныгыз, сезнең кебек... кешенең газабын күрү миңа бер дә җиңел түгел.* Ә.Еники. *Беренче исеменнән мәкалә язу – аның биеклегеннән торып күрү һәм фикерләү дигән сүз.* Ф.Садриев

5) Баштан үткәрү, кичерү; берәр нәрсәгә дучар булу. *Мәрьям абыстай сугыш хикмәтләрен, улының күргәннәрен таңга калып --- тыңлый иде.* Ә.Еники. *Сугышта күргәннәре, кичергәннәре берничә кеше гомеренә тиң бит аның.* И.Юзеев. *Аның иңендә шактый таушалган кара пальто, --- кулында, үзе кебек үк, яшен яшәгән, дөнья күргән сумка иде.* С.Шәмси

6) Берәр нәрсәнең яки берәр эшнеңхәрәкәтнең нәтиҗәсен үз тормышыңда тату, тою, сизү. *Бүген укытучының күңеле аеруча күтәренке: Мәскәүдә өченче дәреслеге басылып чыккан ---. Ничә еллык хезмәтнең җимешен күрү, кулыңда тоту дигән сүз бит бу!* М.Маликова // Нинди дә булса күңелсезлеккә, авырлыкка дучар булу. *Ихтыярның да, зыян күргән кеше буларак, үтенечен исәпкә алганнар ахрысы: егетләргә кисәтү ясадылар да --- чыгарып җибәрделәр.* Р.Вәлиев. *Кәбир бу явызлыгы өчен күрер әле, Гөлчирәнең күз яшьләре томмый калмас, томар.* Х.Сафина

7) Ирешелгән максатның нәтиҗәсен тою. *Синеңчә, балалар үстерү, эшләгән эшеңнең нәтиҗәсен күрү --- кызык түгелмени?* Ф.Яруллин. *--- бүген, Фатих Кәрим биеклегеннән караганда, иҗатының бу чорында без ул күтәреләсе биеклекнең нигезләрен күрәбез.* И.Юзеев

8) Берәр нәрсәгә ия булып, аңардан файдалану, аның белән эш итү. *Безнең аның шикелле генә акча күргәнебез бар.* Г.Камал. *Әти-әни күрмәгән, алар кия алмаган киемнәрне киябез без хәзер.* Татар иле

9) Кемне яки нәрсәне билгеле күзлектән бәяләү, күз алдына китерү дип санау. *Иялешермен, җайлашырмын, мәхәббәт насыйп түгел икән, нишлим, ирем итеп, баламның атасы итеп якын күрергә тырышырмын.* Ә.Еники. *--- барыбер аның итен ашый алмас иде, ул аларны оҗмах кошларыдай күрде.* М.Хәбибуллин. *Санын җыя алмаган картны, ямьсез хатыннарны үз балаңдай күрү өчен акылдан шашкан булырга кирәк!* М.Маликова

10) Берәр нәрсәнең шаһиты булу, белү

11) Күзаллау, хыялда, планда күз алдына китерү

12) Нинди дә булса күңелсезлекнең сәбәпчесе итеп табу; кемне дә булса гаепле дип санау. *Хатынының еш кәефсезләнүен авырлы булудан күрде Фатыйх.* Ф.Яруллин. *Атасы --- Зәйнәпне битәрли, эше уңмаганлыкларны Зәйнәптән күрә.* М.Гафури

13) *-а/-ә, -и/-ыйга* беткән хәл фигыльләрдән соң боерык фигыль формасында килеп, үтенүне, ялваруны яки боеруны, теләкне белдерә. *[Нәгыймә:] Ярар, кызым, бар. Минем өчен эшеңнән кала күрмә.* Г.Камал. *[Разия:] Сезнең белән юньләп исәнләшә дә алмадым, кичерә күрегез.* Г.Ибраһимов

14) *күч.* Ахыргача аңлап, белеп бетерү. *[Яңгура:] Мин дә сезне күреп җиткерә алмаганмын. Сез күзгә төтен җибәрергә нык остарып кайткансыз.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* **күреп**. Кемгә яки нәрсәгә дә булса ияреп, үрнәк алып. *Күршедән күреп эшләү*

**3.** *кер. сүз функ.* 1) *сөйл.* **күр**. Гаҗәпләнүне белдерә. *[Гарәфи:] Күр, без вагонга утырганнан бирле, яткан урыныбыздан кузгалганыбыз юк.* Г.Әпсәләмов

2) **күрерсең, күрерсез, күрербез**. Киләчәктә ачыкланыр, киләчәктә билгеле булыр. *– Бар да, бар да рәтләнер, Хаҗи. Тик, зинһар, артык борчыла күрмә... Менә күрерсең... Күрерсең менә... [диде Һаҗәр].* М.Хәсәнов. *– Юк, Заһид, – диде ул ышанычлы тавыш белән, – иртәгә көн аяз булачак, мин беләм, менә күрерсең...* Р.Төхфәтуллин

**4.** *ярд. ф. функ.* 1) *итү* ярдәмче фигыленең мәгънәсенә туры килеп, исемнәрдән тезмә фигыль ясый. *Ашлыкны кыш көне әвен белән сугуда әллә ничаклы файда күрә.* Г.Ибраһимов. *Өстәлдәге дәфтәрнең пароход машинасы белән ничек-ничек эш күрәсен өйрәткән җирен укып чыкты.* Ф.Әмирхан

2) *сөйл. -еп/-ып* формалы хәл фигыльгә кушылып тезмә фигыль ясый торган *карау* сүзен алыштыра. *Гомерендә бер мәртәбә булсын либретто язып күрмәгән --- кешегә --- зур либретто язарга яки зур операны тоташ тәрҗемә итәргә тапшыру мөмкин түгел иде.* М.Җәлил. *Татып күрсен инде хәзер Ачы үлем чишмәсен.* Ф.Бурнаш

3) Кайбер исемнәрдән соң килеп, шул исем белән белдерелгән эш-хәлне башкаруны аңлата. *Хәзер --- биредә көне-төне үрсәләнеп чабарга, --- өлкә комитеты секретарен каршылау һәм озату хәстәрен күрергә туры киләчәк.* Ф.Садриев. *Безнең Аяз өстәлнең мул булуын таләп итә иде һәм --- кунак чакырган көннәрдә, аш-су әзерләшү хәстәрен күрү эшендә катнашып яшәде.* Н.Гыйләҗева. *Каникулның соңгы көне юл хәстәрлеген күреп үтте.* Р.-Н.Гүнтәкин

◊ **Күрә торып** 1) Ачыктан-ачык, бер дә тартынмыйча. *[Вәли карт:] Күрә торып, кеше җиренә, кеше хакына керәсез!* Ш.Камал; 2) Белә торып. *Күрә торып үлемгә барып булмый инде,*

*юлны таба алсам, кире Чүкәйгә генә кайтырмын, дип, әллә ни гомер эзләп караса да, юк, тәки таба алмады Равил юл катысын.* В.Нуруллин. *«Хәйретдин агайны күрә торып үлемгә бирмәскә кирәк», – дип кабатлады ул күңеленнән.* А.Гыйләҗев. **Күр дә тор** Һичшиксез, чыннан да, чынлап та, дөрестән дә. *Безнең капкага да Сәмруг кошы кунар әле. Күр дә тор менә.* М.Кәрим. *Платон Платонович мине ярата, кафедрада эшкә калдыра. Күр дә тор, профессор булачакмын.* А.Гыйләҗев. **Күрер күзгә** Беренче карашка; карап торганда. *Ә Рухияне авызына караткан теге Эшләпә күрер күзгә дә алай бөтенләй үк бетерепташларлык нәрсә түгел.* В.Нуруллин. *Бакча каравылчысы – без көлеп йөргән, ямьсез генә, күрер күзгә күрексез генә тол хатын.* И.Юзеев. *Әнисе дә күрер күзгә сылу гына икән.* Н.Гыйматдинова. **Күрмәгәнен күрсәтү** Нинди дә булса катгый чара куллану. *Ә без аларга [фрицларга] янә күрсәтәбез күрмәгәннәрен.* Ш.Рәкыйпов. *Хөппежиһанның кулы каты. Күрмәдем дисәң, күрмәгәнеңне күрсәтер.* Г.Мөхәммәтшин. *Бүтәннәр дә шаулаша башлады: – Әйе, әйе, шунда күрсәтербез без сиңа күрмәгәнеңне!* В.Нуруллин. – *Кара, кабахәт, мир алдында нәрсә сөйләп тора! --- Күрмәгәнеңне күрсәтермен!* Ә.Моталлапов. **Күрмәгәнне күрү** Авырлык күрү; нинди дә булса җәза алу. *Ярый, бәхете бар икән, китеп котылды, күрмәгәнен күргән булыр иде.* А.Алиш. **Күрмәмешкә салыну** Берәр кешене яки нәрсәне күреп тә, күрмәгән булып кылану, үзеңне аны күрмәгән кебек тоту. *[Әтиең] Хәзер бөтенләй күрмәмешкә салына.* Р.Вәлиев. **Күрмәмешкә салышу** *к.* **күрмәмешкә салыну**. *Гайфулла аны күрмәмешкә салышып, пластмасс шешәне шарт-шорт китерә-китерә, су эчте.* Ф.Яруллин. *Караватянында басып торган Анна Ивановна, кереп баскан докторны күрмәмешкә салышып, Диңгә таба иелде ---.* М.Маликова. *Мансур Ибраһимович укытучы лабаса ---! Әлбәттә, ул Гөлкәйне күрмәмешкә салыша!* Х.Ширмән. **Күрми күрү** Беренче тапкыр күрү

**Күрә башлау** Күрерлек дәрәҗәгә җитү. *Гамир әнисенең салып кайтканын --- йөзеннән дә күрә башлады.* З.Фәйзуллин

**Күреп алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә күрү. --- *танкка каршы ата торган туп бәләкәй нәрсә түгел. [Фашистлар] күреп алдылар.* Ш.Рәкыйпов. --- *Миләүшә үзләренә таба килүче авыл егетләрен күреп алды.* Ф.Яруллин. *Бер мизгелдә аның йөзен күреп алды ---.* М.Маликова

**Күреп бетерү** Бөтенесен дә, барысын да күрү

**Күреп җиткерү** *к.* **күреп бетерү**

**Күреп калу** Күрергә өлгерү. *Николай үзеннән арттарак туп төшеп шартлавын да, взвод командирын һава дулкыны җиргә сылавын да бер мизгелдә күреп калды.* Ш.Рәкыйпов. *Моны карчыкның яныннан китми төн уздырган фельдшер кыз гына күреп калды.* С.Шәмси. *Ул бары үзенә ташланучыларның биш кеше --- икәнлеген генә күреп калды.* В.Нуруллин

**Күреп килү** Күптәннән, озак вакыт дәвамында күрү. *Алар нәселенә кагылышлы күңелсез хәлләрне дә Лиза күреп һәм сизеп килде.* Г.Әдһәм

**Күреп тору** Әледән-әле, ара-тирә яки даими күрү. *[Рухия] Равил күреп торган чакларда, бүтән малайлар янында юри чытлыклана башлады.* В.Нуруллин. *Ихтыяр болай да барысын белеп, күреп тора лабаса.* Р.Вәлиев. *Исламның да йөрәк яна, ул бит сукыр түгел – кызның үзенә ничек тартылуын күреп тора.* С.Шәмси

**КҮРҮК** *и. диал.* 1) *к.* **күрек** II (*2 мәгъ*). *Былтыр Мәскәүдән зур бер министр килгәч, --- ашап-эчеп утыра торган урынны --- күрүкләр белән чебенчеркидән саклаганнар иде.* Ф.Садриев

2) *к.* **күрек** II (*3 мәгъ*). *Ул да әнә шулай, ярсып тальян күрүген тартатарта, сугышка киткәндә, соңгы тапкыр урам әйләнгән, диләр.* И.Юзеев

**КҮРШЕ** *и.* **1.** Янәшәдә, каршыда яки якында яшәүче, торучы кеше. *Ул, күршеләрен уятмаска тырышып, --- ишекнең ачкычын бик әкрен генә борды.* М.Маликова. *Бергә күрше булып үскәннәр. --- Эстәрле суында кәрҗин белән ташбаш, маймыч, эт балыклары тотканнар.* З.Зәйнуллин. *Аяк тавышларыннан Мирза шуны чамалады: бу ханымнар --- күршеләр булдылар.* Ә.Моталлапов

**2.** *с. мәгъ.*1) Янәшә булган, якын торган. *Зөфәр урамга чыкканда, күрше капка төбендә ике әби утыралар иде.* Н.Әхмәдиев. *Машина тавышларына --- кушылып, күңелләрне сыкратып, күрше бүлмәдән моңлы җыр агыла да агыла.* Р.Вәлиев. *Вагонда барысы да йоклыйлар. Тик күрше купеда гына берәү йокысы күптән качкан тавыш белән сөйли ---.* Р.Төхфәтуллин

2) Үзара янәшә торган; бер-берсенә чиктәш булган. *Икенче елга калган Овчинников күршесенә төртеп алды ---.* Җ.Тәрҗеман. *Лариса күрше кафедрага Дәүләтшин кул астына күчкәннән бирле, аның белән сирәк күрешелә.* М.Маликова. *Опера тәмамлангач, күршедә утырганнар уята мине ---.* З.Зәйнуллин

◊ **Күршегә кереп торасы юк** «Үзебездә дә бар», «үзебездә дә җитәрлек» дигән мәгънәне белдерә. *[Камышев:] Тәҗрибәң ике кешегә җитәрлек! Осталык өчен дә күршегә кереп торасың юк.* И.Гази. **Күршегә кереп торырга түгел** *к.* **күршегә кереп торасы юк**

**КҮРШЕ́-КАРШЫ** *җый. и. сөйл. к.* **күрше-күлән**. *Күрше-каршы, кардәшыру, савылып, иртәдән Сәләхетдиннәргә кереп китте.* А.Гыйләҗев

**КҮРШЕ́-КОЛАН** *җый. и. сөйл. к.* **күрше-күлән**. *[Мәһди:] – Тик бел аны: күрше-коланга безнең хакта, бигрәк тә киленең хакында нахак сүз, гайбәт сүзе сөйләп йөрисе булма ---, – диде дә ишекне каты ябып чыгып китте.* Ш.Максудова. *Әмма Зөләйха апа үзенең бөркетенә күз түйганчы карарга да, күрше-колан арасында әз-мәз мактанып, горурланып калырга да өлгермәде.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮРШЕ́-КҮКЕРТ** *җый. и. сөйл. к.* **күрше-күлән**. *Яренгә --- бер кайтып килербез әле. Туган-тулпы, күршекүкертне күрербез.* Х.Сарьян. *Алар исәп-хисапны төгәл белүләре белән күрше-күкерт арасында аерылып торалар --- иде.* Г.Ахунов

**КҮРШЕ́-КҮЛӘМ** *җый. и. сөйл. к.* **күрше-күлән**. *[Җәләл:] Әнкәй дә, сеңел дә, акыллырак кардәш-кабилә дә, күрше-күләм дә мәслихәт таптылар.* Ш.Камал

**КҮРШЕ́-КҮЛӘН** *җый. и.* Күршеләр, бер-берсе белән янәшә яшәүчеләр. *Күрше-күлән кыяр орлыкларын сорап теңкәгә тияләр иде.* М.Хәсәнов. *Шакир абыегыз --- мин бүлнистә чакта балаларны да әйбәт караган. Күрше-күлән исе китеп сөйли.* Г.Галиева. *Күрше-күләннең күпчелеге авылдан килеп урнашкан халык булып, барысы да диярлек завод-фабрика тирәсендә яисә шофёр булып эшли ---.* С.Шәмси

**КҮРШЕ́-КҮРПЕ** *җый. и. сөйл. к.* **күрше-тирә**. *Минем абыемны бөтен күрше-күрпе мактап сөйлидер иде.* Ф.Әмирхан

**КҮРШЕЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Күршеләр кебек, күршеләр булып. *Алар, ахыр чиктә, --- бөтен мәсьәләләрне --- яхшы күршеләрчә – туганнарча хәл итәргә кирәклеген аңлаганнар.* Чын мирас

**КҮРШЕЛЕК** *и.* Күрше булу, янәшә яшәү. *Кайсы аңа бурычка баткан, кайсы сәдакасын алган. Туган-тумачалык, күршелек хакы --- дип тә кыймыйлар.* Т.Әйди. *--- авылда гел шулай, ике «ипи салу» арасында бер өзеклекне «әҗәткә кереп» ялгыйсы; бу – күршелекне беркетеп торучы гаять әһәмиятле бер хәл.* М.Мәһдиев. *Мирсәетнең Төркия белән Совет иле арасында яхшы күршелек мөнәсәбәтләре урнаштыру юлында җан атып йөрүе кайберәүләрнең эчен пошырган күрәсең.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮРШЕ́-ТИРӘ** *җый. и.* 1) Күршеләр, күршедә яшәүче кешеләр. *Күрше-тирәдән керүчеләр дә бар иде ахрысы ---.* Ә.Еники. *Агай-эне белән, күрше-тирә белән болай да, кунаклашып та йөрешү юк.* З.Зәйнуллин. *Ул уйланып торган арада күрше-тирә бала-чагалары да өстәлеп, уен шактый кызып китте ---.* Г.Галиева

2) *к.* **күрше 2.** (*2 мәгъ.*). *Хәзер анда инде күрше-тирәдән күчеп килгән татарлар яши.* М.Мәһдиев. *Чабак елгасы ярындагы авылларда гына түгел, бөтен күрше-тирә районнарда да беренче күмәк бакча – колхоз бакчасы була бу.* Г.Мөхәммәтшин

**КҮСӘ** *с.* **1.** Сакалы үсмәгән яки сакал төкләре бик сирәк булган. *Икесе дә көбә кебек күсә йөзлеләр.* Т.Нәбиуллин. *Үз гомерендә әле бу салпы колаклы, күсә чырайлы --- кеше җиңүчеләр татый торган ширбәттән дә, качаклар һәм тоткыннарга тиеш ачы шәрабтан да авыз итәчәк.* Р.Зәйдулла. *Ул --- җирән төстәге күсә сакаллы, зур ачылган зәңгәр күзләре --- мәэюс кенә елмайган Гайсә сурәтләрен хәтерләтә иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**2.** *и. мәгъ.* Сакалсыз кеше, сакал үсмәгән кеше. *Һәр сакаллы берәр төк бирсә, күсә дә сакаллы булыр.* Мәкаль

**КҮСӘБӘ** *и. диал.* Зур кисәк. *Палас өстендәге зур чиста кәгазьгә күсәбәсе белән пешкән ит куйдылар ---.* М.Мәһдиев

**КҮСӘК** *и.* **1.** 1) Бәрү, ору, сугу, авыр әйберләрне каерып күтәрү һ.б.ш. өчен кулланыла торган, бер башы юанрак, икенче башы тотар өчен юнып нечкәртелгән агач. *Алда --- бүрәнәләр арасында аркылы-торкылы күсәкләр салынган кара чокыр пәйда булгач, Дамирның йөрәге жу итеп китте.* С.Шәрипов. *[Хәдичә] Садри каршына килеп басты да, күсәгенә куш куллап таянган килеш, элеп тә алды ---.* М.Хәсәнов. *Аннан бер-ике метр озынлыгындагы (кибәннең зурлыгына карап) күсәкләр белән як-ягыннан терәтәсең.* М.Мәһдиев

2) *күч. гади с.* Мәгънәсез, тәрбиясез кеше турында. *Синең шулай тормышның өстеннән генә шуып яшәвең аркасында, Рашат күсәк булып үсте!* Ф.Садриев. *Оятсыз, күсәк! Шушындый балдызың өчен син учыңда аш пешереп бирергә тиеш.* Ф.Яруллин. *Дәрте булса да, дәрман ягының сай икәнлеген, тәләге булса да, үзенең бер эшне дә төпле итеп белмәвен, егерме яшьлек күсәк булуын шунда аңлады ул.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Нинди дә булса тупас көч кулланучы. *Патша заманының тупас күсәге – кызыл борынлы исерек урядниклар – аларның яшьлек истәлегендә имәнеч шомлы карачкы булып гәүдәләнеп калган.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* Тәрбиясез, әдәпсез, тупас яки аңгыра. *Инспектор --- каршында басып торган инвалид сторожның өстенә төкерекләрен чәчә-чәчә: – Тинтәк! Күсәк! – дип чәрелдәде.* Җ.Тәрҗеман

◊ **Күсәк белән ору** Көтелмәгәндә ишетелгән хәбәрнең яки сүзнең авыр тәэсир итүе турында. *Ленар Сафин, гүя күсәк белән ордылармыни, миңгерәүләнеп калды.* Р.Айзатуллин. **Күсәк белән тондыру** *к.* **күсәк белән ору**. *Гүяки, минем артымнан килеп, зур күсәк белән тондырдылар ---.* Ф.Яруллин. **Күсәк күтәрү** Кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы бару; көрәшү. *– Үзеңне тиңсенмәгәннәргә күз алартып йөрисең дә юк, бөтен дөньяга күсәк күтәрүең инде, гафу ит, акылсызлык, малай-шалайлык.* Т.Әйди. *– Кешеләр бер-берсенә күсәк күтәрергә тиеш түгел, – диде Рәшидә.* М.Маликова. **Күсәкнең юан башы төшү** Күмәк кылган эш-гамәлләр өчен, аерым бер кешене генә җәзага тарту. *Әмма ләкин күсәкнең юан башы Рәшиткә төшәргә тиеш.* Ф.Яруллин

**КҮСӘКЛӘШҮ** *ф. сөйл.* Күсәкләр белән сугышу, кыйнашу

**КҮСЕ** *и.* 1) Тычкансыманнар семьялыгыннан, тычканнан зур, соры йонлы, озын койрыклы кимерүче хайван. *Ә хәзер колхозчының амбары-келәте тулы, өйалды тулы икмәк, күселәр анда колония-колония булып яшиләр ---.* Ф.Яруллин. *Шул күл суын озакламый шешәләргә тутырып, --- күсе агуы итеп кибетләрдә сатачаклар икән дип ишеттем.* Р.Вәлиев. *Япония галимнәре, ген инженериясе нигезендә, кош кебек сайраучы күселәр китереп чыгарган.* Ирек мәйданы

2) *күч. сөйл.* Нинди дә булса тыныч һәм табыш китерә торган урында эшләп, борчылмыйча рәхәт яшәүче кешегә карата нәфрәт хисе белән әйтелә. *«Ә син үзеңнең кемлегеңне онытма: безнең паёкны ашап симергән күсе!» – дип кычкырды Ленар.* Р.Айзатуллин. *Гордов, элеккеге кәнсәләр күсесенең ике мәгънәле сүзен ишетмәгәнгә салынып, ишеккә юнәлде.* Ш.Рәкыйпов. *Мөгаен, хакимияттән тинтерәтүче бүлек «күсе»седер, гадәттә алар тәкәббер кылана.* Н.Гыйматдинова

**КҮСЕЛЕК** *и. диал.* Чалбар якасы, чалбар изүе. *[Кавын башлы татарның] юлда ике төймәгә чак эләгеп торган*

*чалбарының күселегеннән --- ирлеге бүлтәеп чыккан.* А.Гыйләҗев

**КҮСТӘРҮ** *ф. иск. к.* **күрсәтү**. *Йөзең күстәр, [пәрдәңне] ач.* Г.Тукай

**КҮСТЕНҮ** *ф. диал.* Ыңгырашу. *Зәгыйфь вә кызганыч бер мәхлук, --- йомшак кына җан сулышы белән күстенеп-күстенеп, бертөрле йокы белән --- йоклый иде.* Ш.Камал

**КҮТӘМӘ** *и. зоол.* Этбалыклар семьялыгына кергән вак балыкларның бер төре, зурлыгы ягыннан ташбаш балыгыннан беркадәр кечерәк; *русчасы:* **вьюн**

**КҮТӘРГЕЧ** *и. махс. к.* **күтәрткеч**. *Гидравлик күтәргеч. Күтәргеч машинисты*

**КҮТӘРЕЛЕШ** *и.* 1) Икътисади һәм социаль шартларның яхшыруын таләп итеп оештырылган халык яки аерым төркемнәрнең хакимияткә каршы чыгышы; гамәлдәге иҗтимагый стройны юкка чыгару яки яңа хөкүмәт төзү өчен коралллы восстание. --- *Степан Разин күтәрелешендә катнашкан гаярь гыйсьянчы бабабыз --- һәм аның уллары --- нәкъ менә шул шомлы чорда – унҗиденче гасырда – чагыштырмача тыныч Болын ягына күченеп китәләр.* А.Сункишев

2) Хакимияткә каршы заговор юлы белән оештырылган коралллы чыгыш; бунт, фетнә. *Ләкин бу, күзен кан баскан, котырган кулак күтәрелешен җиңәргә ялгыз егетнең көче җитә алмады.* Г.Ибраһимов

3) Нәрсәнең дә булса көчле үсеш алуы, алга китүе. *Авыл хуҗалыгы күтәрелеше*

**КҮТӘРЕЛМӘ** *с.* 1) Күтәрелеп куела торган. *Күтәрелмә күпер*

2) *лингв.* Тоны күтәрелә торган. *Күтәрелмә дифтонг. Күтәрелмә интонация*

**КҮТӘРЕЛМӘЛЕ** *с. к.* **күтәрелмә**. *Бу чокырдан үтү өчен, күтәрелмәле күперне төшерергә кирәк булачак.* Ә.Айдар. *Беренче аваз – ярым сузык, икенчесе тулы сузык булса, күтәрелмәле дифтонг барлыкка килә.* Хәзерге татар әдәби теле

**КҮТӘРЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **күтәрү**. *Мәҗлес шактый кызган иде, капитанның сүзләрен хуплап янә бер тост күтәрелде.* Ф.Яруллин. *[Миңнулла] --- мәсьәләне тавышка куйды: – Кем дә кем --- үзе теләп фронтка китәргә риза, шуларның кул күтәрүләрен сорыйм. – Бер кул да күтәрелмәде.* В.Нуруллин

2) Югарыга менү. *Шомарып беткән баскычтан икенче катка күтәрелдем.* Х.Сарьян. *Траптан күтәрелгән сабыйлар әби-бабаларының кочагына менеп кунаклый барды.* Р.Мөхәммәдиев. *Уртадагы ике-өч аратасы кайчандыр янып күмерләнгән --- баскычтан Ирек икенче катка күтәрелде.* Ф.Садриев

3) Түбәннән югарыга таба сузылу, түбәннән биеккә менү (юл һ.б.ш. буенча). *Менә мин Агыйдел белән өскә күтәреләм.* Х.Сарьян. *Алар бодай кыры эченнән әкрен генә үргә күтәрелделәр.* Ә.Галиев. *Яз башында ук бригада Ост-Кейптан Краблы елгасы буйлап бик югарыга, Избяноега күтәрелде.* А.Мифтахетдинов // Биеклеккә ашу; өскә таба сузылу. *Ә каршыда теп-текә кара яр, аның өстендә, биек яшел стена булып, наратлык күтәрелә.* Ф.Садриев

4) Нәрсәнең дә булса өске, югарыгы торышка килүе. *Мостафин, сөенеп, Наҗиясен бер кулы белән күкрәгенә кыса, ә Наҗия, аяк очларына күтәрелеп, тиз генә иренен суза.* Ә.Еники. *Кыз аңа күтәрелеп карады да: – Юк, ашыкмыйм, – диде.* С.Шәмси

5) Вертикаль юнәлештә хәрәкәт итеп ачылу. *Тәрәзәсен чиртүгә, ялт итеп, ак пәрдәсе күтәрелде.* Ш.Җиһангирова

6) Утырган яки яткан урыннан торып басу, калку. *Абдулла аягына күтәрелде дә кашларын җыерып, хатынының шәл очыннан тартты ---.* Э.Касыймов. *Солтанның йөзе яктырып китте, ул: – Иншалла, барысы да әйбәт булыр, – дип сөйләнә-сөйләнә, урыннан күтәрелде.* Х.Сафина. *Җәмил ишегалдында күренүгә, лапас күләгәсендә утырган Фирүзә фыр итеп күтәрелде ---.* А.Гыйләҗев

7) Һавага очып менү. *Нинди уҗым басуы инде ул, ук булып ыргылып күккә тургай күтәрелеп сайрамаса?* М.Мәһдиев. *Янәшәдәге куаклыктан бер көтү кызылтүш пырылдап күтәрелде ---.* Ә.Гаффар. *Автоматтан кыска очередь бирдем. Шунда ук һавага ракета күтәрелде.* Г.Сабитов // Югарыга таба чәчелү, кубу, тузу (тузан, кар һ.б.ш.). *Туктаусыз хәрәкәттә булган салам селеккечтән болыт булып тузан күтәрелә.* Х.Сафина. *Көннең икенче яртысында җирдән себерә торган буран күтәрелде.* М.Шаһимәрдәнов. *Кара болыт күтәрелсә, Гөлҗиһан морҗаларны, тәрәзә-тишекләрне томаларга ашыга ---.* К.Тимбикова

8) Нинди дә булса биеклеккә җитү. *Бу дәвердә --- Каспий диңгезе көтмәгәндә 19 метрга күтәрелде.* М.Хәбибуллин. *Идел суы егерме сигез метрга күтәрелде.* Р.Кәрами. *Кушылдыклары мул сулы булганда, күл 1,5–2 метрга хәтле күтәрелә ---.* А.Муранов // Буйга үсү, үсеп озынаю, биегәю (үсемлекләр тур.). *Саматов җитлегеп килгән бодай басуларыннан, буйга күтәрелгән яшел кукурузлардан --- күзен ала алмыйча карап тора.* Г.Минский

9) Горизонт өстенә чыгу; өскә менү, югары таба хәрәкәт итү, калку (кояш, ай тур.). *Озакламый Казан өстендә кояш күтәрелер ---.* Ф.Латыйфи. *Ихата буйларына шомлы күләгә ташлап, ай күтәрелә.* М.Галиев. *Кояш инде күктә тәртә буе күтәрелгән ---.* Р.Зәйдулла // Югарыга үрләү. *Елгачык өстеннән әрфия ашъяулык кебек томан күтәрелгәнне карап торырга ярата.* М.Хәбибуллин. *Салкынча икән казармада, әкрен-әкрен җылы һава өскә күтәрелә.* С.Шәрипов. *Якында гына, яр читендә, өч казан асканнар – өсләреннән кайнар бу күтәрелә.* Э.Касыймов

10) *кит.* Төзелү, салыну, үсеп чыгу. *Алтын Урда ханына кала салуга --- Багдадтан да осталар чакыртылган иде. Әнә шулай, ике-өч ел эчендә, тиңе булмаган хансарай күтәрелде.* М.Хәбибуллин

11) Алга китү, юлга салыну, рәтләнү, җайлану, яхшыру. *Самат агроном булып эшләгән елларда колхоз шактый күтәрелде.* Г.Галиева

12) Нинди дә булса эш-хәрәкәт башлап җибәрү, керешү. *Менә шушы сәгатьтә кемнәрдер --- атакага*

*күтәрелә.* Т.Таһиров. --- *полк штабы начальнигы майор Вайнтрауба һөҗүмгә күтәрелү турында дивизиядән --- әлегә берниди боерык алынмавын әйтте.* Ш.Рәкыйпов // Баш күтәрү, восстание күтәрү, фетнә кубару. *Француз революциясенең туплары тынып өлгермәде, Испаниядә көрәш башланды, Италиядә карбонарийлар күтәрелеп чыкты.* Җ.Тәрҗеман. *Икмәген Совет талый башлагач, мужик тиз күтәрелер.* Х.Сафина. *Горур табигатьле халык яулап алучыларга баш иеп тормаган, әледән-әле ирек өчен көрәшкә күтәрелгән.* А.Муранов // Ризасызлык белдереп яки кискен рәвештә каршы төшү. *Ил сөяр җанлы шагыйрьләр һәрвакыт, ирек җырчысы булып, коллыкка, вәхшилеккә каршы күтәрелделәр.* И.Юзеев. *Ялгышасың, Галкин ---. Мин ялгыз түгел! --- Кирәксә, минем өчен йөзләр, меңнәр күтәрелер...* М.Хәсәнов. *Һарун Фаикъка каршы күтәрелде: – Ашыкма! Иртәрәк...* А.Вергазов

13) Кайбер исемнәрдән соң килеп, эш яки хәрәкәтнең башлануын, барлыкка килүен белдерә. *Кычкырыш-тавыш күтәрелде.* Г.Исхакый. *Пионинога кагылмас булды. Гауга күтәрелүгә караганда, уйнамый тору хәерлерәк иде...* Ә.Моталлапов. *Күлдә штормнар бик еш булып тора. Алар кинәт кенә күтәреләләр ---.* А.Муранов

14) Нинди дә булса эш, мәсьәлә кузгалу. *Моңарчы күтәрелеп тә, томалана барган мәсьәләләр яңарып калкып чыктылар.* М.Әмир

15) Таралу, җәелү, яңгырау; ишетелү. *Йоклаган халыкның хырылдау тавышы һавага күтәрелә.* Ш.Усманов

16) Кайсы да булса өлкәдә тагын да югарырак дәрәҗә яулау. *«Дәрәҗә» күтәрелгәннән-күтәрелде, --- малайлар минем якын дус булып тору юлларын эзли башладылар.* М.Гафури. *Фатих Кәрим сугыш чорында иҗатының иң югары ноктасына – халыкчанлыкка күтәрелә.* И.Юзеев // Нәрсәнең дә булса микъдары, күләме арту, күбәю; нәрсәнең дә булса бәясе арту, үсү турында. *Шуның белән бергә, жалованье да дүрт сумнан җиде сумга күтәрелде.* М.Гафури. --- *Бохарада мамык, җиләк-җимеш бәяләре инде шактый күтәрелде.* Т.Әйди. *Икмәкнең бәясе бик каты күтәрелде.* Х.Сафина // Нәрсәнең дә булса көчәю, интенсивлыгы арту. *Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы көченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә.* Г.Кутуй. *Студия еллары яшь татар композиторларының иҗат активлыгы күтәрелү белән характерлы.* М.Җәлил

17) *күч.* Кемнең дә булса каршында абруй арту. --- *Сабитов эшләгәнне --- әйтмәгән суратта, беренче секретарь каршында аның дәрәҗәсе бер башка күтәреләчәк ---.* Ф.Садриев

18) *күч.* Үсешнең югарырак дәрәҗәсенә ирешү, камилләшү. *Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан күтәрелгән кыяга менәрлек яшьләребез бармы?* И.Юзеев. *Беренче татар опера театрының төзелүе – татар совет культурасының --- яңа баскычка күтәрелүен күрсәткән факт.* М.Җәлил

19) *күч.* Үсү, башкалардан өстен булу. *Тел остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелә алды ул.* С.Поварисов. *Арсланов Татарстан Югары Советына депутатлыкка сайлау кампаниясендә аны үзенең ышанычлысы итеп алды. Менә шунда ул үзенең апогеена күтәрелде.* Ф.Садриев. *[Диктор тавышы]: --- Манзара авылы илебез картасында зур хәрефләр белән язылырлык дәрәҗәгә күтәрелде.* К.Ситдиков // Дәрәҗә ягыннан өстенлеккә ирешү. *Башта Хәмитне институтта калдырдылар. Шуннан кинәт күтәрелде.* М.Мәһдиев. --- *кичәге студент өчен кыска вакыт эчендә өлкән инженерга күтәрелү – зур казаныш.* Р.Мөхәммәдиев. *Авылга кайтып хезмәт куймакчы иде, шәһәр кешесенә әйләнде, дәрәҗәле урынга күтәрелде...* Ә.Моталлапов

20) *күч.* Нинди дә булса сәбәпләр белән кешенең физиологиясендә үзгәреш барлыкка килү. *Тегесе авыр эндәшә, аның температурасы күтәрелгән, ябыккан, йончыган.* М.Мәһдиев. *Январь азакларында Ирекккә әллә нәрсә булды. Кич җитүгә, аның башы авыртырга тотына, күңеле болгана, кан басымы күтәрелә ---.* Ф.Садриев. *Ул көнне Назлыгөл мәктәпкә барырга әзерләнә, сеңлесе тән кызуы күтәрелеп авырып ята иде.* Ф.Җамалетдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* **күтәрелеп**. Бердәм, берьюлы, дәррәү. *Бөтенесе күтәрелеп көлделәр.* Ф.Садриев

◊ **Күтәрелеп бәрелү** Бик нык ачулану, тиргәү; кызып китү; тузыну. *[Сәет] – Газиз әткәбезне искә алыйк... – Василий күтәрелеп бәрелде: – Әһә, хәзер исеңә төштеме?* Ф.Латыйфи. *Ихтыяр --- күңел түрендә ачу кайнавын сизсә дә, Нурисламга күтәрелеп бәрелүдән тыелды.* Р.Вәлиев. *Андый хәлләрдә күтәрелеп бәрелү акыллы эш булмасын Сөләйманов белә иде.* Ф.Галиев. **Күтәрелеп карамау** Игътибар итмәү, әһәмият бирмәү. *Үткән-сүткәннәр аңа игътибар итәләр, таныганнары кычкырып исәнләшәләр, Митрәй агай аларга күтәрелеп тә карамый ---.* М.Хәбибуллин. **Күтәрелеп чыгу** Үсү, башкалардан аерылып тору. *--- әдәбиятка-сәнгатькә, эстетикага игътибар бирелгән мәктәпләрдән чын талантлар: язучылар, артистлар күтәрелеп чыга.* И.Юзеев. *Гомуми культурабызга, әдәбиятыбызга һәм сәнгатебезгә зур өлеш керткән Гафур Коләхмәтов, --- Кави Нәҗми кебек, мишәр арасыннан күтәрелеп чыккан әдипләр, язучылар аз түгел бездә.* Э.Касыймов. **Күтәрелмәгән чирәм** Кайсы да булса өлкәдә әлегә кадәр игътибардан читтә торган, аз өйрәнелгән мәсьәлә, проблема

**Күтәрелә бару** Вакыт үткән саен ныграк күтәрелү. *Вакыт үткән саен, комиссар улы аның каршында гел күтәрелә барды.* Г.Бәширов. *Егет кызның аягына кадалган чүпне эзләгәндә, аяк һаман югарырак күтәрелә барды.* Ф.Яруллин

**Күтәрелә башлау** Күтәрелергә тотыну. *Менә тирә-якка пар чәчеп, (шәмнең) беренчесе күтәрелә дә башлады.* М.Хәсәнов. *Әнисе сөйләнә-сөйләнә өйдән чыкты. Тупсадан төшкәндә, кинәттән туктады да кире күтәрелә башлады.* А.Хәлим. *Әкренләп башка яшьләр дә ярга күтәрелә башладылар.* Ф.Яруллин

**Күтәрелә төшү** Беркадәр, аз гына күтәрелү. *Шул урында Равил Идрисович --- күтәрелә төште, куллары*

*ирексездән нәрсәдер эзләгәндәй итте.* Ф.Галиев. *Тәслимә түти чак кына терсәгенә күтәреләтөште.* М.Шаһимәрданов. *Күңелләр тагын да күтәреләтөште.* Г.Сабитов

**Күтәрелеп алу** Аз вакытка гына, билгеле бер вакыт аралыгында гына күтәрелү. *[Әткәйнең] Мине күргәч, кәефе беразга гына күтәрелеп алды ---.* Р.Вәлиев

**Күтәрелеп бару** *к.* **күтәрелә бару**. *Сүз Нәҗип турында бара, кызым. --- Әнә хәзердән үк ничек күтәрелеп бара.* Ә.Еники. *Барлас Камалов хикәядән хикәягә, әсәрдән әсәргә үсә бара, әдәбият баскычыннан күтәрелә бара ---.* Х.Сарьян. *Ай отыры биеккәрәк күтәрелә бара.* М.Галиев

**Күтәрелеп җитү** Билгеле бер дәрәҗәгә кадәр күтәрелү. *Авторның ашыга төшкәнлеге сизелә. Шул сәбәпле бик зур мөмкинлеге булган яшь кеше образы зур герой дәрәҗәсенә кадәрле үк күтәрелеп җитмәгән.* Г.Ахунов. *Кояш төшлеккә күтәрелеп җиткәндә, мотоциклының артына Сәбиләне утыртып, Нурислам килеп төште.* Р.Вәлиев

**Күтәрелеп калу** Ниндидер бер вакыйгадан, хәлдән соң күтәрелгән хәлгә килү. *Иске «Жигули» артыннан тузан өермәсе генә күтәрелеп калды.* Р.Мөхәммәдиев

**Күтәрелеп килү** Менә-менә күтәреләбашлау. *Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Яруллин әле иҗатының күтәрелеп килгән чорында.* И.Юзеев. *Яңа гына кояш күтәрелеп килә.* Ә.Галиев. *Тәрәзә артында, кул сузымы гына ераклыктагы офыкта --- кояш күтәрелеп килә.* Р.Вәлиев

**Күтәрелеп китү** Кинәттән күтәрелү. *[Шаһсуарзадә:] Шунысын исеңдә тот: болай тиз күтәрелеп киткәч, матрослыкның түбән сизми калуың бар.* М.Юныс. *Аның хәле авырайганнан-авырая барды. Кан басымы күтәрелеп китте.* Г.Галиева. *Казлар йөгерешеп барганнар да канатларын җилпеп күккә күтәрелеп киткәннәр ---.* Р.Вәлиев

**Күтәрелеп кую** Кисәк, бер мәртәбә күтәрелү. *[Теге хәшәрәт]: «--- Бармак очы белән генә кызга кагыла алсаң да – кыз синеке!» – ди. Ә үзе, Миңнулла Зәйнәпкә үрелеп җитәм дигәндә генә, ялт, күтәрелеп куя.* В.Нуруллин

**Күтәрелеп тору** Әледән-әле күтәрелү яки күтәрелгән хәлдә булу. *Өстәлдә --- олы табак белән китереп куйган бәрәңгедән, ашыйсы килүне котыртып, җылы бу күтәрелеп тора.* Ә.Еники. *Кан басымының эше бер күтәрелеп, бер төшеп тору инде аның.* И.Нәбиуллина. *Аның чәчәк таҗы кечкенә күбәләкнең күтәрелеп торган канатларына охшаган 5 төрле таҗ яфракчыгыннан тора.* Ботаника

**КҮТӘРЕНКЕ** *с.* 1) Тирәсендәгеләргә караганда бераз биегрәк, калкурак. *Инешнең аръягында --- биек булмаган күтәренке таучыкларны каплаган әрәмәлек – бәләкәй урманлык башлана.* Ш.Камал // Бераз күтәрелеп торган. *Соңгы вакытларда картаюын тоя башласа да, --- аның гәүдәсе төз-тыгыз, иңбашлары күтәренке.* М.Хуҗин. *Койган да куйган әнисе инде: зәңгәрсу күзләре өстендә дугаланып торган куе кара кашлар, чак кына күтәренке борын ---.* Х.Сафина. *Ул таманча буйлы, шадра битле, бөдрә чәчле, күтәренке җәлпәк борынлы --- кеше иде.* И.Тургенев

2) *к.* **күтәрмә** I **2.** (*2 мәгъ.*). *Аның өстендә алтын төймәле, күтәренке якалы, карасу зәңгәр постаудан тегелгән сюртугы бик килешле утыра.* Җ.Тәрҗеман

3) Югары, зур. *Авыруның тән температурасы күтәренке*

4) Көр, шатлыклы (тавыш тур.). *Әлегә янәшә басып торсалар да, аерылу авырлыгы күңелне изә башлаган, ләкин үзләре моны сиздермәскә тырышалар, күтәренке тавыш белән шаярышалар иде.* М.Маликова // Шат, көр; дәртле. *Зариф Шәймөхәммәтович, кичә сез киңәшмәдән соң бик күтәренке күңел белән таралышкансыз дип ишеттем.* Ф.Садриев. *Аның күңеле күтәренке иде.* Ф.Яруллин. *--- ниндидер тыелгысыз күтәренке рухка, эчтән ургылып чыккан дәрт-дәрманга ия иде егет.* Г.Әдһәм

5) Югары; арткан, күтәрелгән (бәяләр). *Ел коры булу сәбәпле, игеннәрнең бәясе шактый күтәренке*

**КҮТӘРЕНКЕЛЕК** *и.* Күтәренке булу; көр булу; шатлыклы булу. *Һәркайда елына бер генә була торган күтәренкелек, һәммә тәрәзәләрдә төрле төсләрдәге утлар җемелди.* М.Маликова. *Ә менә Саматның мондый мәҗлес-кичәләрдәге гадәти күтәренкелеге, шуклыгы сизелмәде.* Г.Галиева. *--- мин үземдә әллә ниткән бер җиңеллек, күтәренкелек тоям, әйтерсең лә миңа канатлар үскән ---.* Гөлшаһидә // Күтәренке күңел, күтәренке рух. *Дөньяда безнең авылның --- борчак кузакланган кояшлы көннәре кадәр ямьле вакыт, рухи күтәренкелек --- тагын кайда була икән?* М.Мәһдиев. *Чыгышлый Ислам Кәримгә дә күз салып алырга өлгерде --- һәм, бөтен тәнендә ниндидер күтәренкелек тойган хәлдә, бусагадан тышка атлады.* С.Шәмси. *Зөфәр Шәрипович үзенә чакырылган җитәкчеләрнең һәрберсен күтәренкелек белән кабул итте.* Ф.Садриев

**КҮТӘРЕНҮ** *ф.* Берьюлы берничә әйберне күтәрү. – *--- әйберләреңне җыеп алып чык, китәбез, – дип боерды Николай. Зөбәйдә --- тиз арада күтәренеп килеп чыкты.* Ә.Моталлапов. *Салихҗанга ике яшь тулгач, әтисе, күтәренеп, каядыр чыгып китте дә шуннан бүтән авылда эз яңартмады.* Н.Гыйматдинова

**КҮТӘРМӘ** I *и. диал.* **1.** 1) Өйалды баскычы; болдыр. *Шулчак, тышкы күтәрмәдән үк дөбердәп, өйгә ике кара малай чабып керде.* Х.Сарьян. *Заһир ---, капканы ачып, --- күтәрмәгә таба атлады.* Т.Таһиров. *Яңа йортның биек киң күтәрмәсенә утырам да янәшәмдәге алмагачтан --- алма өзеп алам.* Д.Булатова

2) Баскычның бер басмасы. *Чиста итеп юган баскыч күтәрмәсенә --- Айтуган карт та килеп утырды.* Г.Бәширов

3) Печәнлек. *Сукмакны салып бетергәч, күтәрмәдән малларга печән төшерергә кирәк иде.* Р.Зәйдулла

4) Басма яки күпернең, саклык өчен, ике ягына беркетеп эшләнгән коймасыман култыкса. *Ул бик озак тынычлана алмады, күпер күтәрмәсеннән иелеп, суга карады.* З.Кадыйрова

5) Аскуйма. *Рядовой Тарарушкинның кулында күңелле генә көй чыгара тор-*

*ган локатор станциясе моделе иде. Ул китап зурлыгындагы күтәрмәгә утыртылган.* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күтәренке, аз гына күтәрелеп торган. *Кәпәренеп йөргән күтәрмә борыннарның якаларыннан гына тотып күтәрәм ---.* А.Гыйләҗев. *Утыз яшьләр тирәсендәге кечкенә, ябык кына, --- җәенке күтәрмә борынлы --- Виктор Хлопаков --- ярминкәләрнең берсен дә калдырмый.* И.Тургенев

2) Кайтарып куелмый торган, төз итеп бастырылган; утырма. *Бераз читтәрәк --- көмеш укалы күтәрмә якалы зәңгәр постау мундир кигән ике егет тора.* Җ.Тәрҗеман. *Һай өс-башлары, бер дә галәмәт икән: аякларында ялтырап торган яхшы хром итекләр --- һәм күтәрмә изүле, утыртма җилкәле әфисәрләр гимнастёркасы ---.* Ф.Яхин. *--- дәү әтинең күтәрмә якасы камыт кебек селкенеп тора иде.* В.Астафьев

3) *к.* **күтәрелмә** (*1 мәгъ.*). *Капка алдында тирән чокыр булып, кирәк чакта гына аның аркылы күтәрмә күпер төшерелеп, шул күпердән кереп-чыгып йөргәннәр.* Җ.Тәрҗеман

**КҮТӘРМӘ** II *и. сөйл. к.* **күтәртмә**. *--- ул үскән заманнарда хатын-кыз чалбар да, язлыкта кия торган чабата күтәрмәседәй биек табанлы туфли дә --- кими иде.* Р.Кәрами

**КҮТӘРМӘЛЕ** *с.* 1) *к.* **күтәртмәле** (*1 мәгъ.*). *Яр буенда күтәрмәле чабата кигән бәләкәй Хәллә йөгереп йөри.* Г.Сабитов

2) Болдырлы. *Бу келәт кебек алачыклары урынына ул алты почмаклы, --- зәңгәр күтәрмәле йорт бетерәчәк ---.* А.Хәлим

**КҮТӘРТКЕЧ** *и. махс.* 1) Нәрсәне дә булса күтәреп икенче урынга күчерү җайланмасы, күтәрү машинасы; кран. *Шулвакыт бик каты итеп җил китереп бәрде, тракторның кайсыдыр җире шартлап китте. Нәзир, --- тракторны алга кузгалтты һәм үзе: – Бу тирәгә якын килмәгез, күтәрткеч сынды! – дип --- кычкырып җибәрде.* Ф.Яруллин

2) Нинди дә булса авыр предметны беркадәр өскәрәк күтәртү җайланмасы, домкрат. *[Автомобильнең] көпшәк шины ләшперәп төшкән, тәмам бушаган. Җирдә насос, күтәрткеч һәм ачкычлар таралып ята.* А.Шамов

**КҮТӘРТМӘ** *и.* **1.** 1) Язын яки көзен, су үтеп аякны юешләтмәс өчен, чабата яки юкә башмак астына куела торган, баш-башы шакмакланып эшләнгән җайланма. *– Кар суы үтәр, – диде әти. Сөяннән күтәртмә ясап, чабата табанына беркетте.* Г.Сабитов

2) *к.* **күтәрмә** I **1.** (*1 мәгъ.*). *--- фрезерчы Бәһрам, кемнеңдер күтәртмә баскычына килеп басуын сизеп, артына борылып карады ---.* Н.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Астына нәрсәдер өеп, биегәйтеп эшләнгән. *Ә трактор --- күтәртмә юлга ыргылды.* Н.Гыйматдинова. *Күтәртмә сәхнәдә озын өстәл.* Н.Хәсәнов

**КҮТӘРТМӘЛЕ** *с.* 1) Күтәртмә куелган, астына күтәртмә беркетелгән. *[Гафият] аякларына күтәртмәле чабата, өстенә --- мамыклары чыккан солдат сырмасы кигән.* И.Гази

2) Күтәртмәләре I (*1, 2 мәгъ.*) булган. *Томилин --- ике күтәртмәле баскычтан үрмәләп өйалды ишеген дөбердәтте.* Х.Камалов

**КҮТӘРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **күтәрү**. *Ике домкрат белән мунчаның ике почмагын күтәртү --- алай ук авыр булмады.* С.Шәмси. *Өйне үзебезнең болгар осталарыннан күтәрткән идем ---.* М.Хәбибуллин

2) Нинди дә булса корылманы биегрәк урнаштыру. *Күтәртеп, вакытлыча ясалган трибунага якынлашкан саен, бару кыенлашканнан-кыенлаша төште.* Р.Мөхәммәдиев

**Күтәртеп кую** Күтәрелгән хәлгә китерү

**КҮТӘРӘМ** I *и.* Печән яки салам җыйганда, бер күтәреп алырлык итеп әзерләнгән печән яки салам өеме; күбә. *Галимә апа печәнне үзе биеклеге булганчы тәгәрәткәч, әтинең: «Галимә кызым, --- күтәрәмнәр тигез булсыннар ---», – дип әйткәнен ишеткәч кенә туктады.* М.Гафури // Бер күтәреп алырлык әйбер. *Бездә тыгыз, дигән сылтау белән --- икенче ротадан лейтенант Зотов бер күтәрәм әйбере белән күчеп килде.* С.Шәрипов

**КҮТӘРӘМ** II *и. сөйл.* Кеше ярдәменнән башка тора да, йөри дә алмый торган хәлсез кеше яки арык терлек. *Аксак – күтәрәмнән яхшырак.* Мәкаль

◊ **Күтәрәмгә калдыру** Хәерчеләндерү, ярлы хәлгә төшерү. *--- хәл кадәри талантларны күтәрергә кирәк, чөнки --- талантларын күтәрә белмәгән илне талантсызлар күтәрәмгә калдырачаклар.* Мәдәни җомга. **Күтәрәмгә калу** 1) Азык җитмәүдән хәлсезләнеп, басып тора алмаслык хәлгә килү (терлек тур.). *Нәсел айгырын теләсә кем җикми, ул күтәрәмгә калган колхоз алашасы түгел, үз кадерен үзе белә.* Н.Әхмәдиев. *Тәүлегенә 200 грамм фураж бирелә. Аның белән генә ат туйдырып буламыни? Күтәрәмгә калды малкайлар.* А.Фәләх. *Күтәрәмгә калган ат хәлендәге бу колхозны торгызып, урта куллар рәтенә чыгарсаң, --- Ленин ордены синеке.* Р.Айзатуллин; 2) Берәр төрле эш-хәрәкәттән яки көчле авырудан соң бик нык хәлсезләнү, аякка баса алмаслык хәлгә килү (кеше тур.). *Анда ул бик авыр операция кичерә. Операциядән соң күтәрәмгә кала.* М.Мәһдиев. *Алсызялсыз чаба торгач, үзе күтәрәмгә калды ---.* А.Гыйләҗев. *Юлдашы күтәрәмгә калган иде инде, Мирсәет аны почмакта торган утыргычка китереп утыртты.* Р.Мөхәммәдиев; 3) Бик газаплы, ач һ.б.ш. авыр чор кичерү. *Күтәрәмгә калган чорны Сез ул күтәрүчеләр, Теш кысып, бар авырлыкны Эшләп үткәрүчеләр.* Ш.Галиев

**КҮТӘРҮ** *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса торган җиреннән, урыныннан алу, өстә тоту. *Ихтыяр эскәмиядә торган сулы чиләкне өскә күтәрде дә башына койды.* Р.Вәлиев. *Укытучы артыннан карт сторож --- күрсәтмә әсбаплар салынган кәрзин күтәреп керттe.* Җ.Тәрҗеман. *Ирләр карчыкны саклык белән генә күтәреп алалар ---.* С.Шәмси // Кулга тоту, тотып алу. *Йөзү шартлары билгеләнгәч, Бикбайның киемнәрен күтәрдем дә, чалкан ятып, икенче якка йөзә башладым.* Г.Кашшаф. *Үндүрт-унбиш яшьтән дә артык биреп булмас үзләренә, ә шулай да чалгы күтәргән булганнар...* Ф.Яруллин. *Малайның әнисе ---, фотоны*

*күтәреп, туп-туры мәктәпкә килгән.* Җ.Дәрзаман // Төшкән әйберне алу. *Шулай да идәнгә иелеп, кәгазь кисәген күтәрергә, аны бөгәрләп почмакка томырырга көче җитте үзенең.* Ирек мәйданы

2) Нәрсәне дә булса югарыга карату; югарырак хәлгә китерү. *Матусов башын күтәрде дә тикшерүчегә гамьсез, салкын караш ташлады.* М.Насыйбуллин. *Яле, ташлагыз әле кораларыгызны да күтәрегез кулларыгызны!* В.Нуруллин. *[Гали] үзе абына, үзе ыштанын күтәрә, --- үзе кычкыра: – Әни, сугыш беткән!* Р.Төхфәтуллин // Нәрсәне дә булса югарырак, биегрәк, калкурак итү. *Аннары без, көрәкләребезне алып, --- кабер туфрагын тигезләп күтәрдек.* А.Шамов // Әйләндереп югарыга таба кайтару. *Малай бүрек колакларын күтәреп бәйләгән иде.* М.Мәһдиев

3) Югарыга, өскә таба күчерү, югарырак торышка китерү. *Баланың кыймылдаганын сизеп, йөзен каплаган челтәрле ак тукыманы күтәрде ---.* М.Маликова. *Өстемнән җылы юрган шуып төшә, --- керфегемне күтәрүгә --- кояш нуры күзләрне чагып ала.* М.Галиев. *Кулларын күтәреп дога кылганнан соң, бераз вакыт Кәбиргә карап торды.* Х.Сафина

4) Ауган, егылган нәрсәне яңадан торгызу. *Ауган капканы күтәрү*

5) Парга калдырылган яки чирәм җирне сөрү, эшкәртү. *Пар күтәрү. Чирәм күтәрү*

6) Эшкәртеп югарырак итү. *Түтәл күтәрү*

7) Нәрсәне дә булса өскә таба туздыру; югарыга чәчелдерү. *Җил шыр ялангач кыр буенча чаба, юлында очраган шәрә куаклар арасында сызгыра, корыган үләннәрне һавага күтәрә.* Г.Әпсәләмов. *Тузан күтәрү*

8) Берәр корылма салу, төзү; әзер бураны мүкләп өю. *Әнә кара, сыер абзарларының нигезе казылган килеш ята, йортларның стеналарын күтәрделәр дә туктадылар ---.* Р.Вәлиев. *Бердәнбер нәрсә – өй күтәргәндә өмә ясау гадәте яшәп килә ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Өйне буш урынга күтәрде.* Ә.Моталлапов

9) Авырлыкны тотып тору. *Ул хәтле ризыкны өсталләре ничек күтәргәндер.* Ф.Яруллин

10) Нәрсәнең дә булса күләмен, микъдарын күбәйтү, ишәйтү. *Иген уңышын күтәрәбез, Эшлибез бер теләктән.* М.Җәлил // Арттыру. *Кушма Штатларда --- укытучылар, дәресләрен ташлап, эш хакын күтәрүне сорыйлар.* М.Юныс. *Син дә эшкә кушылсаң, редактор эш хакыңны күтәрер ---.* Р.Мөхәммәдиев. *– Ник артты хезмәт хакыгыз өч тапкыр? – Аны без күтәрмәдек, Татарстан күтәрде, – дип акланды ТСЖ рәисе.* Ирек мәйданы // Үстерү. *Шулай, дуслар, күбрәк бирегез Мех туннарны тагын һәм тагын! Сыйфатны да яхшы итегез, күтәрерлек булсын ил данын.* Ә.Исхак // Яхшырту. *Сортларның һәм токымнарның продуктлылык сыйфатларын саклау һәм күтәрү өчен, --- шартлар тудырырга кирәк.* Дарвинизм нигезләре

11) Көчәйтү. *– Ник икәнен белсәм, үзем генә әйтер идем! – директор тавышын шактый нык күтәрде.* Ф.Садриев

12) Нинди дә булса мәсьәләне, проблеманы кузгату, алга кую. *Яңа өй салу мәсьәләсен Харис берничә мәртәбә күтәрде ---.* Ә.Моталлапов. *Әнәснең башкалардан өстенлеге тик шунда гына: ул русчаны бик шәп белә һәм җыелышларда, юк кына нәрсәләрне дә зур итеп күтәреп чыгып, озаклап сөйли ала.* В.Нуруллин. *Вахитовның --- ул күтәргән мәсьәләләрне җиңел генә урап узарга омтылуы бигүк ошап җитмәде Мирсәеткә.* Р.Мөхәммәдиев

13) Кемгә дә булса югарырак вазифа йөкләү. *Башта Хәмитне институтта калдырдылар. Шуннан кинәт күтәрелде. --- Бер-ике ел эчендә егетне тагы да югарырак күтәрделәр.* М.Мәһдиев. *Кайберләрен эшләрендә күтәрделәр я икенче җиргә күчерделәр – андыйлары безне хәзер кызыксындырмый.* Р.Мирхәйдәров. *Каханымны юлдан яздырды, ил белән идарә итү өчен, үзе тәрбияләгән балакаем Йосыфымны үтә яшьли тәхеткә күтәрде.* М.Хәбибуллин // Үстерү. *Алар татар шигъриятен дөньяга күренерлек биеклеккә күтәрделәр.* И.Юзеев. *Кызы да нинди бит! --- авылда бер чибәр, авылда гынамы – тирә-якның данын күтәрерлек.* М.Галиев. *Эшләгән кешене Гайсә күтәрде, әрәмтамакларга, ялкауларга көн күрсәтмәде ---.* Ф.Садриев

14) Кемнең дә булса каршында абруйны арттыру. *Сәдаканы мул биргәннәрнең гөнаһлары да мул, ләкин муллалар да, Ходай үзе дә азгын бәндәләрен бик теләп кичерә, әүлиялар санына күтәрә.* Г.Әпсәләмов. *Бу повестьлар --- Х.Сарьянны күренекле язучылар рәтенә күтәрде.* Ә.Нигъмәтуллин

15) Югарырак итү, камилләштерү, арттыра төшү, дәрәҗәсен үстерү (аңбелемне, культураны һ.б.). *Венага барышлый Кёнигсбергта, --- Прагада булдык ---. Ничек тә рухи яктан баерга, белемебезне күтәрергә тырыштык.* Җ.Тәрҗеман. *Анда [Эчке эшләр министрлыгында] бераз эшләгәч, Мәскәүгә белемен күтәрергә китә.* М.Насыйбуллин. *--- ул үзенең аң-белемен һәм теоретик хәзерлеген күтәрү өстендә дә өзлексез --- эшләвен дәвам итә.* Р.Мөхәммәдиев

16) Нинди дә булса иҗтимагый эчтәлекле эш-хәрәкәткә кузгату, җилкендерү. *Имеш, әйттеләр, пуп белән кушылган да, икәвесе, фетнә күтәрмәкче булып, савитка каршы йөргәннәр...* Э.Касыймов. *Ул кеше әле генә Златоусттан кайтып төшкән икән, анда эшчеләр восстание күтәргән, ди.* Р.Мөхәммәдиев. *Тау халкы күбесе елганың түбән агымына качкан, андагы кабиләләрне күтәреп, көрәшне дәвам иткәннәр.* А.Муранов // Күмәк, дәррәү хәрәкәткә китерү. *Мин моны бу килеш кенә калдырмаячакмын! Бөтен авылны күтәрәчәкмен!* Ф.Яруллин. *Иптәш кызы авылны күтәргәндер инде.* Х.Ширмән. *[Азат Мусин] --- салкын буранлы төндә барлык милиция хезмәткәрләрен күтәрә ---.* Мәдәни җомга // Ризасызлык белдерү, килешмәү. *Минем, бөтен тыюларга, «ярамый»ларга төкереп, язмышыма каршы бунт күтәрәсем килә.* Ф.Яруллин. *Зариф үз гомерендә беренче тапкыр әнә шулай «бунт» күтәрде.* Г.Әдһәм

17) Шатлык, куаныч хисе уяту; яхшы тәэсир итү. *Әгәр җәй көне булса, бәлки, Гөлчәчәгенең кәефен күтәрергә әнә*

*шушы бакча ярап куяр иде.* Ф.Яруллин. *Һаҗәрнең күңелен күтәрү, күңелен күрү өчен хәзерләнгән сүзләр югалалар да калалар.* М.Хәсәнов

18) Кичерү, баштан үткәрү; түзү (авырлыкларга һ.б.ш.). *Утыз алты ел тыелам инде мин, хатын. Утыз алты ел астыртын гына әр-хур күтәрәм.* Ш.Рәкыйпов. *Билгеле, ул түзәр, барысын да күтәрергә тырышыр.* Г.Әдһәм. *Хәзер --- авырлыкны күтәрергә өйрәндем.* Р.Кәрами

19) Берәр яман сүзне һ.б.ш.ларны авырсынмыйча кабул итү, үз өстенә алу; кичерү, үткәреп җибәрү. *Гайсә Батталович миңа күпме пычрак атты – мин барысын да күтәрәм.* Ф.Садриев. – *Үз хурлыгымны үзем күтәрермен, Җәләл абзый, – диде Гөлчирә.* Х.Сафина. *Мондый мыскыллауны Вәлиулла күтәрә алмады.* Ф.Яхин

20) Үз өстенә алу, түләү (чыгымнарны). *Ахырда Әбелмәних үзенең иң зур соравын бирде: – Алексей Петрович, бетереп булгач, бетереп сөйләшик: укыткан өчен күпме алырлар? Күтәрә алырбызмы?* Г.Әпсәләмов. *Туй чыгымнарын да үзем күтәрәм, ди.* М.Хәбибуллин. *Улә калсаң, иске зиратка күмдер. Бөтен расходларын үзем күтәрәм.* А.Гыйләҗев

21) Нинди дә булса бәйрәм, тантана уңаеннан теләк белдереп эчемлек эчү. *Икегезнең бәхете өчен туегызда тост күтәрдем һәм шуннан айный алмадым.* Р.Мингалим. *Үзебезнең Казан халкы исеменнән кыю диңгезчеләр хөрмәтенә, аларның исәнлегенә тост күтәрдем.* Җ.Тәрҗеман

22) *сөйл.* Гомумән спиртлы эчемлек эчү. *Көзне мактадык, күңелдәге моңсу уйларны да әйтеп, чәркәләрне күтәрдек.* Г.Ахунов. *Малайлар рюмкаларын күтәрергә генә торганда, Гөлҗиһан: «Юк, балалар, юк! --- Бәхиллегем юк!»* Ф.Яруллин

23) *сөйл.* Нинди дә булса исемгә, дәрәҗәгә ия булу. *[Депутат:] Әгәр бу мәсьәлә милләт теләгәнчә хәл ителмәсә, --- безгә депутат исемен күтәрүдә мәгънә калмый.* Ш.Камал

24) Йөкле булу, карында бала йөртү. *Әгәр дә хатыннар корсак күтәрү, --- бала күмү хәсрәтенә күмелеп кенә яши торган булса, ул ничек ирләр белән тигез хокуклы була алсын, ди?* М.Маликова. *Ул бит бер мәртәбә дә корсак күтәрмәде: Габдерәхименә тугры Рабига ят ирдән бала табу турында уена да китереп карамады.* Н.Гыйматдинова

25) Хуҗалыкны, аның тармакларын яхшырту, торгызу, юлга салу. *«Киләчәккә хатлар» --- авылда колхоз төзү һәм завод-фабрикада социализм ярышын алып баруны, промышленностьны күтәрүне сурәтли.* Г.Нигъмәти. *[Егет:] Без күмәкләштерелгән авыл хуҗалыгын тагын да күтәрергә, колхозчыларны таза тормышлы итәргә --- тиеш.* А.Шамов. *Гел халык өчен тырышты, колхозны күтәрәм дип тырмашты ---.* М.Маликова

26) Нәрсәне дә булса билгеле бер югарылыкка җиткерү. --- *көчәнә торгач, пар басымын тиешле атмосферага күтәрдем.* М.Юныс. *Моның өчен төнгә мичкә ягалар, температураны гадәттәгедән 3 градуска күтәрәләр.* Яшелчәчелек. *Мульчалау бик күп яшелчә культураларының уңышын күтәрә.* Мәйдан

27) Нindидер таләпләргә, шартларга җавап бирү. *Элек төзегән ферма тораклары, мастерскойлар да искерде, --- замана таләпләрен күтәрә алмый башладылар.* Ф.Садриев

28) Организмның йогышлы авыруларга һәм генетик чит матдәләргә каршы тора алучанлыгын ныгыту. *Фейхоа салкын тиюдән саклый, иммунитетны күтәрә.* Ирек мәйданы

29) *мат.* Санны яки алгебраик аңлатманы күрсәтелгән мәртәбә үз-үзенә тапкырлау. *Вакланманы дәрәҗәгә күтәрү өчен, санаучыны һәм ваклаучыны аерым-аерым шул дәрәҗәгә күтәрергә һәм беренче нәтиҗәне икенчесенә бүләргә кирәк.* Алгебра

30) Кайбер исемнәрдән соң килеп, шул исем белдергән эш-хәрәкәтне башлауны аңлата. *Волком персидәтеле рөхсәтеннән башка беркемне дә ябарга хакыбыз юк безнең, дигән идек, бик каты тавыш күтәрделәр.* В.Нуруллин. *Хуҗаның давыл күтәрәсенә ышанып, шомланып та калдылар.* Ә.Моталлапов. *[Клабуковның] күргәне-ишеткәне бар, комбат – кәеф кешесе, юкка гына кырын сүз әйтеп тавыш күтәрергә дә әвәс.* С.Шәрипов

◊ **Күтәреп алу** 1) Бик теләп кушылу; хуплап каршы алу. – *Шулай-шулай, дөрес сөйлисең, – дип күтәреп алды Миләүшә җиңгәсе.* Р.Мөхәммәдиев. *Гөлбикә карчык картының сүзләрен хуплап күтәреп алды.* Ф.Яруллин; 2) Бердәм, берьюлы, дәррәү, бергә, бер үк вакытта башлау. *Нечкә генә тавыш белән башланган җырны әйләнәдәгеләр бердәм күтәреп алып киттеләр.* К.Тимбикова. *Өмәче хатыннар җырны күтәреп алдылар ---.* Х.Сафина. *Җырның кушымтасын Мирсәет тә күтәреп алды.* Р.Мөхәммәдиев. **Күтәреп чыгу** Нинди дә булса мәсьәләне башлап, беренчеләрдән булып күтәрү. *Бозыла башлаган икмәкне әлеге пункттан суга түктеләр. Мин шуны матбугатта күтәреп чыктым.* Ф.Садриев. *Бераз дөньялар үзгәреп, колхозның тамагы тук булырга тиешлеге турында гапгади бер законны күтәреп чыкканнар иде ---.* М.Мәһдиев. *Философ үзенең ул хезмәтендә мин сезгә әле генә сөйләгән мәшһүр космогоник гипотезаны күтәреп чыкты.* Җ.Тәрҗеман

**Күтәрә бару** Булган берсен күтәрү, рәттән, эзлекле күтәрү; тагын да югарырак күтәрү. *Моңа кадәр кабып кына куя торган егет иде үзе. Ә бүген авызланды, салган берсен күтәрә барды.* Ф.Яхин

**Күтәрә бирү** Бернигә карамастан күтәрү; бераз күтәрү. *Бу сүзләрне ишеткәч, майор, кашларын күтәрә биреп, чын соклану белән Галимҗан абзыйга беравык карап тора ---.* Ә.Еники. *Мин, чиләкне азрак күтәрә биреп, астына үзем язган «листовка»ны кыстырам ---.* З.Зәйнуллин. *Ул балаларныкы шикелле кечкенә арык күкрәген калкытып, ияген күтәрә биреп --- сузылып тик ята иде.* З.Биишева

**Күтәрә тору** Әледән-әле яки даими күтәрү

**Күтәрә төшү** Аз гына күтәрү. --- *честьны егетләрчә бирергә өйрән. --- Терсәгеңне күтәрә төш.* С.Шәрипов. *Сезнең эш хакын бераз күтәрә*

*төшәргә вакыт җитмәдеме икән, дим.* Р.Мөхәммәдиев. *Ир кеше башын күтәрә төште ---.* Ф.Галиев

**Күтәреп бетерү** Ахыргача, бөтенләй күтәрү. *Вахтада торучы матрос трапны күтәреп бетергән иде.* М.Юныс

**Күтәреп җибәрү** Кисәк күтәрү, артык югары күтәрү; күтәреп кую. *Бакчачы карт сөйләгәннәрне китаптан, чыннан да, таптым мин. Бу аның абруен күтәреп җибәрде.* Ш.Рәкыйпов. *Теге иптәш аны эчкә чакырган да: «Менә, агайне, --- менә бу стаканны яңа йортны котлап күтәреп җибәр», – дигән.* М.Мәһдиев. *Шулчак Ания: – Безнең әтиләр болай уйный белмиләр, – дип, өлкәннәрнең кәефен тагын да күтәреп җибәрде.* Г.Галиева

**Күтәреп кую** Бер тапкыр яки тиз арада күтәрү. *Әйдә, әйдә, егет кеше булуың өчен бер күтәреп куйыйк әле.* Р.Вәлиев. *Сәмигулла --- якасын күтәребрәк куйды.* Ф.Яруллин. *Уфа педагогия институтын яңарак кына тәмамлаган --- җәендә ул туган авылында ике катлы өй күтәреп куя.* Л.Хәмидуллин

**Күтәреп тору** Гел, даими күтәрү; хәзерге вакытта күтәргән булу

**КҮЧ** I *и.* 1) Ана кортка ияреп, аерым төркем булып бүленеп чыккан бал кортлары гаиләсе. *Хикмәт абзыйның бакча башында буш умарта оясы бар* (*күч төшеп оялар дип куйган инде ул аны*). М.Галиев. *Аның уйлары хәзер соң чиккә җитеп буталган, әйтерсең баш сөяге эчендә умарта күче оялаган иде.* Р.Вәлиев. *Бал кортларының бер күчендә меңләгән эшче корт, зуррак бер ана корт һәм --- соры кортлар була.* Биология

2) *сөйл.* Бер төргә караган вак хайваннар төркеме. *Люцерна кибәненең --- өстендә бер күч мәче ята.* М.Мәһдиев. *Әти сөйли торган иде, күгәрчен күченә козгын җитәкче булса, бөтен күгәрчен дә үләксә ашый башлар, дип.* Ф.Яруллин. *Бер сәгатьтән, бу күчне ачып, балыкның бер өлешен ашыйлар, калганын сатарга алып китәләр.* А.Муранов

3) *сөйл.* Бергәлек, оешканлык. *Ә Миңнулланы: – Андый-мондый хәл килеп чыгып, мамин кына күтәрелергә туры килә калса, бер күчтә булуыгыз хәерлерәк, – дип, отряды белән бергә ике катлы бер зур йортка урнаштырды.* В.Нуруллин // Нинди дә булса бер җирдә бергәрәк яисә тупланып торган нәрсәләр. *Шулай да аның күзләре гаҗәеп бер нәрсәгә төште: юлдан сул кулда, сазлыкка әйләнгән бер кечкенә уйсулыкта, күче белән сары чәчәкләр үсеп утыра.* Ә.Еники

4) Каядыр күчеп баручы төркем, халык. *Арбам сынды дип күчтән калма, башым авырта дип эштән калма.* Мәкаль. *Күч микән, кәрван микән, дәрдемә дәрман микән?* Дастан

**КҮЧ** II *и. рус сөйл.* Өем. *Анда-санда колхоз комбайннары йөргәли, алар артыннан җыйнак кына салам күчләре утырып кала.* Х.Ибраһим

**КҮЧӘ** *и. иск.* Кечкенә урам. *Шул заман киемнәрен алмаштырып, вәзирен янына алып, күчәләрне акрынлап сәер кылып килгәндә күрделәр кем, бер дәрвиш хуш аваз илән кычкырып әйтер ки ---.* Дастан. *Соңгы нурлар Төрле тыкрыктан үтеп, Тар күчәләрдән, Өйдән, Землянкадан Портка кудылар Халкын бер итеп.* М.Җәлил

**КҮЧӘН** *и.* 1) Яфраклары бербереенә тыгыз булып береккән кәбестә башы. *«Ир – баш, хатын – муен», – дигәннәр. --- гаиләнең асылына шайтан хуҗа булып алганда, «ир-баш» кәбестә күчәненә әйләнә.* А.Гыйләҗев. *Бер күчән кәбестәне алып, --- вак кына итеп телемләп турарга --- кирәк.* Йорт эшләре. *Һәм шулардан чыккан кортлар яшь күчәнне тиз арада зарарлый.* Сөембикә

2) Кәбестә башының үзәге

◊ **Күчән баш** Уйламыйча эш йөртүче. *Ә бу күчән башлар мунчага «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртканнар.* Р.Вәлиев

**КҮЧӘР** *и.* 1) Башларына тәгәрмәчләр кидерелә торган үзәк. *Олаучылар һәм кучерлар, --- сынган күчәрләрне, ватылган тәгәрмәчләрне рәткә кертеп азапланалар иде.* Җ.Тәрҗеман. *Урман авызына килеп керүгә, ат --- юл читендәге каенга арбаның арт күчәрен китереп ордырды да туктап калды.* М.Галиев. *Хәтта атлар да --- күчәр әйләнәсендә --- үз өлешләренә төшкән «йөк»не сөрлегә-сөрлегә тарттылар.* Н.Хәсәнов

2) *тех.* Механизмнарның әйләнә торган өлеше беркетелгән үзәк. *Бораунын күчәренә басым аз булмаячак.* М.Хәсәнов

3) *махс.* Берәр җисемнең яки пространствоның үзәген тәшкил иткән шартлы туры. *Безнең планетабыз 24 сәгать эчендә бер тапкыр үз күчәре тирәсендә әйләнеш ясый.* Табигать белеме. *[Сарут] чәчәк төркеменең үзәк күчәрендә, бодайдагы кебек, аерым башакчыклар утыра ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Саннар күчәре өстендәге һәрбер ноктага анык булган бердәнбер реаль сан тиңдәш була ---.* Математика

◊ **Күчәр башлары орыну** *к.* **күчәр башлары эләгешү**. *Телендә каргау сүзләренең барын белми иде әле ул моңарчы, кайбер бәндәләр белән күчәр башлары орынганда, алар --- үзләреннән-үзләре телгә киләләр икән...* А.Гыйләҗев. **Күчәр башлары орышу** *к.* **күчәр башлары эләгешү**. *Бикхуҗаевлар бер нәрсәне исәпкә алмадылар: Шубарин --- эшнең һәм акчаларның хуҗасы дип фәкать үзен генә саный. Кыскасы, күчәр башлары орышты.* Р.Мирхәйдәров. **Күчәр башлары эләгешү** Тиргәшү, ачуланышу, кычкырышу

**КҮЧӘРБАШ** *и. окказ.* Арбага җигелгән атны тотучы кучер. *Алпар йөзбаш --- арбадан артык әйберләрне бушаттырды да, күчәрбаш биреп, бала белән Айбибигә утырырга кушты.* М.Хәбибуллин

**КҮЧӘТ** *и. диал.* Күчереп утырту өчен үстерелгән яшелчә үсентесе

**КҮЧЕМ** *и.* Бер көн эчендә туктамыйча үтелә торган юл арасы, бер көнлек юл, мәрхәлә. *Шәһәрдән ике күчемлек юл*

**КҮЧЕМЛЕ** *с.* 1) *лингв.* Эш яисә хәрәкәтнең төшем килешендә тәгъбир ителгән объектка күчүен белдерә торган. *Эшне, гамәлне белдерүче фигыльләр күчемле була ---.* Татар грамматикасы. *Күчемле фигыльләрдә эш-хәл һәрвакыт туры объектка юнәлгән була ---.* Татар теле морфологиясе. *Фигыльләрнең күчемле яки күчемсез булуы җөмлә эчендә билгеләнә ---.* Ч.Харисова

2) *икът. к.* **күчмә 1.** (*11 мәгъ.*)

**КҮЧЕМЛЕЛЕК** *и. лингв.* Күчемле булу (фигыль тур.). *Фигыльгә юнәлеш кушымчалары ялгау аның күчемлелеген яки күчемсезлеген үзгәртә ала.* Татар грамматикасы

**КҮЧЕМСЕЗ** *с.* 1) *лингв.* Үзеннән соң килгән тәмамлыкның төшем килешендә булуын таләп итми торган. *Хәрәкәт фигыльләре, физик һәм психик халәтне, --- билгенең үсешен һ.б.ш. мәгънә белдерүче фигыльләр күчемсез була ---.* Татар грамматикасы. *Күчемсез фигыльләрдә эш объектка юнәлми, гадәттә субъект белән чикләнә ---.* Татар теле морфологиясе. *Кайтым юнәлешендәге күчемсез фигыльләр эшнең кабатлануын --- белдереп килә ---.* Ч.Харисова

2) *икът.* Урыны даими булган, җир һәм корылмалардан гыйбарәт (мөлкәт)

**КҮЧЕМСЕЗЛЕК** *и. лингв.* Күчемсез булу (фигыль тур.). *Күчемлелек-күчемсезлек --- фигыльләрнең гомумиләштерелгән лексик-семантик мәгънәләренә бәйле ---.* Татар теле морфологиясе

**КҮЧЕНҮ** I *ф.* 1) Яшәү яки эшләү өчен, бер урынны икенчесенә алыштыру. *Әнисе үлгәч, мөгаен, тиздән күченермен, дип хат язды ---.* Ф.Галиев. *Казанга --- Мәскәүдән иң югары хөкүмәт учреждениеләре күченде ---.* Җ.Тәрҗеман. *Авылга кайту белән күченү хәстәренә керештеләр.* Ш.Максудова

2) Башка өйгә яки квартирга күчү. *Ташлыяр аръягында --- яшәп яткан ятим-ялпы хуҗалыклар да тиз-тиз авыл уртасында бушаган пуҗумнарга күченделәр ---.* А.Гыйләҗев. *Мәгъшия апа яңа йортка күченүне өнәми килде.* К.Тимбикова. *Аннары алар финанс-икътисад институты янындагы бер өйгә күченделәр.* Ә.Әдиятуллина

3) Күчмә тормыш алып барганда, бер урыннан икенче урынга китү, күчү. *Заманында Мөхәммәд хан кан кардәшләре, --- күчмә халык буларак, көчәеп килгән угызлардан куркып, көнбатышка таба күченделәр.* М.Хәбибуллин

**Күченә башлау** Күченү эшенә керешү. *Күченә башлагач, мәшәкате күп була икән аның.* В.Нуруллин

**Күченеп бетү** Тулысынча, бөтенләй күченү. *Сыер асрар хәлләре булганнар авылда калмады, алар май-каймак ашарга калаларга күченеп бетте.* А.Гыйләҗев. *Казан-йорт тирәсендәге авыллардан качкан ярлы-ябагай да отыры шушында күченеп бетте.* Р.Батулла

**Күченеп йөрү** Һәрвакыт күченү хәлендә булу. *Әле берничә генә ай элек --- татар-башкорт балаларын урысчага өйрәтеп, авылдан-авылга күченеп йөргән җирләреннән туган яклары Кырмыскалыга кайт[тылар] ---.* Р.Мөхәммәдиев

**КҮЧЕНҮ** II *и.* 1) Күченү I процессы

2) Акрынлап үзгәрү; күчеш. *Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына ... тагын күтәрелә.* Г.Кутуй

**КҮЧЕРГЕЧ** *и.* **1.** 1) *сөйл.* Өлге, үрнәк (чигү, тегү эшендә)

2) *тех.* Әйләнү хәрәкәтен җайланманың бер өлешеннән икенче өлешенә күчерү механизмы. *Автомобильләрдә һәм тракторларда төрле тизлек булдыру өчен күчергечләр тартмасы кулланыла.* Физика. *Гидравлик күчергеч. Тешле күчергеч. Чылбырлы күчергеч*

3) *тех.* Нәрсәнең дә булса эшен, хәрәкәтен үзгәртү җайланмасы. *Диапазоннар күчергеч. Электр күчергече*

4) *күч. иск.* Башкаларга мисал булырлык нәрсә, үрнәк, өлге. *[Рөстәм:] Орденнарны --- колхозларда, завод-фабрикаларда бөтен кешеләр өчен күчергеч булырлык зур эшләр эшләгән өчен бирәләр.* Г.Гали

**2.** *с. мәгъ.* Күчермә алу өчен хезмәт итә торган. *Күчергеч кәгазь*

**КҮЧЕРЕЛМӘ** *с.* 1) *махс.* Нинди дә булса башка зурлыкларда, күрсәткечләрдә чагылдырылган. *Тулай продукция --- күчерелмә шартлы берәмлекләр (мәс., азык берәмлекләре, калорияләр) белән күрсәтелергә мөмкин.* Социалистик Татарстан

2) *лингв.* Туры булмаган, төп мәгънәсе булмаган. *Сүзләрне күчерелмә мәгънәдә куллануда иң киң таралган типик күренеш булган метафора ул төрле әйберләрнең төсләре, формалары, хәрәкәт үзенчәлекләре охшашлыгы нигезендә ясала.* И.Бәширова. *Күчерелмә мәгънәдә әйбер шул ук сүзнең башка мәгънәләре аша чагыла: якты бүлмә – якты уйлар ---.* Хәзерге татар әдәби теле

3) *к.* **күчермә** (*1 мәгъ.*). *Амбулатория картасының күчерелмәсен җибәрергә вәгъдә иттеләр.* Ф.Галиев. *Яшүсмер Мичурин үзенең күчерелмәләрен матур, ачык итеп язуы белән --- стихияләргә каршы аңлы рәвештә көрәш башларга җыенганлыгын күрсәтә.* А.Бахарев, П.Яковлев. *Карточка бушлай бирелә, аны алу өчен, кибеткә гариза язарга, шәхес буларак документ күчерелмәсен бирергә һәм бланк тутырырга кирәк.* Ватаным Татарстан

4) *к.* **күчмә** I (*1 мәгъ.*). *Рәт араларын эшкәртүне механикалаштырырга комачаулый торган агызу буразналары урынына алдынгы колхозлар күчерелмә җиңел трубалар – су сибү трубопроводы кулланалар ---.* Яшелчәчелек

**КҮЧЕРЕЛМӘЛЕ** *с.* Күчерелә торган, күчерелү өчен җайлаштырылган. *Күчерелмәле лампа*

**КҮЧЕРМӘ** *и.* **1.** 1) Төп нөсхәнең төгәл копиясе; икенче нөсхә. *Ике көннән соң Өметгалидән телеграмма килде: «Габдрахман, аттестатыңны ун көнгә алып торырга рөхсәт иттеләр. --- Күчермәсен эшләтеп кире җибәр ---».* М.Юныс. *Безнең Әгъләм абый --- классик әсәрләрнең күчермәсен ясарга куша.* М.Маликова. *Ренуар картинасының күчермәсе икән. Исеме белән дә күңелне кытыкларлык: «Жанна Самари портреты».* А.Әхмәтгалиева

2) *сөйл.* Берәр тексттан күчереп алынган өзек, өземтә, цитата. *Сүз башыннан озын бер күчермә китергән өчен укучы безгә рәнҗемәс дип ышанабыз.* В.Ленин

3) *күч. сөйл.* Икенче берәүгә бик охшаш булган зат. *Хатыннарның таныш тоелганы коеп куйган Фәндәрия бит! Аның беренче мәхәббәте Фәндәриянең күчермәсе.* Ә.Моталлапов. *Зеленовский кадрлар бүлеге начальнигының кечерәйтебрәк ясалган күчермәсен хәтерләтә иде.* М.Юныс. *– Кыскасы, иптәшләр, – диде Дамир, – сабыйлар – тач аталары, ягъни безнең күчермә.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ. лингв. к.* **күчерелмә** I (*2 мәгъ.*). *Һәр сүзе күчермә мәгънәдә түгелме әле моның?* Ш.Рәкыйпов

**КҮЧЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **күчерү**. *Дәрес күчерткән өчен, мәктәпкә бәлеш ташып безне сыйлап йөргән бер надан Уча малае гына бит ул!* Х.Ибраһим

2) Нинди дә булса матди милекне рәсми рәвештә кемнеңдер исеменә яздыру. *[Гайнулла:] Йорт-җиреңне дә хатының исеменә күчертергә кирәк һәм кибеттәге товарыңны да чамалы гына калдыр.* Ш.Мөхәммәдев

**КҮЧЕРҮ** *ф.* 1) Берәр предметны күтәреп, этеп, бер урыннан алып икенче урынга кую; нәрсәнеңдер урынын үзгәртү. *Корреспондент кыз, Ихтыярның тавышы күтәрелгәнне сизеп, микрофонны читкәрәк күчерде ---.* Р.Вәлиев

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса урнашкан урынын үзгәртү. *Реанимация палатасыннан күчерсәләр дә, Нәҗип янына бик авырлык белән генә керттеләр Наиләне ---.* А.Гыйләҗев. *Шундый тынгысыз көннәрдә, 109 нчы дивизияне алгы сызыкка күчерергә, дигән әмер алынды.* Ш.Рәкыйпов. *--- әледән-әле, язудан тукталып, тышка күз салырга туры килә: анда минем әйберләрне экипаждан экипажга күчерәләр ---.* Җ.Тәрҗеман

3) Текстта юлга сыймаган сүзнең калган өлешен, тиешле грамматик кагыйдәләрне саклаган хәлдә, икенче юлга язу. *Соңгы иҗекне икенче юлга күчерү*

4) Бер урыннан икенче урынга илтү, алып бару (кешеләрне). *[Трамвай һәм автобус] --- һәр көнне берничә йөз меңәр кешене Парижның бер җиреннән икенче җиренә күчерәләр.* Г.Гали

5) Берәр нәрсә аша чыгару. *Көймәче бу кешеләрне суның аръягына күчергәч тә, куллары белән күрсәтеп, юллар тәгъриф итә иде.* Ш.Камал

6) Яшәү, тору урынын алыштыру; кемне дә булса бер яшәү урыныннан икенчесенә җибәрү, илтү. *Мәрьямне яңа квартирына бөтен бригада белән күчерделәр.* Р.Вәлиев

7) Берәр эштән азат итеп, икенче эшкә кую, икенче эшкә билгеләү. *Азактан, Фаилнең сүзләрен искә төшереп: «Участокка прораб, һич булмаса, бригадир итеп күчерүегезне сорыйм», – диде.* Р.Вәлиев. *--- мин эшли башлагач, --- сөекле редакторыбызны алып, газетага бөтенләй катнашы булмаган икенче эшкә күчерделәр.* Х.Сарьян. *1786 нчы елның башында ук Иван Максимовичны канцеляриягә күчерәләр ---.* Җ.Тәрҗеман

8) Бер баскыч югарырак сыйныфта яки курста укырга хокук бирү. *Рәшатны класстан класска күчереп, тизрәк аттестат тоттыру өчен, мескен укытучылар ниләр генә кыланмадылар.* Ф.Садриев. *Зәйтүннең язмадан һәм арифметикадан өчле чыкты, аны икенче класска авырлык белән генә күчерделәр.* А.Гыйләҗев

9) Эш, хәрәкәт, гамәл юнәлтелгән объектны үзгәртү, шуларны икенче объектка юнәлтү. *– Син үзең соң! Чәукә борыныңны туры дип уйлыйсыңдыр әле, кесәңдә көзге йөртеп, – дип, һөҗүмне ул Фирзанга күчерә.* М.Галиев. *– Ә син үзең кайда яшәмәкче буласың? – Аңысын күз күрер. – Күз күрер дә күз күрер! – Зыятдин карт ачуын Ихтыярга күчерде.* Р.Вәлиев

10) Карашны бер нәрсәдән икенчесенә юнәлтү; нәрсәгә дә булса төбәлү. *Әлфред карашын авырлык белән генә читкә күчерде.* Ф.Яруллин. *Сөләйманов, ниһаять, карашын капитан өстәлендә яткан җинаять эшләренә күчерде.* Ф.Галиев

11) Нәрсәнең дә булса торышын үзгәртү, икенче торышка китерү. *Ирен-нәрен түгәрәкләп, стенадагы сәгатьне үчекли, ярый инде, миннән булсын яхшылык дигәндәй, диванга басып, телләрен күчерә.* Р.Вәлиев. *Ир, --- Сәвилә күндәм генә «ярар» дигәч, каушады: балтасын әле бер кулына, әле икенчесенә күчерде.* Н.Гыйматдинова

12) Сүзне, эчтәлекне һ.б.ларны икенчегә бору, аларга башка юнәлеш бирү. *Иңнәрен әчкә тартып, сүзне ничек итеп икенче нәрсәгә күчерергә белмичә, бер урында басып торды.* Җ.Тәрҗеман. *Болары Зәйтүн әнкәсенең сүзләре булса да, Әнәскә бик авыр ишетелделәр, ул кызарынып-бүртенеп, ызгышны олыларга күчерде.* А.Гыйләҗев // Сүзне, хәбәрне һ.б.ш. бер кешедән икенчесенә сөйләү, ишеттерү, тапшыру. *[Язкилдедә] Берәрсе ялгыш төртеп җибәрсә дә, аны олы әдәпсезлек, юньсезлеккә чыгарып, телдән телгә күчереп, еллар буе мисал итеп сөйлиләр иде.* А.Гыйләҗев

13) Берәр нәрсәнең эшләү режимын, башкарылу рәвешен үзгәртү. *Мичләрне сүтеп, өйләрне пар белән җылытуга күчерделәр.* А.Гыйләҗев. *Ягурны үткәч, Галимҗан атны җиңел юыртуга күчерде.* Т.Таһиров

14) Банк аша башка затка акча җибәрү. *Харрас ---, юк, сөйләшүләр барды, без риза идек, акча күчермәделәр, дигәч тә аптырап калмады.* К.Тимбикова. *Театрга тагын бер тапкыр акча күчерергә исәп.* Н.Гыйматдинова

15) Нинди дә булса бурычны үтәүнең, эш-хәрәкәт башкаруның вакытын, урынын, башкаручысын һ.б. үзгәртү. *[Приказчик:] Суконщиклар узган ел ителми калган пасха бәйрәмен көзгә күчереп, менә бүген шуны итеп йөриләр.* М.Гали. *Якуб мәсьәләне авыл җыенына күчерде.* И.Гази

16) Текстны яңабаштан үзгәртмичә язып чыгу, язып, күчермәсен алу. *Соңыннан ул «әсәр»не, орфографик хаталардан арындыра-арындыра, өчмедүртме тапкыр акка күчереп, мин ничек аптырап беткән идем бит!* М.Шаһимәрдәнов. *Ул әле бер төркемгә, әле икенчесенә ташланды, ләкин анда --- барысы да кәгазь-каләм белән нидер күчерә, чәбәләнә.* Ф.Садриев. *Төрмәдә язылган җырлар, --- шигырьләр нигә? Менә бу блокнот шундый юк-бар белән тулган. --- мин синең юк-бар әйбер күчереп әрәмгә киткән вакытыңны җәллим.* С.Шәрипов

17) Оригиналдагы рәсем, саннар һ.б.ш.ны фотога яки кәгазьгә төшерү. *Нижнийда Коля китаптан сурәтләр күчереп ясарга --- ярата иде.* Җ.Тәрҗеман. *Габдулла абзый --- сыер савучыларның стенага эленгән исемлеге янына килеп, куен дәфтәреннән кемнең күпме сөт сауганлыгын «иртәнге савым» дигән графага күчерә башлады.* М.Хәсәнов. *Экспедициядә бергә йөргән иптәшләренең портретларын ясады. Кайткач, эскизларны, этюдларны тукымага күчерде.* Ә.Моталлапов

18) Кемнең дә булса иҗатын яки башка төрле эшен үзеңнеке итеп күрсәтү. *Сәйдәш --- халык музыкасына*

*сукырларча иярмәде, аларны күчерү белән генә шөгыльләнмәде.* М.Җәлил. *[Ирек:] Күчереп язып, нәрсәсен аңларсың? Утыр менә, мин хәзер сиңа аңлатып бирәм.* Д.Аппакова

19) Нинди дә булса тәҗрибәне куллану, аны гамәлгә кертү. *Заманында апаслылар Ипатово игенчеләре алымын күчереп, ялгышмадылар.* Йолдыз

20) Бер телдәге текстны икенче телдәге чаралар белән бирү, икенче телгә тәрҗемә итү. *Бу шулай ук рус теленең «говорит на русском языке» дигән грамматик формасын телебезгә күчереп әйтүдән таралып киткән.* Х.Сарьян. *«Лукиан Самосатский әңгәмәләре». Өченче том. Грекчадан рус теленә Иоанн Сидоровский күчерде.* Җ.Тәрҗеман

21) Нәрсәне дә булса башка шартларга кую, туры китерү. *Ул --- табигать белән багланышын күңеленә җыеп асрый һәм гаять матур итеп үз кулы белән салган йортларына күчерә иде.* Г.Ахунов. *Бу тәгълимат тарафдарлары --- Библиядәге дөнья яратылуы турындагы әкиятләрне фәнгә күчерделәр.* Дарвинизм нигезләре

22) Нәрсәне дә булса башка формада чагылдыру. *Без барасы юллардагы соңгы үзгәрешләрне --- карталарга күчереп, корректура ясарга кирәк иде.* М.Юныс. *Образлар теленә күчергәндә, болай дияргә мөмкин булыр иде ---.* Җ.Тәрҗеман. *Глобус ул – Җир шарын кечкенә масштабка күчерү продукты.* Татар иле

23) Билгеләнгән вакытны соңгырак вакытка кичектерү. *Әмма кыз, әллә инде өйдән чыгу вакытын күчерде, әллә маршрутына үзгәреш кертте, һаман очрамады да очрамады.* С.Шәмси. *Ярый, ярый, совет утырышын бишкә күчерүләре әйбәт булган.* Г.Шакирова // Гомумән вакытны үзгәртү. *Шуның белән Русиядә сәгать телләрен кышкы һәм җәйге вакытка күчерү туктатыла.* Ирек мәйданы. *Хәзер дөньяның 82 илендә җәйге вакытка күчәләр, ә 159 илдә сәгатьне беркайчан да күчермиләр.* Мәдәни җомга

24) Теге яки бу әйбергә, милеккә икенче кешене хуҗа, ия итү. *Ә йорт-җир – һәммәсе Сәйдә исеменә. Ялгыш итте Кәрим: үз исеменә күчерергә башы җитмәде.* Ә.Галиев

**Күчерә башлау** Күчерергә керешү. *Озын-озын ике урамы да гөрләп торган матур авылыбызны --- Иске Крахмал авылына күчерә башладылар.* Г.Мөхәммәтшин. *Польша белән ике арада килешү көтелгәнлектән, көзгә таба армиянең бер өлешен Врангель фронтына күчерә башлаганнар.* Г.Бәширов. *– Әйдәгез, кызлар, шобага тотышыйк ---, – диде Әсма. Кызлар ---, орчыкны тотып, кулларын күчерә башладылар.* Х.Сафина

**Күчерә тору** Ниндидер эш барышында яки эш башланганчы күчерү. *Моңарчы дөньяның бирмешенә шөкер кылып, өметне алдагыга күчерә торып гомер кичерелгән бит.* М.Галиев. *Балдызның үзенә раскладушкасын, урын-җирен чыгарам. Куләгә күчкән саен, аларны да күчерә торам.* Ф.Яруллин

**Күчереп алу** Үзеңә күчерү. --- *үзен кызыксындырган адәмнәрне ачыклау өчен, кунакханә бусагасын атлап чыгасы булмады: күршесенең теге калын дәфтәреннән күчереп алды.* Р.Мирхәйдәров. *Яшьләр альбом битләренә күчереп алырдай табигый хисле шигырь юллары укучыларның күңеленә хуш килде.* И.Юзеев. *Өйдә эшләп килергә биреп җибәрелгән мәсьәләләрне Рухия үзе чишми, --- Равилдән генә күчереп ала торган иде.* В.Нуруллин

**Күчереп бару** Даими, һәрвакыт күчерү, булган берсен күчерү. *Дөрес, Рухиянең гел үзеннән генә күчереп баруын Равил бик үк өнәп бетерми.* В.Нуруллин

**Күчереп бетерү** Тулысынча, бөтенләй күчерү. *Аида ---, күчереп бетергәч, кәгазьләренең төп нөсхәсен шул папкага, ә яңаларын яшел папкага салды ---.* Ф.Садриев. *Берничә ураудa сейфтагы акчаларны үзенекенә күчереп бетерде дә --- аска төшеп китте ---.* Р.Мирхәйдәров. *Онкологик чир очракларын киметү өчен, Фукусима әйләнәсендәге 200 чакрым ераклыктагы һәркемне күчереп бетерергә кирәк.* Мәдәни җомга

**Күчереп килү** *к.* **күчереп бару**

**Күчереп чыгу** Һәрберсен, булган берсен күчерү

**КҮЧЕРЕП УТЫРТУ** *ф. а.х.* 1) Үсемлекне, яшелчә үрентесен казып алып, икенче урынга утырту. *Кыярны күчереп утырту алдыннан --- парникларны төнгелеккә рамалар белән капламыйлар.* Яшелчәчелек. *Ташкабакны --- тамырын имгәтмичә, туфрагы белән алып --- ачык грунтка күчереп утырталар.* Җиләк-җимеш

2) Кешенең кайсы да булса органын икенче бер кеше организмына урнаштыру. *Күчереп утырту өчен органнарны сәламәт кешедән алу – бик катлаулы һәм җитди эш.* Социалистик Татарстан

**КҮЧЕРЕП ЯЗУЧЫ** *и. к.* **күчерүче**

**КҮЧЕРЕП ЯЛГАГЫЧ** *и. тех.* Нәрсәнең дә булса эш характерын (юнәлешен, көчен һ.б.) үзгәртү өчен хезмәт итә торган җайланма; *русчасы:* **переключатель**

**КҮЧЕРҮЧЕ** *и.* Текстларны күчереп язу белән шөгыльләнүче кеше

**КҮЧЕШ** *и. махс.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса бер сыйфаттан, халәттән икенче сыйфатка, халәткә үзгәрү процессы. --- *Идел буе Болгары Мөхәммәд ханның икенче кызын Йосыф каханга кырык беренче хатын йөзендә тарттыргач, Булат бәктә үзе дә аңлап бетермәгән күчеш булды, аң күчеше.* М.Хәбибуллин. *Материаль ноктаның механик хәрәкәтен тасвирлау өчен траектория, үтелгән юл, күчеш зурлыгы --- төшенчәләре кертелә.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. *Кызга аның мондый күчеше сәер тоелмады, егете белән --- тормыш мәшәкатьләре турында да сөйләшергә рәхәтләнеп риза иде ул.* Ирек мәйданы

2) Берәр нәрсәнең торган урынын үзгәртү, бер урыннан икенче урынга күчерү процессы. *Солтангалиев: – Дөрес аңласам, Лев Давыдович, тиздән мат игълан итәчәкмен дигән сүзегезне?! Ашыкмагыз ---. Әгәр дә мәгәр без, әйтик, менә мондый күчеш ясап алсак?* Р.Мөхәммәдиев

**КҮЧЕШСЕЗ** *с. махс.* Күчми, үзгәрми торган. *Иске төр яңа төрне бернинди күчешсез һәм ара формаларсыз гына китереп чыгара.* Биология

**КҮ́Ч-КҮЧ** *рәв.* Өем-өем. *Үсемлекләрдән башка кул эчендә корыган үлән*

*сабакларыннан оешкан утраулар бар, алар күч-күч оешып, су эчендә зур саллар кебек йөзеп йөриләр ---.* А.Муранов

**КҮЧМӘ** I *с.* **1.** 1) Бер урыннан икенче урынга күчә торган, хәрәкәттә булган. *Зәңгәр күктәге күчмә ак болытларга карап, бик озак басып торды ул дала уртасында.* З.Зәйнуллин. *Насос установкалары вакытлы яки күчмә һәм бер урында берничә ел эшли торган даими булалар.* Яшелчәчелек. *Күчмә саранча*

2) Бер урыннан икенче урынга күчеп яши торган, утрак тормышлары булмаган. *Күчмә татарлар --- яңа барлыкка килгән --- Нугай Урдасы дәүләте тирәсенә тупланганнар.* М.Әхмәтҗанов. *Бу сяолар, бәлки, борынгы чорда Мисырны яулап алган күчмә гиксосларның бабаларыдыр?* А.Муранов. *Игенчеләр Сахара чигендә яшәүче күчмә халыклар белән сәүдә итәләр ---.* Урта гасырлар тарихы

3) Бер урыннан икенче урынга торак һәм мал-мөлкәт белән күчүгә бәйләнешле. *Балхаш шәһәрен төзүчеләр арасында элек күчмә тормыш белән яшәгән казакълар да күп иде.* А.Муранов

4) Халыкның утрак тормыш белән яшәгәнгә кадәр булган дәверенә караган. *Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык – шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык.* Г.Тукай

5) (Сезонга бәйле рәвештә) очып китә һәм кайта торган (кошлар тур.). *Көзге яфраклар коелу, күчмә кошларның җылы якларга китүе --- – болар һәммәсе дә тереклек ияләренең табигатьтәге сезонлы үзгәрешләргә җайлануы.* Табигать белеме. *Тургай – безнең якларга яз көне иң алдан килә торган күчмә кошларның берсе.* Кошлар: табигатькә сәяхәт

6) Хәрәкәт итә ала торган, хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә торган (җайланмалар, механизмнар тур.). *Кәтүкләр арасына кәгазьдән эшләнгән күчмә балдак киертелә, аңа кайтма бәйләнеш кәтүгә урала.* Радио сөюче. *Күчмә кран. Күчмә блок*

7) Үзенең эшен бер урыннан икенче урынга күчеп башкара торган. *Сабитова --- күчмә китапханә алып бара.* Ф.Садриев. *Күчмә театр. Күчмә күргәзмә*

8) Тәгәрмәчләргә урнаштырылган эш объекты. *Чыннан да, үргә күтәрелүгә, стан күренә. Бирге почмакта – күчмә кухня.* И.Салахов // Бер урыннан икенче урынга күчереп йөртә торган. *--- бәләкәй генә күчмә прожектор белән яктыртылган базга --- криминалисит төшеп китте.* Ф.Галиев

9) Даими урыннан кайда да булса китеп, читтә үткәрелгән (башкарылган). *Райком киңәше белән үземә --- күчмә суд утырышлары уздырырга туры килде.* Җ.Фәйзи

10) Регуляр үткәрелгән ярышларда элекке җиңүчедән яңа җиңүчегә күчә, алып бирелә торган. *Бөтен республиканы шаулаттылар, --- районга күчмә Кызыл байрак тапшырдылар.* Р.Хәбибуллина. *Икенче кварталда да Нефть промышленносте министрлыгының күчмә Кызыл байрагы безнең трест кулында калдырылды.* М.Хәсәнов. *Кечкенә гәүдәле, --- кысык күзле Мусаның чырае идарәдә торган күчмә Кызыл байрак төсенә керде ---.* Х.Ибраһим

11) *икът.* Җир белән турыдан-туры бәйләнмәгән һәм күчереп була торган (мөлкәт)

12) *лингв. к.* **күчерелмә** (*2 мәгъ.*). *--- хәзерге татар телендә --- «күчерелмә мәгънә» дигән термин актив кулланыла. «Аңлатмалы сүзлек»тә ул термин «күчмә мәгънә» дип бирелә ---.* И.Бәширова

**2.** *и. мәгъ. күпл.* Бер урыннан икенче урынга күчеп яши торган халык. *Бу көрәштә кенәзләр һәм бөек кенәзләр күчмәләр (кыпчаклар, бәҗәнәкләр, берендейлар, карабүреклеләр) көченнән файдалансалар да, Кыпчак иле үзе яңа көч җыя, аякка баса.* Р.Фәхретдинов. *[Болгарга] Алтын Урда ханнары, дала күчмәләре әледән-әле һөҗүм итеп торалар.* Казан утлары

**КҮЧМӘ** II *и. диал.* Су аша салынган басма, күперчек. *Күчмә өстеннән су алганда, Башмакларым чылanganга Салып куйган идем шунда – Оныткан-мын башмагымны.* Җыр

**КҮЧМӘЛӘ́Ү** *ф. иск.* Бал әчетергә кую, бал кою. *Вакытында колмагын да, салатын да таба алмаганга, без бу ел күчмәләп маташмаган идек, гаеп итмәгез инде, егетләр.* М.Гали

**КҮЧМӘЛЕ** *с. к.* **күчмә** I (*2 мәгъ.*). *Ак бүкәнне чатыр димә, күчмәлегә утыр димә.* Мәкаль

**КҮЧМӘЛЕК** *и.* Бер урыннан икенче урынга күчеп яшәү. *Халык кичке ашны хәстәрләргә кереште. Күчмәлектә тереклек иткән халык өчен гадәти хәлдер.* М.Хәбибуллин

**КҮЧМӘН** *и. к.* **күчмә 2.** *Башка күчмәннәр кебек үк, нугайлар да, шиксез, шәһәрләрсез яши алмаган.* Чын мирас

**КҮЧТӘНӘЧ** *и. рус* Хөрмәт йөзеннән яки бүләк итеп бирелә торган ашамлык. *Килгән кунаклар --- күчтәнәчләрен калдыралар да тизрәк чыгып китү ягын карыйлар.* Ф.Яруллин. *Зәйтүнә юл уңаеннан алган күчтәнәчләрне --- өстәлгә куйды да остазына таба атлады.* М.Маликова. *Кызы, сөйләнә-сөйләнә, алып килгән күчтәнәчләрен бушатты ---.* С.Шәмси

**КҮЧТЕРӘ** *и. рус. диал.* Кыяклылар семьялыгыннан чүп үләне, сарут; *рус-часы:* **костёр**

**КҮЧҮ** *ф.* 1) Бер урыннан икенче урынга бару (килү), барып (килеп) урнашу. *Дуслары һәм укучылары күп иде аның... Дөресен әйтик, аларның да күпләре Сарьян кебек бакый дөньяга күчте, сирәгәйде.* Г.Садә. *Серёжа артыннан уң якка әле күптән түгел генә гимназиядә купкан бунт нәтиҗәсендә бер атна карцерда утырып чыккан Балясников Пётр күчте.* Җ.Тәрҗеман. *Шәрифулла агай белән Сәүрә апа мәңгелек йортка күчкәннәр.* М.Юныс

2) Бер транспорттан төшеп, икенчесенә кереп утыру. *Арбадан пароходка, пароходтан поездга күчә-күчә эштән чыккан бичара ахыры бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым.* Г.Тукай

3) Яшәгән, торган төбәктән китеп, башка җиргә урнашу. *Янгыннан соң, Садыйк вакытлыча кодаларына күчте ---.* Х.Сафина. *Солнцев --- обер-прокурор Столыпин җитәкчелеге астында Казанга күчә.* Җ.Тәрҗеман. *--- мондагы азатлык сөюче, горур халыкны*

*кол итә алмаганнар, алар кул эчендәге утрауларга күчкәннәр.* А.Муранов

4) Әлегә хәтле яшәгән өйне, фатирны калдырып, башкасына китеп урнашу. *Мөһимәнең чираты җиткән дә, торак мәйданы бирәләр: ике бүлмәле фатирның кече ягына күчәргә тәкъдим итәләр икән.* М.Маликова. *Туйдан соң ук яшьләр Нижний Новгородка, Аверкиевның Сретенский урамындагы иркен йортына күчтеләр.* Җ.Тәрҗеман. *Иптәш кызларым юк. Шуңа күрә Зөбәйдә әбинең урман йортына бик теләп күчтем.* Ф.Яруллин

5) Күчмә тормыш алып бару. *Күчеп йөрү чегәннәргә килешә, ул – аларның милли сыйфаты.* А.Гыйләҗев

6) Бер нәрсәдән икенчесенә куну, килеп утыру. *Ә безнең Нечкәбил башка чәчәккә күчә.* А.Алиш

7) Урын алыштырып, кемгә яки нәрсәгә дә булса елышу, якынлашу. *Башкалар да Вильгельм янына күчеп утырды.* Ә.Галиев. *Табиб борчу тулы йөзен читкә бора, аннары --- башка авыру янына күчеп утыра.* Ирек мәйданы

8) Нинди дә булса аралыкны үтеп чыгу. *[Галләметдин], боз аркылы күчеп, тау сукмагы белән шәһәр ягына үрмәләде.* Ш.Камал

9) Таралу, җәелү. *Шулчак --- уң кулы сызларга тотынды, сызлау тора-бара бөтен гәүдәсенә күчте.* Р.Вәлиев

10) Бер эш урыныннан китеп икенчесенә урнашу (керү); эш урынын алыштыру. *Лариса күрше кафедрага Дәүләтшин кул астына күчкәннән бирле, аның белән сирәк күрешелә.* М.Маликова. *Гомере буе беркемгә дә «ярар» димәгән Шәвәлиев, райкомга эшкә күчкәч, әлеге сүзне Арслановка көн саен, сәгать саен кабатларга тиеш булып чыкты.* Ф.Садриев. *Ә Әминә үзе эштән эшкә күчеп, Казанга сатучылыкка китә.* Кызыл таң

11) Берәр төрле эш-хәрәкәтнең башкаручысы үзгәрү, алмашу. *Быел Сабан туена җитәкчелек Совет кулына күчте.* Х.Сафина

12) Кайсы да булса сыйныфны, курсны тәмамлап, аның югарырак баскычына күтәрелү. --- *Краснов класстан күчми калган ике малайны чәчләреннән эләктереп алды һәм берберсенә башлары белән китереп бәрде.* Җ.Тәрҗеман. *[Касыйм]: [Балаларның] берсе ике ел класстан класска күчмәде, икенчесе – өч ел.* З.Хәким. *Әлифә инде, бишенчене тәмамлап, алтынчыга күчте.* Г.Сабитов

13) Милләтне, динне алыштыру, үзгәртү. *Инде шул чорларда кылыч аша ислам динен кабул иткән хәзәрлеләр --- без хазарлыларны ислам диненә күчәргә мәҗбүр итәләр.* М.Хәбибуллин. --- *башка милләткә күчкән яисә күчәргә әзер кешеләрне мин җәмгыятьнең иң тотрыксыз һәм ышанычсыз әгъзалары дип беләм...* Р.Мөхәммәдиев. --- *туган-тумачалары аны ислам диненә күчкән бер сәүдәгәргә бирмәкче иделәр.* А.Тимергалин

14) Эш итү рәвешен үзгәртү, башка ысул куллана башлау. *Әнә хәзер ясалма орлыкландыруга күчәргә, диләр.* М.Мәһдиев. *Колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында менә атна-ун көн инде, механикалаштырылган савуга күчәбез дип мәш киләләр.* М.Хәсәнов. *Бригадирларның җил-давылына каршы шәп кенә ышык булды бу [справка], һәм ул үз җаена вак-төяк кәсепләр белән яшәүгә күчте.* Э.Касыймов

15) Берәр төрле эш яки хәрәкәтне тәмамлап яки калдырып, икенче бер эш яки хәрәкәтне башлау. --- *Миңнулла --- Кызыл Армиягә кешеләр мобилизацияләү мәсьәләсенә күчеп, Совет хөкүмәтенең шул турыдагы декретын укыды.* В.Нуруллин. *Бүген килгән газета һәм журналларны өстән-өстән генә караштыргалап, хатларга күчте.* Җ.Тәрҗеман. *Капитан Боҗедомов фикердән фикергә оста күчә, шуңадырмы, һәр сүзе адресатына эләгә.* С.Шәрипов // Сөйли башлаган сүзне, әңгәмәне тәмамлап яки бүлдереп, башка теманы башлау. *Шамкаев --- шактый борычлы яңа мәзәк сөйләп көлде, аннары гына төп сүзгә күчте.* Р.Вәлиев. *Сүз үзеннән-үзе әйберләрнең кыйбатлануына, тормышның авырая баруына күчте.* Ф.Яруллин. *Акрынлап сүз тагын постулатларга күчте.* Җ.Тәрҗеман

16) Нәрсәнең дә булса хуҗасыннан алынып, башкалар милкенә әйләнүе, кемнең дә булса карамагына бирелүе. *Тегермәннәр советка күчкәч тә, ул һаман шул эшендә калган.* Ә.Еники

17) Үзара көрәш шартларында торак пункт, административ биналар, хакимият һ.б.ш.лар каршы як кулына төшү. *Тиздән кызылларның тагын бер бик мөһим үзәге – Казан шәһәре дә безнең кулга күчәргә тиеш.* В.Нуруллин. *Кайбер авыллар берничә тапкыр кулдан-кулга күчте.* Ш.Рәкыйпов. *Ул көннәрдә булсын, Петроградта һәм Казанда власть большевиклар кулына күчкән тарихи сәгатьләрдә булсын, Хәрби шура солдатлары казармаларыннан чыкмады.* Р.Мөхәммәдиев

18) Бер урыннан икенче урынга куелу, китерелү (әйбер тур.). *Һәм авыр таш, йөк, бүрәнә, ирләр куәтенә буйсынып, урыныннан күчә иде.* М.Мәһдиев. *Мунча алдына иске «Саратов» холодильнигы илтеп утырттылар, элеккеге атаклы шарлы башлы тимер караватлар да мунча алдына күчте.* А.Гыйләҗев

19) Нинди дә булса объектның яки әйбернең башкалар җаваплылыгына тапшырылуы турында. *Китапханә кулдан кулга күчсә дә, бер генә мәртәбә дә тиешенчә тапшырылмаган һәм тиешенчә кабул ителмәгән ---.* Җ.Тәрҗеман. *Хуҗалык дилбегәсе яшь, үзеннән-үзе канәгать чырайлы майор кулына күчте.* С.Шәрипов. *Болар – бәхетлеләр, чөнки, иртәме-соңмы, карурманга хуҗа булачаклар, андагы байлыклар алар кулына күчәчәкләр.* Ш.Рәкыйпов

20) Сүз, хәбәр һ.б.ш.ның кешедән кешегә тапшырылуы турында. *Берме, икеме кешенең колагына салынган бу сүз яшен тизлеге белән телдән телгә күчә.* Ә.Фәйзи. *Исәнме, Байкал! --- Телдән телләргә Күчеп йөргән күл!* Ш.Маннур

21) Бер тел чараларын икенче тел чаралары белән бирү; икенче телдә сөйләшә башлау. *Үткәннәрне искә төшергәндә Шикоян, латинчага күчеп, сагышлы гына әйтеп куяр иде ---.* М.Галиев. *Ә инде «мин татар телендә сөйләшәм» дигәне телебездә кулланылса да, анысы русча әйтелештән күчкән.* Х.Сарьян. *Менә ул татарча матур*

*тел белән сөйләп килгән җиреннән кинәт русчага күчте.* Р.Мөхәммәдиев

22) Вакытны үзгәртү. *Хәзер дөньяның 82 илендә җәйге вакытка күчәләр, ә 159 илдә сәгатьне беркайчан да күчермиләр.* Мәдәни җомга. *15 майдан җәйге вакытка күчәбез.* Ирек мәйданы

23) Интенсивлыгы, көче үзгәрү (тавыш, тон тур.). *– Барырга кирәк, Николя, бармый ярамый, – диде Симонов, шаяртып сөйләшүдән бик тиз җитди тонга күчеп.* Җ.Тәржеман. *– Юк-юк, уйлама да. Җае чыкмый калмас, – дип каршы төште Әзизә, кырыс, усал тавышка күчеп.* Э.Касыймов. *Садыйк үзе дә сизмәстән иркәләүчән йомшак тавышка күчеп: – Чибәрем минем, – дип куйды.* Х.Сафина

24) Нинди дә булса эш, гамәл, хәрәкәт рәвешен алыштыру. *Тик Галия дүртенче тизлектән курыкты. Өченче тизлеккә дә теләр-теләмәс кенә күчте...* М.Хәсәнов. *Аннары [елан] Миңнулланың буш кул белән калганын күреп, үзе һөҗүмгә күчте.* В.Нуруллин. *Ныклы һөҗүмгә күчәргә җыенабыз.* Ә.Галиев

25) Бер ноктадан төрле якка таралу, җәелү. *Ботакларга тоташ ут күчкәнен күреп, Бибинурның эченә өмет җылысы йөгерде.* А.Гыйләҗев

26) Уй-фикерне үзгәртү; икенче төрле уйлый башлау. *Әле генә Зәйнәпне сүгеп, каһәрләп торган хатыннар, аның ягына күчеп, хихылдарга, Халисәне үртәргә тотындылар ---.* А.Гыйләҗев

27) *күч.* Хисләр, уй-фикерләр, эшгамәлләр бер кешедән икенче кешегә бирелү, таралу. *Сезгә бала имезгәндә болай борчылу ярамый. Ул бит сөт белән балага да күчә.* Г.Галиева. *– Ярый, Зәйтүнә апа, артык борчылмагыз. – Аннары уйлары Кәбиргә күчте.* Ф.Яруллин. *Минем дуамаллык аларга да күчте булса кирәк, тегеләр дә кызып-кызып эшләргә тотындылар.* В.Нуруллин

**Күчә бару** Әкренләп күчү. *--- сыер савучы Мөсфирә кара көнләшү белән янды: аңа булырга тиешле мактау кәгазьләре --- әкренләп Бибинур кулына күчә барды.* Х.Ибраһим. *Тик онытма: күргән файдаңның, тапкан малыңның уннан берсе Казан-йорт казнасына, тагын да бер өлешенең яртысы уртак маяга күчә барыр.* Ф.Латыйфи. *Экрандагы күңел күтәренкелеге ак халатлы ике кызга да акрынлап күчә барды.* Г.Әдһәм

**Күчә башлау** Күчү билгеләре күренү. *Адәми зат, атлы телгә хыянәт итеп, машина теленә күчә башлады.* М.Галиев

**Күчә килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә күчү. *Тел ул – буыннан буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мөкатдәс бер мирас ---.* Х.Сарьян

**Күчә тору** Әкренләп, аз-азлап күчү. *Чыга торган тишек бик ерак тоелды. Кешеләр чиратка тезелешеп басканнар, ул да шым гына басты. --- Ниһаять, күчә торгач, аңа да өстән яктылык күренде.* З.Кадыйрова

**Күчеп бетү** Тулысынча, бөтенләй күчү. *--- үткән ел безнең авылда алты ата каз унар йомырка салдылар, --- судагы балыклар Әчтерхан диңгезенә очып күчеп беттеләр ---.* Әкият. *Яшьләре читкә эшкә чыгып киткән, карткорысы мәңгелек йортка күчеп беткән.* Ф.Яруллин. *[Тимери] чүмәләдәге иген ындыр эченә күчеп беткәнче, --- ике арада өермәдәй бөтерелеп йөрде.* Г.Бәширов

**Күчеп йөрү** Даими рәвештә күчү. *Җәләл: – Әйдә, дуслык өчен берәрне тотыйк әле, – дип кыстый-кыстый, берсе яныннан икенчесе янына күчеп йөрде.* Х.Сафина. *Һәр җәй Лох-Несс күле буена меңләгән туристлар агыла башлады, бинокльләр --- белән коралланган бу эшсез халык серле Нессины күрү өмете белән төрле урынга күчеп йөри.* А.Муранов

**Күчеп калу** Кинәт күчү. *Калын, көчле тавышы кайчак тәрәзә пыялаларын зыңгылдаткандай итә, ә кайчак бөтенләй пышылдауга гына күчеп кала.* Д.Галимов

**Күчеп килү** *к.* **күчә килү**. *Нәфрәтләре буыннан буынга күчеп килә.* Ә.Моталлапов

**Күчеп китү** Бөтенләй күчү. *Шуны әйтим, ул бик күп русча кыстырып сөйли иде, кайчак бөтенләй русчага күчеп китә ---.* Ә.Еники. *Бүген дә ул чәй янында башта дөнья --- хәлләре турында азрак сөйләп алганнан соң, --- төрле-төрле авырулар, алардан ничек савыгу мәсьәләләренә күчеп китте.* З.Биишева

**КҮШ** *и.* Ябулы арба яки чананың өсте, түбәсе

**КҮШӘ** I *и. махс.* Туку станында буй җепнең койрыктан (*7 мәгъ.*) соң махсус элмәкләү юлы белән үрелгән һәм туку процессында әкренләп сүтелә бара торган өлеше

**КҮШӘ** II *и. диал.* Көпшә, балтырган көпшәсе. *Урман буенда күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге очрый.* М.Мәһдиев

**КҮШӘГӘ** *и. иск.* 1) *к.* **кашага**

2) Җилән, бөркәнчек. *Кигән ыштанны кем күрә, күшәгәне ил күрә.* Мәкаль

**КҮШӘК** *и.* Баганаларга утыртылган, стеналары булмаган яки бер яктан гына стенасы булган гөмбәзсыман түбәле җиңел корылма. *Урамнан, күшәк артыннан, Гөлбикә әбинең бишек арбаны этәреп килгәне күренә.* Н.Исәнбәт

**КҮШӘЛӘ́Ү** *ф.* Туку станындагы койрыкка кадәр булган буй җепне элмәкләп үрү, күшә ясау

**КҮШӘЛЕ** *с.* Күшәсе булган. *--- ул җәй игенле, җиләкле, печәнле, --- булды; урманы мул кура җиләкле, күшәле, еланлы, бурсыклы булды ---.* М.Мәһдиев

**КҮШӘМ** *и. махс.* Күшәүче хайваннарның ашказаныннан кире китерелеп, кабат чәйнәлгән азык

**КҮШӘНҮ** *ф. сөйл.* Чәйнәү, ашау. *Түшәге бар түшәнер, икмәге бар күшәнер.* Мәкаль

**КҮШӘРЕЛҮ** *ф. диал.* Ургылып, бик көчле булып агу. *Габидуллинның бот итен зур гына мина китеге умырып алды. Күшәрелеп кан ага башлады.* Ш.Маннур

**КҮШӘҮ** *ф.* 1) Ашказанындагы азыкны кире чыгарып кабат чәйнәү (күшәүче хайваннар тур.). *Бу минутларда сарыклар кутанда тыныч кына күши, --- учактагы күмерләр сүрән генә көйри ---.* Т.Әйди. *Малайларга бик тавышланмаска кушып ишарәлибез дә*

*гамьсез генә күшәп яткан бозау янына киләбез.* М.Галиев. *Күп ашап корсакларын тутырганнан соң, күшәп, тыныч кына ятарга яраткан сыер ыруы, атлардан ераккарак китеп, үзләре өчен тынычрак урын эзли.* З.Зәйнуллин

2) *гади с. кимс.* Ашау. *Баем, баем, бай кеше. Җимерелеп бара һәр эше, Ул да кара икмәк күши.* Г.Камал

**Күшәп йөрү** Гел, даими күшәү. *Иң алга Нәүширван абзыйның урамда да гел коры ипи күшәп йөри торган бүксә Гамиры килеп баса.* М.Галиев

**Күшәп тору** Күшәгән хәлдә булу. *Кәҗә дә күшәп тора, өйне өйгә охшатып, үзенчә ямь өстәп.* Г.Якупова

**Күши башлау** Күшәргә тотыну

**Күши бирү** Бернәрсәгә карамастан күшәүне дәвам итү. *[Кәҗә] --- яңа гына бурлыкта тотылуын онытып, матур иренен кыйшайта-кыйшайта күши бирә.* М.Галиев

**КҮШӘҮЧЕЛӘР** *и. күпл. зоол.* Партояклы хайваннарның ашаган азыгын кире чыгарып чәйни торган бер төркеме; *русчасы:* **жвачные**. *Сыер күшәүчеләргә керә*

**КҮШЕГҮ** *ф.* 1) Суыктан яки салкын яңгырдан тән өшү, аның хәрәкәтчәнлеге, тою сәләте кимү. *Аякларым чыйраган, авыз-борыннарым күшеккәнлеген шунда гына аңладым.* Р.Мөхәммәдиев. *Туманов ---, кабинетка теге «экспедитор»ның милиция лейтенанты формасыннан килеп керүен күргәч, күшеккән кебек бөрешеп калды ---.* Ф.Галиев

2) Суыктан яки салкын судан, яңгырдан өшү, туңу, калтырап тору. *Авылга салкын, пычрак көзләрдә барып, бәрәңге казып йөрде. Чыланды, күшекте ---.* Ә.Еники. *Аның каравы ул су коенгач күшеккән тәннәрен җылытырга дип, инеш буасы ярына чыгып утырган малайларның учлап-учлап ком сибешеп уйнаганнарын күреп алды.* Ә.Гаффар. *Ә җил суык, куллар күшегә.* М.Мәһдиев

**Күшегә төшү** Азрак, бераз күшегү. *Солтангалиев күшегә төшкән уч төпләрен бер-беренә ышкып алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Күшегеп бетү** Тәмам, бөтенләй күшегү. *[Самат:] – Күшегеп беткәнсең бит, кызыкай, бөтен гәүдәң дерелди, – дип, кызганып, аны юатырга керешә.* Г.Галиева. *Көне буе салкын тимер боргалаганнан соң күшегеп беткән куллар белән ягылмаган өйгә аяк басуның бер кызыгы юк иде.* Ә.Моталлапов. *Николай, --- кул-аяклары тәмам күшегеп беткәч кенә, университет ягына кайтты.* Җ.Тәрҗеман

**Күшегеп тору** Әле, шушы моментта күшеккән булу. *Шакир кызның алсу йөзенә, күшегеп торган кызыл иреннәренә сокланып карый.* Р.Кәрами

**Күшегеп чыгу** Тиз арада күшегү. *Якмаган мунчада да салкын, бармаклар шунда ук күшегеп чыга.* Н.Әхмәдиев

**Күшегеп яту** Шактый озак вакыт күшегү. *Висланың уң як ярында --- карлы-бозлы яңгырлардан күшегеп ятучы частьләр --- байтак җыелган, бернитә понтон күпер генә аларны үткәреп бетерә алмый иде.* Ф.Хөсни

**КҮШЕК** *и. фар.* 1) Урта гасырларда Урта Көнчыгыш илләрендә балчык нигезгә чи кирпечтән (соңрак кирпечтән һәм таштан) төзелгән торак манара – ныгытылган сарай үзәге. *Йете диңгез артында күшек бар, аның эчендә бер кыз бар ---.* Ырым. *[Хәйбүш Хуҗаны] киредән күшеккә утыртып, чаршауны яба.* Н.Исәнбәт

2) Гадәттә бакча уртасында бизәкләп эшләнгән түбәле корылма. *Алар җимеш бакчасы түренә эшләнелгән күшек-беседка эчендә мәхәббәт алышырга яраталар.* Ф.Яхин

**КҮШЕ́К-САРАЙ** *и.* Юлчылар туктый торган кечкенә бина. *Аларга каршы якта түбәсе яссы, кечерәк бер күшек-сарай: патшалар, хөкем кешеләре төшү урыны.* Н.Исәнбәт

**КҮШИЛ** *и. рус диал.* Юкәдән үрелгән кәрзин. *Ул Төлкене ничек булса да тотып, күшиленә салды, балыклар катына.* Әкият

**КҮШЛЕ** *с.* Күше булган. *Буран иде. Ишегалдына ямщик та зур күшле чанага пар алаша җигеп килгән иде.* Г.Газиз

**КХ** *иярт. к.* **кых**. *Урлаштымы – терсәгеннән кх! Кеше җанын кыйдымы – муенын бор.* А.Гыйләҗев

**КХЕ-КХЕ** *иярт. к.* **кыхым**. *«Юк... Кхе-кхе...» – Секретарь, бункерга иелеп, баланы бишеккә салып маташкан Шәфыйкага ымлады.* А.Хәлим

**КХ ИТҮ** *ф. к.* **кых итү**. *Җирән этме? Без аны... (муенын күрсәтеп) кх итәрбез, сэр.* А.Хәсәнов

**КХМ** *иярт. к.* **кыхым**. *Дөрес, [карабодай балын] капкан шәпкә башта җиңелчә генә кхм, кхм йөткереп аласың.* А.Хәсәнов

**КХМЕР** *и.* Кампучиядә яшәүче төп халык атамасы. *Әнә Кампучидә «кызыл кхмерлар» илнең бөтен укымышлы кешеләрен юк иттеләр ---.* В.Юныс

**КХМ ИТҮ** *ф. к.* **кыхым итү**

**КХЫМ** *иярт. к.* **кыхым**. *[Милиционер] --- «кхым, кхым» дип ютәлләштергәләде һәм, торып, тәрәзәсез яктагы икенче ишекнең биген шалтыратырга кереште.* Ф.Латыйфи

**КҺЕ-КҺЕ** *иярт.* Җиңелчә йөткерү тавышын белдерә. *Теге хатын көянтәчиләгән асып, моның ихатасына аяк басуы була, бу кһе-кһе дип тотына йөткерергә.* Әкият

**КЫБЫРДАТУ** *ф. сөйл.* 1) *к.* **кыймылдату**. *[Софья] Бер минут чамасы хатка карап торды, --- кипшергән иреннәрен кыбырдатып бераз укып торды.* А.Иванов

2) Нәрсә булса да эшләү, хәрәкәт итү, булдыру. *Теле белән тегермән тарттыра, кулы кыл да кыбырдата алмый.* Н.Исәнбәт

**Кыбырдатып алу** Көтмәгәндә яисә бераз кыбырдату

**Кыбырдатып карау** Кыбырдатырга тырышу. *Бармак очларында кан йөгергән сыман булгач, кулларын кыбырдатып карады [Рөстәм Газизович].* М.Кәбиров

**Кыбырдатып кую** Бераз, аз гына, бер тапкыр кыбырдату

**Кыбырдатып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле кыбырдату

**КЫБЫРДА́У** *ф. сөйл. к.* **кыймылдау**. *Чыпчык кыбырдамый торалмый.* Әйтем. *Кыбырдаган кыр ашкан.* Мәкаль

**Кыбырдап алу** Көтмәгәндә яисә бераз кыбырдау

**Кыбырдап кую** Бераз, кинәт кыбырдау; бер тапкыр хәрәкәт ясау. *Ул [Азамат] үзенең тиресе астында Әюп пәйгамбәр тәнен кимергән кортларның*

*кыбырдап куюын тойгандай булды.* М.Кәбиров

**Кыбырдап тору** Бертуктаусыз кыбырдау

**Кыбырдап утыру** *к.* **кыбырдап тору**

**КЫБЫРДЫК** *и. сөйл. к.* **кыбырсык**. *Фазылетдин абыем да кыбырдык иде, кеше эшенә кысыла... Без аның белән икебез бер калыптан...* Б.Камалов

**КЫБЫРҖУ** *ф. диал. к.* **кыбырсу**. *Әнә тәмам инде сихәтләнеп җитте дигән икенче бер йөрәк ярасы кыбырҗып маташа башлады анда...* Р.Төхфәтуллин. *Хәзер герман фашистлары котырына, самурайлар кылыч уйната, финнар кыбырҗый.* Г.Әпсәләмов

**Кыбырҗып алу** *к.* **кыбырсып алу**. *Төп кода урынында кыбырҗып алды.* А.Хәлим

**Кыбырҗып кую** Кинәт кыбырҗу; бер тапкыр кыбырҗу. *Газзән утырган урынында кыбырҗып куйды.* Г.Әпсәләмов

**Кыбырҗый башлау** Кыбырҗырга тотыну. *Аның йөрәге тагын кыбырҗый башлады.* Ә.Гаффар

**КЫБЫ́Р-КЫБЫР** *иярт.* Чак кына селкенгән, кыймылдаган хәрәкәтне белдерә. *Әлеге горурлык кыбыр-кыбыр үзен сиздерүенә шушы нәрсә дә сәбәп өстәде булса кирәк.* Р.Төхфәтуллин

**КЫБЫРСУ** *ф.* 1) Боргалану-сыргалану, борсалану, хәрәкәтләнү, хәрәкәткә килү. *Үрәтник кигәвен кунган корчаңгы ат кебек кыбырсып, ярсып, билендәге кәкре кылычын тартып алды, күзләрен акайтып кычкырды ---.* Ш.Шәйдуллин. *Баядан бирле тамагым кипте дип кыбырсыйсың.* Н.Гыйматдинова

2) Тынычсызлану, рухи тынгысызлык кичерү. *Синең хатын өчен генә, бәлки, болай кыбырсып йөрмәс тә идем.* Т.Галиуллин. *[Разживин] Иштәсе килмәгән сүзгә кучсәң, әңгәмәне икенчегә бора, утырган урынында кыбырсый, чәбәләнә, кирәкмәгәнгә җикеренә башлый, шулай итеп гади генә мәсьәлә дә чишелә алмаслык төенгә әйләнә.* Ф.Сафин

3) Тик тормау, эшләү. *Кыбырсыган кызыл кияр.* Мәкаль. *Кыбырсы, мыштырдасаң – премияң фыйт.* С.Шәрипов

4) *күч.* Җилкенү, ашкыну. *Аның күңеле кичә күргән гүзәл зат турында бер-бер хәбәр белергә тели, шул хакта нәрсәдер эзләп табар сыман кыбырсый, алгысына иде.* М.Вәлиев

**Кыбырсый башлау**. Кыбырсырга тотыну. *Һич тә истә-оста югында көтмәгәндә-уйламаганда алынган әлеге хәбәрдән тәмам тәкатен җуйган Гази: «Инде нишләп карарга?» – дип ут йотып кыбырсый ук башлады.* М.Хәсәнов. *Балаларның күздән югалуы булды, ашыгып йөреп машина астына эләгә күрмәсеннәр болар, дигән уй тагын эчтә кыбырсый башлады.* Р.Төхфәтуллин. *Получка алу белән күңел кыбырсый башлады.* М.Юныс

**Кыбырсып алу** Бераз кыбырсу. *Йөрәк тирәсендә нәрсәдер кузгалып, кыбырсып алды.* Ф.Сафин

**Кыбырсып йөрү** Әле, хәзер, сөйләү моментында кыбырсу. *Мин сорадыммы, берәрсе куштымы? Әллә үзеңнең кыбырсып йөрүеңме?* М.Хуҗин. *Баядан бирле кыбырсып йөргән бер чая хатын, сорап та тормыйча, унберенче булып чирәмгә төртелде.* Н.Гыйматдинова. *[Попугай балык] Тирәндә арлыбирле кыбырсып йөри торгач, яныңа килеп очлы борыны белән тәнеңә дә төрткәләп карый.* М.Юныс

**Кыбырсып кую** Көтмәгәндә, кыска гына арада кыбырсу, бер тапкыр кыбырсу. *«Сигналлар? Нинди сигналлар?» – дип, Зәйнагов утырган урындыгында кыбырсып куйды.* Х.Камалов. *Әти янә кыбырсып куйды.* Ф.Шәфигуллин

**Кыбырсып төшү** Артык тынычсызлану. *Бер исәпләсәң, кунак дип кыбырсып төшәсе дә түгел инде.* Б.Камалов

**Кыбырсып тору** Туктаусыз, әледәнәле кыбырсу. *[Габдулла] --- бераз гына кыбырсып торды да әйтеп куйды: – Шаһинур каениш, син атларга бүген дә ипи алып төшәсеңме?* Р.Сибат

**Кыбырсып утыру** Бертуктаусыз кыбырсу. *Женя исә, әллә нигә, пошынгангамы, сөенгәнгәме, кыбырсып утырды.* Б.Камалов

**Кыбырсып чыгу** Билгеле бер вакыт арасын кыбырсып үткәрү. *Никадәр генә үземне тынычландырырга азаплансам да, --- котылу юлы күренми иде. Төне буе кыбырсып чыктым.* Ф.Латыйфи

**КЫБЫРСЫК** *с.* **1.** 1) Тиктормас, хәрәкәтчән. *Бик җитез, кыбырсык булгангамы, Алёшка аны кәлтәгә охшата.* А.Иванов. *Кыбырсык бала*

2) Тынгысыз. *Ниләр генә күреп үсмәде безнең яланаяклы, юеш борынлы кыбырсык токым!* Г.Бәширов. *Шулдыр раушан чагың, И, кыбырсык җаным.* Г.Сәлим. *Булганына шөкер итми торган, кыбырсык җанлы кеше ул минем яшьтәшем Һабил.* Р.Фәизов

**2.** *и. мәгъ.* Тынгысыз кеше. *Кыбырсык ни чапмас, ни утырмас, ни тынмас.* Әйтем. *Дөньяда ике кыбырсык булса, берсе нәкъ менә шушы тегүче Корбангалидер, мөгаен.* Ф.Хөсни

◊ **Кыбырсыгын китерү** Хирысын уяту, шуңа этәргеч бирү. *Юк инде, дус кеше, филфакта укучы егетләрнең күбесен каләм тибрәтү кыбырсыгын китергән.* М.Юныс

**КЫБЫРСЫКЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **кыбырсу**

**КЫБЫРСЫЛА́У** *ф. диал. к.* **кыбырсу**

**КЫБЫРСЫНУ** *ф. сөйл. к.* **кыбырсу**. *«Синнән генә тормый лабаса котельный кору, син бит үзеңә тиешлесен эшләдең, бинаны торгызып куйдың, нигә кыбырсынасың әле син, иптәш Сәфәров?» – дип каршы төште битараф бер уй.* Г.Кашапов. *Диспетчерны бимазалыйлар. Кыбырсыну, киеренке, кырыс тынгысызлык.* М.Юныс

**Кыбырсынып алу** Бераз кыбырсыну

**Кыбырсынып йөрү** Һаман да кыбырсыну. *Янымда попугай балыклар кыбырсынып йөри.* М.Юныс. *[Ректорга] --- күптән күңел түрендә кыбырсынып йөргән сорауны бирергә форсат табылды.* Ватаным Татарстан

**Кыбырсынып кую** Көтмәгәндә, кинәт кыбырсыну; бер тапкыр кыбырсыну. *Юлдаш әби утырган урынында кыбырсынып куйды.* З.Хөснияр

**Кыбырсынып тору** Даими, әледәнәле кыбырсыну. *Кыбырсынып торган таза күк айгырны җиңел пролёткага җигеп, шәһәр уртасыннан узып китүе үзе нәрсә тора!* Ә.Фәйзи

**КЫДРАЧ** *с. диал.* Һавалы, масаючан, мактанчык. *[Әсма:] Кыяфәтләрегез дә мәзәк. Сугышырга торган кыдрач әтәч шикелле.* А.Гыйләҗев

**КЫДРАЧЛАНУ** *ф. диал.* 1) Масаю, һавалану

2) Кызып китү; әтәчләнү

**Кыдрачланып алу** Бераз кыдрачлану

**Кыдрачланып йөрү** Гел, бертуктаусыз кыдрачлану. *Йорт салам, йорт кына түгел, дворец салам, дип, бик кыдрачланып йөргән идең дә, эштән чыгарып, урлашыр җиреңбеткәч, кикригең шиңдеме?!* Татарстан яшьләре

**Кыдрачланып китү** Көтмәгәндә, кинәт кыдрачланырга тотыну

**Кыдрачланып тору** Әледән-әле, еш кыдрачлану

**КЫДРАЮ** *ф. диал. к.* **кыдрачлану**. *Хәбиб, мактаганга кыдраеп, Таҗи Гыйззәтнең биленнән ала.* Р.Батулла

**КЫДЫРМА** *с. диал. к.* **кыдырым**. *Комагай кылкыннан яза, кыдырма аягыннан яза.* Әйтем

**КЫДЫРУ** *ф.* 1) Күп йөрү, бөтен тирәлекне йөреп әйләнеп чыгу. *Күп яшәгән белмәс, күп кыдырган белер.* Мәкаль. *Икенче көнне иртә белән Мансур әфәнденең сабакка барасы булганга, Габдулла әфәнде үзе генә бернигадәр фәкыйрьләр өен кыдырмакчы булды.* Г.Исхакый. *Бүрек белән киңәшеп ятам да менә, бүрек миңа әйтә: син йөрерсең, тиле күркә, урман кыдырып, ди, ә яңа йортны син түгел, синең күршең салып керер, ди.* Ф.Хөсни

2) Ашыктыру. *[Уразаев] --- тегене печәнлектә изрәп йоклап яткан җиреннән уятып, кыдырып юл башына алып килде.* Я.Зәнкиев. – *Фаяз абый, мине бик кыдырып кияүгә сорыйлар,* – *диде.* Х.Камалов

3) Эшләү, булдыру, майтару. *Персидәтелдән чыгарылгач, бригадир булып җөргән булдың. Нәрсә кыдырдың инде син анда?* В.Нуруллин

**Кыдырып йөрү** 1) Һәрберсен дә кыдыру. *Аксак бүре, урыс авылларын ерактан әйләнеп үтеп, татар авылларын кыдырып йөрде.* Т.Мөбарәков

2) Әле, сөйләү моментында кыдыру. *Син дә мондамыни әле, Хәйрулла әфәнде? Ниләр кыдырып йөрү?* В.Нуруллин

**Кыдырып чыгу** Бөтен җирдә булу, бер җирне калдырмыйча рәттән йөрү

**КЫДЫРЫМ** *с. диал.* Биләмче, йөремсәк. *Кыдырым хатын өенә җиткәндә алгысар.* Әйтем

**КЫЕГАЙТУ** *ф.* 1) Кыек хәлгә китерү, янтайту, чалшайту, кыйшайту. *Тимерче, гаепле кешедәй телен тешләп, башын әле уңга, әле сулга кыегайтып, хәйраннар булып, Мишухага беравык карап торды ---.* А.Иванов. *Лениза, тузган чәчле башын кыегайтып, аңа сынап карап тора башлады.* Х.Камалов. *Шакир, авызын кыегайтып, зәһәр генә елмаеп куйды.* Р.Төхфәтуллин

2) Бозу, эчтәлеген, мәгънәсен үзгәртү. *Чынлыкта, «Коръән серләре»нең сере андагы ялганнардан, аятьләрне кыегайтып тәрҗемә итүдән генә тора.* Р.Батулла

**Кыегайта бару** Торган саен ныграк кыегайту

**Кыегайта төшү** Бераз кыегайту. *Аннары, башын бер якка кыегайта төшеп, мандолинасына төбәлгән күе, дәртләнеп уйнап җибәрде.* М.Шаһимәрдәнов

**Кыегайтып алу** Бераз вакытка кыегайту, кыегайткан хәлдә тоту. *Ә бүген ул [Галимша] кызган башын кыегайтып алган да сигез телле тальянкада сиптерә.* М.Мәһдиев

**Кыегайтып бетерү** Бик кыек итү, бөтенләй кыек хәлгә китерү

**Кыегайтып җибәрү** Бераз гына кыегайтып кую

**Кыегайтып кую** Кыегайтылган хәлгә китереп калдыру. *--- ягулык салырга дип кыегайтып куйган лампа филтәсеннән кулмәккә гөлт итеп ут капты.* Ә.Сәлах

**Кыегайтып тору** Даими, әледән-әле кыегайту; әле, сөйләү моментында кыегайту. *Сания оялган сыман бераз башын кыегайтып торды, да, ялындырмыйнитми генә кычкырып җырлап җибәрде.* А.Гыйләҗев

**КЫЕГАЮ** *ф.* 1) Кыек хәлгә килү, бер якка авышлану; кыйшаю, кыңгыраю, чалшаю. *Бераздан авызы чалшаеп китте дә мыегы бер якка кыегаеп катып калды.* А.Иванов. *Баганалар кыегайган, читән стеналар чүккән, салам түбәләр черегән...* М.Әмир. *Чатан, калтыравык урындык белән бергә ул үзенең дә янтаюын, кыегаюын, ава башлавын гына тойды.* Р.Мулланурова

2) *күч.* Бозылу, начарлану

3) *күч.* Үпкәләү, читләшү; ризасызлык күрсәтү. *Искәрмә ясаган идем – кыегайды, кафедрага да керми башлады. Борын чөеп йөри.* Х.Сарьян. *«Бер сүз дә әйтергә ярамый, кыегаерга гына торалар ---», – диде рәис, тагы да ныграк кайнап.* Х.Камалов

◊ **Кыегаеп утыру** Күңелсезләнү, үпкәләп борын салындыру

**Кыегаеп бетү** Тәмам, бик нык кыек хәлгә килү. *Әнә Мөгелсәмәттәйләрнең өенең почмаклары кыегаеп беткән, алай да торалар.* Ф.Яруллин. *Шушындый затлы сөяк тәбәнәк буйлы, сул якка каптырыла торган шәкерт бишмәте, таушалып беткән чалбар, кыегаеп беткән аяк кабы кигән.* Р.Батулла

**Кыегаеп калу** Нинди дә булса вакыттан, сәбәптән соң кыегайган торышка килү. *Зәңгәр һиндыбалар ат тояклары астында таптала. Кайберләре янтаеп, кыегаеп кала.* Р.Батулла

**Кыегаеп китү** Кинәт кыегаю; бераз кыегаю. *Ул [Миңлеасия] кайнатасының башы кыегаеп китүдән аның җан биргәнен аңлады – үксеп елап җибәрде.* Г.Ахунов. *Вафин ---, ничектер, кыегаеп китеп, урындыкка таянды һәм шартлап идәнгә ауды.* Ф.Садриев

**Кыегаеп төшү** Кыегайган хәлгә килү. *Капка баганалары да, исерек кеше шикелле, бер якка кыегаеп төшкән.* С.Поварисов

**Кыегая төшү** Бераз кыегаю

**КЫЕК** I *и.* **1.** 1) Корылманың, өйнең кыеклап эшләнгән түбәсе. *Келәт кыегы астына потлы тимер үлчәү иңсәсе элгәннәр ---.* Ә.Гаффар. *Урман беткән җирдә ниндидер каралты кыеклары күзгә чалынды.* Х.Камалов. *Елама, сабыем, кояш ызба кыегына күтәрелгәч, елга буена төшәрбез.* Н.Гыйматдинова

2) Кыек түбәнең эчке почмагы. *Күзгә нык ташланган нәрсә: йортлар кызыл чирәп түбәле булып, кыеклары бик текә очлы итеп, биек эшләнгән.* Х.Камалов. *Мин дә бит йортың янар*

*алдыннан гына кыекка кунган бер килбәтсез кош күрдем.* Н.Гыйматдинова. *Әнә [йорт] кыегына «Картлар интернат йорты» дип язганнар.* А.Гыйләҗев

3) *махс.* Авыш итеп ясалган өслек. *Затвор кыегы*

4) *сөйл.* Кисәк, ярчык, кыйпылчык. *Көзге кыегы*

5) *диал.* Тукыманы берәр нәрсә тегү өчен кискәннән соң калган вак кына кисәк, кисәк-посак. *Кыеклардан җыеп ясалган бизәк*

**2.** *с. мәгъ.* Кыеклардан торган. *Итәк тоту өчен кыек буйлар алырга кирәк.* Файдалы киңәшләр

**КЫЕК** II *с.* **1.** 1) Нинди дә булса яссылыкка карата авыш булган, авышлыкта торган, авышлык ясаган. *Баскычларыгыз биек – меналмам, Тәрәзәгез кыек – кералмам, Каршылар чыгып алмагачтын, Өегезгә кыеп кералмам.* Җыр. *Шура китте, ә Алексей һаман утыра иде, алдында, теп-тере булып, кызның коңгырт кара кыек күзләре көлеп тора иде.* А.Иванов. *Аякларында бик һәйбәт резин итекләр, өсләрендә кыек кесә кырыйларына күн тасма куеп тегелгән өр-яңа зәңгәр телогрейка, башларында затлы мамык шәл.* М.Мәһдиев

2) Чалыш, чалышайган; кыегайган. *Баһау карт ат башыннан җәһәт кенә эләктереп алып, кәкре борыны белән кыек яңагын миңа төбәде.* Х.Сарьян

3) Өчпочмак формасындагы. *Әлбәттә, ул минем тавышны ишетмәде, мәгәр кул болгавымны күрде, үзе дә башындагы кыек яулыгын салып, ашыга-ашыга селки башлады.* Х.Сарьян. *[Мөнәвәрә апа] Ашык-пошык рәхмәт әйтеп, бер кулына кыек яулыгын, икенчесенә чолан почмагында сөялеп торган саженын эләктереп чыгып йөгерде.* Ф.Шәфигуллин. *[Тайганда] Кулны кыек яулык яисә бинт белән муенга асарга, ә аякка, кул астындагы әйберләрне файдаланып, шин салырга кирәк.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

4) *махс.* Тәэсире, йогынтысы турыдан-туры булмаган, башка элементларны активлаштыра торган. *Кыек ашлама* // Читләтеп эшләнгән, нинди дә булса шартларга бәйле рәвештә салынган. *Пётр I патшалык иткән чорда, туры һәм кыек салымнар биш ярым тапкыр арта ---.* И.Гафаров

5) *лингв.* Баш килешкә карамаган, баш килеш булмаган (килешләр тур.)

6) *куч.* Начар, шелтәле, авыр; дөрес түгел, иҗтимагый таләпләр белән ярашмаган. *Әткәйнең әнкәйгә ялгыш кына кыек сүз әйткәнен белмим мин.* Б.Камалов. *[Мәрҗия әби:] Юк, юк, улым, берсе хакында да кыек сүз әйтә алмыйм.* Ә.Сафиуллин. *Кыек юлда йөргәнемне сизенгән иде лабаса ул.* В.Нуруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Чалыш, авыш, кәкре итеп. *[Чалбар төймәмне] Инде тагып бетердем дисәм, кыек тагылган бит.* А.Алиш

2) *куч.* Гадел булмаганча, бозык, ялгыш. *Саескан туры очса да, кыек яшәр.* Мәкаль

**3.** *и. мәгъ.* Дөрес булмаган нәрсә. *Аннары, тормышның бөтен кыегын сиңа гына турайтырга, сиңа гына төзәтергә димәгән ич?!* М.Хуҗин // Гаеп, кимчелек. *Рәсемнең берәр кыегы булса, башың белән җавап бирергә тиешсең бит.* В.Нуриев

◊ **Кыек авыз** Гайбәтче. **Кыек атып туры тидерү** Читләтеп әйтеп үз фикереңне җиткерү, белмичә әйтеп дөресенә туры килү. *Сукыр аучы кыек атып туры тидергән төсле.* Әйтем. *«Кыек атып туры тидерүләр» Булгалый шул кайчак... булгалый.* Х.Туфан. *Ләкин [Равил] кыек атып туры тидергән булып чыкты.* В.Нуруллин. **Кыекка саплау** 1) Булсынга эшләмәү; 2) Уңай сүзне бозып, кире мәгънәгә борып аңлау яки сөйләү. **Кыек килмәү** Туры килү. *Әмма һәр җирдә тугры килгән «яшьлек – юләрлек» мәкале безнең бала козгынга да кыек килмәде.* Г.Тукай. **Кыек көзге** Чынлыкны, дөреслекне бозып күрсәтә торган нәрсә. *Билгеле бер чорны идеологик яктан тәэмин итүче күрсәтмәләр белән эш итү әнә шулай әдәбиятның кыек көзге булуына китерде.* Ф.Галимуллин. **Кыек көзгедә күрү** Ялгыш аңлау. **Кыек куллы** Урлашучан. *Кыек куллы, пычак күзле, үз мәнфәгатьләре өчен бүтәннәрне бугазлап ыргытырга әзер торучыларны власть үзе эзләп тапты.* А.Гыйләҗев. **Кыек күз белән карау** 1) Шикле итеп, шөбһәле итеп карау; 2) Читләтү, үз итмәү; игътибарсыз булу. *Рус мәктәпләрендә укыган кешеләргә кыек күз берлән карау азая башлады.* Г.Исхакый. **Кыек күрү** Нәрсәне дә булса начар дип санау, начарга чыгару. *Сез менә каныгу дисез. Мин бу сүзне болай аңлыйм: әгәр берәүгә каныкса, ул аның яманатын сатып йөри, аның һәр эшен кыек күрә, җай чыккан саен аңа бәйләнә.* Ә.Еники. **Кыек сукмак** *к.* **кыек юл**. **Кыек эш** Начар, гадел булмаган эш. *Күпме гомер итеп, әтәсенең дә, әнәсенең дә бер кыек эшен дә хәтерләмим.* М.Вәлиев. *Ни өчен кыек эшне фәкать Елан гына башкара ---?* С.Шәмси. **Кыек юл** Бозык юл, ялгыш юл; бозык тормыш. *Чөнки Ханәфи көн саен сәрхуш кайта, кыек юлдан чыга алганы юк, һәм болар барысы да ана кешегә ишетелеп тора.* В.Нуруллин. *Кыек юлга кереп киткән ир экзотик җәнлекләр, кошлар белән кызыксына башлады.* Безнең гәҗит

**КЫЕКБАШ** *и. этн.* 1) Ике яктан да очлары кыеклап киселгән таякчыкны, очына икенче таякчык белән сугып очырып, түгәрәккә кертүдән гыйбарәт балалар уены

2) Бу уенда кулланыла торган ике ягы да очлы таякчык, чүрәкәй

**КЫЕКЛАНДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **кыегайту**

**КЫЕКЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **кыегаю**

**Кыеклана бару** Торган саен ныграк кыеклану

**Кыеклана төшү** Бераз кыеклану

**Кыекланып калу** Ахырда кыек хәлне саклау

**Кыекланып китү** Бераз кыеклану. *Һава тын, завод трубаларыннан кара төтеннәр әкрен генә тузылып, кыекланып китә иделәр.* Ш.Камал

**Кыекланып тору** Кыек хәлдә булу

**КЫЕКЛАП** *рәв.* 1) Нинди дә булса яссылыкка авышлык яисә почмак ясап. *Ишектән кыеклап сузылган кояш нурлары күчеп йөриләр.* К.Нәҗми. *Тагын бераз гына барсалар, менеп тә җитәчәкләр. Ташлы яр, кыя турын кыеклап үтәсе дә...* Н.Хәсәнов. *Көчле агым аны кыеклап бик тиз теге ярга алып чыкты.* Я.Зәнкиев

2) Өчпочмаклап, өчпочмак ясап. *Яулыкны кыеклап бәйләү*

3) *куч.* Турыдан-туры әйтмичә. *Бусы [Линар сүзләре] инде кыеклап Алтынчәчкә дә бәрелгәндәй булды.* М.Маликова

**КЫЕКЛАТА** *рәв. сөйл. к.* **кыеклап**. *«Мин – кара фил, син – ак фил, – ди. – Әйдә, йөр», – ди. Хәтәр җирдән алып чыкты кыеклата, «Диагональләр теориясен яхшы бел», – ди!* Ш.Мөдәррис

**КЫЕКЛАТУ** *ф.* **1.** Кыек, авыш итү. *Зәңгәр конвертның тышында эре хәрефләр белән кыеклатып язылган адрес.* Г.Бәширов. *Пропеллерның калаклары кыеклатып ясалганга күрә, әйләнгән чакта ул һаваны бораулап, көрәп артка ташлый.* С.Баттал

**2. кыеклатып** *рәв. мәгъ. к.* **кыеклап**. *Кыеклатып искән әче җилгә каршы асфальт юл белән атлады ул.* Э.Касыймов. *[Мари Ковалы] --- хатын-кызлары итәкләре һәм изүләре чигелгән күлмәкләрен ике чугы бер якка асылынып торган билбау белән буган, кыеклатып ачык төстәге яулык бәйләгән.* А.Вергазов. *Амбарга төнге эшкә чаккач та, ерак басуда тары кишәрлеген утаганда да, читләтеп, кыеклатып, яшь, чибәр киленчәк белән кети-мети уйнарга теләге барлыгын аңлатырга маташып карады.* Р.Мулланурова

◊ **Кыеклатып әйтү** Турыдан-туры әйтмичә, читләтеп, киная белән әйтү. **Кыеклатып карау** Шик белдерү, ышанып бетмәвен сиздерү. *Кыеклатып карама, алдамадым, бер тәңкәңне генә алдым.* Р.Вәлиев. *[Миңнурый] Газинурга ачулы күзләре белән кыеклатып карап алды.* Г.Әпсәләмов. **Кыеклатып турыдан җибәрү** Астыртын эшләү. *[Кәримҗан:] Син башка якларны да кыеклатып турыдан җибәргәнсеңдер әле, мөгаен?..* А.Гыйләҗев

**Кыеклатып алу** Бераз кыеклату

**Кыеклатып җибәрү** *к.* **кыеклатып алу**

**Кыеклатып тору** Әле, сөйләү моментында кыеклату

**КЫЕКЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Кыек ясау, кыек итү. *Буровой вышкаларын тәгәрмәчләр куеп, рельстан тәгәрәтеп йөриләр, скважиналарны кыеклап бораулыйлар.* Ш.Бикчурин. *Чәчәкне кыеклап кисү кулайрак.* Серле календарь

2) *к.* **кыегаю** (*2 мәгъ.*)

**Кыеклап җибәрү** Бераз кыеклау

**Кыеклап китү** Кинәт кыеклау. *Авып барган озын чыршы, кыеклап китеп, төбе черек булган каен өстенә килеп төшә ---.* Н.Хәсәнов

**Кыеклап тору** Әледән-әле кыеклау

**Кыеклый башлау** Кыекларга тотыну. *Тормыш юлы бер кыеклый башласа, аны турайту кыен була дип укыганым бар.* С.Рәфыйков

**КЫЕ́К-МЫЕК** *с.* **1.** 1) Кыек, чалыш-полыш, билгеле бер яссылыкка карата туры булмаган, төрле юнәлештәге. *Кыек-мыек эшләпә, Хакын бирми эшләтә.* Такмак. *Язган чакта хәрефләрем дә кыек-мыек булып чыга.* Н.Дәүли

2) *куч. к.* **кыек** II (*3, 4 мәгъ.*). *– Әйтеп тә бакма син миңа андый кыек-мыек сүзләрне, – диде Нәби ---.* Р.Төхфәтуллин. *Ул – утны-суны кичкән адәм, Вилсурның кыек-мыек шөгыльләре буенча уң кулы.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Чалыш-полыш итеп; туры булмаган, төз түгел. *Кыек-мыек аткан, боерык тыңламаган шул бер мең чамасы ир белән сине, үземне, туганнарымны, бар байлыгымны мин ничек саклармын да ничек якларрмын?* Н.Фәттах

2) *куч.* Туры җаваптан качып, дөресен әйтмичә. *Мин алай кыек-мыек сөйләшергә өйрәнмәгән...* Н.Хәсәнов

**3.** *и. мәгъ.* Гадел булмаган эш(ләр). *Мөмкин булган чакта ул кыек-мыекны тирәләп узу, кагылмау ягын карый.* Р.Хафизова

◊ **Кыек-мыек сөйләү** *к.* **кыеш-мыеш сөйләү**. *Банкет булмаса, артистлар кыек-мыек сөйләгән килеш кайтып җитәселәр иде.* К.Кәримов. **Кыек-мыек сүз** *к.* **кыеш-мыеш сүз**

**КЫЕ́К СӨЙЛӘМ** *и. лингв.* Үзгәртеп кулланылган чит сөйләм. *Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерүдә төп өч очрак бар.* М.Зәкиев

**КЫЕ́К ТӘМАМЛЫК** *и. лингв.* Процесска турыдан-туры катнашы булмаган әйберне, күренешне белдергән тәмамлык (гадәттә күчемсез фигыльгә ияргән сүзләр белән белдерелә). *Бу очракта да төрле килештәге исемнәр субъект мөнәсәбәтен белдерәләр, ә синтаксик яктан алар кыек тәмамлык булып киләләр.* Ф.Хисамова

**КЫЕКЧА** *и. сөйл.* **1.** Өчпочмак формасындагы кечкенә яулык; кыек яулык, косынка. *Капчык өстендә башка бәйләр өчен ак кыекча, битлек, бала чүпрәге зурлыгындагы клеёнка [ята].* М.Маликова. *Дикопольцев --- эсэсовчылар урынына башына кызыл хач төшерелгән ак кыекча бәйләгән түгәрәк йөзле яшь хатынны күреп, гаҗәпләнеп калды.* Г.Кашапов. *[Яшь хатын] Үзе яланбаш, муенына чәчәкле кыекча салган.* З.Фәтхетдинов

**2.** Өчпочмак формасындагы. *Башына бәйләгән җете ак кыекча яулыгы бик килешеп торганын күрде [егет].* Х.Камалов

**КЫЕЛУ** *ф.* **1.** 1) Кыйпылу, киселү, кыеп алыну. *Текә кыя да кыелган...* Л.Шагыйрьҗан

2) Югалып калу, каушап китү

3) Һәлак булу, кырылу, юкка чыгу. *Кан җыелып хасил булмаганмы Нефть атлы сыек ябышкак? Шул урынга мулдан җыелган ул, Кайда күпләп халык кыелган.* И.Гыйләҗев

4) *сир.* Беленү, яралу (таң тур.). *Таң кыелгач, аккош көтүе кебек, Ак томаннар килеп чорнала.* Ә.Ерикәй

**2. кыелган** *с. мәгъ.* Кыйгач, сызылып киткән. *Өзгәләнеп калтырана Кыелган каш ---.* Р.Бикбаев

**Кыелып бару** Бер-бер артлы кыелу. *Еллар арты еллар кыелып бара. Нидер кала бездән дөньяда...* К.Булатова

**Кыелып бетү** Бөтенләй кыелу. *Пулялар белән кыелып беткән зәңгәр кыңгырау чәчәкләргә гаҗәпләнеп карап тора иде.* И. Гази

**Кыелып китү** Кинәт кыелу. *Кайчакта алар [атлар] өркеп тә, кыелып та китәләр.* Ш.Әхмәдиев

**Кыелып тору** Кыелган булу. *Әниемнең борыны туры, күзләре бәрхет төсле кара, кашлары күмер белән сызгандай кыелып тора.* Г.Якупова

**Кыелып төшү** 1) Авып китү, егылу. *Немецлар өчесе дә, чалгы белән чапкан сабак төсле, кыелып төштеләр.* Х.Камалов

2) Кинәт югалып калу. *Зифаның чалгы йөзенә эләккән үлән төсле кыелып төшкәнен сиземләде бугай, бу юлы да Мәгубә үз вакытында ярдәм кулын сузды.* В.Имамов

**КЫЕН** с. **1.** 1) Башкару, үтәп чыгу өчен көч, тырышлык һәм зур хезмәт сорый торган. *Бик беләмен: хәреф тезү – кыен бер эш, Кыен эшләр җиңеләя, булсаң тырыш.* Ш.Бабич. *Күп разведкаларда аеруча кыен заданиеләрне Попов үти.* Ә.Айдар. *Әйе, кеше булып туган кешегә бөтен гомере буе кеше булып калу һәм, ниһаять, кеше булып дөньядан китү – шактый кыен эш.* Ф.Шәфигуллин

2) Аңлау, төшенү яисә чишү өчен зур акыл көче, зиһен сорый торган. *Бүген мин әллә нинди саташулы бер кыен йокы эчендә начар төшләр күрдем.* Х.Сарьян. *Кыен мәсьәлә*

3) Җайсыз, читен, уңайсыз, ипсез. *Буш арбаны икәүләп тартып баруы кыен гына ул.* И.Сирматов. *Мостафин ике ут арасында калган кебек иде --- һәм ул шушы кыен хәлдән чыгу өчен тиз-тиз сөйләргә тотынды.* Х.Камалов. *Болар барысы да мине бик кыен хәлгә куйды.* М.Вәлиев. *Без монда шактый кыен хәлдә калдык бит әле.* Ф.Галиев

4) Авырлык, кайгы-хәсрәт, мохтаҗлыклардан гыйбарәт. *Дөнья булгач, төрле хәлләр була, Аерылудан кыен хәлләр юк.* Җыр. *Сугыштан соң бөтенебез өчен Кыен иде, белә бер Ходай.* Г.Сәгыйров

5) Шартлары уңайсыз, мөмкинлекләре чикләнгән; кулай түгел, читен. *Урманнар, сазлар, таулар һәм исәпсез-хисапсыз күлләр, елгалар белән капланган Карелия җире сугыш операцияләре алып бару өчен иң кыен урыннарның берсе санала.* Г.Әпсәләмов

**2.** *и. мәгъ.* Авырлык, читенлек, кыенлык. *Бала чакта Йосыф бер төш күргән иде --- аннары күп кайгы-хәсрәт чиккән иде – төрле-төрле кыеннарга тарып имди.* Кол Гали. *Бер куәтләү сүзе Илнең миңа Йөз кыенны җиңәрмә терәк.* Ф.Галиев. *Белегез: хатын-кызлар кыен килгәндә җебеп төшкән ирләрен аямыйлар, кичермиләр, йомшаклыкны гафу итмиләр.* А.Гыйләҗев. *Аның ни кыены булсын!* А.Иванов

**3.** *хәб. сүз функ.* Авыр, читен. *Кыен миңа: сүнми йөрәгемдә ялкыннары үткән назларның.* Г.Сәгыйров. *Кешегә үз асылыңны аңлату кыен шул.* Н.Гыйматдинова. *Бу аның чын исемеме, юкмы – әйтүе кыен.* Г.Әпсәләмов

◊ **Кыен ашау** Кыйналу, җәберсетелү; авырлыкка дучар булу. *Ләкин ул [Сабира] тыела алмады, иреннән ашаган кыеннарын, әрнүләрен башкалар өстенә түгә торган булды.* Г.Ибраһимов. *Тотсалар – [балалар] кыен ашадылар, тотмасалар – шатландылар.* Г.Кашапов. *Шуның аркасында [Йомабикә] иреннән яхшы сүз ишетмәде, гомере буе кыен ашады.* Я.Зәнкиев. *Никадәр кыен ашасам да, яшьли буразна арасына тәгәрәп керсәм дә, мин – күңелемә авыл турында олы уйлар төяп, олы юлга чыккан кеше.* А.Гыйләҗев. **Кыенга туры килү** Башкарып чыгуы авыр булу, читенгә әйләнү. *Ярдәмчесез кыенга туры килә бит.* А.Иванов. *Балаларны укырга йөртү генә кыенга туры килер иде килүен, чөнки станциядән шәһәргә тикле ара – егерме миль.* А.Тимергалин. **Кыен күрү** *к.* **кыен ашау**

**КЫЕНАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **кыенлаштыру**. *Ә бу [фрагментарлык] истә калдыруны кыенайта, редакторга да, укучыга да үзләштерү процессын авырайта.* М.Вәли-Барҗылы

**Кыенайта бару** Торган саен ныграк кыенайту

**Каенайта төшү** Бераз кыенайту

**Кыенайтып тору** Гел кыенайту

**КЫЕНАЮ** *ф.* Кыен булып китү, читенләшү, авырлашу. *Хәлләр кыенаю*

**Кыенаеп калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң кыенлык барлыкка килү

**Кыенаеп китү** Кинәт кыенаю

**Кыенаеп тору** Әледән-әле, торган саен кыенаю

**Кыеная бару** Торган саен ныграк кыенаю

**Кыеная төшү** Бераз кыенаю

**КЫЕ́Н-ҖӘБЕР** *җый. и.* Һәртөрле кыенлыклар, җәберләүләр. *Моңа хәтле үз башына төшкән барлык кыен-җәберенә тешен кысып эндәшми түзгән Павел Демидов шунда тыелып кала алмады ---.* А.Иванов

**КЫЕНЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **кыенлашу**

**Кыенлана бару** Торган саен ныграк кыенлану

**Кыенлана төшү** Бераз кыенлану

**Кыенланып тору** Әле, хәзер, бераз кыенлану

**КЫЕНЛА́У** *ф.* Кыен итү. *[Ваһим:] Торсын. Кыенламый. Хет тонналы нәрсә асып куй – бөгелмәячәк.* М.Хуҗин

**Кыенлап җибәрү** Кинәт кыенлау

**Кыенлап тору** Даими кыенлау

**Кыенлый төшү** Бераз кыенлау

**КЫЕНЛАШТЫРУ** *ф.* Читен итү, авырлаштыру, кыен хәлгә китерү. *Татарның киләнәкле (традицион) көнкүреше, --- аның азчылык булып читкә, ят халыклар арасына сибелүе һәм тарихи ватанында да шәһәрләрдә күпчелек тәшкил итә алмавы табигый никахларга керү мөмкинлеген бик нык кыенлаштырды ---.* Т.Әйди. *Дөресен генә әйткәндә, йон катлавы аларның [тюленьнәрнең] суда хәрәкәтләнүен кыенлаштыра.* Хайваннар турында очерклар

**Кыенлаштыра бару** Торган саен күбрәк кыенлаштыру

**Кыенлаштыра төшү** Бераз кыенлаштыру

**Кыенлаштырып бетерү** Тулысынча, бөтенләй кыенлаштыру

**Кыенлаштырып җибәрү** Көтмәгәндә, бераз кыенлаштыру

**Кыенлаштырып килү** Электән үк, даими кыенлаштыру. *Халыкның состав ягыннан үзгәрүчән булуы аны һәр илдә нинди киңлектә, нинди күләмдә күрү мәсьәләсен кыенлаштырып килде.* К.Гыйззәтов

**Кыенлаштырып тору** Әледән-әле, даими кыенлаштыру

**КЫЕНЛАШУ** *ф.* 1) Берәр эшне башкару авырлашу, тоткарлыклар барлыкка килү. *Мал курмысы табу бик кыенлашты.* М.Мәһдиев. *Эшкә, хезмәт дисциплинасына контроль ясау кыенлаша.* Казан утлары. *Соңга калганга, авыруны дәвалау бермә-бер кыенлашкан була.* Иң шәп календарь

2) Кыенлыклар булу, кыенлыклар күбәю, авырлашу. *Туры сүзле, намуслы кешеләргә яшәү нык кыенлашты ---.* А.Гыйләҗев

3) Авыр хәлгә төшү, начарлану. *Икенче май көнне аның [Фәрзинең] хәле аеруча кыенлашты.* Г.Кашапов

**Кыенлаша бару** Торган саен ыграк кыенлашу. *Кызганычка каршы, эчендәге серләрен актарып салгач та, ул көткән бушану килмәде, киресенчә, аңа көнләп түгел, сәгатьләп кыенлаша барды.* Г.Кашапов. *Ә менә елга «сәяхәтчеләренә» юллар ел саен кыенлаша бара.* Кызыклы ихтиология. *Халыкка терлек асрау кыенлаша бара.* Мәдәни җомга

**Кыенлаша башлау** Кыенлашуы сизелү; кыенлашырга тотыну. *Үземне үзем тоту кыенлаша башлый.* Г.Бәширов

**Кыенлаша төшү** Тагын да кыенлашу; бераз кыенлашу. *Җитмешенче еллар ахырында, белүемчә, һәм рухи, һәм матди хәлегез тагын да кыенлаша төшкән ---.* Р.Юсупова

**Кыенлышып бару** *к.* **кыенлаша бару**. *Бер бездә генә түгел, бөтен Көнчыгыш фронтта хәлләр кыенлашып бара.* В.Нуруллин

**Кыенлашып килү** Кыенлаша башлау; акрынлап, аз-азлап кыенлашу. *Гаиләнең матди хәле кыенлашып килүгә карамастан, Мирсәетнең әле даими эшләгән урыны юк.* Р.Мөхәммәдиев

**Кыенлашып китү** Көтмәгәндә бераз кыенлашу. *Соңгы вакытларда тамак авыруы көчәеп китүе сәбәпле, театрда артист булып уйнавы кыенлашып киткән Габдулла Кариев Саттар ролендә чыгыш ясаган.* Г.Исхакый

**КЫЕНЛЫК** *и.* 1) Кыен (*1, 2 мәгъ.*) булу. *Сөйләшү кыенлыгы бетте диярлек, кан басымы гадәти хәлгә кайтты.* Б.Камалов. *Калада яшәп тә, аның сыман мал-туар асраучылар белә ул кыенлыкны.* Ж.Рәхимов

2) Авыр хәл, авырлык. *Патрон белән снаряд юклык безгә зур гына кыенлык ясый, шуңа карамастан сугышчыларның күңелләре күтәренке.* Ш.Усманов. *Төрле кыенлыклар аркасында бәхетеңә соңга калма.* Г.Сәгыйров. *Беренче кыенлык чыгуга чигенергә ашыкмыйк әле.* Казан утлары

**КЫЕНСЫНУ** I *ф.* 1) Читенсенү, тартыну, оялу. *Шулай да, кызлар кергәч, Дәүләкәндә нинди үзгәрешләр булганын менә хәзер мин язарга кыенсынам.* Ә.Еники. *Карт кыенсынып кына бүреген салды, бүреккә ияреп чыккан түбәтәен төзәтеп киде ---.* М.Мәһдиев. *Стенада тора ул көйләгән сәгать, ятим калган өйнең вакытын кыенсынган кебек тып-тын саный, сугулары да бик акыртын.* М.Галиев. *Әмма егетләр бу кишәрлекне бүген ничек тә бетерәсе иде дип тырышалар, халыктан кыенсынмыйча күңел ачып йөрүчеләргә ачулары да килә.* М.Вәли-Барҗылы

2) Берәр эшкә батырчылык итмәү, эшләргә теләмәү, авырсыну. *Ләкин Фидаил абый --- сөйләшеп торганда, кеше китмичә, беренче булып үзе китәргә кыенсына иде.* Х.Сарьян

3) Кыенлык сизү, кыенлык күрү. *Кыенсынып яшәү*

**Кыенсына башлау** Кыенсынырга тотыну. *--- күрәләтә ямьсез бер кызга Гүзәл дип әйтергә кыенсына башлыйсың.* Х.Сарьян

**Кыенсына бирү** Кыенсынуын дәвам итү. *Алар өчен Нажар кыенсына икән, кыенсына бирсен ---.* Ә.Баян

**Кыенсына төшү** Бераз кыенсыну. *Шунда икенчесе кыенсына төшеп җавап бирде: – Анда безне кыерсыталар.* Н.Хәсәнов

**Кыенсынып йөрү** Күп вакытлардан бирле кыенсыну кичерү. *Саттар улым, син кыенсынып йөрмә, бар.* Э.Яһудин

**Кыенсынып калу** Көтмәгәндә, кинәт кыенсыну кичерү. *Мин җавап бирергә кыенсынып калдым.* Х.Сарьян

**Кыенсынып китү** Ниндидер сәбәптән кинәт кыенсыну. *[Кәшшаф] Кыенсынып та китте.* М.Әмирханов. *Аны [Сиражины] эштән туктатуы өчен, Ирек кыенсынып китте.* Ф.Садриев. *Зәйтүнәне күргәч, ул [Әзһәр] кыенсынып киткәндәй булды, арткарак чигенде ---.* М.Маликова

**Кыенсынып кую** Бераз, кыска вакытка кыенсыну кичерү. *Хәзер искә төшкәндә дә шул сүзләре өчен оялып, кыенсынып куя [Мәрьям].* М.Маликова

**Кыенсынып тору** Бераз вакыт кыенсыну. *[Килгән кешеләр] Ишектән кергәч түргә узарга кыенсынып торырлар.* Ф.Шәфигуллин. *Мин сезне үзем чакырырга теләсәм дә, кыенсынып тора идем.* В.Нуруллин. *Урлап алганда кыенсынып тормагансың бит.* Ф.Яруллин

**КЫЕНСЫНУ** II *и.* Оялу, читенсенү, тартыну хисе. *Оялу да, кыенсыну да, бу миңа үпкәләмәде микән, дигән шик әсәре дә юк иде бугай анда.* М.Маликова

**КЫЕНСЫТУ** *ф.* Оялту, тартындыру, читенсендерү. *Бәлки, әнә шул ят күз карашлары аларны кыенсытып, телләрен бәйдә тотадыр?* А.Гыйләҗев

**Кыенсытып алу** Бераз кыенсыту

**Кыенсытып тору** Вакытлыча, әлегә кыенсыту

**КЫЕРЛА́У** *ф. диал.* 1) Кимерү; тешләү. *[Кәҗә] Алгы аяклары белән коймага таяна да, сузылып, чаган яфракларын кыерларга керешә.* М.Галиев. *Төнлә бүре килгән! Малларны кыерлап киткән...* М.Галиев

2) *күч.* Нык итеп сүгү, ачулану. *Шуннан соң [яшь артистларның хокуклары турында байтак сөйләгәннән соң] тотындылар олы артистлар безне кыерларга ---.* Р.Батулла

**КЫЕРСЫТУ** *ф.* Кимсетү, рәнҗетү; читкә кагу. *Аның [әбинең] кайчан да булса бер кул күтәреп безне кыерсытканын хәтерләмим мин.* Г.Сәгыйров. *Их, абыем булса, мине болай кыерсытмаслар иде.* М.Маликова. *[Дания]: Авыр сүзне яра диләр дөрләп янган йөрәккә, дигәндәй, Кәрим абый, алай кыерсытмагыз әле, пожалысты...* Б.Камалов. *Мин аны, ул мине кыерсытмый: безнең арада тулысынча хөрлек, туганлык!* Р.Низамиев

**Кыерсыта башлау** Кыерсытырга тотыну. *Абыйлар мине чүт кенә кыерсыта башласалар да, әләкләргә әни янына йөгерә торган идем.* А.Гыйләҗев

**Кыерсыта төшү** Бераз кыерсыту

**Кыерсыта калу** Кыерсыту очрагы булу. *Баламны кыерсыта калсалар ни хәлләр итәрмен, дигән уй тоташ тукып торды.* Б.Камалов

**Кыерсытып бетерү** Бик нык кыерсыту. *[Карлыгач (ат)] Картаеп та килә, берәр рәхимсезенә эләгеп, кыерсытып кына бетермәсәләр ярар иде.* Ф.Шәфигуллин

**Кыерсытып йөрү** Озак вакытлар дәвамында һәрберсен кыерсыту.

*Гөнаһлысын да, гөнаһсызын да кыерсытып йөрисең икән.* Р.Батулла

**Кыерсытып тору** Әледән-әле, еш кыерсыту. *Аның [төпчекнең] бу юлы да бераз иркәләнәсе килгәндер. Чөнки абыйлары да гел кыерсытып кына торалар бит үзен.* А.Хәсәнов

**КЫЕРСЫТУЛЫ** *с.* Кыерсыта торган. *Тел күтәреп кыерсытулы сүз әйтмәде ул ---.* Б.Камалов

**КЫЕРЧЫК** *и.* 1) Икмәкнең читеннән башлап кисеп алынган зур телем; ипи кисәге. *Суга чылаткан ипи кыерчыгы ыргыткач алмады, канлы ит кисәгенә риза булды.* Ә.Гаффар. *[Куян күчтәнәченең] Өйдән алып киткән чәй, өйдән алып киткән ипи кыерчыгы икәнен дә беләм югыйсә, ә барыбер тәме икенче.* М.Галиев. *Капчыкта – Тукай, Такташ китаплары, бер кыерчык ипи һәм чүлли шешәсенә тутырган сары май.* А.Гыйләҗев

2) *диал.* Икмәк салганда, күәс төбендә калган камырны җыеп пешерелгән кечкенә ипи

**КЫЕШ** *с. сөйл. к.* **кыек** II. *Кыеш агачның ботагы да туры булмас.* Мәкаль. *Җиде-сигез метрдан артмаган, кыеш иданле бүлмә уртасында киң итәкле марҗа булып акшарлы мич утыра ---.* А.Гыйләҗев

◊ **Кыеш ката** *мыск.* Бушка йөрүче кеше

**КЫЕ́Ш-МЫЕШ** *рәв.* **1.** *к.* **кыекмыек.** *Аның --- хәрәкәтләре һаман да элеккечә, кыеш-мыеш килеп торган җил тегермәнен хәтерләтә.* Ф.Яхин. *Күрче, зинһар, авызын кыеш-мыеш китереп, «кырык яшь» дип торуларын гына күр!* М.Хәсәнов. *Бүлмәсендәге әйберләр, тәрәзәләр рәшә эчендәге кебек кыеш-мыеш килеп төтәделәр дә юкка чыктылар.* Ф.Садриев

**2.** *и мәгъ. күч.* Хилаф эш. *Мәгәр аның [Мөхәммәтнең] кыеш-мыешлары җитәрлек.* Я.Зәнкиев. *Кемнән яшерәсең инде кыеш-мыешларыгызны?* Н.Гыйматдинова

◊ **Кыеш-мыеш йөрү** 1) Бик үк дөрес булмаган эшләр эшләү; 2) Эшен, бурычларын өстән-өстән генә үтәү, тырышлык күрсәтмәү. *Ашыгу-кабалану аркасында, коллективка очраклы кешеләр дә килеп эләкте, элкен-селкен, кыеш-мыеш йөрүләр күренгәли башлады ---.* Җ.Рәхимов. **Кыеш-мыеш сөйләү** Килешсез, тиешсез сүзләр сөйләү; уен кушып сөйләү. *Кыеш-мыеш сөйләгән булып, баланың башын катырасың.* Ш.Камал. **Кыеш-мыеш сүз** Килешсез сүз, төрлечә аңлашыла торган сүз. *[Фәйзи:] Һичбер андый-мондый кыеш-мыеш сүз булмады.* Ш.Камал. **Кыеш-мыеш юл** 1) Бик үк туры булмаган алым, бик гадел булмаган юл; 2) Читләтеп, астыртын йөрткән эш. *Тик ул турыда кыеш-мыеш юлларга кермичә, мәсьәләне турыдан-туры ачып салу кирәк иде.* Ш.Камал

**КЫЕШУ** *ф.* 1) *сөйл. урт. юн. к.* **кыю** II

2) *диал.* Бәхәсләшү, ачуланышу. *Ир белән хатын иртәнчәк кыешалар, кичтән сөешәләр.* Мәкаль. *Галимҗан, Оренбургка җыелган башкорт корылтаена барып, милләтче Зәки Вәлиди белән дә кыешып кайтты.* И.Рәмиев

3) *диал.* Алыш-биреш вакытында сатулашу, бәя турында бәхәсләшү

4) *диал.* Маташу. *Юк белән кыешма*

**Кыешып алу** Бераз кыешу

**Кыешып китү** Кинәт, көтмәгәндә кыеша башлау

**КЫЖРА́У** *ф. сөйл.* 1) Берәр эшне эшләргә бик нык омтылу, дәртләнеп тору, бик нык теләү. *[Гөлҗиһан:] Син өйгә кайтып кергәннән бирле нидер әйтергә кыжрыйсың.* А.Расих

2) *күч.* Теш шыкырдату, теш кайрау. *Чын чәчән теш кыжраганда сүз башлар.* Мәкаль

**Кыжрап алу** Бераз, аз гына кыжрау. *Казанлыларны туктатырга кыжрап алгалыйлар алуын, тик куллары кыска.* М.Әмирханов

**Кыжрап йөрү** Нәрсәдер эшләргә планлаштыру. *Соры болытлар --- нәкъ аның сугылып бетмәгән эскертләренә яварга кыжрап йөриләр кебек.* Г.Бәширов. *Ике-өч малай сафка басмаган, бер кырыйда турник тирәсендә ниндидер күнегүләр ясарга кыжрап йөри иделәр.* К.Миңлебаев

**Кыжрап килү** Күптәннән, әллә кайчаннан кыжрау. *Сакчыларны, ук атарга кыжрап килгән ат караучыларны күлнең таллар, гөлҗимеш, балан, карлыган куаклары каплаган башына җибәрделәр.* В.Имамов

**Кыжрап кую** Кинәт кыжрау. *--- балалык ашкынуы белән залимнәрне, кан коючыларны пыран-заран китереп, тузгытып ташларга кыжрап куя.* М.Җәлил

**Кыжрап тору** Ниндидер эшкә ашкыну. *Иргалинең түземсезләнеп, кыжрап торуын абайлапмы, кичекмәстән, хәзер үк Гөлниса янына барып килергә кушты.* М.Хәсәнов

**Кыжрый башлау** Кыжрарга тотыну. *--- денсез кешенең өч бармагы берләшеп, маңгайга кунып алырга кыжрый башлыйдыр...* Р.Зәйдулла

**КЫЖЫ́Р-БЫЖЫР** *и. сөйл.* Төрле күңел ачулар. *Егерме яшькә җитеп, кичке уеннар, биюләр, клублар --- кыжырбыжырлар белән артык мавыгып китә алмаган Гәүһәрия --- үзен хиссез кеше дип саный.* А.Гыйләҗев

**КЫЗ** *и.* 1) Хатын-кыз җенесендәге бала. *Кечкенә кыз Фагыйлә арды, кояштан тирләп, кызарынып бетте.* Г.Ибраһимов. *Минем әби әйтә, ул инде без чәчби кыз чакта ук карчык иде, ди.* Р.Зәйдулла

2) Үзенең ата-анасына карата хатын-кыз җенесеннән булган бала. *Кызым, сиңа сөйлим, киленем, син тыңла.* Мәкаль. *Ата улны белмәде, Ана кызны белмәде, Кем урдасы кем якта – Явыр явын белмәде.* Дастан. *[Шәйхел:] – Шаһвәли бабай, син миңа кызың Мәрхәбәне бир! – диде.* Г.Ибраһимов. *[Гайшә:] Кызымны да шәһәрдә әйбәт эшкә кертәлсәм, тормыш төрле яктан түгәрәкләнә, Ходай кылса.* С.Поварисов

3) Җенси яктан өлгергән, ләкин әлегә кияүгә чыкмаган хатын-кыз. *Монда бытбылдык, тургай тавышлары аның кыз вакытта үзенең тиңдәшләре белән урак урып, печән җыйнап йөргән заманнарын искәртә иделәр.* Ш.Камал. *Өмәгә җыелган кызлар, суелган казларның йоннарын йолкып, түшкәләрен көянтә башларына элделәр дә, инеш буена төшеп, әйбәтләп юып-чистартып менделәр.* М.Галәү. *Гүя ул [Акъәби] ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын*

*чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.* Ә.Еники

4) Кияүгә чыгучы кыз; кәләш. *– Ярый алайса! Аллага тапшырып, башлыйбыз, кызның, кияүнең вәливәкилләре хәзердер бит, – диде [ахун].* Г.Ибраһимов. *Әйт әле: сезнең авылда кияүгә чыгасы кызны ничек киендерәләр?..* М.Галәү. *Самавыр кебек нәрсәне кияүгә чыгучы кызга гына илтәләр түгелме соң?* Ә.Еники

5) Кызлыгын, гыйффәтен югалтмаган хатын-кыз, бакирә, бикер, гафифә. *Кылый булса да кыз булсын.* Мәкаль. *Кучкар аның [Филисәнең] кыз булуын шарт итеп куймаган иде дә. Утыздан узган гүзәл бөтен була ала микәнни?* Р.Батулла. *Китәрсең дә барырсың кук, Бибинур... Шулай икән, кыз килеш кит.* А.Гыйләҗев

6) **кызым** *тарт. форм.* Өлкән яшьтәге кешенең кызы булырлык яшь хатын-кызга иркәләп эндәшү сүзе. *Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.* Ә.Еники. *[Миңлекамал:] Ни булды, бабай? [Шәвәли:] Әй кызым, кызым, картлык шатлык түгел дип, белми әйтмәгәннәр икән шул ---.* С.Поварисов // **кызлар** *күпл.* «Иптәшләр», «дуслар» мәгънәсендә үзара эндәшү сүзе. *Ул учак янында гитарага җырлап утырулар дисеңме, ул биюләр, ул сөйләшүләр... шундый романтика анда, кызлар, шундый романтика!!!* Х.Ширмән. *Өстәлләрне күрсәгез, кызлар, исегез китәр!* Безнең гәҗит

7) *иск. сөйл.* Фахишә, бозык, уйнашчы хатын. *Җиңгәчинең төне буе бар кызлары Хаҗи байны сый итәләр төрлечә.* Г.Тукай. *Бай абзыйның акчасы күп, Рәхәт тора кызлар кочып.* Н.Исәнбәт // Сөяркә. *Байлар эчәләр, тарталар, карта уйныйлар, бишәр җирдә матур кыз асрыйлар.* Г.Ибраһимов. *[Хан] --- гәрчә хатыны ханбикәне яратса да, читтә кызлар асрый иде.* М.Хәбибуллин

8) *күч.* Үз ишенә, үз даирәсенә хас сыйфатларга ия буларак хатын-кыз. *Һәйкәл куям шигъри гөлләр бостанымда Милләтемнең ир йөрәкле кызларына.* С.Әхмәтҗанова. *Син башында егерменче йөзнең, Ә мин менә егерме берендә – Ике чор һәм ике халык кызы Язмышларның уртак элмәгендә.* К.Булатова

**КЫЗА** *и. зоол. диал. к.* **елак карчыга**

**КЫЗАЛАК** *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан калпак рәвешендәге ачык төсле чәчәкле, суганчадан тарала торган күпьеллык декоратив үсемлек; лалә, тюльпан. *Көзге артына шулай ук үсемлек, бигрәк тә лалә, кызалак (тюльпан) рәсемнәре ясала.* Р.Фәхретдинов. *[Шилке ханның үзендә калдырган хатын-кызлар арасында] Кызалактай сылу, күз яшедәй керсез Койтым кыз да бар иде.* Н.Фәттах. *Сезнең, бәлки, күргәнегез бардыр, әгәр кызалак (тюльпан) чәчәген салкыннан җылы урынга кертсәң, беркадәр вакыттан соң ул ачыла, һәм киресенчә.* Биология

**КЫ́З АЛУ** *ф.* Кызны хатын итеп алу, бер гаиләнең кызын килен итеп үз гаиләңә китерү. *Ул менә өйләнмәгәнгә, менә мулла кызын ала, туй итә.* Г.Исхакый. *Гали – егет һәм кыз алырлык егет.* Ф.Әмирхан. *Бирьяктагылар аръяктагыларга кыз бирми, бирьякнылар аръяктан кыз алгалый, калымсыз булгач, ярлырак нәселле егетләр аръякка кияү булгалый.* Р.Батулла

**КЫ́З АЛЫШ** *и.* Яшьләрнең кичке уеннарыннан берсе. *Яшь күңелләр ашкына, җырлый, уйный, сикерә, көлә, Төрле шатлыклы уен һәм «кыз алыш»лар да була.* З.Ярмәки. *Ямьле Олы су буенды һаман уен бара, бишле бишләр, җырлыйлар, «кыз алыш» уйныйлар.* А.Гыйләҗев

**КЫЗАМЫК** *и. мед.* Сулыш юлларының ялкынсынуы, бөтен тәнне вак кына кызыл бөрчекләр каплавы, югары температура белән үтә торган йогышлы балалар авыруы; *иск.* сәрәхчә. *Киләсе гаеткә Кәҗә Вәлинең килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер.* Г.Исхакый. *Кадриям кызамык белән авырый.* Г.Кутуй. *Әткәй белән әнкәйне тагын бер мәртәбә сөргенгә озатып, өйдә караусыз-нисез биш яшь бала ятим калгач, бер ай чамасы үтүгә үк, миннән дә кече дүрт бала кызамыктан, ачлыктан бер атна эчендә кырылгач, ә үзем нииндидер могҗиза белән терелеп исән калгач, мин, ун яше тулган малай, мәктәбемә киттем.* Ф.Баттал

◊ **Кызамык чыгару** Кызамык авыруы белән авыру. *Кәҗә Вәлинең килененең угылы кызамык чыгарган икән, угылым, ул сиңа дигәнне [читекне], ураза гаетенә генә өлгертәм, диде.* Г.Исхакый

**КЫЗАН** *и. диал. зоол. к.* **кыза**

**КЫЗАРТКЫ** *и. сөйл.* Мичтә икмәк, күмәч, чүрәк кебек камыр ашлары пешергәндә, мич алдына өеп куелган куз, утлы күмер

**КЫЗАРТМА** *и. кулин.* Юка гына туралган сыер итен башта кыздырып, соңыннан шулпада томалап пешерелгән ашамлык. *Кызартма табынга кайнар көе бирелә.* Татар халык ашлары

**КЫЗАРТУ** *ф.* 1) Тәнне кан тирегә күбрәк килерлек итеп уып, суккалап һ.б.ш. кызгылт төскә кертү, кызылландыру. *Рәхәт кебек, бәлки, бу суыкның Сафлыгыдыр йөзне кызарта?* Ф.Яхин. *--- әти озаграк кырынмаса, битендәге кыллары белән минем битне кытыклап кызарта иде.* А.Костюнин. *Аракы ак булса да, йөзне кызарта, намусны каралта дип, борынгылар бик белеп әйткән.* Р.Низамиев

2) Кызыл төскә кертү, кызылландыру. *Чаналар тирәсе акшар кебек агартылган, уртасы алма кебек кызартылган битләр, мамык шәлләр, аллы-кызыллы, каралы-зәңгәрле чүпрәкләр белән тулды.* Г.Ибраһимов. *Кино лентасыннан тәмле ис килә, соңгы рәтләрдә, аппарат янында гына, мул итеп вазелин яккан, бит урталарын кызарткан кызлар утыра.* М.Мәһдиев. *Кулындагы кисәү агачын өреп кызартты да Мирвәлинең шәрә күкрәгенә китереп тәрде...* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Оялту, оялтып йөзен кызылландыру; уңайсыз хәлдә калдыру. *Билгеле, миңа бу эпизодны искә төшереп, аны кызартырга кирәк булмагандыр.* Ф.Яруллин. *Мин сине бервакытта да кеше алдында кызартмам.* М.Мәһдиев. *«Гариза да тутыра белмисезме әллә?» – дип, оешма җитәкчеләрен кызартырга тырышты Рөстәм Миңнеханов.* Ватаным Татарстан

4) *кулин.* Нинди дә булса ашамлык әзерләгәндә, аның өстендә күрәнсу кызгылт төсле катысы барлыкка килгәнче яки шундый төскә кергәнче кыздыру, куыру. *Өйдә безне өстәлдә шаулап утырган ак самавыр белән әнкәебезнең мич каршында кызартып кына пешергән тәмле эремчек коймаклары көтә иде.* Ф.Төхбәтуллин. *Сөягеннән аерылган, ярылары алынган итне, я сөякле түш итен, я түш яны итен 4–5 бармак киңлегендә аркылыга чабалар, тоз, борыч сибеп, духовкада кызарталар.* Татар халык ашлары. *Кәстрүлгә бераз сөт салып, шуңа кәбестә белән алманы салып пешерергә. Кызартырга ярамый.* Ватаным Татарстан

5) *күч.* Коммунистик идеология төсмере бирү. *Менә әсәр шуларга [аппаратчикларга] барып төртелде дә, алар аны алып ташладылар. Мин аны яңадан төзәттем, яңадан төзәттем. Аптырагач, аны бераз кызартырга тырыштым, чыксын дип.* М.Мәһдиев

**Кызарта бару** Барысын да рәттән кызарту

**Кызарта башлау** Кызартырга тотыну

**Кызарта төшү** Тагын бераз кызарту

**Кызартып алу** Кыска гына вакыт аралыгында бераз кызарту. *60–65 г лы эремчек кисәкләрен онда әвәләп, яссы биточки рәвешенә китерәләр дә, кызу майлы табада әйләндерә-әйләндерә кызартып алгач, 3–5 минутка духовкага куеп тоталар.* Татар халык ашлары

**Кызартып бетерү** 1) Тәмам кызыл төскә кертү. *Бармагы белән сөртәсөртә, борын астын кызартып бетерде.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Оялту, йөзгә кызыллык килгәнче уңайсыз хәлгә калдыру

**Кызартып җибәрү** Кинәт, капыл кызарту; кызарган хәлгә китерү. *Михаил Хәятка туры гына карап утыра, урыны килгәндә мактау сүзләре әйтеп китәргә дә онытмый һәм бу эше белән Хәятны кайсы вакыт кызартып та җибәрә иде.* Ф.Әмирхан. *Сәеркәй көзге янында бөтерелә башлады. Кашларын сызды, иреннәрен кызартып җибәрде, колак артларына ислемай сөртте.* Р.Сәгъди. *Кечкенә кызның бу соравы мине бераз кызартып җибәрде.* М.Гали

**Кызартып чыгару** Тәмам кызарту. *Моңа кадәр татымаган оят һәм курку хисе катыш дәрте кузгалып, [Шәрифәнең] бәгыре киселде. Тойгылары йөзенә бәреп, бит алмаларын кызартып чыгарды.* Ф.Яхин. *Әйтерсең лә кемнеңдер тылсымлы кулы табигать белән шаярып, вакытыннан бик күпкә алдан миләш тәлгәшен кызартып чыгарды.* Ә.Гаффар

**КЫЗАРУ** I *ф.* 1) Кызыллану, кызыл төс алу; кызыл төскә керү. *Җәйге иртә. Кызарып кояш чыга. Аның алсу нурлары болыннарга тарала.* С.Поварисов. *Иткә тоз, борыч сибеп, майлы табада кызарганчы яхшылап кыздыралар ---.* Татар халык ашлары. *Сопка артына төшеп кояш баеды. Шунда ук көньяк кызарды.* И.Салахов

2) Пешеп җитеп, өлгереп, кызыл төскә керү. *Җир җиләге кызарып пеште, бөрлегән, каен җиләге менә бүген-иртәгә өзәргә тулышып килә*ләр. Г.Ибраһимов. *Күзләрен, тук җимеш өлгергәч, Кызарып, алланып сөенә.* Р.Вәлиев. *Кояшка үрелеп, Кызара чияләр. «Сез икәү, сез икәү Пар килгән!» – диялә*р. Ф.Мөхәммәтова

3) Тән, йөз алсулану, кызгылт төскә керү. *Туктамыштай олы хан, Укыган соң бу хатны, --- Сум тимердәй кызарды.* Дастан. *Командир, Зарифның тирләп кызарган йөзенә текәлеп карап: – Иң элек тынычланыгыз! – диде.* Ә.Еники. *Гайшә карчык аның күшеккән тәнен кар белән бик каты итеп угач, кызарып кан йөгерә башлаганчы, коры киндер чүпрәк белән ышкыды ---.* З.Зәйнуллин

4) *күч.* Оялу, уңайсызлану, хурлану. *Табындым, сәҗдә кыйлдым мин сөйгән җанашның алдында, Өмид иттем вә курктым да, кызардым һәм оялдым да.* Г.Тукай. *Ике тапкыр тотылды [Шәйхел], оялмады, кызармады, атасы белән туп-туры: – Үзең базарлык бер тиен дә бирмәгәч, урламый ни эшлим? – дип телләште.* Г.Ибраһимов. *Мәктәптә ата-аналар җыелышында балалары өчен аларның кызарганы булмады, оланнар яхшы укый.* Р.Батулла

**Кызара бару** Торган саен кызару, әкренләп кызыл төскә керү. *--- ләкин комсомол секретареның хәзерге хәлен, аның кызара барган чыраен абайлап, [Хәбиб] сүзне башкага борды.* Г.Минский. *Алдан тау итәге буйлап борылып барган паровоз да, хәтта аның өстендәге бөркелеп барган төтен-толымнар да алсу яныл, һаман-һаман кызара бара...* И.Салахов. *Сәйфинең йөзе комач төсле кызара баруын күргән Сәрвәр апа сүзен тиз тотты.* А.Алиш

**Кызара башлау** Кызарырга тотыну. *Әни, әни, әнә почмакта торган бәлеш кызара башлаган бит, анысын алырга да вакыттыр!* Г.Галиева. *Хәерчегә җил каршы, дигәндәй, көнчыгышта офык кызара башлады.* И.Хуҗин

**Кызара төшү** Бераз кызару; тагы да ныграк кызару. *– Алай икән, – диде Гасыйм Сәләхович, кызара төшеп. – Күрәсең, бик байлардыр инде.* Ә.Еники. *Сәгыйрәнең болай да алсу йөзе тагын да кызара төште.* М.Шаһимәрдәнов. *Шулчак аның шактый кызара төшкән күз төпләрендә яшь тамчылары булуын абайлап өлгердем.* Р.Мөхәммәдиев

**Кызарып алу** Кыска бер вакытка кызару. *Ә үзенең колаклары гына түгел, берара бөтен йөзе кызарып алды.* М.Хуҗин

**Кызарып бетү** Тәмам кызару. *Шәмси аның күзенең елый-елый кызарып беткәнен күрергә өлгермәде, ул тагы кычкырып-кычкырып еларга тотынды.* Г.Исхакый. *Елап күзләре кызарып беткән түтине күргәч, Ханиевнең уйчан күзләре кинәт елтырап китте.* М.Шаһимәрдәнов. *Хилхәл атакай Винитар корольнең кызарып беткән кулларына, читлектән чыгардай булып елышкан кан сауган йөзенә күз төшереп алды.* М.Хәбибуллин

**Кызарып килү** Соңгы вакытларда яки хәзер акрынлап кызару. *Ә-әнә теге буйлар нинди матур булып кызарып килә.* Г.Гобәй. *Бакчада чияләр кызарып килә.* И.Гази. *--- алма кызарып килә, менә-менә өзеп ашарга инде ---.* М.Мәһдиев

**Кызарып китү** Кинәт, капыл гына кызару. *Клара, җиңгәчәсенең комган*

*тотып көтеп торуын күргәч, уңайсызланып, кызарып китте.* Ә.Еники. *Җиләк кайнатма-вареньесын кашыклап кына каба биреп, [Хәдичә апа] тулы һәм кызарып киткән бит очларына бәреп чыккан эссе тир бөртекләрен яулык читенә җыя-җыя сөйли торды.* Ф.Яхин. *Галимәрдән кызарып китте.* М.Шаһимәрдәнов

**Кызарып кую** Тиз арага кызару. *Кыз кызарып куйды.* Ә.Еники. *Соңгы вакытларда алдынгы кумхуҗчылар исемлегенә керә башлаган яшь хатын, Латыйп абзыйларга килен тиешле Наилә, ашыгып соравын үзе дә сизеп, кызарып куйды.* Ф.Яхин. *Фәһимә ашыкмый гына ашап утырган җиреннән уңайсызланып кызарып куйды.* М.Шаһимәрдәнов

**Кызарып тору** Кызарган хәлдә булу. *[Мирсәетнең] Бит алмалары, борын очлары кызарып тора, ә авызы ерык.* Р.Мөхәммәдиев. *Тәбәнәк, соргылт куктә – өч кояш. Өчесе дә кызгылт бөҗралар эчендә. Бу кояшлар гадәттәге кояш кебек балкып нур чәчми, бик сүрән кызарып кына торалар.* И.Салахов. *Офык кызарып тора иде.* Г.Гобәйдуллин

**Кызарып чыгу** Тулысынча һәм тиз арада кызару. *Йөзе күркәдәй кабарып һәм кызарып чыкты, мин-минлеге чиксез-чамасыз иде шул, күзләренә кан сауды кебек хәтта.* Р.Мөхәммәдиев. *– Мин – белемем буенча сәүдәгәр... Сезгә тәэминатчы кирәк дип ишеткән идем... – дип, Җаббаров кыяр-кыймас кына, сүзләрен уйлап кына әйтеп маташа иде, сул тезе өстенә куйган соры эшләпәсен кинәт идәнгә төшереп җибәрде дә, эшләпәне иелеп алганда, йөзенә кан йөгереп, чөгендердәй кызарып чыкты.* М.Шаһимәрдәнов. *Малайның ике бит уртасы кызарып чыкты.* Н.Акмал

**КЫЗАРУ** II *и.* Кызыл төс яки кызыл төскә керү процессы. *Аның [Анна Васильевнаның] йөзенә әллә нинди кызару чыккан, күзләрендә шатлыкны яшерә алмаенча нур түгелеп тора, селкенүенә, йөрүенә, кыланышына тизлек, егетлек кушылган.* Г.Исхакый. *Чыннан да, Фәниянең йөзе кып-кызыл булып чыккан иде: артык ак тәнле шул ул, ак тәнлеләрнең кызаруы да бөтен дөньяга кычкыра.* Р.Зәйдулла

**КЫЗАРУ́-БҮРТЕНҮ** *ф. к.* **кызарыну-бүртенү**. *[Аракының] Ачысыннан кызарып-бүртенеп, бераз тынсыз торды да сүзен дәвам итте: – Син, «брат, понимаешь», аңламыйсың әле, ә мин – беләм...* Ф.Яхин

**Кызарып-бүртенеп чыгу** *к.* **кызарып чыгу**. *Министр кызарып-бүртенеп чыкты, шулай да сабырлыгы җитмәде, үзенә юнәлтелгән төртмә сүзгә җавап бирергә кирәк тапты.* Р.Мөхәммәдиев. *Камил Хафизович үзен горур тотарга тырышса да, ачуыннан кызарып-бүртенеп чыгуын сизенми калды.* Ф.Яхин

**КЫЗАРЫНУ** *ф.* 1) Кызыл төскә керү, кызару. *Әминәнең тулырак кына яңак урталары эсседән матур гына кызарганнар да, бераз тирләгәннәр дә иде.* Ф.Әмирхан. *Бит-куллары кояшта кызарынган, бригадирлары кебек үк таза-таза биш-алты кыз, үзара нидер сөйләшә-сөйләшә, алдан кайталар иде.* Г.Бәширов

2) Оялудан, уңайсызланудан, ачудан һ.б.ш. кызару, йөзгә кызыллык йөгерү. *Гариф бераз кызарынды.* Ш.Камал. *Мөгаллим әфәнде кызларны күргәч каушап китте һәм бер дә сәбәпсез кызарынды да күзләрен идәнгә төшерде.* Ф.Әмирхан. *Сабира кызарынды, илдә йөргән гайбәтләр турында тел ачмакчыдыр дип, катырак бәреп ташлады: – Харап икән! ---.* Г.Ибраһимов

**Кызарынып бетү** Тәмам кызарыну, кызыл төскә керү. *Кечкенә кыз Фагыйлә арды, кояштан тирләп, кызарынып бетте.* Г.Ибраһимов. *Хан шулай диюгә, булачак килене аңа елаудан кызарынып беткән күзләре белән карап алды һәм елмаерга тырышты бугай, әмма ни елмаю, ни елау килеп чыкмады, кыз кинәт башын түбән иде.* М.Хәбибуллин

**Кызарынып китү** Кинәт кызарыну. *Газизә кызарынып китте.* Ш.Камал. *--- сез үзегез белми торгансыз, сез хәзер шәһәребезнең беренче гүзәле бит... – дип, [Михаил] тагы мактау сүзләрен әйтә башлаган иде, Хәят кызарынып китте дә күзләрен җиргә төшерде.* Ф.Әмирхан. *Исәнтәй, йөзенә китереп суккандай, кызарынып китте.* Н.Фәттах

**Кызарынып кую** Бик тиз кызарыну. *Албуга, әллә кызның кул кайнарлыгыннан, әллә әнисенең хәйләсеннән уңайсызланып, җиңелчә генә кызарынып куйды.* Н.Фәттах

**Кызарынып тору** Кызарынган хәлдә булу

**Кызарынып чыгу** Тәмам кызарыну. *Күркәм хатынның йөзенә гүя ут капты: кызарынып чыкты.* М.Хәбибуллин

**КЫЗАРЫНУ́-БҮРТЕНҮ** *ф. сөйл.* Ачудан, көчәнүдән һ.б.ш. бит мускуллары хәрәкәткә килеп, йөз кызару. *Саҗидә, кызарынып-бүртенеп, урыныннан сикереп торды.* М.Галәү. *Кызарынган-бүртенгән энесе дә аннан [Мисбахетдиннән] калышмады.* М.Шаһимәрдәнов. *Тәрбиясе болай да чамалы булган яңа хуҗаның сабырлыгы шунда төкәнде, кисәк кенә «сез»дән «мин»гә сикереп, кызарынып-бүртенеп җикеренә башлады.* Р.Габделхакова

**Кызарынып-бүртенеп бетү** *к.* **кызарынып бетү**

**Кызарынып-бүртенеп чыгу** *к.* **кызарып чыгу**. *Янә әллә кай арада күркәнеке сыман булып муеннары кызарынып-бүртенеп чыкты [генералның].* Р.Мөхәммәдиев

**КЫЗА́У** *и.* 1) Җиләк-җимеш җыю, сибелүчән, чәчелүчән әйберләрне салып кую өчен, кабыктан, чыбыктан һ.б.ш. ясалган төрле зурлыктагы савыт. *Кыз урлаган егеткә кызау да кыз күренгән.* Мәкаль. *Паңгы [гөмбә] булдыңмы – кер кызауга.* Мәкаль. *Тугызак әби, тугыз улына тугыз юкә кызау биреп, урманга җибәрде.* Ф.Вәлиев

2) Тегермәндә тартыласы ашлык салына торган улак, *диал.* кауша. *1980 елларда, Равил Гарәфиев рәислек иткәндә, электрик Фәйзерахманов Габделбәр җитәкчелегендәге группа үз проектлары белән 8 ташлы, 4 кызаулы тегермән ясадылар.* Тирән тамырлы Түнтәрем

3) *к.* **козау**

**КЫ́З БАГУ** *и. этн.* Кияүнең һәм аның туганнарының кыз белән танышу йоласы. *Һәрхәлдә, затлы күлмәкләремнең берсен дә алмыйм: минем анда кыз багар өчен килүчеләргә күренәсем*

*юк әле.* Ә.Еники. *Аңа [Бакый Урманче премиясенә] «Нәкыш» номинациясендә «Кыз багу йоласы», «Алтынчәч», «Бәйрәм коймаклары» кебек бер шәкел эшләре өчен Рабис Мөгаллим улы Саляхов --- лаек булдылар.* Шәһри Казан

**КЫ́З БАЛА** *и. к.* **кыз** (*1 мәгъ.*). *Кыз бала – кызыл комач.* Мәкаль. *[Айсылу:] Теге вакытта кечкенә генә кыз бала идең.* С.Поварисов. *Һай, шунда кыз бала булып дөньяга килгән булса, әнисе аны чәчәктән-чуктан гына киендереп йөретер иде, ата-бабадан килгән гүзәл тәрбиясен биреп, күгәрчен итәр иде.* Ф.Яхин

**КЫ́З БИРҮ** *ф.* Кызны кияүгә бирү, үз гаиләндәге кызны башка бер гаиләгә килен итү. *Манҗурлар, шәркый төрекләр вә кытайлар арасында борынборыннан кыз алып, кыз биреп торулар булганын, бер ыруг икенче ыругтан булган гаиләләрне, хәтта кечерәк ыругларны бөтене берлә әсир итеп алып китүләр булганын күрсәтәләр.* Г.Шәрәф. *Карт --- Шәйхелнең битенә карады: – Синә, – диде, – ничек кыз бирәсең? Бай дисәң – малың юк, атаң куып чыгарды.* Г.Ибраһимов. *Хәтта «бывший кулак»ка кызларын бирергә атлыгып тора башладылар.* Р.Батулла

**КЫ́З БҮЛӘГЕ** *и. этн.* Кызның ата-аналарыннан яки якын туганнарыннан, кызны кияүгә бирергә ризалык алгач, аерым акча бәрабәренә килешү билгесе итеп алдан бирелә торган бүләк (ашъяулык, яулык, җәймә, кульяулык, янчык һ.б.). *Шунда ук егерме биш тәңкә акча чыгарып салып, кыз бүләген алып кайткан.* Г.Ибраһимов

**КЫЗГАНДЫРУ** *ф.* 1) Кемдә дә булса кызгану хисе уяту. *Елап, Габдрахманнан үзләрен кызгандырып, кәртечкегә төшәселәре килә иде аларның.* З.Зәйнуллин

2) *з.-сыз* Кызгану хисе биләп алу. *Аты урланган теге ярлы бик тә кызгандырды.* Г.Бәширов. *Хәтеренә балта чабылган зат кызгандыра, уйландыра.* Ф.Сафин

**Кызгандыра башлау** Кызгандырырга тотыну. *Ул үзенә кирәк кеше янына бара да үзен кызгандыра башлый.* С.Алишев

**Кызгандыра төшү** Элеккедән дә ныграк кызгандыру, тагын да ныграк кызгандыру. *Тагын да кызгандыра төшү өчен, Хәлим үзен әнисез дә итеп, түгәрәк ятим итеп күрсәтмәкче иде.* И.Гази

**Кызгандырып алу** Бер вакыт аралыгында кызгандыру. *Бер-береңә янау, үз теләгәнеңне булдыру өчен икенче кешене бераз куркытып, үзеңне кызгандырып алу – кешелек дөньясында буыннан-буынга тапшырылып килә торган гадәт.* Ялкын

**Кызгандырып йөрү** Гел, һәрвакыт, даими рәвештә кызгандыру. *Сәхнәдә басып торырга хәлем бетсә дә, җәфаланып, кызгандырып йөрергә җыенмыйм.* Кәеф ничек?

**Кызгандырып кую** Тиз арада, азга гына кызгану хисе уяту. *Физик кимчелеге булган кеше ирексездән күзгә ташлана, кызгандырып та куя әле.* Безнең гәҗит

**Кызгандырып тору** Әле, хәзер яки һәрвакыт кызгандыру

**КЫЗГАНДЫРЫРЛЫК** *с.* **1.** Кызгану хисе уята торган. *Берәүләр йөзәрләгән миллион акча эшләвен яшермәсә, башкалар үзләрен кызгандырырлык суммалар күрсәтә.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Кызгану хисе уятырлык итеп, шундый дәрәҗәдә. *Үземчә хатны бик дәртле, кызгандырырлык, кызларны соклandырырлык итеп яздым.* Ә.Айдар

**КЫЗГАНУ** I *ф.* 1) Авыр хәлдә калган кешегә теләктәшлек белән карау, аны җәлләү. *Шәмсинең сүзләре, кылынышларымы, күзенең кызганып карауларымы тәэсир итте, ни булса да булды, Анна акыртын гына сабырлана башлады.* Г.Исхакый. *Кызганып егетне, елыйлар Миләүшә һәм лалә чәчәге.* М.Җәлил. *[Гөлшат] Илшатны да ни өчендер кызгана иде.* Ф.Яхин

2) Шәфкать күрсәтү, аяу; зарар китермәү; тимәү. – *Казый абзый! Безне син кызган, – дибез.* Г.Тукай. *Аңа баш иеп, карт җавап биргән: «Кызган син мине, алтын балыгым!»* А.Пушкин. – *Кызган мине, хуҗам! Ана-кам мине абаларга бирәчәк, ул мине утлы табада кыздырачак, ул мине терелә җиргә күмәчәк! – диде ул такмаклап, өзгәләнеп.* Н.Фәттах. *Баламбир оланны исә бөтенләй кызганмады, баш-аягы белән Сафура бикәгә калдырды.* М.Хәбибуллин

3) Җәлләү, әрәм дип санау. *Абыстай теләгән вакытта кайнаган каймак, сары май, былтыргы балны кызганмады.* Г.Исхакый. *Икенчедән, ул хатын --- аны, ягъни Фәридун Идиятовны, җанын һәм малын кызганмыйча назларга, карарга, һәр теләгәнен үтәп торырга тиеш иде.* Ә.Еники. – *Карак!.. – дип бакырды, булган бар тавышын кызганмыйча.* Р.Мөхәммәдиев

**Кызгана башлау** Кызганырга тотыну. *Мин апайны чын күңелдән кызгана башладым.* Г.Бәширов

**Кызгана төшү** Тагы да бераз кызгану

**Кызганып бетерү** Берсен дә калдырмыйча, барысын да кызгану. – *Ул бер генә, без бик күп, – диде мәзин. – Барыбызны да каян кызганып бетерсен?* Г.Бәширов

**Кызганып йөрү** Кемгә яки нәрсәгә дә булса карата һәрвакыт кызгану хисе тою. *Күрше бүлмәдә яшәүче Фирая исемле кыз бу хәлне күреп-күзәтеп, эчтән генә егетне кызганып йөргән икән.* Н.Акмал

**Кызганып кую** Аз гына вакытка кинәт кызгану хисе кичерү. *Бик сәер булып тоелды бу эш миңа, хәтта иптәш Сабирҗанны кызганып та куйдым.* Ә.Еники. *Олыгаеп килгән әтисен Миргалим җәлләп-кызганып куйды.* Ф.Яхин. *Гөлсылу кинәт юкка чыккан әлеге сәфәрчеләрне кызганып куйды.* М.Шаһимәрдәнов

**Кызганып тору** Даими рәвештә кызгану хисе кичерү. *Җанварларга шушылай дип хәбәр салды: «Кызганып тора идем үзем сезне, Ачулансам – калдырмамын һичберегезне».* М.Гафури. *[Сафагәрәй хан:] Башыңны чабармын, кызганып тормам, Я урының булыр караңгы зиндан!* Ф.Яхин. *Һәй, мондый чакта егет кеше фонарь кызганып торамы инде кызлар өчен, бигрәк тә Бәкки өчен!* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗГАНУ** II *и.* Шәфкать, миһербанлылык хисе. *Карт үзенең хатынына ачу катнаш кызгану белән, мыскыл*

*белән карады.* Г.Ибраһимов. *Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә, күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән?..* Ә.Еники. *Ахылдап, лап-лып атлап килеп җиткән Рәйхананы азрак хәл алып өлгергән хатыннар, кызгануларын сиздермәскә тырышып, якты йөз белән каршылады.* З.Зәйнуллин

**КЫЗГАНУЛЫ** *с.* 1) Кызгану хисе белдергән. *Кызганулы бер өн чыгарып, ул ыңгырашып куйды, авыраеп калган хатынны шашып кочагына алды, битенә, күзләренә карады.* Н.Фәттах. *– Ашказаныңдыр инде, брат? – дип, миңа ул кызганулы караш ташлады.* Ә.Сафиуллин

2) *к.* **кызганычлы**. *Кызганулы хәл*

3) Жәлләү хисе булган, күпсенгән, әрәмгә санаган. *Атның авыз кырыеннан саламга аккан аракыга фельдшер кызганулы караш ташлады.* М.Мәһдиев

**КЫЗГАНУСЫЗ** *с.* **1.** 1) Кызгану хисе белдермәгән; шәфкатьсез, аяусыз. *Тупка каршы тупның җавабы бар. Бу җавап каты була. Кызганусыз була.* К.Нәҗми

2) Жәлләү хисе булмаган, әрәм дип уйламаган

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кызганмыйча. *Ә иске өйләрне берниндн кызганусыз сүтеп, җимереп ташлаганнар.* М.Галәү. *Йөрү тыелган төштә күренү белән, берницди кызганусыз, аларга ук аттылар, таш аттылар я булмаса көтмәгәндә китереп сөңге белән тондырдылар.* Н.Фәттах

2) Жәлләүсез. *Әмма ул берниндн кызганусыз ымсындыргыч мөмкинлекләрдән баш тартты, күңеле, бөтен барлыгы туган якларына ыргылა иде.* Р.Мирхәйдәров

**КЫЗГАНЫЧ** *с.* **1.** 1) Жәлләү хисе уята торган, кызгану хисе тудыра торган. *Мәктәп су янында, озынчарак, зур түгел генә бер бина булып, башы кызылга буялган, --- тышкы яктан әллә нинди иске су тегермәне яисә борынгы алпавыт утарларындагы ташланган флигель төсле килешсез вә кызганыч рәвештә күренә иде.* Ш.Камал. *Кыскасы, алар кеше танымаслык, кызганыч бер кыяфәттә иделәр.* М.Галәү. *Шәмсинур әби дерт итеп сискәнеп китте һәм ни дә булса аңлаудан гаҗиз, кызганыч бер кыяфәт белән катып калды.* Ә.Еники

2) Кызгану белдерә торган. *Ләкин Аннаның кызганыч йөзен күргәч, тагы туктады.* Г.Исхакый. *Галимҗан абзый улына кызганыч елмаю белән, ышанмыйча карый, Мәрьям абыстай исә, бөтенләй таңга калып, бернәрсә аңламаган кыяфәт белән, күзләрен зур ачып, улына текәлгән иде.* Ә.Еники. *– Эчем авырта, бөек каган! – диде дунху бәге, кызганыч йөз белән.* Н.Фәттах

3) Бик мескен булган, бичара; ярдәмчесез. *Ул шунда гомерендә беренче мәртәбә үзенә-үзе бик кызганыч, бик бәхетсез кеше булып тоелды.* Г.Бәширов. *Гатауллин вак һәм олы кайгыларны авыр кичерүчән, шул ук вакытта ничектер югалып китә торган, кызыклы һәм кызганыч кеше булуы белән беррәттән, усал җанлы бәндәләр сыйфатында да йөргән гаять аңлашылусыз зат кебек күренсә дә, аның бу үзенчәлекләрен белеп бетергән хатыны Алсу --- мескенен иркәлисе, юатасы килгән минутларын тормышында күп татыды.* Ф.Яхин

4) Авыр кичерешләр уята торган, фаҗигале. *[Мәрьям] Нииндидер бер кызганыч роман укып, күз яшьләре дә түкте шикелле.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кызгану хисе уятып, кызгану чагылдырып. *Картның торышы, төсе байтак кызганыч күренде.* Г.Ибраһимов. *Озаткан чакта ул, дымланган күзләре белән кызганыч елмаеп, безгә: «Хушыгыз, дуслар, әгәр күрешмәсәк, яманат белән искә алмагыз!» – дип китте.* Ә.Еники. *Бичара ат, авыртуга чыдый алмыйча, кызганыч итеп чинап, кешнәп җибәрде.* Н.Фәттах. *Ул [Йосыф абзый] кызганыч елмаеп куйды.* Р.Зәйдулла

2) Мескен, чарасыз хәлдә, жәлләү хисе уятып

**3.** *хәб. функ.* 1) Кызгану, жәлләү хисе тудыра торган булу. *Ә күзләре шундый моңсу, шундый кызганыч: төнге күктә балкучы гөнаһсыз йолдызлар кебек иде...* Ф.Яхин. *Ул, миңа таба авыша төшеп: – Шулай да... китабында «Коньяк» дигән әсәрнең булмавы кызганыч, чөнки шунсыз аны тулаем аңламаулары мөмкин һәм мәңге басылып чыкмавы бар! – диде.* М.Шаһимәрдәнов. *Ябалак кызганыч. Бөтен гомерен шушында уздырды: яуга йөрмәде, күченмәде.* Н.Фәттах

2) Кызгану хисе уята торган, чарасыз, мескен хәлдә булу. *Ул бу вакытта елаганнан да артык кызганыч иде.* Г.Гобәй

**4.** *кер. сүз мәгъ. к.* **кызганычка каршы**. *Кызганыч, әлеге сорауга җавап һаман табылмаган әле.* Р.Фәхретдинов. *Бер хатта: «Сез матур, сез Шәрык хикәяләрендә очрый торган пәри падишаһларының могҗизалы гүзәл кызларыннан да матур; кызганыч ки, миңа сезне күрергә бик сирәк туры килә», – дип язылган иде.* Ф.Әмирхан. *– Кызганыч, әмма беренче мәхәббәтең мин үзем булсам кирәк дип уйларга да өлгергән идем. Ялгышканмын икән, – диде ханым, бераз үпкәләгән төс чыгарып.* Ф.Яхин

◊ **Кызганычка каршы** *кер. сүз* Нәрсәгә дә булса үкенеч белдереп әйтелә; ни үкенеч, тәәссефкә каршы, мәгаттәәссеф. *Кызганычка каршы, ул урында вакытында археологик тикшеренүләр ясалмаган.* Р.Фәхретдинов. *Аның өчен елына бер генә килә торган бәхет бит бу, гел шуны көтеп яши иде бит ул, тик менә, кызганычка каршы, урын өстендә каршы алырга туры килде үзләрен.* Ә.Еники. *[Фәрит:] Чынмы бу, Айсылу? Әллә ялгыш ишетәмме? [Гәрәй:] Кызганычка каршы, чын.* С.Поварисов. **Кызганычка күрә** *кер. сүз к.* **кызганычка каршы**. *Кызганычка күрә, берни дә мәңгелек түгел.* Р.Зәйдулла

**КЫЗГАНЫЧЛЫ** *с.* 1) *к.* **кызганыч** (*1 мәгъ.*). *Сугыш башлану белән, бөтен Россиядә гаять кызганычлы елау һәм аһ-ваһлар күтәрелде.* Г.Тукай. *– Я Хода, үзеңә тапшырдык, – дип, карчыгына кызганычлы бер караш ташлады да урыныннан торды.* М.Мәһдиев. *Миңа сынап, кызганычлы карашын җайлап кына салып ала да яңалык чыгара: – Син нәстә диярсең инде, энем, килен*

*марҗадан бит!* З.Зәйнуллин. *Кызганычлы тавыш. Кызганычлы кыяфәт*

2) Фаҗигале, авыр кичерешләр уята торган, тәәссефле. *Бервакыт, Мохтар унбер-унике яшьләрдә булгандыр, аларның өендә бик кызганычлы хәл булды.* Ш.Камал. *Ул үзенең асрауларын мәсхәрәле, кызганычлы хәлгә төшерә.* М.Гали. *Кызганычлы вакыйга. Кызганычлы нәтиҗә*

**КЫЗГАНЫЧСЫЗ** *с.* **1.** Кызгану, җәлләү хисе белдермәгән, аяусыз. *Шул көннән алып авыл байлары, җирләре тартып алынган алпавытлар кызганычсыз рәвештә үч алу эшенә керештеләр.* Г.Гали. *Бу күренешкә каршы ригаясез сатира, үтереп ташларлык сарказм, ачуланган памфлет кирәк иде. Кызганычсыз ирония кирәк иде.* Г.Халит

**2.** *рәв. мәгъ.* Кызганмыйча, җәлләмичә, кызганмый. *Язмыш кайбер вакытта бичара адәмнең өстеннән үтә кызганычсыз көлеп куя.* Г.Ибраһимов. *Кызны кызганычсыз гына биреп җибәрделәр.* М.Хәбибуллин

**КЫЗГАЧ** *и. зоол. диал. к.* **кызгыч**. *Кыйгулама, кызгач кош, Тавышың зарлы байгыш кош.* Дастан

**КЫЗГЫЛТ** *с. ким.* 1) Кызылсу, ачык кына кызыл дип әйтерлек булмаган, берникадәр кызыл; кызыл төс төсмерләнгән. *Офык читләре генә баеп барган кояшның кызгылт нурларына манчылган.* М.Галәү. --- *тау ягыннан төшкән кызгылт кояш шәүләсе боларны [лабаз белән казарманы] бик юаш һәм моңлы күрсәтә.* Ш.Камал. *Котлетны, кипкән бодай ипие валчыгында әвәләп, кызган майлы табада әйләндерә-әйләндерә, кызгылт матур төскә кергәнче кыздыралар.* Татар халык ашлары

2) Башка бер төскә берникадәр кызыл төсмер кушылуын белдерә. *Аның аз гына кызгылт ак йөзе, кош борынына охшаулырак килешле борыны, уйчан кара күзләре дә бер караштa гади генә күренәләр.* Ш.Камал. *Җәй уртасында исә теге эзнәк кызгылт алсу төстәге куе сироп белән каплана, һәм аңа чебен, шөпшә куна иде.* М.Мәһдиев. *Вахитов киез эшләпәне башыннан йокып алды: тонык ут яктысында аның кызгылт җирән бөдрә чәчләре ялкын телләредәй дулкынланып күренде.* Г.Ахунов. *Кызгылт көрән сутлы балчык бездә Һәр нәрсәне сөйли ул үзе.* Ф.Шәрипова

**КЫЗГЫЛТЛЫК** *и.* Кызгылт төс. *Аның [Хәятның] матур йөзе нурлы кызгылтлык белән капланган иде.* Ф.Әмирхан

**КЫЗГЫЧ** *и. зоол. диал.* Тәкәрлек. *Кыйкулама, кызгыч кош, Канатың куш, муйның буш, Авызың-борының мөгез кош, Авазың яман зарлы кош!* Дастан

**КЫ́З ДИМЛӘҮ** *ф. этн.* Кемгә дә булса билгеле бер кызга өйләнергә тәкъдим итү, өйләнергә киңәш бирү. *Күңлем керде, хәслем салдым, Кызыңны димләп алдым мин.* Җыр. *Шуңарга Көязебаш авылыннан унҗиде яшьлек бер кызны димләгәннәр.* Р.Мөхәммәдиев. *Хөсникамал түти ни итсә-итте, күрше-күлән карчыкларын көйләп-яраштырып, алардан кыз димләттерде.* Ф.Яхин

**КЫЗДЫРГАН** *с. к.* **кыздырылган**. *Ләкин кыздырган яки тапап куырган итләрне бер дә алмый диярлек [профессор] ---.* Ә.Еники. *Хатыны кыздырган ит китергән иде – шуны ашагач эче авырта башлавын җае белән дежур милиционерга кичтән үк әйтеп куйды.* М.Мәһдиев. *Әзер котлетны бизәкләп кисеп кыздырган ипи кисәге өстенә куеп, янына кыздырган бәрәңге, --- яшел тәмләткечләр салалар.* Татар халык ашлары

**КЫЗДЫРГЫЧ** *и.* 1) Тәннең авырткан урынын җылытып тотар өчен куела торган дарулы бәйләвеч

2) *тех.* Башлыча трактор дизельләрен кабызып җибәрү өчен хезмәт итә торган, кечерәк егәрлекле эчке янулы карбюраторлы двигатель

**КЫЗДЫРМА** I *и. кулин.* Майда кыздырылган ашамлык (гадәттә иттән әзерләнә). – *Кәбестә салаты, өч телем икмәк, компот, өйдәгечә әзерләнгән кыздырма! [сорадым] – 64 сум! – диде кассир.* Кызыл таң. *Ит ризыклары, биграк тә кәтлит, кыздырма янына менә дигән өстәмә.* Ватаным Татарстан. *Кыздырманы табынга кайнар килеш, аерым пешергән яки кыздырган бәрәңге белән бирәләр.* Татар халык ашлары

**КЫЗДЫРМА** II *с.* 1) *техн.* Металларны чыныктыру яки эретү өчен хезмәт итә торган. *Кыздырма мич*

2) *физ.* Вольфрам спиральгә ток бирү нәтиҗәсендә кызып яктылык бирү принцибына нигезләнгән. *Рус инженеры А.Н.Лодыгин уйлап тапкан кыздырма лампа Яблочков шәменә алмашка килде.* Физика

**КЫЗДЫРУ** I *ф.* 1) Каты әйберне югары температурага җиткәнче утта тоту; эсселәтеп, каты әйбердә югары температура барлыкка китерү. *Таңбатыр «юлда кирәк булыр» дип, әнисе биреп җибәргән энәсен ала да, ут ягып, шул энәне утта кыздырып, бик шәп бер кармак ясый.* Әкият. *Сәйфулла хәзрәткә акчасын ышкып, кыздырып тоттыра, хәзрәтнең кулы пешә.* Ф.Бурнаш. *Йөрәгем ташка әверелгән, аны мәхәббәт уты түгел, тәмуг та кыздыра алмас тәгаен!* Ф.Яхин

2) Кояш турында: һаваны бик нык җылыту, эсселәтү. *Ком диңгезен каплап торган соргылт зәңгәр күк йөзендә берьялгызы йөзгән кояш зур ут шары шикелле кыздыра, яндыра, көйдерә.* М.Галәү. *Тагы кояш әүвәлге кебек кыздырырга тотынды.* Г.Исхакый. *Урамга чыгып кояшка эләккәч тә, ул аның агарган тимердәй кыздыруын тойды.* Ә.Еники

3) *з.-сыз* Бик эссе булу (һава торышы тур.). – *Кыздыра-а, ява-ар... – диде дә Айдаш баба урак машинасының тәртәсен, вәлүкләрен күтәртеп куйды.* Р.Батулла. *Көндез бик кыздырды, хәзер елгадан рәхәт салкынча һава бөркелә.* Г.Әпсәләмов

4) Нәрсәне дә булса майлы табада яки башка шундый берәр савытта яки күмерләр өстендә кызуда тотып, ашамлык итеп хәзерләү, пешерү. *Хилхәл атакай белә иде: алар, һичшиксез, поши я булмаса болан сыеры булса да ауларлар, аннары түшкәне тунарлар да ап-ак карга куеп, әйләндерә-әйләндерә кыздырырлар.* М.Хәбибуллин. *[Кайнатып алган] Суын түккәч, бу пешкән гөмбәләрне кыздырырга, яисә алардан аш пешерергә мөмкин.* Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр

5) *куч.* Кемне дә булса ачуландыру, ачуын чыгару, чыгырыннан чыгару.

*Безнең Сәйдәш ачулы әле, Камилла. Бабай кыздырган егетне.* Н.Гыйматдинова. *Кыздырма мине*

6) *күч. сөйл.* Ачулану, бик каты тиргәү, орышу. *Сез югында әллә нинди бер кыяфәтсез карт кереп йөдәтә башлаган иде, мин аны бик кыздырып, сакалыннан каенга бәйләп куйдым.* Әкият. *Артельщик булгач, безне дә шулай кыздырырлар.* Ш.Камал. *Чөнки беренче секретарьның бу эш өчен Хәйруллинны кыздырганын, гомумән, бу эшне ашыгыч рәвештә әвәләп ташлаган өчен, бюро членнарына ризасызлык белдергәнен ишеткән иде.* М.Мәһдиев

7) Кыйнау, тәпәләү. *Әле бит теге... борчак кузагына баргач, каравылчы Әхмүш абзыйның кычыткан белән кыздырганына да күп үтмәгән төсле.* Г.Толымбай

8) *күч.* Йөгерү күнекмәләре биреп, атны алдан ярышка әзерләү. *Эчләре җыелып килсен, сулышлары иркен булсын өчен, аларга ипи белән солы гына ашаталар. Койрыкларын кыска гына бәйләп, аякларын кыздырырга йөртәләр.* Г.Бәширов. *Быел ат аягы кыздырырга чыгучы да күренмәде.* Г.Ахунов

9) Җилкендерү, дәртләндерү, дәрт бирү. *«Бер шигырь яз!» – дип мине кыздырса дәрт.* Ш.Бабич. *Җил кай якка иссә, шул якка борылучан икейөзле байлар, куштаннар һәм мулла-мәзиннәр халыктагы бу омтылышны төрлечә кыздырырга тырыштылар.* М.Галәү. *Гадәттә, гади кешеләрнең патриотик хисләрен сугыш вакытында махсус кыздыралар.* Р.Зәйдулла

10) *күч.* Көчәйтү; арттыру. *Гәрәй дә, Госман да аның сүзен тыңладылар, талашны кыздырмадылар.* Г.Ибраһимов

11) Кабызып, җылынганчы эшләтеп тору (двигательне)

**Кыздыра бару** Торган саен ныграк кыздыру. *Кояш кыздырганнан-кыздыра бара.* И.Салахов

**Кыздыра башлау** Кыздырырга тотыну. *...Ул көнне иртәдән үк кыздыра башлады.* Сабантуй

**Кыздыра бирү** Бернигә карамастан кыздыруны дәвам итү, һаман кыздыру. *Шуңа күрә ул алашаны кыздыра бирде.* С.Поварисов

**Кыздыра тору** Берәр нәрсә эшләп алганчы кыздыруга керешү. *Хуҗа боржоми салырга ымлады да сүз җебен суза бирде: – Мин, егетләрең белән бар да, элек ничек эшләгән булсаң, шулай кылан, бушка тартып ал дип, Әкмалны кыздыра торам.* Р.Мирхәйдәров. *Син чыкканчы, мин машинаны кыздыра торырмын*

**Кыздыра төшү** Элеккедән дә ныграк кыздыру. *Сасыган салат микробларының бу сыйнфый булмаган бәрелешне кыздыра төшүе генә мәгълүм.* Җ.Юныс

**Кыздырып алу** Аз бер вакыт кыздыру. *Инде сүзне синең хатыңа борыйк; хәзер мин сине бераз кыздырып алмакчы булам.* Г.Тукай. *Шуңа күрә үзен бераз гына тәҗрибәле санап, өйрәтергә хаклы санап, җиңелчә генә аны «кыздырып» алган булды, көлепшаяртып, аның авыз читләрен сөрткәләде.* Н.Фәттах. *Әйтик, мактәп линейкасында кыздырып алырга мөмкин.* Г.Гыйльманов

**Кыздырып җибәрү** Соңгы вакытта гына, хәзер кыздыра башлау. *Һәм Локман карт та мондый көнне җәйгечә кыздырып җибәргән кояштан эреп, рәхәтләнеп тик кенә утыра.* Ә.Еники. *Гөлбикә апа үзе дә сизмәстән улын кыздырып җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Ә кояш, мәгълүм булганча, яктыртып, җылытып кына калмыйча, күзләрне дә чагылдыра, миләрне, каннарны да кыздырып җибәрә.* Г.Гыйльманов

**Кыздырып йөрү** Күптәннән кыздыру; озак вакыт кыздыру. *[Госман] --- колагына яулык бәйләгән, ал күлмәген балкытып, атның аякларын кыздырып йөргән була.* Ф.Хөсни

**Кыздырып кую** Алдан ук кыздыру, кыздырган хәлгә китереп әзер итү. *Аяз йокысыннан торуга, әбисе бик тәмле итеп балык кыздырып куя.* Д.Каюмова. *Иван дәдәй мунчаны шәп итеп кыздырып куйган.* Н.Гыйматдинова

**Кыздырып тору** Әледән-әле, бертуктаусыз кыздыру. *Әле ярый бензиның беткәч стартер белән кыздырып тормагансың, инжекторлы моторның бензонасосы бик тиз янып чыгучан.* Ш.Алпар. *Әмма мәгълүмат чаралары аны кыздырып тора һәм төрле котыртту, провокацияләр белән агрессия дәрәҗәсенә җиткерә.* Безнең гәҗит // Әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда кыздыру. *Инде көзнең соңгы көннәре булуга да карамастан, кояш быел җәйге кебек көләч: кыздырып тора.* И.Салахов

**КЫЗДЫРУ** II *и.* Эсселек, кызулык. *Кояшның кыздыруы сүрелгәнче, дөяләр бераз хәл алганчы, алар үзләре дә ял итә торырга булып, үз көймәләренә таралыштылар.* М.Галәү. *Сары борчак сибелгән көрән бумази күлмәгенең җиңнәрен сызганып җибәргән дә бите белән кулларын кояш нуры кыздыруына рәхәтләнеп утыра.* Г.Бәширов. *Кояшның уттай кыздыруы алар файдасына булды бүген.* С.Поварисов

**КЫЗДЫРЫЛГАН** *с.* Кыздырып әзерләнгән. *Анна Васильевна: – Тагы туеп куйма, – дип, ашханәгә барып, балык, бәрәңге берлән кыздырылган тәкә ите китерде.* Г.Исхакый. *Әйтик, кыздырылган күркә яки җимеш белән тутырган тавык бик шәп булып чыга иде.* Ә.Еники. *Анда кыздырылган мәрсин балыклары, кызыл, кара уылдыкның исәбе-кадере юк ---.* Р.Батулла

**КЫЗДЫРЫШ** *и.* 1) Кыздыру эше яки процессы

2) *күч.* Тиргәү, әрләү, ачулану. *Янә җыелыш, янә кыздырыш.* Ф.Баттал

**КЫ́З ЕЛАТУ** *и. этн.* Кызны кияү йортына озатыр алдыннан, аның якыннарын һәм иптәш кызларын җыеп, кыз исеменнән моңланып бәет әйтүдән гыйбарәт мәҗлес; чеңләү. *Саулармы сез, абыстакайлар, Кызны елатырга килдек без.* Җыр. *Кыз елату җырлары элек мишәрләр яшәгән урыннарда, керәшеннәрдә һәм Себер татарлары арасында аеруча киң таралган була.* М.Бакиров. *Кыз елату гадәтен яхшы белүче һәм кыз озату җырларын башкаручы хатын-кыз, кияүгә китүче кыз өенә килеп кергәч, исәнлек-саулык сорашканнан соң эшкә керешә.* М.Акчурина

**КЫ́З КАРДӘШ** *и.* Апа; сеңел. *Тик, сеңелләр, чибәр кыз кардәшләр, Бик күп әле илдә яралар.* М.Җәлил. *Сабый я зәгыйфь булган, мәхрүм, өлешсез калган мескен ир кардәшләрен вә фәкыйрь кыз кардәшләрен тәрбия кылу мөэмин*

*мөселман булган кешегә фарыздыр.* Ә.-Һ.Максуди. *Шул ук вакытта әлегә аларның бертуган Камилә исемле кыз кардәшләре булуы гына билгеле, аның да язмышы ачыкланмаган.* Л.Хәмидуллин

**КЫЗ-КАТЫН** *җый. и. гади с.* Хатын-кыз. *Сөйләшә беләсең... Ә кыз-катын матур сүзгә үлеп китә.* Р.Зәйдулла

**КЫ́З КАЧЫРУ** *ф. этн. к.* **кыз урлау**. *Боларда кабиләчелек талашлары, җәйләүләре, кымызлары, калымнары, кыз качырулары, тагын әллә нихәтле безнең өчен яңа, ят булган экзотикалары белән күз алдына бастырылган казакъ хәяты да бар.* Г.Нигъмәти. *Ләкин егет бер ахмаклык эшли: ат яллап, кызны качырып алып киткән төнне ул бер уңайдан Гали абзыйның капкасын да дегеткә буяп китә.* Ә.Еники

**КЫ́З КИЛЕШҮ** *и. этн.* Ата-анасыннан яки якын кардәшләреннән кызны кияүгә бирергә ризалык алу. *Болар тотканнар да миңа күрше авылдан бер кыз килешеп куйганнар.* Г.Ибраһимов. *Аларның байтак өлеше, мәсәлән, кыз сорарга бару, килешү, никах укыту, кияү каршылау, «ишек бавы» йоласы, бүләк бирешү, кияү мунчасы, килен төшерү, су юлы күрсәтү, туй күтәрешү кебек горефләр, заман рухына ярашып, бүген дә дәвам итә һәм безнең йола иҗатының милли рухын билгели.* М.Бакиров

**КЫ́З КУЕНЫНА КЕРҮ** *ф. этн.* Никахтан соң кияүнең беренче тапкыр кыз янына куна керүе. *Кыз куенына кергән чакта, Егет шадырланадыр.* Җыр. *Ә патшаның кыз куенына керәсе бик килә.* Әкият. *Бу мәҗлесләр барчасы тәмам булганнан соң, кияү кыз куенына керәдер.* К.Насыйри

**КЫЗ-КЫМЫЗ** *җый. и. сөйл. к.* **кыз-кыркын** (*1 мәгъ.*). *Ә Нурулла кызлар күзенә ешрак чалынырга кирәк, Гаделияне күреп әйтмәсләрме дигән өмет белән, тагын кыз-кымыз тирәсенә елышты.* И.Гази. *Шигърият дип җан атып тормаган бу заманда (андый заман юк та бугай) һәр талантның халык файдасына тулырак көчендә эшләве безнең өчен бик мөһим. Шигърият мәйданында, ир-егетләрдән бигрәк, кыз-кымыз мәш килгән чорда бигрәк тә.* Р.Фәйзуллин

**КЫЗ-КЫРКЫН** *җый. и.* 1) Төрле яшьтәге кызлар. *Аннары гармун тотып егетләр килде, күрше татар авылыннан җәяүләп кыз-кыркын, ишәкләргә атланып, карчык-корткалар һәм остабикә килде.* М.Галәү. *Җилферди киртәдә Эленгән ак чыптам. Көлешә кыз-кыркын: – Ай чыккан! Ай чыккан!* Н.Гамбәр. *Еш игътибар итәм: егетҗилән генә түгел, орчык буйлы гына кыз-кыркын да машинада чатыр чаба хәзер.* Л.Лерон

2) *тар.* Әсир төшерелеп колга әйләндерелгән хатын-кызлар, кол кызлар, көңнәр, җарияләр, кәнизәкләр. *Өлкән хатын ул ашау-эчүне, өй караучы, кием-салым җитештерүне, терлек карауны, бинең бүтән хатыннарын, барлык балаларын, колларын-чураларын, кыз-кыркыннарын үз кулында тотарга тиеш иде.* Н.Фәттах

**КЫЗЛЫК** *и.* **1.** 1) Кыз (*1–3 мәгъ.*) хәле, кыз булу. *Каргалының атларында Тезген бавы мунчала, Кызлыкларын белдергәннәр Су илткәндә мунчага.* Бәет. *[Мәрьям] --- ачык, аңлы карашлы кызлар, китаплар, сөйләнгән яңалыклар эчендә үзенең кызлыгын, кыз йөрәклеген сизә башлады.* Г.Ибраһимов. *Мондыйлар олыгаеп карчык булгач та кызлык чалымнарын җуймыйлар.* Р.Зәйдулла

2) Кыз чак; кызның кияүгә чыкканчы үткән вакыты. *Закир кияүнең көймәсенә өч ат җигеп, Гөлбануны иптәш кызлары белән бергәләшеп шул көймәгә утыртып, кызлык гомере үткән яланнардан, таулардан, урманнардан йөртеп, исәнләштереп кайтарганда, бу өч арчи бөтенләй әзерләнеп беткәннәр иде инде.* Г.Ибраһимов. *Ләкин Әминә, бу сәбәпкә бер дә исе китмичә, башка төрле сәбәпләр күрә иде: уналтыунҗиделәрдә үк кияүгә чыкканда, кызлык вакыты бик әрәм кала --- дип уйлый иде.* Ф.Әмирхан. *Кызлык, кызның алтын чоры узып бара.* А.Гыйләҗев

3) Гыйффәт, бәкярәт, бикер. *Синең кызлык өлешеңә кул ягарга кыенсынам [Бибинур].* А.Гыйләҗев. *Җиңсәгә керү юлы кызларда тоташтыргыч яры – кызлык пәрдәсе белән капланган була.* Биология. *Кызлык пәрдәсе дә зарарланмаган килеш Линаның йөкле булуына табиблар да шаккаткан.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Гаиләгә бала итеп, балалыкка. *Шушы баланы үзебезгә кызлыкка алып үстердек.* Ш.Камал. *Туктагыз әле, ә ни өчен сез бирәр баланы уллыкка яисә кызлыкка алмыйсыз?* Г.Гыйльманов

**КЫЗЛЫКЛЫ** *с.* Гыйффәтле, җенси мөнәсәбәттә булмаган. *Яңалык – кызлыклы кыз кебек, Искелек – тол хатын кебек.* Мәкаль. *Әйтелмәгән сүз — кызлыклы кыз шикелле, әйткән сүз – әби карчык шикелле.* Мәкаль

**КЫЗМА** *и.* 1) Югары температурага кадәр кыздырылган һәм чүкү өчен әзер булган металл кисәге

2) *диал.* Кызулык, ярсу. *[Шәкерт:] Үземне үзем белмичә, чиктән тыш бер кызма белән, кармакны яр башына аттым.* Г.Ибраһимов

◊ **Кызма тоту** *сир.* Исерү. *Тәмам шунда исердек, Бөтен бит-баш кызарды, тотты кызма.* Г.Тукай

**КЫЗМА́ЧА** *с.* **1.** Исерткеч эчемлек эчеп бераз исереп алган, беркадәр исерек, салып алган. *Шәрәфи агай аңар: – Утыр, якташ! Әнә солдат янына, – дип урын күрсәтте. Ул бераз кызмачарак иде.* Ш.Камал. *Ләкин ул [шагыйрь] бүген дә кызмача иде шикелле.* Ә.Еники. *Галиулланың сүзенә түзгән дә булыр иде әле, кызмача кеше ни әйтмәс.* Р.Зәйдулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Исерек килеш, салган баштан. *Үзенең мужик исәбендә [җизнә] егетне кыз янына бераз кызмача кертүне уйлады.* Г.Ибраһимов. *Иптәшләрен белешергә дип чыгып киткән Миңлегали бераздан кызмача кайтып керде.* М.Мәһдиев. *Нәрсә булды, чынлап та, ничек болай кызмача кайттың әле?* Җ.Юныс

**3.** *хәб. мәгъ.* Исерек хәлдә булу. *Ул үзе [Шәрифулла], бераз эчеп алганга, кызмача.* Ә.Еники

◊ **Кызмача баштан** *к.* **кызган баштан.** *Аны эчтек тә, кызмача баштан, коеныр урын эзләргә керештек.* М.Галәү. *Дөрес, урамда кызмача баштан күренүем шул бер генә булды.* М.Мәһдиев. *Икенче тапкыр, кызмача баштан: «95 яшь тулды бит инде сиңа, җен*

*карчыгы, тагын күпме яшәргә җыенасың?» – дип бәйләнде.* Шәһри Казан

**КЫЗМА́ЧАЛЫК** *и.* Беркадәр исерек булу. *Әхәт, кызмачалыгын яшерергә тырышып, иреннәрен кысты, шым гына эчкәрге ак якка узды.* А.Гыйләҗев. *Аның кызмачалыгы алдан ук бар иде булса кирәк.* Ф.Яхин. *– Нишләп әле синең мужигың булыйм мин? – ди, аңа каршы кызмачалыгы күзенә чыккан Мисбахетдин, тәкәбберләнеп. – Хатыныммени син?!* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗ-МЫЗ** *җый. и. сөйл. к.* **кызкымыз**

**КЫ́З ОЗАТУ** *и. этн.* Кияүгә чыккан кызны кияү өенә җибәрү, озату. // Шуның белән бәйләнгән йола. *Иделләр кичеп, юлда кунып, Кыз озатырга ла килдек без.* Җыр. *Печән өсләре якынлашу белән инде кыз озату, килен төшерү чорлары керер.* Г.Ибраһимов. *Никах төне кыз ягында үткәндә, әлбәттә, туйның үзенә бәйләнешле төп йолалар кыз ягында башкарыла, һәм алар түбәндәгеләрдән тора: кыз елату, никах укыту һәм никах мәҗлесе үткәрү, кияү каршылау, туй мәҗлесе уздыру, кыз куйнына керү, архаик йолалардан янә кияүләп йөрү һәм, ахыр килеп, кыз озату.* М.Бакиров

**КЫ́З СОРАУ** *ф. этн.* Кызга өйләнер өчен, аны ата-аналарыннан яки якын туганнарыннан хатынлыкка сорау. *Әнисен, Ходайга тапшырып, күрше авыл мулла кызын сорарга да йибәрде.* Г.Исхакый. *Кыз сорарга килгән кеше чалбарының бер балагы төшкән, берсе менгән була. Бер балагы чыгарылган була. Бу – кыз сорап килүнең билгесе.* Г.Юсупова, Ф.Юсупов. *Галимулла таң белән китеп барды. «Кыз сорарга кирәк булса, мине чакыр, җырлатып алып кайтырбыз!» – дип тә әйтте әле йокы аралаш саубуллашып калган авылдашына.* Ф.Яхин

**КЫЗТӘКӘ** *и. гади. с.* 1) Ирлек һәм хатынлык билгеләренә ия, шул исәптән ир-ат һәм-хатын-кыз җенси әгъзалары да булган организм; хонса, гермафродит. *Ләкин кызтәкә Хәлилә белән укытучы Билал ни турында сөйләшә, берсе дә белми, белсә дә, тыңлап торсалар да, алар берни дә аңламаган булыр иде.* Р.Батулла

2) *кимс.* Хатынша, хатын-кызлар эшенә тыгыла торган ир кеше

3) *кимс.* Ирдәүкә, кыланыш-торышы белән ирләргә охшарга тырышкан кыз, үз-үзен ирләргә охшатып тоткан кыз

**КЫ́З ТУГАН** *и.* Хатын-кыз җенесендәге туган-тумача. *Өч кыз туган, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.* Әкият. *Куандыкка мин кыз туганнарыма кунак булып кайткан идем.* Ә.Еники. *Мөхәммәтсадыйкның кыз туганнары булганмы-юкмы, әлегә билгесез.* Л.Хәмидуллин

**КЫЗУ** I *ф.* 1) Эсселәнү, югары температура барлыкка килү (берәр предмет тур.). *Кызган тимер белән көйдереп бетерер идем мин аларны [угрыларны]!..* Ә.Еники. *Ул арада уттагы тимер дә кып-кызыл булып кызган.* Ф.Яхин. *Әнә хатын кайнаган чәйнек астына да, кызган таба астына да сезнең китапны куеп кинәнә.* Ф.Дәүләтбаев

2) Һава эсселәнү, һаваның температурасы югары күтәрелү. *Һава бөркү. Кыза дөнья, сабыр җитми, Җил исми аз гына да, бер генә яфракны селкетми.* Г.Тукай. *Тик кызган һава тиз генә суынмады.* Г.Гобәй. *Өй эче шартлар хәлгә җитеп кызган иде.* А.Хәлим

3) Утта, табада пешү, пешеп, ашамлык хәленә килү. *Бераздан борыннарга утта кызган бәрәңге исе бәрелде.* К.Нәҗми. *Гөлбану ике генә чынаяк эчеп өлгерде, тигез кызалармы икән дип, мичне ачып, икмәкләрен карады да яңа оеган катыкны күтәреп тышка чыкты.* Г.Ибраһимов

4) Дымлылыктан җылынып бозылу, чери, бурсый башлау (печән, ашлык һ.б.ш.). *Гәрәбә бодайлар каралалар, күгәрәләр, кызалар, төтенләп яна башлыйлар.* И.Салахов. *Басудан керсә ни, амбарда кызган ашлык әйләндереп бер булабыз. Ашыктырып кертеп тутырттырдылар да, әнә кызып ята игеннәре.* Д.Булатова. *Төнгә кадәр эшлибез, арыттыра, өйгә кайтып тормыйча, кызган ашлык өстенә ятып йоклыйбыз.* Кызыл таң

5) Тәннең температурасы күтәрелү, эсселәнү. *Мәгъсүм торып утырды, анасының кулыны үпте, янә аркасы үзрә ятты, тәннәре кызып, сусаган кеби булып, су сорады.* З.Һади. *Тәннәрем бер кызды, бер туңды.* М.Әмир

6) Җылыну (двигатель тур.). *Кызган мотордай, Сабир да кызды.* А.Алиш. *Автомобиль бензинда эшли башлап, двигатель билгеле бер температурага кадәр кызгач, автомат рәвештә метанга күчә.* Безнең гәҗит

7) Тизлекне арттыру, йөрешне тизләтү. *Трактор төтен чәчеп кызып китте.* М.Гафури. *Баш килә, шундый каты, шундый кызып, полный ход килгән трамвайдан узып.* Г.Тукай

8) *күч.* Җанлану, җанланып китү; шәбәю, интенсивлашу. *Төш алдына хәтле бәйрәм кызмады.* Ш.Камал. *Уеннарның кызган чагы, болын өсте яшьләр белән кайнап тора.* М.Галәү. *Сөйләшүнең иң кызган җирендә бака тавышы белән телефон чөрелдәп куйды.* Ә.Дусайлы // Көчәю, көчәеп китү. *Ләкин ачу моның белән бетми, Кызган саен кыза тагын да.* З.Мансур. *Авылда хәзерге көндә сыйнфый көрәш иң кызган вакыт.* Һ.Такташ

9) Зур киеренкелек барлыкка килү, вакыйгалар катлауланып китү. *Сәяси тормыш кызып, тыныч тору дәверенең канлы корбаннарын китереп чыгаруга барып җитә.* Г.Нигъмәти

10) *күч.* Ярсу, ярсып китү. *Шибай карт авырып ята иде, шулай да кызмады, бераз көлде.* Г.Ибраһимов. *[Госман:] Гайшә апа, кызмагыз әле, Зәйтүнә бик дөрес эшләгән...* С.Поварисов. *– Әхәт Сабирович, кызма инде. Тынычлан. Эчмәгән кешенең авызына коеп булмый бит, – дип тынычландырырга тырышты аны банкир.* Р.Мөхәммәдиев

11) *күч. сөйл.* Беркадәр исерү, исерек хәлгә килү. *Батыргали агай, бик исерек булмаса да, яхшы ук кызган, күз аллары томалана башлаган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Әхмәди яхшы ук кызган, башкалар да бераз кызмачалар, егет гармонен бик нык тартып уйный.* А.Әхмәт

12) *күч.* Кызыгу, кызыксыну уяну. *Хатка каршы хат языйм! Эчтән уйлыйм: – Тукта, дим, кызлар кызарлык шәп языйм.* Ш.Бабич. *Шулкадәр зур дәүләт иясе булганга, башка кешеләр*

*һәрвакыт кызып карыйлар иде.* Г.Исхакый

13) Түмен таба башлау, мавыгып китү. *Тора-бара уенчылар кыздылар*

◊ **Кызган баштан** Исерек килеш, исерек хәлдә, салган баштан. *Кызган баштан чатыр чабып, атны күбеккә батырып авылга кайтып кердем дә урам уртасында тавыш чыгардым.* М.Мәһдиев. *Әгәр кызган баштан сугышка чыгып, аларны бәхетсезлеккә дучар итсәгез, үзегез үк үкенәчәксез бит, җан тынычлыгы тапмаячаксыз.* М.Кәбиров. --- *ул, чынлап та, колхоз амбарына ут төрткән булган. Кулак дип, келәтеннән соңгы икмәген алып чыгып киткәч, кызган баштан барган да төрткән…* Г.Гыйльманов. **Кызган табага бастыру (утырту)** Кемне дә булса бик нык тиргәү, орышу, ачулану; утлы табага бастыру. *Шулай ул, меңләгән кешене кызган табага утырткандай авызына каратып, очкынлы сүзләрен як-якка чәчте-чәчте дә сүзне кинәт икенче якка борып җибәрде.* Н.Фәттах. *Ә мин ике ревизия арасында ут йотып, әнә көям, менә янам дип, кызган табага баскандай сикергәлим.* И.Салахов. *Кызган табага да утырганны Кайчакларда сизми каласың.* Ә.Ситдыйкова. **Кызган тимер белән көйдерү** Барлык чараларны кулланып, нәрсәнедер һич аяусыз юк итү, бетерү. *Һәртөрле җебегәнлекле салкынлыкны, җавапсызлыкны кызган тимер белән көйдерәчәк.* Ә Еники

**Кыза бару** Торган саен кызу. *Ә мәҗлес кызганнан-кыза бара.* Ә.Еники. *Аңлый ул: хәзер Зәйнулла, эчтән кыза барып, килүчеләргә бәйләнергә юл эзләячәк.* З.Зәйнуллин. *Кояш күтәрелгән саен, Сабантуй кыза барды.* Ф.Яхин

**Кыза башлау** Кызарга тотыну. *Болайга киткәч, Гыйльми түти дә кыза башлады.* Г.Бәширов

**Кыза китү** *к.* **кызып китү**. *Ә кияү инде кыза киткән иде.* М.Мәһдиев

**Кыза төшү** Элеккедән дә ныграк кызу. *– Кем соң сез, профессиягез буенча кем? – дидем, үзем дә сизмәстән кыза төшеп.* Ә.Еники. *– Зур Рәсәйнең проблемасы да зур аның, – диде Илвир кыза төшеп.* М.Шаһимәрданов. *Бераз кыза төшкәч, бу сакаллы тагын сикереп торды: «Милләт өчен! – дип кычкырды. – Торып басып эчик».* Р.Зәйдулла

**Кызып алу** Исереп җитү. *Мәҗлес уртасында, бераз кызып алгач, сүз тагын төсле тәнлеләр тирәсендә бөтерелә башлады.* Р.Батулла. *Бераз кызып алгачмы, әллә үртәлепме яки артык мактап ташлаулары күңеленә хуш килепме, ни сәбәпледер җырлап җибәргән бу.* Ф.Яхин. *Заһри кода да ярыйсы гына кызып алган иде.* М.Мәһдиев

**Кызып бару** *к.* **кыза бару**. *Мәҗлес әле кызып кына барса да, [Хәлил] кузгалырга вакыт җиткәнлеген чамалады.* Ә.Еники. *Официантка, аларның кызып барган әңгәмәсен өзмәскә теләп, тын гына кайнар солянкалар китереп куйды.* А.Гыйләҗев. *Кызып барган манзарабызны сүрелдерергә теләпме, әллә инде карт кешене тынычландырырга теләпме, моңа кадәр дәшми генә утырган бер журналист әйтә куйды: ---.* Шәһри Казан

**Кызып бетү** Тулысынча кызу. *Кызып беткән уен, сугыш бу вакытта туктап тора.* М.Мәһдиев

**Кызып җитү** Тәмам кызу. *Сафа белән Саҗидә бии-бии тәмам кызып җиттеләр.* М.Галәү. *Мәүлиха тәмам кызып җиткән, аның борын канатлары селкенгәләп китә, күзләре ачулы карый иде.* Г.Бәширов. *Зәйнәпнең тавышы куркыныч булып, коточкыч булып яңгырады. Тик Ильяс та кызып җиткән иде инде.* К.Тимбикова

**Кызып китү** Кинәт кызу; хәзер, шушы минутта кызу. *Дусларның хәзергә кадәр кызып китә алмаган сөйләшүләренә дә җан керде.* Ф.Әмирхан. *– Әх син, туң күчән, иштең ишәк чумарын! – дип кызып китә хәлфә.* Ә.Еники. *Тегенең [председательнең] кызып китеп артыгын әйтеп ташлый торган гадәте бар иде.* З.Зәйнуллин

**Кызып ташлау** *к.* **кызып китү**. *– Алай булгач, Сабан туенда мәйданга чыгып көрәшик без, кем җиңә, Сөембикә шуңа була, – дип кызып ташлаган, ди, Тәфкил.* М.Шаһимәрданов

**Кызып тору** Кызган хәлдә булу. *Элекке кебек тоттыру кая, пырыхпырых итеп, үзалдына холыксызланып, кызып тора [ат].* Г.Ибраһимов. *Ул үзе яңакларының бик озак кызып торуын сизеп алды.* Г.Әпсәләмов

**Кызып чыгу** Тәмам кызу. *Дежур хатынның бите тимгел-тимгел кызып чыкты.* А.Гыйләҗев

**КЫЗУ** II *с.* **1.** 1) Кызган, эсселәнгән; югары температуралы, бик эссе. *Социалистик илебез тарихи, зур вакыйгалар алдында торган чакта, сез, мунчаның кызу ләүкәсеннән чабынып төшкән картлар төсле, хәлсезлеккә сабышкансыз.* К.Тинчурин. *Гөлбануның өстеннән тау төште, мичennән күмерләрен бер чүлмәккә алып сүндерде, куна такта өстендә камырны зур-зур икмәкләр ясап әвәләде, онлады да кызу мичкә тыкты.* Г.Ибраһимов. *Шатлык килә кызу ялкын булып, Күтәрелеп домна мичennән ---.* Х.Рахман

2) Эссе һавалы, эссе. *Көн кызу булырга чамалый иде.* М.Галәү. *Шушындый кызу көндә өйдә утыру бик үк рәхәт булмаса да, солдаттан кайткан егетнең бөтен эч сере, үткәннәре белән уртаклашмагач ни була, ди, ул?* Ф.Яхин. *[Мальтада] Җәйнең иң кызу көннәрендә дә эсселек егерме биш градустан күтәрелми, кышның иң салкын көннәрендә дә термометрның терекөмеше плюс ундүрттән аска төшми.* М.Юныс

3) Зур тизлекле, тизлеге зур булган; бик тиз бара, ага, үтә торган. *Ишек алларында, тыкрыкларда, урамнарда кызу хәрәкәт башланды.* Г.Бәширов. *Шәмси салкын су берлән юынып, тәнендәге ялкаулыкларны өстеннән төшерү өчен кызу-кызу хәрәкәтләр ясап барганда, Анна Васильевна миләш төбендәге өстәлгә аш урыны хәзерләгән, ап-ак ашъяулык өстенә тәрилкәләр, чәнечкеләр, салфетлар куйган иде.* Г.Исхакый. *Юыла-юыла агарып беткән кәчтүм-чалбары, чалбар балакларын кыстырып куйган оекбашлары, йомшак башмаклары, киез эшләпәсе һәм дә кызу-кызу адымнары аңа бик килешеп тора иде.* Ф.Яхин

4) *күч.* Киеренке, ашыгыч башкарыласы эшләр күп булган. *Шуңа күрә дә, «Һәйәт» идарәсе урнашкан йортта ул көннәрне кызу эш кайнап торды.*

М.Галәү. *Болар кайтып йортка кергәндә, инде монда иртәнге эшкә кызу хәзерлек башланган иде.* Г.Ибраһимов. *Ничек инде ул, шундый кызу эш вакытында сугыш башлыйлар?* М.Мәһдиев. *Җитмәсә ул да [Хәйретдин агай да] кызу эш өстендә каланчада йокы симертә.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Бик көчле, каты; вакыйгаларга бай булган. *Яңадан бер-ике сәгатьлек гаять кызу сугыштан соң, дошман көймәләре качарга тотындылар.* Ф.Әмирхан. *Бу еллар – кызу сыйныф көрәше, революция көрәше еллары.* Г.Нигъмәти. *Һәркайда таралып яткан җимерек коймалар, кыйшайган йортлар, җимерек коелар гына кайчандыр монда кызу тормыш барганлыгы, язмышлар яшьнәгәнлеге хакында сөйли.* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Бик көчле, дәртле, тирән, кайнар (хис тур.). *Алар кызу, кайнар мәхәббәт белән тулган хатлар языштылар.* А.Шамов // Хисле, тойгылы, хискә бай, тойгыга бай. *Гөл битеннән үпсәм кызу ирнем белән, Бар вөҗүдемне илаһи бер мөкатдәс нур баса.* М.Гафури. *Кызу дәрт*

7) *күч.* Тиз ярсый торган, тиз әсәрләнүчән, тиз кабынучан, хискә тиз бирелүчән. *Берәү кылыч булса, берәү кын булсын, берәү кызу булса, берәү тын булсын.* Мәкаль. *– Кызуын кызу түгел мин, ләкин юләрен юләр инде, – диде.* А.Шамов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Һава эсселәнүенең, җылынуының югары дәрәҗәсе, эсселек. *Мунча җәһәннәм кебек кайнады, кызуга чыдарлык хәл калмады, сулыш алырга һава бетте, чуаш карчыгы үзе, кызның түзә алмый акырынуына карамастан, ләүкәдә аны туктаусыз әйләндерә башлады.* Г.Ибраһимов. *Шаушулы ыгы-зыгысы, тынны кыса торган кызуы, тәртипсез гөрелдәве белән көндез мине чуалта, томаландыра һәм ялкауландыра да Хәятны үзенә кирәкле мәсьәләдән аерып тора иде.* Ф.Әмирхан. *«Самавыр куйсаң, самавырга юшкыны утырмый, җәйге кызуда урак урганда эчеп җибәрсәң, үзенең салкынлыгы бөтен тәнгә тарала, әллә нинди баллы эчемлекләрең дә кирәкми!» – дип куялар [Миләүшә авылы халкы елга сулары турында].* А.Алиш

2) Дәрт, көчле хис. *Кызу сүнде йөрәктә.* Г.Тукай. *Йөрәкләрендә утыз ел элек кабынган мәхәббәт ялкынының кызуы басылмады.* Г.Минский

3) Температура. *Гөлбану үзенең кечкенә дусты Фагыйльне бүген авыру кызуында менә шул вакыты, шул җиләкләре белән сагынды.* Г.Ибраһимов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Югары температура хасил итеп, эссе булырлык итеп. *Мунча үзе, кергәч тә башны куырып алырлык итеп, кызу ягылган.* М.Гали. *Мунча чиксез кызу ягылган, тәнне пешерерлек итеп эссе салынган иде.* М.Галәү. *Шуннан ике сәгать үткәч, [карчык Хәернисаны] кызу ягылган кара мунчага алып барды.* Г.Ибраһимов. *Кызу яну*

2) Тиз, шәп, ашыгып; зур тизлек белән. *Ул сүзне кызу сөйли һәм «инде»ләрне күбрәк ычкындыра иде.* Ш.Камал. *[Анна] Кызу-кызу иттереп ишекне шылтыратты.* Г.Исхакый. *Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.* Ә.Еники

3) **кызуында**. Кызган вакытта, кызган чакта. *Бервакыт җәйнең кызуында, эш өстендә, боларның усаллыкларына чыдый алмыйча, хезмәтчеләре чыгып киткән.* Әкият. *Шатлыкның кызуында туйны итик.* М.Фәйзи

**4.** *хәб. функ.* 1) Эссе, температурасы югары булу. *Өйдә чыдап булмаслык кызу.* Ф.Яруллин. *Палаталары бик кызу икән. Форточканы гел ачык тоталар.* Ф.Яруллин. *Көннәр бик кызу тора, игеннәр дә ярыйсы гына.* М.Мәһдиев. *Көне дә бүген артык кызу.* Г.Галиева

2) Киеренке булу, тизрәк эшләп бетерәсе булу. *[Ирбулат:] Беләсең, бездә хәзер эш нинди кызу.* Р.Ишморат. *Исәнтәй бәйләнеп тормады: эше кызу иде.* Н.Фәттах

3) *күч.* Тыныч түгел, ярсу. *Кит лә, кояш! Уйнап йөрмә монда, Болай да бик кызу йөрәктә.* Һ.Такташ

◊ **Кызу канлы** Тиз ярсучан, кызып китүчән. *Әмма ачуы кузгалган кызу канлы Гайния бу эшне болай гына калдыра алмады.* Ф.Хөсни. *Үзе холыкка җиңел, кызу канлы иде Вәликәй Капар малае Миңлебай.* З.Зәйнуллин. *Өйдәге, чоландагы, тагын синнек-келәтләрдәге күгәрек исле барча иске-москы туннар да кызу канлы Газзә тарафыннан җентекләп тикшерелде.* М.Шаһимәрдәнов. **Кызу канлылык** Тиз ярсучан, кызып китүчән булу, хискә бик тиз бирелүчәнлек. *Икенчедән, Казанны саклаучыларны символлаштыра торган Чура батырның үз-үзен тотышында да вакыт-вакыт кызу канлылык, дуамаллык һәм күбрәк үз көченә генә таяну кебек сыйфатлар да сизелеп кала.* М.Бакиров. **Кызу кулдан** Бер кызгач, бер кызып киткәч. *Кызу кулдан [бу эшне] бетереп алдык.* Г.Ибраһимов. *Исән-сау калган кешеләрнең күбесе фронттан кайтканга күрә, урамнарда ир-ат күбәйде, кызу кулдан туй уйнатып алучылар да булгалады.* Ә.Еники. **Кызу табигатьле** *к.* **кызу канлы**. *Кызу табигатьле, көчен кая куярга белми торган Григорян үз взводына күтәренке күңел белән кайтты.* Г.Әпсәләмов. **Кызу тоту** 1) Тиз эшләү, озакка сузмау. *Шул арада Исак килеп керде. – Ну, егетләр, кызурак тотыгыз, бүген бетерергә кирәк, иртәгә калмасын, кич белән неводчылар килә, иртәгә невод салырга булыр, – диде.* Ш.Камал. *Эшне кызу тоталар.* Р.Әмирхан. *Ярман кәмпүтере эшне ай-һай кызу тота икән: өч көннән безне чакыртып та китертте.* М.Шаһимәрдәнов. 2) Ашыктыру, тизләтү. *Алар вакытны бик кызу тотарга һәм бөтен эшне күз ачып йому тизлегендә башкарырга булдылар.* Г.Минский. **Кызу холыклы** *к.* **кызу канлы**. *Әти – горур һәм кызу холыклы нәселдән.* Безнең гәҗит

**КЫЗУЛАНУ** *ф.* 1) Кызу, эсселәнү, температура күтәрелү (һава тур.). *Җәй йитеп, көн кызуланган саен, кан сыекланганнан-сыеклана бара.* Г.Исхакый

2) Тизлекне арттыру; йөрешне тизләтү. *Ат кызуланганнан-кызуланды.* Г.Исхакый. *Бер сәгать тә, сәгать ярым да узып китте, полк шулай кызуланып баруында дәвам итте.* Г.Бәширов. *Бер авылны узып, кызулана гына башлыйсың, алда икенче авыл күренә.* Шәһри Казан

3) Ашыгу, кабалану. *[Үрдәкләрнең] Арттагылары, быкылдауны тагы арттыра төшеп, кызулана-кызулана, ярлардан тәгәрәп төшteләр.* Г.Исхакый. *Кыз, балаларча чынлык белән, бөтен вакыйганы яңадан, каушап, кызуланып сөйләп бирде.* Г.Ибраһимов

4) Ярсу, ярсып чыгу, кызып китү, әсәрләнү. *Вәли кызуланып сугам дигәндә, Фәтхи тайпылып кала.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Яшермим, мин Уфадан шактый кызуланып кайткан идем.* А.Хәлим. *Кызуланып әйткән сүзләренең рас килүеннәндерме, Гөлсинә апа ул вакытта әле аңышып та бетми.* Ватаным Татарстан

5) Җанлану; көчәю, шәбәю. *Соңыннан, нинди генә кыенлыклар булса да, эшләр кызулана, киң колач җәеп җибәрә.* Ватаным Татарстан

**Кызулана бару** Торган саен кызулану. *Глобализация, ассимиляция кызулана барган саен, хәл катлаулана, четерекләнә генә бара.* Р.Фәйзуллин

**Кызулана башлау** Кызуланырга тотыну

**Кызулана төшү** Бераз кызулану. *Иделнең салмак агымы кызулана төшкән туры[сыннан] узышлый, Гәрәй уйчан гына әйтеп куйды.* К.Нәҗми

**Кызуланып алу** Беразга кызулану

**Кызуланып бару** *к.* **кызулана бару**. *Манёврлар әле яңа гына кызуланып бара башлады.* Һ.Такташ

**Кызуланып йөрү** Күпмедер вакыт кызуланган хәлдә булу. *Бер көн иртә белән начальник белән могавин (ярдәмче) икесе дә кызуланып йөри, надзирательләр чабыша, әбрәкәйләр тазартылды, карбулка сибелде, өй аллары белән коридорларга нарат майлары сибелде...* Г.Бубый. *Мәнә-мәнә яңгырлар башланмагае дип, шуңарчы уракны ничек тә төгәллисе иде дип, бик тә кызуланып йөргән көннәр иде бу.* Р.Төхфәтуллин

**Кызуланып китү** Соңгы вакытта, ниндидер вакыттан яки вакыйгадан соң кызулану; ярсуын тота алмау. *– Ә азәрбайҗаннарга каршы сез нәрсә әйтә аласыз? – дип кызуланып китте мәдәният министры Әюп улы.* В.Исламетдин

**КЫЗУЛАТУ** *ф.* 1) Тизләтү, шәбәйтү. *Оста йолдыз ярып килә торган көймәне күргәч тә юлын кызулатты.* Г.Исхакый. *Ул, авылга кергәч, йөрешен кызулатты.* Ш.Камал. *Эшне кызулаттылар.* А.Алиш

2) Ашыктыру

**Кызулата башлау** Кызулатырга тырышу

**Кызулата бару** Торган саен ныграк кызулату. *Хәрәкәтләрне башта салмак эшләү, ә аннары кызулата бару*

**Кызулата төшү** Тагын да ныграк кызулату. *Рәхмәй абзыйсы атны кызулата төште, һәм алар тузан, йон, сөт исе аңкыган көтүнең нәкъ алдыннан уздылар.* Ә.Еники. *Әдһәм, адымнарын кызулата төшү генә түгел, хәтта чаба ук башлаганын үзе дә сизми калды.* Ф.Хөснетдинов. *Илвир Чулманский адымнарын кызулата төште.* М.Шаһимәрдәнов

**Кызулатып җибәрү** Соңгы вакытта гына, хәзер кызулата башлау. *Эшне кызулатып җибәрделәр*

**КЫЗУЛА́У** *ф.* **1.** 1) Тизлекне арттыру; тиз бара башлау. *Поезд кызулый. Вагон тәгәрмәчләре рельс ялгаулары өстеннән тигез тавыш белән сугып үтүләрен ешлата баралар.* Ә.Еники. *Ялына, маңгай чәчләренә, койрыгына төрле төстәге тасмалар, тимер, бакыр кисәкләре тагылган акбүз ат, су исе, кырлар исе сизеп, куанып кешнәп җибәрде, куганны да көтмәстән, кызуларга тотынды.* Н.Фәттах. *Ләкин арыган аяк буыннары аны тыңламый интектерде: адымнары ешайса да, әллә ни кызулый алмады ул.* Г.Гыйльманов

2) Ашыктыру, тизләтү. *Урам буйлап үтеп-сүтеп йөрүчеләрнең беришесе, --- кинәт туктала да, башын чайкап, тоткыннар төркеменә бик озак карап кала, ә беришесе, киресенчә, --- адымын кызулый иде.* М.Галәү. *Шәмси арбачыны кызулый-кызулый кайтып керде.* Г.Исхакый. *– Әнә теге зәңгәр тәрәзәле йорт, узмагаек тагы, [атларны] алай кызулама, – диде әни.* Н.Гыйматдинова

**2. кызулап** *рәв. мәгъ.* Тиз-тиз, шәп итеп, ашыгып. *Ул [ай], шундагы элек чыккан йолдызларны куып йитәргә теләгән кебек, кызулап йөзәргә кереште.* Г.Исхакый. *Исәнтәй кызулап төньякка таба юнәлде.* Н.Фәттах. *Гыймаделислам, ярык каба төбе белән нык кына кизәнеп, Бибиәсманың җилкәсенә тондырды һәм кызулап өйдән чыгып китте.* Д.Каюмова

**Кызулап тору** Бертуктаусыз кызулау, ашыктыру. *Шуңа күрә дә Сабир бүген үзе чуерташ юучыларны кызулап торачак, инженерга әйтеп, мотористның «кнопка»сын бераз басачак.* А.Алиш

**Кызулый бару** Торган саен кызулау. *Фәрхетдин ирексездән кызулаганнан-кызулый барды.* А.Расих. *Түбәнгәрәк төшкән саен, чәнәшкәң һаман кызулый бара.* Г.Бәширов

**Кызулый башлау** Кызуларга тотыну

**Кызулый төшү** Бераз кызулау; тагы да кызулау. *Саткай, ахрысы, хәл җыя баргандыр: болын уртасындагы зур таллыкларны үткәч кызулый төште.* Г.Ибраһимов. *Ул, авылга кергәч, бабайны әйдәп, тагы да кызулый төште.* Г.Гобәй. *Алар [Тотыш белән Аппак] атларын кызулый төштеләр.* Н.Фәттах

**КЫЗУЛЫК** *и.* 1) Эсселек, эсселек дәрәҗәсе, югары температура. *Ул аның башын тотты. Ут кебек яна торган баштан кызулык өреп китте.* Г.Исхакый. *Көннең кызулыгы кайта башлаган булса да, сулыш алырга авыр иде.* Ш.Камал. *Өй эчендәге кызулыктан миләр пешәрлек була.* Г.Галиева

2) Тизлек. *Зәһәр ысылдап, Ибәтулла абзый Гамисны күтәреп җиргә бәрде дә, атына атланып, килгән кызулыгы белән чаптырып китеп тә барды.* М.Галиев. *Тикшерү пунктына якынлаша башлаганда, шофёрым кызулыгын киметте.* Безнең гәҗит

3) Ашыгычлык. *Аннан соң да озак ял итеп ятмадылар, тиз-тиз генә тамак ялгап алдылар да шул кызулык белән елга аръягындагы басуларга чыгып киттеләр.* Г.Гыйльманов. *Бераз тынычлана төшкәч, үзенең кызулык белән иренә әйткән сүзләрен кабат-кабат исенә төшерде һәм бу гаугага үзенең төп гаепле кеше икәнен аңлады.* Д.Каюмова. *Ул кызулык белән Сөмбел апага да кимсетүле сүзләр әйтеп ташлый.* Безнең гәҗит

4) Нинди дә булса эшне тиз башкарырга омтылу, ашкынучанлык. *Ал-*

*тынбай гаҗәп бер кызулык белән эшкә тотынды, бер көн кичектерми, кар яуганчы яңа хуҗалыгын аякка бастыру эшенә керешге.* Г.Ибраһимов. *Яшьләр шунда ук суд ясарга хәзерләнделәр. Тик Петров кына аларның кызулыгын бераз сүрелдерде.* К.Нәҗми. *Карт урманчының бу сүзләре Газинурның кызулыгын беркадәр сүрелдерде.* Г.Әпсәләмов

5) Җанлылык, активлык. *Кешеләр Насрыйның сүгенүенә илтифат итмәгән төсле кылансалар да, көлү, кычкыруларның кызулыгы сүрелде.* Ш.Камал. *Ара-тирә бәхәс кызулыгы белән арттырып җибәрүе дә юк түгел.* Г.Тукай

6) *күч.* Ярсу, ярсу тойгысы. *Коданың әзрәк кызулыгы бар инде, нишләтәсең.* З.Зәйнуллин. *Ул әле генә сөйләгәннәренең кызулыгыннан айнымаган һәм һаман уйларының очын эзләп башын катыра иде.* Ф.Яхин. *Таңнурның: «Гаеп миндә түгел, сездә, күсәкнең юан башы сезнең җилкәгә төшәчәк», – дигән җавабы уйланып җитмәгән, бары тик кызулыктан гына әйтеп ташланган шикелле иде.* М.Шаһимәрдәнов

**КЫ́З УРЛАУ** *ф. этн.* Кызны, аның яки гаиләсенең ризалыгыннан башка урлап, хатынлыкка алу. *Ат урлаган бур булыр, кыз урлаган хур булыр.* Мәкаль. *Кызны урларга һаман җай юк бит.* А.Шамов. *Кыз урлау гадәте бу якларда борын-борыннан килсә дә, хәзер күбрәк кызны үз теләге белән «урлыйлар» шул.* Р.Зәйдулла. *Ат җигеп, кыз урларга киттек.* Ватаным Татарстан

**КЫЗУЧАН** *с.* Хискә тиз бирелүчән, ярсып китүчән. *Кризислы хәлләр килеп туганда, андыйлар тиз кызучан, күңел төшенкелегенә бирелүчән һәм сүлпәнгә әверелүчән була.* Өмет

**КЫЗУЧАНЛЫК** *и.* Кызучан булу

**КЫЗ-ХАТЫН** *җый. и. сөйл.* Хатын-кыз. *Мәйханәдә халык шактый иде. Арада «тегенди» кыз-хатыннар да күренгәлиләр.* С.Сүнчәләй. *Мин монысына бик ышанмадым, кыз-хатын арттырып сөйләргә ярата бит, үзегез беләсез.* Р.Зәйдулла. *Ачылган сер – урамда шәрә йөргән кыз-хатын бит ул.* Т.Миңнуллин

**КЫ́З ЧАК** *и.* Кияүгә чыгуга кадәрге хәл, кызлык (*2 мәгъ.*) чоры. *Кыз чак – көяшлы көн.* Мәкаль. *Озак күзәтеп йөргәнгә, ахры, менә хәзер ул [Локман карт] Зәйтүнәнең кыз чагын шактый ачык итеп күз алдына китерә ала.* Ә.Еники. *Хатыны Газизәдән дә бик уңды ул, кыз чагында чибәр булды, гаиләгә коргач, тәүфыйгы артты, эшчән вә тырыш та иде.* Ф.Яхин

**КЫЗЧЫК** *и.* Кечкенә кыз бала, кече яшьтәге кыз. *Монда бит аның анасы, хатыны калган иделәр, аның бит кечкенә кызчыгы да бар иде... Алар кайда соң?* Ш.Камал. *Ул чакта бәләкәй генә бер кызчык иде әле Саҗидә.* М.Галәү. *Ә кызчыкны нәкъ курчак төсле итеп киендергәннәр ---.* Ә.Еники // Яшүсмер кыз. *Кызлар киткәч, Михаил урындыкның аркасынарак ята төште дә аякларын киеребрәк алга сузды һәм: – Шулай ук бу кызчык минем башны әйләндерермени? Матурлык! Менә матурлык! – дип уйланды.* Ф.Әмирхан. *Ул үзе туктаган турыдагы йортның тәрәзәсен шакыды, тәрәзәне унике-унөч яшьләрдәге кызчык ачты.* А.Гыйләҗев

**КЫЗЫГУ** I *ф.* 1) Нәрсәне дә булса булдырырга теләү, аңа ия булырга омтылу. *Тотыш ачу белән кулын тартып алды да көмешкә кызыккан иргә сугып җибәрде, ач яңаклыга аягы белән типте.* Н.Фәттах. *Менә ни өчен бу болынга бер кеше дә кызыкмаган!* Ф.Яхин

2) Күңел төшү, күз кызу, ымсыну. *Синең кай җиреңә кызыкты икән инде ул татарның бичара баласы?* Р.Галиуллин. *Егерме тәңкә иде алганда [пенсиясе], авызы явыз, тәмлегә кызыкты, бер тәңкәлек чуклы кәгазьле кәнфит алып кайтып суырып бетерде [Бибинур].* А.Гыйләҗев. *[Шөһрәт:] Кызыгам. Кем шундый кәләшкә кызыкмасын!* Ф.Яруллин

3) Көнләшү, көнләшеп карау; көнчелек хисе туу. *Көтмә күңел, өмет итмә: Ятларда шул сөйгән ярың. Кызыгып гомер үтәр микән Бәхетенә парлыларның?* Ф.Дәүләтбаев. *Апалары: «Килмә, йөрмә!» – дип кусалар да, ул [Исхак] уенга еш төшә. [Гармунчы] Шадра Василгә кызыгып карап тора.* А.Гыйләҗев. *[Бөкресе булганнарның] Кайберләре үзләренең гариплекләреннән читенсенеп, кешеләр белән аралашмас була, кимсенә, мескенлеккә төшә, сәламәт яшьтәшләренә кызыгып, ялгызлыкта яши.* Р.Батулла

**Кызыга башлау** Кызыгырга тотыну. *Юкса Мәскәү өлкәсендә угрылар ветераннарның хәрби бүләкләренә кызыга башлаган икән.* Ватаным Татарстан

**Кызыгып йөрү** Күптәннән кызыгу, кызыгу хисе кичерү. *Минем андый карандашым юк, малайларда күреп, андыйга әллә кайчаннан бирле кызыгып йөри идем.* Г.Бәширов. *Мин дә күптән кызыгып йөргән ике дәү курчакны кочаклап өйгә кайттым.* Л.Хәмидуллин. *Ханиев Нәсимәгә яшертен генә кызыгып йөри иде бит.* М.Шаһимәрдәнов

**Кызыгып китү** Кинәт кызыга башлау

**Кызыгып кую** Кинәт азга гына, бер мәлгә кызыгу хисе уяну. *Без бермәл аларга [Идеал белән Ләмигага] кызыгып та куйдык хәтта.* М.Шаһимәрдәнов. *Кем белә, авылда күз атып йөргән берәр ярлы-ябагай кызыгып куеп, эшне бозуы да бар.* Ф.Яхин

**Кызыгып тору** Әле, хәзер, сөйләп торганда кызыккан хәлдә булу

**КЫЗЫГУ** II *и.* 1) Мавыгу, кызыксыну. *Соклану һәм кызыгуга ихтирам дигән тагын бер хис килеп өстәлде.* Г.Әдһәм. *Һәрхәлдә карчык артыннан күзәтүе хәер акчасына кызыгудан түгел.* М.Кәбиров

2) Көнләшү, көнләү хисе. *Мәгълүм ки, кызыгуны «китап» та яманламый.* Ф.Әмирхан. *Ни хасият көнче кызыгудан, Язмышыңа ләгънәт атудан?!* М.Сәгъдиев

**КЫЗЫЙ** *и. сөйл. фам.* Кыз кеше яки гомумән хатын-кыз турында беркадәр фамильярлык төсмере белән сөйләгәндә, яисә аңа мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. *Хәят аның күзләрендә: – Я әле, кызый, син шәпме? Миңа катын булырга ярарлыкмы? – дигән сүзләрне күрә дә Салихтан да, үз-үзеннән дә ояла, әллә нәрсәдән хурлана.* Ф.Әмирхан. *Күрәсең, кайчандыр яшь кенә кызыйга булган мәхәббәттән тыш, аның эчендә озак еллар буенча нииндидер бүтән кичерешләр дә акрынлап җыела килгән.* Ә.Еники. *Егетҗиләннән тартынып, уеннарга чыкмады кызый, кичке утырмаларда да*

*гел почмак якта гына утырды, бүтән кызлар кебек идән такталарын сыгылдырырлык итеп бию бәхетләре тимәде аңар.* З.Зәйнуллин

**КЫЗЫК** *с.* **1.** 1) Кызыксыну уята торган, кызыксындыра торган, игътибарны җәлеп итә алырлык; мавыктыргыч. *Арада кызык бер әңгәмә бара.* Г.Ибраһимов. *Һич борын төшерми, кайгырмый, нинди дә булса бер кызык уен, сүз табып кына тора.* И.Салахов. *Ныклабрак карагач, күз алдында гаҗәеп кызык манзара барлыкка килде: әнә алан читендә, куе, мәһабәт нарат ышыгында, яртылаш җиргә иңгән алачык тора, аның янында икенчесе, кечерәге.* Г.Гыйльманов. *Кызык китап. Кызык вакыйга. Кызык кино*

2) Көлкеле, көлдерә торган, мәзәк. *Ул үзе турында да, башкалар турында да гаҗәеп моңлы итеп сөйли, гыйбрәтле хәлләр белән рәттән көлеп туймаслык кызык мәзәкләр сөйләү остасы да.* Р.Батулла. *Кичә бакчада бер кызык хәл булды.* Ф.Яруллин. *Кызык булмаса да кызык чыгарып, дәррәү көлешеп алган булдылар.* Р.Мөхәммәдиев

3) *сөйл.* Үзенчәлекле, үзенә бер төрле; гадәти түгел, оригиналь. *Кызык халык соң бу кешеләр, минә инде очарга гына торалар.* Ш.Камал. *Кызык та син, адәм баласы!* Н.Арсланов. *– Бигрәк кызык кеше сез! – диярәк хуҗам сөйләнеп калды, мин, үземә чыгып, тизрәк телефонга ябыштым.*Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кызыксыну уята торган, күңелне җәлеп итә торган әйбер яки күренеш; кызыклы, мавыктыргыч нәрсә. *Аларның күбесе бирегә кызык карарга, ягъни йөзләрен ачык йөртүче татар хатын-кызларын күрергә дип килгән иде.* М.Галәү. *Берниндн кызык та, матурлык та тапмады ул [Клара] анда [авыл җирендә].* Ә.Еники. *Сигезенче сыйныфтан бирле шушы егет кисәгә аның артыннан калмый, әле бакчаларына сикереп төшеп, сандугач булып сайрый, әле бүтән кызык уйлап табып, тынгы бирми.* Ф.Яхин

2) Көлкеле нәрсә, эш, көлдерә торган күренеш; мәзәк. *Кымыз барда кызык бар.* Мәкаль. *Базардан базарга, кунактан кунакка гел бал, кымыз эчеп тә кызык сөйләп, җыр җырлап йөргән бу кешенең мулла булуына ышануы да читен иде.* Ә.Еники. *Җантимер аларга төрледән-төрле кызыклар сөйләп бетерде, чая кыз һаман да аның беләгендә йөрде, күңеле хушланудан айный алмый идеме, әллә шушындый егетне күптән эләктерәсе килгәнме?* Ф.Яхин

3) Берәр нәрсәнең яки эш-хәрәкәтнең кызыктыра торган ягы, үзенчәлеге. *Шул сүзләрдән көннең бөтен кызыгы бетә, рәхәте китә.* Ф.Җамалетдинова. *Дөньяның кызыгы, яме калмады, Кем авызга алсын черек алманы?* Р.Ханнанов. *Адәм баласын билгесезлек җәлеп итми башласа, дөньяның кызыгы бетәдер ул.* Ф.Яхин

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Үзенә бер төрле рәвештә, оригиналь булып; мавыктыргыч булып. *Аның болай сөйләнүе башкаларга кызык тоела.* Ш.Камал. *Ә минем истә: ул вакытта бу сүзләрең үземә бик тә кызык тоелган иделәр.* Ф.Яхин. *Гөлфаяга кызык булып китте.* Ә.Дусайлы

2) Көлкеле итеп, көлдереп. *Мәҗлес кызык барды.* Г.Ибраһимов

**4.** *кер. сүз мәгъ.* Кызыксыну уятуны белдерә. *Кызык, нишләп торасы килми икән аның шундый яшь углан янында?* Н.Фәттах

**КЫЗЫКАЙ** *и. к.* **кызый**. *Кызыкай миннән нидер көтә, кулындагы җәтмәне кулдан кулга күчерә, кул беләзеге бау эзеннән сырланып, кызарып беткән.* А.Гыйләҗев. *И кызыкаем, япь-яшь башыңнан каян килә синә шулкадәр усаллык, ә?* Г.Галиева. *Шундый да ягымлы елмая кызыкай, янәшәсендә мин булгангамы әллә?* Ш.Галиев

**КЫЗЫ́К ИТҮ** *ф.* Мәзәк өчен кешене уңайсыз хәлдә калдыру, шаярту. *– Зариф, әйдә, директор сине чакыра, кызык ит әле үзләрен! – дип, мине өстерәп диярлек залга чыгарды.* Р.Яхин. *Минә шуннан башта яшьтәш малайлар, аннан авылдашлар, кызык итеп һәм үз итеп, «карак» дигән кушамат тактылар үземә.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә-ә-ә, шулаймы, кызык итим әле мин сезне, дидем дә, «эһе-е, эләктегезме» дип, ишекне ачтым.* Г.Галиева

**КЫЗЫКЛАНДЫРУ** *ф. сир.* 1) *к.* **кызыклату**

2) Кызыксыну уяту, кызыксындыру. *[Ул] Үзенең материалының яшеренлеге белән арада аеруча кызыкландырган шаһитларның берсе булып чыкты.* Г.Ибраһимов

**Кызыкландырып алу** Бераз, әледән-әле, еш кызыкландыру. *Шуңа да колониаль хакимият әледән-әле үзенең максатына ирешү юлларын эзләп, тормышыбызны «кызыкландырып» ала.* И.Сираҗи

**КЫЗЫКЛАНУ** *ф. сир.* 1) Кызыклы күренешкә әйләнү, үзенә бер төрле кызык төс алу. *Безнең көрәш шушы сөю белән Кызыкланды, Үсте, Ямьләнде.* М.Җәлил. *«Ы»ны ялгыш «ый» дисәң, Кызыклана бигрәк.* Мөҗәһит

2) *сөйл.* Кызык табу; мавыгу. *Кызлар аерым бер төркем булып күзгә бәреләләр. Алар нәрсә сөйләп кызыклана торганнардыр – белеп булмый.* М.Гафури. *Балаган янына барып, курчак сөйләгәнне тыңладылар һәм, кырыгынчы мәртәбә ишетүләре булса да, әүвәлге мәртәбәдәге шикелле кызыкландылар.* Ф.Әмирхан

**Кызаклана бару** Торган саен кызыклану. *Атна кичләрне була торган гадәтчә җыр кичәләре Габдулла һәм аның иптәшләренең берәр төрле яңалык кертүләре белән төрләнә, кызыклана барды.* Ә.Фәйзи

**Кызыклана төшү** Берникадәр кызыклану, бераз кызыкка әйләнү

**Кызыкланып китү** Кинәт кызыклану

**КЫЗЫКЛАТУ** *ф.* Кызыклы итү; кызыклы итеп күрсәтү. *Моннан тыш бу каһарманнарның әсәргә кертелүе сюжетны катлауландырып, хикәяләүне кызыклатуга да күп ярдәм иткән.* Г.Нигъмәти

**Кызыклата төшү** Бераз кызыграк итү

**КЫЗЫКЛЫ** *с.* 1) *к.* **кызык 1.** (*1, 2 мәгъ.*) *Үзенә бертөрле кызыклы, катлаулы тормыш кайный иде бу кырмыска оясында.* М.Галәү. *Мактанудан түгел, ә мисал итеп кенә мин сезгә бер кызыклы вакыйга сөйлим әле...* Ә.Еники. *Ләкин пьесаны аныңча эшли башлагач, кызыклы урыннары төшеп кала.* Ф.Яруллин

2) *махс.* Мавыктыргыч, мавыктыра торган. *Кызыклы физика*

**2.** *рәв. мәгъ к.* **кызык 3.** *Ә ул, кешеләргә карап, кызыклы гына иттереп күз кысты да: – Картларны сыйламаганда да ярар иде, әнә егетләрне кирәк, – диде һәм бердән генә йотып та куйды.* Ш.Камал. *Ә «Казан утлары»ннан башка әдәбият дәресләре кызыклы үтә алмый, укучыларны бүгеннән үк журналны укырга күнектерергә, түмен белергә өйрәтергә, тирән белем чыганагы икәнлегенә инандырырга кирәк.* Р.Фәйзуллин. *Икенче бер төркем --- белән танышу да бик кызыклы узды.* Безнең гәҗит

**КЫЗЫКЛЫК** *и.* 1) Кызыксыну уятырлык, гаҗәпкә калдырырлык, күңелне тарта торган булу; мавыктыргыч булу. *Шуңа күрә дә андый шәхси хисләрнең бүтәннәр өчен кызыклыгы да чамалы.* Р.Фәйзуллин. *Шунлык белән генә дә күп кенә ирләр өчен, өйләнгәннән соң, үз хатыны белән җенси мөнәсәбәткә керү кызыклыгын югалта.* Ватаным Татарстан

2) *иск.* Мәнфәгать; мавыгу. *Әйе, татар хатыны берлән үз тормышын бүлешер өчен, барын-югын бергә күрер, бергә татыр өчен, татар баласы булгач, татар гаиләсе ясап, татар балалары тудырыр, үстерер өчен, үзенең шәхси кызыклыкларын корбан итте.* Г.Исхакый

**КЫЗЫКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Кызыксыну уятмый торган; күңелне, игътибарны җәлеп итми торган. *[Галиябану:] Унөч яшемнән алып йөрәгемә кереп утырган Хәлилем бар чагында, аның кызыксыз байлыгына бер дә исем китми.* М.Фәйзи. *Бу кызыксыз, шау-шулы мәҗлестә, ялгызлыкка бирелеп, Ләйләне генә уйлап, Ләйләне генә сагынып утыру аңа гүя нииндидер моңсу, хәсрәтле бер рәхәтлек китерде.* Ә.Еники. *Бу кызыксыз, мәгънәсез тамаша Сөләйман хәзрәт күңелендә нинди хисләр кузгаткандыр, билгесез.* М.Шәһимәрданов

2) Күңелгә ошамый торган, күңелсез; начар. *[Лутов:] Бүген шактый кызыксыз бер вакыйга булды.* Ш.Камал. *Аның сүзе дә яман түгел иде. Әмма бик текә кисеп әйткәнгә күрә, миңа шактый кызыксыз тәэсир ясады.* Ш.Камал. *Кызыксыз хәл килеп чыгу*

**2.** *рәв. мәгъ.* Кызык түгел, кызыксыну уятмыйча, игътибарны тартмыйча. *Ләкин Сәмигуллин әйтә: ул беренче баруда гына шулай кызыксыз тоела икән.* Ш.Камал. *Мин беләм шундый шәхесләрне: аларның куәсе дә бар, иҗаты да мул, ләкин кара-каршы әңгәмәдә алар югалып кала, сөйләшергә сүз табалмый интегә. Сөйләгәндә дә коры итеп, кызыксыз сөйлиләр.* Р.Батулла

**КЫЗЫКСЫЗЛЫК** *и.* Кызыксыз булу. *«Икәү»нең бер абстракт нәрсә икәнлеге һәм үтә дә кызыксызлыгы гына исемдә калган булып чыкты.* Идел. *Хикәягә эпиграф итеп сайланган Г.Тукайның --- сүзләре, шактый күләмле фәлсәфи кереш өлеше белән тоташып, кеше гомеренең кызыксызлыгына, әлеге газаплы гомердә мәхәббәтнең бәхет, яктылык алып килүенә ишарә ясый.* Казан утлары

**КЫЗЫКСЫНДЫРУ** *ф.* 1) Кемдә дә булса кызыксыну уяту; кемнең дә булса уен, игътибарын җәлеп итү. *Вәлиевне бер момент кызыксындырды, ахры, ул сорау биреп куйды: – Сезнең чыгышыгыз ничек?* А.Алиш. *Хикмәтле камчы шунда ук барысын да бик кызыксындырды.* Ә.Еники. *Аннан соң хатынны нииндидер негрлар, индеецларның мәсьәләләре кызыксындырмый иде.* Р.Батулла

2) Хуплап, ярдәм итеп, кемдә дә булса берәр эш башкарырга, эш сыйфатын яхшыртырга теләк тудыру. *Премияләр белән кызыксындыру*

**Кызыксындыра бару** Торган саен ныграк кызыксындыру

**Кызыксындыра башлау** Кызыксындырырга тотыну; кызыксыну хисләре уятып җибәрү. *Ихтыярның фикере аны да кызыксындыра башлаган ---.* Раз.Вәлиев

**Кызыксындыра төшү** Тагын да кызыксындыру, бераз кызыксындыру. *Озын гәүдәлесенең документы зәңгәр фуражкалы кешене кызыксындыра төште, ахры, кесәсеннән телеграмма чыгарды.* А.Алиш

**Кызыксындырып җибәрү** Кинәт кенә кызыксындыру. *Шунысы гаҗәп, бу формула психиатрны да кызыксындырып җибәрде.* А.Тимергалин

**Кызыксындырып тору** Гел, һәрвакыт кызыксындыру. *Журналист һәрвакыт укучыларын үз фикерләре белән кызыксындырып торырга тиеш.* Безнең гәҗит

**КЫЗЫКСЫНУ** I *ф.* Кем яки нәрсә турында булса да күбрәк белергә тырышу; кемгә яки нәрсәгә дә булса игътибарны арттыру. *Тынычланып, элекке халәтенә кайткач, сүзне ул Әкрәм кариның үзенә күчерде, аның эшекәсебе белән кызыксынды, шәһәрдәге йомышы турында сорашты.* М.Галәү. *– Нимесләр көчкә ничекләр, алдырып буламы аларны? – дип кызыксынды Гыйният.* З.Зәйнуллин

**Кызыксына бару** Торган саен кызыксыну арту. *Нәфисә сөйләгәндә, Мансуров, торган саен ныграк кызыксына барып, ара-тирә аңа да күз төшереп алгалый.* Г.Бәширов

**Кызыксына башлау** Кызыксынырга тотыну. *Николай Николаевич яшь мастерның уңышлары белән тагын да ныграк кызыксына башлады.* Г.Ахунов. *Үзенең серле хәрабәләре белән бу кала Русиядәге археология фәнендә исемле галимнәрне дә кызыксындыра башлый.* М.Хәбибуллин

**Кызыксына төшү** Тагын да ныграк кызыксыну. *Николай Михайлович моны ничектер эчке бер кызгану белән әйткән кебек булды, һәм мин моңа, билгеле, игътибар итмичә калмадым, шунлыктан тагы да кызыксына төшеп сорадым ---.* Ә.Еники. *– Син соң ни кинәш итәсең, Сатылмыш? – диде хан, кызыксына төшеп.* Н.Фәттах. *Мин аңа, тагын нинди әкәмәт сүз әйтер икән бу чибәркәй дигәндәй, кызыксына төшеп һәм төбәлебрәк карап тора башладым.* М.Шәһимәрданов

**Кызыксынып алу** Бер вакытка гына кызыксыну. *Акча биргәндә, Сенатор процентлар алырга теләмәде, бары бу кадәр сумманың нигә кирәк булуы белән генә кызыксынып алды ---.* Р.Мирхәйдәров

**Кызыксынып бару** Күптәннән даими рәвештә кызыксыну. *Башка халыклар әдәбияты белән кызыксынып*

*барган хәлемдә, үзебезнең татар прозасын бик хөрмәт итәм, аны инде күптән дөнья аренасында үз урынын алырлык зур әдәбият дип карыйм.* М.Кәбиров

**Кызыксынып карау** Кызыксынырга тырышу, белергә омтылу. *Клара аларның көнкүреш хәлләре белән дә, читләтеп кенә булса да, кызыксынып карады.* Ә.Еники

**Кызыксынып йөрү** Күптәннән кызыксыну. *Бу хәл белән күптәннән инде фаҗиганамә язучы Төтенбаш кызыксынып йөри ---.* Р.Нуруллин

**Кызыксынып килү** Электән һәм даими рәвештә кызыксыну. *Бу өлкәдә әлегәчә аерым һәвәскәрләр генә кызыксынып килде.* Ә.Кәримуллин

**Кызыксынып китү** Соңгы арада яки берәр вакыйгадан соң кызыксына башлау. *Шуңа күрә ул мине шунда ук үтермәде, ә киресенчә, кызыксынып китте.* В.Исламетдин. *Авыр атлетика, культуризмда беренче уңышка ирешсә, кызыксынып китүе мөмкин.* Сабантуй

**Кызыксынып кую** Кинәт кызыксыну уяту. *Ишек төбендәге кеше, кыңгырау шалтыратып, карлыгып беткән тавышы белән «пожалсто, пожалсто» дип кычкыра-кычкыра, тамашачылар җыйный, Тукай да кызыксынып куйды: – Карап чыкмыйбызмы, Мәрҗән?* М.Галәү. *– Мин үзем дә нәкъ шундый фикердә, ә син ничек шундый фикергә килдең, Рәшит абый? – дип, бик нык кызыксынып куйды Фәнис.* Ш.Алпар

**Кызыксынып тору** Һәрвакыт, әледән-әле кызыксыну // Кызыксынуны кирәк дип табу. *Бикәгә бу турыда әйткәннәр иде инде, ләкин урдада ул андый нәрсәләр белән кызыксынып тормады.* Н.Фәттах. *Мин ул кадәресе белән кызыксынып тормадым.* Ф.Шәфигуллин

**КЫЗЫКСЫНУ** II *и.* Берәр кешегә яки нәрсәгә карата булган игътибар. *Шуңа күрәниндидер могҗиза белән бу авылда сакланып калган бердәнбер ала каз безнең солдатларда зур кызыксыну тудырды.* Ә.Еники. *Адресларына кадәр күрсәтүемнең хикмәте шунда ки, хәзерге һәм киләчәк буын кешеләре дә олуг язучыларыбызның кай тирәдә, кайсы йортларда, нинди шартларда яшәп, кайсы урамнар буйлап йөри-йөри фани дөньядан китүләрен тыштан карап булса да белсен, кызыксынулары куәтле булса, кереп карарга да мөмкинлек тапсын димәктән...*Ф.Баттал. *Җитди кызыксыну тудырды бу миндә.* Р.Мөхәммәдиев

**КЫЗЫКСЫНГАН** *с.* Судта теге яки бу эштә, теге яки бу бәхәстә билгеле бер мәнфәгать күзәткән. *Шуңа күрә бердәй концепция эшләргә һәм аны барлык кызыксынган якларны җәлеп итеп тикшерергә кирәк.* Шәһри Казан

**КЫЗЫКСЫНУЧАН** *с.* Һәр яңа нәрсә белән кызыксыну гадәте булган, һәрнәрсәне белергә омтылучан. *Башка чакларда җәмәгать эшләре белән кызыксынмаучан чабатачы һәм чыптачылар да, эшләрен бүлеп, яланаякка тишек киез ката элеп, үтәли җил өреп торган иске чикмәннәрен киеп, шунда йөгерделәр.* М.Галәү. *Суфиҗан – кечкенәдән бик кызыксынучан малай иде ул.* Р.Сабыр. *Кызыксынучан карашлы Көмеш Елгалар арасында, башларын чак кына бер-берсенә таба авышытып, Мисбахетдин белән Шиһабетдин сөйләшеп маташа.* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗЫКСЫНУЧАНЛЫК** *и.* Кызыксынучан булу. *Ләкин малай барган җирендә дә үтә кызыксынучанлыгы һәм тиктормаслыгы аркасында нинди дә булса бер маҗарага тармый калмый иде.* М.Шаһимәрдәнов. *Фил миңа каш астыннан карап куйды. Мондый кызыксынучанлыкны яратып бетермәде булса кирәк.* Р.Зәйдулла. *Аның яшьтән үк кызыксынучанлыгы, барысын да үзе төпченеп аңларга, белергә омтылуы, күргәннәрен-белгәннәрен сеңдереп бару гадәте була.* Ф.Галимуллин

**КЫЗЫКТЫРГЫЧ** *с.* **1.** Нинди дә булса ягы белән кызыксыну уята торган; мавыктыргыч. *Ә бүгенге көн шулкадәр матур, Зөфәрнең тирә-ягы искиткеч бай, кызыктыргыч дәрәҗәдә төрле-төрле иде.* А.Гыйләҗев. *Күңелегезгә авыр алмагыз, сезнең тәкъдим сезгә я миңа бик тә аңлаешлы, бик тә кызыктыргыч булса да, кызганычка каршы, татарча түгел шул.* Х.Сарьян. *Өстәвенә кызыктыргыч бер уй иркәләде төшкән күңелне: ---.* С.Баттал

**2.** *рәв. мәгъ.* Кызыктырып, игътибарны җәлеп итеп. *Киленнәр дә озак көттермәде, шәрә балтырларын кызыктыргыч ялтыратып, алар да [буага] төшеп җитте.* А.Гыйләҗев

**КЫЗЫКТЫРУ** I *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса ия булу теләге яки соклану хисе тудыру; үзенә тарту, ымсындыру. *Кызыктырмагыз әллә нинди зәңгәр күлле, бозлы-карлы тауларыгыз белән.* Ф.Яхин. *Ул авыл малайларын кызыктырып, ымсындырып, чакырып торган иң гаҗәеп, иң серле урын булгандыр...* Г.Гыйльманов

2) Көнләштерү, көнләү хисе уяту. *Ул аллы-гөлле зур резина туп күтәреп чыкмаган булса һәм аның белән бөтен малайларны кызыктырып уйнамаган булса, бернәрсә дә булмаган булыр иде.* А.Шамов. *Дилбәрнең теләсә кем каршында югалып калмавы, һәр очракта үткен сүз табуы аларны кызыктыра.* К.Тимбикова

3) Нинди дә булса берәр эшкә дәртләндерү, берәр эш башкарырга, үтәргә теләк уяту. *Солдат та, башка иптәшләре дә яңа килгән егетләрне мондагы эшкә кызыктыра һәм үзләре белән калырга димли иделәр.* Ш.Камал. *Әмма бер таныш гәҗитче иптәш, шалтыратып, бушка бер билеты барлыгы белән кызыктырып көндерде шул.* Ф.Яхин

4) Кемдә дә булса берәр нәрсә белән кызыксыну хисе уяту; кызыксындыру, мавыктыру. *Менә таушалган йөзле яшь кенә бер марҗа, ир-атны кызыктырмаммы дип, ахрысы, ботларын уйната-уйната киләп сарып йөри.* М.Галәү. *Аннары аулак өйдә калу да бик кызыктыра бит әле.* Ә.Еники. *Хәйдәр булачак хатыны турында артык озаклап уйламады, аны машина бик нык кызыктырды.* А.Гыйләҗев. *Ә мөмкинлекләр күп: төрле-төрле рекламалар, белдерүләр чит илләрдәге рәхәт тормышка кызыктыра, эшкә чакыра: стриптизёрша булып, официантка яисә хәтта ки фотомодель булып...* Р.Зәйдулла

**Кызыктыра башлау** Кызыктырырга тотыну. *Фазулланың бу нияте мине дә кызыктыра башлады.* Г.Бәширов

**Кызыктыра төшү** Бераз кызыктыру

**Кызыктырып йөрү** Күптәннән кызыктыру

**Кызыктырып килү** Электән һәм даими рәвештә кызыктыру. *Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыктырып килделәр.* Л.Хәмидуллин

**Кызыктырып кую** Кинәт кызыктыру уяту. *Һадиның бер хаты Әскәрне кызыктырып куйды.* А.Гыйләҗев

**Кызыктырып тору** Һәрвакыт, гел кызыктыру. *Берсеннән-берсе матур бизәкле сыралар, коньяклар шыплап тезелеп,ерактан ук кызыктырып тора шул.* Безнең гәҗит

**КЫЗЫКТЫРУ** II *и.* Кызыксындыру. *Күзгә ташлана торган кыйммәтле асылташлар белән ирләрне кызыктыру, үз җенесенә чакыру ята бизәнүнең төбендә.* Р.Батулла

**КЫЗЫКТЫРЫРЛЫК** *с.* **1.** Кызыктыру хисләре уята алырлык. *Кызый, әллә ничек кызыктырырлык булып, Габделбасыйрның алдында басып тора.* Ф.Әмирхан

**2.** *рәв. мәгъ.* Кызыктыру хисләре уятырлык итеп, шундый дәрәҗәдә. *Рекламасы тулы һәм кеше кызыктырырлык яхшы сайланган.* Ш.Камал

**КЫЗЫЛ** I *с.* **1.** 1) Спектрның төп төсләреннән иң беренчесе төсле, кан төсендәге. *Андагы [Шүлгәнташ мәгарәсендәге] эчке биек кыя битләренә кызыл буяу белән мамонтлар, атлар һәм мөгезборын сурәтләре ясалган.* Р.Фәхретдинов. *Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә.* Ә.Еники. *Таралыр вакытлар якынлаша башласа, читән тыкрыктан кызыл француз яулык бәйләгән Садрикамал түти килеп чыга.* З.Зәйнуллин

2) *сөйл.* Йоны, төкләре кызгылт көрән, куе җирән төсле (сыер, бозау төсе тур.). *Шул көнне үк абзарны Закирдан киртә-салам белән бүлдерде, ялгаш куйдырды да кызыл башмакны сугымга ашатырга аерып япты.* Г.Ибраһимов. *[Күлнең] Ярында – аркылы-торкылы гранит ташлар. Кайсы кит балыгын хәтерләтә, кайсы дөя, кайсы кызыл сыер булып тездән су эченә кереп баскан.* И.Салахов. *Кара сыер астында кызыл бозау.* Табышмак // Туры (ат төсе). *Атыгызның берсе тимер күк, икенчесе кызыл туры идеме?* Ә.Еники. *Айгырдан да уңдылар алар, гәүдәгә ул тиклем булмаса да, киң күкрәкле, нык аяклы, озын мул яллы кызыл айгыр юрталыкта үз ишләренә һич ал бирми торган иде.* А.Гыйләҗев. *Бәхет эзләп һаман, һаман алга чаба Ялкын яллы кызыл чаптарым!* Р.Вәлиев // Җирән (кешенең чәче, сакалы төсе тур.). *Кич утырырга йөрүчеләр арасында Мазлуманың сипкел битле, кызыл сакаллы җизнәсе дә бар.* Г.Бәширов

3) Кызыл төс алган, беркадәр кан төсе кергән, кызарган. *Урысның бер гавере – Төлкедәй кызыл чырайлы, Авызы төкле кенәҗ – Ул килеп басты йортымны.* Дастан. – *Урыска түгел, Иблиснең үзенә дә барырмын, иллә-мәгәр маңгай тирем белән тапкан бер тиенемне дә кешегә калдырмам, калдырмам дигәч калдырмам...*– *дип, сәке читенә зур, кызыл йодрыгы белән каты китереп сукты [Алтынбай].* Г.Ибраһимов. *Нәкъ шушы минутта алар янына графин белән аракысын, тәлинкә белән закускасын күтәргән кызыл чырайлы бер юан кеше килеп басты.* Ә.Еники

4) *тар.* Октябрь революциясенә, революциядә катнашучыларга, большевикларга, революцион эшчәнлеккә бәйләнешле; Советлар Союзына, Кызыл Армиягә караган. *Шушы Варес тарафына карьера яратучы кызыл фикерле берничә язучы да туплана. Алар коммунистик рухтагы әсәрләр язып, эстон халкының нәфрәтенә дучар була.* Ф.Баттал. *--- авылның диндар картлары аны, кызын Пәнҗәрдә рус мәктәбендә укытканы өчен, кәфер дип, кызыл мулла дип күзен ачтырмадылар.* Г.Ахунов. *Ни кызыл комсомол вә коммунистлар да «газиз бала» һәм «газиз җан» төшенчәләренең бер дә юк сүз түгеллеген аңлап, Аллаһы Тәгаләне исләренә төшерделәр.* Ф.Яхин

5) *иск. тар.* Җәдитчеләр хәрәкәтендә катнашучы, җәдитчелек тарафында булган. *Кызыл яшьләрнең бер төркеме Гәрәй Солтанның теленә, кискенлегенә иярә башлыйлар.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Һич тайпылмыйча билгеле бер карашны яклаучы, эзлекле тарафдар булган, ортодокс булган. *Әлхасыйль, бигрәк җете кызыл мөэмин булып кылана.* Г.Тукай. *[Муса:] Без һәр адымыбызда артык дәрәҗәдә кызыл, чәчрәп торган ортодокс булып кылангаладык.* Ш.Маннур. *Менә шул Гарифә җиңгинең мамык түшәкләре талангannан соң, Совет власте аны алтмыш сигез яшьлек Мөбарәкҗан хәзрәт дигән кызыл муллага кияүгә бирә.* К.Тинчурин

7) Ботаника, зоология, минералогия кебек фәннәрдәге кайбер тезмә терминнарның беренче компоненты буларак кулланыла. *Син ач шунда кәнсир заводы, помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме – үстереп өлгертәбез.* М.Әмир. *Крыжовник һәм кызыл карлыган өчен җылылык һәм кояш нурлары кара карлыганга караганда күбрәк кирәклеге мәгълүм.* Җиләк-җимеш бакчасы утырту. *Кызыл элмә. Кызыл ярканат. Кызыл болан. Кызыл бүре. Кызыл якут. Кызыл лалә. Кызыл мәк. Кызыл солыча*

8) Югары пробалы, саф (кыйммәтле металлар тур.). *Әһә, син идеңме әле минем кызыл алтын тарагымны урлаган?* Әкият. *Йөрәксездер колын, әмма Кызыл алтын аның бәһасы, үзе инсанга юлдаш.* Дәрдемәнд. *Җиз дә түгел, кызыл бакыр Мунчадагы тазлары.* В.Ильясов. *Һәйкәл түбәсе кызыл бакыр, Җир астында батырлар ятыр.* Ә.Бәюсов

9) Югары уку йортын «бик яхшы» билгеләре белән генә тәмамлаган студентларга бирелә торган (диплом тур.). *Гел бишлегә генә тәмамларга, кызыл диплом алырга тиешле кыз ике фәннән дүртле билгесенә тапшырды.* Д.Каюмова. *Беренче улы Мәскәү университетының биология факультетын кызыл диплом белән тәмамлаган ---.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кызыл төс. *Мәктәп су янында, озынчарак, зур түгел генә бер бина булып, башы кызылга буялган, --- тышкы яктан әллә нинди иске су тегермәне яисә борынгы алпавыт утарларындагы ташланган флигель төсле килешсез вә кызганыч рәвештә күренә иде.* Ш.Камал. *Картоннан кисеп*

*кызыл белән өртелгән биш чачаклы йолдыз түшәмнең нәкъ уртасына асылып, тирәләй нурлар чәчеп торган бер рәвешкә кертелгән.* М.Фәйзи. *Күркә дигән асыл кош Кызыл күрсә күперә.* Х.Туфан

2) Помада. *Бит-кулын юды, ирененә кызыл сөртте [Нина Михайловна].* А.Гыйләҗев. *Әминә дә әүвәле битен корытты, аннары җиңелчә крем сылады, сизелер-сизелмәс кенә, чама белән, ирененә кызыл сөртте.* Г.Минский. *Калган җиде сумга нәрсә алырга? «Алтын балык» авторучкасымы, оекмы, таракмы, ирен кызылымы, --- браслетмы?* Г.Мөхәммәтшин

3) *к.* **кызыл аракы**. *Рәхмәй үзеннән дә өстәп ике шешә акны, бер шешә кызылны алды.* Ә.Еники. *Хәлим тиз генә эшен бетерде дә (ул урам себерүчесе булып урнашкан иде) кибеттән ике тәңкә дә егерме тиенгә бер «кызыл» алып чыкты.* Р.Зәйдулла. *Шуннан утырып аңлаттым да, кибеттән өч кызыл алып, күршемнең арбасына аттым, Хәсән абыеңны беләсең бит!..* Ф.Яхин

4) *тар.* Алтын. *Шул теләк белән тудырдым, Дүрт кырлап учак өйдердем, Кызылдан бишек кылдырдым, Алтыннан чөмәк уйдырдым, Көмештән төбәк койдырдым, Уен осталардан уйдырдым, Сырын сырлаучылардан сырдырдым ---.* Дастан. *Бер чигәсе мең кызылга бетмәгән – Ханияң көбә бирәдер, Кисәнә, Идегәй, кисәнә!* Дастан

5) **кызыллар** *күпл. тар.* Россиядә гражданнар сугышы вакытында революция тарафдары, революционер. *Әле алпавытны туздырганга, кызыллар белән аклар сугышканга да былтыр гына кебек, ә исәпләп карасаң, бармаклар да җитми.* Г.Толымбай. *Дәүләкәнгә беренче тапкыр кызыллар килеп керделәр.* Ә.Еники. *Ихтыярсыз аклар һәм кызылларга бүленгән ватандашларның бер-берсе белән сугышуы организмдагы ак һәм кызыл кан тәнчекләренең үзара көрәшенә охшый.* З.Мансуров

6) *иск.* Җәдитчеләр, җәдитчелек тарафдары (кадимчеләр телендә). *Тирәяктагы берничә мөгаллим өстеннән ниндидер бер карт мулла: «Алар кызыллар, алар падишага каршы халыкны котырталар», – дип әләкләгән.* Г.Ибраһимов

◊ **Кызыл авыз** *кимс.* 1) Тапкыр телләнүче, кешедән көләргә яратучы кеше турында. *Анда сезнең язучылар арасында кешедән көләргә яратучы кызыл авызлар да бар.* С.Җәләл. *Ханифәнең ул эшкә барып җитәрлек аңы юк, ләкин бит яркәмнәр, авылның кызыл авызлары аның күзен ачмаслар, күңеленә коткы салмаслар дип кем әйтә ала.* Г.Ахунов. *Ул кызыл авыз парторг чагында гаеплеләрне сүксә, мулла булгач – вәгазь укып, үгет-нәсыйхәт тукып теңкәләренә тия иде!* М.Шаһимәрдәнов; 2) *иск.* Кадимчеләрнең җәдитче яшьләргә карата кимсетеп әйтә торган сүзләре. *[Шкафчы:] Әдәбият кичәсе, имеш! Анда авыз күтәреп җырлыйлар, ди, сөйлиләр, ди. Җыен кызыл авызлар чыгып скрипка, гармонь уйныйлар, ди.* Г.Камал. 3) *иск.* Октябрь революциясен, Совет хакимиятен актив яклаучы кешеләргә карата мыскыллап әйтелгән сүз. *[Камали:] Кара син аларны, замана фетнәләрен, ә, хәмсәмул булганнар, имеш. Кая качтылар әле үзләре? Бирермен мин сезгә, кызыл авызлар!* Ф.Бурнаш. *Бу хәерче кызыл авызлар кайдан килеп чыктылар соң, явызлар?.. Хәзрәтләр бар чагында урысны сайларга димлиләр бит.* Г.Ибраһимов; 4) Яшь, тәҗрибәсез, дөнья күрмәгән кеше; буш сүз сөйләүче. *Бу Казан кунагы ниндирәк кеше икән? Мужикның хәленә керерлекме, әллә кызыл авыз гынамы?* И.Гази. *Тәҗрибәсез, дөнья күрмәгән, пешмәгән. Кит аннан, кызыл авыз, кит!* Г.Камал. **Кызыл авызлану** Мактану, кәперәю, масаю. *Кызыл авызланып, үзе теләп сугышка китмәс иде.* Г.Зәйнашева. *Бик тә тәкатең калмаган икән, фермада кызыл авызланырсың!..* Б.Камалов. **Кызыл этәч** Янгын. *Уникенче елны безнең Атҗабарны кызыл этәч ялап алды. Бөтен кешенең диярлек йорт-җире янды, этинеке читтәрәк булгач, зыян тимәде.* М.Мәһдиев. *Быел гына салган мунчамны кызыл этәчтән талатыр хәлем юк.* Г.Сабитов. *Бу юллар язылганда, кызыл этәч 60 гектарлап мәйданда котыра иде.* Безнең гәҗит. **Кызыл этәч җибәрү** Яшертен рәвештә ут төртү, яндыру. *Байга үч итеп, йортына кызыл этәч җибәрәләр.* С.Поварисов. *– Ә үзе кулына бензин салынган канистр тоткан! – Ник?! – Сафатдинның өенә кызыл этәч җибәрергә!* М.Шаһимәрдәнов. *Үзенә бер телем икмәк тә калмый торган итеп продналог салырга кирәк аңа, йорт-курасына кызыл этәч җибәрергә кирәк.* Ф.Баттал. **Кызыл дөя бәясенә** Бик кыйммәткә, югары бәягә. *Интернет пәрәвезе буйлап үрмәли торгач, Украинага барып җиттек, ә үзебезнең иксез-чиксез киң илебездә юк яки шәхси заказ белән генә ясыйлар, җитмәсә, кызыл дөя бәясенә.* Шәһри Казан. **Кызыл җеп булып сузылу** Төп идея булып аерылып тору, төп идея итеп чагылдырылу. *Бу җырларның барысыннан да коллективчылык тойгылары кызыл җеп булып сузылалар.* М.Җәлил. *Әсәрнең тәрбияви функциясе шуннан гыйбарәт, ягъни, куркак булсаң да мәкерле булма, хәйләкәр бул, дигән формула бу әкиятнең башыннан ахырына кадәр кызыл җеп булып сузыла.* Ф.Яхин. *Ул хикмәтләрнең эчтәлегендә, шәригать таләпләрен төгәл үтәми торып, суфичылык белән шөгыльләнү, рухи үсү мөмкин түгел, дигән идея кызыл җеп булып үтә.* В.Якупов. **Кызыл камыт кидерү** 1) Сую, бугазлау (терлек тур.); 2) Суеп үтерү. *Шуларга теләктәшлек белдергәнең өчен генә дә синең муеныңа кызыл камыт кидерергә була.* Р.Батулла. **Кызыл камыт кию** Суелу, бугазлану (терлек тур.). *[Яшь көтүче Әйдүк:] – Авылга аклар килсә, кызыл камыт киясегезне белмисезмени, – дип сөйләнеп маташса да, сыерлар авылга аклар киләсен, килгәч аларга уңайсыз буласын аңларга теләмәделәр.* Һ.Такташ. **Кызыл кар яугач (яуганда)** Бервакытта да, беркайчан да, һичкайчан (булмаячак эш тур.). *[Галимә:] Булыр, көтеп тор әле син кызыл кар яуганын.* А.Алиш. *– Мин кайчан очучы булырмын да самолёт йөртә башлармын икән? – Кызыл кар яугач, – ди әнисе, он иләгән җиреннән көлемсерәп кенә.* Р.Низамов. *– «Галия» мәдрәсәсен төзегәч, шәкертләргә ятак булачак, билгеле. – Кайчан? Кызыл кар*

*яугачмы?* С.Поварисов. **Кызыл кәгазь** *иск.* Революциягә кадәр ун сумлык кәгазь акча. *Ул хәзрәткә бер кызыл кәгазьне һәйбәтләп яудырырга кирәк.* Г.Ибраһимов. **Кызыл киселү** *к.* **кызыл кисү. Кызыл кисү** Үтә катгый фикерле, фанатик карашлы булу. *Мәрвәре күптән инде бик тырыш, бик уңган хозяйкага әвереледе, кызыл кисеп, активист булып йөрүләре әллә кайчан бетте.* Ә.Еники. **Кызыл күлмәк кидерү (кидертү)** Сую, үтерү (кешене). *Берсе Хәлимгә пычак күрсәтеп китте: «Кара аны, студент, безнең кызлар янында бик чуалсаң, кызыл күлмәк кидертербез!» – дип, пычагы белән мәгънәле генә селтәнде.* И.Гази. **Кызыл сүз** Риялы мактау сүзе. *Кызыл сүзнең күчәре тиз сына.* Мәкаль. *Әгәр дә минем урында яшь, чибәр хатын булса, Вилданов (холкын яхшы беләм) аны да, кызыл сүзләр сибә-сибә, баскычтан менәргә мәҗбүр итәр иде.* М.Шаһимәрданов. *Канның да, купшы, кызыл сүзләрнең дә төсе бер төсле иде...* Ф.Бәйрәмова. **Кызыл сыер** *к.* **кызыл этәч**. *Алла сакласын, башыңа киләсе каза булса, кызыл сыер әнә шулай ялый да ала инде...* Г.Бәширов. **Кызыл тел** Матур, оста һәм урынлы әйтелгән акыллы сүз. *Һөнәр башы – кызыл тел.* Мәкаль. *Кыз авызында кызыл тел.* Мәкаль. **Кызыл үгездән сөздерү** 1) Яндыру. *[Бигәш:] Сөздерик кызыл үгездән [шүрәлене], – тотыйк та салыйк утка.* Д.Гобәйди; 2) Ришвәт бирү; аракы эчерү. **Кызыл фонарь** *иск.* Фәхешханә. *Ул гына да түгел – аны теге дөньяга, кызыл фонарьларга йөри имеш, дип сөйлиләр.* Г.Ибраһимов. *[Шәһәрдә] 1200 ләп рәсми «кызыл фонарь» йорты саныйлар.* Г.Гобәй. **Кызыл чүлмәк** Авыз. *Аратирә, ихтыярыбыз төкәнеп, [җиләкне] кызыл чүлмәкләргә дә шудыргалыйбыз.* Ф.Шәфигуллин. **Кызыл ыштан кидерү (кидертү)** Малайларны сөннәткә утырту, сөннәтләү. **Кызыл ыштан тегү** *к.* **кызыл ыштан кидерү**. *Шулай итеп, аны ышандырып йиткергәч, аңар: «Кызыл ыштан, тәти ыштан тегәмез, менә үлчик әле», – дип яткыра да, --- кисеп ала да, акыра-бакыра торган малайның җәрәхәтенә черегене сибеп, чыгарырга куша иде.* Г.Исхакый. **Кызыл ыштан үлчәү** *к.* **кызыл ыштан кидерү**. *Яхшы ата-ана баласы, кендек әбисе артына берне чәпелдәткәч, барлык сабыйлар сыман акырып елап җибәргән; көне килгәч, аңа да «кызыл ыштан» үлчәгәннәр, үскән-үрмәләгән, йөгереп тә киткән.* А.Гыйләҗев

**КЫЗЫЛ** II *и. бот.* 1) Көньякта үсә торган каты үзагачлы куак яки кечкенә агач. *Кызыл ботагы*

2) Шул агачның куе кызыл төстәге, авызны камаштыра торган әчкелтем җимеше. *Кызыл җыю*

**КЫЗЫЛ АГАЧ** *и.* 1) *бот.* Кипарисчалар семьялыгыннан көрәнсу кызыл үзагачлы, көньякта үсә торган мәңге яшел ылыслы агач; кызыл секвойя. *Аларның [икеөлешлеләрнең] күбесе кыйммәтле үзагачы белән билгеле, мәсәлән, тик, кара һәм кызыл агач.* Биология

2) Югары сыйфатлы агач әйберләр ясауда кулланылган кызыл һәм көрәнсу төсле кайбер кыйммәтле агачларның үзагачы. *Йомшак урындыклар, көзгеләр, язу, туалет өстәлләре, алтын тышлы китаплар белән тулы кызыл агач шкафлар нечкә зәвык белән тезелгәннәр.* Г.Ибраһимов. *Идәндә озын аяклы кыйммәтле радиоалгыч. Кызыл агачтан!* А.Гыйләҗев. *Кызыл агачтан ясаган тартманы идәннән алып өстәлгә куйдым.* М.Юныс. *Кызыл агач остасы*

**КЫЗЫЛ АЙ** *и.* Ак җирлектә кызыл төсле ярымайдан гыйбарәт, Халыкара Кызыл Хач һәм Кызыл Ай хәрәкәтенең өч эмблемасыннан берсе

**КЫЗЫЛ АРАКЫ** *и.* Җимеш суларыннан әчетеп әзерләнгән исерткеч эчемлек. *Карт, кайдандыр кызыл аракы алып кереп, очучының авызына чәй кашыгы белән азлап-азлап кына сала башлады.* А.Шамов. *Кызыл аракыга карлыган-кырлыган, җиләк яфраклары тутырып, сарымсак турап ит кыздырдык, кем әйтер начар дип?!* А.Гыйләҗев. *Җитмәсә, арба төбеннән бер кызыл аракы да чыкты.* Ф.Яхин

**КЫЗЫЛАРМЕ́ЕЦ** *и.* Кызыл Армия сугышчысы. *Әти-әнисез калган Разинне авылга килгән бер кызылармеец шәһәргә алып китеп балалар йортына бирә.* А.Алиш. *Дошман самолёты күренә калса, тизрәк агачлар арасына яшеренергә уңай булсын дип, кызылармеецлар юлның ике ягыннан пар-пар тезелешеп баралар.* Ә.Еники. *Мичкә янәшә стенада башына йолдызлы шлем кигән кызылармеец, Колчак солдатын штык белән эләктереп, биек ярдан Тын океан дулкыннарына ыргытырга җыена...* М.Юныс

**КЫЗЫЛ А́РМИЯ** *и. тар.* Совет армиясенең 1918–1946 еллардагы рәсми исеме. *Шуңа күрә Кызыл армия сафларында татар-башкорт бригадалары акларны җиңүдә вакыты-вакыты белән хәлиткеч рольне уйный.* Ә.Шакиров. *Шулар өстенә, Киев шәһәрен югалту һәм тулы бер фронтның немецлар тарафыннан туракланып юк ителүе, фронтның командующие генерал Кирпоносның үзен-үзе атып үтерүе Кызыл Армия өчен зур фаҗига булды.* З.Зәйнуллин. *– Иптәшләр, белеп торыгыз, – дип сүзен тәмамлады ул, – безнең Кызыл армия герман армиясен барыбер җиңәячәк, сугыш бетәячәк.* М.Мәһдиев

**КЫЗЫЛА́РМИЯЧЕ** *и. к.* **кызылармеец**. *Ярты чакрым алдарак агач төбе саен кәкрәеп туңган безнең кызылармиячеләр утыра.* З.Зәйнуллин. *Мәдәният тарихында кызылармияче Нәгыймҗан Мирсаяповның Украинаның Кировоград шәһәреннән драма актёры Арслан Мөбарәковка язган хаты да билгеле.* Кызыл таң

**КЫЗЫЛАЯК** *и. зоол.* Шөлди кошлар семьялыгыннан озын гына кызыл аяклы, саргылт көрән төсле күчмә саз кошы; *русчасы:* **красноножка**

**КЫЗЫЛ ӘЛӘМ** *и. к.* **кызыл байрак**. *[Фәтхия:] Ходаем, бар икән кодрәтең! Менә ничә атналар инде көн үтәләр, төн үтәләр! Туплар! Кызыл әләмнәр! Илаһым, хуҗам, кайдан килә, кая бара бу бәндәләрең?!* Г.Ибраһимов. *Урта бер җиренә урак белән чүкеч сурәте төшерелгән кызыл әләм аның [Шәфигулла агайның] җилкәсендә тыныч җилферди.* Ф.Әмирхан. *Ячейкадан кызыл әләм алып чыгып таягына кара тасма бәйләделәр.* А.Гыйләҗев

**КЫЗЫЛ БАЙРАК** *и.* 1) 1871 елдан алып революцион азатлык көрәшенең

халыкара символы буларак кызылга манган тукыма. *Барысы да имәннең иң югары ботагына урнашкан кызыл байракка әйләнеп карадылар.* К.Нәҗми

2) СССРның дәүләт байрагы. *Юлның ике ягына да багана утыртып, капка сыман бер нәрсә ясап куйганнар. Аның башында Кызыл байрак җилферди.* А.Алиш. *Әй Кызыл байрак, Нур бир җиһанга! Әйдә, эшчеләр, Алга вә алга!..* М.Гафури. *Ә Хаҗәтнең өен тануы җиңел: кыегында язын да, көзен дә кызыл байрак эленеп тора.* Р.Зәйдулла. *Шул көннән башлап [Алексей Иннокентьевич Антонов], Кызыл Байрак астына басып, 1962 елның 18 июненә кадәр Советларның Кораллы Көчләре сафында бертуктаусыз хезмәт итә.* З.Зәйнуллин

**КЫЗЫЛ БАЛЫК** *и.* Мәрсин һәм сөләйман балыклар семьялыгына керә торган кыйммәтле балыкларның (чөгә, кырпы балыгы һ.б.) гомуми исеме // Шул балыкларның ите. *Иртән торсам, әти белән әни мактый-мактый кызыл балык ашап утыралар.* А.Гыйләҗев. *1640 елда Җаек елгасының Каспий диңгезенә койган урыннарыннан 16 гына чакрымда, казакларга сиздермичә генә, рус сәүдәгәре Гурий Назарьев тарафыннан, кызыл балык тоту өчен, эре балык промыселы (балык кәсебе) хуҗалыгы – --- укчылар сагындагы каланчалар белән таш коймалар куела.* Т.Кәримов. *Тиешле урында ишетсәләр, бу кадәр кара уылдык, кызыл балык өчен бу кешенең башын гомер буе төрмәдә черетәчәкләр ләбаса!* Сөембикә

**КЫЗЫЛБАШ** I *и. бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык тамыр-сабаклы дару үләне; кантуктаткыч үлән, чыяна; *русчасы:* **кровохлёбка.** *Мондый болыннарда ак һәм ал клевер, болын кукчәчәге, кузгалак, эт какысы, кызылбаш, --- тычкан борчагы һәм башка күп кенә үләннәр үсә.* Умартачылык. *Кызылбашның тамырларыннан һәм тамырчыкларыннан эшләнгән төнәтмәләрне эч китүләрдән бөрештергеч дару, кан төкергәндә кан туктаткыч --- чара буларак файдаланалар.* Урман аптекасы

**КЫЗЫЛБАШ** II *и.* 1) *тар.* XV–XVI гасырларда Иран, Анатолия (Анадолу) һәм Азәрбайҗан территорияләрендә күчмә төрки кабиләләр берләшмәсенә караган кеше

2) *тар.* Фарсы, фарсы кешесе, иранлы. *Мәскәү һәм Варшава фабрикантлары һәр елны әрмәннәр илә кызылбашларга көтәсегә ничә миллионлык мал саталар.* Ш.Мөхәммәдев. *Мөхәммәтҗан байга да бу фикер ошап куйды: – Без тимер юл үткәрсәк, әгелчәннең кызылбашлар, һиндлар белән сәүдәсенә китереп суга шул бу!..* Ә.Фәйзи

3) Шига, шигый мәзһәбендәге кеше. *Бер кызылбаш безнең бүлмәбезгә кереп, үзенең Коръән китабын чыгарып, «һүәл-ләзи ---» аятен күрсәтеп, тәфсирен сорады ---. Үз мәзһәбләренчә намазны олылап, догаларны дөрес укуыннан бу кешене «яхшы галимдер» дип хисаплап калдым.* Р.Фәхретдин. *Урта гасырларда кызылбашлар хәрәкәтенә бәйле шигыйлар да аның исеме астында хәрәкәт иткәннәр.* Ф.Яхин

4) **кызылбашлар** *этн. күпл.* XVIII гасырда Ираннан качып, Оренбургта татар халкы составына кергән качкын этник төркем

5) **кызылбашлар** *күпл.* Әфган халкы составына кергән, дари телендә аралаша торган аз санлы бер этник төркем

**КЫЗЫЛБАШ** III *и. иск. сөйл.* 1917 елгы инкыйлапка кадәр: шешәсенең авызы кызыл сургыч белән ябыштырылган аракы; төрек малае, фәсле малай. *Карт-коры, мулла-мунтагай күрмәгән арада төшергәләү өчен, чиреге белән менә бу кызылбашларны китертеп куям...* Г.Ибраһимов. *Әнвәр кул сумкасы эченнән кызылбашны чыгара. Бутылканы уч төбенә бик каты итеп бәрә. Улы Касыйм, өйгә йөгереп кереп, чәшке алып чыга.* А.Алиш

**КЫЗЫЛ БИЛЕТ** *и. тар.* Революциягә кадәр хәрби хезмәткә каралган вакытта армиягә алынмыйча, ләкин бер айга хәрби хезмәтне өйрәнергә барып кайтырга тиешле кешеләргә бирелгән билет. *Кызыл билетка калганнарны, икенче төрле итеп, чабаталылар дип тә йөрттәләр иде.* М.Гали

**КЫЗЫЛ БОРЫЧ** *и.* 1) *бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан кызыл кузаклар бирә торган көньяк үсемлеге, кузаклы борыч. *Менә ул, кызыл борыч шикелле юан бармагын ничек кирәк алай бөгеп, Рәшадны якынрак килергә чакырды.* А.Тимергалин. *[Ибрай:] Помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме, үстереп өлгертәбез.* М.Әмир

2) Шул үсемлекнең аш тәмләткеч буларак кулланыла торган ачы кузагы. *[Ике стаканның] --- берсенә күп кенә итеп төйгән кызыл борыч салып, кашык сабы белән бик ныклап буташтыргач, Җиһангир картка тоттырды.* Ш.Камал. *Тәненең кызыл борыч белән угандай кызуына рәхәтләнеп бии-бии сөртенгәндә, чишмә өстендәге өянкеләргә күзе төште.* Г.Бәширов

**КЫЗЫЛ ГАЛСТУК** *и. тар.* Совет чорында пионерлар муенга тага торган өчпочмаклы кызыл яулык. *[Яшүсмерләрнең] Икесенең дә муенында кызыл галстук. Берсе авызына җиз торба капкан, икенчесе барабан аскан.* М.Мәһдиев. *Кызыл галстук аның муенында, ә күңеле һаман, һаман уенда.* Д.Аппакова. *Ә менә күкрәкләренә комсомол значогы таккан игезәк абыйлары белән муенына кызыл галстук бәйләп йөргән апасының исә әби кешене «диндар», «надан» дип атаулары һәм Алланың юклыгын тырыша-тырыша исбат итеп маташулары Илвирга һич аңлашылмый иде.* М.Шаһимәрданов

**КЫЗЫЛ ГАСКӘР** *и. тар.* 1) *к.* **кызыл армия**. *Хаклык алдын барчадан, Өстен барча нәрсәдән! Кызыл гаскәр көче берлән Өстен булды һаман.* М.Җәлил. *Гражданнар сугышы вакытында Гомәр кызыл гаскәргә языла, кулына корал тотып, совет властен яклый.* Р.Мостафин

2) Кызыл Армия подразделениеләре. *Күңелем дә, җаным да, иманым да бергә --- Очтылар сахралар, урманнар өстеннән, Куе калын томаннар эченнән Кызыл гаскәрләр өстенә.* Һ.Такташ. *Минск янында уратып алынган кызыл гаскәрләр, каршылык күрсәтмичә коралларын ташлап, немецларга әсирлеккә бирeләләр.* З.Зәйнуллин

**КЫЗЫЛГАТ** *и. бот. диал.* 1) Бөрлегән. *Яңгыр тулган кызылгат, Аны ширбәт кылып эчиек!* Дастан

2) *к.* **кызыл карлыган**

**КЫЗЫЛГВАРДЕ́ЕЦ** *и. тар.* Кызыл гвардия сугышчысы. *[Батырхан:] Хатыннарыгызны, кызларыгызны плен алып, казармалар, күперләр юдырып, кызыл гвардеецларга никахсыз кияүгә бирерләр...* К.Тинчурин. *Бер төркем кызыл матрослар һәм кызылгвардеецлар ак офицерлар һөҗүменә каршы торырга, аларны үткәрмәскә, җиңәргә тиешләр.* М.Юныс. *812 нче санлы таныклама исә Шакировның элекке кызылгвардеец һәм кызыл партизан икәнлеген раслый.* Н.Юзиев

**КЫЗЫЛ ГВА́РДИЯ** *и. тар.* 1917–1918 елларда РКП(б)ның коралланган отрядлары, Октябрь инкыйлабы чорында хакимият өчен көрәштә, Гражданнар сугышы чорында хакимиятне кулда тотар өчен, аның төп хәрби көче. *Кызыл гвардия частьларының банданың эзенә төшүе турында хәбәрләр булды.* Г.Минский. *– Өч көн эчендә, – дип яза газета, – Кызыл гвардиягә егерме биш мең эшче язылды.* И.Гази

**КЫЗЫЛ ГВАРДИН** *и. сөйл. к.* **кызылгвардеец**. *Ә ул югалмаган, үлмәгән, Петроградта кызыл гвардин булып, патша төшереп йөри икән.* Г.Бәширов

**КЫЗЫЛГВА́РДИЯЧЕ** *и. к.* **кызылгвардеец**. *Тротуарда эшсез, тамаша кылучы Англия триколорына киенгән кешеләргә караганда, йөзләре корымга буялган, җилкәләренә винтовкалар күтәргән сәләмә кызылгвардиячеләр аңа [Сөләйманга] бу юлы мәһабәтрәк тә, эчтәлеклерәк тә булып күренделәр.* К.Тинчурин. *Янә Петроградтан 600 матрос, 17 нче Себер полкы, Ш.Усманов җитәкчелегендә яңа гына оешып алган кызылгвардиячеләр отряды җибәрелә.* С.Поварисов. *Кызылгвардияче Солтан кызу-кызу бара.* Г.Ахунов

**КЫЗЫ́Л ГӨМБӘ** *и. бот.* Ал гөмбәчәләр семьялыгыннан, аксыл кызыл эшләпәле, үскән саен бүрәнкәләнә һәм йөнтәс кырыйлары кайтарыла бара торган ашарга яраклы гөмбә; йонлач (йөнтәс) гөмбә; *русчасы:* **волнушка**. *Кызыл гөмбәне һ.б. эре гөмбәләрне тозлау өчен, эшләпәсен һәм сабагын аерым-аерым кисәкләргә бүлгәләргә кирәк.* Й.Әхмәтҗанов

**КЫЗЫЛҖИМЕШ** *и.* Кызылча II (*1 мәгъ.*) куагының җимеше

**КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ** *и.* Кызыл армия символы, шулай ук күп кенә илләрнең байракларында һәм гербларында урын алган геральдик билге, биш канатлы фигура. *Аларның очлы башлы бүрекләрендә кызыл йолдызлар ялтырый.* Һ.Такташ. *Солтанны ул [Нурия] солдат итекләреннән, яшькелт гимнастёркадан, кызыл йолдызлы, очлы башлы шлемнан итеп күз алдына китерде.* Г.Ахунов

**КЫЗЫЛ КАЗ** *и. зоол.* Кызылканатлылар семьялыгыннан, озын муенлы һәм озын аяклы, аска бөгелгән зур томшыклы, ал каурыйлы, тропикларда һәм субтропикларда яши торган су кошы; фламинго

**КЫЗЫЛКАНАТ** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан төче суда яши торган кызыл канатлы балык; *русчасы:* **краснопёрка**. *Төбәнәчә яп-якты булып ялтыраган күл суында уйнаган кызылканат балыкларны карады, якын ук килгән бер алабугага кинәт тотам дип кулын сузганда егылып, өс-башын сулатты [Фагыйлә].* Г.Ибраһимов. *Кызылканат та, алабуга да бар, имеш. Ә чуртан юкмы, чуртан?* Ә.Еники. *Уч төбенә сыярлык чабак һәм түбәнкә-ташбашлар, анда-санда кызылканатлар каптырырга яратам мин, әнә теге кызыл яр култыгына кармак ташлап.* Ф.Яхин

**КЫЗЫЛ КАН ТӘНЧЕКЛӘРЕ** *и. биол.* Тукымаларга кислород, сулыш органнарына углекислый газ йөртә торган кеше һәм хайван каны күзәнәкләре; эритроцитлар. *Ихтыярсыз аклар һәм кызылларга бүленгән ватандашларның бер-берсе белән сугышуы организмдагы ак һәм кызыл кан тәнчекләренең үзара көрәшенә охшый.* З.Мансуров. *Чөнки кан составындагы кызыл кан тәнчекләре – эритроцитлар мембранасында сапонин һәм холестерин кушылмалары барлыкка килә.* Ф.Закиров

**КЫЗЫЛ КАРЛЫГАН** *и. бот.* Крыжовникчалар семьялыгыннан ашарга яраклы җиләге кызыл була торган куак; кызылгат. *Бәлки, кызыл карлыганны моңарчы ашап карамаганга күрә, миндә шундый реакция булгандыр...* Ә.Еники. *Андагы җиләк-җимеш!.. Ул шомырт, миләш дисеңме, кара һәм кызыл карлыган дисеңме.* С.Поварисов. *Крыжовник, кара һәм кызыл карлыган, җир җиләге марганец җитешмәүдән башка культураларга караганда сирәк зыян күрәләр.* Бакчачы белешмәсе

**КЫЗЫЛ КА́РТОЧКА** *и. спорт* Футбол, гандбол, туплы хоккей, регби, җиңел атлетика кебек спорт төрләрендә, уен кагыйдәләрен тупас бозуы өчен, спортчының уен кырыннан вакытлыча яки бөтенләй чыгарылуын белдереп күрсәтелә торган билге. *«Рубин» катнашындагы матчлар кызыл карточкасыз уза димени!* Ватаным Татарстан

**КЫЗЫЛ КИТАП** *и.* Сакланырга тиешле (аулау яки җыю тыелган) сирәк очрый торган яки югалу куркынычы астында булган үсемлекләр һәм хайваннар турында мәгълүмат җыелган халыкара исемлек. *Һәм кинәт кенә аңында бүгенге кулланышта сирәк очрый торган сүз – вөҗдан сүзе калкып чыкты, әйтерсең үзе дә сизми Кызыл китапның «В» хәрефе куелган битен ертып алды.* Р.Мирхәйдәров. *Әле хәзергә Кызыл китапка кертелгән кыргый ишәк – колан, Пржевальский аты, кыргый дөя сакланган.* Материклар һәм океаннар. *Кыргый инҗир Кызыл китапка кертелгән.* Урман аптекасы

**КЫЗЫЛКОЙРЫК** *и. зоол. к.* **уткойрык**; *русчасы:* **горихвостка**

**КЫЗЫЛ КӨРТМӘЛЕК** *и. бот. диал.* Нарат җиләге, саз чиясе

**КЫЗЫЛ КРИСТАЛЛ** *и.* Ак җирлеккә төшерелгән кызыл ромбтан гыйбарәт, Халыкара Кызыл Хач һәм Кызыл Ай хәрәкәтенең өч эмблемасыннан берсе

**КЫЗЫЛКҮЗ** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан төче суда яши торган кызыл күзле балык; *русчасы:* **красноглазка**. *Кояш чыгып бераз күтәрелгәч, алабуга, кызылкүз чиртә башлады, шыртлака кабып аптыратты.* А.Гыйләҗев

**КЫЗЫЛЛАНДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **кызыллату**

**Кызылландыра төшү** Тагын бераз кызылландыру

**Кызылландырып кую** Кызылланган хәлгә китерү

**КЫЗЫЛЛАНУ** *ф.* 1) Кызыл төс керү, кызылга әйләнү; кызару. *Аллан-дылар мәгъриб болытлары, Кызыллан-ды кояшның нуры...* Г.Рамазанов. *Синең көлеңә тигәч, куллар кызыллана...* Х.Бикколов // Кызыл булып күренү. *Ка-далды ук йөрәгемнең түренә, Кызылла-нып, җәрәхәттән кан ага.* М.Җәлил. *Кичә яшел, бүген кызылланып Балкый өстә безнең өтек байрак.* Ф.Яхин

2) *күч. сөйл.* Сул карашлыга әйләнү, карашлары суллану; революцион юлга басу. *[Гыйниятулла] --- бу вакыт эчендә сәяси яктан хәзер шактый ук суллашты, кызылланды.* С.Җәләл. *[Сө-ләйман:] Ә син алай артык кызылла-нып маташма!* Һ.Такташ

**Кызыллана бару** Торган саен ныг-рак кызыллану. *[Чәчәкләрнең] Юылу-дан кызыллыгы бетми, Киресенчә, кы-зыллана бара.* А.Нәҗми

**Кызыллана башлау** Кызылланыр-га тотыну. *Таң атып, офык кызыллана башлагач, төнне йокысыз үткәргән Мәргәннең алачыгына Сары Каен йөге-реп керде.* И.Хуҗин. *Азатлыкка теше-тырнагы белән каршы торган монар-хист реакция елларында, җилкәсенә заман бүрәнәсе төшүдән куркып кы-зыллана башлый, хөкүмәтне халыкка хөррият бирмәүдә гаепли.* С.Поварисов

**Кызыллана төшү** Элеккедән дә ныграк кызыллану; бераз кызыллану

**Кызылланып алу** Берара кызыл-лану. *Сул карашлыга әйләнеп, берара кызылланып алу*

**Кызылланып бетү** Тәмам кызылга әйләнү

**Кызылланып йөрү** Күптәннән бирле, соңгы вакытларда кызыллан-ган булу (үтә сул карашлы булу). *Әйт-кәннәр иде аны, калада бик тә кызыл-ланып йөри, дип [Хәләф].* Ф.Яхин

**Кызылланып китү** Кинәт кызыл-ланган төскә керү; соңгы вакытта кы-зыллана башлау. *Минем читегемнең битлеге бөтенләй кып-кызыл. Бал-тырының кайбер җирендә кап-кара нәрсә ялтырап торса да, кай җирлә-рендә кызылланып киткән, ул ала-кола.* Г.Исхакый

**Кызылланып кую** Тиз арада кы-зыллану

**Кызылланып тору** Кызарган хәлдә булу. *Моннан егерме еллар тирәсе элек тә сөякчел яңаклар шулай кызылланып тора иде.* Ватаным Татарстан

**Кызылланып чыгу** *к.* **кызарып чыгу**

**КЫЗЫЛЛАТУ** *ф.* Кызыл төскә кертү, кызарту, кызылландыру. *Күкне кызыллатып көн батуын, җәйге таң атуын яратам.* Ә.Ерикәй

**Кызыллата төшү** Элеккедән дә ныграк кызыллату

**КЫЗЫЛЛЫ** *с.* 1) Кызыл төстәге, кызыл төс катнашкан, кызыл төсмерле. *Урамга купецлар туктаган, Кызыл-лы яулык алыгыз; Без ашаганга, без эчкәнгә Риза-бәхил булып калыгыз.* Җыр. *Ул әбинең балкыган тышка уты бик якты, ди; Һәм ул ут чиксез матур: күкле, кызыллы, аклы, ди.* Г.Тукай. *Кар-чык Газизәгә дигән кызыллы күлмәген күз алдына китереп уйлап торганда, картның әллә ниткән бер русны мак-тауларын, сагынып сөйләүләрен бер дә әһәмият биреп тыңламый.* Ш.Камал

2) Катлаулы төсне белдергәндә: кы-зыл белән башка ниндидер төсләр ара-лашкан. *Алар кызыллы-күкле, эреле-ваклы флаглар белән бизәлгән зур кап-кадан кергәндә, ярмарка халык белән кайнап тора иде инде.* Ә.Фәйзи. *Вәкил френч кесәсеннән кызыллы-зәңгәрле карандашын алды.* М.Мәһдиев. *Ун-бишенче уен да уртакка төгәлләнгәч, директор компьютер экранында пәйда булган кызыллы-аклы билгеләргә бак-ты.* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗЫЛЛЫК** *и.* 1) Кызыл булу. *Карбызның эче кып-кызыл булса да, ул кызыллык кап-кара орлык белән кәрәзләнгән бит.* С.Поварисов. *Ә Хаҗәтнең өен тануы җиңел: кые-гында язын да, көзен дә кызыл байрак эленеп тора. Кызыллыгы инде аның ташка үлчим, җилдә ашалып, төсен аныклавы да кыенлаша төшкән ---.* Р.Зәйдулла. *Ишеткәч, алар комач кебек кызардылар төсле. Төнлә аның кызыл-лыгы күренми дә инде.* Н.Гыйматдинова

2) Кояш баткан яки чыккан чакта, күк гөмбәзе офык янында балкудан барлыкка килгән кызгылт төс, шәфәкъ төсе. *Тышта әле артык караңгы түгел; шәфәкъ кызыллыгы караңгылыкны аз-рак сыеклатып тора.* Ш.Камал. *Кояш чыгышы ягыннан кызыллык беленде.* А.Алиш. *Карасу-кызыл моңсу кояш ерактагы таулар артыннан сүлпән генә күтәрелеп килә. Җир өстенә кы-зыллык иңгән.* М.Юныс. *Әнәс күзләрен көнчыгыш яктан күк йөзенә җәелә бар-ган шәфәкъ кызыллыгына төбәп уйга калды.* М.Шаһимәрдәнов // Янгынның, көчле атышның күктә чагылуыннан барлыкка килгән кызгылт төс

3) Канның тирегә күбрәк килүе ар-касында, тәндә барлыкка килә торган кызыл төс. *Хәят үзенең кызарганлы-гын белә, колакларының ялкынсыз ян-ганлыгын да сизә; һәм хәзер генә булып узган эш аның алдында томан эчен-нән карап, шатлыклы елмаеп торган шикелле була да, йөздәге кызыллык, колаклардагы яну тагы да көчәя иде.* Ф.Әмирхан. *Йөзләргә кызыллык йөгер-де, күзләр майланып елтырады, сүз куера төште.* М.Галәү. *– Уноч тулды инде, үзем кадәр булды, – ди ул [ха-ным], һәм, ни өчендер, бөтен йөзенә кызыллык йөгерә.* Ә.Еники

4) *күч.* Сул карашлы булу. *Әби-бабайларның комсомолларга карата мондый мөнәсәбәте бер дә дин вә шә-ригать хөкемен өстен күрүдән түгел, бәлки бары тик аларның кызыллыкла-рын яратмауларыннан килеп туган сүзләр иде.* Ф.Яхин

**КЫЗЫЛ МАЛ** *и. иск.* Тукымалар, мануфактуралар, аршынлы мал. *Бу кәрванчы байларның берсе – Үргәнеч белән Казан арасында кәрван йөртеп сату итүче, эчке Русиядән Үргәнеч һәм Хивага кызыл мал, китап, Коръән, савыт-саба, тимер һәм чуен әйберләр шикелле фабрик һәм завод маллары илтеп, аннан ефәк, каракүл, илтер, җимеш һәм дөге шикелле нәрсәләр алып кайтып кәсеп итүче атаклы һәм данлыклы Мортаза бай иде.* М.Галәү. *Бүген төнлә Низам байның кладовоен-нан егерме йөк кызыл мал төяп алып киткәннәр.* К.Тинчурин. *Иранның көньяк-көнбатышындагы Шираздан килгән Шәмсетдин Мөхәммәт атлы бай гына бер сәүдәгәр, Урта Азиядә алыш-биреш иткәннән соң, 1438 елның*

*җәендә Сарай-Батуга 21 мең динарга Көнчыгышның татлы ашамлыкларын: алай, гамбәр, борыч, имбир, мөшкәт чикләвеге һ.б. алып килә дә кызыл мал, ягъни мануфактура төяп китә.* Р.Фәхретдинов

**КЫЗЫЛ МАЛЧЫ** *и. иск.* Мануфактура белән сәүдә итүче, бәззар. *Кызыл малчы Габделхәлим аларны бергә кушып бәхетле итмәкче иде.* Г.Ахунов. *Көфер почмагы да гөрләп тора, анда һәр көн йөрүче вак сәүдәгәрләр, кырык тартмачылар, кибет тотучы, кызыл малчы, тирече, кәвешче, кәләпүшчеләр үз эшләре белән мәшгуль, кычкырыпкычкырып товар мактыйлар, узганбарганнан көлеп, оятсыз сүзләр аралаштырып мыскыллыйлар.* А.Расих

**КЫЗЫЛ МАРҖА** *и. диал. зоол.* Кызыл кандалалар семьялыгыннан, колонияләр булып җирдә яши торган 9–11 мм зурлыгындагы кызыллыкаралы бөҗәк; мәчет тараканы, канатсыз кызыл кандала; *русчасы:* **клоп-солдатик**. *Иске коймалар янындагы кызыл-кызыл марҗалар да бик һаваланып кына кояшның җылысында рәхәтләнәләр, туйлар ясыйлар.* Г.Исхакый

**КЫЗЫЛ ОБОЗ** *и. к.* **кызыл олау**. *Кызыл обоз көннәре Күңелле һәм хикмәтле. Бер кайгыларым калмады, Колхозчылар икмәкле.* Җыр. *– Да-а, кызыл обоз киләсе көн иде бит бүген, – диде Хәйруллин папиросын чәйнәп, – болай булса эш харап.* М.Мәһдиев

**КЫЗЫЛ ОЛА́У** *и. тар.* Дәүләтнең ашлык җыю пунктларына ашлык тапшыру өчен, крестьяннар-колхозчылар тарафыннан оештырылган, берсе артыннан берсе бара торган, кызыл флаглар тагылган берничә олау. *Юл буйлап, ашлык төяп Кызыл олаулар килә.* Җыр. *Председатель Тимерхан лодырь чутыннан йөргән Борһанга да хезмәт көненә тиешле ярты пот бодайны кызыл олау белән илттерде.* М.Мәһдиев. *Иген уңган елларда ашлыкны кызыл олаулар белән хуҗалыктан хуҗалыкка таратып йөрделәр.* Ф.Садриев. *Шушы ук юллардан кызыл олаулар белән илгә икмәк озаттылар...* Р.Юсупова

**КЫЗЫЛ ПОЧМАК** *и. иск.* Нинди дә булса эшханә яки учреждениедә агитация һәм сәяси агарту эшләре алып бару өчен билгеләнгән бүлмә, бүлмәнең бер өлеше яки махсус конструкция (стенд). *Көннәрдән бер көнне, узып барышлый гына, тулай торакның беренче катында урнашкан «кызыл почмак»ка күз салып узыйм дисәм, ишектән башым тыгуым булды, телсез-өнсез торып калдым.* Р.Мөхәммәдиев. *Экипажны кызыл почмакка чакырдылар. Эшне ташлап очтык. Кызыл почмак ялт итеп тора.* М.Юныс. *Һәм кызыл почмакта сыйланып утырганда, мөдир Сафатдин: – Нурсадә каравыл йортында бозауның дөньяга килгәнен сагалап утыра, – диде.* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗЫЛСУ** *с. кимл. дәр.* Берникадәр кызыл, кызгылт, ал. *Ул [кояш] бердән кып-кызыл яна торган ут кебек булып кызыктыра, бердән кызылсу көзге кебек булып күзне камаштыра иде.* Г.Исхакый. *Әле тагын – безне гелә түгел, шактый гаиләне авыр елларда суыктан һәм ачлыктан саклап калган, бөтен дөньяга танылган Zinger тегү машинасы, әбиебез әниемә бүләк итеп биргән, кызылсу алтыннан ясалган күбәләк рәвешендәге брошка.* Т.Кәримов

**КЫЗЫЛ СЫР** *и. иск.* 1) Кызыл төстәге минерал – күкертле терекөмеш

2) Шул минералдан алынган кызыл буяу; *русчасы:* **киноварь**

**КЫЗЫЛ ТАКТА** *и. иск.* Алдынгы эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең исеме язылган яки рәсемнәре куелган мактау тактасы. *Су алгыч янына ук комсомоллар «Кызыл такта» белән «Кара такта»ны китереп урнаштырганнар.* А.Алиш. *Эшче полклар һаман арталар (Артып тора кызыл такталар).* Һ.Такташ. *Кабере, мин сиңа әйтим, изге революция шәһитләре белән беррәттән, мәңге йөз аклыгы, мин сиңа әйтим, бөтен эшче-крәстияннең күз өстендә каш. Исеме мәңге кызыл тактада.* Ф.Әмирхан

**КЫЗЫЛ ТАЛ** *и. бот.* Талчалар семьялыгына керә торган, үсеп чыкканда кызгылт көрән төстә булган куак яки агач; *русчасы:* **краснотал**. *Әнә урам чатында сакаллы бер урыс карты көмеш бөреләр җибәргән кызыл тал чыбыклары сатып тора.* Р.Туфитуллова. *Өстәвенә һәр агачның үзенә хас дәвалау сәләте бар. Мәсәлән, кызыл тал тынычландыра, йөрәк чирләрен дәвалый, баш авыртуын һәм теш сызлавын баса.* Ватаным Татарстан

**КЫЗЫЛТАМЫР** *и. бот.* Эфедрачалар семьялыгыннан, җиләксыман орлыгын урап алган яралгылары ашарга яраклы, кызыл тамырлы үләнчел үсемлек; *русчасы:* **кузьмичёва трава, эфедра колосковая**

**КЫЗЫЛ ТАРАКАН** *и.* Торак йортларда яши торган озын мыеклы кызыл төстәге бөҗәк; өй тараканы. *Без дә Олы җиңүгә зур өлеш керттек, син уйлаганча, мич башында чикерткә сайраганны тыңлап, кызыл тараканнар санап ятмадык!* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗЫ́Л ТӘНЛЕ** *и.* Көньяк һәм Төньяк Америкада яшәүче җирле халык вәкиле, индеец. *Алар негр балалары белән бер мәктәптә укыды, ләкин Кристоның кара тәнлеләргә, кызыл тәнлеләргә мондый нәфрәте барын белмәгән иде.* Р.Батулла. *Ахырда кызыл тәнлеләр тарафыннан әлегә урыннан кузгалмаска, ләкин сак булырга һәм коралларны әзер тотарга карар кылынды.* И.Хуҗин. *Заманында ак тәнле басып алучыларның кызыл тәнлеләрне кыруы тарихта билгеле.* А.Хәлим

**КЫЗЫЛ ТӘРЕ** *и. сөйл. к.* **Кызыл Хач**. *Бер-бер артлы тезелеп киткән яшел вагоннарның стеналарында зурзур кызыл тәреләр күренә.* Г.Гобәй. *Болар Кызыл Тәре һәм Кызыл Ярымай җәмгыяте активистлары була.* З.Хәсәнова

**КЫЗЫЛ ТЕРРОР** *и. тар.* Россиядә 1917–1922 елгы Гражданнар сугышы чорында большевикларның сыйнфый дошманнар дип игълан ителгән социаль төркемнәргә һәм контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнгән затларга каршы үткәрелгән җәзалау чаралары. *1917 елның октябреннән бирле ЧКдан, «кызыл террордан» иза чиккән Русиядә большевикларга каршы короллы көрәш башлана.* З.Зәйнуллин. *Совет хакимиятенә каршы вакытлы матбугат кызыл террор, кызыл армия сафларына көчләп мобилизация үткәрү һәм шунлыктан барлыкка килә торган*

*дезертирлык күренешләре, крестьяннардан продразвёрстка салымы буенча көчләп азык-төлек тартып алу, ирексезләп гомуми-мәҗбүри хезмәт кертү кебек большевиклар кылган эшләр турында хәбәр итеп тора.* Гасырлар авазы. *Эш шунда ки, бу яклардагы Семочки һәм Пашат дип аталган ике татар авылында кызыл террор 1919 елда ук була.* Безнең гәҗит

**КЫЗЫЛ ТОВАР** *и. иск. к.* **кызыл мал**

**КЫЗЫЛ ТУЙ** *и.* Октябрь революциясеннән соң дини йолалар урынына яңа йолалар белән үткәрелә торган туй. *Мин, кызыл туйның ничек яралуы турында хуҗа хатыннан сорашыр өчен, беразга өйдә калдым.* А.Шамов. *Мәнә синең үзеңне дә шундый кызыл туйлар ясап кияүгә бирербез әле.* Г.Камал. *Егетләр китә солдатка – Кемдә юк кызыгулар! Тынычлык белән кайтыгыз – Ясарбыз кызыл туйлар…* Р.Рәкыйпов

**КЫЗЫЛ ТУРМАЛИН** *и. мин.* Алсу кызыл төсле үтә күренмәле кыйммәтле таш; рубеллит, апирит, даурит

**КЫЗЫЛ ТУРЫ** *с.* **1.** Гәүдәсе куе җирән яки кызгылт көрән, ялы, койрыгы һәм аякларының аскы өлеше кара төсле (ат тур.). *Нинди төсле булды икән [колын үсеп җиткәч]? Җирәнме, әллә кызыл турымы?* Г.Бәширов. *– Атыгызның берсе тимер күк, икенчесе кызыл туры идеме? – Шулай, тәкъсир, бик дөрес, тимер күк белән кызыл туры! – диләр кәрванчылар өметләнеп.* Ә.Еники. *– Я, сезнең татарда кызыл ат буламы? – Безнең өчен бу сорау – сорау да түгел. – Кызыл туры! – дип кычкырабыз.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* Шундый төстәге ат. *Абыйның кызыл турысы кичә колынлаган*

**КЫЗЫЛТҮШ** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан, түше һәм ян яклары кызыл, кечкенә сайрар кош; *русчасы:* **зяблик**. *Кызылтүшләр чут-чут сайрый, Яңгыратып урманны.* Л.Шәех. *[Сыерчык] Бака булып та бакылдый, Тартар да була ала. Кызылтүш кебек тә сайрый Канатын кага-кага.* Н.Мадьяров. *Җәй ахырларында, балалары үсеп җиткәч, кызылтүшләр көтү-көтү булып көньякка очып китәләр.* Кошлар

**КЫЗЫЛ ҮҢӘЧ** *и. диал.* Кешедә һәм хайваннарда азык кайнату трактының авыз куышлыгыннан алып ашказанына кадәр булган өлеше

**КЫЗЫЛ ҮРДӘК** *и. зоол.* Үрдәк кошлар семьялыгыннан кызгылт көрән төсле су кошы; *русчасы:* **огарь**

**КЫЗЫЛ ФЛОТ** *и. тар.* Совет хәрби-диңгез көчләренең 1918–1946 еллардагы рәсми исеме

**КЫЗЫЛФЛОТЧЫ** *и. иск.* СССРның Хәрби-Диңгез Флотында 1918–1946 елларда: матрос званиесе һәм шул званиегә ия хезмәт итүче. *Машинаны орденлы кызылфлотчыга бирү турында сүз чыккач, бу карарга парткомда да, профкомда да каршы төшмиләр.* Р.Мирхәйдәров. *Өлкән кызылфлотчы*

**КЫЗЫЛ ХАЧ** *и.* Ак җирлектә туры почмак ясап кисешкән ике тигез кызыл буйдан гыйбарәт, Халыкара Кызыл Хач һәм Кызыл Ай хәрәкәтенең өч эмблемасыннан берсе. *Мәнә кафе ишек төбенә алгы тәрәзәсенә кызыл хач төшерелгән «Москвич» килеп туктады.* А.Гыйләҗев. --- *рәсемдә пилоткасын кыңгыр салган, беләгенә кызыл хач бәйләп, янына дәү сумка аскан солдат дусты Гөлзәбәр елмаеп тора.* Г.Бәширов. *Рәй кызыл хач сурәте төшерелгән аптечканы ачты.* А.Тимергалин

**КЫЗЫЛЧА** I *и.* 1) *мед.* Чирләгәндә бөтен тәнгә кызыл бөрчекләр чыга, балалар авырый торган йогышлы чир (беркадәр кызамыкны хәтерләтә). *Алар [вируслар] чәчәк авыруы, гепатит, энцефалит, кызылча, кызамык, котыру авыруы, грипп һәм башка шундый күп кенә куркыныч йогышлы авыруларны кузгатучылар булып тора.* Биология. *Прививка баланы полиомиелит, дифтерия, бума ютәл (коклюш), туберкулёз, столбняк, В гепатиты, кызамык, колак арты бизе шешү, кызылча кебек чирләрдән саклый.* Ватаным Татарстан. *Тиздән республикада эндемик кызамык та бетереләчәк. Дифтерия, столбняк, бума ютәл, кызылча, туберкулёз, вируслы В гепатиты белән авыручылар саны да кимегән.* Кызыл таң

2) *вет.* Дуңгызларда була торган йогышлы авыру, эризипелоид

**КЫЗЫЛЧА** II *и. бот.* 1) Яфраклары җәен куе яшел, көзен кызыл булып, вак кына ак яки ал чәчәк ата торган куак үсемлек; *русчасы:* **кизильник**. *Кызылча әрәмәлекләре тау-дала, урман һәм биек тау тирәсе поясларында үсә.* Урман аптекасы

2) Шул куакның бик әче, ашаганда авызны камаштыра торган карасу кызыл җимеше

**КЫЗЫЛЧА** III *и. диал.* Кызыл чөгендер

**КЫЗЫЛЧА** IV *с.* Кызгылт, кызылсу. *Кызылча йөзле, яшь чырайлы, картая белмәс Карибулла хәзрәттән бусын ук көтмәгән иде колхоз председателе.* М.Шаһимәрдәнов

**КЫЗЫЛЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Вак чәчәкле һәм вак җимешле мәңге яшел яки яфракларын коя торган агачлар яки куаклар семьялыгы

**КЫЗЫЛЧАТЫР** *и. бот.* Гентианачалар семьялыгыннан ал чәчәкләр ата торган үләнчел үсемлек; *русчасы:* **золототысячник**. *Хәзерләгәндә, кызылчатыр үләнен тамыр тирәсе яфрак җәелешләре белән бергә кисеп алалар һәм күләгәдә киптерәләр.* Урман аптекасы. *Кече кызылчатыр*

**КЫЗЫЛ ЧЕРЕК** *и. бот.* Зарарлы гөмбәләр тәэсире нәтиҗәсендә ылыслы агач үзагачының кызгылт көрән төскә кереп таркалуыннан гыйбарәт авыру. *Кызыл черек гөмбәсенең споралары агачның үзагачына гадәттә киселгән урыннан керәләр. Үзагач череге, типлары төсләренә карап, ак, кызыл, көрән, чуар һәм зәңгәр черек була ала*

**КЫЗЫЛ ЭРЕМЧЕК** *и.* Эремчекне кызарганчы кайнатып, махсус ысул белән ясалган ашамлык; корт. *Ә ашъяулык өстендә төче күмәч, бавырсак, кызыл эремчек, калай савытта бал белән май – Чикерткәнең тәмам күзләре яна.* Ә.Еники. *Чәй янына бал, каймак, кызыл эремчек килде.* М.Юныс. *Ак эремчек, кызыл эремчек, каймак кебек ризыкларны яратып кулланганнар.* М.Шәмсетдинова. *Кайбер капчыкларда хуш исле бавырсак та була. Тагын карындыкка төргән кайнаткан кызыл эремчек, ягъни корт.* Ватаным Татарстан

**КЫЗЫЛ ЮЛ** *и.* 1) Абзацның тоташ тексттан бераз эчкә керебрәк башланган беренче юлы

2) *тип.* Кәгазь битенең уртасына басыла торган баш юл

**КЫЗЫЛ ЯКУТ** *и. мин.* Кызыл төсле кыйммәтле асылташ; ләгыль, рубин. *Бәйтүл-Мәгъмур эв (өй) ирде, кызыл якуттин ирде.* М.әл-Болгари. --- *кардәшләриңә сәни ул кавыштырды, кызыл якут беләзек ул вирди имди.* Кол Гали. *Шәрифәнең сүзләренә ияреп чыккан күз яшьләре алсу бите буйлап йөгерде, кызыл якут иреннәннән узып, ияк очына төште.* Ф.Яхин

**КЫЗЫЛ ЯРЫМАЙ** *и.* **Кызыл ай**

**КЫЗЫНУ** I *ф.* 1) Үзеңне, үзеңнең тәнеңне җылыту; җылыну (мич, учак һ.б.ш. янында). --- *управляющий, бер караганда, тел-тел булып һавага сузылган ялкынга карап кызына, бер караганда, гүя тарала барган халыкның артыннан мылтык төзи иде.* М.Галәү. *Анда [мич алдында] ертык күлмәкле ябык бер хатын белән җиде яшьлек малай утта кызыналар.* Г.Ибраһимов. *Тышта нинди генә салкын яки юеш булмасын, [солдатлар] ут чәчеп торган мич каршында кызыналар.* Ф.Баттал

2) Тәнне кояш нурлары тәэсире астына кую; тәнне кояш нурларында кыздыру. *Эш эшли алырдай сәламәт кешеләр инде һәммәсе дә кырларда, басуларда, йорт яны бакчаларында кызына, сәламәтләнеп җитмәгәннәре исә, шифалы яз һавасыннан үзләренә көч туплап, кояшта кызыналар иде.* М.Галәү. *Тау итәгендә атларны ял иттереп, кояшка арканы куеп бераз кызындык та.* Ф.Хөсни. *Гәпләшеп утырганнан соң, алар [Гадилә белән Шөһрәт] тагын су коеналар, комда кызыналар.* Ф.Яруллин

**Кызына башлау** Кызынырга тотыну

**Кызына бирү** Бернигә дә карамыйча кызынуны дәвам итү

**Кызына төшү** Тагын бераз кызыну

**Кызынып алу** Күпмедер вакыт кызыну. *[Лида:] Сез теләсә нишләгез, мин бераз кызынып алам.* А.Гыйләҗев. *Шулай укый-укый, [Илһам] берничә сәгать кояшта кызынып алды.* М.Шаһимәрдәнов

**Кызынып калу** Берәр хәл булганчы кызынып өлгерү

**Кызынып йөрү** Әле, хәзер шактый вакыттан бирле кызыну. *Юкка кан коеп, чыкмаган кояшка кызынып йөрмиме, янәсе?* С.Поварисов

**Кызынып тору** Хәзерге вакытта кызыну, кызыну хәлендә булу

**КЫЗЫНУ** II *и.* Җылыну; тәнне кояш нурларында тоту. *Бу хәлдән соң беребездә дә кызыну теләге калмады.* Р.Туфитуллова. *Нигә безне кызынудан, Коенудан тыясың?* Мөҗәһит

**КЫЗЫШТЫРУ** *ф. сөйл.* Берәр эшкә дәртләндерү, дәрт-теләк уяту. *Ул да булмады, Хафизулла бу эшкә кемнәрнедер кызыштырырга теләп кычкыра башлады.* Г.Минский

**Кызыштырып тору** Гел кызыштыру

**КЫЗЫШУ** I *ф.* 1) Эсселәнү, кызу; организмның, тәннең температурасы күтәрелү. *Тау үрен менгән саен туктап ял итәсе, кызышып тирләгән эссе тәнне җилгә ачып суытасы килә, утырып я ятып, арыган аякларга аз гына булса да ял бирәсе килә.* З.Зәйнуллин. *Төне буе кызышып елады, үрсәләнде сабый.* Ф.Яхин. *Йөрәгем дөп-дөп сикерде, суккан саен учым әчетеп кызышты.* Н.Гыйматдинова // Ялкынсыну. *Дөрес, тамак төбе кызышып, ютәлләп, атнага якын толып астында ятты, мәгәр үз сүзен сүз итте.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Ярсу, ярсып чыгу, кызып китү. *Ахыр, бер аш ашап утырган чакта, кызышып, үзен үзе югалтты [Шәйхел], аш куйган табынга төкерде дә каргап, рәнҗеп чыгып китте.* Г.Ибраһимов. *Уч кызышса кылыч сабын эзләп, Йодрык яный заман өрәге.* М.Галиев. --- *йөрәк кызыша дип, [Фәнис] төне буе йоклый алмыйча бәргәләнеп чыкты, кулларына урын тапмыйча җәфаланды.* Ф.Яруллин

3) Исерү. *Кайдадыр бик озак ябылып утырганнар, ахрысы, барысы да кызышканнар, үзләре бик шатлар, бертуктаусыз көләләр...* Ә.Еники

4) *диал.* Дымлылыктан җылынып чери башлау, черү, яну, бурсу (ашлык тур.). *Ничәмә тонна ашлык кызышып исләнгән һәм күгәрек гөмбә белән капланган*

**Кызыша бару** Торган саен кызышу. *Халык эчкән саен кызыша барды.* С.Сүнчәләй. *Укыган саен колак очларым кызыша бара: шулкадәр дә ахмак, ваемсыз булганмын икән...* А.Гыйләҗев. *[Нурия] --- бит алмаларының көне буе мич каршысында торгандай кызыша баруын тойды, әмма мәҗлес теләген үтәми торып котыла алмаячагын аңлады.* Г.Ахунов

**Кызыша башлау** Кызышырга тотыну. *Чишмә суы белән битен-башын юды, якынаеп килгән көзнең салкын сулышына бирешмәс өчен, битләрен, беләкләрен, кып-кызыл булып кызыша башлаганчы, каты киндер сөлге белән ышкыды.* Г.Ахунов

**Кызыша төшү** Элеккедән дә ныграк кызышу

**Кызышып алу** Кыска бер вакыт эчендә кызышу. *Кәгазь гүя уч төбен пешерде, бармаклар кызышып алды.* Н.Гыйматдинова

**Кызышып бетү** Тәмам кызышу

**Кызышып китү** Кинәт кызыша башлау. *Аның [Зөфәрнең] яңаклары кызышып китте.* А.Гыйләҗев. *[Самат Ландышка (сугыш кырына ишарәләп):] Биграк кызышып киттеләр.* С.Гаффарова. *Нәкъ шул чагында, әйтерсең лә кызган тимер бастылар, Надирның култык асты кызышып китте, кинәт сулышы капты.* Ә.Шәмин

**Кызышып тору** Кызышкан хәлдә булу. *Хәзердән үк йөзем кызышып тора.* Г.Гыйльметдинова

**КЫЗЫШУ** II *и.* Югары температура. *Әле салкыннан калтырана-калтырана, әле кызышудан үз-үзен кая куярга белмичә чәбәләнә-чәбәләнә, бик озак хаста булып ятты ул.* М.Галәү

**КЫ́З ЯРӘШҮ** *ф. сөйл.* Кызны кеменең дә булса кәләше дип белдерү, кәләше итеп игълан итү. *Кибетченең бердәнбер улы Насыйбка Бикьярдан Бака Харис дигән крестьянның кызын ярәштеләр.* Г.Ибраһимов. *Нишләптер капканы яртылаш кына ачып, яртылаш кына ачылганга күрә, олы гәүдәсе белән сыя алмыйча кысыла-кысыла, Минһаҗ абый килеп керде һәм кыз ярәшергә килгән егет кебек оялып кына сәлам бирде.* Н.Гыйматдинова

**КЫ́З ЯУЧЫЛАУ** *ф. к.* **кыз сорау**

**КЫЙ** I *и. диал.* 1) Кипкән тизәк (гадәттә кәҗә-сарык малыныкы). *Кый түгү*

2) Йорт тирәсендә тирес өсләрендә үсә торган чүп үләне. *Мал кый белән (туя), кунак сый белән.* Әйтем

**КЫЙ** II *кис. диал.* Ич, бит; лә, ләбаса. *Араларыннан берсе: «Фёдор кый», – дип әйтеп куйган. Шуннан соң бу авылны «Фёдорки» дип йөртә башлаганнар.* Риваять. *– Мин син чакырганга килдем кый, – дигән ул [карт бабай].* Әкият. *Ул вакыттан бу яклар күңелгә парник эчендә иртә өлгергән кыярлары, халык белән шыгрым тулы мәдәният сарайлары, --- кый да кый килгән карт-карчыклары белән истә калды.* Р.Рахман. *Ә Имашевлар – гүя «кый» дип сөйләшә торган шушы төбәкне мәркәзебез Казан белән бәйләүче илчеләр.* Сөембикә

**КЫЙ** III *иярт.* Казларның кычкыру тавышын белдерә. *Кый-кый итте – кыйкылдады, чи-чи итте – чикелдәде дә югалды. (Каз һәм бәпкәләре)* Табышмак. *Каз, поварны аңлагандай, җанланып сөйли башлый: «Кый-кый, каг-каг», – ди, һәм поварга бер-ике тапкыр ышкылып үтә: «Кыйгак-кыйгак!» – ди.* Ә.Еники

**КЫЙБАТ** *с. гар.* **1.** *к.* **кыйммәт 1.** *Дегет, ятьмәише товарларны ерак җирдән очсыз хакка алып, Донга кайткач, аларны кыйбат бәядән сатарга ният корган Пугачёв.* В.Имамов. *Җәнлекнең тиресе никадәр кыйбат булса, аның гомере шулкадәр кыска.* Р.Батулла. *Кибет киштәсендә йөз илле сумлык китап күргән татар кешесе язучыны каргап сукрана-сукрана ары китә: «Шул тиклем кыйбат хакка сата! ---».* М.Кәбиров

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **кыйммәт 2.** *Без күрәбез ки, итекләр бер вакытта үзләренең чын бәһаләреннән кыйбат сатылдылар, ә икенче вакыт арзанрак сатылдылар.* Г.Тукай. *Үз баласы юклыктан, асрауга алган улын хатыны, бала-чагасы белән, көздән үк монда ашлыкны кыйбат сатып, --- иген арзан җирдә кыш чыгарсыз дип, Төркестанга китүче ачлар белән җибәргән иде.* Г.Ибраһимов. *Югалтмам, төнлә аракы эчәргә яратасың икән, акча янчыгыңны ач, яхшы сервис бөтен дөньяда кыйбат тора.* Р.Мирхәйдәров

**3.** *хәб. мәгъ.* Бәясе югары булу; өстен булу; зур әһәмияткә ия булу. *Ник ак була икән таш пулат? Маллар кыйбат түгел, баш кыйбат.* Җыр. *Акыллы сүз алтыннан кыйбат.* Мәкаль. *Эшче куллар кыйбат; үзең кыйбат безгә акчаңнан!* С.Баттал

◊ **Кыйбат алмау** Тартынмау, нәрсәгәдер әзер булу, оялып тормау. *[Гапсаттар:] Читләтеп әйткәнне аңламасаң, туп-туры әйтергә дә кыйбат алмам мин.* Ю.Әминов. **Кыйбатка төшү** *к.* **кыйммәткә төшү**. *Әскәр Моратовның авылын яшәтү кыйбатка төшкән...* А.Гыйләҗев. *Кыйбатка төшә дип, кибет аракысы да алмыйлар.* Г.Мөхәммәтшин. *Тегендә үзе сыер тотмый икән, чөнки кышка печән әзерләүләр кыйбатка төшә, биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян буласы.* А.Тимергалин. **Кыйбат сорамау** *к.* **кыйбат алмау**. *Тегеләр кайткан чакта, караңгыда берәрсен пешереп алырга да ул кыйбат сорамас, шулай түгелме?* Ш.Камал. **Кыйбат түләү** Гөнаһы, ялгышы өчен җәзасын күрү. *[Аучы:] Бу эш өчен ул бүреләр Кыйбат түләрләр, Җавап бирерләр баш белән һәм кан түгәрләр.* А.Алиш

**КЫЙБАТЛАНУ** *ф. к.* **кыйммәтләнү**. *[Әхмәт:] Хәзер бит, үзегезгә мәгълүм, чәйләр кыйбатланды.* Г.Камал. *Ә хакыйкатьтә товарлар кыйбатланмаган, акчалар арзанайган.* Г.Тукай. *Кунакханәдә тору да сизелерлек кыйбатланган.* Ватаным Татарстан

**Кыйбатлана бару** Торган саен кыйбатлану. *Гадәттә хаҗ хакында сүз чыкса, байтак кына агай-эне, елдан-ел кыйбатлана бара, хаҗны тәмам коммерциягә әйләндереп бетерделәр, дигән дәгъва белдерә.* Ватаным Татарстан. *Төзүчеләр хәзер үк инде цементның җитмәвенә, аның елдан-ел кыйбатлана баруына зарланалар.* Татарстан яшьләре

**Кыйбатлана башлау** Кыйбатланырга тотыну. *--- бара-бара безнең үз товарыбыз да кыйбатлана башлый.* Г.Тукай

**Кыйбатлана тору** Гел, һәрвакыт кыйбатлану

**Кыйбатлана төшү** Элеккегә караганда тагын бераз кыйбатлану

**Кыйбатланып алу** Бер ара кыйбатлану

**Кыйбатланып бетү** Тәмам кыйбатлану. *Машиналар кыйбатланып беткән*

**Кыйбатланып китү** Кинәт кыйбатлану. *Кайвакытта кисәктән товар кыйбатланып китә.* Г.Тукай

**Кыйбатланып тору** Әледән-әле кыйбатлану

**КЫЙБАТЛЫ** *с.* 1) *к.* **кыйммәтле** (*1 мәгъ.*). *Димәк ки, алтын берлән көмешкә зур нәрсәләрне, кечкенә нәрсәләрне, кыйбатлы нәрсәләрне, арзанлы нәрсәләрне – һәммәсен алмаштырып алып буладыр.* Г.Тукай. *Алар өстендәге кыйбатлы чапаннарны да, атларны бизәгән чуклы япмаларны да ерактан шәйләделәр.* В.Имамов. *Моннан кыйбатлы җәнлек тиреләре алып барганы өчен, аны Урта Азия, Кытай түрәләре бик тә яраткан.* Р.Батулла

2) Зур чыгымнар һәм көч сорый торган. *[Әхмәтҗан:] Ходайга шөкер, кыйбатлы туйдан котылдым.* Г.Камал. *Кыйбатлы проект. Кыйбатлы операция. Кыйбатлы төзелеш*

**КЫЙБАТЛЫК** *и.* Кыйбат булу, кыйммәтлек. *Әкрәмхуҗаевның гуманлык акты атаклы гаиләгә шактый кыйбатка төшкән, имеш. Ләкин бу «кыйбатлык» саннар белән күрсәтелмәгән иде.* Р.Мирхәйдәров. *Әмма кыйбатлыгы сыйфатында әллә ни чагылыш тапмый үзе: әллә ничә кат кулланылу вакыты чыккан эремчек, сөт алып авыз пешкән булды.* Шәһри Казан. *Азык-төлеккә бәяләрнең кыйбатлыгы*

**КЫЙБАТЛЫЛЫК** *и. к.* **кыйбатлык**

**КЫЙБАТСЫНУ** *ф.* Кыйбат табу, кыйбатракка санау. *Иннокентий да кыйбатсынгач, теге, елтыр-елтыр килеп торган алтын тешле авызын ерып, дорфа гына әйтте ---.* З.Мәхмүди. *Сукыр Исмәгыйль белән Әсфәндияр акчалата утыздан кимгә риза булмыйлар, җәмәгать аны кыйбатсына.* М.Гали. *Авыл «байлыклары» турындагы сюжетның берсендә бер апаең бәрәңге хакын кыйбатсынып «ду» китерә.* Безнең гәҗит

**Кыйбатсына төшү** Бераз кыйбатрак дип санау

**Кыйбатсынып тору** Кыйбатсынудан тоткарлану, тукталып калу

**КЫЙБАТЧЫЛ** *с.* Артык кыйбат сорый торган. *Кыйбатчыл сәүдәгәр*

**КЫЙБАТЧЫЛЫК** *и. к.* **кыйммәтчелек**. *[Карт] --- кыйбатчылыктан зарланып язган.* Ш.Камал. *Узган ел кыйбатчылык булса да, кибетләрдә бөтен нәрсә булып торды.* Ф.Яруллин

**КЫЙБЛА** *и. гар.* 1) Мөселманнарның кайбер гыйбадәтләрне үтәгәндә йөзләре белән торган Мәккә ягы; Мәккәдәге Кәгъбәгә караган як. *Ярмөхәммәт тиз генә кулларын, битен-башын сөннәтләп килде, кулларын кушырып, йөзе белән кыйблага таба карап басты.* Р.Батулла. *Карибулла озынча йөзен кыйблага юнәлтеп, тәкъбир әйтә иде инде.* М.Шәһимәрдәнов. *Ак әбиләр, көннәр буе ураза тотып, дога кылып, шул тау башында кыйбла тарафына йөз сөртүләрен дәвам ителәр.* Ф.Яхин

2) Көньяк, җәнүб. *Кыйбла якка искән җилдән «Син кайдан?» дип сорадым.* Р.Зариф. *Туры атны әйбәтләп җигәләр, юрган-мендәрләрен --- тарантаска чыгарып салалар, үзләре, әгузебисмиллаларын әйтеп, иплэп кенә менеп утыралар да, Аллага тапшырып, кыйбла тарафка карап чыгып та китәләр.* Ә.Еники. *Зиреклебаш авылының кыйбла ягында урнашкан рус һәм татар мәктәпләре арасындагы мәйдан төрле телдә сөйләшүче халык белән тулы.* З.Зәйнуллин

3) *күч.* Кешеләрнең күңелен җәлеп иткән тараф; нәрсәнең дә булса үзәге. *Хәзер СССР булып әверелде Бөтен Җир шарының кыйбласы.* М.Гафури

4) *күч.* Кемнең дә булса яратканы, сөйгәне. *[Таһир:] Тапшырыгыз, гидай исәр җилләр, сәламемне Зөһрәмкыйблама.* Ф.Бурнаш. *Син генә җәйге алсу таң, Син генә алтын кыйбла.* Ә.Ерикәй

5) *күч.* Кемнең дә булса ныклы фикере, мәсләге. *Падишаһ әллә Кудрявцевның тырышлыгын күрде, әллә үзенең тоткан кыйбласы да шундый иде.* В.Имамов. *Чөнки сәясәттә кыйблалары юк, койрыксыз төлке хәлендә хәзер Византия.* М.Хәбибуллин. *Шулай да, кояш нурларының төсе күп, шифасы төрле булган кебек, гәрчә мәсләкләр уртак булса да, юл тоткан кыйблага баруда тайпылмышлар да сизелгәли.* С.Поварисов

**КЫЙБЛАНАМӘ** *и. гар.-фар.* Компас. *Ярты сәгать үткәндә без инде, кыйбланамә белән турылап, пароходыбызны юлга салып өлгергән идек.* Ф.Әмирхан. *Ул сандыкта әнинең кызыл башлы хуш исле ап-ак киндер сөлгеләре, --- кыйбланамәсе һәм Самара губернасыннан әти алып кайткан француз ислемаеның әле дә хуш ис бөркеп утырган буш шешәсе саклана иде.* М.Мәһдиев

**КЫЙБЛАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Фикерсез, мәсләксез, идеясез. *Кыйбласыз кешене теләсә кайсы якка аудару өчен, менә дигән шартлар туды.* Ватаным Татарстан

2) Юлдан язган, адашкан. *Тукай да бурычлы булып калмаган. Надан динчеләрне, кыйбласыз милләтчеләрне, акылсыз мәгърифәтчеләрне, каләм тибрәтә белмәгән шагыйрь-голәмаларны, сукыр тарихчыларны тәнкыйть табасында биеткән.* А.Хәмзин

**2.** *рәв. мәгъ.* Максатсыз, мәсләксез. *Кыйбласыз яшәү авыр. Шул авырлык җиңеллеккә этәрә. Ә аның җимешләре – аракы, наркомания, фахишәлек...* Н.Гариф. *Корьән, мәчетләр була торып та динсез, кыйбласыз яшәгән милләттәшләребез бик кызганыч та, иң ачы тәнкыйтькә дә лаек шул.* Шәһри Казан

**КЫЙБЛАСЫЗЛЫК** *и.* Кыйбласыз булу. *Космополит алар, асылда, Ә яшиләр Совет илендә, Кликушалар наказын үтәп, Кыйбласызлык туглап шигырьдә.* Х.Туфан. *Бу нәрсә халкыбызның нигез ташларын какшатуга, кыйбласызлыкка китермиме?* Раз.Вәлиев

**КЫЙ-ГА-ГА** *иярт. к.* **кыйгак**. *Шул арада [ана каз] үзе шыпырт кына, үзалдына сөйләшкәндәй пышылдап кына «кый-га-га, кый-га-га» ди.* Г.Бәширов

**КЫЙГАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **кыегайту**. *Алай селкеп карый, болай кыйгайта аягын, чыкмый гына нәләт суккан таш!* А.Гыйләҗев. *Башын әле бер якка, әле икенче якка кыйгайтып, җанга үтәрлек итеп карап торучы Аккүз берни дә аңламый иде.* Г.Гыйльманов. *Сабир иреннәрен кыйгайтып елмайды.* Ә.Дусайлы

**Кыйгайта төшү** Тагын да ныграк кыйгайту; бераз кыйгайту. *Фәрит, учын кыйгайта төшеп, [өн тишеген] иптәшләренә күрсәтте дә тагын шап итеп томалап куйды.* Г.Гобәй. *Заһит башын бормыйча, күз кабагы астыннан гына Гаянга мәгънәле караш ташлады, мыекларын сыпыргалап, башын кыйгайта төшеп, Сырур түтигә төбәлде.* Ә.Дусайлы

**Кыйгайтып алу** Тиз арада кыйгайту яки беразга гына кыйгайту // Кыйгайткан хәлгә китерү. *Ә бүген ул, кызган башын кыйгайтып алган да, сигез телле тальянкада сиптерә.* М.Мәһдиев

**Кыйгайтып бетерү** Тәмам кыйгайту. *Минем аяклар гына шулай кыйгайтып бетерә аяк киемен.* Р.Батулла

**Кыйгайтып кую** Кыйгайган хәлгә китерү. *Идәндә күз явыңны алырлык матур келәмнәр, карсак өстәлләрдә, зур ташаяк чүлмәкләрдә күз күрмәгән гөлләр чәчәк аткан, диварларга кыйгайтып куелган мөштекләрдә сандал агачы яна.* Р.Батулла

**КЫ́ЙГАК, КЫ́ЙГАК-КЫ́ЙГАК** *иярт.* **1.** Казлар, аккошлар кычкыру тавышын белдерә. *Кыйгак-кыйгак каз кычкыра, Адашып калган микән? Һаваларга оча алмый, Канаты талган микән?* Ф.Яруллин. *Каз, поварны аңлагандай, җанланып сөйли башлый: «Кыйкый, каг-каг», – ди, һәм поварга бер-ике тапкыр ышкылып үтә: «Кыйгак-кыйгак!» – ди.* Ә.Еники. *Казлар: «Кыйгак! – диде. – Саудыр кыяк иле, Шаулый булыр безнең дәрьялар».* Э.Гадел

**2.** *с. мәгъ.* Кыйгаклаучы, кыйгылдый торган. *Кыйгак казлар, Кыйгак казлар, Бармыйсызмы безнең якка?* Әкият

**КЫЙГАКЛА́У** *ф.* Өзек-өзек авазлар чыгарып кычкыру (гадәттә казлар тур.), каңгылдау. *Казлар сыман кыйгаклап кычкырган яшь кызлар, чыр-чу килеп, көлешеп, шаулашып, кияүне ирдән үк тартып төшерделәр, шаярып,*

*әрсезләнеп, аның беләгенә асылындылар.* Н.Фәттах. *Аккошлар кыйгакларга (кара аккош) яки ысылдарга гына мөмкин.* Кошлар

**Кыйгаклап алу** Сирәк кенә кыйгаклау. *Очарга дип талпыналардыр, урамда казлар тук тавышка кыйгаклап ала.* М.Галиев

**Кыйгаклап йөрү** Һәрвакыт кыйгаклау

**Кыйгаклап кую** Бер тапкыр кыйгаклау

**Кыйгаклап тору** Бертуктаусыз кыйгаклау

**Кыйгаклый башлау** Кыйгакларга тотыну

**КЫЙГАЧ** *с.* **1.** 1) Горизонталь өслеккә авыш; кыек, кыегаеп торган. *Утыз өченче ачлык елда урам аша кыйгач күршебез Каюп бабай мине, Димдә балык тотарга дип, үзе белән Тирәк асты дигән борылмага алып килде.* М.Кәрим. *Пәрдәне ачып җибәргәч, идәндә яңадан кыйгач нурлар сикереште, шуларның шәүләсе түшәм-стена почмакларын яктыртты.* Р.Низамиев. *Бабайга ләм-мим, өс-башымны алмаштырам да Шәрбән кырындагы кыйгач сукмактан гына Актайга чабам.* Н.Гыйматдинова

2) Көянтә, дуга кебек формада булган, дуганы хәтерләткән. *Ике туры ат уйныйдыр, муйны кыйгач буйлыдыр.* Г.Тукай. *Күктә – кыйгач ай, тау астында – каракучкыл ярым ай, туган авыл йокымсырый.* Р.Батулла. *Кыйгач ай нәп-нәзек, Әйтерсең беләзек.* Г.Ибушев // *шигъ.* Дугаланып торган, кыйгачланып торган (кашлар тур.). *Карлыгач канаты кебек синең кыйгач кашларың.* Җыр. *Кашларың кыйгач кына... Әйтер сүзләр искә төшә Озатып куйгач кына.* Г.Шаһи. *Синең назлы күз карашың, Ярымайдай кыйгач кашың Мәңге яши минем күңелдә.* М.Гобәйдуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Туры юнәлешкә почмак ясап, кыек итеп. *Кистем дә ләй агач, Китте лә кыйгач, Очып китте аннан сандугач.* Җыр. *Каш астыннан кыйгач карап Ул да мине күзләде...* Р.Вәлиева. *Әллә кайдан ялгыз акчарлак күтәрелә дә, кыйгач очып, диңгез томанына кереп югала.* Г.Әпсәләмов

**3.** *и. этн.* Тукыма яки башка юка материалның бер формага салып, кыйгачлап киселгән өлеше; өлге. *Аклы ситсы күлмәгемнең итәге алты кыйгач.* Җыр

**КЫЙГАЧЛАНУ** *ф.* 1) Кыеклану, кыек ясау. *Киек казлар кайта илләренә, Кыйгачланып сафка тезелеп. Көз киткәндә, йөрәк-бәгырьләре Кала һәр ел шунда өзелеп.* Ф.Тарханова

2) Дугалану, көянтә сыман бөгелү, кәкре сызык рәвешен алу. *Аның сул күзенең өсте маңгай аркылы кыйгачланып сыдырылган.* Ә.Фәйзи. --- *нәзек кыйгач кашлары тагын да кыйгачланды --- күзләреннән өмет шаукымнары бөркелде.* А.Хәлим

**Кыйгачланып килү** Аз-азлап, тигез кыйгач торыш алу; кыйгач хәлгә килү. *Кыйгачланып килгән кашлары әле җыерыла, әле бөтен бит йөзендәге сипкелләрне күмеп, бит алмаларына кызыллык йөгерә.* М.Хәбибуллин

**Кыйгачланып китү** *к.* **кыйгачланып тору**. *Койкам янында өстенә кара халат кигән, чем кара чәчле, кош канатлары сыман кыйгачланып киткән шундый ук кара кашлы, урта буйлардагы берәү басып тора.* Г.Әпсәләмов

**Кыйгачланып тору** Кыйгач хәлдә булу. *Чем кара кашлары ясап куйгандай кыйгачланып тора, керфекләре озын, куе.* Татарстан яшьләре

**КЫЙГАЧЛА́У** *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса билгеле бер яссылыкка карата кыек итеп урнаштыру, кыек итеп эшләү, урау, кисү һ.б.ш. *Билләремдә чиккән ак алъяпкыч, Кош телләре кисәм кыйгачлап.* Э.Шәрифуллина. *Таудан кыйгачлап сузылган озын күләгәләрен күрсәтеп, Нурислам кычкырып көлгән иде: – Кара, Маһи, без синең белән колгалар булдык! – дигән иде...* А.Гыйләҗев. *Сукмак кыйгачлый да текәләнә, бераздан баскычка әйләнә.* Л.Зөлкарнәй

2) Туры юнәлешкә карата кыек хәрәкәт итү, кыек бару. *Таможня мәйданын кыйгачлап үттем дә скверга кердем.* М.Юныс. *Су өстеннән кыйгачлап үрдәкләр очып үтә.* А.Гыйләҗев. *Таймас, чирәмлекне кыйгачлап кистереп, олы юлга чыкты һәм, эре-эре атлап, Хутор урманына юнәлде.* А.Тимергалин. *Ә кулындагы кәгазьләре тупыл яфраклары сыман кыйгачлап җиргә сибелә.* Н.Гыйматдинова

**2. кыйгачлап** *рәв. мәгъ.* Кыйгач булып, кыек килеш, почмак ясап. *Болдыр ишегеннән ялан тәпие белән этәреп җибәрде – итәге калку сайгакка төртелгәч, ишек дерелдәп торды һәм кыйгачлап ачык калды.* М.Хуҗин

**КЫЙГАЮ** *ф. сөйл. к.* **кыегаю**. *Мөгыйннең авызы кыйгайды, бик әшәке сүз әйтеп салмакчы булды, теленә ул сүз килмәде.* Г.Ахунов. *Әтәч-генерал тибенүдән туктап, килеп җитә язган яңгыр болытына кыйгаеп бер карады да --- күкрәк тавышы белән бик шәпләп бер кычкырды.* Р.Батулла. – *И, син аны бервакыт кызык иткән идең, – диде ана каз аңа кыйгаеп, яратып карап.* Б.Ислам

**Кыйгаеп бетү** Тәмам кыйгаю. *Хәйруш кыйгаеп беткән тарантасыннан төшеп, чатанлый-чатанлый, атның тезгенен корыган имән ботагына бәйләп куйгач кына җавап бирде.* З.Хәким

**Кыйгаеп калу** Кыек хәлгә килү. *Зәңгәр һиндыбалар ат тояклары астында таптала. Кайберләре янтаеп, кыйгаеп кала.* Р.Батулла. *Мескен радио бу кадәр акыруыннан үзе дә каушап, ишек ягы диварына эленеп куелган калын һәм озын кадагыннан ычкынып төшеп китә язды, кыйгаеп калды.* Ф.Яхин

**Кыйгаеп китү** Кинәт кыйгаю. *Басканда, җирләр селкенә, өйләр, келәтләр күтәрелеп кыйгаеп китә дә яңадан үз урынына төшеп утыра.* Әкият. *Сәхиләнең бармаклары өстендә генә торкан подносы чайкалып китте, үзе әллә абынды, әллә сөртенде, кыйгаеп китеп, якындагы бер буш урындыкка утырды.* Д.Каюмова

**Кыйгая бару** Торган саен кыйгаю

**Кыйгая башлау** Кыйгаерга тотыну. *Өйләре кырына кайтып җиткәч, туктап калды: кыйгая башлаган салам түбәле йорт, асылынып төшкән йорт капкасы, анда-монда сүтелеп беткән читәннәр.* З.Кадыйрова

**Кыйгая төшү** Бераз кыйгаю

**КЫЙГУЛА́У** *ф. диал. к.* **кыйкулау**. *Кыйгулама, кызгач кош, Тавышың зарлы байгыш кош.* Дастан

**Кыйгулап алу** Кинәт кенә бераз вакыт кыйгулау

**Кыйгулап йөрү** Һәрвакыт кыйгулау

**Кыйгулап кую** Бер тапкыр кыйгулау

**Кыйгулап тору** Бертуктаусыз кыйгулау

**КЫЙГЫЛДА́У** *ф.* Бик нык кычкырмыйча гына кыйгаклау. *Күңел сүз куша киек кошларга: Сәлам әйтергә кыйгылдап кына Безне үстергән Идел халкына.* Х.Туфан. *[Күргәнегез бармы ата каз биегәнен] Ул, кыйгылдап, әнкә казны Яратып сөйләшкәнен, Сары йомгак бәпкәләргә «Гаң-гаң» дип эндәшкәнен.* Э.Шәрифуллина. *Урман эчендә култык булып уелып кергән аланнан казлар кыйгылдаганы, аларның тонык кына гүләгәннәре ишетелә иде.* Г.Бәширов

**Кыйгылдап алу** Кинәт кенә кыйгак дигән тавыш чыгару

**Кыйгылдап йөрү** Һәрвакыт кыйгылдау

**Кыйгылдап кую** *к.* **кыйгылдап алу**

**Кыйгылдап тору** Бертуктаусыз кыйгылдау

**КЫЙГЫР** *и.* 1) *зоол.* Лачыннар семьялыгыннан урманда яши торган кечерәк кенә ерткыч кош; яңгыр теләнчесе; *русчасы:* **чеглок**. *Коры ботакка кыйгыр кунмас.* Табышмак. *Ул дигәндә, бу дигәй: Кыелып төшеп ак кыйгыр, Оча белән түш итен Кагып алды кулымнан.* Дастан. *Кыйгыр яңгыр алдыннан кычкыра.* Сынамыш

2) *күч.* Елгыр, үткен, булдыклы; мут. *Кызлар – кыйгыр тамак.* Мәкаль. *--- милләтнең нинди бөек, нинди илаһи көчкә ия булуын раслаган шәхес, чиксез татар киңлекләренең кыйгыр карлыгачы ул [Усман Әлмиев].* А.Хәлим

**КЫЙК** *иярт.* Казларның бер тапкыр кычкырып куюын белдерә. *Ул да түгел, теге каз, муенын суза төшеп йөгереп китте дә, «Кыйк!» дип, һавага күтәрелде.* Г.Бәширов

**КЫЙКУЛА́У** *ф. диал.* Каты кычкыру, төрле ямьсез тавышлар чыгару. *Кыйкулама, кызгыч кош, Канатың куш, муйның буш, Авызың-борының мөгез кош, Авазың яман зарлы кош!* Дастан. *Ач бүредәй чыелдап, Читәнеңнән кыйкулап Ачы сөрән салмасам, --- Баба Төкләс бабам биргән Идегәй атым корысын!* Дастан

**Кыйкулап алу** Кисәк кенә кыйкулау

**Кыйкулап йөрү** Һәрвакыт кыйкулау

**Кыйкулап кую** Бер тапкыр кыйкулау, бер кыйкулап күрсәтү

**Кыйкулап тору** Бертуктаусыз кыйкулау

**КЫЙКЫЛДА́У** *ф. сөйл.* 1) *к.* **кыйгаклау**. *Каз арткa тартылып ычкына, аннан муенын сузып, батыраеп, кыйкылдап, поварга һөҗүм итә.* Ә.Еники. *Кый-кый итте – кыйкылдады, чи-чи итте – чикелдәде дә югалды.* Табышмак

2) *диал.* Очкылык тоту

**Кыйкылдап алу** Кинәт кенә кыйкылдау

**Кыйкылдап җибәрү** Кыйкылдый башлау

**Кыйкылдап йөрү** Һәрвакыт кыйкылдау

**Кыйкылдап кую** Бер тапкыр кыйкылдау

**Кыйкылдап тору** Бертуктаусыз кыйкылдау

**Кыйкылдый башлау** Кыйкылдарга тотыну

**КЫЙЛАНМЫШ** *и. к.* **кыланыш**. *Бу хатынның соң дәрәҗәдә мәшәкать вә михнәттә торганы кыяфәтеннән, кыйланмышыннан мәгълүм, үзе күтәрә алмаслык кайгыларны йотарга тырышканы хәрәкәт вә күзләреннән билгеле иде.* М.Гафури

**КЫЙЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **кылану**. *Морза, эре генә кыйланып, төймәләре фил сөягеннән кырып ясалган бәләкәй генә счётны үзенә таба шудырып китерде дә, Әкрәм карига ишетелерлек итеп, тотыласы чыгымнарны исәпли башлады.* М.Галәү. *Нәрсә теләсәләр, шуны кыйлансыннар, ирек куегыз!* З.Зәйнуллин. *Кәрәз кебек, озак файдаланмый торса, яктыда да карая башлый торган мичкәнең табынга төшүеннән җанланып киткән хатыннар, --- кызык өчен, тавышка куйгандай, кулларын күтәргән булып кыйландылар да, --- зур вакыйга көткәндәй, табын тирәсенә елыштылар...* А.Хәлим

**Кыйлана башлау** Кыйланырга тотыну. *Әгәр дә ауыл присидәтеле --- артыграк кыйлана башласа, эчәргә яратучан булса, кулакка ярдәм итсә, --- халыкка аңлатырга кирәк.* Р.Батулла

**Кыйлана бирү** Бернигә дә карамыйча кыйлануын дәвам итү

**Кыйлана төшү** Бераз кыйлану

**Кыйланып алу** Кыска бер вакыт аралыгында кыйлану

**Кыйланып йөрү** Һәрвакыт кыйлану. *Ә Шәрәф үзе исе дә китмәгән кебек кыйланып йөри бирә.* М.Яһудин

**Кыйланып кую** *к.* **кыйланып алу**

**Кыйланып тору** Гел яки билгеле бер вакытта кыйлану

**КЫЙЛАНЧЫК** *с. иск.* **1.** *к.* **кыланчык**. *Ишек тавышсыз гына ачылды да, бүлмәгә көмеш поднос күтәреп, көяз, кыйланчык хәрәкәтле асрау кыз керде.* М.Галәү

**2.** *и. мәгъ.* Кыланырга яратучан кеше. *[Гыйльманов:] Шул инде, үзе, Абаев дигән кыйланчык.* Ш.Камал

**КЫЙЛАНЫШ** *и. иск. сөйл.* 1) *к.* **кыланыш**. *Хәзер аның күз алдында бу кыйланышлар бөтенләй икенче мәгънә аңлата башладылар.* Ф.Әмирхан. *Ул [Күчем батыр] болай да ярсулы, ә чакырылмаган көенчә ишектән атылып кергән егетнең кыйланышы түземлеген тәмам корыткан иде.* В.Имамов. *Нәрсәне аңлата инде бу кыйланышы моның?* З.Зәйнуллин

2) *күч. иск. сөйл.* Хәл; гореф-гадәт. *[Күгәрчен:] Мин кай җирдә нинди гаҗәпләр күргәнемне һәм кайда нинди гадәтләр, нинди кыйланышлар барлыгын сиңа хикәят итәрмен.* Г.Тукай

**КЫЙЛА́У** *ф. диал.* Тизәкләү, тизәк түгү (басуга)

**Кыйлап тору** Вакыты-вакыты белән, даими кыйлау

**КЫЙЛУ** *ф. иск. к.* **кылу**. *Әмма зәнкиләр шаһзадәне, кырык хезмәтчеләрен нәфис вә ләззәтле тәгамнар белән тәрбия кыйлдылар.* К.Насыйри. *Табындым, сәҗдә кыйлдым мин сөйгән җанашның алдында, Өмид иттем вә курыктым да, кызардым һәм оялдым да.* Г.Тукай. *Бармак башы кадәр бер эш кыйлса, алтын йомырка салган тавык сымак, башкалар ишетсен өчен кыткылдап йөри ул.* С.Поварисов

**КЫЙЛЬ** *и. гар. иск.* Әйтелгән сүз, кәлимә

◊ **Кыйль вә каль** *иск.* Имеш-мимеш, икән-микән, гайбәт, юк-бар сүз. *Инан*

*биллаһи сүземә, түгелдер кыйль вә калләрдән.* Г.Кандалый. *Бу хәл шәһәр әһалисенә гаять тәэсир итеп, күп төрле кыйль вә кальгә сәбәп булды.* Г.Тукай. *Бер исе юк; мәгәр дөньясы тулган яшь вә кан берлән, Тынычсызлык, усаллык һәм явызлык, кыйль вә каль берлән.* Г.Шәрифи // Бер-бер кәлимә, сүз. *Бабай бик йөдәткәнгә: «Тагы бер-бер риваять булмасмы, китапта бер-бер кыйль вә каль булмасмы, яравына риваять юкмы», – дип, бик озак китап караса да, алдыруның файдасына һичбер дәлил таба алмады.* Г.Исхакый

**КЫЙММӘТ** *с. гар.* **1.** Бәясе югары булган; кыйммәтле, бәһале, кыйбат; *киресе:* **арзан**. *Алка нихәтле кыйммәт булса да, колак бәясе тормый.* Мәкаль. *Әбүгалисина боерды, башына яшел зөбәрҗәт ташыннан тукыган бер таҗ вә аркасына кыйммәт бәһәле яшел хилгать кидереп җибәрделәр.* К.Насыйри. *Шунлыктан беренче буын шәкертләр, сыйныф-сыйныф бүленеп, өч аерым бинада укыйлар. Шул арада байлар шәһәр үзәгендә шактый кыйммәт хакка җир сатып алалар һәм мәдрәсәнең үз утарын төзергә керешәләр.* Л.Хәмидуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Югары бәягә (бәядән), югары хакка (хактан), зур акчага, кыйбатка. *--- заманында казакъ даласында йон-ябаганы чирек хакка алып, әйберне биш мәртәбә кыйммәт сатып, үлчәүдә һәр ике тәкъдирдә алдашып баеп киткән якын шәһәрнең татар сәүдәгәре моңа каршы тагын арттырды.* Г.Ибраһимов. *Арзан алалар да кыйммәт саталар, ягъни табыш базарда товар алмаштырудан килә.* Г.Тукай. *Анда эш хакы түләмиләр, шуңа күрә акча кыйммәт йөри.* Г.Гыйльманов

**3.** *и. мәгъ.* 1) Әһәмият; аерылып торган өстенлек, мөһимлек. *Ягъни табигатькә фәкать сумнар, тиеннәр күзлегеннән генә карый. Аның эстетик ягына, рухи кыйммәт булуына төкерми дә.* Г.Бәширов. *Мин натурализмга каршы. Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп, дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк.* Г.Ибраһимов. *Аларның исә, демократик кыйммәтләр турында сөйләнгән хәлдә, власть вертикален тәгаен игълан итүләре бик күп кешеләргә тарихи сабакны, репрессив ысулларны искә төшерде.* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Кадер, бәя; тоткан урын. *Хосусән, шәҗәрәнең кыйммәте әби берлән бабай алдында бик зур иде.* Г.Исхакый. *Тормышның ямен, яшәүнең кыйммәтен алар сыман нечкә сиземләүче бар идеме икән әле монда?!* М.Шаһимәрдәнов

3) *мат.* Математик зурлыкларның эчтәлеге, мәгънәсе. *Кыйммәтләрен үзгәртмичә саклый торган зурлыклар даими зурлыклар дип аталалар.* Алгебра

4) *икъм.* Товарны җитештерү өчен, билгеле бер микъдарда сарыф ителгән һәм шушы товарда матдәләштерелгән абстракт хезмәт. *Кыйммәт – товар җитештерүчеләрнең товарда әйберләшкән иҗтимагый хезмәте ул.* Политэкономия. *Хосусый милек хөкем сөргәндә, кыйммәт законы котылгысыз рәвештә капиталистик мөнәсәбәтләр, эксплуатация мөнәсәбәтләре тудыра.* Политэкономия

**4.** *хәб. мәгъ. к.* **кыйбат 3.** *Боланның – башы, филнең теше кыйммәт.* Мәкаль. *Чабакның үзеннән бигрәк чупырдавы кыйммәт.* Мәкаль. *– Юк инде, – диде әтисе, кинәт киреләнеп. – Миңа аның кырык сумыннан бигрәк гаделлеге кыйммәт.* Н.Көбәш

◊ **Кыйммәт алмау** *к.* **кыйбат алмау**. **Кыйммәткә төшү** 1) Күп чыгымнар тотылу. *– Беләсезме, алар [никрутлар] халыкка нинди кыйммәткә төшәләр.* Г.Ибраһимов. *Византиядә кызларны көчләү көчләүчегә бик кыйммәткә төшә: ул кеше кызның гаиләсенә яисә үзенә 280 солид түләргә тиеш була.* М.Хәбибуллин; 2) *күч.* Авырга туры килү (авыр кичерешләр белән бәйләнгән булу, күп көч, энергия таләп ителү). *--- һәм болар барысы да киләчәктә җәмгыятькә кыйммәткә төшәчәк, бик кыйммәткә...* М.Шаһимәрдәнов. *Каһәгатькә кыйммәткә төшә бу үзе салган нәфис сызыклар. Ул гынамы – алар аңа каршы эшлиләр иде.* А.Хәлим. **Кыйммәт сорамау** *к.* **кыйбат алмау**. **Кыйммәт түләү** Теләсә нинди шартларга да риза булу яки бик авырга туры килү. *Хәзер бу урында мин алар белән – ул ике иптәш белән сөйләшер өчен, бик кыйммәт түләр идем.* Ш.Камал

**КЫЙММӘТДАР** *с. гар.-фар. иск. к.* **кыйммәтле**. *Эрмитажда фәүкыльгадә нәфис вә зиядасилә кыйммәтдар улмак үзрә ике меңнән зияда рәсем вә ләүхәләр вардыр ---.* Ф.Кәрими. *--- бик кыйммәтдар бер картина манзарасы тәшкил итәдер.* Сөембикә

**КЫЙММӘТЕ́НЧӘ** *рәв.* Бәясенә туры килгән, кыйммәтенә бәрабәр. *Инде хәзинә бер тәңкәлек кәгазь акчага саф үз кыйммәтенчә көмеш бирми, тик 60–70 тиен яки 50 тиен генә бирә, башка кәгазьләргә тагы шулай.* Г.Тукай

**КЫЙММӘТЛӘНҮ** *ф.* Нәрсәнең дә булса хакы, бәясе арту; кыйбатлану. *Агачы да ел саен кыйммәтләнә.* Г.Мирһади. *Ел саен әле бер, әле икенче әйбер кыйммәтләнде, кайбер товарларның бәяләре берьюлы икеләтә, хәтта өчләтә.* Р.Мирхәйдәров

**Кыйммәтләнә бару** Торган саен кыйммәтләнү. *Чөнки елдан-ел мәктәп белән хушлашу кыйммәтләнә бара.* Өмет

**Кыйммәтләнә башлау** Кыйммәтләнергә тотыну. *--- заграничный товарлар кыйммәтләнә башлады ---.* Г.Тукай

**Кыйммәтләнә тору** Гел, һәрвакыт кыйммәтләнү

**Кыйммәтләнә төшү** Бәясе элеккедән бераз арту

**Кыйммәтләнеп алу** Берара кыйммәтләнү

**Кыйммәтләнеп китү** Билгеле бер вакыттан, сәбәптән соң кинәт кыйммәтләнү

**Кыйммәтләнеп кую** Кинәт кенә кыйммәтләнү

**Кыйммәтләнеп тору** Әледән-әле кыйммәтләнү

**КЫЙММӘТЛЕ** *с.* 1) Югары бәяле, бәясе, хакы зур; бәһалы, кыйбатлы. *Гадиләне судан тартып чыгаруны зур батырлыкка санап, чын күңелдән рәхмәт әйтүләре һәм кыйммәтле костюм бүләк итүләре Шөһрәтне нык дулкынландырды.* Ф.Яруллин. *Кул бармагы саен берсеннән-берсе эре ташлы кыйммәтле балдаклар.* М.Хәбибуллин. *Күзгә ташлана торган кыйммәтле*

*асылташлар белән ирләрне кызыктыру, үз җенесенә чакыру ята бизәнүнең төбендә.* Р.Батулла

2) *махс.* Бәясе, хакы күрсәтелгән; бәяле, кыйбатлы. *Кыйммәтле кәгазьләр (акцияләр, облигацияләр һ.б.) фонд биржаларында сатып алыналар һәм сатылалар.* Политэкономия. *Кыйммәтле хат* (бәясе күрсәтелгән, шуннан чыгып акча түләп алына торган хат). *Кыйммәтле посылка. Кыйммәтле бандероль*

3) Үзе ише булган әйберләрдән озак саклана алуы, тиз бозылмавы, файдасы һ.б.ш. югары сыйфатлары белән аерылып торган. *Тау башында төрле-төрле кыйммәтле ташлар: зөбәрҗәтләр, ахаклар һәм башка эре-эре матур ташлар бик күп икән.* А.Алиш. *Түшләренә кыйммәтле ташлар, алтын-көмешләр тагып, бүрекләренә кош каурыйлары кадап, бай киемле туган-тумача, ялтйолт килеп, өй әйләнә аягөсте басып тордылар.* Н.Фәттах. *Кыйммәтле металлар* (*алтын, көмеш, агалтын һ.б.*)

4) *куч.* Әһәмиятле, мөһим. *Син бел ки, вакыт – бик кыйммәтле нәрсә.* М.Акъегет. *Кыйммәтле сүзләр уттан шулай саклансын өчен, бабайлар сүзләрне дәфтәр уртасына багана итеп яза торган булганнар.* Р.Батулла. *– Башка малайларны якын китермә, – дип, кыйммәтле киңәшен бирә Хәйрүш.* Р.Зәйдулла

5) *куч.* Кадерле, якын, газиз. *Газиз, туганым, хәзер дөньяда иң кыйммәтле кешем – син.* М.Әхмәр. *Ирек! Азатлык! Синнән дә татлырак, синнән дә кадерлерәк, кыйммәтлерәк тагын нәрсә бар дөньяда?* И.Салахов

6) *мат.* Кыйммәте (*3 мәгъ.*) булган, эчтәлеге булган. *Кыйммәтле цифр*

**КЫЙММӘТЛЕК** *и.* Кыйммәт булу, кыйбатлык. *Фатирларына килүчеләрне --- җиһаз ягыннан шаккатыра алмасалар да, кигән киемнәренең кыйммәтлеге һәм ашарга әзерләгән ризыкларының затлылыгы белән хәтта министрларның да исләрен китәрә бу икәү!* М.Шаһимәрдәнов. *Һәм нәкъ менә Мәхәббәт аша дөньяның матурлыгы, кыйммәтлеге ачыладыр да.* И.Вәлиулла

**КЫЙММӘТЛЕЛЕК** *и. к.* **кыйммәтлек**

**КЫЙММӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Бәясе булмаган, очсыз. *Сез үзегез алтыннан да кыйммәтсез.* З.Зәйнуллин. *Морадым чыннан да кыйммәтсез димәк иде.* Р.Фәхретдин

2) *мат.* Кыйммәте (*3 мәгъ.*) булмаган, эчтәлеге юк. *Кыйммәтсез цифр*

**2.** *хәб. мәгъ. куч. сөйл.* Кадерсез, әһәмиятсез, бәясез. *Хәмдиягә, асыл егетләр булса, шул җитә. Бүтәннәр аның каршында кыйммәтсез.* М.Фәйзи. *Марҗа энҗе кебек тешләрен күрсәтеп елмайды: – Утын нәрсә ул! Сез үзегез алтыннан да кыйммәтсез. Мужиклар бит!* З.Зәйнуллин

**КЫЙММӘТСЕНҮ** *ф.* Кыйммәт дип уйлау, бәясен югары санау. *Мин кыйммәтсенеп сатулаша башладым. – Сатулашма, Мәрҗән! – диде Тукай. – «Өйләнгән» елны егетләр юмарт булалар...* М.Галәү. *Утә гомер, кайчак хакы бетә, Ә кайвакыт арта бәясе. Очсызланган чакта, кыйммәтсенеп, Тими китә тормыш бәласе.* Ф.Яхин. *Үзләре кыйммәтсенгән була, үзләре җиде сум булса да, базарга төшеп алырга ялкаулана.* Безнең гәҗит

**Кыйммәтсенә төшү** Бераз кыйммәтсенү

**Кыйммәтсенеп йөрү** Күптәннән бирле кыйммәтсенү; озак вакытлар кыйммәткә санау

**Кыйммәтсенеп кую** Кинәт кенә кыйммәт икәнен искәртү

**Кыйммәтсенеп тору** Озак вакыт кыйммәтсенү

**КЫЙММӘТЧЕЛ** *с.* **кыйбатчыл**

**КЫЙММӘТЧЕЛЕК** *и.* Бәяләрнең бик югары булуы; *киресе:* **арзанчылык**. *Типография эшчеләре, кыйммәтчелек сәбәпле, эш хакы арттыруны һәм типографиянең управляющиен алмаштыруны таләп иткән иделәр.* Ш.Камал. *Кыйммәтчелекнең газабын, төп расход тотучы буларак, Хәдичә авыр кичерде.* А.Расих. *Җәй килде, корылык, кыйммәтчелек белән җәй килде.* М.Мәһдиев

**КЫЙМШАНУ** *ф. к.* **кымшану**. *– Билне бирми, гәүдә кыймшанмый, – диде ул. Үз гомеремдә беренче мәртәбә мин аның зарланганын ишеттем.* А.Гыйләҗев. *[Маһинур апа] Әрнеп-әрнеп ыңгырашты, кыймшанды һәм торырга тырышты.* Ф.Яхин

**Кыймшанып кую** Аз гына кыймшану

**КЫЙМШАТУ** *ф. к.* **кымшату**. *Кешеләрнең уйларында яшәп килгән туктаусыз теләк, кушылырга омтылу аларның акылдан гына торган хәтерләрен дә кыймшата башлады.* Ф.Бәйрәмова

**КЫЙМЫЛДАТУ** *ф.* Беркадәр селкетү, сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәтләндерү. *Күтәреп барганда да, өйгә кергәч тә, Туңгак алып әледән-әле ыңгырашып куйды, нидер әйтергә теләгәндәй иреннәрен кыймылдатты.* Н.Фәттах. *[Айдаш карт] Ихтыярсыз яткан кулын хәлсез генә кыймылдатып, аптыратма инде, барыгыз, хәл алырга ирек куегыз дигәндәй ишарәләде дә, чак ишетелерлек итеп: – Ярмөхәммәт кайтмадымы? – дип сорады.* Р.Батулла. *Ул күрде, күзәтте, кунаклар арасындагы олы яшьтәге агайлар күзләрен сөрткәләп алдылар, яшьрәкләре исә җырга кушылгандай иреннәрен кыймылдатып утырдылар.* М.Хәбибуллин

**Кыймылдата төшү** Бераз кыймылдату

**Кыймылдатып алу** Аз гына кыймылдату. *Теге мескененең күзләре яшь белән тулды, һәм ул аралыкка кереп нәрсәләрнедер кыймылдатып алды.* Р.Гаязетдин. *Өч дус та иреннәрен кыймылдатып алып бит сыйпадылар.* И.Хуҗин

**Кыймылдатып кую** Бер тапкыр кыймылдату. *Аннары зәгыйфь кенә елмая, иреннәрен кыймылдатып куя: нидер әйтергә тели ахрысы...* Ә.Еники. *Ул гына да түгел, гүзәл кызның көчле нәфрәте, ачуы һәм җирәнүле карашы, үлемнән көчле булган мәхәббәте һәм «сөйгәне өчен корбан булган» егетнең үлек гәүдәсе, күрәсең, аның йокламаган намусын, егетлек горурлыгын да беркадәр кыймылдатып куярга мәҗбүр итә.* И.Нуруллин

**Кыймылдатып тору** Әледән-әле кыймылдату

**КЫЙМЫЛДА́У** I *ф.* 1) Беркадәр селкенү, сизелер-сизелмәс хәрәкәтләнү. *Борчак җиренә килеп җиткәч, карт анда ниндидер бер чүмәләчекнең*

*кыймылдаганын күрде.* М.Мәһдиев. *Шәһәр загсының чак кыймылдый торган дәү, авыр ишеген көч-хәл белән ачып, салкынча бүлмәгә керделәр.* А.Гыйләҗев. *Ул кыймылдамаган булса, Ярмөхәммәт аны бөтенләй күрмәс иде.* Р.Батулла // Гәүдәнең теге яки бу әгъзасы хәрәкәткә килү, хәрәкәтләнү. *Германрих король сөйләде, ләкин кызы аны ишетмәде, корольнең янә тавышы беткән иде, авызы ачыла, иреннәре кыймылдый, ә тавышы чыкмый.* М.Хәбибуллин

2) *күч. сөйл.* Хәрәкәт итү, эшчәнлек күрсәтү, эшләү. *– Тизрәк кыймылдарга кирәк, – диде ул, янындагы озын буйлы яшь иргә эндәшкән сыман итеп.* Н.Фәттах. *Трактор аның белән чагыштырганда бик акрын кыймылдый кебек иде.* Ф.Яхин

3) *күч.* Барлыкка килү, үзен сиздерү, чагылып китү (уй-фикер, хисләр һ.б. тур.)

**Кыймылдап алу** Кыска гына вакытка селкенү, хәрәкәтләнү. *Почмакка поскан шомлы шәүләләр әкрен генә кыймылдап алалар.* М.Юныс. *Ул елмаерга теләде бугай, иреннәре кыймылдап алды, аннан тораташтай катып калган сержантка таба карап куйды да миңа текәлде.* Д.Каюмова. *Көн кызуына чаклы кыймылдап алырга кирәк булыр.* Р.Гаязетдин

**Кыймылдап кую** Чак кына кыймылдау. *Башта Мостафинның күңелендә хурлану һәм оялу кебек нәрсә кыймылдап куйды, ләкин ул бу тойгыны тизрәк басарга тырышты.* Ә.Еники. *Ниһаять, ул кыймылдап куйды, зур башын күтәреп хатынына төбәлде: – Аңыма һич сыйдыра алмыйм: ничек итеп син шундый җирәнгеч эшне эшли алдың икән?!* М.Шаһимәрданов. *Әминәнең куе керфекләре кыймылдап куйдылар, ул күзләрен ачты.* Л.Шафикова. *Бишектәге сабый, тынычсызланып, кыймылдап куя.* Ф.Бәйрәмова

**Кыймылдап тору** Бертуктаусыз кыймылдау. *Тәлинкәне ул авызына таба китерә, авызы гел кыймылдап тора.* Г.Ахунов. *Җиен-кышын бертуктаусыз кыймылдап торгач, монда нинди бозыклыкка, эчүчелеккә урын калсын.* Ватаным Татарстан

**Кыймылдый башлау** Кыймылдарга тотыну. *Каз өмәләре башланды, авыр елда өйләнә алмый калган егетләр дә кыймылдый башладылар.* М.Мәһдиев

**Кыймылдый бирү** Һаман кыймылдау, кыймылдаудан туктамау. *Моны һәркем сизде, тик аңлый гына алмады, буталды, шуңа күрә халык акрын кыймылдый бирде: шунлыктан нефть үзенә кешеләрне төрле яклардан җыйды.* Ф.Яхин

**Кыймылдый төшү** Хәрәкәтлерәк кыймылдау

**КЫЙМЫЛДА́У** II *и.* Сизелер-сизелмәс хәрәкәт. *Ул, кыймылдаудан, каядыр чыгарга азапланудан туктап, уйлаштыра башлады.* Н.Фәттах

**КЫЙМЫ́Л-КАМЫЛ** *ияpт. к.* **кыймыл-кыймыл**. *Шул егылудан Сабир тормады. Бераз мыгырданып, кыймыл-камыл килеп, толып итәге белән каплангандай итте дә тынды.* Р.Батулла. *Тургай үзен төргән чүпрәкләрне, өстенә салынган япмаларны һич тә яратмый, кыймыл-камыл килеп бушайта, сүтә иде.* Ф.Садриев

**КЫЙМЫ́Л-КЫЙМЫЛ** *ияpт.* Кешенең хәрәкәткә килүен, хәрәкәтен, яисә берәр нәрсәнең җиңелчә селкенүен белдерә. *Күк гөмбәзе бәләкәй генә калган, йолдызлар ишелелектән кысылышып тартышалар, кыймыл-кыймыл киләләр, алар күкне җиргә сөйрәп төшерерләр кебек тоела.* А.Гыйләҗев. *Йомабикәнең маңгаена сырлар тәгәрәшкән, бите куе кершән яккандагы кебек кып-кызыл, ике аяк өстенә өченчесе басып килә, хәрәкәтләре салмакланган, күзләре генә элеккечә майланып, чакырып торалар, нәзек иреннәре кыймыл-кыймыл килеп хәрәкәтләнеп, кемнедер каядыр өндиләр кебек.* Я.Зәнкиев. *Еланның кузгалмый сузылып ятканын күргәч, ул да иреннәрен кыймыл-кыймыл иттереп шаккатып торды.* С.Әдһәмова

**КЫЙНАЛУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кыйнау**. *Әллә ул теге чактагы ярым ач, ярым ялангач, кыйналган сабый Әхнәфне кызганып җылыймы?* Р.Батулла. *Шуның өчен сарай хезмәтчеләре шаһиншаһларыннан кыйналуны бәхеткә санаганнар иде.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Нәрсәдән дә булса газаплану, иза чигү, кыенлык күрү, интегү. *Хәзер ул [Әскәр] сүзсез, кыйналган хәлдә калган иде.* А.Гыйләҗев. *Матди яктан да бик кыйналдым...* Ә.Еники. *Айдар барыбер баш бирмәде, кыйналса кыйналды, әмма Хәмиснең куштаны булмады.* Г.Гыйльманов

◊ **Кыйналып ташлангандай, кыйналып ташлаган кебек** Тән авыртып, изелеп; арып. *Үземне кыйналып ташлангандай хис итәм.* Ф.Дәүләтбаев. *Синең хыялыйлыгың аркасында бөтен халык кыйналып ташланган кебек йөри ләса!..* Г.Гыйльманов

**Кыйнала башлау** Кыйналырга тотыну. *Әхмәтнең аларны болай гына чыгарып җибәрәсе килми, егетләрнең үпкәләвеннән аның да җаны кыйнала башлаган иде.* Р.Вәлиев

**Кыйнала төшү** Тагын да ныграк кыйналу

**Кыйналып бетү** Нык кыйналу, бик озак итеп кыйналу. *Озак та үтмәде, кыйналып беткән һәм куллары артка каерылып бәйләнгән Әхмәтне халык каршысына китереп бастырдылар.* М.Шаһимәрданов. *Ләкин, җәмәгать, аларны кыйналып беткән сүзләр белән түгел, яңача тәкъдим итү мөһим!* Шәһри Казан

**Кыйналып йөрү** 1) Әледән-әле кыйнау, сугу һ.б.ш. кимсетүләр кичерү

2) *күч.* Һәркайда, һәрчак яклаучысыз булу, тәнкыйтьләнү

**Кыйналып тору** Гел, һәрвакыт кыйналу. *Шуңа күрә [егет] бандитлар тарафыннан гел кыйналып тора.* Безнең гәҗит

**КЫЙНАЛУ** II *и.* Кемнең дә булса тарафыннан физик рәнҗетелү ысулы. *Аның игътибарына лаек булу өчен, ул Бикчура Ишиев тарафыннан хәтта тагын бер кат кыйналуга да әзер иде.* В.Имамов. *Кыйналудан, газаплаулардан үзен-үзе тота алмас хәлгә килгән Айдаровны ике партизан җилкәләренә салып алып чыктылар.* Г.Ахунов. *Эш серле кыйналуларга, үтерүгә барып терәлгәч, тынгысыз прокурор: – Кем соң монда җинаятьче? – дип сорап куйды.* М.Шаһимәрданов

**КЫЙНА́У** I *ф.* 1) Кул яки башка берәр нәрсә белән тәнгә күп мәртәбә

сугу, тәпәләү. *Җәмига апа уллары Әхнәф белән Кәримулланы кыйный иде.* Р.Батулла. *Ак өйнең ишеге янында кыйнаганда, Туңгак алыпның кулын имгәттеләр, базга ташлаганда, ул ялгыш басып аягын тайдырды.* Н.Фәттах. *Әхмәтне гел кыйныйлар икән, чөнки сорау алганда я эт булып өрә, я тавык булып кытаклый, ди.* М.Шаһимәрдәнов

2) Таяк, камчы һ.б.ш нәрсә белән хайваннарга ору, сугу. *Ишәкне кыйнап кына ат итеп булмый.* Мәкаль. *Ул алашаны кыйный-кыйный арган, толып өстерәп хәле беткән, махмырдан хәле киткән килеш, үрәчәгә утырып, ихтыярсыз гына аяк астын күзәтә.* Р.Батулла. *Чыбыркысы белән яман селтәнгәләсә дә, сыерга сукмый [Талип]. --- Үзе шабыр тиргә батар, әмма сыерны кыйнарга кодрәте җитмәс.* Н.Гыйматдинова

3) *сөйл.* Нәрсәгә дә булса берничә тапкыр бәрү; шакылдату. *Карт, үзенүзе белмичә, арба кендеге белән рельс кисәген кыйнады.* М.Мәһдиев // Берәр әйбер икенче әйбергә берничә тапкыр яки бертуктаусыз бәрелеп тору, орыну. *Ак яллы яшькелт дулкыннар корабны кыйныйлар.* М.Юныс. *Миңа бераз җил көчәйде, көймә кабыргаларын шап та шоп кыйнарга тотынды.* А.Гыйләҗев. *Парктагы агачлар бер-берсен кыйныйкыйный бәргәли, яман шаулаша, көтүкөтү карга өере тынычсызланып каркылдый иде.* Н.Гыйматдинова

4) *куч. сөйл.* Сугышта җиңү, өстен чыгу; (дошманны) тар-мар итү. *[Якуб Шәрифҗанга:] – Немецлар бик каты кыйнамадыларамы соң үзегезне? – Төрле чак булды инде, Якуб абзый, кыйнаткан чак та, кыйнаган чак та.* И.Гази. *Миңа, әти, мине гафу иттеләр, мин хәзер чорма тузанында ятучы куркак Нургали түгел, ә фашистларны кыйнап кайткан батыр сугышчы.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Кыерсыту, рәнҗетү; газаплау, иза чиктерү. *Шаярыр идек – әле генә язмыш ханым кыйнаган; елар идек – әле күздән яшебез дә кипмәгән.* Г.Тукай. *Апагыз да хасталанып торгач, җизнәгезнең җанын кыйнамагыз, ди атаң.* А.Гыйләҗев. *Кыйнады еллар, кыйнады, кыйный-кыйный ташка әйләндерде.* Ф.Бәйрәмова // *күч.* Тәнкыйтьләү. *Тәнкыйтьчеләр дигән сукбайлар бар, Көн аралаш тотып кыйныйлар.* Һ.Такташ

◊ **Кыйнап ташлаган кебек** *к.* **кыйналып ташлангандай**

**Кыйнап ташлау** Тиз арада кыйнау **2.** *Эшне кайдан, ничек башлап җибәрергә дип озак баш ватарга туры килмәде, юлыма очраган төпчек улың Мисбахетдинне эт итеп кыйнап ташладым элек!* М.Шаһимәрдәнов

**Кыйнап тору** Вакыт-вакыт яки һәрвакыт кыйнау. *Мәктәптән начар билгеләр алып кайтканы өчен, 10 яшьлек кыз баланы ата-анасы ач тотып, кыйнап торган.* Ватаным Татарстан

**Кыйный башлау** Кыйнарга тотыну. *Мин ишекне кыйный башладым. Рәхимле бер надзиратель икән, бер кружка су бирде.* И.Салахов

**Кыйный бирү** Кыйнавын дәвам итү

**Кыйный төшү** Тагын да ныграк кыйнау

**КЫЙНА́У** II *и.* Күп тапкыр сугу; физик рәнҗетү ысулы. *Ашыгыч процесслар атулар, көне-төне туктаусыз сорау алулар, кыйнаулар, гариплəндерүләр, мәсхәрәләүләр белән узды.* И.Салахов

**КЫЙНАШ** *и.* Бер-береңне кыйнау. *Бу хәл --- еш кабатлана, күршеләре дә, авыл халкы да бу гаугага, бу кыйнашка күнегеп бара.* Р.Батулла

**КЫЙНАШУ** I *ф.* 1) *урт. юн.* Бербереңне кыйнау, сугышу, үзара бәргәләшү. *Ә без шул агачлар күләгәсендә – йомшак чирәмдә – бер кочак китапларны, конспектларны чәчеп ташлап, аунап укыйбыз, укыйбыз. Башлар томалана башлый – сугышып китәбез. Кыйнашабыз.* И.Салахов. *Элек тә сугыша идек без. Борыннар канаганчы, башлар тишелгәнче, йодрыклар белән кыйнаша идек.* Н.Гыйматдинова

2) *сөйл.* Кемне дә булса кыйнау. *[Хәлим Мәхмүткә:] Нишләп кыйнашасың... Көчең бик күпмени?* Ш.Камал. *Теге кызның артыннан җитеп, сөякләч аркасын дөпелдәтеп китмичә күңел тынычланмады. Хәзер инде кызлар бөтенесе тавыш кубардылар: – Әһә, кыйнашамы? Уйнатмыйбыз булгач, уйнатмыйбыз!* Г.Бәширов

3) Сугышырга, кыйнашырга һәвәс булу, сугышу гадәте булу. *Шакир үзе усал, кыйнаша.* М.Җәлил

**Кыйнашып алу** Кыска бер вакыт эчендә кыйнашу

**Кыйнашып бетү** Бөтенесе үзара кыйнашу

**Кыйнашып йөрү** Булган бер җирендә кыйнашу. *Бер дә апасына охшамаган, һаман кыйнашып-сугышып йөри, аның белән уйный башласаң, эш шуның белән тәмамлана.* Ф.Яхин

**Кыйнашып тору** Гел, һәрвакыт кыйнашу

**КЫЙНАШУ** II *и.* Үзара сугышу, тәпәләшү, тукмашу. *Мондагы «бәйрәм» исергәнче аракы эчү, җыр, көй тарту һәм шул арада кычкырышу, кыйнашудан гыйбарәт иде.* Ш.Камал

**КЫЙНАШЧЫ** *и. диал.* Сугышырга яратучы, кыйнашырга һәвәс кеше, сугыш чукмары. *Мин совет йорты янына килеп җиткәндә, авылның мәшһүр кыйнашчысы Исмай агай кемнеңдер ата-бабасына хәтем укый, дөнья җимереп тавыш күтәреп ятадыр иде.* Һ.Такташ

**КЫЙҢ** *иярт.* Үсә төшкән каз бәпкәләренең кычкыру тавышын белдерә. *Читән белән бүленгән аралык артында каз бәпкәләре моңсу тавыш белән «кыйң» дип әнкәләренә дәшәләр.* А.Гыйләҗев

**КЫЙПТЫЙ** *и. гар.* Мисыр гарәпләренең христиан динен тота торган этноконфессиональ төркеме һәм шул төркемнең бер вәкиле. *Ахырда кыйптыйлар аларга да дошманлык күрсәтеп, һәртөрле җәбер-золым кыла башлыйлар.* Г.Исхакый

**КЫЙПЫК** *и.* 1) Китек, кыйпылчык. *Пулемёт утлары, снаряд шартлаулары, гөрелдәп очкан кыйпыклар арасында алты-җиде сәгать булу – әйтергә генә ансат ул.* Х.Мөҗәй. *Сатучы «палка»дан кечерәк кенә бер кыйпык кисеп, Галәвигә сузды.* Ф.Имамов. *Чүлмәк кыйпыклары*

2) Тукыма яки башка әйберне кискәннән соң калган кисәк, корама. *Ситсы кыйпыклары*

**КЫЙПЫЛУ** *ф.* 1) Кыек ярылу. *Бер агачны ярганда, бер якка китсә, «кыйпылды» диләр.* К.Насыйри

2) Кителү, кителеп төшү (китек, кыйпылчыклар тур.). *Дөньяның бер чите кыйпылды диярсең, шулхәтле көчле гөрселдәп күк күкрәде.* Татар иле

**Кыйпылып китү** Кинәт кыйпылу

**Кыйпылып кую** Кыйпылган хәлгә килү

**Кыйпылып тору** Әледән-әле кыйпылу

**КЫЙПЫЛЧЫК** *и.* 1) Каты әйбердән кителеп, ватылып төшкән кисәк. *Шап-шоп!.. Як-якка агач кыйпылчыклары чәчрәп-чәчрәп оча!..* М.Шаһимәрдәнов. *Палубада электрод калдыклары, тимер кыйпылчыклары, майга буялган чүпрәкләр, линолеум кисәкләре аунап ята иде.* М.Юныс. *– Габдулла, теге пыяла кыйпылчыгы кайда? – диде Алкин, тирә-якка каранып.* И.Салахов

2) Бомба, граната яки снаряд шартлаганда кителеп очкан кисәк, ярчык. *Снаряд кыйпылчыгы Хисмәтнең тез башын чәлпәрәмә китерде, иптәшләре белән йөгереп барган Хисмәт нарат астындагы чокырга гөрселдәп барып төште.* М.Мәһдиев. *Өстәвенә, кулына ядрә кыйпылчыгы тиеп, [Пугачёв] «падишаһ» яралана.* В.Имамов. *Мине дә яраладылар. Бер кыйпылчык сулъяк кулбашымны умырып алды, икенчесе – аякны.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Зур бер бөтеннең кечкенә өлеше. *Мөстәкыйльлеккә йөз тоткан Көнчыгыш империя кыйпылчыгы тиз арада экономик яктан көрәеп, яхшы гына аякланып китте.* М.Хәбибуллин. *Керсәләр дә, яхшы ният белән кермәсләр, я соңгы кыйпылчык җиреңне, я авызыңнан соңгы валчык икмәгеңне тартып алырга керерләр.* Ф.Шәфигуллин

4) *күч. сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса хәтерләткән кеше, әйбер, күренеш һ.б.ш. *Я, егет кыйпылчыгы, әйт тизрәк.* Г.Бәширов. *Көнләшү дигән нәрсәнең кыйпылчыгы да булмаган, ахры, синдә, әбекәй.* Г.Галиева

**КЫЙРАӘТ** *и. гар. иск.* Уку, кычкырып уку; яттан уку. *...Моңа кадәрле күрелмәгән ят бер кыйраәт китабының үзе ят булганы кеби, аны балаларга укыту рәвеше дә ят тоелачактыр.* Г.Тукай

**КЫЙРАӘТХАНӘ** *и. фар.* Уку өе, бүлмәсе, залы. *Ә кыйраәтханәсенә барсаң, шул ук яшьләр китап тирәсендә кайнышйлар.* М.Фәйзи. *Шунлардан котылу өчен ул, Печән базары ягына кайтып, көтепханәләргә керде, кыйраәтханәгә барды.* Г.Ибраһимов. *Вилаятьтә йөздән артык татарча китапханәләр төзелә, бернichә йөз уку өйләре [кыйраәтханәләр] ачыла ---.* Гасырлар авазы

**КЫЙРАКЛА́У** *ф. диал.* Качу. *Миңа иркенлек кирәк!.. Сизәм, син үзең дә моннан кыйракларга җыенасың ---.* А.Гыйләҗев

**КЫЙРАЛУ** *ф. сөйл.* 1) Ватылу, кырылу, җимерелү. *Шулчак --- бер әтәч, бәрәңге бакчасыннан канатын чак сөйрәп килеп чыкты да, телсез калган халыкка да, вәйран кыйралып яткан төягенә дә илтифат бирми, --- тимер караватның аркасына --- очып менеп, «кикрикүк»не кычкырып җибәрде.* Г.Якупова

2) *күч.* Дулкынлану, тирбәлү. *Таулы дала бер офыктан икенче офыкка Газиз бабасының буш җиңсәсендәге кылганнар кебек миллионлаган көмеш учмалар белән кыйралып тирбәлә иде!* А.Хәлим

**Кыйралып бетү** Бөтенләй, тулысынча җимерелү, кыйралу; кыйралган хәлгә килү. *Шул ук ишек аша ян-якка янтаеп, кыйралып беткән, урыны-урыны белән кычыткан басып киткән читәннәр, --- бакча артында гына шарлап агып яткан өязе таллыкларыннан өйгә кайры әчесе керә.* А.Хәлим

**Кыйралып яту** Күптәннән бирле кыйралган хәлдә булу

**КЫЙРАЛЫШ** *ф. иск. к.* **кырылыш**. *--- Фанилык белән Мәңгелек арасында өзлексез кыйралыш барган.* М.Кәрим. *Бу җыруның бары тик фаҗигадән соң гына тууы мөмкин иде. Гүя көтелмәгән кыйралыш, коточкыч җиңелүдән соң --- качаклар караңгы төннәрдә, атларын һау-һаулап, урманнарның үрләреннән күтәрелә...* А.Хәлим

**КЫЙРАТ** *и. гар. иск.* Алмаз кебек асылташларны үлчәү берәмлеге, карат. *Ике кыйрат алмаз*

**КЫЙРАТУ** *ф. сөйл.* 1) Вату, җимерү, кыру. *--- ихатадан ихатага уртак бер зур бакча булып сузылган йөзем, груша, слива агачлары – барысы җимерелгән, кыйратылган --- иде.* А.Хәлим

2) Тар-мар китерү, кыйнау, юк итү. *[Таһир:] Сөйлә, сугышларда йөрдеңме? --- Кыйраттыгыз ничек дошманны?* Ф.Бурнаш. *Хәзергә минем төннәр буе бакчада ялгызым утырырлык кыюлыгым да, бөтен буржуйларны кыйратып, барлык колларны азат итәрлек дәрманым да юк.* М.Кәрим. *– Сугыш өйрәтә, өйрәнмәсәң, кыйрата, – дип кеткелдәде ул.* Х.Камалов

3) *күч.* Ашау. *Шатлыгыннан абыйсы ат булып аунап алды да, өсләрен каккалагач, балтырганнарны берәмберәм кыйратырга кереште.* Ә.Баян

4) *күч.* Берәр эш башкару, нәрсә дә булса эшләү, майтару. *Соңыннан класссташ иптәшләре ---: – Кем, нинди булмасын, ул – укытучы, холык күрсәткән булып пычагым кыйратмакчы идеңме? – диделәр.* З.Вәли. *Берәр бәхәс купса, милиция нәрсә кыйратсын сиңа!* Н.Гыйматдинова. *Иптәш-юлдашлары Нәҗипкә сиздермичә генә шактый кара эшләр кыйратканнар икән ---.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Булдыру, хәлдән килү. *Сугышу дип, әллә ни кыйратканым юк әле.* М.Җәлил. *Каршылык күрсәтерлек корал аз, дивизия таркалган-чәчелгән, --- аларның танкларга каршы әллә ни кыйрата алмаячаклары көн кебек ачык иде.* Т.Әйди. *Дөрестән дә, холык күрсәтеп кенә әллә ни кыйрата алмассың.* З.Вәли. *Өлкән кардәшенең моңа да җавабы әзер: – Бар! Синең кебек эшсез әтрәк-әләмнәр, фәкыйрьфокралар каланың үзендә беткән, ди. Тик шуны бел: берни дә кыйрата алмассың.* М.Хәсәнов

6) *күч.* Чабу, кисү. *Кинәт каяндыр килеп чыккан күзгә күренмәс гигант печәнче каршыга ыргылган төркемне чалгы белән кыйрата башлагандай булды. Немецларның беренче сафтагылары бөтенләй диярлек авып бетте.* Г.Нәбиуллин

**Кыйрата башлау** Кыйратырга тотыну

**Кыйратып бетерү** Тәмам, ахыргача кыйрату

**Кыйратып йөрү** Һәрвакыт, гел кыйрату

**Кыйратып яту** Әле, шушы моментта кыйрату. – *Советлар Берлин капкасын кыйратып ятканда, нинди бетмәгән үҗәтләнү ул синең? – диде кунак, утырган урыныннан дәррәү кубып.* Т.Әйди

**КЫЙСАС** *и. гар.* 1) Кемгә булса карата булган үч, кемнән дә булса алынасы үч. *Уйлар вакыт түгел, хәл итегез: Җинаятькә кыйсас кем ала?* Ф.Бурнаш

2) *этн.* Канга каршы кан белән җәза бирү. *Кыйсас таләп кыйла [яраланган] Бүре теге Үгездән.* М.Гафури

**КЫЙСЕМ** *и. гар. иск.* Бер бөтеннең бер өлеше, кисәге; бүлем. --- *ясаклы крестьяннарның --- бер кыйсеме үз кул көче белән торучы авыл кешесе булып калса, бер кыйсеме сәүдәгәргә әйләнеп китте.* Г.Гобәйдуллин. *Солтангәрәев әфәнденең тәшәббәсе буенча, солдатларның аңлы кыйсме, урра кычкырып, гүзәл мөнәҗәт укыдылар.* К.Нәҗми. *Тел гыйлеменең үзен иң элек ике кыйсемгә аерырга мөмкин.* Җ.Вәлиди

**КЫ́ЙСМӘН** *рәв. гар. иск. кит.* Өлешчә, кисәк буларак. --- *бу хәрәкәт басылгач, татар крестьяны кыйсмән «ясаклы» булып, кыйсмән үз милли алпавытларының колы булып калды.* Г.Гобәйдуллин. *Хәтта кыйсмән бу сүзләр өчен мин рәхмәт әйтергә дә бурычлымын.* Ф.Әмирхан. *1909–1913 нче еллар Россиядә --- иҗтимагый кузгалыш, эшчеләр хәрәкәте, шулай ук кыйсмән революция идеяләренең җанлана башлаган вакыты иде.* Г.Нигъмәти. *Мин моңа кыйсмән иштирак итәм.* Г.Ибраһимов

**КЫЙСМӘТ** *и. гар. иск.* 1) Кисәк, өлеш. *Бу өязне кыйлыйк өчкә кыйсмәт.* Бәет

2) Язмыш, тәкъдир. *Ләкин ни көтәсең, бервакыт җәй башы иде, ир уртасы гына гаилә башы ата-ана белән кызны шул алдау вә ялган белән тулы дөньяда бер дә билгесез бер кыйсмәтнең ихтыярына ташлады да китте.* Ш.Камал

3) Бәхет; үз өлеше, насыйп нәрсә. *Кыйсмәт булса, Әхмәди байның кызын алырмын.* З.Бигиев

**КЫЙССА** *и. гар.* 1) Тарихи вакыйга яки риваятькә нигезләнгән, берничә сюжетлы, тезмә яки чәчмә рәвештә язылган әдәби әсәр жанры; дастанның бер төре.

2) Шул жанрда язылган матур әдәбият әсәре. *Анда татарча эт бетергесез хикәяләр, кыйссалар өстенә, төрек романнарының да исәбе-хисабы юк иде.* Г.Ибраһимов. *«Аның хакында фикерфәлән сөйләп торасы юк, тик Крылов бабайның «Күке илә әтәч» кыйссасын гына искә төшерәсе бар», – диде.* Г.Тукай. *Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри, халык арасында йөргәндә легендаларны туплап, «Әбүгалисина» кыйссасын яза.* Мәгърифәт

3) Әүлиялар, пәйгамбәрләр тормышы турында дини-тарихи хәбәр, риваять, легенда. *Укыталар иде ул вакытта Төрле пәйгамбәрләр кыйссасын һәм аларның төрле могҗизасын.* М.Гафури

4) Тормышта булган хәл, вакыйга турында ирекле рәвештә сөйләп бирелгән хикәя. *Мин исә, мәҗлес халкына мәзәк әйтү чутыннан, теге ике бәрәңге кыйссасын сөйләп бирдем.* Р.Фәизов. *Эссе кояш астында, ялтырап яткан су буенда, Гадил ул кыйссаны бик җиңел генә, шаярып кына сөйләп ташлады.* М.Маликова

**КЫЙТГА** *и. гар.* 1) Бөтеннең бер өлеше, кисәге; бүлем

2) Җир шарының бер кисәге, континент; материкның бер кисәге. *Күрәсең, урман-кырлар, бөтен-бөтен кыйтгалар буенча каңгырап йөри торгач, бирегә килеп чыккан немецлар гаиләсе иде бу.* Р.Фәизов. *Күл һәм елга буйларына кеше үзенә торак төзегән, судан азык таркан, су юллары белән дөньяның башка кыйтгаларына барган.* А.Муранов. --- *тереклек ияләрен дөньяның бер кыйтгасыннан икенчесенә күчереп йөртү --- күпчелек очракларда зур зыяннар --- китерә.* Кызыклар дөньясында

3) *әд.* Шигырь жанры; кыска гына язылган шигырь, парча. *Шигырь вә кыйтгаларда булган бәгъзы читенрәк сүзләрне аңлатыр өчен, сәхифә төбенә шәрех тә төшерелде.* Г.Тукай

**КЫЙТЫ** *с. диал. к.* **койты**. *Кыйты бала*

**КЫЙТЫК** *с. диал.* **1.** *к.* **китек**. *[Юлдашевка] ачыктан-ачык сөйләшергә, күңелдәге кыйтык урыннарны ачыкларга, алгы көндә ничегрәк эшләү турында киңәшергә кирәк иде.* Г.Ахунов

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Берәр кишәрлекнең, мәйданның почмагы, почмакланып торган җире. *Комбайн керә алмаган кыйтыкларны урып яталар.* Н.Фәттах

**КЫЙТЫЛАНУ** *ф. диал. к.* **койтылану**. *Март урталарында атларга азык бик кыйтыланды.* А.Гыйләҗев

**КЫ́Й ҮЛӘНЕ** *и. бот. диал.* Тычкан борчагы. *Кый үләне каплап киткән*

**КЫЙШАЙТУ** *ф.* 1) Авыш хәлгә китерү, кыегайту. *Сираҗи, чүпрәк белән тотып, савытны электр плитәсеннән алды һәм, өстендәге капкачын ачкач, яктыга – тәрәзәгә таба кыйшайтты.* Ф.Садриев. *[Зөһрә] җиләкле савытын кыйшайтып күтәргән килеш чыга башлый.* А.Әхмәт

2) Кыегайту, бер якка салындыру (башны, иңбашларны). *Талда чутылдашып утырган чыпчык малайларына кадәр башларын кыйшайталар да елтыр күзләрен сары башмакларга төбиләр.* Д.Аппакова. *Госман бик үк үзе теләгәнчә булып бетмәгән бер эш хакында әйткән сыман, башын кыйшайтты да җавап бирде.* Г.Ибраһимов

3) Кия-кия чалшайту, кыегайту (аяк киеме тур.). *Күн итекнең үкчәләрен кыйшайту*

4) Йөзне, авызны һ.б.ш. бозу, кыегайту, ямьсезләндерү; чырай бозу. *Аңа нәрсә генә сөйләсә дә килешә, авыз-борыннарын ничек кенә итеп кыйшайтса да урынлы чыга.* М.Әмир. *Хатын, ашыгып, Таһирның бердәнбер рәсемен ак тастымал белән каплады. Таһирның күзе елтырый, ирен читен кыйшайтып көлә сыман.* Р.Мулланурова. *Соңра Хәбибуллин, ничектер, күңеле нечкәрүдән булса кирәк, авызын елмаюга охшатып бер якка кыйшайта.* Ә.Еники. *Каландаров ---, теше белән чикләвек ваткандай, авызын кыйшайтып: – Зөлфакаров – уңган бригадир! – диде.* А.Каһһар

5) *сөйл.* Кулны, аякны каймыктыру, тайдыру, сөякне буыннар тоташкан урыннан чыгару. *[Гыймади:] Анысы*

*йөгерүен йөгерербез, тик минә беләк авырта, әле бер көн уйнаганда, кулны кыйшайткан идем, көрәшеп булса ярар иде.* М.Гали

**Кыйшайта бару** Торган саен күбрәк кыйшайту

**Кыйшайта башлау** Кыйшатырга тотыну

**Кыйшайта тору** Берничгә карамастан кыйшайту

**Кыйшайта төшү** Аз гына кыйшайту. *Язгы кояшка башларын кыйшайта төшеп ара-тирә карап куйгалаган солдатлар тыныч нәрсәләр турында тыныч кына сөйләшәләр.* Г.Ибраһимов. *Карт, кулы белән себерке сабына тотынып, башын кыйшайта төшебрәк кеткелдәп көлә.* Г.Әпсәләмов. *Һәм ул, ләззәтен татырга теләп булса кирәк, башын бер якка кыйшайта төшеп, тәмләп чәйнәргә тотынды.* А.Шамов. *– Бу суны чиләкләп эчсәң дә башка менмәячәк. Минем исерәсем килә, – дип, Смекун, стаканны кыйшайта төшеп, аның эченә күз салды.* М.Юныс

**Кыйшайтып бетерү** Бөтенесен дә, барысын да кыйшайту

**Кыйшайтып җибәрү** Кинәттән, кисәк кыйшайту, кыйшайган хәлгә китерү. *Шулвакыт мәчет өстендә асылынып калган болыт чиләген кыйшайтып җибәрде.* М.Әмирханов

**Кыйшайтып йөрү** Кыйшайту белән шөгыльләнү, кыйшайту эшен дәвам итү

**Кыйшайтып карау** Кыйшайтырга тырышу

**Кыйшайтып кую** Кыйшайган хәлгә китерү. *Гайниҗамал аның капкачын чама белән бер читтән ачык калдырып, кыйшайтыбрак куйды.* А.Шамов // Көтмәгәндә, уйламаганда яки кисәк кыйшайту. *Сәйфи авызын бөрештереп, башын кыйшайтып куйды.* Г.Бәширов. *Каюмның бу сүзләренә каршы Миңсылу авызын кыйшатып куйды.* Ш.Камал. *Ата кеше артта мыш-мыш килгән тавышны ишеткәч, елмайган төсле итеп иренен кыйшайтып куйды.* Р.Зәйдулла

**Кыйшайтып тору** Берникадәр вакыт эчендә кыйшайткан хәлдә булу

**Кыйшайтып чыгу** Берәм-берәм, һәрберсен кыйшайту

**КЫЙШАННАК** *и. диал.* **1.** Кыланчык кеше

**2.** *с. мәгъ.* Кыланчык, кыланчыкланырга яратучы. *Кыйшаннак кыз*

**КЫЙШАННА́У** *ф. диал.* Кемгә дә булса ошарга тырышу, кыланчыклану, чытлыклану

**КЫЙШАЮ** *ф.* 1) Авыш хәлгә килү, кыегаю, кыеклану, авышлану. *Авылның читендә кечкенә генә, бер якка кыйшайган өй тора.* Ә.Айдар. *Анда иңкәйгән, кыйшайган иске кабер ташлары күп.* Ә.Еники. *Табаннары кыйшайган калтыравык кул чанасын көчәнеп сөйрисөйри тәмам алҗыган иде ---.* Р.Мулланурова. *Алар уң якка кыйшайган, урамга караган ике кечкенә тәрәзәле, каралган салам башлы йортка җитә башладылар.* З.Зәйнуллин

2) Кия-кия чалшаю, кыегаю (аяк киеме тур.). *Ул тәмәке төпчеген ачу белән идәнгә ыргытып, аны үкчәләре кыйшайган ертык ботинкасы белән тибә-тибә сүндерде.* Г.Бәширов

3) Йөз, авыз, ирен һ.б.ш. бозылу, кыегаю, ямьсезләнү; чырай бозылу. *Әмир Хаҗинең күзләре акайган, авызы кыйшайган, ил башы үз-үзен белештермәс хәлгә җиткән иде.* М.Хәбибуллин. *Аның төсе сулган, күзләре нурсыз, йөзе кыйшайган иде.* Ш.Камал. --- *Тимеринең --- салам юанлыгы гына итеп калдырылган көл төсле мыегы мыскыллап кыйшайды.* Г.Бәширов. *Яшь туташның матур йөзе зәһәрләнеп кыйшайган иде.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Акылга җиңеләю. *Картның бит әнә «түбәсе» кыйшайган. Нормаль кеше түгел ул!* Н.Гыйматдинова

**Кыйшая бару** Торган саен күбрәк кыйшаю. *Бер якка тәмам кыйшая, читкә янтая барган малайны әнисе шундук күреп алды.* А.Хәлим. *Салихҗан --- капкадан керә-керешли бик эшлекле кыяфәттә --- бер якка кыйшая барган каралтыларны караган була.* А.Вергазов

**Кыйшая башлау** Кыйшаерга тотыну

**Кыйшая төшү** Берникадәр, бераз кыйшаю. *Нигезне тигез утыртмаганнармы, яңгыр, кар сулары кара эшен эшлиме, йорт кыйшая, чүгә төшкән.* Р.Мулланурова

**Кыйшаеп бетү** Тәмам, бөтенләй кыйшаю, тулысынча кыйшайган хәлгә килү. *– Күрәсең бит, дәү әниеңнең бармаклары ничек яргаланып, тубырланып беткән, минекен кара тагы!.. – Зариф абый агач тамыры кебек борғаланып, кыйшаеп беткән бармакларын күрсәтеп алды.* З.Фәйзи. *Мөслихә әби, торып чыккач, үз күзенә үзе ышанмады: элекке череп кыйшаеп беткән баганалар урынына таза, нык наратлар килеп утырган.* Я.Зәнкиев. *Минә үкчәсе ашалып, кыйшаеп беткән тупас ботинкалы бирәү үтеп китә.* А.Шамов

**Кыйшаеп калу** Берәр хәлдән, гамәлдән соң, нинди дер сәбәпләр аркасында кыйшайган хәлгә килү

**Кыйшаеп китү** Кисәк, кинәт, көтмәгәндә кыйшаю. *[Укытучы] кайбер дәфтәрне почмагыннан чеметеп, җирәнеп кенә кулына ала, авызы кыйшаеп китә, йөзе чытыла.* М.Мәһдиев. *Галиулла картның җитен сакалы җилгә сибелә, киез эшләпәсе бер якка кыйшаеп киткән.* Ф.Шәфигуллин. *Утыргыч кыйшаеп китте, аяклар педальдән шуышып төштеләр.* М.Юныс

**Кыйшаеп кую** *к.* **кыйшаеп китү**. *Өстәлдәге томалаулы ашамлыкны күргәч, Тукайның иреннәре кыйшаеп куйды.* И.Нуруллин

**Кыйшаеп тору** Кыйшайган хәлдә булу

**КЫЙШЫК** *с.* 1) Кыек, авыш хәлгә килгән, авышланган, кыегайган. *Без мәктәп янындагы кысан, тар, тәбәнәк, почмакларыннан әче дым китмәгән кыйшык өйдә яшәп ятабыз.* А.Гыйләҗев. *Әмма шул мизгелдә нинди дер могҗизалы көч аны кочагында биешкән тәлинкә-савытлары, кыйшык урындыгы белән бергә кочаклап алды.* Р.Мулланурова. --- *бүлмә --- керле юрган япкан кыйшык тимер кровать белән --- өстәл һәм ике урындыктан гыйбарәт.* А.Каһһар

2) Кия-кия чалшайган, кыегайган (аяк киеме тур.). *Оялма бу киемнең тишегеннән, Катаңның катканыннан, кыйшыгыннан.* Г.Тукай. *Итеге башсыз булыр, --- Үкчәсе кыйшык, Кунычы китек --- булыр.* Н.Исәнбәт

3) Табигый булмаган рәвешкә килгән; чалыш, кыек (авыз, күз һ.б. тур.). *[Кияүнең] буе тәбәнәк, йөзе яман шадра, борыны томшык, күзе кыйшык.* Г.Ибраһимов. *Гает алдыннан тегүчегә озын буйлы, --- кыйшык күзле, үзсүзле --- бер байбәтчә керде.* Ш.Маннур

**КЫЙШЫКЛЫК** *и.* 1) Авышлык, кыегайганлык, чалшайганлык

2) Кыегаю, авышлану дәрәҗәсе

**КЫЙШЫК-МЫЙШЫК** *с. сөйл.* 1) Кыегаеп беткән, чалшайган, авышкан. *Шуның өстенә квартирасы да әйбәттән түгел, Ягеднидәге авылча кара-каршы салынган кыйшык-мыйшык бер өй кисәгенең ярты ягыннан гыйбарәт иде.* Г.Гобәй. *Әмма гамьсез казлар аны танымады. Алай гына да түгел, шушы кыйшык-мыйшык каз бәбкәсенең алар суында йөзеп йөрүен һич кенә өнәмәде.* В.Нуриев

2) Кыек-мыек. *Аннары, эш өстәлендә өем-өем дәфтәр көтә иде, килеп утырды да кызыл карандашын кыйшык-мыйшык юллар өстендә йөртә башлады.* Г.Гобәй

**КЫЛ** I *и.* **1.** 1) Ат койрыгында, ялында, сыер койрыгында, кәҗә, дуңгыз һ.б. тиресендә була торган каты чәчсыман үсенте. *Барлык белән калсалар, бихисап мәшәкатьләрдән, --- ул кадәр сыгылмаслар да иде, нужа очына ат кылы таккан чыбыркысы белән арканы каезлаудан туктамый иде шул!* Б.Камалов. *--- кулларына кылдан үргән нечкә баулар тоткан нәүкәрләр Сәеткә торган саен якыная иде.* В.Имамов. *Балчык арасыннан ат кылы, йоннар, үлән кисәкләре күренеп тора.* М.Юныс. *Балыкны чебен, кигәвен, ат кылы, әтәч каурые һәм хәтта кеше сакалы йонын кармакка төреп тә тоталар.* Кызыклар дөньясында

2) Кайбер кешеләрнең битендә, миңендә, касыгында үсә торган каты төк. *--- бу кешенең танау мөшкәләреннән генә түгел, хәтта --- затлы кыска тунының ачык изүе аша күкрәгеннән челек сыман эре кыллар тырпаеп чыккан.* А.Хәлим. *Кызлар касыгыннан берничә кыл алып, борынга төртсәң – борының башка бервакытта да канамас.* Юлдаш

3) Каты сакал-мыекның төге. *--- ерымнар белән ермакланып беткән яңакларны, --- ияк асларын, бугаз тирәләрен, бигрәк тә --- бугаз төере тәңгәлендәге каты кылны кыру аның өчен --- авыр эшләрнең берсе иде.* А.Хәлим

4) Кайбер музыка коралларында тарттырып беркетелгән һәм тибрәткәндә музыкаль тавыш чыгара торган, металлдан яки сеңерләрдән ясалган сыгылмалы җеп. *Җик Мәргән думбраны көйләп, башын кырын сала төшеп, күзләрен йомды, кылларга чиртеп алды.* М.Хәбибуллин. *Берәү, Кәримнең бер кылы өзек гитарасына кыл куеп, көйгә китереп азаплана ---.* Ф.Әмирхан. *Ишан --- бармакларын дөтәргә тидермичә, кылларына гына чиертеп уйнап җибәрде.* А.Каһһар

5) Кылган чугы. *Кылган сабакларының астагы һәм өстәге буыннарыннан --- як-якка бүселеп чыккан йомшакзәңгәрсу кыллар --- көмеш рәшә булып бар тарафларга чайкала.* А.Хәлим

6) *физ.* Электр лампаларында кулланыла торган нечкә металл чыбык. *Лампа кылы*

7) *күч.* Хис, тойгы, эчке кичерешләр, эчке дөнья. *Бу сорау Илфат күңелендәге әллә кайсы гына кылны өзде дә куйды ---.* Б.Камалов. *Алар арасында нииндидер күзгә күренми торган, соңгы чиккә кадәр тартылган һәм һәр минутта өзелергә торган кыл сузылган иде.* А.Шамов. *Ул фамилиясен әйтмәде, Гадилнең йөрәк түрендәге кыл чыңлап куйды.* М.Маликова. *Йосыф әфәнде чак-чак кына чиертеп куйды, югыйсә... Аһ, гөслә кылларына түгел шул, түгел, күңелем кылларына кагылгандай булды ул...* Р.-Н.Гүнтәкин

8) *күч.* Яктылык сызыгы, нур. *Кояшның кызган кылларында гүләп-кызарып янган урманга туры карап та булмый.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кылдан ясалган, кылдан гыйбарәт. *Кыл иләктән генә иләп коймак пешергән.* М.Мәһдиев. *Кызның өстендә хәрби кием, каешында хәнҗәр, иңендә җәя, кулында нечкә кыл арканның бер очы.* М.Хәбибуллин. *Идрис, кыл чәчләрен артка сыпыра-сыпыра, --- болай диде ---.* Р.Кәрами

2) *күч. сөйл.* Бик нечкә, бик нәзек (гадәттә, муен тур.). *И кыл муен, шул тирескә каткан көрәген кызганган була.* И.Гази. *Менә мин кыяр башлының кыл муеныннан эләктереп алдым, икенче кулым белән сакаллы албастының ипи шүрлегенә менеп төштем.* Шатлыклы кайгы

◊ **Кыл (башы) да кыбырдатмау** *к.* **кыл (башы) да кыймылдатмау**. **Кыл (башы) да кыймылдатмау** Бер нәрсә дә эшләмәү. *Бу вакытта яралы хатын, доктор киңәшен тотып, кыл кыймылдатмыйча ята иде ---.* Г.Гобәй. *Бура кайда, егетләр? Капкадан чыктым да карыйм, юк кына! --- Чынлап, кыл да кыймылдатмагансыз лабаса...* Б.Камалов. *Син гүя ярдәмгә мохтаҗ: кыл да кыймылдата алмый ятасың.* Ш.Рәкыйпов. *Һушсыз булып, кыл кыймылдатмыйча сихерләнеп тыңлыйлар.* Н.Исәнбәт. **Кыл (башы) да селкетмәү** *к.* **кыл (башы) да кыймылдатмау**. *Монда утары бар Минһаҗетдинның. Үзе кыл да селкетми. Бик үткен приказчигы бар, шуның аша гына эш йөртә.* М.Хәсәнов. *Шан-шәрәфле бер түрәнең кыл да селкетмичә җанын сатуына хәйраннар булдым.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Кыл бөртегенә асып кую** *к.* **кыл өстендә калу**. *Фәез --- бер ярдәмсез укыды. Гомерен кыл бөртегенә асып куя-куя йөрде.* Ә.Баян. **Кыл бөртек әйберсез калу** Бернәрсәсез торып калу. *Халык урманда, сүндерер кеше юк: унлап хуҗалык кыл бөртек әйберсез калды.* Ш.Маннур. **Кыл булып тартылу** Туры басу. *Теге адәм хәрбиләрчә кыл булып тартылды, казармада кизү торучы солдат кебек кычкырып җавап бирде ---.* З.Фәтхетдинов. **Кылга асылынып тору** *к.* **кыл өстендә калу**. **Кылдай нечкә** Бик нечкә. *Токмачны кылдай нечкә итеп кисәргә безне әнкәй балачактан ук өйрәткән иде.* Р.Мулланурова. *Табигать белән аралашкан урманчының югыйсә күңеле дә, хисләре дә кылдай нечкә булырга тиеш иде.* Н.Гыйматдинова. *Пыяла йөзе һәм малайның пыялада иҗат иткән якты, кылдай нечкә эзе яхшырак күренсен дип, ул тагын да бераз алгарак үтте.* А.Хәлим. **Кылдан нечкә** Артык назлы,

артык нәзакәтле. *[Шәрипов:] Әй, гафу итәсез, туташ, мин сезнең бу кадәр кылдан нечкә булуыгызны уйламаган идем.* Ф.Бурнаш. **Кылдан таю** Кәеф китү, хәтер калу, үпкәләү. *Я, нәрсәгә әле шулай кылдан тайдың.* Н.Исәнбәт. **Кыл да сыймаслык** Аралары шул дәрәҗәдә якын, тыгыз. *Шул ук өйдә бер мәче баласы да булып, сыерчык илә моның араларына кыл да сыймаслык дәрәҗәдә дус иде.* Г.Тукай. **Кыл да үткәрә алмау** Бер сүз дә каршы әйтә алмау; берничек тә тәэсир итә алмау. *[Хисапчы:] Законны, малай, синең белән миңа караганда яхшырак белә ул. Кыл да үткәрә алмыйсың.* Р.Төхфәтуллин. **Кыл иләктән уздыру** Бик җентекләп, җиренә җиткереп тикшерү. *Безнең халыкта вакчылрак берәр җитәкче турында сүз барса, «кыл иләктән уздыра инде» дип сөйлиләр.* М.Мәһдиев. *Мене шулай танышып киткән иргегетләрнең байтагы, остаханәгә килеп, кыл иләктән узды инде.* М.Шаһимәрдәнов. **Кыл кадәр (дә)** Аз гына да. *Миңнур карт исә моны күреп кыл кадәр дә урыныннан кузгалмады.* А.Шамов. **Кыл күпер өстендә тору** *к.* **кыл өстендә тору**. *Харисовның ачуы чыкты: Сафин кыл күпер өстендә тора, алай да шартлар куеп маташа.* Р.Айзатуллин. **Кыл кыймылдатырлык та (тибрәтерлек тә)** Аз гына да, һич кенә дә. *Мин арыган идем, кыл тибрәтерлек көчем калмаган иде.* А.Шамов. *Чыгып йөрерлек түгел, кыл кыймылдатырлык та хәл калмый иде.* Г.Мөхәммәтшин. --- *мәктәптә укулар башлангач, кыл кыймылдатырлык та вакытың булмас* ---. Р.-Н.Гүнтәкин. **Кыл кыймылдату** Берәр кечкенә генә эш эшләү. *Берчакта да кыл кыймылдатмаган «верхушка» рәхәт чигеп, кәеф-сафа корып яшәде...* А.Гыйләҗев. *Инде шауламагыз, кыл кыймылдатасы булмагыз.* Г.Гобәй. *[Һөрениса] көн буена кыл да кыймылдатмый, гел арттан йөреп, өйрәтеп торырга гына белә.* А.Каһһар. **Кыл кырыкка ярылыр чак** Бик тыгыз вакыт, бик мәшәкатьле, күп эшләр белән мәшгуль булган чак. *Нәчәлник урынбасарын сүгеп чыгарды: – Кылның кырыкка ярылыр чагы, панимаеш, ә син каладан әртисләр чакыргансың!* Х.Ибраһим. **Кылны кырыкка бүлү** *к.* **кылны кырыкка яру**. --- *болай да кылны кырыкка бүләрдәй булып йөргән көннәрдә Мирсәет Солтангалиев киеренке вакыйгалар чоңгылында берьялгызы дип әйтерлек торып кала.* Р.Мөхәммәдиев. **Кылны кырыкка яру** 1) Бик булдыклы булу, уңган булу. *Быел сабакка барыр ул, Шигырьләр, җырлар отар, Кылны кырыкка ярыр ул, Күктә йолдызлар тотар.* Г.Афзал. *Типсә тимер өзәрлек таза хатын. Үзе матур, үзе уңган. Шундый хатыннар турында бит инде, кылны кырыкка ярыр, дип әйтәләр.* М.Хәсәнов; 2) Вакчыл кеше булу; вакчыллану. **Кылны кырыкка яручы (ярырлык, бүлүче)** Бик булдыклы, уңган кеше. *Ачык йөзле, тәмле телле, киң күңелле, кылны кырыкка ярырлык хатын иде Хәмдия апа.* Р.Төхфәтуллин. --- *Әбүгалисина яшьтән үк китаплар укуга бирелде. Шуңа күрә бик күп нәрсәләр белде. Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка яручы» бер бала иде.* Мәгърифәт. **Кылны кырыкка ярыр (ярырдай) чак (вакыт)** *к.* **кыл кырыкка ярылыр чак**. *Авыл халкының кылны кырыкка ярырдай булып, куна-төнә кырда яткан чагы.* В.Имамов. *Кылны кырыкка ярырдай чаклар бихисап: печән өсте, урып-җыю, чәчү-мазар вакытларында эшче куллар артык буламыни?!* Р.Мулланурова. *Авылда кылны кырыкка ярыр вакыт...* Р.Мөхәммәдиев. **Кыл очында тору** *к.* **кыл өстендә тору**. **Кыл очында гына калу** Чак-чак кына һәлак булмыйча калу. **Кыл өзәрлек тә** *к.* **кыл кыймылдатырлык та (тибрәтерлек тә)**. *Кыл өзәрлек тә хәле калмаган Өммегөлсемне кабердән Никодим күтәреп диярлек чыгарды.* А.Хәлим. **Кыл өзелү** Рухи бәйләнеш юкка чыгу, күңел кителү. *Нәркиснең тамагында әллә нинди кыллар өзелгәндәй итте, әйтерсең күз яше көйгә тавыш булып кушылды.* М.Мәһдиев. *Улы шыңгырдап торган ак чыршы бүрәнәләр кайтарып аударды. Карчыкны бу дөнья белән бәйли торган бер кыл өзелгәндәй булды. Осталар килеп бүрәнәне таслый башлагач, янә бер кыл чыртлап өзелгәнен ул үзе сизде.* Р.Мулланурова. **Кыл өстенә баскан чак** Бик хәтәр, җаваплы, акыл дәрт-хистән көчлерәк чор. *Хәлимәне күздән ычкындырмагыз, яме? Кыл өстенә баскан чагы аның.* Н.Исәнбәт. *– Әлбәттә, балалар. Канат йоннары каткан булса да, табигать җиңгән, ә башлары эшләмәгән, – диде тыныч кына Матвеев. – Кыл өстенә баскан чаклары.* А.Мифтахетдинов. **Кыл өстенә куелу** *к.* **кыл өстендә тору**. *Революциянең барлык киләчәге кыл өстенә куелган шушы дәһшәтле моментта Ленин, Үзәк комитет утырышын җыеп, көн тәртибенә кораллы күтәрелеш мәсьәләсен куйдылар.* К.Нәҗми. **Кыл өстенә кую** Зур куркыныч астына кую. *Врачлар Асиягә яңадан бала табарга киңәш итмәде, тормышын кыл өстенә куячагын кисәттеләр.* Ә.Моталлапов. **Кыл өстендә булу** *к.* **кыл өстендә тору**. *Операциядән соң [врач] өч тәүлек буена Фәйзерахман янында китмәде. Кеше гомере кыл өстендә иде ---.* Б.Камалов. --- *кызның язмышы бүген кыл өстендә була.* М.Мәһдиев. *Үзеңә мәгълүм: сугыш вакыты хәзер – яралыларның җаннары кыл өстендә.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Диагноз минем иң начар шикләремне раслады: бу рак иде. --- Минем гомерем кыл өстендә иде.* Юлдаш. **Кыл өстендә (генә) йөрү** Тәвәккәлләп куркыныч эшләргә керешү, бик нечкә, хәтәр юлдан йөрү. --- *Сәлим хан яшелле-зәңгәрле тавыш белән бакырып җибәрде: – Хайван, --- мин анда кыл өстендә йөрим, ә ул кымыз чөмереп ята. Яу, яу чык калага!* М.Хәбибуллин. **Кыл өстендә калу** 1) Көчкә-көчкә, чак-чак кына исән калу, бетә язу; юкка чыга язу. *Син ай ярым урын өстендә яттың, кыл өстендә калган чакларың булды.* Ә.Ерики. *Менә әле кышның бер ае үткән юк, ике адәмне шул бураннар шәһит җибәрде. Ничәләренең җаннары кыл өстендә калып, бик зур бәхет илә генә котылдылар.* Г.Ибраһимов; 2) *к.* **кыл өстендә тору**. *Язмышы кыл өстендә генә эленеп калды.* К.Нәҗми. *Тагын берничә минуттан ротаның хәле кыл өстендә калачак.* Г.Бәширов. **Кыл өстендә тору** Һәлакәт, бетү алдында тору; куркыныч, хәтәр хәлдә

булу. *Ә мин курыкмыйм, каравылбаш. Гомере кыл өстендә торган ханнан куркып буламы?* М.Хәбибуллин. *Күрдегезме уң һөҗүмчене? Һи-и-и... Пенальтины ничек бирде? Кыл өстендә тора иде бит команда.* М.Мәһдиев. *Илебезнең язмышы кыл өстендә торганда, --- төннәр буе микроскоп өстендә утыру Дәүләтшинга әллә ничек оят кебек тоела.* И.Гази. *Агаңның язмышы кыл өстендә тора, Камали энем.* М.Әмир. **Кыл сыймаслык (сыймаган)** Бик тыгыз, тар. – *Син кайтмасаң, бер мәшәкать кимрәк булыр иде, дим. Нәрсә, авыл кешесенең башка эше, башка кирәге беткән иде, дисеңме? Болай да... кыл сыймаган чакта эч пошырып йөрисең, [– диде Нәҗип].* Р.Мөхәммәдиев. *Вакытың кыл сыймаслык, төрле кызыклы эшләрең күп була икән – картаерга вакыт юк, димәк.* Мәдәни җомга. **Кыл сыймау** Эш тыгыз булу, эш күп булу. – *Сезнең ише урындагы кешенең артына кыл сыймый торган вакытыдыр, – дигән булып, хәйләкәрләнеп, тегенең салпы ягына салам кыстырып маташты.* Ф.Хөсни. **Кыл сыярлык та** Бернинди, һичнинди. *[Тәнкыйтьләү] өчен кыл сыярлык та урын калдырмадың.* А.Шамов. **Кыл тибрәтү** *к.* **кыл кыймылдату**. **Кыл чабата кидерү (киендерү)** Бик нык алдау. *Син инде теге юлы да бер миңа кыл чабата кидердең.* Ш.Камал. **Кыл чаклы (да)** *к.* **кыл кадәр (дә)**. *[Җәлал:] Мин гомеремдә кешедән бер кыл чаклы нәрсә алганым, ярдәм күргәнем юк.* Г.Ибраһимов. **Кылы бушау** Булган көче, дәрманы озакка бармау, хәле бетү. *Габделбәр тыштан һичкемгә сер бирергә исәбе юк шикелле күренергә тырышса да, эчтән кайсыдыр кылы бушый башлаганын тойды.* Б.Камалов. **Кылына кагылу** *к.* **кылын тартып (тарткалап, чиертеп) карау** *Яннарына бар, тартынма... Кылларына кагыл, сөйләш!* Р.Рахман. **Кылын басу** Кешенең билгеле бер ягын (үзенчәлеген) белеп эш йөртү, эш алып бару; ул үзенчәлектән файдалану. *[Анасы] мондый вакытларда аның кайсы кылын басарга кирәклеген ачык белә.* Г.Ибраһимов. **Кылын селкетү** Хис-тойгы, кызыксыну уяту. *--- ачык йөзле, җылы сүзле, тәмле ашлы булып та синең кылыңны да селкетә алмаган, ягъни син аңа битараф булган хатын-кыз белән яшәү дөресме?* Ф.Фәтхелислам. **Кылын тартып (тарткалап, чиертеп) карау** Кемнең дә булса уй-фикерен белү өчен, аны сынап карау, киная белән сорашып, аның уен-фикерен белергә тырышу. *Серне бирми генә, кайчан мин аның кылларын тарткалап карыйм.* А.Шамов. *Моннан берничә көн элек аны авыл советына чакырып, кылын тартып караганнар иде.* А.Гыйләҗев. *Бәлки, Бәлкыйс ирләр тарафыннан рәсми булмаган мөнәсәбәткә мохтаҗдыр? Тукта әле, кылларын тартып карарга кирәк.* М.Мәһдиев. **Кылын тибрәтү (чиртү)** *к.* **кылын тартып (тарткалап, чиртеп) карау**. *Хәзер инде колхозчыларның иң нечкә кылын чиертергә кирәк иде.* Г.Бәширов. *Кайсы кылны чиртергә дә белә бу хитрый, дип уйлады.* Г.Ахунов. *Хәмидулла солдат ул аның нинди кылына чиртәсен белә.* М.Гали. **Кылы да селкенмәү** Ис китмәү; борчылмау. *Кая ул үкерә-үкерә хатынын тукмаган атаның кулына сугу, өйдә кара тавыш тынганчы, багана хәтле гәүдәсе белән тышта йөри иде малай. Әнкәсенең күз яшьләренә аның кылы да селкенмәде.* Н.Гыйматдинова. *--- генерал Клембовскийның кисәтүле боерыгын укыдылар: «Әгәренки солдатлар сугышырга теләмиләр икән, бу очракта барлык туплар үз окопларыбызга ут яудырачак». Кыллары да селкенмәде 10 нчы полктагыларның!* Ш.Рәкыйпов

**КЫЛ** II *кис. сөйл.* Нәкъ, төгәл. *Станция каузында су ургып шаулый, аның тыгыз көче, меңнәрчә елларны кыл урталай бүлеп, --- авыш сигезле булып бөтерелгән шкиф каешын әйләндереп ята иде.* Ә.Гаффар. *Дикопольцевның баш миен маңгае турысыннан кыл урталай бүлеп, яшен кылычы ярып үтте.* Г.Кашапов. *Әйе, җәмәгать, мин сезгә кыл дөресен әйтәм, денебезне бетермәкче безнең ул камунистлар.* В.Нуруллин

◊ **Кыл өстенә басу** Нәкъ турысын, дөресен әйтү

**КЫЛАВЫН** *с. диал.* Бик юка, бик нечкә

◊ **Кылавын кебек калу** Бик югары, бик югага әйләнү (тукыма кебек әйберләр тур.)

**КЫЛАЙТУ** *ф.* Күзне кылыйлатып карау, күзнең кырые белән карау. *Хәлим әле тишектән күренеп торган винтовка түтәсенә карап ала, әле чаттагы кешеләргә күзләрен кылайта.* И.Гази

**Кылайтып тору** Сөйләү моментында күзләрне кылайту // Күзләрне һәрвакыт кылайту

**КЫЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсә эшләгәндә, мәзәк яки кирәксез, урынсыз кыланышлар ясау. *Ул чырайларын әллә нишләтеп, еларга хәзерләнгән шикелле кыландыра.* Ш.Камал. *Рәсим абый, әллә ниткән фырт егетләр сыман, бер бармагын гына рульгә тидергән була. Ә аяклары белән ниләр генә кыландырмый!* Р.Мулланурова

2) Төрлечә эшләп карау; төрлечә маташтыру. *Бу лагерь бик зур, берничә йөзләгән бүлекләргә бүленгән, лагерь эченә лагерь корганнар. Андагы чәнечкеле чыбыкларны ничек кенә кыландырып урап бетермәгәннәр.* С.Шакир

3) Берәр нәрсә китереп чыгару, нәрсә дә булса эшләү. *[Сәләхи] булса, тагын да хикмәтләр кыландырыр иде.* Ш.Камал

**Кыландыра бирү** Бернигә карамыйча кыландыру

**Кыландырып йөрү** Һәрвакыт, гел кыландыру

**КЫЛАНМЫШ** *и. сөйл. к.* **кыланыш** (*1 мәгъ.*). *Сәлиме Начтыйга карап көлгән була, тегесе аска караган була. Икесенең дә кыланмышлары кырга сыймый.* И.Сирматов. *Баштарак Әхнәфнең кыланмышларына гаҗәпләнеп караган классташлары --- малайдан көлә башладылар.* Ф.Сафин. *Мүҗгәннең кыланмышын һич оныта алмыйм. Исемә төште исә, өстемә кайнар су сипкәндәй була иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КЫЛАНУ** *ф.* 1) Табигый булмаган кыланышлар (хәрәкәтләр) ясау. *Ирләр затына артык каршылык күрсәтү гадәте булмаган Айгөл бу юлы да баш тарта алмады. Керделәр. Утырдылар. --- Биегән булып кыланып, бөтерелеп тә алдылар.* Ә.Моталлапов. – *Кыланма, шамакайланма, – диде Җик Мәргән ---.*

*– Коръән тоту өчен әүвәл сиңа аны укый белергә кирәк.* М.Хәбибуллин

2) Үз-үзеңне табигый тотмау; кыланчыклану; назлану. *Хан кызы түгел, яван кызы, иллә гүзәл, сылу, бераз һавалырак кылана кылануын, иллә гүзәл.* М.Хәбибуллин. *--- ул кайбер вакыт килененең артык иркен, артык уенчак кылануыннан да пошаланып кына: «Балам, Сабир, безнең Камиләбез артык җиңел, артык җиңел лә!» – дип куя.* Г.Ибраһимов. *«Сөям, көям» дигән булып Юри кыланган идем.* М.Җәлил

3) Үз-үзен тотуда берәр сыйфатны калку итеп күрсәтергә тырышу. *[Ул мөселман] бигрәк җете кызыл мөэмин булып кылана.* Г.Тукай. *Җик Мәргән кайткач күрде: абыйсы үзен ил иясе итеп тота, эре кылана, ---.* М.Хәбибуллин. *Мин Гөлзадә урынында булсам, бер дә яратмасам да, егетнең күңеле өчен генә дә яраткан булып кыланыр идем.* Р.Ишморат. *Шәмсетдинов --- егетләрнең гайрәтен сүндерерлек берике генә җөмлә әйтте: – Беренчедән, – диде ул, елмайган килеш, – беренчедән: мин кайбер иптәшләрдән шыпыртрак кылануны сорар идем.* М.Мәһдиев

4) Үз-үзен тотышында кемгә дә булса охшарга тырышу. *Кара әле, Иделгарский, син чынлап та теге Бохарадан кайткан хәлфә төслерәк кыланасың.* Ш.Камал. *Менә сиңа мә! Ничек сөйләшә яңа мыек тибә башлаган үсмер зат. Балигъ егетләрчә кылана.* М.Хәбибуллин. *Катышкан кешең бай булгач, сиңа да азрак кешечә кыланмый туры килми.* М.Фәйзи. *Аның һәр төрле иркәлекләренә өйрәнгән атасы белән абзаларына да аның болай һаман яшь балаларча кылануы кызык тоела.* Ш.Камал

5) Эш итү, эшләү. *Икесенең дә тез буыннары калтырый инде. Ну берберсенә сиздермәгән булып кыланалар.* И.Сирматов. *Хатын-кыз синең холкыңфигылең, гадәтең-җаең белеп алдымы, юха еландай кылана башлый: ни тели, шуны алдыра; ни тели, шуны эшләтә.* М.Хәбибуллин. *Әгәр иптәшләре --- әйдә, теләсә ничек кылан, дип, аңа кул селтәсәләр, ул [Миләүшә] болай чәбәләнеп йөрмәс тә иде.* З.Вәли. *Кәмран ап-ак бузарынды. Шул килүдән соң ул бүтән күренмәде. Мин аның белән бик каты кыландым, билгеле.* Р.-Н.Гүнтәкин

6) Берәр эш башкарган булып күренү, күренергә тырышу. *Юк, үпкәләмәде Зәнфирә, юри генә кылана ул.* Ф.Садриев. *[Песинең] күзләре йомык. Йоклый, имеш. Малай белә, ул шулай кыланган гына була.* А.Хәлим. *Мөнисә гаебен танымады. Ә инде минем аңа ышанмавымны күргәч, шыңшыган булып кыланды.* Р.-Н.Гүнтәкин

◊ **Кылануы кырга сыймау** *к.* **кыланышы кырга сыймау.** *[Бану:] Уйный белгән кеше кебек пианинога җәелеп утырган. Кылануы кырга сыймый.* Р.Ишморат

**Кылана башлау** Кыланырга тотыну

**Кылана бирү** Бернигә карамыйча кылануын дәвам итү

**Кыланып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә кылану

**Кыланып йөрү** Гел, һәрвакыт кылану

**Кыланып тору** Даими рәвештә кылану

**КЫЛАНЧЫК** *с.* **1.** Кыланышы ясалма, табигый булмаган; чытлык. *Кыланчык кыз*

**2.** *и. мәгъ.* Ясалма кыланышлы кеше. *Үҗәтлегем: йөрмә, укасы коелмас, аның кебек кыланчыкларны беренче тапкыр гына күрүең түгел, ди.* М.Маликова. *Мин Мөнисәне акылга өйрәткәнче, ул үзе мине бер кыланчыкка әйләндереп куймагае әле.* Р.-Н.Гүнтәкин

**3.** *рәв. мәгъ. – Диләә, бир үзенә сабак! – дип таләп итә халык. Бетте баш. Инде нишләргә? Диләә исә... кыланчык елмаеп: – Фирдүс, ник алай эшлисең? – диде.* Р.Фәизов

**КЫЛАНЧЫКЛАНУ** *ф.* Үз-үзен тотышында ясалма кыланышлар булу; чытлыклану. *[Яңгураз] сок һәм бутербродлар белән сыйлаганда, юри кыланчыкланып: – Ә минем Аллам – гүзәл хатын-кыз, – диде.* Т.Әйди. *Алекси апа үзенең җиңелгәнен сиздермәс өчен, кыланчыкланып, битемә чиертте ---.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Кыланчыклана башлау** Кыланчыкланырга тотыну

**Кыланчыклана бару** Торган саен күбрәк кыланчыклану

**Кыланчыклана башлау** Кыланчыклык билгеләре белену, күренү

**Кыланчыклана бирү** Бернигә карамыйча кыланчыклану

**Кыланчыклана төшү** Беркадәр, бераз кыланчыклану

**Кыланчыкланып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә кыланчыклану

**Кыланчыкланып йөрү** Һәрвакыт, гел кыланчыклану

**Кыланчыкланып китү** Кисәк, уйламаганда кыланчыклана башлау

**Кыланчыкланып тору** Ниндидер вакыт дәвамында кыланчыклану

**КЫЛАНЧЫКЛЫК** *и.* Кыланчык булу. *Хәмит белән Сәгыйдәдә бернинди ясалмалык, кыланчыклык, хәйләкәрлек юк.* Ә.Еники. *Чак кына мактанчыклык, кыланчыклык та бар бугай Рәсим абыйда.* Р.Мулланурова. *Кайчагында көчләрен кая куярга белмәгән, --- кыланчыклыгы чиктән ашкан яшь юлбарыслар дәү дуңгызларга һөҗүм итәләр.* Кызыклар дөньясында

**КЫЛАНЫШ** *и.* 1) Кемнең дә булса үз-үзен тотуы, аның тәртибе. *Олан гаепле түгел, моны Сәлим хан белә иде, гаеп үзендә булды. Оланның андагы кыланышы итагать билгесеннән узмады ---.* М.Хәбибуллин. *Шәрәфи картның кызы Газизә, ягымлы кыланышы, уйчан карашлары белән Хәлимәне җанлы рәвештә гәүдәләндереп, аның исенә төшерә иде.* Ш.Камал. *Юка күлмәге аша сизелеп торган каты күкрәкләре исә җилкәмә кадала... Мин Диләнең бу кыланышларына артык әһәмият бирмим.* Р.Фәизов

2) Кемнең дә булса үз-үзен тотуының тышкы формасы; манера, гадәт. *Насыйх ага, соңыннан, инде кызы үсә төшеп аяк астында күбрәк болгана башлагач, аның кайбер сәер кыланышларын күргәләде.* З.Вәли. *Михаил рәсемгә бик озак карап торды да аңар хыялый бер тереклек бирде һәм Хәятның бөтен кыланышларын, күз йөртешләрен --- күз алдына китерергә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Дисәнең үз-үзен тотышына, кыланышларының тыйнак-әдәпле булуына --- бик күпләр дикъкать итәләр.* М.Хәсәнов

3) Берәр эшләгән эш, башкарылган эш-хәрәкәт. *Сәлим хан --- җиләнен са-*

*лып атты. Кыз исә аның бу кыланышына коты алынып карап торды да һуштан язды.* М.Хәбибуллин. *Миңа кем дә булса ошап куя икән, мин аның өстенә бүре баласыдай атылып киләм, --- бу тупас кыланышларым белән теге мескенне үземнән шундук биздерә торган идем.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Гелиогабалның тормыштагы бар кайгысы һәм төп максаты яңадан-яңа кыланышлар, рәхәт чигүләр эзләп табу була.* Кызыклы дөнья

◊ **Кыланышы кырга сыймау** Артык, чамадан тыш кылану, кыланчыклану турында. *Ә дигәнче зур урамнар сузалар. Кыланышлары кырга сыймый, инде күккә дә үрмәли башладылар.* Г.Мөхәммәтшин. *Кунаклар килгән. Мулла абзый никах укырга җыенган. Тик бер генә нәрсә – кәләш кенә җитми. – Кыланышлары кырга сыймый. Килешмәгәнне! – дип, кунаклар үпкәли.* Р.Мулланурова. *Кырым кебек ата-баба илен Сагалаган һәрчак мең үлем, Кыланышлары кырга сыймыйча, Эт көтүе корыткан телен.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**КЫЛАНЫШ-ТОРЫШ** *и.* Кешенең үз-үзен тотуы һәм аның тышкы чагылышы. *Гайшәдән соң керәшен бабай кертелде. Башында картуз... бөтен кыланышы-торышы буенча коеп куйган рус мужигы.* Г.Ибраһимов

**КЫЛА́У** *и.* Күзнең мөгез катлавы калынаюдан килеп чыккан авыру; катаракта. *Аның сәламәтлеге инде какшады, күзләрен кылау тәмам басты.* М.Хуҗин. *Кылауны күз табибына күрсәтү*

**КЫЛАЮ** *ф. диал.* 1) Кыегаю, авышу. *Сыңар тәрәзнең бака кашыгы төсле утлы-яшелле өч өлгесе өчесе өч якка кылайган.* Г.Бәширов

2) Ничек туры килде шулай аву, яту. *Ә таң алдыннан --- кайсың кайда кылаеп, черем итеп аласың.* Ф.Хөсни

**Кылая башлау** Кылаерга тотыну

**Кылаеп бетү** Тәмам, бөтенләй кыегаю, кылаю

**Кылаеп тору** Сөйләү моментында кылаю // Һәрвакыт, гел кылаю

**КЫЛБЫРДАК** *и. диал.* Ыгы-зыгы, шау-шулы тәртипсез эш-хәрәкәт

**КЫЛБЫРДА́К КИЛҮ** *ф.* Ыгызыгы килү. *Йортлар тирәсендә кылбырдак киләләр, тыз-быз йөриләр.* А.Гыйләҗев

**КЫЛГАН** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан яфракларын озын тар кыяклар тәшкил иткән, йомшак себеркәч чәчәкле үлән (даланың кыйммәтле терлек азыгы булып саналган төп үсемлеге), әби чәче. --- *мин кылган букет исемә төшерә торган бу истәлекле вакыйганы тагын --- бер кат күңелемнән кичерәм...* Ф.Хөсни. *Сәет куе кылган каплаган иксез-чиксез дала буенча барып, бер якта дөя өркәчләре сыман калкып торган биек тау янына җитте.* В.Имамов. *Харис, елмаеп, малайның кыска итеп алынган, кылган төсле чәченнән сыйпады ---.* З.Вәли

**КЫЛГАНЛЫК** *и.* Тоташтан кылган үсеп утырган урын, тоташтан кылган каплаган җир. *Агыйдел дә буе, ай, кылганлык, бер бөртекләре дә кыл кебек.* Җыр

**КЫЛДА́У** *и.* Чиләк бавы. *Кылдавына бау бәйләнгән чын чиләк тотып, Майсәрә кое янына барып басты.* Н.Фәттах

**КЫЛДЫ-БЫЛДЫ** *рәв. сөйл. к.* **кылдый-былдый**. *Син алай кылдыбылды буталып йөрмә, яме?* Т.Гыйззәт

**КЫЛДЫЙ-БЫЛДЫЙ** *рәв. сөйл.* Кыек-мыек, авыш-түеш. *Суык таш диварлар арасына кертеп кыстырылган бөҗәк кенә түгел, син – нул, юк син, кылдый-былдый чүплеккә барган арба кучәреннән төшеп калган сынык чәкүшкә син.* А.Гыйләҗев. --- *инде кояш, Зиннәт бабайның арбасындагы кылдый-былдый барган тәгәрмәч сыман, йокымсырап кына --- чит якларга тәгәри икән ләбаса.* И.Юзеев

**КЫЛДЫЙ-ПЫЛДЫЙ** *рәв. сөйл. к.* **кылдый-былдый**

**КЫЛДЫРЧА** *и. диал. к.* **калтырча**. *Редакциянең «кылдырчасы» да лаеклы ял сорый, тимер дә искерә-туза.* Н.Гыйматдинова

**КЫЛ ЕЛАН** *и. зоол.* Җепкә, чәчкә охшаган, суда яши торган паразит корт; җеп елан; *русчасы:* **волосатик**

**КЫЛҖАЮ** *ф. диал. к.* **калҗаю**. *Алганда аның стеналарыннан җил өреп, түбәсеннән яңгыр үтеп торса да, Гыйльмениса җиңги, үзенең булганлыгы аркасында, стеналарын кызыл балчык белән сылап, кылҗайган бүрәнәләрен терәтеп, түбәсенә балчык өеп, яхшы гына ныгыткан иде.* М.Гали

**КЫЛҖИ́-МЫЛҖИ** *рәв. диал.* 1) Кыек-мыек (атлау)

2) *күч.* Бер болай, бер тегеләй; җитди түгел (сөйләү, фикер йөртү). *[Ярми карт] хәзерге халыкны «кылҗимылҗи»сы өчен сүгеп, әүвәлгеләрне сагына.* Г.Ибраһимов

**КЫЛКА** *с. диал.* **1.** 1) Тузып теткәләнгән, тузып, теткәләнеп, телгәләнеп беткән. *Безнең ертык, юеш, кылка киемнәребез арасында ул [Кәүсәрия] курчак кебек.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Артык ябык, ябыгып беткән; арык (кеше тур.)

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тузып, теткәләнеп, телгәләнеп беткән сәләмә кием; сәләмәләр. --- *син --- краннан су тамганын көтеп торган арада, синең киемсалымың эссе камерада пешә. --- Барабара өс киемнәреңнең кылкасы гына кала.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса иң кечкенә, иң вак өлеше, әсәре, бөртеге. *«Заря» ресторанында дүрт ел директор булды, ә бавырының кылкасы да калмаган. Бавыр белән китмәде тагын, йөрәккә бәргән.* Сөембикә

◊ **Кылкага калу** Киеме тузып, җепләре теленеп беткән хәлгә калу. *Кичәге Вәли байны күрдегезме? Киеме бөтенләй беткән, кылкага калган.* Н.Исәнбәт

**КЫЛКАЛАНУ** *ф. диал.* Тузып теткәләнү, теткәләнеп, телгәләнеп бетү (кием тур.)

**Кылкаланып бетү** Бөтенләй, тәмам тузу, кылкалану. *Минем өскә киярге булмаганга, иртәнге салкыннарда киеп йөрерсең дип, әни әтинең иске тәвәккәл бүреген һәм --- искереп, кылкаланып беткән тула чикмәнен бирде.* М.Гали

**КЫЛКАЛӘМ** *и.* Вак, нәфис рәсемнәр, язулар һ.б.ш. эшләү өчен, сапка беркетелеп, кыл, чәч кебекләрдән ясалган кечкенә пумала. *Гомумән, рәссамнар каршында бөтен шагыйрьләр исеменнән баш иям! Сезнең кылкаләмегез безнең каурый каләмнән көчлерәк.* М.Маликова. *Үткән ел Татарстан Рәссамнар берлеге җөмһүриятебездә*

*яшәп иҗат итүче кылкаләм осталарының 40 лап күргәзмәсен оештырды.* Мәдәни җомга

**КЫЛКАЛЫ** *с.* Авыр, борчулы. *Уйлабрак карагыз, килен чакларыгызны, сугыш елларын капшап дигәндәй карагыз. Бәлки, шунда кылкалы еллар арасыннан бер яшь малай, бер яшь егетне җитәкләп шушы көнгә чыгара алырсыз.* Ә.Баян

**КЫЛКОЙРЫК** *и.* 1) Үрдәк кошлар семьялыгыннан, башка үрдәкләрдән аермалы буларак, ата үрдәкнең койрыгында ике тар һәм озын каурые булган кыргый елга үрдәге, безкойрык; *русчасы:* **шилохвост**

2) *күч. диал.* Алдакчы, үз сүзендә тормаучан кеше

**КЫЛКОЙРЫК БАЛЫК** *и. зоол.* Алабугасыманнар отрядыннан, гәүдәсе нечкә генә җеп шикелле үсенте белән беткән, авырлыгы 1 кг чамасы булган көмешсыман тәңкәле балык; *русчасы:* **сабля-рыба, волосохвост**

**КЫЛКУБЫЗ** *и.* Төрки халыкларның кыллы музыка коралы

**КЫЛКЫЛДА́У** *ф. сөйл.* Атлыгу, ашкыну, түземсезләнү

◊ **Кылкылдап тору** Нәрсәне дә булса ашарга, эчәргә яки берәр эшкә атлыгып, ашкынып тору

**КЫЛКЫН** *и. диал.* Бугазның башланган урыны. *Комагай кылкыныннан яза, кыдырма аягыннан яза.* Әйтем

**КЫЛКЫНУ** *ф. диал.* 1) Кайнашу, буталу; сырпалану. *[Марзия:] Һи! Синнән яшьрәкләр әле аның тирәсендә кылкынып йөрерләр, Халикъ абзый.* Ш.Камал

2) Төелү, үңәчтән үткәрә алмый тору, ялгыш юлга китү. *Капкан ризыгын йотып та җибәрә алмый, кире дә чыгара алмый – тик тора үрдәк кебек кылкынып.* Ф.Шәфигуллин

3) *күч.* Нык түземсезләнү, зур түземсезлек күрсәтү. *Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә, кылкынып ук көтеп торган халык алдына килеп, көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады.* Ш.Камал

**Кылкынып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә кылкыну

**Кылкынып йөрү** Һәрвакыт, гел кылкыну

**Кылкынып кую** Бер тапкыр кылкыну. *Әти тамагына нидер тыгылгандай кылкынып куйды.* Г.Бәширов

**Кылкынып тору** Нииндидер вакыт дәвамында кылкыну

**КЫЛЛА́У** *ф. сөйл.* **1.** Йонны, мамыкны кылдан арындыру, аралау. *Дебет кыллау*

**2. кыллап** *рәв. мәгъ.* Кыл кушып, кыл катнаштырып. *Камчыларын кырлап үргән, Тармакларын кыллап үргән.* Ш.Маннур

**Кыллый бару** Берсен дә калдырмыйча, барысын да кыллау

**Кыллый башлау** Кылларга тотыну

**Кыллый бирү** Бернигә карамастан кыллау эшен башкару

**Кыллап алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә кыллау, кыллау эше белән шөгыльләнү

**Кыллап бетерү** Беткәнче, ахырга кадәр кыллау

**Кыллап карау** Кылларга тырышу

**Кыллап кую** Кылланган хәлгә китерү

**Кыллап тору** Дәвамлы яки даими кыллау

**Кыллап чыгу** *к.* **кыллап бетерү**

**КЫЛЛЫ** *с.* 1) Кыл катнашкан, кылы булган. *Түгәрәк-түгәрәк сиртмәләр белән сиртмәләнгән, бөҗралар белән бөҗраланган, бөдрәләр белән бөдрәләнгән нәзек кыллы мамыклардан йомшак нурлар ургылып чыга ---.* А.Хәлим. *Мамыгы кыллы шәл*

2) Кыллары (*4 мәгъ.*) булган, кыллар ярдәмендә музыкаль тавыш чыгара торган. *Көйчеләр дә чакырулы икән, тын гына кыллы коралда уйный башладылар ---.* М.Хәбибуллин. *Радио сөйли – Казан станциясе кыллы инструментта «Нәфисә» көен тапшыра.* М.Мәһдиев

3) Шундый музыка коралларыннан торган. *Кабакларда кыллы оркестрлар мазуркалар белән яңгырый.* Һ.Такташ. *Кыллы квартет*

4) *физ.* Нечкә металл чыбыгы булган. *Кыллы гальванометр*

**КЫЛМА́-КЫЛ** *рәв.* Төп-төгәл, нәкъ тиешенчә, дөп-дөрес. *Кылма-кыл үлчәп бирү*

**КЫЛМЫШ** *и. сир. к.* **кыланыш** (*1 мәгъ.*). *Мөдирә кырыс тавыш белән мине үз янына дәшеп китерде: – Фәридә, ни кылмышың бу, аңлатып бир әле? – Мин үземнең кылмышымда бернинди начарлык күрмәдем ---.* Р.-Н.Гүнтәкин

**КЫЛПА** *с. иск.* Кысык, тар (күз тур.)

◊ **Кылпа күз** Кырын карау; үз итмәү. *[Карчык] көтмәгәндер карттан андый кылпа күз, Көтмәгәндер мондый ямьсез, дорфа сүз.* Н.Исәнбәт

**КЫЛПАЙТУ** *ф. иск. к.* **кылпакландыру**

**КЫЛПАКЛАНДЫРУ** *ф. иск.* Кысу, кысып карау. *Күзне кылпакландыру*

**Кылпакландырып бетерү** Ахырга кадәр, тулысынча кылпакландыру

**КЫЛСЫЗ** *с.* Кылы, кыллары булмаган. *Кылсыз йомшак мамык шәл*

**КЫЛТ** *рәв.* Капыл, кинәт. *Хәлим колхоз председателен уятырга йөгерде һәм кылт туктап калды.* Г.Гобәй. *Берәр кеше яңа кием кисә, күңеленең бер кылы, «Солтанга охшар идеме» дип, кылт кына чиертеп ала.* Р.Хафизова

◊ **Кылт итеп искә (хәтергә) төшү** Нәрсә дә булса кинәт искә төшү; уйламаганда искә килеп төшү. *Хәлимнең исенә кылт итеп шул сүзләр төште.* Г.Гобәй. *Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре.* Г.Тукай. *Якынрак килгәч, кылт итеп көндез бер әбинең елгага салам көле түккәнен күрүем хәтергә төште.* Г.Камал. *Өйдәгеләрне урнаштыргач, кылт итеп Сара искә төште.* Н.Гыйматдинова

**КЫЛТАЙ** *с. диал.* **1.** Мактанчык, шапырынырга яратучы; тәкәббер. *Соңгылары күбесенчә кылтай ир-егетләр, мыек та чыкмаган әче телле яшүсмерләр.* Э.Касыймов

**2.** *и. мәгъ. диал.* Зыян. *Газизов исә бу хәлне класс җитәкчесенә җиткерде, аның үз абруена кылтай китерергә исәбе юк иде ---.* З.Вәли

**КЫЛТА́Й-МЫЛТАЙ** *с. диал.* Кыек-мыек. *Миләүшәне Харис Ганиев әләктереп алды һәм ниндидер ике көпчәкле кылтай-мылтай арбага утыртты ---.* З.Вәли

**КЫЛТАЙТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **кылтаю**. *Хәлгә кереп, мине кылтайтасыгыз киләме?* Ә.Моталлапов

2) *диал.* Аз гына ачып кую

**Кылтайтып кую** Аз гына кылтайту, бераз гына ачу. *Ишекне бераз кылтайтып кую*

**КЫЛТАЙЧЫК** *с. диал. к.* **кылтай**. *Кызлар кылтайчык булалар, гәрчә минем туташым андый булмаса да.* М.Хәбибуллин

**КЫЛТАКЛАНУ** *ф. диал. к.* **кылтаю**

**Кылтакланып китү** Кисәк, уйламаганда кылтаклана башлау

**КЫЛТАМАК** *и. сөйл.* 1) Аш үтмәү; ашый алмау чире. *– Аппетиты да югалып тора бит әле аның, Хәбиб абзый, – диде Илфат. – Чыннан да, аның тамагы нечкәреп калган иде. – Кылтамак чире генә йокмасын.* Б.Камалов. *Ул сүзне кылтамак авыруыннан үлгән карчыгы Мәргыя әбигә күчерде.* Г.Ибраһимов. *Ә кешеләр шым гына үзара кайгырышалар да тыналар: – Кылтамак авыруына сабышкан бит, бичара. Тамагына бер кабым аш та үтми икән...* З.Биишева

2) Аш үтмәү чире белән авырган кеше

**КЫЛТАЮ** *ф.* 1) *сөйл.* Үпкәләү, хәтер калу. *Велосипедым юк минем, кешедән алып торган велосипед кына иде ул, дияр иде – болай да кылтаерга гына торган иркә кызның кәефе кырылып, бөтенләй читләшеп китүе мөмкин.* В.Нуруллин. *Ризыкны яратмаган булып кылтаерга һич тә ярамый ич, балам.* Р.Мулланурова

2) *сөйл.* Эреләнү, тәкәбберләнү, борын күтәрү. *Азатлар янында Әмир Хаҗиның каравыш кызлары урала. Кылтая, ирәешә, күз кысыша, көлешәләр.* М.Хәбибуллин. *Миндә Нәдидәгә карата бер фикер туды: бу тәкәббер күркә укудан бигрәк сыйныфташлары, хәтта укытучылар алдында кылтаеп йөрү өчен генә киләдер кебек тоела.* Р.-Н.Гүнтәкин

3) *диал.* Үсенү, үсенеп китү (балалар тур.)

4) *диал. к.* **кыйшаю** (*1 мәгъ.*). *Йорт --- ермак ягына таба кылтайган.* З.Вәли

5) Кылану, чытлыклану. *Нәсимәнең тавышы артистларча кылтаебрак, назлы-иркә аһәңнәр беләнрәк ишетелде.* М.Вәли. *И кылтайдылар да инде алабайлар. Бер-берсен төзәттеләр, бүлдерделәр, астан гына әйтеп тордылар.* Ф.Латыйфи

**Кылтаеп алу** Аз гына, кыска вакыт кына кылтаю

**Кылтаеп җибәрү** Кисәк, уйламаганда кылтая башлау

**Кылтаеп йөрү** Һәрвакыт, гел кылтаю, кылтайган хәлдә булу

**Кылтаеп китү** *к.* **кылтаеп җибәрү**. *– Мин дә тик син шул мәктәптә укыганга гына укып йөрим бит инде, Рухия! – диде Равил дә, ниһаять, йөрәксенеп. Һәм ул, бу кызый тагын кылтаеп китмәсә ярый инде дип, шикләнеп тә куйды.* В.Нуруллин. *Теге көннән соң тагын да кылтаебрак киттем бит, әй!* Г.Мөхәммәтшин. *Чынлыкта Глафираның җиргә бөтенләй төшәсе килми, карышып маташуы да юрамалый гына. Егет артык кылтаеп, масаеп китмәсен, янәсе.* Т.Әйди

**Кылтаеп кую** Кинәттән, уйламаганда кылтаю

**Кылтаеп тору** Ниндидер вакыт дәвамында кылтаю, кылтайган хәлдә булу

**Кылтая төшү** Аз гына кылтаю. *Кызларның кайсыдыр хәмер койды, ханга сузар алдыннан үзе эчте һәм, серем белерсең дигән ишарә белән, бераз кылтая --- төшеп, чокырны ханга сонды.* М.Хәбибуллин

**КЫЛТЕШ** *и. зоол.* Икетешлеләр семьялыгыннан гәүдәсе энәләр белән капланган, тропик диңгезләрдә яши торган балык; керпе балык; *русчасы:* **двузубка**. *Сыртмөгез һәм кылтеш балыкларының эчке органнары һәм мускуллары агулы була.* Кызыклы ихтиология. *Кылтеш балыклары семьялыгына керә торган балыкларның иң киңе – косколая, ул Цейлонда яши.* Кызыклы ихтиология

**КЫЛТЫ́Й-МЫЛТЫЙ** *рәв. сөйл.* 1) Кыек-мыек, кәкре-бөкре. *Алай дисәң, нигә ул Зөлфә яшәгән тулай торак турысыннан, юлның кылтый-мылтый булуына карамастан, көн саен диярлек фырылдатып үтеп китә?* Э.Касыймов

2) Кыек-мыек басып, алпан-тилпән

**КЫЛТЫ́Й-ПЫЛТЫЙ** *рәв. сөйл. к.* **кылдый-былдый**. *Биктаһир, малайның кулыннан капчыкны алып, борын астыннан нидер сөйләнә-сөйләнә, келәткә таба кылтый-пылтый китеп барды.* И.Гази

**КЫЛТЫК** *с. диал.* **1.** *к.* **кылтым**. *Сирин кызның ирен читенә кунаклаган елмаюын күрмәмешкә салынды. Ниндидер бер кылтык чәтнәби почтабикәнең кыланмышына карап торыр чак түгел.* Ф.Латыйфи. *[Фатин:] Бигрәк кылтык кыз икәнсең, минем кай җирем ошамый сиңа?* С.Яһүдин. *Хатын, авыр сулап, --- кухняга кереп китте. Сәбәбен дә яхшы беләм белүен: Җәләе – кылтык, Җәмиләсе – җилбәзәк...* Шатлыклы кайгы

**2.** *и. мәгъ.* Тәкәббер, эре кеше. *[Гайниҗамал:] И кылтыклар, кыланган булдылар тагы!..* И.Гази. *И кылтык!.. Әллә берәр рәтле сүз әйтәме дип торам.* Г.Мөхәммәтшин

**КЫЛТЫКЛАНУ** *ф. диал.* Чытлыклану, кылану. *Әбүзәрнең Таймас белән дусларча (һәм чак кына кылтыкланып) кул кысышканын көлемсерәп күзәттеләр.* А.Тимергалин

**КЫЛТЫМ** *с. сөйл.* Үз-үзен зур саныган, тәкәббер, эре. *Бу егетнең офтанганына каршы бу кылтым бай, нишләр икән дип, кызык өчен моңар бер йөз тәңкә акча биреп тора: – Баегач кайтарырсың, – ди. Әкият. – Менә әфәндем! Тырыштым инде! --- Сез килә дип тырыштым!.. – Шулай дип, ул үзе әзерләгән өстәлгә күрсәтте, бер Билалга, бер табынга карап, чын хуҗаларча – шаян һәм бераз кылтымрак хуҗаларча --- тантана итте.* М.Вәли. *Менә, мөгаллим, улымны синең карамакка ышанып тапшырам. Үзсүзле, кылтым холыклы, хәр табигатьле, әмма нечкә күңелле эчкерсез бала.* М.Кәрим

**КЫЛТЫМЛАНУ** *ф. сөйл.* Тәкәбберләнү, эреләнү. *Алар сүзгә керешкәч тә кылануга бирелмәделәр, кылтымлану (моңарчы үзара мөнәсәбәттә аларга монысы да хас иде) сизелмәде.* М.Хуҗин

**КЫЛТЫН** *с. сөйл. к.* **кылтым**. *Сельпо халкы, медпункттагы яшь, кылтын ике кыз, китапханә, клуб кешеләре бер почмакка җыелганнар.* М.Мәһдиев. *Кылтын яшьләр*

**КЫЛТЫРАТУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне селкетеп яки нинди дә булса башка юллар белән кылтыр-кылтыр китерү

2) *з.-сыз* Куркудан, салкыннан һ.б.ш. эчтән калтырау

**Кылтыратып алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында кылтырату

**Кылтыратып җибәрү** Кинәт, кисәк яки уйламаганда кылтырату

**Кылтыратып кую** Бер яки берничә тапкыр кылтырату

**Кылтыратып тору** Туктаусыз, берөзлексез кылтырату

**КЫЛТЫРА́У** *ф.* Кылтыр-кылтыр килү, кылтыр-кылтыр иткән тавыш чыгару. *Бер үлчәүдә: кырау, сорау, мияу, мырау, һәм кылтырау, һәм шылтырау, һәм кыңгырау*. Г.Тукай

**Кылтырый бирү** Бернигә дә карамый кылтырау

**Кылтырый башлау** Кылтырарга тотыну

**Кылтырап алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында кылтырау

**Кылтырап китү** Кисәк, кинәттән кылтырау

**Кылтырап кую** Бер яки берничә тапкыр кылтырау // Кисәк, өзек-өзек кылтырау

**Кылтырап тору** Туктаусыз, берөзлексез, һәрвакыт кылтырау

**КЫЛТЫ́Р-КЫЛТЫР** *иярт.* Эче куыш яки артык авыр булмаган әйберләргә бәргәндә яки алар бер-берсенә җиңелчә бәрелеп торган вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә

**КЫЛТЫ́Р-КЫЛТЫР ИТҮ** *ф. к.* **кылтыр-кылтыр килү**. *Ул, ниһаять, аңлап алгач, кесәсеннән ак төенчек чыгарды да кылтыр-кылтыр итеп чишә башлады.* И.Гази

**КЫЛТЫ́Р-КЫЛТЫР КИЛҮ** *ф.* Кылтырау. *Тәрәзә пыялалары кылтыр-кылтыр килеп тора.* Г.Ахунов

**КЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *кит.* Берәр эш эшләү, берәр эш башкару. *Ана, хәлдән таеп, ни кылырга белми, әле анда, әле монда ташланганда, берәм-берәм башкалар да уяндылар.* Г.Ибраһимов. *– Кылган һөнәрең ни? – дип сорый хан. – Табиблык кылудыр, – ди гарәп.* М.Хәбибуллин. *Ни кылганымны үзем дә төшенмәстән, урындык алып утырдым да яраткан гимннарымның берсен --- уйный башладым.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Әмма ана ни генә кылсын, күршеләр белән сүзгә килеп, ямьсезләнеп булмый бит инде.* Дин вә йола

2) Нәрсәне дә булса оештыру, үткәрү; ясау. *Туйны зурдан кылдылар.* Г.Ибраһимов

**2.** *ярд. ф. функ. кит. к.* **итү**. *Кубрат хан Чулман елгасының иң биек ярына чатыр корып кунарга карар кыла.* М.Хәбибуллин. --- *татарлар: «Безнең җирләребез аз вә начар, шуның өчен тамак туйдыру һәм салымнар түләү өчен сәүдә кылабыз», – дигәннәр.* Г.Гобәйдуллин. *Сәҗдә кылырга син әмер иттең, Мин карыштым: сәҗдә кылмадым.* М.Гафури. *Хуҗа --- сәке йөзлегенә килеп утырып: «Ләхәүлә...» – дип, йоласын китереп, озаклап дога кылды.* М.Хәсәнов

**КЫ́Л ҮЛӘН** *и. бот.* Карабодайчалар семьялыгыннан күпьеллык икеөйле үләнчел үсемлек; кузгалакның бер төре; төче кузгалак, чыпчык кузгалагы; *русчасы:* **щавелёк**

**КЫЛЧЫК** *и.* **1.** 1) Кыяклы игеннәрнең башагындагы озынча нечкә каты мыекча, үсенте. *Йөрәк – иләк сыман, арышка охшаган вак-төякләрнең бөтенесен или, әмма кылчыгын үзендә калдыра.* Н.Гыйматдинова. *Апаең: «Шундый куе, килешле кара кашны болай тузгытып йөрү шәп түгел», – ди һәм арпа кылчыкларыдай төрлесе төрле якка тырпаешканнарын кисеп ташлый.* Б.Камалов. *Бездән дә юньсезрәк берсе барыбызны да уздырып тешләрен ыржайта да, малайның күлмәк якасын ачып, тирле аркасына бер уч арпа кылчыгы сала ---.* М.Мәһдиев

2) Балыкның кабырга сөякләре, гомумән вак сөякләре. *Гурий истәлеккә ике «сувенир» бирде: берсе балык кылчыгыннан ясалган шоп-шома нык инә иде, икенчесе --- төймә иде.* А.Гыйләҗев. *Аның --- почык борыны тирләп чыкты, тамагына кылчык утырган шикелле булды ---.* Ә.Гаффар. *Күземнән яшь ага, авызымны тамагына кылчык кадалган кош баласыдай ачып --- туктаусыз калтырана идем.* Р.-Н.Гүнтәкин

**2.** *с. мәгъ.* 1) *күч.* Бәйләнчек, төртмә телле. *Карыйм, искә төшерергә тырышам: кайда күрдем соң бу кылчык бәндәне? Исемә төште... Комсомол билетымны мич арасыннан табып алган бәндә ич бу!* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Каты, тырпаеп торган (чәч, төк тур.). *Бетон багана сыман почмаклы, сары кылчык кашлы --- бу кешенең --- кыска тунының ачык изүе аша күкрәгеннән челек сыман эре кыллар тырпаеп чыккан.* А.Хәлим

◊ **Кылчык булып кадалу** Гел борчу, бимазалау. *Әгәр исән-сау авылга кайтсаммы... Ә мин барыбер кайтачакмын! Күзләренә кылчык булып кадалып яшәячәкмен!* А.Гыйләҗев. *«Кемнеңдер тамагына кылчык булып кадалган инде бу Дардиев», – дип фикер йөртте Фаикъ ---.* З.Фәтхетдинов. *[Р.Нуриевның] җитмәсә, күпләр күзенә кылчык булып кадалган эреле-ваклы гөнаһлары да әкәмәт күп.* Р.Вәли. **Кылчык кадалган кебек (күк)** Каты әрнү, сызлау (күңел тур.). *Шул бер-ике сүзе дә кайчак җитә кала: йөрәгеңне кылчык кадалган күк сызландыра.* Н.Хәсәнов

**КЫЛЧЫКЛАНУ** *ф.* 1) Башакта кылчыклар, озынча мыекчалар барлыкка килү

2) *күч.* Киреләнү. *Асылбикә түти генә кылчыкланып маташты: – Һе, кара әле, нәкъ әтәч итеп килештереп ясауларын, – дип, әтәчне --- малайның үзенә кире бирде.* Ф.Хөсни

**Кылчыклана бару** Торган саен күбрәк, ныграк кылчыклану

**Кылчыклана башлау** Кылчыкланырга тотыну

**Кылчыкланып бетү** Бөтенләй, тулысынча кылчыклану

**Кылчыкланып җитү** Тиешле дәрәҗәгә килеп кылчыклану

**КЫЛЧЫКЛЫ** *с.* 1) Башагы кылчыклана торган, башагында кылчыклар үсә торган. *Караңгы төшкәч, ригада кылчыклы салам өстенә яткач авыр Хәдичәгә ---.* М.Маликова. *Кылганның бөртекчәсе йонлач һәм җиңел каурыйсыман кылчыклы озын кабырчык белән капланган.* Ботаника

2) Балык турында: кабырга сөякләре күп булган, кылчыклары күп булган.

*Кылчыклы балыкларның ике борын тишеге ис сизү органы булып санала.* Кызыклы ихтиология. *Диңгез суларында һәм төче суларда балыклар арасында сөяк скелетлы сөякчел (кылчыклы) балыклар өстен урын тотканнар.* Дарвинизм нигезләре

**КЫЛЧЫКСЫЗ** *с.* 1) Башагы кылчыкланмый торган, башагында кылчык үсми торган. *Кылчыксыз бодай. Кылчыксыз кындырак*

2) Кабырга сөякләре булмаган яки бик аз булган; вак сөякләре аз булган (балык тур.). *Хәбәрче: – Балык кылчыксыз булмый, энем, тәртелер җирләрегез дә бар, – диде.* З.Вәли

**КЫЛЫЙ** *с.* **1.** 1) Күз каралары бер юнәлештә булмаган, төрле юнәлештә булган, төрле юнәлешкә караган. *Баядан бирле бер читтә торган, көчек буйлы, кылый күз Гыймади карт --- уртага керде дә сүзгә тыгылды.* Г.Ибраһимов. *Аның тегә Хафият абзыйлар урамындагы Сергей Степаныч пекарниенда атасы кылый күз Егорка белән эшләгәннәрен үзем беләм ич.* Ш.Камал. *Ачыграк урыннарга кылый куяннар өчен тозлы сәйлүн чәе түкте.* И.Нуруллин

2) *сөйл.* Шундый күзле. *Садриҗәләл абзыйның үзен --- строевойга алмадылар алуын, әмма ниндидер сукыр закун нигезендә, әллә берәр кылый писарь ялгышы белән тагын, хезмәт армиясенә алын[ды].* А.Хәлим. *Бу килеп керүче – Хафизулла байның батрагы кылый Әхмәтҗан иде.* М.Гафури. *Кайчангача, кылый куян булып Посынырсың, Гата, син болай?* Ш.Маннур

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Куян. *Ә кылый нишли? Ул явыз ерткычларның килеп җитүләрен көтеп тормый, тизрәк табан ялтырату ягын карый.* Г.Хәсәнов. *Үткән ел «кылый»ларны фара утлары яктысында аулау очрагы буенча 3 җинаять эше кузгалтылды.* Авыл утлары

**КЫЛЫЙК** *и. диал.* Бармак юанлыгындагы кыска гына агач кисәгенең бер ягын очлап, икенче ягына үзенә бер төрле ике каурый утыртып һавага ата торган балалар уенчыгы

**КЫЛЫЙЛАНУ** *ф.* Кылыйга әйләнү, кылый калу

**Кылыйлана бару** Торган саен ныграк, катырак кылыйлану

**Кылыйлана башлау** Кылыйланырга тотыну

**Кылыйлана төшү** Бераз, беркадәр кылыйлану

**Кылыйланып бетү** Тәмам, бөтенләй кылыйлану

**Кылыйланып калу** Ниндидер вакыйгадан соң кылыйлану, кылыйланган хәлгә килү. *Авыл кешесенең аңгыралыгы һәм медицинаның арттальгы нәтиҗәсендә, шушы авыруыннан соң, авылыбызның искитмәле гүзәл кызы, җырчы Гәүһәр күзләре кылыйланып, буйга үсмәс булып калды ---.* Мәдәни җомга

**Кылыйланып китү** Кинәт, кисәк яки берникадәр кылыйлану. *Шунда Фазылҗан абзый Касыймның болай чибәр генә кара күзләре чыннан да борын төбенәрәк бик яман кылыйланып киткәнен күреп алды.* Р.Төхфәтуллин

**КЫЛЫЙЛЫК** *и.* Күз каралары төрле юнәлешкә караган булудан гыйбарәт күз авыруы. --- *хатынының --- уң күзе бераз кылый икән; әмма бу кылыйлык уймак кебек җыйнак гәүдәле Зәлифәнең йөзенә гарип җитешсезлек түгел, киресенчә --- ниндидер кызгандыручан камиллек --- өсти.* А.Хәлим

**КЫЛЫЙ-МЫЛЫЙ** *с. сөйл. к.* **кылый**. *– Ник белмисең, белергә кирәк иде, минем ише кылый-мылыйдыр инде... Я, атлагыз! – дип бакырды чуваш үгезләргә.* К.Латыйп

**КЫЛЫК** I *и. иск., диал.* Эшләгән, башкарган эш; эшли, башкара торган эш. --- *ташларда исемнәре язылган кешеләр бу дөньядан китүләре белән түгел, шушы җиргә килүләре, җирдә яшәүләре, эшләгән эшләре, кылган кылыклары белән кызыклылар.* М.Кәрим. *Кымыз кылыкны арттырыр.* Мәкаль

◊ **Кылыкны кылу** Холыксызлык күрсәтеп, кеше арасында сынатып бозылышып бетү. *Ныграк кирәк иде әле бәдбәхеткә, кылыкны кылды.* К.Мотыгый

**КЫЛЫК** II *гар. диал.* Холык. *Ул һавалы фәкыйрьләрнең сәер кылыкларын мин соңрак, олыгая төшкәчрәк кенә төшендем.* М.Кәрим

**КЫЛЫКЛЫ** *с. диал.* Яхшы, күркәм холыклы. *Һөнәрле булып ул үссен, кылыклы булып кыз үссен.* Мәкаль

**КЫЛЫМ** *и. иск. лингв.* Фигыль

**КЫЛЫНДЫРУ** *ф. диал. к.* **кыландыру** (*1 мәгъ.*). *Чырайларын әллә нишләтеп, еларга хәзерләнгән шикелле кылындыра.* Ш.Камал

**КЫЛЫНМЫШ** *и. иск.* Эшләгән эш. *Агач беленә җимешеннән, адәм – кылынмышыннан.* Мәкаль

**КЫЛЫНЫШ** *и. диал. к.* **кыланыш**. *Татарча театрларга каршы кешеләр үз кылынышларын шул ук татар театрына барып күрсеннәр!* Ф.Әмирхан

**КЫЛЫЧ** I *и.* **1.** 1) Чабып яки чәнчеп үтерү яисә яралау өчен хезмәт итә торган озын салкын коралның исеме. *Иелгән башны кылыч кисмәс.* Мәкаль. *Тыштан чабып кергән баланың билендә кылыч, кулында ук-җәя күреп, Ихсан йөзен чытты.* М.Хәбибуллин. *Ул мәчет янындагы тупларны, иярле атларны, кылыч таккан кавалеристларны күреп кайткан иде.* И.Гази. Кылыч өч төрле була: а) бер йөзе генә үткен кәкре корыч пластинкадан гыйбарәт корал; *русчасы*: **сабля, шашка**. *Татарлар сул якка салындырып кәкре кылыч асканнар, яннарына җәя һәм ук тага торган савыт такканнар.* Г.Гобәйдуллин. --- *беренче ишеккә җитүгә үк, кынсыз, кәкре кылыч таккан пәһлевандай сакчылар Сәет белән Габдрахманның коралларын алып калды.* В.Имамов. *Ул буш кулы белән кәкре кылычын кынынан алды да, уңга-сулга болгый-болгый, --- төтен күтәрелгән җиргә ташланды.* Г.Гобәй; ә) ике йөзе дә үткен, озын туры корыч пластинкадан гыйбарәт борынгы корал; *русчасы*: **меч**. *Почмакларга Урта гасыр рыцарьларының корыч киемнәрен бастырып куйганнар. Аларның билләрендә – озын туры кылыч, кулларында – сөңгеле айбалта.* М.Юныс. *Дошманның туры кылычын – татарның кәкре кылычы, сөңгене калкан каршылый, сөрәнгә сөрән авазы җавап бирә.* С.Шәмси. *[Бронзадан ясалган сында] Карл императорлык билгеләре белән сурәтләнгән: башында таҗ һәм сул кулында держава, уң кулына озын кылыч тоткан.* Урта

гасырлар тарихы; б) ике ягы да үткен булган аз гына кәкре кыска корыч пластинкадан гыйбарәт корал; *русчасы*: **палаш**. *Атлар урыннарында басып тора алмыйлар, таптаналар, пошкыралар, --- яугирләр, гасабиланып, кәкре кылычларын калканнарына каккалап куялар.* Р.Зәйдулла. *Такатока бәхетсез Дзироның арзанлы коралын – кыска кылычны – җирдән күтәреп ала.* Кызыклар дөньясында

2) *күч. иск.* Сугышчы кавалерист, кылычлы сугышчы. *Өч йөз кылычтан торган отряд*

3) *күч.* Кылычны хәтерләтә торган озынча әгъза. *Укбалык --- ау вакытында үзләренең табигый коралларыннан – кылычтан файдаланалар. Кылычлары белән алар балыкларны яралыйлар яки үтерәләр.* Кызыклы ихтиология

4) *күч.* Ялтырап киткән нур, яктылык тасмасы. *Кинәт бар дөнья яктырды. Көтүче чыбыркы чыжлаткандай, уңлы-суллы яшен кылычы уйнады, күп тә үтмәде, күк күкрәгән тавыш бәләкәй өйне тетрәтте.* Р.Мулланурова. *Күк йөзен әле кара болыт каплый, әле яшен кылычлары телгәли.* Г.Галиева

5) *күч.* Нәрсәне дә булса юкка чыгара торган көч, куәт символы. *Бөтен дөнья контрреволюциясе, башы өзелгән аждаһа кебек, пролетариат кылычы астында өзеләчәк!* Г.Ибраһимов. *--- бу хәтәр шөгыль --- бик куркып кына кылына. Курыкмассың, бар! Баш очында гына үткен кылыч – Җинаять кодексының 120 һәм 121 нче маддәләре эленеп торсын да!* Р.Вәли

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кәкрәеп торган. *Бераздан соң: – Таптык, таптык! --- дип, кәкре койрыклы, балаклы, кылыч кикрикле, --- әтәчне чырылдатып күтәреп чыктылар.* М.Гали. *Каландаров бу мактауга кылыч мыегын боргалый-боргалый кәперәеп утырды.* А.Каһһар

2) Тар, юка сыртлы, туп-туры (борын). *--- өстәл янында погонсыз хәрби кием кигән, ак чырайлы, ач яңаклы, кылыч борынын пенснэ белән чеметтергән бер кеше --- утыра иде.* И.Гази. *Инсафның --- ике шәһәр малае юлына аркылы чыкты. Берсе ак футболкадан, киңчәрәк җилкәле. Икенчесе кылыч борынлы, чырае ак.* Н.Хәсәнов. *Рухияне авызына караткан әлеге Эшләпә күрер күзгә дә бөтенләй үк бетереп ташарлык нәрсә түгел. Килешле генә кылыч борын, тигез ак тешләр, чиста түгәрәк йөз.* В.Нуруллин

◊ **Кылыч белән килү** *к.* **кылыч күтәрү**. *Киләчәктә дә шулай булачак: безнең илгә кылыч белән килгән кешеләр кылычтан үләчәк.* А.Муранов. **Кылыч болгау** *к.* **кылыч уйнату**. *Мөхәммәдәминнең үз язмышында да кылычын болгап алды Арча.* М.Әмирханов. **Кылыч йөзеннән (йөзенә басып) йөрү** Хәтәр, начар эш белән шөгыльләнү. *Былтыргы җәйдәге кебек кылыч йөзеннән йөрергә туры килмәсә ярый ла.* Ф.Яруллин. *– Иптәш Шиһабетдинов үзенә хәвеф янавын сизенә идеме? – Бу хакта уйламаска тырыша, кылыч йөзенә басып йөрергә күнеккән иде ул.* Т.Әйди. **Кылычка алу** Кылыч белән кисү, чабу, үтерү. *Жансакчыларда өмет юк, кыюлар, кансызлар: хан боерса, теләсә кемне кылычка алырга торалар.* М.Хәбибуллин. **Кылычка кылыч килү** Якыннан торып сугышу, кара-каршы килеп сугышу. *Әнә Мөбәрәк абый да сугышта булган. Ул да дошман белән кылычка кылыч килеп йөргәндер инде.* Г.Нәбиуллин. **Кылыч кисмәс, ук тимәс** 1) Сугышта бәхете булган; 2) Яклаулы, җиләңгыр тими, авырлык күрми торган. *--- Каландаров район кешеләренең генә түгел, үзәктәге җитәкчеләрнең дә канаты астына кереп ышыкланды да, картлар әйтмешли, кылыч кисмәс, ук тимәс булды.* А.Каһһар. **Кылыч күтәрү** Сугыш ачу, сугыш башлау. *Ундүрт илнең буржуйлары күтәрде безгә кылыч.* Г.Хуҗиев. **Кылычны кынысыннан чыгару** *к.* **кылыч күтәрү**. *Арча ягы һәрвакыт ханлыкның терәге булды. Киләчәктә дә шулай булып калыр, иншаллаһ. Вәләкин кем дә кем кылычын кынысыннан чыгара икән, үзенә үпкәләсен.* М.Әмирханов. **Кылычтан кичерү** Кылыч белән чабып үтерү, үтереп бетерү, кыру. *Калалар бер-бер артлы халык кулына күчә, андагы бөтен алпавыт һәм түрәләр кылычтан кичерелләр ---.* Г.Гобәйдуллин. **Кылычтан уздыру** *к.* **кылычтан кичерү**. *Ул аларны [качкыннарны] Төрек елгасына җитәрәк куып җитте һәм һәммәсен дә кылычтан уздырырга боерды.* М.Хәбибуллин. **Кылычтан үткәрү** *к.* **кылычтан кичерү**. *– Качкын сатлыкларны да кире бирсеннәр, – диде Дингиз. – Аларның барысын да кылычтан үткәрәчәкбез. – Атилланың кашлары җыерылды.* Р.Зәйдулла. **Кылыч уйнату** 1) *к.* **кылыч күтәрү**. *Я Ходай, элек базар-калалар өчен сәүдәгәрләр генә ызгышыр иде, хәзер әнә ханнар кылыч уйната башлады.* М.Хәбибуллин; 2) Яшьнәү (яшен тур.). *Ул арада туктап торган яшен яңадан шәһәр өстендә ялт-йолт килеп кылыч уйната башлады.* Г.Әпсәләмов; 3) Кешеләр өстендә гайрәт күрсәтү. **Кылыч уйнау** Куркыныч янау, хәтәр хәлләр булу. *Без «Кыскача курс»тан имтихан биргәндә, училище өстендә «халыклар атасы»ның кылычы нык уйнап алды.* М.Мәһдиев

**КЫЛЫЧ** II *и.* 1) Туку станогында: һәр аркылы җепне (аркауны) сугыла торган тукымага китереп беркетеп куярга ярдәм итә торган, зур тарак сыман әсбап. *Шул ачуны миңа хәзер Аллаярдан алырга иде дә, әни өйдә, ыстан алдында кылычны шап-шоп китереп, киндер сугып утыра.* Ф.Мансуров. *--- кылыч сүзе тора-бара тукучылык коралын – туку калагын һәм шул калак функциясен үтәгән тешле-ярыклы җайланманы да белдерә башлаган.* Р.Әхмәтьянов. *Сул кулда кылыч шуа, уң кулда соса йөри.* Ә.Гаффар. *Чачаклы киң сөлге тукыр идем, Үткәзә алсам киң иңле, әй, кылычка.* Җыр

2) *диал.* Җитенне, киндерне талкыганнан соң сүсне йомшарту һәм чистарту өчен кулланыла торган юка агач калак

**КЫЛЫ́Ч БАЛЫК** *и. зоол.* 1) Алабугасыманнар отрядыннан диңгездә яши, озынлыгы ике метрга җитә торган, югары казналыгы кылычсыман очлаеп үскән, гәүдәсе тәңкә белән капланмаган зур балык; *русчасы*: **меч-рыба**. *Элеккечә, тыннар җитмәстәй тирәнлекләргә чумып та азапланмаган Дәй бу юлы коточкыч сигезаяклар,*

*дәһшәтле кылыч балыклар --- белән дә сугышып-көрәшеп мәшәкатьләнмәгән.* Р.Төхфәтуллин. *Пенсионеркалар --- сумкаларын тоталар да кибеткә китәләр. Ә анда көн саен яңалык: --- туңдырылган «кылыч» балык яки мойва кайт[кан]!* М.Мәһдиев. *Кылыч балыкның гәүдәсе тасмасыман, ул ерак Көнчыгышта яши.* Кызыклы ихтиология

2) *диал.* Карплар семьялыгыннан төче суларда яши торган юка сыртлы балык, кәлчәк; *русчасы*: **чехонь**

**КЫЛЫЧАЮ** *ф.* Кылыч кебек булып күренү; кылыч формасын алу. *Ә кылычаеп торган озын һәм матур борын егетнең йөзенә горурлык биреп тора.* Ә.Фәйзи

**КЫЛЫЧБАЗЛЫК** *и. иск. к.* **кылыч уены**

**КЫЛЫЧЛЫ** *с.* **1.** Кылыч таккан, кылыч белән коралланган. *Шулай көзнең караңгы авыр төненең берсендә кылычлы, мылтыклы кешеләр килделәр.* Г.Ибраһимов. *Аларның [мәхбүсләрнең] барын да бер җиргә җыеп, вокзалның ары башына илтеп тезделәр. Әлеге кылычлы солдатлар аларны тирәли чолгап алдылар.* С.Җәләл. *--- һәр капка төбендә ялангач кылычлы сакчылар тора.* С.Шәмси

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кылыч белән коралланган, кылыч таккан кеше. *Кылычлылар тагын кереп, ишекнең як-ягына бастылар.* Г.Гобәй. *Володя артлы чанага утырды, ике ягына ике кылычлы сикереп менде.* Г.Әпсәләмов. *Тирәсендә ике йөз мең кылычлы бар.* К.Гали

2) *иск. сөйл.* Полициядә хезмәт итүче түбән чинлы кеше. *Ике данә кылычлы янга килгән.* Г.Тукай. *Өйгә бербер артлы дүрт кылычлы килеп керде.* Ә.Фәйзи

**КЫЛЫ́Ч УЕНЫ** *и. спорт* Салкын корал (рапира, шпага һ.б.) белән эш итү осталыгына нигезләнгән уен

**КЫЛЫ́Ч УТЫ** *и. бот. диал. к.* **кылыч үлән**

**КЫЛЫ́Ч ҮЛӘН** *и. бот.* Ароидчалар семьялыгыннан сазлыкта үсә торган кылычсыман кыяклы күпьеллык үлән үсемлек; сусын; *русчасы*: **аир**. *Сару кайнаудан котылу өчен, бер кисәк кылыч үлән тамырын чәйнәп йотарга кирәк.* Мәдәни җомга. *Чәч коелганда, кавыкланганда, җир тамыры, кылыч үлән --- булыша.* Сәламәт булыйк!

**КЫЛЫЧЧЫ** *и.* Кылыч ясаучы оста

**КЫМҖЫТУ** *ф.* Бутау. *Башкала кырмыска оясы кебек гүли, аны кемдер таяк тыгып кымҗыткан әллә?* Казан утлары

**Кымҗыта бару** Торган саен күбрәк кымҗыту

**Кымҗыта төшү** Бераз кымҗыту

**Кымҗытып алу** Берара, аз гына кымҗыту

**Кымҗытып тору** Бертуктаусыз кымҗыту

**КЫ́М-КЫРЫС** *с. к.* **кым-кырыч**. *Кым-кырыс кына эшем төшеп, Лениногорскидан нефтьчеләр башкаласы Әлмәткә барып кайтыйм дип чыкканыем мин бу хәвефле сәфәргә.* А.Хәсәнов

**КЫ́М-КЫРЫЧ** *с.* **1.** 1) Бик күп, исәпсез-хисапсыз. *[Давытның] Дусише кым-кырыч аның.* А.Гыйләҗев. *Өйдә дә эшем кым-кырыч.* А.Гыйләҗев

2) Тар, аз, кысан (вакыт тур.)

**2.** *рәв. мәгъ.* Мәш килеп, мавыгып, бик тырышып. *Әнә шулай тылда калган карт-коры, хатын-кыз белән янәшә фронт өчен дип кым-кырыч эшли, тормыш йөген тарта торгач, зар-интизар булып көткән Җиңү көннәре дә килеп җитте.* Җ.Дәрзаман

**КЫ́М-КЫРЫЧ КИЛҮ** *ф.* Мәш килү, нинди дә булса эш белән мавыгу. *[Кайниш:] Утар-абзарларны төзәтеп, атлар двуры ясыйбыз. --- Кым-кырыч киләбез.* С.Рәфыйков. *Җиһанда әшмәшә, ыгы-зыгы, кым-кырыч килү бара.* Р.Батулла

**КЫМТУ** *ф.* 1) *сөйл.* Атка атланып барганда, аны тизләтү өчен аяклар белән янтыгына төртү. *Закир --- – атны аяклары белән бер кымтый, чыбыркы белән кабыргага, очага бер бирә дә дулатып чаптырып китә.* Г.Ибраһимов

2) *сөйл.* Төрткәләү, капшау. *Кинәт ул [Канәгать] аяк чәлтерләрен төрле яклап нәрсәнеңдер кымтый, кытыклый башлавын тойды.* А.Хәлим. *[Вак балык] --- әниләренең корсагы астыннан имчәк эзләгән сукыр песи балалары кебек, кечтеки авызлары, борыннары, мыеклары белән аны кымтыпмы кымтыйлар, капшапмы капшыйлар!* А.Хәлим

3) *сөйл.* Нык кысу. *[Мөдәррис] --- ачуы килеп, гадәтенчә, аскы ирене белән өске иренен шундый көчле итеп кымтыды ки, гүя өске ирен шундук ашалды, юкка чыкты, ә менә аскы ирене танавына кереш сыман тартылып кушылды ---.* А.Хәлим

4) *диал.* Бөкләү, кыстыру, җыю, җыеп кую. *Итәкне кымтып утыру*

5) *сөйл.* Суыру, имү. *Ул ирене белән иренен кымтып, җаны ләззәт кичерде һәм Ходай Тәгаләнең мондый тел ачкычлары бирүенә чиксез куанды.* А.Хәлим

**Кымтып алу** Тиз генә бераз кымту. *Искәндәр иреннәрен кымтып алды.* М.Кәбиров

**Кымтып кую** Сизмәстән, бер тапкыр кымту. *Малай аңа мөлдерәтеп карады да иренен кымтып куйды ---.* М.Кәбиров

**Кымтып тору** Бертуктаусыз кымту

**Кымтып яту** Озак вакытлардан бирле кымту, суырып, имеп яту. *Нәгыймнең үзенә дә караклык тәме йөгермәгәнмени? Ничә еллардан бирле алар шыпырт кына тимер юлны, станцияне кымтып яталар ич!* А.Гыйләҗев

**КЫМТЫРЫКЛА́У** *ф.* 1) *сөйл.* Кармау, кармалау; капшау. *[Сәфәргали] --- кесәсендәге сабынын кымтырыклый.* Ф.Хөсни. *Менә син мине базарга йомышка җибәргән арада, кара өйгә кереп, минем хатынны кымтырыклыйсың ---.* М.Мәһдиев

2) *сөйл.* Өзлексез сорап тору, үтенү; сорашып йөдәтү

3) *диал.* Аз-азлап алып тору; сиздермәстән алу

**Кымтырыклый башлау** Кымтырыкларга тотыну. *Тәнне суык кымтырыклый башлады.* Ф.Сафин. *Икенчесе: «Син, агайне, Татарстанныкымы, әллә Себер егетеме?» – дип, Мәхмүтне кымтырыклый башлады.* З.Фәтхетдинов

**Кымтырыклый бирү** Һичнигә карамыйча кымтырыклавын дәвам итү

**Кымтырыклап алу** Бераз кымтырыклау

**Кымтырыклап йөрү** *к.* **кымтырыклап тору**

**Кымтырыклап тору** Бертуктаусыз кымтырыклау. *Хәерниса --- тегене кыл, моны эшлә дип, гел кымтырыклап тора.* Т.Галиуллин

**КЫМШАНУ** *ф.* 1) Урыныннан кузгалу, аз гына хәрәкәткә килү. *...Кем уйный? – Иртә ягыннан Яңгырый сихри моңнар. Күзләрен ачты… тыңлады… Кымшанды хәлсез куллар.* Г.Сәгыйров. *Тыны бетте – [Нурлыбикә] аны сизмәде, чигәләренә нидер кадалгандай булды – кымшанмады: ничек туктап калса, шул халәтендә тора бирде.* Г.Кашапов. *Ләкин кеше дигәнең һичнинди хәрәкәтсез тора алмый: кымшана, селкенгәли.* Ф.Яруллин

2) Эш башлау, нәрсә дә булса эшләргә тотыну; кузгалу. *Гражданнар! Учак әкрен яна... Кымшаныгыз инде шундый чакта!* Зөлфәт. *Аллага ышан, үзең кымшан дигәндәй, Алла бирмәгәнне мулла бирмәсен бик яхшы беләсең син.* М.Хәсәнов // Нәрсә дә булса эшләргә уйлау; берәр эш эшләргә булу, карар итү. *[Җәлал:] Бурычка дигән булып, азрак кылын тартып караган идем, бер дә кымшанмый.* Ш. Камал

3) Бушаудан һ.б. сәбәпләрдән какшап, селкенеп тору, урыныннан кузгалу. *[Гәрәй:] Кайбер кымшаныбрак торган забойлар була ич.* Ш.Камал. *Кымшанган botaклардан эре тамчылар коелды ---.* М.Маликова

**Кымшанып карау** Кымшанырга омтылу; *юкл. форм.* чак кына да, аз гына да кымшанмау. *Әйберләремне капчыкка төйнәгәч, уятам моны [сержант хатынны], кымшанып та карамый.* Х.Камалов

**Кымшанып кую** Бераз, сизелерсизелмәс кымшану. *Тавыш чыкмады, тешләр арасына тулган ком бөртекләре шыгырдады да, бүрәнәдәй шешенгән тел кымшанып куйды.* Х.Ширмән. *Кымшанып куйды туфрак җир. Диварлар түкте яшь.* Г.Морат

**КЫМШАТУ** *ф.* Нәрсәне дә булса урыныннан кузгату, хәрәкәткә китерү. *Аңа [козгынга] киләчәкнең барысы да билгеле, шуңа күрә ул юк-барга илтифат итеп вакланып та, канатларын кымшатып та маташмый.* А.Хәлим

**Кымшатып карау** Кымшатырга омтылу. *Лениза сиздерми генә янәшә торган капчыкны кымшатып карады.* М.Маликова. *Юл кырыендагы кәсләрне аяк белән кымшатып карадык.* Идел

**Кымшатып кую** Аз гына кымшату. *Еракта алтын төлке җемелдәп торган койрыгын кымшатып куйды.* Р.Зәйдулла

**КЫМША́У** *ф. диал. к.* **кымшану**

**Кымшап кую** Бераз кымшау, селкенеп кую. *Кымшап куйды гәүдә кан эчендә, Ишеттеме үлем сүзләрен, – Пышылдады: «Кайтам... әниемә... Мин... күрәсем килә... түзәрмен...».* Г.Сәгыйров

**КЫМЫЗ** I *и.* 1) Бия, дөя яки кәҗә сөтеннән махсус ысул белән ачытып ясалган эчемлек (кайбер авыруларны дәвалау өчен дә кулланыла). *Ачы гына баллар, төче баллар Әтиемә кымыз күренгән.* Җыр. *[Бай] Җәйләүдән җәйләүгә йөреп, кымыз эчеп, кәеф-сафа коруны гына белгән улларыннан мине якынрак күрде.* А.Расих

2) *сөйл.* Кымыз белән дәвалану урыны. *[Гали Зөләйхага:] – Хәзер авырыйм, кымызга барып кайтыйм әле, – дип әйттең. Әмма кымызга бармадың.* Г.Коләхмәтов

**КЫМЫЗ** II. *и. диал. к.* **кымызлык**. *Малай чакта Абсатый бабаена ияреп, кымызга, болынга йөргәндәге кебек.* С.Шәрипов

**КЫМЫЗЛЫК** *и. бот.* 1) Кымызлыкчалар семьялыгыннан, өчәрле яки бармаксыман катлаулы яфраклы, яфракларында һәм сабагында әче кислотасы булган үлән үсемлек; *русчасы:* **кислица**. *Чыршы урманындагы үләнчел үсемлекләрнең күпчелеге (ландыш, кымызлык, бүре җиләге) тамырчалардан үрчиләр.* Ботаника. *Алар янында сез яфрагы өчәрле кымызлык, ат тоягы эзенә охшаган яфраклы тайтояк үләне --- һәм башка кайбер үсемлекләрне очратырсыз.* Ботаника

2) Карабодайчалар семьялыгыннан шактый биек сабаклы, яфрагының ике ягы да очлы, ак чәчәкле, яшь вакытында әчкелт көпшәсе ашала торган үлән үсемлек; Альп кырлачы; *русчасы:* **кислянка, кислец**. *Ак чәчәкләр, кыңгыраулар, мәтрүшкәләр, андыз, бөхтә, кымызлык үләннәре чалгы чапкан уңайга исерткеч хуш ис бөркә, сут агыза.* Г.Якупова. *Кылганнар арасында тамак ялгарлык бернинди үлән әсәре – кымызлык, кузгалак, балтырган, сарана, җиләк сыман нәрсә күзгә чалынмады.* А.Хәлим

**КЫМЫЗЛЫКЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Кымызлык ишеннән тагын 800 ләп төрдәге үлән үсемлекләрне берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **кисличные**

**КЫМЫЗХАНӘ** *и.* Кымыз эчә торган урын. *Кымызханәдә утыру*

**КЫМЫЗЧЫ** *и.* 1) Кымыз ясаучы, кымыз ясау остасы яки кымыз сатучы. *Тукай көнозын кымызчы казаклар янында яки үз бүлмәсендә язу-сызу, газета-журналлар уку белән мәшгуль.* С.Сабиров

2) *сөйл.* Кымыз белән дәваланучы. *[Хәйри:] Кымызчылар ята торган башкорт авылларына берничә кеше җибәрсеннәр.* Г.Ибраһимов

**КЫМЫЗЧЫЛЫК** *и.* Хуҗалыкның кымыз әзерләү тармагы

**КЫМЫРҖУ** *ф.* 1) Чымырдау; тәндә яки аның кайбер урыннарында җиңелчә генә чәнчешү, калтыраган сыман булу. *Каравылчының кинәт чәч төпләре кымырҗыды, аркасы чымырдап куйды.* Ш.Шәйдуллин. *Аның хәзер күңеле тыныч, бөтен тәне рәхәт бер талу белән тымызык кына кымырҗый иде.* Р.Төхфәтуллин

2) Күбекләнеп әчү, әчешү. *Ул заманда татарлар бал эчәләр иде, койган баллары мичкәсе белән җылы мич башында кымырҗып, әкрен генә шаулап утыра иде.* Ә.Еники

3) Селкенү, кыбырдау. *[Сәвиләнең] Кесәсендә чикерткә кымырҗый.* Н.Гыйматдинова. --- *Ибрай Зәкуанов әле авызын ачты, әле мыек очын чәйнәде, әле ботларын угалады, кымырҗыды, әле уфылдады, әле ухылдады.* Ә.Гаффар

4) *күч.* Омтылу, нәрсәдер эшләргә талпыну; тынычсызлану. *Нурия шул сүздән соң иренең авыру икәнен, стройга ярамавын да әйтергә кымырҗыган иде, әллә нишләп батырчылыгы җитмәде.* Г.Ахунов. *Әхмәдиша агайны эчтән корт кимергәне, нәрсәдер әйтәсе килеп кымырҗыганы сизелә.* Т.Галиуллин

**Кымырҗып алу** Кыска вакыт эчендә кинәт кымырҗу. *Янчуринның арка сөякләре, ничектер, салкынаеп китте, кымырҗып алды.* Ш.Шәйдуллин

**Кымырҗып китү** Көтмәгәндә, кинәт кымырҗу. *Эчемдә боз яткан кебек, әледән-әле аркам кымырҗып китә, яңадан туңа башлаган шикелле булам ---.* Ә.Еники. *Ул [Мөдәррис] шигырь укыганда, тәннәр кымырҗып китә.* Н.Гамбәр. *Тамак шулкадәр кымырҗып китте, тәһарәтне бозмый булдыра алмадым.* Б.Камалов

**Кымырҗып кую** Аз гына кымырҗу. *Бу минутта Нургалинең дә күңеле нечкәреп китте, ничектер, күзләре дымланып, тамак төбе кымырҗып куйды.* Ә.Еники. *Тик, нигәдер, йөрәге кымырҗып куйды солдатканың.* М.Әмирханов. *Башкаларның хәлен белмим, минем күзләрем кымырҗып куйды, бугазыма төер килеп тыгылды.* Р.Мөхәммәдиев

**Кымырҗып тору** Бертуктаусыз кымырҗу. *Салкын балчык ерып килгән аяклар беренче дәреснең буеннан-буена кымырҗып тора.* Б.Камалов. *[Ирекнең] Күңеле мөдирне ярсытырга кымырҗып торганлыктан шулай килеп чыкты.* Ф.Садриев. *Мирхас тагы шаккатып калды, ул эчтән бу хакта дусты Әсәткә сөйләрмен дип кымырҗып тора.* Х.Камалов

**КЫМЫРҖЫЛА́У** *ф. к.* **кымырҗу**

**Кымырҗылап алу** Бераз гына кымырҗылау

**Кымырҗылап тору** Бертуктаусыз, әледән-әле кымырҗылау. *Әллә ниме, күңелең теге нәмәрсәкәйгә кымырҗылап торамы, Хода бәндәсе?* Э.Касыймов

**КЫМЫРҖЫТУ** *ф.* 1) Чымырдату

2) Шомландыру, калтырату; тынгы бирмәү. *Ара-тирә алашам колагын шомрайтып ала: андый чакта тәннәремне кымырҗытып, йөрәккә шом төшә.* Х.Сарьян. *Ә синең уйлы, даһи башта нибары бер фикер миеңне кымырҗытыр.* Р.Гаффар

**Кымырҗытып алу** Аз гына кымырҗыту. *--- тун якасыннан кар тузаны үтеп керә дә тәнеңне кымырҗытып ала ---.* К.Миңлебаев. *Кинәт кенә күңелемне кызгану, якын итү хисләре кымырҗытып алды.* Х.Ширмән

**Кымырҗытып тору** Бертуктаусыз кымырҗыту. *Зур каравай калачның күз алдында торуы авызларыбыздан сулар китерә, тамакларыбызның төбен кымырҗытып тора иде.* М.Гафури. *Яңа бинаны күрәсе килү күңелне гел кымырҗытып тора иде.* Т.Нәҗмиев

**Кымырҗытып узу** Бик тиз арада кымырҗытып алу. *Ләкин [бабайның] алҗыган гәүдәсе таң йокысында чынчынлап изрәп китәргә дә өлгермәде, күңелдән авыр дулкын кымырҗытып узды ---.* Э.Касыймов

**КЫМЫРЫСКА** *и. диал. к.* **кырмыска**. *Мин кымырыска булып та, Син Сөләйман түгелсең.* Дастан

**КЫН** I *и.* Кылыч, хәнҗәр кебек коралларның савыты, футляры. *Иделләрнең ары ягында Ялтырап ята пәке кынысы.* Җыр. *[Искәндәр Зөлкарнәй] Кыныннан кылычын суырып чыгарган да теге төенне чапкан да ташлаган.* Ә.Гаффар. *Алып аның кылычын, Салдыра да кынысын, Карый вәзир кылычка Һәм төшә куркынычка.* Ш.Маннур. *[Зөнүн] Пычагын кыныннан чыгарып, кулдашының борыны алдына куйды.* М.Юныс

**КЫН** II *и. махс.* Франс ярусының астан икенче катлавы – геологик катлау. *Кын балчыгыннан соң 100 метрлы интервал нибары бер тәүлектә үтелде.* Социалистик Татарстан

**КЫНА** I *и. гар. бот.* 1) Каты курайчалар семьялыгыннан эссе климатлы зоналарда үсә торган куак үсемлек; *русчасы:* **хна**

2) *махс.* Чәчне, тырнакларны, тәнне (элек тешне дә) буяу өчен, шулай ук төрле рәсемнәр төшерү максаты белән кулланыла торган, шушы куакның киптерелгән яфракларыннан ясалган саргылт кызыл буяу. *Комод өстендә хатынкызның бизәнү әйберләре. Иннек, кершән, сөрмә, кына, лак, чәч ныгыткыч, чәч йомшарткыч, чәч бөдрәләткеч ---.* Ф.Шәфигуллин. *[Ярашовичның] Кына төшерелгән тырнаклары --- сыгылмалы зифа гәүдәсе, оетып кына йөреше, балдан татлы тавышы нәкъ алиһәләрнеке төсле!* Ш.Рәкыйпов. *Кына һәм басма чәч өчен зарарлы түгел, киресенчә, алар чәчне үстерә һәм ныгыта.* Файдалы киңәшләр

◊ **Кынасы су күтәрмәү** Тәнкыйтьне кабул итмәү, тиз үпкәләүчән булу

**КЫНА** II *и. иск.* Хин агачының кабыгыннан алынган ак төстәге порошок, бизгәккә каршы кулланыла торган дару; хинин. *[Җәүдәт:] Ник калын киендегез, әллә хәма (бизгәк) хәстәлегенә бирелдегезме? Кына, кына эчәргә кирәк.* Г.Газиз

**КЫНА** III *кис. к.* **гына**. *Лениза тыңлап кына утырды.* М.Маликова. *Күп сөйләмә, җавабыңны уйлап кына бир.* Ә.Еники. *Шатлык кына шытсын диеп, чәчкән идем мул итеп мин гел Өмет орлыклары.* Р.Фәйзуллин

**КЫНА́ ГӨЛЕ** *и. бот.* Кыначалар семьялыгыннан, өйдә үстерелә торган алсу чәчәкле гөл; *русчасы:* **бальзамин**. *Тәрәзә төпләре гөл генә, Кына гөле бер генә.* Җыр. *Әйтик, татарның яран гөлен, кына гөлен таба аласыңмы син калмык халкында?* А.Хәлим. *Тәрәзә төбендә – песи яфрагы, ак кына гөлләре.* Г.Әпсәләмов

**КЫНДЫРАК** *и. бот.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан кыяк яфраклы, себеркәчкә тупланган вак чәчәкле, шуышма тамырлы, терлек азыгы буларак көтүлекләрдә үстерелә торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **костёр**. *Аерым төр күпьеллык үләннәрнең туфрак эрозиясенә йогынтысын өйрәнү өчен, түбәндәге күпьеллык үләннәрне чәчеп карадык: клевер, тимофеевка, клевер+тимофеевка, люцерна, кындырак.* Күпьеллык үләннәр. *Болында тукранбашлар, тычкан борчагы, кырлы борчак, казаяк, олыбаш, кындырак, төлкекойрык һ.б. болын кыяклылары үсә.* Татарстан географиясе. *Арыш кындырагы орлыгыннан ботка пешерергә һәм солы кесәленә охшаган кесәл әзерләргә мөмкин.* Робинзон эзләреннән

2) Кыяклылар семьялыгыннан, озынча нечкә тар яфраклы, күч-күч булып үсә торган үлән; *русчасы*: **полевица обыкновенная**

3) *сөйл.* Кындырак (*1 мәгъ.*) үләне үскән болын. *Кындыракта чәчәк җыйдым Тәмле ислесен генә.* Җыр

**КЫНҖЫРАК** *и. этн.* Ат, сыер аягы тиресеннән чабата сыман итеп тегелгән аяк киеме

**КЫНТА́Р КАБАГЫ** *и. бот.* Кабакчалар семьялыгыннан, җимеше билле шешә рәвешендә үсә, яшел чагында ашарга мөмкин булган, өлгергәннәре савыт яки музыкаль инструмент ясауда кулланыла торган үсемлек; калабас, калабаш; *русчасы*: **горлянка; лагенария**

**КЫНТЫРЫКЛА́У** *ф. диал. к.* **кымтырыклау**

**КЫҢГЫР** *с.* **1.** 1) Беркадәр янтайган, авышкан. *Кыңгыр фуражка астыннан тырпаеп торучы тузгак чәчле бу «киткән башлар» иртә таңнан ук карта уйнарга тотынганнар ахры.* К.Нәҗми

2) *күч.* Кирәкмәгән, тыелган, бозык, ярамаган. *Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә.* Мәкаль. *Кыңгыррак кеше дә була бит, кешесенә карап, җиңе дә начар утыра, ди торган иде.* З.Рәмиев. *Көннәрдән бер көнне хатынымның кыңгыр эшемне сизенүен аңладым.* Татарстан яшьләре. --- *борынгы заманнарда аларның зур күпчелеге мондый кыңгыр эшләр белән гомумән шөгыльләнмәгән.* Кызыклар дөньясында

3) *күч.* Хаталык, кимчелекле. *[Нәсимә:] Тора башлаганыбызга кырык көн юк, синең инде кырыктан артык кыңгыр ягың килеп чыкты.* Р.Ишморат

**2.** *рәв. мәгъ.* Беркадәр кырынайтып, янтайтып, авыш итеп. *Башында кыңгыр киелгән камалы бүрек.* М.Фәйзи. *– Нажия Бариевна, бу сорауга иртәгә җавап бирсәң дә буламы? – дип, башын гадәтенчә кыңгыр салыбрак сорады малай.* Р.Хафизова. *Башын кыңгыр салып, гамьсез кыяфәт белән сөйләнгән кыз якын, бик якын иде аңа.* Р.Мулланурова. *Киндер алъяпкыч бәйләп, чигүле түбәтәен кыңгыр салып җибәргән карт та, чәчләре чаларган булуга карамастан, яшьләрчә матур күренә.* З.Фәйзи

◊ **Кыңгыр карау** Начар мөнәсәбәттә булу, яратмыйча карау, чит итү. *«Шушма башы» [газетасы] укучылары англичаннарга көннән-көн дошманлыкларыны арттырып, кыңгыр карый башладылар.* Ш.Мөхәммәдев. **Кыңгыр китмәү** Начар булмау, зарар килмәү. *Муса энекәш, абзарыңны бу кадәр караганчы, йортыңны карасаң да кыңгыр китмәс иде бит, син буйга җиткән инде, өйләнергә дә вакыт.* Р.Ильяс

**КЫҢГЫРАВЫК** *и. сөйл.* Кечкенә кыңгырау, шөлдер. *Кыңгыравык – яңгыравык, Чылтыравык, чыңлавык. Синең көмеш тавышыңны Ун ел буе тыңладык.* В.Хәйруллина

**КЫҢГЫРАЙТУ** *ф.* Нинди дә булса әйберне кыңгыр хәлгә китерү, кыңгыр салу, авыштыру. *Ул Гыйммранның чәченнән сыйпамакчы иде, ир башын кыңгырайтты.* Н.Гыйматдинова. *Бабай укалы тирән түбәтәен аз гына кыңгырайтып, җиләнен төз гәүдәсенә сыландыра да: – Фәрхизә, – ди, – синең карашыңа тиңләшерлек гүзәллек юк.* М.Хуҗин

**Кыңгырайта бару** Акрынлап кыңгырайту

**Кыңгырайта төшү** Бераз кыңгырайту

**Кыңгырайтып кую** Кыңгыр хәлгә китерү. *Хәзрәт өйгә кайтышлый Әхмәттән Миңлесылу кодачаның үзләрендә икәнлеген ишеткәч, эшләпәсен бераз кыңгырайтып куйды.* Ф.Әмирхан

**КЫҢГЫРА́У** *и.* 1) Металлдан (бакырдан яки аның эретмәсеннән) ясалган, яңгыравыклы тавыш чыгару өчен теле булган, конус рәвешендәге эче куыш җайланма; чаң. *Анда христиан чиркәүләре салырга, безнең мәчетләребезне ватарга әмер иткән, кыңгыраулар асарга кушкан, диелгән имеш, ---.* Г.Гобәйдуллин. *Көньяк Африка Республикасының Пайнтаун шәһәрендә төсле металл караклары чиркәүдән моннан 200 ел элек Шотландиядә коелган кыңгырауны урлап киткән.* Мәдәни җомга

2) Атка, колынга, сыерга һ.б. хайваннарга кайдалыгын белдереп тавыш бирү өчен тагыла торган кечкенә шөлдер. *Иясе, бу ишәкне урманда табу читен булмасын өчен, муенына кыңгырау такты.* Г.Тукай. *Концерт өчен аның бик үк ярап бетмәгәнен искә алып, колын муенына тага торган кыңгырау табып алып килделәр.* Ш.Камал. *Каяндыр ерактан ап-ак арыш кырлары түреннән «зиң-зиң» чыңлаган кыңгырау тавышлары ишетелде.* Ә.Еники

3) Сигнал бирү җайланмасы. *Дүртенче катка күтәрелеп, кирәкле квартир ишегенең кыңгырау төймәсенә басты.* Х.Вәлиәхмәтов. *Нажиянең уйларын бүлеп, кыңгырау чылтырады.* Р.Хафизова. *Егет күздән югалып, унегерме минут та узмады, ишектә кыңгырау чыңлады.* Т.Әйди

4) Чыңлап тавыш бирә торган, эче куыш шар яки ярымшар формасында эшләнгән музыка коралы яки аның бер җайланмасы. *Саратский яшел гармонь, Көмеш кыңгыраулары. Бу көмеш кыңгырауларның Кичке яңгыраулары ---.* Ф.Кәрим

5) Үсемлекнең кыңгырау рәвешендәге чәчәге. *Бүре җиләге (бүре юкәсе – волчье лыко) куагы үзенең алсу миләүшә төсендәге хуш исле кечкенә кыңгырауларын элеп куйган.* Мәдәни җомга

6) Акваланглар булмаган вакытта су астына төшү өчен файдаланылган кыңгырау формасындагы гөмбәз. *Шуннан инде унике югары квалификацияле водолаз, водолаз кыңгыравына кереп утыралар да, су төбенә төшеп китәләр.* Кызыклар дөньясында

◊ **Кыңгырау кагу** Берәр хәбәрне бөтен халыкка тарату, бар кешегә белдерү. *Гаеп миндә, өстемә алам, нигә инде бөтен совхозга кыңгырау кагарга.* И.Салахов. *Туган-тумача, чыбык очы, канкардәш, кода-кодача, дус-ишнең һәммәсенә кыңгырау кактык.* Идел

**КЫҢГЫРА́У ГӨЛ** *и. бот.* Кырлыганчалар семьялыгыннан җәй буе чәчәк ата торган, салынкы чәчәкләре ачык кызыл төстәге гөл. *Син яраткан чәчәкләрне җыеп, Такыялар үреп киямен. Ап-ак ромашкалар – мәхәббәтең, Сары төнбоеклар – синең сагышың, Миләүшәләр – миңа хыянәтең, Кыңгырау гөл – көлгән тавышың.* Аманулла

**КЫҢГЫРАУЛА́У** *ф.* Кыңгырау тагу, кыңгырау бәйләү (дугага, хайван муенына һ.б.). *Кыңгыраулап җигелгән өч атны кучер атлатып кына китерә.* Г.Ибраһимов

**КЫҢГЫРАУЛЫ** *с.* 1) Кыңгыравы булган; кыңгырау тагылган. *Төнлә елга буйларында Кыңгыраулы атларның*

*Хәтерлим әле, хәтерлим Утлап йөргән чакларын.* З.Мансур. *Малай абыйсыннан сорый: – Кыңгыраулы кармак – балыклар адашмаскамы ул? – Без килеп каптык! – дип шылтыратыр өчен...* Ш.Галиев. *Кыңгыраулы тальян гармун фронтка китүчеләрне җырлатып урам әйләндерә.* Ш.Маннапов

2) *күч.* Теләсә нинди сүз, гайбәтябыша торган; гаугалы. *Ирсез хатын кыңгыраулы була ул.* М.Мәһдиев. *«Кыңгыраулы» шәхес буларак, синең үзеңә дә тәнкыйть шактый эләгеп тора.* Н.Гамбәров

**КЫҢГЫРА́У ҮЛӘН** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан, туры сабакка утырган орлык тартмачыгы кыңгырауга охшаган чүп үләне; *русчасы:* **хлопушка**

**КЫҢГЫРА́У ЧӘЧӘК** *и. бот.* Кыңгыраучәчәклеләр семьялыгыннан, куе зәңгәр яки шәмәхә төсендәге чәчәге кечкенә кыңгырауга охшаган үләнчел үсемлек; *русчасы:* **колокольчик**. *Ә кыңгырау чәчәк, туып килгән якты көнгә сокланып, иртәнге җыр сузды: «Теңә-теңә, тең-тең-тең, теңтеңгелтеңгелә!»* Ф.Зариф. *Нәни кояшка охшаган ак таҗлы ромашкалар, Лираның күзенә охшаган зәп-зәңгәр кыңгырау чәчәкләр, алсу тукранбашлар, зәңгәрсу бөрчекле күгәрчен күзләр, эреле-ваклы ак чәчәкләр – һәммәсе бар.* Р.Хафизова

**КЫҢГЫРАЮ** *ф. сөйл.* Кыңгыр хәлгә килү; беркадәр бер якка кырынаю, авышу

**Кыңгыраеп китү** Кинәт, көтмәгәндә кыңгыраю; тагын да азрак, беленербеленмәс кенә кыңгыраю. *Салам эскерте җил белән кыңгыраеп киткән*

**Кыңгыраеп тору** Кыңгырайган хәлдә булу; әледән-әле яисә даими кыңгыраю

**Кыңгырая бару** Акрынлап кыңгыраю; торган саен ныграк кыңгыраю. *Аларның авылдагы ата-аналарыннан калган иске өйләре ел саен ныграк кыңгырая бара*

**Кыңгырая төшү** Тагын да азрак кыңгыраю

**КЫП** I *рәв. диал.* Кыл, нәкъ, тач. *[Газинең] --- кып урталай бүленгән уң кашының кыйгачланып килгән өлеше нәкъ кош канаты кебек өскә чөелде ---.* М.Хәсәнов

**КЫП-** II *кис.* [ҝ] авазына башланган кайбер сыйфат яки рәвешләр алдына ялганып һәм һәрвакыт басымны үзләренә алып артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәчә, мәс., *кып-кызыл, кып-кыска, кып-кыек*

**КЫ́П ИТТЕРҮ** *ф.* Туры китерү. *[Сәхәп] Яныңдагы урындыкны чак кына күтәреп, кып иттереп урынына төшереп куя.* Н.Исәнбәт

**КЫ́П ИТҮ** *ф.* Бик төгәл туры килү, ярашу. *Әнисенә нәрсә кисә дә килешә. Кып итеп кенә тора.* А.Хәлим

**КЫПКЫН** *и. иск.* Очкын, чаткы

**КЫПКЫНЛАНУ** *ф. иск.* Очкынлану, очкынланып яну

**КЫПСУЫР** *и. диал.* Келәшчә, каргаборын

**КЫПТЫР** *с. иск.* Тупас иләнгән (хәрәкәтләнгәндә кыптырдап торуыннан чыгып бирелгән). *Кырык кат чабадан кыптыр тун артык.* Мәкаль. *Кайттың, абый, Өстә кыптыр туның, Аягыңда иске чабата. Акларга үч янган күзләреңне Каплый төшкән тузган папаха.* Х.Туфан

**КЫПТЫРДА́У** *ф. сөйл.* Каты гына кыштырдау

**Кыптырдап алу** Бераз, җиңелчә кыптырдау

**Кыптырдап кую** Көтмәгәндә, кинәт, кыска гына кыптырдау

**Кыптырдап тору** Бертуктаусыз кыптырдау

**Кыптырдый бирү** Кыптырдавын дәвам итү

**КЫПТЫ́Р-КЫПТЫР** *иярт.* Берәр каты нәрсәгә бәрелүдән, тиеп китүдән чыккан тавышны белдерә. *Тигезсез сафлар булып, кыптыр-кыптыр чыгып китәләр.* А.Гыйләҗев

**КЫПТЫ́Р-КЫПТЫР ИТҮ** *ф. к.* **кыптырдау**

**КЫПТЫ́Р-КЫПТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **кыптырдау**

**КЫПЧАК** *и.* XI гасырдан XIII гасыр урталарына кадәр Дунайдан алып Иртышка кадәр территорияне биләгән күчмә төрки телле халык атамасы (хәзерге вакытта бу тел татар, башкорт, карачай-балкар, нугай, казак, каракалпак, комык телләренең нигезен тәшкил итә) һәм шул халыкның бер кешесе (Азиядә – кыпчаклар, Русьта – половецлар, Европада – куманнар дип йөртелгән). *Бату ханның исәпсез-хисапсыз бәни әс-фарлар кавеме баскынынннан соң Дәште Кыпчак бетеп – кыпчагы, Бөек Болгар бетеп – болгары агылып килгән ---.* Х.Сарьян. *Әгәр синең тәнеңдә кыпчак каны акса, син салкын коралга һич тә битараф кала алмыйсың.* М.Юныс. *Җайдак аттай үргә чаба Һуннар, кыпчак, болгарлар. Кырыс тарих битләрендә Үлмәс яугир булганнар!* Р.Рахмани. *Түбән Идел буйларында алар кыпчак җирләрен, Саксин шәһәрен басып алалар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**КЫПЫ́Л-КЫПЫЛ** *иярт.* Күз яше тамуны белдерә. *Конрад инде баядан бирле Наҗиянең кыпыл-кыпыл тамган күз яшьләрен күреп бара.* Н.Дәүли

**КЫР** I *и.* **1.** 1) Урман яки елга, авыл яки шәһәр утырган урыннан аермалы буларак, берни белән дә ышыкланмаган тигезлек, зур, киң, ачык мәйдан. *Кырда салкынча, себерә торган буран.* М.Мәһдиев. *Терлекләрен иртәрәк кырга чыгарып өлгерергә кирәк.* Н.Дәүли. *Алда иксез-чиксез карлы кыр, карлы кыр читендә авыл утлары ачылды.* Ф.Шәфигуллин

2) Иген игү, чәчеп үлән үстерү өчен эшкәртелә торган җир мәйданы; ашлык үстерелә торган мәйдан, басу. *Авылның кырыеннан ук киң авыл кыры башлана.* Ә.Еники. *[Зәки абзый] Үзебезнең кырда азык ягы сыегайса, көтүне күрше колхоз кырына алып килеп ашатып чыгарга да күп сорамый.* В.Нуруллин. *Юлның ике ягы да яшел диңгез: бодай кыры чайкалып, дулкынланып тора.* Х.Камалов

3) Нинди дә булса эш-хәрәкәтләр барган җир, урын. *Яу кырында башын салганнары да байтак.* И.Сирматов. *Каты сугышның күп корбаннар алуын, кемнәрнеңдер газиз уллары, сөйгән ирләре, кадерле якыннары сугыш кырында торып калуын белә ул.* Ә.Еники. *Әнә безнең очның Әтнәләргә, Арчаларга хәтле барып Сабантуйлары тотып йөргән Ярау Гаяз сугыш кырыннан*

*ике буш җиңен селкеп кайтып керде.* А.Хәсәнов

4) Нинди дә булса эшләр башкарылган, нәрсәләрдер урнаштырылган яки нинди дә булса хәлгә дучар ителгән участок, урын. *Мирхас карап торучылар янына килеп туктаганда, сержант, капсульләр тулы бүреген алга тотып, мина кырыннан болай атлый иде.* Х.Камалов. *Безнең хәрби шәһәрчектә полигон, ату кырлары, стадион, тагын әллә ниләр бар иде.* Ф.Яруллин

5) Нинди дә булса аерым бер максат өчен билгеләнгән участок, җир. *Нәфисә үзен шул тәҗрибә кырына беркетүне сорады.* Г.Бәширов

6) *сөйл.* Спорт уеннары өчен мәйдан. *Атна саен Конгода 25 мең футбол кыры кадәр мәйданда агач егыла.* Мәдәни җомга // Спорт әсбабының мәйданчыгы. *Шахмат кыры*

7) *кит.* Территория, җир (ешрак күплектә кулланыла). *Совет кырларында туп ядрәләре соңгы мәртәбә яңгырадылар да, еллар артыннан еллар үтте.* Һ.Такташ

8) *шигъ.* Җәмгыять. *Бишьеллыкның бөек гигантлары һаман үсә, һаман күккә таба үрелә. Башларыннан инде сез яшәгән коммунизм кыры күренә.* Һ.Такташ

9) *физ.* Нинди дә булса көчләрнең хәрәкәте, эшчәнлеге таралган пространство, киңлек. *Бернотас, дәрвишлек язмышына һәм тормышына дәгъва итеп, шәһәрне, цивилизация үзәген ташласа да, әдәбиятның төп магнит кырыннан, үзәк юнәлешеннән читкә китә алмаган.* Т.Галиуллин. *Яңа корабларның пластик стеналарына электр кыры туплана икән.* М.Юныс. *Күпчелек кошларның күрү кыры шулай ук 360 градус.* Кызыклар дөньясында. *Төрле чыганакларның электр кырлары кушылса, суммар электр кыры көчәнешлелеге аерым кыр көчәнешлелекләренең векторча суммасына тигез була.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

10) *лингв.* Билгеле бер мәгънәне белдерә торган тел чаралары җыелмасы. *Ә югарыда саналган барлык кушымчаларны исә --- килеш категориясенең кулланылыш буенча тирә-юне, ягъни функциональ-семантик кыры дип карарга мөмкин.* Ф.Хисамова

11) Мичтә махсус мәйданчык, киртләп эшләнгән урын, кучкар. – *Нәрсә булган? – Мич кырыннан Минем әлифбам егылган.* Ш.Маннур

12) *күч.* Берәр эшчәнлек яки эш өлкәсе, эшчәнлек сферасы. *Матур әдәбият мәсьәләсе – Татарстан җөмһүрияте кебек автономияле җөмһүриятләр өчен бик зур эш кыры ул.* Г.Толымбай. *Корыч атым иярендә Йөрмәм, бәлки, гомергә. Гыйлем тавына менәрмен, Фән кырларын сөрергә.* Г.Нәбиуллин. *Шунысы да искә алына: аның белән бергә эшләгән күп кенә юристлар аның югары һөнәрмәндлеген, хокук кырында бик яхшы ориентлашу сәләтен билгеләп үтәләр.* Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү белән бәйләнгән; игенчелеккә, кырчылыкка караган. *Авылларда туй үткәрер мәл, кыр эшләре очланган, сугым суелган.* Г.Якупова. *Бөтен сынамышлар буенча уңыш мул булырга тиеш иде – халык җиң сызганып кыр эшенә тотынды.* М.Мәһдиев

2) Кырда булган, кырга урнашкан, кыр буйлап барган --- *алар берберләренә сыенып диярлек, кыр юл буйлап китеп бардылар.* Ф.Бәйрәмова

3) Кырда үсә торган; культуралаштырылмаган (үсемлекләр тур.). *Менә тагын без атлыйбыз бергә, Кыр гөлләре синең кулыңда.* Г.Ибушев. *Әмма алар барыбер кыр чәчәкләре кебек нык булып үсә алмый.* Ф.Яруллин

4) Сугыш яки поход шартларындагы хәрәкәтләргә, эшләргә бәйләнешле. *Кыр госпитале. Кыр хезмәте уставы*

5) Кыр шартларына җайлаштырылган. *Аннары [Букреев]: – «Бөркет»кә әйтергә кирәк, – дип, кыр телефонына үрелде.* Г.Паушкин. *[Якупов] Бодай башакларын өзеп алып, бармак битләрендә тәгәрәтеп карый да, кәгазьгә төреп, кыр сумкасына сала.* Г. Гобәй

◊ **Кыр кебек** Бик зур, киң, иркен. *Кыр кебек өйдә япа-ялгызы торып калды [Мәдинә].* Р.Хафизова. *Кыр кебек зал шыгрым тулы: Халык көн-төн кайнап тора ---.* Р.Рахмани. **Кыр талашып** Каты итеп. *Бәлкем, без талчыбыктай нечкә билле кыз өчен кыр талашып сугышканбыздыр.* Ф.Хөсни

**КЫР** II *и.* **1.** 1) *сөйл.* Нәрсәнең дә булса чите, кырые; тирәсе. *Сызыклар артык туры, калын, кисешмиләр: сыза башлаган да дәфтәр бите кырында өзелеп калган.* Ә.Гаффар. *Вера тиз генә арба кырына сикереп утырды.* Ә.Еники. *Хуҗа, сиңа күз кыры белән генә карап, чәй эчеп утыра.* М.Юныс

2) Эшләпәнең бөкләнеп куелган кырые. *Аның [Мөдәрриснең] маңгаенда кызарып калган эшләпә кырының эзе хәсрәт сызыгы булып тоела.* М.Маликова

3) Аерым урын, як, тараф. *[Карадәрвиш:] Килеп җиттек бугай. (Сакчы, капчыгын кочаклап, бер кырга утыра.)* Р.Батулла

4) Ян. *Тынычлык проспектына кыры белән баскан мәһабәт йорт шулай итеп бертөсле гадәти плитәләр белән торгызылды.* Г.Кашапов. *Ул ике таш плитә өстендә торган, металл кырларында күмердән төшкән ялкын нурлары уйнаган рациясенә табарак шуышып утырды.* Г.Паушкин. *Чиратгагы әйләнештә инде көпчәкләргә басар дигән соңгы өметне кыя ташлары кырына килеп бәрелгән запас көпчәк челпәрәмә китерә.* Р.Сафин

5) *геом.* Предметта үзе кебек үк өслек белән почмак төзегән яссы өслек, бер як ян. *Алмаз, тирескә күмелсә дә, асыл сыйфатын җуймый, алтын кысага алсаң, бөтен кырларын ялтыратып нур чәчә.* Т.Әйди. *Кубның күләме V га тигез. Дәрәҗәнең вакланма күрсәткечләреннән файдаланып, куб кырының мәйданы S ны аның күләме V аша табыгыз.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

6) *геом.* Геометрик фигураның өслекләрен чикләгән туры сызык. *Өчпочмак кыры*

7) *юн. кил. форм.* Янына, алдына, читенә. *Кырыңа килми торсам, борлыкма, Шытырга торган орлыгым!* Г.Сәлим. – *Әйдә, сыйдан рәхим итегез, – дип, Борһан егетләрне сәке кырына утыртты.* М.Мәһдиев

**2. кырындагы** *с. мәгъ. сөйл.* Янындагы, тирәсендәге. *Яратмады ул*

*кырындагы Йосыф кахан шымчыларын, яратмады һәм бер тапкыр да алар белән ачылып сөйләшмәде.* М.Хәбибуллин

**3. кырыннан** *рәв. мәгъ. сөйл.* Бер читтән, бер яктан; кырынлатып. *Ходайбирде, кырыннан гына, Гөлҗиһанга карый иде.* М.Гафури

**4.** *бәйл. функ.* 1) **кырында** *сөйл.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса янында. *Яньчелгән, ярым ватык каскам ятып калды окоп кырында.* М.Җәлил. *Тик каderле ханчам кырында Корбан булсам икән юлында.* Ф.Бурнаш

2) **кырыннан** *сөйл.* Яныннан, кыриеннан. *Арба кырыннан дилбегә тотып, бер агай бара, ә шактый арттан, башын түбән иеп, кулларын артка куеп, иптәш Сабирҗанов үзе атлый.* Ә.Еники

◊ **Кырга сыймый** Хис-тойгы, үйөмет ташкынының чамасыз күп булуы. *Кырга сыймас шатлыкларым ташып, Мин дөньяга туам кабаттан.* Ф.Суфиянов. *[Хәлиманең] Куанычы кырга сыймый.* Г.Галиева

**КЫР** III *иярт.* Кайбер кошларның кыркылдавын, чыркылдавын белдерә

**КЫРА** *рәв. диал.* Кискен, кискен итеп

**КЫРАГАЙ** *с. диал.* **1.** 1) Кырыс. *Кырагай табигатьле Иван Нилович участок начальнигы Смирновны элеп алып селкеп салды.* М. Хәсәнов

2) Кыргый. *Туфайловның кырагайрак, кешеләрдән кача, хатын-кыздан курка торган сыйфатлары бар иде.* Х.Камалов. *Арыслан тикле арысланны да кулга ияләштерәләр. Ә бу, мин сиңа әйтим, кадерле редакция, кырагайның кырагае.* Ф.Шәфигуллин. *Сарыклар да кырагай булып чыкты, малайларга баш иеп дуслашырга теләмәделәр ---.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Әз генә дә. – *Сулагай китми ул! ... – Тыңчым, шаһит бул Куйнымда кырагай кайгы югына!* Г.Сәлим

**КЫРАКЛА́У** *ф.* Кытаклау (утыра торган, чебиләре булган тавык тур.). *Әй кыраклый тавык, кыраклый, Әллә карчыгалар килгәнме?* Җыр

**КЫРАН** *с.* Оста, житез, елгыр, күп һәм җиңел аулый торган. *Каратургай дигән кушаматка Кыран бөркет күптән күнеккән.* Н.Дәүли

◊ **Кыранга килмәү** Гадәттән тыш эш, гамәл кылу, сүз әйтү. *Ә «кыранга килмәгән» дигәнне ничек аңларга?* М.Мәһдиев. **Кыран галәмәт кылану** Бик нык гаугаланып, мәж килеп йөрү. **Кыран да булмый (булмас)** *диал.* «Нәрсә дә булмый», «бернәрсә дә булмас» мәгънәсендә кулланыла

**КЫ́Р АТАСЫ** *и. миф.* Борынгы ышанулар буенча кырга хуҗа дип уйланылган мифик зат. *Кырда урак урганда «җир хакы» бирү, «җир иясе»н, «кыр атасы»н ризалату кебек борынгыдан килгән ышанулар белән бәйле йолалар да булган.* Мәгърифәт

**КЫ́Р АТЫ** *и. зоол.* Тарпан

**КЫРА́У** *и.* Көндез һаваның җиргә якын катлавында яки туфракта температура җылы булып, кичен яки төнлә 0°тан түбән төшкәндә барлыкка килә торган бәс, сыкы. *Инде җирдәге кырау көндезләрен эреми ---.* М.Мәһдиев. *Агачлар тәмам шәрәләнеп калды, елгалар-күлләр юка гына боз белән капланды, ялан-кырларга ак кырау ятты.*Ә.Еники. *Төнлә каты кырау төшәчәк икән.* М.Маликова

**КЫРА́У АЛУ** *ф.* 1) Кыраудан зарарлану, һәлак булу (игеннәр, яшелчәләр, җиләк-җимешләр тур.). *Карабодайны кырау алды, борчак, җир өстендә үк ярылып, орлыгын да кайтармады.* Г.Бәширов. *Кырау да, салкын да алмый торган бу чәчәкләр тере түгел, бәлки чын терелекне имитацияләү генә.* А.Тимергалин

2) *күч.* Зыян килү, бетерү, юкка чыгару. *Чәчәк аткан яшьлегеңне Көзге кырау алмасын.* Ә. Ерикәй

**КЫРА́У КУНУ** *ф.* 1) Кырау төшү

2) *күч.* Агару; чалару. *Чигәләргә еллар кыравы кунса да, маңгайда сырлар күренсә дә, рәнҗер хәлең юк.* Б.Камалов

**КЫРАУЛАНУ** *ф.* 1) Кырау төшү. *[Мәче башлы ябалаклар] --- йонналары, канатлары кырауланып катса да, алар аның өчен борчылмыйлар, тик үзләренең саргылт күзләрен уйнатып --- кычкырышалар, шаулашалар [иде].* Ш.Әхмәдиев

2) *күч. сөйл.* Агару, чалару

**Кыраулана башлау** Кыраулана башларга тотыну. *Галиәкбәр абзый кыраулана башлаган куе кара мыегын сыпырасыпыра болай диде.* И.Туктар

**КЫРАУЛЫ** *с.* 1) Кырау төшкән. *Кемгә ничек, Айрат Арслановның тавышын тыңлаганда, минем күз алдыма кыраулы һәм чалт аяз көзге таң килә.* Р.Заһидуллина

2) Кыраудан бәсәргән, сыкыланган. *[Бай:] Куркыныч бит, кышны сезчә кышласаң. Ул кара көзнең кыраулы кырлары, Чиркәнеч һәм вак, суык яңгырлары!* Г.Тукай. *Көз иде... Җирнең шушындый Күңелсез чагы иде, Астралар, гөлләр кыраулы, Каеннар сары иде.* Х.Туфан

**КЫРА́У СУГУ** *ф. к.* **кырау алу**. *Үзе [Фатыйма] исә кырау суккан бәрәңгесенә алмаш орлык эзләп чыккандыр...* А.Хәлим. *Ай да йөзен сирәк ача күк иле гөмбәзендә, Кыраулар суккан таңнарда җир йөзе бизәген дә.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *[Сәлимә:] Өченчедән, районда синең абруйга кырау сукты, бәгырь.* Н.Гыйматдинова

**КЫРА́У ТӨШҮ** *ф.* 1) Җир өстендә кырау барлыкка килү. *Берничә көн рәттән иртән түбәләрне һәм чирәмнәрне агартырлык булып кырау төште.* М.Гали. *Бу таңда чынлап та көчле кырау төшкән, һәм бу кырау --- бәрәңге үсентеләрен карасу шәмәхә ялкын белән көйдергән иде.* А.Хәлим

2) *к.* **кырау алу** (*2 мәгъ.*). *Башыңа сырхау килсә, кесәңә кырау төшә.* Мәкаль. *Ярты еллап элек югалган ферма мөдиренең табылуы көтелмәгән ыгы-зыгы тудырды, өмә халкының кәефенә кырау төште.* Н.Әхмәдиев

3) *күч.* Көч, дәрт бетү. *Агарса да чәчләр көмеш кебек, кырау төшмәс безнең йөрәккә.* М.Җәлил. *Әмма каршылыклы уйлар ирек бирмәде, аның [Ринатның] берничә минут элек кабынган хисләренә кырау төште, дәртле уйларын юкка чыгарды.* Н.Хәсәнов

**КЫРАЧ** *с.* Үзәккә үтә торган, бик салкын һәм кискен (җил тур.). *Әмма җәйнең эссе кояшында көеп, көзнең кырач җилендә өтелгән, янып торган кызгылт көрән битле, ялкын чәчрәтердәй үткен күзле бу яшь киекләрдән*

*[кызлардан] бетмәс-төкәнмәс яшьлек дәрте бәреп тора.* Г.Бәширов

**КЫРАША** *и. диал.* Карпсыманнар семьялыгына караган, төче суда яши торган балык; кара табан балык. *Салих кармактан каралҗым яшькелт озын кыраша ычкындырып күпергә ыргытты.* Г.Мөхәммәтшин

**КЫ́Р ӘЛҮЕ** *и. бот. к.* **әлүчә**

**КЫР-БАСУ** *җый. и.* Кырлар һәм басулар. *Колхоз рәисе чагында ук Лотфулла кыр-басуда адашкан сыер-сарыкны фермага куып яптыра --- иде.* Н.Гыйматдинова

**КЫ́Р БӘРӘҢГЕСЕ** *и. бот. диал.* Мәкчәчәклеләр семьялыгыннан абагасыман яфраклы, сабак очында чукка тупланган сары, аксыл, миләүшә төсендәге чәчәкле, чәчәкләрендәге нектарны озын борынлы бөҗәкләр генә суыра ала торган күпьеллык үлән үсемлек; сәрдәнә, калфакчәчәк; *русчасы:* **хохлатка**. *Безнең вакыт күп: тимер юлда коелып калган патроннарны җыеп, учак яндырып шартлатырга да, кыр бәрәңгесе, кузгалак кебек нәрсәләрне табып чәйнәргә дә өлгерәбез.* Г.Сәгыйров

**КЫ́Р-БОЛЫН** *җый. и.* Кыр һәм болын. *[Фазылҗан абый] --- бер дә йомышың юк икән, әйдә, Хөббиниса апаны утырт та кыр-болыннарга хозур кылып булса да кайт.* Р.Төхфәтуллин

**КЫРГАВЫЛ** *и.* Фазан кошлар семьялыгыннан, ата төрләре озын койрыклы, матур чуар каурыйлы булу белән аерылып торган эре киек кош; фазан. *Кызым баласы – кыргавыл.* Әйтем. *Отрядта алты семьялык: озын аяклылар яки чүп тавыклары, краксլар, кыргавыллар, көртлекләр, мисыр тавыклары һәм күркәләр.* Биология. Хайваннар

**КЫРГАВЫЧ** *и. диал. к.* **кыргыч** (*1 мәгъ.*) *[Нургали сыер савучыларга:] Бүген үк, сыерларыгызны кояшка чыгаргач, себерке, кыргавычлар белән коралланасыз да һәммәсен дә ялт иттереп куясыз.* Ә.Еники

**КЫРГАЯК** *и. зоол.* Тигез аяклы кысласыманнар асотрядыннан, юеш урыннарда үрчи торган, төнлә тереклек итүгә җайлашкан күп аяклы бөҗәк; юеш таракан; *русчасы:* **мокрица**. *Кыргаяк дигән бөҗәкне барыгыз да беләсез.* М.Мәһдиев. *Кышкы көннәрдә кайнар кер суы парыннан тәрәзәләр елый, чатлыклар юешләнә, кыргаяклар тагын да арта.* А.Шамов. *Кухня тәрәзәсенең тупсасы купкан, бәдрәфтәге торбадан су ага, кыргаяк оясына әйләнгәнен күрәсеңме?* Н.Акмал

**КЫРГЫЗ** *и.* 1) Телләре төрки телләр семьялыгының кыпчак төркеменә караган, Кыргызстанда яши торган, ислам диненең сөннилек юнәлешендәге төп халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Ниһаять, бик еракка китеп кояш та бата, җир өстенә бик тиз караңгылык иңә, ә күктә, төнгелеккә бер җиргәрәк җыелган кыргыз малларыдай, бихисап йолдызлар калка.* Ә.Еники. *Кыргыз, үзбәк – тел кардәшләребез, белорус, грузин – берсе дә чит түгел миңа.* Р.Ишморат. *[Егетләрнең] Берсе кыргызмы, казахмы шунда, икенчесе сап-сары башлы – әллә урыс, әллә украин инде.* Э.Касыймов

2) *иск.* XX гасыр башына кадәр: казак халкы. *Шәкертләрнең кайберәүләре кыш уртасыннан башлап кыргыз арасына тарала башлаганга күрә, самавыр куйдыручылар да азая башлады.* М. Гафури. *Ел башында далага – кыргызларга чыгып керәсем бар.* Ә.Гаффар

**2.** *с. мәгъ.* Кыргыз яки казак халкына караган, кыргыз яки казак халкы белән бәйләнешле. *Балтыйк буе әдәбиятларында, кыргыз әдәбиятларында һәм башка республикаларда да шулай ул.* Л.Ихсанова. *Ул татар, инглиз, кытай, уйгыр, үзбәк, кыргыз, казак һәм башка төрки телләрне камил белә һәм җиңел аңлаша ала.* А.Хәлим

**КЫРГЫ́ЗЧА** *рәв.* **1.** 1) Кыргыз телендә. --- *тантана башыннан ахырына кадәр диярлек кыргызча, дөресрәге, төрки телләрдә барды.* Р.Фәйзуллин

2) *иск.* Казак телендә, казакча

3) Кыргызлар яки казаклар кебек. *Татар бер кабат кыргыз җиренә чыгып йөрсә, җаны-тәне берлә кыргызга биреләдер. Үзенең өенә кайткач та, кыргызча утыра, аныңча әңгәмә суга, аныңча согындырышадыр.* Г.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Кыргыз телендәге. *Иң элек әсәрнең кыргызча оригиналын тәгәл укып чыктым.* М.Госманов

**КЫРГЫЗЧАЛАШТЫРУ** *ф. сөйл.* Кыргызчага тәрҗемә итү, кыргыз теленә күчерү

**КЫРГЫЙ** *с.* **1.** 1) Кулга ияләштерелмәгән (хайваннар һәм кошлар тур.). *Ыруг җирләре күп, хәтта чикләре дә мәгълүм түгел: болын-тугайларында елкылдап чапкан елкы көтүе; елгакүлләрендә балык, кондыз; карт юкә, имән куышларында аюлар гына менгән кыргый корт балы.* Х.Сарьян. *Кыргый атның горур башын элмәкләгән табунчыдай, кулга ала да берәү Вакытны, сөйри, сөйри үз юлына!* Р.Фәйзуллин. *Кояштыр, дип ант иткән Латышев Ләйлә исемле кызның гүзәллеге, чаялыгы, иң кыргый аттан да курыкмавы турында сөйләп утырган.* Х.Камалов

2) Культуралаштырылмаган, игеп үстерелми торган, махсус чәчелмәгән, коелган орлыктан үсеп чыккан (үсемлекләр һәм аларның җимешләре тур.). *Урманда кыргый алмагач Ялгызы үсте. Язын чәчәк койды, көзен Алмасы пеште.* Р.Гаташ. *Бакыр-тау калага бара торган юл буендагы гөлҗимеш, кыргый алмагач һәм груша куаклары арасыннан көтмәгәндә ниндидер --- ирләр килеп чыкты.* Н.Фәттах. *Бу семьялыктан кыргый үсемлекләр дә җитәрлек.* Кызыклар дөньясында

3) Кеше эзе салынмаган, каралмаган, эшкәртелмәгән; кеше яшәмәгән, табигый, беренчел. *Ашы тулган кукуруз чәкәненең яңа гына бөркелеп чыккан пумаласы төсле, кыргый болынлыкта елкылдап яткан көзге сусән уты сыман ул чәч Хәмидәнең йөзенә нур бөркеп тора.* К.Кәримов. *Чишмә бөтенләй кыргый түгел, кеше кулы тигәне сизелеп тора.* М.Галиев. *Ә монда? Ходай белсен, кыргый оҗмах.* М.Мәһдиев

4) Цивилизация үсешенең иң түбән баскычындагы; җәмгыять үсешенең борынгылык дәверенә караган. *Берваkыт, әни кайтып кергәндә, лампочкалар ватыгы өстендә кыргый индеецлар биюе биеп ята идек, бик каты эләкте үзебезгә.* Ф.Яруллин. *Рәсми тарих минем ерак бабаларымны күчмә тормышта яшәгән, артта калган кыргый төркиләр дип расләй.* М.Юныс. *Бу хәл*

*кыргый адәмнең тормышын тамырдан үзгәртә.* Кызыклар дөньясында

5) Бик борынгы, әллә кайчангы. *Сафыйларның бакчасында әле теге кыргый заманнардан ук калган, егерме метр биеклегендә бер кара чыршы бар иде.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Вәхши, җәмгыятьнең мораль-этик кагыйдәләренә буйсынмаган, кешелексез (кешеләр тур.). *Кыргый фашистлар*

7) *күч.* Тупас, надан, тәрбиясез. *Димәк, син дә күктәге йолдыз түгел? Шушы кыргый Шабановлар төсле үк?* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Аралашмаучан, тартынучан, оялчан. *Хуш исләре нинди – ничәмәничә төрле чәчкәләрнең суты җыелган чаер мае белән сыланган ---, таңгы офык сафлыгы күчкән бу кыргый балага.* Г.Якупова. *– Мәҗүси син, Трак, кыргый кеше, – диде штурман Маркин, баруыннан туктап.* М.Юныс

9) *күч.* Котырынкы, ярсулы, тыелгысыз; усал. *Күзләреннән кыргый очкыннар чәчрәтә башлаган Кадыйрның тиз генә басылырга нияте юк иде бугай.* М.Хәсәнов. *– Нишләп җанымны тотып торасың, җибәр! --- – диде ир кыргый тавыш белән.* Н.Гыйматдинова. *Генераллыкка омтылган солдат – искиткеч кыргый, куркыныч көч ул.* М.Юныс. *Казлар оча, кыргый аваз салып Җаннар сыман дөнья өстеннән – Кычкыралар алар Дөньяларның Газап ияләре исеменнән...* Зөлфәт

10) *күч.* Чиктән тыш, гадәттән тыш; сәер. *Авыл мәктәбендә сүзсез буйсыну, ихтирам-хөрмәт күреп ияләнгән директорга мондагы салкынлык һәм битарафлык кыргый, сәер иде.* В.Имамов. *Шул авазлар гына җиңәр Җанга ияләнгән кыргый курку хисен.* Л.Шагыйрьҗан

11) *күч. махс.* Нинди дә булса оешмага кермәгән, берләшмәгән; контрольдән читтә калган. *Кыргый артельләр. Кыргый предприятиеләр*

12) *күч.* Алдан махсус юллама алмыйча, ял итүче кеше үз көенә оештырган. *Трамвай йөртүчеләрнең күбесе – Олы фонтанда дача биләүчеләр һәм «кыргый» ысулда ял итәргә килгән турист халкы.* М.Юныс

**2.** *и. мәгъ.* 1) Цивилизация үсешенең түбән баскычында торган кабилә кешесе. *Кулга-кул тотышып, кыргыйлар кебек сикергәли-сикергәли әйләнәләр.* А.Гыйләҗев

2) *сөйл.* Кешеләр белән аралашмый торган кеше. *Әгәр Хәйдәр ялгышмаган булса, бу кыргыйның озын керфекләре арасында үчекләү очкыны да чәчрәп китмәде микән әле.* Г.Бәширов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Кулга ияләштерелмичә. *Гомер-гомергә [умарта] кортлар[ы] кыргый яшәгән, кеше аларны кулга ияләштергән.* Ф.Яруллин

2) Кешеләр белән аралашмыйча. *Мин – бер мишәр улы, кыргый үскән, ә син – күрше чуваш халкыннан.* Һ.Такташ

3) Ямьсез, тупас итеп. *Гөрләп бара вагон тулы кеше. Басып тора карчык, бөрешеп. Кырыенда ике яшь пар утыра Җәелешеп, кыргый көлешеп.* Г.Ибушев

**КЫРГЫ́Й ДУҢГЫЗ** *и. зоол.* Кабан. *Дымлы климатта кошлар йомыркаларны да көньяктагылардан күбрәк салалар, андагы җанварлар балаларны да ишлерәк китерә, кыргый дуңгызлар да эрерәк була.* Кызыклар дөньясында

**КЫРГЫ́Й ҖИТЕН** *и. бот. к.* **баллы чәчәк**. *Кыргый җитен препаратлары агулы, шуңа күрә, аларны эчкәнгә кадәр, врач белән киңәшергә кирәк.* Урман аптекасы

**КЫРГЫ́Й ЗӘЙТҮН** *и. бот.* Зәйтүнчәләр семьялыгыннан, тар озынча аскы ягын көмешсыман кунык капланган көрән яшел төстәге яфраклы, чәчәкләре хуш исле, чәнечкеле куак яки агач; *русчасы*: **лох**

**КЫРГЫ́Й КИШЕР** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан, як-якка тармакланып киткән нечкә тармаклары булган юан үзәк тамырлы, сабагы кырланып торган буразналы, сары, яшел яки ак төстәге чәчәкле, имән, нарат урманнарында, сазлыклы болыннарда үсә торган баллы үсемлек; *русчасы:* **горичник**

**КЫРГЫЙЛАНУ** *ф.* 1) Кыргыйга әйләнү, кыргый булып китү. *Өркеп, сагаеп кына Йөри ул [мәче] кырыйлардан, Сөю-сыйпау күрмәгәч, Ничек тиз кыргыйланган.* Ш.Галиев. *Аннары, бүреләр бетсә, икенче җәфа: кыргыйланган этләр аларның урынын алырга мөмкиннәр.* Кызыклар дөньясында

2) Эшкәртелмәү, каралмау. *Карлы кантар асларында Орлыклар өшеп ята, Кыргыйланган кыр, сагынып, Моң суза безнең хакта.* Зөлфәт. *Салабаш урманы чыннан да кыргыйланды.* Н.Гыйматдинова

3) Усаллану, вәхшиләнү. *Төн уртасы. Буран тынып калды, Кыргыйланмый урап өйләрне.* Г.Сәгыйров. *Моңарчы ирешелгән цивилизация казанышлары юкка чыга, кеше бик күп нәрсәләрне оныта, кыргыйлана ---.* С.Шәмси

4) Кеше белән аралашмый башлау

**Кыргыйлана бару** Торган саен ныграк кыргыйлану

**Кыргыйлана башлау** Кыргыйлык билгеләре күренү. *Тормышта кыйналакыйнала, соңгы чиктә без – адәм балалары – үзебезнең кыргыйлана башлаганыбызны сизмибез.* З.Хөснияр

**Кыргыйланып бетү** Тәмам кыргыйлану. *Кайчандыр тәрбияләп, карап кына үстергән чәчәкләр тәмам кыргыйланып беткәннәр, әрекмән яфраклары астыннан чак кына күренәләр.* А.Тимергалин

**Кыргыйланып йөрү** Берникадәр вакыт аралашмау, үз-үзеңне начар тоту

**Кыргыйланып китү** Кинәт яисә бераз кыргыйлану

**КЫРГЫЙЛА́РЧА** *рәв.* 1) Кыргыйлар кебек, кыргыйлар гадәтенчә

2) Ямьсез итеп. *Раббани, сары тешләрен ыржайтып, кыргыйларча көлә башлады.* Ш.Шәйдуллин. *Ниһаять, «өн» эчендә кемдер кыргыйларча кычкырып җибәрде.* Г.Паушкин

3) Тупас, дорфа итеп

**КЫРГЫЙЛАШУ** *ф. к.* **кыргыйлану.** *Йодрык селки кыргыйлашкан өер, Ирек бирсәң, җәлләп тормаслар.* Р.Низамиев

**Кыргыйлаша бару** *к.* **кыргыйлана бару**

**Кыргыйлашып китү** *к.* **кыргыйланып китү**

**КЫРГЫЙЛЫК** *и.* 1) Цивилизация үсешенең түбән баскычына караган, шул чор белән чагыштырып бәяләнгән күренеш. *Дөньяда шуныңчы кыргыйлык яшәгән.* Ф.Яруллин. *Кыргыйлыкка*

*охшаш бер гадәтме – Тәртипсезлек булса бүлмәмдә, Мин үземне иркен итеп тоям, Мин баерак кебек бу мәлдә.* М.Галиев

2) Вәхшилек; тупаслык. *Кул күтәреп суга алмый ул студент егеткә, хәленнән дә килми, табигате дә сыйдырмый андый кыргыйлыкны.* Ә.Еники. *Бу кадәр кыргыйлык, хайванлык каян килә?* Ф.Яруллин. *Табигатьне саклауда, бәлки, безгә дә, андый кыргыйлыкларга барып җитмәстән, үтемлерәк чаралар күрү кирәктер.* Кызыклар дөньясында

**КЫРГЫЙ САЛАТ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, сабакларында һәм яфрагында сөтсыман суты булган үләнчел үсемлек; агулы билчән; күк билчән; *русчасы:* **латук**

**КЫРГЫЙ САРЫК** *и. зоол.* Аргали; куышмөгезлеләр семьялыгыннан, бормаланып торган зур мөгезле эре тау сарыгы

**КЫРГЫЙ СЛИВА** *и. бот.* Күгән; розачәчәклеләр семьялыгыннан, куның каплаган караңгы зәңгәр төстәге, эчендә сөякле төше булган җимешле, чәнечкеле куак; *русчасы:* **тёрн**

**КЫРГЫЙ ТАРЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, терлек азыгы буларак кулланыла торган үләнчел үсемлек; кан туктаткыч үлән; *русчасы:* **росичка.** *Без алып кайта торган бер арба кычыткан, күзлут, сусән уты, эт эчәгесе, кыргый тары үләннәреннән, киптергәч, сыер белән сарыкларга өч салырлык печән чыга.* Ә.Гаффар

**КЫРГЫЙ УКРОП** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан, яфраклары каурыйсыман җепселләргә телгәләнгән, сары чәчәкле үлән; фенхель. *Кан басымы, атеросклероз белән авыручылар җәй буе бакчаларда календула, ромашка, петрушка, кыргый укроп, алабута үстерә һәм җыя алалар.* Ватаным Татарстан

**КЫРГЫН** *и. сир.* 1) Сугыш. --- *Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасындагы яман кыргыннан соң ---.* Х.Сарьян. *Татар: «Азатлык!» – дип кычкырса, Җавап булыр микән кыргын, үлем, Дөнья халкы карап тик торса.* Л.Садри

2) Кешеләрнең күпләп үлүе. *Кыргын төшсә дә кырык ел чыдар.* Мәкаль

**КЫРГЫЧ** *и.* 1) Нәрсәне дә булса кырып чистарту җайланмасы. *[Котырынкы уйларны] Кыргыч белән дә кырып төшерә алмассың.* Б.Камалов. *Буяу, пумала, кыргыч, кадак, тагын әллә никадәр кирәк-ярак төяп, төш авышкач кына кайтып төште ул.* Р.Мулланурова. *Казу эшләре вакытында таштан ясалган эш кораллары – чапкычлар, кыргычлар, кискечләр һәм, сирәк булса да, кыргый хайван сөякләре табыла.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Атны чистарту өчен махсус тимер щётка; кашау, кашавыч. *Металл ватыклары арасында «Зингер» тегү машинасы, ухватлар, ат кыргычлары, бизмәннәр --- бар иде.* М.Мәһдиев

3) Аш-су әзерләгәндә яшелчәләрне ваклау җайланмасы. --- *фужерлар, кычкырып торган чәчкәле чәйнекләр һәм чәйнүшкәләр, тоткычлар һәм кыскычлар, кыргычлар һәм угычларның берсенең дә бәяләмә хаклары куптарылмаган ---.* А.Хәлим. *[Әби] [кызыл чөгендерне] --- аннары кыргычтан уа, песок сала.* Г.Кашапов. *Калынрак киселгән кыяр башларын вак тишекле кыргыч аша үткәреп, биткә тигезләп җәясең һәм 15–20 минут ятып торасың.* Серле календарь

4) *тех.* Нефть скважинасын парафиннан чистарту җайланмасы. *Нефть көпшәсенә утырган парафинны скважинага кыргыч төшереп, аны чыгыр белән күтәртәләр...* Ш.Бикчурин. *Чыбыгы өзелеп, кыргычы скважинага төшеп киткән һәм анда бик уңайсыз яткан ахры, нефть чыгу сизелерлек кимеде.* Р.Төхфәтуллин

5) *зоол.* Кайбер хайваннарда: каты тешчекләр белән капланган тел. *Анда [йоткылыкта] каты тешчекләр белән капланган итчел тел урнашкан, бу кыргыч дип атала.* Биология: хайваннар

6) *сир.* Бетергеч

**КЫРГЫЧЛА́У** *ф.* 1) Кыргыч белән эшләү, чистарту, ваклау. *Ат сараеи ындыр табагы төсле чиста тотты Хәйретдин агай, атны кыргычлап, ялтыратып, коендырырга Олы суга алып төште ---.* А.Гыйләҗев. *Ат түгелдер бит ул кыргычларга?* Р.Мулланурова

2) *күч.* Кыйнау. *Ләкин партизан туплары, Мылтык һәм кылычлары Самурайлар токымының Аркасын «кыргычлады».* Ш.Маннур. *Ә теге, синең тез астыңны портфель белән кыргычлаган юан гәүдәле абзый, сыңар кул белән тотынып, асылынып барганда, сиңа талон бирә.* М.Мәһдиев

**Кыргычлап алу** Тиз генә кыргычлау

**Кыргычлап бетерү** Кыргычлауны тәмамлау

**Кыргычлап җибәрү** Тиз генә бераз кыргычлау. *Черегән ниргәләрне алыштырып, каралганнарын эчен-тышын кыргычлап җибәргәч, өй менә дигән булды.* Ф.Яруллин

**Кыргычлап тору** Әледән-әле, еш кыргычлау; һәрвакыт кыргычлау. *Ул хисләр еллар юшкынын кыргычлап торырга тиеш.* Ш.Галиев

**Кыргычлап чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр бер-бер артлы кыргычлау. *Мин үземнең акыл тирәнлегенең сай казанын кыргычлап чыктым, бер касмагы да калмады.* М.Галиев

**КЫР-ДАЛА** *җый. и.* Кыр һәм дала. *Кыр-даланы иңләп атлар чаба, Ау этләре кала көнләшеп.* Р.Сафин

**КЫРДАШ** *с.* **1.** 1) Кем белән булса да бер басуда, кырда бергә эшләгән. --- *җәенә өч-дүрт мәртәбә һәр чөгендер үсентесе белән күзгә-күз карашырга, хәер-фатыйха теләп төбен йомшартырга, --- җилле кырдаш күршеләреңнән бер карышка да калышмаска кирәк.* Ф.Җамалетдинова

2) *геом. иск.* Чиктәш. *Кырдаш почмаклар*

**2.** *рәв. мәгъ.* Янәшә. *Ай чамасы узгач, минем белән кырдаш йоклаган Янис Цивинып миңа пышылдый: – Кызыл Армия белән Латвиядән китеп, без ялгыштык.* З.Зәйнуллин

**КЫ́Р ҖИТЕНЕ** *и. бот. сөйл.* Күккүз; күкбаш; *русчасы:* **василёк**. *Өммегөлсем Гарифуллины эре сабаклы әрекмәннәр, зәңгәр кыр җитене баскан тыкрыктан алып керде.* А.Хәлим

**КЫ́Р ЗӘГЪФРАНЫ** *и. бот.* Сусынчалар семьялыгыннан, тамыры бүлбегә охшаган, кыска сабаклы, иртә язда зәңгәр, ак, сары төстәге чәчәк ата торган көньяк үсемлеге; *русчасы:* **крокус**

**КЫРКА** *рәв. диал.* Кискен, коры итеп. *Кырка сөйләшү*

**КЫ́Р КАЗЫ ЮЛЫ** *и.* Киек каз юлы. *Бераздан йолдызлар арасындагы, кыйблага таба сузылган, сыеграк, киңрәк салават күпере шикелле булып, ап-ак, бормалы-бормалы Кыр казы юлы да беленде.* М.Гали. *Мамык перчаткаларыңны кидем дә кулларыма, Карадым зәңгәр күктәге Кыр казы юлларына.* Ф.Кәрим

**КЫРКАПКА** *и.* Авылны әйләндереп алган киртәнең капкасы. *Кыркапка ачык калган.* Ә.Галиев. *Урман читендә урнашкан авыл кыркапкасына, тузан туздыра-туздыра, зәгъфран төсендәге «Жигули» килеп керде.* Г.Кашапов. *Кыркапка түбәндәге басудан да ярты сәгать кайта [ул].* Б.Камалов

**КЫ́Р КӘБЕСТӘСЕ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан, түбәнге яфраклары лирасыман, югарыдагылары тоташ читле, сары чәчәкле үләнчел үсемлек; эт какысы; *русчасы*: **сурепка**

**КЫ́Р КӘҖӘСЕ** *и. зоол.* Боланнар семьялыгыннан, кырда, урманда яши торган, ата төрләрендә 3–4 тармаклы кечкенә мөгезе булган, партоялы имезүче хайван; коралай; *русчасы*: **косуля**. *Көтүче кыш көнендә урманда агач төбеннән берничә кыр кәҗәсе тапты.* Г.Тукай. *Агач асларында бозау тикле кыр кәҗәләре көтүе ята.* М.Мәһдиев. *Сазлыклы урманнардагы боланнар һәм кыр кәҗәләре начар үсәләр, һәм аларның мөгезләре дә гарипләнгән төсле бөгелеп-сыгылып беткән.* Кызыклар дөньясында

**КЫ́Р КИШЕРЕ** *и. бот. к.* **кыргый кишер**

**КЫРКУ** I *ф.* 1) Кисү, кисеп җыйнаклау. *– Үсә, күп үсә [курай], бер колач кыркып китерергә була, – диде ул [агай], кәефле генә елмаеп.* Ә.Еники. *Хәлдән тайганчы печән чаба ул, сәндерәсен тутыра, тезмәсен тутыра, бакча буенда кибән өя, әле һаман җитми аңа, урман аланын кыркый.* Н.Гыйматдинова

2) Урак белән ашлык уру. *Хатыннар гына түгел, малайлар, егетләр дә башак кыркый иде.* Ә.Баян. *Арыш аз гына балавызландымы, Адюк башак кырка башлый.* Ш.Маннапов

3) Тешләре белән кисеп, өзеп алу (терлек тур.). *Таралышып, маллар уҗым кыркый.* Н.Әхмәдиев. *Атлар, ара-тирә пошкыра-пошкыра, салмак кына печән кыркый.* Р.Батулла

4) Сарык, куй һ.б.ш. хайваннарның кайчы яки махсус җайланма белән йонын алу. *Куйны кырыкканда, тәкә калтырый.* Мәкаль. *Хәтта бер көнне [Тамара] шуның [этнең] йонын кырыккан да ваннада юындырып чыгарган.* Ф.Яруллин. *Әни белән Садыйка түти сарыкларының чалыштырып тышаулаган чәлтерләренә тезләнеп алганнар да, кырт-кырт иткән кайчы тавышы --- чыгарып, йон кыркалар.* А.Хәлим

5) Атларның ялын, койрык кылларын кисү

6) *сөйл.* Чәчне түбеннән үк алу, бик кыска кисү. *[Мин] Военкоматта чәчне кыркып кайтаргач, кызларга күренергә оялып йөрдем.* М.Мәһдиев. *Гыйләҗи абзый аларның башларын сабынлыйсабынлый кырмый, ә кайчы белән кырка.* Ф.Яруллин

7) Сакал-мыекны кыру

8) *күч. сөйл.* Даими талау, кеше исәбенә яшәү

**Кыркый бару** *к.* **кыркып бару**

**Кыркый башлау** Кыркырга тотыну. *Җайдаксыз калган атлар, туктап, чирәм кыркый башлый.* Р.Батулла

**Кыркый бирү** Бернәрсәгә карамастан кыркуны дәвам итү

**Кыркый төшү** Бераз кырку

**Кыркып алу** Тиз генә кырку

**Кыркып ату** Тиз арада кырку

**Кыркып бару** Тоташтан кырку

**Кыркып бетерү** Тулысынча кырку; барысын да кырку

**Кыркып йөрү** Әле, хәзерге вакытта кырку. *Казыкка кыска бау белән бәйләп куйган тәбәнәк соры сыер җәймә зурлыгы чирәмлекне кыркып йөри.* М.Юныс

**Кыркып кую** Алдан ук кырку. *Басу шәрә. Комбайннар Тигез итеп кыркып куйган.* Ш.Галиев

**Кыркып ташлау** Тиз генә, җәһәт кенә кырку // Рәхимсез кырку. *Чалгы белән кыркып ташлагандай түнгән хәлсез солдатлар тау өстеннән я корсакларында шуышып, я тәгәрәшеп аска коелалар.* Р.Сафин

**Кыркып тору** Даими, әледән-әле кырку. *[Минем чәчләрне] Кырыкмый торсаң, кап-кара тубал кебек үсәләр.* Р.Хафизова. *Пычранган йонны кыркып торырга һәм артык үскән тоякларны саклык белән кыскартып кисәргә кирәк.* Йорт эшләре

**Кыркып чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тулысынча кырку. *«Ур, ур, урагым. Саплы, затлы коралым», – дип пышылдавың була, урагың кулдан ычкынып, бөтен басуны кыркып чыга.* Р.Хафизова. --- *Әхәт солыны кыркып чыкты.* Р.Кадыйров

**КЫРКУ** II *с.* **1.** 1) Артык тозлы, артык ачы (аш һ.б.ш. тур.). *Әйтик, «кырку аш» – тозы бик күп салынган аш ---.* М.Мәһдиев. *Гашыйк кешенең ашы кырку була ул...* Р.Вәлиев

2) Көчле тәэсир итә торган, зәһәр. *Эчемлек кырку, зәһәр иде. Коньяк диярсең.* Х.Камалов

3) Усал, кырыс; кызу канлы. *Шәрифә бераз кыркурак та, теллерәк тә булып китә, ләкин Рәүфә моны аның чит күрүе итеп түгел, ә олылыгы итеп хисаплый иде.* А.Шамов. *Атаңның холкы бик кырку бит.* Р.Вәлиев. *Дөрес, кырку да син, каудар да син кайчакта.* С.Лашманчы

**2.** *рәв. мәгъ.* Кырыс, кырыс итеп. *– Нәрсә кыяфәтең бик кырку күренә? – дип сүз катты аңа колхоз башлыгы.* Р.Вәлиев. *Ул ятарга җыенып йөргән икән, кәефсез каршылады чакырылмаган кунакны, кырку сөйләште.* Р.Камалов

**КЫРКУЛАНУ** *ф.* 1) Озак кайнау сәбәпле тозлы, әче булып китү (аш тур.)

2) Артык әчеләнү (сыра, бал тур.)

3) *күч.* Кырысланy, усаллану

**Кыркулана бару** Торган саен кыркулыгы арту

**Кыркулана төшү** Бераз кыркулану

**Кыркуланып бетү** Бик нык кыркулану. *[Маһибәдәр:] Шулпам да кыркуланып беткәндер инде, и балакаем!..* А.Гыйләҗев

**Кыркуланып китү** *к.* **кыркулана төшү**

**Кыркуланып тору** Кыркуланган булу

**КЫРКУЛЫК** I *и. сөйл.* Сарык кырку өчен кайчылар

**КЫРКУЛЫК** II *и.* 1) Кырку булу, тозлылык; артык ачылык (аш һ.б.ш. тур.)

2) *күч.* Кырыслык; кызу канлылык. *[Бәһрам:] – Серкәң су күтәрми, сүз көрәштереп мәгънә чыкмаячак, җитмәсә тагын кирәкмәгән дуамалсың, шул кыркулыгыңны белгәнгә күрә әйтәм бу сүзләрне, – дип өстәп куярга да онытмады.* М.Хәсәнов

**КЫРКУЧЫ** *и.* Сарык йонын алучы кеше. *Өмәгә кыркучылар чакыру*

**КЫРКУЧЫ ТИМРӘҮ** *и. мед.* Тире, чәч, тырнакларны зарарлый, кайчак кычыту белән дә характерлана торган йогышлы гөмбәчек авыруы; *русчасы:* **стригущий лишай, трихофития.** *Кыркучы тимрәү йоктыру*

**КЫ́Р КҮГӘРЧЕНЕ** *и. зоол.* Күгәрченнәр семьялыгыннан, күгелҗем төстәге зур булмаган урман кошы; әберчен; *русчасы*: **вяхирь**. *[Габдерәшит бабай карчыганың] Кечерәген, көче җитмәс дип, бoҗыр, кыр күгәрчене күк ваграк кошларга гына җибәрә иде.* Г.Рәхим

**КЫР КҮГӘРЧЕ́Н КҮЗЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгына караган, зәңгәр биш таҗ яфракчыклы, уртасында сары күзе булган вак чәчәкле чүп үлән; *русчасы:* **незабудка полевая**

**КЫРКЫЛДА́У** *ф.* Кыр-кыр килгән тавыш чыгару, кыткылдау. *Күпме кыркылдаса да, тавык очып тау ашмый.* Мәкаль. *Галимҗан оныгы чиркәү кадәрле йортта күперенеп йөргәндә, нигә Сәвилә тавык кетәклегендә кыркылдарга тиеш, ди.* Н.Гыйматдинова

**Кыркылдап алу** Бераз кыркылдау

**Кыркылдап кую** Кинәт, бер тапкыр кыркылдау

**КЫРКЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кырку**. *Чулпылары чыңлап торган озын толымнар урынына ирләрчә кыркылган чәч ---.* Р.Төхфәтуллин. *Балаларның чәчләре кайчы белән керделе-чыктылы кыркылган ---.* А.Иванов

2) Ышкылудан тузу

**Кыркыла бару** Торган саен ныграк кыркылу

**Кыркылып бетү** Бик нык кыркылу, сизрәп тузган кыяфәткә килү. *[Халәп агай] --- кыркылып беткән бүреген салып, тез башына кидереп куяр иде.* М.Хәсәнов

**КЫРКЫЛЫК** *и. диал.* Сарык йонын алу өчен зур кайчы

**КЫРКЫЛЫШУ** *ф. диал.* Сатулашу

**Кыркылышып алу** Бераз кыркылышу

**КЫРКЫМ** *и.* Бер кыркып алынган йон күләме. *Киткәндә әнисе: «Үзеңә пирчәтке бәйләп киярсең, бармакларың да бишинә тотудан бизмәсен», – дип, бер кыркым язгы йон тыккан иде.* Р.Төхфәтуллин

**КЫРКЫН** *и. иск.* Кол кыз, кәнизәк, кырнак, җария

**КЫ́Р КЫНАСЫ** *и. бот.* Кыңгыраучәчәклеләр семьялыгыннан, тармакланмаган туры озын сабаклы, башак чәчәк төркеменә тупланган зәңгәр чәчәкле декоратив үсемлек; *русчасы:* **колокольчик болонский**. *Күләгәле урыннарда бик кызыклы бер үсемлек – кыр кынасы (тидермәс) очрый.* Ботаника

**КЫ́Р-КЫР** *иярт.* 1) Бака һ.б.ш. кычкырган тавышны белдерә

2) Йөткерү-какыру тавышын белдерә. *Йөткерә чахотка күк кырр! кырр!* Г.Камал

**КЫ́Р-КЫР КИЛҮ** *ф. к.* **кыр-кыр итү**. *[Тавыклар] Йоттылар да, кыр-кыр килеп, Тик йөриләр җырлашып. Вәсимә белән без генә торабыз аптырашып.* Ш.Галиев

**КЫРКЫРЫЙ** *и. бот. к.* **кәҗә чәчәге**

**КЫРКЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **кырку** I (*1, 2 мәгъ.*)

2) *диал.* Сатулашу, кыркылышу. *Әти бик озак сатулашып, бик нык кыркышканнан соң гына, кәҗәне ике сум егерме биш тиен көмешкә сатып җибәрде.* М. Гафури

**Кыркышып алу** *к.* **кыркылышып алу**

**КЫРЛАНГЫЧ** *и. иск. к.* **карлыгач**

**КЫРЛА́У** I *ф.* **1.** 1) Кыр II (*2 мәгъ.)* ясау, кырлы итү. *Камчыларын кырлап үргән, Тармакларын кыллап үргән.* Ш.Маннур

2) Кырып һәм шомартып, ташка (пыялага, металлга һ.б.ш.га) почмак ясап кисешә торган яссы өслекләрдән торган форма бирү. *Сүзлектә кулланылган «кырлау» терминын ювелирлык эшендәге «огранка»га калдырыйк ---.* А.Тимергалин. *Кырлап ясалган бриллиант матурлык, камиллек, бәһасезлек үлчәме итеп санала.* Татарстан

**2.** *и. мәгъ.* Кыру, кисеп, шомартып билгеле бер формага кертү эше. *Киевның алмаз кырлау фабрикасында эшләүче 24 яшьлек Людмила С. 15 мең долларлык 25 бриллиант йоткан.* Иң шәп календарь

**3. кырлап, кырына** *бәйл. функ.* Яныннан, янәшәсеннән; янына, янәшәсенә. --- *барам елга кырлап әкрен генә, теге карчык керне юа да елга кырына өя.* Әкият

◊ **Кырлап килү** Тутыру, түгәрәкләү. *Инде кырыкны кырлап килгән Галимҗан өчен бигрәк тә тансык иде.* С.Поварисов. *Ни әйтсәң дә, Тимергали бабай унынчы дистәне кырлап килә.* В.Имамов

**КЫРЛА́У** II *ф.* Кыр-кыр иткән тавыш чыгару. *Күзләрен әйләндереп салган тавык кырлап кычкырып җибәрде.* Г.Толымбай. --- *тавыклар, аның дәртдәрманын көчәйтеп кырлый-кырлый, читән күләгәсендә сырпаландылар.* А.Гыйләҗев

**Кырлап алу** Бераз кырлау

**Кырлап йөрү** Бертуктаусыз кырлау. --- *Шамил атылып ишегалдына барып керде, кырлап йөргән ваемсыз тавыклар төрекөмеш сыман төрле якка сибелделәр.* Я.Зәнкиев

**Кырлап йөрү** Бертуктаусыз кырлау

**Кырлап кую** Кинәт, бер тапкыр кырлау

**КЫРЛАЧ** I *и.* 1) Кышның иң салкын ике аеннан гыйбарәт сезон (декабрь – январь). *Энем кырлач* (*январь*) *агам кырлачны* (*декабрь*) *уздырам дип әйтә, ди.* Әйтем. *Бу декабрь кырык икенче елның кырлач суыгына ялганып китте.* Х.Сарьян. *Безнең илләр матурлыгы: кышын – кырлач, җәен – чиллә.* Г.Афзал. *Кырлач дип кышның иң суык вакытларына әйткәннәр.* Мәдәни җомга

2) *тар.* Көзнең соңгы көннәрендә яки кыш башында кыргый тояклы хайваннарга оештырылган ау

**КЫРЛАЧ** II *и. бот.* Карабодайчалар семьялыгыннан чәчәкләре ике җенесле, башаксыман яки себеркәчсыман чәчәк төркеменә берләшкән үсемлек; кымыз-

лык (*2 мәгъ.*). *Бабам кырлач яфрагын турап, төрле салат әзерләде, ә яшь сабакларын тамыр белән бергә кушып --- ботка итеп пешерде.* К.Тәхау

**КЫРЛАЧ** III *и. диал.* Басуның башбашларында эшкәртелми чи калган яки урылмый, чабылмый калган кечкенә җир почмагы. *Сукалаганда, кырлач калдырырга ярамый*

**КЫРЛАЧ** IV *и. диал.* 1) Биеклек, биек урын

2) Тау сырты. *Кылганнар арасында тамак ялгарлык бернинди үлән әсәре – кымызлык, кузгалак, балтырган, сарана, җиләк сыман нәрсә күзгә чалынмады. Тау кырлачында аларның булуы мөмкин дә түгел иде.* А.Хәлим

**КЫРЛАЧ** V *с. диал.* Юка һәм төз (борын тур.). *Кырлач танаулы егет урлаган иде аның йокы фәрештәсен.* Г.Якупова

**КЫРЛЫ** *с.* Кырлап эшләнгән. *Ул [Тимерхан] хәзер чиста-пөхтә йөри, Фәрхеҗиһан түтәсе аның күлмәкыштаннарын гел юып-киптереп, кырлы бәләк белән тәгәрәтеп бирә.* Г.Ахунов. *Халидә мәҗлес алдыннан кибеткә барып, җиде тиенлек кырлы стаканнар алып кайтты.* К.Кәримов. *Мәйдан уртасында кызгылт көрән лабрадордан ясалган дүрт кырлы биек монумент тора.* М.Юныс

**КЫРЛЫ́ БОРЧАК** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, башка үсемлекләрнең сабагына уралып эләктерергә мыеклары булган, борылмалы түшәлмә сабаклы, терлек азыгы итеп кулланыла торган үсемлек; *русчасы:* **чина.** *Болында тукранбашлар, тычкан борчагы, кырлы борчак, казаяк, олыбаш, кындырак, төлкекойрык һ.б. болын кыяклылары үсә.* Татарстан географиясе

**КЫРЛЫГАН** *и. бот.* Мәрсидчәләр рәте кырлыганчалар семьялыгыннан, тармакланмаган, төз, туры, озын сабаклы, озынча тар яфраклы, сабак очында чукка тупланган ачык алсу кызыл чәчәкле күпьеллык үлән; *русчасы:* **кипрей.** *Калкулыкларда, иңкүлекләрдә, урман кисентеләрендә кырлыган җете кызыл чәчәк аткан.* К.Тәхау. *СССР-ның урта һәм төньяк зоналарындагы урманнарда түбәндәге баллы үсемлекләр үсәләр: кырлыган, дәгил, клевер, мәтрүшкә, күкебаш --- һәм башка күп кенә үләннәр.* Умартачылык. *Кырлыганның чәчәкләре, башка үсемлекләрнең чәчәкләренә караганда, балны күбрәк бирәләр.* Робинзон эзләреннән

**КЫРЛЫГАНЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Хан үләне, фуксия, урман чәе кебек икеөлешле үсемлекләрне берләштерә торган бер семьялык

**КЫРЛЫ́ ҖИМЕШ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан, күбрәк Уралда үсә, кипкән сабакларыннан башкортлар милли музыкаль уен коралы – курай ясый торган күпьеллык үсемлек; кырлыкурай; *русчасы:* **ребро-плодник**

**КЫРЛЫК** *и. бот.* 1) Канәферчәләр семьялыгыннан, нечкә йомшак сабаклы, ян тармаклары нык тармакланып киткән үзәк тамырлы, басуда үсә торган чүп үлән; *русчасы:* **торица**. *Чүпле орлык чәчкәннең кырын кырлык басар.* Мәкаль. *Тымызык көнне тырма тотып бөтнек, кырлык үләне, кура җиләге исе килеп торган урман печәнен кабартып йөргән яшьтәш, ничектер, картларга охшап калган иде.* М.Мәһдиев. *Кипшеп яргаланган ләм, чирәм, кырлык үләне, кычыткан баскан ---.* Р.Төхфәтуллин. *Ул, янәсе, кырлык арасындагы бодай.* С.Поварисов

2) *сөйл.* Ашлыктан аерып алына торган чүп үлән орлыклары. *Кырлык аеру*

**КЫРЛЫ КУГА** *и. бот.* Берөлешле үсемлекләр классы сусынчалар семьялыгыннан, калын юан тамырлары горизонталь таралган, кылычсыман калын озынча яфраклы, төз, юан, озын сабакка утырган матур чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы*: **касатик, ирис**

**КЫРЛЫКУРА** *и. бот.* Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан, каурый сыман яфраклы, сары чәчәкле, юан тамырлы үлән үсемлек: *русчасы:* **пастернак луговой**

**КЫРЛЫКУРАЙ** *и. диал. к.* **кырлы җимеш**. *Кайчандыр сугышка кадәр киндер ашы, җитен чәчелеп, чөгендер, суган, мал тормасы утыртылып, үзендә дөрес чәчү әйләнеше саклаган җир ---, урыны-урыны белән үзен урман кебек басып киткән кырлыкурай, ат кузгалагы, әче гөрләпәләр, тагын да әллә ниткән эт эчәгеләре, билчән, кузаклы һәм кузаксыз, күзәнәкле һәм күзәнәксез үлән үсемлек кыргыйлашкан халәттә гомер сөреп ята иде.* А.Хәлим

**КЫРЛЫ́-МЫРЛЫ** *с. сөйл.* **1.** 1) Җитешсез, каршылыклы. --- *кырлы-мырлы, кара якларны аңа гына аударды да куйды.* С.Поварисов

2) Кирәкле-кирәксез. *Аңа [кунак хатынга] кырлы-мырлы сүзләр ычкындырырга яисә «кара нинди масайган» дип кенә әйтергә дә урын юк иде.* Г.Бәширов

**2.** *рәв мәгъ.* 1) Коры, төксе. *[Зиннәт:] Я инде, кырлы-мырлы сөйләшмә, принцесса, ди.* Н.Гыйматдинова

2) Турысын, дөресен әйтеп, киная кулланмыйча. *Тоттым да әлеге дулкынга ияреп, кырлы-мырлы кыланмыйча --- ирен арасыннан сытып чыгардым: «Минем исәп татар әдәбияты бүлегенә керү иде, профессор».* Э.Касыймов

**КЫРЛЫ́-СЫРЛЫ** *с. сөйл.* Сырланган. *Бала чагыннан ук таныш булган кырлы-сырлы вак кына хәрефләргә күзе төшүгә, дулкынланып, хатны укырга кереште.* Г.Бәширов

**КЫРМА** I *с.* 1) Кыркылган, кыркып кыскартылган. *Әмма малай җитез икән, тәңкәгә урелгән сукбайларның берсенең яңагына китереп кундырды, икенчесенең, кырма башы белән, корсагына бәрде.* Я.Зәнкиев

2) Кырылганнан соң үсеп чыккан. *Садыйк кырма сакал баскан йөзен шартлаган якка борды ---.* А.Алиш. *Яртылаш чаларган кырма сакал-мыеклы, алтмыш яшьләр чамасындагы бер карт икән курай чыжылдатучы.* З.Зәйнуллин

**КЫРМА** II *и. диал.* Трахома (күздә була торган йогышлы авыру)

**КЫРМА́ БҮРЕК** *и. этн.* Кыска цилиндрик формадагы, яссы түбәле колакчынсыз каракүл бүрек. *[Бабайның] Башында түгәрәк, кара төстәге кырма бүрек.* З.Зәйнуллин

**КЫРМАВЫК** *и. диал.* 1) Тигәнәк. *Кырмавык үзенә тигән һәркемгә ябыша.* Мәкаль. *Кәҗә койрыгына кырмавык ябышмый булмый.* Мәкаль. *Тик бәйләнчек чир кырмавыктан да зәһәррәк.* Н.Гыйматдинова. *Әмма, ни гаҗәп,*

*монда адәмнән биек билчән, алабута, кырмавык туйрасы тантана итсә дә, озын завод каралтылары әле исән булып чыкты.* С.Хафизов

2) *күч.* Начар як, начарлык, кимчелек. *Алар арасында шагыйрьнең күңелен тырнаган кырмавыклар да байтак булган.* Г.Халит

◊ **Кырмавык телле** Усал, ачы телле. *[Зөлфия]: Нәкъ синең кебек кырмавык телле дә булган әле үзе.* Т.Галиуллин

**КЫРМЫЗЫЙ** *с. иск.* Кызыл. *Мәҗнүн һәр сабах --- йөзене әргуан чәчәге кеби кырмызый итеп, Ләйлә тарафыннан искән җилгә бу бәетне сөйләде.* Дастан. *Бүлек мөдиренең ак йөзе яшен җиргә коярга әзер болыттай каралды, озын муены кырмызый төскә манчылды.* Т.Галиуллин

**КЫРМЫСКА** *и.* 1) Элпәканатлылар семьялыгыннан, җирдә, таш асларында, черегән үзагачта оя ясап, ишле гаилә булып яши торган бөҗәк. *Кырмыскалар, төш вакытының эссе кояшында мыжгып, миллиард кызыл ылыстан корылган йортларын селкетәләр иде.* М.Мәһдиев. *Рәтле яшисең килсә, кырмыскалар кебек, йокы турында онытасың инде.* Т.Галиуллин. *Куышлар тирәсендә, кырмыскалар шикелле, кешеләр кыймылдаша.* Н.Фәттах. *Нечкә билле кара кырмыскалар үлән төбендәге сукмакларыннан, ашыгып, кышка азык әзерләп йөриләр.* М.Юныс

2) *күч. сөйл.* Күзгә артык бәрелеп тормаган, ләкин тырыш, эшчән кеше

◊ **Кырмыска йөгерешү** Куркудан һ.б. хис-кичерешләрдән тән чемердәү. *Ул чаклар искә төшкәч, Илфатның аркасыннан хәзер дә кырмыскалар йөгерешә башлый, беләкләренә, ботларына «каз тәне» чыга.* Б.Камалов. **Кырмыска күзе кадәр** Бик кечкенә. **Кырмыскалы йөрәк** Тынгысыз. *– Ну әткәй, бу тикле дә кырмыскалы йөрәк булырсың икән! – дип куйды ул [Харис], үтә борчылып.* Б.Камалов

**КЫРМЫСКААШАР** *и. зоол.* Тулы булмаган тешлеләр отрядыннан озынча көпшәсыман борынлы, озын ябышкак теле бөҗәкләрне аулауга җайлашкан, тропик урманнарда яши торган хайван; *русчасы:* **муравьед**

**КЫРМЫСКА́ ИЛӘВЕ** *и. к.* **кырмыска оясы**. *Алар ашханәдән чыкканда, халык кырмыска иләве кебек булып мыжлап тора иде.* Ф.Кәрим

**КЫРМЫСКА́ ИЛЕ** *и. к.* **кырмыска оясы**. *Кырмыска иле сыман Мыжлап, кайнап торган, тырыш, тынгысыз, Чыдам Йортым – чыр-чуым кала.* Н.Арсланов

**КЫРМЫСКА́ КӘЛТӘСЕ** *и. зоол.* Кәлтәгә охшаш тәне мөгезсыман тәңкәле, аякларындагы озын очлы тырнаклары я озын ябыштыручан теле белән кырмыска казып ашый торган имезүче хайван; *русчасы:* **панголин**

**КЫРМЫСКА́ КИСЛОТАСЫ** *и.* Кырмыска бүлендекләрендә, ылыста, кычыткандa, бал корты агуында була торган иссез, төссез органик кислота. *Гәрчис кебек борын эчен ярып, кырмыска кислотасы керде.* Х.Камалов. *Барыннан да бигрәк кислоталарның тарихи рәвештә барлыкка килгән исемнәре (кырмыска кислотасы, серкә кислотасы һ.б.) кулланыла.* Химия. *Аларда [валериана тамырларында] эфир мае бар, ә аның составында валериан-борнеол эфиры, --- спиртлар, кырмыска кислотасы, серкә һәм май кислоталарының борнеолэфирлары керә.* Урман аптекасы

**КЫРМЫСКА́ МАЕ** *и. к.* **кырмыска кислотасы**. *Нарат урманнары уртасыннан узганда, чәер исе, кырмыска мае исе, дымлы туфрак исе борынга бәрелде.* Г.Ахунов

**КЫРМЫСКА́ ОЯСЫ** *и.* 1) Кырмыскаларның туфрактан, ылыстан, вак чыбык-чабыктан, кипкән яфраклардан өеп ясаган торагы. *Кырмыска оясына, төпләрдәге мүкләргә карап та юлны чамалар идең, агачлар арасында төпсез караңгылык.* Г.Нәбиуллин. *Аякларың сызлыймы – кырмыска оясы иснәргә бар.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Күп кеше кайнашып торган урын. *Беренче нәүбәттә --- мохтаҗ хуҗалыкларның --- исемлеге укылгач, «кырмыска оясы» бермәл таяк тыкмыйча ук тузгып китте.* Ф.Хөсни. *Ул кырмыска оясында Минем булганым булды; Мәскәүлеләр өйгә кертмәгәч... Шунда кунганым булды.* Р.Рахмани

**КЫРПА** I *с. сөйл. к.* **кырпу** (*1 мәгъ.*). *Кырпа бүрек*

**КЫРПА** II *и. диал. к.* **кырпак**

◊ **Кырпа төшү** *к.* **кырпак төшү**

**КЫРПА** III *с. диал.* Коры, усал. *Холкы бик кырпа бит картның, әче теленә чыдап кына тор аннан.* Ш.Бикчурин

**КЫРПАК** *с.* **1.** 1) Вак, вак бөртекле (кар, бәс тур.). *Быел көзне, шакырдап катырган җир өстенә кырпак кар төшүгә, район базарына илтеп актык сыерны да сатарга туры килә.* А.Иванов

2) Юка гына, көпшәк (вак кар катлавы тур.). *Вакыт ага ашыкмыйча көзләр аша, Кырпак кар әле эри, тагын ята.* Г.Ибушев

3) *күч.* Ак, чал төшкән. *Калын, таза муенлы булганга, җитү сакалы, чылгыйланып торган кырпак мыегы бик килешеп тора үзенә.* Ә.Галиев. *Ул ай Разыяның кырпак сибелгән чәчләренә ак калфак булып укаланган.* А.Хәлим

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Юка гына булып төшкән кар катлавы; беренче вак кар. *Кырпак төшкән көзге коры көннәрнең берсе иде – мондый вакытта кеше кышка әзерләнә.* М.Мәһдиев. *Салкын, тын, аяз көзге төн җиргә ак кырпак сибә.* Г.Ибушев. *Ә хәзер комбайн белән кырпак төшкәнче маташалар.* Р.Вәлиев

◊ **Кырпак төшү** Агару, чал төшү. *Коточкыч хәбәрдән борын кырые җыерчыклары тагы да каралыбрак тирәнәйгән, инде агара башлаган чәчләренә бер сәгатьтә кырпак төшкән тәбәнәк таза гәүдәле Якуб карт та давылга эләккән көймә кебек чайкалып тора.* Р.Сибат

**КЫРПУ** *и.* **1.** 1) Киемнең, гадәттә баш киеменең, читенә тотылган мех. *Кырпуын затлы мехтан тekkәннәр.* М.Әмирханов

2) *сөйл.* Баш киемнәренең кырые. *[Миеклы] Конфедератка козырёгының никельләнгән кырпуы астыннан хәрәкәтсез, төссез күзләре белән карап тора.* Н.Островский. *Кәләпүшнең түбәсендә, кырпусында чын энҗедән чигелгән роза чәчкәсе бизәкләре.* Р.Юныс

3) Гомумән, нәрсәнең дә булса чите, кырые. *Кырпу астындагы киртәләрне күтәреп карадым.* Ф.Шәфигуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Читләре мехлы, мех тотылган. *Кыз янына кара җилән, кырпу*

*бүректән кияү эре генә менеп утырды.* Ә.Еники. *[Картлар] Кырпу бүрек, озынча җыйнак пальто кигәннәр.* М.Мәһдиев. *Башымда кыршылып беткән кырпу бүрек.* А.Хәлим

2) Тигез, куе булып үскән вак бөртекле, күпереп торган. *Күл буендагы куе камыштан соң хәтфәдәй яшел кырпу үлән башлана, шушы үзәнлектә хан чатыры.* М.Хәбибуллин

**КЫРПУК** *и. диал.* Рубин. *Кырпук кашлы йөзек*

**КЫРПУЛА́У** *ф.* Киемнең кырыена мех тоту, кырпу тоту. *Бүрекне кырпулау*

**Кырпулап алу** Тиз генә кырпулау

**Кырпулап бетерү** Кырпулауны тәгәлләү

**Кырпулап чыгу** Башыннан ахырына кадәр бөтен әйләнәсен тирәләп кырпулау

**КЫРПУЛЫ** *с.* Мех тотылган, читенә озын тар мех тегеп куелган. *Кунак иң әүвәл ашыкмыйча гына кәвешләрен чишеп ишек төбенә куйды, аннан кырпулы бүреген, кыптыр тунын чишеп, стенадагы юан чөйгә элде.* Я.Зәнкиев. --- *Санук янәшәсендә яшел кырпулы фуражка кигән, биленә җилкәсеннән алдырып каеш буган егет пәйда булды.* Г.Кашапов. *Галәк бабай озын ак күлмәк өстеннән җиңсез казаки кигән, аягына каталар элгән, башында кырпулы бүрек.* Г.Әпсәләмов

**КЫРПУСЫЗ** *с.* Кырыйларына мех тотылмаган. *Кырпусыз бүркен басып киеп, тула оек өстеннән чабата кигән тәбәнәк бер кеше кычкырды.* М.Галәү

**КЫРПЫ** *и. к.* **кырпы балыгы**. *Олы кунак килеп җиткәнче, кырпыларны, чөгә-мәрсиннәрне тере килеш сулыкларда сакларга!* А.Гыйләҗев

**КЫРПЫ БАЛЫГЫ** *и.* Мәрсинчәләр семьялыгыннан, берничә елга бер тапкыр уылдык чәчеп үрчи торган иң зур балык, кыйммәтле промысел балыгы; *русчасы:* **белуга**. *Балык болганчык суда ята иде.* --- *Чаныш аны шунда ук таныды: кырпы балыгы икән.* Ә.Гаффар. *Каспий диңгезендә бик зур балыклар бар. 1827 елда биредә 1440 килограммлы кырпы балыгы тотканнар.* Кызыклар дөньясында

**КЫ́Р САБЫНЫ** *и. бот. диал.* Сабын үләне; *русчасы:* **мыльнянка**. *Чәчәгенең ике серкәче һәм биш таҗ яфракчыгы бар. Бу үсемлек кыр сабыны дип атала.* Робинзон эзләреннән

**КЫ́Р САКАЛЫ** *и. миф.* Ышанууларга күрә, урак уруны тәгәлләгәндә, кыр атасы өчен басу очында урмыйча калдырылган берничә тотам иген

**КЫ́Р САРЫМСАГЫ** *и. бот.* Суганчалылар семьялыгыннан, тәме белән бакчада үсә торган сарымсакны хәтерләткән кыргый үсемлек; *русчасы:* **черемша**. *Кыр сарымсагы зәңгеләдән һәм атеросклероздан файдалы, ул эчәклекнең перистальтикасын көчәйтә һәм суалчаннарга каршы тәэсир итә.* Урман аптекасы. *Кыргый үсемлекләр арасында кыр суганының сусыл йомшак кыякларын һәм кыр сарымсагының җирдә генә түгел, «һавада» да – чәчәк сабы өстендә үсә торган зәһәр башчасын тануы бик җиңел.* Робинзон эзләреннән

**КЫРТ** I *рәв.* Кинәт, капыл; бик тиз. *[Мәсәви саилче] Беравык бер урында таптанып торды да кырт кына арткa борылды ---.* Н.Фәттах. *Ул [карачкы], әйтәсе фикеренең эзенә төшкәндәй, кырт борылып Ибрайга карады.* Н.Хәсәнов

◊ **Кырт киселү** Кинәт өзелү, бүленү (сүз, сөйләү тур.). **Кырт кисеп** 1) Кискен рәвештә, катгый итеп. *Яңа директорның болай кырт кисеп куюыннан уңайсызланган Василий Степаныч машинасын караңгы тыкрыкка борды.* Г.Әпсәләмов; 2) Катгый рәвештә әйтеп; кисәтеп. *Бер аулакта мин аңа кырт кисеп куйдым.* А.Шамов. **Кырт кистерү** *к.* **кырт кисү**. **Кырт кисү** 1) Туктату, кинәт бүлү, өзү. *Бабай кайчак шулай кырт кисеп куя.* Н.Дәүли; 2) Катгый һәм кыска җавап бирү. *– Барыгыз! – дип кырт кисте баш врач.* М.Хәсәнов. *Бик яшь тә, чибәр дә булган заманында Маһибадәр апа, кияүгә чыгарга каршы килгән, кырт кискән.* Ш.Бикчурин. *Чибәрлеген сөйләп тормыйм: Гашыйк булырлык һәркем. «Сүз куешкан кешем бар» дип Кырт кистем сүзне ләкин.* З.Мансур. **Кырт өзелү** *к.* **кырт киселү**. *Шул урында Айсылуның уе кырт өзелде.* Г.Якупова. *Кырт өзелә нәсел чылбырлары... Китеп барам кабат үткәнгә.* Р.Рахмани. *Кинәт музыка кырт өзелде, һәм югарыдан көр, гайрәтле тавыш яңгырады ---.* Э.Касыймов

**КЫРТ** II *иярт.* Кайчы белән кискәндә яисә җеп һ.б.ш. нәрсәләр өзелгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Кырт итеп кисеп ташлау*

**КЫ́Р ТАВЫГЫ** *и. зоол.* Тавыклар семьялыгыннан, ата төрләре кара, лирасыман койрыклы, анасы чуар төстә булган кыргый кош; көртлек; *русчасы*: **тетерев**. *Зыңлауда үз аһәңен табыпмы, --- пырлап, кыр тавыклары күтәрелә.* М.Хәбибуллин. *Көзен кыр тавыклары, көртлекләр аерата тәмле, ләззәтле була.* А.Гыйләҗев. *Аның азыгы – куяннар, вак боланнар, кыр тавыклары, дуңгыз балалары, кимерүчеләр.* Кызыклар дөньясында. --- *Озакламый ак кыр тавыклары бөтенләй диярлек юкка чыга.* Кызыклы ихтиология

**КЫ́Р ТАРАКАНЫ** *и. зоол.* Бызылдавыклар семьялыгыннан озынча гәүдәле, җепсыман мыеклы, йөгерүгә җайлашкан озын аяклы, кара яки чуар төстәге, авыл хуҗалыгы корткычлары белән туклана торган ерткыч бөҗәк; *русчасы:* **жужелица**

**КЫ́РТ ИТҮ** *ф.* **1.** Кырт II иткән тавыш чыгару

**2. кырт итеп** *рәв. мәгъ.* Яхшы итеп

**3. кырт иткән** *с. мәгъ. сөйл.* Матур; менә дигән. *Салих өендә --- килешле борынлы, күтәренке яңаклы, чибәр йөзле һәм кырт иткән гәүдәле ханымны күргәч югалып калды.* Т.Галиуллин

**КЫ́РТ-КЫРТ** *иярт.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса кытырдатып чәйнәгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Кырт-кырт ипи кимергәч, Мин бик тиз симерермен, Аннан синең яныңа – Бирегә йөгерермен.* Г.Исхакова

2) Тавык кыртлаган тавышны белдерә

3) *к.* **кырт** II. *Әни белән Садыйка түти, сарыкларының чалыштырып тышауланган чәлтерләренә тезләнеп алганнар да, кырт-кырт иткән кайчы тавышы --- чыгарып, йон кыркалар.* А.Хәлим

**2.** *рәв мәгъ. куч.* Бәйләнешсез, ялганып китмәгән. *[Вәһимнең] Моназыйр мунчасында утыруы күз алдыннан китмәгәнгә күрә, солдат егет белән сөйләшүе кырт-кырт һәм мәгънәсез чыкты.* М.Хуҗин

**КЫ́РТ-КЫРТ ИТҮ** *ф. к.* **кыртлау**

**КЫ́РТ-КЫРТ КИЛҮ** *ф. к.* **кыртлау**. *Ана тавык кырт-кырт килеп торыр.* Мәкаль

**КЫРТЛАТУ** *ф.* **1.** Кисү. *Һәм Сәхия югалып калмады, өрлектән түбәнгә үрелеп, айгырның колагын кыртлатты да алды.* Ф.Яруллин

**2. кыртлатып** *рәв. мәгъ.* 1) Кырт иткән тавыш чыгарып, кырт иттереп. *– Сый беткәч килдегез бит әле, – дип, буш шешәне читкә тибеп очырды Рембрандт, кыртлатып кыяр чәйнәп.* Д.Бүләков

2) *сөйл.* Яхшы итеп, җиренә җиткереп

**КЫРТЛА́У** *ф.* 1) Тавык һәм башка кайбер кошлар турында: кыска-кыска гына итеп тавыш бирү, өзек-өзек авазлар чыгару. *Ишегалдын бер итеп кыртлый чуар тавык, үзе чебешләр тирәли йөри чабып ---.* А.Алиш

2) Йомырка салудан туктап, йомырка басарга йөрү билгесе буларак, тавыкның өзек-өзек авазлар чыгаруы. *Чуар тавык кайда туры килсә шунда тибенә, атнага бер-ике йомырка сала, күп вакыт кыртлап кына кала.* А.Алиш

**Кыртлап алу** Бераз кыртлау

**Кыртлап җибәрү** Кыртлый башлау. *Чуар тавык моны бик тиз сизенде, бик әче тавыш белән кыртлап җибәрде.* А.Алиш

**Кыртлап йөрү** Әле, хәзерге вакытта бертуктаусыз кыртлау

**Кыртлый башлау** Кыртларга тотыну. *[Хәкимҗан:] Элек тавыклар кыртлый иде, хәзер этәчләр кыртлый башлады.* К.Әмири

**КЫРТЫМ** *и. гар. бот.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан, аксыл, тармакланучан каты сабаклы, орлыкларыннан май алу өчен, терлек азыгы буларак игелә торган буяулы берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **сафлор**. *Кыртым мае*

**КЫ́Р ТЫЧКАНЫ** *и. зоол.* Тычканнар семьялыгыннан йорт тычканнарыннан көрән сыртында кара сызык булу белән аерылып торган кырда яшәүче кимерүче хайван; *русчасы:* **полёвка**. *Калмый чуар кортларың, Хәтта кыр тычканнарың. Без барын да кортабыз Игеннең дошманнарын.* Ш.Маннур

**КЫРТЫШ** *и.* **1.** 1) Бүрәнәне тактага ярганда аның ике кырыенда кала торган, бер ягы киселмәгән такта, кырый такта; *русчасы:* **горбыль.** *Кыртышы черегән бүрәнәнең үзәге дә тиз черүчән.* Мәкаль. *Кара пулатның аскы тәрәзәсен томалаган кәкре кыртыш такталарны дипломатымдагы киләшчә белән каеру әллә ни кыен булмады.* А.Тимергалин

2) *диал.* Яру өчен уңайсыз, катлаулары борылмалы булып үскән яки күп ботаклы агач. *Әле дә яхшы сукмады, кыртыш белән тукмады.* Такмаза

3) *диал.* Туфракның үлән үскән иң өске катлавы, кәс. *Кыртыш сөрү*

4) *диал.* Шыртлака. *Кармагымда кыртыш чыга, җәен чыккандай судан.* Р.Мингалим

**2.** *с. мәгъ.* Бүрәнәнең ян-ягында бер ягы киселмичә кала торган (такта тур.). *Бүрәнә дип әйтерлек кыртыш такталардан тезгән бу койма борынгы шәһәр ныгытмаларын хәтерләтә.* А.Тимергалин

**КЫРУ** I *ф.* 1) Берәр нәрсәнең өске катлавын чистарту, ябышкан нәрсәдән арындыру. *Карап торам кышкы тәрәзәгә, Тырнак белән кырам бәсләрен.* И.Хөснетдинов. *[Рафаил:] [Балыкның] Тәңкәләрен үзем кырырмын, Сәвилә ханым, күлмәгең буялмасын.* Н.Гыйматдинова

2) Чәчне, сакал-мыекны һ.б.ш.ны пәке белән төбеннән үк кисү, кисеп алу. *[Мияссәр:] Кер, сакалыңны кырырмын. Йөрмә болай йонга батып.* А.Гыйләҗев. *Тимерхан абзый, Миңлеасиясенең йокысын бүлмәс өчен, шыпырт кына урыныннан торды, ваннага кереп, битен юды, сакал-мыегын кырды ---.* Г.Ахунов. *– Сакал-мыек кырып торырга вакыт юк әле, Насыйр абзый, – диде Шөгаеп ---.* М.Гали. *Килер дә ул, кырып, такырлатып, бабайларча чәчең китәрер.* Ш.Мөдәррис

3) Махсус җайланма(лар) белән билгеле бер рәвеш биреп кисү. *[Фельдшерица] Кашын беткәнче кырган.* М.Мәһдиев. *Бездә лезвие ясарга өйрәнеп баралар. Кая, кырыйм үзеңне...* Б.Камалов. *[Рәхмәтулла:] Аякларың кырып ясалган кебек шул.* Т.Галиуллин

4) Төптән үк кистереп чабу. *Аның кулында чалгы клеверны төптән кырып кына сала иде, минем арттан исә киселгән сабаклар тырпаешып кала.* М.Хуҗин. *Бугаз тәңгәлендәге каты кылны кыру аның өчен гүяки үз тәнеңне кайрак белән кайрау, телеңне аркылы тешләп, тау чарлагындагы җиз үлән, кылган кыру кебек авыр эшләрнең берсе иде.* А.Хәлим

5) Металлның яки агачның өске катлауларын махсус станокта билгеле бер формага китерү. *Фрезер станоклары үзләренең үткен тешләре белән тимерләрне кырып, кирәкле хәлгә китерәләр.* А.Алиш. *Металл кырдым, магистральләр салдым, Мендем буровойлар сөңгесенә.* Н.Хәсәнов. *Бу – аяклары кырып ясалган бик матур, ләкин бик иске өстәл иде.* Х.Сарьян

6) Кыргычка ышкып ваклау (яшелчә тур.). *Искәндәрнең кинәт кенә кухня өстәле артына утырып кишер кырасы килеп китте.* Р.Вәлиев. *Әзер массаны баклажаннар эченә тутырып, өстенә кырган сыр сибегез.* Безнең гәҗит

7) Тирене суйдыру, җәрәхәтләү. *Йөгерсәләр, аякларын итек кырды.* Ф.Яруллин. *– Эрҗинкә аякны кырды, уф, үләм, – дип, юл буе зарланып барды Сәмига.* М.Әмирханов

8) *тар.* Хәрби хезмәткә яраклы дип табу, солдатка алу (элек хәрби хезмәткә яраклы дип табылганнарның чәчен кырудан килеп чыккан мәгънә). *Зыя алынган, мәхдүмне яңадан кырганнар иде.* Г.Ибраһимов

9) *куч.* Борчу, тынгысызлау, бимазалау. *Ә шулай да кире уйлар Һаман кыра йөрәкне.* М.Җәлил. *[Мирхас] Тагы сарайга керде, әчтәге борчу кыра, тынгы бирми иде.* Х.Камалов. *Бу сүзләр егетнең күңелен кырса да, каршы әйтергә теле кычытса да, ничектер, кирәкле сүзләр табылмады.* М.Маликова. *Ләкин ул, кызның күңелен кырмас өчен, бәхәсләшеп тормый.* В.Нуруллин

◊ **Кырган да борган** Нинди булса эшнең бер кеше өчен тәмамланган, беткән саналуы яисә нәрсәнең дә булса әзер исәпләнүе. *[Олаучы абый:] Синең эш кырган да борган.* Ә.Фәйзи. **Кырып ташлау** Фикерне, уйны һ.б.ш. күңелдән чыгарып ташлау. *Нәфисә уяна гына башлаган бу яңа өметне дә күңеленнән кырып ташлады.* Г.Бәширов

**Кыра бару** Тоташтан кыру, һәрберсен, булган берсен кыру

**Кыра башлау** Кырырга тотыну. *Алар, Киб белән икәүләп, тырышыптырышып, шырпы башыннан күкерт кыра башладылар.* А.Тимергалин

**Кыра бирү** Бернигә карамый кыруны дәвам итү

**Кыра төшү** Бераз кыру. *Киштәдән кайрак төшә, Тирә-якны кыра төшә.* Табышмак

**Кырып алу** *к.* **кырып ату**. *Бер тотынгач, Ташкәй туктамады, башта Чырыкның кәҗә сакалын кырып бетерде, аннан башын кырып алды ---.* Я.Зәнкиев

**Кырып ату** Тиз генә кыру. *Кырып ата бит сакал-мыекларын.* Ф.Шәфигуллин // Кырып юк итү, бетерү. *Мыегын кырып атса, бөтенләй юаш кешегә охшап калыр иде ул, мөгаен.* Ф.Шәфигуллин

**Кырып бару** Рәттән, барысын да кыру. *Ызанда чүп котырып үскән. Шуларны кәтмән белән кырып барасың.* Х.Камалов

**Кырып бетерү** Бик каты кыру. *[Атның] Сыртын – ыңгырчак, муенын камыт кырып бетергән.* Ф.Яруллин. *[Фаягөл:] Шул [туфли] аякларымны кырып бетерде.* Т.Миңнуллин // Баштан ахырынача кыру. *Бер тотынгач, Ташкәй туктамады, башта Чырыкның кәҗә сакалын кырып бетерде, аннан башын кырып алды ---.* Я.Зәнкиев

**Кырып җибәрү** Тиз генә кырып алу. *Бу кыз, көннәрдән бер көнне, кемнән күреп-өйрәнептер, кашларын кырып җибәрде дә ай урагы кебек кенә сызыклар сыздыртты.* М.Мәһдиев

**Кырып йөрү** Даими кыру. *[Нәбинең картайганлыгы] Чәчен, сакал-мыегын кырып йөргәнгә генә сизелми, юкса, сентябрь кыравы төшкәндәй чал чәчле ул хәзер.* Р.Төхфәтуллин

**Кырып ташлау** *к.* **кырып ату**. *[Ул] Мыегын да кырып ташлаган.* Ф.Шәфигуллин. *[Морат:] Ярар соң, кырып ташлармын [сакалны]...* Э.Яһудин

**Кырып тору** Даими, әледән-әле кыру

**Кырып чыгу** Тиз арада башыннан ахырына кадәр кыру, һәрберсен кыру

**Кырып яту** Әле, хәзерге вакытта кыру. *Ни эш кырып ята идең?* Р.Вәлиев

**КЫРУ** II *ф.* 1) Күпләп үтерү, юк итү; бетерү. *Бер үләт тә, ваба да ул чаклы кырмагандыр халыкны.* А.Шамов. *Икенче елны ящур дигән авыру чыгып, ферма малын кырды.* Х.Камалов. *Монгол яулары Болгар җирләрен басып алалар, шәһәрләрен һәм авылларын талыйлар, халкын кыралар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Ул елгакүлләрдәге башка балыкларны кыра, төрле җәнлекләрне тотып ашый.* Кызыклар дөньясында

2) Ату, атып үтерү. *Яклаучысыз әсирләрне йөзәрләп кыра фашист ---.* Х.Камалов. *Полковник сугышта ничә кеше кырганын сөйләр, ә син гектардан күпме уңыш алганыңны.* Ә.Гаффар

3) Бәреп вату. *[Әлтафның] Исәбе – тәрәзәләрне кыру иде.* М.Әмирханов. *Савыт-сабаларны кырдым, урындыкларны тибеп аудардым.* Ф.Шәфигуллин. *Бервакыт, Альфред тугач, ул, эчеп кайтып, өйдәге савыт-сабаны кырды.* Ф.Садриев

4) Җимерү; юкка чыгару, бетерү. *Шалакма чәчле малай Ибәтулла абзый [фигураларны] тезеп бетергәнне түземсезлек белән көтеп торды һәм тагын кырырга кереште.* Ф.Шәфигуллин

5) *күч.* Берәр эш эшләү. *Зурларның көче җитмәгәндә, без, балалар, нәрсә кыра алабыз соң?* Ф.Яхин. *– Я, ни эш кыру? – диде Шәукәт.* М.Маликова. *Димәк, ул берни дә кырмады, ә төрле яктан Япон, Дулкын Назарович, хәтта Акмал хан да аңа «кулларын салдылар» ---.* Р.Мирхәйдәров. *Кыш кыра алмаганны җәй көне генә әллә ни кырырмын дип әйтә алмыйм.* Ф.Хөсни

6) *күч.* Берәр эштә нәтиҗәгә ирешү. *[Гыйльмениса җиңги:] Буең күсәк кадәр булганчы укып йөрдең, нәрсә кырдың инде.* М.Гали. *– Әтиләрне өйдә калдырып, сугышка безне җибәргән булсалар, без сугышны әллә кайчан бетереп кайткан булыр идек инде, – дидем мин ---. – Кырыр идең пычагымны, – диде Апуш ---.* М.Юныс

**Кыра бирү** Бернигә карамый кыруын дәвам итү

**Кырып бару** Рәттән кыру, тоташтан кыру. *Урманның иң әйбәт җирен, наратларны чалгы белән чапкандай, кырып кына баралар.* Ю.Әминов. *Бу көйдә бөтен нәрсәне кырып, җимереп барган ташуларның гөрләве ишетелә иде.* А.Шамов. *Ул [тайфун] очраган бөтен нәрсәне кырып бара.* Могҗизалар энциклопедиясе

**Кырып бетерү** Бөтенләй, тулысынча кыру, юк итү. *Барлык дошманнарны кырып бетермичә, безгә ял юк.* Г.Әпсәләмов. *Бу Гитлер, башы беткере җан, нүжәли бар егетебезне кырып бетерер икән, нүжәли миңа насыйп берәрсе – кара мыеклысы калмас икән.* А.Хәсәнов. *Сугышка үләр өчен бармыйлар, мимеч фашистларын кырып бетерү өчен баралар.* Р.Ишморат. *Разинның канечкеч байларны-алпавытларны, боярларны һәм воеводаларны кырып бетерергә чакырган өндәмәләре изелгән халыкны кузгатып җибәрә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**Кырып йөрү** Барысын да рәттән кыру. *Немец самолётлары шәһәрдән качып котылырга тырышкан бу бичараларны пулемёттан кырып йөргән икән.* Ә.Еники. *[Тәлгатьнең әтисе] Сугышта булган, буржуйларны кырып йөргән ---.* Ф.Хөсни

**Кырып килү** Электән үк, озак вакытлардан бирле кыру. *Таш гасырыннан бирле алар [малярия черкиләре] җир йөзендәге халыкның яртысын диярлек кырып килгәннәр.* Кызыклар дөньясында. *Ләкин... бөтенесен кырык ел буе кырып килгән Актаныш батыры аны да җиргә салды.* Х.Сарьян

**Кырып салу** *к.* **кырып ташлау**. *Бәлки, сугыш түгел, ә үләт чире бөтен халыкны кырып салгандыр.* И.Сирматов. *Безнең Идел буен егерме беренче елгы ачлык кырып салды.* Ә.Галиев. *Арган солдатлар бер-берсенә карап алдылар: сәгатьләрчә сугышып, моннан аз*

*гына элек дошман батальонын кырып салдылар.* Н.Хикмәт. *Аннары ниндидер авыру бу маймылларны кырып сала, нибары өчесе генә исән кала.* Кызыклар дөньясында

**Кырып ташлау** Тиз арада юк итү. *Ләкин Бөек Ватан сугышы алдыннан халкыбызда булган тирән һәм олы патриотик хисләр, теләсә нинди дошманны бик тиз рәвештә генә кырып ташларга, сугышчыларыбызның дошман белән очрашуда һәр яктан да өстен булачагына ышаныч шулкадәр зур иде ---.* К.Гыйззәтов. *Юл ясаучылар бульдозер белән яр буендагы таларны да кырып ташлаганнар.* М.Юныс. *Ачудан яңа бер авыру уйлап табып, меңнәрне кырып ташламасыннар.* М.Галиев

**Кырып тору** Даими, әледән-әле кыру

**Кырып чыгу** Һәммәсен рәттән кыру. *Гомерендә үрдәк-казга тимәгән малай, таш атып, йортның тәрәзәләрен кырып чыккан.* Р.Мулланурова

**КЫРУ** III *иярт. к.* **кыр** III. *Куе шомыртлык янында, кояшлы алан түрендә урман тавыгы корылдый: – «Кыру-кыру-кыру».* М.Мәһдиев

**КЫРУЛЫ** *с.* Кырылган, пөхтәләнгән (сакал-мыек тур.). *Беренче татар урта буйлы, сирәк сакаллы һәм мыеклы. Авыз тирәсе кырулы.* Г.Коләхмәтов

**КЫР-УРМАН** *җый. и.* Кыр һәм урман. *Инде миналар кую, кырны-урманны минадан чистарту буенча практик занятиеләр башланган иде.* М.Мәһдиев. *Шәһәр кешесе, авылга кайткач, кыр-урман чәчәкләренең исен иснәгәндәй, рәхәтләнеп, комсызланып суладыРәсим абзар һавасын.* Ф.Шәфигуллин

**КЫ́Р ҮРДӘГЕ** *и. зоол.* Үрдәкләр семьялыгыннан, ата төрләре язын яшел башлы, яшел муенлы, канатында зәңгәрсу шәмәхә юллы, ә ана төрләре карасу көрән төстә булган, Евразиядә, Төньяк Америкада киң таралган кош; *русчасы:* **кряква**. *Безнең тугай күлләренә кыр үрдәкләре килә ---.* Ә.Еники. *Тиздән елгалар ташыр, Кыр үрдәкләре кайтыр.* Ш.Маннур

**КЫРЧЫ** *и. сөйл.* Авыл хуҗалыгының игенчелек тармагында эшләүче. *Юлчы – юлда, кырчы – кырда.* Әйтем

**КЫРЧЫ́-ИГЕНЧЕ** *и. к.* **кырчы**. *«Берәү» повестенда кырчы-игенче баласы, туган ягын, кешеләрен аерым бер сизгер мәхәббәт белән ярата ала торган Исхак Батуллин турында сүз бара.* А.Гыйләҗев

**КЫРЧЫЛ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, себеркәч чәчәкле терлек азыгы үләне; *русчасы:* **полевица**

**КЫРЧЫЛЫК** *и.* 1) Бөртекле, техник һәм терлек азыгы культураларын игү эше. *Монда килсәң, көнозын минем белән ызгышып ятар идең бугай. Кырчылык бригадасына бар.* Ю.Әминов. *Кырчылыкта эшләүчеләрне ашату юк.* В.Нуруллин. *1955 елдан [М.Мансуров] --- комплекслы кырчылык бригадасын җитәкли.* Мәдәни җомга

2) Иген игү белән шөгыльләнә торган авыл хуҗалыгы тармагы. *--- ә бу план терлекчелекнең тоткан урынын күтәрүне, кырчылык системасыннан кырчылык-терлекчелек юнәлешенә күчүне күздә тотты.* Татарстанда терлекчелек

**КЫРЧЫН** *и.* 1) Корчаңгы авыруының бер төре (терлекләрдә). *Кырчын йоктыру*

2) Шундый авырулы хайван

3) Чәч астындагы тиредә эренле кутыр барлыкка китерә торган йогышлы авыру

4) Шундый авырулы кеше. *Тазы табылды, тагын кырчыны гына кирәк.* Әйтем. *[Пилюгина:] Кырчын өерен дә өр-яңадан киендергән.* А.Иванов

◊ **Кырчын таз** *тирг.* Юньсез, яман кеше

**КЫРЧЫ́Н ТАЛЫ** *и. бот.* Талчалар семьялыгыннан, аксыл яшел көмешсыман яфраклы, ярымшарсыман булып үсә торган, зур булмаган куак; талның бер төре; *русчасы:* **желтолоз**

**КЫРЧЫ́Н ТИМРӘҮ** *и. мед.* Тиредә була торган йогышлы гөмбәчек авыруы

**КЫРША́У** I *и. диал. к.* **коршау**. *Миңа койрыктагы күперчеккә тезелгән мичкәләрнең кыршауларын ныгытырга кушканнар иде.* Ф.Шәфигуллин. *Бармактан нечкә чылбырның ике як очында да беләзеккә охшаш кыршау болтларга кигертелгән.* М.Юныс. *Кисеп менеп зәңгәр биеклекне, Ыргылдылар өстән дошманга; Туздырдылар аның кара сафын Һәм алдылар утлы кыршауга.* Ш.Маннур. *[Берсе:] «Мичкәң кыршау аткан, юл буенча суы агып килә, ник аны карамадың», – дип бабайга тагы берне сугып җибәрде.* М.Гали

◊ **Кыршау арасына кертү** *к.* **коршау арасына кертү**. *Ә Билал ашыкмый иде. Барып җиткәнче, аның әле үз уйларын тагын бер кат кыршау арасына кертәсе --- бар.* Р.Фәизов. **Кыршау ату** *к.* **коршау ату**. *– Әхмәтсафа агай кыршау аткан, Әхмәров шартлаган, – дип сөйли башлаганнар иде.* Ш.Мөхәммәдев

**КЫРША́У** II *ф. диал. к.* **коршау** II

**КЫРШАУЛА́У** *ф. диал. к.* **коршаулау**. *[Карама агачы:] Миннән чана табаннары, дугалар бөгәләр, көянтәләр ясыйлар, минем белән мичкәләр кыршаулыйлар.* Г.Галиев. *Бакыр балдак белән кыршаулаган кечкенә челемен генә күреп калган идем.* Г.Бәширов. *Төн карасына манчылган күзләрдә поскан курку бәләкәчне тәмам кыршаулаган, ул ни кычкырмый, ни ычкынырга маташып чәбәләнми ---.* Н.Гыйматдинова

**Кыршаулап алу** *диал.* Тиз арада кыршаулау. *[Чәч бөртегенең] Берсе аның аякларын кыршаулап алган, икенчесе биленә уралган, өченчесе кулларына асылынган.* Р.Хафизова // Тиешле дәрәҗәдә, җиренә җиткереп кыршаулау. *Ярылган керамиканы шул тасма белән тыгыз итеп кыршаулап алырга һәм тасма очларын кайтарып куярга кирәк.* Файдалы киңәшләр

**Кыршаулап бетерү** *диал.* Тулысынча, барысын да кыршаулау

**Кыршаулап кую** *диал.* Кыршаулаган хәлгә китереп калдыру. *Ул [Зоя] кылган үләне төсле аксыл чәчен җыйнап, челтәрле калфагы белән кыршаулап куйган.* Ш.Бикчурин

**Кыршаулап тору** *диал.* Даими, әледән-әле кыршаулау

**Кыршаулап чыгу** *диал.* Тиз арада кыршаулау; һәммәсен баштан ахыргача кыршаулау

**КЫРШАУЛЫ** *с. диал. к.* **коршаулы.** *[Арбаның] Икенче ягында – биш пот сыешлы, кыршаулы, ялтырап беткән тимер кисмәк.* Х.Сарьян. *Җикерә*

*ул: – Әй, кыршаулы мичкә! Әйләнүең бел, – ди, – син, карт юләр!* Зөлфәт. *Башына ул ят кош каурыйлары кадап ясалган, затлы ташлар белән бизәлгән алтын кыршаулы калпак кигән.* Н.Фәттах

**КЫРШАУЛЫК** *и. к.* **коршаулык**. *Кыршаулык әзерләү*

**КЫРШАУЧЫ** *и. диал. к.* **коршаучы**

**КЫ́Р ШПАТЫ** *и. минер.* Каркаслы силикатлар төркеменә караган, тау токымы тәшкил итә һәм керамика, фарфор, пыяла, цемент җитештерүдә кулланыла торган минерал. *Кыр шпаты су һәм углекислый газ белән тәэсир итешә.* Анатомия. *Ә менә Ай ташлары арасында кыр шпаты һәм оливин күп булуы ике күрше планетаның кардәш икәнлеген дәлилли.* Кызыклар дөньясында

**КЫРШУ** I *ф. сөйл.* Берәр өслекне кыру, ышку. *Майның ышкылу үзлеге зурайгач, системаның көче кими, димәк, мотордагы узеллар бер-берсен кыршыйлар.* Х.Камалов

**Кыршып алу** Аз гына кыршу

**Кыршып ату** Бик тиз арада кыршу

**Кыршып бару** Һәммәсен рәттән кыршу

**Кыршып тору** Даими, әледән-әле кыршу

**Кыршып чыгу** Башыннан ахырына тикле кыршу. *Бу буразнаны кәтмәнләп бетерәм дә шуннан соң гына ялга утырам. Юк, аны бетергәч, тагы икенчесен кыршып чыгам.* Х.Камалов

**КЫРШУ** II *ф. сөйл.* Нәрсәне дә булса берәр әйбер белән әйләндереп алу; каплау. *Кырыйдан такта белән кыршу*

**Кыршып ату** Бик тиз арада кыршу

**Кыршып бару** Һәммәсен рәттән кыршу

**Кыршып кую** Кыршыган хәлгә китереп калдыру

**КЫРШЫК** *и. диал.* Тискәре, кире кеше, кире беткән кеше

**КЫРШЫЛДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **кыршу** I

**Кыршылдырып алу** *к.* **кыршып алу**

**Кыршылдырып ату** *к.* **кыршып ату**

**Кыршылдырып бару** *к.* **кыршып бару**

**Кыршылдырып тору** *к.* **кыршып тору**

**КЫРШЫЛУ** *ф.* 1) Даими рәвештә ышкылу сәбәпле кырылу, тузу. *Ләкин күпме генә азапланмасын, беләзекнең кыршылмыйча калган урынындагы «...гәүһәр таш улмаз...» һәм «...кадерене ахмак белмәз...» дигән сүзләрне генә аера алды.* Ф.Латыйпов. *Эче тулы зар булса да, тәмәке сасысына туенган бу ямьсез бинада, кыршылган, таплы өстәл янында, тупас ирләрнең йонлы колагына түгә торган түгел инде.* М.Маликова. *[Павканың] Авыр патрон сумкалары белән кыршылып, чиләнеп беткән тәне инде төзәлеп өлгерде ---.* Корыч ничек чыныкты

2) Мехның йоны кырылу. *Тунының җиң очлары кыршылган*

3) Ару, хәлсезләнү. *Моның шикелле өзелеп җитмәгән карарлар, башланып кына тукталган киңәшләшүләрдән соң, бу ике – кыршылып искергән, изелеп арган мәхлуклар эчләреннән нәрсә уйлый ---.* Ш.Камал

4) *диал.* Үтмәсләнү, үтмәс хәлгә килү (кисү кораллары тур.). *Чалгы кыршылган*

5) *куч.* Нинди дә булса эш башкару, эш башкару өчен көч кую

6) *куч.* Нинди дә булса гадәткә ия булу; остарып, шомарып бетү; сүзгә, хәйләгә маһир булу. *Күпне күргән, күп кыршылган Гайфулла. Рәүф янында шулай йомшак ялагайланса, Искәндәр янында ул башка төслерәк сөйли.* Г.Нигъмәти. *Күршем дә кыршылган нәрсә икән. Аның тыңламаган булып кылануына игътибар итмичә, үзенең сүзен дәвам итә.* М.Әмир

7) *кимс. сөйл.* Күзгә күренергә тырышып бер дә юкка йөрү яки басып тору. *Юлга әзерләнмичә, нәрсәгә монда кыршылып торасың.* К.Тинчурин

**Кыршыла төшү** Бераз кыршылу. *Халиков Солтанның кыршыла төшкән каракүл якалы пальтосына --- күз төшереп алды.* А.Расих

**Кыршылып бетү** Нык кыршылган хәлгә килү. *Малай салкыннан күшеккән кулына кыршылып беткән мәктәп портфеле тоткан иде.* А.Иванов. *Әмма [Гыйлембай] үз-үзен бер дә карамый, өстендә җәен-кышын шул таушалып беткән пинжәге, тезләре бүселгән чалбар, кыршылып беткән пәлтәсе.* Р.Фәизов. *Бәлки, миллионер минеке сыман кыршылып беткән куртка һәм джинсы чалбар киеп йөрсә дә, гаеп итмиләрдер.* Р.Мулланурова. *Кортка-бикә башына куян тиресе тотылган мескен бүрек, өстенә җирән йон күлмәк, --- аякларына кыршылып беткән болан итекләр кигән иде.* Н.Фәттах

**КЫРЫГАЛДАР** *и.* 1) *сөйл.* Һәрвакыт алдый торган кеше, алдакчы. *Аның [Диләрәнең] әнисе – кырыгалдар, белдеңме? --- Әнисе нинди булса, кызы да шундый була, дия, гел тукый безнең әби.* Х.Камалов

2) Аферачы. *Кырыгалдарлар заманы*

**КЫРЫГАР** *сан сөйл. к.* **кырыгышар**. *Кайбер спектакльләргә кырыгар бит текст ятлыйсы булды.* Т.Нәҗмиев

**КЫРЫГЫНЧЫ** *сан* Бер-бер артлы санаганда урыны кырык белән билгеләнгән тәртип саны. *Җилкәнле корабка утырып, «үкереп кырыгынчы параллельләр» аша үтүче, --- горур ялгызлыкта сәяхәт кылучы сукбай чын романтик булып тоела миңа.* М.Юныс. *Кырыгынчы елны ак мунчаны тегүче Хөснетдин абзый салып куйды.* М.Мәһдиев. *«Болгар номерлары»... Кырыгынчы бүлмә. Шигъри учак...* Р.Фәйзуллин

**КЫРЫГЫШАР** *сан.* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) бертигез күләмдә кырык булуны белдергән бүлем саны. *Җилкәнле флот чорында бер кубрикта кырыгышар кеше яшәгәндә, диңгезчеләр тәүлегенә унсигезәр сәгать эшләгәннәр.* М.Юныс

**КЫРЫГЫШАРЛАП** *рәв.* 1) Кырыгышар итеп, кырыгышарга бүлеп

2) Якынча кырыгышар

**КЫРЫЙ** *и.* **1.** 1) Нинди дә булса бер предметның чите, ян-ягына якын урыны. *Шулвакыт аның күзләре өстәл кырыенда Хәйри онытып калдырган пәкене күрделәр.* Г.Минский. *[Сестра] Нуруллин баш астындагы мендәрне уңайлады, одеял кырыйларын кыстырды.* А.Шамов

2) Берәр урынның (урманның, аланның, торак пунктның һ.б.ш.ның)

тирәсе, аның читендәге җир. *Минем урыным сәке кырыендагы тәрәзә янына туры килде.* Ә.Еники. *Иртәнге сорылыкта урман кырыендагы училище бинасы күренә.* М.Мәһдиев. *Кайта идек без җиләктән Урман кырые буйлап.* Ш.Маннур

3) Янынnan ара калдырып читтәрәк, арырак булган урын. *Ул [йөрәк] күкрәк читлегеннән бер кырыйга алып куйган сыман яман тыпырчына, сәер тасырдый.* М.Хәсәнов. *Бер кырыйда тулган ай, урман эчләренә моңсу ак нурын сибеп, әкрен генә йөзә.* Г.Әпсәләмов. *Кырыйдан карап тору*

4) Нәрсәнең дә булса яны, бик якын җире. *Колак кырыеннан гына выжт-выжт итеп пулялар сызгырганы ишетелә ---.* Х.Камалов

5) Буй юнәлештәге әйбернең (юл, елга, урман һ.б.) читендә буйдан-буйга сузылган пространство. *Болар урман кисә, төп чыгара, питомник утырта, канаулы юл кырыен чүп үләннән чистарта, ботак яндыра, квартал баганалары ясый, кыскасы, урманны үз балалары кебек кадерләп, саклап торалар иде.* М.Мәһдиев. *Асаф юл кырыена килеп урнашты, Лукин белән Габделнур мина ташыдылар.* М.Мәһдиев

6) Эшләпәнең түгәрәк, киң горизонталь чите. *[Күзлекле абыйның] Эшләпәсенең кырыйларыннан шыбырдап су ага.* Г.Нәбиуллин

7) Кайбер баш киемнәрен уратып ала торган тар полоса, кырпу. *Киң кырыйлы, кокарда фуражкалары аларның ак казаклар икәнлеген белдереп тора иде.* Ш.Усманов

8) Нинди дә булса бер мәйданның чите, чиге. *Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала.* А.Алиш. *Бу хәл 1941 елны булды. Алгы кырыйга бик ашыгып барганда ---.* А.Шамов

9) Нинди дә булса бер предметның ян өслеге, бер ягы, сырты. *[Рәйханә] Чәчләрен рәтләде, күзләренә бәреп чыккан яшьләрен кул кырые белән сөртеп алды ---.* Р.Ишморатова

10) Нинди дә булса бер савытның авыз чите, ирнәве. *[Сәлимә:] Вазаларның зәңгәр читлеләрен куйма: аның берсенең бер кырые бераз кителгән, ал читлеләрен куй.* Ф.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Үзәктән читтә булган, нәрсәнең дә булса читендәге; читтәге. *Әнә имән сайгак җәйгән кырый бүлектә бүген-иртәгә бозауларга тиешле сыер тора.* М.Хәсәнов. *Бакча түрендәге иң кырый тәрәзә – Лопесныкы.* М.Галиев

2) Ахыргы, соңгы. *Ярабби, дигәнең китми әрәмгә: Иң кырый зәррәгә кадәр уела!..* Г.Сәлим

◊ **Кырыйга кагу** 1) Кыерсыту, рәнҗетү. *Татар буржуазиясе моның өчен мине кырыйга гына какты.* Г.Камал; 2) Чит күрү, кабул итмәү. **Кырыйга кую** Баш тарту, кулланмау. *Кәбестәсенкыярын да кырыйга куймадым.* И.Сирматов. **Кырыйда калу** 1) Нәрсәдер житешмәү; 2) Нәрсәдәндер хәбәрдар булмау. **Кырыйда тору** Катышмау

**КЫРЫ́Й-КЫЛТЫКТАН** *рәв.* Читтән, дөрес булмаган юл белән. *Кырый-кылтыктан акча керә торгач, прораб типтереп көн итәргә күнегеп киткән.* Б.Камалов

**КЫРЫЙЛАП** *рәв. сөйл. к.* **кырыйлатып**. *Буага җитәрәк, сукмак тау кырыйлап үтә ---.* Р.Төхфәтуллин

**КЫРЫЙЛАТЫП** *рәв.* Берәр нәрсәнең кырыеннан, читеннән. *Яр кырыйлатып тартма белән бер генә урыйсың – тартып чыгарып булмый.* А.Хәсәнов. *Ул [Миңниса җиңги] абзар кырыйлатып бәрәңге бакчасына таба йөгерде.* А.Хәлим

**КЫРЫ́Й ЧЫГЫШ** *и.* Балалар уенының бер төре. *[Кыз балалар] Караңгы төшә башлагач, «кырый чыгыш», «түндек алыш» --- уйнарга тотыналар.* Ш.Әхмәдиев

**КЫРЫК** *сан* **1.** 1) 40 санын, микъдарын белдергән сан атамасы. *«Кырык, илле, алтмыш...» Нигәдер, җитмешне кушарга икеләнә [мастер].* М.Галиев. *Кырык чакрымлы сикәлтәле юлдан ничек үтсен, ди, ул?* Я.Зәнкиев. *Мөдәррисне әкияттәгечә «кырык көн уен итеп, кырык көн туен итеп», бәйрәмнәр ясый-ясый озатты.* Ф.Мөслимова

2) Кырык санына туры килгән озынлык, вакыт аралыгы, яшь. *Кырыктан уздык, дөньяда урыныбызны табар вакыт җитте.* Р.Мирхәйдәров. *Кыяфәтенә караганда кырыклар тирәсендә булырга охшый.* З.Фәйзи. *Әле бит аңа кырык та юк, чәчләренең инде яртысы ак.* Ф.Яруллин. *Факиһә дигәннәре – яше кырык тирәләрендәге шадра, тәбәнәк, ләкин бик сөйкемле пешекче хатын.* Ш.Бикчурин

3) *күч.* Бик күп, бихисап. *Көн саен кырык төрле эш чыгып тора.* Ф.Яруллин. *Керде Гәрәй – аның күз алдында Кырык ямау баскан ярлылар.* Зөлфәт. *Дүрт килене кырык эшен ташлап, тирәсендә бөтерелеп йөрде.* М.Галиев. *[Җәүһәрия] Кырык эшен кырык якка ташлап, шундук табын әзерләде, чәенмәен дә чыгарып куйды.* М.Хәсәнов

**2. кырыгы** *и. мәгъ. дини* Кеше үлгәннән соң кырык көн үткәч, аны искә алып үткәрелә торган йола. *Раббым! Урын-җир җыеп куелган, ястык күпертелгән, атаң гына юк мендә... Кырыгын укытканыма да атна-ун көн узып киткән икән бит инде!* Г.Сәлим. *Кырыгы җитеп килә, тып-тын йортта Ике шаулә – килен, кайнана...* Г.Сәгыйров. *Корьәнен дә чыгаралар. Өчесен дә үткәрәләр, җидесен, кырыгын... елын...* Ә.Гаффар

◊ **Кырыгы кырык якта кырылып яту** Эшләнәсе эшләрнең бик күп булуы. *Кырык якта кырылып эшләр көтә – Дөнья, гүя, мәңге яшь килен...* Ф.Җамалетдинова. **Кырыгына бер иман** Барысы да ышанычсыз. *[Шәмсетдин:] Андыйлар бит тегендә дә атылалар. Андыйларның бит аның кырыгына бер иман.* Г.Бәширов. **Кырык бер кат** *к.* **кырык бер мәртәбә**. **Кырык кат** *к.* **кырык бер мәртәбә**. *Кырык кат әйтү.* **Кырык бер мәртәбә** Бик күп мәртәбә, бик күп тапкыр. **Кырык даланың кырыена** Бик еракка, билгесез, белмәгән-күрмәгән ерак җиргә. *[Сафия:] Ышанмаган булсам, синең белән бер ялгызым кырык даланың кырыена килмәгән булыр идем.* Ш.Камал. **Кырыкка бер тулмаган** *гади с.* Юләр, ахмак кеше турында. **Кырыкка бөгү** Ихтыярсыз, көчсез кеше белән ничек теләсәң, шулай эш итү, аны теләсә нинди эшкә күндерү. **Кырыкка бүлену** Берьюлы берничә эш башкару. *Хатны*

*кырыкка бүленеп язу.* **Кырыкка телгәләнеп беткән** 1) Тузган, сәләмәләнеп беткән; 2) Хәлсезләнгән. *Кырыкка телгәләнеп беткән йөрәк.* **Кырыкка төрләнү** Гел үзгәреп тору. *И дөньялар, Тимерхан яшәгән чорда гына да сез кырык төрлегә төрләндегез бит!* Г.Ахунов. *Фәридун Фазлыев --- язын кешеләрнең кәефе кырыкка төрләнүе турында гамьсез генә бер-ике сүз әйтеп салды.* А.Гыйләҗев. **Кырыкка ярылу** Эш бик тыгыз һәм күп булганда, берьюлы берничә эшне башкару яки берничә урында булу кирәклеге турында. *Булатлар кырыкка ярылалар. Магниттан түгәрәккә, түгәрәктән заводка, аннан массовкага чабалар.* Г.Ибраһимов. *Бер кеше кырыкка ярылыр вакытта колхоз эшенә төкереп, туй итеп йөрдең.* Г.Бәширов. *Кырыкларга кайчак ярыла Кырык кылдай көнгә адәмнәр, Җитмеш төрле төскә керәсең дә, Ул да итми кайчак ярдәмнәр.* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Кырыкмаса кырык** Бик күп, исәпсез-хисапсыз. *Яшь чагындарак ишеткән вакыйгаларны кырыкмаса кырык тапкыр сөйләгән булса да сөйли белә – Рәхмәтулла андый йомакларны, әкиятләрне ярата.* Я.Зәнкиев. *Фатыйманың башына кырыкмаса кырык төрле уй килә.* Ә.Сафиуллин. *[Сөмбелә] Кырыкмаса кырык тапкыр алышынган чыбык элгечкә килеп кагылган гына иде, кемдер ишек шакыды.* К.Кәримов. *Сибгать бертуктаусыз Җәмилә хакында сөйләде, кырыкмаса кырык җирдә кабатлады.* Ф.Яхин. **Кырыктан артык кыңгыр як** Бик күп җитешсезлекләр, кимчелекләр. **Кырык тармаклы итеп** Бөтенесен дә искә алып, күздә тотып. *Бер-берсенең күңелләренә охшаштылар булса кирәк, чәйдән соң бик тәмләп, иркенләп сөйләшеп киттеләр. Кырык тармаклы итеп гәпләштеләр.* Б.Камалов. **Кырык фарыз** *дини* Мөселман кешегә белү һәм башкару мәҗбүри булган гамәлләр. *Коллык күрсәтү кебек эшләр --- иман шартларындагы кырык фарызларны ятлаудан да, намаз вакытында әгъзаларны туры тотудан да авыр булды.* М.Гафури. **Кырык чөе кырылып китмәгәе** *к.* **кырык чөйләре кырылып бетсен**. *Кырык чөең кырылып китмәгәе дип карап, үзләренә печәнгә йөрүчеләр --- уңдылар.* Р.Төхфәтуллин. **Кырык чөйләре кырылып бетсен** Теләсә нәрсә булсын, теләсә нинди хәлгә килсен. *[Биби:] Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда.* Г.Камал. **Кырык ясин чыгу** *дини* Кеше үлгәннән соң, кырыгына кадәр, һәркөн бер тапкыр Коръәннең «Ясин» сүрәсен укып багышлау

**КЫРЫК-ИЛЛЕ** *сан* Кырык белән илле арасында булуны белдергән чама саны; кырыктан иллегә кадәр. *Булса кырык-илле кеше бардыр.* Х.Сарьян. *Һавада, башкалар идарә иткән самолётка утырып, кырык-илле минут җир белән элемтә тотып йөрүнең әллә нәрсәсе юк иде.* Ф.Яруллин. *Бу якларда авыллары да бик бай, аралары да ерак шул: кырык-илле чакрым.* Р.Фәизов

**КЫРЫККАРТА** *и.* 1) Күшәүче хайваннар ашказанының бер өлеше. *Зур кәстрүлгә башта иттарткычтан чыгарылган эч мае, аның өстенә ваклаңган сыер аяклары салына, кырыккарта ваклап турала.* Юлдаш

2) *күч.* Билгесез нәрсә. *Кызлар – кырыккарта, башта ал да гөл, татлытәмле, аннары убырга әйләнәләр.* Х.Камалов

**КЫРЫК КАТЛАМА** *и. этн.* Катлап пешерелгән камыр ашы

**КЫРЫК КОРАМА** *и.* 1) Бик күп төрле вак чүпрәк кисәкләреннән, кыеклардан тегеп ясалган әйбер. *Кырык корама юрганда Мин ятмыйм икән нигә?* А.Хәлим

2) *күч. кимс.* Төрле төрдәге әйберләрнең, төрле караштагы кешеләрнең кушылмасы. *«Мөселман иттифакы»ның әгъзалары --- мәсләк – уй җәһәтеннән кырык корамадан гыйбарәт иде.* Г.Исхакый

**КЫРЫККЫЧ** *и.* Секатор. *Кырыккыч белән эшләү*

**КЫРЫКЛАП** *сан* Якынча кырык булуны белдергән чама саны. *Кырыклап олау, ике йөзләп кеше; березы ат өстендә, ә күпчелеге – җәяүле гаскәр.* Ә.Еники. *Өйрәнүләр раслаганча, таш гасырның башлангыч чорларында һәр 100 кешенең кырыклабы 14 яшькә тикле үлә торган булган, унбишләбе генә 20 яшькә тикле яшәгән.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**КЫРЫКЛЫ** *с.* **1.** 1) Кырыгынчы үлчәмдәге. *Түшәмдә тәлинкәсез генә асылынып торган кырыклы лампочка кабынды.* З.Фәтхетдинов. *Арабыздагы мәхәббәт кылларының кырыклы кәтүк җебедәй нечкәрүенә эчем пошып, мин дә хатын янына үрмәләдем.* Ф.Шәфигуллин

2) *күч. гади с.* Бик зур. *Кырыклы итек*

3) Кырык градуслы (спиртлы эчемлекләр тур.). *Кызылның да кырыклысы була икән.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ. гади с.* Кырык градуслы аракы. *[Җәүһәрия:] Кыз башым белән кырыклы ташып йөрисем юк.* Р.Ишморат. *Кырыклыны кәгеп алган булгандыр ул.* Б.Камалов

**КЫРЫКЛЫК** *и. иск.* Сыешлыгы 10 литрлы чиләкнең 1/40 өлешенә тигез булган шешә

**КЫРЫКМА** *с.* Билгеле бер рәвешкә китереп кырылган. *Кырыкма сакал*

**КЫРЫКМЫШ** *и.* **1.** Икенче яшенә чыккан, ялы, койрыгы кыркылган тай. *Кырыкмыш шикелле, азгын язмышына бирелеп чыгып киткән --- [Нурлыбикә].* Г.Кашапов. *Урман аланында утлап йөргән атлар арасыннан ул берьюлы ике кырыкмыш тотып килде.* М.Мәһдиев. *Башта бу эшне ошатмыйча, тәртә арасына яңа керткән кырыкмышлар кебек тибенгәләп карасак та – булмады.* Р.Хафизова. *Газоннарга утыртылган чәчкәләр кояшка елмая, тигез кыркылган яшел үләннәр, яшь кырыкмыш тәнедәй елкылдап, күзләрне иркәли.* Н.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Икенче яшенә чыккан, ялы, койрыгы кыркылган (тай тур.). *Көтүеңдә бер кырыкмыш ат бар бит әле.* Р.Зәйдулла. *Безнең әти узган ел көз икенче яшькә чыгып кына калган кырыкмыш тай алып калдырган иде.* М.Гали. *Син – авыл малае, күргәнең бармы, кырыкмыш тайны ничек җигәргә өйрәтәләр?* Ш.Бикчурин. *Койрык чәнчеп чапкан кырыкмыш тай сыман йөрим бит дип, үзен гаепләде ул, ниһаять.* Б.Камалов

2) Яшел кыягы өчен үстерелә торган (суган төре). *Кырыкмыш суган*

3) *күч.* Яшь; җилбәзәк, төптән уйлап бетерми торган. – *Кушаматың җукмыни? Ә минеке бар. Кырыкмыш Гыймади мин. – Кырыкмыш тай гына була ул.* Ә.Гаффар

**КЫРЫК ТАРТМА** *и. иск.* Йөреп сатучы җилкәсенә аскан, вак-төяк әйберләр тутырылган тартма. *[Хизбулла] Кырык тартма белән канәфер, дарчин, бадиян сатып, күз буяп йөри.* К.Нәҗми. *Эт тә, мәче дә кызыгырлык нәрсә юк анда, кызыл мал белән кырык тартма товарлары гына.* М.Гали

**КЫРЫКТАРТМАЧЫ** *и. иск.* Гадәттә, авылдан-авылга йөреп галантерея әйберләре белән сату итүче. *Кибет прилавкалары артында – түбәтәйле, казакилы юан сәүдәгәрләр. Муеннарына такта әрҗә «кибет»ләрен аскан, канәфер, дарчин, борыч яисә каптырма, сәдәф, төймә сатып йөрүче көр тавышлы кырыктартмачылар.* А.Расих. *«Алла бирсә, баесамнитсәм, камалы тун тектерәм», – дигән кырыктартмачы үсмер кебек, ул [Сәдит] сәгатьне, чынлап та, баеган хәлендә сатып алырга җыена иде.* А.Хәлим

**КЫРЫК ТЕШ** *и. тех.* Тегермәндә су яки җил көчен тегермән ташына тапшыра торган деталь, тешле тәгәрмәч

**КЫРЫК ТЫРНАК** *и. к.* **кырык теш**

**КЫРЫК ЧӨЙ** *и. диал. к.* **кырык теш**. *Җизни мине тегермәннең астына алып төшә, кырык чөйләрне күрсәтә.* Ф.Хөсни

**КЫРЫЛДА́У** *ф. к.* **кырлау**. *Бакчы, [тавык] ничек кырылдый.* Ф.Шәфигуллин

**Кырылдап алу** *к.* **кырлап алу**

**Кырылдап йөрү** *к.* **кырлап йөрү**. *Теге Миңлиса тавыгы йомырка салмый башлаган, кырылдап йөри.* К.Тинчурин

**КЫРЫЛУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кыру** I. *Кайсыдыр елны, күрше районнан кайтканда, аның машинасының арткы күчәре кырылып чыкты.* Ф.Садриев

2) *диал.* Ышкыла-ышкыла яки озак киюдән тузу, өске каты зарарлану (кием һ. б. ш. тур.)

**КЫРЫЛУ** II *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **кыру** II

2) Күпләп үлү (кешеләр тур.). *Ачлыгы, тифе-ние белән дөнья кырылды.* Ә.Галиев // Терлекләр күпләп үлү, үләт төшү. *Малларның кырылуы сәбәпле, иптәш Дөмәнтиевны урыныннан алып, төрмәгә утырттылар.* Р.Батулла

3) Ватылу, чәлпәрәмә килү. *Чынаяклар кырылу вакыйгасын әтисе әнә шундый истәлек итте.* М.Хуҗин

4) Җимерелү. *Мондый кырылу, ватылулар тракторчы өчен әллә ни искитәрлек нәрсә түгел.* Н.Фәттах

5) Ачулану, үпкәләү. *Син дөньяга кырылып йөрмә.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв мәгъ.* Күпләп. *Әгәр бүгенге көндә Илһам Шакировның мемуарлары, истәлекләре басылып чыкса, минемчә, халык аларны кырылып укыр иде.* Р.Вәлиев

**Кырыла бару** Торган саен ныграк, күбрәк кырылу. *Эшкә чыкмаучының исә бернинди өмете юк – бер-бер артлы ачтан кырыла баралар.* Р.Мостафин

**Кырыла бирү** Күрелгән чараларга да карамыйча кырылуын дәвам итү. *Галимнәр әллә нинди лабораторияләр ачтылар, әллә ниткән штатлар алып бетерделәр, өйрәнепме-өйрәнәләр, ә дуңгыз балалары кырыла бирә.* М.Мәһдиев

**Кырылып бетү** Тулысынча, барысы да кырылу. *Балыклы чишмәсендә үрчегән балыклар да күптән кырылып беткән булыр иде.* М.Юныс. *Ярдәмгә безнең танклар Килеп җиткәндә, инде Немецларның танклары кырылып беткәннәр иде.* Ә.Исхак. *Шуннан шул: кандалалар күршегә керәләр дә шундагы кандалалар белән сугышып кырылып бетәләр.* М.Мәһдиев

**Кырылып тору** *к.* **кырыла бирү.** *Сугышта татар өлкән абыйлардан да күбрәк кырылып тора.* М.Юныс

**Кырылып яту** Күпләп кырылу. *Ләкин җилкәләр чиләнеп тарткан зур, авыр колхоз эше кырылып ятканда, берәүнең сыеры югалган кебек бәләкәй эшләрнең кирәге булмагандыр ---.* Х.Сарьян

**КЫРЫЛЫШ** *и.* Күп корбанлы сугыш. *Кырык ел кырылыш булса да, әҗәле җиткәннәр генә үлә, дигән...* Х.Сарьян. *Без ---, әниләр кичкелекне ашарга чакыргач, нинди генә кырылыш баруга карамастан, солых та төзеп тормастан, өйләребезгә тарала идек.* М.Юныс. *Кайчан бетәр икән кешелек тарихында тиңе булмаган бу дәһшәтле кырылыш?* М.Хуҗин. *Гомер буе – сугыш, гомер буе – кырылыш.* Р.Вәлиев

**КЫРЫЛЫШУ** *ф.* **1.** Күпләп һәлак булу

**2. кырылышып** *рәв. мәгъ.* Күпләп. *[Пароходтан] Кырылышып халык төшә башлады.* Х.Сарьян. *Хәер, андый советтан бер аспирант та калмый, --- өйрәнер өчен, андый гыйльми советка кырылышып йөриләр иде.* Х.Сарьян

**КЫРЫМСАГЫЗ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, тузганакка охшаган, югары сыйфатлы табигый каучукка бай күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **крым-сагыз**

**КЫРЫ́МЧА** *рәв.* Кырым татарлары кебек, Кырым татарларына хас булганча. *Анысыннан да бигрәк, Нилүфәр җиңгинең кырымча сөйләшүен рәхәтләнеп тыңлый идем.* Х.Сарьян. *Җырла әле бик матур итеп үзебезнең кырымча татар көен.* Х.Сарьян

**КЫРЫН** *рәв.* **1.** 1) Билгеле бер өслеккә авышлык ясап, авышып. *[Каюм] Кулларын артка куйган, башын кырын салган, хәчтеруш.* М.Әмирханов. *Төшеп идәнгә кырын, Ул сындырган койрыгын.* Ш.Маннур. *Ул [Ирек] утырып та укыды, чалкан ятып та, кырын ятып та ---.* Ф.Садриев

2) Беркадәр борылып; ян белән. *Миңа кырын борылып, хатын уч-уч кар белән битен, беләкләрен уа да кереп китә.* Ә.Гаффар. *Җизни, ничектер, башын артка ташлап, каенишенә өстән һәм кырын карап, сүзләрне теш арасыннан чыгарып җибәрде.* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Дөрес түгел, начар. *Ә берсөнне купты илдә Түнтәрелеш... Кырын китте милләт юлы, Бар изге эш!* Р.Рахмани

**2.** *с. мәгъ.* Начар; гадел булмаган; әхлаксыз; авыр. *Кырын эш кырык елдан соң да беленә, диләр.* Х.Сарьян. «*Нишләптер хәзрәт сине чит күрә, ят итә башлады, яшерен таш төрән сындыра, ди, искәрмәстән генә берәр кырын эш*

*эшләп куймагае», – дип сүз салучылар да булды [Иргалигә].* М.Хәсәнов. *Ләкин бу – иренә каршы килүдән түгел, --- бары тик әлеге ана хисләренең какшамас нык булуыннан, баласына ничек тә кырын сүз тидерәсе килмәгәнлектән генә тыпырчынуы иде.* Ф.Хөсни

**3.** *бәйл. функ.* Таба. *Тәзкирә апа, иртәгә кичкә кырын барсам, ничек булыр?* А.Шамов. *Кич кырын Инсаф тулай торакка кайтып керде ---.* Ә.Моталлапов

◊ **Кырын багу** *к.* **кырын карау**. *Җылылыкны мең кат күбрәк алып, туклык тоеп үскән балалар, Милләт туңган чакта... кайда алар, Нигә аңа кырын багалар?* Р.Рахмани. **Кырын карау** Үз итмәү. *Аңа [профессорга] бик кырын карыйлар: ул – дөньяга мәшһүр ботаник, университет галимнәре арасында Октябрь революциясенә кадәр үк профессор исемен алган бердәнбер кеше.* М.Мәһдиев. *Йөз чытмадым язмышыма кырын карап, Посарга җай эзләмәдем борылгалап, Халкым белән тоташ кыя булганга мин ---.* Н.Арсланов. *Сизсен генә [эт] миңа кемнеңдер кырын караганын, бирим генә бер сигнал – филеңә дә барып ябышачак.* Ф.Латыйфи. **Кырын күз белән карау** *к.* **кырын карау**. **Кырын күзен салу** 1) *к.* **кырын карау**; 2) Тиз генә сиздермичә карап алу. *Кырын күзен генә салып чамалап алды Зәйтүнә: класста икәнлеген оныткан шикелле малай.* Ф.Хөсни. **Кырын тору** 1) Начар мөнәсәбәттә булу. *Һаҗәр мине яратмавын электәге шикелле ачык күрсәтми һәм ачыктан-ачык кырын да тормый.* Ә.Еники; 2) Төрле авырлыклар, кыенлыклар чыгып тору. **Кырын яту** 1) Эшсез, үз көеңә, үз дәрәҗәңне белеп яшәү. *Әбекәем, булып көек, Йөрмәсәнә нужа чигеп; Картайгансың, хәлдән тайган. Бирмәсләрме сиңа урын, Мич башында ятсаң кырын?..* Г.Сәгыйров. *[Әнвәрия:] Кырын ятып радио тыңлар көннәр булырмы бер.* А.Гыйләҗев; 2) Җайлап урнашу. *Сабирҗан да алар тирәсеннән урын тапты, кырын ятты.* Ф.Яхин

**КЫРЫНАЮ** *ф.* Кыегаю, бер якка авышу. *[Пароход] Халык җыелган якка шактый кырынаеп, үзенчә гайрәтләнгән булып, зур калаклы тәгәрмәчләрен шапылдата-шапылдата, ул елга уртасына таба борылды.* Ә.Еники. *Җиләк җыеп арган карчык кебек Кырынаеп байый кояшы.* М.Галиев

**Кырынаеп бетү** Бик авыш хәлгә килү

**Кырынаеп китү** Бераз кырынаю

**Кырынаеп тору** Кырынайган хәлдә булу. *Кырынаеп тора иске йортлар.* К.Сибгатуллин

**Кырыная башлау** Авыша, кырыная төшү. *Беренче көнне кукәй кузәнәк стеналарына параллель хәлдә тора; икенче көнне ул бераз кырыная башлый ---.* Умарта кортлары

**КЫРЫНГЫЧ** *и. сөйл.* Сакал-мыекларны кыру әсбабы. *Мине күргәч, электр кырынгычың шул көе безелдәп эшләп калды, ә син, мине күтәреп алып, өй буенча әйләнеп йөри башладың.* Ф.Садриев. *Сабый, көтә-көтә арыгач, дәү әтисенең «Агыйдел» кырынгычын ала да, --- «Әти, кайт, әни, кайт», – дип, телефоннан сөйләшеп утыра икән.* Сәхнә

**КЫРЫНДЫ** *и. диал.* Күәс төбе камырыннан пешерелгән кечкенә ипи

**КЫРЫНДЫК** *и.* **1.** 1) Савыт төбеннән кырып-себереп алган калдык

2) *к.* **кырынды**

**2.** *с. мәгъ.* Күәс төбе камырыннан пешерелгән. *Сиңа кырындык ипи пешердем.* Ф.Шәфигуллин

**КЫРЫ́Н-КЫРЫН** *рәв. сөйл.* 1) Туры итеп түгел, күз кырые белән генә. *Караңгы чырайлы кеше янында Сөләймановның үзенең дә күңеле боега башлады, һәм ул Коненкога кырын-кырын карап алды.* И.Гази. *Күршеләргә килгән башка чир дә безнең өй турыннан кырын-кырын гына карап үтә.* Х.Сарьян

2) Ян белән. *Рокыя, шәленә капланып, кырын-кырын чыгып китә.* Ф.Әмирхан. *[Тәлгать] --- бишмәтен бүреген кигән килеш, кырын-кырын чыгып китә.* Ф.Хөсни. *Атлар, сискәнеп, башларын күтәрәләр, --- кырын-кырын атлап китәләр, колакларын шәмрәйтәләр.* Ф.Шәфигуллин

3) Кача-поса, яшеренеп. *Бүтәннәре, кырын-кырын, капка артына яшеренделәр.* Г.Бәширов

**КЫРЫНЛАП** *рәв.* Кырый, ян белән. *Кан сауган бәбәкләрнең агы белән генә карап, янлап, кырынлап, миңа таба якынлаша бу [үгез].* М.Хәсәнов

**КЫРЫНЛЫК** *и.* Начарлык, комачаулык. *Кырынлык эшләү*

**КЫРЫ́Н-МЫРЫН** *рәв. сөйл.* 1) Төрлесе төрле якка авышып. *Ул тыңлар-тыңламас, кырын-мырын утырган шәкертләрнең үзенә ышанмыйча күлеп караган күз карашлары астында [сабакны] дәвам итте.* Ә.Фәйзи

2) *күч.* Килешмичә, тискәре; каршы

**КЫРЫНТЫК** *и.* **1.** Кисәк-кисәк, вак кисәкләр (күн һ.б.ш. әйберләрнең калдыклары тур.). *Кырынтыклардан тегү*

**2.** *с. мәгъ.* Кисәк-косактан, вак кисәкләрдән торган. *Кырынтык күннәр ялгау эше*

**КЫРЫНУ** *ф.* Пәке яки махсус кырыну әсбабы белән сакал-мыекны төбеннән кистереп алу. *Бүген Нил Хачатурович ике тапкыр кырыначак, диләр.* Х.Камалов. *Капитан кырынмаган, бите-күзе кызарган, ачулы кыяфәттә.* М.Мәһдиев. *Чал мыеклы полицмейстер --- бүген генә кырынган ияген әллә ничек килешсез селкетеп кычкырды.* К.Нәҗми. *Поход, сугыш алдыннан ул кырынмыйча калмый ---.* И.Туктар

**Кырынып алу** Тиз генә кырыну. *[Габделбәр] беренче эш итеп кырынып алырга ниятләде.* Б.Камалов. *[Шефның] «КамАЗ»кабинасы төсле ялык-йолык килеп торган шома ишекләренә карап, күз ачып йомганчы кырынып алырлык.* Р.Вәлиев. *Бүлмәгә килеп керүгә, ул иң әүвәл кырынып алырга булды.* М.Хәбибуллин

**Кырынып ату** Бик тиз арада кырыну

**Кырынып бетерү** Кырынуны тәмамлау. *Тукта, мин кырынып бетерим инде. Аннары ашны чыгып карарга булыр.* М.Хәбибуллин. *Моратбакый кырынып бетергәч тә көзгене үз урынына элмәде.* М.Галиев

**Кырынып бетү** *к.* **кырынып бетерү**. *Кырынып беткәннән соң, Сәфәргали үзенең фронт истәлеге итеп саклый торган гимнастёркасын алды, солдат гадәте буенча, аңарга эчтән ак яка текте, сугыш значокларын алып такты.* Ф.Хөсни. *Кырынып беткәч,*

*башта җылы, аннары салкын (яки бары тик салкын) су белән юынганнан соң, тирене дезинфекцияләү өчен, биткә одеколон --- сөртү файдалы.* Файдалы киңәшләр

**Кырынып җибәрү** *к.* **кырынып алу**. *– Яле, солдат, кырынып җибәрик, – диде [бабай].* Н.Дәүли

**Кырынып йөрү** Даими кырыну. *Ул бит пөхтә, кырынып йөри, чәч үстерми.* Б.Камалов

**Кырынып кую** Алдан кырыну. *Сезне каршы алырга кырынып куйдым.* В.Нуриев

**Кырынып ташлау** *к.* **кырынып ату**. *Мифтахның кәеф-сихәтләре күтәрелеп китте, кырынып ташлады.* Т.Галиуллин

**Кырынып тору** Даими кырыну // Әле, хәзер кырыну. *Ике-өч көннән ванна бүлмәсенә керсәм, ыспай гына бер егет кырынып тора!* Ф.Баттал

**Кырынып чыгу** Һәрберсе берәмберәм кырыну. *Бу калайны цемент идәнгә ышкып үткенлиләр дә бөтен камера – утызлап кеше – ялт итеп кырынып чыга.* Р.Мостафин

**КЫРЫ́Н-ЯРЫН** *рәв. к.* **кырынмырын.** *Чтапан кайтып киткәч, әти кырып-ярын ятып, кәефләнеп бер җырлап та алды.* Г.Афзал

**КЫР-ЯЛАН** *җый. и.* Кырлар, яланнар. *Аста кыр-яланнар, авыллар, төзелешләр, юллар – адәм балаларының җирдә калдырган эзләре.* М.Юныс

**КЫРЫ́П-БЕТЕРЕП** *рәв.* Тулысынча, бөтенләй юкка чыгарып, ахырга, нигезенә кадәр юк итеп. *Шушы икән инде ул бәйдән ычкындырып җибәрелгән өер! Ватып-җимереп, яндырыпкөйдереп, кырып-бетереп килүче «батырлар».* Ә.Еники. *Һәм алар башка хайваннар ашамый торган 570 төрле чүп үләнен кырып-бетереп торалар икән.* Кызыклар дөньясында

**КЫРЫ́П-ҖИМЕРЕП** *рәв.* Юлындагы бөтен нәрсәне ватып һәм юкка чыгарып. *Тышта, ишегалдында, әллә нәрсәләр, әллә кемнәр, дию пәриедәй дулап, үкереп, бөтен нәрсәне кырыпҗимереп йөриләр сыман.* Г.Бәширов

**КЫРЫ́П-СЕБЕРЕП** *рәв.* Берсен дә, бер дә калдырмыйча; барысын да җыеп. *Ярар, булган кадәр акчабызны кырып-себереп бирим инде алайса.* З.Фәйзи. *– Бөтенесен дә кырыпсеберереп җыйдыгыз ич, кырыгынчы үлчәм, – диде җавапчы, рәнҗетелгән кеше сыман.* М.Насыйбуллин. *Ул чорда амбардагы ашлыкның бөртеген дә калдырмыйча, кырып-себереп алдылар.* Татарстан яшьләре

◊ **Кырып-себереп ташлау** Юк итү, юкка чыгару. *«Черек стройны кырып-себереп ташлаячак революция давылының якынлашуы» турында борчулы сүзләр ишеткәләгәч, ул үзенең барлык эшләренә кул селтәде дә тизрәк Казанга ашыкты.* К.Нәҗми

**КЫРЫ́П-ТҮГЕП** *рәв.* Ахырга кадәр бетереп, тулысынча чистартып. *Өйдәге бар ризыкны кырып-түгеп, ишектәрәзәләрне ачып куеп, берничә көн шулай тоттылар.* Татарстан яшьләре

**КЫРЫС** *с.* **1.** 1) Кирәгеннән артык җитди, каты күңелле, кискен холыклы. *Кыргызга тартым кыяфәтле, ләкин озын буйлы, арык кына кырыс адәм.* А.Гыйләҗев. *Кырыс, усал, гаярь кеше иде безнең әткәй.* Р.Мулланурова. *Апа, әби шикелле, кырыс холыклы, дары мичкәсе сыман гөлт итеп кабынучан.* Сөембикә. *Яңа өйләнешкән чорлары булса да, инде иренең кырыс, вакчылрак холыклы икәнен чамалый башлаган хатыны, тавыш чыгасын сизеп, эндәшми кала.* Мәгърифәт

2) Җитди кыяфәтле, мөгамәләдә артык коры. *Ул – монда төп хуҗа, иртән кәрә, кырыс күзләре белән камераның һәр почмагын, борылышын җентекләп капшап үтә, кермәгән ярык, күрмәгән нокта калмый аңардан.* А.Гыйләҗев. *Бу юлы да чыгышым ошамады, тәнәфестә яныма кырыс кына бер ир кеше килде.* А.Гыйләҗев

3) Каты күңеллелекне, артык җитдилекне белдереп торган. *Бу сүзләрне тимер тәнле, кырыс Пермяков күз яшьләренә манчып сөйләде.* А.Гыйләҗев. *Чәчтараш арган, ул бүген йөзләгән кешене кырыккан, ул кырыс, усалланган.* А.Гыйләҗев

4) Миһербансыз, аяусыз. *Бу мәсьәләдә, кирәк икән, кырыс та, аяусыз да булырга тиешбез.* Мәдәни җомга. *Үзенә РФ Җинаять кодексының «Мошенниклык» дигән 159 маддәнең иң кырыс 4 нче кисәге буенча белдерелгән гаепләүне тикшерү барышында да, инде узган елның 6 маеннан бирле дәвам иткән суд утырышында да кире кагып барды.* Мәдәни җомга. *Кырыс чынбарлык дәрьясының кайбер тамчылары гына әле бу.* Мәгърифәт

5) Кулга ияләшеп җитмәгән, баш бирми торган; усал, дуамал. *Кырыс айгыр, артык көч белән тартылып, көтүчене ярым еккан, ләкин аякларын ирдән, өзәңгедән чыгарып җиргә төшерә алмаган иде.* Г.Ибраһимов

6) Тормыш итү өчен кыен, яшәү өчен авыр, уңайсыз булган. *Тәмле төшләр күреп йоклый идек – Кырыс заман төртеп уятты.* Зөлфәт. *Без бит һәммәбез кырыс дөньяда яшибез.* Ф.Яруллин. *Әнә шул елларда ук Фән үзендә кырыс бер яшәү ритмы тоеп ала...* Идел

7) Каты, тәләпчән, җитди. *Фюрерның тынгысыз көрәше, каты куллы булуы һәм кырыс тәртипләр урнаштыруы аркасында, илдә тормыш дәрәҗәсе нык кына күтәрелде...* Т.Әйди. *Мондый кырыс чикләү фәнни гаделлеккә каршы килсә дә, ничәмә-ничә еллар буе шул хата идеология өстенлек итте.* И.Надиров

8) Кискен, ачы. *Кырыс җилләр, ачы бураннар белән көрәшергә өйрәнгән ялгыз үскән агач төсле, Әлфия бары тик үз көченә, үз акылына, үз ихтыярына таяна.* Т.Галиуллин. *Көйгән, корыган тигәнәкләрне, әрсез алабуталарны селкетеп, кырыс җил исеп куйды, ул җил авыл ягыннан янгын исе, көйгән ит исе алып килде.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Артык кискен, җитди, катгый. *– Утрауга ул үзе баргандыр, – диде ул кырыс кына.* М.Насыйбуллин. *Кирәк булганда, дөреслек, гаделлек өчен кырыс та була белә.* М.Әмир. *Беренче карашка кырыс күренгән бу кеше чын күңелдән безне кайгыртты.* Ф.Фәтхелислам. *Миңа бик кырыс кына кисәтү ясадылар.* М.Мәһдиев. *«Ә сезгә юк», – диде ул, хатыннарга кырыс карап.* Ф.Яруллин

**КЫРЫСЛАНУ** *ф.* 1) Каты күңелләнү, рәхимсезләнү. *Алар сүзенә*

*караучы Самат исә, алыштырган кебек булып, башка чыгу планын телдән төшереп, көннән-көн кырыслана.* З.Фәйзи. *Дөресен әйтергә кирәк, кеше аннан гаять кырысланып, кыргыйланып, рухияттән, Раббыбыздан бик нык ераклашып, матдиятчелеккә тәмам кереп баткан хәлдә чыкты.* С.Шәмси. *Болай да тартылган кыл шикелле киеренке мөнәсәбәтләр тагын да кырыслана.* Т.Галиуллин. *Шәһәрнең тынычсыз ыгы-зыгысында мин чыныктым, кырысландым.* Мәдәни җомга

2) Җитдиләнү. *[Иргалинең] Йөзе кинәт кырысланды, яңак калканнары хәрәкәтләнеп, зураеп киткән сыман булды.* М.Хәсәнов. *Бары тик көләч йөзе кырысланды, һәм каш араларына тирән сызык чыкты.* Г.Әпсәләмов

3) Шартлар авырлашу, уңайсызга әйләнү. *Ирләр булса, мондагы дөнья, мондагы тормыш, ни өчендер, катыланыр, кырысланыр, һәрхәлдә, минем файдага булмас кебек иде.* А.Хәлим. *Биредә табигать тагы да кырысланган, төньяк җилләре җиләк-җимеш үстерергә мөмкинлек бирми.* Татарстан яшьләре

**Кырыслана бару** Торган саен, вакыт үткән саен кырыслыгы арту. *Капитанның йөзе кырысланганнан-кырыслана барды, кашлары җыерылды.* Г.Әпсәләмов. *Алтын гасыр дәверен үтеп, аннан ераклаша барган саен, Җирдә рухият сүрелә, тормыш үзе дә, андагы тәртипләр дә кырыслана бара...* С.Шәмси. *Роберт Миңнуллин шигыренең эмоциональ яңгырашы, кайгы-хәсрәтле хис-кичерешләр өермәсе торган саен кискенләшә, кырыслана бара.* Ф.Урманче

**Кырыслана башлау** Кырыслану билгеләре күренү

**Кырыслана бирү** Үзеннән-үзе кырыска әйләнү, кырыслануын дәвам итү

**Кырыслана төшү** Тагын да кырыслану; бераз кырыслану. *Ләкин беркем бер сүз әйтмәде, беркем берни белдермәде, бары тик чырайлар гына кырыслана төште дә, кысылган күзләрдә очкыннар гына күбәйде.* Н.Фәттах. *Хөкем карары укылгач та, бу батыр кешеләрнең [җәлилчеләрнең] бер генә мускулы да калтыранмый, бары тик аларның йөзләре генә тагы да кырыслана төшә.* Р.Мостафин

**Кырысланып алу** Бераз гына кырыслану, кыска бер вакыт аралыгында кырыслану. *Аның тавышы сизелер-сизелмәс кырысланып алды.* Н.Әхмәдиев

**Кырысланып бару** Аз-азлап, акрынлап кырыслыгы арту. *Чакырсын гына Дамир, җир читенә барып, аякларын салындырып утырыр иде. Кырысланып барган күңелләре эреп китә бит аны күрсә...* С.Шәрипов

**Кырысланып бетү** Тәмам кырыслану. *Рамиләнең әтисе – ут сүндереп йөреп кырысланып беткән кеше – тикшерүчән карашын миңа төби.* Р.Рахман. *Корычланып, кырысланып беттем, – Еллар мине шулай иттеләр.* Х.Туфан

**Кырысланып җитү** Инде тәмам кырысланган булу

**Кырысланып калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан, вакыйгадан соң кырыслану. *Әмма яңа кешенең моңа сизелеп үк хәтере калгандай булды: җил кискән каракучкыл йөзе тагын да ныграк караңгыланып, кырысланып калды.* Н.Фәттах. *Аның йөзе әледән-әле үзгәреп тора: бер уйчанлана, бер ачылып-яктырып китә. Вакыт-вакыт кырысланып та кала ул.* Н.Хәсәнов

**Кырысланып китү** Көтмәгәндә, кинәт кырыслану. *Аның йөзе кырысланып китте: – Рәхмәт әйтсеннәр! – диде.* М.Маликова. *Ул, моңарчы булмаганча, җитдиләнеп, кырысланып киткән иде.* З.Фәйзи

**Кырысланып кую** Кинәт кенә, аз гына вакыт аралыгында кырыска әйләнү

**Кырысланып тору** Әле, хәзерге вакытта кырыслану

**КЫРЫСЛЫК** *и.* 1) Каты күңеллелек, кирәгеннән артык җитдилек, таләпчәнлек. *Бәлки, яшьлек кырыслыгы узар, тормышның касыкка суккалый торуы аны да һавалану чиреннән аралар иде.* Б.Камалов. *Кызның кырыслыгын, үз итмәвен чамаласа да, Чырык Абдрахманның сүзләре аңа гайрәт биргән иде.* Я.Зәнкиев. *Ул үзе балаларын кырыслык белән тәрбияләү ягында иде.* Р.Ханзафаров

2) Артык җитдилек, кискенлек. *– Нигә яхшылап карамадыгыз? – дип, Сәлим нечкә тавышына эрелек һәм кырыслык бирергә тырышты.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин бригадир якынрак килүгә, Зиннәт аның чырае кырыслыгына хәйран калды.* Г.Бәширов

3) Кыргый булу; кулга ияләшмәгән булу. --- *дошман кулына беренче мәртәбә эләгеп,* --- *аяк-кулына тимер богау салынган вакытта, яшь әсир үзен ничек хис кылса, ала айгырның курку катыш кырыслыгы аңардан бик күп көчле иде.* Г.Ибраһимов

4) Җайсызлык, яшәү, тормыш итү барышында барлыкка килгән авыр шартлар. *Кая карама – кырыслык, кырыслык...* М.Мәһдиев. --- *планетада гадәттән тыш кырыслык һәм вәхшәт хөкем сөрә – бу дәвер борынгы чыганакларда Тимер гасыр (Кали Юга) дип атала.* С.Шәмси. *Мондый кырыслыкны аклап, философ кешелекнең үлемсез булырга тиешлеген дәлил итеп китерә.* Кызыклар дөньясында

**КЫРЫШТЫРУ** *ф. сөйл.* 1) Бер җирне дә калдырмыйча эзләп йөрү, эзләнеп йөреп чыгу. *Ул көн буе шәһәрнең бөтен урамнарын кырыштырып, үзенә бүлмә эзләп йөргән, вә шунлыктан соң дәрәҗәдә арыган иде.* Ф.Әмирхан

2) Кырып-себереп, бар булганын җыеп алу. *Кесә төпләрен кырыштырып, концерт-спектакльләргә чабабыз.* Р.Батулла

3) Бернәрсә дә калдырмыйча, рәттән барысын да юк итү, бөтенесен юкка чыгару. *Буржуйлар эшче белән крестьян җилкәсенә менеп алганнар да ике яклап кырыштыралар, сволочьлар.* Ш.Камал. *Илдар шкафтагы имтомнарны кырыштыргач, алгы якка чыкты.* Татарстан яшьләре

4) *диал.* Барысын да җимерү, рәттән вату. *Әнә балтасы белән кизнәкизнә, гомере буе казганып җыйган малларын кырыштыра, турый, ә аннары, эх тә итми, барысын да утка ата?* Ф.Әһлия

**Кырыштыра бару** Рәттән, бөтенесен дә кырыштыру

**Кырыштыра башлау** Кырыштырырга тотыну

**Кырыштыра бирү** Кырыштыруны дәвам итү

**Кырыштыра төшү** Тагын да бераз кырыштыру

**Кырыштырып алу** Бераз кырыштыру. *Шулай да кесәләрдән егерме тиенләп акча кырыштырып алдылар – анысы метрога кирәк булды.* А.Гыйләҗев

**Кырыштырып бетерү** Тулысынча, барысын да кырыштыру. *Бөтен дөньяны кырыштырып бетерсәм бетерәм, бөтен кешеләрне үтереп бетерсәм бетерәм, барыбер аны җибәрмим, белдеңме?* Т.Миңнуллин

**Кырыштырып йөрү** Рәттән, барысын да кырыштыру. *Заманында якынтирәнең атларын кырыштырып йөргән Заһри, эшләр чуала башлагач, Ташлытауга күчеп утырды.* М.Мәһдиев

**Кырыштырып килү** 1) Күп заманнардан бирле бертуктаусыз кырыштыру

2) Әле, сөйләү моментында барысын да рәттән, тоташ кырыштыру

**Кырыштырып тору** Даими, әледәнәле кырыштыру

**КЫСА** I *и.* 1) Нәрсәнең дә булса читләрен тирәләп, кырыйларын беркетеп, ныгытып куя торган җайланма. *Иләгенә күрә кысасы.* Әйтем. *Әмма ул алтын кысада йөзек кашы булса яхшырак.* Т.Әйди

2) Күзлек пыялаларын беркетеп куя торган рамка. *Калын кашлары астыннан, күзлек кысалары өстеннән кешеләргә сынап һәм сокланып төбәлгән карашы гына калды.* Мәдәни җомга

3) Рам, тәрәзә рамы. *Ләкин тәрәзә кысалары арасыннан туктаусыз ыжгырып торган кызганычсыз җилнең көйләве --- Искәндәрнең --- планын җимереп ташлый.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Сакчылар абайлаганчы, ул аяклары белән тәрәзә кысаларын тибеп очырды да аска сикерде.* Р.Батулла. – *Армиядән кайттым да ишекләр, урындыклар, тәрәзә кысалары ясый башладым, – дип сөйли Рамил Маликов.* Татарстан яшьләре

4) *махс.* Машина, җайланма утыртылган стан, каркас, рама. *Велосипедның көпчәк өстендәге кысалары хромланган, кул тормозы да, матур фарасы да бар, утыргычы күннән, звоногы, багажнигы, арткы көпчәге канатында кып-кызыл булып стоп-сигналы янып тора.* Р.Мирхәйдәров. *Автомашина кысасы*

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса чиге; сәясәт, тормыш, яшәү рәвешенең тәртибе, шарты, кагыйдәсе, таләбе. *Ә татар халкы тарихы әлеге кысаларга гына сыймый бит.* С.Алишев. *Ә совет чорында хакимият халыкны дәһрилек идеологиясе кысаларында күпме генә тотарга тырышса да, ислам дине гореф-гадәт, йола рәвешендә яшәвен дәвам итте.* И.Надиров. *Хәзерге биеклектән торып ни сөйләшкәннәребезне аерып-аерып хәтерләмим, иң кирәге: без татар милләтенең кысада, чикләнгән аралыкта яшәвен төрле мисалларда бер-беребезгә аңлата идек.* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Эшләнү рәвеше, тәртибе, калыбы. *Сабан туен стандартлар кысасына куып кертергә кирәкми.* Р.Ягъфәров

7) *күч.* Тоткарлык, комачау, чикләү, киртә. *Шундыйлардан иҗатта хөрлек таләп итүне, сәнгатьле иҗатны берниндә киртәләр, кысалар белән чикләпбикләп куймауны алга сөрүне, тарихилык принцибының бөреләнә башлавын күрсәтергә мөмкин.* А.Әхмәдуллин

8) *күч.* Аерым өлешләрдән торган эш, чара, процессларны берләштергән гомуми тема, программа. *Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты студентларының әлеге фестиваль кысасындагы сәнгать бәйрәме Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында узды.* Мәгърифәт

◊ **Кысага керү** Билгеле бер таләпләргә, шартларга туры килү. **Кысага салу** *к.* **кысага утырту**. *Чөнки [бер агай-эне] китапны укыганда, ул автор язганнарны ниндидер калыпка, кысага салырга маташып укый.* Т.Миңнуллин. **Кысага утырту** Билгеле бер таләпләр, шартлар кую, шуларны үтәргә мәҗбүр итү. **Кысадан чыгу** 1) Билгеләнгән кагыйдәләрдән, шартлардан читкә тайпылу. *Әгәр дә федератив кысалардан чыга башлыйлар икән, бу мәсьәлә куерачак.* Татар милләт календаре; 2) Берәр нәрсәнең чигеннән, территориядән читкә китү, чигеннән ашу. *Сез тиздән мәктәп кысаларыннан чыгып китәчәксез.* Мәгърифәт. **Кысасына сыймау** Кабул ителгән гадәткә, кагыйдәгә, карашка туры килмәү, билгеләнгән шартларга буйсынмау

**КЫСА** II *и.* 1) Хатын-кызлар күлмәгенең билдән өске өлеше. *Пионер блузасын да укучылар формасының кысасы кебек ук тегәләр.* Йорт эшләре

2) *сөйл.* Тәнгә сыланып торган кием, кофта. *Кыса кигән*

**КЫСАН** *с.* **1.** 1) Кечкенә һәм тар, мәйданы бик аз булган. *Кысан сукмактан вак агачларны аралап керүгә, --- ике гамак күзгә ташлана.* З.Фәйзи. *Колхоз активистларына кермибез, партиялеләрне урап үтәбез, йортларыннан куылып, таш амбарларга, кысан мунчаларга күчкән кешеләргә керәбез бит әй!* А.Гыйләҗев. *Идарәнең «Агроном» дип язылган кысан бүлмәсендә аны --- мөлаем егет каршылады.* М.Мәһдиев. – *Кара әле, Яңгураз, мин әлегә кысан фатирда берничә егет белән бергә торам бит, – диде.* Т.Әйди

2) Кысынкы, тыгыз, кыса торган, тар (кием тур.). *Аяк киемең кысан булса, дөньяның иркенлегеннән ни файда.* Әйтем. *Наҗия аның очлары алсуланып торган табак битенә, артык кысан сары күлмәгенә, юан беләкләренә карап әйтеп куйды.* Р.Хафизова. *Аяк киеме кысан булганда, кайчакта тырнак эчкә батып үсә.* Йорт эшләре

3) Аз, тар, чикләнгән. *Озакламый таң ата, иркенләп гәпләшергә вакыт кысан, шул гына.* Ф.Сафин

4) Киеренке, уңайсыз, кырыс. *Кысан чорның үз кешеләре табылып тора.* Х.Камалов. *Кысан шартларга баш бирергә теләмәгән Вәлишин авиация институтыннан китәргә мәҗбүр була.* Идел

5) *күч. сөйл.* Авыр, кыен, начар, чикләнгән. *Дөрес, хәзер кыш ахыры, азыкның бик кысан чагы.* Ә.Еники. *Нинди кысан, чикләнгән, бозылган язмыш!* Идел

**2.** *рәв. мәгъ.* Чикләп, кысып. *Әллә син аш-суыңны кысан тотасыңмы?* А.Хәсәнов

**КЫСАНАЙТУ** *ф.* Тарайту, кысан итү, тыгызлау. *Зур шкаф бүлмәне кысанайта*

**Кысанайта бару** Акрынлап, торган саен ныграк кысанайту

**Кысанайта төшү** Тагы да кысанайту; бераз кысанайту

**Кысанайтып бетерү** Тәмам, бик нык кысанайту

**Кысанайтып җибәрү** Бераз, берникадәр кысанайту

**КЫСАНАЮ** *ф. сөйл. к.* **кысанлану**. *Балага дәрес әзерләргә өстәл дә куйгач, бүлмә кысанайды.* Сөембикә. *Тормыш кысанаю*

**Кысанаеп калу** Нинди дә булса шартлардан соң, билгеле сәбәпләр аркасында кысанаю

**Кысанаеп килү** Акрын-акрын кысанаю, кысынкылык аз-азлап арта, көчәя бару

**Кысанаеп китү** Беркадәр, кинәт кысанаю

**Кысаная бару** Торган саен ныграк кысанаю

**Кысаная төшү** Тагын да бераз кысанаю

**КЫСАНЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Бинаның, бүлмәнең һ.б.ш.ларның файдалана торган мәйданы кимү, урын тараю. *Балалар үссә, йөрергә дә урын кысанлана, диләр, хак икән...* Ф.Яхин

2) *күч.* Начарлану, авырлашу, кыенлашу

**Кысанлана бару** Торган саен ныграк кысанлану

**Кысанлана төшү** Беркадәр кысанлану; тагын да кысанлану. *Урынның тагын да кысанлана төшүен алда утыручылар яратып бетермәделәр.* Г.Мөхәммәтшин

**Кысанланып бару** *к.* **кысанлана бару**. *Безнең больница да кысанланып бара.* А.Гыйләҗев

**Кысанланып калу** Берәр сәбәп аркасында кысанлану. *[Трюм эче] Без кереп тулгач, кысанланып та калды.* М.Әмирханов. *Алар [җиһазлар] ничек кирәк алай урнашканлыктан, өй эче бөтенләй кысанланып калган.* М.Кәбиров

**Кысанланып килү** Аз-азлап кысанлану, кысанга әверелү

**Кысанланып китү** Бераз, берникадәр кысанлану; кинәт кысанлану. *Эш җитәрлек, әмма малайларның вакыты кысанланып китте.* Ф.Яруллин

**Кысанланып кую** Билгеле бер вакыт эчендә кысан хәлгә килү, кинәт кысанлану. *Алар кереп тулгач, кечкенә бүлмә кысанланды да куйды.* А.Хәлим

**КЫСАНЛАШУ** *ф. сөйл. к.* **кысанлану**

**Кысанлаша бару** Вакыт үткән саен тагын да кысанлашу

**Кысанлаша төшү** Тагын да кысанлашу; бераз кысанлашу

**КЫСАНЛЫК** *и.* 1) Тарлык, урын аз булу, тыгызлык. *Бүлмәдә кирәксез әйберләрнең күп булуы, гадәттә, кысанлык тудыра.* Йорт эшләре

2) *күч.* Авырлык, кыенлык, мохтаҗлык. *Әле сезгә килүнең сәбәбе дә нәкъ шул тормыш кысанлыгына бәйле.* З.Фәйзи. *Көнбакты кешеләре, авыллары көлгә кадәр янып беткәч, әлеге урмандагы зимләнкәләрендә ничек кирәк алай кыш чыктылар. Яшәр өчен җайлашмаган кысанлыкта, юеш, салкын шартларда картлар, бала-чагалар байтак кырылдылар.* Т.Нәбиуллин

3) *күч.* Ирексезлек, хокуксызлык. *Капитал коллыгы кайтып, Кысанлык җилләре исте.* Г.Камал. *Бу нигездә беркайчан да кысанлык сизмәдек.* З.Фәйзи

**КЫСКА** *с.* **1.** 1) Озын түгел, озынлыгы зур булмаган; *киресе*: **озын**. *Кечкенә апай итекләрдән, кыска итәкле күлмәктән, өстенә килешле утырган сырмадан, башына ак шәл бәйләп, ул армый-талмый эшләп йөри.* Ә.Еники. *Өс-башы ташка үлчим: ямау өстенә ямау чәпәлгән тышсыз кыптыр кыска тун, башында чите камалы мескен бүрек, түбе асылынып торган ычкырлы киндер ыштан.* М.Хәсәнов. *Ярга җитәрәк туктап, үзенең кыска күләгәсенә карап тора.* А.Гыйләҗев

2) Озынлыгы гадәтидән кимрәк, кирәк булганнан азрак. *Әмма бу кыска муен, зур баш, сирәк кенә шадралы йөз, яссы борын, суйган да каплаган, берниндиди шиккә урын юк.* Ә.Еники. *Егет кыска бармаклы кулларын угалап, өстәлдәге нигъмәтләргә тагын бер кат күз йөртеп чыкты.* Ә.Хәсәнов. *Ул хәзер, җитәкче оешмаларда эшләүче җаваплы иптәшләргә охшарга теләп, яшел гимнастёрка белән яшел чалбар кигән, мыегын да Мансуров кебек очларын кыска калдырып кырдырган.* Г.Бәширов. *Әпипә яшел кашлы көмеш йөзек кигән кыска бармагы белән ялкау гына орлык чүпли-чүпли --- көлеп куйды.* Г.Бәширов

3) Буйга озын булмаган, тәбәнәк. *Беренче тапкыр миңа иптәшләр антракт вакытында «Шәрык клубы»ның фойесында кыска буйлы, чандыр гәүдәле, бөдрәрәк җиткән чәчле яшь бер егетне «менә Тукай шул инде» дип читтән төртеп күрсәттеләр.* М.Гали. *Ә үзләренең күз алдына кыска, ләкин таза буйлы, акыллылыгы йөзенә чыккан Әкбәрев килеп баса.* А.Әхмәт. *Мин укыган китапта, хатынның буе иреннән бераз кыскарак булсын, дигән.* Г.Камал. *Берсе кыска, берсе юан, Берсе ябык аз гына.* Казан утлары

4) Дәвамлы түгел, озакка сузылмаган (вакыт ягыннан). *Бу эш махсус программа белән, либреттистлар өчен кыска сроклы курс-семинар үткәрү, музыка белгечләренең системалы лекцияләрен оештыру төсендә була.* М.Җәлил. *Җәйнең төннәре бик кыска.* Г.Ибраһимов. *Бик кыска арада әнә шундый ярсып, әрнеп әйтелгән үпкә тулы сүзләр Нургалинең күңеленә килеп киттеләр.* Ә.Еники. *Җәйнең гомере кыска, яңа уку елы да бик тиз килеп җитәчәк.* Мәгърифәт

5) Бик тиз башкарыла торган; озак дәвам итми торган. *Кыска, матур, җиңел көй уйнап җибәрә.* А.Әхмәт. *Бу аз сүзле, кыска җыелыш аны чиксез дулкынландырган иде.* Г.Әпсәләмов. *Әлеге кыска әңгәмә сәнгатьчә нинди югарылыкта тасвирлана.* Мәдәни җомга

6) Үзенең күләме, эчтәлеге белән озын, зур булмаган, җыйнак. *Бу кыска хатны җавапсыз калдырырга Зыя үзендә куәт тапмады, җиңелде.* Г.Ибраһимов. *Башлады сөйләргә Иблис кыйссасын. Баштан узган кыйссасының кыскасын.* Ш.Бабич. *Килсә, җавап кыска булыр, Юкка хыялланма син!* М.Җәлил. *Ә ул бик кыска, апа.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Озынга сузмыйча, артык киңәйтмичә. *Ә беләсең, шул ук газетада бер хәбәр бар, кыска гына итеп язылган.* Һ.Такташ. *Гомәр хатын-*

*кызларның уллары яки ирләре турында --- сорауларына кыска гына булса да тынычландырырлык җавап бирергә тырыша.* Ә.Еники. *Моннан соң инде алар чәй эчүне бик кыска тоттылар.* Т.Әйди. *Юлда кыска-кыска гына сөйләшеп алдык.* А.Гыйләҗев

◊ **Кыска акыллы** Бик үк акыллы булмаган; хәбәрдарлыгы җитешмәгән. *[Фәхрелбәнат:] Сезнең күргән төшләрегезгә безнең кеби кыска гакыллы адәмнәрнең гакылы җитешә алмыйдыр.* З.Һади. **Кыска аяк** *иск. кимс.* Хатын-кызга карата кимсетеп әйтү сүзе. *Арада Зыяның кендек әбисе Бәдри карчык, Фатыйма бикә, Мәрьям туташ, тагы берничә кыска аяк бар иде.* Г.Ибраһимов. **Кыска гомерле** Озак дәвам итмәгән, тиз узып киткән. *Шул кыска гомерле яктыда аның бик серле итеп ярым кысылган зур күзләре аны күреп алды.* К.Нәҗми. **Кыска гына (итеп) әйткәндә** Аз сүзләр белән әйткәндә; җыеп әйткәндә. *Ягъни, кыска гына итеп әйткәндә, авыруга алка такмыйлар, дигән кагыйдә буенча, комиссия ул нәрсәләрне монда тотуны барыбер файдасыз тапты.* Ш.Камал. *Кыска гына әйткәндә, бөтенләй чеп-чи надannar, шулай була торып та, ирләрен үз әмерләре белән йөртергә тырышалар.* Г.Камал. **Кыска койрык** *сөйл. кимс.* Алдакчы, хәйләкәр, эш-гамәлләрендә җаваплылыгы җитми торган кеше. *Бу шайтан кыска койрыклар үзләре сайланмакчы да, анда Петербург марҗаларына динне сатып кайтмакчы.* Г.Ибраһимов. **Кыска сүзле** Күп сөйләргә яратмаучы. *Кыска сүзле, чая күзле, Аңарда көч җилкенә.* Ф.Кәрим. **Кыска тәртәле** Тиз үпкәләүчән, холыксыз (кеше)

**КЫСКАЛЫК** *и.* 1) Озын булмау. *Алдыгызга китерегез хәзерге шәкертнең ачлыгын, үз җәһаләтен төшенүен, чәченең кыскалыгын, үзенең чыра шикелле ябыклыгын.* Ф.Әмирхан

2) Дәвамлы булмау, аз вакыт алып тору. *Төрле буын шагыйрьләре кеше гомеренең ифрат кыскалыгын, иҗтимагый гамәли тормыштан, кырыс яшәештән башкарак хисләрнең дә шигъриятта урын алырга хакы барлыгын искә төшерәләр.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Нәрсәне дә булса аңлатканда, фикерне аз сүзләр белән генә белдерү; сөйләмдә аз сүзләр куллану. *Кыскалыкта – осталык.* Мәкаль. *Алар тик күрүченең хәтерендә калганнары, өзек истәлекләре рәвешендә яки хроника кыскалыгы белән хикәя итү юлында гына күрсәтелә.* Г.Нигъмәти. *[Гариф] Арыган кыяфәттәрәк, бер терсәге белән өстәлгә таянып, янтайган килеш утырган, кыскалык белән өзеп-өзеп, баштан үткәннәрен аңлата.* Ш.Камал. *Поэмалар язарга тырышмагыз, кыскалыкта – осталык, 3–4 куплет җибәрсәгез дә бик җиткән.* Татарстан яшьләре

**КЫСКА ОЕК** *и.* Тезгә кадәр генә булган оек; *к.* **гольф**. *Юлда балалар кибетенә керде, бүләкләр – күлмәк, туфлиләр, кыска оек алды.* М.Галиев

**КЫСКАРТМА** *и.* 1) Берничә сүзнең баш хәрефләреннән генә ясалган сүз; аббревиатура (мәс.: БМО, БДБ). *Безнең телебездә рус теле аркылы кергән кыскартма исемнәр дә кулланылалар.* Татар теле грамматикасы

2) Ике сүзнең аерым кисәкләрен кыскарту юлы белән ясалган кушма сүз (мәс.: *профком, профорг, агитплакат*)

3) Сүзләрнең язуда кулланыла торган махсус шартлы билгеләре: һ.б. (һәм башкалар); һ.б.ш. (һәм башка шундыйлар); һ.ш.о. (һәм шуңа охшаганнар); к. (кара)

**КЫСКАРТМАЛЫ** *с. мат.* Кыскартылмалы, кыскартырга мөмкин булган. *Кыскартмалы вакланма*

**КЫСКАРТУ** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса күләмен, санын яки озынлыгын киметү. --- *минем таныш аппаратчик белән уен-көлке сөйләште, муенына тастымаллар салды, кул белән дә, электр машинасы белән дә тегенең чәчен кыскартты.* М.Мәһдиев. *Минем өскә кияргә булмаганга, иртәнге салкыннарда киеп йөрерсең дип, әни әтинең тәвәккәл бүреген һәм, җиңнәрен бераз кыскартып, аның кылкаланып беткән тула чикмәнен бирде.* М.Гали. *Ләкин кыскарткач та ул чикмән бик озын калганлыктан һәм бик киң дә булганлыктан, әни аның итәкләрен күтәреп, чабуларын кыстырып, минем билгә юкә яки юкәдән ишкән бау белән бәйли.* М.Гали. *Әйтәм аны, сакал-мыекларын кыскартып, яңа күлмәк-ыштаннарын киеп купшыланып чыгып китте.* Т.Гыйззәт

2) Дәвамлылыгын киметү. *Әгәр тракторны актык көченә кадәр кусаң, майлауга-көйләүгә вакытны тагын бераз кыскартып булса, көндезге ялга туктатмасаң, сөреп бетереп була.* Г.Бәширов. *Берәүләрнең авызы йомыла, икенче берәүләр сүз булмаса да сөйләшеп, вакытны кыскарта.* А.Гыйләҗев. *Утка-суга кердек, яндык-көйдек, ләкин дошман гомерен кыскарттык.* Ә.Ерикәй

3) Берәр нәрсәнең күләмен, микъдарын, санын киметү, азайту. *Аннан соң башкорт телен татар мәктәпләрендә дә кертү татар телен укыту дәресләрен кыскарта.* Ф.Фәтхи

4) Юлны кистереп чыгу, урап йөрмичә, турыдан гына үтү. *Кыр ышыклау урманы буена җиткәч, үгез көенә атлауга Гариф түзмәде, юлны кыскартып, авылга полоса буйлап кына китәргә булды.* Н.Хәсәнов

5) Нәрсәнең дә булса аерым кисәкләрен төшереп калдыру. *Бу поэма «Сөембикә» журналының 1916 елгы 2 нче санында бер бүлеге кыскартып басылган.* Н.Исәнбәт. *Ләкин кәгазьгә теркәгәннән соң артык киткән сүзләрне кыскарту, аны матурлату – шиксез кирәк шарт.* М.Җәлил. *Без «Мөсафир» әфәнденең хатын кыскартып бастык.* Ш.Маннур. *Ә.Н.Хәйруллин тарафыннан әзерләнгән һәм 1989 елда дөнья күргән «Мөстәфадел-әхбар»ның бүгенге татар теленә тәрҗемәсе, заманның идеологиясеннән чыгып, шактый кыскартылган.* Гасырлар авазы

6) Исемнең, сүзнең, фразаның бер өлешен төшереп калдырып әйтү. *Көмеш кенә түгел, Эрмәскөмеш минем исемем, монда килгәч кенә кыскартып әйтеп киттеләр.* М.Фәйзи. *Мондый ахирәт дусларны бу якта шулай кыскартып «әхи» генә диләр.* А.Хәлим. *Арпа оны да бар, аны карчык-коры кыскартып «арпоны» дип кенә сөйләшә.* М.Мәһдиев. *Барыбер элеккечә аны «кәкре муен Сәләхи», яисә кыскартып, «кәкре муен» дип кенә йөртә иделәр.* Ш.Камал

7) Нинди дә булса сәбәпләр нәтиҗәсендә эшләүчеләрне киметү, эш урынын бетерү, ябу. *Тик, ни хикмәт, озак та үтми, мәктәпне кыскарттылар.* З.Рәмиев. *Кыш бабайны пенсионер буларак кыскартсалар, бүләксез калабыз, баш бетте, дип кайгырдык.* Татарстан яшьләре

8) Авазларны, сүзләрне тиз әйтү, сузмау. *Бервакыт уяндым – өй хуҗасының бер озынайтып, бер кыскартып, моңлы гына мәкам белән иртә намазы укыганлыгы ишетелеп тора.* Ш.Камал.

9) Кыскартма ясау. *Профсоюз малай дүрт яшьлек улы Рабисны[ң] --- исем тарихын Габделхәмит болай аңлатты: «Рабоче-крестьянское искусство» сүзеннән кыскартып ясалган», – диде.* М.Мәһдиев

10) *мат.* Санаучысын да, ваклаучысын да бер үк санга бүлеп, вакланманың кыйммәтен үзгәртмичә кечкенәрәк саннар белән белдерү. *Вакланманы кыскарту*

**Кыскарта бару** Аз-азлап, акрынлап кыскарту; берәм-берәм һәрберсен кыскарту. *Гафур бабай аны [кармак җебен], өздермәс өчен, бер бушатып, бер тартып, һаман кыскарта бара.* З.Фәйзи

**Кыскарта башлау** Кыскартырга керешү

**Кыскарта бирү** Бернигә дә карамый кыскартуны дәвам итү

**Кыскарта тору** Бертуктаусыз, даими кыскарту

**Кыскарта төшү** Бераз, беркадәр генә кыскарту. *Гомумән, бу сөйләнгән моментларны кертми калдырганда яки, кыскарта төшеп, башка берәр шапка ялгаганда зарар итмәс, киресенчә, әсәр төзелештә, тәэсирдә матурлана төшәр иде.* Г.Нигъмәти. *Шуның өстенә, пьесадагы кирәксез урыннарны кыскарта төшкәндә, пьесаның динамикасы арта төшәчәк.* Һ.Такташ

**Кыскартып алу** Тиз арада бераз кыскарту. *Чәчемне бераз кыскартып алырга кирәк*

**Кыскартып ату** Тиз генә аннан-моннан кыскарту. *Язган җыр текстымны кыскартып аттым*

**Кыскартып бетерү** Тулысынча, күп итеп кыскарту; ахырына кадәр, барысын да кыскарту. *«Йомарлам» дигән поэмамны бастырганда шулкадәр кыскартып бетергәнсез: хәзер бернәрсә дә аңлашылмый.* Л.Лерон

**Кыскартып җибәрү** Бераз, беркадәр кыскарту. *Әлеге сүз аның үзенә әйләнеп кайтты. Сәрвәретдин аны әйтергә җиңелрәк булсын дип кыскартып җибәрде.* С.Поварисов

**Кыскартып калу** Вакытыннан алда кыскарту; билгеле бер вакыйгага, вакытка кадәр кыскартырга өлгерү

**Кыскартып карау** Кыскартырга омтылу. *Ярәшер вакыт җиткәч кенә тезгенне кыскартып караганнар иде дә, соң булып чыкты.* М.Әмирханов

**Кыскартып килү** Электән үк, дәвамлы рәвештә, системалы кыскарту. *Бигрәк тә сәясәт өлкәсендә, хәер, бөтен өлкәләрдә дә, аларны [милләтне үзе артыннан ияртеп, әйдәп баручы көчле элитаны] «югартып», «кыскартып» килгәннәр.* Р.Вәлиев

**Кыскартып кую** Кыскартылган хәлгә китереп калдыру. *Дәфтәр тышына ГРОБ дип язылган. Сискәнеп, сәерсенеп ачсам, «Гражданская оборона»ны кыскартып куйган икән.* Ш.Галиев // Кинәт, көтмәгәндә кыскарту. *Ә ул мине кыскартып куйды. Кая барырга? Айлык хезмәт хакы алып килмәгәч, очын очка ялгау кыенлашты.* А.Хәсәнов

**Кыскартып тору** Даими рәвештә, һәрвакыт кыскарту

**Кыскартып чыгу** Башыннан ахырына кадәр, һәрберсен кыскарту

**КЫСКАРТУ** II *и.* Нәрсәнең дә булса күләмен, санын киметү эше. *Аның каравы, эштән кыскартулар, хезмәт хакларының кимүе көтелә.* Татарстан яшьләре. *Хәзер халык тоташ стресс хәлендә яши, эшен югалтудан, хезмәт хакын кыскартудан курка.* Татарстан яшьләре

**КЫСКАРТЫЛМА** *и. к.* **кыскартма**

**КЫСКАРТЫЛМАЛЫ** *с. мат.* Кыскартырга мөмкин булган, кыскартып була торган. *Кыскартылмалы вакланма*

**КЫСКАРТЫЛМАС** *с. мат.* Кыскартып булмый торган. *Кыскартылмас вакланма*

**КЫСКАРТЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кыскарту**. *Ләкин бик каты редакцияләнгән һәм кыскартылган.* Н.Исәнбәт. *Нәтиҗәдә, 2012 елга коры җир гаскәрләрендә генә дә хәрби хезмәткәрләр саны 270 мең кешегә кыскартылачак.* Мәдәни җомга. *Ул, 8 ел Казахстан якларында хезмәт иткәннән соң, кыскартылуга эләгеп, туган ягына әйләнеп кайта.* Мәгърифәт

2) Кыскартма (*1 мәгъ.*) ясау. *Кыскартылып ясалган исемнәр*

**Кыскартыла бару** Бер-бер артлы кыскартылу. *Эш урыннары кыскартыла бара*

**Кыскартыла башлау** Кыскартылырга тотыну. *Чамадан тыш күпертелгән штатлар кыскартыла башлады.* Р.Мостафин

**Кыскартыла тору** Вакыт-вакыт, үз уңае белән кыскартылу

**Кыскартылып бетү** Берсе дә калмыйча кыскартылу. *--- түгәрәкләр саны әле бер ел эчендә генә кыскартылып бетми.* З.Кириллова

**КЫСКАРУ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса озынлыгы кимү, кыска булып калу. *--- нур вә чәчәктән ясалган, адәм сыйфатына кергән фәрештәнең – нәзек вәназлы туташның хәзер буе бераз кыскарган.* Г.Ибраһимов. *Туктый-туктый, Нәҗипне әле берсе, әле икенчесе аркасына күтәреп барганга, юл бик әкрен кыскарды.* Г.Бәширов. *Залдагы баганалар, ничектер, кыскарган һәм юанайган кебек булып киттеләр.* А.Шамов

2) Күренешнең, эшнең дәвамлылыгы кимү, дәвам итү вакыты азаю. *Яз җитсә – төн кыскарыр, көн озаер, Кояш та иртә чыгып бик соң баер.* М.Гафури. *Әбиләрнең йокысыз төннәре шактый кыскарды.* Г.Бәширов. *Хосусан, заман ахырларында, китап әйтүе буенча, адәм балаларының гомерләре кыскара --- диган риваятьләр бар.* Ш.Камал. *Көз һәм кыш айларында көннәр кыскара, караңгы бик тиз төшә...* Р.Мөхәммәдиев

3) *анат.* Мускулларның кысылуы яки киңәюе нәтиҗәсендә озынлыгы кимү. *Мускулларның кыскаруы өчен энергия кирәк.* Анатомия. *Бу процесста аңа скелет мускуллары (алар 600 дән артык) ярдәмгә килә. Аларның һәрберсе кыскарып калыная һәм кан*

*тамырларын кысып, андагы канны хәрәкәткә китерә.* Сәламәт яшәү нигезләре

**Кыскара бару** Аз-азлап, акрынлап, бертуктаусыз кыскару. *Бу җеп көннән-көн калыная бара, кыскара бара, безне һаман-һаман бер-беребезгә якынрак-якынрак тартып китерә...* Г.Ибраһимов. --- *шәүлә озынайган саен, яшәү белән үлем арасы кыскара бара...* Р.Харис. *Айның күтәрелүе белән кыскара барган агач күләгәләре Хәятның күңелендә хыялый картина тудырдылар.* Ф.Әмирхан

**Кыскара башлау** Кыскарырга тотыну. *Көннәр озая, төннәр кыскара башлады.* Н.Фәттах

**Кыскара бирү** Бернигә дә карамый кыскаруны дәвам итү

**Кыскара килү** Аз-азлап, акрынлап, бертуктаусыз кыскару. *Веда язмаларында әйтелгәнчә, кешеләр һәм кавемнәр рухи яктан деградацияләнгән саен, гомерләре кыскара килгән.* Р.Сафин

**Кыскара төшү** Бераз кыскару. *Кояш юлы кыскара төшкәч, их, әрәм була озын көннәр, дип уфтанулар башлана.* К.Кәримов. *Иҗек уртасында һәм басымсыз булганда, [сузык авазлар] бары да бераз кыскара төшәләр.* Г.Алпаров

**Кыскарып бетү** Тәмам, бик нык кыскару. *Анасы аңа кием ярата алмыйча аптырый. Теккәне кыскарып беткән, яңасына рәт юк.* Р.Батулла. *Төш җиткән инде әллә – Кыскарып беткән шәүлә!* Б.Хәлимов

**Кыскарып калу** Нинди дә булса бер сәбәптән соң кыскару. *Әхмәди мыекларын бөтергәләп, кыскарып калган сакалын сыйпап, әйбәтләнеп куйды.* Г.Бәширов. *Очлый торгач шактый кыскарып калган карандашын алды.* Ф.Җамалетдинова

**Кыскарып китү** Үзеннән-үзе кыскару; кинәт кыскару. *Шуның белән тормыш ямьләнеп, көз кыскарып китте.* М.Мәһдиев

**Кыскарып кую** Бераз гына, кинәт кыскару. *Әмма, кем әйтмешли, Әнвәр өйләнгәч, төннәр генә түгел, көннәр дә кыскарып куя.* Р.Ибраһимов

**Кыскарып тору** Даими рәвештә бертуктаусыз кыскару

**КЫСКАРУЧАН** *с. махс.* Кыскару үзлегенә ия булган. *Кыскаручан мускуллар*

**КЫСКАРУЧАНЛЫК** *и.* Кыскара ала торган булу, кыскару үзлеге булу

**КЫСКАСЫ** *кер. сүз* Җыеп әйткәндә, йомгаклап әйткәндә. *Кыскасы, бу мәктәптә моңарчы мин күрмәгән яңалык һәм башка төрле тәртип күренеп тора.* М.Гафури. *Кыскасы, ул, асылда, йөрәк кешесе булганга күрә, хайваннарның кичерешләренә бервакытта да салкын канлы булып кала алмый иде.* Ә.Еники. *Кыскасы, аларга барсам, физик яктан да, мораль яктан да чынчынлап ял итеп кайтам.* М.Җәлил

**КЫСКАСЫ ШУЛ** *кер. сүз к.* **кыскасы**. *Кыскасы шул, әйтмәгән сүзләремне калдырмадым.* А.Шамов. *Кыскасы шул, Ринат Харисовның иҗаты милли рухыбызны көчәйтү, мәдәни зәвыгыбызны тәрбияләү сыйфатына ия.* Мәдәни җомга

**КЫСКА́ЧА** *с.* **1.** 1) Озын түгел, кыскарак булган. *Аның өстендә кыскача сары тун, аягында яңа чуар киез итекләр иде.* Ш.Камал

2) Аз сүзләр белән аңлатыла, әйтелә яки языла торган. *Беренче мәсьәлә турында мин, озын тукталмыйча, кыскача мәгълүмат бирәм.* Ш.Камал. *Сәләхи шул арада Нәгыймәгә иртәгә кич дингә каршы кичә үткәреләчәкне, кичәнең кыскача планын сөйләгән иде.* Ш.Камал. *Болай: көн тәртибендә әллә нинди зур мәсьәләләр булмас, башта кыскача информациягезне тыңларбыз, ячейканың эше һәм аның хәле турында.* М.Әмир

**2.** *рәв. мәгъ.* Аз сүзләр белән, артык киң җәелмичә, кыскартып. *Сәнгать һәм шигърият, бөтенесен әйтеп бетермичә, кыскача төп фикерне генә бирергә тиеш.* Т.Гыйззәт. *Мостафин, ашыкмыйча, никадәр ихлас күңелдән сөйләвен сиздереп торган акрын, йомшак тавыш белән Наҗиягә үзенең үткән тормышын кыскача гына сөйләп бирде.* Ә.Еники. *Шуннан соң, кыскача гына, ул безгә үзенең бездән киткәннән соң кайларда булганын, ниләр эшләгәнен сөйләп чыкты.* М.Гали. *Кыскача гына әйткәндә, бу төркем яшьләрне үзенә тарта.* Татарстан яшьләре

**КЫСКАЧАЛЫК** *и.* Сөйләүдә, язуда аз сүзләр кулланып фикер белдерү, фикерне кыска итеп, артык җәелмичә бәян итү үзлеге. *Аның чыгышларына кыскачалык хас*

**КЫСКЫЧ** I *и.* **1.** 1) Утлы күмерне, кисәүне әйләндерү яки кыстырып алу өчен металлдан эшләнгән ике япьле корал. *Беркөнне тегермәнче Мироннарга кыскыч ясап керттеңме?* Т.Гыйззәт. --- *ахак кебек кызган тимерләрне кыскыч белән эләктереп алып, пар чүкечләрне сандалына салып, үзләрен уенчыклар кебек әйләндергәләп торучы, колачтай киң иңсәле Назыйм --- бетәшеп калган иде.* З.Фәйзи. *Янып торган мичтән идәнгә утлы күмер чәчрәп төшсә --- – яндыра, тотарга тиз генә соскычы я кыскычы табылмый, кул белән дә тотып булмый...* М.Маликова. *Шуны [тәмәкене] алып килә дә, --- мичтән кыскыч белән күмер ала, тәмәкесенә ут кабыза.* М.Мәһдиев

2) Әйберне кысу-кыстыру яки эләктереп, тартып алу өчен кулланыла торган җайланма. *Махсус кыскычы була торган иде, шуның белән бик тырышып чыра башын өзеп утыра идем, ди.* Ә.Еники. *Хәер, җәлләүдән дә бигрәк, малайның киләчәген уйлап хәвефләнү аны тимер кыскычтай кыса...* Р.Мулланурова. *Кыскыч, зыңгылдап, алтын тавышын бирә.* Н.Исәнбәт. *Әллә нинди шейкерлар, --- тоткычлар һәм кыскычлар, кыргычлар һәм угычларның берсенең дә бәяләмә хаклары куптарылмаган, һәм алар, гүяки, очып барышлый гына монда ялга туктаганнар...* А.Хәлим

3) *зоол.* Кысла аягының нәрсәне дә булса эләктереп алу өчен хезмәт итә торган ике тармаклы очы. *Дөрес, ат өстендә Харис яки Күгерт Җәлил кебек күкрәген киереп, аякларын яккака тырпайтып утыра алмый әле ул, атының ялларына тотына, аяклары белән ат биленә кыскыч кебек чытырдап ябыша.* Г.Гобәй

**2.** *с. мәгъ.* Кысып, тыгызлап тора торган. *Газларны егәрле кыскыч насослар – компрессорлар ярдәмендә кысалар.* Физика

◊ **Кыскычка алу, кыскыч эченә алу** Камап алу, блокадага алу. *Немец-*

*лар --- Мәскәүне бик зур «кыскыч» эченә алырга омтылдылар.* СССР тарихы

**КЫСКЫЧ** II *и. иск. к.* **кысла**. *Каз үзенең бәпкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле бакалар, татлы кыскычлар тотып китерә икән.* А.Алиш

**КЫСЛА** *и.* 1) *зоол.* Буынтыгаяклы хайваннар классына кергән, алгы очлыкларының очында кыскычлары булган, кабырчык белән капланган, умырткасыз, төче су хайваны. *Алар, кочаклашып диярлек, сагынышып күрешәләр, сүзләр борчак урынына тәгәри, кемнеңдер бәхетле туган көне, затлы коньяклар, сыралар, кыслалар турында фикер алышалар.* А.Гыйләҗев. *Мин украин кояшы астында янып, тыштан, чынлап та, кысла сыман тутыгып кызарган төстәге, эчтән исә тирләгән-пешенгән, Казан – Симферополь поездында Кырым тарафларына китеп барам.* А.Хәлим. *Ә менә кыслаларның никадәр серле җаннар икәнлеген беләсезме сез?* Кызыклар дөньясында

2) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган унике йолдызлыкның берсе; саратан. *Ай Кыслада чакта хыялыйлык арта, шуңа күрә һәр сүзгә ышанырга ярамый.* Мәдәни җомга

3) Зодиак системасына керә торган шул йолдызлык тамгасы. *Шул рәвешле үстерелгән үсентене җиргә Айның Кысла билгесендә торган чагында 19–20 майда утырту кулай санала.* Сөембикә

4) Кояш календаренең өченче ае

5) Кояш шул йолдызлыкта чакта (22 июнь – 22 июль) туган кеше. *Кыслалар йомшак күңелле, гаиләдә юл куючан.* Мәдәни җомга

◊ **Кысланың кайда кышлаганын күрсәтү** Бик нык янауны белдерә. *[Әсир:] Бәхетең, Потапов качып өлгерде. Югыйсә, ул сиңа күрсәтер иде кысланың кайда кышлаганын.* Н.Дәүли

**КЫСЛАНКЫ** *и. диал.* 1) Чәчелми калган, кысыр җир; *к.* **калдау**

2) Кысыр калган терлек. *Кысланкы сарык*

**КЫСЛАСЫМАННАР** *и. зоол.* Гәүдәсенең йомшак өлешләрен хитин япма саклый, кайбер төрләре җирдә дә яши ала торган, сулыш органнары саңаклар булган буынтыгаяклы хайваннарның бер классы. *Елга кысласы, дафния --- буынтыгаяклыларның кысласыманнар классына керәләр.* Зоология. *Кысласыманнар – суда яшәүче буынтыгаяклылар, аларның сулыш органнары – саңаклар.* Биология

**КЫСМА** I *и.* 1) Камыштан ясалган читән

2) Камыштан, саламнан һ.б.ш.лардан ясалган маты

**КЫСМА** II *с.* Нәрсәнең дә булса (оекбаш, бияләй, җиң очы һ.б.ш.) тартканда беркадәр киңәя, бушатканда яңадан кысыла торган итеп бәйләнгән өлеше. *Оекбашның кысма кунычы*

**КЫСМАЛА́У** *ф.* Чыбык-чабыкны, вак ботакны тыгызлап тезеп, чыпта сыман итеп бәйләү. *Гөлҗимеш әби сәке түрендә ---, ахшам намазы уку өчен, кулларына хөрмә төшеннән тезелгән тәсбих (дисбе) тотып, бик тирән уйларга батып, камыштан кысмалаган намазлык өстендә кояшның баеп беткәнен көтеп утыра.* М.Гали

**КЫСМЫР** *с.* Саран; комсыз. *Ленар кебек кысмыр, сукыр бер тиененә табынган карун өчен мондый чагыштыру әрәм инде.* Т.Галиуллин. *Апасы элек-электән кысмыр иде.* Мәдәни җомга

**КЫСМЫРЛЫК** *и.* Саранлык. *Без – бер тиенне учта кысып тотып, ун тиен югалтучылар. Шул кысмырлыктан арынасы иде.* Т.Миңнуллин. *Урман каравылчысының кысмырлыгы аркасында чыкты низаг.* Р.Мулланурова

**КЫСРЫК** *с.* **1.** Урыны, мәйданы тар, кечкенә булган; кысан. *Кысрык кына бүлмәдә биш кеше яши.* Ватаным Татарстан. *Кысрык урамнар буенча барган машина кинәт аркылыга салынган йортка килеп төртелде.* Мәдәни җомга

**2.** *и. мәгъ.* Тар урын; урын азлык, тарлык, тыгызлык. *Бу һава, бу яз галәмәте кешеләрне урамнарга тарта, кысрыктан иркенгә өстери.* Ф.Әмирхан. *Инде кырык ел шушы кысрыкта яшәп ятам менә.* Мәдәни җомга

**КЫСРЫКЛА́У** *ф.* 1) Кешене яки хайванны бер якка да китә алмаслык итеп тарлыкка куып кертү, бер почмакка китереп терәү. *– Бозауларын берәр җиргә кысрыклап, чыбыркы белән бер рәхәтләнеп туныйм әле! – дип уйлый.* М.Гали. *Һавада күсәкләр, казыклар, тимер сәнәкләр күренде, ярсыган халык, үкереп, казакларны койма буена китереп кысрыклады.* И.Гази

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса урынны аз калдыру; этәрә-этәрә тыгызлык барлыкка китерү. *Ул, кызны юл кырыена табан кысрыклап, җилкәсе белән ышыклады.* Н.Гыймматдинова. *Тамашачылар, берсен-берсе юлга этеп, юлны кысрыклауда, килгәннәрен карап торырга җайлырак урыннар эзләп, юл аркылы тыз-быз килеп йөгерүдә булды.* М.Гали

3) Дошманга һөҗүм итеп, аны чигендерү, чигенергә мәҗбүр итү. *Бәгъзе вакытта шушы халыклар төрекләргә һөҗүм итеп, аларны кысрыклыйлар.* Г.Гобәйдуллин. *Габдулла авылындагы кызыл отрядларның командиры Газиз штабтан гаскәрләрен, акларны кысрыклап, Олы Ширмә авылына күчерергә әмер алды.* Һ.Такташ. *Каты, озак сугышлардан соң ул, Кызыл Армияне кысрыклап, Днепрны кичте, хәтта аның уң ягындагы берникадәр җирне дә алды.* А.Шамов

4) Кыен хәлдә калдыру; уенда җиңелергә мәҗбүр итү. *[Шәрәфи агай] Солдат ягыннан төшеп, Гарифны бер-ике мәртәбә рәттән кысрыклап җиңделәр.* Ш.Камал. *Минем фигуралар арасыннан король янына үтеп кереп, аны почмакка кысрыклап, хурлыклы рәвештә мат куйды бу.* Г.Афзал

5) *күч.* Берәр эш башкарырга мәҗбүр итү, эшне үтәтергә басым ясап, тынгылык бирмәү. *Һичбер көчләү, һичбер кысрыклаусыз, бары сине тирән сөйгәнгә, Йөрәгемне сиңа бирмәдемме?* М.Җәлил

6) Тәнкыйтьләгәндә, сүз көрәштергәндә кире кага алмаслык дәлилләр китереп, кешене каршы сүз әйтә алмаслык дәрәҗәгә җиткерү. *Ферманың азмы-күпме уңышларын телгә алып сүзен башлаган яшь председатель акрынлап, ләкин эзлекле һәм рәхимсез рәвештә ферма мөдирен кысрыкларга тотынды.* Ә.Еники

7) *күч.* Уңайлыкларны, мөмкинлекләрне тартып алу, уңайсыз шартларда

калдыру. *Сакаллы сабыйларына ул акыл өйрәтте бугай, ике буш куык, авыл халкын кысрыклый-кысрыклый, кыр хәтле бакчалар сөдереп, ел саен шунда чүп үстерде.* Н.Гыйматдинова // Чикләнү, тыелу, мәхрүм ителү. *Аларга комачаулыйм икән, ачыктан-ачык әйтсен, фатир табыгыз, Ирек, без үзебезне кысрыклап сезне асрый алмыйбыз, дисен.* Г.Тавлин

8) *күч.* Изү, кысу; җәберләү, рәнҗетү. *Мине, шушы җирнең хакыйкый гражданын һәм халык язучысын, телемне кысрыклый һәм кимсетә торган мондый мәкерле кануннар бик рәнҗетә.* Р.Фәйзуллин. *Урыс телен яки милләтен кысрыклау турында сүз дә юк.* Татар милләт календаре. *«Дәү туганы» аларны төрлечә кысрыклый, рәнҗетә.* Мәгърифәт. *Татар теле кысрыклана, дисәк тә, киләчәгебез якты күренә.* Мәдәни җомга

9) *күч.* Яшәргә мөмкинлек калдырмау, шартларны юкка чыгару, бетерү. *Әмма кеше аларны үзенең эшчәнлеге, завод-фабрикалары, елга-күлләргә агызган пычрак сулары белән кысрыклый.* Кызыклар дөньясында

10) *күч.* Уй-хисне бер-бер артлы башка уй, хис һ.б. алмаштыру; күңелдәге нинди дә булса бер уйдан, хистән читләштерү. *Әмма Луизаның ымсындыргыч ялангач сыны кадерле шәүләне кысрыклый, этә, назлары белән аның үзен дә эретә иде.* Р.Мулланурова

**Кысрыклап алу** Төрле яктан кысрыклау. *Теге кара тешле убырлы карчык белән тагын шундый бер зобани вагонда кысрыклап алдылар да, тын алырга да чама калмады.* Г.Бәширов

**Кысрыклап бару** Азлап-азлап, акрынлап кысрыклау. *Бу имлялар эчендә хәзер мәктәп дөньясында зур игътибар казанып, урта имляны акрын гына кысрыклап бара торган мәгъруф имля – мөгаллим һәм педагогларыбыздан Мөхетдин әфәнде Корбангалиев имлясыдыр.* Җ.Вәлиди

**Кысрыклап килү** Эзлекле рәвештә, системалы кысрыклау; күптәннән бирле кысрыклау. *Кысрыклап килә-килә, кәрзине белән өстенә бастырып алам дигәндә генә, балык кул астыннан шуып узды.* Н.Хәсәнов. *Җыр базарының (яки базар җырының) әрсезләре җанныбыздан Сәйдәшләрне җиңел генә кысрыклап килә, берниндн каршылык та күрсәтмибез, киресенчә, сәнгать шамакайларын кул чабып үсендерәбез.* Р.Шәрәфиев

**Кысрыклап тору** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында кысрыкланган булу. *Сәгыйть ниндидер аралыкта бүтәннәрдән аерылып калды һәм ике ягыннан да биек шомырт, кара зелпе агачлары кысрыклап торган озын, тар ачыклыкка килеп чыкты.* Н.Фәттах

**Кысрыклап чыгару** Нәрсәне дә булса кысрыклап, тәмам юк итү, аны башкага алыштыру. *Бүген бер карыш чигенсәләр, иртәгәсен чакрымлап һөҗүм иттеләр, Кызыл гаскәрне бөтенләй кысрыклап чыгарырга, тагын патшаны, Керенскийны кайтарырга, алпавытлар, байлар властен торгызырга теләделәр.* Г.Гобәй. *Бик тиз арада аның геройлары күңеленә берсен икенчесе юкка чыгара торган капма-каршы уй-хисләр килеп китә. Берсе икенчесен кысрыклап, төртеп чыгара, берсе икенчесен җиңә.* Ф.Хатипов. *Рок культура милли культураны кысрыклап чыгара.* Идел

**Кысрыклый бару** Азлап-азлап, акрынлап кысрыклау; торган саен ныграк кысрыклау. *Ләкин бер дә безнең файдага түгел, дошман безне гел кысрыклый бара.* Г.Гобәй --- *корыч аргамаклар тере атларны елдан-ел кысрыклый барса да, укып, механизатор таныклыгы алса да, күрше абый атларга мәхәббәтендә тугрылыклы булып калды.* Ш.Маннапов

**Кысрыклый башлау** Кысрыкларга тотыну. *Чалбайлыларның күбесе тарлавык бугазында ятып калган иде. Исәннәрен болгарлар кысрыклый башладылар.* М.Хәбибуллин

**Кысрыклый бирү** Һичнигә карамый кысрыклавын дәвам итү. --- *тик [кайбер алынма терминнар] үз мәйданбиләмәләреннән чыгып, алым, ысул, акча, чара, өлкә, тармак, юнәлеш, мәсьәлә, тоткарлагыч, өстәмә, җитештерү, хисап кебек гомуми сүзләрне кысрыклый бирә.* И.Низамов

**Кысрыклый тору** Бертуктаусыз кысрыклау. *Як-яктан кысрыклый торгач, егет чикләвек кебек ярылды, шәһәрдә булган хәлне сөйләп бирде.* Г.Галиев. *Кысрыклый торгач, аргы урам малайлары үз якларына шылдылар.* Х.Туфан

**КЫСРЫКЛЫК** *и.* 1) Урын аз булу, тарлык. *Иртән халык эшкә барганда, 485 пассажирга исәпләнгән составка 870 кеше кереп тула, иске вагоннардагы кысрыклыктан меңнәрчә кеше интегә.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Кысу, изү, кимсетү. *Аннан соң, билгеле, реакция баскынлыгы, жандарм, урядниклар кысрыклыгы башлана.* Ш.Камал

**КЫСРЫНКЫ** *с. диал. к.* **кысрык**. *Бары шәһәрдә, толчок базарында мондагы шикелле кысрынкы була.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**КЫСТАЛУ** I *ф.* 1) Табигый ихтыяҗны канәгатьләндерәсе килү, тышка чыгасы килү. *Әллә шунда күпләрнең боендырыгы томмый, кысталалар, бәдрәф сорала.* А.Гыйләҗев. *Аның урамнарында кысталып-нитеп, сидек куыгың шартлап үлүең мөмкин.* А.Хәлим. *Малай тышка чыгарга кысталып уянды да әниләренең йокы бүлмәсенә керде.* Т.Мөбарәков

2) Бала тудыру вакыты җитү, тулгак тоту. *Байдек ашап туйганнан соң, хатын әйтте: «Мин бала табарга кысталып ятамын. Күрше авылда минем анам бар. Шул анамны алып килсәнә, туганым», – дип җибәрде.* К.Насыйри. *Римманың алар турында артык нәрсә белмәвен Фабарисов үзе дә сизеп тора бит, нигә һаман кысталган мәче кебек аның тирәсендә бөтерелә соң ул?* Ф.Бәйрәмова

**Кысталып бару** Беркадәр кысталу, табигый ихтыяҗны үтисе килү. *Мирвәли, поездан төшкәннән бирле, кеч-кенә йомыш белән кысталып бара иде.* А.Гыйләҗев

**Кысталып бетү** Бик каты, түзеп булмаслык итеп кысталу

**Кысталып йөрү** Әле, хәзерге вакытта күптәннән бирле кысталган булу. *Үзенең дә бер дуңгызы балаларга кысталып йөри иде.* Р.Төхфәтуллин

**Кысталып кую** Кинәт кенә, көтмәгәндә кысталу

**Кысталып тору** Даими рәвештә, һаман да кысталу

**КЫСТАЛУ** II *и.* Табигый ихтыяҗ, тышка чыгасы килү теләге. *Шулай Кызыл мәйданда йөргәндә, карлы яңгыр астында кинәт кенә кысталуым килде, һәм мин, табигыйдер ки, табарыма һич тә ышанмыйча, тирә-ягымда биобәдрәф кебек нәрсә эзли башладым.* Татарстан яшьләре

**КЫСТАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **кыстау**

2) Нинди дә булса эшне кат-кат үтендереп, соратып кына үтәү; ялындыру. *Кыстатмады, рюмкасын да бик оста тотты.* Ә.Хәсәнов. *[Әсма:] Я, җырла инде, нигә җырламыйсың. Мин үзем җырлый белсәм бер дә кыстатмас идем.* Г.Ибраһимов. *Гыйзденур чәйне кыстатып кына эчте, ипине әз-әз генә кабып ашады.* Р.Хәбибуллина

**Кыстата бирү** Нәрсәне дә булса эшләргә ашыкмау, кыстатуын дәвам итү

**Кыстата төшү** Тагын да бераз кыстату

**Кыстатып тору** Озак кыстату; даими рәвештә кыстату. *Без, билгеле, кыстатып тормадык: шәриктәшеңә кереп чәй эчеп, күңел ачып чыгу – шәкертләр өчен табигый бер низам инде ул.* Ә.Еники. *Карт кыстатып тормады ---.* М.Хәсәнов. *Килеп җитте, туктады, Бик кыстатып тормады.* Д.Аппакова

**Кыстатып утыру** Кат-кат үтенергә мәҗбүр итү. *«Бу симез ич, мондыйны яратмыйм», – дип, киреләнеп, ашамыйча кыстатып утыра иде.* Ф.Яруллин. *– Эч, кыстатып утырма! – дидем.* Ә.Айдар

**КЫСТАТУЧАН** *с.* Кыстата торган. *Кыстатучан кыз*

**КЫСТА́У** *ф.* 1) Ашарга-эчәргә кат-кат тәкъдим итү, сорау, үтенү. *Мунчадан соң чәйгә керергә дә кыстаган иде.* Ш.Камал. *Яңгураз кунакларын сыйланып утырырга кыстады, стаканнарына яңадан шнапс тутырып чыкты.* Т.Әйди. *Ул безгә сирәк булса да кергәләп йөри, аш өстенә туры килгән чаклары да була, ләкин, үтереп кыстасаң да, табынга утырмый...* А.Гыйләҗев

2) Кемнең дә булса нәрсәдер эшләвен кат-кат сорау, үтенү. *Өйгә кергәннән соң, алырга килгән егетне төрлесе төрле яклап өстен чишенергә бик нык кыстасалар да, ул чишенеп тормады.* М.Гали. *Сәхип картлар да моны аңлыйлар һәм Нигъмәтне күнәргә кыстыйлар.* Ә.Фәйзи. *Мирсәлимне үзәккә – хакимияткә күчәргә кыстадылар.* Н.Гыйматдинова

3) *сөйл.* Ашыктыру, әйдәләү. *Мине кыстый, арттан тәрткәли башладылар.* А.Шамов. *Ә Георгий Фёдорович үтереп кыстый, дулкынланудан әтинең ирен читләре калтырый.* А.Гыйләҗев

**Кыстап алу** Тиз, кыска гына вакыт аралыгында кыстау

**Кыстап йөрү** Бертуктаусыз, күптәннән бирле нәрсә дә булса эшләргә кыстау

**Кыстап карау** Бераз кыстау, нинди дә булса эшкә чакырырга омтылу. *Ашап туйгач, Мансур аны да уенга кыстап карады, ләкин ул баш тартты.* Н.Фәттах // Бик нык кыстау. *Даут аптырашта кала, аны төрлечә үгетләп, кыстап карый.* Ф.Садриев

**Кыстап кую** Ара-тирә кыстау. *--- сәке йөзлегенә утырган җиңги сүзгә катнашмый, сүз өзелеп торган араларда гына безне ашарга-эчәргә кыстап куя.* М.Әмир

**Кыстап тору** Әледән-әле, еш кыстау; бертуктаусыз кыстау. *--- өй хуҗасы буларак Нәсимә дә бертуктаусыз диярлек кыстап торды.* М.Вәли-Барҗылы // Әле, сөйләү моментында кыстау. *Кабат кыстап торуда мәгънә юк иде.* З.Фәйзи

**Кыстый башлау** Кыстарга тотыну. *Бераздан хәзрәт Әхмәтне иске китаплар саклана торган җиргә барырга кыстый башлады.* Ф.Әмирхан. *Сәлим төрлечә әйтеп, Мәрданша бабайны кайтырга кыстый башлады.* Г.Гобәй

**Кыстый төшү** Тагы да кыстау; бераз кыстау

**КЫСТЫБЫЙ** *и.* 1) Уртасыннан бөкләгән юка төче камыр җәймәсе эченә изгән бәрәңге, тары боткасы һ.б.ш.ларны салып пешерелгән ашамлык. *Пристаньга кыстыбый сатарга бардым.* Т.Гыйззәт. *Кайбер җирдә кыстыбыйны «күзикмәк» тә диләр. Кыстыбый эченә төйгән бәрәңге, тары боткасы, төйгән киндер орлыгы, мәк һ.б. салалар.* Ю.Әхмәтҗанов. *– Кыстыбый пешер әле, карчык, күптәннән кыстыбый пешергәнең юк, – дип елмайды.* Татарстан яшьләре

2) *күч. сөйл.* Туган-тумача, дусиш, фикердәш, әшнә. *Нигә яклыйсың, кыстыбыйларыгыз түгелдер бит.* Т.Гыйззәт

3) *күч.* Каяндыр килеп кергән, яңа кушылган, әле үз булырга өлгермәгән кеше. *Аннан тагы, теге, яңа килгән кыстыбыйлар да һөнәрләрен күрсәтәчәкләр, ди.* Т.Гыйззәт

**КЫСТЫРГЫЧ** *и.* 1) Юылган керне һ.б.ш.ларны бауга элгәч, җил очыртмасын өчен, бауга эләктереп, кыстырып куя торган җайланма. *Керне кыстыргычлардан алырга да өлгермәде, боз яварга тотынды.* Сөембикә

2) Нәрсәне дә булса кысу, кыстырып кую өчен ясалган әсбап

3) *тех.* Эшкәртелә торган детальне беркетеп куя торган җайланма; *русчасы:* **тиски**

4) *физ.* Үткәргечләрне берәр механизмга беркетү җайланмасы, клемма

**КЫСТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **кысу** (*1 мәгъ*). *[Агай:] Менә [стенаның] шул җирләре җәй көне тәмам кибеп ачылган иде. Узган атна гына әле бик һәйбәт кыстырып төзәттердек.* Ш.Камал

2) Тәннең кайсы да булса өлешен нәрсәдер арасында калдырып авырттыру, имгәтү. *Әбүзәр карт --- бакча башына үзе куйган бүре капканына аягын кыстырып, чүт өздермәде.* Татар иле

3) Берәр нәрсә арасына урнаштыру, этәреп кертү, тар, кысан җиргә тыгып кую. *Доктор, әле хәзергә шикләнерлек бер күренеш тә тапмагач, авыруның култык астына термометр кыстырды.* Г.Минский. *Мин коймалар арасына төрле кыр чәчәкләрен кыстырып яки пар алма элеп китәм.* Ф.Яруллин. *[Наилә] Тар, кара вак вельвет чалбарын биек, коңгырт итальян итекләренә кыстырган.* Т.Галиуллин

4) Беркетү, эләктереп кую. *Алар түшләрендәге киң-киң текә кесә капламычларына кыстырылган алтын*

*каурый каләмнәрен чыгарып, нindидер куркынычлы, явыз кәгазьләргә әллә нинди дәһшәтле сүзләр язалар, саныйлар, теркиләр.* А.Гыйләҗев. *Бабасы әйтә, кышкы кичләрдә, бөтен өй эче кул эше белән утырганда, миңа шәмдәлгә кыстырган чыраларның күмерен сулы ләгәнгә өзеп төшерергә кушалар иде, ди.* Ә.Еники

5) Киемнең чабуларын, күлмәкнең итәкләрен һ.б.ны бөкләп, билбау, каеш астына кертеп тоттырып кую. *Ул ак яулыгын колак артына бәйләгән, җиңнәрен сызганган, күлмәк итәген кыстырган килеш, кар базыннан иртәнге сөтне алып чыга иде.* Г.Әпсәләмов. *Бүреген кырын киеп, озын шарфын муеныннан уратып, очларын билбавына китереп кыстырган Сәлим керде.* М.Гафури. *Күлмәк итәкләрен кыстырган, ябык гәүдәле, әрлән кебек җитез яшь кенә хатын иде ул үзе.* Ә.Фәйзи

6) Ачылып китә торган буш ишек, капка кебек әйберләр арасына берәр нәрсә куеп, тыгызлык барлыкка китерү. *Өйнең стеналары алга таба --- киткәнлектән, ишекне бер дә әйбер кыстырмый ябар хәл юк, хәзер ачылып китәдер иде.* М.Гали. *Яшь хатын имчәк баласын бишеккә иплән кенә яткыза да, келәт ишеген сызык кына калдырып, ябылып бетмәслек иттереп, тупсасына чүпрәкише нәрсә кыстыра.* К.Миңлебаев

7) Нәрсәне дә булса ике яктан китереп кысу, кысып тоту яки кысып тоттыру. *Бикбулатов нечкә бармакларына кыстырып, конверт эченнән кыска гына язылган хатны тартып чыгарды.* А.Әхмәт

8) Култык астына кысып тоту. *10 әлифбамны кыстырып 1–4 сыйныфларга кердем.* Мәгърифәт. *Кич утырырга куенына «Йосыф–Зөләйха» я «Таһир–Зөһрә», я «Мәликә китабы»н кыстырып, Гыйльменисатти килеп җитә.* М.Мәһдиев. *Аны уңайлап култык астына кыстыра да суга чума.* Кызыклар дөньясында

9) Култыклау, терсәгеннән тотып бару. *Нечкә сыйраклы нәрсәсен култыгына кыстыра да театрына китә, бакчасына чыгып китә.* Г.Ибраһимов

10) Берәр нәрсәне кемнең дә булса кулына тоттыру, бирү; биреп җибәрү. *Шул арада Сиражетдин бик кечкенә итеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра.* Г.Камал. *Зәйнәпбануның әнисе: «Йөрәгең бик өзелгәндә кабып җибәрерсең» – дип, бераз эремчек кыстырган икән, аны да куйдылар.* Г.Бәширов

11) Тиз генә сатып алу, юл уңаеннан, эш арасында алу. *Әлфис автовокзал янындагы кибеттән тагын бер ярты кыстырып чыга.* Мәдәни җомга

12) Сөйләп яки язып торганда, берәр үзенчәлекле сүз өстәп, берәр үзгә фикер әйтеп, өстәп җибәрү; берәр кеше сөйләп торганда, читтән бер сүз әйтү. *– Әйе, әйе, без бит синең белән бер читтә, кабак орлыгы ашап, көлеп карап тордык, – дип кыстырды Фәрваз да.* Р.Мөхәммәдиев. *Бигештә күргәннәремне дә кыстырам.* А.Гыйләҗев. *– Икәү генә түгел, өчәү без, – дип кыстырды Нурсия.* Н.Гыйматдинова

13) *сөйл.* Кабу, тешләү. *Теш арасына кыстырырга бер кабым икмәк юк.* Г.Ибраһимов

14) *сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса исемлеккә теркәү, кертү яки берәр нәрсәгә катнаштыру. *Туй-мазар була калса, Илдар, мөгаен, исемлеккә Зифаны кыстырмый калмас.* Г.Гобәй

15) *куч.* Кирәкле-кирәксез, урынлы-урынсыз җиргә китереп кую, тыгу; тыгылу. *Ат аягын дагалаганда, бака ботын кыстыра.* Әйтем. *Рус телен дә татарчага Шүрәледәй кыстырмыш.* Ш.Галиев. *Әй Нурсия, Нурсия. Озын борыныңны бер кыстырасың инде.* Н.Гыйматдинова

16) *куч.* Эләктерү, кешегә сиздермичә генә эләктереп чыгу, урлау. *Беркемгә бер башак өзәргә, бер көлтә кыстырып алып кайтырга рөхсәт итмәделәр.* А.Гыйләҗев. *Йорттагы затлы әйберләрне куенына берәм-берәм кыстырып алып чыгып, арзан гына бәягә озата торды.* Мәдәни җомга

**Кыстыра башлау** Кыстырырга тотыну. *Күзлек сүзе чыктымы, егетләр аңа отыры бәйләнеп, мине дә кыстыра башлыйлар.* Х.Сарьян. *Бик яратып, якын күреп, ягымлы итеп эндәшкәндә, Хәсәнә абыстай, иреннән үрнәк алып, үзе дә «әй» ымлыгын кыстыра башлады.* С.Поварисов

**Кыстыра бирү** Бернигә дә карамый кыстыруын дәвам итү

**Кыстыра тору** Мөмкинлек чыгудан файдаланып, берсе артыннан икенчесен кыстыру, әле берсен, әле икенчесен кыстыру

**Кыстыра төшү** Тагы да ныграк кыстыру. *Карт, туңып киткәндәй, тун чабуларын тезләре арасына кыстыра төшә.* Ә.Еники

**Кыстырып бетерү** Һәммәсен кыстыру, ахырга кадәр барысын да кыстыру

**Кыстырып җибәрү** Ара-тирә кыстыру; кыстырырга өлгерү. *Башта ул ак ромашкаларны тезә, арасына урыны-урыны белән кыңгырау чәчәкләре кыстырып җибәрә.* Р.Хафизова. *– Габдулла әфәнде, – диде, – гармунчы мишәр килеп чыккан. Арага кыстырып җибәрерсез, шаять.* И.Нуруллин. *Иң азакта: «Бу төрмәне төзеткән архитекторның үзен дә утыртып куйганнар!» – дип кыстырып җибәрәләр.* А.Гыйләҗев

**Кыстырып йөрү** Һәрвакыт үзе белән алу, үз янында йөртү

**Кыстырып калу** Тиз генә кыстыру, кыстырырга өлгерү

**Кыстырып кую** 1) Бер мәртәбә кыстыру; кыстырган хәлдә калдыру. *Икенче килүемдә, ул аларны алган һәм шул урынга үзе дә бер нәрсә кыстырып куйган була.* Ф.Яруллин. *Ахырда ул, турая төшеп, шыгырдый-шыгырдый, кыска саплы челемен чыгарды; бик озак мыштырдап бармагы белән баса-баса, аңа тәмәке тутырды; аны тешләре арасына кыстырып куйганнан соң, тагын бераз утырды.* Г.Бәширов

2) Ара-тирә, әледән-әле кыстыру. *Мусаның иң сөймәгәне – фикерен тыңлап бетермәстән аны бүлдерү, белдекләнеп, әңгәмәнең кызуын сүрелдерерлек сүз кыстырып кую.* Ф.Сафин

**Кыстырып тору** Даими рәвештә бертуктаусыз кыстыру

**Кыстырып чыгу** Бер уңайдан, рәттән кыстыру. *Кайтышлый Мулла-Гөлем авылына туктап, гармун ясау остасы Мөстәкыйль абзыйсыннан култык*

*астына унике телле, шыңгыр бакалы тальян да кыстырып чыкты.* А.Хәлим

**КЫСТЫРУЛЫ** *с.* Билбау, каеш астына кертеп куелган (кием чабуы, күлмәк итәге һ.б.ш.ларны). *Килен үзе дә җиңнәрен сызганып алган, итәк кыстырулы, кулы кулга йокмый.* Ф.Хөсни

**КЫСУ** I *ф.* 1) Берәр нәрсәгә көч белән басу, басым ясау. *Әйтерсең күкнең барлык кара болытлары тау-тау булып иңнәремә ишелеп төштеләр дә мине җиргә кыстылар.* Ф.Яруллин. *Ул арада Саранцев кабат көндәшен кулыннан эләктерде, кискен генә чүгеп, аны гәүдәсе аша әйләндереп ыргытты һәм, кымшана алмаслык итеп, келәмгә кысты.* Ф.Галиев. *Әмма еш кына буйвол да аның үзен мөгезенә күтәреп ала һәм җиргә китереп кыса.* Кызыклар дөньясында

2) Кемне яки нәрсәне дә булса кулның учы, бармаклар белән каты итеп тоту. --- *барысы да рәхмәтләрен әйттеләр, кулын кыстылар.* Ә.Еники. *Аның салкынчарак кулчыкларын үземнең эссе учларым эчендә кадерләп, иркәләп, кысып, үземә таба тарттым.* Ф.Әмирхан. *Ручка сабын кысып тотудан тагын да алсулана төшкән бармаклары зәңгәр дәфтәр тышында шушы гадәттән тыш вакыйганы сурәтли башлады.* А.Хәлим

3) Кул(лар) белән уратып алып тоту, кочакка алу, кочаклау. *Күзгә күренмәгән ниндидер бер көчнең икебезне берьюлы йомшак, рәхәт кочагына кыса барганын, ул кысылыш безнең йөрәк тибешләрен якынайтканын сизеп утырабыз.* Ф.Яруллин. *Сине күрмичә, кочагыма бер кысмыйча кайтып китәр бу дип уйлама.* Ф.Яруллин. *[Сафура:] Чүчү, кызым, кысып үтерәсең.* Т.Гыйззәт

4) Сәламләшү, саубуллашу, тәбрикләү йөзеннән ике кеше үзара берберсенең кулларын билгеле бер рәвеш белән тотышу. *Гатиятуллинга орденның таныклыгын һәм буш кабын тапшырып кулын кысканда, аларның карашлары очрашты.* А.Хәлим. *Алар мине үз эшләренең дәвамчысы дип кабул иттеләрме, һәркем җылы бер сүз әйтергә, кулымны кысарга тырышты.* А.Гыйләҗев

5) Берәр кешене яки нәрсәне дә булса үзеңә якын китереп, түшкә, күкрәккә сыендыру. *Ә кисеп бетергәч, бер сүз дә әйтмичә, Хәлимне арык күкрәгенә кысып, сөеп торды.* Г.Гобәй. *Мин, кимерү генә түгел, бу шикәрне кабып йотардай булып, күкрәгемә кыстым.* Ф.Яруллин. *Саҗидә бик аз гына карап торды да төенчекне күкрәгенә кысты.* А.Әхмәт. *Шуңа күрә ул әнисе кулына алып йөрткәнне, күкрәгенә кысканны, гәүдәсен сыйпаганны бик ярата.* Сөембикә

6) Кемне яки нәрсәне дә булса тарлыкка китереп кысрыклау, камап алу. *Ул арада атлар, өркеп китеп, аны ике арба арасына китереп кыстылар.* А.Шамов. *Барын, сарык көтүе кебек, чиләкләре, читекләре белән тар бер почмакка китереп кысалар да тенти башлыйлар.* Г.Ибраһимов

7) Ачуланганда, нәфрәтләнгәндә иреннәрне, тешләрне көч белән бик каты итеп бер-беренә тидерү, йому. *Нажия, хатын алдында елап җибәрмәс өчен, тешләрен кысты, тырнаклары батып керерлек итеп, йодрыкларын йомарлады.* Р.Хафизова. *Үз гомерендә өч-дүрт сугышны башыннан уздырган, үз баласын гына түгел, балаларының балаларына кадәр сугышка озаткан, каныңны өшетерлек дәһшәтле хәбәрләрне дә тешен кысып тыңларга өйрәнгән ак чәчле әбиләр, кырыс чырайлы солдат хатыннары күзләрен сөртәсөртә кул чабалар.* Г.Бәширов. *Рәмзия ханым иреннәрен кысарга мәҗбүр булды.* Ә.Еники

8) Берәр механизмны хәрәкәткә китерү, эшләтә башлау өчен, аның тиешле төймәсенә, пультына басу, басым ясау. *Лётчик шулай диюгә, ромблы кеше гашеткаларны кысты.* Г.Гобәй. *Хәлим --- гармоненың мехларын кысты. – Я, тагы уйна әле, кәбәм. Уйна, йөрәк маем, уйна.* Г.Гобәй

9) Нинди дә булса кием бәләкәй, кысан яки тар булу сәбәпле, тәннең тиеп торган җирен авырттыру. *Итек бик матур тегелгән, әмма аякны кыса, алай да Алсу, сер бирмичә, таман гына, дигән булды. Аның һич кенә дә итекне кире кайтарып бирәсе килми иде.* Татарстан яшьләре. *Нихәл, егетләр, җилән кысмыймы?* Г.Камал // Тар урынга, ике әйбер арасына кертеп, басып авырттыру. *Беләм, бармак буыннарыңны ишек ярыгына кыссалар, тырнак асларына инә кадасалар, --- сынмас җирдән сынарсың.* А.Гыйләҗев

10) Бик нык тарттыру, буу, тарттырып бәйләү. *Ул билендәге каешын ныклабрак кысты, кызыл тәреле сумкасын рәтләде һәм Салават аерып куйган патроннарны җитез генә кулына алды.* А.Шамов. *Шул ук вакытта баскычта башына куе зәңгәр фуражка, өстенә шундый ук төстәге гимнастёрка кигән, билен киң каеш белән кысып буган, беләгенә юл плащы салган Гали абзый үзе дә күренде.* Г.Әпсәләмов. *Җаныңны тимер кыршау белән кыс, аркан белән уратып бәйлә – әнә шул көч, кыя-тауларны ишеп, дәрьяларны ташытып, яраткан кешең белән тоташтыра.* Н.Гыйматдинова

11) Ишекне һ.б.ш. ачыла-ябыла торган әйберләрне аз гына ара калдырып ябу. *Сәрви сикереп торды һәм, барып, ишекне кысып кына ачып куйды.* Ә.Фәйзи

12) Нәрсәләрне дә булса араларында бушлык, ярык калмаслык итеп тыгызлау. *[Ярулла:] Менә бит, төбен кыскач, кыршавын суккач, шап-шактый кисмәк булды.* Ф.Бурнаш

13) Нәрсәнең дә булса күләмен, микъдарын, көчен азайту, киметү. *Ишеткәнем бар синең әкиятеңне, диде дә, утны кысып, урынына ятты.* Ш.Камал. --- *алыр урының такыр булгач, расходыңны кысарга кирәк.* Урал. *Кыйммәтле аракы, сыра, шәраблар элеккечә киштәләрдә ялтырап утырачак, ә халык акчасын кысып тота башлаячак.* Татарстан яшьләре

14) Сулыш алуны махсус әкренәйтү; суламый тору. *Бөтенесе дә, сулуларын кысып, тыңлап утырдылар.* И.Гази. *Шәрифҗан, аның янына тезләнеп, киңәшләр бирде: бер дә ашыкма, крючокка басканда сулуыңны кыс, тирәюнеңдә кешеләр барлыгын бөтенләй онып, берүзем дип уйла.* И.Гази

15) Йөрәктә, күкрәктә нинди дә булса бер авырлык, авырту барлыкка килү. *Йөрәк менә тире астында гына*

*тибә кебек: бер авырттырып кыса, бер җибәрә, бер кыса, бер җибәрә.* Ә.Еники. *Гүя бүлмәдә урнашкан авыр тынлык аны бугазыннан кыса иде.* Ф.Галиев. *Тын кысуын онытырга тырышып, ул Өязенең башта гади генә чишмә булуы --- турында уйларга тырышты.* А.Хәлим. *Аякларым камыр булды, күкрәгем кыса, чүлдәге кебек авызым кипте.* Ф.Галиев

16) Башак чыгара башлау (игеннәр тур.). --- *туң тәрәзәләрдә ут алынды, басуларда башаклар баш кысты, кайдадыр агымсулардан чайпылдап саллар акты...* А.Хәлим

17) Штанганы, герне баш өстенә күтәргәнче, кискен хәрәкәт белән күкрәккә кую

18) *физ.* Газ яки сыеклыкларның басым ярдәмендә күләмен кечерәйтү. *Компрессорлар ярдәмендә газны меңнәрчә атмосфера басымга кадәр кысарга була.* Физика

19) *күч.* Бик нык чикләү, мөмкинлек бирмәү, берәр яктан бик авыр хәлгә кую. *Үз-үзенә ясап куйган бу рамкасы бәгъзы вакытларда аны бик каты кыса, бик күп уңайсызлыкларга сәбәп була, ләкин ул шулай да бирешми, нинди авырлык белән булса да җиңеп чыга иде.* Ф.Әмирхан. *Тарихта канлы эз калдырган большевиклар властьны кулга алуга, ил киңлегендә хөрлекне кысалар, сүз иреген буалар, халыкның рухын сындырып, коллык дөньясы ясыйлар.* А.Гыйләҗев. *1953 елда Балтикада кече офицерлар курсын бетергәндә, фамилия мине китереп кысты.* М.Мәһдиев

20) *күч.* Саранлану, кысмырлану. *Сәхип – акчаны бик артык кысып тота торган кешеләрдән, чөнки аңа үз гомере буена, ярты кадак арыш икмәге алыр өчен бер тиен бакыр таба алмыйча ач утырырга, билендәге каешын кибетчегә салып, кәмәрсез йөрергә бикбик күп туры килгәләде.* Г.Ибраһимов. *Ашауны бик кысарга ярамый.* Г.Ибраһимов. *Саулык дигәндә акчаны учыңда кысып тоту ярый торган эш түгел.* Мәгърифәт

21) *күч.* Эшләргә яки сөйләргә, нәрсәне дә булса бирергә мәҗбүр итү, нәрсәне дә булса бик каты таләп итү. *Син алай дисең дә бит, хәзрәт безне кыса.* Т.Гыйззәт

22) *күч.* Бик каты изү; җәберләү, рәнҗетү. *Халыкны чиксез каты кыссалар да, күңелләре төшенке түгел әле.* Ф.Бурнаш. *Алар ханга үзләренә бирелгән өлеш өчен бер микъдар акча бирәләр дә халыктан үзләре теләгәнчә салым җыялар, халыкны бик каты кысалар.* Г.Гобәйдуллин. *Ул – ана кеше, ул гына малаен аңлый, кызгана, ә син – деспот, син бары кысу, тыюны гына беләсең.* Ә.Еники. *Мин ничек чыдыйм андый итеп кысуга?* М.Мәһдиев. *Ишеткәнсездер, теге елларны бик кыстылар, кыерсыттылар.* Т.Гыйззәт

◊ **Кыса башлау** Таләпләрне көчәйтү. *Ярый әле, әтиләре бик кыса башлагач, Сылу Бариевна янына килә белде.* Р.Хафизова. *Китереп кыса башлагач, аның хәлле дигәне дә, нәкъ кәлтә еланы кебек, төрле кыяфәткә керә, унҗидегә бөтерелә...* М.Хәсәнов. **Кысып калу** Яшереп, үзләштереп калу. **Кысып карау** Нинди дә булса эшкә тартырга тырышу, нәрсәдер эшләтергә омтылу. *Шәрәф Мөдәррискә кара яктырырга теләп, ул мине атна буе кысып карады, сүз ала алмады.* А.Гыйләҗев. **Кысып чыгару** Әкрен генә, теләр-теләмәс, яки ачу белән нинди дә булса сүз әйтү яки җырлау. *Аннан тагын өйгә кайтып тәрәзә янына утырды да, куллары белән иягенә таянып, урамны күзәтте: яңакларын тыны белән кабартып, ireннәреннән нindидер сагышлы көй кысып чыгарырга тотынды.* Ә.Фәйзи. *Ниһаять, теләр-теләмәс кенә сүзләрен кысып чыгарды.* М.Галиев

**Кыса бару** Акрынлап-акрынлап, торган саен ныграк кысу. *Үземне чорнап алган бу мәгънәсез кыршаудан – мине һәрьяклап кыса барган боҗрадан чыгу юлларын таба алмам кебек.* З.Зәйнуллин. *Бу татлы упкын аны мәрхәмәтсез рәвештә һаман суыра бара, кочагына кыса бара, аның саен Гайнанның сулышы тарая бара.* Г.Бәширов

**Кыса башлау** Кысарга тотыну. *Уйлана торгач, Иванның чигәсе кыса башлады.* М.Әмирханов

**Кыса бирү** Бернәрсәгә дә карамый кысуны дәвам итү, һаман да кысу

**Кыса төшү** Тагы да кысу. *Ул үзе сөйләште, үзе болай ды кысып куелган сукыр лампаны кыса төшеп, маскировканың бер читен күтәреп, тәрәзәнең күкле-яшелле пыяласы аша ишегалдына карап утырды.* Г.Гобәй. *– Ватылды, дисең инде алайса? – диде ул, күзен хәйләкәр кыса төшеп.* Ф.Яруллин. *Күрегеңне кыса төш, кыса төш.* Н.Исәнбәт. *Ирек, күзләрен кыса төшеп, күтәрелеп күккә карады.* Р.Мулланурова

**Кысып алу** Әйберне нәрсә белән булса да һәр яктан әйләндереп, уратып кысу; кыскан хәлендә тоту. *Кинәт әйләнсәм, ни күрим: ике кондуктор, күз карашы белән ашарга торгандай ачулы йөзле бер контролёр безне ике яктан кысып алганнар.* Г.Ибраһимов // Көтмәгәндә, кинәт кысу. *Шамил кызны кадерләп күкрәгенә кысып алды һәм капкага атлады.* Я.Зәнкиев. *Яңгураз аска убылганда гына --- кыз кинәт аның күкрәгенә капланды һәм аның биленнән чытырдатып кысып алды.* Т.Әйди

**Кысып бетерү** Тәмам, ахыргача кысу

**Кысып калу** Кысарга өлгерү

**Кысып карау** Кысарга омтылу

**Кысып килү** Шактый вакыттан бирле кысу. *Садыйк карт дача янына килеп җиткәч, юл буенча аның йөрәген кысып килгән яман хисләр бераз таралa төшкән кебек булды.* Ш.Камал

**Кысып кую** Озак вакытка кысу, кыскан хәлдә калдыру. *Хатын, шыпырт кына килеп, ишекне аз гына кысып куйды.* К.Миңлебаев. *Бераз сүзсез торганнан соң, ул, урынынnan торып, лампа янына барды, аны югарырак алып элде һәм сүнәр-сүнмәслек итеп кысып куйды.* А.Шамов. *Табак-савыт юганда да телефон трубкасын колагына кысып куйган булыр.* Сөембикә // Тиз генә кысу. *Наҗия җавап бирмәде, күңеленнән рәхмәт әйтеп, аның беләген кысып куйды.* Р.Хафизова. *Бер очтан җәт кенә дустына күз кысып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**Кысып тору** Даими рәвештә кысу. *Мәхәббәтеннән исәрләнеп, Гөлүсә белән саташып хараплар гына булмаса ярар иде дип, җаннарымны уч төбендә кысып торам.* М.Хәсәнов. *Агарып*

*күренгән сөлгене кулына алды, битләренә тигезеп, күкрәгенә кысып торды.* Р.Мулланурова

**Кысып утыру** Әле, хәзер кысып тоткан булу. *Шушы сүзләрен әйткәндә дә, ул буылып-буылып ютәлләде, ютәле тыелгач, ике кулы белән күкрәген кысып утырды.* А.Гыйләҗев

**Кысып чыгару** Нинди дә булса сыешлыкны кысып, эчендәге сыеклыгын агызып бетерү

**Кысып чыгу** Барысын да, рәттән кысу

**КЫСУ** II *и. спорт* Штанганы, герне һ.б.ш.ларны күтәрүнең бер ысулы. *Кысуда күтәрү максаты штанганы күкрәккә алу булса, биредә күтәрү дәвамында штанга астына чүгәләргә кирәк.* Социалистик Татарстан

**КЫСУЧЫ** *и.* 1) Изүче, эксплуататор, халыкны изеп хакимлек итүче. *[Рус, татар алпавытлары һәм промышленниклары] Бергәләшеп һәм рус, һәм татар крестьянын, эшчеләрне кысмыйлармы, кысучыларның һәр икәвесен хөкүмәт яклап килмәдеме, хәзер дә якламыймы?* Ш.Камал

2) Җәберләүче, кимсетә торган кеше. *Бу юлда шаула, матбугат! Хатыннарны кысучыларга каршы ач сугыш, ук ат.* Г.Тукай

**КЫСЫК** *с.* 1) Кысан, кысрык, тар. *Димәк, син кысык казармада да шаярып хат язарлык кәеф таба аласың.* Г.Ибраһимов. *Бөтен җыелышны да шул шәкерт уты эчендә яндырдылар, ул үзенең рәхәт күрмәве белән башлый, җиде яшьтән алып тар, кысык, сасы татар мәдрәсәләрендә ми черетүен сөйли.* Г.Ибраһимов

2) Кысылган, киметелгән, чикле. *Вәли бай йортындагы кысык ут шәүләсеннән башка, авылда бер яктылык та күренми.* Һ.Такташ

3) Күз кисеме тар, кысынкы булган. *Болай да кысык күзен тагын да кыса төшеп, Раил башын янтайтыбрак миңа төбәлде.* Ә.Хәсәнов. *Шулчак мәктәп капкасында кап-кара чәчле, кысык кара күзле, чандыр гәүдәле кыз күренде.* Р.Хафизова. *– Хатының белән әйбәт, сөешеп торасыңмы? Аны иркәли, сөя, назлый беләсеңме? – ди ул, кысык күзләрен тагын да кыса төшеп.* Мәдәни җомга

4) Тавышны баса төшеп, сүзне теш арасыннан гына чыгарып әйтү. *Пышылдауга якын бер кысык, азаплы бер тавыш белән: – Инде булмый, – диде.* Г.Бәширов

5) *күч.* Чикләнгән, тар карашлы, рухи яктан ярлы. *Кысык, тар гаилә тормышы эчендә --- үткәрелгән шәкертлек гомере мәдрәсә яшьләренең йөзенә каторга келәймәсе суга.* Г.Ибраһимов

**КЫСЫКЛЫК** *и.* Тарлык, кысанлык, тыгызлык. *Йөзендәге кырыслык – Елан коты очарлык. Күзендәге кысыклык – Ташның суын сыгарлык.* Ш.Гаделша

**КЫСЫЛА́-КЫСЫЛА** *рәв.* Бик тар урыннан яки бик күп җыелган кешеләрне аралап, ерып. *Халык тагы кысыла-кысыла кызыл өйнең кыйбла як миче тирәсенә җыелды.* Г.Ибраһимов. *Әхтәм кысыла-кысыла өстәл янына үтте, бертын эндәшми торды да әкрен генә сөйли башлады.* Ф.Галиев. *Ул киртә арасыннан кысыла-кысыла кереп, әтисе янына килде.* Г.Бәширов. *Һәм шул сынык рәшәткә арасыннан кысыла-кысыла каток эченә кереп киткәнен дә сизми калды.* А.Шамов

**КЫСЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кысу**

2) Тараю, аралыгы, киңлеге кимү. *Безнең белән бергә килүче Агыйдел дә безгә табан кысылып тарая һәм агымын тизләтә, әйтерсең алар ике яклап безне кысарга сүз берләшкәннәр.* М.Әмир. *Тавыш резонаторлары ачык, тавыш кысылмыйча, табигый ачыла, сулышы иркен, тигез җырлый.* Мәдәни җомга. *Дымлы учыгызны биткә һәм муеныгызга куеп торыгыз – сез кан тамырлары кысылудан котылырсыз.* Мәгърифәт

3) *физ.* Күләме, зурлыгы кимү; басылу, тыгызлану. *Җирнең өс кабыгы, эчендәге матдәгә караганда тыгызрак булганга күрә, акрынрак кысыла.* Ф.Әмирхан. *Гүяки нindидер тупас көч галәмнең саф һавасын дустанә суырып алып, бер пешкәк эченә куып кертте дә, һава шартлар чиккә җитеп кысылды.* А.Хәлим

4) Күзләр беркадәр йомыла төшү. *Яңагы шешеп, бер күзе бөтенләй кысылган.* Ш.Камал. *Ханымның күзләре кысылды, усал карашы, энәләр шикелле, егеткә кадалды.* Ә.Еники. *Кеше урамга чыгарга өлгерми, күзләре кысыла, кар бөртекләренә карап ирексездән елмая.* Р.Хафизова. *Күзләре кысылып идәнгә караган [Галинур] учы белән бертуктаусыз маңгаен сыпыра.* М.Хуҗин

5) Бик нык тоташу (иреннәр, тешләр тур.). *Иреннәре бер-берсенә ныграк кысылган.* Ш.Камал. *Тешләр кысылган, күз яшьләре күзге яңгыр булып аккан.* А.Гыйләҗев. *Хурлануыннан йодрыклары йомарланып, тешләре кысыла аның.* И.Гази

6) Бармаклар йодрыкка төйнәлү, уч йомылу. *Тимеринең борын төбендә кодасының чытырдап кысылган кечкенә көрән йодрыгы ялтырап тора.* Г.Бәширов

7) Берәр нәрсә арасына кереп эләгеп калу; ике яктан кысу. *Барсам, башка берәү дә юк, бу берүзе чокыр эчендә: «Ай Ходаем, алтыннар арасына аягым кысылды», – дип кычкырып елап тора.* Ш.Камал. *Ул аны чөйде, һәм туп түбә калае тишегенә кысылды да калды.* А.Шамов. *Төлке кетәклеккә керим дигәндә генә, капкын «шап» итә. Төлкенең аягы кысыла, ул чыелдый.* А.Алиш

8) Төрле яктан уратып алыну, камап алыну, ике предмет арасында калу. *Теләнче Тамакта имтихан биреп йөргән вакытлар, август башында, пароход койрыгына төялгән мичкәләр арасына кысылып, Казанга барулар...* А.Гыйләҗев. *Яр өстендә аунап яткан ватык, ятим гитараның исән кыллары арасына кысылып, гарип җил уйнады.* А.Гыйләҗев

9) Тыгыз урынга үтеп керү; тыгызлану. *Үзе шикелле соңга калып, артта басып торучылар арасына килеп кысыла да зал эченә саф-саф тезелеп утырган кешеләр өстенә карый.* И.Гази. *Алар белән бергә ишек төбенә килеп, кабыргаларны сындырырлык кысылдык.* А.Шамов. *Табынга сый юнәтү артыннан чаба-чаба, яңа алып кигән сандалиемнең табаны кубып чыкты, чиратларда кысылып йөри-*

*йөри, кешелеккә кия торган кәчтүннең җиңнәре умырылды.* Идел

10) Тавыш, яктылык, ут һ.б.ш.ларның көче, интенсивлыгы кимү. *Ул арада өй эчендә кысылып кына янып тора торган кечкенә асылмалы лампадагы ут та күтәрелде.* М.Гали. *Аның кысылып чыккан һәм шул ук вакытта ягымлы тавышы Хәдичә түтинең йөрәгенә барып тиде.* Г.Бәширов

11) Сулыш алу авырлашу, сулыш тыгызлану. *Таңга калу һәм соклануның чиге юк, укыганда тыннар кысыла.* С.Шәмси. *Әле генә таудан йөгереп менгән булырга кирәк, малайның сулышы кысылды, һәм ул беравык сүзен әйтә алмый еш-еш сулап торды.* Ә.Фәйзи. *Монда янган тимер, кызган кирпеч һәм көек исеннән тыннар кысыла.* Г.Бәширов

12) Көчле хисләрдән, авыр күтәрүдән яки башка физиологик халәттән йөрәктә, күкрәктә авырту сизү, авыраю. *Тузган йөрәк авырттырып кысылды.* Р.Мулланурова. *[Асафның] Тамагы кысылды, тын алуы кыенлашты.* М.Мәһдиев. *Безнең йөрәкләребез кысылды, тыннарыбыз бетте.* М.Мәһдиев

13) Кем беләндер сөйләшкән вакытта, икенче берәү сүзгә кушылу. *Ул Якубтан нидер сорамакчы иде, ахры, арага Шәрифҗан кысылып бүлдерде.* И.Гази. *Бөтенләй көтелмәгән урынга шул «яңабаштан» килеп кысылгач, тыңлаучылар кычкырып көлеп җибәрә.* Ә.Хәсәнов. *Кулына бер бөтен бәрәңге тотып өлгергән Халикъ яңадан сүзгә кысылды.* Г.Әпсәләмов

14) Нәрсә беләндер шөгыльләнгәндә, икенче бер эш килеп чыгып комачаулау. *Арага башка нәрсә килә дә кысыла, килә дә кысыла.* Г.Ибраһимов. *Яңа бер мәсьәлә килеп кысылды*

15) *күч.* Кемнәрнеңдер эшләренә, үзара мөнәсәбәтләренә катнашу, тыкшыну. --- *ир белән хатын арасына килеп кысылмасаң, эшең беттемени?* Г.Бәширов. *Син, Гаян, ул яңалыкларның нәрсә икәнен дә белмисең бит әле, кысыласың тагын.* А.Әхмәт. *Я ике йөрәк арасына өченче берәү чөй булып кысылырга тырыша.* Ф.Яруллин. *– Карале моны бер генә, ир башы белән хатын-кыз арасына кысыла, – диде калын гәүдәлесе.* Татарстан яшьләре

16) *күч. сөйл.* Берәр нәрсә бик аз калу, бик нык кимү, азаю; берәр әйберне табуы авырлашу. *Шулай итеп, акча ягыннан кысылды да китте кеше.* Ш.Камал. *[Директор:] Без кисә торган утынның күбесе хәрби паровозларны йөртергә китә. Үзегез беләсез, ташкүмер ягы кысылды.* Г.Гобәй

17) Нәрсә белән дә булса чикләнү, тоткарлану. *Шулай итеп, аның эчендәге музыка дөньясы, музыкадан ләззәт алу өчен яратылган тойгылары күп елларгача шәкерт вә мәдрәсә галәменең куәтле рамкалары эченә кысылып, әллә кайда төптә, рухының әллә нинди эчке катлауларында бикләнеп ятырга мәҗбүр булалар.* Г.Ибраһимов

18) Чикләнү, тыелу, мәхрүм ителү. *Шулай итеп, бала акчасыннан мәхрүм ителеп, яшь әнинең һәм аның баласының конституцион хокуклары кысылган.* Татарстан яшьләре

**Кысыла бару** Торган саен ныграк кысылу. *Үзе көчсез, һаман кысыла бара.* Ш.Камал. *Гадәттә, айның 3 нче чирегеннән 4 нче чирегенә кадәр организм кысыла бара.* Мәдәни җомга

**Кысыла башлау** Кысылырга тотыну. --- *Шәмсетдиннең тамагы исә һаман төзәлми дә төзәлми, ул бары көзгә таба йомырка-сөт кысыла башлагач кына сихәтләнә башлый торган иде.* Г.Бәширов

**Кысыла бирү** Торган саен үзеннән-үзе кысылу, кысылуын дәвам итү

**Кысыла төшү** Беркадәр кысылу. *Бары тик кысыла төшкән күзләре генә аның эчке уйларга йотылып баруын күрсәтәләр.* Ә.Еники

**Кысылып бетү** Тәмам, бик нык кысылу

**Кысылып җитү** Ахыргача, тиешле дәрәҗәдә кысылу

**Кысылып йөрү** Һәрвакыт кысылу; бөтенесенә дә кысылу

**Кысылып калу** Кысылган хәлгә килү. *Башы белән алгы аякларын тегеякка чыгарса да, арт саны кысылып калды.* Ф.Кәрим. --- *арбалар арасында кысылып калган өр-яңа кухня күзгә ташланды.* Ш.Усманов. *Мәктәп ишегалдына кысылып калган мунча мүген тәмәке итеп тартып йөрүче шамакайлар да мине ияртеп китә алмый.* А.Гыйләҗев

**Кысылып килү** Кинәт кысылу. *Шатохин пружина кебек кысылып килде.* Ф.Галиев

**Кысылып китү** Көтмәгәндә, кинәт кенә кысылу. *Хәдичә түти кунак солдатның Гафифәне яңадан телгә алуыннан куркып, --- тагы йөрәге кысылып китә иде.* Г.Бәширов. *Бик күпләрнең йөрәкләре бердән кысылып китте.* К.Нәҗми

**Кысылып кую** Кинәт кенә, аз вакытка кысылу. *Габдулланың йөрәге рәхәт кенә кысылып куйды.* Ә.Фәйзи

**Кысылып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз кысылу

**КЫСЫЛУЧАН** *с.* Тышкы басым нәтиҗәсендә күләме кими, кечерәя торган. *Кысылучан утырымның аерымлыгы исә басым аермасы үсү нәтиҗәсендә кими.* Химик технологиянең гидромеханик процесслары

**КЫСЫЛУЧАНЛЫК** *и. физ.* Тышкы басым нәтиҗәсендә матдәнең үз күләмен кечерәйтә алу сәләте. *Барлык төшләрдәге масса тыгызлыгының чама белән бер үк булуы төшнең кысылучанлыгы сизелерлек булмавын күрсәтә.* Физика

**КЫСЫЛЫП** *рәв.* 1) *к.* **кысыла-кысыла**. *Әптерәш, Насыйп, Ярми тоткын ягына кысылып үтәргә омтылалар.* Г.Ибраһимов

2) Тыгызлашып, бер-берсен тыгызлап. *Егетләр бит алар кысылып утырырга өйрәнгән булалар.* Ф.Бурнаш. *Учакны урап алганнар, кысылып түгәрәкләнеп утырганнар.* А.Гыйләҗев

3) *күч. сөйл.* Бик акрын тавыш белән. *Дулкынланудан тавышы кысылып, акрын гына әйтте.* Р.Хафизова. *Дулкынланудан кысылып чыккан тавышында ачу яңгырады.* Г.Бәширов

**КЫСЫЛЫ́П-КЫСЫЛЫП** *рәв. к.* **кысыла-кысыла**. *Халык кысылып-кысылып чыга башлады.* Ф.Әмирхан. *Насыйп, Ярми, Әптерәш, алар артыннан башка ярлылар да, кысылып-кысылып, Гайнетдиновка таба барырга кузгалалар.* Г.Ибраһимов

**КЫСЫЛЫШ** *и. сөйл.* 1) Тыгызлык, кысанлык. *Шул көнге кысылышта аның җиде кабыргасын сындырганнар, үпкәсенә, бавырына зыян килгән.* М.Юныс

2) *күч.* Берәр эшкә мөнәсәбәт, бәйләнеш. *Димәк ки, сагына белүгә катылыкның, йомшаклыкның кысылышы юк.* С.Поварисов

**КЫСЫЛЫШУ** *ф.* Тыгызланып, бер-берենә бик якын килү. --- *тоткыннар мичкәдәге балыклар кебек кысылышып ятсалар да, дәррәү кычкырып көлеп җибәрәләр...* А.Гыйләҗев

**Кысылышып алу** Беркадәр тыгызланышу

**Кысылышып кую** Бераз вакытка кысылышу

**КЫСЫМ** *и.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса басым ясау; һөҗүм

2) Изү, кысу. *Боларның бер өлеше элек-электән шунда яшәгән булса, шактые – Казан егылганнан соң төрле гасырларда изелүләрдән, түзә алмастай салым кысымыннан, чукындыру сәясәтеннән качып киткән татарлар.* И.Таһиров

**КЫСЫНКЫ** *с.* **1.** 1) Беркадәр кысан, тар, кечкенәрәк. *Безнең өй кысынкы, тәрәзәләре дә кояшка карамый.* Ә.Фәйзи. *Әллә сезне тар, кысынкы төрмәләр үтердеме?* Һ.Такташ

2) Бераз кыса торган (аяк киеме һ.б.). *Кысынкы ботинкалардан юка, саргылт оек эчендәге кечкенә генә нәфис аяклар килеп чыктылар.* Ф.Әмирхан

3) Күз кисеме кысылыбрак торган, бераз таррак булган. *[Асрау карчыкның] Күзләре кечкенә, кысынкы.* Г.Коләхмәтов

4) Яшәү, тормыш шартларында авырлыклардан, киеренкелектән гыйбарәт; ирекне, шәхесне кыскан. *Гомер буенча искечә, кара, кысынкы тормышка каршы протест белән, көрәш белән барды.* Г.Ибраһимов

5) Катгый, кырыс, ташламалары булмаган (таләпләр, кагыйдәләр һ.б.). *Ул үз гаиләсенә Ташаяк шикелле җирләргә барырга рөхсәт биргәндә дә уңайсызланып кына һәм бик кысынкы шартлар белән генә рөхсәт бирә иде.* Ф.Әмирхан. *Хәзрәтнең кысынкы кагыйдәләре эчендә яшәгән шәкертләр --- башларына килгән һәрбер эшләрне кыла башладылар.* Г.Ибраһимов

6) Нәрсә дә булса җитешмәгән, аз булган. *Тик [Зәбировның] вакыты гына бик кысынкы.* Г.Әпсәләмов. *Алар ярдәменнән башка Карлен Татлян Мәскәүне һич кенә дә өйрәнеп-аңлап бетерә алмас, димәк, үзенә йөкләнгән бурычны да тиз генә үтәп чыкмас иде, ә вакыт һәрвакыттагыча кысынкы булды.* Казан утлары

7) *мат.* Туры почмактан кечерәк булган. *Барлык почмаклары кысынкы булган өчпочмак кысынкы почмаклы өчпочмак дип атала.* Геометрия

**2.** *рәв. мәгъ.* Экономияләп, аз-азлап, кысмыр. *Дөрес, кысынкы яшәделәр, ярлы да булсын, ди, тормышлары, әмма аны шулкадәр хурлап, хәерче дип мыскыл итәргә ---.* Р.Мулланурова

**КЫСЫНКЫЛАНУ** *ф. сөйл.* Шартлар авырлашу, кыенлану

**Кысынкылана бару** Вакыт үткән саен кысынкылану

**Кысынкылана башлау** Кысынкыланырга тотыну

**Кысынкылана төшү** Тагын да кысынкылану

**Кысынкыланып алу** Бер аралыкта, күпмедер вакыт эчендә кысынкылану

**Кысынкыланып калу** Кинәт кысынкылану. *Керде исә, никтер бик моңсу, бик күңелсез булыр шикелле булып, дөнья кинәт тараеп, кысынкыланып калыр шикелле булып тоелды.* Н.Фәттах

**Кысынкыланып китү** Билгеле бер моменттан башлап, кинәт кысынкылану

**Кысынкыланып тору** Әле, хәзерге вакытта кысынкылану

**КЫСЫНКЫЛЫК** *и.* 1) Кысанлык, тарлык, кысынкы булу. *Гимназия үзенең бик кысынкылыгы белән бу соңгы ике елда бик туйдырган иде.* Ф.Әмирхан. *Кечкенә хикәя кысынкылыкны, кыскалыкны тели.* Г.Нигъмәти

2) Изелү, эксплуатацияләнү, ирек һ.б.ш.лар чикләнгән булу. *Студентлар арасында оппозицион хәрәкәт башлану һәм самодержавиенең нигезе какшау милли кысынкылыкларга каршы булган бу хәрәкәткә зур этәреш бирделәр.* М.Җәлил. *Шулай булгач, татар алпавыты, татар буржуасының дини-милли кысынкылыклар «күрүе» турында күздән яшь агызуның ни мәгънәсе бар?* Ш.Камал

3) Артык катгый куелган таләп, тәртип; шәхескә үсү ирегә бирмәү. *Һичбер төрле көчләү, кысынкылык, мәшәкать һәм борчу тидермәсеннәр.* Сәхиб Гәрәй хан ярлыгы. *Зыя иске мәдрәсәне яратмый, аның кысынкылыгыннан тарлана, ташлап чыга.* Г.Нигъмәти

4) Җитмәүчелек, мохтаҗлык; тормыш авырлыгы. *Тукай 1907 нче елның башында бөтенләй эшсезлек һәм гадәттән тыш материаль кысынкылык эчендә кала.* Г.Халит

5) Төркем эчендә тыгызлык, урын булмау. *Пристаньдагы халык касса тирәсенә җыела башлады, бер дәкыйка эчендә өченче класс билетларының касса тәрәзәсе төбендә биниһая дәрәҗәдә бер кысынкылык тәшкил итте.* Ф.Әмирхан

**КЫСЫ́П-КЫМТЫП** *рәв.* Аз-азлап, бик азлап (җыю, туплау һ.б.)

**КЫСЫР** *с.* 1) Тумасы булмаган, үрчем бирмәгән, аталанмаган. *Бая алар ат җигеп көтүгә киткән булганнар икән, менә шуннан бер кысыр сарыкны алып кайтып суйганнар.* Ә.Еники. *Сабантуйга чиккән тастымалын, бүләген, тәкәсен түгел, кысыр тавыгын да бирми, малай.* А.Хәлим. *Юк шул инде, әниемнең дә, минем дә күз яшьләрем төшкәндер үзенә: кысыр хатын булып гомер кичерә килде.* Х.Ширмән

2) Җимеш, уңыш бирми торган. *Кайбер бакчачылар кысыр чәчәкләрне чүпләп, өзеп ташлап хур була, ди Рифкат әфәнде.* Мәгърифәт. *Сынган һәм кысыр ботакларны кисеп алырга, ә яфракларына көл эремәсе бөркергә киңәш ителә.* Безнең гәҗит

3) Сукаланмыйча, эшкәртелмичә ташланып торган; эшкәртелеп, иген чәчелмәгән. *Бөтен бер басулар кысыр калып, әрем-алабута, төрле чүп үләне басты.* Ф.Хөсни. *Училищега килеп җитәргә дүрт чакрымнар кала, сул якта зур кысыр басу ---.* М.Мәһдиев. *Кысыр басуларда кинәнә-кинәнә чүп үләне үсте.* Н.Гыйматдинова

4) Пулясы булмаган, дары белән генә корылган. *Архангельский --- күк гөрелтеләр, яшеннәр чәчә иде. Ләкин эшкә җитдирәк караучы халыклар күптәннән инде ул гөрелтеләргә «кысыр патроннар гөрелтесе» дип карыйлар иде.* Ш.Камал

5) Итсез пешерелгән, ите булмаган. *Умачны итле, сөтле һәм, шулай ук, кысыр ашларга да салалар.* Татар халык ашлары

6) Буш. *– Аянычка каршы, минем дә кесә кысыр чак, – диде ул, уңайсызланып.* З.Фәйзи

7) Яңгырсыз, явым-төшем китерми торган болыт. *Кысыр болытлардан шифалы яңгыр көтеп йөргән ач күңелемә бәйрәм килде: барам!* А.Гыйләҗев

◊ **Кысыр кайгы (хәсрәт)** Бер дә юкка кайгыру, бушка борчылу. *Машинасы бәрелеп ватылган, имеш, бу әле кысыр кайгы гына, иң мөһиме: үзе исән калган.* Заман – Татарстан. **Кысыр көек** *к.* **кысыр кайгы**. *Йөрмә кысыр көек булып.* А.Хәлим

**КЫСЫР КАЛУ** *ф.* Тумасы булмау, үрчем китермәү

**КЫСЫРЛЫК** *и.* Кысыр калу, тумасы булмау. *Ген мутациясе кысырлыкка, гарипләр, чирле балалар тууга, иртә үлемгә китерә.* Татарстан яшьләре

**КЫСЫРЛАНУ** *ф.* Саегу, бөтенләй суы бетү. *Ни гаҗәп, шуннан соң елга бөтенләй кысырланды.* Н.Гыйматдинова

**Кысырланып бару** Акрынлап кысырлану

**КЫТАЙ** *и.* 1) Телләре кытай-тибет телләре семьялыгына караган, төп диннәре конфуцианлык, даосизм, буддизм булган, Кытайның төп халкы атамасы (үзатамалары – хань) һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Без аның да, башка кытайлар кебек, уң кулының баш бармагын күтәреп, «шонго!» дип исәнләшүен көткән идек.* А.Шамов. *Мин ут ташлаган җирдә японнарның барлык сугыш коралы, снарядлары, азыклары һавага очып, ун меңләп солдаты да һәлак булган дип, кытайлар килеп сөйләделәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Кытай, җиргә башын бәрә-бәрә, миңа рәхмәтләр укый.* А.Гыйләҗев

2) Кайбер ботаник һәм зоологик атамаларның беренче кисәге (компоненты). *Кытай тарысы*

◊ **Кытай диварлары** *к.* **Кытай стенасы**. **Кытай стенасы** Нинди дә булса берәр күренешкә, эшкә зур комачау булып торган нәрсә

**КЫТАЙЛА́РЧА** *рәв.* Кытай халкына хас итеп, охшатып, кытайлар кебек

**КЫТАЙЛЫ** *и.* Кытайда яшәүче кеше

**КЫТА́Й РОЗАСЫ** *и.* Мальвачалар семьялыгының гибискус ыругына караган, бүлмә яки оранжерея гөле итеп үстерелә торган эре яфраклы һәм җете төстәге эре чәчәкле үсемлек. *Кытай розасы – мәңге яшел, күп таралган гөл.* Йорт эшләре

**КЫТА́ЙЧА** *рәв.* 1) Кытай телендә. *Тыныч булыгыз, сезнең дәфтәрегез белән нишләсеннәр соң, әгәр укучы кирәк булса, анда немецчә генә түгел, кытайча укучылар да бар.* Г.Гобәй. *Кичә иртән, аннары бераз соңрак кытайча белүче берничә кеше очраган да булган, ләкин алары аңа бары рәхмәт әйтеп, бик ашыгып китеп барганнар.* А.Шамов

2) Кытайларга хас булганча. *Кытайча Яңа ел курантлары дыңгырдатып сугарга ярты сәгать калгач --- «Бәхетле бул» дигән байгуралар кибетенә сугылып чыктым әле менәтерә.* Мәдәни җомга

**КЫТАЙ ЧИКЛӘВЕГЕ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгына караган, бер яки күпьеллык үләнчел үсемлек; җир чикләвеге, арахис. *Көмешле күлнең уртасы кытай чикләвегенең биле кебек тараеп нечкәреп тора.* Г.Гобәй

**КЫТАКЛА́У** *ф.* Кыска-кыска һәм өзек-өзек итеп тавык, әтәч кычкыру. *Аларга кушылган сыман, ишегалдында тавык кытакларга тотынды...* Ә.Гаффар. *Фатих ага Хөсни әйтмешли, тавык кытаклаган саен алтын йомырка салмый!* А.Гыйләҗев. *Кайсыдыр күршесе ихатасында аяныч итеп тавык кытаклады.* А.Хәлим. *--- бөтен авылны шаулатып тавыклар кытаклый.* Г.Бәширов

**Кытаклап алу** Кыска гына итеп бераз кытаклау. *Чаттан тавышсыз гына шуышып ак машина килеп керүгә, урамдагы зур кызгылт әтәч куркынып кытаклап алды, тавыклар телендә «игътибар, тапталмагыз» дигән сыман команда бирде.* М.Мәһдиев

**Кытаклап җибәрү** Кинәт кытакларга тотыну. *Хәер, ара-тирә шоссе юлдан узучы машиналар тавышы ишетелә, күршедә генә тавык кытаклап җибәрә.* Ә.Гаффар

**Кытаклап йөрү** Әле, хәзерге вакытта кытаклау. *Бер тапкыр «Галиябану»ны уйнаганда, ул [Кәрим Тинчурин] сәхнәгә тавыклар, әтәчләр чыгара. Бәдри карт ишегалдында җим чүпләп, кытаклап йөрергә тиешле тавыклар тамаша залына очып төшә башлыйлар.* Р.Батулла

**Кытаклап кую** Кыска гына бер тапкыр кытаклау. *Колак салды: тышта Аюлы күл чишмәсе гөрелди, ябык ишек аша тавыклар кыртлавы, әтәчнең, адашып, кытаклап куйганы, әниләренең эчке якта һаман быдыр-быдыр сөйләшкәне ишетелә.* А.Хәлим

**Кытаклап тору** Бертуктаусыз кытаклау. *Ибраһимның бәхет белән мөлдерәмә тулы күңеле бу минутта яңа гына күкәй салган тавык шикелле кытаклап тора иде.* В.Имамов

**КЫТАТ** *и. иск.* 1) Борынгы вакытта Кытайда эшләнгән тыгыз ефәк тукыма, парча. *Бистә хатыннары, Давыт бәк кытат җилән тектергән, имеш, дип күрергә барырлар иде.* К.Насыйри

2) Киҗе-мамык тукыма. *Анасы Казан байларының элекке комач, кытат фабрикаларында эшләп гомер иткән.* Г.Ибраһимов

3) *диал.* Клеёнка

**КЫТКЫЛДА́У** *ф.* **1.** 1) *к.* **кытаклау**. *Чуар тавык кыткылдый-кыткылдый күрше Шәвәлиләр янындагы койма астыннан чыгып килә.* А.Шамов. *Хәтта тавыклар кыткылдаган тавышлар да ишетелми.* Н.Дәүли. *Ул арада, күкәй салган тавык кебек кыткылдап, өйдән аналары килеп чыкты.* Р.Хафизова. *Мин үзем әбәткә бер тавык сыпырып куйдым – кыткылдамыйм, юкә балы белән каһвә эчеп куйдым.* Мәдәни җомга

2) *куч. сөйл.* Сөйләргә ярамаган сүзне тиешсез вакытта, урында сөйләргә тырышу

3) *күч.* Кыска-кыска, өзек-өзек тавыш чыгарып көлү. *[Кошчак] --- арты белән бозга егылганын исенә төшереп, тыела алмый кыткылдый иде.* Р.Батулла

**2. кыткылдап** *рәв. мәгъ.* 1) Бик артык шаркылдамыйча. – *Исемеңне дә белүче юк, фамилияңне дә белүче юк, һәммәсе үзеңне генә белә, – дип кыткылдап көләргә тотынды.* М.Гали

2) Астыртын эш йөртеп, үзара сөйләшеп. *Анасы таныш-белеш аша кыткылдап, арткы ишектән кертмәкче булса да, тәки институтка уза алмады.* М.Насыйбуллин

**Кыткылдап алу** Бераз гына, кыска вакытка кыткылдау. *Чебиләрен иярткән тавык, Кәриманә күрүгә, тынычсызланып кыткылдап алды.* Р.Хафизова. *Бодай сибүгә, тавык бер бөртекне генә авыз итеп карады да, аның чыннан да бодай икәненә ышангач, сөенеченнән кыткылдап алды.* Р.Вәлиев

**Кыткылдап җибәрү** Кинәттән кыткылдый башлау

**Кыткылдап йөрү** Һәрвакыт кыткылдау. *Кычкырыша торгач, чуар тавыкның Шәвәлиләр лапасында түгел, ә бакчада, Шәмгун картларның үз мунчалары тирәсендә һәр көнне кыткылдап йөргәне билгеле булды.* А.Шамов // Әле, хәзер, сөйләү моментында кыткылдау. *Язгы кояш карларны эреткәнгә, төрле яктан бәләкәй гөрләвекләр ага, ишегалдында тавыклар кыткылдап йөри.* Д.Гыйсметдин

**Кыткылдап кую** Кинәт, кыска гына кыткылдау. *Чеби чырылдап кычкырып җибәрде, ---. Әнкә тавык аңа ни булуын аңламыйча, борчылып кыткылдап куйды.* Р.Хафизова

**Кыткылдап тору** Бертуктаусыз кыткылдау. *Ашказаны «давай, давай!» дип кыткылдап тора.* Г.Мөхәммәтшин. *[Хәниф:] Я, Закир. Баядан бирле кыткылдап торуыңны сизәм.* А.Гыйләҗев

**Кыткылдый башлау** Кыткылдарга тотыну. *Хуҗа кешенең ишегалдына кайтып керүен сарай эчендәге тавыклар тиз сизеп алдылар, җанланып, үзара кыткылдаша башладылар.* Н.Хәсәнов

**Кыткылдый бирү** Бернигә карамый кыткылдавын дәвам итү

**КЫТКЫЛДЫК** *с. сөйл.* 1) Кыткылдый торган. *Әйтергә кирәк, минем Мияубикәм дә, кыткылдык тавыкларым да бер төстәләр.* Казан утлары

2) Кирәгеннән артык күп сөйли торган

3) Кыткылдап көлә торган

**КЫ́Т-КЫТ** *иярт.* 1) *к.* **кыт-кытак**. – *Кыт-кыт, – ди бер әтәч, – тавыкларым, Килегез тиз, таптым борчак, – ди.* Б.Рәхмәт

2) Кыткылдап көлү тавышын белдерә. *Үзе көлә кыт-кыт итеп, егылып төшә шап итеп.* Н.Исәнбәт

**КЫТ-КЫТАК** *иярт.* Тавык, әтәчнең кычкыру тавышын белдерә

**КЫТ-КЫТЛА́У** *ф.* Өзек-өзек авазлар чыгару, кытаклау (тавык, әтәч тур.)

**Кыт-кытлап җибәрү** Көтмәгәндә, кинәт кыт-кытлый башлау

**Кыт-кытлап кую** Кинәт кенә бер тапкыр кыт-кытлау тавышы чыгару

**КЫТ-КЫТЫЙ** *иярт. к.* **кыт-кытак**. *Чуаркаем, җим чүплә, Торма анда бер читтә. [Тавык:] Кыт-кытый, кыт-кытый, Хуҗам мине онытмый.* Ф.Яруллин

**КЫТ-КЫТЫЙК** *иярт. к.* **кыт-кытак**

**КЫТ-КЫТЫЙ КҮЗ** *и. сөйл.* Эңгер-меңгердә начар күрүдән гыйбарәт күз авыруы; *русчасы*: **куриная слепота**

**КЫТЛЫК** *и.* **1.** 1) Азык-төлеккә һәм икмәккә мохтаҗлык; ачлык. *Язмыш мине тагын тоташ ачлык, кытлык белән күзгә-күз очраштырды.* А.Гыйләҗев. *Шундый кытлыкта нинди бәйрәм дә, нинди урыс аракысы.* Ә.Гаффар. *Ләкин кытлык совет заманында туганнарыңның, якыннарыңның үз авызларыннан өзеп, туймас төрмә тамагын тыгындырып йөрүләрен уйласаң... передача алуның шатлыгы җил күзендә утырган шәмдәй дөртләп сүнә.* А.Гыйләҗев

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса чиктән тыш мохтаҗлык; җитешмәүчелек. *Кышкы кичләрдә, хәтеремдә, керосинга кытлык бик зур иде...* М.Мәһдиев. *«Бездә укытучыларга кытлык, кал», – дигәч, әз генә дә ялындырмадым...* Н.Гыйматдинова. *Сезнең монда җитәкче кадрларга кытлык икән ләбаса!* А.Хәлим. *Рус теленең дистәләгән сүзлеген табып булса да, туган телебез сүзлекләренә зур кытлык.* Р.Фәтхрахманов

**2.** *с. мәгъ.* Азык-төлек һәм икмәк җитешмәгән, бик аз күләмдә булган; уңыш булмаган. *Мондый кытлык елны хәерче кызларын андый хакка кеше сатып аламы?* Т.Гыйззәт

**КЫТМЫЛДАП** *рәв. иск. диал.* Аңга бәйсез рәвештә, уйламыйча, кинәттән

**КЫТМЫР** *с. к.* **кысмыр**

**КЫТМЫРЛАНУ** *ф.* Вакчыллану, һәр тиенне санап яшәү

**КЫТНА́У** *ф. сөйл. к.* **кытаклау**. *Шуңа көләм мин, ди, кытнап, Үтерә ич кытыклап.* Н.Исәнбәт

**Кытнап алу** Тиз генә, бераз гына кытнау

**Кытнап җибәрү** Кисәк кенә кытнау

**Кытнап кую** Тик торган җирдән кытнау

**Кытнап тору** Бертуктамый кытнау

**Кытнап утыру** Әле, хәзерге вакытта кытнау. *--- бар да кесәләренә берәр йомырка алып яшергәннәр, аннан: «Әйдә, йомырка салабыз», – дип, тавык булып кытнап утыргач, яшергән йомыркаларын чыгарып Хуҗага күрсәткәннәр.* Н.Исәнбәт

**КЫТЫ́Й-КЫТЫЙ** *и. к.* **кети-кети**. *Кытый-кытый уйнау*

**КЫТЫК** *и.* Җиңелчә генә тәнгә орынып алудан тәннең үзенчәлекле тәэсирләнүе. *Кытыгын әзләп куен тирәсеннән Култык асларына үтте ул.* М.Җәлил. *Ул да түгел, берәүнең кытыгы кычуга әверелде ахрысы.* М.Хәсәнов

**КЫТЫК КИЛҮ** *ф. к.* **кытыклану**

**КЫТЫКЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Тәннең кытыгын китерү, кытыклау. *Салихның куе мыегы Хәятның йөзен дә, борынын да, маңгаен да кытыкландырыр.* Ф.Әмирхан. *Минем дә шулай, яланаягымны кытыкландырып, үлән арасында йөгереп йөрисем --- килә.* Г.Бәширов

2) *күч.* Күңелне тәэсирләндерү, җилкендергеч хисләр уяту. *Диңгез ягыннан искән йомшак кына җил --- битләрне сыйпый, миләрне кытыкландырып, күңелләрне рәхәтләндерә иде.* Ш.Камал. *Яшел сахралар, караган саен, күзләрне ягымлы гына тибрәтәләр, күңелне*

*нечкә генә кытыкландырган хәлдә, табигатьнең чиксез-кырыйсыз матурлыкларына тартып ашкындыралар.* Ш.Камал

**Кытыкландырып алу** Кинәт бераз гына кытыкландыру

**Кытыкландырып кую** Уйламаганда, көтмәгәндә, кыска вакыт арасында кытыкландыру тою

**Кытыкландырып тору** Бертуктаусыз кытыкландыру

**КЫТЫКЛАНУ** *ф.* 1) Тәнгә җиңелчә кагылудан кытык хисе барлыкка килү. *Мәче --- койрык очы белән генә байның борынын кытыклый икән. Байның борыны кытыкланып, бик каты итеп төчкереп җибәргән икән, алтын балдак атылып төшеп тә киткән.* Әкият

2) Берәр төрле истән, күңелгә килгән уйдан кымырҗу барлыкка килү, кымырҗып тору. *Бичара, ят ризыкны өнәмәде, иснәде дә, борыны кытыкланып, өч тапкыр төчкерде.* Н.Гыйматдинова. *Акрын, назлы гына: – Әтиең, әниең бармы? – дип сорады, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланган шикелле булды.* Ә.Еники

3) *күч.* Хисләр кузгалу, тәэсирләнү; җилкенү. *Гарәфи абзыйның да күңеле кытыкланды булса кирәк, яткач тәмәке тарта торган гадәте булмаса да, торып, тәмәке төрә башлады.* Г.Әпсәләмов. --- *бу күренештән күзләр генә түгел, күңелләр дә, ничектер, кытыкланып, җилкенеп китә торган иде.* Ә.Еники. *Болай булгач, чикми булмый артка таба, Йөрәк яна, күңел һаман кытыклана.* М.Гафури

4) *күч. диал.* Ымсыну; көнләшү, көнчелек килү. *Кеше әйбере, үтереп кытыкланса да, Нурсөя тартмачыкка кагылмады.* Н.Гыйматдинова

**Кытыклана башлау** Кытыкланырга керешү. *Айсылу аның әрсезлегенә кытыклана башлаган иде инде.* Г.Бәширов

**Кытыкланып йөрү** Күптәннән, әллә кайчаннан нәрсәдер эшләргә теләп җилкенү; нәрсәгәдер кызыгу

**Кытыкланып китү** Кинәт кенә тәэсирләнү. *Боларны хыялына китергәч, Хәят чынлап та кытыкланып китте, кызарынды һәм, үз-үзеннән оялып, мендәренә барып капланды.* Ф.Әмирхан. *«Әти, миңа автомат алып кайт», – дип, сабыйларча мөлаемлык белән язып торуы исенә төшкәч, күңеле тулып, тамак төпләре кытыкланып китте.* И.Гази. *Һидият нәрсәгә чакырылуларының сәбәбен Фәтхи белгәнлекне чамалагач, аның күңеле кытыкланып китте.* Ш.Камал

**Кытыкланып кую** Кинәт аз гына вакытка кытыклану. *Аның тамагы кытыкланып-кытыкланып куйды.* Г.Ибраһимов. *«Чибәр» сүзен ишеткәч, күңеле барыбер кытыкланып куйды.* Ә.Моталлапов

**Кытыкланып тору** 1) Шушы мизгелдә кытыклану

2) Сабырсызланып тынычсызлану

**КЫТЫКЛА́У** *ф.* 1) Җиңелчә генә тәнгә тиеп, орынып, тәнне үзенчәлекле тәэсирләндерү, кытыгын китерү. *Нindider көч аларның дүртесен дә яңадан җиргә сугып екты да аяусыз төстә кытыкларга, акыртып көлдерергә тотынды.* Ә.Гаффар. *Мин синең муеныңны, аяк асларыңны кытыкладым.* Ф.Яруллин. *Каты, тупас бармаклар малайның муенын, колак артын кытыклады.* Р.Мулланурова. *Тополь яфраклары аның ялангач аркасын кытыклады.* М.Мәһдиев

2) Кымырҗыту, кымырҗу барлыкка китерү. *Борынны кытыклаган бу гаҗәеп хуш ис шулардан тарала икән.* Ә.Еники. *Баскычка утырып, чабаталарын кага-кага, аякларын киенеп ятучы Җиһанша җизнинең борынына кояш нурлары кереп кытыклады, ул борынын күтәрде дә төчкереп җибәрде.* Һ.Такташ. *Корбан яки Нәүрүз бәйрәмнәрендә гимназиябез янында тергезгән учакта пешкән итнең танауларны кытыклавы истән чыгарлыкмыни?..* Мәгърифәт

3) *күч.* Хис уяту, тәэсирләндерү, җилкендерү. *Ул адымнар минем күңелемне кытыклыйлар.* Ф.Әмирхан. *Әнә шул яңа тормыш нindider зур эш башкарырга өндәп күңелне кытыклый, ашкындырып тора иде.* Г.Бәширов. *Аның тавышы салмак, йомшак, ул йөрәкнең иң яшерен тирәнлекләренә кадәр үтеп керә, күңелне кытыклый...* Ә.Айдар. --- *бу китапта язылган мәсьәлә Гыймадиның күңелен аеруча кытыклаган мәсьәлә булып чыкты.* Ә.Фәйзи

**Кытыклап алу** Бераз кытыклау. *Газинур аяклары янына килеп иркәләнә башлаган Сарбайның колак артларын кытыклап алды да көлеп җавап бирде.* Г.Әпсәләмов. *Тәүдә танауны симез елкы шулпасының буы кытыклап алды, бераз торгач, бәлеш көегенең исе килеп сугылды.* М.Кәрим. *«Менә шуларның кулында милләтебезнең киләчәге» дигән уй күңелне кытыклап алды.* И.Надиров

**Кытыклап җибәрү** 1) Җиңелчә генә тәэсирләндерү, бераз кытыклау. --- *җырлаган тавыш боларның күңелләрен тагын кытыклап җибәрде.* М.Гафури

2) Кинәт кытыклый башлау. *Ишектән килеп керүгә, инде казанда акрын гына гобыр-гобер кайнаган итнең өйгә чыккан буы, мичтән чыккан бәлеш исе борынны кытыклап җибәрә.* Ә.Еники

**Кытыклап йөрү** Дәвамлы рәвештә, күптәннән бирле кытыклау. *Әллә кайчаннан күңелне кытыклап йөри.* Г.Ибраһимов

**Кытыклап кую** Бераз гына кытыклау. *Каңгатьнең шәрә балтырларын нәрсәдер, бая елгадагы вак балыклар сыман кытыклап куйды.* А.Хәлим. *Кызы Нәфисәнең күз кабаклары шешенеп, чыраена хаста төсе керүе аның да күңелен кытыклап куйды.* Г.Бәширов

**Кытыклап тору** Бертуктаусыз кытыклау. *Кызыксынуы кытыклап торса да, кеше алдында әнисеннән ни дә булса сорашырга кыймады.* Т.Әйди. *Инде ул яшьләр аның битен чылатмый, ә вак җыерчыклар челтәрләгән күз төбен генә кытыклап тора.* Ә.Гаффар. *Битләрне кытыклап торган җиңелчә салкыннарда көзге кебек ялтырап торган боз өстендә уйнаулар бигрәк тә күңелле була торган иде.* М.Гали

**Кытыклый башлау** Кытыкларга тотыну. *Кинәт ул аяк чәлтерләрен төрле яклап нәрсәнеңдер кымтый, кытыклый башлавын тойды.* А.Хәлим

**Кытыклый тору** Һәрвакыт, гел кытыклау. *Минем йөрәгемне кытыклый торган сын Алядан башка кемдә булырга мөмкин!* Ф.Әмирхан

**Кытыклый төшү** Бераз кытыклау

**КЫТЫК САЛУ** *ф. к.* **кытыклау**. *Өметем – җанга кытык салырга өлгергән бу кызыйны күрү иде.* Ф.Яруллин

**КЫТЫКЧАН** *с.* Кытыгы бик тиз килә торган. *[Хәйретдин:] Мин бик кытыкчан шул.* Ш.Камал

**КЫТЫ-МЫТЫ** *җый. и. сөйл.* 1) Вак-төяк ашамлык, коры-сары. *Хәзергә кыты-мыты белән карын ялгап алгандай ит тә, кичкә берәр төрле таба ашы әзерләрмен...* М.Хәсәнов. *Бар чагында – бал да май, юк чагында – кыты да мыты.* Мәкаль

2) Зур мәҗлесләрдән яки гомумән ашаудан соң калган калдык-постык ашамлык. *Кунак җыйган көннәрдә безгә дә майлы бәлеш төпләре, кыты-мытылар күп эләгә.* Казан утлары

3) *диал.* Тормышны авырлык белән очын-очка ялгап алып бару турында; юклы-барлы хәл

◊ **Кыты-мыты итү** Вак сәүдә белән шөгыльләнү, алып сату белән шөгыльләнү. *Синнән яшерен-батырын түгел инде, апа, мин кала белән авыл арасында кыты-мыты итәргә керештем.* Т.Гыйззәт

**КЫТЫР** *и. сөйл.* Берәр әйбер өстендәге төерчек, кечкенә чыгынты. *Кофта өстендә кытырлар барлыкка килү*

**КЫТЫРДАТУ** *ф.* Берәр нәрсәне кырып, кимереп яки тырнап, кытыр-кытыр иткән тавыш чыгару. *Тәрәзә артында буран сызгыра, өй нигезенә терәлеп үскән тигәнәкме, нәрсә, буран белән селкенеп стенаны кытырдата.* М.Мәһдиев. *Исеме уйларыма ябышты, токмач кунасын кытырдатып кимергән сычкан шикелле, гел бимазалап, тыкырдатып тора башлады.* А.Гыйләҗев. *Өстенә тоз сибеп киптерелгән ипи телемнәре балаларга башта кытырдатып кимерергә кызык һәм тәмле тоелса да, ашаулары озакка бармады.* З.Фәйзи

**Кытырдата башлау** Кытырдатырга тотыну. *Атлары үлән кытырдата башлагач, [Дәүран] чирәмгә ятып, баш астына кулларын куйды да күк йөзенә бакты.* М.Хәбибуллин

**Кытырдатып алу** 1) Бераз гына кытырдату

2) *күч.* Аз гына берәр әйбер белән тамак ялгау

**Кытырдатып тору** 1) Бертуктаусыз кытырдату

2) *күч.* Һәрвакыт коры-сары ашау

**КЫТЫРДА́У** *ф.* **1.** Кытыр-кытыр килгән тавыш чыгару. *Күзне генә йомасың, караватка каршындагы комод тартмасында күсе кытырдый.* Г.Тукай. *Ул ничек итеп кизәнгәнен сизмәде дә, бары финкасының нииндидер бер тыгыз әйбергә кытырдап кереп батканын гына тойды.* Х.Камалов

**2. кытырдап** *рәв. мәгъ.* Артык көчле кычкырмыйча, артык шаркылдамыйча. *Сөйләшкән вакытта еш-еш уң күзен кыса, сүзе бетәр-бетмәс кытырдап көләргә тотына.* Ш.Әхмәдиев

**Кытырдап алу** Кыска гына вакыт аралыгында кытырдау

**Кытырдап кую** Өзек кенә кытыр-кытыр иткән тавыш чыгару

**Кытырдап тору** Берөзлексез кытырдау

**Кытырдый бирү** Бернигә дә карамый кытырдавын дәвам итү

**КЫТЫ́Р-КЫТЫР** *иярт.* 1) Нинди дә булса бер өслекне башка әйбер белән кырганда яисә берәр каты ашамлыкны кимергәндә яки чәйнәп ашаганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Әни табак-савыт шылтырата, кашык белән кытыр-кытыр нәрсәдер кыра.* Ф.Шәфигуллин. *Койма буенда кытыр-кытыр үлән чүпләп, Зөләйха апа янына бер ат килеп туктады.* Г.Мөхәммәтшин

2) Артык көчле кычкырмыйча, артык шаркылдамыйча көлгән тавышны белдерә. *– Белмим анысын: ыштаны эченә счётчик куеп булмый бит, – дип, кытыр-кытыр көлеп җибәрде Миңнехан абый.* Г.Сәгыйров

**КЫТЫРЛАНУ** *ф. сөйл.* Кытырлар барлыкка килү, кытыршылану. *Тәннәре ярылып беткән, кытырланган.* Н.Думави

**Кытырлана бару** Торган саен ныграк кытырлану

**Кытырлана бирү** Һаман да кытырлар барлыкка килү дәвам итү

**Кытырланып бетү** Тоташ, бик нык кытырлану

**Кытырланып калу** Нииндидер сәбәптән соң кытырланган хәлгә килү, кытырлар белән каплану

**Кытырланып тору** Урыны-урыны белән кытырлар барлыкка килү

**КЫТЫРЛЫ** *с. сөйл.* Кытырлары булган

**КЫТЫ́Р-МЫТЫР** *и.* Астыртын, дөрес булмаган эш; кыңгыр эш. *– Аның теге сестра белән кытыр-мытыры булды бит, – дип, Фролов Рувимның барча гөнаһларын санарга кереште.* Х.Камалов

**КЫТЫ́РТ-КЫТЫРТ** *иярт.* 1) *к.* **кытыр-кытыр**

2) Кайчы белән кискәндә чыккан тавышны белдерә. *Кытырт-кытырт иттереп кисте дә атты*

**КЫТЫРШЫ** *с.* **1.** 1) Яргаланган, кытыршыланган; шома булмаган. *Никитин эчкә батып кергән кытыршы яңакларын сыпырып куйды.* М.Галиев. *Ибрай аның кура җиләге кызылына буялган кытыршы учларына су агызып торды.* Ә.Гаффар. *Капшангалый торгач, Гайфулланың кытыршы куллары Зөһрәнең аякларына тиде.* Ф.Яруллин. *Әнисенең күзеннән туктаусыз яшь ага, үзе кытыршы куллары белән кызының чәченнән сыйпый иде.* Р.Хафизова

2) Төерчекле, кытырлы, кытырлары булган. *Гадәттә, болытлы көнне кар көртләре өстеннән җил шуышып уза, каршыга исә торганы булса, йөзгә кытыршы кар бөртекләре белән бәрә, уңайга искәне алга таба этә, адымнарны тизләтә...* Х.Ширмән. *Кыз чагында кичен яшьләр уенынннан кайткандагы кебек, койма өстеннән сузылган кытыршы яфраклары белән аның битен сыйпап калган шомырт агачлары тын гына аңа карап торалар.* Г.Бәширов. *Сыер, авыр гәүдәсен авыш-тәвеш китереп, тагын бер-ике адым алга таба атлады да үзенең кайнар, дымлы, чалгы янавыдай кытыршы ирене, теле белән Иргалинең сузылган кулына төртелде.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Нинди дә булса кимчелекләре булган. *Шәяхмәт үзенең кытыршы теле белән русча, вата-сындыра, Фәхринең язмышын сөйләп китте.* Г.Ибраһимов. *Тел ягыннан кытыршы җырлар очрыйлар.* М.Җәлил. *М.А.Таҗетдинов тәрҗемәләре исә беренчедән оригиналдан бик ераклар, икенчедән,*

*кытыршылар, өченчедән, шигъриятле түгелләр*. Р.Харис

**2.** *и. мәгъ.* Төерчек, кытыр. *Мәдинәнең уч эчендә бераз кытыршылар барлык сизелә һәм шушы кытыршылар аркылы Фәтхинең йөрәгенә ягымлы һәм матур мәгънәле җылылык агып торган төсле тоела.* Ш.Камал

**КЫТЫРШЫЛАНУ** *ф.* 1) Кытыршыга әйләнү, кытыршы хәлгә килү. *Салкын су белән юынсам, кулым кытыршылана*. М.Сәлим

2) *күч.* Сыйфаты, эчтәлеге, мәгънәсе бозылу, кимчелек килү

**Кытыршылана бару** Торган саен ныграк кытыршылану

**Кытыршылана төшү** Бераз кытыршылану

**Кытыршыланып бетү** Тәмам кытыршылану. *Хөсәен Җәгъфәрнең дә андый шигырьләре шактый, һәм һәркайсында ана образының бер ягы ачыла: --- кытыршыланып беткән куллары белән оныкларын иркәләүче әби, басу юлында карашын олы юлга төбәп басып торучы ана.* Н.Габдуллина

**Кытыршыланып калу** Нәрсәнең дә булса тәэсиреннән соң кытыршылану. --- *ватык тракторын бер сүтеп, бер җыеп изалана торгач, --- дегет сеңгән куллары рашпиль сыман бирчәеп, кытыршыланып калган.* Ф.Баттал

**Кытыршыланып китү** Тиз арада кытыршылану. *Аның күз алдында тавышы үзгәреп, ничектер кытыршыланып киткән иде.* З.Фәйзи

**Кытыршыланып тору** Әле хәзерге вакытта төрчекләре, кытырлары булу. *Ләкин аның [Гәрәй абзыйның] күңел төбе һаман эреп бетми, теле аңкавына ябышкандай кытыршыланып тора*. А.Вергазов

**КЫТЫРШЫЛА́У** *ф.* 1) Кытыршыга әйләндерү, кытыршы хәлгә китерү

2) *күч.* Сыйфатны, эчтәлекне, мәгънәне бозу, кимчелек китерү. *Ләкин бу тышкы шомалык, һичшиксез, мәгънәне кытыршылый*. Х.Туфан

**КЫТЫРШЫЛЫК** *и.* 1) Төерчекле, кытырлы булу. *Кытыршылык чыгынтылары янында өстәмә өермәләр хасил була, димәк, этемнең югалу һәм каршылык коэффициенты арта*. Гидравлика һәм гидравлик машиналар

2) *күч.* Беркадәр каршылык, аңлашылмаучылык. *Арада кытыршылыклар булгаласа да, матур гына яшәп ята идек.* З.Фәйзи. *Нәтиҗәдә үзара аңлашудагы кытыршылыклар бетәр.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Кимчелек, җитешсезлек. *Сәхифәләрне һич үзгәртмичә, кайбер тел кытыршылыкларын ипләштереп кенә теркәп узам.* А.Гыйләҗев. *Урыны белән ритмик төгәлсезлекләр, рифмакафия кытыршылыклары, тиешсез кулланылган сүз-гыйбарәләр күзгә ташлана*. Х.Миңнегулов. *Шунысын да әйтергә кирәк: тамашаның алып барылуында кытыршылыклар да булгалады.* Мәдәни җомга

**КЫХ** *иярт.* **1.** 1) Терлекне, кошкортны суйганда барлыкка килә торган тавышны белдерә

2) Җиңелчә ютәлләгәндә, көлгәндә һ.б.ш. вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Карт, бугазыннан кых дигән аваз чыгарып, карашын түбән төшерде.* А.Хәлим

**2.** *хәб.мәгъ.* 1) Сую, чалу мәгънәсен белдерә. – *Әти бер әтәчне кыхх!.. – диде Гали, бармагы белән муенына сызып.* Р.Төхфәтуллин

2) *күч.* Баш бетү, юкка чыгу, үлү. – *Уңнан китсәм, үземнең баш – кых. Сулдан китсәм, син, Кораңгыш, аяк сузасың*. Р.Батулла

**КЫ́Х ИТҮ** *ф.* 1) Балалар телендә кисү

2) Сую, чалу. *Сөекле оныгына икеле куйган өчен, ул --- кых итә.* Р.Хафизова

**КЫ́Х-КЫХ** *иярт.* Йөткергәндә, җиңелчә көлгәндә кыхылдаган тавышларны белдерә. *Сәрвәретдин, аяклары белән атының корсагына тибеп, кыхкых көләргә тотынды*. Г.Бәширов

**КЫХЫ́К-КЫХЫК** *иярт. к.* **кыхкых**. *Муса, тончыгып, кыхык-кыхык йөткерә башлады.* Ш.Маннур

**КЫХЫЛДА́У** *ф.* Кых-кых иткән тавышлар чыгару

**Кыхылдап алу** Бераз кыхылдау

**КЫХЫМ** *иярт. к.* **кыһым**. *[Гөлбану:] Эһем, кыхым! Кара син аны, нинди белмәмешкә салынган булып маташа бит.* Г.Камал

**КЫҺЫМ** *иярт.* Тамак кырган вакытта барлыкка килә торган тавышны белдерә. *Комга утырган баржалар су арткач урыныннан кузгалып киткән шикелле, Галиәкбәр агай да, битенә кояш төшеп кыздыра башлагач урыныннан кузгалып, ишегалдының икенче тарафында булган контор баскычына күләгәгә утырып, «Кыһым!» диеп, бер тамак кырды.* Ш.Мөхәммәдев

**КЫЧКЫРТУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **кычкыру** (*1–4 мәгъ.*). *[Десятник] Аннан соң әтәчне кычкыртып, сул канатындагы йоннарын берәм-берәм йолкып чыкты.* М.Гали

2) Махсус җайланма ярдәмендә авазлар чыгарып сигнал бирү. *Урман аша үтеп, бистә башына кергәндә генә, арттан машина кычкыртты.* Н.Гыйматдинова. *Моны сугыш узган җирләр дип әйткәннәр иде без килеп туктаганда. Паровоз кычкыртты. Тагын, тагын.* М.Мәһдиев. *Шулай ыгы-зыгы киләбез, ул арада күрше купеда баян тавышы ишетелде, сузып-сузып паровоз кычкыртты, моңланып елады.* М.Мәһдиев

3) Нинди дә булса инструментта уйнап, авазлар барлыкка китерү, авазлар чыгару. *Ә мин быргы кычкыртырга ярата идем.* М.Мәһдиев

4) *сөйл. кимс.* Оста уйный белмәгән килеш гармунда уйнау, начар уйнау, гармун шыңгырдату

**2. кычкыртып** *рәв. мәгъ.* 1) Махсус сигнал биреп. *Быргы кычкыртып, дружина сборын да җыярга өлгергәннәр.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Мәҗбүр итеп, көчләп. --- *һәр көн татар авылларына «штурмовые бригады» дип аталган җәза төркемнәре чыгып китә, халыкның соңгысын кычкыртып талау башлана.* Ф.Бәйрәмова. *Шәйдулла бөтен вагон халкын ноль урынына да күрмичә, кычкыртып, минем кулларны боргычлап (сумкасын идәнгә куеп торып), кесәгә өч тиен акча салды.* М.Мәһдиев

**Кычкырта башлау** Кычкыртырга тотыну

**Кычкырта бирү** Бернигә дә карамыйча, игътибар итмичә кычкыртуын дәвам итү

**Кычкырта килү** Электән үк, даими кычкырту

**Кычкырта төшү** Тагын да бераз кычкырту

**Кычкыртып алу** Бераз, кыска гына кычкырту. *Машина бер кычкыртып алды да салмак кына кузгалды.* Р.Батулла

**Кычкыртып бетерү** Кычкыртудан туктау. *Менә пароходчык кычкыртып бетерде, әнә басманы да ала башладылар.* Ф.Әмирхан

**Кычкыртып җибәрү** Кинәт кычкырта башлау. *Шулвакыт кыз каты иттереп быргы кычкыртып җибәрә дә, бөтен уеннар туктый, тавыш тына.* Әкият. *Завод торбаларының ачы итеп кычкыртып җибәрүенә икесе дә сискәнеп киттеләр.* Ф.Бәйрәмова

**Кычкыртып йөрү** Төрле урыннарда кычкырту. *Яңгырга шәбәреп, гармун кычкыртып йөрүдән башка ни кыра аласың?* А.Гыйләҗев

**Кычкыртып карау** Тавышының матурлыгын сынау өчен кычкырту. *Янында калган олырак малайларны кычкыртып карады.* Г.Бәширов. *Радик Мәрзия ападан тартынып кына гармунны алды һәм әкрен генә кычкыртып карады да кире Мансурга сузды.* Р.Бакиров

**Кычкыртып кую** Бер тапкыр кычкырту. *Пароход озак тормады: төшерәсе кешеләрен төшереп, утыртасыларын утыртып бетерде дә, «китте-е-ек!» дигәндәй, сузып кычкыртып куйды һәм тәгәрмәчләрен соргылт суга шапылдатып бәрә-бәрә китеп тә барды.* Г.Мөхәммәтшин

**Кычкыртып тору** Әле, хәзерге вакытта берөзлексез кычкырту. *Без утырасы поездның берничә вагоны инде тагылган, паровоз бер якта пош-пош килеп кычкыртып тора.* Г.Гомәр

**КЫЧКЫРТТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **кычкырту**

2) **кычкырттырып** *рәв. мәгъ. күч. к.* **кычкыртып**. *Сөннәтләргә кирәк булгач, кычкырттырып сөннәтләгәннәр.* Һ.Такташ

**КЫЧКЫРУ** I *ф.* 1) Бик көчле аваз чыгару, каты итеп тавыш бирү (кешеләр тур.). *«Ильяс, мине куып тот!» – дип кычкырасың.* Ф.Яруллин. *Без абый белән «һөст!», «төнчә!» дип кычкыра-кычкыра, ара-тирә сызгыргалап, чыбыркыларны шартлатып, көтүнең артыннан куып барабыз.* М.Гали. *Фамилияңне кычкыралар, атылып чыгып исемеңне, әтиең исемен, статьяңны, срогыңны әйтеп, коридорның икенче ягына барып кысыласың.* А.Гыйләҗев

2) Кошларның, хайваннарның аваз салуы. *--- сарыклар, борыннарын җиргә төртеп, үзләре бертуктаусыз бә-ә-әү дип кычкыра-кычкыра, кырт-кырт үлән йолкалар.* М.Гали. *--- ул [Җәүдәт] күке кычкырганны, урман күгәрченнәре гөрләгәнне ишеткәндәй була.* Г.Бәширов. *Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшыга килә.* Мәдәни җомга

3) *к.* **кычкырту** (*2 мәгъ.*). *Вокзал ягыннан батыр тавыш белән сузып-сузып паровоз кычкырган тавышлар ишетелә.* Ш.Камал

4) Көчле тавыш белән барысына да, бөтен тирә-якка ишетелерлек итеп әйтү яки сөйләү. *Салихов Бондаревага кычкырырга гына өлгерде: «Машина янына барып, безне көтеп торыгыз!»* Ф.Галиев. *Барыбыз да тезелеп беткәч, ул, тынын эчкә алып, күкрәген бераз күтәрә төшеп, башын артка ташлап кычкыра: – Слушай мою команду!* М.Мәһдиев. *Затлы кубанка, билле көрән тун кигән, алап иренле, дәү авызына ярты пот алтын сыйдырган берәү читлек рәшәткәсе аша тәмәкесенең хуш исен өреп: «Не горюй, папаша!» – дип кычкырды.* А.Гыйләҗев

5) Көчле яңгыравыклы тавыш белән кемне дә булса чакыру. *«Әни, әни! Әти!» Яр буендарак сайлыкта кызлары Лилия чупырдап ята, үзе көлә, әтиәнисенә кычкыра.* Ф.Галиев

6) Кемне дә булса тавыш күтәреп әрләү, җикеренү. *Кычкырырга беләсез, әөскә-башка ясарга белмисез, менә алъяпкычларым тузып беткән, кычкырганчы, бер алъяпкыч алып бир.* Г.Камал. *Горур халык баласы бит: үзенә кычкыру, кул күтәрүне кичерми.* Я.Зәнкиев. *– Ух, корт чаккыры! – дип кычкыра Габделфәрт абый, ачуына чыдаша алмыйча.* Мәдәни җомга. *Ләкин кайвакыт Сталин үз-үзен кулда тота алмыйча кызып китә, тупас сүзләр кычкыра, берәр кешегә кул күтәрергә дә күп сорап тормый.* Татарстан яшьләре

7) *сөйл.* Кем яки нәрсә турында булса да артык күп сөйләү, игътибарны җәлеп итү өчен чыгышлар ясау, артык күп шаулау. *Бу вакытта ул билгесез көчләргә, кануннарга каршы, шәхси иректе яклап кычкыра.* Г.Нигъмәти. *[Фазыл] --- да калышмаска тырыша бугай, әллә нинди оешмалар корып, --- съездларда кычкыра.* Г.Ибраһимов

◊ **Кычкырып тору** Күзгә бик нык бәрелү, ачык беленеп, аерылып, күренеп тору. *Шигырьләргә биргән бәясеннән авторның поэзияне аңлап җиткермәве кычкырып тора.* И.Нуруллин. *[Аяз:] Мин фәлән кеше булам дип үзеңне дәртләндереп, җилкендереп торган берәр төпле ниятең булса икән. Кычкырып торган бер омтылышың!* Г.Бәширов. *«Менә син минем кулда, теләсәм изәм, сытам», – дигән уе кычкырып тора.* Р.Мулланурова. *«Мин – Каһәгать абзый бакчасы!» – дип кычкырып тора.* А.Хәлим

**Кычкыра башлау** Кычкырырга тотыну. *--- җәй буе эшләгәненә нибары унөч сум акча алгач, Хәмит ачынып кычкыра башлый.* Р.Батулла

**Кычкыра бирү** Бернигә дә карамый кычкыруны дәвам итү. *Ләкин ничек кенә булмасын, Хәлил кереп өстен салырга да өлгермәде, бу кычкыра биреп әйтеп тә куйды.* Ә.Еники // Бераз көчлерәк тавыш белән сөйләү. *– Саумы, Акъәби? – диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп.* Ә.Еники

**Кычкыра тору** Озак кычкыру; күп тапкырлар кычкыру. *Шулай кычкыра торгач, Янтак ханның азатлары укоралларын ташлап әсир төшә башлыйлар.* М.Хәбибуллин

**Кычкыра төшү** Тагын да бераз кычкыру // Тавышын бераз көчәйтеп әйтү. *– Кабаланмагыз, – диде ул, бераз кычкыра төшеп. – Ачыграк аңлатыгыз... Мин язып барам.* М.Насыйбуллин

**Кычкырып җибәрү** Кинәт кычкыра башлау. *Егет башта танымады, кулын биргәндә танып, кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Шуңа күрә Мотаһир биек агачлар яныннан, ургып*

*аккан су буйлап сукмактан барганда, әледән-әле урман яңгыратып кычкырып җибәрә.* Р.Кәрами. *Латыйпов исә пистолетын тартып чыгарып алга ташланды: «Кем ул?» – дип кычкырып җибәрде.* М.Галиев. --- *газиз, кадерле, сөйкемле исне тагын бер кат күкрәге тулганчы, тыны җиткәнче иснәде дә, тун астында киерелеп, кычкырып җибәрде.* А.Хәлим

**Кычкырып йөрү** Теләсә кайсы урында, теләсә нәрсә әйтеп кычкыру. *Әтиләрне милиция алып киткәч, теге апа: «Күрсәттем күрмәгәннәрен, төрмәдә башлары череячәк», – дип, кычкырып йөргән.* Т.Миңнуллин

**Кычкырып калу** Кычкырырга өлгерү. *Тозлап-борычлап сүгенәсе, матур сынны авыр сүзләргә батырасы килсә дә, югалып калды. «Үкенерсең әле!» – дип кычкырып калудан узмады.* Т.Галиуллин

**Кычкырып карау** Ишеттерергә омтылып кычкыру. *Зиратка хәтле барып җиттем, койма буенда туктап кычкырып карыйм, Лёвка җавап бирми.* Ф.Галиев. *Курай-малай ары йөгерде, бире йөгерде. «Талсылу! Талсылу!» – дип кычкырып карады.* Р.Хафизова

**Кычкырып кую** Көтмәгәндә, кинәт, кыска гына кычкыру; бер тапкыр кычкыру. *Ханым егетнең бу бер генә сүзгә никадәр ачу-нәфрәт салып әйткәнлеген ачык сизде, әлбәттә, ләкин юри, гүя ныграк үртәргә теләгәндәй, балаларча кычкырып куйды.* Ә.Еники. *Кошлар сайрый, сирәк-сирәк кәккүк кычкырып куя.* А.Әхмәт. --- *чит-ят утарга кергән бәрәннәрнең ара-тирә кычкырып куюы гына ишетелеп кала.* Г.Гыйльманов

**Кычкырып тору** Бертуктаусыз кычкыру; даими кычкыру. *Һәр очрашкан саен, җаным: «Айгөлеңә хыянәт итәсең! Хыянәт... Хыянәт...» – дип кычкырып торды.* Ф.Яруллин // Һәрберсен бер-бер артлы кычкыру. *Корабтагы сөрән салучы баскычка баскан һәр кешенең исемен, титулын кычкырып торды.* М.Хәбибуллин

**КЫЧКЫРУ** II *и.* Каты тавыш, аваз. *Кулында винтовка булмагач, «власть, советлар» дип кычкырудан ни мәгънә чыга?* Ш.Камал. *Ләкин бу кычкыруларга берәү дә буйсынырга теләми, дөресе, монда да төнге атышларны ишетеп, аптырашта калган яралыларны буйсындырырлык, аларны бергә тупларлык көч юк, паника өстенлек алып бара.* А.Шамов. *Алар аны кычкыру дип саный: күпме катырак кычкырсаң, димәк, тавышың да шулкадәр моңлырак.* Татарстан яшьләре

**КЫЧКЫРЫК** *и. иск.* 1) Бүлепбүлеп әйтелгән яңгыравыклы тавыш, авазлар. *Төрле тавыштан гаҗәеп бер матур гөрелте чыга: әллә кайларда чылтырап аккан елга тавышлары, --- бишек тирбәткән көйләр, әллә кайда ишетелгән көтүче кычкырыклары.* Ш.Камал

2) Кошлардан чыккан өзек-өзек, кискен аваз. *Карга, саескан, күке кычкырыклары*

3) *лингв.* Сүз булып оешып җитмәгән авазлар; ымлыклар. *Кешеләр көчле әсәрләнү, тойгылану, көчәнү кебек хәлләрдә авызларыннан ирексез һәртөрле авазлар чыгаралар. Менә шушы тойгылы кычкырыклар, ымлыклар бара-бара мәгънәле сүзгә әйләнеп киткәннәр, телдәге сүзләр шуннан таралган дип карала.* Г.Алпаров

**КЫЧКЫРЫНУ** *ф.* 1) Үзалдына кычкыру, кычкыра-кычкыра сөйләү. *– Әйе, әйе, мин аның авызын кысып тоттым, кычкырырга ирек бирмәдем! – дип кычкырынды һаман Лачугин.* Ф.Галиев. *Вак-төяк нәрсәләр өчен дә кызып китәләр, бер-берләренә кычкырыналар, шулай итеп йөрәктәге әрнүләрен басарга тырышалар иде.* А.Шамов

2) Шаулау, каты аваз салу. --- *кызыл йөзле капитаннары, тагы да кызара төшеп, быргылар аркылы әллә нәрсәләр кычкырыналар.* Ф.Әмирхан. *Шул рәвешчә кычкырынгач туктады, Мендәрендә гырлый-гырлый йоклады.* Ш.Бабич

3) Кычкырып әрләү, каты тавыш белән тиргәү. *Мин килә башладым исә, «Таларга киләсең!» – дип кычкырынырга тотына.* Г.Камал. *– Кем машина астына керә шулай? – дип кычкырынырга тотынды.* Р.Мулланурова. *Әхмәтнең әйткәнен онытып, урыныннан торып, бик ямьсез тавыш белән кычкырынырга тотынды.* Ф.Әмирхан. *Я, хәзер ничек итеп сүгенергә, бәйләнергә, кычкырынырга кирәк?* А.Шамов

4) Өзек-өзек каты авазлар чыгару. *Ишек ярыгыннан сузылып торган кояш нуры, тупыллардагы кара каргаларның тынгысыз кычкырынулары, Ильясның нинди дер мәгънә турындагы урынсыз, аңлаешсыз сүзләре аларның аңын курку хисеннән арындырды.* Ә.Гаффар

**Кычкырына башлау** Кычкырынырга тотыну. *Мич артына аеруча дикъкать белән карый да бераз каушаулы, ашыгыч, каты тавыш белән кычкырына башлый.* Г.Ибраһимов

**Кычкырына бирү** Бернәрсәгә дә игътибар бирмичә кычкырынуын дәвам итү

**Кычкырына төшү** Бераз кычкырыну

**Кычкырынып алу** Беркадәр, бераз кычкырыну

**Кычкырынып бетерү** Кычкырынуны тәмамлау. *Бары кычкырынып бетергәч кенә ул Ләләгә: – Бу бүлмәдә Миңлесылу кодагый чәчләрен өртмичә ятып тора! – ди.* Ф.Әмирхан

**Кычкырынып йөрү** Әле, хәзерге вакытта, һәркемгә кычкырыну. *– Нәрсә, юләр төсле кычкырынып йөрисең? – диде.* Ш.Камал

**Кычкырынып китү** Нинди дә булса бер сәбәптән, вакыйгадан соң кычкыра башлау. *Һичкемгә аңлашылмаган бер телдә кычкырынып китте.* Г.Ибраһимов

**Кычкырынып тору** Бертуктаусыз кычкырыну. *Ләкин анда инде кешеләр стена шикелле булып тыгызланган иделәр, кондуктор вагон площадкасыннан кычкырынып тора иде: – Урын юк, иптәшләр! Вагон шыгрым тулы!* Ш.Камал

**КЫЧКЫРЫРЛЫК** *рәв.* Кычкыру дәрәҗәсенә җиткән, эченә сыймаслык. *Нурсөянең хәлләре бишбылтыр ук авыл уртасында басып кычкырырлык иде бит.* Н.Гыйматдинова. *– Дөрестән дә, былтыр кыстырганга быел кычкырырлык икән шул бу, – диде ул, бармагы кытыклануга чыдый алмыйча көлеп.* Ә.Гаффар

**КЫЧКЫРЫШ** *и.* 1) Кычкырып сөйләшкән тавышлар, кычкырган аваз-

лар; шау-шу. *Тугайны яңгыраткан кошлар концерты, шаян кычкырыш, шат кеше тавышлары күмде.* М.Әмир. *Бөтен цирк мәйданын ут чыккандагы кебек бер тоташ кычкырыш, йөгереш каплый.* Г.Ибраһимов. *Болар лабазга кергәндә, анда кычкырыш, шау-шу бара иде.* Ш.Камал. *Алгы якта кычкырыш, елаш: нәрсәдер әллә чатнаган, әллә җимерелгән.* Татарстан яшьләре

2) Кычкырып тиргәшү, кара-каршы кычкырып әрләшү, талаш. *Җыр, гауга, тавыш, кычкырыш белән бөтен мәдрәсә селкенгән минутта, идарәнең ишеге ачыла да көтмәгән кеше – Кадыйр бай үзе килеп чыга.* Г.Ибраһимов. *Банк сугучылар һәм, зуррак банкларны сугып, уенны ташлап китүчеләр арасында кычкырышлар да булып алды.* М.Гали. *[Себер бае:] Әллә сез шәһәрегездә талаш, кычкырыш, җәнҗал белән генә тамак туйдырасызмы?* Г.Камал

**КЫЧКЫРЫШ-ТАЛАШ** *җый. и.* Һәртөрле тиргәшү, әрләшү, талаш. *Кычкырыш-талаш китте. [Пьесада] Җәдитчеләр тарафыннан оештырылган клуб күренешендә дә иң зур культура эше булып лото, домино уйнау күрсәтелә. Ул да зур кычкырыш-талаш һәм тәртипсезлекләр белән бара.* М.Гали

**КЫЧКЫРЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **кычкыру** (*1, 3 мәгъ.*). *Тәкәрлекләр ачыргаланып кычкырышты.* Ә.Гаффар. *Әтиләргә «ура» кычкырышып, Мин ятканмын ул чак биләүдә.* З.Мансур. *Биеклектә почмак булып, кычкырышып – торналар, каңгылдашып, кыр казлары ашыга-ашыга очып үтә.* Мәдәни җомга

2) Үзара кычкырып талашу, тиргәшү. *Эшсезләр колакны тондырырлык итеп кычкырышалар, һәркайсы этәтөртә эчкә кермәкче була.* И.Нуруллин. *Эшне бергә эшлибез, урамга чыгып кычкырышмыйбыз.* Татарстан яшьләре

**Кычкырыша башлау** Кычкырышырга тотыну. *Без беркадәр вакыт берберебезгә бирешми азаплангач, арттан: – Аерып кушарга кирәк, аерып! – дип кычкырыша башладылар.* М.Гали

**Кычкырыша бирү** Бернигә дә карамый кычкырышуны дәвам итү

**Кычкырышып алу** Кыска гына вакыт арасында бераз кычкырышу. *Идрисов аңа яңа гына туган обстановканы аңлатырга кирәште. Бераз кычкырышып алдылар.* Х.Камалов. *Алар [әрмәннәр] үзара тиз-тиз нидер сөйләшә башладылар. Ара-тирә кычкырышып алалар, кулларын бутыйлар. Талашалармы, ярашалармы, Алла белсен.* Р.Зәйдула

**Кычкырышып бетү** Үзара талаш кубару, кычкырышу дәрәҗәсенә җитү. *Андыйлар бер көнлек походка чыккач та иптәшләре белән талашып, кычкырышып бетәләр.* А.Хәсәнов. *Катяны тартып йөртер өчен кычкырышып бетәләр.* Г.Афзал

**Кычкырышып йөрү** Гел, бертуктаусыз кычкырышу, төрлесе-төрле яктан кычкырышу. *Әле кайчан гына сарык, кәҗә бәкәйләре өебездә кычкырышып йөриләр иде.* Ф.Яруллин. --- *кичке якта өере-өере белән каргалар кычкырышып йөрде.* М.Мәһдиев // Һәрберсе белән дә кычкырышу

**Кычкырышып китү** Нинди дер сәбәп белән кинәт кычкырыша башлау. *Икенчесе әйтте: «Мин Аллаһтан сорыймын, синең куйларыңны килеп бүре ашаса иде», – диде. Болар бик кычкырышып киттеләр.* К.Насыйри

**Кычкырышып тору** Даими, һәрвакыт кычкырышу. *Иренең сүзенә асла колак салмас иде. Һәрни хосуста ире белән кычкырышып торыр иде.* К.Насыйри

**КЫЧУ** I *и.* Тән тиресенә кычу бете үтеп керүдән барлыкка килгән, бик нык кычыттыра торган йогышлы авыру; *русчасы:* **чесотка**. *Кычудан үлмиләр, тик рәхәт тә күрмиләр.* Мәкаль

**КЫЧУ** II *ф. диал. к.* **кычыту**. *Эшсезнең кулы кычыр.* Мәкаль

**КЫЧУЛА́У** *ф.* Кычу авыруы йогып, тән вак кына сулы төекчекләр белән каплану

**Кычулап алу** Бераз, берникадәр кычулау

**Кычулап бетү** Тоташ кычу басу

**КЫЧУ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Төкчәлеләр семьялыгыннан, чәчәге мамык сыман төк бирә торган, чәнечкеле озын сабаклы үләнчел үсемлек; *русчасы:* **ворсянка**. *Өермә үләне, ачык сары кычу үләне һ.б. төрләр өстәмә исемлеккә кертелде.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КЫЧЫНУ** *ф. сөйл.* 1) Тән кычыту. *Синең үзеңне кыргычларга кирәк башта, бүтән кычынмаслык итеп...* Р.Мулланурова

2) *күч. гади с.* Нәрсә дә булса эшләргә бик нык теләү, омтылу. *Мин кычынмасам да, гөнаһ шомлыгына каршы, барган булдым инде.* Ш.Камал

**Кычына башлау** Кычынырга тотыну

**Кычына бирү** Кычынуын дәвам итү

**Кычынып алу** Бераз, кыска вакытлы кычыну

**Кычынып йөрү** Гел, бертуктаусыз кычыну. *Бу көннән соң озак вакыт авыртынып, кычынып йөрдем.* Я.Шәфыйков. *– Бездә мулла булу өчен кычынып йөрүчеләр бар, – диде ул һәм әлеге кама бүрекле, кәҗә сакаллы мөтәвәллигә карап алды.* А.Шамов. *Нәкъ әнә шул җинаятьчел документ – шаһитларны роман канвасына керткән өчен кемнәрнеңдер кычынып йөрүен дә сизеп алды ул.* Ф.Сафин

**Кычынып китү** Кинәттән кычына башлау

**Кычынып кую** Көтмәгәндә, аз гына кычынып алу

**Кычынып тору** Бертуктаусыз кычыну // Әле хәзерге вакытта кемнедер якларга, араларга омтылу, яклап ни дә булса эшләргә, әйтергә омтылу. *[Гыйсми:] Мулла налогын түләргә кычынып торасыз... Әйтерсең үзенең хәле җитми аның.* А.Шамов

**КЫЧЫТКАН** *и.* Кычытканчалар семьялыгыннан, сабагында һәм яфракларында тәнне чага торган төкләре булган, яфраклары витаминга бай бер яки күпьеллык үләнчел үсемлек. *Әле киртә буйларында ашка салырлык кычыткан өлгермәгән иде...* М.Мәһдиев. *Ярыша-ярыша, кузгалак, кычыткан, кыр какысы җыярга тотындылар.* Р.Мулланурова. *Ул да шунда гына иде: мунча баскычына утырган да каз, үрдәк бәпкәләренә дип, тәпке белән әрекмән яфраклары, кычыткан чабып тураклый.* Ә.Гаффар

◊ **Кычыткан себеркесе белән чабу** Җиңелчә җәза бирү. **Кычыткан тел**

Бик усал телле, зәһәр кеше. *Каһәр суккан кызлар кычыткан телле булалар бит.* И.Салахов

**КЫЧЫТКА́Н БИЗГӘГЕ** *и. мед.* Тәңгә кычыткан чакканга охшаган чабырткылар чыга торган, кычыткылары булган авыру; бүре уы; *русчасы:* **аллергия**

**КЫЧЫТКАН ГӨЛ** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, яфраклары кычыткан яфрагына охшаган, вак чәчәкләре зәңгәр яки аксыл шәмәхә төсендәге бүлмә гөле; әдрәс гөл; *русчасы:* **колеус**

**КЫЧЫТКА́Н ЕФӘГЕ** *и. бот.* Кычытканчалар семьялыгыннан, кычыткан сабагына уралып үсә һәм аннан тукландыргыч матдәләр суыра торган яфраксыз һәм тамырсыз паразит үсемлек

**КЫЧЫТКА́Н КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Нимфалидалар семьялыгыннан, күкәйләрен кычытканга сала торган чуар күбәләк

**КЫЧЫТКА́Н КЫНАСЫ** *и. бот. к.* **кычыткан ефәге**

**КЫЧЫТКАНЛЫК** *и.* Кычытканнар күпләп үскән урын. *Озак сәүдәләшмәдек, мин, читән аркылы төшеп, кычытканлыкта ятарга булдым, ә иптәшләрем, уйнаган булып, тавыкларны минем янга куып китермәк булдылар.* Ә.Айдар

**КЫЧЫТКАНЧАЛАР** *и. бот.* Яфраклары каршыдаш урнашкан һәм чаккыч төкчәләр белән капланган туры озын сабаклы үсемлекләр семьялыгы

**КЫЧЫТКА́Н ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* 1) Чыпчыклар отрядыннан, урманда яши һәм кычыткан орлыклары белән туклана торган соры көрән төстәге кечкенә сайрар кош. *Сандугач, кычыткан чыпчыклары сайраган, тартай тавышлары ишетелеп торган таң манзараларының җанга кинәнеп туймаслык рәхәтлек бирүен әйтеп торасы да юк.* З.Фәйзи

2) *күч. сөйл.* Теләсә нинди сүзгә, эшкә катнашырга яратучы, тиктормас кеше. *Ах сине, кычыткан чыпчыгы!* Г.Бәширов. *Юкка гына кычыткан чыпчыгына шоколадымны ашаттым.* Т.Гыйззәт

**КЫЧЫТКЫ** *и.* 1) Кычыттырып, чабырып чыккан кабырчык. *Кычыткан җирдән кул китмәс, кычыткы җирдән сүз китмәс.* Мәкаль

2) *сөйл. к.* **кычу** I

**КЫЧЫТТЫРУ** *ф.* 1) Кычыту барлыкка китерү, тәнне кымырҗыту. *Ана суалчан арт юл ачыклыгыннан тышка чыга һәм, кычыттырып, тирегә күкәйләрен сала.* Биология

2) *күч.* Төрттереп, кимчелекләргә басым ясап сөйләү. *Мәрфуга иренең шулай авырткан төшне кычыттырып сөйләшүенә күнегеп беткән инде.* М.Шаһимәрдәнов

**Кычыттыра башлау** Кычыттырырга тотыну

**Кычыттырып алу** Бераз гына кычыттыру

**Кычыттырып йөрү** *күч.* Юкны бар итү, кирәкмәгән эш эшләү. *[Заһидә апа] – Үлмәгән! Тегеләр ... кычыттырып йөри, – диде Рузия. – Кыстыбый белән рәхәтләнеп чәй эчте. Тегеләр икәнен белеп, юри дәшми, аларга ачмый ул.* Р.Батулла

**Кычыттырып кую** Кинәт кенә кычыттыру

**Кычыттырып тору** Бертуктаусыз кычыттыру // Берәр сүзне әйтергә әзер булу. *Кожевниковның телен кычыттырып торган сүз төптәрәк ята.* М.Вәли-Барҗылы

**КЫЧЫТУ** *ф.* 1) Тәнне кашыйсы килү халәтен тою, тән тынычсызлану. *Кычытса аркагыз – без басарбыз, Муеныгыз кычытса – без асарбыз!* Г.Камал. *Яңагындагы җәрәхәт күңелен борчымый, бәлки әрнеп кычыта гына иде.* Ш.Камал. *Яраланган аягының бармаклары өзелеп-өзелеп, сулкылдап-сулкылдап кычыта иде.* Җ.Дәрзаман

2) Тамак төбе кымырҗу, кымырҗыту. *Бервакыт тамак төбем кычытып йөткерәсем килде.* Ф.Кәрим

3) Карын ачу, ашыйсы килү. *Умарта кортлары кебек өерелеп, бу баскычта кеше кайнап тора иде – ипи аз, тамак кычыта.* Р.Харис

4) *күч. сөйл.* Нәрсә дә булса эшлисе яки кирәк-кирәкмәгән урында кешеләр сүзенә кушыласы килеп тору. *– Телең кычытса, хатыныңнан мунча яктырып, кычыткан минек белән чабарга кирәк, – диде.* Ш.Камал. *Кычкырып сөйләргә тел кычыта да, килешеп бетмәс шул, килешеп бетмәс.* Ф.Сафин. *Берәр әйбер ватмаса я төзәтмәсә, күрәсең, аның кулы кычыта.* Р.Мулланурова

◊ **Кычытмаган җирне кашу** Кирәкмәгән эш белән шөгыльләнү; урынсыз сүз сөйләү. *Әй дорфа да инде син, Гыймран. Кычытмаган җиреңне кашыма, зинһар!* Н.Гыйматдинова

**Кычыта башлау**. Кычытырга тотыну. *Рәшит түзмәде, Низамыйга карап: – Кая, нигә китермисез балыгызны? – диде. – Тамак кычыта башлады.* Н.Фәттах. *Әлеге дарудан соң хатынның бөтен тәне кычыта башлаган һәм ачык кызыл төстәге таплар белән капланган.* Мәдәни җомга

**Кычытып алу** Аз-аз, вакыт-вакыт кычыту тою. *Тик йоклаган вакытта [аяксыз] аяк бармаклары сызлый, шайтан сөяге янында кычытып ала иде.* М.Мәһдиев

**Кычытып йөрү** Күптәннән, әллә кайчаннан кычыту. *Аңарга яхшылык эшлисебез килеп кулларыбыз кычытып йөри.* Ф.Яруллин

**Кычытып китү** Кинәт кычыту. *Дус, әллә нишләп аркам кычытып китте, борча кердеме дим, һич чыдап булмый бит.* Т.Гыйззәт. *Аптыраган Рудольф, ниһаять, хәйлә кулланып карарга булды: – Нишләптер, борын очым кычытып китте бит әле, Владимир Дмитриевич.* Р.Вәли

**Кычытып кую** Кинәт кенә бераз вакыт кычыту тою. *Кайвакыт мәнә шушындый бәйләнчекләргә карата тел кычытып куйса да, түзәм, дәшмим.* М.Әмир. *Сарык ите казанда гөбергөбер кайный башлады, учак янына урнашкан кешеләргә тәмле ит исе килеп җитте, ашказанын җилкендереп, тамак кычытып куйды.* М.Хәбибуллин

**Кычытып тору** Бертуктаусыз кычыту. *Минем куллар кычытып тора әле.* Г.Әпсәләмов. *Кадыйрның «үрәткәләргә, төзәткәләргә» бер дә кулы кычытып тормый иде...* Ф.Яруллин

**КЫШ** *и.* 1) Ел фасылларының берсе, көз белән яз арасы, елның иң салкын вакыты. *Әмма хәзер бик артык ютәлләмичә бер кышны русча укып чыгарга кирәк.* Г.Ибраһимов. *Кышның яңа*

*яуган ап-ак карларын күңел сафлыгың итеп күз алдына китерәм.* Ф.Яруллин. *Көз җитте, салкынайтты, кыш якынлаша, ә мин әрекмәнне тагын чыгып чаптым.* Т.Миңнуллин

2) Кышкы салкын, суык. *Минем хәтеремдә: тышта шыкырдап торган каһәрле кыш иде.* Ш.Камал. *Кыш бетте дип тун сатма, янә кыш бар.* Әйтем. *Әче җилләр белән шаярган кыш юашлана төште.* А.Гыйләҗев. *[Боровинка] Кышка бик чыдамлы һәм авыруларга каршы түземле, ләкин алмалары еш кына кутырлыйлар.* Җиләк-җимеш

◊ **Кыш бавыры** Кыш вакыты. *Кыш бавыры бик озын.* Әйтем. **Кыш көне кар бирмәс** Саран. **Кышның корсагы зур (киң)** Кышын салкыннар җиткәч, ягулыкка, азык-төлеккә, кирәк-яракка ихтыяҗның зур булуына ишарә. *Кышның корсагы зур... Утыз ике җитезне киштәдә тотып булмас.* А.Гыйләҗев. *Кышның корсагы уйлаганнан да зуррак икән. Ә алда – кара яз.* Ә.Баян

**КЫ́Ш БАБАЙ** *и.* Кышның, кышкы суыкның символы; җылы тун һәм бүрек кигән, ап-ак сакаллы һәм мыеклы карт рәвешендәге фантастик зат. *Быелгы чыршы бәйрәмендә дә Кыш бабай безгә бүләкләр өләште.* Татарстан яшьләре. *Кичәне Кыш бабай ачты.* Р.Хафизова

**КЫШКЫ** *с.* 1) Кыш көнендә була торган, кышка караган, кышка бәйләнешле. *Биек-биек коймалар, кышкы карда куян эзе сыман чигелгән чәнечкеле тимерчыбык киртә-аулары...* А.Гыйләҗев. *Тәрәзә башларында сыерчык ояларының кышкы хуҗалары – чыпчыклар чыркылдаша.* Р.Хафизова. *Урман инде кышкы кардан арынып беткән диярлек.* Ф.Яруллин

2) Җимеше соң өлгерә һәм озак вакыт бозылмый саклана ала торган. *Алмалары озак вакыт саклау өчен яраклы кышкы сортлар: антоновка, әнис, пепин, славянка.* Җиләк-җимеш

3) Кыш өчен билгеләнгән, кыш көне кулланыла, файдаланыла торган. *Кышкы бишмәтемне бер калай кружка солы ярмасына алыштырдым.* А.Гыйләҗев

**КЫШКЫЛЫК** *с. сөйл. к.* **кышлык**. --- *кем капчык асып, кем уфалла арбасы тартып, көтү йөргән җирләрдән кышкылык кизәк җыеп алып кайтты.* Н.Әхмәдиев

**КЫШКЫЛЫККА** *рәв. сөйл. к.* **кышлыкка**. *Алар чиләк-чиләк шомырт җыеп, яртысын базарда сата, яртысын киптереп-төеп, иләктән иләп, кышкылыкка саклый иде.* Н.Гыйматдинова. *Иртә таңнан эшкә – урманга, кышкылыкка утын әзерләргә чыгып китәләр.* Г.Гыйльманов. *Кышкылыкка салам белән тышланган тәрәзәгә бактылар.* Р.Батулла

**КЫШКЫЛЫКТА** *рәв. сөйл. к.* **кышлыкта**. *Кышкылыкта, беләсезме, нинди мәрәкә булды?! Филшерның миче җимерелде.* Г.Бәширов

**КЫШКЫ́ЧА** *рәв.* Кыш көнендәгечә, кыш өчен билгеләнгәнчә. *Урам ягына караган асфальт тигезлегендәге тәрәзә төбенә җәен дә кышкыча киенгән әби баскан.* Ш.Галиев

**КЫШКЫ ЧЕЛЛӘ** *и.* Кышын була торган иң салкын көннәр. *Туган җирем, кышкы чилләләрдә Ыжгырганда синең җил-карың.* Ш.Маннур. *Әмма боларның тәэсире кышкы челләнекеннән дә яманрак.* Г.Ибраһимов. *Ә бу хәл үзе кышкы челләдә булган.* Г.Ибраһимов

**КЫШЛАВЫК** *и.* Кышлый торган урын; кыш яши алырлык җылы өй. *Ике уртадагы авылларның кайбер башлыкларына кыйммәтле мылтыклар бүләк итте, берсенә, кышлавыкка кайткач бирергә дип, үзе яратып менгән аргамакларның берәвен вәгъдә кылды.* Г.Ибраһимов

**КЫШЛАК** *и.* Урта Азиядәге авыл, яшәү урыны. --- *дүрт-биш мең метр биеклектәге тауларга менеп, кышлаклардан кышлакларга ут бирде.* А.Хәлим. *Анда нindидер бер кышлак рәисе, акча төртеп, язулар ясаткан булган.* А.Алиш. *Шул биек тауларның нәкъ итәгендә борынгы бер кышлакның балчык өендә булган.* Д.Аппакова

**КЫШЛА́У** I *ф.* Кышны үткәрү, уздыру, кыш чыгу. --- *анда ел саен ике-өч пар үрдәк кыш кышлый иде.* Н.Гыйматдинова. *Кыш кышладык, җәй җәйләдек; Кәфенебезне муенга бәйләдек. Залимнәр белән сугышыр өчен, Без сезне Думага сайладык.* Ш.Мөхәммәдев. --- *солдатлар һәм түбән дәрәҗәле командирлар салкын, юеш окопларда, блиндажларда, землянкаларда һәм палаткаларда кышладылар.* М.Гали. *Салкыннар килгәч тә җылы якларга очмаган, шул ояда кышлаган ул чыпчык.* А.Алиш

**КЫШЛА́У** II *и.* Кышын яши торган урын; кечерәк кенә авыл. *Бик артык каты буран көннәрдә генә болар тибенүдән кышлауның тар, тыгыз ышыкларына кайтып сыгыналар.* Г.Ибраһимов. *Халыкның кышлаудан чыккан чагы, кайда яшел үлән күрсә, шунда барып ябырылырга әзер тора.* К.Кәримов. *Кораллы аучылар булганын белә торып, урмандагы кышлау йортлары янына килә, ит урларга маташа.* Кызыклар дөньясында

**КЫШЛА́У** III *с.* 1) Туганнан соң бер кыш кышлаган (терлек тур.). *Безнең кышлау тәкәне кертмибез. Әниләр күрмәгәндә, чыбык белән сыптырып, югары очка куып җибәрәбез.* Г.Мөхәммәтшин. *Республиканың иң атаклы ветеринария врачлары сәламәтлеген кат-кат тикшергәннән соң, аерып куелган кышлау печкән үгез белән сөттән бүтән ризыкны татып карамаган яшь бозауга да берәр врач, икешәр карауч беркетелде.* А.Гыйләҗев. *Аның ике сыеры, бер кышлау үгезе, сигез сарыгы, тагын әллә никадәр мал-туары бар.* Ф.Яхин

2) Бал кортларын кыш чыгару өчен көйләнгән. *Җитәрлек санда умарталар булдырган, склад, кышлау урын, умартачы йорты төзегән.* Татар балы

**КЫШЛА́У ӨЕ** *и.* Кыш көне умарталарны куяр өчен ясалган өй; *русчасы:* **омшаник**. *Умарталарның кышлау өендә термометр, психрометр кебек приборлар булырга тиеш.* Ф.Яруллин. *Әгәр кышлау өендә салкын һәм тынчу булса, кортлар катырак гөжлиләр.* Җиләк-җимеш

**КЫШЛАУ УМАРТА** *и.* Бал кортларын кыш чыгару өчен көйләнгән умарта. *Берзаман камера ишегеннән кышлау умарта сыман юантык, алагаем дәүдәү йодрыклы, чуен муенлы, ияк асларын, яңакларын куе төк баскан берәүне китереп керттеләр.* А.Гыйләҗев

**КЫШЛЫЙ** *рәв. сөйл. к.* **кышын**. *– Тегеләр кышлый яфракларын коялар, ә чыршы кышын-җәен бакчаны җилдән ышыклап торачак, – диде ул.* И.Гази

**КЫШЛЫК** *с.* **1.** Кыш аенда кулланыла, файдаланыла торган, кыш өчен билгеләнгән; кыш чыгарга җитәрлек. *Хәтта тиеннәр дә, ата-бабаларыннан килгән шартлы рефлексны бозып, кышлык хәзинәләренә өлгереп җитмәгән чикләвек җыя хәзер.* К.Кәримов. *Әнә ул кортлар инде, уракчыларны сыйларга дип, ашыгып-ашыгып бал ташып йөриләр, алар хәзер инде үзләренә кышлык запас әзерләделәр.* М.Гали. *Монда үсә безгә ашлык, мондадыр кышлык азык.* М.Гафури

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* 1) Кыш сезоны, кыш вакыты. *Алар җәен үз авылларына кайтып иген иккәннәр, кышын янә шахтыга килгәннәр. --- Ягъни кышлык эшчеләре.* Ә.Галиев. *Шул ук вакытта Әхмәт үзенең семьясы белән һәм дә Каюмның хатыны ике баласы белән кышлык өчен шәһәргә күчеп киткән иделәр.* Ш.Камал

2) Кыш чыгарга җитәрлек азык. *Җылы көн, кулда форсат бар вакыт кышлык әзерлиләр.* М.Гафури

◊ **Кышлыгы юк** Кыш көне туңучан, тиз өши торган кеше

**КЫШЛЫККА** *рәв.* Кышны уздыру өчен, кыш чыгу өчен. *Шулай итеп, кышлыкка шактый гына печән дә әзерлим.* З.Фәйзи. *Алда печән өсте тора, кышлыкка утын, ташкүмер тупларга кирәк – ул эчемлеккә зәмзәм суыдай табыныр чак якынлаша.* Ә.Гаффар. *Өлгергән җиләк-җимешне кышлыкка әзерләп куярга кирәк.* Безнең гәҗит

**КЫШЛЫКЛЫ** *с.* Кышка чыдам, кыш салкынына түзә торган. *Кышлыклы алмагач*

**КЫШЛЫКТА** *рәв.* Кыш көне, кыш вакытында. *Атларны безгә кышлыкта, яз көне яхшылап карарга иде.* Т.Гыйззәт *Райпотребсоюзга, сельпога товар ташучылар кышлыкта бу араны ике көн йөриләр иде.* А.Хәсәнов

**КЫШЛЫКСЫЗ** *с.* Кышкы салкынга түзми торган, туңучан. *Эшлексез кеше кышлыксыз.* Мәкаль. *Җылыга иyләшмәгез, кышлыксыз булырсыз, дип кисәтәсе килә.* Ш.Галиев

**КЫШЛЫКСЫЗЛАНУ** *ф. сөйл.* Суык көннәрне (кышны) авыр үткәрә торганга әйләнү, салкынга түзмәү. *Әйдә, урам күрик. Өйдә ятып кышлыксызлануың бар.* М.Хәсәнов

**Кышлыксызлана бару** Еллар үткән саен кышны авыр үткәрә торганга әйләнү

**Кышлыксызланып калу** Ниндидер авырудан яки башка сәбәпләрдән тиз туңучанга әйләнү

**Кышлыксызланып китү** Кинәт кышлыксызлану

**КЫШТЫР** *с. к.* **кыптыр**. *Майлы бүркем минем, кыштыр туным, Чабатаның шәбе – яңасы...* Р.Назаров

**КЫШТЫРДАВЫК** *с. к.* **кыштырдавыклы**. *Ул күз кырые белән генә подноска төргәге-төргәге белән очкан яшел долларларны күрде, кыштырдавык кәгазь өеме арткан саен, эчендәге җанвар да куәтләнде...* Р.Мулланурова

**КЫШТЫРДАВЫКЛЫ** *с.* Кыштыр-кыштыр килеп торган. *Ялтырап торган кыштырдавыклы каты кәгазьгә йомшак кына тел белән --- Зиннәтне, кызганычка каршы, музыка мәктәбенә кабул итә алмаулары турында язганнар иде.* Г.Бәширов

**КЫШТЫРДАТУ** *ф.* 1) Коры, юка әйберне кузгатып, кыштыр-кыштыр иткән тавыш чыгару. *Кәгазьне тагын да шәфкатьсезрәк кыштырдатырга кереште.* Ш.Камал. *Ул [җил] куакларның шәрә ботагында сызгыра, коры яфракларны кыштырдатып үзәнгә куа, агач башларын атындыра иде.* Г.Гобәй. *Аның янында сипкел төшкән озынча битле, саргылт чәчле укытучы Гөлзәбәр каләмен тиз-тиз кыштырдатып беркетмә яза.* Г.Бәширов

2) Ни булса да язу. *Улым, ташла син бу кәгазь кыштырдатуыңны!* А.Гыйләҗев

3) Язучылык, иҗат эше белән шөгыльләнү. *Ялгызлыктан, подвал суыгыннан, күселәрдән һәм куркыныч ыржаеп торган киләчәктән гаҗиз бичара шагыйрь минем университет студенты икәнлегемне, әз-мәз кәгазь кыштырдатуымны да белгәч, чиксез куанды.* А.Гыйләҗев

4) *к.* **кытырдату**

**Кыштырдата башлау** Кыштырдатырга тотыну. *--- аксыл-зәңгәр чаршау кырыеннан кече якка керер китте дә, сөйләнә-сөйләнә, нидер кыштырдата башлады.* Г.Бәширов

**Кыштырдата бирү** Кыштырдатуын дәвам итү

**Кыштырдата төшү** Бераз кыштырдату

**Кыштырдатып алу** Кыска гына вакыт кыштырдату. *Ягымлы җылымса җил битләрне, чәчләрне иркәли, көздән коелмый калган яфракларны кыштырдатып ала.* З.Фәйзи

**Кыштырдатып йөрү** Бертуктаусыз кыштырдату

**Кыштырдатып кую** Көтмәгәндә, кинәт, азга гына кыштырдату. *Наҗия вакыт-вакыт кулындагы кәгазь кисәген кыштырдатып куя.* К.Тимбикова. *Бары тик елгага буйсынмас, йокы белмәс шаян җил генә яр буе камышларын кыштырдатып куя.* Р.Мирхәйдәров

**Кыштырдатып тору** Бертуктаусыз, өзлексез кыштырдату. *Печән кыштырдатып торган атлар да дөр итеп сискәнешеп, кайберләре сикереп үк киттеләр.* Ш.Камал

**Кыштырдатып яту** Әле, хәзерге вакытта әкрен генә кыштырдату. *Мин бабайның чабатасын тезеп утырам, кырыкмыш яткан җиреннән печән кыштырдатып ята.* М.Гали

**КЫШТЫРДА́У** *ф.* 1) Кәгазь, печән, салам кебек әйберләргә кагылганда, өзек-өзек җиңелчә тавыш барлыкка килү, кыштыр-кыштыр килгән тавыш чыгу. *Койманың теге ягында нәрсәдер кыштырдый иде.* Н.Гыйматдинова. *Бакчада инде агачлар саргая башлаган, аяк астында коелган яфраклар кыштырдый.* Р.Хафизова. *Шунда мич торбасы артында нидер кыштырдады, кинәт кенә чинап ниндидер шәүлә атылып чыкты.* М.Галиев

2) *куч. сөйл.* Әкрен генә, ашыкмыйча берәр эш эшләп йөрү. *Шәрига йорт тирәсендә кыштырдап көн үткәрә.* Ф.Латыйфи. *Госман абый озак кыштырдаганнан соң, музыканың шәбен тапты.* Мәдәни җомга

◊ **Кыштырдап торган** 1) Яңа, тауушалмаган (кәгазь, акча һ.б.); 2) Әлегә

билгеле булмаган. *Менә кыштырдап торган тавышлары белән «Айфара» егетләре килеп чыкты эфирга.* Мәдәни җомга. **Кыштырдый торган** Акча. *Дәрт бар, дәрман юк дигән шикелле, хәзер ул теләк дигән нәрсәдән бигрәк кыштырдый торганы кирәк. Алдан акча йөри торган замана бит хәзер!* А.Сафиуллин

**Кыштырдап алу** Тиз, кыска гына вакыт эчендә кыштырдау. *Агачтан төшкән яфрак кыштырдап алса да йөрәге дерт итеп, буыннары калтырап куйды Гамирның.* З.Фәйзуллин

**Кыштырдап йөрү** Әле, хәзерге вакытта бертуктаусыз кыштырдау. *Аның кухня ягында кыштырдап йөрүен, анда-санда савыт-саба шалтыратып куюын ул беркавым тын гына тыңлап ятты.* Л.Гыймадиева

**Кыштырдап кую** Азга гына бер тапкыр кыштырдау. *Ул гына да түгел, ботак-яфрак тагын берничә җирдә кыштырдап куйды.* И.Хуҗин. *Яр читендә сылу камышлар. Рәхим итегез, гүзәл илнең бәхетле балалары, дигән кебек кыштырдап куялар.* Л.Ихсанова

**Кыштырдап тору** Даими, бертуктаусыз кыштырдау. *Ләкин салкын су урынына куш учына кыштырдап торган ком гына эләкте.* Ә.Гаффар. --- *һәр йортның стеналарына эленгән түгәрәк эшләпә сыман радио дигән «тәлинкәләр» эчләренә таракан кергән кебек кыштырдап тордылар да кинәт җыр сузып җибәрделәр.* Г.Галиев

**Кыштырдап утыру** Әле, хәзерге вакытта, сөйләгән моментта кыштырдау. *Башаклары саллы, һич ялган түгел, берәр карыш, сабак-саламы да адәм әйтеп адәм ышанырлык түгел, тач җиткән камышыдай чайкалып, кыштырдап утыра.* М.Хәсәнов

**Кыштырдый башлау** Кыштырдарга тотыну. *Йокысы килгәч, ул [песи баласы] йомшак урынына кереп йокларга гына җыенган икән, шул вакыт нидер кыштырдый башлаган.* А.Алиш

**Кыштырдый бирү** Кыштырдавын дәвам итү, һаман да кыштырдау

**Кыштырдый төшү** Бераз кыштырдау

**КЫШТЫРДЫК** *с. сөйл.* Кыштырдавык, кыштырдап торган, кыштырдый торган. *Менә кыштырдык плащ тагын лап-лоп бирегә якынлаша.* Р.Төхфәтуллин

**КЫШТЫ́Р-КЫШТЫР** *иярт.* 1) Коры үлән сабаклары бер-берсенә тиюдән, берәр юка, җиңел нәрсәнең икенчесенә җиңелчә орынуыннан, ышкылуыннан, нинди дә булса хәрәкәттән барлыкка килгән өзек-өзек тавышны белдерә. *Әмма Нәфисәгә абыйсы янында утыру, аның кычкырып-кычкырып телефонда сөйләшүен, башын кыйшайта төшеп, кыштыр-кыштырниләрдер язуын карап утыру бик-бик рәхәт була иде.* Г.Бәширов. *Төн кундык без урман куышында. Безнең яшел куыш өстеннән, Кыштыр-кыштыр тиеп ябалдашка, Җәйге яшел җилләр истеләр.* Зөлфәт. *Кайберләре, көзге җил агач ботакларыннан йолкып-йолкып алган коры яфраклар сыман, кыштыр-кыштыр арлы-бирле талпындылар, тик, билгеле бер фикергә оешып бетә, укмаша алмыйча тузгып, чәчелеп бетеләр.* Ә.Гаффар

2) Вак ташлар яки ком өстеннән барганда барлыкка килгән өзек-өзек тавышларны белдерә. *Менә шулай таза «Газ-67» машинасы ташлы ком сипкән юлдан кыштыр-кыштыр чапкан чакта, ул аны гүя янәшәсендә тоеп бара иде.* Ә.Еники

3) Терлекләр салам, печән кебек азыкны чәйнәгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Төяләрнең кыштыр-кыштыр әллә нәрсә чәйнәгәннәре ишетелә иде.* Г.Тукай. *Аты кыштыр-кыштыр салам чәйни, ә ул үзе, бәйләп куелган кебек, аркасын баганага терәп тора да тора.* И.Гази

**КЫШТЫ́Р-КЫШТЫР ИТҮ** *ф.* Өзек-өзек җиңелчә саңгырау тавыш чыгу, кыштырдау. *Кипкән әрем кыштыр-кыштыр итә.* Г.Афзал

**КЫШТЫР-КЫШТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **кыштыр-кыштыр итү**. *Салкынча урын дип куйган сөтле банканы тоткан килеш, кыштыр-кыштыр килеп, йомырка эзләп маташты.* Р.Мулланурова. *Дәрес бара, --- һәркем кыштыр-кыштыр килеп нәрсәдер эшли, артка борыла, кемнәндер нәрсәдер сорап ала, мышкылдый.* М.Мәһдиев. *Әй тырыша ул чакны ана каз! Ул үзенең оясында гел кыштыр-кыштыр килә.* Г.Бәширов

**КЫШТЫ́Р-МЫШТЫР** *иярт.* 1) *к.* **кыштыр-кыштыр**. *Ишекнең эчке ягында кыштыр-мыштыр атлаган тавыш ишетелде, кемдер капшана-капшана ишек келәсен эзләде...* Ф.Баттал. *Идарә коридорында кыштыр-мыштыр килгән булып кызыксынып йөрүчеләр байтак иде.* М.Мәһдиев

2) Ашыкмыйча гына кыймылдау, әкрен генә берәр эш эшләп йөрүне образлы белдерү. *Өй тирәсендә кыштыр-мыштыр эш тоткан булам, абзар-кураны чистартам, кар көрим.* А.Гыйләҗев

**КЫШТЫ́РТ-КЫШТЫРТ** *иярт. к.* **кыштыр-кыштыр**. *Түбәндә, тәгәрмәчләр астында, арбаның тик тормаганын сиздереп, кыштырт-кыштырт вак ташлар изелде, арбаның кай җиредер әллә нинди моңсу тавыш чыгарып, шыгырдап-шыгырдап куйды.* Н.Фәттах

**КЫШЫН** *рәв.* Кыш көне, кыш вакытында. *Махсус бригада карьерны кышка әзерли, кышын кулдан казылачак мәйдан өстенә калын такталардан түшәм җәя.* А.Гыйләҗев. *Кышын кар күп булса, җәен иген уңа дигән борынгылар ---.* Г.Ибраһимов. *14–15 яшьлек чагымда җәен дә, кышын да мин суга барырга ярата идем.* Х.Ширмән

**КЫШЫ́Н-ҖӘЕН** *рәв.* Һәрвакыт, елның һәр фасылында, төрле табигать шартларында. *Гыйззәт абзый үзе эчәргә бик яратса да, теләсә, кышын-җәен эш табып алган акчасын өйгә кайтара торган иде.* М.Гали. *Чабата базары белән бер: кышын-җәен ул сигез тиен.* Ф.Бурнаш

**КЫЮ** I *с.* **1.** 1) Куркусыз, батыр йөрәкле. *Мин ул кыю егетнең кем икәнлеген соңыннан гына белдем.* А.Әхмәт. *Бер ел эчендә ул үзен батыр, кыю, курыкмас егет итеп танытты.* А.Шамов. *Безнең кыю егетләребез үзләренең эшләрен эшләп тә бетерделәр һәм искән җил кебек юкка да чыктылар.* И.Гази

2) Батырлыкны, тәвәккәллекне белдереп, күрсәтеп торган. *Закир үзенә-*

*үзе ышанган кыю хәрәкәт белән башын селекте.* Ш.Камал. *«Нихәл, матур егетләр!» – дип, кыю, шаян тавыш белән исәнләште.* М.Әмир. *Әллә ачык елмаюы аның, Әллә кыю сүзе, белälмәдем, Кешедәге әчке матурлыкны, Гүзәллекне миңа сөйләде.* З.Мансур. *Мондый кыю операциядән дошман башта, әлбәттә, бераз югалып калыр, аны авылдан бәреп чыгару, бәлки, әллә ни читен булмас.* И.Гази

3) Кыенлыклардан курыкмый торган; яңага омтылучан. *Ни өчен син шулай матур, таза, кыю фикерле, акыллы кеше?* Д.Аппакова. *Бернәрсәсе белән дә күзгә ташланмый торган бу кеше Вакытлы хөкүмәт турында, эсерлар, меньшевиклар турында дөрес, кыю һәм үткен фикерләр әйтте.* И.Гази

**2.** *и. мәгъ.* Курку хисенә бирелми торган, курыкмас кеше. *Кыюның бәхете алдан йөрер.* Мәкаль. *Мин үзем кыюларны яратам, адымнарның үлчәүгә сыймаганын...* А.Гыйләҗев. *Аның өчен бик күп кыюларны Үтерделәр качып почмактан.* Ә.Исхак

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Курыкмыйча, батырларча. --- *партком җыелышы булачак бүлмәгә каты басып, кыю атлап, короллы жандармнары белән килеп керде.* Г.Ибраһимов. *Шул арада Мансуров бу тәҗрибәне бик кыю төстә һәм барлык колхозларда да киң күләмдә куллана башлау кирәклеген уйлап алды.* Г.Бәширов. *Ул бара кыю басып.* Ә.Ерикәй

2) Кискен, икеләнергә урын калдырмыйча. *Аннары кыю рәвештә ишекне тартып ачты.* Г.Әпсәләмов. *Син нинди ачык һәм кыю итеп сөйлисең хәзер.* Р.Ишморат

3) Тартынмыйча, уңайсызланмыйча; оялмыйча. *Ул инде аны үзенең йөри торган кызы һәм булачак хатыны кебек хис итеп, кыю гына кочагына ала торган булып китте.* А.Шамов. *Алар да үзләрен иркенрәк, кыюрак тота башладылар.* А.Шамов

**КЫЮ** II *ф.* Базу, батыраю, батырчылык итү (күбрәк юкл. форм. кулланыла). *Эшпошыргыч тынлыктан туеп, эш вакытында бер генә шаян сүз әйтергә дә кыймаган Газинур берьюлы җанланып китте.* Г.Әпсәләмов. *[Исмәгыйль:] Мин барында, ничек аңа бирергә кыйсыннар.* М.Фәйзи. *Хисмәт абзый үзе, эченнән күпме уйланса да, ни өчен, нәрсәсе белән «Шаляпин» булуын һич аңлый алмады, башкалардан сорарга кыймады.* Ә.Еники

**Кыймый калу** Кыярга өлгермәү, кыймыйча тоткарлану. *Класс сулыш алырга кыймый калды.* Ә.Фәйзи

**КЫЮ** III *ф.* 1) Берәр нәрсәнең өстен кисү; кистерү. *Ят куллар кагылды исә, Яшәр гомерен кисә, – Сабагын кыеп өзсә...* Р.Идиятуллин

2) Чабу, чабып алу. *Кайнар граната ярчыклары Кул-аягын кыеп өлгерде.* Г.Сәгыйров. *Селтәгән кылыч атаның Кыеп төшерде кулын.* Г.Сабиров

◊ **Кыеп алу** Кистереп, катгый итеп әйтү, башкача сүз кузгалтмаслык итү. *Теле дә аның чалгы кебек: кыеп кына ала.* А.Хәлим. **Кыеп салу** Тиз арада кирәген бирү, тиешле отпор бирү. *[Комиссар:] Дошман агентын беренче сүзендә үк кыеп салырга кирәк.* Г.Бәширов

**Кыеп алу** Беркадәр кыю. *Су буенда кыяк үлән – Кыеп аласы иде.* Җыр

**Кыеп бару** Рәттән, барысын да кыю. *Бер хөрмәтле шагыйребез, яшь бер шагыйрь иҗатын тикшергәндә, үләннәрне кыеп баручы чалгыны Җир шары өстендә яшен кебек ялтыратырга чакырган иде.* Р.Миңнуллин

**Кыеп йөрү** Әле, хәзер барысын да кыю. *– Игеннәрнең башларын кыеп йөргәч, нигә үтермәсеннәр, – дип, Нечкәбил [Саранча белән] сүзен бетерә.* А.Алиш

**Кыеп китү** Үтеп барышлый кыю. *Снаряд кыеп киткән бер кәкре агач сынган ботаклары белән таянып тора.* И.Гази

**Кыеп кую** Кыйган хәлгә китерү, алдан кыю. *Зур түрәләр кушса, сорап тормый, Кыеп куя адәм җанын да.* Р.Гарифуллина

**Кыеп салу** Күпләп чабып үтерү, кыйган кебек итү (сугышта)

**Кыеп төшерү** Бер сугуда кыю. *Ул агачны гына түгел, каты ташны да кыеп төшерде.* Г.Ибраһимов

**Кыеп чыгу** Һәрберсен, башыннан ахырына кадәр кыю. *Араларына килеп керә дә, ике кулында ике кылыч уйнатып, барсын да уңлы-суллы кыеп чыга.* Т.Нәбиуллин

**КЫЮЛАНУ** *ф.* 1) Батырлану, кыюга әйләнү, тәвәккәлләнү. *Ул түгәрәкләнә төшеп, тагын да матурланган һәм шактый ук кыюланган булырга охшый иде.* Г.Бәширов. *Кияү, кыюланып, серле караңгылыкка атлады.* Н.Фәттах. *Акрын-акрын кыюланып, зур таш бинаның почмакларына, капкаларына чаклы килеп җиттеләр.* Г.Ибраһимов

2) Батырчылык итү, базу, кыю. *– Ялчыгыз турында сорыйм, – диде яшь егет, бераз кыюланып.* А.Шамов. --- *күпсанлы нәни пьесалар язып, сәхнәдән бер дә төшмичә, спектакльләрдә, шахмат ярышларында чуалып йөрүем, чаңгы кроссында дүртенчебишенче урыннарга чыгуым аркасында мин, кыюланып, алар арасына барып кысылдыммы?* А.Гыйләҗев. *Ул, аптырап, аны ничек юатырга, аңа нәрсә дип әйтергә белмичә, берничә секунд торды, аннары, кыюланып, аның бөдрә чәчләрен әкрен генә сыйпарга тотынды.* А.Шамов

3) Көчәю. *Инде хәтәр холыклы кешеләр яшәгән Мөрәлене дә чыктык, алда әле ике үзән бар, буран да кыюланды.* М.Мәһдиев

**Кыюлана бару** Торган саен ныграк кыюлану. *Соңгы вакытларда көннән-көн кыюлана барган Күчәрбай көттереп тормады.* М.Әмир. *Кызый, торган саен кыюлана барып, тагын да шәбрәк сайрарга тотынды.* Г.Бәширов

**Кыюлана башлау** Кыюланырга тотыну. *– Ярый безгә, каткан тезгә, Равилә апаның помошнигы да, – дип җавап кайтара иде кыюлана башлаган Идрис.* Ф.Яруллин

**Кыюлана бирү** Кыюлануын дәвам итү, һаман да кыюлык күрсәтү. *– Ә сезне бер дә алдаганнары юкмы? – Кыюлана биреп, сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды ул.* Х.Камалов

**Кыюлана төшү** Беркадәр кыюлану. *Аклар, моны сизеп, кыюлана төштеләр.* Г.Бәширов. *Шуны искәреп, ул тиз үк кыюлана төште.* Ф.Галиев

**Кыюланып алу** Бераз, азга гына кыюлану. *Чөнки ул [Мөхетдинов] рәис-*

*тән шүрли. Бу юлы ничектер кыюланып алды.* Х.Камалов. – *Шулкадәр җир килеп, әллә чәй дә эчертмәс идеңме? – дип, Фәтхерахманга үз баласы шикелле итеп кыюланып алды.* К.Тинчурин

**Кыюланып бетү** Тәмам кыюлану

**Кыюланып җитү** Тәмам кыюга әйләнү

**Кыюланып китү** Кинәт кенә батыраю; нинди дә булса сәбәптән, вакыттан, вакыйгадан соң кыюлану. *Ул бердән кыюланып китте.* Р.Хафизова. *Эчми эчкән аракыдан Сәет шактый ук кыюланып китте.* Ф.Яруллин. *Ә балачагалар безгә булган шундый яхшы мөнәсәбәтне күргәч, бөтенләй кыюланып киттеләр, бер-берләрен этеп-төртеп, машинага, Чжу карт янына менеп кунакладылар.* А.Шамов

**КЫЮЛА́РЧА** *рәв.* Батырларча, кыюлык күрсәтеп. *Кыюларча көрәшкә омтылу*

**КЫЮЛЫК** *и.* 1) Кыю булу, батырлык; тәвәккәллек. *Бу урынга җиткәч, батыр кызчыкның кыюлыгы югалды.* М.Әмир. *Язу рәвеше дә, җөмләләрнең берсе өстенә берсе өстәлеп куерткан уйлары да, кыюлыгы да ошады миңа ошбу хат иясенең.* А.Гыйләҗев. *Сугыш башларга кыюлыгы җитмәде ахрысы.* Р.Мулланурова

2) Кыю эш, кыю хәрәкәт, кыю кыланыш. *Гришаның бу кыюлыгы бабайга бик үк ошап бетмәде.* А.Әхмәт. *Мине аларның күп белүе, кыюлыгы, иманнарының бөтенлеге таң калдырды.* А.Гыйләҗев. *Махночылар, көтелмәгән бу кыюлыктан гаҗәпкә калып, кинәт туктадылар, акайган күзләре белән «максим»ның үзләренә төбәлгән кара көпшәсенә текәлеп катып калдылар.* Г.Бәширов

**КЫЮСЫЗ** *с.* **1.** Кыю булмаган, кыюлыгы җитмәгән; куркак. *Без нинди хәрәкәт ясарга, нәрсә дип сүз башларга белмичә, уңайсыз тик тору бәласенә дучар булган кыюсыз кунаклар хәлендә калдык.* М.Әмир. *Ни әйтсәң дә, Фәтхи кыюсыз.* Ш.Камал. *Шул юаш, йомшак, оялчан, кыюсыз Нәфисәгә мондый куәт кайдан килгән?* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Куркып, шүрләп; тартынып, уңайсызланып. *Хатын кабинетка кыюсыз гына атлап керде, әзерләп куелган урындыкка утырды.* М.Галиев. *Гөлбикә карчык бераз уйланып торды һәм, әйтимме-юкмы дигәндәй, кыюсыз гына болай диде.* Ф.Яруллин. *Менә ул юаш малай кебек кыюсыз гына сәке читендә утыра.* Р.Мулланурова

**КЫЮСЫЗЛАНУ** *ф.* Кыюсызга әйләнү; курку, тартыну, уңайсызлану, базмау. *Илсөяр бер-ике атлады да кыюсызланып туктап калды.* Г.Гобәй. *Шәкерт, кыюсызланып, әйтергә ярыймы-юкмы дип икеләнеп торды да кинәт ачып җибәрде.* Г.Ибраһимов. – *Ә монда ничек соң, Мәхмүт Исламович? – дип кыюсызланып кына сорады тикшерүче.* М.Галиев

**Кыюсызлана бару** Вакыт үткән саен кыюсызлыгы арту

**Кыюсызлана бирү** Һаман да кыюсызлану, кыюсызлануын дәвам итү

**Кыюсызлана төшү** Бераз кыюсызлану

**Кыюсызланып бетү** Тәмам кыюсызлану

**Кыюсызланып йөрү** Күптәннән бирле нәрсә дә булса эшләргә кыюлыгы җитмәү

**Кыюсызланып калу** Кинәт кенә кыюсызга әйләнү. *Ул ничектер кыюсызланып калган, элекке Әбүзәргә тамчы да охшамаган иде.* А.Тимергалин

**Кыюсызланып китү** Тик торган җирдән кинәт кыюсызлану

**Кыюсызланып тору** Кыюлык җитмичә тукталып калу, беразга тоткарлану. *Актүш бераз кыюсызланып торды да көймәгә керде һәм Илсөяр каршысына килеп утырды.* Г.Гобәй. *Иргали янә икеләнә калды, үзе турында хәбәр саларга кыюсызланып торды.* М.Хәсәнов

**КЫЮСЫЗЛЫК** *и.* 1) Үз-үзеңә ышанмаудан килгән куркаклык. *Шат, уенчак алсу йөз белән мәдрәсәгә килгәннәр, берничә ел анда яшәсә, --- мөгамәләсендә кыюсызлык, дәртсезлек, өметсезлек башлана.* Г.Ибраһимов. *Бер-берләрен өзелеп сөйгән кешеләр дә я чамасыз горурлык-юләрлек, я кыюсызлык, я булмаса башка юк кына сәбәпләр аркасында кавыша алмый ялгыз гомер кичерәләр.* Р.Хафизова. *Бу нинди кыюсызлык сездә?* Ә.Еники

2) Уңайсызлану, тартыну, базмау. *Оялчанлыкның, кыюсызлыкның әсәре дә юк иде анда.* М.Әмир. *Ул бераз тартынып, бераз кыюсызлык белән башласа да тиз ачылды, сүзгә күп колак салмыйча, бәлешләрне, салкын каз итләрен туктаусыз йота башлады.* Г.Ибраһимов

**КЫЮЧЫЛЫК** *и. сир.* Батырчылык, кыюлык, тәвәккәллек итү, базу. *Урыслар, татарларны Мәскәү тирәсенә килгәннәрдер дип уйладыклары сәбәпле, каланың тышына чыгарга кыючылык кыла алмадылар.* Һ.Атласи. *[Бари:] Без сезгә турыдан-туры бүләк итеп бирергә кыючылык итә алмаган булыр идек.* М.Фәйзи

**КЫЯ** *и.* 1) Бик текә таш тау; шундый тауның текә бите. *Ярлары кай урында шактый текә, корып, ярмаланып торган балчык кыяларны керәшәләр каян белеп тапканнардыр.* А.Гыйләҗев. *Ерак төньякның караңгы таш кыялары өстендә басып торган сакчылар, --- бормаланып узган окопларда утыручы совет солдатлары – бөтенесе күз алдыннан узды.* Г.Бәширов. *Халыкның алгы рәте, зур магазиннар тезелгән урамга җитәрәк, текә кыяга бәрелгән төсле, кинәт кенә туктады.* К.Нәҗми

2) Тауның тоташ таштан гыйбарәт калку өлеше. *Кыя ташында Ажгыра җилләр: – Кызган үзеңне, Яндырма, – диләр.* З.Мансур. *Мин торам бүген ярыңда, Басып кыя ташыңа.* Ә.Исхак. *Алга карыйм: бозлар кыясында Седов тора, алга кул сузган.* Ф.Кәрим

**КЫЯ ТАУ** *к.* **кыя**. *Уң һәм сул якта ташлы кыя тау астында бер малай елгада кармак салып утыра.* А.Әхмәт. – *Әтием, сине барыбер эзләп табармын мин, – дип җырлый-җырлый, Назлыгөл биек Кыя тау янына килеп чыкты.* Д.Гайнетдинова

**КЫЯК** I *и.* 1) Сарымсакта, суганда, бөртекле культураларда һәм үләннәрнең кайбер төрләрендә була торган озын тар яфрак. *Аларның күз яшедәй авыраеп тулышканнары яфрак, кыяк очларыннан җиргә тамды.* Ә.Гаффар. *Икенче көнне, кояш тегермән канатлары өстенә калкып, үлән кыякларындагы чык тамчылары ялтыр-йолтыр*

*итә башлаган вакытта, Фатыйма белән Хәлим, --- солы урырга чыгып киттеләр.* И.Гази. *Көн көяшлы, җылы, кар инде эреп беткән, аяк асты кипкән, яшел чирәм кыяк ярган, койма буйларындагы куаклар сары чәчәк ата башлаган иде.* Т.Әйди. *Бу кыяклар аңа, тора торгач, табигатьнең ул аңлап бетермәгән, бары сизә генә башлаган нindидер серләрен төшендерергә тырышалар кебек.* Г.Бәширов

2) *сөйл. к.* **кыяк үлән**; **күрән**. *Куе мәтрүшкә, кыяк, бөтнек үләннәре арасыннан эзләп табарлык та түгел.* Ә.Гаффар

◊ **Кыяк кебек** Бик үткен кешегә карата әйтелә. **Кыяк тешләү** Сәүдәгәрләрнең, бөлгәннән соң, үзләре акча алган кешеләреннән качып йөрүләре. *Эшләр чуала башлагач, байлар кыяк тешлиләр.* Ш.Мөхәммәдев

**КЫЯК** II *и. диал.* Каурый. *Толпардан тояк, шоңкардан кыяк калыр.* Мәкаль

**КЫЯК** III *и.* Сызып уйнала торган ике кыллы уен коралы. *Кыякта уйнау*

**КЫЯК ГӨЛ** *и. бот.* Агавачалар семьялыгыннан, ачык яшел, озын тар яфраклы гөл; *русчасы:* **драцена**

**КЫЯКЛАНУ** *ф.* Кыяклар җибәрү, кыяклар чыгару. *[Агроном:] Ә тарыгыз кыяклангач, тагы утарсыз.* Г.Гобәй

**Кыяклана бару** Торган саен күбрәк кыяк чыгару

**Кыяклана башлау** Кыякланырга тотыну

**Кыяклана төшү** Бераз кыяклану

**Кыякланып бетү** Кыяк чыгару процессы төгәлләнү

**Кыякланып килү** Беркадәр кыяклану; кыяклана башлау

**КЫЯКЛА́У** *ф. сөйл.* Качу, качып китү, тиз генә качып юкка чыгу. *Авылдан кыякласаң, егетләр яллап, җир тишегеннән дә таптырам.* Н.Гыйматдинова. *Сәүбәннең шактый вакыт үзе белән бергә булып та, кырын килә башлагач, аны-моны уйлап тормыйча, бер җаен табып, кызыллар ягына кыяклавын язган иде.* Ф.Хөсни

**КЫЯКЛЫ** *с.* 1) Яфрагы кыяк булган, кыяклар җибәрә торган. *Берөлешлеләр классына кыяклы ашлыклар (бодай, кукуруз, арыш, дөге, тимофеевка), кайбер яшелчә үсемлекләр (суган, сарымсак) керәләр.* Ботаника

2) Кыяк үлән белән капланган, күпләп кыяклар үскән. *Саз эчендә кыяклы түмгәк өстенә чыбык-чабыклар өеп, үрдәкләр оя ясаганнар.* А.Алиш. *Ул ярымутраулар куе соры тал һәм киңкиң кыяклы камыш белән капланганнар.* М.Әмир

**КЫЯКЛЫ ГӨЛ** *и. бот. к.* **кыяк гөл**. *Тәрәзәдән, кыяклы гөл аша, Карап тора төн.* Ф.Кәрим

**КЫЯКЛЫК** *и.* Кыяк үскән урын, кыяк үскән җир. *Шул вакыт күлнең икенче ярында, яр буенча куе булып үскән кыяклык арасында, шыртлап агач сынган, кеше йөргән тавышлар ишетелде.* Х.Ибраһимов

**КЫЯКЛЫЛАР** *и. бот.* Чәчәкле үсемлекләр арасында иң зур семьялыкның берсен тәшкил иткән пар озын яфраклы (кыяклы), сабаклары буынтыклы һәм эче куыш булган бер өлешле үсемлекләр семьялыгы. *[Гөмбә белән] Зарарлану аскоспоралар белән кыяклылар чәчәк атканда бара.* Л.Мәүлүдова. *Кыяклыларның барысы да диярлек – үләнчел үсемлекләр.* Ботаника

**КЫЯКЛЫ СУГАН** *и. к.* **кыяк суган**. *Җәй көннәрендә куас, кыяклы суган, кыяр, каты пешкән йомыркалар алып, үзе салкын аш әзерли.* Р.Батулла

**КЫЯК СУГАН** *и.* Лаләчәләр семьялыгыннан, озын тар кыяклы, кыяклары ашамлык итеп кулланыла һәм кыяк өчен үстерелә торган суган; *русчасы:* **лук-батун**. *Нәҗипләр калкына башлаган түтәлдән бер-ике кыяк суган өзеп каптылар.* А.Гыйләҗев

**КЫЯК ҮЛӘН** *и. бот.* Күрәнчәләр семьялыгыннан, чәчәкләре башакчыкка тупланган, терлек ашатуга китә торган кыяк яфраклы күпьеллык чүп үлән: *русчасы:* **осока**. *Су буйлары кыяк үлән, чабып аласы иде; Мәңге сагынмаслык итеп Карап каласы иде.* Җыр. *Озын ял ярдан ерак та түгел, кайчандыр күл булып, хәзер кыяк үлән үскән чокырга кереп баткан иде.* А.Гыйләҗев

**КЫЯМ** *и. гар.* 1) Аягүрә басып тору, аяк өстендә тору. *Булма бер җирдә кыям, әй, юкка шатланган куян.* Ш.Бабич

2) Кемне дә булса, хөрмәт йөзеннән, аягөсте каршылау

3) Намазның аягүрә үтәлә торган өлеше. *Кулларны кендек өстенә баглап кую бары намаз укыганда дөрес. Кулларны шулай тоту кыямның сөннәте.* Инсан һәм дин

4) Баш күтәрү, кузгалыш, чуалыш. *Капчык һәр яктан тишек, ә союзник ямый алмый, көн-төн ишетелеп тора яңа халык кыямы.* Г.Камал

**КЫЯМӘТ** *и. гар.* 1) Дини тәгълиматта: ахырзаман җитеп, Исрафил пәйгамбәр сурга өргәннән соң, үлгән кешеләр барысы да терелгәч, аларга карата Аллаһ тарафыннан ясала торган хөкем чыгарыласы көн; дөнья беткән көн. *Курка инсаннар: «Кыямәт җитте», – дип.* Ш.Бабич. *Бу дөньяда ни гамәлне кылырсың – Кыямәттә җәзасын һәм күрерсең.* Ә.Фәйзи. *– Алар Кыямәт якынлашкан чорда хәзрәте Гайсәнең мөселман буларак дөньяга кайтачагына һәм бөтен кешеләрне «бер Тәңре» идеясе астында туплаячагына да ышана, – дип яза профессор Сәййид Насыйр.* Татар милләт календаре. *Кыямәт (гарәпчә – үлгәннән соң терелү), мөселманнар ышануынча, мәетләр яңадан терелеп, хисап бирү көне.* Мәдәни җомга

2) *күч. сөйл.* Шау-шу, зур ыгызыгы, тәртипсезлек. *Ахырзаман анда, кыямәт, үзара талаш, кычкырыш бара!..* Т.Гыйззәт. *Газеталар, кыямәт купкан шикелле, төрле-төрле хәбәрләр, бик күп ялганнар яза башладылар.* Ш.Мөхәммәдев. *Октябрь инкыйлабы болай да тәмам какшаган Рәсәй тормышын чыгырдан чыгарды, әйтерсең Кыямәт көне җитте.* Х.Миңнегулов

◊ **Кыямәткәчә, кыямәткә кадәр (чаклы, тикле)** Ахырзаманга кадәр, дөнья беткәнчегә кадәр; нәрсәнеңдер чигенә ерак булу. --- *Кыямәткә чаклы җиһан сараенда минем исемем мәшһүр булып калсын.* К.Насыйри

**КЫЯМӘТЛЕК** *и.* **1.** *этн.* Керәшен татарларындагы гореф-гадәт буенча, үлгән кешене киендереп күмә торган кием; исламда – кәфенлекнең беренче, аскы каты

**2.** *с. мәгъ.* Никах вакытында кәләш белән кияүнең әти-әнисе ролен үтәүче кешеләрне элек шулай атаганнар. *Килен белән кияү тарафыннан кыяматлек әни яки әти тирән ихтирам ителергә тиеш.* Ф.Урманче. *Хан пошаманга төшкән: «Син инде минем кыяматлек карендәшем бул», – дип, сараена кайтып киткән.* Мәдәни җомга

**КЫЯР** *и. гар.* 1) Кабакчалар семьялыгыннан, үрмәләп үсәргә мыекчалары булган, озын куыш сабаклы, озынча сусыл җимеш (яшелчә) бирә торган берьеллык үлән үсемлек. *Помидор, кыярларга, үзләре дауламасалар да, су бирми хәлең юк.* Ш.Камал. *Барыбер, барыбер яз килер, һәм сез тагын да алма, кыяр бакчаларына дүрт аякланып кунакка йөрерсез.* Һ.Такташ. *– Бакчагызны җәллим, кыярларыгыз бик уңа иде. – Синеке дә уңа, Мөршидә апа, ачуымны китерсәң, өлгергәч тә кыярларыңны урып чыгармын әле.* Н.Гыйматдинова

2) Шул үсемлекнең ашый торган озынча, яшел төстәге сусыл җимеше. *Ашъяулык өстендә тәлинкәләр, пычаклар, икмәкләр, кыярлар, кәбестәләр, чынаяк чокырлары.* Г.Ибраһимов. *Төннәрен яшелчә бакчасына – кыяр, кырга борчак кузагы урларга барганда, аны үзләре белән тиң санап алалар иде.* Р.Хафизова. *Самавыр кадәр карбызлар, ат башы кадәр татлы кавыннар, беләк кадәр кыярлар үстерәчәк.* А.Хәлим

**КЫЯРАК** *и.* Ботка яки култык астына чыга торган авыртулы шеш, биз. *Безнең күрше малае таз Габсәләм әйтә: – Йөгереп булса ярар иде әле, ботка кыярак чыккан, йөгергәндә авырта, – диде.* М.Гали

**КЫЯ́Р-КЫЙМАС** *рәв.* Тартынып, бик оялып, беркадәр курка төшеп. *Мин аңа, кыяр-кыймас кына булса да, «Этот непобедимый чеченец»ны бүләк иттем, дидем.* А.Хәлим. *Бала, читкәрәк китеп, стенага сөялде, ана кыяр-кыймас кына ишек шакыды.* А.Әхмәт. *Гөлзәбәр кыяр-кыймас аңа кулын сузды: – Рәхмәт, Мансуров абый, яхшы киңәшегезгә.* Г.Бәширов

**КЫЯРЛАНУ** *ф.* Кыярга төймәләнү, вак кыярлар барлыкка килү. *Яңгыр кояр кыярларга Кыяр кыярланганда.* Ә.Ерикәй. *Кыяр орлыкларын 50–60 градус температурада 2 сәгать буена җылыту аның уңышын 80 процентка кадәр арттыра һәм ана чәчәкләрнең атуын, кыярлануын шактый тизләтә.* Йорт эшләре

**КЫЯРЛА́У** *ф. диал.* 1) Бакчадан яшелчәне яки җимешне күп итеп урлау. *Варис --- малай чакта күршеләрнең алар ягына авышкан шомыртларын кыярлый торган иде.* М.Хәсәнов

2) *сөйл.* Юк-бар, ялган сөйләү, арттырып сөйләү. *Ну, кыярлыйсың да инде*

**КЫЯР ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан, каты төкле яфракларыннан кыяр исе килә торган, ашарга яраклы берьеллык үсемлек; *русчасы:* **бурачник**. *Кыяр үләннәр гадәттә үзенә бертөрле кылсыман каты йонча белән капланган. Аларның уртак билгесе булып, шулай ук чәчәк төркеменең махсус тибы – бөтеркә тора.* Л.Мәүлүдова

**КЫЯРЧАЛАР** *и. бот.* Күкчелчәләр рәтендәге, куак, ярымкуак төрләре дә булган, сабаклары, яфраклары үзенә бертөрле кылсыман каты йонча белән капланган, чәчәкләре ике җенесле, бөҗәкләр ярдәмендә серкәләнә торган кыяр үләннәре семьялыгы атамасы. *Кыярчалар арасында күгәрчен күзе ыругыннан вак, ләкин ачык зәңгәр чәчәкле төрләре – саз күгәрчен күзе һәм кыр күгәрчен күзе билгеле.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**КЫЯС** *и. гар.* 1) Охшату, чагыштыру аша хөкем йөртү. *Әгәр берәр мәсьәләгә карата Коръәндә, сөннәттә һәм абруйлы руханилар җавабында-фикерендә бердәмлек (иҗмаг) булмаса, кыяс нигезендә җавап бирелә.* Мәдәни җомга

2) Үрнәк, мисал, үлчәү. *Кылган эшең ничә мең кат артып китә, кыяс кылып караганда мәгарифкә тоткан расходка.* М.Гафури

**КЫЯС ИТҮ** *ф. иск.* Чагыштыру, охшатып тиңләштерү. *Кил, кыяс ит, ни булгай ул сәгать Татлы җан чыкса, калса тән хали.* С.Сараи

**КЫЯС КЫЛУ** *ф. иск. к.* **кыяс итү**. *И туган! Минем хәлемне ярканатка кыл кыяс: Калка гаклым башыма тик үткәч эш, баткач кояш.* Ш.Бабич. *Анда Кол Галинең: «Гәүһәр ташдыр, ләкин һәр таш гәүһәр улмас, Гәүһәр кадерен тикмә кемсә кыяс кыйлмас», – дигән сүзләре язылган.* Ф.Хуҗин

**КЫЯФӘТ** *и. гар.* 1) Кешенең тышкы күренеше, килеш-килбәте. *Минем белән сөйләшкән егетнең кыяфәтен кат-кат сорады.* А.Шамов. *Зыяның атасы Җәләш хәзрәт кыяфәте белән бабаларына охшый.* Г.Ибраһимов

2) Кешенең эчке халәтенең тышкы чагылышы. *Малай күңелсез генә кыяфәт белән борылып китте.* Ш.Камал. *Кунакларның һәммәсенә, эчендәге салкынлыгын яшерергә тырышкан бер кыяфәт белән, берәм-берәм көлкеләр сөйләде, бераз шаярды.* Г.Ибраһимов. *Аның янында каушаган кыяфәттә хатыны тора.* М.Галиев. *Аннары, ул әллә кайчангы таныш сыман миңа күз кысты да бик җитди кыяфәт белән аңлатырга керешә.* Ә.Хәсәнов

3) Нәрсәнең дә булса тышкы күренеше, көйләп куелган рәвеше. *Кайчандыр чиста вә бөтенлектән нурланып тора торган бу коридор, бу бүлмәнең бүгенге кыяфәте үк мине инде шушындый бер мәлгунь сүз ишетергә әзерләп куйган ---.* Ф.Әмирхан. *Елганың аръягында тау артыннан сузылган завод морҗалары караңгылык эчендә әллә нинди күңелсез һәм куркынычлы кыяфәттә күренә иде.* Ш.Камал. *Шыксыз кыяфәткә кереп, борыны белән суга чумган машинабыз әллә ни кыстатып тормады, чирәмгә чыгып басты.* К.Миңлебаев

4) *әд. иск.* Образ, тип. *Кыяфәтләрне сайлап алуга килсәк, хикәядә икенче дәрәҗәдәге кешеләр һәммәсе бик яхшы табигый кыяфәтләрдә алынган булса да, хикәянең ике каһарманы Гали илә Зөләйха кыяфәтләренең дә дөньяда булуы бәгыйдь күренәдер.* К.Насыйри

**КЫЯФӘТСЕЗ** *с.* **1.** Шыксыз, ямьсез, матур түгел. *Бу кыяфәтсез карчык белән бу хәрабә ишегалдында ялгыз калганлыгымны күргәч, мин, куркына башлаган шикелле, җәһәт-җәһәт өй ишегенә таба атладым.* Ф.Әмирхан. *Ә хәзер миңа кешеләр тоташ бер масса*

*булып, төссез, кыяфәтсез җанварлар булып кына күренәләр*... Т.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ.* Ямьсез кыяфәтле кеше. *Авызда фафирус, башта картуз!.. Кыяфәтсез!.. Егетләр яратмас үзеңне*. Г.Зәйнашева

**КЫЯФӘТСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Ниндидер сәбәпләр аркасында килеш-килбәт шыксызлану, таушалып ямьсезләнү

**Кыяфәтсезләнеп китү** Ниндидер бер вакыт эчендә кинәт кыяфәтсезләнү

**КЫЯФӘТСЕЗЛЕК** *и.* Шыксызлык, ямьсезлек

**КЮВЕТ** *и. фр.* Юлның һәр ике ягында су агып төшә торган канау. *Юл буенда кюветта алты яралы кеше утыра иде*. Г.Хисамов

**КЮВЕ́ТА** *и. фр. махс.* Фотографик пластинкаларны, фотографик сурәтләрне эшкәртү һәм юу өчен, төбе сырлы кечкенә савыт

**КЮВЕ́ТКА** *и. махс. к.* **кювета**

**КЮРАСО** *и. порт.* Әфлисун ликёры

**КЮРЕ** *и. фр. дини* Француз телле католикларда мәхәллә рухание

**КЮРИ** *и. махс.* Радиоактивлыкны үлчәү берәмлеге. *Кюри 1 секунд эчендә $3{,}7\cdot10^{10}$ таркалуга тигез.* Физика, химия һәм химия технологиясе буенча русча, татарча, инглизчә аңлатмалы сүзлек-белешмә

**КЮРИЙ** *и. лат. махс.* Менделеев таблицасында тәртип номеры 96 булган химик элемент. *Кюрий – актиноидларның берсе, ак ялтыравыклы металл.* Физика, химия һәм химия технологиясе буенча русча, татарча, инглизчә аңлатмалы сүзлек-белешмә

**КЯЗИП** *и. гар. иск.* Ялганчы, алдакчы. *Бу дөньяда --- Садыйк исемле кязиплар --- күп бит.* Г.Тукай

**КЯМИЛ** *с. гар. иск. к.* **камил**

**КЯ́МИЛӘН** *рәв. гар. иск.* Бөтенләй, тулаем, тулысынча. *Октябрь уннарыннан соң матди җәһәт бик начарланган вә эти берлә арамыз кямилән суыгаеп җиткән иде.* Ф.Әмирхан

**КЯН** *и. фар. иск. кит. к.* **кән**

**КЯР** *и. фр. иск.* 1) Эш

2) Тәэсир

3) Файда

**КЯР ИТҮ** *ф.* 1) Тәэсир итү, йогынты ясау. *Үшән атка камчы кяр итмәс.* Мәкаль

2) Файдасы булу, ярдәм итү. *Күгәрченкәем шунда ук ава, Кяр итми дәва.* Г.Тукай

**КЯР КЫЛУ** *ф. к.* **кяр итү**. *Кызның атасы исә, гайрәт уты җанына кяр кылып, хасталыгыннан җан биреп җан алмакта.* К.Насыйри

**КЯРХАНӘ** *и. фар. иск.* Эшханә, һөнәрче мастерское, кечкенә фабрика. *Габделхәйнең Мәскәүдә үз йорты булган, --- ул шәм, сабын кайната торган кярханә* (*фабрика*) *тоткан*. Идел

**КЯТИП** *и. гар. иск. к.* **катип**. *Шул ук Бәхет килгән заманда, икенче кардәше мәхкәмәдә кятип иде*. Г.Тукай

**КЯФ** *и. гар.* Гарәп алфавитында нечкә «к» (ك) хәрефенең исеме. *[Сүз], саңгырау кяфлар гарәпчәдә булмаганга күрә, үзгәртелмәде.* Г.Тукай. *Икенчедән монда «кяф»тан соң «әлиф», «ара»дан соң «е» бар.* Ф.Әмирхан

**КЯФЕР** *и. гар.* 1) *дини* Ислам динендә: Аллаһының барлыгын һәм берлеген инкяр итә торган кеше. *Оренбургтагы, хөррият тарафында йөрүче яшь һәм карт мөселманнарның барын да кяфер диюче Гаяз мулла дигән кешенең агасы яңа закон чыгарган.* Ш.Мөхәммәдев. *Ләкин күңелендәге белемсез курку һаман бетмәде генә түгел, бәлки көчәйде генә: студент та «кяфер», --- кызыл иренле Евгений да «кяфер», әллә кемнәр дә «кяферләр» – һәммәсе «кяфер», «кяфер», «кяфер».* Ф.Әмирхан

2) *сөйл.* Мөселманнарда: башка дин кешесе. *Бакчада Михаилдан йөгереп качканда күңеленә килгән китеклекне ул хәзер генә аңлап җиткерде: «Михаил мөселман түгел бит, ул кяфер бит».* Ф.Әмирхан. *Форточкадан пырхылдап Иннокентий очып керде. – Булды, мин сүземдә тордым! – ди бу, мине кочаклап. – Әтәч булып кычкырырга әзерләп, хәзер Татарстанда хәтта кяферләр дә татарча гына сөйләшә.* З.Мәхмүди

**КЯФЕРЛЕК** *и.* Ислам динендә: башка дин кешесе булу, башка динне тоту күренеше. *Европа «кяферләре»нең мөселманнарны гына түгел, --- бөтен Шәрык халкын кол итеп талауларын, --- шуңа күрә монда эш кяферлектә түгел, башка нәрсәдә икәнен искә алмадылар.* М.Гафури

# ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Справочное издание

# ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

(на татарском языке)

## Том III
## (К)

Редактор *Н.К. Нотфуллина*
Корректоры: *Н.К. Нотфуллина, Р.К. Сагдиева*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 17.11.2017.
Формат 84×108 $^1/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 78,1. Уч.-изд. л. 93,2
Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20